мәңгегә *нареч.* наве́ки, насовсе́м, наве́чно, навсегда́, вове́к; *моннан ~ китәм* уезжа́ю отсю́да навсегда́ (насовсе́м); ~ *дуслар* друзья́ наве́ки; друзья́ до гробово́й доски́ ◊ ~ **күз йому** умере́ть; ~ **югалу** ка́нуть в ве́чность

мәңгеләштерел|ү *страд. от* **мәңгеләштерү**; увекове́читься || увекове́чение

мәңгеләштерү *понуд. от* **мәңгеләшү**; увекове́чивать/увекове́чить || увекове́чение; *геройның исемен ~* увекове́чить и́мя геро́я

мәңгеләшү *неперех.* увекове́чиваться/увекове́читься

мәңгелек *сущ.* ве́чность, бессме́ртие; *шагыйрь үзенең җыры белән ~не яулады* свое́й пе́сней поэ́т завоева́л себе́ бессме́ртие || *прил.* **1.** ве́чный; бессме́ртный; ~ *дан* ве́чная сла́ва; ~ *бәхет* ве́чное сча́стье; ~ *җыр* бессме́ртная пе́сня; ~ *истәлек* ве́чная па́мять; ~ *йокыга талу* засну́ть ве́чным сном; ~ *двигатель* ве́чный дви́гатель **2.** вековóй, ве́чный; ~ *сазлыкларга барып җиттек* подошли́ к вековы́м боло́там; ~ *тугел* не ве́чный ◊ ~ **суы эчмәгән** не пи́л из ча́ши бессме́ртия; ~ **туфрагы** ло́но ве́чности; **~нең куены** объя́тия ве́чности

мәңге-мәхшәргәчә *нареч.* во ве́ки веко́в

мәрә *сущ. диал.* **1.** круг (игра́ющий) **2.** *см.* **мәрәй**

мәрәй *сущ. диал.* **1.** 1) мише́нь (*для стрельбы из лука*) 2) стрельба́ из лу́ка (*как состязание, вид спорта*) **2.** круг, нача́ртенный на земле́ и́ли углубле́ние на земле́ для разли́чных игр (*для попадания в них мячом издали*) **3.** игрова́я площа́дка **4.** назва́ние игр (*в которых, бросая чем-л., надо попасть в круг, в точку и т. п.*) **5.** би́та (*в игре*) ◊ **~гә тәгәрәү** идти́, приближа́ться к це́ли (*о делах, событиях*)

мәрәкә *сущ.* **1.** *ист.* аре́на, пло́щадь, площа́дка для представле́ний **2.** *разг.* заба́ва, поте́ха; поте́шное зре́лище; ~ *инде менә!* поте́ха и то́лько! *~се бер тәңкә* поте́ха на це́лый рубль || *прил.* заба́вный, поте́шный; ~ *кеше син* заба́вный ты челове́к □ ~ **күрсәтү 1.** пока́зывать/показа́ть но́мер (номера́) **2.** поте́шить (*людей*)

мәрәкәче *сущ.* **1.** поте́шник **2.** скоморо́х

мәрәләү *неперех. диал.* **1.** (*долго*) це́литься **2.** *что-л.* де́лать чрезвыча́йно тща́тельно и до́лго; занима́ться *чем-л.* ме́дленно и тща́тельно

мәрвәрит *сущ.* кра́сный же́мчуг; ме́лкий кора́лл □ ~ **чәчәге** *бот.* маргари́тка

мәргән *сущ.* **1.** сна́йпер, ме́ткий стрело́к; *маһир ~* иску́сный стрело́к; *күп аткан белән ~ булмас* (*погов.*) не тот сна́йпер, кто мно́го стреля́ет; ~ *туры бәргән* (*погов.*) сна́йпер бьёт то́чно в цель **2.** охо́тник; *боланның качуына — ~нең атуы* (*посл.*) вся́кий яд име́ет противоя́дие (*букв.* оле́нь бежи́т — охо́тник стреля́ет)

мәргәнлек *сущ.* **1.** ме́ткость, мастерство́ сна́йпера; уме́ние хорошо́ стреля́ть **2.** заня́тие (профе́ссия) охо́тника

мәргәннәрчә *нареч.* по-сна́йперски, ме́тко

мәрҗән *сущ.* **1.** кора́лл, кора́ллы || кора́лловый; *затлы ~* благоро́дный кора́лл; ~ *муенса* кора́лловое ожере́лье **2.** бу́сина, бу́синка; ~ *белән чиккән* вы́шито бу́синками **3.** *диал.* ожере́лье, бу́сы; *кызыл ~ сатып алу* купи́ть кра́сное ожере́лье □ ~ **агачы** *сущ. диал.* бузина́ кра́сная

мәрҗәнле *прил.* с кора́ллами; укра́шенный кора́ллами

мәркәз *сущ. книжн.* **1.** 1) центр (*комнаты, стола; города, посёлка и т. п.*), середи́на *чего-л.*; *шәһәрнең ~е* центр го́рода 2) *в знач. прил.* центра́льный; *шәһәрнең иң ~ урамы* са́мая центра́льная у́лица го́рода; ~ *статистика идарәсе* центра́льное статисти́ческое управле́ние **2.** вы́сший руководя́щий о́рган, пра́вящий о́рган, центр (*страны, республики, края*); ~ *белән бәйләнеш* связь с це́нтром; *~дән күчеп китү* перее́хать из столи́цы **3.** *перен.* осно́ва, центр, сте́ржень, гвоздь *чего-л.* (*науки, культуры и т. п.*); *бүгенге мәсьәләнең ~е* осно́ва сего́дняшней пробле́мы

мәркәзләштерелү *страд. от* **мәркәзләштерү**

мәркәзләштерү *перех. уст. книжн.* централизова́ть || централиза́ция; *тәэмин оешмаларын ~* централизова́ть о́рганы снабже́ния

мәркәзләш|ү *неперех. уст. книжн.* централизова́ться || централиза́ция (*какого-л. управленческого аппарата, руководящих органов какой-л. области и т. п.*)

мәркәзчелек *сущ. уст. книжн. полит.* центри́зм

мәрмәр *сущ.* **1.** мра́мор; *ак ~* бе́лый мра́мор; *~гә охшаган обой* обо́и под мра́мор; *~дән салынган сарай* дворе́ц из мра́мора; мра́морный дворе́ц **2.** *прил. прям., перен.* мра́морный; ~ *балкон* мра́морный балко́н; ~ *плитә* мра́морная плита́; ~ *тавы* мра́морная гора́; ~ *теш* мра́морные зу́бы (*о белых, красивых зубах*); ~ *маңгай* мра́морный лоб (*о белом, гладком и холодноватом лбе*)

мәрмәрләү *перех. спец.* мрамори́ровать || мрамори́рование; мраморирóвка (*отделывание под мрамор*); *кәгазьне ~* мрамори́ровать бума́гу; мраморирóвка бума́ги; *китап кисемнәрен (кырларын) ~* мрамори́рование обре́зов книг

мәрмәрташ *сущ.* **1.** мра́мор **2.** надгро́бная мра́морная плита́

мәрмәрче *сущ. спец.* **1.** мра́морщик (*мастер по обработке мрамора*) **2.** мрамори́ст (*мастер по окрашиванию чего-л. под мрамор*)

мәрсин *сущ. зоол.* осётр || осетрóвый, осетри́нный; ~ *кызыл балыклар группасына керә* осётр отно́сится к гру́ппе кра́сных рыб; ~ *уылдыгы* осетрóвая икра́ □ ~ **ите** осетри́на

мәрсия *сущ. книжн. лит.* эле́гия (*стихотворение, посвящённое чьей-л. памяти*)

мәрт *сущ. мед.* летарги́я, летарги́ческий сон ◊ **~кә китү 1.** впасть в летарги́ю (летарги́ческий сон) **2.** засну́ть глубо́ким, кре́пким сном **3.** *перен.* засну́ть ве́чным сном; **~тән кайту** проснýться от летарги́ческого сна

мәртәбә I *нареч.* раз; *берничә ~* не́сколько раз; неоднокра́тно; *бер-ике ~* раз-друго́й, ра́за два; *дүрт ~* четы́ре ра́за, четы́режды; *күп ~* мно́го раз, многокра́тно; *икенче ~* 1) второ́й раз 2) втори́чно 3) в друго́й раз

мәртәбә II *сущ. книжн.* **1.** чин, зва́ние, положе́ние, *см. тж.* **дәрәҗә**; *аның ~се олы* он занима́ет высо́кое положе́ние (высо́кий чин) **2.** честь, прести́ж, авторите́т; *бу минем өчен зур ~* э́то для меня́ больша́я честь; *останың*

~се шәкертенә карап (посл.) об учи́теле су́дят по его́ ученику́; авторите́т учи́теля — по его́ ученику́ **3.** *степень интенсивности душевного состояния кого-л.*; *рәнҗүдән әллә ниләр эшләр ~гә җиттем* от оби́ды неве́сть что мог натвори́ть ◊ **~ артыннан чабу** гна́ться за чина́ми; **~ иясе 1.** авторите́тное лицо́; уважа́емый челове́к **2.** челове́к с положе́нием; высокопоста́вленное лицо́; **~гә ирешү** дости́чь положе́ния; получи́ть зва́ние; **~гә күтәрү** возвели́чивать/возвели́чить, предста́вить вели́ким, превознести́; возвели́чение; **~се төшү** потеря́ть авторите́т

мәртәбәләп *нареч.* сто́лько-то раз; -кра́тно; *йөз ~* со́тни раз; *күп ~* многокра́тно, не́сколько раз, по не́скольку раз

мәртәбәле I *прил. соответствует второй части сложных слов* -ра́зовый, -кра́тный; *өч ~* трёхкра́тный; *ун ~* десятикра́тный

мәртәбәле II *прил.* **1.** сано́вный, име́ющий высо́кий чин, высокопоста́вленный; *~ зат* высокопоста́вленное лицо́ **2.** авторите́тный, уважа́емый (*человек*) **3.** *перен. поэт.* возвы́шенный; одухотворённый (*чувства, стремления, взгляд и т. п.*) **4.** прести́жный, чти́мый, цени́мый, це́нный, высо́кий; *~ һөнәр* высо́кое (це́нное) ремесло́

мәрхәбә *межд. книжн.* добро́ пожа́ловать! пожа́луйста! пожа́луйте! ми́лости про́сим!

мәрхәмәт *сущ.* милосе́рдие, ми́лость; сострада́ние, сочу́вствие, снисхожде́ние, пощада; *ялган сөйләсәң, миннән ~ көтмә* е́сли солжёшь, не жди от меня́ пощады; *табигать ~е поэт.* ми́лости приро́ды; *~ сорау* проси́ть снисхожде́ния ◊ **~ итү (кылу, күрсәтү)** проявля́ть/прояви́ть милосе́рдие (ми́лость); ока́зывать/оказа́ть милосе́рдие (ми́лость), проявля́ть жа́лость (сострада́ние); **~ йөзеннән** из жа́лости, в ви́де снисхожде́ния; **~е килде** он сми́лостивился; **~ иясе** ми́лостивец, милосе́рдный челове́к; **~ күрсәтүчән** снисходи́тельный

мәрхәмәтле *прил.* **1.** ми́лостивый, милосе́рдный, снисходи́тельный; отзы́вчивый, сострада́тельный, учáстливый, сердобо́льный; *~ булу* быть милосе́рдным; *~ кеше* милосе́рдный челове́к **2.** до́брый, доброжела́тельный; *~ күзләр* до́брые глаза́; *~ караш* до́брый взгляд; *~ дустым* доброжела́тельный мой друг

мәрхәмәтлек *сущ.* **1.** ми́лостивость, милосе́рдность, снисходи́тельность; ми́лость, милосе́рдие, снисхожде́ние **2.** доброта́, доброжела́тельность

мәрхәмәтлән|ү *неперех.* уми́лостивиться, станови́ться/стать ми́лостивым, милосе́рдным, снисходи́тельным

мәрхәмәтлелек *сущ.* ми́лость, милосе́рдие, снисходи́тельность, сострада́тельность; *~ күрсәту* ока́зывать/оказа́ть милосе́рдие, снисходи́тельность

мәрхәмәтсез *прил.* **1.** 1) безжа́лостный, беспоща́дный, бессерде́чный, жесто́кий; *~ караш* безжа́лостный взгляд 2) *в функ. нареч.* безжа́лостно, беспоща́дно, жесто́ко; *~ кылану* поступа́ть безжа́лостно (бессерде́чно) **2.** жесто́кий, беспоща́дный; *~ сугыш* жесто́кая (беспоща́дная) война́

мәрхәмәтсезлек *сущ.* безжа́лостность, беспоща́дность, жесто́кость, неми́лость; *~ күрсәту* проявля́ть жесто́кость

мәрхүм *прил.* **1.** поко́йный, уме́рший **2.** *в знач. сущ.* усо́пший *уст.*; поко́йный; поко́йник; *~нең истәлеге* па́мять поко́йного

мәрхүмә *прил.* **1.** поко́йная, уме́ршая, усо́пшая *уст.* **2.** *в знач. сущ.* поко́йная, поко́йница; *~не мин белә идем* я знал поко́йную

мәсәл *сущ.* ба́сня || ба́сенный; *Крылов ~ләре* ба́сни Крыло́ва; *~ләр язучы* баснопи́сец; *~ләр җыентыгы* сбо́рник ба́сен; *~ стиле* ба́сенный стиль

мәсәлән *вводн. сл.* **1.** наприме́р, к приме́ру; *~, кичә шундый хәл булды* наприме́р, вчера́ был тако́й слу́чай; *~, әйтик...* к приме́ру, ска́жем... **2.** хоть, хотя́ бы; *~, бер фактны алыйк* возьмём хотя́ бы оди́н факт

мәсәлче *сущ.* баснопи́сец

мәсгуд *прил. уст. книжн.* счастли́вый, благополу́чный; *~ бала* счастли́вое дитя́

мәсгудият *сущ. уст. книжн.* сча́стье, блаже́нство, благополу́чие; *гаилә ~е* сча́стье (благополу́чие) семьи́; *адәмнең ~е өчен көрәш* борьба́ за сча́стье челове́ка

мәсих *сущ. рел.* мессия́; Христо́с

мәскәүле *сущ.* москви́ч, жи́тель Москвы́

мәслә|к *сущ. уст. книжн.* **1.** убежде́ние, мировоззре́ние; *аларның ~кләре башка* у них ино́е мировоззре́ние **2.** *перен.* при́нцип, иде́я, цель; *һәркемнең үз ~ге* у ка́ждого свой при́нцип

мәсләкле *прил. книжн.* убеждённый, иде́йный; име́ющий свои́ при́нципы

мәсләксез *прил. книжн.* беспринци́пный, не име́ющий определённых при́нципов, безыде́йный; *~ яшәү* бесце́льное существова́ние, жить без *каких-л.* при́нципов

мәсләктәш *сущ. книжн.* единомы́шленник; *сез ~ләрме?* вы единомы́шленники?

мәслихәт *сущ. книжн.* сове́т, рекоменда́ция; *кешеләрнең күплеге эшкә ярар, ~кә ярамас* (*посл.*) большо́е коли́чество люде́й приго́дно для рабо́ты, но не для сове́та; *сиңа бер ~ем бар* у меня́ для тебя́ есть сове́т || *предик.* хорошо́; хоро́шее де́ло; уме́стно; целесообра́зно; добро́; — *кунакка чакырсам, ни әйтерсең? — бик ~, диярмен* — е́сли позову́ в го́сти, что ска́жешь? — скажу́: о́чень хорошо́ □ **~ бирү** дава́ть/дать сове́т, сове́товать; **~ бирүче** сове́тчик, консульта́нт ◊ **~ булу** быть уме́стным, целесообра́зным; *шулай ~ булыр* так бу́дет целесообра́зно; **~ булмау** быть неуме́стным, нецелесообра́зным; **~ итү 1.** посове́товаться **2.** сове́товать, посове́товать; **~ күрмәү** не одобря́ть, не счита́ть целесообра́зным; **~ күрү** одо́брить, сове́товать, находи́ть (счита́ть) целесообра́зным; **~ кылу (кылышу)** посове́товаться, проконсульти́роваться; **~ мәҗлесе (җыелышы)** *уст. книжн.* совеща́ние; **~ эш** сто́ящее де́ло; де́ло, досто́йное одобре́ния

мәслихәтл|әү *перех.* **1.** *уст. книжн.* одобря́ть, находи́ть целесообра́зным **2.** дава́ть, дать сове́т (консульта́цию) **3.** посове́товаться *с кем-л.*

мәслихәтләш|ү *неперех. уст. книжн.* сове́товаться, посове́товаться ме́жду собо́й; *эшне ~еп башлау* начина́ть рабо́ту посове́товавшись

мәслихәтле *прил. уст. книжн.* согласо́ванный, вы́полненный по совме́стному реше́нию; *~ эш таркалмас* (*посл.*) что согласо́вано, то про́чно; *~ тун тар булмас* (*погов.*) шу́ба, сши́тая по сове́ту, бу́дет впо́ру

мәслихәтче *сущ. уст. книжн.* **1.** сове́тчик; челове́к, даю́щий сове́ты **2.** сове́тник, консульта́нт

мәстәр *сущ.* **1.** грифлёная кни́га, тетра́дь для веде́ния ежедне́вника и т. п. за́писей **2.** сме́та (*расходов и доходов*)

мәсхәрә *сущ.* **1.** позо́р; срам, посме́шище; *~ бит бу!* э́то же позо́р! **2.** насме́шка, издёвка, издева́тельство □ **~ булу 1.** опозо́риться, быть опозо́ренным **2.** подверга́ться насме́шкам, быть посме́шищем, предме́том насме́шек; **~ ителгән 1.** опозо́ренный **2.** осме́янный, уни́женный, оскорблённый; **~ итү (кылу)** 1) опозо́рить, осрами́ть,

изнаси́ловать 2) оскорбля́ть/оскорби́ть; ~ **итүче** наси́льник, оби́дчик; **~гә алу** 1. обижа́ться/оби́деться *за что-л.*, приня́ть *что-л.* за оскорбле́ние 2. опозо́рить, осрами́ть; **~гә калу (төшү)** *см.* **мәсхәрә булу**

мәсхәрәләнү 1. *страд. от* **мәсхәрәләү**; быть опозо́ренным, опоро́ченным, оскорблённым 2. обижа́ться/оби́деться *за что-л.*, приня́ть *что-л.* за оскорбле́ние; *см.* **мәсхәрәгә алу**

мәсхәрәләү *перех.* 1. позо́рить, опозо́рить; срами́ть, осрами́ть, поноси́ть, поро́чить, опоро́чить 2. изнаси́ловать, наси́ловать 3. насмеха́ться, высме́ивать, надруга́ться, издева́ться, измыва́ться *над кем-л., чем-л.* 4. унижа́ть/уни́зить, конфу́зить, сконфу́зить; *~эп кычкыру (сызгыру)* освиста́ть

мәсхәрәләшү *взаимно-совм. от* **мәсхәрәләү**; руга́ться, ссо́риться, оскорбля́я друг дру́га; жесто́ко оскорбля́ть друг дру́га

мәсхәрәле *прил.* 1. позо́рный, посты́дный; *~ хәл* позо́рное положе́ние; *~ хәлдә калу* оказа́ться в позо́рном положе́нии 2. издева́тельский; высме́ивающий; насме́шливый; *~ көлү* издева́тельский смех; *~ тавыш* насме́шливый го́лос 3. *в функ. нареч.* с насме́шкой, насме́шливо, издева́тельски, ирони́чно; *~ елмаю* ирони́чно улыбну́ться; *~ чалышаю* кри́во усмехну́ться

мәсхәрәче *сущ. уст. книжн.* 1. насме́шник 2. кло́ун, ко́мик

мәсьәлә *сущ.* 1. вопро́с, пробле́ма; зада́ча; *аграр ~* агра́рный вопро́с; *азык ~се* продово́льственная пробле́ма; *~нең асылы* суть (су́щность) вопро́са 2. *мат.* зада́ча; *~ бирелмәсе* да́нные зада́чи; *~ләр җыентыгы* сбо́рник зада́ч; зада́чник ◊ **~нең асылына төшенү** смотре́ть в ко́рень

мәсьүл *прил. уст. книжн.* 1. зака́занный; *~ нәрсәләрне китерү* принести́ зака́занные ве́щи 2. отве́тственный; *~ редактор* отве́тственный реда́ктор 3. *в знач. нареч.* отве́тственно; *һәр сүзем өчен үземне ~ саныйм* за ка́ждое сло́во считаю себя́ отве́тственным

мәсьүлият *сущ. уст. книжн.* отве́тственность; *~кә тартылу* привлека́ться к отве́тственности

мәсьүлиятле *прил. уст. книжн.* 1. отве́тственный; *~ редактор* отве́тственный реда́ктор 2. ва́жный, отве́тственный; *~ эш* ва́жное де́ло; *~ мәсьәлә* ва́жный вопро́с

мәсьүлиятлелек *сущ. уст. книжн.* отве́тственность; ва́жность (*вопроса, работы, дела, проблемы и т. п.*)

мәсьүлиятсезлек *сущ. уст. книжн.* безотве́тственность; хала́тность (*в работе*)

мәтәкләү *неперех. диал. см.* **мәтәлү**

мәтәлдерү *понуд. от* **мәтәлү** 1. уда́ром (толчко́м) кувырну́ть, перекувырну́ть *кого-л.* 2. вали́ть, свали́ть, повали́ть *что-л.* ре́зким уда́ром 3. опроки́дывать/опроки́нуть (*толчком, нечаянным движением и т. п.*) 4. *перен. разг.* сверга́ть/све́ргнуть, низверга́ть/низве́ргнуть *кого-л., что-л.* (*царя, диктатора, власть, гнёт, господство кого-л., чего-л. и т. п.*)

мәтәлү *неперех.* 1. кувырка́ться/кувыркну́ться, кувырну́ться, перекувырну́ться; *~еп барып төшү* покати́ться ку́барем, загреме́ть; *~еп китү* упа́сть (полете́ть) вверх торма́шками 2. *перен. разг.* быть све́ргнутым, низве́ргнутым (*о чьей-л. власти, господстве и т. п.*), све́ргнуться *уст.*

мәтәлчек *сущ.* кувыро́к; кувырка́ние; *~ атышу* кувырка́ться; *~ атып егылып китү* полете́ть кувырко́м, кувыркну́ться

мәтәлчекләп *нареч.* кувырко́м, кувыркну́вшись; *~ бару* идти́ кувырко́м (*спортивная игра*), кувырка́ться

мәте *сущ. диал.* 1. ил, ти́на 2. вя́зкая, желтова́тая гли́на

мәтле *прил.* мя́тный; *~ конфет* мя́тные конфе́ты; *~ тамчылар* мя́тные ка́пли

мәтрүшкә *сущ. бот.* души́ца; *~ төнәтмәсе (суы, чәе)* насто́й души́цы; *сары ~* зверобо́й

мәтрүшкәләп *нареч.* с души́цей; *~ чәй эчү* пить чай с души́цей

мәтрүшкәлек *сущ.* ме́сто, где мно́го души́цы; поро́сшее души́цей ме́сто

мәхәббәт *сущ. в разн. знач.* любо́вь, симпа́тия *к кому-л.* || любо́вный; *~ турында язу (сөйләү)* писа́ть (говори́ть) о любви́; *~ турында җыр* пе́сня о любви́; *олы ~* больша́я любо́вь; *балаларга ~* любо́вь к де́тям; *~ суыну* разлюби́ть; *~ тоту* люби́ть; *~ тотышу* люби́ть друг дру́га; *~ утында яну* пыла́ть любо́вью ◊ **~ең бакага төшсә, күл буеннан китмәссең** (*погов.*) любо́вь зла, полю́бишь и козла́ (*букв.* любо́вь к лягу́шке привя́жет к бзеру)

мәхәббәтле *прил.* симпати́чный, располага́ющий к себе́; *~ бала* симпати́чный ребёнок; *~ кыз* симпати́чная де́вушка

мәхәббәтлелек *сущ.* симпати́чность; *синдәге ~ миндә булса иде!* был бы я таки́м же симпати́чным, как ты!

мәхәббәтсез *прил.* 1. не симпати́чный, неприя́тный; безобра́зный, непригля́дный 2. *употр. как уничиж., бран. и шутл.* уро́дина; *нишләп утырасың, ~?* что ты сиди́шь, уро́дина?

мәхәббәтсезлек *сущ.* несимпати́чность, непригля́дность, безобра́зность; *абау, ~ге!* ой, како́й некраси́вый! *аның ~ге* его́ безобра́зность

мәхәл *сущ. книжн.* 1. 1) ме́сто прожива́ния 2) пропи́ска 2. уме́стность; *~енә күрә* к ме́сту; по ме́ре уме́стности

мәхәллә *сущ.* 1. 1) прихо́д; *күрше ~* сосе́дний прихо́д; *~ халкы* прихожа́не 2) кварта́л 2. *прил.* прихо́дский; *~ кешесе* прихожа́нин; *~ мәктәбе* прихо́дская шко́ла; *~ мөтәвәллие* прихо́дский попечи́тель

мәхәлли *прил.* 1. прихо́дский 2. ме́стный

мәхбүб *сущ. уст. книжн.* возлю́бленный, люби́мый; *минем ~ем* мой возлю́бленный

мәхбүбә *сущ. уст. книжн.* возлю́бленная, люби́мая; *~мә хат яздым* написа́л письмо́ свое́й возлю́бленной

мәхбүс *книжн.* 1. у́зник, аресто́нт 2. нево́льник, пле́нник

мәхдүм *сущ. книжн.* махду́м (*почтительное название духовных лиц и родственников мужского пола, чаще всего сына муллы*)

мәхдүмә *сущ. книжн.* махдума́ (*почтительное название родственниц духовных лиц, чаще всего дочери муллы*)

мәхзән *сущ. уст. книжн.* 1. кладова́я в медресе́ 2. *перен.* сокро́вищница, клад; святи́лище; *фәннәр ~е* святи́лище нау́к

мәхзүн *прил. уст. книжн.* печа́льный, гру́стный, опеча́ленный, огорчённый

мәхкәмә *сущ. книжн.* 1. *ист.* суд, суде́бное учрежде́ние 2. учрежде́ние

мәхкүм *прил. книжн.* осуждённый; приговорённый, обречённый; *~ булу* быть осуждённым; *~ итү* осужда́ть/осуди́ть, приговори́ть

мәхкүмлек *сущ. книжн.* обречённость

мәхлук *сущ. разг.* **1.** тварь; живо́е существо́; *язны бөтен ~ көтә* весну́ ждёт ка́ждое живо́е существо́ **2.** *см.* **алла бозавы**

мәхлукат *сущ. собир. книжн.* живо́й мир, живы́е существа́; всё живо́е

мәхрүм *прил.* лишённый, лиша́вшийся *кого-л., чего-л.* (*отца, матери, детей, семьи, жилья, прав, свободы, премии, покоя, хлеба, возможности сделать что-л. и т. п.*) || *предик.* лишён *кого-л., чего-л.*; *ул ана булудан ~* она́ лишена́ матери́нства; *ул укый белә, ә язудан ~* он чита́ть чита́ет, а писа́ть не уме́ет □ **~ булу** быть лишённым, лиши́ться *кого-л., чего-л.*; **~ итү** лиши́ть *кого-л., чего-л.*, отнима́ть *что-л.*, оставля́ть без *кого-л., чего-л.*; **~ калу 1.** утра́тить, лиши́ться *кого-л., чего-л.* **2.** оста́ться ни с чем, проморга́ть, проворо́нить, лиши́ться *чего-л.*

мәхрүмлек *сущ.* **1.** обездо́ленность **2.** лише́ния, нужда́, недоста́ток; *~ләрдән ардым инде* уста́л я от э́тих лише́ний

мәхү: мәхү булу *уст.* теря́ться, потеря́ться, пропада́ть/пропа́сть; **мәхү итү** *уст.* теря́ть, потеря́ть, уничтожа́ть/уничто́жить

мәхшәр *сущ.* **1.** *рел. то же, что* **мәхшәр көне 2.** *перен.* сумато́ха, сумя́тица, столпотворе́ние, кутерьма́, да́вка; *автобус тукталышында шундый ~ иде* на авто́бусной остано́вке бы́ло тако́е столпотворе́ние ◊ **~ көне 1.** *рел.* день стра́шного суда́, день воскресе́ния из мёртвых **2.** *перен. разг.* сумато́ха, сумя́тица, столпотворе́ние

мәһабәт *прил.* **1.** держа́вный, велича́вый, соли́дный, внуши́тельный, ста́тный, оса́нистый; *~ кыяфәт* велича́вый вид; *~ ир* о́чень симпати́чный и ста́тный мужчи́на; *~ рәвештә* велича́во **2.** вели́чественный, велича́вый; *~ Кавказ таулары* вели́чественные (велича́вые) Кавка́зские го́ры **3.** си́льный, прекра́сный (*о голосе*)

мәһабәтлек *сущ.* **1.** ста́тность, соли́дность, велича́вость (*о человеке*) **2.** вели́чие, вели́чественность, велича́вость; *биек биналарның ~ге* вели́чие высо́тных зда́ний

мәһәр *сущ. этногр.* кали́м, вы́куп за неве́сту; *~ һәркемнең хәленчә салына* вы́куп вно́сится по возмо́жности

мәһәрле *прил.* доста́точно состоя́тельный, что́бы заплати́ть вы́куп (кали́м)

мәһәрсез *прил.* **1.** *нареч.* без вы́купа, без кали́ма; *кияүгә ~ чыгу* вы́йти за́муж без кали́ма **2.** *прил. перен.* небога́тый, несостоя́тельный (не име́ющий возмо́жности заплати́ть вы́куп, кали́м)

мәче *сущ.* ко́шка ‖ коша́чий; *~ләр миялулавы* коша́чий конце́рт; *ата ~* кот; *ана ~* ко́шка; *~ баласы* котёнок; *~ токымы* коша́чья поро́да; *аларның ~се дә куян тота* (*погов.*) у них и кот за́йцев ло́вит (т.е. *им во всём везёт*); *~ ялап алгандай* (*погов.*) бу́дто кот слизну́л; *~гә уен, тычканга кыен* (*яки тычканга улем, ~гә көлке*) (*погов.*) ко́шке игру́шки, а мы́шке — слёзки □ **~ башлы ябалак** *зоол.* сова́; фи́лин; **~ борчагы** *бот.* просвирня́к, алте́й; **~ бөтнеге** *бот.* молоча́й, бара́нчики; **~ койрыгы** *бот.* подсвеко́льник; **~ үләне** *бот.* валерья́на ◊ **араларыннан кара ~ узган** ме́жду ни́ми пробежа́ла чёрная ко́шка; **~ ашаган** *шутл.* об исче́знувшей, поте́рянной ве́щи

мәчет *сущ. рел.* мече́ть; *мулласына күрә ~е (посл.)* како́в поп, тако́в и прихо́д (*букв.* како́в мулла́, такова́ и мече́ть)

мәчетле *прил.* с мече́тью, име́ющий мече́ть (*деревня, село*); *ике ~ авыл* дере́вня с двумя́ мече́тями (*т. е. большая деревня*)

мәчкәй *сущ. миф.* ве́дьма, колду́нья, ба́ба-яга́

мәчкәү *сущ. диал. охот.* петля́ (*проволочная — для ловли зайцев, волосяная — для ловли птиц*)

мәш: мәш килү копоши́ться, сумато́шиться, кружи́ться, суети́ться, вози́ться; *мәш килеп* оживлённо; суетли́во; *мәш килә башлау* захлопота́ть

мәшәкать *сущ.* **1.** забо́та, хло́поты, труд; беспоко́йство, возня́, суета́; моро́ка; *вак-төяк ~ләр* ме́лкие забо́ты; *дөнья ~ләре* жите́йские хло́поты **2.** муче́ние, страда́ние □ **~ чигү 1.** испы́тывать лише́ния (тру́дности, затрудне́ния) **2.** му́читься, страда́ть; **~ ясау (тудыру, чыгару) 1.** причиня́ть/причини́ть беспоко́йство **2.** создава́ть/созда́ть хло́поты **3.** стесня́ть; **~кә юлыгу (грифтар булу)** *см.* **мәшәкать чигү**; **~кә салу** беспоко́ить *кого-л.*, причиня́ть/причини́ть *кому-л.* беспоко́йство, затрудне́ния

мәшәкатьләнү *неперех.* **1.** забо́титься, озабо́титься, хлопота́ть, беспоко́иться, побеспоко́иться, утруждать себя́, утруждаться, суети́ться; *үтенеп сорыйм, ~мәгез* умоля́ю, не утруждайте себя́ (не беспоко́йтесь) **2.** потруди́ться, му́читься; *сиңа бераз ~ергә туры килер* тебе́ придётся немно́го потруди́ться **3.** *в функ. вспомогат. гл.* 1) пыта́ться, попыта́ться; *чәйнекне төзәтеп ~ү* пыта́ться отремонти́ровать ча́йник 2) утруждать себя́, утруждаться; *көтеп ~мәгез, ул бүген кайтмас* не утруждайте себя́ ожида́нием, он сего́дня не придёт

мәшәкатьләү *перех.* стесня́ть/стесни́ть, беспоко́ить, побеспоко́ить, трево́жить, потрево́жить, утруждать/утруди́ть *кого-л.*; *картларны ~* стесня́ть (беспоко́ить) стариков; *төнлә сезне ~ ярамас* не сто́ит (не годи́тся) вас но́чью трево́жить

мәшәкатьле *прил.* **1.** хло́потный, хлопотли́вый, затрудни́тельный, обременительный, ма́етный **2.** тру́дный, сло́жный, тяжёлый; *~ эш* тяжёлая (тру́дная, сло́жная) рабо́та; *чокыр казу бер дә ~ эш түгел* рыть я́му не тако́е уж сло́жное де́ло **3.** мучи́тельный

мәшәкатьлелек *сущ.* хлопотли́вость, хло́потность

мәшәкатьсез *прил.* **1.** бесхло́потный, необременительный; *~ эш* бесхло́потная рабо́та; рабо́та, не свя́занная с хло́потами **2.** нетру́дный, несло́жный, не тяжёлый □ **~ генә** без хлопо́т, бесхло́потно; *~ генә яшәү* жить бесхло́потно; жить споко́йно (без суеты́)

мәшәләнү *неперех.* (*с оттенками: некстати, не вовремя*) вози́ться *с чем-л.*, занима́ться *чем-то*

мәшгулият *сущ. книжн.* **1.** за́нятость; заня́тие *каким-л.* де́лом **2.** де́ятельность, делови́тость, трудолю́бие

мәшгуль *модальн. сл.* за́нятый; *ул бик ~* он о́чень за́нят □ **~ булу** быть за́нятым, продолжа́ть занима́ться *чем-л.*; *эше белән ~ булды* он продолжа́л занима́ться де́лом

мәшгульлек *сущ.* за́нятость; *бүтән эшләр белән ~ аркасында* из-за за́нятости други́ми дела́ми

мәшкә *сущ.* **1.** гриб-трутови́к **2.** *см.* **мәшкәк 3.** *диал. см.* **гөмбә 4.** *диал.* про́бка из гнилу́шки

мәшкәк *сущ.* **1.** *см.* **тузгак гөмбә 2.** труха́, гниль внутри́ де́рева

мәшрикъ *сущ. книжн.* восто́к; *беребез ~тә, беребез мәгъриптә* оди́н (из нас) на восто́ке, друго́й на за́паде

мәшһүр *прил.* **1.** изве́стный, популя́рный, знамени́тый, просла́вленный; *~ язучы* изве́стный писа́тель; *~ артист* знамени́тый (популя́рный) арти́ст; *~ нефтьче* просла́вленный нефтяни́к; *~ галим* изве́стный (знамени́тый) учёный **2.** *в функ. сказ.* изве́стен, просла́влен, знамени́т *чем-л., как-л.*; *ул маркалар җыю белән ~* он

знамени́т как собира́тель ма́рок; *ул композитор булара́к* ~ он изве́стен как компози́тор

мәшһүрлек *сущ.* изве́стность, просла́вленность, знамени́тость, популя́рность; ~ *казану* снисска́ть себе́ популя́рность

мәэлдәт|ү *понуд. от* **мәэлдәү**

мәэлдә|үү *неперех.* бле́ять (*о козе, овце*); *кәҗә ~и башлады* коза́ забле́яла

мәэлдәш|ү *взаимно-совм. от* **мәэлдәү**

мәэмә: мәэмә итү (*в детской речи*) бить, уда́рить, сде́лать бо́льно

мәэюс *прил. уст. книжн.* **1.** 1) уны́лый, печа́льный; ~ *караш* печа́льный взгляд 2) *в знач. нареч.* уны́ло, печа́льно; ~ *елмаю* улыбну́ться печа́льно **2.** отча́явшийся, потеря́вший наде́жду *на что-л.*

мәэюслән|ү *неперех. уст. книжн.* **1.** станови́ться/стать уны́лым; впада́ть/впасть в уны́ние, уныва́ть **2.** отча́иваться; па́дать ду́хом, огорча́ться

мәэюслек *сущ. уст. книжн.* уны́ние; отча́яние; *~кә калу (төшү)* впада́ть в уны́ние; отча́иваться, па́дать ду́хом

ме́бел|ь *сущ.* ме́бель *мн. нет* (*полированная, модная, импортная, кухонная, мягкая*) || ме́бельный; *йоклы бүлмәсе ~е* ме́бель для спа́льни; *~ь кибете* ме́бельный магази́н □ **~ь остасы (ясаучы)** ме́бельщик

мебельче *сущ.* ме́бельщик

мегаватт *сущ. физ.* мегава́тт (*1 млн ватт*)

мегавольт *сущ. физ.* мегаво́льт (*1 млн вольт*)

мегагерц *сущ. физ.* мегаге́рц (*1 млн герц*)

мегакало́рия *сущ. физ.* мегакало́рия (*1 млн калорий*)

мегато́нна *сущ. спец.* мегато́нна

мегато́нналы *прил.* мегато́нный; ~ *водород бомбалары* мегато́нные водоро́дные бо́мбы

медал|ь *сущ.* меда́ль || меда́льный; *сугышчан ~ьләр* боевы́е меда́ли; *Алтын Йолдыз ~е* меда́ль Золота́я Звезда́; *мәктәпне алтын ~ь белән тәмамлау* око́нчить шко́лу с золото́й меда́лью; *истәлек ~е* па́мятная меда́ль; *~ь лентасы* меда́льная ле́нточка ◊ **~ьнең икенче ягы** оборо́тная сторона́ меда́ли

медальле *прил.* с меда́лью, награждённый меда́лью || медали́ст, медалено́сец

медальон *сущ.* медальо́н

медицина́ *сущ. мат.* медицина́

медиа́тор *сущ. муз.* медиа́тор

ме́дик *сущ.* ме́дик

медикамент *сущ.* медикаме́нты (*ед.* медикаме́нт)

ме́диум I *сущ.* ме́диум (*по мистическим представлениям спиритов: посредник между людьми и миром духов*)

ме́диум II *сущ. муз.* ме́диум (*средний регистр женского певческого голоса*)

медиумизм *сущ.* медиуми́зм (*посредничество между людьми и миром духов, осуществляемое медиумом*) || медиуми́ческий

ме́диумик *прил.* медиуми́ческий

медици́на *сущ.* медици́на (*лечебная, экспериментальная, судебная*) || медици́нский (*пункт, институт*); *~ фәне* медици́нская нау́ка; *~ хезмәткәрләре* медици́нские рабо́тники; *ашыгыч ~ ярдәме* ско́рая медици́нская по́мощь

медпункт *сущ.* медпу́нкт (медици́нский пункт)

медсанбат *сущ.* медсанба́т (ме́дико-санита́рный баталь о́н); *яралыларны ~ка озату* отпра́вить ра́неных в медсанба́т

медсестра *сущ.* медсестра́ (медици́нская сестра́); *см. тж.* **шәфкать туташы**

медуза *сущ. зоол.* меду́за

межа *сущ.* межа́ || межево́й; *см. тж.* **кызан**; *чәчүлек җирләрен аерып торган ~лар* ме́жи, разделя́ющие посевны́е зе́мли □ **~ салу (сызу, яру)** межева́ть; **~ салу кораллары** межева́льные инструме́нты

межалану *страд. от* **межалау** межева́ться, отмежёвываться

межалату *понуд. от* **межалау**

межалау *перех.* межева́ть, отмежёвывать/отмежева́ть || межева́ние, межёвка; отмежева́ние, отмежёвка (*земельных участков, лесов*); *болыннарны ~* межева́ть луга́

межалы *прил.* с межа́ми; отмежёванный; ~ *басулар* отмежёванные поля́

меҗелдәү *неперех.* мя́млить, говори́ть невня́тным го́лосом

мәҗелдәшү *совм. от* **меҗелдәү** (*о многих*) *разг.*

меҗелдек *сущ. разг.* бормоту́н, бормоту́нья

меҗер-меҗер *подр. звуку медленного кипения жидкости* □ **меҗер-меҗер итү (килү)** кипе́ть, бу́лькать

меҗ-меҗ *подр. тихому невнятному голосу* □ **меҗ-меҗ итү (килү)** *см.* **меҗелдәү**

мезантро́пия *сущ. книжн.* мезантро́пия (*человеконенавистничество*)

мезантро́пик *прил.* мезантропи́ческий (*характер*)

мезозой *сущ. геол.* мезозо́й || мезозо́йский □ **~ эрасы** мезозо́йская э́ра

мезон *сущ. физ.* мезо́ны (*элементарные частицы*)

мезонлы *прил. физ.* мезо́нный; ~ *атом* мезо́нный а́том; мезоа́том

мезонин *сущ.* мезони́н || мезони́нный; ~ *бүлмәләре* мезони́нные ко́мнаты

мезонинлы *прил.* с мезони́ном; ~ *дача йортлары* да́чные дома́ с мезони́нами

мекердәү *неперех.* бле́ять (*о ягнёнке*) || бле́яние

мекердәшү *совм. от* **мекердәү** бле́ять (*о многих*)

мекер-мекер *подр. звуку блеяния ягнят, коз* □ **мекер-мекер итү** *см.* **мекердәү**

мекерт-мекерт *подр. хрусту сена, соломы, капусты и т. п. при разжёвывании* □ **мекерт-мекерт итү** хрусте́ть || хруст

ме́ксикалы *сущ.* мексика́нец

мексикан *сущ.* мексика́нец; *~нар иле* страна́ мексика́нцев || мексика́нский; ~ *эшләпә* мексика́нская шля́па

меланж *сущ. текст.* мела́нж (*пряжа или ткань различных по окраске волокнистых материалов*) || мела́нжевый; ~ *җеп* мела́нжевая ни́тка; ~ *тукымалар* мела́нжевые тка́ни

меланхо́лик *сущ.* меланхо́лик, меланхоли́чка || *прил. в разн. знач.* меланхоли́ческий; меланхоли́чный (*темперамент, человек, голос*); ~ *характер* меланхоли́ческий хара́ктер; ~ *кәеф* меланхоли́ческое настрое́ние; ~ *җыр* меланхоли́ческая пе́сня

меланхо́лия *сущ.* меланхо́лия; *~гә бирелү* предава́ться меланхо́лии; ~ *белән җәфалану* страда́ть меланхо́лией

мелинит *сущ. хим.* мелини́т

мелинитлы *прил.* мелини́товый; ~ *шартлаткыч* мелини́товая взрывча́тка

мелиоратив *прил.* мелиорати́вный; ~ *корылмалар* мелиорати́вные сооруже́ния

мелиора́тор *сущ.* мелиора́тор (*специалист по мелиорации*)

мелиора́ция *сущ. с.-х.* мелиора́ция (*улучшение плодородия земель путём их осушения или орошения*) || мелиорати́вный, мелиорацио́нный; ~ *чаралары* мелиорацио́нные мероприя́тия; ~ **үткәрү** мелиори́ровать

мелиора́циялә̆ү *перех.* мелиори́ровать (*заболоченные места*)

мели́сса *сущ. бот.* мели́сса; *см. тж.* **лимон бөтнеге**

мелодекламáция *сущ.* мелодекламáция; ~ *сөйләү* мелодеклами́ровать

мело́дик *прил.* **1.** мелоди́ческий; *җырның ~ төзелеше* мелоди́ческое строе́ние пе́сни **2.** *лингв.* мелоди́ческий; ~ *басым* мелоди́ческое ударе́ние

мело́дика *сущ. иск.* **1.** мело́дика (*учение о мелодии*); *Көнчыгыш илләр ~сы* мело́дика восто́чных стран **2.** мело́дика (*совокупность мелодических средств*); *сөйләм ~сы* мело́дика ре́чи

мело́дия *сущ. муз.* мело́дия; *см. тж.* **көй**

мелодра́ма *сущ. в разн. знач.* мелодра́ма || мелодрамати́ческий; ~ *уйнау* разы́грывать мелодра́му; ~ *геройлары* геро́и мелодра́мы

мелодра́малы *прил. см.* **мелодрама́тик**

мелодраматизм *сущ.* мелодрамати́зм; *әсәр ясалма ~ белән сугарылган* произведе́ние насы́щено иску́сственным мелодрамати́змом

мелодрама́тик *прил.* мелодрамати́ческий, мелодрамати́чный; ~ *роль* мелодрамати́ческая роль; ~ *куренеш* мелодрамати́чная сце́на

меломан *сущ. книжн.* мелома́н (*страстный любитель музыки и пения*)

мелома́ния *сущ. книжн.* мелома́ния (*чрезмерная страсть к музыке и пению*)

мелт-мелт: мелт-мелт итү **1.** морга́ть, мига́ть (*о глазах, веках*); дрожа́ть (*о губах*) **2.** мерца́ть, мига́ть, мелька́ть, трепета́ть (*об огне, пламени, свете*); **мелт-мелт килү** *см.* **мелт-мелт итү 1**

мельхиор *сущ.* мельхио́р || *прил.* мельхио́ровый; ~ *кашыклар* мельхио́ровые ло́жки

мембра́на *сущ. физ., тех.* мембра́на (*телефонной трубки, наушника*); *металл ~* металли́ческая мембра́на

мембра́наллы *прил.* мембра́нный (*насос, манометр*)

мемора́ндум *сущ. офиц.* мемора́ндум; *хөкүмәт ~ы* мемора́ндум прави́тельства

мемориал *сущ.* **1.** мемориа́л (*архитектурное сооружение, воздвигнутое для увековечения памяти о ком-л., чём-л.*); *тарихи ~ларны саклау* охра́на истори́ческих мемориа́лов **2.** мемориа́л (*спортивное соревнование, посвящённое памяти выдающихся спортсменов*)

мемориаль *прил.* мемориа́льный (*музей, центр*); ~ *такта* мемориа́льная доска́

мемуар *сущ. лит.* мемуа́ры; *сугыш еллары ~лары* мемуа́ры вое́нных лет || *прил.* мемуа́рный (*жанр*); ~ *әдәбият* мемуа́рная литерату́ра

мемуарчы *сущ.* мемуари́ст, мемуари́стка

менә *мест. указ.* вот, во *прост.*; ~ *кәгазь, каләм, әнә өстәл — утырыгыз да языгыз* вот бума́га, ру́чка, вон стол — сади́тесь и пиши́те; ~ *сез сораган кеше* вот челове́к, кото́рого вы спра́шивали || *частица* **1.** *усил.* 1) *употр. для усиления, подчёркивания значения последующего или предыдущего слова* вот; ~ *килеп тә җиттек* вот и прие́хали; ~ *монысы ярый (шәп)!* а вот э́то подхо́дит, да! *күршебез авырып китте* ~ сосе́д вот заболе́л 2) *употр. с указ. и относит. мест., а также с нареч. места, времени и т. п. для уточнения и усиления их значения* вот, вон; ~ *шундый хәлләр* вот таки́е дела́; ~ *нинди күңелле хәбәр!* вот кака́я прия́тная весть! ~ *монда сезнең урыннарыгыз* вот тут ва́ши места; ~ *үзе дә килде* вот и сам пришёл 3) *употр. для привлечения внимания собеседника к чему-л.* вот; ~ *төсле телевизор алдык* вот купи́ли цветно́й телеви́зор; ~ *күрәсезме, күпме генә калды эш* вот смотри́те, совсе́м немно́го оста́лось рабо́ты 4) *разг. преимущ. постпозитивно выражает предостережение или угрозу* вот (ну) погоди́; вот (ну) смотри́; *әниеңә әйтим әле* ~ вот погоди́, скажу́-ка твое́й ма́ме; *бөтен серләреңне сөйлим дә бирәм* ~ ну смотри́, возьму́ да и расскажу́ все твои́ секре́ты 5) *употр. в восклиц. предл. для усиления эмоциональной окрашенности* вот; ~ *шатланырлар инде балалар!* вот обра́дуются де́ти! ~ *рәхәт,* ~ *тамаша!* вот благода́ть, вот весе́лье (ди́во!) 6) *употр. в знач. связки при именном сказуемом* вот; *тынычлык сагында уяу булу — ~ безнең максатыбыз* быть бди́тельными на стра́же ми́ра — вот на́ша цель **2.** *усил.* уж; *шундый сагындым, шундый сагындым ~ үзеңне!* уж так соску́чился, так соску́чился по тебе́! *ничә тапкыр әйттем ~, ишетергә дә теләми* уж ско́лько раз говори́л, слы́шать да́же не хо́чет **3.** *усил.* да́же; *кararга куркыныч ~* смотре́ть да́же стра́шно; *нич сөйләп бетерерлек түгел ~!* да́же всего́ и не расска́жешь! **4.** *огранич.* так, наприме́р: хотя́ бы; ~ *тәртип мәсьәләсен генә алып карыйк* так, наприме́р, возьмём вопро́с о дисципли́не **5.** *утверд. (обычно в повторной ф.)* вот-во́т; и́менно так; ~, ~, *бик дөрес әйтәсең* вот-во́т, о́чень пра́вильно говори́шь; ~, ~, *шуңар аптырыйм да мин* и́менно так, э́тому-то я и удивля́юсь **6.** *в знач. нареч.* (*чаще в ф. повтора*) вот-во́т, ещё немно́го и ..., вот сейча́с; *менә-менә яңгыр яварга тора* вот-во́т дождь начнётся; ещё немно́го и дождь пойдёт; ~ *кайта,* ~ *кайта, дип көтеп утырабыз* ждём, ду́маем, вот-во́т вернётся **7.** *перен., разг., употр. при нанесении побоев или порицании* во́т тебе́! ~ *күп сөйләнеп торсаң* во́т тебе́ за твою́ ли́шнюю болтовню́ **8.** *перен. см.* **менә сиңа кирәк булса;** ~ *үпкәләдә дә инде* вот те на, уже́ и оби́делась **9.** *межд.* во!, вот!, *см. тж.* **менә дигән;** *аның егете — ~!* жени́х её — во! ◊ ~ **әкәмәт!** вот так фунт! вот так клю́ква! ~ **бәла!** вот беда́! вот так ока́зия! ~ *бәла, инде нишләргә?* вот так ока́зия, что́ же тепе́рь де́лать? ~ **булдырдың!** ай да молоде́ц! ~ **генә 1.** вот же, совсе́м ря́дом, ря́дышком **2.** вот-во́т, то́лько что; ~ **дигән 1.** что на́до, хоть куда́; сла́вный, мирово́й, запра́вский **2.** отли́чно, кома́р но́са не подто́чит (*о какой-л. работе*); ~ **дигән итеп** о́чень хорошо́, блестя́ще, великоле́пно, класси́чески; ~ **инде!** *см.* **менә тагын 1**; ~ *инде, елый да башлады* вот те на, уже́ начала́ пла́кать; ~ **кайда икән йомгакның очы** вот, ока́зывается, где соба́ка зары́та; ~ **кара (күр) инде** вот полюбу́йся; ~ **карап тор,** ~ **күр дә тор** вот уви́дишь; ~ **мин дип (кычкырып) тора** ле́зет в (на) глаза́ *кому-л.*; броса́ется пря́мо в глаза́ *кому-л.*; ~ **мин сине** вот я тебя́ (*употр. при угрозе, порицании*); ~ **нәрсә!** *см.* **менә ничек;** ~ **ничек!** вот как! вот (вон) оно́ что! ~ **син (э)** *см.* **менә сиңа кирәк булса;** ~ *син, э! ышанып йөр аңа* вот те раз! вот и верь ему́ по́сле э́того; ~ **сиңа! 1.** во́т тебе́! (*т. е. получай заслуженное наказание*); ~ *сиңа, күп сөйләсәң!* во́т тебе́ за твою́ болтовню́! **2.** *ирон. (выраж. удивление и порицание)* вот так **3.** *см.* **менә (сиңа) кирәк булса;** ~ *сиңа! бу ни дигән сүз?* во́т тебе́ на! что э́то зна́чит? ~ **сиңа әкият!** вот так шту́ка! вот так клю́ква! ~ **(сиңа) кирәк булса!** во́т тебе́ (и) на! вот те (и) на! во́т тебе́ раз! вот так шту́ка! вот так финт! ми́ленькое де́ло; ~ **(сиңа) мә!** *см.* **менә (сиңа) кирәк булса;** ~ **сүз** вот те (и) раз! ~ *сүз, эш*

белән йөрим! вот те раз, по де́лу хожу́; ~ **тагы (тагын)!** 1. во́т тебе́ (и) на! во́т тебе́ (те) раз! ~ *тагын, нигә дөресен сөйләп бирмәскә?* вот те раз! почему́ же не рассказа́ть пра́вду? 2. ну и что́ же; *җырласалар ни, ~ тагын!* ну и что́ же, пусть поют! ~ **шул (гына)** вот и всё; во́т тебе́ и весь сказ! ~ **шулай була ул!** то́-то, вот оно́ и есть! ~ **шул-шул** та́к-то вот, вот та́к-то оно́

менәтерә *частица усил. диал. см.* **менәтерәк** ◊ ~ **вәт!** *прост.* вот те на!

менәтерәк *частица усил. разг. см.* **менә** 1; *бигрәкләр дә кызганыч булды* ~ о́чень уж жа́лко бы́ло, вот ◊ ~ **вәт!** вот те на!

менбәр *сущ.* 1. *рел.* минба́р (*возвышение в мечети, с которого имам произносит проповедь*) 2. трибу́на, ка́федра

менгәләү *многокр. от* **менү**; поднима́ться (*иногда, время от времени*)

менге *прил.* верхово́й; ~ *ат* верхова́я ло́шадь; *~гә генә тота торган атлар* ко́ни, содержа́щиеся то́лько для верхово́й езды́

менгезү *перех. разг. см.* **мендерү** 1—3

менгерү *перех. разг. см.* **мендерү** 1—3

мендәр *сущ.* 1. поду́шка (*пуховая, поролоновая, ковровая, диванная*); *~гә тышлык кидерү* наде́ть на́волочку на поду́шку; *баш астына ~ салу* подложи́ть поду́шку под го́лову; *~ мамыгы* поду́шечный пух 2. *спец.* поду́шка (*опора, основание чего-л.*); *ияр ~е* поду́шка седла́; *арбаның ал күчәре ~е* поду́шка пере́дней оси́ теле́ги; *фундамент ~е* поду́шка фунда́мента □ ~ **конфет** *разг.* поду́шечка; ~ **тышы** на́волочка; ~ **япмасы** наки́дка

мендәрче *сущ. этногр.* посте́льница (*женщина, готовящая невесту к брачной постели*)

мендәрче|к *сущ. уменьш.-ласк.* поду́шечка; *энә ~ге* поду́шечка для иго́лок; *бала ~ге* де́тская поду́шечка

мендерү *перех.* 1. поднима́ть/подня́ть наве́рх *кого-л., что-л.* (*лодку на берег, груз на платформу*); *машина белән ~* поднима́ть на маши́не; *кулдан тартып ~* подня́ть за́ руку 2. помога́ть/помо́чь влеза́ть (влезть, поднима́ться/подня́ться) наве́рх *кому-л.*; *вагонга ~* помо́чь влезть в ваго́н; *баскычтан җитәклән ~* помога́ть подня́ться по ле́стнице 3. сажа́ть, посади́ть, подса́живать *кого-л.* (*на коня*) 4. повыша́ть/повы́сить, поднима́ть/подня́ть (*цены, зарплату*); *см. тж.* **күтәрү** 3 5. *перен. разг.* выдвига́ть/вы́двинуть *кого-л.* (*на какую-л. должность*) || выдвиже́ние 6. *перен. разг.* прота́лкивать/протолкну́ть (*на сцену, какую-л. пьесу*)

менел|ү *безл. от* **менү**; прихо́дится поднима́ться; *кирәк булса, тауга да ~ә* е́сли на́до (есть нужда́), прихо́дится и на го́ру поднима́ться

ме́нзула *сущ. спец.* ме́нзула (*геодезический прибор*)

мензу́рка *сущ.* мензу́рка || мензу́рочный

менингит *сущ. мед.* менинги́т (*воспаление оболочек головного и спинного мозга*)

менла *сущ.* 1. *уст. см.* **мулла** 2. старшеку́рсник медресе́

менструа́ция *сущ. физиолог.* менструа́ция; *см. тж.* **күрем**

ментол *сущ.* менто́л (*прозрачное кристаллическое вещество с сильным мятным запахом*) || менто́ловый; ~ *мае* менто́ловая мазь

ментоллы *прил.* менто́ловый, с менто́лом

мен|ү *неперех.* 1. 1) поднима́ться/подня́ться вверх; восходи́ть, всходи́ть/взойти́ || подъём, восхожде́ние (*на берег, на десятый этаж, на крыльцо, на трибуну*); *тауга ~үе авыр, төшүе җиңел* (*посл.*) на го́ру поднима́ться тяжело́, спуска́ться легко́ 2) *прям., перен.* поднима́ться/подня́ться; *су тезгә кадәр ~де* вода́ поднялась до коле́н; *чын сәнгать әсәрләре дәрәҗәсенә ~ү* подня́ться до у́ровня произведе́ний настоя́щего иску́сства 3) поднима́ться/подня́ться; распространя́ться/распространи́ться наве́рх (*о дыме, запахе, голосе, песне и т. п.*); *чәнчү күкрәккә, кулбашларына ~ә* ко́лики поднима́ются до груди́, к плечевы́м суста́вам 2. въезжа́ть, въе́хать || въезд; *олаулар тауга ~деләр* подво́ды въе́хали на го́ру 3. влеза́ть/влезть, залеза́ть/зале́зть, забира́ться/забра́ться, взбира́ться/взобра́ться (*на дерево, на крышу, на мачту*) 4. поднима́ться/подня́ться, взлета́ть/взлете́ть; *югарыга, биеккә ~ү* подня́ться (взлете́ть) ввысь; *айга ~еп, түбән карап, сине күрәсем килә* (*песня*) взлете́ть бы на луну́ да, гля́нув вниз, узре́ть тебя́ 5. *разг.* поднима́ться/подня́ться, повыша́ться/повы́ситься (*о температуре, цене, зарплате*) 6. *прям., перен.* сади́ться/сесть *на кого-л.*; сесть верхо́м; *атка ~ү* сесть на коня́; сесть верхо́м на ло́шадь; *җилкәсенә ~еп атлану* сесть на ше́ю 7. *перен.* ударя́ть/уда́рить; *башка ~де* уда́рило в го́лову (*о спиртном*) 8. *имеет индив. переводы: власть (эш) башына ~ү* захвати́ть власть; *зур дәрәҗәгә ~ү* дости́чь высо́кого зва́ния (больши́х посто́в); доби́ться большо́й до́лжности □ **~еп бару** 1. поднима́ться 2. въезжа́ть; **~еп җитү** 1. взобра́ться 2. дости́гнуть (*вершины горы*); **~еп килү** поднима́ться; **~еп төшү** 1. сла́зить; *түбәгә ~еп төшү* сла́зить на кры́шу 2. сходи́ть; *югары очка ~еп төшү* сходи́ть на ве́рхнюю окра́ину (*села*) 3. слета́ть; *айга ~еп төшү* слета́ть на Луну́ 4. *перен. прост.* съе́здить; *авызына ~еп төшү* съе́здить по мо́рде; **~ү аты** верхова́я ло́шадь

меньшевизм *сущ.* меньшеви́зм || меньшеви́стский; ~ *тарафдары* сторо́нник меньшеви́зма, меньшеви́к; ~ *карашлары* меньшеви́стские взгля́ды

меньшевик *сущ. ист.* меньшеви́к || меньшеви́стский; *~лар партиясе* меньшеви́стская па́ртия

меньшеви́стик *прил.* меньшеви́стский; ~ *тайпылышлар* меньшеви́стские укло́ны; ~ *лозунглар* меньшеви́стские ло́зунги

меню *сущ. кулин.* меню́; *бай ~лы ашханә* столо́вая с бога́тым меню́; *~ны карап чыгу* просмотре́ть меню́

мең *числ. колич.* 1. ты́сяча; *мең сум* ты́сяча рубле́й; *меңгә якын кеше* о́коло ты́сячи челове́к; *унар мең* деся́тки ты́сяч; *мең дә бер кичә* ты́сяча и одна́ ночь; *мең бәлагә — бер җавап* (*погов.*) семь бед — оди́н отве́т; *алган бер языклы, алдырган мең языклы* (*посл.*) взя́вший гре́шен еди́ножды, потеря́вший — тысячекра́тно (*может подозревать любого*) 2. *в сочет. со словами на* **-лы, -лык** тысяче-; *меңь еллык* тысячеле́тний; *мең километрлы* тысячекилометро́вый; *мең башлы* тысячеголо́вый 3. ты́сяча, мно́жество; *мең сәбәп табу* найти́ ты́сячу причи́н; *халык мең күзле (погов.)* у наро́да ты́сяча глаз 4. *перен.* ты́сячу (ты́сячи) раз; *мең әйттем* говори́л ты́сячу раз; *дошманыңнан бер саклан, яман дустан мең саклан (посл.)* от врага́ берегись оди́н раз, от плохо́го дру́га — ты́сячу раз; *мең тыңла, бер сөйлә (погов.)* ≈ сло́во — серебро́, молча́ние — зо́лото (*букв.* ты́сячу раз послу́шай, оди́н раз скажи́) 5. *мн. разг.* ты́сячи (*о больших деньгах, капитале*); *меңнәр белән эш йөртә* воро́чает ты́сячами □ **мең башы** *ист.* ты́сяцкий; ты́сячник; **меңнәр классы** *мат.* второ́й класс, класс ты́сяч ◊ **мең бәла (газап) белән** с огро́мными (неимове́рными) тру́дностями; **мең гафу!** ты́сячу извине́ний!; **мең дә береңче**

тапкыр (кат) *см.* **мең кат** 1; **мең дә берне белү** *ирон.* быть всезна́йкой; **мең җан белән** всей душо́й, всем се́рдцем; *мең җан белән гашыйк булу* влюби́ться всем се́рдцем; **мең кат (мәртәбә, тапкыр)** 1. ты́сячу (ты́сячи) раз; тысячекра́тно 2. *со сравн. ст. прил.* в ты́сячу раз; *мең тапкыр яхшырак* в ты́сячу раз лу́чше; **мең киртә аша үтеп** *см.* **мең бәла (газап) белән**; **мең (мең-мең) рәхмәт** ты́сяча благода́рностей, огро́мное спаси́бо; **мең ризалык белән** с больши́м удово́льствием; **мең (меңнәр) яшә!** живи́ (здра́вствуй) ты́сячу лет! **мең яшәгән, мең яшәрле(к)** тысячеле́тний, долголе́тний; **меңгә тапкырлану** увели́чиваться тысячекра́тно; **меңгә ярылу** разрыва́ться на ча́сти

меңаяк *сущ. зоол.* кився́к

меңәр *числ. разд.* 1. 1) по ты́сяче; *~ сум отыш алу* вы́играть по ты́сяче рубле́й 2) *с логич. ударением* до ты́сячи; по ты́сяче; *сменага ~ тонна күмер чыгару* добыва́ть за сме́ну до ты́сячи тонн угля́ 2. **меңәрдән** из расчёта по ты́сяче 3. *в сочет. со словами на* **-лы** тысяче-; *~ килограммлы* тысячекилограмм о́вый; *~ километрлы* тысячекилометро́вый 4. *см.* **меңнәрчә**; *~ чакрым җәяү үтү* пройти́ пешко́м ты́сячи киломе́тров; *~ километр юл очып үтү* пролете́ть ты́сячи киломе́тров

меңәрләгән *числ. прибл., то же, что* **меңләгән**; *удар төзелешкә ~ яшь көчләр килде* на уда́рную стро́йку наéхали ты́сячи молоды́х си́л

меңәрләп 1. *числ. разг.* по ты́сяче, ты́сячами; *~ өләшү* раздава́ть по ты́сяче; *~ санау* счита́ть ты́сячами 2. *числ. прибл. чаще в ф. повтора* ты́сячами; *~ юкка чыгу* исеза́ть ты́сячами; *саранчалар меңәрләп-меңәрләп очып киләләр* саранча́ налета́ет ты́сячами

меңәү *числ. собир.* ты́сяча; *алар ~* их ты́сяча

меңбаш: меңбаш үлән *бот.* тысячеголо́в

меңгер-меңгер *нареч.* ти́хим, невня́тным го́лосом (*зубрить что-то, бормотать про себя, говорить*)

меңгер|ү *перех. разг. см.* **менгерү** □ **~еп җибәрү** посла́ть (напра́вить) *кого, что* наве́рх

меңенче *числ. порядк.* ты́сячный; *миллиметрның ~ өлеше* ты́сячная до́ля миллиме́тра; *газетаның ~ саны* ты́сячный но́мер газе́ты; *~ километрны очу* налета́ть ты́сячный киломе́тр

меңләгән *числ. прибл.* 1. о́коло ты́сячи; ты́сячи, не́сколько ты́сяч; *алар бик күп, ~* их мно́го, ты́сячи; *мәйданга ~ кеше җыелган* на пло́щадь собрали́сь ты́сячи люде́й 2. многоты́сячный; *~ гаскәр туплау* сколоти́ть многоты́сячную а́рмию; *~ сайлаучылар* многоты́сячные избира́тели

меңләп *числ. прибл.* 1. о́коло (до) ты́сячи; приме́рно (приблизи́тельно) ты́сяча; с ты́сячу; *~ тамашачы* о́коло ты́сячи зри́телей; приме́рно ты́сяча зри́телей 2. *в знач. нареч. в ф. повтора* **меңләп-меңләп** ты́сячами; *меңләп-меңләп һәлак булу* ги́бнуть ты́сячами

меңләтә *нареч. разг.* в ты́сячу раз, мно́жество раз; тысячекра́тно; *ул ~ хаклы* он прав ты́сячу раз; *~ көчәйтү* уси́ливать тысячекра́тно

меңле *см.* **меңлек** 1; *илле ~ гарнизон* пятидесятиты́сячный гарнизо́н

меңлек *в сочет. с колич. числ.* 1. -тысячный; *кырык ~ гаскәр* сорокаты́сячное во́йско; *өч меңлек тираж белән* трёхты́сячным тиражо́м 2. на ... ты́сяч; *ун ~ товар сату* прода́жа това́ров на де́сять ты́сяч рубле́й

меңнәрчә *числ. прибл.* 1. ты́сячи (*неопределённо много*); *~ батыр сугышчылар һәлак булды* поги́бли ты́сячи хра́брых во́инов; *~ йолдызлар җемелди* мерца́ют ты́сячи звёзд 2. *в сочет. со словами, обозначающими время и меру длины* тысяче-; *~ еллар дәвамында* в тече́ние тысячеле́тий; *~ километрлы юл* тысячекилометро́вый путь

меңче *сущ.* 1. *ист. см.* **мең башы** 2. *разг.* ты́сячник (*передовой рабочий, колхозник, выполняющий десять и более норм за рабочий день*); *~ләр хәрәкәте* движе́ние ты́сячников

меңьеллы|к *сущ.* тысячеле́тие; *кешелек тарихының киләчәк ~гы* бу́дущее тысячеле́тие исто́рии челове́чества

меңьяфрак *сущ. бот.* тысячели́стник; *тал яфраклы ~* иволи́стный тысячели́стник

ме́ргель *сущ. геол.* ме́ргель (*осадочная горная порода*) || ме́ргельный; *~ катламы* ме́ргельный пласт; *~ белән ашлау, ~ керту* мергелева́ние

мере́жка *сущ.* мере́жка (*способ вышивания*)

мере́жкалау *неперех.* отде́лать мере́жкой; мережкова́ть || де́лать, сде́лать мере́жку; *төсле җепләр белән ~* сде́лать мере́жки разноцве́тными ни́тями

мере́жкалы *прил.* мере́жчатый; *~ бизәк* мере́жчатый узо́р

меридиа́н *сущ. геогр.* меридиа́н || меридиа́нный; *күк ~ы астр.* небе́сный меридиа́н; *Җир ~ы* земно́й меридиа́н; *~ яссылыгы* меридиа́нная пло́скость

меридиональ *прил.* меридиона́льный; *~ сызык* меридиона́льная ли́ния

меринос *сущ.* 1. мерино́с (*порода овец, имеющих тонкую белую шерсть*) 2. мерино́с (*шерсть такой овцы или ткань из этой шерсти*) || мерино́совый; *~ сарыклары* мерино́совые о́вцы; *~ шәле* мерино́совая шаль

меркантилизм *сущ.* 1. меркантили́зм (*экономическое учение и политика торговой буржуазии Европы XV—XVIII вв.*) 2. *перен. книжн.* меркантили́зм (*мелочная расчётливость, склонность всё рассматривать с точки зрения материальной выгоды*)

меркантилист *сущ.* меркантили́ст

меркантили́стик *прил.* меркантилисти́ческий; *~ политика* меркантилисти́ческая поли́тика

меркантиль *прил.* мерканти́льный; *~ система* мерканти́льная систе́ма; *~ мәнфәгатьләр* мерканти́льные интере́сы

мер-мер: мер-мер килү мурлы́кать, говори́ть ти́хим го́лосом

мер|ү *неперех. диал.* 1. кре́пко спать; *см. тж.* **меснәү** 2. *в знач. нареч.* **мереп** кре́пко, сла́дко; *~еп йокыга китү* кре́пко засну́ть □ **~еп китү** кре́пко засну́ть (усну́ть)

мираж *сущ. прям., перен.* мира́ж || мира́жный; *чүлдәге ~ мираж* в пусты́не; *көтмәгәндә ~дай калкып чыгу* неожи́данно возни́кнуть, как мира́ж; *бу бит хыял, ~ гына!* э́то же то́лько мечта́, мира́ж!

миражланып *нареч.* как мира́ж; *~ күренү* видне́ться, как мира́ж

мирас *сущ.* **1.** насле́дство || насле́дственный; *атадан калган ~* насле́дство, оста́вшееся от (по́сле сме́рти) отца́; *дәгъвалы ~* спо́рное насле́дство; *~ милке* насле́дственное иму́щество; *~ хокукы* насле́дственное пра́во (пра́во насле́дования) **2.** насле́дие; *Г. Тукайның әдәби ~ы* литерату́рное насле́дие Г. Тука́я; *ата һөннәре — балага ~* профе́ссия (ремесло́) отца́ — сы́ну насле́дие; *сүзлекләр — киләчәк буыннарга ~* словари́ — насле́дие бу́дущим поколе́ниям □ **~ алу** получи́ть насле́дство; унасле́довать; **~ буенча калган** унасле́дованный, насле́дственный; доста́вшийся, передава́емый, полу́ченный по насле́дству; **~ булып калган** унасле́дованный, насле́дованный; **~ булып калу** оста́ться, доста́ться в насле́дство, по насле́дству *от кого-л.*

мираслы *прил.* с насле́дством; с насле́дием; *бай ~* с бога́тым насле́дием

мираслык *сущ.* прее́мственность, насле́дственность; *~ күренеше* явле́ние насле́дственности (прее́мственности) || *прил.* предназна́ченный для насле́дников; *~ йорт* дом, предназна́ченный для насле́дников

мирасчы *сущ. разг.* **1.** насле́дник, насле́дие; *~лар арасында бай мирас буленде* ме́жду насле́дниками бы́ло разделено́ бога́тое насле́дство **2.** *перен.* прее́мник, насле́дник; *әдәби традицияләр ~лары* прее́мники литерату́рных тради́ций

мирза *сущ.* **1.** *ист. наследственный титул с приблизительным значением* князь **2.** *ист.* грамоте́й, писе́ц **3.** *ист.* мурза́ (*дворянин из татар, башкир*); *күрше утар ~сы* мурза́ сосе́днего име́ния; *~ кызы* дочь мурзы́; *~ йорты* дом мурзы́ **4.** *перен. уст.* господи́н, хозя́ин, глава́; *этәч үз чуплегендә үзе ~* (*погов.*) пету́х — господи́н на свое́й сва́лке **5.** *см.* **морза ◊ чабаталы ~** *пренебр.* вы́скочка; ни́щий князь

мирзалык *сущ. ист.* положе́ние мурзы́

ми́рра *сущ. бот.* **1.** ми́рра || ми́рровый; *~ исе* ми́рровый за́пах; *~ мае* ми́рровое ма́сло; *~ төнәтмәсе* ми́рровая насто́йка **2.** ми́рра, ми́рровое де́рево, бальза́мное де́рево || ми́рровый; *~ ботаклары* ми́рровые ве́тки; ве́тки бальза́много де́рева (ми́рры)

мирт *сущ. бот.* **1.** мирт || ми́ртовый; *мәңге яшел ~ агачы* ве́чнозелёное де́рево мирт (ми́ртовое де́рево); *аланда ~ чәчәк аткан вакыт* вре́мя, когда́ на поля́не цветёт мирт; *~ җиләге* ми́ртовые я́годы; *~ куагы* ми́ртовый куста́рник **2.** *мн.* **миртсыманнар** ми́ртовые; *канәфер агачы, эвкалипт ~сыманнар семьялыгына керәләр* гвозди́чное де́рево, эвкали́пт относя́тся к семе́йству ми́ртовых

мисал *сущ.* **1.** приме́р, образе́ц; *~ итеп алырлык* мо́жно приня́ть за образе́ц **2.** 1) ча́стный слу́чай, приводи́мый в поясне́ние, в доказа́тельство, приме́р; *~ белән аңлату* объясни́ть приме́ром (на приме́ре); *~га (~ итеп) әлеге яңа картинаны күрсәтергә була* возьмём для (в ка́честве) приме́ра (как приме́р) но́вую карти́ну 2) *в ф. местно-вр.п.притяж.* **мисалында** на приме́ре, по приме́ру *кого-л., чего-л.* (учи́ть, учи́ться *чему-л.*) **3.** 1) иллюстра́ция; *сүзлектә аңлатмадан соң китерелгән ~лар* иллюстра́ции, приведённые в словаре́ по́сле толкова́ния сло́ва 2) приме́р, зада́ча (*из учебника, задачника*); *~ны күчерү (чишү, тикшерү, язу)* переписа́ть (реши́ть, прове́рить, написа́ть) приме́р □ **~ өчен** *вводн. сл.* к приме́ру, наприме́р; *~ өчен, былелгы уңышны әйтик* к приме́ру, ска́жем о ны́нешнем урожа́е; **~ы булмау (күренмәү)** быть еди́нственным, беспримерным

мисаллы *прил.* **1.** име́ющий приме́ры, с приме́ром, с иллюстра́цией; *~ аңлатма* толкова́ние с иллюстра́цией (приме́ром) **2.** *в знач. послелога, уст. книжн.* подо́бный; подо́бно; наподо́бие; *заман явызлар заманы булса, адәмнәр буре ~ булырлар* (*посл.*) е́сли придёт вре́мя жесто́ких, то лю́ди ста́нут подо́бно волка́м

мисалындагы *послелог. разг.* как, подо́бно, сло́вно; *фәрештә ~ бәндә* челове́к как а́нгел

мисвәк *сущ. уст.* зубочи́стка (*из особого сорта ароматического дерева*)

мисез *прил. разг.* безмо́зглый, бестолко́вый, тупо́й, глу́пый

мисезлек *сущ. разг.* безмо́зглость, ту́пость, глу́пость

мисек *сущ. уст.* му́скус || му́скусный за́пах

миски *сущ. разг.* кастрю́ля, ми́ска; *зур ~* больша́я кастрю́ля; *эмаль ~* эмалиро́ванная ми́ска

мисле *предлог, книжн.* подо́бный, подо́бно *кому-л., чему-л.*; сло́вно *кто-л., что-л.*; *мыегы бар ~ күсе койрыгы* подо́бные крыси́ному хвосту́ у него́ усы́ ◊ **~ булмау** быть еди́нственным; *дөньяда ~ булмаган (~ юк) гүзәл кыз* еди́нственная по красоте́ де́вушка; **~ күренмәгән** неви́данный, беспримерный

мисраг *сущ. лит. уст.* **1.** мисра́, полусти́шие **2.** строфа́, куплет

мисрый *прил.* **1.** *уст.* еги́петский; *~ әһрамнар* еги́петские пирами́ды **2.** *ист.* обуча́вшийся в Еги́пте (*преимущ. о религиозных деятелях*); *~ хәзрәт* хазре́т (*духовное лицо*), обуча́вшийся в Еги́пте || *сущ. книжн.* египтя́нин; *мн.* египтя́не; *~лар вә кыйбтыйлар* египтя́не и ко́пты

мисс *сущ.* **1.** мисс 1) *вежливое название и обращение к незамужней женщине в англоязычных странах* 2) мисс (*англичанка — воспитательница в дореволюционной России*) **2.** *неол.* мисс (*женщина, девушка, занявшая первое место на конкурсе красоты в определённой местности, области*)

миссионер *сущ.* миссионе́р || миссионе́рский; *~ язмалары* запи́ски миссионе́ра; *~ вәгазьләре* миссионе́рские про́поведи; *~лар мәктәбе* миссионе́рская шко́ла

миссионерлык *сущ.* миссионе́рство, де́ятельность миссионе́ра; *~ программасы* миссионе́рская програ́мма

ми́ссис ми́ссис (*вежливое название и обращение к замужней женщине в Англии и Америке*)

ми́ссия *сущ. в разн. знач.* ми́ссия; *мөһим ~* ва́жная ми́ссия; *сәүдә ~се* торго́вая ми́ссия; *хәрби ~* вое́нная ми́ссия

ми́стик *сущ.* ми́стик (*человек, склонный к мистике; последователь какого-л. религиозно-методического учения*) || *прил.* мисти́ческий (*верования, теории*); *~ секта* мисти́ческая се́кта; *~ карашлар* мисти́ческие взгля́ды

ми́стика *сущ.* ми́стика (*суеверие; суеверная, несостоятельная аналогия, используемая для различного рода объяснений, предсказаний и т. п.*)

мистифика́тор *сущ. книжн.* мистифика́тор || мистифика́торский; *~ уйдырмалар* мистифика́торские вы́думки

мистифика́ция *сущ. книжн.* мистифика́ция, мисти́ческое объясне́ние

мистицизм *сущ. книжн.* скло́нность к ми́стике, мистици́зм

мисыр *сущ.* 1) Еги́пет || еги́петский; *~ пирамидалары* еги́петские пирами́ды; *~ иероглифлары* еги́петские иеро́глифы □ **~ бодае** *уст. книжн.* кукуру́за;

~ **кабиләсе** цыга́не, *ср. русск.* фараóново плéмя; ~ **күгәрченнәре** еги́петские гóлуби; ~ **тавыгы** цеса́рка; ~ **тарысы** сóрго

мисырлы *сущ.* **1.** 1) египтя́нин, египтя́нка; *мн.* египтя́не, египтя́нки; жи́тель, жи́тельница Еги́пта; ~ *хатын-кыз* египтя́нка; ~ *киеме* оде́жда египтя́нина (египтя́нки) 2) *мн.* **мисырлылар** египтя́не; *борынгы ~ларга ук башка планеталар барлыгы мәгълүм булган* уже́ дре́вним египтя́нам бы́ло изве́стно о нали́чии други́х плане́т **2.** *уст.* цыга́не

мисырлыла́рча *нареч.* как египтя́не, как у египтя́н; ~ *бию* танцева́ть как египтя́не; ~ *язарга өйрәтү* обуча́ть писа́ть как египтя́не, как у египтя́н

ми́тинг *сущ.* ми́тинг (*массовое собрание*); ~ *уткәрү* устра́ивать, проводи́ть ми́тинг; митингова́ть *разг.*

миткаль *сущ. текст.* миткáль || миткáлевый; из миткаля́; ~ *тукылышына охшаш* вы́ткан как миткáль; переплете́ние как у миткаля́; ~ *цехы* миткáлевый цех; ~ *кулмәк* миткáлевая руба́шка; руба́шка из миткаля́

митрополит *сущ. церк.* митрополи́т || митрополи́тский; митрополи́чий; ~ *вазифасы* обя́занности митрополи́та; ~ *флагы* митрополи́чий флаг; ~ *казнасы* митрополи́чья казна́

митропóлия *сущ.* митропóлия; *Киев ~се* ки́евская митропóлия

миф *сущ.* **1.** миф (*древнее народное сказание о легендарных героях, богах и т. п.*) **2.** *перен.* миф, вы́думка, *что-л.* недостове́рное, неправдоподóбное

ми́фик *прил.* **1.** мифи́ческий; ~ *образ* мифи́ческий óбраз; ~ *сюжет* мифи́ческий сюже́т; *әсәрнең ~ характеры* мифи́ческий хара́ктер произведе́ния; ~ *булу* мифи́чность **2.** *перен.* мифи́чный, мифи́ческий, вы́мышленный, вы́думанный

ми́фиклы|к *сущ.* мифи́чность; *образның ~гы* мифи́чность óбраза

мифóлог *сущ.* мифóлог, специали́ст по мифоло́гии

мифоло́гик *прил.* мифологи́ческий (*сюжет, персонаж и т. п.*); ~ *герой* мифологи́ческий геро́й

мифоло́гия *сущ. в разн. знач.* мифоло́гия || мифологи́ческий; *грек ~се* гре́ческая мифоло́гия; ~ *буенча бәхәсләр* диску́ссии по мифоло́гии; *~гә охшаш* подóбно мифоло́гии; ~ *риваятьләре* мифологи́ческие преда́ния

михнәт *сущ.* **1.** страда́ние, нужда́, мыта́рство, му́ка (*из-за бедности, нищеты, нищенства и т. п.*); *~тә яшәү* жить в бе́дности, нищете́, ни́щенствовать; *бер ~кә бер рәхәт* (*погов.*) нет ху́да без добра́ **2.** *уст. книжн.* нелёгкий труд, напряжённая рабóта, ка́торжные уси́лия; ~ *белән тапкан бер тәңкә тиген килгән казнадан яхшырак* (*посл.*) зарабóтанный рубль дорóже дармовóй казны́; *~ең каты булса, капканың татлы булыр* (*посл.*) рабóтай до пóту — поéшь в охóту □ ~ **чиген йөрү** хожде́ние по му́кам; ~ **чигү (күрү)** жить в кра́йней нужде́, терпе́ть му́ки, страда́ть; ма́яться; *рәхәтен күргәнсең, ~ен дә күр* (*посл.*) лю́бишь ката́ться, люби́ и са́ночки вози́ть; *бик күп ~ чиккән (күргән)* многострада́льный, му́ченический; ~ **чигүче** страда́лец, му́ченик; **~кә төшерү** *кого-л.* обрека́ть/обре́чь на страда́ния (мыта́рства)

михнәтләп|ү *неперех.* **1.** 1) испы́тывать нужду́, ни́щенствовать; *балачакта ~ү* ни́щенствовать в де́тстве 2) страда́ть, му́читься; мыта́риться; *чит җирләрдә ~ү* мыта́риться в чужи́х края́х; *авыр эштә ~ү* му́читься (испы́тывать физи́ческие страда́ния) на тяжёлой рабóте; *монда ~гәнче, мин әйткәнчә генә эшлә* чем здесь мыта́риться, сде́лай так, как я сказа́л (лу́чше послу́шай меня́) **2.** *в знач. нареч. в ф.* **михнәтләнеп** 1) в нужде́, в му́ках, в нищете́; *~еп яшәү* жить в нужде́, ни́щенствовать 2) с тру́дностями, мыта́рствами; *~еп барып җиту* дое́хать с больши́ми тру́дностями (мыта́рствами); *~еп килеп йөрү* зря беспоко́иться, посеща́я *кого-л., что-л.*; *~еп йөрмә* не утружда́й себя́, не му́чайся, не мыта́рься

михнәтле *прил.* тяжёлый, тру́дный, хло́потный, му́чительный (*в связи с нищетой, бедностью, нуждой*); ~ *тормыш (дөнья)* тяжёлая (ни́щенская) жизнь; *эшнең башы ~ булса, төбе хикмәтле була (погов.)* чем трудне́е нача́ло де́ла, тем отра́днее его́ результа́т

михнәтсез *прил.* **1.** нетру́дный, бесхло́потный, нетяжёлый; ~ *тормыш* нетяжёлая жизнь; ~ *юл* нетру́дная доро́га; доро́га без мыта́рств **2.** нетру́дный, лёгкий, несло́жный, необремени́тельный; ~ *эш* необремени́тельная рабóта; ~ *эш — тозсыз аш (погов.)* рабóта без труда́, что суп без со́ли || *нареч.* **1.** без мыта́рств, без хлопо́т; ~ *көн күрү (яшәү)* жить беззабóтно (без хлопо́т); ~ *барып җиту* дое́хать без хлопо́т (без мыта́рств) **2.** нетру́дно, легко́, без хлопо́т; несло́жно, необремени́тельно; не прилага́я труда́, физи́ческих уси́лий, без труда́; ~ *акча эшләү* зарабóтать (зараба́тывать) де́ньги без осóбого труда́; *бер ~ урнашып калу* легко́ устро́иться (устро́иться без хлопо́т)

михнәтсезлек *сущ.* **1.** состоя́ние, положе́ние, не свя́занное с тру́дностями, страда́ниями **2.** бесхло́потность; состоя́ние, положе́ние, не свя́занное с забóтами, мыта́рствами

михнәттәш *сущ.* това́рищ по страда́ниям и мыта́рствам, страда́лец *уст.*; *аның ~ләрен икенче язмыш көтә иде* ина́я у́часть ждала́ его́ това́рищей по мыта́рствам

михнәттәшлек *сущ.* **1.** состоя́ние, положе́ние вме́сте стра́ждущих; совме́стные, о́бщие страда́ния **2.** *уст.* сотру́дничество, совме́стная рабóта (*в трудных условиях*)

михраб *сущ.* михра́б (*ниша во внутренней стене мечети, указывающая направление к Мекке, там молится мулла*)

миһаһай *звукоподр. ржанию лошади* □ ~ **итү** *см.* **миһаһайлау**

миһаһайл|ау *неперех. в разн. знач.* ржать; *ат ~ый* ло́шадь ржёт; *~ап көлү пренебр.* ржать как ло́шадь (*о человеке*)

миһербан *сущ.* страда́ние, жа́лость, ми́лость, милосе́рдие, великоду́шие; ~ *иясе* доброде́тель; *~ы килү* сми́лостивиться; *ахырда аның ~ы килер, бәлки* мóжет быть, он ещё сми́лостивится

миһербанлы *прил.* **1.** милосе́рдный, добросерде́чный; до́брый, мя́гкий; мягкосерде́чный, великоду́шный; ~ *кеше* добросерде́чный челове́к; ~ *йөз* великоду́шное (до́брое) лицó **2.** страда́тельный; чу́ткий, жа́лостливый (*чувствительный к несчастьям других*); ~ *җан* страда́тельная душа́; ~ *мөнәсәбәт* страда́тельное (чу́ткое) отноше́ние

миһербанлык *сущ.* благоскло́нность, милосе́рдие, добросерде́чность; доброта́, мя́гкость, мягкосерде́чность, страда́тельность, великоду́шие ◊ ~ **белән** чу́тко, добросерде́чно, великоду́шно; ~ **итү** проявля́ть доброту́ (добросерде́чность); ~ **күрсәтү** ока́зывать ми́лость, милосе́рдие, благоскло́нность; **(күңеленә) ~ салу** станови́ться (стать) великоду́шным, до́брым, милосе́рдным

миһербанлылы|к *сущ.* добросердéчие, мягкосердéчие; сострадáтельность, великодýшие; *кеше үзенең ~гы белән матур* человéк краси́в свои́м великодýшием

миһербансыз *прил.* жесто́кий, бессердéчный, немилосéрдный

миһербансызлану *неперех.* проявля́ть/прояви́ть жесто́кость, бессердéчие (бессердéчность)

миһербансызлык *сущ.* жесто́кость, бессердéчность

мич *сущ.* **1.** печь, пéчка || печно́й; *мич авызы* ýстье печи́; *голланд миче* голла́ндская печь; *домна миче* до́менная печь; до́мна; *урыс миче* ру́сская печь; *мич томалау* закрыва́ть/закры́ть печь; *мич үрләтү* зата́пливать/затопи́ть печь; *мич үздыру* протопи́ть печь; *мич корымы* печна́я са́жа; *мич торбасы* печна́я труба́; *мич капкачы* печна́я засло́нка **2.** то́пка; *паровоз миче* парово́зная то́пка □ **мич алды 1.** шесто́к (*передняя часть печи*) **2.** ку́хня; **күп вакытны мич алдында үткәрү** мно́го вре́мени проводи́ть на ку́хне; **мич арты** заку́тка, закуто́к (*пространство между стеной дома, комнаты и задней стенкой печи*); **мич артында калу** быть отóрванным от жи́зни, труда́; **мич ашы (ашлары)** печёные ку́шанья из муки́ (*треугольник, бялиш, пироги и т. п.*); **мич башы** лежа́нка на печи́; *акыл өләшкәндә мич башында калган* (*погов.*) при разда́че ума́ он оста́лся на печи́ (лежа́нке), *соотв.* глу́пый, дура́к; **мич кашагасы** пере́дняя часть над шесто́м (*у русской печи*); **мич көймәсе** свод печи́; **мич куышы** ни́ша, печу́рка (*у русской печи*); **мич салучы (чыгаручы)** печни́к; **мич урыны (казнасы)** основа́ние, кле́тка (*русской печи*); **мич ягучы** истопни́к; **мичтә кайнау** топи́ться в печи́ (*о молоке*) ◊ **мич башына менү** отрыва́ться от жи́зни, труда́, безде́льничать; **мич башында шалкан пешми** (*погов.*) ре́пу па́рят не на печи́ (а в печи́); **мич башында яту** лежа́ть на печи́, лентя́йничать, безде́льничать; **монысы әле баласы, мичтә аның анасы** (*погов.*) э́то то́лько цвето́чки, я́годки пото́м

мичәү *сущ. спец.* **1.** постро́мки; бечева́, бечёвка (*у бурлаков*); *очка җигү ~ләре* уносны́е постро́мки **2.** запря́жка цу́гом **3.** пристяжна́я ло́шадь **4.** *перен.* помо́щник; *бер-береңә ~ булу* быть помо́щником, быть опо́рой (*в трудностях, в преодолении трудностей*) || *прил. диал.* пристяжно́й; *~ ат* пристяжна́я ло́шадь || *гл. перех. редко.* **1.** запряга́ть/запря́чь пристяжны́м, припряга́ть/припря́чь; *~ләп җигелгән* запряжённая с пристяжно́й (*телега*) **2.** доба́вочно назнача́ть помо́щника □ **~гә җигелү** выполня́ть тру́дную рабо́ту; взя́ться, бра́ться за са́мое тру́дное (*в нужный момент*); **~гә җигү 1.** запряга́ть/запря́чь пристяжны́м **2.** сде́лать себе́ основны́м помо́щником; заставля́ть/заста́вить выполня́ть тру́дную рабо́ту; **~дә бару (йөрү)** постоя́нно выполня́ть тру́дную (*но непрестижную*) рабо́ту

мичәүләт|ү *понуд. от* **мичәүләү**

мичәүлә|ү *перех.* **1.** запряга́ть/запря́чь пристяжны́м, припря́чь (*лошадь*) **2.** *перен.* испо́льзовать *кого-л.* подру́чным, помо́щником; *~әп җигү* 1) присты́жка, припря́жка 2) цугова́я запря́жка

мичәүле *прил.* **1.** име́ющий пристяжну́ю ло́шадь, присты́жку, припря́жку, уносны́х **2.** с пристяжно́й ло́шадью

мичкә *сущ.* **1.** бо́чка || бочо́ночный, бо́чечный, бо́чковый; *агач ~* деревя́нная бо́чка; *аракы ~се* ви́нная бо́чка; *кечкенә ~* бочо́нок; *су ~се* водово́зная бо́чка; *кәбестә ~се* бо́чка из-под капу́сты; *~ коршавы* бо́чечный (бочо́ночный) о́бруч; *~ сырасы* бо́чечное (бо́чковое) пи́во; *~ мае* бо́чковое ма́сло **2.** *перен. пренебр.* бо́чка, бо́чка бо́чкой (*о слишком толстом человеке*); *кара, бер ~ китеп бара* смотри́, идёт бо́чка ◊ **~ кебек 1.** бочкова́тый, бочкообра́зный; кру́то изо́гнутый, вы́пуклый (*человеческая фигура и какие-л. ёмкости*) **2.** *перен.* как бо́чка, бо́чка бо́чкой; **~ корсак** толстобрю́хий; **~дәге балык кебек; ~дәге балыктай** как ры́ба в бо́чке (*о скоплении большого количества людей в тесном помещении*)

мичкәдәй *прил.* бочкова́тый; бочкообра́зный, бочкови́дный (*о полном, жирном, тучном человеке*)

мичкәләп *нареч.* бо́чкой, бо́чками, в бо́чках; *кымызны ~ китерәләр* кумы́с приво́зят бо́чками (в бо́чках)

мичкәле *прил.* бо́чковый; бо́чечный; в бо́чке; *~ балык* бо́чковая ры́ба; *~ бал* бо́чечный (бо́чковый) мёд

мичкәче *сущ.* бо́нда́рь; боча́р || бонда́рный, бо́нда́рский; *~ мичкәгә коршау кагып маташа* бо́нда́рь набива́ет о́бручи на бо́чку; *~ һөнәре* бонда́рное (бонда́рское) ремесло́; *~ улы* бо́нда́рский сыно́к; сын бо́ндаря́

мичкәчелек *сущ.* бо́нда́рство; бонда́рное де́ло || бонда́рный, бо́нда́рский; *~ белән шөгыльләну* занима́ться бонда́рным ремесло́м; бонда́рить; *~ һөнәренең үсүе* разви́тие бо́нда́рского ремесла́; *~ цехы* бонда́рня (*мастерская*)

мичлек *прил.* печно́й (*предназначенный для сложения или топки печи*); *~ кирпеч* печно́й кирпи́ч; кирпи́ч для кла́дки печи́; *бер ~ кирпеч* кирпи́ч, доста́точный на одну́ печь; *бер ~ утын* дрова́ на одну́ то́пку

ми́чман *сущ.* ми́чман || ми́чманский; *~ вазифасы* обя́занности ми́чмана; *~ фуражкасы* ми́чманка, фура́жка ми́чмана; *~ званиесе* ми́чманское зва́ние; *~ эполетлары (погоннары)* ми́чманские эполе́ты (пого́ны)

ми́чманлык *сущ.* до́лжность ми́чмана; *ул ~ка күчкән* он перешёл на до́лжность ми́чмана

Мичу́рин *имя собственное* Мичу́рин || мичу́ринский; *~ алмасы* мичу́ринский сорт я́блок; *~ өйрәтүләре* мичу́ринское уче́ние; *~ методы* мичу́ринский ме́тод

мичу́ринча *нареч.* по-мичу́рински, как Мичу́рин; *биология фәнен ~ файдалану* применя́ть биологи́ческую нау́ку по-мичу́рински

мичу́ринчы *сущ.* мичу́ринец; *~лар съезды* съезд мичу́ринцев; *~ язмалары* запи́ски мичу́ринца

мичче *сущ.* печни́к; *~ ярдәмчесе* подру́чный печника́; *~ хезмәте* труд печника́

миччелек *сущ.* заня́тие, ремесло́ печника́; *~кә өйрәну* учи́ться ремеслу́ печника́

мишә *сущ. редко.* дубня́к, дубра́ва

мишәр *сущ. этногр.* миша́рин; *мн.* миша́ри || миша́рский; *~ хатыны (кызы)* миша́рка; *~ диалекты* миша́рский диале́кт; *~ авылы* миша́рское село́; *~ акценты* миша́рский акце́нт

мишәрләш|ү *неперех.* омиша́риваться/омиша́риться; *~кән авыллар* омиша́рившиеся дере́вни; *~кән кияү* омиша́рившийся зять

мишәрлек *сущ.* миша́рство; принадле́жность к миша́рам

миша́рчә 1. *нареч.* по-миша́рски; *~ сөйләшү* говори́ть по-миша́рски **2.** *прил.* миша́рский; *~ акцент* миша́рский акце́нт

миша́рчәләп *нареч.* по-миша́рски, с миша́рским акце́нтом; *~ җырлау* петь с миша́рским акце́нтом (по-миша́рски)

мишень *сущ. в разн. знач.* мише́нь || мише́нный; *күчерелмәле ~* перено́сная мише́нь; *калай щитка ~*

беркетү укрепи́ть мише́нь на желе́зном щите́; *ак фуражка — бик шәп ~ ул* бе́лая фура́жка — прекра́сная мише́нь; *каламбурлар өчен ~ булу* стать (быть) мише́нью для каламбу́ров

мияу *звукоподр. однократному мяуканью кошки* □ **~ итү** мяу́кнуть

мияубикә *сущ. разг.* ки́са, ки́ска (*ласкательная кличка кошки*)

мияул|ау *неперех.* мяу́кать, издава́ть, изда́ть мяу́канье || мяу́канье; *песи ~ый* ко́шка мяу́кает; *тигр баласының ~авы* мяу́канье тигрёнка

мияулаш|у *взаимно-совм. от* **мияулау**; *песиләр ~а* мяу́кают ко́шки

мияу-мияу *подр. неоднократному мяуканью кошки*

мнемо́ник *прил. книжн.* мнемони́ческий; *~ алымнар* мнемони́ческие приёмы (спо́собы) || *сущ. книжн.* мнемо́ник, специали́ст по мнемо́нике

мнемо́ника *сущ. книжн.* мнемо́ника (*совокупность правил и приёмов, помогающих запоминать нужные сведения*); *~ профессоры* профе́ссор мнемо́ники

мобилизацион *прил.* мобилизацио́нный; *~ планнар* мобилизацио́нные пла́ны

мобилиза́ция *сущ. в разн. знач.* мобилиза́ция || мобилизацио́нный; *гомуми ~* всео́бщая мобилиза́ция; *~ планы* мобилизацио́нный план; *~ эшләре* мобилизацио́нные рабо́ты □ **~ ясау** мобилизова́ть; мобилиза́ция

мобилиза́цияләнү *страд. от* **мобилизацияләү**; мобилизова́ться; быть мобилизо́ванным; *зур төзелешкә ~* мобилизова́ться на большу́ю стро́йку

мобилиза́цияләү *перех.* мобилизова́ть *кого-л., что-л.* || мобилиза́ция; *армияне ~* мобилизова́ть а́рмию; *коллективны ашыгыч эшкә ~* мобилизова́ть коллекти́в на сро́чную рабо́ту

могҗиза *сущ.* чу́до; волшебство́; чудеса́ *мн.*; *сиңа бер зур ~ сөйлим* расскажу́ тебе́ вели́кое чу́до; *сәламәтләнүем ~ кебек булды* моё выздоровле́ние бы́ло как чу́до; *сәнгать ~лары* чудеса́ иску́сства □ **~ булдыру** твори́ть чудеса́; *ул — ~ булдырырлык кеше* он спосо́бен твори́ть чудеса́; **~ иясе, ~лар күрсәтүче** 1. чудотво́рец 2. волше́бник; **~ кебек** бу́дто (сло́вно) чу́до; **~ күрсәтә торган** чудотво́рный; **~ның ~сы** чу́до из чудес; **нинди ~ бу?** что за чу́до? что за чудеса́! (*выражение удивления, изумления*)

могҗизалы *прил.* чудоде́йственный; чудотво́рный; соверша́ющий чудеса́; волше́бный; *~ көч* чудоде́йственная си́ла; *~ табигать* чудотво́рная приро́да; *врачның ~ куллары* чудотво́рные (чудоде́йственные) ру́ки врача́; *~ гармун* волше́бная гармо́нь

могикан *сущ.* могика́нин, могика́нка; *мн.* могика́не; *~нарның соңгысы* после́дний из могика́н

могтәбәр *прил.* почте́нный, авторите́тный, по́льзующийся а́вторите́том; *~ авылдашлар* почте́нные односельча́не; *~ бабам* почте́нный мой дед

могыл *сущ. разг.* 1. бугоро́к на те́ле, ши́шка (*обычно безболезненная*) 2. *см.* **оры**

мо́да *сущ.* мо́да; *~ буенча киенү* одева́ться по мо́де; *~да очлы башлы аяк киеме* в мо́де узконо́сая о́бувь; *~дан калышмау* не отставать от мо́ды; *сезон ~лары* мо́ды сезо́на □ **~га керү** стать мо́дным; **~да булу** быть в мо́де (мо́дным); **~дан чыгу** вы́йти из мо́ды; переста́ть быть мо́дным; **~лар ателье́сы** ателье́ мод; **~лар йорты** Дом мо́ды

мо́дадагы *прил.* мо́дный (*одежда, песня и т. п.*)

мо́далы *прил. в разн. знач.* мо́дный; *~ кием* мо́дная оде́жда; *~ күлмәк* мо́дное пла́тье; *~ әйберләр кибете уст.* мо́дный магази́н, мо́дная ла́вка

мо́далылык *сущ.* мо́дность

модаль *прил. лингв.* модаль́ный; *~ фигыльләр* модаль́ные глаго́лы; *~ сүзләр* модаль́ные слова́

модальлек *сущ. лингв.* модаль́ность

мо́дача *нареч.* мо́дно, по-мо́дному, в соответствии с мо́дой; *~ киенгән кыз* мо́дно оде́тая де́вушка; *~ тегелгән күлмәк* по-мо́дному сши́тое пла́тье

моделизм *сущ. тех.* модели́зм (*конструирование, постройка и испытание моделей машин, механизмов и сооружений*)

моделист *сущ.* модели́ст, модели́стка, моделье́р; *~лар ярышы* соревнова́ние модели́стов (модельеров); *~лар слёты* слёт модели́стов (модельеров); *сеңлем хәзер — таныльган ~* тепе́рь моя́ сестра́ — изве́стная модели́стка

модел|ь *сущ.* 1. *в разн. знач.* моде́ль; *кыз балалар күлмәгенең яңа ~е* но́вая моде́ль пла́тья для де́вочек; *станокның агачтан ясалган ~е* деревя́нная моде́ль станка́; *корабль ~е* моде́ль корабля́; *планер ~е* моде́ль пла́нера 2. тип, ма́рка, моде́ль, образе́ц констру́кции; *автомобильнең яңа ~е* но́вая моде́ль автомоби́ля 3. образе́ц, шабло́н, моде́ль || моде́льный; *башта балчыктан тарелканың ~ен ясыйлар, аннан шул ~ь буенча гипс форма төшерәләр* снача́ла из гли́ны ле́пят моде́ль таре́лки, а пото́м с э́той моде́ли снима́ют ги́псовую фо́рму; *~ь цехы* моде́льный цех

модельләү *перех.* модели́ровать || модели́рование; *хатын-кызлар (ирләр) пальтосы ~* модели́ровать да́мское (мужско́е) пальто́

модельер *сущ.* моделье́р; *~ булып эшләү* рабо́тать моделье́ром

модельле *прил.* моде́льный, мо́дный (*изготовленный по последним моделям*); *~ аяк киеме* моде́льная о́бувь

модельче *сущ.* модели́ст, модели́стка; моде́льщик, моде́льщица

модерн *сущ.* моде́рн; *~ стилендәге бина* зда́ние в сти́ле моде́рн

модернизация *сущ.* модернизация || модернизацио́нный; *станокны ~гә бирү* отда́ть стано́к на модернизацию; *борынгы нәрсәләргә ~ кертү* модернизация стари́нных вещей; *~ эшләре* модернизацио́нные рабо́ты

модернизацияләү *перех.* модернизи́ровать || модернизи́рование; *станокны ~* модернизи́ровать стано́к; *борынгы легенданы ~* модернизи́ровать ста́рую леге́нду

модернизм *сущ.* модерни́зм; *~ тарафдары* сторо́нник модерни́зма, модерни́ст

модернист *сущ.* модерни́ст, после́дователь модерни́зма || модерни́стский

модификатор *сущ. в разн. знач.* модифика́тор

модификация *сущ. в разн. знач.* модифика́ция

модификацияләнү *страд. от* **модификацияләү**; модифици́роваться

модификацияләү *перех.* модифици́ровать || модифици́рование

мо́дуль *в разн. знач.* мо́дуль (*название некоторых коэффициентов, мерил каких-л. величин*)

мозаик *прил. иск.* мозаи́чный; мозаи́ческий; *~ рәсем* мозаи́чный рису́нок

моза́ика *сущ. иск.* моза́ика; *агач ~* деревя́нная моза́ика; *агач ~ белән бизәү* укра́сить деревя́нной моза́икой

моза́икачы *сущ.* худо́жник, специали́ст по моза́ике

моле́кула *сущ. физ.* моле́кула || молекуля́рный; *~ авырлыгы* молекуля́рный вес; *~ теориясе* молекуля́рная тебрия

моле́кулаара *прил.* межмолекуля́рный; *~ көч* межмолекуля́рная си́ла

молекуляр *прил. физ., хим.* молекуля́рный; *~ авырлык* молекуля́рный вес; *~ физика* молекуля́рная фи́зика

молескин *сущ. текст.* молески́н, чёртова ко́жа || *прил.* молески́новый; *~ пиджак* молески́новый пиджа́к; *~ комбинезон* молески́новый комбинезо́н

молибден *сущ. хим., мин.* молибде́н (*химический элемент, твёрдый металл с серебристо-белым блеском*) || *прил.* молибде́новый; *~ тимерчыбык* молибде́новая про́волока, про́волока из молибде́на

молибденлы *прил.* молибде́новый (*содержащий молибден*); *~ рудалар* молибде́новые ру́ды; *~ корыч* молибде́новая сталь

моллюск *сущ. зоол.* моллю́ск || моллю́сковый; *диңгез ~лары* морски́е моллю́ски; *җир өсте ~лары* назе́мные моллю́ски; *~ кабырчыклары* моллю́сковые ра́ковины

мо́лния *сущ.* мо́лния (*род металлической или пластмассовой задёргивающейся застёжки*)

молоти́лка *сущ. с.-х.* молоти́лка; *атлы ~* ко́нная молоти́лка; *моторлы ~* мото́рная молоти́лка

мольберт *сущ. иск.* мольбе́рт

момент *сущ.* 1. моме́нт; *~ны кулдан ычкындыру* упусти́ть моме́нт; *уңай ~ сайлау* выбира́ть удо́бный (подходя́щий) моме́нт 2. *разг. в знач. нареч.* момента́льно, жи́во, в то́т же моме́нт, сейча́с (ту́т) же; ми́гом, вмиг; *~ әйләнеп киләм* ми́гом верну́сь; *~ эшләп ташлыйм* вмиг (в моме́нт) сде́лаю

моментлык *прил. разг.* моментáльный, мгнове́нный (*осуществляемый очень быстро*); *~ эш* моментáльная рабо́та

моназара *сущ.* диску́ссия, ди́спут, поле́мика; *~ кылу* дискути́ровать; вести́ поле́мику

моназаралы *прил.* спо́рный, дискуссио́нный, полеми́ческий

монар *сущ. диал.* 1. мгла; *см. тж.* **рәщә** 2. ма́рево, мира́ж

монарлан|у *неперех. диал.* принима́ть (приня́ть) мгли́стый вид; *һава ~ып кызды* во́здух накали́лся и стал мгли́стым

монарлы *прил. диал.* мгли́стый; *~ һава* мгли́стый во́здух

монарх *сущ. полит.* мона́рх (*единовластный глава государства — царь, король, император и т. п.*) || мона́рший

монархизм *сущ. полит.* монархи́зм (*политическое направление, признающее монархию единственной формой государственной власти*); *см. тж.* **патшачылык**

монархист *сущ.* монархи́ст, сторо́нник монархи́зма || монархи́стский; *~лар заговоры* монархи́стский за́говор

монархи́стик *сущ. полит.* монархи́ческий; *~ власть* монархи́ческая власть

мона́рхия *сущ. полит.* мона́рхия; *абсолют ~* абсолю́тная мона́рхия; *конституцион ~* конституцио́нная мона́рхия; *француз ~се* францу́зская мона́рхия

монастыр|ь *сущ.* монасты́рь || монасты́рский; *ирләр (хатын-кызлар) ~е* мужско́й (же́нский) монасты́рь; *~ьга китү* уйти́ в монасты́рь; *~ь тормышы* монасты́рская жизнь; *~ь җирләре* монасты́рские зе́мли

монафикъ *сущ.* лицеме́р, двуру́шник

монафикълык *сущ.* лицеме́рие, двуру́шничество

мона|у *мест. указ. разг.* вот э́то; *~у кеше* вот э́тот челове́к; *~вы тагы* ещё вот э́тот (*мешает*)

монах *сущ.* мона́х || мона́шеский; *~ язмышы* судьба́ мона́ха; *~ тормышы* мона́шеский о́браз жи́зни; *~ рясасы* мона́шеская ря́са; *~ хөҗрәсе* мона́шеская ке́лья; *~ бүреге* клобу́к

мона́хиня *сущ.* мона́хиня

монахлык *сущ.* мона́шество, мона́шеская жизнь; *~ка китү* приня́ть мона́шество; *иң югары ~ дәрәҗәсе церк.* схи́ма

мона́шка *сущ. разг.* мона́хиня, мона́шка, мона́шенка

монгол *сущ.* 1. монго́л || монго́льский; *~ хатыны (кызы)* монго́лка; *~ теле* монго́льский язы́к; *~ киеме* монго́льская оде́жда 2. *как составная часть некоторых ботанических и зоологических названий; ~ аты* монго́льская ло́шадь □ *~ зелпесе* монго́льская жи́молость; *~ имәне* монго́льский дуб

монголлаштыру *понуд. от* **монголлашу**; омонго́лить || монголиза́ция; *~ политикасы* поли́тика монголиза́ции

монголлаш|у *неперех.* омонго́литься; *~ып беткәннәр* совсе́м омонго́лились

монголлы|к *сущ.* 1. принадле́жность монго́льской на́ции; *~гы битенә язылган* то, что монго́л, напи́сано на лице́ 2. монго́льство, монго́льский мир || монго́льский; *~к заманнарында* во времена́ монго́льства; в монго́льские времена́ (*об определённом периоде истории некоторых стран Евразии*)

монго́лча *нареч.* 1. по-монго́льски, на монго́льском языке́; *~ сөйләү (белү)* говори́ть (объясня́ться) по-монго́льски, на монго́льском языке́ 2. по-монго́льски, как монго́л, как монго́лы; *~ киену* одева́ться по-монго́льски, как монго́лы || *прил.* на монго́льском языке́, монго́льский; *~ кулъязмалар* монго́льские ру́кописи; ру́кописи на монго́льском языке́; *~ спектакль кую* ста́вить спекта́кль на монго́льском языке́

монго́лчалап, монго́лчалатып *нареч. разг.* по-монго́льски, на монго́льском языке́, на языке́ монго́лов; *кемдер ~ сөйләп китте* кто́-то заговори́л на монго́льском языке́ (на языке́ монго́лов)

монда *нареч.* 1. здесь, тут; *~ юк инде ул* его́ уж нет здесь; *~ ни эшләп торасың?* что ты тут де́лаешь? *тегендә дә, ~ да* и там, и тут; *бер аягың анда булса, бер аягың ~ булсын (погов.)* бы́стренько сбе́гай (*букв.* пусть одна́ нога́ бу́дет там, друга́я — здесь) 2. в э́том, в э́том де́ле; *~ мин сиңа ярдәм итә алмыйм* в э́том (де́ле) я тебе́ не смогу́ помо́чь 3. сюда́; *~ кил инде* иди́-ка сюда́; *~ хәтле (чаклы)* досю́да

мондагы *прил.* зде́шний; ме́стный; *~ гореф-гадәтләр* зде́шние (ме́стные) обы́чаи

мондый *мест. указ.* 1. тако́й, подо́бный (э́тому), э́того (подо́бного) ро́да; *менә ~* вот тако́й; *~ көннәр сирәк була* таки́е (подо́бные) дни быва́ют ре́дко; *~ көндә юньле хуҗа этен дә чыгармый (погов.)* в таку́ю (э́дакую) пого́ду толко́вый хозя́ин и соба́ку (*из дома*) не вы́пустит; *~ тугел иде ул* он не́ был таки́м 2. сле́дующий; *~ көн тәртибе тәкъдим ителә* предлага́ется сле́дующая пове́стка дня

моне́та *сущ. разг.* моне́та || моне́тный; *см. тж.* **тәңкә**

моне́талы *прил.* в моне́тах; *~ акча* де́ньги в моне́тах

монизм *сущ. филос.* мони́зм; *материалистик ~* материалисти́ческий мони́зм; *идеалистик ~* идеалисти́ческий мони́зм

мони́стик *прил. филос.* 1. монисти́ческий; *дөньяга ~ караш* монисти́ческий взгляд на мир; *~ философия*

монисти́ческая филосо́фия **2.** монисти́чный, прони́кнутый мони́змом

монистла́рча *нареч. филос.* монисти́чески; *~ фикер йөртү* мы́слить монисти́чески

монитор *сущ. спец.* **1.** монито́р; *диңгез ~ы* морско́й монито́р; *елга ~ы* речно́й монито́р **2.** *см.* **гидромонитор**

моннан *исх.п. указ. мест.* **бу 1.** 1) от него́ (неё), от э́того (э́той) (*узнать, брать, ждать, что-л. отстать, быть далеко*); *~ бернәрсә алма* от него́ (э́того, неё) ничего́ не бери́; *~ игелек көтмә* от э́того (э́той), него́ (неё) добра́ не жди 2) *указывает на что-л. абстрактное* от э́того; *~ берни дә булмый* от э́того ничего́ (*хуже, лучше*) не бу́дет; *~ берни дә килеп чыкмый* из э́того ничего́ не вы́йдет (не полу́чится) **2.** *при сравн.*; его́, её, чем он (она́, оно́); чем э́тот (э́та); *~ яхшысы юк* лу́чше его́ (её), чем он (она́) нет || *нареч.* отсю́да, от э́того ме́ста; *чык ~* вы́йди отсю́да; *кит ~* уходи́ отсю́да (от э́того ме́ста) □ **~ ары 1.** да́лее, да́льше; *~ ары барып булмый* да́льше невозмо́жно идти́ **2.** в сле́дующий раз, в друго́й раз; отны́не; *~ ары ярдәм итәрбез* в сле́дующий раз помо́жем; помо́жем в друго́й раз; **~ башка** кро́ме того́, кро́ме э́того; *~ башка көн тәртибендә ике җитди мәсьәлә бар* кро́ме э́того, на пове́стке дня име́ются два серьёзных вопро́са; **~ болай** отны́не; *~ болай үзеңне яхшы тот* отны́не веди́ себя́ присто́йно; **~ да бигрәк** ещё бо́льше, ещё важне́е, по сравне́нию с э́тим; **~ соң 1.** впредь, в дальне́йшем **2.** отны́не; *~ соң очрашмабыз* отны́не не встре́тимся; **~ соңгы 1.** в дальне́йшем, да́лее **2.** дальне́йший; *~ соңгы эшләр уңышлы булды* дальне́йшая рабо́та была́ уда́чной (успе́шной); **~ элекке** предше́ствующий

моноблок *сущ. страд.* моноблО́к || моноблО́чный; *~ төзелеш* моноблО́чное сооруже́ние

моногáмия *сущ. этногр.* моногáмия; единобра́чие || моногáмный

монограмма *сущ.* монограмма (*сплетение, вязь из двух или нескольких букв в виде вензеля*)

монографик *прил.* монографи́ческий; *~ тикшеренү* монографи́ческое иссле́дование; *~ хезмәт* монографи́ческий труд

монография *сущ.* монография; *Х. Туфан иҗаты турында ~* монография о твóрчестве Х. Туфа́на

монокль *сущ.* моно́кль

монокристалл *сущ. спец.* монокриста́лл (*одиночный кристалл*)

монокультур *прил.* монокульту́рный

монокульту́ра *сущ. с.-х.* монокульту́ра

монокульту́ралы *прил.* монокульту́рный (*регион*)

монокульту́ралылык *сущ.* монокульту́рность

монолит *сущ. книжн.* **1.** *в разн. знач.* монолИт (*большая глыба камня, что-л. единое и целостное*) **2.** *прил.* монолИтный; *~ бердәмлек* монолИтное единство

монолитлы|к *сущ. книжн.* монолИтность; *тау токымының ~гы* монолИтность го́рной поро́ды

монолог *сущ. лит., театр.* монолóг

монолóгик *прил. лит., театр.* монологи́ческий; *~ сөйләм* монологи́ческая речь

монометалл *прил.* монометалли́ческий; *~ система* монометалли́ческая систе́ма

монометаллизм *сущ. спец.* монометалли́зм (*денежная система, при которой в основу денежного обращения положен один металл — золото или серебро*)

моноплан *сущ. авиа.* моноплáн (*самолёт с одной несущей поверхностью*)

монополист *сущ.* монополи́ст

монополи́стик *прил. экон.* монополисти́ческий; *~ капитал* монополисти́ческий капита́л; *~ берләшмә* монополисти́ческое объедине́ние; *~ капитализм* монополисти́ческий капитали́зм

монопóлия *сущ. эк.* **1.** *прям., перен.* монопóлия; *эчке сәүдә ~се* монопóлия вну́тренней торго́вли; *тоз ~се* монопóлия на соль; *аракы ~се* ви́нная (во́дочная) монопóлия; *балык тоту ~се* монопóлия на ры́бную ло́влю **2.** *прил.* монопóльный; *~ хокукы* монопóльное пра́во □ **~ керту** монополизи́ровать

монопóлияләштерелү *страд. от* **монополияләштерү**; монополизи́роваться, станови́ться/стать предме́том монопóлии || монополиза́ция; *сәүдә (оешмалары) ~* монополиза́ция торго́вли

монопóлияләштерү *перех. книжн.* монополизи́ровать || монополиза́ция; *тышкы базарны ~* монополизи́ровать вне́шний ры́нок

монопóлияле *прил. книжн.* монопóльный; *~ сәүдә* монопóльная торго́вля; *~ файдалану* монопóльное по́льзование; *~ хуҗалык* монопóльное хозя́йство

монопóлияче *сущ. книжн.* **1.** монополи́ст (*крупный капиталист, представитель монополистического капитала*) **2.** *прил.* монополисти́ческий; *~ союзлары* монополисти́ческие сою́зы

монорельс *сущ.* моноре́льс

монорéльслаштыру *перех.* провести́, установи́ть, сооруди́ть моноре́льс

моноспектакль *сущ.* моноспекта́кль, спекта́кль одного́ актёра

монотемáтик *прил.* монотемати́ческий; *~ принцип* монотемати́ческий при́нцип

монотемáтика *сущ.* монотема́тика

монотемати́зм *сущ.* монотемати́зм

монотип *сущ. полигр.* **1.** монотИп (*вид наборной машины*); *~та эшләү* рабо́тать на монотИпе; *~та эшләнгән* сде́ланный на монотИпе **2.** *прил.* монотИпный; *~ лентасы* монотИпная ле́нта; *~ наборы* монотИпный набо́р

монотипчы *сущ. полигр.* монотипи́ст; набо́рщик; рабо́тающий на монотИпе

монотон *прил. разг.* моното́нный; *~ гүләү* моното́нный гул

монотонлы *прил.* моното́нный; *~ тавыш* моното́нный го́лос; *перен. ~ тормыш* моното́нная жизнь

монпаси *сущ.* монпансье́

монсыз *указ. мест.* без э́того (э́той); *~ (да) яшәп була* без э́того мо́жно жить

монтаж *сущ. в разн. знач.* монта́ж || монта́жный; *электростанция ~ы* монта́ж электроста́нции; *әдәби ~* литерату́рный монта́ж; *музыкаль ~* музыка́льный монта́ж; *~ эшләре* монта́жные рабо́ты; *~ схемасы* монта́жная схе́ма; *~ бригадасы* монта́жная брига́да □ **~ ясау** смонти́ровать; *бораулау җиһазларына ~ ясау* смонти́ровать буровóе обору́дование

монтажёр *сущ.* монтажёр, специали́ст по монтажу́ (*в кинематографии, фотографии*)

монтажлан|у *страд. от* **монтажлау**; монти́роваться; смонти́роваться; *станок ~а* монти́руется стано́к; *яңа фильм ~ды* смонти́рован но́вый фильм

монтажлату *понуд. от* **монтажлау**; веле́ть (поруча́ть, заставля́ть) монти́ровать, производи́ть монта́ж *чего-л.*

монтажлау *перех. в разн. знач.* монти́ровать, смонти́ровать || монти́рование; *фильм ~* монти́ровать фильм;

станок ~ монти́ровать стано́к; *бораулау җиһазларын ~* монти́ровать буровóе обору́дование; *блоклап-блоклап ~* монти́ровать бло́ками

монтажлы *прил.* монта́жный, свя́занный с монтажо́м; монтиро́вочный; *~ эшләр* монта́жные (монтиро́вочные) рабо́ты

монта́жник *сущ.* монта́жник; *см. тж.* **монтажчы**; *механик корылмаларны монтажлау өчен ~лар чакыру* приглаша́ть монта́жников для монти́рования механи́ческих сооруже́ний

монтажчы *сущ.* монта́жник; *~лар бригадасы* брига́да монта́жников

монтажчылык *сущ.* монта́жное де́ло || монта́жный

монтар *сущ. диал.* загражде́ние, прегра́да, препя́тствие; *аккан суга ~ юк (посл.)* теку́щей воде́ нет прегра́д

монтёр *сущ. тех.* **1.** монтёр, монта́жник; сбо́рщик и устано́вщик маши́н **2.** *разг.* электромонтёр, специали́ст по электрообору́дованию

монтёрлык *сущ.* заня́тие и до́лжность монтёра; *~ка уку* учи́ться на монтёра

монумент *сущ. книжн.* **1.** монуме́нт; *Муса Җәлил ~ы* монуме́нт Мусе́ Джали́лю; *кабер өстендәге ~* надгро́бный монуме́нт **2.** *прил.* монуме́нтный; *~ мастерское* монуме́нтная мастерска́я; *~ эшләре* монуме́нтные рабо́ты

монументалист *сущ.* монументали́ст (*автор монументальных работ в скульптуре*)

монументаль *прил.* **1.** монументáльный; вели́чественный, мо́щный; *~ корылма, бина* монументáльное сооруже́ние, зда́ние; *~ скульптура* монументáльная скульпту́ра **2.** кру́пный, соли́дный, монументáльный (основа́тельный, глубо́кий по содержа́нию); *~ хезмәт* монументáльный труд; *~ ачыш* монументáльное откры́тие

моны *указ. мест. вин. п.* **бу 1.** 1) э́то, э́того (*знать, строить, защищать, учить, торопить*); *~ бөтенесе дә аңлар дип уйлыйм* ду́маю, что э́то все пойму́т 2) (про) э́то, об э́том; *~ бөтен урам белә* (про) э́то зна́ет вся у́лица; *кем әйтте ~?* кто э́то (тебе́) сказа́л? **2.** *при замещении слов, имеющих форму только мн. числа* э́тих, их; *~ (чаңгыны) майлысы бар* их (лы́жи) на́до сма́зать || *с частицей* **гына** *обычно переводится с усилит. частицей* уж **1.** э́то уж, э́того уж, э́тот уж; *~ гына беләбез* э́то уж зна́ем; *~ гына эшләрбез* э́то уж то́чно) сде́лаем **2.** э́того уж, его́ уж; *~ гына җиңәрбез* э́то уж (*о трудностях или о каком-то субъекте*) оси́лим (вы́держим, одоле́ем, победи́м)

моныкы *указ. мест.* **бу**; принадлежи́т ему́ (ей), э́тому (э́той); его́, её; *яңа йорт ~* но́вый дом принадлежи́т э́тому (ему́); э́то его́ дом; *~на кагылырга ярамый* его́ ве́щи нельзя́ тро́гать; *~н белмәссең (аңламассың)* не узна́ешь (поймёшь), что у э́того на уме́; *~ның башы эшли* у э́того голова́ сообража́ет (рабо́тает)

монысы *указ. мест.* э́тот, э́то (*из числа близких, известных предметов, субъектов*); *тегесен беләм, ә ~ каян килде?* того́ (то) зна́ю, а э́тот (э́та, э́то) отку́да появи́лся (пришёл)? *бу сиңа булак, ~ — балага* э́то тебе́ пода́рок, а э́то — ребёнку; *~ әле баласы, мичтә аның анасы (погов.)* э́то то́лько цвето́чки, а я́годки впереди́

моң *сущ.* **1.** мело́дия, моти́в, напе́в; *халык моңнары* наро́дные мело́дии (напе́вы); *башкорт моңнары* башки́рские мело́дии; *концерт моңнары* мело́дии (зву́ки) конце́рта **2.** глубо́кое чу́вство; си́льная эмо́ция; *моң белән җырлау* петь с глубо́ким чу́вством (эмоциона́льно) **3.** уны́ние, печа́ль, грусть; *аның бернинди моңы юк* нет у него́ (никако́й) печа́ли; *үзгәрде егет, аны моң басты* па́рень измени́лся, на него́ нашло́ уны́ние **4.** *уст.* нужда́; *моңлы моңын сөйләр* у кого́ что боли́т, тот о том и говори́т (*букв.* кто живёт в нужде́ — о нужде́ и говори́т) **5.** *диал.* дефе́кт, поро́к, изъя́н; *җирнең моңы юк, җир начар түгел, үзебез аны карый белмибез* у земли́ нет изъя́на, она́ не плоха́, мы са́ми не уме́ем уха́живать за ней □ **моң булу 1.** печа́литься, грусти́ть, унывáть; *моң булып утырма* не грусти́ (не печа́лься) **2.** жить в нужде́, нужда́ться; *ипине ташлама, моң булырсың* не броса́й хлеб, бу́дешь жить в нужде́; **моң гына** дово́льно печа́льно, гру́стно

моңа *в ф. направит. п. мест.* **бу 1.** э́тому; *~ барсын да сөйләп тормыйм* э́тому я не всё (не обо всём) расска́зываю; *~ да тыңлат* дай и э́тому прослу́шать (*магнитофонную запись*) **2.** к э́тому; *~ кушылып китү* присоедини́ться к э́тому; *~ кереп чыгу* зайти́ к э́тому **3.** на э́того, на него́; *~ таянсаң да ярый* на э́того (него́) мо́жно положи́ться; *~ үпкәләп тә буллмый* на него́ и обижа́ться нельзя́ **4.** в э́то; *холодильник зуррак кирәк ул: ~ аз сыя* холоди́льник ну́жен побо́льше: в э́тот помеща́ется о́чень ма́ло **5.** до э́того, до него́; *бала елаганы ~ ишетелмәде* де́тский плач до него́ не дошёл; *~ җитәргә әле күп кирәк* до э́того дотяну́ться ещё далеко́ **6.** для э́того (лица́); *ул хәбәр ~ яңалык түгел* тот слух для э́того (него́) не но́вость **7.** э́того (э́то); *мин ~ кагылмадым да* я э́того и не тро́гал **8.** от э́того; *~ бәйле булу бик авырга килер* зави́сеть от э́того (него́) бу́дет о́чень тяжело́ **9.** э́тим; *~ барысы да сокланалар* э́тим (им) все восхища́ются **10.** с э́тим; *~ ни булган?* что с э́тим (ним) случи́лось? **11.** э́тому; с э́того (с него́); *~ җитәр инде* хва́тит с э́того (него́) □ **~ кадәр** до э́того, до сего́ вре́мени, до сих пор, поны́не, досе́ле; *~ кадәр яңгыр булмады* до сего́ вре́мени (до э́того) не́ было дождя́; *~ кадәр укыдым да укыдым* до э́того (до сих по́р) я всё учи́лся и учи́лся

моңаеш|у *взаимно-совм. от* **моңаю**; *~лар сабыйлар* грустя́т де́ти

моңайт|у *понуд. от* **моңаю 1.** вы́звать *в ком-л.* чу́вство гру́сти, печа́ли, сде́лать печа́льным, гру́стным; *хатлар көтү кешене ~а* ожида́ние пи́сем де́лает челове́ка гру́стным; *~ма киленне, тынычландыр* успоко́й неве́стку, не заставля́й её печа́литься **2.** *безл.* **моңайта** нагоня́ет грусть; охва́тывает грусть; *никтер кинәт ~а, никтер йөрәкне яндыра* отчего́-то внеза́пно охва́тывает грусть, отчего́-то се́рдце щеми́т (жжёт)

моңарга *разг. см.* **моңа**

моңа́рчы *нареч.* до сих по́р, досе́ле, поны́не, до сего́ вре́мени; *~ бик тыныч иде* до сих пор бы́ло о́чень споко́йно; *~ мин аңа ышана идем* до сего́ вре́мени я ве́рил ему́

моңа́ча *нареч. см.* **моңарчы**

моңа|ю *неперех.* **1.** унывáть, печáлиться, опечáлиться; тосковáть, затосковáть; грустúть, загрустúть; впадáть/впасть в уны́ние; *син нигә ~ясың?* отчего́ ты печáлишься (загрустúл)? *айлы кичтә бер дә ~йма син!* не грусти́ ты в лу́нную ночь! **2.** 1) становúться/стать невесёлым, апати́чным, пáдать (пасть) ду́хом, загрустúть; *~ерлык сәбәп юк* нет причúны (не́ от чего), что́бы пáдать ду́хом; *ник син алай гел ~ясың?* отчего́ ты всегда́ невесёлый? 2) предавáться чу́вству, эмóции, расчу́вствоваться, растрóгаться; *үз кайгың белән ~ерга да мөмкинлек юк* нет возмóжности да́же предавáться чу́вству (наедúне) **3.** петь уны́ло, с чу́вством, петь гру́стно; *синең ~юыңнан җылыйсы килә* от твое́й гру́стной пе́сни плáкать хóчется **4.** *перен. поэт.* быть уны́лым,

быть оку́танным печа́лью (*о предметах, о пейзаже*); *агач яфраклары саргайган, ~йган* ли́стья дере́вьев пожелте́ли, вы́глядят уны́ло **5.** *в знач. нареч.* **моңаеп** уны́ло, печа́льно, несчастли́во, гру́стно, тоскли́во; *кызның күзләре ~еп карыйлар* глаза́ де́вушки грустны́ (печа́льны, тоскли́вы)

моңдаш *сущ.* тот, кто разделя́ет *чью-л.* печа́ль; сболе́знующий, сочу́вствующий; сострада́лец; *ай — юлчының юлдашы, гашыйкларның ~ы* (*посл.*) луна́ пу́тнику — попу́тчик, а влюблённым — сочу́вствующий; *ул минем сердәшем һәм ~ым* он мой са́мый бли́зкий друг и сострада́лец

моң-зар *сущ. собир.* печа́ль, грусть; боль, пережива́ния; *сөйлә, дустым, безгә барлык моң-зарыңны* расскажи́ нам, друг, всю печа́ль свою́

моң-зарлы *прил.* печа́льно-гру́стный, печа́льно-жа́лобный, гру́стный; несча́стный; *моң-зарлы карт ана* печа́льно-гру́стная ста́рая мать

моңландыр|у 1. *понуд. от* **моңлану 2.** *безл.* **моңландыра** охва́тывает грусть; *көн яңгырлы, болытлы — ~а* день дождли́вый, о́блачный — ду́шу охва́тывает грусть, печа́ль

моңлан|у *неперех.* **1.** станови́ться (стать) заду́мчивым; заду́маться, призаду́маться; погружа́ться/погрузи́ться в разду́мье (ду́мы, размышле́ния); *ул соңгы вакытта бик ~ып китте (калды)* в после́днее вре́мя он стал о́чень заду́мчивым **2.** 1) петь гру́стные (печа́льные) пе́сни; *синең тавышың ~ыр өчен түгел* го́лос твой не подхо́дит для (пе́ния) гру́стных пе́сен; *су буенда, яр башында яшь егетләр ~а* у реки́, на берегу́ па́рни пе́сни гру́стные (поют) 2) *поэт.* петь (*о птицах*); *тирәкләрдә сандугачлар ~а* соловьи́ поют на тополя́х 3) *в знач. нареч.* **моңланып** гру́стно; *~ып җырлау* петь гру́стно **3.** печа́литься, опеча́литься; грусти́ть; *ул, авыру карт исенә төшкән саен, авыр ~а* он, как вспо́мнит больно́го старика́, ка́ждый раз тя́жко печа́лится; *син нәрсәдән ~асың?* отчего́ ты грусти́шь?

моңл|ау *неперех. диал. см.* **моңлану** 2, 3; *~ап утыру* сиде́ть призаду́мавшись; *яшьләр еш кына яңа көйне ~ыйлар* молодёжь о́чень ча́сто гру́стно поёт но́вую мело́дию; *аның ~ап җырлавы ошый миңа* его́ задуше́вное пе́ние мне нра́вится

моңлы *прил.* **1.** 1) эмоциона́льный, глубоко́ лири́чный, лири́ческий (*стих, песня, произведение*); *~ җырлар* лири́ческие пе́сни 2) мелоди́чный, напе́вный, певу́чий (*голос*) **2.** печа́льный, гру́стный; тоскли́вый; *~ йөз* печа́льное лицо́; *~ күзләр* гру́стные глаза́ **3.** *о пейзаже*: тако́й, что навева́ет печа́ль, грусть; *җырдагы төсле ~ елга ул Агыйдел* река́ Бе́лая, как печа́льная пе́сня, навева́ет грусть || *нареч.* **1.** печа́льно, гру́стно, тоскли́во; *сеңел ~ җырлый* сестрёнка поёт гру́стно **2.** эмоциона́льно, лири́чно, с глубо́ким чу́вством

моңлы-зарлы *прил.* печа́льно-гру́стный, гру́стный, по́лный печа́ли и гру́сти; *моңлы-зарлы замана* по́лные печа́ли времена́

моңлык *сущ.* **1.** *см.* **моңлылык 1**; *күңелне ~ били* грусть напа́ла на ду́шу; ду́шу охва́тывает грусть **2.** навева́ющая печа́ль тишина́; *тирә-юньдә ~ круго́м* навева́ющая печа́ль тишина́ **3.** 1) гру́стная пе́сня, мело́дия, напе́в 2) *фольк.* ли́рико-драмати́ческая поэ́ма; *~ әйтү* **1.** петь гру́стную пе́сню **2.** расска́зывать ли́рико-драмати́ческую поэ́му

моңлылан|у *неперех.* **1.** стать опеча́ленным (го́рестным) *чем-л.*, быть, находи́ться в угнетённом состоя́нии, унывать; *~у хәлендә булу* унывать, быть в угнетённом состоя́нии; *~у хәле* состоя́ние угнете́ния, уны́ния **2.** стать гру́стным, печа́льным (*о голосе, песне*) **3.** стать музыка́льным, мелоди́чным; *ахырга таба җырчының тавышы ~ыбрак китте* к концу́ го́лос певца́ стал мелоди́чнее

моңлылы|к *сущ.* **1.** состоя́ние гру́сти, уны́ния, тоски́, ску́ки; *~кта утыру* грусти́ть, тосковать; быть в уны́нии **2.** печа́ль, грусть; *аның күз карашында тирән ~к* в его́ взгля́де глубо́кая печа́ль **3.** 1) печа́льность, насы́щенность гру́стью; *җырның ~гы* печа́льность пе́сни 2) музыка́льность, лири́чность, мелоди́чность; *тавышның ~гы* мелоди́чность го́лоса

моңсу *прил.* **1.** 1) печа́льный, гру́стный; тоскли́вый; уны́лый; *~ йөз* гру́стное лицо́; *~ караш* тоскли́вый (гру́стный) взгляд 2) печа́льный, гру́стный; навева́ющий печа́ль; *~ җыр* печа́льная пе́сня **2.** *об окружающей обстановке*: печа́льный, уны́лый, гру́стный, невесёлый; *~ урман* уны́лый лес; *~ станция* уны́лая ста́нция || *нареч.* печа́льно, гру́стно, тоскли́во, уны́ло; *кунаклар киткәч ~ була* по́сле ухо́да госте́й быва́ет гру́стно □ **~ каен** плаку́чая берёза

моңсуландыр|у 1. *понуд. от* **моңсулату**; вы́звать *в ком-л.* чу́вство печа́ли, гру́сти, сде́лать печа́льным; *начар хәбәрләр бу гаиләне ~ды* плохи́е ве́сти сде́лали печа́льной э́ту семью́ **2.** сде́лать печа́льным, опеча́ленным, гру́стным (*о лице, глазах*); *саубуллашу аны ~ды* проща́ние его́ опеча́лило **3.** *безл.* **моңсуландыра** (*о печальном, грустном, тоскливом состоянии*); *төн караңгы, тынлык ~а* ночь тёмная, тишина́ навева́ет грусть

моңсулан|у *неперех.* **1.** приходи́ть/прийти́ в печа́льное, гру́стное настрое́ние, стать печа́льным, заду́мчивым; *кичкә таба ул ~ды* к ве́черу он загрусти́л (стал печа́льным) **2.** (*об окружающей обстановке*) станови́ться (стать) уны́лым, тя́гостным, невесёлым; *көз җитте, урман ~ды* пришла́ о́сень, лес стал уны́лым

моңсулат|у *перех.* **1.** опеча́лить, огорча́ть/огорчи́ть *кого-л.*; *~ма анаңны* не огорча́й свою́ мать **2.** *безл. о грустном* (*тоскливом, печальном*) *настроении, состоянии*; *~ты* ста́ло гру́стно

моңсулык *сущ.* **1.** грусть, лёгкая печа́ль; уны́ние, уны́лость; *күңелне ~ басты* ду́шу охвати́ла грусть; *~та утыру* сиде́ть в уны́нии **2.** *об окружающей обстановке, наводящей грусть, печаль, уныние, тоску, унылость*; *тирә-якта ~ хөкем сөрә* вокру́г цари́т уны́лость

моңсыз *прил.* **1.** беспе́чный, беззабо́тный; *~ кеше* беспе́чный челове́к; *керсез ай, ~ ходай (погов.)* без гря́зи — ме́сяц, без печа́ли — бог **2.** немелоди́чный, испо́лненный без души́, не от се́рдца (*о голосе, песне и т. п.*) || *нареч.* беспе́чно, беззабо́тно; *~ яшәү (көн күрү)* жить беспе́чно (беззабо́тно); без души́, не от се́рдца

моңчан *прил.* постоя́нно испы́тывающий уны́ние; гру́стный, печа́льный; *~ кеше* гру́стный челове́к

моңчы *сущ.* исполни́тель гру́стных, печа́льных пе́сен

мопед *сущ.* мопе́д

мопс *сущ.* мопс (*порода комнатных собак*)

морад *сущ. книжн.* жела́ние, стремле́ние, цель; *см. тж.* **максат** □ **~ка ирешү (җитү)** достига́ть жела́емого; достига́ть це́ли; *сабыр иткән ~ына ирешкән (погов.)* терпели́вый добьётся своего́ (добьётся це́ли); *ижтиһат иткән ~ына җиткән (погов.)* кто стара́ется, тот дости́гнет це́ли

морал|ь *сущ. в разн. знач.* **1.** мора́ль, нра́вственность, пра́вила нра́вственности; *буржуаз ~ь* буржуа́зная мора́ль **2.** нра́вственный вы́вод, уро́к *из чего-л.*; *гадәттә, һәр мәсәлнең ~е була* обы́чно у ка́ждой ба́сни быва́ет мора́ль **3.** *разг.* нравоуче́ние, поуче́ние, наставле́ние, мора́ль; *~ь уку* чита́ть нравоуче́ние (наставле́ние, мора́ль) || *прил.* мора́льный; *~ь принциплар* мора́льные при́нципы; *~ь нәтиҗә* **1.** мора́льный вы́вод **2.** духо́вный, вну́тренний; мора́льный; *~ь ярдәм* мора́льная подде́ржка (по́мощь); *~ь җаваплылык* мора́льная отве́тственность

моральлек *сущ.* нравоуче́ние, поуче́ние || нравоучи́тельный; *әсәрнең коры ~ ягын бәяләү* оцени́ть лишь нравоучи́тельную сто́рону произведе́ния

морато́рий *сущ. полит.* морато́рий (*отсрочка какого-л. события: платежей, испытаний оружия и т. п.*)

морг I морг, поко́йницкая

морг II морг (*земельная мера около 0,5 га в Польше и Литве*)

мордар *сущ. уст.* **1.** па́даль, труп живо́тного **2.** мародёр, граби́тель тру́пов **3.** *перен.* прохво́ст, негодя́й, подле́ц, мерза́вец, него́дник, мразь, гад, га́дина; *~ның ~ы* зако́нченный негодя́й, подле́ц из подлецо́в; *дошманнардан, ~лардан үч алу* отомсти́ть врага́м, га́дам (мра́зи) || *прил.* по́длый, гря́зный, него́дный; *~ кеше* по́длый челове́к ◊ **~ китү (булу)** *рел.* **1.** поги́бнуть без покая́ния || самоуби́йство; *~ киткән кешене өйгә кертер хәлем юк* не могу́ допусти́ть в дом уме́ршего без отпуще́ния грехо́в **2.** забива́ться без освяще́ния; *мал суючы куп булса, хайван ~ китәр* (*посл.*) когда́ мно́го мясников, скот забива́ют без освяще́ния

мордарлык *сущ. уст.* по́длость; ни́зость, гну́сность, бесче́стность; *~ кылу* де́лать по́длость (бесче́стность)

мордва *сущ. этногр.* мордви́н; *мн.* мордо́вцы, мордва́; мордо́вка, мордви́нка || мордо́вский; *см. тж.* **мукшы**; *~ телләре* мордо́вские языки́ (*т. е. эрзянский и мокшанский*); *~ халкы* мордо́вский наро́д

мордва́ча *нареч.* по-мордо́вски, на мордо́вском языке́; *~ сөйләштеләр* разгова́ривали на мордо́вском языке́ || *прил.* на мордо́вском языке́, мордо́вский; *~ китап* кни́га на мордо́вском языке́, мордо́вская кни́га

мордва́чалап, мордва́чалатып *нареч. разг.* по-мордо́вски, на языке́ мордвы́, мордо́вцев (*заговорить, переговариваться*); *куршем ~ сөйләп китте* сосе́д заговори́л по-мордо́вски (на языке́ мордвы́)

море́на *сущ. геол.* море́на

морж *сущ. прям., перен.* морж || моржо́вый; *Тын океан ~ы* тихоокеа́нский морж; *ана ~* моржи́ха; *~лар группасы спорт.* гру́ппа морже́й; *~лар ярышы спорт.* состяза́ние морже́й; *~ мае* моржо́вый жир; *~ сөяге* моржо́вая кость; *~ тиресе* моржо́вая шку́ра; *~ каешы* моржо́вые ремни́ (*сделанные из шкуры моржа*)

морза *сущ.* **1.** мурза́; *~ малае* сын мурзы́; *~ йорты* дом мурзы́ **2.** *диал. в ф.* **морзам** мой ми́ленький; мила́ша; ми́ленький; ле́йший

морзалы|к *сущ.* (*социальное*) положе́ние мурзы́; *аның ~гында минем өчен бер караңгы нәрсә бар иде* в его́ положе́нии мурзы́ для меня́ бы́ло одно́ нея́сное обстоя́тельство

Мо́рзе: Мо́рзе аппараты аппара́т Мо́рзе; **~ әлифбасы** а́збука Мо́рзе

морзист *сущ.* морзи́ст (*телеграфист, работающий на аппарате Морзе*)

моро́шка *сущ. бот.* моро́шка; *см. тж.* **саз җиләге, саз карлыганы**; *тундра өсте ~ белән капланган* ту́ндра сплошь покры́та моро́шкой

морс *сущ.* морс (*прохладительный напиток*); *алма ~ы* я́блочный морс; *мүк җиләге ~ы* клю́квенный морс

морти́ра *сущ. ист. воен.* морти́ра || морти́рный; *яр буе ~сы* береговая морти́ра; *~ батареясы* морти́рная батаре́я; *~ дивизионы* морти́рный дивизио́н

морфе́ма *сущ. лингв.* морфе́ма

мо́рфий *сущ. фарм.* мо́рфий, морфи́н (*наркотическое болеутоляющее и снотворное средство, добываемое из млечного сока мака*); *соңгы көннәрен ул ~ белән генә торды* после́дние дни он жил то́лько на мо́рфие

морфинизм *сущ.* морфини́зм (*болезненное пристрастие к морфию как к наркотику, один из видов наркомании*), наркома́ния

морфо́лог *сущ.* морфо́лог, специали́ст по морфоло́гии

морфоло́гик *прил.* морфологи́ческий; *~ анализ* морфологи́ческий ана́лиз; *сүзнең ~ составы* морфологи́ческий соста́в сло́ва; *~ тикшеренүләр* морфологи́ческие иссле́дования

морфоло́гия *сущ. в разн. знач.* морфоло́гия; *эксперименталь ~* эксперимента́льная морфоло́гия; *бактерияләр ~се* морфоло́гия бакте́рий; *туфрак ~се* морфоло́гия почв; *татар теле ~се* морфоло́гия тата́рского языка́

моряк *сущ.* моря́к; *см. тж.* **диңгезче**; *хәрби ~* вое́нный моря́к

моря́на *сущ. мор.* моря́на (*морской ветер, ветер с моря*)

моржа *сущ.* **1.** труба́; *паровоз ~сы төтенли* труба́ парово́за дыми́т; *бай кешенең ~сы кыек булса да, төтене туры чыга* (*посл.*) у бога́того пусть труба́ и крива́, но дым поднима́ется пря́мо (бога́тый всегда́ прав) **2.** *диал.* печь; *~ акшарлау* побели́ть (бели́ть) печь □ **~ капкачы** вью́шка; **~ тазартучы (чистартучы)** трубочи́ст ◊ **~дан очу** обанкро́титься; вы́лететь в трубу́; **~дан очыру** **1.** пусти́ть (вы́пустить в трубу́; растра́тить, растранжи́рить) *что-л.* **2.** разори́ть *кого-л.*; **~дан төтен чыгару** жить, пожива́ть как все; дыша́ть, быть живы́м; существова́ть

моржалы *прил.* име́ющий трубу́; *ике ~* **1.** двухтру́бный **2.** *перен.* зажи́точный челове́к

моржасыз *прил.* курно́й; *~ мунча* курна́я ба́ня; ба́ня по-чёрному

моржачы *сущ.* трубочи́ст, чи́стильщик труб, дымохо́дов; *минем бабай ~ булган* мой дед был трубочи́стом

моржачылык *сущ. разг.* заня́тие трубочи́ста; *~ итү* быть трубочи́стом, занима́ться чи́сткой труб, дымохо́дов

мосафир *сущ. книжн.* **1.** пу́тник; прохо́жий; прое́зжий; путеше́ственник; пассажи́р; *~ларга культуралы хезмәт күрсәтү* культу́рно обслу́живать пу́тников (прое́зжих, пассажи́ров) **2.** стра́нник; пало́мник; тури́ст

мосафирханә *сущ. уст.* гости́ница, номера́ для стра́нников прое́зжих, путеше́ственников *и т. п.*

москит *сущ.* **1.** *зоол.* моски́т (*мелкое двукрылое кровососущее насекомое южных стран, причиняющее болезненные укусы*) || моски́тный; *~ бизгәге* моски́тная лихора́дка, моски́тка; *~ күче* (*өере, төркеме*) моски́тный рой; *~ ятьмәсе* (*битлеге*) моски́тная се́тка **2.** *мн. спец.* моски́ты (*мелкие быстроходные военные корабли,*

самолёты, предназначенные для боевых действий большими группами) || моски́тный; *~лар флотилиясе* моски́тная флоти́лия

мо́стик *сущ. спорт.* мо́стик (*в гимнастике: вытянутое, изогнутое положение тела, обращённого грудью вверх и опирающегося на пол пятками и ладонями*); *сикерү, йөгерү һәм ~ ясау* пры́гать, бе́гать и де́лать мо́стик

мостовой *сущ. разг.* мостова́я; *~ буйлап бару* е́хать (идти́) по мостово́й; *~ аша чыгу* перейти́ мостову́ю; *агач (бүкәннәр) түшәлгән ~* торцо́вая мостова́я

мосье *сущ.* мосье́, мсье (*вежливое обращение к мужчине во Франции; обычно ставится перед именем или фамилией*)

мотив *сущ. в разн. знач.* моти́в; *үзеңнең ~ларыңны китерү* вы́сказать свои́ моти́вы; *повестьның төп ~ы* основно́й моти́в по́вести; *халык ~лары буенча чигү* вы́шивка по наро́дным моти́вам; *операдан алынган таныш сүзләр һәм ~лар* знако́мые слова́ и моти́вы из о́перы

мотивлаштыру *перех.* мотиви́ровать; *см. тж.* **дәлилләү**; *соңга калуны ~* мотиви́ровать опозда́ние; *әдәби әсәрдә тормыш күренешләрен дөрес ~* правди́во мотиви́ровать жи́зненные явле́ния в худо́жественном произведе́нии

мотивлаштырылу *страд. от* **мотивлаштыру**; мотиви́роваться

мотлак *нареч. уст.* абсолю́тно, безусло́вно, непреме́нно; *сезнең җәзагызны ~ кабул итәмен* ва́ше взыска́ние гото́в приня́ть безусло́вно

мотлакан *нареч. уст.* абсолю́тно, безусло́вно, несмотря́ ни на что́, непреме́нно; *ул тормышыннан ~ канәгать* он абсолю́тно дово́лен жи́знью

мото- *первая часть сложных слов* мото-, *соответствующая по значению* мото́рный; моторизо́ванный; мотоцикле́тный

мотовоз *сущ.* мотово́з (*локомотив малой мощности, приводимый в движение двигателем внутреннего сгорания*)

мотоколя́ска *сущ.* мотоколя́ска; коля́ска с мото́ром

мотокросс *спорт.* мотокро́сс, мотопробе́г

мотокроссчы *сущ.* уча́стник мотокро́сса, мотого́нщик

мотомеханиза́ция *сущ.* мотомеханиза́ция

мотомеханиза́цияләштерел|ү *неперех.* мотомеханизи́роваться; *~гән гаскәри часть* мотомеханизи́рованная войскова́я часть

мотомеханиза́цияләштерү *перех.* мотомеханизи́ровать

мотопехо́та *сущ.* мотопехо́та || мотопехо́тный; *~ полкы* мотопехо́тный полк

мотор *сущ.* мото́р, дви́гатель || мото́рный; *автомобиль ~ы* мото́р автомоби́ля; *~ны кабызу* включи́ть мото́р; *~ цехы* мото́рный цех

моториза́ция *сущ.* моториза́ция; *авыл хуҗалыгында ~ үткәрү* моториза́ция се́льского хозя́йства

мотори́кша *сущ.* мотори́кша

моторист *сущ.* мотори́ст; *тегермәндә ~ булып эшләү* рабо́тать мотори́стом на ме́льнице

мото́рка *сущ. разг.* мото́рка, мото́рная ло́дка; *~да йөрү* ката́ться на мото́рке; *агымга каршы ~да бару* подня́ться на мото́рке про́тив тече́ния

моторлаштыр|у *перех.* моторизова́ть, осуществля́ть моториза́цию, снабжа́ть мото́рами || моториза́ция; *батальонны ~* моторизова́ть батальо́н

моторлаштырыл|у *страд. от* **моторлаштыру**; моторизова́ться, подверга́ться моториза́ции; *~ган дивизия* моторизо́ванная диви́зия

моторлы *прил.* **1.** мото́рный, с мото́ром; *~ көймә* мото́рная ло́дка; *~ пычкы* мото́рная пила́; мотопила́; *ике ~* двухмото́рный **2.** моторизо́ванный; *~ авыл хуҗалыгы* моторизо́ванное се́льское хозя́йство

моторо́ллер *сущ.* моторо́ллер || моторо́ллерный; *~ моторы* моторо́ллерный мото́р

моторчы *сущ.* моторис́т, специали́ст по мото́рам, сбо́рщик мото́ров

мотоспорт *сущ.* мотоспо́рт

мотоцикл *сущ.* мотоци́кл; *коляскалы ~* мотоци́кл с коля́ской; *узышу ~ы* го́ночный мотоци́кл

мотоциклет *сущ. см.* **мотоцикл** || мотоцикле́тный; *~ заводы* мотоцикле́тный заво́д; *~ кроссы* мотоцикле́тный кросс; *~та узышу* мотоцикле́тные го́нки; *~ коляскасы* мотоцикле́тная коля́ска

мотоциклист *сущ.* мотоцикли́ст; *см. тж.* **мотоциклчы**

мотоцикли́стка *сущ.* мотоцикли́стка

мотоци́клчы *сущ.* **1.** *см.* **мотоциклист** **2.** специали́ст по мотоци́клам

мохбир *сущ. устар. книжн.* корреспонде́нт (*газеты*)

мохер *сущ.* моха́р || моха́ровый; *~ шарф* моха́ровый шарф

мохит *сущ.* среда́, окружа́ющая среда́; *тышкы дөнья һәм ~* вне́шний мир и окружа́ющая среда́; *~не саклау* защи́та окружа́ющей среды □ **~ диңгезе** *уст.* океа́н

мохлис *прил. книжн.* и́скренний, пре́данный, че́стный

мохтаҗ *прил.* нужда́ющийся *в чём-л.*, испы́тывающий нужду́, бе́дный, ни́щий, убо́гий; *~ семья* бе́дная семья́ || *предик.* нужда́ющийся *в чём-л.*; *ул кеше ярдәменә ~* он нужда́ется *в чьей-л.* по́мощи; *акчага ~ булу* нужда́ться в деньга́х

мохтаҗлык *сущ.* **1.** нужда́, бе́дность, убо́гость; лише́ния; *этисезлек һәм ~* безотцо́вщина и нужда́ (лише́ния, бе́дность); *~ка төшү* терпе́ть нужду́ (лише́ния), оказа́ться в нужде́; *~та яшәү* жить в нужде́ (бе́дности); *~ юк* нет нужды́ **2.** *после направ. падежа* сте́пень нужды́, потре́бности; нужда́емость *в ком-л., чём-л.*; *дусларча ярдәмгә ~* потре́бность в дру́жеской по́мощи; *күз врачларына ~* нужда́емость в глазны́х врача́х

мохтәсар *прил. уст.* кра́ткий, сокращённый, небольшо́й, резюми́рованный; *~ мәкалә* кра́ткая (небольша́я) статья́ □ **~ кылу** **1.** сократи́ть (*текст*) **2.** сократи́ть, останови́ться, прерва́ть (*разговор*)

мочал *сущ. книжн.* двенадцатиле́тний живо́тный цикл летосчисле́ния (*каждый год этого цикла носит название какого-л. животного: год мыши, коровы, тигра, зайца, рыбы, змеи, лошади, барана, обезьяны, курицы, собаки, свиньи*)

мошенник *сущ. разг.* **1.** моше́нник, нече́стный челове́к, обма́нщик, плут, вор; жу́лик; *аның ~ икәнлеге беренче карауда күренә* ви́дно с пе́рвого взгля́да, что он моше́нник (нече́стный челове́к, жу́лик *и т. д.*) **2.** *бранное слово: нәрсә кирәк сиңа монда, ~?!* что тебе́ здесь ну́жно, моше́нник?!

мошкы *сущ.* **1.** семенна́я конопля́; матёрка *обл.* **2.** па́кля, конопля́ное волокно́ не лу́чшего ка́чества; *см.* **баса**

мөштым *сущ.* **1.** *ист.* грому́ла, боеви́к, де́йствующий по указа́нию своего́ патро́на; *кулак ~нары* кула́цкие грому́лы **2.** *диал. см.* **мыштым**

мөәзин *см.* **мәзин**

мөәннәс *сущ. уст. лингв.* же́нский род

мөбарәк *прил. рел. устар. книжн.* **1.** свяще́нный, высо́кий; *~ дәрәҗә (урын)* свяще́нный (высо́кий) сан (пост); *~ бәйрәм* свяще́нный пра́здник **2.** *высок.* благослове́нный; счастли́вый; *~ җир* благослове́нная земля́; *бәйрәмегез ~ булсын!* да бу́дет благослове́н ваш пра́здник! поздравля́ю вас с пра́здником! с пра́здником! *яшь гаилә ~ булсын!* да бу́дет сча́стлива молода́я семья́!

мө́гаен *вводн. сл.* наве́рное, наве́рно, по-ви́димому, очеви́дно; *болар, ~, безгә киләләр* э́ти, наве́рное, иду́т к нам; *~, китап быел басылып чыкмас* очеви́дно, кни́га в э́том году́ не вы́йдет из печа́ти

мөгаллим *сущ.* учи́тель

мөгаллимә *сущ.* учи́тельница

мөгаллимәлек *сущ.* учи́тельство, учи́тельствование же́нщины, до́лжность учи́тельницы □ **~ итү** быть учи́тельницей

мөгаллимлек *сущ.* учи́тельство; до́лжность учи́теля; *~тән ваз кичү* уходи́ть (уйти́) из учи́тельства; отказа́ться от учи́тельской до́лжности

мөгам *сущ.* **1.** *рел.* мело́дия дервиш ских раде́ний **2.** *диал.* мело́дия пля́ски, та́нца

мөгамәлә *сущ.* отноше́ние *к кому-л., чему-л.*, обраще́ние *с кем-л., чем-л.*; *йомшак ~ итү* обраща́ться снисходи́тельно; *тупас ~ итү* гру́бое обраще́ние; обраща́ться гру́бо; *тәкәллефле ~* изы́сканное, любе́зное отноше́ние; *әдәпле ~* учти́вое обраще́ние

мөгамәләле *прил.* име́ющий определённое отноше́ние к други́м; *яхшы ~* обходи́тельный; *каты ~ кеше* грубия́н, гру́бый челове́к

мөгәрич *сущ. разг.* магары́ч; *~ эчү* распи́ть магары́ч; *монысы ~кә* э́то на магары́ч

мөгәричлек *сущ. разг.* на магары́ч; *~ бир* дай на магары́ч

мөгез *сущ.* **1.** рог, рога́ (*у животных*); *болан ~е* оле́ньи рога́; *берәүгә ~е кыйбат, берәүгә — үгезе (посл.)* одному́ до́рог бык, друго́му — рога́; *сөзгәк сыерга алла ~ бирми (погов.)* бодли́вой коро́ве бог рога́ не дал **2.** *перен.* ши́шка на лбу (*от удара, какой-л. болячки*); *нинди ~ синең маңгаеңда?* что за ши́шка на твоём лбу? **3.** *муз.* рожо́к; *см. тж.* **быргы**; *көтүче ~е* пасту́ший рожо́к **4.** 1) *спец.* рога́ (*сырьё для галантерейного производства*) 2) *прил.* роговой; *~ матдә* роговое вещество́; *~ тарак* роговой гре́бень; *~ эшкәртү эше* роговой кустарный про́мысел; *~ тирәле күзлек* очки́ в роговой опра́ве □ **~ йомычкасы** роговы́е стру́жки (*удобрение*); **~ катлау** *зоол. см.* **мөгезсыман**; **~пәрдә** *анат.* рогови́ца; рогова́я оболо́чка ◊ **~ кую (утырту)** наста́вить рога́ (*об измене жены*); **елан ~е генә юк** (*погов.*) нет то́лько пти́чьего молока́ (*букв.* нет то́лько змейных рого́в) (*т. е. всё есть, всё в изобилии, всего много*); **~ен сындыру** успоко́ить, уня́ть я́рость *кого-л.* (*букв.* оброма́ть, слома́ть рога́ *кому-л.*); **үгезне ~еннән эләктерү** брать быка́ за рога́; **~ чыгару** выду́мывать небыли́цы; **~ чыгу** *ирон.* возвыша́ться, повыша́ться в чи́не (*по службе*)

мөгезборын *сущ. зоол.* **1.** носоро́г **2.** рога́тик, рога́ч

мөгезләнү *неперех.* рогове́ть

мөгезләч *сущ. зоол.* жук-рога́ч

мөгезле *прил.* **1.** рога́тый; *~ эре терлек* кру́пный рога́тый скот; *зур ~* рога́стый; *зур ~ үгез* рога́стый бык **2.** *перен. разг., чаще в отрицательной ф. означает:* тако́й же; тако́й же, как все; ничего́ необы́чного, обыкнове́нный; *анда да ~ләр эшләми, синең белән минем кебекләр* и там рабо́тают не рога́тые, а таки́е же, как мы с тобо́й; *~ тугел* ничего́ необы́чного; похо́ж на всех; тако́й же (таки́е же) **3.** *разг.* обма́нутый жено́й, рога́тый; *~ ир* рога́тый муж; рогонбсец; *~ булу* быть рогоно́сцем; стать рогоно́сцем; быть обма́нутым жено́й □ **~ле коңгыз** *зоол.* жук-рога́ч, рога́тик; *обл. см. тж.* **мөгезборын** 2

мөгезсез *прил.* **1.** безро́гий, комо́лый; *~ тананы болынга чыгару* вы́пустить на луг двухгодова́лую комо́лую тёлку **2.** *перен. ирон. о неосторожном, неаккуратном в движениях и о невоспитанном, невежливом, неделикатном по отношению к людям человеке* грубия́н; неве́жа; *и ~, нигә монда аяк астында буталасың?* ты что, неве́жа, пу́таешься тут под нога́ми? ◊ **~ сыер (тәкә) кебек** *уничиж. ирон.* **1.** *о неосторожном, грубом, неаккуратном в движениях человеке* **2.** *о невоспитанном, невежливом, неделикатном по отношению к людям человеке*

мөгезсыман *прил.* рогови́дный; *~ катлау* рогови́дный слой

мөгезтеш *сущ. зоол.* рогозу́б (*рыба*)

мөгезчел *прил.* рогови́дный; *~ күзәнәкләр* рогови́дные кле́тки

мөгрәү *неперех.* мыча́ть || мыча́ние; *сыер кебек ~* мыча́ть, как коро́ва; *бозау ~ве* мыча́ние телёнка

мөгердәү *неперех. см.* **мөгрәү**

мөдафәга: мөдафәга кылу *уст. книжн.* оборона́ться, защища́ться, сопротивля́ться, оказа́ть сопротивле́ние

мөдәррис *сущ.* **1.** преподава́тель **2.** мударри́с (*старший преподаватель медресе*)

мөдәррислек *сущ.* до́лжность, обя́занности преподава́теля, мударри́са; *~ итү* преподава́ть, учи́тельствовать

мөддәт *сущ. книжн.* **1.** срок; *~е җитмәгән әле* срок ещё не подошёл; *зур ~* большо́й срок **2.** вре́мя, промежу́ток вре́мени

мөддәтле *прил. книжн.* сро́чный, огранич енный *каким-л.* сро́ком, име́ющий *какой-л.* срок; *~ эш алдым* взял сро́чную рабо́ту

мөддәтсез *прил. книжн.* бессро́чный

мөдир *сущ.* заве́дующий, управля́ющий; *ферма ~е* заве́дующий фе́рмой; завфе́рмой; *булек ~е* заве́дующий отде́лом, завотде́лом; *кафедра ~е* заве́дующий ка́федрой, завка́федрой

мөдирлек *сущ.* до́лжность, положе́ние заве́дующего; *~ итү* рабо́тать заве́дующим, заве́довать *чем-л.*

мөең *сущ. диал.* **1.** у́гол, уголо́к (*в здании*); *кыйбла ~е* у́гол на ю́жной стороне́ (*дома, комнаты и т. п.*) **2.** закругле́ние угла́ **3.** ма́ленькая пеще́рка

мөешләндерү *перен.* закругля́ть/закругли́ть углы́

мөешләнү *неперех.* закругля́ться/закругли́ться (*об углах*)

мөҗавир *сущ.* **1.** охра́нник святы́х мест **2.** кладби́щенский сто́рож

мөзакәрә *сущ. уст. книжн.* обсужде́ние, обме́н мне́ниями

мөзәккар *сущ. уст. грам.* мужско́й род

мөкаддимә *сущ. уст. книжн.* введе́ние, вступле́ние; предисло́вие; проло́г; *әсәргә ~не танылган әдип язган* введе́ние к произведе́нию написа́л изве́стный писа́тель

мөкатдә *сущ. уст.* ра́ньше, в про́шлом; *см. тж.* **элек, элгәре**

мөкатдәр *сущ. уст. книжн.* судьба́; *~дә язылгандыр* вида́ть, так напи́сано в кни́ге су́деб (ви́дно, на роду́ напи́сано)

мөкатдәс *прил. устар. книжн.* **1.** *рел.* свяще́нный **2.** *перен.* свяще́нный, свято́й; *~ бурыч* свяще́нный долг; *~ эш* свято́е (свяще́нное) де́ло

мөкатдәслек *сущ.* свяще́нность; вели́чественность, вели́чие

мөкәммәл *прил. книжн.* **1.** *см.* **камил 2.** совреме́нный; улу́чшенный; *~ театр* совреме́нный теа́тр

мөкәммәлләштерү *понуд. от* **мөкәммәлләшү**; совершéнствовать, доводи́ть/довести́ до совершéнства || совершéнствование; *проектны ~* совершéнствовать прое́кт

мөкәммәлләшү *неперех. книжн.* совершéнствоваться, доводи́ться до совершéнства || совершéнствование

мөкәммәллек *сущ. книжн.* **камиллек**

мөкиббән: мөккибән булу (китү) 1. па́дать ничко́м **2.** увле́чься всецело́ *кем-л., чем-л.*, забыва́ться/забы́ться, увлёкшись, забыть обо всём; боготвори́ть *кого-л., что-л.* ◊ **~ булып (китеп) карау** смотре́ть (гляде́ть) во все глаза́, гляде́ть боготворя́, не находя́ сил оторва́ться; **~ китеп тыңлау** заслу́шаться, слу́шать, сосредото́чив всё внима́ние, обрати́ться в слух; **~ китеп (булып) уку** зачита́ться, чита́ть с увлече́нием

мөлаем *прил.* **1.** ла́сковый, мягкосерде́чный, не́жный, мя́гкий; *~ күз карашы* ла́сковый (не́жный, мя́гкий) взгляд; *~ тавыш* ла́сковый (мя́гкий) го́лос **2.** симпати́чный, обая́тельный, милови́дный; *~ хатын* обая́тельная же́нщина □ **~ гына** ла́сково, не́жно, мя́гко; *~ гына елмаю* не́жно говори́ть (разгова́ривать)

мөлаемлан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать ла́сковым, мягкосерде́чным, станови́ться/стать не́жным, мя́гким; *аның тавышы ~ды* его́ го́лос стал не́жным **2.** станови́ться/стать симпати́чным, обая́тельным, милови́дным

мөлаемлы|к *сущ.* **1.** ла́сковость, не́жность, мя́гкость; *тавышның ~гы* не́жность го́лоса **2.** симпати́чность, обая́тельность, милови́дность; *хатынының ~гы* обая́тельность жены́; *кыз баланың ~гы* милови́дность де́вочки

мөлдерәмә *прил.* **1.** перепо́лненный, о́чень по́лный; *сөт белән ~ стакан* по́лный до краёв стака́н молока́ **2.** *в знач. нареч.* до краёв (*о жидкости в посуде*); *~ тулы* на́лито до краёв □ **~ булу 1.** быть перепо́лненным **2.** быть в слеза́х (*о глазах*); **~ итү** нали́ть до краёв, перепо́лнить

мөлдерәп: мөлдерәп торган перепо́лненный; *~ тору* быть перепо́лненным до краёв

мөлдерәт|үү напо́лнить до краёв, перепо́лнить (*жидкостью посуду*) ◊ **күзләрне ~еп карау 1.** смотре́ть сквозь слёзы (слёзно), смотре́ть пе́чально (пе́чальными глаза́ми) **2.** смотре́ть с мольбо́й *о чём-л.*, смотре́ть в ожида́нии *чего-л.*

мөлдер|әү налива́ться/нали́ться (*слезами — о глазах*) ◊ **~әп карау** *см.* **күзләрен мөлдерәтеп карау; ~әп китү** переплива́ться/перели́ться че́рез край; **~әп торган** перепо́лненный; **~әп тору** быть перепо́лненным, напо́лненным до краёв; **~әп тулу** *см.* **мөлдерәп тору** (*о бочке, ведре, стакане, тарелке и т. п.*)

мөлдер-мөлдер *звукоподр. тихому течению струи воды*

мөле|к *сущ. разг.* **1.** недви́жимое иму́щество; владе́ние, владе́ния **2.** *книжн.* страна́, о́бласть; *Әҗәм ~ге* о́бласть Ира́на, страна́ Ира́н **3.** *в ф.* **мөлкендә** во владе́нии *кого-л.*

мөлкәт *сущ.* **1.** иму́щество, добро́; *ата ~е* отцо́вское добро́; *мал-~ бүлешү* делёж иму́щества, разде́л дви́жимого и недви́жимого иму́щества **2.** *прил.* иму́щественный; *~ цензы юр.* иму́щественный ценз; *~ мәсьәләләре* иму́щественные вопро́сы

мөлкәтле *прил.* состоя́тельный, зажи́точный, бога́тый, иму́щий; *~ (мал-~) кеше* состоя́тельный (бога́тый) челове́к; зажи́точный челове́к

мөлкәтлелек *сущ.* состоя́тельность, зажи́точность

мөлкәтсез *прил.* несостоя́тельный, небога́тый, бе́дный, незажи́точный

мөлчәр *сущ. ист.* строй войск

мөмкин *модальн. сл.* **1.** 1) мо́жно, возмо́жно, есть возмо́жность; *язарга, рәсем ясарга ~* мо́жно писа́ть, рисова́ть; *авылда да үз белгечлегең буенча эшләргә ~ бит* и в дере́вне мо́жно рабо́тать по свое́й специа́льности 2) мо́жно, допусти́мо; ла́дно, хорошо́; *бу булмәдә дә урнашырга ~* мо́жно устро́иться и в э́той ко́мнате 3) *в ф.* **мөмкинме?** разреши́те? мо́жно ли? *сорарга ~ме?* разреши́те спроси́ть? *бу китапны алырга ~ме?* мо́жно взять э́ту кни́гу? **2.** возмо́жно, мо́жет быть; *алай булуы да ~* и так мо́жет быть **3.** *в знач. сущ. разг.* возмо́жность, возмо́жное; *~нең төбе киң* (*погов.*) возмо́жностям нет преде́ла, нет преде́ла возмо́жному; *~не һәркем эшли, ~ түгелне үткен эшли* (*посл.*) возмо́жное вся́кий сде́лает, а невозмо́жное — лишь ло́вкий □ **~ булган кадәр(ле), ~ булганынча** по ме́ре возмо́жности; **~ булгач та** при пе́рвой возмо́жности; **~ булмаган** невозмо́жный, несбы́точный; *~ булмаган хәл* невозмо́жный слу́чай; **~ булмады** не́ было возмо́жности; не удало́сь, не получи́лось, не вы́шло; **~ булмасмы икән?** нельзя́ ли?, нет ли возмо́жности? **(әгәр) ~ булса** е́сли есть возмо́жность; **~ кадәр (хәтле)** по возмо́жности, по ме́ре возмо́жности; как мо́жно; **~ кадәр яхшырак** как мо́жно лу́чше; по возмо́жности лу́чше; **~ саналган** допусти́мый

мөмкинле|к *сущ.* **1.** возмо́жность; *миңа көньякка китәргә ~к бар* мне предоставля́ется (у меня́ есть) возмо́жность пое́хать на юг; *производство ~кләре* произво́дственные возмо́жности **2.** вероя́тность; *аның китү ~ге бар* вероя́тно, что он уйдёт; по всей вероя́тности, он уйдёт □ **~ге аз булган** маловероя́тный; **~к бирү** предоставля́ть возмо́жность; **~кләрдән чыгып эш итү** де́лать *что-л.* исходя́ из возмо́жностей

мөмтаз *прил. уст. книжн.* **1.** и́збранный, отбо́рный **2.** превосходя́щий; выделя́ющийся *чем-л.*; *шуклык белән ~ малай* ма́льчик, выделя́ющийся озорство́м ◊ **~ ясау (ясату)** сде́лать так, что́бы выделя́лся среди́ други́х, превосходи́л *чем-л.*

мөмтәнл|әү *неперех. диал.* жева́ть, пережёвывать, пожева́ть беззу́бым ртом; жева́ть губа́ми; пережёвывание пи́щи беззу́бым ртом

мөнәҗәт *сущ. рел.* **1.** моли́тва (*мольба к Аллаху или прославление имени Аллаха*) **2.** мунаджа́т, религио́зный гимн, псало́м □ **~ әйтү** моли́ться; **~ әйтүче** *см.* **мөнәҗәтче**

мөнәҗәтче *сущ.* чтец мунаджа́та (*у христиан:* псало́мщик)

мөнәсәбәт *сущ.* **1.** отноше́ние; *дусларча ~* дру́жеское отноше́ние; *кешелекле ~* челове́ческое отноше́ние; *үзара ~* взаимоотноше́ния **2.** 1) связь, отноше́ние; сноше́ние; *ул кешегә бернинди ~ем юк* к нему́ (к тому́ челове́ку) не име́ю никако́го отноше́ния 2) любо́вная связь,

инти́мные отноше́ния; *ул хатынын икенче бер ир белән ~тә гаепли* он обвиня́ет жену́ в любо́вной свя́зи с други́м; *җенси ~* полово́е сноше́ние **3.** причáстность, связь, отноше́ние *к чему-л.*; *бу эшкә аның ~е юк* он не причáстен к э́тому де́лу; он к э́тому де́лу не име́ет отноше́ния; *бу хәлләрнең бер-беренә ~е бардыр дип уйламым* не ду́маю, что ме́жду э́тими собы́тиями есть кака́я-то связь **4.** *филос.* взаимосвя́зь, взаимообусло́вленность; *аңның яшәешкә ~е* взаимосвя́зь ме́жду бытие́м и созна́нием (бытие́ определя́ет созна́ние) **5.** *разг. редко какое-л.* де́ло, на́добность; *берәр ~ чыкса, барып кайтырбыз* е́сли бу́дет в э́том на́добность, съе́здим; е́сли бу́дет *какое-л.* де́ло, съе́здим ◊ **~е белән (илә)** *уст. книжн.* по слу́чаю, в связи́ *с чем-л.*; *бәйрәм ~е белән* по слу́чаю пра́здника, в связи́ с пра́здником

мөнәсәбәтле *прил.* име́ющий отноше́ние *к чему-л., кому-л.*; име́ющий связь *с кем-л., чем-л.*; *болар — театрга ~ кешеләр* э́то лю́ди, име́ющие отноше́ние к теа́тру □ **~ сүз** *лингв.* moда́льное сло́во; **~ булу** име́ть отноше́ние, быть причáстным *к чему-л.*

мөнәсәбәтлек *сущ. лингв. см.* **мөнәсәбәтле сүз**

мөнәсәбәтсезлек *сущ. книжн. редко* безотноси́тельность

мөнәсәбәттәшлек *сущ. книжн.* соотноси́тельность

мөнбәр *сущ.* **1.** *рел.* менба́р (*возвышение в мечети, с которого имам произносит проповедь*) **2.** трибу́на, ка́федра

мөндәриҗә *сущ. уст. книжн.* содержа́ние; *докладның ~се* содержа́ние докла́да

мөңрә|ү *неперех. диал. см.* **мөгрәү**

мөрәббия *сущ. книжн.* воспита́тельница (*родительница или заменяющая её женщина*)

мөрәҗәгать *сущ. книжн.* обраще́ние *к кому-л.*; *тынычлык яклаучыларның бөтендөнья конгрессы ~е* обраще́ние всеми́рного конгре́сса защи́тников ми́ра □ **~ итү** 1. обраща́ться/обрати́ться *к кому-л.*; *директорга ~ итү* обрати́ться к дире́ктору 2. обрати́ться *к чему-л.*, испо́льзовать *для чего-л.*; *сүзлекләргә ~ итү* по́льзоваться словаря́ми; *фольклор материалларына ~ итү* обрати́ться к фолькло́рным материа́лам; испо́льзовать *для чего-л.* фолькло́рный материа́л

мөрәҗәгатьнамә *сущ. уст. книжн.* пи́сьменное обраще́ние, воззва́ние

мөрәүвәт *сущ. книжн.* **1.** до́блесть, му́жество **2.** снисходи́тельность, челове́чность, гума́нность; великоду́шие, благоро́дство; **~ күрсәтү** проявля́ть снисходи́тельность

мөрәүвәтле *прил. книжн.* **1.** челове́чный, гума́нный; великоду́шный, благоро́дный **2.** снисходи́тельный; *~ бул* будь снисходи́тельным

мөрәүвәтсез *прил. книжн.* бесчелове́чный, жесто́кий, немилосе́рдный

мөрәүвәтсезлек *сущ. книжн.* бесчелове́чность, жесто́кость, немилосе́рдность

мөрит *сущ.* **1.** *рел.* мюри́д (*последователь — ученик ишана или шейха*) **2.** 1) аде́пт, после́дователь, приве́рженец *кого-л.* 2) *перен. уничижит. ирон.* подхали́м, блюдоли́з

мөритлек *сущ. рел.* **1.** *см.* **мөрит 2.** мюрида́зм **3.** *перен. ирон.* приве́рженность

мөрит-мөхлис *сущ. уст. собир.* после́дователи и приве́рженцы (*ишана или шейха*)

мөритчелек *сущ. рел.* мюрида́зм

мөртәт *сущ.* **1.** 1) *рел.* вероотсту́пник; безбо́жник; *~ китү* вероотсту́пничество 2) *перен.* отрёкшийся *от чего-л.*, ренега́т **2.** *разг.* преда́тель, изме́нник **3.** *прост. бран.* безбо́жник, и́род; *и, ~, нәрсә сөйлисең?* тьфу, безбо́жник, что ты болта́ешь?

мөртәтлек *сущ.* **1.** 1) *рел.* вероотсту́пничество 2) *перен.* отрече́ние, отка́з *от чего-л.* (*от идеала, жизни, дружбы и т. п.*) **2.** *разг.* преда́тельство, изме́на

мөршид *сущ. книжн.* **1.** *рел.* мюрши́д (*духовный руководитель, наставник*) **2.** проводни́к; *см. тж.* **кулавыз, юламан**

мөсанниф *сущ. уст. книжн.* а́втор, состави́тель (*книги, какого-л. издания, сборника*)

мөсафир *сущ. книжн.* **1.** стра́нник, пу́тник, путеше́ственник **2.** прие́зжий; челове́к, находя́щийся на чужби́не ◊ **~ этнең койрыгы кысык** (*посл.*) = на чужо́й стороне́ и со́кола зову́т воро́ной (*букв.* на чужби́не и у соба́ки хвост поджа́т)

мөсафирлык *сущ. книжн.* **1.** стра́нствование, путеше́ствие; *~та йөрү* путеше́ствовать, стра́нствовать **2.** жизнь на чужби́не; *гомер ~та үтте* жизнь прошла́ на чужби́не

мөсафирханә *сущ. уст. книжн.* гости́ница, номера́ (*для приезжих*)

мөселман *сущ. рел.* **1.** мусульма́нин, *мн.* мусульма́не || мусульма́нский; *~ дине* мусульма́нская рели́гия, ислáм; *~ гореф-гадәтләре* мусульма́нские обы́чаи **2.** *разг. уст.* тата́рин

мөселманлы|к *сущ.* **1.** то же, что мусульма́нин; *аның ~гы* (то), что он мусульма́нин **2.** мусульма́нство

мөселманчылык *сущ.* мусульма́нская, общеисла́мская солида́рность □ **~ күрсәтү (кылу)** ока́зывать гостеприи́мство, по́мощь и т. п., исходя́ из общеисла́мской солида́рности

мөстәкыйль *прил.* **1.** 1) *в разн. знач.* самостоя́тельный, суверéнный, незави́симый; *~ дәүләт* незави́симое (суверéнное) госуда́рство; *~ бүлек* самостоя́тельный отде́л; *~ бала* самостоя́тельный ребёнок 2) *в знач. нареч.* самостоя́тельно, незави́симо; *үзеңне ~ тоту* держа́ться незави́симо; держа́ть себя́ незави́симо; *~ эшләү* рабóтать самостоя́тельно **2.** вы́полненный без посторóнней пóмощи, без *чьего-л.* вмеша́тельства; самостоя́тельный; *~ эш* самостоя́тельная рабóта □ **~ җөмлә** *грам.* самостоя́тельное предложе́ние; **~ рәвештә** самостоя́тельно, незави́симо

мөстәкыйльлек *сущ., в разн. знач.* самостоя́тельность, незави́симость; суверените́т; *милли ~* национáльный суверените́т; *~ өчен көрәш* борьба́ за незави́симость, за суверените́т; *~ тәрбияләү* воспита́ние самостоя́тельности

мөфт *прил.* **1.** соверше́нно дешёвый; почти́ беспла́тный; *мөфт бәягә сату* продава́ть по дешёвке **2.** *в знач. сущ.* де́мпинг

мөфти *сущ. рел.* му́фтий (*глава мусульманского духовенства определённой территории; толкователь шариата, законовед, дающий заключение по духовным и юридическим вопросам*)

мөфтилек *сущ. рел.* обя́занности, положе́ние му́фтия

мөхаль *прил. книжн.* **1.** невозмóжный, невероя́тный, неосуществи́мый; *~ эш* невозмóжное (невероя́тное) де́ло; *~ булу* быть неосуществи́мым **2.** *в функ. сказ.* невозмóжно; невероя́тно

мөхәррәм *сущ. книжн.* мухарра́м (*название первого месяца мусульманского лунного года*)

мөхәррир *сущ.* **1.** реда́ктор; *нәшрият ~е* изда́тельский реда́ктор; реда́ктор изда́тельства **2.** 1) *устар.*

писáтель; áвтор; *рус ~ләре* рýсские писáтели 2) журнали́ст

мөхәррирлек *сущ.* **1.** занáтие, дóлжность редáктора **2.** 1) писáтельская дéятельность (дéятельность писáтеля); *~тән килгән акча* гонорáр за писáтельскую дéятельность 2) журнали́стская дéятельность, дéятельность журнали́ста

мөхбир *сущ. книжн.* корреспондéнт

мөхбирлек *сущ. уст. книжн.* профéссия (занáтие) корреспондéнта; дóлжность (мéсто) корреспондéнта; *~кә тәкъдим итү* предложи́ть на дóлжность корреспондéнта

мөхлис *прил. уст. книжн.* и́скренний, прéданный (*друг*) || *сущ.* покло́нник, почитáтель

мөхлислек *сущ.* и́скренность, прéданность в дрýжбе

мөхмәс *сущ. уст. книжн.* **1.** *мат.* пятиугóльник **2.** *лит.* мухаммáс (*название стихотворной строфы, состоящей из пяти полустиший*)

мөхтәрәм *прил. книжн.* **1.** уважáемый, глубокоуважáемый, почтéнный, достопочтéнный; *авылның ~ кешесе* уважáемый человéк селá **2.** *в знач. сущ. мн.* **мөхтәрәмнәр** почтéнные лю́ди; *районның ~нәре* почтéнные лю́ди райóна

мөхтәсәр, мөхтәсар *прил. книжн.* **1.** крáткий, сокращённый **2.** *в знач. нареч.* крáтко, сокращённо □ **~ кылу** сократи́ть (*текст, письмо*), прервáть (*разговор*)

мөхтәсиб *сущ. книжн.* **1.** контролёр, инспéктор; мухтасúб (*лицо, наблюдающее за исполнением предписываемых шариатом религиозных обрядов и правил поведения*); учёный богослóв **2.** окружнóй муллá

мөһелдәү *неперех.* негрóмко ржать (*о лошади*)

мөһер *сущ.* печáть; *~ басылган* удостовéренный печáтью □ **~ басу (сугу)** **1.** *уст.* стáвить, приложи́ть печáть **2.** *перен. пренебр.* дать кли́чку, дать прóзвище; **~ саклаучы** храни́тель печáти

мөһерләү *перех.* **1.** прикладывать/приложи́ть печáть; скрепля́ть/скрепи́ть печáтью || приложéние печáти; скреплéние печáтью **2.** опечáтывать/опечáтать сургýчной печáтью; опечáтывание сургýчной печáтью **3.** *перен. см.* **мөһер басу (сугу)**

мөһим *прил.* **1.** вáжный, существéнный, серьёзный; крýпный; *~ эш белән килдем* пришёл по вáжному дéлу **2.** вáжный, знамена́тельный; *~ дата* знамена́тельная (вáжная) дáта; *иң ~* сáмый вáжный, сáмый глáвный; *иң ~е* сáмое глáвное, сáмое вáжное; важнéе всегó, главнéе всегó

мөһимлек *сущ.* **1.** вáжность, существенность, серьёзность **2.** вáжность, знамена́тельность; *датаның ~ген онытырга ярамый* нельзя́ забывáть знамена́тельность дáты

мөшәрәф *прил. книжн.* почтéнный, уважáемый (*человек*)

мөшкә *сущ.* **1.** лотóк на мéльнице; *~дән капчыкка он агызу* ссыпáть мукý из лотка́ в мешóк **2.** бýнкер (*у комбайна*) ◊ **~ башында тору (булу)** *ирон.* быть хозя́ином *чего-л.*, быть главóй *какого-л.* предприя́тия, учреждéния; главéнствовать; **~се тулы** как пóлная чáша; **~се тулы булу** быть (жить) в благополýчии

мөшкәле *прил.* лотковóй (*мельница*); *ике ~* двухлотковóй

мөшкәт *сущ. уст.* мускáт

мөшкел *прил.* трýдный, тяжёлый, затрудни́тельный; плачéвный; *~ хәлдә калу* оказáться в трýдном положéнии; *~ мәсьәлә* трýдный вопрóс; *эшләр ~* делá плóхи; *хәлең ~ синең* положéние твоё тяжёлое

мөшкелләнү *неперех.* дéлаться, сдéлаться трýдным, затрудни́тельным; ухудша́ться/ухýдшиться, осложня́ться/осложни́ться || осложнéние; *хәл ~де* положéние сдéлалось затрудни́тельным; положéние осложни́лось; *авыруның хәле ~ә бара* состоя́ние больнóго ухудша́ется

мөшкеллек *сущ.* трýдность, затрудни́тельность, затруднéние; *~тән котылу юлы* спóсоб избавлéния от трýдностей (затруднéний)

мөшмәлә *сущ. бот.* мушмулá (*южный плодовый кустарник и его плоды*)

мөштәри *сущ. уст.* **1.** подпи́счик (*периодического издания*) **2.** постоя́нный покупáтель; клиéнт

мөштек *сущ. разг.* мундштýк

мөэмин *сущ. рел., прил.* **1.** вéрующий (мусульмáнин), правовéрный **2.** *перен.* смúрный, скрóмный

мрáмор *сущ. в разн. знач.* мрáмор; *см. тж.* **мәрмәр**; *кызгылт ~* розовáтый мрáмор; *соры ~* сéрый мрáмор; *ак ~* бéлый мрáмор || *прил.* 1) *в разн. знач.* мрáморный; *~ өстәлчек* мрáморный стóлик; *~ фонтан* мрáморный фонтáн; *~ ваза* мрáморная вáза; *~ чыганаклары* мрáморные месторождéния 2) *перен.* мрáморный, глáдкий; бéлый и холóдный, как мрáмор; похóжий на мрáмор (*кожа, цвет лица*); *~ йөз* мрáморное (бéлое и холóдное) лицó; *кызның ~ җилкәләре* мрáморные плéчи дéвушки 3) мрáморный, сдéланный под мрáмор, похóжий на мрáмор; *~ линолеум* мрáморный линóлеум; *~ кәгазь* мрáморная бумáга; *~ бизәкле обойлар* мрáморные обóи

муар *сущ. текст.* муáр; *кулмәклек ~ сатып алу* купи́ть муáр на плáтье; *белдерү матур шрифт белән алсу ~га басылган иде* афúша былá напечáтана красúвым шрúфтом на рóзовом муáре || *прил.* 1) муáровый; из муáра; *~ кулмәк* муáровое плáтье; *~ тасма* муáровая лéнта; *~ ефәк* муáровый шёлк 2) муáровый, как муáр (*расцветкой*), похóжий на муáр; *~ обойлар* муáровые обóи

муафыйк *прил. книжн.* **1.** соответствующий, подходя́щий *для чего-л.*; *~ юлдаш тапмыйча, сәфәр чыкма* (*посл.*) пока́ не найдёшь подходя́щего спýтника, не отправля́йся в дорóгу; *үзенә бик ~ эш тапкан* он нашёл себé подходя́щую рабóту; *план үтәү өчен ~ чаралар курелде* для выполнéния плáна прúняты соответствующие мéры **2.** *предик.* 1) соответствует, подхóдит *кому-л., чему-л.*; *кызның исеме җисеменә ~ икән* и́мя дéвушки соответствует её сýти 2) гóден, пригóден *к чему-л., для чего-л.*; *бу егет хәрби хезмәткә ~* э́тот пáрень гóден к воéнной слýжбе; *белмим, нинди эшкә ~ диярләр аны* не знáю, к какóй рабóте найдýт егó пригóдным **3.** согласно *чему-л.*; в соответствии *с чем-л.*; *законга ~* согласно закóну, в соответствии с закóном; *максатка ~* 1) соответствующий цéли 2) в соответствии с цéлью, целесообрáзно □ **~ булу** **1.** оказáться гóдным, удóбным, приéмлемым *для чего-л.*, соответствующим *чему-л.*; совпадáть по врéмени **2.** быть, находúться в соответствии *с чем-л.*, соответствовать *чему-л.*; *эш урынына ~ булмау* не соответствовать занимáемой дóлжности **3.** быть рáвным, не уступáть *кому-л. в каком-л.* отношéнии, соответствовать; *яңа агроном укытучы кызга ~ булыр* нóвый агронóм подхóдит (годúтся) учúтельнице; **~ күрү (табу)** **1.** считáть целесообрáзным (умéстным, нýжным, необходúмым); *ташка язып куюны ~ тапты* счёл нýжным надписáть на кáмне; *башта туган авылга керуне ~ күрде* посчитáл целесообрáзным побывáть в пéрвую óчередь в роднóм аýле **2.** считáть, найтú гóдным, пригóдным *для чего-л., к чему-л.*; *типография эшенә ~ күрү*

счита́ть приго́дным *кого-л.* к типогра́фской рабо́те **3.** счита́ть са́мым подходя́щим, лу́чшим вариа́нтом; вы́брать *что-л.*; *ул узенә фән юлын ~ тапты (күрде)* он посчита́л са́мым подходя́щим для себя́ нау́ку (нау́чную рабо́ту) **4.** счита́ть са́мым подходя́щим, ра́вным *в каком-л.* отноше́нии; *аның үзенә ~ кургән кызы бар* у него́ есть де́вушка, кото́рую он счита́ет са́мой подходя́щей для себя́

муафыйклану *неперех.* **1.** станови́ться/стать соответствующим, подходя́щим *для чего-л., к чему-л.* **2.** станови́ться/стать го́дным, удо́бным, прие́млемым *для чего-л.*, соответствующим *чему-л.* **3.** станови́ться/стать целесообра́зным

муафыйклаштыру *понуд. от* **муафыйклашу**; приспоса́бливать/приспосо́бить, приводи́ть/привести́ в соответствие; сде́лать го́дным, подходя́щим, прие́млемым *для чего-л.*; приго́дным для испо́льзования в ка́честве *чего-л.* || приспоса́бливание, приведе́ние в соответствие

муафыйклаштырылу *страд. от* **муафыйклаштыру**; приспоса́бливаться, быть приспосо́бленным, быть приспоса́бливаемым *к чему-л., для чего-л.*, дать возмо́жность освои́ться *с чем-л.*, приобрести́ на́выки, уме́ния и примени́ть их *где-л.* (*к новой работе, жизни, окружающей среде*)

муафыйклашу *неперех.* приспоса́бливаться/приспосо́биться, применя́ться/примени́ться; приноровиться; освои́вшись *с чем-л.*, приобрести́ на́выки, уме́ния, примени́ться *к чему-л.* || приспоса́бливание (*к жизни, новой работе*); *мохитка ~* приспоса́бливаться/приспосо́биться к окружа́ющей среде́

муафыйклы|к *сущ.* **1.** соответствие **2.** целесообра́зность; *үткәрелгән чараның ~гы* целесообра́зность проведённого мероприя́тия; *яшьләрнең бер-беренә ~гы* соответствие молоды́х друг дру́гу □ **законга ~к** соответствие зако́ну; **максатка ~к** целесообра́зность

муаффәкыять *сущ. уст. книжн.* **1.**успе́х, уда́ча; достиже́ние; *алар бу ~ләргә ничек ирештеләр?* как они́ дости́гли таки́х успе́хов? **2.** превосхо́дство, преиму́щество, привиле́гия; *башка кешеләр аңламый торган телдә зур китаплар укуым бик зур ~ исәпләнә иде* то, что я чита́л кни́ги на непоня́тном для други́х языке́, счита́лось больши́м преиму́ществом □ **~ белән 1.** успе́шно, уда́чно **2.** с превосхо́дством

муел *сущ диал.* черёмуха || черёмуховый; *~ларда җырлый сандугач* в черёмухе поёт соловей́; *~ куагы* черёмуховый куст

муен *сущ.* **1.** ше́я || ше́йный; *озын ~* дли́нная ше́я; *кыска ~* коро́ткая ше́я; *коляшта янган ~* загоре́лая ше́я; *колын ~ы* ше́я жеребёнка; *~ умырткалары* ше́йные позвонки́; *~ нервы* ше́йные не́рвы **2.** го́рло, го́рлышко (*бутылки, кувшина и т. п.*) **3.** *с.-х.* ше́йка (*место прикрепления косы с помощью кольца к косовищу*); *чалгының ~ын яңа божра белән ныгыту* закрепи́ть ше́йку косы́ но́вым кольцо́м **4.** *геогр.* переше́ек; *авыл күл белән бугаз арасындагы ~га урнашкан* село́ расположено на перешейке ме́жду о́зером и проли́вом **5.** *в ф. исх.* **муеннан** 1) по го́рло, до го́рла; *елганың суы ~нан* вода́ в реке́ до го́рла (по го́рло); *~нан суда тору* стоя́ть по го́рло в воде́ 2) *перен.* о́чень мно́го, по го́рло, нава́лом; *эш ~нан* рабо́ты по го́рло; *бьел бәрәңге, яшелчә ~нан* в э́том году́ карто́феля, овоще́й нава́лом ◊ **~ белән күтәрү** быть в ответе *за что-л.*; отве́тить (отвеча́ть) голово́й; *кулың белән эш кылгансың, ~ың белән күтәр* (*посл.*) сде́лал рука́ми де́ло, отве́тишь голово́й; **~ тамыры бүртү (кабару)** серди́ться, рассерди́ться, зли́ться, гне́ваться; **(гаепне) ~га алу** взять вину́ на себя́, признава́ть вину́, осознава́ть вину́; **~га асылыну (асылу, сарылу) 1.** броса́ться *к кому-л.* с ла́сками, обнима́ть за ше́ю *кого-л.* **2.** уси́ленно добива́ться расположе́ния, любви́ *кого-л.* **3.** быть *кому-л.* обу́зой (бре́менем, в тя́гость); надоеда́ть; **~га бау (җеп, элмәк) салу** (*букв. накинуть петлю на шею*) **1.** пове́ситься, удави́ться **2.** созда́ть для себя́ и́ли для *кого-л.* тяжёлое, безвы́ходное положе́ние; **~га бау (җеп, элмәк) салырлык** хоть в петлю́ лезь (*о тяжёлом, безвыходном положении*); **~га камыт кию** наде́ть на себя́ хому́т (ярмо́); впря́чься в непоси́льную, тяжёлую рабо́ту; *өйләнгәч тә, ~га камыт киясең* как же́нишься, так и наде́нешь на себя́ хому́т; **~га менеп атлану** (*букв. сесть на шею кому-л.*) **1.** стать *чьим-л.* иждиве́нцем, обременя́я *кого-л.* **2.** госпо́дствовать, главе́нствовать *над кем-л.*; **~га тагылган таш кебек** как ка́мень на ше́е (*быть обузой, бременем, в тягость кому-л.*); **~га тагылу** *см.* **муенга менеп атлану**; **~нан ашу** сли́шком мно́го, чересчу́р мно́го; **~нан бурычка бату** быть по́ уши в долга́х; **~нан чуму** быть постоя́нно в дела́х, забо́тах и т. п.; **~ны кисү** *о ком-л., чём-л.* досажда́ющем, меша́ющем; *синең ялганың минем ~ны кисә* твоя́ ложь меня́ ре́жет; **~ы булса, камыты табылыр** (*погов.*) была́ бы ше́я, хому́т найдётся; **~ы сынсын (сынгыры), ~ы астына килсен (килгере)** *бран. прост.* пропади́ про́падом; что́бы тебе́ пу́сто бы́ло; что́бы ты сверну́л (слома́л, свихну́л) ше́ю; **~ы сыну** приложи́ть мно́го труда́, уси́лий и не спра́виться *с чем-л.*; не доби́ться це́ли, потерпе́ть неуда́чу, поги́бнуть; подо́хнуть; *тиздән дошманның ~ы сыначак* ско́ро враг себе́ ше́ю слома́ет; **~ын бору 1.** искале́чить; погуби́ть *кого-л.*; задуши́ть **2.** наказа́ть, порица́ть, отчи́тывать/отчита́ть; **илнең эше ир кулында, ирнең эше ил ~ында** (*посл.*) судьба́ наро́да в рука́х мужчи́н, судьба́ мужчи́н в рука́х наро́да

муенлы *прил.* **1.** с ше́йкой; *~ комган* кумга́н с ше́йкой **2.** с определённого ка́чества ше́ей; *калын ~* толстоше́ий; *нечкә ~* тонкоше́ий □ **тар ~ чүлмәк** кри́нка

муенса *сущ.* **1.** бу́сы, колье́; ожере́лье; *кызыл ~* кра́сные бу́сы; *бриллиант ~* бриллиа́нтовое ожере́лье **2.** *разг.* оше́йник; *эт ~сы* оше́йник соба́ки

муенсалы *прил.* **1.** с ожере́льем **2.** *разг.* с оше́йником (*собака*)

муенсыз *прил. разг.* бесхара́ктерный, бесхребе́тный, беспринци́пный, слабохара́ктерный; *~ ир — ир түгел* бесхара́ктерный мужчина́ — э́то не мужчи́на □ **~ калу** заболева́ние ше́и, ше́йных мышц (*от простуды*)

муентык *сущ. в разн. знач.* ше́йка; суже́ние, су́женное ме́сто *чего-л.*; *шешә ~гы* ше́йка буты́лки

муенча|к *сущ.* **1.** оше́йник; *сары ~клы эт* соба́ка с жёлтым оше́йником; *бозауның ~гы чишелгән* у телёнка развяза́лся оше́йник **2.** *перен. о смерти через повешение:* пе́тля; *сатлык җаннарның язмышы һәркайчан йә ~к, йә пуля белән тәмамлана* судьба́ преда́телей всегда́ завершается и́ли петлёй, и́ли пу́лей ◊ **~к кию** ве́шать себе́ на ше́ю хому́т, обременя́ть себя́ *чем-л.*; созда́ть для себя́ тяжёлое, безвы́ходное положе́ние; *өйләну — ~к кию белән бер* жени́тьба — э́то зна́чит ве́шать себе́ на ше́ю хому́т; **~к салу 1.** наде́ть (наки́нуть) пе́тлю *кому-л.*, ве́шать, пове́сить; казни́ть че́рез пове́шение **2.** принужда́ть, вынужда́ть; принево́ливать/принево́лить; нево́лить; заставля́ть/заста́вить; принужде́ние, принево́ливание; *~к салып эшләтү* заставля́ть/

заста́вить рабо́тать **3.** обу́здывать/обузда́ть, укроща́ть/укроти́ть; *хулиганнарга ~к салу* обузда́ть хулига́нов

муенчакл|ау *перех.* **1.** 1) наде́ть, наки́нуть, привяза́ть оше́йник; *этне ~ау* наде́ть оше́йник на соба́ку; *бозауны ~ау* привяза́ть телёнка 2) *в знач. нареч.* **муенчаклап** с оше́йником (на шее); *кэҗәне ~ап калдырганнар* козу́ оста́вили с оше́йником (привяза́ли за оше́йник) **2.** *перен.* казни́ть че́рез пове́шение, пове́сить; *сатлык җаннарны ~адылар* преда́телей пове́сили **3.** *перен.* принужда́ть, вынужда́ть, принево́лить, невóлить, заставля́ть/заста́вить || принужде́ние, приневóливание; *олы кешене ~ап булмый инде* взро́слого челове́ка нельзя́ приневóлить **4.** *перен.* обу́здывать/обузда́ть, укроща́ть/укроти́ть || обу́здывание, укроще́ние; *хулиганнарны ~арга вакыт* пора́ обузда́ть хулига́нов

мужик *сущ. уст.* **1.** *разг.* мужи́к, крестья́нин || мужи́цкий, мужи́чий; *кук күкрәмәсә, ~ укынмый (погов.)* пока́ гром не гря́нет, мужи́к не перекре́стится; *~ балалары* мужи́цкие де́ти; *~ кызы* мужи́цкая дочь **2.** *прост. уст. бран.* о гру́бом, неве́жественном челове́ке

муз- *первая часть сложных слов* муз-, *соответствующая по значению слову* музыка́льный; *музкомедия* музкоме́дия; *музтүгәрәк* музкружо́к

му́за *сущ. в разн. знач.* **1.** му́за (*одна из девяти богинь — покровительниц наук и искусств в греческой мифологии*) **2.** *перен.* му́за *поэт.* (*творческое вдохновение, источник творчества*) || *книжн.* тво́рчество поэ́та, поэ́зия, пе́сня

музе|й *сущ.* музе́й || музе́йный; *тарих ~е* истори́ческий музе́й; *сынлы сәнгать ~е* музе́й изобрази́тельных иску́сств; *Тукай ~е* музе́й Тука́я; *зоология ~е* зоологи́ческий музе́й; *~й заллары* музе́йные за́лы; *~й экспонантлары* музе́йные экспона́ты □ **~й белгече** музеве́д; **~й белеме 1.** музееве́дение **2.** музееве́дный, музееве́дческий; **~й белеме бүлеге** музееве́дческое отделе́ние ◊ **~йда гына очрый торган** музе́йная ре́дкость

музейчы *сущ.* музеевéд, специали́ст по музееве́дению; сотру́дник музе́я; *~ булу* быть музеевéдом; *~ булып эшләү* рабóтать в музе́е, быть сотру́дником музе́я

му́зыка *сущ.* **1.** *в разн. знач.* му́зыка || музыка́льный; *вокаль ~* вока́льная му́зыка; *~ тарихы* исто́рия му́зыки; *Чайковский ~сы* му́зыка Чайко́вского; *~ мәктәбе* музыка́льная шко́ла; *~ кичәсе* музыка́льный ве́чер; ве́чер, посвящённый му́зыке; *~ коралы* музыка́льный инструме́нт **2.** *перен.* му́зыка (*гармоническое, приятное для слуха, мелодическое звучание чего-л.*); *сөйләм ~сы* му́зыка ре́чи; *шигырь ~сы* му́зыка стиха́; *урман ~сы* лесна́я му́зыка □ **~ белгече** музыковéд; **~ белеме** музыковéдение; **~ остасы** музыка́нт; **~га салу 1.** положи́ть на му́зыку; писа́ть му́зыку на слова́, стихи́, пье́су **2.** *в знач. нареч.* **~га салып** музыка́льно, в зву́ках, сре́дствами му́зыки; **~га сәләтле** музыка́льный, спосóбный к му́зыке

му́зыкалаштыру *перех.* **1.** класть, положи́ть на му́зыку; сде́лать музыка́льным; писа́ть му́зыку на слова́, стихи́; *поэманы ~* писа́ть му́зыку к поэ́ме; поэ́му сде́лать музыка́льной **2.** сде́лать с му́зыкой, внести́ (вноси́ть) му́зыку (мело́дии, пе́сни); *драманы ~* внести́ му́зыку в дра́му

му́зыкалы *прил.* **1.** музыка́льный, с му́зыкой; *~ һәм җырлы драма* мелодра́ма; музыка́льная дра́ма **2.** музыка́льный, мелоди́чный (*о голосе*); *матур, ~ тавыш* краси́вый, мелоди́чный го́лос **3.** музыка́льный, с встро́енным инструме́нтом, воспроизводя́щим *какую-л.* му́зыку, мело́дию; *~ сәгать* музыка́льные часы́; *Кремльнең ~ сәгате* музыка́льные часы́ Кремля́

музыкаль *прил.* **1.** музыка́льный, выража́емый сре́дствами му́зыки; *~ аккомпанемент* музыка́льное сопровожде́ние **2.** спосóбный к му́зыке, то́нко понима́ющий её, музыка́льный; *~ бала* музыка́льный ребёнок; *бик ~ кеше* о́чень музыка́льный челове́к **3.** музыка́льный, благозву́чный, мелоди́чный; прия́тный для слу́ха; *~ тавышлы кыз* де́вушка с мелоди́чным го́лосом **4.** сопровожда́емый му́зыкой, музыка́льный; *~ комедия* музыка́льная коме́дия; опере́тта

музыкальле|к *сущ.* **1.** музыка́льность, спосóбность к му́зыке, к понима́нию му́зыки; *студентның ~ге* музыка́льность студе́нта **2.** мелоди́чность, благозву́чность, музыка́льность; *Такташ әсәрләренең ~ге* мелоди́чность (музыка́льность) произведе́ний Такта́ша

музыкант *сущ. в разн. знач.* музыка́нт || музыка́нтский; *ул — ~* он — музыка́нт; *~ бүлмәсе* музыка́нтская ко́мната, *мн.* **музыкантлар** музыка́нтский, состоя́щий из музыка́нтов; *~лар командасы* музыка́нтская кома́нда, вое́нный орке́стр

му́зыкачы *сущ.* **1.** музыка́нт **2.** знато́к му́зыки; специали́ст по му́зыке; *~лар семинары* семина́р музыка́нтов; *~лар очрашуы* встре́ча музыка́нтов

муйнак *сущ.* соба́чка, собачо́нка, кутёнок; *муенчаклый алмассың, алар ~ түгел* их не приневóлишь, э́то не соба́чки

муксун *сущ. зоол.* муксу́н (*рыба семейства лососевых*)

мукшы *сущ.* мокша́нин, *мн.* мокша́не; мо́кша *собир.* || мокша́нский; *~ хатыны (кызы)* мокша́нка; *~ халкы* мокша́нский наро́д, мо́кша, мокша́не; *~лар горефгадәте* мокша́нские обы́чаи; *~ бию* мокша́нский та́нец

мукшыла́рча *нареч.* по-мокша́нски, как мо́кша, как мокша́не; как у мо́кши, как у мокша́н; *~ киену* одева́ться как мо́кша (как мокша́не, по-мокша́нски)

мукшы́ча *нареч.* по-мокша́нски, на языке́ мо́кша; *~ сүз башлау* заговори́ть по-мокша́нски, на языке́ мо́кша; *~ язу* писа́ть на языке́ мо́кша, писа́ть по-мокша́нски || *прил.* мокша́нский, как у мо́кши, как у мокша́н; *~ радиотапшырулар* радиопереда́чи по-мокша́нски (на мокша́нском языке́)

мукшы́чалап *нареч. разг. см.* **мукшычалатып**

мукшы́чалатып *нареч. разг.* **1.** по-мокша́нски, как мо́кша, мокша́не; как у мо́кши, мокша́н; *~ киену* одева́ться по-мокша́нски; *күлмәкне ~ тегә башлау* шить пла́тье как мокша́не (как мо́кша, как у мо́кши, по-мокша́нски) **2.** по-мокша́нски, на языке́ мо́кша, мокша́н; *~ сүз башлау* заговори́ть на языке́ мо́кша (мокша́н); *~ гәп сату* перегова́риваться по-мокша́нски

мул I *сущ. с.-х.* мул (*домашнее животное, помесь осла с кобылой*)

мул II *прил.* **1.** 1) оби́льный, изоби́льный, бога́тый; приво́льный; *мул уңыш* бога́тый (оби́льный, изоби́льный) урожа́й; *мул акча алу* получа́ть/получи́ть больши́е де́ньги; *мул сый* оби́льное угоще́ние; *мул тормыш* зажи́точное, приво́льное житьё; *мул тормышта тору* жить зажи́точной жи́знью; жить зажи́точно; *мул тормышлы* зажи́точный челове́к **2.** бога́тый, урожа́йный; благода́тный; *мул җәй* урожа́йное ле́то; *мул ел* бога́тый (урожа́йный) год; *мул җирләр* бога́тые (благода́тные) зе́мли, края́ **3.** *разг.* большо́й, свобо́дный, широ́кий

(*размер*); *мул плащ* свобо́дный (большо́й, широ́кий) плащ; *артык мул халат* сли́шком свобо́дный хала́т || *нареч.* **1.** бога́то, в доста́тке; *мул яшәү* жить в доста́тке **2.** оби́льно, в изоби́лии; *ашамлык мул әзерләнде* еду́ пригото́вили оби́льно **3.** свобо́дно, широко́; *күлмәк мул тегелгән* пла́тье сши́то свобо́дно; *костюм бераз мул тора* костю́м широкова́т ◊ **мулдан булу** **1.** рассчи́тывать на бо́льшее, предполага́ть, полага́ть, счита́ть возмо́жным *что-л.*, наде́яться на осуществле́ние *чего-л.* бо́льшего, зага́дывать по-кру́пному, не мелочи́ться; *алдагысын кем белсен, өметләнгәндә мулдан буласың* никто́ не зна́ет, что ждёт впереди́, но всегда́ рассчи́тываешь (наде́ешься) на бо́льшее **2.** тра́тить неэконо́мно, разбаза́ривать, растранжи́ривать **3.** раздава́ть/раздать; дава́ть/дать други́м, не жале́я, не соблюда́я чу́вства ме́ры; *ул нәрсә сорасалар да бирде, мулдан булды* что бы у него́ ни проси́ли, он всё раздава́л; **мулдан кылану (кубару, ычкындыру)** де́лать всё так, что́бы обрати́ть внима́ние на своё бога́тство, де́лать напока́з; переба́рщивать/переборщи́ть, перехва́тывать/перехвати́ть, не соблюда́ть чу́вства ме́ры, проявля́ть неуме́ренность *в чём-л.*; **мулы белән** с избы́тком, сверх поло́женного; бо́лее, чем ну́жно; *күлмәккә өч метр материя мулы белән җитә* на пла́тье три ме́тра мате́рии да́же с избы́тком

мулат *сущ.* мула́т, мула́тка (*потомок от смешанного брака белых и негров*); *тән төсе белән ~ка охшаган булу* по цве́ту ко́жи быть похо́жим на мула́та; *~ хатын-кызы* мула́тка

мула|ю *неперех. разг.* **1.** быть, станови́ться/стать оби́льным, изоби́льным, бога́че, приво́льней; станови́ться/стать бо́льше; *эш хакы ~йды* за́работная пла́та ста́ла бо́льше; *тормыш ~йды* жизнь ста́ла бога́че, изоби́льней **2.** станови́ться/стать бо́льше, ши́ре, свобо́днее (*размером*); *авырганнан соң чалбар ~йды* по́сле боле́зни брю́ки ста́ли свобо́днее

мулине, мулинә *сущ.* мулине́; *~ белән яулык чигәм* вышива́ю плато́к с мулине́

мулла *сущ.* **1.** *рел.* мулла́; *яшь ~* молодо́й мулла́; *~ малае* сын муллы́; *Хафиз ~* мулла́ Хафи́з **2.** *в препозиции к имени собст.*: старшеку́рсник имяре́к (*в медресе*); *~ Кәрим* старшеку́рсник Кари́м **3.** *перен.* гра́мотный, учёный, образо́ванный, всезна́ющий челове́к; *укып ~ булмассың (погов.)* ско́лько ни учи́сь, всё равно́ не ста́нешь учёным; *син дә ~, мин дә ~, атка печән кем сала (погов.)* мы о́ба образо́ванные, кто же зада́ст корм лошади́м ◊ **~ булырсың** (*погов.*) *ирон.* бу́дешь мулло́й; **~ икәнсең!** како́й ты у́мный!

муллабикә *сущ.* жена́ муллы́; *см. тж.* **остабикә**

муллакә *сущ. уст.* **1.** уча́щийся медресе́ (*преимущ. о старшекурснике*) **2.** сын муллы́

муллала́рча *нареч.* как му́лла; *үзеңне ~ тоту* вести́ себя́ как мулла́

муллалык *сущ.* до́лжность, обя́занности муллы́; *~ка урын юк* на до́лжность муллы́ нет вака́нсии; *~ны алып бару* исполня́ть обя́занности муллы́; *~ка уку* учи́ться на муллу́ □ **~ итү** быть мулло́й, справля́ть до́лжность муллы́

муллану *неперех. редко см.* **мулаю** 2; расхо́довать, не счита́ясь с затра́тами

мулла-мунтагай *сущ. пренебр. собир.* название *служителей культа*; му́ллы и тому́ подо́бные

муллык *сущ.* изоби́лие, оби́лие, бога́тство; доста́ток, дово́льство || ро́скошь, пы́шность; *~та яшәү* жить в доста́тке; *язгы яңгыр — көзге ~ (посл.)* весе́нний дождь — осе́ннее изоби́лие (бога́тство, дово́льство); *өй җиһазларының ~ аңкый* от дома́шней обстано́вки ве́ет ро́скошью

мул-мул *прил.* оби́льный || *нареч.* ка́ждый раз в изоби́лии, в доста́точном коли́честве; *мул-мул уңыш җыйдык* собира́ли оби́льный урожа́й

мулчылык *сущ.* **1.** *см.* **муллык** 2. ще́дрость, тарова́тость; разма́х по-широ́кому

мультипликацион *прил. спец.* **1.** мультипликацио́нный, относя́щийся к мультипликáции; *~ станок* мультипликацио́нный стано́к; *~ съёмкалар* мультипликацио́нные съёмки **2.** мультипликацио́нный, рисо́ванный; *~ кадрлар* мультипликацио́нные ка́дры; *~ фильм* мультипликацио́нный фильм; мультфи́льм

мультипликáция *сущ. спец.* **1.** мультипликáция || мультипликацио́нный; *~ методы белән документаль фильмнар төшерү* снять документа́льные фи́льмы ме́тодом мультипликáции **2.** мультипликáция, мультфи́льм, мультипликацио́нный фильм; *~ ярату* люби́ть мультипликáцию (мультфи́льмы); *~ хәзерләү* изготовля́ть мультипликáции

мультфильм *сущ.* мультипликацио́нный фильм

му́льча *сущ. спец.* му́льча (*материал для мульчирования почвы*); *тупәлне ~ белән каплау* покры́ть гря́дку му́льчей; мульчи́ровать гря́дку

мульчирлан|у *страд. от* **мульчирлау** **1.** мульчи́роваться; *көзен җиләкнең ~уы мәҗбури* о́сенью я́годы обяза́тельно должны́ быть мульчи́рованы (мульчи́рование я́год о́сенью обяза́тельно) **2.** *в знач. прил.* **мульчирланган** мульчи́рованный; **~ган чәчүлекләр** мульчи́рованные посе́вы

мульчирла́у *перех. спец.* мульчи́ровать || мульчи́рование; *уҗым бодаен ~* мульчи́ровать зи́мую пшени́цу; *чәчүлекне торф белән ~* мульчи́рование посе́вов то́рфом; *~ турында сөйләшү* бесе́да о мульчи́ровании

мум *сущ. уст.* воск, вощи́на || восково́й; *бал корты мумы* пчели́ный воск; *ясалма мум* иску́сственный воск; *мум чәм* восковáя свеча́; *мум фигуркалар* восковы́е фигу́рки

мумиё *сущ.* мумиё

мумифика́ция *сущ. спец. в разн. знач.* мумифика́ция; *~ ысуллары* спо́собы мумифика́ции; *мәетләрнең табигый рәвештә ~се* есте́ственная мумифика́ция тру́пов

мумифика́циялә|ү *перех. спец.* мумифици́ровать; бальзами́ровать || мумифика́ция; *мисыр фирғавеннәренең ~нган мәетләре* мумифици́рованные тру́пы еги́петских фарао́нов

мумифика́циялән|ү *неперех. спец. в разн. знач.* мумифици́роваться; *табигый тоз эретмәсендә кеше мәетләре ~ә* в приро́дном раство́ре соле́й челове́ческий труп мумифици́руется; *изге хайваннарның үле гәүдәләре ~гәннәр* тру́пы свяще́нных живо́тных мумифици́ровались

му́мия I *сущ. в разн. знач.* му́мия (*набальзамированные останки покойника*); *мисыр ~ләре* еги́петские му́мии; *саркофагтагы ~не карау* смотре́ть му́мию в саркофа́ге ◊ **~гә әйләнү** мумифици́роваться || мумифика́ция; *~гә әйләнгән мәет* труп, превати́вшийся в му́мию

му́мия II *сущ.* му́мия (*минеральная краска от светло-красного до красновато-коричневого цвета*); *~ белән буяу* покра́сить му́мией; *~ суда, бензинда, спиртта тиз эри* му́мия бы́стро растворя́ется в воде́, бензи́не, спи́рте

мумл|ау *перех. уст.* покры́ть во́ском; *су үтмәсен вчен мичкәне ~ыйлар* для того́, что́бы не протека́ла, бо́чку покрыва́ют во́ском

мундир *сущ.* мунди́р || мунди́рный; *~ чистарту* чи́стить мунди́р; *~ салу* сня́ть мунди́р; *офицер ~ы* офице́рский мунди́р; *~ төймәләре* мунди́рные пу́говицы

мундирлы *прил.* **1.** в мунди́ре; *~ егет* па́рень в мунди́ре **2.** *разг.* мунди́рный; *~ һәм мундирсыз кешеләр* лю́ди в мунди́рах и без мунди́ров ◊ **~ бәрәңге** *разг.* карто́шка в мунди́ре (*картофель варёный или печёный в кожуре*)

муниципал *сущ.* муниципа́л (член муниципа́льного сове́та)

муниципализа́ция *сущ.* муниципализа́ция; *~ ясау (үткәрү)* муниципализи́ровать

муниципализа́цияләү *перех.* муниципализи́ровать || муниципализа́ция

муниципализа́цияләнү *1. страд. от* **муниципализацияләү**; муниципализи́роваться **2.** *в знач. прил.* **муниципализацияләнгән** муниципализи́рованный

муниципалитет *сущ.* муниципалите́т (*орган местного самоуправления в некоторых странах*) || муниципа́льный; *шәһәр ~ы* городско́й муниципалите́т; *~ йорты* муниципа́льный дом

муниципаль *прил.* муниципа́льный (*орган*)

муниципальләштерелү *страд. от* **муниципальләштерү**; муниципализи́роваться || муниципализа́ция

муниципальләштерү *перех.* муниципализи́ровать || муниципализа́ция

муниципальләшү *неперех.* муниципализи́роваться || муниципализа́ция

мунча *сущ. в разн. знач.* ба́ня || ба́нный; *коммуналь (җәмәгать) ~сы* коммуна́льная ба́ня; *ак ~* бе́лая ба́ня (*с дымоходом*); *кара ~* курна́я (чёрная) ба́ня; *~ алды (чоланы)* предба́нник; *~ көне* ба́нный день; *~ сабыны* ба́нное мы́ло; *~ себеркесе* ба́нный ве́ник □ **~ хезмәтчесе** ба́нщик ◊ **~ кебек 1.** о́чень жа́рко, как в ба́не (*в комнате, в помещении*) **2.** о́чень ма́ленький, сли́шком ма́ленький; **~ кергән шикелле** как из ба́ни; **~ кертү** зада́ть ба́ню *кому-л.*, сде́лать вы́говор *кому-л.*, наказа́ть *кого-л.*; **~ керү 1.** мы́ться в ба́не **2.** получи́ть стро́гий вы́говор, быть нака́занным, подверга́ться кри́тике, критикова́ться; **~ тараканы** *пренебр.* ба́нный тарака́н (*о человеке*); **~ ташы (кебек шома)** *об очень хитром, смекалистом, шустром и хватком человеке;* **~ фәрештәсе (пәрие)** ба́нный а́нгел (чёрт) (*пренебрежительное выражение о безобразной, некрасивой, неприглядной, несимпатичной женщине*); **~да чабыну** па́риться в ба́не; **~да себерке хуҗа** (*погов.*) гла́вное в ба́не — хоро́ший ве́ник (*букв.* в ба́не ве́ник господи́н); **иске ~, иске таш** (*погов.*) всё без измене́ний

мунчак *сущ. разг. см.* **муенчак 1**; *бер үгезгә бер юкә ~ житәр* (*погов.*) одному́ быку́ доста́точно одного́ оше́йника

мунчала *сущ.* **1.** моча́ло, моча́лка || моча́льный; *~дан бау ишү* вить верёвку из моча́ла; *~ белән капчык бәйләү* повяза́ть моча́лкой мешо́к; *~ цехы* моча́льное произво́дство **2.** моча́лка (*пучок мочал или каких-л. других волокон для мытья, стирания грязи*) || моча́льный (*сделанный из мочала*); *диңгез үләненнән ясалган ~* моча́лка из морско́й травы́; *арканы ~ белән ышку* тере́ть спи́ну моча́лкой; *~ щетка* моча́льная щётка **3.** полова́я тря́пка **4.** *перен. прост.* безво́льный челове́к, тря́пка || *прил.* **1.** моча́льный; *~ бау* моча́льная верёвка **2.** *перен.* моча́листый; *~ чәч* моча́листые во́лосы ◊ **~ булып уралу** меша́ть, помеша́ть, тормози́ть, препя́тствовать, преграждать *кому, что-л.*; **~ кашыгы ясау** скандали́ть, поскандали́ть; устра́ивать/устро́ить перепло́х; будора́жить, взбудора́жить; **~ кебек булу** быть изно́шенным до преде́ла; измоча́литься, измоча́ливаться; **~ төшеру (сую, каезлау)** драть волокно́ из лубяно́го сло́я коры́ путём вымачивания; драть лы́ко; **~ чәйнәү** жева́ть моча́лку (*говорить нудно, бестолково, об одном и том же; долго и нудно обсуждать одно и то же*)

мунчалаландыр|у *понуд. от* **мунчалану 1.** раздира́ть на воло́кна, на моча́ло; моча́лить, превраща́ть/превратить/превращать в моча́ло; *юкә кайрысын ~у (мунчала чыгару)* моча́лить лы́ко **2.** *разг.* измоча́ливать/ измоча́лить, истрепа́ть, сде́лать похо́жим на моча́ло; *яхшы гына бауны ~ганнар* хоро́шую верёвку совсе́м измоча́лили **3.** *перен.* приводи́ть/ привести́ в беспоря́док, ха́ос, измоча́лить; *юган керләрне ~у* измоча́лить сти́раное бельё **4.** *перен. разг.* моча́лить, му́чить, терза́ть; *тормыш аны да ~ды* и его́ жизнь измоча́лила

мунчалалан|у *неперех.* **1.** образова́ться (*о мочале в лубяном слое липовой коры*) **2.** превраща́ться/преврати́ться в моча́ло; измоча́ливаться/измоча́литься, истрепа́ться, стать похо́жим на моча́ло; *бау ~ган* верёвка совсе́м измоча́лилась **3.** *перен.* приходи́ть/прийти́ в беспоря́дочное, хаоти́ческое состоя́ние (*о вещах*); измоча́литься

мунчалалату *перех. см.* **мунчалаландыру**

мунчалалау *перех.* измоча́ливать/измоча́лить, истрепа́ть, сде́лать похо́жим на моча́ло

мунчачы *сущ.* ба́нщик; ба́нщица; *~ булып эшләү* рабо́тать ба́нщиком; *~ вазифасы* обя́занности ба́нщика; *~ хатын* ба́нщица

мур *сущ. прост.* эпиде́мия, мор, холе́ра; *чума муры* эпиде́мия чумы́; *мурдан үлү* умере́ть от холе́ры ◊ **мур кыргыры!** мор на вас! (*бранное выражение, употребляемое в сильном гневе, возмущении*); **мур кыру** коси́ть, губи́ть, погуби́ть мно́жество жи́зней (*об эпидемии*); *терлекне мур кырган* мор вы́косил скот

мурал *сущ. бот.* рододендро́н

му́рда *сущ. разг.* мо́рда, ве́рша (*рыболовная снасть*)

мурт *прил.* **1.** прогни́вший (*о дереве и мехе*) **2.** дря́блый, ры́хлый, трухля́вый, непло́тный, мя́гкий (*о дереве*); *зирек утыны ~ була* дрова́ из ольхи́ быва́ют не пло́тные **3.** *перен.* дря́хлый

мурта *сущ. диал.* **1.** *см.* **умарта 2.** пчела́

муртайту *понуд. от* **муртаю**

муртлану *диал. см.* **муртаю**

муртаю *неперех.* **1.** прогнива́ть/прогни́ть, подгнива́ть/подгни́ть **2.** станови́ться/стать ве́тхим, дря́блым, ры́хлым, трухля́вым, мя́гким; ветша́ть, обветша́ть, трухля́веть **3.** *перен.* дряхле́ть

муртылу *неперех.* не́сколько подгнива́ть/подгни́ть

мускат *сущ. в разн. знач.* **1.** муска́т (*ароматические семена из тропической Азии*) **2.** муска́т (*сорт винограда, а также вино из этого винограда*) || муска́тный; *ак ~* бе́лый муска́т; *алсу ~* ро́зовый муска́т; *~ исе* муска́тный за́пах; *~ төсе* муска́тный цвет; *~ мае* муска́тное ма́сло □ **~ агачы** муска́тник, муска́тное де́рево; **~ чикләвеге** муска́тный оре́х, муска́т, муска́тное се́мя

муска́тник *сущ.* муска́тник (*тропическое вечнозелёное дерево с мясистыми жёлтыми плодами, содержащими семя — мускатный орех*)

му́скул *сущ. анат.* **1.** му́скул, му́скулы, мы́шца; *муен ~лары* ще́йные му́скулы; *йөрәк ~лары* серде́чные мы́шцы **2.** му́скульный, мы́шечный; *~ тукымалары* му́скульные (мы́шечные) тка́ни; *~ үсентесе* (*анат.*) мы́шечный отро́сток; *~ киеренкелеге* мы́шечное (му́скульное) напряже́ние

мускулату́ра *сущ. собир.* мускулату́ра, мы́шцы; *очлыклар ~сы* мускулату́ра коне́чностей

му́скуллы *прил.* му́скулистый, с ра́звитыми му́скулами; *таза ~ куллар* му́скулистые ру́ки

му́скус *сущ.* му́скус (*остро пахнущее вещество, вырабатываемое железами самца кабарги и некоторых других животных*) || му́скусный; *~ исе* за́пах му́скуса, му́скусный за́пах

муслин *сущ. спец. текст.* муслин || муслино́вый; *~ тукыма* муслино́вая ткань; *~ шарф* муслино́вый шарф; *~ күлмәк* муслино́вое пла́тье

мусс *сущ. кул.* мусс; *алма ~ы* я́блочный мусс; *мүк җиләге ~ы (мүк җиләгеннән ясалган ~)* клю́квенный мусс

муссон *сущ. геогр.* муссо́н (*ветер*); *җәйге ~* ле́тний муссо́н; *кышкы ~* зи́мний муссо́н

мустанг *сущ.* муста́нг (*одичавшая лошадь в Америке*)

мут *прил. разг.* **1.** хи́трый, ло́вкий, плутова́тый || хитре́ц, ше́льма, шельме́ц, ловка́ч, плут, пройдо́ха; *мут егет* хи́трый па́рень; хитре́ц; ловка́ч; *мут кеше* ло́вкий челове́к; хитре́ц, ловка́ч, плут **2.** озорно́й, шаловли́вый, шутли́вый, шу́стрый, бо́йкий; *мут күз* озорны́е глаза́; *мут бала* озорно́й ребёнок **3.** похотли́вый; *мут караш* похотли́вый взгляд; *мут ир* похотли́вый мужчи́на; *тышы — ут, эче — мут (погов.)* в ду́шу вьётся, а в карма́н ле́зет

мута́ция *сущ. биол.* мута́ция || мутацио́нный; *~ теориясе* мутацио́нная тео́рия; *~ чоры* мутацио́нный пери́од

мутландыр|у *понуд. от* **мутлану** 1; *күзләрен ~ып карый* смо́трит похотли́выми глаза́ми

мутлан|у *перех.* **1.** станови́ться/стать хи́трым, ло́вким, плутова́тым; стать озорны́м, шаловли́вым; *хәзер ул бик ~ган* тепе́рь он стал о́чень хи́трым (ло́вким, плутова́тым) **2.** озорнича́ть, шали́ть; вести́ себя́ легкомы́сленно, несерьёзно, дура́читься; *туктагыз әле, ~магыз* переста́ньте, не озорнича́йте

мутлык *сущ.* **1.** хи́трость, плутова́тость **2.** озорство́, шаловли́вость **3.** похотли́вость; *йөзендә үк ~ күренә* да́же по лицу́ видна́ его́ похотли́вость □ **~та йөрү** озорнича́ть, шали́ть; *ул төн буе ~та йөри* он (она́) всю ночь шали́т ◊ **~ башы мулладан** похотли́вость от муллы́ (исхо́дит, начина́ется)

мутон *сущ.* мутон (*особо выделанная овчина*) || *прил.* мутоно́вый; *~ яка* воротни́к из мутона, мутоно́вый воротни́к; *~ тун* мутоно́вая шу́ба; *~ бүрек* мутоно́вая ша́пка, ша́пка из мутона

му́фель *сущ. тех.* му́фель || му́фельный; *~дан чыккан эссе һава* раскалённый во́здух от му́феля; *~ буяулары* му́фельные кра́ски

му́фельле *прил.* му́фельный; с му́фелем; *~ мич* му́фельная печь; *~ пресс* му́фельный пресс

му́фельче *сущ. тех.* му́фельщик; *гомер буе ~ булып эшләдем* всю жизнь был (рабо́тал) му́фельщиком

муфлон *сущ. зоол.* муфло́н (*дикий баран*)

му́фта I *сущ.* му́фта (*принадлежность женской одежды*); *каракуль ~* кара́кулевая му́фта; му́фта из кара́куля

му́фта II *сущ. тех.* му́фта || му́фтовый; *агач ~* деревя́нная му́фта; *~ торба* му́фтовая труба́; *~ вентиле* му́фтовый ве́нтиль

му́шка *сущ. воен.* му́шка □ **~га алу** брать (взять) на му́шку, прице́ливаться *в кого-л., что-л.*; *дошман солдатын ~га алу* взять, посади́ть на му́шку вра́жеского солда́та, прице́ливаться/прице́литься во вра́жеского солда́та

мушкет *сущ. ист.* мушке́т || мушке́тный; *~танату* вы́стрелить из мушке́та, мушке́тный вы́стрел; *~дарысы* мушке́тный (предназна́ченный для мушке́та) по́рох

мушкетёр *сущ. ист.* мушкетёр || мушкетёрский; *~ мундиры* мушкетёрский мунди́р (мунди́р мушкетёра); *~лар полкы* мушкетёрский полк

мушкетчы *ист. то же, что* **мушкетёр**; солда́т, вооружённый мушке́том

муштра *сущ. в разн. знач.* муштра́; *солдат ~сы* солда́тская муштра́; *иске мәктәп ~ мәктәбе иде* ста́рая шко́ла была́ шко́лой муштры́

мүкәләп *нареч.* на четвере́ньках (кара́чках); *~ йөрү* ходи́ть (ползти́) на четвере́ньках

мүкәләү *неперех.* ходи́ть (идти́ ползти́, тащи́ться) на четвере́ньках

мүкелдәтү *перех. прост.* есть с аппети́том

мүкләгеч *сущ. спец.* конопа́тка

мүкләк *прил.* **1.** комо́лый, безро́гий; *~ тана* комо́лая тёлка; *~ кәҗә* безро́гая коза́ **2.** *перен.* 1) проны́рливый (*о человеке*) 2) *в знач. сущ.* проны́ра (*о человеке*) **3.** *перен.* 1) тихо́ня; бесхара́ктерный (слабово́льный) мужчи́на ◊ **~ сыер 1.** комо́лая корова **2.** *перен.* проны́ра, проны́рливый челове́к

мүкләнү 1. *страд. от* **мүкләү**; конопа́титься **2.** обомше́ть, обрасти́ мхом; *йөргән таш шомара, яткан таш ~ә* (*посл.*) под лежа́чий ка́мень вода́ не течёт (*букв.* без движе́ния и ка́мень мхом обрастает)

мүкләү *перех.* конопа́тить, законопа́тить, набива́ть (затыка́ть) мхом, па́клей

мүкләүче *сущ.* конопа́тчик

мүкле *прил.* мша́ный, мши́стый; *~ сазлык* мши́стое боло́то; *~ таш* мши́стый ка́мень

мүксыманнар *сущ. биол.* мохообра́зные; *~ семьялыгы* семе́йство мохообра́зных

мүчкәй *сущ. диал.* мо́ська, мопс

мыгырдавык *прил. см.* **мыгырдык**; *~ карт* ворчли́вый стари́к; ворчу́н, брюзга́

мыгырдан|у *возвр. от* **мыгырдау 1.** брюзжа́ть, бурча́ть, ворча́ть (*непрерывно, постоянно*); *күршем нәрсәдер ~а* сосе́д что́-то бурчи́т **2.** бормотать про себя́ □ **~ып алу** пробормота́ть, проворча́ть

мыгырдау *неперех.* **1.** ворча́ть, бурча́ть, проворча́ть, брюзжа́ть || ворча́ние, бурча́ние **2.** бормота́ть || бормота́ние; *борын астыннан гына ~* пробормота́ть под нос

мыгырдаулы *прил.* ворчли́вый, брюзгли́вый; сварли́вый; выража́ющий недово́льство; *~ тавыш* ворчли́вый (брюзгли́вый) го́лос

мыгырдаучан *прил.* **1.** ворчли́вый, брюзгли́вый, скло́нный к се́тованию (ропта́нию), сварли́вый; *ул бик ~ кеше* он о́чень ворчли́вый (брюзгли́вый, сварли́вый) челове́к; он — ворчу́н (брюзга́) **2.** говоря́щий непоня́тно, бормота́нием, бурча́нием (*о человеке*); *~ хатын* бормоту́нья

мыгырдаучанлык *сущ.* ворчли́вость, брюзгли́вость, сварли́вость

мыгырдаш|у *взаимно-совм. от* **мыгырдау**; бормота́ть, пробормота́ть, бурча́ть, ворча́ть, брюзжа́ть, ропта́ть, се́товать (*о многих*)

мыгырдык *сущ.* бормоту́н, бормоту́нья, ворчу́н, ворчу́нья; брюзга́; *нинди ~ икәнсең син!* кака́я же ты ворчу́нья, ока́зывается! || *прил.* ворчли́вый, брюзгли́вый; *~ карт* брюзгли́вый стари́к; *~ тавышлы* с ворчли́вым го́лосом

мыгыр-мыгыр *звукоподр. одновременному и нудному бормотанию, ворчанию многих; мыгыр-мыгыр сөйләшүләр ачык ишетелә* я́сно слышны́ бормота́ния

мыдырда|у *неперех.* **1.** *см.* **мыгырдау 2.** ти́хо, шёпотом говори́ть, разгова́ривать (*с кем-л. или про себя*); *өстәл артында икәүдән-икәү ~п утыралар* за столо́м вдвоём ти́хо разгова́ривают

мыдыр-мыдыр *нареч.* ти́хо, шёпотом

мые|к *сущ.* **1.** усы́, ус, у́сики *уменьш.*; *~к җиткерү (үстерү)* отра́щивать усы́; *кара ~к* чёрные усы́; *~кларны тырпайту* топо́рщить усы́ **2.** *разг.* челове́к с больши́ми уса́ми, уса́тый челове́к, уса́ч; *бер кара ~к килеп керде* зашёл челове́к с чёрными уса́ми; *теге ~кны яңадан очратмадык* того́ уса́ча (уса́того челове́ка) бо́льше не встре́тили **3.** *спец.* усы́, у́сики (*у растений, животных, насекомых*); *~к мәчедә дә бар (погов.)* усы́ и у ко́шки есть; *морж ~гы* усы́ моржа́; *кама ~гы* усы́ вы́дры; *бакча җиләге ~к белән үрчетелә* садо́вые я́годы размножа́ются у́сиками (уса́ми); *~к астыннан көлү (көлеп кую)* ухмыльну́ться, слегка́ улыбну́ться; усмехну́ться в усы́ ◊ **~к кабарту (күпертү) 1.** ворча́ть, руга́ть; разгорячи́ться, разгне́ваться; разозли́ться, рассерди́ться **2.** высокоме́рничать, чва́ниться, ва́жничать, зава́жничать, зазнава́ться/зазна́ться, задава́ться; *артык ~к кабартмыйсыңмы син?* не сли́шком ли ты чва́нишься? **~к та селкетмәү** и в ус не дуть, как с гу́ся вода́; *ул ~к та селкетми* он и в ус не ду́ет; ему́ и го́ря ма́ло; ему́ как с гу́ся вода́; **~к та чыкмаган** ещё мо́лод, зе́лен; **~к тибү** стать совершеннолетним, достичь совершенноле́тия; **~к чуалу 1.** быть (находи́ться) в плохо́м настрое́нии **2.** разла́живаться/разла́диться (*о работе, деле*); **~к чуалту** беспоко́ить, обеспоко́ить, создава́ть/созда́ть ли́шние хло́поты; **~к чыгу 1.** *см.* **мыек тибү 2.** износи́ться (*об обуви*); *~клары чыккан ботинкалар* изно́шенные боти́нки; **~кка урау (чорнау)** намота́ть себе́ на ус; закрепи́ть в па́мяти, запо́мнить

мыекбай *сущ.* уса́ч, уса́тый, челове́к с больши́ми уса́ми; *~ очрадымы?* не встре́тился уса́ч?

мыеклач *сущ.* **1.** челове́к с (больши́ми) уса́ми; уса́тый **2.** *зоол.* уса́ч (*рыба*) **3.** *зоол.* уса́ч, дровосе́к; *кара ~* чёрный уса́ч

мыеклы *прил.* име́ющий усы́, уса́тый, с уса́ми; *сары ~ йөз* лицо́ с ры́жими уса́ми; *чал ~* седоу́сый; *~ мәче* уса́тый кот ◻ **~ балык** уса́ч (*рыба*)

мыекча *сущ.* у́сики (*у земляники, огурца*)

мыекчан *прил.* уса́тый, с уса́ми, уса́ч; *безнең күрше ~* наш сосе́д — уса́тый (с уса́ми, уса́ч)

мыекчыл *сущ. зоол.* мирон (*рыба из семейства карповых*)

мыж *предик.* о́чень мно́го; кишмя́ кише́ть, так и киши́т (киша́т); *өйдә мыж таракан* в до́ме полно́ тарака́нов (дом киши́т тарака́нами) ◻ **мыж килү (килеп тору, итү, кайнау, кайнап тору) 1.** кише́ть, кишмя́ кише́ть **2.** суети́ться, сумато́шиться, копоши́ться

мыжгак *прил. диал.* **1.** дождли́вый, па́смурный, с оса́дками; *~ көз* дождли́вая о́сень **2.** ворчли́вый, брюзга́ || *сущ.* ворчу́н, ворчу́нья, брюзга́; *~ карчык* ворчли́вая стару́ха; ворчу́нья **3.** сумато́шный, суетли́вый

мыжг|у *неперех.* **1.** кише́ть, кишмя́ кише́ть; *урамнарда, мәйданнарда кешеләр ~ый* на у́лицах, площаля́х киша́т лю́ди **2.** *диал.* ворча́ть, брюзжа́ть (*постоянно, беспрестанно*); *~удан туктасаң иде* переста́л бы брюзжа́ть (ворча́ть) ◻ **~ып тору 1.** кише́ть, кишмя́ кише́ть **2.** постоя́нно ворча́ть, брюзжа́ть

мыжгык *прил. то же, что* **мыжгак**; *~ һава* па́смурная пого́да; *~карт* стари́к-брюзга́

мыжгылд|ау *неперех.* **1.** кише́ть, кишмя́ кише́ть; *тропик урманнарда еланнар ~ый* в тропи́ческих леса́х киша́т зме́и **2.** ворча́ть, брюзжа́ть; *сәбәпсез ~ау* ворча́ть без причи́ны; *көн буе ~ый* це́лыми дня́ми (це́лый день) ворчи́т (брюзжи́т) **3.** 1) жа́лобно говори́ть, расска́зывать 2) жа́лобно пла́кать; собира́ться пла́кать

мыжгылдык *прил.* **1.** ворчли́вый, брюзгли́вый || ворчу́н, брюзга́; *~ карт* ворчли́вый стари́к; стари́к-ворчу́н (брюзга́) **2.** плакси́вый || пла́кса; *~ бала* плакси́вый ребёнок; ребёнок-пла́кса

мыжгырдату *перех.* трево́жить, растрево́жить (*змей*)

мыжгырд|ау: мыжгырдап тору кишмя́ кише́ть (*о змеях, рыбах*)

мыжгыту 1. *понуд. от* **мыжгу 2.** трево́жить, растрево́жить (*насекомых*)

мыжл|ау *неперех.* **1.** кише́ть, жужжа́ть, кишмя́ кише́ть; *базар кырмыска оясы кебек ~ый* база́р киши́т, как муравейник **2.** *разг.* ворча́ть, брюзжа́ть (*надоедливо повторять, твердить что-л.*); *нигә ~ыйсың инде?* с како́й ста́ти ворчи́шь?

мыж-мыж, мыж-ж *звукоподр. жужжанию, дребезжанию* ◻ **мыж-мыж итү (килү) 1.** кише́ть, кишмя́ кише́ть **2.** жужжа́ть, производи́ть однообра́зно дребезжа́щий звук **3.** *перен. разг.* жужжа́ть, бормота́ть, надое́дливо повторя́ть, твердить *что-л.* **4.** *перен. разг.* ворча́ть, брюзжа́ть

мыжык *прил.* **1.** ворчли́вый, брюзгли́вый || ворчу́н, ворчу́нья, брюзга́; *~ күрше туры килде* попа́лся ворчли́вый сосе́д **2.** плакси́вый, капри́зный || пла́кса; *~ бала* плакси́вый ребёнок; *их, ~, кайчан мыжлаудан туктыйсың?* эх, пла́кса, когда́ же ты переста́нешь пла́кать?

мыжылд|ау *неперех.* **1.** кише́ть, кишмя́ кише́ть; *базар ~ый* база́р киши́т **2.** ворча́ть, брюзжа́ть; бормота́ть; *үзалдына ~ау* ворча́ть про себя́; бормота́ть **3.** (*долго и нудно*) пла́кать

мыҗырд|ау *неперех.* перекиса́ть/переки́снуть; броди́ть || перекиса́ние, броже́ние; *ачы бал ~авы* броже́ние бра́ги (медка́); *апара* (*камыр*) *~ый* опа́ра бро́дит

мыҗыр-мыҗыр *подр. брожению, перекисанию чего-л.*; *ачы бал мыҗыр-мыҗыр килә* медо́к бро́дит

мызз-з-з *звукоподр. жужжанию*; *~ итү* жужжа́ть

мызылд|ау *неперех.* жужжа́ть, стрекота́ть, треща́ть (*о насекомых*); *черки ~ап үтте* комар прожужжа́л; *колак төбендә бал корты ~ый* над у́хом жужжи́т пчела́

мыйк: мыйк итү 1) пища́ть, издава́ть писк 2) писк; **~ та итмәү** не изда́ть ни зву́ка, не произнести́ ни сло́ва

мыйкылдык *прил.* ту́чный; *~ тән* ту́чное те́ло

мыйкылдат|у *перех.* трясти́ при движе́нии (*тучным телом и частями тела*)

мыйкылд|ау *неперех.* трясти́сь при движе́нии || подра́гивание (*само собой — о полном, тучном теле и частях тела*); *янбашлары ~ый* трясу́тся его́ по́лные бока́ ◻ **~ап тору** о ту́чном, по́лном челове́ке

мыймылдат|у *перех.* **1.** *см.* **мыйкылдату 2.** причмо́кивать, де́лать каки́е-то движе́ния губа́ми при еде́ и́ли пе́ред приёмом пи́щи (*предвкушая*)

мыймылд|ау *неперех.* **1.** трясти́сь при движе́нии (*о полном теле и частях тела*) **2.** *о беззвучном движении губами при еде, перед приёмом пищи* □ **~ап тору** о по́лном и здоро́вом челове́ке (*обычно о женщине*)

мыймылдык *прил. разг.* **1.** ту́чный, по́лный, то́лстый, ожире́вший; *~ казлар, үрдәкләр* жи́рные гу́си, у́тки **2.** *разг. в знач. сущ. о ком-л. тучном, полном, толстом и ожиревшем* (*о человеке, животных*); пы́шка, пы́шечка (*о полной и румяной женщине*); *егет аның ~ чагын хәтерли* па́рень по́мнил её румя́ной пы́шкой

мыймыл-мыймыл: мыймыл-мыймыл итү *см.* **мыймылдау**

мыкырдау *неперех.* ворча́ть, брюзжа́ть беспреры́вно, надоеда́ть свои́м брюзжа́нием, ворчли́востью

мыкырдык *прил.* ворчли́вый, брюзгли́вый (*голос, человек*)

мылты|к *сущ.* ружьё; винто́вка || ружёйный, винто́вочный; *ау ~гы* охо́тничье ружьё; *ике көпшәле ~к* двуство́льное ружьё, двуство́лка; *~к тавышлары* винто́вочная трескотня́; *~к(тан) атышлар* ружёйные вы́стрелы; *~к патроны* винто́вочный патро́н; *~к цехы* ружёйный цех □ **~к мае** ружёйное ма́сло; **~к остасы** ружёйный ма́стер; **~к түтәсе** прикла́д ружья́; **~к ясаучы** оружёйник; **сындырмалы ~к** *разг.* центра́лка

мылтыклап *нареч.* под ружьём; *~ алып бару* вести́ под ружьём, конвои́ровать

мылтыклы *прил.* с ружьём, с ору́жием, име́ющий при себе́ ружьё, винто́вку, вооружённый || вооружённый челове́к; *~ кеше* челове́к с ружьём (с винто́вкой); вооружённый челове́к

мылтыкчы *сущ.* **1.** ружёйный охо́тник **2.** оружёйник

мынтыр *прил. диал.* то́лстый, пы́шный, пу́хлый (*преимущ. женщина*), доро́дный (*мужчина*); *~ абзый* доро́дный дя́дя

мыңгырда|у *см.* **мыгырдау**; ворча́ть, брюзжа́ть; *~выңны ташла инде* переста́нь ворча́ть, брось ворча́ть (брюзжа́ть)

мыңгырдаш|у 1. *взаимно-совм. от* **мыңгырдау 2.** сто́риться, поссо́риться; *тагын нәрсә өчен ~каннар?* из-за чего́ они́ опя́ть поссо́рились?

мыңгыр-мыңгыр *звукоподр.* ворчанию, брюзжанию; *мыңгыр-мыңгыр килү* ворча́ть (под нос)

мырау *подр. мурлыканью кошки* мур □ **~ итү** мурлы́кать

мыраул|ау *неперех.* мурлы́кать, урча́ть (*о кошке и других кошачьих*) || мурлы́канье; *якында гына мәче ~ый* где́-то ря́дом мурлы́чет ко́шка; *мәче ~авы* мурлы́канье ко́шки; *песи ~аган тавыш ишетелә* слы́шно мурлы́канье ко́шки

мыраулаш|у *взаимно-совм. от* **мыраулау**; *мәчеләр ~а* мурлы́чут ко́шки

мыр(ы)к-мыр(ы)к *звукоподр. хрюканью свиньи* хрюхрю □ **мырык-мырык итү** хрю́кать; хрю́канье

мыркылд|ау *неперех.* **1.** хрю́кать || хрю́канье; *дуңгыз балалары ~ыйлар* хрю́кают порося́та; *дуңгыз ~авы* хрю́канье свиньи́; *чучка үлә язса да ~авын куймас* (*погов.*) да́же при́ смерти свинья́ не переста́нет хрю́кать **2.** *перен. разг.* **1)** ворча́ть, брюзжа́ть; *нәрсә өчен ~ый башладың әле?* отчего́ на́чал брюзжа́ть? **2)** пере́чить, прекека́ться; *~ама, әйткәнне эшлә* не пере́чь, де́лай что ска́зано □ **~ап тору** ворча́ть постоя́нно; **~ап кую** побрюзжа́ть

мыркылдаш|у 1. 1) *взаимно-совм. от* **мыркылдау**; *бакча артында дуңгызлар ~а* за огоро́дом хрю́кают сви́ньи 2) *перен. разг.* ворча́ть; *һәр иртә куршеләр ~а* ка́ждое у́тро сосе́ди ворча́т **2.** *перен. разг.* сс́риться, брани́ться, побра́ниваться, поруга́ться (*друг с другом*) || сс́ора, брань, ру́гань (*между собой*); *балалар, алар ~алар да, шунда ук килешәләр дә* де́ти, они́ тут же браня́тся, и тут же ми́рятся

мыркылды|к *сущ. разг.* **1.** *перен. разг.* ворчу́н, брюзга́; *шул ~кның тавышын да яратмыйм* не люблю́ да́же го́лос э́того ворчуна́ (брюзги́) **2.** *разг.* свинья́, хрю́шка

мырл|ау *неперех.* **1.** *см.* **мыраулау**; *песи ~авы* мурлы́канье ко́шки **2.** *перен. разг.* петь ти́хим го́лосом, напева́ть/напе́ть; *әни әкрен генә ~ый* ма́ма ти́хим го́лосом напева́ет **3.** *перен. разг.* спать; *балакайларым инде ~ыйлар да икән* ока́зывается, мои́ де́тки уже́ спят

мырлаш|у *взаимно-совм. от* **мырлау**; *песиләр ~алар* мурлы́чут ко́шки; *елга буенда кызлар әкрен генә ~алар* у ре́чки ти́хо пою́т де́вушки

мыр(р)-мыр(р) *подр.* **1.** *мурлыканью кошки и других кошачьих* мур-мур; *мыр-мыр итү* мурлы́кать; *песи мыр-мыр итеп аяк астында бутала* ко́шка, мурлы́ча, пу́тается под нога́ми **2.** *храпению, сиплым звукам во время сна, при тихом разговоре, пении и т. п.*; *мыр-мыр итеп йоклап ята* спит с хра́пом; *ана белән кыз почмакта әкрен генә мыр-мыр итеп сөйләшәләр иде* мать и дочь ти́хо (ти́хими голоса́ми) разгова́ривали в углу́

мырылд|ау *неперех.* **1.** мурлы́кать || мурлы́канье; *мәче ~арга тотынды* ко́шка замурлы́кала; *сиам мәчесенең ~авы* мурлы́канье сиа́мской ко́шки **2.** *перен. разг.* 1) ворча́ть, брюзжа́ть; *нәрсә өчен әле ~ыйсың?* из-за чего́ ты ворчи́шь? 2) бормота́ть под нос, говори́ть невня́тно, непоня́тно, нея́сно (*недовольным голосом*); *нәрсә турында ~ады ул?* о чём он бормота́л? *ачык сөйлә, ~ама* говори́ отчётливо, не бормочи́

мыс *сущ. геогр.* мыс; *Челюскин мысы* мыс Челю́скина

мыскал *сущ. ист. в разн. знач.* миска́ль, золотни́к (*мера веса, употреблявшаяся до введения метрической системы, равная 1/96 фунта или 4,26 г, и гиря весом в золотник*); *бер ~ май* золотни́к ма́сла; *ит бер ~га ким* мя́са недостаёт на оди́н золотни́к; *үлчәүгә бер ~ны куй* поста́вь на весы́ оди́н золотни́к ◊ **(бер) ~ да, ~ кадәр дә** ниско́лько, ни на йо́ту, ни в мале́йшей сте́пени, соверше́нно; *(бер) ~ да акылың юк* у тебя́ ниско́лько (соверше́нно) нет ума́; *~ да ышанмыйм сиңа* я тебе́ ни на йо́ту не ве́рю; **~га салу 1.** взве́шивать/взве́сить золотника́ми; *майны ~га салу* ма́сло взве́шивать/взве́сить золотника́ми; взве́шивание ма́сла золотника́ми **2.** скря́жничать, проявля́ть/прояви́ть чрезме́рную ску́пость **3.** поду́мать, обду́мать всесторо́нне, доскона́льно; **~ы да** ниско́лько, соверше́нно; *көзен икмәкнең ~ы да җирдә калмады* осенью соверше́нно не́ было поте́ри урожа́я

мыскалла|у *перех.* **1.** взве́шивать/взве́сить золотника́ми || взве́шивание золотника́ми **2.** *перен. разг.* скря́жничать, проявля́ть чрезме́рную ску́пость; *ярар инде, ~ма, үз кызың бит, бир дә җибәр* ла́дно уж, не скря́жничай, твоя́ же дочь, отда́й, да и всё **3.** *в знач. нареч.* **мыскаллап 1)** золотника́ми, золотнико́м; *гәүһәрне ~п үлчиләр (погов.)* же́мчуг взве́шивают золотника́ми 2) *перен. разг.* по крупи́нке, по кро́хам; по мелоча́м; *өйдәге бөтен нәрсә үз кул көче белән ~п җыелган* всё, что есть в до́ме, нако́плено че́стным трудо́м, по крупи́нке 3) *перен. разг.* понемно́гу, понемно́жку, понемно́жечку; часта́ми; потихо́ньку, ме́дленно;

авыру батманы белән керер, ~п чыгар (*посл.*) болéзнь вхóдит батмáнами, а выхóдит золотникáми (*т.е. входит быстро, а выходит медленно*)

мыскаллы *прил.* золотникóвый, вéсом в золотни́к, рáвный по вéсу одномý золотнику́; *~ гер* золотникóвая ги́ря; *~ май* золотникóвое мáсло

мыскаллык *сущ.* золотни́к, ги́ря вéсом в золотни́к; *үлчәүгә ~ны китерче* принеси́, пожáлуйста, ги́рю в золотни́к || *прил.* золотникóвый; *~ гер* золотникóвая ги́ря

мыскыл *сущ.* **1.** насмéшка; *аның тавышында мин зәһәрле ~ сиздем* в егó гóлосе я почýвствовал язви́тельную насмéшку (издёвку) **2.** унижéние, оскорблéние; издёвка, издевáтельство; *синең ~ларыңа түзәр хәлем калмады* сил у менá бóльше нет терпéть твои́ оскорблéния (унижéния) □ **~ ителгән 1.** оскорблённый, уни́женный **2.** опозóренный, опорóченный; **~ ителү 1.** быть оскорблённым, уни́женным **2.** быть опозóренным, опорóченным; **~ итеп** насмéшливо, издевáтельски, оскорби́тельно; *~ итеп карау* смотрéть с насмéшкой; насмéшливый взгляд ◊ **~ итү 1.** насмехáться, потешáться, высмéивать, измывáться *над кем-л., чем-л.*; *ул һәрвакыт мине ~ итә, симез урдәккә охшыйсың, ди* он всегдá насмехáется надо мнóй, говори́т, что я похóжа на жи́рнуюýтку; *~ итеп торма әле* перестáнь насмехáться (брось свои́ шýточки) **2.** унижáть/уни́зить, оскорбля́ть/оскорби́ть, надругáться, издевáться, глуми́ться; *ул бит сине ~ итәр өчен йөрми* он не для того́ хóдит, чтóбы тебя́ унижáть **3.** позóрить, опозóрить, срами́ть, посрами́ть, порóчить, опорóчить; *ул кызны ~ иткән* он опозóрил дéвушку; **~га калу 1.** оказáться в смешнóм положéнии; стать посмéшищем **2.** опозóриться, осрами́ться

мыскыллан|у *неперех.* **1.** *страд. от* **мыскыллау**; быть оскорблённым, оскорбля́ться, оскорби́ться; *бу югары баскычка ~улар аша да килде ул* он на э́ту вы́сшую ступéнь поднялся и чéрез унижéния **2.** *в знач. сущ.* **мыскылланганнар** уни́женные, оскорблённые, опозóренные; *җәберләнгәннәр һәм ~ганнар* уни́женные и оскорблённые **3.** *в знач. нареч.* **мыскылланып** с унижéнием; с позóром; *~ып китеп бару* уйти́ с позóром

мыскылл|ау *перех* **1.** насмехáться, потешáться *над кем, чем-л.*, высмéивать/вы́смеять, осмéивать/осмея́ть, подвергáть злой насмéшке || насмéшка, высмéивание, осмéивание; *аны күргән саен көләсе, ~ыйсы килә* кáждый раз, как егó ви́жу, появля́ется желáние посмея́ться, насмехáться над ним; *аның күзенә усал ~ау билгеләре чыкты* в егó глазáх появи́лись при́знаки злой насмéшки **2.** унижáть/уни́зить, оскорбля́ть/оскорби́ть, надругáться, издевáться || унижéние, оскорблéние, надругáтельство, издевáтельство, издёвка; *зинһар, ~ама аны* пожáлуйста, не издевáйся над ним; *аңлашылды, бу сезнең ~авыгыз икән* тепéрь стáло я́сно, что вы издевáетесь; *кеше үзен ~аганга түзми, дисеңме?* говори́шь, человéк не тéрпит, когдá егó унижáют? **3.** позóрить/опозóрить, срами́ть, посрами́ть, порóчить/опорóчить || посрамлéние, поношéние; *ай-һай, ~адың син мине* ай-яй, посрами́л ты менá **4.** наси́ловать/изнаси́ловать || наси́лие, изнаси́лование; *кызны ~аганнар да, елага ташлаганнар* дéвушку изнаси́ловали, а потóм брóсили в péку **5.** *в знач. прил.* насмéшливый, издевáтельский; оскорби́тельный, унизи́тельный; *~ау күзе* насмéшливые глазá; насмéшливый взгляд; *~аган тон, ~ау тоны (тавышы)* издевáтельский (унизи́тельный) тон (гóлос); *~ау сүзе* оскорби́тельное слóво **6.** *в знач. нареч.* **мыскыллап** 1) насмéшливо, с насмéшкой, с издёвкой, издевáтельски; *~ап сөйләшү* говори́ть (*друг с другом*) с насмéшкой (издёвкой); насмехáться друг над дрýгом; *~ап карау* смотрéть (взглянýть) с насмéшкой (насмéшливо); смотрéть с издёвкой; *~ап көлү* насмехáться *над кем-л., чем-л.*; вы́смеять, осмея́ть *кого-л., что-л.*

мыскыллаулы *прил. см.* **мыскыллы**; *~ караш* насмéшливый взгляд

мыскыллаучы *сущ.* **1.** насмéшник, насмéшница **2.** оскорби́тель, оскорби́тельница; оскорбля́ющий, унижáющий **3.** тот, кто позóрил, срами́л, порóчил и́ли позóрит, срами́т, порóчит *кого-л.*

мыскыллашу *взаимно-совм. от* **мыскыллау 1.** насмехáться, издевáться друг над дрýгом, высмéивать друг дрýга **2.** унижáть/уни́зить, оскорбля́ть/оскорби́ть друг дрýга словáми **3.** позóрить/опозóрить, срами́ть, опорóчить друг дрýга

мыскыллы *прил.* насмéшливый, презри́тельный; издевáтельский, унижáющий, высмéивающий; *~ сүзләр* издевáтельские словá; *~ караш* насмéшливый взгляд; *~ тон* презри́тельный тон

мыскылчан *прил. см.* **мыскыллаулы**

мыскылчанлык *сущ.* презри́тельность, издевáтельство, издёвка (*в словах, во взгляде, в разговоре*)

мысыр *сущ. см.* **мисыр**

мышкылдату *понуд. от* **мышкылдау** 1; *борын ~* сопéть нóсом, шмы́гать нóсом

мышкылд|ау *неперех.* **1.** сопéть (*носом*) || сопéние; *нишләп ~ыйсың, салкын тидеме әллә?* отчегó сопи́шь, простуди́лся, что ли? **2.** 1) пыхтéть, сопéть, тяжелó дышáть, отдувáться (*при быстрой ходьбе, физической работе и от тяжести*) 2) *в знач. нареч.* **мышкылдап, мышкылдый-мышкылдый** пыхтя́, сопя́, тяжелó дыша́, отдувáясь; *алар ~ап килеп керделәр* они́ вошли́ тяжелó дыша́ 3) *разг.* си́литься, напрягáть/напря́чь си́лы, напрягáться; пыхтéть; *шкафны күчергәндә ~арга туры килде* чтóбы перенести́ шкаф, пришлóсь попыхтéть 4) беззвýчно плáкать

мышкылдык *прил.* **1.** сопя́щий; сопли́вый **2.** неторопли́вый, медли́тельный || *сущ.* **1.** неторопли́вый человéк, медли́тельный человéк; копýн, копýша; *бу ~ безне куып җитә алмас* э́тот копýша нас не догóнит **2.** *перен.* коро́ва

мышлау *неперех. см.* **мышкылдау, мышнау**

мыш-мыш *подр.* **1.** *пыхтению, сопению при быстрой ходьбе, физической работе, от тяжести, простуды или другой болезни* **2.** *беззвучному плачу; мыш-мыш елау* беззвýчно плáкать □ **мыш-мыш килү** *см.* **мышнау, мышкылдау**; пыхтéть, сопéть, тяжелó дышáть

мышнавык *сущ.* тот, кто чáсто сопи́т (пыхти́т), сопýн

мышнату *понуд. от* **мышнау 1.** сопéть; *борын ~* сопéть нóсом **2.** загоня́ть, загнáть; *атны ~* загнáть лóшадь

мышн|ау *неперех.* **1.** пыхтéть, тяжелó дышáть, сопéть || пыхтéние, сопéние; *ул авыр күтәргәндә бик ~ый иде* он всегдá пыхтéл от тяжёлой нóши **2.** *в знач. нареч.* **мышный-мышный**; пыхтя́, сопя́, тяжелó дыша́; *ул мышный-мышный йөгерде* он побежáл сопя́ (тяжелó дыша́)

мыштым *прил.* **1.** скры́тный; *~ кеше* скры́тный человéк **2.** медли́тельный, неторопли́вый, споко́йный (*человек*) **3.** *перен. разг.* тáйный, скры́тный, скрыва́-

емый; ~ *эш* та́йное де́ло || *сущ.* **1.** медли́тельный, молчали́вый, споко́йный челове́к **2.** скры́тный челове́к; *бу ~ биредә ни эшләп йөри?* что тут де́лает э́тот молчу́н? □ ~ **гына 1.** втихомо́лку, исподтишка́, скры́тно; ти́хой са́пой; ~ *гына эшләү* де́лать исподтишка́ (скры́тно) **2.** споко́йно, ти́хо; неслы́шно, тихо́нько, ме́дленно; ~ *гына йөрү* ходи́ть ти́хо (ме́дленно); ~ *гына сөйләшү* говори́ть ти́хо, споко́йно; говори́ть негро́мко **3.** незаме́тно; тихо́нько; *сузне ~ гына икенчегә бордым* незаме́тно переменил те́му разгово́ра; ~ *гына китеп бару* уйти́ незаме́тно

мыштыр *прил.* медли́тельный, неторопли́вый; ~ *кеше* неторопли́вый челове́к; копу́н, копу́ша, копоту́нья *прост.*; ~ *кеше иртә дә ~, кич тә ~* (*погов.*) неповоро́тливый челове́к копоши́тся и у́тром, и ве́чером □ ~ **гына** ме́дленно, медли́тельно; не торопя́сь; споко́йно и до́лго (*возиться*); ~ *гына эшләп маташу* не торопя́сь вози́ться *с каким-л.* де́лом

мыштырд|ау *неперех.* ме́дленно, до́лго вози́ться, копоши́ться, ме́шкать || возня́; *бакчада ~ау* вози́ться в саду́; *тагын бераз ~асам, соңга кала идем* е́сли бы копоши́лся ещё немно́го, опозда́л бы 2) занима́ться *чем-л.*, де́лать *что-л.*, вози́ться 3) ме́дленно дви́гаться, шевели́ться ко́е-ка́к (ме́дленно, лени́во); *бигрәк ~ыйсың, кызурак атласаңчы* ты е́ле шевели́шься, шага́й побыстре́е

мыштырдаучан *прил.* медли́тельный, неповоро́тливый, копотли́вый; ~ *бала ул* он медли́тельный ребёнок, копу́ша; ~ *характер* копотли́вый хара́ктер

мыштырдык *сущ.* копу́ша

мышык-мышык *подр. беззвучному плачу*

мышылд|ау *неперех. см.* **мышкылдау**; *~ап килеп керү* прибежа́ть тяжело́ дыша́

мышьяк *сущ. в разн. знач.* мышья́к || мышьяко́вый, мышья́чный; ~ *кушылмасы* соедине́ние мышьяка́; *врач ~ белән дәвалый* врач ле́чит мышьяко́м; ~ *кислотасы* мышьяко́вая (мышья́чная) кислота́; ~ *эретмәләре* мышьяко́вые раство́ры

мышьяклы *прил. спец.* мышья́чный; ~ *тозлар* мышья́чные со́ли; ~ *рудалар* мышья́чные ру́ды

мэр *сущ.* мэр; *шәһәр мэры* мэр го́рода

мэ́рия *сущ.* мэ́рия; *Казан ~се* мэ́рия Каза́ни

мю́зик-холл *сущ.* мю́зик-хо́лл; *Мәскәү мюзик-холы* Моско́вский мю́зик-хо́лл; *мюзик-холл программасы* програ́мма мю́зик-хо́лла

мю́ль-маши́на *сущ. спец.* мю́ль-маши́на (*один из видов прядильной машины*) || мю́льный; *мюль-машина тәгәрмәче* мю́льное колесо́

Н

на *меж.* но! (но-о) (*возглас при понукании лошади*); *на-на-на! — диеп атын куа иде* но-о! понука́л он свою́ ло́шадь

набат *сущ.* наба́т || наба́тный; *~ чаңы* наба́тный ко́локол □ **~ кагу (суту)** бить в наба́т, ударя́ть в наба́т

набо́йка *сущ. спец.* набо́йка; *укчәгә ~ суктыру* прибива́ть (набива́ть) набо́йку на каблу́к

набор *сущ. спец.* набо́р || набо́рный; *~ны чәчү* рассы́пать набо́р; *ике полоса ~* две полосы́ набо́ра; *~ кассасы* набо́рная ка́сса

набо́рщик *сущ. спец.* набо́рщик, набо́рщица

набо́рщиклык *сущ. спец.* профе́ссия набо́рщика

нава́га *сущ. зоол.* нава́га || нава́жий; *~ уылдыгы* нава́жья икра́

навига́тор *сущ. спец.* навига́тор

навига́ция *сущ. спец. в разн. знач.* навига́ция || навигацио́нный; *~ буенча дәреслек* уче́бник по навига́ции; *~ ачылу* откры́тие навига́ции; *~ приборлары* навигацио́нные прибо́ры; *~ чоры* навигацио́нный пери́од

навО́дка *сущ. спец.* навО́дка; *туры ~ белән ату* бить прямо́й навО́дкой

нагайбәк *сущ.* нагайба́ки, нагайба́к (*этнографическая группа татар, а также представитель этой группы*) || нагайба́кский *~ җырлары* нагайба́кские пе́сни

нага́йка *сущ.* нага́йка; *полицейскийның кулында ~ иде* в рука́х полице́йского была́ нага́йка

наган *сущ. воен.* нага́н || нага́нный; *~ патроннары* нага́нные патро́ны

на́гель *сущ. спец.* на́гель; *калын такталарны ~ белән беркетү* то́лстые до́ски прикрепи́ть на́гелем

нагру́зка *сущ. спец.* нагру́зка; *сынау ~сы уңышлы алып барылды* испыта́тельная нагру́зка вела́сь успе́шно

надан *прил.* **1.** негра́мотный; не обуча́вшийся гра́моте **2.** безгра́мотный, малогра́мотный, полугра́мотный; *~ җаваплар* безгра́мотные отве́ты; *~ укытучы* безгра́мотный учи́тель **3.** неве́жественный, неучёный, необразо́ванный, неквалифици́рованный, непросвещённый, малообразо́ванный; тёмный, се́рый; *~ белгеч* неквалифици́рованный специали́ст; *~ калу* оста́ться необразо́ванным || *сущ.* **1.** не́уч, недоу́чка **2.** неве́жда, неве́жа; *юргалы белән юлдаш булма, ~ белән сердәш булма* (*посл.*) вса́дник не́шему не спу́тник, неве́жда образо́ванному не сове́тчик || *нареч.* безгра́мотно, малогра́мотно, полугра́мотно; *хат бик ~ язылган* письмо́ напи́сано соверше́нно безгра́мотно

наданлану *неперех.* станови́ться/стать неве́жественным, неве́ждой

наданлык *сущ.* **1.** негра́мотность; безгра́мотность, малогра́мотность; *укучыларның грамматикадагы ~лары язма эшләрдә бигрәк тә күренә* безгра́мотность уча́щихся в грамма́тике осо́бенно наблюда́ется в пи́сьменных рабо́тах **2.** неве́жественность, неве́жество, необразо́ванность, неквалифици́рованность, непросвещённость, се́рость; *үзеңдәге ~ны сизү авыр* признава́ть свою́ неквалифици́рованность тяжело́

надзира́тел|ь *сущ.* надзира́тель || надзира́тельский; *төрмә ~е* тюре́мный надзира́тель; *~ь вазифасы* надзира́тельская до́лжность

надзор *сущ.* надзо́р; *техник ~* техни́ческий надзо́р; *суд ~ы* суде́бный надзо́р

надир *прил. уст. книжн.* ре́дкий, ре́дко встреча́ющийся

надсмо́трщик *сущ.* надсмо́трщик, надсмо́трщица

наёздни|к *сущ. спец.* наёздник; *цирк ~гы* цирково́й наёздник

наёмщик *сущ. уст. разг.* наёмник (*человек, нанятый для службы в солдатах*)

наждак *сущ.* наждА́к || наждА́чный; *металлны ~ белән шомарту* шлифова́ть мета́лл наждако́м; *~ порошогы* наждА́чный порошо́к

наждаклы *прил.* наждА́чный, содержа́щий наждА́к; *~ кәгазь* наждА́чная бума́га

наз *сущ.* **1.** ла́ска, не́жность, не́га; *наз тулы күзләр* перепо́лненный ла́ской взгляд; *әтисенең назы рәхәтләндерә иде* ла́ска (не́жность) отца́ доставля́ла ему́ удово́льствие; *аның күз карашында шундый ярату, әтавышында шулкадәр наз!* в его́ глаза́х така́я любо́вь, а в го́лосе така́я не́жность! **2.** 1) капри́з; при́хоть; *бу кызның тик бер назыдыр* э́то, наве́рное, како́й-то капри́з де́вушки 2) *перен.* забо́та; тре́бование; *кызы барның назы бар* (*посл.*) у кого́ дочь, у того́ и забо́ты; *бал кортының балы бар, балга хәтле назы бар* (*посл.*) *букв.* у пчелы́ есть мёд, но до мёда мно́го и забо́т

назар *сущ. уст. книжн.* **1.** взгляд, взор; то́чка зре́ния; *минем ~ымда ул әйбәт кеше* на мой взгляд (по-мо́ему), он хорбшний человек; *Җәмилә мыскыл ~ы белән бага* Джамиля́ броса́ет иронический взгляд **2.** внима́ние, соображе́ние □ **~га алу** принима́ть во внима́ние, име́ть в виду́; **~ итү (кылу)** смотре́ть, рассма́тривать; созерца́ть; *тирә-ягыңа бер ~ кыл* посмотри́ хоть раз вокру́г себя́

назаран *нареч. книжн.* согла́сно, сообра́зно с, по; су́дя по, смотря́ по, в зави́симости от; *шуңа ~* согла́сно тому́, су́дя по тому́

назари *прил. уст. книжн.* теорети́ческий; умозри́тельный; *мәсьәләнең ~ ягы* теорети́ческая сторона́ вопро́са

назария, назарият *сущ. уст. книжн.* тео́рия, доктри́на; *гыйльми коммунизм ~сенә нигез салучылар* основополо́жники тео́рии нау́чного коммуни́зма

назландыр|у *перех.* **1.** позволя́ть/позво́лить ласка́ться, приласка́ться, не́житься, разне́живаться/разне́житься **2.** позволя́ть/позво́лить жема́ниться, жема́нничать, лома́ться; мане́рничать **3.** *разг.* заставля́ть/заста́вить упра́шивать; *~ып тормау* не заставля́ть себя́ упра́шивать

назлан|у *возвр. от* **назлау** **1.** не́житься; ласка́ться, приласка́ться, не́жничать, разне́живаться/разне́житься || не́жность; *төче ~улар* теля́чьи не́жности; *аңа әнисе янында озак ~ырга туры килмәде* ему́ не пришло́сь до́лго не́житься о́коло ма́тери **2.** жема́ниться, жема́нничать, лома́ться, мане́рничать || жема́нство, кривля́нье; мане́рность, мане́рничанье *разг.*; капри́з, при́хоть; *кинога барырга риза булмый ~ып торды* не хоте́л в кино́

идти́, жема́нился 3. *разг.* заставля́ть/заста́вить упра́шивать; *~ып тормады, өстәл янына утырды* не заста́вил упра́шивать, сел за стол

назлануча́н *прил.* жема́нный, кокéтливый

назланы́шу *совм. от* **назлану**

назлату *понуд. от* **назлау**; дать возмóжность и́ли заставля́ть нéжить (*себя*)

назл|ау *перех.* нéжить, изнéжить, изнéживать, ласка́ть || нéжность, ла́ска; нéжный, ласка́тельный; *ана баласын ~ый* мать ласка́ет ребёнка; *~ау җитми аңа* емý не хвата́ет ла́ски; *~ау сүзләре* ласка́тельные слова́, нéжные слова́; *баланы ~ап бозу* изнéжить ребёнка

назлы *прил.* 1. нéжный, ла́сковый; мя́гкий; избало́ванный, изнéженный; *~ бала* ла́сковый ребёнок; *~ кыз* изнéженная дéвушка 2. нéжный, ла́сковый, прия́тный, любéзный (*голос, взгляд, приём и т. п.*); *~ тавыш* нéжный гóлос; *~ сүзләр* ла́сковые слова́ 3. капри́зный, приверéдливый, разбóрчивый; *ашауга ~ бала* разбóрчивый в едé ребёнок; *~ назланып торганчы, кыю ашап түйган* (*погов.*) пока́ приверéдливый жема́нился, смéлый наéлся 4. жема́нный, капри́зный, церемóнный; *~ кунак* церемóнный гость; *җырчылар һәрвакыт ~ булалар* певцы́ всегдá быва́ют капри́зными 5. изя́щный, грацио́зный; *~ хәрәкәт* грацио́зное движéние || *сущ.* нéженка, ба́ловень || *нареч.* 1. нéжно, ла́сково; *~ эндәшү* обрати́ться ла́сково 2. жема́нно, кокéтливо; *үзеңне ~ тоту* держа́ть себя́ жема́нно ◊ **~ туташ** кисéйная ба́рышня

назлылы|к *сущ.* 1. нéжность, ла́сковость, мя́гкость; *баланың ~гы миңа ошый иде* мне óчень нра́вилась нéжность ребёнка 2. нéжность, ла́сковость, прия́тность, любéзность (*слова, взгляда, голоса и т. п.*); 3. жема́нность, жема́нство, капри́з, церемóнность; *өстәл артындагы ~к бөтенләй кирәксез* жема́нство за столóм совершéнно ни к чемý 4. изя́щность, грацио́зность; *йөрешнең ~гы* изя́щность похóдки

наз-нигъмәт *сущ. уст.* 1. вся́кие угощéния, ла́комства 2. жи́зненные бла́га и наслажде́ния

назыйм *сущ. уст.* 1. стихотвóрная речь, стихи́, поэ́зия; *~ төзелеше* строй стихотворéния 2. стихи́, котóрые поются (*преимущ. тексты духовного, религиозного содержания*) 3. *перен.* ви́рши; стихи́ □ **~ әйтү** петь (духóвные) стихи́ (хóром)

назыймчы *сущ. уст.* 1. *поэт.* 2. виршеплёт, рифма́ч

назыйр *сущ. уст. книжн.* мини́стр

наиб *сущ. уст. книжн.* найб, намéстник, замести́тель

наиблык *сущ. уст. книжн.* 1. представи́тельство 2. намéстничество

най *сущ. муз.* най (*восточный музыкальный инструмент*)

наказ *сущ.* нака́з; *сайлаучылар ~ы* нака́з избира́телей; *~ бирү* дава́ть нака́з || *ист.* наказно́й; *~ грамотасы* наказна́я гра́мота

намаеш *сущ. уст.* демонстра́ция, пара́д; *~ка барган-дай* как бýдто идýт на пара́д

нечкәлә|ү *перех.* 1. утончáть/утончи́ть; *бик ~сәң — өзелер* (*посл.*) ста́нешь си́льно утончáть — оборвёшь 2. детализи́ровать, вдава́ться в дета́ли, подро́бности; разбира́ть/разобра́ть подро́бно, по дета́лям; обду́мывать/обду́мать всесторо́нне; *артык ~сәң — бернәрсә дә чыкмас* е́сли начнёшь вдава́ться в дета́ли, ничего́ не полу́чится 3. де́лать *что-л.* аккура́тно, тща́тельно; обраща́ть внима́ние на ме́лочи, дета́ли; *өстәлне тизрәк әзерләгез, бик ~мәгез* накрыва́йте быстре́е на стол, не обраща́йте внима́ния на ме́лочи 4. *в знач. нареч.* **нечкәлән** 1) то́нко; *~п телгәләнгән чыра* то́нко ще́панная лучи́на 2) подро́бно, дета́льно, тща́тельно, доскона́льно, всесторо́нне; скрупулёзно; *сәламәтлеге турында ~п сорашу* подро́бно расспра́шивать о его́ здоро́вье; *хезмәтне ~п анализлау* скрупулёзно анализи́ровать рабо́ту 3) тща́тельно, стара́тельно, усе́рдно, аккура́тно, по всем пра́вилам; *җирне ~п эшкәртү* тща́тельно обраба́тывать зе́млю 4) при́стально, внима́тельно, тща́тельно; *портретны ~п карау* внима́тельно рассма́тривать портре́т

нечкәле|к *сущ.* 1. то́нкость; *сызыкның ~ге* то́нкость ли́нии; *бил ~ге* то́нкость та́лии 2. *мн.* **нечкәлекләр** то́нкости; мельча́йшие подро́бности, осо́бенности, дета́ли; *дәрес уткәрүнең бөтен ~кләренә кадәр планда язылган иде* проведе́ние уро́ка до мельча́йших подро́бностей бы́ло опи́сано в пла́не 3. *перен.* щекотли́вость, делика́тность; *мәсьәләнең ~ге* делика́тность вопро́са 4. *перен.* то́нкость, не́жность, утончённость; *хисләрнең ~ге* то́нкость чувств 5. *лингв.* палата́льность, мя́гкость; *тартыкларның ~ге* мя́гкость согла́сных; *~к билгесе лингв.* мя́гкий знак

нечкәртелү *страд. от* **нечкәртү** 1. утончáться/утончи́ться, де́латься/сде́латься то́нким 2. *лингв.* смягче́ние, палатализа́ция; *авазлар ~е* палатализа́ция зву́ков

нечкәрт|ү *перех.* 1. *в разн. знач.* утончáть/утончи́ть, де́лать/сде́лать бóлее то́нким || утончéние; *таякны ~ү* утончи́ть па́лку; *кара төс гәүдәне ~ә* чёрный цвет утончáет фигу́ру; *зәвыкларны ~ү* утончáть вку́сы 2. *лингв.* смягча́ть/смягчи́ть, палатализова́ть || смягче́ние, палатализа́ция 3. *перен.* умиля́ть/умили́ть, растро́гать, взволнова́ть *чем-л.*, заста́вить расчу́вствоваться || умиле́ние; *аның сүзләре күңелне ~еп җибәрде* его́ слова́ растро́гали мою́ ду́шу; *музыка безнең хисләрне ~ә* му́зыка де́лает на́ши чу́вства то́ньше, нежне́е

нечкәр|ү *неперех.* 1. *в разн. знач.* тончáть, истончáть, утончáться/утончи́ться, становúться/стать то́нким; *озак авырудан соң кыз бөтенләй ~гән* по́сле продолжи́тельной боле́зни де́вушка ста́ла совсе́м то́ненькой; *таяк очка таба ~ә* па́лка бли́же к концу́ утончáется 2. становúться/стать то́ньше, вы́ше обы́чного (*о голосе, звуках*); *җырчының тавышы ахырга таба ~ә* го́лос певца́ к концу́ стано́вится вы́ше 3. *лингв.* смягча́ться/смягчи́ться, палатализова́ться || смягче́ние, палатализа́ция; *аваз ~ү* смягче́ние, палатализа́ция зву́ка 4. *перен.* умиля́ться/умили́ться, растро́гаться, расчу́вствоваться; *күңел ~ү* умиля́ться, растро́гаться

ни I *мест.* 1. 1) *вопр. мест.* что; *ни булды?* что случи́лось? *ни кирәк сиңа тагын?* что ещё тебе́ на́до? 2) *в вопр. оборотах* что́-то, что́-л., что́-нибудь; *күңел бушлыгын ни белән булса да тутырырга кирәк иде* на́до бы́ло чем-то запо́лнить душе́вную пустоту́; *нидән башларга белмим* не зна́ю, с чего́ нача́ть 2. *в риторических вопр. и воскл. предл. вопр. мест.* как, како́в, како́й; *минем монда ни гаебем бар?* кака́я моя́ вина́ в э́том? *балаң авырмыйча гына үссә, ни бәхет!* е́сли ребёнок растёт не боле́я, како́е сча́стье! *ни рәвешле (ни төсле) килеп чыгар бит* как ведь полу́чится 3. *в сложн. предл. употр. в составе сложного союзного сл.* **ни ... шул, ни ... шуны** что ..., то ; *ни чәчсәң, шуны урырсың* (*посл.*) что посе́ешь, то и пожнёшь; *күңелендә (уенда) ни, телендә шул* (*погов.*) что на уме́, то и на языке́ 4. *в сочет. с сущ. образует парные слова и придаёт собирательное знач.* вме́сте с ...; *өстәле-ние белән* вме́сте со столо́м; *урындыгы-ние белән* вме́сте со сту́лом □ **ни арада** когда́ то́лько; **ни бар, ни булган** весь, всё; что есть; *үзенең ни бар китаплары белән уртаклашты* он подели́лся все́ми кни́гами, что есть; **нибары** всего́, всего́-на́всего; **ни барысы (шул)** то́лько и всего́; да и то́лько; **ни булганы** что есть, весь; *ни булганы — өстәлдә* что есть — всё на столе́; **ни булса (да) булыр** будь что бу́дет, была́ не была́; **ни гомер, ни гомердән бирле** давно́, о́чень давно́, с да́вних времён; це́лая ве́чность,

це́лая жизнь; **ни күзем белән күрим, ни күрәм** *вводн. сл.* что я ви́жу ◊ **ни җитте 1.** плохо́й, нека́чественный, неподходя́щий, него́дный, нехоро́ший; како́й уго́дно (*о вещах, товарах, продуктах, овощах и т. п.*) **2.** плохо́й, несто́ящий, непутёвый (*о человеке*); *ни җитте кешеләр белән аралашмыйм инде анысы* вообще́-то с несто́ящими людьми́ не обща́юсь; **ни пычагыма** на ко́й чёрт; **ни чарадан бичара** во́лей-нево́лей, хо́чешь не хо́чешь

ни II *частица* **1.** *усил.* ско́лько (бы), сто́лько, как ни, ещё бо́лее; *ни гомер узган* ско́лько вре́мени прошло́; *ни тырышмасын, барыбер куып җитә алмый* как ни стара́ется, всё равно́ не догна́т **2.** *употр. при выражении несогласия, иронии и т. п.* как бы ..., как же ...; *туганы өчен кайгыртмыйча ни, кайгырта инде* как же не забо́тится о ро́дственнике, коне́чно, забо́тится; *син күрсәткәч күрмичә ни, күрдем инде* как же не ви́деть, раз ты пока́зываешь, уви́дел; *егылдым ди, егылмыйча ни* как же (как бы не так), сейча́с вот упаду́; *еладым ди, еламый ни* как же, сейча́с вот и запла́чу **3.** ну (и) что; ну (и) пусть; *булса ни* ну и что (из э́того); *күрсә ни, күрсен* ну и пусть ви́дит **4.** *союз* ни ..., ни ...; *ни ары, ни бире* ни туда́, ни сюда́; *ни алга, ни артка* ни наза́д, ни вперёд; *ни уңга, ни сулга* ни впра́во, ни вле́во ◊ **ни аллага, ни муллага** ни бо́гу све́чка, ни чёрту кочерга́; **ни он түгел, ни камыр түгел** ни ры́ба ни мя́со

ни́бары *нареч.* то́лько, всего́, всего́-на́всего; и то́лько; *~ биш кеше килгән* пришло́ всего́ пять челове́к; *китап ~ ике сум тора* кни́га сто́ит то́лько два рубля́

нивелир *сущ. спец.* нивели́р || нивели́рный; *геодезистлар ~ы* нивели́р геоде́зистов

нивелирлану *возв. страд. от* **нивелирлау**; нивели́роваться || нивели́ровка

нивелирлау *перех.* нивели́ровать || **1)** нивелиро́вка **2)** нивелиро́вочный; *аэродромны ~* нивели́ровать аэродро́м; *~ рейкасы* нивелиро́вочная ре́йка

нивелиро́вкачы *сущ.* нивелиро́вщик, нивелиро́вщица

нивх *сущ.* нивх (*народность, живущая в нижнем течении Амура и на Сахалине*) || ни́вхский; *~ теле* ни́вхский язы́к; *~ хатыны (кызы)* ни́вхка

ни́гә *мест. вопр.* **1.** для чего, зачем, с какой целью, по какой причине, с чего; *~ кирәк булды икән аңа ул китап?* заче́м пона́добилась ему́ э́та кни́га? **2.** почему́, заче́м, с како́й ста́ти; *~ сөйләшмисең?* почему́ не разгова́риваешь? *~ барыйм мин анда?* с како́й ста́ти я туда́ пойду́? **3.** *в начале вопр. предл. для усиления вопроса*: *~, икәү булса начармыни?* почему́, е́сли бу́дет два, ра́зве пло́хо? □ **~ шунда** хоть там ..., пусть хоть ...; *~ шунда утермиләр, барыбер бармыйм* пусть хоть убью́т, всё равно́ не пойду́

ни́гәдер *мест. неопр.* заче́м-то, почему́-то, что́-то; *ул ~ сөйләшми* он почему́-то не разгова́ривает; *~ булмә салкын* что́-то в ко́мнате хо́лодно

нигез *сущ.* **1.** фунда́мент, основа́ние, опо́рная часть || фундамента́льный; *йорт ~е* фунда́мент до́ма; *таш ~* ка́менный фунда́мент; *йорт салу авыр тугел, ~ салу авыр* (*погов.*) не так тру́дно избу́ срубить, тру́дно фунда́мент заложи́ть; *һәйкәл ~е* основа́ние па́мятника, пьедеста́л; *~ ташы* фунда́ментный ка́мень **2.** зава́линка; *~нең туфрагы утырган* осе́ла земля́ зава́линки **3.** *перен.* осно́ва, исто́ки, ко́рни; родно́й, о́тчий дом; *апа ~ен ташлап китә алмады* сестра́ не смогла́ поки́нуть родно́й дом; *безнең ~ебез монда* на́ши ко́рни здесь **4.** *перен.* **1)** осно́ва, основа́ние, ядро́, исхо́дный материа́л (*для создания чего-л.*); *операның ~енә әкият салынган* в осно́ве о́перы — ска́зка; *бакчаның ~е алма агачы булды* исхо́дным материа́лом са́да была́ я́блоня; *коллекция музейның ~е була ала иде* колле́кция могла́ стать осно́вой музе́я **2)** осно́ва, основа́ние, фунда́мент, ба́за, опо́ра, гла́вное в *чём-л.* **3)** *перен. мн.* осно́вы, нача́ла, усто́и; *гаилә ~ләре* усто́и семьи́; *хезмәт оештыруны фәнни ~гә кору* организа́цию труда́ стро́ить на нау́чной осно́ве **5.** *перен. мн.* осно́вы, основа́ния, исхо́дные, основны́е положе́ния (при́нципы), нача́ла; *дарвинизм ~ләре* основа́ния дарвини́зма; *марксизм-ленинизм ~ләре* осно́вы маркси́зма-лениниз́ма **6.** суть, су́щность; ядро́; сте́ржень; смысл; ко́рень; *эш — тормышның ~е* рабо́та — осно́ва жи́зни; *хаклык ~е* ко́рень справедли́вости **7.** *перен.* основа́ние, причи́на, по́вод; *әйтергә ~ем бар* у меня́ есть основа́ние сказа́ть; *борчылырга ~ бар иде* был по́вод беспоко́иться **8.** *спец.* осно́ва || основно́й; *см. тж.* **буйлык**; *~ җепләре* основны́е ни́ти **9.** *мат.* основа́ние; *өчпочмак ~е* основа́ние треуго́льника **10.** *хим.* основа́ние; *органик ~ләр* органи́ческие основа́ния **11.** *лингв.* осно́ва; *сүз ~е* осно́ва сло́ва || *прил.* основно́й, гла́вный; *~ шарт* основно́е усло́вие; *~ сәбәп* гла́вная причи́на □ **~ булу** лечь в осно́ву, служи́ть осно́вой; **~ итеп алу** брать за осно́ву, класть (положи́ть) в осно́ву; **~ кору (булдыру) 1.** заложи́ть осно́ву **2.** обоснова́ться, постро́ить свой дом; **~ туфрагы, ~ читәне** зава́линка; *см. тж.* **туфракса**; **~ салу 1.** заложи́ть фунда́мент **2.** заложи́ть осно́ву; **~ салучы** основа́тель, основополо́жник ◊ **~ кору** исчеза́ть бесследно, вымира́ть/вы́мереть; **~ен корыту** искорени́ть, уничтожа́ть/уничто́жить, стере́ть с лица́ земли́; **~ күрше** бли́зкий сосе́д; **~ ташы** краеуго́льный ка́мень

нигездә *вводн. сл.* в основно́м; в осно́ве; по существу́; *диссертация ~ тәмамланган* диссерта́ция в основно́м завершена́

нигездән *нареч.* в ко́рне, коренны́м о́бразом; по́лностью, целико́м, всецело́; с основа́ния; *хикәяне ~ үзгәртү* по́лностью измени́ть расска́з

нигездәш *сущ.* сосе́д по фунда́менту; сосе́д, живу́щий в до́ме, постро́енном на одно́м фунда́менте

нигезе-төбе *сущ.* са́мая суть; су́щность; *авыл хуҗалыгындагы эшнең нигезе-төбе — югары уңыш алу* суть се́льского хозя́йства — получи́ть высо́кий урожа́й

нигезлә́нмәгән *прил.* необосно́ванный, неоснова́тельный, неопра́вданный, голосло́вный; *~ гаепләүләр* необосно́ванные обвине́ния; *~ дәлилләр* голосло́вные доказа́тельства

нигезлән|ү 1. осно́вываться/основа́ться, быть осно́ванным, аргументи́роваться || основа́ние; *гаепләү тикшерелгән фактлар белән ~ә* обвине́ние осно́вывается на прове́ренных фа́ктах **2.** осно́вываться/основа́ться, сели́ться, посели́ться, находи́ть приста́нище; обосно́вываться/обосноваться, седа́ть/осе́сть || основа́ние, посеще́ние, обоснова́ние *разг.*; *авылда ~ү* поселиться в дере́вне **3.** осно́вываться/основа́ться, держа́ться, стро́иться, бази́роваться, опира́ться на *что-л.*, исходи́ть из *чего-л.*, отправля́ться от *чего-л.*, отта́лкиваться от *чего-л.*, класть в осно́ву *что-л.*, брать за осно́ву *что-л.*, зи́ждиться *книжн.* || основа́ние, бази́рование; *законга ~ү* опира́ться на зако́н; исходи́ть из зако́на; *тәҗрибәгә ~ү* осно́вываться на пра́ктике; *поэма романтикага ~гән* в осно́ву поэ́мы поло́жена рома́нтика

нигезлә|ү *перех.* **1.** осно́вывать/основа́ть, закла́дывать/заложи́ть осно́ву, фунда́мент; *Тукай көчле сатирик мәктәпне ~де* Тука́й заложи́л осно́ву сатири́ческой

шкóлы **2.** *перен.* обоснóвывать/обосновáть, аргументи́ровать; *үз фикереңне ышандырырлык итеп ~ү* убеди́тельно аргументи́ровать свою́ мысль

нигезләүче *сущ., прил.* **1.** родоначáльник, основáтель, основополóжник || основáвший **2.** тот, кто обосновáл || обосновáвший

нигезле *прил.* **1.** 1) с фундáментом, имéющий фундáмент, оснóву, оснóванный на фундáменте; *биек ~ йорт* дом с высóким фундáментом 2) имéющий жильё, имýщество; устрóенный; *~ тормыш* устрóенная жизнь **2.** основáтельный, обоснóванный, солúдный, фундаментáльный; глубóкий (*о знаниях, исследовании и т. п.*) **3.** обоснóванный, вéский, аргументúрованный, оправданный, убеди́тельный; *~ утенеч* убеди́тельная прóсьба; *~ дәлил* обоснóванное, аргументúрованное доказáтельство; *~ шикләнүләр* обоснóванные подозрéния; *~ сәбәпләр* вéские причúны **4.** обоснóванный, действúтельный, правдúвый; состоя́тельный; *имеш-мимешләр ~ булып чыкты* слýхи оказáлись обоснóванными; *~ булмаган фикер* несостоя́тельное мнéние **5.** умéстный □ **~ рәвештә** основáтельно; обоснóванно; фундаментáльно, аргументúрованно, вéско, убеди́тельно

нигезлелек *сущ.* **1.** основáтельность; фундаментáльность (*знания, мысли, суждения и т. п.*) **2.** обоснóванность, вéскость; аргументúрованность, оправданность; убеди́тельность; *таләпләрнең ~ге* обоснóванность трéбований; *дәлилләрнең ~ге* вéскость доказáтельств **3.** обоснóванность, действúтельность; правдúвость, состоя́тельность; *хәбәрнең ~ге* реáльность слýха **4.** умéстность

нигезсез *нареч.* необоснóванно, безосновáтельно, неосновáтельно, бездоказáтельно, беспóчвенно, неоправданно, неаргументúрованно, голослóвно; *~ көнләшү* необоснóванная рéвность || *прил.* необоснóванный, безосновáтельный, неосновáтельный, бездоказáтельный, неубеди́тельный, недоказáтельный, несостоя́тельный, беспóчвенный, неоправданный, неаргументúрованный, голослóвный; *~ бәйләнүләр* необоснóванные придúрки; *~ гаепләү* необоснóванное обвинéние

нигезсезлек *сущ.* необоснóванность, безосновáтельность, неосновáтельность, бездоказáтельность, несостоя́тельность, неубеди́тельность, беспóчвенность, неоправданность, голослóвность; *нәтиҗәләрнең ~ге* безосновáтельность заключéний; *гаепләүнең ~ге* необоснóванность обвинéния

нигилизм *сущ. книжн. в разн. знач.* нигилúзм; *милли ~га бирелү* впадáть в национáльный нигилúзм

нигилист *сущ. книжн.* нигилúст

нигилúстик *прил.* нигилистúческий, нигилúстский; *~ караш* нигилистúческий взгляд

нигилистлáрча *нареч.* нигилистúчески, подóбно нигилúсту

нигъмәт *сущ.* **1.** пúща, едá, кýшанье, снедь; я́ства; *төрле ~ләр* разлúчные я́ства **2.** изы́сканная едá

нигъмәтле *прил.* имéющий пищевы́е продýкты (припáсы); обеспéченный изы́сканной едóй

нида *сущ. уст.* **1.** зов, призы́в; восклицáние; *заман ~лары* призы́вы врéмени (эпóхи); *ерактан көчле ~ ишетелә* издалекá слы́шен грóмкий зов **2.** *поэт.* звýки плáча; рыдáния, стóны, вóпли; *кара туфрак тулы мазлум ~сы* земля́ полнá стóном угнетённых

нидалы *прил. уст.* востóрженный, рáдостный (*о голосе*); *~ тавышлар белән кунакларны каршылау* рáдостными вóзгласами встречáть гостéй

ни́дән *мест. вопр.* отчегó, почемý, из-за чегó, с чегó; *аның эче поша, ~, үзе дә белми* у негó болúт душá, отчегó, и сам не знáет

ни́дәндер *мест. неопр.* отчегó-то, почемý-то; *~ күңелсез булып китте* почемý-то стáло грýстно

ни́дер *мест. неопр.* нéчто; чтó-то; *~ җитми* что-то не хватáет; *~ эшләргә кирәк* нáдо чтó-то дéлать; *~ бирергә кирәк* нýжно чегó-то дать

нидерланд *сущ.* нидерлáндец, нидерлáндка

низаг *сущ. уст. книжн.* спор; ссóра, рáспря; *туганнар арасында төрле ~лар чыга башлады* мéжду рóдственниками началúсь рáзные ссóры

низаглаштыру *понуд. от* **низаглашу**; заставля́ть ссóриться, поссóрить

низаглашу *неперех. уст. книжн.* спóрить, ссóриться, поссóриться, быть в ссóре || спор, ссóра

низаглы *прил. уст.* **1.** спóрный, оспáриваемый; *~ мәсьәләләр* спóрные вопрóсы **2.** конфлúктный, бýрный, скандáльный; *~ җыелыш* скандáльное собрáние

низаглылык *сущ. уст.* **1.** спóрность **2.** конфлúктность, скандáльность

низам *сущ. уст.* **1.** распоря́док дня (*в медресе*); *см.* **тәртип** **2.** распоряжéние, постановлéние **3.** расписáние

низамлы *прил. уст. см.* **тәртипле**

низамнамә *сущ. уст.* **1.** собрáние (свод) закóнов **2.** положéние; прáвила, устáв

ник *мест. вопр.* зачéм, почемý, отчегó; *~ безгә килмисең?* почемý к нам не прихóдишь?; *~ килдең?* зачéм пришёл?; *~ шунда шартламый* по мне, пусть хоть лóпнет; *~ шунда дөньясы асты вскә килми* ≈ да горúонó сúним плáменем ◊ **~ бардым көненә төштем** пожалéл (раскáялся), что пошёл

ни́кадәр *мест. вопр.* **1.** сколь, скóлько; *~ китап укылды!* скóлько книг прочúтано!; *~ кәгазь кирәк?* скóлько бумáги нýжно!; *бу көннәрдә ~ яшь тугелде* скóлько слёз прóлито в э́ти дни **2.** в какóй стéпени, до какóй стéпени, до чегó; какóй, как; *~ җәваплы эш!* какáя ответственная рабóта! *син минем ~ сагынуымны белсәң иде* éсли бы ты знáла, как я соскýчился **3.** *в сост. союз. сл.* скóлько ..., стóлько; чем ..., тем ...; *баланы ~ иркәләсәң, шулкадәр бозыла гына* чем бóльше балýешь ребёнка, тем он бóльше пóртится; *дусларың ~ күп булса, шулкадәр син бәхетле* чем бóльше друзéй, тем ты счастлúвее

никадәрле *мест. см.* **никадәр**

никах *сущ.* **1.** *уст.* никáх (*мусульманский религиозный обряд бракосочетания*); *~ уку* читáть специáльную молúтву во врéмя обря́да бракосочетáния **2.** брак, бракосочетáние; брáчный договóр; брáчный союз; *аларның ~ын уңышлы дип әйтеп булмый* нельзя́ их брак назвáть удáчным □ **~ мәҗлесе** *уст.* угощéние гостéй пóсле чтéния молúтвы бракосочетáния; **~ уку (укыту)** *уст.* читáть специáльную молúтву во врéмя обря́да бракосочетáния; **~ яңарту** *уст.* женúться вторúчно; **~тан тыш** внебрáчный

никахландыру *перех.* совершáть/совершúть обря́д бракосочетáния || совершéние обря́да бракосочетáния над *кем-л.*

никахлану *неперех.* **1.** быть совершённым (*об обряде бракосочетания*) **2.** женúться на *ком-л.*, выходúть зá́муж *за кого́-л.*

никахлау *перех. см.* **никахландыру**

никахлы *прил.* **1.** *уст.* офóрмленный религиóзным обря́дом (*о браке*) **2.** 1) регистрúрованный,

узако́ненный (*о браке*) 2) состоя́щий в зако́нном бра́ке (*мужчина*)

никахсыз *нареч.* без бра́ка, без регистра́ции (*о сожительстве*) || *прил. уст.* **1.** не офо́рмленный религио́зным обря́дом (*о браке*) **2.** внебра́чный; ~ *бала* внебра́чный ребёнок

никахсызлык *сущ.* **1.** 1) отсу́тствие офо́рмленного религио́зным обря́дом бра́ка 2) отсу́тствие офо́рмленного бра́ка **2.** безбра́чие

ни́кель *сущ.* ни́кель; *кашыкларга ~ йөгертү* покры́ть ло́жки ни́келем, никелирова́ть ло́жки || *прил.* ни́келевый; ~ *кашыклар* ни́келевые ло́жки

ни́кельләнү *страд. от* **никельләү**; никелирова́ться, быть никелиро́ванным; *чәйнек ~гән* ча́йник никелиро́ван

ни́кельләү *перех.* никелирова́ть, покры́ть ни́келем || никелирова́ние, никелиро́вка; *самоварны ~* никелирова́ть самова́р

ни́кельләүче *сущ.* никелиро́вщик

ни́кельле *прил.* никелиро́ванный; ~ *карават* никелиро́ванная крова́ть

никотин *сущ.* никоти́н || никоти́нный; никоти́новый; ~ *үпкәгә бик нык зыянлы* никоти́н о́чень вре́ден для лёгких; ~ *исе* никоти́нный за́пах

никотинлы *прил.* никоти́нный, никоти́новый, содержа́щий никоти́н

никрут *сущ. уст. разг. см.* **рекрут**

никрутлык *сущ. уст. разг. см.* **рекрутлык**

ни́ктер *мест.* почему́-то, отчего́-то, заче́м-то; ~ *булмә салкын* почему́-то в ко́мнате хо́лодно; ~ *баш авырта* отчего́-то боли́т голова́

ни́лектән *мест. вопр., причины* почему́, отчего́, с чего́; ~ *ул болай?* почему́ э́то так?

ни́мфа *сущ. миф.* ни́мфа (*божество в виде женщины*)

ни́нди *мест. вопр.* **1.** *в разн. знач.* како́й, како́в; ~ *чәчәк?* како́й цвето́к?; ~ *күлмәк кирәк?* како́е пла́тье ну́жно?; ~ *матур көн!* како́й хоро́ший день! **2.** что, что за; ~ *кеше ул?* что он за челове́к? *бу ~ эш?* что э́то тако́е? **3.** *в составе союзн. сл.* **нинди ..., шундый** како́й ..., тако́й ..., тако́в ...; *дустың ~, кадерең шундый* (*посл.*) како́в друг, таково́ уваже́ние □ **~ булса да** любо́й, како́й уго́дно; ~ **генә булмасын** како́й бы ни был; како́й ни на есть; ~ **генә булса да** хоть како́й-нибудь, хоть како́й-то; ~ **дә булса** како́й-либо; како́й ни на есть

ни́ндидер *мест. неопр.* како́й-то; ~ *кеше* како́й-то челове́к

ни́ндирәк *мест. вопр.* како́в, како́в из себя́; ~ *кеше ул?* како́в он из себя́?

ни́ппел|ь *сущ. тех.* ни́ппель; *велосипед ~е* велосипе́дный ни́ппель

ниргә *сущ.* **1.** вене́ц, звено́, оди́н ряд сру́ба (*связь четырёх брёвен одного ряда сруба*) || вене́чный; *егерме ~ле йорт* дом, состоя́щий из двадцати́ венцо́в; ~ *атламасы* вене́чная скоба́ **2.** фунда́мент; основа́ние

нисан *сущ. уст.* **1.** апре́ль (*по сирийскому календарю*) **2.** пе́рвый апре́льский дождь; *см. тж.* **ләйсән**

нисбәт *сущ.* **1.** связь, отноше́ние; *музыка белән аның арасында нинди ~?* ме́жду ним и му́зыкой кака́я связь?; *ике зурлык арасындагы ~ мат.* отноше́ние ме́жду двумя́ величи́нами **2.** пропо́рция, соотноше́ние, соразме́рность; сте́пень; *көчләр ~е* соотноше́ние сил

нисбәтән *нареч. уст.* по сравне́нию, по отноше́нию; сравни́тельно с *кем-л., чем-л.*; *бу әсәр яңаларга ~ начаррак* э́то произведе́ние по сравне́нию с но́выми ху́же

нисбәтендә *предл.* в связи́, из-за, по, по отноше́нию к ..., в отноше́нии..., по ме́ре ...; по слу́чаю; *шәхси тормышы юклыгы ~ Тукаев үзенең әдәби тормышына ныграк бирелә* Тука́ев из-за отсу́тствия ли́чной жи́зни ещё бо́льше отдава́лся литерату́ре

нисбәтлек *сущ.* **1.** *см.* **нисбилек 2.** *см.* **мөнәсәбәтлелек**

нисби *прил.* относи́тельный, релати́вный; ~ *сыйфатлар* относи́тельные прилага́тельные; ~ *хакыйкать* относи́тельная и́стина

нисбилек *сущ.* относи́тельность; *төшенчәнең ~ге* относи́тельность поня́тия; *~к теориясе* тео́рия относи́тельности

ни́ткән *мест. см.* **нинди** 1, 2; ~ *эш бу?* ну что э́то?

нитрат *сущ. хим.* нитра́т; ~ *бактерияләре* бакте́рии нитра́та

нитроглицерин *сущ. хим.* нитроглицери́н; *табиб килгәнче авыруга ~ яки валидол бирергә кирәк* до прихо́да врача́ больно́му ну́жно дать нитроглицери́н и́ли валидо́л

нитрон *сущ. спец.* нитро́н; *йонны ~ белән алмаштыру* замени́ть ше́рсть нитро́ном

нитроэмаль *сущ.* нитроэма́ль; *идәнне ~ белән буяу* пол покра́сить нитроэма́лью

нифак *сущ. уст. книжн.* **1.** нейскренность, фарисе́йство, лицеме́рие, фальшь, двули́чие, двоеду́шие **2.** разно́ры, ра́спри; *бетсен ~, яшәсен иттифак!* (*погов.*) долго́й ра́спри, да здра́вствует согла́сие! ◊ **~ базары** я́рмарка тщесла́вия; борьба́ под ви́дом благожела́тельности

нифаклы *прил. уст. книжн.* нейскренний, лицеме́рный, двули́чный, фальши́вый, притво́рный, фарисе́йский; поддельный; ~ *сүзләр* фальши́вые слова́; ~ *елмаю* лицеме́рная улы́бка

ни́хәл *межд. вопр.* как дела́, как поживаешь, как живёшь; *~, көннәр ничек үтә?* как дела́, как дни прохо́дят?; ~ *итү* что де́лать, что сде́лать (*быть в недоумении, оказаться в затруднительном положении*); ~ *итим, ничек булышыйм сиңа?* не зна́ю, что и де́лать, как тебе́ помо́чь?

ни́хәтле *мест. вопр. см.* **никадәр**

ниһая *сущ. книжн.* коне́ц, преде́л, оконча́ние; *~се булмаган юл* доро́га, не име́ющая конца́

ниһаясез *прил. уст. в разн. знач.* бесконе́чный, безграни́чный, беспреде́льный, безбре́жный; ~ *кыр һәм урманнар* бесконе́чные поля́ и леса́; ~ *җыр яңгырый* звучи́т бесконе́чная пе́сня || *нареч.* **1.** *в разн. знач.* бесконе́чно, безграни́чно, беспреде́льно, безме́рно, без конца́ и кра́я; ~ *ачулану* бесконе́чно серди́ться; ~ *ярату* безме́рно люби́ть; *су ~ җәелгән* вода́ безбре́жно разлила́сь **2.** ви́димо-неви́димо, о́чень мно́го; *халык ~ җыелган* наро́ду собрало́сь ви́димо-неви́димо || *частица* о́чень, беспреде́льно, необыча́йно, безграни́чно, чрезвыча́йно, безме́рно; ~ *биек таулар* необыча́йно высо́кие го́ры; ~ *зур ташлар* о́чень больши́е ка́мни; ~ *олы мәхәббәт* безграни́чная любо́вь

ни́һаять|ь *сущ.* коне́ц, преде́л, оконча́ние; *~е булмаган юл* доро́га, не име́ющая конца́; *~е булмаган нәфрәт* не име́ющая преде́ла не́нависть || *вводн. сл.* наконе́ц, в конце́ концо́в; *~ь, кыш җитте* наконе́ц, пришла́ зима́; *~ь, үзе дә аңлады* наконе́ц, и сам по́нял □ **~ь дәрәҗәдә** в вы́сшей сте́пени; кра́йне, о́чень, весьма́

ни́чаклы *мест. вопр. см.* **никадәр**

ни́чә *мест.* **1.** *вопр.* ско́лько; *бакчаңда ~ алмагач бар?* ско́лько я́блонь в твоём саду́? **2.** *относит.* ско́лько,

ско́лько раз; ~ *күрсәң дә, ул әштә булыр* ско́лько раз ты его́ ни уви́дишь, он бу́дет за рабо́той

ни́чәдер *мест. неопр.* ско́лько-то, ско́лько; *кешеләр бар, ~, белмим* лю́ди есть, но ско́лько, не зна́ю

ни́чәләп *мест.* **1.** по ско́льку; ~ *буләбез?* по ско́льку бу́дем дели́ть? **2.** приме́рно, приблизи́тельно ско́лько; ~ *кеше бар икән җыелышта?* приме́рно ско́лько челове́к на собра́нии?

ни́чәле *мест. вопр. разг.* како́го разме́ра (*об обуви*), ско́лько ли́ний (*о лампе*); ~ *галош?* како́го разме́ра гало́ши?

ни́чәле|к *отвл. сущ.* коли́чество (ско́лько); *кардәшләреңнең ~ген санап кара* посчита́й, ско́лько у тебя́ ро́дственников

ни́чәмә-ни́чә *нареч. разг.* ви́димо-неви́димо; мно́го, о́чень мно́го; *ничәмә-ничә тапкыр чакырды* звал мно́го раз

ни́чәнче *мест. вопр.* кото́рый (по счёту), како́й (по поря́дку); ~ *класста укыйсың?* в како́м кла́ссе у́чишься?

ни́чәнчеле|к *отвл. сущ.* ме́сто (в поря́дке, сте́пени); *урыныңның ~ген беләсеңме?* зна́ешь но́мер своего́ ме́ста?

ни́чәсе *мест. вопр.* како́й (*о дне недели, месяца*); *бүген ~?* како́е сего́дня число́?; ~ *икәнен дә белгән юк* да́же не зна́ю, како́е число́

ни́чәү *мест. разг.* ско́лько всего́?; *алар ~?* ско́лько их всего́?

ни́чәшәр *мест. вопр.* по ско́льку; ~ *китап алырга кирәк?* по ско́льку книг (на ка́ждого) ну́жно купи́ть?

ни́чәшәрләп *мест. вопр. см.* **ничәшәр**

ни́чек *мест. вопр.* **1.** как, каки́м о́бразом; ~ *кердең минем янына?* как ты зашёл ко мне? *бу китап ~ сиңа эләкте?* каки́м о́бразом э́та кни́га попа́ла к тебе́? **2.** *в ритор. вопр. и воскл.* как, как же; ~ *шатланмаска ди!* как же не ра́доваться!; ~ *мин сине ялгызыңны калдырыйм?* как я оста́влю тебя́ одного́? **3.** как, како́в, како́й; *тормышларың ~ соң бара?* как идёт твоя́ жизнь?; *кәефең ~?* как твоё настрое́ние? **4.** как (*при удивлении, восхищении, негодовании, сожалении и т. п.*); ~ *матурланып киткәнсең!* как похороше́л!; ~, *син наман мондамыни?* как, ты всё ещё здесь?; ~ *теле бара?* как язы́к повора́чивается? **5.** как, каки́м о́бразом (о́браз де́йствия); *нәрсәдер сөйләү түгел, аны ~ итеп сөйләү әһәмиятле* не ва́жно что говори́шь, а ва́жно, как говори́шь **6.** *в составе союзн. сл.* **1)** *в прид. предл. образа действия* как ..., так ...; *кигән кием ~ туза, яшь гомер шулай уза* как изна́шивается оде́жда, так и мо́лодость прохо́дит **2)** *в придат. опред. соотв.* како́й, како́в; *сәламе ~, җавабы да шундый* (*погов.*) како́в приве́т, тако́в и отве́т; *башы ~ — ахыры шулай* каково́ нача́ло, тако́в и коне́ц □ ~ **алай** как так; ~ **кенә** как, как бы; да как ◊ ~ **итте (кирәк, җитте) алай (шулай)** **1.** е́ле-е́ле, едва́, с трудо́м, едва́-едва́, ко́е-ка́к; че́рез си́лу, с го́рем пополам, наси́лу; ~ *кирәк алай капчыкны күтәрдем* с трудо́м по́днял мешо́к **2.** небре́жно, неаккура́тно, неря́шливо, невнима́тельно, ко́е-ка́к; как попа́ло, как придётся, спусти́ рукава́, тяп-ля́п; ка́к-нибудь; ~ *кирәк алай киенеп эшкә йөгердем* оде́лся как попа́ло и побежа́л на рабо́ту; ~ **кенә** **1.** как, каки́м о́бразом (при беспоко́йстве, пережива́нии и *т. п.*); ~ *кенә укырсың икән?* как бу́дешь учи́ться?; *автобуска ~ кенә утырырсың икән?* как ся́дешь в авто́бус? **2.** как, ка́к бы, как то́лько (*обозн. сильное желание*); ~ *кенә бу китапны алырга?* ка́к бы доста́ть э́ту кни́гу?; ~ **кенә булмасын** ка́к бы то ни́ было, во вся́ком слу́чае, при всех усло́виях, как-ника́к; ~ **кенә булса да** во что́ бы то ни ста́ло; ка́к бы то ни́ было; та́к и́ли ина́че; ~ **кенә әле** ещё как; ~ **килеп чыгар** как полу́чится; ~ **тә** в любо́м слу́чае; ~ **туры килә шулай** ко́е-ка́к

ни́чектер *мест.* **1.** *неопр.* как-то; ~ *мин аны бер кургән идем* как-то я его́ встреча́л **2.** *относит.* как уж; *анда эшләр ~ инде, белмим* я не зна́ю, ка́к уж там дела́

нишан *сущ. книжн.* **1.** *диал.* знак, при́знак, приме́та; след; *~ы да калмады* не оста́лось и следа́ **2.** мише́нь **3.** пода́рок в знак ве́рности (*кольцо*) **4.** *ист.* о́рден, почётный значо́к

ни́шлә|ү *перех.* что де́лать, сде́лать *с кем-л., с чем-л., что-л.* де́лать, сде́лать (*по отношению к кому-л., чего-л.*); *~әсең бит, язмышың шундый булгач* что поде́лаешь, е́сли судьба́ твоя́ такова́

ни́шлә|ү **1.** *неперех.* 1) что де́лать (сде́лать), как поступи́ть, как быть, чем заня́ться; *син ~исең, өйгә кайтасыңмы әле?* что ты де́лаешь, собира́ешься ли домо́й? *~им, нәрсә дип әйтим?* как быть, что сказа́ть? 2) *в ф.* **ништләп** почему́, по како́й причи́не; за что; *~әп килми икән безгә?* почему́ же он не прихо́дит к нам? *~әп ул миңа үпкәләде икән?* интере́сно, за что э́то он оби́делся на меня́? **2.** что́-то де́лать, сде́лать, как-то поступа́ть/поступи́ть, занима́ться/заня́ться че́м-нибудь; *малайлар шофёрның ~әгәнен карап торалар* ма́льчики наблюда́ют за тем, что шофёр де́лает □ **~әргә дә белмим** не зна́ю, что и де́лать; **~исең бит** *вводн. сл.* что поде́лаешь, ничего́ не поде́лаешь; *~әмәк кирәк?* что (ты) тут поде́лаешь?

ният *сущ.* **1.** 1) наме́рение, цель, план, за́мысел, предложе́ние, побужде́ние, устремле́ние; *эшнең башы — ~ (погов.)* наме́рение — нача́ло де́ла; ~ *гамәлдән артык (погов.)* цель важне́е де́ла; ~ *~кә җиткерә (погов.)* наме́рение приближа́ет к це́ли; *бернинди ~ем юк иде* никако́го пла́на (за́мысла) у меня́ не́ было 2) по́мысел, у́мысел (*о тайном, чаще предосудительном*); *явыз (усал, яман) ~ белән* со злым у́мыслом; умы́шленно **2.** *рел.* моли́тва, сотворённая во исполне́ние жела́ний □ ~ **итү (кылу)** намерева́ться, име́ть наме́рение; предполага́ть, заду́мать, реши́ть; **~кә ирешү (җитү)** доби́ться це́ли (жела́емого); **~тән кайту, үзгәртү** измени́ть наме́рение, переду́мать, отказа́ться от це́ли (наме́рения)

ниятлән|ү *неперех.* **1.** *страд. от* **ниятләү**; быть заду́манным; ста́виться це́лью; *~гән эш* заду́манное де́ло **2.** *см.* **ниятләү**

ниятлә|ү *перех.* **1.** намерева́ться, вознаме́риваться/вознаме́риться, име́ть наме́рение, заду́мывать/заду́мать, ста́вить, поста́вить себе́ (своей) це́лью (зада́чей), замышля́ть/замы́слить, реша́ть, принима́ть/приня́ть реше́ние, ду́мать, рассчи́тывать, предполага́ть; поду́мывать || наме́рение, реше́ние, предположе́ние; *иртәгә китәргә ~де* вознаме́рился за́втра уе́хать; *аспирантурага керергә ~ү* ста́вить свое́й це́лью поступи́ть в аспиранту́ру; *өйләнергә ~ү* заду́мать жени́ться **2.** *рел.* посвяща́ть/посвяти́ть *чему-л.*; *намаз ~ү* посвяти́ть намаз

ниятле *прил.* **1.** наме́ренный, зара́нее обду́манный; ~ *эш* зара́нее обду́манное де́ло **2.** име́ющий наме́рение, цель, с наме́рением; *изге ~ кеше* челове́к с до́брыми наме́рениями; *явыз (усал) ~* с плохи́ми наме́рениями; зло́стный, зловре́дный, кова́рный

нова́тор *сущ.* нова́тор || нова́торский; *сәнгать ~лары* нова́торы иску́сства; *~лар башлангычы* нова́торский почи́н

нова́торларча *нареч.* по-нова́торски; *~ эшләү* рабо́тать по-нова́торски

нова́торлык *сущ.* нова́торство || нова́торский; *техникадагы ~* нова́торство в те́хнике; *поэзиядәге ~* нова́торство в поэ́зии; *~ методы* нова́торский ме́тод

нове́лла *сущ. лит.* нове́лла; *Каюм Насыйри ~лары* нове́ллы Каю́ма Насыри́

нове́ллачы *сущ.* новелли́ст; *Чехов — ~* Че́хов — новелли́ст

новокаин *сущ. мед.* новокаи́н || новокаи́новый; *~ блокадасы* новокаи́новая блока́да

ногман: ногман чәчәге *бот.* анемо́на

ногыр *сущ. этногр.* ногы́р (*название казанских татар у татар-мишарей*)

ногыт *сущ. бот.* бобы́ (*как вид растения*) || бобо́вый; *ат ~ы* ко́нские бобы́; *~ кузагы* бобо́вый стручо́к □ **~ борчагы** бобы́; нут; **~ салу** гада́ть на бобо́х; **~ куагы** *бот.* бобо́вник

ногытчы *сущ. уст.* ворожея́ на бобо́х

ножо́вка *сущ. разг.* ножо́вка; *фанерны ~ белән кисү* распи́ливать фане́ру ножо́вкой

нока́ут *сущ. спец.* нока́ут; *ике удардан ~ ясау* по́сле двух уда́ров посла́ть (отпра́вить) в нока́ут

нокда́ун *сущ. спец.* нокда́ун; *~ санау* засчита́ть нокда́ун

нократ *сущ.* **1.** *ист.* серебро́; серебряная моне́та; *~ның нуктасы юк* (*посл.*) *букв.* у серебряной моне́ты нет по́вода **2.** река́ Вя́тка || вя́тский; *~ буйлары* берега́ Вя́тки **3.** *~лар* вя́тичи; нукра́тские тата́ры || *прил.* серебряный; *~ балдак* серебряное кольцо́

ноксан *сущ. уст. книжн.* недоста́ток, дефе́кт, изъя́н; недочёт; *см. тж.* **җитешсезлек**; *әсәрдә ~ бик күп* в произведе́нии о́чень мно́го недоста́тков

нокта *сущ.* **1.** *в разн. знач.* то́чка; *кара ~* чёрная то́чка; *кисешү ~сы* то́чка пересече́ния; *тауның иң биек ~сы* са́мая высо́кая то́чка горы́; *җөмлә ахырындагы ~* то́чка в конце́ предложе́ния **2.** то́чка, ме́сто, пункт; *сәүдә ~сы* торго́вая то́чка; *күзәтү ~сы* пункт наблюде́ния, наблюда́тельный пункт; *пулемёт ~сы* пулемётная то́чка **3.** то́чка, преде́л, у́ровень; *су иң югары ~га җитте* вода́ дости́гла вы́сшего у́ровня; *аңлашу иң кискен ~га җитте* объясне́ние дости́гло са́мой реши́тельной то́чки □ **~ кебек (төсле)** как то́чка (*об очень маленьком*) ◊ **~ кую** поста́вить то́чку, конча́ть, прекраща́ть *какое-л.* де́ло; **(бер) ~га карау (текәлү)** смотре́ть/гляде́ть, уста́виться в одну́ то́чку; **(бер) ~га бәрү** бить в одну́ то́чку; **(бер) ~ны да калдырмый, ~сына кадәр** до то́чки, в мельча́йших подро́бностях, в совершенстве (*знать, видеть, решить и т. п.*); **~сы ~га туры килү** совпада́ть точь-в-точь, то́чка в то́чку, целико́м, по́лностью; **~сына тию (бәрү)** попа́сть в са́мую) то́чку

нокталау *перех.* пункти́ровать, отмеча́ть то́чками (пункти́ровом); *картаны ~* пункти́ровать ка́рту

нокталы *прил.* **1.** с то́чкой, име́ющий то́чку (то́чки); *~ хәреф* бу́ква с то́чкой **2.** то́чечный, состоя́щий из то́чек, пункти́рный, пункти́рованный; *~ бизәк* то́чечный узо́р; *~ контур* то́чечный ко́нтур; *~ сызык* пункти́рная (то́чечная) ли́ния; пункти́р □ **~ бегония** *бот.* бего́ния рекс; **~ өтер** то́чка с запято́й

ноктюрн *сущ. муз.* ноктю́рн; *Шопен ~ы* ноктю́рн Шопе́на

ноль, нуль *числ.* **1.** ноль, нуль || нолево́й, нулево́й; *~ температура* нолева́я температу́ра; *~ зурлык* нулева́я величина́ **2.** *перен.* ноль, ничто́, пусто́е ме́сто (*о незначительном, ничтожном человеке, о событии, деле, не имеющем значения*); *синең тырышуың минем өчен ~* твой стара́ния для меня́ ничто́

ноль-ноль *нареч.* **1.** ноль-ноль, ро́вно, то́чно; ни мину́той ра́ньше и́ли по́зже; *ике сәгать ноль-нольдә мин килермен* в два часа́ ноль-ноль я приду́ **2.** *спорт.* ноль-ноль; ничья́; *футбол ноль-ноль белән бетте* футбо́л заверши́лся вничью́

номенклату́ра *сущ.* номенклату́ра; *медицина ~сы* медици́нская номенклату́ра; *хайваннар һәм үсемлекләр дөньясындагы төрләрне исемләү ~сы* номенклату́ра назва́ний ви́дов в ми́ре живо́тных и расте́ний

номенклату́ралы *прил.* номенклату́рный; *~ исемлек* номенклату́рный спи́сок; *~ урыннарда эшләү* рабо́тать на номенклату́рных должностя́х; *~ хезмәткәр* номенклату́рный рабо́тник

но́мер *сущ. в разн. знач.* но́мер; *йорт ~ы ун* но́мер два́дцать де́сять; *машина ~ы* но́мер маши́ны; *газетаның яңа ел ~ы* новогодний но́мер газе́ты

но́мерлан|у *страд. от* **номерлау**; нумерова́ться, быть нумеро́ванным; *бүлмәләр ~ган иде* ко́мнаты уже́ бы́ли нумеро́ваны

но́мерлату *понуд. от* **номерлау**

но́мерлау *перех.* номерова́ть, нумерова́ть; *дәфтәр битләрен ~* нумерова́ть страни́цы тетра́ди; *йортларны ~* номерова́ть дома́

но́мерлы *прил.* **1.** нумеро́ванный, име́ющий но́мер; име́ющий номерно́й знак; *~ урыннар* нумеро́ванные места́; места́, име́ющие номера́ (*в автобусе, в театре и т. п.*) **2.** име́ющий *какой-л.* но́мер, за но́мером ..., под но́мером ...; *15 ~ документ* докуме́нт за но́мером 15

номинал *сущ. спец.* номина́л; *~ буенча сату* прода́жа по номина́лу

номиналь *прил. спец.* **1.** номина́льный; *~ бәя* номина́льная цена́; *~ эш хакы* номина́льная за́работная пла́та **2.** номина́льный; фикти́вный; *~ хезмәткәр* номина́льный сотру́дник

номинатив *прил. лингв.* номинати́вный; *сүзнең ~ функциясе* номинати́вная фу́нкция сло́ва; *~ җөмлә* номинати́вное предложе́ние

номогра́мма *сущ. мат.* номогра́мма

нонпарель *сущ. спец.* нонпаре́ль; *~ шрифты петит-тан да ваграк* шрифт нонпаре́ль ме́льче да́же пети́та

норвег *сущ.* норве́жец || норве́жский; *~лар арасында* среди́ норве́жцев; *~ теле* норве́жский язы́к

норвегияле *сущ.* норве́жец, жи́тель Норве́гии

норд *сущ. спец.* **1.** норд: се́вер, се́верное направле́ние || но́рдовый; *~ дулкыннары* но́рдовые во́лны **2.** норд; се́верный ве́тер

норд-вест *сущ. спец.* **1.** норд-ве́ст (*северо-запад, северо-западное направление*) || норд-ве́стовый; *норд-вест җиле* норд-ве́стовый ве́тер **2.** норд-ве́ст (*северо-западный ветер*)

норд-ост *сущ. спец.* **1.** норд-о́ст (*северо-восток, северо-восточное направление*) || норд-о́стовый; *норд-ост җиле* норд-о́стовый ве́тер **2.** норд-о́ст (*северо-восточный ветер*)

но́рма *сущ. в разн. знач.* но́рма; *ашау-эчү ~сы* но́рма пита́ния; *әдәби тел ~лары* но́рмы литературного языка́; *~га керү* войти́ (прийти́) в но́рму; *~ билгеләү* нормирова́ть; *~га куелган* нормиро́ванный; *~га салу* нормирова́ть; *~га салыну (китерелү)* нормирова́ться

но́рмалан|у *страд. от* **нормалау**; нормирова́ться, быть нормиро́ванным; *көнлек эш ~ган* дневна́я рабо́та нормиро́вана

но́рмалау *перех.* норми́рова́ть || норми́рова́ние; норми́ро́вка; *эшне ~* нормирова́ть рабо́ту; *эш хакын ~* нормирова́ть за́работную пла́ту

но́рмалаучы *сущ.* норми́ро́вщик, норми́ро́вщица; *эш көнен ~* норми́ро́вщик рабо́чего дня

но́рмалаштыру *перех.* норми́рова́ть || норми́рова́ние, норми́ро́вка; *эш куләмен ~* нормирова́ть объём рабо́ты

но́рмалаштырылу *страд. от* **нормалаштыру**; нормирова́ться || нормирова́ние, норми́ро́вка

но́рмалы *прил.* **1.** норми́ро́ванный; име́ющий но́рму; *~ эш көне* норми́ро́ванный рабо́чий день **2.** норми́ро́ванный; устано́вленный, определённый, введённый но́рмой (но́рмами); *~ йоклау* норми́ро́ванный сон; *~ ашау* еда́, устано́вленная но́рмой (но́рмами)

нормаль I *сущ. мат.* норма́ль

нормаль II *прил.* **1.** норма́льный, соответствующий но́рме, есте́ственный, обы́чный; *~ пульс* норма́льный (соответствующий но́рме) пульс; *~ куренеш* обы́чный вид, обы́чное явле́ние **2.** норма́льный, здоро́вый (*психически*); *~ кеше* норма́льный челове́к □ **~ булмау (булмаганлык, түгеллек)** ненорма́льность; **~ түгел** ненорма́льный

нормальләнү *неперех.* нормализова́ться, станови́ться/стать норма́льным; *баланың сөйләве ~де* речь ребёнка нормализова́лась

нормальләштерү *перех.* нормализова́ть, стабилизи́ровать || нормализа́ция; *эш шартларын ~* нормализова́ть усло́вия труда́

нормальләшү *неперех.* нормализова́ться, станови́ться/стать норма́льным, стабилизи́роваться || нормализа́ция; *мөнәсәбәтләр ~те* отноше́ния ста́ли норма́льными

норман *сущ.* норма́нн, норма́нны || норма́ннский; *~ кабиләләре* норма́ннские племена́

норматив I *сущ.* норма́тив; *техник ~лар* техни́ческие норма́тивы

норматив II *прил. в разн. знач.* норма́тивный (*о грамматике, запасе чего-л., системе оплаты и т. п.*)

нормировщик *сущ.* норми́ро́вщик, норми́ро́вщица

норсульфазол *сущ. мед.* норсульфазо́л

носи́лка *сущ.* носи́лки; *~ белән ком ташу* на носи́лках таска́ть песо́к; *яралыны ~га салу* укла́дывать ра́неного на носи́лки

носи́льщик *сущ. разг.* носи́льщик; *вокзалда ~ булып эшләү* рабо́тать на вокза́ле носи́льщиком

но́та I *сущ.* муз. но́та; но́ты || но́тный; *бас ~сы* басо́вая но́та; *~га салу* записа́ть на но́ты; *~ буенча җырлау* петь по но́там; *~ кәгазе* но́тная бума́га; *~ билгесе* но́тный знак

но́та II *сущ. дипл.* но́та; *протест ~сы* но́та проте́ста

нотариаль *прил. в разн. знач.* нотариа́льный; *~ контора* нотариа́льная конто́ра; *~ күчермә* нотариа́льная ко́пия

нота́риус *сущ.* нота́риус; *документларны ~тан раслату* заве́рить докуме́нты у нота́риуса

нота́ция *сущ. в разн. знач.* нота́ция; *~ уку* чита́ть нота́цию

нотификация *сущ. дипл.* нотифика́ция (*извещение о чём-л. нотой*)

нотык *сущ.* речь; *~ сөйләү* держа́ть (говори́ть) речь, выступле́ние с ре́чью

ноябрь *сущ.* ноя́брь || ноя́брьский; *~ башларында* в нача́ле ноября́; *~ көннәре* ноя́брьские дни

нөҗүм *сущ. уст. книжн.* звёзды □ **~ гыйлеме** астроно́мия

нөктә *сущ.* **1.** *см.* **нокта 2.** *перен.* оби́да на *кого-л.*; *күңелдә ~ саклау* храни́ть в душе́ оби́ду

нөктәле *прил.* **1.** *см.* **нокталы 2.** *перен.* затаи́вший оби́ду; *см. тж.* **кинәле**

нөре *сущ.* **1.** 1) распло́д насеко́мых; распло́д пчёл 2) личи́нка; личи́нки (*находящиеся вместе*) **2.** ра́зовое появле́ние мно́жества насеко́мых одного́ ви́да; *кырмыска ~се* внеза́пное появле́ние муравьёв **3.** *перен.* многочи́сленное семе́йство □ **~ күбәләге** подёнка; **~ корты** пчели́ная вошь (*черви, уничтожающие пчёл*)

нөрләү *неперех.* **1.** появля́ться/появи́ться (*о множестве червей, личинок*) **2.** *перен.* расти́ вме́сте (*о многодетной семье*)

нөсхә *сущ.* шту́ка, экземпля́р; *ничә ~ китап?* ско́лько экземпля́ров книг? *төп ~* оригина́л, по́длинник, по́длинный экземпля́р

нөсхәлек *прил.* белова́я (*о бумаге*)

ну *межд. разг.* ну (*выражает призыв к действию, удивление, несогласие, неудовлетворённость и т. п.*); *ну, ничек, китап ошадымы?* ну как, понра́вилась кни́га? *ну, хәзер ял итәм инде* ну, тепе́рь бу́ду отдыха́ть; *ну, иптәш, киттек авылга!* ну, това́рищ, пое́хали в дере́вню!

нуга|й *сущ.* **1.** 1) ноге́ец || ноге́йский; □ *астерхан ~е* астраха́нский ноге́ец; *~й хатыны (кызы)* ноге́йка; *~й теле* ноге́йский язы́к 2) *разг.* ноге́йцы, ноге́йский наро́д; *~й арасында* среди́ ноге́йцев **2.** *диал.* тата́рин || тата́рский; □ **~й авылы** куре́нь, вре́менное селе́ние; **~й камчысы 1.** нага́йка **2.** *бот.* чертополо́х курча́вый; **~й сабыны** *бот.* мыльня́нка

нуга́йча *нареч.* по-ноге́йски; на ноге́йском языке́; *~ сөйләшү* говори́ть на ноге́йском языке́ || ноге́йский, на ноге́йском языке́; *~ китаплар* кни́ги на ноге́йском языке́

нужа *сущ. разг.* нужда́, лише́ния, невзго́ды; *~ печән ашата (погов.)* го́лод не тётка (*букв.* нужда́ заставля́ет есть се́но); □ **~ күрү (чигү)** терпе́ть нужду́, лише́ния; **~ төшү** свали́ться на го́лову (*о беде, несчастье, затруднениях*); **~га калу** впада́ть/впа́сть в нужду́, в бе́дность, в затрудне́ния; ◊ **~ иләген иләү** знать, узна́ть, почём фунт ли́ха (*букв.* се́ять че́рез си́то нужды́); **~м төшмәгән** не моя́ забо́та; мне не́чего надрыва́ться

нужалан|у *неперех. разг.* **1.** попада́ть в тру́дное положе́ние (*из-за бедности*); бе́дствовать **2.** (зря) му́читься, би́ться *над чем-л.*; *юкка ~ма* не надрыва́йся впусту́ю

нужалы *прил. разг.* с нуждо́й; в лише́ниях, в нужде́; *~ тормыш* жизнь в нужде́

нужару *неперех. разг.* **1.** станови́ться/стать затрудни́тельным **2.** *см.* **нужалану**

нукта *сущ.* недоу́здок; *атка ~ кидерү (кидертү)* одева́ть на ло́шадь недоу́здок; *тумаган тайга ~ үрмә (посл.)* не плети́ недоу́здок для не роди́вшегося жеребца́

нукталану *страд. от* **нукталау**

нукталату *понуд. от* **нукталау**

нукталау *перех.* надева́ть/наде́ть недоу́здок; взну́здывать/взнузда́ть || взну́здывание; *атны ~* взну́здывать ло́шадь

нуль *сущ. см.* **ноль**

нумератив *прил.* нумерати́вный; *~ сүзләр* нумерати́вные слова́

нумера́ция *сущ.* нумера́ция; *~ сулдан башлана* нумера́ция начина́ется сле́ва

нумера́цияләнү *страд. от* **нумерацияләү**; нумерова́ться || нумера́ция

нумера́циялэ́тү *понуд. от* **нумерациялэ́ү**

нумера́циялэ|ү *перех.* нумерова́ть || нумера́ция; *йорт-ларны ~п чыгу* пронумерова́ть дома́

нумизмат *сущ.* нумизма́т

нумизма́тика *сущ.* нумизма́тика || нумизмати́ческий; *борынгы акчалар музейның ~ бүлегендә саклана* старин-ные моне́ты храня́тся в нумизмати́ческом отде́ле музе́я

нур *сущ.* **1.** луч, свет, сия́ние; *кояш нуры* луч со́лнца; *айның зәгыйфь нуры* сла́бое сия́ние луны́ **2.** *мн.* лучи́; *рентген нурлары* рентге́новы лучи́; *катод нурлары* като́дные лучи́; *радий нурлары* лучи́ ра́дия **3.** *перен.* луч, сия́ние, блеск (глаз) □ **нур авыруы** *мед.* лучева́я боле́знь; **нур рәвешендәге** лучеви́дный; **нур сибелү** излуча́ться; **нур сибү (чәчү) 1.** излуча́ть, озаря́ть **2.** сия́ть; **нур сынышы** *физ.* лучепреломле́ние; **нур уйнау 1.** игра́ луче́й **2.** *перен.* быть приве́тливым; сия́ть (*о глазах*); **нур чәчү** сия́ть, излуча́ть/излучи́ть; **нур чыгару** *физ.* радиа́ция ◊ **нур өстенә нур булу** (*погов.*) ≈ ка́шу ма́слом не испо́ртишь (*букв.* к све́ту добавля́ется свет); **нур сибеп торган** лучеза́рный; **нурга күмелү** озаря́ться/озари́ться луча́ми; **нурлар бөжрасы** орео́л, световы́е кольцо́

нурани *прил. уст. книжн.* све́тлый, сия́ющий; *~ хыял* све́тлая мечта́; *~ мәхәббәт* све́тлая любо́вь

нурландыр|у *перех.* **1. 1)** озаря́ть/озари́ть, освеща́ть/осветѝть *кого-л., что-л.*; *яз кояшы Иделне ~ды* весе́ннее со́лнце озари́ло Во́лгу 2) *перен.* озаря́ть/озари́ть, осия́ть (*лицо, глаза*) **2.** *перен.* 1) украша́ть/укра́сить; кра́сить; *чал чәчләр аның йөзен ~а иде* седы́е во́лосы украша́ли его́ лицо́ 2) вдохновля́ть/вдохнови́ть, воодушевля́ть/воодушеви́ть; дава́ть/дать си́лу, эне́ргию || вдохнове́ние, воодушевле́ние; *күңелне мәхәббәт ~а* любо́вь вдохновля́ет ду́шу

нурлан|у *страд. от* **нурлау 1.** свети́ться, лучи́ться; излуча́ться/излучи́ться, озаря́ться/озари́ться || лучеиспуска́ние, излуче́ние, озаре́ние; *йолдыз ~ып тора* звезда́ све́тится **2.** *перен.* сия́ть, засия́ть, блиста́ть, блесте́ть, просветле́ть, озаря́ться/озари́ться; оживи́ться (*о лице, глазах*)

нурланыш *сущ.* излуче́ние; *якты́лык ~ы* световы́е излуче́ние

нурл|ау *перех.* **1.** 1) излуча́ть/излучи́ть, озаря́ть/озари́ть; освеща́ть/осветѝть 2) *перен.* озаря́ть (*лицо, глаза*) **2.** *перен.* украша́ть/укра́сить, кра́сить; *хатын-кызны чәч ~ый* же́нщин украша́ют во́лосы

нурлы *прил.* **1.** лучи́стый, лучеза́рный, сия́ющий, све́тлый; *~ йолдыз* сия́ющая звезда́; *~ күзләр* лучи́стые глаза́ **2.** *перен.* приве́тливый, све́тлый; *~ йөз* приве́тливое лицо́

нурлыландыру *перех. см.* **нурландыру**

нурлылы|к *сущ.* лучеза́рность; *йөз ~гы* лучеза́рность лица́

нурсыз *прил.* **1.** ту́склый; блёклый, бле́дный; тёмный; *~ йолдыз* бле́дная звезда́; *~ йөз* блёклое (бле́дное) лицо́ **2.** поме́ркший; му́тный, без бле́ска, ту́склый (*о глазах*) **3.** *перен.* се́рый, зауря́дный; *~ тормыш* се́рая жизнь

нурсызлан|у *неперех. в разн. знач.* тускне́ть/потускне́ть, ме́ркнуть, блёкнуть; *йолдызлар ~а һәм сүнәләр* звёзды ме́ркнут и га́снут; *күзләре ~ган* глаза́ его́ потускне́ли

нурсызлык *сущ.* ту́склость, блёклость, бле́дность

ну́трия *сущ. зоол.* ну́трия || ну́триевый; *~ тиресе* ну́триевая шку́рка; *~ тун* ну́триевая шу́ба

ныгаю *неперех. см.* **ныгу**

ныг|у *неперех.* **1.** *в разн. знач.* кре́пнуть/окре́пнуть, укрепля́ться/укрепи́ться, станови́ться/стать бо́лее кре́пким, си́льным, усто́йчивым || укрепле́ние (*растения, здоровья, тела, нервов и т. п.*); *бодай үсте, ~ыды* пшени́ца подняла́сь, окре́пла; *елгада боз ~ыды* на реке́ лёд окре́п; *дуслык көннән-көн ~ый* дру́жба кре́пнет день ото дня; *куллары ~ымаган, күтәрә алмас* ру́ки ещё не окре́пли, подня́ть не смо́жет **2.** 1) укрепля́ться, сосредото́чивать, сконцентри́ровать си́лы; *без авылда ~ып алып, дошманның атакасын кайтарырга тиешбез* мы должны́ укрепи́ться в дере́вне и отрази́ть ата́ку врага́ 2) кре́пнуть/окре́пнуть, укрепля́ться/укрепи́ться, стать бо́лее мо́щным || укрепле́ние; *хуҗалык көннән-көн ~ый бара* хозя́йство кре́пнет (стано́вится бо́лее мо́щным) день ото дня; *авылда тормыш ~ый бара* жизнь в дере́вне всё бо́лее кре́пнет (укрепля́ется) **3.** укрепля́ться/укрепи́ться, упро́чиваться/упро́читься; стать про́чным, надёжным || укрепле́ние, упрочне́ние *книжн.*; *аңа карата хисләрем ~ыды* чу́вства мои́ к нему́ упро́чились; *илнең халыкара хәле ~ыды* междунаро́дное положе́ние страны́ упро́чилось **4.** укрепля́ться/укрепи́ться, упро́чиваться/упро́читься; про́чно утвержда́ться/утверди́ться, устана́вливаться/установи́ться || укрепле́ние, установле́ние; *класста тәртип ~ыды* в кла́ссе укрепи́лась дисципли́на **5.** кре́пнуть/окре́пнуть, устана́вливаться/установи́ться, скла́дываться/ сложи́ться, определя́ться/определи́ться || установле́ние; *үсмер малайның йөреше әле ~ып җитмәгән* у подро́стка ещё похо́дка не сложи́лась

ныгыткыч *сущ.* **1.** крепле́ние, крепёж **2.** *фото.* закрепи́тель || *прил.* крепёжный; *~ болт* крепёжный болт

ныгытма *сущ.* **1.** укрепле́ние, кре́пость; *см. тж.* **кальга, кирмән**; *тимер-бетон ~лар* железобето́нные укрепле́ния; *озак вакытлы ~лар* долговре́менные укрепле́ния **2.** крепле́ние, крепь; *шахталардагы ~лар* крепле́ния на ша́хтах; *чаңгы ~лары* крепле́ния для лыж; *бурап ясалган ~ горн.* сру́бовая крепь

ныгыттыру *понуд. от* **ныгыту**

ныгыт|у *перех.* **1.** *в разн. знач.* крепи́ть, укрепля́ть/укрепи́ть, прикрепля́ть/прикрепи́ть, закрепля́ть/закрепи́ть, подкрепля́ть/подкрепи́ть (*забой на шахтах, детали, паруса, плотину, фундамент, корпус лодки, крышу дома, пески для лесопосадок и т. п.*) || 1) прикрепле́ние, закрепле́ние, подкрепле́ние 2) крепи́тельный, крепёжный; *~у материаллары* крепи́тельные материа́лы; *~у эшләре* крепёжные рабо́ты; *фоторәсемне ~у* закрепи́ть фотосни́мок; *чаңгыларны ~у* закрепи́ть лы́жи; *стеналы терәү белән ~у* подкрепи́ть сте́ну подпо́ркой **2.** укрепля́ть/укрепи́ть, оздоровля́ть/оздорови́ть; укрепле́ние; оздоровле́ние; *саф һава, җәяү йөрү аны физик яктан ~ты* све́жий во́здух, ходьба́ пешко́м физи́чески укрепи́ли его́ **3.** укрепля́ть/укрепи́ть, упро́чивать/упро́чить; *гаиләне ~у* укрепи́ть семью́; *фәнни бәйләнешләрне ~у* укрепи́ть нау́чные свя́зи; *тәртипне ~у* укрепи́ть дисципли́ну; *тынычлыкны ~у* упро́чить мир; *көнкүрешне ~у* упро́чить быт **4.** 1) крепи́ть, укрепля́ть/укрепи́ть, упро́чивать/упро́чить, уси́ливать/уси́лить; де́лать/сде́лать бо́лее си́льным, мо́щным; *илнең оборонасын ~у* крепи́ть оборо́ну страны́; *авыл хуҗалыгын ~у* упро́чить се́льское хозя́йство 2) укрепля́ть/укрепи́ть, упро́чивать/упро́чить; подкрепля́ть/подкрепи́ть || упро́чение; подкрепле́ние; *мәктәпне кадрлар белән ~у* укрепи́ть шко́лу ка́драми; *эшчеләрнең инициативасын техника белән ~у* подкрепи́ть инициати́ву рабо́чих те́хникой **5.** закреп-

олуг *прил. книжн.* **1.** вели́кий, знамени́тый, почте́нный, высокопоста́вленный **2.** пожило́й, ста́рый ‖ *мн.* **олуглар** пожилы́е, ста́ршие; *~лар сүзен тоту* слу́шаться ста́рших (пожилы́х) **3.** большо́й, огро́мный, грома́дный; *~ бәйрәм* большо́й пра́здник; *~ талантка ия булу* облада́ть больши́м тала́нтом ◊ *~* **җанлы** *см.* **олы җанлы**; *~* **күрү** ока́зывать уваже́ние (честь, почёт); почита́ть, благогове́ть

олуглау *перех. см.* **олылау**

олуглык *сущ.* велича́вость, авторита́рность □ **~ күрсәтү** почита́ть, ока́зывать уваже́ние (честь, почёт)

олы *прил.* **1.** 1) большо́й; *олы урамга чыгу* вы́йти на большу́ю у́лицу; *олы йортка ни кирәк — кече йортка шул кирәк* (*погов.*) то, что ну́жно большо́му до́му, необходи́мо и ма́ленькому до́му; *олы телдән үтмәде, кече телгә җитмәде* (*погов.*) по уса́м текло́, а в рот не попа́ло (*букв.* по большо́му языку́ не прошло́, до ма́ленького языка́ не дошло́) 2) большо́й, огро́мный, кру́пный (*успех, талант и т. п.*); *олы җиңү* кру́пная побе́да; огро́мное достиже́ние; *олы бәхет* большо́е сча́стье 3) высо́кий, большо́й (*авторитет*); *олы дәрәҗәгә ирешү* доби́ться высо́кого положе́ния; *олы хөрмәт күрсәтү* ока́зывать большу́ю (высо́кую) честь; *олы ышаныч* высо́кое дове́рие 4) вели́кий, большо́й; *олы мәмләкәтләр* вели́кие держа́вы; *олы акыл ияләре* вели́кие мысли́тели; *олы шатлык* больша́я ра́дость **2.** ста́рший (*по возрасту*); *олы ага — икенче ата* (*погов.*) ста́рший брат как второ́й оте́ц; *олы кыз* ста́ршая дочь; бо́льшенькая; *олы малай* ста́рший сын; бо́льшенький; *олы хатын уст.* ста́ршая (пе́рвая) жена́; *олы улы сугышта* ста́рший сын на фро́нте; *ул миннән олы* он ста́рше меня́ **3.** 1) ста́рший; взро́слый; пожило́й; *олы кешеләр* взро́слые (пожилы́е) лю́ди; лю́ди прекло́нного во́зраста; *олы буын язучылар* писа́тели ста́ршего поколе́ния 2) *мн. в знач. сущ.* **олылар** ста́ршие, пожилы́е, взро́слые; *олылар сүзенә колак салу* присл у́шиваться к слова́м ста́рших (взро́слых); *олылар белән олыларча сөйләшү* разгова́ривать со ста́ршими с почте́нием 3) *в знач. сущ. в притяж. ф.* **олысы** *разг.* больша́к, большу́ха; *өлкән улы — йортның олысы* ста́рший сын — больша́к до́ма **4.** почте́нный, досто́йный уваже́ния; почётный; благоро́дный; *ул безнең өчен бик олы кеше* для нас он весьма́ почте́нный челове́к; *икмәктән ~ аш юк* (*погов.*) нет

почётнее пи́щи, чем хлеб; хлеб всему́ голова́ □ **олы авыру үләне** *см.* **эт җиләге**; **олы аналык чоры** матриарха́т; **олы ата(й)** аксака́л, старе́йшина ро́да; **олы аталык чоры** патриарха́т; **олы итү** *см.* **олылау**; **олыны олы итү** уважа́ть (почита́ть) ста́рших; **олы юл** больша́я доро́га, тракт; магистра́ль, шоссе́; **олы як** больша́я, све́тлая полови́на до́ма; **олы яшьтә** в года́х, в во́зрасте ◊ **олы авыз** болту́н; **олы бавырлы** *см.* **олы җанлы**; **олы башны кече итеп** 1. проявля́я снисхожде́ние, великоду́шие 2. теря́я своё досто́инство; **олы башы (башыгыз) белән** намёк на соли́дный во́зраст и на жи́зненный о́пыт (*при упрёке за необдуманный поступок*); **олы иман** чи́стая со́весть; и́скренняя ве́ра; **олы йомыш** больша́я нужда́ (*о естественном отправлении*); **олы йөрәкле** великоду́шный; **олы җан иясе** челове́к большо́й души́; **олы җанлы** великоду́шный; челове́чный; *ср.* **олы йөрәкле**; **олы җанлык** великоду́шие, челове́чность; **олы күтәрү** 1. бра́ться/взя́ться за непоси́льную рабо́ту 2. мно́го брать на себя́; **олы кылану** ва́жничать; **олы сабый** юро́дивый; **олы сөйләү (сөйләшү)** говори́ть (разгова́ривать) свысока́; **олы сүз** ну́жное (поле́зное) сло́во; **олы сүздә оят юк** (*погов.*) пра́вды не́чего стыди́ться; **олы юлга чыгу** вы́йти на большу́ю доро́гу (встать на пра́вильный путь); **олыга җибәрү** *см.* **зурга җибәрү**; **олыга китү** *см.* **зурга китү**; **олыга сан булу** повзросле́ть; становя́ться/стать взро́слым; **олыдан кечегә хәтле** *см.* **олысы-кечесе**; **олыдан кубу** *см.* **зурдан кубу**

олыгайганлык *сущ.* прекло́нность во́зраста; ~ *үзен сиздерә* во́зраст (прекло́нность во́зраста) даёт себя́ знать

олыгайт|у *перех.* взрасли́ть □ **~ып күрсәтү** взрасли́ть, ста́рить, пока́зывать бо́лее взро́слым *кого-л.* (*чем он есть на самом деле*)

олыга|ю *неперех.* старе́ть/постаре́ть; становя́ться/стать пожилы́м, ста́рым; *күзгә күренеп ~я* пря́мо на глаза́х старе́ет □ **~еп китү** 1. повзросле́ть 2. постаре́ть; **~я бару** 1. взросле́ть 2. старе́ть; **~я башлау** нача́ть взросле́ть; **~я төшү** 1. повзросле́ть 2. постаре́ть

олы-кары *сущ. собир. разг.* 1. почте́нные лю́ди (старики́) 2. *см.* **карт-коры**

олылану *возвр. от* **олылау** 1. по́льзоваться уваже́нием, быть почита́емым (уважа́емым) 2. *перен.* горди́ться, ки́читься, ва́жничать, высокоме́рничать, зазнава́ться

олыла́рча *нареч.* 1. как взро́слый (*человек*); как пожило́й челове́к; ~ *фикер йөртү* мы́слить как взро́слый (*человек*); ~ *акрын кыймылдау* шевели́ться (дви́гаться) ме́дленно, как пожило́й челове́к; ~ *җитди сөйләшү* разгова́ривать серьёзно, как взро́слые лю́ди 2. как челове́к ста́ршего (пожило́го) во́зраста; как челове́к, умудрённый о́пытом жи́зни; ~ *эшлекле киңәш бирү* дать де́льный сове́т, как челове́к, умудрённый о́пытом жи́зни

олыла|у *перех.* 1. чтить, почита́ть, уважа́ть *кого-что*; ока́зывать/оказа́ть почте́ние, внима́ние *кому-чему* || почте́ние, уваже́ние *к кому-чему* (*к родителям, ветеранам войны, к старшим, к чьему-л. труду, к чьим-л. заслугам*); *икмәкне ~у* уважа́ть хлеб; *аның хезмәтләре ~уга лаеклы* его труды́ досто́йны внима́ния 2. *в знач. нареч.* **олылап** с почте́нием, уваже́нием (*встречать, вспоминать кого-л.*); *~п озату* провожа́ть с почте́нием 3. че́ствовать, прославля́ть/просла́вить (*ветеранов войны, передовиков производства, сельского хозяйства; видных деятелей искусства*) || че́ствование, прославле́ние; *хезмәт алдынгыларын ~у* че́ствовать передовико́в труда́ □ **~п баш ию** преклоня́ться, глубоко́ уважа́ть; **~у тантанасы үткәрү** че́ствовать

олылы|к *сущ.* 1. прекло́нный (пожило́й) во́зраст; *~гын исәпкә алу* име́ть в виду́ (его́) прекло́нный во́зраст 2. величина́, разме́р *чего-л.* (*строительства, дворца культуры, археологических работ и т. п.*) 3. авторите́т, честь, почёт; *~гың артыкан саен кечелегең артсын* (*посл.*) авторите́т и снисходи́тельность должны́ сопу́тствовать друг дру́гу 4. старшинство́, главе́нство; *~к даулау* претендова́ть на старшинство́ (главе́нство) 5. *перен.* вели́чие, си́ла (*духа, подвига*); *халык шагыйре Г. Тукайның ~гы* вели́чие наро́дного по́эта Г. Тука́я

олылы-кечеле *прил.* 1. ра́зного во́зраста; ста́ршие и мла́дшие (*люди*) 2. ра́зной величины́ (*о больших, средних и маленьких величинах*)

олылыкла|у *перех. редко см.* **олылау**; *~п исәнләшү* поздоро́ваться с почте́нием

олылыклы *прил. редко* почте́нный, уважа́емый (*человек, деятель искусства*)

олысы-кечесе *сущ. собир.* все — от ма́ла до вели́ка; *халык олысы-кечесе үзәк мәйданга агыла* наро́д от ма́ла до вели́ка вали́т на центра́льную пло́щадь

олысымакландыру *перех.* взрасли́ть, ста́рить

олысымакла|ну *неперех.* 1. становя́ться/стать взро́слым, взросле́е; держа́ть (вести́) себя́ как взро́слые 2. *перен.* ва́жничать, кичи́ться, чва́ниться □ **~ып китү** повзросле́ть (*чуть-чуть, несколько*)

олысымаклык *сущ.* ка́жущийся взро́слый вид (*на лице*); ка́жущаяся взро́слая мане́ра (*в походке*)

ом *сущ. физ.* ом (*единица измерения электрического сопротивления*)

омар *сущ. зоол.* ома́р (*морской краб*)

омбы *сущ.* 1. *ист.* тара́н 2. *зоол. диал. см.* **чөгә**

оме́га *сущ.* оме́га (*название последней буквы греческого алфавита*)

омлет *сущ.* омле́т

омметр *сущ.* омме́тр (*прибор для измерения электрического сопротивления*)

омо́граф *сущ. лингв.* омо́граф

омо́ним *сущ. лингв.* омо́ним || омонимі́ческий, омонимі́чный; ~ *сүзләр* омонимі́чные слова́

омоними́к *прил.* омонимі́чный; ~ *рифмалар* омонимі́чные ри́фмы

омони́мика *сущ. лингв.* 1. омони́мика (*совокупность омонимов какого-л. языка*) 2. омони́мика (*раздел лексикологии, изучающий омонимы*)

омо́нимлык *сущ.* омонимі́чность; ~ *күренешләре* явле́ния омонимі́чности

омофон *сущ. лингв.* омофо́н (*разные слова, одинаково звучащие при различии морфологического состава*)

омтылдыру *перех.* устремля́ть/устреми́ть *кого*; поощря́ть/поощри́ть; ободря́ть/ободри́ть; *см. тж.* **ашкындыру**

омтылу *неперех.* 1. устремля́ться/устреми́ться, стреми́ться, рва́ться (*вдаль, ввысь и т. п.*) || устремле́ние стремле́ние, рве́ние; *туган якларга ~* рва́ться в родны́е края́; *алга ~* устремля́ться вперёд 2. стреми́ться, рва́ться, вле́чься, тяну́ться к *кому-л., чему-л.*; жа́ждать *чего* || стремле́ние, рве́ние, влече́ние, тя́га, жа́жда; *тыныч-лыкка ~* стреми́ться к ми́ру; жа́ждать ми́ра; *властька ~* рва́ться к вла́сти; *сәнгатькә ~* тя́га к иску́сству; *бәхеткә ~* жа́жда сча́стья 3. стреми́ться, прорва́ться, норови́ть, пыта́ться *что-л.* сде́лать || стремле́ние, попы́тка; *планны срогыннан алда үтәргә ~* стреми́ться вы́полнить план досро́чно; *аякка басарга ~* пыта́ться

встать на́ ноги; *качарга ~* порыва́ться убежа́ть; *җитәкчелеккә ~* стреми́ться на руководя́щий пост **4.** посяга́ть/посягну́ть, покуша́ться/покуси́ться на *что-л.*; *илнең бәйсезлеген бетерергә ~* посяга́ть на незави́симость страны́; *үтерергә ~* покуша́ться на жизнь *кого-л.*

омтылулы *прил.* стреми́тельный, поры́вистый (*взгляд, характер*); *~ хисләр* поры́вистые чу́вства

омтылучан *прил.* стремя́щийся, устремля́ющийся, порыва́ющийся (*что-л. делать*); *гел алга ~ кеше* всегда́ стремя́щийся (порыва́ющийся) вперёд челове́к

омтылучанлык *сущ.* стремле́ние, устремле́ние, влече́ние, тя́га; *матурлыкка ~* влече́ние к прекра́сному

омтылыш *сущ.* **1.** стремле́ние, устремле́ние (*о движении*); *алга ~* стремле́ние вперёд **2.** стремле́ние, поры́в; накло́нность, влече́ние, тя́га, пристра́стие *к кому-л., чему-л., что-л.* сде́лать; *гуманистик ~лар* гуманисти́ческие устремле́ния; *хезмәткә ~* трудово́й поры́в; *фәнгә ~* тя́га к нау́ке; *күңел ~ы* поры́в души́; *уртак ~* о́бщий поры́в; *эчке ~* вну́треннее влече́ние **3.** цель, жела́ние, жа́жда; *көрәшкә ~* жа́жда борьбы́; *безнең ~ — яңа сугыш уты кабынмасын!* на́ша цель — чтоб не разгоре́лось пла́мя но́вой войны́! **4.** попы́тка; *язучылык хезмәтенә ~ ясау* сде́лать пе́рвую попы́тку к писа́тельскому труду́

омтылышлы *прил.* **1.** стреми́тельный, поры́вистый; *~ адымнар белән* стреми́тельными шага́ми **2.** целенапра́вленный, целеустремлённый; *тормышка ~ караш* целенапра́вленный взгляд на жизнь; *~ яшь белгечләр* целеустремлённые молоды́е специали́сты || *нареч.* **1.** стреми́тельно, поры́висто; *~ хәрәкәт итү* де́йствовать стреми́тельно **2.** целенапра́вленно, целеустремлённо

омтылышлылык *сущ.* **1.** стреми́тельность, поры́вистость **2.** устремлённость; *максатка ~* целеустремлённость

омтылышсыз *прил.* вя́лый, ине́ртный, пасси́вный, без стремле́ния; *~ хәрәкәт* пасси́вное (ине́ртное) де́йствие || *нареч.* вя́ло, ине́ртно, пасси́вно, без стремле́ния; *~ яшәү* жить пасси́вно

омтылышчанлы|к *сущ.* целеустремлённость; *геройның эчке дөньясын, ~гын ачып бирү* раскры́ть вну́тренний мир, целеустремлённость геро́я

он *сущ.* **1.** мука́ (*пшеничная, ржаная, белая и т. п.*) || 1) мучно́й 2) мукомо́льный (*комбинат, завод*); *он тарту* моло́ть зерно́ на муку́; помо́л; *вак тарттырылган он* мука́ ме́лкого помо́ла (разме́ла); *онның тартылышы* изме́л; *он иләү* проси́вать муку́; *онга (онда) әвәләү* обвиля́ть в мукé (*котлеты, фрикадельки, рыбу и т. п.*); *он ашы* мучна́я похлёбка; *он төсендәге* мучно́го цве́та; *он сәүдәсе* мучна́я торго́вля **2.** 1) мука́ (*измельчённые в порошок животные и минеральные вещества*); *үлән оны* травяна́я мука́; *сөяк оны* ко́стная мука́; *балык оны* ры́бная мука́; *бәрәңге оны* карто́фельная мука́ 2) порошо́к; мука́; *см. тж.* **онтак**; *алебастр оны* алеба́стровый порошо́к; *кирпеч оны* кирпи́чный порошо́к; *доломит оны* доломи́товая мука́ □ **он ашы** *см.* **камыр ашы**; **он итү, онга әйләндерү** *см.* **онландыру** 2; **он күбәләге** огнёвка мучна́я; **он коңгызы** *зоол.* мукое́д; **он корты** *зоол.* мучно́й червь; **он суы** по́йло, болту́шка из муки́; **он талпаны** *зоол.* ака́р, мучно́й клещ ◊ **он да юк, сөт тә юк** как от козла́ молока́; **он суы да, тоз суы да юк** *см.* **йон да юк, ит тә юк**

онагр *сущ. зоол.* она́гр; *см. тж.* **колан**

онгон *сущ. уст.* язы́ческое божество́; *һәр ыругның үз ~ы булган* ка́ждый род име́л своё язы́ческое божество́

онда́тра *сущ.* онда́тра || онда́тровый; *~ мехы* мех онда́тры || *прил.* онда́тровый; *~ бүрек* онда́тровая ша́пка

онко́лог *сущ.* онко́лог (*врач-специалист по онкологии*)

онколо́гик *прил.* онкологи́ческий; *~ тикшеренүләр* онкологи́ческие иссле́дования

онколо́гия *сущ.* онколо́гия (*наука, изучающая опухоли и методы их лечения*) || онкологи́ческий; *~ институты* онкологи́ческий институ́т

онландыру *перех.* **1.** посы́пать/посыпа́ть муко́й; обва́ливать/обваля́ть в мукé (*рыбу*) **2.** размáлывать/размоло́ть (*пшеницу, кукурузу*) **3.** растира́ть/растере́ть, превраща́ть/преврати́ть *в* порошо́к

онлану *возвр.-страд. от* **онлау** **1.** *возвр.* па́чкаться муко́й **2.** *страд.* посыпа́ться муко́й, обва́ливаться в мукé

онлата *нареч.* муко́й; *бурычны ~ түләү* распла́чиваться муко́й

онлату *перех.* перемоло́ть на муку́ *что-л.*

онлау *перех.* посы́пать/посыпа́ть муко́й; обва́ливать/обваля́ть в мукé (*заготовки из теста для выпечки*)

онлы *прил.* **1.** испа́чканный, перепа́чканный муко́й; в мукé, с муко́й; *~ капчык* мешо́к с муко́й **2.** посы́панный муко́й **3.** *бот.* мучни́стый; *~ тамыр* мучни́стый ко́рень

онлык *прил.* предназна́ченный для разме́ла (*горох*)

онлылык *сущ.* мучни́стость (*нового сорта пшеницы*)

онлыча *сущ. бот.* марь; *см. тж.* **алабута**; *кызыл ~* кра́сная марь; *кылчыклы ~* марь ости́стая

ономáстика *сущ. лингв.* **1.** ономáстика (*совокупность собственных имён, имеющихся в языке*) **2.** ономáстика (*раздел языкознания, изучающий собственные имена*)

онтак *сущ.* **1.** мучна́я пыль **2.** порошо́к

онтау *перех.* тере́ть/стере́ть в порошо́к

ончы *сущ.* торго́вец муко́й

ончыл *прил.* **1.** мучни́стый (*содержащий муку или крахмал*); *~ банан* мучни́стый бана́н **2.** *биол.* мучни́стый (*о болезни растения*); *~ кунык* мучни́стое пятно́; мучни́стый налёт **3.** мучни́стый, бе́лый; *~ төс* мучни́стый цвет □ **~ чык** *бот.* мучни́стая роса́ (*болезнь растений*)

ончыллык *сущ.* мучни́стость; *см. тж.* **ончыл** 1

онык *сущ.* внук, вну́чка; *~ — киләчәктә чәчәк атар орлык* (*погов.*) внук — се́мя, кото́рое зацветёт в бу́дущем

оныттыр|у **1.** *понуд. от* **оныту** **2.** изгла́живать/изгла́дить; своди́ть на нет; *күңелсез тәэсирләрне ~у* изгла́дить неприя́тное впечатле́ние **3.** *разг. в отриц. повел. ф.* **оныттырма(гыз)** напо́мни(те); *бригадирны кисәтергә ~магыз* напо́мните (мне) предупреди́ть бригади́ра

оныт|у *перех.* **1.** *перех.* забыва́ть/забы́ть, позабыва́ть/позабы́ть, запа́мятовать *кого-что о ком-чём* (*о родителях, о поручении, об обиде*), *про кого-что* (*про детей, про поездку*) || забыва́ние; забве́ние *уст.*; *яхшылыкны ~у* забыва́ть доброту́ (хлеб-соль); *хат турында тагын ~кансың* о письме́ опя́ть позабы́л; *~ырга ярамый* не сле́дует забыва́ть; *мәңге ~асым юк* вове́к не забу́ду; *бөтенләй ~канмын* совсе́м забы́л; из ума́ вон **2.** разу́чиваться/разучи́ться; отвыка́ть/отвы́кнуть; *баянда күптән уйнаган юк, ~канмындыр инде* давно́ не игра́л на бая́не, наве́рное, уже́ разучи́лся **3.** *в знач. нареч.* **оныты́п** по забы́вчивости, по рассе́янности, случа́йно; *~ып синең күзлекне алып киткәнмен* случа́йно захвати́л твои́ очки́ □ **~а башлау** нача́ть забыва́ть, разу́чиваться, отвыка́ть; **~ып җибәрү** позабы́ть, запа́мятовать; упус-

ти́ть и́з виду; **~ып бетерү** 1. перезабыва́ть 2. разучи́ться, отвы́кнуть; **~ып калдыру** забы́ть, позабы́ть *что-л. где* (*в автобусе, на работе, дома, у товарищей*) ◊ **~канда бер** иногда́, и́зредка; когда́ вспо́мнится

онытучан *прил.* 1. забы́вчивый; беспа́мятный 2. рассе́янный ◊ **~ кеше** дыря́вая голова́, дыря́вая па́мять

онытучанлык *сущ.* 1. забы́вчивость 2. рассе́янность; *мондый таркаулык, ~ны гафу итеп булмый* нельзя́ прости́ть таку́ю неорганизо́ванность, рассе́янность

онытчак *прил. диал. см.* **онытучан**; *~ буркен югалтыр, куркак башын югалтыр* (*погов.*) забы́вчивый потеря́ет ша́пку, а трус — го́лову

онытылмас *прил.* незабыва́емый, незабве́нный (*друг, вечер и т. п.*); неизгладимый; *~ еллар* незабыва́емые го́ды; *~ тәэсир калдыру* оста́вить неизгладимое впечатле́ние

онытылмаслык *прил. см.* **онытылмас**; *яшьлекнең ~ хатирәләре* неизгладимые воспомина́ния мо́лодости

онытыл|у *страд.-возвр. от* **оныту** 1. *страд.* забыва́ться; *күп нәрсә ~ган* мно́гое забы́то 2. *безл.* забыва́ться, забы́ть, позабы́ть; из головы́ вон; *хәтер начар: тиз ~а* па́мять плоха́я: бы́стро забыва́ется; *хат язарга ~ган* забы́л написа́ть письмо́; *кисәтергә ~ган* предупреди́ть — из головы́ вон 3. *возвр.* (*увлёкшись, забыть обо всём*) забыва́ться/забы́ться; впасть в забытьё; *эштә ~у* забыва́ться на рабо́те; *кешеләр арасында ~у* забыва́ться на лю́дях; *музыка тыңлап ~у* забыва́ться, слу́шая му́зыку; *ул тагын ~ды* он опя́ть впал в забытьё; он опя́ть лежи́т в забытьи́ 4. *возвр. перен.* (*не сдержать себя*) забыва́ться, забы́ться; *кинәт ярсып китү, ~у* вдруг разгорячи́ться, забы́ться; *~асыз, кайда утырганыгызны белмисезмени?* забыва́етесь, ра́зве не зна́ете, где вы нахо́дитесь? 5. *в знач. нареч.* **онытылып** с увлече́нием; *переводится тж. приставкой* за-; *~ып тыңлау* слу́шать с увлече́нием (затаи́в дыха́ние); заслу́шиваться/заслу́шаться; *~ып уку* чита́ть с увлече́нием (запо́ем); зачи́тываться/зачита́ться; *~ып уйнау* игра́ть с увлече́нием; зайгрываться/заигра́ться; *~ып йоклау* заспа́ться; *~ып эшләү* рабо́тать с увлече́нием; зараба́тываться/зарабо́таться 6. *в знач. нареч.* **онытылганчы** пока́ не забы́то, по горя́чим следа́м; *~ганчы мәсьәләне ачыклап куярга кирәк* на́до вы́яснить вопро́с по горя́чим следа́м (пока́ не забы́лось) 7. *в знач. прил.* **онытылган**; забы́тый, зате́рянный; *~ган традицияләрне яңарту* восстана́вливать забы́тые тради́ции; *~ган археология истәлекләре* зате́рянные археологи́ческие па́мятники ◻ **~ып калу** 1. остава́ться/оста́ться забы́тым 2. *см.* **онытылып китү**; **~ып китү** забыва́ться/забы́ться; увлека́ться/увле́чься *чем-л.*; **~ып тору** 1. забыва́ться (*на некоторое время*) 2. *перен.* замечта́ться; **~ып утыру** 1. заси́живаться/засиде́ться 2. *перен.* забыва́ться/забы́ться; уйти́ в себя́; замечта́ться

онытылулы *прил.* безмяте́жный, споко́йный; *~ халәттә булу* быть (находи́ться) в безмяте́жном состоя́нии

онытылучан *прил.* рассе́янный; беспе́чный; *шул кадәр ваемсыз, шул кадәр ~ булырга инде!* на́до же быть таки́м беспе́чным, таки́м рассе́янным!

оңгы *сущ.* 1. проу́шина (*топора*) 2. петля́ у лапте́й 3. скоба́

оңгылы *прил.* 1. име́ющий проу́шину, с проу́шиной 2. *диал.* име́ющий отве́рстие, с отве́рстием

оңгыт *сущ. зоол.* онгу́т (*подвид совы*); *кош яманы ~* (*погов.*) са́мая скве́рная пти́ца — онгу́т

оп: оп итү упа́сть (*в языке детей*)

опак *сущ.* 1. опа́к (*сорт белой глины*) 2. опа́к (*гончарные изделия из такой глины*) || опа́ковый (*кувшин*)

опал *сущ. мин.* опа́л (*стекловидный камень различной окраски*) || опа́ловый (*браслет*); *~ кашылы йөзек* пе́рстень с опа́лом

опаллы *прил.* с опа́лом; *~ йөзек* пе́рстень с опа́лом

опе́ка *сущ.* 1. опе́ка (*попечение о личных и имущественных правах недееспособных, малолетних граждан*) 2. опе́ка (*экономическая и политическая над какой-л. страной*); *халыкара ~* междунаро́дная опе́ка; *милләтләр лигасы ~сында булу* находи́ться под опе́кой Лиги на́ций 3. *перен.* опе́ка (*покровительство, попечение*); *аның даими ~сыннан котылу* изба́виться от его́ постоя́нной опе́ки ◻ **~га алу** 1. опека́ть 2. учреди́ть опе́ку над *кем-чем-л.*; взять под опе́ку *кого-л.*

опе́калы *прил.* подопе́чный; *~ балалар* подопе́чные де́ти; *~ территорияләр* подопе́чные террито́рии

опекун *сущ.* 1. опеку́н; *см. тж.* **багавыл**; *~ бурычлары* обя́занности опекуна́ 2. *перен.* покрови́тель, опеку́н; *кызның ~ына әйләну* стать покрови́телем (опекуно́м) де́вушки ◻ **~ карамындагы** *см.* **опекалы**

опекунлык *сущ.* опеку́нство || опеку́нский; *~ка риза булу* согласи́ться на опеку́нство (быть опекуно́м *кого-л.*); *~ хокуклары* опеку́нские права́ ◻ **~ итү** 1. опеку́нствовать, быть опекуно́м 2. *перен.* покрови́тельствовать, опеку́нствовать

опе́калау *перех.* 1. опека́ть, осуществля́ть опе́ку над *кем-л., чем-л.* 2. *перен. см.* **опекунлык итү** 2 3. *спорт.* опека́ть (*в игре в футбол, хоккей*); *иң җитез һөҗүмчене ~* опека́ть са́мого бы́строго нападающего

о́пера *сущ.* 1. о́пера || о́перный; *классик ~ларны ярату* люби́ть класси́ческие о́перы; *~ либреттосы* либре́тто о́перы; *~ җырчысы* о́перный певе́ц 2. о́перный теа́тр; *~ артистлары* арти́сты о́перного теа́тра

оператив *прил. в разн. знач.* операти́вный; *~ бәлешмә* операти́вная сво́дка; *~ эш планы* операти́вный план рабо́ты; *~ оешмалар* операти́вные о́рганы; *~ ярдәм күрсәту* оказа́ть операти́вную по́мощь; *~ җитәкчелек* операти́вное руково́дство || *нареч.* операти́вно; *~ хәрәкәт итү* де́йствовать операти́вно; *~ манёврлау* маневри́ровать операти́вно

оперативлык *сущ.* операти́вность, де́йственность; *~ күрсәтү* проявля́ть операти́вность; *эштә ~* операти́вность в рабо́те

оператив-та́ктик *прил. спец.* операти́вно-такти́ческий; *оператив-тактик ракета* операти́вно-такти́ческая раке́та

оператив-те́хник *прил. спец.* операти́вно-техни́ческий (*отдел*)

опера́тор *сущ. в разн. знач.* опера́тор || опера́торный (*отдел*); *идарә пульты ~ы* опера́тор пу́льта управле́ния; *тимер юл станциясе ~ы* опера́тор железнодоро́жной ста́нции; *радио ~ы* радиоопера́тор; *тавыш ~ы* звукоопера́тор; *~ булмәсе* опера́торная; опера́торская

опера́торлык *сущ.* заня́тие, профе́ссия опера́тора || опера́торский; *~ эше* опера́торская рабо́та

опера́ция *сущ.* 1. *мед.* опера́ция, на *что* (*на глаза, желудок, сердце, лёгкие*) || операцио́нный; *авыруны ~гә хәзерләү* гото́вить больно́го к опера́ции; *~ ясау* де́лать/сде́лать опера́цию; опери́ровать; *~ өстәле* операцио́нный стол; *~ булмәсе* операцио́нный кабине́т; операцио́нная 2. *воен.* опера́ция (*координированные военные действия*) || операцио́нный (*план*); *һава десанты*

~се опера́ция возду́шного деса́нта; *каты сугыш ~ләрендә катнашу* уча́ствовать в ожесточённых боевы́х опера́циях **3.** *спец. в разн. знач.* опера́ция (*почтовая, банковская, торговая*); *катлаулы технологик ~* сло́жная технологи́ческая опера́ция

опера́циялә̆у *перех.* опери́ровать || опери́рование

опера́цияче *сущ.* операцио́нист, операцио́нистка (*в банке*)

опергру́ппа *сущ.* опергру́ппа (*оперативная группа милиции*)

опере́тта *сущ.* опере́тта || опере́точный; *~ театры* теа́тр опере́тты; *~ артисты* арти́ст теа́тра опере́тты

опере́ттачы *сущ.* актёр (актри́са) опере́тты

о́пись *сущ.* о́пись (*имущества, архива, библиотечного фонда*); *гидрографик экспедиция ~лары* о́писи гидрографи́ческой экспеди́ции; *~ ясау (уткәрү)* производи́ть о́пись

оп-озын *прил. превосх. ст. от* **озын 1.** дли́нный-предли́нный, са́мый дли́нный; *оп-озын юлны сайлау* вы́брать са́мый дли́нный путь **2.** о́чень дли́нный (высо́кий); *оп-озын буйлы* о́чень высо́кого ро́ста

оп-олы *прил. превосх. ст. от* **олы** *разг.* **1.** великово́зрастный; настоя́щий взро́слый; *оп-олы улыңны баласытып йөрмә* не балу́й как ребёнка своего́ великово́зрастного сы́на; *кара инде малаеңны, оп-олы егет булган* смотри́-ка, сын твой стал настоя́щим взро́слым джиги́том (па́рнем) **2.** ста́рый, престаре́лый; *түрдә оп-олы кешеләр утыра* на почётном ме́сте сидя́т ста́рые-престаре́лые лю́ди **3.** са́мый ста́рший, са́мый почётный (*перен.*); *безнең арада оп-олы кеше — ул* среди́ нас са́мый ста́рший (са́мый почётный) — он

ополче́ние *сущ. ист.* ополче́ние (*войско, создаваемое в помощь регулярной армии из гражданских лиц*) || ополче́нский; *халык ~се* наро́дное ополче́ние; *~ отрядлары* ополче́нские отря́ды; *~ гаскәре төзү* созда́ть ополче́нское во́йско

оп-очлы *прил. превосх. ст. от* **очлы;** о́чень о́стрый, пребо́стрый; *оп-очлы борын* пребо́стрый нос

оппозицион *прил.* оппозицио́нный; *~ хәрәкәт* оппозицио́нное движе́ние; *~ партияләр* оппозицио́нные па́ртии

оппози́ция *сущ. полит.* **1.** оппози́ция (противоде́йствие); *~дә булу* быть (находи́ться) в оппози́ции **2.** оппози́ция (*партия или группа внутри какого-л. государственного органа, партии и т. п.*); *контрреволюцион ~* контрреволюцио́нная оппози́ция; *партия эчендәге ~* внутрипарти́йная оппози́ция; *хәрби ~* вое́нная оппози́ция

оппонент *сущ.* оппоне́нт; *рәсми ~* официа́льный оппоне́нт □ **~ булу** оппони́ровать, быть оппоне́нтом

опри́чнина *сущ. ист.* **1.** опри́чнина (*система внутриполитических мер Ивана Грозного (в 1565 — 1572 гг.) для борьбы с княжеско-боярской оппозицией*) **2.** опри́чнина (*название особого войска царя Ивана Грозного, созданного для этой цели*); *~ еллары* го́ды опри́чнины

опри́чник *сущ. ист.* опри́чник (*служилый дворянин, состоящий в рядах опричнины*)

опта́ция *сущ. юр.* опта́ция (*право выбора гражданства*)

опта́циялә̆ну *возвр.-страд. от* **оптациялә̆у**; *юр.* опти́роваться (*избирать себе то или иное гражданство, пользуясь правом оптации*)

опта́циялә̆у *перех. юр.* опти́ровать (*осуществить по отношению к кому-л. право оптации*)

о́птик *сущ.* о́птик (*специалист по оптике*) || *прил.* **1.** опти́ческий; *көзгенең ~ үзәге* опти́ческий центр зе́ркала; *~ сурәт* опти́ческое изображе́ние; *~ ераклык үлчәгеч* опти́ческий дальноме́р **2.** опти́ческий, светово́й (*сигнал*); *~ күренеш* опти́ческое явле́ние

о́птика *сущ.* **1.** о́птика (*раздел физики, изучающий свойства света*) || опти́ческий; *~ законнары* зако́ны о́птики; *геометрик ~* геометри́ческая о́птика; *нурлар ~сы* лучева́я о́птика; *~ институты* опти́ческий институ́т **2.** *собир.* о́птика (*приборы и инструменты, действие которых основано на законах отражения и преломления света*) || опти́ческий; *~ булеге* отде́л о́птики; опти́ческий отде́л; *~ җиһазлары* опти́ческие прибо́ры

оптималь *прил.* оптима́льный (*срок, вариант, режим, план*); *~ йөкләмәләр алу* брать оптима́льные обяза́тельства □ **~ рәвештә** оптима́льно (*использовать что-л.*)

оптимальләштерү *перех.* оптимизи́ровать, де́лать/сде́лать оптима́льным (*разработку комплексных планов научного исследования*)

оптимальлек *сущ. неол.* оптима́льность; *~ критерие* крите́рий оптима́льности

оптимизм *сущ.* оптими́зм; *~ тойгылары* чу́вство оптими́зма; *~ белән сугарылган* одухотворённый оптими́змом; жизнеутверждающий

оптимист *сущ.* оптими́ст, оптими́стка; *~ларга хас ышанычлылык* уве́ренность, сво́йственная оптими́стам

оптими́стик *прил.* оптимисти́ческий, оптимисти́чный (*дух, пафос, взгляд*); *~ табигатьле кеше* челове́к с оптимисти́ческой нату́рой; *~ рухлы* оптимисти́чно настро́енный || *нареч.* оптимисти́чески, оптимисти́чно; *киләчәккә ~ карау* смотре́ть оптимисти́чески на бу́дущее

оптимистлану *неперех.* станови́ться/стать оптими́стом

оптимистла́рча *нареч.* оптимисти́чески, оптимисти́чно; *~ рухта булу* быть настро́енным оптимисти́чески || *прил.* оптимисти́ческий, оптимисти́чный; *~ ышаныч* оптимисти́ческая уве́ренность

оптимистлык *сущ.* оптими́зм; *тормышчан ~* жизнеутверждающий оптими́зм

опты *сущ.* язь (*рыба*) || язёвый (*клёв*)

ора-ера *нареч.* энерги́чно раста́лкивая; *кешеләрне ора-ера алга омтылу* энерги́чно раста́лкивая люде́й, устреми́ться вперёд

ора́кул *сущ. прям., перен.* **1.** ора́кул (*в античном мире; жрец-прорицатель воли мифического божества*) **2.** *перен. книжн.* ора́кул (*лицо, чьи суждения признаются непреложной истиной, откровением*) || ора́кульский; *~ юрамалары* ора́кульские прорица́ния

оран *сущ.* боево́й клич, призы́в ◊ **~ салу** броса́ть/бро́сить клич (вы́зов); кли́кнуть

орангутан, орангутанг *сущ.* орангута́нг (*человекообразная обезьяна*)

оранжере́я *сущ.* оранжере́я (*теплица*) || оранжере́йный; *~ чәчәкләре* оранжере́йные цветы́

ора́тор *сущ.* ора́тор; *~ чыгышы* речь ора́тора

ората́рия *сущ. муз.* ората́рия (*крупное музыкальное произведение для хора, солистов-певцов и оркестра*) || ората́рный; ораториа́льный; *~ әсәрләре* ората́рные сочине́ния

ора́торлану ора́торствовать, разглаго́льствовать

ора́торларча *нареч.* по-ора́торски, ора́торски || *прил.* ора́торский

ора́торлык *сущ.* ора́торство; *~ка сәләт* спосо́бность к ора́торству □ **~ итү** ора́торствовать

орби́та *сущ.* **1.** *астр.* орби́та (*какая: земная, лунная, окололунная; чего: Земли, Марса*); *Җир тирәли ~га космик корабль чыгару* вы́вести на околозе́мную орби́ту косми́ческий кора́бль; *~дан чыгу* сойти́ с орби́ты; *~дан хәбәрләр* ве́сти с орби́ты **2.** *перен. книжн.* орби́та (круг); *үз ~сына алу* втяну́ть (вовле́чь) в свою́ орби́ту *кого*; *йогынты ~сы* орби́та влия́ния **3.** *перен. в ф.* **орбита́сында** на ... орби́те (*в области чего*); *футбол ~сында* на футбо́льной орби́те

орби́тадагы *прил.* орбита́льный; находя́щийся на орби́те; *~ вахта* орбита́льная ва́хта; *~ очышны күзәтү* наблюда́ть за орбита́льным полётом

орбита́ль *прил.* орбита́льный (*полёт, отсек корабля*); *~ фәнни станция* орбита́льная нау́чная ста́нция; *~ очыш* орбита́льный полёт

о́рган I *сущ.* **1.** *биол.* о́рган (*часть животного или растительного организма*); *аш кайнату ~нары* о́рганы пищевари́ения; *кан әйләнеше ~нары* о́рганы кровообраще́ния; *вегетатив ~нар* вегетати́вные о́рганы **2.** о́рган (*учреждение, организация*); *җитәкче ~нар* руководя́щие о́рганы; *тикшерену ~нары* сле́дственные о́рганы; *югары дәүләт ~нарына сайлаулар* вы́боры в вы́сшие госуда́рственные о́рганы; *сәламәтлек саклау ~нары* о́рганы здравоохране́ния **3.** о́рган (*печатный*); *«Казан утлары» журналы — Татарстан Язучылар берлеге ~ы* журна́л «Каза́нские огни́» — о́рган Сою́за писа́телей Татарста́на

орган II *муз.* орга́н || орга́нный (*концерт, звук*); *~да уйнау* игра́ть на орга́не; *~ музыкасы* орга́нная му́зыка

организм *сущ.* **1.** организ́м (*живое существо*); *үсемлек ~нары* расти́тельные организ́мы; *хайван ~нары* живо́тные организ́мы; *~ның климат шартларына җайлашуы* приспособле́ние организ́ма к климати́ческим усло́виям; *~ның авырудан соң хәлсезләнүе* ослабле́ние организ́ма по́сле боле́зни **2.** организ́м (*совокупность духовных и физических свойств какого-л. человека*); *спорт белән чыныккан ~* закалённый спо́ртом организ́м; *~ның йогышлы авыруларга каршы тору сәләте* невосприи́мчивость организ́ма к инфекцио́нным боле́зням **3.** *перен.* организ́м (*о сложном организованном единстве*); *дәүләт ~ы* госуда́рственный организ́м; *җир асты коммуникацияләре үзенә бер ~ ул* подзе́мные коммуника́ции — э́то осо́бый организ́м

орга́ник *прил.* **1.** *в разн. знач.* органи́ческий; *~ дөнья* органи́ческий мир; *~ кушылмалар* органи́ческие соедине́ния; *~ матдәләр* органи́ческие вещества́; *~ калдыклар* органи́ческие оста́тки; *~ ашламалар* органи́ческие удобре́ния; *~ пыяла* органи́ческое стекло́, оргстекло́ **2.** *перен.* органи́ческий (*внутренний, естественный*); *~ бәйләнеш* органи́ческая связь; *нәрсәнең дә булса ~ кисәге* органи́ческая часть *чего-л.* || *нареч.* органи́чески; *~ бөтен булган* органи́чески це́лостный; *~ керешү* органи́чески переплета́ться; *~ хас булган* органи́чески прису́щий; *~ ярашучы* органи́чески сочета́ющийся □ **~ рәвештә** органи́чески; *~* **химия** органи́ческая хи́мия

органчы *сущ.* органи́ст

оргау *неперех. диал.* **1.** оягни́ться **2.** *уст.* роди́ть (*о женщине*); *см. тж.* **үрчү**

оргач *сущ.* **1.** *диал.* овцема́тка; са́мка (*преимущественно мелкого рогатого скота*) **2.** *уст.* повива́льная ба́бка

о́ргия *сущ.* о́ргия (*разгульное пиршество*)

оргпыяла *сущ.* оргстекло́ (*органическое стекло*)

орда *сущ.* **1.** *см.* **урда 2.** орда́ (*полчище*); *фашист ~лары* фаши́стские о́рды

о́рден I *сущ.* о́рден (*Красного Знамени, Красной Звезды, «Знак Почёта»*) || о́рденский; *сугышчан ~нар* боевы́е ордена́; *~ кенәгәсе* о́рденская кни́жка

о́рден II *сущ. ист.* о́рден (*община католической церкви с определённым уставом*) || о́рденский; *иезуитлар ~ы* о́рден иезуи́тов; *~ уставы* о́рденский уста́в

о́рденлы *прил.* орденоно́сный || орденоно́сец, орденоно́ска; *~ Татарстан* орденоно́сный Татарста́н; *ул дивизия комиссары, ~* он комисса́р дивизии, орденоно́сец

о́рдер *сущ.* о́рдер (*документ на выдачу, получение чего-л.*); *квартира ~ы* о́рдер на кварти́ру; *касса ~ы* ка́ссовый о́рдер; *керем ~ы* прихо́дный о́рдер

ордина́та *сущ. мат.* ордина́та; *~ күчәре* ось ордина́ты

ордина́тор *сущ.* ордина́тор (*лечащий и ведущий научные исследования врач больницы, клиники*)

ординату́ра *сущ.* ординату́ра (*род практической медицинской аспирантуры*); *~га керү* поступи́ть в ординату́ру

орды-бәрде *нареч. прил. см.* **ордым-бәрдем**

ордылы-бәрделе *прил. прост.* сумасбро́дный, ненорма́льный || *нареч. см.* **ордым-бәрдем 1**

ордым-бәрдем *нареч. разг.* **1.** суетли́во, торопли́во, суматошно; ко́е-ка́к, как попа́ло; *ордым-бәрдем эшләү* де́лать суетли́во; *ордым-бәрдем генә уку* учи́ться ко́е-ка́к **2.** гру́бо; неучти́во, развя́зно; *ордым-бәрдем сөйләшү* разгова́ривать гру́бо || *прил.* **1.** суетли́вый, торопли́вый, суматошный **2.** сумасбро́дный, безрассу́дный, бесшаба́шный; гру́бый, развя́зный; *ордым-бәрдем кыланыш* безрассу́дный посту́пок; *бераз ордым-бәрдем малай ул* он не́сколько сумасбро́дный па́рень ◊ **ордым-бәрдем түгел** *прост.* поря́дочный, такти́чный

ордыру **1.** *понуд от* **ору 2.** *перех. см.* **орытдыру**

ореол *сущ. книжн.* орео́л (*атмосфера обаяния, славы, почёта, успеха и т. п. окружающие кого-л., что-л.*); *изгелек ~ы* орео́л свя́тости

оригинал *сущ.* оригина́л (*подлинник*); *бу күчермә генә, ~ түгел* э́то то́лько ко́пия, не оригина́л; *кулъязманың ~ы* оригина́л ру́кописи

оригиналдагы *прил.* име́ющийся (*содержащийся*) в оригина́ле; *~ төзәтмәләр* исправле́ния, содержа́щиеся в оригина́ле

оригиналдагы́ча *нареч.* как в оригина́ле; по оригина́лу

оригиналь *прил.* **1.** оригина́льный, по́длинный (*экземпляр*) **2.** оригина́льный, самостоя́тельный (*труд*) **3.** оригина́льный, самобы́тный, своеобра́зный (*стиль, поэт, художник*) ◊ **~ булып кылану** оригина́льничать

оригинальлек *сущ.* **1.** (*подлинность*) оригина́льность (*документа, рукописи*) **2.** (*самостоятельность, индивидуальность*) оригина́льность (*научного исследования*) **3.** (*самобытность, своеобразность*) оригина́льность (*манеры, стиля писателя*)

ориенталист *сущ.* ориентали́ст (*востоковед*)

ориентали́стика *сущ.* ориентали́стика (*востоковедение*)

ориента́ция *сущ.* **1.** (*определение своего местонахождения*) ориента́ция, ориентиро́вка (*по компасу, на местности*) **2.** ориента́ция *на кого-что* (*на массового читателя, на экономическую помощь развитых стран*) **3.** *перен.* (*умение разобраться в чём-л.*) ориента́ция (*в текущей политике, в исторических фактах, в архивных материалах*) □ **~ тоту** ориенти́рова́ться *на кого-что*;

социализмга ~ тотучы илләр стра́ны, ориенти́рующиеся на социали́зм

ориента́цияләнү *страд. от* **ориентацияләү**; ориенти́роваться

ориента́цияләү *перех.* **1.** (*направлять*) ориенти́ровать *кого-что* || ориенти́рование; ориентиро́вка; *космик корабль хәрәкәтен ~* ориенти́ровать движе́ние косми́ческого корабля́ **2.** *перен.* (*помочь кому-л. разобраться в чём-л.*) ориенти́ровать (*нового директора в положении дел на заводе*)

ориентир *сущ. прям., перен.* ориенти́р; *күзәтү ~лары* наблюда́тельные ориенти́ры; *яктылык ~ы* световóй ориенти́р; *киләчәккә ышанычлы ~лар билгеләү* наме́тить надёжные ориенти́ры на бу́дущее

ориентирлаштыру *перех.* ориенти́ровать || ориенти́рование, ориентиро́вка; ориента́ция; *см.* **ориентацияләү** 1; *космик корабльне кулдан ~* ручна́я ориентиро́вка косми́ческого корабля́

ориентлашу *неперех.* **1.** ориенти́роваться || ориента́ция, ориентиро́вка, ориенти́рование (*на местности, в лесу, по компасу, звёздам*); *~ ярышлары* соревнова́ния по ориенти́рованию; *космик корабльнең ~ системасы* систе́ма ориента́ции косми́ческого корабля́ **2.** ориенти́роваться на *кого-что* (*на массового читателя, на удачный исход чего-л., на поддержку с флангов*) **3.** ориенти́роваться в *чём* (*в обстановке, в обстоятельствах, в сложных ситуациях*)

оркестр *сущ.* орке́стр || оркестро́вый; *~га кушылып җырлау* петь в сопровожде́нии орке́стра; *~да уйнау* игра́ть в орке́стре; *~ музыкасы* оркестро́вая му́зыка □ **~га салу** *см.* **оркестрлаштыру**

орке́стрлаштыру *перех.* оркестрова́ть || оркестри́рование, оркестро́вка; *халык көйләрен ~* оркестрова́ть наро́дные мело́дии

орке́стрлаштырылу *страд. от* **оркестрлаштыру**; оркестрова́ться

оркестрчы *сущ.* оркестра́нт

орлык *сущ.* **1.** *бот.* се́мя, се́мечко || семенно́й; зерно́, зёрнышко *уменьш.-ласк.*; *чәчәк ~лары* семена́ цвето́в; *~ чүпләү* клева́ть зерно́ (*о птицах*); *карбыз ~лары* се́мечки арбу́за; *~ сыеклыгы* семенна́я жи́дкость; *~ тартмачыклары* семенны́е коро́бочки **2.** *с.-х.* семена́ *мн.* || семенно́й; *чәчүлек ~лары* посевны́е семена́; *~ка калдыру* оставля́ть на семена́; *~ларны җылыту* обогре́в семя́н; *~ салу* засы́пка семя́н; *~ бодае* семенна́я пшени́ца; *~ фонды* семенно́й фонд **3.** *физиол.* се́мя, спе́рма || семенно́й; *см. тж.* **мәни**; *~ чыгару юлы* семявынося́щий прото́к; *~ куыкчыгы* семенно́й пузырёк **4.** зерно́, зёрнышко || зерново́й; *~ чистарту машинасы* маши́на для очи́стки зерна́ **5.** *диал.* конопля́ посевна́я, конопля́ное се́мя || конопля́ный; *~ пәрәмәче* шаньга́, пригото́вленная с толчёным конопля́ным се́менем; *~ мае* конопля́ное ма́сло; *~ оны* конопля́ная мука́ **6.** *бот.* зерно́вка **7.** *перен. разг.* поро́да; пото́мок, пото́мство □ **~ ваклагыч** зернодроби́лка; **~ җитен** льносе́мя; **~ кабыгы** *бот.* лузга́; **~ коңгызы** зерно́вка; клещ зерново́й; **~ күбәләге** огнёвка (*зерновая*); **~ сабы** *бот.* семяно́жка; **~ суган** лук-севóк; **~ тазарткыч (чистарткыч)** зерноочисти́тель; **~ тергезү** размноже́ние посевны́х семя́н; **~ тышчасы** семявмести́лище; **~ чыгару** *физиол.* семяизвержéние; **~ юлы 1.** *бот.* семявхо́д **2.** *физиол.* семяпро́вод; **~ яны яфрагы** *бот.* присеменни́к; **~ яргыч (арындыргыч)** *спец.* ша́сталка; **~ яру** *спец.* ша́стать ◊ **~гы Бохарада (Мәкәрҗәдә) түгел** ≈ найдётся; мóжно сде́лать (*изобрести, достать*), *букв.* семена́ его́ не в Бухаре́

орлыкбөре *сущ. бот* семяпóчка

орлыкашар *сущ. зоол.* семяе́д

орлыкландыру *перех.* семеня́ть/осемени́ть || осемене́ние; *ясалма ~* иску́сственное осемене́ние (*коров*)

орлыкландырылу *страд. от* **орлыкландыру**; осеменя́ться

орлыклан|у *неперех.* **1.** осеменя́ться/осемени́ться (*о некоторых видах рыб*) **2.** налива́ться/нали́ться (*о зерне*); *бодайлар ~а башладылар* пшени́ца начина́ет налива́ться

орлыклы *прил.* име́ющий се́мя, с се́менем, семенно́й; *җимешнең ~ өлеше* семенна́я часть плода́

орлыклык *сущ.* **1.** *бот.* семенни́к; *яшелчә ~лары* семенники́ овоще́й; *нарат ~лары* со́сны-семенники́ **2.** семена́; *см. тж.* **орлык** 2; *~ өчен үстерү* вы́растить на семена́ **3.** *физиол.* семенни́к (*мужская половая железа*) || *прил.* семенно́й, семенико́вый (*овёс, лук, картофель*); *~ җир* семенно́й (семенико́вый) уча́сток; семенни́к □ **~ киндер** ма́терка; *см. тж.* **ана киндер**

орлыклылы|к *сущ.* семенно́е сво́йство (*качество*); *кавынның ~гы* семенно́е сво́йство ды́ни

орлыксыз *прил.* бессемя́нный; *~ үсемлекләр* бессемя́нные расте́ния □ **~ җимеш** бессеменни́к; **~ үрчү** вегетати́вное размноже́ние

орлыксызландыру *перех. мед.* стерилизова́ть *кого-что*

орлыксызландырылу *страд. от* **орлыксызландыру**

орлыкча *сущ. бот.* семя́нка (*подсолнуха, огурцов*)

орлыкчы *сущ. с.-х.* семеново́д

орлыкчылык *сущ.* семеново́дство || семеново́дческий; *~ районнары* семеново́дческие райóны

ормыт *сущ. диал.* **1.** следы́; оста́точные явле́ния **2.** *в ф.* **ормыты да ничегó**, абсолю́тно ничегó; *~ын да калдырмау* не оставля́ть абсолю́тно ничегó; обобра́ть на́чисто || *нареч.* (*обычно с частицей* **та**) ниско́лько, ниско́лечко, ничу́ть; абсолю́тно, соверше́нно; *~ та акылың юк икән* ока́зывается, ты соверше́нно безрассу́дный; у тебя́ ниско́лечко нет ума́; *~ та кызганмау* да́же ничу́ть не жале́ть

орна́мент *сущ.* **1.** орна́мент (*потолка, ворот, стены*) || орнамента́льный; *~лар белән бизәү* украша́ть орна́ментом; *~ бизәкләре* орнамента́льные украше́ния; *~ сәнгате* орнамента́льное украше́ние; *~ эшләре* орнамента́льные рабóты **2.** *см.* **орнаментика** 3

орнаме́нталь *прил.* **1.** *иск.* орнамента́льный; *чигү бизәкләрендәге ~ формалар һәм мотивлар* орнамента́льные фóрмы и моти́вы в узóрах вышива́ния **2.** *перен. лит.* орнамента́льный (*слишком вычурный, пёстрый*); *~ стиль* орнамента́льный стиль

орнаментáция *сущ. иск.* **1.** орнамента́ция (*украшение орнаментом*) **2.** орнамента́ция (*совокупность элементов в каком-л. стиле*)

орнаме́нтика *сущ. иск.* **1.** *см.* **орнаментация** 2; *татар ювелирлык сәнгате ~сы* орнаме́нтика тата́рского ювели́рного иску́сства **2.** *муз.* орнаме́нтика (*совокупность звуков, украшающих основной мелодический рисунок*)

орна́ментлану *страд. от* **орнаментлау**; орнаменти́роваться

орна́ментлау *перех. иск.* орнаменти́ровать || орнаменти́рование, орнамента́ция, орнаментиро́вка; *циркның гөмбәзен ~* орнаменти́ровать свод ци́рка

орна́ментлаштыру *перех. то же, что* **орнаментлау**

орна́ментлаштырылу *страд. от* **орнаментлаштыру**; орнаменти́роваться

орна́ментлы *прил.* **1.** орна́ментный; *~ бизәкләр* орна́ментные узо́ры **2.** *см.* **орнаменталь** 2

орна́ментчы *сущ.* орнаменти́ст; *~ архитектор* архите́ктор-орнаменти́ст; *~лар бригадасы* брига́да орнаменти́стов

орнито́лог *сущ.* орнито́лог (*специалист по орнитологии*)

орнитоло́гик *прил.* орнитологи́ческий; *~ җәмгыять* орнитологи́ческое о́бщество □ *~* **фауна** орнитологи́ческая фа́уна

орнитоло́гия *сущ.* орнитоло́гия (*раздел зоологии, изучающий птиц*)

о́роч *сущ.* о́рочи (*народность — ед.* о́роч, оро́чка) || оро́чский; *~ йолалары* оро́чские обы́чаи

ортодокс *сущ. книжн.* ортодо́кс (*человек ортодоксальных взглядов*)

ортодоксаль *прил. книжн.* ортодокса́льный (*последовательный, неуклонно придерживающийся какого-л. учения, мировоззрения*)

ортодоксальлек *сущ. книжн.* ортодокса́льность (*взглядов*)

ортодо́кслану *перех. книжн.* проявля́ть/прояви́ть ортодокса́льность

ортопед *сущ.* ортопе́д (*специалист по ортопедии*)

ортопе́дик *прил.* ортопеди́ческий; *~ аяк киеме* ортопеди́ческая о́бувь

ортопедия *сущ.* ортопе́дия (*раздел медицины, включающий изучение, лечение и профилактику стойких искривлений, деформаций позвоночника, конечностей*)

ортын *нареч. диал. см.* **орынтын**; *~ гына кайту* возврати́ться тайко́м

ортын-портын *нареч. диал.* воровски́; втиху́ю, тишко́м

ору *неперех., перех.* **1.** *неперех.* ударя́ть/уда́рить, сту́кнуть (*с размаху*) *кого-что*, по *чему* и́ли во *что*; *см. тж.* **сугу**; *йодрык белән ору* сту́кнуть кулако́м; *атка камчы белән ору* уда́рить ло́шадь кнуто́м; *башына ору* сту́кнуть по голове́ **2.** *перех. редко* бить, избива́ть/изби́ть; *балаларны ормау* не бить, не обижа́ть дете́й **3.** *перех.* броса́ть/бро́сить, мета́ть/метну́ть, швыря́ть/швырну́ть; *җиргә ору* бро́сить о́земь; *йөзгә ору* бро́сить в лицо́; *бомба ору* броса́ть бо́мбу; *таш белән ору* мета́ть камня́ми **4.** *прям., перен.* ударя́ть/уда́рить; поража́ть/порази́ть; *агачны яшен орды* мо́лния уда́рила в де́рево; *үзеңне яшен орсын* пусть порази́т тебя́ мо́лния **5.** *перен.* бить, громи́ть, уничтожа́ть/уничто́жить; *дошманны ору* бить (уничтожа́ть) врага́ **6.** *в знач. нареч.* **орып** *перен. разг.* ливмя́; *орып яңгыр ява* ливмя́ льёт дождь; идёт о́чень си́льный дождь ◊ **орып бәрү (салу)** *прост.* намно́го лу́чше *кого-чего*; ≈ дава́ть/дать сто очко́в вперёд

ору́дие *сущ. разг. см.* **туп**; *~ләр залпы* залп ору́дий

орфогра́фик *прил.* орфографи́ческий (*словарь*); *~ кагыйдәләр* орфографи́ческие пра́вила

орфогра́фия *сущ.* орфогра́фия || орфографи́ческий; *татар теленең ~сен камилләштерү* усоверше́нствовать орфогра́фию татарского языка́; *~ күнегүләре җыентыгы* сбо́рник орфографи́ческих упражне́ний

орфогра́фияче *сущ. лингв.* специали́ст по орфогра́фии

орфоэ́пик *прил.* орфоэпи́ческий; *телнең ~ нормалары* орфоэпи́ческие но́рмы языка́; *~ сүзлек* орфоэпи́ческий слова́рь

орфоэ́пия *сущ.* орфоэ́пия (*система правил, определяющих правильное литературное произношение*) || орфоэпи́ческий; *~ кагыйдәләре* орфоэпи́ческие пра́вила

орхидея *бот* орхиде́я; *см. тж.* **күке яше**

орчы|к *сущ.* **1.** веретено́ || веретённый; *~к бөтерү* враща́ть, крути́ть веретено́; *якорь ~гы* веретено́ я́коря; *~к тавышы* веретённое жужжа́ние; *~к җебе* веретённая пря́жа **2.** шпи́ндель (*в прядильной машине*) **3.** ось, сте́ржень || осево́й, стержнево́й □ **~к оясы (төбе)** подпя́тник (*на мельнице*); **~к пальмалар** веретенообра́зные па́льмы; **~к сөяк** *анат.* лучева́я кость; це́вка ◊ **~к буе** ма́ленький ро́стом; ка́рликовый; **~к кебек 1.** как юла́ **2.** *см.* **орчык буе**; **~к шикелле (сыман) бөтерелү, ~ктай бөтерелү 1.** пляса́ть ви́хрем, верте́ться волчко́м **2.** ≈ ходи́ть (стоя́ть) на за́дних ла́пах

орчыкбаш *сущ.* пря́сло, пря́слица

орчыклы *прил.* веретённый; *~ җеп* веретённая пря́жа

орчыклык *сущ. спец.* подпя́тник

орчыкча *сущ. зоол.* **1.** медяни́ца, веретённица (*безногая ящерица*); *см. тж.* **бакыр кәлтә 2.** медяни́ца (*насекомое, вредитель яблоневых и грушевых деревьев*)

орышын|у *неперех. диал.* брани́ться, брани́ть себя́; *үзенең тетмәсен тетеп ~а* брани́т себя́ на чём свет стои́т

орыш *сущ.* разго́р, ра́спря, брань, перебра́нка, ру́гань, руга́тельство

орыш|у *неперех.* брани́ться/побрани́ться, поруга́ться/поруга́ться, перебра́ниваться/перебрани́ться, вздо́рить/повздо́рить с *кем* || перебра́нка; *см. тж.* **ачуланышу**; *күршеләр тагын ~каннар* сосе́ди опя́ть поруга́лись □ **~ып бетү** перебрани́ться (*со всеми, со многими*)

оры *сущ.* **1.** желва́к, ши́шка (*на теле человека, животных*) **2.** наро́ст (*у некоторых животных*); *борын өсте ~сы* наро́ст над но́сом (*у гусака*) **3.** *бот.* кап, наплы́в, вы́рост (*на столе, корнях, ветвях деревьев*); *~ катылыгы ягыннан таштан аз гына калыша* по свое́й твёрдости кап чуть уступа́ет лишь ка́мню

орыла-бәрелә, орылып-бәрелеп *нареч.* толка́я (раста́лкивая) окружа́ющих; *орыла-бәрелә үтү* протолкну́ться (пройти́) толка́ясь □ **орыла-бәрелә йөрү** толка́ться

орыла-сугыла, орылып-сугылып *нареч. см.* **орыла-бәрелә**; *орыла-сугыла халык арасыннан чыгу* прота́лкиваясь, вы́браться из толпы́; протолкну́ться сквозь толпу́

орылу *страд. от* **ору**; выбра́сываться, быть вы́брошенным

орылы *прил.* с наро́стом; шишкова́тый; *~ маңгай* лоб с наро́стом; *~ тамыр* шишкова́тый ко́рень

орындыру *перех.* зацепля́ть/зацепи́ть за *что*

орынма *сущ. мат.* каса́тельная || *прил.* каса́тельный; *~ магнит угы* каса́тельная магни́тная ли́ния; *~ сызык* каса́тельная ли́ния; *~ яссылык* каса́тельная пло́скость

орынтын *нареч. разг.* та́йно, вта́йне, скры́тно; втихомо́лку, исподтишка́, укра́дкой; *~ эшләү* де́лать скры́тно; *см. тж.* **яшертен** || *прил.* та́йный, потаённый; скры́тный; *~ юллар белән* та́йными путя́ми

орын|у *неперех.* **1.** ударя́ться/уда́риться, сту́каться/сту́кнуться *обо что-л.*; *ян белән ~у* уда́риться бо́ком **2.** задева́ть/заде́ть, тро́гать/тро́нуть *кого-л., что-л.*; притра́гиваться/притро́нуться, дотра́гиваться/дотро́нуться, каса́ться/косну́ться, прикаса́ться/прикосну́ться

к кому-л., чему-л. || каса́ние; *очкыч шассие белән җиргә ~ды* шасси́ самолёта коснýлось земли́; *бу әйберләргә ~асы булмагыз* не сме́йте притра́гиваться к э́тим вещам 3. соприкаса́ться/соприкосну́ться с *кем-л., чем-л.* || соприкаса́ние; *аларның иңнәре бер-берсенә ~ды* их пле́чи соприкоснýлись 4. цепля́ться/зацепля́ться, зацепи́ться за *кого-что-л.*, проходя́ ми́мо 5. *в знач. нареч.* **орынып** о́чень бли́зко, ря́дом; *елга безгә ~ып тора* река́ протека́ет ря́дом с на́ми 6. *перен.* задева́ть/заде́ть, тро́гать/тро́нуть; *көз сулышы каеннарга да ~ды* дыха́ние о́сени тро́нуло и берёзы 7. *перен.* покуша́ться/покуси́ться (*на чью-л. свободу, честь, жизнь и т. п.*); *см. тж.* **каст итү**; *Ватан иминлегенә ~у* покуша́ться на свобо́ду (поко́й) Ро́дины □ **~у ноктасы** *мат.* то́чка каса́ния; **~ып алу (кую)** коснýться, дотро́нуться; **~ып китү** прикоснýться, коснýться, заде́ть; **~ып тору** соприкаса́ться, прилега́ть; **~ып узу (үтү, китү)** прикоснýться, заде́ть ◊ **~ып торган** о́чень бли́зкий; *алар ~ып торган күршеләр* они́ о́чень бли́зкие сосе́ди

орынчы: орынчы яссылык *мат.* соприкаса́ющаяся пло́скость; **~ әйләнә** *мат.* соприкаса́ющаяся окру́жность

орынчак *прил. редко* лю́бящий тере́ться, потере́ться, чеса́ться обо *что-л.*; *~ атта ял юк* (*посл.*) у ло́шади, кото́рая лю́бит тере́ться, чеса́ться, гри́вы не быва́ет

орынчык *сущ. диал.* 1. (*место, где река встречает препятствия*) стремни́на 2. поме́ха, препя́тствие

орынчыклау *перех. диал.* лезть не в своё де́ло; меша́ть други́м

орынышу *совм. от* **орыну**; прикаса́ться (прикосну́ться) друг к дру́гу (*о многих*)

орып-бәреп *нареч.* 1. о́чень си́льно, ливмя́; как из ведра́; *орып-бәреп яңгыр ява* (как из ведра́) льёт дождь 2. *разг. см.* **ордым-бәрдем** I (1); *орып-бәреп эшләү* рабо́тать как попа́ло (*безалаберно*) 3. *см.* **ора-ера**

орып-ерып *нареч. см.* **ора-ера**

орыш *сущ.* 1. ру́гань, брань; руга́тельство; *бу юлы ~ булмады* на э́тот раз ру́гани не́ было 2. ссо́ра, дра́ка; *һәр көн ~ та талаш* ка́ждый день ссо́ры да дра́ки 3. *уст.* война́, би́тва, сраже́ние; брань; *~ кырында* на по́ле бра́ни; *~ка чыгу* идти́ войно́й; *кан койгыч ~* кровопроли́тная би́тва □ **~ кылу** сража́ться, дать бой

орыш-кырылыш *сущ. собир.* 1. кру́пная ссо́ра-дра́ка 2. кровопроли́тная би́тва, сраже́ние

орыш-кычкырыш *сущ. собир. см.* **орыш-талаш**

орыш-талаш *сущ. собир.* ссо́ра, перебра́нка; неуря́дица, нелады́; дебо́ш

орыштыргалау *многокр. от* **орышту**; поро́гивать

орыштыру *многокр. см.* **орыштыргалау**

орыш|у *перех.* руга́ть, обру́гивать/обруга́ть, брани́ть/побрани́ть; поро́гивать/поруга́ть, жури́ть/пожури́ть, отчи́тывать/отчита́ть || ру́гань, брань, руга́тельство; *бик каты ~у* пожури́ть □ **~ып алу** побрани́ть

ос *сущ. диал.* уме́ние; ум (*в деле*)

осетин *сущ.* осети́н, осети́нка || осети́нский (*язык, танец*); *~ хатыны (кызы)* осети́нка

осети́нча *нареч.* по-осети́нски, на осети́нском языке́ (*читать, писать, говорить*) || *прил.* осети́нский; на осети́нском языке́ (*журнал, книга*)

осётр *сущ.* осётр (*рыба*) || осетро́вый; *~ икрасы* осетро́вая икра́; *~ ите* осетри́на || осетри́нный

осётрчалар *сущ. мн. зоол.* осетро́вые (*семейство осетровых*)

оскы *сущ. диал. см.* **коткы** ◊ **~ уты үрләтү** *см.* **оскыту**

оскыту *перех. диал.* 1. подстрека́ть/подстрекну́ть, натра́вливать/натрави́ть *кого* на *кого-что* 2. разъря́ть/разъяри́ть, взбудора́жить *кого*

ослы *прил. диал.* сообрази́тельный; у́мный (*в деле, работе*)

оста *сущ.* 1. мастер, специали́ст, квалифици́рованный рабо́чий; *юл ~сы* ма́стер доро́жных дел; *агач ~сы* ма́стер деревообрабо́тки; *югары уңыш ~лары* мастера́ высо́ких урожа́ев; *һәр эшнең үз ~сы бар* (*погов.*) в любо́м де́ле есть свой ма́стер 2. ма́стер, уме́лец, иску́сник, знато́к; *нәфис сүз ~сы* ма́стер худо́жественного сло́ва; *каләм ~лары* мастера́ пера́; *чигү ~лары* уме́льцы по вышива́нию; *үз эшенең ~сы* знато́к своего́ де́ла; *эш ~сыннан курка* (*погов.*) де́ло ма́стера бои́тся; *~ны «~» диләр, эшен күргәч* (*погов.*) уме́льца называ́ют ма́стером по его́ рабо́те 3. *в сочет. с некоторыми сущ. образует названия профессии*; *балта ~сы* пло́тник; *сәгать ~сы* часовщи́к; часово́й ма́стер; *ефәк ~лары* шелково́ды || *прил.* 1. уме́лый, иску́сный, о́пытный; *~ эш* иску́сная рабо́та; *~ төзүчеләр* о́пытные строи́тели; *~ уенчы* о́пытный игро́к; *~ кулда һөнәр бар* (*погов.*) в уме́лых рука́х ремесло́ во́дится 2. ло́вкий, сноро́вистый, запра́вский; *~ аучы* запра́вский охо́тник; *~ алдакчы* ло́вкий плут 3. *в знач. сказ.* ло́вок; гора́зд, масте́р (*прост.*); *хәйләләргә ~* гора́зд хитри́ть || *нареч.* 1. уме́ло, иску́сно, ма́стерски; краси́во; *скрипкада ~ уйный* ма́стерски (виртуо́зно) игра́ет на скри́пке; *~ сөйли* говори́т иску́сно 2. ло́вко, сноро́висто; *~ ата* стреля́ет ло́вко (*метко*) 3. *перен.* хи́тро, ло́вко; *~ алдалау* ло́вко обману́ть (одура́чить) □ **~ итеп** уме́ло, иску́сно; **~ эшләнгән (башкарылган)** иску́сный ◊ **~ кул** уме́лец; **~ куллы** уме́лый; **~ телле** красноречи́вый; **~ теллелек** красноре́чие

остабикә *сущ.* 1. остабико́ (*жена муллы*) 2. *см.* **мәгаллимә**

остаз *сущ.* учи́тель; наста́вник; *һәр эшнең остасы бар, һәр останың ~ы бар* у вся́кого ремесла́ есть свой ма́стер, а у ка́ждого ма́стера быва́ет наста́вник; *завод яшьләренең ~ы* наста́вник заводско́й молодёжи

остазлык *сущ.* 1. до́лжность, заня́тие учи́теля (*наставника*); *~ка дәгъва кылу* претендова́ть на до́лжность учи́теля 2. наста́вничество; *~ хәрәкәте* движе́ние наста́вничества

остала́рча *нареч.* ма́стерски, иску́сно; *~ эшләнгән сәнгать әсәре* ма́стерски вы́полненное произведе́ние иску́сства

осталы|к *сущ.* 1. уме́ние; спосо́бность; *эшкә ~к* уме́ние (*способность*) к рабо́те; *җырга һәм биюгә ~к* уме́ние петь и пляса́ть; *кул эшләренә ~к* спосо́бность к рукоде́лию; *телгә ~к* уме́ние краси́во говори́ть; красноре́чие 2. мастерство́, иску́сство; *профессиональ ~к* профессиона́льное мастерство́; *сәхнә ~гына өйрәнү* учи́ться сцени́ческому мастерству́ (иску́сству); *~к күрсәтү* пока́зывать мастерство́; *музыка язу ~гы* иску́сство компози́ции 3. до́лжность, заня́тие ма́стера 4. ло́вкость, сноро́вка; *кул ~гы* ло́вкость рук; *бу эш зур ~к таләп итә* э́та рабо́та тре́бует большо́й сноро́вки; *~к белән* уме́ло, иску́сно

остар|у *неперех.* 1. наловчи́ться; поднаторе́ть *прост.*; *тиз эшләргә ~у* наловчи́ться де́лать бы́стро 2. *перен. ирон.* стара́ться пока́зывать/показа́ть зна́ние (осведомлённость, компете́нтность); *урынлы-урынсыз ~у* к ме́сту и не к ме́сту стара́ться показа́ть своё зна́ние □ **~а бару (төшү)** станови́ться бо́лее иску́сным (ло́вким); **~ып беткән** искушённый, наторе́лый *прост.*; **~ыц бетү** наловчи́ться, поднаторе́ть *прост.*; **~ып җитү** наловчи́ться

остаханә *сущ.* мастерска́я

отделе́ние *сущ. воен.* отделе́ние; ~ *командиры* кома́ндир отделе́ния

откалау *многокр. от* **оту**; вы́игрывать (*время от времени*)

откыр *прил.* **1.** смышлёный, даро́витый, одарённый; ~ *укучы* одарённый учени́к **2.** воспри́имчивый; ~ *акыл* воспри́имчивый ум

отли́чни|к *сущ.* отли́чник; *уку ~гы* отли́чник учёбы; *сәүдә ~клары* отли́чники торго́вли

отли́чно **1.** *нареч.* отли́чно; *эшләр ~ бара* дела́ иду́т отли́чно **2.** *в знач. сущ.* отли́чно (*самая высшая оценка*); *~га гына уку* учи́ться то́лько на отли́чно

отпор: отпор бирү *разг.* дать отпо́р

отряд *сущ.* **1.** *воен.* отря́д || отря́дный; ~ *командиры* кома́ндир отря́да; *десантчылар ~ы* отря́д деса́нтников; *партизаннар ~ы* партиза́нский отря́д; *су асты көймәләре ~ы* отря́д подво́дных ло́док; ~ *өйрәнүләре* отря́дные уче́ния **2.** отря́д (гру́ппа, коллекти́в) || отря́дный; *пионер ~лары* пионе́рские отря́ды; *археологлар ~ы* отря́д архео́логов; ~ *сборы* отря́дный сбор **3.** *зоол.* отря́д (подразделе́ние) в систе́матике живо́тных; *имезүчеләр ~ы* отря́д млекопита́ющих; *кимерүчеләр ~ы* отря́д грызуно́в

отста́вка *сущ.* отста́вка; *~га чыгу (китү)* вы́йти в отста́вку; *~га чыккан офицер* офице́р в отста́вке; *хөкүмәтнең ~га китүе* отста́вка прави́тельства

отста́вкадагы *прил.* отставно́й (*генерал, полковник*)

о́ттиск *сущ. полигр.* о́ттиск (*типографский отпечаток текста, рисунка*); *гравюра ~ы(сы)* о́ттиск грави́юры; *корректура ~ы(сы)* корректу́рный о́ттиск; *~лар төпләмәсе* подши́вка о́ттисков

оттыр|ү **1.** *перех.* прои́грывать/проигра́ть *что* (*бой, сражение, деньги; ладью, матч, турнир*) *кому* в *чём*, на *чём* (*в карты, на бильярде, в соревновании, в споре*) **2.** *неперех.* прогада́ть, прои́грывать/проигра́ть; *дусларның киңәшләрен тыңламыйча ~у* прогада́ть, не послу́шавшись сове́та друзе́й; *вакытта ~у* прогада́ть (проигра́ть) во вре́мени □ **~ып бетерү** проигра́ть, проигра́ться

оттырыш *сущ. в разн. знач.* про́игрыш (*в сражениях, в войне, в споре, в матче по футболу*); *зур суммага ~* про́игрыш в кру́пной су́мме □ **~та калу** быть (оказа́ться) в про́игрыше

оттырышлы *прил.* про́игрышный; ~ *ен* про́игрышная па́ртия (*в шахматной игре*)

оттырышсыз *прил.* беспро́игрышный (*заем*); ~ *лотерея* беспро́игрышная лотере́я

оту *перех.* **1.** 1) *в разн. знач.* вы́игрывать/вы́играть *что* (*бой, битву, поединок, матч, пари*), у *кого*, в *чём*, на *чём* (*в соревнованиях, в матче, турнире, чемпионате*) || вы́игрывание, вы́игрыш; *лотерея билетына оту* вы́играть по лотере́йному биле́ту 2) обы́грывать/обыгра́ть *кого-л.* (*в шахматы, на бильярде, в карты*) || обы́грывание **2.** выга́дывать/вы́гадать, вы́игрывать/вы́играть || выга́дывание; *вакыт оту* вы́играть вре́мя; *материаль яктан оту* вы́гадать материа́льно **3.** усва́ивать/усво́ить, запомина́ть/запо́мнить, вы́учивать/вы́учить || усва́ивание, запомина́ние, вы́учивание; *көй оту* усво́ить моти́в (*песни*); *яңа җыр оту* вы́учить но́вую пе́сню; *сүзләрен оту* запо́мнить слова́ □ **отып алу** **1.** вы́играть **2.** усво́ить; **отып бетерү** обыгра́ть; **отып калу** усво́ить, запо́мнить

отчёт *сущ.* отчёт || отчётный; *аванс ~ы* ава́нсовый отчёт; ~ *ясау (тоту)* де́лать (держа́ть) отчёт пе́ред *кем-чем*; ~ *чоры* отчётный пери́од

отылу *возвр.-страд. от* **оту** **1.** *возвр.* прои́грываться/проигра́ться; *картада бик нык ~* си́льно проигра́ть в ка́рты **2.** *страд.* прои́грываться

отыры *нареч. разг.* всё бо́льше и бо́льше, всё бо́лее и бо́лее; ещё пу́ще *прост.*; *җил ~ көчәя* ве́тер всё бо́льше и бо́льше уси́ливается

отырдан-отыры *нареч. диал.* ещё бо́лее; ещё пу́ще *прост.*; *отырдан-отыры ераклашу* ещё бо́лее удаля́ться

отыш *сущ.* **1.** вы́игрыш; *зур суммалы отыш* кру́пный вы́игрыш; *отыш таблицасы* табли́ца вы́игрышей **2.** побе́да, успе́х; *игенчеләрнең зур ~ы* больша́я побе́да хлеборо́бов; *~ка ирешү* доби́ться успе́ха; *сәяси ~* полити́ческая побе́да **3.** вы́года, по́льза; вы́игрыш; *һәр техник яңалык нинди дә булса ~ бирә* ка́ждое техни́ческое но́вшество прино́сит каку́ю-нибудь по́льзу □ **~ уеннары** аза́ртные и́гры

отышлы *прил.* **1.** вы́игрышный; ~ *заем* вы́игрышный заём; ~ *позиция* вы́игрышная пози́ция **2.** уда́чный; вы́годный; ~ *тема* уда́чная те́ма **3.** поле́зный; экономи́чный (*метод*); *ике як өчен дә ~ экономик бәйләнешләр* взаимовы́годные экономи́ческие свя́зи □ **~ уеннар** *см.* **отыш уеннары**

отышлылык *сущ.* вы́годность, экономи́чность

отышсыз *прил. спорт.* ничейный; ~ *уен* ничейная игра́ || *нареч.* вничью́; *уен ~ тәмамланды* игра́ зако́нчилась вничью́

отышханә *сущ. уст.* иго́рный дом

офицер *сущ.* **1.** офице́р || офице́рский; *~лар составы* офице́рский соста́в **2.** *мн.* **офицерлар** *собир.* 1) офице́рство 2) офицерьё *прост. пренебр.*

офицерлык *сущ.* офице́рство; зва́ние (чин) офице́ра

офсет *сущ. полигр.* офсе́т (*способ печатания*) || офсе́тный; ~ *кәгазе* офсе́тная бума́га; ~ *ысулы белән* офсе́тным спо́собом

офтандыру *понуд. от* **офтану**; вынужда́ть/вы́нудить раска́иваться

офтан|у *неперех.* ка́яться, раска́иваться/раска́яться, сожале́ть || раска́яние, сожале́ние; *хат язмаганлыгына ~а* ка́ется, что не написа́л письмо́

офтанулы *прил.* с раска́янием *чем*; испо́лненный чу́вства раска́яния (сожале́ния); ~ *тавыш белән* (с) ка́ющимся го́лосом

офтанышу *совм. от* **офтану** (*о многих*)

офык *сущ.* **1.** горизо́нт, небоскло́н; даль **2.** *перен.* горизо́нт, масшта́б; *әдәбият ~лары* небоскло́н литерату́ры

ох *межд. см.* **ой**

о́хра *сущ.* о́хра || о́хровый, о́хренный, охря́но́й; ~ *белән буяу* кра́сить о́хрой; о́хрить

о́хралы *прил.* о́христый; ~ *балчык* о́христая гли́на

охра́нка *сущ. ист.* охра́нка (*охранное отделение*); *патша ~сы* ца́рская охра́нка

охшат|у *перех.* **1.** уподобля́ть/уподо́бить *кого-что кому-чему*, сра́внивать/сравни́ть, сопоставля́ть/сопоста́вить, находи́ть/найти́ схо́дство с *кем-чем* || уподобле́ние, сопоставле́ние, сравне́ние; *яшьлекне язга ~у* уподобля́ть мо́лодость весне́; *халык җырларына ~ып* уподобля́я наро́дным пе́сням; *романның героен үзенә ~у* сравне́ние геро́я рома́на с собо́й; *баланы атасына ~у* найти́ в ребёнке схо́дство с отцо́м **2.** принима́ть/приня́ть (*по ошибке*) за *кого-что*; *аны сеңлесенә ~каннар*

её прúняли за сестрý **3.** 1) подража́ть *кому-чему*, имити́ровать *кого-что* || подража́ние, имита́ция; *өлкәннәргә ~у* подража́ть взро́слым; *~ырга сәләтлелек* спосо́бность к подража́нию (имита́ции); *сандугач тавышына ~ып сайрау* имити́ровать соловьи́ное пе́ние 2) имити́ровать/сымити́ровать || имита́ция, подде́лка под *что*; *энҗегә ~у* имита́ция под же́мчуг; подде́лка под же́мчуг **4.** *в знач. сущ. лингв. см.* **чагыштыру**; *поэмада бик оста ~улар бар* в поэ́ме встреча́ются о́чень уда́чные сравне́ния **5.** *в знач. предлога* **охшатып** 1) наподо́бие, вро́де *кого-чего*; *хикәя, сәхнә әсәренә ~ып, диалог формасында язылган* расска́з напи́сан в фо́рме диало́га, наподо́бие сцени́ческих произведе́ний 2) под *что*; *имәнгә ~ып буяу* вы́красить под дуб; *мраморга ~ып эшләнгән* отде́ланный под мра́мор □ **~ып кул кую** подде́лать *чью-л.* по́дпись; **~ып эшләнгән (ясалган)** подде́ланный, фальши́вый

охшатылу *страд. от* **охшату**; уподобля́ться, сопоставля́ться, сра́вниваться

охша|у *неперех.* **1.** походи́ть, быть похо́жим (подо́бным) *кому-чему*; гляде́ть, вы́глядеть *кем-чем* || схо́дство; *ике тамчы су кебек бер-берсенә ~у* как две ка́пли воды́ быть похо́жим друг на дру́га; *очраклы ~у* случа́йное схо́дство; *баһадирга ~у* вы́глядеть богатырём **2.** быть (вы́глядеть) *каким*; похо́же (на то), что ...; *арыганга ~ган* вы́глядит уста́лым **3.** *см.* **ошау**; *тамашачыларга ~у* понра́виться зри́телям □ **~рга тырышу** подража́ть || подража́ние

охшаулы *прил. см.* **охшаш** 1; *көнләшүгә ~ хис* чу́вство, подо́бное ре́вности

охшаш *прил.* **1.** похо́жий на *кого-что*; схо́дный, схо́жий с *кем-чем*; подо́бный *кому-чему*; аналоги́чный; *тулган айга ~ йөзе* лицо́ её подо́бно по́лной луне́; *елаганга ~ тавыш* го́лос, похо́жий на плач; *~ шартлар* аналоги́чные усло́вия **2.** тожде́ственный, одноро́дный, однотипный, иденги́чный; *~ чагыштырулар* однотипные сравне́ния **3.** *лингв.* созву́чный; *~ сүзләр* созву́чные слова́ **4.** *в знач. сущ.* **охшашы** подо́бие, схо́дство; *җирдә юк моңа ~ы* нет подо́бия э́тому на земле́ □ **~ы буыннар** *мат.* подо́бные чле́ны ◊ **~ы булмаган** несравни́мый, непревзойдённый

охшашландыру *перех. лингв.* уподобля́ть/уподо́бить; ассимили́ровать || уподобле́ние, ассимиля́ция; *прогрессив ~* прогресси́вное уподобле́ние

охшашлану *неперех. лингв.* уподобля́ться/уподо́биться, ассимили́роваться || уподобле́ние, ассимиля́ция; *~ юлы белән синтаксик синонимнар ясалу* образова́ние синтакси́ческих сино́нимов путём уподобле́ния

охшашлы *прил. см.* **охшаш** 1; *мандолинага ~ уен коралы* музыка́льный инструме́нт, схо́жий с мандоли́ной

охшашлы|к *сущ.* **1.** схо́дство, схо́дность, схо́жесть, анало́гия, аналоги́чность; *характерлар ~гы* схо́дство хара́ктеров; *язуларының ~гы* схо́жесть по́черка; *табигатьтән ~клар эзләү* иска́ть анало́гии в приро́де **2.** тожде́ственность, одноро́дность, иденги́чность **3.** *мат.* подо́бие; *ике өчпочмакның ~гы* подо́бие двух треуго́льников

охшашу *неперех.* **1.** быть похо́жим (схо́дным), походи́ть друг на дру́га || схо́дство, схо́жесть; *бу ике кыз арасында нинди́дер бер ~ бар* ме́жду э́тими двумя́ де́вушками име́ется како́е-то схо́дство **2.** *лингв. см.* **охшашлану**

охшашсызлану *неперех. лингв.* расподобля́ться, подверга́ться/подве́ргнуться расподобле́нию (диссимиля́ции) || расподобле́ние, диссимиля́ция; *~ күренеше* явле́ние диссимиля́ции

оһо *межд. выраж. чувства восхищения, удивления* ого́!; *оһо, эш зурга киткән икән!* ого́, ока́зывается де́ло зашло́ далеко́!

оч I *сущ.* **1.** коне́ц, ко́нчик; *борын очы* ко́нчик но́са; *бармак очлары белән капшау* ощу́пывать ко́нчиками па́льцев; *тел очында* на ко́нчике языка́; *бурәнәнең юан очы* то́лстый коне́ц бревна́; ко́мель бревна́ **2.** шпиль; *манара очы* шпиль ба́шни (минаре́та) **3.** верши́на, верху́шка, ма́ковка, маку́шка (*дерева*) || верху́шечный; *манараның оч өлеше* верху́шечная часть минаре́та; *оч бөресе* верху́шечная по́чка; *очтан үсү* верху́шечный рост **4.** остриё, ко́нчик, носо́к; заостре́нный коне́ц *чего-л.*; *энә очы белән* остриём иго́лки; *чалгы очы* носо́к косы́; *урак очы* ко́нчик се́рпа **5.** *см.* **очлык**; *чаңгы таякларының тимер очы* желе́зные наконе́чники лы́жных па́лок; *сөңге очы* наконе́чник пи́ки **6.** край, оконе́чность, окра́ина; коне́ц (*села*); *шәһәрнең югары очы* ве́рхняя окра́ина го́рода; *авыл очында* на краю́ села́; *түбән очка юнәлү* напра́виться на ни́жний коне́ц (*деревни*); *аргы очтан икенче йорт* второ́й дом с да́льнего кра́я; *авылның бер очыннан икенче очына чабу* бежа́ть из одного́ конца́ дере́вни в друго́й коне́ц **7.** носо́к; *итек очлары* носки́ сапо́г; *аяк очларында йөрү* ходи́ть на носка́х (*на цыпочках*) **8.** голо́вка; *кискеч очы* голо́вка резца́ **9.** *перен.* нача́ло, осно́ва; *милли культурабызның очы* нача́ло (осно́ва) на́шей национа́льной культу́ры **10.** *перен.* коне́ц, преде́л (*какого-л. дела*); *эшнең очы күренми әле* пока́ не ви́дно конца́ рабо́ты || *прил.* концево́й; *оч тамырлар* концевы́е сосу́ды □ **очка жигелгән, очка жигә торган** уносно́й, уно́сный; цугово́й; *очка жигелгән пар ат* уно́сная па́ра лошаде́й; **очка җигү** запря́чь цу́гом (уно́сным); **очтан очка** из конца́ в коне́ц; **очы бетү** затупи́ться; **очын бетерү** затупи́ть; **очын кисү** подре́зка (*кустарников*) ◊ **очны очка ялгау** своди́ть концы́ с концо́м; **очны өзү** испо́ртить взаимоотноше́ния; порыва́ть/порва́ть, связь с *кем-л.*; **очы очка бәйләнмәү (ялганмау)** концы́ с концо́м не вя́жутся (не схо́дятся); **очы (килеп) чыгу** проясни́ться; станови́ться/стать изве́стным; **очы юк** *см.* **очы-кырые күренмәү (юк)**; **очын табарлык булмасын** чтоб бы́ло ши́то-кры́то; чтоб концы́ в во́ду; **очын (суга) яшерү** пря́тать концы́ в во́ду; хорони́ть концы́; **очына алып барып чыгу** довести́ до конца́; **очына чыга алмаслык хәл** заколдо́ванный круг; **очына чыга алмау 1.** не обходи́ться (обойти́сь) без *кого-чего* **2.** концо́в не найти́; **очына чыгарлык түгел 1.** конца́-кра́ю нет **2.** сам чёрт не разберёт; концо́в не найти́; **очына чыгу 1.** зако́нчить, заверши́ть, довести́ до конца́, поста́вить то́чку **2.** разобра́ться, распу́тать, найти́ коне́ц

оч II *сущ.* кусо́к, тюк, шту́ка (*о рулоне ткани*); *ике оч комач* два тю́ка кумача́; *бер очтан тегелгән күлмәкләр* платья́, сши́тые из одного́ куска́ (*ткани*)

оча *сущ. анат.* таз □ **оча башы сөяге** кресте́ц; **оча сөяге** та́зовая кость; таз

оча-куна *нареч.* **1.** бы́стро, как на кры́льях; *оча-куна йөрү* ходи́ть как на кры́льях **2.** *перен. разг.* крити́чески, агресси́вно; *оча-куна сөйләү* говори́ть крити́чески; раскритикова́ть

очалык *сущ.* отко́сник, отко́сный реме́нь (*у шлеи*)

очан I *сущ. анат.* метеори́зм (*болезнь — вздутие живота*)

очан II *сущ. ист.* лёгкая плоскодо́нная ло́дка

очанак *прил.* 1. вспы́льчивый; ~ *характерлы кеше* челове́к со вспы́льчивым хара́ктером 2. *перен.* жизнера́достный, весёлый; игри́вый; ~ *яшь кызлар* игри́вые молоды́е де́вушки

очар *прил.* перелётный, отлётный; ~ *кошлар төркеме* карава́н перелётных птиц □ ~ **балык** *зоол.* лету́чая ры́ба; ~ **кәлтә** *зоол.* лету́чий драко́н ◊ ~ **кош** лету́н

о́черкчы *сущ.* очерки́ст

очкак *прил.* мя́гкий, пуши́стый, лету́чий; ~ *кар* пуши́стый снег || *сущ. бот.* лету́чка (*семя или плод некоторых растений с крыловидными выростами*)

очкалак *сущ. бот.* 1. бе́лка-лета́га 2. *перен. редко* лету́н, лету́нья (*о человеке*) 3. *перен.* непосе́да, озорни́к, озорни́ца; □ ~ **бака** *зоол.* лету́чая лягу́шка; *см. тж.* **агач бакасы**

очкалакчы *прил. бот.* лету́чий (*о семенах с крыловидными выростами*)

очкалаклык *сущ.* непосе́дливость, озорство́

очкалау *многокр. от* **очу**; полётывать

очко 1. *спорт.* очко́; *«Спартак» хоккейчылары 37 ~ җыйдылар* хоккеи́сты «Спартака́» набра́ли 37 очко́в 2. *прост.* очко́ (*род азартной игры; двадцать одно*) ◊ ~ **бирү** дать сто (две́сти) очко́в вперёд

очкылык *сущ.* ико́та □ ~ **тоту** ика́ть/икну́ть || ика́ние; ~ **үләне** *бот.* ико́тник

очкын 1. *прям., перен.* и́скра || искрово́й; *учак ~нары* и́скры костра́; *чакма таш ~ы* кремнёвая и́скра; *электр ~нары* электри́ческие и́скры; *~нан ялкын кабыныр* из и́скры возгори́тся пла́мя; *күздән ~нар чәчрәү* посы́пались и́скры из глаз; ~ *методы* искрово́й ме́тод 2. *перен.* (*проблеск, проявление какого-л. чувства*) и́скра *чего* (*надежды, любви, творческого вдохновения*); *күзләрдә ачу ~нары* в глаза́х и́скры гне́ва; *шатлык ~нары* и́скры ра́дости 3. *прям., перен.* блёстки (*ед.* блёстка); *иртәнге чыкның алмаз ~нары* алма́зные блёстки у́тренней росы́; *талант ~нары* блёстки тала́нта; *уткенлек ~нары* блёстки остроу́мия □ ~ **кайтаргыч (тоткыч)** искродержа́тель, искроулови́тель; ~ **сүндергеч** искрогаси́тель; ~ **үлчәгеч** искроме́р; ~ **чыгару** 1. искри́ть 2. высека́ть ого́нь; ~ **чыгу** искри́ться || искре́ние; **~га сынау** *физ.* про́ба на и́скру

очкынлан|у *неперех.* 1. искри́ться, и́скриться; сы́пать и́скры, искри́ться бле́ском || искре́ние; *учак җилдә ~а* костёр искри́тся на ветру́; *йолдызлар ~ган кебек җемелдиләр* звёзды мерца́ют, сло́вно искря́тся 2. *в знач. нареч.* **очкынланып** искри́сто, и́скрами; *~ып учак яна* искри́сто (я́рко) гори́т костёр; *~ып җемелдәү* блесте́ть искри́сто; *моржадан ~ып төтен ургыла* из трубы́ и́скрами вали́т дым 3. *перен.* блесте́ть, сверка́ть, искри́ться (*о глазах*); *күзләре ~а* глаза́ (его́) сверка́ют

очкынл|ау *неперех. редко см.* **очкынлану** 1; *учак наман ~лый* костёр всё ещё искри́тся

очкынлы *прил.* 1. искрово́й, искри́стый; ~ *ялкын* искри́стое пла́мя 2. *перен.* искря́щийся, искромётный, жгу́чий (*взгляд*); ~ *күзләр* искря́щиеся глаза́ □ ~ **бушану** *физ.* искрово́й разря́д

очкыр *прил.* иску́сно (бы́стро) лета́ющий || лету́н, лету́нья; *торымтайдай очкыр кош булмас* нет летуна́ лу́чше пустельги́

очкыч *сущ.* 1. лета́тельный аппара́т; самолёт, аэропла́н; *космик ~лар* косми́ческие лета́тельные аппара́ты; *~лар һавага күтәрелде* самолёты взлете́ли 2. игру́шечный самолёт; моде́ль самолёта 3. лету́н; *вертолёт мондый һавада ~ түгел* вертолёт в таку́ю пого́ду не лету́н || *прил.* лета́тельный; *ракеталы ~ аппаратлар* раке́тные лета́тельные аппара́ты

очлайма *прил.* исти́стый; ~ *тишек* исти́стое отве́рстие

очлайту *перех.* 1. заостря́ть/заостри́ть; де́лать/сде́лать о́стрым, остроконе́чным (*вершину стога*) 2. оттопы́ривать/оттопы́рить, вытя́гивать (*пальцы*)

очлайтылу *страд. от* **очлайту** 1. быть заострённым 2. оттопы́риваться, вытя́гиваться

очлам *сущ.* конц о́вка (*заключительная часть какого-л. произведения*); *әкиятнең ~ы* конц о́вка ска́зки

очландыру *перех. см.* **очлайту**

очлан|у *возвр.-страд. от* **очлау** 1. *возвр. разг.* ока́нчиваться/око́нчиться, завершáться/заверши́ться, зака́нчиваться/зако́нчиться, довершáться/довершúться; *аңламассың, кайда башлана, кайда ~а* не поймёшь: где начина́ется, где зака́нчивается 2. заостря́ться/заостри́ться; *бите ~ган* лицо́ (его́) заостри́лось 3. *разг.* запряга́ться гусько́м (*мальчики в сани*) 4. *страд.* заостри́ться, зата́чиваться, очиня́ться

очлап I *нареч.* куска́ми, тю́ками (*о ткани*); ~ *сату* продава́ть куска́ми

очлап II *нареч.* цу́гом, гусько́м; ~ *җигү* запряга́ть цу́гом □ ~ **җигелгән** цугово́й

очлату *понуд. от* **очлау** 1—3

очла|у *перех.* 1. остри́ть, заостря́ть/заостри́ть, зачи́нивать/зачини́ть, точи́ть, очи́нивать, очиня́ть/очини́ть, зата́чивать/заточи́ть || заостре́ние, очи́нка, точе́ние; *казык ~у* заостри́ть кол 2. *с.-х.* завершáть/заверши́ть, верши́ть/поверши́ть (*стог, скирду, постройку*); *чүмәлә ~у* верши́ть копну́ 3. *разг.* конча́ть/ко́нчить, завершáть/заверши́ть, зака́нчивать/зако́нчить; довершáть/довершúть; *башланган эшне ~у* заверши́ть на́чатое де́ло; *башладым да ~дым* на́чал и зако́нчил 4. *перен.* промота́ть (*деньги*); разоря́ть/разори́ть (*хозяйство*) □ **~п кую** 1. начини́ть (*много карандашей*) 2. заверши́ть, довершúть (*какую-л. работу*) 3. *перен.* промота́ть (*все деньги; разорить всё хозяйство*); **~п чыгу** 1. очини́ть (*все карандаши*) 2. *перен.* заверши́ть, доко́нчить; **~ый төшү** затеса́ть (*кол*)

очлашу 1. *взаимно-совм. от* **очлау** 1, 2 2. *неперех.* соприкаса́ться, грани́чить (*в садовом участке*)

очла|ю *неперех.* 1. станови́ться/стать о́стрым (остре́е); заостря́ться/заостри́ться (*о конце, крае чего-л.*) 2. заостря́ться/заостри́ться, обостря́ться/обостри́ться (*о чертах лица*); *борыны, ияге бик нык ~ган* нос, подборо́док (его́) си́льно заостри́лись; *авыруның йөзе ~йды* лицо́ больно́го обостри́лось (осу́нулось) □ **~еп килү** заостри́ться (*книзу*)

очлы *прил.* 1. о́стрый, остроконе́чный; ~ *без* о́строе ши́ло; ~ *таяк* остроконе́чная па́лка 2. о́стрый, заострённый (*о чертах лица*); ~ *борын* о́стрый нос; ~ *ияк* о́стрый подборо́док 3. острове́рхий; островерши́нный; ~ *чыршы* острове́рхая ёлка; ~ *бүрек* острове́рхая ша́пка; ~ *кибән* островерши́нный стог 4. *в сочет. со словами на* **-лы** остро-; ~ *сакаллы* остроборо́дый; ~ *томшыклы* остроклю́вый; ~ *яңаклы* остроску́лый; ~ *башлы манара* остроконе́чная ба́шня □ ~ **почмак** *мат.* остроуго́льник; ~ **почмаклы** остроуго́льный; ~ **сәтлегән** *бот.* о́стрый молоча́й; ~ **тау түбәсе** пик; ~ **тешле** остроз у́бый, остроз у́бчатый; ~ **чаш** *бот.* осо́ка заострённая ◊ ~ **колак** чу́ткий на слух; чу́ткое у́хо; ~ **күз (күзле)** остроглáзый, глазáстый; о́стрый на глаз, намётанный глаз; ~ **сүз** ко́лкость; *см. тж.* **чәнечкеле сүз**; ~ **тел (телле)** остроязы́чный, о́стрый на язы́к

очлыборын *сущ. зоол.* остронóс, остронóсик (*морская рыба семейства кефалей*)

очлы|к *сущ.* **1.** наконéчник (*карандаша, стрелы, клизмы*); *сөнге ~гы* наконéчник копья́ **2.** *анат. мн.* **очлыклар** конéчности; *алгы ~клар* пере́дние конéчности **3.** *см.* **төпчек** 2; *папирос ~клары* оку́рки папиро́с

очлыктыру *перех.* **1.** *диал. см.* **ыргыту 2.** *перен. прост. см.* **олактыру** 3

очлыпый *прил. диал.* островéрхий; *~ башлык* островéрхий башлы́к (капюшóн)

очлыяфрак *сущ. бот.* остроли́ст, па́дуб (*вечнозелёный кустарник*)

очма: очма крепость лета́ющая кре́пость

очрак *сущ.* **1.** слу́чай; *тәртипне бозу ~лары* слу́чаи нарушéния дисципли́ны; *аерым ~ларда* в отдéльных слу́чаях; *күпчелек ~ларда* в большинствé слу́чаев **2.** момéнт, возмóжность, слу́чай; *бәхетле ~* счастли́вая случа́йность; *уңай ~* удóбный слу́чай; *~тан файдалану* пóльзоваться момéнтом; *мондый ~ башка туры килмәс* така́я возмóжность бóльше не предста́вится **3.** *в знач. союза* **очракта** в слу́чае; в слу́чае, éсли ...; *поезд соңга калган ~та* ... в слу́чае, éсли пóезд запоздáет ...; *кирәк булган ~та* в слу́чае необходи́мости

очраклы *прил.* **1.** случа́йный, неожи́данный, непредви́денный; *~ бер вакыйга* (одно́) случа́йное событие; *~ күрешү* случа́йная встрéча; *~ җиңү* случа́йная побéда; *~ аңлашылмаучылык* случа́йное недоразумéние **2.** случа́йный (*непостоянный, появляющийся иногда*); *~ табыш белән яшәү* жить случа́йными за́работками; *~ кешеләр белән аралашу* обща́ться со случа́йными людьми́; *~ таныш* случа́йный знако́мый **3.** *филос.* случа́йный (*необоснованный, нетипичный, незакономерный*); *~ фактларга таяну* опира́ться на случа́йные фа́кты; *~ күренешләр җыелмасы* совоку́пность случа́йных явлéний || *нареч.* случа́йно; *~ гына килеп чыгу* появи́ться случа́йно; *~мы бу?* случа́йно ли э́то?; *~ гына таныштык* познако́мились случа́йно □ *~* **рәвештә** случа́йно, случа́йным о́бразом; *~* **хәл** случа́йность; дéло слу́чая

очраклылык *сущ.* случа́йность; *була бит тормышта ~лар* быва́ют же в жи́зни случа́йности; *бәхетле ~ аркасында* по счастли́вой случа́йности

очрат|у *перех.* **1.** встреча́ть/встрéтить *кого-что, где* (*знакомого, земляка, группу альпинистов; в лесу, на автодроме, около входа*); *очраклы рәвештә ~у* встрéтить случа́йно **2.** набреда́ть/набрести́ на *кого-что*; *малайлар төркемен ~у* набрести́ на ватагу ребя́т **3.** обнару́живать/обнару́жить, встреча́ть/встрéтить у *кого, где*; *мондый стилистик алымны Тукайда еш ~абыз* тако́й стили́стический приём ча́сто встреча́ем у Тука́я; *кулъязмада таныш булмаган яңа җырлар да ~у* обнару́жить в ру́кописи та́кже незнако́мые но́вые пéсни **4.** заста́ть *кого-л., где*; *аны өйдә ~уы кыен* его́ тру́дно заста́ть до́ма

очра|у *неперех.* **1.** встреча́ться/встрéтиться, попада́ться/попа́сться (*на пути*); *каршыга ~ау* попада́ться навстрéчу; *еш ~у* встреча́ться (попада́ться) ча́сто; *сирәк ~у* встреча́ться (попада́ться) рéдко; *әледән-әле таныш йөзләр ~ды* то и дéло встреча́лись знако́мые ли́ца **2.** попада́ться/попа́сться, подвёртываться/подверну́ться; *яхшы юлдашлар ~ды* подверну́лись хоро́шие поду́тчики; *кирәк китаплар ~мады* ну́жные кни́ги не попа́лись **3.** обнару́живаться/обнару́житься, попада́ться/попа́сться, наблюда́ться (*об археологических находках, редкостных рукописях, удачных выражениях*) **4.** ната́лкиваться/натолкну́ться, натыка́ться/наткну́ться *на кого-что*; встреча́ться/ встрéтиться *с кем-л*; *кыенлыклар ~у* натолкну́ться на тру́дности; встрéтиться с тру́дностями (с затрудне́ниями); *засадага ~у* натолкну́ться на заса́ду; *көчле каршылыкка ~у* натолкну́ться на си́льное сопротивле́ние; встрéтиться с сопротивле́нием **5.** попада́ть/попа́сть (*в историю, в метель, в бурю*); ока́зываться/оказа́ться (*в каком-л. положении*); *бәлагә ~у* попа́сть в бедý; оказа́ться в беде́; *күңелсез хәлгә ~у* оказа́ться в неприя́тном положе́нии; *бозлы яңгырга ~у* попа́сть под град **6.** потерпéть *что-л.*; *уңышсызлыкка ~у* потерпéть неуда́чу; *һәлакәткә ~у* потерпéть катастро́фу **7.** подверга́ться/подве́ргнуться *чему-л.* (*гонениям, насмешкам*); *бандитлар һөҗүменә ~у* подверга́ться нападе́нию банди́тов; *тәнкыйткә ~у* подве́ргнуться кри́тике **8.** претерпева́ть/претерпéть (*изменения*); *төрле үзгәрешләргә ~у* претерпéть разли́чные измене́ния □ **~п тору** то и дéло встреча́ться (попада́ться) ◊ **~ган бер кеше, ~ган берсе** ка́ждый (вся́кий) встре́чный

очрашлы *разг.* встреча́ющийся; *сирәк ~* ре́дко встреча́ющийся

очрашкалау *многокр. от* **очрашу**; встреча́ться *с кем-л.* (*изредка, временами*)

очраштыргал|ау *многокр. от* **очрау 1.** встреча́ть, ви́деть *кого-л.* (*изредка, какое-то время*) **2.** встреча́ться, попада́ться, наблюда́ться (*изредка*); *соңга калган юлчылар ~лый* и́зредка встреча́ются запозда́лые пу́тники

очраштыр|у 1. *перех.* своди́ть/свести́ *кого-что* с *кем-чем*; *туганнарны ~у* свести́ родны́х; *безне язмыш ~ды* нас свела́ судьба́ **2.** *многокр. от* **очрау** 1; встреча́ться (*изредка, иногда*); *см. тж.* **очраштыргалау** 2

очраш|у *от* **очрау 1.** *в разн. знач.* встреча́ться/встрéтиться, повстреча́ться, ви́деться, повида́ться, уви́деться с *кем-л.* || встрéча, свида́ние; *билгеләнгән вакытта ~у* встрéтиться в назна́ченное врéмя; *~ырга мөмкинлек булмау* не имéть возмóжности повида́ться; *еш ~у* ча́сто ви́деться; *ике ил вәкилләре ~у* встрéча представи́телей двух стран; *дусларча ~у* дру́жественная встрéча; *~у кичәсе* вéчер встрéчи; *сугыш ветераннары белән ~у* встрéча с ветера́нами войны́ **2.** сходи́ться/сойти́сь, ста́лкиваться/столкну́ться с *кем-чем-л.* || схождéние, столкновéние; *юлда ~у* сойти́сь в доро́ге; *ишек янында ~у* столкну́ться у две́ри; *тау белән тау гына ~мый, кеше белән кеше ~а* (*посл.*) гора́ с горо́й не схо́дятся, а челове́к с челове́ком столкнётся **3.** *спорт.* встреча́ться/встрéтиться, состяза́ться, сходи́ться/сойти́сь || встрéча, состяза́ние, схождéние; *шахмат өстәле артында ~у* сходи́ться за ша́хматной доско́й; *фигуралы шуу осталарының ~уы* состяза́ние мастеро́в фигу́рного ката́ния; *~у уртак нәтиҗә белән тәмамланды* встрéча зако́нчилась ничéйным результа́том (вничью́)

очсыз *прил.* **1.** тупо́й; *~ без* тупóе ши́ло **2.** испи́санный (*о карандаше, пере*) **3.** *перен. см.* **очсыз-кырыйсыз** 1

очсыз *прил. разг.* дешёвый, недорого́й (*товар*); *см. тж.* **арзан**; *~ бәя* недорога́я цена́; дешёвка; *~ның арты тыныч сыз* (*посл.*) дешёвому това́ру дешёвая и цена́ (*букв.* у дешёвого товара беспоко́йное положе́ние) || *нареч. разг.* дёшево, недóрого; по дешёвке; *см. тж.* **очсызга**; *~ сату (биру)* прода́ть дёшево; продешеви́ть; *~га алу* купи́ть по дешёвке

очсыз-кырыйсыз *прил.* **1.** безграни́чный, безбре́жный, неизмери́мый, необозри́мый, бесконéчный; без конца́ и кра́я; *см. тж.* **иксез-чиксез**; *очсыз-кырыйсыз*

диңгез безбре́жное мо́ре; *очсыз-кырыйсыз бушлык* безграни́чное простра́нство; *очсыз-кырыйсыз дала киңлекләре* необозри́мые степны́е просто́ры 2. бесчи́сленный, бессчётный; *см. тж.* **исәпсез-хисапсыз**; *очсыз-кырыйсыз мал көтүе* бесчи́сленные стада́ живо́тных; *куктәге очсыз-кырыйсыз йолдызлар саны* бесчи́сленное коли́чество звёзд на не́бе

очсыз-кырыйсызлык *сущ. собир.* безграни́чность, безбре́жность, необозри́мость, бесконе́чность

очсызландыру *перех.* 1. тупи́ть, затупля́ть/затупи́ть (*иголку, шило*) 2. испи́сывать/исписа́ть (*карандаш*)

очсызландыру *перех. разг.* удешевля́ть/удешеви́ть, уценя́ть/уцени́ть (*товар*) || удешевле́ние, уце́нка

очсызлан|у I *неперех.* 1. тупи́ться, затупля́ться, затупи́ться (*шило, иголка*) 2. испи́сываться/исписа́ться (*о карандаше, пере*)

очсызлан|у II *неперех.* 1. *разг.* удешевля́ться/удешеви́ться, дешеве́ть/подешеве́ть (*о товарах, продуктах*); *самолётка билетлар ~ды* биле́ты на самолёт подешеве́ли 2. *перен.* продешеви́ть себя́ □ **~а төшү** подешеве́ть; **~ып китү** удешеви́ться

очсызлы *прил. разг.* 1. *см.* **арзанлы** 2. *перен.* дешёвый; *~ эффектлар* дешёвые эффе́кты

очсызлык *сущ. разг.* дешеви́зна

очтагы *прил.* 1. концево́й, коне́чный, наконе́чный; *~ гайка* наконе́чная га́йка 2. уносно́й, уно́сный; *~ ат* уно́сная ло́шадь

очташ *сущ.* живу́щий с *кем-л.* на одно́м конце́ села́ и́ли го́рода; *без аның белән ~лар* мы с ним с одного́ конца́ (села́) || *прил.* 1. сме́жный, располо́женный ря́дом; *см. тж.* **ызандаш** 2. *в знач. сказ.* быть ря́дом, примыка́ть друг к дру́гу (*о земельных участках*)

очу *неперех.* 1. 1) *в разн. знач.* лете́ть, лета́ть, полета́ть || полёт, лёт (*о летательных аппаратах, птицах, насекомых; о пулях, снарядах, лёгких предметах и т. п.*); *самолётта очу* лете́ть на самолёте; лете́ть самолётом; *Уфага ике сәгать очасы* до Уфы́ лете́ть два часа́; до Уфы́ два часа́ лёта (лёту, полёта); *хыял канатында очу* лете́ть на кры́льях мечты́; *очуын оча да, кая төшәр* (*погов.*) высоко́ лета́ет, но где ся́дет 2) лете́ть/полете́ть, улета́ть/улете́ть куда́ (*на самолёте в Киев, за границу, на Север*); *уйлар әллә кая очтылар* мы́сли улете́ли куда́-то вдаль 3) лета́ть, кружи́ться, пари́ть, ре́ять; *канатларын җәеп, күктә лачын оча* распласта́в кры́лья, в не́бе ре́ет со́кол 2. *спец.* налётывать/налета́ть (*определённые часы без аварии*); *миллион километрдан артык очу* налета́ть свы́ше миллио́на киломе́тров 3. улету́чиваться/улету́читься, испаря́ться/испари́ться || испаре́ние (*о дыме, запахе, жидкостях и т. п.*); *очучан матдәләр* испаря́ющиеся вещества́ 4. выцвета́ть/вы́цвести || выцвета́ние; *тәрәзә йөзлекләренең буяулары очкан* кра́ски око́нных нали́чников вы́цвели 5. *перен.* лете́ть/полете́ть; мча́ться/помча́ться, нести́сь/понести́сь (*о коне, машине*); *мотоцикл җил кебек оча* мотоци́кл мчи́тся как ве́тер 6. *перен. разг.* улета́ть/улете́ть, уплыва́ть/уплы́ть (*о деньгах*); исчеза́ть/исче́знуть; *карандашлар тагын каядыр очкан* каранда́ш опя́ть куда́-то исче́зли 7. *перен. разг.* слета́ть/слете́ть, полете́ть (*с работы, с поста руководителя*) □ **оча башлау** полете́ть; **очкан шәпкә** *см.* **очып барганда**; **очкандай чабу** нести́сь; **очу кыры** *ав.* лётное по́ле, аэродро́м; **очу өчен уңайлы** лётный (*о погоде*); **очу тизлеге** *пчел.* лето́к; **очудан туктау** отлета́ть, отлета́ться (*о лётчике, самолёте*); **очып алу** полета́ть; **очып әйләнеп чыгу** 1. облета́ть, излета́ть || облёт; *вертолётта очып әйләнү* сде́лать облёт вертолётом 2. кружи́ться *над кем-л., чем-л.*; **очып барганда** 1. на лету́, влёт 2. с налёта (налёту); *очып барганда бәрелү* уда́риться с налёта (налёту); **очып бару** 1. лете́ть (*в данный момент*) 2. лете́ть *на чём-л.*; *вертолётта очып бару* лете́ть на вертолёте 3. перелёт; 4. мча́ться, лете́ть на кры́льях; **очып барып җитү** 1. долета́ть/долете́ть (*до требуемого или назначенного места, до цели, до объекта*) 2. *перен.* примча́ться (*бегом, на тройке, на машине*); **очып барып кайту (килү)** *прям., перен.* слета́ть; **очып барышлый** пролётом; **очып бету** 1. разве́яться (*о дыме, запахе, пыли*) 2. улету́читься (*о жидкостях*) 3. вы́цвести (*о краске*); **очып йөрү** 1. лета́ть, кружи́ться (*продолжительное время вокруг, около кого-л., чего-л., над кем-л., чем-л.*) 2. *прям., перен.* порха́ть; **очып кайту** 1. прилета́ть/прилете́ть || прилёт; 2. *прям., перен. см.* **очып барып кайту**; **очып калу** лета́ть, вдо́воль полета́ть (*пока есть возможность*); **очып карау** 1. полета́ть, попро́бовать полета́ть на *чём-л.* 2. подлётывать; **очып кереп тулу** налета́ть/налете́ть (*о насекомых, о пыли*); **очып керү** 1. залета́ть/залете́ть, влета́ть/влете́ть || влета́ние, залёт 2. впорхну́ть, запорхну́ть (*о бабочках, пташках*) 3. подлета́ть/подлете́ть || подлёт (*под крышу, мост, арку*); **очып килгән** залётный (*о птицах*); **очып килеп төшү** 1. прилета́ть/прилете́ть, слета́ться/слете́ться 2. *перен.* слета́ть/слете́ть, полете́ть (*с крыши, ворот*); **очып килү** 1. прилета́ть/прилете́ть *куда-л.* || прилёт 2. подлета́ть/подлете́ть || подлёт; **очып китү** 1. улета́ть/улете́ть, вылета́ть/вы́лететь || вы́лет; *сәгать өчтә очып китәбез (очабыз)* вылета́ем (лети́м) в три часа́ 2. отлета́ть/отлете́ть || отлёт; *кошларның җылы якка очып китүләре* отлёт птиц на юг 3. взлета́ть/взлете́ть // отлёт 4. слета́ть/слете́ть; полете́ть; **очып китәргә генә тора** вот-вот (взлети́т) улети́т; **очып куну** 1. перелета́ть/перелете́ть || перелёт (*с цветка на цветок, с дерева на дерево*) 2. *перен.* набра́сываться/набро́ситься, налете́ть (наки́нуться) ко́ршуном *на кого-л.*; **очып менү (күтәрелү)** 1. взлета́ть/взлете́ть, залета́ть/залете́ть || взлёт, залёт; *айга очып менү* взлете́ть на луну́; *югары очып менү* залете́ть высоко́ 2. вы́порхнуть (*о бабочках*); **очып сыналу** облётываться/облета́ться; **очып сынау (сынап карау)** облётывать/облете́ть || облётывание; **очып таралу** разлета́ться/разлете́ться || разлёт; **очып тору** лете́ть (*постоянно, регулярно*); **очып төшеп калу** *прям., перен.* слете́ть (*о шапке, платке с головы*); *йөк өстеннән очып төшеп калу* слете́ть с во́за; **очып төшү** 1. слета́ть/слете́ть 2. приземля́ться/приземли́ться (*о самолёте*) 3. *разг. прям., перен.* полете́ть (*с лестницы, с места работы*); **очып тутыру (бетерү)** излета́ть, отлета́ть (*свой срок*); **очып узу (үтү)** 1. пролета́ть/пролете́ть (*над кем-л., чем-л., мимо кого-чего, какое-л. расстояние*) || пролёт; *куркыныч урынны очып үтү* пролете́ть над опа́сным ме́стом 2. перелета́ть/перелете́ть || перелёт, перелета́ние (*через моря и океаны, через линию фронта*); **очып узышлый** мимолётом; **очып чыгу** 1. вылета́ть/вы́лететь *откуда-л.* || вылета́ние, вы́лет (*из гнезда, клетки, улья*) 2. перелета́ть/перелете́ть че́рез *что* || перелёт; **очып чыгып китү** *см.* **очып чыгу** 1 ◊ **оча торган палас** (*фольк.*) ковёр-самолёт; **очарга (гына) тору** сли́шком торопи́ться; спеши́ть; порыва́ться что-то де́лать; **очып кына йөрү** лета́ть на кры́льях; **очып тора** подви́жный, порыви́стый; ого́нь (*о человеке*)

очучы *сущ.* лётчик, лётчица; авиа́тор, пило́т (*полярный, морской, гражданский и т. п.*) || лётный (*костюм, шлем*);

хәрби ~ булу быть воéнным лётчиком; *югары класслы ~ пилот* вы́сшего кла́сса; *~лар мәктәбе* лётная шко́ла

очучылык *сущ.* профе́ссия лётчика, лётное де́ло || лётный; *~ осталыгы* лётное мастерство́

очы-башы: очы-башы юк (күренми) 1) ничего́ неизве́стно 2) запу́танно, по́лный беспоря́док; *очы-башы күренү (табылу)* проясня́ться, выясня́ться; реша́ться

очык I *сущ.* 1. мяки́на; обо́йка 2. *диал.* пушо́к (*у птиц*) □ **~ печән** *бот.* тысячели́стник обыкнове́нный; *см. тж.* **меңьнфрак**

очык II *сущ.* 1. недержа́ние мочи́ 2. *редко* о боле́зни гла́за (*появление красноты у наружного угла глаза*)

очы-кырые: очы-кырые булмау (күренмәү) 1) (ни) конца́, (ни) кра́ю нет 2) бескра́йний, необозри́мый

очынгалау *многокр. от* **очыну**

очынгыч *прил. разг.* легкомы́сленный; кокéтливый (*преимущ. о женщинах*); *ул сөйкемле, иркә, ләкин ~ түгел* она́ обая́тельная, изне́женная, но не кокéтливая

очындыр|у *перех.* 1. развева́ть, трепа́ть, колыха́ть (*флаг, занавеску*); *җил чәчәкләрне ~а* ве́тер тре́плет во́лосы 2. *перен.* потака́ть, потво́рствовать || потака́ние, потво́рство высокоме́рию *кого-л.*; позволя́ть/позво́лить вести́ себя́ с го́нором *кому-л.* 3. *перен.* воодушевля́ть/воодушеви́ть, ободря́ть/ободри́ть, подзадо́ривать/подзадо́рить *кого-что* || воодушевле́ние, ободре́ние, подзадо́ривание □ **~ып кую** *однокр.* 1. всколыхну́ть 2. *перен.* воодушеви́ть, подзадо́рить

очынкы I *сущ. бот.* очáнка (*сорная трава из семейства норичниковых*)

очынкы II *прил.* лету́чий; *~ орлыклар* лету́чие семена́

очын|у *неперех.* 1. лета́ть, порха́ть, кружи́ть || порха́ние; *ишек алдында күбәләкләр ~а* во дворе́ порха́ют ба́бочки; *пароход өстендә акчарлаклар ~ды* над парохо́дом кружи́лись ча́йки 2. маха́ть (взма́хивать, замаха́ть) кры́льями; *карга чебеш ала, тавык ~ып кала* (*посл.*) воро́на цыпля́т умыка́ет, а ку́рица то́лько кры́льями взма́хивает (хло́пает) 3. *в знач. нареч.* **очынып** стремгла́в; *атлар ~ып чабалар* ко́ни ска́чут стремгла́в 4. *перен.* чва́ниться, кичи́ться; бахва́литься; *артык ~асың түгелме?* не сли́шком ли кичи́шься? *телгә килсә ~ган, эшкә килсә кычынган* (*посл.*) ло́вок языко́м трепа́ть (*т.е. бахвалиться*), да лени́в рабо́тать 5. *перен.* рва́ться, порыва́ться (*что-то делать*) || поры́в; *көрәшкә ~у* рва́ться на борьбу́ 6. *перен.* возбужда́ться/возбуди́ться, петуши́ться, горячи́ться; налета́ть/налете́ть на *кого-л.*; *нәрсәгә дип шул кадәр ~асың әле син?* с чего́ э́то ты так петуши́шься?; *этәчләр шикелле бер-берсенә ~ырга гына торалар* гото́вы, как петухи́, налете́ть друг на дру́га 7. *в знач. нареч. перен.* **очынып, очына-очына** гнéвно, раздражённо; я́ростно; *~ып этләр өрә* я́ростно ла́ют соба́ки 8. *перен.* 1) воодушевля́ться/воодушеви́ться; не чу́ять под собо́й ног; *шатлыктан ~у* 2) *в знач. нареч.* **очынып** вдохновéнно, с воодушевле́нием, с энтузиа́змом; пры́гать (ликова́ть) от ра́дости; *~ып эшләү* рабо́тать с энтузиа́змом ◊ **~ып йөрү** не чу́ять под собо́й ног; быть на седьмо́м не́бе; **~ып чабу** лете́ть (мча́ться, нести́сь) на кры́льях (*о коне*)

очынулы *прил.* возбуждённый, ра́достный; *~ йөзләр* возбуждённые ли́ца; *~ хисләр* возбуждённые чу́вства

очыргыч *сущ. см.* **очырткыч**

очырма *сущ. разг.* 1. *диал. см.* **чорма** 2. черда́к (*над дверной частью амбара для голубей*)

очырткыч *сущ.* змей (*детская игрушка*); *кәгазь ~* бума́жный змей; *~ җибәрү (очырту)* запусти́ть змея́

очырт|у 1. *понуд. от* **очыру** 2; *самолётка утыртып ~у* отпра́вить самолётом 2. *перех. см.* **очыру** (*в знач.* 1, 3, 4, 8); *космик корабльләр ~у* запусти́ть косми́ческие корабли́; *җил юл буенча тузан ~а* ве́тер вдоль доро́ги пыль метёт 3. гоня́ть (заставля́я взлете́ть); *күгәрченнәр ~у* гоня́ть голубе́й 4. *перен.* мчать, гнать (*машину, лошадь*) 5. *перен.* рабо́тать (де́лать) бы́стро (прово́рно) 6. *неперех. перен.* сли́шком торопи́ться (*при чтении, разговоре*) 7. *перех. перен. прост.* сти́брить, сты́рить, слимо́нить (*чужую вещь*) 8. *неперех. перен. прост.* врать, лгать □ **~ып алып китү** умча́ть; **~ып илтү (илтеп җиткерү)** бы́стро довезти́; **~ып китерү (китереп җиткерү)** примча́ть; **~ып сынау** испы́тывать/испыта́ть за́пуском ◊ **~ып мактау** *см.* **күккә күтәреп мактау**

очыртылу *страд. от* **очырту**; запуска́ться

очыр|у *перех.* 1. запуска́ть/запусти́ть, пуска́ть/пусти́ть (*планёр, змей, спутник, космический корабль*) || за́пуск, пуск; *баллистик ракеталар ~у* за́пуск баллисти́ческой раке́ты; *сабын куыгы ~у* пуска́ть мы́льные пузыри́ 2. дава́ть/дать возмо́жность улете́ть; выпуска́ть/вы́пустить в во́здух; *читлектәге кошны ~у* вы́пустить пти́цу из кле́тки 3. мести́, развéивать/развéять (*снег, песок*); *җил тузанны ~а* ве́тер метёт пыль 4. трепа́ть, колыха́ть; развева́ть, раздува́ть (*флаг, верхушки деревьев, дым*); *җил байракларны ~а* ве́тер коли́шет знамёна 5. поднима́ть/подня́ть, вздыма́ть, клуби́ть (*снег, пыль, пух*); *машина юлның тузаннарын ~а* маши́на вздыма́ет доро́жную пыль 6. срыва́ть/сорва́ть, уноси́ть/унести́, сдува́ть/сдуть (*бумаги со стола, шляпу с головы ветром*) 7. учи́ть лета́ть (*о птицах*); *сыерчыклар бала ~а* скворцы́ у́чат лета́ть свои́х птенцо́в 8. *перен. разг.* пуска́ть/пусти́ть, швыря́ть/швырну́ть (*с силой вверх или в сторону*); отшвы́ривать/отшвырну́ть (*пинком, ударом*); *урындыкны тибеп ~у* пинко́м отшвырну́ть табуре́т 9. *перен. разг.* сбра́сывать/сбро́сить, отки́дывать/отки́нуть *кого-что* (*вниз, под гору, под откос, в овраг*) 10. *перен. разг.* разогна́ть (*сон*); рассéивать (*тоску*) 11. *перен. разг.* разбра́сывать/разброса́ть, пуска́ть/пусти́ть на ... (*о деньгах, богатстве*); *акчаны җилгә ~у* пусти́ть де́ньги на ве́тер 12. *перен. прост.* выгоня́ть/вы́гнать; вышиба́ть/вы́шибить; *эшеннән ~у* вы́шибить с рабо́ты □ **~ып бетерү** 1. развéять 2. *перен.* поста́вить на́ ноги, устро́ить *чью-л.* семéйную жизнь (*родители о детях*); **~ып йөртү** 1. носи́ть (*о ветре*) 2. *перен. разг.* легко́ (игра́ючи) поднима́ть (*что-л. тяжёлое*) 3. *перен. разг.* води́ть/вести́ иску́сно (уме́ло) (*комбайн*)

очы-төбе: очы-төбе күренмәү *см.* **очы-кырые булмау (күренмәү)**

очы-чиге: очы-чиге булмау (күренмәү) *см.* **очы-кырые булмау (күренмәү)**

очыш *сущ.* 1. полёт (*вращательный, горизонтальный, рекордный, ночной, космический*); лёт || 1) лета́тельный, лётный, полётный, -полётный 2) пролётный; *космик ~лар* косми́ческие полёты; *сынау ~ы* испыта́тельный полёт; *өйрәнү ~лары* уче́бные полёты; *~ ераклыгы* да́льность полёта; *кошларның ~ юллары* пролётные пути́ птиц; *~ ярысы* лета́тельные перепо́нки (*у летучих мышей*); *~ авырлыгы* полётный вес; *~ алды хәзерлекләре* предполётная подгото́вка; *һәр кошның ~ы үзенчә* (*погов.*) у ка́ждой пти́цы свой полёт 2. лёт; пролёт (*о птицах*); *кошларның көзге ~лары* осéнние пролёты птиц 3. перелёт; *җир әйләнә ~ ясау* соверши́ть кругосвéтный перелёт; *Төньяк котып аша ~* перелёт че́рез Се́верный по́люс □ **~ кыры** *см.* **очу кыры**

очышлы *прил.* -летя́щий; *биек ~* высоколетя́щий; *тиз ~* быстролетя́щий; *ераккa ~ континентара баллистик ракета* (*индив.*) межконтинента́льная баллисти́ческая раке́та да́льнего де́йствия

ошак *сущ. диал. см.* **әләк**; *~ сөйгәннең пычагы теләдә* (*посл.*) у я́бедника нож на языке́ (*букв.* у того́, кто лю́бит доноси́ть, нож на языке́) □ **~ сөйләү** нау́шничать, кля́узничать, доноси́ть

ошаклау *неперех. диал. см.* **әләкләү**

ошакчы *сущ. диал. см.* **әләкче**; *~ның, ошак сөйләми торса, теле кычыта, ди* (*погов.*) говоря́т, е́сли фиска́л не бу́дет нау́шничать, у него́ че́шется язы́к ◊ **~ капчык** *диал.* я́беда

ошанкырау *неперех. диал.* (не́сколько) быть похо́жим *на кого-что*; напомина́ть *кого-что*

ошардай *прил. см.* **ошарлык**

ошарлык *прил.* досто́йный одобре́ния, подходя́щий, прили́чный

ошат|у *перех.* **1.** люби́ть *кого-что-л.*; симпатизи́ровать *кому-чему-л.*; благоволи́ть к *кому-л.* || благоволе́ние; *бер-берсен ~у* симпатизи́ровать друг дру́гу **2.** одобря́ть/одо́брить; понра́виться || одобре́ние; *проектны ~у* одо́брить прое́кт; *бер күрүдә ~у* понра́виться с пе́рвого взгля́да **3.** предпочита́ть, выбира́ть *кого-что*; *ир балалар техник фәннәрне ~алар* ма́льчики предпочита́ют техни́ческие нау́ки **4.** облюбо́вывать/облюбова́ть; *күл буендагы тын урынны ~у* облюбова́ть ти́хое ме́сто у о́зера **5.** *см.* **охшату** □ **~ып бетермәү** не одобря́ть, недолю́бливать

ош|ау *неперех.* нра́виться/понра́виться; полюби́ться, пригляну́ться; прийти́сь по вку́су, по душе́ *кому-л.*; *~арга тырышу* стара́ться понра́виться; *миңа ~аганнарга мин ~амыйм* тем, кото́рые пригляну́лись мне, я не по душе́; *кемгә нәрсә ~ый* кому́ что нра́вится; де́ло вку́са □ **~ап бетмәү (җитмәү)** не по душе́; **~ап кую** понра́виться; **~ый төшү** бо́лее по душе́, бо́лее нра́вится

ошаулы *прил.* **1.** прия́тный, прили́чный; *күңелгә ~* прия́тный для души́; по душе́ **2.** *см.* **охшаулы**

ошаш *прил. см.* **охшаш**; *~ы булмаган матурлык* бесподо́бная красота́

ошашлы *прил. см.* **охшашлы**

ошашлык *сущ. см.* **охшашлык**

ошашу *взаимно-совм. от* **ошау**; нра́виться (пригляну́ться) друг дру́гу

ошбу *мест. указ. книжн.* сей; да́нный

ою I *неперех.* **1.** дрема́ть, задрёмывать/задрема́ть || дремо́та; *утырган урында ою* дрема́ть си́дя **2.** неме́ть/занеме́ть, онеме́ть, зате́чь, деревене́ть/одеревене́ть, мертве́ть/омертве́ть (*от неподвижности*); *тән ойый* те́ло неме́ет; *куллар-аяклар оеды* ру́ки-но́ги занеме́ли; *бармаклар ойый* па́льцы деревене́ют **3.** мертве́ть/омертве́ть, помертве́ть (*от си́льного испуга или холода*); коченеть/закоченеть; *салкыннан куллар оеды* ру́ки закоченели́ от хо́лода; *куркудан ою* омертве́ть от испу́га **4.** млеть, замира́ть/замере́ть || замира́ние (*от наслаждения, восторга*) **5.** *перен.* забыва́ться/забы́ться; *юк-бар хыялларга ою* забы́ться в несбы́точных мечта́х **6.** *перен.* замыка́ться/замкну́ться, уединя́ться/уедини́ться; *тыныч тормышка ою* замкну́ться в споко́йной жизни **7.** *в знач. нареч.* **оеп** *перен. разг.* за́мкнуто; *оеп яшәү* жить за́мкнуто **8.** *перен. редко* сле́довать/после́довать *за кем-чем* (*в делах, поступках*); *аңа оючылар торган саен кимеде* всё ме́ньше и ме́ньше станови́лось после́довавших за ним люде́й **9.** *перен.* быть зави́симым от *кого*, приспособля́ться/приспосо́биться к *кому-чему*, подчиня́ться/подчини́ться *кому-чему*; *заманга оемый хәлең юк* понево́ле приспоса́бливаешься к совре́менной жи́зни; *тимерче күмерчегә оер* (*погов.*) кузне́ц зави́сим от углежёга □ **оеп калу** омертве́ть; **оеп китү** задрема́ть; **оеп утыру 1.** клева́ть но́сом **2.** млеть **3.** *перен.* забы́ться; **оеп яту** дрема́ть, лежа́ть в забытьи́

ою II *неперех.* свёртываться/сверну́ться, проква́ситься, ки́снуть/ски́снуть (*о молоке*) || свёртывание; *кан ою* свёртывание кро́ви □ **оеп җитү** проква́ситься ◊ **оеган катык кебек йөрү** быть не в ду́хе, име́ть ки́слое настрое́ние

оюлы *прил.* дремо́тный; *~ хәл* дремо́тное состоя́ние; *~ тынлык* дремо́тная тишина́

прика́зчиклык *сущ.* положе́ние и́ли до́лжность прика́зчика; *~ка кучеру* переводи́ть на до́лжность прика́зчика; *~та йөрү* ходи́ть (быть) в прика́зчиках (в положе́нии прика́зчика) □ **~ итү** выполня́ть (занима́ть) до́лжность прика́зчика, быть прика́зчиком *в разн. знач.*

приклад *сущ. воен.* прикла́д; *см. тж.* **мылтык түтәсе**; *~ белән сугу* ударя́ть прикла́дом

прилавка *сущ. редко* прила́вок; *см. тж.* **сату өстәле**; *~га җәеп салу* разложи́ть (*товары*) на прила́вке

при́ма *сущ. муз. в разн. знач.* при́ма

при́ма-балери́на *сущ. театр.* при́ма-балери́на

примадо́нна *сущ. театр.* примадо́нна; *бу безнең ~* э́то на́ша примадо́нна

примат *сущ.* **1.** *филос.* прима́т, пе́рвенство; *рухның ~ы* прима́т ду́ха **2.** *биол.* 1) прима́т, представи́тель отря́да прима́тов (*у млекопитающих*); *горилла — ~ларның берсе* гори́лла — оди́н из прима́тов 2) *мн.* **приматлар** прима́ты (*высокоорганизованные млекопитающие, составляющие отдельный отряд, куда относятся обезьяны и человек*)

примитив *прил. в разн. знач.* примити́вный; *~ инструмент* примити́вный инструме́нт; *~ караш* примити́вный взгляд; *~ культура* примити́вная культу́ра; *~ төзелешле* примити́вного строе́ния || *нареч. редко.* примити́вно; *~ аңлау* примити́вно понима́ть || *сущ. иск., лит.* примити́в; примити́вное явле́ние; *~тан качу* избега́ть примити́ва

примитивизм *сущ. филос., иск.* примитиви́зм; *конструкциянең ~ы* примитиви́зм констру́кции; *рәссамчылыкта ~ юнәлеше* направле́ние примитиви́зма в жи́вописи

примитивлаштыру *перех.* де́лать/сде́лать примити́вным; упроща́ть/упрости́ть (*с ущербом для дела*) || упроще́ние (*постановки сложного вопроса, образа жизни и т. п.*)

примитивлаш|у *неперех.* станови́ться/стать примити́вным; упроща́ть, упрости́ться; регресси́ровать || регресси́рование, регре́сс; *~а бару* станови́ться всё бо́лее примити́вным

примитивлык *сущ.* **1.** примити́вность; *~ үрнәге* приме́р примити́вности **2.** *см.* **примитивизм**

примитивчылык *сущ.* примити́вность, скло́нность к примити́вности, упроще́нство; *сәнгатьчә ~* упроще́нство в иску́сстве

при́мула *сущ. бот.* при́мула; *см. тж.* **нәүрүз чәчәге (гөле)**

при́мус, приму́с *сущ.* при́мус, керосинка; *~та кайнату* кипяти́ть на при́мусе

принц *сущ.* принц; *см. тж.* **шаһзадә**

принцесса *сущ.* принце́сса; *см. тж.* **кәникә, ханәкә, ханча**; *~лар шикелле* как принце́сса

принци|п *сущ.* **1.** *в разн. знач.* при́нцип, при́нципы; *гомуми ~плар* о́бщие при́нципы; *тарихилык ~бы* при́нцип истори́зма **2.** *в знач. нареч.* **принципта** в при́нципе; *~нта каршы түгел* в при́нципе не про́тив ◊ **~шка бару** идти́ на при́нцип; упря́мствовать

принципиаль *прил.* **1.** принципиа́льный; *~ каршылыклар* принципиа́льные разногла́сия; *~ мәсьәлә* принципиа́льный вопро́с; *~ эһәмияткә ия* име́ет принципиа́льное значе́ние **2.** принципиа́льный, стро́го приде́рживающийся при́нципов; *~ кеше* принципиа́льный челове́к || *нареч.* принципиа́льно; *~ хәл итү* принципиа́льно реша́ть (реши́ть); *мәсьәләне ~ кую* ста́вить вопро́с принципиа́льно □ **~ рәвештә (төстә)** принципиа́льным о́бразом; принципиа́льно

принципиальләнү *неперех.* станови́ться/стать принципиа́льным (*о человеке*)

принципиальләшү *неперех.* станови́ться/стать принципиа́льным (*о вопросе, деле, споре и т. д.*)

принципиальлек *сущ.* принципиа́льность; *~кә ия булу* облада́ть принципиа́льностью; *~ сыйфаты* ка́чество принципиа́льности

при́нциплы *прил.* с при́нципом, принципиа́льный (*о человеке*)

при́нципсыз *прил.* беспринци́пный; *~ кеше* беспринци́пный челове́к || *нареч.* без при́нципа (при́нципов); беспринци́пно; *~ яшәү* жить без при́нципов; жить беспринци́пно

при́нципсызлы|к *сущ.* беспринци́пность; *~кә нәтиҗәсендә* в результа́те беспринци́пности; *~гы билгеле* изве́стна его́ беспринци́пность

при́нципчыл *прил.* принципиа́льный, стро́го приде́рживающийся при́нципов (*о человеке*)

при́нципчыллык *сущ. см.* **принципчылык**

при́нципчылык *сущ.* **1.** принципиа́льность **2.** педанти́ческая приве́рженность при́нципам; постоя́нная отсы́лка к при́нципам; *кирәксез ~* нену́жная (педанти́чная) приве́рженность при́нципам

приоритет *сущ. в разн. знач.* приорите́т; *галимнең ~ы* приорите́т учёного; *закон ~ы* приорите́т зако́на

приоритетлы *прил.* приорите́тный; *~ өлкә* приорите́тная о́бласть

при-парә: при-парә булу (килү) *см.* **тар-мар булу, пыран-заран булу** □ **~ китерү** *см.* **тар-мар итү, пыран-заран китерү**

припас *сущ. разг.* припа́с; *сугыш ~лары* боевы́е припа́сы, боеприпа́сы

при́став *сущ.* при́став; *полиция ~ы* полице́йский при́став

при́стан|ь *сущ.* при́стань; *Казан ~е* каза́нская при́стань

при́станьдагы *прил.* что на при́стани; находя́щийся на при́стани; *~ йөкләр* находя́щиеся на при́стани гру́зы

прися́жный *сущ.* прися́жный заседа́тель (*в суде*); *~лар сайлау* вы́боры прися́жных заседа́телей

прися́жныйлык *сущ.* до́лжность и́ли обя́занности прися́жного заседа́теля

притон *сущ. разг.* прито́н; *караклар ~ы* воровско́й прито́н

приход *сущ.* прихо́д (*низшая церковная организация у христиан*); *см. тж.* **мәхәллә**

прицел *сущ.* прице́л; *~га алу* взять на прице́л; *~га алып* прице́льно

прицеллы *прич.* прице́ленный, с прице́лом || *прил.* прице́льный; *~ атыш* прице́льный ого́нь

прицепщик *сущ. разг.* прице́пщик; *~ булып эшләү* рабо́тать прице́пщиком

прицепщиклык *сущ.* рабо́та и́ли обя́занности прице́пщика; *~та йөрү* ходи́ть в прице́пщиках

причал *сущ.* прича́л; *~да тору* стоя́ть у прича́ла □ **~га кую** поста́вить на прича́л; прича́лить (*судно*)

причёска *сущ. разг.* причёска; *ыспай ~* аккура́тная причёска; *~ ясату* де́лать причёску (*при помощи другого лица*)

пришан *прил. см.* **пәришан**

приют *сущ.* **1.** *ист.* прию́т (*сиротский дом*) **2.** *разг.* детдо́м; *~ка биру* отдава́ть в детдо́м

про́ба *сущ. разг.* **1.** про́ба (*предварительный экземпляр, часть чего-л., взятая как образец*); *~ алу* брать про́бу **2.** про́ба (*количество весовых частей благородных металлов в сплаве и клеймо на изделиях, указывающее это количество в процентах, промиллях и т. п.*); *югары ~* высо́кая про́ба; *түбән ~* ни́зкая про́ба; *туксан алтылы ~* девяно́сто шеста́я про́ба (*96 % чистого благородного металла в сплаве*) □ **~ сугу 1.** ста́вить клеймо́ (*указывающее относительное количество благородного металла в сплаве*) **2.** *перен.* определя́ть и ука́зывать це́ну, це́нность *кого-л., чего-л.*

про́балы *прил.* с про́бой, име́ющий определённую про́бу; *84 ~ көмеш* серебро́ (серебряная вещь) 84-й про́бы

проби́рка *сущ.* проби́рка; *~га алу* взять в проби́рку

про́бка *сущ. тех.* про́бка (*вид электрического предохранителя*); *~ кую* поста́вить про́бку

проблем *прил.* пробле́мный; сомни́тельный; *~ мәсьәлә* пробле́мный вопро́с

пробле́ма *сущ.* пробле́ма; *актуаль ~* актуа́льная пробле́ма; *социаль ~* социа́льная пробле́ма; *кадрлар ~сы* пробле́ма ка́дров

пробле́малы *прил.* пробле́мный; *~ доклад* пробле́мный докла́д

пробле́малылы|к *сущ.* пробле́мность; *мәкаләнең ~гы* пробле́мность статьи́

проблематик *прил.* **1.** *см.* **проблемалы 2.** 1) проблемати́чный, нерешённый, явля́ющийся пробле́мой 2) проблемати́ческий; спо́рный, сомни́тельный; *~ эсәр* проблемати́ческое произведе́ние

проблема́тика *сущ.* проблема́тика (*совокупность взаимосвязанных проблем или тем*); *татар тарихы ~сы* проблема́тика тата́рской исто́рии

проблема́тиклы|к *сущ.* проблемати́чность; *мәсьәләнең ~гы* проблемати́чность вопро́са

прови́зия *сущ. спец.* прови́зия (*съестные припасы военных и т. п. отходов*); *~ туплау* накопи́ть (запасти́) прови́зию

прови́зор *сущ.* **1.** прови́зор (*работник аптеки высшей квалификации*); *~ булып эшләү* рабо́тать прови́зором (фармаце́втом) || *прил.* прови́зорный (предвари́тельный; вре́менный); *~ чаралар* прови́зорные ме́ры **2.** предвари́тельный, вре́менный

провинциал *сущ. разг.* провинциа́л (*житель провинции*); *~лар арасында* среди́ провинциа́лов

провинциализм *сущ.* **1.** провинциали́зм (*явления, свойственные провинции*) **2.** *лингв.* провинциали́зм — диалекти́зм

провинциаль *прил.* **1.** провинциа́льный; *~ сәүдәгәр* провинциа́льный купе́ц **2.** *перен.* захолу́стный; дереве́нский; *~ карашлар* захолу́стные взгля́ды

провинциальләшү *неперех.* станови́ться/стать провинциа́льным, захолу́стным; отстава́ть от жи́зни

прови́нция *сущ.* **1.** *ист.* прови́нция (*завоёванная Древним Римом целостная территория*) **2.** *в разн. знач.* прови́нция; *илнең иң зур ~се* са́мая больша́я прови́нция страны́; *~дә яшәү* жить в прови́нции (*не в столице*)

прови́нциядәге *прил.* провинциа́льный, *в знач.* живу́щий или быту́ющий в прови́нции; *~ туташлар* провинциа́льные ба́рышни; *~ гадәтләр* провинциа́льные обы́чаи (нра́вы)

провитамин *сущ. биол.* провитами́н (*вещество, из которого в организме животных и человека могут образоваться витамины*); *~га баегу* обогаща́ться провитами́ном

провитаминлы *прил.* провитами́нный; *~ үсемлекләр* провитами́нные расте́ния

проводни|к *сущ.* проводни́к (*вагонов и т. п.*); *тимер юл ~гы* железнодоро́жный проводни́к

проводниклык *сущ.* до́лжность и́ли обя́занности проводника́; *~та йөрү* ходи́ть в проводника́х; име́ть до́лжность проводника́

провока́тор *сущ.* провока́тор; *~лар җибәрү* посыла́ть провока́торов; *~ коткысы* подстрека́тельство провока́тора

провокацион *прил.* **1.** провокацио́нный; *~ акция* провокацио́нная а́кция **2.** провокацио́нный; подстрека́тельский; *~ сорау* провокацио́нный вопро́с

провока́ция *сущ.* провока́ция □ **~гә бирелү** подда́ваться/подда́ться провока́ции; *~ ясау* устро́ить провока́цию, провоци́ровать

провока́циялә́ү *перех.* провоци́ровать; *~ өчен* что́бы провоци́ровать

провока́цияле *прил. см.* **провока́цион**

провока́цияче *сущ.* уча́стник провока́ции; *см. тж.* **провокатор**; *~ләр төркеме* гру́ппа уча́ствующих в провока́ции, гру́ппа провока́торов

провока́цячел *прил.* скло́нный к провока́циям; провокацио́нный; *~ элементлар* провокацио́нные эле́менты

прогимна́зия *сущ.* прогимна́зия (*неполное среднее учебное заведение в царской России, в котором учились дети неимущих классов*); *~ укучысы* учени́к прогимна́зии

прогноз *сущ.* прогно́з; *~ кую* ста́вить прогно́з; *~ төзү* составля́ть прогно́з

прогнозлау *перех.* прогнози́ровать; *яңгыр(лар) ~* прогнози́ровать дождь

прогнозчы *сущ.* прогнози́ст

программ *прил.* програ́ммный; *~ мәкалә* програ́ммная статья́ || *сущ. см.* **программа**

програ́мма *сущ. в разн. знач.* програ́мма; *эш ~сы* програ́мма рабо́ты; *дәрес ~сы* програ́мма уро́ков; *концерт ~сы* програ́мма конце́рта; *~га керту* включи́ть в програ́мму; *машинага ~ бирү* вводи́ть в маши́ну програ́мму; *~ ясау* вы́работать програ́мму; *~ төзү* составля́ть програ́мму; *~ны үзләштерү* усво́ить програ́мму (*в учёбе*)

програ́ммалаштыру *перех. см.* **программалау**

програ́ммалаштырылу 1. *страд. от* **программалау 2.** *в знач. прил.* **программалаштырылган** запрограмми́рованный

програ́ммалау *перех.* программи́ровать; снабжа́ть, снабди́ть програ́ммой (*машину*)

програ́ммалы *прил.* **1.** программи́рованный; *~ идарә* программи́рованное управле́ние **2.** *спец. муз.* програ́ммный; *~ симфония* програ́ммная симфо́ния

програ́ммалык *сущ.* программи́рованность

програ́ммачы *сущ.* программи́ст

прогресс *сущ.* прогре́сс (*переход на более высокие ступени развития*); *см. тж.* **алгарыш, тәрәккыят**; *~ юлыннан* по пути́ прогре́сса; *~ка каршы* про́тив прогре́сса

прогрессив *прил.* **1.** прогресси́вный, передово́й; *~ идеялар* прогресси́вные иде́и; *~ кешелек дөньясы* прогресси́вное челове́чество **2.** прогресси́вный (*растущий по мере роста других факторов*); *эш башыннан*

~ *эш хакы* прогресси́вная сде́льная за́работная пла́та; ~ *салым* прогресси́вный нало́г

прогресси́вка *сущ. разг.* прогресси́вка (*вид дополнительной оплаты за работу*); ~ *түләү* плати́ть прогресси́вку

прогрессивлы|к *сущ.* прогресси́вность; *чара күрүләрнең ~гы* прогресси́вность мероприя́тий; *карашларның ~гы* прогресси́вность взгля́дов

прогре́ссия *сущ. мат.* прогре́ссия; *геометрик ~* геометри́ческая прогре́ссия

прогресслану *неперех. редко см.* **алгару**

прогресслы *прил.* име́ющий прогре́сс; прогресси́рующий; ~ *хәрәкәт* прогресси́рующее движе́ние

прогрессчы *сущ.* сторо́нник (побо́рник) прогре́сса; прогресси́ст; ~ *галим* учёный-побо́рник прогре́сса

прогрессчылык *сущ.* прогресси́зм; увлече́ние прогре́ссом (прогресси́вностью); *бу ~ның кыйммәткә төшүе бар* э́то увлече́ние прогре́ссом мо́жет обойти́сь до́рого

прогул *сущ. разг.* прогу́л; ~ *ясау* прогу́ливать, прогуля́ть, соверша́ть (соверши́ть) прогу́л

прогулчы *сущ. разг.* прогу́льщик

продналог *сущ. ист.* проднало́г; *~ка күчү* переходи́ть на проднало́г

продотряд *сущ. ист.* продотря́д

продотрядчы *сущ. ист.* рабо́тник (член) продотря́да; *~лар төркеме* гру́ппа рабо́тников продотря́да

продукт *сущ. в разн. знач.* проду́кт || продукто́вый; ~ *магазины* продукто́вый магази́н; *~лар алмашу* продуктообме́н; ~ *бирү* дава́ть/дать проду́кт (проду́кцию); ~ җитештерү производи́ть проду́кт (проду́кцию)

продуктив *прил. в разн. знач.* продукти́вный, даю́щий мно́го проду́кции; ~ *терлек* продукти́вный скот; ~ *хезмәт* продукти́вный труд; ~ *кушымча лингв.* продукти́вный су́ффикс

продуктивлану *неперех.* станови́ться/стать продукти́вным

продуктивлы|к *сущ.* продукти́вность; *кәсәбәнең ~гы* продукти́вность предприя́тия

проду́ктлата *нареч.* в ви́де проду́ктов, в проду́ктах, проду́ктами, нату́рой

проду́ктлы *прил.* **1.** с проду́ктом; даю́щий проду́кт (проду́кты) **2.** *в соот. номинативных сочет.* -продукти́вный; *югары ~* высокопродукти́вный

проду́ктлылы|к *сущ.* продукти́вность; *хезмәтнең ~гы* продукти́вность труда́; *кушымчаның ~гы* продукти́вность су́ффикса

проду́кция *сущ.* проду́кция, совоку́пность проду́ктов (*деятельности труда*); *еллык ~* годова́я проду́кция; *тулай ~* ва́ловая проду́кция; *әзер ~* гото́вая проду́кция

проект *сущ.* прое́кт || прое́ктный; ~ *төзү* составля́ть прое́кт; *~та* в прое́кте; *закон ~ы* прое́кт зако́на; ~ *бюросы* прое́ктное бюро́

проектант *сущ.* проекта́нт (*составитель проекта*)

проектив *прил. мат.* проекти́вный; ~ *геометрия* проекти́вная геоме́трия

прое́ктлану *страд. от* **проектлау**; проекти́роваться

прое́ктлау *перех.* проекти́ровать, составля́ть, разраба́тывать прое́кт || проекти́рование; *йорт ~* проекти́ровать дом

прое́ктлаштыру *перех.* проекти́ровать || проекти́рование, проектиро́вка

прое́ктлаштыручы *сущ.* проектиро́вщик || *прил.* проекти́рующий; прое́ктный; ~ *оешма* проекти́рующая организа́ция

прое́ктлаштырылу *страд. от* **проектлаштыру**

прое́ктор *сущ.* прое́ктор; проекцио́нный аппара́т; *~дан (~ белән) карау* смотре́ть при по́мощи проекцио́нного аппара́та

прое́ктчы *сущ.* проектиро́вщик, состави́тель прое́кта (прое́ктов); специали́ст по составле́нию прое́ктов (домо́в)

прое́ктчылык *сущ.* де́ло проекти́рования; увлече́ние проекти́рованием

проекцион *прил.* проекцио́нный; ~ *аппарат* проекцио́нный аппара́т; ~ *лампа* проекцио́нная ла́мпа

прое́кция *сущ.* **1.** *мат.* прое́кция (*изображение объёмных фигур на плоскости*); ~ *ысуллары* спо́собы прое́кции; *см. тж.* **сагым 2.** прое́кция, изображе́ние на экра́не, получа́ющееся вслéдствие направле́ния световы́х луче́й; *куләгә — шул ук ~* тень — э́то та́ же прое́кция

проецияләнү *страд. от* **проецияләү**; проеци́роваться; *сурәт кәгазьгә ~ә* изображе́ние проеци́руется на бума́гу

проецияләү *перех.* проеци́ровать (*чертить или передавать на экран проекцию*)

прожект *сущ.* проже́кт (*несерьёзный, ненужный проект*); ~ *төзү* соста́вить авантю́рный прое́кт

прожектёр *сущ. ирон.* прожектёр (*составитель несерьёзных проектов*)

прожектёрлык *сущ. ирон.* прожектёрство; *см. тж.* **проектчылык**

проже́ктор *сущ.* проже́ктор (*осветительный прибор*) || проже́кторный; ~ *белән яктырту* освеща́ть проже́ктором; ~ *лампасы* проже́кторная ла́мпа

проже́кторчы *сущ.* прожектори́ст (*специалист по работе с прожекторами*)

про́за *сущ. прям., перен.* про́за || прозаи́ческий; ~ *белән язылган* напи́сано про́зой; ~ *әсәре* прозаи́ческое произведе́ние; *тормыш ~сы* жи́зненная про́за

прозаи́к I *прил.* прозаи́ческий; ~ *әсәр* прозаи́ческое произведе́ние; ~ *әйбер* прозаи́ческая вещь

прозаи́к II *сущ.* прозаи́к (*писатель, литератор, пишущий прозой*); *атаклы ~* знамени́тый прозаи́к

прозаи́клык *сущ.* прозаи́чность

про́зачы *сущ. лит. см.* **прозаик** II

про́зачылык *сущ.* увлече́ние про́зой

произво́дство *сущ.* произво́дство || произво́дственный; *см. тж.* **җитештерү**; *~да эшләү* рабо́тать на произво́дстве; ~ *практикасы* произво́дственная пра́ктика; ~ *мөнәсәбәтләре* произво́дственные отноше́ния

производстводагы *прил.* **1.** произво́дственный; ~ *кадрлар* произво́дственные ка́дры **2.** находя́щийся в произво́дстве (*изделие, книга*)

прокат I *сущ. тех.* прока́т || прока́тный; *тимер ~* желе́зный прока́т; ~ *цехы* прока́тный цех

прокат II *сущ.* прока́т; *~ка алу* взять на прока́т

прокатлау *перех.* производи́ть/произвести́ прока́т; обраба́тывать прока́том; ~ *юлы белән* спо́собом прока́та, путём прока́та

прокатчы *сущ. тех.* прока́тчик; ~ *булып эшләү* рабо́тать прока́тчиком

прокла́мация *сущ.* прокла́мация, листо́вка; *~(ләр) тарату* распростране́ние прокла́маций

прокурату́ра *сущ.* прокурату́ра; ~ *органнары* о́рганы прокурату́ры

прокурор *сущ.* прокуро́р || прокуро́рский; *район ~ы* райо́нный прокуро́р; *хәрби ~* вое́нный прокуро́р; ~ *нотыгы* прокуро́рская речь

прокурорлык *сущ.* до́лжность, обя́занности прокуро́ра; прокуро́рство || прокуро́рский; *~ белән шөгыльләнү* быть прокуро́ром, занима́ть до́лжность прокуро́ра; *~ вазифалары* прокуро́рские обя́занности; *~ка укы* учи́ться на прокуро́ра

пролетар *прил.*ролета́рский; *~ интернационализм* пролета́рский интернационали́зм; *~ бердәмлек* пролета́рское еди́нство, пролета́рская солида́рность || *сущ. см.* **пролетарий**

пролетариат *сущ.* пролетариа́т || пролета́рский; *~ диктатурасы* диктату́ра пролетариа́та; *~ культурасы* пролета́рская культу́ра

пролетариза́ция *сущ.* пролетариза́ция

пролета́рий *сущ.* пролета́рий; *бөтен дөнья ~лары, берләшегез!* пролета́рии всех стран, соединя́йтесь!

пролетарлаштыру *перех.* пролетаризова́ть || пролетариза́ция (*населения*)

пролетарлашу *неперех.* пролетаризова́ться || пролетариза́ция; *вак буржуазиянең ~ы* пролетариза́ция ме́лкой буржуази́и

пролётка *сущ.* пролётка (*двухместный экипаж*); *~га утырып* в пролётке

пролог *сущ.* проло́г; *әсәрнең ~ы* проло́г произведе́ния; *вакыйга ~ы* проло́г собы́тия

промкомбинат *сущ.* промкомбина́т; *~та эшләү* рабо́тать в промкомбина́те

промтовар *сущ.* промтова́ры || промтова́рный; *~лар сату* продава́ть промтова́ры; *~ магазины* промтова́рный магази́н

промфинплан *сущ.* промфинпла́н (промы́шленно-фина́нсовый); *еллык ~* годово́й промфинпла́н; *~ үтәү* вы́полнить промфинпла́н

про́мысел *сущ. в разн. знач.* про́мысел || промысло́вый; *кит аулау ~ы* китобо́йный про́мысел; *~ кошлары* промысло́вые пти́цы

про́мыселчы *сущ.* промысло́вик (*человек, профессионально занимающийся промыслом; рабочий промысла*); *аучы-~* охо́тник-промысло́вик

промысло *сущ. разг. см.* **промысел**; *~да эшли* рабо́тает в про́мысле

промы́шленни|к *сущ.* промы́шленник; *күмер ~гы* у́гольный промы́шленник

промы́шленност|ь *сущ.* промы́шленность || промы́шленный; *см. тж.* **сәнәгать**; *эшкәртү ~е* обраба́тывающая промы́шленность; *авыр ~ь* тяжёлая промы́шленность; *~ь районы* промы́шленный райо́н

прообраз *сущ. лит.* прообраз; *геройның ~ы* прообраз геро́я

пропага́нда *сущ.* пропага́нда; *революцион ~* революцио́нная пропага́нда; *~ булеге* отде́л пропага́нды

пропага́ндалан|у *страд. от* **пропагандалау**; пропаганди́роваться, быть пропаганди́рованным

пропага́ндалау *перех.* пропаганди́ровать; *коммунизм идеяләрен ~* пропаганди́ровать иде́и коммуни́зма

пропага́ндачы *сущ.* пропаганди́ст; *оешманың ~сы* пропаганди́ст организа́ции

пропагандистлы|к *сущ.* до́лжность пропаганди́ста; пропаганди́стское де́ло || пропаганди́стский; *синең ~гың инде!* како́й из тебя́ пропаганди́ст! *~к осталыгы* пропаганди́стское иску́сство

пропан *сущ. хим.* пропа́н; *~ тутырылган баллон* балло́н, напо́лненный пропа́ном

пропе́ллер *сущ.* пропе́ллер, возду́шный винт; *самолёт ~ы* пропе́ллер самолёта

пропе́ллерлы *прил.* пропе́ллерный, име́ющий пропе́ллер, с пропе́ллером; *~ насос* пропе́ллерный насо́с

пропилен *сущ. хим.* пропиле́н (*органического происхождения*)

пропиленлы *прил.* пропиле́новый; с пропиле́ном; *~ кушылма* пропиле́новое соедине́ние

пропи́ска *сущ.* пропи́ска; *см. тж.* **мәхәл**; *даими ~* постоя́нная пропи́ска; *~га керү* прописа́ться (*по месту жительства*); *~дан чыгу (төшү)* вы́писаться (*с места жительства*); *~га теркәлгән* пропи́сан

пропи́скалы *прил.* пропи́санный; *~ кешеләр* пропи́санные лю́ди

пропи́скасыз *прил.* не пропи́санный, не име́ющий пропи́ски || *нареч.* без пропи́ски; *~ яшәү* жить без пропи́ски

пропо́лис *сущ. пчел.* пропо́лис; *см. тж.* **тома балавыз**

пропорциональ *прил. в разн. знач.* пропорциона́льный; *~ нисбәттә* в пропорциона́льных отноше́ниях; *~ үсеш* пропорциона́льное разви́тие; *әһәмиятенә ~* пропорциона́льный своему́ значе́нию; *~ зурлыклар* пропорциона́льные величи́ны *в мат.* || *нареч.* пропорциона́льно; *~ бүлү* пропорциона́льно дели́ть; *~ үсү* пропорциона́льно развива́ться

пропорциональле|к *сущ. в разн. знач.* пропорциона́льность; *үсешнең ~ге* пропорциона́льность разви́тия; *~к билгеләре* при́знаки пропорциона́льности; *~к коэффициенты мат.* коэффицие́нт пропорциона́льности

пропо́рция *в разн. знач.* пропо́рция; *арифметик ~* арифмети́ческая пропо́рция; *геометрик ~* геометри́ческая пропо́рция; *~ саклау* соблюда́ть пропо́рцию; *нинди ~дә?* в како́й пропо́рции?

пропо́рцияле *прил.* пропорциона́льный □ **~ рәвештә** пропорциона́льным о́бразом, пропорциона́льно

пропо́рциялелек *сущ. см.* **пропорциональлек**

про́пуск *сущ.* про́пуск (*официальный документ на право входа в закрытое заведение*); *~лар системасы* систе́ма пропуско́в; *~лар бюросы* бюро́ пропуско́в

про́пуксыз *нареч.* без про́пуска; *~ керү* вход без про́пуска

про́пускы *сущ. разг. см.* **пропуск**

прораб *сущ.* прора́б (*инженер или техник, руководитель строительства отдельного объекта*); *~ булып эшли* рабо́тает прора́бом

прораблык *сущ.* до́лжность и́ли обя́занности прора́ба || прора́бский; *~ вазифалары* обя́занности прора́ба □ **~ итү** выполня́ть обя́занности прора́ба

проре́ктор *сущ.* проре́ктор, замести́тель ре́ктора; *кичке булек буенча ~* проре́ктор по вече́рнему отде́лению (*вуза*)

проре́кторлык *сущ.* до́лжность и́ли обя́занности проре́ктора □ **~ итү** выполня́ть обя́занности проре́ктора

проспект I *сущ.* проспе́кт (*широкая прямая улица*); *Г. Ибраһимов ~ы* проспе́кт (и́мени) Г. Ибраги́мова

проспект II *сущ.* **1.** проспе́кт (*план, краткое изложение содержания выпускаемого издания*) **2.** проспе́кт (*справочное издание рекламного характера*)

простра́нство *сущ. филос.* простра́нство; *см. тж.* **фәза**

простыня *сущ. см.* **җәймә**

протез *сущ.* проте́з || проте́зный; *~ кию* надева́ть проте́з; *~ кую (ясау)* протези́ровать; *~ заводы* проте́зный заво́д; *~ аяк* проте́зная нога́

проте́за *сущ. лингв.* проте́за (*присоединение добавочного звука к началу слова, наблюдающееся при заимствованиях и пр. случаях, напр.*, стакан > ыстакан)

протезлан|у *страд. от* **протезлау**; быть протези́рованным; *~ган кул* протези́рованная рука́

протезлау *перех.* протези́ровать || протези́рование; *теш ~* протези́рование зубо́в

протезлы *прил.* с проте́зом; *~ аяк* нога́ с проте́зом

протезчы *сущ.* протези́ст, ма́стер по изготовле́нию проте́зов

протеид *сущ. биол.* протеи́д (*сложный белок*); *~лар* протеи́ды

протеин *сущ. биол.* протеи́н (*вид белка, играющий важнейшую роль в живых организмах*)

протеинлы *прил. с.-х.* протеи́новый; *~ азыклар* протеи́новые корма́

протекцион *прил.* **1.** протекцио́нный, осо́бо защища́ющий *кого-л.* **2.** *экон.* протекционисти́ческий; *хөкүмәтнең ~ чаралары* протекционисти́ческие ме́ры правительства

протекционизм *сущ. экон.* протекционизм (*защита собственного рынка буржуазными государствами*); *~ тарафдары* сторо́нник протекционизма

проте́кция *сущ.* проте́кция (*покровительство, влиятельная поддержка кого-л.*); *~ ясау* оказа́ть проте́кцию

проте́кциялэү *перех.* оказа́ть проте́кцию, защища́ть *кого-л.* (*о влиятельном органе, личности*)

проте́кцияче *сущ.* влия́тельный челове́к, ока́зывающий проте́кцию, проте́ктор

протест *сущ.* **1.** *в разн. знач.* выраже́ние несогла́сия, проте́ст; *катгый ~* реши́тельный проте́ст **2.** *спец.* проте́ст; возраже́ние; *~ йөзеннән* в знак проте́ста; *~ ясау* протестова́ть

протестант *сущ. рел.* протеста́нт || протеста́нтский; *~ чиркәве* протеста́нтская це́рковь

протестантизм *сущ. см.* **протестантчылык**

протестантлык *сущ.* протеста́нтство; *см. тж.* **протестантчылык**

протестантчылык *сущ. ист., рел.* протестанти́зм (*явление разрыва с официальным католичеством и организация собственной церкви у ряда западноевропейских народов в XVI веке*)

противогаз *сущ.* противога́з || противога́зный; *~ сумкасы* противога́зная су́мка

противогазлы *прил.* с противога́зом, име́ющий противога́з; *~ кеше* челове́к с противога́зом, челове́к в противога́зе

протодья́кон *сущ. рел.* протодья́кон (*дьякон высшего чина*)

протоиерей *сущ. рел.* протоиере́й (*священник высшего чина*)

протон *сущ. физ.* прото́н (*часть ядра атома*)

протоплáзма *сущ. биол.* протопла́зма (*основное вещество клетки живых организмов*); *~ составы* соста́в протопла́змы

прототи|п *сущ. книжн.* **1.** прототи́п (*лицо, послужившее источником создания литературного образа*) **2.** прототи́п (*предшественник или образец кого, чего-л.*); *тере организмнарның ~бы* прототи́п живы́х организмов

протубера́нец *сущ. астр.* протубера́нец (*образование из раскалённых газов, срывающееся с поверхности Солнца в окружающее пространство*); *~ телляре* языки́ протубера́нца

профан *сущ.* профа́н (*несведущий в какой-л. области человек*); *музыкада мин ~ я* профа́н в му́зыке

профана́ция *сущ.* профана́ция (*искажение чего-л. невежественным обращением*)

профанлык *сущ.* неве́жество (*в какой-л. области*); *~ күрсәтү* показа́ть себя́ профа́ном, неве́ждой (*в какой-л. области*)

профаши́стик *прил. полит.* профаши́стский; *~ оешма* профаши́стская организа́ция

профбюро *сущ.* профбюро́ (*бюро профсоюзной организации*)

профгрупорг *сущ.* профгрупо́рг, руководи́тель профгру́ппы; *~ итеп сайлау* вы́брать профгрупо́ргом

профгру́ппа *сущ.* профгру́ппа (*профсоюзная группа*); *~ җыелышы* собра́ние профгру́ппы

профессионал *сущ.* профессиона́л (*человек, сделавший какое-л. занятие своей профессией*); *~лар һәм үзешчәннәр* профессиона́лы и люби́тели

профессионализа́ция *сущ.* профессионализа́ция (*спорта, искусства*); *см. тж.* **профессионаллашу**

профессионализм *сущ.* **1.** профессионали́зм (*в спорте и т. п.*) **2.** *лингв.* профессионали́зм (*слова, обороты речи и т. п., свойственные людям определённой профессии*); *~нар куллану* употребля́ть профессионали́зм

профессионаллашу *неперех.* переходи́ть (перехо́д) в профессиона́лы (*из любителей*)

профессиональ *прил. в разн. знач.* профессиона́льный; *~ чир* профессиона́льная боле́знь; *~ художник* профессиона́льный худо́жник; *~ белгеч* профессиона́льный специали́ст; *~ спортчы* профессиона́льный спортсме́н □ **~ рәвештә** профессиона́льно; **~ союз** профессиона́льный сою́з

профессиональлек *сущ.* положе́ние и́ли обя́занности профессиона́ла (*в какой-л. области деятельности*); *~кә күчү* переходи́ть в профессиона́лы

профе́ссия *сущ.* профе́ссия; *см. тж.* **һөнәр**; *~ алмаштыру (сайлау)* меня́ть (выбира́ть) профе́ссию; *укытучы ~се* профе́ссия учи́теля; *~се буенча эшләү* рабо́тать по (свое́й) профе́ссии

профе́ссор *сущ.* профе́ссор; *математика ~ы* профе́ссор матема́тики

профе́ссорлык *сущ.* зва́ние, положе́ние и́ли обя́занности профе́ссора; профе́ссорство; *~ка омтылу* стреми́ться в профессора́ (в профе́ссорство) □ **~ итү** выполня́ть обя́занности профе́ссора, профе́ссорствовать

профессу́ра *сущ.* **1.** профессу́ра (*звание, должность профессора*) **2.** *собир.* профессу́ра (*профессора, состав профессоров*); *кызыл ~* кра́сная профессу́ра

профила́ктик *прил.* профилакти́ческий; *~ чаралар* профилакти́ческие ме́ры

профила́ктика *сущ.* **1.** *мед.* профила́ктика (*мероприятия, предохраняющие от болезней*) **2.** *тех.* профила́ктика (*мероприятия, предохраняющие от преждевременного износа, порчи и т. п.*); *~ үткәрү* проводи́ть профила́ктику **3.** *перен.* о вся́ких предупреди́тельных, пресека́ющих, опережа́ющих проти́вника и т. п. де́йствиях; *~ тәртибендә кулга алу* арестова́ть в поря́дке профила́ктики

профилакто́рий *сущ. мед., с.-х., тех.* профилакто́рий; *техник ~* техни́ческий профилакто́рий; *~да булу* побыва́ть в профилакто́рии

про́фил|ь *сущ. в разн. знач.* про́филь; *йөз ~е* про́филь лица́; *күпер ~е* про́филь моста́; *хуҗалык ~е* хозя́йственный про́филь

про́фильле *прил.* име́ющий определённый про́филь, про́фильный; *киң ~ вуз* широкопро́фильный вуз, вуз широ́кого про́филя

про́фильләү *перех.* профили́ровать, придава́ть пра́вильный, ну́жный про́филь (сече́ние) || профили́рование, профилиро́вка; *юл ~* профили́ровать доро́гу

профком *сущ.* профко́м (*профсоюзный комитет*); *~ утырышы* заседа́ние профко́ма

профоешма *сущ.* профорганиза́ция (*местная организация профессионального союза*)

профорг *сущ.* профо́рг, профгруппо́рг; *~ булып эшләү* рабо́тать профо́ргом

профсоюз *сущ.* профсою́з (*профессиональный союз*); *~ члены* член профсою́за; *~лар берләшмәсе* объедине́ние профсою́зов

проходчы *сущ. спец.* прохо́дчик (*в шахте*); *~лар бригадасы* бригада́ прохо́дчиков

процедур *прил.* процеду́рный; *~ кабинет* процеду́рный кабине́т || *сущ. разг. см.* **процедура**

процеду́ра *сущ. книжн.* **1.** процеду́ра; *см. тж.* **мәрасим**; *сайлау ~сы* процеду́ра вы́боров **2.** *мед.* процеду́ра, лечёбная ме́ра (мероприя́тие); *~га йөрү* ходи́ть на процеду́ру

процент *сущ. в разн. знач.* проце́нт, проце́нты; *планны йөз ~ка үтәү* вы́полнить план на сто проце́нтов □ *~ чыгару* вычисля́ть проце́нты; *~ эшләү* рабо́тать на изде́льщину; *~ка акча бирү* ссуди́ть де́ньги под проце́нты

процентла|у *перех.* **1.** вычисля́ть/вы́числить || вычисле́ние проце́нтов *чего-л.*; *~п карагач* когда́ вы́числили проце́нты **2.** исчисле́ние в проце́нтах; *~п чагыштырганда* е́сли сра́внивать (да́нные) в проце́нтном отноше́нии

процентлы *прил.* **1.** проце́нтный; *~ хисап* проце́нтное исчисле́ние; *~ үтеч* проце́нтная ссу́да **2.** -проце́нтный (*в составе сложных слов*); *йөз ~* стопроце́нтный; *өч ~ эретмә* трёхпроце́нтный раство́р

процесс *сущ. в разн. знач.* проце́сс; *эш ~ы* рабо́чий проце́сс; *үсеш ~ы* проце́сс разви́тия; *савыгу ~ы* проце́сс выздоровле́ния (*больного*); *суд ~ы* суде́бный проце́сс

проце́ссия *сущ. книжн.* проце́ссия, ше́ствие; *хәрби ~* вое́нная проце́ссия

процессуаль *прил. юр.* процессуа́льный (*требующий рассмотрения по всем правилам судебного дела*); *~ җинаять* процессуа́льное преступле́ние; *~ кодекс* процессуа́льный ко́декс

прс *межд. см.* **пырыс**

пружин *прил. разг.* пружи́нный; *см.* **пружиналы**; *~ механизм* пружи́нный механи́зм || *сущ. разг. см.* **пружина**

пружи́на *сущ. прям., перен.* пружи́на; *см. тж.* **силә**; *сәгать ~сы* часова́я пружи́на; *эчке ~лар* вну́тренние пружи́ны (*какого-л. общественного движения, явления и т. п.*) ◊ **~сы ычкыну** теря́ть/потеря́ть терпе́ние; не совлада́ть с собо́й; **~сын бору** нажима́ть/нажа́ть на пружи́ны *кого, чего*

пружи́наланы *прил.* пружи́нный, снабжённый пружи́ной; *~ үлчәү* пружи́нные весы́; *~ тарантас* пружи́нный тарантас; *~ механизм* пружи́нный механи́зм

пружи́наланы|у *неперех.* **1.** *страд. от* **пружиналау** **2.** *возвр.* пружи́ниться, проявля́ть упру́гость (*о вещах*); *~ып торган аркан* пружи́нящий арка́н

пружи́налау *перех.* снабжа́ть/снабди́ть пружи́ной (*механизм, устройство, процесс и т. п.*)

прусс *сущ. этногр.* прусс, пру́ссы || пру́сский; *~лар яшәгән җир* земля́, где жи́ли пру́ссы; *~ кабиләләре* пру́сские племена́

пруссак *сущ.* пруссак (*немец — житель Пруссии*)

пруссаклык *сущ.* пруссачество (*милитаристский и феодально-бюрократический режим, особенно бывший свойственным Пруссии*)

прх *межд. см.* **пырых**

псалтырь *сущ. рел.* псалтырь; *~ уку* чита́ть псалтырь

псевдоклассицизм *сущ. лит., архит.* псевдоклассици́зм; *~ алымнары* приёмы псевдоклассици́зма

псевдоним *сущ.* псевдони́м; *Г. Тукай ~нары* псевдони́мы Г. Тука́я

псевдонимлаштыр|у *перех.* превраща́ть/преврати́ть в псевдони́м; *ул туган як атамасын ~ган* он преврати́л в свой псевдони́м назва́ние родно́й стороны́

псих *сущ. разг. прост.* псих, психопа́т

психасте́ник *сущ. мед.* психасте́ник (*человек, болеющий психастенией*) || *прил.* психастени́ческий; *~ синдром* психастени́ческий синдро́м

психастени́я *сущ. мед.* психастени́я (*психическая болезнь, характеризующаяся повышенной впечатлительностью и неуверенностью в себе*); *~ белән авыру* боле́ть психастени́ей

психиатр *сущ. мед.* психиа́тр (*врач по психическим болезням*)

психиа́трик *прил. мед.* психиатри́ческий; *~ больница* психиатри́ческая больни́ца

психиатри́я *сущ. мед.* психиатри́я (*часть медицины, занимающаяся психическими болезнями*); *~ китабы* кни́га по психиатри́и

пси́хик *прил.* психи́ческий; *~ үзенчәлекләр* психи́ческие осо́бенности; *~ атака* психи́ческая ата́ка (*в войне*); *~ авыру* психи́ческое заболева́ние □ *~ яктан (җәһәттән)* психи́чески; *~ яктан сәламәт* психи́чески здоро́в

пси́хика *сущ.* пси́хика; *кеше ~сы* пси́хика челове́ка; *~га тәэсир итү* повлия́ть на пси́хику

психоанализ *сущ.* психоана́лиз (*метод психотерапии и психологическое учение*)

психоаналити́к *прил.* психоаналити́ческий, осно́ванный на психоана́лизе; *~ күзәтүләр* психоаналити́ческие наблюде́ния

психоз *сущ.* психо́з; *~ белән азапланы* страда́ть от психо́за; *сугыш ~ы* вое́нный психо́з

психо́лог *сущ.* **1.** психо́лог, специали́ст по психоло́гии **2.** психо́лог (*человек, хорошо разбирающийся в психологии людей*); *син шәп ~ икәнсең* ты, ока́зывается, хоро́ший психо́лог

психологизм *сущ.* **1.** *иск., лит.* психологи́зм, увлече́ние изображе́нием и́ли описа́нием пси́хики, психи́ческих явле́ний; *сәнгатьтә ~* психологи́зм в иску́сстве **2.** *филос.* психологи́зм (*объяснение социальных явлений психологическими факторами*)

психоло́гик *прил.* психологи́ческий; *~ закон* психологи́ческий зако́н; *~ фактор* психологи́ческий фа́ктор; *~ әсәр* психологи́ческое произведе́ние

психологист *сущ. филос.* психологи́ст, сторо́нник психологи́зма

психологистлык *сущ. филос.* **1.** поэ́зия, взгля́ды и т. п. психологи́ста, психологи́стов; психо́логи; *~та гаепләү* обвиня́ть в психологи́зме **2.** сужде́ние, реше́ние и т. п. с пози́ции психологи́зма

психоло́гия *сущ. в разн. знач.* психоло́гия; *~ дәреслеге* уче́бник психоло́гии; *бала ~се* психоло́гия ребёнка; *сугыш ~се* психоло́гия войны́

психоневроло́гик *прил.* психоневрологи́ческий

психоневроло́гия *сущ. мед.* психоневроло́гия (*болезни на основе психических расстройств и наука о таких болезнях*); *~ белгече* специали́ст по психоневроло́гии

психопа́т *сущ. разг.* психопа́т; челове́к, больно́й психи́ческой боле́знью (*поэтому особо субъективный, мнительный, раздражительный, неуверенный и т. п.*)

психопа́тия *сущ.* психопа́тия (*расстройство психической деятельности*)

психопато́лог *сущ.* психопато́лог, специали́ст по психопатоло́гии

психопатоло́гик *прил.* психопатологи́ческий, свя́занный с психопатоло́гией

психопатоло́гия *сущ.* психопатоло́гия (*наука о психических расстройствах и их лечении*); *~ белгече* специали́ст по психопатоло́гии

психотерапевт *сущ.* психотерапе́вт (*врач-специалист по психотерапии*)

психотерапи́я *сущ.* психотерапи́я (*совокупности методов лечения путём воздействия на психику человека*); *~ кабинеты* кабине́т психотерапи́и

психофи́зик *прил.* психофизи́ческий, относя́щийся к психофи́зике

психофи́зика *сущ.* психофи́зика (*раздел психологии, изучающий между силой раздражения и величиной вызываемого им ощущения*)

психофизиоло́гик *прил.* психофизиологи́ческий; *~ эксперимент* психофизиологи́ческий эксперимент

психофизиоло́гия *сущ.* психофизиоло́гия (*наука о соотношениях и взаимосвязях психических и физиологических явлений, напр., о влиянии голода, усталости на психику, страха, веселья и т. п. на физиологию*)

психро́метр *сущ.* психро́метр (*прибор для измерения влажности воздуха*); *~ белән улчәү* измеря́ть психро́метром

пу, пуһ *подр. звукам выстрела пугача, мелкокалиберного пистолета и т. п.*

пу́блика *сущ. собир.* **1.** пу́блика (*совокупности посетителей, зрителей в местах зрелища — в театре, цирке и т. п.*) **2.** *разг.* пу́блика (*общество или группа лиц, объединённые по каким-л. общим признакам*); *см. тж.* **җәмәгать**; *хөрмәтле ~* почте́нная пу́блика (*обращение говорящего к толпе, всем слушателям*)

пук, пук-пук *подр. несильным взрывам* (*при стрельбе из пистолета, воздушного ружья и т. п.*) □ **~ итү 1.** слы́шать (*о мягких взрывах*) **2.** стреля́ть (*из пистолета*)

пул I *сущ. уст.* **1.** металли́ческие де́ньги; ме́дная моне́та **2.** де́нежная едини́ца, полу́шка; *бер ~ тора* сто́ит оди́н пул **3.** кон в игре́; *~га кую* ста́вить на кон **4.** *диал.* небольшо́е накопле́ние для осо́бой нужды́, деньжа́та; *бераз ~ым бар* есть у меня́ немно́го де́нег (деньжа́т)

пул II *сущ. диал.* **1.** по́лка, ла́вка (*в бане*); *~га менеп чабыну* хлеста́ться, па́риться (*веником*) на по́лке **2.** мо́стик при игре́ в тука́н (*на который ставится палочка, по которой ударяют другой длинной палкой*)

пул III *сущ.* пул (*форма капиталистической кооперации*)

пулат *сущ. разг.* пала́ты, дворе́ц; *см. тж.* **ташпулат**; *~та торсаң ни, келәттә торсаң ни* (*посл.*) живи́ хоть в пала́тах, хоть в кле́ти (жизнь одна́)

пулемёт *сущ.* пулемёт || пулемётный; *кул ~ы* ручно́й пулемёт; *зенит ~ы* зени́тный пулемёт; *эре калибрлы ~* крупнокали́берный пулемёт; *~ ротасы* пулемётная ро́та

пулемётчылык *сущ. воен.* до́лжность пулемётчика (*в расчёте взвода*); *~ка уку* учи́ться на пулемётчика

пуловер *сущ.* пуло́вер (*шерстяной свитер без воротника*); *~ кигән* в пуло́вере

пу́льман: пу́льман вагоны пу́льмановский вагон

пульс *сущ.* **1.** *мед.* пульс (*ритмическое давление артериальной крови в кровеносных сосудах*); *~ санау* счита́ть пульс; *~ы — минутына туксан тибеш* его́ пульс — девяно́сто уда́ров в мину́ту; *~ы ешайды* пульс его́ участи́лся **2.** *перен.* пульс, ритм (*темп жизни, жизнедеятельности, общественного и т. п. процесса*); *матбугатның ~ тибеше* бие́ние пу́льса пре́ссы

пульсар *сущ. астр.* пульса́р (*звезда с пульсирующим радиоизлучением*)

пульса́ция *сущ. мед., тех.* пульса́ция (*биение пульса; ритмическое усиление давления, тока, течения и т. п.*)

пульса́цияле *прил.* пульси́рующий; *~ ток* пульси́рующий ток

пульса́цияләү *неперех.* пульси́ровать

пульт *сущ.* **1.** пульт (*подставка для ног*) **2.** *тех.* пульт (*место, на котором в определённом порядке размещены приборы управления машинами, технологическими процессами и т. п.*); *дирижёр ~ы* дирижёрский пульт; *идарә ~ы* пульт управле́ния; *диспетчерлык ~ы* диспе́тчерский пульт

пу́ля *сущ.* пу́ля || пулево́й; *яндыргыч ~* зажига́тельная пу́ля; *~ ярасы* пулево́е ране́ние; *~ кебек* как пу́ля (*быстрый*)

пу́ма *сущ. зоол.* пу́ма (*крупное животное из семейства кошачьих, встречающееся в Америке*)

пумала *сущ.* **1.** помело́; *см. тж.* **мич себеркесе 2.** кисть, ки́сточка (*для окраски, обмазки или рисования, живописи*); *дегет ~сы* кисть для обма́зывания дёгтем (*колёс и т. п.*) **3.** *перен. прост. см.* **пумалабаш**

пумалабаш *сущ. разг. уничиж.* растре́па (*преимущ. о женщине*)

пумалалану *неперех.* растре́пываться/растрепа́ться (*о волосах и т. п.*); измы́згиваться/измы́згаться; измоча́ливаться/измоча́литься || измоча́ливание

пу́нкция *сущ. мед.* пу́нкция, прокóл те́ла (*при вакцинации, уколах и т. п.*); *~ ясау* де́лать пу́нкцию

пуп *сущ. разг. см.* **поп**

пупалау *неперех. прост. см.* **пупәләү**

пуризм *сущ. лингв.* **1.** пури́зм (*стремление к строгости нравов*) **2.** пури́зм (*стремление освободиться от лексических заимствований, борьба против неологизмов*)

пурист *сущ.* пури́ст, сторо́нник пури́зма

пури́стик *прил.* пури́стский; *~ омтылышлар* пури́стские устремле́ния

пуристлык *сущ. см.* **пуризм**

пуритан *сущ.* **1.** пурита́н (*сторонник религиозно-политического течения в среде английской буржуазии XVI—XVII вв., характеризующегося требованиям простоты и строгости обрядов и нравов*) **2.** *перен.* пурита́нин (*сторонник простых и строгих нравов*) || пурита́нский; *~ тәрбиясе* пурита́нское воспита́ние

пуританлы|к *сущ.* пурита́нство; пуритани́зм; *~гы белән билгеле* изве́стный свои́м пурита́нством

пурки *сущ. разг. ист.* **1.** прижива́л (*сопровождающий приглашённого в гости*) **2.** шаки́рд (*живущий за счёт подаяний в гостях, на похоронах и т. п.*) **3.** непро́шеный гость

пуркилану *неперех. разг. ист.* **1.** увя́зываться, навя́зываться, напра́шиваться в го́сти **2.** превраща́ться/преврати́ться в прижива́ла

пуркилык *сущ. разг.* **1.** навя́зывание себя́ в го́сти **2.** положе́ние прижива́ла

пурый *сущ. эвф.* **1.** заме́на обы́чных назва́ний чёрта (*говорится, чтобы чёрт не пришёл на помине*) **2.** за́яц, за́йчик (*в детском языке*)

пуст *сущ. ист.* ко́жаный мешо́к; мех; *акча ~ы* сума́ с деньга́ми; *ышанма дустыңа, энә тыгар ~ыңа* (*посл.*) не верь дру́гу — проткнёт твой мех

пута I *сущ. этногр.* широ́кий куша́к, по́яс; плато́к, слу́жащий по́ясом; *ефәк ~* шёлковый куша́к; *~ бәйләү* подпоя́сываться кушако́м

пута II *сущ. диал.* пла́нка (*прибиваемая для связки досок крыши*); *~ кагу* прибива́ть пла́нку (*на концы досок*)

путал *сущ.* **1.** пота́ль (*сплав меди и цинка, цветом напоминающий золото*) **2.** фольга́ золоти́стого цве́та **3.** зо́лото, *в знач.* золота́я кра́ска; позоло́та; *~ белән басылган хәрефләр* тиснёные зо́лотом бу́квы || *прил. см.* **путаллы**

путаллан|у *страд. от* **путаллау**; кра́ситься, быть раскра́шенным под зо́лото; *~ган шамаил* раскра́шенный золоты́ми кра́сками шамаи́л

путаллату *понуд. от* **путаллау**

путалла|у *перех.* кра́сить зо́лотом, золото́й кра́ской; *~п язылган* напи́сано золото́й кра́ской

путаллы *прил.* **1.** золото́й (*о краске*) **2.** раскра́шенный под зо́лото; *~ медаль* раскра́шенная под зо́лото меда́ль; *~ чынаяк* раскра́шенный золоты́ми кра́сками фарфо́р

путч *сущ.* путч (*попытка государственного переворота, предпринятая сравнительно небольшой группой лиц, а также такой переворот*)

пуф, пуфф **1.** *подр. шумному выдоху* пуф **2.** *подр. выдуванию дыма изо рта при курении, выпусканию колец и т. п.* □ **пуф итү** **1.** губа́ми издава́ть зву́ки при выдыха́нии **2.** *перен.* пуши́ться, быть вспу́шенным; *мыеклары пуф итеп тора* усы́ его́ пуши́лись (постоя́нно) **3.** *перен. разг.* фуфы́риться, расфуфы́риться

пуф-пуф *подр. многокр. от* **пуф**; *пуф-пуф тын алу* шу́мно и до́лго дыша́ть, отдыша́ться □ **пуф-пуф итү (килү)** **1.** отдыша́ться, шу́мно выдыха́я во́здух; постоя́нно шу́мно дыша́ть **2.** *перен.* беспоко́йно торопи́ться *куда-л.* **3.** бить струёй (*о дыме, парах*)

пуфылдату *понуд. от* **пуфылдау**

пуфылда|у *неперех.* **1.** шу́мно дыша́ть **2.** шу́мно бить па́ром (*о чём-л. кипящем, о паровозе и т. п.*), шипе́ть □ **~п тора** так и шипи́т

пух *подр.* **1.** *не очень громкому звуку выстрела* бух; бах-бабах **2.** *шумному выдоху* ух □ **пух итү** **1.** ба́хнуть, баба́хнуть (*из пистолета, ружья*) **2.** гро́мко вы́дохнуть **3.** набуха́ть от еды́; е́ле дыша́ть от перепо́лненности желу́дка **4.** наеда́ться до отва́ла; *сыерлар пух иткән* коро́вы нае́лись до отва́ла

пух-прах, пух-пырах *предик. см.* **пыран-заран**

пу́шка *сущ.* **1.** пу́шка; *см. тж.* **туп** II; *~дан ату* стреля́ть из пу́шки **2.** *спец.* пу́шка (*аппарат, действием или видом напоминающий пушку*); *радиоактив ~* радиоакти́вная пу́шка **3.** *разг.* фи́гушка-фигу́ра при игре́ в городки́ ◊ **~ ите** пу́шечное мя́со; **~га алу** взять/брать на пу́шку; обману́ть

пушкачы *сущ. редко* **1.** пушка́рь (*литейщик пушек*) **2.** пушка́рь (*воин, стреляющий из пушки, артиллерист*)

пушкинист *сущ. лит.* пушкини́ст; *~лар җыелышы* собра́ние пушкини́стов

пушни́на *сущ.* пушни́на || пушно́й; *~ белән сәүдә итү* торго́вля пушни́ной; *~ товары* пушно́й това́р

пушниналы *прил.* **1.** с пушни́ной, име́ющий пушни́ну; *~ олау* обо́з с пушни́ной **2.** пушно́й (*зверь, промысел*)

пүкелдәтү *перех. разг.* пу́кать *чем*; хло́пнуть *чем*; производи́ть треск, (*слабый*) взрыв; *браунингны ~ү* пу́кать бра́унингом

пүкелдә|ү *неперех. разг.* хло́пать ритми́чески, ритми́чно тарахте́ть, издава́ть зву́ки вы́хлопа (*о стационарных двигателях*); *көне-төне ~п утыра* днём и но́чью ритми́чно тарахти́т

пүләп *сущ. разг.* **1.** поле́но; *см. тж.* **түмәр, бүкән** **2.** пла́ха; *см. тж.* **ярка**; *мичкә бер ~ өстәү* доба́вить в пе́чку одну́ пла́ху

пүнәтәй *сущ. разг.* **1.** понято́й; *см. тж.* **шаһит, танык**; *~ләр алдында* пе́ред понятыми́, при засвиде́тельствовании понятых **2.** *перен.* подначáльник; клевре́т

пүнәтәйлек *сущ. разг.* **1.** обя́занности понято́го **2.** *перен.* са́мая ни́зкая администрати́вная до́лжность

пүпәләү *неперех. прост.* ко́е-ка́к объясня́ться (*на малознакомом языке или будучи глухонемым и т. п.*)

пүчиңкә *сущ. диал.* почи́нок, вы́селок (*деревушка, стоявшая поодаль от села и обычно отделившаяся от него*); *~ белән авыл арасы* расстоя́ние ме́жду вы́селком и село́м

пүчицкә *сущ. диал.* па́реная ре́пка и́ли свекла́

пүчтәк *сущ. разг.* пустя́к, пустяки́; *~не сөйләү* говори́ть пустяки́ (*о пустяках*) || *прил.* пустя́чный; пусто́й; *~ сәбәп белән* по пустя́чным причи́нам; *~ сүз* пусто́е (необосно́ванное) сло́во

пфе́ннинг *сущ.* пфе́ннинг (*мелкая денежная единица в Германии*); *унбиш ~* пятна́дцать пфе́ннингов

пф, пффи *межд.* пф

пшик *межд.* пшик, ничто́; всё, коне́ц всему́ (*хорошему*)

пывын *диал.* **1.** *см.* **бил** 1 **2.** *зоол.* вид насеко́мого (*из семейства пчелиных*)

пыж *сущ.* пыж; *патронга пыж тыгу* наби́ть пыж в патро́н

пыжгырту *перех. см.* **выжгырту**

пыжик *сущ.* пы́жик (*детёныш северного оленя и его мех*) || *прил.* пы́жиковый; *~ мех* пы́жиковый мех; *~ бүрек* пы́жиковая ша́пка

пыжу *неперех. диал. см.* **пәжү**

пыжы|гу *неперех. прост. диал.* **1.** преть; *терлек абзарда ~гып ята* скот пре́ет в хлеву́ **2.** *в знач. прил. в ф.* **пыжыккан** пре́лый; *~ккан салам* пре́лая соло́ма

пыжык *прил. диал. см.* **мыжык**

пыжылдау *неперех. см.* **быжылдау**

пыжыту I *перех. диал.* допуска́ть/допусти́ть пре́ние, гние́ние (*с выделением тепла*), размягче́ние *чего*

пыжыт|у II *перех. диал.* наде́лать (*дел*); по́ртить/напо́ртить; наломáть дров; *~кан икән* наде́лал же (он) дел; наломáл (он) дров

ныл *сущ. уст. см.* **пел**

пылау *сущ.* плов; *~ пешерү* (при)гото́вить плов

пылаулык *прил.* приго́дный и́ли доста́точный для пло́ва; на плов; *~ дөге* рис для пло́ва

пылаучы *сущ.* **1.** ма́стер по приготовле́нию пло́ва **2.** кухме́йстер (*знатного лица*)

пылаяк *прил. с.-х.* белоно́гий (*о лошади*); *~ ат* белоно́гий конь

пылдырдау *неперех.* хло́пать на ветру́ (*о твёрдых предметах, напр., о доске, жести на весу*)

пылдыр-пылдыр *подр. шумному хлопанью, качанию* (*преимущ. о твёрдых предметах*) □ **пылдыр-пылдыр килү** верте́ться, пока́чиваться (*о вертушке*)

пылт *подр. звуку громкого одиночного или редкого падения капли, выхлопа пробки* кап; *см.* **пелт** □ *~* **итү** гро́мко ка́пнуть

пылт-пылт *подр. звукам редкого капания, падения капель* кап-ка́п; *пылт-пылт тама* ка́пает кап-ка́п □ **пылт-пылт итү** не́сколько раз (и́ли продолжи́тельно) ка́пать кру́пными ка́плями

пыр, пыр-р *подр. вспархиванию, внезапному взлёту с шумом* □ **пыр итү** 1. взлета́ть с порха́нием 2. поднима́ться столбо́м (*о пухе, пыли*); **пыр туздыру** 1. поднима́ть пыль (пух и т. п.) столбо́м; *см.* **порхыту** 2. *перен.* разнести́ в пух и прах; рвать и мета́ть; громи́ть *кого, что*; **пыр тузу** 1. поднима́ться столбо́м (*о пухе, пыли и т. п.*) 2. приводи́ть в беспоря́док; лежа́ть вкривь и вкось; *пыр тузып ята* (всё) лежи́т вкривь и вкось 3. *перен.* вспыли́ть, разрази́ться гне́вом; рвать и мета́ть; *юк өчен пыр тузды* разрази́лся гне́вом из-за пустяко́в ◊ **пыр туздырып** 1. во всю; *пыр туздырып тырга* руга́ет во всю 2. с бле́ском и тре́ском; бы́стро и бо́йко; *пыр туздырып эшли* рабо́тает с бле́ском и тре́ском; **пыр тузыну** *см.* **тузыну**; **пыр тузып** шу́мно, гро́мко, возбуждённо; нейстово; *пыр тузып кул чаптылар* нейстово аплоди́ровали

пырак *сущ. миф.* 1. пура́к, бура́к (*летающая лошадь пророка Мухаммеда*) 2. пура́к, бура́к (*райская лошадь*)

пыран-заран *предик.* в по́лном расстро́йстве; хана́, крах; *эшләр пыран-заран* дела́ хана́ □ **пыран-заран килү** 1. разбра́сываться, быть разбро́санным (*о чём-л. ранее упорядоченном*) 2. приходи́ть в по́лное расстро́йство; растра́чиваться (*о нажитом*) 3. разруга́ться, распуме́ться; **пыран-заран китерү** 1. разбра́сывать/разброса́ть (*вещи*) 2. рассе́ять, разгроми́ть (*врага*) 3. сокруша́ть, круши́ть *кого-л., что-л.* в гне́ве 4. разбаза́ривать/разбаза́рить, растра́чивать/растра́тить (*нажитое*); **пыран-заран яту** лежа́ть в беспоря́дке, в разва́линах

пыран-заранга *нареч.* впусту́ю, почём зря (*об издержках, о расходах, тратах*); *пыран-заранга җибәрү* пусти́ть по ве́тру (*нажитое*); *пыран-заранга китү* растра́чиваться впусту́ю

пыранлат|у *перех. разг.* 1. разогна́ть, прогна́ть (*с шумом*); рассе́ять ‖ разго́н, рассе́ивание; *көчек күгәрченнәрне ~ты* щено́к разогна́л голубе́й 2. поруга́ть, разруга́ть, обруга́ть (*многих сразу, так чтобы все забегали*)

пыранла|у *неперех.* вспыли́ть, вспы́льчиво (гне́вно, в гне́ве) выража́ть недово́льство; *бүлмәдән ~п чыгып китте* разгне́ванно, вы́скочил из ко́мнаты

пыргу *неперех. разг.* бить струёй; си́льно бры́згать/бры́знуть (*о жидкости*); *көпшәдән ~* бить струёй из тру́бочки

пыргы *сущ.* 1. брандспо́йт 2. разбры́згиватель 3. насо́с

пыргыт|у *перех.* 1. поливáть, бры́згать си́льной струёй; направля́ть/напра́вить струю́ (*жидкости*); *су ~ып тора* стои́т и направля́ет струю́ воды́ (*о человеке*) 2. *см.* **пыранлату**

раслама *сущ. редко* **1.** да́нный в подтвержде́ние, обоснова́ние; *~га нәрсәң бар?* что у тебя́ есть для подтвержде́ния? чем подтверди́шь? *төрле ~лар китерү* приводи́ть ра́зные да́нные в подтвержде́ние **2.** утвержде́ние; *яклау яхшы узды, ~сы куренми әле* защи́та прошла́ хорошо́, но пока́ утвержде́ния нет

раслан|у *страд. от* **раслау 1.** подтвержда́ться; *фактлар белән ~мый* не подтвержда́ется фа́ктами **2.** заверя́ться, удостоверя́ться; *имзасы ~ган* по́дпись заве́рена; *белешмә секретариатта ~а* спра́вка заверя́ется в секретариа́те **3.** утвержда́ться; *көн тәртибе ~а* утвержда́ется пове́стка дня; *доклад тезислары ~ды* те́зисы докла́дов утверждены́

раслат|у *понуд. от* **раслау** **1.** заставля́ть подтверди́ть/подтверждать *что-л.* **2.** дава́ть/дать на заве́рение (*документ, бумагу, подпись и т. п.*); удостове́рить; дать на утвержде́ние, провести́ утвержде́ние; *планны ~у өчен* для утвержде́ния пла́на, что́бы утверди́ли план

расл|ау *перех.* **1.** подтверждать/подтверди́ть, дока́зывать/доказа́ть || подтвержде́ние; доказа́тельство; *сүзнең дөреслеген ~ау* доказа́ть достове́рность слов; *бүгенге җиңү планның реальлеген ~ый* сего́дняшняя побе́да подтверждает реа́льность пла́нов; *документның ялган булуын ~ау* установи́ть подло́жность докуме́нта **2.** заверя́ть/заве́рить, удостоверя́ть/удостове́рить, свиде́тельствовать, засвиде́тельствовать || заве́рение, удостоверение, засвиде́тельствование; *имзаны ~ау* заве́рить по́дпись; *үлемнең йөрәк авыруыннан булуын врач ~ды* врач удостове́рил, что смерть произошла́ от серде́чной боле́зни **3.** утверждать/утверди́ть (*документ, план работы, проект, повестку дня и т. п.*) || утвержде́ние; *филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәне ~ау* утверди́ть учёную сте́пень до́ктора филологи́ческих нау́к; *профессор исеменә ~ау килде* полу́чено утвержде́ние на зва́ние профе́ссора; *киресен ~ау* утверждать/ути́вное **4.** *полит.* ратифици́ровать || ратифика́ция; *договорны ~ау* ратифици́ровать догово́р

раслаучы *сущ.* заверитель; *бу документка ике ~ кул куйган* на э́том докуме́нте есть по́дписи двух заверителей; *~ имзасы* по́дпись заверителя || *прил.* заверя́ющий, удостоверя́ющий

раслы|к *сущ.* пра́вильность, ве́рность, и́стинность, достове́рность; пра́вда, и́стина; *әйткән сүзенең ~гын күрсәтү өчен* что́бы доказа́ть пра́вильность свои́х слов; *фактларның ~гы* достове́рность фа́ктов; *хикәядәге вакыйгаларның ~гына ышану* ве́рить в и́стинность собы́тий расска́за

распашник *сущ. с.-х.* распа́шник; *~ белән җирне йомшарту* разрыхли́ть зе́млю распа́шником

распашо́нка *сущ.* распашо́нка; *фланель ~* флане́левая распашо́нка

расписа́ние *сущ. в разн. знач.* расписа́ние; *см. тж.* **җәдвәл**; *дәрес ~се* расписа́ние уро́ков; *поездлар ~се* расписа́ние поездо́в; *~гә кертү* включи́ть в расписа́ние

распи́ска *сущ.* распи́ска; *акча алу турында ~* распи́ска о получе́нии де́нег; *бурыч ~сы* долгова́я распи́ска

рассада *сущ. с.-х.* рассада; *кәбестә ~сы* рассада капу́сты; *~ утырту* сажа́ть рассаду □ **~ тутәле** рассадник, гря́дка рассады

рассадник *сущ. с.-х.* рассадник

рассо́льник *сущ. кулин.* рассо́льник; *~ пешерү* вари́ть рассо́льник; *~ка дип калдырган кыяр* огурцы́, оста́вленные для рассо́льника

растан *нареч. разг.* в са́мом де́ле, действи́тельно; *~ да* и в са́мом де́ле; *~ да, син сөйләгән идең бит* и в са́мом де́ле, ты же говори́л

растра́та *сущ. разг.* растра́та; *~ өчен судка бирү* отда́ть под суд за растра́ту; *~ тулау* возмести́ть растра́ту □ **~ ясау** де́лать/сде́лать растра́ту, растра́тить; **~ ясаучы** растра́тчик, растра́тчица

расход *сущ.* расхо́д || расхо́дный; *см. тж.* **чыгым**; *~ларны язып бару* запи́сывать расхо́ды; *~ кенәгәсе* расхо́дная кни́га; кни́га (за́писи) расхо́дов; *~ка язу* записа́ть в расхо́д (*в категорию расходов*) □ **~ чыгару (ясау)** изде́рживаться/издержа́ться; **~ын каплау** возмеща́ть/возмести́ть расхо́ды; окупа́ть, оправда́ть расхо́ды; **~ын күтәрү** взять на себя́ расхо́ды ◊ **~ка чыгару (җибәрү)** **1.** списа́ть в расхо́д; ликвиди́ровать, уничтожа́ть/уничто́жить *что-л.* **2.** пусти́ть в расхо́д (*прост.*) расстреля́ть, уби́ть *кого-л.*; **~ка чыгу (китү)** расхо́доваться

расходландыру *понуд. от* **расходлану**

расходлан|у *неперех.* **1.** изде́рживаться/издержа́ться; *~асы килми* не хо́чется расхо́доваться; *туй үткәреп ~* израсхо́доваться на сва́дьбу; *бу айда мин бик ~дым* за э́тот ме́сяц я о́чень (си́льно) потра́тился **2.** израсхо́доваться, потра́титься; *акча юк-барга ~ган* де́ньги потра́чены на пустяки́ || изде́ржки, расхо́дование

расходлы *прил.* свя́занный с расхо́дами, тре́бующий расхо́дов (изде́ржек), с расхо́дами; *~ эш* де́ло, тре́бующее расхо́дов; *зур ~ туй* сва́дьба с больши́ми расхо́дами

расходлык *прил.* на расхо́ды; расхо́дный, предназна́ченный на расхо́ды, для расхо́дов; *~ акчаны бирдем* о́тдал де́ньги, предназна́ченные для расхо́дов

расчёт *сущ. в разн. знач.* расчёт || расчётный; *~ көтү* ожида́ть расчёта; *~ таләп итү* тре́бовать расчёт; *пулемет ~ы воен.* пулемётный расчёт; *~ командиры воен.* команди́р расчёта; *~ кассасы* расчётная ка́сса; *расчёт ае* расчётный ме́сяц □ **~ алу** рассчита́ться; получи́ть (взять) расчёт и уво́литься; **~ бирү** дать расчёт (уво́лить); рассчита́ть; **~ ясау** **1.** рассчита́ть, произвести́ расчёт **2.** *разг.* рассчита́ться, расплати́ться, произвести́ *с кем-л.* расчёт **3.** *разг. перен.* свести́ счёты, расплати́ться, отомсти́ть *кому-л.*; разде́латься *с кем-л., чем-л.*

расчётлы *прил. разг.* **1.** расчётливый, осмотри́тельный **2.** по расчёту, осно́ванный на расчёте, на вы́годе; *~ никах* брак по расчёту

расчётчы *сущ. спец.* расчётчик

расшифро́вка *сущ.* расшифро́вка, дешифро́вка; *~ ясалган* расшифро́ванный; *~ ясалу* расшифро́вываться; *~ ясау* расшифро́вывать; *~ ясаучы* расшифро́вщик, дешифрова́льщик

расшифро́вкалау *перех.* расшифро́вывать/расшифрова́ть, дешифро́вывать/дешифрова́ть || расшифро́вка; дешифро́вка; *яшерен телеграмманы ~* расшифрова́ть секре́тную телегра́мму; *геологик документларны ~* расшифрова́ть геологи́ческие докуме́нты

расшифро́вкалаучы *сущ.* расшифро́вщик, расшифро́вщица, дешифрова́льщик, дешифрова́льщица

расында *сущ. разг.* в действи́тельности, в са́мом де́ле; действи́тельно (*в знач. вводн. сл.*); *~ ул алай ук булмаган* в са́мом де́ле не совсе́м так бы́ло

ратин *сущ.* ратин; *пальтолык ~ сатып алу* купи́ть ратин на пальто́ || *прил.* рати́новый; из рати́на; *~ пальто* рати́новое пальто́

ратифика́ция *сущ. полит.* ратифика́ция || ратификацио́нный; *үзара сәүдә договорына ~ ясау* ратифици́ровать торго́вый догово́р; *~ грамотасы* ратификацио́нная гра́мота

ратифика́циял|әү *перех. полит.* ратифици́ровать || ратифика́ция, *экономик хезмәттәшлек договорын ~* ратифици́ровать догово́р об экономи́ческом сотру́дничестве

ра́тник *сущ. ист.* ра́тник; *Мәскәү ~лары* Моско́вские ра́тники

ра́туша *сущ. ист.* ра́туша; *шәһәр ~сы* городска́я ра́туша; *~ члены* член ра́туши

рауан *уст., диал. нареч.* бы́стро; *~ китеп барды* бы́стро удали́лся

рауза *уст.* **1.** *миф.* назва́ние ра́йского са́да **2.** *поэт.* роза́рий; цветни́к, сад цветов **3.** *сущ.* разде́л поэти́ческих тетра́дей, глава́ кни́ги; *беренче ~* пе́рвый разде́л кни́ги, пе́рвая часть поэти́ческого сочине́ния; *әүвәлге ~* нача́льный разде́л

ра́унд *сущ. спорт.* ра́унд; *беренче ~* пе́рвый ра́унд; *чемпион икенче ~та гына һөҗүмгә күчте* чемпио́н то́лько во второ́м ра́унде перешёл в ата́ку

раушан *прил.* **1.** *книжн.* лучи́стый, лучеза́рный, сия́ющий; *~ йолдыз* лучи́стая (сия́ющая) звезда́; *~ күзләр* лучеза́рные (лучи́стые) глаза́ **2.** чи́стый, без при́месей; прозра́чный, хруста́льный; *~ көзге* чи́стое зе́ркало

раушани *прил. книжн.* чи́стый; без грехо́вных по́мыслов; *~ күңел белән* с чи́стой душо́й, с чи́стой со́вестью, чистосерде́чно

рафик *сущ. книжн.* **1.** това́рищ, друг; спу́тник; *зәгыйфьләргә ~ бул* будь дру́гом сла́бых **2.** супру́г

рафика *сущ. книжн.* супру́га, подру́га жи́зни, спу́тница жи́зни; *~гызны күрдем* ви́дел ва́шу супру́гу; *~гыз сәламәтме?* здоро́ва ли ва́ша супру́га?

рафинад *сущ.* рафина́д || рафина́дный; *~ шикәр* са́хар-рафина́д; *~ заводы* рафина́дный заво́д

рафинадлан|у *страд. от* **рафинадлау**; быть рафини́рованным; *~ган шикәр* рафини́рованный са́хар

рафинадлау *перех.* рафини́ровать || рафини́рование; *шикәрне ~* рафини́ровать са́хар

рафинёр *сущ. тех.* рафинёр || рафинёрный; *~ машинасында эшләү* рабо́тать на рафинёре; *~ цехы* рафинёрный цех

рафинёрлау *перех. см.* **рафинадлау**

рафинёрчы *сущ. спец.* рафинёрщик, рафинёрщица

рахит *сущ. мед.* рахит; *~ авыруы* рахи́т; *~ авырулы* рахити́чный, рахити́ческий; *~ авырулы балалар* де́ти, больны́е рахи́том; рахи́тики

рахи́тик *сущ.* рахи́тик, рахити́чка; *~ балалар* де́ти-рахи́тики

рахитлык *сущ.* рахити́зм; рахити́чность; *~ билгеләре* при́знаки рахити́зма; *~ка каршы көрәш чаралары* ме́ры борьбы́ про́тив рахити́зма

рахман *прил. уст.* ве́щий, свято́й; милосе́рдный, ми́лостивый (*эпитет бога*); *~ Ильяс рел.* свято́й Илья́с (Илья́-проро́к)

рахмани *прил. уст.* бо́жий, бо́жеский; боже́ственный; ве́щий, свято́й; *см. тж.*; *~ төш* ве́щий сон; *кемнең төше ~ да, кемнең шайтани погов.* у одного́ сон ве́щий (бо́жеский), а у друго́го бредо́вый (дья́вольский)

раһиб *сущ. уст. книжн.* мона́х (христиа́нский), подви́жник *церк.*; *~ләр йорты* монасты́рь

раһибә *сущ. уст. книжн.* мона́хиня, мона́шка *разг.*, подви́жница *церк.*

рацион *сущ.* рацио́н; *тәүлеклек ~* су́точный рацио́н; *~ны яхшырту* улу́чшить рацио́н; *маллар ~ы* рацио́н живо́тных

рационализа́тор *сущ.* рационализа́тор || рационализа́торский; *~лар киңәшмәсе* совеща́ние рационализа́торов; *алдынгы ~* передово́й рационализа́тор; *~ хезмәте* рационализа́торский труд

рационализа́торлык *сущ.* рационализа́торство || рационализа́торский; *~ мәсьәләсе* вопро́с рационализа́торства; *~ тәкъдиме* рационализа́торское предложе́ние; рацпредложе́ние; *~ таланты* рационализа́торский тала́нт

рационализа́ция *сущ.* рационализа́ция; *җир эшкәртүдәге ~* рационализа́ция земледе́лия; *~ мәсьәләсе* вопро́с рационализа́ции; *~ ясау (кертү)* рационализи́ровать

рационализм *сущ. филос.* рационали́зм; *француз ~ы* францу́зский рационали́зм; *~ идеяләре* иде́и рационали́зма; *~ тарафдары* рационали́ст

рационалист *сущ. филос.* рационали́ст, рационали́стка; *~ кешеләр* рационали́сты

рационали́стик *прил.* рационалисти́ческий; *~ философия* рационалисти́ческая филосо́фия

рационаллаштыру *перех.* рационализи́ровать || рационализа́ция; *машина детальләрен эшкәртү процессын ~* рационализи́ровать проце́сс обрабо́тки дета́лей маши́н; *~ өлкәсендәге уңышлар* успе́хи в о́бласти рационализа́ции

рационаллаштыручы *сущ.* рационализа́тор; *скважина ремонтлауны ~лар* рационализа́торы ремо́нта сква́жин

рационаллашу *неперех.* рационализи́роваться, рационализова́ться; станови́ться/стать бо́лее рациона́льным; усовершéнствоваться, улучша́ться || рационализа́ция; усовершéнствование, улучшéние; *җитештерү процессының ~ы* рационализа́ция проце́сса произво́дства

рациональ *прил.* **1.** *мат. филос.* рациона́льный; *~ метод филос.* рациона́льный ме́тод; *~ саннар мат.* рацона́льные чи́сла **2.** рациона́льный, разу́мный, целесообра́зный **3.** *в знач. нареч.* рациона́льно, разу́мно, целесообра́зно; *эш сәгатеннән ~ файдалану* рациона́льно испо́льзовать рабо́чее вре́мя

ра́ция *сущ.* ра́ция; *радист ~не көйләде* ради́ст настро́ил ра́цию; *~ буенча элемтәгә керү* связа́ться по ра́ции

рашкы *сущ. разг.* ме́лкий град, сне́жная крупа́; *~ ява* идёт ме́лкий град, идёт сне́жная крупа́; *каз авызын шакылдатса, ~ көт* е́сли гусь щёлкает клю́вом — быть гра́ду (*примета*); *тургайга яңгыр тисә, баласын яшерә, ~ тисә, үз башын яшерә посл.* жа́воронок от дождя́ пря́чет птенцо́в, а от гра́да спаса́ет себя́ (свою́ го́лову)

ра́шкылы *прил.* с гра́дом, со сне́жной крупо́й; *~ яңгыр* дождь с гра́дом, дождь со сне́жной крупо́й

ра́шпиль *сущ.* ра́шпиль || ра́шпильный; *~ белән кыру* счища́ть ра́шпилем; *~ сыры (теше)* ра́шпильная насе́чка (зу́бчики)

раштуа *сущ. разг.* рождество́ || рожде́ственский; *~да бер көрәк кар бирмәс погов.* у него́ средь зимы́ сне́га не вы́просишь; *букв.* в рождество́ (когда́ мно́го сне́га) лопа́ты сне́га не даст (*об очень скупом человеке*); *~ суыклары* рожде́ственские моро́зы; *~ туды, барын да кырдан куды (барын да өйгә куды) посл.* рождество́ го́нит всех с по́ля, в рождество́ все иду́т к теплу́

рәва *предик. уст. разг.* **1.** непло́хо; годи́тся; *тәмәке трава, аны тартсаң ~* таба́к, в су́щности, трава́, но закури́ть непло́хо **2.** мо́жно, разреша́ется; ла́дно

рәван *прил. книжн.* **1.** прошéдший, ушéдший (в небытие́); *~ заманнар* (давно́) ушéдшие времена́ **2.** проходя́щий; быстроте́чный; *~ гомер* быстроте́чная жизнь □ *~ җан рел.* **1.** душа́ уме́ршего (*приходящая домой с просьбой помолиться за него*) **2.** при́зрак

рәвән *сущ. бот.* ревéнь; *~ орлыгы* семена́ ревеня́

рәвеш I *сущ.* **1.** внéшний вид; внéшний о́блик, обли́чье; фо́рма; *элеккеге ~ен саклау* сохрани́ть

пре́жнюю фо́рму, пре́жний вид; *чырайга эшлекле ~ бирү* прида́ть лицу́ делово́е выраже́ние 1) вид, о́браз, укла́д; *яшәү ~е* о́браз жи́зни 2) мане́ра; хара́ктер, тон; *эшне башкару ~е* хара́ктер веде́ния де́л; хара́ктер выполне́ния; *үз-үзен тоту ~* хара́ктер поведе́ния **2.** *в ф.* **рәвештә** 1) *в сочетании с прилагательными или причастиями на* **-ган** *образует наречные словосочетания:* **ашыгыч ~тә** спе́шно, неме́дленно; **көтелмәгән ~тә** неожи́данно; **шашынган ~тә** бе́шено 2) *в ряде случаев* о́бразом; в ... ви́де; **шул ~тә** таки́м о́бразом; **тәҗелле ~тә** спе́шным о́бразом; спе́шно; **күңелле ~тә** в весёлом настрое́нии с весёлым ви́дом **3.** *после сущ-го в знач. послелога* **рәвешендә** как, в ви́де, в о́блике, с ви́дом; *иллюстрация ~ендә китерелгән* приведённый как иллюстра́ция; *проект ~ендә эшләнгән тематик план* тематический план, соста́вленный в ви́де прое́кта; *шаяру ~ендә җавап бирү* отве́тить шу́ткой; отшути́ться □ **~ белән** *см.* **рәвеш** 2, **рәвештә**; *мыскыл иткән ~ белән* насме́шливо; *җитди ~ белән* серьёзно; **~(ен) үзгәртү** (вне́шне) преобразо́вывать/преобразова́ть; **~енә кертү (китерү)** превраща́ть (преврати́ть) *во что-л. кого-л.*

рәвеш II *сущ.* наре́чие || наре́чный; *урын ~ләре* наре́чия ме́ста; *~ ясалышы* образова́ние наре́чий; *~ тезмәләре* наре́чные (обстоя́тельственные) словосочета́ния □ **иярчен ~ җөмлә** обстоя́тельственное прида́точное предложе́ние; **~ хәле** обстоя́тельство о́браза де́йствия

рәвешендәге *прил. см.* **рәвешле**; *каурый ~ яфраклар* ли́стья, име́ющие фо́рму пе́рьев, ли́стья пе́ристой фо́рмы; *йөрәк ~ медальон* медальо́н в ви́де серде́чка

рәвеш-кыланыш *сущ. собир. разг.* поведе́ние, пова́дки; *рәвеш-кыланышлары белән атасына охшаган* пова́дками похо́ж на отца́ (напомина́ет отца́)

рәвеш-кыяфәт *сущ. разг. собир.* о́блик, обли́чье, вне́шний вид; *рәвеш-кыяфәте бик матур* о́бликом прекра́сен

рәвешле *прил.* **1.** име́ющий *какую-л.* фо́рму (о́браз, цвет), похо́жий на *что-л.*; *соры томан ~ сыек болытлар* жи́дкие облака́, похо́жие на се́рый тума́н 2) в ви́де *чего-л.*; *сәнәк ~ тамга* ли́чный знак (тамга́) в ви́де вил **2.** *в знач. послелога* как; подо́бный; *үзе ~ хатыннар (кешеләр) белән* вме́сте с таки́ми же же́нщинами (людьми́), как она́ сама́ **3.** *с мест.* **бу, шул, шушы, ни** образу́ет местоимённо-наре́чные словосочета́ния: так, таки́м о́бразом; *сүзне бу ~ башлау* разгово́р нача́ть так; *шушы ~ ачулану* так руга́ть; *ни ~* как, каки́м о́бразом; *үзен ни ~ тотарга белмәү* не знать, как себя́ вести́

рәвешләндерү *перех.* придава́ть/прида́ть вид; сформирова́ть

рәвешләнү *неперех. диал.* **1.** сформирова́ться, принима́ть/приня́ть надлежа́щий вид **2.** *см.* **рәешләнү 3.** принима́ть определённые очерта́ния

рәвешләш|ү *неперех. лингв.* адвербиализи́роваться || адвербализа́ция; *сыйфатларның ~уе* адвербализа́ция прилага́тельных

рәвешсез *прил.* **1.** 1) бесфо́рменный; *~ масса* бесфо́рменная ма́сса 2) несура́зный; *~ сорау* несура́зный вопро́с **2.** *разг.* несоразме́рный, безобра́зный; нескла́дный; *~ борын* безобра́зный нос; *~ гәүдә* нескла́дная фигу́ра

рәвештәге *прил. см.* **рәвешле** 1; *төрле ~* име́ющий ра́зные фо́рмы; *башка ~* друго́го ви́да, име́ющий другу́ю фо́рму, друго́й

рәвешчә *нареч.* таки́м о́бразом; *см. тж.* **рәвешле** 2; *шул ~* так, таки́м о́бразом (мане́ром); *син әйткән ~ эшләсәк* е́сли сде́лаем так, как ты сказа́л (таки́м о́бразом); *елдагы ~ чәчәрбез инде* се́ять бу́дем так, как се́яли ка́ждый год

рәгый *ист. прил.* по́дданный; верноподданный; *см. тж.* **табигъ** || *сущ.* по́дданный-немусульма́нин (*в мусульманских странах*); рая́, райя́

рәгыйять *сущ.* **1.** *книжн.* ма́сса по́дданных; все по́дданные государ́ства **2.** дисципли́на в государ́стве; *ил көче ~ белән, ~ гаделлек белән* (*посл.*) си́ла страны́ — в дисципли́не, дисципли́на достига́ется справедли́востью

рәд *сущ. уст. книжн.* **1.** отка́з; отверже́ние **2.** *юр.* реабилита́ция □ **рәд итү (кылу) 1.** отка́зывать/отказа́ть; отверга́ть/отве́ргнуть; не принима́ть, не приня́ть (*просьбу, предложение и т.п.*); *кыз аның тәкъдимен ~ кылды* де́вушка отве́ргла его́ предложе́ние **2.** отка́зываться/отказа́ться *от чего-л.*; *чәйне ~ кылу* отказа́ться от чае́пития

рәдде *уст. книжн. сущ.* **1)** проти́вное; *см. тж.* **киресе**; *~ раслау* утверждать проти́вное; *~сенә ышандыру* убеди́ть в проти́вном 2) *см.* **рәд**

рәддия *сущ. книжн.* **1.** опроверже́ние; *~ бирү* дать опроверже́ние **2.** крити́ческий о́черк

рәдиф *сущ. поэт.* реди́ф (*повторяющееся после каждой строфы слово в стихе*)

рәеш *сущ.* **1.** вы́ход в лю́ди; пра́здничная фо́рма (оде́жды); *~ күлмәге* пра́здничное (выходно́е) пла́тье **2.** *в ф.* **рәешкә** на вы́ход (вы́езд); выходно́й, выездно́й; *~кә кия торган күлмәк* выходно́е пла́тье **3.** отде́лка, доработка (*с це́лью прида́ния ви́да*)

рәешләнү *неперех.* принаряди́ться; приня́ть надлежа́щий вид

рәешле *прил.* **1.** пра́здничный, привлека́тельный, нарядный (*одежда*) **2.** ви́дный собо́й, представи́тельный (*преимущ. девушки*)

рәҗәп *сущ. уст.* раджа́б (*название седьмого месяца мусульманского лунного года*)

рәис *сущ.* **1.** глава́ (*делегации*); руководи́тель **2.** председа́тель || председа́тельский; *колхоз ~е* председа́тель колхо́за; *дәүләт ~е* глава́ государства; *~ вазифасы* председа́тельская до́лжность □ **~ булып эшләү** председа́тельствовать, рабо́тать председа́телем

рәисле|к *сущ.* ме́сто (пост, до́лжность) председа́теля; председа́тельство || председа́тельский; *~ккә сайлау* вы́брать председа́телем; *~ктән төшерү* освободи́ть от председа́тельства; *кемнең ~гендә* под председа́тельством кого́ □ **~к итү** председа́тельствовать; **~к итүче** председа́тельствующий

рәислегендәге *прил.* проходи́вший под председа́тельством *кого; Самат ~ җыелыш* собра́ние, проходи́вшее под председа́тельством Сама́та

рәйхан *сущ. бот.* базили́к || базили́ковый; *~ гөле* базили́к как декорати́вное расте́ние

рәкабәт *сущ. уст. книжн.* соревнова́ние, сопе́рничество, конкуре́нция; *~тә галиб булу* победи́ть в конкуре́нции, вы́йти победи́телем

рәкәгать *сущ. рел.* река́т (*часть намаза, совершаемого с тремя обязательными движениями: стоя, с поклонами, касаясь лбом пола*); *фарыз ~* обяза́тельный река́т

рәкугъ-сәждә *сущ. рел.* покло́н с моли́твой, моли́тва во вре́мя покло́на река́та, коленопреклоне́ния

рәкыйб *сущ. уст. книжн.* конкуре́нт; ~ *булу* быть конкуре́нтом (опе́рником)

рәмел *сущ. уст.* **1.** гада́ние (*обычно на мелких камешках*) **2.** *лит. в системе стихосложения аруз*: разме́р стиха́ — вид стопы □ ~ **кылу** гада́ть, предска́зывать бу́дущее и́ли узна́ть настоя́щее; ~ **тактасы 1.** *миф.* зе́ркало, в кото́ром ви́дно бу́дущее **2.** доска́, разграфлённая для гада́ний

рәнҗетел|ү *страд. от* **рәнҗетү**; быть кра́йне оби́женным || оскорбле́ние; оби́да; ~ү *тойгысы* чу́вство оскорбле́ния, оби́ды; *хаксызга* ~ү быть оби́женным незаслу́женно

рәнҗеткеч *прил.* оби́дный, обижа́ющий, оскорби́тельный

рәнҗеттер|ү *понуд. от* **рәнҗетү**; позволя́ть обижа́ть/оби́деть; дава́ть в оби́ду; *мин алардан ~мәм* я не позво́лю, что́бы меня́ оби́дели; я не дам себя́ в оби́ду

рәнҗет|ү *перех.* **1.** обижа́ть/оби́деть *кого-л.*; наноси́ть/нанести́ оби́ду *кому-л.*; оскорбля́ть/оскорби́ть, наноси́ть/нанести́ оскорбле́ние *кому* || нанесе́ние оби́ды, нанесе́ние оскорбле́ния; *авыр сүзләр әйтеп ~мә* не обижа́й оскорби́тельными слова́ми; *күңелне ~ү* ра́нить ду́шу **2.** *в знач. прил.* **рәнҗетерлек** оби́дный; оскорби́тельный; *~ерлек сүз* оби́дное (оскорби́тельное) сло́во; *күңел ~ерлек берни дә эшләмәдем* ничего́ я оскорби́тельного не сде́лал

рәнҗетүле *прил.* о́чень оскорби́тельный, осо́бо оби́дный; ~ *сүзләр сайлау* выбира́ть осо́бо ядови́тые слова́

рәнҗетүсез *нареч.* не обижа́я, не причиня́я оби́ды, оскорбле́ния *кому*; без оскорбле́ний || *прил.* необи́дный, безоби́дный

рәнҗетүче *сущ.* оби́дчик, оби́дчица; обижа́ющий; *~гә җәза бирү* наказа́ть оби́дчика (обижа́ющего)

рәнҗеш *сущ.* **1.** оби́да, недово́льство; упрёк, уко́р; *һәрвакыт үпкә, ~ кенә ишетү* слы́шать всё вре́мя оби́ду да упрёки **2.** огорче́ние, боль, душе́вная тра́ма; *ата-ана ~еннән куркам* бою́сь причини́ть боль роди́телям; күңел ~е душе́вная боль **3.** бесслове́сное прокля́тие □ ~ **белдерү (күрсәтү)** упрека́ть/упрекну́ть *кого-л.*; бро́сить упрёк *кому-л.*; выража́ть укори́зну, недово́льство *за что-л.*; ~ **төшү** *см.* **каргыш төшү**

рәнҗешле *прил.* оби́женный; с уко́ром, укори́зненный; ~ *караш белән* (с) оби́женным (укори́зненным) взгля́дом

рәнҗешү *взаимно-совм. от* **рәнҗү**; обижа́ться (оби́деться) друг на дру́га || взаи́мная оби́да; *күршеләрдәге үзара* ~ взаи́мная оби́да сосе́дей

рәнҗү *неперех.* **1.** си́льно обижа́ть; разоби́деться; оскорбля́ться/оскорби́ться || си́льная оби́да; душе́вная боль; *күңел ~ге* душе́вная оби́да (боль); *~еп калмагыз (китмәгез) инде* не взыщи́те, не обижа́йтесь, не обессу́дьте (*говорят, когда расстаются с гостями*) **2.** *разг.* боле́ть, страда́ть *какой-л.* боле́знью || *сущ. диал.* боле́знь || *прил.* больно́й; ~ү *кеше* больно́й челове́к

рәнҗүле *прил.* **1.** оби́женный; оби́девшийся; выража́ющий чу́вство оби́ды; ~ *караш* оби́женный взгляд **2.** *разг.* больно́й; боле́зненный; ~ *кеше кебек* как больно́й; как челове́к, страда́ющий како́й-то боле́знью; ~ *чырай* оби́женное лицо́, ки́слая физионо́мия

рәң *сущ. диал.* **1.** цвет, расцве́тка; тон; *рәңе матур* расцве́тка краси́ва **2.** цвет лица́; *рәңе киткән* на нём нет лица́; *ср.* **төсе киткән**

рәсем *сущ.* **1.** 1) рису́нок || рису́ночный; *тушь белән ясалган ~* рису́нок ту́шью; *балалар ясаган ~нәр* де́тские рису́нки; ~ *остасы* ма́стер рису́нка; *кеше ~е* портре́т; ~ *сырасы* карти́нная галере́я 2) рисова́ние; жи́вопись || рисова́льный, живопи́сный; ~ *дәфтәре (альбомы)* тетра́дь (альбо́м) для рисова́ния; *~гә өйрәнү* учи́ться рисова́ть, мастерству́ рисова́ния **2.** *уст.* пра́вило, о́браз, обы́чай; официа́льный церемониа́л; профо́рма; *~е шундый* такова́ профо́рма (э́того де́ла) **3.** фотоснимок, сни́мок, фо́то (*разг.*); фотока́рточка, ка́рточка (*разг.*); *безгә улының ~ен күрсәтте* показа́л нам фотока́рточку сы́на; *~не фиксажлау фото.* закрепи́ть рису́нок ◊ ~ **алдыру, ~гә төшү** фотографи́роваться, сфотографи́роваться; ~ **белән бизәү (стеналарны)** разрисо́вывать/разрисова́ть, распи́сывать/расписа́ть (сте́ны); ~ *белән бизәлгән* разрисо́ванный, расписно́й, укра́шенный рису́нками; ~ **төшерү (ясау)** рисова́ть, нарисова́ть

рәсемдәге *прил.* **1.** то, что на рису́нке, карти́нке; изображённое на приведённом рису́нке **2.** *уст.* при́нятый; ~ *тәртип* при́нятый поря́док ◊ ~ **кебек** как карти́нка (*красивая — о девушке*)

рәсемлә|ү *перех.* украша́ть/укра́сить рису́нками; иллюстри́ровать; *журналны ~п чыгара башладылар* журна́л на́чали выпуска́ть с иллюстра́циями

рәсемле *прил.* **1.** иллюстри́рованный, снабжённый рису́нками, иллюстра́циями; ~ *журнал* иллюстри́рованный журна́л; ~ *китап* кни́га с рису́нками (с иллюстра́циями), кни́га с худо́жественным оформле́нием **2.** разрисо́ванный; расписно́й; ~ *тәрәзә капкачлары* расписны́е ста́вни; *хәзер стеналарны ~ ясый башладылар* ста́ли сте́ны де́лать расписны́ми **3.** рису́нчатый; с рису́нками, с узо́рами; ~ *клеёнка* рису́нчатая клеёнка

рәсемче *сущ.* рисова́льщик; худо́жник-портрети́ст; *см. тж.* **рәссам**; *һәвәскәр ~* худо́жник-люби́тель, рисова́льщик; *~лар группасы* гру́ппа рисова́льщиков

рәсемчелек *сущ.* жи́вопись, изобрази́тельное иску́сство

рәсмән *нареч.* официа́льно, форма́льно; ~ *ул минем җитәкчем* форма́льно он мой руководи́тель

рәсме-хат *сущ. уст.* чистописа́ние (*в школе*)

рәсми *прил.* **1.** официа́льный; ~ *вәкил* официа́льный представи́тель; ~ *документ* официа́льный докуме́нт; ~ *аңлатма* официа́льное разъясне́ние **2.** 1) декларати́вный, официа́льный; церемониа́льный; ~ *белдерү* официа́льное (декларати́вное) заявле́ние; ~ *кабул итү* церемониа́льный (торже́ственный) приём; ~ *очрашу* официа́льная встре́ча (церемониа́льная встре́ча) 2) официа́льный, форма́льный; свойственный при́нятому обы́чаю; ~ *тел* официа́льный язы́к, язы́к (стиль) деловы́х бумаг; ~ *терминология* официа́льная термино́логия, термино́логия (сти́ля) деловы́х бума́г 2) неи́скренний; прояв́ленный то́лько вне́шне; ~ *елмаю* нейскренняя, официа́льная улы́бка **3.** *редко* лега́льный □ ~ **булмаган** неофициа́льный; ~ **рәвештә 1.** официа́льно **2.** лега́льно; *ярым ~ рәвештә* полуофициа́льно; ~ **юл белән** официа́льным путём; официа́льно ◊ ~ **кылану** *разг. неодобр.* официа́льность

рәсмиләштер|ү *перех.* **1.** узако́нивать/узако́нить; утвержда́ть/утверди́ть; придава́ть/прида́ть официа́льную фо́рму, хара́ктер; оформля́ть/офо́рмить, регистри́ровать, зарегистри́ровать || узаконе́ние, утвержде́ние; оформле́ние, регистра́ция; *улының варислык хокукын ~ү* утверди́ть (узако́нить) сы́на в права́х насле́дства; *никахны ~ү* зарегистри́ровать (офо́рмить) брак **2.** придава́ть/прида́ть официа́льный хара́ктер; *мөнәсәбәтләрне ~ү*

прида́ть отноше́ниям официа́льный хара́ктер **3.** легализи́ровать, легализова́ть || легализа́ция; *газетаны ~у* легализова́ть газе́ту; *~у мәсьәләсе* вопро́с легализа́ции

рәсмиләш|ү *неперех.* **1.** узако́ниваться/узако́ниться; оформля́ться/офо́рмиться; быть узако́ненным, установленным; принима́ть/приня́ть официа́льную фо́рму, зако́нную си́лу || приня́тие официа́льной фо́рмы (зако́нной си́лы); *~кән кагыйдә* узако́ненное пра́вило **2.** принима́ть/приня́ть официа́льный тон (хара́ктер) || официа́льное отноше́ние; *сөйләшүләренә хәтле ~кән* да́же речь его́ ста́ла носи́ть официа́льный хара́ктер; да́же разгова́ривает официа́льным то́ном **3.** легализи́роваться/легализова́ться; переходи́ть/перейти́ на лега́льное положе́ние (*о печати, партии и т. п.*)

рәсмиле|к *сущ.* **1.** официа́льность, официа́льный тон (обраще́ние); форма́льность; *белдерунең ~ге* официа́льность сообще́ния; *мөнәсәбәтендәге ~к* форма́льность в его́ отноше́ниях; *~кне саклау* соблюда́ть официа́льность, официа́льный тон **2.** лега́льность; *газетаның ~генә ирешү* доби́ться лега́льности газе́ты

рәсмият *сущ. уст. книжн.* **1.** *см.* **рәсмилек**; *~ вә җитдият белән* с официа́льностью и серьёзностью; официа́льно и серьёзно **2.** *в. ф.* **рәсмияттә** *см.* **рәсмән**

рәсмиятсез *уст. книжн.* без форма́льностей, не соблюда́я форма́льностей; неофициа́льно; за́просто (*разг.*); *бернинди ~, дусларча гына җавап кайтарды* отве́тил за́просто, по-това́рищески

рәссам *сущ.* худо́жник, худо́жница, живопи́сец; *талантлы ~ ясаган картина* карти́на, напи́санная тала́нтливым худо́жником; *~ иҗаты* тво́рчество худо́жника; *профессионал ~* худо́жник-профессиона́л, профессиона́льный худо́жник; *үзешчән ~* самодея́тельный худо́жник; худо́жник-люби́тель

рәссамлык *сущ.* заня́тие (профе́ссия) худо́жника, живопи́сца || худо́жнический; *~ка уку* учи́ться на худо́жника; *~ сәләте* худо́жнические спосо́бности; *~ иҗаты* худо́жническая де́ятельность

рәсүл *сущ. рел.* посла́нник Бо́га, проро́к; *~ебез Мөхәммәт* проро́к Мухаммед

рәт I *сущ.* **1.** 1) *в разн. знач.* ряд; *йортлар рәте* ряд домо́в; *ике рәт (булып)* в два ряда́; *партерның соңгы рәте* после́дний ряд парте́ра; *рәт араларында йөрү* прохаживаться ме́жду рядами́; *ике рәт булып тезелү* стро́иться в два ряда́, в две шере́нги; *сәүдә рәтләре* торго́вые ряды́, ряд магази́нов (ла́вок) 2) *мат., хим.* ряд; *так саннар рәте* ряд нечётных чи́сел; *геометрик рәт* геометри́ческий ряд; *радиоактив рәт хим.* радиоакти́вный ряд 3) *с.-х.* ряд, ряда́; *буразналар рәте* ряд боро́зд; *агачларны ике рәт итеп утырту* сажа́ть дере́вья в два ряда́; *аркылы рәтләр* попере́чные рядки́ **2.** *перен.* 1) поря́док, лад; *рәте белән генә сөйләү* расска́зывать по поря́дку; *һәр эшнең үз җае, үз рәте бар* (*посл.*) ка́ждое де́ло тре́бует определённого подхо́да и поря́дка; ка́ждому де́лу свой лад; *сүз рәтен белми* не уме́ет разгова́ривать, не име́ет подхо́да 2) *перен.* толк; по́льза; *аңардан рәт юк* от него́ то́лку нет (то́лку ма́ло); *анда барудан рәт булырмы соң?* вы́йдет ли толк от э́той пое́здки (от э́того посеще́ния)? **3.** *перен. разг.* о́чередь, черёд; очерёдность; ряд, после́довательность, поря́док; *зурларга да көрәшергә рәт җитте* подошла́ о́чередь соревнова́ться в борьбе́ и взро́слым; *үләттән калсаң да рәттән калма* (*посл.*) мо́жешь быть и нездоро́вым (то́лько что переже́вшим моровóе пове́трие), но свою́ о́чередь не пропуска́й; *һәрнәрсәнең үз вакыты, үз рәте бар* всему́ свой срок, своя́ о́чередь **4.** 1) *перен. разг.* возмо́жности; сре́дства, доста́ток, бога́тство; *кесә ягы ничек, рәт бармы?* как насчёт карма́на, есть ли возмо́жности? *пальто алырлык та рәтең юкмы?* у тебя́ что, и на пальто́ нет де́нег (сре́дств)? 2) *при отрицательных словах* **юк, бу́лмау, бетү, ка́лмау** *обозначает отсутствие или недостаточность сил, здоровья, качества, богатства и т. п., переводится разными словами*; *былгы җәйнең рәте юк (булмады)* ны́нешнее ле́то нева́жное; в э́том году́ ле́то бы́ло неуда́чное; *быел бәрәңге уңышының рәте булмады* в э́том году́ карто́фель не уроди́лся; *яңгырларның рәте юк әле* нева́жно (пло́хо) с дожде́м (иду́т неравноме́рно и́ли вообще́ не иду́т); *картның рәте беткән (юк)* пло́хи дела́ у старика́; стари́к сдал; *рәте беткәнче эшләде* рабо́тал, пока́ мог □ **рәт авыруы (хастасы)** *уст.* пова́льная боле́знь, эпиде́мия; **рәт аралары (рәтләр арасы) 1.** междуря́дье **2.** междуря́дный; **рәт белән чәчү** рядово́й посе́в; **рәт билгеләгеч** *спец.* поря́дковка ◊ **рәт чыгу 1.** быть уда́че, уда́ться; доставáться/доста́ться; приобрета́ться/приобрести́сь **2.** получа́ться/получи́ться (хоро́шим); **рәт чыкмас** ничего́ пу́тного (хоро́шего) не вы́йдет; не бу́дет то́лка; **рәте китү** ухудша́ться/уху́дшиться, разла́диться, расстро́иться (*о делах, жизни*); быть в плохо́м состоя́нии; **рәте чуалу** пу́таться, запу́тываться/запу́таться; ошиба́ться, сбива́ться; **рәтен белеп** уме́ло; **рәтен белү** быть толко́вым, сообрази́тельным; *машинаның рәтен белү* знать маши́ну, разбира́ться в маши́не, уме́ть рабо́тать на маши́не; **рәтен җибәрү (китәрү, бозу)** приводи́ть/привести́ в беспоря́док, в него́дность; расстра́ивать/расстро́ить *что-л.*; разла́дить *разг.*; испо́ртить; *машинаның рәтен китәрү* испо́ртить маши́ну; **рәтен табу** найти́ вы́ход (*из трудного положения*); найти́ спо́соб (*что-л. делать*); умудри́ться, изловчи́ться, ухитри́ться; **рәтенә басу** станови́ться/стать *кем*; **рәтенә керту** причисля́ть к ..., присоедини́ть к ..., включа́ть/включи́ть в ряды́, в число́ *кого-л.*; *язучыны классиклар рәтенә кертү* причисля́ть писа́теля к кла́ссикам; **рәтенә китерү** *см.* **рәткә кертү (китерү)**; **рәтенә төшү** сообрази́ть, смекну́ть, догада́ться; разобра́ться; **рәтендә йөрү 1.** счита́ться (*каким или кем*); *яхшылар рәтендә йөрү* чи́слиться в хоро́ших; счита́ться хоро́шим **2.** ходи́ть, име́ть хожде́ние среди́ (*в рядах, в числе*); *алдынгылар рәтендә йөрү* ходи́ть в числе́ передовико́в; **рәткә керту (китерү) 1.** приводи́ть/привести́ в поря́док; разобра́ть (*книги, бумаги, рукописи*) **2.** упоря́дочить, регули́ровать, урегули́ровать, нала́дить (*работу транспорта, движение поездов и т. п.*) **3.** нала́дить, испра́вить, восстанови́ть (*что-л. испорченное, разбитое*) **4.** привести́ себя́ (*свой внешний вид*) в поря́док, прихора́шиваться **5.** нала́живать/нала́дить жизнь, обеспе́чить себя́ необходи́мым (*приобрести себе одежду, обувь и т.п.*); **рәткә керү (килү) 1.** прийти́ в поря́док; нала́диться **2.** упоря́дочиться, ула́диться, нормализова́ться; пойти́ на лад (*работа, движение транспорта, семейная жизнь и т. п.*) **3.** *разг.* поправля́ться/попра́виться (*после болезни*) **4.** зажи́ть в дово́льстве; нача́ть жить как сле́дует (*по-человечески*); **рәткә салу 1.** приводи́ть/привести́ в поря́док; поправля́ть/попра́вить; нала́дить **2.** упоря́дочить, урегули́ровать, нала́дить, ула́дить, напра́вить (*жизнь, работу*)

рәт II *нареч. разг.* раз; -крат(но); *см. тж.* **кабат, кат, тапкыр**; одна́жды; *бер рәт* 1) оди́н раз 2) одна́жды,

как-то; *тагын бер рәт эшләп кара* попро́буй ещё (оди́н) раз; *бер рәт шулай булган иде инде* одна́жды так уже́ бы́ло; *бернич рәт* не́сколько раз; неоднокра́тно; *соңгы рәт килүендә* в после́дний прие́зд

рәткә *нареч. диал. см.* **рәттән** 3—7; *биш ел ~ отлично гына укып килде* пять лет подря́д учи́лся то́лько на отли́чно

рәтлән|ү *неперех.* **1.** прийти́ в поря́док, в норма́льное состоя́ние; нормализова́ться; *йөрәк тибеше ~де* сердцебие́ние нормализова́лось (стабилизи́ровалось) **2.** нала́живаться/нала́диться, идти́ на лад, ула́живаться/ула́диться *прост.*, упоря́дочиваться/упоря́дочиться; утряса́ться/утрясти́сь *прост.* || упоря́дочение (*организации труда*); *~ә бару* идти́ на лад; *эшләр ~де* дела́ нала́дились; *вакыты белән бар да ~ер* со вре́менем всё утрясётся (ула́дится) **3.** устана́вливаться/установи́ться || установле́ние; *һавалар (һава шартлары) ~де* пого́да установи́лась **4.** улучша́ться/улу́чшиться || улучше́ние; *тормышлар ~үгә бара* жизнь идёт к улучше́нию; жизнь улучша́ется **5.** приводи́ть/привести́ себя́ (свой вне́шний вид) в поря́док; *көзге каршында ~ү* пе́ред зе́ркалом привести́ себя́ в поря́док **6.** поправля́ться/попра́виться || попра́вка, поправле́ние, выздора́вливать/вы́здороветь || выздоровле́ние; *хәле дә ~еп килә* выздора́вливает, идёт на попра́вку; *озак авырудан соң ~ә башлау* по́сле до́лгой боле́зни нача́ть поправля́ться

рәтләп *нареч.* **1.** ряда́ми; в ряд; *~ тезү* установи́ть в ряд; постро́ить ряда́ми **2.** по поря́дку; *~ кенә сөйлә әле* расскажи́-ка по поря́дку; говори́ то́лком **3.** то́лком; как сле́дует, хорошо́нько; путём (*разг.*); *~ берни дә эшли алмый* то́лком ничего́ не уме́ет де́лать; *~ ашамаган да әле* то́лком ещё и не пое́л; *соңгы сүзләрен ~ ишетмәдем дә* после́дних слов и не расслы́шал как сле́дует

рәтләтү *понуд. от* **рәтләү**; заставля́ть приводи́ть в поря́док

рәтләштер|ү *многокр. от* **рәтләү** **1.** ко́е-как (и́ли немно́жко) наводи́ть/навести́ поря́док; ко́е-ка́к нала́дить, испра́вить *что-л.*; *бүлмәне ~еп куй* приведи́ ко́мнату немно́го в поря́док; *чәчләрне ~ү* слегка́ попра́вить во́лосы **2.** попра́вить, улучша́ть/улу́чшить, нала́живать/нала́дить (*материальное положение*); *хуҗалыкны ~ү* немно́жко попра́вить хозя́йство

рәтл|әү *перех.* **1.** приводи́ть/привести́ в поря́док; разобра́ть/разбира́ть; *эш кәгазьләрен ~әү* привести́ в поря́док деловы́е бума́ги **2.** прибира́ть/прибра́ть, убира́ть/убра́ть; наводи́ть/навести́ поря́док; *өстәл өстен ~әү* прибра́ть (навести́ поря́док) на столе́ **3.** поправля́ть/попра́вить, оправля́ть/опра́вить; *көзге каршында өсбашын ~әү* пе́ред зе́ркалом попра́вить оде́жду **4.** поправля́ть/попра́вить, починя́ть/почини́ть, исправля́ть/испра́вить, обла́дить *прост. обл.*; *чәкәнә ~әп кую* пригото́вить са́ни; *электр приборларын ~әп бирү* почини́ть электроприбо́ры *кому-л.* **5.** регули́ровать, отрегули́ровать, настра́ивать/настро́ить, нала́живать/нала́дить || регули́рование, нала́живание; *телевизорның тавышын ~әү* регули́ровать звук телеви́зора **6.** нала́живать/нала́дить, устра́ивать/устро́ить, ула́живать/ула́дить, упоря́дочивать/упоря́дочить (*жизнь, дела, какую-н. работу*); *тормышны ~әми торып өйләнмиләр* не же́нятся, пока́ не нала́дят жизнь; *һәркем үз дөньясын үзенчә ~и* ка́ждый по-сво́ему устра́ивает свою́ жизнь **7.** справля́ть/спра́вить (*одежду*) **8.** *разг.* устра́ивать/устро́ить, доставля́ть/доста́ть, предоставля́ть/предоста́вить *кому-л. что-л.*; *см. тж.* **әмәлләү**; *бер билет ~ә әле* устро́й мне оди́н биле́т; *путевканы үзем ~әрмен* доста́ну путёвку сам **9.** *разг.* гото́вить, пригото́вить, доставля́ть/доста́ть, приобрести́ *что-л.* (*с трудом или кое-как*), ухитря́ться/ухитри́ться *что-л.* де́лать; *акчаның җитмәгәнен дә ~әдек* недостающие де́ньги то́же доста́ли; *ашарга ~әү* собра́ть на стол, доставля́ть еду́ □ **~әп карау** про́бовать нала́дить, устро́ить, попра́вить *что-л.*; **~әп кую** нала́дить *что-л.*; **~әп тору** поправля́ть, оправля́ть *что-л.* (*постоянно*)

рәтле *прил.* **1.** име́ющий ряды́; -ря́дный; *киң ~* широкоря́дный; *тар ~ чәчкеч с.-х.* узкоря́дная се́ялка; *күп ~ арпа с.-х.* многоря́дный ячме́нь; *бер ~ агрегат с.-х.* шере́нговый агрега́т **2.** поря́дочный; пу́тный, путёвый; *~ адәм баласы* сын поря́дочного челове́ка (*порядочных людей*); *~ кеше булу* быть поря́дочным челове́ком; *~ генә күренү* каза́ться дово́льно-таки поря́дочным, пу́тным; *аңадан ~ эш чыкмас* из него́ ничего́ пу́тного не вы́йдет (не полу́чится) **3.** толко́вый, пу́тный, де́льный, путёвый, у́мный; *~ сүз* у́мное (толко́вое) сло́во; *~ фикер ишетмәдем* не слы́шал у́мной мы́сли (иде́и) **4.** *разг.* норма́льный, удовлетвори́тельный, хоро́ший; *~ тормыш күрмәү* не ви́деть норма́льной (хоро́шей) жи́зни; *~ киемәү* не носи́ть хоро́шей оде́жды; *җәй үзып бара, ~ көннәр булмады* ле́то уже на исхо́де, а норма́льных (тёплых) дней не́ было **5.** *разг.* го́дный, подходя́щий, сто́ящий (*о товаре, о вещах*); *кибетләрендә ~ әйбере дә юк бит әле* в магази́нах нет же и подходя́щего това́ра **6.** *разг.* име́ющий ресу́рсы; де́нежный, бога́тый; *~рәк ирләрне үзенә карату* очаро́вывать, завлека́ть де́нежных мужчи́н **7.** *в знач. сказ.* в поря́дке; норма́льный, хоро́ший; *документларың ~ме?* докуме́нты в поря́дке? *юллар хәзер ~* доро́ги сейча́с хоро́шие (в поря́дке) □ **~дән түгел** нева́жное || *нареч.* **1.** поря́дочно, пу́тно; *үзеңне ~ тоту* вести́ себя́ поря́дочно **2.** толко́во, умно́; пу́тно; *~ сөйли* говори́т толко́во **3.** норма́льно, удовлетвори́тельно, хорошо́; *~ яшәү* жить хорошо́; *~ йоклап булмады* не удало́сь норма́льно поспа́ть (вы́спаться)

рәтле-башлы *прил.* ско́ль-нибудь прили́чный *см. тж.* **рәтле** (*знач.* 2—4); *рәтле-башлы кеше* поря́дочный челове́к; *рәтле-башлы эш тапмау* не найти́ прили́чную рабо́ту; *рәтле-башлы юллары да юк әле аның* нет же и норма́льной доро́ги; *рәтле-башлы эшли алмадым* не мог рабо́тать как сле́дует || *нареч.* прили́чно; *рәтле-башлы яши башлагач* когда́ ста́ли жить прили́чно (хорошо́, по-челове́чески)

рәтлелек *сущ.* **1.** поря́дочность; *егетнең ~ге* поря́дочность па́рня **2.** толко́вость; толк; *сүзенең ~ге* толко́вость сло́ва (суждения или разгово́ра)

рәт-рәт *нареч.* ряда́ми; *рәт-рәт (булып) тезелү* выстра́иваться ряда́ми; *рәт-рәт тезелгән колонналар* стоя́щие ряда́ми коло́нны

рәтсез *прил.* **1.** беспоря́дочный, неупоря́доченный; безала́берный; неустро́енный, бессисте́мный; *~ хуҗалык* беспоря́дочное хозя́йство; *~ тормыш* неустро́енная жизнь; *~нең эше дә ~* у бестолко́вого и рабо́та бестолко́вая **2.** бестолко́вый; нела́дный, непутёвый (*о человеке*); *~ егет булып чыкты ул* он оказа́лся бестолко́вым па́рнем **3.** него́дный, неприме́нимый, непригодный, неиспра́вный; *~ машиналар гына калды* оста́лись то́лько неиспра́вные маши́ны; *атың ~ булса, эшеңнең дә рәте юк* е́сли ло́шадь него́дная, то и де́ло не ла́дится

рәтсезлән|ү *неперех.* **1.** ухудша́ться/уху́дшиться (*о хозяйстве, здоровье*); по́ртиться, испо́ртиться, стать

него́дным (*о маши́не*); разла́диться, расстро́иться (*о делах, жизни*); *баланың укуы ~еп китте әле* да вот учёба ребёнка ухуди́лась (ста́ла ху́же); *~гән хуҗалыкны аякка бастырырга кирәк иде* на́до бы́ло восстанови́ть расстро́енное хозя́йство **2.** становиться/стать бестолко́вым, непутёвым; вести́ себя́ пло́хо, непоря́дочно □ **~еп йөрү** вести́ себя́ ду́рно, совершать дурны́е посту́пки

рәтсезлек *сущ.* **1.** беспоря́дочность, неупоря́доченность, неустро́енность (*хозяйства, дела*); безала́берность (*в работе, в изложении мысли*), бессисте́мность; *тормышның ~ге* неустро́енность жи́зни; *мондый ~к белән* с тако́й безала́берностью **2.** бестолко́вость; *~ге күренеп тора* бестолко́вость его́ очеви́дна

рәттән *нареч.* **1.** ря́дом, о́коло, во́зле *чего́, кого-л.*; *бу өй белән ~ шундый ук тагы бер өй бар иде* ря́дом с э́тим до́мом был то́чно тако́й же; *сарай белән ~ мунча* о́коло сара́я ба́ня; ря́дом с сара́ем ба́ня **2.** ря́дом; рядко́м; в одно́м ряду́ (строю́); *~ тору* стоя́ть ря́дом, стоя́ть рядко́м **3.** подря́д; оди́н за други́м (без переры́ва); *ике көн ~ буран котырды* два дня подря́д бушева́л бура́н; *~ ун сәгать йоклаганмын* проспа́л де́сять часо́в подря́д; *~ ике отыш* два вы́игрыша подря́д **4.** по поря́дку; *бөтенесен ~ сөйләп бирде* всё изложи́л по поря́дку; *~ санау* счита́ть по поря́дку **5.** наряду́, наравне́; *башкалар белән ~* нарядý с други́ми; *хатыннар да ирләр белән ~ эшлиләр* и же́нщины рабо́тают наравне́ с мужчи́нами **6.** попу́тно, заодно́; *~ китапханәгә дә керергә кирәк* заодно́ ну́жно зайти́ в библиоте́ку **7.** подря́д, всё подря́д (без разбо́ра); *~ ашап бетерә бара* съеда́ет всё подря́д; *барысын ~ укый* чита́ет всё подря́д; *барыбызны да ~ сүгеп ташлады* он отруга́л всех подря́д

рәт-чират *сущ.* како́й-то поря́док; подо́бие поря́дка □ **рәт-чират юк (калмау, китү, бетү) 1.** нет (не оста́лось) никако́го поря́дка **2.** оста́ться без ничего́; не име́ть ничего́ (*о денежных или пищевых ресурсах*); *кесәдә рәт-чират юк* в карма́нах нет ничего́ **3.** оста́ться ли́шним, не име́ть к себе́ хоро́шего отноше́ния; *монда да безгә рәт-чират юк (беткән, калмаган)* и здесь мы ли́шние; нам и здесь не́чего де́лать; **рәт-чираты булмау 1.** не име́ть никако́го поря́дка, быть в по́лном беспоря́дке **2.** ни скла́ду, ни ла́ду; нет ла́ду; не ла́диться; *тормышларының (яшәүләренең) рәт-чираты юк әле* их семе́йная жизнь не ла́дится **3.** нет никако́го то́лка; бестолко́вость; бестолко́во, пло́хо; *рәт-чираты юк эшенең* от его́ рабо́ты то́лка нет; *укуының рәт-чираты юк* у́чится пло́хо; **рәт-чиратын белмәү** не разбира́ться, не понима́ть; не смы́слить; ничего́ не сообража́ть; *машинаның рәт-чиратын белми ул* он в маши́нах совсе́м не разбира́ется; **рәт-чиратын таба алмау (тапмау)** (*в положит. ф. почти не употребляется*) не разобра́ться, не догада́ться, не сообрази́ть

рәт-юнь *сущ. собир. см. тж.* **рәт-чират** толк □ **рәте-юне булмау (юк) 1.** быть бестолко́вым (*о человеке*) **2.** *см.* **рәте-чираты булмау (юк)**

рәхәт *сущ.* **1.** блаже́нство, наслажде́ние, удово́льствие; не́га; прия́тность *разг.*; отра́да, усла́да *уст.*; *үз ~е турында гына кайгырту* забо́титься то́лько о своём удово́льствии; *~ен яраткач, михнәтен дә ярат* (*погов.*) лю́бишь удово́льствие, люби́ и хло́поты (труды́); лю́бишь ката́ться, люби́ и са́ночки вози́ть; *михнәтсез ~ юк* (*погов.*) без трудá (муче́ния) нет и отра́ды; *яшәү ~е* удово́льствие (сча́стье) жить **2.** бла́го; *тормыш ~ләре* бла́га жи́зни **3.** *уст.* споко́йствие, поко́й, безмяте́жность; *кичке ~* вече́рний поко́й; *иртә туды — михнәт туды, кич туды — ~ туды* (*посл.*) у́тро прино́сит хло́поты (труд), а ве́чер — поко́й (споко́йствие) || *прил.* **1.** благода́тный, прия́тный, счастли́вый, блаже́нный, благослове́нный; *~ кич* благода́тный ве́чер; *~ гаилә тормышы* счастли́вая семе́йная жизнь **2.** споко́йный, безмяте́жный; *~ йокы күрмәү* не ви́деть споко́йного сна; *~ көннәр көтү* ожида́ть безмяте́жных дней || *нареч.* **1.** споко́йно, безмяте́жно, сча́стливо; *~ йоклау* споко́йно (безмяте́жно) спать; *~ (итеп) елмаю* сча́стливо улыба́ться **2.** *в знач. сказ.* благода́ть, блаже́нство; хорошо́; чуде́сно; *монда нинди ~!* кака́я тут благода́ть; *кичләрен бигрәк ~* вечера́ми осо́бенно хорошо́; *монда сулыш алулары да ~* здесь и ды́шится хорошо́ □ **~ күрсәтмәү** не дать споко́йно жить, не дать жи́зни; меша́ть жить; **~ күрү** благоде́нствовать; блаже́нствовать, хорошо́ жить; **~ табу** наслажда́ться, получа́ть удово́льствие (наслажде́ние); **~ тормыш 1.** безмяте́жная (споко́йная) жизнь **2.** благоде́нствие; сча́стье; **~ чигү (сөрү)** *см.* **рәхәт яшәү (тору); ~ яшәү (тору) 1.** жить споко́йной и счастли́вой жи́знью **2.** благоде́нствовать; блаже́нствовать, наслажда́ться; **~ен күрү** досто́йно воспо́льзоваться *чем-л.*; **~кә бирелү** предава́ться/преда́ться удово́льствиям, наслажде́ниям; **~кә чуму** *поэт.* блаже́нствовать, наслажда́ться; **~кә чыгу** уви́деть сча́стье, нача́ть хорошо́ жить; почу́вствовать себя́ счастли́вым; **~тә йөзү** *см.* **рәхәткә чуму; ~тә тору** *см.* **рәхәт яшәү (тору)**

рәхәтләндер|ү *перех.* **1.** наслажда́ть/наслади́ть *книжн.*; доставля́ть/доста́вить наслажде́ние, удово́льствие; *җырын белән (күңелләрне) ~әсең* свое́й пе́сней доставля́ешь удово́льствие (наслажде́ние); *~еп җибәрү* доста́вить удово́льствие (наслажде́ние) **2.** дава́ть/дать о́тдых и поко́й; *яшеллек күзләрне ~* зелёный цвет даёт глаза́м о́тдых и поко́й **3.** ра́довать, обра́довать *чем-л.*; *балкорты, ичмасам, балы белән ~ә* пчела́, по кра́йней ме́ре, ра́дует мёдом; *эшләп ~ү* рабо́тать как сле́дует, ра́довать свое́й рабо́той

рәхәтлән|ү *неперех.* **1.** наслажда́ться/наслади́ться (*жизнью*), испы́тывать/испыта́ть наслажде́ние, удово́льствие; блаже́нствовать; получа́ть/получи́ть удово́льствие || наслажде́ние, блаже́нство; *музыка тыңлап ~ү* наслажда́ться му́зыкой; *ашагыз, аша, ~егез* ку́шайте, ку́шайте наслажда́йтесь **2.** по́льзоваться, получа́ть по́льзу от *чего-л.*; по́льзоваться результа́тами *чего-л.*; *см. тж.* **рәхәтен күрү 3.** *после деепричастия на* **-п** де́лать, сде́лать *что-л.* для со́бственного удово́льствия вдово́ль, вво́лю; *эшләп ~ү* рабо́тать вво́лю; пораба́тать всласть **4.** *в. ф.* **рәхәтләнеп 1)** с удово́льствием, с наслажде́нием; *~еп карау* с удово́льствием смотре́ть; *~еп йоклау* с наслажде́нием спать; *эшләп акча тап, ~еп ял итеп ят* (*посл.*) трудо́м зараба́тывай де́ньги да с удово́льствием отдыха́й 2) охо́тно, с охо́той, с удово́льствием, с жела́нием; *~еп ярдәм итәрмен* с удово́льствием помогу́; *~еп риза булу* охо́тно согласи́ться □ **~еп китү (калу) 1.** отдыша́ться (*после боли, гнёта и т. п.*) **2.** успоко́иться

рәхәтлек *сущ.* **1.** блаже́нство, наслажде́ние; удово́льствие; бла́го; *см. тж.* **рәхәт 1**; *яшәү ~ге* блаже́нство жить; *~кләр көтү* ждать благ; ждать удово́льствий; *~ хисе* чу́вство удово́льствия **2.** прия́тность; *җылы өйдә кышкы кичнең ~ге* прия́тность зи́мних вечеро́в в тёплом до́ме **3.** поко́й, споко́йствие; *күңел ~ге* душе́вный поко́й □ **~к бирү** *см.* **рәхәтләндерү 1**; **~к табу (кичерү)** *см.* **рәхәт табу**

рәхәт-локым *сущ. кул.* раха́т-луку́м (вид сла́дости)

рәхим *сущ. редко* милосе́рдие, ми́лость, сострада́ние; жа́лость; *синдә бер дә ~ юк икән* нет у тебя́, ока́зывается, никако́й жа́лости □ **~ итү 1.** пожа́ловать; *~ итегез* добро́ пожа́ловать! бу́дьте любе́зны! **2.** соизво́лить; дава́ть/дать из милосе́рдия; *биш сум ~ итмәссезме икән?* не дади́те ли мне пять рубле́й? да́йте, пожа́луйста, мне пять рубле́й; *бәлки берәр кило он ~ итәрсез* мо́жет, дади́те килогра́мм муки́?; **~ көтү** ждать пощады́, наде́яться на милосе́рдие **~ кылу** пожале́ть; проявля́ть ми́лость;; **~е (~ем, ~ең) килү** и (вдруг) пожале́ть; *~ем килде дә, сукмадым* (вдруг) я пожале́л и не уда́рил

рәхимле *прил.* **1.** милосе́рдный, ми́лостивый; мягкосерде́чный; жа́лостливый, уча́стливый, сострада́тельный; снисходи́тельный (*о человеке*); *сүздә генә ~ булу җитми* недоста́точно быть милосе́рдным то́лько на слова́х; *~ кеше* милосе́рдный (сердобо́льный) челове́к, ми́лостивец **2.** милосе́рдный (*поступок*), ми́лостивый; сострада́тельный, уча́стливый (*взгляд*) **3.** благода́тный; благотво́рный; *~ яз килде* пришла́ благода́тная весна́; *туган якның йомшак, ~ җилләре* мя́гкие, благотво́рные ве́тры родно́й страны́ □ **~ рәвештә** милосе́рдно, ми́лостиво, ми́ло, сердобо́льно; чу́тко

рәхимлеләндер|ү *понуд. от* **рәхимлеләнү**; *музыка рәхимсезне ~ә* му́зыка бессерде́чного (жесто́кого) челове́ка де́лает мягкосерде́чным

рәхимлеләнү *неперех.* станови́ться/стать милосе́рдным, мягкосерде́чным; подобре́ть; уми́лостивиться; *~ә төшү* стать бо́лее мягкосерде́чным

рәхимлелек *сущ.* **1.** милосе́рдие; уча́стливость; снисходи́тельность; *~ тәрбияләү* воспи́тывать милосе́рдие **2.** добросерде́чие, доброду́шие; доброта́; *~ белән* с добротой́; *үтә ~* изли́шнее доброду́шие, добросерде́чие; *балалардагы ~* добросерде́чие дете́й □ **~ күрсәтү 1.** милосе́рдствовать, проявля́ть сострада́ние, милосе́рдие; поступа́ть великоду́шно; проявля́ть ми́лость **2.** пожале́ть, испыта́ть жа́лость (сострада́ние) *к кому*, сжа́литься *над кем*, сми́лостивиться *над кем*

рәхимсез *прил.* **1.** бессерде́чный, безжа́лостный, беспоща́дный, свире́пый, ожесточённый (*книжн.*); жесто́кий; немилосе́рдный; *иң ~ кеше* са́мый жесто́кий челове́к; *кайсы ~енең эше бу?* како́й бессерде́чный челове́к сде́лал э́то? *~ мөнәсәбәт* безжа́лостное отноше́ние **2.** бесчелове́чный, беспоща́дный, неща́дный; ва́рварский, звери́ный; свире́пый, крова́вый (*о действиях, нравах, расправе*); *~ гадәтләр* свире́пые нра́вы; *~ кыйнаулар* бесчелове́чные распра́вы **3.** суро́вый, жесто́кий, свире́пый, лю́тый; си́льный (*о морозе, ветре*); *~ салкынлар* жесто́кие (лю́тые) холода́; *төньякның ~ җиле* свире́пый ве́тер се́вера || *нареч.* бессерде́чно, безжа́лостно, беспоща́дно; неща́дно, жесто́ко; *~ җәзалау* жесто́ко кара́ть; *урманнарны ~ кисү* безжа́лостно руби́ть (вырубать) леса́ □ **~ рәвештә 1.** беспоща́дно, бессерде́чно, неща́дно, безжа́лостно **2.** жесто́ко, зве́рски, ва́рварски; бесчелове́чно; *~ рәвештә кыйнап ташлаганнар* зве́рски изби́ли

рәхимсезләндер|ү *перех.* ожесточа́ть/ожесточи́ть, сде́лать бездушным, бесчелове́чным || ожесточе́ние; *сугыш безнең йөрәкләрне ~мәдә* война́ не ожесточи́ла на́ши сердца́

рәхимсезләнү *неперех.* ожесточа́ться/ожесточи́ться, станови́ться/стать бессерде́чным, безжа́лостным, суро́вым || ожесточе́ние; *йөрәгемә суыныргa, ~ергә бирмә* не дава́й се́рдцу осты́ть, ожесточи́ться; *кызның тавышы ~ә төште* го́лос де́вушки станови́лся суро́вым

рәхимсезлек *сущ.* **1.** бессерде́чность, безжа́лостность, бесчелове́чность, беспоща́дность; свире́пость, жесто́кость; *~ күрсәтү* прояви́ть бессерде́чность; *матурлыкны ярату белән ~ бергә сыеша алмый* любо́вь к прекра́сному и жесто́кость несовмести́мы **2.** суро́вость, лю́тость, свире́пость (*зимы*) □ **~ белән** безжа́лостно, бессерде́чно; беспоща́дно; жесто́ко; зве́рски, ва́рварски

рәхимчел *прил. см.* **рәхимле**; скло́нный быть ми́лосе́рдным, мягкосерде́чным, жа́лостливым; *ачуланмас, ул ~ кеше* не рассе́рдится, он челове́к мягкосерде́чный

рәхимчеллән|ү *неперех.* обрести́ мягкосерде́чие; *см.* **рәхимлеләнү**; *кинәт ~еп китү* вдруг подобре́ть; *~еп күренү өчен* что́бы показа́ться мягкосерде́чным

рәхимчелле|к *сущ. см.* **рәхимлелек** 1; *~ген саклап калу* остава́ться милосе́рдным, жа́лостливым

рәхим-шәфкать *сущ.* сочу́вствие, жа́лость, милосе́рдие, сострада́ние; пощада́; *әгәр алдасаң, рәхим-шәфкать көтмә* е́сли обма́нешь, не жди пощады́ □ **рәхим-шәфкать күрсәтү 1.** проявля́ть сочу́вствие и жа́лость **2.** поми́ловать

рәхим-шәфкатьле *прил.* милосе́рдный, ми́лостивый, до́брый, добросерде́чный; *рәхим-шәфкатьле кешеләр* добросерде́чные лю́ди

рәхман *прил. уст. рел. см.* **рәхимле**; милосе́рдный, ми́лостивый (эпи́тет бо́га); *хода кадир, хода ~* бог вели́к, бог ми́лостив; *раббем ~* ми́лостивый мой бог

рәхмани *прил. уст. рел.* бо́жий, бо́жеский, божественный; ниспо́сланный бо́гом; *~ хисләр* божественные чу́вства

рәхмәт *сущ.* **1.** *рел.* 1) ми́лость (бо́жья), милосе́рдие; жа́лость; благода́ть, бо́жья благода́ть *уст.*; *ср.* **мәрхәмәт**; *ходай ~е (белән) (илә)* бо́жьей ми́лостью; *ходай ~ кылсын* да бу́дет ми́лость бо́жья; *йә хода, ~еңнән ташлама* о бо́же, будь ми́лостив (*букв. не лишай милости*) 2) благода́тный; *~ яңгыры* благода́тный дождь **2.** благода́рность; призна́тельность || благода́рственный; *~ хисе* чу́вство благода́рности, призна́тельности; *аңа ~ем зур* я о́чень благода́рен ему́; *~ хаты* благода́рственное письмо́ **3.** *офиц.* благода́рность; спаси́бо; *кемгә ~, кемгә премия* кому́ благода́рность, кому́ пре́мия; *~не сорап алмыйлар* (благода́рность) не выпра́шивают; *~ белән тун тегмиләр* (*погов.*) за спаси́бо шу́бу не шьют || *модальн. сл.* **1.** спаси́бо; благодарю́, благода́рствую; призна́телен (*кому*); спаси́бо, поко́рнейше (поко́рно) благодарю́, о́чень призна́телен; *ярдәмегез өчен ~* спаси́бо за по́мощь; *киңәшегезгә (киңәшегез өчен) чын күңелдән ~* серде́чное спаси́бо за сове́т **2.** *разг. ирон.* спаси́бо, спаси́бочки; позво́льте; извини́те (*при отказе от чего-л. неприемлемого, нежелательного*); *имчегә барырга? юк инде, рәхмәт* идти́ к зна́харю? нет уж, извини́те; *мин гаепле икәнмен, ~ !* ока́зывается винова́т я, спаси́бочки □ **~ белдереп 1.** с благода́рностью (призна́тельностью), благода́рно **2.** призна́тельный, благода́рный (*взгляд*); **~ белдерү (әйтү) 1.** вы́разить призна́тельность; благодари́ть, поблагодари́ть **2.** *офиц.* объяви́ть благода́рность *в связи с чем, по случаю чего* ◊ **~ яусын (яугыры) 1.** большо́е спаси́бо; поко́рнейше благодарю́ **2.** да бу́дет ми́лость бо́жья, да будь благослове́н; **~еңә рәхмәт** пожа́луйста (*как ответ на благода́рность*); **~кә эшләү** рабо́тать за (одно́) спаси́бо; рабо́тать да́ром, задарма́ (*прост.*); **~ләр уку** рассыпа́ться в благода́рностях; выража́ть и́скреннюю (бесконе́чную) благода́рность

рәхмәтдар *прил.* призна́тельный; *ышанычыңа ~мын* я призна́телен за твоё дове́рие □ **~ булу 1.** быть благода́рным **2.** отблагодари́ть

рәхмәтле *прил.* благода́рный, призна́тельный; *~ караш белән* с благода́рным, призна́тельным взгля́дом

Рәчәй *сущ. прост.* Росси́я || росси́йский; *бөтен Рәчәй* вся Росси́я; *Рәчәй халкы* росси́йский наро́д

рәшә *сущ.* **1.** пелена́ сухо́го тума́на; ма́рево; мга, мгла; *аксыл ~* белёсое ма́рево; *басу өстен зәңгәрсу ~ каплаган* по́ле укры́то синева́тым ма́ревом **2.** мира́ж, ма́рево; *коры чүлдәге ~ кебек* как ма́рево (мира́ж) в пусты́не □ **~ уйнау** игра́ во́здуха в жа́ркое вре́мя ле́та (*обычно над ржаным полем*)

рәшәләнү *неперех.* покрыва́ться/покры́ться пелено́й сухо́го тума́на, ма́рить

рәшәле *прил.* с ма́ревом, мглой; *~ офык* горизо́нт в ма́реве

рәшәткә *сущ.* **1.** решётка, огра́да, и́згородь в ви́де решётки; пери́ла || огра́дный, пери́льный; *тәрәзә ~се* око́нная решётка; *бакча ~се* садо́вая решётка (огра́да); *күпер ~се* пери́ла моста́ **2.** колосники́ || колосniко́вый; *мич ~се* колосники́ пе́чи; *~ күзе* колосniко́вая ячея́

рәшәткәлән|ү *страд. от* **рәшәткәләү**; обреше́чиваться/обреше́титься; быть огорождённым (огоро́женным) решёткой; огражда́ться/огради́ться решёткой; *йортның тәрәзәләре ~гән* о́кна до́ма обреше́чены

рәшәткәләт|ү *понуд. от* **рәшәткәләү**

рәшәткәл|әү *перех.* **1.** огражда́ть/огради́ть, огора́живать/огороди́ть решёткой (*сад, огород, сквер, двор, могилу и т. п.*); *~әп алу* огороди́ть решёткой **2.** обреше́чивать/обреше́тить; поста́вить, вде́лать решётку (*в окно*) || обрешётка **3.** *спец.* решети́ть, укрепля́ть/укрепи́ть решети́ны □ **~әп ясау** де́лать, сде́лать реше́тчатым (*забор, ворота*); **~әп чигү** вышива́ть (вышива́ние) ришелье́

рәшәткәләнү *совм. от.* **рәшәткәләү**

рәшәткәле *прил.* реше́тчатый; с решёткой; *~ күпер* реше́тчатый мост, мост с реше́тчатыми пери́лами; *~ тәрәзәләр* о́кна с решёткой □ **~ ферма** *тех.* реше́тчатая фе́рма, сквозна́я фе́рма

рәшәткәлек *прил.* необходи́мый для решётки; предназна́ченный для решётки; *~ дранча* дра́нка для решётки

рәшәткәсыман *прил. тех.* реше́тчатый; *~ фланец* реше́тчатый фланец

рәшек *сущ. уст.* за́висть, ре́вность; *см. тж.* **кончелек**

рәшке *сущ. диал. зоол.* ме́лкая му́ха

рәшмән *сущ. диал. зоол.* кру́пный паву́к, вид пауко́ □ **~ тозагы** паути́на ◊ **~ тозагына эләгү** попа́сть в се́ти *к кому́-л.*, дать себя́ обману́ть

ре *сущ. муз.* ре (*музыкальный звук и нота*)

реабилита́ция *сущ. юр.* реабилита́ция; *~ таләп итү* тре́бовать реабилита́ции; *~ мәсьәләсе уңай хәл ителгән* положи́тельно решён вопро́с о реабилита́ции

реабилита́цияләнү *страд. от* **реабилитацияләү**; реабилити́роваться || реабилита́ция; *Верховный суд тарафыннан ~де* был реабилити́рован Верхо́вным судо́м; *~гән хәрби әсирләр* реабилити́рованные военнопле́нные

реабилита́цияләү *перех. юр.* реабилити́ровать || реабилита́ция; *гаепсезләрне аклау һәм ~* оправда́ть и реабилити́ровать неви́нных

реабилита́цияле *прил.* реабилити́рованный

реаге́нт *сущ. хим.* реаге́нт; *см. тж.* реакти́в; *күкерт кислотасының ~ буларак тәэсире* возде́йствие се́рной кислоты́ как реаге́нта; *торф ~ы* реаге́нт то́рфа

реагирл|ау *неперех. спец.* **1.** реаги́ровать *на что* || реа́кция *на что; тамашачы аның уенына төрлечә ~ый* пу́блика по-ра́зному реаги́рует на его́ игру́ (роль); *үсемлекләр җир тартымы юнәлешенә дә ~ыйлар* расте́ния реаги́руют и на притяже́ние земли́ **2.** *хим. см.* **реакциягә керү**; *күкерт кислотасы металл оксиды белән ~ый* се́рная кислота́ реаги́рует с о́кисями мета́ллов

реагирлаш|у *хим. см.* **реакциягә керү**; *кислоталарның (үзара) ~ы* реа́кция кисло́т

реактив *сущ. хим.* реакти́в, реаге́нт; *химик ~лар* хими́ческие реакти́вы; *~лар ярдәмендә химик составны билгеләү* определе́ние хими́ческого соста́ва при по́мощи реакти́ва || *прил. в разн. знач.* реакти́вный; *~ хәрәкәт* реакти́вное движе́ние; *~ двигатель* реакти́вный дви́гатель; *~ авиация* реакти́вная авиа́ция

реактивлы|к *сущ. хим. физиол.* реакти́вность; *матдәнең ~гы* реакти́вность вещества́; *югары нерв элементының ~гы* реакти́вность вы́сшего не́рвного элеме́нта

реактивчы *сущ. неол.* реакти́вщик; *~ очучы* лётчик-реакти́вщик (*лётчик рективного самолета*)

реактоген *прил. спец.* реактоге́нный (спосо́бный вы́звать реа́кции); *~ вакцина* реактоге́нная вакци́на

реа́ктор *сущ. в разн. знач.* реа́ктор; *электр ~ы* электри́ческий реа́ктор; *атом ~ы* а́томный реа́ктор, я́дерный реа́ктор

реа́кторлы *прил.* с реа́ктором (*преимущ. с атомным*); *~ бүлмә* помеще́ние с реа́ктором

реа́кторчы *неол.* реа́кторщик, специали́ст по реа́кторам; *~ларның уңышы* успе́хи реа́кторщиков

реакцион *прил.* реакцио́нный; *~ буржузия* реакцио́нная буржуази́я; *~ политика* реакцио́нная поли́тика

реакционлы|к *сущ.* реакцио́нность; *карашларның ~гы* реакцио́нность взгля́дов; *буржуазиянең ~гы* реакцио́нность буржуази́и

реакционер *сущ.* реакционе́р; *бер группа ~лар* гру́ппа реакционе́ров

реа́кция I *сущ. в разн. знач.* реа́кция || реакцио́нный; *организмның тышкы ярсыткычларга ~се* реа́кция организма на вне́шние раздражи́тели; *фотоактив ~ (биол.)* фотоакти́вная реа́кция; *таркалу ~се* реа́кция разложе́ния; *~ камерасы (хим.)* реакцио́нная ка́мера □ **~гә керү** *хим.* реаги́ровать *с чем*

реа́кция II *сущ. полит.* реа́кция; *1905 елгы революциядән соңгы ~* реа́кция по́сле револю́ции 1905 г.; *~ корбаннары* же́ртвы реа́кции

реа́кциячел *прил.* реакцио́нный; *~ хөкүмәт* реакцио́нное прави́тельство; *хөкүмәтнең ~ политикасы* реакцио́нная поли́тика прави́тельства

реал I *сущ.* реа́л (испа́нская моне́та)

реал II *сущ. типогр.* реа́л; *~ артына басу* вста́ть за реа́л, станови́ться/стать набо́рщиком

реализа́цияләнү *неперех. спец.* реализова́ться; *~ә ала торган* реализу́емый; ликви́дный; *~гән билетлар* реализо́ванные биле́ты

реализа́цияләү *неперех. спец.* реализова́ть || реализа́ция; *товарларны ~* реализова́ть това́ры

реализм *сущ. в разн. знач.* реали́зм || реалисти́ческий; *чынбарлыкка карашта ~* реали́зм в отноше́нии к действи́тельности; *XIX йөз философиясендә ~*

реали́зм в филосо́фии XIX ве́ка; *музыкада ~ юнәлеше* реалисти́ческое направле́ние в му́зыке; *~ методы* реалисти́ческий ме́тод

реа́лий *сущ.* реа́лия; *төрле ~ләр атамалары* назва́ния ра́зных реа́лий

реали́ст I *сущ.* реали́ст, реали́стка; *~ язучы* писа́тель-реали́ст; *тормышта аек ~ булу* быть тре́звым реали́стом в жи́зни

реали́ст II *сущ. уст.* реали́ст (*ученик реального училища*); *~ киеменнән* в фо́рме реали́ста

реали́стик *прил.* **1.** реалисти́ческий; *~ роман* реалисти́ческий рома́н; *музыкада ~ юнәлеш* реалисти́ческое направле́ние в му́зыке **2.** реалисти́чный; *тормышка ~ мөнәсәбәт* реалисти́чное отноше́ние к жи́зни

реалистла́рча *нареч.* реалисти́чно, реалисти́чески; *мәсьәләгә ~ карау* на вопро́с смотре́ть реалисти́чески

реалистлы|к *сущ.* реалисти́чность || реалисти́чный; *романтик-идеалистлыктан ~кка үсү* разви́тие от рома́нтика-идеали́ста до реали́ста; *авторның ~гы* реалисти́чность а́втора

реаль *прил.* **1.** *физ.* реа́льный; *~ газ* реа́льный газ **2.** реа́льный, действи́тельный; *~ тормыш* действи́тельная жизнь; *~ шартлар* реа́льные усло́вия **3.** реа́льный, объекти́вный, вещественный, предме́тный; *сүзнең ~ мәгънәсе* реа́льное значе́ние сло́ва **4.** *в знач. сказ.* реа́льно; реалисти́чески, реалисти́чно; *план ~ түгел* план не реа́лен **5.** реа́льный, прикладно́й; *~ фәннәр* реа́льные (прикладны́е) нау́ки || *нареч.* реа́льно, реалисти́чески, реалисти́чно; *тормыш ~ чагылган* жизнь отражена́ реа́льно; *тормышка ~ карау* смотре́ть на жизнь реа́льно; *хәлгә ~ бәя бирү* реалисти́чески оце́нивать обстано́вку □ **~ булмаган (түгел)** нереа́льный; **~ түгел** ирреа́льный; **~ чынбарлык** реа́льность; действи́тельность; **~ эш хакы** реа́льная за́работная пла́та

реальләштер|ү *перех.* де́лать, сде́лать реа́льным; реализова́ть, осуществи́ть; *тәкъдимне ~ү* реализова́ть предложе́ние

реальләш|ү *неперех.* станови́ться/стать реа́льным, реализо́ванным; реализова́ться, осуществля́ться/осуществи́ться; *билгеләнгән планнар ~ә* наме́ченные пла́ны реализу́ются; *хыяллар ~ә* мечты́ осуществля́ются

реальле|к *сущ.* реа́льность; объекти́вность; *тәкъдимнең ~ге* реа́льность предложе́ния; *образларның ~ге* реа́льность о́бразов; *объектив ~к* объекти́вная реа́льность; *дөньяның ~ге* реа́льность ми́ра

реальлекле *прил.* реа́льный, осуществи́мый; *~ планнар* осуществи́мые пла́ны

реальлексез *прил.* нереа́льный; неосуществи́мый; непроду́манный

реальный; реальный училище *уст.* реа́льное учи́лище; *~ училищеда укучы* учени́к реа́льного учи́лища, реали́ст

реанимато́лог *сущ. мед.* реаниматолог; *~лар киңәшмәсе* совеща́ние реаниматологов; *совет ~лары* сове́тские реаниматологи

реаниматоло́гик *прил.* реаниматологи́ческий; *~ чаралар* реаниматологи́ческие мероприя́тия

реаниматоло́гия *сущ. мед.* реаниматоло́гия; *~ — яңа фән* реаниматоло́гия — но́вая нау́ка

реанима́тор *сущ. мед.* реанима́тор, врач-реанима́тор; *~лар бригадасы* брига́да реанима́торов

реанима́ция *сущ. мед.* реанима́ция, оживле́ние || реанимацио́нный; *клиникада ~ бүлеге бар* в кли́нике име́ется отделе́ние реанима́ции; *~ үзәге* реанимацио́нный центр

ребо́рда *сущ. тех.* ребо́рда; *~дан ычкыну* соскочи́ть с ребо́рды

ре́бус *сущ.* ре́бус; *~ чишү* реши́ть ре́бус

ре́буслы *прил.* ре́бусный; с ре́бусом; *журналның ~ бүлеге* ре́бусный разде́л журна́ла; *~ сәхифә* страни́ца с ре́бусом

реванш *сущ. полит.* рева́нш || реванши́стский; *~ алу* брать (взять) рева́нш; *~ка әзерләнү* гото́виться к рева́ншу; *~ планнары* реванши́стские пла́ны

реваншизм *сущ. полит.* реванши́зм

реваншист *сущ.* реванши́ст

реванши́стик *прил.* реванши́стский

реваншистлык *сущ.* реванши́зм || реванши́стский; *~ күренеше* проявле́ние реванши́зма; *~ омтылышлары* реванши́стские устремле́ния; *~ политикасы* реванши́стская поли́тика

рева́ншчы *сущ.* реванши́ст; *фашист ~лары* фаши́стские реваншисты; *~лар чыгышы* выступле́ние реваншистов

рева́ншчылык *сущ.* реванши́зм || реваншистский; *~ карашлары* реваншистские взгля́ды

реввоенсовет *сущ. ист.* реввоенсове́т (революцио́нный вое́нный сове́т); *~ члены* член реввоенсове́та

ревень *сущ. бот.* реве́нь || реве́нный; *бакча ~не* садо́вый (овощно́й) реве́нь; *дәва ~е* лека́рственный реве́нь; *~ яфрагы* реве́нный лист

реверанс *сущ.* реверанс; *~ ясау* сде́лать реверанс

ре́верс *сущ. спец.* ре́верс; *~ны кире юнәлешкә кую* перевести́ ре́верс в обра́тное положе́ние

реверсив *прил. спец.* реверси́вный; *~ двигатель* реверси́вный дви́гатель; *~ механизм* реверси́вный механи́зм, ре́верс

реве́рсия *сущ. спец. биол.* реве́рсия; атави́зм; *~ күренешләре* явле́ния реве́рсии (атави́зма)

ре́верслау *перех. тех.* реверси́ровать || реверси́рование; *(машинаның) ~ рычагы* рычаг реверси́рования (маши́ны)

реве́рсор *сущ. спец.* реве́рсор

ревиз *сущ. ист.* реви́зия, пе́репись; *соңгы ~ вакытында* во вре́мя после́дней реви́зии; *яңа ревизиягә эләгү* попа́сть в но́вую реви́зию □ **~ исемлеге** *ист.* реви́зия, реви́зская ска́зка (*список лиц податного сословия, составляемый при ревизии*); *~ исемлегендәге кеше* реви́зская душа́

ревизионизм *сущ. филос.* ревизиони́зм || ревизиони́стский; *хәзерге заман ~ы* совреме́нный ревизиони́зм; *~ тарафдары* сторо́нник ревизиони́зма, ревизиони́ст; *~ политикасы* ревизиони́стская поли́тика

ревизионист *сущ. филос.* **1.** ревизиони́ст, ревизиони́стка; *марксизм философиясенә каршы ~ларның атакалары* ата́ки ревизиони́стов про́тив маркси́стской филосо́фии **2.** *в знач. прил.* ревизиони́стский, явля́ющийся ревизиони́стом; *~ социал-демократлар* социа́л-демокра́ты ревизиони́сты

ревизионистлык *сущ. филос.* ревизиони́зм || ревизиони́стский; *~ карашлары* ревизиони́стские взгля́ды; *см.* **ревизионизм**

реви́зия *сущ. в знач.* **1.** реви́зия || ревизио́нный; *көтмәгәндә ~ килеп төште* неожи́данно нагря́нула реви́зия; *~ зур гына җитмәучелекне тапты* реви́зия обнару́жила большу́ю растра́ту; *~ комиссиясе* ревизио́нная коми́ссия, ревкоми́ссия **2.** *ист.* реви́зия

(в XVIII и в начале XIX в.: перепись в России населения для учёта и исчисления подушной подати) □ **~ ясау (үткәрү)** ревизова́ть, производи́ть реви́зию, подверга́ть реви́зии || ревизова́ние; реви́зия; *см. тж.* **ревизиялəү**

реви́зиял|əү *перех.* ревизова́ть, обревизова́ть, производи́ть реви́зию; подверга́ть реви́зии || реви́зия; *квартал отчетын ~əу* ревизова́ть кварта́льный отчёт

реви́зияләүче *сущ.* **1.** *см.* **ревизор; 2.** *см.* **реви́зия** 1

ревизор *сущ. в разн. знач.* ревизо́р; *район ~ы* райо́нный ревизо́р; *тимер юл ~ы* железнодоро́жный ревизо́р; ревизо́р движе́ния

ревизорлык *сущ.* заня́тие (профе́ссия) ревизо́ра; ревизо́рство; *~ка ризалык бирү* дать согла́сие на до́лжность ревизо́ра; *~ бурычлары* ревизо́рские обя́занности; *~ эше (вазифасы)* ревизо́рская до́лжность, до́лжность ревизо́ра

ревком *сущ. ист.* ревко́м (революцио́нный комите́т) || ревко́мовский; *~га адресланган радиограмма* радиогра́мма, адресо́ванная ревко́му; *~ комиссары* ревко́мовский комисса́р

ревкомиссия *сущ.* ревкоми́ссия (ревизио́нная коми́ссия)

ревматизм *сущ. мед.* ревмати́зм || ревмати́ческий; *буын ~ы* суставно́й ревмати́зм; *~ белән җәфалану* страда́ть ревмати́змом; *~ авырулы (кеше)* больно́й ревмати́змом; ревма́тик; *~ авыртуы (сызлавы)* ревмати́ческие бо́ли

ревмати́змлы *прил.* больно́й ревмати́змом; ревмати́ческий; *~ кеше* челове́к, больно́й ревмати́змом; ревма́тик; *~ аякларын көчкә өстерәп йөри* хо́дит, с трудо́м передвига́я ревмати́ческие но́ги

ревма́тик *сущ.* ревма́тик; *~лар палатасы* пала́та ревма́тиков

ревмато́лог *сущ.* ревмато́лог; *район ~ы* райо́нный ревмато́лог; *~ бүлмәсе* кабине́т ревмато́лога

ревматоло́гия *сущ.* ревматоло́гия || ревматологи́ческий; *хәзерге заман ~се* совреме́нная ревматоло́гия; *~ фәненең казанышлары* достиже́ния ревматоло́гии; *~ больницасы* ревматологи́ческая больни́ца; *клиниканың ~ бүлеге* ревматологи́ческое отделе́ние кли́ники

револьвер *сущ.* револьве́р || револьве́рный; *~дан ату ярышлары* соревнова́ния по стрельбе́ из револьве́ра; *~ таккан кеше* челове́к с револьве́ром (на по́ясе); *~ төзәү* навести́ револьве́р *на кого; ~ кобурасы* револьве́рная кобура́ □ **~ станок** револьве́рный стано́к; *~ станокта эшләүче* (то́карь) челове́к, рабо́тающий на револьве́рном станке́, револьве́рщик

револьверчы *сущ.* револьве́рщик, револьве́рщица; *~ булып эшләү* рабо́тать револьве́рщиком; *цех ~лары арасында* среди́ цеховы́х револьве́рщиков

революцион *прил.* революцио́нный; *~ җыр* революцио́нная пе́сня □ **~ демократ** *ист.* **1.** революцио́нный демокра́т; *татар демократлары* тата́рские революцио́нные демокра́ты **2.** *в знач. прил.* революцио́нно-демократи́ческий; *демократ язучылар* революцио́нно-демократи́ческие писа́тели

революцион-демокра́тик *прил.* революцио́нно-демократи́ческий; *революцион-демократик партияләр* революцио́нно-демократи́ческие па́ртии

революционер *сущ.* революционе́р; *татар ~лары* тата́рские революционе́ры; *чын ~ булып җитешү* преврати́ться в настоя́щего революционе́ра

революционерлык *сущ.* революцио́нность (челове́ка); революционе́рство; де́ятельность революционе́ра; *~ юлына басу* встать на путь революционе́ра; стать революционе́ром; *~та гаепләнә* обвиня́ется в революционе́рстве

революционлаштыру *перех.* революционизи́ровать || революционизи́рование; *армияне ~* революционизи́ровать а́рмию

революционлаштыручы *прил.* революционизи́рующий; *крестьян массасын ~ көчләр* си́лы, революционизи́рующие крестья́нские ма́ссы

революционлашу *неперех.* революционизи́роваться || революционизи́рование; *пролетариатның ~ процессы* проце́сс революционизи́рования пролетариа́та

революционлы|к *сущ.* революцио́нность; революцио́ни́зм; *карашларның ~гы* революцио́нность взгля́дов

революция *сущ. в разн. знач.* революция || революцио́нный; *Октябрь социалистик ~се* Октя́брьская социалисти́ческая революция; *культура ~се* культу́рная революция; *фән-техника ~се* нау́чно-техни́ческая революция; *~ теориясе* революцио́нная тео́рия; *~ хәрәкәте* революцио́нное движе́ние □ **~гә чаклы (кадәрге)** дореволюцио́нный

революцячел *прил.* революцио́нный, настро́енный на революцию; *~ партияләр* революцио́нные па́ртии

революцячеллек *сущ.* революцио́нность (*преимущ. настроений, намерений*)

ревтрибунал *сущ. ист.* ревтрибуна́л (революцио́нный трибуна́л)

ревю *сущ.* ревю́; *музыкаль ~* музыка́льное ревю́

рега́лия *сущ. ист.* рега́лия, рега́лии; *монархлык ~ләре* рега́лии мона́рха; *мундир һәм ~ләрен киде* наде́л мунди́р и рега́лии

рега́та *сущ. спорт.* рега́та; *ишкәкле ~* гребна́я рега́та; *җилкәнле регата* па́русная рега́та

ре́гби *сущ. спорт.* ре́гби; *~ уйнау* игра́ть в ре́гби; *~ буенча Европа чемпионы* чемпио́н Евро́пы по ре́гби

ре́гбичы *сущ. спорт.* регби́ст; *~лар командасы* кома́нда регби́стов; *совет ~лары* сове́тские регби́сты

ре́гель *сущ. спец.* ре́гель; *см. тж.* **буй өрлек**

регенера́т *сущ. техн.* регенера́т || регенера́тный; *резина ~ы* регенера́т рези́ны; *~ цехы* регенера́тный цех

регенерати́в *прил. тех. биол.* регенерати́вный; *һаваны җылытуның ~ ысулы* регенерати́вный спо́соб нагрева́ния во́здуха; *тукымаларда ~ сәләт* регенерати́вная спосо́бность тка́ней (органи́зма)

регенера́тор *сущ. тех.* регенера́тор || регенера́торный; *халык хуҗалыгында ~ларның әһәмияте* значе́ние регенера́торов в наро́дном хозя́йстве; *~да җылынган һава, ~ һавасы* регенера́торный во́здух

регенера́ция *сущ. тех., биол.* регенера́ция || регенерати́вный, регенерацио́нный; *техник майлар ~се* регенера́ция техни́ческих ма́сел; *сөяк ~се* ко́стная регенера́ция; *хайваннарда ~ процессы* регенерацио́нный проце́сс у живо́тных

регенера́циялән|ү *неперех. биол.* регенери́ровать, регенери́роваться || 1) регенери́рование 2) регенерацио́нный; *~гән орган* регенери́рованный о́рган; *~у процессы* регенерацио́нный проце́сс

регенерациял|әү *перех. тех.* регенери́ровать || регенери́рование; *һаваны ~әү* регенери́ровать во́здух

ре́гент *сущ. ист.* ре́гент || ре́гентский, относя́щийся к ре́генту; *~ итеп чакыру* пригласи́ть ре́гентом;

~ регалияләре ре́гентские регáлии; *~ хокуклары* ре́гентские правá

ре́гентлык *сущ. ист.* ре́гентство || ре́гентский; относя́щийся к ре́гентству; *~ чоры* пери́од ре́гентства; *~ дәрәҗәсе (вазифасы)* ре́гентство; *~ советы* ре́гентский сове́т

региональ *прил. спец.* регионáльный; *~ киңәшмә (конференция)* регионáльное совещáние (конферéнция); *~ пакт (килешү)* регионáльный пакт (соглашéние)

регистр *сущ. в разн. знач.* регúстр || регúстровый; *кергән-чыккан кәгазьләр ~ы* регúстр входя́щих и исходя́щих бумáг; *китап һәм журналлар ~ы* регúстр книг и журнáлов; *машинкадагы югары ~* вéрхний регúстр пúшущей машúнки; *~ планкасы (гармунда)* регúстровая плáнка (в гармони)

регистрáтор *сущ.* регистрáтор, регистрáторша; *поликлиникада ~ булып эшли* рабóтает регистрáторшей в поликлúнике; *~лар делегатларны язып бардылар* регистрáторы запúсывали (регистрúровали) делегáтов

регистратýра *сущ.* регистратýра || регистратýрный; *гостиницадагы ~* регистратýра в гостúнице; *медицина картасын ~дан алу* взять в регистратýре медицúнскую кáрту; *~ бүлеге* регистратýрный отдéл

регистрáция *сущ.* регистрáция || регистрацúонный; *~дән соң* пóсле регистрáции; *~ кәгазе* регистрацúонный лист □ **~ алып бару (ясау)** регистрúровать; **~гә алу (кертү)** зарегистрúровать; **~гә алыну (керү)** быть зарегистрúрованным; зарегистрúроваться

регистрáцияләнү *страд. от* **регистрацияләү**; регистрúроваться

регистрáцияләү *перех.* регистрúровать, зарегистрúровать || регистрúрование; регистрáция; *туу һәм үлүләрне ~ бүлеге* отдéл регистрáции рождéния и смéрти; *съезд делегатларын ~* регистрúровать делегáтов съéзда

регистрáцияләүче *сущ. см.* регистрáтор

регламéнт *сущ.* регламéнт || регламéнтный; *~ билгеләү* установúть регламéнт; регламентúровать; *~ саклау* соблюдáть регламéнт; *~ тәртибе* регламéнтный порядóк

регламентáция *сущ.* регламентáция; *җитештерү процессы ~се* регламентáция произвóдственного процéсса

регламентáциялəү *перех.* регламентúровать || регламентúрование, регламентáция; *эчке сәүдәне ~* регламентúровать внýтреннюю торгóвлю

регламéнтлаштыру *перех.* регламентúровать || регламентúрование; *көн тәртибен ~* регламентúровать повéстку дня

реглáн *сущ.* регláн || *прил.* регláн; *~ кулмәк* (пальтó) плáтье (пальтó) регláн

регресс *сущ.* регрéсс; *противоп.* прогрéсс; *гакыл ~сы*ýмственный регрéсс; *экономик ~* регрéсс в экономúке □ **~ кичерү** регрессúровать

регрессив *прил.* регрессúвный; *~ үзгәрешләр* регрессúвные изменéния; *~ процесслар* регрессúвные процéссы □ **~ ассимиляция** *лингв.* регрессúвная ассимилáция

регрессивлык *сущ.* регрессúвность; *үсештәге ~* регрессúвность развúтия

регрéссия *сущ. спец.* регрéссия

регулирлау *перех.* регулúровать, отрегулúровать || регулúрование, регулирóвка; *поездлар йөрешен ~* регулúровать движéние поездóв; *радиоалгычның тавыш көчен ~* отрегулúровать сúлу звýка радиоприёмника

регулирóвщик *сущ.* регулирóвщик, регулирóвщица; *~ машиналарга юл күрсәтеп тора* регулирóвщик укáзывает маршрýты автомашúнам; *~ кыз* регулирóвщица

регуляр *прил.* регуля́рный; *поездларның ~ хәрәкәте (йөреше)* регуля́рное движéние поездóв; *~ дәреслəр* регуля́рные заня́тия || *нареч.* регуля́рно; *~ кабатлана торган* регуля́рно повторя́ющийся □ **~ армия** регуля́рная а́рмия; **~ рәвештә** регуля́рно

регулятив *прил. книжн.* регулятúвный; *~ идея* регулятúвная идéя; *~ принцип* регулятúвный прúнцип; *~ дисциплина* регулятúвная дисциплúна

регуля́тор *сущ. спец.* регуля́тор || регуля́торный; *тизлек ~ы физ.* регуля́тор скóрости; *тавыш ~ы* регуля́тор грóмкости; *үсеш ~ы биол.* регуля́тор рóста; *~ тартмасы* регуля́торная корóбка

регуля́ция *сущ. биол.* регуля́ция; *гомораль регуляция биол.* гумора́льная регуля́ция

редáктор *сущ.* редáктор; *нәшрият ~ы* издáтельский редáктор; *газета ~ы* редáктор газéты || редáкторский; *~ төзәтмәләре* редáкторские попрáвки; *~лар советы (коллегиясе)* редакцúонный сове́т (коллéгия), редсове́т (редколлéгия) □ **~ булу (булып эшләү)** редáкторствовать, быть редáктором

редáкторлык *сущ.* редáкторство || редáкторский; *~ны кемгә тапшырабыз?* кому́ пору́чим редáкторство? *~ вазифасы* редáкторская обя́занность, обя́занность редáктора

редактýра *сущ. спец.* редактýра; *беренче ~* пéрвая редактýра; *~ вакытында төшереп калдыру* опустúть (пропустúть) во врéмя редактýры

редакцион *прил.* редакцúонный; *~ төзәтмәләр* редакцúонные попрáвки

редáкция *сущ. в разн. знач.* редáкция || редакцúонный; *кулъязма беренче ~не үтте* рýкопись прошлá пéрвую редáкцию; *профессор ~сендә* под редáкцией профéссора; *~ мәкаләсе* редакцúонная статья́

редáкцияләнү *страд. от* **редакцияләү**; редактúроваться; *мәкалә яхшы ~гән* статья́ хорошó отредактúрована

редáкцияләү *перех.* редактúровать || редактúрование; *кулъязманы ~* редактúровать рýкопись; *~п чыгу* отредактúровать до концá; *~ү эше* редакцúонная рабóта, рабóта по редактúрованию

редис *сущ.* редúс; *~ үстерү* выра́щивать редúс; *~ салаты* салáт из редúса; *~ орлыгы* семена́ редúса

редúска *сущ. разг. см.* **редис**; *киветкә яңа өлгергән ~ чыккан* в магази́н поступúла свéжая редúска

редколлéгия *сущ.* редколлéгия (редакцúонная коллéгия); *стена газетасы ~се* редколлéгия стенно́й газéты; *~ члены* член редколлéгии

редýктор *сущ.* редýктор; *реверсив ~* реверсúвный редýктор; *күп баскычлы ~* многоступéнчатый редýктор; *~ цехы* редýкторный цех

редýкторлы *прил.* редýкторный; *~ мотор* редýкторный двúгатель

редýкция *сущ. в разн. знач.* редýкция || редукцúонный; *җир асты хайваннарында күз ~се биол.* редýкция глаз у подзéмных живóтных; *пар басымы ~се тех.* редýкция давлéния пáра; *басымсыз ижекләрдә сузыклар ~се лингв.* редýкция глáсных в безудáрных слогáх

редýкцияләнү *в разн. знач.* редуци́роваться || редуци́рование; *кайбер органнарның ~е биол.* редуци́рование

не́которых о́рганов; *~гән сузыклар лингв.* редуци́рованные гла́сные

реду́кциял|әү *в разн. знач.* редуци́ровать || редуци́рование; реду́кция; *басымны ~әү* редуци́ровать давле́ние

редупликáция *сущ. лингв.* редупликáция; *~ юлы белән сүз ясау* словообразова́ние путём редупликáции

редут *сущ. воен.* реду́т; *дошман ~ына атака* ата́ка на вра́жеский реду́т

реéстр *сущ. книжн.* реéстр || реéстровый; *милек ~ы* реéстр иму́щества; *~ бланклары* реéстровые бла́нки; *~га кертелгән (теркәлгән)* реéстровый, включённый в реéстр

режим *сущ. вразн.* режи́м; *халык демократиясе ~ы* наро́дно-демократи́ческий режи́м; *иске ~* ста́рый режи́м; *ашау ~ы* режи́м пита́ния; *~ белән яшәү* жить, соблюда́я режи́м (распоря́док дня)

режимлы *прил.* режи́мный; -режи́мный, с режи́мом; *иске ~* старорежи́мный; *каты ~* строгорежи́мный

режимсыз *нареч. и прил.* без режи́ма || безрежи́мный

режиссёр *сущ.* режиссёр || режиссёрский; *спектакль (фильм) ~ы* режиссёр спекта́кля (фи́льма); *~ булып эшләү* рабо́тать режиссёром, режиссёрствовать; *~ таләпләре* режиссёрские тре́бования

режиссёрлык *сущ.* режиссёрство, режиссу́ра || режиссёрский; *~ка тарту* привле́чь к режиссу́ре; *~ сәләте* режиссёрское дарова́ние

режиссу́ра *сущ. книжн.* режиссу́ра; *театрда рәссамның эше ~ белән ныклы бәйләнештә алып барыла* рабо́та худо́жника теа́тра те́сно свя́зана с режиссу́рой

резеда *сущ. бот.* резеда́ || резедо́вый; *хуш исле ~* души́стая резеда́; *~ букеты* буке́т резеды́; *~ мае* резедо́вое ма́сло; *~ исе* резедо́вый за́пах □ **~ күбәләге** *зоол.* резедо́вая беля́нка

резéкция *сущ. мед.* резéкция; *калкансыман бизгә ~ резéкция щитови́дной железы́; ~ ясау (үткәрү)* резци́ровать

резерв *в разн. знач. сущ.* резéрв; *азык ~ы* продово́льственный резéрв (запа́с); *хезмәт ~лары* трудовы́е резéрвы; *~тан бер рота җибәрү* посла́ть одну́ ро́ту из резéрва || *прил.* резéрвный; *~ егәрлек* резéрвная мо́щность; *~ гаскәр* резéрвные войска́ □ **~ка калдыру 1.** отвести́ в резéрв (*роту, группу*) **2.** оста́вить в резéрве (в запа́се); не мобилизова́ть, оста́вить резерви́стом; **~та тора торган** резéрвный; *см. тж.* **резервтагы**; **~та тоту (саклау)** резерви́ровать, держа́ть в резéрве (в запа́се)

резервация *сущ.* резерва́ция; *индеецлар ~се* резерва́ция инде́йцев; инде́йская резерва́ция; *~дәге яшәү (тормыш) шартлары* жи́зненные усло́вия (жизнь) в резерва́ции

резервист *сущ. воен.* резерви́ст; запасни́к; *~ларны һәм запастагы офицерларны чакыру* сбор (призы́в) резерви́стов и офице́ров запа́са

резéрвник *сущ. воен.* резéрвник

резéрвтагы *прил.* резéрвный; *~ полк* резéрвный полк; *~ капитал* резéрвный капита́л; *~ фонд* резéрвный фонд, золото́й фонд

резервуар *сущ.* резервуа́р || резервуа́рный; *нефть ~лары* нефтяны́е резервуа́ры; *җир асты ~ы* подзе́мный резервуа́р; *~ паркы* резервуа́рный парк; *~ краны* резервуа́рный кран

резидент *сущ. в разн. знач.* резиде́нт || резиде́нтский; *Германия ~ы* герма́нский резиде́нт; *~ биргән инструктаж* инструкта́ж резиде́нта; *~ эшчәнлеге* резиде́нтская де́ятельность

резиде́нция *сущ.* резиде́нция; *хөкүмәтнең вакытлы ~се* вре́менная резиде́нция прави́тельства; *король ~се* корол**е́**вская резиде́нция

резин *прил. разг.* рези́новый; из рези́ны; ла́стиковый; *~ туп* рези́новый мяч; *~ таяк* рези́новая па́лка; *~ бәйләвечләр* рези́новые (ла́стиковые) подвя́зки

рези́на *сущ.* рези́на || рези́новый; *күзәнәкле ~* по́ристая рези́на; *~дан ясалган әйберләр* изде́лия из рези́ны; *~ җилеме (клее)* рези́новый клей, клей для рези́новых изде́лий || *прил.* рези́новый, рези́нный; из рези́ны; *см. тж.* рези́н □ **~ сөндерелү** *тех.* прореза́ться; *~ сөндерелгән тукыма* прореза́ная ткань; **~ сөндерү** *тех.* прореза́ть/прореза́ть; **~ сөю** прореза́ться/прореза́ться

рези́наланы *неперех.* станови́ться/стать, как рези́на

рези́налау *перех. см.* **рези́на сөндерү**

рези́налы *прил.* прореза́ный, с рези́ной; *~ комбинезон* прореза́ный комбинезо́н

рези́нка *сущ.* **1.** рези́нка, рези́новый шнур; *эшләпә ~сы* рези́нка (шнур) шля́пы; *җиң очына ~ куелган* в рукава́ вде́та рези́нка, рукава́ со́браны рези́нкой **2.** *школьн.* рези́нка; ла́стик *разг.*; *см. тж.* **бетергеч**; **бозгыч**; **карандаш ~сы** каранда́шная рези́нка; *кара ~сы* черни́льная рези́нка **3.** *разг.* рези́новые гало́ши; *киез итек резинкасы* (рези́новые) гало́ши для ва́ленок; *тирән ~лар* глубо́кие гало́ши; *аягында иске ~* в ста́рых гало́шах

резинкалану *страд. от* **резинкалау**; прореза́ться, пропи́тываться рези́ной

резинлау *перех.* прореза́ть, пропи́тывать рези́ной

резолю́ция *сущ. в разн. знач.* резолю́ция; *~ проекты* про**е́**кт резолю́ции; *конференция бер тавыштан ~ кабул итте* конфере́нция единогла́сно приняла́ резолю́цию

резонанс *сущ. в разн. знач.* резона́нс || резона́нсный; *токлар ~сы физ.* резона́нс то́ков; *акустик ~ физ. муз.* акусти́ческий резона́нс; *тирбәнешләрнең ~ы физ.* резона́нс колеба́ний

резона́нслы *прил. тех.* резона́нсный; *~ трансформатор тех.* резона́нсный трансформа́тор; *~ көчәйткеч физ.* резона́нсный усили́тель

резона́тор *сущ. в разн. знач.* резона́тор || резона́торный; *күләмле ~* объёмный резона́тор; *электромагнитлы ~* электромагни́тный резона́тор; *~ куышлыгы* резона́торная по́лость

резона́торлы *прил. спец.* резона́торный; *~ аппарат* резона́торный аппара́т

резонёр *сущ.* резонёр || резонёрский; *~ амплуасындагы артист* актёр с амплуа́ резонёра; *~ роле* резонёрская роль

резонёрла́рча *нареч.* (по-) резонёрски || резонёрский; *~ үгетләү* резонёрски наставля́ть, резонёрское наставле́ние; *~ үгет тоны* резонёрский тон

резонёрлык *сущ.* резонёрство; *педагогикада ~* резонёрство в педаго́гике; *~ка бирелү* резонёрствовать; *~ итү* резонёрствовать

ре́зус: резус-фактор *мед.* ре́зус-фа́ктор; *уңай (кире) ~-фактор* положи́тельный (отрица́тельный) ре́зус-фа́ктор

резьба *сущ. тех.* резьба́ || резьбо́вый; *см. тж.* **сыр**; *тышкы ~* нару́жная резьба́; *өчпочмаклы ~* треуго́льная

резьба́; ~ *адымы* шаг резьбы́; ~ *калибры* кали́бр резьбы́ □ ~ **ясау** наре́зка резьбы́; ~ **ясаучы** резьбо́вщик

резьбалы *прил.* резьбово́й; с резьбо́й; ~ *тоташтыру* резьбово́е соедине́ние; ~ *очы* голо́вка (коне́ц) с резьбо́й, резьбово́й наконе́чник (коне́ц)

резюме *сущ. книжн.* резюме́; *мәкаләнең ~сы русча* резюме́ статьи́ на ру́сском языке́; ~ *язу* писа́ть резюме́ □ ~ **ясау** резюми́ровать

рей, ре́я *сущ. мор.* рей, ре́я

рейд I *сущ. мор.* рейд || ре́йдовый; *~та тору* стоя́ть на ре́йде; *~та тору урыны* ре́йдовая стоя́нка

рейд II *сущ. в разн. знач.* рейд || ре́йдовый; *кавалерия ~ы* кавалери́йский рейд; *~та катнашучы* уча́стник ре́йда, рейдови́к; ~ *отряды* ре́йдовый отря́д; ~ *бригадасы* ре́йдовая брига́да □ ~ **ясау (үткәрү, оештыру)** рейди́ровать

ре́йдчы *сущ.* рейдови́к, уча́стник ре́йда; *~лар группасы* гру́ппа рейдовико́в

ре́йка *сущ. в разн. знач.* ре́йка; *кар үлчи торган* ~ снегоме́рная ре́йка; *су үлчи торган* ~ водоме́рная ре́йка; *~лардан ясалган* сде́ланный из ре́ек, ре́ечный

ре́йкалы *прил.* ре́ечный; ~ *механизм* ре́ечный механи́зм; ~ *домкрат* ре́ечный домкра́т; ~ *пресс (стан)* ре́ечный пресс (стан)

рейс *сущ.* рейс || ре́йсовый; *соңгы ~ белән китү* уе́хать после́дним ре́йсом; ~ *самолёты* ре́йсовый самолёт

ре́йсмус *сущ. тех.* ре́йсмус; ~ *ярдәмендә сызык сызу* провести́ ли́нию при по́мощи ре́йсмуса || *прил.* ре́йсмусовый; ~ *станок* ре́йсмусовый стано́к

рейсфе́дер *сущ. спец.* рейсфе́дер; *~га куелган карандаш* каранда́ш, вста́вленный в рейсфе́дер

рейсши́на *сущ. спец.* рейсши́на; *сызым өстәле өстендәге* ~ рейсши́на на чертёжной доске́

ре́йтер *сущ. тех.* ре́йтер

рейтуз *сущ.* рейту́зы (*мн. ч.*); *йон* ~ шерстяны́е рейту́зы; *балалар ~ы* де́тские рейту́зы

рейхска́нцлер *сущ. ист.* рейхска́нцлер; *яңа* ~ но́вый рейхска́нцлер

рейхстаг *сущ. ист.* рейхста́г; ~ *утырышы* заседа́ние рейхста́га

реквизит *сущ. театр., юр.* реквизи́т || реквизи́тный; *театр ~ы* театра́льный реквизи́т; *сәхнә өчен ~ җитми* реквизи́т для сце́ны недоста́точен; ~ *цехы* реквизи́тный цех

реквизи́тор *сущ. театр.* реквизи́тор; ~ *вазифасы* до́лжность реквизи́тора

реквизи́ция *сущ.* реквизи́ция || реквизицио́нный; *шәхси автомашиналарга* ~ реквизи́ция ча́стных автомаши́н; ~ *отряды* реквизицио́нный отряд □ ~ **ясалу** *см.* **реквизицияләнү**; ~ **ясау** реквизи́ровать, производи́ть реквизи́цию

реквизи́цияләнү *страд. от* **реквизицияләү**; реквизи́роваться; быть реквизи́рованным; *~гән атлар* реквизицио́нные ло́шади, реквизи́рованные ло́шади

реквиза́цияләү *перех.* реквизи́ровать || реквиза́ция; *фронт өчен мотоциклларны ~* реквизи́ровать мотоци́клы для фро́нта

рекла́ма *сущ.* рекла́ма || рекла́мный; *сәүдә ~сы* торго́вая рекла́ма; *театр ~сы* театра́льная рекла́ма; *~лар бүлеге* рекла́мный отде́л; ~ *тактасы* рекла́мная доска́ □ ~ **ясау (тарату)** реклами́ровать; реклами́рование

рекла́малау *перех.* реклами́ровать || реклами́рование; *яңа товарларны ~* реклами́ровать но́вые това́ры; *спектакльне артык ~* разреклами́ровать (чрезме́рно реклами́ровать) спекта́кль

рекла́ция *сущ. книжн.* рекла́ция || рекламацио́нный; *сатып алган товарга ~* рекла́ция на ку́пленный това́р; ~ *суммасы* рекламацио́нная су́мма

рекла́мачы *сущ.* **1.** реклами́ст, реклами́стка; *сайлау алды ~лары* предвы́борные реклами́сты **2.** рекламода́тель; *~лар файдасына* в по́льзу рекламода́телей

рекогносцирóвка *сущ. воен.* рекогносцирóвка || рекогносцирóвочный; *атлы* ~ ко́нная рекогносцирóвка; *~га бару* ходи́ть на рекогносцирóвку; ~ *мәгълуматлары* рекогносцирóвочные да́нные □ ~ **ясау (үткәрү)** рекогносци́ровать; сде́лать, произвести́ рекогносцирóвку

рекогносцирóвкал|ау *перех.* рекогносци́ровать || рекогносцирóвка; *дошманның алгы позицияләрен ~* рекогносци́ровать передовы́е пози́ции проти́вника

рекогносцирóвкачы *сущ. воен.* рекогносцирóвщик; *~лар группасы* гру́ппа рекогносцирóвщиков

рекомендáция *сущ.* рекомендáция || рекомендáтельный; *см. тж.* **мәслихәт, тәкъдим, тәклиф**; *комсомол ~се* комсомо́льская рекомендáция; ~ *хаты* рекомендáтельное письмо́ □ ~ **бирү** дать рекомендáцию; рекомендовáть; ~ **бирүче** рекоменду́ющий

реконструктúв *прил.* реконструкти́вный; ~ *чаралар* реконструкти́вные мероприя́тия

реконстру́кция *сущ.* реконстру́кция || реконструкти́вный; *халык хуҗалыгына техник ~* техни́ческая реконстру́кция наро́дного хозя́йства; *завод ~се буенча белгеч* специали́ст по реконстру́кции заво́да; *хуҗалыкны үстерүдә ~ чоры* реконструкти́вный пери́од в разви́тии хозя́йства □ ~ **ясау (үткәрү)** *см.* **реконструкцияләү**

реконстру́кцияләнү *страд. от* **реконструкцияләү**; реконструи́роваться

реконстру́кциял|әү *перех.* реконструи́ровать || реконструи́рование; реконстру́кция; *Мәскәүне ~* реконструи́ровать Москву́

реконстру́кцияче *сущ.* специали́ст по реконстру́кции

рекорд *в разн. знач. сущ.* **1.** реко́рд || реко́рдный; *дөнья ~ы* мирово́й реко́рд; ~ *кую (биру)* установи́ть реко́рд; ~ *срокта тәмамлау* заверши́ть в реко́рдный срок **2.** *в знач. прил.* реко́рдный, явля́ющийся реко́рдом; ~ *тизлек* реко́рдная ско́рость

рекордлы *прил.* реко́рдный; ~ *уңыш алу* получи́ть реко́рдный урожа́й

рекордсмен *сущ.* рекордсме́н; *чаңгы спорты ~ы* рекордсме́н лы́жного спо́рта; *йөзүдә ~* рекордсме́н по пла́ванию

рекордчы *сущ.* рекордсме́н, рекордсме́нка; рекорди́ст, рекорди́стка || рекорди́стский; рекордсме́нский; ~ *булу* быть рекорди́стом, вы́йти в рекорди́сты

рекордчылык *сущ.* **1.** рекордсме́нство; *спортны ~ка гына әйләндерергә кирәкми* не на́до спорт превраща́ть в рекордома́нию, рекордсме́нство **2.** рекорди́зм; ~ *белән мавыгу* увлека́ться рекорди́змом

ре́крут *ист. сущ.* ре́крут; новобра́нец; *см. тж.* **никрут** || рекру́тский; ~ *җыю* набира́ть ре́крутов, брать в ре́круты; ~ *итеп алу* рекрути́ровать; *~ка (рекрут итеп) алыну* рекрути́роваться; ~ *яше* рекру́тский во́зраст

ре́крутлык *сущ. ист.* рекру́тчина, рекру́тство || рекру́тский; *~лыктан котылу* освободи́ться от рекру́тства; ~ *йөкләмәсе* рекру́тская пови́нность

ректификат *сущ. спец.* ректифика́т (очи́щенный спирт)

ректифика́тор *сущ. спец.* ректифика́тор (очища́ющий аппара́т)

ректифика́ция *сущ. спец.* ректифика́ция || ректификацио́нный; *спирт ~се* ректифика́ция спи́рта; *~ процессы* ректификацио́нный проце́сс

ректифика́ция|ләү *сущ. спец.* ректифици́ровать || ректифици́рование; ректифика́ция; *бензинны ~әү* ректифици́ровать бензи́н

ре́ктор *сущ.* ре́ктор || ре́кторский; *университет ~ы* ре́ктор университе́та; *~ урынбасары* замести́тель ре́ктора, проре́ктор; *~ кабинеты* ре́кторский кабине́т □ **~ булу (булып эшләү)** ре́кторствовать; ре́кторство; *~ дәрәҗәсе (урыны)* ре́кторство; до́лжность ре́ктора

ректорат *сущ.* ректора́т; *~ка чакыру* вы́звать в ректора́т; *~ утырышы* заседа́ние ректора́та

ре́кторлык *сущ.* ре́кторство || ре́кторский; *~так киту* оста́вить ре́кторство; *~ тәкъдим итү* предложи́ть ре́кторство (до́лжность ре́ктора); *~ вазифалары* ре́кторские обя́занности □ **~ итү** ре́кторствовать

реле *сущ. физ., тех.* реле́; *телеграф аппаратының ~се* реле́ телегра́фного аппара́та; *вакыт ~се реле́* вре́мени; *газлы ~* га́зовое реле́

рели́квия *сущ. книжн.* рели́квия; *семья ~се* семе́йная рели́квия; *узган көннәрнең ~се итеп саклау* храни́ть в ка́честве рели́квии про́шлого

реликт *сущ. книжн.* 1. рели́кт; *борынгы ~* рели́кт дре́вних эпо́х || *прил.* 2. рели́ктовый; *~ җәнлекләр* рели́ктовые зве́ри

рельеф *сущ. вразн. знач.* рельёф; *~ белән ясалган портрет* рельёфный портре́т; *дала ~ы* рельёф степи́

рельефлы *прил. в разн. знач.* рельёфный, вы́пуклый; с рельёфом; *~ тукыма* рельёфная ткань; *~ чигү* выши́ва́ть рельёфом; вы́шивка рельёфом; рельёфная вы́шивка; *Азиянең ~ картасы* рельёфная ка́рта Азии

рельефлылы|к *сущ.* рельёфность; *әсәрдәге образларның ~гы* рельёфность о́бразов произведе́ния

рельс *сущ.* рельс || ре́льсовый; *трамвай ~ы* трамва́йный рельс; *тимер юл ~лары* железнодоро́жные ре́льсы, ре́льсы желе́зной доро́ги; *контакт ~ы тех.* конта́ктный рельс; *~ корычы* ре́льсовая сталь; *~лар тоташмасы* стык ре́льсов; *~ профиле тех.* ре́льсовый про́филь □ **~ беркеткеч** *тех.* противоуго́н; **~ прокаткалау** прока́т ре́льсов || рельсо-прока́тный; **~ прокатлаучы** рельсопрока́тчик; **~ салу** путеукла́дка; **~ салучы** путеукла́дчик; **~ларның шуулы** *тех.* уго́н пути́; **~тан чыгу** 1. сойти́ с ре́льса (*о поезде*) 2. *перен.* разла́диться, расстро́иться (*о делах*)

ре́льслы *прил.* ре́льсовый; *~ юл* ре́льсовая доро́га, ре́льсовый путь; *~ транспорт* ре́льсовый тра́нспорт

рема́рка *сущ. лит. театр.* рема́рка; *~ларны төшереп уку* чита́ть без рема́рок; *режиссер ~лары* режиссёрские рема́рки

ремиз *сущ. спец.* реми́з; *см. тж.* **көре**

ремилитариза́ция *сущ. полит.* ремилитариза́ция; *~ үткәрү* проводи́ть ремилитариза́цию

ремилитариза́циялә̆ү *перех. полит.* ремилитаризи́ровать, ремилитаризова́ть || ремилитариза́ция; *илне ~* ремилитаризи́ровать страну́; ремилитариза́ция страны́

ремонт *сущ.* ремо́нт || ремо́нтный; *профилактик ~* профилакти́ческий ремо́нт; *~ка бирү* отда́ть в ремо́нт; *~ паркы* ремо́нтный парк; *~ эшләре* ремо́нтные рабо́ты □ **~ ясау (үткәрү)** ремонти́ровать, отремонти́ровать; проводи́ть ремо́нт; **~ (ясау) остасы** ма́стер по ремо́нту

ремо́нтара *прил.* межремо́нтный; *автомобильнең ~ йөреше* межремо́нтный пробе́г автомоби́ля

ремонтлан|у *страд. от* **ремонтлау**; ремонти́роваться, отремонти́роваться; *~ган вагон* отремонти́рованный ваго́н

ремонтлату *понуд. от* **ремонтлау**; заставля́ть/заста́вить ремонти́ровать; зака́зывать/заказа́ть ремо́нт, почи́нку

ремонтла|у *перех.* ремонти́ровать, отремонти́ровать; производи́ть/произвести́ ремо́нт, чини́ть || ремо́нт, ремонти́рование; почи́нка, ремонтиро́вка *разг.; квартираны ~у* ремонти́ровать кварти́ру; *~п чыгу* отремонти́ровать

ремонтчагы *прил.* ремонти́руемый; находя́щийся на ремо́нте; *~ өй* ремонти́руемый дом

ремонтчы *сущ.* ремо́нтник; *~лар бригадасы* брига́да ремо́нтников

ренегат *сущ. книжн.* ренега́т, ренега́тка; *эшчеләр хәрәкәте ~лары* ренега́ты рабо́чего движе́ния

ренегатлы|к *сущ. книжн.* ренега́торство || ренега́тский; *~гын яшерә* скрыва́ет своё ренега́тство; *~к тенденцияләре* ренега́тские тенде́нции

ренет *сущ. бот.* ренёт; *см. тж.* **ранёт**; *~ алмасы* я́блоко-ренёт; *«алтын ~» сорты* сорт «золото́й ранёт»

ренклод *сущ. бот.* ренкло́д (*сорт сливы*)

ре́нта *сущ. фин., экон.* ре́нта || ре́нтный; *җир ~сы* земе́льная ре́нта; *~ хисабына яшәү* жить за счёт ре́нты; *абсолют ~* абсолю́тная ре́нта; *дәүләт ~сы* государственная ре́нта; *~ фонды* ре́нтовый фонд

рента́бельле *прил. книжн.* рента́бельный; *~ эш* рента́бельная рабо́та; *~ хуҗалык* рента́бельное хозя́йство

рента́бельлек *сущ. книжн.* рента́бельность; *~не күтәрү* повы́сить рента́бельность; *~кә ирешү* достиже́ние рента́бельности

ре́нталы *сущ. фин.* ре́нтный; *~ заём* ре́нтный заём

рентген *сущ. в разн. знач.* рентге́н || 1) рентге́новский; *~нан карау* просве́чивать рентге́ном; *~ аппаратлары* рентге́новские аппара́ты; *~ кабинеты* рентге́новский кабине́т; *~ трубкасы* рентге́новская тру́бка 2) рентгено- ; *~ техникасы* рентгенотехника □ **~ нурлары** рентге́новские (рентге́новы) лучи́

рентгенограмма *сущ. спец.* рентгенограмма; *~ анализы нәтиҗәсе* результа́т ана́лиза рентгенограммы

рентгенографик *прил. спец.* рентгенографи́ческий; *~ тикшеренүләр* рентгенографи́ческие иссле́дования; *~ анализ* рентгенографи́ческий ана́лиз

рентгенография *сущ. спец.* рентгенография || рентгенографи́ческий; *металлар ~се* рентгенография мета́ллов; *~ булеге* рентгенографи́ческий отде́л; отде́л рентгенографии

рентгено́лог *сущ. мед.* рентгено́лог; *~ка күренү* показа́ться рентгено́логу; *~ларның зональ киңәшмәсе* зона́льное совеща́ние рентгено́логов

рентгенологик *прил. спец.* рентгенологи́ческий; *~ тикшеренүләр* рентгенологи́ческие иссле́дования

рентгенология *сущ. мед.* рентгенология || рентгенологи́ческий; *хәзерге заман ~сенең үсеше* разви́тие совреме́нной рентгенологии; *~ кабинеты* рентгенологи́ческий кабине́т

рентгеноскопи́я *сущ. мед.* рентгеноскопи́я || рентгеноскопи́ческий; *~ методы* рентгеноскопи́ческий ме́тод; *~ аппараты* рентгеноскопи́ческий аппара́т

рентгенотерапи́я *сущ. мед.* рентгенотерапи́я; *хәзерге медицинада ~нең роле* роль рентгенотерапии в совре́менной медици́не

ребра́ф *сущ. неол.* ребра́ф; *~ ярдәмендә капилляр-ларда кан күламен тикшерү* изуче́ние сте́пени наполне́ния кро́вью капилля́ров при по́мощи ребра́фа

реогра́фия *сущ. неол.* реогра́фия; *~дән файдалану* испо́льзование реогра́фии

ребо́метр *сущ. спец.* ребо́метр; *~ ярдәмендә газның агым тизлеген үлчәү* измере́ние ско́рости протека́ния га́за при по́мощи ребо́метра

реорганиза́ция *сущ.* реорганиза́ция || реорганизацио́нный; *армия һәм флотта ~* реорганиза́ция а́рмии и фло́та; *~ чоры* реорганизацио́нный пери́од

реорганиза́цияләү *перех.* реорганизова́ть || реорганиза́ция; *укыту системасын ~* реорганизова́ть систе́му обуче́ния

реостат *сущ. спец.* реоста́т; *рычаглы ~* рыча́жный реоста́т

репарацион *прил. полит.* репарацио́нный; *~ түләүләр* репарацио́нные платежи́; *~ план* репарацио́нный план

репара́ция *сущ. полит.* репара́ция || репарацио́нный; *~ таләп итү* тре́бовать репара́ции; *~ түләү* плати́ть репара́цию; *~ суммасы* репарацио́нная су́мма

репатриант *сущ.* репатриа́нт, репатриа́нтка; *~ларны торак белән тәэмин итү* обеспе́чить репатриа́нтов жильём

репатриа́ция *сущ.* репатриа́ция; *~ бүлеге* отде́л репатриа́ции; *~ проблемасын хәл итү* разреши́ть пробле́му репатриа́ции

репатриа́цияләнү *страд. от* **репатрацияләү**; репатрии́роваться; *~гән әсирләр партиясен кабул итү* принима́ть па́ртию репатрии́рованных пле́нных

репатриа́цияләү *перех.* репатрии́ровать || репатриа́ция; *хәрби әсирләрне ~* репатрии́ровать военнопле́нных

репертуар *сущ.* репертуа́р || репертуа́рный; *яңа ~* но́вый репертуа́р; *классик ~* класси́ческий репертуа́р; *~ планы* репертуа́рный план; *~ пьесасы* репертуа́рная пье́са

репети́тор *сущ.* репети́тор, репети́торша; *математиканы вйрәтүче ~* репети́тор по матема́тике; *уларын югары уку йортына әзерләү өчен ~ алганнар* взя́ли репети́тора для подгото́вки сы́на в вуз

репети́торлык *сущ.* репети́торство || репети́торский; *~ белән шөгыльләнү* занима́ться репети́торством; *~ акчасы* репети́торские за́работки □ **~ итү** репети́торствовать, репети́торство

репети́ция *сущ.* репети́ция || репетицио́нный; *~ вакыты* вре́мя репети́ции; *генераль ~* генера́льная репети́ция; *~ ясау (үткәрү)* репети́ровать □ **~ залы** репетицио́нный зал

репети́цияче *сущ.* уча́стник репети́ции, репети́рующий

реплантация *сущ. неол. мед.* реплантация; *теш ~сен стоматология практикасына кертү* ввести́ в стоматологи́ческую пра́ктику реплантации зу́ба

ре́плика *сущ. в разн. знач.* ре́плика; *~ ташлау* пода́ть, бро́сить ре́плику

репортаж *сущ.* репорта́ж; *радио аша ~* репорта́ж по ра́дио; *футбол кырыннан ~* репорта́ж с футбо́льного по́ля

репортёр *сущ.* репортёр, репортёрша || репортёрский; *радиокомитеттан килгән ~* репортёр из радиокомите́та; *~ булу* быть репортёром, репортёрствовать; *~ эшчәнлеге* репортёрская де́ятельность, репортёрство

репортёрлык *сущ.* репортёрство || репортёрский; *~ белән тамак туйдыру* добыва́ть сре́дства на жи́знь репортёрством; *~ хезмәте (эше)* репортёрская рабо́та

репрессив *прил.* репресси́вный; *~ чаралар* репресси́вные ме́ры

репре́ссия *сущ.* репре́ссия || репресси́вный; кара́тельный; *~ чаралары* репресси́вные (кара́тельные) ме́ры

репре́ссияләү *перех.* репресси́ровать || репре́ссия; *студентларны ~* репресси́ровать студе́нтов; *~ политикасы* поли́тика репре́ссий

реприз, репри́за *сущ. муз.* репри́за; *~ билгесе (но́тный)* знак репри́зы; *клоун өчен язылган ~* репри́за для кло́уна

репринт *сущ. неол.* репри́нт (*репродуцирование книг, чертежей электрическим способом*)

репроду́ктор *сущ.* репроду́ктор; *урамдагы ~* у́личный репроду́ктор

репродукцион *прил. спец.* репродукцио́нный; *~ объектив тех.* репродукцио́нный объекти́в

репроду́кция *сущ. в разн. знач.* репроду́кция || репродукцио́нный; репродукти́вный; *~не төп нөсхә белән чагыштыру* сравни́ть репроду́кцию с по́длинником; *~ эшләре* репродукцио́нные рабо́ты; *~ процессы* репродукти́вный проце́сс □ **~ ясау** репроду́цировать

репроду́кцияләнү *страд. от* **репродукцияләү**

репроду́кцияләү *перех. спец.* репроду́цировать || репроду́цирование; *буяулы рәсемнәрне ~әү* репроду́цировать произведе́ния жи́вописи; репроду́цировать карти́ны; *тавышны ~әү тех.* воспроизведе́ние зву́ка

репс *сущ.* репс; *~ белән тышланган диван* дива́н, оби́тый ре́псом; ре́псовый дива́н || *прил.* ре́псовый; *~ тышлык* ре́псовая оби́вка

рептилия *сущ. зоол.* рептилия; *борынгы ~ларне өйрәнү* изуче́ние дре́вних рептилий

репута́ция *сущ.* репута́ция; *~гә тап төшерү, ~не бозу* испо́ртить (запятна́ть) *чью-л.* репута́цию

репута́цияле *прил.* име́ющий (*какую-л.*) репута́цию; по́льзующийся (*какой-л.*) репута́цией; с (*какой-л.*) репута́цией; *яхшы ~ гаилә* семья́ с хоро́шей репута́цией

реском (республика́нский комите́т) *сущ.* реско́м (республика комитеты)

ре́слер *сущ. спорт.* ре́слер, спортсме́н по ре́слингу

ре́слинг *сущ. спорт.* ре́слинг; *~ — профессиональ көрәшнең бер төре* ре́слинг — оди́н из ви́дов профессиона́льной борьбы́

респира́тор *сущ.* респира́тор || респира́торный; *индивидуаль саклану чарасы буларак ~ның әһәмияте* роль (значе́ние) респира́тора как сре́дства индивидуа́льной защи́ты; *~ фильтры* респира́торный фильтр

респирацияле *прил. лингв.* респирато́рный; *~ аваз-лар* респирато́рные зву́ки

респу́блика *сущ. в разн. знач.* респу́блика || республика́нский; *демократик ~* демократи́ческая респу́блика; *идарә итүнең ~ формасы* республика́нская фо́рма правле́ния; *~ гербы* республика́нский герб

респу́бликакүләм *прил.* общереспублика́нский; республика́нский; *~ ярышлар* общереспублика́нские (республика́нские) соревнова́ния

респу́бликачы *сущ. ист.* **1.** республика́нец; *~лар җиңүе* побе́да республика́нцев **2.** *в знач. прил.*

республика́нский; ~ *хөкүмәт* республика́нское прави́тельство; ~ *партияләр* республика́нские па́ртии

рессор *сущ.* рессо́ра || рессо́рный; *автомобиль ~лары* рессо́ры автомоби́ля; *винтсыман* ~ винтообра́зная рессо́ра; ~ *болты* рессо́рный болт; ~ *корычы* рессо́рная сталь

рессорлы *прил.* рессо́рный; ~ *экипаж* рессо́рный экипа́ж; экипа́ж на рессо́рах

рессорлык *прил.* рессо́рный; кото́рый идёт на рессо́ры; ~ *корыч* рессо́рная сталь

реставра́тор *сущ. в разн. знач.* реставра́тор; *тәжрибәле* ~ о́пытный реставра́тор; *иске картиналар ~ы* реставра́тор стари́нных карти́н; *капитализм ~лары* реставра́торы капитали́зма

реставра́торлык *сущ.* реставра́торство 1) *иск.* реставрацио́нный 2) *полит.* реставра́торский; *сынлы сәнгатьтә* ~ реставра́торство в жи́вописи; ~ *сәләәте* реставрацио́нная спосо́бность; ~ *ниятләре* реставра́торские наме́рения (за́мыслы)

реставрацион *прил.* реставрацио́нный; ~ *эшләр* реставрацио́нные рабо́ты

реставра́ция *сущ. вразн. знач.* реставра́ция || реставрацио́нный; ~ *эшләре* реставрацио́нные рабо́ты □ ~ **ясау** реставри́ровать ◊ ~ **дәвере** *ист.* эпо́ха реставра́ции (например, во Фра́нции)

реставра́цияләнү *страд. от* **реставра́цияләү**; реставри́роваться; *~гән портрет* реставри́рованный портре́т

реставра́цияләү *перех. в разн. знач.* реставри́ровать || реставра́ция; *борынгы чиркәүне* ~ реставри́ровать стари́нную це́рковь; реставра́ция стари́нной це́ркви

реставра́цияче *сущ. в разн. знач.* реставра́тор; *~ләр группасы* гру́ппа реставра́торов

ресторан *сущ.* рестора́н || рестора́нный; *беренче класс ~нар* первокла́ссные рестора́ны; *«Идел» ~ы* рестора́н «Во́лга»; ~ *бәясе* рестора́нная цена́

ресурс *сущ. в разн. знач.* ресу́рс; *эчке ~лар* вну́тренние ресу́рсы; *финанс ~лары* фина́нсовые ресу́рсы; *табигый ~лар* приро́дные ресу́рсы

ретинит *сущ. мед.* ретини́т (воспале́ние сетча́тки гла́за)

ретóрта *сущ.* ретóрта; *~га сыеклык салу* налива́ть жи́дкость в ретóрту

ретрансля́тор *сущ. тех.* ретрансля́тор; *радиодулкынарны ~ ярдәмендә ераккa тапшыру* посыла́ть (переда́вать) радиово́лны на да́льние расстоя́ния при по́мощи ретрансля́тора

ретрансляцион *прил.* ретрансляцио́нный; ~ *радиостанция* ретрансляцио́нная радиоста́нция

ретрансля́ция *сущ.* ретрансля́ция || ретрансляцио́нный; ~ *мәсьәләсен хәл итү* реша́ть вопро́с ретрансля́ции; ~ *җайланмасы* ретрансляцио́нная устано́вка

ретрансля́цияләү *перех.* ретрансли́ровать || ретрансля́ция; *Мәскәү тапшыруларын* ~ ретрансли́ровать моско́вские переда́чи

ретроград *сущ. книжн.* ретрогра́д, ретрогра́дка, реакционе́р || *прил.* ретрогра́дный; реакцио́нный; ~ *карашлар* ретрогра́дные взгля́ды

ретроградлык *сущ. книжн.* ретрогра́дство; *~та гаеплә̆ү* обвини́ть в ретрогра́дстве

ретроспектив *при. книжн.* ретроспекти́вный; *мәсьәлә не ~ яктырту* ретроспекти́вное освеще́ние вопро́са

ретроспе́кция *сущ. книжн.* ретроспе́кция; ~ *рубрикасы белән* под ру́брикой ретроспе́кции

ре́тушь *сущ.* ре́тушь; ~ *яхшы чыккан* ре́тушь получи́лась уда́чной □ ~ **белән төзәтү** ретуши́ровать; ~ **ясау** *см.* **ре́тушьлау**; ~ **ясаучы** ретушёр; *см. тж.* **ре́тушьчы**

ре́тушьла|у *перех.* ретуши́ровать || ретуши́рование; *негативны ~у* ретуши́ровать негати́в; *~п төзәту* ретуши́ровать; *~у остасы* ма́стер по ретуши́рованию (ре́туши), ретушёр

ре́тушьчы *сущ.* ретушёр; *~лар группасы* гру́ппа ретушёров

реферат *сущ.* рефера́т || рефера́тный, реферати́вный; ~ *язу* писа́ть рефера́т; рефери́ровать; *язучының тормыш юлы хакында* ~ рефера́т о жи́зненном пути́ писа́теля; ~ *хәлендә (формасында, рәвешендә)* в фо́рме рефера́та

рефератив *прил.* реферати́вный; ~ *журнал* реферати́вный журна́л

рефератчы *сущ.* референ́т; лицо́, чита́ющее рефера́т; *~ның фикере буенча* по мне́нию референ́та

референдум *сущ. полит.* референ́дум; *тынычлыкны яклау мәсьәләсендә бөтенхалык ~ы* всенаро́дный референ́дум по вопро́су защи́ты ми́ра

референт *сущ. книжн.* референ́т; *төзелеш начальнигы ~ы* референ́т нача́льника строи́тельства; ~ *вазифасы утәү* выполня́ть обя́занность референ́та

референция *сущ. спец.* референ́ция (о́тзыв, рекомендация); *элекгеге эш урыныннан алган* ~ референ́ция, полу́ченная с пре́жнего ме́ста рабо́ты

рефери *сущ. спорт.* ре́фери, рефери́; судья́; *баскетбол ярышларында ~ вазифасын миңа тапшырдылар* обя́занности рефери́ в соревнова́ниях по баскетбо́лу поручи́ли мне

рефлекс *сущ. физиол.* рефле́кс; *шартлы* ~ усло́вный рефле́кс; *яңа төр ~ тудыру* вызыва́ть (выраба́тывать) но́вый вид рефле́кса

рефле́ксия *сущ. псих.* рефле́ксия; *поэзиядә* ~ рефле́ксия в поэ́зии

рефле́кслы *прил. физиол.* рефлекто́рный; рефлекси́вный, рефлекти́вный (о движе́нии); ~ *реакция* рефлекто́рная реа́кция; ~ *хәрәкәт белән* рефлекти́вным движе́нием □ ~ **схема** *физ.* рефле́ксная схе́ма

рефлексо́лог *сущ. спец.* рефлексо́лог; *~лар фикеренчә* по мне́нию рефлексо́логов

рефлексоло́гия *сущ. спец.* рефлексоло́гия || рефлексологи́ческий; ~ *белгече* специали́ст по рефлексоло́гии, рефлексо́лог; ~ *кабинеты* рефлексологи́ческий кабине́т

рефлектив *прил.* рефлекти́вный, рефлекси́вный; рефлекто́рный; ~ *хәрәкәтләр (реакция)* рефлекти́вные (рефлекто́рные) движе́ния (реа́кция)

рефле́ктор I *сущ. в разн. знач.* рефле́ктор || рефлекто́рный; *лампага ~ кую* наде́ть на ла́мпу рефле́ктор; *булмәне ~ белән җылыту* обогрева́ть ко́мнату рефле́ктором; ~ *көзгесе* рефлекто́рное зе́ркало

рефлекто́р II *прил.* рефлекто́рный, рефлекти́вный, рефлекси́вный; ~ *реакция* рефлекто́рная реа́кция; ~ *хәрәкәтләр* рефлекто́рные (рефлекти́вные) движе́ния

рефо́рма *сущ. в разн. знач.* рефо́рма || 1) реформа́торский 2) рефо́рменный; *парламент ~сы* парла́ментская рефо́рма; *орфографиягә* ~ рефо́рма орфогра́фии (правописа́ния); *~лар юлы* реформа́торский путь; ~ *чоры* рефо́рменный пери́од; *~га кадәрге (кадәр булган)* дорефо́рменный; *~дан соңгы* порефо́рменный, случи́вшийся по́сле рефо́рмы □ ~ **ясау (үткәрү, кертү)** реформи́ровать, преобразова́ть путём рефо́рмы, проводи́ть рефо́рму

рефо́рмалау *перех. см.* **рефо́рмалаштыру; рефо́рма ясау (кертү, үткәрү);** *дини мәктәпләрне ~* реформи́ровать религио́зные уче́бные заведе́ния (медресе́)

рефо́рмалаштыру *перех.* реформи́ровать || реформи́рование; *динне ~* реформи́ровать рели́гию

реформат *сущ. рел.* реформа́тор || реформа́торский; протеста́нтский; *~лар* протеста́нты; *~ чиркәве* реформа́торская це́рковь

реформа́тор *сущ.* реформа́тор; преобразова́тель; *К. Насыйри — татар теленең береңче ~ы* К. Насыри́ — пе́рвый реформа́тор татарского языка́

реформа́торлык *сущ.* реформа́торство || реформа́торский; *~ омтылышлары* реформа́торские устремле́ния; реформа́торские попы́тки; *~ идеяләре* реформа́торские иде́и

реформацион *прил.* реформа́тский; *~ идеяләр* реформа́тские иде́и; *~ хәрәкәт* реформа́тское движе́ние

реформа́ция *сущ. ист.* реформа́ция || реформа́тский; *феодализмга каршы көрәштә ~нең тоткан урыны* роль реформа́ции в борьбе́ про́тив феодали́зма; *Европадагы ~ хәрәкәте* реформа́тское движе́ние в Евро́пе

рефо́рмачылык *сущ. полит.* реформи́зм || реформи́стский; *~ка каршы көрәш* борьба́ про́тив реформи́зма; *~ партияләре* реформи́стские па́ртии

реформизм *сущ. полит.* реформи́зм || реформи́стский; *буржуаз ~* буржуа́зный реформи́зм; *~ программасы* реформи́стская програ́мма; *~ политикасы* реформи́стская поли́тика

реформист *сущ. полит.* реформи́ст, реформи́стка; сторо́нник реформи́зма

реформи́стик *прил. полит.* реформи́стский; *~ теория* реформи́стская тео́рия; *~ практика* реформи́стская пра́ктика

реформистлык *сущ. полит.* явле́ние и́ли сво́йство реформи́зма || реформи́стсткий; *~ тактикасы* реформи́стская та́ктика

рефракто́метр *сущ. физ.* рефракто́метр; *лаборатория ~ы* лаборато́рный рефракто́метр

рефра́ктор *сущ. физ.* рефра́ктор || рефра́кторный; *~ны Айга юнәлтү* напра́вить рефра́ктор в сто́рону Луны́; *~ объективы* рефра́кторный объекти́в

рефракцион *прил. физ.* рефракцио́нный; *~ күренешләр* рефракцио́нные явле́ния

рефра́кция *сущ. физ., астр.* рефра́кция; *күрү ~се* рефра́кция гла́за; *яктылык (тавыш) ~се* рефра́кция све́та (зву́ка)

рефрен *сущ. филол., муз.* рефре́н; *см. тж.* **кушымта, кушым;** *~ өлешен бергәләп кабатлау* хо́ром повтори́ть рефре́н

рефрижера́тор *сущ. спец.* **1.** рефрижера́тор || рефрижера́торный; *итне ~да тоту (саклау)* держа́ть мя́со в рефрижера́торе **2.** *в знач. прил.* рефрижера́торный, явля́ющийся рефрижера́тором; *~ җайланма* рефрижера́торная установка

рефрижера́торлы *прил. спец.* с рефрижера́тором; рефрижера́торный; *~ судно* рефрижера́торное су́дно

рецензент *сущ.* рецензе́нт; *диссертация ~ы* рецензе́нт диссерта́ции; *~ бәяләмәсе* о́тзыв рецензе́нта

рецензентлык *сущ.* до́лжность, роль рецензе́нта || рецензе́нтский; *~ гонорары* рецензе́нтский гонора́р

рецензия *сущ.* рецензия; *яңа китапка ~* рецензия на но́вую кни́гу; *~гә бирү* отда́ть на рецензию; *~ язу* писа́ть рецензию, рецензи́ровать

рецензияләү *перех.* рецензи́ровать || рецензи́рование; *спектакльне ~ү* рецензи́ровать спекта́кль; *~п чыгу* прорецензи́ровать

рецепт *сущ. в разн. знач.* реце́пт || реце́птный; *күзлеккә ~* реце́пт на очки́; *тәрбия эшендә әзер ~лар юк* в де́ле воспита́ния нет гото́вых реце́птов; *~ бланкы* реце́птный бланк; *~ печате* реце́птная печа́ть

рецепта́р *сущ.* рецепта́р; *аптеканың ~ы* рецепта́р апте́ки; *~ кыз* де́вушка-рецепта́р

реце́птор *сущ. физиол.* реце́птор; *күрү ~ы* зри́тельный реце́птор

рецепту́ра *сущ.* рецепту́ра || рецепту́рный; *хушбуйлар ~сы* рецепту́ра духо́в; *~ белешмәләре* рецепту́рные спра́вки

рецидив *в разн. знач.* **1.** *сущ.* рециди́в; *бизгәк (авыруы) ~ы* рециди́в маляри́и **2.** *прил.* рециди́вный; *~ күренешләр* рециди́вные явле́ния; *~ җинаять* рециди́вное преступле́ние

рецидивист *сущ. юр.* рецидиви́ст, рецидиви́стка; *~ны хөкем итү* суди́ть рецидиви́ста

речитатив *сущ. муз.* речитати́в

речь *сущ. разг.* речь, выступле́ние; *тәбрикләү рече белән чыгу* вы́ступить с приве́тственной ре́чью; *речь сөйләү (тоту)* выступа́ть с ре́чью, держа́ть речь

реэвакуа́ция *сущ.* реэвакуа́ция || реэвакуацио́нный; *~ мәсьәләсе* вопро́с реэвакуа́ции; *~ комиссиясе* реэвакуацио́нная коми́ссия

реэвакуа́цияләнү *страд. от* **реэвакуацияләү;** реэвакуи́роваться; быть реэвакуи́рованным; *~гән кешеләр* реэвакуи́рованные лю́ди

реэвакуа́цияләү *перех.* реэвакуи́ровать || реэвакуа́ция; *заводны ~* реэвакуи́ровать завод

реэксперт *сущ. книжн.* реэксперт; *бодай ~ы* реэксперт пшени́цы

реэмигрант *сущ. книжн.* реэмигра́нт, реэмигра́нтка; *~ әрмәннәр* арме́не-реэмигра́нты

реэмигра́ция *сущ. книжн.* реэмигра́ция

реэмигра́цияләү *перех. книжн.* реэмигри́ровать, верну́ть эмигра́нтов на ро́дину || реэмигра́ция

риа *сущ. см.* **ри́я**

риал *сущ.* риа́л (де́нежная едини́ца Ира́на)

риба *сущ. уст. книжн.* **1.** лихои́мство; *~ илә мал казану* 1) разбогате́ть лихои́мством 2) жить на проце́нты **2.** незако́нная при́быль □ *~* **алу** получа́ть проце́нты со ссу́ды; **~га бирү** ссужа́ть под проце́нты

рибахур *сущ. уст. книжн.* ростовщи́к

рибачы *сущ. уст. книжн.* ростовщи́к, взя́точник; *см. тж.* **рибахур**

рибачылык *сущ. уст. книжн.* **1.** ростовщи́чество **2.** взя́точничество; *~ кылу* занима́ться взя́точничеством, брать взя́тки

ривая *сущ. уст. см.* **риваять**

риваять *сущ.* **1.** *фольк.* преда́ние; леге́нда, сказа́ние; ве́рсия; *борынгыдан килгән ~* дре́внее преда́ние; *Казан тарихына караган ~лар* леге́нды (ве́рсии) по исто́рии Каза́ни; *татар (халык) ~ләре* преда́ния татарского наро́да **2.** *разг.* слух, молва́; ска́зка (*перен.*); *тереклек суы хакындагы ~лар* ска́зки о живо́й воде́ □ *~* **итү (кылу)** повествова́ть; расска́зывать об исто́рии *чего-л.*, об истори́ческих собы́тиях

риваятче *сущ.* скази́тель, скази́тельница; расска́зчик, расска́зчица леге́нд, преда́ний

ригая *сущ. книжн.* внима́ние, внима́тельное отноше́ние *к чему-л.*; соблюде́ние *чего-л.*, подчине́ние пра́вилам *чего*; уваже́ние зако́нов и т. п.; *олылар сүзенә*

~ внима́тельное отноше́ние к слова́м ста́рших; *йолаларга ~ йөзеннән* из уваже́ния к обы́чаям, тради́циям □ ~ **итәрлек** досто́йный уваже́ния; ~ **итү (кылу)** 1. внима́тельно относи́ться *к чему-л.;* соблюда́ть *что,* подчиня́ться *чему,* сле́довать *чему; синең киңәшеңне ~ итеп* сле́дуя твоему́ сове́ту; *тәртипне ~ итү* соблюда́ть (блюсти́) поря́док 2. уважа́ть, почита́ть *кого-л.;* ува́жить *кого-л.; аналарны ~ кылу* уважа́ть матере́й; ~ **күрсәтү** *см.* **ригая итү** 2; ~ **күрү** встреча́ть почёт и уваже́ние, по́льзоваться почётом и уваже́нием

ригаяле *прил. уст.* внима́тельный; чу́ткий, учти́вый, почти́тельный; уважи́тельный; *балаларны олыларга карата ~ итеп тәрбияләү* воспи́тывать дете́й почти́тельными к ста́ршим

ригаятән *перех. уст.* почти́тельно, с уваже́нием; из уваже́ния; *ата-ананы ~* из уваже́ния к твои́м роди́телям

ригаять *сущ. уст. см.* **ригая**; *нәзафәткә ~* соблюде́ние гигие́ны

ригаятькяр *прил. уст. книжн. см.* **ригаяле**

ригаятьсез *прил. уст.* неучти́вый, непочти́тельный, невнима́тельный; неприве́тливый; *~ адәмнәр* неприве́тливые лю́ди; *~ мөнәсәбәт* невнима́тельное отноше́ние

ригаятьче *сущ. уст.* учти́вый, внима́тельный, предупреди́тельный челове́к; ока́зывающий уваже́ние к други́м

рида *сущ. уст.* широкопо́лая плащ-оде́жда де́рвишей; ри́за

ридван *сущ.* 1. *диал.* больша́я теле́га для перево́зки снопо́в, се́на, соло́мы и т.п. 2. *ист.* рыдва́н (больша́я каре́та для да́льних пое́здок)

ридикюль *сущ.* ридикю́ль; *бизәкле ~* разукра́шенный ридикю́ль

ри́за *сущ.* ри́за; *атлас ~ кигән поп* поп в атла́сной ри́зе; *патша ~сы* ца́рская ри́за

риза *модальн. сл.* 1. 1) согла́сен *с кем-л., чем-л.; бөтенесе белән дә ~* со всем согла́сен; *төнлә эшләргә дә ~* согла́сен и но́чью рабо́тать; *кандала кан эчү өчен ярыкта яшәргә дә ~ посл.* клоп согла́сен (гото́в) и в щёлочке жить, лишь бы кровь пить 2) *в знач. прил.* согла́сный; согласи́вшийся; *укырга китәргә ~ кешеләр* лю́ди, согла́сные (согласи́вшиеся) пое́хать учи́ться 2. 1) дово́лен *чем;* согла́сен, удовлетворён *чем;* дово́льствоваться *чем; үз вендә кара икмәккә ~* в своём до́ме (у себя́ до́ма) согла́сен и на чёрный хле́б; *тормышыннан ~ тугел* не дово́лен свое́й жи́знью; *азга да ~* дово́льствуется ма́лым 2) *в знач. прил.* дово́льный, удовлетворённый; *эшеннән ~ кешеләр* лю́ди, дово́льные свое́й рабо́той || *сущ. см.* **ризалык**; *ата-анасы ~сыннан башка* без согла́сия роди́телей; *ике якның ~сы белән* по обою́дному согла́сию □ ~ **булу** 1. согласи́ться *на что-л.;* дать согла́сие, быть согла́сным 2. быть дово́льным, удовлетворённым; дово́льствоваться; ~ **итү** 1. *см.* **ризалату** 2. удовлетвори́ть, дать удовлетворе́ние

ризаландыру *см.* **ризалату**; *укырга китәргә ~* уговори́ть пое́хать учи́ться

ризалан|у *неперех. см.* **риза булу**; *тиз генә ~мады* не сра́зу согласи́лся

ризалат|у *перех.* 1. угова́ривать/уговори́ть; склоня́ть/склони́ть *к чему-л.* и́ли *на что-л.;* получа́ть/получи́ть согла́сие *на что-л.; хакын төшерергә ~у* склони́ть к усту́пкам (сбить це́ну); *бергә яшәргә ~а алмады* не смог уговори́ть жить вме́сте 2. рассчи́тываться/рассчита́ться, распла́чиваться/расплати́ться; удовлетвори́ть *чьё-л.* тре́бование за (его́) рабо́ту и́ли в ку́пле-прода́же; *өенә бер сыер биреп ~тым* рассчита́лся коро́вой за его́ дом; *эше өчен кулмәклек биреп ~тым* удовлетвори́л её, отда́в за рабо́ту материа́л на пла́тье

ризалаш|у *неперех.* 1. согласи́ться, прийти́ к обою́дному согла́сию; вы́разить своё согла́сие *с кем-л., чем-л.; өйне сатарга ~тык* согласи́лись прода́ть дом; *бу фикерең белән ~а алмыйм* не могу́ согласи́ться с э́тим твои́м мне́нием 2. согласи́ться, дать согла́сие *на что-л.; см. тж.* **риза булу** 1; *операциягә ~у* согласи́ться на опера́цию; *иртәгә эшкә чыгарга ~тык* мы согласи́лись за́втра вы́йти на рабо́ту 3. быть дово́льным, удовлетворённым; дово́льствоваться; *ачыксаң азга да ~асың посл. букв.* проголода́ешься, дово́льствуешься и ма́лым

ризалы|к *сущ.* 1. согла́сие *на что-л.;* разреше́ние, позволе́ние; *җитәкченең ~гын сорау* проси́ть у руководи́теля разреше́ния; *~к белдереп, кыз башын иде* в знак согла́сия де́вушка склони́ла го́лову; *сезнең ~к белән* с ва́шего позволе́ния (разреше́ния) 2. жела́ние, во́ля; согла́сие; *үз ~гы белән китте* он ушёл по свое́й (со́бственной до́брой) во́ле; *ике якның да ~гы белән* по обою́дному согла́сию (жела́нию) 3. благослове́ние; *ата-ананың ~гы* благослове́ние роди́телей 4. удовлетворённость; удовлетворе́ние; *күңел ~гы өчен* ра́ди удово́льствия души́, ра́ди своего́ удовлетворе́ния; для души́; *алла ~гы өчен* ра́ди бо́га □ **~к (~гын) алу** 1. получа́ть/получи́ть согла́сие, разреше́ние, благослове́ние *на что;* благослови́ться 2. уговори́ть, склони́ть *к чему-л. на что-л.;* убеди́ть; **(~гы) белән** 1. с согла́сия, с ве́дома; по разреше́нию; **~ктан (~гыннан) башка** без ве́дома 2. по до́брой во́ле; **~к бирү (белдерү)** 1. дать (изъяви́ть) согла́сие *на что-л.* 2. разреши́ть, дать разреше́ние *на что-л.* позво́лить *что-л.* 3. благослови́ть/благослови́ть

ризалыксыз *нареч.* без разреше́ния *кого-л.;* без согла́сия; ~ *эшләнгән эш* де́ло, вы́полненное без разреше́ния

ризасыз *нареч. см.* **ризалыксыз**; ~ *олы юлга чыкмыйлар* без разреше́ния не выхо́дят в да́льнюю доро́гу || *прил.* недово́льный; ~ *кыяфәттә* с недово́льным ви́дом; ~ *тавыш белән җавап кайтарды* отве́тил недово́льным го́лосом

ризасызлык *сущ.* 1. недово́льство, несогла́сие (разла́д, ссо́ра); *үзара ~* несогла́сие ме́жду собо́й 2. недово́льство, проте́ст; волне́ние, броже́ние (мно́гих); *үз-үзеңә ~* недово́льство собо́й; *эшчеләр арасында ~ башланды* среди́ рабо́чих начало́сь броже́ние □ **~ авазы** ро́пот, слова́ недово́льства (проте́ста); ~ **белдерү** 1. выска́зывать (выража́ть) недово́льство, проте́ст; роптать, возропта́ть *поэт.* 2. протестова́ть

ризван *сущ. рел.* ризва́н (сто́рож ра́йского са́да; а́нгел, стоя́щий на стра́же у воро́т ра́я)

ризы|к *сущ.* 1. пи́ща, хлеб, еда́, ку́шанье; съестны́е припа́сы; продово́льствие, прови́зия; пищевы́е проду́кты; *үзенә ~к табу өчен* для добыва́ния себе́ пи́щи; *ашамый тамак туймый, эшләми ~к булмый посл.* не пое́в, сыт не бу́дешь, без труда́ хлеб не добу́дешь; *~к белән тулы өстәлләр* столы́, по́лные яств 2. пропита́ние, хлеб насу́щный; *көндәлек ~к* каждодне́вное пропита́ние 3. *см.* **нәфәка**; *~к булса* е́сли нам сужде́но, е́сли предназна́чено нам (о пи́ще), е́сли сужде́но жить, е́сли поживём ◊ **~к киселү (өзелү, бетү)** 1. теря́ть исто́чник дохо́да, оста́ться без хле́ба (пи́щи) 2. наступле́ние сме́рти, кончи́на; ~ *киселмәгән булса, кайтыр әле* е́сли

суждено́ быть живо́му, вернётся; бу́дет жив — вернётся; **~гын кисү (өзү, кыю)** 1. лиши́ть исто́чников дохо́да, оста́вить без хле́ба (пи́щи) 2. прерва́ть жизнь, существова́ние, уби́ть; **~гын киң булсын!** да воздаст тебе́ бог сто́рицей *букв.* да бу́дет хлеб твой оби́льный; **~к тарта** тя́нет *куда-л.;* судьба́ направля́ет; **~к тарту** по судьбе́, по во́ле судьбы́ (о переме́не ме́ста жи́тельства); **~к тартып китерде** судьба́ привела́; **~к үтмәү** *см.* **тамактан үтмәү, тамакка бармау; ~ктан олы түгелсең** возда́й пи́ще до́лжное; не отка́зывайся от еды́, сади́сь и отве́дай; не пренебрега́й пи́щей

ризыкландыр|у *перех. разг.* корми́ть, пита́ть; обеспе́чивать едо́й, содержа́ть || обеспе́чение, содержа́ние; *әле һаман ата-анасы ~ып тора* всё ещё ко́рмят роди́тели, всё ещё на иждиве́нии роди́телей

ризыклан|у *неперех.* 1. 1) пита́ться *чем; бәрәңге белән ~ам* пита́юсь (обыкновенно) карто́шкой 2) есть, пое́сть; ку́шать, поку́шать; *көндез ашханәдә ~ды* днём он пое́л в столо́вой 2. корми́ться, пита́ться, пропита́ться; быть на иждиве́нии *кого*; *балаларында ~а* нахо́дится на иждиве́нии дете́й

ризыкланыш *сущ.* пита́ние, спо́соб пита́ния; усло́вия пита́ния; *карганың ~ы авылда* ворона́ пита́ется (обыкнове́нно, преиму́щественно) в дере́вне (*в населенных пунктах*)

ризыклы *прил.* 1. име́ющий пи́щу, хлеб; с хле́бом; *~ кешеләр ашарга утырдылар* у кого́ был хлеб (пи́ща), се́ли есть 2. обеспе́ченный пропита́нием (хле́бом насу́щным), иму́щий; *~ адәмнәр йөрешә* иму́щие хо́дят в го́сти 3. пита́тельный; содержа́щий пита́тельные вещества́, калори́йный; *~ азык* калори́йная, пита́тельная пи́ща

рик *сущ. ист.* рик (райо́нный исполни́тельный комите́т), райисполко́м; *рик председателе* председа́тель райисполко́ма

рикошет *сущ.* рикоше́т (полёт твёрдого предме́та по́сле отско́ка) □ **~ ясап** рикоше́том; **~ ясау** рикошети́ровать; *пулялар ташка бәрелеп ~ ясый* пу́ли рикошети́руют о ка́мни

ри́кша *сущ.* ри́кша; *япон ~лары* япо́нские ри́кши; *~ яллау* наня́ть ри́кшу

Рим *сущ.* Рим || ри́мский; *рим папасы* па́па ри́мский, ри́мский па́па □ **рим хокукы** *юр.* ри́мское пра́во; **рим цифрлары** ри́мские ци́фры; **рим чиркәве** ри́мская це́рковь, католи́ческая це́рковь

римлы *сущ.* ри́млянин, ри́млянка; *~лар сугышчан булган* ри́мляне бы́ли вои́нственными

ринг *сущ. спорт.* ринг; *~ка чыгу* вы́йти на ринг

риноло́гия *сущ. мед.* риноло́гия || ринологи́ческий; *~ кафедрасы* ринологи́ческая ка́федра

риноплáстик *прил. мед.* ринопласти́ческий; *~ операция* ринопласти́ческая опера́ция

риноплáстика *сущ. мед.* ринопла́стика

риноскоп *сущ. мед.* риноско́п; *борын куышлыгын ~ белән тикшеру* осмо́тр по́лости но́са риноско́пом; риноскопи́я

риноскопи́я *сущ. мед.* риноскопи́я

рисалә *сущ. уст.* 1. 1) тракта́т, рефера́т; статья́; эссе́; *зур булмаган ~ләр авторы* а́втор небольши́х стате́й 2) сообще́ние (*в научном журнале*); *мәкалә һәм ~ләр* статьи́ и сообще́ния 2. брошю́ра; *татарча китап вә ~ләр чыга* выхо́дят кни́ги и брошю́ры на тата́рском языке

рисаләт *сущ. уст. рел.* посла́ние, ми́ссия; проро́ческая ми́ссия

рисва|й *прил.* опозо́ренный, обесче́щенный; посрамлённый; *~й башкаем* опозо́ренный (*букв. опозоренная моя головушка*); *тәхет, таҗлар ~й буген* сего́дня посрамлены́ тро́ны и коро́ны || *сущ. редко* позо́р, посме́шище; *адәм ~е* посме́шище пе́ред людьми́ □ **~й булу** 1. позо́риться, опозо́риться, осрами́ться 2. подверга́ться насме́шкам; служи́ть посме́шищем; *халык алдында ~й булыр хәлем юк* не хочу́ опозо́риться пе́ред наро́дом; **~йгаләм** опозо́ренный пе́ред всем наро́дом, ми́ром; осрамлённый; **~й итү (ясау)** позо́рить, навлека́ть позо́р на *кого*; поро́чить, черни́ть, пятна́ть *чьё имя*; выставля́ть на позо́р; *ата-анаңны ~й итәсең* позо́ришь свои́х роди́телей; **~йга калу** *см.* **рисвай булу**

рисвайлы *прил.* опозо́ренный, посрамлённый; *~ исем* опозо́ренное и́мя; запя́тнанная репута́ция; дурна́я сла́ва

рисвайлык *сущ.* позо́р, срам, бесче́стие; *~лар күрү (баштан кичерү)* пережи́ть (испыта́ть) позо́р; *~ны күтәрә алмау* не вы́нести позо́ра □ **~ка төшерү** позо́рить, опозо́рить *кого;* **~ка төшү** позо́риться, опозо́риться, осрами́ться

ри́ска *сущ. тех.* ри́ска

рисман *сущ. уст.* кана́т, дли́нная верёвка (*через реку и т. п.*)

ристан *сущ.* 1. *разг. уст.* аресто́нт, аресто́нтка || аресто́нтский; *~нар җыры* аресто́нтская пе́сня, пе́сня аресто́нтов 2. *прост.* руга́тельное сло́во; прокля́тый, окая́нный; *шауламагыз, ~нар* не шуми́те, окая́нные (*дети*); *перес, ристан!* брысь, прокля́тый! (*о кошке*); *кайда йөрисең тагы, ~?* где ты, окая́нный, пропада́ешь (пропа́л)?

ритм *сущ. в разн. знач.* ритм; *музыка ~ы* музыка́льный ритм, ритм му́зыки; *шигъри ~* стихотво́рный ритм, ритм стиха́; *хәрәкәт ~ы* ритм движе́ния; *бер ~да* в одно́м ри́тме, ритми́чно; в ри́тме □ **~ белән** ритми́чно, разме́ренно, ме́рно; **~га җайлашу** *физиол.* усвое́ние ри́тма; **~га салу** *см.* **ритмлаштыру**; *эшне ~га салу* ритми́ровать рабо́ту, ритми́чно вести́ рабо́ту

ри́тмик *прил. в разн. знач.* ритми́ческий; ритми́чный; *~ хәрәкәтләр белән* ритми́ческими движе́ниями; *~ музыка* ритми́чная му́зыка; *~ гимнастика* ритми́ческая гимна́стика; *~ басым муз.* ритми́ческое ударе́ние, акце́нт

ри́тмика *сущ. в разн. знач.* ри́тмика; *шигырь ~сы* ри́тмика стиха́; *~ дәресе* уро́к ри́тмики; *хәрәкәт ~сы* ри́тмика в движе́ниях, ри́тмика движе́ний

ри́тмлаштыр|у *перех.* ритми́ровать || ритмиза́ция; *хәрәкәтне ~у* ритми́ровать движе́ние; ритмиза́ция движе́ния; *эш процессын ~у* ритмизи́ровать проце́сс труда́; ритмиза́ция проце́сса труда́

ри́тмлы *прил.* ритми́ческий, ритми́чный; ритмизи́рованный; разме́ренный, ме́рный; *~ авазлар* ритми́ческие зву́ки; *моторның ~ тавышы* ритми́чный звук мото́ра; *~ хәрәкәтләр* разме́ренные движе́ния; *~ булу* ритми́чность || *нареч.* ритми́чно; *ел буена ~ эшләү* це́лый год (в тече́ние го́да) рабо́тать ритми́чно

ри́тмлылы|к *сущ.* ритми́чность; разме́ренность, ме́рность; *хәрәкәт ~гы* ритми́чность (ме́рность, разме́ренность) движе́ний; *эштә ~кны саклау* соблюда́ть ритми́чность в рабо́те

ритмоплáстика *спец.* ритмопла́стика, ритми́ческая гимна́стика; *~ белән шөгыльләнү* занима́ться ритмопла́стикой, ритми́ческой гимна́стикой

ри́тмсыз *прил.* неритми́чный; аритми́чный, аритми́ческий; *~ эш* неритми́чная рабо́та || *нареч.* неритми́чно,

аритми́чно; аритми́чески; *йөрәге ~ тибә* се́рдце (его́) бьётся аритми́чно (неритми́чно)

ритмсызлык *сущ.* **1.** неритми́чность, аритми́чность (*работы*); *~ аркасында* из-за неритми́чности **2.** *мед.* аритми́я; *йөрәк тибешендәге ~* аритми́я се́рдца

рито́рик *сущ. прил.* риторический; *сөйләмнең ~ бизәкләре* риторические украше́ния ре́чи; *поэзиядә ~ фигуралар* риторические фигу́ры в поэ́зии; *~ алым* риторический приём □ **~ сорау** *филол.* риторический вопро́с

рито́рика *сущ. в разн. знач.* рито́рика; *~ дәреслеге* уро́ки рито́рики; *ясалма ~* фальши́вая (ло́жная) рито́рика

рито́риклык *сущ.* риторичность, риторизм; *автор әсәрләрендәге ~* риторичность в произведе́ниях а́втора; *артык ~* изли́шний риторизм

ритуал *сущ.* ритуа́л; церемо́ния; церемониа́л; *дини ~* религио́зный ритуа́л; *туй ~ы* сва́дебный ритуа́л; *бүләкләр тапшыру ~ы* ритуа́л, церемониа́л награжде́ния

ритуаллаштыру *перех.* ритуализи́ровать

ритуаллаш|у *неперех.* ритуализи́роваться

ритуаль *прил.* ритуа́льный; *~ бәйрәмнәр* ритуа́льные пра́здники; *~ тантана* ритуа́льное торжество́

риф *сущ.* риф (*скалистые возвышения морского дна, опасные для судов*); *коралл рифлары* кора́лловые ри́фы

ри́фма *сущ. лит.* ри́фма; *поэзиядә ритм, ~ мәсьәләсе* вопро́с ри́тма и ри́фмы в поэ́зии; *аралаш ~* перекрёстная ри́фма □ **~га салу** рифмова́ть; **~га салыну** рифмова́ться; **~га тезү (уру)** рифмова́ть

ри́фмадаш *прил.* рифмо́ванный, рифму́ющиеся; *~ тезмәләр* рифмо́ванные стро́ки; *~ авазлар* рифмо́ванные зву́ки; *~ булу (килү)* рифмова́ться

ри́фмалану *неперех. см.* **рифмалашу**

ри́фмаланыш *сущ.* рифмо́вка; *ирекле ~* во́льная рифмо́вка

ри́фмалау *неперех.* рифмова́ть, образова́ть ри́фму

ри́фмалаштыру *перех. см.* **рифмалау**; *җөмләләр азагын ~* рифмова́ть концы́ предложе́ния

ри́фмалашу *неперех.* рифмова́ться || рифмо́вка; *юл аралаш ~* рифмо́вка че́рез строку́

ри́фмалы *прил.* рифмо́ванный; *~ юллар* рифмо́ванные стро́ки

ри́фмасыз *прил.* без ри́фмы (рифмо́вки); *~ шигырь филол.* бе́лый стих

ри́фмачы *сущ. разг.* рифма́ч, рифмо́вщик, рифмоплёт

ри́фмачылык *сущ. разг.* рифмоплётство, рифма́чество

ришвәт *сущ.* взя́тка, подма́зка *прост.*; мзда *уст.*; *~ бирү* дава́ть взя́тки; *~ бируче* взяткода́тель, мздода́тель; *~ алу* брать взя́тки; *~ алучы* взя́точник; мздои́мец *уст.*; *~ алмый торган (кеше)* неподку́пный (челове́к)

ришвәтче *сущ.* взя́точник, мздои́мец *уст.*

ришвәтчелек *сущ.* взя́точничество || взя́точнический; *~ дөньясы* мир взя́точничества; *~не тамырыннан юк итү* искорени́ть взя́точничество; *~ алымнары* взя́точнические приёмы

ришелье *сущ.* ришелье́ (*нескл., ср.*); *~ чигүе* вы́шивка ришелье́

риштә *сущ. зоол., мед.* ре́шта, волоса́тик; *см. тж.* **җепҗылан**

рия *сущ.* лицеме́рие, двули́чие; притво́рство; *һәр сүзендә ялган һәм рия сизелеп тора* в ка́ждом сло́ве его́ чу́вствуются ложь и лицеме́рие □ **рия сату** притворя́ться; лицеме́рить, вести́ себя́ двули́чно; *кем икәненне беләм, рия сатып маташма* я зна́ю, кто ты, не́чего притворя́ться

риядан *нареч.* лицеме́рно, неискренне, притво́рно; *~ мактау* лицеме́рно хвали́ть; *~ (гына) елмаю* лицеме́рно (неискренне) улыба́ться; *~ гына шатлану* притво́рно (неискренне) ра́доваться; притворя́ться, что рад □ **~ булган** неискренний, притво́рный; **~ булганлык** притво́рность; *куз яшенең ~ булганлыгы күренеп тора* ви́дно, что пла́чет притво́рно

риязәт *сущ. уст. книжн.* воздержа́ние, умертвле́ние пло́ти, аскети́ческий о́браз жи́зни, аскети́зм; *~ әһле* аске́т

риялану *неперех.* лицеме́рить, двуру́шничать; проявля́ть нейскренность; притворя́ться || притво́рство, двули́чие, двуру́шничество, лицеме́рие; *~ , кылану, хәйләләү сиңа килешми* не идёт (*не к лицу*) тебе́ лицеме́рить, рисова́ться, хитри́ть

риялы *прил.* лицеме́рный, двули́чный, притво́рный, нейскренний; *~ елмаю белән* с лицеме́рной улы́бкой || *нареч.* лицеме́рно, неискренне; притво́рно; *~ рәвештә* лицеме́рно; *~ кыланып* притво́рно; *үзен серле, ~ тота* ведёт себя́ непоня́тно, неискренне

риялылы|к *сущ.* лицеме́рие, двули́чие, притво́рство; притво́рность; нейскренность, лицеме́рность; *сүзенең ~гы* нейскренность (лицеме́рность) слов; *~кта гаеплә́ү* обвиня́ть (обвини́ть) *кого-л.* в притво́рстве (в двули́чии) □ **~ белән** лицеме́рно

риясыз *прил.* **1.** беспристра́стный, бескоры́стный; объекти́вный; *~ тәнкыйть* беспристра́стная кри́тика; *~ мәхәббәт* бескоры́стная любо́вь; *~ җавап* объекти́вный ответ **2.** и́скренний, прямоду́шный, прямо́й (*человек*); бесхи́тростный; *~дуслар* и́скренние друзья́ **3.** нелицеприя́тный || *нареч.* и́скренне, объекти́вно; *~ гына әйтегез әле* скажи́те и́скренне □ **~ булу** прямоду́шие, прямота́

риясызлы|к *сущ.* **1.** беспристра́стие, бескоры́стие; беспристра́стность; объекти́вность; отсу́тствие пристра́стия, притво́рства, лицеме́рия; *мөнәсәбәтендәге ~к* беспристра́стность (его́) отноше́ния **2.** и́скренность, серде́чность; *сүзеңнең ~гында шигем юк* у меня́ нет сомне́ния (я не сомнева́юсь) в и́скренности твои́х слов □ **~к белән** объекти́вно; нелицеприя́тно

риячы *сущ.* нейскренний, двули́чный челове́к, лицеме́р, притво́рщик; двуру́шник; *эгоистлар, ~лар белән дөнья тулган* мир по́лон эгои́стами, лицеме́рами

робагый *сущ. лит.* рубаи́, четверости́шие; *~лар авторы* а́втор рубаи́; *~лар язу* писа́ть (сочиня́ть) рубаи́

ро́бот *сущ. прям., перен.* ро́бот; *~лардан файдалану* испо́льзование ро́ботов; *аяклы ~ка әйләндерү* превра́ти́ть (челове́ка) в ходя́чий ро́бот; *оператор ~* ро́бот-опера́тор; *күп станокчы ~* ро́бот-многостано́чник

ро́ботлаштыру *перех.* роботизи́ровать || роботиза́ция

рога́тка *сущ.* **1.** рога́тка (*с резинкой для метания*); *~дан таш атып чыпчык үтерү* уби́ть воробья́, вы́стрелив из рога́тки; из рога́тки уби́ть воробья́; *~ җебе* рези́нка рога́тки **2.** *воен.* рога́тка, рога́тки || рога́точный; *танкка каршы ~лар воен.* противотанковые рога́тки

ро́дий *сущ. хим.* ро́дий || ро́диевый; *~ кушылган эретмә* ро́диевый сплав

ро́жа *сущ. мед.* ро́жа *см. тж.* **кызанкы**; *~ белән авыру* заболе́ть ро́жей; *~дан үлү* умере́ть от ро́жи

Рождество *сущ. разг.* Рождество́ || рожде́ственский; *см. тж.* **рашту**а; *~ алдыннан гына* пе́ред рождество́м; *~ суыклары* рожде́ственские моро́зы

ро́за *сущ. бот.* ро́за || ро́зовый; *кытай ~сы* кита́йская ро́за; *~ куагы* ро́зовый куст; *~ букеты* ро́зовый буке́т; буке́т роз □ *~* **бакчасы** роза́рий, цветни́к из роз

роза́ри|й *сущ. книжн.* роза́рий; *ботаника бакчасы ~енда берничә төрле роза үсә* в роза́рии ботани́ческого са́да растёт не́сколько ви́дов роз

ро́зачалар *сущ. бот.* розоцве́тные; ро́зовые; *чия ~лар семьялыгына керә* ви́шня вхо́дит в семе́йство розоцве́тных

розе́тка *сущ. в разн. знач.* розе́тка; *варенье салган ~* розе́тка с варе́ньем; *электр ~сы* электри́ческая розе́тка

рокиро́вка *сущ. шахм.* рокиро́вка; *~ ясау* де́лать рокиро́вку; рокирова́ться

рококо *сущ. архит., иск.* рококо́; *~ стиле* стиль рококо́; *~ стилендәге мебель* ме́бель в сти́ле рококо́

рокфор *сущ.* рокфо́р; *~ сыры* сыр-рокфо́р

ро́лик *сущ.* ро́лик

ро́ликлы *прил.* ро́ликовый; *~ тимераяк спорт.* ро́ликовые конько́и; *~ подшипник тех.* ро́ликовый подши́пник; *~ конвейер тех.* ро́ликовый конве́йер; рольга́нг

роль *сущ. в разн. знач.* роль; *баш (төп) роль в разн. знач.* гла́вная роль; *рольне ятлау (өйрәну)* вы́учить роль; *рольгә (роленә) керү* войти́ в роль; войти́ в роль *кого-л.; актив (пассив) роль уйнау* игра́ть акти́вную (пасси́вную) роль

рольганг *сущ. спец.* рольга́нг, ро́ликовый конве́йер; *йөкне ~ка кую* поста́вить груз на рольга́нг

ром *сущ.* ром || ро́мовый; *чәйгә ром салып (тамызып) эчү* пить чай с ро́мом (подба́вив ро́му); *ром исе* ро́мовый за́пах; *ром тәме* ро́мовый вкус; вкус ро́ма

роман I *сущ. в разн. знач.* рома́н; *тарихи ~* истори́ческий рома́н; *~ язу* писа́ть рома́н; *икесе арасындагы ~ перен.* рома́н ме́жду ни́ми

роман II *сущ. этногр. и лингв.* рома́н || рома́нский; *~ халыклары* рома́нские наро́ды; *~ культурасы* рома́нская культу́ра; *~ стиле* рома́нский стиль

романизм *сущ. филол.* романи́зм; *әсәрдәге ~* романи́зм в произведе́ниях; *славян теллөрендә ~ күренешләре* явле́ния романи́зма в славя́нских языка́х

романист *сущ.* романи́ст, романи́стик, фило́лог по рома́нским языка́м; *совет ~лары* сове́тские романи́сты, сове́тские специали́сты по романи́стике

романи́стика *сущ. спец.* романи́стика; рома́нская филоло́гия; *~ның хәзерге көндәге торышы* совре́менное состоя́ние романи́стики

романс *сущ. в разн. знач.* рома́нс || рома́нсный; *М. Җәлил сүзләренә ~* рома́нс на слова́ М. Джали́ля; *М. Мозаффаров ~лары* рома́нсы М. Музафа́рова; *~ стиле* рома́нсный стиль; *~ формасы* рома́нсовая фо́рма

романтизм *сущ. в разн. знач.* романти́зм || романти́ческий; *Г. Ибраһимов иҗатында ~ элементлары* эле́менты романти́зма в тво́рчестве Г. Ибраги́мова; *~ тарафдары* сторо́нник романти́зма; рома́нтик; *~ мәктәбе* романти́ческая шко́ла

рома́нтик I *сущ. в разн. знач.* рома́нтик; *~лар белән классицизм тарафдарлары арасында көрәш* борьба́ ме́жду рома́нтиками и классици́стами; *яшь ~лар* молоды́е рома́нтики

рома́нтик II *прил.* **1.** *в разн. знач.* романти́ческий; романти́чный; *~ поэзия* романти́ческая поэ́зия; *эшнең ~ ягы* романти́ческая сторона́ де́ла; *~ очрашу* романти́ческая встре́ча; *~ хисләр* романти́чные, прони́кнутые рома́нтикой чу́вства **2.** *в знач. нареч.* романти́чески, романти́чно; *~ яңгырау* звуча́ть романти́чно

рома́нтика *сущ. в разн. знач.* рома́нтика; *яшьлек ~сы* рома́нтика ю́ности; *көрәш ~сы* рома́нтика борьбы́

рома́нтикларча *нареч.* романти́чески, романти́чно; *~ дәртләнеп (эшләү)* романти́чески воодушевлённо (труди́ться)

рома́нтиклаштыру *перех.* романтизи́ровать, идеализи́ровать; *уткәнне ~* романтизи́ровать про́шлое; *авыл тормышын ~* романтизи́ровать (идеализи́ровать) дере́вню (дереве́нскую жизнь)

рома́нтикли|к *сущ.* романти́зм; романти́чность; *табигать күренешен бирүдәге ~к* романти́зм в описа́нии приро́ды; *~гын саклау* сохрани́ть романти́чность

рома́нча *прил.* рома́нный; *сюжетның ~ төзелеше* рома́нное постро́ение сюже́та

романчы *сущ. разг.* романи́ст, писа́тель-романи́ст (а́втор рома́нов); *татар ~лары* тата́рские романи́сты; *~ Г. Әпсәләмов* романи́ст Г. Абсаля́мов

рома́шка *сущ. бот.* рома́шка || рома́шковый; *ак ~* бе́лая рома́шка; *сары ~* жёлтая рома́шка, златоцве́т; *~ суы* рома́шковый отва́р; *~ төнәтмәсе* рома́шковый насто́й

ромб *сущ. в разн. знач.* ромб; *~ сызу* начерти́ть ромб □ *~* **формасындагы (рәвешендәге)** *см.* **ромбсыман**

ро́мбик *прил.* ромби́ческий, ро́мбовый; *~ антенна тех.* ромби́ческая анте́нна

ромбсыман *прил.* ромбови́дный; ромби́ческий; *~ антенна тех.* ромби́ческая анте́нна

ромштекс *сущ. кул.* ромште́кс; *икенчегә бәрәңге боткасы белән ~* на второ́е ромште́кс с карто́фельным пюре́

ромбо́ид *сущ. мат.* ромбо́ид, параллелогра́мм

ромбоидаль *прил. мат., минер.* ромбоида́льный; *~ геометрик җисем* ромбоида́льное геометри́ческое те́ло; *~ кристалл* ромбоида́льный криста́лл

ромлы *прил.* ро́мовый, с ро́мом; *~ пирожный* ро́мовая ба́ба, ром-ба́ба; *~ эссенция* ро́мовая эссе́нция

ро́ндо I *сущ. нескл. муз.* ро́ндо

ро́ндо II *сущ. филол.* ро́ндо (*стихотворная форма*); *гади (катлаулы) ~* просто́е (сло́жное) ро́ндо

ро́ндо III *сущ.* ро́ндо; *~ шрифты* шрифт ро́ндо; *~ каләме* перо́ ро́ндо

Россия *сущ.* Росси́я || росси́йский; *~ тарихы* росси́йская исто́рия; *~ табигате* росси́йская приро́да

росси́яле *сущ.* россия́нин, россия́нка, жи́тель Росси́и; росс *уст.* || *прил.* росси́йский; *~ татар* росси́йский тата́рин (тата́рка)

россиян *сущ. см.* **росси́яле**

ро́стбиф *сущ. кул.* ро́стбиф, жа́реная говя́дина

ро́стверк *сущ. тех.* ро́стверк (*нижняя часть фундамента сооружения*)

ростовщик *сущ.* ростовщи́к, ростовщи́ца; кредито́р; проце́нтщик *уст.; см. тж.* **рибачы**; *хәзерге заман ~лары* совре́менные ростовщики́

ростовщиклык *сущ.* ростовщи́чество || ростовщи́ческий; *см. тж.* **рибачылык**; *~ белән шөгыльләнү* занима́ться ростовщи́чеством; *~ капиталы (процентлары)* ростовщи́ческий капита́л (проце́нты)

ростр *сущ. архит.* ро́стра (*украшение в виде носовой части судна*)

ро́стралы *прил. архит.* ростра́льный, с ро́страми; *~ колонна* ростра́льная коло́нна

ро́та *сущ. воен.* ро́та || ро́тный; *пехота ~сы* пехо́тная ро́та; *~ командиры* ро́тный командир; командир ро́ты

ротапринт *сущ. спец.* ротапри́нт; *чакыру кәгазен ~та бастыру* размножа́ть пригласи́тельный биле́т на ротапри́нте

рота́тор *сущ. спец.* рота́тор || рота́торный (*зал*); *~ кәгазе* рота́торная бума́га

ротацизм *сущ. спец.* ротаци́зм (*картавость, неправильность в произношении звука «р»*)

ротацион *прил.* ротацио́нный; *~ машина полигр.* ротацио́нная маши́на; рота́ция; *~ насос (вакуум-насос) тех.* ротацио́нный насо́с (ва́куум-насо́с)

рота́ция *сущ. в разн. знач.* рота́ция; *~ срогы с.-х.* срок рота́ции; *табаклы ~ полигр.* листова́я рота́ция

ро́тмистр *сущ. ист.* ро́тмистр; *~ дәрәҗәсе* чин ро́тмистра

рото́нда *сущ. в разн. знач.* рото́нда; *парктагы ~* рото́нда в па́рке; *хатыныңың өстендә бәрхет тышлы ~* на его́ жене́ ба́рхатная рото́нда

ро́тор *сущ. спец.* ро́тор || ро́торный; *синхрон ~* синхро́нный ро́тор; *~ның әйләнү тизлеген арттыру* увели́чить ско́рость враще́ния ро́тора; *~ калаклары* ро́торные лопа́тки; лопа́тки ро́тора □ **~ белән бораулау** ро́торное буре́ние

ро́торлы *прил.* ро́торный; *~ судно* ро́торное су́дно; *~ экскаватор* ро́торный экскава́тор

рояль *сущ.* роя́ль || роя́льный; *~ янына утыру* сесть за роя́ль; *~да уйнау* игра́ть на роя́ле; *~ клавишы* роя́льная кла́виша; кла́виша роя́ля

рөкүгъ *сущ. рел.* поясно́й покло́н (во вре́мя моли́твы); *см. тж.* **рөкәгать; ~кә бару** де́лать (сде́лать) покло́н, бить покло́ны, кла́няться (во вре́мя моли́твы); *~кә целү (китү)* глубоко́ приседа́ть □ **~ итү** кла́няться; бить покло́ны

рөхсәт *сущ.* **1.** разреше́ние, позволе́ние, дозволе́ние *уст.; рәсми ~* официа́льное разреше́ние; *сезнең ~егез белән* с ва́шего позволе́ния; *аның ~еннән башка* без его́ разреше́ния **2.** (пи́сьменное) разреше́ние, докуме́нт, са́нкция; *см. тж.* **рөхсәт кәгазе (язуы); *кулында ~е була торып*** име́я на рука́х разреше́ние (докуме́нт) □ **~ алмый(ча) (гына)** *см.* **рөхсәтсез** (*уйти с работы, войти куда-л.*); **~ алу** получа́ть (получи́ть) разреше́ние (*на что-л.*); **~ бирү** разреши́ть, позво́лить; дать разреше́ние *на что-л.*; санкциони́ровать, дать са́нкцию *на что-л. юр.*; **~ итегез!** позво́льте! разреши́те! прошу́ Вас! прошу́ (Ва́шего) позволе́ния! **~ ителмәү** запреща́ться/запрети́ться, не разреша́ться; воспреща́ться/воспрети́ться *книжн.; керергә ~ ителми* вход воспрещён; **~ ителү** разреша́ться, позволя́ться; *~ ителмәгән ысул* недозво́ленный (запрещённый) приём (ме́тод); **~ итү** разреша́ть/разреши́ть, позволя́ть/позво́лить, допуска́ть/допусти́ть, дава́ть/дать; санкциони́ровать *книжн.;* дозволя́ть/дозво́лить *уст.;* **~ кәгазе (язуы, документы)** разреше́ние (пи́сьменное), докуме́нт о разреше́нии; са́нкция *книжн.;* **~ем юк** не позво́лю

рөхсәтнамә *сущ.* пи́сьменное разреше́ние, докуме́нт; про́пуск; *см. тж.* **рөхсәт кәгазе (язуы, документы)**

рөхсәтсез *нареч.* без разреше́ния (позволе́ния), без спро́са; самово́льно; *~ китү* уйти́ самово́льно; уйти́ без разреше́ния; *чакырмый килгән кунакка ~ китәргә ярый* (*посл.*) незва́ному го́стю мо́жно уйти́ без разреше́ния □ **~ алу** взять без спро́са (без разреше́ния); красть (укра́сть), присво́ить чужо́е, ворова́ть

рөшди *прил. уст.* **1.** уже совершенноле́тний; перехо́дного во́зраста **2.** *ист. пед.* сре́дний; *~ сыйныфлар* сре́дние кла́ссы (**ибтидаи** — нача́льный; **~** — сре́дний, **игъдади** — старший, **гали** — вы́сший); *~ сыйныф баласы* учени́к сре́днего кла́сса; **~ мәктәп** *см.* **рөшдия**

рөшдия *сщ. уст.* рюшти́я (*дореволюционная средняя школа у татар*)

РСДРП *сущ. ист.* РСДРП (*Российская социал-демократическая рабочая партия*); *~ның Казан комитеты* Каза́нский комите́т РСДРП

РСФСР *сущ.* РСФСР (*Российская Советская Федеративная Социалистическая Республика*); *РСФСР гербы* герб РСФСР

РТС *ист.* РТС (*ремонтно-техническая станция*); *~ директоры* дире́ктор РТС

рубаб *сущ. муз.* рубаб (*4—6 струнный щипковый музыкальный инструмент у большинства народов Азии*)

руберо́ид *сущ.* руберо́ид || руберо́идовый; *бер рулон ~ оды́н* руло́н руберо́ида: *~ заводы* руберо́идовый заво́д || *прил.* руберо́идовый; руберо́идный; *~ изоляция* руберо́идовая изоля́ция; *~ түбә* руберо́идная кры́ша

руби́льник *сущ. тех.* руби́льник; *~ тартмасы* футля́р руби́льника; *кайтармалы (вч полосалы) ~* перекидно́й (трёхполо́сный) руби́льник

рубин *минер.* руби́н || руби́новый; *~ кашлы йөзек* коле́чко с руби́ном; *~ ташлары* руби́новые ка́мни || *прил.* руби́новый; *~ беләзек* руби́новый брасле́т, брасле́т с руби́ном; *~ йолдыз* руби́новая звезда́ □ **~ төсендәге (төсле)** руби́новый, руби́нового цве́та, я́рко-кра́сный

ру́бка *сущ. в разн. знач.* ру́бка; *командир ~сы* команди́рская ру́бка; *радиостанция ~сы* ру́бка радиоста́нции

руда *сущ.* руда́ || ру́дный; *уран ~сы* ура́новая руда́; *тимер ~сы* желе́зная руда́, железня́к; *бакыр ~сы* ме́дная руда́, купри́т *геог.;* *~ ятмалары* ру́дные за́лежи □ **~ баеткыч** рудообогати́тель || рудообогати́тельный; **~ баету** обогати́ть руду́; обогаще́ние руды́; *~ баету заводы* рудообогати́тельный заво́д; **~ казу (чыгару)** добыва́ть руду́; добы́ча руды́

рудалы *прил.* рудоно́сный, ру́дный; *~ урыннар* ру́дные места́ (месторожде́ния); *~ токым* ру́дная поро́да; *~ катлам* рудоно́сный слой

рудераль: рудераль үсемлекләр *бот.* рудера́льные расте́ния

рудимент *сущ. биол.* рудимен́т; рудимента́рный о́рган

рудиментар *прил. биол.* рудимента́рный; *~ орган* рудимента́рный о́рган; рудиме́нт; *~ мускуллар биол.* рудимента́рные му́скулы; *~ күренешләр в разн. знач.* рудимента́рные явле́ния

рудни|к *сущ.* рудни́к || рудniко́вый; рудни́чный; *ташкүмер ~гы* каменноуго́льный рудни́к; *~к эшчеләре* рудniко́вые рабо́чие; *~к тузаны* рудniко́вая пыль

руза *сущ. разг. см.* **ураза**

рула́да *сущ. муз.* рула́да

рулево|й *сущ. спец.* рулево́й; *пароходның ~е* рулево́й парохо́да; *~й вазифасы* обя́занности рулево́го

рулет *сущ. кулин.* руле́т; *бәрәңге ~ы* карто́фельный руле́т; *мәкле ~* руле́т с ма́ком

руле́тка *сущ.* **1.** руле́тка (метро́вка) || руле́точный; *корыч ~* стальна́я руле́тка; *~ футляры* руле́точный футля́р **2.** руле́тка (аза́ртная игра́)

рулон *сущ.* руло́н || руло́нный; ро́льный, ролево́й; рол, роль; *кәгазь ~ы* руло́н бума́ги; рол (роль) бума́ги;

рубероид ~ы руло́н руберо́ида; *~ кәгазе* руло́нная бума́га; *~ итеп төрү см.* **рулонлау**

рулонлау *перех.* свора́чивать (сверну́ть) в руло́н || свора́чивание в руло́н *что*

рулонлы *прил.* руло́нный, ро́льный; *~ бакыр* ро́льная медь

рул|ь *сущ. в разн. знач.* руль || рулево́й; *борылу ~е* руль поворо́та; *велосипед ~е* руль велосипе́да; *~ь валы* рулево́й вал □ **~ь тоту** быть у руля́; быть рулевы́м; **~ьгә утыру** сесть за руль; **~ьне бору** рули́ть || руле́ние

рульле *сущ.* с рулём; снабжённый рулём; рулево́й; *~ идарә* рулево́е управле́ние

румын *сущ.* румы́н, румы́нка || румы́нский; *~ кызы* румы́нка; *~ теле* румы́нский язы́к; *~ татарлары* румы́нские тата́ры □ **~ халкы** румы́ны, румы́нский наро́д

румы́нияле *сущ.* жи́тель Румы́нии; румы́н, румы́нка

румы́нча *нареч.* 1) по-румы́нски; на румы́нском языке́; *~ сөйләшү* говори́ть на румы́нском языке́ 2) по-румы́нски, (так) как у румы́н; по румы́нскому обы́чаю (*одеваться, жить, накрывать стол*) || *прил.* 1) румы́нский, на румы́нском языке́; *~ газета* газе́та на румы́нском языке́ 2) румы́нский, (тако́й) как у румы́н; *~ туй* румы́нская сва́дьба

рун *сущ. ист.* ру́на, ру́ны || руни́ческий; *төрки руннар* тю́ркские ру́ны (*письменность тюрков 5—11 вв.*); *рун язмалары* руни́ческие письмена́, ру́ны

ру́ник *прил. ист.* руни́ческий; *~ язмалар* руни́ческие письмена́, ру́ны

ру́пия *сущ.* ру́пия (*денежная единица в Индии и Пакистане*)

ру́пор *сущ. прям., перен.* ру́пор; *граммофон ~ы* ру́пор граммофо́на; *реваншистлар ~ы перен.* ру́пор реванши́стов

ру́порлы *прил.* с ру́пором; ру́порный; *~ граммофон* ру́порный граммофо́н; граммофо́н с ру́пором

ру́порсыман *прил.* ру́порный; подо́бный ру́пору; *~ антенна* ру́порная анте́нна; *~ репродуктор* ру́порный репроду́ктор, громкоговори́тель

рус *сущ.* ру́сский, ру́сская; русс; руса́к *разг.* || ру́сский; росси́йский; *рус һәм татар* ру́сский и тата́рин; *рус халкы* ру́сский наро́д; ру́сские; *руслар арасында яшәү* жить среди́ ру́сских; *рус милләте* ру́сская на́ция □ **рус теле белгече** руси́ст; **рус теле гыйлеме** руси́стика, ру́сская лингви́стика

русизм *сущ. филол.* руси́зм; *персонаж телендәге ~нар* руси́змы в языке́ персона́жа

русист *сущ.* руси́ст, руси́стка, специали́ст по ру́сскому языку́; *чит ил ~лары* зарубе́жные руси́сты

руси́стика *сущ.* руси́стика; ру́сская филоло́гия; *совет чорындагы ~ның үсеше* разви́тие руси́стики в сове́тский пери́од

русифика́тор *сущ. полит.* русифика́тор; *XIX гасырның миссионер ~лары* миссионе́ры-русифика́торы XIX века

русифика́торлык *сущ. полит.* русифика́торство || русифика́торский; *~ идеяләре* иде́и русифика́торства; *~ политикасы* русифика́торская поли́тика

руси́яле *сущ. уст. книжн. см.* **росси́яле**

руслаштыру *перех.* русифици́ровать, обруси́ть || 1) русифика́ция 2) русифика́торский, обруси́тельный; *~ политикасы* русифика́торская поли́тика; *чиновникларның ~ эше* обруси́тельная де́ятельность чино́вников

руслаштыручы *сущ. полит., ист. см.* **русифика́тор**

руслаш|у *неперех. полит.* русифици́роваться; обруси́ть || обруси́ние; *бабасы ~кан татар булган* дед его́ был обруси́вший тата́рин; *~кан немец* обруси́лый (обруси́вший) не́мец

руст *сущ. строит.* руст; *(йортларын) ~ белән тышлау* облицева́ть (дома́) ру́стами, рустова́ть

ру́стика *сущ. архит.* ру́стика; *биек йортларны төзегәндә ~дан файдалану* применя́ть ру́стику в строи́тельстве высо́ких домо́в

рустл|ау *перех. строит.* рустова́ть || руста́вка; *беренче этаж стенасын ~ау* рустова́ть сте́ну пе́рвого этажа́; *~анган таш белән фасадны тышлау* рустова́ть фаса́д, облицева́ть фаса́д руста́ванными пли́тками

ру́сча *нареч.* 1) по-ру́сски, на ру́сском языке́; *~ сөйләшү* говори́ть по-ру́сски; *~ укый-яза белү* уме́ть (уме́ние) чита́ть и писа́ть по-ру́сски 2) русско-; *~-татарча* ру́сско-тата́рский; *~-чувашча* ру́сско-чува́шский; *~-үзбәкчә* ру́сско-узбе́кский (*словарь*) || *прил.* на ру́сском языке́, ру́сский; *~ (язылган) текст* текст, напи́санный на ру́сском языке́; ру́сский текст; *үсемлекнең ~ атамасы* ру́сское назва́ние расте́ния; *~га тәрҗемә итү* переводи́ть на ру́сский язы́к

ру́счалап *нареч. разг.* по-ру́сски; на ру́сском языке́; *~ әйтсәк (әйткәндә)* е́сли говори́ть по-ру́сски; *~ сорау* спроси́ть по-ру́сски, спроси́ть на ру́сском языке́, по-ру́сски

ру́счалатып *нареч.* **1.** наро́чно по-ру́сски; *см.* **русчалап**; *~ сүгенеп җибәрде* наро́чно вы́ругался по-ру́сски **2.** переводя́ на ру́сский язы́к; *~ әйткәндә* е́сли перевести́ на ру́сский язы́к

руслаштыр|у *перех. разг.* переводи́ть/перевести́ на ру́сский язы́к; де́лать, сде́лать перево́д на ру́сский язы́к || перево́д на ру́сский язы́к; *текстны ~у (эше)* перево́д те́кста на ру́сский язы́к

ру́счалык *сущ.* руси́зм

ру́та *сущ. бот.* ру́та || ру́товый; *~ куагы (яфрагы)* ру́товый куста́рник (лист) □ **~ мае** ру́товое ма́сло

ру́тача: ру́тачалар *бот.* ру́товые; *~лар семьялыгы* семе́йство ру́товых, ру́товые

руте́ний *сущ. хим.* руте́ний || руте́ниевый; *лампаның ~ кыллары* руте́ниевые волоски́ электрола́мпы

рутинёр *сущ. книжн.* рутинёр, рутинёрка || рутинёрский; *~ чыгышлары* рутинёрские вы́ходки

рутинёрлык *сущ. книжн.* рутинёрство, рутини́зм, ко́сность || рутинёрский; *~та гаепләү* обвиня́ть (обвини́ть) в рутинёрстве; *~ карашлары* рутинёрские взгля́ды

сана|у *неперех.* **1.** счита́ть, сосчи́тать || счёт; *унга кадәр ~у* счита́ть до десяти́; *кирегә ~у* счита́ть в обра́тном поря́дке; *йөзгә кадәр ~у* счёт до ста **2.** счита́ть, сосчита́ть, посчита́ть, подсчи́тывать/подсчита́ть, счесть || **1)** счёт, подсчёт, подсчи́тывание 2) счётный; *акча ~у* счита́ть де́ньги; *чыгымнарны ~у* подсчи́тывать расхо́ды; *~у комиссиясе* счётная коми́ссия **3.** счита́ть, сосчита́ть, посчита́ть || счёт; *яздан ~саң — ике ел* е́сли счита́ть с весны́ — два го́да; *почмактан ~саң — икенче тәрәзә* счита́я от угла́ — второ́е окно́; *эш хакы, премияләрне ~масаң — ике йөз сум* не счита́я пре́мий, зарпла́та две́сти рубле́й **4.** *в знач. вводн. сл.* **сана(гыз)** счита́й(те); *сана, гомер буе монда яшәдем* счита́й, всю жизнь про́жил тут; *санагыз, ул монда иң кирәк кеше* он здесь, счита́йте, са́мый ну́жный челове́к **5.** счита́ть, счесть, посчита́ть *за кого-л, чего-л.*; расце́ниваться *каким-л.* о́бразом, воспринима́ться *как-л.*; признава́ться, счита́ться *каким-л.*, о́бразом; *кирәксезгә ~п кәгазьләрне ерту* порва́ть бума́ги, приня́в за нену́жные; *үземне бәхетле дип ~ыйм* счита́ю себя́ счастли́вым; *ул үзен хаклы дип ~ый* он счита́ет себя́ пра́вым □ **~п чыгару** насчита́ть, вы́считать, исчи́слить; **~п чыгу** пересчита́ть, высчи́тывать/вы́считать

санаулы *прил.* **1.** счи́танный, ограни́ченный; *~ казлар* счи́танные гу́си; *~ акча* счи́танные де́ньги; *залга ~ кешеләр генә керә алды* в зал смогли́ пройти́ то́лько счи́танные лю́ди **2.** *перен. в знач. нареч.* ма́ло, на счету́; *бездә белгечләр ~ гына* у нас специали́стов о́чень ма́ло; *һәр минуты ~* ка́ждая мину́та на счету́

санаусыз *прил.* бессчётный, несчётный, неисчисли́мый; бесчи́сленный; *~ мал* бесчи́сленное коли́чество скота́, несчётное мно́жество скота́; несчётное бога́тство (добро́); *~ акча булмый* бессчётных де́нег не быва́ет; *ул вакыттан бирле ~ көннәр үтте* с тех пор прошло́ бессчётное мно́жество дней

санаучы *сущ.* **1.** счётчик, счита́ющий; *кем күпме эшләгән белмибез, ~ юк* кто ско́лько сде́лал, не зна́ем, нет счётчика **2.** *мат.* числи́тель

санаш|у **1.** *взаимно-совм. от* **санау** 1, 2 **2.** счита́ться, посчита́ться; *ул үзенең вакыты белән ~ып тормады* он не стал счита́ться со свои́м вре́менем; *бөтен эшне дә телэп башкарды, ~ып тормады* ни с чем не счита́лся, всякую рабо́ту де́лал с охо́той **3.** счита́ться, посчита́ться, относи́ться с уваже́нием; принима́ть/приня́ть во внима́ние; *коллектив фикере белән ~у* счита́ться с мне́нием коллекти́ва; *бу хәл белән ~мыйча булмый* нельзя́ не принима́ть во внима́ние да́нное обстоя́тельство

санәм *сущ.* и́дол (*статуя, изваяние, которому язычники поклоняются как божеству*); *алтын ~* золото́й и́дол; *килбәтсез фарфор ~* безобра́зный фарфо́ровый и́дол

сангви́ник *сущ.* сангви́ник || *прил.* сангвини́ческий; *~ темперамент* сангвини́ческий темпера́мент

сандал I *сущ.* накова́льня; *тимерче ~ы* кузне́чная накова́льня □ **~ сөяк** *анат.* накова́льня (*косточка среднего уха*)

сандал II *сущ.* санда́лия, санда́лии; *малай аягына челтәрле ~ кигән* у ма́льчика на нога́х плетёные санда́лии

сандал III *сущ.* санда́л || санда́ловый; *~ агачы* санда́ловое де́рево; *~ мае* санда́ловое ма́сло

сандалет *сущ.* сандале́та; *баланың аякларында матур ~лар* на нога́х ребёнка краси́вые сандале́ты

сандали *сущ. см.* **сандал** II

сандугач *сущ. зоол.* **1.** соловей́ || соловьи́ный; *~ сайравы* пе́ние соловья́; *~ чутылдавы* трель соловья́ **2.** *перен. поэт.* **сандугачым** (*ласкательное обращение к любимой*) соло́вушка мой; *~ым, кил яныма* иди́ ко мне, соло́вушка мой □ **~ тавышлы** с соловьи́ным го́лосом, с го́лосом соловья́; **~ телле** говори́т, как соловей́; **~ түше** *бот.* бегóния; **~ чәчкәсе** *бот.* глоксиния ◊ **~ булып сайрау** петь (залива́ться) соловьём; **~ йокысы** коро́ткий сон

сандык *сущ.* сунду́к || сунду́чный; *агач ~* деревя́нный сунду́к; *~та саклау* храни́ть в сундуке́; *~ йозагы* сунду́чный замо́к ◊ **~ка салу** отложи́ть в до́лгий я́щик

сандыкча *сущ.* сундучо́к; *җыйнак кына ~* аккура́тный сундучо́к

сандыкчы *сущ.* ма́стер, изготовля́ющий сундуки́

санитар, санита́рка *сущ.* санита́р; *~лар яралыларны госпитальгә китерделәр* санита́ры привезли́ ра́неных в го́спиталь || *прил.* санита́рный; *~ поезд* санита́рный по́езд; *~ машина(сы)* санита́рная маши́на

санитари́я *сущ.* санитари́я || санита́рный; *~ врачы* санита́рный врач; *~ техникасы* санита́рная те́хника □ **~ эшкәртүе** санобрабо́тка

санитарлык *сущ.* до́лжность санита́ра, санита́рная слу́жба; *~ вазифасын үтәү* выполня́ть обя́занности санита́ра

санки *союз уст. книжн.* **1.** *сравн. см.* **гүя** **2.** *соед.* почти́ что, счита́й, что

са́нкция *сущ. спец.* са́нкция; *Югары суд ~се* са́нкция Верхо́вного суда́; *финанс һәм хәрби ~* фина́нсовая и вое́нная са́нкция; *кулга алырга прокурор ~се кирәк* что́бы арестова́ть, нужна́ са́нкция прокуро́ра

са́нкцияләнү *страд. от* **санкцияләү**; санкциони́роваться/дать утвержда́ть/утверди́ть, одобря́ть/одо́брить || санкциони́рование, одобре́ние, утвержде́ние на *что-л.*

са́нкцияләү *перех. спец.* санкциони́ровать, дава́ть на са́нкцию *что-л.*

санла|у *перех.* счита́ться, почита́ть, уважа́ть, слу́шаться || почита́ние, уваже́ние; *ата-ананы ~у* почита́ть роди́телей; *өлкәннәрне ~у* счита́ться со ста́ршими; *укытучының сүзен ~у* слу́шаться учи́теля; *авыл гадәтләрен ~* почита́ть дереве́нские обы́чаи

санлашу *перех. разг. см.* **санлау**

санлы I *прил.* **1.** чи́сленный, числово́й; *~ бүлүче* чи́сленный дели́тель; *~ масштаб* чи́сленный масшта́б; *~ күплек* числово́е мно́жество **2.** цифрово́й; *~ мәгълүматлар* цифровы́е да́нные

санлы II *прил.* уважа́емый, почте́нный; ~ *кешеләр белән аралашу* обща́ться с почте́нными людьми́

санскрит *сущ.* санскри́т || санскри́тский; ~ *белгече* знато́к санскри́та, специали́ст по санскри́ту; ~ *теле* санскри́тский язы́к; ~ *телендә язылган кулъязма* санскри́тская ру́копись

сансыз I *прил.* бесчи́сленный, бессчётный, несме́тный; ~ *күп* бесчи́сленное мно́жество; ~ *еллар аша* че́рез бессчётные го́ды

сансыз II *прил.* **1.** 1) непочти́тельный, неуважи́тельный, де́рзкий; *бигрәк ~ малай* о́чень уж непочти́тельный ма́льчик 2) непутёвый, беспу́тный; *бигрәк ~ нәрсә булып чыкты килен* о́чень непутёвой оказа́лась сноха́ **2.** непочита́емый, неуважа́емый, нену́жный; *ялгыз кеше — ~ кеще* (*посл.*) одино́кий челове́к — непочита́емый челове́к

сансыз III: **сансыз калу** потеря́ть спосо́бность дви́гаться, лиши́ться подви́жности

сансызлану **1.** станови́ться/стать непочти́тельным, непослу́шным **2.** проявля́ть/прояви́ть непочти́тельность

сансызлык I *сущ.* бессчётность, несме́тность

сансызлык II *сущ.* непочти́тельность, неуваже́ние, невнима́тельность; *тирә-юньдәгеләргә карата ~* неуваже́ние к окружа́ющим

сансыз-санаксыз *прил. разг. усил. см.* **сансыз** I; бесчи́сленный, несчётный, несме́тный; *сансыз-санаксыз мал-мөлкәт* несме́тное бога́тство (состоя́ние)

сансын|у *перех.* счита́ться, почита́ть, уважа́ть || почте́ние, уваже́ние; *ул аның белән ~ып сөйләште* он с ним говори́л с почте́нием

сантехник *сущ.* сантехник

сантехника *сущ.* сантехника || сантехни́ческий; ~ *эшләре* сантехни́ческие рабо́ты; ~ *җиһазлары* сантехни́ческое обору́дование

сантим *сущ.* санти́м (*разменная монета Франции, Бельгии, Швейцарии и др. стран*)

сантиметр *сущ.* **1.** сантиме́тр (*единица длины, равная одной сотой доле метра*) **2.** сантиме́тр (*лента метровой длины с нанесенными на ней сантиметровыми делениями*); ~ *белән баланың буен үлчәү* изме́рить санти́метром рост ребёнка

сантиме́тла|у *перех.* **1.** ме́рить сантиме́трами (*делить точно*); *ярар инде, ~п торма, бүлгәлә шунда ла́дно*, дели́ ка́к-нибудь, не мерь сантиме́тром **2.** дели́ть, разделя́ть/раздели́ть *что-л.* на сантиметро́вые деле́ния; *~нган таяк* па́лка, поделённая на сантиме́тры

сантиме́трлап *нареч.* сантиме́трами; ~ *үлчәү* ме́рить сантиме́трами

сантиме́трлы *прил.* сантиметро́вый; -сантиметро́вый; ~ *линейка* сантиметро́вая лине́йка; *икс* ~ двухсантиметро́вый; *өч* ~ трёхсантиметро́вый

сантиме́трлык *сущ.* -сантиметро́вый; *ун* ~ десятисантиметро́вый

сантый *сущ разг.* глупе́ц; межеу́мок *прост.*; *~га чын сүз — ул нигә?* глупцу́ правди́вое сло́во ни к чему́ || *прил.* глу́пый, придуркова́тый; ~ *кыз* придуркова́тая де́вушка; ~ *сүз* глу́пое сло́во

сантыйлан|у *неперех. разг.* **1.** глупе́ть; станови́ться/стать глу́пым, придуркова́тым; *аларның баласы ~ган бугай* ка́жется, у них ребёнок стал придуркова́тым **2.** дура́читься, приду́риваться; *кызым, ~ма, алай килешми!* до́ченька, не дура́чься, так нехорошо́!

сантыйлык *сущ. разг.* **1.** глу́пость, дурь, дура́чество **2.** ту́пость

сану́зел *сущ. разг.* сану́зел

са́нча *прил.* числово́й; ~ *кыйммәт* числово́е значе́ние

санчасть *сущ. разг.* санча́сть; *авыруны ~кә озату* отпра́вить больно́го в санча́сть

саңак I *сущ.* **1.** жа́бры (у ры́бы) || жа́берный; ~ *дугалары* жа́берные ду́жки **2.** *диал.* ни́жняя че́люсть; *см. тж.* **аскы казналык 3.** *тех.* вы́ступ пло́тничьего топора́, боро́дка **4.** черено́к за́ступа

саңак II *сущ.* две́рца, ство́рка; *ишек ~лары* ство́рки две́ри (*двустворчатой двери*); *см. тж.* **ишек канатлары (ябылмалары)**

саңаклы *прил.* жа́берный, с жа́брами; *кызыл ~* с кра́сными жа́брами

саңгырау *прил.* **1.** глухо́й || глухо́й челове́к **2.** глухо́й, незво́нкий, приглушённый; ~ *тавыш* глухо́й го́лос; ~ *кайтавыз* глухо́й о́тзвук

саңгырауландыру *перех.* оглуша́ть/оглуши́ть

саңгыраулану *неперех.* **1.** оглуша́ться/оглуши́ться, гло́хнуть, огло́хнуть; станови́ться/стать глухи́м; *бомба шартлаудан ~* оглуши́ться взры́вом бо́мбы **2.** приглуша́ться/приглуши́ться (*о голосах, шуме*)

саңгыраулату *перех. см.* **чукраклату**

саңгыраулаштыру *перех. лингв.* оглуша́ть/оглуши́ть || оглуше́ние

саңгыраулаштырылу *страд. от* **саңгыраулаштыру**

саңгыраулашу *неперех. лингв.* оглуша́ться/оглуши́ться || оглуше́ние; *яңгырау тартыкларның ~ы* оглуше́ние зво́нких согла́сных

саңгыраулык *сущ.* **1.** глухота́; *см. тж.* **чукраклык 2.** *лингв.* глу́хость (*звука*)

сап I *сущ.* **1.** черено́к; *көрәк (сәнәк, себерке һ. б. ш.) сабы* черено́к лопа́ты (вил, метлы́ *и т. п.*) **2.** дре́вко; *сөңге сабы* дре́вко копья́ (пи́ки); *багор сабы* дре́вко багра́ **3.** рукоя́тка, рукоя́ть; *см. тж.* **тотка, кулса**; *урак сабы* серпови́ще, рукоя́тка серпа́; *балта сабы* топори́ще; рукоя́тка топора́; *чыбыркы сабы* кнутови́ще, рукоя́тка кнута́; *чалгы сабы* косови́ще; рукоя́тка косы́; *пычак сабы* рукоя́тка ножа́; *хәнҗәр сабы* рукоя́тка кинжа́ла; *кылыч (гранат, наган) сабы* рукоя́тка са́бли (грана́ты, нага́на) **4.** ло́же (*винтовочное, ружейное*) **5.** сте́бель, черешо́к; *см. тж.* **сабак, сабакча**; чем; *чәчәк (үлән) сабы* сте́бель цветка́ (травы́); *яфрак сабы* черешо́к ли́стика

сап II *сущ.* сап; *см. тж.* **маңка авыруы**

сап III *перепозит. частица усил., присоединяемая к прилагательным, начинающимся на* **са-**: *сап-салкын* холо́дный-прехоло́дный, *сап-сары* жёлтый-прежёлтый

сапёр *сущ. воен.* сапёр || сапёрный; *~лар отряды* отря́д сапёров; ~ *эше* сапёрное де́ло; *мина кырына ~лар чакыру* вы́звать сапёров на ми́нное по́ле

саплам *сущ.* ни́тка длино́й (*приблизительно*) в оди́н обхва́т, доста́точный оди́н раз вдеть в иго́лку (*при ручном шитье*); *бер ~ жеп калмаган* нет ни одно́й сажёни (ни одного́ арши́на, ни одного́ обхва́та) ни́тки; *~ыңны озын итмә* не де́лай дли́нной ни́тку ◊ **(бер) ~ жеп бирмәс, (бер) ~ жеп (сорап) ала алмассың, (бер) ~ жебен кызганыр** скупо́й, жа́дный (*букв.* ни вершка́ ни́тки не даст); ~ *буе* о́чень коро́ткий (*о зимнем дне и летней ночи*)

саплама́лау *перех.* отме́рить (ни́ток) на не́сколько обхва́тов (*для вдевания в иголку*)

саплану *страд. от* **саплау**

саплату *понуд. от* **саплау**; попроси́ть, заказа́ть, наса-ди́ть черено́к, рукоя́тку и т. п.

саплау *перех.* **1.** насáживать/насадúть *что-л.* на черенóк, на дрéвко, придéлывать (придéлать) рукоя́тку || насáживание на черенóк, придéлывание рукоя́тки; *балта ~у* насáживать (налáдить) топóр на топорúще; *көрәк ~у* насадúть лопáту на черенóк; *сөңге ~у* насадúть копьё на дрéвко; *шөшле (өтерге) ~у* насадúть рýчку на кочеды́к (на долотó) **2.** вдевáть/вдеть, продевáть/продéть (нúтку в игóлку) **3.** *перен.* лóвко выполня́ть/вы́полнить *что-л.*

саплаяк *сущ.* сосýд с рýчкой (*ковш, половник, и т. п.*)

саплы *прил.* с рукоя́ткой, с черенкóм; насáженный на рукоя́тку (черенóк), имéющий рукоя́тку (черенóк), снабжённый рукоя́ткой (черенкóм); *~ көрәк* лопáта с черенкóм; *сөяк ~ пычак* нож с костянóй рукоя́ткой; *агач ~ чүкеч* молотóк с деревя́нным черенкóм □ **~ ук** самострéл (*букв.* стрелá с черенкóм) ◊ **~ җинги** *шутл.* мужчúна, вмéшивающийся в жéнские делá

саплык I *прил.* предназнáченный для изготовлéния черенкá, рукоя́тки и т.п. (*материал*)

саплык II *сущ. диал. см.* **ямаулык**

сапма *сущ. диал.* **1.** разновúдность пелерúны; *см. тж.* **изүчә, алынча, артча** **2.** растрýб (*сапог*)

сапмалы *прил. диал.* с растрýбом (*сапоги*)

сап-сай *прил. превосх. ст.* совершéнно (совсéм) мéлкий (*озера, реки*)

сап-салкын *прил. превосх. ст.* совершéнно (совсéм) холóдный; холóдный-прехолóдный; *сап-салкын су* óчень холóдная водá

сапсан *сущ. зоол.* сапсáн (*разновидность сокола*)

сап-сары *прил. превосх. ст.* жёлтый-прежёлтый, совершéнно жёлтый

сап-сасы *прил. превосх. ст.* тýхлый-претýхлый, вонюúчий, совсéм вонюúчий (*испорченная рыба*)

сап-сау *прил. превосх. ст.* здорóвый, здорóвенький, совершéнно здорóвый

сап-саф *прил. превосх. ст.* чúстый-пречúстый, свéжий, совсéм свéжий (*о воздухе, воде*)

сап-саңгырау *прил. превосх. ст.* совершéнно глухóй

саптыр|у *понуд. от* **сабу** **1.** приставúть, придéлать, пришúть нóвую голóвку к óбуви; обсоюзить, обновúть голóвку сапóг, связáть носовýю часть чулóк зáново **2.** сбить, застáвить сходúть/сойтú с (прáвильного) путú; *юлдан ~ды* сбил с путú

сапфир *сущ., мин.* сапфúр; *см. тж.* **зәңгәр якут**

сар *сущ. уст.* пáдаль □ **сар кошы** *зоол.* канюк; *см. тж.* **сарыч**

саравыч *сущ.* **1.** *ист.* козырёк шлéма; надлóбная часть шлéма **2.** *диал.* 1) чéпчик для старýх 2) платóк, котóрый нóсится в надвúнутом вперёд вúде

сара|й *сущ.* **1.** дворéц, хорóмы, палáта, зáмок || дворцóвый, палáтный; *патша ~е* цáрский дворéц; *Мәдәният ~е* Дворéц культýры; *Хезмәт ~е* Дворéц трудá **2.** *разг.* сарáй, дровянúк; *см. тж.* **лапас**

саран *прил.* **1.** скупóй, прижúмистый || скряга, скупéц; *ср.* **комсыз**; *~ байның малы чери* (*погов.*) у скупóго богачá имýщество (*товар*) гниёт; *~ ишеген кунак какмас* в дверь скря́ги никтó не постучúт; *~ның сарае салкын, өйрәсе сыек* у скупóго дом холóдный, суп (из крупы) жúдкий; *~нан бүз сорама, наданнан сүз сорама* у скупóго не вы́просишь бя́зи, от невéжды не добьёшься пýтного слóва (к невéжде не обращáйся с вопрóсом); *~ның ~ы* скря́га из скряг **2.** (*-га ~*) скупóй на...; избегáющий издéржек *в чём-л.*, скупóй; *мактауга ~ укытучы* учúтель, скупóй на похвалý; *хат язарга бик ~* óчень скупóй на пúсьма

сарáна *сущ. бот.* сарáна, сарáнка (*луковичное растение из семейства лилейных*)

саранаю *неперех. прост. см.* **сараплану**

саранлан|у *неперех.* **1.** скупúться, поскупúться, скря́жничать; *бакчачы ~мады, балалар теләгән кадәр алма җыйдылар* хозя́ин сáда не стал скупúться, дéти собрáли я́блок стóлько, скóлько хотéли **2.** становúться/стать скупы́м *на что; сүзгә ~у* стать немногослóвным (*букв.* скупы́м на слова́)

саранлашу **1.** *неперех. см.* **саранлану** **2.** *взаимн.* отказáть друг дрýгу *в чём-л.* из-за скýпости

саранча *сущ. зоол.* саранчá || саранчóвый; *сыерчыклар ~ белән дә туена* скворцы́ питáются и саранчóй; *~ көтүе* саранчóвая тýча, саранчóвое стáдо, пóлчище саранчú; *~ курчагы* саранчóвая личúнка

саратан I *сущ. зоол.* верблюдка (*вид насекомого*)

саратан II *сущ.* **1.** *книжн. уст.* сарáтан (*название четвёртого месяца солнечного года, соответствует периоду с 22 июня по 21 июля*); *~ башы* начáло июня; *җәйнең ~ы* начáло лéта **2.** *астр.* созвéздие Рáка **3.** *мед.* рак || рáковый; *~ шеше* рáковая óпухоль

сарафан *сущ.* сарафáн || сарафáнный (*женское платье без рукавов*); *өстенә ак кофта, кара ~ кигән* на ней бéлая кóфточка и чёрный сарафáн; *~га дигән тукыма* ткань для сарафáна

сарачин, саричин *сущ. уст.* сарацúн (*название арабского населения северо-западной Аравии*) □ **~ тарысы** рис; *см. тж.* **дөге**

сараяк *сущ. диал.* телёнок коровы-первотёлки

сарбай *сущ.* **1.** 1) *обычная кличка собак рыжего (или желтоватого) цвета* 2) *перен.* дворня́жка **2.** *диал. перен.* малоавторитéтный человéк

саргаеш|у **1.** *совм. от* **саргаю** **1**; желтéть, пожелтéть (*о многих*); *агач яфраклары ~ты* лúстья дерéвьев пожелтéли **2.** *перен.* чáхнуть, сúльно тосковáть (*грустить, переживать*), сúльно печáлиться (*о многих*); *сагыштан ~у* пожелтéть от тоскú; *ата-ана ерактагы балаларын сагынудан ~тылар* родúтели пожелтéли от тоскú по дéтям, живýщим вдалекé

саргайт|у *перех.* **1.** желтúть, вызывáть/вы́звать желтизнý; окрáшивать/окрáсить в жёлтый цвет; дéлать, сдéлать жёлтым; *мичне ~у* окрáсить в жёлтый цвет печь; *лампа яктысы булмә стеналарын ~ып күрсәтә* свет лáмпы желтúт стéны кóмнаты **2.** *понуд. от* **саргаю** 2 *перен.* опечáливать/опечáлить, вызывáть/вы́звать печáль, тоскý; заставля́ть/застáвить тосковáть, горевáть, печáлиться; *сагындыра, ~а сөйгән яр* заставля́ет тосковáть и печáлиться любúмая

сарга|ю *неперех.* **1.** желтéть, пожелтéть, желтúться; *~йган кавын* спéлая (*букв.* жёлтая) ды́ня; *~йган кыяр* жёлтый огурéц, желтя́к; *агач яфраклары ~йды* пожелтéли лúстья дерéвьев; *өлгергән сырганак ~ая* спéлая облепúха желтéет **2.** *перен.* переживáть, тосковáть продолжúтельно, печáлиться сúльно, сóхнуть, вы́сохнуть, чáхнуть, зачáхнуть; *сагынудан ~ю* вы́сохнуть (*букв.* пожелтéть) от тоскú □ **~еп бетү** *прям., перен.* пожелтéть, истосковáться, вы́сохнуть, чáхнуть от тоскú, печáли

саргылт *прил. уменьш. ст.* **1.** желтовáтый, с желтовáтым оттéнком; *кояшның алсу-~ нурлары* рóзово-желтовáтые лýчи сóлнца; *көзге ~ яфраклар* осéнние желтовáтые лúстья **2.** *как первый компонент парных*

прил. желтова́то-, жёлто-; ~ *-кызыл* желтова́то-кра́сный; ~ *яшел* желтова́то-зелёный

саргылтлан|у *неперех.* приобрета́ть/приобрести́ желтова́тый цвет (отте́нок), слегка́ желте́ть, пожелте́ть; *диңгез эле ~а, эле зәңгәрләнә* мо́ре то пожелте́ет, то посине́ет

саргылтлык *сущ.* желтова́тость

саргылтсу *прил. уменьш. ст. см.* **саргылт, саргылтым**

саргылтым *прил. уменьш. ст.* слегка́ желтова́тый, чуть желтова́тый; ~ *кәгазь* бума́га чуть желтова́того отте́нка

сардар *сущ.* **1.** *уст.* полево́й команди́р **2.** *ист.* боеви́к (*активный участник движения вайсовцев в 1860—1918 гг.*)

сарде́лька *сущ.* сарде́лька (*вид толстой сосиски*)

сардин, сарди́на *сущ. зоол.* сарди́на, сарди́нка (*рыба*)

сардо́ник *прил.* сардони́ческий (*язвительный, злобно-насмешливый*); *см. тж.* **саркастик**

сардо́никс *сущ. мин.* сардо́никс (*разновидность агата*)

са́ржа *сущ. текст.* са́ржа (*подкладочная ткань с гладкой блестящей лицевой стороной*), подкла́дка; *бизәкле ~дан тегелгән халат* халат из цвета́стой са́ржи; ~ *эчлек* са́ржевая подкла́дка || *прил.* са́ржевый

са́ри *сущ.* са́ри (*женское одеяние в Индии*)

сарказм *сущ.* саркази́зм (*язвительная насмешка*); *аның бу сүзләрендәге киная усал ~ булып яңгырады* ирони́я в его́ слова́х прозвуча́ла злым саркази́змом

саркастик *сущ.* саркасти́ческий (*язвительно-насмешливый*); ~ *көлү* саркасти́ческий смех

саркома *сущ. мед.* саркома́ (*вид злокачественной опухоли*); *мускуллар ~сы* саркома́ (мышц) му́скулов; *сөяк ~сы* саркома́ косте́й

саркофаг *сущ.* саркофа́г (*каменный гроб или надгробие*); *фиргавен ~ы* саркофа́г фарао́на

сарк|у *неперех.* **1.** проса́чиваться/просочи́ться, сочи́ться, проника́ть/прони́кнуть (*о жидкости*) || проса́чивание, проника́ние; *бинт аркылы кан ~ый* сквозь бинт проса́чивается кровь; *боз ярылган җирдә су өскә ~ып чыккан* че́рез тре́щины льда вода́ просочи́лась наве́рх **2.** *см.* **киптерү, кишертү**; *аяк асты бераз ~сын* пусть земля́ (*букв.* под нога́ми) немно́жко подсо́хнет **3.** *перен.* доноси́ться, слы́шаться; проса́чиваться/просочи́ться, проника́ть/прони́кнуть че́рез прегра́ды (*о звуках, лучах и т. п.*); *бүлмәгә алсу яктылык ~ып керә* в ко́мнату проника́ет (проса́чивается) ро́зовый свет; *калын ишек аша коридорга көлү тавышы ~ып чыга* че́рез то́лстую дверь в коридо́р доно́сятся (проса́чиваются) зву́ки сме́ха

саркыл|у *неперех. см.* **сарку** 1, 3; *шәһәргә чехлар ~ып кергәнен хәбәр иттеләр* извести́ли, что в го́род просочи́лись че́хи

саркым *сущ.* **1.** то́нкая струя́ и́ли ка́пельки при проце́живании **2.** *см.* **саркынды 3.** натёк; *нарат агачындагы сагыз ~ы* натёк смолы́ на сосне́

саркынды, саркынты *сущ.* жи́дкость, получа́ющаяся по́сле проце́живания сырых протёртых фру́ктов и овоще́й, а та́кже сы́воротка, остающаяся при прессова́нии тво́рога

саркыт *сущ.* **1.** сы́воротка (от молока́); *эркете миңа, ~ы сиңа* гу́ща простокваши́ мне, сы́воротка тебе́ **2.** *диал.* оста́тки угоще́ния пи́ра **3.** *диал. перен. единственный ребёнок, родившийся у немолодых родителей; заведомо первый и последний ребёнок*

саркыттыр|у *понуд. от* **саркыту**

саркыт|у *перех.* **1.** пропуска́ть/пропусти́ть (жи́дкость) че́рез *что-л.*; цеди́ть, проце́живать/процеди́ть || проце́живание, пропуска́ние че́рез *что-л.*; *юылган карлыганны иләккә салып ~у* проце́живать мы́тую смороди́ну че́рез си́то **2.** *диал.* суши́ть, вы́сушить, проса́шивать/просуши́ть (*что-л. влажное*)

саркытылу *страд. от* **саркыту**

сармак *сущ. см.* **самак**; ба́йка, прибау́тка || *прил.* словоохо́тливый; разгово́рчивый; ~ *хатын* словоохо́тливая же́нщина

сарман *сущ. диал.* желе́зный наконе́чник дерева́нного плу́га; ле́мех

сармат *сущ. ист.* сарма́т || сарма́тский; *~лар турында әсәр* произведе́ние о сарма́тах; ~ *ядкарьлекләре* сарма́тские па́мятники

сарнау *неперех. диал.* **1.** петь эле́гию, пе́сню о поко́йнике **2.** *перен.* петь жа́лобную (однообра́зную уны́лую) пе́сню

сарпат *сущ. уст. диал.* воспи́танность, досто́инство, скро́мность; *см. тж.* **тәрбиялелек, әдәплелек**; *форсатың китсә ~ың бетә (погов.)* е́сли упу́стишь (удо́бный) моме́нт, потеря́ешь досто́инство в глаза́х люде́й

сарпатлы *прил. диал.* с досто́инством, степе́нный, воспи́танный, сде́ржанный, скро́мный; *см. тж.* **тотнаклы, вәкарьле**; *кызлар ~ булырга тиеш* де́вушки должны́ быть сде́ржанными

сарпатсыз *прил. диал.* **1.** невоспи́танный, несде́ржанный, бесцеремо́нный, недосто́йный; *см. тж.* **тотнаксыз, тәкәллефсез 2.** небре́жно, неря́шливо; *киемне бик ~ кию* носи́ть оде́жду небре́жно || *нареч.* невоспи́танно, бесцеремо́нно, недосто́йно; *үзен ~ тоту* вести́ себя́ бесцеремо́нно

сарпинка *сущ. текст.* сарпи́нка (*вид ткани*) || сарпи́нковый; *см. тж.* **сәрфинкә**; ~ *яулык* сарпи́нковый плато́к

сарт *сущ.* **1.** *уст. разг.* 1) назва́ние коренны́х жи́телей городо́в Сре́дней А́зии 2) узбе́к **2.** *ист.* среднеазиа́тский купе́ц

сар|у I *перех.* **1.** обступа́ть/обступи́ть, окружа́ть/окружи́ть, оку́тывать/оку́тать || окруже́ние; *см. тж.* **әйләндереп алу, чолгап алу**; *агач ботагын кырмыска ~ган* ве́тку де́рева оку́тали муравьи́ **2.** облепля́ть/облепи́ть (*о пчёлах и подобных им насекомых*); *агачка ~ган күчне тубалга җыю* собра́ть рой, облепи́вший де́рево, в кузово́к **3.** 1) покрыва́ть/покры́ть, обраста́ть/обрасти́ *чем*; *см. тж.* **каплау**; *бу алмагачны язын чәчәк, көзен алма ~а* весно́й э́ту я́блоню покрыва́ют цветы́, о́сенью — я́блоки; *черегән агачны мүк ~а* гнило́е де́рево обраста́ет мхо́м **4.** *индив. переводится разными глаголами со знач.* покрыва́ть/покры́ть *чем*; *кар ~ган җир* засне́женная земля́; *юлчыларның вслярен бәс ~ган* оде́жда пу́тников заиндеве́ла; *буранда ышык тыкрыкларны көрт ~а* во вре́мя мете́ли глухи́е закоу́лки зано́сятся сугро́бами **5.** мота́ть, нама́тывать/намота́ть || нама́тывание, намо́тка; *җепне йомгактан (әвернәдән) киләпкә ~у* нама́тывать пря́жу с клубка́ (мотови́ло) в мото́к; *элек карчыклар башларына тастар ~ганнар* в старину́ же́нщины нама́тывали на го́лову тастар (*белый льняной платок*) **6.** обвива́ть/обви́ть; оку́тывать/оку́тать (*дымом*); *пәрәвез ~ган агач* де́рево, обви́тое паути́ной □ **~ып алу** обступи́ть, окружи́ть; обложи́ть **7.** *перен.* охва́тывать/охвати́ть; *мине сагыш ~ды* меня́

охвати́ла тоска́ **8.** *перен.* озаря́ть/озари́ть; *яктылык ~ды* озари́ло све́том

сару II *сущ.* **1.** желчь **2.** изжо́га □ **~ кайнаткыч 1.** то, что вызыва́ет изжо́гу **2.** *перен.* надое́дливый, неприя́тный; **~ кайнату 1.** вызыва́ть изжо́гу **2.** *перен.* доводи́ть до тошноты́ (*навязчивостью*); *бу яңгыр ява да ява, тәмам ~ны кайнатты* э́ти дожди́ совсе́м надое́ли; **~ кайнау 1.** страда́ть изжо́гой || изжо́га **2.** *перен.* тошни́ть, затошни́ть || тошнота́; *кыланышына ~ кайнау* от его́ криви́ляния то́шно; его́ неприли́чное поведе́ние вызыва́ет тошноту́; **~ суы** желчь, поступа́ющая в по́лость рта

сарулы *прил.* намо́танный, в намо́танном ви́де; *см. тж.* **киләпле** □ **~ җеп** пря́жа в мотке́

сарут *сущ. бот.* пыре́й, пыре́йник (*вид сорных и кормовых злаков*), костёр || пыре́йный; *см. тж.* **актамыр, сусән ут, күчтәр**; *шушима ~* пыре́й ползу́чий; *тамырсабаклы (арадаш) ~* пыре́й промежу́точный; *~ сабагы* сте́бель пыре́я; *~ тамыры* пыре́йный ко́рень; *~ исе* за́пах пыре́я

сарутлык *сущ.* ме́стность, поро́сшая пыре́ем

сары *прил.* **1.** жёлтый; *~ төс* жёлтый цвет; *~ буяу* жёлтая кра́ска; *аксыл ~* све́тло-жёлтый; белоку́рый; *кара ~* тёмно-жёлтый; *куе ~* гу́сто-жёлтый, лимо́нно-жёлтый; *кызыл ~* краснова́то-жёлтый; ры́жий; *зәгъфран ~* шафра́нно-жёлтый; *эфлисун ~* апельси́ново-жёлтый, ора́нжевый; *көрән ~* бе́жевый, коричнева́то-жёлтый; *гәрәбәдәй ~ бал* мёд цве́та янтаря́ **2.** *как первый компонент составных терминов цвета* жёлто-, желтова́то- || *сущ.* **1.** жёлтый цвет; *~га буяу* кра́сить в жёлтый цвет **2.** желто́к; *йомырка ~сы* желто́к яйца́ **3.** желту́ха || желту́шный; *см. тж.* **сары авыруы**; *~ төшеп авыру* заболе́ть желту́хой **4.** *мед.* жёлтая вода́, глауко́ма; *см. тж.* **сары авыруы**; *см. тж.* **сары су авыруы** □ **~ авыруы** *мед.* гепати́т, желту́ха; **~ ат 1.** була́ная ло́шадь **2.** савра́сая ло́шадь; **~ баллыкай** *бот. диал.* льня́нка; *см. тж.* **дала җитене, маржа башмагы, башмак чәчәк**; **~ бизгәк** жёлтая лихора́дка (*болезнь*); **~ билчән** *бот.* бодя́к полево́й; *~ буяк* вид травы́, из кото́рой получа́ют жёлтый краси́тель; **~ гөмбә** *бот.* лиси́чки (гриб); *см. тж.* **этәч гөмбә(се)**; **~ иңү, ~ керү** желте́ть, пожелте́ть; **~ камчау** *бот.* скаби́оза жёлтая; **~ корсак** *зоол.* желтопу́зик (*змеевидная ящерица*); **~ -көрән** желтова́то-кори́чневый; **~ -кызыл** жёлто-кра́сный; **~ кына** *бот. диал.* чистоте́л; *см. тж.* **~ сөтле үлән**; **~ май** топлёное ма́сло; **~ мәтрүшкә** *бот.* зверобо́й; **~ раса** жёлтая ра́са, монголо́идная ра́са; **~ сандугач 1.** *народно-поэт.* соловей́ (мой) желтопёрый **2.** *диал. см.* **кенәри**; **~ су 1.** ли́мфа **2.** сы́воротка; **~ су авыруы** *мед.* **1.** жёлтая вода́, глауко́ма **2.** водя́нка; **~ тамыр** *бот.* керме́к саре́птский; *см. тж.* **тары чүбе**; **~ тәнле** желтоко́жий; *ср.* **краснокожий, чернокожий**; **~ төнбоек** кубы́шка жёлтая; **~ тутлы** белобры́сый, с кра́пинками пигме́нта, с ры́жими пя́тнышками, весну́шчатый; *ср.* **кара тутлы**; **~ төскә керү** желте́ть, пожелте́ть; **~ туфрак** желтозём; *ср.* **краснозём, чернозём**; **~ үлән** *см.* **сарыбаш**; **~ үрмәләвек** паху́чий красоте́л; **~ чыпчык** чиж; **~ чәчәк** *диал.* **1.** куросле́п, желтоцве́т **2.** вса́кий жёлтый цвето́к; **~ шәңгә (тәтәй)** *диал. бот.* пупа́вка; **~ -яшел** жёлто-зелёный, оли́вковый ◊ **~ йорт** *уст.* жёлтый дом (*больница для душевнобольных*)

сарыбаш *сущ. бот.* **1.** желту́шник; *соргылт ~* се́рый желту́шник (*лекарственное растение*); *урман ~ы* лесно́й желту́шник **2.** ске́рда (*сорная трава*); *япмалы ~* ске́рда кро́вельная

сарыгу *неперех. см.* **сарку**

сары|к *сущ.* овца́ || ове́чий; *ана ~к* овцема́тка; *бәрән ~к* я́рка; *буаз ~к* суя́гная овца́; *ит ~гы* мясно́й поро́ды овца́; *йон ~гы* поро́да ове́ц с дли́нной ше́рстью; *каракүл ~гы* караку́льская овца́; *нечкә йонлы ~к* тонкошёрстная (тонкору́нная) овца́; *меринос ~гы* мерино́совая овца́ □ **~к абзары** овча́рня; **~к асраучылык 1.** овцево́дство (*отрасль*) **2.** овцево́дческий (*хозяйство, ферма*); **~к бәрәне** ягнёнок; **~к ите** бара́нина; **~к йоны** ове́чья шерсть; **~к кайчысы** но́жницы для стри́жки ове́ц; **~к караучы** овча́р; **~к көтүе** ота́ра ове́ц, ста́до ове́ц; **~к көтүчесе** чаба́н; **~к сөте** ове́чье молоко́; **~к сыман үгез** овцебы́к; **~к тәкәсе** бара́н; **~к тиресе** овчи́на, ове́чья шку́ра; **~к үрмәкүче** каракурт, чёрный пау́к; **~к үрчетү** разведе́ние ове́ц; **~к үрчетүче** овцево́д; **~к фермасы** овцефе́рма, овцево́дческая фе́рма; **~к эремчеге** бры́нза ◊ **~к баш** глу́пый, глупова́тый, несообрази́тельный

сарык-кәҗә *сущ. собир.* ме́лкий скот, о́вцы-ко́зы, о́вцы и ко́зы

сарыкма *сущ.* оса́док; *ср.* **саркым, саркынды**

сарыкчылык *сущ.* овцево́дство || овцево́дческий (*совхоз*); *см. тж.* **сарык асраучылык**

сарыландыр|у *понуд. от* **сарылану**

сарылан|у *неперех.* желте́ть, пожелте́ть || пожелте́ние; *ср.* **саргаю**; *сары авыруы вакытында күз агы, аяк куллар ~а* при боле́зни желту́хой белки́ глаз, ру́ки и но́ги желте́ют

сарылдыру *понуд. от* **сарылу**

сарыл|у *неперех.* **1.** *возвр. от* **сару**; ви́ться, обвива́ться/обви́ться; *см. тж.* **уралу 2**; *үрмәле үсемлекләр башка үсемлекләргә ~ып үсәләр* вью́щиеся расте́ния расту́т обви́вшись вокру́г други́х расте́ний **2.** нама́тываться/намота́ться (*о пряже, нитке*); *см. тж.* **чорналу**; *эрләнгән җеп орчыкка ~а бара* пря́деная ни́тка нама́тывается на веретено́ **3.** льнуть, прильну́ть, обхва́тывать/обхвати́ть, обнима́ть/обня́ть, жа́ться, прижима́ться/прижа́ться; повис́нуть (рука́ми); *см. тж.* **сарышу** (*о выражении ласки*); *муенга ~у* повис́нуть на ше́е; обхвати́ть ше́ю рука́ми; *бала әнисенә ~ды* ребёнок прильну́л к ма́тери **4.** облепля́ть/облепи́ть, окружа́ть/окружи́ть, обступа́ть/обступи́ть; *см. тж.* **сару, сарыш алу**; *балга чебен ~ган* мёд облепи́ли му́хи; *укучылар укытучыга ~дылар* учени́к обступи́ли (окружи́ли) учи́теля

сарылучан *прил.* **1.** скло́нный льнуть *к кому-л.*; тот, кто име́ет привы́чку нава́зываться *к кому-л.*, нава́зчивый, прили́пчивый; *см. тж.* **сырышучан 2.** име́ющий сво́йство ви́ться, обвива́ться, сплета́ться (*о растениях*); *колмак — ~ үсемлек* хмель — вью́щееся расте́ние

сарылы *прил.* **1.** с желтизно́й, с желтова́тым пятно́м (отте́нком) и т. п. **2.** *в парных прил.* жёлто-, вперемёжку с жёлтым; *~ -кызыллы* жёлтый вперемёжку (чересполо́сно) с кра́сным, жёлто-кра́сный

сарылы|к *сущ.* **1.** желтизна́; *яфрак ~гы иңгән* охва́чен желтизно́й лист **2.** желтова́тость

сарымсак *сущ.* чесно́к || чесно́чный, чесноко́вый; *~ исе* чесно́чный за́пах; *~ булемтеге (теше)* до́льки (зу́бки) чеснока́; чесно́чные до́льки (зу́бки); *~ яфрагы* чесно́чные ли́стья

сарымсаклы *прил.* с чесноко́м, (пригото́вленный) из чеснока́, чесно́чный; *~ тозлык* рассо́л с чесноко́м; *~ тәмләткеч* припра́ва из чеснока́

сарымык *сущ. диал. см.* **сары авыруы**; желту́ха

сарын *сущ. диал.* **1.** эле́гия; элеги́ческая пе́сня **2.** *перен.* жа́лобная пе́сня вообще́

сарыф I *сущ. грам. уст.* морфоло́гия || морфологи́ческий; *гарәп ~ы* ара́бская морфоло́гия, морфоло́гия ара́бского языка́; *~ һәм нәхү* морфоло́гия и си́нтаксис; *~ укý* изуча́ть морфоло́гию

сарыф II: **сарыф итү** расхо́довать, израсхо́довать, тра́тить, истра́тить, употребля́ть/употреби́ть (*энергию, силу, здоровье, время*) || расхо́ды, тра́та; неразу́мная тра́та (*денег*); *туйга ~ иткән акча* де́ньги, израсхо́дованные на сва́дьбу

сарыфлау I *перех. уст. грам. см.* **төрләндерү**

сарыфлау II *перех. уст. см.* **сарыф итү**

сарыч *сущ. зоол.* кани́к, сары́ч (*хищная птица семейства ястребиных*)

сарыча *сущ. диал.* и́волга; *см. тж.* **шәүлегән**

сарычын I *сущ. диал.* пыльца́; (*цветочная*) перга́; *см. тж.* **серкә, чыршын**; *тәпиләренә ~ кунган төклетура* шмель с ла́пками в пыльце́

сарычын II *прил.* желтова́того цве́та; темнору́сый

сас|у *неперех.* **1.** ту́хнуть, протуха́ть/проту́хнуть, по́ртиться/испо́ртиться || протуха́ние; *~ыган ит* проту́хшее мя́со; *акмый торган су ~ый* стоя́чая вода́ ту́хнет □ **~ып бетү** проту́хнуть **2.** воня́ть/провоня́ть; быть вони́чим; ду́рно па́хнуть

сасы *прил.* **1.** злово́нный, вони́чий, провоня́вший, неприли́чно па́хнущий, смердя́щий, источа́ющий смрад; *см. тж.* **сасык, сасыган**; *~ ис* дурно́й за́пах; *~ һава* злово́нный во́здух; *~ тирес* пре́лый навоз; *~ гөмбә* вони́чий гриб; *~ ис килү* воня́ть; *~ исле* вони́чий; *~ ис чыгару* издава́ть дурно́й за́пах **2.** *в знач. сущ.* **сасысы** дурно́й за́пах; *тәмәке ~сы киемгә сеңә* дурно́й за́пах табака́ впи́тывается в оде́жду □ **~ бака** *см.* **гөберле бака; ~ какы** *бот.* болиголо́в кра́пчатый; *см. тж.* **сасыкай, елан көпшәсе, тимгелле түндербаш; ~ көзән** *зоол.* хорь, хорёк; **~ үлән** *бот.* воня́чка

сасыган *прил. см.* **сасы, сасык**; *~ идән асты* за́тхлое подпо́лье; *~ кымыз* вони́чий кумы́с

сасык I *прил.* **1.** *см.* **сасы 2.** *о некоторых животных:* вони́чий

сасык II *сущ. диал. см.* **кандала**

сасыкай *сущ. бот. см.* **сасы какы**

сасылык *сущ.* **1.** злово́нность, за́тхлость **2.** злово́ние, злово́нное ме́сто; *~ка килеп керү* оказа́ться в злово́нном ме́сте

сасыт|у *перех.* распространя́ть/распространи́ть злово́ние (вонь); навоня́ть; *бүлмәне тәмәке исе белән ~у* провоня́ть ко́мнату табако́м

сатай-мотай: сатай-мотай китерү *разг.* пу́тать, переставля́ть/переста́вить; *см. тж.* **буташтыру, саташтыру**

сатанкан *прил. разг.* **1.** поме́шанный *на чём-л.*, фанати́чно увлечённый *чем-л.* **2.** шально́й, ша́лый, сумасбро́дный, безрассу́дный

саташтыру *перех.* **1.** сбива́ть/сбить с то́лку, пу́тать, запу́тывать/запу́тать **2.** *см.* **буташтыру**; *хәрефләрне ~* пу́тать бу́квы **3.** пу́тать *кого-л. с кем-л.*

саташ|у *неперех.* **1.** бре́дить || бред; *яралы солдат ыңгыраша, ~а* ра́неный солда́т сто́нет, бре́дит **2.** сбива́ться/сби́ться с то́лку; пу́таться, запу́таться **3.** спу́тываться/спу́таться, ошиба́ться/ошиби́ться; *см. тж.* **ялгышу, бутау**; *шигырь сөйләгәндә ~у* сби́ться при чте́нии стихотворе́ния наизу́сть; *санаганда ~у* спу́таться при счёте **4.** *перен.* увлека́ться/увле́чься *чем-л.*, помеша́ться *на чём-л.*; оказа́ться поглощённым, захва́ченным *чем-л.* (*театром, спортом, ролью*)

саташулы *прил.* бредо́вый, перемежа́емый бре́дом; *авыруның ~ халәте* бредо́вое состоя́ние больно́го; *~ йокы (төш)* бредо́вый сон

саташучан *прил.* скло́нный бре́дить, ча́сто бре́дящий (во сне)

сателлит *в разн. знач.* сателли́т

сатин *сущ.* сати́н (*плотная шелковистая ткань*) || *прил.* сати́новый; *~ халат* сати́новый хала́т

сатинет *сущ.* сатине́т (*тонкий сатин*) || *прил.* сатине́товый; *яшел ~ күлмәк* зелёная сатине́товая руба́шка

сати́ра *сущ.* сати́ра || сатири́ческий; *~ жанры* жанр сати́ры

сатирик I *прил.* сатири́ческий (*рассказ*)

сатирик II *сущ.* сати́рик

саткалау *перех. многокр. от* **сату**; иногда́, и́зредка продава́ть *что-л.*

саткын *сущ. диал.* прода́жа, распрода́жа □ **~ алу** купи́ть (*оптом*)

сатлык *прил.* **1.** продаю́щийся, прода́жный, предназна́ченный для прода́жи (*товар, одежда, овощи и т. п.*) **2.** 1) *перен.* прода́жный; *~ җан* прода́жная душа́ 2) *в знач. сущ.* прода́жный челове́к, преда́тель, изме́нник

сатрап *сущ.* сатра́п (*правитель, наместник-деспот*); *патша ~лары* ца́рские сатра́пы

саттыр|у *понуд. от* **сату**; заставля́ть/заста́вить, обя́зывать/обяза́ть, вынужда́ть и́ли разреша́ть продава́ть/прода́ть *что-л.*; *машинаны ~у* прода́ть маши́ну че́рез *кого-л.*

сат|у *перех.* **1.** продава́ть/прода́ть; сбыва́ть/сбыть, реализова́ть || 1) прода́жа, сбыт, реализа́ция 2) прода́жный; *алып ~у* перепродава́ть, занима́ться ску́пкой-прода́жей (перепрода́жей); *~у бәясе* прода́жная цена́; *ваклап ~у (~у итү)* торгова́ть в ро́зницу, ро́зничная торго́вля; *күплэп (күмәртәләп) ~у* продава́ть (торгова́ть) о́птом, о́пто́вая торго́вля; *уптым-илаһи ~у разг. см.* **күплэп сату 2.** *перен.* предава́ть/преда́ть, изменя́ть/измени́ть || преда́тельство, изме́на; *сер ~у* преда́ть огла́ске секре́т; *илне ~у* измени́ть Ро́дине; *антын ~у* измени́ть прися́ге **3.** *перен. неодобр.* занима́ться (*не тем*), разглаго́льствовать *о чём; акыл ~у* у́мничать, у́мничание; *мораль ~у* чита́ть мора́ль; разглаго́льствовать о мора́ли; *гыйлем ~у* разглаго́льствовать о нау́ке; стара́ться каза́ться просвещённым, многозна́йкой; *гыйшык ~у* притворя́ться влюблённым **4.** *перен.* говори́ть, распространя́ть спле́тни, слу́хи; спле́тничать; *ялган ~у* распространя́ть ложь, клевету́; *әкият ~у* расска́зывать ска́зки; *ахмаклык ~у* говори́ть, де́лать глу́пости; занима́ться глу́постью ◊ **~ып бирә (җибәрә)** 1. не чета́ *кому-чему*; перепл́юнет *кого-что* **2.** прода́ст, недо́рого возьмёт

сату-алу *сущ.* ку́пля-прода́жа, торго́вля; комме́рция; *сату-алу эшләре белән йөрү* занима́ться ку́плей-прода́жей (торго́влей)

сатулау *перех. редко см.* **сатулашу**

сатулаш|у *перех.* **1.** торгова́ться, ряди́ться, догова́риваться об усло́виях поку́пки, о цене́; *базар-базар инде, ~асың* база́р есть база́р — торгу́ешься, ряди́шься **2.** спо́рить, поспо́рить *о чём-л.* оспа́ривать *что-л.*; добива́ться/доби́ться *чего-л.* || притяза́ние, оспа́ривание; *кем хаклы булу турында ~у* поспо́рить о том, кто прав

сатучы *сущ.* продаве́ц, продавщи́ца, торго́вец, торго́вка; рабо́тник торго́вли, коммерса́нт; *см. тж.* **сәүдәгәр**; *~ булып эшләү* рабо́тать продавцо́м, продавщи́цей; *~лар киңәшмәсе* совеща́ние рабо́тников торго́вли

сатучылык *сущ.* торго́вое де́ло, торго́вля; *~ белән шөгыльләну* занима́ться торго́влей, рабо́тать в торго́вле

сатыл|у *страд.-возвр. от* **сату** 1. *страд.* продава́ться, быть про́данным; *бу әйбер ~дымы (~уда булдымы?)* э́тот това́р продава́лся (был в прода́же)? 2. *возвр. перен.* прода́ться; измени́ть, преда́ть; *см. тж.* **хыянәт итү**; *дошманга ~у* прода́ться врагу́

сатылучан *прил.* 1. хо́дкий (*товар*); *~ булу* быть хо́дким 2. *перен.* покупно́й, прода́жный; *~ булу* быть прода́жным; *~ кеше* прода́жный челове́к

сатылучанлык *сущ. редко* подку́пность, прода́жность

сатын|у *неперех. прост.* руга́ться, матюка́ться; *син бик ~ма* ты не о́чень руга́йся

сатышу *перех. взаимно-совм. от* **сату**; помога́ть/помо́чь *кому-л.* торгова́ть

сау *прил.* 1. здоро́вый, невреди́мый; здра́вый || здоро́во; здра́во; *см. тж.* **сәламәт**; *сау түгеллеге куренә* ви́дно, что не здоро́в; *баш сау булса (бүрек) табылыр (погов.)* была́ бы голова́ цела́, а ша́пка найдётся; *авыруның хәлен сау белмәс (погов.)* чужа́я боля́чка не боли́т (*букв.* здоро́вый больно́го не поймёт) 2. *см.* **исән, тере** 3. *в ф.* **саумы(сыз)** здра́вствуй(те)! здоро́во! □ **сау бул(ыгыз)** будь(те) здоро́в(ы); до свида́ния, проща́й(те); **сау булу** здра́вствовать, быть здоро́вым; быть в до́бром здра́вии; **сау калу** 1. оста́ться здоро́вым (живы́м); *биш балабыз үлде, берсе генә сау калды* пя́теро дете́й у́мерли, оди́н то́лько живо́й оста́лся 2. вы́жить, уцеле́ть; **сау фикерле** здравомы́слящий

саубуллашу *неперех.* проща́ться, попроща́ться, прости́ться || 1. проща́ние 2. проща́льный; *ике куллап ~* попроща́ться двумя́ рука́ми; *соңгы мәртәбә ~* проща́ться в после́дний раз; *мәңгегә ~* проща́ться навек; *см. тж.* **бәхилләшү**

саугыч *сущ.* до́йник, дойльник, подо́йник; *сөт ~ савыт (чиләк)* дойльное ведро́, подо́йник

саудыр|у 1. *понуд. от* **саву** 2. *см.* **саву** I; *савымчылар аппарат белән иллешәр сыер ~а* доя́рки аппара́том до́ят по пятьдеся́т коро́в

сау-исән *прил. см.* **сау-сәламәт**

саулану *неперех. см.* **савыгу, сәламәтләну**

сауләт *сущ. уст.* 1. мощь, вели́чие; *~ вә дәүләт* вели́чие и бога́тство 2. стреми́тельный на́тиск, мо́щное нападе́ние

саулык I *сущ.* здоро́вье, здоро́вое состоя́ние; *см. тж.* **сәламәтлек, тазалык**; *~ — зур байлык* здоро́вье — бога́тство; *сезнең ~ка!* за ва́ше здоро́вье! *~ бетү* потеря́ть здоро́вье; *~ китте* здоро́вье пропа́ло; *~ какшады* здоро́вье пошатну́лось; *~ны саклау* бере́чь здоро́вье || охра́на здоро́вья, здравоохране́ние □ *~ саклау бүлеге (министрлыгы)* отде́л (министе́рство) здравоохране́ния

саулык II *сущ.* са́мка, ма́тка (*о козлёнке, ягнёнке*); *см. тж.* **теше**; *кәҗә бәтиләренең берсе ~, берсе тәкә* из козля́т одна́ са́мка, друго́й саме́ц || *прил. см.* **савым**; *~ сыер* до́йная коро́ва; *~ бия* до́йная кобы́ла

саулык-сәламәтлек *сущ. собир.* здоро́вье и благополу́чие; *саулык-сәламәтлек ничек?* как (твоё) житьё-бытьё (здоро́вье-настрое́ние)?

саумал *сущ. диал.* до́йный скот; коро́вы и ко́зы

сау-сәламәт *прил.* здоро́вый, живо́й-здоро́вый, живздоро́в; живо́й-невреди́мый; *сау-сәламәт булыгыз* бу́дьте здоро́вы, до свида́нья; *сау-сәламәт (барып) җитү* добра́ться живы́м и здоро́вым; *сау-сәламәт котылу* спасти́сь (оста́ться) живы́м и здоро́вым; *сау-сәламәт кенә яшибез* живём благополу́чно (жи́вы-здоро́вы)

сау-сәламәтлек *сущ. см.* **саулык-сәламәтлек**; *сау-сәламәтлекләрегез ничек?* как Ва́ше здоро́вье?

саусыз *прил.* не совсе́м здоро́вый; хво́рый; *ср. тж.* **сырхау, авыру**

саусызлан|у *неперех.* заболе́ть, занемо́чь; *см. тж.* **авырып китү, сырхаулау**

саусызлык *сущ.* недомога́ние, нездоро́вье, отсу́тствие здоро́вья; *см. тж.* **сырхаулык**

саути *прил. в разн. знач.* звукова́й

саутия *сущ. ист.* звукова́й ме́тод (*в обучении*)

саф I *прил.* 1. чи́стый (не загрязнённый, без при́месей); *см. тж.* **чиста**; *саф авырлык* чи́стый вес; *саф алтын* чи́стое зо́лото; *саф тавыш* чи́стый (зво́нкий) го́лос 2) настоя́щий, по́длинный; *саф татар* настоя́щий тата́рин; *см. тж.* **чын** 2. *перен.* све́жий; *саф һава* све́жий во́здух; *саф җил* све́жий ве́тер; *саф кар* све́жий снег; *саф баш белән эшләп алу* пораба́тать на све́жую го́лову 3. правди́вый, че́стный, благоро́дная душа́; *саф вөждан* чи́стая со́весть 4. че́стный, неви́нный, безгре́шный, де́вственный; *саф кыз* неви́нная (непоро́чная) де́вушка; целому́дренная де́вушка; де́вственница 5. *перен.* высо́кий, настоя́щий, чи́стый, возвы́шенный; *саф мәхәббәт* настоя́щая возвы́шенная любо́вь 6. *перен.* чи́стый, нали́чный; *саф акча* нали́чные де́ньги; *саф килер* чи́стый дохо́д; *саф табыш* чи́стая при́быль □ **саф акыл** здра́вый смысл; **саф баштан** на све́жую го́лову; **саф канлы** чистокро́вный; **саф күңел (йөрәк)** благоро́дная душа́; **саф күңелдән** от чи́стого се́рдца; **саф күңелле** че́стный, с чи́стой со́вестью; **саф күңеллелек** и́скренность, чистосерде́чность; чистосерде́чно; **саф нәселле (токымлы)** чистопоро́дный; **саф чишмә суы** чисте́йшая ключева́я вода́

саф II *сущ.* ряд, шере́нга, строй, коло́нна; *см. тж.* **рәт**; *алгы сафта* в пере́днем ряду́; *алгы сафта булу (бару)* быть (идти́) в пере́дних рада́х; *демонстрацияче-ләр сафы* строй (ряд, шере́нга) демонстра́нтов □ **сафка тезелү** вы́строиться, постро́иться; **сафка тезү** вы́строить, постро́ить *кого*; **сафны икелә(тү** ряды́ вздво́ить ◊ **сафка басу** вступа́ть/вступи́ть в строй де́йствующих (рабо́тающих); **сафтан чыгару** выводи́ть/вы́вести *кого-что* из стро́я; **сафтан чыгу** выходи́ть/вы́йти из стро́я

сафа *сущ.* блаже́нство, споко́йствие, безмяте́жность, беспе́чность, поко́й, о́тдых; *см. тж.* **кәеф-сафа**; *әүвәле җәфа, соңра ~ (погов.)* не потруди́вшись, не вкуси́шь и плодо́в своего́ труда́ (*букв.* снача́ла ма́яться, пото́м блаже́нствовать) □ *~ сөрү* блаже́нствовать, наслажда́ться (*прогулкой на лоне природы*)

сафа́ри *сущ.* сафа́ри

сафландыргыч *прил.* освежа́ющий || освежи́тель

сафландыру *перех.* 1. очища́ть/очи́стить (*воду, воздух, комнаты*) || очище́ние 2. *перен.* освежа́ть/освежи́ть || освеже́ние; *башны ~* освежи́ть го́лову; *хәтерне ~* освежи́ть па́мять 3. *перен.* облагора́живать/облагоро́дить || облагоро́жение; *үсемлекне ялгау юлы белән ~* облагоро́дить расте́ние приви́вкой; *сыерларның токымын ~* облагора́живать поро́ду коро́в

сафландырылу *страд. от* **сафландыру** 1. очища́ть/очи́ститься, быть очи́щенным 2. *перен.* освежа́ться/освежи́ться, быть освежённым 3. *перен.* облагора́живаться/облагоро́диться, быть облагоро́женным

сафлан|у I *возвр. от* **сафлау** 1. очища́ться/очи́ститься, станови́ться/стать чи́стым || очище́ние; *чишмә суы ~ды* родни́к стал чи́стым 2. *перен.* освежа́ться/освежи́ться, станови́ться/стать све́жим || освеже́ние;

яңгырдан соң һава ~ды после дождя́ во́здух стал све́жим; *ял иткәннән соң баш ~ып китте* по́сле о́тдыха голова́ ста́ла свежее́ **3.** *перен.* облагора́живаться/облагоро́диться || облагора́живание

сафлану II *неперех.* стро́иться, постро́иться (*рядами, в шеренгу*), выстра́иваться/вы́строиться; *өчәр булып ~* постро́иться в ряды́ по три

сафлату *перех. см.* **сафландыру**

сафлау *перех. редко см.* **сафландыру**

сафлор *сущ. бот.* сафло́р (*однолетнее техническое растение и краска из цветов этого растения*) □ **~сыман левзея** левзея сафлорови́дная *или* мара́лий ко́рень

сафлы *прил.* состоя́щий из ряло́в, постро́енный ряда́ми (*колонна солдат, демонстрантов, физкультурников*)

сафлы|к *сущ.* **1.** чистота́, незагрязнённость, све́жесть; *һаваның ~гы* чистота́ во́здуха; *хәтернең ~гы* све́жесть па́мяти **2.** *перен.* правди́вость, че́стность, благоро́дство; чистота́; *күңел ~гы* благоро́дство души́; *вөҗдан ~гы* чистота́ души́ **3.** *перен.* чистота́, по́длинность, безупре́чность; *мөнәсәбәтләрнең ~гы* безупре́чность взаимоотноше́ний **4.** *перен.* че́стность, неви́нность, непороч́ность, безгре́шность

сафлы-сафлы *прил.* во мно́гих ряда́х, коло́ннами (*о массах людей*); *см. тж.* **саф-саф**

сафранин *сущ. тех.* сафрани́н (*шафранная краска*); *см. тж.* **зәгъфран буявы**

сафрол *сущ.* сафро́л (*шафранное масло*); *см. тж.* **зәгъфран мае**

сафсата *сущ.* **1.** болтовня́, вздор, пусты́е рассужде́ния, бессмы́слица **2.** софи́зм; демаго́гия ◊ **~ сату (кору)** нести́ вздор, поро́ть чепуху́; *ср.* **лэчтит сату, гэп сату; ~ сатучы** 1) болту́н, пустоме́ля 2) демаго́г

сафсатачы *сущ.* **1.** софи́ст **2.** демаго́г; *см.* **сафсата сатучы**

саф-саф *нареч.* в ви́де шере́нг, рядо́в; ряда́ми; *саф-саф (булып) тезелү* постро́иться ряда́ми; *саф-саф булып бару* идти́, вы́строившись ряда́ми

сахабә, сәхабә *сущ.* **1.** *ист.* сподви́жник проро́ка Мухамме́да **2.** *перен.* сора́тник, сподви́жник; клевре́т

сахиб *сущ. уст.* **1.** хозя́ин, владе́лец; *см. тж.* **ия, хуҗа 2.** спу́тник, друг; *см. тж.* **юлдаш, дус**

сахра *сущ.* **1.** по́ле, степь, простор **2.** пусты́ня

сахтыян *сущ. см.* **сәхтиян**

сач *сущ. уст. поэт. см.* **чәч**

саяк *сущ. диал.* броди́га, безде́льник, гуля́ка; *см. тж.* **биләмче**; *~ кәҗә кебек бөвдә тормый ул* она́, как броди́га-коза́, до́ма не быва́ет

саяк-сандрак *сущ. разг. см.* **сояк-сандак**; *ср.* **калдык-постык, вак-төяк**

саяру *неперех. диал. см.* **саегу**

сәбә|п *сущ.* **1.** причи́на (*явления, успеха, неудачи, несчастного случая*); подопле́ка, подосно́ва; *~бен эзләү* иска́ть причи́ну *чего*; *~бенә күрә чарасы* какова́ причи́на, такова́ и ме́ра; *узем янам, узем көям, белмим ~бен* (*песня*) я горю́, я пыла́ю, а причи́ну всё не зна́ю **2.** *разг.* 1) вино́вник, вино́вница; *см. тж.* **сәбәпче** 2) пови́нный; *ә бу эшкә син ~п* повинен в э́том ты **3.** по́вод; предло́г; отгово́рка; *см. тж.* **сылтау**; *~п табып* найдя́ предло́г; *... дигән ~п белән* под предло́гом *того, что ...* **4.** *уст. юр.* (доста́точный) по́вод для возбужде́ния, де́ла, и́ска; *см. тж.* **сәбәплек 5.** *в знач. союза подчин.* **сәбәптән, сәбәбеннән** по причи́не *того, что*; *шул ~птән* по той причи́не; вследствие того́; *кыенлык ~беннән* вследствие тру́дности □ **~бенә керешү (керү)** принима́ть/приня́ть ме́ры *для чего*; *булсын дисәң бер эш, ~бенә кереш (посл.)* хо́чешь что-нибу́дь сде́лать — приступа́й к де́лу; **~и җөмлә** *грам.* прида́точное предложе́ние причи́ны; **~п итү** указа́ть причи́ной *что*; ссыла́ться *на что;* отгова́риваться/отговори́ться; *шуны ~п итеп* ссыла́ясь на э́то; **~и хәл(е)** *грам.* обстоя́тельство причи́ны; **~пкә сылтау** отгова́риваться || отгово́рка; *бу бит ~кә сылтау гына* э́то ж то́лько отгово́рка

сәбәпле *прил.* **1.** причи́нный; *~ бәйләнешләр* причи́нные свя́зи **2.** *предик.* име́ющий || име́ет причи́ны; *сәбәпсез түгел, әлбәттә, ~* не без причи́ны, коне́чно, име́ет (свою́) причи́ну || *послелог после гл. на* **-у/-ү**; по причи́не (вследствие, ввиду́) *того, что ... урманда йөрү ~* по причи́не того́, что был (ходи́л) в лесу́

сәбәплек *сущ.* **1.** *юр.* по́вод для возбужде́ния де́ла **2.** *см.* **сәбәплелек**

сәбәплелек *сущ. филос.* причи́нность; детермини́зм; *~ күренеше* явле́ние причи́нности; *~ категориясе* катего́рия причи́нности

сәбәпсез *нареч.* без причи́ны, без по́вода, беспричи́нно; *~ көлү — бөлүгә (погов.)* смех без причи́ны — к разоре́нию || *прил.* беспричи́нный; *~ эш* беспричи́нное де́ло

сәбәпчән *нареч. редко* причи́нно; *~ бәйле (баглы)* причи́нно свя́зано

сәбәпче *сущ.* вино́вник, вино́вница *чего* (*торжеств, события; опоздания кого*); причи́на *чему* || повинный, вино́вный *в чём* (*преимущ. в положительном знач.*); *безнең уңышыбызга ~ кеше* челове́к, повинный в на́ших успе́хах

сәбәпчелек *сущ. уст. диал.* повинность, вино́вность (*в каком-л. событии*); *...-га ~ итү* послужи́ть причи́ной, быть причи́ной *того, что*

сәбәт *сущ.* **1.** *диал.* корзи́на с кры́шкой; закры́тая кле́тка (*из прутяного каркаса, на который натягивается шкура или ткань*) **2.** *ист.* 1) большо́й ларь (*для зерна, муки*) 2) хле́бница

сәбзә *сущ. кулин. диал.* зе́лень, сала́т (*подаваемый на стол*)

сәвәл *сущ.* **1.** *этногр. ист.* **~ тун** шама́нская оде́жда **2.** *диал. см.* **сәвәләй**

сәвәләй *сущ. этногр.* **1.** 1) ря́женый (*во время новогодних игрищ*) 2) шут, шути́ха, кло́ун **2.** руба́ха, хала́т с о́чень дли́нными рукава́ми (*для новогодних представлений*) □ **~ көне** дни новогодних и́грищ, представле́ний, шутовства́

селтәм *сущ. разг.* взмах, мах; *кул ~е* взмах рукú (рук); *~гә бару* идтú мах за мáхом (о косаря́х); *ишкәк ~е* взмах вёслами

селтәнгәләү *многокр. от* **селтәнү**; замáхиваться, размáхивать (рукáми)

селтәндерү *понуд. от* **селтәнү**

селтәнеш *сущ. см.* **селтәм**

селтәнешү *взаимно-совм. от* **селтәнү**

селтән|ү *возвр. от* **селтәү 1.** размáхиваться/размахнýться (*рукой, топором, кнутом, палкой*) для удáра, броскá; *чыбыркы белән ~ү* размáхиваться кнутóм **2.** замáхиваться/замахнýться *на кого чем* (*револьвером на противника, палкой на собаку*); *см. тж.* **кизәнү** □ **~еп ыргыту** закúдывать/закúнуть, отбрáсывать/отбросúть с сúлой (*борцы на состязаниях, при драке*)

селтәнчек *прил. разг.* **1.** лю́бящий, привы́кший размáхивать (*руками, кнутом, вёслами, косой и т. п.*) **2.** замáхивающийся, норовя́щий удáрить

селтә|ү *перех.* **1.** махáть/махнýть, размáхивать/размахнýть || махáние, размáх, размáхивание; *см. тж.* **селкү 3**; **болгау**; *марш көенә кулларны ~ү* на мотúв мáрша размáхивать рукáми; *койрык ~ү* махáть хвостóм **2.** *разг.* бросáть/брóсить, вы́бросить, кидáть/кúнуть; *см. тж.* **ыргыту, чөю 3.** *разг.* удря́ть/удáрить **4.** *жарг.* укрáсть, утащúть, сперéть; *ишек алдындагы чананы берәү ~гән* сáнки во дворé кто́-то спёр

селте *сущ.* **1.** щёлок, отзóл (*раствор, полученный от кипячения в воде древесной золы*) || щелочнóй; *~ ясау* готóвить щёлок (щелочнóй раствóр); *~ суы* щёлок, отзóл; вода́, разбáвленная золóй; *~ суы керләрне агарта* щёлок отбéливает бельё **2.** *хим.* щёлочь (*растворимое в воде химическое вещество*) || щелочнóй; *төз белән кислота кушылганда ~ барлыкка килә* при соединéнии сóли с кислотóй образýется щёлочь; *барий ~се* бáриевая щёлочь; *сәһәр ~* éдкая щёлочь; *~ тәме* щелочнóй прúвкус; *~гә чыдамлы* щелочеупóрный

селтеләнү *возвр. от* **селтеләү**; щелочи́ться || щелоче́ние; *каен көле яхшы ~ә* зола́ берёзы хорошо́ щелочи́тся

селтеләү *перех.* щелочи́ть || щелоче́ние; *керне ~п юу* стира́ть бельё щёлоком (щелочно́й водо́й)

селтеле *прил.* **1.** щелочно́й, содержа́щий щёлочь, образу́ющий щёлочь; *~ су* щелочна́я вода́; *~ туфрак* щелочна́я по́чва; *~ металлар* щелочны́е мета́ллы **2.** *спец.* щелочно́й (*действующий с помощью щёлочи*); *~ аккумулятор* щелочно́й аккумуля́тор

селтелелек *сущ.* щёлочность; *~к дәрәҗәсе* сте́пень щёлочности; *туфракның ~ге* щёлочность по́чвы

селтеле-әчеле *прил.* щёлочно-кисло́тный

сельдерей *сущ. бот.* сельдере́й || сельдере́йный

сельдь *сущ.* сельдь (*морская рыба*) || сельдяно́й; *~ мичкәсе* сельдяна́я бо́чка

селькор *сущ.* селько́р (се́льский корреспонде́нт)

сельмаг *сущ.* сельма́г (се́льский магази́н)

сельпо *сущ.* сельпо́ (се́льское потреби́тельское о́бщество); *~ магазины* магази́н сельпо́

сем *прил.* ти́хий, прити́хший □ **сем генә** тихо́нько; ти́хо; *сем генә утыр!* сиди́ ти́хо!

сема́нтик *прил. лингв.* семанти́ческий; *~ анализ* семанти́ческий ана́лиз; *~ тикшерену* семанти́ческое иссле́дование

сема́нтика *сущ. лингв.* **1.** сема́нтика; *см. тж.* **мәгънә 2.** *то же, что* **семасиоло́гия**

семасиоло́гик *сущ. прил.* семасиологи́ческий

семасиоло́гия *сущ. лингв.* семасиоло́гия (*раздел языкознания о значениях слов и выражений*)

семафор I *сущ.* **1.** семафо́р (*сигнальное устройство*) **2.** семафо́р (*береговой знак — мачта с реем*) **3.** семафо́р (*сигнализация путём движений рук флажками*)

семафор II *сущ.* семафо́рщик

семәйтү *диал. перех.* заставля́ть присмире́ть, сбить спесь с *кого*; *см.* **юашландыру**; *мин, мин дигән егетләрне бу дөньялар ~ә (песня)* зазна́вшихся молодцо́в жизнь заставля́ет присмире́ть

семәк *сущ.* шпиль (*на шлеме*)

семә|ю *неперех. диал.* присмире́ть, затиха́ть/зати́хнуть (*от неудачи*); *~еп утыра* сиди́т себе́, пережива́я неуда́чу

сёмга *сущ.* сёмга || сёмужий; *~ икрасы* сёмужья икра́

семе́стр *сущ.* семе́стр (*половина учебного года в вузах и техникумах*) || семестро́вый; *беренче ~* пе́рвый семе́стр; *~ имтиханнары* семестро́вые экза́мены

семинар *сущ.* **1.** семина́р (*групповые занятия в вузах по какому-л. спец. предмету, теме*) **2.** семина́р (*групповые занятия по повышению квалификации*) || семина́рный, семина́рский; *татар теле ~ы* семина́р по тата́рскому языку́; *бригадирлар ~ы* семина́р бригади́ров

семинарист *сущ.* семинари́ст (уча́щийся семина́рии)

семина́рия *сущ.* семина́рия (*до революции среднее педагогическое и духовное учебное заведение*); *руханилык ~се* духо́вная семина́рия; *укытучылык ~се* учи́тельская семина́рия

семио́тика *сущ.* семио́тика (*наука, изучающая свойства знаков и знаковых систем*)

семит *сущ.* семи́т, семи́ты (*группа народов: арабы, евреи, эфиопы и др.*) || семи́тский; *~ телләре* семи́тские языки́

семья *сущ. разг. см.* **гаилә**

семьялы *прил. разг. см.* **гаиләле**; *~лар торагы* общежи́тие семе́йных

семьялы|к *сущ. биол.* семе́йство; *башаклылар ~гы* семе́йство зла́ковых

семьясыз *прил. см.* **гаиләсез**

семьячылык *сущ. см.* **гаиләчелек**; *ср.* **кода-кодагыйлык**

сенат *сущ. в разн. знач.* сена́т || сена́тский (*совет*); *~ йорты* сена́тский дом

сена́тор *сущ.* сена́тор (*член сената*)

сена́торлык *сущ.* сена́торство (*степень, сан, звание*)

сенбернар *сущ. зоол.* сенберна́р (*порода рослых служебных собак с волнистой шерстью*)

сенсацион *прил.* сенсацио́нный; *см. тж.* **сенсацияле**

сенса́ция *сущ.* сенса́ция (*неожиданное событие, сообщение, производящее сильное впечатление*)

сенса́цияле *прил.* сенсацио́нный; *~ хәбәр* сенсацио́нное изве́стие

сенса́циялелек *сущ.* сенсацио́нность

сенса́циячелек *сущ.* сенсацио́нность

сенсуализм *сущ* сенсуали́зм (*направление в теории познания*)

сенсуалист *сущ.* сенсуали́ст, сторо́нник сенсуали́зма

сенсуаль *прил.* сенсуа́льный, осно́ванный на чу́вствах, ощуще́ниях (*опыт*)

сенте́нция *сущ.* сенте́нция (*изречение нравоучительного характера*)

сентиментализм *сущ.* сентименталúзм (*течение в литературе и искусстве*)

сентименталь *прил.* сентимента́льный; *см. тж.* **хисле, хисси**; *әдәбиятта ~ юнәлеш* сентимента́льное направле́ние в литерату́ре

сентименталләнү *неперех.* сентимента́льничать || сентимента́льничанье; *см. тж.* **хискә бирелү**

сентименталлек *сущ.* сентимента́льность; *см. тж.* **хислелек, хиссилек**

сентябрь *сущ.* сентя́брь || сентя́брьский; *~ ае* ме́сяц сентя́брь; *~ көннәре* сентя́брьские дни; *~дә син дә бер, мин дә бер* в сентябре́ и у воробья́ пи́во (*букв.* в сентябре́ все равны́, т.е. все бога́ты)

сеньор *сущ.* **1.** сеньо́р (*в средние века: земельный собственник в Италии, обладавший властью*) **2.** сеньо́р (*почтительное наименование мужчины в Испании; ср.* **әфәнде** — *после имени*)

сеньо́ра *сущ.* сеньо́ра (*почтительное наименование замужней женщины в Испании*); *ср.* **ханым**

сеньори́та *сущ.* сеньори́та (*почтительное наименование незамужней женщины*; *ср.* **туташ** — *после имени*)

сеньо́рия *сущ. ист.* сеньо́рия (*в средние века в Западной Европе; область, принадлежавшая сеньору*)

сеңәл *сущ.* взвесь, суспе́нзия; жи́дкий раство́р (*извести и т. п.*) || *прил. диал.* жи́дкий (*о тесте, глине, пище, супе*); *камырым ~рәк булган* те́сто получи́лось жидкова́тым || *нареч. диал.* жи́дко; *балчыгыңны бик ~ изгәнсең* гли́ну замеси́л о́чень жи́дко

сеңәлле *прил.* взве́шенный; *~ хәлдә* во взве́шенном состоя́нии

сеңгертү *понуд. от* **сеңгерү**

сеңгер|ү *неперех.* сморка́ться, вы́сморкаться || сморка́ние; *борын ~у* сморка́ться □ **~еп ташлау** вы́сморкаться

сеңдерел|ү *страд.-возвр.* **1.** впи́тываться/впита́ться, быть впи́тываемым **2.** пропи́тывать/пропита́ться, быть пропи́тываемым; *май ~гән* пропи́танный ма́слом **3.** усва́иваться/усво́иться, перева́риваться/перевари́ться, быть усва́иваемым; *кечкенә чакта гадәтләр яхшы ~ә* в де́тстве привы́чки хорошо́ усва́иваются

сеңдерепле *прил. см.* **сеңдерүчән**

сеңдерт|ү **1.** *понуд. от* **сеңдерү** **2.** спосо́бствовать впи́тыванию, пропита́ть; *~еп майла* хорошо́ сма́зывай, пусть впи́тывается

сеңдер|ү *перех.* **1.** 1) *прям., перен.* впи́тывать/впита́ть *что* || впи́тывание; *дым ~ү* впи́тывать вла́гу; *олифа ~ү* впита́ть оли́фу; *хәтергә ~ү* впита́ть в па́мять 2) пропи́тывать/пропита́ть *чем; тозлык ~гән* пропи́танный соля́ным раство́ром **2.** *перен.* втолко́вывать/втолкова́ть, внедря́ть/внедри́ть *что*; *массалаларның аңына ~ү* внедри́ть в созна́ние масс **3.** *перен.* уса́ивать/усво́ить *что* || перева́ривание, уса́ивание, усвое́ние; *азык ~ү* перева́ривать пи́щу **4.** *перен. простореч.* присва́ивать/присво́ить, де́лать, сде́лать свои́м || присва́ивание, присвое́ние; *кеше малын ~ү* присво́ить чужо́е добро́ **5.** *перен. простореч.* вали́ть, свали́ть на зе́млю; *бандитны сугып ~ү* свали́ть банди́та уда́ром □ **~ә бару** *прям., перен.* впи́тывать (*постепенно*); **~еп бетерү** впита́ть *что-л.*; **~еп калу** усво́ить; **~еп кую** пропита́ть *чем*

сеңдерүчән *прил.* легко́ впи́тывающий (вса́сывающий, переваривающий), спосо́бный хорошо́ впи́тывать (вса́сывать)

сеңдерүчәнлек *сущ.* спосо́бность впи́тывать, абсорби́ровать

сеңел, сеңле *сущ.* **1.** мла́дшая сестра́, сестрёнка || се́стрин; *кече ~* мла́дшая сестра́; *туганнан туган ~м* моя́ двою́родная сестра́ **2.** *в обращении* **сеңлем** сестри́ца, сестри́чка; *~м! су гына бирче* сестри́чка! дай, пожа́луйста, воды́

сеңелкәй *сущ.* сестри́ца, сестри́чка (*обращение*); *син кем кызы буласың, ~?* ты чья до́чка, сестри́ца?

сеңер *сущ.* **1.** сухожи́лие, свя́зка; *аяк ~е тартылу* растяже́ние свя́зок; *тез асты ~е* коле́нные сухожи́лия; *~не иттән аеру* отдели́ть сухожи́лие от мя́са **2.** *диал.* рези́на; подвя́зка для чуло́к

сеңерләнү *неперех.* **1.** станови́ться/стать жи́листым **2.** станови́ться/стать ги́бким, упру́гим

сеңерле *прил.* **1.** жи́листый, сухоща́вый; *~ куллар* жи́листые ру́ки **2.** с жи́лами (жи́лками); *~ яшел яфрак* зелёный лист с жи́лками

сеңерчә *сущ. анат.* **1.** жи́лка **2.** *бот.* жи́лка; хо́рда; *яфрак ~ләре* жи́лки ли́стьев

сеңеш *сущ.* сво́йство впи́тываться/впита́ться || впи́тываемость; *матдәләр ~е* впи́тываемость веще́ств

сең|ү *неперех.* **1.** *прям., перен.* впи́тываться/впита́ться *чем* || впи́тывание; *су җиргә ~де* вода́ впита́лась в зе́млю; *канга ~ү* впита́ться (войти́) в кровь; *хәтергә ~ү* впита́ться в па́мять **2.** пропи́тываться/пропита́ться *чем*; *май ~ү* пропита́ться ма́слом; *балык исе ~ү* пропита́ться за́пахом ры́бы **3.** вса́сываться/всоса́ться; *канына ~гән* всоса́лось (впита́лось) в кровь; *ана сөте белән ~гән* всоса́лось с молоко́м ма́тери **4.** уса́иваться/усво́иться, переваривáться/перевари́ться || уса́ивание, переваривание; *азык ~ми* пи́ща не уса́ивается **5.** *разг.* припада́ть/припа́сть, льнуть, прижима́ться/прижа́ться *к кому-чему*; *ул җиргә ~де* он прижа́лся к земле́; *почмакка ~ү* вжа́ться в у́гол **6.** *перен.* пропада́ть/пропа́сть; исчеза́ть/исче́знуть, скрыва́ться/скры́ться || исчезнове́ние; *төн караңгылыгына кереп ~ү* скры́ться в темноте́ □ **~ә бару** *прям., перен.* впи́тываться (*постепенно*); **~еп калу** впита́ться, пропита́ться

сеңүчән *прил.* **1.** спосо́бный впи́тываться/впита́ться; спосо́бный вса́сываться/всоса́ться; *су тиз ~* вода́ спосо́бна бы́стро впи́тываться; *хәтергә тиз ~* спосо́бный бы́стро впи́тываться в па́мять (*материал*) **2.** удобовари́мый; *тиз ~ азык* удобовари́мая (*легкоусваиваемая*) пи́ща

сепарат I *сущ.* **1.** сепара́тор (*аппарат, служащий для отделения одного вещества от другого*) || сепара́торный; *~ цехы* сепара́торный цех **2.** сепари́рование || сепари́рованный; *~ сөте* сепари́рованное молоко́ □ **~ булмәсе** сепара́торная

сепарат II *прил. полит.* сепара́тный; *~ төркемнәр* сепара́тные гру́ппы; *~ солых (килешү)* сепара́тный догово́р

сепаратив *сущ. полит.* сепарати́вный; *~ омтылышлар* сепарати́вные устремле́ния (тенде́нции)

сепаративлык *сущ. полит.* сепарати́вность, сепарати́зм

сепаратизм *сущ. полит.* сепарати́зм (*стремление к отделению, обособлению*); *~ тарафдары* сторо́нник сепарати́зма, сепарати́ст

сепаратист *сущ. полит.* сепарати́ст

сепаратчы *сущ. с.-х.* сепара́торщик; челове́к, рабо́тающий с сепара́тором

се́псис *сущ. мед.* се́псис (*заражение крови гноеродными микробами*)

септет *сущ. муз.* септе́т (*произведение для семи инструментов или голосов и ансамбль из семи исполнителей*)

се́птик *сущ. мед.* септи́ческий (*ангина*)

се́птима *сущ. муз.* се́птима (*седьмая ступень от данной в диатонической гамме*)

сер *сущ. в разн. знач.* **1.** та́йна, секре́т; не́что сокры́тое, скры́тое, потаённое; *җир асты серләре* та́йны подземе́лья; *табигать серләре* та́йны приро́ды; *сер саклау* храни́ть та́йну; *дәүләт сере* госуда́рственная та́йна **2.** *в притяж. ф. при определит. словах* **сере** та́йна, секре́т *чего-л.*; *уңышның сере* секре́т успе́ха; *озак яшәүнең сере* секре́т долголе́тия □ **сер(ен) алу** заста́вить (*хитростью, обманом, угрозой*) раскры́ть секре́т *о чем-л.*; **сер(ен) ачу** **1.** откры́ть (разглаша́ть) та́йну **2.** *перен.* вы́болтать/вы́болтнуть та́йну ◊ **сер бирмәү** **1.** не пода́вать ви́да **2.** не подкача́ть, поступа́ть досто́йно; **сер бирү** **1.** выдава́ть волне́ние и т. п. **2.** подкача́ть, подвести́, не оправда́ть наде́жду; **сер итеп әйтү** сказа́ть по секре́ту; **сер сынатмау** *см.* **сер бирмәү; сер сыя (саклый) торган** нем как ры́ба; **серен чишү** раскры́ть та́йну, раскры́ться; **серләре килешә** закады́чные друзья́; нахо́дят о́бщий язы́к; *см. тж.* **боткалары пешә**

серадéлла *сущ. бот.* серадéлла (*ценное кормовое растение из семейства бобовых*)

сераль *сущ. ист.* сера́ль; гаре́м

серә|ю *неперех. разг.* столбене́ть, остолбене́ть; *атла, нәрсә ~йдең анда* шага́й, что там остолбене́л □ **~еп тору** *прям., перен.* торча́ть; выдава́ться/вы́даться (образова́в вы́ступ); *юл буенда ~еп тору* торча́ть о́коло доро́ги

серб *сущ.* серб, се́рбка (*мн. сербы, сербки*) || се́рбский; *~ теле* се́рбский язы́к

се́рбияле *прил.* сербия́нин, серб, челове́к из Се́рбии

сервант *сущ.* серва́нт (*низкий буфет для посуды и столового белья*)

се́рвиз *сущ.* серви́з || серви́зный; *аш ~ы* супово́й серви́з; *чәй ~ы* ча́йный серви́з; *~ тәлинкәсе* серви́зная таре́лка

сервис *сущ.* се́рвис (*бытовое обслуживание населения*); *см. тж.* **хезмәт күрсәтү**

сердәш *сущ.* напе́рсник, напе́рсница, закады́чный друг; тот, кому́ доверя́ют та́йну; *балачактан бергә уйнап-үскән ~ләр* закады́чные друзья с де́тства

сердәшлек *сущ.* положе́ние напе́рсника (напе́рсницы); серде́чная дру́жба; единомы́слие

сердәшче *сущ. см.* **сердәш**

серена́да *сущ. муз.* серена́да; *~ җырлау* петь серена́ду

сержант *сущ.* сержа́нт || сержа́нтский; *~ званиесе* зва́ние сержа́нта; сержа́нтское зва́ние; *милиция ~ы* сержа́нт мили́ции

сержантлык *сущ.* сержа́нтский; *~ погоннары* сержа́нтские пого́ны; *~ вазифасы* сержа́нтские обя́занности

се́рия *сущ. в разн. знач.* се́рия; *китаплар ~се* се́рия книг; *лотерея билетының ~ саны* но́мер се́рии лотере́йного биле́та; *кинофильмның ике ~сен тоташтан күрсәтү* показа́ть две се́рии кинофи́льма подря́д

се́рияләп *нареч.* се́риями; *фильмны берәр ~ кенә күрсәтү* пока́зывать фильм по одно́й се́рии; *станокларны ~ чыгару* вы́пуск станко́в се́риями; *~ җитештерү* сери́йное произво́дство

се́рияле *прил.* сери́йный; -сери́йный; *~ станоклар* сери́йные станки́; *~ җитештерү* сери́йное произво́дство; *ике ~ фильм* двухсерийный фильм

се́рияләлек *сущ.* сери́йность; *эшләнмәләрне җитештерүне сериялелекка көйләү* нала́дить сери́йное произво́дство изде́лий

серкә I *сущ. бот.* пыльца́, пыли́нка || пыльцево́й; *~ бөртеге* пыли́нка, пыльцево́е зерно́; *~ләр (тупланмасы, җыелмасы)* пыльца́; пыльцево́й мешо́чек □ **~ очыру** отцвести́ (*о злаках*); рассе́ять пыльцу́; **~гә утыру** (*о хлебных злаках*) **1.** опыля́ться **2.** цвести́ ◊ **~се су күтәрми** оби́дчивый

серкә II *сущ.* гни́да; *бет ~се* гни́да вши; *кандала ~ләре* гни́ды клопо́в; *~ басу* покрыва́ться гни́дами ◊ **~ хәтле генә** о́чень ма́ленький

серкә III *сущ.* у́ксус, у́ксусная эссе́нция || у́ксусный (*острая приправа*); *~ әчесе (тәме) килә торган; ~ тәмле* уксусноки́слый □ **~ агачы** *бот.* у́ксусное де́рево (*вид сумахи — южного дерева*); **~ әчелеге (кислотасы)** у́ксусная кислота́; **~ зәһәре, зәһәр ~** у́ксусная эссе́нция; **~ савыты** у́ксусник, у́ксусница

серкәдәй *прил.* о́чень ма́ленький; *см. тж.* **серкә хәтле генә**

серкәләндерелү *страд. от* **серкәләндерү**

серкәләндерү *перех.* опыля́ть/опыли́ть || опыле́ние; *читтән ~ү* перекрёстное опыле́ние; *ясалма ~ү* иску́сственное опыле́ние; *җил чәчәкләрне ~ә* ве́тер опыля́ет цветы́

серкәләнешү *взаимно-совм. от* **серкәләнү** I; взаимоопыля́ться/взаимоопыли́ться || взаимоопыле́ние

серкәләнү I *неперех. бот.* опыля́ться/опыли́ться || опыле́ние; цвести́ || цвете́ние (*о злаках*); *җил яки бөжәкләр ярдәмендә ~ү* опыле́ние при по́мощи ве́тра и́ли насеко́мых; *арыш ~ә башлаган инде* рожь уже́ начала́ цвести́

серкәләнү II *неперех.* покрыва́ться/покры́ться гни́дами

серкәләү *перех.* поливать/поли́ть у́ксусом; сме́шивать/смеша́ть с у́ксусом (*воду*)

серкәләүче *сущ.* опыли́тель (*о насекомых*) || опыля́ющий

серкәле I *прил.* в пыльце́; *~ арыш башаклары* коло́сья ржи в пыльце́

серкәле II *прил.* с гни́дами; *~ баш* голова́, усы́панная гни́дами

серкәле III *прил.* у́ксусный; с у́ксусом; содержа́щий в себе́ у́ксус, поли́тый у́ксусом; *~ шешә* бутылка с у́ксусом; у́ксусная бутылка; *~ маринад* у́ксусный марина́д

серкәлек *сущ. бот.* пы́льник, пыли́нки; *~ аталык орлыкларыннан тора* пы́льники состоя́т из мужски́х семя́н □ **~ сабагы (җебе)** тычи́ночная нить

серкәч *сущ. бот.* тычи́нка; *тал мамыкларындагы алтынсыман ~ләр* золоти́стые тычи́нки в пуху́ и́вы

серләш|ү *неперех.* откровенничать, дели́ться друг с дру́гом та́йнами, секре́тами; взаи́мно секре́тничать; доверя́ть/дове́рить друг дру́гу та́йны, секре́ты; *язны сөешү һәм ~ү вакыты диләр* говоря́т, весна́ — э́то пери́од любви́ и откровенных призна́ний; *сөйләшәсе, ~әсе килә* хо́чется поговори́ть и подели́ться свои́ми секре́тами (*сокровенными мыслями*)

серле *прил.* **1.** та́йный, таи́нственный, потаённый, скры́тый, зага́дочный; *табигатьнең ~ күренешләре* зага́дочные явле́ния приро́ды; *~ елмаю* зага́дочная улы́бка; *~ сүз* таи́нственное сло́во, таи́нственный разгово́р; *~ караш* зага́дочный взор **2.** секре́тный, с секре́том; *~ хат* секре́тное письмо́; *~ йозак* замо́к с секре́том **3.** романти́чный, поэти́чный; зага́дочный, непоня́тный, стра́нный; *язның ~ айлы кичә* романти́чный лу́нный ве́чер весны́; *~ кеше* стра́нный (зага́дочный) челове́к; *~ сорау* стра́нный (непоня́тный) вопро́с; *зәңгәр күзләрендә ~ матурлык* в голубы́х глаза́х (её) зага́дочная краса́; □ **~ рәвештә** таи́нственным о́бразом; таи́нственно

серлелән|ү *неперех.* станови́ться/стать таи́нственным, зага́дочным, стра́нным, непоня́тным; *кыз бөтенләй ят кешегә әйләнгән, ~гән* де́вушка ста́ла совсе́м незнако́мой, зага́дочной

серлелә|к *сущ.* таи́нственность, зага́дочность, секре́тность, стра́нность, романти́чность; *табигатьнең искиткеч ~ге* удиви́тельная таи́нственность приро́ды

сероводород *сущ. хим. см.* **күкертле водород**

серотерапи́я *сущ. мед.* серотерапи́я (*лечение сыворотками*)

серпантин *сущ.* серпанти́н (*клубки узкой разноцветной бумажной ленты*)

серри *прил. книжн. поэт. см.* **сихри, серле**; *~ бер ләззәт эченә чуму* забы́ться в како́м-то волше́бном наслажде́нии

серрият *сущ. книжн. см.* **серлелек, сихерләүчәнлек**

сертотмас *сущ.* болту́н; *ср.* **тишек авыз**

сессия *сущ.* **1.** се́ссия (*заседание представительных органов и коллегиальных учреждений*) || сессио́нный; *Татарстан Республикасы Югары Советы ~се* се́ссия Верхо́вного Сове́та Респу́блики Татарста́н **2.** се́ссия (*экзамены в высших и средних специальных учебных заведениях*) || сессио́нный; *кышкы ~* зи́мняя се́ссия; *~гә хәзерләну* гото́виться к се́ссии

сестра *сущ. мед.* сестра́; *см. тж.* **шәфкать туташы**; *дежур ~* дежу́рная сестра́; *медицина ~сы* медици́нская сестра́

сетка *сущ.* **1.** се́тка (*авоська, сумка*) || се́точный; *бер ~ бәрәңге* це́лая се́тка карто́феля; *ефәк ~* шёлковая се́тка **2.** *спец.* се́тка (*расписание, шкала*) || сетево́й; *тариф ~сы* тари́фная се́тка; *география ~сы* географи́ческая се́тка

си *сущ. муз.* си (*седьмая нота в музыкальной гамме*)

сиам *сущ.* сиа́м || сиа́мский; *~ мәчесе* сиа́мский кот; *~ игезәкләре* сиа́мские близнецы

сибәл|әү *неперех.* **1.** моросúть, накрáпывать || накрáпывание; *яңгыр ~әп тора* накрáпывает дождь; *көн саен яңгыр ~и* кáждый день моросúт дождь **2.** порошúть, запорошúть; *иртәдән кар ~и* с утрá порошúт снег

сибелдер|ү *понуд. от* **сибелү**; разбры́згивать, рассыпáть, рассéивать □ **~еп тарау** расчёсывать (*волосы*) так, чтóбы онú рассы́пались по плечáм

сибелмә *прил.* **1.** рассыпнóй; *~ алтын ятмасы* рассыпнóе месторождéние зóлота **2.** разбрóсанный, раскúданный || *сущ.* рóссыпь; *ашлык ~се* рóссыпь зернá; *алмаз ~се* рóссыпь алмáзов □ **~ чәчәкләләр** *бот.* метéльчатые растéния

сибелмәле *прил. см.* **сибелмә 1**

сибел|ү *страд. возвр. от* **сибү 1.** поливáться (быть пóлúтым) **2.** сы́паться, посыпáться/посы́паться, рассыпáться, быть рассы́панным; *идәнгә мәрҗән ~де* бýсы рассы́пались по пóлу; *җиргә борчак ~де* по землé рассы́пался горóх; *очкын ~де* посы́пались úскры **3.** *прям., перен.* разбрáсываться/разбросáться, быть разбрóсанным (раскúданным); лежáть вразбрóс, в беспоря́дке; *идәндә төрле әйберләр ~еп ята* на полý разбрóсаны (раскúданы) рáзные вéщи; *авыллар бер-берсеннән ерак ~еп утырганнар* дерéвни разбрóсаны далекó друг от дрýга **4.** *прям., перен.* лúться; рассéиваться/рассéяться || рассéивание; *яктылык нурлары ~ә* льётся свет; *уйлары төрле якка ~де* мы́сли егó спýтались (рассéялись) **5.** испускáться/испустúться, распространя́ться/распространúться (*о свете от фары*) **6.** растрепáться, разметáться (*о волосах*) **7.** разбры́згиваться/разбры́згаться (*о воде*) □ **~еп китү 1.** рассы́паться **2.** растрепáться (*о волосах*) **3.** разбры́згаться (*о воде*)

сибелүчән *прил.* сыпýчий; *~ мәк* сыпýчий мак; *кайсыбер сорт ефәк ~* нéкоторые сортá шёлка сыпýчи

сибенү *возвр. от* **сибү**; обливáться/облúться

сибештергәл|әү *многокр. от* **сибү 1.** врéмя от врéмени посыпáть **2.** иногдá (врéмя от врéмени) поливáть (разбры́згивать), душúться; *кайчак хушбуй ~им* иногдá пóльзуюсь духáми

сибешү *взаимно-совм. от* **сибү**; брызгáться, брызгáть друг в дрýга

сиб|ү 1. сы́пать, посыпáть/посы́пать, насыпáть/насы́пать *что* || насы́пка; насыпáние; *юлга ком ~ү* посыпáть дорóгу пескóм; *тавыкларга бөртек ~ү* насы́пать кýрам зернá **2.** сы́пать; рассыпáть/рассы́пать, разбрáсывать/разбросáть *что* || разбрáсывание; *әйберләрне төрле якка ~ү* разбросáть вéщи в рáзные стóроны **3.** сы́пать, присыпáть/присы́пать *что чем* || присыпáние; *чиләнгән урынга тальк ~ү* натёртое мéсто присы́пать тáльком **4.** *перен.* сы́пать *чем*; *цитаталар ~ү* сы́пать цитáтами; *матур сүзләр ~ү* сы́пать красúвыми словáми **5.** лить, испускáть/испустúть, распространя́ть/распространúть *что* || испускáние, распространéние; *кояш нурларын ~ә* сóлнце испускáет лучú; *хуш ис ~ү* распространя́ть прия́тный зáпах **6.** *перен. разг.* лить; *тышта яңгыр ~ә* на ýлице льёт дождь **7.** *прям., перен.* поливáть/полúть || полúвка, полúв; *тутәлләргә су ~ү* полúть гря́дки (водóй); *гөлләргә су ~ү* поливáть цветы́; *автоматтан ут ~ү* поливáть огнём из автомáта **8.** опры́скивать/опры́скать, окропля́ть/окропúть, обры́згивать/обры́згать, разбры́згивать/разбры́згать *что, чем* || опры́скивание, разбры́згивание; *иске май ~ү* побры́згать духáми; *алмагачларга тәмәке төнәтмәсе ~ү* опры́скивать я́блони табáчным настóем **9.** *перен. разг.* трáтиться, транжúрить, растранжúривать/растранжúрить *что*; *акчаны уңга да сулга да ~ү* трáтить дéньги напрáво и налéво; сорúть деньгáми напрáво и налéво

сибыт *сущ. уст. книжн.* род, колéно (*в генеалогии*)

сигáра *сущ.* сигáра || сигáрный; *~ тарту* курúть сигáру; *~ исе* сигáрный зáпах; *~ төтене* сигáрный дым □ **~ савыты (тартмасы)** сигáрочница

сигáрачы *сущ.* **1.** изготовúтель сигáр **2.** сигáрочник, продавéц сигáр

сигарет *сущ.* сигарéта || сигарéтный; *фильтрлы ~лар* сигарéты с фúльтром

сигәк *прил. прост.* страдáющий недержáнием мочú; мóчащийся под себя́

сигәкл|әү 1. мочúться под себя́, болéть (заболéть) недержáнием мочú **2.** *перен. прост.* трýсить, плáкаться; *~әп йөрмә* не трусь

сигез *числ. колич.* **1.** 1) вóсемь; *~ ярым* вóсемь с половúной; *~ сәгать бару* éхать вóсемь часóв; *хәзер сәгать ~* сейчáс вóсемь часóв 2) *в ф.* **сигездән** *мат.* а) от восьмú; *~дән өчне алу* от восьмú отня́ть три б) восьмáя; *~дән бер* однá восьмáя (часть) **2.** *в знач. сущ.* 1) вóсемь лет; *~дә укырга керү* пойтú в шкóлу в вóсемь лет 2) вóсемь часóв; *~дән тору* встава́ть в вóсемь (часóв) □ **~ сәгатьлек эш көне** восьмичасовóй рабóчий день; **~гә ~** вóсемь на вóсемь

сигезаяк *сущ. зоол.* осьминóг, спрут

сигезәр *числ. раздел.* по восьмú, по вóсемь; восьми-; *~ кешеле сафлар* колóнны по вóсемь человéк; *~ көн йөреп кайту* разъезжáть по вóсемь дней; *~ катлы йортлар* восьмиэтáжные домá; *~ потлы капчыклар* восьмипудóвые мешкú

сигезәрләп *нареч.* по восьмú; ввосьмерóм; *~ тезелү* пострóиться по вóсемь; встать в строй по восьмú

сигезәү *числ. собир.* вóсьмеро; ввосьмерóм; *~ килдек* пришлú ввосьмерóм

сигезәүләп *нареч.* ввосьмерóм; *~ чыгып киттеләр* ушлú ввосьмерóм

сигезсуна *сущ. зоол.* гагáра (*вид крупной водоплавающей птицы*)

сигéзурынлы: сигéзурынлы сан *мат.* восьмизнáчное числó

сигéзьеллык *прил.* **1.** восьмилéтний; *~ план* восьмилéтний план **2.** *в знач. сущ. разг.* 1) восьмилéтка; *ул ~ны тәмамлады* он окóнчил восьмилéтку 2) восьмилéтие

сигнал *сущ.* **1.** сигнáл || сигнáльный; *яктылык ~ы* световóй сигнáл; *~ утлары* сигнáльные огнú; *~ ракетасы* сигнáльная ракéта **2.** *перен.* сигнáл (*сообщение, известие, весточка и т. п.*); *урыннардан алынган ~* сигнáлы с мест || *прил.* сигнáльный; *~ экземпляр* сигнáльный экземпля́р (*книги, журнала*) □ **~ биргеч** сигнализú́рующий прибóр, сигнализáтор; **~ бирү 1.** дава́ть/дать сигнáл, сигнализúровать, сигнáлить; *флаг белән ~ бирү* сигнализúровать флáгами **2.** *перен.* дава́ть/дать знать, сигнализúровать *о чём*; *эштәге җитешсезлекләр турында ~ бирү* сигнализúровать о недостáтках в рабóте; **~ бирүче** сигнáльщик; **~ корылмасы** системá сигнализáции

сигнализáтор *сущ.* сигнализáтор (*прибор, аппарат, подающий сигналы*); *янгын ~ы* пожáрный сигнализáтор; *автомат ~* автоматúческий сигнализáтор

сигнализáция *сущ. в разн. знач.* сигнализáция || сигнализациóнный; *яктылык ~се* световáя сигнализáция; *~не тоташтыру* включúть сигнализáцию

сигналчы *сущ.* сигнáльщик; *~ матрос* матрóс-сигнáльщик

сидек *сущ. физиол.* моча́ || мочево́й; *~ составы* соста́в мочи́ □ *~* **ачу** *физиол.* мочеизнуре́ние; *~* **бүлеп чыгара торган** *анат.* мочеотдели́тельный; *~* **көшәсе** *анат. см.* **сидек юлы**; *~* **куыгы** *анат.* мочево́й пузы́рь; *~* **юлы** *анат.* мочеиспуска́тельный кана́л, мочето́чник

сидекле *прил.* вы́моченный в моче́, (весь) в моче́; *~ юрган* одея́ло, вы́моченное в моче́

сидерткеч *сущ.* мочего́нный; *~ дарулар* мочего́нные сре́дства

сидертү *понуд. от* **сию** 1. 1) заставля́ть моти́ться 2) вы́вести помочи́ться 2. *перен.* 1) запуга́ть, перепуга́ть на́смерть 2) наступа́ть/наступи́ть на мозо́ль; наро́чно раздража́ть, раздрази́ть зави́стливого и т. п. челове́ка

сидерү *перех. см.* **сидертү**; *баланы ~* вы́вести (поса́ди́ть) ребёнка мочи́ться

сизгер *прил.* 1. чу́ткий, чувстви́тельный; *~ нерв* чувстви́тельный нерв; *төрле искә ~ булу* быть чувстви́тельным к разли́чным за́пахам; *тәннең ~ урыннары* чувстви́тельные места́ те́ла 2. *перен.* чу́ткий, отзы́вчивый, внима́тельный; *~ йөрәк* чу́ткое се́рдце; *~ ана* чу́ткая мать; *~ җитәкче* внима́тельный руководи́тель 3. чу́ткий, с хоро́шим чутьём (нюхом); *~ эт* соба́ка с хоро́шим нюхом 4. бди́тельный; *~ булу* будь бди́тельным

сизгерләндерү *понуд. от* **сизгерләнү**

сизгерләнү *неперех.* 1. станови́ться/стать чу́тким, проница́тельным; *күңел ~ә* душа́ стано́вится чу́ткой 2. станови́ться/стать чувстви́тельным; *сүзгә ~ү* стать чувстви́тельным к слова́м

сизгерлек *сущ.* 1. чу́ткость; чувстви́тельность; *күңелнең ~ге* чувстви́тельность души́; *приборның ~ге* чувстви́тельность прибо́ра 2. чутьё, нюх; *этнең ~ге* чутьё соба́ки 3. *перен.* чутьё; *кешелэрчә ~к* челове́ческое чутьё; *ана ~ге* чутьё ма́тери 4. *перен.* бди́тельность; *сәяси ~к күрсәтү* прояви́ть полити́ческую бди́тельность

сизгеч *сущ. неол.* да́тчик (*прибора*)

сиздермәстән *нареч. см.* **сиздермичә**

сиздермичә *нареч.* незаме́тно, укра́дкой; и́сподволь, **втихомо́лку**; *~ генә карап алу* взгляну́ть укра́дкой; *берсенә дә ~ китеп бару* уйти́ незаме́тно для всех; *~ килеп чыгу* заяви́ться неожи́данно

сиздер|ү *неперех.* 1. дава́ть/дать о себе́ знать; дава́ть/да́ть обнару́жить, заме́тить; ска́зываться/сказа́ться; *авыру үзен ~ә* боле́знь даёт о себе́ знать; *арыганлык ~ә* ска́зывается уста́лость; *яшь үзен ~ә* во́зраст даёт о себе́ знать 2. выдава́ть/вы́дать, проявля́ть/прояви́ть, обнару́живать/обнару́жить *что*; *ул үзенең хисләрен ~мәде* она́ не вы́дала свои́х чувств 3. намека́ть, де́лать намёк; **дава́ть/дать поня́ть** (почу́вствовать); *ул үзенең каршы икәнлеген ~де* он дал поня́ть, что он про́тив

сизелгәләү *многокр. от* **сизелү**

сизелерлек *прил. прям., перен.* чувстви́тельный, ощути́мый; суще́ственный, заме́тный; *~ салкын* ощути́мый хо́лод; *~ тетрәү* чувстви́тельный толчо́к; *~ зыян* ощути́мый уро́н (ущёрб); *~ үзгәрешләр* ощути́мые переме́ны; *~ нәтиҗәләр* ощути́мые результа́ты; *~ аерма* суще́ственная ра́зница; *нык ~ чыгымнар* весьма́ чувстви́тельные расхо́ды; *~ булу* быть осяза́емым; *~ уңышлар* ощути́мые успе́хи; *~ йогынты* заме́тное влия́ние ‖ *нареч. прям., перен.* чувстви́тельно; заме́тно, суще́ственно, ощути́мо; *һава ~ салкынайды* заме́тно похолода́ло; *~ киму* ощути́мо уба́виться; *~ аерылып тору* заме́тно отлича́ться

сизелер-сизелмәс *прил.* е́ле (едва́) ощути́мый, е́ле (едва́) заме́тный, е́ле (едва́) улови́мый; *сизелер-сизелмәс селкену* е́ле заме́тный толчо́к; *сизелер-сизелмәс эз* е́ле улови́мый след; *сизелер-сизелмәс җил* е́ле ощути́мый ветеро́к ‖ *нареч.* е́ле ощути́мо, е́ле заме́тно, е́ле улови́мо; *сизелер-сизелмәс хәрәкәтләну* е́ле заме́тно дви́гаться

сизелмәле *прил. см.* **сизелерлек**

сизел|ү *возвр. от* **сизү** 1. чу́вствоваться; ощуща́ться; *үз-үзенә ышаныч ~у* ощуще́ние уве́ренности (в себе́); *бензин исе ~ә* чу́вствуется за́пах бензи́на; *ял итү кирәклеге ~ә* ощуща́ется потре́бность отдохну́ть; *ерактан диңгез сулышы ~ә* издалека́ ощуща́ется дыха́ние мо́ря 2. чу́вствоваться, обнару́живаться/обнару́житься; замеча́ться, ска́зываться/сказа́ться, проявля́ться/прояви́ться; *үзгәреш ~ми* не чу́вствуется измене́ний; *арыганлык ~ә* ска́зывается уста́лость; *поэзияне яхшы белүе ~ә* чу́вствуется, что он хорошо́ зна́ет поэ́зию 3. *в знач. нареч.* **сизелмичә** незаме́тно; *көн ~мичә үтеп китте* день прошёл незаме́тно 4. *в знач. прил.* **сизелмәслек** 1) неощути́мый, незаме́тный, неприме́тный; *~мәслек булсын* пусть бу́дет незаме́тным 2) *в знач. нареч.* незаме́тно, неощути́мо; неприме́тно; *җәйләре ~мәслек итеп тегү* сшить, что́бы швы бы́ли незаме́тны

сизелүчән *прил.* ощути́мый, заме́тный; *нык ~* хорошо́ заме́тный

сизелүчәнлек *сущ.* ощути́мость

сизем *сущ.* 1. чутьё, нюх (*у животных*); *хайваннарда ~ көчле* у живо́тных си́льно ра́звито чутьё 2. *перен.* чутьё, смека́лка, нюх (*у людей*); *~ белән аңлау* поня́ть чутьём; *сәяси ~* полити́ческая смека́лка; *аңарда эт ~е* у него́ соба́чий нюх 3. ощуще́ние; восприя́тие; осяза́ние; спосо́бность чу́вствовать (ощуща́ть, воспринима́ть, осяза́ть)

сиземләнү *страд. от* **сиземләү**; *см.* **сизелү** 2

сиземл|әү *перех.* чу́ять, почу́ять, чу́вствовать, почу́вствовать, осяза́ть, воспринима́ть/восприня́ть *что* ‖ чутьё; осяза́ние; восприя́тие; *яңалыкны тиз ~и алу* спосо́бность бы́строула́вливать но́вое; *матурлыкны ~и белү* уме́ние воспринима́ть красоту́; *~әү органнары* о́рганы чувств; *музыканы ~әү* чу́вствовать му́зыку

сиземле *прил.* 1. чувстви́тельный; *аның бармаклары ~* у неё чувстви́тельные па́льцы; *аеруча ~ аппарат* осо́бо чувстви́тельный аппара́т 2. дога́дливый, поня́тливый, проница́тельный, смека́листый

сиземлеле|к *сущ.* чувстви́тельность, спосо́бность чу́вствовать, ощуща́ть; *кешедәге ~к* спосо́бность челове́ка чу́вствовать (ощуща́ть); *бармакларның ~ге* чувстви́тельность па́льцев

сиземчән *прил. редко* 1. чувстви́тельный, о́стро чу́вствующий; воспри́имчивый; *балаларның психикасы бик ~* пси́хика дете́й о́чень воспри́имчива 2. чу́ткий, внима́тельный; отзы́вчивый; *бик ~ кеше* о́чень чувстви́тельный челове́к

сизен|ү *возвр. от* **сизү** 1. чу́вствовать, почу́вствовать; предчу́вствовать *что* ‖ чу́вствование; *күңелсезлек буласын күңел алдан ~де* се́рдце предчу́вствовало нела́дное; *ялгыш эшләвен ~де* он почу́вствовал, что поступи́л непра́вильно 2. дога́дываться/дога́даться; спохва́тываться/спохвати́ться; сообража́ть/сообрази́ть, смека́ть/смекну́ть ‖ дога́дка; *сүзнең кем турында барганлыгын ~ү* дога́даться, о ком идёт речь; *мин аларның кем булуларын тиз ~дем* я бы́стро сообрази́л, кто они́ на са́мом де́ле □ **~еп алу** смекну́ть, сообрази́ть

сизерәтү *перех.* истрепа́ть, изна́шивать/износи́ть, истаска́ть *что* ‖ изна́шивание; *күлмәкне ~* истрепа́ть, износи́ть руба́шку

сизерә|ү *неперех.* **1.** истрёпываться/истрепáться, изнáшиваться/износúться, расползáться/расползтúсь (*о ткани*); *күлмәк якасы ~гән* воротнúк рубáшки распóлзся; *җиң очлары ~гән* манжéты истрепáлись **2.** *в знач. прил.* **сизерәгән** износúвшийся; *~гән кием* износúвшаяся одéжда

сизмәмешкә: сизмәмешкә салышу притворя́ться/притвори́ться не замечáющим *кого-что*, не чýвствующим *чего-л.*; *аның килгәнен ~ салыну* притвори́ться, бýдто не замéтил егó прихóд

сизрәү *неперех. см.* **сизерәү**

сиз|ү *перех.* **1.** *в разн. знач.* чýвствовать, почýвствовать *что*; *ис ~ү;* чýвствовать зáпах; *авырту ~ү* чýвствовать боль; *ялгызлык ~ү* чýвствовать одинóчество; *җаваплылык ~ү* чýвствовать ответственность **2.** ощущáть/ощути́ть *что* || ощуще́ние; *салкынны ~ү* ощути́ть хóлод; *тәм ~ү* ощущáть вкус **3.** чýять, почýять, учýять *разг.* (*о животных, птицах, рыбах*); *ау эте исне тиз ~ә* охóтничья собáка бы́стро чýвствует зáпах **4.** замечáть/замéтить, обнарýживать/обнарýжить, примечáть/примéтить *что*; *берәү дә ~мәде* никтó не замéтил; *вакыт үткәнен ~мәдек* мы не замéтили, как прошлó врéмя **5.** догáдываться/догадáться *о чём*, чýвствовать, почýвствовать, смекáть/смекнýть *что* || догáдка; *ул берни дә ~мәде* он ни о чём не догадáлся; *аның сүзләреннән ~дем* я догадáлся (почýвствовал) по егó словáм; *үз гаебен ~ү* чýвствовать свою́ вину́; *хәйләне ~ү* замéтить улóвку **6.** предчýвствовать, чýвствовать/почýвствовать (интуити́вно); чýять, почýять; *ср.* **сизенү**; *йөрәгем ~ә* сéрдце чýет; *аның киләсен күңелем ~ә* чýет моё сéрдце, что он придёт **7.** *спец.* осязáть 1) осязáние; *~ү органнары* óрганы чувств 2) *перен.* чутьё, инстúнкт; нюх; догáдливость, сообрази́тельность, смётка **8.** *в знач. нареч.* **сизмәстән** *нареч.* нечáянно; незамéтно для себя́; бессознáтельно, самопроизвóльно, непроизвóльно; *~мәстән әйтеп кую* непроизвóльно вы́сказать; *үзе дә ~мәстән җырлап җибәрде* он запéл незамéтно для себя́; *~мәстән атып җибәрү* нечáянно вы́стрелить □ **~ә килү** (постоя́нно) замечáть/замéтить, догадáться; **~еп алу 1.** учýять, уловúть **2.** догадáться; **~еп калу** проморгáть; **~ми калу** не замéтить; пустúть из ви́ду; прозевáть

сизүлек *сущ. редко* чутьё; догáдка

сизүчән *прил.* **1.** чувствúтельный, óстро чýвствующий; *ис ~* óстро чýвствующий зáпах **2.** *перен.* догáдливый, сообрази́тельный; имéющий нюх *разг.* (*человек*)

сизүчәнле|к *сущ.* **1.** чувствúтельность; *тиренең ~ге* чувствúтельность кóжи **2.** *перен.* догáдливость, сообрази́тельность

сикәлтә *сущ.* **1.** ры́твина, ухáб, вы́боина, я́ма (*на дороге*); *юл ~се* вы́боина (*на дороге*); *~сез юл булмас (погов.)* не всё рóвно, есть и ухáбы **2.** *перен.* ухáб; *тормышта ~ләр* неуря́дицы в жúзни

сикәлтәле *прил.* **1.** ухáбистый, вы́битый, в вы́боинах (*о дороге*); *~ юл* ухáбистая дорóга **2.** *перен.* нелáдный, неустрóенный; в передря́гах; *~ тормыш* жизнь вся в передря́гах

сикелтә *сущ. разг. см.* **сикәлтә**; *юлдагы ~ләр* ухáбы на дорóге

сикелтәле *прил. разг. см.* **сикәлтәле**; *~ юл* ухáбистая дорóга

сикерә-сикерә *нареч.* вприпры́жку, подпры́гивая; *сикерә-сикерә хәлдән таю* напры́гаться, устáть от дóлгого пры́ганья

сикергәк: сикергәк коңгыз *зоол.* жук-скакýн

сикергәләнү *неперех. редко* **1.** *см.* **тыпырчыну 2.** *см.* **сикергәләү**

сикергәләп *нареч.* вприпры́жку; *~ йөгерү* бежáть вприпры́жку

сикергәл|әү 1. *многокр. от* **сикерү** 2; попры́гивать, подпры́гивать || подпры́гивание; *җылыныр өчен ~әү* попры́гивать чтóбы согрéться **2.** трясти́сь, подпры́гивать; *цирдә ~әп бару* трясти́сь в седлé; *машина чокырлар аша ~әп бара* машúна идёт, подпры́гивая на вы́боинах □ **~и башлау** запры́гать (*на месте от радости, нетерпения и т. п.*)

сикергеч *сущ.* скакáлка, пры́галка; *~тән сикерү* пры́гать со скакáлкой □ **~ уенчык** скакунóк (*прыгающая детская игрушка*)

сикерем *сущ. редко см.* **сикереш**

сикеренү *неперех.* попры́гать, попры́гивать (*некоторое время, время от времени, продолжительно*); *бер урында ~* попры́гивать на однóм мéсте

сикереп-сикереп *нареч.* **1.** вприпры́жку, подскáкивая; *сикереп-сикереп йөгерү* бежáть вприпры́жку **2.** бýрно, бурли́во; *сикереп-сикереп агу* течь бýрно, стреми́тельно □ **сикереп-сикереп кую** подпры́гивать (*время от времени*)

сикереш *сущ.* **1.** прыжóк; *балаларның ~е* прыжки́ детéй; *~ ясалды* совершён (сдéлан) прыжóк **2.** *перен.* си́льное биéние, скачóк; *йөрәк ~е* сердцебиéние, си́льное биéние сéрдца **3.** *перен.* скачóк; *эштә алга таба зур ~ ясау* сдéлать большóй скачóк в рабóте; *революцион ~* революциóнный скачóк; *уйларның ~е* скачóк мы́слей

сикерешле *прил.* скачкообрáзный, неравномéрный; *~ үсеш* скачкообрáзное развúтие || *нареч.* скачкообрáзно, скачкáми, неравномéрно; *~ үсү* развивáться скачкообрáзно

сикерешлелек *сущ.* скачкообрáзность, неравномéрность (*о развитии*)

сикереш|ү *совм. от* **сикерү 1.** пры́гать, запры́гать (*о многих*); *шатлыктан ~ү* запры́гать от рáдости; *бакалар ~әләр* лягýшки пры́гают; *ераста утлар ~ә* вдали́ мерцáют огни́ **2.** подпры́гивать, подскáкивать; *балалар ~әләр* дéти подпры́гивают **3.** зы́биться, игрáть (*о волнах*)

сикертеп *нареч.* **1.** вскачь, галóпом; *~ чабу* скакáть галóпом **2.** *перен.* пропускáя, с прóпуском, с пробéлами; *~ уку* читáть с прóпусками

сикерткәләү *многокр. от* **сикертү**

сикертмә *сущ.* **1.** *см.* **сикәлтә 2.** трамплúн; *чаңгы белән ~дән сикерү* пры́гать на лы́жах с трамплúна ◊ **~ каш** бровú с излóмом

сикертмәләнү *неперех.* становúться/стать ухáбистым; *юл ~гән* дорóга вся в ухáбах (стáла ухáбистой)

сикертмәле *прил.* **1.** *см.* **сикәлтәле**; *~ юл* ухáбистая дорóга **2.** *см.* **сиртмәле**; *~ кәнәфи* пружúнное крéсло **3.** *см.* **сикерешле**

сикерт|ү 1. *понуд. от* **сикерү**; *~мә аны* не давáй емý пры́гать **2.** *перех.* подбрáсывать/подбрóсить, швыря́ть, трясти́ || подбрáсывание, швыря́ние, тря́ска; *машиналы чокырларда ~ә* машúну подбрáсывает (трясёт) на ухáбах; *баланы түшәмгә ~ә* он подбрáсывает ребёнка (под потолóк); *дулкыннар көймәне ~ә* вóлны швыря́ют лóдку (в рáзные стóроны) **3.** дёргать, подёргивать, пожимáть, поводúть (плечáми); *ул җилкәләрен ~еп алды* он пожáл плечáми; *каш ~ү* подёргивать бровя́ми **4.** *перен.* пропускáть/пропустúть, дéлать (сдéлать) прóпуски; перескáкивать; *ул ~еп укый* он читáет с прóпусками; *бер сораудан икенчесенә ~ү* перескáкивать с одногó вопрóса

на друго́й □ **~еп алу (җибәрү)** 1. подбро́сить, швырну́ть 2. пусти́ть *кого-л.*; **~еп чабу** пусти́ть (коня́) вскачь, скака́ть гало́пом

сикер|ү *неперех.* 1. пры́гать/пры́гнуть, скака́ть/скакну́ть || пры́ганье, прыжо́к, скака́ние; *биеклеккә ~ү* пры́гать в высоту́; *колга белән ~ү* пры́гать с шесто́м; *озынлыкка ~ү* прыжо́к (прыжки́) в длину́; *парашют белән ~ү* пры́гать с парашю́том; *туп яхшы ~ә* мяч хорошо́ пры́гает 2. перепры́гивать/перепры́гнуть; *чокыр аша ~ү* перепры́гнуть че́рез я́му; *ботактан ботакка ~ү* перепры́гивать с ве́тки на ве́тку 3. *в знач. нареч.* **сикереп** 1) вприпры́жку; *~еп чабу* бежа́ть вприпры́жку 2) бы́стро, ми́гом; *~еп тору* ми́гом подня́ться; бы́стро вскочи́ть на́ ноги 4. *перен.* скака́ть, броса́ться, переска́кивать (*от одной мысли к другой*); *бер әйбердән икенчесенә ~ү* переска́кивать с одного́ предме́та на друго́й 5. *перен. пренебр.* пляса́ть, заплеса́ть; *ялкаулансаң, ел ахырында ~ерсең* е́сли поле́нишься, запля́шешь в конце́ го́да 6. *перен. пренебр.* зазнава́ться/зазна́ться; □ **~еп йөгерү** бежа́ть вприпры́жку; **~еп керү** впры́гнуть; **~еп китү** внеза́пно подпры́гнуть, отпры́гнуть; **~еп кую** подпры́гнуть; **~еп менү** вскочи́ть, вспры́гнуть *на что-л.*; **~еп тору** 1. бы́стро вскочи́ть на́ ноги, внеза́пно подня́ться 2. скака́ть, подска́кивать, подпры́гивать (*многократно*); **~еп төшү** спры́гнуть, соскочи́ть *с чего-л.*; **~еп чыгу** вы́прыгнуть; запры́гнуть *за что-л.*; перепры́гнуть *через что-л.*; **~ү басмасы** трампли́н

сикерүле *прил.* скачкообра́зный, неравноме́рный; *~ хәрәкәт* скачкообра́зное движе́ние

сикерүчән *прил.* 1. спосо́бный хорошо́ пры́гать; лю́бящий пры́гать 2. прыгу́чий

сикерүче *сущ.* прыгу́н; *~ләр ярышы* соревнова́ние прыгуно́в □ **~ кыз** прыгу́нья

сиккатив *сущ. спец.* сиккати́в (*вещество, ускоряющее высыхание масел, красок и лаков*)

сиксән *числ. колич.* 1. во́семьдесят; *~ сум* во́семьдесят рубле́й; *~ яшь* во́семьдесят лет 2. *в сочет. со словами на* **-лы, -лык** восьмидесяти-; *~ яшьлек* восьмидесятиле́тний 3. *в знач. сущ. обычно в косв. ф. разг.* во́семьдесят лет; восьмидеся́тый год; *~гә кадәр яшәү* жить до восьми́десяти лет

сиксәндәге *прил.* восьмидесятиле́тний; *~ карт* восьмидесятиле́тний стари́к

сиксәненче *числ. порядк.* восьмидеся́тый; *~ елларда* в восьмидеся́тые го́ды

сиксәнешәр *числ. разд.* по восьми́десяти; по во́семьдесят; *~ сум* по восьми́десяти рубле́й

сиксәнешәрләп *числ. прибл., разд.* по восьми́десяти

сиксәнләп *числ. прибл.* о́коло восьми́десяти, с во́семьдесят; *җыелышта ~ кеше катнашты* в собра́нии уча́ствовало о́коло восьми́десяти челове́к; *~ кеше бар иде* бы́ло челове́к с во́семьдесят

сил *сущ.* 1. сель (*грязевой или грязекаменный поток*); *таулардан сил төште* с гор хлы́нул сель 2. шуга́, са́ло, то́нкий осе́нний лёд; *елга сил белән капланган* река́ покры́лась сплошно́й шуго́й

силә *сущ. см.* **сиртмә** 2; *тарантас ~се* пружи́на тарантаса; рессо́ра тарантаса

силикат *сущ.* силика́ты (*минералы и синтетические химические соединения, а также изделия из них*) || силика́тный; *~ эшләп чыгару* произво́дство силика́тов; *~ җилеме* силика́тный клей; *~ заводы* силика́тный завод || *прил.* силика́тный; *~ бетон* силика́тный бето́н; *~ кирпеч* силика́тный кирпи́ч

силикатлау *перех. спец.* силикати́ровать; *бетонны ~* силикати́ровать бето́н

силикатчы *сущ. разг.* силика́тщик

силлабик *прил. лит.* силлаби́ческий, слогово́й; *~ үлчәм* силлаби́ческий разме́р; *~ шигырь төзелеше* силлаби́ческое стихосложе́ние

силлабо-тоник *прил. лит.* силлабо-тони́ческий; *силлабо-тоник шигырь төзелеше* силлабо-тони́ческое стихосложе́ние

си́лос *сущ. с.-х.* си́лос; *кукуруза ~ы* кукуру́зный си́лос; *катнаш ~* сме́шанный си́лос; *~ массасы* си́лосная ма́сса || *прил.* си́лосный; *~ азыклар* си́лосные корма́ □ **~ салу** закла́дывать си́лос; **~ төягеч** *тех.* силосопогру́зчик; *~ турагыч (ваклагыч, кискеч)* *тех.* силосоре́зка;

си́лослан|у *возвр. от* **силослау**; силосова́ться || силосова́ние; *~а торган үсемлекләр* расте́ния, приго́дные (испо́льзуемые) для силосова́ния

си́лослату *понуд. от* **си́лослау**

си́лослау *перех.* силосова́ть *что* || силосова́ние; *чөгендер сабагын ~* силосова́ть ботву́ свёклы; *кукуруз ~* силосова́ть кукуру́зу

си́лослы *прил.* си́лосный; *~ азыклар* си́лосные корма́

си́лослык *прил.* си́лосный; предназна́ченный, приго́дный на си́лос; *~ культуралар* си́лосные культу́ры

силуэт *сущ. в разн. знач.* силуэ́т; *кош ~ы* силуэ́т пти́цы; *күпер ~ы* силуэ́т моста́; *күлмәк ~ы* силуэ́т пла́тья

симбиоз *сущ. биол.* симбио́з; *тере организмнар ~ы* симбио́з живы́х органи́змов

си́мвол *сущ.* си́мвол; *азатлык ~ы* си́мвол свобо́ды

символизм *сущ. лит., иск.* символи́зм (*литературное течение*) || символи́стский; *~ поэзиясе* символи́стская поэ́зия

симво́лик *прил.* символи́ческий, символи́чный; *~ сурәтләү* символи́ческое изображе́ние; *~ хәрәкәт* символи́ческий жест; *~ мәгънә* символи́ческий смысл □ **~ рәвештә** символи́чески

симво́лика *сущ. в разн. знач.* симво́лика; *пионер ~сы* пионе́рская симво́лика; *олимпиада ~сы* олимпи́йская симво́лика; *саннар ~сы* симво́лика чи́сел; *образлар ~сы* симво́лика о́бразов

символист *сущ. лит., иск.* символи́ст; *~ шагыйрьләр* поэ́ты-символи́сты

си́мволлаштыру *перех.* символизи́ровать, превраща́ть/преврати́ть в си́мвол || символиза́ция; *ср.* **гәүдәләндерү**; *абстракт идеяләрне ~* символизи́ровать абстра́ктные иде́и

си́мволлаштырылу *страд. от* **си́мволлаштыру**

си́мволлы *прил.* символи́ческий, символи́чный; с си́мволом; *~ рәсем* символи́ческий рису́нок

симез *прил.* 1. жи́рный; *~ ит* жи́рное мя́со 2. ту́чный, жи́рный; упи́танный, пу́хлый; *~ сарык* жи́рный (ту́чный) бара́н; *~ хатын* ту́чная же́нщина; *~ гәүдәле* с упи́танным те́лом, ту́чный; *~ терлек* упи́танный скот ◊ **~ калҗа каеру** получи́ть (содра́ть) жи́рный (соли́дный) куш

симезле|к *сущ.* жи́рность; полнота́, ту́чность; упи́танность; нагу́л; *артык ~к сәламәтлек өчен зарарлы* изли́шняя полнота́ вредна́ для здоро́вья ◊ **~генә чыдый алмый** с жи́ру бе́сится

симертел|ү *страд. от* **симертү**; *сугымга ~гән* отко́рмленный на уб о́й

симерткеч *прил.* **1.** спосо́бствующий ожире́нию **2.** отко́рмочный

симерттерү *понуд. от* **симертү**

симерт|ү *перех.* отка́рмливать/откорми́ть, дава́ть/дать нагу́ливать (скот, пти́цу) || отка́рмливание; отко́рм, нагу́л; *каз ~ү* отка́рмливать гусе́й; *~ергә кую* ста́вить на отко́рм; *мал ~ү* отко́рм скота́ □ **~ә торган** отко́рмочный; **~ү базасы** отко́рмочная ба́за

симертүдәге *прил.* отко́рмочный; *~ үгезләр* отко́рмочные быки́

симер|ү *неперех.* жире́ть, разжире́ть, ожире́ть, тучне́ть, отъеда́ться/отъе́сться, располне́ть, растолсте́ть || ожире́ние; *үрдәкләр ~де* у́тки разжире́ли □ **~еп китү** разжире́ть, располне́ть, раздобре́ть

симерүчән *прил.* скло́нный к бы́строму ожире́нию

симменталь *прил. с.-х.* симмента́льский; *~ нәсел* симмента́льская поро́да

симме́трик *прил. см.* **симметрияле**; *~ тәртип* симметри́ческий поря́док

симме́трия *сущ.* симме́трия; *геометрик фигуралар ~се* симме́трия геометри́ческих фигу́р

симме́трияле *прил.* симметри́чный, симметри́ческий; *~ тәртиптә* в симметри́ческом поря́дке || *нареч.* симметри́чно, симметри́чески; *рәсемнәрне ~ тезү* разве́сить рису́нки симметри́чно

симме́трияле|к *сущ.* симметри́чность; *әйберләрнең ~ге* симметри́чность предме́тов

симме́триясез *прил.* асимметри́чный || *нареч.* асимметри́чно

симме́триясезлек *сущ.* несимметри́чность, асимметри́чность

симпа́тик *прил. анат. мед.* симпати́ческий; *~ авыртулар* симпати́ческие бо́ли; *~ нерв системасы* симпати́ческая не́рвная систе́ма

симпо́зиум *сущ.* симпо́зиум; *халыкара ~* междунаро́дный симпо́зиум

симулянт *сущ.* симуля́нт || симуля́нтский; *ул ~ бит* он же симуля́нт; *~ кыланышы* симуля́нтское поведе́ние

симулянтлану *неперех.* симули́ровать, станови́ться/стать симуля́нтом

симулянтлык *сущ.* симуля́нтство, симуля́ция || симуля́нтский □ **~ авыруы** симуля́нтство

симуля́ция *сущ. см.* **симулянтлык**

симфо́ник *прил.* симфони́ческий; *~ оркестр* симфони́ческий орке́стр; *~ концерт* симфони́ческий конце́рт; *~ музыка* симфони́ческая му́зыка

симфо́ния *сущ.* симфо́ния || симфони́ческий; *Чайковский ~се* симфо́ния Чайко́вского

син *мест. личн.* **1.** ты (*синең* твой; *сиңа* тебе́, к тебе́; *сине* тебя́; *синнән* от тебя́; *синдә* у тебя́); *без сиңа барабыз* мы идём к тебе́; *син кайт инде* ты уж возвраща́йся **2.** *этногр.* ты (*ф. обращения жены к мужу*); *син, ашарга утыр* ты, сади́сь за стол; *сиңа әйтәм* тебе́ говорю́! □ **син дигәнчә** по-тво́ему ◊ **син дә мин, Мөхәммәтәмин** раз-два и обчёлся; **син дигәндә, аяк идәндә** для ми́лого дружка́ и серёжку из ушка́; **син күр дә мин күр** то́лько его́ и ви́дели; **сиңа яраган миңа ярамый** на вкус, на цвет това́рища нет

синагóга *сущ. рел.* синагóга (*еврейский молитвенный дом*)

сингармонизм *сущ.* сингармони́зм || сингармони́ческий; *~ законы* зако́н сингармони́зма

сингармо́ник *прил. лингв.* сингармони́ческий

сингармо́ния *сущ. лингв.* сингармо́ния

сингармо́нияле *прил. лингв.* сингармони́ческий, облада́ющий сингармони́змом

синдикализм *сущ. полит.* синдикали́зм (*политическое течение*) || синдикали́стский

синдикалист *сущ. полит.* синдикали́ст

синдикали́стик *прил. полит.* синдикали́стский; *~ юнәлеш* синдикали́стский укло́н; *~ карашлар* синдикали́стские взгля́ды

синдикат *сущ. в разн. знач.* синдика́т; *нефть ~ы* нефтяно́й синдика́т; *профсоюзлар ~ы* синдика́т профсою́зов

синдикатчы *сущ.* основа́тель, член, руководи́тель синдика́та; *нефть ~лары* руководи́тели нефтяно́го синдика́та

синдром *сущ. мед.* синдро́м; *авыру ~нары* синдро́мы боле́зни

сине́кдоха *сущ. лит.* сине́кдоха (*один из видов метонимии*); *сөйләмдә ~лар куллану* испо́льзовать в ре́чи сине́кдоху

синеке *притяж. от мест.* **син** твой, твоя́, твоё; *бу бүлмә ~* э́то твоя́ ко́мната ◊ **синеке-минеке юк** нет твоего́-моего́ (всё о́бщее)

сине́нчә *мест.* по-тво́ему; *~ булсын ди* пусть бу́дет по-тво́ему

синко́па *сущ. лингв.* синко́па (*выпадение звука в середине слова*)

синкрет *прил.* синкре́тный, синкрети́ческий

синләү *перех. редко* ты́кать, обраща́ться *к кому-л.* на «ты»

синод *сущ. рел.* сино́д (*высший коллегиальный орган русской православной церкви*) || синода́льный, сино́дский

сино́дик *прил. астр.* синоди́ческий; *~ дәвер* синоди́ческий пери́од

сино́лог *сущ. спец.* сино́лог; китаевéд; *телче-синолог* языковéд-сино́лог

сор|ау I *перех.* **1.** 1) *в разн. знач.* спра́шивать/спроси́ть *кого-что*, обраща́ться/обрати́ться с вопро́сом *к кому*; *исемен ~ау* спра́шивать его́ и́мя; *Мусаны ~ау* спра́шивать Мусу́; *сәбәбен ~ау* спра́шивать причи́ну 2) спра́шивать/спроси́ть *у кого*, расспра́шивать/расспроси́ть *кого о ком-чём*; *нәрсә кирәклеге турында ~ау* расспра́шивать о том, что ну́жно; *нәрсә укуын ~ау* расспра́шивать, что чита́ет; *нәрсә булганын ~ау* спра́шивать, что случи́лось; *кемнән ~арга?* у кого́ спра́шивать? 3) спра́шивать/спроси́ть, справля́ться/спра́виться *о комчём*; *сәламәтлеге турында ~ау* справля́ться о здоро́вье 4) *разг.* (*обычно с отрицанием*) спра́шивать/спроси́ть, узнава́ть/узна́ть *чьё-л.* мне́ние, спра́шивать разреше́ния; *бездән ~амаслар* нас не спро́сят **2.** спра́шивать/спроси́ть, вызыва́ть/вы́звать; *укучыдан уткән дәресне ~ау* спра́шивать у ученика́ про́шлый уро́к **3.** спра́шивать/спроси́ть, тре́бовать, потре́бовать выполне́ния *чего-л.*; *миннән эш ~ама* не тре́буй с меня́ рабо́ты **4.** спра́шивать/спроси́ть, взыскивать/взыска́ть *с кого за что*; *бу эш өчен миннән ~аячаклар* за э́то спро́сят с меня́ **5.** спра́шивать/спроси́ть, проси́ть, попроси́ть, тре́бовать, потре́бовать, вы́звать *кого-л.*; *сине ~ыйлар* тебя́ спра́шивают **6.** *перен.* тре́бовать; *озак әзерләнүне ~ый* тре́бует дли́тельной подгото́вки **7.** проси́ть, попроси́ть *чего*; *су ~ау* проси́ть воды́; *киңәш ~ау* проси́ть сове́та; *ярдәм ~ау* проси́ть по́мощи; *бурычка ~ап алу* попроси́ть в долг; *сүз ~ау* проси́ть сло́ва; *~амагыз да* и не проси́те; *~ап та торма* не́чего и спра́шивать **8.** проси́ться; *отпуск ~ау* проси́ться в о́тпуск; *бригадага алуны ~ау* проси́ться в брига́ду **9.** проси́ть, попроси́ть, назнача́ть, назна́чить це́ну; *эш өчен күпме ~ый?* ско́лько про́сит за рабо́ту? *~аган бәягә* за назна́ченную, запро́шенную це́ну **10.** проси́ть, попроси́ть, хлопота́ть *за кого-что*; *аның өчен ~ама* не проси́ за него́, не хлопочи́ за него́ **11.** сва́таться, проси́ть руки́; *Галим кызын ~ау* сва́таться за дочь Гали́ма; *кулын ~ау* проси́ть руки́; *хатынлыкка ~ау* проси́ть в жёны **12.** запра́шивать/запроси́ть *кого-что, о чём*; *редакция фикерен ~ау* запроси́ть мне́ние реда́кции □ **~аган кадәр** сто́лько, ско́лько про́сят; **~ап**

алу 1. брать/взять с разреше́ния 2. вы́просить *что* 3. (*обычно с отрицанием*) допроси́ться; *аңардан кышын кар ~ап алып булмый* у него зимо́й сне́га не допро́сишься (не вы́просишь); **~ап белү** разузна́ть, расспроси́ть, спра́виться *о ком-чём;* дозна́ться путём расспро́сов; **~ап йөрү** выспра́шивать; **~ап китү** отпра́шиваться/отпроси́ться; **~ап кую (ташлау)** спроси́ть (*обычно неожиданно*); *үйламаганда ~ап кую* спроси́ть неожи́данно; **~ап тору** 1. спра́шивать, проси́ть, тре́бовать 2. попроси́ть на вре́мя; **~ап чыгу** опра́шивать/опроси́ть всех; **~ый бирү** продолжа́ть проси́ть (несмотря́ ни на что) ◊ **~аган өчен авызына сукмаслар** за вопро́с по ры́лу не уда́рят; **~аганга су бир** не откажи́ в про́сьбе

сора|у II *сущ.* 1. вопро́с; *куелган ~уга җавап бирү* отве́тить на поста́вленный вопро́с; *көтелмәгән ~у* неожи́данный вопро́с; *~у туа* возника́ет вопро́с; *~улар белән күму* засы́пать вопро́сами; *~у кую* поста́вить вопро́с 2. вопро́с, пробле́ма, де́ло; *см. тж.* **мәсьәлә**; *мине бер ~у борчый* меня́ му́чает оди́н вопро́с; *кызыксындырган ~улар* интересу́ющие вопро́сы 3. допро́с; *~ башлана* начина́ется допро́с; *~ вакытында* во вре́мя допро́са 4. про́сьба; *аның ~вы буенча* по его́ про́сьбе; *~уны кире какмау* не отказа́ть в про́сьбе 5. тре́бование; *кемнең дә булса ~уларын үтәү* удовлетвори́ть чьи́-либо тре́бования 6. *в разн. знач.* запро́с; *сатып алучыларның ~уларын өйрәнү* изучи́ть запро́сы покупа́телей; *депутат ~вы* депута́тский запро́с 7. *экон.* спрос, тре́бование; *~у һәм тәкъдим* спрос и предложе́ние □ **~у алмашлыгы** *грам.* вопроси́тельное местоиме́ние; **~у алу** 1. снима́ть/снять показа́ния *с кого,* допра́шивать/допроси́ть *кого* 2. допро́с; *~у алу башланды* начался́ допро́с 3. опра́шивать/опроси́ть; *шаһитлардан ~у алу* опро́с свиде́телей; **~у алучы** допра́шивающий; **~у билгесе** *лингв.* вопроси́тельный знак; **~у галәмәте** *лингв. уст. см.* **сорау билгесе**; **~у җөмлә** *грам.* вопроси́тельное предложе́ние ◊ **~вына күрә җавабы** како́в приве́т, тако́в и отве́т; **(зур) ~у астында** под (большим) вопро́сом; проблемати́чен; **~у көне** *рел.* день Стра́шного суда́; Су́дный день

сораулы *прил.* 1. вопроси́тельный, вопроша́ющий; *~ караш* вопроси́тельный взгляд; *~ күзләр* вопроша́ющие глаза́ 2. проси́тельный

сораулык *сущ.* вопро́сник; *~ төзү* соста́вить вопро́сник

сораусыз *нареч.* без спро́са, без разреше́ния; *~ алу* взять без спро́са

сораучы *сущ.* 1. проси́тель 2. задаю́щий вопро́с 3. спра́шивающий; *мине ~ булмадымы?* никто́ не спра́шивал меня́?

сорашкалау *многокр. от* **сорашу**; спра́шивать, расспра́шивать (*время от времени*)

сораштыргалау *многокр. от* **сораштыру**

сораштыр|у *перех.* расспра́шивать (*время от времени*) *о ком-чём* || расспро́с, расспра́шивание; *тормыш турында ~у* расспра́шивать о жи́зни; *күп ~а торгач* по́сле до́лгих расспро́сов

сораш|у *взаимн. от* **сорау** I 1. расспра́шивать/расспроси́ть *о ком-чём* || расспра́шивание, расспро́с; *аның турында ~ты* он расспра́шивал про него́; *~ыр нәрсә бар* есть о чём расспра́шивать 2. спра́шивать, справля́ться/спра́виться *о ком-чём*; *исәнлек-саулык ~у* справля́ться о здоро́вье; *тормыш хәлләрен ~у* справля́ться о житье́-бытье́; *эш турында ~у* справля́ться о рабо́те; *~каным юк* не спра́шивал (не справля́лся) 3. *редко* опра́шивать/опроси́ть || опро́с; *галимнәр арасында ~у үткәрү* провести́ опро́с среди́ учёных 4. *редко* попроша́йничать || попроша́йничанье; *см.* **сорану** □ **~а- ~а, ~ып белү** разузна́ть (*путём расспросов*); **~ып карау** про́бовать расспра́шивать; **~ып тору** 1. расспра́шивать 2. постоя́нно справля́ться; **~ып чыгу** опра́шивать/опроси́ть *кого*

сорбит *сущ. мед.* сорби́т (*безглюкозный сахар*); *чәйгә ~ салу* класть сорби́т в чай

соргавыл *сущ. уст.* за́дний дозо́р, арьерга́рд

со́рго *сущ. бот.* со́рго || со́рговый; *~ саламы* со́рговая соло́ма

соргылт *прил. уменьш. от* **сары**; серова́тый; *~ күзләр* серова́тые глаза́; *~ тузан* серова́тая пыль; *~ болыт* серова́тое о́блако; *~ төс* серова́тый цвет □ **~-зәңгәр** серова́то-голубо́й; **~-зәңгәр күк** серова́то-голубо́е не́бо; **~-кара** цве́та маре́нго; **~-көрән** *прил.* серова́то-бу́рый; се́ро-бу́рый; *~* **тузан** серова́то-бу́рая пыль; *~* **төстә** серова́то-бу́рого цве́та; *~* **күк** серова́то-ды́мчатый; *~* **күзләр** серова́то-ды́мчатые глаза́; **~-яшел** серова́то-зелёный

соргылтландыру *понуд. от* **соргылтлану**

соргылтлан|у *неперех.* станови́ться/стать серова́тым, принима́ть/приня́ть серова́тый отте́нок; *күзләр ~ды* глаза́ его́ при́няли серова́тый отте́нок

соргылтлы|к *сущ.* серова́тость; *йөзенең ~гы* серова́тость его́ лица́

сорка *сущ.* 1. *зоол.* суро́к 2. мех сурка́; *см. тж.* **сөркә**

сорнай *сущ.* 1. *муз.* сурна́; зурна́; волы́нка; *~ өрү* дуть в волы́нку; *~ уйнау* игра́ть на зурне́ 2. *диал.* сурна́ (*щипковый инструмент*) 3. *перен. диал.* долгова́язый, высокоро́слый, высоче́нный челове́к ◊ *~* **буй** *диал.* долгова́язость, высоче́нность; *~* **буйлы** *диал.* долгова́язый; высо́кий как шест

сорнайчы *сущ. муз.* волы́нщик; музыка́нт, игра́ющий на сурна́е (зурне́)

сорт *сущ.* 1. сорт (*категория по качеству*) || сортово́й; *беренче ~ он* мука́ пе́рвого со́рта; *икенче ~ һинд чәе* инди́йский чай второ́го со́рта; *~ күрсәткечләре* сортовы́е показа́тели; *~ чисталыгы* сортова́я чистота́; *~ үләнү* сортово́е засоре́ние; *~ участогы* сортово́й уча́сток 2. сорт (*разновидность культурного растения*) || сортово́й; *яңа ~ бодай* но́вый сорт пшени́цы; пшени́ца но́вого со́рта; *иртә өлгерешле ~* скороспе́лый сорт; *суыкка чыдам ~лар* зимосто́йкие сорта́; *җирле ~* ме́стный сорт 3. сорт (*разновидность по материалу*); *ике төрле ~ конфет* конфе́ты двух сорто́в; *төрле ~ шәраблар* ви́на ра́зных сорто́в 4. *разг.* сорт, вид; *бу андый ~ түгел* э́то не тако́го (не того́) со́рта □ **~ сынаучы** сортоиспыта́тель; *~* **яңарту** сортообновле́ние; **~лар сынау** сортоиспыта́ние || сортоиспыта́тельный; **~ларга аеру** сортирова́ть *что*; *см.* **сортлау** || сортиро́вочный; **~ларга аеручы** сортирова́льный; *~ аеручы машина* сортирова́льная маши́на || сортиро́вщик

сортиро́вка *сущ.* сортиро́вка || сортиро́вочный; *~ станциясе* сортиро́вочная (ста́нция); *~да эшләү* рабо́тать на сортиро́вке

сортиро́вкалау *перех.* сортирова́ть *что* || сортиро́вка, сортирова́ние; *ашлык ~* сортирова́ть зерно́; *агач ~* сортирова́ть дере́вья

сортлагыч *сущ.* сортиро́вка, сортиро́вщик (*машина*); *күмер ~* сортиро́вка для у́гля; *бәрәңге ~* карто́фельная сортиро́вка

сортлан|у *страд. от* **сортлау**; сортирова́ться, отсортиро́вываться; *~ган орлыклар* отсортиро́ванное зерно́

сортла|у *перех.* 1. сортирова́ть, рассортирова́ть, отсортиро́вывать/отсортирова́ть *что*; *орлык ~у* сортирова́ть зерно́ || сортирова́ние; *тире ~у* сортирова́ние ко́жи 2. сортиро́вка || сортирова́льный; *~у машинасы* сортирова́льная маши́на □ **~п бетерү (бирү, кую)** рассортирова́ть

сортлаучы *сущ.* сортиро́вщик, сортиро́вщица

сортлы *прил.* сортово́й; -со́ртный; *~ орлыклар* сортовы́е семена́; *~ бәрәңге* сортово́й карто́фель; *~ чәчүлекләр* сортовы́е посе́вы; *~ металл спец.* сортово́й мета́лл; *~ тимер спец.* сортово́е желе́зо

сортлылы|к *сущ. спец.* со́ртность; -со́ртность || сортово́й; *орлыкның ~гы* со́ртность семя́н; *югары ~к* высокосо́ртность; *продукциянең ~гын билгеләү* определе́ние со́ртности проду́кции; *~к таныклыгы* сортово́е свиде́тельство; *орлыкларның ~к сыйфатлары* сортовы́е ка́чества семя́н

сортсыз *прил.* несортово́й, низкосо́ртный; *~ бәрәңге* низкосо́ртный карто́фель; *~ ашлык* несортово́е зерно́

сары *прил.* 1. се́рый; *~ күзләр* се́рые глаза́; *~ бүре* се́рый волк; *~ төсле* се́рого цве́та; *~ шинель* се́рая шине́ль; *~ куян* се́рый за́яц 2. се́рый, ту́склый; бесцве́тный; *~ томан* се́рый тума́н; *~ бушлык* се́рая пустота́ □ **~ күсе** *зоол.* се́рая кры́са, пасю́к; *~* **тутый** *зоол.* жако́; *~* **ябалак** *зоол.* нея́сыть (*птица*) ◊ *~* **шинельләр** се́рые шине́ли, солда́ты, солдатня́

сорыкорт *сущ.* 1. *зоол.* тру́тень (*пчелиный самец*) || трутнево́й; *~ курчагы* трутнева́я ку́колка 2. *перен. неодобр.* тру́тень, тунея́дец, дармое́д; *~ булып яшәү* вести́ о́браз жи́зни тру́тня; жить тру́тнем (*дармоедом*)

сорыкортлы|к *сущ.* тунея́дство, дармое́дство, паразити́зм; *каракларның ~гы* паразити́зм воро́в

сорыландыру *перех.* де́лать, сде́лать се́рым; покрыва́ть/покры́ть се́рым

сорылан|у *неперех.* сере́ть, посере́ть, засере́ть, засере́ться; *аның күзләре ~ган* глаза́ его́ посере́ли

сорылы|к *сущ.* се́рость; *тиресенең ~гы* се́рость (его́) шку́ры

соса *сущ.* 1. челно́к (*ткацкий*); *тукучылык ~* кру́глый челно́к; *туку станогы ~сы* челно́к тка́цкого станка́ 2. *перен. см.* **маңка борын**

соси́ска *сущ.* соси́ска, соси́ски || соси́сочный; *дуңгыз ~сы* свины́е соси́ски; *нечкә ~* то́нкая соси́ска; *~ фаршы* соси́сочный фарш

соскак *сущ. диал.* ча́шка (*чайная*)

соскалау *многокр. от* **сосу**

соскы *сущ.* сово́к || совко́вый; *күмерне ~ белән җыеп алу* сгрести́ у́голь совко́м; *он ~сы* сово́к для муки́; *~ көрәк* совко́вая лопа́та

соскылы *прил.* совко́вый, с совко́м, име́ющий сово́к

соскыч *прил.* черпа́льный; *~ машина* черпа́льная маши́на || *сущ.* 1. черпа́к, ковш; поло́вник, поварёшка; *агач ~* деревя́нный черпа́к; *тимер ~* желе́зный поло́вник (черпа́к); *озын саплы ~* черпа́к с дли́нной ру́чкой 2. *диал. см.* **соскы**; *күмер ~ы* сово́к для у́гля

сосла *сущ.* су́сло; *куе ~* густо́е су́сло; *~ кайнату* вари́ть су́сло

сослан *сущ. с.-х.* суслó́н; *көлтәләрне ~га салу* положи́ть снопы́ в суслóн

сослóвие *сущ. ист.* сослóвие; *см. тж.* **тәбәка**; *ясак түләүчеләр ~се* податно́е сослóвие; *мещан ~се* мещáнское сослóвие; *өченче ~* тре́тье сослóвие; *~ләрне бетерү* упразднúть сослóвия; *~ләргә бүленү* деле́ние на сослóвия

сослóвиеле *прил. ист.* сослóвный; *~ җәмгыять* сослóвное óбщество □ **~ монархия** *ист.* сослóвная монáрхия

сослóвиечел *прил. ист.* сослóвный; *~ рух* сослóвный дух; *~ дәүләт* сослóвное госудáрство

сослóвиечелек *сущ.* сослóвность; *~кә каршы көрәш* борьбá прóтив сослóвности

состав *сущ.* 1. состáв, совокýпность людéй; *җирле комитетның яңа ~ы* нóвый состáв мéстного комитéта; *президиум ~ын раслау* утвердúть состáв президиума; *делегация ~ына кертү* ввестú в состáв делегáции; *командирлар ~ы* комáндный состáв 2. состáв, совокýпность частéй; *телнең сүзлек ~ы* словáрный состáв языкá; *җөмлә ~ы* состáв предложéния; *туфрак ~ы* состáв пóчвы; *даруның химик ~ы* химúческий состáв лекáрства 3. состáв, соединéние, смесь; *киемдәге тапны бетерә торган ~* пятновыводя́щий состáв 4. *ж.-д.* состáв, ряд вагóнов; *йөкле ~* гружёный состáв; *тимер юл ~ы* железнодорóжный состáв; *озын ~* длúнный состáв

составлы *прил. лингв.* составнóй; -состáвный; *~ сүзләр* составны́е словá; *бер ~* односостáвный; *ике ~ җөмлә* двусостáвное предложéние

состыру 1. *понуд. от* **сосу** 2. *перех. прост.* улепётывать, дрáпать, давáть хóду; *озын аяклары белән ~* улепётывать на своúх длúнных ногáх

сос|у *перех.* 1. чéрпать, зачéрпывать/зачерпнýть *что* || чéрпание; чéрпать суп; *бер чүмеч пилмән ~у* зачерпнýть поварёшку пельмéней 2. разливáть/разлúть *что*; *аш ~у* разливáть суп; *кайнар шулпа ~у* разлúть горя́чий бульóн 3. *перен. прост.* жрать, пожрáть, лóпать, слóпать, трéскать *что*; *китергәннең барысын да ~у* слóпать всё пóданное 4. *перен. прост.* хáпать/хáпнуть, прикармáнивать/прикармáнить *что*; *чит кешеләр малын ~у* хáпнуть чужóе добрó 5. *перен. прост.* трáхать/трáхнуть *кого-что*; *таяк белән ~у* трáхнуть пáлкой □ **~а бару; ~а бирү** 1. разливáть (*по ходу*) 2. *перен. прост.* дубáсить, молотúть (*подряд*); **~ып алу** 1. зачерпнýть *что* 2. *перен. прост.* отдубáсить; **~ып бетерү** разлúть (*полностью*); **~ып кую** разлúть; **~ып тору** разливáть, чéрпать (*по ходу, по порядку*); **~ып чыгу** разлúть (*всем*)

сосылу *страд. от* **сосу**

сóтник *сущ. ист.* сóтник (*казачий чин*); *см.* **йөзбашы**; *атлы ~* кóнный сóтник

сóус *сущ. кул.* сóус || сóусный; *томат ~ы* томáтный сóус; *гөмбә ~ы* грибнóй сóус; *салкын һәм кайнар ~лар әзерләү* готóвить холóдные и горя́чие сóусы; *~ исе* зáпах сóуса □ **~ савыты** сóусник

сóуслы *прил.* сóусный; с сóусом; *~ гарнир* гарни́р с сóусом

софа *сущ.* софá (*широкий низкий диван*)

софúстик *прил. книжн.* софисти́ческий; *~ алым* софисти́ческий приём; *~ бәхәсләр* софисти́ческие спóры

софúстика *сущ. кул.* софúстика; *чеп-чи ~* сáмая настоя́щая софúстика

сухари *сущ.* сухáрь || сухáрный; *~ киптерү* сушúть сухáри; *~ квасы* сухáрный (хлéбный) квас □ **~ савыты** сухáрница

сохбәт *сущ. уст. книжн.* дрýжеская бесéда □ **~ итү (кылу)** бесéдовать *с кем-чем; см. тж.* **сөхбәт**

социал *сущ. разг. см.* **социалист**

социал- социал- (*первая составная часть сложных слов, соответствующая по значению слову* социáльный; социал-демократия, социал-шовинизм и т. п.)

социал-демократ *сущ.* 1. социáл-демокрáт; *татар социал-демократлары* татáрские социáл-демокрáты;

социал-демократ депутатлар депута́ты из социа́л-демокра́тов **2.** *во мн. ч.* **социал-демократлар** социа́л-демокра́ты, социа́л-демократи́ческий; *социал-демократлар партиясе* социа́л-демократи́ческая па́ртия

социал-демократик *прил.* социа́л-демократи́ческий; *социал-демократик карашлар* социа́л-демократи́ческие взгля́ды; *Россия социал-демократик эшчеләр партиясе* Росси́йская социа́л-демократи́ческая рабо́чая па́ртия

социал-демократия *сущ.* социа́л-демокра́тия; *рус социал-демократиясе* ру́сская социа́л-демокра́тия

социал-демократлык *сущ. книжн.* социа́л-демократи́зм

социализа́ция *сущ.* социализа́ция; *~ үткәрү* проводи́ть социализа́цию □ *~ ясау* социализи́ровать

социализа́циялә̆ү *перех.* социализи́ровать, подверга́ть/подве́ргнуть социализа́ции || социализа́ция; *җирне ~* социализа́ция земли́

социализм *сущ. в разн. знач.* социали́зм || социалисти́ческий; *~ төзү* постро́ение социали́зма; *~ төзүче* строи́тель социали́зма; *фәнни ~* нау́чный социали́зм; *утопик ~* утопи́ческий социали́зм; *~ илләре* стра́ны социали́зма; *~ тәгълиматы* уче́ние социали́зма, социалисти́ческое уче́ние; *~ хуҗалыгы* социалисти́ческое хозя́йство

социалист *сущ. в разн. знач.* социали́ст || социалисти́ческий; *сул ~лар* ле́вые социали́сты; *Мөселман ~лар комитеты* Мусульма́нский социалисти́ческий комите́т

социалистик *прил. в разн. знач.* социалисти́ческий; *~ җитештерү мөнәсәбәтләре* социалисти́ческие произво́дственные отноше́ния; *~ милекне саклау* охра́на социалисти́ческой со́бственности; *~ революция* социалисти́ческая револю́ция; *~ җәмгыять* социалисти́ческое о́бщество; *~ төзелеш* социалисти́ческое строи́тельство; *~ Хезмәт Герое* Геро́й Социалисти́ческого Труда́ □ *~ реализм* социалисти́ческий реали́зм; *~ ярыш* социалисти́ческое соревнова́ние; соцсоревнова́ние

социалист-революционер *сущ. ист.* социали́ст-революционе́р (*член партии эсеров*); *социалист-революционерлар политикасы* поли́тика социали́стов-революционе́ров

социаллаштыру *перех.* социализи́ровать || социализа́ция

социаллашу *неперех.* социализи́роваться || социализи́рование

социаль *прил.* **1.** *в разн. знач.* социа́льный **2.** *см.* **иҗтимагый**; *~ чыгыш* социа́льное происхожде́ние; *җәмгыятьнең ~ катлаулары* социа́льные слои́ о́бщества; *~ шартлар* социа́льные усло́вия; *~ гаделлек* социа́льная справедли́вость; *~ тигезсезлек* социа́льное нера́венство; *~ хәл* социа́льное положе́ние

социаль-кә́нкүреш *прил.* социа́льно-бытово́й; *профкомның социаль-көнкүреш секторы* социа́льно-бытово́й се́ктор профко́ма; *социаль-көнкүреш мәсьәләләре* социа́льно-бытовы́е вопро́сы

социаль-политик *прил.* социа́льно-полити́ческий; *см. тж.* **иҗтимагый-политик**

социаль-экономик *прил.* социа́льно-экономи́ческий; *см.* **иҗтимагый-икътисади**; *илнең социаль-экономик үсеше* социа́льно-экономи́ческое разви́тие страны́; *социаль-экономик политика* социа́льно-экономи́ческая поли́тика

социо́лог *сущ.* социо́лог; *яшь ~* молодо́й социо́лог; *~лар күзәтүенә караганда* су́дя по наблюде́ниям социо́логов

социологизм *сущ.* социологи́зм; *вульгар ~* вульга́рный социологи́зм

социоло́гик *прил.* социологи́ческий; *~ тикшеренүләр* социологи́ческие иссле́дования

социоло́гия *сущ.* социоло́гия; *~не фәнни нигезгә кую* поста́вить социоло́гию на нау́чную осно́ву

соцстрах *сущ.* соцстра́х || соцстра́ховский; *~ путёвкасы* соцстра́ховская путёвка

сочине́ние *сущ. пед.* сочине́ние; *ср.* **инша**; *~ язу* написа́ть сочине́ние; *~ темасы* те́ма сочине́ния; *ирекле темага ~ язу* написа́ть сочине́ние на свобо́дную те́му

союз *сущ.* **1.** сою́з (*тесное единение*); *эшче һәм крестьяннар ~ы* сою́з рабо́чих и крестья́н; *халыкларның туганнарча ~ы* бра́тский сою́з наро́дов **2.** сою́з (*объединение*) || сою́зный; *хәрби ~* вое́нный сою́з; *~ төзү* заключи́ть сою́з; *~ карамагыннан чыгару* вы́вести из сою́зного подчине́ния **3.** сою́з (*общественная организация*); *см. тж.* **берлек**; *яшьләр ~ы* сою́з молодёжи; *профессиональ ~лар* профессиона́льные сою́зы; *иҗади ~лар* тво́рческие сою́зы; *~га керү* вступи́ть в сою́з

сою́зара *прил.* межсою́зный; *~ конференция* межсою́зная конфере́нция

союздаш *прил.* сою́зный; *~ республика* сою́зная респу́блика; *~ илләр* сою́зные стра́ны; *~ армия* сою́зная а́рмия

союздашлык *сущ.* сою́зничество || сою́знический; *~ны ныгытырга* укрепи́ть сою́зничество; *~ мөнәсәбәтләре* сою́знические отноше́ния; *~ йөкләмәләре* сою́знические обяза́тельства

сою́зник *сущ.* сою́зник; сою́зница; *хәрби ~* вое́нный сою́зник; *бердәнбер ~* еди́нственный сою́зник

сою́зниклык *сущ. см.* **союздашлык**

со́я *сущ. бот.* со́я || со́евый; *соя чәчүлекләре* посе́вы со́и; *соя борчагы* со́евые бобы́; *соя сөте* со́евое молоко́; *соя мае* со́евое ма́сло □ **соя үстерүче** соево́д

со́ялы *прил.* со́евый; *~ конфетлар* со́евые конфе́ты

сөаль *сущ. уст. см.* **сорау** II; *~ бирү* вопроша́ть, задава́ть вопро́с

сөальләү *неперех. уст.* вопроша́ть; задава́ть/зада́ть вопро́с

сөбха́наллаһ *межд. (говорится в порыве восхищения)* бо́же ми́лостивый! о, бо́же! бо́же свя́тый! сла́ва тебе́ го́споди!

сөгезәк *сущ. диал.* **1.** нано́сы; дю́на; песча́ный о́стров **2.** коса́ **3.** *см.* **сөзәк**

сөгезлән *сущ. диал. зоол.* моллю́ск-слизня́к

сөек *сущ. диал.* **1.** ла́ска (*обращённая к кому-л.*); ра́дость (*при виде кого-л.*); *сөйгәнгә ~, көйгәнгә көек (погов.)* кому́ в ра́дость, кому́ в го́ре **2.** любо́вь, умиле́ние; *~ белән карау* смотре́ть с умиле́нием

сөекле *прил.* **1.** *в разн. знач.* люби́мый; *~ бала* люби́мое дитя́; *~ ризык* люби́мое блю́до **2.** *в ф.* **сөеклем** 1) (*мой*) люби́мый; (*моя*) люби́мая; *~мә бүләк* пода́рок мое́й люби́мой 2) *в разн. знач.* ми́лый, ми́ленький; *син, ~м, чыгып торыр идең* ты, ми́ленький, вы́шел бы на не́которое вре́мя **3.** *редко в ф.* **сөеклең** (*твой*) люби́мый, (*твоя*) люби́мая; **сөеклесе** (*его*) люби́мый; (*её*) люби́мая

сөексез *прил. редко* **1.** нелюби́мый; нему́лый; *~ кеше* нелюби́мый челове́к **2.** *см.* **сөйкемсез**

сөелү *страд. от* **сөю**; быть люби́мым, ласка́емым, обла́сканным; *иркәсеннән ~* быть ласка́емым (*своим*) ми́лым

сөенде|к *сущ. разг. диал.* по́вод для ра́дости; *~ге әллә ни түгел* не бог весть кака́я ра́дость

сөендекләнү *неперех.* **1.** почём зря ра́доваться **2.** иску́сственно весели́ться, де́лать весёлый вид || де́ланная весёлость; *~еп кылану* вести́ себя́ так, как бу́дто (*ему*) ве́село

сөендергеч *прил.* ра́дующий, весля́ющий ра́дость; *~ хәбәрләр* весля́ющие ра́дость ве́сти

сөендерү *перен.* **1.** ра́довать, весля́ть ра́дость **2.** обра́довать *кого*, пора́довать; *рәхмәт, мине ~дең* спаси́бо, пора́довал меня́

сөенеч *сущ.* **1.** ра́достное собы́тие, ра́достная весть; по́вод для ра́дости; *~е ни тора* одна́ то́лько ра́дость чего́ сто́ит; *~тән (~еннән)* на ра́достях; от ра́дости **2.** *см.* **сөенче**

сөенечле *прил.* **1.** ра́достный, отра́дный; *~ көн* ра́достный день; *~ хәл* ра́достное собы́тие **2.** ра́достный, выража́ющий ра́дость □ **~ тавыш белән** ра́достным го́лосом

сөенечлелек *сущ.* ра́достность, отра́дность; *хәбәрләрнең ~ге* отра́дность вести́

сөенешү *совм. от* **сөенү**; ра́доваться, обра́доваться вме́сте; *~ерләр инде* вот уж они́ бу́дут ра́доваться

сөенү *неперех.* ра́доваться, обра́доваться; *~еп бетәлми* не нара́дуется; *~уен күрсәң иде!* ви́дел бы ты, как он ра́довался! □ **~еп китү** совсе́м повесели́ть

сөенче *сущ.* **1. колак ~се** ра́достная весть; *~ китерү* принести́ ра́достную весть **2.** *этногр.* пода́рок, кото́рый вруча́ется тому́, кто принёс ра́достную весть; *~гә (~сенә) ни бирәсең?* что дашь, е́сли я скажу́ одну́ ра́достную весть? || *межд., которым оповещают о радости для кого*; испола́ть! с тебя́ пода́рок! □ **~ (~сен) алу** пе́рвым приноси́ть ра́достную весть (*и получить за это подарок*)

сөеш|ү *взаимно-совм. от* **сөю**; **1.** ласка́ть друг дру́га (*похлопыванием*) **2.** люби́ть друг дру́га; *~еп өйләну* вступа́ть в брак по любви́

сөзгәйт|ү *перех.* де́лать, сде́лать поло́гим (*отлогим, покатым*); *баскычны ~еп кую* ста́вить ле́стницу поло́го

сөзгә|ю *неперех.* станови́ться/стать пока́тым, поло́гим, отло́гим; *калкулыклар ~я башлады* холмы́ ста́ли пока́тыми

сөзә|к *прил.* пока́тый, поло́гий, отло́гий; *~ яр* поло́гий бе́рег || *сущ.* поло́гость, отло́гость, отко́с (*места, поверхности чего-л.*); поло́гий склон; *см. тж.* **сөзәклек**; *үр ~гендә* на отко́се холма́

сөзәкләндерү *перех. см.* **сөзәгәйтү**

сөзәкләнү *неперех.* **1.** *см.* **сөзәгәю**; *тора-бара яр ~гән* со вре́менем бе́рег стал поло́гим **2.** *в знач. нареч.* **сөзәкләнеп** поло́го; *~еп түбәнәйгән басу* поло́го спуска́ющееся по́ле

сөзәклән *нареч.* по отло́гости, пока́тости; *тауга ~ күтәрелү* поднима́ться в го́ру по отло́гости

сөзәкле|к *сущ. в разн. знач.* поло́гость, пока́тость; *тауларның ~ге* поло́гость гор; *~ктә урнашкан авыл* дере́вня, располо́женная на поло́гом скло́не

сөзге *сущ.* **1.** *см.* **сөзгеч 2.** (ма́лый) бре́день, сачо́к (*для ловли рыбы*); *~ белән тоту* лови́ть бре́днем (сачко́м)

сөзгеч *сущ.* **1.** цеди́лка, си́течко (*для процеживания молока*) **2.** шумо́вка, дуршла́г; *см. тж.* **кишкер, чулпы 3.** фильтр (*для жидкостей*); *бензобак ~е* фильтр бензоба́ка || *прил.* проце́живающий, фильтру́ющий; *~ җайланма* фильтру́ющее устро́йство

сөзгечлән|ү *страд. от* **сөзгечләү**; фильтрова́ться; *бензин берничә кат ~ә* бензи́н фильтру́ется не́сколько раз

сөзгечләү *перех.* проце́живать/процеди́ть || проце́живание че́рез си́течко (фильтр); фильтрова́ть || фильтро́вка

сөзгәк *прил.* бодли́вый (*бык, козёл*); *~ сыер мукләк була (посл.)* бодли́вой коро́ве бог рог не даёт (*букв.* бодли́вая коро́ва быва́ет комо́лой)

сөзгәкле|к *сущ.* бодли́вость; *~ге белән билгеле сыер* коро́ва, изве́стная свое́й бодли́востью

сөздерү I *понуд. от* **сөзү I**; позволя́ть/позво́лить бода́ть, бода́ться; *тәкәдән ~у* позво́лить козлу́ бода́ть *кого*

сөздерү II *понуд. от* **сөзү** II; заставля́ть/заста́вить веле́ть проце́живать

сөзек *сущ.* **1.** то, что остаётся на цеди́лке, си́те, решете́ **2.** *диал. см.* **сөт өсте 3.** *диал.* прозра́чный; *~ су* чи́стая (прозра́чная) вода́

сөзел|ү *страд. от* **сөзү** II; проце́живаться, быть проце́живаемым (*о кислом молоке*); *~гән сөт* проце́женное молоко́

сөзем *сущ. см.* **сөземтә**

сөземтә *сущ.* **1.** *см.* **сөзек 2.** *перен.* вы́вод; ито́г; обобще́ние; *тәҗрибәдән ~ ясау* де́лать вы́воды из о́пыта

сөземтәлә|ү *перех. разг.* подыто́живать/подыто́жить || подыто́живание; *см. тж.* **йомгаклау, нәтиҗәләү**; *~п кую* подвести́ ито́ги

сөземтәле *прил.* с вы́водом, с ито́гом, с обобще́нием; *~ доклад* докла́д с вы́водом

сөземтәсез *прил.* без вы́вода, без обобще́ния

сөзешкәк *прил.* **1.** лю́бящий бода́ться (*козлик, телёнок*) **2.** *перен. разг.* лю́бящий спо́ры, препира́тельства и т. п.; зади́ристый; *~ малай* зади́ристый ма́льчик

сөзештерү I *понуд. от* **сөзешү**; заставля́ть/заста́вить бода́ться; *тәкә(ләр) ~* заста́вить бода́ться козло́в ра́ди поте́хи

сөзештерү II *многокр. от* **сөзү** II; *балык ~* (*иногда, время от времени*) лови́ть ры́бу бре́днем

сөзеш|ү *взаимн. от* **сөзү** I; бода́ться (*о быках, козлах, баранах*); *икә тәкә басма өстендә ~ә башладылар, ди* говоря́т, два козла́ ста́ли бода́ться на мо́стике

сөзмә *сущ. кул.* сюзьма́ (*процеженная масса катыка, заправленная сметаной, молоком*); *~ сөзү* де́лать сюзьму́

сөз|ү I *перех.* **1.** бода́ть/бодну́ть || бода́ние **2.** *перен.* смотре́ть исподло́бья (*но внимательно*) □ **~еп егу** забода́ть; **~еп җибәрү** бодну́ть; **~еп үтерү** забода́ть на́смерть

сөз|ү II *перех.* **1.** цеди́ть, проце́живать, профильтрова́ть || проце́живание, фильтрова́ние; *сөт ~у* проце́живать молоко́ **2.** 1) вы́ловить *что* из жи́дкости 2) лови́ть, выла́вливать/вы́ловить || лов ры́бы бре́днем, се́тью и т. п. □ **~еп алу 1.** сце́живать/сцеди́ть **2.** вы́ловить бре́днем; **~еп бирү** нацеживать/нацеди́ть

сөйгән *прил.* **1.** люби́мый; *~ ашым* моё люби́мое блю́до; *~ кешесе бар* у него́ есть люби́мый челове́к **2.** *в знач. сущ.* люби́мый, возлю́бленный; зазно́ба; *~ем* моя́ люби́мая; *аның ~е* её возлю́бленный

сөйдергеч *сущ. этногр.* прису́ха (*средство, заставляющее влюбляться в кого*) || *прил.* прису́шивающий; заставля́ющий влюбля́ться *в кого*; *~ бәти* прису́шивающий амуле́т-запи́ска; *~ дога* прису́шивающая моли́тва

сөйдергеч-көйдергеч *сущ.* **1.** *см.* **сөйдергеч 2.** *прост.* зазно́ба; краса́вица (*в которую все влюбляются*)

сөйдерт|ү *понуд. от* **сөю 1.** заставля́ть/заста́вить влюбля́ться *в кого*, заста́вить полюби́ть *кого* (*преимущ. себя*); влюби́ть в себя́ **2.** 1) заставля́ть/заста́вить ласка́ть себя́ (*о ребёнке, младенце*) свои́м ви́дом 2) быть привлека́тельным, ми́лым *чем*; *карашлары ~ә* мила́ свои́м взгля́дом

сөйкәлеш|ү *взаимн. от* **сөйкәлү**; прильну́ть друг к дру́гу; *~еп тору* стоя́ть вплотну́ю друг к дру́гу; ла́ститься, льнуть друг к дру́гу

сөйкәл|ү 1. *возвр. от* **сөйкәү**; прислони́ться (*почти не касаясь*); притули́ться, приткну́ться *к чему, куда* 2. *перен.* увива́ться *около кого*, оха́живать *кого*; льнуть, ла́ститься *к кому*; *песи хуҗасына ~ә* ко́шка ла́стится к хозя́ину; *сөймәгәнгә ~мә (посл.)* не увива́йся о́коло того́, кто не лю́бит (тебя́)

сөйкән|ү *неперех.* 1. *см.* **сөйкәлү** 2 2. *см.* **ышкылу** 2

сөйкәү *перех.* (слегка́) прислони́ть, притули́ть, приткну́ть *к чему*; ста́вить, поста́вить, класть/положи́ть ря́дом, вплотну́ю *с чем; см. тж.* **сөяү**

сөйкем *сущ. разг.* милови́дность, симпати́чность, симпа́тия, обая́ние *кого*; *~е бар* у него́ есть обая́ние

сөйкемләнү *неперех. разг. см.* **сөйкемләнү**

сөйкемле *прил.* привлека́тельный, симпати́чный; обая́тельный, ми́лый, прия́тный; *һәр җәһәттән ~* прия́тный во всех отноше́ниях; *~ кеше* симпати́чный челове́к; *~ йөз* привлека́тельное лицо́; *~ тавыш* ми́лый го́лос □ **~ генә** ми́ленький тако́й; **сөяк** 1. что́-то притяга́тельное, обая́тельное *в ком*; *~ сөяге бар* в ней есть что́-то привлека́тельное 2. люби́мец, симпа́тия (всех) 3. *ирон.* люби́мчик

сөйкемләнә|ү *неперех.* станови́ться/стать симпати́чным, привлека́тельным, обая́тельным; *~еп китте* (он) стал обая́тельным

сөйкемлелек *сущ.* привлека́тельность, симпати́чность; обая́тельность; *үзенә бер төрле ~* своя́ осо́бая привлека́тельность

сөйкемсез *прил.* непривлека́тельный, несимпати́чный, неприя́тный; га́дкий; *см. тж.* **мәхәббәтсез**; *~ үрдәкәч* га́дкий утёнок □ **~ генә** малосимпати́чный, не о́чень симпати́чный

сөйкемсезләндерү *неперех.* де́лать, сде́лать непривлека́тельным, несимпати́чным, неприя́тным

сөйкемсезлән|ү *неперех.* станови́ться/стать непривлека́тельным, несимпати́чным, неприя́тным; теря́ть, потеря́ть обая́ние, обая́тельность

сөйкемсезлек *сущ.* непривлека́тельность, несимпати́чность; неприя́тность (*наружности, поведения и т. п.*)

сөйләк *сщ.* 1. коро́ткий у́стный расска́з (*о примечательном случае*); *сөйләсәң ~* расска́жешь — полу́чится расска́з 2. *фольк.* сказ || ска́зовый; *~ жанры* жанр ска́за; ска́зовый жанр; **~кә керү** станови́ться/стать ска́зом, леге́ндой

сөйләкче *сущ.* 1. скази́тель; люби́тель переска́зывать достопримеча́тельные слу́чаи 2. иссле́дователь ска́зов (*сказовых жанров фольклора*)

сөйләм *сущ.* 1. речь (*выражение мыслей средствами языка*); *телдән ~* изу́стная речь; *язма ~* пи́сьменная речь 2. речь, мане́ра говори́ть, мане́ра выража́ться || речево́й; *персонаж ~е* речь персона́жа 3. речь, разнови́дность ре́чи; *сәнгатьчә ~* худо́жественная речь; *гади ~* просторе́чие

сөйләмдәге *прил.* речево́й, наблюда́ющийся в ре́чи; *~ интонацияләр* речевы́е интона́ции

сөйләмле *прил.* речево́й, со стороны́ ре́чи; *~ характеристика* речева́я характери́стика (*персонажей*)

сөйләмчәк *прил.* говорли́вый, речи́стый; *~ хатын* говорли́вая же́нщина

сөйләмчәкләнә|ү *неперех.* станови́ться/стать говорли́вым, речи́стым; *~еп китте* совсе́м стал говорли́вым

сөйләндер|ү *понуд. от* **сөйләнү**; 1. позволя́ть/позво́лить, дава́ть/дать говори́ть (*что попало*); *күп ~мә* не дава́й ему́ говори́ть мно́го; *нигә ~еп торасың?* чего́ позволя́ешь ему́ распуска́ть язы́к? 2. занима́ть/заня́ть разгово́ром (*ребёнка*)

сөйләнел|ү *страд. от* **сөйләү**; 1. говори́ться, выска́зываться/вы́сказаться, обсужда́ться; *бу турыда күп ~де* об э́том говори́лось мно́го 2. *безл.* приходи́ться/прийти́сь говори́ть; *~де инде* пришло́сь уж говори́ть; *~мәгән сүзләр* невы́сказанные слова́

сөйләнчәк *сущ. разг.* болту́н, говору́н 2. ворчу́н

сөйләнчек *прил. разг.* говорли́вый, болтли́вый

сөйләнә|ү *возвр. от* **сөйләү**; 1. **үз алдына ~ү** говори́ть про себя́; говори́ть себе́ под нос; *нәрсәдер ~ә* что́-то говори́т, бормо́чет, бубни́т, ворчи́т про себя́ 2. *перен.* болта́ть вздор, говори́ть что попа́ло; трепа́ться; *...дип ~еп йөрде* всё вре́мя болта́л о том, что...; *күп ~ү* распуска́ть язы́к

сөйләттер|ү *понуд. от* **сөйләтү**; *син аны ~ә алмассың* ты его́ не заста́вишь расска́зывать

сөйләтү *понуд. от* **сөйләү**; 1. заставля́ть/заста́вить, веле́ть, проси́ть, говори́ть, расска́зывать/рассказа́ть; *әкият ~* заста́вить рассказа́ть ска́зку (ска́зки) 2. включа́ть/включи́ть ра́дио (*телевизор*)

сөйл|әү *неперех.* 1. 1) *в разн. знач.* говори́ть (*в отличие от русского соответствия данный глагол не вводит прямую речь в речь говорящего; для этого используется другой глагол* — **дию** сказа́ть); *күп ~әү* мно́го говори́ть; *кызык ~и* он говори́т интере́сно; *ике үйла, бер ~ә (посл.)* два́жды поду́май, оди́н раз скажи́ 2) сказа́ть, вы́сказаться; доводи́ть/довести́ до све́дения; *см. тж.* **әйтү**; *~ә барын да* вы́скажись по́лностью; *яшермичә ~ә* говори́ без ута́йки 3) говори́ть *о, об* (*про, насчёт*); *яшьләреген ~әү* говори́ть о свое́й мо́лодости 2. 1) чита́ть наизу́сть, вслух (*определённый текст*); *шигырь ~әү* чита́ть наизу́сть стихотворе́ние 2) расска́зывать/рассказа́ть; *әкият ~әү* расска́зывать ска́зку (ска́зки) □ *см.* **әйтәсе дә юк**; **~әп бетерү** 1. рассказа́ть до конца́; зако́нчить расска́з 2. договори́ть, вы́сказаться до конца́; **~әп бирү** изложи́ть, рассказа́ть, списа́ть (в слова́х); **~әп йөрү** всё вре́мя (то и де́ло) говори́ть, болта́ть *о чём* (*порочащие кого-л. слухи, мнения*); **~әп ташлау** наговори́ть (*лишнего*); **~әү теле** *лингв.* разгово́рный язы́к

сөйләүлек *сущ.* разгово́рник

сөйләүчән *прил.* 1. **(күп ~)** словоохо́тливый, многоречи́вый; разгово́рчивый 2. скло́нный заводи́ть речь; охо́чий до выступле́ний (*на собраниях*); *~ кеше инде ул* он-то лю́бит выступа́ть

сөйләүчәнлек *сущ.* (**күп ~к**) словоохо́тливость; многоречи́вость; скло́нность заводи́ть речь, выступа́ть (*на собраниях*); *~ге белән атаклы* изве́стен свое́й словоохо́тливостью

сөйләүче *сущ.* 1. говоря́щий, расска́зчик; *~ тынып торган арада тыңлаучылар фикер алышты* пока́ расска́зчик де́лал переры́в (па́узу), слу́шатели обменя́лись мне́ниями 2. выступа́ющий, ора́тор (*на собрании*); *~ләр күп булды* выступа́ющих бы́ло мно́го || *прил.* говоря́щий; *~ робот* говоря́щий ро́бот

сөйләш *сущ.* 1. *уст.* разгово́р; разгово́ры, слу́хи 2. *лингв.* го́вор; *Минзәлә ~е* минзели́нский го́вор (*среднего диалекта татарского языка*)

сөйләшел|ү 1. *страд. от* **сөйләшү**; говори́ться, быть говорённым *между кем-л.*; *бу турыда күп ~де инде* об э́том говори́ли мно́го 2. *безл.* говори́ться; приходи́ться/

прийти́сь разгова́ривать; *сездә озак ~де* у вас говори́лось (пришло́сь разгова́ривать) до́лго

сөйләшенгән *прил.* согласо́ванный; *~ мәсьәлә* согласо́ванный вопро́с; *~, килешенгән* по́лностью согласо́ванный

сөйләшенгәнлек *сущ.* согласо́ванность (*вопроса и т. п.*)

сөйләшен|ү *неперех.* обгова́риваться/обговори́ться; догова́риваться/договори́ться *насчёт чего* || договорённость; *бу эш турында ~де* э́то де́ло обговори́ли; по да́нному вопро́су договори́лись; *~ буенча* по договорённости

сөйләштер|ү I *перех.* **1.** *понуд. от* **сөйләшү**; заставля́ть/заста́вить разгова́ривать; разговори́ть; *сөйләшмәгәнне ~ү* разговори́ть неразгово́рчивого **2.** 1) дава́ть/дать возмо́жность говори́ть, разгова́ривать, разговори́ться (*в тюрьме*); *монда күп ~миләр* тут не разговори́шься (не разреша́ют) 2) разреша́ть/разреши́ть, допуска́ть/допусти́ть к телефо́ну (*в переговорном пункте*); *ун минут кына ~әләр* разреша́ют разгова́ривать то́лько де́сять мину́т

сөйләштерү II *неперех. многокр. от* **сөйләү**; говори́ть, разгова́ривать (*время от времени, иногда*)

сөйләш|ү *неперех.* **1.** *в разн. знач.* разгова́ривать, бесе́довать || разгово́р, бесе́да **2.** вести́ перегово́ры || перегово́ры; *~үләр соңында* по оконча́нии перегово́ров **3.** *диал. см.* **сөйләнү** □ **~еп китү** разговори́ться; **~еп кую** догова́риваться/договори́ться; **~ү буенча** по договорённости

сөймән *сущ.* пешня́ (*лом, которым долбят лёд*); *~ белән боз ваклау* долби́ть лёд пешнёй

сөйрәк *сущ.* во́лок; *~ белән* во́локом; *см. тж.* **сөйрәтеп**

сөйрәлдер|ү *перех.* **1.** разреша́ть/разреши́ть, дава́ть/дать возмо́жность волочи́ться, допуска́ть/допусти́ть волоче́ние; *~мә син аны* не дава́й ему́ волочи́ться **2.** *см.* **сөйрәтү**

сөйрәлчек *прил.* **1.** волоча́щийся; тако́й, что е́ле та́щится; *~ йөк* волоча́щийся груз **2.** медли́тельный; отстаю́щий; *бу ~ арбалар белән ерак китәлмәссең* с э́тими медли́тельными теле́гами далеко́ не уе́дешь || *сущ.* **1.** *груб.* потаску́ха **2.** ба́бник, *уст.* волоки́та; *~кә әверелү* превати́ться в ба́бника

сөйрәл|ү *неперех.* **1.** 1) тащи́ться, волочи́ться; *см. тж.* **өстерәлү**; *чыбыркы очы җирдән ~еп бара иде* коне́ц кнута́ волочи́лся по земле́ 2) плести́сь; *көчкә ~ә* е́ле плетётся (*о пешеходе*) **2.** *перен.* отстава́ть; плести́сь (тащи́ться) в хвосте́; *артта ~еп бару* плести́сь позади́ (*об информации, о литературе*) **3.** *перен.* таска́ться (*о женщине*); волочи́ться (*о мужчине*); *урамда ~ү* таска́ться по у́лице (*с целью привлечения мужчин или приставая к женщинам; говорится тж. о пьяницах, бездельниках и т. п.*)

сөйрәлүче *сущ.* **1.** *см.* **сөйрәлчек 2.** *зоол.* пресмыка́ющийся; *~ләр отряды* отря́д пресмыка́ющихся || *прил.* отстающий, плету́щийся в хвосте́; *эшебездә ~ләр булмасын иде* хоте́лось бы, что́бы в на́шей (о́бщей) рабо́те не́ было плету́щихся в хвосте́

сөйрәтел|ү *страд. от* **сөйрәтү**; тащи́ться, волочи́ться *кем-чем*; быть тащи́мым, волочи́мым; *бик зур бүрәнәләр трактор белән ~ә* о́чень больши́е брёвна волоку́тся тра́кторами

сөйрәтеп *нареч.* во́локом; *~ алып кайту* привози́ть во́локом (*воз сена, брёвна*)

сөйрәткеч *сущ.* **1.** *в разн. знач.* волоку́ша; *~ белән печән тарттыру* перевози́ть се́но при по́мощи волоку́ши **2.** тяга́ч; *см. тж.* **тарткыч**

сөйрәттер|ү *понуд. от* **сөйрәтү** 2

сөйрәт|ү *перех.* **1.** 1) тащи́ть, волочи́ть, воло́чь || волоче́ние (*при помощи чего*); *трактор белән ~ү* тащи́ть (перета́скивать) при по́мощи тра́ктора (тра́ктором) 2) *см.* **сөйрәү** 1 **2.** *см.* **сөйрәлдерү**; *итәген ~еп* волоча́ подо́л

сөйр|әү *перех.* **1.** таска́ть/тащи́ть, воло́чь, волочи́ть; тяну́ть; *аска ~әү* ста́скивать; тяну́ть вниз; *суда кием аска ~и* в воде́ оде́жда тя́нет вниз; *өскә ~әү* зата́скивать (вверх); *тышка ~әү* выта́скивать; *эчкә ~әү* вта́скивать; *читкә ~әү* отта́скивать **2.** воло́чь, волочи́ть || волоче́ние (*ноги или обуви*); *аягын көчкә ~и* е́ле волочи́т но́ги; *башмакларын ~и* волочи́т (*при хождении*) башмаки́ **3.** *перен. разг.* воло́чь, тяну́ть (*о выполнении трудных обязанностей*) **4.** *в знач. нареч.* 1) **сөйрәп** волоча́; *итеген ~әп йөри* хо́дит, (е́ле) волоча́ сапоги́ 2) *см.* **сөйрәтеп** □ **~әп бару** *см.* **сөйрәү** 3; **~әп җиткерү** дота́скивать/дотащи́ть; **~әп китерү (кайту)** прита́скивать/притащи́ть, подта́скивать/подтащи́ть; **~әп ташу** ната́скивать/натащи́ть; **~әп төшерү** стащи́ть (*с крыши, со стола*)

сөйре *сущ. зоол.* длинноно́гий кома́р; вид кру́пного комара́ □ **~ чебен** му́ха-кровосо́с

сөйрек *сущ. зоол.* севрю́га; *см. тж.* **сөрек**

сөйсәл|ү *неперех. диал.* де́лать грацио́зные телодвиже́ния, коке́тничать (*о женщине*)

сөкә *сущ.* ве́рша; *~ белән балык тоту* лови́ть ры́бу ве́ршей

сөкәт *сущ.* **1.** *ист.* скульпту́рное изображе́ние **2.** чу́чело; *салам тутырган ~* чу́чело с соло́мой внутри́ **3.** (*нормальная*) фигу́ра; (*приличный*) вид; *~е бар аның* фигу́ра у него́ есть (*хорошая*)

сөләйман: сөләйман балыгы *зоол.* лосо́сь; *сөләйман балыгы ите* лососи́на

сөлге *сущ.* полоте́нце; *чиккән ~* вы́шитое (с узо́рами) полоте́нце

сөлгеле *прил.* с полоте́нцем; *~ кыз* де́вушка с полоте́нцем

сөлгелек *прил.* полоте́нечный; приго́дный и́ли предназна́ченный для (изготовле́ния) полоте́нца; *~ тукыма* полоте́нечная ткань || *сущ.* ткань для полоте́нца, полоте́нечная ткань

сөле|к I *сущ. зоол.* пия́вка; *медицина ~ге* медици́нская пия́вка; *~к кую* ста́вить (приста́вить) пия́вку

сөлек II *сущ. ист.* (*лучший*) солда́т; тренированный во́ин □ **~ кебек** о́чень стро́йный и физи́чески ра́звитый; краса́вец краса́вцем

сөлекче *сущ.* **1.** лове́ц пия́вок **2.** ле́карь, ле́чащий пия́вками; *~ әби* ба́бушка-ле́карь, ле́чащая пия́вками

сөлтәр *сущ.* **1.** скеле́т; *елакка елан ~е (погов.)* пла́ксе — змейный скеле́т **2.** жа́лкие оста́тки *чего-л.*; *~е генә калган* оста́лись то́лько жа́лкие оста́тки **3.** *миф.* дух, при́зрак, привиде́ние (*в виде скелета*)

сөм *сущ.* **1.** осяза́ние; чу́вство осяза́ния; *сөм белән эзләп табу* находи́ть иглу́ при по́мощи осяза́ния **2.** *разг.* то́нкое чутьё; биопо́ле; *бармак сөме* то́нкое чутьё па́льцев; *борын сөме* обоня́ние, чутьё но́сом **3.** *перен.* такт, такти́чность; чу́вство прили́чия **4.** *физ.* по́ле; *кисәкчә (зәррә) сөме* по́ле части́цы □ **сөм тоймаган (тоймас)** бесчу́вственный; беста́ктный; **сөм тою 1.** осяза́ть || осяза́ние **2.** спосо́бность понима́ть намёк; при́знаки *чего-л.* (*настроение другого человека*)

сөмә|ю *неперех. см.* **семәю**

сөмбаш *сущ.* **1.** *зоол.* сёмга || сёмговый **2.** *кул.* лосо́сина и́ли мя́со сёмги

сөмбел *сущ.* **1.** *бот.* гиацинт || гиацинтовый; ~ *чәчәге* гиацинт (цветок) **2.** *разг. см.* **сөмбелә** □ ~ **чач** белоку́рые во́лосы; ~ **чәчле** белоку́рый; *чәчең ~, узең былбыл* твои́ во́лосы белоку́ры, а сама́ ты, что па́ва (*букв.* соловей)

сөмбелә *сущ.* **1.** 1) *астр.* созве́здие Де́вы, Де́ва 2) зодиака́льный знак созве́здия Де́вы; ~ *билгесендә* под зна́ком Де́вы **2.** 1) *название шестого месяца солнечного календаря, соответствует периоду с 22 августа по 22 сентября* 2) *диал.* а) а́вгуст б) сентя́брь **3.** ~ **бәйрәме, ~ көне** пра́здник осе́ннего равноде́нствия (*21—22 сентября*); пра́здник урожа́я и сватовства́ ≈ Валенти́нов день **4.** де́вушка, де́вочка, олицетворя́ющая о́сень (*на празднике осеннего равноденствия*) **5.** *перен. поэт. (белокурая)* краса́вица

сөмбелле *прил.* гиацинтовый; с гиацинтами; ~ *тундәк* гиацинтовая клумба

сөмсез *прил.* **1.** одеревене́лый, онеме́лый; ~ *бармаклар* онеме́лые па́льцы **2.** *перен.* нечу́ткий, недога́дливый; чёрствый **3.** *перен.* беста́ктный, бесцеремо́нный; наха́льный || *нареч.* беста́ктно, бесцеремо́нно, наха́льно; ~ *кылану* поступа́ть (вести́ себя́) беста́ктно

сөмсезләнүү *неперех.* **1.** одеревене́ть, онеме́ть || одеревене́ние, онеме́ние **2.** *перен.* вести́ себя́ беста́ктно, бесцеремо́нно, наха́льно; наха́льничать

сөмсезлек *сущ.* **1.** одеревене́лость, онеме́лость (*частей тела*) **2.** 1) нечу́ткость, недога́дливость 2) бесчу́вствие, равноду́шие (*к чужой беде, боли*); чёрствость **3.** беста́ктность, бесцеремо́нность; наха́льность, наха́льство

сөмсер, сөм-сер *сущ.* **1.** *этногр. уст.* одно́ из явле́ний души́: «гро́зная душа́»; дух хра́брости и со́бственного досто́инства **2.** норма́льное самочу́вствие □ **~е коелу** **1.** соверше́нно растеря́ться; побледне́ть; потеря́ть вид **2.** быть мра́чным, хму́рым; расстро́иться

сөннәт *сущ. рел.* **1.** су́нна (*догмат, догматы религии, которых в Коране нет, но которые по традиции, идущей от пророка Мухаммеда, должны исполняться; сунниты признают эти догматы, шииты не признают*) **2.** обы́чай обреза́ния (*выполняемый по сунне*); обреза́ние (*крайней плоти*) □ **~кә бирү (утырту)** подверга́ть обреза́нию, обре́зать (ма́льчиков)

сөннәтләнүү *страд. от* **сөннәтләү**; быть обре́занным (*по сунне*)

сөннәтләтү *понуд. от* **сөннәтләү**; заставля́ть/заста́вить и́ли проси́ть, вели́ть обре́зать (*мальчиков*)

сөннәтләү *перех.* **1.** обреза́ть || обреза́ние (*крайней плоти у мальчиков*); *см. тж.* **бабага бирү** **2.** *что-л.* соверша́ть/соверши́ть по су́нне, в соответствии с тре́бованиями су́нны **3.** *перен. шутл.* «ре́зать», «обре́зать» — си́льно сократи́ть (*при редактировании*)

сөннәтле *прил. рел.* **1.** обре́занный как поло́жено (*о мальчике, мужчине*) **2.** би́тый, ре́занный с соблюде́нием мусульма́нских обря́дов (*о скоте, о мясе*) □ ~ **бүрек** ша́пка с кру́глым око́лышем (*без наушников*)

сөннәтсез *прил.* **1.** необре́занный (*о мальчике*) **2.** не вы́полненный с до́лжным соблюде́нием су́нны (*о битой скотине*)

сөннәтче *сущ.* **1.** челове́к, занима́ющийся обреза́нием ма́льчиков **2.** *редко* знато́к су́нны

сөнни *прил.* сунни́тский; ~ *мәзһәб* сунни́тская се́кта, сунни́тское направле́ние (*в Исламе*) || *сущ.* сунни́т; *татарлар ~ булган* татары́ бы́ли сунни́тами

сөңге *сущ.* **1.** копьё, пи́ка; ~ *сугышы* война́, би́тва ко́пьями, пи́ками **2.** *перен.* сосу́лька **3.** *перен.* шпиль; *манара ~се* шпиль ба́шни

сөңгеләнүү *неперех.* принима́ть/приня́ть вид копья́, пи́ки; заостря́ться/заостри́ться наподо́бие копья́; быть заостри́вшимся, заострённым (*как копьё*); *~еп торган бозлар* льди́нки, заостри́вшиеся как ко́пьё

сөңгеле *прил.* с копьём; вооружённый копьём и́ли пи́кой; ~ *сакчы* часово́й с копьём ◊ ~ **Сөләйман** вои́нственный упря́мец

сөңгече *сущ.* **1.** *ист.* копьено́сец, копе́йщик; во́ин, вооружённый копьём; *~ләр отряды* отря́д копьено́сцев **2.** *спорт.* копьемета́тель

сөр *сущ.* **1.** *миф.* дух; гро́зная душа́ (*одна из составных частей души*) **2.** *диал. см.* **сөмсер** **3.** *физ.* заря́д □ **сөре коелу (очу)** *см.* **кот очу; сөрен җуйган (җигән)** **1.** уби́тый го́рем **2.** потеря́вший вся́кое самолю́бие

сөрәкә *сущ. диал.* бре́день; ~ *белән балык тоту* лови́ть ры́бу бре́днем

сөрән *сущ.* **1.** *ист. воен.* 1) (*тревожный*) боево́й клич; трево́га 2) крик пе́ред бо́ем **2.** *этногр.* сурэ́нь (*обряд и праздник изгнания злых духов весной и летом, если случались засуха, град и т. п.*) **3.** *диал.* ма́ссовые ко́нные ска́чки (*во время сабантуя*); ко́нные и́гры, и́грища □ ~ **салу (кычкыру)** **1.** бить трево́гу **2.** громогла́сно звать (*бегая по улицам*) на пра́здник сурэ́нь, на ко́нные ска́чки **3.** *перен.* крича́ть исто́шным го́лосом; ~ **сугу** **1.** стоя́ть на карау́ле (*готовый бить тревогу*) **2.** *перен.* безде́льничать; ~ **чабу** уча́ствовать на ма́ссовых ко́нных ска́чках; **~гә йөрү (чыгу)** **1.** звать на пра́здник сурэ́нь всех по о́череди (*при этом хозяева домов должны угощать зовущего — обычно мальчика или группу мальчиков*) **2.** *перен.* без де́ла ходи́ть из до́ма в дом (*угощаясь бесплатно*)

сөрәнләү *неперех.* **1.** (*криком*) бить, поднима́ть трево́гу; крича́ть карау́л; *бик каты ~и башладылар* ста́ли о́чень гро́мко крича́ть (*бить тревогу криками*) **2.** *перен.* вообще́ гро́мко крича́ть || гро́мкий крик

сөрәнче *сущ.* **1.** *ист. этногр.* волхв — организа́тор пра́здника (обря́да) изгна́ния ду́хов **2.** глаша́тай (*в частности, поднимающий тревогу*) **3.** сбо́рщик полоте́нец, платко́в, яи́ц и др. вещей для пра́здников сурэ́нь, сабанту́й и т. п.

сөрге *сущ. уст.* **1.** ки́сточка для нанесе́ния кра́ски на ве́ки **2.** смычо́к

сөрген *сущ.* ссы́лка, изгна́ние; *~гә җибәрү* ссыла́ть/сосла́ть, подверга́ть/подве́ргнуть изгна́нию

сөргенләү *перех.* высыла́ть/вы́слать || вы́сылка; официа́льно изгна́ть || официа́льное изгна́ние

сөргенче *прил.* ссы́льный, вы́сланный, со́сланный, и́згнанный || изгна́нник

сөргеч *сущ.* **1.** *уст. см.* **сөрге** **2.** снегопа́х; па́щущее, вспа́хивающее устро́йство

сөрдерүү **1.** *понуд. от* **сөрү** I 1) заставля́ть/заста́вить пахать, вспахать 2) производи́ть вспа́шки приуса́дебных уча́стков (*тракторами*) **2.** бороздить; *җир ~еп бурәнә сөйрәтү* бороздя́ зе́млю, волочи́ть бревно́

сөрек *сущ. зоол.* севрю́га (вид ры́бы) || севрю́жий; ~ *уылдыгы* севрю́жья икра́; ~ *ите* севрю́жина

сөрелүү I *страд. от* **сөрү** I; пахаться, вспа́хиваться; быть вспа́ханным; *~гән җир* вспа́ханная земля́

сөрелүү II *страд. от* **сөрү** II **1.** гна́ться, изгоня́ться, быть и́згнанным; *илдән ~гән* и́згнанный из страны́ **2.** ссыла́ться, быть со́сланным

сөрелү III *страд. от* **сөрү** III; дви́гаться *кем*, подвига́ться *кем*; передвига́ться *кем*; быть дви́гаемым, передвига́емым; *бер якка ~* быть передвига́емым в одну́ сто́рону

сөрем *сущ.* **1.** 1) гарь, чад; дым с за́пахом, смрад; *паровоз ~е* дым от (трубы́) паровоза 2) ко́поть; *лампа ~е* ла́мповая ко́поть 3) *диал.* уга́р; *см. тж.* **ис** II **2.** *перен.* дурма́н, уга́р; хмель, похме́лье; *дин ~е* религио́зный дурма́н; *шовинизм ~е* уга́р шовини́зма; шовинисти́ческое похме́лье **3.** *диал. перен.* дурно́е влия́ние; дурно́й пережи́ток

сөремлән|ү *возвр. от* **сөремләү**; копти́ться, закопти́ться; *~гән дивар* закопчённая стена́

сөремләү **1.** *неперех.* копте́ть; *см. тж.* **төтенләү** **2.** *перех.* копти́ть (*в знач. покрывать/покрыть копотью*)

сөремле *прил.* **1.** 1) ча́дный, чадя́щий; ко́потный, коптя́щий; *~ лампа* чадя́щая ла́мпа 2) закопте́лый, закопчённый (*камин*) **2.** уга́рный, ды́мный (*воздух*) **3.** *перен.* смра́дный (*об общей атмосфере*)

сөрендер|ү *понуд. от* **сөрен**ү; заставля́ть/заста́вить спотыка́ться (*и падать телом вперёд*); *тигезсез җир ~э* неро́вное ме́сто заставля́ет спотыка́ться

сөренте *сущ.* па́шня, (неда́вно) вспа́ханный уча́сток; *~ өстеннән бару* идти́ (е́хать) по вспа́ханному уча́стку || *прил.* **1.** вспа́ханный, запа́ханный; *~ җир* вспа́ханная, но ещё не боронованная земля́; *см. тж.* **сөрүле** **2.** *диал.* па́хотный (*о земле*)

сөреш *сущ.* **1.** *уст.* подви́жка, продвиже́ние, передвиже́ние (*в одном направлении*); *алга ~* подви́жка **2.** ход, тече́ние, проце́сс; *сүз ~е* проце́сс ре́чи (говоре́ния)

сөрешү *взаимно-совм. от* **сөрү** I; помога́ть паха́ть; совме́стно паха́ть

сөркә *сущ.* **1.** *диал. зоол.* суро́к, разнови́дность сурка́; *см. тж.* **суыр** **2.** *уст.* суро́к, сурко́вая шку́ра (*как предмет торговли*); *~ сатучы* продаве́ц сурко́в || *прил.* сурко́вый; *~ тун* сурко́вая шу́ба

сөркәче *сущ. ист.* торго́вец сурка́ми (*дешёвым мехом*)

сөрле|гү *неперех.* **1.** *прям., перен.* оступа́ться/оступи́ться; спотыка́ться/споткну́ться || спотыка́ние; *тигез урында ~кте* споткну́лся на ро́вном ме́сте **2.** вали́ться, повали́ться (в одну́ сто́рону), полега́ть/поле́чь (*о хлебах на корню, о деревьях в лесу*)

сөрлектер|ү **1.** *понуд. от* **сөрлегү**; заставля́ть/заста́вить спотыка́ться/споткну́ться; запина́ться/запну́ться, оступи́ться **2.** *безл.* приходи́ться/прийти́сь спотыка́ться/споткну́ться

сөрмә *сущ.* **1.** сурьма́, сурьми́ло (*мазь, крем, краска*) (*для крашения ресниц и век, чернения волос*) **2.** *хим.* сурьма́ || сурьмя́ный, сурьмяно́й; *~ рудалары* сурьмя́ные ру́ды **3.** *диал.* графи́т □ **~ тарту** сурьми́ть, насурьми́ть (*брови*); *см. тж.* **сөрмәләү**

сөрмәлән|ү *возвр.-страд. от* **сөрмәләү**; сурьми́ться, насурьми́ться; *ул көн дә ~э* она́ ка́ждый день сурьми́тся; *~гән кашлар* насурьмлённые бро́ви

сөрмәләү *перех.* сурьми́ть, насурьми́ть, надсурьми́ть; подводи́ть, подвести́ || подведе́ние сурьми́лом

сөрмәле *прил.* **1.** *хим.* сурьмяни́стый, сурьмя́ный; *~ көмеш* сурьмяни́стое серебро́; *~ кула* сурьмя́ный сплав **2.** насурьмлённый, подведённый сурьми́лом (*тушью*) **3.** окаймлённый, затенённый (*о глазах*); *~ күз* затенённые (*от природы*) глаза́

сөрсегән *прил.* **1.** 1) ту́хлый, проту́хший (*мясо*) 2) за́тхлый, нехоро́ший (*воздух*) **2.** *перен.* ко́сный, закосне́лый **3.** *перен.* 1) залежа́лый (*товар*) 2) наси́женный, засиде́лый (*девушка; должностное лицо*); закорене́лый; *~ бюрократ* закорене́лый бюрокра́т

сөрсе|к *сущ.* **1.** гни́лостный за́пах; зловоние, смрад **2.** гниль; *~ге килә* па́хнет гни́лью; несёт нехоро́шим ду́хом

сөрс|ү *неперех.* **1.** *спец.* отвали́ться (*о мясе на шкуре при её выделке*) **2.** ту́хнуть, протуха́ть/проту́хнуть || протуха́ние (*мяса, яиц, рыбы*); *~и башлаган* на́чал протуха́ть

сөртел|ү *страд. от* **сөртү** **1.** утира́ться, вытира́ться, быть вы́тертым **2.** натира́ться, быть натёртым (*о мазях, кремах и т. п.*); нама́зываться, быть нама́занным *чем*; *май ~гән* нама́занный ма́слом

сөртенгеч *сущ.* утира́льник; *кулына ~ бирү* дать в ру́ки утира́льник || утира́льный; *~ яулык* утира́льный плато́к

сөртен|ү I *возвр. от* **сөртү** **1.** утира́ться/утере́ться, вытира́ться/вы́тереться (*полотенцем*); *озак ~де* до́лго вытира́лся **2.** натира́ться/натере́ться (*мазью*); надуши́ться; *кершән ~ү*; нанести́ себе́ (*на лицо*) бели́ла

сөртен|ү II *неперех.* спотыка́ться/споткну́ться, оступа́ться/оступи́ться; запина́ться/запну́ться || спотыка́ние; *~мәс тояк юк (посл.)* ≈ конь о четырёх нога́х и то спотыка́ется

сөртешү *взаимно-совм. от* **сөртү**; утира́ть/утере́ть, вытира́ть/вы́тереть друг дру́га; наноси́ть/нанести́ *что* друг дру́гу; *сөрмә ~* насурьми́ть друг дру́га

сөрткеч *сущ.* тря́пка для вытира́ния; *кул (бит) ~* утира́льник

сөрттер|ү **1.** *понуд. от* **сөртү**; заставля́ть/заста́вить, проси́ть утира́ть, вытира́ть; *битендәге канны ~ү* проси́ть, заставля́ть, вытира́ть с лица́ кровь **2.** *перен. прост. см.* **сөртү** 3

сөрт|ү *перех.* **1.** утира́ть/утере́ть, вытира́ть/вы́тереть || утира́ние, вытира́ние; *тузанны ~ү* вытира́ть пыль; *йөзен ~ү* утира́ть своё лицо́ **2.** 1) нама́зывать/нама́зать || нама́зывание (*тонким слоем*); *вазелин ~ү* нама́зывать вазели́ном 2) *индив.* надуши́ть; *чәчкә исле май ~ү* надуши́ть во́лосы духа́ми **3.** *перен. прост.* красть, стырну́ть □ **~еп алу** **1.** стере́ть, вы́тереть (*пятно и т. п.*) досуха, на́чисто **2.** *перен. разг.* подтере́ть (*пол*)

сөр|ү I *перех.* **1.** паха́ть, вспа́хивать/вспаха́ть || вспа́шка (земли́); *тирән ~ү* глубоко́ паха́ть; *трактор белән ~ү* паха́ть тра́ктором; *туңга ~ү* паха́ть под зябь **2.** *перен.* вспа́хивать (*снег*), меси́ть грязь (*снег, песок*); идти́, дви́гаться, утопа́я в грязи́ (*в снегу, песке*); *кар ~еп бара* идёт, вспа́хивая снег

сөр|ү II *перех.* **1.** 1) гоня́ть, гнать (*в одном направлении, всю массу*); *җил болытларны ~ә* ве́тер го́нит ту́чи (*в одном направлении*) 2) изгоня́ть/изгна́ть || изгна́ние; *илдән ~ү* изгоня́ть из страны́ **2.** ссыла́ть/сосла́ть || ссы́лка; *Себергә ~ү* сосла́ть в Сиби́рь □ **~еп чыгару** выгоня́ть/вы́гнать (*всеми средствами, с треском*)

сөрү III *перех.* **1.** *уст.* дви́гать, продвига́ть, передвига́ть || движе́ние *кем*; *алга ~* продвига́ть вперёд; *артка ~* дви́гать, тяну́ть наза́д **2.** *в знач. вспом. гл. с абстракт. зн. в им. п. образует составные глаголы; гомер ~* жить, влачи́ть существова́ние; жить в труда́х; *патшалык ~* ца́рствовать; *хөкем ~* хозя́йничать; *рәхәт ~* наслажда́ться; получа́ть удово́льствие

сөрүле *прил.* вспа́ханный; ~ *җирләр* вспа́ханные зе́мли

сөрүлек *сущ.* па́хотная земля́; *~ләр һәм болыннар* па́хотные зе́мли и луга́; ~ *мәйданы* пло́щадь па́хотных земе́ль || *прил.* па́хотный, па́шенный; ~ *җирләр* па́хотные зе́мли

сөрхәнтәй *сущ. разг.* балбе́с, болту́н, безде́льник; ~ *егет* па́рень-безде́льник; *ялкау* – лени́вый балбе́с

сөт *сущ.* **1.** *в разн. знач.* молоко́, молочко́ || моло́чный, мле́чный; *сөттә пешкән ботка* ка́ша, пригото́вленная на молоке́; ~ *бизе* моло́чная железа́; *сөт заводы* моло́чный заво́д; *известь сөте* известко́вое молоко́; *сөт эшкәртүче* молокоперераба́тывающий; *сөт әзерләүче* молокозаготови́тель **2.** молоко́, мле́чный сок (*растений и т. п.*); *билчән ~е* молоко́, молочко́ осо́та □ **сөт аерту** сепари́ровать, пропуска́ть молоко́ че́рез сепара́тор; **сөт бирү** дава́ть молоко́, дои́ться; **сөт өсте** сли́вки; **сөт сатучы** моло́чница: продаве́ц молока́; **сөт төшү** наполня́ться молоко́м (*о молочных железах, о вымени*); набира́ться — о молоке́; **сөт чиләге** подо́йник, моло́чное ведро́; **сөте кибү (кору)** вы́доиться; теря́ть моло́чность ◊ **сөт анасы (инәсе, әнисе)** же́нщина, корми́вшая (не бу́дучи ма́терью) *кого*; **сөт тә юк, йон да юк** *см.* **он да юк, йон да юк; сөттән ак, судан пакь** ≈ безви́нный а́ки а́гнец (*букв.* беле́е молока́, чи́ще воды́)

сөтагы, сөт-агы *сущ.* моло́чный проду́кт; *см. тж.* **сөт-катык**

сөт-катык *сущ. собир.* моло́чные проду́кты

сөтләнү *неперех.* **1.** налива́ться/нали́ться молоко́м, мле́чным со́ком (*о хлебных злаках*) **2.** *разг. см.* **сөтләнү**

сөтләп *нареч.* с молоко́м; ~ *чәй эчү* пить чай с молоко́м

сөтләч *прил.* **1.** моло́чный, удо́йный (*о породе коров или конкретной корове*); ~ *токым* моло́чная поро́да; ~ *түгәнәбез бар* у нас (*для получения молока*) есть бурёнушка **2.** *разг. см.* **сөтле** 2

сөтле *прил.* **1.** с молоко́м; с мле́чным со́ком; содержа́щий молоко́ и́ли мле́чный сок; ~ *савыт* сосу́д с молоко́м; ~ *үлән* трава́ с мле́чным со́ком **2.** моло́чный, удо́йный; дающий мно́го молока́; ~ *сыер* удо́йная коро́ва **3.** *кул.* моло́чный; пригото́вленный с молоко́м, на молоке́; ~ *аш* моло́чный суп; ~ *маргарин* моло́чный маргари́н □ ~ **билчән** *бот.* осо́т жёлтый; ~ **текәнәк** молока́н тата́рский

сөтлегән *сущ. бот.* молоча́й || молоча́йный; ~ *сөте* мле́чный сок молоча́я; ~ *яфраклары* молоча́йные ли́стья

сөтлек *прил.* доста́точный и́ли приго́дный для молока́, для обеспече́ния молоко́м; ~ *акча* де́ньги на молоко́; ~ *мал-туар* скоти́на для обеспече́ния молоко́м

сөтлекле *прил.* моло́чный, до́йный; ~ *сыер* до́йная коро́ва

сөтлелек *сущ.* **1.** моло́чность, до́йность (*коровы, козы и т. п.*) **2.** удо́й, удо́йность; ~ *дәрәҗәсе* сте́пень удо́йности

сөтләнү *неперех.* станови́ться/стать моло́чным, до́йным

сөтсез *нареч.* без молока́; ~ *пешерү* вари́ть без молока́ || *прил.* безмоло́чный; немоло́чный; не дающий (мно́го) молока́; ~ *сыер* немоло́чная коро́ва

сөтсезләнү *неперех.* теря́ть молоко́ (*о корове, козе и т. п.*)

сөтсезлек *сущ.* отсу́тствие молока́; необеспе́ченность молоко́м; *сыерның ~ге* отсу́тствие молока́ у коро́вы

сөтче *сущ.* продаве́ц молока́; моло́чник, моло́чница; ~ *хатын* моло́чница, же́нщина-моло́чница

сөтчел *прил.* **1.** удо́йный; ~ *сыер* удо́йная коро́ва **2.** мле́чный; ~ *сыекча* мле́чная жи́дкость (сок)

сөтчелек *сущ.* моло́чное хозя́йство || моло́чный (*о хозяйстве*); ~ *фермасы* моло́чная фе́рма

сөхбәт *сущ.* **1.** *уст.* (дру́жеская) бесе́да; собесе́дование; (*фәләннең*) *-енә ирешү* удосто́иться дру́жеской бесе́ды (*знаменитого лица*) **2.** *диал.* сове́т ро́да

сөхбәтләшү *неперех. уст.* бесе́довать, собесе́довать; *озак ~* до́лго бесе́довать

сөхбәтче *сущ. уст.* собесе́дник; бесе́дующий *с кем-л.*; *~ләр җыелды* собрали́сь собесе́дники

сөхбәтчелек *сущ.* обы́чай собесе́дования; постоя́нные бесе́ды

сөч *сущ.* **1.** грех на́ душу; *сөч алу* взять грех на́ душу **2.** ко́свенная вина́, ко́свенное соуча́стие

сөю *перех.* **1.** (*преимущ. с ф. на* **-дан**) ласка́ть || ла́ска, похло́пывание (руко́й); *аркасыннан сөю* ласка́я, похло́пывать по спине́ **2.** *в разн. знач.* люби́ть || любо́вь; *эш сөю* люби́ть рабо́ту; любо́вь к рабо́те (труду́); *табигать сөю* люби́ть приро́ду; *сөймәс кеше көймәс (погов.)* не лю́бит, так и не горю́ет (*и горя у него мало*) **3.** *сущ.* любо́вь, влюблённость || любо́вный; *сөю газаплары* му́ки любви́

сөюле *прил.* влюблённый, любо́вный (*взгляд, голос, обращение*); ~ *күзләр* влюблённые глаза́

сөючән *прил.* **1.** скло́нный люби́ть *кого, что; см. тж.* **сөюче 2.** *редко* влю́бчивый

сөючәнлек *сущ.* **1.** любо́вь, скло́нность люби́ть *что, кого*; *әдәбият ~* любо́вь к литерату́ре **2.** *редко* влю́бчивость

сөюче *сущ.* **1.** люби́тель *чего*; *музыка ~* люби́тель му́зыки **2.** покло́нник *кого* || *прил. в номинативных словосоч.* -люби́вый; *эш ~* трудолюби́вый

сөя|к *сущ.* **1.** скеле́т, опо́ра те́ла; *~ге җиңел* с хру́пким скеле́том; хру́пкий на вид **2.** кость || ко́стный; *эт күңеле — бер ~к (погов.)* соба́чья любо́вь сто́ит одно́й ко́сточки; *~к кыйпылчыгы* оско́лок ко́сти; *~к эшкәртү* обраба́тывать (ре́зать) кость; *~ктән ясалган* сде́ланный из ко́сти; *~к чире* ко́стная боле́знь **3.** *ист.* род, «колено»; подро́д, сеок (*у тюркских народностей*), «кровь»; *үз ~гем* свой ро́дственник; своя́ кровь; *ак ~к* бе́лая кость (*«голубая» кровь*); *солтан ~ген сүкмәс (посл.)* до́брый мо́лодец своё происхожде́ние не проклянёт (*букв.* царе́вич не бу́дет руга́ть свой род) **4.** *диал.* 1) ко́сточка (*фруктов*) 2) костри́ка (*льна, конопли*) || *прил.* костяно́й, сде́ланный из ко́сти; *~к тарак* костяно́й гребешо́к; костяна́я расчёска ◊ **~ген юу** перемыва́ть ко́сточки; **~к йомшарту (язу)** 1. разминаться/размя́ться (*умываясь в бане, делая физические упражнения*) **2.** немно́го вы́пить, вы́пить, что́бы снять уста́лость; **~к (~ген) тоту** хорони́ть со́бственной руко́й; прису́тствовать на похоро́нах *кого*; **~ккә калу** си́льно исхуда́ть (похуде́ть); **~ккә** *калган* ко́жа да ко́сти

сөякләнү *неперех.* **1.** окостене́ть || окостене́ние (*кожной ткани*) **2.** *в знач. прил.* **сөякләнгән** окостене́лый; *~гән куллар* окостене́лые ру́ки

сөякләч *прил.* костля́вый, кости́стый (*о туловище, частях тела*); ~ *куллар* костля́вые ру́ки

сөякләчләнү *неперех.* станови́ться/стать кости́стым, костля́вым; *картаеп ~* стать костля́вым в ста́рости

сөякләчлек *сущ.* костля́вость; *нәселдән килгән ~* костля́вость от приро́ды; насле́дственная костля́вость

сөякле *прил.* 1. с ко́стью (костя́ми), костя́стый (*о мясе*) 2. *см.* **сөяклэч** □ ~ **балыклар** *зоол.* костя́стые ры́бы

сөяк-сана|к *сущ. собир.* 1. все ко́сти; *сөяк-санак авырта* боля́т (все) ко́сти 2. *перен.* о сложе́нии те́ла; *сөяк-санагы матур* хорошо́ сложён 3. мосо́л, мослы́; *сөяк-санак сату* продава́ть мослы́; *сөяк-санагы күренеп тора* видны́ (торча́т, выпира́ют) все мослы́ 4. *пренебр.* ко́стные оста́тки

сөяксез *прил.* 1. *в разн. знач.* беско́стный, без косте́й; *тел ~ (погов.)* язы́к (он) без косте́й 2. *перен.* бесхребе́тный, не сто́йкий в свое́й пози́ции; ~ *кеше* бесхребе́тный челове́к □ ~ **балыклар** *зоол.* беско́стные (*хрящевые*) ры́бы

сөяксезлек *сущ. прям., перен.* бесхребе́тность

сөякчэн *прил.* масла́стый; кости́стый; крупноко́стный

сөякчэнлек *сущ.* кости́стость, худоба́

сөякче *сущ.* 1. сбо́рщик косте́й 2. *мед.* ле́карь-костопра́в 3. которе́з

сөякчел *прил. см.* **сөяклэч**

сөял *сущ.* 1. (суха́я) мозо́ль; ~ *чыкты* наби́лась мозо́ль 2. борода́вка ◊ ~**енэ басу** (*букв.* наступи́ть на (люби́мую) мозо́ль)

сөялдерү *перех. разг. см.* **сөяү**

сөялләндерү *понуд. от* **сөялләнү**; мозо́лить, намозо́лить; *эш эшләп кулларны ~* мозо́лить ру́ки (*беспрерывной*) рабо́той

сөялләнү| *неперех.* покрыва́ться/покры́ться (сухо́й) мозо́лью (мозо́лями); ~*еп каткан* отверде́вший от мозо́лей

сөялле *прил.* 1. мозо́листый; с мозо́лью; ~ *куллар* мозо́листые ру́ки; ~ *урын* ме́сто (на те́ле) с мозо́лью 2. с борода́вкой, борода́вчатый

сөял|ү *возвр.-страд. от* **сөяү**; 1. прислоня́ться/прислони́ться *к чему*; *агачка ~у* прислони́ться к де́реву; *баскыч коймага ~гән* ле́стница прислонена́ к стене́ 2. облока́чиваться/облокоти́ться; *см. тж.* **таяну**

сөям *сущ.* пядь, че́тверть арши́на; *бер ~ җир* пядь земли́; *ике ~ тирәнлеге кар* снег глубино́й в пол-арши́на

сөямләү: сөямләп үлчәү ме́рить пя́дями

сөямле *прил.* 1. длино́й в определённое коли́чество пя́дей; *кырык ~ бүрәнә* бревно́ в со́рок пя́дей 2. разделённый на пя́ди (*о мерной палке, мерной ленте*)

сөян *сущ.* 1. обо́дранная ли́па; ствол ли́пы, с кото́рого сня́та кора́ 2. *диал.* ли́па || *прил.* из обо́дранной ли́пы; ли́повый; ~ *бүрәнә* (ошку́ренное) ли́повое бревно́; ~ *бура* ли́повый сруб

сөяркә *сущ.* любо́вница, сожи́тельница, содержа́нка □ ~ **булу** быть любо́вницей; ~ *тоту* содержа́ть любо́вницу

сөят|ү *понуд. от* **сөяү**; заставля́ть/заста́вить и́ли проси́ть, веле́ть прислоня́ть/прислони́ть

сөя́|ү *перех.* прислоня́ть/прислони́ть; приставля́ть/приста́вить; подпира́ть/подпере́ть || прислоне́ние, приставле́ние, подпира́ние; *см. тж.* **терәү**

сөяүле *прил.* прислонённый; *әнә, ~ тора* вон стои́т, прислонённый

спазм, спа́зма *сущ. мед.* спазм, спа́зма (*судорожное сокращение мышц*); *нерв ~лары* не́рвные спа́змы

спазма́тик *прил. мед.* спазмати́ческий; ~ *өянәк* спазмати́ческий припа́док □ ~ **рәвештә** спазмати́чески

спа́змлы *прил. мед.* спазмати́ческий

спартакиада *сущ.* спартакиа́да; *җәйге ~* ле́тняя спартакиа́да; *мәктәп ~сы үткәрү* проведе́ние шко́льной спартакиа́ды

спартакиа́дачы *сущ.* уча́стник спартакиа́ды

спартан *сущ.* спарта́нец, спарта́нка (*о людях, ведущих суровый образ жизни*) || спарта́нский; *чын ~* настоя́щий спарта́нец; ~ *тормышы алып бару* вести́ спарта́нскую жизнь

спарта́нча *нареч.* 1. спарта́нски, по-спарта́нски, как спарта́нец; ~ *яши* живёт по-спарта́нски 2. *в знач. прил.* спарта́нский; ~ *тормыш* спарта́нская жизнь; ~ *тәрбия* спарта́нское воспита́ние

спектакль *сущ.* спекта́кль; ~ *кую* ста́вить спекта́кль; *кичке ~* вече́рний спекта́кль; ~ *карау* смотре́ть спекта́кль

спекулянт *сущ.* спекуля́нт || спекуля́нтский; *вак ~* ме́лкий спекуля́нт; ~ *бәяләре* спекуля́нтские це́ны; ~ *хатын-кыз* спекуля́нтка

спекулянтлык *сущ.* спекуля́ция; заня́тие спекуля́цией

спекуля́нтча *нареч.* по-спекуля́нтски, спекулятѝвно; как спекуля́нт

спекулятив *прил.* спекулятѝвный; ~ *бәяләр* спекулятѝвные це́ны; ~ *сәүдә* спекулятѝвная торго́вля

спекуля́ция *сущ. прям., перен.* спекуля́ция; ~ *белән шөгыльләнү* занима́ться спекуля́цией; ~ *белән баю* обогаща́ться спекуля́цией; ~ *өчен судка тартылу* привлече́ние к суду́ за спекуля́цию □ ~ **ясау** спекули́ровать *чем*

спе́рма *сущ. физиол.* спе́рма (*жидкость с мужскими половыми клетками*)

специальләштерел|ү 1. *страд. от* **специальләштерү**; специализи́роваться 2. *в знач. прил.* **специальләштерелгән** специализи́рованный; ~*гән магазин* специализи́рованный магази́н; ~*гән совхоз* специализи́рованный совхо́з

специальләштерү *перех.* специализи́ровать || специализа́ция; *ит җитештерүне ~* специализи́ровать мясно́е произво́дство; *халык хуҗалыгын ~* специализа́ция наро́дного хозя́йства

специальләшү *неперех.* специализи́роваться || специализа́ция; *сарык үстерүгә ~* специализи́роваться по овцево́дству; *дәүләтара ~* межгосуда́рственная специализа́ция *в чём*

спидо́метр *сущ.* спидо́метр (*прибор, указывающий скорость движения*); ~ *курсәтүе буенча* по показа́ниям спидо́метра

спи́кер *сущ.* спи́кер (*председатель палаты*)

спи́ннинг *сущ.* спи́ннинг (*рыболовная снасть*) || спи́ннинговый; ~ *белән балык тоту* уди́ть ры́бу спи́ннингом; *җыелма ~* складно́й спи́ннинг; ~ *кәтүге* спи́ннинговая кату́шка

спи́ннингчы *сущ.* спиннинги́ст; ~*лар ярышы* соревнова́ния спиннинги́стов

спира́ль *сущ.* спира́ль; ~*ь буенча күтәрелү* поднима́ться по спира́ли; *электр плитасының ~е* спира́ль электропли́тки; ~*ь рәвешендә* в ви́де спира́ли || *прил.* спира́льный; ~*ь сызык* спира́льная ли́ния; ~*ь баскыч* спира́льная ле́стница

спирт *сущ. в разн. знач.* спирт || спиртово́й; ~*та тонәту* настоя́ть на спирту́; *медицина ~ы* медици́нский спирт; *аракы ~ы* ви́нный спирт; *агач ~ы* древе́сный спирт; *нашатырь ~ы* нашаты́рный спирт; *коры ~* сухо́й спирт; ~ *исе* спиртово́й за́пах; за́пах спи́рта

спиртлану *возвр.-страд.* спиртóвываться/спиртовáться, заспиртóвываться/заспиртовáться; пропúтываться/пропитáться спúртом

спиртлáу *перех.* спиртовáть, заспиртóвывать/заспиртовáть ‖ спиртовáние; *виноград согын ~* спиртовáние виногрáдного сóка; *сирәк балыкны ~* заспиртовáть рéдкий вид рыбы

спиртлы *прил.* **1.** спиртнóй; *~ эчемлекләр* спиртны́е напúтки **2.** спиртовóй; *~ лаклар* спиртовы́е лáки; *~ компресс* спиртовóй компрéсс □ *~* **эчемлек** спиртнóе

спóнсор *сущ.* спóнсор (*организация или лица, ссужающие средства*); *~ табу* найтú спóнсора; *күргәзмәнең ~ы* спóнсор вы́ставки

спóра *сущ. биол.* спóра; *үсемлекләрнең ~ ярдәмендә үрчүе* размноже́ние расте́ний спóрами; *тын ~* покóящаяся спóра □ *~* **бөресе** *бот.* спорáнгий

спóралы *прил. биол.* спóровый; *~ үсемлекләр* спóровые расте́ния

спорт *сущ.* спорт ‖ спортúвный; *~ның җәйге төрләре* ле́тние ви́ды спóрта; *парашют ~ы* парашю́тный спорт; *~ мастеры* мáстер спóрта; *~ уеннары* спортúвные и́гры; *~ мәйданчыгы* спортúвная площáдка; *~ товарлары* спортúвные товáры

спортзал *сущ.* спортзáл (*спортивный зал*); *күнегүләрне ~да үткәрү* проведе́ние трениро́вок в спортзáле

спортклуб *сущ. спорт.* спортклýб; *«Рубин» ~ы* спортклýб «Рубúн»

спортлото *сущ.* спортлотó; *~ билеты* билéт спортлотó; *~ тиражы* тирáж спортлотó

спортчы *сущ.* спортсмéн, спортсмéнка; *разрядлы ~* спортсмéн-разря́дник

спринт *сущ. спорт.* спринт (*бег, плавание на короткую дистанцию*)

спри́нтер *сущ. спорт.* спри́нтер (*спортсмен по спринту*) ‖ спри́нтерский; *~ тизлеге* спри́нтерская ско́рость; *~ дистанциясенә йөгерү* бег на спри́нтерскую диста́нцию

спринтчы *сущ. спорт. см.* **спринтер**

спрут *сущ. зоол.* спрут; *см.* **сигезаяк**

спýтник *сущ. разг.* (*космический летательный аппарат*); *см. тж.* **иярчен** II

сро|к *сущ.* **1.** срок; *см. тж.* **мәҗәл, мөддәт**; *гарантия ~гы* гаранти́йный срок; *сынау ~гы* испыта́тельный срок; *актык ~к* после́дний срок; *ике айлык ~к билгеләү* установи́ть двухме́сячный срок; *икенче ~кка калу* оста́ться на второ́й срок **2.** *в знач. нареч.* **срогына** во́время, к назна́ченному сро́ку; *~гына өлгертергә* приготóвить к назна́ченному сро́ку (во́время) □ **~гыннан алда (элек)** досро́чно

сроклы *прил.* **1.** сро́чный; -сро́чный; *~ кертем* сро́чный вклад; *~ ссуда* сро́чная ссу́да; *озак ~* долгосро́чный; *кыска ~* краткосро́чный **2.** рассчúтанный на определённый срок; вре́менный; *~ эш* вре́менная рабóта

сроклылык *сущ.* сро́чность

сроксыз *прил.* бессро́чный пáспорт

ссýда *сущ. экон.* ссýда ‖ ссýдный; *банк ~сы* бáнковская ссýда; *озак сроклы ~* долгосро́чная ссýда; *кыска сроклы ~* краткосро́чная ссýда; *~ алу* брать/взять ссýду; *~ кассасы* ссýдная кáсса; *~ капиталы* ссýдный капитáл □ *~* **алучы** *экон.* ссудополýча́тель; *~* **бирү** выдава́ть/вы́дать ссýду, ссужáть/ссудúть; *~* **бирүче** *экон.* ссудода́тель

стабилизáтор *сущ.* **1.** *авиа, воен.* стабилизáтор (*устройство для сообщения телу устойчивости*); *самолёт ~ы* стабилизáтор самолёта; *бомба ~ы* стабилизáтор бóмбы **2.** *эл.* стабилизáтор (*устройство для поддержания постоянного тока*); *көчәнеш ~ы* стабилизáтор напряже́ния; *ешлык ~ы* стабилизáтор частоты́ колеба́ния **3.** *хим.* стабилизáтор (*вещество*); *пластмасс ~ы* стабилизáтор пластмáсс

стабиль *прил. книжн.* стабúльный; *ср.* **тотрыклы**; *~ дәреслекләр* стабúльные учéбники; *~ бәяләр* стабúльные цéны

стабильләштерү *перех. книжн.* стабилизúровать, стабилизовáть *что* ‖ стабилизáция; *см.* **тотрыкландыру**; *нормаларны ~* стабилизовáть нóрмы; *политик хәлне ~* стабилизовáть политúческую обстанóвку

стабильләшү *неперех. книжн.* стабилизúроваться, стабилизовáться ‖ стабилизáция; *см.* **тотрыклану**; *бәяләр ~* стабилизáция цен; *дәреслекләр ~* стабилизáция учéбников

стабильле|к *сущ. книжн.* стабúльность; *см.* **тотрыклылык**; *хәлнең ~ге* стабúльность положе́ния; *икътисади ~к чоры* перúод стабúльности экономúки

стáвка *сущ. воен.* стáвка; *баш командующий ~сы* стáвка главнокомáндующего; *~га чакыру* вы́звать в стáвку

ставри́да *сущ. зоол.* ставри́да; *кыздырылган ~* жáреная ставри́да; *ысланган ~* копчёная ставри́да; *~ көтүе* стáя ставри́ды

стадиáль *прил. книжн.* стадиáльный; *~ үсеш* стадиáльное разви́тие; *~ теория* стадиáльная тео́рия □ *~* **рәвештә** стадиáльно

стадиальле|к *сущ. книжн.* стадиáльность; *үсешнең ~ге* стадиáльность разви́тия

стадион *сущ.* стадио́н ‖ стадио́нный; *ачык ~* откры́тый стадио́н; *ябык ~* кры́тый стадио́н; *мәктәп ~ы* шкóльный стадио́н; *су ~ы* вóдный стадио́н; *~ җиһазлары* стадио́нное оборýдование

стáдия *сущ.* стáдия; *үсешнең түбәнге һәм югары ~ләре* ни́зшие и вы́сшие стáдии разви́тия; *тәҗрибә ~сендә* на óпытной стáдии; *чәчәк ату ~се* стáдия цвете́ния; *яралгы ~сендә* в стáдии зарóдыша

стáдияле *прил.* стади́йный; -стадийный; *~ үсеш теориясе* тео́рия стади́йного разви́тия; *~ процесс* стади́йный проце́сс

стáдиялелек *сущ. книжн.* стади́йность

стаж *сущ. в разн. знач.* стаж; *гомуми эш ~ы* óбщий трудовóй стаж; *фәнни эш ~ы* стаж нáучной рабóты; *кандидатлык ~ы* кандидáтский стаж

стажёр *сущ.* стажёр, стажёрка; *~ булып эшләү* рабóтать стажёром

стажёрлык *сущ.* стажёрство, стажиро́вка ‖ стажёрский; *~ка җибәрү* послáть на стажиро́вку

стажиро́вка *сущ.* стажиро́вка ‖ стажиро́вочный; *~да булу* быть на стажиро́вке; *~ срогы* срок стажиро́вки; *кыска сроклы ~* краткосро́чная стажиро́вка □ *~* **итү** проходи́ть стажиро́вку, стажирова́ть, стажирова́ться

стажлы *прил.* со стáжем; *зур ~* с большúм стáжем; *~ эшче* рабóчий со стáжем

стáйер *сущ. спорт.* стáйер (*спортсмен (бегун, пловец и т. д) на длинные дистанции*) ‖ стáйерский; *~ дистанциясенә* на стáйерскую дистáнцию

стакан *сущ.* **1.** стакáн ‖ стакáнный; *бер ~ чәй* стакáн чáю; *кырлы ~* гранёный стакáн; *~га агызу* налúть в стакáн **2.** *тех.* стакáн (*полый цилиндр*)

стаканлап *нареч.* стакáнами; *җиләкне ~ сату* продавáть я́годы стакáнами

стаканлы *прил.* в стака́не; нали́тый в стака́н; ~ *чәй* чай, нали́тый в стака́н

сталагмит *сущ.* сталагми́т || сталагми́товый; ~ *багана* сталагми́товый столб

сталагмитлы *прил.* сталагми́товый, со сталагми́тами; ~ *мәгарә* сталагми́товая пеще́ра

стан I *сущ.* стан, ла́герь; *кыр ~ы* полево́й стан; *бригада ~ы* брига́дный стан

стан II *сущ. тех.* **1.** стан (*машина*); *прокат ~ы* прока́тный стан **2.** стано́к (*приспособление*); *туку ~ы* тка́цкий стано́к; *ат дагалау ~ы* стано́к для подко́вывания лошаде́й; *кул ~ы* ручно́й стано́к; *түгәрәк пычкы ~ы* кругопи́льный стан

стандарт *сущ. в разн. знач.* станда́рт (*типовой образец*); *халыкара ~ буенча* по международному станда́рту; *дәүләт ~ы* госуда́рственный станда́рт; *~ка туры килү* соотве́тствовать станда́рту || *прил.* станда́ртный; ~ *йортлар* станда́ртные дома́; ~ *мебель* станда́ртная ме́бель; ~ *алым* станда́ртный приём; ~ *җавап* станда́ртный отве́т □ ~ **булмаган** нестанда́ртный; **~ка салу** стандартиза́ция

стандартлаштыру *перех.* стандартизи́ровать, стандартизова́ть *что* || стандартиза́ция; *детальләрне ~* стандартизи́ровать дета́ли; ~ *институты* институ́т стандартиза́ции

стандартлаштырылу *страд. от* **стандартлаштыру**; стандартизи́роваться, стандартизова́ться

стандартлашу *неперех.* стандартизи́роваться, стандартизова́ться || стандартиза́ция

стандартлы|к *сущ.* станда́ртность; *җиһазларның ~гы* станда́ртность обору́дования

стани́ца *сущ.* стани́ца || стани́чный; *казак ~сы* каза́чья стани́ца; ~ *советы* стани́чный сове́т; ~ *урамы* стани́чная у́лица □ ~ **казагы** стани́чник

становой *сущ. ист. разг.* станово́й; ~ *пристав* станово́й при́став

стано|к *сущ.* **1.** стано́к || стано́чный; *кыру ~гы* тока́рный стано́к; *кайрау ~гы* точи́льный стано́к; *заводның ~к паркы* стано́чный парк завода́ **2.** *воен.* стано́к, лафе́т; *пулемёт ~гы* стано́к пулемёта □ **~к төзү** станкострое́ние || станкострои́тельный; *~к төзү заводы* станкострои́тельный заво́д; **~к төзүче** станкострои́тель

станоклы *прил. воен.* станко́вый; ~ *пулемёт* станко́вый пулемёт

станокчы *сущ.* стано́чник, стано́чница; *күп ~* многостано́чник; *алдынгы ~* передова́я стано́чница

ста́нция *сущ. в разн. знач.* ста́нция || станцио́нный; *тимер юл ~се* железнодоро́жная ста́нция; *автобус ~се* авто́бусная ста́нция; *тәжрибә ~се* о́пытная ста́нция; *метеорология ~се* метеорологи́ческая ста́нция; *электр ~се* электри́ческая ста́нция; *орбиталь ~* орбита́льная ста́нция

ста́нцияле *прил.* станцио́нный, име́ющий (*свою*) ста́нцию; ~ *посёлок* посёлок со свое́й (*железнодорожной*) ста́нцией

ста́пель *сущ.* ста́пель, ста́пели *мн.* || ста́пельный; *теплоходны ~дән төшерү* спуск теплохо́да со ста́пеле́й

ста́роста *сущ.* **1.** *ист.* ста́роста; *авыл ~сы* се́льский ста́роста; *чиркәү ~сы* церко́вный ста́роста **2.** ста́роста; *класс ~сы* ста́роста кла́сса; *түгәрәк ~сы* ста́роста кружка́; ~ *сайлау* вы́боры ста́росты □ ~ **хатыны** *ист.* ста́ростиха *прост.*

ста́росталык *сущ.* до́лжность ста́росты; *~тан баш тарту* отказа́ться от до́лжности ста́росты

старт *сущ.* старт || ста́ртовый; *~ка хәзерләнү* подгото́виться к ста́рту; ~ *бирү* дать старт; ~ *мәйданчыгы* ста́ртовая площа́дка; ~ *сызыгы* ста́ртовая ли́ния; ~ *пистолеты* ста́ртовый пистоле́т □ ~ **алу** брать/взять старт, стартова́ть

ста́ртер, стартёр *сущ. тех.* ста́ртер, стартёр || ста́ртерный, стартёрный; *механик ~* механи́ческий ста́ртер; ~ *ачкычы* ста́ртерный ключ; *~га басу* нажа́ть на ста́ртер

стартчы *сущ. спорт.* ста́ртер, стартёр

старшина *сущ.* **1.** *воен.* старшина́; *рота ~сы* старшина́ ро́ты; *беренче статьялы ~* старшина́ пе́рвой статьи́; *гвардия ~сы* гва́рдии старшина́ **2.** *ист.* старшина́; *волость ~сы* волостно́й старшина́; *цех ~сы* старшина́ це́ха; ~ *сайлау* вы́боры старшины́

старшиналык *сущ.* до́лжность старшины́; *~ка сайлау* вы́брать старшино́й, на до́лжность старшины́

ста́тик *прил.* **1.** *физ.* стати́ческий; ~ *басым* стати́ческое давле́ние; ~ *электр* стати́ческое электри́чество **2.** *книжн.* стати́чный; ~ *поза* стати́чная по́за || *нареч.* стати́чно; ~ *куренелү* пока́зываться стати́чно

ста́тиклык *сущ. физ.* стати́чность

стати́стик *прил.* статисти́ческий; ~ *мәгълүматлар* статисти́ческие да́нные; ~ *метод* статисти́ческий ме́тод

стати́стика *сущ. в разн. знач.* стати́стика || статисти́ческий; ~ *бүлеге* отде́л стати́стики; *рәсми ~* официа́льная стати́стика; *математик ~* математи́ческая стати́стика; *туу ~сы* стати́стика рожда́емости

ста́тус *сущ.* ста́тус; *дипломатик ~* дипломати́ческий ста́тус; *ирекле шәһәр ~ы* ста́тус во́льного го́рода; *союздаш республика ~ы* ста́тус сою́зной респу́блики

статут *сущ.* стату́т, уста́в (*свод правил*); *Дан ордены ~ы* стату́т о́рдена Сла́вы; *юридик ~* юриди́ческий стату́т; *Берләшкән Милләтләр Оешмасы ~ы* стату́т Организа́ции Объединённых На́ций

статья *сущ.* **1.** *юр. фин.* статья́; *Җинаятьләр кодексының 70 нче ~сы* статья́ 70 Уголо́вного ко́декса; *бюджетның керем һәм чыгым ~лары* статьи́ дохо́дов и расхо́дов в бюдже́те **2.** статья́, вид; *экспортның мөһим ~сы* ва́жная статья́ э́кспорта

статьялап *нареч.* постате́йно; ~ *төзелгән* соста́влен постате́йно

статьялы *прил. воен.* име́ющий статью́; разря́д; *икенче ~ старшина* старшина́ второ́й статьи́

стаха́новчы *сущ. ист.* стаха́новец, стаха́новка || стаха́новский; *данлыклы ~лар* знамени́тые стаха́новцы; *~лар киңәшмәсе* совеща́ние стаха́новцев; ~ *хәрәкәте* стаха́новское движе́ние □ ~ **хатын-кыз** стаха́новка

стационар *сущ.* стациона́р; *~да дәвалану* лечи́ться в стациона́ре; *~да уку* учи́ться в стациона́ре || *прил.* стациона́рный; ~ *авыру* стациона́рный больно́й; ~ *бүлек* стациона́рное отделе́ние; ~ *уку йорты* стациона́рное уче́бное заведе́ние

ста́чка *сущ. ист.* ста́чка (*забастовка*) || ста́чечный; *гомуми ~* всеоо́бщая ста́чка; ~ *уткәрү (ясау)* проводи́ть ста́чку; ~ *хәрәкәте* ста́чечное движе́ние; ~ *комитеты* ста́чечный комите́т

ста́чкачы *сущ.* ста́чечник, ста́чечница; *~лар пикеты* пике́т ста́чечников

ствол *сущ.* ствол (*в шахте*) || ство́льный; *шахта ~ы* ствол ша́хты; ~ *үтү* прохо́дка ствола́

стеарин *сущ.* стеари́н || стеари́нный, стеари́новый; ~ *табы* пятно́ стеари́на; ~ *заводы* стеари́новый заво́д; ~ *цехы* стеари́новый цех || *прил.* стеари́новый; ~ *шәмнәр* стеари́новые све́чи

сте́ла *сущ.* сте́ла (*вертикально стоящая памятная каменная плита с надписью*)

стеллаж *сущ.* стелла́ж || стелла́жный; *сүтелмә ~* разбо́рный стелла́ж; *китап ~ы* кни́жный стелла́ж

стеллажлы *прил.* обору́дованный стеллажа́ми, име́ющий стеллажи́; *~ булмә* ко́мната, обору́дованная стеллажа́ми

стена *сущ.* **1.** стена́, сте́нка || стенно́й; *см. тж.* **дивар**; *өй ~сы* стена́ до́ма; *таш ~* ка́менная стена́; *бүрәнә ~лар* бревё́нчатые сте́ны; *вагон ~лары* сте́нки ваго́на; *юка ~ аркылы* че́рез то́нкую сте́нку; *~ сәгате* стенны́е часы́; *~ көзгесе* стенно́е зе́ркало **2.** стена́, высо́кая огра́да; *крепость ~лары* крепостны́е сте́ны; *шәһәр ~сы* городска́я стена́ **3.** *перен.* стена́, сплошна́я прегра́да; *ут ~сы* о́гненная стена́, стена́ огня́ □ **~ бизәү** стенопи́сный; **~ газетасы** стенна́я газе́та ◊ **~ булып тору** стоя́ть стено́й; **~га борчак синкәндәй** как об сте́нку горо́х; **~га терәү 1.** припере́ть (прижа́ть) к сте́нке **2.** ста́вить к сте́нке, расстреля́ть

стенгазе́та *сущ.* стенгазе́та (*стенная газета*) || стенгазе́тный; *~ чыгару* выпуска́ть стенгазе́ту; *мәктәп ~сы* шко́льная стенгазе́та

стенд *сущ.* **1.** стенд (*щит, стойка*); *күргәзмә ~ы* вы́ставочный стенд; *~тагы экспонатлар* экспона́ты на сте́нде **2.** стенд (*установка для сборки и испытания*) || сте́ндовый; *сынау ~ы* испыта́тельный стенд; *җыю ~ы* сбо́рочный стенд; *~ сынаулары* сте́ндовые испыта́ния

стенка *сущ.* **1.** сте́нка (*комплект комбинированной мебели*); *~ сатып алу* купи́ть сте́нку **2.** *спорт.* сте́нка; *~га тезелү* вы́строиться в сте́нку

стеногра́мма *сущ.* стеногра́мма || стеногра́ммный; *кыскартылган ~* сокращённая стеногра́мма; *съезд ~сын уку* чита́ть стеногра́мму съе́зда; *~ материалы* стеногра́ммный материа́л

стенографи́к *прил.* стенографи́ческий; *~ отчёт* стенографи́ческий отчёт

стенографи́ст *сущ.* стенографи́ст; стенографи́стка; *~ язуы* за́пись стенографи́ста; *~лар курсы* ку́рсы стенографи́стов

стенографи́я *сущ.* стенографи́я; *~ дәреслеге* уче́бник по стенографи́и

стенографи́ялә́ү *перех.* стенографи́ровать *что*; *чыгышларны ~* стенографи́ровать выступле́ния

стенокарди́я *сущ. мед.* стенокарди́я (*сердечное заболевание*), грудна́я жа́ба

стерео- стерео- *первая часть сложных слов, соответствующая по значению слову* **стереоскопик**: стереому́зыка, стереофи́льм

стереотип *прил.* **1.** стереоти́пный; *~ басма* стереоти́пное изда́ние **2.** трафаре́тный, шабло́нный; *~ сүзләр* стереоти́пные слова́; *~ җавап* стереоти́пный отве́т □ **~ рәвештә** стереоти́пно

стереотиплы|к *сущ.* стереоти́пность; *җавабының ~гы* стереоти́пность отве́та

стереотруба *сущ.* стереотруба́ (*оптический прибор*); *~дан күзәту* наблюда́ть в стереотрубу́

стерилиза́цияләнү *возвр.-страд. от* **стерилизацияләү**; стерилизова́ться

стерилиза́цияләтү *понуд. от* **стерилизацияләү**

стерилиза́цияләү *перех.* стерилизова́ть || стерилиза́ция; *см.* **стерильләү**; *консервларны ~* стерилизова́ть консе́рвы; *керне ~* стерилиза́ция белья́ □ **~ аппараты** стерилизацио́нный аппара́т, стерилиза́тор

стериль *прил. в разн. знач.* стери́льный; *~ бинт* стери́льный бинт; *~ мамык* стери́льная ва́та; *~ күзәнәк* стери́льная кле́тка

стерильләү *перех.* **1.** стерилизова́ть || стерилиза́ция; *сөтне ~* стерилиза́ция молока́ **2.** *мед.* стерилизова́ть *кого-что*; *см.* **орлыксызландыру**

стерильләштерелү *страд. от* **стерильләштерү**; стерилизова́ться

стерильләштерү *перех.* стерилизова́ть *что* || стерилиза́ция; *туфракны ~* стерилиза́ция по́чвы; *~ аппараты* стерилизацио́нный аппара́т

стерильле|к *сущ. в разн. знач.* стери́льность; *хирургик операция коралларының ~ге* стери́льность хирурги́ческих инструме́нтов; *җенси күзәнәкнең ~ге* стери́льность полово́й кле́тки

сте́рлинг *сущ.* сте́рлинг || сте́рлинговый; *фунт ~* фунт сте́рлингов; *~ зонасы* сте́рлинговая зо́на

стетоскоп *сущ. мед.* стетоско́п (*медицинский инструмент*); *мембраналы ~* мембра́нный стетоско́п; *сулыш алуын ~ белән тыңлау* слу́шать дыха́ние стетоско́пом

стилист *сущ. лит.* стили́ст (*писатель, редактор*); *бик шәп ~* превосхо́дный стили́ст; *нечкә ~* то́нкий стили́ст

стилистик *прил.* стилисти́ческий; *~ ялгышлар* стилисти́ческие оши́бки; *~ үзенчәлекләр* стилисти́ческие осо́бенности; *~ чаралар* стилисти́ческие сре́дства

стили́стика *сущ. в разн. знач.* стили́стика || стилисти́ческий; *татар теленең ~сы* стили́стика татарского языка́; *~ укыту* преподава́ть стили́стику; *әсәрнең ~сы* стили́стика произведе́ния

стил|ь I *сущ.* **1.** 1) *иск., лит.* стиль || стилево́й; *готика ~е* готи́ческий стиль; *барокко ~ендә* в сти́ле баро́кко; *әдәбиятта романтизм ~е* стиль романти́зма в литерату́ре; *Тукай ~е* стиль Тука́я; *~ь үзенчәлекләре* стилевы́е осо́бенности 2) *лингв.* стиль || стилево́й, стилисти́ческий; *публицистика ~е* публицисти́ческий стиль; *эш кәгазьләре ~е* стиль делопроизво́дства; *фәнни ~* нау́чный стиль; *югары ~ьдә* возвы́шенным сти́лем; *~ь өстендә эшләү* рабо́тать над сти́лем; *~ь хаталары* стилисти́ческие оши́бки **2.** стиль, спо́соб, мане́ра; *эштә бюрократик ~ь* бюрократи́ческий стиль в рабо́те; *эш ~е* стиль рабо́ты; *җитәкчелек итү ~е* стиль руково́дства; *бу минем ~ьдә түгел* э́то не в моём сти́ле □ **~ьгә салу** стилизова́ть || стилиза́ция

стиль II *сущ.* стиль (*способ летосчисления*); *иске ~ белән 25 октябрьдә, яңа ~ белән 7 ноябрьдә* по ста́рому сти́лю 25 октября́, по но́вому сти́лю 7 ноября́

стильләштерү 1. *перех.* стилизова́ть || стилиза́ция **2.** стилиза́торский; *бизәкләрне ~* стилизова́ть орна́мент; *~ алымы* приём стилиза́ции, стилиза́торский приём

стильләштерелү *страд. от* **стильләштерү**; стилизова́ться

стильләштерүче *сущ.* стилиза́тор; *әкиятләрне ~* иску́сный стилиза́тор ска́зок

стильле *прил.* **1.** сти́льный; *~ кием* сти́льная оде́жда; *~ мебель* сти́льная ме́бель **2.** *в знач. нареч.* сти́льно; *~ киену* одева́ться сти́льно

стильче *сущ.* стили́ст; *оста ~* иску́сный стили́ст

стиля́га *сущ. разг. неодобр.* стиля́га || стиля́жный

сти́мул *сущ.* сти́мул; *материаль ~* материа́льный сти́мул; *мораль ~* мора́льный сти́мул □ **~ бирү** стимули́ровать

сти́муллау *перех.* стимули́ровать || стимули́рование; *см. тж.* **сти́муллаштыру**

сти́муллаштыру *перех.* стимули́ровать || стимули́рование, стимуля́ция; *хезмәтне ~* стимули́рование труда́; *~ фонды* фонд стимули́рования; *терлек үстерүне ~* стимули́рование животново́дства; *материаль якта ~* материа́льное стимули́рование

сти́муллаштырылу 1. *страд. от* **сти́муллаштыру** 2. стимули́роваться || стимули́рование; *эшчеләрнең хезмәте ~* стимули́рование труда́ рабо́чих

сти́муллашу *неперех.* стимули́роваться || стимуля́ция

стимуля́тор *сущ. спец.* стимуля́тор (*вещество*); *үсеш ~ы* стимуля́тор ро́ста; *нерв эшчәнлеге ~лары* стимуля́торы не́рвной де́ятельности

стипендиат *сущ.* стипендиа́т; *колхоз ~ы* колхо́зный стипендиа́т; *Тукай ~ы* тука́евский стипендиа́т

стипе́ндия *сущ.* стипе́ндия || стипендиа́льный; *~ алу* получа́ть стипе́ндию; *~ фонды* стипендиа́льный фонд; *күтәренке ~* повы́шенная стипе́ндия; *~ комиссиясе* стипендиа́льная коми́ссия □ **~ алучы** стипендиа́т, стипендиа́тка

стихи́я *сущ.* 1. стихи́я (*явление природы*) || стихи́йный; *су ~се* во́дная стихи́я; *һава ~се* возду́шная стихи́я; *~ көчләре* си́лы стихи́и; стихи́йные си́лы 2. *перен.* стихи́я, среда́, круг; *вак буржуа ~се* мелкобуржуа́зная стихи́я; *үз ~сендә булу* быть в свое́й стихи́и

стихи́яле *прил.* стихи́йный; *~ көчләр* стихи́йные си́лы; *~ үсеш* стихи́йное разви́тие; *~ төс ала* принима́ет стихи́йный вид; *~ чыгыш* стихи́йное выступле́ние □ **~ рәвештә** стихи́йно

стихи́ялеле|к *сущ.* стихи́йность; *табигать көчләренең ~ге* стихи́йность сил приро́ды

стихи́ячел *прил. см.* **стихияле**; *~ көч* стихи́йная си́ла

стихи́ячелек *сущ.* стихи́йность || стихи́йный; *см.* **стихи́ялелек**; *~кә юл куймау* не допуска́ть стихи́йности

сто́ик *сущ. филос.* сто́ик

столбняк *сущ. мед.* столбня́к (*инфекционное заболевание*) || столбня́чный; *~ микробы* столбня́чный микро́б; *~ка каршы укол* противостолбня́чный уко́л

столяр *сущ.* столя́р || столя́рный; *~ мастерское* столя́рная мастерска́я; *~га үку* учи́ться на столяра́ □ **~ иту** столя́рничать

стомато́лог *сущ. мед.* стомато́лог; *~ врач* врач-стомато́лог

стоматоло́гик *прил. мед.* стоматологи́ческий; *~ тикшеренүләр* стоматологи́ческие иссле́дования

стоматоло́гия *сущ. мед.* стоматоло́гия || стоматологи́ческий; *~ поликлиникасы* стоматологи́ческая поликли́ника; *~ институты* стоматологи́ческий институ́т

стопа *сущ. лит.* стопа́ (*ритмическая единица стиха*); *см.* **бәхер**; *өч иҗекле ~* трёсло́жная стопа́

стра́жник *сущ. ист.* стра́жник (*низший полицейский чин*); *атлы ~лар* ко́нные стра́жники

стратег *сущ. в разн. знач.* страте́г; *хәрби ~* вое́нный страте́г; *революция ~ы* страте́г революции

страте́гик *прил.* стратеги́ческий; *~ чимал* стратеги́ческое сырьё; *~ авиация* стратеги́ческая авиа́ция; *~ корал* стратеги́ческое ору́жие; *~ план* стратеги́ческий план

страте́гия *сущ.* 1. *воен.* страте́гия (*военное искусство*) || стратеги́ческий; *хәрби ~* вое́нная страте́гия; *~ курсы* курс страте́гии 2. *перен.* страте́гия (*искусство руководства*); *революцион ~* революцио́нная страте́гия

стратосфе́ра *сущ. спец.* стратосфе́ра (*верхний слой атмосферы*) || стратосфе́рный; *~га мену* подня́ться на стратосфе́ру; *~ катламнары* стратосфе́рные слои́

страхова́ние *сущ. фин.* страхова́ние || страхово́й; *социаль ~* социа́льное страхова́ние; *ирекле ~* доброво́льное страхова́ние; *мәҗбүри ~* обяза́тельное страхова́ние; *катнаш ~* сме́шанное страхова́ние; *~ агенты* страхово́й аге́нт

страхо́вка *сущ. разг.* 1. страхо́вка, страхова́ние || страхово́й; *~ акчасы* страховы́е де́ньги 2. *спорт.* страхо́вка || страхо́вочный; *~ бавы* страхо́вочная верёвка

страхо́вкалану *возвр. от* **страховкалау**; страхова́ться, застрахова́ться *от кого-чего*

страхо́вкалау *перех.* 1. страхова́ть, застрахова́ть *кого-что*; *өйне ~* застрахова́ть дом 2. *спорт.* 1) страхова́ть || страхо́вка 2) страхо́вочный; *гимнастны ~* страхова́ть гимна́ста

страхо́вкалаучы *сущ.* 1. страхова́тель 2. страхо́вщик

стре́лка *сущ. ж.-д.* стре́лка || стре́лочный; *~ кучерү* перевести́ стре́лку; *трамвай юлы ~сы* стре́лка трамва́йных путе́й; *~ җайланмалары* стре́лочные устро́йства

стре́лкачы *сущ. ж.-д.* стре́лочник, стре́лочница

стрептомицин *сущ. фарм.* стрептомици́н (*антибиотик*) || стрептомици́новый; *~ мае* стрептомици́новая мазь

стрептоцид *сущ. фарм.* стрептоци́д (*лекарственный препарат*) || стрептоци́довый; *~ төймәсе* табле́тка стрептоци́да; *~ мае* стрептоци́довая мазь

стро́нций *сущ. хим.* стро́нций (*лёгкий металл*) || стро́нциевый

строп *сущ. тех.* строп (*канат, трос*); *парашют ~лары* стро́пы парашю́та

строфа *сущ. лит.* строфа́; *см.* **куплет**; *дүрт юллы ~* четырёхстро́чная строфа́; *шигырьнең өченче ~сы* тре́тья строфа́ стихотворе́ния

строфалы *прил. лит.* строфи́ческий; стро́фный; *дүрт ~ шигырь* четырёхстро́фное стихотворе́ние

струк *сущ.* струг, руба́нок; *тактаны ~ белән шомарту* острога́ть до́ску стру́гом (руба́нком); *ике куллы ~* двуру́чный струг

струклану *гл.* 1. *страд. от* **струклау** 2. строга́ться, отстрога́ться

струклау *перех. разг.* строга́ть, отстрога́ть || строга́ние; *см.* **ышкылау**; *тактаның ике ягын да ~* отстрога́ть о́бе стороны́ доски́; *~ станогы* строга́льный стано́к

структур *прил.* структу́рный; *туфракның ~ үзенчәлекләре* структу́рные осо́бенности по́чвы; *~ анализ* структу́рный ана́лиз; *~ үзгәрешләр* структу́рные изме́нения

структу́ра *сущ.* структу́ра || структу́рный; *вак төерле ~* мелкокомкова́тая структу́ра; *кантарлы ~* комкова́тая структу́ра; *җәмгыятьнең икътисади ~сы* экономи́ческая структу́ра о́бщества; *~ төзелеше* структу́рное строе́ние

структу́ралы *прил.* структу́рный; *~ туфрак* структу́рная по́чва

структу́ралылы|к *сущ.* структу́рность; *туфракның ~гы* структу́рность по́чвы

структураль *прил. спец.* структура́льный; *тикшеренүдә ~ ысул* структура́льный ме́тод иссле́дования

студент *сущ.* 1. студе́нт || студе́нческий; *университет ~ы* студе́нт университе́та; *беренче курс ~ы* студе́нт пе́рвого ку́рса, первоку́рсник; *~ чакта* в студе́нческие го́ды 2. *в ф.* **студентлар** *собир.* студе́нчество || студе́нческий; *Казан ~ы* каза́нское студе́нчество; *~ тулай торагы* студе́нческое общежи́тие

студентлык *сущ.* студе́нчество || студе́нческий; *~ елларыгы* студе́нческие го́ды; го́ды студе́нчества

сту́дия *сущ. иск.* **1.** сту́дия (*творческая мастерская*); *рәссам ~се* сту́дия худо́жника; *скульптор ~се* сту́дия ску́льптора **2.** сту́дия (*школа*) || студи́йный; *театр ~сендә уку* учи́ться в театра́льной сту́дии; *балет ~се* бале́тная сту́дия; *~ спектакле* студи́йный спекта́кль **3.** сту́дия (*театральный, сценический коллектив*); *яшь артистлар ~се* сту́дия молоды́х арти́стов; *опера театры ~се* сту́дия о́перного теа́тра; *музыкаль ~* музыка́льная сту́дия **4.** сту́дия (*предприятие по производству фильмов и телепередач*); киносту́дия || студи́йный; *документаль фильмнар ~се* сту́дия документа́льных фи́льмов; *кинохроника ~се* сту́дия кинохро́ники □ **~ укучысы** студи́ец, студи́йка

сту́дияче *сущ.* студи́ец, студи́йка; *~ләр күргәзмәсе* вы́ставка студи́йцев

стюарде́сса *сущ.* стюарде́сса (*служащая, обслуживающая пассажиров на борту судна или самолёта*); *«Аэрофлот» ~сы* стюарде́сса «Аэрофло́та»

су I *сущ.* **1. 1)** вода́ || во́дный, водяно́й; *салкын су* холо́дная вода́; *кайнар су* горя́чая вода́; *кайнамаган су* сыра́я вода́; *агым су* прото́чная вода́; *чишмә суы* ключева́я вода́; *диңгез суы* морска́я вода́; *газлы су* газиро́ванная вода́; *минераль су* минера́льная вода́; *кар суы* та́лая вода́; *су процедуралары* во́дные процеду́ры; *су тамчылары* водяны́е ка́пли; *су тузаны* водяна́я пыль **2)** *первый компонент составных слов, соответствующий русскому* водо- *су үлчәгеч* водоме́р; *су бүлгеч* водоотво́д **2.** *перен. разг.* вода́; пусто́е многосло́вие; *китапның ярты суы* полови́на кни́ги состои́т из воды́ **3.** вода́, водоём || во́дный; водяно́й; *тирән су* глубо́кая вода́; *су кимәле* у́ровень воды́; *су этеме* напо́р воды́; *су өсте* во́дная пове́рхность; *су юлы белән* во́дным путём; *су тегермәне* водяна́я ме́льница **4.** *обычно мн.* **сулар** во́ды; *территориаль сулар* территориа́льные во́ды **5.** *разг.* река́, ре́чка (*употр. с именем собственным*); *Ык суы* река́ Ик; *Казан су* река́ Каза́нка; *киң су* широ́кая река́; *су ярларыннан чыкты* река́ вы́шла из берего́в **6.** *разг.* сок; *каен суы* берёзовый сок; *ашказаны суы* желу́дочный сок; *җимеш суы* фрукто́вый сок **7.** *разг.* раство́р, рассо́л, сы́воротка; *сабын суы* мы́льный раство́р; *селте суы* щелочно́й раство́р; *эремчек суы* твороо́жная сы́воротка; *кәбестә суы* капу́стный рассо́л; *тозлаган кыяр суы* огуре́чный рассо́л □ **су агызгыч** *гидротех.* **1.** водосли́в **2.** водосли́вный; *су агызгыч җайланма* водосли́вное устро́йство **3.** водосто́к; **су агымы** *гидротех.* водото́к; **су алгыч 1.** *гидротех.* водоприёмный; *су алгыч корылма* водоприёмное сооруже́ние **2.** *диал.* мо́стик (*на берегу водоёма*); **су алмашы** *биол.* водообме́н; **су алу** *гидротех.* водозабо́р; **су алу җайланмасы** *гидротех.* водозабо́р; **су анасы** *миф.* водяна́я; **су асты дөньясы** подво́дный мир; **су аткыч** *тех.* **1.** водомёт **2.** водомётный; **су атчыгы** *зоол.* водоме́рка (*насекомое*); **су әйләнеше** водооборо́т; **су балтырганы** *бот.* ядови́тый; **су баркылдагы** *зоол. см.* **су чыпчыгы**; **су басу 1.** затопля́ть/затопи́ть *что* **2.** наводне́ние, затопле́ние; пото́п; **су башнясы** водонапо́рная ба́шня; **су башы** исто́к (*реки*); **су белән җылыту** водяно́е отопле́ние; **су белән суыту** водяно́е охлажде́ние; **су билгеләре** *спец.* водяны́е зна́ки (*на бумаге, на деньгах*); **су бите** *диал.* бе́рег (*реки, озера*); **су борчасы** *зоол.* да́фния; **су борычы** *бот.* водяно́й пе́рец; **су бөтнеге** *диал.* мя́та водяна́я; **су бүлгеч 1.** водоотво́д **2.** водоотво́дный; *су бүлгеч канал* водоотво́дный кана́л; **су гөле** *диал.* бальзами́н; **су еланы** *зоол.* водяна́я змея́; **су җәелү** разли́в; **су җибәргеч** водоспу́ск; **су җыйгыч** *гидротех.* **1.** водосбо́р **2.** водосбо́рный **3.** водоприёмник; **су җылыткыч 1.** водонагрева́тель; водогре́йка **2.** водонагрева́тельный; **су җылыту** водогре́йный; *су җылыту казаны* водогре́йный котёл; **су кисе** *миф.* водяно́й; **су йөрү каналлары** *бот.* водоно́сные сосу́ды; **су кайту** *мор.* отли́в; **су каналы** водокана́л; **су кандаласы** *зоол.* жук-водоме́р, водоме́рка (*насекомое*); **су колонкасы** водоразбо́рная коло́нка; **су комае** *бот.* ма́нник водяно́й; **су коңгызы** *зоол.* верете́ница, вертля́чка (*жук*); **су кошы** водопла́вающая пти́ца; **су көпшәле** водотру́бный; *су көпшәле казан* водотру́бный котёл; **су куу** кача́ть во́ду (*насосом, по трубам*); **су кынасы** *бот.* око́пник лека́рственный; **су кычытканы** *бот.* роголи́стник; **су кыягы** *диал.* осо́ка; **су күзе** промо́ина, полынья́; **су күләме** *гидр.* во́дность; **су күрәне** *бот.* осо́ка во́дная; **су күсесе** ондатра; **су күтәрелү, су күтәрелеше** прили́в; **су күтәрткеч 1.** водоподъёмник **2.** водоподъёмный; **су күтәртү** водоподъёмный; **су лаләсе** *бот.* ли́лия водяна́я; **су өләшкеч 1.** водораздато́чник **2.** водораздато́чный; **су пәрие** *миф.* водяно́й; **су по́лосы** *спорт.* во́дное по́ло; **су салмалы** водоналивно́й; **су сыеры** бегемо́т; **су сыерчыгы** *см.* **су чыпчыгы**; **су сыешлык** водоёмкость; **су тавыгы** *зоол.* лысу́ха; **су талпаны** *зоол.* клещ водяно́й (*насекомое*); **су ташлагыч** *гидротех.* **1.** водосбро́с **2.** водосбро́сный; **су ташучы** водово́з; водоно́с; **су ташуы** разли́в, па́водок; **су торбасы** водосто́чная труба́; **су төшергеч** *гидротех.* **1.** водосли́в **2.** водосли́вный **3.** водопу́ск; **су төшү** *вет.* опо́й; **су тычканы** *зоол.* водяна́я полёвка; **су упкыны** водяна́я я́ма; **су үгезе** *зоол.* жерля́нка; **су үрмәкүче** *зоол.* водяно́й пау́к; **су үткәргеч 1.** водово́д **2.** водопрово́д; **су үткәрмәүчән** водонепроница́емый, непромока́емый; **су үткәрмәүчәнлек** водонепроница́емость; **су үткәрү** промока́ть/промо́кнуть; **су үткәрүчән** водопроница́емый; *су үткәрүчән катлау* водопроница́емый слой; **су үткәрүчәнлек** водопроница́емость; **су үтү** протека́ть/проте́чь, промока́ть/промо́кнуть; **су чаңгысы** *спорт.* во́дные лы́жи || воднолы́жный; *су чаңгысы спорты* воднолы́жный спорт; **су чаңгычысы** *спорт.* воднолы́жник; **су чаяны** *зоол.* водяно́й скорпио́н (*насекомое семейства водяных жуков*); **су чәчәге** *мед.* ветряна́я о́спа; **су чигеше** *мор.* отли́в; **су чистарткыч** *тех.* **1.** водоочисти́тель **2.** водоочисти́тельный; **су чистарткыч корылмалар** водоочистны́е сооруже́ния; **су чистарту** *тех.* **1.** водоочи́стка **2.** водоочи́стный, водоочистно́й; **су чыпчыгы** *зоол.* оля́пка; **су шөпшәсе** *зоол.* гла́дыш; **су эте** *уст.* тюле́нь; **су юлы 1.** во́дный путь **2.** ру́сло **3.** *диал.* фу́ги (*на краях крыши для стока воды*); **су юлын күрсәтү** показа́ть доро́гу за водо́й (*ритуал первого дня пребывания невесты в доме жениха*); **су юнәлткеч колаша** *спец.* разжело́бки; **су язы** ра́нняя весна́; **суга алып бару** води́ть/вести́ на водопо́й; **суга баткан кеше** уто́пленник; **суга бату** тону́ть, утону́ть; **суга төшү 1.** упа́сть в во́ду **2.** приводни́ться (*о самолёте*); **суга чыдам(лы)** водосто́йкий; водоупо́рный; **суга чыдамлылык** водосто́йкость; **суда эрүчән** водораствори́мый; **суда эрүчәнлек** водораствори́мость; **судан файдалану** водопо́льзование; **судан файдаланучы** водопо́льзователь ◊ **су баштан болгана** (*погов.*) ры́ба гние́т с головы́; **су белән дә аера алмассың** водо́й не разольёшь; не разле́й вода́; **су белән юып алгандай булды** ≈ как ве́тром сду́ло; как бу́дто коро́ва языко́м слизну́ла; **су болгату** мути́ть во́ду; **су кебек ага** течёт, что вода́ (*о больших расходах*); **су**

кебек агылу течь рекóй; течь широ́ким пото́ком; **су кебек (урынына) эчү** знать назубо́к; отвеча́ть без запи́нок; **су кушу** прибавля́ть/приба́вить от себя́; залива́ть; **су сибеп үстергәндәй** как грибы́ по́сле дождя́; **су төбенә китү** идти́ ко дну; утону́ть; **су төбенә җибәрү** пусти́ть (отпра́вить) на дно; утопи́ть; **су язып, май төшмәс** (*погов.*) во́ду толо́чь —ма́сла не бу́дет (вода́ и бу́дет); **суга батканда саламга ябышу** хвата́ться за соло́минку; **суга салу** 1. пуска́ть/пусти́ть на ве́тер 2. обрека́ть/обре́чь на страда́ния; **суга сәнәк белән язган (язылган)** на воде́ ви́лами напи́сано; **суга төшеп югалган кебек** как в во́ду ка́нул; **суга төшкән тавык кебек** как мо́края ку́рица; как в во́ду опу́щенный; (ходи́ть) мо́крой ку́рицей; **суга төшкәндәй булды** как в во́ду ка́нул; **суга төшсә, судан да коры чыга торган** из воды́ сухи́м вы́лезет; **судагы балык кебек** как ры́ба в воде́; **судан коры чыгу** вы́йти сухи́м из воды́; **сусыз юа, җилсез киптерә** языко́м сте́лет; язы́к хорошо́ подве́шен

су II *сущ.* су (*французская мелкая монета*)

суалма *сущ. диал.* заливно́й луг

суалчан *сущ.* 1. червь, черня́к || червяко́вый; черня́чный; *яңгыр ~ы* дождево́й червь; *~ боргалана* черня́к извива́ется; *~ йомыркалары* червяко́вые я́йчки 2. глист || гли́стный □ *~ куа* **торган** глистого́нный; *~* **личинкалары (нөреләре)** *зоол.* червели́нки

субай *сущ.* сва́я; *күпер ~лары* сва́и моста́; *тимербетон ~лар* железобето́нные сва́и || *в знач. прил.* сва́йный; *~ нигез* сва́йный фунда́мент □ *~ суру* заби́ть сва́ю; *~* **сугучы** *тех.* копёрщик; *~* **суккыч** *тех.* копёр

субайлы *прил.* сва́йный; *~ күпер* сва́йный мост; *~ буа* сва́йная плоти́на

субайлык *прил.* предназна́ченный на сва́и; *~ бүрәнәләр* брёвна, предназна́ченные на сва́и

субайчы *сущ. см.* **субай сугучы**

субасар *прил.* заливно́й, по́йменный; *~ болыннар* по́йменные луга́

субси́дия *сущ. книжн.* субси́дия; *см. тж.* **нәфәка** I; *дәүләт ~се* госуда́рственная субси́дия □ *~* **бирү** дава́ть/дать субси́дию, субсиди́ровать *что*

субси́дияләнү *страд. от* **субсидияләү**; субсиди́роваться

субси́дияләү *перех.* субсиди́ровать; *төзелешне ~* субсиди́ровать строи́тельство

субстантив *прил. грам.* субстантиви́рованный; *см.* **исемләшкән**

субстрат *сущ.* субстра́т; пита́тельная среда́ || *прил. лингв.* субстра́тный; *телдәге ~ күренешләр* субстра́тные явле́ния в языке́

субтро́пик *прил.* субтропи́ческий; *~ илләр* субтропи́ческие стра́ны; *~ үсемлек* субтропи́ческое расте́ние; *~ климат* субтропи́ческий кли́мат

субуяр *сущ. бот.* водокра́с (*растение*)

субүләр *сущ.* водорazде́л; *см. тж.* **сиңгәр** || *прил.* водоразде́льный; *~ калкулыклар* водоразде́льные возвы́шенности

субъект *сущ.* 1. *филос., лог., юр.* субъе́кт, индиви́д, лицо́; *танып белүнең ~ы һәм объекты* субъе́кт и объе́кт познания; *хөкемнең ~ы һәм предикаты* субъе́кт и преди́кат суждения; *хокук ~ы* субъе́кт пра́ва 2. *грам.* субъе́кт, подлежа́щее; *җөмләнең ~ы* субъе́кт предложе́ния 3. *перен. разг.* субъе́кт, ли́чность; *шикле ~лар* подозри́тельные субъе́кты

субъектив *прил. в разн. знач.* субъекти́вный; *~ сәбәпләр* субъекти́вные причи́ны; *минем ~ фикер* моё субъекти́вное мне́ние; *~ бәя* субъекти́вная оце́нка; *~ идеализм* субъекти́вный идеали́зм; *~ сиземләү* субъекти́вное восприя́тие

субъективлы|к *сущ.* субъекти́вность, субъективи́зм; *хөкемнең ~гы* субъекти́вность сужде́ния; *~ктан арыну* освобожда́ться от субъекти́вности (субъективи́зма)

суверен *прил.* сувере́нный; самостоя́тельный; *~ дәүләтләр* сувере́нные госуда́рства; *~ республика* сувере́нная респу́блика; *~ хокуклар* сувере́нные права́

суверенитет *сущ.* суверените́т; *илнең ~ы* суверените́т страны́

суверенлык *сущ.* 1. сувере́нность; *милләтләрнең ~гы* сувере́нность на́ций; *дәүләтнең ~гы* сувере́нность госуда́рства 2. *см.* **суверенитет**

сувó́ровчы *сущ.* сувó́ровец (*воспитанник суворовского училища*)

суган *сущ.* лук || лу́ковый; *яшел ~* зелёный лук; *башлы ~* ре́пчатый лук; *кыр ~ы* ди́кий лук; *татлы ~* сла́дкий лук; *~ кыягы* стре́лка лу́ка; *~ утырту* посади́ть лук; *~ әрчү* чи́стить лук; *~ исе* лу́ковый за́пах; *~ басуы* лу́ковое по́ле; *бер баш ~* лу́ковица; голо́вка лу́ка ◊ *~* **сату** болта́ть (моло́ть) чепуху́; *~* **суы суыру** класть зу́бы на по́лку; жить впро́голодь

суганбаш *сущ.* лу́ковица; голо́вка лу́ка

суганлану *неперех.* превраща́ться/преврати́ться в лу́ковицу

суганлап *нареч.* с лу́ком; *бәрәңгене ~ кыздыру* жа́рить карто́шку с лу́ком

суганлап-борычлап *нареч.* 1. с лу́ком и пе́рцем; *см. тж.* **тозлап-борычлап**; *суганлап-борычлап әзерләнгән* пригото́влен с лу́ком и пе́рцем 2. *перен.* кре́пко, зло, с пе́рцем; *суганлап-борычлап сүгү* кре́пко отруга́ть ◊ **суганлап-борычлап кыздыру** зада́ть пе́рцу; пробра́ть с пе́рцем

суганлы *прил.* 1. с лу́ком; *~ капчык* мешо́к с лу́ком 2. бога́тый, урожа́йный на лук; *~ ел* год бога́тый (*урожайный*) на лук

суганлы-борычлы *прил.* кре́пкий, злой; *суганлы-борычлы сүзләр* кре́пкие (*злые*) слова́; *суганлы-борычлы хат* зло́е (*колючее*) письмо́

суганлык *сущ.* лу́ковое по́ле; лу́ковая гря́дка, поса́дки лу́ка

суганча *сущ. бот.* лу́ковица; *лалә ~сы* лу́ковица тюльпа́на; *чәчәкне ~дан үстерү* выра́щивать цвето́к из лу́ковицы

суганчалы 1. *прил. бот.* лу́ковичный; *~ үсемлекләр* лу́ковичные расте́ния 2. *в знач. сущ. мн.* **суганчалылар** лу́ковичные (*название группы растений*) □ *~* **арпа** *бот.* ячме́нь лу́ковичный; *~* **йонча** *бот.* лу́ковичный мя́тлик

сугаргыч *сущ. с.-х.* пои́льный аппара́т

сугарту *понуд. от* **сугару**

сугар|у *перех.* 1. ороша́ть/ороси́ть *что* || 1) оро́шение, иррига́ция 2) оросительный, ирригацио́нный; *басуларны ~у* ороси́ть поля́ 2. полива́ть/поли́ть *что* || 1) поли́в 2) поливно́й; *чәчүлекне ~у* полива́ть посе́вы 3. пои́ть, напои́ть *кого-что* || пое́ние; *атларны ~у* напои́ть коне́й; *көтү ~у* пои́ть ста́до 4. *перен.* насыща́ть/насы́тить, наполня́ть/напо́лнить *чем*; *әсәрне кешелеклелек рухы белән ~у* напо́лнить произведе́ние ду́хом гуманизма 5. *спец.* закаля́ть/закали́ть *что*; *корычны ~у* закаля́ть сталь □ *~а тору* 1. ороша́ть 2. полива́ть; *~ып алу* напои́ть; *~ып чыгу* 1. ороси́ть 2. поли́ть (*полностью*)

сугарулы *прил.* 1. ороша́емый; *~ җирләр* ороша́емые зе́мли 2. поливно́й; *~ культуралар* поливны́е культу́ры;

~ *игенчелек* поливно́е земледе́лие; ~ *көтүлек* поливно́е па́стбище

сугаручы *сущ. с.-х.* оросйтель, иррига́тор

сугарылу *страд. от* **сугару**; *халык каны белән* ~ поливáться наро́дной кро́вью; *аңа карата җылы хисләр белән* ~ наполня́ться тёплыми чу́вствами к нему́; *күз яше белән* ~ орошáться слеза́ми

сугарышу *взаимно-совм. от* **сугару**

су|гу *перех.* 1. ударя́ть/уда́рить, стуча́ть, сту́кать/сту́кнуть, бить *кого-что во что, по чему* || уда́р; *аркага сугу* сту́кнуть (уда́рить) по спине́; *кадакка сугу* уда́рить по гвоздю́; *таяк белән сугу* уда́рить па́лкой; *йодрык белән өстәлгә сугу* сту́кнуть (бить) кулако́м по столу́; *чигәсенә сугу* уда́рить в висо́к 2. си́льно стуча́ть, си́льно бить; *йөрәк суга* се́рдце си́льно стучи́т 3. *прям., перен.* ударя́ть/уда́рить, бить *во что, по кому-чему; чаң сугу* уда́рить (бить) в ко́локол; *камчы белән сугу* бить (уда́рить) нага́йкой; *кесәгә сугу* бить по карма́ну; *сыйфатка сугу* бить по ка́честву; *көтелмәгән яктан китереп сугу* уда́рить с неожи́данной стороны́ 4. *в знач. нареч.* **сугып**; уда́ром 5. *перен.* уда́рить, внеза́пно порази́ть, хвати́ть (уда́р) || уда́р; *аны эссе суккан* его́ хвати́л тепло́вой уда́р; *паралич сукты* уда́рил (хвати́л) паралич; *бу йортны яшен суккан* в э́тот дом уда́рила мо́лния; э́тот дом порази́ла мо́лния 6. бить, поби́ть *что чем*; *игеннәрне боз сукты* хлеба́ поби́ло гра́дом; *салкын сугу* поби́ло моро́зом 7. бить, проби́ть, отбива́ть (отби́ть) уда́р || бой; *сәгать төнге унике суга* часы́ бьют по́лночь; *курантлар суга* бьют кура́нты; *сәгать алтыны сукты* проби́ло шесть часо́в 8. *разг.* отбива́ть/отби́ть *что*; *телеграмма сугу* отби́ть телегра́мму 9. набива́ть/наби́ть *что на что*; *кисмәккә коршау сугу* наби́ть о́бручи на ка́дку 10. подбива́ть/подби́ть; уве́чить; ушиби́ть; *ат муенын камыт сугу* подби́ть ше́ю коня́ хомуто́м; *ыңгырчак сугу* подбива́ть седёлкой 11. молоти́ть, намолоти́ть *что* || молотьба́; *игенне комбайн белән сугу* намолоти́ть хлеб на комба́йне; *борчак сугу* молоти́ть горо́х; *чәчүлек орлык сугу* намолоти́ть семенно́е зерно́ 12. *разг.* ста́вить, поста́вить *что*; *пичәт сугу* поста́вить печа́ть; *келәймә сугу* поста́вить клеймо́; *тамга сугу* поста́вить ме́тку 13. чека́нить, отчека́нить *что* || чека́нка; *акча сугу* чека́нить моне́ты 14. изгота́вливать/изгото́вить (*керамические изделия*); *кирпеч сугу* изгота́вливать кирпи́ч; *чирәп сугу* изгота́вливать черепи́цу 15. ткать *что* || тканьё; *киндер сугу* ткать полотно́; *чыпта сугу* ткать рого́жу; *сөлге сугу* ткать полоте́нце 16. *перен. прост.* зашиба́ть/зашиби́ть *что*; *акчаны күп сугу* зашиби́ть больши́е де́ньги 17. *перен. разг.* игра́ть, сыгра́ть (*в игры, сопровождаемые ударами*); *домино сугу* игра́ть в домино́; *шар сугу* игра́ть в гольф; *кузна сугу* игра́ть в ба́бки 18. *перен. прост.* руба́ть, уплета́ть, ло́пать *что*; *бер үзенә бер ипине сугу* сло́пать одну́ (це́лую) буха́нку хле́ба 19. *перен. прост.* осуши́ть, опорожни́ть, раздави́ть (*бутылочку*); *бер ярты́ны сугу* раздави́ть поллитро́вку 20. *перен. прост.* таска́ть, тащи́ть, стащи́ть, тяну́ть, стяну́ть, утяну́ть, пере́ть, спере́ть, сти́брить *что*; *аның акчасын сукканнар* у него́ спёрли де́ньги 21. *уст.* надева́ть на коло́дку и т. п.; *йөгән сугу* взнузда́ть □ **суга бару** 1. ударя́ть (*по ходу*) 2. ста́вить (*по ходу, по мере...*); **суга тору** 1. ударя́ть, бить (*пока*) 2. молоти́ть (*пока*); **сугып алу** 1. *однокр.* уда́рить, сту́кнуть 2. намолоти́ть (*быстро*) 3. поста́вить (*быстро, печать*) 4. *перен.* ца́пать/сцапнуть (*вещь на базаре*); **сугып бетерү** намолоти́ть (*полностью*); **сугып егу** свали́ть; **сугып җибәрү** *однокр.* уда́рить, нанести́ уда́р, влепи́ть, шара́хнуть; **сугып торып җибәрү** тра́хнуть, шара́хнуть, влепи́ть; **суктым-ектым** вот, тра́хну, вот гро́хну (*при угрозе*) ◊ **сукса тимер өзәрлек (өзәрдәй)** дю́жий мо́лодец; кровь с молоко́м; здоро́в как бык

сугыл|у *страд.* 1. *страд. от* **сугу**(*в знач.* 7—8, 11—15) 2. *возвр.* ударя́ться/уда́риться, би́ться; *ярга ~у* би́ться о бе́рег 3. подава́ться/пода́ться, броса́ться/бро́ситься, шара́хаться/шара́хнуться; *атлар бер читкә ~ды* ко́ни подали́сь в сто́рону; *бер яктан икенче якка ~у* шара́хаться из стороны́ в сто́рону 4. заходи́ть/зайти́, заезжа́ть/зае́хать (*по пути*), загля́дывать/загляну́ть, наве́дываться/наве́даться *к кому-чему*; *кайтышлый сезгә ~дым* по пути́ загляну́л к вам; *Мәскәүгә ~у* зае́хать в Москву́ 5. *перен.* доходи́ть/дойти́ *до кого-чего*; *бу хәбәр аның колагына ~ды* э́та весть дошла́ до его́ ушей

сугым *сущ.* 1. убо́й || убо́йный; *~га калдыру* оста́вить на убо́й; *~га ашату* корми́ть на убо́й; ~ *үлчәме* убо́йный вес; ~ *малы* убо́йный скот 2. скот, предназна́ченный (*откормленный*) на убо́й (*забой*); ~ *сую* забо́й скота́ □ ~ **ае** *ист.* дека́брь ◊ **~га симертү** корми́ть на убо́й

сугымлык *сущ.* скот, отко́рмленный для убо́я (*для забоя*); ~ *сатып алу* купи́ть скот на убо́й || *прил.* убо́йный; ~ *терлек* убо́йный скот

сугымчы *сущ.* скотоббец; ре́зчик скота́

сугыш *сущ.* 1. война́ || вое́нный, вои́нственный; *икенче бөтендөнья ~ы* втора́я мирова́я война́; *гражданнар ~ы* граждáнская война́; *Бөек Ватан ~ы* Вели́кая Оте́чественная война́; ~ *хәле* вое́нное положе́ние; ~ *техникасы* вое́нная те́хника; ~ *вакыты* вое́нное вре́мя 1) начина́ть/нача́ть войну́, развя́зывать/развяза́ть войну́ 2) зате́ять войну́; ~ *планнары* пла́ны войны́, вои́нственные пла́ны 2. сраже́ние, би́тва, бой; *штык ~ы* штыково́й бой; ~ *кыры* по́ле би́твы; *~лар бара* иду́т бои́; *~та җиңеп чыгу* вы́играть сраже́ние; *разведка ~ы* разве́дка бо́ем; *этәч ~ы* петуши́ный бой 3. дра́ка, схва́тка; ~ *чыктысы* завяза́лась дра́ка □ ~ **аты** боево́й конь; ~ **башлаучы** 1. поджига́тель войны́ 2. забия́ка; ~ **кирәк-яраклары** *воен.* боеприпа́сы *мн.*; **~ка сәләтле** боеспосо́бный; **~ка сәләтлелек** боеспосо́бность; ~ **чукмары** 1. кисте́нь, булава́ 2. *перен.* забия́ка, драчу́н, зади́ра 3. *перен.* воя́ка 4. *перен.* поджига́тель войны́ ◊ ~ **алласы** бог войны́; артилле́рия; ~ **төтене иснәү** понюхать по́роху; ~ **уты кабызучы** поджига́тель войны́; ~ **чукмарлары** *собир.* вое́нщина

сугыштыру *понуд. от* **сугышу**

сугыш|у 1. воева́ть, сража́ться, би́ться || сраже́ние, би́тва, бой; *фронтларда ~ып йөрү* воева́ть на фронта́х; *бәйсезлек өчен ~у* сража́ться за незави́симость 2. дра́ться, подра́ться || дра́ка; *күрше малайлары белән ~у* дра́ка с сосе́дскими мальчи́шками □ **~ып алу** 1. завоёвывать/завоева́ть, отвоёвывать/отвоева́ть *что* 2. повоева́ть 3. подра́ться; **~ып китү** (*неожиданно*) подра́ться

сугышучан *прил.* 1. драчли́вый, зади́ристый; *бик ~ малай* драчли́вый, зади́ристый ма́льчик 2. вои́нственный; ~ *кыяфәт* вои́нственный вид

сугышучы *прил.* 1. воюющий; ~ *яклар* воюющие сто́роны 2. деру́щийся

сугышчан *прил.* 1. боево́й; ~ *хәзерлек* боева́я гото́вность; ~ *бурыч* боева́я зада́ча; ~ *приказ* боево́й прика́з; ~ *тәртип* боево́й поря́док 2. вои́нственный, вои́нствующий; ~ *кабиләләр* вои́нственные племена́; ~ *кыяфәт* вои́нственный вид; ~ *алласызлар* вои́нствующие атеи́сты || *сущ.* боец, драчу́н

сугышчанлы|к *сущ.* **1.** боеви́тость; *газетаның ~гы* боеви́тость газе́ты **2.** вои́нственность; *кыяфәтнең ~гы* вои́нственность о́блика

сугышчы *сущ.* **1.** во́ин, бое́ц; *тәҗрибәле ~* о́пытный бое́ц **2.** *воен. (рядовой)* бое́ц, солда́т; *взвода биш ~ калды* во взво́де оста́лось пя́теро бойцо́в || *прил.* драчли́вый, зано́зистый, зади́ристый; *~ халык* зади́ристый наро́д

суд *сущ.* **1.** *в разн. знач.* суд || суде́бный; *халык суды* наро́дный суд; *интәшләр суды* това́рищеский суд; *намус суды* суд че́сти; *район суды* райо́нный суд; *суд карары* приго́вор суда́; *суд җаваплыгына тарту* привле́чь к суде́бной отве́тственности; *суд утырышы* суде́бное заседа́ние **2.** суд, суде́бное разбира́тельство; *ачык суд* откры́тый суд, откры́тое суде́бное разбира́тельство; *ябык суд* закры́тый суд; *суд чыгымнары* суде́бные изде́ржки; *суд медицинасы* суде́бная медици́на **3.** суди́лище *неодобр.* ◻ **суд төзелеше** судоустро́йство; **суд хөкеме** приго́вор суда́; **суд эшләрен башкару (йөртү)** судопроизво́дство; **судка бирү** подава́ть/пода́ть в суд; отдава́ть/отда́ть под суд ◊ **суд алдына (каршысына) басу, суд эскәмиясенә утыру** привлека́ться к суде́бной отве́тственности

судан: судан үләне *бот.* суда́нка, суда́нская трава́

судланлы *сущ.* жи́тель Суда́на

судлаш|у *неперех. разг.* суди́ться *с кем*; *колхоз белән ~у* суди́ться с колхо́зом ◻ **~ып йөрү 1.** суття́жничать **2.** суття́жничество; **~ып йөрүче** суття́жник

су́дно *сущ.* су́дно || судово́й; *хәрби ~* вое́нное су́дно; *транспорт ~лары* тра́нспортные суда́; *~ журналы* судово́й журна́л; *~ механигы* судово́й меха́ник; *~лар йөртү* води́ть суда́, судовожде́ние; *~лар йөртүче* води́тель судо́в, судоводи́тель; *~лар төзүче* строи́тель судо́в, судострои́тель ◻ **~ күтәргеч** судоподъёмный; **~ күтәргеч механизм 1.** судоподъёмный механи́зм **2.** судоподъёмник; **~лар йөреше** судохо́дство; **~лар йөрешле** судохо́дный

су́дночы *сущ. спец.* судострои́тель; *Чистай ~лары* чистопо́льские судострои́тели

су́дночылы|к *сущ.* судохо́дство; *диңгез ~гы* морско́е судохо́дство

судсыз-нисез *нареч.* без суда́ и сле́дствия; *судсыз-нисез сөргенгә җибәрү* сосла́ть без суда́ и сле́дствия; *судсыз-нисез төрмәдә черетү* сгнои́ть в тюрьме́ без суда́ и сле́дствия

судья *сущ.* **1.** *юр.* судья́ || суде́йский; *халык ~сы* наро́дный судья́; *~ булмәсе* суде́йская ко́мната **2.** *спорт.* судья́ || суде́йский; *беренче категорияле ~* судья́ пе́рвой катего́рии; *халыкара категорияле ~* судья́ междунаро́дной катего́рии; *~лар коллегиясе* суде́йская колле́гия

судьялык *сущ.* **1.** суде́йство **2.** до́лжность судьи́; *~ка уку* учи́ться на судью́ ◻ **~ итү** суди́ть

суел|у *возвр.-страд. от* **сую 1.** заре́заться, быть заре́занным; *берни эшләп булмый, хет ~* ничего́ нельзя́ сде́лать, хоть заре́жься **2.** сдира́ться/содра́ться; *бәрелеп тез ~у* от уда́ра содрала́сь ко́жа на коле́нках ◻ **~ып бетү** содра́ться совсе́м; **~ып үлү** *см.* **суелу** 1

суенты *сущ.* я́зва; *ашказаны ~сы* я́зва желу́дка

суер *сущ. зоол.* глуха́рь || глухари́ный; *см. тж.* **урман тавыгы**

суеру *перех. диал.* сдира́ть/содра́ть (*кору с дерева*); *см.* **сыдыру**; *юкә ~* сдира́ть ли́пу

суеш *сущ.* резня́; бо́йня; *канлы ~* крова́вая резня́ (бо́йня); *~ оештыручылар* организа́торы резни́

суеш-кырылыш *сущ. собир.* резня́

суешу *взаимно-совм. от* **сую**; ре́заться || резня́; *канлы ~лар* крова́вая резня́

суҗыяр *сущ. бот.* водосбо́р, аквиле́гия (*травянистое растение*)

сузан *прил.* **1.** долговя́зый || ды́лда; дли́нный; *~ егет* долговя́зый па́рень; *~ дөяләр* долговя́зые верблю́ды **2.** дли́нный, удлинённый; *~ муен* дли́нная ше́я; *~ бармаклар* дли́нные па́льцы **3.** дли́нный, продолгова́тый; *~ бина* продолгова́тое зда́ние **4.** дли́нный, длинноство́льный; *~ агач* длинноство́льное де́рево ◻ **~ буйлы** долговя́зый, дли́нный

сузанлан|у *неперех.* станови́ться/стать дли́нным; долговя́зым; расти́ в длину́; *ул ~ган* он стал долговя́зым

суза|ю *перех. диал.* **1.** *см.* **сузанлану 2.** удлиня́ться/удлини́ться; *аның йөзе ~йган* лицо́ её удлини́лось ◻ **~еп китү** удлини́ться; **~я бару** (*постепенно*) удлиня́ться ◊ **~еп тору** вы́тянуться; стоя́ть как столб

сузгалау *многокр. от* **сузу**

суздыру *понуд. от* **сузу**; *сузне озакка ~* дать затяну́ть разгово́р

сузма *сущ. диал.* доро́жка; подсти́лка из во́йлока

суз|у *перех.* **1.** *прям., перен.* тяну́ть, расти́гивать/растяну́ть *что к чему* || расти́гивание, растяже́ние; *чыбык ~у* тяну́ть про́вод; *резина ~у* тяну́ть резину; *җыр ~у* тяну́ть пе́сню; *докладны ~у* растяну́ть докла́д **2.** выти́гивать/вы́тянуть *что*; *муен ~ып* вы́тянув ше́ю; *аякларын ~у* вы́тянуть но́ги **3.** 1) *прям., перен.* проти́гивать/протяну́ть *кому что* || проти́гивание; *төргәкне энисенә ~у* протяну́ть свёрток ма́тери; *кул ~у* протяну́ть ру́ку; *озакка ~мас* до́лго не проти́нет 2) простира́ть/простере́ть *что* || простира́ние; *кулларны алга таба ~у* простере́ть ру́ки вперёд **4.** 1) *перен.* зати́гивать/затяну́ть *что с чем* || зати́гивание, зати́жка; *чәчүне ~у* зати́гивать с се́вом; *эшне озакка ~у* затяну́ть рабо́ту надо́лго 2) отти́гивать/оттяну́ть *что* || отти́гивание; *вакытны ~у* оттяну́ть вре́мя; *карар чыгаруны ~у* отти́гивать вынесе́ние реше́ния ◻ **~а бару 1.** тяну́ть, расти́гивать **2.** оти́гивать; **~а бирү 1.** тяну́ть, расти́гивать, выти́гивать (*несмотря ни на что*) **2.** *перен.* зати́гивать (*несмотря ни на что*); **~а тору 1.** тяну́ть, расти́гивать (*по ходу действия*) **2.** *перен.* зати́гивать, отти́гивать (*несмотря ни на что*); **~а төшү 1.** чуть вы́тянуть **2.** *перен.* чуть оттяну́ть (*во времени*); **~ып алу** вы́тянуть, протяну́ть (*на время, быстро*); **~ып эйтү** расти́гивать/растяну́ть; *авазларны сузып эйтү* растяну́ть зву́ки; **~ып бетерү** растяну́ть (*до конца*); **~ып җибәрү** вы́тянуть; **~ып йөрү (килү)** (всё) зати́гивать, отти́гивать; **~ып кую** (*быстро*) растяну́ть; **~ып салу (ташлау)** растяну́ть (*во всю длину*); **~ып чыгу** растяну́ть (*по всей поверхности*)

сузык *прил. лингв.* гла́сный || гла́сный звук; *~ аваз* гла́сный звук; *ирен ~лары* огу́бленные гла́сные; *басымсыз ~лар* безуда́рные гла́сные

сузылгалау *многокр. от* **сузылу**

сузылдыру *понуд. от* **сузылу**

сузылма *прил.* эласти́чный, тягу́чий; *~ әйберләр* эласти́чные ве́щи

сузылмалану *неперех.* станови́ться/стать тягу́чим, эласти́чным

сузылмалы *прил. см.* **сузылма**

сузыл|у *страд.-возвр. от* **сузу 1.** *прям., перен.* тяну́ться, расти́гиваться/растяну́ться || расти́гивание; *резинка ~ды* рези́нка растяну́лась; *чылбыр булып ~у* растяну́ться цепо́чкой; *обозлар ~а тәнутся* обо́зы; *эш озакка ~ды* де́ло затяну́лось надо́лго **2.** выти́гиваться/вы́тянуться || выти́гивание; *озын (саф) булып ~у* вы́тянуться дли́н-

ной шере́нгой **3.** простира́ться/простере́ться; *еракларга ~у* простира́ться далеко́ **4.** *прям., перен.* протя́гиваться/протяну́ться || протя́гивание; *тәрәзәдән кул ~ды* в окно́ протяну́лась рука́; *юл йөзләрчә километрга ~ган* доро́га протяну́лась на со́тни киломе́тров **5.** тяну́ться, потяну́ться *за кем-чем, к кому-чему*; *китапка ~у* потяну́ться за кни́гой; *койма аркылы ~у* тяну́ться че́рез забо́р □ **~а бару** растя́гиваться, вытя́гиваться; **~а бирү** растя́гиваться, вытя́гиваться (*несмотря ни на что*); **~а төшү** (*несколько*) растяну́ться, вы́тянуться; **~ып алу (кую)** вы́тянуться (*на время, быстро*); **~ып китү 1.** растяну́ться, вы́тянуться **2.** потяну́ться, простере́ться; **~ып яту** растяну́ться, вы́тянуться

сузылучан *прил.* растяжи́мый, эласти́чный, упру́гий

сузылучанлык *сущ.* растяжи́мость, эласти́чность, упру́гость

сузылыш|у *совм. от* **сузылу** (*о многих*) □ **~ып яту** лежа́ть вы́тянувшись (*о многих*)

сузым *сущ. диал.* протяже́ние

сузынкы *прил.* протя́жный; *~ тавыш* протя́жный звук; *~ көй* протя́жный моти́в

сузынкылы|к *сущ.* протя́жность; *җыр тавышының ~гы* протя́жность пе́ния

сузып-сузып *нареч.* протя́жно, нараспе́в; *сузып-сузып сөйләү* говори́ть нараспе́в

сузышу *совм. от* **сузу** (*о многих*); *кулны кулга ~* протя́гивать друг дру́гу ру́ки

суйдыру 1. *понуд. от* **сую 2.** *перех.* сдира́ть/содра́ть || сдира́ние; *тезне ~* содра́ть коле́но

суйкак *прил.* поло́гий, отло́гий; *~ яр* поло́гий бе́рег

суйлак *прил. диал.* лежебо́ка, лю́бящий не́житься в посте́ли

суйлаклан|у *неперех. диал.* **1.** лени́ться встава́ть **2.** облени́ться

суйлаклап: суйлаклап яту лежа́ть (*по утрам*) не встава́я с посте́ли

сука *сущ. с.-х.* **1.** соха́; *агач ~* деревя́нная соха́ **2.** вспа́шка, па́хота || па́хотный; *~га чыгу* вы́йти на вспа́шку; *язгы ~* весе́нняя вспа́шка (па́хота); *каты ~* пар, парова́я па́хота; *~да йөрү* ходи́ть на вспа́шку; *сабан ~сы* весе́нняя па́хота □ **~ баш** *сущ. с.-х.* сошни́к; *см.* **сука тимере**; **~ башы** *с.-х.* рукоя́тка сохи́; **~ боты** *диал. см.* **сука башы**; **~ калагы** *с.-х.* **1.** отва́л (*у сохи*) **2.** лопа́тка для очище́ния ле́меха от приста́вшей земли́; **~ кысасы** гря́диль; **~ пычагы** *диал. см.* **сука тимере**; **~ сукалау** паха́ть зе́млю; **~ тимере** *с.-х.* сошни́к; **~ тоткасы** *с.-х.* обжа́, о́бжа; **~ тоту** занима́ться хлебопа́шеством; **~ уклавы** валёк; **~ чәчәге** *диал.* василёк посевно́й; **~га төшү** приступа́ть/приступи́ть к па́хоте

сука|й *сущ.* **1.** специа́льно сде́ланный спуск к реке́ (*к броду, причалу и т. п.*); *~й казу* проры́ть спуск к реке́ **2.** мель, тра́верс по дну реки́, зали́ва и т. п. (*по которому переходят вброд*); *~ен белмичә суга кермә (посл.)* не зна́я бро́ду, не су́йся в во́ду

сукайлау *неперех.* **1.** спуска́ться/спусти́ться по накло́нной (*по косогору*) **2.** переходи́ть/перейти́ вброд по накло́нной пове́рхности к бе́регу (*т. е. не по кратчайшему пути*)

сукайлы *прил.* **1.** с поло́гим (*удобным*) спу́ском к воде́ **2.** с косы́м, накло́нным бро́дом; *~ елга* река́ с накло́нным бро́дом

сукалан|у *страд. от* **сукалау**; *җир яхшы ~ган* земля́ хорошо́ вспа́хана

сукалату *понуд. от* **сукалау**

сукал|ау *перех.* **1.** паха́ть, вспа́хивать/вспаха́ть *что чем* || па́хота, вспа́шка; *бакча ~ау* вспаха́ть огоро́д, вспа́шка огоро́да; *җир ~ау* паха́ть зе́млю; *тирән ~ау* глубоко́ паха́ть **2.** *перен. разг.* говори́ть, разгова́ривать; *русча яхшы ~ау* прили́чно говори́ть по-ру́сски; *дөрес ~ыйсың* пра́вильно говори́шь **3.** *перен. разг.* уме́ть чита́ть; *газетаны иркен ~ый* чита́ет газе́ту свобо́дно □ **~ап алу (кую)** вспаха́ть (*быстро*); **~ап бетерү** (*полностью*) вспаха́ть; **~ап бирү** вспаха́ть *кому*; **~ап чыгу 1.** вспаха́ть *что* **2.** *перен. разг.* проштуди́ровать

сукалаштыру *многокр. от* **сукалау** 1

сукалашу *взаимно-совм. от* **сукалау** 1

сукачы *сущ.* **1.** па́харь; *~лар ялга туктадылар* па́хари останови́лись на о́тдых **2.** землепа́шец, земледе́лец; крестья́нин; *ул ~ малае* он сын землепа́шца

сукачылык *сущ.* землепа́шество

сукбай *сущ.* броде́га, бося́к || броде́жий, бося́цкий; *билгесез ~* неизве́стный броде́га; *ике ~* два босяка́; *~ тормышы* бося́цкая жизнь; *~ кыяфәте* бося́цкий вид || *прил.* броде́жий, броде́чий; *~ эт* броде́чая соба́ка ◊ **~лар командасы** золота́я ро́та

сукбайлану *неперех.* броде́жничать, боса́чествовать

сукбайлык *сущ.* броде́жничество, боса́чество || броде́жнический, бося́цкий □ **~та йөрү** броде́жничать, броде́жить

суккалану *возвр. от* **суккалау** *диал.* **1.** *см.* **бәргәләнү 2.** *см.* **каккалану**

суккалау *многокр. от* **сугу 1.** постёгивать (*время от времени*); *чыбык белән ~* постёгивать лозо́й **2.** поколо́чивать (*время от времени*); *аркасына ~* поколо́чивать его́ по спине́

суккалаштыру *многокр. см.* **суккалау**

суккыч *сущ. с.-х.* **1.** би́ло **2.** молоти́лка; *атлы ~* ко́нная молоти́лка; *комбайн ~ы* молоти́лка от комба́йна **3.** *второй компонент сложных слов:* **ашлык суккыч** молоти́лка □ **~ асты** *с.-х.* подби́чник

суклыгу *неперех. диал. см.* **сугылу** 4

сукма *сущ. диал.* шёлковая ле́нта с позуме́нтом

сукма|к *сущ.* тропа́, тропи́нка; *урман ~гы* лесна́я тропи́нка; *тау ~гы* го́рная тропи́нка; *~к буйлап* по тропи́нке; *җәяүлеләр ~гы* пешехо́дная тропа́ □ **~к салу** проложи́ть тропи́нку ◊ **~к суынып тормас** не зарастёт тропа́

сукно *сущ. прил. см.* **постау** ◊ **~ астына салу (кую)** положи́ть под сукно́

суконгыз *сущ. зоол.* водожу́к

сукрандыру *понуд. от* **сукрану**

сукран|у ворча́ть, се́товать, брюзжа́ть, канюч́ить || ворча́ние, брюзжа́ние; ро́пот; *~ырга ярату* люби́ть ворча́ть (брюзжа́ть); *тормыштан ~у* се́товать на жизнь; *үз алдына ~у* ворча́ть про себя́; *~уыңны күй* оста́вь своё ворча́ние; переста́нь ворча́ть □ **~ып алу (кую)** поворча́ть, побрюзжа́ть; **~ып йөрү** ворча́ть, брюзжа́ть

сукранучан *прил.* ворчли́вый, брюзгли́вый; *~ карчык* ворчли́вая стару́ха; *~ кеше* ворчу́н, брюзга́

сукранучанлык *сущ.* ворчли́вость, брюзгли́вость

сукранышу *совм. от* **сукрану** (*о многих*)

сукта *сущ. диал.* **1.** дома́шняя ли́верная колбаса́ **2.** вид ко́нской копчёной колбасы́

суктырту 1. *понуд. от* **суктыру 2.** ударя́ть/уда́рить *по чему-л.*; *машинаны яны белән ~* уда́рить маши́ну бо́ком

суктыр|у 1. *понуд. от* **сугу 2.** сечь, вы́сечь, поро́ть, вы́пороть || по́рка; *чыбык белән ~у* сечь лозо́й; *камчы*

белән ~у поро́ть плетьми́ **3.** щёлкать/щёлкнуть, бить; *борынына ~у* щёлкать (бить) по но́су **4.** молоти́ть; *борчак ~у* молоти́ть горо́х; *комбайнда ~у* молоти́ть на комба́йне **5.** *перен. разг.* говори́ть/сказа́ть (*обинякáми, издалека*); *читлəтеп ~у* говори́ть обиняка́ми; *~ып сөйлəү* расска́зывать обиняка́ми; *ерактан ~у* говори́ть издалека́ **6.** *перен. прост.* руба́ть, тре́скать, упи́сывать, умина́ть *что*; *бер бөтен ипине ~у* умя́ть це́лый карава́й хле́ба **7.** изготовля́ть/изгото́вить *что*; *кирпеч ~у* изготовля́ть кирпичи́; *камыт ~у* изгото́вить хому́т **8.** валя́ть; *киез итек ~у* валя́ть ва́ленки **9.** *диал.* сепари́ровать; *сөт ~у* сепари́ровать молоко́

суктырылу *страд. от* **суктыру**

сукуыш *сущ.* водоизмеще́ние; *танкерның ~ы* водоизмеще́ние та́нкера

сукуышлы *прил.* водоизмеще́нием; *йөз мең тонна ~ корабль* кора́бль водоизмеще́нием в сто ты́сяч тонн

сукыр *прил.* **1.** *прям., перен.* слепо́й || слепе́ц, слепо́й; *~ карт* слепо́й стари́к; *тумыштан ~* слепо́й от рожде́ния; *~лар əлифбасы* а́збука для слепы́х; *~ мəхəббəт* слепа́я любо́вь; *~ ышану* слепа́я ве́ра; *~ ачу* слепа́я я́рость; *~ күп күрер, аксак күп йөрер (погов.)* слепо́й мно́го ви́дит, хромо́й мно́го хо́дит **2.** *перен.* слепо́й, неве́жественный, тёмный; *~ көчлəр* слепы́е (*невежественные, тёмные*) си́лы **3.** *перен.* дыря́вый, испо́рченный; *~ чикləвек* гнило́й оре́х ; *~ акча* дыря́вая моне́та □ **~ инə** иго́лка без у́шка; **~ кигəвен** сле́пень; **~ кычыткан 1.** *бот.* ясно́тка, глуха́я крапи́ва **2.** *диал.* пусты́рник пятило́пастный; **~ лампа** копти́лка, ла́мпа-мига́лка; **~ тап** *анат.* слепо́е пятно́ (*на глазу*); **~ тары** *диал.* ежо́вник, кури́ное про́со; **~ тəкə** жму́рки (*детская игра*); *~ тəкə(ле) уйнау* игра́ть в жму́рки; **~ тəрəзə** глухо́е окно́; **~ тычкан** *зоол.* крот, землеро́йка; **~ ут** *см.* **сукыр лампа**; **~ чебен (черки)** мо́шка, мошкара́; **~ чəчəк** *бот.* смолёвка бе́лая, смолёвка обыкнове́нная; хлопу́шка; **~ эчəк** *анат.* слепа́я кишка́, аппе́ндикс ◊ **~ бəхет** слепо́й слу́чай; **~ бер тиенгə (тиен дə) тормый** грош а́ ме́дного (ло́маного) не сто́ит; вы́еденного яйца́ не сто́ит; **~ бер тиенем дə юк** нет ни гроша́ за душо́й; **~ бер тиенгə куймый** ни в грош не ста́вит; **~ да күрерлек** и слепо́му ви́дно; **~ көе** *см.* **сукырларча**; **~ тавыгы да юк** ни гроша́ за душо́й; **~ тавык** *уничиж.* **1.** слепа́я ку́рица, слепе́ц **2.** неве́жда; **~ чебен урынына** как мошкара́; **~ ышану** слепа́я ве́ра; **~ ябалак** *см.* **сукыр тавык 1**; **~га суд юк** дурако́ву зако́н не пи́сан

сукырайттыру *понуд. от* **сукырайту**

сукырайту *перех. прям., перен.* ослепля́ть/ослепи́ть, лиша́ть/лиши́ть зре́ния || ослепле́ние, лише́ние зре́ния; *күзларне ~* ослепля́ть глаза́

сукырайтылу *страд. от* **сукырайту**; ослепля́ться, быть ослеплённым

сукыра|ю *неперех. прям., перен.* сле́пнуть, осле́пнуть || ослепле́ние, лише́ние зре́ния; *аның күзləре ~йган* он осле́п; *~ерга мөмкин* мо́жно осле́пнуть; *сəяси яктан ~ю* полити́ческая слепота́; полити́ческое ослепле́ние □ **~еп бару (килү)** постепе́нно сле́пнуть; **~еп бетү (калу)** осле́пнуть

сукырлану *неперех. см.* **сукыраю**

сукырларча *нареч.* сле́по; *~ ышанырга* сле́по ве́рить || *прил.* слепо́й; *~ яру* слепо́й подража́тель; *~ ышаныч* слепа́я ве́ра

сукырлы|к *сущ. прям., перен.* слепота́; *ике күзнең дə ~гы* слепота́ на о́ба гла́за; *дəм ~к* по́лная слепота́; *сəяси ~к* полити́ческая слепота́

сукыр-чукрак: сукыр-чукрак туган *прил.* слепоглухорождённый; *сукыр-чукрак туган бала* слепоглухорождённый ребёнок

сул *прил.* **1.** ле́вый; *сул кулы белəн* ле́вой руко́й; *сул ягына əйлəнеп яту* повернýться на ле́вый бок; *елганың сул кушылдыгы* ле́вый прито́к реки́; *сул яктан* с ле́вой стороны́, сле́ва; *бүлмəнең сул почмагы* ле́вый у́гол ко́мнаты **2.** ле́вый, нелицево́й, изна́ночный; *тукыманың сул ягы* изна́ночная сторона́ тка́ни **3.** *перен.* 1) ле́вый, радика́льный; *сул партиялəр* ле́вые па́ртии; *сул карашлы кеше* челове́к с ле́выми взгля́дами; *сул көчлəр* ле́вые си́лы; *сул тайпылыш* ле́вый укло́н; *сул эсерлар* ле́вые эсе́ры; *сул фразалар артына яшеренеп* скрыва́ясь за ле́выми фра́зами 2) *в знач. сущ.* **суллар** ле́вые, радика́лы; левак и́ **4.** *первый компонент составных прилагательных, соответствующий по значению* лево-; *сул экстремистик төркемнəр* левоэкстреми́стские группиро́вки; *сул флангтагы* левофланго́вый **5.** *перен. разг.* ле́вый, побо́чный; незако́нный; *сул рейс* ле́вый рейс □ **сул белəн** нале́во (*команда*); **сул кулда** в ле́вую сто́рону, по ле́вую сто́рону; вле́во, нале́во; **сул күз кабагы тарту** *этногр. (по суеверным приметам)* быть беде́; **сул як 1.** ле́вая сторона́ **2.** изна́нка; **сул якка** в ле́вую сто́рону; по ле́вую сто́рону; вле́во, нале́во; *сул якка бару* поверну́ть нале́во; **сул якта** по ле́вую сто́рону; сле́ва ◊ **сул аягы белəн торган** встал с ле́вой (не с той) ноги́; **сул аягы нəрсə (ни) тели** чего́ ле́вая нога́ захо́чет (*о капризном, сумасбродном человеке*)

сула I *сущ. зоол.* берш (*рыба семейства окуневых*)

сула II: **сула кату** *диал.* **1.** запо́р (*задержка стула*) **2.** задыха́ться/задохну́ться

сулагай *прил.* **1.** 1) ле́вый || левша́; *~ кул белəн язу* писа́ть ле́вой руко́й 2) *перен. ирон. см.* **сул 5**; *~ эш* ле́вая рабо́та **2.** *в знач. нареч. см.* **сулагайлап**; *~ уру* жать ле́вой руко́й

сулагайлану станови́ться/стать левшо́й

сулагайлап *нареч.* ле́вой руко́й; *~ сугу* бить ле́вой руко́й; *~ рəсем ясау* рисова́ть ле́вой руко́й

сулагайлык *сущ.* владе́ние ле́вой руко́й

сулама *сущ.* водосто́чный жёлоб

суламык *прил.* си́льно увлажнённый; *~ урын* си́льно увлажнённое ме́сто (*в поле*) || *сущ.* **1.** си́льно увлажнённая земля́; *~та үскəн камышлар* камыши́, расту́щие на увлажнённом ме́сте **2.** ме́сто, где из земли́ сочи́тся вода́

суламыклану *неперех.* станови́ться/стать си́льно увлажнённым (*о земле*)

суландыру *перех.* обводня́ть/обводни́ть *что*; *даланы ~* обводни́ть степь || *сущ.* обводне́ние || обводни́тельный; *~ эшлəре* обводни́тельные рабо́ты; *~ каналы* обводни́тельный кана́л

суландырыл|у *страд. от* **суландыру**; обводня́ться, быть обводнённым; *меңнəрчə гектар көтулекләр ~ачак* бу́дут обводнены́ ты́сячи гекта́ров па́стбищ

сулан|у I *возвр. от* **сулау** I **1.** станови́ться/стать вла́жным; *һава үз алдына ~ып бара* во́здух стано́вится всё влажне́е **2.** покрыва́ться/покры́ться волдыря́ми; наполня́ться/напо́лниться водяни́стой жи́дкостью; *тəндəге кабырчыклар ~а башлады* те́ло на́чало покрыва́ться волдыря́ми **3.** увлажня́ться/увлажни́ться; *җир ~ган* земля́ увлажни́лась **4.** мо́кнуть, намока́ть/намо́кнуть, промока́ть/промо́кнуть; *см.* **чылану 5.** сыре́ть, отсыре́ть; *өй стеналары ~ган* сте́ны до́ма отсыре́ли **6.** *страд. от* **сулау** I □ **~а бару 1.** станови́ться всё бо́лее вла́жным **2.** всё бо́лее намока́ть (сыре́ть); **~ып бетү 1.** намо́кнуть,

промóкнуть 2. отсырéть; **~ып китү (калу)** 1. намóкнуть 2. отсырéть

сулану II *страд. от* **сулау** II

суланыш *сущ. см.* **сулыш**

сулату *понуд. от* **сулау** I

сула|у I *перех.* 1. увлажня́ть/увлажни́ть *что чем* || увлажне́ние; *см.* **дымландыру**; *чалбарын ~п үтүклəү* утю́жить брю́ки, увлажня́я водо́й 2. сма́чивать/смочи́ть *что чем* || сма́чивание; *сохариларны ~у* смочи́ть сухари́; *чүпрəкне ~у* сма́чивать тря́пку 3. обводня́ть/обводни́ть *что* □ **~п алу (кую)** увлажни́ть, смочи́ть

сула|у II *неперех.* 1. дыша́ть || дыха́ние; *тигез ~у* дыша́ть ро́вно; *тирəн ~у* дыша́ть глубоко́; *борын аша ~у* дыша́ть че́рез нос; *саф һава ~у* дыша́ть све́жим во́здухом; *тире аша ~у* дыша́ть че́рез ко́жный покро́в 2. вдыха́ть/вдохну́ть *что*; *һава ~у* вдыха́ть во́здух 3. вздыха́ть/вздохну́ть || вздох; *авыр ~у* тяжело́ вздохну́ть; *иркен ~п* легко́ вздохну́в □ **~п алу (кую)** 1. вдохну́ть 2. вздохну́ть

сулга *нареч.* 1. вле́во; нале́во; *~ борылу* свернýть вле́во; *уңнан ~* спра́ва нале́во 2. ле́во; *сулгарак тот* держи́ ле́вее ◊ **~ эшлəү** 1. ле́вая рабóта, ле́вый за́работок 2. рабóтать нале́во

сулган *прил.* увя́дший, завя́дший, блёклый, поблёкший; ча́хлый; *~ гөл* увя́дший цветóк; *~ үсемлек* ча́хлое расте́ние; *~ йөз* поблёкшее (*увядшее*) лицó

сулганлык *сущ.* ча́хлость

сулда *нареч.* нале́во, вле́во; сле́ва; *~ урман* нале́во лес; *ишектəн ~* сле́ва от две́ри; *~рак тора* стои́т чуть левée

сулдан *нареч.* сле́ва; с ле́вой стороны́; *җил ~ исə* ве́тер ду́ет сле́ва; *~ уза* прохóдит сле́ва

сулдыру *понуд. от* **сулу**

сулкылдату *понуд. от* **сулкылдау**; *йөрəкне ~* заста́вить се́рдце су́дорожно би́ться

сулкылда|у *неперех.* 1. всхли́пывать, су́дорожно вздыха́ть || всхли́пывание; *~удан иңбашлары селкенə* трясýтся плéчи от всхли́пывания 2. сверли́ть, свербéть; *теш ~п сызлый* зуб сверби́т от бóли 3. трепыха́ться; су́дорожно, конвульси́вно би́ться; *йөрəк ~вы* су́дорожное биéние сéрдца □ **~п елау** всхли́пывать || всхли́пывание; **~п кую (җибəрү)** 1. всхли́пнуть 2. встрепенýться

сулкыту *перех. см.* **сулкылдату**; *йөрəкне ~* заста́вить сéрдце су́дорожно би́ться

суллану *неперех. см.* **суллашу**

суллап *нареч.* 1. сле́ва; *уңлап, ~* спра́ва и сле́ва 2. *редко* ле́вой руко́й; *~ эшлəү* рабóтать ле́вой руко́й

суллашу *неперех.* леве́ть, полеве́ть; *сəяси яктан ~* полеве́ть в полити́ческом отношéнии

суллык *сущ.* 1. левизна́; *~ авыруы* болéзнь левизны́ 2. лева́чество || лева́цкий; *сəяси ~* полити́ческое лева́чество; *~ кыланышлары* лева́цкие вы́ходки

сулмас *прил. прям., перен.* неувяда́емый; *~ гөл* неувяда́емый цветóк; *~ яшьлек* неувяда́емая мóлодость

сулпа|ю *неперех.* тера́ть, потеря́ть фóрму, утра́чивать/утра́тить фóрму; *чар ~йды* точи́ло потеря́ло свою́ (*округлую*) фóрму

сулпык *сущ. диал.* вещь, потеря́вшая былу́ю фóрму

сул|у I *неперех.* 1. вя́нуть, завя́нуть, ча́хнуть, зача́хнуть, увяда́ть/увя́нуть (*о растительности*) || увяда́ние; *чəчəклəр ~ды* цветы́ увя́ли; *корылыктан ~у* увя́нуть (зача́хнуть) от за́сухи 2. *прям., перен.* увяда́ть/увя́нуть, ча́хнуть, зача́хнуть || увяда́ние (*о человеке*); *аның чибəрлеге ~ган* красотá её увя́ла; *төрмəдə ~у* зача́хнуть в тюрьмé 3. *перен.* блёкнуть, поблёкнуть (*о лице*); *аның йөзе ~ган* лицó её поблёкло; *кайгыдан ~у* поблёкнуть от гóря □ **~а бару** увяда́ть, вя́нуть; **~а төшү** чуть (*несколько*) завя́нуть, поблёкнуть; **~ып бетү** завя́нуть, зача́хнуть; увя́нуть; **~ып калу** увя́нуть, зача́хнуть; **~ып китү (төшү)** *прям., перен.* 1. поблёкнуть 2. увя́нуть, зача́хнуть

сулу II *сущ. разг.* 1. дыха́ние; *см.* **сулыш**; *~ы авырайды* дыха́ние его́ затрудни́лось 2. издыха́ние; *актык (соңгы) ~ларына кадəр* до после́днего своего́ издыха́ния □ **~ алу** 1. дыша́ть || дыха́ние; *авыр ~ алып* тяжело́ дыша́ 2. *перен.* передохну́ть, перевести́ дух 3. переды́шка; *бераз ~ алгач* по́сле небольшо́й переды́шки 4. вздыха́ть/вздохну́ть; *иркен ~ алып* легко́ вздохну́в; **~ кабу** задыха́ться/задохну́ться; **~ каплану** *диал. см.* **сулу кабу**; **~ кысыла** спира́ет дыха́ние; **~ тараю** спира́ть/спере́ть, затрудня́ть/затрудни́ть дыха́ние; **~(~га) тыгылу** задыха́ться/задохну́ться ◊ **~ алмыйча** не переводя́ дыха́ния (*слушать*)

сулчылык *сущ.* лева́чество || лева́цкий; *~ агымы* лева́цкое тече́ние

сулы *прил.* 1. напóлненный водóй; с водóй; *~ чилəк* ведрó с водóй; *~ чокыр я́ма,* напóлненная водóй 2. вла́жный, мóкрый; пропи́танный водóй; *~ чүпрəк белəн* вла́жной тря́пкой; *~ җир* вла́жная земля́; *~ урыннар* мóкрые местá 3. *хим.* вóдный; *~ кушылмалар* вóдные соедине́ния 4. *см.* **сусыл** 5. водонóсный; *~ горизонт* водонóсный горизóнт; *~ катлау* водонóсный слой 6. *вторая часть составных слов соотв. русскому* -водный; *тирəн ~* глубоковóдный; *сай ~* мелковóдный; *күп ~* многовóдный □ **~ чəчəк** *бот.* бéлая смолéвка

сулы|гу I *неперех.* худéть, похудéть, осýнуться; увяда́ть/увя́нуть; *йөзе ~ккан* лицó её осýнулось □ **~га бару** всё бóлее худéть, вя́нуть (*о человеке*); **~га төшү** нéсколько похудéть; **~гып калу** совсéм осýнуться

сулыг|у II *неперех. диал. см.* **сулкылдау** □ **~ып елау** всхли́пывать || всхли́пывание

сулык *сущ.* 1. водоём; *ясалма ~* иску́сственный водоём; *табигый ~лар* есте́ственные водоёмы 2. *диал.* водостóк (*на крыше дома*)

сулык-сулык *нареч.* су́дорожно; *сулык-сулык елау* су́дорожно всхли́пывать; *бит сулык-сулык яна* лицó гори́т так, что чу́вствуется ка́ждое биéние пу́льса □ **сулык-сулык итү (килү)** конвульси́вно би́ться, пульси́ровать

сулыландыру *перех.* обводня́ть/обводни́ть || обводне́ние; *далаларны ~* обводне́ние степи́

сулыландырыш *сущ.* обводнённость

сулылык *сущ.* 1. водяни́стость 2. вла́жность

сулыш *сущ.* 1. *прям., перен.* дыха́ние || дыха́тельный; *аның ~ы тигез* дыха́ние его́ ро́вное; *~ органнары* о́рганы дыха́ния; *җылы ~ын тою* почу́вствовать её тёплое дыха́ние; *ясалма ~ алдыру* де́лать иску́сственное дыха́ние; *яз ~ы* дыха́ние весны́; *икенче ~* второ́е дыха́ние; *актык ~ына кадəр* до после́днего дыха́ния (вздóха); *~ юллары* дыха́тельные пути́ 2. выдыха́емый (и́ли вдыха́емый) вóздух; *~ белəн керү* пони́кнуть вме́сте с вдыха́емым вóздухом 3. *перен. разг.* миг; *шул ~та* ук в тóт же миг; *бер ~та* в оди́н миг □ **~ алу** 1. *прям., перен.* дыша́ть, подыша́ть 2. вдыха́ть/вдохну́ть 3. переводи́ть/перевести́ дыха́ние 4. *перен.* передохну́ть; **~ бетү** *см.* **сулыш кабу**; **~ җиңелəю** *см.* **сулыш иркенəю**; **~ иркенəю (киңəю)** *прям., перен.* легко́ дыша́ться; **~ кабу** задыха́ться/задохну́ться; **~ көпшəсе** *анат.* ды́хальце; **~ кысылу** 1. оды́шка 2. задыха́ться/задохну́ться; **~ тараю** тяжело́ дыша́ть, задыха́ться; **~ чыгару** 1. выдыха́ть/вы́дохнуть 2. вы́дох; **~ны буу** спере́ть (*затруднить*)

дыха́ние ◊ ~ **алмыйча (алмастан)** затаи́в дыха́ние; *~ алмыйча тыңлау* слу́шать, затаи́в дыха́ние; ~ **киселү (өзелү)** испусти́ть дух; ~ **өрү** вдохну́ть жизнь; **~ны кысып** затаи́в дыха́ние

сулышлык *сущ. анат* ды́хальце; *см. тж.* **сулыш көпшәсе**

сульфат *сущ. хим.* сульфа́т || сульфа́тный; *аммоний ~ы* сульфа́т аммо́ния; *кальций ~ы* сульфа́т ка́льция; *~ кислотасы* сульфа́тная кислота́

сульфатлы *прил.* сульфа́тный; *~ туфрак* сульфа́тная по́чва; *~ сабын* сульфа́тное мы́ло

сульфит *сущ. хим.* сульфи́т || сульфи́тный; *натрий ~ы* сульфи́т на́трия; *~ кислотасы* сульфи́тная кислота́

сульфитлашу *сущ. хим.* сульфита́ция

сум *сущ.* рубль; *бер сум* оди́н рубль; *меңнәрчә сум* ты́сячи рубле́й || *прил. уст.* **1.** чи́стый, без при́меси; *сум тимер* чи́стое желе́зо **2.** состоя́щий из одно́й мя́коти, без косте́й и хрящей; *итнең сум җире* кусо́к мя́са из одно́й мя́коти **3.** *перен.* чи́стый, непоро́чный, безгре́шный; *см.* **саф**; *сум йөрәк* чи́стое се́рдце □ **сум ит** мя́коть, ссек

сума *сущ.* **1.** капита́л, состоя́ние; *зур ~* большо́е состоя́ние; *~ ясау* накопи́ть капита́л; *кулымда шактый ~* в мои́х рука́х значи́тельный капита́л; *төп ~* основно́й капита́л **2.** *разг.* сто́имость, цена́; *товарның ~сы* сто́имость това́ра; *~сы 1 сум* цена́ 1 рубль **3.** *разг.* су́мма; *табыш ~сы* су́мма при́были; *зур ~да заем бирү* предоста́вить заём на большу́ю су́мму □ **~сын чыгару 1.** покры́ть расхо́ды **2.** *перен.* перемыва́ть *кому-л.* ко́сточки

сумала *сущ.* **1.** смола́ || смоляно́й; смоли́стый; *нарат ~сы* сосно́вая смола́; *тау ~сы* го́рная смола́; *синтетик ~лар* синтети́ческие смо́лы; *кайнар ~* горя́чая смола́; *~ кайнату* кури́ть смолу́, смолокуре́ние; *~ кайнату заводы* смолого́нный заво́д; *~ эретү* топи́ть смолу́; *~ ябыштыру* прилепи́ть смолу́; *~ мичкәсе* смоляна́я бо́чка; *~ исе* смоли́стый за́пах **2.** *см.* **сагыз**; *~ исе белән аңкыган урманнар* леса́, па́хнущие смоло́й □ **~ кайнатучы** смолоку́р, смолого́н; *~* **сендерелгән** смолёный; *~* **сылау** смоли́ть, осмоли́ть, вы́смолить; **~га катыру** засмоли́ть ◊ *~* **сагыз** назо́йливая му́ха; **~га утыру** си́днем сиде́ть

сумаладай *нареч.* смоли́сто; *~ кара чәч* смоли́сто-чёрные во́лосы

сумалалану *возвр.-страд. от* **сумалалау**

сумалала́ү *перех.* смоли́ть, осма́ливать/осмоли́ть, засма́ливать/засмоли́ть, высма́ливать/вы́смолить *что чем* || 1) осмоле́ние, осмо́лка 2) смоли́льный; *арканны ~у* вы́смолить кана́т; *көймәне ~у* осмоли́ть ло́дку; *~у җайланмалары* смоли́льные приспособле́ния ◊ **~п алу, бетерү, кую, чыгу** вы́смолить

сумалалаучы *сущ.* смоли́льщик

сумалалы *прил.* **1.** смоли́стый; *~ такта* смоли́стая доска́ **2.** смолёный; осмолённый; *~ җеп* смолёная ни́тка; *~ сүс* осмолённая куде́ль

сумалалылык *сущ.* смоли́стость

сумалану наживáть/нажи́ть капита́л, состоя́ние

сумалы *прил.* **1.** с капита́лом; *зур ~* с больши́м капита́лом **2.** состоя́тельный; *~ кеше* состоя́тельный челове́к

сумасыз *прил.* несостоя́тельный; *~ сәүдәгәр* несостоя́тельный купе́ц

сумасызлану *разг.* станови́ться/стать несостоя́тельным; лиша́ться/лиши́ться капита́ла (состоя́ния)

сумка *сущ.* **1.** су́мка, су́мочка || су́мочный; *күн ~* ко́жаная су́мка; *кыр ~сы* полева́я су́мка; *хатын-кыз ~сы* же́нская су́мочка; *~ каешы* су́мочный реме́нь **2.** *зоол.* су́мка, по́лость; *көнгерә ~сы* су́мка кенгуру́ **3.** *анат.* су́мка; *йөрәк ~сы* околосерде́чная су́мка

сумкалы *прил.* **1.** име́ющий су́мку, с су́мкой **2.** *зоол.* 1) су́мчатый; *~ күсе* су́мчатая кры́са; *~ көнгерә* су́мчатый кенгуру́; *~ буре* су́мчатый волк; *~ аю зоол.* су́мчатый медве́дь, коа́ла 2) *в знач. сущ.* **сумкалылар** *мн.* су́мчатые

сумлап *нареч. в словосочетаниях с числ. колич.*; о́коло ... рубля́, о́коло ... рубле́й; *йөз ~ акчам калган* у меня́ оста́лось о́коло ста рубле́й

сумлык *прил.* рублёвый; на ... рубле́й; *бер ~ акча* рублёвая моне́та (ассигна́ция); рублёвка; *йөз ~ билет* сторублёвый биле́т; *мең ~ товар* това́р на ты́сячу рубле́й; *икә йөз ~ костюм* двухсотрублёвый костю́м

су́мма *сущ.* **1.** *мат.* су́мма; *икә сан ~сы* су́мма двух чи́сел; *күпбуыннар ~сы* су́мма многочле́нов **2.** су́мма (*количество денег*); *бик зур ~ җыйналды* набрала́сь о́чень больша́я (*изрядная*) су́мма; *чыгымнар ~сы* су́мма затра́т □ **~сын чыгару** выводи́ть (вы́вести) су́мму; сумми́ровать, суммирование

су́ммалануучан *прил. мат.* суммируемый; *~ функция* суммируемая фу́нкция

су́ммалауучы *прил. мат.* суммирующий; *~ машиналар* суммирующие маши́ны

суммар *прил. книжн.* суммарный; *~ куәт* суммарная мо́щность; *~ чыгым* суммарный расхо́д; *~ мәгълүмат* суммарные све́дения

сумса *сущ. кул.* сумса́ (*национальное мучное изделие*); пирожо́к || пирожко́вый; *ит ~сы* мясно́й пирожо́к; *кайнар ~* горя́чий пирожо́к; *~ камыры* пирожко́вое те́сто □ *~* **кибете (кафесы)** пирожко́вая

сумсалык *прил.* приго́дный (*подходящий*) для пирожка́, сумсы́; *~ ит* мя́со, приго́дное для пирожка́

сумсачы *сущ.* специали́ст по изготовле́нию сумсы́ (*пирожков*); продаве́ц пирожко́в

суна *сущ. зоол.* **1.** больша́я ди́кая у́тка **2.** гага́ра; *см. тж.* **сигезсуна**

сунар *сущ.* охо́та || охо́тничий; *см.* **ау**; *~га чыгу* выходи́ть на охо́ту; *~ эте* охо́тничья соба́ка

сунарчы *сущ.* охо́тник; *см.* **аучы**; *атаклы ~* знамени́тый охо́тник ◊ *~* **сунарчыны ерактан таный** рыба́к рыбака́ ви́дит издалека́

сунарчылык *сущ.* заня́тие охо́той; охо́та; *см.* **аучылык**; *~ка өйрәтү* учи́ть на охо́тника

супа *диал. сущ.* **1.** гли́няная печь (вы́ложен без примене́ния кирпича́) **2.** гли́няная фигу́ра, истука́н || *прил.* **1.** гли́няный, вы́лепленный из гли́ны (*о чём-л. таком, что обычно делается из других материалов*); *~ сәке* гли́няные на́ры **2.** аляпова́тый, невырази́тельный; мрачнова́тый

супаю *неперех. диал.* мрачне́ть, помрачне́ть; окамене́ть (*о лице*) □ **супаеп йөрү** ходи́ть с мра́чным ви́дом (мра́чно)

супергигант *сущ.* **1.** супергига́нт **2.** *в знач. прил.* супергига́нтский; *~ төзелеш* супергига́нтская стро́йка

суперкубок *сущ.* суперку́бок || суперку́бковый; *~ өчен көрәш* борьба́ за суперку́бок

супермен *сущ. ирон.* суперме́н, сверхчелове́к

суперта́нкер *сущ.* суперта́нкер (*танкер водоизмещением свыше ста тысяч тонн*)

супертышлык *сущ.* суперобло́жка || суперобло́жечный; *ялтыравык ~* блестя́щая суперобло́жка

суперфосфат *сущ. хим.* суперфосфа́т (*удобрение*) || суперфосфа́тный; *бөртекле (гранулаланган) ~* гранули́-

рованный суперфосфа́т; ~ *заводы* суперфосфа́тный завод; ~ *җитештерү* произво́дство суперфосфа́та, суперфосфа́тное произво́дство

суп-суык *прил. превосх. ст. от* **суык**; *суп-суык су* о́чень холо́дная (*студёная*) вода́; *суп-суык көн* о́чень холо́дный (*студёный*) день

сур *сущ. уст.* **1.** рог, труба́ **2.** рито́н □ **сур өрү** труби́ть в рог

сура *прил. диал.* **1.** шёлковый; ~ *күлмәк* шёлковая руба́шка **2.** ба́рхатный; ~ *күлмәк* ба́рхатное пла́тье

сура|ю *неперех. диал.* выта́гиваться/вы́тянуться; засты́ть вы́тянувшись ◊ **~еп тору (калу)** стоя́ть столбо́м; **~еп кату** столбене́ть, остолбене́ть

сурәт *сущ.* **1.** изображе́ние; рису́нок; портре́т; *кеше ~е* челове́ческое изображе́ние; изображе́ние челове́ка; *кыз ~е* портре́т де́вушки; *йолдыз ~е* изображе́ние звезды́ **2.** 1) вид; *күңелсез ~тә* в печа́льном ви́де; *төрле ~ләргә керү* принима́ть ра́зные ви́ды; *гаҗәпсенгән ~тә* с удивлённым ви́дом; *көлке ~тә* в смешно́м ви́де 2) о́браз; *аның ~ен күз алдына китерү* предста́вить его́ о́бразом; *реаль ~* реа́льный о́браз **3.** литерату́рный о́браз; *сәнгатьчә ~ләр* худо́жественные о́бразы; *традицион ~ләр* традицио́нные о́бразы; *җанлы ~ләр* живы́е о́бразы; *~ләргә бай* бога́т о́бразами; *шигъри ~* поэти́ческий о́браз **4.** *прост. груб.* образи́на; чу́чело огоро́дное; *кит моннан, ~ уйдың* от меня́, образи́на □ **~ төшерү** рисова́ть *кого-что*; **~ ясау 1.** рисова́ть *кого-что* **2.** *прям., перен.* изобража́ть/изобрази́ть *кого как*; **~кә төшерү** *разг.* снима́ть/снять, фотографи́ровать *кого-что*; **~кә төшү** *разг.* снима́ться/сня́ться, фотографи́роваться

сурәтләмә *сущ. уст.* о́браз; *кинаяле ~* иноскава́тельный о́браз

сурәтләндерелү *страд. от* **сурәтләндерү**

сурәтләндерү *перех. редко см.* **сурәтләү**; *берьяклы ~* односторо́ннее изображе́ние

сурәтләну *страд. от* **сурәтләү**

сурәтлә|ү *перех.* изобража́ть/изобрази́ть, рисова́ть *кого-что*; *диңгез күренешен ~ү* изобрази́ть карти́ну мо́ря; *эшчеләр тормышын ~ү* изобража́ть жизнь рабо́чих □ **~п алу** изобрази́ть, нарисова́ть (*за короткое время*); **~п бирү** изобрази́ть *кого-что*; **~п китү** начина́ть (нача́ть) изобража́ть; **~п ташлау** *разг. см.* **сурәтләп алу**

сурәтләү *сущ.* изображе́ние || изобрази́тельный; *тулы ~* по́лное изображе́ние; *оста ~* ма́стерское изображе́ние; *~ алымы* изобрази́тельный приём

сурәтле *прил. уст.* **1.** иллюстри́рованный; с карти́нками; *~ журнал* иллюстри́рованный журна́л; *~ китап* кни́га с карти́нками **2.** рису́нчатый **3.** кра́сочный; *~ стена* кра́сочная стена́

сурәттә *союз* е́сли, е́сли то́лько; в слу́чае; в слу́чае, е́сли; *көн аяз торган ~* е́сли то́лько день бу́дет пого́жим; *киткән ~ дә* и в слу́чае отъе́зда || *послелог (в словосочет. с нареч. знач.)* с ... ви́дом, каки́м о́бразом; *катгый ~* категори́чески, категори́чно; с категори́чным ви́дом; *тиешле ~* до́лжным о́бразом; *фаҗигале ~* траги́чески; траги́ческим о́бразом; *җитди ~* с серьёзным ви́дом; серьёзно

сурәтче *сущ. уст.* худо́жник, живопи́сец; *оста ~* иску́сный худо́жник

сурәтчелек *сущ.* **1.** заня́тие худо́жника **2.** жи́вопись

сургыч *сущ.* **1.** сургу́ч; *~ белән мөһерләү* запеча́тать сургучо́м **2.** *в знач. прил.* сургу́чный; *~ мөһер* сургу́чная печа́ть

сургычлану *страд. от* **сургычлау**

сургычлату *понуд. от* **сургычлау**

сургычла|у *неперех.* запеча́тывать/запеча́тать сургучо́м; *конвертны ~у* запеча́тать конве́рт сургучо́м □ **~п алу (кую, чыгу)** запеча́тать сургучо́м

сургычлы *прил.* **1.** запеча́танный сургу́чной печа́тью; с сургу́чной печа́тью; *~ пакет* паке́т с сургу́чной печа́тью **2.** сургу́чный; *~ мөһер* сургу́чная печа́ть

сү́ри|к *сущ.* сү́рик (кра́ска); *кургашын ~гы* свинцо́вый сү́рик || *прил.* сү́риковый

сурлы *прил. уст.* рога́тый; *см.* **мөгезле**; *~ терлек* рога́тый скот

суррогат *сущ. разг.* суррога́т, замени́тель; *кофе ~ы* суррога́т ко́фе; *ашамлык ~лары* пищевы́е суррога́ты || *прил.* суррога́тный; *~ азык* суррога́тная пи́ща; *~ май* суррога́тное ма́сло; *~ күн* суррога́тная ко́жа

сурыгу *неперех.* подсыха́ть/подсо́хнуть; *җир ~ккан* земля́ подсо́хла □ **~га бару** постепе́нно подсыха́ть; **~га төшү** чуть подсо́хнуть

сурыктыру *понуд. от* **сурыгу**

сусаганлык *сущ.* жа́жда; *~ тою* испыта́ть жа́жду; *канга ~* жа́жда кро́ви

сусак I *сущ. диал.* большо́й деревя́нный черпа́к; ведро́ с дли́нной ру́чкой (*для очистки колодца и т. п.*)

сусак II *сущ. бот.* суса́к, часту́ха; *зонтлы ~* зо́нтичный суса́к

су́саклагыч *сущ.* водохрани́лище; *Түбән Кама ~ы* Нижнека́мское водохрани́лище

сусакчалар *сущ. мн. бот.* часту́ховые

сусаль *прил.* суса́льный; *~ алтын* суса́льное зо́лото

сусан: сусан печән *бот.* овся́ница восто́чная; *см. тж.* **сүсән**

сусанкырау *неперех.* чу́вствовать, почу́вствовать жа́жду; хоте́ть, захоте́ть пить

сусар *сущ. зоол.* куни́ца || ку́ний; *~ мехы* ку́ний мех || *прил.* ку́ний; *~ яка* ку́ний воротни́к

сусат|у *неперех.* вызыва́ть/вы́звать жа́жду; *тозлы балык ~а* солёная ры́ба вызыва́ет жа́жду

суса|ю *неперех. прям., перен.* жа́ждать, испы́тывать/испыта́ть жа́жду; си́льно хоте́ть пить || жа́жда; *бик ~дым* о́чень хо́чется пить; *суга ~у* испы́тывать жа́жду; *дымга ~у* жа́ждать вла́ги; *мәхәббәткә ~у* жа́ждать любви́; *белемгә ~у* жа́жда зна́ний; *иркенкә ~у* жа́жда свобо́ды; *~уны басу* утоли́ть жа́жду □ **~п бетү** си́льно жа́ждать, испыта́ть си́льную жа́жду; **~п китү** жа́ждать (*на время*); **~п тору** жа́ждать (*какое-то время*)

сусаучы *прил.* жа́ждущий, томи́мый жа́ждой

сусән *сущ. бот.* метли́ца (*растение*)

сусөяр I *прил.* водолюби́вый; *~ үсемлек* водолюби́вое расте́ние

сусөяр II *сущ. зоол.* водолю́б, жук-водолю́б

сусыз *прил.* безво́дный, без воды́; *~ дала* безво́дная степь; *~ үзән* безво́дное ру́сло; *~ чиләк* ведро́ без воды́ ◊ **~ кашыктан ~ суырып йотарлык** пи́саная краса́вица; **~ мунчала белән арка ышку** корми́ть пусты́ми обеща́ниями; **~ самавыр шикелле кызу** кипяти́ться по́пусту; **~ юу; ~ юып, җилсез киптерү** льстить, уле́щивать, умасливать

сусызландыру *перех.* обезво́живать || обезво́живание

сусызлану *неперех.* обезво́живаться || обезво́живание; *организм ~* обезво́живание организма

сусызлык *сущ.* безво́дье; *~тан һәлак булу* поги́бнуть от безво́дья; *~тан интегү* страда́ть от безво́дья

сусыл *прил.* **1.** со́чный; *~ азыклар* со́чные корма́; *~ алма* со́чное я́блоко; *~ үлән* со́чная трава́; *~ иреннәр*

со́чные гу́бы **2.** водяни́стый; *~ бәрәңге* водяни́стая карто́шка; *~ күзәнәкләр* водяни́стые кле́тки

сусыллан|у *неперех.* станови́ться/стать со́чным, водяни́стым; *җиләк-җимеш ~ды* я́годы ста́ли со́чными

сусыллы|к *сущ.* со́чность; *силосның ~гы* со́чность си́лоса

сусылу *сущ. миф.* руса́лка

сусын I *сущ.* жа́жда; *~ ачылу* хоте́ть пить □ **~ басылу (кайту)** быть утолённым (*о жажде*); **~ кандыру** утоли́ть жа́жду, напи́ться; **~ны басу (кайтару)** утоли́ть жа́жду

сусын II *сущ. бот.* каса́тик, и́рис, са́бельник боло́тный (*растение*)

сут *сущ. прям., перен.* сок (*растительный*); *үлән суты* расти́тельный сок; *агачка сут төшү* появле́ние со́ка в дере́вьях; *яшәү суты* жи́зненный сок

суткак *прил. диал.* **1.** о́чень вла́жный **2.** боло́тистый; *~ урын* боло́тистая ме́стность **3.** вя́зкий; *~ пычрак* вя́зкая грязь || *сущ.* вя́зкая гли́на; *см. тж.* **сутлы** 1

сутлы *прил.* **1.** вя́зкий; *~ балчык* вя́зкая гли́на **2.** жи́рный, слегка́ вла́жный (*земля*); *~ җир* жи́рная (*слегка влажная*) земля́ **3.** со́чный; *үләннең ~ чагы* со́чный пери́од расте́ния; *~ үлән* со́чная трава́

сутлылык *сущ.* **1.** вя́зкость; *балчыкның ~гы* вя́зкость гли́ны **2.** со́чность; *үләннең ~гы* со́чность травы́

сутый *сущ. разг.* со́тка (*сотая часть гектара*); *егерме биш ~ җир* два́дцать пять со́ток земли́

сутыйлык *прил.* доста́точный на определённое коли́чество со́тых

сүүлчәгеч *сущ. тех.* водоме́р (*прибор для измерения расхода воды*) || водоме́рный; *~ рейка* водоме́рная ре́йка

сүүлчәр *сущ. зоол.* водоме́рка (*насекомое, живущее на воде*)

сүүсем *сущ.* во́доросль (*обычно мн.* во́доросли); *яшел ~нәр* зелёные во́доросли; *көрән ~нәр* бу́рые во́доросли; *~нәр белән туенучы* пита́ющийся во́дорослями

сүүткәргеч *сущ.* водопрово́д || водопрово́дный

суфи *прил. рел.* **1.** на́божный, благочести́вый; *~ кеше* на́божный челове́к; *~ карт* благочести́вый стари́к **2.** *в знач. нареч.* на́божно, благочести́во; *ул ~ гына йөри* он де́ржится благочести́во || *сущ.* **1.** 1) на́божный, благочести́вый челове́к, благочести́вец; *ишанның ~лары* благочести́вые помо́щники ишана́; *сукыр ~* слепо́й благочести́вец 2) су́фий; аске́т, ми́стик; *~лар партиясе* па́ртия ми́стиков; *~ шагыйрь* поэ́т-ми́стик **2.** *перен. разг.* ханжа́ □ **~ кысла** *зоол.* **1.** рак-богомо́л **2.** *перен. пренебр.* ханжа́; **~ чикерткә** *зоол.* богомо́л

суфилан|у *неперех.* **1.** представля́ться/предста́виться благочести́вым, на́божным; *~ып йөрү* представля́ться благочести́вым **2.** предава́ться/преда́ться аскети́зму, мистици́зму

суфила́рча *нареч.* по-суфи́стски; благочести́во; *башын ~ иеп* благочести́во опусти́в го́лову || *прил.* суфи́стский; *~ кыланыш* суфи́стские пова́дки

суфилы|к *сущ.* **1.** благочести́вость, на́божность || благочести́вый, на́божный; *~гын күрсәтү* показа́ть свою́ благочести́вость **2.** аскети́зм, мистици́зм || аскети́ческий, мисги́ческий; *~к әдәбияты* мисги́ческая литерату́ра; *шигърияттә ~к юнәлеше* мисги́ческое направле́ние в поэ́зии ◊ **~к сату** *ирон.* представля́ться/предста́виться на́божным, благочести́вым

суфичыл *прил.* аскети́ческий, мисги́ческий; *~ караш* мисги́ческий взгляд

суфичылык *сущ.* суфи́зм, аскети́зм, мистици́зм || суфи́стский, мисги́ческий; аскети́ческий; *~ идеологиясе* идеоло́гия суфи́зма; *~ны алга сөрү* пропаганди́ровать суфи́зм (аскети́зм, мистици́зм); *~ әдәбияты* мисги́ческая (суфи́стская) литерату́ра

суфле *сущ. кул.* суфле́

суфлёр *сущ. театр.* суфлёр || суфлёрский; *~ сүзләре* слова́ суфлёра; *~ будкасы* суфлёрская бу́дка

суфлёрлык *сущ.* суфлёрство □ **~ итү 1.** суфли́ровать **2.** *перен.* подска́зывать/подсказа́ть *кому что*

сүффикс *сущ. лингв.* су́ффикс; *сүз ясаучы ~лар* словообразу́ющие су́ффиксы; *алынма ~* заи́мствованный су́ффикс; *~ ярдәмендә сүз ясау* образова́ть сло́во при по́мощи су́ффикса □ **~лар ялгау (кушу)** суффикса́ция

сухта *сущ.* **1.** *ист.* бе́дный шаки́рд (*который живёт прислуживанием богатым шакирдам*); слуга́ из шаки́рдов **2.** *презр.* ни́щий, попроша́йка (*из духовенства*) **3.** *карт.* вале́т

сучы *сущ.* **1.** водово́з **2.** водоно́с

сүшка, сүшки *сущ. кул. разг.* су́шка (*мелкий крендель, мелкая баранка*)

суык *сущ.* **1.** 1) хо́лод, моро́з; стынь; *~лар килә* наступа́ют холода́; *~ка чыгару* вы́нести на моро́з; *кышкы ~та* в зи́мние холода́; в зи́мний моро́з; *утыз градус ~* три́дцать гра́дусов моро́за; *~тан калтырану* дрожа́ть от хо́лода; *~та тоту* держа́ть в хо́лоде (на моро́зе); *чатнама (каты) ~* жёсткий моро́з, сту́жа 2) холодо́к; *иртәнге ~* у́тренний холодо́к **2.** *мн.* холода́, моро́зы; *~лар башланды* наступи́ли холода́; *кышкы ~лар* зи́мние холода́; *декабрь ~лары* дека́брьские моро́зы || *прил.* **1.** моро́зный; холо́дный; *~ көн* холо́дный (моро́зный) день; *~ бүлмә* холо́дная ко́мната; *~ һава* моро́зный (холо́дный) во́здух; *~ җил* холо́дный ве́тер; *~ чәй* холо́дный чай; *~ су* холо́дная (студёная) вода́; *~ куллар* холо́дные ру́ки **2.** *перен.* прохла́дный; холо́дный; *~ мөгамәлә* прохла́дное отноше́ние **3.** *в знач. нареч.* 1) хо́лодно, моро́зно; *бүген бик ~* сего́дня о́чень хо́лодно (моро́зно) 2) *перен. разг.* хо́лодно; *ул ~ кына җавап бирә* он отвеча́ет дово́льно хо́лодно □ **~ алдыру** *см.* **суык тидерү; ~ алу** *см.* **суык тию; ~ бабай** *см.* **Кыш бабай;** *~ бабай, кил безгә* приходи́ к нам, Дед Моро́з; **~ канлы** *диал. см.* **салкын канлы; ~ канлылар** *см.* **салкын канлылар; ~ канлылык** *см.* **салкын канлылык; ~ сугы** *диал. см.* **суык тию; ~ тешләү** (чу́точку) схвати́ть моро́зом; **~ тидерү 1.** простужа́ться/простуди́ться, просты́ть (*по своей вине*) **2.** простужа́ть/простуди́ть *кого-что*; **~ тию** простужа́ться/простуди́ться; *~ тиюдән дәвалану* лечи́ться от просту́ды; **~ тиючән** просту́дливый; **~ чир** *диал. см.* **бизгәк; ~ка бирешмәүчән** холодосто́йкий; **~ка бирешмәүчәнлек** холодосто́йкость; **~ка чыдамлы** морозосто́йкий; морозоусто́йчивый; *см. тж.* **кышлыклы;** *~ка чыдамлы алмагач* морозосто́йкая я́блоня; **~ка чыдамлылык** морозосто́йкость, морозоусто́йчивость ◊ **~ абзый** моро́з-ба́тюшка; **~ аяк 1.** *прост. пренебр.* зимого́р, бося́к **2.** незва́ный гость; **~ оста** *пренебр.* шаба́шник; **~ туңдырып йөрү 1.** безде́льничать, броди́ть по́пусту **2.** броди́ть нараспа́шку, налегке́

суыклан|у *неперех. диал. см.* **суыну;** *мич ~а* печь остыва́ет; *үзара мөнәсәбәтләр ~а* охлажде́вают взаимоотноше́ния

суыклату *неперех. диал. см.* **суыту**

суыклы|к *сущ.* **1.** хо́лод, хо́лодность, прохла́да; *кышның ~гы* хо́лодность зимы́; *~ктан интегү* му́читься от хо́лода **2.** *перен.* хо́лодность, прохла́дность; *мөгамәләдәге ~к* хо́лодность отноше́ний

суыкс|у *неперех. диал.* зя́бнуть, озя́бнуть, чу́вствовать, почу́вствовать озно́б; *бер ~ыйм, бер янам* то начина́ю зя́бнуть, то броса́ет в жар □ **~ып китү** зя́бнуть; озя́бнуть

суыксыну *неперех. диал.* чу́вствовать, почу́вствовать озно́б

суындыр|у *неперех.* охлажда́ть/охлади́ть, остужа́ть/остуди́ть *кого-что; см.* **суыту**; *күңелне ~у* охлади́ть се́рдце; *коры мөгамәлә аны тиз ~ды* холо́дное отноше́ние бы́стро охлади́ло его́

суын|у *неперех.* **1.** стыть, стынуть, остыва́ть/остыть; простыва́ть/просты́ть || остыва́ние; *өй ~ды* дом остыл; *аш ~а* суп стынет; *мич ~ды* печь остыла; *тәне ~ган* те́ло его́ остыло **2.** *перен.* охладева́ть/охлади́ть, остыва́ть/остыть || охлажде́ние; *күңеле ~ган* се́рдцем остыл; *дәрте ~ды* чу́вство её остыло; *аралар ~у* охлажде́ние отноше́ний **3.** *перен.* простыва́ть/простыть; *эзе ~ды* след его́ простыл □ **~а бару (бирү, тору)** постепе́нно охлажда́ть (остыва́ть); **~а төшү** *прям., перен.* чуть остыть; **~ып бетү (китү)** остыть, охлади́ться

суынышу *взаимн.-совм. от* **суыну**; охлажда́ть/охлади́ть друг к дру́гу || взаи́мное охлажде́ние

суыр *сущ.* суро́к || суро́чий, сурчи́ный; суркО́вый; *~ тиресе* суркО́вая шку́рка; *~ мае* сурчи́ный жир; *~ өне* суро́чья но́рка

суыргалау *многокр. от* **суыру**

суыргыч I *сущ.* **1.** насо́с || насо́сный; *автомат ~* автомати́ческий насо́с **2.** *вторая часть сложных слов, соответствующая по значению основе* -сос; *тузан ~* пылесо́с || *прил.* отса́сывающий, отсо́сный; *~ насос* отсо́сный насо́с; *~ пластырь* отса́сывающий пла́стырь

суыргыч II *сущ. диал.* ве́ялка; *см. тж.* **җилгәргеч**

суырткыч *сущ.* **1.** *вторая часть сложных слов, соответствующая по значению основе* -сос; *җир ~* землесо́с **2.** *диал.* промока́шка || *прил.* втяжно́й; *~ җиңсә* втяжно́й рука́в

суырттыру *понуд. от* **суырту**

суырт|у I *перех.* **1.** отса́сывать/отсоса́ть, кача́ть, выка́чивать/вы́качать, отка́чивать/откача́ть *что* || отса́сывание, отка́чка, отка́чивание, выка́чивание; *мичкәдән бензин ~у* выка́чивать из бо́чки бензи́н; *су ~у* кача́ть во́ду **2.** выдёргивать/вы́дернуть, удаля́ть/удали́ть *что* || удале́ние, выдёргивание **3.** *прям., перен.* вытя́гивать/вы́тянуть *что* || вытя́гивание; *һава ~у* вытя́гивать во́здух; *акча ~у* вытя́гивание де́нег **4.** гоня́ть, гнать *что; бал ~у* мёд гнать; *бал ~у машинасы* медогО́нная маши́на, медогО́нка □ **~а бару** постепе́нно удаля́ть; **~ып алу (чыгару) 1.** кача́ть, выка́чивать/вы́качать, отка́чивать/откача́ть *что; һаваны ~ып алу* вы́качать во́здух; *идән астыннан су ~ып чыгару* откача́ть во́ду из подва́ла **2.** выка́чивание, отка́чивание; отка́чка **3.** вы́тянуть *что; вентиляция белән төтенне ~ып алу* вы́тянуть дым вентиля́цией

суырт|у II *перех.* ве́ять, прове́ять *что; ашлык ~у* прове́ять зерно́ □ **~ып алу (кую)** прове́ять (*зерно*)

суыртылу *страд. от* **суырту** 1, 2

суыр|у I *прям., перен.* **1.** соса́ть *что* || соса́ние; *конфет ~у* соса́ть конфе́ты; *имчәк ~у* соса́ть грудь; *бармак ~у* соса́ть па́лец; *трубка ~у* соса́ть тру́бку **2.** вса́сывать/всоса́ть, впи́тывать/впита́ть *что* || вса́сывание, впи́тывание; *чәчәктән бал ~у* вса́сывать нектар из цветка́; *коры агач су ~а* сухо́е де́рево впи́тывает влагу **3.** *прям., перен.* выса́сывать/вы́сосать *что* || выса́сывание; *сөлек кан ~а* пия́вка выса́сывает кровь; *сөякнең җелеген ~у* выса́сывать ко́стный мозг **4.** *прям., перен.* выка́чивать/вы́качать *что* || выка́чивание; *нефть ~у* выка́чивать нефть; *акча ~у* выка́чивать де́ньги **5.** тяну́ть, втя́гивать/втяну́ть *что* || втя́гивание; тя́га; *мич төтенне яхшы ~а* печь хорошо́ тя́нет дым; *упкын ~ды* втяну́ла (поглоти́ла) пучи́на **6.** *прям., перен.* вытя́гивать/вы́тянуть, втя́гивать/втяну́ть *что* || **1)** вытя́гивание, вы́тяжка 2) вытяжно́й; *билет ~у* вы́тянуть биле́т; *пластырь эренне ~а* пла́стырь вытя́гивает гной; *бөтен җелекләрен ~у* вы́тянуть все со́ки; *кирәкле мәгълүматларны ~у* вытя́гивать ну́жные све́дения; *~у шкафы* вытяжно́й шкаф; *насосның ~у җиңсәсе* втяжно́й рука́в насо́са **7.** затя́гивать/затяну́ть *что* || затя́жка; *ике-өч ~ырлык* на две-три затя́жки; *сазлык ~ды* затяну́ло боло́то **8.** выта́скивать/вы́тащить *что чем; кылычны кынысыннан ~у* выта́скивать са́блю из но́жен **9.** выдёргивать/вы́дернуть, вырыва́ть/вы́рвать, удаля́ть/удали́ть *что* || выдёргивание; удале́ние; *казык ~у* вы́дернуть кол; *кадак ~у* вы́дернуть гвоздь; *теш ~у* удали́ть зуб **10.** *в знач. нареч.* **суырып** взасо́с; *саф һаваны ~ып сулау* вдыха́ть взасо́с све́жий во́здух; *~ып үбешү* целова́ться взасо́с □ **~а бару 1.** постепе́нно выка́чивать **2.** постепе́нно втя́гивать (*в себя*) **3.** постепе́нно вытя́гивать; удаля́ть; **~а бирү 1.** знать себе́ соса́ть, продолжа́ть соса́ть **2.** знать себе́ выка́чивать, продолжа́ть выка́чивать; **~а төшү** не́сколько (чу́точку) всоса́ть; **~ып алу 1.** *прям., перен.* вы́качать *что; суны ~ып алу* вы́качать во́ду **2.** *прям., перен.* всоса́ть, вы́сосать *что* **3.** отсоса́ть *что* **4.** затяну́ть *кого-что* **5.** вы́дернуть, удали́ть, вы́рвать; *теш ~ып алу* удали́ть зуб **6.** вы́тянуть, вы́тащить *что;* **~ып бетерү 1.** вы́сосать до конца́ **2.** отсоса́ть *что;* **~ып ташлау** вы́дернуть *что;* **~ып чыгару 1.** вы́дернуть *что* **2.** вы́тянуть *что* ◊ **~ да йот; ~ып йотарлык** пи́саная краса́вица; кровь с молоко́м

суыр|у II *перех.* ве́ять, прове́ивать *что* || прове́ивание; *машина белән ~* прове́ивать на маши́не; *арыш ~у* прове́ивание ржи □ **~у машинасы** ве́ялка; *см. тж.* **җилгәргеч; ~ып алу** прове́ять

суырыл|у I **1.** *страд. от* **суыру** I; *каны ~ган* кровь вы́сосана; *өермәгә ~ган* втя́нут в вихрь (ви́хрем) **2.** вырыва́ться/вы́рваться *из чего; аның кочагыннан ~а* вырыва́ется из его́ объя́тий **3.** *перен. разг.* худе́ть, похуде́ть, та́ять; *ул күз алдында ~ды* она́ та́яла на глаза́х **4.** осу́нуться; *аның йөзе ~ган* лицо́ его́ осу́нулось **5.** впада́ть/впасть; *яңаклары ~ган* щёки его́ впа́ли; *эче ~ган* живо́т его́ впал **6.** *в знач. нареч.* **суырылып** вы́тянувшись в стру́нку; *ат ~ып чаба* конь бежи́т вы́тянувшись □ **~а төшү 1.** чуть (слегка́) похуде́ть, осу́нуться **2.** слегка́ впасть (*о щеках*)

суырыл|у II *страд. от* **суыру** II; *~ган арыш* прове́янная рожь

суыткыч *сущ.* **1.** холоди́льник; *~тан сөт алу* взять из холоди́льника молоко́ **2.** морози́льник, морози́лка, морози́льная ка́мера; *~ка ит кую* положи́ть в морози́льник мя́со **3.** охлади́тель; *сөт ~* охлади́тель молока́; *пар машинасы ~ы* охлади́тель паровО́й установки || *прил.* **1.** морози́льный, холоди́льный; *~ камера* морози́льная (холоди́льная) ка́мера; *~ җайланма* холоди́льная установка **2.** охлади́тельный; охлажда́ющий; *~ катнашма* охлади́тельная смесь; *~ сыеклык* охлажда́ющая жи́дкость

суыт|у *перех.* **1.** *прям., перен.* охлажда́ть/охлади́ть *что* || охлажде́ние; *суны ~у* охлади́ть во́ду; *дәртен ~у* охлади́ть пыл **2.** *неперех.* охлади́ть; *күңелне ~у* охлади́ть се́рдцем **3.** остужа́ть/остуди́ть *что; өйне ~у* остуди́ть

дом; *кайнар сөтне ~у* остуди́ть молоко́; *ашны ~у* остуди́ть суп **4.** *безл.* холода́ть, холоди́ть, похолода́ть, моро́зить; *бүген ~ып тора* сего́дня моро́зит; *көн ~ты* похолода́ло **5.** выва́живать/вы́водить *кого* || выва́живание; *атны ~у* выва́живать коня́ **6.** *перен. прост.* тяну́ть, стяну́ть, стащи́ть, утяну́ть, упере́ть; *кеше әйберен ~у* стяну́ть чужу́ю вещь □ **~а төшү** ещё (чуть) бо́льше похолода́ть; **~у җайланмасы** холоди́льная установка; **~ып алу** охлади́ть, остуди́ть; **~ып бетерү** остуди́ть, заморо́зить; **~ып җибәрү** похолода́ть (*о погоде*)

суытылу *неперех.* охлажда́ться/охлади́ться || охлажде́ние; *су белән ~* водяно́е охлажде́ние; *һава белән ~* возду́шное охлажде́ние

су|ю *перех.* **1.** ре́зать, заре́зать, коло́ть, заколо́ть, бить, забива́ть/заби́ть *кого* || убой, забо́й; *мал сую* ре́зать скот; *сугым сую* забива́ть скот; *дуңгыз сую* заколо́ть свинью́; *тавык сую* ре́зать ку́рицу **2.** *прям., перен.* ре́зать, заре́зать; *урынсыз сорау белән суйды* заре́зал неуме́стным вопро́сом **3.** сса́живать/ссади́ть, сдира́ть/содра́ть, натира́ть/натере́ть *что* || сдира́ние; *тиресен сую* содра́ть ко́жу; *тезен сую* ссади́ть коле́но **4.** *диал.* сдира́ть/содра́ть *что* || сдира́ние; *юкә сую* сдира́ть лы́ко □ **суеп алу, суеп ату** *разг.* заре́зать; **суеп ташлау** заре́зать; **суеп төшерү** содра́ть; **суеп чыгу** вы́резать подря́д ◊ **суеп каплаган** *см.* **суйган да каплаган; суйган да каплаган 1.** вы́литый; похо́жий, как две ка́пли воды́ **2.** к ме́сту; как бу́дто для вас; **суйсагыз да, суйсаң да** хоть заре́жь(те)

суючы *сущ.* ре́зчик скота́; скотобо́ец; *см.* **сутымчы**

сүяргыч *сущ. мор.* водоре́з

сүбәт *сущ. этногр.* **1.** семе́йный сове́т (*с приглашением в гости к одному из членов большой семьи*) **2.** пир в честь рожде́ния ребёнка, новосе́лья и т. п. собы́тий

сүгелгән *прил.* обру́гательный, жесто́ко раскритико́ванный; *~ кеше* обру́ганный челове́к

сүгел|ү *страд. от* **сүгү 1.** быть обру́ганным; *кем тарафыннан ~у* быть обруганным *кем* **2.** *перен.* жесто́ко раскритико́вываться; *~гән әсәр* жесто́ко раскритико́ванное произведе́ние

сүгенгәлә|ү *многокр. от* **сүгенү;** руга́ться вре́мя от вре́мени; поруга́ться □ **~п алу** вы́ругаться, ругну́ться

сүгендер|ү *понуд. от* **сүгенү;** допуска́ть/допусти́ть ру́гань; *~мә син аны* не дава́й ему́ руга́ться

сүген|ү *возвр. от* **сүгү;** руга́ться (*матом*), брани́ться, матери́ться, скверносло́вить, выража́ться (*нецензурными словами*) || скверносло́вие; *~ергә тотынды* на́чал руга́ться, заруга́лся □ **~үче сүзләре** нецензу́рные слова́, мат, матерщи́на

сүгеш *сущ.* ру́гань, брань; скверносло́вие; *бар ишеткәнем ~* слы́шу то́лько брань

сүгешү *взаимно-совм. от* **сүгү;** брани́ться, руга́ться *с кем*; брани́ть, руга́ть друг дру́га

сүгенүле *прил.* руга́тельный, руга́тельский, ма́терный; *~ сүзләр* ма́терные слова́

сүгенүчән *прил.* скверносло́вный

сүгенүче *сущ.* матерщи́нник, скверносло́в

сүгү *перех.* руга́ть, обруга́ть, поруга́ть, брани́ть, вы́бранить; костери́ть, кости́ть, матери́ть || ру́гань, брань в а́дрес *кого; нәрсә дип сүгү* руга́ть каки́ми слова́ми, обзыва́ть кем; *сүксәң сүгәрсең инде* мо́жешь ско́лько уго́дно руга́ть □ **сүгеп җибәрү** отосла́ть, посла́ть; **сүгеп ташлау** вы́ругать, заруга́ть, изруга́ть; вы́бранить, кости́ть

сүз *сущ.* **1.** *в разн. знач.* сло́во, слово- || слова́рный; лекси́ческий; *сүз төрләндергеч кушымчалар* словоизмени́тельные су́ффиксы; *сүз ясагыч кушымчалар* словообразова́тельные су́ффиксы; *сүз ясалышы* словообразова́ние; *сүздән эшкә күчү* переходи́ть от слов к де́лу; *сүзе эштән аерылмый* (*погов.*) ≈ слов на ве́тер не броса́ет (*букв.* слова́ его́ не отрыва́ются от де́ла); *әйткән сүз — аткан ук* (*посл.*) ≈ сло́во не воробе́й, вы́летит — не пойма́ешь (*букв.* вы́сказанное сло́во — вы́пущенная стрела́) **2.** 1) разгово́р, речь; обсужде́ние; *сүз барышында* в хо́де разгово́ра (обсужде́ния); *сүзгә катнашу* уча́ствовать в разгово́ре, обсужде́нии; *сүзне икенчегә бору* перевести́ разгово́р на другу́ю те́му; перемени́ть те́му; *сүзеңне бүләм* прерыва́ю твою́ речь 2) сло́во, выступле́ние (на собра́нии); *кунакларга сүз бирү* дать сло́во (*для выступления*) гостя́м; *соңгы сүз* после́днее сло́во, после́днее выступле́ние; *сүздән мәхрүм итү* лиша́ть сло́ва; *председатель сүзеннән соң* по́сле выступле́ния председа́теля **3.** 1) мне́ние, мысль; оце́нка, взгляд; *кеше сүзе* чужо́е мне́ние; *ул үз сүзендә калды* он оста́лся при своём мне́нии; *сүз аңлату* разъясни́ть (свою́) мысль 2) молва́, слух; *шундый бер сүз йөри* хо́дит тако́й слух (така́я молва́) 3) выска́зывание; предложе́ние; повеле́ние; пожела́ние, заве́т; *минем сүзем шул сезгә* моё предложе́ние к вам таково́; *ата-ана сүзе* заве́т (пожела́ние) роди́телей; *кем сүзенә ышанасың?* кому́ (*букв.* чьим выска́зываниям) ты ве́ришь (доверя́ешь) 4) изрече́ние, афори́зм; *ата-бабалар сүзе* изрече́ния пре́дков; *гыйбрәтле сүз* му́дрое изрече́ние **4.** обеща́ние, сло́во; договорённость; завере́ние; *сүз бирү* дава́ть сло́во; *сүзне кире алу* отка́зываться от сло́ва (обеща́ния, завере́ния) **5.** *перен.* 1) спле́тня, пересу́ды, то́лки, клевета́, поклёп; порица́ние, обвине́ние; инсину́ация; *сүз иреш-теру (җиткеру)* доводи́ть до све́дения *кого* 2) вы́говор, порица́ние; попрёк, упрёк; *синең өчен сүз ишетәсем килми* я не хочу́ из-за тебя́ получи́ть вы́говор (выслу́шивать упрёки) □ **сүз арттыру (үрчетү)** плоди́ть словеса́, занима́ться суесло́вием (трепотнёй, болтовнёй); **сүз байлыгы** лекси́ческое бога́тство; **сүз составы** соста́в сло́ва; **сүз тамыры** ко́рень сло́ва ◊ **сүз алу 1.** брать/взять сло́во, начина́ть речь **2. (сүзен алу)** добива́ться обеща́ния; **сүз агышында (барышында)** по хо́ду разгово́ра; **сүз алышу** *см.* **фикер алышу; сүз арасында 1.** ме́жду про́чим, к сло́ву, кста́ти говоря́ **2.** ме́жду разгово́рами; **сүз әйтү 1.** упрека́ть, выгова́ривать **2.** руга́ть; оби́деть сло́вом **3.** вноси́ть предложе́ние, вста́вить (своё) сло́во; **сүз башлау** приступи́ть к расска́зу (выступле́нию); нача́ть речь; **сүз башы** введе́ние; **сүз буткасы** суесло́вие; болтовня́; **сүз буткасы пешерү (кайнату, ясау)** занима́ться суесло́вием, пустосло́вием; мно́го и бесполе́зно говори́ть; **сүз белән сыйлау** угоща́ть слова́ми; корми́ть обеща́ниями; **сүз бер (булу) 1.** быть единогла́сным, приде́рживаться одного́ мне́ния **2.** держа́ться да́нного сло́ва; **сүз беркетү (берләштерү)** договори́ться (торже́ственно, убеди́тельно) обеща́ть друг дру́гу; *шулай дип сүз беркеттеләр* на том и договори́лись; **сүз бирешү** договáриваться; дава́ть сло́во ве́рности друг дру́гу; **сүз бирү** дава́ть сло́во (обеща́ние, кля́тву); **сүз дә юк 1.** не́чего и говори́ть; *бу шартларда эш турында сүз дә юк* не́чего и говори́ть о рабо́те в э́тих усло́виях **2.** коне́чно же; *сүз дә юк, бу план үтәләчәк* коне́чно же, э́тот план бу́дет вы́полнен; **сүз итеп сөйләү** всерьёз говори́ть (чушь); **сүз нәрә сүз** сло́во за́ слово; **сүз нәрә сүз чыгу** *см.* **сүздән сүз чыгу; сүз йөрткән — күз йөрткән** (*посл.*) кто спле́тничает, тот разно́сит ого́нь; **сүз йөртү** спле́тничать; доноси́ть, кля́узничать; **сүз йөртүче** спле́тник,

кля́узник; **сүз кайтару** *см.* **тел кайтару**; **сүз көрәштерү** спо́рить, пререка́ться (зря); спо́рить по́пусту; **сүз көрәштерүче** спо́рщик; люби́тель пререка́ний; **сүз куерту** 1. (*словами*) толо́чь во́ду в ступе (*букв.* сгуща́ть слова́) 2. раздува́ть спор, ссо́ру, препира́тельства; **сүз куешу** дава́ть обеща́ние друг дру́гу; **сүз кузгату** заговори́ть, нача́ть разгово́р *о чём;* поднима́ть вопро́с *о ком, о чём*; **сүз кушу (кату)** 1. заговори́ть *с кем-л.*, обраща́ться *к кому* (*выражая своё мнение, вопрошая и т. п.*); вме́шиваться в разгово́р, пода́ть ре́плику 2. *см.* **тел кату**; **сүз кую** обеща́ть, дава́ть обеща́ние (*что-л. сделать*); **сүз рәте** 1. толк в рача́х 2. пра́вила разгово́ра, ре́чи; **сүз салу** сде́лать предложе́ние (в немно́гих слова́х); замо́лвить слове́чко; **сүз тидерү** *см.* **тел тидерү**; **сүз тию** *см.* **тел тию**; **сүз тыңлау** слу́шаться, послу́шаться; быть покла́дистым; **сүз тыңлаучан** послу́шный; покла́дистый; *сүз тыңлаучан кеше* покла́дистый челове́к; **сүз уйнату** занима́ться суесло́вием, пустосло́вием (*букв.* игра́ть слова́ми); **сүз эзләп күршегә керми** (*погов.*) за сло́вом в карма́н не ле́зет; **сүз юк** 1. не́чего и возрази́ть; возраже́ний нет 2. безупре́чный; *аның тәртибенә сүз юк* его́ поведе́ние безупре́чно; **сүзгә, (кемнең) сүзенә (сүзләренә) карау** изли́шне реаги́ровать (*букв.* взира́ть) на (чьи) слова́; **сүзгә килү** поссо́риться; повздо́рить; *юк өчен сүзгә килделәр* повздо́рили из-за пустяко́в; **сүздә тору** быть ве́рным своему́ сло́ву; *әйткән сүзеңдә торырга кирәк* дал сло́во — держи́; **сүздән калу** *см.* **телдән калу**; **сүздән (сүз артыннан сүз) чыгу** за сло́вом сло́во; **сүздән сүз чыга** сло́во сло́во роди́т, а тре́тье само́ бежи́т; **сүзе (сүзләре) берегү** приходи́ть/прийти́ к еди́ному (о́бщему) мне́нию, договори́ться; *сүзегез берексен* да бу́дет ме́жду ва́ми мир да согла́сие! **сүзе утә** к его́ слова́м прислу́шиваются; **сүзен бирмәү** ни за что́ не соглаша́ться; наста́ивать на своём (*вопреки очевидности*); **(үз) сүзен сүз итү** упо́рно добива́ться своего́; **сүзендә тору** сдержа́ть сло́во; **(кемнең) сүзеннән чыкмау** не сметь осла́шаться; всегда́ сле́довать сове́ту, мне́нию *кого;* **сүзне җилгә ташламау** не броса́ть слов на ве́тер

сүзәнә *сущ.* сюзане́ (*вышитая узорами ткань — настенное украшение*)

сүзгә-сүз *нареч. см.* **сүзмә-сүз**

сүздә *нареч.* на слова́х; *~ генә* то́лько на слова́х

сүздәге *прил.* 1. име́ющийся в сло́ве; слове́сный; *~ мәгънә* слове́сное значе́ние 2. *что* на слова́х; *~ уңышлар* успе́хи на слова́х

сүзләшү *неперех. разг.* 1. догова́риваться/договори́ться 2. *см.* **сүзгә килү**

сүзле *прил.* 1. 1) со сло́вом (слова́ми), име́ющий сло́во (слова́); *~ музыка* му́зыка со слова́ми 2) *в составе номинативных сочет.* -сло́вный; *күп ~* многосло́вный; *аз ~* немногосло́вный, молчали́вый 2. слове́сный; *~ тәгъбирләнеш* слове́сное выраже́ние 3. канда́льный; *~ кеше* канда́льный челове́к

сүзлек *сущ.* слова́рь, глосса́рий || слова́рный; *~ составы* слова́рный соста́в; *~кә кергән* при́нятый в (норма́тивный) слова́рь

сүзлекләш|ү *неперех.* принима́ться, быть при́нятым в (норма́тивный) слова́рь (словари́); *~еп бетмәгән* ещё не при́нят в словари́

сүзлекчә *сущ. уменьш. от* **сүзлек**; слова́рик, небольшо́й глосса́рий; *китап азагындагы ~* слова́рик в конце́ кни́ги

сүзлекче *сущ.* состави́тель словаре́й, слова́рник, лексико́граф; *~лар киңәшмәсе* совеща́ние лексико́графов

сүзлекчелек *сущ.* слова́рное де́ло; составле́ние словаре́й || слова́рный; *~ группасы* слова́рная гру́ппа

сүзмә-сүз *прил.* дослóвный; *сүзмә-сүз тәрҗемә* дослóвный перево́д

сүзчән *прил.* словоохо́тливый; *~ хатын* словоохо́тливая же́нщина

сүзчәнләну *неперех.* станови́ться/стать словоохо́тливым

сүзчәнлек *сущ.* словоохо́тливость

сүкәмәч *сущ. диал. кул.* ша́рики и́ли лепёшки из густо́й ка́ши (*берутся в дорогу*); сы́рник, запека́нка

сүкмән *сущ. диал.* 1. плащева́я ткань 2. вы́шитая (*в ходе изготовления*) ткань 3. плащ, чекме́нь || *прил.* из плащево́й тка́ни; *~ яка* вы́шитый воротни́к

сүктер|ү *понуд. от* **сүгү** 1. заставля́ть/заста́вить, веле́ть руга́ть, отруга́ть *кого* 2. допуска́ть/допусти́ть, что́бы руга́ли, поноси́ли *кого; үзеңне кешедән ~мә* не допуска́й, что́бы тебя́ руга́ли, поноси́ли

сүл *сущ.* 1. ли́мфа || лимфати́ческий; сы́воротка кро́ви; *каның-сүлең эчеңдә булсын* (*посл.*) (*букв.* и кровь и ли́мфа должны́ быть внутри́) не подава́й ви́ду, е́сли да́же истека́ешь кро́вью; *сул бизләре* лимфати́ческие же́лезы 2. су́кровица 3. сок расте́ний

сүләмә *сущ.* сулема́; *~ эретмәсе* раство́р сулемы́

сүллән|ү *неперех.* наполня́ться и́ли увлажня́ться ли́мфой (сы́вороткой кро́ви, су́кровицей); *~гән яра* напо́лненная су́кровицей ра́на

сүлле *прил.* су́кровичный; серо́зный; *~ яра* су́кровичная ра́на; *~ тукыма* серо́зная ткань

сүлпән *прил.* 1. 1) вя́лый, медли́тельный; анеми́чный (*человек, его действия*) 2) лени́вый; равноду́шный (*к какой-л. деятельности*) 2. *перен.* мино́рный; печа́льный || *нареч.* 1. вя́ло, медли́тельно; лени́во, с ленцо́й; *см. тж.* **сәлпән**; *~ кылана* де́йствует с ленцо́й 2. *см.* **сүрән** □ **~ карау** относи́ться прохла́дно, без энтузиа́зма (спустя́ рукава́); **~ караш** равноду́шие

сүлпәнәйт|ү *перех.* де́лать, сде́лать вя́лым, медли́тельным; замедля́ть, сбавля́ть/сба́вить (*темп*); *көрәш темпын ~ергә ярамый* нельзя́ сбавля́ть темп борьбы́

сүлпәнә|ю *неперех.* замедля́ться, теря́ть си́лу, интенси́вность; сдава́ть; *эшләр ~йде* дела́ заме́длились; *~йдең әле син* ты что́-то сдал

сүлпәнләндерү *перех.* сбавля́ть/сба́вить, замедля́ть/заме́длить (*интенсивность, темп чего-л.*); *см. тж.* **сүлпәнәйтү**

сүлпәнләнү *возвр. от* **сүлпәнәю**; станови́ться/стать вя́лым, медли́тельным, пону́рым; блёкнуть (блёкнуть)/поблёкнуть (поблёкнуть); *ул ничектер ~де* он ка́к-то стал пону́рым; он ка́к-то поблёк

сүлпәнлек *сущ.* 1. вя́лость, медли́тельность; ле́ность, ленца́; *~ белән* вя́ло, с ленцо́й 2. *см.* **сүрәнлек**

сүнгән *прил. в разн. знач.* уга́сший, поту́хший; *~ тормыш* уга́сшая жизнь

сүндергеч *сущ.* 1. **ут ~** огнетуши́тель; *~ ярдәмендә* огнетуши́телем, при по́мощи огнетуши́теля 2. *тех.* гаси́тель; *яктылык ~* гаси́тель све́та; *тирбәнешләр ~е* гаси́тель колеба́ний || *прил.* для туше́ния; предназна́ченный и́ли спосо́бный туши́ть ого́нь; *~ җайланма* приспособле́ние для туше́ния (огня́)

сүндерел|ү *страд. от* **сүндерү**; гаси́ться, туши́ться, быть поту́шенным; *~гән пожар* поту́шенный пожа́р

сүндерешү *взаимно-совм. от* **сүндерү**; помога́ть гаси́ть, туши́ть (*огонь*); совме́стно гаси́ть, туши́ть

сүндертү *понуд. от* **сүндерү**; заставля́ть/заста́вить туши́ть (*огонь и т. п.*)

сүндерү *перех.* **1.** *в разн. знач.* туши́ть, потуши́ть, гаси́ть, погаси́ть || туше́ние, гаше́ние **2.** выключа́ть/вы́ключить || выключе́ние (*ламп, нагревателей и т. п.*); *телевизоры ~* вы́ключить телеви́зор **3.** *перен.* подавля́ть/подави́ть, охлажда́ть/охлади́ть, подави́ть || подавле́ние, охлажде́ние (*пыла, страсти*); *дәртне ~* охлади́ть поры́в **4.** гаси́ть, погаси́ть, унима́ть/уня́ть (*спор, недобрые наклонности и т. п.*) **5.** гаси́ть/погаси́ть || гаше́ние (*извести и т. п.*)

сүнек *прил.* **1.** поту́хший, поме́ркший, безжи́зненный; ага́сший (пога́сший), ту́склый; *~ учак* поту́хший (пога́сший) костёр; *~ караш* поту́хший взгляд **2.** пода́вленный; *~ күңел* пода́вленное настрое́ние **3.** упа́дочный; *~ рух* упа́дочный дух

сүнмәс *прил.* неугаси́мый, неутоми́мый (*страсть*); *~ утлар* неугаси́мые огни́

сүн|ү *неперех.* **1.** *в разн. знач.* га́снуть, пога́снуть, потуха́ть/поту́хнуть; затуха́ть/зату́хнуть || затуха́ние **2.** *в разн. знач.* пога́снуть, угаса́ть || угаса́ние; *кояшның соңгы нурлары ~гәч* по́сле того́, как пога́сли после́дние лучи́ со́лнца □ **~әм, ~әм дип тора 1.** мига́ет (от недоста́тка горю́чего) **2.** бли́зок к сме́рти; при́ смерти

сүр *сущ. ист.* сму́шка || *прил.* сму́шковый

сүрә I *сущ. диал. см.* **сүрәтке**

сүрә II *сущ. рел.* су́ра (*раздел Корана*); *бер ~ уку* проче́сть одну́ су́ру (из Кора́на)

сүрәкә *сущ. этногр.* сорбка (*головной убор замужних женщин в виде колпака с двумя рожками спереди*)

сүрән *прил.* **1.** 1) дово́льно сла́бый; нежа́ркий, не я́ркий (*лучи солнца, пламя костра и т. п.*) 2) па́смурный, нена́стный **2.** непропечённый, сырова́тый; *см. тж.* **тачка 3.** *перен.* вя́лый; пода́вленный, гру́стный, апати́чный **4.** небре́жный, лени́вый, не энерги́чный || *нареч.* **~ генә 1.** сла́бо; нежа́рко; нея́рко **2.** вя́ло; пода́вленно, гру́стно; *~ генә елмайды* сла́бо (гру́стно) улыбну́лся **3.** лени́во; небре́жно; ко́е-как; *эшләр ~ бара* дела́ иду́т ко́е-как

сүрәнәю *неперех.* станови́ться/стать вя́лым, угаса́ть, слабе́ть

сүрәт *сущ.* **1.** *разг. см.* **сурәт 2.** карикату́ра (*на человека*)

сүрәтке *сущ.* волоку́ша; *см. тж.* **сөйрәткеч**

сүрәткеләү *перех.* **1.** обраба́тывать (*пашню*) **2.** сгреба́ть, подвози́ть (*сено, солому*) волоку́шей

сүре|к *сущ. диал.* **1.** коро́ткая па́лка **2.** шкво́рень, сте́ржень; *арба ~ге* шкво́рень теле́ги

сүрелдерү *перех.* уба́вить, сба́вить (*горение, жар, свет, температуру*)

сүрелү 1. *страд. от* **сүрү** 1) убавля́ться, сбавля́ться || сбавле́ние (*горения, жара и т. п.*) 2) охладе́ть || охлажде́ние (*от желания, порыва, страсти*); *сөям сине, сөям сине сүрелмәс булсаң гына* (*песня*) люблю́ тебя́, бу́ду люби́ть, е́сли ты не охладе́ешь **2.** *см.* **сүренкеләнү, сүрәнәю**

сүренке *прил.* **1.** *см.* **сүрән 2.** 1) гру́стный, уны́лый; мино́рный; *~ күңел* мино́рное настрое́ние; мино́рный настро́й души́ 2) упа́дочный; *~ моң* упа́дочный моти́в

сүренкеләнү *неперех.* **1.** *см.* **сүрелү 2.** загрусти́ть, приуны́ть

сүренкелек *сущ.* **1.** *см.* **сүрәнлек 2.** грусть, уны́лость, мино́рность

сүрү I *перех.* **1.** сбавля́ть/сба́вить || сбавле́ние (*жары, температуры печи*) **2.** *перен.* 1) отгова́ривать/отговори́ть *от чего-л.* 2) притупля́ть/притупи́ть || притупле́ние (*решимости, пыла и т. п.*)

сүрү II *сущ.* **1.** на́волочка (на поду́шке); чехо́л, пододея́льник; *мендәр ~е* на́волочка; *юрган ~е* пододея́льник **2.** *биол. физ.* 1) оболо́чка 2) плёнка

сүрүлек *прил.* приго́дный, предназна́ченный и́ли доста́точный для изготовле́ния на́волочки, чехла́, оболо́чки; на́волочный || *сущ.* материа́л (*ткань, плёнка и т. п.*), го́дный для изготовле́ния на́волочек, оболо́чек и т. п.

сүс *сущ.* **1.** пенька́, куде́ль; *киндер сусе* пенька́; *җитен сусе* куде́ль льна **2.** волокно́; *капрон сусе* капро́новое волокно́ **3.** *разг.* па́кля; подчёс; *бурага сус алу* приобрета́ть па́клю для сру́ба || *прил.* пе́нько́вый; *сус аркан* пенько́вый арка́н (кана́т) □ **сүс чистарткыч** трася́на (маши́на); **сүс чистартучы** трася́льщик (челове́к)

сүсән *сущ. бот.* тимофе́евка || *прил. диал.* мете́льчатый; *~ үләннәр* мете́льчатые тра́вы

сүсәрт|ү *перех.* растрепа́ть, истрепа́ть, измоча́лить, износи́ть (*до нитки*) || трепа́ние; *бау ~ү* мшить верёвку

сүсәрү *неперех.* растрепа́ться, измоча́литься; излохма́титься; распада́ться на отде́льные воло́кна

сүсләндерү *понуд. от* **сүсләнү**; *см.* **сүсәртү**

сүсләнү *возвр. от* **сүсләү**; **1.** 1) достига́ть/дости́чь ну́жной волокни́стости (*о растениях*) 2) трепа́ться, моча́литься, лохма́титься; *~еп бетү* растрепа́ться, размоча́литься **2.** *страд. от* **сүсләү**; конопа́титься, законопа́чиваться; быть конопа́ченным па́клей

сүсләү *перех.* конопа́тить, законопа́чивать/законопа́тить (*щели, отверстия*); закла́дывать па́клей

сүсле *прил.* **1.** с волокно́м; даю́щий волокно́; *~ үсемлекләр* расте́ния с волокно́м, с волокни́стым сте́блем **2.** волокни́стый; *~ минерал* волокни́стый минера́л

сүсчел *прил.* волокни́стый (*строение вещества*) □ **~ болытлар** пе́ристые облака́

сүте|к *прил.* **1.** распо́ротый (*по швам*) **2.** расплетённый (*верёвка, коса и т. п.*) **3.** полуразо́бранный (*дом, мост*) || *сущ.* распо́ротый шов; проре́ха; разры́в шва; *сүзнең ~ге юк* (*погов.*) у ре́чи нет проре́хи □ **~ юл** доро́га, состоя́щая из ря́да паралле́льных прое́зжих поло́с

сүтелдерү *понуд. от* **сүтелү**; де́лать, сде́лать (и́ли допуска́ть/допусти́ть, что́бы бы́ло) распо́ротым, разо́бранным, раска́танным, расплетённым, расстро́енным

сүтелмә *прил. см.* **сүтелмәле**

сүтелмәле *прил.* разбо́рный; *~ өйләр* разбо́рные дома́; *~ мебель* разбо́рная ме́бель

сүтел|ү *страд.-возвр. от* **сүтү 1.** поро́ться, распа́рываться/распоро́ться; быть распо́ротым; *җәве ~ә* шов его́ распа́рывается; *~гән итек* распо́ротый (*по шву*) сапо́г **2.** разбира́ться/разобра́ться, быть разбира́емым и́ли разо́бранным; *бу йорт ~ә* э́тот дом разбира́ется; *~гән мотор кисәкләре* ча́сти разо́бранного мото́ра **3.** распуска́ться/распусти́ться, быть распу́щенным, раска́танным; расплета́ться/расплести́сь, быть расплетённым; *~гән толым* распу́щенная (расплетённая) коса́ **4.** расстра́иваться/расстро́иться, быть растро́енным (*о планах, делах*)

сүтмә: сүтмәсен сүтү *см.* **тетмәсен тетү** (*см.* **тетмә**); *сүтмәләрен сүтәрмен, тетмәләрен тетәрмен* покажу́ я им ку́зькину мать

сүттер|ү *понуд. от* **сүтү**; заставля́ть/заста́вить распа́рывать (поро́ть, разобра́ть, раската́ть, расплета́ть, отка́зываться (*от планов, намерений*)

сүт|үү *перех.* **1.** поро́ть, распа́рывать/распоро́ть, спа́рывать/споро́ть, расшива́ть (*уже сшитое*) || распа́рывание, расшива́ние; *иске кием ~у* распа́рывать ста́рую оде́жду **2.** 1) разбира́ть/разобра́ть; разнима́ть/разня́ть (*соединение деталей*) || разбо́рка; разъём; *моторны ~у* разбо́рка мото́ра (*с целью выявления дефекта*) 2) раска́тывать/раскати́ть (*сруб*) || раска́тывание **3.** 1) распуска́ть/распусти́ть, развива́ть/разви́ть (*свитое*), расплета́ть/расплести́ (*косу*) 2) разма́тывать/размота́ть || размо́тка (*клубка, катушки*) 3) разворáчивать, развёртывать/развернýть (*узелок*); раска́тывать/раскати́ть (*скатку, скатанное*) **4.** *перен.* 1) расстра́ивать/расстро́ить || расстра́ивание (*дел*) 2) разду́мывать/разду́мать, отка́зываться/отказа́ться || отка́з (*от планов, намерений*) **5.** *перен. разг.* 1) громи́ть, разгроми́ть; устра́ивать/устро́ить погро́м *кому; мин аларны ~әм хәзер* я сейча́с покажу́ им, где ра́ки зиму́ют 2) поноси́ть, си́льно руга́ть; *ул аны ~те дә ~те* он его́ поноси́л и поноси́л □ **~еп алу** отпоро́ть (*заплатку*)

сфера *сущ.* **1.** сфе́ра (шар); *җир ~сы* земна́я сфе́ра **2.** *мат.* сфе́ра || сфери́ческий **3.** сфе́ра (*область деятельности*); *көнкүреш хезмәте күрсәтү ~сы* сфе́ра бытово́го обслу́живания; *җитештерү ~сы* сфе́ра произво́дства; *йогынты ~сы* сфе́ра влия́ния

сфе́рик *прил.* **1.** сфери́ческий; *~ өсйөз* сфери́ческая пове́рхность; *~ линза* сфери́ческая ли́нза; *~ гөмбәз* сфери́ческий ку́пол **2.** *мат.* сфери́ческий; *~ геометрия* сфери́ческая геоме́трия

сфериклык *сущ.* сфери́чность *чего-л.*

сфинкс *сущ.* **1.** сфинкс; *Борынгы Мисыр ~лары* сфи́нксы Дре́внего Еги́пта **2.** *зоол.* сфинкс (*род бабочек*) **3.** сфинкс (*узконосая обезьяна рода павианов*)

схе́ма *сущ. прям., перен.* схе́ма; *телевизор ~сы* схе́ма телеви́зора; *төзелеш урынының ~сы* схе́ма ме́ста стро́ительства; *доклад ~сы* схе́ма докла́да; *әдәби ~лар* литерату́рные схе́мы

схемалаштыр|у *перех.* схематизи́ровать || схематиза́ция, схематизи́рование; *образны ~ып бирү* дать о́браз в схематизи́рованном ви́де

схемалаштыручы *сущ.* схематиза́тор

схемалаштырылу *страд. от* **схемалаштыру**; схематизи́роваться

схема́тик *прил. книжн.* **1.** схемати́ческий *~ план* схемати́ческий план; *~ карта* схемати́ческая ка́рта **2.** схемати́чный; *~ образ* схемати́чный о́браз; *~ алым* схемати́чный приём || *нареч.* схемати́чески, схемати́чно; *образ ~ бирелгән* о́браз дан схемати́чно □ **~ рәвештә (сурәттә)** в ви́де схе́мы

схема́тиклы|к *сущ.* схемати́чность; *сурәтләүнең ~гы* схемати́чность изображе́ния

схе́мачыл *прил. см.* **схематик** 1; *~ типлар* схемати́ческие ти́пы

схе́мачылык *сущ.* схемати́чность, схемати́зм; *~тан арыну* освободи́ться от схемати́зма; *сурәтләүдә ~* схемати́чность описа́ния (изображе́ния); *коры ~* сухо́й схемати́зм

схо́дка *сущ.* схо́дка; *студентлар ~сы* студе́нческая схо́дка

схоласт *сущ. в разн. знач.* схола́ст; *~ шәкерт* шаки́рд-схола́ст

схола́стик *прил.* **1.** схоласти́ческий; *~ белем* схоласти́ческое образова́ние; *~ философия* схоласти́ческая филосо́фия; *~ мәктәпләр* схоласти́ческие шко́лы **2.** схоласти́чный; *~ фикерләү* схоласти́чное мышле́ние; *~ бәхәсләр* схоласти́чные спо́ры □ **~ рәвештә** схоласти́чески, схоласти́чно; *~ рәвештә фикер йөртү* рассужда́ть схоласти́чно

схола́стика *сущ.* схола́стика; *~ тарафдары* после́дователь схола́стики; *~ ысуллары* приёмы схола́стики; *мөселман ~сы* мусульма́нская схола́стика

сцена́рий *сущ.* сцена́рий || сцена́рный; *әдәби ~* литерату́рный сцена́рий; *~ язу* писа́ть сцена́рий; *~ факультеты* сцена́рный факульте́т; *~ материалы* сцена́рный материа́л

сцена́рийчы *сущ.* сценари́ст; *тәҗрибәле ~* о́пытный сценари́ст

счёт *сущ.* **1.** *фин.* счёт; *газ һәм электр энергиясе өчен ~* счёт за газ и электри́чество; *~ буенча түләү* уплати́ть по счёту; *колхоз ~ына акча күчерү* перевести́ де́ньги на колхо́зный счёт; *шәхси ~* лицево́й счёт; *исәп-хисап ~ы* расчётный счёт; *агымдагы ~* теку́щий счёт **2.** счёты || счётный; *см. тж.* **чут**; *кулына ~ алу* взять в ру́ки счёты; *~ төймәләре* косте́шки счето́в □ **~ кәгазе** счёт; **~ салу; ~ка салу** счита́ть на счётах

съезд *сущ.* съезд || съе́здовский; *см. тж.* **корылтай**; *язучылар ~ы* съезд писа́телей; *~ ачылу* откры́тие съе́зда; *~ карарлары* реше́ния съе́зда; *~ резолюциясе* съе́здовская резолю́ция; *~ делегатлары* делега́ты съе́зда

сыбай *сущ. диал.* вса́дник □ **~ мену** сади́ться верхо́м на коня́

сыбызгы *сущ.* **1.** свисто́к, свире́ль; ду́дка; *милиция ~сы* свисто́к милиционе́ра; *боцман ~сы* бо́цманская ду́дка; *~ тавышы* звук свистка́; звук свире́ли; *~ кычкырту* дуть в ду́дку **2.** свисту́лька (*детский игрушечный свисток*); *таш ~* гли́няная свисту́лька **3.** *перен. разг.* свисту́н; трещо́тка; соро́ка, балабо́лка □ **~ куагы** *диал.* жёлтая ака́ция; **~ сызгырту** 1. свисте́ть; свисте́ть в свисто́к 2. дава́ть/дать свисто́к ◊ **~ борын** свисту́н, трещо́тка; **~ тоттыру** обдури́ть; **~сына бию** пляса́ть под чью-л. ду́дку

сыбызгычы *сущ.* свире́льщик, дуда́рь *обл.*

сы́воротка *сущ. мед., биол.* сы́воротка; *см.* **сул**; *дифтерия́гә каршы ~* противодифтери́йная сы́воротка

сыгу I *перех.* **1.** *прям., перен.* выжима́ть/вы́жать *что* || выжима́ние, отжа́тие, отжи́мка; *юеш чүпрәкне сыгу* отжа́ть мо́крую тря́пку; *юеш чәчне сыгу* отжа́ть во́лосы; *кер сыгу* отжи́мка белья́ □ **сыгып алу** 1. вы́давить *что* 2. *прям., перен.* вы́жать *что*; **сыгып бетерү** вы́жать (отжа́ть) до конца́; **сыгып чыгару** 1. *прям., перен.* вы́давить *что* 2. вы́жать 3. отжа́ть ◊ **сыгып ташланган лимон кебек** как вы́жатый лимо́н (*о вконец усталом или опустошённом человеке*)

сыгу II *перех.* гнуть, нагиба́ть/нагну́ть, сгиба́ть/согну́ть, прогиба́ть/прогну́ть; *ботакларны сыгу* гнуть ве́тки; *басмачаларны сыгу* гнуть подмо́стки □ **сыга төшү** чу́точку прогну́ть; **сыгып алу** согну́ть, прогну́ть

сыгылгалау *многокр. от* **сыгылу** II

сыгылдыр|у 1. *понуд. от* **сыгылу** II 2. *см.* **сыгу**; *агач ботакларын ~у* нагиба́ть (наклоня́ть) ве́тки де́рева; *көянтәсен ~у* прогиба́ть коромы́сло; *гәүдәсен ~ып* сгиба́я своё те́ло

сыгылма *прил.* **1.** ги́бкий, упру́гий; *~ чыбык* упру́гая ве́тка; *~ гәүдәле* с ги́бким те́лом; *~ пружина* упру́гая пружи́на **2.** пружи́нистый; *~ челтәрле карават* крова́ть

с пружи́нистой се́ткой 3. пласти́чный; ~ *хәрәкәт* пласти́чное движе́ние 4. *перен.* ги́бкий; ~ *алымнар* ги́бкие приёмы

сыгылмалы *прил.* 1. упру́гий, ги́бкий; ~ *җиңсә (тех.)* ги́бкий рука́в 2. пружи́нный; ~ *карават* пружи́нная крова́ть 3. пласти́чный, пружи́нистый; ~ *хәрәкәт* пласти́чное (пружи́нистое) движе́ние; ~ *йөреш* пружи́нистая похо́дка; ~ *басмачалар* пружи́нистые подмо́стки 4. *перен.* ги́бкий; ~ *акыл* ги́бкий ум

сыгылмалылы|к *сущ.* 1. ги́бкость, упру́гость, эласти́чность; *гәүдәнең ~гы* ги́бкость те́ла; *пружинаның ~гы* упру́гость пружи́ны; *~к теориясе (физ.)* тео́рия упру́гости 2. пружи́нистость, пласти́чность 3. *перен.* ги́бкость; *холкының сыгылмалылыгы* ги́бкость его́ хара́ктера

сыгыл|у I *возвр.-страд. от* **сыгу** 1; *~ып күз яшьләре чыкты* вы́давились слёзы; *керләр ~ды* бельё отжа́то

сыгыл|у II 1. *возвр.-страд. от* **сыгу** 2 2. *возвр.* гну́ться, прогиба́ться/прогну́ться, сгиба́ться/согну́ться || прогиб, сгиба́ние; *агачлар җилдән ~а* дере́вья гну́тся от ве́тра; *шурлекләр товардан ~ган* по́лки прогну́лись от това́ров; *үз авырлыгына үзе ~у* прогну́ться под со́бственной тя́жестью; *тезләре ~а* сгиба́ются коле́ни 3. провиса́ть/прови́снуть || прове́с; *өрлек ~ган* прови́сла ба́лка; *тушәм ~а* провиса́ет потоло́к 4. *перен.* гну́ться, сгиба́ться/согну́ться; *күңелсез хәбәрдән ~у* согну́ться от неприя́тной ве́сти □ **~а бару** 1. всё бо́льше прогиба́ть (провиса́ть) 2. *прям., перен.* всё бо́льше сгиба́ться; **~ып бетү** прогну́ться (согну́ться) оконча́тельно; **~ып китү** сгиба́ться/согну́ться, прогиба́ться/прогну́ться; **~ып төшү** 1. прогну́ться 2. прови́снуть 3. *прям., перен.* согну́ться, сго́рбиться; опусти́ться

сыгылучан *прил.* ги́бкий, упру́гий, эласти́чный

сыгылучанлык *сущ.* ги́бкость, эласти́чность, упру́гость

сыгылыш *сущ.* 1. прогиб; *буеның ~ы* прогиб её ста́на 2. прове́с; *такта ~ы* прове́с доски́ 3. *перен.* изворо́тливость, выкрута́сы; *дипломатик ~лар* дипломати́ческая изворо́тливость

сыгымча *сущ. редко см.* **сыгынты**

сыгынты *сущ.* 1. вы́жимки, отжи́мки; *кишер ~сы* морко́вные вы́жимки 2. вы́тяжка, экстра́кт (*вещество из растительной или животной ткани*) 3. *перен. диал.* стена́ния, плач; *җан ~сы* душе́вные стена́ния

сыгындыру *понуд. от* **сыгыну**; брать/взять, отдава́ть/отда́ть под защи́ту; *үзеңә ~* возьми́ под свою́ защи́ту

сыгыну *неперех. книжн.* 1. поклоня́ться/поклони́ться *кому-чему; аллага ~* поклоня́ться бо́гу 2. взыва́ть о по́мощ'и, иска́ть защи́ту; *башкалар көченә ~* иска́ть защи́ту у други́х 3. находи́ть/найти́ убе́жище, покро́в; *ана канаты астына ~* найти́ защи́ту под крыло́м ма́тери

сыгыр *сущ. уст. см.* **сыер**

сыдыргалау *многокр. от* **сыдыру** 1. обдира́ть (*во многих местах*) || обдира́ние (*во многих местах*) 2. постёгивать, похлёстывать || постёгивание, похлёстывание; *чыбыркы белән ~* постёгивать кнуто́м

сыдыргыч *сущ. диал.* обди́рка (*инструмент для снятия коры с дерева*)

сыдырту *перех.* 1. сдира́ть/содра́ть, сса́живать/ссади́ть *что; тирене ~* содра́ть ко́жу; *аякны канаганчы ~* ссади́ть но́гу до кро́ви 2. цара́пать, поцара́пать, расцара́пать *что*; *идәнне ~* поцара́пать пол 3. обдира́ть/ободра́ть *что; ярма ~* обдира́ть крупу́ 4. *диал.* обтира́ть/обтере́ть *что чем; киемне стенага ~* обтере́ть оде́жду об сте́ну 5. *перен. разг.* удра́ть, драпану́ть; *урамга ~* удра́ть на у́лицу

сыдыр|у *перех.* 1. драть, сдира́ть/содра́ть, обдира́ть/ободра́ть *что* || сдира́ние, обдира́ние; *кулны ~у* ободра́ть ру́ки; *тирене ~у* содра́ть ко́жу; *ботактан яфрак ~у* ободра́ть ли́стья на ве́тке; *канат ~у* сдира́ть пух с пе́рьев 2. цара́пать, поцара́пать, расцара́пать *что* || цара́пание 3. задира́ть/задра́ть, засучи́ть *что; җиңнәрен ~ып* засучи́в рукава́ 4. *разг.* стега́ть, отстега́ть, хлеста́ть, отхлеста́ть *кого-что; чыбыркы белән ~у* хлеста́ть кнуто́м 5. *в знач. нареч.* **сыдырып** *перен. разг.* расторо́пно, бы́стро; *өй эшләрен ~ып эшләү* де́лать дома́шние дела́ расторо́пно (бы́стро) 6. *перен. прост.* уплета́ть, упи́сывать/описа́ть, руба́ть *что; ни әләкә шуны ~у* уплета́ть всё, что попадётся по́д руку 7. *перен. прост.* кида́ть/ки́нуть, швыря́ть/швырну́ть; *бала-чаганы ~у* отшвырну́ть мелкоту́ □ **~ып алу (кую), ташлау** 1. содра́ть, ободра́ть 2. *разг.* отстега́ть, отхлеста́ть; **~ып бетерү** содра́ть, вконе́ц ободра́ть ◊ **~ып салу** *прост.* уплести́, описа́ть

сыдырыл|у *страд.-возвр. от* **сыдыру** 1. сдира́ться/содра́ться, цара́паться, расцара́паться; *аның бите ~ган* у неё поцара́пано лицо́; *чыбыкларга ~у* расцара́паться о ве́тки 2. сдира́ться/содра́ться, снима́ться/сня́ться; *җирнең өске катламы бульдозер белән ~ган* ве́рхний слой земли́ снят (со́дран) бульдо́зером 3. задира́ться/задра́ться; *аның уң балагы ~ган* пра́вая штани́на его́ задрала́сь 4. цепля́ться; *болытлар агач башларына ~ып үтә* облака́ проплыва́ют, цепля́ясь за кро́ны дере́вьев □ **~а бару** задира́ться (*по ходу*); **~ып алу** содра́ться (*быстро*); **~ып бетү** расцара́паться; *аяклары ~ып беткән* но́ги его́ расцара́паны; **~ып китү** содра́ться

сыегайттыру *понуд. от* **сыегайту**

сыегайту *перех.* 1. разжижа́ть/разжиди́ть, сжижа́ть/сжи́дить *что чем* || разжиже́ние; сжиже́ние; *алма пюресын ~* разжиди́ть я́блочное пюре́ 2. разбавля́ть/разба́вить, разводи́ть/развести́ *что чем; буяуны ~* развести́ кра́ску

сыегайтылу 1. *страд. от* **сыегайту** 2. *в знач. прил.* **сыегайтылган** сжи́женный; *~ган газ* сжи́женный газ

сыега|ю 1. разжижа́ться/разжиди́ться || разжиже́ние; *кесәл ~йды* кисе́ль разжиди́лся 2. разбавля́ться/разба́виться, разводи́ться/развести́сь *чем*; *кара ~йган* черни́ла разведены́ 3. тускне́ть, потускне́ть, бледне́ть, побледне́ть; *ачык төсләр ~йды* я́ркие цвета́ потускне́ли 4. *прям., перен.* реде́ть, пореде́ть, рассе́иваться/рассе́яться; раста́ять; *томан ~йды* тума́н поредел; *төтен ~йды* дым стал рассе́иваться, та́ять; *караңгылык акрынлап ~йды* темнота́ та́яла; *аның чәчләре ~йды* во́лосы его́ поредели 5. *перен. разг.* та́ять, раста́ять, уменьша́ться/уме́ньшиться; *акча ягы ~йды* де́ньги раста́яли □ **~я бару (төшү)** 1. постепе́нно разжижа́ться 2. постепе́нно рассе́иваться, раста́ять; **~еп бетү** разжиди́ться оконча́тельно (вконе́ц); **~еп китү** потускне́ть, побледне́ть

сыек *прил.* 1. 1) жи́дкий; ~ *аш* жи́дкий суп; ~ *газ* жи́дкий газ; ~ *ягулык* жи́дкое то́пливо; ~ *ботка* жи́дкая ка́ша; ~ *җисемнәр* жи́дкие тела́ 2) жи́дкий, водяни́стый; ~ *кара* жи́дкие черни́ла; ~ *сөт* жи́дкое молоко́ 2. *диал.* жи́дкий, ре́дкий; сла́бый; ~ *чәчләр* жи́дкие во́лосы; ~ *болытлар* жи́дкие (ре́дкие) облака́; ~ *томан* сла́бый тума́н 3. *перен.* жи́дкий, сла́бый; ~ *мускуллар* жи́дкие му́скулы; *тез буыннары ~* коле́ни слабова́тые; ~ *кул чабулар* жи́дкие аплодисме́нты; ~ *такталар* жи́дкие до́ски; ~ *оборона* сла́бая оборо́на 4. ги́бкий,

эласти́чный; ~ *чыбык* упру́гая лоза́, ги́бкий прут **5.** сла́бый, бле́дный; ту́склый; ~ *яктылык* сла́бый свет; ~ *караңгылык* ту́склая темнота́; ~ *шәүлә* сла́бая (бле́дная) тень **6.** *первая часть составных прилагательных, соответствующая значению* бледно-; ~ *яшел* бле́дно-зелёный; ~ *зәңгәр* бле́дно-голубо́й **7.** *перен.* бле́дный, ску́дный, убо́гий; ~ *эчтәлек* ску́дное содержа́ние; ~ *сый* ску́дное угоще́ние || *нареч.* **1.** жи́дко **2.** *перен.* сла́бо, бле́дно, ту́скло; *буяулары ~ чыга* кра́ски проявля́ются ту́скло (сла́бо)

сыеклагыч *сущ. тех.* разбави́тель, разжижи́тель, разбавля́ющий; сжижа́ющий; *кислород ~* разжижи́тель кислоро́да; ~ *матдә* разжижа́ющее вещество́

сыекландыргыч *прил. см.* **сыеклагыч**

сыекландыру *перех.* **1.** разжижа́ть/разжиди́ть, сжижа́ть/сжиди́ть *что чем* || разжиже́ние, сжиже́ние; *кара ~* разжиди́ть черни́ла; *газ ~* сжиди́ть газ **2.** разбавля́ть/разба́вить, разводи́ть/развести́

сыекландырыл|у *страд. от* **сыекландыру** □ **~ган газ** сжи́женный газ

сыеклан|у *неперех.* **1.** *в разн. знач.* разжижа́ться/разжиди́ться *чем* || разжиже́ние; *кан ~ган* кровь разжиди́лась; *мие ~ган* у него́ разжиди́лся мозг **2.** разбавля́ться/разба́виться, разводи́ться/развести́сь *чем* || разбавле́ние, разведе́ние **3.** *прям., перен.* реде́ть, пореде́ть, рассе́иваться/рассе́яться; *томан ~а* тума́н рассе́ивается; *залдагы халык ~ган* наро́д в за́ле пореде́л **4.** *перен. разг.* та́ять, раста́ять, уменьша́ться/уме́ньшиться; *төн караңгысы ~а* та́ет ночна́я темнота́; *матди мөмкинлекләр ~ды* материа́льные возмо́жности раста́яли (оскуде́ли) **5.** *перен. разг.* слабе́ть, ослабева́ть/ослабе́ть; теря́ть/потеря́ть си́лу; *аның мускуллары ~а* му́скулы его́ постепе́нно слабе́ют (теря́ют си́лу) **6.** *перен. разг.* оскудева́ть/оскуде́ть; *аның акылы ~ган* ум его́ оскуде́л **7.** *перен. разг.* спада́ть/спасть; *эш ~а төшкәч* когда́ спадёт темп рабо́ты □ **~а бару** всё бо́льше и бо́льше разжижа́ться (рассе́иваться); **~ып алу** разжиди́ться на вре́мя; **~ып бетү** оконча́тельно разжиди́ться, рассе́яться; **~ып китү** стать разжижённым (разжи́женным); рассе́яться

сыеклаткыч *прил. сущ. см.* **сыеклагыч**

сыеклату *перех.* **1.** разжижа́ть/разжиди́ть *что чем; куасны ~* разжиди́ть квас **2.** разбавля́ть/разба́вить, разводи́ть/развести́ *что чем; әйрән ~* разба́вить айра́н **3.** рассе́ивать/рассе́ять *что; караңгылыкны ~* рассе́ивать темноту́

сыеклатылу *страд. от* **сыеклату**

сыекл|ау *перех.* **1.** разжижа́ть/разжиди́ть, сжижа́ть/сжиди́ть *что* || разжиже́ние, сжиже́ние; *газ ~ау* сжижа́ть газ **2.** разбавля́ть/разба́вить, разводи́ть/развести́ *что чем* || разбавле́ние, разведе́ние; *буяу ~ау* развести́ кра́ску; *измә ~ау* разводи́ть раство́р □ **~ап алу (кую, таплау)** развести́; **~ый бирү** разбавля́ть (*несмотря ни на что*); **~ый төшү** чуть разба́вить

сыеклы|к *сущ. в разн. знач.* жи́дкость || жи́дкостный; *төссез ~к* бесцве́тная жи́дкость; *җилемнең ~гы* жи́дкость кле́я; *~к үзлекләре* жи́дкостные сво́йства; *~к хәлендә* в жи́дкостном состоя́нии

сыекча *сущ.* **1.** жи́дкость; *~лар үлчәве* ме́ры жи́дкостей; *ягулык ~* горю́чая жи́дкость **2.** жи́жа; *тирес ~сы* навозная жи́жа; *куе ~* густа́я жи́жа; *болганчык ~* му́тная жи́жа **3.** сок; *ашказаны ~сы* желу́дочный сок; *~ бүлеп чыгару* вы́делить сок || *прил. диал.* **1.** жи́дкий, ре́дкий; *~ болытлар* жи́дкие облака́ **2.** сла́бый, ту́склый; *~ караңгылык* ту́склая темь

сыекчалы *прил.* **1.** с жи́дкостью; *~ шешә* бутылка с жи́дкостью **2.** жи́дкостный; *~ двигатель* жи́дкостный дви́гатель

сыем *сущ.* вмести́мость, ёмкость; *үпкәнең ~ы* вмести́мость (ёмкость) лёгких

сыемлы *прил.* ёмкий, вмести́тельный

сыемлык *сущ.* вмести́тельность

сыендыру *перех.* **1.** прижима́ть/прижа́ть *к кому-чему; баланы үзенә ~* прижима́ть ребёнка к себе́ **2.** приюти́ть *кого*, дава́ть/дать убе́жище, приюти́ть *кому; эзәрлекләнүчене үзендә ~* приюти́ть пресле́дуемого **3.** укрыва́ть/укры́ть, пря́тать/спря́тать *кого; канат астына ~* укры́ть под своё крыло́ **4.** *перен.* брать/взять под своё покрови́тельство, под свою́ защи́ту || покрови́тельство

сыен|у *неперех.* **1.** жа́ться, прижима́ться/прижа́ться, льнуть, прильну́ть *к кому-чему; анасына ~у* прильну́ть к ма́тери; *җиргә ~у* прижа́ться к земле́; *күкрәгенә ~у* прильну́ть к его́ груди́; *бер-берсенә ~ып* прижима́ясь друг к дру́гу **2.** юти́ться, приюти́ться; *почмакка ~у* приюти́ться в углу́; *тыкрыкка ~ып утырган өй* приюти́вшийся в переу́лке до́мик; *урман кочагына ~ып* приюти́вшись в лесу́ **3.** укрыва́ться/укры́ться, пря́таться, спря́таться; *чатыр эченә ~у* укры́ться под шатро́м; *мич артына ~у* спря́таться (укры́ться) за пе́чью **4.** *перен.* прибега́ть/прибе́гнуть к покрови́тельству (под защи́ту) *кого; аллага ~у* прибе́гнуть к покрови́тельству бо́га □ **~а төшү** слегка́ прижима́ться/прижа́ться, льнуть; **~ыр урын** прию́т, приста́нище ◊ **~ыр урын тапмау; сыеныр урын таба алмау** не найти́ себе́ приста́нища; **~ыр урын юк** не́где (не́куда) го́лову приклони́ть (приткну́ть)

сыеныч *сущ.* **1.** приста́нище, прию́т **2.** убе́жище; *~ табу* находи́ть убе́жище; *сәяси ~ урыны* полити́ческое убе́жище

сыенышу *взаимно-совм. от* **сыену**; *бер-беренә ~* прильну́ть друг к дру́гу

сыер *сущ.* **1.** коро́ва || коро́вий; *кысыр ~* я́ловая коро́ва; *буаз ~* сте́льная коро́ва; *мукләк ~* комо́лая коро́ва; *савым ~* до́йная коро́ва; *сөзгәк ~* бодли́вая коро́ва; *нәсел ~ы* племенна́я коро́ва; *~ сөте* коро́вье молоко́; *~ саву* дои́ть коро́ву; *~ы барның сые бар* коро́ва на дворе́ — харч на столе́ **2.** *перен. прост.* коро́ва, неуклю́жий (*человек*); *~ шикелле ята* улёгся, как коро́ва **3.** *вторая часть составных названий рогатых животных, соответствующая суффиксам* -уха, -иха *или слову* са́мка; *болын ~ы* олену́ха; *поши ~ы* лоси́ха □ **~ абзары** коро́вник; **~ бозаулау 1.** тели́ться, отели́ться **2.** оте́л; **~ елы** *ист.* Год коро́вы (*второй год двенадцатилетнего цикла в древнетюркском календаре*); **~ ите** говя́дина; **~ караучы** коро́вница, ско́тник, ско́тница; **~ койрыгы** *бот.* коровя́к мете́льчатый; коровя́к мучни́стый; **~ күзе** *бот.* рома́шка тысячелистная; **~ савучы** дояр, доя́рка; **~ теле** *бот.* пастерна́к посевно́й; **~ тизәге** коровя́к; **~ тиресе** я́ловка; **~ шалканы** *диал.* брю́ква ◊ **~га камыт кидеру; ~ дагалап йөрү** занима́ться бессмы́сленной рабо́той; пуста́я зате́я

сыер|у *перех. диал.* **1.** сдира́ть/содра́ть, ободра́ть *что чем; см.* **сыдыру**; *аякны ~у* ободра́ть но́гу; *тирене ~у* сдира́ть ко́жу **2.** засу́чивать/засучи́ть *что; җиңнәрен ~ып* засучи́в рукава́

сыерчык *сущ.* скворе́ц || скворе́чий; скворе́чный, скворчи́ный; *~лар килделәр* прилете́ли скворцы́; *~ сайрау* скворе́чий ще́бет; ще́бет скворца́; *ана ~* скворчи́ха □ **~ баласы** скворчо́нок; **~ бураны** апре́льские мете́ли; по́здние бура́ны; **~ оясы** скворе́чник, скворе́чница, скворе́чня

сыерыл|у *страд. от* **сыеру**; сдира́ться, быть со́дранным

сыеш *сущ.* вмести́мость, ёмкость

сыешлы *прил.* **1.** вмеща́ющий, вмести́мостью в ...; *йөз баш бозау ~ абзар* сара́й (теля́тник) вмести́мостью в сто теля́т **2.** *вторая часть словосочетаний, обозначающая размер, ёмкость чего-л.*; ёмкостью в ..., вмести́мостью в ...; -ный; *бер чиләк ~ самавыр* самова́р ёмкостью в одно́ ведро́, ведёрный самова́р; *йөз тонна ~ силос базы* си́лосная я́ма ёмкостью в сто тонн, стото́нная си́лосная яма **3.** *вторая часть словосочетаний, обозначающая размер;* умеща́ющийся в ...; ...-ного разме́ра; *кесәгә ~* умеща́ющийся в карма́не, карма́нного разме́ра

сыешлы|к *сущ.* ёмкость; *савытның ~гын билгеләү* определи́ть ёмкость сосу́да; *электр үткәргеченең ~гы* ёмкость электропро́вода

сыешмау *неперех.* не совмеща́ться || несовмести́мость; *психологик яктан ~* психологи́ческая несовмести́мость

сыеш|у *неперех.* **1.** *взаимно-совм. от* **сыю** совмеща́ться/совмести́ться || совмеще́ние **2.** умеща́ться/умести́ться, помеща́ться/помести́ться, вмеща́ться/вмести́ться *во что; елга ярларына ~мый* река́ не умеща́ется в свои́х берега́х; *юлга ~а алмыйлар* не вмеща́ются в доро́гу; *шатлык эчкә ~мый* ра́дость не умеща́ется во мне **3.** *редко перен.* укла́дываться/уложи́ться *во что; см.* **сыю**; *аның җавабы башка ~мый* его́ отве́т не укла́дывается в голове́ **4.** *перен.* (*со словом* **үзара**) совмеща́ться/совмести́ться || совмести́мость; *бу фикер икенчесе белән үзара ~маска да мөмкин* э́та иде́я мо́жет не совмеща́ться с друго́й; *бу принциплар үзара ~мый* э́ти при́нципы не совмеща́ются; *психологик яктан үзара ~у* психологи́ческая совмести́мость **5.** *перен.* ужива́ться/ужи́ться; *кешеләр белән ~мый* не ужива́ется с людьми́ **6.** *перен.* (*после слов, обозначающих различные чувства*) держа́ть, сде́рживать *что*; кипе́ть; *ачуга ~а алмый* кипи́т от зло́сти; *дәртенә ~а алмый* не мо́жет сдержа́ть свою́ страсть

сыза I *сущ.* **1.** ба́лка, сухая́ ба́лка (*длинный овраг*); *~ларга су төшкән* в ба́лках появи́лась вода́ **2.** *диал.* межа́; *~ калдыру* оста́вить межу́

сыза II *нареч.* чу́точку, нешироко́, у́зко; *тәрәзәне ~гына ачып* чуть приоткры́в окно́

сызгалан|у *возвр.-страд. от.* **сызу**; *аның маңгае җыерчыклар белән ~ган* его́ лоб исчёрчен морщи́нами

сызгал|ау **1.** *многокр. от* **сызу** **2.** черка́ть, расчёркивать, исчёркивать *что по чему*; *өстәл тактасына ~ау* черка́ть по пове́рхности стола́; *җиргә ~ау* расчёркивать по земле́ **3.** *перен.* начёркивать/начерка́ть, набра́сывать/наброса́ть *что; куен дәфтәренә берничә сүз ~ау* начерка́ть не́сколько слов в записну́ю кни́жку; *аның рәсемен ~ау* наброса́ть её портре́т **4.** *перен. разг.* дра́пать, удира́ть *от кого-чего; малайлар берәм-берәм ~ый башладылар* ма́льчики на́чали по одному́ удира́ть □ **~ап алу** начерти́ть, наброса́ть; **~ап бетерү** **1.** исчерка́ть, исчерти́ть *что* **2.** исписа́ть; **~ап ташлау (кую)** наброса́ть, начерка́ть *что*; зачеркну́ть

сызгандыру *понуд. от* **сызгану**

сызган|у *перех.* **1.** засу́чивать/засучи́ть, зака́тывать/зака́тать *что* || засу́чивание; *җиң ~у* засучи́ть рукава́; *чалбар балакларын тезгә кадәр ~у* зака́тать штани́ны до коле́н **2.** обнажа́ть/обнажи́ть, оголя́ть/оголи́ть *что; аякны ~у* оголи́ть но́ги; *беләкләрен ~у* оголи́ть ру́ки **3.** *в знач. нареч. перен.* **сызганып** всей душо́й, с гото́вностью; *кызларын бирергә ~ып торалар* всей душо́й гото́вы отда́ть свою́ дочь □ **~а төшү** не́сколько засучи́ть, зака́тать *что;* **~ып алу** засучи́ть, зака́тать (*быстро или на время*); **~ып ату (ташлау)** (бы́стро) засучи́ть, зака́тать *что;* **~ып кую** засучи́ть, зака́тать (*заранее*)

сызганулы *прил.* **1.** зака́танный, засу́ченный; *~ балак* зака́танные штани́ны **2.** *в функции сказуемого* зака́таны; *җиңнәре ~* рукава́ засу́чены

сызганышу *взаимно-совм. от* **сызгану**

сызгы *сущ. спец.* черти́лка (*в плотницком деле*)

сызгырак: сызгырак чыпчык *зоол.* свири́стель; *см. тж.* **урман чыпчыгы**

сызгыргала|у *многократ. от* **сызгыру**; посви́стывать, насви́стывать || посви́стывание, насви́стывание; *күңелле ~у* ве́село посви́стывать □ **~п кую** насви́стывать; посви́стывать

сызгыргыч *сущ. см.* **сызгырткыч**

сызгырткыч *сущ.* свисто́к, свисту́лька; *паровоз ~ы* свисто́к парово́за

сызгыртма *сущ. диал. см.* **сыбызгы**; *~ ясау* сде́лать свисто́к

сызгыртты́ру **1.** *понуд. от* **сызгырту**; заставля́ть/заста́вить посвисте́ть **2.** дава́ть/дать гудо́к (*о паровозе и т. п.*)

сызгырт|у *перех.* **1.** свиста́ть, свисте́ть, посвисте́ть || свист; *уенчык сыбызгы ~у* свисте́ть в свисту́льку (ду́дку); *чыбыркы ~у* свисте́ть кнуто́м; *паровоз ~а* парово́з свисти́т; *сузып ~у* протя́жный свист **2.** свисте́ть, насви́стывать; *моңлы бер көй ~у* насви́стывать гру́стную мело́дию **3.** *перен. разг.* свисти́нуть, спере́ть; *акчаны ~у* спере́ть де́ньги □ **~а бирү, ~уын дәвам итү** продолжа́ть свисте́ть; **~кан тавыш** свисто́к; **~ып алу (кую)** свисти́нуть; **~ып җибәрү** свисти́нуть

сызгыр|у *неперех.* **1.** *в разн. знач.* свиста́ть, свисте́ть, посвисте́ть, издава́ть/изда́ть свист || свист, по́свист; *эче итеп ~у* ре́зко (пронзи́тельно) свисте́ть; *җил ~а* сви́щет ве́тер; *сандугач ~уы* тре́ли соловья́; *пулялар ~а* свиста́т пу́ли; *~а торган уклар* свиста́щие стре́лы **2.** свисте́ть, насви́стывать *что; күңелле көй ~у* насви́стывать весёлую мело́дию **3.** *в знач. нареч.* **сызгырып** со сви́стом; *~ып очалар* лета́ют со сви́стом □ **~а бирү** продолжа́ть свисте́ть; **~ган тавыш** свист; *ачы итеп ~ган тавыш* пронзи́тельный свист; **~ып алу** посвисте́ть; **~ып җибәрү (кую)** **1.** сви́стнуть **2.** засвисте́ть; **~ып көйләү** насви́стывать; **~ып чакыру** посвиста́ть ◊ **~а беләсеңме?** вот тебе́ и на; вот те на; вот тебе́ раз

сызгырулы *прил. лингв.* свиста́щий; *~ тавыш* свиста́щий звук; *~ тартыклар* свиста́щие согла́сные; *~ авазлар* свиста́щие зву́ки

сызгырчык *сущ.* **1.** свисту́лька **2.** свисту́н **3.** свистунно́к (*вид некоторых птиц и грызунов*)

сызгырык *сущ. диал.* свист, по́свист; *шайтани ~* дья́вольский свист (по́свист)

сызгырын|у *неперех.* насви́стывать, посви́стывать || насви́стывание, посви́стывание (*про себя*); *ул бер көй ~а* он насви́стывает (одну́) мело́дию □ **~ып йөрү** постоя́нно насви́стывать (*на ходу*)

сызгырышу *взаимно-совм. от* **сызгыру**

сызгыч I *сущ.* **1.** лине́йка || лине́ечный; *агач ~* деревя́нная лине́йка **2.** *тех.* ре́йсмус

сызгыч II *сущ. муз.* смычо́к; *скрипка ~ы* смычо́к скри́пки

сызгыч III *сущ.* **1.** нама́зка (*на спичечном коробке*) **2.** *диал.* спи́чки *мн.*

сызды-быздыбыздый *прил. см.* **сыздый-быздый**

сыздый-быздый *прил.* **1.** небре́жный, небре́жно испо́лненный; неаккура́тный, неря́шливый; *сыздый-быздый рәсемнәр* небре́жно сде́ланные рису́нки **2.** *в знач. нареч.* небре́жно, неаккура́тно; неря́шливо; *сыздый-быздый буялган* покра́шено кра́йне небре́жно (неря́шливо)

сыздырт|у *гл.* **1.** *понуд. от* **сыздыру 2.** *разг.* стега́ть/стегну́ть, стегану́ть *прост.; камчы белән ~у* стега́ть кнуто́м **3.** *перен. разг.* наи́ривать, шпа́рить, иску́сно игра́ть; *гармунда ~у* шпа́рить на гармо́ни; *«Карурман» көен ~у* иску́сно заигра́ть мело́дию «Карурма́н» **4.** *перен. прост.* дра́пать, драпану́ть, дава́ть/дать дра́пу, дава́ть/дать стрека́ча; стрекану́ть; убира́ться/убра́ться; *ул инде куптән ~кан* он уже́ давно́ драпану́л; *~ моннан* убира́йся отсю́да **5.** спи́сывать/списа́ть (*со счетов и т. п.*); убира́ть/убра́ть (*из списка*); **~ып алу** стегну́ть, стегану́ть *прост.*

сыздыртыл|у *страд. от* **сыздыру** (*преимущ. от знач.* 5); *~ган әйбер* спи́санная вещь

сыздыр|у 1. *понуд. от* **сызу** 1 **2.** *разг.* стега́ть/стегну́ть, стегану́ть *прост. см. тж.* **сыдыру, сыеру**; *аркасына ~у* стегну́ть по спине́; *чыбыркы белән ~у* стега́ть кнуто́м **3.** *перен. разг.* тяну́ть, проте́жно петь (игра́ть) (*на музыкальном инструменте*) **4.** *перен. разг.* наи́ривать, шпа́рить, иску́сно игра́ть (сыгра́ть); *ул баянын ~ып җибәрде* он на́чал иску́сно игра́ть на баяне; *бию көен ~у* сыгра́ть плясову́ю мело́дию; *сандугач ~а* соловей́ залива́ется; *~ып уйный* иску́сно игра́ет **5.** *перен. прост.* дра́пать/драпану́ть, дава́ть/дать дра́пу, дава́ть/дать стрека́ча; убира́ться/убра́ться; *урманга ~у* дра́пать в лес ◻ **~ып алу 1.** стегну́ть, стегану́ть **2.** сыгра́ть; **~ып кую** сыгра́ть

сыздырылу *страд. от* **сыздыру**

сызлавык *сущ.* чи́рей, боля́чка, фуру́нкул; *~ чыккан* вскочи́л чи́рей; *~ тишелде* прорва́лся фуру́нкул; *бөтен тәне ~ белән капланды* всё его́ те́ло покры́лось чи́рьями

сызландыр|у 1. *понуд. от* **сызлану**; *бу уйлар аның йөрәген ~а* э́ти мы́сли заставля́ют ныть её се́рдце **2.** *безл.* ломи́ть (*о теле*)

сызлан|у *неперех.* **1.** чу́вствовать, почу́вствовать но́ющую боль; ныть, заны́ть; стона́ть, страда́ть; *ярадан ~у* страда́ть от ра́ны **2.** *перен.* горева́ть, кручи́ниться, изболе́ться душо́й, изболе́ть; стена́ть, ныть; *кешеләр өчен ~у* изболе́ться душо́й за люде́й; *җан ~а* душа́ изболе́лась; *йөрәк ~а* се́рдце но́ет || *сущ.* **1.** (но́ющая) боль, нытьё, страда́ние; *чамасыз ~у* нестерпи́мая но́ющая боль; *~уга чыдый алмау* не выде́рживать бо́ли; *эчтән ~у* вну́тренняя боль **2.** *перен.* го́ре, кручи́на; страда́ние; *күңел ~у* душе́вное страда́ние ◻ **~у тавышы** стон; *~у тавышы ишетелә* слы́шится стон ◻ **~ып алу, китү 1.** застона́ть; *авыру ~ып куйды* больно́й застона́л **2.** заны́ть

сызланулы *прил.* по́лный бо́ли; *~ караш* взгляд, по́лный бо́ли; *~ хәрәкәт* движе́ние, по́лное бо́ли

сызланучан *прил.* скло́нный всё вре́мя ныть (стона́ть); *~ хатын* же́нщина, скло́нная всё вре́мя ныть

сызлаткыч *прил.* заставля́ющий ныть (боле́ть); *йөрәк ~ хәбәр* весть, заставля́ющая ныть се́рдце

сызлату *понуд. от* **сызлау**; *йөрәкне ~* заста́вить ныть се́рдце; *теш ~* заста́вить боле́ть зуб

сызл|ау *неперех.* **1.** ныть, боле́ть || нытьё, боль; *теш ~ый* боли́т зуб; *баш ~ый* голова́ боли́т; *йөрәк ~ый* се́рдце но́ет; *ярасы ~ый* но́ет ра́на **2.** ломи́ть || ломо́та; *бил ~ау* ломо́та в поясни́це; *сөякләре ~ый (безл.)* ло́мит ко́сти **3.** гуде́ть, мозжи́ть; *аяклар ~ый* но́ги гудя́т ◻ **~ап алу (кую)** поны́ть; **~ап йөрү (тору)** ныть, боле́ть (*хронически, беспрерывно*)

сызлаулы *прил.* но́ющий, больно́й; *~ яра* но́ющая ра́на; *~ аяклар* больны́е но́ги

сызлаусыз *прил.* (*в заклинаниях, пожеланиях*) здоро́вый, не боле́ющий; *аяк-кулың ~ булсын* пусть твои́ ру́ки и но́ги не боля́т (да бу́дут здоро́вы)

сызлаучан *прил.* **1.** посто́янно жа́лующийся на бо́ли (*о человеке*); *башы ~ карчыклар* стару́шки, у кото́рых посто́янно боли́т голова́ **2.** посто́янно боля́щий (*части тела*); *аның башы ~* у него́ посто́янно боли́т голова́

сызлаштыр|у *многокр. от* **сызлау**; пода́ливать, вре́мя от вре́мени боле́ть (ныть); *кулы азрак ~а* рука́ его́ пода́ливает, вре́мя от вре́мени понемно́гу боли́т

сызма I *прил. с.-х.* пропашно́й; *~ культуралар* пропашны́е культу́ры; *~ система* пропашна́я систе́ма

сызма II *сущ.* **1.** эски́з; набро́сок; *юл ~лары* путевы́е эски́зы; *план ~лары* набро́ски пла́на **2.** *в знач. прил.* эски́зный; *~ план* эски́зный план

сызмалы *прил. мат.* начерта́тельный; *~ геометрия* начерта́тельная геоме́трия

сыз|у I *перех.* **1.** *прям., перен.* черти́ть, нача́ртивать/начерти́ть, прочёркивать/прочерти́ть, линова́ть || черче́ние; линова́ние; проводи́ть/провести́ ли́нию; *сызык ~у* начерти́ть ли́нию; *кәкре сызык ~у* прочерти́ть криву́ю; *түгәрәк ~у* начерти́ть круг; *план ~у* черти́ть план; *карта ~у* начерти́ть карту; *схема ~у* начерти́ть схе́му; *туры юл ~у* начерти́ть пра́вильный путь **2.** *прям., перен.* 1) чи́ркать/чи́ркнуть *что чем; шырпы ~у* чи́ркнуть спи́чкой 2) води́ть, тяну́ть; *смычокны ~у* води́ть смычко́м 3) черкну́ть; *бер-ике сүз ~ды* черкну́л не́сколько слов **3.** зачёркивать/зачеркну́ть *что* || зачёркивание; *язылганны ~у* зачёркивать напи́санное **4.** вычёркивать/вы́черкнуть *что* || вычёркивание; *исемлектән ~у* вы́черкнуть из спи́ска **5.** *перен. разг.* стега́ть/стегну́ть, стегану́ть *прост.; чыбыркы белән ~у* стегану́ть кнуто́м; *камчы белән ~у* стегну́ть пле́тью **6.** проводи́ть/провести́ || проведе́ние (*рубежей, границ и т. п.*); *межа ~у* провести́ межу́; *буразна ~у* провести́ борозду́ **7.** разрыхля́ть/разрыхли́ть, оку́чивать || разрыхле́ние, оку́чивание (плу́гом); *рәт араларын ~у* разрыхля́ть междуря́дья; *бәрәңгене сука белән ~у* оку́чивать карто́фель **8.** *перен. разг.* иску́сно игра́ть (сыгра́ть), тяну́ть; растя́гивать; *гармун ~у* растя́гивать гармо́шку; *скрипка ~у* игра́ть на скри́пке; *көй ~у* тяну́ть мело́дию **9.** *перен. прост.* дра́пать/драпану́ть, дава́ть/дать стрека́ча, удира́ть/удра́ть; убира́ться/убра́ться; *авылдан ~дылар* убрали́сь из села́; *~ моннан* убира́йся отсю́да; *берәр яры ~у* удра́ть куда́-нибудь; *тиз генә ~у* поскоре́е убра́ться ◻ **~а бару 1.** черти́ть, проводи́ть ли́нию **2.** зачёркивать, вычёркивать (*постоянно*); **~а бирү** черти́ть, проводи́ть ли́нию (*несмотря ни на что*); **~а килү** *см.* **~а бару** 2; **~а тору** черти́ть, проводи́ть ли́нию (*пока*); **~а язу** чуть не вы́черкнуть; **~ып җибәрү 1.** чи́ркнуть; *ул смычогын ~ып җибәрде* он чи́ркнул смычко́м; *шырпы ~ып җибәрү* чи́ркнуть спи́чкой **2.** *разг.* заигра́ть; *гармунда ~ып җибәрү* заигра́ть на гармо́ни; **~ып ташлау 1.** вы́черкнуть; *исемлектән ~ып ташлау* вы́черкнуть из спи́ска **2.** зачеркну́ть; *язганны ~ып ташлау* зачеркну́ть напи́санное **3.** черкну́ть **4.** бы́стро начерти́ть; **~ып чыгу 1.** расчерти́ть *что*; *картаны квадратларга ~ып чыгу* расчерти́ть ка́рту на квадра́ты **2.** *перен.* начерти́ть; *гомер юлын ~ып чыгу* начерти́ть жи́зненный путь

сыз|у II *неперех.* **1.** тлеть; *учакта кумер ~ып ята* в очагé тлéет уголёк **2.** *прям., перен.* тáять, растáять, стáять; *язгы кар акрын гына ~а* весéнний снег постепéнно тáет; *авырудан күзгә күренеп ~у* от болéзни тáять на глазáх **3.** *перен.* горевáть, кручи́ниться, беспокóиться; болéть; *эчтән ~у* горевáть про себя́; *ялгыз башы ~ып йөри* горюет одинóко; *йөрәк ~а* сéрдце нóет □ **~а бару** (*постепенно*) тáять

сызучы *сущ.* линовáльщик

сызы|к I *сущ.* **1.** *в разн. знач.* ли́ния, чертá; *туры ~к* прямáя ли́ния (чертá); *кәкре ~к* кривáя ли́ния; *дулкынлы ~к* волни́стая ли́ния (чертá); *горизонталь ~к* горизонтáльная ли́ния; *утлы ~клар* óгненные ли́нии; *офык ~гы* ли́ния горизóнта; *сюжет ~гы* сюжéтная ли́ния **2.** ли́ния, рубéж; *яр ~гы* береговáя ли́ния; *оборона ~гы* ли́ния оборóны; *фронт ~гы* ли́ния фрóнта; *алгы ~к* передовáя ли́ния **3.** *уст.* ли́ния; *телеграф ~гы* телегрáфная ли́ния; *тимер юл ~гы* ли́ния желéзной дорóги **4.** *лингв.* тирé; *ия белән хәбәр арасына ~к кую* стáвить тирé мéжду подлежáщим и сказýемым **5.** склáдка, ли́ния (*на лице*); *ике каш арасындагы ~клар* склáдки меж двух бровéй; *авыз читендәге ~клар* склáдки у рта **6.** *перен. уст.* чертá, свóйство, осóбенность; *шәхеснең характерлы ~клары* характéрные черты́ (осóбенности) ли́чности **7.** клáссы, дóмики (*детская игра*); *~к уйнау* игрá в дóмики □ **~к сызу** проводи́ть/провести́ ли́нию; линовáть, разлиновáть *что*

сызык II *сущ.* шквáрка, шквáрки *мн; см. тж.* **сызыл**; *ашка ~ салу* положи́ть в суп шквáрки; *~ белән бәрәңге* картóшка со шквáрками

сызыклы I *прил.* **1.** 1) линéйный; *~ яшен* линéйная мóлния 2) линóванный, графлёный; *~ дәфтәр* линóванная тетрáдь; *~ бланк* графлёный бланк **2.** *в знач. сущ.* дóмики (*детская игра*); *~ уйнау* игрáть в дóмики

сызыклы II *прил.* **1.** со шквáрками, припрáвленный шквáрками; *~ бәрәңге* картóшка со шквáрками; *~ токмач (кул.)* лапшá со шквáрками **2.** шквáристый; *~ май* шквáристое сáло

сызык-сызык *прил.* линéйчатый; преры́вистый (*о линиях*); *сызык-сызык өслек* линéйчатая повéрхность; *сызык-сызык яктылык нурлары* преры́вистые лучи́ свéта

сызыклы-сызыклы *прил.* линéйчатый; *сызыклы-сызыклы яфрак* линéйчатый лист

сызыкча *сущ.* **1.** чёрточка **2.** склáдочка; *күз тирәсендәге ~лар* склáдочки у глаз **3.** *лингв.* чёрточка, дефúс; *~ кую* стáвить дефúс || *прил. мат.* **1.** линéйный; *~ үлчәнеш* линéйное измерéние; *~ тигезләмә* линéйное уравнéние; *~ берәмлек* линéйная единúца; *~ бәйләлек* линéйная завúсимость **2.** линéйчатый; *~ геометрия* линéйчатая геомéтрия; *~ өслек* линéйчатая повéрхность □ **~ тизлек** *физ.* линéйная скóрость

сызылмалы *прил.* линéйный; *~ орнамент* линéйный орнáмент

сызыл|у I *неперех.* **1.** *страд. от.* **сызу** I; *карандаш белән ~ган* вы́черкнутый карандашóм; *планнар ~ган* начéртаны плáны **2.** прочéрчивать/прочертúть, обозначáться/обознáчиться; проступáть/проступúть; *аның ~ып мыегы чыга* у негó пробивáются ýсики; *күз тирәләрендә җыерчыклар ~ган* под глазáми обознáчились морщúны; *күк фонында беленер-беленмәс үрләр ~ган* на фóне нéба едвá проступáют ли́нии возвы́шенностей **3.** тянýться, вытя́гиваться/вы́тянуться ли́нией; *кара кашлары матур ~ган* у неё краси́во вы́тянулись чёрные брóви; *тау башыннан сукмак ~ган* по верши́не горы́ вы́тянулась тропи́нка; *тәрәзәдән нурлар ~ган* от окнá тя́нутся лучи́ **4.** *перен.* тянýться, доноси́ться; *ераклардан моңлы бер көй ~а* издалекá донóсится грýстная мелóдия □ **~ып алу** обознáчиться; **~ып китү** прочерти́ться

сызыл|у II *неперех.* болéть, тревóжиться, беспокóиться, кручи́ниться; *эчем ~а* душá боли́т; *йөрәк ~ып китте* сéрдце защеми́ло

сызылыш *сущ.* очертáние; *ирен ~лары* очертáния губ

сызым *сущ.* **1.** чертёж || чертёжный; *яңа машина ~нары* чертежи́ нóвой машúны; *бина ~ы* чертёж здáния; *~ тактасы* чертёжная доскá **2.** черчéние; *~ дәресе* урóк черчéния □ **~ бүлмәсе** чертёжная; **~ геометриясе** начертáтельная геомéтрия; **~ сызучы** чертёжник

сызымта *сущ.* очертáние; *ерактагы тауларның ~лары* очертáния далёких гор

сызымчы *сущ.* чертёжник; *см.* **сызым сызучы**

сый *сущ.* **1.** 1) *прям., перен.* угощéние; *бәйрәм сые* прáздничное угощéние; *кунакка төрле сый кую* выставить гóстю рáзные угощéния; *сый тулы тәлинкәләр* тарéлки, пóлные угощéния; *дошман «сые»* «угощéние» от протúвника 2) пир, угощéние; *сыйга чакыру* пригласúть на пир; *сый башланды* начáлся пир **2.** *диал. этногр. трёхдневное угощение, устраиваемое родственниками жениха в честь родителей невесты (свадебный обряд)* ◊ **сыйда йөзү** катáться как сыр в мáсле

сыйга *сущ. грам. уст.* спряжéние; *фигыль ~сы* спряжéние глагóла

сыйдыр|у **1.** *понуд. от* **сыю**; *сыймаса ~ырбыз аны* éсли не умещáется — застáвим уместúться **2.** вмещáть/вместúть *кого-что во что; мичкә илле чиләк су ~а* бóчка вмещáет пятьдеся́т вёдер воды́; *зал барлык теләүчеләрне ~а алмый* зал не мóжет вместúть всех желáющих **3.** *прям., перен.* умещáть/уместúть, уклáдывать/уложúть *кого-что в чём; китапларны чемоданга ~у* уместúть книги в чемодáне; *көймәгә ~у* уместúть в лóдку; *моны башка ~ып булмый* э́то не уклáдывается в голове́; *куанычын эченә ~а алмый* не мóжет скрыть (уместúть в себе́) свою́ рáдость **4.** помещáть/поместúть, поселя́ть/поселúть, приютúть *кого; карчыкны үзебездә ~ырбыз* старýху приютúм у нас **5.** *перен.* совмещáть/совместúть; *законга ~у* совмещáть (согласовáть) с закóном; *логикага ~у* совместúть с лóгикой; *ике тәкә башын бер казанга ~у* совмещáть несовместúмое **6.** *перен.* позволя́ть/позвóлить; дава́ть/дать возмóжность; *вакыт ~мый* врéмя не позволя́ет; *күләм ~мый* размéры не позволя́ют; *вөҗданы ~мый* сóвесть не позволя́ет □ **~а язу** чуть не уместúть (уложúть); **~ып бетерү** уместúть, уложúть *кого-что*

сыйдырыш *сущ.* **1.** вместúмость, ёмкость **2.** водоизмещéние; *суднының ~ы* водоизмещéние сýдна

сыйдырышлы *прил.* **1.** вмещáющий *что, сколько*, ёмкостью (вместúмостью) в ...; *ике тонна ~ цистерна* цистéрна, вмещáющая две тóнны; цистéрна ёмкостью в две тóнны; *өч кубометр ~ савыт* сосýд ёмкостью в три кубомéтра; *алты мең кеше ~ зал* зал, вмещáющий шесть ты́сяч человéк **2.** вместúтельный; *~ савыт* вместúтельный сосýд

сыйдырышлы|к *сущ.* вместúмость, ёмкость; *вагонның ~гы* вместúмость вагóна

сыйдырышлылы|к *сущ.* **1.** вместúтельность **2.** *см.* **сыйдырышлык**; *мичкәнең ~гы* ёмкость бóчки

сыйлангалау *многокр. от* **сыйлану**

сыйлан|у *неперех.* угощáться/угостúться, лáкомиться, полáкомиться *чем* || угощéние; *туйда ~у* угощáться на

сва́дьбе; *кеше исәбенә ~у* угоща́ться за счёт други́х; *җилә́к белән ~у* пола́комиться я́годами; *мин моны ~у өчен эшләмәдем* я сде́лал э́то не ра́ди угоще́ния □ **~а бирү (тору)** продолжа́ть ла́комиться; **~ып алу** пола́комиться; **~ып яту** гости́ть

сыйланышу *взаимно-совм. от* **сыйлану**

сыйлап-сыйлап *нареч.* ума́сливанием, угоще́ниями; *сыйлап-сыйлап кына эш итә* он де́йствует ума́сливанием (угоще́ниями)

сыйлап-сырлап *нареч.* путём подноше́ний, угоще́ний; ума́сливанием; *байлар сыйлап-сырлап үз малларын алып калдылар* богачи́ суме́ли сохрани́ть свой скот путём ума́сливания (*начальства*)

сыйлату *понуд. от* **сыйлау**

сыйл|ау *неперех. прям., перен.* угоща́ть/угости́ть, по́тчевать, попо́тчевать *кого, чем* || угоще́ние, по́тчевание; *кунак ~ау* угоща́ть го́стя; *алма белән ~ау* угости́ть я́блоком; *камчы белән ~ау* «угости́ть» пле́тью; *үгетнәсихәт белән ~ау* по́тчевать наставле́ниями □ **~ап алу** угости́ть; **~ап ташлау** угости́ть (ненаро́ком); **~ап чыгу** угости́ть (подря́д); **~ый бару** угоща́ть (*по ходу*); **~ый бирү (тору)** продолжа́ть угоще́ние, продолжа́ть по́тчевать ◊ **~аганда су эч** дово́льствоваться ма́лым (*погов.*) (*букв.* когда́ угоща́ют, и во́ду пей)

сыйлаучан *прил.* хлебосо́льный, раду́шный, гостеприи́мный; *кунак ~ кеше* гостеприи́мный челове́к

сыйлаштыру *многокр. от* **сыйлау**; *кунак ~* вре́мя от вре́мени угоща́ть госте́й

сыйлашу *взаимно-совм. от* **сыйлау**; угоща́ть друг дру́га

сыйлы *прил.* **1.** по́лный яств; *~ табын* стол, по́лный яств **2.** хлебосо́льный, гостеприи́мный; *~ хуҗа* хлебосо́льный хозя́ин **3.** сы́тый; *көтүченең тормышы ~* жизнь у пастуха́ сы́тая; *~ көн* сы́тая жизнь

сыймаслык: акылга сыймаслык 1. уму́ непостижи́мый, невероя́тный **2.** уму́ непостижи́мо, невероя́тно

сыйнфый *прил.* **1.** кла́ссовый; *~ көрәш* кла́ссовая борьба́; *~ аң* кла́ссовое созна́ние; *~ дошман* кла́ссовый враг; *~ аерымлыклар* кла́ссовые разли́чия; *~ бердәмлек* кла́ссовая солида́рность; *~ җәмгыять* кла́ссовое о́бщество **2.** *в знач. нареч. ~ чикләнгән* кла́ссово ограни́ченный

сыйнфыйлык *сущ.* кла́ссовость

сыйныф I (сыйныф-) *сущ.* класс (*социальная группа*) || *уст.* кла́ссовый; *эшчеләр ~ы* рабо́чий класс; *изелгән ~лар* угнетённые кла́ссы; *буржуазия ~ы* класс буржуази́и; *~ көрәше* кла́ссовая борьба́; *~ эше* кла́ссовое де́ло; *~ аермалары* кла́ссовые разли́чия □ **~тан тыш** вне́классовый

сыйныф II *сущ. уст. в разн. знач.* класс (*учебный*) || кла́ссный; *беренче ~та уку* учи́ться в пе́рвом кла́ссе; *~ка керү* войти́ в класс; *~ агаҗурә басты* класс встал; *дүрт ~лы авыл мәктәбе* четырёхкла́ссная се́льская шко́ла □ **~ бүлмәсе** кла́ссное помеще́ние, класс

сыйныфлы *прил.* кла́ссовый; *~ җәмгыять* кла́ссовое о́бщество; *~ тормыш* кла́ссовая жизнь

сыйныфлык *сущ.* кла́ссовость || кла́ссовый; *~ нигезендә* на осно́ве кла́ссовости; на кла́ссовой осно́ве || *прил. уст.* кла́ссный; *ике ~ мәктәп* двухкла́ссная шко́ла

сыйныфсыз *прил.* бескла́ссовый; *~ җәмгыять* бескла́ссовое о́бщество

сыйныфсызлану *неперех. неол.* декласси́роваться

сыйныфсызлык *сущ.* бескла́ссовость

сыйныфташ I *прил.* **1.** кла́ссовый, принадлежа́щий одному́ кла́ссу; *~ туганнар* кла́ссовые бра́тья **2.** *в знач. сущ.* представи́тель своего́ кла́сса; *~ларга хыянәт итү* измени́ть представи́телям своего́ кла́сса

сыйныфташ II *сущ. уст.* однокла́ссник; това́рищ по кла́ссу

сыйныфчылык *сущ. уст.* кла́ссовость; *~ позициясенән* с пози́ции кла́ссовости

сыйпалан|у *неперех.* **1.** ласка́ться, ла́ститься *разг.; аяк астында ~* ла́ститься в ногах (*о кошке*) **2.** *см.* **сыйпану 1**; *көзге алдында ~* прихора́шиваться пе́ред зе́ркалом

сыйпалату *понуд. от* **сыйпалау**; позволя́ть/позво́лить гла́дить

сыйпал|ау *перех.* **1.** *многокр. от* **сыйпау**; погла́живать **2.** гла́дить, погла́дить, ласка́ть, приласка́ть *кого-что; башыннан ~ау* гла́дить по голове́; *мәчене сыртыннан ~ау* гла́дить ко́шку по спине́ □ **~ап алу (кую)** погла́дить (бы́стро и́ли чуть-чу́ть); **~ап тору** гла́дить (*постоянно*); **~ый бирү** продолжа́ть гла́дить

сыйпал|у 1. *страд. от* **сыйпау**; гла́диться; погла́живаться, быть погла́женным **2.** ла́ститься, прила́ститься; *җиңелчә җил биткә ~а* лёгкий ветеро́к ласка́ет лицо́ (*букв.* ла́стится к лицу́)

сыйпангалау *многокр. от* **сыйпану**

сыйпану *неперех.* **1.** пригла́живаться, прихора́шиваться **2.** *диал. см.* **капшану**

сыйпату *понуд. от* **сыйпау**

сыйп|ау *перех.* **1.** гла́дить, погла́дить, ласка́ть, приласка́ть *кого-что* || погла́живание; *аркадан ~ау* гла́дить по спине́; *баштан ~ау* погла́дить по голо́вке; *чәчләрен ~ау* гла́дить во́лосы **2.** ласка́ть, приласка́ть *кого-что; җил чәчне ~ый* ве́тер ласка́ет во́лосы □ **~ап алу (кую)** погла́дить, приласка́ть; **~ый бирү** продолжа́ть гла́дить (ласка́ть)

сыйпаштыргалау *неперех.* **1.** *многокр. от* **сыйпау 2.** погла́живать вре́мя от вре́мени; *авырткан тезне ~* погла́живать вре́мя от вре́мени больно́е коле́но

сыйпаштыру *многокр. от* **сыйпау**; слегка́ погла́живать; *чәчләрен ~* слегка́ погла́живать во́лосы

сыйпашу *взаимно-совм. от* **сыйпау**; *баштан ~* гла́дить друг дру́га по голове́

сыйра|к *сущ.* **1.** го́лень; бёрце, берцо́ || берцо́вый; *~ктан тешләү* укуси́ть за го́лень; *~к сөяге* берцо́вая кость **2.** *разг.* нога́; *нечкә ~к* то́нкая но́жка; *озын ~к* дли́нная нога́; *арт ~гыннан эләктерү* схвати́ть за за́днюю но́гу

сыйраклы *прил.* **1.** голена́стый; *озын ~* голена́стый **2.** *вторая часть составных слов, соответствующая рус.* -но́гий; *нечкә ~* тонконо́гий; *озын ~* длинноно́гий

сыйрап *сущ. разг. см.* **сырат**

сыйсыз: сыйсыз көн *диал.* нена́стный день

сыйфат I *сущ.* **1.** *в разн. знач.* ка́чество || ка́чественный; *микъдарның ~ка күчүе* перехо́д количества в ка́чество; *уңай ~* положи́тельное ка́чество; *шәхси ~* ли́чное ка́чество; *эшнең ~ы* ка́чество рабо́ты; *кешелек ~лары* челове́ческие ка́чества; *югары ~* высо́кое ка́чество; *~ комиссиясе* коми́ссия по ка́честву; *~ анализы хим.* ка́чественный ана́лиз; *~ үзгәрешләре* ка́чественные измене́ния **2)** сво́йство, осо́бенность, черта́; *аңа хас ~* характе́рное его́ сво́йство; *характерлы ~лар* характе́рные осо́бенности; *уртак ~лар* о́бщие черты́; *индивидуаль ~лар* индивидуа́льные осо́бенности (черты́) **3)** *уст.* вид; *тәкәббер ~та* с надме́нным ви́дом; *сүзенә көлү ~ы бирү* придава́ть свои́м слова́м вид насме́шки **2.** вид, о́блик, вне́шность, обли́чье; *фәрештә ~ында* в о́блике

а́нгела; *адәм ~ына керү* приобрести́ о́блик челове́ка □ **~ ягыннан** ка́чественно; *~ ягыннан яңа баскыч* ка́чественно но́вая ступе́нь; *~* **ягыннан оту** *шахм.* вы́играть ка́чество; **~ы белән** *уст.* в ка́честве *кого; см.* **сыйфатында**; *приказчик ~ы белән* в ка́честве прика́зчика; *урынбасар ~ы белән* в ка́честве замести́теля

сыйфат II *сущ. грам.* и́мя прилага́тельное; *асыл ~* ка́чественное прилага́тельное; *нисби ~* относи́тельное прилага́тельное □ **~ дәрәҗәләре** *грам.* сте́пени сравне́ния прилага́тельных; *~* **фигыль** *грам.* прича́стие

сыйфатлама *сущ. уст. редко* характери́стика; описа́ние; *паспортындагы ~сы буенча* исходя́ из характери́стики по па́спорту

сыйфатландыру *перех. редко* характеризова́ть, охарактеризова́ть *кого-что* || характери́стика

сыйфатландырыл|у *страд. от* **сыйфатландыру**; *ныграк ~ып бирелгән* наибо́лее си́льно охарактеризо́вано

сыйфатланмыш *сущ. грам. уст.* определя́емое сло́во; *сыйфат һәм ~тан торган катлаулы атамалар* составны́е те́рмины, состоя́щие из определе́ния и определя́емого сло́ва

сыйфатлан|у *неперех.* **1.** характеризова́ть, охарактеризова́ться; *бу чор тубәндәгечә ~а* э́тот пери́од характеризу́ется сле́дующим о́бразом **2.** обрисо́вываться/обрисова́ться, опи́сываться *чем*

сыйфатла|у *перех.* **1.** характеризова́ть, охарактеризова́ть *кого-что* || характери́стика; *оста ~у* ма́стерская характери́стика; *иҗтимагый күренешләрне ~у* охарактеризова́ть обще́ственные явле́ния **2.** обрисо́вывать/обрисова́ть, опи́сывать/описа́ть *кого-что* || обрисо́вывание, описа́ние; *табигать күренешләрен ~у* описа́ние пейза́жа □ **~п бирү** *1.* охарактеризова́ть *кого-что* **2.** обрисова́ть, описа́ть *кого-что*

сыйфатлашу *сущ. грам.* адъективи́рация; *~ процессы* проце́сс адъективи́рации

сыйфатлы *прил.* **1.** ка́чественный; *~ кирпеч* ка́чественный кирпи́ч; *~ ашлык* ка́чественное зерно́ **2.** *в словосочетаниях с прилагательными* **яхшы, югары, түбән** *соответствует русскому* ка́чественный, ка́чества; *югары ~* высокока́чественный; *түбән ~* ни́зкого ка́чества; *яхшы ~* хоро́шего ка́чества; с хоро́шим ка́чеством, доброка́чественный; *төрле ~* ра́зного ка́чества **3.** *в словосочетаниях с некоторыми прилагательными и существительными соответствует русскому* ви́да, в о́блике, подо́бный; *куркыныч ~* стра́шного ви́да; *рус ~* в о́блике ру́сского

сыйфатлылы|к *сущ.* **1.** ка́чественность **2.** ка́чество; *продукциянең ~гын күтәрү* подня́ть ка́чество проду́кции; *орлык ~гын билгеләү* определе́ние ка́чества зерна́

сыйфатсыз *прил.* **1.** нека́чественный; недоброка́чественный; *~ продукция* нека́чественная (недоброка́чественная) проду́кция **2.** *в знач. нареч.* нека́чественно, недоброка́чественно; *~ эшләнгән* сде́лано нека́чественно

сыйфатсызлы|к *сущ.* нека́чественность, недоброка́чественность; *эшләнмәнең ~гы* недоброка́чественность изде́лия

сыйфатында *послелог* в ка́честве; *күзәтче ~* в ка́честве наблюда́теля; *корреспондент ~* в ка́честве корреспонде́нта

сый-хөрмәт *сущ. собир.* **1.** угоще́ние; *сый-хөрмәтегез өчен рәхмәт* спаси́бо за угоще́ние; *сый-хөрмәттән баш тартмау* не отказа́ться от угоще́ния; *мул сый-хөрмәт* оби́льное угоще́ние **2.** *перен.* че́ствование, почёт, честь; *сый-хөрмәт күрсәтү* оказа́ть почёт □ **сый-хөрмәт мәҗлесе** пир

сыккалау *многокр. от* **сыгу**

сыккыч *сущ.* пресс, соковыжима́лка

сыкра *диал. прил.* **1.** не держа́щий мочу́; *~ малай* ма́льчик, страда́ющий недержа́нием мочи́ (*во время сна*) **2.** *перен.* брюзгли́вый, брюзжа́щий; ворчли́вый **3.** *перен.* скупо́й; *~ кеше* скупо́й челове́к || *сущ. мед.* недержа́ние мочи́; *~ белән авыру* страда́ть недержа́нием мочи́

сыкрандыргыч *прил.* заставля́ющий ныть; *йөрәктәге ~ бушлык* пустота́ в се́рдце, заставля́ющая ныть ду́шу

сыкрандыру *понуд. от* **сыкрану**

сыкран|у *неперех.* ныть, заны́ть, стона́ть || ны́тьё, но́ющая боль; *ярадан ~у* ныть (стона́ть) от ра́ны; *күңел ~а* душа́ боли́т (сто́нет); *йөрәк ~а* се́рдце но́ет □ **~а бирү** продолжа́ть ныть (стона́ть); **~ып алу (китү), кую** заны́ть, застона́ть; **~ып җибәрү** застона́ть

сыкранулы *прил.* но́ющий, сто́нущий; напо́лненный сто́ном, выража́ющий стон; *~ тавыш* го́лос, напо́лненный сто́ном; сто́нущий го́лос

сыкрануч ан *прил.* постоя́нно но́ющий, постоя́нно жа́лующийся □ **~ кеше** ны́тик

сыкранышу *взаимно-совм. от* **сыкрану**

сыкрап-сыктап *нареч.* со сто́ном, со стена́нием; *сыкрап-сыктап дөнья көту* жить со сто́нами (со стена́ниями)

сыкраткыч *прил.* заставля́ющий стона́ть (ныть); *күңелне ~ чынбарлык* действи́тельность, заставля́ющая стона́ть (вызыва́ющая стон душй)

сыкрату *понуд. от* **сыкрау**

сыкр|ау *неперех.* **1.** ныть, заны́ть *от чего* || но́ющая боль; *яра ~ый* ра́на но́ет; *куллар ~ый* но́ют ру́ки; *әнисен сагынып ~ады* страда́л от тоски́ по ма́тери **2.** *перен.* стона́ть, застона́ть, стена́ть || стон, стена́ние; *күңел ~ый* се́рдце сто́нет; *җир ~ый* земля́ сто́нет; *моңлы ~ау белән* с печа́льным сто́ном; *эчке ~ау* вну́тренний стон □ **~ап алу (кую, китү, җибәрү) 1.** заны́ть **2.** застона́ть; **~ап елау** стена́ть; пла́кать со сто́ном; **~ап тору** постоя́нно ныть; **~ый бирү** продолжа́ть ныть (стона́ть, стена́ть)

сыктак *прил. диал.* **1.** плакси́вый **2.** *в знач. сущ.* пла́кса; *ул ~ түгел* он не пла́кса

сыктану *неперех. диал. см.* **сыкрану**; *сагынып ~* ныть (стона́ть) от тоски́

сыкт|ау *неперех.* ти́хо пла́кать, всплакну́ть, всхли́пывать/всхли́пнуть, хны́кать || ти́хий плач, всхли́пывание, хны́канье; *бала ~ап йөри* ребёнок хо́дит хны́ча; *борынгыны сагынып ~ау* плач по старине́ □ **~ап алу (кую)** всплакну́ть; **~ап җибәрү** запла́кать; **~ый бирү** продолжа́ть пла́кать (хны́кать)

сыкташ *сущ. редко* ти́хий плач, всхли́пывание; хны́канье; *бөтен җирдә елаш та ~* повсю́ду плач да хны́канье

сыкы I *сущ.* и́морозь; *агач ботакларын ~ сарган* ве́тви дере́вьев оку́таны и́морозью; *юлга ~ кунган* доро́га покры́та и́морозью; *һавага ~ төшкән* во́здух пропи́тан и́морозью

сыкы II *прил. диал.* гря́зный, немы́тый (ни́тка, домотка́нная мате́рия); *~ җеп* гря́зная нить

сыкылану **1.** *страд. от* **сыкылау** **2.** *см.* **сыкылау**

сыкыла|у *неперех.* **1.** покрыва́ться/покры́ться, оку́тываться/оку́таться и́морозью, и́ндевє́ть/заи́ндевє́ть **2.** пропи́тываться/пропита́ться и́морозью; *һава ~ган* во́здух пропи́тан и́морозью

сыкылы *прил.* **1.** покры́тый (оку́танный) и́зморозью; заиндеве́лый; *атның ~ аркасы* заиндеве́лая спина́ ло́шади **2.** попи́танный и́зморозью; *декабрьнең ~ таңы* попи́танная и́зморозью дека́брьская заря́; *~ иртә* попи́танное и́зморозью у́тро

сыл *сущ. диал.* **1.** специа́льно пригото́вленная жи́дкость из хме́ля для заварно́го хле́ба **2.** дро́жжи, пригото́вленные путём ква́шения вы́севок в воде́

сыла *сущ. зоол.* суда́к || судако́вый, суда́чий; *кыздырган ~* жа́реный суда́к □ **~ балыгы** суда́к

сылавыч *сущ. этногр.* же́нский головно́й убо́р, в кото́рый убира́ется со́бранная узло́м коса́

сылама *сущ. диал.* **1.** дёготь **2.** мазь || *прил. диал.* по́лный до краёв □ **~ булу** напо́лниться до краёв; *чиләк ~ булды* ведро́ напо́лнилось до краёв; *~ итү* напо́лнить посу́дину до краёв

сыландыру *понуд. от* **сылану**

сылан|у **1.** *страд.-возвр. от* **сылау**; ма́заться, замáзываться/замáзаться; намáзываться/намáзаться; обмáзываться/обмáзаться; *тәрәзә ~ды* окно́ замáзали; *ак балчык белән ~ган өй* дом, обмáзанный бе́лой гли́ной **2.** *возвр. разг. неодобр.* ма́заться, намáзаться, кра́ситься; *хатын бик ~ган* же́нщина уси́ленно намáзалась; *иннек белән ~у* намáзаться (накра́ситься) румя́нами **3.** обля́пываться/обля́паться; облепля́ться/облепи́ться **4.** прилипа́ть/прили́пнуть *к кому-чему; итекка балчык ~ган* к сапога́м прили́пла гли́на; *пычрак тәгәрмәчләргә ~ды* грязь прили́пла к колёсам; *чи ипи тешкә ~а* недопечённый хлеб прилипа́ет к зуба́м; *тәнгә ~у* прилипа́ть к те́лу **5.** *перен.* льнуть, прильну́ть *к кому-чему; тәрәзәгә килеп ~у* прильну́ть к окну́; *җиргә ~ып* прильну́в к земле́; *чит ирләргә ~у* льнуть к чужи́м мужчи́нам □ **~а бару** ма́заться ещё бо́льше; **~а бирү** продолжа́ть льнуть (несмотря́ ни на что́); **сылана тору** (постоя́нно) намáзываться, прилипа́ть; **~ып бетү** **1.** замáзаться, обмáзаться **2.** облепи́ться (со всех сторо́н); *чана кар белән ~ып беткән* са́ни облéплены сне́гом; **~ып тору** пло́тно облега́ть (*тело*)

сыланучан *прил.* **1.** ма́жущийся **2.** вя́зкий; *авыр, ~ балчык* тяжёлая, вя́зкая гли́на **3.** *перен.* ли́пкий, прили́пчивый, липу́чий, пристаю́щий; *~ хатын* прили́пчивая же́нщина

сыланчык *прил. прям., перен.* ли́пкий, ли́пнущий, пристаю́щий; *~ туфрак* ли́пкая земля́; *~ кеше* прили́пчивый челове́к

сылата: сылата буран *прил. диал.* позёмка

сылату *понуд. от* **сылау**

сыл|ау *перех.* **1.** ма́зать, замáзывать/замáзать, намáзывать/намáзать; обмáзывать/обмáзать *что чем; ярыкларны ~ау* замáзывать ще́ли; *сумала ~ау* замáзать смоло́й; *ипигә май ~ау* намáзать на хлеб ма́сло; *биткә иннек ~ау* намáзать лицо́ румя́нами; *читәнне ~ау* обмáзать плете́нь; *мичне ~ау* обмáзать печь **2.** *перен. прост.* 1) влепля́ть/влепи́ть, залепля́ть/залепи́ть, ма́зать, сма́зать *кому; колагына берне ~ау* влепи́ть в у́хо; *яңак төпкә ~ау* влепи́ть в щёку 2) гро́хнуть, баба́хнуть, тра́хнуть; *егетне җиргә ~ау* гро́хнуть па́рня о зе́млю **3.** прилепля́ть/прилепи́ть *что к чему; белдерү ~ау* прилепи́ть объявле́ние **4.** 1) натира́ть/натере́ть *что чем; аякны елан мае белән ~ау* натере́ть но́гу змеи́ной ма́зью; 2) масси́ровать, массажи́ровать *что; билне ~ау* масси́ровать поясни́цу **5.** *перен. прост.* сбыва́ть/сбыть *кому что; бракны ~ау* сбыть брак; *гарип кызын ~ау* сбыть дочь-кале́ку **6.** *перен. прост.* припи́сывать/приписа́ть *что кому; бу кимчелекларне миңа ~амагыз* не припи́сывайте э́ти недоста́тки мне □ **~аган өй** ма́занка; **~ап алу (кую)** **1.** замáзать, намáзать, обмáзать *что* **2.** *прост.* сма́зать, влепи́ть, залепи́ть; **~ап ату** (бы́стро) замáзать, намáзать, обмáзать; **~ап бару** ма́зать, замáзывать, обмáзывать (*по ходу*); **~ап бетерү** замáзать, намáзать, обмáзать (со всех сторо́н); **~ап бирү** замáзать, намáзать, обмáзать *кому;* **~ап ташлау** (бы́стро) замáзать, намáзать, обмáзать; **~ап чыгу** обмáзать, намáзать, замáзать (*со всех сторон*); **~ый төшү** **1.** (чу́точку) замáзывать, обмáзывать **2.** (чу́точку) масси́ровать, массажи́ровать

сыла|у-сыйпа|у *перех. преимущ. в сочет. с глаголами-модификаторами* **1.** ласка́ть, приласка́ть, гла́дить, погла́дить; не́жить; *сылап-сыйпап узу* по́ходя приласка́ть (погла́дить) **2.** *перен.* гла́дить, погла́дить по голо́вке (по ше́рсти); *аны сылап-сыйпап кына торып булмас* не уда́стся всегда́ гла́дить его́ по голо́вке **3.** уха́живать, забо́титься, позабо́титься, проявля́ть/прояви́ть забо́ту; бере́чь *кого; үзеңне үзең сылап-сыйпап йөрмәсәң* е́сли ты не позабо́тишься о себе́ **4.** *перен.* замáзывать, прикрыва́ть, скрыва́ть *что*; (*докладта*) *кимчелекларне сылап-сыйпап үтү* замáзывать (в докла́де) недоста́тки; *гаепләрен сылап-сыйпап калдыру* скрыва́ть (прикрыва́ть) их вину́

сылаучы *сущ. редко* массажи́ст

сылаштыру *многокр. от* **сылау**

сылашу *взаимно-совм. от* **сылау**

сылбырап *нареч. диал.* ро́бко; *~ җавап бирү* отвеча́ть ро́бко

сылбырау *неперех. диал.* размя́кнуть; раскиса́ть/раски́снуть, робе́ть

сылтама *сущ. редко* ссы́лка, отсы́лка || ссы́лочный, отсы́лочный; *~ итеп китерелгән искәрмә* ссы́лочное примеча́ние

сылтану **1.** *страд. от* **сылтау** **2.** ссыла́ться/сосла́ться *на кого-что* || ссы́лка; *газетаның баш мәкаләсенә ~у* ссыла́ться на передови́цу газе́ты **3.** припи́сываться/приписа́ться; *аның өстенә гайбәтләр ~а* ему́ припи́сываются сплéтни

сылт|ау *перех.* **1.** 1) сва́ливать/свали́ть (вину́) *на кого-что*; припи́сывать/приписа́ть *кому-чему; гаебен башкаларга ~ау* сва́ливать вину́ на други́х; *бала-чагага ~ау* приписа́ть де́тям 2) ссыла́ться/сосла́ться *на кого-что*, отсыла́ть/отосла́ть, кива́ть/кивну́ть *кому-чему; наданлыкка ~ау* ссыла́ться на негра́мотность; *нервлар киеренкелегенә ~ау* сосла́ться на не́рвное напряже́ние; *Гали Вәлигә ~ый* Ива́н кива́ет на Петра́, Пётр на Ива́на **2.** отгова́риваться/отговори́ться, ссыла́ясь *на кого-что* || *сущ.* по́вод, предло́г; отгово́рка; *~ау тапты* нашёл предло́г; *бәйләнергә ~ау эзләү* иска́ть предло́г (по́вод) для ссо́ры; *уңайлы ~ау белән* под благови́дным предло́гом; *әллә ни кадәр ~аулар тапты* нашёл многочи́сленные отгово́рки □ **~ап бетерү** свали́ть всё на *кого-то*; **~ый килү** (*всё время*) сва́ливать *на кого*

сылтаулау *неперех. диал. см.* **сылтау** 1; *урманга китәсем бар дип ~* отговори́ться, ссыла́ясь на пое́здку в лес

сылтыклау *гл. диал.* хрома́ть, прихра́мывать; *аз гына ~* слегка́ хрома́ть

сылу *прил.* **1.** стро́йный, изя́щный; *~ гәүдә* стро́йное те́ло, стро́йная фигу́ра; *~ сын* изя́щная фигу́ра; *~ буйлы* со стро́йным те́лом (ста́ном) **2.** *разг.* краси́вый; кра́сный, прекра́сный; *~ йөз* краси́вое лицо́; *~*

күренү показа́ться краси́вым; ~ *хатын* краси́вая же́нщина **3.** *в знач. сущ.* краса́вица; *курыкма, ~ым* не бо́йся, краса́вица □ ~ **егет** краса́вец; ~ **кыз** краса́вица; кра́сна де́вица; **~ларның сылуы** краса́вица из краса́виц; распрекра́сная

сылулацдыру *понуд. от* **сылулану**

сылулан|у *неперех.* **1.** хороше́ть/похороше́ть; *кыз көннән-көн ~а* де́вушка хороше́ет день ото дня́ **2.** станови́ться (стать) стро́йным, изя́щным □ **~а бару** хороше́ть (*день ото дня*); **~а бирү** хороше́ть (*несмотря ни на что*); **~а төшү** (ещё) похороше́ть; **~ып килү (китү)** хороше́ть (*на глазах*)

сылулату *перех. см.* **сылуландыру**

сылулы|к *сущ.* **1.** стро́йность, изя́щность, изя́щество; *гәүдәсенең ~гы* стро́йность её фигу́ры **2.** красота́, мило́видность; *~к белән дан алу* сла́виться свое́й красото́й; *кызның ~гы* красота́ де́вушки

сымак *послелог, частица разг. см.* **сыман**; *абзар ~* вро́де хле́ва; *гаҗәпләнгән ~* как бу́дто удивлён

сыман *послелог* **1.** 1) подо́бно, как, наподо́бие; *кыр казы ~* подо́бно ди́кому гу́сю; *диңгез ~* как мо́ре; *квартира ~ нәрсә* подо́бие кварти́ры 2) *в сочет. с сущ. соответствует компонентам:* -подо́бный, -ви́дный, -образный; *кеше ~ маймыл* человекообра́зная обезья́на; *ук ~* стрелови́дный; *дуга ~* дугообра́зный **2.** бу́дто бы, как бу́дто бы; вро́де как; *бар ~* как бу́дто бы име́ется; *үпкәләгән ~* вро́де как оби́делся

сымбат *сущ. уст.* **1.** телосложе́ние **2.** стро́йность (*мужчины*)

сымбатлы *прил. уст.* стро́йный, атлети́ческого сложе́ния

сын I *сущ.* **1.** извая́ние, скульпту́ра, скульпту́рная фигу́ра; *таш сын* ка́менное извая́ние; *лачын сыны* скульпту́ра со́кола **2.** и́дол; *мәҗүси сыннар* языческие и́долы **3.** стан, оса́нка, фигу́ра, те́ло, ко́рпус; *сынын иеп изогнув* свой стан; *төз сын* стро́йная фигу́ра; *сынын турайту* вы́прямить свой стан; *мәһабәт сын* могу́чий стан **4.** *редко* вне́шний вид, о́блик; о́браз; *анда кеше сыны калмаган* он потеря́л челове́ческий о́блик **5.** изображе́ние, рису́нок; *ат сыны* изображе́ние ло́шади □ **сын бирләү** измени́ть свой о́блик; **сын төшерү (ясау)** *диал.* рисова́ть; **сынга табыну** идолопокло́нство ◊ **сын кату 1.** остолбене́ть, оцепене́ть, окамене́ть, одеревене́ть, засты́ть; *кайгыдан сын кату* засты́ть от го́ря; *гаҗәпләнүдән сын кату* оцепене́ть (засты́ть) от удивле́ния **2.** задохну́ться; *көлә-көлә сын кату* задохну́ться от сме́ха **3.** *в знач. сущ.* столбня́к

сын II *сущ. уст.* спосо́бность оце́нивать по ви́ду

сынагыч *сущ. тех.* ме́ггер (*агрегат для испытания изоляционных материалов*)

сыналган *прил.* испы́танный, прове́ренный; надёжный; *~ алым* испы́танный приём; *~ чара* испы́танное сре́дство; *~ кеше* испы́танный (прове́ренный) челове́к; *~ дус* испы́танный (надёжный) друг

сынал|у **1.** *страд. от* **сынау 1 2.** испы́тываться, проверя́ться; *ат чанада, батыр яуда ~а* ло́шадь проверя́ется в у́пряжи, богаты́рь испы́тывается в бою́; *эштә ~у* проверя́ться в рабо́те

сынамыш *сущ.* приме́та, приме́ты *мн.*; пове́рье; *~ларга караганда* су́дя по приме́там

сынат|у *неперех. обычно в отрицательной ф.* **сынатмау 1.** *понуд. от* **сынау 1 2.** подкача́ть, не выде́рживать (не вы́держать) испыта́ния, поддава́ться/подда́ться *чему; кешеләр алдында ~ма* не подкача́й пе́ред людьми́; *беркайда да ~маячак* нигде́ не подкача́ет **3.** не подава́ть (не пода́ть) ви́да, не выдава́ть (не вы́дать) себя́; *сер ~у* выдава́ть та́йну □ **~а язу** чуть не подкача́ть

сын|ау I *перех.* **1.** испы́тывать/испыта́ть, подверга́ть/подве́ргнуть испыта́нию; проверя́ть/прове́рить *кого-что; мотор ~ау* испы́тывать мото́р; *тормышта ~ау* испыта́ть на пра́ктике; *яңа хезмәткәрне ~ау* прове́рить но́вого сотру́дника; *рухи ныклыгын ~ау* испы́тывать мора́льную сто́йкость; *~ар өчен әйтү* сказа́ть с це́лью прове́рки **2.** *перен.* пыта́ть, попыта́ть, испы́тывать/испыта́ть *что; бәхет ~ау* испыта́ть сча́стья (пойти́ на риск) **3.** про́бовать, испро́бовать, опро́бовать *что; үзеңнең көчеңне ~ау* про́бовать свою́ си́лу; *каләм ~ау* про́бовать перо́ **4.** экзаменова́ть, проэкзаменова́ть *кого*; принима́ть/приня́ть экза́мен; *укучыларны математикадан ~ау* экзаменова́ть уча́щихся по матема́тике □ **~ап алу** испыта́ть, испро́бовать *что; кешене ~ап алу* испыта́ть челове́ка; **~ап йөрү** проверя́ть *кого-л.*; **~ап калу** испыта́ть, испро́бовать; **~ап карау 1.** опро́бовать, испро́бовать; *яңа коралны ~ап карау* испро́бовать но́вый инструме́нт; *күп профессияләрне ~ап карау* испро́бовать мно́го профе́ссий; *көчне ~ап карау* попро́бовать си́лы **2.** испыта́ть *что; яңа моторны ~ап карау* испыта́ть но́вый мото́р **3.** *перен.* попыта́ть; *бәхетне ~ап карау* попыта́ть сча́стья **4.** попыта́ться *что-л.* де́лать **5.** броса́ть (бро́сить) испы́тывающий взгляд; **~ап килү** испы́тывать, подверга́ть испыта́нию, проверя́ть (*долго*); *аны ничә еллар ~ап килдем* ско́лько лет я испы́тывал (проверя́л) его́; **~ый карау 1.** броса́ть (бро́сить) испы́тывающий взгляд **2.** испыту́ющий взгляд; *аның ~ый каравы астында* под его́ испыту́ющим взгля́дом; **~ый төшү** (чуть) попро́бовать (испы́тывать)

сынау II *сущ.* **1.** *прям., перен.* испыта́ние || испыта́тельный; *зур ~лар үтәргә* пройти́ больши́е испыта́ния; *дәүләт ~лары* госуда́рственные испыта́ния; *тормыш ~лары* жи́зненные испыта́ния; *авыр ~* тяжёлое испыта́ние; *~ очышы* испыта́тельный полёт **2.** *пед.* экза́мен, испыта́ние || экзаменацио́нный; *язгы ~лар* весе́нние экза́мены; *язма ~* пи́сьменный экза́мен; *~ билетлары* экзаменацио́нные биле́ты *~ комиссиясе* экзаменацио́нная коми́ссия **3.** о́пыт, наблюде́ние; про́ба; *хайваннар өстендә ~ үткәрү* провести́ о́пыт над живо́тными **4.** апроба́ция □ **~ алу** экзаменова́ть, проэкзаменова́ть; **~ алучы** экзамена́тор; **~ бирү** экзаменова́ться, сдава́ть/сдать экза́мен; **~ бирүче** экзамену́емый ◊ **~ күзе** испы́тывающий (пытли́вый) взгляд; *аңа ~ күзе белән карау* бро́сить на него́ испы́тывающий взгляд; **~ ташы** про́бный ка́мень

сынаулы *прил.* **1.** испыту́ющий, пытли́вый; *~ караш ташлау* бро́сить испыту́ющий взгляд **2.** *в знач. нареч.* испыту́юще, пытли́во; *~ карау* смотре́ть испыту́юще

сынаулык *сущ. редко* **1.** про́ба; *кан ~лары алу* брать про́бы кро́ви **2.** *в знач. прил.* про́бный; *~ көлтә* про́бный сноп

сынаучан *прил.* пытли́вый; *~ караш* пытли́вый взгляд

сынаучы *сущ.* испыта́тель; *~ очучы* лётчик-испыта́тель

сынаш *сущ.* **1.** про́ба; *көч ~* про́ба сил **2.** апроба́ция **3.** *редко* испыта́ние; *икенче зур ~* второ́е большо́е испыта́ние; *соңгы ~* после́днее испыта́ние

сынаштыру *многокр. от* **сынау** I

сынаш|у **1.** *взаимно-совм. от* **сынау** I **2.** *перен.* тяга́ться, потяга́ться, ме́ряться, поме́ряться; *көч ~у*

поме́ряться си́лами; *соңгы тапкыр ~у* в после́дний раз потяга́ться □ **~ып карау** поме́ряться, потяга́ться

сынгалану *страд. от* **сынгалау**; лома́ться, переломи́ться; *меңгә ~* переломи́ться на ты́сячи кусков

сынгал|ау *многокр. от* **сыну**; *коры чыбыклар ~ый* вре́мя от вре́мени ломаются сухи́е ве́тки

сындыргалау *многокр. от* **сындыру**; *коры-сары ~* лома́ть сушня́к

сындырту 1. *понуд. от* **сындыру** 2. *перен.* лома́ть, слома́ть *что; кулын ~* слома́ть ру́ку

сындыр|у *перех. в разн. знач.* 1. *прям., перен.* лома́ть, слома́ть *что; ботак ~у* слома́ть сук; *куакларны ~у* лома́ть куста́рник; *теш ~у* слома́ть зуб; *җылы сәяк ~мас* жар косте́й не ло́мит; *каршылыкны ~у* слома́ть сопротивле́ние; *муенын ~у* слома́ть себе́ ше́ю; *кайгы кешене ~а* го́ре лома́ет челове́ка 2. разла́мывать/разлома́ть, разломи́ть, переломи́ть, переломи́ть *что* || разла́мывание; *икмәкне ~у* разломи́ть хлеб; *урталай ~у* переломи́ть пополам 3. *перен. разг.* (ре́зко) потепле́ть || (ре́зкое) потепле́ние; *бүген бераз ~ган* сего́дня не́сколько потепле́ло; *көнне ~а* тепле́ет 4. *перен. прост.* распива́ть/распи́ть, осуши́ть *что* || распи́тие; *яртыны ~у* распи́ть поллитро́вку; *мәгәричне ~у* распи́ть магары́ч 5. *перен. уст.* нару́шить, по́ртить *что; тәнәрәтне ~у* нару́шить омове́ние □ **~а бару (килү)** лома́ть, разла́мывать (по хо́ду); **~а бирү** продолжа́ть лома́ть (несмотря́ ни на что); **~а язу** чуть не слома́ть; **~ып алу** отломи́ть; *кумәчне ~ып алу* отломи́ть кусо́к калача́; **~ып бетерү** переломи́ть; *егылганда кабыргаларны ~ып бетерү* переломи́ть рёбра при паде́нии; **~ып ташлау** слома́ть, разломи́ть, обломи́ть, переломи́ть; *ботакны сындырып ташлау* обломи́ть сук; **~ып чыгару** разломи́ть, переломи́ть; **~ып чыгу** облома́ть *что; коры ботакларны ~ып чыгу* облома́ть су́чья

сындырылу *страд. от* **сындыру**

сынҗыр *сущ. диал.* цепь, цепо́чка; *см. тж.* **зынҗыр**; *ишек ~ы* цепо́чка на две́ри

сынландыру *перех.* олицетворя́ть/олицетвори́ть *что* || олицетворе́ние; *әсәрдә ~ алымы куллану* испо́льзовать в произведе́нии приём олицетворе́ния

сынлан|у *неперех.* олицетворя́ться/олицетвори́ться || олицетворе́ние; выража́ться || выраже́ние; *башкача ~* олицетворе́ние по-ино́му

сынлы I *прил.* 1. *в словосочетаниях с прилагательными* хорошо́ сложённый; хоро́шего сложе́ния; ста́тный, стро́йный; *матур ~ егет* хорошо́ сложённый па́рень; *мәһабәт ~* могу́чего сложе́ния 2. *диал.* краси́вый, симпати́чный □ **~ сәнгать** изобрази́тельное иску́сство; *~ сәнгать музее* музе́й изобрази́тельного иску́сства

сынлы II *послелог диал.* как, подо́бно; *сөт ~* подо́бно молоку́; *аю ~* как медве́дь; *этиең ~ нык бул* будь твёрдым, как твой оте́ц

сынлылык *сущ.* ста́тность, стро́йность; оса́нистость

сын-сыйфат *сущ. собир. диал.* стан, стать; телосложе́ние

сын-сыйфатлы *прил. диал.* ста́тный; *сын-сыйфатлы егет* ста́тный па́рень

сын|у *неперех.* 1. *прям., перен.* лома́ть, слома́ть, излома́ться; *канат ~ды* слома́лось крыло́; *пычкы ~ды* слома́лась пила́; *ботак ~а* лома́ется ве́тка; *кешенең ихтыяры ~ды* у челове́ка слома́лась во́ля 2. *перен.* лома́ться, слома́ться, пропада́ть/пропа́сть; *аның тавышы ~ды* у него́ слома́лся (пропа́л) го́лос; *аның рухы ~ды* он слома́лся мора́льно 3. перела́мываться/переломи́ться; *өрлек ~ды* переломи́лась ма́тица; *чыбык сынды* переломи́лась ве́тка; *икегә ~у* переломи́ться на две ча́сти; *таяк урталай ~ды* па́лка переломи́лась пополам 4. *физ.* преломля́ться/преломи́ться; *кояш нуры ~а* преломля́ется со́лнечный луч 5. *перен.* ре́зко потепле́ть; *көн ~ды* ре́зко потепле́ло; *салкыннар ~ды* моро́зы прекрати́лись || *сущ.* 1. перело́м; *сәяк ~у* перело́м косте́й; *бил ~у* перело́м поясни́цы 2. *физ.* преломле́ние; *~у почмагы* у́гол преломле́ния □ **~а бару** лома́ться (всё вре́мя); **~ган урын** 1. изло́м, ме́сто перело́ма 2. слом; **~ып бетү** 1. поломаться, слома́ться 2. переломаться; **~ып китү** (внеза́пно) слома́ться; **~ып кую** 1. слома́ться 2. *перен.* потепле́ть; **~ып төшү (чыгу)** обломи́ться, отломи́ться; *урындык аягы ~ып төшкән* но́жка скаме́йки отломи́лась; *баскыч култыксасы ~ып төшкән* обломи́лись пери́ла ле́стницы

сынучан *прил.* 1. ло́мкий, хру́пкий; *салкында ~* ло́мкий на хо́лоде 2. преломля́ющийся

сынучанлык *сущ.* 1. ло́мкость, хру́пкость 2. *физ.* преломля́емость

сынчы *сущ.* ску́льптор; *борынгы ~* дре́вний ску́льптор

сыны|к *прил.* 1. сло́манный; ло́маный; *~к тәртә* сло́манная огло́бля; *~к теш* сло́манный зуб; *~к пәке* сло́манный но́жик; *~к такта кисәге* кусо́к сло́манной доски́; *~к урак* сло́манный серп 2. *перен.* пода́вленный, угнетённый; *~к күңелле* с пода́вленным настрое́нием; *~к тавышлы* с пода́вленным го́лосом || *сущ.* 1. обло́мок; кусо́к; *чалгы ~гы* обло́мок косы́; *карандаш ~гы* обло́мок (огры́зок) карандаша́ 2. кусо́к, ломо́ть, объе́док; *бер ~к икмәк* кусо́к хле́ба; *бәлеш ~гы* кусо́к пирога́ □ **~ сызык** *мат.* ло́маная ли́ния, зигза́г ◊ **~кка сылтау** 1. всегда́ находи́ть (найти́) отгово́рку; отгова́риваться/отговори́ться; лентя́ю лишь бы по́вод найти́; *теге юк, бу юк дип, ~кка сылтап йөри* он отлы́нивает от рабо́ты, отгова́риваясь отсу́тствием то того́, то другого́ 2. отгово́рка; *~кка сылтау гына бу* э́то лишь отгово́рка 3. по́вод, предло́г

сыныклы|к *сущ.* угнетённость, пода́вленность; *күңел ~гы* пода́вленность настрое́ния

сынык-санык *сущ. собир. разг.* 1. объе́дки, оста́тки еды́; *сынык-санык ашау* есть объе́дки 2. кро́шки; *кирпеч сынык-саныклары* кирпи́чные кро́шки

сынык-сылтау *сущ. собир. разг.* предло́г, по́вод; *корылыкны сынык-сылтау итеп* под предло́гом за́сухи

сыныш *сущ. физ.* преломле́ние; *нурлар ~ы* преломле́ние луче́й

сыңар *прил.* 1. оди́н (одна́, одно́) из па́ры; *~ итек* оди́н сапо́г; *~ биялә* одна́ рукави́ца; *~ күл белән, ~ күлдап* одно́й руко́й; *~ күз белән генә карау* посмотре́ть одни́м гла́зом; *игезнең ~ы* оди́н из дво́йни 2. оди́н-еди́нственный; *~ ат калды* оста́лась одна́-еди́нственная лошадёнка; *~ шырпым да калмады* ни одно́й спи́чки не оста́лось; *~ кашык* одна́-еди́нственная ло́жка; *стенага ~ кадак та какмаган* он не забил в сте́ну ни одного́ гвоздя́ 3. *перен.* похо́жий, вы́литый; *шуның ~ы* вы́литый он; *Нәфисә ~ы* вы́литая Нафиса́ 4. *в знач. сущ. в притяж. ф.* ко́пия; *атасы ~ы* ко́пия отца́ □ **~ аяклы** однonóгий; **~ куллы** однору́кий; **~ күз** *зоол.* цикло́п; **~ күзле** одногла́зый; **~ мөгез** *зоол.* 1. нарва́л 2. единоро́г; **~ тояклылар** *зоол. см.* **так тояклылар**

сыңарлап *нареч.* по одному́ □ **~ калу** *диал.* оста́ться одино́ким

сыңарлы *прил.* односторо́нний, с одни́м шабло́ном

сыңарлы-сыңарсыз *прил.* 1. непáрный, без пáры; *сыңарлы-сыңарсыз итек* непáрный сапóг 2. *в знач. нареч.* непáрно, без пáры; *сыңарлы-сыңарсыз кию* одéть непáрно

сыңарсыз *прил.* непáрный, без пáры, одúн-едúнственный; ~ *оек* чулóк без пáры

сыпка *сущ. диал.* грязь, грязное пятнó; *~ларны сөртү* вытереть пятна || *прил.* мýтно-грязный; загрязнённый; *~ су* грязная водá

сыпкалы *прил. диал.* грязный

сыпкы *сущ. диал.* слякоть, хлябь *разг.; арба тәгәрмәчләреннән ~га баткан* телéга по колёса утонýла в слякоти

сыпкылы *прил. диал.* 1. слякотный, грязный; *~ юл* слякотная дорóга 2. *в знач. предик.* слякотно; *аяк асты ~* под ногáми слякотно

сыпра *сущ.* 1. кóжаная скáтерть 2. *см.* **сыпыра**

сып-сыек *прил. превосх. ст. от* **сыек**; *сып-сыек чәй* жúдкий-прежúдкий чай

сып-сылу *прил. превосх. ст. от* **сылу**; *сып-сылу кыз* раскрасáвица

сыптыргалау *многокр. от* **сыптыру**

сыптыргыч *сущ. диал.* плеть; *~ белән сугу* удáрить плéтью

сыптырту 1. *понуд. от* **сыптыру** 2. *неперех. перен. разг.* удрáть, дрáпать, улепётывать

сыптыру *перех.* 1. стегáть/стегнýть, хлестáть/хлестнýть, хлестанýть; *камчы белән ~у* хлестнýть плéтью; *дилбегә белән ~у* стегнýть вожжáми; *аркага чыбык белән ~у* хлестнýть прутóм по спинé 2. *разг.* ударя́ть/удáрить; *биткә ~ды* удáрил по лицý; *~ырмын берне* удáрю (дам, врéжу) разóк 3. *перен. разг.* мчáться, нестúсь, дуть; *турыга гына ~у* нестúсь (дуть) по прямóй; *биш чакрымга ~у* дуть на пять вёрст; *~ моннан!* дуй отсю́да! 4. *перен. прост.* уплетáть/уплестú, жрать, пожрáть *что; ашны ~у* уплетáть суп; *ипине ~у* уплетáть хлеб 5. *перен. прост.* перéть, упереть, таскáть; тащúть, утащúть *кого-что; алманы ~у* утащúть я́блоко; *хуҗалар әйберен ~у* упереть хозя́йские вéщи □ **~а бирү** 1. *разг.* дрáпать, нестúсь (*несмотря ни на что*) 2. *прост.* уплетáть, жрать (*несмотря ни на что*); **~а килү** *прост.* толкáть, перéть; **~ып алу (җибәрү)** хлестнýть, стегнýть *чем; чыбыркы белән ~ып алу* хлестнýть кнутóм; **~ып кую (салу, ташлау)** *прост.* уплестú, сожрáть; **~ып чыгу** утащúть, упереть (*всё*)

сыптырылу 1. *страд. от* **сыптыру** 2. *возвр. диал.* ударя́ться/удáриться *во что; агачка ~* удáриться о дéрево

сыптырынкы *прил. диал.* 1. с вúду скрóмный; *~ кыз* с вúду скрóмная дéвушка 2. *в знач. нареч.* (*с виду*) скрóмно; *~ йөрү* вестú себя́ врóде скрóмненько

сыпы *прил. диал.* сдéржанный в едé; *~ кеше* человéк, сдéржанный в едé

сыпыем *прил. диал.* слúшком чистоплóтный; *~ кеше* слúшком чистоплóтный человéк, чистоплю́й

сыпыемлану *неперех. диал.* бывáть (быть) слúшком чистоплóтным, чистоплю́йничать

сыпый *прил. диал. см.* **сыпы**

сыпыл|у *неперех.* 1. лохмáтиться, излохмáтиться, измы́згаться, расплетáться/расплестúсь; *чүпрәк читләре ~ган* края́ тря́пки излохмáтились 2. сéчься; *чәч ~а* вóлосы секýтся

сыпыра *прил. уст.* глáдкий; *~ сынлы* с глáдким стáном

сыпырама *прил. нареч. диал. см.* **сылама**; *ул сөтне ~ салган* онá налилá молокá до краёв

сыпыргалау 1. *многокр. от* **сыпыру** 2. *перех.* погла́живать/погла́дить; *мыек ~* погла́живать усы́

сыпырткы *сущ. диал.* хлыст; кнут; *~ белән сугу* удáрить хлыстóм

сыпырт|у 1. *понуд. от* **сыпыру** 2. *неперех. перен. прост.* мчáться, нестúсь, дуть; *ул шушы юл белән ~а* он несётся (дýет) по э́той дорóге; *~ моннан* дуй отсю́да 3. *перен. прост.* дрáпать/драпанýть, улепётывать, стреканýть, уноси́ть/унести́ нóги; *дошманнан ~у* дрáпать от врагá; *моннан тизрәк ~ырга кирәк* нáдо отсю́да быстрéе уноси́ть нóги 4. *перен. прост.* уплетáть/уплестú, жрать, сожрáть *что; өстәлдәге ашамлыкны ~у* бы́стро уплетáть съестнóе на столé 5. *перен. разг.* бы́стро (спóро) рабóтать; *ул эшне ~а* рабóту он дéлает спóро 6. *перен. прост.* перéть, упереть, таскáть/тащúть, утащúть, свúстнуть *что* ◊ **~а бирү** *прост.* продолжáть нестúсь (мчáться); **~а тору** *прост.* продолжáть уплетáть, жрать

сыпыр|у *перех. прост.* 1. глáдить, погла́живать/погла́дить, пригла́живать/пригла́дить *что по чему; башыннан ~у* глáдить по голóвке; *чәчне ~у* пригла́живать вóлосы; *җыерчыкларны ~у* пригла́живать склáдки 2. *прям., перен.* сметáть/сместú *что с чего; өстәл өстеннән ~у* сместú со столá; *бөтен малны ~у* сместú всё богáтство 3. слегкá стирáть/стерéть; *маңгай тирен ~у* стерéть со лба пот; *идәнне ~у* слегкá протерéть пол 4. *диал.* подметáть; *идән ~у* подметáть пол 5. *перен. разг.* стегáть/стегнýть, отстегáть/отстегнýть, хлестáть/хлестнýть *по кому-чему; этләрне чыбык белән ~у* отстегáть собáк прутóм 6. *перен. прост.* уплетáть/уплестú, жрать, сожрáть *что; икесенә бөтен бер каз ~у* уплестú на двои́х цéлого гýся́; *берүзенә егерме йомырка ~ды* он одúн уплёл два деся́тка я́иц 7. *перен. прост.* перéть, упереть, таскáть, утащúть *что; кешенекен ~* упереть чужóе □ **~ып алу** 1. сместú всё 2. протерéть; *битеннән тир ~ып алу* вытереть пот с лицá; **~ып ату** сместú (всё); **~ып кую (җибәрү)** 1. погла́дить *что; башыннан ~ып кую* погла́дить по голóвке 2. вы́тереть *что* 3. *перен. прост.* уплестú (всё); **~ып төшерү** сместú *что с чего; ипи валчыкларын өстәлдән ~ып төшерү* сместú со столá хлéбные крóшки ◊ **~а бару** уплетáть, жрать (*всё подряд*); **~а бирү** продолжáть уплетáть (жрать); **~ып алгандай** как бýдто вéтром сдýло; **~ып салу (ташлау)** *прост.* 1. уплестú (всё) 2. отдубáсить (*всех*); **~ып чыгару** вы́гнать

сыпырын|у 1. *возвр. от* **сыпыру** 2. пригла́живаться; *ул ~а башлый* онá начинáет пригла́живаться (пригла́живать себя́)

сыпырып 1. *деепр. от* **сыпыру** 2. *в знач. нареч.* бы́стро, спóро, подря́д; *~ эшләү* дéлать спóро (подря́д)

сыпырышу *гл. взаимно-совм. от* **сыпыру**

сыр I *сущ.* 1. нарéзка, нарéз, резьбá; *винт сыры* винтовáя нарéзка (резьбá); *шәреп сырлары ашалган* стёрта нарéзка у шурýпа; *гайканы бер сырга бушату* ослáбить гáйку на одúн оборóт 2. узóр, резнóй узóр; протéктор; *машина тәгәрмәченең сырлары* резнóй узóр (протéктор) машúнного колесá 3. *диал.* ýзкая лéнта, нашива́емая на низ жéнского плáтья; *сыр тоту* нашúть ýзкую лéнту 4. лúния, склáдка; *см.* **җыерчык**; *сырлары үтүкләнгән чалбар* брю́ки с отутю́женными склáдками; *уч сырлары* лúнии ладóни; *йөздәге сырлар* склáдки лицá; *юрган сырлары* склáдки у стёганого одея́ла 5. *анат.* борóздка, извúлина; *см.* **җыерчык**; *ми сырлары* извúлины мóзга; *маңгай сырлары* борóздки на лбу

сыр II *сущ. диал.* 1. кра́ска; *сырга буялу* испа́чкаться кра́ской; *зәңгәр сыр* голуба́я кра́ска; *сары сыр* жёлтая кра́ска 2. ки́новарь (*порошок красного цвета для лечения*); серни́стая ртуть; *дәва сыры* лече́бный порошо́к

сыр III: **сыр салу** *диал.* де́лать, сде́лать предложе́ние

сыр IV (сыйр) *сущ.* сыр || сы́рный; *голланд сыры* голла́ндский сыр; *йомшак сыр* пла́вленный сыр; *бер кисәк сыр* кусо́к сы́ру; *сыр массасы* сы́рная ма́сса □ **сыр җитештерү** 1. сыровре́ние, сыроде́лие 2. сырова́ренный, сырова́рный; *сыр җитештерү сәнәгасе* сырова́ренная промы́шленность; **сыр заводы** сырова́ренный (сыроде́лательный) заво́д; **сыр кайнату** 1. сыровре́ние, сыроде́лие 2. сырова́ренный, сыроде́лательный; **сыр кайнатучы** сырова́р, сыроде́л; **сыр тәлинкәсе** сы́рница; **сыр ясау** 1. сыроде́лие 2. сыроде́льный; *сыр ясау сәнәгасе* сыроде́льная промы́шленность

сыра *сущ.* пи́во || пивно́й; *кубекле ~* пе́нистое пи́во; *Жигули ~сы* жигулёвское пи́во; *шешәле ~* буты́лочное пи́во; *~ кружкасы* пивна́я кру́жка □ **~ заводы** пивова́ренный заво́д; **~ кайнату** 1. пивовре́ние 2. пивова́ренный; *~ кайнату сәнәгасе* пивова́ренная промы́шленность; **~ кайнатучы** пивова́р ◊ **~ мичкәсе** *неодобр.* пивна́я бо́чка, толстопу́зый, пуза́тый

сыраҗ *сущ. бот.* нори́чник (*травянистое или полукустарниковое растение*)

сыраҗчалар *сущ. мн. бот.* нори́чниковые

сыралык *прил.* 1. предназна́ченный для пи́ва 2. доста́точный для поку́пки пи́ва; *~ акча* де́ньги, доста́точные и́ли предназна́ченные для поку́пки пи́ва

сыраханә *сущ.* пивна́я, пивно́й бар; *~гә керү* войти́ в пивно́й бар

сырачы *сущ.* 1. пивова́р 2. продаве́ц пи́ва, торго́вец пи́вом

сырга *сущ.* 1. *бот.* серёжка (*соцветие в виде кисти мелких цветов*); *тал ~сы* серёжки и́вы; *каеннар матур ~ларын ачалар* берёзы распуска́ют краси́вые серёжки 2. *диал.* се́рьги; *кашлы ~* се́рьги с камо́ньями 3. *диал.* серёжки (*у коз*); *кара ~лы кәҗә* коза́ с чёрными серёжками □ **~ гөл** *диал. см.* **тамчы гөл**; **~ үлән** *бот.* луши́нка; **~ үләне** *бот.* подмаре́нник це́пкий

сыргавыл *сущ. уст.* шест, столб

сыргак I *сущ. бот.* подмаре́нник мя́гкий

сыргак II *прил. диал.* сыро́й, промо́зглый; *~ көн* сыра́я (промо́зглая) пого́да

сыргалан|у *неперех. разг.* 1. *прям., перен.* ви́ться, извива́ться; *кызлар тирәсендә ~у* ви́ться вокру́г де́вушек; *тимер чыбык ~а* про́волока вьётся 2. *перен.* лома́ться, жема́нничать, кокéтничать || кокéтничанье; жема́нничанье, жема́нство □ **~ып алу** ви́ться (*на какое-то время*) ◊ **~ып йөрү** лома́ться, кокéтничать

сыргалау 1. *многокр. от* **сыру** I 2. *перех.* простёгивать || простёгивание; *юрган ~* простёгивать одея́ло

сыргалаштыру *гл. многокр. от* **сыру** I

сырган 1. *прич. от* **сыру** I 2. *прил.* стёганый; *~ бишмәт* стёганое пальто́; *~ юрган* стёганое одея́ло; *~ чалбар* стёганые (ва́тные) брю́ки

сырганак *сущ. бот.* 1. облепи́ха 2. чередá трёхразде́льная □ **~ чәчәге** *диал.* жи́вокость

сыргаташ *сущ. бот.* 1. бурачки́ 2. бурачо́к ча́шечный

сырдыру *понуд. от* **сыру** I

сыркай *сущ. диал.* 1. стёганая безрука́вка; душегре́йка 2. матра́ц; *аска ~ салу* положи́ть под себя́ матра́ц

сырк|у I *неперех. диал.* цеди́ться, проце́живаться; *су ~ыды* вода́ проце́живалась

сырку II *неперех. диал.* жа́ться, прижима́ться/прижа́ться, льнуть, прильну́ть *к кому-чему; мичкә ~* прильну́ть к печи́

сыркыту *перех. диал.* цеди́ть, проце́живать/процеди́ть *что* || проце́живание; *катык ~* процеди́ть кати́к

сырлан *сущ. бот.* 1. липу́чка, липу́чка раски́дистая (*растение*); *киемгә ябышкан ~* липу́чка, прили́пшая к оде́жде 2. подмаре́нник це́пкий

сырландыр|у *перех. диал.* оставля́ть/оста́вить бо́розды (узо́ры); *басуларны ~ып сөру* паха́ть поля́ ме́лкими бороздáми

сырлан|у *неперех.* 1. *страд. от* **сырлау** 2. *диал.* кра́ситься 3. *перен. разг.* лома́ться, кривля́ться, жема́нничать; *ул ~ып утыра* она́ жема́нничает (кривля́ется); *я, ~магыз* ну ла́дно, не лома́йтесь ◊ **~ып алу** лома́ться, покривля́ться, пожема́нничать

сырлап-бизәп *нареч.* с узо́рами, с резьбо́й; *сырлап-бизәп салынган йорт* дом, постро́енный с узо́рами (с резьбо́й)

сырлату *понуд. от* **сырлау**

сырл|ау I 1. нарезáть/нарéзать *что; винт ~ау* нарéзать винт 2. рéзать, прорéзывать/прорéзать *что; аның маңгаен җыерчыклар ~аган* его́ лоб прорéзали морщи́ны 3. вырезáть/вы́резать, выводи́ть/вы́вести узо́ры; *таяк ~ау* выводи́ть узо́ры на па́лке; *тәрәзә яңаклары ~ап эшләнгән* око́нные косяки́ вы́полнены с узо́рами 4. *перен. разг.* выводи́ть/вы́вести вязь; *гарәп хәрефләре ~ау* выводи́ть ара́бскую вязь □ **~ап алу** нарезáть, вы́резать; **~ап ату (кую, ташлау)** 1. (*быстро*) нарезáть, вы́резать 2. (*быстро*) вы́вести вязь; **~ап бару** нарéзывать, вырезáть (*по ходу действия*); **~ап чыгу** нарезáть, вы́резать (по́лностью); **~ый төшү** (чуть, слегка́) выводи́ть узо́ры ◊ **~ап сөйләү** *разг.* выводи́ть коле́нца (*в речи*)

сырлау II *перех. диал.* кра́сить, покра́сить *что чем; койманы ~* покра́сить забо́р; *төрле сырга ~* покра́сить в ра́зные цвета́; *идән ~* кра́сить пол

сырлау III *перех. диал.* ката́ть (гла́дить) бельё ска́лкой; *кер ~* ката́ть бельё

сырлау IV: **аш сырлау** *диал.* приверéдничать

сырлы I *прил.* 1. резно́й; *~ шкаф* резно́й шкаф; *~ бизәк* резны́е узо́ры 2. нарезно́й; *~ көпшә* нарезно́й ствол 3. рифлёный, гофри́рованный, ребри́стый; *~ басма буенча* по ребри́стому тра́пу 4. гранёный; *~ стакан* гранёный стака́н □ **~ бәләк** ска́лка (ребри́стая, для белья́)

сырлы II *прил.* 1. полоса́тый; *~ кулмәк* полоса́тое пла́тье; *~ чапан* полоса́тый чапа́н 2. *диал.* кра́шеный, покра́шенный; *~ идән* кра́шеный пол; *~ йомырка* кра́шеное яйцо́

сырлы-мырлы *прил. пренебр.* с ра́зными узо́рами, с ра́зной резьбо́й

сырлы-сырлы *прил.* 1. узо́рчатый, с резны́ми узо́рами 2. рифлёный, ребри́стый; *сырлы-сырлы басмалар* ребри́стые ступéньки 3. гранёный; *сырлы-сырлы стаканнар* гранёные стака́ны

сырма *прил.* 1. стёганый; *~ юрган* стёганое одея́ло; *~ чалбар* стёганые (ва́тные) брю́ки 2. *в знач. сущ.* 1) стёганая фуфа́йка, телогре́йка; *~ кигән* оде́т в телогре́йку 2) стёганый матра́ц; *астына ~ җәю* подстели́ть стёганый матра́ц □ **~ үлән** *бот.* одува́нчик по́здний

сырмавык *сущ. бот.* ясмéнник (*травянистое растение*)

сырмак *сущ. диал.* стёганый бешмéт в та́лию

сырмыш *сущ. диал.* стёганка, телогре́йка

сырпалан|у *неперех.* **1.** ласка́ться, ла́ститься; *мәче аяк астында ~а* ко́шка ла́стится во́зле ног; *ул әнисе янында ~а* она́ ла́стится к ма́тери **2.** *перен. диал.* льстить, уго́дничать; *начальник алдында ~у* уго́дничать пе́ред нача́льством □ **~а бирү** ласка́ться (*несмотря ни на что*); **~а тору** продолжа́ть ласка́ться; **~а төшү** ещё бо́лее ласка́ться; **~ып алу (кую)** пола́ститься

сырпанчак *прил. диал.* приве́дливый, разбо́рчивый; *ашауга ~* приве́дливый (разбо́рчивый) в еде́

сырт *сущ.* **1.** 1) хребе́т, спина́, спи́нка ‖ хребто́вый, спинно́й; *ат ~ы* спина́ ло́шади; *балык ~ы* хребе́т ры́бы; *буй-буй ~лы* с полоса́той спино́й; *~ йоны* хребто́вая шерсть 2) хребе́т, кряж, гре́бень ‖ хребто́вый; *тау ~ы* го́рный хребе́т; *сөзәк ~* поло́гий гре́бень; *дулкын ~ы* гре́бень волны́ **2.** тыл, ты́льная сторона́; *кул ~ы белән* ты́льной стороно́й ладо́ни; *бармак ~ы* ты́льная сторона́ па́льца; *пычак ~ы* ты́льная сторона́ ножа́ **3.** *в знач. прил.* 1) возвы́шенный; хребто́вый; *~ җир* возвы́шенное ме́сто; *~ урыннар* возвы́шенные места́ 2) *диал.* за́дний; *~ капка* за́дние воро́та □ **~ йөзгече** *зоол.* плавни́к спинно́й; **~ кабарту 1.** вы́гнуть спи́ну **2.** *перен.* рассерча́ть, рассерди́ться, осерча́ть; **~ сөяге** *диал.* позвоно́чник; **~ сындыру** *прям., перен.* слома́ть; пересо́лить, сразу́ *кого*; **~ як** *диал.* за́дняя сторона́ ◊ **~ бирү** повора́чиваться (поверну́ться) спино́й; *эш кушсаң, ~ын гына бирә* е́сли пору́чишь что́-либо, он то́лько повора́чивается спино́й; **~ каезлау (яру)** *разг.* погре́ть спи́ну; потрепа́ть, отдубасить, поколоти́ть; *~ын чыбыркы белән каезлау* погре́ть спи́ну плёткою; *дошманның ~ын каезлау (яру)* поколоти́ть врага́; **~ кую** *см.* **сырт бирү**; **~ сукмагы белән маташу** кривы́ть душо́й; **~ сынса да сынатмау (сер бирмәү)** не подава́ть (не пода́ть) ви́ду; **~ны җиргә тидермәү 1.** не подкача́ть **2.** не подава́ть ви́ду

сыртлан *сущ. зоол.* гие́на

сыртлап *нареч.* гре́бнями; *~ кар өю* навали́ть сне́гу гре́бнями; *көлтәләрне арбага ~ төяү* навали́ть снопы́ на телёгу гре́бнями

сыртлы|к *сущ.* **1.** небольша́я возвы́шенность; плато́; *елга буендагы ~к* возвы́шенность на берегу́ реки́ **2.** *диал.* потни́к ‖ потнико́вый **3.** *диал.* чересседе́льник; *атның ~гы күтәрелгән* у ло́шади приподня́лся чересседе́льник

сыртсыз *прил. прям., перен.* бесхребе́тный; *~ кеше* бесхребе́тный челове́к

сыртта *нареч. диал.* **1.** сза́ди, позади́, за; *бакчабыз ~* наш огоро́д за до́мом **2.** навы́пуск; *күлмәкне чалбардан ~ калдыру* руба́шку наде́ть навы́пуск

сырттан *нареч. диал.* сза́ди; *~ һөҗүм итү* напада́ть сза́ди; *~ тәрәзәләргә тулганнар* сза́ди за́няли все о́кна; *~ караганда* е́сли смотре́ть сза́ди

сыртча *сущ. зоол.* киль (*костяной продольный гребень у птиц*)

сыр|у I *перех.* стега́ть, выстёгивать/вы́стегать, простёгивать/простега́ть *что; буйга ~у* стега́ть продо́льно; *юрган ~у* стега́ть ва́тное одея́ло; *матур бизәкләр белән ~у* простёгивать краси́выми узо́рами □ **~ып бетерү** вы́стегать; *юрган ~ып бетерү* вы́стегать одея́ло; **~ып тегү** вы́стегать; *~ып теккән халат* стёганый халат; **~ып чыгу** простега́ть *что* (*полностью, всё*)

сыр|у II *перех.* **1.** *прям., перен.* облепля́ть/облепи́ть *кого-что; чия агачын чәчәк ~ган* ви́шня вся облепла́ цвета́ми; *балакны сырлан ~ган* штани́ны облепи́ла липу́чка; *бүрекне кар ~ган* ша́пка облепла́ сне́гом **2.** *перен.* облепля́ть/облепи́ть, обступа́ть/обступи́ть *кого-что; см. тж.* **сару**; *аны чебен ~ган* его́ облепи́ли му́хи; *төрле яктан халык ~ган* его́ со всех сторо́н обступи́ли лю́ди □ **~а бару** постепе́нно облепля́ть, обступа́ть; **~ып алу 1.** облепи́ть *кого-что; бал кортлары кәрәзне ~ып алганнар* пчёлы облепи́ли со́ты; *тавыклар ипине ~ып алган* ку́ры облепи́ли хлеб **2.** обступи́ть *кого-что; балалар укытучыны ~ып алганнар* де́ти обступи́ли учи́теля

сырулы *прил. см.* **сырган**; *~ бишмәт* стёганый бешме́т

сыручы *сущ.* стега́льщик; *юрган ~* стега́льщик одея́л

сырха|у I *прил.* **1.** больно́й, хво́рый; *~у кеше* больно́й (хво́рый) челове́к; *~у хатын* больна́я же́нщина **2.** *в знач. сущ.* 1) больно́й (хво́рый) челове́к; *~уга әйләнү* преврати́ться в больно́го (больну́ю) 2) боле́знь, хворь, недомога́ние; *аның ~вы* его́ боле́знь; *~уга дәва* лека́рство от боле́зни; *томау ~вы* на́сморк □ **~у булу** боле́ть, хвора́ть; испы́тывать/испыта́ть недомога́ние; **~уга сабышу** заболе́ть, захвора́ть

сырх|ау II *неперех. уст.* боле́ть, хвора́ть, недомога́ть; *ул төгәл бер атна ~ады* она́ боле́ла ро́вно неде́лю; *кай җирең ~ый?* что у тебя́ боли́т? □ **~ап алу (кую)** приболе́ть; **~ап китү** заболе́ть, захвора́ть; **~ап тору** недомога́ть; *әни ~ап тора* мать недомога́ет (хвора́ет)

сырхаулану *неперех. редко см.* **сырхаулау**

сырхаула|у *неперех.* боле́ть, хвора́ть, недомога́ть; *ул гел ~п йөри* он ча́сто боле́ет (хвора́ет) □ **~п алу (кую)** *см.* **сырхап алу (кую)**; **~п китү** *см.* **сырхап китү**; **~п тору** *см.* **сырхап тору**

сырхаулы *прил.* **1.** боле́зненный; *~ чак* боле́зненное состоя́ние, боле́зненный пери́од **2.** больно́й, хво́рый

сырхаулы|к *сущ.* боле́зненное состоя́ние; недомога́ние; боле́знь; *~кны җиңеп* одоле́в боле́зненное состоя́ние; *~гына карамыйча* несмотря́ на своё боле́зненное состоя́ние (боле́знь)

сырхаштыру 1. *многокр. от* **сырхау** 2 **2.** *неперех.* похва́рывать

сырхуат *сущ.* **1.** ко́жная боле́знь (*которая появляется вследствие наличия внутренних болезней или беременности*) **2.** *бот.* зверобо́й изя́щный (*которым лечат кожные болезни*)

сырчы *сущ.* ре́зчик

сырыгу *неперех. диал.* облепля́ть/облепи́ть *что чем*

сырылмалы *прил. вторая часть парного слова* **борылмалы-сырылмалы**

сырылу I *страд. от* **сыру I**; стега́ться, быть простёганным

сырылу II *неперех.* **1.** облепля́ться/облепи́ться *чем*, приставать/приста́ть *к кому-чему; см. тж.* **сарылу**; *кар белән ~* облепля́ться сне́гом **2.** *перен.* ла́ститься, жа́ться; *әтисенә ~* жа́ться к отцу́; *матур кызга ~* ла́ститься (жа́ться) к краса́вице

сырынды *сущ. диал. см.* **сырынты**; *койма янындагы ~* сугро́б у забо́ра

сырынты *сущ.* **1.** сугро́б, сне́жный зава́л; *капка төбендәге ~лар* сугро́бы у воро́т **2.** нале́п; прилёп, прилёпа; *кар ~сы* сне́жный нале́п; *мамык ~сы* ва́тный нале́п

сырынтылап *нареч.* сугро́бами, в ви́де сугро́ба; *буран карны ~ салган* бура́н намёл сугро́бы

сырыну *неперех. редко см.* **сырылу**

сырышкак *прил.* **1.** це́пкий; *~ усемлек* це́пкое расте́ние **2.** *перен.* навя́зчивый, назо́йливый; *~ кеше* навя́зчивый челове́к

сырышма *прил.* цепля́ющийся; *~ сабак* цепля́ющийся сте́бель

сырыштыр|у *перех.* **1.** *многокр. от* **сырышу 2.** дава́ть/дать втере́ться, подпуска́ть/подпусти́ть бли́зко; *аны үзеңә ~ма* не подпуска́й его́ к себе́ бли́зко

сырыш|у *неперех.* **1.** облепля́ть/облепи́ть *кого-что; сиңа тигәнәк ~кан* тебя́ облепи́л репе́й; *җепшек кар киемгә ~ты* мо́крый снег облепи́л оде́жду **2.** *перен.* обступа́ть/обступи́ть *кого; балалар укытучыга ~каннар* де́ти обступи́ли учи́теля; *караңгылык һәр яктан ~а* темнота́ обступа́ет со всех сторо́н **3.** *перен.* льнуть, прильну́ть, жа́ться, прижима́ться/прижа́ться *к кому-чему; җиргә ~у* жа́ться к земле́; *ул миңа ~ты* он прижа́лся (прильну́л) ко мне; *стенага ~у* прижима́ться к стене́ **4.** *перен.* втира́ться/втере́ться, затеса́ться, втеса́ться; *безнең компаниягә ~у* втеса́ться в на́шу компа́нию □ **~а бару 1.** (постепе́нно) облепля́ть, обступа́ть **2.** *перен.* (постепе́нно) затеса́ться, втере́ться; **~ып бетү** облепи́ть, обступи́ть (*всё*)

сырыш|у-сырмаш|у *неперех.* льнуть, прильну́ть *к кому-чему; ул миңа сырышып-сырмашып йөри* он льнёт ко мне

сырышучан *прил.* **1.** це́пкий, цепля́ющийся (*растения*) **2.** *перен.* навя́зчивый, назо́йливый

сысылау *неперех. редко* сюсю́кать || сюсю́канье

сыткалау *многокр. от* **сыту**

сыткы *сущ.* прыщ, у́горь; *биттәге ~* прыщ на лице́ □ **~ чыгу** прыща́веть ◊ **~ сагыз** назо́йливая му́ха

сыткый *сущ. диал.* се́ра хво́йных дере́вьев ◊ **~ сагыз** *см.* **сыткы сагыз**

сыткылану *неперех. разг.* навя́зываться/навяза́ться *кому-чему*

сыткылау прыща́веть; покрыва́ться/покры́ться прыща́ми, угря́ми

сыткылы *прил.* прыща́вый, угрева́тый; *~ йөз* прыща́вое лицо́

сыттыру *понуд. от* **сыту**

сыттырылу *страд. от* **сыттыру**

сыт|у *неперех.* **1.** *прям., перен.* дави́ть *на что;* разда́вливать/раздави́ть *кого-что чем; җирне ~у* дави́ть на зе́млю; *йомырканы ~у* раздави́ть яйцо́; *үт куыгын ~у* раздави́ть же́лчный пузы́рь; *басып ~у* раздави́ть нога́ми **2.** выда́вливать/выдавить *что; сыткы ~у* вы́давить прыщ; *шешне ~у* выда́вливать нары́в **3.** *перен.* хму́рить, нахму́рить, мо́рщить, намо́рщить *что; чыраен ~у* нахму́рить лицо́ □ **~а бирү** продолжа́ть дави́ть; **~ып бетерү** раздави́ть, вы́давить (*всё*); **~ып керү** вдави́ться; **~ып ташлау** раздави́ть *кого-что;* **~ып чыгару** вы́давить *что*

сытык *прил.* **1.** разда́вленный, смя́тый; *~ йомырка* разда́вленное яйцо́; *~ лимон* разда́вленный лимо́н **2.** *перен.* угрю́мый, хму́рый, нахму́ренный; ки́слый; *~ чырай* угрю́мое (ки́слое) лицо́ **3.** *перен. диал.* плакси́вый, слезли́вый; *~ бала* плакси́вый ребёнок **4.** *в знач. сущ. диал.* пла́кса, нюня; *әй ~!* ой пла́кса!

сытыклы|к *сущ.* **1.** разда́вленность, смя́тость **2.** *перен.* угрю́мость, хму́рость; *см. тж.* **чытык**; *йөзенең ~гы* угрю́мость (хму́рость) его́ лица́

сытыл|у 1. *страд. от* **сыту**; *урындык ~ды* скаме́йка разда́влена; *шеш ~у* прорва́лся нары́в **2.** *перен.* хму́риться, нахму́риться; *~ып җылый башлады* он нахму́рился и на́чал пла́кать; *чырае ~ды* лицо́ её нахму́рилось **3.** *перен.* пла́кать, хны́кать; *юк-бар сүзгә дә ~а* пла́чет из-за пустяко́в

сытышу *взаимно-совм. от* **сыту**

сы|ю *неперех.* **1.** *прям., перен.* умеща́ться/умести́ться, помеща́ться/помести́ться; вмеща́ться/вмести́ться; *залга сыймау* не умеща́ться в за́ле; *чемоданга сыю* вмести́ться в чемода́не; *барыбыз да бер өйгә сыймабыз* в оди́н дом все не уме́стимся; *елга ярга сыймый* река́ не вмеща́ется в свои́ берега́ **2.** *перен.* укла́дываться/уложи́ться; *башка (акылга) сыймый* не укла́дывается в голове́ **3.** лезть, быть в по́ру; *аякка сыю* лезть на́ ноги; *бармак сыя* па́лец ле́зет; *кулмәккә сыймау* не влеза́ть в руба́шку **4.** *перен.* лезть, сходи́ться, совмеща́ться/совмести́ться *с чем,* подходи́ть/подойти́ *к кому-чему; логикага сыю* быть в лада́х с ло́гикой; *законга сыймый* не совмеща́ется с зако́ном; *әдәпкә сыймый* не совмеща́ется с благовоспи́танностью; *әхлак нормаларына сыймый* не совмеща́ется с но́рмами мора́ли **5.** *перен.* быть при́нятым, станови́ться/стать свои́м; *семьяга сыймадым* я не был при́нят э́той семьёй **6.** *диал.* попада́ть/попа́сть *во что; кыскартуга сыю* попа́сть под сокраще́ние **7.** *диал.* относи́ться; *без ул кабиләгә сыймыйбыз* мы не отно́симся к э́тому пле́мени □ **сыеп бетү (җиту) 1.** умести́ться; *чемоданга сыеп бетмәделәр* в чемода́н не умести́лись **2.** укла́дываться/уложи́ться; *нормага сыеп бетми* не совсе́м укла́дывается в но́рмы **3.** совмести́ться; **сыя бару** умеща́ться, вмеща́ться (*по ходу*); **сыя язу** чуть не умести́ться

сыя *сущ. диал.* **1.** черни́ла; тушь **2.** грязево́й пото́к, сель

сыя|к *сущ. диал.* вне́шний вид, обли́чье; *~гыннан ук билгеле* мо́жно определи́ть по одному́ вне́шнему ви́ду

сыяу *сущ. диал.* кочедык; *кулга ~ алу* брать в ру́ки кочедык

сэр *сущ.* сэр (*обращение к мужчине в Англии и в США*); *сэр, рәхим итегез* пожа́луйста, сэр

сюжет *сущ.* сюже́т || сюже́тный; *тарихи ~* истори́ческий сюже́т; *романның ~ын сөйләп чыгу* переска́зать сюже́т рома́на; *кызыклы ~* интере́сный сюже́т; *төп ~ сызыгы* основна́я сюже́тная ли́ния

сюжетлы *прил.* сюже́тный, с сюже́том; *~ әсәр* сюже́тное произведе́ние; *~ җыр* сюже́тная пе́сня; *кискен ~* остросюже́тный

сюжетлылык *сущ.* сюже́тность; *кискен ~* остросюже́тность

сюита *сущ. муз.* сюи́та (*музыкальное произведение*) || сюи́тный; *~ның беренче кисәге* пе́рвая часть сюи́ты; *балет ~сы* бале́тная сюи́та

сюрприз *сущ. книжн.* **1.** сюрпри́з (*неожиданный подарок или неожиданное событие*); *минем өчен бу ~* э́то для меня́ сюрпри́з; *күңелле ~ ясау* сде́лать прия́тный сюрпри́з **2.** *в знач. прил.* сюрпри́зный; *~ тартма* сюрпри́зная коро́бка

сюрреализм *сущ.* сюрреали́зм (*авангардное направление в искусстве и литературе*); *француз ~ы* францу́зский сюрреали́зм

сюрреали́стик *прил.* сюрреалисти́ческий; *~ манера* сюрреалисти́ческая мане́ра

сюртук *сущ.* сюрту́к (*мужская верхняя двубортная одежда с длинными полами*) || сюрту́чный; *~ кию* наде́ть сюрту́к; *~ төймәләре* сюрту́чные пу́говицы

Т

та *частица*

та *предлог уст.* до; по; пока́; *та кыямәт* до оконча́ния ми́ра, до светопреставле́ния; *та кыямәтсез кавышу юк безгә фольк.* мы не сви́димся до са́мого светопреставле́ния □ **та әзәлдән бирле** начина́я с сотворе́ния ми́ра; **та теректә** пока́ жив

таба I *сущ.* **1.** сковорода́; сковоро́дка *разг.*; *чуен ~* чугу́нная сковорода́; *~да кыздыру* жа́рить на сковороде́; *майламагач, ~ купмый (посл.)* не подма́жешь — не пое́дешь (*букв.* от сковороды́ не отдерёшь); *~ күмәче см.* **табикмәк** 2. диск (*как часть механизмов*); *чәчкеч ~сы* диск (дисково́на) се́ялки; *рефлектор ~сы* диск рефле́ктора □ **~ ашы** мучны́е изде́лия, изгото́вленные на сковороде́ ◊ **~ исе чыгару** печь (испека́ть, испе́чь) *что-л.* (*по приезде гостей, в дни праздников*); **~ ялаган мәче шикелле** как кот в ма́сленицу (*о плутоватом взгляде*); **~ ялау** *см.* **тәлинкә ялау**; **~га бастыру** *см.* **утлы табага бастыру**; **~дан гына төшкән** свежеиспечённый

таба II *послелог направит.* **1.** к (ко), по направле́нию к ...; *ярга ~* к бе́регу; *елгага ~* по направле́нию к реке́; *тәрәзәгә ~ якынлашу* приближа́ться к окну́ **2.** к, ко, под (*при уточнении времени, временных отношений*); *кичкә ~* к ве́черу, под ве́чер; *көзгә ~* к о́сени, под о́сень

таба III *сущ. диал.* порица́ние; *~ ясау* устро́ить порица́ние, позо́рить

табагач *сущ.* сковоро́дник; *~ның озын булса, кулың пешмәс (посл.)* е́сли сковоро́дник дли́нный, ру́ку не обожжёшь (*о заблаговременной подготовке какого-л. дела, мероприятия*)

табагачлы: табагачлы лампа ла́мпа с рукоя́ткой (*при помощи которой она прикреплялась к стене*)

таба|к I *сущ.* **1.** больша́я ча́ша (*для приноса горячей пищи на стол*); *бер ~ктан ашаган* нонока́шник; *ашына күрә ~гы, балына күрә калагы (посл.)* по се́ньке и ша́пка, по Ерёмке и ермо́лка; по живо́тному и корм, по уму́ и разгово́р (*букв.* по су́пу и ча́ша, по мёду и ло́жка); *~к күрке нәкыш белән түгел, аш белән (посл.)* ≈ изба́ красна́ не угла́ми, а пирога́ми (*букв.* ча́ша красна́ су́пом, а не ро́списью) **2.** весова́я ча́ша; ча́ша у весо́в; *таразы ~гы* ча́ша рыча́жных весо́в **3.** счётное сло́во для предме́тов, приноси́мых обы́чно на ча́ше; *бер ~к ит* (по́лная) ча́ша мя́са **4.** *перен.* дискови́дные предме́ты (*шапка подсолнечника*) ◊ **~к өсте** по́лная ча́ша (выраже́ние изоби́лия); **~к түбәсе** са́мая вку́сная часть пи́щи при обще́ственной тра́пезе; сли́вки, пе́нки; **~к түбәсеннән ашау** есть са́мое вку́сное; снима́ть пе́нки; **~кка салу** класть на весы́ (на ча́шу весо́в); **~кка салып үлчәргә** е́сли то́чно взве́шивать; **~кка төкерү** плева́ть, наплева́ть на ча́шу (*о святотатственном поступке в отношении семьи, друга, Родины и т. п.*), плева́ть Христу́ в бо́роду; не уважа́ть хозя́ина (*о госте*); **~к(тай) бит(ле)** с широ́ким (пло́ским, кру́глым) лицо́м; широколи́цый

табак II *сущ.* **1.** лист (*бумаги, жести, стекла и т. п.*); счётное сло́во для листо́в; *бер ~ кәгазь* (оди́н) лист бума́ги **2.** лист (*единица измерения печатной продукции*); *басма ~к* печа́тный лист; *автор ~гы* а́вторский лист

табакланы *редко страд. от* **табаклау**; *~ган калай* жесть, разре́занная на листы́

табакла|у *перех.* **1.** дели́ть, раздели́ть || деле́ние, раздеде́ние на листы́ **2.** *в знач. нареч.* **табаклап** 1) листа́ми, в ви́де листо́в; поли́стно; *~п алу (сату)* покупа́ть (продава́ть) листа́ми, поли́стно (*бумагу, жесть, шифер и т. п.*) 2) в определённом коли́честве листо́в; *кәгазь биш ~п (булыр)* о́коло пяти́ листо́в бума́ги

табаклы I *прил.* с ча́шами, име́ющий ча́шу; *~ үлчәү* весы́ с ча́шами

табаклы II *прил.* **1.** име́ющий определённое коли́чество (*печатных, учётных*) листо́в, состоя́щий из ... (или в ...) листо́в; *биш ~ китап* кни́га в пять печа́тных листо́в **2.** листово́й; *~ калай* листово́е желе́зо; *~ бал* мёд в вощи́не (*который употребляется в таком виде*); *~ тукыма* листова́я ткань (*которая не ткётся, а делается из синтетических материалов в плоском виде*)

табаклык I *прил.* доста́точный для заполне́ния определённого коли́чества листо́в; *см.* **табаклы**; *ун ~ материал* материа́л, доста́точный для заполне́ния десяти́ печа́тных листо́в; материа́л на де́сять печа́тных листо́в

табаклык II *сущ. этногр.* **1.** стол, накры́тый для сва́дебных госте́й; почётный стол для жениха́ и его́ сопровожда́ющего; *~ янына басу* встать у сва́дебного стола́ (*один из свадебных ритуалов*) **2.** *диал.* посу́дница, по́лка для посу́ды

табак-савыт *сущ. собир.* посу́да (*крупных размеров*); *см. тж.* **савыт-саба**

табак-табак I *прил.* **1.** в (во мно́гих) кру́пных ча́шах; разло́женный в кру́пные ча́ши; *табак-табак ит* мя́со в кру́пных ча́шах **2.** кру́пными, больши́ми ча́шами; *табак-табак энҗе тарту килер үзенә* (*песня*) тебе́ (краса́вица) в ка́честве сва́дебного пода́рка принесу́т отбо́рного же́мчуга больши́ми ча́шами

табак-табак II *прил.* листа́ми; *табак-табак пыяла* мно́жество листо́в стекла́

табакташ *сущ.* (*постоянный*) сотрапе́зник, нонока́шник; *һәр ~ дус түгел (посл.)* не ка́ждый сотрапе́зник — друг

табакча *сущ.* ча́ша, таре́лка; ма́ленькая таре́лка весо́в

табалату *понуд. от* **табалау**

табала|у *перех.* упрека́ть (в чём), попрека́ть (чем), укоря́ть || упрёк, попрёк, уко́р; *ипи белән ~у* попрека́ть хле́бом (*тем, что кто-то ест чей-то хлеб*); *туганнары белән ~у* упрека́ть тем, что родны́е (*братья и сёстры*) таки́е (*нехорошие и т. п.*); *кешене ~ганчы, үзеңне ~ (посл.)* чем упрека́ть друго́го, пеня́й на себя́

табалашу *взаимн.-совм. от* **табалау**; упрека́ть, попрека́ть друг дру́га

табан I *сущ.* **1.** *анат.* ступня́, стопа́, плюсна́; пята́ *уст.* || плюсневы́й; *~ сөякләре* плюсневы́е ко́сти **2.** *уст.* фут; ме́ра длины́, разме́ром в сре́днюю стопу́; *атай заманы пәйгамбәр заманына бер ~ якынрак, ди (посл.)* говоря́т, что вре́мя отцо́в на фут бли́же ко вре́мени проро́ка (*т. е. поскольку эпоха пророка идеальна, а всё на свете идёт к развращению, времена отцов все-таки лучше, чем время сына*) **3.** подо́шва (о́буви); *см. тж.* **табанча, олтан**; *~ салу* приби́ть (приши́ть) подо́шву о́буви **4.** по́лоз, поло́зья (*саней, лыж и т. п.*); *~ бөгү* гнуть поло́зья; *~ сугу* прибива́ть/приби́ть (*железные*) поло́зья

(*к деревянной основе*) **5.** *перен. о рабочих плоских поверхностях некоторых механизмов и машин*: ступня́, башма́к, ре́йка и т. п.; *тегү машинасының ~ы* наступа́тельная ре́йка шве́йной маши́нки □ **~ асты 1.** ступня́; *кешенең ~ астын күргәнче, үзеңнең борын астыңны күр* (*посл.*) чем высма́тривать то, что под пя́ткой у други́х, лу́чше смотри́, что у самого́ под но́сом; ≈ чем замеча́ть соло́минку в чужо́м глазу́, лу́чше убери́ бревно́ из своего́ **2.** положе́ние под пято́й, т. е. уни́женной подчинённости; гнёт; **~ астына салып таптау (изү)** беспоща́дно подавля́ть, угнета́ть; **~ астында** под гнётом, под пято́й *кого*; **~ астында калу** остава́ться/оста́ться под пято́й *кого*; **~ кызу** набира́ть ско́рость; *~ы кызганчы, тай узар, ~ы кызгач, ат узар* (*посл.*) пока́ ло́шадь не набрала́ ско́рость, её обго́нит жеребёнок, но набра́в ско́рость, обойдёт ло́шадь; **~ майлау** гото́виться улизну́ть/утека́ть/убежа́ть (*букв.* сма́зать подо́шву); убега́ть/убежа́ть; *еллаган, айлаган да ~ын майлаган* (*погов.*) прожи́л год, прожи́л ме́сяц, по́сле того́ улизну́л; **~ тирәрлек җирлек** то́чка опо́ры (в жи́зни); **~ терәү** найти́ опо́ру в жи́зни; **~ шомарту 1.** слоня́ться, шата́ться, околачиваться в одно́м ме́сте (*ничего не делая*) **2.** плеса́ть, танцева́ть (*бездельничать*) **3.** *см.* **табан майлау**; **~ ялау** лиза́ть *кому* пя́тки, подхали́мничать; **~(ны) ялтырату** показа́ть пя́тки, засверка́ть пя́тками, пусти́ться наутёк, убежа́ть, удра́ть (*позорным образом*), дать стрекача́ и т. п.; **~нан кереп, түбәдән чыгу** быть отпе́той пройдо́хой; быть ма́стером узнава́ть подного́тную друго́го (*человека*); *~нан керер, түбәдән чыгар* ≈ в одно́ у́хо влезе́т, в друго́е вы́лезет; ≈ из-под стоя́чего подо́шву вы́режет; **~ы пешкән (табага баскан) мәче (песи) кебек (шикелле, төсле һ. б.) йөрү (кылану) 1.** мета́ться/замета́ться **2.** торопи́ться, заторопи́ться; забе́гать, ходи́ть как на уголька́х (*букв.* как ко́шка, обжёгшая ла́пу); носи́ться как угоре́лый; **~ына басу (басып тору)** неотсту́пно преследовать; идти́ по све́жим следа́м; **~ыннан тузган** о низкоро́слом ста́ром челове́ке (*букв.* соста́рился сни́зу)

табан II *сущ.* **1.** карп; линь **2.** кара́сь; *~ (балык) шулпасы* уха́ из карасе́й; *~ тоту* лови́ть карасе́й □ **~ балык** *см.* **табан**

табан III *послелог см.* **таба**

табангы *прил. диал.* обращённый по направле́нию *к чему-л.*; *өйнең урамга ~ ягы* сторона́ до́ма, обращённая к у́лице

табандырык *сущ. диал.* **1.** педа́ль; *см. тж.* **тәбәлдерек 2.** *этногр.* подно́жка кибитки

табанлау I *перех.* **1.** ста́вить, приде́лать поло́зья; *чана ~* приде́лать поло́зья **2.** *редко* измеря́ть фу́тами

табанл|ау II *неперех.* удира́ть/удра́ть; убега́ть, дра́пать, ума́тываться (*пешком*); *әйдә, ~ыйк* дава́й умата́ем

табанлы *прил.* **1.** с (*определённого качества*) подо́швой; *калын ~* с то́лстой подо́швой **2.** с (*определённого качества*) поло́зьями; *тимер ~ чана* са́ни с желе́зными поло́зьями

табанлык I *сущ. прил.* материа́л, го́дный, доста́точный и́ли предназна́ченный для изготовле́ния подо́шв, поло́зьев и т. п.; *см.* **табан**; *~ кун* ко́жа на подо́шву, для подо́швы; *~ тимер* поло́ски желе́за для поло́зьев

табанлык II *сущ. анат.* це́вка

табан-табан *нареч. диал.* неотсту́пно преследуя, по све́жим следа́м; *см. тж.* **эзмә-эз**; *табан-табан куу* неотсту́пно гна́ться по следа́м

табантын *послелог диал.* **1.** по направле́нию в сто́рону *чего-л.* **2.** сторона́, куда́ и́ли отку́да дви́гаются; *бу ~нан* отсю́да, отсе́ль, дви́гаясь отсю́да; *теге ~нан* отту́да, отсе́ль, дви́гаясь отту́да; с того́ ме́ста; *теге ~га* в ту сто́рону

табанча *сущ.* **1.** запла́тка, нака́тка на подо́шву; *~ салу (беркетү)* ста́вить, приклеи́ть запла́ту, нака́тку **2.** желе́зная поло́ска, прибива́емая к поло́зьям сане́й; *~ сугу* приби́ть желе́зную поло́ску (*к полозьям*) **3.** отде́льное звено́ гу́сеницы; *танк ~сы* звено́ гу́сениц та́нка

табанчалау *перех. см.* **табанлау**

табанчылык *сущ. см.* **табанлык**

табарман *сущ. диал.* челове́к-добы́тчик семьи́; *барысына да бер ~* оди́н добы́тчик на всех

табатын *послелог см.* **табантын**

табача *сущ. диал.* **1.** сковоро́дка, ма́ленькая сковорода́ **2.** *диал.* блю́дце, (*фарфоровая*) ча́шка

табачык *сущ. см.* **табача**

та́бель *сущ. в разн. знач.* та́бель || та́бельный; *өлгереш ~е* та́бель успева́емости; *~ тактасы* та́бельная доска́

та́бель-календарь *сущ.* та́бель-календа́рь, календа́рь в ви́де табли́цы

та́бельле *прил.* та́бельный; с та́белью; *~ система* та́бельная систе́ма

та́бельче *сущ.* та́бельщик, учётчик; *~ булып эшләү* рабо́тать та́бельщиком

табиб *сущ. книжн.* **1.** врач, до́ктор, эскула́п; *бар да сау булса, ~ авыру булыр* (*посл.*) е́сли все здоро́вы, сам врач бо́лен; *чыгасы җанны ~ тотып калалмас* (*посл.*) от сме́рти эскула́п не спасёт; от сме́рти лека́рства нет **2.** *перен.* исцели́тель, спаси́тель; *см. тж.* **табибчы**; *тилелеккә ~ юк* (*посл.*) от глу́пости нет спасе́ния (*букв.* спаси́теля)

табибә *сущ. книжн.* врач-же́нщина; врачи́ха, до́кторша

табибла́рча *нареч.* как врач; по поведе́нию, привы́чкам и приёмам врачей́; *~ тыныч булу* быть споко́йным, как врач

табиблык *сущ.* **1.** положе́ние и́ли профе́ссия врача́ || врачебный; *~та йөрү* быть врачо́м, во врача́х (*в определённый период или при определённых обстоятельствах*); *~ мәктәбе* врачебная (*медицинская*) шко́ла, учи́лище **2.** врачева́ние, уха́живание за больны́ми **3.** медици́на; *см. тж.* **табиб** □ **~ итү** врачева́ть; замеща́ть врача́

табибчы *сущ.* **1.** цели́тель, исцели́тель (*от хандры, лени, любовной тоски и т. п.*); *син миңа ~ булдың* ты стал мои́м исцели́телем **2.** *прост. см.* **табиб**

табигат|ь *сущ.* **1.** приро́да (*ландшафт, флора и фауна, а также климат определённой местности*); *көньяк ~е* приро́да и кли́мат ю́га; ю́жная приро́да **2.** приро́да (*совокупность природных богатств*); *бу якларда ~ь ярлы* в э́тих края́х приро́да бедна́ **3.** приро́да, жизнь (*закономерности органического мира; природно-физиологические свойства человека*) *~ь куренешләре* явле́ния приро́ды; *~ь законнары* зако́ны приро́ды; *~ь үлемнән көчле* (*посл.*) жизнь сильне́е сме́рти; *мәхәббәт — ~ь булган* (*посл.*) любо́вь — дар приро́ды **4.** нату́ра, нрав, привы́чки, темпера́мент, хара́ктер; *аның ~е шундый* такова́ его́ нату́ра; он уж тако́в (*его не изменишь*); *син дип башка беркемне дә теләми ~ем* (*песня*) кро́ме тебя́, никого́ не прие́млет душа́ моя́ **5.** приро́да, су́щность, совоку́пность существенных сво́йств; *электр ~е* приро́да электри́чества □ **~е белән** по свое́й приро́де; по свое́й нату́ре; **~ь баласы 1.** дитя́ приро́ды (*человек,*

воспитанный в глуши, на лоне природы, незнакомый с городской жизнью) **2.** (*человек, живущий по велению сердца, т. е. чувствами, а не разумом*); **~ь белгече** натурали́ст, естествове́д, знато́к приро́ды; природове́д; **~ь белеме (гыйлеме)** естествозна́ние, природове́дение; **~ь кочагында (эчендә)** на ло́не приро́ды; **~ь фәннәре** есте́ственные нау́ки; **~ькә чит (ят)** противоесте́ственный; чу́ждый приро́де; **~ьтән өстен** сверхъесте́ственный

табигатьле *прил.* **1.** име́ющий определённые приро́дные усло́вия; *см.* **табигать**; *бай ~ өлкә* о́бласть с бога́тыми приро́дными усло́виями **2.** с определённым нра́вом, хара́ктером; име́ющий определённый нрав, хара́ктер; *йомшак ~* мягкосерде́чный, добронра́вный; *тыныч ~* споко́йного, уравнове́шенного хара́ктера; *җиңел ~* лёгкого нра́ва; легкомы́сленный; ве́треный

табигатьче *сущ.* **1.** натурали́ст; естествоиспыта́тель; естествове́д, природове́д; *~ рәссам* худо́жник-пейзажи́ст **2.** худо́жник-натурали́ст **3.** люби́тель приро́ды

табигатьчелек *сущ.* увлече́ние изуче́нием приро́ды (*ландшафта, климата, растительности и т. п.*)

табигый *прил.* **1.** натура́льный, есте́ственный (*в противоположность искусственному*); *~ бакча* есте́ственный сад (парк); *~ көтүлек* есте́ственное па́стбище; *~ матурлык* есте́ственная красота́; *~ яктылык* есте́ственный свет **2.** приро́дный, есте́ственный; *~ байлыклар* приро́дные бога́тства **3.** приро́дный, и́стинный; *~ талант* (*сәләт һ. б.*) приро́дный тала́нт (спосо́бности и т. п.) **4.** свобо́дный, не де́ланный, ненатя́нутый; чистосерде́чный; просто́й; *~ җавап* просто́й отве́т; *~ башланыш* свобо́дное нача́ло; *~ кыланыш* ненатя́нутое поведе́ние **5.** *вводн. сл.* есте́ственно; (само́ собо́й) разуме́ется; *кеше, ~, көчләүгә каршы* челове́к, разуме́ется, про́тив наси́лия □ **~ афәт** стихи́йное бе́дствие; **~ булмаган (түгел)** неесте́ственный; **~ булмаган рәвештә 1.** неесте́ственным о́бразом **2.** противоесте́ственный; *см. тж.* **гайре табигый**; **~ сайланыш** есте́ственный отбо́р; **~ хаҗәт** есте́ственная потре́бность; **~ хәл (халь) 1.** есте́ственное положе́ние веще́й **2.** есте́ственно; ничего́ удиви́тельного; вполне́ поня́тно

табигыйлан|у *неперех.* станови́ться/стать есте́ственным (*о поведении*); *хәрәкәтләре ~ып китте* его́ движе́ния ста́ли есте́ственными

табигыйлык *сущ.* **1.** есте́ственность, приро́дность; не иску́сственность **2.** ненатя́нутость, свобо́да и простота́ (*в поведении и общении*)

табигый-фәнни *прил.* есте́ственно-нау́чный; *табигый-фәнни аңлату* есте́ственно-нау́чное объясне́ние (разъясне́ние)

табигыять *сущ. уст.* естествозна́ние, есте́ственные нау́ки; *~тән гыйлем алу* приобрета́ть зна́ния по естествозна́нию

табигъ I *предик. сл. уст.* находя́щийся в ве́дении *кого*

табиг|ъ II *книжн.* по́дданный; *бу илнең ~ълары* по́дданные э́той страны́ □ **~ъның ~ы булу** быть в по́дданстве, в ве́дении *кого*; **~ъ булган** находя́щийся в по́дданстве, в ве́дении *кого*

табигълык *сущ. книжн.* по́дданство

табикмәк *сущ. см.* **тәбикмәк**

таблет *сущ. прост. см.* **табле́тка**

табле́тка *сущ.* табле́тка; *~ йоту* приня́ть (*проглотить, глотать*) табле́тку

табле́ткалы *прил.* **1.** содержа́щий табле́тку; с табле́ткой (*коробочка*) **2.** в табле́тках, в ви́де табле́ток; *~ дару* лека́рство в табле́тках; *~ пенициллин* пеницилли́н в ви́де табле́ток

табли́ца *сущ.* табли́ца; *~ төзү* соста́вить табли́цу; *тапкырлау ~сы* табли́ца умноже́ния □ **~га салу** предста́вить *какие-л.* да́нные в ви́де табли́цы

табли́цалы *прил.* **1.** с табли́цей, име́ющий табли́цу **2.** в ви́де табли́цы, табли́чный; *~ отчёт* отчёт в ви́де табли́цы, табли́чный отчёт

табло *сущ.* табло́; *электрон ~* электро́нное табло́

та́бор *сущ.* та́бор; *см.тж.* **табыр**

табра *сущ. диал.* та́вро (*на лошади*)

та|бу I *перех.* **1. 1)** находи́ть/найти́ || нахожде́ние; *акчаны юлдан ~псаң да санап ал* (*посл.*) счита́й де́ньги, е́сли да́же их нашёл на доро́ге **2)** нача́янно обнару́жить; набрести́ *на что*; *йөреп-йөреп ни ~птың?* ну и что ты нашёл в (э́тих) скита́ниях? **3)** находи́ть, встре́тить, повстреча́ть *кого-л.* (*в дальних краях*); *якташларыңны ~бу* находи́ть свои́х земляко́в **4)** найти́/находи́ть, приобрета́ть/приобрести́; достава́ть/доста́ть || нахожде́ние, приобрете́ние, достава́ние (*путём поисков, распросов и т. п.*); *эзләгән ~бар* (*посл.*) кто и́щет, тот найдёт; *эштән көчле нәрсә ~бу мөмкин түгел* (*посл.*) ничего́ сильне́е труда́ нельзя́ найти́ **2. 1)** вы́искивать/вы́искать *что-л.* ну́жное, находи́ть/найти́ || нахожде́ние вы́хода (*из положения*); *көен ~бу* находи́ть/найти́ подхо́д; *чарасын (җаен) ~бу* находи́ть/найти́ сре́дство (*возможность*); *хәйләсен ~бу* находи́ть уло́вку, приду́мывать хи́трость, ухитря́ться/ухитри́ться **2)** находи́ть/найти́ || нахожде́ние необходи́мого в тру́дных усло́виях, крити́ческих ситуа́циях; *вакыт ~бу* находи́ть вре́мя; *үзендә көч ~бу* найти́ в себе́ си́лы **3)** найти́/находи́ть, извлека́ть/извле́чь || извлече́ние, нахожде́ние по́лного отве́та путём вы́кладок и вычисле́ний; *санның тамырын ~бу* извлека́ть/извле́чь ко́рень числа́; *мәсьәләнең җавабын ~бу* вы́числить отве́т зада́чи **3.** извлека́ть/извле́чь, добыва́ть/добы́ть || извлече́ние, добыва́ние (*из руды, из горных пород и т. п.*); *алтын ~бу* добыва́ть, извлека́ть из поро́д зо́лото **4.** добыва́ть/добы́ть || добыва́ние (*средств, материальных ценностей*); зараба́тывать/зарабо́тать; *акча (мал) ~бу* добыва́ть/добы́ть де́ньги (добро́); *~пкан — капкан, ~пмаган — капмаган* (*посл.*) кто добыва́ет, тот и наслажда́ется добы́тым **5.** рожа́ть, роди́ть || рожде́ние дете́й; *биш бала ~бу* роди́ть пятеры́х дете́й; *игезәк ~бу* роди́ть близнецо́в **6.** обнару́живать/обнару́жить || обнару́живание/обнаруже́ние *чего-л.*; *хаталарны ~бу* обнару́живать оши́бки; *җитмәүчелекне ~бу* обнару́жить недоста́чу **7.** обрета́ть/обрести́, находи́ть/найти́ || обрете́ние, нахожде́ние удовлетворе́ния (*в каких-л. конкретных средствах, обстоятельствах*); *үзеңә теләктәшлек ~бу* находи́ть/найти́ удовлетворе́ния, удово́льствия для себя́; *ләззәт (тәм) ~бу* найти́ удовлетворе́ния, удово́льствия *в чём-л.*; *шифа ~бу* найти́ исцеле́ние; *юаныч ~бу* найти́ развлече́ние **8.** достига́ть/дости́чь || достиже́ние *чего-л.* (*определённого желаемого, искомого положения или ожидаемого состояния*); *тынычлык ~бу* достига́ть, дости́чь успокое́ния; *шөһрәт табу* достига́ть/дости́чь сла́вы **9.** приходи́ть/прийти́ || прихо́д к логи́ческому, ожида́емому результа́ту; находи́ть/найти́ || нахожде́ние *в чём-л.*; *гәүдәләнеш ~бу* находи́ть воплоще́ние; *чагылыш ~бу* находи́ть отраже́ние (*в докладе*) **10. (дип табу)** быть в определённом мне́нии, счита́ть, полага́ть; реши́ть, что ... ; *кирәк (дип) ~бу* счита́ть ну́жным, необходи́мым; *тиеш (дип) ~бу* счита́ть до́лжным, обя́занным; *яхшы дип ~бу* подтверждать, реши́ть, что хорошо́ (хоро́-

ший) **11.** *в функ. модальн. сл.* **тапкан, таптың, таптыгыз** и т. п.; выража́ет неодобре́ние, презре́ние к слова́м и де́йствиям *кого-л.*; то́же мне (вот уж); ну и нашёл (*нашли и т. п.*); *~птың әйтер сүз* то́же мне, нашёл, что сказа́ть; *~пкан сәяр кешесен* вот уж нашёл кого́ полюби́ть; *~птылар бер проблема* то́же мне (ну и) нашли́ пробле́му □ **~быш алу 1.** найти́, набрести́, подобра́ть (неча́янно, вдруг) **2.** раздобы́ть (себе́); *~быш аласы бар* на́до ещё находи́ть, найти́; **~быш бирү** раздобы́ть (друго́му); **~быш йөрү** добыва́ть, подбира́ть (*уроненное, потерянное*); **~быш кую** зара́нее добыва́ть, добы́ть, подгото́вить, пригото́вить ну́жное; **~пкан (таптың, таптыгыз h. б.) бер** *см.* **тапкан, таптың** и т. п.; **~пма да, бүлешмә дә** лу́чше не свя́зываться *с кем*; не приведи́ бог зна́ться *с кем*; не дай бог име́ть де́ло *с кем* (*о человеке, с которым нелегко прийти к соглашению, общему мнению и т. п.*)

табу II *сущ.* табу́ (*запрет на какое-л. слово или действие по языческому обычаю*); *~ салу* наложи́ть табу́, запре́т

табугъ *сущ. уст. книжн.* покло́н, поклоне́ние □ **~ сәлам** приве́тствование покло́ном

табун *сущ. диал.* табу́н, ста́до; *см.тж.***табын, табыр**

табурет *сущ.* табуре́т, табуре́тка

табут *сущ.* гроб; *~ка салу* класть, положи́ть в гроб; *~ капкачы* кры́шка гро́ба □ **~ арбасы** катафа́лк

табутла|у *неперех.* положи́ть в гроб; *~п күму* хорони́ть в гробу́ (*что в целом необычно для татар, хотя и не запрещалось*)

табутлы *прил.* с гро́бом, име́ющий на себе́ гроб; *~ арба* теле́га с гро́бом

табутчы *сущ.* гробовщи́к; *~ һөнәре* профе́ссия гробовщика́

табылгала|у *многокр. от* **табылу**; иногда́ (и́зредка) находи́ться (мо́жно найти́); *~п тора* то и де́ло нахо́дится; нере́дко нахо́дится

табылдык I *сущ.* **1.** нахо́дка; *~лар бюросы* бюро́ нахо́док **2.** *редко* подки́дыш (*ребёнок неизвестных родителей*)

табылдык II *прил.* **1.** на́йденный; *~ мал* на́йденное добро́ **2.** *редко* подки́нутый (*о ребёнке*)

табыл|у 1. *страд. от* **табу** I (1—5); находи́ться, отыскиваться, обнару́живаться; *~ган әйбер — үлҗә* (*посл.*) (*букв.* то, что на́йдено — трофе́й) **2.** *дип ~у* счита́ться, подтверждаться; выноси́ться (*о решении*) || подтвержде́ние; вынесе́ние определённого реше́ния; *кирәк дип ~ды* сочли́ ну́жным; реши́ли, что на́до (ну́жно) **3.** *безл.* быть таки́м, что мо́жно найти́; найти́сь; *камышы күренсә, чишмәсе ~ыр* (*посл.*) (*букв.* е́сли камыши́ видны́, сам родни́к найдётся); *залим булган җирдә хаин дә ~а* (*посл.*) (*букв.* там, где име́ется тира́н, найдётся и преда́тель)

табын *сущ.* **1.** 1) круг гостей́ (*сидящих по-старинному на полу или на широких нарах*) 2) *уст.* стол на четы́ре челове́ка; счётное сло́во для едоко́в (гостей́); *ике ~ ашыйбыз* на во́семь (*букв.* две по четвёрке) едоко́в **2.** (*накрытый*) стол (*гостей*) **3.** *перен.* засто́лье, засто́льная компа́ния || засто́льный; *~ җыры* засто́льная пе́сня; *~ның яме* краса́ засто́лья; душа́ засто́льной компа́нии **4.** *диал.* табу́н (*организованное стадо животных*); *атлар ~ы* табу́н лошаде́й; *сарыклар ~ы* гру́ппа овец (*неразлучных друг с другом*) **5.** *диал.* тебенёвка; *атларны ~га җибәрү* отпуска́ть лошаде́й на тебенёвку □ **~ җәю** накры́ть стол; **~ җыю** убира́ть стол (со стола́); **~ үткәрү (уздыру)** созыва́ть гостей́

табындаш *сущ.* **1.** сотрапе́зник; *һәр ~ тугандаш түгел* не ка́ждый сотрапе́зник — друг и брат **2.** *перен.* однока́шник, сотова́рищ; *~ дус* друг-однока́шник

табындашлык *сущ.* сотрапе́зничество □ **~ итү** сотрапе́зничать

табындыр|у *понуд. от* **табыну**; *потка ~у* заставля́ть почита́ть и́долов; *бурыч багындыра, кылыч ~а* (*посл.*) (*букв.* долг ста́вит в зави́симость, меч заставля́ет поклоня́ться)

табынлык I *сущ. уст.* **1.** широ́кая кошма́, где сиде́л круг гостей́; ме́сто, где уса́живали гостей́ за тра́пезу; *~ка дәшү* пригласи́ть в круг гостей́, сидя́щих на кошме́ **2.** *см.* **табын** 1 **3.** я́ства, еда́ и питьё для гостей́

табынлык II *прил.* **1.** доста́точный и́ли приго́дный для угоще́ния приглашённых **2.** предназна́ченный для гостей́

табынмыш *сущ.* покло́нник; *талантлар һәм ~лар* тала́нты и покло́нники || *предик. сл.* явля́ется покло́нником, влюблён; *сиңа ~* явля́ется твои́м покло́нником

табын-табын *нареч.* сме́на за сме́ной, многокра́тно (*о приёме и угощении гостей*); *табын-табын кунак* мно́жество (*в несколько смен*) гостей́

табыну *неперех.* **1.** поклоня́ться || поклоне́ние *кому, чему; аллага ~* поклоня́ться алла́ху; *потка ~* поклоня́ться и́долу **2.** преклоня́ться || преклоне́ние *перед кем, чем*, чрезме́рно почита́ть || почита́ние *кого*; раболе́пствовать || раболе́пствование *перед кем* **3.** *перен.* чрезме́рно увлека́ться/увле́чься || увлече́ние *каким-л.* занятием; влюбля́ться || влюблённость *в кого, во что*; *кызларга ~* увлека́ться де́вушками, влюбля́ться в де́вушек; *шахматка ~* отдава́ться (*во вред другим интересам*) ша́хматам

табынучан *прил.* скло́нный к поклоне́нию и раболе́пствию; *хатын-кыз ~ була* же́нщина скло́нна к поклоне́нию

табынучы *сущ.* **1.** поклоня́ющийся (*божествам*); -покло́нник; *утка ~* огнепокло́нник **2.** покло́нник, почита́тель; *үзенең ~лары белән* со свои́ми покло́нниками

табынучылык *сущ.* покло́нничество; *потка ~* идолопокло́нничество

табынчы *сущ.* **1.** челове́к, раздаю́щий я́ства; угоще́ния на пиру́; гла́вный разда́тчик, кра́вчий **2.** тамада́; *~ итеп сайлау* вы́брать тамадо́й

табынчылык *сущ.* **1.** обя́занности (*работа*) разда́тчика, кра́вчего при угоще́нии пиру́ющих **2.** угоще́ние гостей́ (*как деятельность, требующая определённых знаний и навыков*)

табыр *сущ.* **1.** коса́к, табу́н; *см.тж.* **табын** 2—3; *атымны җибәрдем ~га, маңгай ялын үрдем танырга* (*песня*) гуля́ет конь мой в табуне́, и он приме́тен у меня́ — с плетёной чёлочкой на лбу **2.** водопо́й (*скота, стада*); *см.тж.* **туплау**; *~га төшү* спусти́ться к ме́сту водопо́я **3.** зато́птанное копы́тами ме́сто (*в поле, на лугу и т. п.*); *~га әйләндерү* затопта́ть дочерна́ **4.** ток, гумно́; *басу ~ы* полево́й стан (*с необходимыми постройками*); *~да куну* ночева́ть в по́ле на гумне́ **5.** *ист.* та́бор, вое́нный ла́герь, окружённый теле́гами

табырдау *неперех.* греме́ть (*издавать шум множеством копыт*) || гром, стук, перестук копы́т; *см. тж.* **таптырдау, тупырдау**

табырла|у *перех.* **1.** покрыва́ть/покры́ть ма́ссой, скопле́нием (*поле, луг*); занима́ть/заня́ть мно́жеством; *ул җирне атлар ~ган* то ме́сто заняло́ ста́до лошаде́й **2.** затопта́ть || затопта́ние поле́й и луго́в так, что травы́ почти́ не ви́дно □ **~п бетерү** затопта́ть догола́

табыр-тобыр *подр. шуму, топоту, издаваемому множеством копыт (при прохождении стада через мост)*; *см.* **тапыр-топыр**

табыш *сущ.* 1.находка, найденная вещь; ~ *табу* найти находку 2. добыча охотника, искателя или хищника; (*кемнең дә булса*) *~ы булу* стать (быть) добычей *кого-л.* 3. заработок; прибыль (*предприятия*); нажива, разжива *прост.*; *эстәмә кешегә сагыш, эстә үзеңә ~* (*посл.*) не желай чужому беды, пожелай себе выгоды 4. *экон.* прибыль; барыш; дивиденд; ~ *массасы* масса прибыли 5. взяток (*у пчелы*) ◊ ~ **куу** гоняться за прибылью

табыш-киңәш *сущ. собир. см.* **киңәш-табыш** □ **табыш-киңәш итү** держать совет, совещаться

табышлан|у *неперех. прост.* получать/получить прибыль; поживиться, разживиться/разжиться || получение прибыли, пожива, разжива; *~ып кайткан* вернулся с поживой

табышлы *прил.* 1. с добычей, имеющий добычу (*об охотнике, звере и т. п.*); ~ *бүре — өнендә, табышсыз бүре — баз төбендә* (*посл.*) волк с добычей — у себя в норе, волк без добычи — на дне ловушки 2. имеющий заработок, удачу в предприятии; удачливый; ~ *кеше танышлы* (*посл.*) у кого удача, у того и сдача (*букв.* человек с добычей имеет много знакомых) 3. прибыльный; выгодный; рентабельный; ~ *кәсеп* прибыльный промысел; ~ *эш* прибыльное дело 4. взяточный (*об улье*); ~ *ел* медовый год, в котором сбор мёда хорош □ ~ **булу** добыть, находить *что-л.*; быть обладателем находки, добычи, поживы и т. п.

табышмак *сущ.* 1. загадка (*как жанр фольклора*); ~ *әйтәм, үзең тап* (формула загадывания) скажу тебе загадку, а разгадай сам; *такмак — тел ачкычы, ~ — зиһен ачкычы* (*посл.*) прибаутка — ключ к языку, загадка — ключ к смекалке; *табылган ~ җиңел була* (*посл.*) разгаданная загадка легка 2. *перен.* что-нибудь таинственное, малопонятное; *мәхәббәт ул — ~* (*посл.*) любовь — это загадка || *прил.* загадочный, таинственный; ~ *кеше* загадочный человек □ ~ **табу** разгадывать загадку

табышмаклы *прил.* головоломный, загадочный; малопонятный; интригующий; ~ *мизгел* загадочный (интригующий) момент

табышсыз *нареч.* без добычи; без прибыли/наживы || *прил.* 1. бесприбыльный, неприбыльный; ~ *сәүдә* бесприбыльная торговля; ~ *кибетче көлмәс* (*посл.*) бесприбыльный торговец не смеётся 2. недобычливый, не приносящий добычи (*охотник*); ~ *сунарчыдан суйлак бия артык* (*посл.*) ленивая кобыла лучше охотника без добычи

табышсызлык *сущ.* бесприбыльность (*работы*); бесполезность (*поисков, охоты и т. п.*); состояние бесприбыльности, бесполезности

табыштыр|у *перех.* помогать найти друг другу, свести/свести; устраивать/устроить встречу

табыштыру-кавыштыру *перех.* соединить || соединение (*достойных пар*); способствовать соединению

табыш|у *взаимно-совм. от* **табу** I 1. находить/найти || нахождение друг другу; *берегез алма, берегез хөрмә — каян ~тыгыз сез* (*песня*) один из вас — яблочко, другой — финик, как вы сумели встретиться (найти друг другу) 2. помогать/помощь в поисках или добыче *чего-л.*; *эзләп ~у* помогать в поисках, розысках и т. п.

табышчы *сущ. разг.* 1. барышник, калымщик 2. добытчик (*для семьи, близких*); *бердәнбер ~* единственный добытчик

табышчылык *сущ. разг.* барышничество; ~ *белән шөгыльләнү* заниматься барышничеством

тавил *сущ. уст.* 1. длинный, рослый человек; *һәр ~ — ахмак* (*шуточная посл.*) ≈ телом вырос, умом нет 2. *поэт.* амфибрахий (*размер стопы*)

тавис *сущ.* 1. павa, павлин; ~ *койрыгына ышаныр* (*посл.*) павлин надеется на свой хвост 2. *перен.* щёголь, франт □ ~ **күз** *зоол.* павлиний глаз (*бабочка*) ◊ ~ **койрыгы таккан карга** ворона в павлиньих перьях (*букв.* ворона, нацепившая павлиний хвост)

тавтологик *прил.* тавтологический; ~ *раслама* тавтологическое утверждение; ~ *ялгышлар (хаталар)* тавтологические ошибки

тавтология *сущ.* тавтология (*повторное обозначение уже названного понятия другим словом*); *хөкемдәге ~* тавтология в рассуждении

тавтологияле *прил.* тавтологический; имеющий, содержащий тавтологию

тавык *сущ.* курица, курочка || куриный; *~к йомыркасы* куриное яйцо; яйцо курицы; *~к төшенә тары керә* (*посл.*) курице снится просо (*т.е. кому — что*); *күршенең ~гы каздай, хатыны кыздай* (*посл.*) у соседей куры — что гуси, жена — что девица; *~к белән ят, этәч белән тор* (*посл.*) ложись вместе с курицей (*т. е. сразу после наступления сумерков*), вставай вместе с петухом (*т.е. пораньше*); *эчкәндә ~к та тәңрегә карар* (*посл.*) когда пьёт, и курица глядит на небо (*на бога*) □ **~к асрау** заниматься куроводством; разводить кур; **~к асраучылык** куроводство, разведение кур; **~к елы** год курицы (*по двенадцатилетнему животному циклу летоисчисления*); **~к ите** курятина, куриное мясо; **~к карчыгасы** ястреб-тетеревятник; **~к кетәге** курятник; **~к күз (күзе)** 1. куриная слепота (*болезнь зрения, заключающаяся в том, что человек перестаёт видеть уже при сумерках*) 2. *бот.* куросле́п (*трава с мелкими красноватыми цветами*); ~ **мендәре** подушка с куриным пухом; ◊ ~ **алачыгы (керәге, оясы) кадәр (кебек, шикелле)** очень маленький, тесный (*о размерах жилища или жилой комнаты*); **~к аягы (тәпие)** *эвф.* 1. крест, носимый у христиан на шее 2. крест как медаль или орден; **~к аяк** человек, который при ходьбе часто задевает ногой вещи; **~к бете** *прост.* мелочный человек; **~к йөрәк (җан)** трус (*букв.* куриное сердце, куриная душа); **~к кетәгенә кертү** загнать, поставить в глупое положение; **~к кичүе** куриный брод (*очень мелкое место*); **~к ми (мие, миле), ~к мие эчкән** (*ашаган*) безмозглый, пустоголовый, тупица; плохо соображающий; глупый; *~к мие эчкән нәрсә* эх, ты, тупица (дубина); **~к чүплән бетергесез** куры не клюют; видимо-невидимо; без счёта (*о мелких предметах или мелких заботах*); **~клар көләр (көләрлек)** курам на смех; очень глупый, нелепый и смешной

тавыкбаш *сущ.* недотёпа, глупец, олух || *прил.* глупый; ~ *кешеләр* глупые люди

тавыкканат *прил.* недалёкий (*о человеке*); *шундый бер ~ инде ул* такой уж он недалёкий человек

тавыккүз *прил.* больной куриной слепотой; ~ *Гарифулла* Гарифулла, больной куриной слепотой

тавыксыман *прил.* 1. куроподобный 2. *в знач. сущ.* **тавыксыманнар** *зоол.* куриные, куроподобные (*отряд птиц*)

тавыкчык *сущ. уменьш.-ласк. от* **тавык**; курочка

тавык-чебеш, тавык-чеби *сущ. собир.* куры, куриные (*как домашняя птица*); всякая домашняя птица куриного

ной поро́ды; *тавык-чебеш ашату* корми́ть кур и цыпля́т; *тавык-чебеш асрау (үрчетү)* разводи́ть кур, кури́ных цыпля́т

тавыч *сущ. диал.* деревя́нный подно́с на но́жках, ста́вец

тавыш *сущ.* **1.** го́лос (*голос человека как предмет вокального или ораторского искусства*) || голосово́й; *ачы ~* ре́зкий (пронзи́тельный) го́лос, крик; *калын ~* ни́зкий го́лос, бас; *карлыккан ~* хри́плый го́лос; *нечкә ~* высо́кий (то́нкий, то́ненький) го́лос; *~ыңнан таныдым я* тебя́ узна́л по го́лосу **2.** тон; го́лос, как выраже́ние душе́вного состоя́ния; *зәһәрле ~* свире́пый (*букв.* ядови́тый) тон; *йомшак ~* ма́гкий го́лос; *кайгылы ~* печа́льный го́лос **3.** звук в музыка́льном иску́стве; *биш ~тан торган көйләр системасы* систе́ма музыка́льных моти́вов, состоя́щих из пяти́ голосо́в (*пентатоника*) **4.** звук, зву́ки; характе́рный шум || звукова́й; *см. тж.* **аваз**; гудо́к, сигна́л и т. п.; *машина ~ы* зву́ки прохожде́ния и́ли гудко́в маши́ны; *аяк ~ы* зву́ки шаго́в; *җил ~ы* шум (*завывание или шум*) ве́тра; *~ көче* си́ла зву́ка; *~ язу* запи́сывать го́лос; *~ үткәрә торган* проводя́щий звук; звукопроводя́щий; *~ дулкыннары* звуковы́е во́лны **5.** шум, шум-гам, го́мон; кри́ки; скандал и т. п.; *~ чыгару (~ куптару, ~ күтәрү)* поднима́ть, подня́ть шум, скандали́ть, крича́ть; *~ куптарсаң, давыл чыгар* (*посл.*) посе́ешь ве́тер — пожнёшь бу́рю (*букв.* е́сли подни́мешь шум, то непреме́нно подни́мется бу́ря) **6.** го́лос (*как право заявлять своё мнение при обсуждении каких-л. вопросов в общественных учреждениях, совещаниях и т. п.*); *киңәшле ~* совеща́тельный го́лос; *~ларның күпчелеге белән* большинство́м голосо́в; *~тан (~ хокуккыннан) мәхрүм итү* лиша́ть пра́ва го́лоса **7.** *в знач. нареч.* **тавыштан** в определённое число́ голосо́в; *ике ~тан җырлау* петь в два го́лоса □ **~ бетү** лиша́ться го́лоса (*вследствие болезни голосовых связок или других причин*); **~ бирү 1.** голоси́ть, подава́ть го́лос (*друг другу в лесу*) **2.** гуде́ть, загуде́ть, сигна́лить; *пароход ~ бирә* гуди́т парохо́д **3.** отда́ть го́лос (голоса́), голосова́ть (*за кого-л. или в пользу какого-л. выдвинутого мнения*); **~ итү** закрича́ть, загомони́ть, зашуме́ть (*о людях*); **~ ярыгы** голосова́я щель; **~ ярылары** голосовы́е свя́зки; **~ны (~ын) күтәрү (төшерү)** повы́сить го́лос (тон); **~ын кысу** (произво́льно) осла́бить го́лос; **~ы кысылды** (вдруг) его́ го́лос осла́б (*от волнения*) ◊ **~ адашырлык** просто́рный, многоко́мнатный (*о квартире*); **~ка кую** ста́вить на голосова́ние (*т. е.* реша́ть большинство́м голосо́в); **~ы бөреннән чыгу, ~ны бөреннән алу** говори́ть, обраща́ться с други́ми самоуве́ренно, спеси́во, дава́я поня́ть о своём превосхо́дстве, си́ле и т. п. преиму́ществах; **~ы таш яра** громогла́сный, с громовы́м го́лосом (*букв.* го́лос взрыва́ет ка́мни); **~ыңны чыгарма (чыгарасы булма)** не смей пи́кнуть, не пи́кни; будь нем, как ры́ба

тавышалгыч *сущ.* звукоприёмник (*аппарат или устройство*); *хәрби ~лар* боевы́е звукоприёмники || *прил.* звукоприёмный; *~ җайланма* звукоприёмное устро́йство

тавыш-гауга *сущ.* скандал, ру́гань; шум, кри́ки; галдёж, гвалт; **тавыш-гауга кубару (куптару, чыгару)** подня́ть шум, кри́ки; скандали́ть, буя́нить

тавышйоткыч *сущ.* звукопоглоща́тель, звукопоглоти́тель || *прил.* звукопоглоща́тельный, звукопоглати́тельный; *~ тукыма* звукопоглоща́тельная ткань (*для драпировки помещений*)

тавышкан *сущ. зоол.* **1.** большо́й тушка́нчик; *см. тж.* **зур кушаяк 2.** *диал.* степно́й за́яц (*не меняющий цвета меха при линьке*) □ **~ елы** год за́йца; *см. тж.* **куян елы**

тавышландыр|у 1. *понуд. от* **тавышлану 2.** озвуча́ть/озву́чивать/озву́чить (*кинофильм*) || озву́чивание **3.** *в знач. нареч.* **тавышландырып** шу́мно, зву́чно; с шу́мом; *~ып иснәү* шу́мно зева́ть

тавышлан|у *неперех.* **1.** издава́ть/изда́ть зву́ки, шуме́ть, зашуме́ть (непроизво́льно) || ра́зные зву́ки, шум (*при движении*) **2.** *см.* **тавышландыру 3**; **~ып сулау** шу́мно дыша́ть **3.** поднима́ть, подня́ть крик, шум; голоси́ть, заголоси́ть; шу́мно, возбуждённо говори́ть || кри́ки, шум, голоса́ возбуждённых люде́й; скандал; *~ыр чак түгел* не тако́е вре́мя, что́бы поднима́ть шум (скандал); *~ырлык эш юк* не́чего шуме́ть, нет по́вода для того́, что́бы поднима́ть шум

тавышлануч|ан *прил.* шумли́вый, крикли́вый; скло́нный к скандалам и ссо́рам; *см. тж.* **тавышчан**

тавышланыш|у *взаимн.-совм. от* **тавышлану**; руга́ться, переруга́ться; ссо́риться ме́жду собо́й *~ып йөриләр* всё вре́мя перери́гиваются || перери́гивание, перепа́лка; суматоха

тавышлау *неперех.* **1.** де́лать *что-л.* с шу́мом (*нарочно*); шуме́ть, зашуме́ть; крича́ть, покри́кивать, стуча́ть, посту́кивать и т. п. **2.** *см.* **тавышлану 3**

тавышлы *прил.* **1.** с определённым го́лосом; име́ющий го́лос определённого сво́йства, ка́чества и́ли коли́чества; *калын ~* име́ющий ни́зкий и́ли си́льный го́лос, с ни́зким си́льным го́лосом; *кәҗә ~* с козли́ным го́лосом; *күп~* многоголо́сый; *көр (көчле, шәп) ~* с зы́чным (си́льным) го́лосом; *чәрелдек ~* с пронзи́тельным же́нским го́лосом; *өч ~* трёхголо́сый **2.** шу́мный; *~ урам* шу́мная у́лица; *~ уеннар* шу́мные и́гры **3.** звукова́й, озву́ченный; шумово́й; *~ кино* звукове́ кино́; *~ сигнал* звукова́й сигна́л **4.** *перен.* шумли́вый, скандальный; *~ эш* скандальное де́ло □ **~ тоткар** шумова́я поме́ха

тавышлыландыру *перех.* озву́чивать/озву́чить (*фильм*)

тавышлылану *неперех.* де́латься/сде́латься шу́мным, звуковы́м; озву́чиваться/озву́читься

тавышлылы|к *сущ.* **1.** озву́ченность; *фильмның ~гы* озву́ченность фи́льма **2.** *перен.* шумли́вость, скандальность; *~гы белән атаклы* изве́стен (изве́стный) свое́й скандальностью

тавышсыз *прил.* **1.** беззву́чный; бесшу́мный, немо́й; *~ тынлык* нема́я тишина́ **2.** ти́хий, кро́ткий, споко́йный, не скандальный (*о человеке*) || *нареч.* беззву́чно, ти́хо, бесшу́мно; *~ елау* беззву́чно пла́кать □ **~ гына 1.** тихо́нько, ти́хо-ти́хо, без шу́ма, бесшу́мно; *~ атлы шагай* без шу́ма **2.** *перен.* не афиши́руя; *~ гына зур эшләр башкару* не афиши́руя, выполня́ть больши́е дела́

тавышсызлан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать беззву́чным, бесшу́мным **2.** станови́ться/стать ти́хим, споко́йным, уравнове́шенным

тавышсызлы|к *сущ.* **1.** беззву́чность, бесшу́мность; *электрлы йөрткечнең ~гы* бесшу́мность электри́ческого дви́гателя **2.** *перен.* споко́йствие, уравнове́шенность (*в семье, нрава, характера*)

тавышсыз-өнсез *нареч. см.* **тавышсыз-тынсыз**; не проронив ни зву́ка; *тавышсыз-өнсез калу* теря́ть, потеря́ть го́лос, спосо́бность что́-нибудь сказа́ть (*от удивления и т. п.*)

тавышсыз-тынсыз 1. *прил.* соверше́нно беззву́чный, безмо́лвный; о́чень ти́хий (до пода́вленности); *тавышсыз-тынсыз кеше* о́чень ти́хий (до пода́вленности) челове́к || *нареч.* соверше́нно беззву́чно, безмо́лвно,

не издава́я ни зву́ка; *тавышсыз-тынсыз утыру* сиде́ть соверше́нно безмо́лвно (*не смея заговорить и т. п.*) **2.** о́чень ти́хо, о́чень осторо́жно **3.** *перен.* тихо́нько, потихо́ньку, негла́сно; *см. тж.* **астыртын, урынтын**

тавыштоткыч *сущ.* звукоулови́тель || *прил.* звукоулови́тельный; ~ *җайланма* звукоула́вливающее устро́йство

тавыш-тын *сущ.* **1.** о зву́ках де́ятельности, движе́ния, дыха́ния; *бер тавыш-тын юк!* ни зву́ка! **2.** слу́хи, разгово́ры, молва́ об определённом предме́те и́ли ли́чности; *бу хакта тавыш-тын ишетелми* (*тавыш-тын юк*) об э́том нет никаки́х разгово́ров □ **тавыш-тының чыкмасын** не смей пи́кнуть; ни-ни́!

тавыш-тынсыз *прил.* **1.** *см.* **тавышсыз-тынсыз 2.** потихо́ньку-полего́ньку; *тавыш-тынсыз гына яшәп яту* жить-поживать себе́ потихо́ньку-полего́ньку (*не давая повода говорить о себе плохого*)

тавышчан *прил.* крикли́вый, скандальный; скло́нный поднима́ть шум; ~ *да, изгелеккә авышчан* (*погов.*) крикли́в, скандале́н, но скло́нен к доброте́

тавышчанлану *неперех.* де́латься/сде́латься скло́нным к скандала́м и кри́кам

тавышчанлык *сущ.* крикли́вость, скандальность, скло́нность к перепа́лкам, ру́гани; *~ка тавышчан инде ул* насчёт крикли́вости он, то́чно, крикли́в

тага *сущ. диал.* подко́ва; *см.* **дага**

таган *сущ.* **1.** трено́жник, трено́г (*устройство из трёх-четырёх кольев, палок, жердей, образующих пирамиду для различных целей*); ~ *кору* соорудить трено́г **2.** *диал.* тага́н, таганок, таганец (*обруч на ножках, служащий как подстава для котла*) **3.** каче́ли на опо́рах; ~ *атыну* кача́ться на каче́лях □ ~ **асты 1.** сбор молодёжи весно́й в определённом ме́сте (*где устраивались качели и играли в различные коллективные игры*); ~ **асу** подве́шивать, подве́сить котёл, ведро́ и пр. на перекла́дину над огнём, костро́м и т. п. (*для кипячения воды*) **2.** вид коллекти́вной игры́ с пля́ской, молодёжный хоровод с пля́ской пар; **~га кую** *см.* **таганлау**

таганлау *перех.* **1.** ста́вить пирами́дой, в пирами́ду (*колья, жерди, брёвна*) **2.** ста́вить стога́ и ски́рды на стожо́рах

таганлык *сущ.* **1.** ме́сто, площа́дка, где сооружа́ли насти́л для обрабо́тки дома́шнего сукна́ (*обработка производилась девушками в порядке помощи — коллективно*) **2.** ме́сто, где производи́лись весе́нние и́гры; *см. тж.* **таган асты**

тагар *сущ. диал.* **1.** колода́ (*большое корыто, жёлоб из цельного дерева*); *см. тж.* **улак**; *савыты ~. балы көчкә тамар* (*погов.*) сосу́д огро́мный, а мёд ка́плями (*о чём-л. несообразном с возможностями*) **2.** продолгова́тый я́щик для выра́щивания ко́мнатных цвето́в

тагарак *сущ.* корму́шка, корыто; *сыерның сөте ~та* (*посл.*) молоко́ коро́вы в корму́шке; *ишәкне табынга тартсаң, ул ~ка встерәр* (*посл.*) пригласи́ осла́ к столу́, он потя́нет тебя́ к корму́шке (*т.е невежественный человек не понимает культурного поведения*)

тагать *сущ. уст. книжн.* **1.** подчине́ние с подобостра́стием; подобостра́стие **2.** поклоне́ние бо́гу, моле́ние бо́гу (*в течение долгого времени*)

тагатьче *сущ.* богомо́лец; челове́к, пре́данный богомо́льству

тагатьчелек *сущ.* богомо́льство; посвяще́ние себя́ богомо́льству; ~ *белән гомер уздыру* корота́ть век в богомо́льстве

та|гу *перех.* **1.** прицепля́ть/прицепи́ть || прицепле́ние; *тракторга чәчкеч ~гу* прицепля́ть/прицепи́ть се́ялку к тра́ктору; *чиләккә кылдау ~гу* прицепля́ть/прицепи́ть ду́жку к ведру́; *арбага ~ккач, дегет чиләге дә хажга барган, ди* (*посл.*) прице́пленная к теле́ге и лагу́нка для дёгтя, говоря́т, соверши́ла путеше́ствие в Ме́кку **2.** нацепля́ть/нацепи́ть, пришива́ть/приши́ть; прикрепля́ть/прикрепи́ть; привя́зывать/привяза́ть; надева́ть/наде́ть || нацепле́ние, прикрепле́ние, пришива́ние, привя́зывание; *медаль ~гу* нацепи́ть меда́ль; *алка ~гу* прикрепи́ть (к ушам) се́рьги; *төймә ~гу* прици́ть пу́говицу (к оде́жде) **3.** надева́ть, наде́ть || надева́ние (*чего-л. такого, которое держится на шнуре, петле*); *асма* (*муенса, галстук*) *~гу* надева́ть/наде́ть подве́ски (ожере́лье, га́лстук) **4.** *перен. прост. неодобр.* таска́ть/тащи́ть, брать/взять с собо́й; вести́ за собо́й *кого; нигә син аны ~гып йөрисең?* чего́ ты повсю́ду таска́ешь с собо́й?; *перен.* нави́зывать/навяза́ть; заставля́ть/заста́вить брать, взять || нави́зывание; *уңган шәкерткә мулла кызын ~гар* (*посл.*) расторо́пному шаки́рду мулла́ нави́зывает свою́ дочь **5.** *перен.* дава́ть/дать (*прозвище*), прида́ть (*имя*), прозва́ть; *кушамат ~гу* дава́ть/дать про́звище; *~кма кешегә исем — үзеңә исем ~гарлар* (*посл.*) не дава́й про́звище друго́му — дадут про́звище и тебе́ самому́ **6.** *перен.* припи́сывать/приписа́ть *кому что*; навлека́ть/навле́чь *на кого что* || припи́сывание, привлече́ние (*чего-л. нехорошего, предосудительного*); *гаеп ~гу* припи́сывать вину́, ло́жно обвиня́ть/обвини́ть; *бәла ~гу* навлека́ть/навле́чь беду́

тагулау *неперех. диал.* помеша́ть; меша́ть; воспрепя́тствовать, препя́тствовать, быть поме́хой

тагулы *прил.* **1.** прице́пленный; *тракторга ~ арбалар* прице́пленные к тра́ктору теле́жки **2.** *в знач. предик.* (уже́) прице́плен

тагулык *сущ.* **1.** то, что прицепля́ется **2.** *перен. см.* **комачаулык**

тагун *сущ. уст.* (**~ хастасы, ~ чире, ~ авыруы**) чума́; *~ кизуе* эпиде́мия чумы́ □ **~ авыруы (хастасы, чиге)** *см.* **тагун**

тагы *нареч.* ещё; *см.* **тагын**

тагыдак *нареч. диал. см.* **тагын**

тагыл *сущ. диал.* **1.** про́волочный узо́р (у ювели́ров); ~ *ясау* де́лать про́волочный узо́р **2.** *см.* **такыл 1**

тагылма *сущ. диал.* про́звище; *см. тж.* **кушамат**; *~га* ~ про́звище к про́звищу (*говорится о случаях, когда прозвище, уже принимаемое как имя, нарочито искажается*) || *сущ.* **1.** прице́п; прицепно́й механи́зм; *трактор ~сы* тра́кторный прице́п; инвента́рь, кото́рый прицепля́ется к тра́ктору; *машинага ~ эшләү* приде́лать прице́п к маши́не **2.** *редко* прида́ток, нагру́зка; *~ белән бирү* дава́ть/дать с прида́тком (с нагру́зкой) **3.** *грам.* приста́вка, второ́й компоне́нт па́рно-копулати́вных сло́жных слов (*таких, как* **төлек** *в слове* **азык-төлек** продово́льствие, **торкылы** в сло́ве **аркылы-торкылы** вдоль и поперёк) || *прил.* прицепно́й; ~ *механизм* прицепно́й механи́зм; ~ *ургыч* прицепна́я жа́тка

тагылмалы *прил.* **1.** име́ющий прице́п, с прице́пом; ~ *трактор* тра́ктор с прице́пом **2.** прицепно́й, предназна́ченный для прицепле́ния □ ~ **парлы сүз** па́рно-копулати́вное сло́жное сло́во (**тиле-миле** глу́пый, глу́пенький; **күрше-күлән** сосе́ди и однодво́рники и т. п.)

тагылмыш *сущ. просторечн. см.* **тагылый**; ~ *булып йөрү* ходи́ть прида́тком; не отставать ни на оди́н шаг

тагыл|у 1. *страд. от* **тагу**; прицепля́ться, быть прице́пленным; навлека́ться, быть да́нным (о про́звище); *исем юкка ~мый (погов.)* про́звище зря не даю́т 2. *перен.* увя́зываться *за кем, чем; көчләп ~ган* наси́льно навя́занный □ **~ып алу** прицепля́ться, зацепля́ться (и не отпуска́ть); **~ып йөрү** неотсту́пно сле́довать, ходи́ть неотвя́зно *за кем-л.*

тагылый *сущ. диал.* тот, кто неотсту́пно сле́дует, хо́дит *за кем-л.*; тот, кто хо́дит по пята́м; *~ булып йөрү* неотсту́пно сле́довать

тагылыну *возвр. от* **тагылу** 2; нава́зываться *кому* в друзья́, в возлю́бленные и т. п.

тагылыш|у *взаимн.-совм. от* **тагылу**; ходи́ть || хожде́ние, сле́довать || сле́дование друг за дру́гом; прицепля́тся || прицепле́ние друг к дру́гу; *~ып йөрү* неразлу́чно ходи́ть вме́сте

тагын I *нареч.* 1. ещё, опя́ть; сно́ва; *тау башында тарым бар, тау астында ~ бар* на горе́ у меня́ есть про́со, а под горо́й — ещё (*загадка о волосах и бороде*) 2. *повторяясь дважды, передаёт оттенок интенсивной многократности*; сно́ва и сно́ва; ещё и ещё; *~ , ~ яңгырый куакларда сандугачның моңлы җырлары* (*песня*) сно́ва и сно́ва в куста́х звуча́т мелоди́чные тре́ли соловья́ 3. ещё и ещё, вдоба́вок, к тому́ же; *монда йөз, тегендә ~ ун* здесь сто, там ещё де́сять; *анысы җитмәгән, ~ монысы* не хвата́ло того́, ещё вот э́то □ **~ бер хәл** (ещё) куда́ ни шло; **~ да** 1. ещё бо́лее, в бо́льшей сте́пени; *~ да усалрак, ~ да шаянрак идегез* вы бы́ли ещё бо́лее озорны́ми, ещё бо́лее бо́йкими 2. и, и ещё; *~ да әйтәсе сүзем бар* и ещё есть у меня́ слове́чко (к тебе́)

тагын II *союз* 1. *соединит. употр. при однородных членах предложения или однородных придаточных предложениях для обозначения чередования, повторяемости*: опя́ть; *~ кукри, ~ яшен яшьни, ~ яңгыр ява* опя́ть гром греми́т, опя́ть сверка́ют мо́лнии, опя́ть идёт дождь 2. *разделит.-перечислит.* то ..., то ...; *~ керде, ~ чыкты* то входи́л, то выходи́л || *частица усилит.* 1. 1) ещё что; *бу ни ~* э́то ещё что (*такое*) 2) ещё бы; *әйтәсең* – ещё бы, сказану́л (не́чего осо́бенно и говори́ть) 2. *после гл. придаёт значению сл. оттенок лёгкого осуждения, нарочитого безразличия или лёгкой зависти*; вишь ты; ишь ты; вот как, ока́зывается (ишь ты, как ему́ к лицу́) 3. *после гл. в ф. повелительного наклонения придает высказыванию оттенок предупреждения, предостережения* смотри́; упаси́ бо́же, как бы ...; *егылма ~* смотри́, не упади́; *белмәсен ~* упаси́ бо́же, как бы он не узна́л 4. *при вопросе передаёт оттенок недовольства поступком вопрошаемого; при переспросе передаёт оттенок осуждения сл. вопрошаемого*; что ещё за; *бу ни эшең ~?* что э́то ещё тако́е (чего́ ты ещё натвори́л?) 5. *при пояснении чего-л. передаёт оттенок лёгкого сожаления, признания небольшой ошибки говорящего*: бы́ло, -таки́; *мин чит кеше дип торам ~* я поду́мал бы́ло, что э́то кто́-то чужо́й

тагыну *возвр. от* **тагу**; наве́шиваться, наве́шивать на себя́ (*украшения, значки и т. п.*); *муенсалар ~* наве́шиваться ожере́льями

таеш|у *совм. от* **таю**; улизну́ть (*о многих*); *барысы да ~тылар* все оди́н за други́м улизну́ли

таҗ *сущ.* 1. коро́на, вене́ц (специа́льный головно́й убо́р, знак отли́чия мона́рхов) 2. *перен.* вы́сший ти́тул, чемпио́нство (*в спорте*); *шахмат таҗы* ша́хматная коро́на 3. вене́ц (венцо́м), коро́на — вид же́нской причёски (*косы, свернутые в виток*) 4. *см.* **такыя** 5. *бот.* вене́чик □ **таҗ иясе** мона́рх, венценосец, царь; **таҗ кидерү** 1. корнова́ть 2. (*у татар-кряшен*) венча́ть (на сва́дьбе) 3. *перен.* объявля́ть пе́рвым *в какой-л.* о́бласти, де́ятельности; чрезме́рно восхваля́ть; **таҗ кию** корнова́ться

таҗгөл *сущ. бот.* амара́нт

таҗдар *прил.* венценосный; *~ хаким* венценосный влады́ка || *сущ.* венценосец □ *~* **тавык** цеса́рка; *см.тж.* **патша тавыгы**

таҗик *сущ.* 1. таджи́к || таджи́кский (*народ, язык, город*); *~ларны белэм мин* я зна́ю таджи́ков 2. *разг. собир.* таджи́ки, таджи́ки, таджи́кский наро́д; *~ бигрәк кызык халык* таджи́ки о́чень интере́сный наро́д

таҗикла́рча *нареч.* по-таджи́кски, на мане́р таджи́ков; *~ киену* одева́ться по-таджи́кски

таҗи́кча *нареч.* 1. по-таджи́кски, на таджи́кском языке́; *~ сөйләү* говори́ть по таджи́кски 2. *см.* **таҗикларча** || *прил.* таджи́кский; на таджи́кском (языке́); *~ акцент* таджи́кский акце́нт; *~ китап* кни́га на таджи́кском (языке́)

таҗлы *прил. прям., перен.* с венцо́м; име́ющий коро́ну, вене́ц; венценосный; корнованный; *~ кош* пти́ца с венцо́м; *~ ахмак* венценосный дура́к

таҗсыз *нареч.* без венца́, без коро́ны; *~ идарә итү* управля́ть без коро́ны || *прил.* не име́ющий венца́, коро́ны; некорно́ванный; *таҗлы һәм ~ хөкемдарлар* корнованные и некорно́ванные влады́ки

таҗ-тәхет *сущ. собир.* 1. атрибу́ты мона́рха; коро́на и трон 2. трон, мона́рхия; мона́рший двор; *таҗ-тәхетләр дер килә* сотряса́ются тро́ны (*монархии*)

таҗчык *сущ.* 1. *в разн. знач.* ве́нчик 2. *бот.* шпо́рец, ве́нчик у цветка́

таз *сущ.* 1. паршá, лишáй на голове́; *таз йоктыру* зараже́ть/зараже́ться паршо́й; *тазы бетсә дә, табы бетми* (*посл.*) е́сли паршá заживёт, пятно́-то оста́нется (*о том, что непростительный поступок не забывается*); *тазы булмаса, кырчыны бардыр* (*посл.*) е́сли и нет у него́ парши́, то, есть наве́рно лишáй (*о подозрительно скромном человеке*) 2. челове́к с паршо́й и́ли плёшью на голове́, шелуди́вый, плеши́вый; *сайланган, сазаган, очраган тазга* (*посл.*) выбира́ла, выбира́ла, на парши́вого напа́ла; *таз таранганчы туй таралган* (*посл.*) пока́ плеши́вый причёсывался, сва́дьба разошла́сь 3. *фольк.* хи́трый и уда́чливый геро́й ска́зок; хитре́ц-плеши́вец; *язмаганны таз укыр* (*погов.*) ненапи́санное (*то, чего нет*) прочтёт лишь плеши́вый хитре́ц 4. *перен.* шельме́ц, постре́л || *прил.* парши́вый, плеши́вый (*о голове*); с парши́вой и́ли плеши́вой голово́й (*о человеке*); *башы таз, күңеле наз* (*посл.*) сам плеши́в, а разбо́рчив (*букв.* тре́бует не́ги) || *сущ. см.* **тас** I

таза *прил.* 1. кре́пкого сложе́ния, здоро́вый (*о людях*); ту́чный, упи́танный, отко́рмленный (*о скоте*); *~ егет* ро́слый, кре́пкий молодо́й челове́к; *~ бозау* упи́танный телёнок 2. тяжёлый, уве́систый, кре́пкий; *~ адымнар белән* уве́систыми шага́ми; *~ куллы кеше* челове́к с кре́пкой руко́й 3. 1) кре́пкий, про́чный (*о вещах*); *~ бүрәнә* кре́пкое (*без пороков*) бревно́; *~ итек* про́чные сапоги́ 2) здоро́вый, не больно́й; *~ чагында таш ташы* пока́ здоро́в — рабо́тай 4. чи́стый, опря́тный; *~ кием* чи́стая оде́жда; *янгын сундергәндә ~ су сайламыйлар* (*посл.*) когда́ ту́шат пожа́р, не до чи́стой воды́ (*букв.* не выбира́ют чи́стой воды́) 5. безупре́чный, беспоро́чный; *~ иман* безупре́чная ве́ра || *нареч.* 1. кре́пко, уве́систо, тяжело́; здо́рово; ве́ско; *~ йөрү* ходи́ть

увéсисто и тяжелó; ~ *эйтү* сказáть вéско; ~ *эйтте* здóрово сказáл (сказанýл) **2.** крéпко, прóчно; ~ *эшлэнгэн* сдéлано (срабóтано) прóчно; ~ *ясалган нәрсә казага юлыкмас* éсли вещь сдéлаешь прóчно — из-за неё в бедý не попадёшь **3.** чи́сто; опря́тно; ~ *итеп юу* чи́сто мыть (стира́ть) **4.** *перен.* беспоро́чно; *гомерлектә* ~ *яшә* проживи́ безупре́чно □ ~ **тормыш** зажи́точная (и че́стная) жизнь; ~ **тормышлы** зажи́точный ◊ ~ **егу** туши́ровать (в борьбе́) вчисту́ю (*т. е. не по баллам*); ~ **Мортаза** челове́к большо́й физи́ческой си́лы, обы́чно посыла́емый на са́мые тяжёлые рабо́ты (*букв.* крепы́ш Муртаза́); ~ *Мортазамыни мин сезгә!* нашли́ Ива́на-дурака́! (*выражение обиды*)

тазалагыч *сущ.* очисти́тель (*воды*) || *прил.* очища́ющий, очисти́тельный (*в физическом, буквальном смысле*), чи́стящий; ~ *состав* очища́ющий соста́в

тазаландыру *перех.* очища́ть || очище́ние (*воды*)

тазалан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать чи́стым и све́жим; станови́ться/стать здоро́вым и кре́пким; ~*ып китү* стать чи́стым и здоро́вым **2.** очища́ться/очи́ститься, умыва́ться/умы́ться

тазал|а́у *перех.* **1.** очища́ть/очи́стить || очище́ние от (*грубой*) гря́зи, навóза, гли́ны и т. п. (*двор, здание*); *идәнне* ~*ау* очи́стить пол **2.** отмыва́ть/отмы́ть || отмыва́ние; *көчкә* ~*ый алдым* я е́ле её отмы́л (от гря́зи)

тазалы|к *сущ.* **1.** здоро́вье; физи́ческая си́ла; *йөзендә* ~*гы куренеп тора* пы́шет здоро́вьем (что ви́дно на лице́); ~*гы бар* обладáет здоро́вьем (*и силой*) **2.** *редко* упи́танность (скота́) **3.** чистота́, опря́тность; *сәламәтлек* ~*к белән* здоро́вье обеспе́чивается чистото́й и опря́тностью

тазарткала́|у *многокр. от* **тазарту**; очища́ть, чи́стить (*время от времени или небрежно, не слишком усердствуя*) □ ~**п алу** поочища́ть

тазарткыч *сущ. в разн. знач.* очисти́тель; -очисти́тель; *пыяла* ~ стеклоочисти́тель; *ашлык* ~ зерноочисти́тель || *прил.* очисти́тельный; *су* ~ *җайланма* водоочисти́тельное устро́йство

тазарт|у I *перех.* **1.** оздоровля́ть/оздорови́ть || оздоровле́ние; *он ашы* ~*а* от мучно́го поправля́ются **2.** чи́стить, очища́ть/очи́стить, вычища́ть/вы́чистить || очище́ние, вычище́ние; *йорт* ~*у* очища́ть (убира́ть) двор **3.** *перен.* чи́стить, освободи́ть от инородных элеме́нтов (*в политических компаниях*)

тазарту II *сущ.* чи́стка (*в партии и т. п. организациях*); ~ *үткәрү* проводи́ть чи́стку

тазартышу *взаимно-совм. от* **тазарту**; чи́стить вме́сте, помога́ть очи́стить

тазар|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать здоро́вым и си́льным; здорове́ть/поздорове́ть; свеже́ть/посвеже́ть; *тәмам* ~*ган* (он) совсе́м поздорове́л, порозове́л, пополне́л **2.** *разг.* поправля́ться/попра́виться || поправле́ние; *авыру* ~*ып килә* больно́й поправля́ется; ~*уга таба бара* идёт на попра́вку **3.** станови́ться/стать све́жим, ту́чным, упи́танным **4.** *диал.* станови́ться/стать чи́стым, *см. тж.* **чистару, сафлану, пакьләну**; *юыныл* ~ умы́вшись, очи́ститься

тазарыну *возвр. от* **тазару**; очища́ться/очи́ститься, очища́ть себя́; умыва́ть/умы́ться (*основательно*) || (само-) очище́ние; умыва́ние (*себя*); *бәйрәмгә каршы* ~ очи́ститься к пра́зднику

тазаяк, тасаяк *сущ.* **1.** большо́й, кру́глый металли́ческий сосу́д, та́зик **2.** *диал.* фарфо́ровое блю́дце (ча́шки); ~*ка салып эчү* пить из блю́дца

таззит *сущ. диал. зоол.* вид болóтной пти́цы (*разновидность чибиса*)

тази *сущ. см.* **тазы**

тазкара *сущ. диал. зоол.* вид пти́цы орли́ной поро́ды (*лысый гриф, сип*)

тазлан|у *неперех.* **1.** паршиве́ть/опаршиве́ть, станови́ться/стать паршивым и́ли плеши́вым **2.** *перен.* хитри́ть, обма́нывать; проявля́ть хи́трость, проны́рливость; *син* ~*ма* ты не хитри́

тазлы|к *сущ.* **1.** паршивость; плеши́вость *редко*; ~*гын тубәтәй яшерә дип уйлый* (*погов.*) ду́мает (полага́ет), что его́ паршивость (поро́ки, недоста́тки) скры́ты тюбете́йкой **2.** *разг.* хи́трость, хитрова́тость, проны́рливость (*соединённая с трусостью или с другими пороками*); ~*гына бара (опять-таки)* проявля́ет свою́ хи́трость

тазы, тазый *сущ.* **1.** борза́я (*гончая, охотничья*) соба́ка; борзова́я соба́ка; *этнең барысы да* ~ *булмас* (*посл.*) не вся́кая соба́ка — борза́я; *заманың төлке булса, син* ~ *бул* (*посл.*) е́сли вре́мя твоё — хи́трая лиса́, ты будь охо́тничьей соба́кой **2.** *в знач. прил.* охо́тничий, го́нчий; беговóй □ ~ **ат** ло́шадь ара́бской поро́ды (*известная своей выносливостью и резвостью*); скаковáя (беговáя) ло́шадь

таифә *сущ. книжн. уст.* **1.** гру́ппа, группиро́вка; *бер* ~ *кеше* гру́ппа люде́й; па́ртия (люде́й) **2.** сосло́вие; просло́йка; *дворяннар* ~*се* сосло́вие дворя́н, дворя́нское сосло́вие **3.** наро́дность, пле́мя, этни́ческая гру́ппа; *мишәр* ~*се* (*этническая*) гру́ппа тата́р-миша́рей

таифәле *прил. книжн. уст.* групповóй; ~ *кунак* групповы́е го́сти

тай I *сущ.* **1.** жеребёнок на второ́м году́, лончáк; *ат эзен тай таптый* (*посл.*) молоды́е иду́т вслед за ста́рыми (*букв.* на след ло́шади наступа́ет жеребёнок); *бүгенге тай иртәгә толпар булгай* (*посл.*) сего́дняшний жеребёнок — за́втрашний боевóй конь; *тайга ишәк ияреп* (*посл.*) тот, кто сле́дует за людьми́ моло́же себя́ — осёл **2.** *диал.* жеребёнок до го́да; вообще́ жеребёнок (*без различения возраста*); *алмачуар тай булмый* (*погов.*) не быва́ет жеребёнка в я́блоках ◊ **тайны тулакка сую** зря раскоше́литься, пойти́ на невозмести́мые расхóды (*букв.* зарéзать жеребёнка ра́ди шку́ры на чу́чело ло́шади, котóрое ста́вили на моги́лу)

тай II *сущ. диал.* **1.** дя́дька; дя́дя (*который брал сына сестры на воспитание по древнему обычаю*) **2.** *в ф. притяжательности 1 л. ед. ч.* **таем** *слово уважительного обращения к мужчине старше себя*

тай III *сущ.* **1.** *уст.* одна́ из двух сторóн — карма́нов хурджи́на — перемётного мешка́ **2.** *диал.* оди́н из боко́в (брусков) тка́цкого станка́

тайга *сущ.* тайга́ || таёжный; ~*да йөрү* ходи́ть по тайге́; ~ *халкы* таёжный наро́д □ ~ **урманы** тайга́ (*как лес*), таёжный лес; ~ **җәнлеге** таёжный зверь

тайгадагы *прил.* таёжный, находя́щийся и́ли име́ющийся в тайге́; ~ *сукмаклар* таёжные тро́пы

тайгак *прил.* **1.** 1) ско́льзкий, оскли́злый; ~ *юл* ско́льзкая доро́га 2) *в функ. сказ.* ско́льзко; *урамда* ~ на у́лице ско́льзко **2.** *перен.* ско́льзкий, ненадёжный; ~ *юлга басу* встать на ско́льзкий путь || *сущ.* ско́льзкое (*обледенение*) ме́сто на доро́ге; ~*та егылу* упа́сть на ско́льзком ме́сте

тайгакландыру *перех.* сде́лать ско́льзким

тайгаклан|у *неперех.* станови́ться/стать ско́льзким; ~*ды юллар, бушап калды кырлар* (*песня*) доро́ги ста́ли ско́льзкими, поля́ опусте́ли

тайгаклат|у 1. *перех. см.* **тайгакландыру** 2. *безл.* станови́ться ско́льзким; *бүген ~ты* сего́дня ста́ло ско́льзко

тайгакл|а́у *неперех.* буксова́ть; *тәгәрмәчләр ~ый* колёса буксу́ют

тайгалак *сущ.* 1. ско́льзкость (*пути и т. п.*) 2. ско́льзкое ме́сто на доро́ге; *~ка тару* набрести́ на ско́льзкое ме́сто 3. *перех.* ненадёжность (*слова, обещания и т. п.*)

тайгалык *сущ.* больша́я тайга́; обши́рный лес (*в Сибири*)

тайгала́у *многокр. от* **таю**

тайгалы *прил.* име́ющий тайгу́, с тайго́й; таёжный; *~ тау* гора́ с тайго́й; *~ яклар* таёжные края́

тайгаклык *сущ.* 1. гололе́дица, гололёд 2. о́чень ско́льзкий (*о дороге и т. п.*)

тайгачы *сущ.* таёжник (*человек, деятельность которого связана с тайгой*); *~лар өе* дом таёжников

тайдыр|у 1. *перех.* выви́хивать/вы́вихнуть; *буынын ~у* вы́вихнуть суста́в 2. *безл.* быть ско́льзким; *~а* ско́льзко, скользи́т

та́йка *сущ. этногр.* та́йка, деви́чья тюбете́йка (*головной убор в виде неглубокого цилиндра с вышитыми краями и пучком перьев с одной стороны*)

тайлак *сущ. редко* молодо́й верблю́д, верблюжо́нок (*на втором-пятом году жизни*)

тайла́у *неперех. диал. см.* **колынлау**

тайлы *прил. диал. см.* **колынлы**; *~ бия* кобы́ла с жеребёнком

тайлы|гу *неперех.* 1. вы́вихнуться (*о суставах рук и ног и т. п.*) 2. хрома́ть/захрома́ть || хромота́ (*от вывиха*); *тай артыннан йөргән ~ккан* (*посл.*) кто вбдится с молоды́ми (*букв.* с двухле́тними) жереба́тами — захрома́ет

тайлыктыр|у *перех.* выви́хивать/вы́вихнуть (*случайно*); *см. тж.* **тайдыру, каймыктыру**

тайм *сущ. спорт.* тайм; *беренче ~* пе́рвый тайм

тайм-а́ут *сущ. спорт.* тайм-а́ут; *тайм-аут алу* взять тайм-а́ут

тайпа *сущ. диал.* родня́, гру́ппа ро́дственников по кро́ви; *кыз бала ~ чәчәге* (*посл.*) де́вочка — цвет родни́

тайпылгала́у *многокр. от* **тайпылу**; уклоня́ться || уклоне́ние (*от чего-л. в разное время, при разных обстоятельствах*)

тайпылдыру *понуд. от* **тайпылу**; заста́вить уклони́ться, отклоня́ться, превраща́ться

тайпылмастан *нареч.* неукло́нно, не уклоня́ясь; *туры юлдан ~* не уклоня́ясь от пра́вильного пути́

тайпыл|у 1. *неперех.* уклоня́ться/уклони́ться, отска́кивать/отскочи́ть; увёртываться/увернýться; сторони́ться/посторони́ться || уклоне́ние; *читкә ~ып өлгерү* успе́ть уклони́ться (отскочи́ть) в сто́рону; *вазифадан ~у* уклоня́ться от свои́х обя́занностей 2. отклоня́ться/отклони́ться || отклоне́ние; *маршруттан ~у* отклони́ться от маршру́та 3. *разг.* выви́хиваться/вы́вихнуться; вывёртываться/вы́вернуться || вы́вих; *кулы ~ган* рука́ его́ вы́вихнулась 4. *полит.* уклоня́ться/уклони́ться || укло́н, уклоне́ние; *см. тж.* **тайпылыш** □ **~у почмагы** *тех.* у́гол отклоне́ния; **~ып китү (чыгу)** вы́вихнуться (вдруг)

тайпылусыз *прил.* неукло́нный; *~ үсеш* неукло́нный рост || *нареч.* неукло́нно; *~ алга бару* неукло́нно идти́ вперёд

тайпылучан *прил.* неусто́йчивый, коле́блющий, ша́ткий *прям., перен.*

тайпылучанлык *сущ.* неусто́йчивость, ша́ткость

тайпылучы *сущ.* уклони́ст, ренега́т

тайпылыш *сущ.* 1. *полит.* укло́н 2. *разг.* уклоне́ние, ренега́тство 3. *диал. разг.* вы́вих □ **~тан түгел** без уклоне́ний, не уклоня́ться

тайпылышлы *прил. редко* 1. неусто́йчивость 2. укло́нчивый 3. зигзагообра́зный; *~ хәрәкәт* зигзагообра́зное движе́ние

тайпылышсыз *прил. см.* **тайпылусыз**

тайпылышу *совм. от* **тайпылу**; уклоня́ться/уклони́ться (*о многих*); *төрле якка ~* разбежа́ться (уклони́ться) в ра́зные сто́роны

тайпылышчы *сущ. полит.* уклони́ст; *уң һәм сул ~лар* пра́вые и ле́вые уклони́сты

тайпылышчылык *сущ.* уклони́зм; *~ зарары* вред (от) уклони́зма

тайра *сущ. уст.* часть родосло́вной, генеалоги́ческая ветвь

тайт 1. *подр.* подпрыгиванию или другим подобным движениям от внезапного испуга; *һайт дигәндә ~ итү* подпры́гивать/подпры́гнуть (подпры́гивание) от кри́ка хайт! 2. *в знач. межд. при появлении кого-л. для его вспугивания в шутку*: гоп! ◊ **~ дигәндә туйт итү** быть спосо́бным к мгнове́нной реа́кции

тайтак *прил. диал.* безво́льный, неспосо́бный сле́довать одно́й ли́нии (*о человеке*)

тайтакла́у *неперех. прост.* идти́ на попя́тную, отка́зываться/отказа́ться от свои́х слов

тайтояк *сущ. бот.* копы́тень европе́йский; *~лар үскән болын* луг, заро́сший копы́тнем

тайтулак, тай-тулак *сущ. собир.* 1. жереба́та всех возрасто́в; вся́кие жереба́та 2. *перен. неодобр.* молодёжь, ра́зные молоды́е лю́ди

тайфун *сущ.* 1. тайфу́н (*ураган разрушительной силы*) 2. *перен.* бу́рный отпо́р; *~га очрау* встре́тить (*на пути*) бу́рный отпо́р

тайфунлы *прил.* с тайфу́ном; тайфу́нный; *~ яклар* тайфу́нные края́

тайчандыру *понуд. от* **тайчану**; позволя́ть/позво́лить сойти́ (*с пути*), уклони́ться

тайчанмастан *нареч.* 1. не уклоня́ясь, упо́рно, непоколеби́мо; *см. тж.* **тайпылмастан** 2. не гнуша́ясь *чего-л.*; без стесне́ния; *ялган сөйләнүдән дә ~* не гнуша́ясь лжи

тайчан|у *неперех.* 1. (наме́ренно) сходи́ть/сойти́ || схожде́ние (*от маршрута*) 2. сбива́ться/сби́ться || сбой 3. уклоня́ться/уклони́ться || уклоне́ние (*от встречи, от какого-л. дела, мероприятия и т. п.*); отойти́, отка́зываться/отказа́ться || отхо́д, отка́з (*от намеченного плана, от дела и т. п.*); *~маган тау җиңгән* (*посл.*) тот, кто не уклони́тся (от тру́дностей), одоле́ет и го́ру 4. *перен.* стесня́ться, не реша́ться; избега́ть *чего-л.* || стесне́ние, нереши́тельность; *очрашудан ~ып йөрү* избега́ть встре́чи (*с кем-л. из-за стеснения*)

тайчанучан *прил.* укло́нчивый, нереши́тельный; избега́ющий *чего-л.*; *туры җаваптан ~* скло́нный избега́ть прямо́го отве́та

тайчанучанлык *сущ.* укло́нчивость, скло́нность уклоня́ться; нереши́тельность

тайчанучы *сущ. см.* **тайпылучы**

тайчы|к *сущ. диал.* 1. *уменьш.-ласк.* жеребёнок, жеребёночек; лоша́дка 2. *ласк. обращение к малышу, мальчику*; *~гым, кил әле* подойди́ ко мне, мой жеребёночек

тайяр *предик. прил. книжн.* подгото́влен к ... ; гото́в вы́полнить, сде́лать *что-л.*; в гото́вности; *илне саклауга*

~ гото́в к защи́те Ро́дины; *хезмәтеңә ~мын* я гото́в служи́ть тебе́; *гайяр вә ~* (*погов.*) по́лон эне́ргии и гото́вности; без стра́ха и упрёка □ **~ булу** *см.* **әзер булу; ~иту (кылу)** де́лать/сде́лать гото́вым

тайярландыру *перех. книжн.* подгото́вить к ...; де́лать/сде́лать гото́вым к ...; подгото́вить к рабо́те (челове́ка)

тайярлану *возвр. от* **тайярлау**; подгота́вливаться/подгото́виться (*духовно*) || подгото́вка; гото́вность *көрәшкә ~* подгота́вливаться к борьбе́, прони́кнуться ду́хом борьбы

тайярла́у *перех. книжн.* подгота́вливать/подгото́вить, приготовля́ть/пригото́вить || подгото́вка, приготовле́ние

тайярлашу *взаимно-совм. от* **тайярлау**

тайярлык *сущ.* 1. гото́вность *к чему-л.*; состоя́ние гото́вности; *эшкә ~* гото́вность (духо́вная и физи́ческая) к рабо́те 2. подгото́вленность; *кирәкле ~* доста́точная подгото́вленность □ **~ күрү** *см.* **хәзерлек күрү**

так I *прил.* 1. нечётный, непа́рный; *так саннар* нечётные чи́сла; *җәп булса да уртак, так булса да уртак* (*погов.*) хоть чётное, хоть нечётное — всё попола́м (*говорится в устном договоре о дружбе*) 2. *в знач. сущ.* нечёт; *җәпме, такмы?* чёт и́ли нечёт? (*говорится в игре*) 3. *диал.* ущёрбный, ми́зерный; бы́стро конча́ющийся, клоня́щийся к концу́; *так булу* конча́ться, идти́ к концу́; *бу дөньяның җәфасы җәп, вафасы так* (*посл.*) в э́том (*бренном*) ми́ре страда́ний бо́льше, чем удово́льствий (*букв.* страда́ний — па́рами, удово́льствий — едини́цами) □ **так күбәләк** *зоол.* непа́рный шелкопря́д; **тактояклылар** непарнокопы́тные (живо́тные) ◊ **такка таяндыру** приводи́ть к разва́лу, кра́ху, разру́хе (*своей бесхозяйственностью*); оста́вить без ничего́ (без краю́хи хле́ба и т. п.); разоря́ть/разори́ть *кого*; **такка таяну** быть, оста́ться в большо́й нужде́; оста́ться без ничего́

так II 1. *подр. звукам удара твёрдым предметом по твёрдому* (*но не металлом по металлу*); стук 2. *в ф.* **так-так, так та так** *о многократном стуке* (*твёрдым по твёрдому*); тук да тук □ **так итү** сту́кнуть (*твёрдым по твёрдому*); **так-так итү** стуча́ть тук-тук; **так: так кату** застыва́ть/засты́ть || застыва́ние (*в определённом положении*)

так III *сущ. архит.* ни́ша; ло́жное окно́

така: така ялгыз соверше́нно одино́кий, совсе́м оди́н

такай *сущ.* 1. *уст.* дя́дя, брат ма́тери 2. *диал.* сестра́ отца́ 3. *диал.* уважа́емая же́нщина ста́ршего говоря́щего; *см. тж.* **апа**

такелаж *сущ.* 1. такела́ж (*оборудование судна*) 2. такела́жные рабо́ты; такела́жное де́ло; *~ җиһазы* такела́жное обору́дование

такелажчы *сущ.* такела́жник (*работник порта; специалист по эксплуатации оборудований судов и портов*)

та́ки I *союз подчин. книжн. уст.* 1. что́бы; для того́ что́бы; *сайлыйк башчы, ~ ул безне тугры юлга башласын* вы́берем одного́ гла́вного, для того́ что́бы он нас повёл ве́рной доро́гой 2. поско́льку; та́к как

таки́ II *частица усил. разг.* 1. та́ки, всё-таки; *~ үзенекен итте* всё-таки настоя́л на своём 2. так и; всё же; *шуннан соң ~ күрмәдем мин аны* по́сле того́ я его́ так и не ви́дел (не встре́тил)

таккаравыл *сущ. детская игра, заключающаяся в том, чтобы водящий как можно дольше оставался одиноким в противоположность другим — парным участникам игры; ~ уйнау* игра́ть в таккарав**ы́**л

таккыч *сущ.* 1. валёк 2. *см.* **тияк**; *~ тагу* прикрепля́ть ко́сточку (*как пуговицы*) к оде́жде

таклы *сущ. см.* **таккаравыл**

такма *сущ.* подве́ска, подве́ски (*монеты и другие украшения, подвешиваемые женщинам на косы*) || *прил.* подвесно́й; *см. тж.* **тагылма такавыч; такавыч**; *сущ. диал.* меша́лка, па́хталка

такмаза *сущ.* 1. прибау́тка, счита́лка (*рифмованная речевая единица, которая не поётся*) 2. *перен.* ви́рши, плохи́е стихи́; *~лар язып йөрү* всё вре́мя писа́ть плохи́е стихи́; *~ сату* балагу́рить; болта́ть вздор, ля́сы точи́ть

такмазачы *сущ.* 1. прибау́точник; тот, кто гора́зд сочиня́ть и́ли исполня́ть прибау́тки, рифмо́вки и т. п. 2. *перен. пренебр.* рифма́ч, рифмоплёт

такмазачылык *сущ. пренебр.* рифма́чество, рифмоплётство

такмак *сущ.* 1. часту́шка, куплёт; *~ чыгару* сочиня́ть часту́шки 2. *пренебр.* ви́рши, стишки́; плохи́е стихи́ 3. *этногр.* 1) причита́ния 2) сва́дебные рифмо́ванные приве́тствия □ **~ әйтешү** *этногр.* обме́ниваться стиха́ми-ре́пликами во вре́мя сва́дьбы (*о брачующихся сторонах*); **~ әйтү** петь часту́шки, прибау́тки

такмакла|у *перех.* 1. исполня́ть/испо́лнить куплёты речитати́вом 2. причита́ть || причита́ние, при́чет, речитати́в; *~п елау* пла́кать с причита́ниями

такмакчы *сущ.* 1. куплети́ст, часту́шечник; импровиза́тор; *~ малай* ма́льчик-куплети́ст 2. *перен. пренебр.* плохо́й по́эт, виршеплёт

та́кса I *сущ. торг.* та́кса, тари́фная цена́ □ **~ билгелә́ү (кую)** такси́ровать

та́кса II *сущ.* та́кса (*порода собак*); *~ токымы* поро́да такс

такса́тор *сущ. торг.* таксатор (*специалист по установлению цен на товары*)

такса́ция *сущ. торг.* такса́ция (*определение цен*); *~ үткәрү* проводи́ть такса́цию

такси *сущ.* такси́; *~ шофёры* шофёр такси́

таксис *сущ. биол.* та́ксис (*реакция организма на внешние раздражители*)

таксичы *сущ.* таксист, води́тель такси́

таксомотор *сущ.* таксомото́р, такси́ || таксомото́рный; *~ паркы* таксомото́рный парк; *~ хуҗалыгы* таксомото́рное хозя́йство

такс|у *неперех. диал.* конча́ться, оскуде́ть, приходи́ть к концу́ (*о запасах пищи*) || оскуде́ние запа́сов и т. п.; *печән ~ыган* запа́сы се́на ста́ли оскудева́ть

таксык *прил. диал.* 1. конча́ющийся, подлежа́щий стро́гой эконо́мии (*о фураже, продуктах и т. п.*); оскудева́ющий; *барда таксык, юкта ~* (*погов.*) когда́ *чего-л.* мно́го (*говорится чего именно*), оно́ с за́пахом (с душко́м), когда́ его́ ма́ло — на́до эконо́мить 2. ску́дный, ми́зе́рный; *~ка (күрә) тансык* (*погов.*) чего́ ма́ло, то и до́рого; чего́ оста́лось ма́ло, того́ и хо́чется

такт I *сущ. в разн. знач.* такт, ритм, ритми́чность; *бию ~ы* такт та́нца, пля́ски; *пешкәк хәрәкәте ~ы* такт движе́ния по́ршня (*в двигателе*)

такт II *сущ.* такт (*чувство меры в обращении с людьми, а также навыки в проявлении вежливости, учтивости, пристойности*); *см. тж.* **вәкарь, сөм, әдәп**

такта *сущ.* 1. *в разн. знач.* доска́, тёс; *~ кагу* приби́ть, пригвозди́ть до́ску; обшива́ть доско́й; *~ түшәү* настели́ть до́ски 2. *разг.* плита́, пли́тка (*пищевых продуктов*);

бер ~ шоколад (одна́) пли́тка шокола́да **3.** *индив.* доска́, пласти́на, плита́ (*предмет с плоской поверхностью, приспособленная для определённой цели*); *курсәткечләр ~сы* доска́ показа́телей; *кабер ~сы* надмоги́льная (надгро́бная) плита́; *өстәл ~сы* столе́шница; *сызым ~сы* чертёжная доска́; *шахмат ~сы* ша́хматная доска́ **4.** закро́й (*в знач. кусок ткани, кожи и т. п., выкроенный в определённой ф. для шитья*); *күлмәкнең ал ~сы* пере́дний закро́й руба́шки **5.** *диал.* односка́тная кры́ша; *без, без, без идек, без уникә кыз идек, бер ~га җыелдык, таң атуга коелдык* нас, нас, нас бы́ло двена́дцать де́вушек, собрали́сь мы на односка́тной кры́ше и посы́пались отту́да на заре́ (зага́дка о созве́здии дев — двена́дцати де́вушек) || *прил.* доща́тый, тесо́вый; *~ басма* доща́тые мостки́; *~ койма* доща́тый забо́р; *~ түбәле өй* дом, кры́тый тёсом □ **~ чәй** пли́точный чай; *~ чәем, ачык чыраем* (*погов.*), чай пли́точный, зато́ хозя́ин раду́шный; *бөртек чәем, төртеп эчәрәем* (*погов.*), чай фами́льный, но хозя́ин ко́лкий; **~ яру** распило́вка брёвен на до́ски ◊ **~ күкрәк(ле)** *пренебр.* плоскогру́дая (*о женщине*)

тактабаш *сущ. диал.* предсе́нник и́ли се́ни (*с односкатной крышей; строение с односкатной крышей*)

такталандыру *понуд. от* **такталану**

такталан|у *страд. от* **такталау**; обшива́ться, быть обши́тым доско́й; *~ган абзар* хлев, обши́тый доско́й

такталан|у *неперех.* **1.** уплотня́ться/уплотни́ться, слежа́ться и стать ро́вным (*о земле, почве*) || уплотне́ние и выра́внивание (*земли, почвы*); *~ган җиргә чәчмиләр* на уплотнённую зе́млю не се́ют **2.** име́ть, заиме́ть твёрдую и гла́дкую пове́рхность; *~ып беткән кайры тун* затверде́вшая шу́ба — дублёнка; *кулы ~ган* рука́ (ко́жа рук) его́ затверде́ла (*букв.* затверде́вшая)

такталату *понуд. от* **такталау**; веле́ть (проси́ть, зака́зывать) обшива́ть доско́й *что-л.*

такталау *перех. разг.* обшива́ть/обши́ть || обшива́ние доско́й; *ишек алдын ~* обшива́ть се́ни

такталы *прил.* **1.** име́ющий до́ску, до́ски **2.** *разг.* из до́сок, доща́тый

такталык *прил.* **1.** приго́дный и́ли предназна́ченный для распи́лки на до́ски (*о брёвнах и т. п.*); распило́вочный; *~ агач* распило́вочный лес **2.** доста́точный для распило́вки и́ли размеще́ния определённого коли́чества до́сок; *биш ~ бүрәнә* бревно́, из кото́рого вы́йдет пять до́сок

тактаяргыч *сущ.* распило́вочный стано́к, пилора́ма; лесопи́лка; *~ кору* соорудить лесопи́лку || *прил.* лесопи́льный, распило́вочный; *~ машина* распило́вочная маши́на

та́ктик *сущ.* та́ктик, знато́к та́ктики || *прил.* такти́ческий; *~ җитәкчелек* такти́ческое руково́дство; *~ үзенчәлекләр* такти́ческие сво́йства (*оружия*) □ **~ өйрәнүләр** такти́ческие уче́ния

та́ктика *в разн. знач.* та́ктика; *көрәш ~сы* та́ктика борьбы́

та́ктикалы *прил.* с (*определённой*) та́ктикой; *сак ~ кеше* челове́к с осторо́жной та́ктикой

та́ктикасыз *нареч.* без та́ктики || *прил.* не име́ющий та́ктики; *~ эш итү* де́йствовать без та́ктики

та́ктлы I *прил.* такти́чный, обходи́тельный, вы́держанный; *см. тж.* **әдәпле, инсафлы**; *~ кеше* такти́чный челове́к

та́ктлы II *прил.* с определённым коли́чеством та́ктов; име́ющий определённое коли́чество та́ктов; *дурт ~ йөрткеч* четырёхта́ктный дви́гатель

та́ктлылык *сущ.* такти́чность, обходи́тельность; *см. тж.* **әдәплелек, инсафлык**

так-ток *подр. звукам удара о твёрдую поверхность твёрдым предметом* (*молотком по доске*) □ **так та ток итү** (*не ритмично*) стуча́ть, посту́кивать; тук да тук; **так та ток килү** стуча́ть непроизво́льно, нежела́тельным о́бразом

та́ктсыз I *нареч.* без та́кта, беста́ктно; *~ кылану* вести́ себя́ без та́кта, беста́ктно

та́ктсыз II *прил.* беста́ктный; *~ кеше* беста́ктный челове́к

та́ктсызлык *сущ.* беста́ктность; *~ күрсәтү* проявля́ть беста́ктность

тактыру *понуд. от* **тагу**; заставля́ть/заста́вить прицепля́ть, наве́шивать *что к чему*

такыл I *сущ.* **1.** струг; *~ белән шомарту* ровня́ть стру́гом **2.** ре́йка; измери́тельная пла́нка; *эштә акыл да кирәк, ~ да кирәк* (*посл.*) в де́ле ну́жен и ум, и лине́йка (*т. е. инструмент*) **3.** *ист.* инструме́нт для выта́гивания (волоче́ния) про́волоки (*у ювелиров*)

такыл II *сущ. диал.* норма́льное состоя́ние (*тела*); *акылында, ~ында чакта* при я́сном уме́ и здоро́вом те́ле; *көчкә ~ булу* е́ле приходи́ть в норма́льное состоя́ние, едва́ встать на́ ноги (*после болезни*)

такылдавык *сущ. см.* **такылдык**

такылдаттыру *понуд.* (*в знач. учащённости*) *от* **такылдату**

такылдат|у **1.** *понуд. от* **такылдау**; дать возмо́жность постуча́ть **2.** (*намеренно*) стуча́ть, бараба́нить *чем-л.*; *см. тж.* **тукылдату** □ **~ып алу** (немно́го) постуча́ть; *балтачылар балталарын ~ып алдылар* пло́тники постуча́ли топора́ми

такылд|а́у *неперех.* **1.** 1) стуча́ть, посту́кивать, бараба́нить || стук, перестук, посту́кивание (*молотком*) 2) тарахте́ть || тарахте́ние (*мотора*); *кайдадыр куласалар ~ый* где́-то со сту́ком враща́ются маховы́е колёса **2.** *перен.* 1) болта́ть, тарато́рить; говори́ть бы́стро, гро́мко || гро́мкая болтовня́ 2) болта́ть, нести́ чепуху́; моло́ть вздор; говори́ть то, что не поло́жено || болтовня́, вздор; *юкны ~ар чак тугел* не тако́е вре́мя, что́бы болта́ть вздор; *кирәкмәгәнне ~аганчы, эшеңдә булу* чем нести́ чушь, лу́чше займи́сь свое́й рабо́той **3.** *перен.* наболта́ть, вы́болтать, вы́дать секре́т || вы́дача секре́та, (ме́лкий) доно́с □ **~ап алу** гро́мко поболта́ть; потарахте́ть; **~ый башлау** затарахте́ть; **~ый язу** чуть не вы́болтать

такылд|а́у *перех.* **1.** наре́зать (ро́вные) лучи́нки; ре́зать/наре́зать, наре́зать ремни́, разре́зать ко́жу на то́нкие по́лосы || нарезáние, разрезáние **2.** обрабо́тать || обрабо́тка стру́гом, на́стругом, строга́ть || строга́ние; *~ап эшкәртү* обрабо́тать стру́гом **3.** худо́жественная резьба́

такылдашу *совм. от* **такылдау**; нести́ вздор, гро́мко суда́чить

такылдык *сущ.* болту́н, говору́н, трещо́тка; *бакылдык бакылдап туймас, ~ такылдап туймас* (*посл.*) квакýша ква́кать не уста́нет, болту́н говори́ть не переста́нет; *кулдан килсә — батырлык, телдән килсә — ~ (диләр)* е́сли гора́зд на де́ло — (*говорят*) геро́йство, е́сли гора́зд на язы́к — (*говорят*) болту́н || *прил.* болтли́вый; гро́мко болта́ющий; *~ кеше* болтли́вый, ча́сто гро́мко болта́ющий челове́к

такыл-такыл *подр.* **1.** о продолжи́тельном, беспреры́вном стуча́нии, переступке **2.** о дли́тельной болтовне́ □ **такыл-такыл килү (итү), такыл да такыл килү (итү)**

1. беспрерывно стучать (*топором, молотком по гвоздям и т. п.*) 2. беспрестанно болтать

такым I *сущ.* 1. *ист.* связка скота; группа людей (*пленных, каторжных и т. п.*), связанных между собой 2. *перен.* группировка, группка; *бер ~ зыялылар* группка интеллигентов 3. *уст.* комитет; *заводта эшчеләр ~ы* рабочий комитет на заводе (*в 20-х годах XX века*)

такым II *сущ. уст.* шпора □ **~ кысу** шпорить, пришпорить (*лошадь*)

такыр *прил.* 1. ровный, укатанный, гладкий; торный (*о дороге*); *ата юлы балага ~* (*посл.*) дорога отца удобна для сына; *~ юлдан йөргәннең аягы сынмый* (*посл.*) тот, кто ходит по торной дороге, ногу не сломает 2. гладко сжатый (*о поле*); гладко выбритый; *~ баш* гладко бритая голова 3. *перен. разг.* пустой; опустошённый, опустелый; совершенно лишённый, нет ничего; *~ келәт* пустая клеть (хоть шаром покати); *~ өстәл* пустой стол; стол, на котором нечего ставить; *кесәң ~ — сүзең бакыр* (*посл.*) (если) карман пуст, то и слова твои — цена грош 4. *перен. предик. прил. разг.* скуден, беден; плох; скудно, бедно, плохо; *икмәк ягы ~* насчёт хлеба плохо; *белем ягы (белеме) ~* беден знаниями, знания скудны || *нареч.* гладко, наголо (*о бритье, жатве, косьбе*); *башы ~ кырылган* голова его брита наголо □ **~ басу (кыр)** поле под паром; паровое поле ◊ **~ калу** совершенно обеднеть, лишаться, лишиться запасов || *сущ.* 1. гладкое, укатанное место; гладь (твёрдой поверхности земли); *урам ~ы* гладь улицы; *юл ~ы* гладь дороги 2. *геогр.* такыр (*дно высохшего водоёма, высохший солончак в пустыне*)

такырайттыру *понуд. от* **такырайту**; заставлять/заставить, ровнять/заровнять

такырайт|у *перех.* 1. делать/сделать ровным, выровнять, заровнять, укатывать/укатать, утаптывать/утоптать; *ындыр табагын ~у* выровнять ток на гумне 2. *перен. разг.* изводить/извести, истощать/истощить (*запасы*)

такырайтыл|у *страд. от* **такырайту**; укатываться, утаптываться/утоптаться; *~ган җир* специально утоптанная земля

такыра|ю *неперех.* 1. становиться/стать ровным, утоптанным, укатанным; укатываться/укататься; утаптываться/утоптаться; выравниваться/выровняться; *см. тж.* **такырлану** 2. *перен.* оскудевать/оскудеть || оскудение; израсходываться, истощаться, ухудшаться (*о снабжении чем-л.*), кончаться || израсходование, истощение (запасов), конец *чего*; *ашау ягы ~йды* стало плохо с едой, с питанием положение (дело) ухудшилось; *кесә ~йды* деньги (*букв.* карман) кончились

такырбаш *прил. разг.* 1. с бритой или лысой головой (*о человеке*); бритоголовый; *~ кешеләр* бритоголовые люди 2. *перен.* 1) невежественный 2) *в знач. сущ.* растяпа, недотёпа, неуч

такырландыру *понуд. от* **такырлану**

такырлан|у *возвр.-страд. от* **такырлау** 1. становиться/стать || становление ровным, укатанным, выровненным 2. *перен. разг.* становиться/стать голым, лишённым содержимого (*о местах, где хранятся запасы и т. п.*) *см.* **такыр** 3. *страд.* оголяться, укатываться; *~ган урын* укатанное место

такырлаттыру *понуд. от* **такырлату**

такырлату *перех. разг. см.* **такырлау**

такырла|у *перех.* 1. укатывать/укатать, выравнивать/выровнять, растаптывать/растоптать || укатывание, выравнивание, растаптывание (*дороги*) 2. *перен.* изводить/извести, истощать/истощить (запасы) || истощение запасов (*кем-л.*) ◊ **~п киту** съесть все запасы *у кого-л.* и уйти

такырлашу *взаимн. от* **такырлау**

такырлы|к *сущ.* 1. ровность, утоптанность, укатанность; *юлның ~гы* удобство дороги; укатанность пути 2. скудость, истощённость (запасов и т. д.); *ашлык ~гы* скудость урожая зерновых 3. голая земля, место без растительности; *см. тж.* **такыр**

такыр-токыр *подр. грохоту телеги на твёрдой почве, дороге* □ **такыр-токыр килү** грохотать, громыхать на твёрдой дороге (*о телеге*)

такы-токы *предик. сл.* еле-еле, мало, скудно; кот наплакал; с гулькин нос; считай, что нет; *ипи такы-токы* хлеба почти нет; *белеме такы-токы* знаний его — кот наплакал || *прил.* скудный, полуголодный *такы-токы ризык белән* на полуголодных харчах □ **такы-токы туену** питаться кое-как, жить впроголодь

такы-токылы|к *сущ.* скудость, нехватка; дефицит; *сабынның такы-токылыгы* нехватка, дефицит мыла

такыя *сущ.* 1. *этногр.* такия, головной убор в виде глубокой тюбетейки, вышитой жемчугами; тафья *ист.*, скуфья *ист.* 2. *разг.* колпак, матерчатый головной убор (*у поваров*) 3. венок (*надеваемый обычно девочками-подростками*) 4. венчик (*цветка*), мутовка

такыя-калфак *сущ. см.* **тайка**

тал I *сущ.* 1. ива, верба; *талны чыбык чакта бөгәләр* иву гнут, когда она является лозой (*т. е. детей надо приучать послушанию с младенчества*) 2. *уст.* 1) пучок; букетик; *бер тал каурый* пучок перьев 2) прядь (*волос*) 3. гладкий ствол или черенок растения; *хөрмә талы* ствол финиковой пальмы; *гөл талы* стебель декоративных растений || *прил.* ивовый; сделанный из ивы; *тал урындык* кресло, сплетённое из ивовых прутьев □ **тал бәбкәсе (бәпчеге, бәбие, песие)** пушистая почка вербы; **тал бөресе** почка ивы; **тал гөле** *см.* **тал-гөл**; **тал кисмәне** скрипун (*вид жука*); **тал куагы** тальник, ивняк; **тал чыбыгы** ивовый прут, лоза ◊ **тал чыбыгы ашау (ашату)** быть наказанным (наказать) розгой; быть накормленным (накормить) берёзовой кашей; **тал чыбыгы шикелле** *см.* **талчыбыктай**

тал II *частица усил.* точно, как раз; *тал ярты* точно (как раз) половина; *см. тж.* **тач, нәкъ**

талай I *диал. сущ.* некоторое (значительное) количество, несколько; группа

талай II *нареч.* значительно, изрядно || значительный, изрядный; *бер ~ кеше* значительная группа людей; *бер ~ вакыт* некоторое, немалое время *~ гына эшләп алу* изрядно поработать, потрудиться; *~ урын алу* занимать значительное место

талайга *нареч. диал.* надолго; слишком много; *~ китә* продолжится слишком долго

тала|к I *сущ. анат.* селезёнка (*орган позвоночных животных и человека*) ◊ **~гы ташу** вконец рассердиться, окончательно разгневаться

талак II *сущ.* 1. развод, расторжение брака (*совершенное в соответствии с правилами шариата*); *~ таләп итү* требовать расторжения брака 2. *восклицание, которое произносится мужчиной, который хочет развестись с женой (развод вступает в силу после слова* талак *в присутствии духовного лица или казыя-судьи)* □ **~ итү (кылу)** 1. объявить жене о разводе 2. разводить супругов (*о духовных лицах и казыях и т. п.*)

талакла|у I *неперех. диал.* **1.** страда́ть боле́знью о́рганов пищеваре́ния; *~п яту* боле́ть (страда́ть) живото́м **2.** *перен.* станови́ться (стать) же́лчным, раздражи́тельным

талакла|у II *перех. уст.* разводи́ть жену́, развести́сь (*по правилам шариата*); *~п аеру* разводи́ть по шариа́ту

талакчы *сущ. уст.* исте́ц в де́ле о разво́де (*тот из супругов, который требует развода*)

талан *сущ. редко* сча́стье, уда́ча, везе́ние; тала́нт; *ялан-ялан ни ~ ?* (*погов.*) что за беспрерывная уда́ча? (*о сомнительных по происхождению удачах и находках*)

талант *сущ.* **1.** тала́нт (*выдающиеся способности обычно к какому-л. определённому виду деятельности*); *язучылык ~ы* писа́тельский тала́нт; *~ның бер өлеше тумыштан, тугыз өлеше тырыштан* (*посл.*) одна́ деся́тая тала́нта — от рожде́ния, де́вять деся́тых — от усе́рдия **2.** *перен.* тала́нтливая ли́чность, тала́нт; *өметле ~* многообеща́ющий тала́нт □ **~ иясе** тала́нтливый челове́к, тала́нтливая ли́чность; облада́тель тала́нта

талантлы *прил.* **1.** тала́нтливый; *~ шагыйрь* тала́нтливый поэ́т **2.** *в знач. нареч.* тала́нтливо; *~ башкару* тала́нтливо исполня́ть (*произведение*)

талантсыз *прил.* без тала́нта, безда́рный, не име́ющий тала́нта; *кош тумый канатсыз, кеше тумый ~* (*посл.*) нет пти́цы без крыла́, нет челове́ка без тала́нта

талан|у **1.** *страд. от* **талау** **2.** *~ган авыл* огра́бленная дере́вня **3.** быть рва́ным, обо́рванным, лохма́тым (*об одежде*); *~ып беткән бишмәт* вконе́ц обо́рванный бишме́т **4.** *в знач. прил.* **таланган** награ́бленный; *~ган мал* награ́бленное добро́

таланылу *страд. от* **талау** *редко*; *см.* **талану**

талаттыру *понуд. от* **талату**

талат|у *понуд. от* **талау** **1.** трави́ть, затрави́ть, веле́ть и́ли позволя́ть/позво́лить гра́бить; отдава́ть/отда́ть на разгра́бление; допуска́ть грабёж *кого-л.*; *илне дошман-нардан ~у* допуска́ть, что́бы страну́ гра́били враги́ **2.** натра́вливать/натрави́ть; напуска́ть/напусти́ть; нау́ськивать (*собаку*); дать возмо́жность искуса́ть, заклева́ть; *этне эттән ~алар* (*посл.*) соба́ку тра́вят соба́кой **3.** *перен.* позволя́ть/позво́лить обруга́ть, оскорбля́ть, обижа́ть

талатылу *страд. от* **талау** I 1, 2

тала|у I *перех.* **1.** куса́ть, искуса́ть; покуса́ть, закуса́ть; терза́ть/растерза́ть || растерза́ние (*о зверях, насекомых и т. п.*); раску́сывание, поку́сывание; *эт ~ганны бет ~р* (*посл.*) того́, кого́ искуса́ла соба́ка, куса́ет и вошь (*т. е. того, кого обижают сильные мира сего, обижают и слабые*) **2.** гра́бить, огра́бить; отнима́ть си́лой || ограбле́ние, грабёж; *~у белән шөгыльләну* занима́ться грабежо́м **3.** *перен.* гра́бить, присва́ивать || присва́ивание (*чужого имущества, чужой доли, результатов чужого труда и т. п.*); *ил ~у* гра́бить наро́д, страну́ **4.** *перен.* выдёргивать, выщи́пывать, надёргивать, выкра́ивать себе́ (*от разных источников*); *аннан ~п, моннан ~п җыйган мал* иму́щество, со́бранное путём надёргивания, обкра́дывания, присвое́ния чужо́го **5.** *перен.* му́чить, изму́чить; терза́ть, истерза́ть || муче́ние, терза́ние (*руганью, оскорблениями, попрёками и т. п.*) □ **~п алу** отнима́ть/отня́ть си́лой; *~п алынган* гра́бленный, награ́бленный; **~п калу** незако́нно уде́рживать (*зарплату*)

тала́у II *сущ.* **1.** боле́знь дома́шнего скота́ (*особенно лошадей*), характеризу́ющаяся тем, что живо́тные не мо́гут стоя́ть на нога́х и ва́лятся на́ спину; столбня́к **2.** боле́знь, характеризу́ющаяся бессо́ницей, беспричи́нным беспоко́йством и т. п. (у люде́й); *тауга ~ тими* (*посл.*) гора́ (*поскольку она бесчувственна и велика*) бессо́нницей не страда́ет

талаула́у *неперех.* **1.** вала́ться, ката́ться на земле́ от бо́ли (*о лошади*); боле́ть столбняко́м **2.** *перен.* 1) страда́ть || страда́ния от беспоко́йства и́ли бессо́нницы 2) *см.* **тулгаклау**

талаулы *прил.* страда́ющий боле́знью живота́ и́ли спины́ (*о скотине*); *~ ат иясенә яу* (*посл.*) ло́шадь, страда́ющая боле́знью живота́ — враг своему́ хозя́ину

талаучы *сущ.* граби́тель, разбо́йник; эксплуата́тор

талаучылык *сущ.* граби́тельство, грабёж; мародёрство (*как общее явление*); *~ белән шөгыльләну* занима́ться грабежо́м, граби́тельством

талаш *сущ.* ссо́ра, скандал, перебра́нка; *~тан тартыш чыга* (*посл.*) ссо́ра рожда́ет потасо́вку; *ачлык ни җидермәс, ~ ни дидермәс* (*посл.*) от го́лода чего́ (то́лько) не съешь, в перебра́нке чего́ (то́лько) не ска́жешь; *~ түгел майлаш* (*посл.*) ссо́ра не ка́ша с ма́слом

талаш-җәнҗал *сущ. см.* **талаш-ызгыш**

талаш-кычкырыш *сущ.* шум-гам и кри́ки (перебра́нка); ссо́ра и скандал

талашлы *прил.* скандальный, сопровожда́емый перебра́нкой; *~ табыннан шайтан туйган* (*посл.*) от скандального стола́ то́лько чёрт, говоря́т, насы́тился; *~ мәсьәлә* скандальный вопро́с

талашлы-тартышлы *прил. см.* **талашлы**; сопровожда́емый дря́згами и перебра́нкой

талашсыз *прил.* **1.** не сопровожда́емый перебра́нкой, споко́йный, ти́хий || *нареч.* без перебра́нки, споко́йно, ти́хо (*о мероприятиях*); *~ гына үтү* проходи́ть без перебра́нки **2.** споко́йный (*по нраву*), не скло́нный к перебра́нке (*о человеке*)

талаш-сугыш *сущ. собир.* перебра́нка и дра́ка; *талаш-сугыш чыгару* вызыва́ть перебра́нку и дра́ку; быть причи́ной перебра́нки и дра́ки

талаш-тартыш *сущ. собир.* ссо́ры и ра́спри

талаш-тиргәш *сущ. собир.* ру́гань и брань, ссо́ра с перебра́нкой

талаштыр|у *перех.* **1.** ссо́рить/поссо́рить, рассо́рить; заставля́ть ссо́риться; *юклык ~а, барлык яраштыра* (*посл.*) нищета́ ссо́рит, доста́ток ми́рит **2.** *разг.* натра́вливать || натра́вливание друг на дру́га; *~ыр да, яраштырыр да* (он) и поссо́рит и поми́рит; *ул безне ~макчы* он наме́рен нас поссо́рить

талаштыручы *сущ.* тот, кто ссо́рит; интриган; скло́чник

талаш|у *неперех.* **1.** ссо́риться/поссо́риться, скандали́ть, руга́ться || ссо́ра, скандал; ру́гань, перебра́нка; *орышкан — ожмахка, ~кан — тамугка* (*посл.*) пожу́ривающий — в рай, поруга́ющий — в ад; *~саң әйт таманын, әйтмә, ләкин, яманын* (*посл.*) да́же в ссо́ре знай ме́ру (*букв.* е́сли и руга́ешься, то говори́ то́лько поло́женное, а не сверх поло́женного) *~ыр чак түгел* не вре́мя ссо́риться; не до ссор **2.** гры́зться, дра́ться || грызня́, дра́ка (живо́тных); *этләр ~ыр~ыр да, авыз борынны ялашыр* (*посл.*) соба́ки деру́тся, деру́тся да обли́зывают друг дру́га (подеру́тся — подру́жатся, т. е. не ра́дуйся, когда́ враги́ ссо́рятся, в слу́чае чего́ они́ найду́т о́бщий язы́к)

талашу-тартышу *неперех.* ссо́риться и пребра́ниваться || ссо́ра, перебра́нка, перетасо́вка

талашчан *прил.* сварли́вый, вздо́рный, скло́чный; ~ *хатын этне туктатыр да үзе өрер* (*посл.*) скло́чная ба́ба остано́вит соба́ку да сама́ зала́ет

талаш-тырыш *сущ. собир.* скандал, ссо́ра, перебра́нка с оскорбле́ниями и ру́ганью; буза́, бесчи́нство

таләбә *сущ. собир. уст.* студе́нчество, студе́нты, уча́щиеся; *Петербург ~се* петербу́ргское студе́нчество; *~ләр ра́зного ро́да уча́щиеся* и студе́нты; *университет ~ләре* обуча́ющиеся в университе́те студе́нты университе́та

таләп *сущ.* 1. тре́бование; *гигиена ~ләре* тре́бования гигие́ны; ~ *кирәк, ~тән элек әдәп кирәк* (*посл.*) на́до тре́бовать, но соблюда́я учти́вость; *хәзерге ~ләр югарылыгында* на у́ровне совреме́нных тре́бований 2. прете́нзия; притяза́ние; *зур ~ләр белән* с большими́ прете́нзиями □ ~ **итү (кылу)** 1. тре́бовать 2. взы́скивать

таләпле *прил.* 1. с тре́бованием, име́ющий тре́бование; взыска́тельный 2. *см.* **таләпчән**

таләпсез *прил.* 1. нетре́бовательный; невзыска́тельный (*человек*) 2. невостре́бованный (*багаж, телеграмма*)

таләпсезлек *сущ.* нетре́бовательность (*в деле*); мя́гкость, мягкоте́лость

таләпчән *прил.* тре́бовательный; взыска́тельный; стро́гий; ~ *бул!* будь тре́бовательным! || *нареч.* тре́бовательно, взыска́тельно; *бик ~ сөйли* говори́т о́чень тре́бовательно

таләпчәнләнү *неперех.* станови́ться/стать тре́бовательным (взыска́тельным); *бик ~еп китү* стать о́чень тре́бовательным

таләпчәнлек *сущ.* тре́бовательность, взыска́тельность; стро́гость; ~ *күрсәтү* проявля́ть тре́бовательность

таләпче *сущ.* 1. претенде́нт (*на вещь, место*) 2. исте́ц (*при денежных делах*)

таләпчесез *прил.* 1. без претенде́нта 2. невостре́бованный (*багаж*)

талбия *сущ.* 1. *диал.* па́луба на корме́ ло́дки (*для хранения рыбы*) 2. *ист.* лежа́нка на спине́ вью́чного живо́тного □ ~ **үләне** во́доросль, употребля́ющаяся для хране́ния ры́бы, а та́кже — в сушёном ви́де — для набива́ния матра́цев

талгак *сущ. диал.* 1. о́страя тя́га к определённым ви́дам пи́щи во вре́мя бере́менности 2. *см.* **тулгак**

талгакла|у *неперех. диал.* жела́ть, пожела́ть || жела́ние, пожела́ние определённых ви́дов пи́щи (*во время беременности*); *~п йөрү* (всё вре́мя) жела́ть определённых ви́дов пи́щи (*о беременной*)

талгөл *сущ.* олеа́ндр (*как комнатное растение*); ~ *чәчәге (чәчкәсе)* цветки́ олеа́ндра

талгы *сущ. диал. зоол.* жук-водолю́б

талгын *прил.* 1. неторопли́вый, разме́ренный; уме́ренный, ти́хий; ~ *адымнар* разме́ренные шаги́; ~ *җил* уме́ренный, ти́хий ве́тер 2. уста́лый, утомлённый; ~ *чырай* уста́лый, утомлённый вид; ~ *хәрәкәт* уста́лое движе́ние 3. уме́ренный, ти́хий; споко́йный (*о явлениях природы*); ~ *кич* ти́хий (споко́йный) ве́чер; ~ *елга* ти́хая река́, река́ с ти́хим тече́нием 4. тёплый, тепло́ватый; ду́шный; застоя́лый; ~ *һава* застоя́лый, душнова́тый во́здух || *нареч.* 1. неторопли́во, разме́ренно; не порыви́сто, ро́вно; ~ *яву* неторопли́во, разме́ренно па́дать (*о дожде, снеге*); ~ *яну* разме́ренно пыла́ть, ро́вно горе́ть 2. уста́ло, утомлённо; тяжело́, ме́дленно; ~ *атлау* шага́ть тяжело́; с трудо́м (*но не как больной*); ~ *юырту* бежа́ть ры́сью без осо́бой ре́звости (*о лошади*) 3. не ско́ро, не спеша́, ме́дленно, заме́дленно; не торопя́сь; ~ *өлгеру* поспева́ть ме́дленно (*о хлебах*); ~ *сөйләү* говори́ть не спеша́, заме́дленно

талгында *нареч.* ти́хо, неторопли́во (*о движении воды, ветра*)

талгынландыру *понуд. от* **талгынлану**; *см. тж.* **талгынлату**

талгынлан|у *неперех.* 1. станови́ться/стать разме́ренным, неторопли́вым; *җил ~у* стать бо́лее ро́вным (*о ветре*) 2. стать тёплым, тепло́ватым (*о воде*) 3. спада́ть (*о жаре*) 4. станови́ться/стать ме́дленным, медли́тельным (*о течении*)

талгынлат|у 1. *понуд. от* **талгынлау** 2. *безл.* станови́ться/стать душнова́тым; *кичкә таба бераз ~ты* к ве́черу ста́ло душнова́то

талгынла|ү *перех.* 1. де́лать/сде́лать разме́ренным, неторопли́вым 2. де́лать/сде́лать уме́ренным; тёплым, тепло́ватым; *см. тж.* **таманлау** 3. *см.* **талгынландыру**; *яңгыр ~ый башлады* дождь стал утиха́ть

талгынлы|к *сущ.* 1. разме́ренность, неторопли́вость, непорыви́стость; *җилнең ~гы* разме́ренность, непорыви́стость ве́тра 2. споко́йствие в состоя́нии уста́лости; заме́дленность, происходя́щая от уста́лости; *хәрәкәт ~гы* заме́дленность движе́ний 3. уме́ренная теплота́ (во́здуха, воды́); уме́ренная све́жесть (во́здуха); *кичке ~к* вечёрняя уме́ренная све́жесть во́здуха

талдау *сущ. см.* **талта**

талдыбый *прил. диал.* доста́точно разва́ренный (о мя́се)

талдыргыч *прил.* 1. утоми́тельный, утомля́ющий (*преимущ. в сочет. со сл.* **күңел, җан, йөрәк, кул** *и т. п.*); *җан (йөрәк) ~* утомля́ющий ду́шу (се́рдце) 2. спосо́бствующий успокое́нию, сну и т. п.; *йокыга ~* усыпля́ющий, клоня́щий ко сну

талдыр|у 1. *понуд. от* **талу**; утомля́ть/утоми́ть; томи́ть; *кулларны ~у* утомля́ть ру́ки; *~ма йөрәккәеңне — үкенечле яр түгел* (*песня*) не томи́ ты своё се́рдце (печа́лью), ведь ми́лая была́ не та (*о ком можно сожалеть*) 2. *безл.* приходи́ться/прийти́сь, устава́ть/уста́ть, утомля́ться/утоми́ться; *бик ~ ды* пришло́сь о́чень утоми́ться 3. *диал.* разва́ривать/развари́ть

та́лер *сущ.* та́лер (*денежная единица*), *см. тж.* **талир**; *бер ~* оди́н та́лер; *биш ~* пять та́леров

та́ли *сущ.* та́ли (*судовое грузоподъёмное устройство*); ~ *белән күтәртү* поднима́ть/подня́ть на та́лях

талиб *сущ. см.* **талип**

талибә *сущ. уст.* студе́нтка, уча́щаяся (*среднего или высшего учебного заведения*); *талип вә ~ләр* студе́нты и студе́нтки

талига *сущ. диал. поэт.* 1. зодиака́льное созве́здие, под кото́рым челове́к роди́лся 2. сча́стье, везе́ние, уда́чливость; *~сы бар* у него́ (неё) есть сча́стье, он (она́) везу́ч (везу́ча); он (она́) роди́лся (родила́сь) под счастли́вой звездо́й

талигалы *прил. диал. поэт.* счастли́вый, везу́чий; ~ *кыз булмадым, туганнар, бәхилләгез* (*песня*) не ста́ла я де́вушкой везу́чей, прости́те, родны́е, меня́

талигасыз *сущ. диал. поэт.* несча́стный, бестала́нный, невезу́чий; ~ *икән башым, яшьтән күп михнәт күрдем* (*песня*) вида́ть, нет мне сча́стья — смо́лоду одни́ страда́ния

талиг|ъ *сущ. уст. книжн.* **1.** *см.* **талига 2.** тала́нт, уда́чные сто́роны хара́ктера; *бәхет булса, ~ъ кирәкми* (*посл.*) е́сли есть сча́стье, то не на́до и хоро́шего хара́ктера (*т. е. человек с неважным характером может быть везучим, и наоборот*) **3.** судьба́, рок, уде́л; *~ы кара* его́ (её) пресле́дует чёрный рок; судьба́ его́ (её) чёрна(я)

талигълы *прил. см.* **талигалы**

талигънамә *сущ.* объясне́ние, толкова́ние хара́ктера, судьбы́ по да́те рожде́ния

талигъсыз *прил. см.* **талигасыз**

талип *сущ. уст.* уча́щийся, студе́нт; *мәдрәсә ~ләре* уча́щиеся в медресе́

талир *сущ. ист.* та́лер (*старинная немецкая, австрийская серебряная монета с изображением императрицы Марии-Терезы, часто употреблялась как монисто и как подарок жениха невесте*); *~ тәңкә* серебряный та́лер, серебряная моне́та

талкан *сущ.* толокно́ ◊ **~ итү** разби́ть на́голову, стере́ть в порошо́к, сде́лать котле́ты *из кого*; **~ талку** говори́ть одно́ и то́ же (многокра́тно, ну́дно); **~ы коры** суро́вый, круто́го нра́ва

талканла́у *перех. диал.* раскроши́ть; тере́ть/стере́ть в порошо́к

талканлык *прил.* приго́дный и́ли предназна́ченный для приготовле́ния толокна́ || *сущ.* овёс, зерно́ для приготовле́ния толокна́

талку *перех.* **1.** мять, трепа́ть, тереби́ть мя́лкой (*лён, коноплю и т. п.*) || трепа́ние, тереблёние **2.** *редко* размина́ть/размя́ть; разбива́ть/разби́ть, кроши́ть/раскроши́ть, дроби́ть/раздроби́ть || размина́ние, разбива́ние, дроблёние, раздроблёние (*камня*) **3.** *перен. разг.* 1) твердить, бубни́ть (*одно и то же*) 2) склоня́ть *чьё-л.* и́мя **4.** *в знач. прил.* **талкыган** трёпаный

талкучы *сущ.* мя́льщик, мя́льщица; трепа́льщик, трепа́льщица

талкуыч *сущ. диал. см.* **талкыгыч**

талкы I *сущ.* **1.** льномя́лка, трепа́лка; *~ белән талку* мять мя́лкой **2.** размина́ние, трепа́ние (*льна*); *көзге ~* осе́нняя пора́, когда́ же́нщины занима́лись трепа́нием льна, конопли́, поскони и т. п. **3.** *перен. разг.* попрёки, ворча́ние, брюзжа́ние (*в адрес кого*); *~ астында* под попрёками, терпя́ попрёки

талкы II *сущ.* лён, конопля́ и т. п., пригото́вленные для размина́ния, трепа́ния; *~ талку* размина́ть (трепа́ть) лён

талкыгыч *сущ.* трепа́лка, трепа́льное устро́йство; *см. тж.* **талкы** I || *прил.* трепа́льный; *җитен ~* льнотрепа́льный; *~ машина* трепа́льная маши́на

талкыла|у *перех.* обраба́тывать, трепа́ть, мять на трепа́лке; □ **~п алу** потрепа́ть на трепа́лке

талкыл|у *страд. от* **талку**; *~ган җитен* трёпаный лён

талкылык *сущ. см.* **талкы** II

талкыну *страд.-возвр. от* **талку 1.** *страд. разг. см.* **талкылау 2.** *возвр. разг.* мота́ться, ма́яться, трепа́ться; *курсларда ~* (зря) трепа́ться на ку́рсах

талкыту *понуд. от* **талку** 1

талкыш I *сущ.* костра́, костри́ка, обо́йки; *җитен ~ы* костри́ка льна

талкыш II: **талкыш кәләвә** талкы́ш-калеве́ (*национальное мучно-сахаристое изделие*)

талкышлы *прил.* неочи́щенный и́ли недоста́точно очи́щенный от костры́ (*о волокнах пакли, кудели*)

талкышсыз *прил.* чи́стый, без костры́ (*о волокнах*)

талкышу *взаимно-совм. от* **талку**

таллану *неперех. разг. см.* **тармаклану** (*о декоративных растениях*)

та́ллаһи *межд. сл. прибавляемое к формуле клятвы* ва́ллахи (и бог свиде́тель); *валлаһи, ~ларны әйтеп* божа́сь, повторя́я кля́твы

таллы *прил.* с и́вой (и́вами); с ивняко́м, ивняко́вый, и́вовый (о за́рослях); *~ болыннар* луга́ с ивняко́м

таллык *сущ.* ивня́к, та́льник, лозня́к

талма *сущ.* **1.** припа́док; при́ступ **2.** серде́чный при́ступ; *талымлыга ~ тия* (*посл.*) у того́, кто сли́шком приверёдлив, мо́жет случи́ться серде́чный при́ступ

талмуд *сущ.* талму́д

талмудчы *сущ.* талмуди́ст

талон *сущ. в разн. знач.* тало́н

талонлы *прил.* **1.** с тало́ном, име́ющий тало́н **2.** продава́емый по тало́нам || продаётся по тало́нам; *~ ашамлык* проду́кт пита́ния, продава́емый по тало́нам; *бу товар ~* э́тот това́р продаётся по тало́нам

талпа *сущ.* **1.** *ист. воен.* отря́д-прикры́тие (*состоящее из ополчения*); ополче́ние **2.** *диал.* ста́йка, ста́я, небольшо́е ста́до; часть ста́да, гру́ппа скота́ (*пасущаяся всегда вместе*)

талпан *сущ. зоол.* **1.** 1) клещ || клещево́й 2) *перен.* кра́йне терпели́вый и упо́рный челове́к **2.** *мн.* **талпаннар** клещи́, класс членистоно́гих □ **~ бизгәге** пироплазмо́з, клещева́я лихора́дка (*лошадей*); **~ энцефалиты** клещево́й энцефали́т ◊ **~ булып кадалу 1.** вгрыза́ться (*в работу, проблему*) **2.** упо́рно мстить

талпа-талпа *нареч. диал.* ста́йками, гру́ппами (*преимущ. о животных*); *талпа-талпа күгәрченне өерәдер карчыга* (*песня*) я́стреб рассе́ивает ста́и голубе́й

талпу *неперех. диал.* маха́ть/махну́ть, сде́лать взмах (*крылом*)

талпындыргыч *прил.* окрыля́ющий, вдохновля́ющий, воодушевля́ющий; *~ хисләр* воодушевля́ющие чу́вства

талпындыр|у *понуд. от* **талпыну 1.** заставля́ть/заста́вить маха́ть кры́льями **2.** маха́ть *чем-л.*; *канатларын ~у* взма́хивать кры́льями **3.** *перен.* окрыля́ть, вдохновля́ть, воодушевля́ть

талпын|у *неперех.* **1.** маха́ть/махну́ть || взмах, мах кры́льями (стремя́сь взлете́ть); порыва́ться взлете́ть; *очаем ла диеп өч ~дым, каерылган икән канатым* (*песня*) три́жды я порыва́лся взлете́ть, но кры́лья мои́ оказа́лись вы́вихнутыми **2.** рва́ться, рвану́ться, де́лать, сде́лать рыво́к || рыво́к; *~ып йөзү* пла́вать рывка́ми **3.** си́льно кача́ться, качну́ться || качо́к в сто́рону; *якякка ~у* кача́ться в ра́зные сто́роны **4.** *перен.* тяну́ться/потяну́ться, стреми́ться || тя́га, стремле́ние *куда, к кому, чему; күңелем сиңа ~а* душа́ моя́ тя́нется к тебе́ **5.** *прям. и перен.* порыва́ться || поры́в (*в желании что-то совершить, сделать*); *ул укырга ~а иде* он порыва́лся учи́ться; *нәрсәдер әйтергә ~а* си́лится что́-то сказа́ть

талпынып *сущ.* **1.** маха́ние, взмах, мах (*крылом, крыльями*) **2.** рыво́к; *бер ~ белән алга чыгу* одни́м рывко́м вы́йти вперёд **3.** рве́ние, стремле́ние, поры́в; *югары ~лар* высо́кие поры́вы

талпынышу *совм. от* **талпыну 1.** маха́ть кры́льями (о мно́гих) **2.** *перен.* многокра́тно порыва́ться (что́-нибудь де́лать/сде́лать)

талта *сущ.* **1.** *ист. воен.* 1) тыл 2) засло́н, защи́та от нападе́ния **2.** *перен. диал.* ве́рное сре́дство, лека́рство **3.** *перен. диал.* утеше́ние, отра́да (*души*); опо́ра (*в судьбе*)

талта|ю *неперех. диал.* стоя́ть с раздви́нутыми нога́ми; *~я басу* встать кре́пче (*готовясь к борьбе*)

тал-тирәк *сущ. бот.* раки́та; раки́тник; *су буена төшкәнем юк — үсә микән ~* (*песня*) не́ был я давно́ на берегу́ ре́чки, не зна́ю — растёт ли там раки́та

тал|у *неперех.* **1.** устава́ть/уста́ть || устава́ние, уста́лость (*преимущ. об отдельных частях тела*); *салкын сулар ала-ала ~мас кулларым ~а* (*песня*) таска́я во́ду из коло́дца, мои́ неутоми́мые ру́ки устаю́т **2.** устава́ть/уста́ть, утомля́ться/утоми́ться, истоми́ться || устава́ние, утомле́ние (*об органах чувств*); *карый-карый күзләр ~ды* глаза́ уста́ли от при́стального вгля́дывания; *көтә-көтә күңел ~ды* от до́лгого ожида́ния утоми́лась душа́ **3.** устава́ть/уста́ть; утомля́ться/утоми́ться, изнуря́ться/изнури́ться (*от длительной работы или напряжения*); *см. тж.* **талчыгу** 2 **4.** приходи́ть в бездея́тельное и́ли апати́чное состоя́ние; *~ып утыру* сиде́ть споко́йно, ти́хо и расслабленно **5.** *диал.* стать доста́точно тёплым, дойти́ до кондиции (*о воде для омовения или умывания*) **6.** *диал.* онеме́ть || онеме́ние (*о частях тела*)

талчук *сущ. разг.* толку́чка, толчо́к, толку́чий ры́нок

талчукчы *сущ. разг.* **1.** челове́к, торгу́ющий на толку́чем ры́нке **2.** завсегда́тай толку́чего ры́нка

талчыбык *сущ.* **1.** лоза́ и́вы, и́вовый прут **2.** *бот.* шелю́га

талчы|гу *неперех.* **1.** си́льно устава́ть/уста́ть; изнуря́ться/изнури́ться || изнуре́ние **2.** чу́вствовать уста́лость, утомля́ться/утоми́ться || уста́лость, утомлённость; чу́вство уста́лости, утомлённости (от физи́ческой рабо́ты) **3.** *см.* **талу** 1; *бии-бии аякларым ~кты* но́ги мои́ уста́ли от до́лгой пля́ски □ **~гып бетү** вконе́ц уста́ть, измота́ться; приутомля́ться

талчыкканлы|к *сущ.* утомлённость; изнурённость; уста́лость; *каты ~гым белән* та́к как я был си́льно утомлён

талчыктыргыч *прил.* утоми́тельный; изнури́тельный; *~ утырышлар* утоми́тельные заседа́ния

талчыктыр|у *понуд. от* **талчыгу 1.** изнуря́ть/изнури́ть, утомля́ть/утоми́ть *кого; атны ~у* переутомля́ть ло́шадь **2.** *безл.* приходи́ться/прийти́сь утомля́ться, изнуря́ться; *эштә буген бик ~ды* сего́дня пришло́сь рабо́тать до изнуре́ния

талы|гу *неперех.* **1.** утомля́ться, си́льно устава́ть || утомле́ние, си́льная уста́лость; *тамыр тарткан ~кмас* (*посл.*) тот, кто созыва́ет на по́мощь родню́, не утоми́тся **2.** задрёмывать || дрёма, дремо́та (*от однообразных движений, звуков*); *см. тж.* **төлерү 3.** *диал. см.* **талгынлану**

талыктыру *понуд. от* **талыгу 1.** утомля́ть/утоми́ть; наводи́ть сон, дрёму **2.** томи́ть (*сердце, душу*) **3.** *см.* **талчыктыру**

талым *сущ.* **1.** приве́дливость, разбо́рчивость (*в отношении еды*); гастрономи́ческие при́хоти; *тәмлегә дә ~ бар* (*посл.*) и из вку́сного выбира́ют то, что нра́вится **2.** *см.* **зәвыкъ**

талымлану *возвр. от* **талымлау**; станови́ться/стать приве́дливым, прихотли́вым

талымла́у *перех.* **1.** приве́дничать, быть прихотли́вым (*к пище*) || приве́дничанье, при́хоть (*беременных женщин*) **2.** *перен.* ста́вить жёсткие тре́бования (*при выборе чего-л.*)

талымлы *прил.* **1.** разбо́рчивый (*в еде*), приве́дливый; прихотли́вый; *туфракка ~ үсемлек* прихотли́вое к по́чве расте́ние; *~ дуңгызга таяк таман* (*посл.*) прихотли́вой свинье́ па́лка впо́ру **2.** изы́сканный, деликате́сный; *~ ашлар* деликате́сные я́ства **3.** взыска́тельный; тре́бовательный (*при выборе, решении*); *~ да бул, ягымлы да бул* будь и взыска́телен и дели́катен

талымлык *сущ.* **1.** *см.* **талым 2.** взыска́тельность, тре́бовательность; *~ белән сайлау* выбира́ть взыска́тельно

талымсак *прил.* прихотли́вый, скло́нный к приве́дничанью; *көмәнле хатын ~ булыр* бере́менная же́нщина быва́ет прихотли́вой

талымсаклану *неперех.* си́льно приве́дничать

талымсыз *прил.* **1.** неприве́дливый, неразбо́рчивый, неприхотли́вый (*в отношении еды*); *тамакка ~* неприве́дливый к еде́; *~га тозсыз умач* (*погов.*) неприхотли́вому затиру́ха без со́ли **2.** неприхотли́вый, нетре́бовательный (*в отношении условий жизни — о людях или условий существования — о животных и растениях*); *кәҗә — ~ терлек* коза́ — скоти́на неприхотли́вая; *туфракка ~ культура* неприхотли́вая, нетре́бовательная к по́чвам культу́ра (культу́рное расте́ние); *~ булу* быть неприхотли́вым **3.** беспринци́пный, неразбо́рчивый в сре́дствах (*для достижения низменных целей*) □ **~ тамак** всея́дная и жа́дная ли́чность

талымсызлан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать неразбо́рчивым, неприхотли́вым в еде́; *ачыккан ~ыр* проголода́вшийся стано́вится неприхотли́вым **2.** станови́ться, стать нетре́бовательным и́ли беспринци́пным вообще́

талымсызлык *сущ.* **1.** неразбо́рчивость; неприхотли́вость; *~ курсәтү* проявля́ть неразбо́рчивость и́ли неприхотли́вость **2.** *книжн.* беспринци́пность, нетре́бовательность (*в выборе чего-л.*); *~ сәнгатьне түбәнәйтә* нетре́бовательность снижа́ет иску́сство

талымчан *прил.* **1.** *см.* **талымсак 2.** разбо́рчивый *см. тж.* **талымлы** 3; приди́рчивый **3.** *см.* **таләпчән**; тре́бовательный

талымчанлану *неперех.* станови́ться/стать приве́дливым, прихотли́вым; *см. тж.* **талымлану**

талымчанлык *сущ.* **1.** приве́дливость (*в еде и т. п.*) **2.** тре́бовательность, взыска́тельность; *югары ~* высо́кая тре́бовательность

талымчы *сущ. разг.* приве́дник

талык *сущ.* тальк (*минерал*)

тальян *сущ.* талья́нка; *~ уйнау* игра́ть на талья́нке □ **~ гармун** *см.* **тальян**

там I *сущ.* **1.** *диал.* ка́пля (*дождевой воды*) **2.** *диал.* гли́на, ком гли́ны (*при сложении стены, глинобитной крыши, глинобитного забора*) **3.** *этногр.* склеп над моги́лой (*у астраханских татар, казахов и т. д.*) **4.** глинобитная и́ли ка́менная стена́, забо́р; *тавык очса — тамга куна, бөркет очса — тауга куна* (*посл.*) ку́рица взлети́т — ся́дет на забо́р, орла́ полёт — вы́ше гор **5.** *уст.* стена́ (*вообще*), пане́ль (*забора*)

там II *нареч. диал.* то́чно; как ра́з; ро́вно; *там ярты-сы* ро́вно полови́на

тамада *сущ.* тамада́; *~ сайлап кую* вы́брать тамаду́

тама|к *сущ.* **1.** го́рло || горлово́й; гло́тка || гло́точный; зев; *см. тж.* **бугаз** (**бугаз** — *горло снаружи*, а **тамак** — *изнутри*); *авызын ачып ~гын курсәтте* откры́в рот, показа́л зев **2.** горта́нь || горта́нный; *~к авазы* горта́нный звук **3.** *перен.* желу́док; кишки́, пищевари́тельные о́рганы; *~к ~ктан көнләшә* (*посл.*) кишка́ кишке́ ку́киш ка́жет; сы́тый голо́дного не разуме́ет (*букв.* кишка́ зави́дует кишке́) **4.** *перен.* еда́, пи́ща; пропита́ние; потре́бность в пи́ще (*о пропитании, хлебе насущном*);

тапканым ~гыма всё мной зарабо́танное — на пита́ние; *~к булмаса, тамук та булмас иде* (*посл.*) (*букв.* не́ было бы потре́бности в пи́ще, не́ было бы и а́да); *~к туташ тугел, суз белән күндерәлмәссең* (*посл.*) го́лод не тётка (*букв.* потре́бность в пи́ще не ба́рышня, слова́ми её не уговори́шь) **5.** *перен.* рот, едо́к; *артык ~к* ли́шний рот; *олы ~ктан кече ~к көчлерәк* ма́ленький едо́к сильне́е большо́го (*о необходимости кормить в первую очередь детей*) **6.** *перен.* у́стье, впаде́ние; *елга ~гы* у́стье реки́ **7.** подъём сапога́ ◻ **~гына каба башлады** стал немно́жко есть, принима́ть пи́щу (*после периода без еды, о больных, сильно подавленных горем людях*); **~к алмасы** кады́к, ада́мово я́блоко; **~к асрау** прожи́ть, пропита́ться (*в трудных условиях*); **~к асты** подборо́док; **~к ачу 1.** *см.* **ачыгу, корсак ачу 2.** *см.* **тамак ачу; ~к бакасы** анги́на, жа́ба (*вызывающая хрипотцу, хрип*); хри́плость; **~к җылыту** попи́ть и́ли угоща́ть хмельны́м (*в качестве взятки*); **~к кибү 1.** жа́жда, чу́вствовать жа́жду **2.** *перен.* жела́ть вы́пить (*хмельное*); **~к киерү** *см.* **бугаз киерү; ~ к кыру 1.** прочища́ть го́рло, издава́я хри́плый звук **2.** выража́ть/вы́разить удовлетворе́ние, издава́я горта́нные зву́ки; **~к төбе** *анат.* гло́тка; **~к чокыры** *груб.* гло́тка, рот; *~к чокыры тирән* (*посл.*) бездо́нная гло́тка; **~кка тыгылу 1.** застрева́ть в го́рле (*о пище*) **2.** *перен.* осека́ться (*от волнения, плача*); **~кка утыру 1.** *см.* **тамакка тыгылу 1 2.** оседа́ть в гло́тке, зе́ве (*о пыли*); **~ктан язу (калу)** лиши́ться аппети́та и́ли возмо́жности есть; переста́ть пита́ться, принима́ть пи́щу (*из-за болезни*) ◊ **~гы нечкә** разбо́рчивый, приве́редливый к пи́ще; **~гы сай (нәзек)** ма́ло есть; малоё́жка; **~гыца таш булсын** пусть ка́мнем застря́нет в твое́й гло́тке (го́рле); **~к (ярысын) майлау** выпива́ть/вы́пить; **~к төбе белән (сөйләшү)** говори́ть, подчёркивая своё превосхо́дство; кобе́ниться; ва́жничать в разгово́ре; **~к туйдыру 1.** есть, ку́шать, сиде́ть за тра́пезой **2.** пропита́ться, находи́ть себе́ хлеб насу́щный; **~к тую 1.** насы́титься **2.** *перен.* достига́ть/дости́чь материа́льного благополу́чия; **~к чайкау (чылату, җебетү)** промочи́ть го́рло, попи́ть хмельно́е; **~к чарлау 1.** треща́ть, болта́ть, говори́ть без у́молку **2.** гро́мко петь для себя́; тренирова́ться в пе́нии; **~к чатнау** си́льно жа́ждать; **~к ялгау** немно́го пое́сть, — замори́ть червячка́; **~к ялына (хакына, бәясенә)**; **~к ялы (хакы, бәясе) өчен** на кошт, на харчи́; задёшево (*о работе, обычно на кого-л.*); **~кка (~гына) ашау (кабу)** есть; выка́зывать жела́ние пое́сть; **~кка бару** быть в состоя́нии приня́ть пи́щу; *~гыма бармый* не могу́ есть (*от горя, огорчения, отвращения*); *~гына ничек бара?* как он мо́жет (*в таком положении*) есть? **~кка пычак (булып) керү (кергере)** *см.* **тамакка таш булу; ~кка ризык үтү** *см.* **тамакка үтү; ~кка таш булу (булып кадалу, булып утыру)** о возме́здии за присвое́ние чужо́й до́ли; **~кка (тамактан) үтү 1.** о возмо́жности проглоти́ть *чего-л.* **2.** *см.* **тамакка бару;** *ашым ~ктан үтми* не могу́ есть; **~кка ягу (йогу)** быть пита́тельным; **~ктан калу** переста́ть пита́ться (*от болезни, горя и т. п.*); **~ктан (~гыннан) өзеп** *см.* **авызыннан өзеп**

тамакай *сущ.* **1.** люби́тель пое́сть; гурма́н, чревоуго́дник **2.** *диал.* обжо́ра

тамакайлану *неперех. разг.* **1.** станови́ться/стать || становле́ние гурма́ном, люби́телем пое́сть **2.** вести́ себя́ как гурма́н, гурма́нничать

тамакландыр|у *перех.* покорми́ть (*немного*), дать пое́сть; *~ырлык ризык* пи́ща, доста́точная, необходи́мая и́ли приго́дная для того́, что́бы покорми́ть

тамаклан|у *неперех.* **1.** пое́сть (*немного*), приня́ть пи́щу || приня́тие пи́щи **2.** пропита́ться; *~ып тору* пропита́ться в тече́ние определённого вре́мени ◻ **~ып алу** пое́сть (*быстро, на скорую руку*)

тамаклы *прил.* предназна́ченный для пропита́ния; на пропита́ние; *~ акча* де́ньги на пропита́ние

тамакса *сущ. этногр.* (обы́чный шерстяно́й) съёмный воротни́к; *~ бәйләү* вяза́ть съёмный воротни́к

тамаксау *прил.* **1.** лю́бящий || люби́тель пое́сть; чревоуго́дный || чревоуго́дник; *~ ул* он лю́бит пое́сть; *~ның үлеме тамактан* чревоуго́дник умира́ет от чревоуго́дия **2.** прожо́рливый (*о скотине*) *~ — димәк сау* (*погов.*) прожо́рлив(а) — зна́чит здоро́в(а)

тамаксыз *прил. разг.* **1.** ма́ло еда́щий, малое́жка **2.** с больши́м го́рлом ◻ *~* **калу** заболе́ть боле́знями го́рла

тамакча *сущ.* подборо́дник (*уздечки*)

тамакчалы *прил.* с подборо́дником (*об уздечке*)

ташлама II *сущ. этногр.* язы́ческий пра́здник хме́ля □ *~ аягы* круговая́ ча́ша; круговой ковш

ташланган *прил. см.* **ташландык**

ташландык *прил.* **1.** вы́кинутый, бро́шенный; ли́шний, нену́жный; *~ кием* вы́кинутая, нену́жная оде́жда **2.** забро́шенный; неухо́женный; *~ йорт* забро́шенный двор; *~ кое* забро́шенный коло́дец; *~ хәлдә* в забро́шенном, неухо́женном состоя́нии **3.** *редко* подки́нутый (*о ребёнке*) || *сущ.* **1.** подки́дыш **2.** изго́й, отщепе́нец; *җәмгыять ~лары* отщепе́нцы о́бщества

ташландыклык *сущ.* бро́шенность, забро́шенность; поки́нутость (*жилья, двора, колодца и т. п.*); *~ кыяфәте* вид забро́шенности, поки́нутости; забро́шенный, поки́нутый о́блик

ташлану *возвр.-страд. от* **ташлау** **1.** *возвр.* броса́ться/бро́ситься || броса́ние (себя́); пры́гать || прыжо́к (све́рху, в сто́рону *за кем-л., чем-л.*); *суга ~* пры́гать в во́ду (*быстро, со всей силой*) **2.** напада́ть/напа́сть; набра́сываться/набро́ситься, бро́ситься || нападе́ние (броско́м); *юлбарыс кебек ~* набро́сится ти́гром (*как тигр*) **3.** устремля́ться/устреми́ться || устремле́ние (в погоню); *дошман артыннан ~* устреми́ться за врагом **4.** *перен.* набра́сываться/набро́ситься, устремля́ться/устреми́ться || устремле́ние *на что-л.* (*на область деятельности*); *китапларга ~* устреми́ться к кни́гам (*чтобы их читать*) **5.** *страд.* быть бро́шенным

ташлаттыру *понуд. от* **ташлату**; заставля́ть/заста́вить бро́сить (*через третье лицо*)

ташлату *понуд. от* **ташлау** 1—5 **1.** *ими ~* отнима́ть/отня́ть ребёнка от груди́ (*букв.* заста́вить бро́сить грудь) **2.** *в разн. знач.* допуска́ть/допусти́ть, что́бы броса́ли/бро́сили

ташл|а́у *перех.* **1.** 1) броса́ть/бро́сить; поброса́ть; швыря́ть/швырну́ть || броса́ние, швыря́ние (*небрежное, не нацеленное*); *суга ~ау* броса́ть в во́ду 2) направля́ть/напра́вить (*взгляд; силы, средства*); *бөтен көчне чәчүгә ~ау* бро́сить все си́лы на сев 3) броса́ть/бро́сить (адресова́ть) *кому*; *шелтә ~ау* броса́ть/бро́сить упрёк; *сүз ~ау* бро́сить ре́плику 4) броса́ть/бро́сить, рвать/порва́ть, разорва́ть, прерва́ть (*любовные связи, узы дружбы и т. п.*); *мин сине сөйдем тиң итеп, син ~адың ким итеп* (*песня*) люби́ла тебя́, счита́я ро́вней, а ты бро́сил меня́, счита́я недосто́йной **2.** броса́ть/бро́сить || броса́ние; переставля́ть/переста́ть занима́ться *чем*; *бер башлый, бер ~ый* то начина́ет, то опя́ть броса́ет; *тәмәкене (тәмәке тартуны) ~ау* переста́ть (броса́ть) кури́ть; *укуны ~ама* не броса́й учёбу; *~агыз әле!* бро́сьте! переста́ньте! **3.** дать, подава́ть/пода́ть || пода́ча (*небрежным движением*); кида́ть/ки́нуть || кида́ние; *см. тж.* **ыргыту**; *миңа ~а* пода́й (кинь) мне **4.** выбра́сывать/вы́бросить, выки́дывать/вы́кинуть || выбра́сывание, выки́дывание (*выборочное*); *алганыңны ал, алмаганыңны ~а* бери́, что на́до, и вы́брось, чего́ не на́до; *~арга кирәк моны* на́до э́то вы́кинуть **5.** 1) оставля́ть/оста́вить, покида́ть/поки́нуть || оставле́ние, покида́ние (*родных мест*); *шәһәрне ~ап авылга кайту* оста́вить го́род и пое́хать в дере́вню 2) броса́ть/бро́сить || броса́ние, покида́ть/поки́нуть || покида́ние на произво́л судьбы́ *кого-л.*; *гаиләсен ~аган кеше* челове́к, бро́сивший (поки́нувший) семью́ **6.** *в словосочет. с исх. п.*; лиша́ть/лиши́ть || лише́ние (*внимания, благосклонности*); *хәер-догадан ~ама* не лиша́й нас благослове́ния **7.** *с определительными сл.* заки́дывать/заки́нуть || заки́дывание; раски́нуть; *артка ~ау* заки́нуть наза́д; *кулларын як-якка ~ап* раски́нув ру́ки в сто́роны **8.** накида́ть/наки́нуть || наки́дывание *на кого что-л.*; *элмәк ~ау* наки́нуть пе́тлю; *кармак ~ау* заки́нуть у́дочку; *җылым ~ау* заки́нуть се́ти **9.** *перен.* (далеко́) оставля́ть/оста́вить за собо́й (*в соревнованиях*); *ун адымга ~ау* оста́вить за собо́й на де́сять шаго́в **10.** *перен. разг.* выки́дывать/вы́кинуть, де́лать/сде́лать вы́кидыш (*о животных*); *авыр эштән колын ~ау* сде́лать вы́кидыш жеребёнком из-за тяжёлой рабо́ты (*о кобыле*) **11.** *в роли вспом. гл. в сочет. с деепричастиями на* **-ып, -еп, -п** *выраж.* 1) реши́тельность; полноту́ (*вместе с тем и грубость, небрежность*) де́йствия; *йолкып ~ау* вырыва́ть/вы́рвать с ко́рнем; соверше́нно уничто́жить (*до основания*), разгроми́ть; *өзгәлән ~ау* растерза́ть 2) быстроту́ и энерги́чность де́йствия; *өй салып ~ау* (бы́стро) сооруди́ть, отгро́хать дом 3) неуме́ренность, чрезме́рность, превыше́ние ме́ры в де́йствиях; *сүгеп ~ау* обруга́ть (сгоряча́); *кыйнап ~ау* приби́ть, отколоти́ть; *әйтеп ~ау* сказа́ть *что-л.* некста́ти, не обду́мавши; *прост.* смороз́ить, сказану́ть

ташлаштыру *многокр. от* **ташлау** **1.** побра́сывать, подбра́сывать, броса́ть (*время от времени*); *учакка утын ~* подбра́сывать дрова́ в костёр **2.** повыки́дывать; *кирәкмәгенне ~* повыки́дывать нену́жное

ташлаш|у **1.** *взаимно-совм. от* **ташлау** 1) броса́ть, кида́ть друг в дру́га 2) помога́ть броса́ть, кида́ть *что во что* **2.** соверша́ть/соверши́ть размо́лвку; расходи́ться/разойти́сь (*прерывая любовные связи*); наруша́ть/нару́шить ве́рность; *алдашмабыз, ~мабыз, алда гомерләр булса* (*песня*) не бу́дем наруша́ть ве́рность друг дру́гу, пока́ мы бу́дем жи́вы

ташлы *прил.* **1.** с ка́мнем (камня́ми), име́ющий ка́мень (ка́мни); с ка́менной ча́стью, с ка́менной дета́лью; на камня́х; *~ сәгать* часы́ на камня́х; *икс ~ тегермән* ме́льница в два поста́ва **2.** каменѝстый, ка́менный (*о местности*); изоби́лующий камня́ми; ска-

ли́стый; ~ *таулар* ка́менные (скали́стые) го́ры; ~ *яр* ка́менный (камени́стый) бе́рег; ~ *җир* камени́стая земля́

ташлы|к *сущ.* 1. ме́сто, где мно́го камне́й; камени́стая ме́стность 2. камени́стая земля́; *~кка тары чәч (посл.)* на камени́стую зе́млю сей про́со 3. *редко* камнело́мня, ка́менный карье́р

ташлылы|к *сущ.* камени́стость; изоби́лие камне́й; *басуның ~гы аркасында* из-за камени́стости (изоби́лия камне́й) в по́ле

ташпулат *сущ.* (*большое, представительное*) ка́менное строе́ние, ка́менное зда́ние; ка́менный дворе́ц; *~лар салу* стро́ить больши́е ка́менные зда́ния; стро́ить дворцы́; *шәһәрнең ак ~лары* белока́менные зда́ния го́рода

ташпулатлы *прил.* с ка́менными строе́ниями; с ка́менными дворца́ми; *ак ~ шәһәр* белока́менный го́род

таштабак *сущ.* ка́менная ча́ша, керами́ческое блю́до (*больших размеров*); *кунакларга ~ка салып ит китерделәр* гостя́м принесли́ мя́со в огро́мном блю́де

таштабан *сущ.* 1. *ист.* башмаки́, ту́фли, сапо́жки с за́гнутыми квёрху носка́ми; чёботы 2. *диал.* 1) опо́рки *обл.* (*старая обувь, приспособленная для ношения дома и во дворе*) 2) коро́ткие лы́жи для ката́ния с го́рок

таштай *прил.* 1. ка́менно-твёрдый; кре́пкий, как ка́мень; ~ *каты* твёрд, как ка́мень 2. *перен.* кре́пкий, кре́пенький, здоро́вый; *сәламәтлеге ничек? — ~ !* как его́ здоро́вье? — кре́пенькое!

таш-та́у *сущ. см.* **тау-таш**

таштыру *понуд. от* **ташу** I; позволя́ть/позво́лить и́ли заставля́ть/заста́вить перекипе́ть, переliва́ться че́рез край; *казанны ~* позволя́ть переliва́ться че́рез край (по́лного) котла́

таш|у I *неперех.* 1. разliва́ться/разли́ться || разliва́ние; разли́в (*весенних вод*); *су ~а, су ~а, йөрәккә дәрт тоташа* (*прибаутка*) вода́ (река́) разliва́ется, вода́ (река́) разliва́ется; до се́рдца волне́ние добира́ется 2. переliва́ться/переlíться || переliва́ние; переlíв (че́рез край); бежа́ть, убега́ть/убежа́ть || убега́ние (*о молоке*) 3. *см.* **ташкынлану** 2 (*о чувствах*) ◻ **~ып чыгу (китү)** 1. *в разн. знач.* бить, переliва́ться че́рез край; **~ып чыккан** бью́щий че́рез край (*о чувствах, силе и т. п.*) 2. быть чрезме́рно больши́м 3. излива́ться/изли́ться (*плачем, слезами*); *кайгым ~ып чыкты* го́ре моё излило́сь (слеза́ми) ◊ **~ып тору (бару)** распира́ть (*о силе*)

ташу II *сущ.* разли́в, полово́дье; та́лые во́ды; *см. тж.* **ташкын**; *язгы ~* весе́ннее полово́дье; *безнең урам — таш урам, ~ ага басудан* (*песня*) на́ша у́лица мощена́ (*камнем*), и по ней та́лые во́ды бегу́т с поле́й ◻ **~ ташу** разliва́ться (*о весенних водах*)

таш|у III (**ташы-**) *перех.* 1. вози́ть/перевози́ть || перево́зка; носи́ть/переноси́ть; таска́ть, перета́скивать/перетаска́ть || перено́ска, перета́скивание (*с места на место*); *йөк ~у* переноси́ть (перевози́ть) тя́жести 2. разноси́ть, разводи́ть || разно́с, развоз; *хат ~у* разноси́ть пи́сьма 3. *перен.* распространя́ть (*слухи*), расска́зывать (*секреты*); *ул гайбәт ~ый* он распространя́ет спле́тни

ташула|у *неперех.* разliва́ться/разли́ться (*широко*); превраща́ться/преврати́ться || превраще́ние в (*бурный*) пото́к; *су ~п ага башлады* вода́ ста́ла течь пото́ком

ташучы *сущ.* разно́счик, во́зчик, подво́зчик; **-воз**, **-но́сец**; *көлтә ~* сноповоз; *су ~* водовоз; *хат ~* письмоно́сец

ташчы *сущ.* 1. *ист.* камнере́з (*специалист по изделиям из камня*) 2. ка́менщик (*специалист по кирпичной, каменной, бетонной кладке*); *~лар бригадасы* брига́да ка́менщиков 3. *редко* камнедроби́льщик; рабо́тник ка́менного карье́ра

ташчыл *прил.* камени́стый; *~ күзәнәкләр биол.* камени́стые кле́тки ◻ **~ үрчем** ка́менный распло́д (*у пчёл*)

ташчылык *прил.* ремесло́, профе́ссия, заня́тие камнере́за, ка́менщика; *~ һөнәре* ремесло́ камнере́за (ка́менщика); *~та эшли* рабо́тает ка́менщиком

ташъязма *сущ.* письмо́, на́дпись на ка́мне; *~лар* на́дписи, письмена́ на ка́мне

ташыл|у I *страд. от* **ташу**; перевози́ться, переноси́ться, перета́скиваться; *йөк ~ып бетте* весь груз перета́щен (перевезён)

ташыл|у II *неперех.* быть чрезме́рно (о́чень) по́лным, ту́чным; *~ып торган беләкләр* о́чень по́лные предпле́чья; *~ып чыккан балтыр* чрезме́рно по́лные и́кры

ташыну *неперех.* перебира́ться, переезжа́ть || переёзд с вещ́ами, тя́жестями с ме́ста на ме́сто; таска́ть/перета́скивать || перета́скивание (*своих вещей*); *~ җиңел түгел* перета́скивать (перета́скиваться) нелегко́

ташыту *понуд. от* **ташу** III; заставля́ть/заста́вить, вела́ть перевози́ть *что-л.*; *йөк ~* заста́вить (заня́ть) перевози́ть груз

ташыш|у *взимно-совм. от* **ташу** III; помога́ть/помо́чь переноси́ть, перевози́ть *что-л.*; *әйберләр ~ты* он помога́л перевози́ть ве́щи

таю *неперех.* 1. поска́льзываться/поскользну́ться; *баткан тайганнан көлгән* (*погов.*) упа́вший смеётся над подскользну́вшимся 2. вы́вихнуться || вы́вих; *тез буыны таю* вы́вих колённого суста́ва 3. *перен.* 1) (незаме́тно) убега́ть/убежа́ть, убра́ться (*восвояси*); ускользну́ть, улизну́ть, утека́ть || утека́ние, побе́г; *таеп өлгергән* он успе́л улизну́ть; *тайган да инде* он уже́ утёк 2) ума́тываться/умота́ться; *исән чагында тай моннан* ума́тывай отсю́да, пока́ жив-здоро́в (цел) 4. *см.* **язу** II; *акылдан (истән, һуштан) таю* лиши́ться созна́ния, теря́ть/потеря́ть созна́ние; *көчтән (хәлдән) таю* соверше́нно обесси́леть, изнемога́ть/изнемо́чь 5. *перен.* попада́ть/попа́сть || попада́ние в беду́ ◻ **таеп егылу** па́дать/упа́сть на ско́льзком ме́сте; **таеп китү** вдруг поскользну́ться; **таеп чыгу** внеза́пно вы́вихнуться

таюла|у *неперех.* 1. *см.* **салулау** 2. *в знач. нареч.* **таюлап**; ю́зом; *машина ~п китте* маши́на пое́хала ю́зом

таюлык *сущ. разг.* ско́льзкое ме́сто (*на дороге*)

таявыч *сущ. см.* **терәвеч, терәү**

таягыч *сущ. см.* **таявыч** || *прил.* подпира́ющий, опо́рный

тая|к *сущ.* 1. па́лка, па́лочка; по́сох, трость; *дирижёр ~гы* дирижёрская па́лочка; *чаңгы ~гы* лы́жная па́лочка; *улчәү ~гы* ме́рная па́лка; *~кка таяну* опира́ться о па́лку (по́сох) 2. ме́рник, ме́рная па́лка; ме́рная са́жень 3. *ист.* 1) са́жень как едини́ца (ме́ра) длины́; *алдыннан биш ~к уру* сжать по́лосу в пять са́жене́й 2) са́жень как ме́ра земе́льной пло́щади (*80 квадратных саженей*); *биш ~к җир* 400 квадра́тных са́жене́й земли́ 4. *перен.* о битье́, наказа́нии па́лкой || па́лочный; *~к та йодрык* то па́лка, то кула́к; *~ктан талак артык* (*погов.*) (*букв.* лу́чше развести́сь, чем терпе́ть побои); *гаеплегә бер ~к, әләкчегә биш ~к* винóвному оди́н уда́р па́лкой, доно́счику — пять (уда́ров) ◊ **~к алу (ашау)** быть би́тым (избива́емым); **~к астында** из-под па́лки; **~к бирү (ашату)** наказа́ть па́лкой, ро́згами; *сабак биргән ~к та бирә* кто у́чит, тот и нака́зывает; **~к дисциплинасы** па́лочная дисципли́на; **~к ике башлы** па́лка о двух концах; **~к ору** бить па́лкой

в наказа́ние; *ерак киянен башына чатыр коралар, якын киянен башына ~к оралар* (*посл.*) *букв.* (далёкому) а́тю — зонт над голово́й, бли́зкому за́тю — па́лкой по голове́; **~к тоту** проводи́ть/провести́ жеребьёвку путём перебо́ра па́лки (*букв.* перебира́ние па́лки); **~к тыгу** ста́вить па́лки (*в колёса*); **~к тыккан (тыгып болгаткан) кырмыска оясы кебек (шикелле)** подо́бный муравейнику, кото́рый развороши́ли па́лкой (*т. е. крайне взбудораженный*); **~кка ~к ялгау** перевира́ть, подтасо́вывать фа́кты; **~кны бөгү (бөгеброк ташлау)** перегиба́ть па́лку; **~кның авыр башы** тяжёлый коне́ц па́лки (*т. е. худшее наказание*); *~кның авыр башы башлыга төшә* отве́т держа́ть тому́, кто умне́е (из гру́ппы)

таяклану *страд. от* **таяклау**; прика́зывать/приказа́ть, веле́ть нака́зывать па́лкой

таякла|у *перех.* **1.** бить, нака́зывать/наказа́ть || битьё, нака́зывание па́лкой, ро́згой **2.** *в знач. нареч.* **таяклап** в едини́цах са́же́ней (*о мере земли*); **~п үлчәү** измеря́ть (зе́млю) са́же́нями ◊ **~п куу** прогоня́ть/прогна́ть па́лкой; прогна́ть си́лой

таяклашу *взаимно-совм. от* **таяклау** **1.** бить друг дру́га па́лкой **2.** би́ться, дра́ться па́лками (*на палках*)

таяклы *прил.* **1.** 1) с па́лкой (тро́стью, по́сохом); *~ кеше* челове́к с па́лкой 2) снабжённый дета́лью в ви́де па́лки, па́лочки; па́льчатый; *~ тәгәрмәч* колесо́ с (*поперечными*) па́лочками **2.** в ви́де па́лки, па́лочки, па́лочкой; па́лочный; *~ морожный* моро́женое на па́лочке; *~ кәнфит* конфе́та с па́лочкой

таяклык *прил.* **1.** *редко* приго́дный для изготовле́ния па́лки; *~ тал* ве́рба, приго́дная для изготовле́ния па́лки **2.** *ист.* в разме́ре определённого коли́чества земли́; *ун ~ җир* земля́ разме́ром в де́сять са́же́ней ширино́й (*при длине 80 саженей*)

таякчы *сущ.* поводы́рь; *сукырның ~сы* поводы́рь слепо́го

таякчы|к *сущ. в разн. знач.* па́лочка; *Кох ~гы* па́лочки Ко́ха (*вид бацилл*)

таян *сущ. диал.* **1.** опо́ра, помо́щник, подде́рживающий; *шаян булсын, наян булсын, ата-анасына ~ булсын* (*пожелание новорождённому*) пусть бу́дет шу́стрым, пусть бу́дет лука́вым, то́лько пусть бу́дет опо́рой роди́телям **2.** *см.* **таянчык**

таянгыч *сущ.* пери́ла, подпо́рка, подлоко́тник || *прил.* опо́рный, слу́жащий опо́рой, подпо́ркой; *~ такта* опо́рная доска́ (дощечка)

таяндыр|у *понуд. от* **таяну** **1.** заставля́ть/заста́вить опере́ться *на кого* **2.** позволя́ть/позво́лить опере́ться/опира́ться; *мин таянган кулбашына ятларны ~ма* (*песня*) не позволя́й други́м каса́ться плеч твои́х, кото́рых каса́лся то́лько я

таян|у *неперех. прям. и перен.* опира́ться/опере́ться || опо́ра *на...*; облока́чиваться/облокоти́ться *на...*; *фәнгә ~ып эш итү* де́йствовать, опира́ясь на нау́ку; *атасына ~а* опира́ясь на отца́ (*т. е. пользуется поддержкой отца*) □ **~ып тору** стоя́ть, опира́ясь и́ли облокоти́вшись *на что*

таянчык *сущ. этногр.* **1.** таянчы́к (*рогатый скот, скотина, на которую опирается невеста, когда слезает со свадебного экипажа перед крыльцом дома жениха — эта скотина отныне считается собственностью новобрачной*) **2.** таянчы́к (*скот в составе приданого или калыма*)

таяныч *сущ. прям., перен.* опо́ра; опло́т; *~ ноктасы* то́чка опо́ры; *~ мәйданы* пло́щадь опо́ры; *ил ~ы ир булыр* мужчи́на есть опо́ра отчи́зны || *прил.* име́ющий опо́ру, подде́ржку; *~ кеше* име́ющий подде́ржку (*со стороны*) челове́к

таянычсыз *нареч., прил.* **1.** без опо́ры || безопо́рный (без подде́ржки) **2.** без защи́ты || беззащи́тный; *~ яшәү* жить без защи́ты; *~ хәлдә* в беспо́мощном (беззащи́тном) положе́нии

таянычсызлык *сущ. перен.* безопо́рность; беззащи́тность

таянышу **1.** *взаимн.* опира́ться друг на дру́га **2.** *совм.* опира́ться (*о многих*)

таяту *понуд. от* **таяу** II; заставля́ть/заста́вить, подпира́ть/подпере́ть

таяу I *сущ. разг.* **1.** подпо́рка, опо́ра, крепь **2.** *перен. см.* **таяныч**; *ир бала — ата-анага ~* сын — опо́ра для роди́телей

таяу II *перех. редко* подпира́ть/подпере́ть (*снизу*)

таяулык *сущ.* материа́л, приго́дный для подпо́рки

тә *частица усил. см.* **та**

тәәссеф I *сущ. уст. книжн.* **1.** скорбь, печа́ль, сожале́ние; *~кә бирелү* предава́ться ско́рби **2.** ско́рбный слу́чай

тәәссеф II *межд.* увы́; *йөз кат ~* стокра́тно увы́ □ **~ итү** горева́ть, печа́литься, скорбе́ть; **~кә каршы** *см.* **кызганычка каршы**

тәәссефле *прил.* ско́рбный; траги́ческий; *~ улем* траги́ческая смерть

тәбарәк *сущ. рел.* аллилу́йя, гро́мкое восхвале́ние бо́га; *~ сүрәсе* су́ра восхвале́ния □ **~ әйтү** **1.** гро́мко чита́ть су́ру восхвале́ния **2.** гро́мко (хо́ром) восхваля́ть бо́га

тәбә *сущ. кул.* яи́чница; *~ куыру* жа́рить яи́чницу; гото́вить яи́чницу □ **~сен чәчү** испо́ртить настрое́ние *кому;* устро́ить ба́ню (*букв.* разбры́згивать яи́чницу)

тәбәга *сущ. собир. уст.* по́дданные, верноподданные; *~ булу* быть верноподданным

тәбәка *сущ. уст.* сосло́вие

тәбәл *сущ.* ло́пасть седла́

тәбәлдерек *сущ.* **1.** 1) педа́ль, подно́жки станка́ 2) педа́ль в автомоби́ле, тра́кторе и т. п. маши́нах **2.** ступе́нька для подъёма *на что-л.* (*на тарантас, пролётку*) **3.** *диал.* кре́пкая верёвочная пе́тля́ (*приспособленная для захватывания*); па́лочка-чека́ (*связанная к концу верёвки, аркана*)

тәбәнәгәю *неперех. см.* **тәбәнәкләну**

тәбәнәк *прил.* **1.** 1) ни́зкий, ни́зенький; *~ өй* ни́зенький до́мик; *~ урындык* ни́зкое сиде́нье 2) невысо́кий; *~ яр* невысо́кий (*низкий*) бе́рег **2.** низкоро́слый; невысо́кий, коро́ткий; *~ ат* низкоро́слая ло́шадь; *~ кеше* невысо́кий челове́к

тәбәнәкләну *неперех.* понижа́ться/пони́зиться, снижа́ться || понижа́ние, снижа́ние (*только в конкретном знач.*); *яр ~де* бе́рег стал ни́же (пони́зился)

тәбәнәкле|к *сущ.* низкоро́слость; призе́мистость; *атның ~ге* низкоро́слость ло́шади; *өйнең ~ге* призе́мистость до́ма

тәбәнчә, тәбәнчәк *прил. диал. см.* **тәбәшәк**

тәбәссем *сущ. книжн.* **1.** улы́бка, ухмы́лка, ехи́дство; *см. тж.* **җемием**; *йөзендә ~* на его́ лице́ ухмы́лка (усме́шка); *мыскыллы ~* издева́тельская усме́шка **2.** иро́ния □ **~ кылу (итү)** **1.** усмеха́ться/усмехну́ться; ухмыля́ться/ухмыльну́ться **2.** иронически осме́ивать/осмея́ть

тәбәссемле *прил. книжн.* **1.** издева́тельский, ехи́дный; *~ елмаю* ехи́дная усме́шка **2.** иронический

тәбәшәк *прил. диал.* **1.** уплощённо-ни́зкий; полого-ни́зкий; ни́зенький; *~ таулар* уплощённо-ни́зкие го́ры

2. призе́мистый; ни́зенький (*и толстенький*); ~ *кыз* призе́мистая де́вушка **3.** *см.* **тәбәнәк**

тәбәшәкләнү *неперех.* **1.** поло́го понижа́ться; *калкулык ~ә башлады* возвы́шенность ста́ла понижа́ться **2.** станови́ться/стать призе́мистым, ни́зеньким

тәбәшәклек *сущ. диал.* ни́зкость; пони́женность; призе́мистость; *тауларның ~ге* пони́женность гор

тәбе *сущ.* **1.** лову́шка, капка́нчик (*для ловли грызунов*); *тычканга ~ кую* ста́вить лову́шку на мыше́й; *~ җиме* прима́нка в лову́шке **2.** *перен.* лову́шка; *~гә эләгү* попа́сть в лову́шку **3.** *диал.* одна́ из фигу́р в игре́ в ба́бки, городки́ и т. п. (*состоящая из фишек, поставленных одна на другую*)

тәбер *мест. указ. диал.* ещё оди́н; оди́н из ря́да

тәберлек, тәбәрлек *сущ. диал.* о́берег, амуле́т (*в виде нитки или шнурка из савана долго прожившей старухи*)

тәберсен *сущ. этногр.* **1.** 1) коллекти́вный тост, коллекти́вное ритуа́льное распи́тие напи́тков 2) языческая моли́тва (исполня́емая хо́ром) **2.** поми́нки (*на кладбище*); моле́ние в честь пре́дков □ **~ итү (кылу) 1.** помина́ть || поминове́ние пре́дков; устра́ивать || устро́йство поми́нок **2.** моли́ться (*перед едой и после еды*)

тәбикмәк *сущ. кул.* **1.** лепёшка (*из кислого теста*); *~ пешерү* печь (испека́ть) лепёшки **2.** *см.* **кыстыбый**

тәбикмәкле *прил.* с лепёшкой; *~ табын* стол с лепёшками

тәбия *сущ. кул.* **1.** *см.* **тәбә 2.** лепёшка из просе́янной муки́ ◊ **~ тансыгы 1.** гость некста́ти **2.** гость — ребёнок (*мальчик или девочка*)

тәбрик *сущ.* поздравле́ние; *~ сүзе* поздрави́тельное сло́во □ **~ итү (кылу)** поздравля́ть, приноси́ть поздравле́ние; *чын күңелдән ~ итәм* поздравля́ю от всей души́; и́скренне поздравля́ю

тәбрикләү *перех.* **1.** поздравля́ть/поздра́вить; приве́тствовать, че́ствовать || поздравле́ние; *~әүләр яуды* завали́ли поздравле́ниями; поздравле́ний бы́ло мно́го **2.** *перен.* горячо́ одобря́ть; *яңа инициативаны ~ибез* одобря́ем но́вую инициати́ву

тәваф *сущ. уст. книжн.* религио́зное турне́; посеще́ние всех святы́х мест; *~ка китү* отпра́виться в святы́е места́ □ **~ итү (кылу) 1.** побыва́ть в святы́х места́х, соверша́ть/соверши́ть турне́ в святы́е места́ (*по святым местам*) **2.** *перен.* дли́тельное вре́мя уни́женно ухаживать; воздыха́ть, преклоня́ться (*перед возлюбленной, возлюбленным*)

тәвә *сущ. уст. см.* **дөя**; *~ләр төркеме* верени́ца верблю́дов □ **~ кошы** стра́ус; *~ кошы кебек башын комга ящерү* пря́тать го́лову в песо́к (*как страус*)

тәвәкәч *сущ.* **1.** *ист.* погоны́щик верблю́дов **2.** *этногр. диал.* ма́льчик на побегу́шках (*на свадьбе*)

тәвәккәл *прил.* **1.** 1) риско́вый, скло́нный идти́ на риск (*о человеке и т. п.*); *~ егет* риско́вый мо́лодец 2) бесшаба́шный; *бик ~ кеше* дово́льно бесшаба́шный челове́к 3) отча́янный, реши́тельный; сме́лый; *~ таш ярыр* сме́лый города́ берёт (*букв.* раско́лет и ка́мни) **2.** риско́ванный (*о деле, предприятии и т. п.*); *~ эш бу* э́то риско́ванное де́ло **3.** *уст.* у́харский; щеголева́тый; *~ егет* бра́вый мо́лодец || *нареч.* **1.** риско́во; риско́ванно; *~ кылану* вести́ себя́ риско́во **2.** *уст.* бра́во, у́харски, щеголева́то; *~ киену* у́харски одева́ться || *сущ. книжн. см.* **тәвәккәллек**; *~гә бару* идти́ на риск □ **~ бүрек** вид национа́льной ша́пки без нау́шников (*букв.* у́харская ша́пка); **~ итү (кылу)** *см.* **тәвәккәлләнү**

тәвәккәллән|ү *неперех.* **1.** преиспо́лняться/преиспо́лниться реши́мости, гото́вности пойти́ на риск; *~еп юлга чыктым* преиспо́лненный реши́мости, я отпра́вился в путь **2.** *см.* **тәвәккәлләү**

тәвәккәлл|әү *неперех.* **1.** 1) реша́ться/реши́ться (*на дело, связанное с риском*); *ни булса шул булыр дип ~әү* реши́ться *на что-л.*, будь что бу́дет 2) проявля́ть/прояви́ть реши́тельность, риско́ванность, риск; *~әгән тау кичкән, уйлаган уйда үлгән* (*посл.*) прояви́вший риско́ванность одоле́л го́ру, сомнева́вшийся у́мер в доли́не **2.** *уст.* дове́риться *кому* (*богу*); *аллага ~әп* дове́рившись бо́гу **3.** *в знач. модальн. сл.* **тәвәккәллик (тәвәккәлләдек)** решено́ (и подпи́сано); *әйдә, ~ик* решено́ — присту́пим (начнём)

тәвәккәлле *прил. прост.* **1.** риско́вый, скло́нный рискова́ть; *~ кеше генә барса барыр бу эшкә* то́лько риско́вый челове́к пойдёт на э́то де́ло **2.** риско́ванный; *~ кәсеп* риско́ванное ремесло́

тәвәккәлле|к *сущ.* **1.** реши́мость, реши́тельность, сме́лость; *~ге белән билгеле* изве́стный свое́й реши́мостью **2.** риск, риско́ванность; *~ккә баглы* свя́зано с ри́ском

тәвәккәлсез *прил.* нереши́тельный, не скло́нный рискова́ть

тәвәккәлсезлек *сущ.* **1.** нереши́тельность **2.** боя́знь ри́ска; осмотри́тельность

тәвәккәлче *сущ. разг.* бесшаба́шная голова́; отча́янно сме́лый челове́к; *~ үлемнән көлгән* (*посл.*) бесшаба́шная голова́ смея́лась над сме́ртью

тәвәккәлчелек *сущ.* риск, реши́мость; *~не тәңре хуплый* риск — благоро́дное де́ло (*букв.* — риск одобря́ет сам бог) □ **~ итү** реша́ться/реши́ться *на что-л.* риско́ванное

тәвәч *сущ. диал. см.* **тигәч**

тәвәче *сущ. ист. см.* **дөяче**; *~ белән курше булсаң, капкаң биек булсын* (*посл.*) е́сли у тебя́ сосе́д — верблюдово́д, пусть твои́ воро́та бу́дут высо́кими

тәвер I *прил. диал.* **1.** простоду́шный, легкове́рный; простова́тый; *~ генә кеше инде ул* он — простова́тый, легкове́рный челове́к **2.** суеве́рный; *~ хатын* суеве́рная же́нщина

тәвер II *сущ. диал.* **1.** дух, настро́й челове́ка **2.** о́браз (*мысленный, воображаемый*); *синең ~еңне күрәм* ви́жу твой о́браз (*в мыслях*)

тәверлән|ү *неперех. диал.* **1.** счита́ть, вообража́ть себя́ не тем, кем челове́к явля́ется (*вид душевной болезни*) **2.** име́ть, заиме́ть в себе́ не́кий дух; чуди́ть; *~дең мәллә?* ты что чуди́шь?

тәверле *прил. диал.* 1) нося́щий в себе́ ду́ха 2) блаже́нный; *~ карчык* блаже́нная стару́шка

тәгаен I *нареч.* **1.** допо́длинно; в то́чности; определённо; *~ белмим* допо́длинно не зна́ю; *~ әйтергә кирәк* на́до сказа́ть определённо **2.** несомне́нно, обяза́тельно; *~ авачак бу йөген* э́тот твой воз обяза́тельно (непреме́нно) опроки́нется || *прил. см.* **тәгаенле**; *бу эшкә ~ кеше* определённый на э́то де́ло челове́к

тәгаен II *вводн. сл. см.* **мөгаен**; *ул, ~, килгәндер* он, наве́рное, пришёл || *сущ.* **1.** *разг.* пра́вда, допо́длинно, надёжное, прове́ренное утвержде́ние (да́нное); *~ен генә әйт* сообщи́ то́лько прове́ренное, то́чно изве́стное; *~е — илле сум* то́чная (цена́) — пятьдеся́т рубле́й **2.** *уст.* назначе́ние; *аның ~е көнендә* в день его́ назначе́ния □ **~ итү (кылу) 1.** *см.* **тәгаенләү**; определя́ть, назнача́ть (*на должность и т. п.*) **2.** поруча́ть (*дело*)

тәгаенләнү *страд, от* **тәгаенләү;** *-гән пенсия* назначенная пенсия; *бу вазифага -гән* (он) назначен на эту должность (на это дело)

тәгаенләтү *перех.* уточнять/уточнить ‖ уточнение; *шартларны ~еп яздыру* заставить записать, уточнив условия

тәгаенләү *перех.* **1.** назначать/назначить ‖ назначение; *пенсия -әү* назначение пенсии **2.** определять/.определить ‖ определение; *кем икәнен ~и алмадым* кто он такбй — я не смог определить **3.** поручать/поручить, возложить ‖ поручение; возложение; *утын яруны аңар -әдек* колку дров поручили ему

тәгаенле *прил.* **1.** определённый, назначенный (на пост, на выполнение *чего); - кеше* назначенный человек **2. 1)** верный, гарантированный; доподлинно ожидаемый; запрограммированный 2) назначенный; *~ сәгатьтә* в назначенный час **3.** урочный, уделённый с определённым сроком; *~ көннәр тиз үтә* урочные (считанные) дни проходят быстро

тәгаенлек *сущ. 1.* определённость, точность; *бу билгеләмәдә - юк* в этом определении нет точности **2.** обязательность *(проявления закона, явления)*

тәгаенлеле|к *сущ.* **1.** назначенность; урбчность; *вакытның ~ге* назначенность времени **2.** определённость, точность; гарантйрованность; *бу эштә ~к зарур* в этом деле необходима гарантйрованность

тәгаҗҗеп *сущ. уст.* удивление, состояние удивления; *- белән* с удивлением ‖ *вводн. межд.* удивительно, странно; поразительно *(что)* • **~ итү (кылу)** удивляться/удивиться, дивиться; *бу хәлгә - иттем* я удивился этому положению

тәгалә *прил. уст. рел.* всевышний; *тәңре* - всевышний, бог; *я,* - о, всевышний!

тәгам|ь *сущ. книжн. 1.* пища, еда; трапеза; *~е балшикәр* его пищу составляют мёд и сахар; *алдына килгән ~ьне дә ашый белергә кирәк* и пйщу, что ужё поставлена перед тобой, надо уметь есть **2.** питание; *балалар ~е* детское питание

тәгамьләнү *возвр. от* **тәгамьләү** *книжн.* **1.** есть, трапезничать, принимать пйщу **2.** питаться; *сөтле аш белән* - питаться молочным супом

тәгамьләү *перех.* съесть, употреблять/употребить ‖ употребление в пйщу; *ерткыч корбанын ~әде* хищник съел свою жертву

тәгамле *прил.* с *(различной)* снедью; имеющий *(много)* съестного *(на выбор); - кеше дә ач тора, ди* говорят, *(иногда)* голодает и человек с припасами

тәгамьлек *сущ. книжн.* съестное, снедь; *төрле -ләребез бар* много у нас различной (всякой) снёди

тәгамьлекле *прил.* питательный; *- ризык* питательная пища

тәганә *сущ.* **1.** позор, позорище; *адәм ~се* позор рода человеческого; отверженный, отщепенец **2.** упрёк, попрёк; претензия; *см. тж.* **тәгънә**

тәганәле *прил. уст.* **1.** критичный, неодобрительный **2.** полный нападок (о *выступлении)*

тәгассып *сущ. уст. книжн.* **1.** фанатизм, нетерпимость; воинственное невежество, мракобесие **2.** реакция • **- итү** проявлять нетерпимость

тәгассыплы *прил. уст. книжн.* невежественный, фанатичный; *~ кеше юлдан язып* фанатичный человек (легко) сбивается с пути

тәгәр *сущ. диал.* колесико; колесо *(детской тележки);* ролик; *-ләре әйләнә* колесики крутятся

тәгәрәтелү *страд, от* **тәгәрәтү**

тәгәрәтү *перех.* **1.** катить, покатить **2.** вывалять *(что-л. круглое)* **3.** свалить, пустить под откос **4.** прокатить на выборах 0 **~еп җибәрү (төшерү)** покатить, скатить, пустить кубарем *(вниз)* **~еп кертү** вкатить, закатить; **~еп китерү** подкатить, прикатить *к чему-л.;* **~еп чыгару** выкатывать/выкатить; **О ~еп кенә тора** так и выдаёт одно за другим *(детей, стихов);* **~кән бәрәңге** картошка, жаренная в печй

тәгәр|әү *неперех.* **1.1)** катиться; *алгы көпчәк кая ~әсә, арткысы шунда ~и (поел.)* куда катятся передние колёса, туда и задние 2) двигаться, передвигаться ‖ передвижение (о *круглых предметах, если даже они не способны, вращаться); кояш тубәнгә ~и* солнце движется вниз **2.** *неперех.* катить (о *предметах с колёсами); тигез юлдан -әгән машина* машина, катившая по ровной дороге **3.** идти вперёд; *тормышыбыз иске эздән ~и* жизнь наша идёт по проложенной колее; *эшләр ~и инде* дела же двигаются своим чередом **4.** *перен. грубо-прост.* улепётывать, катиться ‖ улепётывание; *~ә моннан* катись (улепётывай) отсюда **5.** *в разн. знач.* перекатываться; *түбәнгә таба ~и* перекатывается вниз; *дулкынлар басма өстеннән ~и* волны перекатываются через мостки **6.** *перен.* **1)** с размахом лечь/возлечь; *урын җиргә ~әү* грохнуться на постель 2) лежать, возлежать, валяться ‖ возлежание; *шунда бүрәнәләр -әгән* тут же валяются брёвна **7.** *перен. разг.* падать/упасть, грохнуться ‖ падение; *бер сугу белән ~әде* одного удара хватило — грохнулся **8.** *перен. грубо-прост,* умереть, околеть, отдать богу душу; отдать концы; *ачка ~әү* умереть с голоду **9.** *перен. разг.* уснуть (о *детях)* **10.** *перен. разг.* прокатываться/прокатиться *(на выборах);* свергнуться; *-әячәген сизеп торды* чувствовал, что его прокатят *(на выборах) 11. перен. разг.* скатываться, скатиться назад *(на менее почётные места, позиции и т. п.); утызынчы урынга -әү* скатываться на тридцатое место 0 **~әп китү 1.** *в разн. знач.* покатываться/покатиться **2.** *перен.* помирать; **~әп төшү** скатываться/скатиться; **-әп яту** валяться *(под ногами)* **О -әгәнче ашау (тыгыну)** есть до отвала; **-әгәнче көлү** смеяться до упаду; **~әп кату** *груб,* околеть; *урыныңда -әп кат!* сгинь на месте! **~әп кенә бару** быть на мази *(о делах);* **-әп китим (менә)** с места не сойти *(букв,* пусть грохнусь на месте — *формула клятвы)*

тәгәрәшү *взаимно-совм. от* **тәгәрәү** *(о многих); төрлесе төрле җирдә ~еп яталар* валяются вразброс в разных местах

тәгәри, тәгәрәй *сущ. бот. разг.* перекати-поле; *см. тж.* **камгак • ~ үләне** *см.* **тәгәри**

тәгәрләү *неперех. диал. 1.* кататься/катиться (кубарем); *~п елау* плакать, катаясь (валяясь) на земле **2.** кататься, покататься *на чём*

тәгәрмәч *сущ. 1. в разн. знач.* колесо, колесико; *арба ~е* колесо телёги; *арт ~* заднее колесо; *~ тугымы* обойма колеса; *тешле -* зубчатое колесб; *руль ~е* рулевое колесо **2.** *редко* круг; кружок; *сыр ~е* круг сыра; *ай ~е* круг луны

тәгәрмәчле *прил. 1.* колёсный; *~ транспорт* колёсный транспорт **2.** *редко* в виде круга; *~ сыр* сыр в кругах

тәгъбир *сущ. книжн. 1. лингв.* **1)** выражение; *телгә яңа ~ләр керә* в язык внедряются новые выражения 2) *уст. мат.* выражение **2. 1)** догадка, гипотеза, предположение; *минем -емчә* по моему предположению

2) концéпция, рассуждéние, теóрия; истолкóвывание **3.** смысл, толковáние (*сна*); разгáдка (*загадки*); *төшнең ~е* толковáние сна **4.** чáстное определéние (*решение помимо приговора*) □ **~ итү (кылу) 1.** предполагáть, полагáть **2.** толковáть (*сон*); разгадáть загáдку

тәгъбирл|әү *перех. книжн.* **1.** выражáть/выразить ‖ выражéние (*мысли*); *үз фикереңне ачык ~әү* выражáть свои́ мы́сли чётко **2.** 1) стáвить диáгноз; дéлать предположéние, попы́тку объяснúть *что* 2) *(дип) ~әү* определя́ть/определи́ть *как* (*по-своему*); комменти́ровать, прокомменти́ровать; *шулай ~и* комменти́рует так □ **~әп бирү** толковáть, объясня́ть (*по-своему*) *что-л.*

тәгъбирнамә *сущ. книжн.* **1.** сóнник, толковáтель снов (*книга*) **2.** гипóтеза, толковáние *чего-л.* (*в письменном виде*)

тәгъбирче *сущ. книжн.* толковáтель, предсказáтель; теорéтик, мудрéц

тәгъбирчелек *сущ. книжн.* толковáние, предсказáние

тәгъзир *сущ. уст. юр.* **1.** простýпок, преступлéние трéтьей категóрии (*после хат и кыйсас*), наказýемое обы́чно штрáфом и́ли вы́говором **2.** *перен.* штраф; вы́говор

тәгъзирнамә *сущ. уст. юр.* гражда́нский (неуголóвный) кóдекс; кни́га штрáфов

тәгъзил *сущ. книжн. уст.* некрóлóг

тәгъзыйм|ь *сущ. уст.* **1.** уважéние, окáзывание пóчестей, засвидéтельствование почтéния; *~ белән* почти́тельно, с (глубóким) уважéнием **2.** низкопоклóнство; преклонéние □ **~ итү (кылу) 1.** окáзывать/оказáть уважéние; величáть **2.** яви́ться с поклóном, на поклóн (*к заезжему гостю, знатному лицу*)

тәгъзыймле *прил. книжн.* **1.** уважи́тельный, преиспóлненный уважéния; *~ сәлам* преиспóлненное уважéнием привéтствие **2.** достóйный уважéния, почитáния; высокочти́мый; *~ хәзрәт* высокочти́мый хезрéт **3.** 1) уважáющий, почитáющий (*достойных*) 2) угóдливый, рабóлепный

тәгълим *сущ. книжн.* **1.** обучéние, преподавáние; *~ вә тәрбия* обучéние и воспитáние **2.** воéнная подготóвка; воéнные учéния □ **~ кылу (итү)** обучáть, внедря́ть знáния (*в сознание учащихся*)

тәгълимат *сущ.* учéние, доктри́на; *Маркс ~ы* учéние Мáркса

тәгълиматчы *сущ. ирон. редко* теорéтик, основáтель нóвого учéния

тәгълими *прил.* познавáтельный; *~ әһәмият* познавáтельное значéние

тәгълыйк *сущ. книжн.* тáлик, манéра писáть арáбскими бýквами (*характеризуется «висячими» буквами — конец слов как бы понижается*); *~ белән язу* писáть спóсобом тáлик

тәгънә *сущ. диал. разг.* упрёк; попрёк; недовóльство; претéнзия; *мәгънәсе булмаса, ~се була* éсли от человéка тóлку мáло, то претéнзий мнóго ◊ **~ ору** жестóко критикováть

тәгъриф *сущ.* **1.** *книжн.* 1) описáние; представлéние; детáльное объяснéние 2) вклáдыш к товáру **2.** *уст.* характери́стика; определéние; *«милләткә» ~ биру* давáть определéние понáтию «нáция» **3.** тари́ф; стáвка □ **~ итү (кылу) 1.** представля́ть/предстáвить; *ул ипташен ~ итте* он предстáвил товáрища **2.** определя́ть/определи́ть **3.** выражáть/вы́разить

тәгърифле *прил. книжн.* **1.** 1) с описáнием, с характери́стикой; *~ товар* товáр с описáнием (*со вкладышем-характеристикой*) 2) прóзванный; называ́емый *кем;* изве́стный *как кто; изге ~* прóзванный свя́тым; изве́стный как свя́той **2.** выразúтельный; тóчный и пóлный (*о характеристике*); *~ сүзләр* выразúтельные словá **3.** твёрдо определённый (*об уплате за что-л.*); тари́фный

тәгътил *сущ. уст.* кани́кулы (*у учащихся медресе*); *~гә кайту* возвращáться (домóй) на кани́кулы

тәдбир *сущ. книжн. уст.* **1.** мéра, дея́ние; мероприя́тие; дéйствие, дéятельность; инициати́ва; *акылы вә ~е илә* свои́м умóм и дéятельностью **2.** предусмотри́тельность, мéра предостороóжности □ **~ итү (кылу)** принимáть мéры; дéлать попы́тки

тәдбирле *прил. книжн. уст.* **1.** дéятельный, инициати́вный; дéльный, деловóй; делови́тый; *бик ~ кеше* óчень деловóй человéк **2.** предусмотри́тельный; *~гә тәдбир!* хвалá предусмотри́тельному!

тәдбирсез *прил. книжн. уст.* **1.** бездéятельный, безынициати́вный **2.** непредусмотри́тельный, беспéчный ‖ *нареч.* вя́ло; беспéчно; *~ кылану* вести́ себя́ беспéчно

тәҗәссем: тәҗәссем итү *уст. книжн.* **1.** предстáвить ‖ представлéние (*себе*) **2.** воплоти́ть ‖ воплощéние в óбразе

тәҗвит, тәҗвит *сущ.* **1.** 1) *уст.* орфоэ́пия 2) орфоэ́пия Кора́на; в осóбенности знáние прáвил чтéния Кора́на; *~е дөрес* егó чтéние кора́на (по орфоэ́пии) прáвильно **2.** чтéние Кора́на в мéсяц Рамазáн **3.** *перен.* подрóбные прáвила; *ул җир сөрүнең бөтен ~ен белә* он знáет все прáвила вспáшки земли́; по чáсти вспáшки он — спец ◊ **~ен укыган** знáет всё (*в какой-л. области*)

тәҗвитләп *нареч.* **1.** прáвильно, соблюдáя все прáвила орфоэ́пии (Кора́на); *~ укыды* читáл (Кора́н) по всем прáвилам **2.** *перен.* соблюдáя все прáвила, предписáния, устáвы *в чём-л.;* на ять

тәҗвитче *сущ.* **1.** специали́ст по орфоэ́пии (*Корана*) **2.** 1) *редко перен.* пунктуáльный прогресси́ст, пунктуáльный сторóнник улучшéний, испрáвленный *в какой-л. области* 2) педáнт **3.** чтец Кора́на в мéсяц Рамазáн

тәҗе *сущ.* тяж (телéги); *~ тарттыру* натя́гивать тяж □ **~ бавы** *см.* **тәҗе; ~ бавын өзү** оборвáть постромки́ отцá невéсты (*на свадьбе в знак того, что его дочь оказалась не девственницей*)

тәҗел *прил. диал.* спéшный; безотлагáтельный; óчень нýжный; *~ эш* срóчное и óчень нýжное дéло ‖ *нареч.* срóчно, спéшно; к спéху, безотлагáтельно; *~ генә барасы җир* мéсто, кудá нáдо срóчно прибы́ть (поéхать)

тәҗелл|ә *перех.* си́льно торопи́ть; *~мә әле* сли́шком не торопи́; *~п куа башлады* нáчал гнать со всех сил

тәҗрибә *сущ.* **1.** *в разн. знач.* óпыт ‖ óпытный; *эш ~се* óпыт рабóты; *шәхси ~* ли́чный óпыт; *тормыш ~се* жи́зненный óпыт; *беренче ~* пéрвый óпыт; *химик ~ләр* химúческие óпыты; *~ станциясе* óпытная стáнция; *~ ясау (үткәрү)* проводи́ть, провести́ óпыт (óпыты) **2.** *редко* прáктика; *~гә кертү* вводи́ть, ввести́ в прáктику □ **~ итү (кылу) 1.** испы́тывать/испытáть, проводи́ть испытáния, пóиски **2.** рассмáтривать как примéр, как óпыт *чего-л.* □ **~ күрсәткәнчә** как покáзывает óпыт; **~дән чыгып** исходя́ из óпыта

тәҗрибәл|әү *неперех.* прики́дывать/прики́нуть, раски́дывать/раски́нуть, пораски́нуть умóм (*сравнивая, наблюдая*); *~әп караганда* éсли внимáтельно посмотрéть; éсли хорошéнько пораски́нуть умóм

тәҗрибәле *прил.* 1) óпытный (*человек*); *~ остa* óпытный мáстер 2) намётанный (*о глазе, руке*)

тәҗрибәлек *прил.* **1.** óпытный, предназнáченный для óпытов; *~ үрнәкләр* óпытные óбразцы́ **2.** подóпытный

тәҗрибәлеле|к *сущ.* о́пытность; о́пыт (*как качество личности*); *~ге бар* о́пыт у него́ есть

тәҗрибәсез *прил.* небо́пытный; малоо́пытный; *мин бу эштә ~мен* я в э́том де́ле небо́пытен

тәҗрибәсезле|к *сущ.* небо́пытность, малоо́пытность; *~ге белән* по небо́пытности; *бу кимчелек — ~ктән* э́тот недоста́ток из-за небо́пытности (по небо́пытности)

тәҗрибәче *сущ.* эксперимента́тор, о́пытник; *колхоз ~ләре* колхо́зные о́пытники

тәҗрибәчел *прил.* **1.** о́пытный; наблюда́тельный **2.** скло́нный эксперименти́ровать **3.** эксперимента́торский; *~ фикер* эксперимента́торская иде́я

тәҗрибәчелек *сущ.* эксперимента́торство || эксперимента́торский; *~ дәрте* эксперимента́торский пыл

тәзкирә *сущ. книжн.* **1.** па́мять *о ком, о чём* **2.** вещь на па́мять; *әнием ~се* вещь, оста́вшаяся от ма́тери (*в память о ней*)

тәй *сущ. уст.* **1.** одна́ из сторо́н хурджи́на (*перемётной сумы, двусторонней поклажи*) **2.** вес, противове́с; *тәй асу* ве́шать противове́с **3.** дополни́тельная ги́ря; ма́ленькая (дро́бная) ги́ря; *тәе дә бар* есть и своя́ ги́рька

тәйән I *частица утверд. диал.* соверше́нно; точь-в-то́чь; *см. тж.* **гел**; *~ дөрес* соверше́нно пра́вильно

тәйән II *нареч.* всегда́, постоя́нно; *~ бергә булмабыз* не всегда́ бу́дем вме́сте

тәйгә-тәй *сущ.* **1.** уравне́ние (*в шансах; выигрыше*); ничья́ **2.** кви́ты; *тәйгә-тәй килде инде* вот и кви́ты

тәйкә *сущ. диал.* **1.** а́льчик (*налитый свинцом*) **2.** одна́ из сторо́н а́льчика

тәйәр *см.* **тайяр**

тәк I *межд. разг.* так; так зна́чит; *тәк, тәк* так, так; ага́; ве́рно; *«тәк»,— дип әйтте ди бер тәкә башы, казанга кергәч* (*погов.*) по́здно щу́ке на сковороде́ вспомина́ть о воде́ (*букв.* «так»,— сказа́ла бара́нья голова́, очути́вшись в котле́)

тәк II *нареч. см.* **тик**; *тәк йөрү* безде́льничать; *тәк торганда* ни с того́ ни с сего́

тәкат|ь *сущ.* **1.** терпе́ние, вы́держка; самооблада́ние, душе́вная выно́сливость (*в противостоянии напасти*); *хәл дә, ~ь тә калмады* не оста́лось ни сил, ни терпе́ния **2.** жи́зненные си́лы, здоро́вье; *картайдым хәзер, ~ь бетте* тепе́рь я постаре́л, жи́зненные си́лы на исхо́де ◻ **аның ~е китте** его́ терпе́ние ло́пнуло; **~еннән килү** име́ть доста́точно сил (*о ком-л. обозначенном формами принадлежности*); **~ь итү (кылу)** вы́терпеть, дотерпе́ть, стерпе́ть; **~ь китерү** призва́ть на по́мощь всё своё терпе́ние; **~ь кору (китү)** теря́ть, потеря́ть терпе́ние; ло́пнуть (*о терпении*); **~ь корыту 1.** постепе́нно надоеда́ть/надое́сть; жа́рить на ме́дленном огне́ **2.** доводи́ть/довести́ до кра́йностей; **~ь тоту** (уси́лием во́ли) вы́терпеть, стерпе́ть; *~ь тота алмадым* я не смог вы́терпеть; **~ькә тию** надоеда́ть/надое́сть до преде́ла; доводи́ть/довести́ до взры́ва, ре́зкостей; **~ьтән тыш** сверх сил; **~ьтән язу** потеря́ть терпе́ние, лиши́ться самооблада́ния

тәкатьле *прил.* терпели́вый, выно́сливый, вы́держанный; *~гә тау баш игән* (*посл.*) терпели́вому гора́ поклони́лась

тәкатьсез *прил.* нетерпели́вый, невыно́сливый, не выде́рживающий тру́дностей; *~нең үлеме вакытсыз* (*посл.*) смерть нетерпели́вого безвре́менна ◻ **~ булу (калу) 1.** теря́ть/потеря́ть терпе́ние (самооблада́ние) **2.** доходи́ть/дойти́ до кра́йности; быть без ума́ от... **3.** быть в восто́рге, восхище́нии, приходи́ть/прийти́ в восто́рг

тәкатьсезләндер|ү *перех.* выводи́ть/вы́вести || выведе́ние из терпе́ния; *тәмам ~де* оконча́тельно вы́вел из терпе́ния

тәкатьсезлән|ү *неперех.* **1.** потеря́ть || поте́ря мо́чи (*терпеливости, терпения*); *~еп, җиргә ауды* лиши́вшись мо́чи, упа́л на зе́млю **2.** проявля́ть/прояви́ть || проявле́ние, выража́ть/вы́разить || выраже́ние нетерпели́вости (нетерпе́ния); *~еп кычкыра* кричи́т, выража́я нетерпе́ние

тәкатьсезлек *сущ.* нетерпе́ние, не́мочь; *~тән* от нетерпе́ния (от не́мочи)

тәкә *сущ.* **1.** козёл и́ли бара́н (*с различительными словами*); *кәҗә ~се* козёл; *сарык ~се* бара́н **2. (сукыр) ~** козёл (*в игре в жмурки*) **3.** *перен. диал.* соцве́тие; сопло́дие; *суган ~се* соцве́тие (голо́вка) лу́ка **4.** *перен. кул.* рога́лик; разнови́дность бу́лочки, пирога́ (*пирог в виде рога*); *~ пешерү* печь/испе́чь рога́лики **5.** *перен. диал.* ко́злы (*деревянная подставка на ножках при ремонте телег, распилке дров и т. п.*) ◻ **~ агач** *диал. см.* **тәкә** 5; **~ борчагы** *бот.* бара́ний горо́шек; **~ маңгае** валу́н, бара́ний лоб (*камень, скала со следами движения льдов*); **~ мөгезе 1.** *бот.* до́нник (*вид травянистого растения*) **2.** *см.* **тәкә** 4. **3.** разнови́дность, элеме́нт вышива́емого узо́ра **4.** *перен. груб.* ку́киш, фи́га; *~ мөгезе күрсәтү* показа́ть фи́гу (ку́киш); **~ сакалы** *бот.* ва́йда; **~ талы** *см.* **кәҗәсакал**; **~ чана** подса́нки (*вспомогательные маленькие сани, прицепляемые к основным саням, при перевозке длинных предметов*); **~ як** орёл (*гербовая сторона монеты*)

тәкәббер *прил.* го́рдый, надме́нный, зано́счивый, спеси́вый; *~ кеше* надме́нный (спеси́вый) челове́к || *сущ. книжн.* гордыня, спесь, надме́нность ◻ **~гә (~дән) сана́у** счита́ть за гордеца́ (спеси́вого); *син мине ~гә санама* ты не счита́й меня́ за гордеца́; *күңеле ~дән ерак* его́ душа́ далека́ от гордыни

тәкәбберлән|ү *неперех.* **1.** возгорди́ться, возноси́ться, заноси́ться, станови́ться/стать го́рдым (надме́нным, спеси́вым); *~де ул* он стал го́рдым и надме́нным **2.** выка́зывать спесь (зано́счивость); *~еп йөри* (*всё время*) проявля́ет зано́счивость

тәкәбберлә́рчә *нареч.* как горде́ц (гордя́чка); гордецо́м; по-го́рдому; *~ сәлам бирү* го́рдо поздоро́ваться (по-го́рдому)

тәкәбберлек *сущ.* **1.** гордыня, спесь, надме́нность; *~ күрсәтү* выка́зывать гордыню; *биргәнне кире кагу ~ була* (*посл.*) отверга́ние (отка́з от) даро́в есть гордыня **2.** горделивость, спеси́вость; надме́нное поведе́ние; *сездә булган ~ бездә дә чирләмәгән* (*песня*) е́сли у вас есть гордыня, то и у нас она́ найдётся (*букв.* не заболе́ла)

тәкәдән *сущ. диал.* челове́к, отлы́нивающий от рабо́т (*в то время как другие работают*); *~ булып йөри* (всё вре́мя) избега́ет тяжёлой рабо́ты

тәкәлән|ү *неперех. прост.* покрыва́ться/покры́ться самцо́м (*об овцах и козах*); *~гән сарыклар* покры́тые (самцо́м) о́вцы

тәкәлә́тү *перех. прост.* дать покры́ть самцо́м, осемени́ть (*овец и коз*)

тәкәле *сущ.* вид игры́ в ко́шки-мы́шки; *~ уйнау* игра́ть в ко́шки-мы́шки

тәкәллеф *сущ.* **1.** 1) подчёркнутая ве́жливость, церемо́нность, изы́сканная любе́зность; церемо́ния; *кодаларны ~ белән каршыладылар* сва́тов встре́тили с под-

чёркнутой вéжливостью 2) любéзность, церемониáльность; *тиешле ~ саклау* блюстú необходúмую церемониáльность **2.** *прост.* дéланность, жемáнность, рисóвка (*в обращении*)

тәкәллефләнү *неперех.* церемóнничать, церемóниться, жемáнничать; *артык ~мичә* не слúшком церемóнясь; *юкка ~мәгез* не любéзничайте зря

тәкәллефле *прил.* 1) любéзный; церемóнный; *~ кыз* любéзная дéвушка 2) подчёркнуто вéжливый; манéрный; жемáнный; *~ мөнәсәбәтләр* подчёркнуто-вéжливые отношéния; *~ кыланыш* жемáнное поведéние; *~ сүзләр* манéрные выражéния; *бигрәк ~ инде* óчень уж дéланный; óчень уж манéрный || *нареч.* 1) любéзно, разлюбéзно; *~ сөйләшә* разговáривает любéзно 2) подчёркнуто вéжливо (манéрно, жемáнно); *~ генә* (по-своéму) любéзно, разлюбéзно (*но церемонно*)

тәкәллефлелек *сущ.* **1.** любéзность; церемóнность, предупредúтельность; *~ге өчен ул фәрештә дип аталган* за свою́ любéзность он получúл прóзвище «áнгел» **2.** подчёркнутая вéжливость; церемóнность; *~к курсәту* проявúть (вы́казать) подчёркнутую вéжливость

тәкәллефсез *прил.* **1.** нецеремóнный, фамилья́рный; неманéрный, простéцкий; *~ кеше инде ул* такóй уж он простéцкий человéк **2.** бесцеремóнный; не слúшком любéзный || *нареч.* бесцеремóнно; фамилья́рно, простéцки, по-простéцки; *~ сөйләшү* разговáривать без лúшних услóвностей

тәкәллефсезләнү *неперех.* **1.** становúться/стать простéцким, неманéрным, просты́м (*в обращении*) **2.** бесцеремóнничать, нахáльничать || нахáльничанье, нахáльство □ **~еп китү** становúться нахáльным (бесцеремóнным)

тәкәлефсезлек *сущ.* **1.** простотá (*в обращении*), нецеремóнность, неманéрность **2.** бесцеремóнность, грýбость (*в обращении*); нахáльство; панибрáтство

тәкәллефчел *прил.* склóнный церемóнничать, любúтель церемóнной (подчёркнутой) вéжливости; *бигрәк ~ икәнсез* вы, окáзывается, óчень уж церемóнны

тәкәллефчелек *сущ.* церемониáльность; любóвь к манéрности

тәкәмәгез I *сущ. бот.* дóнник

тәкәмәгез II *прил. диал.* (*как бараний рог*) свёрнутый спирáлью

тәкә-мәкә, тәкә-бәкә *сущ. диал. см.* **әкәм-тәкәм**; *тәкә-бәкә, мәгезеңне чыгар, сыер бирәм, ат бирәм* (*детская частушка*) улúтка-рогáч, вы́пусти рогá, я тебé корóву и лóшадь дам

тәкәрлек I *сущ. зоол.* **1.** пúгалица, чúбис (*вид птицы*); *тау башында ~, мылтык белән атарлык* (*песня*) сидúт на горé чúбис — мóжно стреля́ть из ружья́ **2.** *диал.* улúтка-рогáч □ **~ йомыркасы (күкәе) кебек** веснýшчатый, конопáтый

тәкәрлек II *сущ. диал.* **1.** ритуáльный кувырóк (*в татарском язычестве*) **2.** помúнки усóпшего; *~кә бару* идтú на помúнки (на клáдбище)

тәкбир *сущ. рел.* **1.** величáние, возвелúчивание (*бога*); *~ сүзе* слóво возвелúчивания **2.** *этногр.* обря́д, состоя́щий в повторéнии (хóром) возвелúчивающих бóга слов при определённых слýчаях, аллилýйя; *~ тавышы* голоса́, выполня́ющие обря́д пéния аллилýйи □ **~ әйтү** хóром возвелúчивать бóга при выполнéнии определённых обря́дов (*во время свадьбы, при принятии важных решений всем обществом и т. п.*); *~гә ~ уст. книжн.* по привéту и ответ; какóв привéт, такóв и ответ

тәкбирче *сущ. уст.* учáстник коллектúвного выполнéния обря́да такбúр (возвелúчивания бóга)

тәк-дерәгә *нареч. разг.* понапрáсну, почём зря; *тәк-дерәгә йөрү* почём зря ходúть (éздить)

тәкелдәвек *прил.* **1.** *см.* **тәтелдек 2.** *см.* **такылдавык**

тәкелдәү *неперех.* **1.** *см.* **тәтелдәү 2.** говорúть негрóмким гóлосом, мнóго и бы́стро, воркова́ть || воркова́ние; *~ дә туйдыра* надоедáет и воркова́ние

тәкелдек *прил. см.* **тәтелдек**

тәкел-тәкел *подр.* тúканью (*с призвуком и с нарушенной ритмичностью*)

тәкендерү *перех. прост.* **1.** *см.* **чөйлектерү 2.** перевернýть (*лодку, судно*)

тәкенү *неперех. диал.* **1.** *см.* **абыну 2.** перевернýться (*о лодке, судне*)

тәки *частица усил.* всё-таки; всё же; *~ теләгенә иреште* всё-таки добúлся своегó; *~ белә алмадым* всётаки я не смог узна́ть

тәкия *сущ. ист.* **1.** подýшка (*для сиденья знатного лица*); переносно́е лóже **2.** такия́ (*дом, покои, где дервиши или покаявшиеся лица предавались молитвам и благочестивым размышлениям*); *татарларда ~ләр булган* у татáр имéлись покóи для молéний **3.** род монастыря́; скит **4.** роскóшный склеп, мавзолéй, мéсто успокоéния; *~ кору* устрóить мавзолéй

тәккә *нареч. разг.* **1.** напрáсно, понапрáсну; почём зря; зря; *~ тырышу* зря стара́ться **2.** беспла́тно, да́ром; *~ бирү* да́ром отдава́ть

тәкле *послелог диал. см.* **тикле**

тәклем *послелог см.* **тәкле**

тәклиф *сущ. уст. книжн.* **1.** 1) деликáтное поручéние, (*церемонное, но твёрдое*) возложéние ответственности; *~не үтәү* выполня́ть деликáтное поручéние 2) предписáние, завуалúрованный прикáз; предложéние с жёстким подтéкстом **2.** приглашéние, прóсьба (*равный приказу*) □ **~ итү (кылу) 1.** поручáть/поручúть, возлагáть/возложúть ответственность; *бу эшне сезгә ~ итәм* ответственность за э́то дéло возлагáю на вас **2.** предписáть; *безгә булмас эшне ~ иттеләр* нам предписáли невыполни́мое дéло; **~ язуы** пригласúтельная запúска

тәкмәрлә́нү *неперех.* кувыркáться/кувыркнýться || кувыркáнье, кувырóк; покатúться (*при падении*); *җиргә ~дем* упáл и покатúлся по земле́ □ **~п китү** перекувыркнýться

тәкмәрләшү *взаимно-совм. от* **тәкмәрләү**

тәкмәч *сущ.* кувырóк; кувыркáнье □ **~ ату** перекувыркнýться; пáдать вверх тормáшками; перевернýться в вóздухе

тәкмәч-бәкмәч *неперех.* перекувы́ркиваться/перекувыркнýться, перевёртываться/перевернýться (*делая сальто-мортале*); *бер тапкыр җирдә тәкмәч-бәкмәч ясап алды* одúн раз перекувыркнýлся на земле́

зашúть (*края*); нашивáть/нашúть; подшивáть/подшúть **2.** 1) прикрепля́ть/прикрепúть || прикрепле́ние (*при помощи булавки, нитки и т. п.*); *бүреккә йолдыз ~ү* прикрепúть звёздочку к шáпке 2) сшивáть/сшить, составля́ть и скрепля́ть || сшива́ние, составле́ние и скрепле́ние; *дәфтәр ~ү* сшить (состáвить) тетрáдь **3.** пришивáть/пришúть; прибивáть/прибúть || пришива́ние (*гвоздями*), прибива́ние; *кәрниз ~ү* пришивáть карни́з □ **~еп кую** зашивáть/зашúть; **~еп чыгу** прошивáть/прошúть, прострочúть

тегүле *прил.* **1.** сшúтый; готóвый (*о шитьё*); *~ күлмәк* (*уже*) сшúтая рубáшка **2.** прикреплённый (*шитьём, булавкой*)

тегүлек *сущ.* **1.** вы́кройка, раскрóй; *~ кисү (кисеп бирү)* дéлать вы́кройку **2.** *разг.* всё, что для шитья́; *см.тж.* **тегемлек** || *прил.* прдназнáченный для шитья́

тегү-чәнчү *перех. собир.* занимáться (всяким) шитьём; шить-латáть

тегүче *сущ.* портнóй, портни́ха; швея́ || портнóвский, портня́жный; *~ хатын* портни́ха; *~ кайчысы* портнóвские нóжницы

тегүчелек *сущ.* **1.** портня́жничество, портня́жное ремеслó || портня́жный; швéйный; *~ белән көн итү* жить портня́жным ремеслóм; *~ кәсәбе* портня́жный прóмысел **2.** швéйное дéло

тез *сущ.* **1.** колéно, колéни; колéнный устáв (*людей и животных*); *батырмын дисәң, тезең ныкбулсын* (*посл.*) éсли ты зовёшься богатырём — держúсь крéпче на ногáх (*в коленях*) **2.** часть штанóв, брюк, прикрывáющая колéни; *ярар безгә — ямаулы тезгә* (*погов.*) нам, с заплáтанными штанáми (*которые с заплатками на коленях, т.е. бедным*), и так сойдёт **3.** *в знач. нареч.* **тездән, тезеннән** по колéно; *чыпчыкка муеннан, каргага ~дән* воробью́ по шéе, воронé по колéно; *шинеле, ди, өзелгән, сакалы, ди, тезеннән* (*из сказки*) шинéль рвáная, а борода́ по колéно □ **тез асты** подколéнное углублéние; мéсто на тéле под колéном; **тез башы 1.** мéсто на колéне (колéнях); **тез башына утырту** посадúть на колéни **2.** *см.* **тез капкачы; тез буыны** колéнный устáв; **тез капкачы (күмәче)** колéнная чáшечка; *см.тж.* **тубык; тез күзе** *см.* **тез** 2; **тез чүгеп утыру** сидéть на кóрточках; **тез чүгү 1.** опускáться/опустúться на колéни **2.** *перен.* нúзко клáняться; низкопоклóнствовать || низкопоклóнство, раболéпство; *ятлар алдында тез чүгү* низкопоклóнствовать пéред чужúми **3.** *перен.* сдавáться/сдáться на мúлость победúтеля; **тезгә (тез өстенә) басу (калкыну)** приподнимáться/приподня́ться, опирáясь на колéни ◊ **тез астына (тезгә) сугу** удáрить под колéно; выбивáть/вы́бить пóчву из-под ног; **тез буыны (тезләр) йомшау, бушау, калтырау** терáть/потерáть мýжество (*уверенность в себе*); *тез буыннары йомшарды* у негó тряслúсь поджúлки (*от страха*); **тез буыны (тезе) катмаган** ещё слаб в колéнях; мóлод ещё; ещё не опери́лся; **тез йөгенү** дéлать реверáнс

тезге *сущ.* **1.** *см.* **тезгеч 2.** *см.* **тезе**

тезгеләү *перех.* составля́ть/состáвить || составлéние кукáна (*из пойманных рыб*)

тезген *сущ.* **1.** 1) пóвод, повóдья; *~ каешы* ремешóк пóвода; *атны ~еннән алу* взя́ть лóшадь за повóдья 2) уздá, уздéчка **2.** *перен.* бразды́ (правлéния) □ **~не кулга (үз кулыма, үз кулыңа, үз кулына, үз кулыбызга, үз кулыгызга, үз кулларыбызга) алу** брать/взять бразды́ правлéния в свой рýки (*обо мне, о тебе, о нём, о нас, о вас, о них*); *хатыны (аның) ~ен кулга ала белә* женá умéет взять егó в свой рýки □ **~ салу 1.** умéть освободúться от пóвода, повóдьев (*о некоторых лошадях*) **2.** *перен.* умéло отлы́нивать от обя́занностей; **~дә тоту** держáть в уздé; *см.тж.* **йөгәндә тоту; ~не тоту** управля́ть; *~не буш (бушак) тоту* быть мя́гким (мягкотéлым) в управлéнии; *~не каты (кыска) тоту* быть круты́м, стрóгим в управлéнии; *ат белән хатынның ~ен кыска тот* не допускáй послаблéния (*букв.* держúпóвод покорóче) в обращéнии с лóшадью и женóй; **~не (кулдан) ычкындыру (җибәрү)** запускáть/запустúть бразды́ правлéния; упускáть власть из рук

тезгенләнү *страд. от* **тезгенләү**; быть обýзданным, обýздываться/обуздáться *прям., перен.*

тезгенләү *перех.* **1.** прикрепля́ть/прикрепúть || прикреплéние пóвода к уздé; *йөгәнне ~* прикрепúть пóвод к уздé **2.** *прям., перен.* обýздывать/обуздáть; сдéрживать/сдержáть; удéрживать/удержáть || сдéрживание, удержáние (*от неблаговидных поступков*)

тезгенсез I *прил.* **1.** без пóвода, без повóдьев; *~ йөгән* уздá без повóдьев **2.** *перен.* необýзданный; невы́держанный; распýщенный; *см.* **йөгәнсез** 1; *~ яшьләр* распýщенная молодёжь

тезгенсез II *см.* **йөгәнсез**; *атны ~ җибәрү* пускáть лóшадь без узды́

тезгенсезләнү *неперех.* **1.** становúться/стать необýзданным, невы́держанным, распýщенным; распускáться/распустúться **2.** проявля́ть/проявúть || проявлéние необýзданности, невы́держанности, распýщенности; *~еп йөри* всё врéмя (*то и дело*) проявля́ет распýщенность

тезгенсезлек *сущ.* необýзданность, невы́держанность; распýщенность; *см. тж.* **йөгәнсезлек**; *бу нинди ~тагын?* что э́то за распýщенность?

тезгеч *сущ.* кукáн (*шнур или прутик, на который нанизывают пойманную рыбу*); *~кә тезү* нанúзывать на кукáн

тезгечләү *перех.* нанúзывать/нанизáть || нанúзывание на кукáн □ **~п кую** (*сразу*) нанúзывать на кукáн

тездерү *понуд. от* **тезү**; заставля́ть/застáвить úли велéть нанúзывать на нúтки

тезе *сущ. диал. этногр.* ожерéлье; *әнисендә кызы кайгысы, кызында ~ кайгысы* (*посл.*) мать дýмает о дóчери, дочь дýмает об ожерéлье (*об украшениях*)

тезелеш *сущ.* построéние в ряд; ряд, строй

тезелешү *совм. от* **тезелү**; выстрáиваться/вы́строиться || построéние в ряд (*о многих*); *тиз генә ~егез әле* а нý-ка, бы́стренько вы́строитесь; встава́йте выстрáиваясь/вы́строившись в ряд; *~еп утыру* сидéть/сесть (*в линию, в ряд*) рядышком (*о многих*)

тезелмә *прил. мат.* составнóй; *~ саннар* составны́е чúсла □ **~ тәгъриф** составнóе (*математическое*) выражéние

тезелү *страд.-возвр. от* **тезү 1.** *страд.* нанúзываться/нанизáться; быть нанúзанным; *бауга ~гән крендель* крéндели, нанúзанные на шнурóк **2.** *возвр.* выстрáиваться, строéние; располагáться/расположúться || расположéние в ряд, рядáми, рядышком (*о многих*); *ике рәткә ~ү* расположúться в два рядá; *кызыл-кызыл бөрлегән юл буена ~гән* (*песня*) крáсная-крáсная костянúка вдоль дорóги сплошь и рядáми

тезем *сущ.* **1.** ряд, цепь, чередá, верени́ца; нúзка; *тау ~е* цепь гор, гóрная цепь; *көннәр ~е* чередá дней; *торналар ~е* верени́ца журавлéй; *ике ~* две нúзки (*жемчуга*) **2.** строй (*боевой, пехотный*); *~гә басу* вставáть/встать в строй **3.** покóс; валóк (*сена*); *~нәргә салу* уложúть

(*сено, хлеб*) **4.** *лингв.* перио́д; *озын ~нәр* дли́нные пери́оды (*в речи*)

теземләнү *возвр. от* **теземләү**; располага́ться/расположи́ться, выстра́иваться/вы́строиться ряда́ми, верени́цами (*в ряд, вереницей*); *кыр казлары ~еп оча* ди́кие гу́си лета́т верени́цей

теземләү *перех.* составля́ть/соста́вить (*вереницы, низки*) || составле́ние (*ряда, рядов, верениц, низок*); *җепкә ~* составля́ть ни́зку

теземле *прил.* **1.** це́пью, верени́цей; располо́женный ряда́ми, це́пью; *~ таулар* го́ры верени́цей **2.** в валка́х (*о чём-л. скошенном, сжатом и т. п.*); *~ арышны суктыру* обмолоти́ть (*комбайном*) рожь в валка́х **3.** после́довательный; сле́дующий оди́н за други́м; *~ күчешләр* после́довательные перехо́ды □ **~ рәвештә** после́довательно, оди́н за други́м, подря́д

теземлек *сущ.* **1.** *см.* **тезем 3 2.** *уст. мат.* ряды́; *см.тж.* **бергәлек, чатлашу**

теземлелек *сущ.* ряд, после́довательность (*отдельных предметов, явлений*); непрерывность *чего*; *биредә бер ~ бар* тут име́ется не́которая после́довательность; *~ һәм өзеклек* непрерывность и прерывность

тезешү *взаимно-совм. от* **тезү**; помога́ть/помо́чь расположи́ть в ряд (*рядами, вереницей, низкой*)

те́зис *сущ.* те́зис; *доклад ~лары* те́зисы докла́да

тезләндерү *перех. прям., перен.* ста́вить/поста́вить на коле́ни

тезләнү *неперех.* **1.** станови́ться/стать || становле́ние на коле́ни; стоя́ть || стоя́ние на коле́нях; *алдына ~еп ялвару* умоля́ть на коле́нях **2.** *перен.* покоря́ться/покори́ться *кому*; преклони́ть коле́ни *перед кем* □ **~еп утыру** сиде́ть на коле́нях, сесть на коле́ни

тезмә *сущ.* **1.** *разг. см.* **тезем 1, 2 2.** нака́т, наве́с; насти́л, перекры́тие, состоя́вшее из жерде́й (*потолок хлева*); *~гә печән мендерү* поднима́ть (грузи́ть) се́но на наве́с **3.** *разг. см.* **тезгеч 4.** сочета́ние, еди́нство отде́льных часте́й; *сан ~се* сочета́ние чи́сел; *сүз ~се* словосочета́ние **5.** стихотворе́ние; рифмо́ванная речь; стих || *прил.* **1.** располо́женный це́пью, верени́цей; *~ күлләр* цепь озёр; озёра, располо́женные це́пью; *~ утраулар* цепь островóв **2.** *см.* **тезмәле**; *~ сөйләм* стихотво́рная ритми́ческая речь

тезмәләнү *неперех. см.* **тезмәләү**

тезмәләү *перех.* **1.** *см.* **теземләү 2.** стели́ть, настила́ть/настла́ть нака́т

тезмәле *прил.* **1.** *разг. см.* **теземле 1 2.** нака́тный, с нака́том, с перекры́тием в ви́де ря́да брёвен, жерде́й; *~ түшәм* потоло́к в ви́де нака́та **3.** стихотво́рный, ритми́ческий; рифмо́ванный; *~ юллар* стихотво́рные стро́ки

тезмәлек *сущ.* **1.** *разг.* нака́тник **2.** *мат.* прогре́ссия

тезү I *перех.* **1.** расставля́ть/расста́вить, разложи́ть || расставле́ние, разложе́ние (*по линии, в ряд*); *китапларны ~еп кую* расставля́ть кни́ги по поря́дку (*на полке*); *әйберләрне чыгарып ~ү* разложи́ть ве́щи напока́з (*извлекая из чего-л., из мешка, шкафа и т. п.*); *шахмат фигураларын ~ү* расста́вить ша́хматные фигу́ры (*на доске*) **2.** выстра́ивать/вы́строить || выстра́ивание (*в ряд*); *кешеләрне шеренгага ~ү* вы́строить люде́й в шере́нгу **3.** низа́ть, нани́зывать/нанизáть || ни́зка, нани́зывание (*на шнур*); *гөмбәләрне җепкә ~ү* нани́зывать грибы́ на ни́тку **4.** расставля́ть/расста́вить, уложи́ть, сложи́ть || расставле́ние, уложе́ние, сложе́ние (*по определённому порядку, в ряд и т.п.*); *көлтәләрне киптерергә ~ү* уложи́ть снопы́ для просу́шки; *шпал ~ү* уложи́ть шпа́лы (*на железной дороге*) **5.** сложи́ть, сооружа́ть/сооруди́ть, составля́ть/соста́вить || сложе́ние, составле́ние (*из одинаковых частей*); *мич көймәсен ~ү* сложи́ть, сооруди́ть свод печи́ (*из кирпичей*); *гәрәбә ~ү* соста́вить ожере́лье из янта́рных ша́риков; *тәңкә ~ү* соста́вить мони́сто; *энҗе ~ү* соста́вить узо́ры из же́мчуга **6.** плести́/сплести́ || плете́ние (*из лыка и т. п.*); *см. тж.* **үрү**; *мурда ~ү* плести́ мо́рду (*рыболовную*); *чабата ~ү* сплести́ ла́пти **7.** выска́зываться/вы́сказать || выска́зывание (*соображений, доводов, фактов и т. п.*) одного́ за други́м; *~еп китте, ~еп китте* и стал выска́зываться, одно́ за други́м; и пошёл, пошёл выска́зываться **8.** рифмова́ть, сложи́ть || рифмова́ние, рифмо́вка, сложе́ние (*стиха*); *шигырь ~ү* соста́вить стих (*вирши*) □ **~еп язу** писа́ть ро́вным по́черком, ро́вными краси́выми бу́квами

тезү II *сущ. лингв.* сочине́ние (*тип связи слов в предложении*) □ **~ү бәйләнеше** *см.* **тезүле бәйләнеш**

тезүле *прил.* **1.** расста́вленный, сло́женный, уло́женный (*по порядку*); *көлтәләр ~* снопы́ уло́жены **2.** *лингв.* сочинённый; сочини́тельный □ **~ бәйләнеш** сочини́тельная связь (*слов*)

теизм *сущ. филос.* тейзм (*религиозное мировоззрение, признающее существование бога как абсолютной личности, создавшей мир и управляющей им*); *~ юнәлешләре* направле́ния тейзма

теист *сущ.* тейст, сторо́нник тейзма

тек I *сущ.* вертика́льное положе́ние а́льчика (*в игре в альчики, козны*) || *нареч.* вертика́льное; торчко́м; *тек тору* стоя́ть вертика́льно (торчко́м)

тек II *сущ. бот.* тик (*дерево с плотной, твёрдой древесиной, растущее в Индии, Индонезии; употребляется в кораблестроении, при строительстве портов и т. п.*)

тек III *частица усил., придаёт оттенок подтверждения основного качества чего-л.* так, дык *обл.*; как есть; та́ки есть; *машина тек машина* маши́на есть маши́на (*в знач.* она рабо́тает бы́стро *или* оно́ механи́чески повторя́ет одно́ и то́ же); *җүләр тек җүләр* глуп так глуп; глуп как есть глуп; *уңмаган тек уңмаган* бе́столочь так уж бе́столочь (*что с него возьмёшь?*)

тек IV *подр. лёгкому удару небольшим твёрдым предметом по дому* тик; *тик тә тик* тик да ти́к □ **тек итү** ти́кнуть

текә *сущ. разг. см.* **текәлек**; крутизна́, круто́е ме́сто; *тау ~сендә* на круто́м ме́сте горы́ ◊ **~ башлы (борынлы)** надме́нный, го́рдый; чванли́вый, спеси́вый; **~ күңелле** го́рдый в душе́, (поэ́тому) ре́зкий, неве́жливый в обраще́нии

текәлән|ү *неперех.* станови́ться/стать круты́м *прям., перен.*; *үр ~ә башлады* возвы́шенность станови́лась всё кру́че

текәләү *перех.* при́стально смотре́ть

текәлдер|ү *перех. см.* **текәү**; *күзен ~де* вперúл глаза́

текәле|к *сущ.* **1.** крутизна́; *~ген үлчәү* изме́рить крутизну́ *чего-л.* (*горы, траектории и т. п.*) **2.** кру́тость, сво́йство быть крутым; *тауның ~ге аркасында* из-за кру́тости горы́ **3.** крутóе ме́сто (*горы, дороги и т. п.*); *~ктә туктау* останови́ться на круто́м ме́сте **4.** *перен.* кру́тость, суро́вость, су́хость; надме́нность (*характера или поступка*); *кыланмышының ~ге* кру́тость его́ поведе́ния

текәлешү *взаимно-совм. от* **текәлү 1.** уста́виться друг на дру́га **2.** *см.тж.* **текәшү**

текәл|ү 1. *возвр.-страд от* **текәү**; уста́виться, вперя́ться/вперúться взóром; неотры́вно смотре́ть *на кого,*

что; тоймаганга ~мә, сөймәгәнгә сөйкәлмә (*посл.*) не уставля́йся на того́, кто равноду́шен, не прислоня́йся к тому́, кто не лю́бит **2.** *разг.* упира́ться *во что*; *см.тж.* **терәлү**; *эш шуңа ~ә* де́ло упира́ется в то (э́то) **3.** *в знач. нареч.* **текәлеп** при́стально, внима́тельно; неотры́вно (*о взгляде*); *~еп карау* при́стально смотре́ть

текәнәк *сущ. диал. бот.* колю́чник, колю́чий куста́рник; *см. тж.* **чәнечке**

текәнәкле *прил. диал.* с колю́чниками

текә|ү *перех.* **1. (күз ~ү)** направля́ть (напра́вить, вперя́ть) впе́рить (*взор*) **2.** *разг.* упира́ть/упере́ть *что во что* □ **~п карау** при́стально и внима́тельно смотре́ть, посмотре́ть

текелдәтү *перех.* **1.** (*негромко, слегка*) стуча́ть, посту́кивать/постуча́ть (*по твёрдому*) || посту́кивание (*карандашом по столу, каблучком по паркету*) **2.** строчи́ть || строче́ние; *см.тж.* **текердәтү**

текелдәү *неперех.* **1.** ти́кать, пота́кать || ти́кание (*часов*) **2.** слегка́ стуча́ть, посту́кивать/постуча́ть || посту́кивание, пересту́к (*далёких молотков*) **3.** *разг. см.* **тәтелдәү**

текердәтү *перех.* строчи́ть, хруте́ть, издава́ть стре́кот, производи́ть стре́кот *чем*

текердәү *неперех.* **1.** стрекота́ть || стрекота́ние (*швейной машинки*) **2.** *разг. см.* **кетердәү**

текер-текер *подр. шуму маленьких или далёких машин* □ **текер-текер итү 1.** легко́ строчи́ть (*о швейной машинке*) **2.** где́-то шуме́ть (*о машинах*)

текмә *сущ.* тын, частоко́л; *~ тоту* стро́ить (постро́ить, ста́вить) тын □ **~ читән** *разг. см.* **текмә**

текмәкләү|ү *перех. разг.* дото́шничать, *что-л.* рассма́тривать, расспра́шивать || рассма́тривание, расспра́шивание дото́шно, подро́бно, внима́тельно; *~п карау* дото́шно рассма́тривать; *~п сорашу* дото́шно расспра́шивать; *бик артык ~мә* не о́чень ты дото́шничай

текмәләтү *понуд. от* **текмәләү**; поруча́ть/поручи́ть; веле́ть, заставля́ть/заста́вить; ста́вить тын, огора́живать/огороди́ть ты́ном

текмәлә|ү *перех.* огора́живать/огороди́ть || огора́живание ты́ном, частоко́лом □ **~п алу** огора́живать/огороди́ть (*часть чего*); окружа́ть ты́ном, частоко́лом *что*

текмә-тек *нареч. разг.* **1.** подро́бно; доскона́льно; *текмә-тек белү* знать доскона́льно; *текмә-тек сорашу* подро́бно расспра́шивать **2.** то́чно; *текмә-тек үтәү* вы́полнить то́чно (*как было предусмотрено*)

текст *сущ. в разн. знач.* текст; *доклад ~ы* текст докла́да; *кулъязма ~ын карау* просмотре́ть текст ру́кописи; *җыр ~ы* текст пе́сни

текстиль *сущ.* тексти́ль || тексти́льный (*о предприятиях*); *~ магазины* тексти́льный магази́н; *~ фабрикасы* тексти́льная фа́брика || тексти́льный магази́н (*о тканях и изделиях*); *~ товарлар* тексти́льные това́ры

текстильче *сущ.* тексти́льщик, ткач; *~ләр профсоюзы* профсою́з тексти́льщиков

текстильчелек *сущ.* тексти́льное де́ло (произво́дство); *~тә эшләү* рабо́тать в тексти́льном произво́дстве

те́кстлы *прил.* **1.** с те́кстом; име́ющий текст **2.** текстово́й; *~ материал* текстово́й материа́л

текстолог *сущ. лингв.* тексто́лог (*специалист по текстологии*); *~лар конференциясе* конфере́нция тексто́логов

текстоло́гик *прил. лингв.* текстологи́ческий; *~ анализ* текстологи́ческий ана́лиз

текстоло́гия *сущ.* тексто́логия || текстологи́ческий; *~ фәне* текстологи́ческая нау́ка; *~ белгече* специали́ст по тексто́логии

текстуаль *прил. лингв.* текстуа́льный; *~ тикшеренүләр* текстуа́льные иссле́дования

тек-тек *подр.* **1.** *тиканью* (*часов*); тик-та́к **2.** *строчению* (*на швейной машинке*) **3.** *перестуку каблучков* (*по асфальту, паркету*); *~ басып йөрү* ходи́ть, стуча́ каблучка́ми □ **тек-тек итү** ти́кать

тектерү 1. *понуд. от* **тегү**; заставля́ть/заста́вить; веле́ть, проси́ть/дать зака́з на пошйв; *кием ~* заказа́ть пошйв **2.** *см.* **тегү**

тектер|ү *понуд. от* **тегү**; дава́ть/отдава́ть в пошйв; зака́зывать/заказа́ть пошйв; веле́ть (проси́ть) сшить (*и получить готовую одежду или обувь*) □ **~еп алу** спра́вить (*себе*) но́вую оде́жду у портно́го; **~еп җибәрү** (молоде́цки) спра́вить оде́жду (*у портного*); **~еп кую** зара́нее изгото́вить но́вую оде́жду

тектерүче *сущ.* зака́зчик || зака́зывающий (*у портного, сапожника*)

текто́ник *прил.* тектони́ческий; *~ үзгәрешләр* тектони́ческие измене́ния (*земной коры*)

текто́ника *сущ. в разн. знач.* текто́ника **1.** строе́ние уча́стка земно́й коры́ **2.** разде́л геоло́гии, изуча́ющий структу́ру земно́й коры́ **3.** строй, строе́ние *чего-л.*

текә *прил.* **1.** круто́й, отве́сный, почти́ вертика́льный; *~ тау* крута́я гора́; *тау* (*тавы*) *~* (э́та) гора́ крута́; *~ кыя* отве́сная скала́; *~ сызык* вертика́льная ли́ния **2.** *редко* круто́й, ре́зкий; *~ борылыш* круто́й поворо́т **3.** *перен.* круто́й, суро́вый, сухо́й (*в обращении*); *~ холыклы* с круты́м, суро́вым нра́вом; *холкы ~* его́ нрав крут || *нареч.* **1.** кру́то, отве́сно; *~ борылу* кру́то поверну́ться **2.** *прям., перен.* суро́во, надме́нно; *~ сөйләшә* разгова́ривает надме́нно

текәштер|ү *перех. разг.* упира́ть || упира́ние; ста́вить/поста́вить || постано́вка вприты́к; *~еп кую* ста́вить вприты́к (*друг к другу*)

текәшү *взаимно-совм. от* **текәү**; уста́виться друг на дру́га и́ли вме́сте *на кого, что*

тел I *сущ.* **1. 1)** *анат.* язы́к (*человека и животных*) || языково́й; -язы́чный; *тел очы* ко́нчик языка́; *айры тел* раздво́енный язы́к (*змей*); *арткы тел авазлары* заднеязы́чные зву́ки; *тел дигән арыслан теш дигән текмә артында торсын* (*посл.*) скрипи́ зуба́ми, но терпи́ — не проговори́сь (*букв.* лев, называ́емый языко́м, до́лжен находи́ться за частоко́лом, называ́емым зуба́ми); *сыерның сөте җиленендә түгел, телендә* (*посл.*) молоко́ коро́вы не в вы́мени, а на языке́ (*т. е. больше кормов — больше молока*) **2)** язы́к, язычо́к, вы́ступ в фо́рме языка́; *ялкын телләре* языки́ пла́мени; *шәл теле* вы́ступ волни́стого кра́я ша́ли **2. 1)** *в разн. знач.* язы́к, речь || языково́й, речево́й; *гарәп теле* ара́бский язы́к; *рус теле* ру́сский язы́к; *чит тел* иностра́нный язы́к; *тел культурасы* культу́ра языка́; *язма тел* пи́сьменный язы́к; *дуслык теле* язы́к дру́жбы; *тел чаралары* языковы́е сре́дства; *теле татлы, күңеле таплы* (*погов.*) речь его сладка́, а душа́ гадка́ **2)** *перен. о системах выражения, изображения* язы́к; *сызым — техника теле* чертёж — э́то язы́к те́хники; *музыка теле белән әйтү* вы́сказать языко́м му́зыки **3.** язы́к, язычо́к, язычки́ (*щеколды, колокола, колокольчика, ботинка и т. п.*) **4.** ма́ятник (*настенных часов*) **5.** стре́лка весо́в; *үлчәү теле бер генә* (*посл.*) стре́лка весо́в то́лько одна́ (*правда всегда однозначна*) **6.** кла́вища,

пла́нка (*гармони, баяна*); *тальян гармунның телләре көмеш микән, җиз микән?* (*песня*) сере́бряные ли, лату́нные ли кла́виши у талья́нки? **7.** пи́щик (*внутри гармони, баяна и т.п*) **8.** язы́чок, зазу́брина (*крючка*) **9.** боро́дка (*ключа*) **10.** *перен.* доно́с, я́беда, спле́тня, кля́уза; *кеше өстеннән тел эйтү* кля́узничать (*букв.* вы́сказать кля́узу) о друго́м челове́ке **11.** *перен.* язы́к (*человек из лагеря противника, используемый для получения информации*); *разведчиклар тел алып кайтмылар* развéдчики привели́ языка́ **12.** *в ф. исх. п.* **телдән, теленнән** у́стно ‖ у́стный; *телдән эйтү* вы́сказать у́стно; *телдән җавап* у́стный отве́т **13.** *в ф. направит. п.* **телгә** языко́м, на слова́х; *телгә батыр, эшкә факыр* (*посл.*) языко́м трепа́ть ма́стер, а на де́ле слаб □ **тел агы (аклавы, аклыгы)** сорио́з (*белый грибок, поражающий полость рта, язык у новорождённых*); **тел гыйлеме (белеме)** языкозна́ние, языкове́дение; **тел тартыгы** языково́й согла́сный (звук); **тел шартлау (чыртлау)** щёлкать/щёлкнуть языко́м (*в знак удивления, восхищения или несогласия*) ◊ **тел аерылу** говори́ть на ра́зных языка́х (*не понимать друг друга по причине разности целей, понимания вещей и т. п.*); **тел ачкычы** *о способности красноречиво говорить: дар речи; сиңа тел ачкычы телим, алла тел ачкычы бирсен* тебе́ ни пу́ха ни пера́ (*говорится идущему на экзамены*); *тел ачкычын мәктәптә табалар аны* что́бы обрести́ дар ре́чи, на́до учи́ться в шко́ле; **тел ачу 1.** начина́ть говори́ть (*о маленьких детях*); *бала тел ачканда, өлкәннәр дә аңа иярә* когда́ ребёнок начина́ет говори́ть, взро́слые подража́ют ему́ **2.** *см.* **телен ачу 3. (ни турында, хакында тел ачу)** заговори́ть *о чём; см. тж.* **сүз ачу; тел әйләндерү 1.** шевели́ть языко́м **2.** повора́чивать языко́м; *телен әйләндереп әйтәлмәде* повора́чивая свои́м языко́м, не смог сказа́ть (*не мог говорить ясно или открыто*); **тел әйләнмәү 1.** *см.* **тел көрмәлү 2.** *см.* **тел бармау; тел бару** мочь/смочь, осме́литься говори́ть (*такое, что воспринимается как кощунство*); повора́чиваться (*о языке*); *моны әйтергә тел бармый* язы́к не повора́чивается, что́бы сказа́ть тако́е; *теле барганның кулы да бара* (*посл.*) тот, кто мо́жет сказа́ть э́такое, мо́жет и сде́лать (соответствующее); **тел батырып (күтәреп) сүз әйтү 1.** сказа́ть *что-л.* предосуди́тельное, непотре́бное **2.** сказа́ть в лицо́; **тел(е) белән әйтү** вы́сказать, вы́разить слова́ми; *әйтсәң — телең белән әйт* е́сли говори́шь, так говори́ (скажи́) я́сно и пря́мо; **тел белән әйткесез** невырази́мый слова́ми; **тел белән тегермән кору (тарттыру)** говори́ть (обеща́ть) мно́го, но ничего́ не де́лать; моло́ть языко́м; трепа́ться; **тел белән телү (тету)** бичева́ть сло́вом; жечь глаго́лом; **тел беркетү** договори́ться, заключи́ть сою́з (*в тайне или в стороне от кого-л.*); *см. тж.* **сүз беркетү; тел бирәне** *груб.* болту́н, говору́н (*который не может остановиться*); **тел бистәсе** красноба́й; **теле (телләре) бәйле (баглы)** не мо́жет, не име́ет пра́ва говори́ть; **тел бәйләндергеч 1.** *см.* **тизәйткеч 2.** тру́дный для произнесе́ния, язы́к слома́ешь; **тел бәйләнү 1.** заплета́ться (*о языке*), не быть в состоя́нии говори́ть (*из-за смущения, страха и т. п.*); *әйтим дисәм, телем бәйләнә* захочу́ я вы́сказаться — нет, не могу́, язы́к заплета́ется **2.** *см.* **тел көрмәлү; тел кагу 1.** чо́кнуть, че́кнуть, щёлкнуть языко́м (*погоняя лошадей*) **2.** говори́ть (*о деле*) без необходи́мости, трепа́ть языко́м (*хотя и без вреда*); **тел кайтару** пререка́ться (*со старшими*); *телем яман, телем яман, тел кайтарган килен яман* (*посл.*) я злоречи́ва, злоречи́ва, но и сноха́ плоха́ — пререка́ется; **тел кату 1.** ропта́ть, возропта́ть; *аллага тел кату* ропта́ть на бо́га **2.** осужда́ть *кого*; выска́зывать осужде́ние (*нарушая порядок, закон, обычай, субординацию*); *ата-анага тел катмыйлар аны* нельзя́ осужда́ть роди́телей; неприли́чно пререка́ться с роди́телями; *хөкүмәткә тел кату* выска́зываться про́тив прави́тельства (*осуждая правительство*); **тел кашу** чеса́ть язы́к (языко́м); говори́ть не к ме́сту; **тел көрмәкләнү (көрмәлү) 1.** заплета́ться, с трудо́м повора́чиваться (*о языке больного*); **теле көрмәкләнә башлаган** уже́ при́ смерти **2.** *см.* **тел бәйләнү; тел кузгату (кыймылдатмау)** смолча́ть; умо́лчивать/умолча́ть (*о чём-л., из-за опасения; по тактическим соображениям и т. п.*); **тел күтәрмәү** возде́рживаться/воздержа́ться от ли́шних слов (*по тактическим соображениям*); **тел күтәрелү** *см.* **тел бару; тел күтәрү 1.** *прост. см.* **тел кату 2.** *см.* **тел кузгату; тел озайту**; распуска́ть/распусти́ть язы́к (*осуждая начальство*); пуска́ть, распространя́ть слу́хи, неуго́дные вышестоя́щим; **тел кычыту 1.** чеса́ться (*о языке*); подмыва́ть говори́ть, вы́сказать *что*; *телең кычытса — терпе яла* (*посл.*) е́сли язы́к бо́льно че́шется — лизни́ терпу́г (*но не говори*) **2.** *в ф.* **телләре кычыткан** ну и наговори́ли; де́лать бы́ло им не́чего; **тел очы** пе́рвые слова́, приве́т; *тел очы татлы, төбе каты* (*погов.*) мя́гко сте́лет да жёстко спать (*букв.* пе́рвые слова́ о́чень ве́жливы, сла́дки, но смысл их жёсткий); **тел очына килү** верте́ться на ко́нчике языка́ (*о словах, уже готовых, но по какой-л. причине невысказываемых*); *тел очыма килде — әйтмәдем* слова́ уже́ подверну́лись бы́ло — не вы́сказал **3.** *о словах, которые говорящий силится* (*и почти готов*) *сформулировать или вспомнить*; *тел очымда гына* ве́ртится на ко́нчике языка́ (вот-во́т, ка́жется, сейча́с вспо́мню); **тел өстендә** на уста́х (*у всех*); *кыз язмышы кыл өстендә, кыл өзелсә — тел өстендә* судьба́ де́вушки вися́т на волоске́, оборвётся волосо́к — на уста́х у всех (*т. е. начинают сплетничать*); **тел саклау** ума́лчивать/умолча́ть, промолча́ть из уваже́ния (*к старшим*); **тел сату 1.** пыта́ться выкру́чиваться/вы́крутиться го́лыми слова́ми **2.** разглагóльствовать; лука́во му́дрствовать; **тел сөяксез** язы́к-то без косте́й; **тел сүтү 1.** говори́ть до́лго и подро́бно (*разъясняя смысл сказанного*) **2.** объясня́ть то, что давно́ уже́ я́сно; **тел табу** *см.* **уртак тел табу; тел тегермәне** (*о болтовне, болтливости кого*); *тел тегермәне тарта бирә ул* языко́м-то трепа́ть мо́жно; *аның тел тегермәне тарта* он болта́ет без у́молку; **тел тибрәнү** захоте́ть сказа́ть; чуть не сказа́ть: **тел тибрәтү (тибрәндерү)** (*спокойно, ласково*) *что-то* промо́лвить; **тел тигесез (тидергесез)** безупре́чный; *мораль яктан тел тидергесез* мора́льно безупре́чный; **тел тидерерлек түгел** не́ к чему придра́ться; ни сучка́, ни задо́ринки; кома́р но́са не подто́чит; **тел тидерү 1.** задева́ть/заде́ть слова́ми; броса́ть/бро́сить обвине́ние, упрёк в а́дрес *кого* (*в ходе разговора*) **2.** упрека́ть; придира́ться; хули́ть; **тел тию** приходи́ться/прийти́сь, задева́ть/заде́ть (обвиня́ть); **тел тиярлек түгел** *см. тж.* **тел тигесез; тел тотлыгу** *см.* **тотлыгу; тел туздыру** болта́ть зря; трепа́ть языко́м; **тел төбе** то, к чему́ кло́нит, что име́ет в виду́ говоря́щий (*не высказываясь открыто, не говоря напрямик, начистоту*); *тел төбенең кая барганын белəм* зна́ю, к чему́ ты кло́нишь (куда́ гнёшь); **тел уйнату** игра́ть слова́ми, зайгрывать на слова́х; **тел чарлау** остри́ть, зубоска́лить; точи́ть ля́сы; **тел чишелү** разговори́ться; станови́ться/стать разгово́рчивым; расколо́ться; **тел чишү** откры-

ва́ть/откры́ть секре́ты; разглаша́ть та́йну; доверя́ть ду́шу (мы́сли); **тел чылату** немно́го попи́ть (*необязательно хмельное*); **тел шомарту (таптау, юкарту)** мо́лоть чушь; точи́ть ля́сы; **тел яздыру 1.** заставля́ть/заста́вить выдава́ть/вы́дать секре́ты **2.** с трудо́м понима́ть, доходи́ть до смы́сла (*книги, механизма*); **тел язу** выдава́ть/вы́дать секре́т (*под нажимом или невольно*); **тел яшеру 1.** *этногр.* (*по старинному обычаю*) не говори́ть в прису́тствии де́веря и́ли ста́рших бра́тьев му́жа **2.** ута́ивать/утаи́ть *от кого* (*о двух и более других лицах*); *миннэн тел яшергэнсез* (*знали, но*) утаи́ли от меня́ **3.** говори́ть ме́жду собо́й усло́вными слова́ми, на жарго́не и т. п.; говори́ть на арго́; **телгэ алу** упомяну́ть (*в речи*); *мактап телгэ алу* упомяну́ть с похвало́й; **телгэ алыпу** упомяну́ться, быть помя́нутым/упомя́нутым; *яхшы суз белэн телгэ алынды* был упомя́нут до́брыми слова́ми; **телгэ алынган (алынмыш)** упомя́нутый; **телгэ беткэн** бо́йкий || бо́ек на язы́к; **телгэ йозак салу** запреща́ть/запрети́ть говори́ть; **телгэ керу 1.** станови́ться/стать предме́том разгово́ра, переса́удов, пре́ний **2.** станови́ться/стать изве́стным, знамени́тым; *исеме телгэ кергэн* ста́вший || стал изве́стным, его́ и́мя ча́сто упомина́ется; он изве́стен; **телгэ килешу** *см.* **телгэ килу** 3; **телгэ килу 1.** вдруг заговори́ть, обрести́ дар ре́чи (*в сказках — обычно о не говорящих: о животных, вещах и пр.*) **2.** заговори́ть (*после молчания*) **3. (үзара) телгэ килу** вздо́рить, поруга́ться; **телгэ оста (телгэ чая, үткен, шэп)** бо́йкий || бо́ек на язы́к, речи́стый; **телдэн калу** лиша́ться/лиши́ться да́ра ре́чи (*от болезни, испуга, удивления, страха и т. п.*); **телдэн-телгэ** из уст в уста́ (*о распространении легенд, слухов, новостей и т. п.*); **телдэн төшмәу** быть у всех на устах, *см. тж.* **теленнэн төшермәу**; **телдэн төшу** переста́ть упомина́ться, вспомина́ться; забыва́ться (*о человеке*); **телдэн ычкыну** срыва́ться/сорва́ться с языка́; **теле(ң) авызына (авызга) сыймау (сыешмау)** говори́ть соверше́нно некста́ти; смороз́ить (*чепуху, чушь и т. п.*); *телең авызына сыймады мәллә?* ты чего́, не смог, что́ ли, помолча́ть (промолча́ть)?; **теле ачылу 1.** начина́ть, нача́ть говори́ть (*о маленьких детях*); *баланың теле ачылды инде* ребёнок уже́ говори́т **2.** заговори́ть, стать речи́стым (*о молчащем до сих пор или обычно молчаливом человеке*); **теле кору** отсо́хнуть (*о языке*); *бу сузлэрең өчен телең корыр* язы́к твой отсо́хнет за э́ти твои́ слова́; **теле озын** *неодобр.* язы́к дли́нен — не в ме́ру речи́ст (*о сплетниках, о склонных к препирательству и т. п.*); *теле озынның намусы кыска* (*посл.*) у кого́ язы́к дли́нен — со́весть коротка́; **теле татлы (баллы)** сладкоречи́вый || сладкоречи́в; **теле тезенә җитә** ма́стер на злы́е слова́, ре́чи; **теле телгә йокмый** говори́т без запи́нки (*бойко, красиво, увлечённо*); *аның теле телгә йокмый башлады* он вошёл во вкус и так на́чал сы́пать — заслу́шаешься; **теле чарланган (шомарган)** навостри́лся говори́ть; язы́к непло́хо подве́шен; **теле чыгу 1.** *см.* **теле ачылу 2.** начина́ть/нача́ть откры́то говори́ть нелицеприя́тные слова́; *тире чыкканның теле дә чыга* (*посл.*) кто в поту́ труди́лся, тот и начина́ет говори́ть откры́то; **теле юка** речи́ст и сладкоречи́в; **телен (телне) аркылы тешләп 1.** че́рез си́лу; *телеңне аркылы тешләп булса да түзәсең* те́рпишь че́рез си́лу (*букв.* перекуси́в язы́к) **2.** в кра́йней уста́лости; уста́вши (*в беге и т. п.*); *тел-ләрен аркылы тешләп килеп җиттелэр* прибежа́ли в кра́йней уста́лости (*еле дыша*) (*букв.* вы́сунув языки́); **телен ачу 1.** научи́ть говори́ть гра́мотно (*детей*) **2.** научи́ть заговори́ть, научи́ть говори́ть у́мно; *гыйшык телсез егетнең телен ачар, телчән егетнең телен бәйләр, ди* (*посл.*) любо́вь заставля́ет молчали́вого быть красноречи́вым, а красноречи́вого — быть молчали́вым (*там, где нужно*) **3.** *см.* **телен табу; телен белү** знать в чём де́ло (*букв.* язы́к) (*в обращении с машинами, механизмами и т. п.*); уме́ть обраща́ться (*с чем-л. сложным или капризным*); *дөянең телен кәрванчы белә* (*посл.*) с верблю́дом уме́ет обраща́ться карава́нщик; **телен йоту** упо́рно молча́ть (*букв.* проглоти́ть язы́к); *телен йоткан (йоткандай тора)* упо́рно молчи́т; не мо́лвит ни сло́ва (*от растерянности, от удивления и т. п.*); *телеңне йоттыңмы әллә?* ты что, язы́к проглоти́л?; **телен кыскарту** *в разн. знач.* укороти́ть язы́к, заста́вить замолча́ть; **телен табу** находи́ть/найти́ подхо́д (*к чему, кому-л., сложному, капризному*); **телен чыгарып** изо все́х си́л, вы́сунув язы́к; *см. тж.* **телен тешләп; теленә (теленә) салыну (салышу)** заводи́ть/завести́ спор, перебра́нку, *см. тж.* **телләшү; теленә шайтан төкергән** его́ не переспо́ришь (*букв.* чёрт плю́нул ему́ на язы́к); *телне кыска тоту* придержа́ть язы́к (*букв.* держа́ть язы́к наконоткé); **теленең тупсасы юк** язы́к без шарни́ров, т. е. говори́т без вся́кой осмы́сленности, отве́тственности; *теленең тупсасы юк, авызының туктыйсы юк* (*погов.*) язы́к его́ без шарни́ров, а рот без тормозо́в; **теленнән табу** пострада́ть из-за своего́ языка́; **телне (теленә, телегезне, телен, телемне) тешләү** вдруг замолча́ть, сообрази́в, что собира́лся сказа́ть (*или уже сказал*) ли́шнее; **телне тыю** попридержа́ть язы́к; не распуска́ть язы́к; *оста барда кулың тый, чичән барда телең тый* (*посл.*) не хвали́сь рабо́той в прису́тствии ма́стера, не пыта́йся блесну́ть ре́чью в прису́тствии ба́рда; **теленә йотарсың** язы́к (*вместе с пищей*) прогло́тишь (*такой вкусный*); па́льцы обли́жешь; **теленә сындырырсың** язы́к слома́ешь (*о выговаривании сложного слова*); **теленә тайдырма** не говори́ так краси́во; **теленә теш артында тоту** *см.* **телне кыска тоту**

тел II *сущ. этногр.* языческая моли́тва, за́говор; *елан теле* за́говор от змей; слова́, кото́рыми загова́ривают змей; *тел уку* произнести́ за́говор; *чәчәк теле* за́говор от о́спы

телазар *сущ. диал.* лентя́й-демаго́г; него́дник, бо́йкий на язы́к

телэгәнчә *нареч.* ско́лько хо́чется; вво́лю; вдо́воль; ~ *аша* ешь вво́лю; *см. тж.* **җаны телэгәнчә**

телә|к *сущ.* **1.** жела́ние, охо́та; страсть; *~к ул — тели белсәң ~к, тели белмәсәң — имгәк* (*посл.*) охо́та пу́ще неволи (*букв.* страсть — добро́, е́сли цель благоро́дна, е́сли нет — беда́); *ихтыярың — ~гең, сайладың да тулэдең* (*погов.* -*прибаутка*) как хо́чешь — захо́чешь, выбира́й и заплати́ (вы́берешь и запла́тишь) **2.** 1) пожела́ние (вы́сказанное у́стно); *изге ~к* до́брое пожела́ние 2) языческая моли́тва; *см. тж.* **келәү 3.** цель, наме́рение; *~ккә иресү* дости́чь свое́й це́ли; *яхшы ~к белән* с до́брыми наме́рениями; *яхшы ~к — ярты бәхет* (*посл.*) до́брое наме́рение — полови́на сча́стья □ **(кемнең) ~ге белән** по пожела́нию *кого*; **~ктә тору (калу)** моли́ться *за кого*; быть (остава́ться) в до́бром пожела́нии *к кому; изге ~ктә торам* остаю́сь в доброжела́тельности (*к тебе*); молю́сь (*за тебя*) ◊ **~ккә килү** приходи́ть/прийти́ в полово́е возбужде́ние (*преимущ. о самках животных*)

теләкә *сущ. см.* **тәләкә**

теләктәш *предик.* **(-га ~)** сочу́вствующий; солида́рный, сочу́вствует *кому*; солида́рен *с кем; аларга ~*

кешеләр сочу́вствующие им лю́ди; *ул безгә ~* он сочу́вствует нам; он с на́ми солида́рен || *сущ.* **1. (-ның ~е)** сторо́нник *кого* **2.** сора́тник, сотова́рищ, сою́зник; друг; *~ләр* сотова́рищи, друзья́ **3.** доброжела́тель; *~егез* ваш доброжела́тель

теләктәшлек *сущ.* сочу́вствие, солида́рность; доброжела́тельность; *~ итү* сочу́вствовать; выка́зывать/вы́казать солида́рность

теләктәшче *сущ. редко* доброжела́тель

теләкче *сущ. редко см.* **догачы**; *үзең үлгәч, ~ң калсын* (*посл.*) пусть по́сле тебя́ оста́нется кто́-нибудь, кто помо́лится за тебя́

теләндерү *понуд. от* **теләнү**; заста́вить попроша́йничать

теләнелгән *прил.* жела́емый, жела́нный; *~ нәтиҗә* жела́емый результа́т

теләнелү *неперех. редко* **1.** быть жела́емым **2.** *безл.* приходи́ться/прийти́сь попроша́йничать

теләнү *неперех.* **1.** ни́щенствовать || ни́щенство, ни́щенствование, выпра́шивать/вы́просить; *мәхәббәтне ~еп алмыйлар* (*посл.*) любо́вь не выпра́шивают (*как подаяние*) **2.** *неодобр.* попроша́йничать, надоеда́ть выпра́шиванием || попроша́йничание; *теләнченең әңгәмәсе ~ү белән башлана, ~ү белән тәмамлана* (*посл.*) бесе́да ни́щего начина́ется с попроша́йничания и конча́ется попроша́йничанием

теләнче *сущ.* **1.** ни́щий, попроша́йка; побиру́шка; *см. тж.* **саилче, хәерче**; *~нең байлыгы — таягы да тамагы* (*посл.*) у ни́щего всё добро́ — па́лка да жева́лка; *~гә кәкре кыяр* (*погов.*) на́ тебе, бо́же, что нам него́же (*букв.* ни́щему — коря́вый огуре́ц) **2.** *перен.* голя́к, бедня́к **3.** *перен.* попроша́йка; тот, кто постоя́нно кля́нчит □ **~ көненә калу** кра́йне обедне́ть; пойти́ с сумо́й; **~ тамак 1.** приживал, прижива́льщик; прижива́лка **2.** домовни́к, домовни́ца *обл.* (*тот, кто ходит по домам в надежде поесть что-л.*)

теләнчеләү 1. *неперех.* попроша́йничать, ни́щенствовать **2.** *перех.* кля́нчить; *акча ~* кля́нчить де́ньги

теләнчелек *сущ.* **1.** ни́щенство, попроша́йничество (*как занятие*); *теленсәң дә, ~кә барма* (*посл.*) будь в лохмотьях, но не стань ни́щим **2.** *перен.* попроша́йничество □ **~ итү** ни́щенствовать; занима́ться попроша́йничеством

теләр-теләмәс *нареч.* не́хотя, неохо́тно; без жела́ния *прост.*; *бик теләр-теләмәс җавап бирде* отве́тил о́чень неохо́тно

теләтү *редко понуд. от* **теләү**; заставля́ть проси́ть *кого*

тел|әү *перех.* **1. 1)** жела́ть/пожела́ть || жела́ние, пожела́ние; хоте́ть/захоте́ть || хоте́ние; *ни ~исең, шуны ал* что хо́чешь, то и бери́; *дошманга үлем ~әгәнче, үзеңә гомер ~ә* (*посл.*) чем жела́ть врагу́ сме́рти, пожела́й себе́ жи́зни 2) вы́сказать/выска́зывать || выска́зывание пожела́ния (*доброго или злого*); жела́ть, пожела́ть || пожела́ние *кому что; изге теләк ~әү* выска́зывать до́брые пожела́ния; пожела́ть до́брого; *~әмә озын җәй, ~ә җылы җәй* (*посл.*) не пожела́й до́лгого ле́та, а пожела́й тёплого **2.** *диал.* моли́ться **3.** *в ф. соглас. накл. в препозиции к вопр. сл. выражает субъективную произвольность и переводится конструкциями с частицей* уго́дно, *~әсә кайда* где (*ему*) уго́дно, там и; *~әсә кайдан* отку́да (*ему*) уго́дно, отту́да и; *~әсә кая* куда́ (*ему*) уго́дно; туда́ и; *~әсәм кая* куда́ мне уго́дно (куда́ хочу́), туда́ и; *~әсәң кая* куда́ тебе́ уго́дно (куда́ хо́чешь), туда́ и □ **~әгән(е) бер 1.** кто́ бы ни захоте́л, ка́ждый кому́ не лень **2.** любо́й, вся́кий; *~әгән бер эшкә тотына* берётся за вся́кую рабо́ту; **~әп алу** выма́ливать/вы́молить; **~әсә кем** вся́кий; ка́ждый; любо́й; кто уго́дно (без разбо́ра); *~әсә кемгә ышанма* не доверя́й ка́ждому встре́чному; **~әсә ничек 1.** как ему́ заблагорассу́дится; как ему́ уго́дно **2.** любы́м путём; *~әсә ничек тапсын* пусть найдёт любы́м путём **3.** как попа́ло; **~әсәң ништә 1.** что хо́чешь, то и де́лай **2.** хоть плачь! **~әсә ~әмәсә дә** во́лей-нево́лей; рад не рад; **~әсәң--әмәсәң дә** хо́чешь не хо́чешь; хошь не хошь *прост.*

теләү *сущ.* язы́ческое моле́ние; язы́ческая моли́тва *см. тж.* **келәү**; *~ теләү* соверши́ть язы́ческое моле́ние; моли́ться по-язы́чески

теләүлек *сущ. этногр.* язы́ческий и́дол (*в виде деревянного столба с двойной развилиной сверху или с надетым на верх черепом лошади*) ◊ **~ кебек кату (тору)** стоя́ть болва́ном; стоя́ть как бы безуча́стным к окружа́ющему; **~кә терәүлек 1.** *этногр.* жертвоприноше́ние и́долу **2.** *перен.* по́мощь нену́жному де́лу; по́мощь тому́, кто сам занима́ется пустяка́ми

теләш|ү *взаимно-совм. от* **теләү**; *тартай теләгәнне ~кән бүдәнә ачтан үләр* (*посл.*) пе́репел, моля́щийся в уго́ду коростелю́, умрёт с го́лоду (*о пренебрежении собственными интересами*)

телбизәк *сущ.* идио́ма, троп и т. п. (*украшающие речь*)

телбистә *сущ. разг. см.* **тел бистәсе** (*см.* **тел**)

телбистәлек *сущ. см.* **телбистәчелек**

телбистәчелек *сущ.* **1.** красноба́йство **2.** пустозво́нство, пустосло́вие; *~кә салыну* предава́ться пустосло́вию (*отвлекаться от дела*)

телгәләп|ү 1. *страд. от* **телгәләү**; расщепля́ться, разреза́ться, исполосова́ться **2.** ветша́ть, излохма́титься, измоча́литься; *~гән кием* обветша́лая (ве́тхая) оде́жда, лохмо́тья **3.** *перен. см.* **өзгәләнү** 3; *күңелем ~ә* душа́ моя́ разрыва́ется

телгәләү *многокр. от* **телү 1.** ре́зать, выреза́ть многокра́тно; раскромса́ть **2.** *перен.* исполосова́ть (плёткою) **3.** *перен.* причиня́ть/причини́ть ре́зкую боль (*душе*); *см. тж.* **өзгәләү**

телгәч *сущ. редко* ру́пор (*о человеке, который распространяет чужие слова*); *дошман ~е* ру́пор врага́

телгеч *сущ. диал.* нож, но́жик (*употребляющийся для выщепывания, нащепывания лучин, вырезания ремней и т. п.*); *теле ~ кебек* язы́к его́ — что нож о́стрый

телдәнге *прил. неол.* у́стный, изу́стный; *~ сынау* у́стный экза́мен

телдәр *прил.* **1.** рече́стый, говорли́вый, многорече́вый; *~ хатын* рече́стая же́нщина **2.** красноречи́вый ‖ говору́н; красноба́й; *ачыккан угры булыр, ачынган ~ булыр* (*посл.*) голо́дный ста́нет во́ром, оби́женный ста́нет красноречи́вым (*краснобаем поневоле*)

телдәрлән|ү *неперех.* **1.** 1) становя́ться/стать (сли́шком) красноречи́вым, многорече́вым; краснобайствовать 2) проявля́ть/прояви́ть многорече́вость (*с претензией на красноречие*); *~мә, зинһар* пожа́луйста, не говори́ так краси́во **2.** пререка́ться; препира́ться

телдәрлек *сущ.* **1.** многорече́вость; краснобайство, красноречи́вость **2.** скло́нность к пререка́ниям, к препира́тельству □ **~ итү 1.** занима́ться краснобайством **2.** пререка́ться, препира́ться

телдерү *понуд. от* **телү**; заставля́ть ре́зать (на по́лосы)

теле- *первая часть сл. слов, относящихся к телевидению и управлению по радио* теле-: телеспекта́кль, телесту́дия; телемеха́ника, телесигна́л и т. п.

телеви́дение *сущ.* телеви́дение; ~ *аша* че́рез телеви́дение, по телеви́дению

телевизио́н *прил. в разн. знач.* телевизио́нный; ~ *тапшыру* телевизио́нная переда́ча; ~ *фильм* телевизио́нный фильм

телеви́зия *сущ. см.* **телеви́дение**

телеви́зор *сущ.* телеви́зор; *~да курсәттеләр* показа́ли по телеви́зору

телеграм *сущ. прост.* **1.** *см.* телегра́мма **2.** *уст.* телегра́ф; телегра́фная ли́ния; *олы юллар буйлап ~ Мәскәүләрдән бардыр Казанга* (*песня*) по столбовы́м доро́гам идёт телегра́фная ли́ния от Москвы́ до Каза́ни □ ~ **баганасы** *уст.* телегра́фный и́ли телефо́нный столб; ~ **сугу (бирү, җибәрү)** посыла́ть, посла́ть телегра́мму

телегра́мма *сущ.* телегра́мма; *ерактан ~ алу* издалека́ пришла́ телегра́мма

телеграф *сущ. в разн. знач.* телегра́ф || телегра́фный; ~ *тасмасы* телегра́фная ле́нта; ~ *чыбыгы* (*чыжымы*) телегра́фный про́вод (телегра́фные провода́)

телеграфист *сущ.* телеграфи́ст; ~ *булып эшли* рабо́тает телеграфи́стом

телеграфи́стка *сущ. редко* телеграфи́стка

телеграфи́я *сущ. тех.* телеграфи́я

телеграфчы *сущ.* **1.** челове́к, рабо́тающий в систе́ме и́ли в о́бласти телегра́фного сообще́ния **2.** *см.* **телеграфист**

телем *сущ.* **1.** ло́мо́ть, ло́мтик, отре́занный кусо́к (*арбуза, булки, огурцов*); *бер ~ ипи* кусо́к хле́ба **2.** *редко* полоса́, ле́нта || *прил.* отре́занный; ~ *ипи* отре́занный кусо́к хле́ба

телеме́трик *прил.* телеметри́ческий; ~ *җайланма* телеметри́ческое устро́йство

телеме́трия *сущ. тех.* телеме́трия

телемеха́ник *сущ.* телемеха́ник (*специалист по телемеханике*) || *прил.* телемехани́ческий; ~ *аппаратура* телемехани́ческая аппарату́ра

телемеха́ника *сущ. тех.* телемеха́ника

телемләнү *страд. от* **телемләү**; разреза́ться; быть разре́занным на куски́

телемләп *нареч.* куска́ми; по куску́ (куска́м); ~ *өләшү* раздава́ть куска́ми

телемләү *перех.* ре́зать, разре́зать, наре́зать || ре́зка, нареза́ние на куски́, ло́мтики

телемле *прил.* наре́занный ломтя́ми, ло́мтиками, в ломтя́х, в ло́мтиках

телем-телем *прил.* ломтя́ми, ло́мтиками; в наре́занном ви́де; в наре́зке; *телем-телем ипи* хлеб в наре́зке (наре́занный ломтя́ми) || *нареч.* ло́мтиками, ломтя́ми; *телем-телем кисү* наре́зать на ряд (мно́жество) куско́в

теленмә *прил. см.* **теленмәле** □ ~ **баллут** *бот.* ясно́тка нарезна́я

теленмәле *прил.* рассечённый; ~ *яфрак* рассечённый лист

телен|үү **1.** *страд. от* **телү**; разреза́ться, быть разре́занным; изреза́ться, быть изре́занным; отщепля́ться, быть отщеплённым (*о лучине*) **2.** *перен. разг.* 1) излохма́титься (*об одежде*) 2) быть в лохмо́тьях (*о человеке*)

телепат *сущ.* телепа́т (*человек, обладающий телепатией*)

телепа́тик *прил.* телепати́ческий; ~ *сеанс* телепати́ческий сеа́нс

телепа́тия *сущ. психол.* телепа́тия (*способность узнавать мысли, настроения или состояние другого человека на расстоянии*)

телескоп *сущ. тех.* телеско́п; ~ *аша карау* смотре́ть че́рез телеско́п

телеско́пик *прил. тех.* телескопи́ческий; ~ *җайланма* телескопи́ческое устро́йство

телескопи́я *сущ. тех.* телескопи́я

телесту́дия *сущ.* телесту́дия (телевизио́нная сту́дия)

телетамашачы *сущ. неол.* телезри́тель

телефон *сущ.* телефо́н || телефо́нный; ~ *аркылы* (*~да*) *сөйләшү* разгова́ривать по телефо́ну; ~ *аппараты* телефо́нный аппара́т; ~ *чыбыклары* телефо́нные провода́

телефон-автомат *сущ.* телефо́н-автома́т

телефонист *сущ.* телефони́ст; ~ *булып эшли* рабо́тает телефони́стом

телефони́стка *сущ.* телефони́стка

телефонограмма *сущ.* телефонограмма; ~ *алу* (*кабул итү*) принима́ть телефонограмму

телефончы *сущ.* **1.** *разг.* телефони́ст, телефони́стка **2.** челове́к, рабо́тающий в систе́ме телефо́нной свя́зи

теллән|үү *неперех.* **1.** (*вдруг*) заговори́ть; *см. тж.* **телгә килү**; *ташлар, агачлар сөйләшәләр ~еп* ка́мни и дере́вья заговори́ли **2.** станови́ться/стать (*чересчур, неуместно*) разгово́рчивым; разговори́ться; мно́го говори́ть; *ник бик ~еп торасың әле син?* что э́то ты так разговори́лся? **3.** *см.* **телләшү** **4.** говори́ть || говоре́ние определённого ка́чества языко́м; *татлы ~ү* быть сладкоречи́вым; *усал ~ү* говори́ть зади́ристо (зади́ристым языко́м)

телләнүчән *прил.* зади́ристый, крикли́вый

теллә́ү *перех.* ре́зать/вы́резать, де́лать вы́резы || вырезáние по краям; де́лать/сде́лать волни́стые края́; *шәл читен ~* де́лать волни́стые края́ пухо́вому платку́

телләш|үү *неперех.* вступа́ть/вступи́ть || вступле́ние в пререка́ние (пререка́ния), в спор (*с которыми не положено вступать в спор*); *нигә ~еп торасың шуның белән?* чего́ ты с э́тим вступа́ешь в спор?

телләшүчән *прил.* крикли́вый, языка́стый; зади́ристый на язы́к

телле *прил.* **1.** *разг.* име́ющий язы́к, язычо́к *в разн. знач.*; с определённым языко́м; *көмеш ~* с серебряным язычко́м (*о колокольчике*) **2.** 1) владе́ющий, облада́ющий языко́м определённого хара́ктера, коли́чества и́ли ка́чества 2) -язы́чный; *ике ~* двуязы́чный; *явыз (усал) ~* злоязы́чный; *татар ~* татароязы́чный, говоря́щий на тата́рском языке́ (*население*) **3.** *перен.* уме́ющий говори́ть (*с начальством*); зуба́стый, бо́йкий на язы́к; *~рәк кешене җибәрергә кирәк* на́до посла́ть челове́ка побойче́е на язы́к

теллелек *сущ.* **1.** владе́ние, облада́ние определённого ка́чества языко́м; -язы́чие; *ике ~* двуязы́чие; *усал ~* злоязы́чие **2.** *перен.* уме́ние говори́ть, разгова́ривать (*с разными людьми*); зуба́стый

телле-телле *прил.* волни́стый, изре́занный (*о краях, линиях чего-л.*); зу́бчатый; *телле-телле яфрак* лист с волни́стыми, волни́сто-изре́занными края́ми

телле-тешле *прил.* **1.** лихо́й, не ро́бкого деся́тка; тако́й, что па́лец в рот не клади́ **2.** злой, злоязы́чный; *телле-тешле кешеләр түгел без* мы не злоязы́чные лю́ди

теллин-теллин, теллин-теллим *подр.* **1.** *звону далёких колоколов или колокольчиков* динь-ди́нь **2.** *бренчанию, треньканью музыкальных инструментов* треньбре́нь, трень-тре́нь; *теллин-теллин уйныйдыр, үләм диди елыйдыр* игра́ет трень-тре́нь, пла́чет, говоря́ «умру́» (*загадка о скрипке*)

телмәкер *прил.* **1.** (*очень уж, чересчур*) речи́стый, говорли́вый; красноречи́вый **2.** злоречи́вый; *~гә тап булма* не попада́йся к злоречи́вому || *сущ.* говору́н, красноба́й (*не очень достойный доверия*); демагóг; *~ләр бездә күп* мнóго у нас говорунóв

телмәкерлек *сущ.* речи́стость, говорли́вость; краснобáйство □ **~ итү 1.** ударя́ться/уда́риться в краснобáйство, краснобáйствовать **2.** му́дрствовать лука́во

телмәр *сущ. диал. ист.* **1.** дли́нная речь; *~ сөйләү* говори́ть, произноси́ть дли́нную речь **2.** *см.* **телмәрче** 2

телмәрче *сущ.* **1.** *диал.* ора́тор **2.** *ист.* певéц, бард, воспроизводя́щий, исполня́ющий произведéния други́х певцóв, бáрдов (*певец, бард низшего — третьего ранга после* **чәчән** *и* **бәхши**) **3.** *этногр.* гада́льщик, гада́ющий по пéнию птиц; человéк, растолкóвывающий пéние птиц; *тиле ~ булыр* (*посл.*) гада́льщиком по пéнию птиц станóвится (*лишь*) блажéнный

телмәрчен *сущ. диал.* **1.** *см.* **телмәрче** 2 **2.** болóтная (зелёная) лягýшка («пою́щая» весно́й)

телмәт *прил. диал.* сладкоречи́вый, велеречи́вый; *~ кеше* велеречи́вый человéк

телмәтлек *сущ. диал.* сладкоречи́вость, велеречи́вость

телогрéйка *сущ.* телогрéйка

телогрéйкалы *прил.* **1.** с телогрéйкой **2.** в телогрéйке, одéтый в телогрéйку

телсез *прил.* **1.** *в разн. знач.* без языкá, язычкá (без стрéлки, мáятника и т. п.; *см.* **тел**); лишённый языкá (язычкá); безъязы́кий; *бөҗәкләр — ~ хайваннар* насекóмые — живóтные без языкá; *~ сәгать* часы́ без мáятника **2.** *прям., перен.* немóй; бессловéсный, безмóлвный; *~ атка кулсыз бул* (*посл.*) в отношéнии бессловéсной лóшади будь безрýким (*не бей*); *гайбәт теле озын була, дәреслек ~ булгач* (*посл.*) злы́е языки́ быва́ют дли́нными, éсли прáвда немá **3.** *перен.* безъязы́кий, безъязы́чный, крóткий; *гаиләдә ире күзсез, хатыны ~ булсын* (*посл.*) в семьé муж дóлжен быть безглáзым (*т. е. не замечать лишнего, мелочей*), женá — без языкá **4.** *в знач. сущ.* немóй; *~лар мәктәбе* шкóла немы́х; *акыллы ~ акылсыз телледән яхшы* (*посл.*) ýмный немóй лýчше говоря́щего дурака́ □ **~ калу 1.** *см.* **телдән калу 2.** онемéть, остолбенéть (*от изумления, гнева и т. п.*)

телсезләндер|ү *перех.* лиша́ть да́ра ре́чи; *бу хәбәр мине ~де* э́та весть лиши́ла меня́ да́ра ре́чи

телсезлән|ү *неперех.* **1.** онемéть, переста́ть говори́ть; лиша́ться да́ра ре́чи **2.** *перен.* станови́ться/стать безъязы́ким, молчали́вым; опаса́ться говори́ть ли́шнего; *~еп йөрмә* не будь (*столь*) безъязы́ким

телсезлек *сущ.* **1.** немотá, отсýтствие да́ра ре́чи **2.** бессловéсность, крóтость **3.** *редко* незна́ние языкá; *~ аяктан ега* незна́ние языкá си́льно меша́ет (*букв.* ва́лит с ног)

телсез-өнсез *прил. прям., перен.* бессловéсный; *телсез-өнсез калу см.* **телсез калу**

телсез-тешсез *прил. см.* **тел-тешсез**

телсез-чукрак *сущ.* глухонемóй человéк || *прил.* глухонемóй

тел-теш *сущ. собир.* попрёк; притеснéния, принижéния, оскорблéния; унизи́тельные пересýды; *кулың гел эштә, үзең тел-тештә* (*погов.*) рýки в рабóте, а сам (сама́) в притеснéниях (*в унижении*) □ **тел-теш алу** подверга́ться/подве́ргнуться попрёкам и притеснéниям; **тел-теш тидерү** *см.* **тел тидерү**

тел-тешле *прил. см.* **телле-тешле**

тел-тешсез *прил.* **1.** миролюби́вый, ми́рный (*о человеке*); не скло́нный к ссóрам и ра́спрям **2.** заби́тый, запýганный; *тел-тешсез булып беттек* совсéм запýганными мы ста́ли

тел|ү *перех.* **1.** (*продольно*) разре́зать || разреза́ние; сре́зать || среза́ние по ро́вной ли́нии (*кожу на ремни*); щепа́ть || щепа́ние (*лучины*); наре́зывать/нареза́ть || нареза́ние (*хлеба, сыра и т. п.*) на ло́мтики, на ро́вные кýски; *~еп бирү* нареза́ть и отда́ть *кому-л.* **2.** разреза́ть, кромса́ть, искромса́ть || разреза́ние, кромса́ние; *см. тж.* **телгәләү 3.** *перен.* бить, сечь, стега́ть/стегнýть || битьё, сéчка, стега́ние (*кнутом, плёткой*); *~әләр генә* так и стега́ют, так и секýт □ **~еп алу** вырезáть (*часть*); **~еп бирү** отрéзать *кому*; **~еп җибәрү** полоснýть; **~еп ташлау** раскромса́ть, поразрéзать (*на куски*)

телчән *прил.* **1.** языка́стый, зуба́стый, бóйкий на язы́к; *батыр яуда, ~ дауда беленер* (*посл.*) геро́й познаётся в бою́, языка́стый — в ра́спре **2.** *см.* **телле-тешле**

телчәнлән|ү *неперех.* станови́ться/стать бóйким на язы́к; *~еп китү* (вдруг) стать бóйким на язы́к

телчәнле|к *сущ.* зуба́стость; бóйкость языка́ (на язы́к); *~ге бар* бóйкость на язы́к у негó (у неё) име́ется; язы́к у негó бóйкий; *~к күрсәтү* показáть (вы́казать) бóйкость языка́

телче *сущ.* **1.** языковéд, лингви́ст; *~ләр конференциясе* конферéнция языковéдов **2.** учи́тель (преподава́тель) языка́

телчек *сущ.* **1.** *уменьш. от* **тел**; язычóк **2.** *анат.* кли́тор

тельня́шка *сущ.* тельня́шка; *~ кигән* в тельня́шке; одéтый в тельня́шку

тельня́шкалы *прил.* в тельня́шке; *~ егетләр* мóлодцы в тельня́шках

тéма *сущ.* тéма; *лекциянең ~сы* тéма (да́нной) лéкции; *сүз ~сы* тéма разговóра; (*фәлән*) *~га* (*темасына*) на такýю-то тéму; на тéму *о ком, о чём*

тéмалы *прил.* с (*определённой*) тéмой; -тéмный; *шәп ~ доклад* доклáд с хорóшей тéмой (на хорóшую тéму); *күп ~* многотéмный (*о программе*)

тéмалык *прил.* доста́точный для (на) (*определённого количества*) тéмы (тéму, тем); *биш ~ материал* материа́л, доста́точный для пяти́ тем

тéмалылык *сущ.* тéмность; *күп ~* многотéмность

тема́тик *прил.* тематúческий; *~ план* тематúческий план

тема́тика *сущ. в разн. знач.* тема́тика; (*фәлән*) *~га* на (*определённую*) тема́тику

тема́тикалы *прил.* с (*определённой*) тема́тикой; *киң ~* с широ́кой тема́тикой

тембр *сущ. муз., физ.* тембр (*голоса, звука*) || тéмбровый; *тубән ~да* в ни́зком тéмбре; *~ аермалыклары* тéмбровые разли́чия (гóлоса)

тéмбрлау *перех.* тембри́ровать || тембри́рование (*музыкального инструмента*)

тéмбрлы *прил.* **1.** с (*определённым*) тéмбром; имéющий тембр (*определённого качества*); *йомшак ~* с мя́гким тéмбром **2.** тéмбровый; *өч ~ инструмент* трёхтéмбровый инструмéнт

теми *сущ. диал.* притяза́ние, посяга́ние; *см. тж.* **тәмгы** □ **~ен сузу** притяза́ть *на что-л.*

темп *сущ.* темп; *эш ~ы* темп рабóты; *~ белән* с тéмпом

тéмпера *сущ.* тéмпера (*разновидность художественных красок; произведение, выполненное такими красками*)

темпера́мент *сущ.* темпера́мент; *флегматик (сангвиник, меланхолик, холерик) ~лар* флегмати́чные (сангвини́ческие, меланхоли́ческие, холери́ческие) темпера́менты; *кызу ~ белән* со зно́йным темпера́ментом; о́чень темпера́ментно

темпера́ментлы *прил.* **1.** темпера́ментный (*о человеке*); *~ публицист* темпера́ментный публици́ст; *кайнар ~ кеше* челове́к горя́чего темпера́мента **2.** темпера́ментный, горя́чий (*о речи, пляске, любви и т. п.*) □ **~ нотык** жа́ркая речь

темпераментлылы|к *сущ.* темпера́ментность; *характерның ~гы* темпера́ментность хара́ктера

температур *прил.* температу́рный, свя́занный с температу́рой; *~ үзгәрешләр* температу́рные измене́ния

температу́ра *сущ. в разн. знач.* температу́ра || температу́рный; *эрү ~сы* температу́ра плавле́ния; *югары ~* высо́кая температу́ра; *~ны үлчәү* измеря́ть температу́ру; *~ тирбәлүләре* температу́рные колеба́ния (перепа́ды) □ **~ белән яту** лежа́ть с температу́рой (*о больном*); температу́рить

температу́ралы *прил.* **1.** с (*определённой*) температу́рой, име́ющий определённую температу́ру; -температу́рный; *түбән ~* с ни́зкой температу́рой; *югары ~* высокотемпературный **2.** температу́рный (*с жаром в теле*); *~ авырулар* температу́рные (температу́рящие) больны́е

темсен|ү *неперех. диал.* притяза́ть, посяга́ть *на, вожделе́ть кого, что* || притяза́ние, вожделе́ние; *юкка ~мә дә, көрсәнмә дә (посл.)* не притяза́й на то, что невозмо́жно; не горю́й о том, чего́ нет

тенденциоз *прил.* тенденцио́зный, не объекти́вный; *~ мәкалә* тенденцио́зная статья́ □ **~ рәвештә** тенденцио́зным о́бразом, тенденцио́зно

тенденциозлык *сущ.* (*нежелательная*) тенденцио́зность; *сәнгатьтә ~* тенденцио́зность в иску́сстве

тенде́нция *сущ. в разн. знач.* тенде́нция; *яңа ~ләр* но́вые тенде́нции; *сулльык ~се* тенде́нция левизны́; ле́вая тенде́нция; *~ белән сөйләү* говори́ть с тенде́нцией (тенденцио́зно)

тенде́нцияле *прил.* **1.** с определённой тенде́нцией, име́ющий определённую тенде́нцию; *прогрессив ~ хәрәкәт* (обще́ственное) движе́ние с прогресси́вной тенде́нцией **2.** *см.* **тенденциоз**

тенде́нциялелек *сущ.* **1.** *см.* **тенденциозлык 2.** облада́ние тенде́нцией, напра́вленностью (*в какую-то сторону*)

тенде́нциячел *прил.* тенденцио́зный, небеспристра́стный; необъекти́вный; *~ кеше* необъекти́вный челове́к

тенде́нциячелек *сущ.* (*отрицательная, нежелательная*) тенденцио́зность

тенде́нциячеллек *сущ.* **1.** скло́нность проявля́ть тенденцио́зность, небеспристра́стность **2.** *см.* **тенденцияле**

те́ндер *сущ. тех.* те́ндер; *паровоз ~ы* паровозный те́ндер

те́ндерлы *прил.* с те́ндером, име́ющий те́ндер; те́ндерный (*паровоз*)

те́ннис *сущ. спорт.* те́ннис || те́ннисный; *~ уйнау* игра́ть в те́ннис; *~ мәйданы* те́ннисная площа́дка; площа́дка для игры́ в те́ннис

теннисист *сущ. см.* **теннисчы**

те́нниска *сущ.* те́нниска (*вид одежды*); *~ кигән* в те́нниске

те́ннисчы *сущ.* теннисист; *~лар командасы* кома́нда теннисистов

те́нор *муз. сущ.* те́нор; *~ белән җырлый* поёт те́нором || *прил.* тенорово́й; *~ тавыш* тенорово́й го́лос

те́норлы *прил.* с те́ном, тенорово́й; *~ җырчылар* певцы́-тенора́

тент *сущ.* тент; *~ астында* под те́нтом

тентел|ү *страд. от* **тентү**; обы́скиваться, быть обы́скиваемым (обша́риваемым)

тентен|ү 1. *возвр. от* **тентү**; обы́скивать самого́ себя́ **2.** *разг.* ша́рить, обша́ривать, ла́зить (*везде, непозволительным образом*); *нишләп ~әсең син монда?* что ты тут обша́риваешь?

тентетү *понуд. от* **тентү**; заставля́ть/заста́вить и́ли вели́ть сде́лать о́быск

тентешү *взаимно-совм. от* **тентү 1.** обы́скивать || о́быск (*друг друга*) **2.** помога́ть/помо́чь обы́скивать || по́мощь в о́быске

тент|ү *перех.* обы́скивать/обыска́ть; обша́ривать/обша́рить || обы́скивание, обша́ривание; *бар җирне ~едек* обыска́ли всё круго́м || *сущ.* о́быск; обы́скивание, обша́ривание; *~ ясау* произвести́ о́быск □ **~ кертү** устра́ивать/устро́ить о́быск

теңг *подр. звону колокольчиков* дзинь; звяк! □ **теңг итү** зва́кнуть

теңгел *сущ.* **1.** ось, шпенёк, серде́чник (*небольших размеров*); *кайчы ~е* шпенёк но́жниц **2.** небольшо́е колёсино, ро́лик, подши́пник

теңгелд|әү *неперех.* (*продолжительно*) негро́мко звене́ть || звон (*колокольчиков, бубенчиков*); *шөлдерләр ~и* бубе́нчики позва́нивают

теңгел-теңгел *подр. см.* **теңг-теңг** (*но более звучное*) □ **теңгел-теңгел итү** зву́чно звене́ть (*о колокольчиках*)

теңкә *сущ.* **1.** (*душевная*) бо́дрость, кре́пость (*духа*); душе́вные си́лы; *~м калмады* я оконча́тельно обесси́лел (*душой*); я лиши́лся душе́вных сил **2.** *диал.* 1) нерв, не́рвы 2) не́рвная боле́знь — тик, подёргивание век; *~ булган* заболе́л подёргиванием век □ **~ кору** вы́мотаться, обесси́лить, лиши́ться (*душевных*) сил; **~ корыту** выма́тывать/вы́мотать, изму́чить; изнуря́ть/изнури́ть (*душу*); **~гә тию 1.** донима́ть, докуча́ть, си́льно надоеда́ть (*замечаниями, придирками, просьбами, жалобами и т. п.*); зуде́ть; трепа́ть не́рвы (*душу*) **2.** осточерте́ть (*о работе*)

теңкәләү *неперех. диал.* заболе́ть подёргиванием век, ти́ком

теңг-теңг *подр. продолжительному звону, позваниванию колокольчиков* динь-ди́нь, дзинь-дзи́нь

теодолит *сущ. тех., геол.* теодоли́т; *~ белән үлчәү* измеря́ть теодоли́том

теокра́тик *прил.* теократи́ческий; *~ дәүләт* теократи́ческое госуда́рство

теокра́тия *сущ.* **1.** теокра́тия (*верхушка духовенства*) **2.** теокра́тия (*господство духовенства в государстве*)

теоло́г *сущ.* теоло́г, теоре́тик по теоло́гии

теоло́гик *прил.* теологи́ческий; *~ карашлар* теологи́ческие взгля́ды; *~ әдәбият* теологи́ческая литерату́ра

теоло́гия *сущ. рел.* теоло́гия, богосло́вие (*учение о боге и догмах религии*)

теоре́ма *сущ. мат.* теоре́ма; *~ны исбатлау* дока́зывать теоре́му

теоре́тик *сущ.* теоре́тик; знато́к тео́рии || *прил.* теорети́ческий; *~ журнал* теорети́ческий журна́л; *~ хезмәт* теорети́ческий труд; *~ хәзерлек* теорети́ческая подгото́вка

тео́рия *сущ. в разн. знач.* тео́рия; *тел ~се* тео́рия языка́; *әдәбият ~се* тео́рия литерату́ры; *нисбилек ~се* тео́рия относи́тельности; *~дән чыгып* исходя́ из тео́рии

тео́рияче *сущ.* 1. теоре́тик 2. приве́рженец *какой-л.* тео́рии; *саф сәнгать ~ләре* приве́рженцы тео́рии чи́стого иску́сства

тео́риячелек *сущ.* 1. 1) теорети́зм 2) заня́тие тео́рией 2. увлече́ние тео́рией; стремле́ние приме́нять тео́рию, исходи́ть из тео́рии

тепли́ца *сущ.* тепли́ца || тепли́чный; *~ культуралары* тепли́чные культу́ры

тепли́цачы *сущ.* рабо́тник (рабо́тающий) в тепли́чном хозя́йстве

тепли́цачылык *сущ.* 1. тепли́чное де́ло 2. тепли́чное хозя́йство || тепли́чный; *~ тармагы* тепли́чная о́трасль

теплоход *сущ. тех.* теплохо́д || теплохо́дный

теплу́шка *сущ. тех., ист.* теплу́шка (*отапливаемый товарный вагон, приспособленный для перевозки людей*)

теп-текә *прил. превосх. ст. от* **текә**; соверше́нно круто́й, о́чень круто́й; *теп-текә ярлау* соверше́нно круто́й склон || кру́то; *юл теп-текә менә* доро́га поднима́ется о́чень кру́то

теп-тере *прил. превосх. ст. от* **тере**; соверше́нно живо́й; живёхонький; *теп-тере килеш алдыбызга килеп басты* предста́л пе́ред на́ми соверше́нно живо́й

терапевт *сущ. мед.* терапе́вт; *~ булып эшли* рабо́тает терапе́втом

терапе́втик *прил.* терапевти́ческий; *~ журнал* терапевти́ческий журна́л

терапи́я *сущ. мед.* терапи́я || терапевти́ческий; *~ бүлеге* терапевти́ческое отделе́ние

терә, терәк *частица усил.* (*употр. после указательных мест.* **менә, әнә**) вон, вот тот; *менә ~* вот э́тот; *менә ~ сиңа!* вот те (тебе) на́!; *кулың менә ~, эщең әнә ~, тотын җәһәтрәк* (*посл.*) вот твой ру́ки, а вот рабо́та, приступа́й, не ме́шкай

терәвеч *сущ.* 1. подпо́ра, подпо́рка, па́лка для подпира́ния (*ворот, двери и т. п.*) 2. со́шка, сошни́к (*пулемёта*)

терәгеч *сущ.* 1. *см.* **терәвеч** 1 2. упо́р, опо́ра *для чего*; спи́нка (*стула*) || *прил.* слу́жащий подпо́ркой, опо́рой; опо́рный (*столб, бык*)

терә|к *сущ.* 1. опо́ра, подпо́рка; сто́йка, упо́р; столб; коло́нна; *күпер ~кләре* быки́ моста́ 2. *разг. см.* **терәвеч** 1; 3. *перен.* опо́ра, защи́тник; столп (*государства*); *йорт ~ге ир булыр* (*доблестный*) мужчи́на — опо́ра семьи́ || *прил. в разн. знач.* опо́рный; *~к багана* опо́рный столб; *~к база* опо́рная ба́за; *~ пункт* опо́рный пункт

терәкле *прил.* 1. с опо́рой; име́ющий опо́ру, подпо́рку; *~ күпер* мост с опо́рами (быка́ми) 2. *см.* **терәлгече**; *~ чана* са́ни с поло́зьями

терәксез *прил.* 1. *в разн. знач.* не име́ющий (лишённый) опо́ры, безопо́рный 2. *см.* **терәлгесез**; *~ урындык* сиде́нье без спи́нки

терәлгеч *сущ.* опо́ра, спи́нка (*сиденья*); *урындыкның ~е биек* спи́нка у сту́ла высо́кая

терәлгечле *прил.* с опо́рой, со спи́нкой

терәлгечсез *прил.* без опо́ры, без спи́нки

терәлдерү *понуд. от* **терәлү**; пододви́нуть вплотну́ю

терәлеш|ү 1. *взаимно-совм. от* **терәлү** 2. *перен.* быть совсе́м ря́дом; *ике өй ~еп торалар* два до́ма совсе́м ря́дом

терәл|ү *неперех.* 1. опира́ться/опере́ться *на что*; прислоня́ться/прислони́ться *к чему*; притули́ться; *мичкә ~де* он прислони́лся к пе́чке; *коймага ~ү* притули́ться у забо́ра 2. 1) каса́ться/косну́ться, прикаса́ться/прикосну́ться || каса́ние, прикоснове́ние (вплотну́ю); *бер-берсенә ~еп торган биналар* зда́ния, вплотну́ю каса́ющиеся друг дру́га 2) почти́ каса́ться, быть о́чень бли́зким/сме́жным, сопреде́льным || сме́жность, сопреде́льность; *басуга ~еп торган урман* лес, стоя́щий у са́мого по́ля; *~еп торган куршеләр* сосе́ди (сосе́дние дома́), стоя́щие о́чень бли́зко ря́дом 3) доходи́ть/дойти́ высото́й *до чего*; *башы куккә ~гән* высото́й до небе́с 3. 1) упира́ться/опере́ться *обо что, во что*; *ярга ~ү* упира́ться о бе́рег 2) засто́риваться/засто́риться; приостана́вливаться/приостанови́ться; *һөҗүм ~де* ата́ка засто́рилась 4. *перен.* зави́сеть *от кого, чего*, упира́ться/опере́ться *во что*; *эш акчага ~ә* де́ло зави́сит от де́нег (упира́ется в де́ньги) 5. *см.* **текәлү**; *~еп карау* смотре́ть в упо́р 6. *перен.* 1) смотре́ть, обраща́ться (*с вожделением, с просьбой, с мольбой*); обрати́ться; *байларга ~ү* обрати́ться с мольбо́й к богача́м 2) остана́вливаться/останови́ться (*с надеждой*); *капка саен ~ү* остана́вливаться у ка́ждых воро́т 7. *перен.* приближа́ться/прибли́зиться вплотну́ю; стоя́ть совсе́м бли́зко; *кыш ~еп тора* зима́ близка́; зима́ у поро́га 8. *страд. от* **терәү**; подпере́ться, быть подпёртым □ **~еп тору (кату)** 1. застыва́ть/засты́ть, стоя́ть без движе́ния (*от недоумения, удивления, возмущения и т. п.*) 2. стоя́ть болва́ном, стоя́ть без де́ла (*когда нужно действовать*); *нәрсә ~еп каттың?* чего́ стои́шь болва́ном?; **~еп туктау (калу)** 1. застрева́ть/застря́ть (*о деле*) 2. *см.* **терәлү** 4; **~еп утыру** сиде́ть без де́ла; сиде́ть болва́ном

терәтел|ү *страд. от* **терәтү**; подпира́ться, быть подпёртым *чем-л.*; *терәү белән ~гән* подпёртый подпо́ркой

терәтенү *возвр. от* **терәтү**; подпира́ться/подпере́ться; подпира́ть/подпере́ть себя́ (*свой дом*)

терәтешү *взаимно-совм. от* **терәтү**; помога́ть подпира́ть/подпере́ть *что-л.*

терәттер|ү *понуд. от* **терәтү**; веле́ть, проси́ть и́ли заста́вить подпира́ть/подпере́ть

терәт|ү *перех.* 1. прислоня́ть/прислони́ть, ста́вить накло́нно 2. подпира́ть/подпере́ть || подпира́ние (*чем*) для укрепле́ния: *койманы ~ү* подпере́ть забо́р (*наклонными опорами*); *капканы терәү белән ~ү* подпере́ть воро́та подпо́ркой (*чтобы они не открывались*); □ **~еп кую** приставля́ть/приста́вить вплотну́ю *к чему*; **~еп салу** ста́вить (*дом, здание*) вплотну́ю *к чему*

терәү I *сущ.* 1. подпо́рка; *~ салу* ста́вить подпо́рку (подпо́рки); запере́ть (упира́я подпо́ркой); *берәүгә берәү — баганага ~* (*посл.*) оди́н к одному́ — подпо́рка к столбу́ 2. *см.* **терәк**

терә|ү II *перех.* 1. прислоня́ть/прислони́ть, приставля́ть/приста́вить || приставле́ние (*так, чтобы не валилось, не упало, не падало*); *аркасын мичкә ~п* прислони́вшись спино́й к печи́; *таягын диварга ~де* приста́вил па́лку к стене́; *башын мендәргә ~ү белән* как то́лько прислони́л го́лову к поду́шке 2. упира́ть/упере́ть, упира́ться/опере́ться *чем*; *аягын җиргә нык ~п* кре́пко упира́ясь ногой о зе́млю 3. припира́ть/припере́ть; подпира́ть/подпере́ть 4. приставля́ть/приста́вить || приставле́ние; *кукрәгенә штык ~п* приста́вив штык к груди́ (*в грудь*) 5. *см.* **текәү** 1; *күзгә күзне нык ~п* смотря́ в упо́р (*букв.* упира́я глаза́ в глаза́) 6. *перен.* доводи́ть/довести́ || доведе́ние *до чего*; подводи́ть/подвести́ || подведе́ние *к чему*; *бәхетсезлеккә* (*илтеп*) *~ү* довести́ до несча́стья; *сүзне шул мәсьәләгә ~де* подвёл сло́во к тому́ вопро́су 7. *в знач. нареч.* **терәп** категори́чески; в глаза́, в упо́р; *~п сорау* стро́го спроси́ть, категори́чески ста́вить вопро́с; *~п әйтү* вы́сказать пря́мо и стро́го

терәүләнү *страд. от* **терәүләү**; подпира́ться, быть подпёртым *~гән ишек* подпёртая дверь

терәүләтү *понуд. от* **терәүләү**; веле́ть и́ли проси́ть подпира́ть (*снабдить опорой*)

терәүләү *перех.* **1.** подпира́ть/подпере́ть || подпира́ние (опо́рой, подпо́ркой); *ишекне ~* подпере́ть две́ри опо́рой **2.** подкрепля́ть/подкрепи́ть || подкрепле́ние (опо́рой)

терәүләш *взаимно-совм. от* **терәүләү**; помога́ть подпира́ть

терәүле *прил.* подпёртый, закреплённый опо́рой, подпо́ркой; *~ ишек* подпёртая дверь; *~ койма* забо́р, закреплённый (*подкреплённый*) подпо́ркой

терәүлек *сущ.* **1.** 1) деревя́шка, па́лка, шток и т. п., приго́дные для подпо́рки, опо́рки 2) *см.* **терәү** 1; *~ салу* заложи́ть две́ри подпо́ркой **2.** *перен. этногр.* языческое жертвоприноше́ние || *прил.* приго́дная и́ли предназна́ченная в ка́честве подпо́рки, опо́ры

терәшү *взаимно-совм. от* **терәү** II **1.** помога́ть прислони́ть, припира́ть, подпира́ть **2.** подпира́ть друг дру́га; *аркa ~* подпира́ть друг дру́га спи́нами **3.** уста́виться друг на дру́га; *күз ~* уста́виться в глаза́ друг дру́гу

тергезелү *страд. от.* **тергезү**; оживля́ться, быть оживлённым; восстана́вливаться, быть восстана́вливаемым

тергез|ү *перех.* **1.** 1) *см.* **терелдерү, терелтү** 2) оживля́ть/оживи́ть || оживле́ние 3) выле́чивать/вы́лечить || выле́чивание (*больного*) **2.** *прост.* разводи́ть/развести́ || разведе́ние (*огня в очаге*); раздува́ть/разду́ть || раздува́ние (*самовара и т. п.*); *самавыр ~еп жибәрик* дава́йте, поста́вим самова́р **3.** *перен. прост.* 1) начина́ть/нача́ть || начина́ние (*жизни и т. п.*) 2) восстана́вливать/восстанови́ть || восстановле́ние; *см. тж.* **торгызу**

тере *прил.* **1.** 1) живо́й; *ни үле, ни ~* ни жив, ни мёртв; *~ җан* жива́я душа́; *~ күзәнәк* жива́я кле́тка; *~ табигать* жива́я приро́да; *ул ~ микән әле?* жи́в ли он (она́) ещё?; *үзем ~ чакта* пока́ я жив; *~ләрдән ~рәк* живе́е всех живы́х 2) *кул.* живо́й, све́жий; *~ балык* жива́я (све́жая) ры́ба **2.** *перен.* живо́й, бо́йкий, шу́стрый, подви́жный (*ребёнок*); *см. тж.* **теремек, терчән 3.** *разг.* неразвари́вшийся (*о крупе, рисе*) || *нареч. разг.* жи́во, бо́йко; *бик ~ сөйләшә* говори́т о́чень бо́йко □ **~ килеш (көйгә) 1.** живьём, в живо́м ви́де **2.** *перен. см.* **терәләй** 2; **~ көч(ләр)** жива́я си́ла (живы́е си́лы) (*в составе войск*); **~ чәчәк(ләр)** живы́е цветы́ ◊ **~ зыян** полне́йший убы́ток; **~ исәр (ахмак, тиле h. б.)** кру́глый дура́к; дура́к дурако́м; настоя́щий идио́т, соверше́нный глупе́ц; **~ кайгы (хәсрәт)** несча́стный, жа́лкий (*человек*), го́ре и то́лько (*о человеке, а также о событиях*); **~ надан** дремо́чий неве́жда; **(авызыннан) ~ саескан (чыпчык) очыру 1.** хвали́ться, бахва́литься **2.** врать напропалу́ю; **~ суы** *миф.* жива́я вода́; *~ суы бөркү* окропи́ть живо́й водо́й; **~ тарих** жива́я исто́рия (*человек, который прожил долго и помнит многое из прошлого*); **~ тутый тоткапмыни (шикелле, кебек)** (*словно*) жар-пти́цу пойма́л (*о человеке в чрезвычайно приподнятом настроении*); **~ ялкау** отпе́тый лентя́й; ло́дырь ло́дырем; **~ ятим** кру́глый сирота́; **~ җан** жива́я душа́; *~ җан бармы биредә?* есть ли тут (хоть одна́) жива́я душа́?

терек *прил. см.* **тере** 1 (*только о людях*); *кальга биек, дошман ~* (*погов.*) успока́иваться ещё ра́но; впереди́ ещё мно́го тру́дностей (*букв.* сте́ны вра́жьей кре́пости высоки́, и враг жив); *үлектән ~ артык* (*посл.*) живо́й доро́же мёртвого

терекләндергеч *прил. книжн.* жизнетво́рный; *~ рух* жизнетво́рный дух

терекләнү *неперех.* **1.** станови́ться/стать || становле́ние живы́м; *үлектән ~де* из мёртвого стал живы́м (*поднялся*) **2.** *разг.* жить ко́е-ка́к, существова́ть || существова́ние; *яшәмибез — ~әбез генә* не живём, а существу́ем; *~еп яталар шунда* живу́т-пожива́ют себе́ *кое-как*

терекле|к *сущ.* **1.** жизнь *в знач.*: 1) всё живо́е; *~к чыганагы — кояш* (*погов.*) исто́чник жи́зни — (э́то) со́лнце 2) сво́йство быть живы́м; животво́рное нача́ло; *орлыкның ~ге саклану* сохране́ние жи́зни у семя́н **2.** *см.* **тереклек 3.** жизнь, оживлённость, движе́ние (*на улицах*); *авылда ~к әгәре куренми* в дере́вне не ви́дно никаки́х при́знаков жи́зни **4.** *уст.* жизнь, житьё, житьё-бытьё; *бала ничек уйнаса, үскәч ~ге шул рәвешчә була* како́в ребёнок в игре́, тако́в он бу́дет во взро́слой жи́зни **5.** *в знач. нареч.* **тереклектә** в бы́тности, при жи́зни; *~гендә* в его́ бы́тность, при его́ жи́зни; *~ктә сыйлашмагач, үлгәннән соң елашма* (*посл.*) е́сли уж не зна́лись при жи́зни, не́чего пла́кать по́сле сме́рти □ **~к дөньясы** жива́я приро́да; **~к итү (кылу)** жить, существова́ть; **~к иясе** *см.* **җан иясе**; **~к суы** *см.* **тере суы**

тереклекле *прил.* живо́й, с при́знаками жи́зни (жизнедея́тельности), жило́й, обжи́тый, обита́емый; *~ күренеш* жило́й вид

тереклексез *прил.* безжи́зненный; *~ сахра* безжи́зненная пусты́ня

терекөмеш *сущ.* ртуть || рту́тный; *~ оксиды* рту́тный окси́д, окси́д рту́ти || *прил.* рту́тный; *~ үткәргеч* рту́тный проводни́к

терекөмешле *прил.* рту́тный, с рту́тью; *~ кушылма* рту́тное соедине́ние

терек-терек *подр. быстрому перебиранию (перебору) ногами; терек-терек йөгерә* бежи́т, бы́стро семеня́ нога́ми □ **терек-терек итү** *см.* **теркелдәү**

тереләен *нареч. разг. см.* **терелә́й**

терелә́й *нареч.* **1.** за́живо, живьём, в живо́м ви́де; *~ күмү* закопа́ть живьём; *~ бирелмәм* живьём не сда́мся **2.** *перен.* беспоща́дно, неща́дно; *~ талау (тунау)* неща́дно гра́бить □ **~ (тотып) ашау (йоту)** за́живо съеда́ть/съесть; по́едом есть; заму́чить; терза́ть; **~ җир астына керерлек булу** быть гото́вым живьём сойти́ в моги́лу; **~ тотып ату** расстре́ливать/расстреля́ть на ме́сте; **~ тунау (сую)** обира́ть/обобра́ть; разоря́ть (*путём поборов, налогов, обмана и т. п.*); **~ утка ату** ввергáть в гее́нну о́гненную; **~ утта яну** горе́ть свечо́й; сгоре́ть живьём

терелә́н|ү *неперех.* оживля́ться/оживи́ться; станови́ться/стать || становле́ние живы́м, бо́йким, оживлённым

терелә́тә *нареч. см.* **терелә́й**; *~ (җиргә) күмү* хорони́ть за́живо || *прил.* в живо́м ви́де; живо́й (*о весе животных*); *~ авырлык* живо́й вес

терелдерү *перех. см.* **терелтү**

терел|ек *сущ.* **1.** *контекст.* бытие́; сво́йство быть живы́м; живо́е состоя́ние; *үлелеге-~ге мәгълүм түгел* неизве́стно, мёртв и́ли жив **2.** жизнь, житие́; вре́мя, пора́ жи́зни; *ни күрәсең дә ~ктә, сыйлашкан яхшы берлектә* (*посл.*) что бы ни́ было в жи́зни, на́до уважа́ть друг дру́га **3.** жизнь, бие́ние жи́зни; оживлённость; *берлектә — ~к* (*посл.*) жизнь в едине́нии **4.** *разг.* акти́вность, задо́р; бо́йкость; *~кгә тере инде ул* насчёт акти́вности — э́того у него́ вдо́сталь; задо́ру у него́ доста́точно

терелер-терелмәс *нареч. разг.* ещё не совсе́м вы́здоровевши; ещё не опра́вившись (*от болезни*) □ **терелер-терелмәс көе (хәлдә)** ещё в не совсе́м вы́здоровевшим ви́де

терелткеч *прил.* **1.** живи́тельный, животво́рный; оживля́ющий; *рухны ~ идеяләр* оживля́ющие дух иде́и

2. цели́тельный, исцеля́ющий; ~ *дару* цели́тельное лека́рство

терелтү *перех.* **1.** исцеля́ть/исцели́ть || исцеле́ние; изле́чивать/излечи́ть || изле́чивание, излече́ние (*от болезни*) **2.** *см.* **тергезү** 2; *үлгәнне* ~ воскреси́ть уме́ршего **3.** *перен.* восстана́вливать/восстанови́ть, возрожда́ть/возроди́ть || восстановле́ние, возрожде́ние; *см. тж.* **аякка бастыру**

терелтүче *сущ.* **1.** цели́тель, исцели́тель **2.** оживи́тель || *прил.* **(-ны ~)** цели́тельный, живи́тельный; *см. тж.* **терелткеч**; *җанны* ~ *көч* си́ла, живи́тельная для души́

терел|ү *неперех.* **1. 1)** выздора́вливать/вы́здороветь || выздора́вливание/выздоровле́ние; *тифтән ~де* вы́здоровел от ти́фа, переболе́л ти́фом; превозмо́г тиф 2) оживи́ть/ожи́ть || оживле́ние; *үлеп* (*үлемнән*) ~*ү* умере́ть и о́жить **2.** *перен.* приходи́ть/прийти́ в движе́ние, оживля́ться/оживи́ться || оживле́ние

теремек *прил. диал.* **1.** живо́й, подви́жный (*о ребёнке*) **2.** шу́стрый; ~ *малай* шу́стрый ма́льчик

теремеклән|ү *неперех. диал.* станови́ться/стать || становле́ние живы́м, подви́жным, шу́стрым; *бала ~еп китте* ребёнок стал совсе́м подви́жным

тереск∂к *сущ.* коле́нный вы́ступ за́дней ноги́ живо́тных (*преимущ. у млекопитающихся*)

терит *сущ. диал. разг.* крат; *бер ~ бардым* сходи́л оди́н раз; *ничәнче ~ бу?* э́то кото́рый раз?

теркәвеч *сущ. разг.* прико́лка, шпи́лька, скре́пка; ~ *белән беркетү* приколо́ть шпи́лькой (скре́пкой)

теркәгеч *сущ. грам.* сою́з □ ~ **сүз** сою́зное сло́во

теркәгечле *прил. грам.* сою́зный (*в знач.* осно́ванный на употребле́нии сою́зов); ~ *конструкция* сою́зная констру́кция; ~ *тезмә кушма җөмлә* сою́зное сло́жносочинённое предложе́ние

теркәгечсез *прил. грам.* бессою́зный; ~ *кушма җөмлә* бессою́зное сло́жное предложе́ние

теркәл|ү *возвр.-страд. от* **теркәү** **1.** *возвр. разг. см.* **терәлү** **2.** *страд.* прикрепля́ться, присоедини́ться; подшива́ться; *бер төпсәгә ~гән документлар* докуме́нты, подши́тые в оди́н переплёт **3.** составля́ться, нани́зываться; быть соста́вленным (нани́занным); *бүрәнәләрдән ~гән* соста́вленный из брёвен; *бер җепкә ~гән* нани́занный на одну́ ни́тку

теркәм *сущ. редко* подши́вка

теркәтү **1.** *понуд. от* **теркәү**; заставля́ть/заста́вить, проси́ть и́ли повелева́ть/повеле́ть прислоня́ть, пристёгивать, подшива́ть **2.** *перех.* стыкова́ть/состыкова́ть || стыкова́ние, стыко́вка; *берберсенә* ~ состыкова́ть (*рельсы*)

теркә|ү *перех.* **1.** прислоня́ть/прислони́ть (*всей поверхностью*); прижима́ть/прижа́ть || прижа́тие (*вплотную*); ста́вить и́ли класть в стык и́ли в ряд (*вплотную*); *бүрәнәгә бүрәнә ~ү* класть бревно́ к бревну́ (*вплотную*) **2.** стыкова́ть || стыкова́ние **3.** прикрепля́ть/прикрепи́ть присоедини́ть/присоедини́ть; пристёгивать/пристегну́ть; пришива́ть/приши́ть; приобща́ть/приобщи́ть || прикрепле́ние, присоедине́ние, пристёгивание, пришива́ние, приобще́ние (*к делу, к бумагам*); *шул төпсәгә ~п куй* приобщи́ к тому́ переплёту (*в тот переплёт*) **4. 1)** запи́сывать/записа́ть; фикси́ровать/зафикси́ровать; *протоколга ~ү* записа́ть в протоко́л; *кенәгәдә* ~ фикси́руй в кни́ге за́писей 2) регистри́ровать; *никах ~ү* регистри́ровать бракосочета́ние □ **~п кую** **1.** зафикси́ровать **2.** зарегистри́ровать

теркәүле *прил.* **1.** прикреплённый, пристёгнутый, приши́тый *к чему* **2.** зафикси́рованный, зарегистри́рованный

терке *сущ.* **1.** молода́я сосна́ **2.** молодо́й сосня́к ||молодо́й сосно́вый; ~ *урманы* молодо́й сосно́вый лес

теркелд|әү *неперех.* **1.** тру́сить, легко́ и непринуждённо бежа́ть; *арттан ~и* тру́сить сза́ди **2.** легко́ кати́ться (*о тележе*) □ **~әп бару** *см.* **теркелдәү**

теркелек *сущ.* молодо́й сосня́к; ~ *аша сукмак* тропа́ че́рез молодо́й сосня́к

теркеш *сущ.* **1.** *ист.* колча́н, вмести́лище для стрел; ~ *тулы ук* по́лный колча́н стрел **2.** *диал.* футля́р для посу́ды

терле|к *сущ.* **1.** скот, скоти́на; дома́шнее живо́тное || ско́тный; *см. тж.* **мал**; *сөт ~ге* моло́чный скот; ~*к үрчету* разводи́ть (умножа́ть) скот; ~*к абзары* ско́тный двор **2.** *разг. в сочет. с названиями отдельных видов скота в ф. притяж. 3 л. образует обобщённые наименования; ат ~ге* ло́шадь вообще́; *сыер ~ге* коро́вы и быки́ вообще́; *кош ~ге* дома́шняя пти́ца □ **~к азыгы** корм (*скоту*); **~к асрау** занима́ться скотово́дством; **~к асраучы** скотово́д; *см. тж.* **терлекче**; **~к асраучылык** скотово́дство; *см. тж.* **терлекчелек**; **~ асты** пол хле́ва, ско́тного двора́; ~ *астын чистарту* очища́ть хлев; **~к караучы** ско́тник (*на ферме*); **~к өе** **1.** теля́тник, ягня́тник **2.** зоостациона́р;

терлекле *прил.* **1.** со ското́м; име́ющий скот **2.** с мно́жеством скота́, бога́тый ското́м; ~ *кеше* челове́к, бога́тый ското́м

терлеклек *прил.* для скота́, доста́точный и́ли предназна́ченный для дома́шнего скота́; ~ *печән* се́но для скота́; се́но, доста́точное для скота́

терлексез *прил.* без скота́ || бесско́тный || *нареч.* ~ *яшәү* жить без скота́

терлексезләнү *неперех.* остава́ться/оста́ться без скота́; лиши́ться скота́; обедне́ть || обедне́ние ското́м

терлексезлек *сущ.* **1.** отсу́тствие скота́ **2.** бе́дность ското́м

терлек-туар *сущ. собир. см.* **мал-туар**

терлекче *сущ.* **1.** животново́д, скотово́д || животново́дческий, скотово́дческий; *см. тж.* **малчы** **2.** ско́тник

терлекчелек *сущ.* животново́дство, скотово́дство || животново́дческий, скотово́дческий; ~ *белән шөгыльләнү* занима́ться скотово́дством; ~ *фермасы* животново́дческая фе́рма

те́рма *сущ. в разн. знач.* те́рма; *Рим ~лары* ри́мские те́рмы (*общественные бани*)

термаль *прил. геол.* терма́льный; ~ *чишмә* терма́льный исто́чник

те́рмик *прил. тех.* термо́ический; ~ *эшкәртү* термо́ическая обрабо́тка

те́рмин *сущ.* те́рмин; *биология ~нары* те́рмины биоло́гии

терминоло́гик *прил.* терминологи́ческий; ~ *комиссия* терминологи́ческая коми́ссия

терминоло́гия *сущ.* терминоло́гия; те́рмины; ~*не камилләштерү* усовершéнствование терминоло́гии

термист *сущ. тех.* термо́ист (*специалист по термической обработке металла*)

термит I *сущ. зоол.* термо́ит; ~ *оясы* гнездо́ термо́итов

термит II *сущ. тех.* термо́ит || термо́итный; ~ *снаряды* термо́итный снаря́д

термо́граф *сущ. тех.* термо́граф

термо́метр *сущ.* термо́метр; *терекөмешле* ~ рту́тный термо́метр

термоме́трия *сущ. тех.* термоме́трия

терморегуля́тор *сущ. тех.* терморегуля́тор

те́рмос *сущ.* те́рмос; *вакуумлы ~* ва́куумный те́рмос

термостат *сущ. тех.* термоста́т (*прибор для поддержания постоянной температуры*)

термотерапик *прил. мед.* термотерапевти́ческий; *~ тикшерену* термотерапевти́ческое иссле́дование

термотерапи́я *сущ. мед.* термотерапи́я (*лечение теплом и холодом*); *~ белгече* специали́ст по термотерапи́и

термохи́мик *прил. тех.* термохими́ческий; *~ процесс* термохими́ческий проце́сс

термохи́мия *сущ. тех.* термохи́мия || термохими́ческий; *~ лабораториясе* термохими́ческая лаборато́рия; лаборато́рия термохи́мии

термоэлемент *сущ. тех.* термоэлеме́нт; *~лар батареясы* батаре́я термоэлеме́нтов

тернә|к *сущ. разг.* 1. опо́ра, предме́т, слу́жащий для подде́ржки (*временного сооружения, мостика*) 2. *перен.* 1) опо́ра; защи́тник; защи́та; *акыл ~ге — гыйлем* (*посл.*) нау́ка — опо́ра ума́ 2) подспо́рье; *бераз ~к булсын дип* что́бы бы́ло не́которым подспо́рьем || *прил.* опо́рный; *~к пункт* опо́рный пункт

тернәкләндерү *перех.* вы́лечить, ста́вить на но́ги *кого*

тернәкләнү *неперех.* 1. вы́лечиться, поправля́ться/попра́виться, выздора́вливать/вы́здороветь || поправле́ние, выздоровле́ние (*после сильной болезни, ослабления*) 2. *перен.* встава́ть/встать || встава́ние на́ ноги; набира́ться || набира́ние сил; *безнең хуҗалык та ~де* и на́ше хозя́йство вста́ло на́ ноги □ **~э башлау** 1. идти́/пойти́ на попра́вку 2. пойти́ в рост; *игеннәр ~э башлаган* хлеба́ пошли́ в рост

тернәкле *прил.* 1. име́ющий опо́ру; усто́йчивый; *~ баскыч* ле́стница с (дополни́тельной) опо́рой 2. *перен.* си́льный; кре́пкий; кре́пко сидя́щий (*на своём посту*); *~ кеше тырнаклы* (*посл.*) кре́пкий челове́к когти́ст

терпә *прил.* 1. колю́чий, торча́щий в ви́де щети́ны (*об усах*); *см. тж.* **тырпа** 2. *перен.* круто́й, ре́зкий; гру́бый, неве́жливый; *см. тж.* **дорфа**, **төрпә** || *нареч.* кру́то, ре́зко; гру́бо, неве́жливо; *~ кылану* вести́ себя́ неве́жливо, колю́че

терпәйтү *перех.* ощети́нить, топо́рщить (*усы*); *см. тж.* **тырпайту**

терпәләнү *неперех.* 1. станови́ться/стать гру́бым, ре́зким 2. проявля́ть/прояви́ть || проявле́ние гру́бости, ре́зкости

терпәлек *сущ.* ре́зкость, гру́бость; *см. тж.* **дорфалык**, **төрпәлек**

терпәю *неперех.* 1. ощети́ниться, топо́рщиться; *см. тж.* **төрпәю** 2. *перен.* оби́деться, ду́ться *на кого-л.* || оби́да

терпәюле *прил. разг.* оби́женно-неве́жливый, ко́лкий; *~ караш* ко́лкий взгляд

терпе *сущ. диал.* терпу́г; *~ өстенә тукмак* (*погов.*) на бо́йкого есть побойче́е (*букв.* на терпу́г — колоту́шка)

терракóта *сущ.* терракóта (*обожжённая цветная глина*) || *прил.* терракóтовый (*о материале, о цвете*)

терра́рий *сущ. см.* **терра́риум**

терра́риум *сущ. зоол.* терра́риум (*помещение для содержания мелких земноводных и пресмыкающихся*)

терра́са *сущ.* терра́са (*в земледелии, у здания*); *~ ясау* де́лать терра́су

терра́салау *перех.* террасси́ровать || террасси́рование (*горного склона*)

терра́салы *прил.* 1. с терра́сой (терра́сами); *~ тау бите* склон (*горы*) с терра́сами 2. терра́сный, терра́совый; *~ басулар* терра́совые поля

терра́ска *сущ.* терра́ска; *~да ял итү* отдыха́ть на терра́ске

терренкур *сущ. мед.* терренку́р (*лечебная ходьба в санаториях*)

террикон *сущ. тех.* террико́н; *биек-биек ~нар* высо́кие террико́ны

территориаль *прил.* территориа́льный; *~ сулар* территориа́льные во́ды

территориаль-административ *прил.* территориа́льно-административный; *территориаль-административ буленеш* территориа́льно-административное деле́ние

террито́рия *сущ.* террито́рия; *илнең ~се* террито́рия страны́

террито́рияле *прил.* с (*определённого количества и качества*) террито́рией; име́ющий определённую террито́рию; *зур ~* с большо́й террито́рией

террор *сущ.* терро́р; *~ куллану* примене́ние терро́ра; *~ шартларында* в усло́виях терро́ра

терроризм *сущ. см.* **террорчылык**

террорист *сущ. см.* **террорчы**

террорлану *страд. от* **террорлау**; терроризова́ться, быть терроризо́ванным

террорлау *перех.* терроризи́ровать, терроризова́ть || терроризи́рование; *илатны ~* терроризи́рование насе́ления

террорлык *сущ. разг. см.* **террорчылык**

террорчы *сущ.* террори́ст || террористи́ческий; *~лар группасы* гру́ппа террори́стов; *~лар оешмасы* террористи́ческая организа́ция

террорчылык *сущ.* террори́зм || террористи́ческий; *~ белән шөгыльләну* занима́ться террори́змом; *~ акты* террористи́ческий акт

терсә|к *сущ.* 1. 1) ло́коть, ло́кти || локтево́й; *~кләре чыгып торган* с выступа́ющими локтя́ми; *~к буыны* локтево́й суста́в; *~к сөяге* локтева́я кость; *~ккә кадәр* до локтя́ 2) ло́коть, ло́кти оде́жды (*место рукава, рукавов*) 2. за́дний вы́ступ за́дних ног живо́тных; *см. тж.* **терескәк** 3. коле́но, коле́нце (*выступ в различных устройствах и механизмах*) 4. *диал. см.* **терсәклек** □ **~ккә таяну** облокоти́ться; *см. тж.* **терсәкләнү** ◊ **~ккә терсәк (орынып)** бок о бок, вме́сте; са́мым дру́жественным о́бразом; **~кне тешләү (тешләрдәй булу)** куса́ть ло́кти (*горько раскаиваться*); **~геңне тешли алмассың (~к якын да тешләп булмый)** бли́зок ло́коть, да не уку́сишь

терсәклә|ү *неперех.* 1. облокоти́ться (*на стол*) 2. выступа́ть/вы́ступить || выступа́ние коле́ном, кли́ном; *~еп чыгып торган* выступа́ющий кли́ном

терсәклә|ү *неперех. разг.* 1. толка́ть друг дру́га (*в бок*) локтя́ми (*одёргивая, предупреждая и т. п.*) 2. *перен.* раста́лкивать (рабо́тать) локтя́ми

терсәкле *прил.* 1. коле́нчатый (*о частях механизмов, машин*); *~ вал* коле́нчатый вал 2. с вы́ступом; с подлоко́тником; *~ урындык* сиде́нье (стул) с подлоко́тниками

терсәклек *сущ.* подлоко́тник (*стула*)

терсәкче *сущ.* вы́ступ, у́гол, подлоко́тник (*дивана, кресла и т. п.*)

терт *подр. резкому (но не сильному) вздрагиванию* (*в отличие от* **дерт**) □ **~ итү** ре́зко (*но не сильно*) вздро́гнуть

тертә|ю *неперех. диал.* выпира́ть, выступа́ть || выпира́ние *через что-л.* (*через одежду*); *күкрәкләре ~еп тора*

её гру́ди выпира́ют; *терсәге ~еп чыккан* его́ ло́коть (заме́тно) выступа́ет

тертләү *неперех.* ре́зко (*но не сильно*) вздра́гивать/вздро́гнуть || вздра́гивание

терт-терт *подр. подрагиванию*; *терт-терт йөгерү* труси́ть, бе́гать (бежа́ть) трусцо́й, подра́гивая всем те́лом

терцет *сущ. муз.* терце́т (*произведение для трёх голосов*)

терчә *прил.* **1.** подви́жный, живо́й, бедо́вый (*о ребёнке*) **2.** бо́дрый, де́ятельный, акти́вный; *~ карт* (*бабай*) стари́к-бодрячо́к

терчәлек *сущ.* подви́жность, бо́дрость, акти́вность

терчән *прил. см.* **терчә**

терчәнләнү *неперех.* **1.** станови́ться/стать бо́дрым (де́ятельным, акти́вным) **2.** бодри́ться; подба́дриваться/подбодри́ться, приободри́ться ◻ **~еп китү** приободри́ться

терчәнлек *сущ. см.* **терчәлек**

тетелдерү *понуд. от* **тетелү**; *киемне ~* вконе́ц износи́ть оде́жду

тетел|ү **1.** *страд. от* **тету**; трепа́ться, мы́каться, быть трёпанным, тре́пленным (*о шерсти*); *~гән йон* трёпаная (тре́пленая) шерсть **2.** кроши́ться, раскроши́ться; размельча́ться, измельча́ться (*о комках глины*) **3.** ру́шиться, разруша́ться (*о штабелях дров*) **4.** истрепа́ться, измоча́литься, измы́згаться; изна́шиваться/износи́ться (*об одежде и обуви, а также об организме, органах тела*); располза́ться по швам (*об одежде, постельных принадлежностях, об изделиях из ткани, кожи и т. п.*); быть истрёпанным, растрёпанным (*о книге*) **5.** *перен.* старе́ть/постаре́ть, дряхле́ть/подряхле́ть; вконе́ц износи́ться; теря́ть/потеря́ть здоро́вье и си́лу; *картайдым инде, ~дем* постаре́л я, вконе́ц износи́лся **6.** *см.* **теткәләнү** ◻ **~еп елау** пла́кать навзры́д; **~еп йоклау** спать без па́мяти (*о детях, о сильно уставших, о выздоравливающих после болезни и т. п.*)

тетелүчән *прил.* о́чень хру́пкий, ло́мкий, рассыпа́ющийся

тетеш|ү *взаимно-совм. от* **тету**; помога́ть трепа́ть, мы́кать, тереби́ть *что-л.*

теткәләндер|ү *перех. от* **теткәләнү**; си́льно изна́шивать/поизноси́ть; измоча́ливать/измоча́лить; измы́згать/поизмы́згать; *~еп бетерү* совсе́м (оконча́тельно, вконе́ц) поизноси́ть, измоча́лить, поизмы́згать; *~еп бетергәнсең бит* совсе́м ведь поизноси́л, живо́го ме́ста не оста́вил

теткәләнү *страд.-возвр. от* **теткәләү** **1.** рва́ться, изорва́ться; трепа́ться, си́льно потрепа́ться, истрепа́ться; превраща́ться в кло́чья; *~гән кием* си́льно потрёпанная оде́жда **2.** *перен.* (*со словами* **йөрәк** се́рдце, **күңел** душа́ *и т. п.*); изму́читься, терза́ться, истерза́ться, томи́ться/истоми́ться, издёргаться; *~гән күңел* издёрганная душа́; *йөрәк ~ә* се́рдце терза́ется

теткәлә|ү **1.** *многокр. от* **тету**; потрёпывать, помы́кивать (*шерсть*); трепа́ть, мы́кать (*много раз, не раз и в разное время*) **2.** си́льно потрепа́ть, истрепа́ть, растрёпывать || растрёпывание; превраща́ть/преврати́ть || превраще́ние в кло́чья ◻ **~п бетерү** преврати́ть в кло́чья, вконе́ц истрёпывать/истрепа́ть

теткеч *сущ.* **1.** трепа́ло, трепа́лка; шерстоби́тный луго́к **2.** рабо́чая часть трепа́льных механи́змов и маши́н; зу́бья, зубе́ц || *прил.* трепа́льный; *~ механизм* трепа́льный механи́зм

тетмә *сущ.* мо́чка, пучо́к (*льна, который надо теребить*) ◊ **~сен тету (теттерү)** **1.** громи́ть, разгроми́ть, потрепа́ть (*врага*) **2.** кроши́ть, превраща́ть в пух и прах **3.** разноси́ть/разнести́, учини́ть разно́с; дава́ть/дать трёпку (*жару*)

тетрало́гия *сущ.* тетрало́гия (*четыре произведения искусства, литературы и т. п., объединённых общим замыслом*)

тетра́эдр *сущ. мат.* тетра́эдр

тетрәвек *сущ.* **1.** тряси́на, то́пкое ме́сто (*на болоте, посреди болот*); *~кә басу* наступа́ть на тряси́ну **2.** озно́б, лихора́дка (*от болезни, волнения и т. п.*) || *прил. см.* **тетрәк**

тетрәвекле *прил.* **1.** тря́ский, то́пкий (*о болоте*) **2.** *см.* **тетрәк**

тетрәк *прил.* **1.** дрожа́щий (*о голосе*); *~ тавыш белән* дрожа́щим го́лосом **2.** *диал.* трясу́щийся; *см. тж.* **калтыравык**; *~ куллар* трясу́щиеся ру́ки **3.** *диал.* тря́ский

тетрәкләнү *неперех.* **1.** станови́ться/стать дрожа́щим, трясу́щимся **2.** станови́ться/стать тря́ским

тетрәндергеч *прил.* **1.** броса́ющий в дрожь (*о лекарстве*) **2.** *перен.* потряса́ющий; *~ куренеш* потряса́ющая карти́на || *нареч.* потряса́юще; *~ тәэсир итү* де́йствовать потряса́юще

тетрәндер|ү *понуд. от* **тетрәнү**; заставля́ть/заста́вить дрожа́ть (трясти́сь, о́стро пережива́ть); *музыка таш күңелләрне дә ~ә* му́зыка заставля́ет пережива́ть (*острые чувства*) и ка́менные ду́ши (сердца́)

тетрәш|ү *возвр. от* **тетрәү** **1.** трясти́сь/затрясти́сь, дрожа́ть/задрожа́ть || дрожь **2.** вздра́гивать || вздра́гивание **3.** *перен.* испы́тывать/испыта́ть, пережива́ть || пережива́ние о́стрых чувств (*жалости, страха, сострадания, презрения и т. п.*) ◻ **~еп китү** задрожа́ть (*от страха, жалости и т. п.*)

тетрәүле *прил.* **1.** тре́петный, си́льно взволно́ванный (*о голосе, взгляде и т. п.*) **2.** трясу́щийся; *~ куллары белән* трясу́щимися рука́ми

тетрәткеч *прил.* **1.** сотряса́ющий; сотряса́тельный; *җир ~ көч* си́ла, сотряса́ющая зе́млю **2.** *перен.* потряса́ющий, кра́йне волну́ющий; *күңел ~ вакыйга* потряса́ющее ду́шу собы́тие; *~ музыка* потряса́ющая му́зыка

тетрәтү *перех.* **1.** потряса́ть, сотряса́ть; вызыва́ть дрожь; *җир ~* вызыва́ть сотрясе́ние земли́ (*о тяжёлых локомотивах*) **2.** *перен.* потряса́ть/потрясти́ || потрясе́ние *кого, чего*; *җан ~* потряса́ть ду́шу **3.** *перен.* напуга́ть, запуга́ть, вызыва́ть дрожь (*у врагов*)

тетрә|ү *неперех.* **1.** трясти́сь, сотряса́ться, дрожа́ть || тря́ска, сотрясе́ние, дрожа́ние, дрожь; *җир ~ү* землетрясе́ние **2.** *перен.* дрожа́ть, трепета́ть (*перед кем-л.*) ◻ **~п китү** **1.** задрожа́ть **2.** вздро́гнуть; **~п тору** *прям., перен.* трясти́сь, дрожа́ть (*всё время*); *чиркәнүдән ~п торды* дрожа́л от омерзе́ния

тетрәүле *прил. см.* **тетрәнүле**

теттер|ү **1.** *понуд. от* **тету**; проси́ть, веле́ть и́ли заставля́ть трепа́ть, мы́кать (*лён, шерсть*) **2.** *неперех. перен.* гуля́ть, кути́ть, вести́ разгу́льную жизнь **3.** *в знач. нареч.* **теттереп** 1) о́чень бы́стро, интенси́вно, бу́йно; *~еп яңгыр ява* дождь ли́внем льёт 2) *перен.* припева́ючи; молоде́цки, с у́далью; *~еп яшәү* жить припева́ючи, с у́далью 3) бы́стро и горячо́ (*о разговоре, речи*); *~еп гәпләшү* разгова́ривать бы́стро, горячо́ 4) замеча́тельно, блестя́ще; *~еп эшли* рабо́тает блестя́ще 5) *разг.* бо́йко, без запи́нки; *русча ~еп сөйләшә* по-ру́сски разгова́ривает без запи́нки

тет|ү *перех.* **1.** трепа́ть, мы́кать || трепа́ние (*шерсти, скомканной, свалявшейся массы*) **2.** трепа́ть, истрепа́ть,

износи́ть (*одежду*) **3.** разбива́ть, разруша́ть; растопта́ть, затопта́ть; *тутәлләрне ~у* разруша́ть (зата́птывая) гря́дки **4.** *перен.* громи́ть, разгроми́ть (*врага*) в пух и прах; рассе́ивать (*войска*) **5.** отруга́ть, отчита́ть; брани́ть, хули́ть || брань, хула́ □ **~еп салу** сде́лать разно́с, разнести́ в пух и прах; си́льно отруга́ть; **~еп ташлау** зада́ть трёпку (слова́ми); устра́ивать/устро́ить ба́ню

тетүче *см.* **йон тетүче**

тетүчелек *сущ.* трепа́льное де́ло (*как ремесло*); трепа́ние (*льна*)

тефтә *сущ. бот.* до́нник || до́нниковый; *см. тж.* **кандала үләне**; *~ ябу* наложи́ть до́нниковый пла́стырь (*на рану*)

тех- *первая составная часть сложн. сл., соотв. по значению сл.* техни́ческий, тех-; техперсона́л, техпропага́нда, техреда́ктор

техми́нимум *сущ.* техми́нимум; *~ курсы* курс техми́нимума

те́хник *сущ.* те́хник; *сәләтле ~* спосо́бный те́хник || *прил. в разн. знач.* техни́ческий □ **~ карау** техни́ческий осмо́тр; **~ редактор** техни́ческий реда́ктор; **~ хәшия 1.** техни́ческий журна́л (за́писей) **2.** сертифика́т || *нареч.* техни́чески; *~ чиста* техни́чески чи́стый □ **~ яктан (җәһәттән) 1.** с техни́ческой стороны́ **2.** техни́чески

те́хника *сущ. в разн. знач.* те́хника || техни́ческий; *куәтле ~* мо́щная те́хника; *шигырь ~сы* те́хника стиха́ (*стихосложения*); *~ йорты* дом те́хники; *~ артталыгы* техни́ческая отста́лость; *~ терминнары* техни́ческие те́рмины

те́хникалы *прил.* **1.** 1) техни́чески развито́й, име́ющий (развиту́ю) те́хнику; *~ ил* техни́чески развита́я страна́ 2) с (*определённого качества*) те́хникой; *алдынгы ~* с передово́й те́хникой **2.** техни́чный (о спортсме́нах); *~ чаңгычы* техни́чный лы́жник

те́хникачы *сущ.* **1.** *см.* **технокра́т 2.** техници́ст (*человек, чрезмерно увлекающийся технической стороной дела*)

те́хникачылык *сущ.* **1.** технократи́зм **2.** техници́зм

те́хниклык *сущ.* профе́ссия, заня́тие и́ли положе́ние те́хника; *~ эшендә* рабо́тает те́хником; *~ таныклыгы* удостовере́ние те́хника

те́хникум *сущ.* те́хникум; *электротехника ~ы* электротехни́ческий те́хникум; *~да уку* учи́ться в те́хникуме; *~ янында* о́коло зда́ния те́хникума

те́хникумчы *сущ.* уча́щийся (студе́нт) те́хникума

те́хник-экономи́к *прил.* те́хнико-экономи́ческий; *техник-экономик шартлар* те́хнико-экономи́ческие усло́вия

техницизм *сущ. в разн. знач.* техници́зм; *~ белән мавыгу* увлека́ться техници́змом (*в романе*)

техни́чка *сущ.* техни́чка (*уборщица*); *см. тж.* **җыештыручы**

технократ *сущ.* технокра́т

технокра́тия *сущ.* технокра́тия

техноло́г *сущ.* техноло́г (*специалист по технологии*)

технологи́к *прил.* технологи́ческий; *~ карта* технологи́ческая ка́рта

технология *сущ. в разн. знач.* технология || технологи́ческий; *~ режимы* технологи́ческий режи́м

технорук *сущ.* технору́к (техни́ческий руководи́тель)

теш *сущ.* **1.** зуб, зу́бы, зу́бчик (*малышей*) || зубно́й; *теш чистарту* чи́стить зу́бы; *теш кую* вста́вить зу́бы; *еланның, үзе үлсә дә, теше үлми, ди* (*посл.*) е́сли да́же змея́ умрёт, зу́бы её оста́нутся; *тешең барда таш чәйнә* (*посл.*) пока́ мо́жешь — рабо́тай (*букв.* пока́ есть зу́бы — грызи́ ка́мни); *теш врачы* зубно́й врач; *теш нервы* зубно́й нерв; *теш пастасы* зубна́я па́ста **2.** до́лька, до́льки (*лука, чеснока*) **3.** зубе́ц, зубцы́; зу́бья, зу́бчик, зу́бчики; *пычкы теше* зубе́ц пилы́; *тарак теше* зубе́ц гребёнки **4.** копы́л (*саней*) **5.** пласти́нка **6.** *перен. редко* зуб (*способность дать отпор; мстительное намерение*); *аның сиңа теше бар* он име́ет зуб на тебя́; *эшең дә булсын, тешең дә булсын* (*посл.*) (*букв.* пусть у тебя́ и дела́ иду́т, и зуб бу́дет) □ **теш әнисе** *этногр.* же́нщина (*кроме матери*), пе́рвой уви́девшая зуб младе́нца (*она должна преподнести подарок ребёнку и стать его покровительницей*); **теш бакасы** флюс; воспале́ние дёсен; **теш казнасы** десна́, дёсны; **теш камаштыру 1.** наби́ть оско́мину **2.** причиня́ть боль зуба́м (*о звуках*); **теш камашу 1.** наби́ться (*об оскомине*) **2.** ощуща́ть боль в зуба́х (*от определённых звуков*); **теш карасы** *см.* **тешкара; теш корты 1.** ка́риес зубо́в **2.** *перен. что-л.* надое́дливое, назо́йливое; **теш куышы** дупло́ в зу́бе; **теш оясы** зубно́й свищ; свищ в зуба́х; **теш чистарткыч** зубочи́стка ◊ **теш агарту (ялтырату)** улыба́ться, смея́ться; ска́лить зу́бы; насмеха́ться; **теш арасы(нан) (аралаш)** сквозь зу́бы (*о словах, высказанных негромко, но злобно или неохотно*); **теш арасына кыстыру** пое́сть (*немножко*); **теш арасына кыстырырлык (кыстырырга)** на еду́-питьё (*о запасах*), на пита́ние; **теш арасыннан (тартып, каерып) да алып (әйттереп) булмый** *см.* **авызыннан тартып алып булмый; теш белән эргән уйнау** дрожа́ть (*всем телом, от холода, испуга, волнения*), *см. тж.* **теш шакылдату; теш кайрау 1.** хоте́ть, вожделе́ть есть, пое́сть (*что*) **2.** име́ть зуб, точи́ть зу́бы (*на кого*) **3.** хоте́ть, намерева́ться де́лать, сде́лать *что*; **теш кыжрату** *см.* **теш шыгырдату; теш кыжрау** скре́жет зубо́в; скрежета́ть (*о зубах, при гневе, злобе*); **теш күрсәту** огрыза́ться, пока́зывать зу́бы (*в знач.* показа́ть свои́ агресси́вные наме́рения, гото́вность к отпо́ру); **теш(не) кысып** сти́снув зу́бы, скрепя́ се́рдце; с уси́лием, не́хотя; *теш(еңне) кысып булса да түзәсең инде* прихо́дится терпе́ть, сти́снув зу́бы; **теш сугу (кагу) 1.** спо́рить с божбо́й; пыта́ться внуши́ть (*примитивными методами*); божи́ться **2.** препира́ться (*доказывая своё*); **теш суыру 1.** соса́ть зу́бы — вдыха́ть во́здух че́рез со́мкнутые зу́бы **2.** *см.* **теш шакылдату; теш төбенә төшү 1.** заму́чить (*требованиями; попрёками и т. п.*) **2.** насты́рно проверя́ть; **теш (тешем, тешең, теше, тешләре) төшү 1.** выпада́ть (*о зубах*) **2.** *см.* **теш чыгу; теш уңае** удо́бный предло́г, по́вод; **теш(е) үтү 1.** *прям., перен.* быть по зуба́м; *бу мәсьәләгә минем тешем үтми* э́та зада́ча мне не по зуба́м **2.** не понима́ть, не доставля́ть (*в знач.* не быть доста́точно си́льным); *синең аңа ~ең үтми* ты его́ не поймёшь (не доста́нешь); **теш шакылдату 1.** щёлкать, стуча́ть зуба́ми (*от холода*) **2.** *перен.* сиде́ть без пи́щи, быть голо́дным; зу́бы на по́лку класть; **теш шакылдау** стуча́ть (*о зубах*); **теш шыгырдату (шытырдату)** скрипе́ть, щёлкать зуба́ми, скрежета́ть (*от досады, злости*); **теш шыгырдау** *см.* **теш кыжрау; теш ыржайту** оскла́биться, ухмыля́ться; ска́лить зу́бы; *см. тж.* **теш агарту; теш ястыгы** пи́ща, еда́; **теше сирәк** не уме́ет держа́ть язы́к за зуба́ми (*букв.* зу́бы ре́дки); **теше тешкә тими** зуб о (на) зуб не попада́ет (*от холода, волнения и т. п.*); **теш чыгу 1.** *прям., перен.* станови́ться/стать зуба́стым **2.** съесть зуб (*в каком-л. деле*); соба́ку съесть; *сәүдә эшендә ~е чыккан*

в торго́вом де́ле он соба́ку съел; в торго́вле он зна́ет все ходы́ и вы́ходы; **тешен чүплəү (санау, кою)** вы́бить (все) зу́бы; *сиздек эшеңне — коярбыз тешеңне* (*погов.*) почу́яли мы твои́ дела́ — воздади́м по заслу́гам; **тешкə тию** 1. отража́ться бо́лью в зуба́х (*о резких звуках*) 2. надоеда́ть, заму́чить (*о непосильной работе, о трудностях*); **тешне (тешемне, тешеңне, тешен) кысу** сти́снуть, сжима́ть зу́бы от пережива́ний (*от гнева, злобы, усилия*)

тешəвеч *сущ.* зуби́ло (*для насекания зубьев, зубцов*); *~ белəн тешəү* насека́ть зуби́лом

тешəгеч *сущ. см.* **тешəвеч**

тешəк *прил. с.-х.* двухле́тний (*т.е. в возрасте смены зубов, преимущ. об овцах и козах*); *см. тж.* **шешəк**

тешəл|үү *страд. от* **тешəү**; быть заточённым и́ли засечённым; *яңа гына ~гəн пычкы* то́лько что зато́ченная пила́

тешəт|үү *понуд. от* **тешəү** I □ **~еп алу** дава́ть/дать заточи́ть (*мастеру*); **~еп җибəрү** (*хорошенько*) подзаточи́ть; **~еп йөрү** хлопота́ть о том, что́бы заточи́ли; **~еп кую** зара́нее дава́ть заточи́ть (*мастеру*)

тиле-миле III *сущ. собир.* дурачки́, дурачьё; *төрле тиле-миле* ра́зное дурачьё

тиле-милелек *сущ.* придуркова́тость, приду́рь

тилемсә *прил.* глупова́тый, тупова́тый; подо́бный (похо́жий) на сумасше́дшего

тилемсәрәк *сравн. ст. от* **тилемсә**; немно́го шальнова́тый, не́сколько поры́вистый; шальнова́т, поры́вист

тилергән *прил.* **1.** сумасше́дший, поме́шанный **2.** бе́шеный || *сущ.* сумасше́дший; *см. тж.* **тиле**; *~нәр йорты* сумасше́дший дом

тилерен|ү *неперех.* беси́ться, бу́йствовать; безу́мствовать, дура́читься || бу́йство, безу́мство; дура́чество; **~еп йөрмә** не беси́сь, не безу́мствуй

тилереп *нареч.* с упое́нием, я́ростно; *сандугач ~ сайрый* с упое́нием поёт солове́й

тилерешү *совм. от* **тилерү**; с ума́ сходи́ть, беси́ться, бу́йствовать (*о многих*)

тилермеш *сущ. разг.* сумасше́дший, умалишённый; **~ләр йорты** дом умалишённых; сумасше́дший дом

тилерткеч *сущ.* одуря́ющее сна́добье || *прил.* одуря́ющий; *~ ис* одуря́ющий за́пах

тилерт|ү 1. *понуд. от* **тилерү**; заста́вить сходи́ть/сойти́ с ума́ **2.** своди́ть/свести́ с ума́; *илерткән дә аракы, ~кән дә аракы* (*погов.*) во́дка заста́вит и вопи́ть, заста́вит и с ума́ сходи́ть

тилер|ү *перех.* **1.** оглупе́ть, поглупе́ть, помеша́ться; превраща́ться/преврати́ться в глу́пого (глупца́, в буйнопоме́шанного) || оглупле́ние, поглупле́ние, помеша́тельство; *эчеп ~ү* помеша́ться от пья́нства; *см. тж.* **исәрләнү, юләрләнү 2.** де́лать/сде́лать глу́пости; беси́ться (*будучи вообще умным*) **3.** с упое́нием дура́читься, шали́ть; бушева́ть, де́лать *что-л.* шу́мно, возбуждённо, поры́висто, легкомы́сленно; *см. тж.* **котыру** □ **~еп алу** подура́читься; **~еп йөрү** беси́ться

тиле-тилмән *сущ. собир. диал.* дурачьё

тилеханә *сущ. уст.* дом для умалишённых, сумасше́дший дом

тиле́чә *нареч. разг. см.* **тилеләрчә**; *тиленеке ~* у глупца́ по-глу́пому

тилкен *сущ. диал.* поры́в; мах; *бер ~ белән* одни́м ма́хом

тилкенләй *нареч. диал.* поры́вом, одни́м ма́хом, одни́м поры́вом; с хо́ду; *~ күтәрү* подня́ть одни́м ма́хом

тиллин-тиллин *подр. звукам колокольчика*; звяк, дзинь-дзи́нь

тилмереш|ү *совм. от* **тилмерү**; (*о многих*); *~еп торалар* все томя́тся в страда́ниях

тилмерт|ү *понуд. от* **тилмерү**; заста́вить страда́ть и томи́ться *из-за, от чего-л.*; *ипигә ~ү* заста́вить страда́ть от го́лода (без хле́ба)

тилмер|ү *неперех.* **1.** страда́ть, томи́ться || страда́ние, томле́ние *из-за, от чего*; жа́ждать *чего, кого* || жа́жда *по чему; агым суга төкергән — кабым суга ~гән букв.* кто плюёт в прото́чную во́ду, бу́дет томи́ться (зате́м) без глотка́ воды́; не плюй в коло́дец — пригоди́тся воды́ напи́ться **2.** смотре́ть, гляде́ть с наде́ждой и ожида́нием; тосковáть || тоскá *по кому, чему; ~еп көтү* томи́ться в ожида́нии **3.** моли́ть, умоля́ть || мольба́; *~еп карау* смотре́ть с мольбо́й; *~еп үтенү* о́чень проси́ть, умоля́ть (*со слезами на глазах*)

тилпендерү *понуд. от* **тилпенү**

тилпен|ү *неперех.* **1.** вспáрхивать/вспорхну́ть; маха́ть/махну́ть || вспáрхивание; мах, взмах, маха́ние кры́льями; *см. тж.* **талпыну**; *бер ~ү белән очып китте* вспорхну́л и улете́л **2.** *перен.* пляса́ть/припля́сывать || пля́ска, пляс; *ялкын телләре ~ә* пля́шут язычки́ пла́мени **3.** *перен.* порыва́ться || поры́в (*души*); *~еп кенә калдык* осты́л поры́в наш

тилү I *прил. диал.* припу́щенный к ма́тке; *~ бозау* припу́щенный к ма́тке телёнок

тилү II *перех. диал.* припуска́ть к ма́тке (*теленка*)

тилхат *сущ. уст.* распи́ска; *~ бирү* дава́ть/дать распи́ску

тилчә *сущ. мед.* **1.** золоту́ха; гно́йная о́пухоль; *тилегә ~ тими* (*посл.*) дурале́ю всё нипочём (*букв.* дурака́ золоту́ха обхо́дит) **2.** *диал.* рак || ра́ковый; *~ тамыры кебек* как ра́ковые ко́рни (*метастазы*) **3.** *диал.* я́щур ◊ **~ тел(ле)** злой язы́к, злоязы́чный

тилчәләнү *неперех.* опуха́ть/опу́хнуть || опуха́ние (*острой, болезненной опухолью*)

тилчәле *прил. мед.* **1.** золоту́шный **2.** *диал.* ра́ковый; *~ шеш* ра́ковая о́пухоль **3.** я́щурный; боле́ющий я́щуром; *~ сыерлар* я́щурные коро́вы

тим I *сущ. диал.* **1.** переры́в от дел (*во время работы*); тайм-а́ут **2.** по́рция; *үз тимен алды* он взял свою́ по́рцию □ **тим алу** прерыва́ться, взять переры́в, тайм-а́ут

тим II *сущ. диал.* пятно́, ме́тка (*на коже, шкуре*); *миңе барның тиме бар* (*посл.*) у кого́ ро́динка — у того́ ме́тка □ **тим чуар** пятни́стый (*о лошади*)

тимгел I *сущ.* **1.** кра́пинка, кру́глое пятно́ (*на лице, на цветах и т. п.*); *чәчәктәге ~ләр* кра́пинки на цвета́х; *буяу ~е* пятно́ от кра́ски **2.** сыпь (*на лице, теле*)

тимгел II *прил. см.* **тимгелле**

тимгел-күк *прил.* си́вый, мышáстый, с кра́пинками (*о масти лошади*)

тимгеллән|ү *неперех.* **1.** де́латься/сде́латься кра́пчатым, пятни́стым **2.** покрыва́ться/покры́ться пя́тнами

тимгеллә́ү *перех.* пятна́ть, запятна́ть

тимгелле *прил.* **1.** пятни́стый, с пя́тнами; кра́пчатый, с кра́пинками; *~ йөз* лицо́ с кра́пинками **2.** сыпно́й; усе́янный сы́пью □ *~ тиф* сыпно́й тиф

тимгеллек *сущ.* **1.** *см.* **тимгел 2.** *бот.* крапча́тка (*болезнь растений*)

тимгеллелек *сущ.* пятни́стость, кра́пчатость

тимгел-тимгел *прил.* кра́пчатый, (весь) в кра́пинах (пя́тнах) □ **тимгел-тимгел булу** быть в кра́пинках, име́ть кра́пчатый (пятни́стый) вид

тимгел-чуар *прил.* расплы́вчато-пятни́стый; в расплы́вчатых пя́тнах; *тимгел-чуар бурлы кашка ат* ча́лая ло́шадь в расплы́вчатых пя́тнах и со звёздочкой на лбу

тимер I *сущ.* **1.** желе́зо; *~ оксиды* окси́д желе́за; *~ тапкан тилмермәс* (*посл.*) кто добыва́ет желе́зо, тот не ста́нет тужи́ть; *алтыны ~ таба* (*посл.*) зо́лото добыва́ют желе́зом **2.** *разг.* желе́зка (*металлическая часть чего-л.*); *табагач ~е* желе́зная часть сковоро́дника; *көянтә ~е* металли́ческая зацéпка коромы́сла

тимер II **1.** желе́зный, металли́ческий; *~ сәнәк* желе́зные ви́лы; *~ тасма* поло́ска желе́за; *~ ишек* металли́ческая дверь **2.** *перен.* 1) о́чень кре́пкий, желе́зный; *~ бәдәнле* с желе́зным те́лом; железноте́лый 2) твёрдый, непрекло́нный; неумоли́мый; *~ ихтыяр* желе́зная во́ля; *тормышның ~ кануннары* желе́зные зако́ны жи́зни; *~ логика* желе́зная ло́гика; *~ дисциплина* желе́зная дисципли́на 3) *в эмфатических названиях*; желе́зный, непобеди́мый; *~ гвардия* желе́зная гва́рдия □ **~ агач** желе́зное де́рево (*вид растений*); *~ биялә́й* (*устарелый вид оружия*) желе́зные перча́тки; **~ рудасы** желе́зная руда́; **~ ташы** *см.* **тимерташ**; **~ түбәтәй** *см.* **шлем**; **~ эретмәсе** сплав желе́за; желе́зный сплав; **~ эше** железообраба́тывание, обрабо́тка желе́за; **~ юл** желе́зная доро́га; *~ юл транспорты* железнодоро́жный тра́нспорт ◊ **~ кебек** как желе́зо; желе́зно; **~ талкы (тарак)** *о беспощадной каре, возмездии; о беспощадных репрессиях*

тимераяк *сущ.* конько́; *~та шуу* ката́ться на конька́х

тимербетон I *сущ.* железобето́н; *~нан эшләнгән* сде́ланный из железобето́на

тимербетон II *прил.* железобето́нный; *~ конструкцияләр* железобето́нные констру́кции

тимерказык *сущ.* Поля́рная звезда́ (*букв.* желе́зный кол); *табынсаң, ~ка табын — аңа йолдызлар да табына* (*посл.*) е́сли преклоня́ться, преклони́сь пе́ред Поля́рною звездо́й; пе́ред ней преклоня́ются и звёзды (*о выборе достойного предмета поклонения, преклонения*)

тимеркара *сущ.* **1.** легенда́рная ло́шадь, си́мвол но́чи (*букв.* желе́зно-чёрная) **2.** созве́здие драко́на; *тимерказыкка ~ бәйләнгән* (*загадка об этом созвездии*) к желе́зному ко́лу привя́зана желе́зно-чёрная ло́шадь

тимер-күк *прил.* тёмно-си́вый (*о масти лошади*) || си́вка-бу́рка

тимерләп|ү I *страд. от* **тимерләү**; *~гән арба* око́ванная теле́га; теле́га, снабжённая желе́зными частя́ми (*железной шиной и т. п.*)

тимерләп|ү II **1.** станови́ться, стать желе́зным, суро́вым и твёрдым; *йөзе ~де* лицо́ его́ ста́ло суро́вым (желе́зным) **2.** *перен.* станови́ться/стать неповоро́тливым; *телем ~де* язы́к мой стал неповоро́тливым (сло́вно желе́зным)

тимерләтү *понуд. от* **тимерләү**; дать окова́ть желе́зом

тимерләү *перех.* око́вывать/окова́ть желе́зом; крепи́ть || крепле́ние желе́зной дета́лью; прикрепи́ть || прикрепле́ние желе́зной ча́сти, дета́ли и т. п.; *чана ~* око́вывать поло́зья желе́зом; *сандык ~* окова́ть сунду́к желе́зом

тимерле *прил.* **1.** содержа́щий желе́зо; желе́зистый; желе́зный; *~ руда* желе́зистая (желе́зная) руда́ **2.** име́ющий желе́зную, металли́ческую дета́ль; *~ арба* теле́га с желе́зными частя́ми; *~ итек* ко́ваные сапоги́ **3.** *редко*

имéющий желéзо, владéющий желéзом; ~ *кеше тимтенмәс* (*посл.*) человéк, владéющий желéзом, не бýдет мáяться (*у него хорошие орудия труда*)

тимерле|к *сущ. разг.* кýзница; *колхоз ~ге* колхóзная кýзница; *җиз ~ктә тимер тимерче эшли* в латýнной кýзнице рабóтает желéзный кузнéц (*загадка о колокольчике*)

тимерсез *нареч. прил.* без желéза, без желéзных частéй; ~ *чана* сáни без подрéзов

тимерташ *сущ.* железнякá, желéзная рудá

тимер-томыр *сущ. собир.* 1. металлолóм; *тимер-томыр жыю* собирáть металлолóм 2. желéзные, металли́ческие, скобяны́е издéлия; *тимер-томыр кибете* лáвка скобяны́х издéлий; *тимер-томыр арасында* средú железя́к

тимерхут *сущ. диал.* тарантáс, телéга с желéзным хóдом (на желéзном ходý); ~ *җигу* запрягáть телéгу на желéзном ходý

тимерче *сущ.* кузнéц; ~ *бабай* дед-кузнéц; *~гә күмерче юлдаш* (*посл.*) кузнецýýгольщик собрáт (спýтник) □ ~ **алачыгы** *см.* **тимерлек**; ~ **чүкече** кузнéчный мóлот; *~лар цехы* кузнéчный цех

тимерчелек *сущ.* 1. кузнéчное дéло, кузнéчное ремеслó, занятие кузнецá; ~ *белән шөгыльләнү* занимáться кузнéчным дéлом (ремеслóм) 2. *см.* **тимерлек**

тимерчыбык I *сущ.* прóволока; *бер төргәк* ~ бунт (бýхта) прóволоки; *~тан эшләнгән* сдéланный из прóволоки

тимерчыбык II *прил.* прóволочный; ~ *челтәр* прóволочная сеть

тимерьюлчы *сущ.* железнодорóжник, рабóтник желéзной дорóги; *~лар клубы* клуб железнодорóжников

тимофéевка *сущ. с.-х. бот.* тимофéевка; ~ *чәчү* сéять тимофéевку

тимпан *сущ. архит.* тимпáн (*внутреннее поле фронтона*)

тимрóү *сущ.* экзéма; *~гә тару* заболéть экзéмой

тимрәүлә́ү *неперех.* болéть экзéмой

тимрәүле *прил.* экзéмный, болéющий экзéмой

тимсах *сущ. книжн. уст.* крокодúл || крокодúловый; ~ *йомыркасы* яйцó крокодúла || *прил.* крокодúловый, сдéланный из кóжи (*или имитации кожи*) крокодúла; ~ *портфель* портфéль из крокодúловой кóжи

тимтен|ү *неперех. разг.* 1. 1) помалéньку подвигáть дéло; *ярыйсы гына ~ү* значúтельно продвúнуть (дéло) 2) трудúться по мéре сил 2. жить, проживáть || прожúвание с трудóм; *~сәң дә кимсенмә* (*посл.*) дáже живя́ трýдно, не считáй себя́ ущéрбным

тимурчы *сущ. ист.* тимýровец; *~лар командасы* комáнда тимýровцев

тимурчылык *сущ. ист.* тимýровское движéние

тинтәк I *прил.* 1. недалёкий, глуповáтый, легкомы́сленный; сумасбрóдный (*о человеке*); ~ *кеше* глуповáтый человéк 2. глýпый, легкомы́сленный (*в словах, действиях и т. п.*) ~ *кыланыш* глýпое поведéние; ~ *уйлар* глýпые мысли́шки

тинтәк II *сущ.* дýрень, баламýт, сумасбрóд; ~ *тегелмәгән итеген мактар* (*посл.*) дýрень хвáлит не сши́тые ещё сапоги́; ~ *белән типтергәнче, аңлы белән таш ташы* (*посл.*) чем пировáть с дýрнем (баламýтом), лýчше таскáть кáмни с ýмным; *ике ~ кушылса, яу була, ике ипле кушылса, тау була* (*посл.*) éсли два дýрня объединя́тся, бýдет би́тва, éсли два ýмных объединя́тся, вы́растет горá

тинтәкләнү *неперех.* 1. превращáться/превратúться || превращéние в дýрня, сумасбрóда 2. дурúть, валя́ть дурака́, чудúть □ ~**еп бету** превратúться в дýрня; ~**еп йөрү** дурúть постоя́нно

тинтәкле|к *сущ.* сумасбрóдство, дурь, глýпость; ~*к күрсәтү* проявля́ть сумасбрóдство; *~ге күренеп тора* глýпость егó видна́ срáзу

тинтерә́|ү *перех.* измáтывать/измотáть, надоедáть/надоéсть (*вздорными или несостоятельными просьбами, ненужными проблемами*); *бер тинтәк өйне ~ә, ике тинтәк илне ~ә* (*посл.*) одúн дýрень донимáет семью́, два дýрня донимáют деревню

тинтерә́|ү *неперех.* 1. очумéть, измáтываться/измотáться, обессúлеть (*от хлопот, трудностей или от общения, от приставаний кого-л.*) 2. одурéть || одурéние; *~п беттем* я окончáтельно одурéл

тиң I *предик. прил.* 1. рáвный, равновели́кий || рáвен, равновели́к *чему; диңгезләргә тиң Идел* Вóлга, рáвная (*по величине*) моря́м 2. рáвный, одинáковый, достóйный сравнéния || рáвен, одинáков, достóин сравнéния (*о ком, чем, в чём*); *матурлыкта һичкемгә тиң түгел* в красотé ни с кем не сравни́мая; *эшкә һичнәрсә тиң түгел* ничтó не сравни́мо (достóйно сравнéния) с рабóтой; *кешедән кеше ким түгел, бәхет кенә тиң түгел* (*песня*) одúн человéк не хýже другóго, тóлько вот счáстье не рáвно 3. рáвный *кому*; стóящий, достóйный *кого*; рáвен *кому*; стóит, достóин *кого* (*о людях, оцениваемых с точки зрения сравнения их высоких качеств*); *китән күлмәк киң кирәк, сөйгән ярың тиң кирәк* (*песня*) льняно́е плáтье должнó быть простóрным, а любúмый (дóлжен быть) стóящим 4. достигáющий, доходя́щий до ..., врóвень *с чем; чәче җиргә тиң* вóлосы (её) дохóдят до земли́ (врóвень с землёй) 5. *как первый компонент сложных слов* равно-; *тиң кыйммәтле* равноцéнный; *тиң күләмле мат.* равновели́кий

тиң II *нареч.* 1. врóвень, рóвно; одинáково, одинáковым óбразом; *ике кулы тиң корышкан* óбе рукú одинáково засóхли, *йөгерүчеләр тиң килделәр* бегуны́ прибежáли врóвень 2. на рáвных; *тиң көрәшү* борóться на рáвных

тиң III *сущ.* 1. рóвня; достóйный себé (*человек*); *көрәшсәң — тиңең белән көрәш* (*посл.*) бóрешься — борúсь с достóйным себé; *тиңен тапса, тиген бир* (*посл.*) найдёт рáвного себé — отдáй дáром (*т. е. без калыма*); *ул сиңа тиң түгел* он тебé не рóвня 2. свéрстник, свéрстница; *см. тж.* **кордаш**; *үз тиңнәрем гаеп итмәслəр* мои свéрстники не осýдят менá 3. *этногр.* 1) свáдебная подрýга (*одна из двенадцати девушек-подруг, обязавшихся участвовать на свадьбе друг друга*); *тиңнәр арасында тиң идем, атама моңайган мин идем* (*песня*) я былá однóй из двенáдцати дéвушек, я пéла прощáльную пéсню отцý (*на своей свадьбе*) 2) дрýжка женихá (*на свадьбе*) □ **тиң булу** быть рáвным; **тиң бүлү** делúть пóровну; делúть пополáм; ***кемгә тиң килү*** быть рáвным *кому*; быть рóвней, быть нáрой; **тиң күрү** считáть рóвней себé, равнопрáвным с собóй; **тиңгә тиң** 1. совершéнно рáвный, рáвные (*о сравниваемых предметах*) 2. рáвный средú рáвных ◊ **тиңе юк, тиңе булмаган (күрелмәгән, табылмаган)** *см.* **тиңдәшсез**

тиң IV *послелог диал. см.* **тикле, чаклы; тиңентен**

тиңәш|ү *неперех. диал.* 1. подружúться, побратáться; входúть/вхождéние в дрýжеские, свóйские отношéния;

киңәшмичә тиңмә (*посл.*) не подружи́сь без разбо́ра (*букв.* без сове́та) **2.** сра́внивать себя́ *с кем, чем; см.* **тиңләшү**

тиңгел *сущ. диал.* **1.** ро́вная площа́дка **2.** *в знач. послелога* **тиңгелендә** о́коло *чего,* ря́дом, напро́тив; *яр ~ендә* напро́тив обры́ва, ря́дом с обры́вом

тиңгеллек *~ көне* день равноде́нствия

тиңгенәй *сущ. диал. см.* **тиң** III

тиңдәш I *сущ.* **1.** све́рстник, све́рстница, рове́сник, рове́сница; *атаң ~е* рове́сник твоего́ отца́ **2.** ро́вня, чета́; *сиңа ~ түгел* тебе́ не чета́ **3.** *этногр. см.* **тиң** III

тиңдәш II *прил.* **1.** ра́вный, подо́бный; досто́йный; соотве́тствующий; *ул үзенә ~ көрәшче тапмаган* он не нашёл ра́вного себе́ борца́ **2.** явля́ющийся све́рстником, рове́сником, дру́гом, подру́гой; *~ кызлар* де́вушки-све́рстницы, де́вушки-подру́ги □ **~ кисәкләр** одноро́дные чле́ны предложе́ния; **~е булмаган** *см.* **тиңдәшсез**

тиңдәшлә́рчә I *нареч.* по-сво́йски, по-дру́жески, по-бра́тски; как ра́вный с ра́вными

тиңдәшлә́рчә II *прил.* бра́тский, сво́йский; *~ мөгамәлә* сво́йское обраще́ние

тиңдәшлек *сущ.* **1.** ра́венство; бра́тство **2.** содру́жество, сою́з; *безнең ~* наш сою́з; *~кә керү* входи́ть в сою́з

тиңдәшлелек *сущ. мат.* тожде́ственность, схо́дность

тиңдәшсез *прил.* беспо́добный, беспреме́рный, беспрецеде́нтный, небыва́лый; *~ очрак* беспрецеде́нтный слу́чай; *~ батырлык* беспреме́рный геройзм; *~ оста* беспо́добный ма́стер; *~ дәрәҗәдә* в невероя́тной сте́пени

тиңдәшсезлек *сущ.* беспо́добность

тиңеннән *послелог см.* **тиңентен**

тиңентен *послелог разг.* **1.** вро́вень с; по, до; *бил ~* до по́яса; по по́яс **2.** аж до само́го (*определённого места*); аж из само́го (*определённого места*); *см. тж.* **тикле, чаклы**; *бу ~ җиргә* аж до (*такой далёкой*) ме́стности; *Казан ~ Казаннан* аж из само́й Каза́ни

тиңкәр *сущ. физ.* равноде́йствующая (си́ла) || *прил.* равноде́йствующий; *~ көчләр* равноде́йствующие си́лы

тиңләгесез *прил. см.* **тиңләштергесез**

тиңл|әү *перех.* **1.** равня́ть *с кем, чем*; прира́внивать/приравня́ть *к кому, чему; син үзеңне миңа ~әмә* ты не равня́й себя́ со мно́й **2.** сра́внивать/сравня́ть, сравни́ть || сра́внивание, сравне́ние (*вообще*) **3.** отожествля́ть/отожестви́ть, отождествля́ть/отождестви́ть; *см. тж.* **тиңләштерү, чагыштыру**

тиңләштергесез *прил.* несравни́мый; *~ дәрәҗәдә* в несравни́мой сте́пени; *бусы тегесенә ~* э́тот несравни́м с тем

тиңләштерү *перех.* **1.** равня́ть *с кем*; прира́внивать/приравня́ть *к кому, чему* **2.** уподобля́ть/уподо́бить, сра́внивать/сравни́ть || уподобле́ние, сра́внивание *с кем, чем* **3.** отождествля́ть/отождестви́ть, || отождествле́ние

тиңләш|үү *неперех.* **1.** станови́ться/стать ра́вным, одина́ковым *с кем, чем*; равня́ться, поравня́ться, сра́вниваться/сравня́ться; *алдынгылар белән ~тек* мы поравня́лись с передовы́ми **2.** *разг.* догоня́ть/догна́ть (*при беге*) **3.** *разг.* соразмеря́ться, отождествля́ться/отождестви́ться || отождествле́ние (себя) *с кем, чем* **4.** быть сравни́мым по досто́инствам; *минем шатлыгым белән кемнеке генә ~ер* чья ра́дость мо́жет быть сравни́ма с мое́й

тиңлек *сущ.* ра́венство (*в человеческих и т. п. отношениях*); *~тә кимлек юк, хөрлектә хурлык юк* (*посл.*) в ра́венстве нет униже́ния, в свобо́де нет позо́ра

тиңлекле *прил.* ра́вный, в ра́вных взаимоотноше́ниях

тиңмә-тиң *нареч.* **1.** по́ровну, то́чно в ра́вных доля́х; *тиңмә-тиң бүлешү* подели́ться то́чно по́ровну **2.** то́чно; ра́вно, ра́вным о́бразом; не отстава́я друг от дру́га; *тиңмә-тиң йөгерәләр* бегу́т абсолю́тно ра́вно

тиңпочмаклы *прил. мат.* равноуго́льный

тиңпочмаклык *сущ. мат.* равноуго́льник

тиңсез I *прил.* **1.** несравне́нный, несравни́мый; *~ уңыш* беспримерный успе́х; *см. тж.* **тиңдәшсез 2.** нера́вный; *см. тж.* **тигезсез**

тиңсез II *нареч. диал.* без дру́га (друзе́й); *синсез үтә — ~ үтә гомерем* моя́ жи́знь прохо́дит без тебя́ — без дру́га ми́лого

тиңсезлек *сущ.* **1.** нера́венство (*в обществе, в семье*); *см. тж.* **тигезсезлек 2.** *диал.* одино́чество; жизнь без дру́га

тиңсен|ү *неперех.* счита́ть/счесть себя́ ра́вным *кому, с кем; ~мәсәгез дә без кимсенмәбез* хотя́ вы не счита́ете нас ра́вными себе́, мы не счита́ем себя́ ху́же вас

тиңхокуклы *прил.* равнопра́вный; *~ халыклар* равнопра́вные наро́ды

тип I *сущ.* разнови́дность бараба́на (*у сибирских татар*); дап; *типкә типмә — балаң елак булыр* (*посл.*) не пина́й бараба́н — де́ти твои́ бу́дут плакси́выми

тип II *сущ.* тип **1.** вид, разнови́дность 1) *иск. литер.* обобщённый о́браз 2) вы́сший классификацио́нный разря́д живы́х суще́ств **2.** *в знач. нареч.* **типта** по определённому ти́пу; *яңа ~та эшләнгән* изгото́влен по но́вому ти́пу

тип *прил.* **1.** *см.* **типтагы**; *башка тип әсәрләр* произведе́ния друго́го ти́па; *бер тип кешеләр* тип люде́й, не́которые лю́ди **2.** *в ф.* **типтагы, тибындагы** определённого ти́па; входя́щий в определённый тип; *альфа Центавра тибындагы йолдызлар* звёзды ти́па а́льфа Цента́вра; *беренче типтагы машиналар* маши́ны пе́рвого ти́па; *умырткалылар тибындагы хайваннар* живо́тные, входя́щие в тип позвоно́чных

типаж *сущ.* типа́ж *только ед.* **1.** совоку́пность ти́пов **2.** совоку́пность при́знаков ти́па **3.** актёр (*особенно подходящий для роли*)

типеч *сущ. диал.* **1.** *см.* **тәпәч 2.** дубе́ц, клю́шка при игре́ с деревя́нными шара́ми; *см. тж.* **шартаяк**

ти́пик *прил.* **1.** типи́чный; *~ хәллар* типи́чные обстоя́тельства; *~ лыгырдык* типи́чный болту́н **2.** *лит.* типи́ческий; *~ образ* типи́ческий о́браз

ти́пиклаштыру *перех. лит.* типизи́ровать || типиза́ция; *~ алымнары* приёмы типиза́ции

ти́пиклаштырылу *страд. от* **типиклаштыру**; **типизи́роваться**

ти́пиклаш|у *неперех.* станови́ться/стать || становле́ние типи́чным; типизи́роваться (*само собой*); *мондый очраклар ~ты* таки́е слу́чаи ста́ли типи́чными

ти́пиклык *сущ.* типи́чность

типке *сущ. разг.* побо́и, пинки́, гру́бое обраще́ние; *кеше ~сендә* под пинка́ми чужи́х люде́й; *~ астында* под пинко́м; терпя́ побо́и

типкен I *сущ.* **1.** *диал.* отпо́р, обра́тный уда́р; *~ бирү* дать отпо́р; *гидравлик ~* гидравли́ческий уда́р **2.** прибо́й; прили́в; *диңгез ~е* морско́й прибо́й; *~ вакыты* вре́мя прили́ва **3.** па́водок, полово́дье (*весной*)

типкен II *прил. фольк.* ло́вкий, бо́йкий, добы́чливый (*об охотничьих, ловчих птицах*); *аты чапкыр, кошы ~* конь его́ ре́звый, ло́вчая пти́ца добы́члива

типкеч I *сущ. диал.* **1.** шпо́ры (*петуха и т. п. птиц*) **2.** пушо́к для игры́ в ля́нгу

типкеч II *сущ.* гуля́ка, кути́ла, мот-пьянчу́га, мот-развра́тник, прожига́тель жи́зни; *~нең дусты куп* (*погов.*) у мо́та мно́го друзе́й

типовой *прил.* типово́й (*проект*)

типо́граф *сущ.* **1.** типо́граф **2.** *зоол.* типо́граф (*жук-короед*)

типогра́фик *прил.* типогра́фский; типографи́ческий; *~ кара* типогра́фская кра́ска; *~ юл белән басу* печа́тать типографи́ческим спо́собом

типогра́фия *сущ.* типогра́фия || типогра́фский, типографи́ческий; *~ юлы белән* типогра́фским спо́собом; *~ кәгазе* типогра́фская бума́га

типогра́фияче *сущ.* **1.** рабо́тник типогра́фии; специали́ст по типогра́фии **2.** *уст.* хозя́ин типогра́фии; предприни́матель, владе́лец типогра́фии

типоло́гик *прил.* типологи́ческий; *~ классификация* типологи́ческая классифика́ция

типоло́гия *сущ.* типоло́гия; *телләр ~се* типоло́гия языко́в

типоме́трия *сущ. типогр.* типоме́трия

типсәү *диал. этногр.* **1.** *перех.* петь || пе́ние шутли́вого содержа́ния во вре́мя про́водов неве́сты; *кияү ~* петь пе́сни (*порой уничижительные*) в а́дрес жениха́ **2.** *неперех. диал.* петь, припля́сывая

типсену *неперех.* припля́сывать || припля́сывание (*о лошади*); *аргамак аттай ~* припля́сывать, как поро́дистая ло́шадь

типташ *прил.* **1.** однотипный **2.** *см.* **типовой**; *~ проектлар* типовы́е прое́кты

типтәр *сущ. ист.* тепта́рь (*представитель этнографической группы татар, живший в башкирских землях на правах припущенников*); *~ләр арасында* среди́ тепта́рей □ **~ ясагы** *ист.* тепта́рский оклад (*вид обложения, налагаемый на припущенников*)

типтер|ү *неперех. перен. разг.* кути́ть, гуля́ть || кутёж, гульба́ □ **~еп алу** кутну́ть, погуля́ть; (разо́к) гульну́ть; **~еп йөрү** кути́ть, гуля́ть (*по разным местам*) ◊ **~еп яшәү** жить вольго́тно, жить припева́ючи

ти́п-тигез *прил. превосх. ст.; тип-тигез юл* соверше́нно ро́вная доро́га; *үзара тип-тигезләр* ме́жду собо́й соверше́нно равны́

ти́п-тиген *прил. превосх. ст.*; соверше́нно да́ром; во́все беспла́тно

ти́п-тиле *прил. превосх. ст.*; соверше́нно глу́пый, прегло́упый; глу́пенький

ти́п-тискәре *превосх. ст. прил.*; соверше́нно упря́мый; упря́мый как чёрт, преупря́мый

типчак *сущ. бот.* типча́к (*вид степной травы*); овся́ница боро́здчатая

типчеңү *неперех.* занима́ться шитьём (*ручной иглой*)

тимчетү *понуд. от* **типчү**; заста́вить и́ли поручи́ть намётывать

типчештер|ү *многокр. от* **типчү**; намётывать, понамётывать; *~еп алыйм дигән идем* хотел бы́ло немно́го понамётывать

типчеш|ү *взаимно-совм. от* **типчү**; помога́ть/помо́чь намётывать

типч|ү *перех.* **1.** намётывать/наметáть || намётывание; шить || шитьё (*крупными стежками*); *~еп тегү* шить ручно́й игло́й (*мелкими стежками*) **2.** *диал.* пришпи́ливать/пришпи́лить

тир I *сущ.* пот, испа́рина; *тир тамчылары* ка́пли по́та; *тирең аккан җирнең кадере* дорога́ земля́, кото́рую поли́л по́том □ **тир авыруы (чире) 1.** лихора́дка, лихома́нь *обл.* **2.** *см.* **тиф хастасы; тир алу** вы́потеть || вы́пот в моме́нт кри́зиса боле́зни; *тир алгач, чир китә* по́сле вы́пота боле́знь отступа́ет; **тир бизе** потова́я же́леза; **тир кату** пообсо́хнуть от по́та; поотдохну́ть и прохлади́ться (*после тяжких усилий*); *тир катмыйча, салкын су эчмә* не пей холо́дной воды́, пока́ не пообсо́х; **тир тозы** оса́дки со́ли от по́та (*на одежде*); **тир хастасы (хастәсе, чире)** тиф, горя́чка; **тиргә бату (төшү) 1** пропоте́ть, облива́ться по́том; вспоте́ть, запоте́ть **2.** надрыва́ться (*от усилий*) **3.** впада́ть/впасть в смяте́ние; **тиргә батыру (төшерү)** вгоня́ть/вогна́ть в пот; *авыр сораулар белән тиргә батыру* вогна́ть в пот тру́дными вопро́сами ◊ **тир белән табу** зараба́тывать/зарабо́тать трудо́м; **тир киптерү 1.** отдыха́ть/отдохну́ть во вре́мя рабо́ты **2.** зря проводи́ть рабо́чее вре́мя; прерыва́ть рабо́ту из-за ле́ни и т. п. неуважи́тельных причи́н; загора́ть; **тир салу (түгү)** вложи́ть пот; проliва́ть/проли́ть пот; кропи́ть по́том; **тир түгеп** в по́те лица́

тир II *сущ.* тир; *тирдаату* стреля́ть в ти́ре

тира́да *сущ.* тира́да; *ләгънәт ~сы* тира́да-прокля́тие

тираж *сущ. в разн. знач.* тира́ж; *лотереянең өченче ~ы* тре́тий тира́ж лотере́и; *~ таблицасы* табли́ца тиража́; тира́жная (*справочная*) табли́ца; *китап ~ы* тира́ж кни́ги; *мең данә ~ белән* тиражо́м в ты́сячу экземпля́ров ◊ **~га чыгу** выходи́ть/вы́йти в тира́ж

тиражлы *прил.* тира́жный; *күп ~* многотира́жный

тирак *предик. прил.* прово́рный, раство́пный; прово́рен, раство́пен и кре́пок; *балалы елак булса, анасы ~ була* (*посл.*) е́сли дитя́ плакси́во, мать быва́ет раство́пна и прово́рна

тиран *сущ.* **1.** *ист.* тира́н, единовла́стный прави́тель **2.** тира́н, вла́стный и жесто́кий прави́тель (*начальник и т. п.*) *явыз ~* злой тира́н; *~ булып күренү* каза́ться тира́ном **3.** *мн. тираннар зоол.* тира́ны (*род птиц в южных странах*) □ **~ булу 1.** быть тира́ном **2.** тира́нить, вла́стно и жесто́ко обраща́ться

тиранлан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать || становле́ние тира́ном (*жестоким и властным*); *~ып китте* совсе́м тира́ном стал **2.** проявля́ть/прояви́ть || проявле́ние тира́нства, жесто́кости; тира́нствовать; *гаиләдә ~у* тира́нствовать в семье́; тира́нить семью́

тиранлы|к *сущ.* **1.** тира́нство **2.** тира́нство, жёсткость вла́сти; *хәлифәлек ~гы* жесто́кость вла́сти халифа́та □ **~к итү** тира́нствовать, проявля́ть тира́нство

тиратай *сущ. разг.* **1.** дурале́й, ду́рень (*мальчик, девочка*); *мин ~, ~, кәләш алып бир, атай, синең киленең булыр, минем күңелем булыр* (*песня*) ба́тюшка, я дурале́й, жени́ меня́ поскоре́й, тебе́ бу́дет сноха́, мне бу́дет хорошо́ **2.** шалопа́й, шалопу́т

тиратайлан|у *неперех.* **1.** дури́ть, кривля́ться, глу́по шути́ть || кривля́нье, глу́пая шу́тка; *~ып йөрмә* не дура́чься; не кривля́йся, как ду́рень **2.** шалопа́йничать

тиратайлык *сущ.* **1.** кривля́нье, глу́пые шу́тки; *~ итү* выка́зывать ду́рость, наро́чно дура́читься **2.** шалопа́йничанье

тирә *сущ.* **1.** всё (*что*) вокру́г; всё (*что*) круго́м; *~ ап-ак* всё вокру́г белым-бело́ **2.** *в притяж. ф. переводится сочетаниями с предлогом* вокру́г, круго́м; *минем ~мдә* вокру́г меня́; *кызлар ~сендә йөрү* увива́ться вокру́г де́вушек; *өй ~се — гел үлән* вокру́г до́ма сплошь трава́ **3.** край, кра́ешек; окру́жность; *күл ~сендә* по кра́ю (кра́ем) о́зера; по окру́жности о́зера **4.** окре́стность, окре́стности; ме́стность, окру́га; края́; *безнең бу ~дә* в на́шей зде́шней ме́стности, в на́шей окру́ге; в на́ших

краях 5. *этногр. диал.* занаве́ска, круго́м закрыва́ющая всю ве́рхнюю часть стены́ за́ла (*входила в обязательный комплект приданого невесты*) 6. *в знач. послелога* **тирәсендә (тирәсендәрәк), тирәдә (тирәдәрәк)** *о ком, чём,* насчёт *кого, чего,* относи́тельно *кого, чего* (*делается, говорится — о предмете разговора, речи*); *бәхәсләр әдәбият ~сендә бара* спо́ры иду́т относи́тельно (вокру́г) литерату́ры; *утенечем улым ~сендәрәк иде* моя́ про́сьба была́ насчёт сы́на; *шул ~дәрәк сүз йөрттеләр* вели́ разгово́р приме́рно о том (*упомянутом*)

тирәдәге *прил.* окре́стный, ме́стный; ~ *авыллар* окре́стные дере́вни

тирәз *сущ. диал.* 1. око́нце, око́шко, ма́ленькое окно́ (*бани, хлева и т. п.*) 2. фронто́н

тирә|к *сущ.* 1. то́поль; осо́корь; *ак ~к* серебри́стый то́поль; *кара ~к* чёрный то́поль, осо́корь; *~к мамык очырган чак* пора́ цвете́ния тополе́й (*букв.* когда́ летя́т хло́пья тополе́й) 2. больши́е высо́кое де́рево (*у реки*); *зәйтүн ~ге* де́рево сли́вы 3. *диал. миф.* ска́зочное ю́жное де́рево (*вышивается как орнамент на полотенцах, платках*)

тирәклән: тирәклән чигү вышива́ть расти́тельным орна́ментом

тирәкле *прил.* 1. с то́полем, тополя́ми; тополи́ный; ~ *аллея* тополи́ная алле́я 2. вы́шитый расти́тельным орна́ментом; ~ *сөлге* вы́шитое расти́тельным орна́ментом полоте́нце 3. *разг.* с (*высоким*) де́ревом, с дере́вьями (*о доме, дворе*)

тирәклек *сущ.* 1. то́полевая (тополи́ная) ро́ща; осоко́рник; *~тә кошлар сайрый* в тополи́ной ро́ще пою́т пти́цы 2. ро́ща (*у деревни, у реки*)

тирәлән *послелог разг.* 1. *см.* **тирәли**; *күл ~* вокру́г о́зера 2. *диал.* о, про, каса́тельно, насчёт *кого, чего; кыз ~ яучы сөйләр* (*посл.*) сват (*обычно*) говори́т каса́тельно де́вушки

тирәләтү *понуд. от.* **тирәләү**

тирәл|әү *неперех.* 1. *разг.* окружа́ть/окружи́ть (*оградой*); окаймля́ть (*вышивку*) 2. *перен.* ходи́ть вокру́г да о́коло 3. *перен. разг.* преследовать не́которые це́ли; *ул нәрсәдер ~и* он что́-то хо́чет предприня́ть □ **~әп алу** окружи́ть со всех сторо́н

тирәле *прил. разг.* окаймлённый; ~ *яулык* окаймлённый плато́к

тирәли I *нареч.* 1. вокру́г, круго́м; ~ *әйләнеп чыгу* обойти́ круго́м 2. по края́м; ~ *тегелгән* оши́тый по края́м; ~ *чигелгән* вы́шитый по края́м

тирәли II *послелог* вокру́г; *авыл ~ үскән каеннар* берёзы, расту́щие вокру́г дере́вни; *өй ~ йөрү* ходи́ть вокру́г до́ма

тирән I *прил.* 1. *в разн. знач.* глубо́кий; ~ *елга* глубо́кая река́; ~ *фикер* глубо́кая мысль; ~ *тикшеренү* глубо́кое иссле́дование □ **~ белем (гыйлем)** глубо́кое зна́ние, глубо́кие зна́ния; ~ *кичерешләр* глубо́кие пережива́ния 2. *в знач. сущ. разг.* глубина́; *диңгез ~ендә* в глубине́ мо́ря

тирән II *нареч.* глубоко́; ~ *йөзү* глубоко́ пла́вать (*перен.*) □ **~гә керү** углубля́ться/углуби́ться (*в причинные связи*) в суть, в исто́ки и т. п.; **~гә китү** заходи́ть/зайти́ далеко́; пойти́ вглубь; принима́ть/приня́ть серьёзный оборо́т; *эшләр ~гә китте* дела́ принима́ют серьёзный оборо́т

тирәнәйтү *перех. прям., перен.* углубля́ть/углуби́ть || углубле́ние; *каналны ~* углубля́ть кана́л; *белемнәрне ~* углубля́ть зна́ния; *бәхәсне ~* углубля́ть и осложня́ть спор

тирәнә|ю *неперех. прям., перен.* углубля́ться/углуби́ться; *~йгән елга* углуби́вшаяся река́; *безнең хезмәттәшлек ~я* на́ше сотру́дничество углубля́ется

тирәнге *прил.* глуби́нный; ~ *сулар* глуби́нные во́ды

тирәндәге *прил.* 1. глубоко́ располо́женный, глуби́нный; *см. тж.* **тирәнге** 2. глубоково́дный; ~ *организмнар* глубоково́дные организмы

тирәнләнү *неперех.* углубля́ться/углуби́ться; *см. тж.* **тирәнәю**

тирәнләтү *перех. см.* **тирәнәйтү**; углубля́ть/углуби́ть, де́лать/сде́лать глубо́ким || углубле́ние

тирәнлә|ү *неперех. разг.* 1. вести́ рабо́ту на глубине́; идти́, дви́гаться глубино́й; *көзен балык ~п йөзә* ры́ба о́сенью идёт (пла́вает) глубино́й (на глубине́) 2. *перен.* углубля́ться/углуби́ться; *син бик ~мә* ты не о́чень углубля́йся (*в суть вопроса*)

тирәнле|к *сущ. в разн. знач.* глубина́; глубь; *сулыкның ~ге* глубина́ водоёма; *~кә керү* войти́ в глубину́; *күңел ~гендә* в глубине́ души́; *бакча ~геннән* из глубины́ са́да; *биш километр ~ктән* из глубины́ пяти́ киломе́тров

тирәнлектә *нареч.* на глубину́; *егерме сантиметр ~ сөрү* паха́ть на глубину́ в два́дцать сантиме́тров || *предик. прил.* глубино́й в; *бу күл илле метр ~* э́то о́зеро глубино́й в пятьдеся́т ме́тров

тирәнлектәге *прил.* 1. находя́щийся в глубине́ (*глуби*) 2. име́ющий глубину́ в ...; глубино́й в ...; *унбиш метр ~ кое* коло́дец глубино́й в пятна́дцать ме́тров

тирәннән *нареч. см.* **тирәнтен**; ~ *уйлаганда* е́сли глубоко́ вни́кнуть (поду́мать)

тирәнтен *нареч. в разн. знач.* глубоко́; ~ *йөзү* глубоко́ пла́вать; ~ *яктырту* глубоко́ освеща́ть; ~ *өйрәнү* глубоко́ изуча́ть

тирәсендәге *прил.* 1. находя́щийся о́коло, вокру́г *чего-л.*; *Мәскәү ~ калалар* городá вокру́г Москвы́ 2. *в знач. послелога сочет. с числ.* о́коло (приблизи́тельно) определённого во́зраста; *алтмышлар ~* о́коло шести́десяти лет, приблизи́тельно шестидесятиле́тний

тирәч *сущ.* око́лыш; (*круглая*) опра́ва; *фуражка ~е* око́лыш фура́жки; *күзлек ~е* опра́ва очко́в

тирәчле *прил.* с око́лышком, опра́вой; *мөгез ~ күзлек* очки́ в рогово́й опра́ве

тирә-юнь I *сущ.* окре́стность, окру́га; *тирә-юньне күзәтү* наблюда́ть за окре́стностью; *тирә-юньдә беркем юк* в окру́ге никого́ нет

тирә-юнь II *прил. см.* **тирә-юньдәге**; *тирә-юньдәге йортлар* окре́стные дома́

тирә-юньдәге *прил.* окре́стный, прилега́ющий; то, что вокру́г

тирә-я|к I *сущ.* 1. ме́сто, простра́нство вокру́г; *тирә-ягымда* вокру́г меня́ 2) окру́жность, ближа́йшая окре́стность; *багананың тирә-ягы* окру́жность столба́ 2. ме́стность, окре́стность, окру́га; *безнең тирә-як* на́ша ме́стность; на́ша окру́га

тирә-як II *прил. см.* **тирә-яктагы**; *тирә-як колхозлар* окре́стные колхо́зы

тирә-яктагы *прил.* окре́стный, ме́стный; *тирә-яктагы йортлар* окре́стные дома́

тирә-ян *сущ. см.* **тирә-як**

тирбәй *сущ. диал.* 1. *см.* **тәртип** 2. эконо́мия; экономи́чное, рациона́льное веде́ние хозя́йства

тирбәйлә́ү *перех. диал.* 1. вводи́ть, нала́живать, введе́ние в колею́ || нала́живание (*жизни, дела*) 2. гарантировать || гарантирование 3. рационализи́ровать

тирбәлгәләү *многокр. от* **тирбәлү**

тирбәлдерү *перех.* **1.** колеба́ть, колыха́ть || колыха́ние **2.** кача́ть, раска́чивать/раскача́ть || раска́чивание; *бишек ~* кача́ть лю́льку; *көймәне ~* раска́чивать ло́дку

тирбәлеш *сущ.* **1.** колеба́ние, кача́ние **2.** *см.* **тирбәнеш**

тирбәлешү *взаимно-совм. от* **тирбәлү**

тирбәлмәле *прил.* коле́блющийся, зы́бкий

тирбәлү *неперех.* **1.** колеба́ться, колыха́ться || колеба́ние, кача́ние; *җилдә (җил белән) ~* колыха́ться (ка-ча́ться) на ветру́ **2.** кача́ться, раска́чиваться || раска́чивание (*на люльке, на качалке — услаждая себя*) **3.** *перен.* колеба́ться || колеба́ние (*цен, экон. показателей и т. п.*)

тирбәлүчән *прил. см.* **тирбәнүчән**

тирбәндерү *перех. см.* **тирбәтү**

тирбәнеш *сущ. физ.* колеба́ние, вибра́ция; *сүнәр ~* затуха́ющие колеба́ния

тирбәнешле *прил.* колеба́тельный; *~ хәрәкәт* колеба́тельное движе́ние

тирбәнчек *сущ.* **1.** каче́лка; *~тә кәефләнү* услажда́ться, пока́чиваясь в каче́лке **2.** *см.* **тирбәтмә** 2 || *прил.* кача́ющийся; *~ урындык* кре́сло-каче́лка

тирбәнчекле *прил.* кача́ющийся; *~ урындык* кача́ющееся сиде́нье

тирбәнү *неперех.* **1.** кача́ться || кача́ние (*себя*) в каче́лке; *ботакта ~* кача́ться на ве́тке **2.** *см.* **тирбәлү** 2

тирбәнүле *прил. см.* **тирбәнешле**

тирбәнүчән *прил.* скло́нный кача́ться/пока́чиваться (*о младенце в колыбели*)

тирбәткәләү *многокр. от* **тирбәлү**

тирбәткеч *сущ.* устро́йство для раска́чивания колыбе́ли ного́й (*представляет собой доску, одним концом прикреплённую петлёй к нарам или к полу, а другим концом привязанную к колыбели*) || *прил. физ.* колеба́тельный; *~ контур* колеба́тельный ко́нтур

тирбәтмә *сущ.* **1.** *см.* **тирбәткеч 2.** рессо́ра; *тарантас ~се* рессо́ра тарантаса

тирбәтмәле *прил.* **1.** име́ющий устро́йство для раска́чивания (*колыбели*) **2.** рессо́рный, име́ющий рессо́ры

тирбәттерү *понуд. от* **тирбәтү**; веле́ть кача́ть и́ли колеба́ть

тирбәтү **1.** *перех.* колеба́ть, колыха́ть, кача́ть/пока́чивать, баю́кать || колыха́ние, баю́кание (*ребёнка*); *алдына алып ~у* кача́ть, баю́кать на рука́х (коле́нях) **2.** *см.* **тирбәтү**

тиргәвеч *прил. диал.* бранчли́вый, ворчли́вый; *ире ~ булса, хатыны үрләвеч була* (*посл.*) е́сли муж бранчли́вый, жена́ быва́ет вспы́льчивой

тиргәлү *страд. от* **тиргәү**; быть отру́ганным, пору́ганным; *нахактан ~* быть напра́сно пору́ганным, терпе́ть напра́слину

тиргән|ү *возвр. от* **тиргәү**; ворча́ть, руга́ться/заруга́ться || ворча́ние; *карганма да, ~мә дә, бәрелә кату булыр* (*погов.*) не ворчи́, не руга́йся — по́чки надорвёшь

тиргәттерү *понуд. от* **тиргәтү, тиргәү**

тиргәт|ү *понуд. разг. от* **тиргәү**: заста́вить и́ли веле́ть отруга́ть *кого-л.*; подводи́ть под ру́гань; попрёки и т. п.; *үз-үзеңне ~мә* не дава́й по́вода руга́ть себя́; не подведи́ себя́ под ру́гань

тирг|әү *перех.* **1.** брани́ть, руга́ть; побрани́ть, пору́гать || брань; ру́гань; *~и дә ~и* руга́ет и руга́ет (*и не перестаёт*); *~әсең ~ә; ~әмәсең — юк* руга́й не руга́й; хоть руга́й, хоть нет **2.** *диал.* привере́дничать || привере́дничание; *см. тж.* **талымлау** □ **~эп алу** пору́гать; **~эп ташлау** отруга́ть

тиргәш *сущ.* брань, ру́гань; упрёки, попрёки; *төтен күзгә керә, ~ күңелгә керә* (*посл.*) дым ест глаза́, брань — ду́шу

тиргәштерү **1.** *перех.* ссо́рить, поссо́рить *кого-л.* ме́жду собо́й **2.** *неперех. многокр. от* **тиргәү**; пору́гивать, пожу́ривать

тиргәшчән *прил.* скло́нный руга́ться, брани́ться

тиргәш|ү *взаимно-совм. от* **тиргәү**; руга́ться, брани́ться (*между собой*) || ру́гань, брань; *ике ~кән — ике тиле, кушылган — куш тиле* (*посл.*) дво́е бранящихся — два дурака́, примкну́вший к ним — два́жды дура́к

тиргәшче *сущ.* вздо́рщик, скандали́ст; *см. тж.* **талашчы**; *~гә тиңләшмә, талашчыга таңланма* (*посл.*) не равня́йся на вздо́рщика, не зави́дуй скандали́сту

тире I *сущ.* **1.** ко́жа (*внешняя оболочка организма животных*) || ко́жный; *~ бизләре* ко́жные же́лезы; *~ күзәнәге* кле́тка ко́жи; *~ асты мае* подко́жный жир; *см. тж.* **чел** 2; **2.** шку́ра, ко́жа (*необработанная*); *~ җыю* собира́ть шку́ры; *үтерелмәгән аюның ~сен бүлешмиләр* (*посл.*) шку́ру неуби́того медве́дя не де́лят; *бер ~дән тун тегелми* (*посл.*) из одно́й шку́ры шу́ба не шьётся || *прил.* **1.** ко́жаный (*в знач.: сшитый, сделанный из кожи, шкуры с шерстью*); *~ бияләй* ко́жаные рукави́цы (*с мехом внутрь*); *~ чиләк* ко́жаное ведро́; *~ капчык* ко́жаный мешо́к **2.** ко́жистый; *~ тышча* ко́жистая оболо́чка; ко́жистый чехо́л □ **~ бете** кожее́д; *см. тж.* **тиреашар**; **~ иләү (иеләү)** выде́лывать, обраба́тывать || вы́делка, обрабо́тка шку́ры; *см. тж.* **иләү (иеләү)**; **~ тунау** *см.* **тунау** ◊ **~ җыеп, күн эшлим** *нарочито бессмысленный ответ на вопрос* **нишлисең?** что де́лаешь? (*букв.* собира́ю шку́ры, де́лать юфть); **~ дә (~ белән, ~ эчендә) сөякләре генә калган, ~се сөягенә ябышкан** ко́жа да ко́сти, худо́щий, о́чень худо́й; **~се калын** толстоко́жий (*о человеке, не реагирующем на критику, либо не понимающем тонкие намёки*); **~се юка 1.** оби́дчивый **2.** несто́йкий || несто́ек к невзго́дам; **~сен тунау** драть (сдира́ть) шку́ру *с кого*; **~сенә сыймау (сыймас булу), ~сеннән чыгардай булу (чыга язу) 1.** лезть из ко́жи вон, чрезме́рно усе́рдствовать *перед кем-л.*, стара́ться *в чём-л.* **2.** о́чень си́льно серди́ться **3.** разжире́ть **4.** возгорди́ться

тире II *сущ. лингв.* тире́ (*знак препинания*)

тиреашар *сущ. зоол.* кожее́д

тирес *сущ.* **1.** навоз, назе́м || навозный; *~ түгү* выноси́ть/вы́нести навоз (*из хлева и т. п.*); *кырга ~ чыгару* вывози́ть/вы́везти навоз на по́ле; *~ өеме* навозная ку́ча **2.** *диал.* се́вер, се́верная сторона́; *~тән искән җил* ве́тер с се́вера || *прил.* **1.** навозный, си́льно унавоженный; *см. тж.* **тиресле**; *~ җир* навозное ме́сто; унавоженная земля́ **2.** *диал.* 1) проти́вный; встре́чный (*о ветре, течении*) 2) обра́тный; *~ як* обра́тная (*ненужная, не по пути*) сторона́ 3) изна́ночный; *тукыманың ~ ягы* изна́ночная сторона́ тка́ни **3.** *диал.* упря́мый, несгово́рчивый, капри́зный; *~ кеше дә телдәр, тиген кеше дә телдәр* (*посл.*) упря́мцы и пусты́е лю́ди быва́ют многосло́вны □ **~ бакасы** жа́ба; **~ коңгызы** жук-навозник; **~ корты 1.** личи́нка ма́йского жука́ **2.** *перен.* невзра́чный, но вре́дный, упря́мый человек ◊ **~ тип (күз)** *груб. прост.* проти́вная мо́рда; бесстыжий, бесстыдник, наха́л; **~ ягы белән туган** *прост.* проти́вный, упря́мый

тиреслек *сущ. зоол.* жук-навозник; *см. тж.* **тирес корты**; *~ личинкасы* личи́нка жука́-навозника

тиреслән|ү **1.** *страд. от* **тиреслә́ү**; быть (стать) унаво́женным; *~гән җир* унаво́женное ме́сто **2.** *возвр.* превраща́ться/преврати́ться || превраще́ние в навоз (перегно́й)

тиресла́|ү *перех.* унабо́живать/унабо́зить □ **~п килү** постоя́нно (*каждый год*) унабо́живать; **~п кую** унабо́живать/унабо́зить (*заранее*)

тиресләтү *понуд. от* **тиресләү**; веле́ть и́ли заста́вить унабо́живать

тиресләч *прил. зоол.* набо́зный, живу́щий в набо́зе; *~ бөҗәкләр* набо́зные насеко́мые

тиресле *прил.* **1.** унабо́женный; *~ җир (туфрак)* унабо́женная по́чва; *~ җирдән төяп алырсың* (*погов.*) с унабо́женной земли́ бу́дешь воза́ми вывози́ть (*т. е. урожай будет обильный*) **2.** набо́зный; *~ сыекча* набо́зная жи́жа

тиреслек I *сущ.* **1.** ме́сто, где ска́пливается набо́з **2.** ме́сто, куда́ сво́зят набо́з; сва́лка для набо́за □ **~ башы** *см.* **тиреслек ◊ ~кә тап килгән кабак кебек** как ты́ква, попа́вшая на то́лстый слой набо́за; с быстрото́й ты́квы (*о быстром росте*)

тиреслек II *сущ. разг.* упря́мство, капри́з; наха́льство, бесстыдство

тиressез *нареч. прил.* без набо́за, неунабо́женный; *~ җир* неунабо́женная земля́

тиречә *сущ.* ко́жица; перепо́нка

тиреченә *сущ.* кожевенник, кожевник

тиречек *сущ. биол.* эпиде́рмис, ко́жица; оболо́чка

тиречелек *сущ.* кожевенное де́ло (ремесло́)

тире-яры *сущ. собир.* кожевенное сырьё; *тире-яры җыю* собира́ть кожевенное сырьё

тирке *сущ. диал.* **1.** по́лка для посу́ды **2.** *этногр.* компле́кт посу́ды, кото́рый невеста обя́зана брать с собо́й в дом му́жа; *килен ~се* посу́да невесты **3.** у́тварь

тирләткеч *прил.* потого́нный; *~ дарулар* потого́нные лека́рства

тирләттерү *безл. разг. см.* **тирләтү** 2

тирләт|ү **1.** *понуд. от* **тирләү**; вызыва́ть/вы́звать испа́рину; *атны ~ми йөр* при езде́ не вгоня́й ло́шадь в испа́рину; не вызыва́й испа́рины у ло́шади **2.** *безл.* приходи́ться/прийти́сь поте́ть, попоте́ть; *~те я* вспоте́л; *~ә* жа́рко, пот прошиба́ет

тирлә́|ү *неперех.* **1.** поте́ть/вспоте́ть, запоте́ть || поте́ние; *~п бетү* (*окончательно*) вспоте́ть; *~п эшләү* рабо́тать в по́те; *~гән тәрәзә* запоте́вшее окно́; *~мичә тиен дә табылмый* (*посл.*) без по́та и копе́йки не зараба́тываешь **2.** упа́риться, запа́риться (*в бане*); *мунчада ~п терелү* попа́риться в ба́не и вы́здороветь (*от простуды*) **3.** преть, разопре́ть (*о полях, землях*) и т. п.; *~п яткан җирләр* разопре́вшие зе́мли

тирлә́ү-пешү *неперех.* си́льно поте́ть, покрасне́ть || си́льное поте́ние, покрасне́ние (*от усиленной работы, бега и т. п.*); *тирләмәдем, пешмәдем, эшләдем дә эшләдем* (*погов.*) не поте́л, не красне́л, рабо́тал да рабо́тал □ **тирләп-пешеп** **1.** облива́ясь по́том (*от натуги*) **2.** *перен.* преусе́рдно; изо всех си́л; что есть си́лы; из после́дних сил

тирләүчән *предик. прил.* потли́вый (*в знач. быстро потеющий*) || бы́стро поте́ет; *~ кеше* (бы́стро) поте́ющий челове́к

тирләүчәнлек *сущ.* потли́вость; скло́нность бы́стро поте́ть

тирле *прил.* по́тный; *~ көенчә* в по́тном ви́де; *~ бит* по́тное лицо́

тирлек *сущ.* **1.** *диал.* ни́жняя руба́ха без рукаво́в; *~ кигән* в ни́жней руба́шке **2.** потни́к (*у седла*); *см. тж.* **эчмәк, чапрак**

тирмә *сущ.* **1.** ю́рта; киби́тка, во́йлочное жили́ще (*тюрко-монгольских народов*); *~ кору* сооруди́ть, собра́ть киби́тку (*на новом месте*); *уникe канатлы ~* ю́рта с двена́дцатью кры́льями (*т. е. щитками по бокам*) **2.** *ист.* те́рем; теремо́к || теремно́й; *кыз ~се* теремо́к де́вушки; *~ ишеге* теремны́е две́ри

тирмәле *прил.* **1.** с ю́ртой, с киби́ткой; *~ йорт* двор с ю́ртой **2.** с те́ремом, с теремко́м

тирмән *сущ. диал. см.* **тегермән**

тирмәнлек *сущ. диал.* ме́льница с пристро́йками, ме́льничный дом

тирмәнче *сущ. диал. см.* **тегермәнче**

тирт|ү *неперех.* **1.** чеса́ться с пока́лыванием (*после онемения*); *бармак очы ~еп тора* пока́лывает на концах па́льцев **2.** си́льно, ту́го наполня́ться жи́дкостью (*молоком — о вымени*)

тирү *перех.* **1.** выбира́ть || вы́борка по одному́ (*гороха из стручка*) **2.** расставля́ть || расставле́ние по окру́жности; *өй тирәсенә гөл ~* расставля́ть цветы́ вокру́г до́ма

тирчән *прил.* потли́вый || потли́в; *кеше киеме керчән, кеше аты ~* (*посл.*) чужа́я оде́жда ма́ркая, чужа́я ло́шадь потли́вая (*при взятии на время*)

тирчәнлек *сущ. мед.* потли́вость, оби́льное потоотделе́ние

тирьяк *сущ.* териа́к, лека́рство от я́да, отра́вы; *~ка ышанып, агу эчмә* (*посл.*) не пей я́да, полага́ясь на териа́к

тис *сущ. бот.* тис || ти́совый; *~ урманы* ти́совый лес

тисбе *сущ.* **1.** *см.* **дисбе** 2. *см.* **тәсбих** 2

тискәре *прил.* **1.** обра́тный, изна́ночный; *~ як* обра́тная (изна́ночная) сторона́; *уң ягы булганның ~ ягы да була* (*посл.*) е́сли есть лицева́я сторона́, зна́чит есть и изна́ночная **2.** проти́вный, встре́чный; *~ җил* встре́чный ве́тер, не́тер в лицо́ (*идущему*) **3.** *в разн. знач.* отрица́тельный, нехоро́ший; *~ як (ягы)* отрица́тельная сторона́ *чего-л.*; *тормышның ~ куренешләре* отрица́тельные явле́ния жи́зни; *~ типлар* отрица́тельные ти́пы **4.** *физ. мат.* отрица́тельный; *~ сан* отрица́тельное число́; *~ температура* отрица́тельная температу́ра; *~ заряд* отрица́тельный заря́д **5.** *перен.* реакцио́нный; *~ көчләр* реакцио́нные си́лы **6.** *перен.* негати́вный, отрица́тельный; *~ бәяләмә* негати́вная оце́нка (*кого-л., в отношении чего, кого*) **7.** *разг.* упря́мый, непослу́шный; *~ тиледән яман* упря́мый ху́же дурака́ || *нареч.* **1.** про́тив; *~ сыйпау* гла́дить про́тив *чего* **2.** отрица́тельно; *~ сөйләү* говори́ть отрица́тельно; *~ тәэсир итү* влия́ть отрица́тельно || *сущ. разг.* **1.** се́вер, се́верная сторона́; *~дән (искән) җил* ве́тер с се́вера (се́верной стороны́) **2.** изна́нка; *~гә әйләндерү* перевернуть наизна́нку □ **~ як** **1.** изна́нка **2.** *перен.* отрица́тельные сто́роны, недоста́тки ◊ **~ бару (килү)** упря́миться, выступа́ть/вы́ступить про́тив, (ре́зко) не соглаша́ться/не согласи́ться; **~ (~гә) беткән** *см.* **кире беткән**; **~ тибү** ре́зко отверга́ть/отве́ргнуть; **~гә бору** **1.** толкова́ть ска́занное в друго́м, недо́бром смы́сле **2.** поверну́ть разгово́р, речь в нену́жную, нежела́тельную сто́рону; **~нең ~се** до невозмо́жности упря́м; упря́мый из упря́мых

тискәреге *прил. диал.* **1.** *см.* **тискәре** 1, 2 **2.** се́верный; *~ җил* се́верный ве́тер

тискәреләнү *неперех.* **1.** упря́миться, упря́мствовать, упо́рствовать || упря́мство, упо́рство; супроти́вничание *разг.*; *~уе белән биздерү* отва́дить от себя́ (своим) упря́мством **2.** идти́/пойти́ на разла́д (в разва́л), разла́диться (*о делах*); *хәлләр ~де* дела́ разла́дились

тискәреле|к *сущ.* **1.** упря́мство, неусту́пчивость, несгово́рчивость; *~ккә тискәре инде үзе* насчёт упря́мства, то

у него́ его́ хоть отбавля́й **2.** реакцио́нность; негати́вность, противоде́йствие □ **~генэ бару 1.** проявля́ть своё упря́мство **2.** проявля́ть свою́ реакцио́нность

титак *прил. диал.* хромо́й, прихра́мывающий на одну́ но́гу; шага́ющий вприпры́жку; *~ кеше* хрома́ющий на одну́ но́гу челове́к

титакай *нареч. см.* **тыракай**

титакла|у *неперех.* прихра́мывать, ковыля́ть; припада́ть на одну́ но́гу || прихра́мывание; *~п атлау* шага́ть, припада́я на одну́ но́гу; *~п йогеру* бежа́ть вприпры́жку, прыгая (*на одной ноге*)

титак-титак *нареч.* **1.** прихра́мывая, припада́я на одну́ но́гу; *титак-титак йөри* хо́дит прихра́мывая **2.** вприпры́жку; прыгая на одно́й ноге́ || *сущ.* игра́ в кла́ссы (*игра, в которой до определённого места доходят, прыгая на одной ноге*); *титак-титак уйнау* игра́ть в кла́ссы (кла́ссики)

титан I *сущ.* титан; *~нар һәм аллалар көрәше* борьба́ тита́нов и бого́в; *фикер ~ы* тита́н мы́сли

титан II *сущ. хим.* тита́н (*химический элемент — твердый металл*); *~ эретмәсе* сплав тита́на; *~нан эшләнгән* сде́ланный из тита́на || *прил.* тита́новый; *~ калай* тита́новая жесть; *~ детальләр* тита́новые дета́ли

титан III *сущ.* тита́н (*устройство для нагрева, кипячения воды*)

титанизм *сущ.* титани́зм (*изображение сверхсильных героев, страстей и т. п. в литературе и искусстве*)

тита́ник *прил.* титани́ческий; *~ көч* титани́ческая си́ла

титарай *сущ.* **1.** дурачо́к, ду́рочка; глупе́ц, глупы́ш; *см. тж.* **тиратай** 2; **2.** безде́льник, шалопа́й || *прил.* дура́шливый; *~ кыз* дура́шливая девчо́нка □ **~ тибү** *см.* **тирай тибү**

тити *сущ. разг.* ку́рочка, кво́чка; *этәч белән ~ кебек* как петушо́к с ку́рочкой

тити-мити: тити-мити уйнау 1. занима́ться несерьёзным де́лом, игра́ть в жму́рки **2.** мя́гко обраща́ться, ня́ньчиться *с кем-л.; дошман белән ~ уйнамыйлар* не́чего ня́ньчиться с врага́ми

ти-ти-ти *межд. употр. при призывании кур и цыплят*

титр *сущ.* **1.** титр (*в кино*) **2.** *хим.* титр (*проявитель, индикатор в виде раствора*)

ти́трлау *перех. хим.* титрова́ть (*определять состав и количество составных частей сложного соединения раствора и т. п.*)

ти́тул I *сущ. в разн. знач.* ти́тул; *дворян ~ы* дворя́нский ти́тул; *дөнья чемпионы ~ына ия булу* явля́ться облада́телем ти́тула чемпио́на ми́ра

ти́тул II *прил. см.* **титуллы**; *китапның ~ бите* ти́тульный лист кни́ги

ти́туллану *неперех.* титулова́ться; *мәдәррис дип ~* титулова́ться преподава́телем (*медресе*)

ти́туллы *прил.* **1.** титуло́ванный; *~ князь* титуло́ванный князь **2.** ти́тульный; *~ бит* ти́тульный лист

тиф *сущ.* тиф; *кайтма тиф* возвра́тный тиф; *корсак тифы* брюшно́й тиф; *тиф белән авыру* боле́ть ти́фом; *тифтан үлү* умере́ть от ти́фа

тифлогра́фика *сущ.* тифлогра́фика (*письменность для слепых*)

тифлон *сущ. зоол.* тифло́н (*слепой вид животных, обычно живущих в гротах, под землёй и т. п.*)

тифлы *прил.* **1.** боле́ющий ти́фом **2.** заражённый ти́фом, тифо́зный; *~ окоплар* тифо́зные око́пы

тифоз *прил.* тифо́зный; *~ бактерия* тифо́зная бакте́рия

тише|к *сущ.* **1.** дыра́; брешь; *кием ~ге* дыра́ в оде́жде; *савыт ~ге* дыра́ в посу́де; *ертык сүтектән көлә, ~к икесеннән дә көлә* рвань смеётся над распо́ротым швом, дыра́ смеётся над обо́ими; *какмаган ишеге, кермәгән ~ге юк* (*погов.*) нет две́ри, в кото́рую бы он не постуча́лся, нет дыры́, в кото́рую бы не проле́з (*о проходимце*) **2.** отве́рстие, дупло́; пробо́ина (*сделанная специально*); *~к тишү* сде́лать отве́рстие, проби́ть пробо́ину; *агач ~ге* дупло́ де́рева || *прил.* дыря́вый; *~к кием* дыря́вая оде́жда; *бу савыт ~к* э́та посу́да дыря́вая ◊ **~к авыз** болту́н, трепло́, трепа́ч; **~к бер тиен кебек** тут как тут; **~к борын (танау)** сопля́к, шалопа́й (*о мальчике*); **~к колак** о невнима́тельном, пропуска́ющем ми́мо уше́й ска́занное челове́ке; *~ күз* о невнима́тельном, смотря́щем, но не ви́дящем челове́ке; **~к (тишекле) тиен** ло́маный (*букв.* дыря́вый) грош; **~к тиен дә тормый** не сто́ит и ло́маного гроша́; **~к чуманга (көймәгә) утырту** наду́ть, обману́ть (*букв.* посади́ть в дыря́вый ку́зов); **~ккә тыгын (ямау) булып йөрү 1.** ходи́ть без постоя́нных обя́занностей, ходи́ть туда́, куда́ посыла́ют (*на случайные дела*) **2.** быть ли́шним (*букв.* быть заты́чкой, запла́той к дыре́)

тишекколак *прил. разг.* невнима́тельный, пропуска́ющий ска́занное ми́мо уше́й (*букв.* дыря́вое у́хо); *әйттем бит мин сиңа, ~* сказа́л ведь я тебе́, а ты пропусти́л ми́мо уше́й

тишеккүз *прил. разг. груб.* невнима́тельный; смотря́щий, но не ви́дящий *что-л.* (*букв.* дыря́вый глаз); *алдыңда ята ич, ~* пе́ред тобо́й ведь лежи́т, где твой глаза́?

тишекләнү *неперех.* продыря́вливаться/продыря́виться || продыря́вливание (*само собой*); *см.* **тишкәләнү**

тишекл|әү *перех.* продыря́вливать/продыря́вить || продыря́вливание *чего-л.*; *см.* **тишкәләү**

тишекле *прил.* ды́рчатый, продыря́вленный, с дыро́й, с отве́рстием (отве́рстиями); дупли́стый, с дупло́м; *~ агач* де́рево с дупло́м; дупли́стое де́рево ◊ **~ бер тиен кебек әйләнеп кайту** верну́ться как ло́маный грош; верну́ться как фальши́вая моне́та (*о никчёмном, негодном человеке*)

тишеклек *сущ.* **1.** продыря́вленность **2.** отве́рстие, дыра́, проко́л (*на рабочих поверхностях*); *~ хасил булды* образова́лось отве́рстие (проко́л)

тишекле-тишекле *прил.* весь продыря́вленный, со мно́гими ды́рами (отве́рстиями, ду́плами); *тишекле-тишекле түбә* соверше́нно (наскво́зь) продыря́вленная кро́вля

тишекле-тошыклы *прил.* со мно́гими ды́рами (отве́рстиями)

тишек-тилек *сущ. диал. см.* **тишек-тошык**

тишек-тилексез *прил.* це́лый, без тре́щины, без дыр

тишек-тошык *сущ. собир. разг.* **1.** ра́зные, разли́чные отве́рстия, ды́ры и т. п.; *тишек-тошыкны каплау* прикры́ть (скрыть, закры́ть) ды́ры, отве́рстия; подремонти́ровать; лата́ть/залата́ть дыру́; *тишек-тошыктан җил өрә* ве́тер ду́ет во все ще́ли (*во все дыры*) **2.** *перен.* ды́ры, бре́ши, недоста́чи *и т. п.; бюджеттагы тишек-тошыклар* ды́ры в бюдже́те || *прил.* **1.** многоды́рчатый, дыря́вый; *амбарлар тишек-тошык* амба́ры име́ют мно́го дыр (дыря́вые); *тишек-тошык җилән* дыря́вый, продыря́вленный плащ **2.** ра́зные дыря́вые; *тишек-тошык савытлар* ра́зная дыря́вая посу́да

тишелдерү *понуд. от* **тишелү**; дать возмóжность продыря́виться (*из-за небрежности*)

тишелеш *сущ.* **1.** всхóжесть; *орлыкның ~е* всхóжесть семя́н **2.** процéсс всхóда (*зёрен в поле*)

тишел|ү *страд.-возвр. от* **тишү** **1.** *страд.* просвéрливаться, пробива́ться, прони́зываться, прока́лываться; быть просверлённым (проби́тым, прокóлотым) **2.** *возвр.* продыря́виться (*само собой*), станови́ться/стать дыря́вым (прокóлотым, пóрванным, худы́м) (*о ведре*); *ишелгәнгә ~гән иш* (*погов.*) обвали́вшееся подпира́ют продыря́вленным (дыря́вым) **3.** всходи́ть/взойти́, прораста́ть || всход, прораста́ние (*засеянных зёрен, посаженных клубней и т. п.*); *игеннәр ~еп килә* хлеба́ начина́ют всходи́ть **4.** вы́лупиться, выклёвываться (*о птенцах из яйца*) **5.** прорыва́ться/прорва́ться, открыва́ться/откры́ться (*об опухоли, ране и т. п.*)

тишелүчән *прил.* **1.** (*быстро, легко*) пробива́емый, прока́лываемый **2.** всхóжий, (*быстро, легко*) прораста́ющий; *~ орлык* всхóжее сéмя

тишелүчәнлек *сущ.* всхóжесть

тишем *сущ.* проде́ланное отве́рстие, проббина; ячея́; *~нең диаметры* диáметр отве́рстия, ячей (*сита*)

тишемле *прил.* **1.** с отве́рстием, с проббиной; *киң ~* с широ́ким отве́рстием **2.** с ячеёй (*определённого качества*); *зур ~* с кру́пными ячея́ми

тишкәләнү *страд.-возвр. от* **тишкәләү**; *~еп беткән* весь в ды́рах, совершéнно продыря́вленный

тишкәлә|ү *многокр. от* **тишү**; многокра́тно проде́лывать отве́рстия; пробива́ть, прода́лбливать, прока́лывать, усéивать отве́рстиями; *керәшәләр ярны ~п бетергәннәр* стрижи́ усéяли бéрег отве́рстиями гнёзд

тишкеч *сущ.* пробóйник, шля́мбур; дрель; *~ белән тишү* пробива́ть пробóйником (*стену*) || *прил.* пробóйный; *~ җайланма* пробóйное приспособлéние

тишмән I *сущ.* **1.** большóй бура́в, большóе сверлó **2.** дырокóл

тишмән II *сущ. зоол.* жук-сверли́льщик

тиштер|ү *понуд. от* **тишү**; позвóлить и́ли велеть, проси́ть протыка́ть, зака́зывать, чтóбы пробива́ли, просверли́ли

тиш|ү *перех.* **1.** прока́лывать/проколóть, протыка́ть/проткну́ть, прони́зывать/прониза́ть, пронза́ть/пронзи́ть, прода́лбливать/продолби́ть || прока́лывание, протыка́ние, прони́зывание; *тамчы ташны ~ә* ка́пля прода́лбливает ка́мень **2.** дыря́вить, продыря́вить (*неосторожным обращением*) дóлгим ношéнием и т. п. **3.** *перен. разг.* выдава́ть/вы́дать || вы́дача (*секрета*), проговори́ться, проболта́ться, вы́болтнуть; *серемне бутәннәргә ~ә күрмә* пожа́луйста, не выдава́й моéй та́йны други́м ◻ **~еп бетерү** совсéм продыря́вить, износи́ть до дыр; **~еп чыгару** окончáтельно проби́ть, продыря́вить

ти|ю *неперех.* **1.** каса́ться, прикаса́ться/прикосну́ться, соприкаса́ться, дотра́гиваться/дотрóнуться || каса́ние, прикаса́ние, прикоснове́ние; *бер-берсенә тию* каса́ться друг дру́га; *аяклары җиргә тимичә* не чу́я ног (*букв.* ногáми земли́ не каса́ясь) **2.** доставáть/достáть до ..., дотя́гиваться/дотяну́ться; *башы түшәмгә тия* достаёт головóй до потолка́; *атны җиксәң, җик җирәнен, ялы җиргә тигәнен* (*песня*) коль завóдишь лóшадь, то такýю, чтоб каса́лась гри́вою земли́ **3.** *прям., перен.* задева́ть || задева́ние, попада́ть/попа́сть; *акылым кыска, кулым озын — танавыңа тимәгәй* ум мой кóроток, ру́ки длинны́, как бы твоéй мóрды не заде́ли; *киемгә былчырак тигән* на одéжду попáла грязь **4.** попада́ть/попáсть || попада́ние (*в цель*); *пуля тигән* попáла пу́ля; заде́то пу́лей **5.** бить, уда́рить (*током*) *ток тимәсен* чтóбы не уда́рило (не уби́ло) тóком **6.** *перен.* трóгать/трóнуть, напада́ть/напáсть || трóгание, нападéние; *олыдан көлмә, кечегә тимә* (*погов.*) не смéйся над ста́ршими, не трóгай ма́леньких; *тимәгәнгә тимә, тигәннең тиген калдырма* (*посл.*) не тронь того́, кто тебя́ не трóгает, а того́, кто трóнет, не оставля́й без возмéздия **7.** трóгать/трóнуть; хвата́ть, брать/взять, употребля́ть (*без спроса*), каса́ться *чего; кеше әйберенә тию* трóгать, хвата́ть чужýю вещь; *песи майга тигән, эт таяк җигән* (*погов.*) кóшка съéла са́ло, соба́ке доста́лась па́лка **8.** *разг.* затра́гивать/затрóнуть || затра́гивание (*чьих-л. интересов*); каса́ться *чего*, относи́ться *к кому, чему* || каса́ние; *кар, дисәң, каргага тия, тор, дисәң, торнага тия* (*посл.*) ска́жешь кар! — воро́ну трóнет, ска́жешь тор! (курлы́) — затрóнет журавля́; *бу сүзләр сиңа да тия* э́ти слова́ отнóсятся и к тебé **9.** разъеда́ть, попóртить, повреди́ть || пóрча, повреждéние (*вредными насекомыми*); *көя тигән* моль повреди́ла; повреждён(ный) мóлью; *алмага корт тигән* я́блоко попóрчено червякóм **10.** натира́ть/натере́ть || натира́ние (*кожи лошади, осла, вола*) сбру́ей; *камыт тигән* натёрло хомутóм; *ыңгырчак тигән* натёрло седёлкой **11.** *разг.* хвати́ть, прихвати́ть (*морозом, заморозками*); *кырау тигән бәрәңге басуы* картóфельное пóле, прихва́ченное за́морозками **12.** раздражать || раздражéние; задева́ть (*какие-л. органы, чувства*) *куп ашама — эченә тияр* не ешь мнóго — живóт заболéет (*букв.* бýдет раздража́ть живóт); *төтен күзгә тия* дым раздража́ет (разъеда́ет) глаза́ **13.** доставáться/достáться, приходи́ться/прийти́сь (на дóлю *кого*); *өлешеңә тигән көмешең* (*погов.*) сýженого конём не объéдешь (*букв.* твоё серебрó — доста́лось тебé на дóлю — *о жене, муже*) **14.** доходи́ть/дойти́ (*об очереди, времени и т. п.*); выпада́ть/вы́пасть (*о времени*); *миңа да чират тиде, ниһаять* и до меня́ дошла́ óчередь, наконéц; *ул эшкә вакыт* (*кул*) *тими* до той рабóты ру́ки не дохóдят **15.** приноси́ть/принести́ || принесéние (*пользы, вреда и т. п.*); *файдасы бер тимәсә, бер тияр* не в э́тот раз, так в другóй принесёт пóльзу; *наданлыкның зыяны тияр* невéжество принесёт вред **16.** приходи́ться/прийти́сь кем (*о родственных отношениях*); *ул миңа бажай тия* он мне прихóдится своякóм **17.** *разг. прост. в сравнит. оборотах* каза́ться, показа́ться; *кайдадыр кургәндәй тиясең* ка́жется, я тебя́ ви́дел *где-то* **18.** *преимущ. в. ф.* **тимәгән** не трóнутый; *балта тимәгән урман* не трóнутый топорóм лес; лес, к котóрому не прикоснýлся ещё топóр; *себерке тимәгән йорт* дво́р, котóрого не коснýлась метлá **19.** *в отриц. ф.* **тимә** *разг.* не бóйся, не беспокóйся (всё на мази́) **20.** *с некоторыми сущ. образует составные глаголы со значением вредного воздействия чего-л.; ис тию* угорéть; *салкын тию* простуди́ться ◻ **тиеп китү** задева́ть/заде́ть; **тиеп үтү** заде́ть попу́тно; **тия китү** заходи́ть/зайти́ (по пути́ (по дорóге) ◊ **тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка** наобýм; на авóсь; ли́бо в сук, ли́бо в тетéрю; **тиясе булма** не тронь, не смей трóгать

тияк I *сущ.* **1.** па́лочка, соба́чка для наве́шивания (наки́дывания) пéтли **2.** коро́ткая па́лочка (*употребляется вместо пуговиц*)

тия|к II *сущ.* **1.** специа́льное па́стбище, вы́гон, уча́сток (*для отдельных групп лошадей*); *су, әйләнеп, улагын табар, ат, әйләнеп, ~ген табар* (*посл.*) вода́ покру́тится да найдёт желобóк (сток), лóшадь покру́-

тится да найдёт свой уча́сток (па́стбища) **2.** *перен.* ро́дина, родны́е места́; *сөягем тиягемә кайтсын* (*погов.*) пусть мои́ ко́сти верну́тся (*букв.* верну́тся) в родны́е места́

тияр *прил.* **1.** соотве́тствующий (*о цене*), поло́женный, до́лжный; *~ бәясе* соотве́тствующая цена́; **2.** *в знач. сущ.* до́лжное, поло́женное; *~е түләнде* поло́женное упла́чено

тияр-тимәс *нареч.* **1.** чуть не каса́ясь, едва́ каса́ясь; почти́ каса́ясь **2.** чуть косну́вшись, е́ле косну́вшись ◊ **тияр-тимәс чер итү** чуть что — закрича́ть, заора́ть благи́м ма́том

тиясе *сущ.* то, что полага́ется; *см. тж.* **тияр**; *~н бирү* дать, отда́ть то, что полага́ется; *~н алу* **1.** получа́ть, брать поло́женное **2.** понести́ наказа́ние

тоба, ту́ба *сущ.* **1.** глубо́кий плёс, зато́н; за́йма, за́водь **2.** о́мут, пучи́на; *~га ташлану* броса́ться в о́мут

тобалы *прил.* име́ющий зато́ны, плёсы; изоби́лующий зато́нами, плёсами (*о реке*); *Иж сулары бик ~* река́ (*букв.* во́ды) Иж изоби́лует плёсами

товар *сущ.* това́р; това́ры; *киң куллану ~лары* това́ры широ́кого потребле́ния; *~ алмашу* обменя́ться това́рами; товарообме́н; *~ җитештерү* производи́ть това́р; произво́дство това́ров; *утемсез ~ кыйбатка төшәр* (*посл.*) нехо́дкий това́р обхо́дится до́рого; *асыл ~ арзан булмас, арзан ~ асыл булмас* (*посл.*) ка́чественный това́р не быва́ет дешёвым, дешёвый това́р не быва́ет ка́чественным || *прил.* това́рный; *~ ашлык* това́рное зерно́; това́рный хлеб □ *~ әйләнеше* това́рооборо́т; това́рообраще́ние; *~ җитештерүче* това́ропроизводи́тель

товарлану *неперех.* закупи́ть това́ры (*в большом количестве*); отова́риваться

товарлаштыру *перех.* отова́ривать (*талоны*)

товарлаштырылу *страд. от* **товарлаштыру**; отова́риваться

товарлы *прил.* **1.** с това́ром, това́рный; нагру́женный (загру́женный) това́ром, *~ әрҗәләр* я́щики с това́ром **2.** многотова́рный, бога́тый; бога́т това́рами; *~ кеше* челове́к (купе́ц), бога́тый това́рами

товарлык *прил.* това́рный, предназна́ченный на прода́жу; *~ ашлык* това́рное зерно́

товарлыклы *прил.* това́рный, ка́чественный, хо́дкий; конкуре́нтоспосо́бный; *~ продукция* това́рная проду́кция; *~ тугел* нетова́рный, не мо́жет быть предло́жен в ка́честве това́ра □ *~ җитештерү* това́рное произво́дство

товарлылы|к *сущ.* това́рность (*продукции производства*); *яшелчәчелекнең ~гы* това́рность овощево́дческого хозя́йства

товарчы *сущ.* **1.** *уст.* торго́вец (продаве́ц) вразно́с; *вак ~* ме́лкий торго́вец вразно́с **2.** това́ропроизводи́тель

товарчылык *сущ.* **1.** *ист.* заня́тие торго́влей вразно́с **2.** произво́дство това́ров (*широкого потребления*); *~ артеле* това́рная арте́ль; *~ фермасы* това́рная фе́рма

то́га *сущ.* то́га (*верхняя одежда граждан Древнего Рима*) ◊ **(фәләннең) ~сына төренү** облека́ться/облечься в то́гу *кого; галим ~сына төренү* облека́ться в то́гу учёного

тоек *сущ. поэт.* туюк (*тюркский стих с применением аллитерации и омонимов*)

тоел|у **1.** чу́вствоваться, ощуща́ться; прощу́пываться; отдава́ться; *монда нәрсәдер ~а* здесь что́-то чу́вствуется **2.** представля́ться, каза́ться/показа́ться; *җилкәдә йөк булса, юл озын ~а* (*погов.*) когда́ на плеча́х груз, доро́га ка́жется дли́нной; *сәер ~ды* показа́лось стра́нным **3.** *в сравн. оборотах* чу́диться/почу́диться, каза́ться/показа́ться; *арттан кемдер килгәндәй ~ды* почу́дилось, вро́де кто́-то идёт сза́ди; *бу кеше юкка йөри кебек ~а* (*мне*) ка́жется, что э́тот челове́к хо́дит зря; *аваз ерактан килгән шикелле ~ды* показа́лось, что звук шёл как бы издалека́

тоем *сущ.* **1.** чутьё; (то́нкое, шесто́е) чу́вство, то́нкое ощуще́ние, то́нкий нюх; *см. тж.* **сизем, сол, сөм**; *музыкаль ~* музыка́льное чутьё; *куңел ~ы* душе́вное чутьё; *аның аеруча ~ы бар* у него́ есть осо́бо то́нкий нюх (*на что*) **2.** *биол.* восприя́тие; *сизем һәм ~* ощуще́ние и восприя́тие

тоемлану *страд. от* **тоемлау**; воспринима́ться

тоемлау *перех.* **1.** *биол.* воспринима́ть/воспря́ть (*сигналы органов чувств*) **2.** *см.* **сизем|әү**

тоемлы *прил.* **1.** чувстви́тельный, о́стро воспринима́ющий; чу́ткий на то́нкие сигна́лы **2.** чувстви́тельный, даю́щий о себе́ знать; *~ чыгым* чувстви́тельный расхо́д; чувстви́тельные изде́ржки

тоемсыз *прил.* бесчу́вственный (*человек*); не чу́ткий

тоен|у *перех. диал.* внима́ть/внять *кому, чему; см.* **сизен|ү**

тоеныш *нареч.* **1.** *редко* проникнове́нно; *~ җырлау* проникнове́нно петь **2.** *диал.* внима́тельно; *~ тыңлый* внима́тельно слу́шает

тожрайт|у *перех.* **1.** (*энергично*) вытара́щивать/вы́таращить, выпу́чивать/вы́пучить (*о глазах*) || тара́щение, выпу́чивание; *күзләрен ~ып карау* смотре́ть вы́таращив глаза́ **2.** уста́виться *на кого-л.* глаза́ми; *кемгә күзең ~асың?* на кого́ тара́щишь глаза́?

тожра|ю *неперех.* **1.** тара́щиться/вы́таращиться; выпу́чиваться/вы́пучиться (*о глазах*); *~йган күзле* с вы́таращенными глаза́ми **2.** *перен. диал.* уста́виться *на кого*

тоҗы *прил. диал.* **1.** аккура́тный, чи́стый; приведённый в по́лный поря́док (*дом*); *~ йорт* аккура́тный двор (дво́рик) **2.** хорошо́ и аккура́тно оде́тый (*о человеке*); прили́занный (*о костюме*) || *нареч.* хорошо́; чи́сто и аккура́тно; *~ тору* жить чи́сто и аккура́тно, соблюда́я чистопло́тность; *~ киену* хорошо́ одева́ться

тоҗылык *сущ. диал.* чистота́ и аккура́тность (*в доме, в одежде и т. п.*)

тоҗым *сущ.* **1.** дли́нная паути́на; паути́нка; *~ җепләре* ни́ти паути́нки **2.** сажо́нь; кана́т, натя́нутый ме́жду столба́ми и́ли про́чими опо́рами; верёвка, шнур, про́волока и т. п. (*на плантациях хмеля*); *~ сузу (тартыру)* натя́гивать кана́т

тоҗыр *прил. диал.* вы́пученный, вы́таращенный, широко́ раскры́тый (*о глазах*)

тоҗыр|у *перех. разг.* **1.** наде́лать, натвори́ть *что-л.; ни ~дың инде?* ну, и что ты натвори́л? чего́ ты дости́г (*этим*)? 2) понаде́лать; *~ган икән* понаде́лал, ока́зывается; понаде́лал же он, наколо́л он мне дров **2.** *диал.* воро́чать (дела́ми), де́лать/сде́лать (с разма́хом) *что-то; күп эшләр ~ып була* мо́жно сде́лать нема́ло дел; *~абыз гына* воро́чаем мы дела́ми ◊ **~гансыз (~гансың) икән** *иронический отзыв на гордое, хвастливое сообщение кого-л. о своих достижениях*

тоз *сущ.* **1.** *в разн. знач.* соль || солево́й; *тоз тәме* вкус со́ли; *тоз тәмәйтә* со́лоно; *калий тозы* ка́лийная соль; *таш тоз* ка́менная соль; *тоз заводы* солево́й заво́д; *тоз чыгару* добыва́ть соль; *аш тозы* пова́ренная соль; *ашның тәме тоз белән, өйнең яме кыз белән* (*посл.*) еда́ со́лью вкусна́, го́рница де́вушкой красна́; *тозга да талым бар* (*посл.*) и на соль есть тре́бование

2. *перен.* соль, (*основной*) смысл, толк; то, что де́лает разгово́р, сло́во и т. п. интере́сным, содержа́тельным; *сүзеңнең тозы юк* нет то́лку в твои́х слова́х **3.** *ист. перен.* подноше́ние, пода́рок зна́тному го́стю □ **тоз кайнату** выва́ривать ‖ выва́ривание, вы́варка со́ли, солевре́ние; **тоз ялату** дава́ть/дать скоту́ полиза́ть (ка́менную) соль; **тозы җиңел** недосо́лено; **тозы җиңеллек** недосо́ленность, недосо́л ◊ **~ күз** *см.* **тозкүз**; **~ өстенә торма (дигәндәй)** хрен ре́дьки не сла́ще; было го́ре, да еще несча́стье (*букв.* на соль да ещё ре́дьку); **~ салу** огорча́ть/огорчи́ть, испо́ртить настрое́ние; **~ түгел — эремәссең** не соль — не раствори́шься (*говорится тому, кто боится дождя*); **~ ялаткан кебек (төсле, шикелле)** ≈ как му́хи к мёду (льнут); как мёдом нама́зано

тозайту *см.* **тозландыру** 3 □ **күзне тозайту** пожира́ть глаза́ми, уста́виться, тара́щить глаза́

тоза|к *сущ.* **1.** пе́тля́, сило́к; западня́; *~кка эләгү (төшү)* попа́сться в силки́ (западню́); *~ктан ычкыну* уйти (вы́рваться) из силко́в (западни́) **2.** *перен.* западня́, лову́шка; *дошман ~гы* лову́шка врага́; *хәйлә ~гы* западня́ хи́трости; *яшерен ~к* та́йная лову́шка □ **тозак кору (салу)** расставля́ть/расста́вить силки́ (западню́, пе́тлю); **тозакка төшерү** пойма́ть в силки́, лови́ть в западню́

тозаклы *прил.* име́ющий силки́ (пе́тли, западни́); с силко́м, западнёй; *дошман ишеге ~* (*погов.*) две́ри у врага́ (устро́ены) с силко́м (*имеют петлю, западню*)

тозакчы *сущ.* лове́ц, расставля́ющий силки́ (пе́тли, западню́); *~ үзе күренмәс, җимен генә күрсәтер* (*посл.*) лове́ц не пока́зывается сам, пока́зывает то́лько прима́нку

тозкүз *прил.* со сверка́ющими и́ли водяни́стыми глаза́ми (*о человеке*); с бесцве́тными водяни́стыми глаза́ми

тозлавык *прил.* **1.** пересо́ленный; *~ аш* пересо́ленный суп **2.** *см.* **тозлак**

тозлаган *прил.* солёный; *~ кәбестә* солёная капу́ста; *~ ит* солёное мя́со; солони́на

тозлагыч *сущ. тех.* **1.** соли́льный аппара́т **2.** соли́льная ‖ *прил.* соли́льный

тозлак *сущ.* солонча́к, солоне́ц (*в степи*) ‖ *прил.* солончако́вый; *~ туфрак* солончако́вая по́чва

тозланды́р|у 1. подсоли́ть ‖ подсоле́ние (*почвы*) **2.** *см.* **тозландыру 3.** *перен.* пожира́ть глаза́ми, уста́виться, тара́щить глаза́; *күзләрен ~ып карый* смо́трит пожира́ющим взгля́дом

тозлан|у 1. *страд. от* **тозлау 2.** *в знач. прил.* **тозланган** просо́ленный, засо́ленный; *~ган ит* просо́ленное мя́со; *~ган кыяр* засо́ленный огуре́ц **3.** *возвр.* пропи́тываться/пропита́ться со́лью; *~ып каткан туфрак* по́чва, пропи́танная со́лью и поэ́тому затверде́вшая □ **~ып бетмәгән** недосо́ленный

тозланыш *сущ.* рассо́л; сте́пень солёности; *~ы җиткән* солёность доста́точна

тозлап-борычлап *нареч. разг.* **1.** с серви́ро́вкой; в серви́ро́вке (*с солью и перцем*); *тозлап-борычлап табын хәзерләү* гото́вить стол с по́лной серви́ро́вкой **2.** *перен.* с пе́рцем (т.е. с ко́лкими, язви́тельными выраже́ниями); *тозлап-борычлап сөйләшү* поговори́ть с пе́рцем

тозлат|у 1. *понуд. от* **тозлау 2.** *разг.* насоли́ть, пересоли́ть

тозла́|у *перех.* **1.** соли́ть/посоли́ть, класть соль; посыпа́ть со́лью ‖ соле́ние; *артык ~у аздан яман* (*посл.*) пересоли́ть ху́же, чем недосоли́ть; пересо́л ху́же недосо́ла **2.** соли́ть, засоли́ть, посоли́ть, просоли́ть ‖ соле́ние; засо́л; *кышка кәбестә ~у* засоли́ть на́ зиму капу́сту **3.** *перен.* соли́ть бесполе́зно, зря храни́ть у себя́; *~рга саклыйсыңмы аны* соли́ть, что ли, храни́шь его́ (*о чём-л. несъедобном*) □ **~п кую** засоли́ть; **~у цехы** соли́льный цех

тозлач I *сущ. бот.* галофи́т

тозлач II *прил.* солончако́вый; солелюби́вый; *~ үләннәр* солончако́вые тра́вы

тозлут *сущ. бот.* соля́нка

тозлы *прил. в разн. знач.* **1.** солёный, подсо́ленный; *~ балык* солёная ры́ба; *~ тир* солёный пот **2.** пересо́ленный; *~ аш* пересо́ленный суп **3.** го́рький, с го́речью; *см. тж.* **ачы 4.** *перен. разг.* 1) солёный, кре́пкий, забо́ристый, ядрёный (*о словах, об обращении с кем-л.*); *~ сүзләр ычкындыру* дать во́лю солёным (си́льным) выраже́ниям 2) кре́пкий, си́льный; сокруши́тельный; *~ гына бәру* кре́пенько уда́рить 3) дорого́й, дорогова́тый; тако́й, что куса́ется (*о ценах*); *бәясе ~ икән* цена́-то, ока́зывается, куса́ется ◊ **~ су** слёзы

тозлы-борычлы *прил.* ко́лкий, язви́тельный, с пе́рцем; *сүзнең тозлы-борычлы буласын сиздем* я чу́вствовал, что разгово́р бу́дет с пе́рцем

тозлы|к I *сущ.* **1.** тузлу́к, рассо́л (*солёная вода с накрошенными овощами, в которую макали испечённый без соли хлеб*) **2.** со́ус; нава́р (*который употребляли как соус*); *тиген ашның ~гы юк* (*посл.*) у дарово́го су́па нет нава́ру

тозлык II *сущ.* соля́нка

тозлылык *сущ.* солёность; *~ дәрәҗәсе* сте́пень солёности

тозса́|у *неперех.* хоте́ть со́ли (*о скоте*); *сыерлар ~ган* коро́вы хотя́т со́ли

тозсыз *прил.* **1.** без со́ли; несолёный, малосо́льный; *~ өйрә* несолёная похлёбка; *плансыз эш — ~ аш* (*посл.*) рабо́та без пла́на что суп без со́ли; *~ны күзсез дә белә* (*посл.*) несолёное и слепо́й разбира́ет **2.** *перен.* бестолко́вый, нелёпый, бессмы́сленный, бессодержа́тельный; са́льный, по́шлый; *~ шигырь* бессодержа́тельное стихотворе́ние; *~ сүз* са́льное (или нелёпое) сло́во; *~ кыланыш* бестолко́вая, нелёпая вы́ходка ‖ *нареч.* **1.** без со́ли; *ашны ~ пешерү* вари́ть суп без со́ли **2.** *перен.* нелёпо, бессмы́сленно, бестолко́во; *~ кылану* нелёпо вести́ себя́

тозсызландыру *перех.* обессо́ливать, обессо́лить ‖ обессо́ливание

тозсызлан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать малосо́льным, несолёным; теря́ть, потеря́ть соль в своём соста́ве (*о почве*) **2.** *перен.* станови́ться/стать нелёпым, глупова́тым; *күпкә китсә, сүз ~а* е́сли слов мно́го, они́ стано́вятся глу́пыми **3.** *перен.* вести́ себя́ беспардо́нно, глу́по, нелёпо ‖ беспардо́нное (глу́пое, нелёпое) поведе́ние; *~ып сөйләнү* говори́ть глу́пости, по́шлости и т. п.

тозсызлык *сущ.* **1.** отсу́тствие и́ли недоста́ток, дефици́т со́ли; *~тан интегү* страда́ть от дефици́та со́ли **2.** *перен.* по́шлость, са́льность; глу́пость; *~лар әйтү* говори́ть по́шлости

тозтәгәч *сущ. разг.* соло́нка, деревя́нный и́ли фарфо́ровый сосу́д для со́ли; *тоз ~тә* соль в соло́нке

тоз-тибез *сущ. диал.* **1.** норма́льный вкус, вкусно́та, конди́ция (*пищи*); *тоз-тибезә килгән* доста́точно вку́сно **2.** *собир.* соль и припра́ва

тойгы *сущ.* **1.** чутьё, интуи́ция; *~ белән аңлау* понима́ть чутьём; *~га таяну* опира́ться на интуи́цию (на чутьё); *нечкә ~* то́нкое чутьё; *см. тж.* **сизем 2.** *в разн.*

знач. чу́вство, чу́вствование; *дуслык ~сы* чу́вство дру́жбы; *кардәшлек ~сы* чу́вство бра́тства; *сөю ~сы* чу́вство любви́; *ялгызлык ~сы* чу́вство одино́чества; *ялкынлы ~лар* пла́менные чу́вства **3.** ощуще́ние; курку *~сы* ощуще́ние стра́ха

тойгыландыру *понуд. от* **тойгылану**; придава́ть/прида́ть чу́вственность (*о произведениях искусства*)

тойгылан|у *неперех.* **1.** предава́ться чу́вствам, эмо́циям, ощуще́ниям; углубле́ние в свои́ чу́вства **2.** *в знач. нареч.* **тойгыланып** с чу́вством, с эмо́цией; *~ып сөйләү* говори́ть с эмо́цией, эмоциона́льно

тойгылы *прил.* чу́вственный; *~ образлар* чу́вственные о́бразы

тойгын I *прил.* **1.** чувстви́тельный (*о человеке*), то́нко чу́вствующий; *~ кеше — уйчан кеше* (*посл.*) то́нко чу́вствующий челове́к — заду́мчивый челове́к **2.** чу́ткий, то́нко чу́вствующий; *~ бала* чу́ткий ребёнок

тойгын II *сущ. ист.* кра́сный кре́чет (*как ловчая птица*)

тойгынлык *сущ.* **1.** чувстви́тельность, чу́ткость (*человека*) **2.** углубле́ние в чу́вства

тойгысыз *прил.* бесчу́вственный, неэмоциона́льный, ине́ртный; *~ кеше* бесчу́вственный (неэмоциона́льный) челове́к

тойгысызлык *сущ.* бесчу́вственность, не эмоциона́льность; эмоциона́льная пустота́

тойгычан *прил. поэт.* эмоциона́льный, душе́вный, то́нко чу́вствующий; *~ күңел* эмоциона́льная душа́ (натура)

тойдыр|у **1.** *понуд. от* **тою** **2.** *перен. груб. прост.* дать почу́вствовать; *тоймасаң, ~ырмын мин сиңа* е́сли не чу́вствуешь — я дам тебе́ почу́вствовать (жи́во почу́вствуешь)

тоймас: тоймас кеше не чувстви́тельный, тупова́тый челове́к; *бар икән ~ кеше* быва́ют, ока́зывается, столь тупы́е лю́ди

тоймаслан|у *неперех.* теря́ть/потеря́ть чувстви́тельность || поте́ря чувстви́тельности; одеревене́ть || одеревене́ние; *куллар ~ды* ру́ки одеревене́ли

ток *сущ. тех.* ток; *электр тогы* электри́ческий ток; *ток көчәнеше* напряже́ние то́ка; *ток көче* си́ла то́ка; *ток сугу* уда́рить то́ком; удар то́ком

то́калгы́ч *сущ. тех.* то́коприёмник

токандыру *перех. диал.* заже́чь (*огонь*); *см. тж.* **кабызу**

токан|у *неперех.* охва́тываться/охвати́ться пла́менем; зажига́ться/заже́чься; *учак ~ды* костёр зажёгся (на́чал горе́ть)

то́карь *сущ.* то́карь || тока́рный; *бишенче дәрәҗәле ~* то́карь пя́того разря́да; *~ станогы* тока́рный стано́к

то́карьлык *сущ.* тока́рное ремесло́ (де́ло); тока́рный труд; *~ эшендә* в тока́рном де́ле; *~ һөнәре* специа́льность (квалифика́ция) то́каря; *~ка уку* учи́ться на то́каря

токлан|у *возвр. от.* **токлау**; заряжа́ться/зарядя́ться то́ком; *~ган чыбыклар* заря́женные (то́ком) провода́

токлау *перех.* **1.** заряжа́ть/зарядя́ть то́ком **2.** пропуска́ть/пропусти́ть ток || пропуска́ние то́ка *по чему*; *уткәргечне ~* пропусти́ть ток по проводнику́

токлы *прил.* **1.** име́ющий ток; под то́ком, под заря́дом; заря́женный (*о проводниках, проводах и т. п.*); *~ тимергә тотынма* не каса́йся желе́за, кото́рое под то́ком **2.** *как второй компонент сложн. сл.* -то́чный; *зәгыйфь ~* слабото́чный

токман *сущ. диал.* заго́н; огоро́женная площа́дка для содержа́ния скота́, загоро́дка; *бозауны ~га ябу* запере́ть телёнка в загоро́дке

токмач *сущ.* лапша́; *кыйшык ~ киленнеке* (*посл.*) криву́ю лапшу́ наре́зала неве́стка (*букв.* неве́стина лапша́ криволине́йна); *~ җәю* раска́тывать те́сто для лапши́; *~ кисү* наре́зать лапшу́

токмачлап *нареч.* с лапшо́й; *~ пешерелгән аш* суп, сва́ренный с лапшо́й

токмачлы *прил.* **1.** име́ющий лапшу́ (*в своём распоряжении*); *~ кеше умачлыдан көлә, ди* (*посл.*) челове́к, име́ющий лапшу́, смеётся над тем, кто име́ет то́лько затиру́ху, говоря́т **2.** с лапшо́й (*в своём составе*); *~ аш* суп с лапшо́й

токмачлык *сущ.* мука́, предназна́ченная для лапши́; *~ тарттыру* намоло́ть муки́ для лапши́ || *прил.* предназна́ченный и́ли приго́дный для изготовле́ния лапши́; *~ он* мука́ для изготовле́ния лапши́

то́ксик *прил.* **1.** токси́чный; *~ матдәләр* токси́чные вещества́; **2.** токси́ческий; *~ тәэсир* токси́ческое возде́йствие

то́ксиклык *сущ.* токси́чность; *~ дәрәҗәсе* сте́пень токси́чности

токсиколо́гик *прил.* токсикологи́ческий; *~ тикшерү* токсикологи́ческое иссле́дование

токсиколо́гия *сущ.* токсиколо́гия || токсикологи́ческий; *~ бүлеге* токсикологи́ческое отделе́ние (*больницы*)

токсин *сущ. мед.* токси́н, токси́ческое вещество́

токсинлы *прил. мед.* **1.** токси́чный **2.** име́ющий в своём соста́ве токси́н

токча|й *сущ. диал.* мешо́чек, холщо́вая (*исторически — кожаная*) су́мочка (*другой формы, чем* **букча, букчай**); *~й тегү* сшить су́мочку-мешо́чек ◊ **~ең киң булсын** пусть мешо́чек твой бу́дет широ́ким (*т. е. не жалей денег*)

токым *сущ.* **1.** **1)** *в разн. знач.* сорт, поро́да; *~ы яхшы терлек* скот хоро́шей поро́ды; *тау ~нары* го́рные поро́ды; *каты ~* твёрдая поро́да **2)** род, круг ро́дственников; родня́; *сезнең ~ыгыз шундый* вся ва́ша родня́ такова́ (ваш род тако́в) **2.** *разг.* **1)** наро́дность, пле́мя; *бөтенләй безнең ~ түгел* не на́шей поро́ды; совсе́м не на́шего ро́да-пле́мени (наро́дности) **2)** происхожде́ние (*по национальности или социальное*); *~ың нинди синең?* каково́ твоё происхожде́ние? **3.** *разг.* род, пле́мя (*животного*); *ат ~ы* лошади́ный род, ло́шади (*вообще*); *кәҗә ~ы* ко́зий род, коза́, ко́зы (*вообще*); *мәче ~ыннан бер хайван* не́кое живо́тное (из) кошачьего пле́мени **4.** **1)** пото́мство, пото́мок; *~ының дүртенче буыны* четвёртое поколе́ние чьего пото́мства **2)** отро́дье; *бүре ~ы* во́лчье отро́дье; *шайтан ~ы* чёртово отро́дье **5.** разво́д (*то, что предназначено на разведение*); *күлгә балык ~ы җибәрү* пусти́ть в о́зеро разво́д ры́бы **6.** *в знач. прил.* **токымындагы, токымдагы;** явля́ющийся представи́телем определённой поро́ды; (из) поро́ды; *холмогор ~ындагы сыер* коро́ва холмого́рской поро́ды || *прил. разг.* **1.** (из) поро́ды; *яхшы ~ сыер* коро́ва хоро́шей поро́ды **2.** *диал.* ро́дственный; *безгә ~ кеше* ро́дственный нам челове́к □ **~га калдыру** оста́вить на разво́д; **~ы кору** (*совершенно*) вымира́ть; **~ын корыту** **1.** не оста́вить пото́мства **2.** *перен.* (*совершенно, до единого*) уничто́жить, истреби́ть

токымдаш *прил.* **1.** *биол.* однопо́родный **2.** ро́дственный, одного́ ро́да *с кем-л.*; *~ кабиләләр* ро́дственные племена́

токымлы *прил.* **1.** поро́дистый, племенно́й; *~ үгезләр* поро́дистые (племенны́е) быки́ **2.** плодови́тый, име́ющий многочи́сленное пото́мство; *бик ~ булды* оста́вил многочи́сленное пото́мство

токымлылык *сущ.* то, что на пле́мя, на разво́д; *~ка калдыру* оставля́ть на разво́д

токымсыз *прил.* **1.** беспоро́дный; *~ терлекләр* беспоро́дные дома́шние живо́тные **2.** *прил.* без пото́мства, не име́ющий пото́мства; *~ калу* оста́ться без пото́мства

токымсызлык *сущ.* **1.** беспоро́дность **2.** *сущ.* неиме́ние пото́мства; беспло́дие

токымчы *сущ. разг.* селекционе́р

токымчылык *сущ. разг.* **1.** селе́кция (*выведение сортов и гибридов с.-х. культур и пород скота*); *~ белән шөгыльләну* занима́ться селе́кцией **2.** выра́щивание поро́дистого скота́

токын *диал.* I *сущ.* **1.** загоро́дка (*внутри хлева, коровника*); клету́шка; *тавыкларны ~га ябу* загоня́ть кур в клету́шку **2.** хлев-ма́занка (*преимущ. круглой ф.*) **3.** *см.* **токма́н**

токын II *прил.* **1.** за́мкнутый, огоро́женный, огорождённый со всех сторо́н; глухо́й (*о стене*) **2.** *перен.* за́мкнутый, молчали́вый, неразгово́рчивый

токынлык *сущ.* **1.** за́мкнутость, неразгово́рчивость **2.** заби́тость

тол I *прил.* вдо́вый, вдо́вствующий; *тол булу* стать вдо́вым; *тол ир* вдове́ц, вдо́вый мужчи́на; *тол хатын* вдова́, вдо́вая же́нщина || *сущ.* вдове́ц; вдова́; *толлар һәм ятимнәр* вдо́вы и сиро́ты □ **тол калу** овдове́ть; оста́ться вдово́й (*реже* вдовцо́м); **тол яшәү** жить вдово́й (вдовцо́м) ◊ **тол гамәл (эмәл) 1.** обы́чай воздержа́ния от половы́х сноше́ний во исполне́ние обе́та и́ли по́сле сме́рти супру́га на не́которое вре́мя **2.** *перен.* беспло́дные уси́лия, бесполе́зное усе́рдие

тол II *сущ.* тол (троти́л) || то́ловый; *тол порошогы* то́ловый порошо́к

толлай *нареч.* вдово́й; *~ алу* взять (за́муж) вдово́й

толлану *неперех.* оста́ться вдово́й

толлык *сущ. разг.* вдовство́, сиро́тство; *~та үстек* мы вы́росли в сиро́тстве

толмач *сущ. см.* **тылмач**

толпар *сущ. см.* **тулпар**

толсто́вка *сущ.* толсто́вка (*вид мужской блузы с поясом, надеваемой как верхняя одежда*)

толстойчылык *сущ.* толсто́вство (*учение Л. Н. Толстого и общественно-политическое движение, основанное на его учении*); *~ белән мавыгу* увлече́ние толсто́вством

толчук *сущ. см.* **талчук**

толчукчы *сущ. см.* **талчукчы**

толы|к *сущ. диал.* мешо́к для перево́зки и хране́ния со́ли (*из цельной шкуры животного*); *тоз — ~гы белән, кыз — холыгы белән* (*посл.*) соль — со свои́м мешко́м, де́вушка — со свои́м хара́ктером (*т. е. приятное надо принимать вместе с неприятным*)

толыкман *сущ.* **1.** *диал.* грома́дина, махи́на, глы́ба; *~ы белән* всей глы́бой **2.** бру́тто; *~ы тугыз пот, алыкманы алты пот* бру́тто де́вять пудо́в, не́тто шесть пудо́в

толыкманлап *нареч.* сра́зу помно́гу; о́птом, больши́ми куска́ми; *~ алу* брать помно́гу сра́зу; *~ йоту* схапать целико́м

толыкман-толыкман *нареч. диал.* грома́дами, грома́динами, глы́бами; в ви́де огро́мных куско́в, глыб; *толыкман-толыкман болытлар* ту́чи глы́бами, грома́динами

толым *сущ.* коса́, коси́чка; *~ үрү* заплета́ть ко́су; *~ы беләктән юан, билдән тубән* (*фольк.*) её коса́ то́лще руки́, ни́же по́яса

толымлап: толымлап үрү заплета́ть в ко́сы (коси́чки)

толымлы *прил.* с ко́сами; коси́чками; *~ кызчык* де́вочка с коси́чками, с косо́й; *юан ~* с то́лстой косо́й

толымсыз *прил.* без косы́; *~ гына* не заплета́я в ко́сы (ко́су)

толымча|к, толымчы|к *сущ.* **1.** *разг.* коси́чка **2.** *диал.* люби́мая дочь отца́, люби́мица; *~гым, колынчыгым* (*фольк.*) моя́ люби́мица, мой жеребёночек (*т. е. резвушка*)

толып *сущ.* тулу́п; *~ кигән* в тулу́пе, наде́вший тулу́п; *~ якасы* воротни́к тулу́па

толыплы *прил.***1.** с тулу́пом; име́ющий тулу́п **2.** в тулу́пе; *~ берәү* не́кто в тулу́пе

толь *сущ.* толь; *~ төргәге* руло́н (свёрток) то́ля; *~ белән ябу* крыть то́лем || *прил.* то́левый; *~ түбә* то́левая кры́ша

тольләп *нареч.* с то́лем; применя́я толь; *~ ябу* крыть с то́лем (*под другой материал*)

том I *сущ.* том, то́мик; *бер ~да* в одно́м то́ме

том II *сущ.* (том) *диал.* за́говор, заклина́ние, суеве́рная моли́тва над больны́м

тома I *частица усил.* дрему́че, соверше́нно; *~ надан* дрему́че неве́жественный; *~ сукыр* соверше́нно слепо́й; *~ юкка* соверше́нно напра́сно

тома II: **тома балавыз** пропо́лис, пчели́ный клей

томага *сущ. ист.* нагла́зник, колпачо́к, ша́почка для головы́ охо́тничьей пти́цы (*орла, сокола и т. п.*); *~сын салган бөркеттәй* как орёл, с кото́рого сня́ли нагла́зник

томак *сущ. этногр.* **1.** вид национа́льной ша́пки; киргизская (каза́хская) ша́пка; *~ кигән* в ша́пке тома́к **2.** ша́пка-уша́нка

томалагыч *сущ.* **1.** заглу́шка **2.** глуши́тель || *прил.* **1.** заглуша́ющий, закрыва́ющий **2.** *прост. см.* **колак томалагыч, күз томалагыч**

томалан *сущ.* трю́фель; *~ кыздыру* жа́рить трю́фели

томаландыру *перех.* загрязни́ть (*о волосах*); *гел каты суда юып, чәчне ~* загрязня́ть во́лосы постоя́нным промыва́нием в жёсткой воде́

томалан|у *возвр.-страд. от* **томалау 1.** прикрыва́ться/прикры́ться, ку́таться, заку́тываться/заку́таться, уку́тываться/уку́таться || прикрыва́ние; *~ып яту* лечь, уку́тавшись с голово́й **2.** заку́пориваться/заку́порить ся (*о кровеносных сосудах*) **3.** завола́киваться/заволо́чься, затума́ниваться/затума́ниться || завола́кивание; *яшь белән кузләр ~ды* глаза́ затума́нились слезо́й; *кук ~а* не́бо завола́кивается (*тучей и т. п.*); *аның куз аллары ~ды* у него́ потемне́ло в глаза́х (*от горя, страха, и т. п.*) **4.** *прям., перен.* изоли́роваться || изоли́рование само́ собо́й; *~ып ятабаз* живём в изоля́ции, изоли́ровались (*от мира*) **5.** затума́ниваться/затума́ниться, мути́ться/помути́ться, помрача́ться/помрачи́ться || помрачне́ние (*о сознании, чувствах и т. п.*); *аңы ~ды* созна́ние его́ замути́лось (помрачи́лось) **6.** гло́хнуть, огло́хнуть (*об ушах*) **7.** *диал.* задыха́ться, задохну́ться (*о цыплятах в скорлупе, о семенах и т. п.*); *~ып черу* задохну́вшись, сгнить **8.** *страд.* занаве́шиваться; *~ган тәрәзәләр* занаве́шенные о́кна **9.** затыка́ться, заде́лываться; *тишектошыклар ~ган* все ды́ры заде́ланы **10.** *перен.* оглуша́ться, быть оглушённым

томал|ау *перех.* **1.** прикрыва́ть/прикры́ть, накрыва́ть/накры́ть, закрыва́ть/закры́ть || прикрыва́ние,

закрыва́ние; *ярыкны ~ау* прикрыва́ть дыру́ 2. затыка́ть/заткну́ть, забива́ть/заби́ть, заде́лывать/заде́лать || затыка́ние, забива́ние, заде́лывание; *тишекләрне ~ау* заде́лывать все ды́ры; *авызын ~ады* заткну́л рот *прям., перен.* 3. заку́поривать/заку́порить || заку́поривание (*кровеносных сосудов*) 4. оку́тывать/оку́тать, уку́тывать/уку́тать, заку́тывать/заку́тать || уку́тывание; *җылы итеп ~ау* тепло́ уку́тать; *~ап яткыру* оку́тать и положи́ть (*ребёнка*) 5. глуши́ть, заглуши́ть, приглуши́ть; *самовар ~ау* заглуши́ть самова́р 6. обвола́кивать/обволо́чь || обвола́кивание (*темнотой, туманом и т. п.*); *кояшны буран ~ады* мете́ль обволокла́ со́лнце; *~ап яңгыр килә* обвола́кивая не́бо, идёт дождь 7. заглуша́ть/заглуши́ть, переглуша́ть/переглуши́ть; *игенне чүп үлән ~аган* хлеба́ заглуши́л сорня́к; *шатлыкны кайгы ~ый* чу́вство ра́дости переглуша́ет го́ре 8. оглуша́ть/оглуши́ть, одурма́нивать/одурма́нить || одурма́нивание; *зиһенне ~ау* оглуши́ть созна́ние □ **~ап кую** затыка́ть/заткну́ть (*совсем*); **~ап пешерү** туши́ть (*мясо, овощи*); **~ап чыгу** заде́лывать ды́ры

томан *сущ.* 1. тума́н; *иртән ~, кичен ~, бу ~га ни булган?* (*песня*) у́тром тума́н, ве́чером тума́н, что за тума́ны ве́чные? 2. ды́мка, мгла; *ерактагы ~ эчендә күренгән таулар* го́ры, виднеющиеся в далёкой ды́мке; *бөтенесе эле билгесез, бөтенесе ~ эчендә* всё ещё не́ясно, всё во мгле

томана *прил.* 1. подслепова́тый 2. *перен.* тёмный, неве́жественный; *~ кеше* тёмный челове́к; *~ ул* он неве́жественный, он туп, тёмен, не́уч 3. *диал.* ти́хий, кро́ткий, сми́рный, бессло́весный □ **~ баш** тупо́й; тупи́ца

томаналандыру *понуд. от* **томаналану**

томаналан|у *неперех.* отупе́ть || отупе́ние; станови́ться/стать || становле́ние неве́жественным, бестолко́вым и́ли за́мкнутым; *башы ~ды* голова́ его́ отупе́ла

томаналык *сущ.* темнота́, неве́жество; ту́пость; *~та калу* остава́ться, прозяба́ть в неве́жестве

томанландыру *понуд. от* **томанлану**; затума́нить, тума́нить

томанлан|у *неперех.* 1. превраща́ться/преврати́ться || превраще́ние в тума́н; *куе пар ~а, сирәгәя дә юкка чыга* густо́й пар превраща́ется в тума́н, рассе́ивается и исчеза́ет 2. тума́ниться, затума́ниваться/затума́ниться, отума́ниваться/отума́ниться || затума́нивание; покрыва́ться/покры́ться, затя́гиваться/затяну́ться тума́ном (*дымкой, мглой*); *су өсте ~ды* пове́рхность воды́ затума́нилась 3. 1) тума́ниться, видне́ться в ды́мке, тума́не; *~ып күренгән таулар* го́ры, виднеющиеся в ды́мке 2) тума́ниваться/тума́ниться, затума́ниваться/затума́ниться; мутне́ть/помутне́ть, замутне́ть || замутне́ние гла́з (*от слёз, сильных чувств и т. п.*); *күзләрем (күз алларым) ~ып китте* мои́ глаза́ затума́нились; пе́ред мои́ми глаза́ми всё затума́нилось 4. *см.* **томалану** 5; *аңы ~ган* рассу́док его́ помути́лся

томанл|ау *неперех. безл.* 1. появля́ться/появи́ться || появле́ние тума́на, тума́нов, затума́ниться || затума́нивание; *салкын җил — ~ауга* ве́тер прохла́дный — к тума́ну (*затуманиванию*); *~ап тора* что́-то затума́нивается (*затуманило*) 2. *перех.* тума́нить, затума́нивать/затума́нить, отума́нивать/отума́нить; покрыва́ть/покры́ть, затя́гивать/затяну́ть тума́ном, ды́мкой, мглой; *ул мәсьәләне ~ый* он тума́нит вопро́с (пробле́му)

томанлы *прил.* 1. тума́нный, охва́ченный, оку́танный тума́ном; *~ иртә* тума́нное у́тро; *~ таулар* охва́ченные, оку́танные тума́ном го́ры 2. затума́ненный; *~ караш* затума́ненный взгляд; му́тный взгляд; *~ пыяла* затума́ненное стекло́ 3. *перен.* не́ясный, сму́тный; *~ хәбәрләр* сму́тные изве́стия; *~ күзаллаулар* не́ясные представле́ния || *нареч.* тума́нно, не́ясно, сму́тно; *бик ~ сөйлиләр* говоря́т о́чень не́ясно (тума́нно)

томанлы|к *сущ. астр.* тума́нность; *йолдызлыклар һәм ~клар* созве́здия и тума́нности; *Андромеда ~гы* тума́нность Андроме́ды

томанлылы|к *сущ. прил.* 1. тума́нность, затума́ненность 2. *перен.* не́ясность, сму́тность, запу́танность (*выражения, запоминаний и т. п.*); *мәгълуматларның ~гы* сму́тность да́нных

томансу *прил.* 1. *уменьш. от* **томанлы**; слегка́ затума́ненный; *~ һава* не́сколько тума́нный, затума́ненный во́здух; *~ иртә* затума́ненное у́тро; *~ ераклыклар* чуть затума́ненные да́ли 2. *перен.* затума́ненный (*о взгляде*)

томансулан|у *неперех.* 1. *см.* **томансу** 2. тума́ниться/затума́ниваться/затума́ниться; *күзләре ~а иде* глаза́ его́ затума́нивались

томар *сущ. уст.* 1. о́берег (*заклинания, молитвы, написанные на бумаге и зашитые в кожаный треугольник*); *см. тж.* **бөти** 2. жезл (*полая жестяная трубочка с документами и т. п. бумагами внутри, которую держит должностное лицо в торжественных случаях*)

томат *сущ.* тома́т; помидо́р; *~ пюресе* пюре́ из тома́тов, тома́тное пюре́; *~ согы* тома́тный сок

тому *сущ.* на́сморк, просту́да; грипп; *~ белән интегү* страда́ть на́сморком (просту́дой); *~дан дару* лека́рство от гри́ппа □ **~ төшү (тию)** схвати́ть на́сморк, заболе́ть на́сморком; *борынга ~ тоште* в носу́ на́сморк

томаула|у *неперех.* боле́ть/заболе́ть на́сморком || на́сморк; *~п китте* (*вдруг*) заболе́л на́сморком; *~п торам* я боле́ю на́сморком

томаулы *прил.* 1. боле́ющий на́сморком, на́сморочный; *~ борын* на́сморочный нос 2. вызыва́ющий на́сморк; *~ көн* день, вызыва́ющий на́сморк

томлык *прил.* то́мный, на *столько-то* томо́в; *биш~ хезмәт* пятито́мный (и́ли тре́бующий пяти́ томо́в) труд || *сущ.* -то́мник; *бер ~* одното́мник

томра|у *неперех.* быть ма́товым, ма́тово-тёмным; *~ган кара* ма́тово-чёрный □ **~п агу** течь глубо́кой тёмной ма́ссой (*о реке*); **~п тору** 1. ма́тово поблёскивать 2. пы́хать здоро́вьем

томрый *прил.* ма́товый □ **~ кара** ворона́й (*о лошади*)

томса *прил.* 1. тёмный, ту́склый 2. мра́чный, су́мрачный 3. хму́рый; *~ кеше* хму́рый, непривётливый челове́к

томсалан|у *неперех.* 1. потемне́ть, потускне́ть; *~ган көзге* потускне́вшее зе́ркало 2. *см.* **томсару**

томсалык *сущ. диал.* 1. *см.* **төмсәлек** 2. хму́рость, непривётливость

томсар|у *неперех.* 1. стать/станови́ться || становле́ние хму́рым; хму́риться; обвола́киваться || обвола́кивание ту́чами; *көн ~ып китте* день стал хму́рым 2. *см.* **томсаю**

томса|ю *неперех.* наду́ться, хму́риться, (*молча*) помрачне́ть || помрачне́ние; *~еп утыру* сиде́ть наду́вшись

томсык I *прил.* 1. *см.* **томса** 2. молчали́вый, немногосло́вный; неречи́стый; *~ бала* молчали́вый ребёнок

томсык II *сущ.*: **томсык гөмбә** пога́нка бе́лая (*несъедобный гриб*)

том-том *нареч.* в ви́де мно́гих томо́в, мно́гими тома́ми || *прил.* многото́мный; *том-том хезмәтләр* многото́мные труды́

томпы|к *сущ.* 1. клюв, нос (*птицы*); *карга ~гы* клюв грача́ (воро́ны); *~гы белән элэктерү* схвати́ть клю́вом (*при помощи клюва*) 2. *груб. прост.* мо́рда, ха́ря; *~гына тондыру* дать по мо́рде □ **~к борын** нос крючко́м; крючкова́тый нос

томыл|у *неперех.* бежа́ть || бег во всю прыть (во весь опо́р); *см. тж.* **томырылу**; *~ып чабып килэ* ска́чет/бежи́т во всю прыть

томыр|у *перех.* 1. раска́лывать/расколо́ть || раска́лывание си́льным уда́ром (*чурбан*); подня́ть и уда́рить || уда́р (*о бревно*); *бер ~у белән яру* расколо́ть одни́м уда́ром (*чурку*) 2. *см.* **тондыру** 3

томырык *прил. диал.* 1. ду́шный, спёртый; *~ өйдэ тын тарыга* (*посл.*) в ду́шном до́ме не́чем дыша́ть 2. бесстóчный; глубо́кий и ти́хий (*об озере*); *~ күлдэ корт уйный* (*посл.*) ≈ в ти́хом о́зере че́рти во́дятся (*букв.* че́рви кишат) || *сущ.* бесстóчное ти́хое о́зеро (*в лесу*); *бака да: «комыррыгым, томыррыгым — ожмах» — дигэн, ди* (*посл.*) и лягу́шка, говоря́т, сказа́ла: «мой ти́хий плёс, моё ти́хое о́зеро — рай»

томырыл|у 1. *страд. от* **томыру**; кида́ться/ки́нуться (*очертя голову, кубарем*); броса́ться/бро́ситься || бросо́к; *~ып ташлану* напада́ть/напа́сть броско́м 2. *в знач. нареч.* **томырылып** во весь дух, во весь опо́р; *~ып чабу* скака́ть во весь дух □ **~ып төшү** скати́ться ку́барем (*с горы*) (*о мальчике*); па́дать, упа́сть ка́мнем (*о птице*)

томырышу *взаимно-совм. от* **томыру**

тон I *сущ. в разн. знач.* тон; *югары ~* высо́кий тон; *ачулы ~* серди́тый тон; *яхшы ~* хоро́ший тон; *күңелле ~да (~ белән)* весёлым то́ном, в весёлом то́не; *йөрәк ~нары* то́ны се́рдца; *шул ук ~да* в тон □ **~ бирү** 1. петь определённым то́ном 2. *перен.* дава́ть/дать, задава́ть/зада́ть тон

тон II *сущ. этногр.* пе́рвый ребёнок; *~ угылга тун тияр, актыгына ат тияр, уртанчысына ук та юк, чук та юк* (*посл.*) пе́рвому сы́ну — одея́ния (отца́), после́днему сы́ну — и́мя отца́, сре́днему — ничего́

тон III *прил. диал.* 1. прозра́чный 2. чи́стый, без при́месей

тональ *прил. в разн. знач.* тона́льный; *~ теллэр* тона́льные языки́; *~ күчешлэр* тона́льные перехо́ды

тональлек *сущ.* тона́льность

тондагы *прил.* (*определённого*) то́на; *әйбәт ~* хоро́шего то́на, хоро́ший по то́ну

тондыргыч *сущ.* отстóйник || *прил.* отстóйный; *~ бассейн* отстóйный бассе́йн

тондырма *прил.* отстóйный; *~ су* отстóйная вода́

тондырту *понуд. от* **тондыру** 1—2

тондыр|у *понуд. от* **тону** 1. отста́ивать/отстоя́ть, дать отстоя́ться || отста́ивание (*воды и т. п.*); *суны ~ып ал* бери́ во́ду, отста́ивая её 2. оглуша́ть || оглуше́ние; *колак ~у* оглуши́ть у́ши 3. *перен.* бро́сить/броса́ть, забра́сывать/забро́сить || забра́сывание, кида́ть/ки́нуть, заки́дать/заки́нуть, сбра́сывать/сбро́сить || кида́ние, заки́дывание (*быстрое, энергичное*); сбра́сывание; *ераккa ~у* далеко́ забро́сить (*только в прям.*); *авыр йөкне җилкәдән җиргә ~дым* сбро́сил с плеч тяжёлую но́шу; *сугa ~у* сбро́сить (бултыхну́ть) в во́ду 4. *перен.* дава́ть/дать, удара́ть/уда́рить (*кулаком и т. п.*), резану́ть, долбану́ть, *прост.* сту́кнуть; *берне ~ды* как даст (дал) разо́к

тонзиллит *сущ. мед.* тонзилли́т

тонизм *сущ. лит.* тони́зм (*ритмическое ударение в стихотворении*)

то́ник *прил. в разн. знач.* тони́ческий; *~ принцип* тони́ческий при́нцип (*в стихосло́жении*)

то́нна *сущ.* то́нна; *бер ~ цемент* (одна) то́нна цеме́нта

тоннаж *сущ.* тонна́ж

тоннажлы *прил. как второй компонент сложн. сл.* -тонна́жный; *эре ~* крупнотонна́жный

то́нналап *нареч.* 1. тоннами; по то́ннам; *~ үлчәү* измеря́ть то́ннами 2. о́коло определённого коли́чества тонн; *биш ~* о́коло пяти́ тонн (ве́сом)

то́нналы *прил.* как второ́й компоне́нт *сложн. сл.* -то́нный; *ун ~* десятито́нный (*груз, машина*)

то́нналык *прил.* доста́точный для вмеще́ния определённого коли́чества тонн *чего-л.*; -то́нный; *өч ~ мичкә* трёхто́нная бо́чка

тоннель *сущ.* тонне́ль, туннéль; *~ кору* проры́ть, проложи́ть тонне́ль; *~дән үтү* проезжа́ть че́рез тонне́ль

тоннельче *сущ.* 1. прохо́дчик (*рабочий, производящий проходку горных выработок, туннелей*) 2. маркше́йдер

тон|у *неперех.* 1. отста́иваться/отстоя́ться || отста́ивание; *су болганыр да ~ар, ил болганыр да тынар* (*посл.*) вода́ замути́тся да отстои́тся, общи́на поволну́ется да ути́хнет 2. мутне́ть, замутне́ть || замутне́ние; станови́ться/стать му́тным, сму́тным, нея́сным (*о светящихся предметах*); *ай ~ды* ме́сяц замутне́л; *~ган пыяла* замутнённое стекло́ 3. *перен. см.* **шәрү**; *~ган йомырка* яйцо́-болту́н

то́нус *сущ. мед. прям., перен.* то́нус; *тормыш ~ы* то́нус жи́зни

то́нуслагыч *сущ.* тонизи́рующий соста́в || *прил.* тонизи́рующий

то́нуслау *перех.* тонизи́ровать || тонизи́рование

тончы|гу *неперех.* 1. задыха́ться/задохну́ться; *төтеннән (төтендә) ~гу* задохну́ться от ды́ма (*в дыму*); *~гыл үлү* задохну́ться (*насмерть*) 2. захлёбываться/захлебну́ться || захлёбывание; *куз яшьләреннән (яшьләренә) ~гу* захлёбываться от слёз 3. *перен. груб.* подыха́ть/подо́хнуть, сдо́хнуть; *~кқыры* чтоб (ты) сдох

тончыктыргыч *прил.* 1. уду́шливый, удуша́ющий; *~ ис* уду́шливый за́пах 2. тра́вящий; испо́льзуемый для травле́ния (*грызунов*) || *сущ.* душегу́бка, га́зовая ка́мера

тончыктыр|у 1. *понуд. от* **тончыгу** 2. *безличн.* быть о́чень ду́шным, о́чень спёртым; уду́шливым, удуша́ющим; *~а* ду́шит, о́чень ду́шно; уду́шливо 3. *груб. прост.* удуша́ть/удуши́ть, задуши́ть, погуби́ть, уничтожа́ть/уничто́жить || удуше́ние; уничтоже́ние; *әрләннәрне ~у* удуши́ть хомяко́в; *дошманны ~у* погуби́ть врагов

тонык *прил.* 1. устоя́вшийся, отстоя́вшийся; прозра́чный, чи́стый (*о воде*); *~ күл* прозра́чное о́зеро; *~ су* отстоя́вшаяся вода́ 2. 1) нея́сный (*как бы виднеющийся сквозь воду*); сму́тный (*по очертаниям*); размы́тый; нечёткий, ту́склый; *айның ~ нурлары* ту́склый свет луны́; *~ сурәт* нечёткое (размы́тое) изображе́ние 2) нея́сные, невня́тные, неотчётливые зву́ки 3. му́тный (*как бы невидящий*); водяни́стый (*о взгляде, глазах, взоре*) || *нареч.* 1. 1) ту́скло, ма́тово, размы́то, нечётко; *~ ялтырый* ту́скло проблёскивает; *~ күренгән* нея́сно виднéвшийся; *~ чыккан фотография* нечётко проявивша́яся фотогра́фия 2) *как первый компонент сложн. сл.*: ту́скло-, ма́тово-; *~ ящел* ту́скло-зелёный, ма́тово-зелёный 2. му́тно; *~ караш* му́тный взгляд 3. невня́тно, неотчётливо; нечётко; *~ бирелгән фикер* неотчётливо (нечётко) вы́раженная мысль

тонык|ландыру *перех. см.* **тондыру**

тоныклан|у *неперех.* **1.** *см.* **тону**; станови́ться/стать прозра́чным (*о воде*) **2.** тускне́ть/потускне́ть, бле́кнуть/побле́кнуть; станови́ться/стать нечётким, неясным; *~ган фотография* потускне́вшая фотогра́фия **3.** станови́ться/стать невня́тным, невырази́тельным (*о голосе*) **4.** *перен.* потеря́ть я́сность, отчётливость; станови́ться/стать сму́тным; *~ган хатирәләр* сму́тные воспомина́ния

тоныклы|к *сущ.* **1.** чистота́, прозра́чность (*воды, жидкости*); *кулнең ~гы* прозра́чность о́зера **2.** неясность, нечёткость, ту́склость **3.** невня́тность, невырази́тельность (*голоса*)

топ *нареч. уст.* **1.** кре́пко **2.** с разма́ху; *топ салу* класть с разма́ху □ **топ басу** реши́тельно де́йствовать

топаз *сущ.* топа́з (*драгоценный камень*)

то́пка *сущ.* то́пка (*паровоза*)

топо́граф *сущ.* топо́граф; *~лар отряды* отря́д топо́графов

топогра́фия *сущ.* топогра́фия; *төбәкнең ~се* топогра́фия ме́стности

то́поль *сущ.* то́поль; *см. тж.* **тупыл**

топо́ним *сущ.* топо́ним (*название географического объекта*)

топони́мик *прил.* топонимический; *~ сүзлек* топонимический слова́рь

топони́мика *сущ.* топони́мика

топонимист *сущ.* топонимист (*специалист по топономии или топонимике*)

топ-тоныk *прил. первосх. ст. от* **тоныk**; соверше́нно прозра́чный

тора I *сущ.* **1.** *ист.* языческий храм, ка́пище у тю́рков Повóлжья и За́падной Сиби́ри (*расположенное обычно на возвышенных местах*) **2.** *диал.* го́род, горо́док; *см. тж.* **тура**

тора II: **тора ят 1.** представи́тель пя́того поколе́ния, счита́я от о́бщего пре́дка **2.** чужо́й, не счита́ющийся ро́дственником (*поэтому с ним можно породниться брачными связями*)

тора-бара *нареч.* со вре́менем, постепе́нно; *шундый эшләр, тора-бара нишләр* (*погов.*) таки́е дела́, посмо́трим, как они́ пойду́т со вре́менем; *тора-бара болыт зурайды* постепе́нно ту́ча увели́чилась

торак *сущ.* жили́ще, жильё || жили́щный; *~ мәсьәләсе* жили́щный вопро́с || *прил.* жило́й; *~ мәйдан* жила́я пло́щадь; *~ йорт* жило́е зда́ние, жило́й дом □ *~* **пункт** *см.* **торлак**

тораклану *неперех.* заиме́ть дом, кварти́ру, станови́ться/стать облада́телем до́ма, кварти́ры

тораклы *прил.* с жильём; име́ющий дом, кварти́ру; *~ кеше — тәракле кеше* (*погов.*) челове́к с жильём — челове́к с опо́рой

тораклык *прил.* жило́й, приго́дный для жилья́ || *сущ.* жило́е ме́сто, населённый пункт; *ераста ниндидер ~ куренә* вдали ви́дно како́е-то жило́е ме́сто

тораксыз *нареч. прил.* **1.** без жилья́ (кварти́ры, до́ма); бездо́мный, бесквартирный **2.** беспризо́рный

тораксызлык *сущ.* отсу́тствие жилья́; нехва́тка кварти́р (домо́в)

торакханә *сущ.* **1.** жило́е помеще́ние; *тегермәннең ~се* жило́е помеще́ние ме́льницы **2.** *см.* **ятакханә**

торангы *сущ. бот. редко* **1.** хурма́ **2.** апельси́н

тораташ *сущ. ист.* **1.** ка́менный и́дол, истука́н; свяще́нный ка́мень в языческом хра́ме, то́ра; *~ка табыну* поклоня́ться и́долу **2.** *см.* **балбал** ◊ *~* **булып (шикелле) кату** окамене́ть от си́льных чувств; *~* **кебек тору** стоя́ть безуча́стно к окружа́ющему; стоя́ть болва́ном (истука́ном), быть ине́ртным

торачы *сущ. диал. этногр.* представи́тельница пя́того поколе́ния, счита́я от о́бщего пре́дка

торба I *сущ.* **1.** *в разн. знач.* труба́; *см. тж.* **труба**; *завод ~сы* заводска́я труба́; *~ кычкырту* издава́ть зву́ки трубо́й; издава́ть тру́бные зву́ки **2.** *диал.* дымохо́д

торба II то́рба; то́рбище; *~ төбен иснәмичә, ат туймый* (*посл.*) ло́шадь не насы́тится, пока́ не понюхает то́рбы

торбачы *сущ.* трубач; музыка́нт, игра́ющий на трубе́

торг *сущ.* торг (*торговое учреждение*); *шәһәрнең беренче ~ы* пе́рвый торг го́рода

торганы *нареч. разг.* **1.** всегда́, всё вре́мя, непрерывно; то и де́ло; *~ кайгырды* всё вре́мя горева́л **2.** сплошь; *егет түгел, ~ алтын* не па́рень, а (сплошь) зо́лото (*настолько хорош*)

торги *сущ.* торги́, аукцио́н; *~ белән сату* продава́ть с аукцио́на

торгыз|у 1. *понуд. от* **тору**; *йокыдан ~у* разбуди́ть, заста́вить подня́ться на́ ноги; *бер урында ~у* заста́вить стоя́ть на ме́сте **2.** *перех.* 1) поднима́ть/подня́ть || поднима́ние, подня́тие на́ ноги; *егылганны ~у* подня́ть упа́вшего на но́ги 2) поднима́ть/подня́ть || поднима́ние (*воротника и т. п.; шерсти — о животных*) **3.** ста́вить/поста́вить стоймя́ (*вертикально, торчком*); *колакны ~у* ста́вить у́ши торчко́м; насторожи́ться (*о животных*) **4.** держа́ть, содержа́ть || содержа́ние (*на короткое время*) *где-л.*; *бозауны өйдә ~у* содержа́ть телёнка до́ма **5.** не тро́гать (*оставленные вещи*); *~мыйлар* тро́гают, беру́т (похища́ют) **6.** сооружа́ть/сооруди́ть, стро́ить/постро́ить || сооруже́ние, строи́тельство *чего-л.*; *йорт ~у* стро́ить/постро́ить дом (*на новом месте*) **7.** восстана́вливать/восстанови́ть || восстановле́ние

торгызыл|у *страд. от* **торгызу**; восстана́вливаться, быть восстано́вленным; *~ган шәһәрләр* восстано́вленные города́

торгын *прил.* **1.** засто́йный; ко́сный; *~ куренешләр* засто́йные явле́ния **2.** *физ.* стоя́чий; *~ дулкыннар* стоя́чие во́лны

торгынлану *неперех. см.* **торлаклану**

торгынлы|к *сущ.* засто́й; засто́йность; зати́шье; *экономик ~к* экономи́ческий засто́й; *тормышның ~гы* ко́сность жи́зни; *эш ~гы* засто́й в дела́х; зати́шье на рабо́те

торгынлыктагы *прил.* находя́щийся в засто́е; засто́йный, ко́сный, косне́ющий; *~ кабиләләр* косне́ющие племена́

тореадор *сущ.* тореадо́р

то́рий *сущ. хим.* то́рий (*радиоактивный элемент*)

торкылда|у *неперех.* курлы́кать || курлы́кание; *~ган торна, каркылдаган карга* жура́вль курлы́кающий, грач гра́ющий

торкылдаш|у *совм. от* **торкылдау**; курлы́кать (*о многих*); *торыйк-торыйк торналар ~ып тоналар* (*песня*) курлы́йк-курлы́йк журавли́, курлы́кают дру́жно

торкылдык *прил. разг.* ча́сто курлы́кающий || *сущ. разг. редко* жура́вль

торлак *сущ.* **1.** жильё; приста́нище **2.** постоя́нное ме́сто содержа́ния скота́; *~тагы мал — кулдагы мал, аулактагы мал — юлдагы мал* (*посл.*) скот на ско́тном дворе́ — свой, скот на да́льних па́стбищах — неизве́стно чей (*букв.* ещё на доро́ге к до́му)

торлаклану *неперех.* заиме́ть приста́нище, со́бственное жильё; станови́ться/стать облада́телем жилья́

торлаклы *прил.* с приста́нищем, име́ющий приста́нище

торлаксыз *прил.* без приста́нища, бездо́мный; *~ сукбайлар* бездо́мные броде́яги

торма *сущ.* ре́дька; *ачы ~* го́рькая ре́дька; *~ уу* натере́ть ре́дьку; *~ өстенә тоз* (*погов.*) (*букв.* на ре́дьку да ещё соль)

тормалы *прил.* **1.** *см.* **торырлык 2.** *диал.* что́бы жить, проживать; *~ килдегезме?* жить прие́хали?

то́рмоз *сущ.* **1.** то́рмоз, тормоза́ || тормозно́й; *~ кальıбы* тормозна́я коло́дка; коло́дка тормозно́го устро́йства; *~ механизмы* механи́зм торможе́ния; тормозно́е устро́йство **2.** *перен.* препя́тствие; *см.тж.* **киртә, тоткар** □ **~ бирү** тормозну́ть, затормози́ть; **~ салу** тормози́ть, притормози́ть (*при спуске*) ◊ **~ ясау** тормози́ть, меша́ть (*делу*); возводи́ть препя́тствия (*специально, с умыслом*)

то́рмозлагыч *прил.* **1.** тормозно́й; *~ җайланма* тормозно́е устро́йство **2.** *прям. перен.* заторма́живающий, приторма́живающий, тормозя́щий, меша́ющий || *сущ.* тормозно́й механи́зм

то́рмозлан|у *возвр. от* **тормозлау 1.** заторма́живаться/тормози́ться || торможе́ние, заторма́живание (*само собой*); *эшләр ~ды* дела́ затормози́лись **2.** *в знач. сущ.* **тормозлану, тормозланганлык** торможе́ние; притормо́женность, затормо́женность; *см.тж.* **тыйлыгу**

то́рмозланыш *сущ. биол.* затормо́женность; *~ халәте* состоя́ние затормо́женности

то́рмозлату 1. *понуд. от* **тормозлау**; заставля́ть приторма́живать **2.** *разг.* ста́вить/поста́вить то́рмоз

то́рмозла|у *перех. прям., перен.* тормози́ть, заторма́живать/затормози́ть, приторма́живать/притормози́ть || торможе́ние, заторма́живание; *~п (~ый-~ый) төшү* спуска́ться на тормоза́х (приторма́живая); *эшне ~у* затормози́ть де́ло

то́рмозлы *прил.* с то́рмозом, тормоза́ми; име́ющий то́рмоз, тормоза́; *~ арба* теле́га с тормоза́ми

то́рмозсыз *прил.* без тормозо́в; не име́ющий то́рмоз, тормоза́; *~ төшеп булмый* не спусти́ться без тормозо́в

тормыш *сущ.* **1.** 1) *в разн. знач.* жизнь || жи́зненный, жите́йский; *иҗтимагый ~* обще́ственная жизнь; *~та үз урыныңны табу* находи́ть/найти́ своё ме́сто в жи́зни; *авыл ~ы* дереве́нская жизнь; *иске ~* ста́рая жизнь; *шәхси ~* ли́чная жизнь; *~ мәшәкатьләре* жите́йские забо́ты; *~ тәҗрибәсе* жи́зненный о́пыт; *вокзалда ~ кайнап тора* на вокза́ле жизнь кипи́т 2) материа́льные усло́вия жи́зни; быт || бытово́й; *иркен ~* зажи́точная жизнь, зажи́точность; *~ ваклыклары* бытовы́е ме́лочи 3) перипети́и жи́зни; судьба́; *~ында зур үзгәрешләр* больши́е измене́ния в его́ судьбе́ **2.** существова́ние, бытие́ (*как биологический процесс*); *см.* **яшәү 3.** *в знач. нареч.* **тормышта** за́мужем; *ул инде күптән ~та* она́ давно́ уже́ за́мужем □ **~ дусты (иптәше, юлдашы)** друг (подру́га), спу́тник (спу́тница) в жи́зни; супру́г, супру́га; **~ итеп яткан булабыз** мы живём себе́ так потихо́ньку; **~ итү (көтү, кичерү)** жить, поживать/пожи́ть; проживать/прожи́ть; **~ киңәше** жи́зненный сове́т; **~ кору** *см.* **гаилә кору**; **~ кушуы** веле́ние жи́зни; **~ кушуы белән** по веле́нию жи́зни; **~ рәвеше** о́браз жи́зни; **~ тамыры** жи́зненный ко́рень; коренно́й вопро́с жи́зни, ко́рень жи́зни; **~ юлы** *см.* **гомер юлы**; **~ка ашмастай (ашмаслык)** несбы́точный; **~ка ашу** сбыва́ться/сбы́ться; претворя́ться/претвори́ться в жизнь; осуществля́ться/осуществи́ться в реа́льности; **~ка ашыру** претворя́ть/претвори́ть в жизнь; **~ка бирү** выдава́ть/вы́дать за́муж; **~ка караш** *см.* **дөньяга караш**; **~ка чыгу** выходи́ть/вы́йти за́муж; **~тан алынган** взя́тый из жи́зни; **~тан алынган типлар** взя́тые из жи́зни ти́пы; **~тан артта калу** отстава́ть/отста́ть от жи́зни

тормыш-көнкүреш *сущ.* **1.** быт || бытово́й; *тормыш-көнкүреш хикәяләре* расска́зы из бы́та; бытовы́е расска́зы; *тормыш-көнкүрештә булган* случи́вшийся в быту́ **2.** *разг.* житьё-бытьё; *тормыш-көнкүрешең ничек?* как твоё житьё-бытьё

тормышлан|у *неперех.* выходи́ть/вы́йти за́муж, жени́ться || заму́жество, жени́тьба; *~ган-төпләнгән* жени́лся, остепени́лся

тормышлы *прил.* **1.** *разг.* семе́йный; живу́щий норма́льной семе́йной жи́знью; *ул инде ~* он уже́ семе́йный **2.** име́ющий определённый о́браз жи́зни; *бай ~* зажи́точный **3.** *см.* **тормышчан**

тормышталы *прил.* жи́зненный; *~ хәлләр* жи́зненные ситуа́ции, жи́зненные обстоя́тельства; *~ очрак* слу́чай в жи́зни (из жи́зни)

тормышча *нареч.* как в жи́зни; реа́льно; *менә бусы ~ булды* вот э́то реа́льно

тормышчан *прил.* **1.** жи́зненный; практи́ческий; *~ мәгънә* практи́ческий смысл; *~ идея* осуществи́мая иде́я; *~ җирлек* жи́зненная осно́ва **2.** жизнеспосо́бный органи́зм **3.** *разг. см.* **тормышчыл**

тормышчанлык *сущ.* **1.** жи́зненность **2.** жизнеспосо́бность

тормышчыл *прил.* **1.** *разг.* хозя́йственный; рачи́тельный, практи́чный; *~ хатын* хозя́йственная же́нщина; рачи́тельная хозя́йка **2.** *см.* **тормышчан**

торна *сущ.* **1.** жура́вль || журавли́ный; *инәк (ана) ~* са́мка журавля́, журавли́ха; *иркәк (ата) ~* саме́ц журавля́; *бала ~* подро́сший журавлёнок; *~ оясы* журавли́ное гнездо́ **2.** *см.* **торнакай** □ **~ борчагы** *бот.* **1.** люпи́н **2.** чечеви́чник, чечеви́ца; **~ җиләге (күзе)** *см.* **мүк җиләге** ◊ **~ тәпи алып килү** начина́ть/нача́ть ходи́ть; *(аңар) ~лар тәпи алып килде* (он) на́чал ходи́ть (*о ребёнке*); **~ яраны** *бот.* жураве́льник

торнабаш *сущ. бот.* а́истник

торнабикә *сущ.* журавли́ха

торнакай *сущ. разг.* верзи́ла, ды́лда; *~ булып үскән* вы́рос верзи́лой

торнакач *сущ. диал.* **1.** журавлёнок **2.** *уменьш.-ласк. от* **торна**; жура́влик

торнакүз *сущ. бот. диал. см.* **торна җиләге**

торналык *сущ. разг.* долгова́зость; дли́нный (высо́кий) рост

торнасыйрак *прил. разг.* долгоно́гий; с дли́нными (то́щими) нога́ми

торос *сущ.* торо́с, торо́сы; *боз ~лары* торо́сы льда

торпеда *сущ.* торпе́да || торпе́дный; *~ җибәрү* пуска́ть торпе́ду

торпедалау *перех. разн. знач.* торпеди́ровать

торпедалы *прил.* торпе́дный; несу́щий торпе́ду; *~ катер* торпе́дный ка́тер

торпедачы *сущ.* торпеди́ст

торпыча *сущ.* навива́льник, мотови́ло, мота́лка; тру́бица; *~га җеп урату* навива́ть ни́тку на навива́льник

торс *сущ. в разн. знач.* торс

то́рслы *прил.* с то́рсом; име́ющий торс (*определённого свойства*); *юан ~* с то́лстым то́рсом

торсынга *нареч. разг.* на жизнь, на выжива́ние; *~ карыйсыңмы малыңны, үлсенгәме?* на выжива́ние ты присма́триваешь за ското́м и́ли на вымира́ние?

торт *сущ.* торт; ~ *пешерү* испекáть торт

тор-тор: тор-тордан хәбәр килү о необходи́мости просыпáться, встава́ть со сна (*букв.* пришлá весть от встава́й-встава́й); *тор-тордан хәбәр килде* встава́й; пора́ встава́ть!

тор|у *неперех.* **1.** 1) стоя́ть на нога́х, вертика́льно || стоя́ние; *әнә багана ~а* вон стои́т столб 2) стоя́ть, быть в определённом стоя́чем положе́нии || тако́е положе́ние; *арты белән ~у* стоя́ть за́дом *к кому, чему-л.*; *сакта ~у* стоя́ть на часа́х, быть в положе́нии часово́го; *постта ~у* стоя́ть на посту́, быть постовы́м; *аерым ~у* стоя́ть отде́льно (*от других*); *читтә ~у* стоя́ть в стороне́ (*тж. перен.*); *яманнан ерак ~* (*посл.*) стой пода́льше от плохо́го (*человека*) 3) стоя́ть, предстоя́ть; *алда зур эшләр ~а* пе́ред на́ми стоя́т больши́е дела́ (зада́чи) **2.** отстоя́ть; *биш километр(да) ~у* отстоя́ть в пяти́ киломе́трах **3.** находи́ться || нахожде́ние (*где-л.*); *авыл су буенда ~а* дере́вня наха́дится во́зле воды́; *куйган җирендә ~ыр* бу́дет находи́ться там, куда́ ты поста́вил (положи́л) **4.** встава́ть/вста́ть, поднима́ться/подня́ться || встава́ние (*с сидения, со сна и т. п.*); *урынныннан ~у* подня́ться с ме́ста; *йокыдан ~у* встать со сна (*с постели*) **5.** заде́рживаться/задержа́ться *где-л.*; *бер минут ~ма* ни на мину́ту не заде́рживайся **6.** храни́ться; пролежа́ть (*в запасе*); *озак ~ган бал* до́лго храни́вшийся мед; *юмартта мая ~мас* (*посл.*) у ще́дрого запа́сы не сохраня́тся (не залежа́тся) **7.** *разг.* 1) жить, обита́ть, проживáть, жи́тельствовать || прожива́ние; *авылда ~у* жить в дере́вне; *~ырга килү* прие́хать, что́бы проживáть; *берәү дә туа белми, ~а белә* (*посл.*) никто́ не зна́ет от рожде́ния, а познаёт, живя́ (про́живши); *гомер буе ярлы ~дылар* всю жизнь они́ жи́ли бе́дно 2) жить семьёй, семе́йной жи́знью; *улым белән киленем әйбәт ~алар* мой сын и сноха́ живу́т хорошо́ **8.** быть, пребывáть, находи́ться || пребыва́ние *в каком-л.* состоя́нии; *сак астында ~у* находи́ться под надзо́ром; *тынычлыкта ~у* пребывáть в поко́е; *моңсулыкта ~у* быть, пребывáть в тоскли́вости **9.** стоя́ть, обстоя́ть, быть в определённом состоя́нии; *мәсьәлә болай ~а* вопро́с обстои́т (вот) так; *эшнең шулай ~уы* тако́е состоя́ние дел **10.** быть, приде́рживаться, иметь, облада́ть || облада́ние (*определённым взглядом, качеством, достоинством и т. п.*); *(фәлән) карашта ~у* приде́рживаться тако́го-то мне́ния; *тиешле югарылыкта ~а* находи́ться на до́лжной высоте́ **11.** выка́зывать/вы́казать || выка́зывание *определённого отношения*; *йомшак ~у* быть мя́гким, выка́зывать мя́гкое отноше́ние; *нык (каты) ~у* выка́зывать твёрдое отноше́ние (*в соблюдении принципов*); твёрдо стоя́ть (*на своём*) **12.** 1) состоя́ть из; *отряд 30 кешедән ~ган* отря́д состоя́л из тридцати́ челове́к; *әсәрнең биш бүлектән ~уы мәгълум* изве́стно то, что произведе́ние состоя́ло из пяти́ разде́лов 2) состоя́ть в ...; *дуслык ярдәмләшүдән ~а* дру́жба состои́т во взаимопо́мощи **13.** *диал.* **(өчен ~у)** стоя́ть, быть за ... ; отста́ивать *что*; *дуслар өчен ~ам* стою́ за друзе́й; *бармы бездә милләт өчен ~ган кеше?* есть ли у нас челове́к, кото́рый бо́рется за на́цию?; *тынычлык өчен ~абыз* отста́иваем мир **14.** *в разн. знач.* сто́ить (*о цене, достоинстве*); *кырык сум ~уы мәгълум* изве́стно то, что сто́ит со́рок рубле́й; *бер галим мең наданга ~а* оди́н учёный сто́ит ты́сяч неве́жд; *бер соратуга килми, ике соратуга ~мый* (*погов.*) по пе́рвое сватовство́ не выхо́дит (за́муж), а второ́го сватовства́ не сто́ит **15. (-дан ~у)** зави́сеть *от чего*; упира́ться *во что*; *акчасыннан эш ~мый* де́ло не зави́сит от (*пресловутых*) де́нег (*от платы*); *бөтенесе үзеңнән ~а* всё зави́сит от тебя́ самого́; *мәсьәлә Әхмәтнең килүеннән ~а* вопро́с упира́ется в прие́зд Ахме́та **16. (-да ~у)** сде́рживать/сдержа́ть || сде́рживание (*слова и т. п.*), выполня́ть/вы́полнить || выполне́ние (*обещания*); *әйткәнендә ~ды* сдержа́л своё сло́во (*букв.* — своё ска́занное); *вәгъдәдә ~у* вы́полнить обеща́ние **17.** *в знач. вспом. гл. в сочет. с деепричастиями на* **-а/ә, -ый/и** *(в постпозиции)* **1)** *выраж. оттенок длительности или постоянства:* всё вре́мя, постоя́нно; беспрерывно; *хатлар килә ~ды* пи́сьма всё вре́мя приходи́ли (*не прерывались*); *дусларым арта ~а* мои́ друзья́ всё прибыва́ют, мои́ друзья́ умножа́ются 2) *придаёт оттенок прерывистой длительности:* пока́; не́которое вре́мя; *син уйлый тор, мин җыена ~ам* ты пока́ поду́май, а я тем вре́менем пособеру́сь 3) *усложнённой частицей* **да/дә, та/тә (да ~у, дә ~у, та ~у, тә ~у)** *выражает досаду или удивление говорящего по поводу длительности, повторения чего-л.*; всё вре́мя, без конца́; бесконе́чное; *ишектән салкын керә дә ~а* из двере́й (вот доса́да) всё вре́мя ду́ет ветеро́к; *сөйлисең дә ~асың бер сүз* без конца́ говори́шь одно́ и то же **18.** *в знач. вспом. гл. в ф.* **торып** 1) *выражает значения суффикса* -учи/-ючи; *күрә ~ып һәлакәткә бару* (гля́дючи) идти́ на ве́рную ги́бель; *белә ~ып әйтмәү* зна́я (зна́ючи), не сказа́ть; *хатын була ~ып* бу́дучи (*даже*) же́нщиной; *коралы була ~ып* име́ючи (име́я) да́же ору́жие 2) *в сочет. с отриц. ф. гл.*: **-мый (-мыйча) торып** пре́жде чем не...; *тирең кипми ~ып, су эчмә* пре́жде чем не пообсо́хнешь от по́та, не пей холо́дной воды́; *белми ~ып, сүз әйтмә* не зна́я (в чём де́ло), не говори́ **19.** *вспом. гл. в ф.* **торган** *в сочет. с деепричастием на* **-а/ә, -ый/и** 1) *выражает постоянство свойства, обозначенное основным гл.*; *күп белә ~ган* мно́го зна́ющий; *туры әйтә ~ган кеше* челове́к, говоря́щий напрями́к (пра́вду); *эшли ~ган ат* рабо́тающая (рабо́чая) ло́шадь 2) *тж. осложнённый частицей* **-дыр** *оформляет грамматическую категорию неочевидности, неясности, предположительности*: наве́рно(е), вероя́тно, на́до ду́мать; *ул колхозда эшли ~гандыр* он, наве́рно, рабо́тает в колхо́зе; *үзе белә ~гандыр* сам, наве́рное, зна́ет; *ни уйлый ~гандыр инде* не́ясно, что он ду́мает 3) *дополненный служебной гл. ф.* **иде** *оформляет грамматическую категорию давнопрошедшего очевидного времени:* быва́ло; *өй турендәге талларны тибрәтә ~ган идем; моңлы бала нинди була дип әйтә ~ган идем* (*песня*) я, быва́ло, кача́ла ве́рбы во дворе́; я, быва́ло, спра́шивала, каки́м быва́ет дитя́ печа́ли 4) *дополненный служебной гл. ф.* **булган** *оформляет грамматическую категорию давнопрошедшего неочевидного прерывистого времени; ул бездә эшли ~ган булган* говоря́т, он часте́нько рабо́тал у нас; *әби сөйли ~ган булган* ещё ба́бушка (говоря́т) расска́зывала 5) *дополненный служебной гл. ф.* **булды** *выражает приобретённое постоянное свойство, проявившееся в действии, обозначенном основным глаголом* стал; *ул бездә озак-озак утыра ~ган булды* он стал подо́лгу заси́живаться у нас **20.** *вспом. гл. в сочетании с деепричастиями на* **-ып/еп, -п** *выражает* 1) *сохранение определённого действия или состояния некоторое (нужное, достаточное) время*; *көлеп ~а* (*всё время*) смеётся; *кул кушырып ~у* стоя́ть сложа́ ру́ки (*как выражение приветствия и покорности*); *яшеренеп ~у* притайться и ждать; *бөтенесен белеп ~ды* всё (допо́длинно) знал (*был осведомлён обо всём*) 2) регуля́рное повторе́ние де́йствия и́ли состоя́ния; *хәбәрләшеп ~у* регуля́рно осведомля́ться

друг о дру́ге; всё вре́мя сообща́ться, извести́ться; *яңгырлар явып ~а* дожди́ иду́т всё вре́мя (с переры́вами) 3) *продолжение определённого действия или сохранение состояния ограниченного времени:* немно́жко, пока́; не́сколько, чу́точку; *авырып ~ам* немно́жко боле́ю; *эшкә ярап ~а* пока́ годи́тся для рабо́ты; *яңгыр бөркеп ~а* чу́точку моросѝт дождь 4) *появление чего-л. точно в данный момент; кайтырга ниятләп ~ам* (*вот сейчас*) намерева́юсь верну́ться 5) *в отриц. ф. с частицей* **да/дә, та/тә**; *решительное отрицание возможного, ожидаемого состояния или действия, выраженного основным гл.* не́чего и раздýмывать; *карап та ~мады* не стал да́же смотре́ть; *авырып та ~мыйча* ни чу́точки **не** боле́я **21.** *только в 1 л.* **дип ~у** поду́мать, что; полага́ть, что; прийти́ к мне́нию, что; склоня́ться/склони́ться к мы́сли, бу́дто; *безнеңчә аңламый дип ~ам* я-то ду́мал, что он не понима́ет по-на́шему; *мин сине шәһәрдә дип ~ам* я-то полага́л, что ты в го́роде **22.** *в отриц. ф.* **дип ~мау** не взира́ть ни на что; не заде́рживаться (не задержа́ться) из-за; *караңгы дип ~мадылар* не ста́ли заде́рживаться из-за темноты́; *авыр дип ~мыйча* невзира́я на тру́дности **23.** *вспом. гл. в сочет. с ф. на* **-ырга/ергә, -рга/ргә** *выражает действие, которое вот-вот совершится* вот-вот; то́лько; *чыгып китәргә ~ганда* то́лько собира́лся бы́ло вы́йти; *кузгалыш башланырга ~а* вот-вот начнётся восста́ние; *ул инде кайтырга ~а* он уже́ пригото́вился е́хать домо́й □ **~ган саен 1.** всё вре́мя, то и де́ло **2.** всё бо́льше и бо́льше; **~ып калу** остава́ться/оста́ться *где* (*о вещи, которую носил с собой*); **~ып ~** ожида́ть, ждать, подожда́ть (*своей очереди*) ◊ **~а салып** с хо́ду, вдруг; ни с того́ ни с сего́; *~а салып кычкырма* не кричи́ ни с того́ ни с сего́; **~а тор** погоди́, подожди́

торф *сущ.* торф || торфяно́й, то́рфо-; *~ кистерү* ре́зка то́рфа; *~ насосы* торфяно́й насо́с; *~ чыгару* то́рфодобы́ча; *~ массасы* торфома́сса || *прил.* торфяно́й; сде́ланный из то́рфа; *~ чүлмәк* торфяно́й горшо́к (*для рассады*); *~ брикет* торфяно́й брике́т □ **~ кискеч (кистергеч)** торфоре́зка; **~ муге** сфа́гнум, торфяно́й мох; **~ суктыру** добы́ча то́рфа ручны́м спо́собом

то́рфлан|у 1. *страд. от* **торфлау**; торфова́ться, удобря́ться то́рфом; *~ган җир* удо́бренная то́рфом земля́ **2.** заполня́ться то́рфом (*о болотистых озёрах*)

то́рфлау *перех.* торфова́ть || торфова́ние; удобря́ть || удобре́ние то́рфом; переме́шивать || переме́шивание с то́рфом

то́рфлы *прил.* **1.** торфяно́й; *~ сазлык* торфяно́е боло́то **2.** торфяни́стый; *~ туфрак* торфяни́стая по́чва

то́рфлык *сущ.* торфя́ник; торфяно́е боло́то; за́лежи то́рфа

то́рфлылык *сущ.* торфяни́стость (*почвы*)

то́рфлы-черемәле *прил. с.-х.* торфя́но-перегно́йный, то́рфоперегóнный; *~ чүлмәкләр* то́рфоперегóнные горшки́

то́рфчы *сущ.* то́рфоразрабо́тчик; челове́к, рабо́тающий на то́рфоразрабо́тках

то́рфчылык *сущ.* торфоразрабо́тка (*как отрасль хозяйственной деятельности*); торфяно́е де́ло; *~та эшли* рабо́тает в торфяно́м де́ле

торшер *сущ.* торше́р (*для лампы*)

торы|гу *неперех. диал.* заста́иваться/застоя́ться || заста́ивание; *аранда ~ккан ат* застоя́вшаяся в коню́шне ло́шадь; *~ккан шәраб* застоя́вшееся вино́

торыйк *подр. одиночному крику журавля:* курлы́йк

торыйк-торыйк *подр. курлыканию журавлей* курлы́к-курлы́к; *торыйк-торыйк итү* курлы́кать; *торыйк-торыйк торналар торкылдашып торалар* (*песня*) курлы́к-курлы́к жура́вли курлы́кают вме́сте

торы|к I *сущ.* **1.** звено́, прого́н (*часть загородки или бревенчатой стены от столба до столба*); *бер ~к киртә* (одно́) звено́ загоро́дки **2.** пролёт (моста́), ба́лка **3.** ко́рпус, ту́ловище, экстерье́р; торс; *~гы озын хайван* живо́тное с дли́нным ко́рпусом (ту́ловищем)

торык II *сущ. диал.* нога́; опо́ра; упо́р; *дурт ~, ике борыт* четы́ре опо́ры, два жгута́ (*загадка о винторогой козе*); *пулемёт көпшәсе ~лары* упо́ры ствола́ пулемёта

торыклы I *прил.* **1.** со столькѝми-то зве́ньями; име́ющий определённое коли́чество зве́ньев, пролётов; *өч ~ купер* мост с тремя́ пролётами **2.** с (*определённого качества*) ту́ловищем, экстерье́ром; *озын ~ ат чапкын була* ло́шадь с дли́нным ту́ловищем быва́ет ре́звой

торыклы II *прил.* с упо́ром, с опо́рой, име́ющий (*определённого количества и качества*) упо́р; *нык ~* с кре́пкой опо́рой; с кре́пким упо́ром; *ике ~* с двумя́ упо́рами

торым I *сущ. диал.* **1.** *см.* **торымбаш 2.** *уст.* су́хости, сушня́к, употребля́емый на дрова́

торым II *сущ. разг.* жизнь, отре́зок жи́зни; срок жи́зни; *~ы озак булмас* до́лго не протя́нет; срок его́ жи́зни не бу́дет (уже́) до́лгим; *яхшыга ~ юк, яманга үлем юк* (*погов.*) хоро́шему (челове́ку) нет жи́зни, дурно́му нет сме́рти

торымбаш *сущ.* **1.** головёшка, головня́; *ялгыз ~ ялынсаң да янмас* (*посл.*) одна́ головёшка, хоть проси́, не бу́дет горе́ть **2.** *диал.* колосо́к, поражённый грибко́м, спорыньёй; *см. тж.* **арыш анасы**

торымнан-торымга *нареч.* **1.** вре́мя от вре́мени; поро́й; ры́вками; *торымнан-торымга гына* то́лько вре́мя от вре́мени; *торымнан-торымга вәнәге кузгала* вре́мя от вре́мени страда́ет припа́дками боле́зни; *торымнан-торымга гына чаба* бежи́т ры́вками (*о лошади*) **2.** оди́н за други́м, (с) промежу́тками, с переры́вами; не сплошь; *юлда торымнан-торымга былчырак* на доро́ге места́ми (с промежу́тками) сля́коть; *торымнан-торымга куаклыклар бар* с промежу́тками есть куста́рники

торымсыз *прил. диал.* нежизнеспосо́бный; недолгове́чный; *балалары ~ булды* их де́ти оказа́лись недолгове́чными (нежизнеспосо́бными)

торымтай *сущ. зоол.* пустельга́; *~дан җитез кош булмас, ул да, тургай ташлап, каз тотмас* (*посл.*) нет пти́цы прово́рнее пустельги́, но (тем не ме́нее) и она́ не упу́стит по́йманного жа́воронка ра́ди непо́йманного гу́ся́ (не погóнится за гусём, упусти́в жа́воронка)

торын *сущ. уст.* внук, вну́чка; *тугыз батыр анасы, туксан ~ нәнәсе бул* (*пожелания новобрачной*) будь ма́терью девяти́ богатыре́й, ба́бушкой девяно́ста вну́ков и вну́чек

торып (тырып, тереп) *частица усил. в сочет. с гл. на* **-ып/еп, -п** *означает решительное или молодецкое выполнение действия, выраженного гл.*; *кутәреп ~ бәрде* как заки́нет (*т.е. молодецки закинул*) че́рез го́лову; *салып ~ җибәрер* как даст! (*т. е. как с размаху ударит*)

торып-торып *нареч.* **1.** с переры́вами, (ра́вными) промежу́тками; *торып-торып чаң суктылар* с переры́вами звони́ли колоко́ла **2.** сно́ва и сно́ва; *торып-торып хәйран калам* сно́ва и сно́ва удивля́юсь ◊ **торып-торып торҗәгун** ска́зка про бе́лого бычка́ (*о повторении, понимании того, что уже решено, пройдено, о чём уже говорилось и т. п.*)

торыпша *сущ.* 1. то́рпище, по́лог; *~ ябу* накры́ть по́логом (*кучу зерна*) 2. *см.* **торба** II; *~га солы тутыру* напо́лнить овсо́м то́рбу

торырлык *прил. разг.* 1. жило́й, в жило́м состоя́нии; тако́й, что (там) мо́жно жить (*о доме*) 2. жизнеспосо́бный (*о детёныше*) 3. досто́йный, сто́ящий *кого, чего*; *шуңа ~* досто́йный того́

торыш *сущ.* 1. *с определительными сл.* стоя́ние; вид сто́я; *карап ~лары* то, как он (она́) стои́т и смо́трит 2. сто́йка; по́за сто́я; *~ы ныкего́* (её) сто́йка крепка́; *гимнастлар ~ы* сто́йка гимна́стов; *тиешле ~ ясау* де́лать ну́жную сто́йку 3. положе́ние, состоя́ние; *эш ~ы* положе́ние (состоя́ние) дел; *һава ~ы* пого́да, состоя́ние пого́ды

торыш-йөреш *сущ. собир.* телодвиже́ние; оса́нка, похо́дка; *торыш-йөрешләре ыспай* его́ похо́дка эле́гантна

торыш-килбәт *сущ. собир.* вне́шний вид, оса́нка

торышлый *нареч.* встава́я (*с постели*)

торыштан: бер торыштан *разг.* заодно́, по хо́ду; **шул ~** не изменя́я положе́ния; **килә ~** с хо́ду, по хо́ду

торыш|у 1. *совм. от* **тору**; *бер-берсенә ~у* быть досто́йным друг дру́га; *шаккатып ~у* (все ра́зом) стоя́ть в изумле́нии 2. *разг.* противостоя́ть, успе́шно сопротивля́ться || противостоя́ние, успе́шное сопротивле́ние; *дошманга ~у* успе́шно сопротивля́ться врагу́; *бу эт бүрегә ~а алмас* э́та соба́ка не смо́жет противостоя́ть во́лку

тоска́|у *перех. диал.* 1. поджида́ть || поджида́ние ну́жного моме́нта; *см.тж.* **анду** 2. нацели́ваться/нацели́ться || нацели́вание; *чыбыркы сабын ~п курсәтте* указа́л (нацели́ваясь) кнутови́щем *куда-л.*

тост *сущ. в разн. знач.* тост; *~ күтәрү* подня́ть тост; *~ әйтү* произнести́ тост

тота|к *сущ.* 1. *см.* **тотык** 2. *диал.* захва́т (*руками*); *~гы ныкзахва́т его́ кре́пок

тота-каба *нареч. диал.* необду́манно, на́спех, в пожа́рном поря́дке; *тота-каба эшләнгән эш* необду́манно вы́полненная рабо́та

тотаклату *диал. понуд. от* **тотаклау**

тотакл|ау *перех. диал.* взять, хвата́ть || взя́тие (*руками*), хвата́ние; *~ый башлады* стал хвата́ть (*человека*)

тотаклашу *неперех. разг. см.* **тотынышу**

тотализа́тор *сущ.* тотализа́тор

тоталитар *прил.* тоталита́рный, единовла́стный; *~ режим* тоталита́рный режи́м

тоталитарлык *сущ.* 1. тоталитари́зм 2. тоталита́рный режи́м; *~ астында* под тоталита́рным режи́мом

тоталы: тоталы хәстә *разг. см.* **бума**

тоталь *прил.* тота́льный, всеобщий; *~ мобилизация* тота́льная мобилиза́ция; *~ фонетик күчешләр* тота́льные фонети́ческие перехо́ды

тотам *сущ.* 1. горсть; пучо́к; *бер ~ үлән* (оди́н) пучо́к травы́ 2. *мера длины, расстояния, равная ширине четырёх пальцев — 75 мм* 3. *разг.* кона́нье, жре́бий, жеребьёвка (*производится путём попеременного перехватывания палки или верёвки от начала до конца*) □ **~ бавы** пу́тлица у со́кола (*на языке сокольничих*); **(бер) ~ да калышмау** не отставать ни на шаг; **~ тоту (тотышу)** 1. держа́ть жре́бий; кона́ться на па́лке и т. п. 2. име́ть до́лю *в чём-л.*

тотамлап *нареч.* 1. горстя́ми, пучка́ми, захва́тами (*руки*) 2. ме́ра длины́, ра́вная ширине́ ладо́ни и́ли четырёх па́льцев; *~ үлчәү* измеря́ть (длину́) с по́мощью руки́ (*ширины ладони*) 3. *с определительными числ. биш ~* приблизи́тельно в пять ладо́ней

тотам-тотам *нареч.* 1. в ви́де со́бранных горсте́й, пучко́в; *тотам-тотам салам* соло́ма, со́бранная пучка́ми 2. в ви́де пучко́в разме́ром в оди́н обхва́т

тотанак I *сущ.* эпиле́псия

тотана|к II *сущ. разг.* 1. *см.* **тотнак** 2. вы́держка, вы́держанность, сде́ржанность; *~гы юк* невы́держанный, несде́ржанный 3. воспи́танность, приме́рное поведе́ние

тотанаклы *прил.* 1. *см.* **тотнаклы** 1, 3 2. вы́держанный, сде́ржанный; *~ булу* быть вы́держанным, сде́ржанным; *см. тж.* **тотнаклы** 2

тотанаксыз *прил.* 1. *см.* **тотнаксыз** 1 2. невы́держанный, несде́ржанный, несерьёзный, легкомы́сленный; изме́нчивый, ненадёжный; непосле́довательный; *см.* **тотнаксыз** 2

тотанаксызлан|у *неперех.* 1. станови́ться/стать невы́держанным, несде́ржанным, легкомы́сленным, ненадёжным; *тора-бара ~ды* постепе́нно он стал невы́держанным 2. проявля́ть/прояви́ть невы́держанность, несде́ржанность, легкомы́слие; *~ып йөрмә* не проявля́й легкомы́слия (*всё время*)

тотанаксызлык *сущ. диал.* 1. *см.* **тотнаксызлык** 2. невы́держанность, несде́ржанность; *~ күрсәтү* прояви́ть (вы́казать) несде́ржанность

тоташ *прил.* 1. 1) сплошно́й; сплошь, без просве́тов; *~ сазлык* сплошно́е боло́то; *~ урман* сплошно́й лес 2) сплошно́й, состоя́щий почти́ то́лько из (*о нежелательных примесях*); *~ балчык* сплошна́я гли́на (*о почве*); *~ күрән* сплошна́я осо́ка (*о сене, покосе*); *~ мәшәкатьләр* сплошны́е забо́ты (*и нет радости*) 2. неразры́вный, без разры́вов, сплошно́й; *~ сызык* неразры́вная ли́ния 3. беспреры́вный, беспреста́нный (*дождь*) 4. 1) соединённые ме́жду собо́й, сме́жные (*сосуды*) 2) сро́сшиеся; *~ ботаклар* сро́сшиеся ве́тки 5. це́льный, сли́тный; *~ кисәк* сли́тный комо́к 6. 1) це́льный, сплошно́й, беспреры́вный; *~ өч көн* це́лых три дня 2) сплошно́й, всеохва́тывающий, *~ коллективлаштыру* сплошна́я коллективиза́ция 7. **(-га ~)** примыка́ющий; *шәһәргә ~ авыл* примыка́ющая к го́роду дере́вня || *нареч.* 1. сплошь, неразры́вно, беспреры́вно (*о предметах, имеющих пространственные размеры*); *~ сузылу* тяну́ться сплошь 2. 1) постоя́нно, беспреры́вно, беспреста́нно, всё вре́мя; *өч көн ~ яңгыр ява* три дня беспреры́вно льёт дождь 2) *разг.* ча́сто, системати́чески; *~ дәрес калдыру* системати́чески пропуска́ть уро́ки □ **~ агым** сплошно́й пото́к; *~ спектр* сплошно́й спектр; *~ы белән* по́лностью; целико́м и по́лностью

тоташка *нареч. разг. см.* **тоташтан**

тоташлап *нареч.* сплошь; *~ тикшерү* сплошно́й контро́ль; сплошна́я прове́рка

тоташлый *нареч. разг.* 1. о́птом; *~ сату* прода́ть || прода́жа о́птом; опто́вая прода́жа 2. беспреры́вно, не прерыва́ясь; *~ яву* беспреры́вно идти́ (*о дожде, снеге и т. п.*)

тоташлы|к *сущ.* 1. непреры́вность; *сызыкның ~гы* непреры́вность ли́нии 2. це́лостность, це́льность (*залежей, площади леса*)

тоташма *сущ. физ.* соедине́ние дета́лей, узло́в

тоташтан *нареч.* непреры́вно, беспреры́вно; *см.тж.* **бертоташтан**

тоташтыргыч *сущ. тех.* 1. *сущ.* включа́тель; *~ка басу* нажа́ть на включа́тель 2. сцепле́ние; *машинаның ~ы* сцепле́ние маши́ны || *прил.* 1. включа́ющий; *~ механизм*

включа́ющий механи́зм **2.** сцепля́ющий **3.** соедини́тельный; *~ планка* соедини́тельная пла́нка

тоташтырма *сущ.* **1.** *тех.* перемы́чка; шип; сгон; *торба ~сы* сгон для труб **2.** *мат.* соедине́ние (*цифр*)

тоташтырмалы *прил. тех.* **1.** соедини́тельный; *~ клапан* соедини́тельный кла́пан **2.** *предик.* соединя́ется с ..., присоединя́ется, подсоединя́ется к ... ; *~ түгел* невозмо́жно соединя́ть (подсоединя́ть), соедини́ть (подсоедини́ть)

тоташтыр|у *перех.* **1.** *в разн. знач.* соединя́ть/соедини́ть || соедине́ние; *ике ярны ~ган күпер* мост, соединя́вший два бе́рега; *кулны кулга ~ып* соедини́в ру́ки **2.** подсоединя́ть/подсоедини́ть, подключа́ть/подключи́ть || подсоедине́ние, подключе́ние (*телефона к сети*) **3.** *тех.* включа́ть/включи́ть || включе́ние

тоташтырылган *прил.* подсоединённый, включённый, подключённый; в подсоединённом, включённом, подклю́ченном состоя́нии (*о линиях связи, тока и т. п.*); *токка ~* подключён к (*электрическому*) то́ку

тоташтырыл|у *страд. от* **тоташтыру**; соединя́ться/соедини́ться || соедине́ние *кем между собой, к чему*; подсоединя́ться/подсоедини́ться || подсоедине́ние *кем, к чему* быть соединённым, подсоединённым (*к сети электрического тока*); *~ган савытлар* соединённые (сообща́ющиеся) сосу́ды

тоташ|у *неперех.* **1.** соединя́ться/соедини́ться || соедине́ние (*концами*) **2.** слива́ться/сли́ться || слия́ние; *ике агым бергә ~ты* два пото́ка сли́лись вме́сте **3.** смыка́ться, соприкаса́ться || соприкоснове́ние; *җир белән күк ~кан урын* ме́сто, где соприкаса́ются не́бо и земля́ **4.** впада́ть, влива́ться/вли́ться; *Чулман Иделгә ~а* Кама влива́ется в Во́лгу **5.** прираста́ть/прирасти́, раста́ться/расти́сь/сраще́ние; *җиргә ныык ~кан таш* ка́мень, кре́пко вро́сший в зе́млю; *~кан кисәкләр* сро́сшиеся куски́; *~ып үскән агачлар* сро́сшиеся дере́вья **6.** примыка́ть/примкну́ть, прилега́ть, приткну́ться, грани́чить || примыка́ние, прилега́ние *к чему*; *өйгә ~кан амбар* склад, примыка́ющий к до́му; *басуга ~кан болын* луг, прилега́ющий к по́лю; *урман белән ~у* грани́чить с ле́сом **7.** *перен.* составля́ть/соста́вить || составле́ние еди́нства; *күңелләр күңелгә ~а* ду́ши соединя́ются с ду́шами; ду́ши составля́ют еди́нство **8.** охва́тывать (*об огне, пламени*); *күрше йортка ут ~ты* пла́мя охвати́ло сосе́дний двор □ **~кан савытлар** *физ.* сообща́ющиеся (соединённые) сосу́ды

тотем *сущ.* тоте́м; *~га ышану* ве́ра в тоте́м; *ыру ~ы* тоте́м ро́да

тотемизм *сущ.* тотеми́зм; *~ чоры* эпо́ха тотеми́зма

тоте́мик *прил.* тотеми́ческий; тоте́мный; *~ образ* тотеми́ческий (тоте́мный) о́браз

тотеми́стик *прил.* тотемисти́ческий; *~ карашлар* тотемисти́ческие взгля́ды

тотка *сущ.* **1.** ру́чка (*в виде скобы*), держа́тель, держа́лка; *чәйнек ~сы* ру́чка ча́йника; *ишек ~сы* ру́чка две́ри; *чемодан ~сы* ру́чка чемода́на **2.** рукоя́ть, рукоя́тка; *револьвер ~сы* рукоя́тка револьве́ра; *табагач ~сы* рукоя́тка сковоро́дника **3.** *разг. см.* **тотынгыч**; *басма ~сы* пери́ла мо́стика, ле́стницы **4.** *перен.* опо́ра, усто́и; *эшче-крестьян властеның ~лары* усто́и рабо́че-крестья́нской вла́сти; *эш ~сы ул безнең* он — опо́ра в на́шей рабо́те **5.** *разг.* ду́жка; *см.тж.* **кылдау**; *чиләк ~сы* ду́жка ведра́

тоткавыл *сущ. ист.* **1.** загради́тельный отря́д; *~ чыгару* посла́ть загради́тельный отря́д; *~га тап булу* встре́тить загради́тельный отря́д **2.** заста́ва (*на дороге и т. п.*); *~ кую* ста́вить заста́ву **3.** служи́тель заста́вы; часово́й, во́ин при заста́ве; *~лар тотты* во́ины при заста́ве задержа́ли

тотказ|у *разг.* **1.** *понуд. от* **тоту** 3, 24; позволя́ть и́ли веле́ть держа́ться (держа́ть, храни́ть) *где*; *озак ~ма* до́лго не заде́рживай у себя́ **2.** *см.* **төткәзү**

тотка|к *сущ. разг.* припа́док; схва́тка (*при болезни, а также при родах*); *~кка дучар булу* подве́ргнуться припа́дку □ **~к тоту** пережива́ть припа́док, быть в припа́дке; *~гың тота мәллә?* в припа́дке ты, что ли? (*говорится сердитому, ругающемуся человеку*)

тоткал|ау *многокр. от* **тоту**; *~ап карау* подержа́ть в рука́х, пощу́пать, ощу́пывать

тоткалы *прил.* с ру́чкой (рукоя́ткой); име́ющий ру́чку, рукоя́тку; *~ сандык* сунду́к с ру́чками

тоткалык *прил.* ско́бочный; го́дный и́ли предназна́ченный для изготовле́ния ско́бок, ру́чек и т. п.

тоткар *сущ.* поме́ха, препя́тствие, прегра́да; *җыр дигән толпар, юктыр аңа ~* (*посл.*) есть Пега́с по и́мени пе́сня, и нет ему́ никаки́х прегра́д; *бу безнең өчен ~ түгел* э́то для нас не препя́тствие □ **~ итү (~ ясау)** де́лать поме́хи, устра́ивать/устро́ить прегра́ды; помеша́ть

тоткарлагыч *сущ.* **1.** иску́сственная прегра́да, барье́р; *~ кору (ясау)* ста́вить барье́р, прегра́ду **2.** *воен. см.* **тоткарлама**; *миналы ~* ми́нное заграждде́ние || *прил.* **1.** преграждда́ющий; барье́рный **2.** *воен.* заградительный; *~ ату* заградительный огонь

тоткарлама *сущ. воен.* заграждде́ние; *диңгездәге ~лар* морски́е заграждде́ния; *~ кую* ста́вить заграждде́ния

тоткарландыру *понуд. от* **тоткарлану**; чини́ть препя́тствия; заставля́ть заде́рживаться; *сүз куертып ~* заде́рживать многосло́вием

тоткарлан|у *неперех.* **1.** 1) *в разн. знач.* заде́рживаться/задержа́ться; *озак ~магыз* до́лго не заде́рживайтесь; *эштә ~дым* я задержа́лся на рабо́те; *ничек кешедә ~мак кирәк?* ра́зве мо́жно заде́рживаться у люде́й?; *эш ~макчы* де́ло, похо́же, заде́рживается; *~мастан эшкә кереште* не заде́рживаясь (не ме́шкая), приступи́л к рабо́те; *~мастан килеп җитү* незамедли́тельно прие́хать; *~мыйча җавап бирде* отве́тил без запи́нки (без зами́нки) 2) опа́здывать/опозда́ть; *поездлар ~а* поезда́ опа́здывают **2.** *спец.* тормози́ться, затормáживаться/затормози́ться || торможе́ние, торможе́ние; *~у үзәкләре* це́нтры торможе́ния **3.** *в знач. нареч.* **тоткарланып**; с перебо́ями; с зами́нками, с заде́ржками; *товар ~ып килә башлады* това́р стал поступа́ть с перебо́ями

тоткарланусыз *прил. см.* **тоткарсыз**

тоткарланучан *прил.* скло́нный к заде́рживанию

тоткарланыл|у *безл.* приходи́ться/прийти́сь заде́рживаться; *бераз ~ды* пришло́сь немно́го задержа́ться

тоткарланыш *сущ.* **1.** заде́ржка; проволо́чки **2.** мешкотня́

тоткарланышлы *прил.* с препя́тствиями; с преодоле́нием препя́тствий; *~ юл* доро́га с препя́тствиями, с заде́ржками

тоткарланышсыз *взаимно-совм. от* **тоткарлану**; вме́сте и́ли одновреме́нно заде́рживаться (*в пути*)

тоткарла́|у *перех.* заде́рживать/задержа́ть; препя́тствовать/воспрепя́тствовать || задержа́ние; *эшне ~ма* не заде́рживай рабо́ту; *хәрәкәтне ~мастан (~мыйча)* не препя́тствуя (не воспрепя́тствуя) движе́нию; не заде́рживая движе́ние □ **~п тору** (*временно*) заде́рживать, позадержа́ть; помеша́ть

тоткарлаусыз *прил. см.* **тоткарлыксыз**

тоткарлаучанлык *сущ.* склóнность сдéрживать, задéрживать, препя́тствовать

тоткарлык *сущ.* **1.** задéржка, замúнка; препя́тствие; препóны; *~ килеп чыгу* появлéние замúнки; *төрле ~лар* рáзные задéржки; *~ булмаса* éсли нет препя́тствий; *бернинди дә ~лар юк* нет никаки́х препя́тствий **2.** *см.* **тоткарлама**; *дошман юлына ~лар кору* воздвига́ть/возводи́ть искýсственные препя́тствия на пути́ врага́ □ **~ итү (китерү, ясау)** задéрживать/задержа́ть; препя́тствовать, воспрепя́тствовать; мешáть/помешáть, возводи́ть препя́тствия; *миңа ~ итмә* ты мне не препя́тствуй

тоткарлыксыз *нареч.* без препя́тствий, беспрепя́тственно; бесперебóйно; *~ үткәрү (уздыру)* беспрепя́тственно пропускáть/пропусти́ть, беспрепя́тственно проводи́ть || *прил.* беспрепя́тственный; *~ хәрәкәт* беспрепя́тственное движéние

тоткарсыз I *нареч.* **1.** незамедли́тельно, без замúнки; *см. тж.* **тоткарлыксыз**; *~ килеп җитү* беспрепя́тственно приéхать; *~ эшкә тотын* незамедли́тельно принимáйся за рабóту **2.** бесперебóйно, без проволóчек; *~ алга уздыру* бесперебóйно пропускáть вперёд

тоткарсыз II *прил.* **1.** беспрепя́тственный; *~ алгарыш* беспрепя́тственный прогрéсс **2.** бесперебóйный; *~ тәэминат* бесперебóйное обеспечéние

тоткарсызлык *сущ.* **1.** беспрепя́тственность; *хәрәкәтнең ~гы* беспрепя́тственность движéния **2.** бесперебóйность, незамедли́тельность; *тәэминатта ~* бесперебойность в снабжéнии, в обеспечéнии

тоткасыз *прил.* **1.** без рýчки, без рукоя́ти **2.** *разг. перен.* ненадёжный, не достóйный довéрия (*о человеке*)

ткá(у) *перех. диал. см.* **тоткарлау**

тоткы *сущ. диал.* **1.** *см.* **тотка 2.** скобá для закреплéния брёвен в срýбе; *тимер ~лар* желéзные скóбы **3.** *см.* **тотрык**

тоткылыксыз *прил.* не сдéрживающий, не задéрживающий мочý, страдáющий недержáнием мочи́; *~ бала* ребёнок, страдáющий недержáнием мочи́

тоткын *сущ. ист.* **1.** плéнение; *~ белән шөгыльләнү* занимáться плéнением **2.** 1) плéнный, плéнник; *дошманга ~ булу* быть плéнником (*у врага*) 2) заключённый,ýзник, невóльник; *төрмәдәге ~нар* заключённые в тюрьмé, тюрéмныеýзники; *без барыбыз да язмыш ~нары* все мы невóльники судьбы́ **3.** невóля, плен, тюрьмá; *~да утырганнар* сидя́щие (находя́щиеся) в невóле || *прил.* заключённый, плéнный; *~ кеше* заключённый (аресто́ванный) □ **~ итү 1.** плени́ть, взять, брать в плен; сдéлать плéнным **2.** *перен.* плени́ть, влюбля́ть в себя́; *безне моңы белән ~ итә* пленя́ет нас свои́м пéнием; **~нар йорты** тюрьмá

тоткындагы *прил.* плéнный, заключённый, находя́щийся в плену́ и́ли в заключéнии (заточéнии); *~ кеше* человéк, находя́щийся в заточéнии

тоткынлык *сущ.* **1.** 1) невóля, заключéние, заточéние; *~ хәле* положéние невóли (в невóле); 2) плен, нахождéние в плену́; *~ка элгү* попáсть в плен **2.** *перен.* рáбство; *~та тук булганчы, иркенлектә ипиҫең был* (*посл.*) чем быть сы́тым в рáбстве, будь голóдным (*букв.* без хлéба) на свобóде

тоткыр I *сущ.* замúнка; *см.тж.* **тоткар**

тоткыр II *прил. диал.* спосóбный к охóте, лóвкий (*об охотнике*)

тоткыч *сущ.* **1.** *см.* **тотка**; *чемодан ~ы* рýчка чемодáна **2.** *в сост. терминологических словосочет.* 1) держáтель; *кәгазь ~* бумагодержáтель; *энә ~* иглодержáтель; *борау ~* сверлодержáтель (*в станке*) 2) уловúтель; *тавыш ~* звукоуловúтель; *төтен ~* дымоуловúтель

тоткычлы *прил. см.* **тоткалы**

тотлы|гу *неперех.* **1.** заикáться, запинáться || заикáние, запинáние; *~гып сөйләү* говорúть заикáясь; *~кмастан (~кмыйча)* не запинáясь (заикáясь); *~гып та тормыйча алдый* врёт и не заикáется **2.** *диал.* затмевáться/затмúться || затмéние (*Солнца, Луны*)

тотлыгучан *прил.* (*временами*) заикáющийся, запинáющийся, косноязы́чный

тотлыксыз *нареч.* беспрерывно, не запинáясь; без запúнки; *~ уку* читáть без запúнки

тотлыктыр|у 1. *понуд. от* **тотлыгу 2.** *безл.* приходúться/прийтúсь заикáться; *куркудан ~а* от стрáха прихóдится заикáться

тотма *сущ. диал.* **1.** *см.* **тоткы 2.** *см.* **тотак 3.** *см.* **бума**; *~сы тота* он в припáдке

тотна|к *сущ.* **1.** устóйчивость, крéпость (*устройства, сооружения*); *см.* **тотрык 2.** надёжность, основáтельность (*характера, натуры*); гарантúйность, твёрдость (*слова, обещания и т. п.*) *сүзенең ~гы юк* его́ слóву нельзя́ доверя́ть **3.** вы́держка, вы́держанность, сдéржанность; *см.* **тотнаклылык**

тотнаклы *прил.* **1.** надёжный, основáтельный (*о характере, натуре, личности и т. п.*); внушáющий довéрие, твёрдый (*о слове. обещаниях и т. п.*) *~ хезмәткәр* надёжный сотрýдник; *~ хезмәт* основáтельный труд **2.** вы́держанный, сдéржанный, тактúчный, твёрдый; *~ характер* вы́держанный характéр **3.** надёжный, основáтельный, достóйный довéрия; *аның сүзе ~* его́ слóво достóйно довéрия || *нареч.* вы́держанно, сдéржанно; *~ кылану* вести́ себя́ сдéржанно

тотнаклылык *сущ.* **1.** вы́держка, вы́держанность; сдéржанность, тактúчность; *сүздә ~* сдéржанность в словáх **2.** стóйкость, непреклóнность; *сайлаган юлыңда ~күрсәтү* проявúть стóйкость на úзбранном пути́

тотнаксыз *прил.* **1.** ненадёжный, несерьёзный; не внушáющий довéрия (*о человеке и его обещании*); нестóйкий (*о характере*); *~ элементлар* нестóйкие элемéнты **2.** 1) невы́держанный, несдéржанный; развя́зный 2) нетактúчный 3) *диал.* распýщенный, непристóйный || *нареч.* развя́зно, несдéржанно; *~ кылану* несдéржанно вести́ себя́ **3.** распýщенно, непристóйно; *~ сөйләү* распýщенно разговáривать □ **~ рәвештә** непристóйным óбразом

тотнаксызлан|у *неперех.* **1.** 1) становúться/стать ненадёжным 2) проявля́ть/проявúть нестóйкость, несерьёзность, легкомы́слие **2.** 1) становúться/стать несдéржанным, развя́зным; *ул ~ды* он стал развя́зным 2) проявля́ть/проявúть несдéржанность, развя́зность □ **~ып йөрү** вести́ себя́ развя́зно

тотнаксызлы|к *сущ.* **1.** ненадёжность, нестóйкость; *вәгъдәсенең ~гы* ненадёжность обещáния **2.** невы́держанность, несдéржанность, нетактúчность; *~ күрсәтү (эшләү)* проявúть невы́держанность; поступúть нетактúчно **3.** распýщенность; непристóйность; *хатын-кызга карата ~к* распýщенность в отношéнии жéнщин; *кыланыш ~гы* непристóйность поведéния

тотры|к *сущ.* **1.** устóйчивость, крéпость; спосóбность держáться; *~гы киткән* не спосóбен держáться (*на ногах*); *~гын югалту* теря́ть/потеря́ть устóйчивость; *~гы юк* нет дóлжной крéпости (*о мебели, лестнице*) **2.** *перен.* стóйкость, вы́держка; *см.* **тотнак 3.** постоя́нство;

көннәрнең ~гы юк пого́да (ны́нче) непостоя́нная □ **~к бирү** дать опо́ру, подде́рживать/поддержа́ть

тотрыклан|у *неперех.* устоя́ться; становйться/стать сто́йким, постоя́нным; *нава ~ды* пого́да устоя́лась; *бәяләр ~а* це́ны стано́вятся постоя́нными (стаби́льными)

тотрыклы *прил.* **1.** усто́йчивый, кре́пкий, про́чно стоя́щий (*на ногах, опорах*); *~ баскыч* усто́йчивая ле́стница **2.** хорошо́ держа́щийся (*о почве на краю ямы*); не ры́хлый, не рассыпа́ющийся; не разруша́ющийся **3.** *перен.* 1) сто́йкий, кре́пкий, вы́держанный; *~ кеше* вы́держанный челове́к; *~ иптәш* сто́йкий това́рищ 2) нерушймый; *~ сүз* нерушймое сло́во **4.** 1) усто́йчивый, стаби́льный, твёрдый; *~ бәяләр* усто́йчивые це́ны; *~ валюта* усто́йчивая валю́та; *~ уңыш* усто́йчивый урожа́й 2) неукло́нный, стаби́льный; *~ темплар* стаби́льные те́мпы **5.** неизме́нчивый; неизме́нный, после́довательный; *~ элементлар* неизме́нные элеме́нты; *~ караш* после́довательный взгляд **6.** *спец.* сто́йкий (*к воздействию среды*); *~ токымнар* сто́йкие поро́ды

тотрыклылану *неперех.* **1.** становйться/стать усто́йчивым (*стойким, постоянным, неизменчивым*) **2.** *см.* **тотрыклану**

тотрыклылы|к *сущ.* **1.** *см.* **тотрык 2.** постоя́нство; неизме́нчивость, неизме́нность, неукло́нность; *бәяләрнең ~гы* неизме́нчивость цен **3.** после́довательность; *карарларның ~гы* после́довательность реше́ний **4.** *перен.* вы́держанность; сто́йкость, сде́ржанность (*в поведении*) **5.** *спец.* усто́йчивость су́дна

тотрыксыз *прил.* **1.** неусто́йчивый, ша́ткий (*о мебели и сооружениях*); нетвёрдый (*о шагах больного, пьяного*) **2.** ры́хлый, рассыпа́ющийся (*при нагрузке*), разруша́ющийся (*о почве и т. п.*); *~ җиргә басу* наступйть на рассыпа́ющееся ме́сто **3.** *перен.* несто́йкий, невы́держанный, непосле́довательный, непостоя́нный, ненадёжный; *~ кеше* ненадёжный челове́к **4.** непостоя́нный, изме́нчивый; *~ нава* изме́нчивая пого́да; *~ бәяләр* непостоя́нные це́ны **5.** *хим., геол.* несто́йкий; *~ токымнар* несто́йкие поро́ды; *~ кушылма* несто́йкие соедине́ния || *нареч.* **1.** неусто́йчиво, нетвёрдо, ша́тко; *~ атлый* шага́ет нетвёрдо **2.** ненадёжно; непосле́довательно; *~ эш итү* непосле́довательно де́йствовать **3.** непостоя́нно, изме́нчиво, переме́нчиво □ **~ тигезләнеш** неусто́йчивое равнове́сие; *~ төшләр* нестаби́льные я́дра

тотрыксызлан|у *неперех.* **1.** становйться/стать || становле́ние ша́тким (неусто́йчивым, непостоя́нным, изме́нчивым, несто́йким) **2.** слабе́ть, осла́бнуть || ослабле́ние (*внезапное*); теря́ть/потеря́ть равнове́сие; *башы әйләнеп, ~ып китте* голова́ его́ закружи́лась, и он потеря́л равнове́сие

тотрыксызлы|к *сущ.* **1.** неусто́йчивость, ша́ткость, нетвёрдость; ры́хлость, рассы́пчатость **2.** *перен.* несто́йкость, невы́держанность; *~гы аркасында* из-за его́ невы́держанности **3.** непостоя́нство, изме́нчивость; *көннәрнең ~гы* непостоя́нство пого́ды **4.** *хим., геол.* несто́йкость; *бу матдәнең ~гы* несто́йкость э́того вещества́

тотсак, тотсык *сущ. ист. см.* **туснак**

тоттырма *сущ. диал. см.* **таккаравыл**

тоттыр|у **1.** *понуд. от* **тоту** 1—2, 5—6, 12—21, 28, 33—36; *бауның бер очын ~у* заста́вить держа́ть (дать подержа́ть) оди́н коне́ц верёвки; *балык ~у* веле́ть (и́ли разреши́ть) лови́ть ры́бу; *дин ~у* заста́вить блюсти́ рели́гию; *койма ~у* заста́вить (веле́ть) стро́ить огра́ду; огражда́ть, нанима́я на рабо́ту **2.** *обычно в негативной ф.* **тоттырмау** не дава́ть себя́ лови́ть (пойма́ть), не дава́ться в ру́ки, убежа́ть, убега́ть || убега́ние; *~мый торган ат* ло́шадь, кото́рая не даётся в ру́ки; *~мады, качты* убежа́л, исче́з (*из поля зрения*) **3.** 1) выдава́ть/вы́дать || вы́дача; спосо́бствовать || спосо́бствование поймке (*кого-л. преследуемого*); *дошманга ~у* вы́дача врагу́ 2) раскрыва́ть/раскры́ть, разоблача́ть/разоблачи́ть || раскры́тие, разоблаче́ние (*секретов и т. п.*); *ялганын ~у* раскры́ть, разоблачи́ть ложь (*свою или третьего лица*) **4.** *перен. разг.* вручи́ть; сова́ть, всо́вывать/всу́нуть || вруче́ние, всо́вывание; *кулына карар ~ып* вручи́в реше́ние в ру́ки; *күчтәнәч ~ды* су́нул гости́нец ◊ **~дылар, ди (сиңа)!** ни за что не дадут тебе́ (*т. е. не жди, не надейся*); так и да́ли (даду́т) тебе́!

тө́ньяк *сущ.* **1.** се́вер || се́верный; *~кка күрсәтү* показа́ть на се́вер; *Азиянең ~гы* се́вер А́зии **2.** Се́вер; *Төньяк флоты* Се́верный флот; *Төньякка күчеп килү* переселя́ться на Се́вер || *прил.* се́верный (*в геогр. названиях с прописной буквы*); *~ капка* се́верные воро́та; *Төньяк полюс* Се́верный по́люс; *Төньяк Америка* Се́верная Аме́рика; *Төньяк Каролина* Се́верная Каролина □ **~ балкышы** се́верное сия́ние; **~ боланы** се́верный оле́нь; **~ йомраны** пестру́шка

тө́ньяк-кө́нбатыш *сущ.* се́веро-за́пад; *~ка таба* на се́веро-за́пад, в направле́нии се́веро-за́пада; *илнең ~ы* се́веро-за́пад страны́ || *прил.* се́веро-за́падный; *~ район* се́веро-за́падный райо́н

тө́ньяк-кө́нчыгыш *сущ.* се́веро-восто́к; с се́веро-восто́ка || *прил.* се́веро-восто́чный; *~ өлкә* се́веро-восто́чная о́бласть

тө́ньяклап *нареч. прост.* с се́вера, с се́верной стороны́; *~ искән җил* ве́тер с се́вера

тө́ньяктагы *прил.* се́верный, находя́щийся на се́вере; *~ өлкәләр (районнар)* се́верные о́бласти (райо́ны)

төңгер *сущ. этногр.* (*шаманский*) бу́бен, бараба́н; *~ шалтырату* бить в бу́бен

төп *сущ.* **1.** 1) *в разн. знач.* дно; *күл төбе* дно о́зера; *чокыр төбендә* на дне я́мы 2) дно, до́нце, до́нышко (*сосудов, вместилищ*) 3) *перен.* оста́ток на дне сосу́да; *табак төбе* оста́тки на дне блю́да **2.** низ, подо́шва; *тау төбе* низ, подо́шва горы́ **3.** 1) основа́ние; осно́ва; *колонна төбе* основа́ние коло́нны 2) *о предметах, служащих основанием чего-л.; тәрәзә төбе* подокóнник, основа́ние окна́ 3) ме́сто у основа́ния; ме́сто вокру́г, о́коло чего́ 4) след основа́ния; оста́ток *чего-л.* на ме́сте хране́ния; *кибән төбе* то, что оста́лось от сто́га; одо́нье **4.** ко́мель (*дерева*); *төптән кисү* ре́зать (пили́ть, спили́ть) с ко́мля **5.** ко́рень, куст, ку́стик (*как счетное слово*); *бер төп карлыган* (один) куст смороди́ны **6.** *см.* **төпкә**; *урмандагы төпләр — тәндәге төкләр* (*погов.*) пни в лесу́ — что волоси́нки на те́ле **7.** ни́жняя часть *чего-л.*; *төбеннән күтәрү* поднима́ть, держа́ сни́зу **8.** *перен.* 1) результа́т (*процесса, состояния*); *сабыр төбе — сары алтын* (*посл.*) результа́т терпе́ния — чи́стое зо́лото 2) соль, смысл; *бу сүзеңнең төбе юк* э́ти слова́ твои́ бессмы́сленны **9.** *перен., прост.* исто́к, исто́ки, ко́рень (*рода, племени*); пре́дки; *безнең төп монда күптәннән яши* на́ши пре́дки в э́тих места́х живу́т и́здавна **10.** *перен.* 1) суть; осно́ва; *мәсьәләнең төбе* суть вопро́са 2) усто́и; *патшалыкның төбен җимерү* сокруша́ть усто́и ца́рства **11.** *перен.* причи́на; *ачлыкның төбе социаль факторларда* причи́на го́лода в социа́льных фа́кторах **12.** *перен.* глубина́, не́дра (*души, памяти*); *күңел төбендә* в глубине́ (в не́драх) души́ **13.** *в знач. нареч.* **төптә, төбендә** 1) в су́щности, по су́ти, в своей осно́ве 2) со́бственно говоря́; *төптә бу синең фикер* в су́щности э́то твоя́ мысль (принадлежи́т тебе́) **14.** *в знач. нареч.* **төптән, төбеннән** 1) коренны́м о́бразом, основа́тельно; *төбеннән җимерү* основа́тельно разруша́ть/разру́шить 2) соверше́нно; в осно́ве, в ко́рне; *төптән (төбеннән) ялгыш* соверше́нно (в ко́рне) неве́рно **15.** *в знач. послелога* **төбендә** 1) *под чем-л., у чего-л.; агач төбендә* под де́ревом; *ишек төбендә* у две́рей; *борын төбендә* под но́сом 2) о́коло, вблизи́, близ; *Мәскәү төбендә* под Москво́й || *прил.* **1.** ко́млевый; *бүрәнәнең төп ягы* ко́млевый коне́ц бревна́ **2.** *в разн. знач.* основно́й; *төп закон* основно́й зако́н; *төп бурыч* основна́я зада́ча; *төп өлеше* основна́я часть *чего* **3.** коренно́й, гла́вный; *төп интересләр* коренны́е интере́сы; *төп герой* гла́вный геро́й **4.** коренно́й, ме́стный; *төп милләт* коренна́я на́ция **5.** оригина́льный; пе́рвый; *төп нөсхә* пе́рвый экземпля́р **6.** *этногр.* родно́й, со́бственный (*о родне*); *төп кода* родно́й оте́ц неве́сты и́ли жениха́; *төп кодагый* родна́я мать неве́сты (*в устах родни жениха*) и́ли жениха́ (*в устах родни невесты*) **7.** *диал.* соверше́нный, то́чно как; *төп этисе* соверше́нный оте́ц, то́чно как оте́ц; весь в отца́ □ **төбенә кадәр (хәтле, чаклы)** *прям., перен.* до дна; **төп башы 1.** ко́мель (де́рева) **2.** пень, пенёк; **төп бикләү** закрепи́ться на по́чве (*о растениях*), укорени́ться; **төп көтү (өер, күч)** разводно́е (оставля́емое на разво́д) ста́до; разводна́я гру́ппа живо́тных (скота́); **төп кушу** отраста́ть (*от одного корня —о растениях*); **төп йорт (өй)** роди́тельский, родово́й дом; **төп өйгеч** оку́чник (*сельскохозяйственное орудие*); **төп өю** оку́чивать (расте́ния); **төп сан** *см.* **микъдар сан**; **төп умарта** борть, зада́нье (*вид переносного улья, сделанного из цельного ствола дерева*); **төп юнәлеш** *лингв.* действи́тельный зало́г; **төпкә җигү** запряга́ть в ко́рень, запряга́ть коренны́м; **төптән кисү** сруби́ть (спили́ть) под ко́рень ◊ **~ төбенә тоз (тәмәке) салу** усло́виться серьёзно; надёжно гаранти́ровать; *төбенә тоз салып сөйләшик* поговори́м основа́тельно (*с гарантией выполнения договорённости*); **төбенә төшү 1.** докопа́ться (*до сути, причины*) **2.** поня́ть (*суть, закономерность*); **төп асылда** в действи́тельности; в су́щности; **төп башына (төпкә) утырту** обману́ть, объего́рить; одура́чить; наду́ть; ввести́/вводи́ть в заблужде́ние; **төп башына (төпкә) утыру (утырып калу)**; обману́ться, дать себя́ обману́ть (одура́чить, наду́ть); **төп кебек** корена́стый и здоро́вый; мо́щный; **төп төбендә** в су́щности; по су́ти; *төп төбендә ул сиңа дус* по су́ти, он тебе́ друг; **төпкә җибәрү 1.** топи́ть, потопи́ть **2.** губи́ть/погуби́ть; **төпкә җигелү (җигелеп тарту) 1.** взять на себя́ основну́ю тя́жесть (*работы*) **2.** что́-нибудь де́лать основа́тельно **3.** основа́тельно реформи́ровать, де́лать за́ново; **төпкә төртелү** *см.* **комга төртелү**; **төптән куркып түмгәккә абыну** *см.* **энәдән куркып лом йоту**; **төптән юан (базык)** корена́стый

төпек *прил. диал.* то́лстенький, низкоро́слый и то́лстый; *~ малай* то́лстенький ма́льчик; *~ кенә* то́лстенький || *сущ.* карапу́з, толстячо́к

төпкә *сущ.* (*старый*) пень; гнило́й (*прогнивший*) пень

төпкәле *прил.* со ста́рыми пня́ми; *~ урын* ме́сто с пня́ми (*где много старых пней*)

төпкәлек *сущ.* ме́сто, где мно́го пней; *гөмбә ~тә була* грибы́ быва́ют там, где мно́го ста́рых пней

төпке *прил.* **1.** до́нный, прида́нный; глуби́нный; *~ балыклар* до́нные (прида́нные) ры́бы **2.** коренно́й (*о лошади в упряжке*) **3.** *перен.* глуби́нный; *~ агымнар* глуби́нные тече́ния (*общественной мысли*); *~ хисләр* глуби́нные чу́вства **4.** ни́жний; *~ оч* ни́жний коне́ц

төпкел *сущ.* **1.** воро́нка (*в ландшафте*), окру́глая вы́емка, окру́глое дно (*углубления, воронки и т. п.*); воронкообра́зное углубле́ние на дне водоёма; *~дә үскән агач* де́рево, вы́росшее на дне воро́нки **2.** глубь, са́мое дно; глубина́ *чего*; *тайга ~ендә* в глубине́ тайги́ **3.** глубина́ (*души, мысли и т. п.*); *күңел ~ендә* в глубине́ души́ || *прил.* окру́глый (*о яме, воронке и т. п.*); *~ җир* ни́зменное ме́сто окру́глой фо́рмы

төпкелдәге *прил.* **1.** находя́щийся на дне углубле́ния, воро́нки и т. п. **2.** *перен.* глуби́нный; *~ агым* глуби́нное тече́ние

төпкелле *прил.* с воро́нками, с углубле́ниями (*о местности, о дне водоёма и т. п.*)

төпкеллек *сущ.* **1.** окру́глая вы́емка, воронкообра́зная низи́на (*на поле, в лесу и т. п.*) **2.** глубо́кое ме́сто, о́мут (*на дне*) реки́ и́ли о́зера

төпләгеч *сущ. тех.* **1.** корчева́тель (*на лесоразработках*) **2.** переплётная маши́на; *~тә төпләтү* переплета́ть на переплётной маши́не ‖ *прил.* **1.** корчева́льный (*о машинах и т. п.*) **2.** переплётный; *~ аппарат* переплётный аппара́т

төпләм *сущ.* **1.** подши́вка (*брошюр, журналов, газет и т. п.*) **2.** цикл произведе́ний; *шигырьләр ~е* цикл стихотворе́ний

төпләмә *сущ. см.* **төпләм** 1

төпләнү I *страд. от* **төпләү** 1; *бакыр белән ~гән чиләк* ведро́ со вста́вленным ме́дным дном; *~гән китап* переплетённая кни́га

төпләнү II *неперех.* **1.** *см.* **тамырлану**; *имән каты җиргә ~ер* дуб пуска́ет ко́рни на твёрдой по́чве **2.** *перен.* обоснова́ться (*на жительство*); *монда ~ергә уйлыйм* ду́маю обоснова́ться здесь **3.** *перен.* засе́сть, про́чно сесть, сиде́ть (*на какой-л. должности*)

төпләп *нареч.* **1.** основа́тельно, серьёзно; *~ уйлау* основа́тельно поду́мать **2.** оконча́тельно; про́чно, кре́пко; *~ урнашу* оконча́тельно (*прочно*) обоснова́ться (*на новом месте*)

төпләтү I *понуд. от* **төпләү** I. **1.** дава́ть/дать почини́ть, отдава́ть на почи́нку дна (*подошвы и т. п.*) **2.** отдава́ть на переплёт (*книгу*)

төпләтү II *понуд. от* **төпләү** II; заста́вить, проси́ть и́ли веле́ть корчева́ть

төпләү I *перех.* **1.** вставля́ть и́ли чини́ть, почини́ть ‖ вставле́ние; почи́нка дна, до́нышка; *бидрә ~* вставля́ть до́нышко ведра́ **2.** переплести́/переплета́ть ‖ переплете́ние, переплёт (*книги, подшивки и т. п.*)

төпләү II *перех.* **1.** корчева́ть (*лес*) ‖ корчёвка, корчева́ние **2.** подгото́вка под очи́стку, почи́нок; *җир ~* подгото́вить зе́млю, освобожда́я от ле́са, под посе́в

төпләүче III *перех. прост.* доде́лывать/доде́лать до конца́; заверша́ть/заверши́ть ‖ заверше́ние *чего*; *мин бу эшне ~дем инде* я э́то де́ло уже́ заверши́л

төпләү IV *сущ. диал. см.* **ышна**; *~ тырмасы* борона́ для подгото́вки па́шни, почи́нка (*под посев*) □ **~ җир** подсе́чка

төпле *прил.* **1.** 1) с дном, име́ющий дно, дни́ще; *~ савыт* сосу́д с дном 2) с (*определённого качества*) дном; до́нный; *киң ~* с широ́ким дном, широкодо́нный; *яссы ~ көймә* плоскодо́нная ло́дка **2.** *перен.* 1) серьёзный; надёжный, де́льный (*о человеке и его характере*) 2) обосно́ванный, достове́рный, серьёзный; содержа́тельный, существенный, проду́манный; *~ хәбәр* достове́рная весть; *~ киңәш* де́льный сове́т; *~ караш* серьёзный взгляд 3) основа́тельный, серьёзный, надёжный (*о деле, деятельности, ремесле*); *~ һөнәр* надёжная профе́ссия ‖ *нареч.* де́льно, серьёзно; надёжно; проду́манно, обосно́ванно; *~ сөйли* де́льно говори́т; *план ~ төзелгән* план соста́влен проду́манно

төплек *сущ.* **1.** *см.* **олтанлык, табанлык 2.** корешо́к (*книги, подшивки и т. п.*); *күн ~* ко́жаный корешо́к **3.** *редко см.* **төпкәлек, төпсә**

төплекәй *сущ. диал. кулин.* то́лстая лепёшка (*для изготовления ватрушки*)

төплекле *прил.* с (*определённого качества*) корешко́м (*о книге, альбоме и т. п.*); *киң ~* с широ́ким корешко́м

төплеле|к *сущ.* де́льность; надёжность, серьёзность; *~ге куренеп тора* сра́зу видна́ его́ серьёзность

төпмә *нареч. диал.* соверше́нно, во́все; совсе́м; уж; *~ булмаганны сөйләү* расска́зывать соверше́нно невероя́тное

төпсә *сущ.* **1.** пень, пенёк; *каен ~се* пень (*спиленной*) берёзы; берёзовый пень **2.** *с.-х.* до́нце (*стебель злаков до завязывания первой пятки*) **3.** *диал. см.* **төпчек** ‖ *прил.* корена́стый; ни́зенький и то́лстый; *~ гәүдәле* с корена́стым ту́ловищем

төпсез *прил.* **1.** 1) без дна, дни́ща; *~ кесә* карма́н без дна, дыря́вый карма́н; *~ чиләк* ведро́ без дни́ща 2) *прям., перен.* бездо́нный; необъя́тный, бескра́йний; *~ кайгы* бездо́нное го́ре; *~ тирәнлек* бездо́нная глубина́ **2.** *перен.* несерьёзный, ненадёжный, необосно́ванный □ **~ бәлеш** вид пирога́ на сковороде́; **~ ыштан 1.** штаны́ с вы́резом (*для маленьких детей*); **2.** *перен. прост. см.* **ыштансыз** 2; ◊ **~ арбага (калушка, кәвешкә, көймәгә, чанага, чуманга) утырту** *см.* **төпкә утырту**; **~ мичкә** бездо́нная бо́чка (*дело, предприятие или сторона, человек, без конца требующие деньги*); **~ тубал 1.** говору́н; челове́к, говоря́щий без конца́; писа́тель, пи́шущий непреры́вно и мно́го; графома́н **2.** челове́к, расспра́шивающий без конца́

төпсез-кырыйсыз *прил. см.* **очсыз-кырыйсыз**

төпсезле|к I *сущ.* **1.** бездо́нность **2.** *перен.* бездоказа́тельность; малодостове́рность; необосно́ванность; *сүзләренең ~ге* бездоказа́тельность его́ слов

төпсезле|к II *сущ.* бе́здна, пучи́на; *галәм ~ге* бе́здна вселе́нной; *диңгез ~гендә* в морско́й пучи́не

төпсез-чиксез *прил.* бескра́йний; *төпсез-чиксез урманнар* бескра́йние леса́

төп-тамыр: төбе (төпләре)-тамыры (тамырлары) белән 1) коренны́м о́бразом; оконча́тельно; *төбе-тамыры белән йолку* оконча́тельно искорени́ть 2) со все́ми подро́бностями; *төбе-тамырын белү* знать всю подно́гтную; знать все подро́бности (*всю историю, всю родословную*)

төптәге *прил.* до́нный, находя́щийся на глубине́; глуби́нный; *~ ләм* до́нный ил

төптәй *нареч.* как пень; *~ юан* то́лстый, как пень; *~ ныклы* кре́пкий, как пень

төп-төгәл *превосх. ст. от прил. и нареч.* **төгәл** то́чный-прето́чный; то́чно-прето́чно

төп-төз *превосх. ст. от прил. и нареч.* **төз** прямёхонький, прямо́й-прямо́й; прямёхонько; пря́мо-пря́мо

төп-төп *нареч.* куста́ми, гру́ппами; *~ утыртылганнар* рассе́ажены куста́ми (*ягоды*)

төп-төче *превосх. ст. от прил.* **төче** совсе́м пре́сный, пре́сненький

төпчә *сущ.* **1.** *бот.* до́нышко (расте́ний) **2.** *см.* **төпчек** 2—3

төпчегеч *прил.* дото́шный; *бу кадәр ~ булырсың икән* до чего́ же ты, ока́зывается, дото́шный

төпче|к *сущ.* **1.** пенёк, ма́ленький пень; *~кә абыну* споткну́ться о пенёк **2.** ога́рок (*свечи*) **3.** оку́рок, оку́рыш; *~геңне калдыр әле* оста́вь-ка оку́рок **4.** после́дыш, после́дний ребёнок в семье́; мла́дший **5.** *редко* подо́нок (*о человеке, социальном типе*); насле́дник (*кого-то нехорошего*) ‖ *прил.* после́дний, са́мый мла́дший (*о детях*); *~ кызым* моя́ са́мая мла́дшая дочь

төпчеклә *перех. диал. см.* **төпчекү**

төпчеклек *сущ.* положе́ние после́днего, са́мого мла́дшего ребёнка

төпчелә|ү *перех.* уси́ленно допы́тываться, дои́скиваться; дото́шничать; *см.* **төпчү**; *~ргә тотынды* на́чал (он) дото́шничать (*усиленно расспрашивать*)

төпчендерү *понуд. от* **төпченү**; веле́ть, проси́ть и́ли дава́ть возмо́жность дои́скиваться, допы́тываться

төпчен|ү *перех.* **1.** дои́скиваться, разузнава́ть, дохо́ди́ть/дойти́, выясня́ть (*до сути, до конца*) **2.** дото́шно расспра́шивать; *~ә башлады* на́чал (он) дото́шно расспра́шивать

төпченүле *прил.* дото́шный, пытли́вый; испыту́ющий (*взгляд*); *~ тикшерену* дото́шное рассле́дование

төпченүчән *прил.* пытли́вый; испыту́ющий (*взгляд*); *~ егет* пытли́вый молодо́й челове́к

төпч|ү *перех.* **1.** расспра́шивать, выпы́тывать, выспра́шивать || расспра́шивание, выпы́тывание; *~и дә ~и* всё вре́мя выпы́тывает **2.** рассле́довать || рассле́дование; *үткән эшне ~и* рассле́дует про́шлое де́ло

төр *сущ.* **1.** вид, разнови́дность (*в классификации*); *туфрак төрләре* разнови́дности по́чвы; *продукт төре* разнови́дность проду́кта; *кыяк — яфракның бер төре* злак — э́то вид листа́; *яңа төр товарлар* това́ры но́вого ви́да **2.** *лог., филос.* вид (*в отношении к роду*); *музыка — сәнгать төре* му́зыка — вид иску́сства **3.** *биол.* вид || видово́й; *~ иммунитеты* видово́й иммунитет □ **төргә төрләнү** видоизмене́ние; **төрен төргә аеру** классифици́ровать по ви́дам (сорта́м)

тө́рара *прил. биол.* межвидово́й; *~ көрәш* межвидова́я борьба́

төрән *сущ.* ле́мех; сошни́к; *сабан ~е* ле́мех плу́га □ **~ сабан** тяжёлый плуг для целины́; плуг с тяжёлым ле́мехом; **~ тактасы (кабасы)** о́стов (ле́меха)

төрәнле *прил.* **1.** име́ющий ле́мех, сошни́к; с ле́мехом, с сошнико́м **2.** ле́мешный; *биш ~ сабан* пятиле́мешный плуг

төрбә *сущ.* склеп; мавзоле́й; *~дә җирләү* похорони́ть в скле́пе

төргәк *сущ.* **1.** свёрток; па́чка; свя́зка, рулон; свя́зка (*как единица счёта*); *бер ~ газета* свя́зка газе́т **2.** паке́т

төргәкләнү *страд-возвр. от* **төргәкләү**; завёртываться, упако́вываться

төргәкләү *перех.* завёртывать/заверну́ть, упако́вывать/упакова́ть || завёртывание (*в рулоны, пачки, свёртки и т. п.*); упако́вка (*как действие*)

төргәкле *прил.* свёрнутый в свёрток (*рулон, пачку, связку*); *~ кәгазь* свёрнутая в рулон бума́га

төрген *сущ. диал.* **1.** возвраще́ние, возвра́т **2.** регре́сс **3.** раз, крат; *бер ~* оди́н раз

төргеч *сущ.* **1.** обёртка; *~кә төреп бирү* дать в обёртке (*завёртывая обёрткой*) **2.** *бот.* ча́шечка, чашели́стик (*цветка*) || *прил.* обёрточный; *~ кәгазь* обёрточная бума́га; *см. тж.* **төрем**

төргечлек *прил.* обёрточный; *~ кәгазь* обёрточная бума́га

төрдәш *прил.* **1.** схо́дный, идентичный, одного́ ви́да, одно́й фо́рмы; конфо́рмный; *төрчәләр ~, ләкин аермалары бар* подви́ды быва́ют схо́дны, но не́сколько различа́ются (*между собой*); *~ фигыль* омонимичная фо́рма глаго́лов (*в тат. языке формы на* **-мыш** *и* **-ган** *в отношении друг к другу*) **2.** сме́жный; *~ белгечлек үзләштерү* овладе́ть сме́жной профе́ссией

төрдәшле|к *сущ.* **1.** 1) схо́дство, идентичность (*разных экземпляров*); конфо́рмность; 2) то, что отно́сится к одному́ и тому́ же ви́ду; *бу хайваннарның ~ге* отнесённость э́тих живо́тных к одному́ (и тому́ же) ви́ду

төрек *сущ.* **1.** ту́рок; осма́нец || туре́цкий; *~ теле* туре́цкий язы́к; *~ солтаны* туре́цкий султа́н **2.** *уст.* тюрк || тю́ркский; *~ телләре* тю́ркские языки́; *~ борчагы см.* **ногыт**; *~ канәфере* туре́цкая гвозди́ка (*вид растения*) ◊ **~ малае** *эвф.* кра́сное вино́

төрекләштерү *перех.* отуре́чить || отуре́чивание, отуре́чение; *~ политикасы* поли́тика отуре́чения

төрекләш|ү *неперех.* отуре́чиваться || отуре́чивание; *~еп беткәннәр* совсе́м отуре́чились

төрекле|к *сущ.* сво́йство быть ту́рком; осма́нство; то, что он явля́ется ту́рком; *аның ~ге билгеле* изве́стно то, что он явля́ется ту́рком

төрекмән *сущ.* туркме́н || туркме́нский; *~ әдәбияты* туркме́нская литерату́ра □ **~ бодае** яка́ра (*вид пшеницы с метельчатыми колосьями*); **~ бүреге** папа́ха; **~ егете** *ист.* наёмный солда́т ◊ **~ бабай** *миф.* дух — хозя́ин воды́

төрекмәнчә *нареч.* по-туркме́нски; *~ сөйләшү* разгова́ривать по-туркме́нски || *прил.* туркме́нский; *~ көрәш* туркме́нская борьба́; *~ китап* кни́га на туркме́нском языке́

төрекмәнчәләп *нареч.* по-туркме́нски; *~ җавап бирде* отве́тил по-туркме́нски

төрек-татар *сущ. собир. ист.* тюрк, тю́рки || тю́ркский, туре́цко-тата́рский; *төрек-татарлар* тю́рки, тю́ркские наро́ды; *төрек-татар телләре* ту́рко-тата́рские, туре́цко-тата́рские (*т.е.* тю́ркские) языки́

төрек-тата́рча *нареч. см.* **төркичә**

төрек-татарчы *сущ. ист.* **1.** сторо́нник усиле́ния ро́ли тю́рко-тата́рских языко́в в жи́зни тата́р **2.** тюрко́лог

төре́кчә *нареч.* по-туре́цки; *~ яхшы белә* хорошо́ зна́ет по-туре́цки || *прил.* туре́цкий; на туре́цком языке́; *~ китап* кни́га на туре́цком языке́

төрекчәләп *нареч.* (наро́чно) по-туре́цки; *~ җавап бирде* отве́тил (наро́чно) на туре́цком языке́

төре́кчәләтеп *нареч. см.* **төрекчәләп**

төре́кчәләштерү *перех.* **1.** переводи́ть/перевести́ || перево́д на туре́цкий (язы́к) **2.** де́лать/сде́лать туре́цким (*почти турецким*) по языку́

төрекчәлек *сущ. ист.* ориента́ция на туре́цкий (*о языке писателя, сочинений и т. п.*); скло́нность испо́льзовать туре́цкие слова́ и выраже́ния

төрекче *сущ. ист.* 1) туркома́г 2) пантюркист 3) сторо́нник распростране́ния туре́цкого языка́ (*взамен родного*) среди́ тю́ркских наро́дов

төрелә-төрелә 1) во весь опо́р, ма́хом (*о беге лошадей*); *атлар төрелеп-төрелеп чаптылар* ло́шади бежа́ли ма́хом 2) клубя́сь (*об облаках*); *болытлар төрелеп-төрелеп килә* клубя́сь, приближа́ются ту́чи

төрел|ү **1.** *страд.-возвр. от* **төрү** 1. *страд.* завёртываться; быть завёрнутым (свёрнутым, обёрнутым); *чүпрәккә ~гән* завёрнутый в тря́пки **2.** *возвр. поэт.* покрыва́ться, скрыва́ться *за; томаннарга ~гән* скры́тый за тума́нами **3.** *возвр.* скру́чиваться/скрути́ться, сворачиваться/сверну́ться (*о гусенице*); *бер язгы, бер ~ә* то разворачивается, то сворачивается **4.** *возвр.* завя́зываться/завяза́ться || завя́зывание (*образование завязи у растений*); *кәбестә быел иртә ~де* капу́ста в э́том году́ завяза́лась ра́но **5.** *в знач. нареч.* **төрелеп, төрелеп-төрелеп**

төрен|ү **1.** *возвр. от* **төрү**: обёртываться/оберну́ться, завёртываться/заверну́ться; *шинелен ~еп йоклый* спит, заверну́вшись с свою́ шине́ль **2.** *см.* **төрелү** 2, 3

төрепкә *сущ. разг.* (кури́тельная) тру́бка; *~сен тарта* ку́рит свою́ тру́бку

төрҗәгүн|ь *сущ.* **1.** *рел.* заверша́ющая часть, оконча́ние обще́ственного (*пятничного*) намáза **2.** *перен. уст.* форма́льный коне́ц, оконча́ние (*когда всё по существу уже решено*) **3.** *перен., книжн.* отраже́ние, повторе́ние того́, что уже́ бы́ло; о́тзвук; *талаш ~е* о́тзвук ра́спрей ◊ **~ьгә килү** приходи́ть на ша́почный разбо́р (*т. е. к концу события, чтобы участвовать только формально*)

төрке *сущ. разг. см.* **төркы** II-1; *укыдым гарәп — була яздым харап, укыдым фарсы — сафсата барсы, укыдым ~ — күңелемнең кырке* (*посл.*) учи́л я ара́бский — чуть не свихну́лся, учи́л перси́дский — вздор несусве́тный; учи́лся на языке́ тюрки́ — отра́да души́ □ **~ тану** научи́ться гра́моте на языке́ тюрки́ (на тата́рском)

төркем *сущ.* **1.** 1) гру́ппа, ку́чка; толпа́, гурьба́; *бер ~ кеше* (одна́) гру́ппа люде́й 2) гру́ппа, группиро́вка (*внутри организации*); *оппортунистик ~* оппортунисти́ческая группиро́вка **2.** разря́д; классификацио́нная едини́ца; *~нәргә бүлү* подразделя́ть на разря́ды (гру́ппы); *аксымнар ~е* гру́ппа белко́в □ **~(е) белән 1.** гру́ппой **2.** в соста́ве гру́ппы; **~е(~нәре) белән** всей гру́ппой; *~нәре белән кулга алынганнар* аресто́ваны всей гру́ппой

төркемләнеш *сущ.* **1.** группиро́вка (*как система*); группирова́ние **2.** разделе́ние на гру́ппы; *~е әйбәт түгел* разделе́ние на гру́ппы не хорошо́

төркемлән|ү **1.** *страд. и возвр. от* **төркемләү**; группирова́ться/сгруппирова́ться; быть сгруппиро́ванным || группирова́ние, сгруппирова́ние; *сүзләр төрлечә ~ә* слова́ группиру́ются по-ра́зному **2.** *см.* **төркемләшү**

төркемләп *нареч.* **1.** на гру́ппы, по гру́ппам; *~ аеру* разделя́ть на (отде́льные) гру́ппы **2.** *см.* **төркемләшеп**

төркемләп-төркемләп *нареч.* це́лыми гру́ппами; *төркемләп-төркемләп җибәрелделәр* бы́ли по́сланы це́лыми гру́ппами

төркемлә|ү *перех.* группирова́ть/сгруппирова́ть; разделя́ть, подразделя́ть на гру́ппы || группирова́ние, сгруппирова́ние, разделе́ние на гру́ппы; *төрлечә ~ргә мөмкин* группирова́ть мо́жно по-ра́зному

төркемләшеп *нареч.* образу́я гру́ппу (гру́ппы); гурьба́ми; гру́ппами (ста́ями, ватага́ми, кули́гами); *~ балалар керде* гурьба́ми вошли́ де́ти; *~ казлар оча* ста́ями летя́т гу́си

төркемләш|ү *возвр. от* **төркемләү**; группирова́ться/сгруппирова́ться || группирова́ние; образова́ть || образова́ние групп (стай, ватаг, кули́г); *без ~тек инде* мы уже сгруппирова́лись

төркемле *прил.* в гру́ппе, сгруппиро́ванный; *~ яшьләр* сгруппиро́ванная молодёжь || *нареч. редко* гру́ппой; гру́ппами; *~ эшлиләр* рабо́тают гру́ппами

төркем-төркем *нареч.* гру́ппами; ватага́ми (*о людях*); ста́ями, кули́гами (*о птицах*); *төркем-төркем җыелышып* собра́вшись гру́ппами; *төркем-төркем очалар* летя́т ста́ями || *прил.* собра́вшиеся (со́бранные) в гру́ппы (ватаги, ста́и); *төркем-төркем балалар* гру́ппы дете́й; не́сколько (мно́го) групп дете́й; *төркем-төркем казлар* ста́и гусе́й

төркемчә *сущ.* **1.** *уменьш. к* **төркем** гру́ппочка, гру́ппка; ма́ленькая (ма́лая) гру́ппа **2.** *спец.* подкла́сс, подразде́л; *~ләр аеру* выделя́ть подкла́ссы **3.** *лингв. уст.* вид; *фигыль ~ләре* ви́ды наклоне́ния (глаго́ла)

төркемчәләү *перех.* вы́делить/выделя́ть подкла́ссы, подразде́лы (*внутри класса, раздела и т. п.*); классифици́ровать

төркемче *сущ.* **1.** *неодобр.* член (определённой) гру́ппы **2.** сторо́нник групповщи́ны; *~ләрне мактамыйлар* сторо́нников групповщи́ны не хва́лят

төркемчелек *сущ.* групповщи́на (*в политике, в организации и т. п.*); *~ белән авыру* страда́ть групповщи́ной

төркечә *нареч. см.* **төркичә**

төркы *прил.* тю́ркский; *~ кабиләләр* тю́ркские племена́; *~ телләр* тю́ркские языки́; *~ фигыль* тю́ркский глаго́л || *сущ.* **1.** тюрки́ (*старописьменный язык тюркских народов на основе арабской графики, в силу своих особенностей одинаково отражающий орфоэпические нормы ряда тюркских языков*) **2.** *прост.* тата́рский пи́сьменный язы́к; *мин ~не укыдым* я изуча́л (*в школе*) тата́рский пи́сьменный язы́к **3.** тюрк, представи́тель како́го-нибудь тю́ркского наро́да; *борынгы ~лар* дре́вние тю́рки □ **~ тану** *см.* **төрке тану**

төркиләштерелү *страд. от* **төркиләштерү**; быть отюре́ченным, отюре́чиваться

төркиләштерү *перех.* отюре́чивать/отюре́чить

төркиләш|ү *неперех.* отюре́чиваться/отюре́читься || отюре́чивание; *~еп беткәннәр* соверше́нно отюре́чились

төркиле|к *сущ.* **1.** сво́йство быть тю́ркским, тю́ркский хара́ктер *чего-л.*; *сүзнең ~ге* тю́ркский хара́ктер сло́ва **2.** тю́ркское со́общество; совоку́пность всех тю́рков; *борынгы ~к* дре́внее тю́ркское со́общество

төркичә *нареч.* на пи́сьменном языке́ тюрки́; на старотата́рском литерату́рном языке́; *~ язылган* напи́сано на языке́ тюрки́ || *прил.* **1.** (*написанный, сказанный*) на языке́ тюрки́; *~ китап* кни́га на языке́ тюрки́ **2.** *разг. уст.* (*написанный, сказанный*) на тата́рском языке́; *~ әйт* скажи́ на тюрки́ (на тата́рском языке́); *~ уку* уме́ть чита́ть на старотата́рском (на ара́бском) языке́, учи́ться на старотата́рском языке́

төркиче *сущ. ист.* сторо́нник обуче́ния на языке́ тюрки́; сторо́нник примене́ния э́того языка́ во всех сфе́рах жи́зни; *~ләр корылтае* съезд сторо́нников языка́ тюрки́

төркичелек *сущ. ист.* **1.** примене́ние языка́ тюрки́ в обуче́нии, образова́нии, нау́ке и худо́жественной литерату́ре; увлече́ние пи́сьменным языко́м тюрки́ **2.** обще́ственно-литерату́рное движе́ние, ста́вившее це́лью активиза́цию языка́ тюрки́; *~ агымы* обще́ственно-литерату́рное движе́ние в защи́ту языка́ тюрки́

төрләндергеч *прил. грам.* словоизмени́тельный; *~ кушымчалар* словоизмени́тельные а́ффиксы

төрләнеш *сущ.* **1.** 1) измене́ние, изме́нчивость (*напр., пищи, впечатлений и т. п.*) 2) ход измене́ний, изме́нчивости; *~ процессы* проце́сс измене́ний **2.** *грам.* измене́ние, склоне́ние и́ли спряже́ние; *сүз ~е* словоизмене́ние; *исем ~е* склоне́ние и́мени существи́тельного; *фигыль ~е* спряже́ние глаго́ла

төрләнешле *прил.* **1.** изме́нчивый, переме́нный; *~ процесс* переме́нный проце́сс **2.** *грам.* изменя́емый (*о словах*); *~ сүз төркемнәре* изменя́емые ча́сти ре́чи

төрләнешсез *нареч.* неизме́нно, без измене́ний; однообра́зно; *~ яшәү* жить однообра́зно || *прил.* **1.** неизме́нный, однообра́зный; *~ процесс* неизме́нный проце́сс **2.** *грам.* неизменя́емый (*о частях речи*); *кисәкчәләр — ~ сүз төркеме* части́цы представля́ют неизменя́емую часть ре́чи

төрлән|ү *неперех.* **1.** *см.* **төрлелән|ү**; *~еп барган телә́кләр* жела́ния, кото́рые стано́вятся всё бо́лее разнообра́зными **2.** изменя́ться/измени́ться; видоизменя́ться/

видоизмени́ться; *тугызга (утызга, туксанга и т. п.) ~ер әле* изме́нится ещё де́вять раз (неоднокра́тно) **3.** привере́дничать || привере́дничанье; при́хоть (*беременной или больного*) **4.** *диал.* ряди́ться в ра́зные пла́тья, оде́жды (*у крещёных татар во время святок*) || ря́женье; *см. тж.* **сәвәләй 5.** *грам.* изменя́ться (*о слове*), склоня́ться и́ли спряга́ться || словоизмене́ние, склоне́ние и́ли спряже́ние; *сан ~уе* склоне́ние числи́тельных; *фигыль ~уе* спряже́ние глаго́лов ◊ **~ү бәйрәме** свя́тки (*у крещёных татар*); *см. тж.* **пардуган**

төрләнчек *прил.* разбо́рчивый, привере́дливый (*в еде*); капри́зный, прихотли́вый

төрләнүсез *нареч.* без привере́дничанья, без при́хотей; *~ ашады* (ел)а без при́хотей

төрләнчекләнү *неперех.* **1.** станови́ться/стать привере́дливым, разбо́рчивым (*в еде*) **2.** привере́дничать || привере́дничанье; *~е бетмәде* нет конца́ его́ привере́дничанью

төрле *прил.* **1.** 1) определённого коли́чества ви́дов; *үсемлекләр ике ~ була* расте́ния быва́ют двух ви́дов 2) определённого ви́да; *яңа ~ чәчкеч* се́ялка но́вого ви́да **2.** разли́чный, различа́ющийся; *алар икесе бик ~ кеше* они́ о́ба о́чень ра́зные лю́ди **3.** ра́зный, разнообра́зный; *~ уйлар* ра́зные мы́сли; *~ зурлыктагы* ра́зной величины́

төрле|к *сущ. лингв.* **1.** *уст.* морфоло́гия; *~ китабы* кни́га по морфоло́гии **2.** словоизмени́тельный а́ффикс; *фигыль ~ге* глаго́льные словоизмени́тельные а́ффиксы

төрлексез *прил. диал.* однообра́зный, неизме́нный, засто́йный; *~ тормыш* засто́йная жизнь

төрлеләндерү *перех.* разнообра́зить || (*нарочно созданное*) разнообра́зие; *~ өчен* для разнообра́зия

төрлеләнеш *сущ.* разнообра́зность; изме́нчивость

төрлелән|ү *неперех.* **1.** станови́ться/стать ра́зным, разнообра́зным; разнообра́зиться; *күренешләр ~де* ви́ды ста́ли (бо́лее) разнообра́зными **2.** идти́ вразнобо́й, расходи́ться || расхожде́ние; *фикерләр ~де* мне́ния ста́ли расходи́ться

төрлеле|к *сущ.* разнообра́зие; разнообра́зность, разноро́дность; *тематика ~ге* разнообра́зие темати́ки; *тойгыларның ~ге* разноро́дность чувств

төрле-төрле *прил.* **1.** многообра́зный; разнообра́зный; *төрле-төрле аш(лар)* разнообра́зная еда́ **2.** *прост.* о́чень ра́зные; ре́зко отлича́ющиеся, несхо́жие; *алар икесе төрле-төрле* они́ (*двое*) о́чень ра́зные (они́ ре́зко отлича́ются)

төрлéчә *нареч.* **1.** по-ра́зному, вся́ко, вся́чески, повся́кому; *~ сөйлиләр* говоря́т по-ра́зному **2.** *редко* на ра́зных языка́х; *~ язылган китаплар* кни́ги, напи́санные на ра́зных языка́х

төрмә *сущ.* тюрьма́, темни́ца; остро́г, остро́жек || тюре́мный, остро́жный; *~гә утырту* посади́ть в тюрьму́; *~дә утыру* сиде́ть в тюрьме́; *~ жаргоны* тюре́мный жарго́н; *~ режимы* тюре́мный режи́м □ **~ сакчысы** тюре́мный охра́нник; **~гә керү** попада́ть/попа́сть в тюрьму́; ◊ **~дә туган** кра́йне бесцеремо́нный, бо́йкий и хи́трый (*букв.* роди́лся в тюрьме́) || *сущ. кулин. диал.* вид пирога́; расстега́й

төрмәле *прил.* упако́ванный; *~ товар* упако́ванный това́р

төрмәче *сущ.* тюре́мщик; надсмо́трщик, надзира́тель; *~лэр кулында* в рука́х тюре́мщиков

төрмәчләл|ү *диал. страд. от* **төрмәчләү**; ско́мкаться, свёртываться в у́зел, в клубо́к (*беспорядочным образом*); *әйберләр ~еп ята* ве́щи лежа́т ско́мканными (*в беспорядочном клубке*)

төрмәчлә|ү *перех. диал.* ско́мкать, беспоря́дочно свёртывать в у́зел, в комо́к □ **~п тыгу** су́нуть, ско́мкав в комо́к (комко́м)

төрпә *прил. разг.* **1.** *см.* **дорфа**; *~ карау* смотре́ть во́лком **2.** ко́лкий, е́дкий (*о словах*); насме́шливый и гру́бый (*о человеке*); *~ кеше* насме́шливый челове́к || *нареч.* гру́бо, нела́сково; *~ каршыладылар* встре́тили нела́сково; *~ әйтү* съязви́ть, нагруби́ть

төрпәйту *перех. см.* **тырпайту**

төрпәләп|ү *неперех.* **1.** де́латься/сде́латься насме́шливым и гру́бым; груби́ть, грубия́нить **2.** вести́ себя́ насме́шливо, гру́бо; язви́тельно говори́ть; *ник ~әсең?* почему́ ведёшь себя́ гру́бо?

төрпәлек *сущ. разг.* **1.** гру́бость, ре́зкость **2.** *диал.* насме́шливость

төрпә|ю *неперех. см.* **төрпәләнү**; *төрпәгә иягән ~йгән* (*посл.*) с кем поведёшься, от того́ и наберёшься (*букв.* кто во́дится с грубия́ном, тот сам груби́т)

төрпе *прил.* **1.** ко́лкий, ерши́стый, щети́нистый, топо́рчащийся (*о мелких предметах*); *см. тж.* **тырпа**; *~ кыл* ко́лкая щети́на **2.** *перен.* ко́лкий; *~ сүзләр* ко́лкие слова́ || *сущ. редко* (ко́лкая) шерсти́нка, щети́на; *~се бар* име́ет (*колкую*) щети́ну

төррә *межд.* употребля́ется для отпу́гивания ове́ц

төртек I *сущ. разг.* **1.** тычо́к (*резкое движение кулаком, локтем и т. п. во что-л.*) **2.** *перен.* ко́лкое сло́во; шпи́льки (*в адрес кого-л.*) || *прил.* **1.** тычко́вый; *кирпечнең ~ ягы* тычко́вая сторона́ кирпича́ **2.** *перен.* ко́лкий (*о слове*); *см. тж.* **төртмәле**

төртек II *сущ. см.* **төртке 1**

төртелгән, төртенгән *прил. разг. эвф. см.* **чукынган**; *~ хатын* пога́ная же́нщина; парши́вка

төртел|ү *возвр. от* **төртү 1.** 1) *прям., перен.* упира́ться/упере́ться, утыка́ться/уткну́ться; *көймә ярга ~де* ло́дка уткну́лась в бе́рег 2) натыка́ться/наткну́ться *на что-л.; ташка ~у* натыка́ться на ка́мень **2.** сту́каться, ударя́ться *обо что-л.*; *шалт-шолт ~э* ударя́ется с тре́ском **3.** 1) задева́ть/заде́ть || задева́ние *чем-л., чего-л.; һәрнәрсәгә ~еп йөри* всё вре́мя что́-либо задева́ет 2) задева́ть/заде́ть (сло́вом); *сүзең миңа ~э* твоё сло́во задева́ет меня́ **4.** толка́ться/толкну́ться (*туда-сюда, в угол, в ворота, в двери и т. п.*); *см. тж.* **төртену** 1; *тегендә ~дек, монда ~дек* толкну́лись туда́, толкну́лись сюда́ **5.** *груб. прост.* прислоня́ться/прислони́ться; *ник мичкә ~еп торасың?* чего́ стои́шь, прислони́вшись к пе́чке? **6.** *прост.* уткну́ться; *китабына ~гән дә тик утыра* уткну́лся в свою́ кни́гу и сиди́т **7.** выпира́ть (*из-под оболочки, одежды, шкуры*); *сөякләре ~еп тора* ко́сти выпира́ют (*из-под шкуры, кожи — о худой скотине*) **8.** натолкну́ться; *аңламаган сүзгә ~дем* натолкну́лся на незнако́мое сло́во

төртем *сущ.* **1.** толчо́к (*в бок*) **2.** *перен.* кре́пкая ко́лкость (*слово, выраженное мягко, как бы невинно, но заключающее в себе тяжкое оскорбление*); *~е каты* ко́лкость его́ крепка́ (ощути́ма)

төртемеш *сущ. диал.* бирю́к, нелюди́м (*неразговорчивый, мрачный человек*); *ул ~ бит* он же бирю́к

төртендерү *перех. эвф. см.* **чукындыру**

төртенмеш *сущ. неодобр.* **1.** *см.* **чукынмыш 2.** шату́н, бродя́га, непосе́да; непосе́дливый дура́к (*вмешивающийся в дела других*)

төртенчек *сущ. неодобр. см.* **чукынчык**

төртеп|ү *неперех.* **1.** толка́ться, сова́ться (*туда и сюда*); *~еп йөри* толка́ется (*туда и сюда*) **2.** *разг. см.* **чукыну** 1, 2. **3.** *перен. неодобр.* ходи́ть, е́здить, бу́дучи неприглашённым; толкну́ться *к кому* **4.** *перен. груб.* ре́зко отка́зываться/отказа́ться, упря́миться/заупря́миться **5.** *прост. см.* **төртелү** 6 ◊ **~еп киткән (киткере)** *см.* **чукының киткере**

төртеш *сущ.* толкотня́, толку́чка; толчки́ (*друг в друга*); *~тән чыгу* вы́браться (вы́ход) из толкотни́

төртешле *прил.* сопровожда́емый толкотнёй, толку́чкой; *~ җыен* сбо́рище с толкотнёй || *сущ.* игра́ в толчки́ (*игра, в которой выталкивают друг друга из круга*)

төрткәлә|ү **1.** *многокр. от* **төртү** ты́кать; поты́кать; *бармагы белән ~де* поты́кал па́льцем **2.** толка́ть, подта́лкивать; *~п чыгару* выта́лкивать; подта́лкивать, выгоня́ть

төртке I *сущ.* **1.** *разг.* то́чка; то́чечка: знак в ви́де то́чки, запято́й; *ике ~се бар* име́ет две то́чки (запяты́е) **2.** пя́тнышко (*на ткани*) **3.** *см.* **төртем** 2

төртке II *прил. редко см.* **төртмәле**; *~ суз* ко́лкое сло́во, ко́лкость

төртке III *сущ. диал.* **1.** опо́рное бревно́, опо́рная коло́да (*в бревенчатых сооружениях*) **2.** торе́ц; *~ ягы* торцо́вый коне́ц

төрткеле *прил.* **1.** с то́чечками (то́чками); име́ющий то́чку (то́чки, то́чечки); *биш ~* с пятью́ то́чками **2.** то́чечный; в ви́де мно́жества то́чек; *~ бизәк* то́чечный узо́р

төрткесез *нареч. и прил.* без то́чек; бесто́чечный; *~ генә яз* пиши́ без (ли́шних) то́чек; *~ язу* писа́ть без то́чек (запяты́х)

төрткеч *сущ.* толка́тель (*в механизмах*); *см. тж.* **төрттергеч**

төртмә *прил.* ко́лкий, саркасти́ческий; *~ сүзләр ява тора* ко́лкие слова́ так и сы́плются (*со всех сторон*) || *редко сущ.* ко́лкость, сарка́зм

төртмәкәй *сущ.* зои́л, ехи́дна (*человек с язвительной речью*); *ну, төртмәкәй дә соң син* ну и ехи́дна же ты || *прил. см.* **төртмәле**

төртмәле *прил.* ко́лкий, язви́тельный (*о словах, речи*); *~ сүз белән* с язви́тельным сло́вом

төртмәлелек *сущ.* ко́лкость, язви́тельность (*слова*); *сүзенең ~ге белән атаклы* изве́стен язви́тельностью свое́й ре́чи

төрттергеч *сущ.* 1) толка́тель; 2) бага́р

төрттер|ү **1.** *понуд. от* **төртү** веле́ть, заста́вить и́ли проси́ть толка́ть, прота́лкивать/протолкну́ть, подта́лкивать/подтолкну́ть *что-л.* **2.** *перех.* 1) поддева́ть/подде́ть; *бүрәнә белән ~ү* подде́ть бревно́м 2) подта́лкивать/подтолкну́ть, толкану́ть 3) *перен.* съязви́ть, отпусти́ть ко́лкость (*в адрес кого-л.*); намека́ть/намекну́ть (*в разговоре о чём-л. нехорошем в делах собеседника*); говори́ть недо́брыми намёками; *~еп сөйләмә* не говори́ недо́брыми намёками **3.** *прост.* приставля́ть/приста́вить; стыкова́ть/состыкова́ть *что с чем;* пристра́ивать; *өйгә ~еп келәт салу* пристро́ить к до́му клеть

төрттерүле *прил.* язви́тельный, ко́лкий (*о словах, речах*); *~ искәрмәләр* язви́тельные замеча́ния

төрт|ү *перех.* **1.** 1) ты́кать, толка́ть/толкну́ть; *җиргә ~ү* ты́кать/ткнуть в зе́млю; *таяк белән ~ү* толкну́ть по́сохом; *кабыргага ~ү* толка́ть в бок 2) *перен.* сту́кать/сту́кнуть без разма́ха, но си́льно; чувстви́тельно уда́рить; *~ берне* сту́кни (*ему*) раз **2.** упира́ть, упира́ться (*чем-л.*); *борыным ~еп* упира́я мо́рду, упира́ясь мо́рдой **3.** выпира́ть; *сөякләре ~еп тора* его́ ко́сти выпира́ют (*из-под кожи*) **4.** *перен.* сажа́ть/посади́ть (*растения*) рука́ми **5.** *перен.* 1) незаме́тно сова́ть/су́нуть (*что-л. в руки*) 2) *эвф.* дава́ть/дать взя́тку; *биш мең ~тем* дал (су́нул) пять ты́сяч рубле́й (*взятки*) **6.** *разг.* 1) ста́вить то́чку, запяту́ю и т. п. 2) ко́ротко писа́ть/написа́ть; заноси́ть/занести́ в кни́гу; *бу сүземне дә шунда ~* и э́то моё сло́во занеси́ туда́ (*в книгу*); *~еп бар* посто́янно запи́сывай (заноси́) **7.** устра́ивать/устро́ить (*на работу*); поста́вить (*на работу, на пост, по протекции кого-л.*) □ **~еп аудару** сва́ливать/свали́ть толчко́м (*сооружение*); **~еп егу** повали́ть (сбить, свали́ть) толчко́м (*что-л. неустойчивое или человека*); **~еп җибәрү** оттолкну́ть, подтолкну́ть; **~еп күрсәтү** ука́зывать/указа́ть (*пальцем*); **~еп тишү** протыка́ть/проткну́ть; **~еп төшерү** столкну́ть; **~еп чыгару** *прям., перен.* выта́лкивать/вы́толкнуть; **~еп чыгу** выпира́ть; проявля́ться (*о тенденциях, чувствах и т. п.*)

төрчә *сущ. биол.* подви́д; *тарпан — ул атның ~се* тарпа́н — э́то подви́д ло́шади

төрчек *сущ. уменьш. от* **төр** подви́д; *см. тж.* **төрчә**

төр|ү *перех.* **1.** свёртывать/свернуть || свёртывание; *рулон итеп ~ү* свернуть в рулон **2.** завёртывать/завернуть *во что*, обвёртывать/обвернуть *во что чем* || заку́тывание; *юрганга ~ү* завернуть в одея́ло; *кәгазьгә ~ү* оберну́ть бума́гой (в бума́гу) **3.** заку́тывать/заку́тать || заку́тывание *чем; аякларны юрганга ~ү* заку́тывать но́ги стёганым одея́лом **4.** *спец.* упако́вывать/упакова́ть; обвёртывать/обвернуть || упако́вка, обвёртка; упако́вочный, обёрточный; *~ү цехы* упако́вочный цех; *~ү кәгазе* обёрточная бума́га **5.** *диал.* ко́мкать, мять; ско́мкать, смять **6.** *перен. разг.* глота́ть, есть (*быстро и большими кусками*), ку́шать, жева́ть; *~әм генә, малай* ну и ем же я, друже́ище ◊ **~еп алу** энерги́чно наступа́ть *на кого-л.*, энерги́чно приступа́ть, взя́ться *за кого-л.*; *см. тж.* **бөреп алу**

төрүле *предик. прил.* обёрнутый, упако́ванный; *~ китаплар* упако́ванные кни́ги; *әйберләр ~* ве́щи упако́ваны

төрүлек *сущ.* упако́вочный материа́л (*обёрточная бумага*); *~ цехы* цех упако́вочных материа́лов || *прил.* упако́вочный, обёрточный

төрүче *сущ.* упако́вщик; *пакет ~* упако́вщик паке́тов

төс I *сущ.* **1.** цвет; *яшел төс — яз күрке* (*погов.*) зелёный цвет — краса́ весны́ **2.** 1) раскра́ска, расцве́тка (*ткани и т. п.*); *төсе матур карарга* раскра́ска краси́ва на вид 2) масть (*карты, лошади*); *см. тж.* **төсмер 3.** цвет лица́; обли́чье; выраже́ние лица́; *төскә матур* лицо́м прекра́сна; *ачулы төс белән* с серди́тым выраже́нием лица́; *төсе үзгәрде* он измени́лся в лице́ **4.** о́блик, вид; *бәй эче бәйрәм төсенә керде* до́ма ста́ло пра́здничнo (дом при́нял пра́здничный вид) **5.** оборо́т, фо́рма, вид, хара́ктер (*дела, события и т. п.*); *җитди төстә әйтте* сказа́л с серьёзным ви́дом; *ультиматум төсендә* в фо́рме ультима́тума **6.** 1) *что-л.* сохраня́емое и́ли передава́емое как образе́ц; *ефәк төсе* образе́ц (това́рного) шёлка 2) *что-л.* на па́мять; *төсе итеп йөртү* носи́ть как па́мять *о ком-л.*; *төсең итеп саклыйм* храню́ как па́мять о тебе́ **7.** *в знач. послелога* **төсендә** *с сущ.*, **төстә** *с прил. образует словосочет. в функ. предик. прил.*: 1) (*определённого*) цве́та; *лимон төсендә* цве́та лимо́на, лимо́нного цве́та; *яшел төстә* зелёного цве́та 2) *в виде чего; бүләк төсендә* в ви́де пода́рка **8.** *в знач. послелога* **төсендәге** *с сущ.*; **төстәге** *с прил. образует словосочет. в функ. прил.* цве́та; име́ющий (определённый) цвет; *зәбәрҗәт төсендәге* изумру́дного цве́та; *кызыл төстәге* име́ющий кра́сный цвет

төс II *предик. сл.* подхо́дит; соответствует; досто́йно; прили́чествует; *бу костюм сиңа ~ тугел* э́тот костю́м

тебе́ не к лицу́; *артка калу безгә ~ булмас* отстава́ние нам не прили́чествует □ **төс(ен) алу** принима́ть/приня́ть *какой-л.* вид (цвет, хара́ктер); вы́цветший; **төс(е) бетү (качу, китү, югалу)** теря́ть норма́льный вид (цвет, выраже́ние); **төсе беткән** 1. вы́цветший (*о материале*) с измени́вшимся лицо́м 2. бле́дный, обескро́вленный (*от волнения*); **төс бирү (салу, ташлау)** 1. теря́ть норма́льный цвет лица́; обескро́вливаться/обескро́виться; обесси́леть (*о человеке*) 2. *в отриц. ф.* **төс бирмәү**: быть не ко двору́; не ужива́ться/не ужи́ться; **~(е) бозылу** искази́ться, обезобра́зиться (*о лице*), **төс керү (кую)** оздоровля́ться; приня́ть, заиме́ть здоро́вый вид (*после болезни*); **төс чыгу** выража́ться на лице́ (*о чувствах и мыслях*); *йөзенә хәстәрле төс чыкты* на лице́ вы́разилась озабо́ченность; **төсен дә күрмәү** ви́да не вида́ть; и не ве́дать о существова́нии *чего;* и бли́зко не подходи́ть; *мәктәпнең төсен дә күрмәгән* и бли́зко не подходи́вший к шко́ле 3. измени́ть цвет, линя́ть (*о животных*); **төсен җую (югалту)** 1. *см.* **төсе бетү** 2. изменя́ть цвет, облиня́ть; **төсенә чыгару** выража́ть (*не скрывая*) на лице́ (*свои чувства или мысли*); **төсенә чыгу** выража́ться, отража́ться на лице́ *кого* (*несмотря на желание скрыть — о чувствах и мыслях*); *көнчелеге ~енә чыкты* за́висть его́ отрази́лась на лице́; **төстән китү** *см.* **төсе бетү**; **төстән чыгу** *см.* **төсен җую**

төс-баш *сущ. собир.* вне́шний вид; *төскә-башка (төсе-башы) чибәр* на вид краси́в

төс-бит *сущ. собир. см.* **төс-баш**; *төсен-битен хәтерләмим* вне́шний вид его́ я не по́мню

төс-буй *собир. сущ.* о́бщий о́блик, о́бщий вид; *төсе-буе (төс-буе) килешле* име́ет досто́йный (прили́чный) вид

төскә|ү *перех. диал.* выпрямля́ть, держа́ть пря́мо (*хвост*); *койрыгын ~п* выпрямля́я хвост (держа́ хвост пистоле́том)

төс-кыяфәт *сущ. собир. см.* **төс-буй**

төсләвеч *сущ. диал. см.* **төтәткеч**

төсләнү I *страд. от* **төсләү**: оку́риваться; *гөмбә белән ~гән* оку́ренный грибны́м ды́мом

төсләнү II *неперех. редко см.* **төслелəнү**

төсләү *перех. разг. см.* **төсмерләү**

төсле I *прил.* 1. име́ющий определённый цвет; определённого цве́та; *сары ~* жёлтого цве́та; *яшел ~* зелёного цве́та 2. *с местоименными и наречными определениями: какого-л.* ви́да, о́блика, о́браза; *ни ~ кыз ул?* како́го о́блика она́ — э́та де́вушка? *бар да шул ~* все таки́е же (все тако́го же ви́да)

төсле II *нареч.* о́бразом; *ул башка ~ сөйли* он говори́т други́м о́бразом (*иначе, по-другому*) ‖ *прил.* 1. цветно́й, не чёрно-бе́лый; *~ фильм* цветно́й фильм 2. цветно́й (*не имеющий в своём составе железа — о металлах и сплавах*); *~ металлар* цветны́е мета́ллы □ **~ нурлар** *физ.* цветны́е лучи́; **~ тәнлеләр** *этногр.* цветны́е (*народы не с белой кожей*)

төсле III *послелог, соответствующий русским предлогам* как, подо́бный, подо́бен, ка́к бы; *җен ~* как чёрт; подо́бный чёрту; *очып китәр ~* ка́к бы хо́чет улете́ть; ка́жется, что улети́т

төслелəн|ү *неперех.* 1. принима́ть/приня́ть определённый цвет; *яшел ~ү* принима́ть зелёный цвет; (по)зелене́ть 2. принима́ть/приня́ть определённый (ука́занный) о́браз; *шул ~еп* приня́в тако́й о́браз (*оборот, вид*)

төслелек *сущ.* 1. сво́йство име́ть определённый цвет (*после основ прилагательных, обозначающих цвета*); *яшел ~* быть зелёным (*зелёного цвета*) 2. сво́йство име́ть определённый о́браз, вид; *шул ~* быть таковы́м ‖ *прил.* цве́тность (*фильма, кожи тела и т. п.*)

төсмер *сущ.* 1. *в разн. знач.* отте́нок, тон, тона́льность; *яшел буяуның аксыл яшел ~е* бле́дно-зелёный отте́нок зелёного цве́та; *мәгънә ~е* отте́нок значе́ния 2. масть (*лошади, коровы и т. п.*); *~ен аерып булмый* различи́ть масть невозмо́жно

төсмерләнеш *сущ.* отте́нок, тона́льность выраже́ния (*мысли и т. п.*); *~е чагылу* выраже́ние тона́льности *в чём*

төсмерлəн|ү *перех.* 1. *страд. от* **төсмерләү**; вспомина́ться; *бик начар ~ә* вспомина́ется с трудо́м (*о чертах лица и т. п.*) 2. раскрыва́ться, приходи́ть/прийти́ в го́лову (*в определённых чертах*); *әгәрдәге образлар ачык ~ми* о́бразы, да́нные в произведе́нии, я́рко не раскрыва́ются 3. с трудо́м, е́ле просма́триваться; проступа́ть в не́которых черта́х; *томан артында биек манара ~ә* за тума́ном е́ле просма́тривается высо́кая ба́шня; *юл бик начар ~ә* доро́га проступа́ет о́чень пло́хо (*в темноте*)

төсмерлә|ү *перех.* вспомина́ть/вспо́мнить; уга́дывать/угада́ть, узнава́ть/узна́ть, разузна́ть ‖ воспомина́ние, уга́дывание, узнава́ние (*по некоторым признакам, чертам*); *көчкә ~дем* я е́ле узна́л (*его*)

төсмерле *прил.* 1. *редко* с определённым отте́нком (*выражения*); *яшел ~* с зелёным отте́нком 2. бога́тый отте́нками (*цвета и т. п.*), вырази́тельный (*о чём-л. зримом, о картине, виде*)

төсмерлек *сущ.* 1. тона́льность; *төрле ~лəрдə* в ра́зных тона́льностях 2. *см.* **төсмер** 2

төсмерсез *прил.* 1. невырази́тельный; *~ караш* невырази́тельный взгляд 2. непривлека́тельный, ску́чный (*о виде, картине*); *~ манзара* ску́чный вид

төсмерсезлəну *прил.* станови́ться/стать невырази́тельным, ску́чным (*о видах, картинах и т. п.*)

төссез *прил.* 1. *в разн. знач.* бесцве́тный; *~ сыекча* бесцве́тная жи́дкость; *~ тукыма* бесцве́тная ткань; *~ чырай* бесцве́тное выраже́ние лица́ 2. невырази́тельный; *~ караш* невырази́тельный взгляд 3. бессодержа́тельный

төссезлəн|ү *неперех.* 1. теря́ть/потеря́ть ‖ поте́ря цве́та; обесцве́чиваться ‖ обесцве́чивание (*само собой*); *сыекча ~ә башлады* жи́дкость ста́ла обесцве́чиваться 2. лиша́ться/лиши́ться ‖ лише́ние жи́дкости, приве́тливости (*о выражении лица*); де́латься/сде́латься неприве́тливым, суро́вым (и ску́чным) 3. лиша́ться/лиши́ться вырази́тельности, увлека́тельности (*о художественном произведении*)

төссезлек *сущ.* 1. бесцве́тность (*жидкости, газа, ткани и т. п.*) 2. 1) бле́дность, невырази́тельность (*общего вида; взгляда*) 2) бе́дность, невырази́тельность, неувлека́тельность (*художественного произведения*); *әсәрнең телендә ~ ярылып ята* язы́к произведе́ния невырази́телен

төстәш *прил.* схо́дные по цве́ту, одного́ и того́ же цве́та (*о сравниваемых двух и более предметах*); *~ тукымалар* тка́ни одного́ и того́ же цве́та

төстәшлек *сущ.* схо́дство по цве́ту, сво́йство име́ть оди́н и то́т же цвет (*о двух и более предметах*)

төтәгеч *сущ.* 1. ды́мник, осо́бо си́льно тле́ющее де́рево (*вещество для окуривания комаров*) 2. *см.* **төтәткеч**

төтәк *прил.* тле́ющий, дыма́щийся □ **~ гөмбә** гриб со спо́рами

төтәс, төтәз *сущ. этногр.* 1. благово́ние, куре́ние 2. кури́тельное благово́нное вещество́ ‖ *прил.* обку́ренный, па́хнущий ды́мом

төтәсләвеч *сущ.* **1.** прибо́р для обку́ривания, кури́льница **2.** *см.* **төтәгеч**

төтәсләгеч *сущ. см.* **төтәсләвеч** 1

төтәсләнү *страд.-возвр. от* **төтәсләү** **1.** быть обку́ренным и́ли копчёным **2.** обку́риваться; прокопти́ться, копти́ться; *~гән бала* обку́ренный (*для предохранения от злых духов*) ребёнок **3.** *перен.* прокопти́ться, копти́ться (*о пищевых продуктах*); *см.* **ыслану**

төтәсләү *перех.* **1.** *этногр.* оку́ривать; обку́ривать/обкури́ть || оку́ривание, обку́ривание (*в ритуальных целях*) **2.** обку́ривать, выводи́ть, истребля́ть и́ли отогна́ть || обку́ривание; выведе́ние ды́мом, га́зом и т. п.; *умартаны ~* обку́ривать у́лей **3.**копти́ть ||копче́ние; *см. тж.* **ыслау** **4.** *перен. разг.* кури́ть || куре́ние (*в комнате*)

төтәткеч *сущ.* **1.** дыма́рь (*устройство для обкуривания пчёл и т. п.*) **2.** копти́лка (*устройство для копчения; примитивная лампа, светильник*)

төтәт|ү **1.** *понуд. от* **төтәү**; разжига́ть/разже́чь || разжига́ние огня́ **2.** *перех.* заку́ривать/заку́рить || заку́ривание; *~ик берне* дава́й заку́рим по одно́й

төт|әү *неперех.* **1.** тлеть, дыми́ться; *кайдадыр йон ~и* где́-то тле́ет шерсть **2.** чади́ть; *~и башлаган филтә* фити́ль, нача́вший чади́ть **3.** *см.* **төтрәү** 2; *~әп яуган яңгыр* и́зморось; дождь мельча́йшими ка́пельками

төтәч *сущ. бот.* дымя́нка, чистя́к

төтәчләү *перех. диал. см.* **төтәсләү**

төтек *сущ. разг.* **1.** копти́лка (*светильник, свечка, которые слегка дымят*); *~кә ут кабызу* заже́чь копти́лку **2.** тле́ющий кусо́к (*деревяшки, кизяка — для зажигания трубки, для отпугивания комаров*) **3.** *перен.* тру́бка (*курительная*)

төтен *сущ.* **1.** 1) дым, дымо́к; чад || дымово́й; *аксыл ~* белёсый дым; *тәмәке ~е* таба́чный дым; *~ торбасы* дымохо́д; 2) дымо-; *~ юллыгы* дымохо́д; *~ йоткыч* дымопоглоти́тель **2.** *перен. разг.* 1) интригу́ющая весть, осужде́ние, сплетни; пересу́ды; *~ тарату* распространя́ть сплетни *о ком-л.* 2) осужда́ющий намёк; *эт кузе ~ белмәс* (*посл.*) бесстыжих глаз и дым неймёт (*букв.* соба́чий глаз не чу́вствует ды́ма) **3.** *ист.* «дым», двор, тя́гло (*единица счёта податного населения во многих древних государствах*); *~ башыннан* подымно, подво́рно; подымный, подво́рный; *йөз егерме ~* сто два́дцать податны́х дворо́в □ **~ кайтару (чыгару)** дыми́ть (*о печи с плохой тягой*); **~ салу** задыми́ть, надыми́ть, разложи́ть дым (ку́рево) (*для предохранения от заморозков, отпугивания насекомых и т. п.*); **~ салымы (налогы)** *см.* **төтен** 3 ◊ **~ булып очу** исче́знуть, рассе́яться (*словно дым*); **~ җибәрү** пусти́ть пыль (дым) в глаза́; **~ очыру** **1.** кури́ть **2.** *см.* **төтен җибәрү**; **~ тавы** возду́шный за́мок (*невозможные, неосуществимые обещания, планы, мечты и т. п.*); **~ чигү (чыгару)** **1.** кури́ть таба́к **2.** жить в своём до́ме, вести́ своё хозя́йство; **~ (~ генә) чыга** **1.** то́лько дым идёт столбо́м (*о горячей работе*) **2.** живёт потихо́ньку; *тамак тук, өс бөтен, авыздан чыга ~* живём — не ту́жим (*букв.* сы́ты, обу́ты-оде́ты и изо рта дым идёт); сыт, пьян и нос в табаке́; **~ чыкканчы** *прост.* до упа́ду (*о пляске*), до кро́ви и́з носу (*о работе*), до бе́лой горя́чки (*о пьянстве*); **~е йөри** понима́ет толк (*в чём-л.*), смы́слит; **~е кыек** врёт, привира́ет, пыта́ется обма́нывать; **~е туры (чыга, йөри)** говори́т ве́рно, пра́вильно, и́скренне, не врёт; *~нән котылып, утка төшү* из огня́ да в по́лымя

төтенләнү **1.** *страд.-возвр. от* **төтенләү**; продыми́ться, быть охва́ченным ды́мом **2.** *см.* **төтенләү**; *ике кисәү башы кырда да ~ә* (*посл.*) две головни́ и в по́ле дымя́тся

төтенләтү *перех. см.* **төтәтү**

төтенләү *неперех.* **1.** дыми́ть; дыми́ться; *поход кухнясы ~эргә тотынды* похо́дная ку́хня ста́ла дыми́ть; *ераста нидер ~и* вдали́ что́-то дыми́тся **2.** чади́ть; *лампа бик ~и* ла́мпа си́льно чади́т **3.** кури́ть, пуска́ть струю́ ды́ма, па́ра и т. п.; *~әп торган вулкан* куря́щийся вулка́н **4.** *редко см.* **төтәсләү**

төтенле *прил.* **1.** ды́мный, продымленный; *~ бүлмә* продымленная ко́мната **2.** дымя́щийся, чадя́щий; *~ утын* чадя́щие дрова́ □ **~ дары** ды́мный по́рох

төтенлек *сущ. диал.* ды́мник, ды́мница, га́зовая ка́мера (*помещение для окуривания тела чесоточной лошади; при этом её голова остаётся снаружи*)

төтенсез *прил.* бездымный; *~ ялкын* бездымное пла́мя; *~ һава* бездымный (чи́стый) во́здух □ **~ дары** бездымный по́рох ◊ **~ авыл** кла́дбище (*букв.* аул без ды́ма)

төтенсу *прил.* ды́мчатый; цве́та ды́ма (тума́на); *~ тукыма* ды́мчатая ткань; *см.* **төтрә**

төтенсулану *неперех.* станови́ться/стать ды́мчатым; *~ган офык* ста́вший ды́мчатым горизо́нт

төткәз|ү *неперех.* **1.** бе́режно носи́ть (*одежду, обувь*), бе́режно расхо́довать; *яңа елга кадәр ~ү* расхо́довать (носи́ть) так, что́бы хвата́ло (держа́лось) до но́вого го́да **2.** напаса́ться/напасти́сь *чего*; обеспе́чивать/обеспе́чить (*всё время*) || обеспе́чивание, обеспече́ние; *аңар аяк киеме ~еп булмый* ему́ не напасёшься о́буви

төткәртү *перех. диал.* эксплуати́ровать (*орудие труда*)

төткәр|ү *перех. диал. см.* **төткәзү**; *күпкә (озак) ~ү* до́лго и бе́режно расхо́довать

төтрә *диал.* **1.** *сущ.* негусто́й тума́н; мгла, ма́рево, ды́мка; *офыктагы ~* жи́дкий тума́н на горизо́нте **2.** и́зморось, ме́лкий до́ждик || *прил.* **1.** не́сколько тума́нный; ды́мчатый; *~ томан* ды́мчатый тума́н **2.** ме́лкий, состоя́щий из ме́лких (мельча́йших) ка́пелек; *~ яңгыр* ме́лкий дождь

төтрәләнү *неперех. диал.* **1.** тума́ниться, затума́ниваться, зати́гиваться тума́ном, ды́мкой; *~еп күренә* виднеется в ды́мке (*затянутый дымкой*) **2.** тума́ниться, затума́ниваться (*о глазах*); *кинәт ~де күз алды* вдруг затума́нилось пе́ред глаза́ми (*букв.* то, что пе́ред глаза́ми); потемне́ло в глаза́х

төтрәләү *неперех. диал. см.* **төтрәү**

төтрәле *диал. прил.* **1.** покры́тый зы́бким тума́ном; тума́нный; *~ ераклык* тума́нная даль **2.** моросящий ме́лкими ка́пельками **3.** *перен.* нея́сный, нечёткий, расплы́вчатый || *нареч.* нея́сно, нечётко; ка́к бы в тума́не

төтрә|ү *неперех. диал.* **1.** колеба́ться в тума́не; виднеться в зы́бкой ды́мке; *урман ~п күренә* лес виднеется в зы́бкой ды́мке **2.** ме́лко моросить

төтсендер|ү *перех. диал.* **1.** *см.* **төтрәтү** 2. дава́ть/дать почу́вствовать; отрезвля́ть; *бу хәбәр аны ~де* э́та весть его́ (сра́зу) отрезви́ла

төтсен|ү *неперех. диал.* **1.** *см.* **төтрәну, төтрәү** 2. отрезвля́ться/отрезви́ться

төт|ү *неперех. преимущ. в негативной ф.* **төтмәү** 1) (*надолго*) хвата́ть (*о продуктах и т. п.*); *озак ~мәс, бетер* ненадо́лго хва́тит, зако́нчится 2) (до́лго) держа́ться, служи́ть (*о вещах, орудиях и т. п.*)

төф *подр.* тьфу

төфелдәтү *перех.* (*смачно*) выплёвывать/вы́плюнуть (*лузгу, когда грызут семечки*)

төфелдәү *неперех.* беспрестáнно звýчно плевáть; звýчно плевáться

төфкерү *неперех. разг. см.* **төкерү**

төф-төф (төф тә төф) *подр. беспрестанным плевкам; төф-төф төкеренә* беспрестáнно плюётся

төһмәт *сущ. уст.* клеветá, поклёп; навéт, доно́с □ **~ итү (кылу)** клеветáть, наводи́ть поклёп, доноси́ть

төч *подр. звучному выплёвыванию, выцеживанию сквозь зубы* □ **төч иттереп** смáчно вы́цедив сквозь зýбы (*о плевке*)

төче I *прил.* **1.** 1) прéсный; не солёный; *~ су* прéсная водá 2) прéсный, не ки́слый; *~ камыр* прéсное тéсто **2.** сладковáтый, подслащённый; при́торно-слáдкий; *~ ашамлык* подслащённая едá **3.** *перен.* слащáвый, при́торный; *~ тел (сүз)* слащáвая речь (слóво); *~ караш* слащáвый взгляд; *~ тавыш (тон)* при́торный гóлос (тон) || *сущ.* **1.** слáдость, слащáвость; при́торно-слáдкий вкус (*съедобного*); *бер ~се дә юк* ни малéйшей при́торности **2.** *преимущ. в паре со словом* **ачы** гóречь; рáдости, утéхи жи́зни; *тормышның ачысын күп татыдым, ~сен күрмәдем* мнóго я испытáл гóречи в жи́зни, да не ви́дел (не пережи́л) рáдостей □ **~ авыруы** золоту́ха; **~ коймак** *кулин.* прéсные олáдьи; **~ күмәч** *кулин.* прéсные пы́шки; **~ (татлы) тамыр** *бот.* лакри́ца; солóдка; **~ торма** *см.* **гәрәнкә**; **~ үлән (ут)** *см.* **төчүләп**; **~ чия** черéшня; ◊ **~ корсак** *см.* **тәмле тамак**

төче II *сущ.* **1.** волчáнка; золоту́ха, кóжный туберкулёз **2.** геморрóй **3.** *редко* си́филис □ **~ булган** заболéл волчáнкой (золоту́хой); **~ чире (авыруы)** *см.* **төче II** 1

төчегән *сущ. диал. см.* **төчлегән** □ **~ атнасы** *этногр.* агрáрный прáздник, проводи́мый с 15 по 25 ию́ня (*перед летним солнцестоянием*)

төчек *сущ. диал.* древéсный сок мéжду корóй и стволóм (*дерева*)

төчеләндергеч *прил.* опресни́тельный; *~ аппарат* опресни́тельный аппарáт

төчеләндер|ү *перех.* **1.** опресня́ть/опресни́ть **2.** *прям., перен.* дéлать/сдéлать пря́ным, слащáвым, при́торным; *сүзләрен ~еп сөйләү* говори́ть, послáстив (свой) словá

төчелән|ү *неперех.* **1.** опресня́ться/опресни́ться || опреснéние (*само собой*); *яңгырдан соң диңгез өсте ~ә* пóсле дождя́ повéрхность мóря опресня́ется **2.** слащáво, при́торно говори́ть, обращáться || слащáвость; подслáщивать/подласти́ть речь; *~еп сөйли* слащáво говори́т; *~ү белән кечеләнү бер түгел* (*посл.*) слащáвость и скрóмность не одно́ и то́ же

төчеләтү *перех. см.* **төчеләндерү**

төчеле *прил. см.* **төчкелтем**

төчеле|к *сущ.* **1.** *в разн. знач.* прéсность **2.** *перен.* слащáвость, при́торность (*речи, обращения, улыбки и т. п.*); *~ге белән биздерү* отвращáть своéй слащáвостью

төче-мөче *прил.* вся́кий прéсно-слáдкий, не ки́слый (*солёный*); *төче-мөче тәм* прéсно-слáдкий вкус || *сущ.* вся́кое прéсно-слáдкое; *төче-мөче ашау* есть вся́кое прéсно-слáдкое

төчен|ү *неперех. диал.* **1.** услáждаться, наслáждаться || услáда, услáждение (*себя*) **2.** *перен. см.* **төчеләнү** 2; *~мә инде* не подслáщивай (свои́ словá)

төчерәйтү *понуд. от* **төчерәю**

төчерәю *неперех.* **1.** опресня́ться/опресни́ться || опреснéние **2.** выдыхáться (*о вине и т. п.*)

төчерткеч *сущ.* опресни́тель

төчерт|ү *перех.* **1.** опресня́ть/опресни́ть **2.** солоди́ть, осолáживать; *торманы тоз белән ~әләр* (*посл.*) пожáр унимáют огнём (*букв.* рéдьку солодя́т сóлью) **3.** подсолáживать/подсолоди́ть || соложéние тéста; *камыр ~әм* подсолáживаю тéсто

төчер|ү *неперех.* **1.** *см.* **төчеләнү 2.** подсолáживаться/подсолоди́ться || подсоложéние (*теста*)

төчет|ү **1.** *перех. см.* **төчертү 2.** *перен.* дóлго спать, отсыпáться (*после бессонницы и т. п.*)

төчкелт *прил. уменьш. от* **төче**; сладковáтый, пресновáтый; *~ ис* сладковáтый зáпах

төчкелтем *прил.* **1.** *см.* **төчкелт 2.** *перен.* слáденький, слащáвенький (*о словах, глазах, улыбке и т. п.*); *хатта ~ сүзләр күп иде* в письмé бы́ло мнóго слащáвеньких слов

төчкерек *сущ.* чих, рáзовое чихáнье; *сүзеңә ~* подтверждéние твоим словáм — чих (*это говорится в силу поверья, по которому чиханье вызывается при верных словах*) □ **~ уты (үләне)** чихóтная травá

төчкеренү *неперех.* расчихáться, зачихáться

төчкерт|ү **1.** *понуд. от* **төчкерү**: застáвить чихáть, вызывáть/вы́звать чи́ханье (чих) **2.** *перех. перен.* задирáть/задрáть *кого*; потревóжить; *~им әле мин аны* потревóжу-ка я егó (*немножко*) **3.** *перен. разг.* стреля́ть, пальнýть (*из автомата*)

төчкер|ү *неперех.* **1.** чихáть, зачихáть, чихнýть || чихáнье; чих **2.** *перен. редко* очýхаться, отрезви́ться (*после незаслуженных, лёгких успехов*) □ **~еп кую** чихнýть

төчлегән *сущ. биол.* зáболонь; кáмбий; *каен ~е* берёзовая зáболонь □ **~ коңгызы** *зоол.* жук-заболóнник

төч|ү *неперех.* **1.** становúться/стать прéсным, опреснúться || обпреснéние **2.** *см.* **төчерү** 2. **3.** выдыхáться/вы́дохнуться (*о чём-л. квашеном, кислом, о вине, квасе и т. п.*); *~егән сыра* вы́дохшееся пи́во **4.** *перен.* становúться/стать прéсным, банáльным, неинтерéсным; *~егән вәгазь* прéсная прóповедь **5.** *перен.* размякáть/размя́кнуть (*душой*); впадáть/впасть в сентимента́льное, прéсное настроéние; ударя́ться/удáриться в лири́зм; *мин бераз ~еп киттем* я немнóжко размя́к

төчүләп *сущ. бот.* чистотéл, бородáвник

төш I *сущ.* **1.** сон; сновидéние; *төштә күрү* ви́деть во сне; *төш күрү* ви́деть сон; сновидéние; *өндә дә, төштә дә* и во сне и наяву́; *төшен сөйләде* рассказáл (про свой) сон **2.** *перен. редко* сон, мечтá; мирáж; *төш кенә бит бу* э́то ведь тóлько сон (*не надо волноваться*) □ **төш кую** *см.* **истихарә кылу**; **төш тәгъбире 1.** толковáние сна **2.** *см.* **тәгъбирнамә, төшлек китабы**; **төш юрагыч** *см.* **тәгъбирнамә**; **төш юрау** толковáть сон; **төшкә керү** сни́ться; являться во сне; *төшемә керде* мне присни́лся; я ви́дел во сне (*кого-л. из близких*) ◊ **төш кебек (кенә), төш шикелле (генә)** как далёкий сон; **төшемә дә кермәгән** и во сне не сни́лось; не вéдал ни сном, ни дýхом; **төшеңә (дә) кермәсен** не дай бог, чтóбы сни́лось; не приведи́ бог уви́деть (*о чём-л. отвратительном, ужасном*); **төштә күргән кебек (шикелле, сыман)** как во сне; как сон; смýтно, туманно

төш II *сущ.* **1.** пóлдень; *төш җитте* ужé пóлдень; *төшкә таба* к полу́дню **2.** *уст.* юг; *төш ягында* на ю́жной стороне́; в стороне́ ю́га **3.** *диал. в знач. послелога* **төшендә** за, в течéние; *бер атна төшендә* за недéлю; в течéние недéли || *прил. разг.* ю́жный, полу́денный; *төш якта* на полу́денной стороне́; *төш ягыннан килгән болыт* ту́ча (появи́вшаяся) с полу́денной стороны́ || *редко нареч.* в пóлдень; *төш килмәсә, кич килер* придёт éсли не в пóлдень, то вéчером □ **төш авышкач** за́ пол-

день; **төш вакыты** по́лдень, полу́денное вре́мя; *төш вакытында* в по́лдень; **төштән соң** 1) по́сле полу́дня 2) *перен.* по́сле пожа́ра, за́дним число́м; за́дним уме́м; на ша́почный разбо́р; *татар акылы төштән соң (посл.)* тата́рин за́дним уме́м кре́пок

төш III *сущ.* **1.** 1) ядро́, я́дрышко (*ореха и т. п.*); *см. тж.* **төш** 2; 2) *физ.-хим.* ядро́, я́дрышко || я́дерный; *атом төше* а́томное ядро́; *күзәнәк төше* ядро́ кле́тки (*живого организма*); *төш физикасы* я́дерная фи́зика **2.** *перен.* суть, соль (*вопроса, анекдота*); отга́дка □ **төш кисәкчәсе** *физ.* части́ца ядра́, я́дерная части́ца; **төш көчләре** я́дерные (внутриа́дерные) си́лы; **төш реакторы** я́дерный реа́ктор; **төш чүмече** дуршла́г; *см. тж.* **сөзгеч, чулпы** ◊ **төш кебек** драгоце́нный, взлеле́янный; **төш кебек бала** драгоце́нный (еди́нственный) ребёнок; **төш кенә** (*о чём-л. ценном, качественном*) чи́стое зо́лото, квинтэссе́нция; *кечкенә дә төш кенә* мал золотни́к, да до́рог

төш IV *сущ. диал.* **1.** 1) ме́сто, определённая то́чка; *шушы төштә* на э́том ме́сте 2) определённое вре́мя; *без кайткан төшкә* к на́шему возвраще́нию (*к тому времени, когда мы вернёмся*) **2.** сторона́, отноше́ние; *кай төше беләндер этисенә охшый* че́м-то похо́ж на своего́ отца́; *мәсьәләнең бу төше* э́та сторона́ вопро́са □ **төш булу (килү)** *см.* **туш булу (килү)**

төшек *прил. редко* пони́женный, понижа́ющийся; *батык, ~ җирләрдә бәшмәк булыр, балакай (песня)* в места́х ни́зменных и пони́женных и бу́дет гриб, де́точка

төшел|ү *безличн. от* **төшү**; приходи́ться/прийти́сь спуска́ться/спусти́ться; *таудан озак ~де* пришло́сь до́лго спуска́ться с горы́

төшем I *сущ.* **1.** умоло́т, намоло́т; *игеннәрнең ~е яхшы* умоло́т хлебо́в хоро́ш **2.** *перен. разг.* при́быль, мзда, вы́года, барыш; поступле́ние, дохо́д; *бераз гына ~ дә кала* немно́го остаётся и мзды

төшем II: **~ килеше** вини́тельный паде́ж; *сущ. лингв. уст.* □ **төшем җөмлә** *уст.* дополни́тельное предложе́ние; **төшем тәмамлыгы** *уст.* прямо́е дополне́ние; **төшем юнәлеше** страда́тельное наклоне́ние

төшемле *прил.* **1.** с хоро́шим умоло́том; урожа́йный; *~ арыш* рожь с хоро́шим умоло́том **2.** при́быльный, дохо́дный; *~ кәсеп* при́быльный про́мысел

төшемлелек *сущ.* **1.** ка́чество умоло́та; намоло́т **2.** при́быльность, дохо́дность (*дела, ремесла, промысла*)

төшемсез *нареч. и прил.* **1.** с плохи́м умоло́том; без умоло́та **2.** без при́были, дохо́да, дохо́дности; *~ кайтты* верну́лся без при́были; *~ кәсеп* беспри́быльное ремесло́

төшендер|ү *перех.* разъясня́ть/разъясни́ть *кому-л.*; растолко́вывать/растолкова́ть, втолко́вывать || разъясне́ние, растолко́вывание, втолко́вывание; *кыскача ~ү* ко́ротко разъясни́ть (втолкова́ть); *~ә алу* суме́ть объясни́ть □ **~еп бирү** (*до конца*) разъясни́ть, растолкова́ть

төшенекле *прил. диал.* поня́тный и досту́пный; *сүзең ~ булсын* сло́во твоё должно́ быть поня́тным и досту́пным

төшенке *прил.* **1.** пока́тый (*о плечах*); *~ иңбашлы* с пока́тыми плеча́ми **2.** *диал.* ни́зкий, ни́зенький (*о надворных постройках*); *~ лапас* ни́зенький наве́с **3.** *перен.* 1) упа́дочный, пода́вленный; пессимисти́ческий, пессимисти́чный; *~ күңел* пода́вленная душа́; *~ рух* упа́дочный дух 2) мино́рный; присмире́вший; *~ тавыш* мино́рный го́лос; *~ кыяфәт* присмире́вший вид || *нареч.* пода́вленно, пессимисти́чно; мино́рно (мино́рным го́лосом); *~ генә әйтте* сказа́л пода́вленно (пода́вленным го́лосом)

төшенкелән|ү *неперех.* станови́ться/стать пода́вленным, упа́дочным, пессимисти́чным, мино́рным (*о голосе*); *~еп китте* он стал (совсе́м) пода́вленным

төшенкелек|ү *сущ.* **1.** пока́тость (*плеч*) **2.** *перен.* 1) пода́вленность, пессими́зм, пессимисти́чность; *күңел ~генә бирелмә* не допуска́й пода́вленности души́ 2) мино́рность (*голоса*); *тавышның ~ге* мино́рность го́лоса **3.** (*об общественных явлениях*) упа́док, упа́дочность; *иҗтимагый фикернең ~ге* упа́дочность обще́ственной мы́сли

төшенчә *сущ.* **1.** *разг.* поня́тие, представле́ние *о чём-л.*; *намус турында ~ң бармы?* есть ли у тебя́ поня́тие о че́сти? **2.** *лог.* поня́тие; *күппочмак ~се* поня́тие многоуго́льника; *үзкыйммәт ~се* поня́тие себесто́имости

төшен|ү *неперех.* **1.** понима́ть/поня́ть || понима́ние; доходи́ть/дойти́ (до су́ти); вника́ть/вни́кнуть; *яхшы ~ү* хорошо́ вни́кнуть **2.** осмы́сливать, постига́ть || осмы́сливание, постиже́ние; *кайгы ни икәненә ~де* пости́г, что тако́е го́ре **3.** *в знач. прил.* **төшенерлек** дохо́дчивый; *~ерлек итеп сөйләү* дохо́дчиво говори́ть **4.** *в знач. прил.* **төшенмәслек** непостижи́мый

төшергеч *сущ.* **1.** переводна́я карти́нка **2.** копи́рка, копирова́льная бума́га || *прил.* переводно́й; копирова́льный; *~ кәгазь* копирова́льная бума́га

төшерелмә: төшерелмә дифтонг *лингв.* нисходя́щий дифто́нг

төшерел|ү *страд. от* **төшерү** *знач.* 1—10, 13—12; *аска ~де* был спу́щен вниз; *пароходтан ~де* был сса́жен с парохо́да; *патша ~де* царь был низло́жен; *рәсемгә (фотога) ~гән* нарисо́ванный (сфотографи́рованный); *хакы (бәясе) ~гән товарлар* това́ры по сни́женным це́нам

төшереш *сущ. редко* низложе́ние, сверже́ние; *патша ~ уйнадык* мы игра́ли в сверже́ние царя́

төшерешү *взаимно-совм. от* **төшерү** опуска́ть, спуска́ть друг дру́га; помога́ть опуска́ть (спуска́ть)

төшерттерү *понуд. от* **төшертү**

төшертү *понуд. от* **төшерү** веле́ть и́ли заста́вить опуска́ть, снима́ть и т. п.

төшер|ү **1.** *понуд. от* **төшү** *в знач.* 1—10, 20—25, 28—30; *печәнгә ~ү* направля́ть на сенока́с (*бригаду*); *укырга ~ү* посыла́ть в шко́лу; посади́ть за па́рту **2.** 1) опуска́ть/опусти́ть, спуска́ть/спусти́ть; *караваттан ~ү* помо́чь слезть с крова́ти (*ребёнку*); *пәрдәләрне ~ү* опуска́ть што́ры; *байрак ~ү* спусти́ть флаг 2) спуска́ть/спусти́ть || спуск, спуска́ние, спуще́ние (*по реке, по эскалатору и т. п.*); *сал ~ү* спуск спла́ва, сплавле́ние плото́ **3.** 1) роня́ть/уронить; *чиләкне коега ~ү* уронить ведро́ в коло́дец 2) *перен.* роня́ть/уронить; подрыва́ть/подорва́ть; *авторитетын ~ү* роня́ть (уронить) авторите́т **4.** *перен.* 1) снима́ть/снять, смеща́ть/смести́ть || сня́тие, смеще́ние с до́лжности; *председательлектән ~ү* снима́ть с председа́тельства 2) свергать/све́ргнуть, низлага́ть/низложи́ть || сверже́ние, низложе́ние (*монарха и т. п.*) **5.** *перен.* опуска́ть/опусти́ть, сокраща́ть/сократи́ть || сокраще́ние (*текста и т. п.*); *монысын ~ергә дә мөмкин* э́то мо́жно и опусти́ть **6.** *в разн. знач.* сса́живать, высаживать/вы́садить || сса́живание, высаживание, вы́садка; *поезддан ~деләр* ссади́ли с по́езда; *десант ~ү* вы́садка деса́нта **7.** *перен.* спуска́ть/спусти́ть || спуск, спуска́ние (*приказов, нарядов, указаний по иерархической лестнице*); *директива ~ү* спуск директи́вы (*низовым организациям*) **8.** *перен. разг.* дать, (*хлёстко*) ударя́ть; вы́пать; сту́кнуть; *яңагына ~ү (хлёстко)* уда́рить по щеке́ **9.** направля́ть/напра́вить, ки́нуть, бро́сить (взгляд); *күзен (кара-*

шын) ~де он ки́нул взгляд **10.** наводи́ть/навести́ || наведе́ние (*тени, блика, света и т. п.*); *диварга күләгә ~у* наводи́ть тень на сте́ну **11. 1)** наноси́ть/нанести́, выводи́ть/вы́вести || нанесе́ние, выведе́ние (*знаков*); рисова́ть/нарисова́ть || рисова́ние; *өй сурәте ~у* наноси́ть (нарисова́ть) ко́нтуры до́ма; *тамга ~у* наноси́ть (выводи́ть) тавро́; *чәчәкләр ~еп чигү* вышива́ть цветы́ (*на ткани*) 2) фотографи́ровать/сфотографи́ровать || фотографи́рование 3) снима́ть/снять (*кинофильм и т. п.*) **12.** заполучи́ть (*в руки*); доста́вить/доста́ть || заполуче́ние, доставáние; *каян ~дең син моны?* отку́да ты доста́л э́то (*эту вещь*) **13.** *прост.* зараба́тывать/зарабо́тать; подзараба́тывать/подзарабо́тать, заколáчивать/заколоти́ть || зараба́тывание, подзараба́тывание; *аена күпме ~әсең* ско́лько заколáчиваешь в ме́сяц? **14. (...га ~у)** израсхо́довать, влага́ть/вложи́ть || израсхо́дование, вложе́ние (*определённого количества денег*); *ун меңгә ~еп* вложи́в де́сять ты́сяч **15.** де́лать ударе́ние (*в речи*); *басымны икенче иҗеккә ~у* де́лать ударе́ние на второ́м сло́ге **16.** принима́ть/приня́ть, пуска́ть/пусти́ть || приём (*гостей, постояльцев, жильцов и т. п.*); *фатирга ~у* приня́ть на кварти́ру (*на ночлег*) **17.** *в разн. знач.* понижа́ть/пони́зить, снижа́ть/сни́зить || понижéние, снижéние *чего*; *бәясен ~еп сату* продава́ть, снижáя це́ну; прода́ть по сни́женным це́нам; *тавышын ~у* снижáть го́лос (тон) **18.** (*торжественно*) принима́ть/приня́ть || (*торжественный*) приём; *кунак ~деләр* (*торжественно*) принимáли госте́й; *килен ~дек* (*торжественно*) при́няли сноху́ **19. (~га ~у) 1)** навлека́ть/навле́чь; *хурлыкка ~у* навлека́ть позо́р 2) обрека́ть/обре́чь; повергáть/пове́ргнуть || обречéние *на что; кайгыга ~у* повергáть в го́ре (го́рестное состоя́ние); *коллыкка ~у* обрека́ть на ра́бство; *шиккә ~де* пове́рг (его́) в сомне́ние **20.** зарони́ть/зарони́ть *что*; вызыва́ть/вы́звать || вы́зов определённого состоя́ния; *арага салкынлык ~у* зарони́ть прохлáдность, вызывáть холодо́к в отноше́ниях; *шик ~у* вызывáть подозре́ние, зарони́ть сомне́ние **21.** *перен. жарг.* закла́дывать/заложи́ть; пропусти́ть; выпивáть/вы́пить; *берәрне ~егез әле* пропусти́те-ка по одно́й (*рюмке*) □ **~еп алу 1.** сфотографи́ровать; снять/засня́ть (*на фотокарточку*) **2.** *разг.* (хорошéнько) вы́пить; заложи́ть; **~еп җибәрү** вы́ронить, уронúть

төшерүле *предик. прил.* в опу́щенном состоя́нии, опу́щено; *пәрдә ~* за́навес опу́щен

төшке *прил.* обéденный; полдне́вный, полу́денный; *~ ял* обéденный переры́в; *~ аш* обéд; *~ эссе(лек)* полу́денная жара́

төшкелек *сущ.* **1.** по́лдник, обéд; то, что предназна́чено на обéд; *~не ашау* съедáть, съесть обéд **2.** *диал.* обéденный переры́в || *прил.* обéденный; *см.* **төшке**; *~ чәй* полдне́вный чай

төшкен *прил.* **1.** пони́женный; *~ басым* пони́женное давлéние **2.** *диал. см.* **төшенке**

төшкенлек *сущ. диал. см.* **төшенкелек**

төшләнү I *неперех.* **1.** страда́ть ненорма́льными, навя́зчивыми сновиде́ниями || ненорма́льное сновиде́ние; *~еп гаҗиз булды* совсе́м исстрада́лся сновиде́ниями **2.** *в знач. сущ. мед.* поллю́ция

төшләнү II *неперех.* образовáться || образовáние ядра́ плода́; *~ә башлаган чикләвекләр* оре́хи, у кото́рых на́чали образо́вываться я́дра

төшле *прил.* с ко́сточками, име́ющий ко́сточки; *~ йөзем* виногра́д с ко́сточками; *~ төшендә* (*погов.*) ка́ждый на своём ме́сте; *~ төшендә булсын* пусть ка́ждый зна́ет своё ме́сто; пусть ка́ждый сверчо́к зна́ет свой шесто́к

төшлек I *сущ.* со́нник (*книга толкований снов*); *~ карату* попроси́ть толкова́ть сон по со́ннику (*у грамотея, толкователя*) || *прил.* гада́ющий, толку́ющий сны; *~ әби* ба́бушка, толку́ющая сны; толкова́тельница снов □ **~ салдыру** *этногр.* зака́зывать/заказа́ть (свято́й) сон *о ком-л.* (*который толкуется чаще всего этим же святым*)

төшлек II *сущ.* **1.** по́лдень (*как самое высокое положение солнца в любой день*); *кояш ~тән авышкан* со́лнце перевали́ло за́ полдень **2.** по́лдень как юг, ю́жная сторона́; *~ ягы* полу́денная сторона́ **3.** *см.* **төшкелек** □ **~ сызыгы** полу́денная ли́ния

төшлекче *сущ.* толкова́тель (толкова́тельница) снов

төшле-өнле *прил.* полусо́нный, дремо́тный; *төшле-өнле хәлдә* в полусо́нном состоя́нии

төшмә *прил.* нисходя́щий; *~ линия* нисходя́щая ли́ния

төшмәле *прил. разг. см.* **төшмә** □ **~ түгел** невозмóжно спусти́ться; *бу сукмактан ~ түгел* по э́той тропи́нке невозмóжно спуска́ться

төштәге *прил.* сни́вшийся, сня́щийся; тако́й, кото́рый ви́дится во сне; *~ очыш* полёт во сне

төш-төлек *сущ. собир. разг.* вся́кие сновиде́ния; *төш-төлеккә ышану* ве́рить вся́ким сновиде́ниям

төш|үү *перех.* **1. 1)** спуска́ться/спусти́ться || спуск; *агым белән ~у* спуска́ться по тече́нию; *җиргә ~у* спусти́ться на зе́млю 2) опуска́ться/опусти́ться; *кояш офыкка ~те* со́лнце опусти́лось за горизо́нт **2.** снижáться/сни́зиться, приземля́ться/приземли́ться || снижéние, приземлéние (*самолёта*) **3.** 1) сходи́ть/сойти́ || сход (вниз); слеза́ть/слезть; *ул арбадан ~те* он сошёл с теле́ги; *поезддан ~тем* я сошёл с по́езда 2) сходи́ть, съе́здить; *вокзалга ~у* сходи́ть (съе́здить) на вокза́л (*находящийся в нижней части города*) **4.** 1) па́дать/упа́сть || паде́ние; сва́ливаться/свали́ться; выпада́ть/вы́пасть; *алма пеш, авызга ~* (*погов.*) налива́йся, я́блоко, и па́дай (пря́мо) в рот; *кесәдән ~кән ул* оно вы́пало из карма́на 2) (*неторопливо*) па́дать (*об осадках*); *кар ~ә* па́дает снег (*при обильных осадках говорится: ява*) 3) па́дать (*о лучах света, о тени*); *күләгә ~кән урын* ме́сто, куда́ па́дает тень; *якты күзгә ~те* луч све́та упа́л на глаза́ **5.** снижáться, понижáться || снижéние, понижéние (*температуры, цен*); *авыруның температурасы ~кән* температу́ра у больно́го пони́зилась; *бәяләр ~у* снижéние цен **6.** па́дать, опуска́ться/опусти́ться, ниспада́ть; сползáть || сползáние (*с места — о различных предметах*); *кепкасы күзенә ~кән* его́ ке́пка сползла́ на глаза́ **7.** 1) выпада́ть/вы́пасть || выпадéние; *теше ~кән* у него́ вы́пал зуб 2) *перен.* выпада́ть/вы́пасть (*из поля зрения и т. п.*); *ул игътибардан ~те* он вы́пал из по́ля внима́ния (*т.е. его авторитет пал*) **8.** выпада́ть/вы́пасть (*что-л., на какую-л. поверхность*); появля́ться/появи́ться, образовáться || выпадéние, появлéние, образовáние *чего-л. на какой-л.* пове́рхности (*пятен другого цвета*); выступа́ть/вы́ступить; *ак ~те* появи́лось (вы́ступило) бельмó; *битенә сары ~кән* на его́ лице́ появи́лась желтизна́; *тимергә тут ~кән* на желéзе появи́лось ржáвое пятнó (ржáвчина) **9. 1)** опуска́ться/опусти́ться (*о тумане и т. п.*); *болыннарга томан ~кән* на луга́ опусти́лся тума́н 2) оседáть/осéсть (*о росе*); *яфракларга чык ~кән* на ли́стья осéла роса́ **10. 1)** (*определённым образом*) накла́дываться, наноси́ться (*о мазях, косметике*); *пудра әйбәт ~ә иде* пу́дра наноси́лась хорошó; *буяу әйбәт ~кән*

кра́ска нанесена́ хорошо́ 2) отпеча́тываться/отпеча́таться (на пове́рхности); *акка кара ~кэн* (*погов.*) чёрное отпеча́талось на бе́лом (*говорится о клеветническом писании, о доносе, о несправедливом судебном решении*) **11.** появля́ться/появи́ться, устана́вливаться/установи́ться ‖ появле́ние, установле́ние (*дорог*); *юл ~кэч* по́сле того́, как появи́тся доро́ги (*после весенней распутицы*) **12. (-га, ~ү)** снима́ться/сня́ться (*на фото, в кино*); *фотога ~тек* мы сфотографи́ровались **13.** *перен.* 1) выпада́ть/вы́пасть (*на долю*); обру́шиваться/обру́шиться (*на голову*); *башыма ~кэн бэлалэр* бе́ды, кото́рые обру́шились на мою́ го́лову 2) возлага́ться/возложи́ться *на кого; объявля́ться обя́занностью кого; ат карау миңа ~э* ухо́д за лошадьми́ возлага́ется на меня́ (явля́ется мое́й обя́занностью) **14.** наступа́ть/наступи́ть; опуска́ться/опусти́ться (*о сумерках и т. п.*); *караңгы ~кэч* когда́ насту́пит ночь (темнота́); *эңгер ~те* спусти́лись су́мерки **15.** напа́сть, попа́сть (*на дорогу и т. п.*); *эзгэ ~тем* попа́л на след **16.** устана́вливаться/установи́ться *у кого-л.* устра́иваться/устро́иться (*в гостинице*); *шэһэргэ баргач, танышларга ~тем* прие́хав в го́род, установи́лся у знако́мых **17.** выходи́ть/вы́йти ‖ вы́ход за́муж; *туган җирем алтын, ~кэн җирем көмеш* (*погов.*) ме́сто, где я родила́сь (и вы́росла), золото́е, ме́сто, куда́ я вы́шла за́муж, серебряное (*говорится и наоборот*) **18.** прокра́дываться/прокра́сться; та́йно влеза́ть/влезть, залеза́ть/зале́зть (*с целью грабежа, кражи*); *караклар амбарга ~те* во́ры прокра́лись в амба́р; *бакчага ~ү* залезть в чужо́й сад **19.** напа́сть во мно́жестве (*о вредителях*); *алмагачка корт ~кэн* на я́блоню напа́ли гу́сеницы; *киемгэ көя ~кэн* на оде́жду напа́ла моль (оде́жда изъе́дена мо́лью) **20.** сбива́ться/сби́ться (*о масле*); *язмасаң, май да ~ми* (*погов.*) не бу́дешь сбива́ть, (да́же) и ма́сло не собьётся **21. (-га ~ү)** обходи́ться/обойти́сь *во что; бу эш миңа кыйбат(ка) ~те* э́то де́ло мне обошло́сь до́рого **22.** располага́ться/расположи́ться ‖ расположе́ние; занима́ть/заня́ть ‖ заня́тие (*определённой позиции, положения*); *юлга аркылы ~ү* расположи́ться (встать) поперёк доро́ги; *караватка буй ~еп йоклау* спать, расположи́вшись (*вдоль*) на крова́ти **23. (-га ~ү)** 1) приступа́ть/приступи́ть *к чему*; начина́ть/нача́ть (*сельскохозяйственные работы*); *уракка ~тек* мы на́чали жа́тву; *алар чэчүгэ ~телэр* они́ приступи́ли к се́ву 2) приступа́ть/приступи́ть к изуче́нию *чего-л.; сабакка (укырга) ~ү* идти́ в шко́лу (*букв.* приступа́ть к изуче́нию шко́льных дисципли́н); *фарсыга ~ү* приступа́ть к изуче́нию перси́дского языка́ (*в медресе*) **24. (-га ~ү,** *при субъекте*) 1) возника́ть/возни́кнуть, появля́ться/появи́ться, приходи́ть/прийти́ в го́лову и т. п. (*о мыслях, об идее*); *башыма бер фикер ~те* мне в го́лову пришла́ (*одна*) мысль; *күңеленэ шик ~те* в его́ ду́шу закра́лось сомне́ние 2) обуя́ть; *нинди дэрт ~те сиңа?* кака́я страсть тебя́ обуя́ла? **25. (-га ~ү,** *при объекте*); впада́ть/впасть в определённое (*психическое и т. п.*) состоя́ние; быть обурева́емым *чем-л.; шиккэ ~те* впал в сомне́ние; стал обурева́ться сомне́ниями; *хафага ~тем* я впал в беспоко́йство, в доса́ду; *уйга ~те* впал в раздумье (стал уси́ленно разду́мывать) **26.** *рел. прост.* 1) па́дать/пасть на го́лову (*о проклятии, наговоре и т. п.*); *бэддога ~те* па́ло (*на его голову*) прокля́тие; *каргышы ~те* па́ло его́ прокля́тие на го́лову *кого-то* 2) возде́йствовать (*о доброжелательных молитвах и т. п.*); *алланың рэхмэте ~те* воздала́сь бо́жья благода́ть **27.** гря́нуть, приключа́ться (*о необходимости, о напасти*); *ихтыяҗ ~те* нагря́нула нужда́; *йомыш (үтенеч) ~те* приключи́лось обраща́ться с про́сьбой **28. (-га ~ү)** попада́ть/попа́сть *в какое-л.* положе́ние; попада́ться, быть схва́ченным *кем-л.; коллыкка ~ү* попа́сть в ра́бство; *капкынга ~ү* попа́сть в капка́н; *бэлагэ ~ү* попа́сть в беду́ **29.** случа́ться/случи́ться (*о выкидыше*); выки́дываться/вы́кинуться (*о плоде*); *баласы ~те* у неё случи́лся вы́кидыш (*ребёнка*); *колыны ~ү* вы́кидыш жеребёнка (*у кобылы*) **30.** *см.* **бату**; *кубекэ ~ү* покры́ться пе́ной (*о лошади*); *тиргэ ~ү* покры́ться по́том **31.** *в отриц. ф.* **төшмәү** 1) быть всегда́ при себе́ (на себе́); *кулымнан корал ~мэде* ору́жие всегда́ бы́ло при мне; *җилкэсеннэн көянтэ ~ми* всегда́ на её плеча́х коромы́сло 2) не сходи́ть, быть всегда́ где́-либо на высо́ком ме́сте; *почёт тактасыннан ~ми* (он) не схо́дит с доски́ почёта **32.** *прост. редко* сбавля́ть/сба́вить це́ну (*во время торгов*); *тагын бер сумга ~те* сба́вил це́ну ещё на оди́н рубль **33.** *вспом. гл. с деепр. на* **-а/э, -ый-и** *другого гл. придаёт значение:* 1) *интенсификации действия; тавышын кутэрэ ~те* он (*ещё более*) повы́сил го́лос; *эшлэр тыгызлана ~те* дела́ ста́ли бо́лее напряжёнными 2) *частичного действия, процесса; авырлыгы кими ~кэн* вес его́ не́сколько поуба́вился **34.** *в функции вспом. гл. после частицы* **да(дэ)** *передаёт значение внезапности действия, обозначенного основным гл.; коелдым да ~тем* так и о́бмер; *егылдым да ~тем* так и полете́л (*верх тормашками*) **35.** *в ф. желат.* **төшкере:** пусть бы (*слово, офомляющее выражение с пожеланиями зла и добра*); *каргыш ~кере* пусть бы па́дало прокля́тие; *рэхмэт ~кере* пусть бы па́дала (пролила́сь) благода́ть □ **~еп калу** выпада́ть/вы́пасть ◊ **~еп калган 1.** недотёпа, неполноце́нный **2.** некаче́ственный, второсо́ртный; *~еп калган товар* второсо́ртный това́р; **~еп калганнардан түгел** не лы́ком шит; не ро́бкого деся́тка

төшчек *сущ.* **1.** *уменьш. от* **төш** (ядро́) **2.** *биол.* я́дрышко; часть сло́жного ядра́

төю I *перех.* **1.** толо́чь/растолочь, моло́ть; дроби́ть, кроши́ть ‖ толче́ние, дроблёние, кроше́ние; *тары төю* толо́чь про́со; *киндер төю* толо́чь (мять, трепа́ть) пеньку́ **2.** набива́ть/наби́ть ‖ наби́вка; запиха́ть/запихну́ть; вти́скивать/вти́снуть ‖ вти́скивание *во что; төрепкэ төю* набива́ть тру́бку **3.** *перен. груб.* ло́пать/сло́пать; набива́ть/наби́ть (брю́хо); поруба́ть; *малайлар төя генэ* ма́льчики так и набива́ют (брю́хо) **4.** *перен.* руби́ть, шинкова́ть (*овощи*) **5.** *перен. прост.* 1) колоти́ть, дуба́сить; бы́стро (*попеременно*) бить кулака́ми 2) бить, тузи́ть *кого, во что; башыңны төярмен* бу́ду тузи́ть по твое́й башке́ (*т.е. накажу*) **6.** *в знач. прил.* **төйгэн** толчёный □ **төеп тутыру** ту́го набива́ть (*мешок, в мешок*)

төю II *перех.* **1.** завя́зывать/завяза́ть ‖ завя́зывание узло́м (клубко́м); *чэчлэрен төеп куйды* во́лосы завяза́ла узло́м **2.** вяза́ть/связа́ть *что-л.*; мастери́ть *что-л.* завя́зыванием, вя́зкой; *ефэктэн төймэ төю* из шёлка связа́ть пу́говку

төюле *прил.* завя́занный узло́м, клубко́м (*о волосах*)

төя *сущ. уст. см.* **дөя**

төягеч *сущ.* **1.** погру́зчик (*разных видов*); *асылма ~* подвесно́й погру́зчик; *кранлы ~* кра́новый погру́зчик; погру́зчик с кра́ном **2.** автомаши́на с погру́зчиком ‖ *прил.* погру́зочный; *~ машиналар* погру́зочные маши́ны

төяк *сущ. см.* **тияк** 2

төял|ү *страд.-возвр. от* **төяү** **1.** *страд.* 1) грузи́ться, нагружа́ться; *йөк арбаларга ~э* (весь) груз гру́зится на теле́ги 2) загружа́ться/загрузи́ться ‖ загру́зка **2.** *возвр.*

погружа́ться/погрузи́ться; нагружа́ться/нагрузи́ться; рассе́иваться/рассе́ться (со свои́ми вещи́ в экипа́ж, сре́дства тра́нспорта); *см. тж.* **төяну**; *солдатлар машиналарга ~деләр* солда́ты погрузи́лись на маши́ны (*расселись по машинам*) □ **~үе җитмәү** не загрузи́ться, недогружа́ться/недогрузи́ться || недогру́зка

төян|ү *возвр. от* **төяү**; нагружа́ться/нагрузи́ться; нагружа́ть/нагрузи́ть (*свои вещи на себя*); *~де дә китеп барды* нагрузи́лся (нагрузи́л все свои́ ве́щи) и уе́хал

төя́ү *перех.* **1.** 1) грузи́ть, погружа́ть/погрузи́ть || погру́зка; *капчыклар төяү* грузи́ть мешки́; *төяве җиңел, туләве авыр* (*погов.*) легка́ погру́зка, да дорога́ пла́та; погру́зка ле́гче пла́ты 2) загружа́ть/загрузи́ть || загру́зка; *арбаны төяү* загружа́ть теле́гу **2.** нагружа́ть/нагрузи́ть || нагру́зка; *арбага төяү* нагружа́ть на теле́гу **3.** *перен.* рассе́живать/рассади́ть, посади́ть (*в экипаж, на транспорт*); вози́ть, везти́, перевози́ть; *кеше төяп йөри* во́зит люде́й □ **төяп алу (бирү, кайту, китү)** — о взя́тии, отда́че (поку́пке, приво́зе, уво́зе) помно́гу (возо́ми); *туй малын төяп алдык* возо́ми взя́ли сва́дебное добро́; **төяп бирү** помо́чь грузи́ть; **төяп тутыру** по́лностью запо́лнить (*чем-л. помещение и т. п.*)

төя́үле *прил.* **1.** гружёный, загру́женный; *~ арба* гружёная теле́га **2.** нагру́женный; *~ әйберләр* нагру́женные ве́щи

төяүсез *прил.* 1) незагру́женный 2) недогру́женный

тра́верс, тра́верз *сущ. в разн. знач.* (*воен., мор., авиа., тех.*) тра́верс, тра́верз; *сул ~та* на пра́вом тра́версе; *~ка чыгу* выходи́ть на тра́верс

тра́вма *сущ. в разн. знач.* тра́вма; *җитештерүдәге ~* произво́дственная тра́вма; *рухи ~* душе́вная тра́вма; *~га китерү* привести́ к тра́вме; *~ ясау* де́лать тра́вму, травми́ровать || травми́рование

тра́вмалан|у *неперех. разг.* травми́роваться, быть травми́рованным; *~ган кеше* травми́рованный челове́к

тра́вмалау *перех. разг.* травми́ровать || травми́рование

травматизм *сущ.* травмати́зм; *~ очраклары* слу́чаи травмати́зма

травмато́лог *сущ.* травмато́лог; *~ врач* врач-травмато́лог

травматологи́к *прил.* травматологи́ческий; *~ бүлек* травматологи́ческое отделе́ние (*в больнице*)

травматологи́я *сущ. мед.* травматоло́гия; *~ белгече* специали́ст по травматоло́гии; травмато́лог

траге́дия *сущ.* **1.** траге́дия (*название литературного жанра*); *~ кую (уйнау)* ста́вить (игра́ть) траге́дию **2.** траге́дия (*несчастное происшествие*); *тормыш ~се* жи́зненная траге́дия

траге́дияле *прил.* траги́ческий (*о жизненных явлениях*); *~ тавыш* траги́ческий го́лос

траге́диячел *прил.* трагеди́йный

трагизм *сущ. в разн. знач.* траги́зм; *әхвәлнең ~ы* траги́зм положе́ния

тра́гик *прил.* **1.** траги́ческий, относя́щийся к траге́дии; *~ актёр* траги́ческий актёр **2.** траги́чный; *см. тж.* **фаҗигале**

традицион *прил.* традицио́нный

тради́ция *сущ.* тради́ция; *см. тж.* **ганганә**; *данлыклы ~ләр* сла́вные тради́ции; *милли ~* национа́льная тради́ция

траекто́рия *сущ.* траекто́рия; *см. тж.* **кыялаш**

тракт *сущ.* тракт, больша́к; *Оренбург ~ы* Оренбу́ргский тракт; *Себер ~ы* Сиби́рский тракт

трактат *сущ.* тракта́т; *философик ~* филосо́фский тракта́т; *сәүдә ~ы* торго́вый тракта́т

трактир *сущ.* тракти́р; *~да күңел ачу* весели́ться в тракти́ре

трактирчы *сущ.* тракти́рщик, содержа́тель тракти́ра

тра́ктор *сущ.* тра́ктор || тра́кторный; *тәгәрмәчле ~* колёсный тра́ктор; *чылбырлы ~* гу́сеничный тра́ктор; *~ заводы* тра́кторный заво́д; *~ тагылмасы* тра́кторный прице́п

тракторист *сущ.* тракторі́ст

трактористлык *сущ.* рабо́та, заня́тие и́ли квалифика́ция трактори́ста □ **~ка уку** учи́ться на трактори́ста

тра́кторлаштыру *перех.* оснаща́ть тра́кторами, трактори́ровать || трактори́зация; *авыл хуҗалыгын ~* трактори́зация се́льского хозя́йства

тра́кторчы *сущ.* **1.** трактори́ст; *~лар курсы* ку́рсы трактори́стов **2.** *разг.* челове́к, рабо́та кото́рого свя́зана с тра́ктором (*монтажник на заводе, механик в РТС и т. п.*)

тра́кторчылык *сущ.* **1.** рабо́та и́ли заня́тие, квалифика́ция трактори́ста; *~ эше* рабо́та, заня́тие трактори́ста **2.** рабо́та, де́ятельность, свя́занная с тра́кторами (*их конструированием, внедрением и т. п.*)

трал *сущ. в разн. знач.* трал; *~ калкавычы* поплаво́к тра́ла; *~ тарту* тяну́ть трал

траллау *перех.* тра́лить || тра́ление

трамвай *сущ.* трамва́й || трамва́йный; *~ вагоны* ваго́н трамва́я, трамва́йный ваго́н; *~ йөртүче* води́тель трамва́я, вагоновожа́тый

трамвайчы *сущ.* трамва́йщик; челове́к, рабо́тающий в систе́ме трамва́йного тра́нспорта

трампарк *сущ.* трампа́рк (трамва́йный парк)

трамплин *сущ. прям., перен.* трампли́н; *~нан сикерү* пры́гать с трампли́на; *~ ролен үтәү* выполня́ть роль трампли́на

транзистор *сущ.* транзи́стор

транзисторлы *прил.* транзи́сторный; *~ радиоалгыч* транзи́сторный радиоприёмник

транзит *сущ.* транзи́т; *баҗсыз ~* беспо́шлинный транзи́т; *~ белән шөгыльләну* занима́ться транзи́том || *прил.* транзи́тный; *~ пассажирлар* транзи́тные пассажи́ры; *~ поезд* транзи́тный по́езд; *~ билет* транзи́тный биле́т; *~ зал* транзи́тный зал; *~ вагон* транзи́тный ваго́н

транзитив *прил. спец.* транзити́вный; *фигыльнең ~ формалары* транзити́вные (*переходные*) фо́рмы глаго́ла

транзитлы *прил.* транзи́тный; *~ сәүдә* транзи́тная торго́вля (*между двумя странами через третью страну*)

транс *сущ. мед.* транс

транс- *первая часть слов-терминов со значением* 1) *проходящий через то, что обозначено последующим словом:* **трансатлантик** трансатланти́ческий; **трансконтиненталь** трансконтинента́льный 2) *расположенный за пределами того, что обозначено последующим словом:* **трансуран элемент** трансура́новый элеме́нт

транскрипцион *прил.* транскрипцио́нный; *~ билгеләр* транскрипцио́нные зна́ки

транскри́пция *сущ. лингв., муз.* транскри́пция; *фонетик ~* фонети́ческая транскри́пция

транслитера́ция *сущ. лингв.* транслитера́ция; *~ системасы* систе́ма транслитера́ции

транслитера́циялә́у *перех.* транслитери́ровать || транслитери́рование

транскри́пцияләү *перех.* транскрибі́ровать || транскрибі́рование; ~ *ысулы* ме́тод транскрибі́рования

трансляцион *прил. тех.* трансляцио́нный; ~ *тапшыру* трансляцио́нная переда́ча

трансля́ция *сущ. в разн. знач.* трансля́ция; *Мәскәүдән* ~ трансля́ция из Москвы́

транспарант *сущ.* транспара́нт; *~лар күтәргән колонналар* коло́нны с транспара́нтами

трансплантат *сущ.* трансплантат

трансплантация *сущ. в разн. знач.* трансплантация

тра́нспорт *сущ. в разн. знач.* тра́нспорт || тра́нспортный; *су ~ы* во́дный тра́нспорт; *тимер юл ~ы* железнодоро́жный тра́нспорт; ~ *авиациясе* тра́нспортная авиа́ция; ~ *бригадасы* тра́нспортная брига́да; ~ *сәнәгасе* тра́нспортная промы́шленность; *десант ~ы* деса́нтный тра́нспорт

транспортёр *сущ.* **1.** транспортёр; *тасмалы* ~ ле́нточный транспортёр **2.** *см.* бронетранспортёр

транспортир *сущ.* транспорти́р

тра́нспортчы *сущ.* тра́нспортник; челове́к, рабо́тающий на тра́нспорте; *~лар клубы* клуб тра́нспортников

тра́нспортчылык *сущ.* тра́нспорт (*как отрасль хозяйства*); тра́нспортное де́ло; *~та эшләү* рабо́тать на тра́нспорте

трансформа́тор *сущ. тех.* трансформа́тор || трансформа́торный; *өч фазалы* ~ трёхфа́зный трансформа́тор; ~ *кору* сооружа́ть трансформа́тор; ~ *станциясе* трансформа́торная ста́нция; ~ *уралмасы* трансформа́торная обмо́тка

трансформацион *прил. тех.* трансформацио́нный; ~ *аппаратура* трансформацио́нная аппарату́ра

трансформа́ция *сущ. в разн. знач.* трансформа́ция

трансформа́циялә̆ү *перех.* трансформи́ровать

транше́я *сущ. в разн. знач.* транше́я; ~ *казу* рыть транше́ю; *~ләр системасы* систе́ма транше́й

транше́яле *прил.* транше́йный; ~ *ысул* транше́йный ме́тод

трап *сущ.* трап (*в транспорте*); *~тан төшү* спусти́ться по тра́пу (*или с трапа*); ~ *терәтү* приста́вить трап

трапе́ция *сущ. в разн. знач.* трапе́ция; ~ *формасындагы* в фо́рме трапе́ции; ~ *мәйданын исәпләү* изме́рить пло́щадь трапе́ции; *~дә күнекмә ясау* делать упражне́ния на трапе́ции

тра́сса *сущ. в разн. знач.* тра́сса; *юл ~сы* тра́сса доро́ги; ~ *сызу* прочерти́ть тра́ссу

тра́ссалагыч *прил.* трасси́рующий; ~ *шнур* трасси́рующий шнур

тра́ссалау *перех.* трасси́ровать || трасси́рование; *су үткәргеч челтәрен* ~ трасси́ровать водопрово́дную сеть

тра́улер *сущ.* тра́улер || тра́улерный; ~ *флоты* тра́улерный флот

тра́ур *сущ.* тра́ур || тра́урный; *см. тж.* **матәм**; ~ *игълан итү* объяви́ть тра́ур

трафарет *сущ.* трафаре́т || трафаре́тный; ~ *буенча кисү* крои́ть по трафаре́ту; ~ *тактасы* трафаре́тная доска́ || *прил.* трафаре́тный; ~ *фраза* трафаре́тная фра́за; ~ *схема* трафаре́тная схе́ма; ~ *җаваплар* трафаре́тные отве́ты

трафаретлы *прил.* с трафаре́том; трафаре́тный; ~ *ысул* трафаре́тный спо́соб

трафаретлы|к *сущ.* трафаре́тность; *образларның ~гы* трафаре́тность о́бразов

трафаретчы *сущ.* трафаре́тчик; ~ *оста* ма́стер по трафаре́там

трахе́я *сущ.* трахе́я **1.** *анат.* дыха́тельное го́рло **2.** *зоол.* дыха́тельные тру́бочки у не́которых членистоно́гих живо́тных **3.** *биол.* сосу́ды — у расте́ний; ~ *ярдәмендә сулау* дыха́ние с по́мощью трахе́и

трахо́ма *сущ.* трахо́ма; ~ *белән авыру* боле́ть трахо́мой

трахо́малы *прил.* трахо́мный; ~ *күзләр* трахо́мные глаза́

трахоматоз *сущ.* трахомато́з || трахомато́зный; ~ *институты* трахомато́зный институ́т

тревога *сущ.* трево́га; ~ *күтәрү* поднима́ть/подня́ть трево́гу; ~ *сигналы* сигна́л трево́ги

трево́галы *прил.* трево́жный; ~ *замана* трево́жное вре́мя; *см. тж.* **шөбһәле, дәһшәтле**

тред-юнион *сущ.* тред-юнио́н (*название профсоюзов в англоязычных странах*); *тред-юнион съезды* съезд тред-юнио́нов

тред-юнионизм *сущ.* тред-юниони́зм (*течение в рабочем движении, ограничивающее его профсоюзными делами*); *тред-юнионизм хәрәкәте* движе́ние тред-юниони́зма

тред-юнионист *сущ.* тред-юниони́ст, сторо́нник тред-юниони́зма

трек *сущ.* спорт, трек (*специальное сооружение для проведения соревнований по езде на двухколёсном транспорте*) || тре́ковый; *~та ярышу* соревнова́ться на тре́ке

трель *сущ. спец.* трель (*дорога для вывоза леса из лесоразработок*)

трельяж *сущ.* **1.** трелья́ж (*решётка для вьющихся растений*) **2.** трелья́ж (*трёхстворчатое зеркало*) || *прил.* трелья́жный; ~ *беседка* трелья́жная бесе́дка

тре́нер *сущ.* тре́нер; ~ *булып эшләү* рабо́тать тре́нером; ~ *киңәшләре* сове́ты тре́нера

тре́нерлык *сущ.* тре́нерская рабо́та; де́ятельность тре́нера || тре́нерский; ~ *эше* тре́нерская рабо́та; *~та йөрү* быть тре́нером, ходи́ть в тре́нерах

тренирóвка *сущ. разг.* тренирóвка; ~ *үткәрү (ясау)* проводи́ть тренирóвку; тренирова́ть

трепана́ция *сущ.* трепана́ция; ~ *ясау* сде́лать трепана́цию

трепанг *сущ. зоол.* трепа́нг (*морской ёж, мясо которого употребляется в пищу*)

трест *сущ.* трест; ~ *идарәсе* управле́ние тре́ста; *капиталистик* ~ капиталисти́ческий трест

треф *сущ.* тре́фы, треф (*карточная масть*) || *прил.* трефо́вый; ~ *дама* трефо́вая да́ма

триас *сущ. геол.* триа́с; ~ *чорында* в триа́совый пери́од

трибун *сущ. в разн. знач.* трибу́н; *хәрби* ~ вое́нный трибу́н (*в Древнем Риме*); *революция ~ы* трибу́н револю́ции; ~ *-шагыйрь* поэ́т-трибу́н

трибу́на *сущ. прям., перен.* трибу́на; *см. тж.* **мөнбәр**; *~га күтәрелү* поднима́ться на трибу́ну; *әдәбият ~сы* литерату́рная трибу́на ◊ ~ **бирү** дава́ть трибу́ну (*т.е. возможность публично высказаться*)

трибунал *сущ.* трибунáл; ~ *карары* реше́ние трибунáла; *~га тапшыру* переда́ть в трибунáл

тригонометрик *прил.* тригонометри́ческий; ~ *таблицалар* тригонометри́ческие табли́цы; ~ *функцияләр* тригонометри́ческие фу́нкции

тригонометрия *сущ.* тригоно́метрия; ~ *мәсьәләләре* вопро́сы тригоно́метрии; *турысызыклы* ~ прямолине́йная тригоно́метрия

три́ер *сущ.* три́ер || три́ерный; ~ *белән ашлык чистарту* чи́стить, очища́ть зерно́ на три́ере (три́ером)

три́ерлау *перех.* очища́ть/очи́стить (*зерно*) на три́ере

трико *сущ. в разн. знач.* трико́; *аның өстендә ~* на нём трико́; *чалбарга ~ сатып алу* купи́ть трико́ на брю́ки || *прил.* сши́тый из трико́; трикота́жный; *~ кулмәк* руба́ха из трико́

трикотаж *сущ.* трикота́ж || трикота́жный; *~ магазины* трикота́жный магази́н, магази́н трикота́жа || *прил.* трикота́жный, сши́тый, изгото́вленный из трикота́жа; *~ әйберләр* трикота́жные ве́щи; *~ костюм* трикота́жный костю́м

трикотажчы *сущ.* челове́к, име́ющий (по профе́ссии) де́ло с трикота́жем (*продавец трикотажа, рабочий трикотажной фабрики и т. п.*)

трикотажчылык *сущ.* трикота́жное де́ло; трикота́жная промы́шленность; *~та эшләү* рабо́тать в трикота́жной промы́шленности

триллион *числ. колич.* триллио́н (*тысяча миллиардов 1000000000000*); *~ киловатт-сәгать* триллио́н килова́тт-часо́в; *~ шәм* триллио́н свече́й

триллионна́рча *нареч.* триллио́нами

трило́гия *сущ.* трило́гия; *«Ташкыннар» ~се* трило́гия «Пото́ки»

три́о *сущ. в разн. знач.* три́о; *вокаль ~* вока́льное три́о

триод *сущ. тех.* трио́д (*электронная лампа*)

триодлы *прил. тех.* трио́дный; *~ лампа* трио́дная ла́мпа

три́птих *сущ. иск., лит.* три́птих; *~ның бер өлеше (кисәге)* часть три́птиха

тритон *сущ. зоол.* тритон; *см. тж.* **пакарач**

триумвират *сущ. ист.* триумвира́т; *~ төзү* соста́вить триумвира́т

триумф *сущ.* триу́мф; *~ белән каршы алу* встреча́ть с триу́мфом

триумфаль *прил.* триумфа́льный; *~ марш* триумфа́льный марш; *~ арка* триумфа́льная а́рка

триумфа́тор *сущ.* триумфа́тор

триу́мфлы *прил. см.* **триумфаль**

трихи́на *сущ. зоол.* трихи́на

трихинеллёз *сущ. мед., ветер.* трихинеллёз; *~ белән авыру* боле́ть трихинеллёзом (*о людях и животных*)

трихиноз *прил. мед.* трихино́зный; *~ дуңгыз* трихино́зная свинья́

тро́йка *сущ.* тро́йка; *~ җигеп* на тро́йке; запря́гши тро́йку

троллейбус *сущ.* троллейбус || троллейбусный; *~ туктагалышы* троллейбусная останóвка

тромб *сущ. мед.* тромб (*сгусток крови в кровеносном сосуде*)

тромбоз *сущ. мед.* тромбо́з (*процесс образования тромбов*)

тромбозлы *прил. мед.* тромбо́зный; *~ процесс* тромбо́зный проце́сс

тромбон *сущ. муз.* тромбо́н; *~да уйнау* игра́ть на тромбо́не

тромбончы *сущ. муз.* тромбони́ст

тромбофлебит *сущ. мед.* тромбофлеби́т (*воспаление стен вены*); *~ белән авыру* боле́ть тромбофлеби́том

троп *сущ. лит.* троп; *~лар куллану* примене́ние тро́пов

тро́пик *сущ. геогр. в разн. знач.* тро́пик; *Сәратан ~гы* тро́пик Ра́ка (тро́пик се́верный); *~кларда яшәү* жить в тро́пиках || *прил.* тропи́ческий; *~к урман* тропи́ческий лес; *~к усемлекләр* тропи́ческие расте́ния ◊ **~к ел** тропи́ческий год

тропосфе́ра *сущ.* тропосфе́ра; *~ калынлыгы* толщина́ тропосфе́ры

трос *сущ.* трос; *~ белән тарттыру* тяну́ть тро́сом (*при помощи троса*); *корыч ~* стально́й трос

тротил *сущ.* тротил (*сильное взрывное вещество*)

тротуар *сущ.* тротуа́р; *~дан йөрү* ходи́ть по тротуа́ру

трофей *сущ. прям., перен.* трофе́й; *см. тж.* **улҗа**; *~ алу* взять трофе́й; *~лар өчен сугышмыйлар* воюю́т не из-за трофе́ев || *прил.* трофе́йный; *~ корал* трофе́йное ору́жие

тро́фик *прил. физиол.* трофи́ческий; *~ нервлар* трофи́ческие не́рвы; *~ шеш* трофи́ческая о́пухоль

троцкизм *сущ. ист.* троцки́зм (*течение в российском и международном коммунистическом движении*)

троцкист *сущ. ист.* троцки́ст 1) сторо́нник Тро́цкого 2) сторо́нник троцки́зма

тро́цкийчы *сущ. см.* троцки́ст

тр-р *межд. возглас, которым останавливают лошадей:* тпру

труба *сущ.* 1. труба́ || тру́бный; *су ~сы* водопрово́дная труба́ 2. *муз.* труба́; *~да уйнау* игра́ть на трубе́ □ **~ кискеч** *тех.* труборе́з

трубадур *сущ.* 1. *уст.* трубаду́р; *революция ~ы* трубаду́р револю́ции 2. *перен.* певе́ц, бард

трубач *сущ. муз.* трубач; *оркестр ~ы* трубач оркестра

тру́бка *сущ.* 1. *тех.* тру́бка, тру́бочка; *см. тж.* **көшә**; *телефон ~сы* телефо́нная тру́бка; *телевизор ~сы* тру́бка телеви́зора 2. *см.* **төрепкә**

трубопровод *сущ. тех.* трубопрово́д; *см. тж.* **торба үткәргеч, труба**; *~ линиясе* ли́ния трубопрово́да

тру́ппа *сущ. иск.* тру́ппа; *«Сәйяр» ~сы* тру́ппа «Сайя́р»; *күчмә ~* передви́жная тру́ппа; *~ составында* в соста́ве тру́ппы

трусик *сущ.* трусы́, тру́сики; *~тан гына калу* остава́ться в одни́х тру́сиках

трусикчан *прил.* в трусах (тру́сиках)

трюк *сущ.* трюк; *акробатик ~* акробати́ческий трюк; *оста ~ куллану* применя́ть уме́лый трюк; *клоун ~лары* кло́унские трю́ки

трюкчы *сущ. прям., перен.* трюка́ч

трюкчылык *сущ.* трюка́чество; *сәнгатьтә ~* трюка́чество в иску́сстве

трюм *сущ.* трюм; *буксир ~ы* трюм букси́ра; *театр ~ы* трюм теа́тра

трюмо *сущ.* 1. трюмо́; *~ көзге* зе́ркало-трюмо́ 2. *архит.* трюмо́ (*простенок, украшенный орнаментом*)

трю́фель *сущ. бот.* трю́фель (*вид гриба*); *см. тж.* **томалан**

тсс *межд.* тсс

тукландыр|у *перех.* **1.** корми́ть, прокорми́ть; питáть || кормлéние, прокóрм, питáние *кого; см. тж.* **ашату, туендыру**; *биш баланы ~а* кóрмит пятеры́х детéй; *язгы көн елны ~а* весéнний день год кóрмит **2.** *с.-х.* подкáрмливать/подкорми́ть || подкóрмка; *тамырдан тыш ~у* внекорневáя подкóрмка **3.** *перен. книжн.* питáть; *Тукай поэзиясен ~ган традицияләр* традúции, питáвшие поэ́зию Тукáя

тукланы|у *неперех.* **1.** питáться || питáние; *икмәк белән ~абыз* питáемся хлéбом; *~у режимы* режúм питáния; *аралаш ~у* смéшанное питáние **2.** *перен.* удовлетворя́ться/удовлетвори́ться || удовлетворéние; *күңел ~у* удовлетворя́ться душóй □ **~ып йөрү** постоя́нно питáться *чем-л.*; **~ып тору** врéменно питáться; питáться пока́ *чем*

туклы I *сущ. диал.* **1.** ягнёнок осéннего окóта **2.** ягнёнок курдю́чной овцы́; *~лар йөгерешә* резвя́тся ягня́та курдю́чной овцы́ **3.** ягнёнок-одинóчка; *см. тж.* **берләч**

туклы II *прил.* хорошó питáющийся; ~ *кеше — ныклы* (*посл.*) хорошó питáющийся человéк — крéпкий

туклы|к *сущ.* **1.** *в разн. знач.* сы́тость **2.** довóльствие; довóльство; *көзге ~кта* в осéннем довóльстве **3.** *разг.* питáтельность; *см. тж.* **туклыклылык**; *алманың ни ~гы бар?* какáя в я́блоке питáтельность?

туклыклы *прил.* питáтельный; ~ *ашамлык* питáтельная пи́ща; ~ *шулпа* питáтельный бульóн

туклыклылы|к *сущ.* питáтельность; *ашамлык ~гы* питáтельность пищевы́х продýктов

туклыксыз *прил.* непитáтельный, малопитáтельный; ~ *ризык* непитáтельный (*пищевой*) продýкт

туклыксызлык *сущ.* непитáтельность, малопитáтельность

тукма|к I *сущ.* **1.** колоту́шка, толку́шка; дуби́нка; кувáлда; *утын (балта) ~гы* колоту́шка для кóлки дров; топóрная колоту́шка; *кер ~гы* колоту́шка-катáлка **2.** *диал.* би́ло цепá; *чабагачка ~к бәйләү* привя́зывать би́ло к цепу́ **3.** *диал.* ги́ря часóв **4.** *перен.* дуби́на, тупи́ца □ **~к җилэк** *диал. см.* **җир җиләге**; **~к койрык (ял)** с корóтким хвостóм (с корóткой гри́вой); корóткий хвост (корóткая гри́ва) (*у лошадей*); **~к сөяге** *анат.* **1.** лопáтка **2.** плечевáя кость ◊ **~к борын** нос колоту́шкой

тукмак II *сущ. ист.* **1.** скáтка свежевы́тканного холстá **2.** мéра длины́ — дéсять арши́нов; *бер ~ киндер* дéсять арши́нов холстá

тукмакбаш *сущ. зоол.* **1.** пти́ца семéйства ястреби́ных, подóрлик; ~ *оясы* гнездó подóрлика **2.** *бот.* тимофéевка; ~ *орлыгы* семенá тимофéевки **3.** *разг. см.* **чукмарбаш**

тукмаклан|у I *страд. от* **тукмаклау**; *~ган кер* кáтаное бельё

тукмаклан|у II *неперех.* приня́ть и́ли имéть вид колоту́шки; *борыны ~ган* нос егó при́нял вид колоту́шки

тукмакла|у *перех.* **1.** колоти́ть, стучáть || стучáние колоту́шкой (*при забивании свай, колке дров и т. п.*); *~рга тотындылар* нáчали колоти́ть **2.** катáть/укáтывать || катáние, укáтывание (*белья*); *кер ~у* катáть бельё **3.** *перен. разг.* бить, колоти́ть (*кулаками*)

тукмаклашу **1.** *взаимно-совм. от* **тукмаклау**; *кер ~у* помогáть катáть бельё **2.** *разг.* би́ться, дрáться кулакáми; бокси́ровать; ~ *буенча дөнья чемпионы* чемпио́н ми́ра по бóксу

тукмакчыл *прил.* драчли́вый, склóнный к рукоприкла́дству; *яман сыер сукмакчыл, яман кеше ~* (*посл.*) дурна́я коро́ва гульли́ва, дурно́й человéк драчли́в

тукмала́у *перех. разг.* **1.** мнóго бить, колоти́ть, поколáчивать || битьё, поколáчивание *чего*; *кер ~* колоти́ть бельё **2.** *редко см.* **тукмау**

тукмал|у *страд. от* **тукмау**; быть поби́тым; *күп тапкыр ~ды* мнóго раз был поби́т (бывáл бит)

тукмар *сущ. диал.* **1.** дуби́нка (*полицейская*) **2.** колоту́шка; пáлочка бараба́на

тукма́|у *перех.* **1.** колоти́ть/поколоти́ть; поколáчивать || поколáчивание *чего-л.; ~п йомшарту* смягчи́ть поколáчиванием **2.** *разг.* лупи́ть, бить/поби́ть, прибúть || битьё, побóи; *~п утеру* бить дó смерти; убúть побóями **3.** *разг. перен.* бить, наноси́ть удáры (*по врагу на войне*)

тукран *сущ.* дя́тел; *кара ~* чёрный дя́тел; *кыр ~ы* полевóй дя́тел; *зур чуар ~* большóй пёстрый дя́тел □ **~ бабай карчыгы** назвáние дéтской игры́, в хóде котóрой игрáющие обмéниваются словáми; *тук-тук итэ, ул кемдер? — ~ бабай карчыгы* кто там стучúтся тук-тук? старýшка дéда Дя́тла; **~ печэне (үлэне)** *см.* **тукранбаш; ~ тубалагы** *бот.* пурпýровая заразúха ◊ **~ тэүбэсе** судéйский обéт (*зарок, который много раз даётся, но так и не исполняется*); пустáя кля́тва; **~ туе** свáдьба без угощéния

тукранбаш *сущ. бот.* клéвер; *болын ~ы* клéвер луговóй; *кызгылт ~* клéвер крáсный; *~ чэчэге* цветнúк клéвера

тукрáнсыман *прил.* **1.** похóжий на дя́тла, врóде дя́тла; *~ бер кош* птúца врóде дя́тла **2.** *в знач. сущ.* **тукрáнсыманнар** *зоол.* дя́тловые (*семейство птиц*)

тукрá|у *неперех. диал.* **1.** *см.* **туктау, тукталу 2.** *разг.* рабóтать с перебóями; *~п килэ безгэ товар* товáр к нам прихóдит с перебóями **3.** перестáть рожáть (телúться, ягнúться); *~ган сыер* корóва, перестáвшая телúться

туксак *прил. разг.* (*чаще в паре со словом* **аксак**) хромóй, хúлый; *күп сарыкта аксак та була, ~ та* (*посл.*) в семьé не без урóда (*букв.* средú мнóжества овéц бывáют и хромы́е и хúлые)

туксан 1. 1) *числ. колич.* девянóсто; *~ алты* девянóсто шесть; *~ ел* девянóсто лет 2) *в определённых сочет.* девянóсто-; *~ яшьлек* девяностолéтний **2.** *ист.* зúмний периóд (*с 22 декабря по 22 марта*); *сиксэн чыкмыйча, ~ керми* (*посл.*) пока́ не кóнчится вóсемьдесят (*период от начала октября до 22 декабря*), девянóсто не наступúт (*т.е. всему своё время*) □ **~ тугыз 1.** óчень мнóго, бесчúсленно; *~ тугыз сорау килеп туа* возникáет óчень мнóго вопрóсов **2.** *см.* **~ тугыз(лы); ~ тугыз төрле** óчень рáзный; *~ тугыз төрле кеше бар* (*посл.*) лю́ди бывáют óчень рáзные (*букв.* девянóсто девятú вúдов); **~ тугыз(лы)** недотёпа; недодéланный; дурачóк; **~ тугыз пробалы 1.** сáмой высóкой прóбы (*о золоте*) **2.** *перен.* чúстый, высококáчественный; вы́сшего кáчества в своём рóде, вы́сшей мáрки; *~ тугыз пробалы шагыйрь* поэ́т вы́сшей мáрки; **(үз) ~ы** *~ см.* **тугызы тугыз**

туксандагы *прил.* девяностолéтний; *~ карт* девяностолéтний старúк

туксанлап *числ. приблиз.* óколо девянóста; *~ кеше* óколо девянóста человéк

туксанла́у: (үз) туксанын туксанлау *см.* **үз тугызын тугызлау** (*см.* **тугызлау**)

туксанынчы *числ. порядк.* девянóстый; *~ ел* девянóстый год; *~ яшендэ* на девянóстом годý

туксанышар *числ. разд.* по девянóсто; *~ данэ* по девянóсто штук

туксын|у *неперех.* довóльствоваться || довóльствование (скýдной едóй; *юкка да ~ып йөри ул* он довóльствуется сáмым мáлым (*в пище*)

туксыра́у *неперех. диал.* **1.** *см.* **туксыру 2.** считáть/счесть приéвшимся, надоéдливым *что-л.; балалар чырчуыннан ~* считáть приéвшимся шум-беготню́ детéй **3.** пресыщáться || пресыщéние *чем-л.*

туксыт|у *понуд. от* **туксыру**; *бәрәңге ~мый ул* картóфель (*обычно*) не приедáется

туксыр|у *неперех.* **1.** переедáть/переéсть, есть до отвáла || переедáние (*преимущ. о животных*); *~ган бурелэр* переéвшие вóлки **2.** впúтывать, растворя́ть/растворúть || растворéние *чего-л.* донéльзя; насыщáться; перенасыщáться || перенасыщéние; *тэмам ~ган җир* донéльзя впитáвшая влáгу земля́ □ **~ган эремэ** перенасы́щенный раствóр

тукталгысыз *прил.* **1.** безостановóчный, беспреры́вный; непреры́вный; бесконéчный; *~ яңгыр* бесконéчный, непреры́вный дождь **2.** несдéрживаемый, неудержúмый || *нареч.* беспреры́вно, непреры́вно, бесконéчно; *~ сөйләшү* беспреры́вно болтáть (*говорить про себя*)

тукталу *неперех.* **1.** *в разн. знач.* останáвливаться/остановúться || останóвка; *кинәт ~ды* вдруг (он) остановúлся; *~у белән* как тóлько останóвится (остановúлся) **2.** останáвливаться/остановúться; прекратúться, стать || прекращéние (рабóты); *тегермәннәр ~ды* мéльницы стáли; *сугыш ~сын иде* пусть прекратúтся войнá; войнá бы прекратúлась **3.** 1) прерывáться/прервáться || прерывáние; *укулар ~ды* учёба прервалáсь 2) задéрживаться/задержáться || задéржка; *озакка ~магыз* дóлго (надóлго) не задéрживайтесь; *~у сылтавы белән* под предлóгом задéржки (*чего-л. со стороны*) 3) приостанáвливаться/приостановúться; *тын алырга ~у* приостановúться передохнýть **4.** остановúться, сдержáться, воздержáться || приостанóвка, воздержáние; *тиз генә ~а алмадым* не мог я срáзу сдержáться; *~а бел!* умéй сдержáться (воздержáться) **5. (-га ~у)** 1) останáвливаться/остановúться || останóвка у (в) ... *танышларга ~у* остановúться у знакóмых; *туган авылга ~ып* остановúвшись в роднóй дерéвне 2) останáвливаться/остановúться на ...; *билгеле бер фикергә ~а алмадым* не мог я остановúться на определённой мы́сли **6. (-дан, -ыннан ~у)** перестáть *что* дéлать; *газета чыгудан ~ды* газéта перестáла выходúть □ **~ып калу** задéрживаться/задержáться; **~ып тору** затормáживаться/затормозúться; притормáживаться/притормозúться; **~ып үтү (узу, китү)** остановúться на (*короткое*) врéмя

тукталусыз *прил.* безостановóчный; *~ йөреш* безостановóчный ход || *нареч.* безостановóчно; без переры́вов, без óтдыха; *~ эшләп булмый* невозмóжно рабóтать без переры́вов

тукталыш *сущ.* **1.** переры́в, переды́шка; *~тан соң* пóсле переры́ва **2.** останóвка, мéсто останóвки (*трамвая*) □ **~ ноктасы** мёртвая тóчка (*в движении маховика, колеса поршня и т. п.*)

тукталышлы *прил.* преры́вистый; *~ процесс* преры́вистый процéсс

тукталышсыз *прил.* безостановóчный; *~ хәрәкәт* безостановóчное движéние || *нареч.* безостановóчно; *~ бару* безостановóчно éхать (идтú)

туктаткысыз *прил.* неудержúмый; *~ һөҗүм* неудержúмое наступлéние || *нареч.* неудержúмо

туктаткыч *сущ. тех.* рубúльник (*тока*)

туктат|у *понуд. от* **туктау 1.** останáвливать/остановúть; *поездны ~у* остановúть пóезд; *сугышны ~у* остановúть войнý; *узгынчыны ~ып сорады* остановúл прохóжего и спросúл; *хәрәкәтне ~у* остановúть движéние **2.** прекращáть/прекратúть; *бәхәсне ~у* прекратúть спор; *эш ~у* (официáльно) прекращáть рабóту **3.** *разг.* задéрживать/задержáть *кого-л.; син мине ~ма* ты менá не задéрживай **4.** прерывáть/прервáть (*речь кого-л.*) □ **~ып**

калу удéрживать/удержáть (*от необдуманного поступка*); **~ып тору** приостанáвливать/приостановúть

тукта́|у *неперех.* **1.** *в разн. знач.* останáвливаться/остановúться || останóвка; *барган жирдэн ~у* остановúться с хóду (*вдруг*); *ялга ~у* остановúться на óтдых; *кунарга ~у* остановúться на ночлéг; *авыл саен ~у* останáвливаться в кáждой дерéвне; *машина ~мады* машúна не остановúлась; *~гызчы, ашыкмагыз!* остановúтесь, пожáлуйста, не торопúтесь! **2.** 1) *в разн. знач.* прекращáться/прекратúться, переставáть/перестáть (*о дожде, ссоре и т. п.*) 2) затихáть/затúхнуть (*о ветре, урагане*) □ **~(гыз) эле 1.** не торопúтесь **2.** а ну, éсли; а что, éсли **3.** а что тут, сóбственно **4.** а ну, погодú; **~п калу 1.** (*неожиданно*) остановúться **2.** заглóхнуть, затúхнуть; **~п тору 1.** останáвливаться, стоя́ть (*временно*) **2.** *перен.* простáивать

туктаусыз *прил.* беспрерывный, непрерывный, бесконéчный; *~ тавыш* беспрерывный шум; *~ янаулар* бесконéчные угрóзы || *нареч.* беспрерывно, непрерывно, бесконéчно; *~ яңгыр ява* беспрерывно идёт дождь

тукташ *сущ.* **1.** стоя́нка (привáл) **2.** *ист.* опóрная бáза (*при походах*)

тук-тук *подр. см.* **тук** III

тук|у I *перех.* **1.** ткать, соткáть ||ткáние; *киндер ~у* ткать холст; *келэм ~у* ткать ковёр; *~ып утыру* ткать (*за ткацким станком*) **2.** *в знач. прил.* **тукыган** ткáный; *~ыган сөлге* ткáное полотéнце **3.** плестú, сплетáть/сплестú || плетéние (*из лыка, прутьев и т. п.*); *башмак ~у* плетéние башмачкóв **4.** *перен.* создавáть/создáть *что-л.* (*путём кропотливой, долгой однообразной работы*); *уку — бэхет ~у* (*посл.*) учúться — создавáть (*себе*) счáстье || *сущ.* ткáчество, тканьё; то, что ткётся || ткáцкий, текстúльный; *~у фабрикасы* ткáцкая (текстúльная) фáбрика

туку II *перех.* **1.** *диал. см.* **тукмау**; *йодрык белэн ~* стучáть, бить кулакáми (*о столе*) **2.** долбúть, стучáть, постýкивать || постýкивание; *тукранның агач ~ы тикмәгә түгел* не зря дя́тел постýкивает по дéреву **3.** *перен. разг.* долбúть, твердúть (*одно и то же*)

тукувыч *сущ. диал. см.* **болгаткыч, туглавыч**

тукучы *сущ.* **1.** ткач; *~лар профсоюзы* профсоюз ткачéй; *~ булып эшләү* рабóтать ткачём **2.** текстúльщик

тукучылык *сущ.* **1.** ткáцкое дéло, ткáчество; *ефәк ~* шелкоткáчество; *келәм ~* ковроткáчество **2.** текстúльное дéло, текстúльная промы́шленность || текстúльный; *~та эшләү* рабóтать в текстúльной промы́шленности; *~ комбинаты* текстúльный комбинáт

тукылдату *перех.* постýкивать || постýкивание; *бармак белән ~у* постýкивание пáльцами

тукылд|áу *неперех.* стучáть || стук, стучáние; *поезд тәгәрмәчләре ~ый* стучáт колёса пóезда

тукылдаш|у *совм. от* **тукылдау**; стучáть, постýкивать (*о многих*); *урманда тукраннар ~а* в лесý (*там и сям*) постýкивают дя́тлы

тукылдык *сущ. разг. пренеб.* **1.** тот, кто чáсто стучúт, постýкивает (зря) **2.** *перен.* дя́тел; *әнә ~ килеп кунды* вон прилетéл (и сел) дя́тел

тукыл|у I *страд. от* **туку** I; ткáться; *әйбәтләп ~ган келәм* добротно ткáный ковёр

тукыл|у II *страд. от* **туку**; мнóго повторя́ться, постоя́нно быть повтóренным; *күп ~ды инде бу сүз* слóво повтóрено (повторя́ется) ужé не раз

тукым I *сущ.* **1.** широ́кий потни́к с подбрю́шником; *ияр ~ы* потни́к седлá **2.** верховáя сбрýя; сбрýя верхового́; принадлéжности для езды́ верхóм; *сыбай ~ы* сбрýя кóнного вóина

тукым II *прил. диал.* рóдственный; *безгә ~ кеше* человéк, рóдственный нам

тукыма *сущ.* **1.** *в разн. знач.* ткань; *йон ~* шерстянáя ткань; *киҗе-мамык ~* хлопчатобумáжная ткань; *мускул ~сы* ткань мýскула (мýскулов); *тоташтыргыч ~* соединúтельная ткань (*в живом организме*) **2.** *перен.* текст; *музыкаль ~* музыкáльный текст || *прил. редко* ткáневый, холщóвый; *~ футляр* ткáневый футля́р

тукын|у *неперех. книжн.* **1.** посягáть || посягáтельство; *син аңар тукынма* ты на неё не посягáй **2.** (*издевательски*) дотрáгиваться до ...; задевáть/задéть || задевáние ...; *намусына ~ды* задéл самолю́бие

тукыр (тукыр кош) *сущ. зоол.* птúца-ткач, ткáчик

тукыш I *сущ. уст.* столкновéние, сты́чка; *~та имгәну* изувéчиться в сты́чке

тукыш II *сущ. диал.* кáшица для домáшних птиц (*кур, уток, гусей и т. п.*)

тукышу I *взаимно-совм. от* **туку**; *киндер ~* помогáть при ткáнье полотнá

тукыш|у II *взаимно-совм. от* **туку** 3; *үзара ~тылар* долбúли друг дрýга

тукыя *сущ.* **1.** *см.* бутóн, бутóнчик (*цветка*); *чәчәк ~сы* бутóн цветкá **2.** стéбли лýка семенáми; цветкóвые стéбли лýковичных растéний

тукыяланы *неперех.* образóвывать/образовáть цветкóвые бутóны, цветкóвые стéбли (*о луковичных растениях*)

тукыялы *прил.* **1.** с бутóном; *~ чем* стебелёк с бутóном **2.** с цветкóвыми стéблями (*о луке*)

тул I *сущ. ист.* **1.** конь, снаряжённый для бóя; боевóй конь **2.** *см.* **тулак 3.** мешóк из цéльной лошадúной шкýры

тул II *сущ. уст. геогр.* долготá; *тули-шәрык* востóчная долготá; *тули-гареп* зáпадная долготá

тула *сущ.* **1.** домáшнее сукнó; *~дан чикмән тегү* шить чекмéнь из домáшнего сукнá **2.** обмóтка для ног || *прил.* сукóнный, из домáшнего сукнá; *~ эшләпә* сукóнная шля́па □ **~ басу (бастыру)** валя́ть домáшнее сукнó; **~ басучылык** сукноде́лие; *~ оек уст.* вид длúнных чулóк (*поверх которых надевались лапти*); **~ өмәсе** валя́ние сукнá в поря́дке взаимопóмощи (*с увеселениями молодёжи*); **~ тегермәне** сукновáлка, сукновáльня

тулаем *нареч.* **1.** в совокýпности, вкýпе; óптом, целикóм, в óбщем; *~ кабул итү* приня́ть целикóм; *~ кабул ителү* приня́тие целикóм, без указáния адресáта **2.** пóлностью, до концá; *~ алып бетерү* брать/взять пóлностью, до концá; *~ эшләү* сдéлать всё до концá || *прил.* обзóрный, обобщáющий; *~ караш* обобщáющий взгляд □ **~ алганда 1.** в óбщем, в цéлом **2.** вообщé говоря́, обобщённо говоря́

тулай *прил.* **1.** óбщий, совмéстный; *~ кухня* óбщая кýхня; *~ базар* óбщий ры́нок **2.** всеóбщий; *~ наданлык* всеóбщее невéжество **3.** *экон.* совокýпный; валовóй; *~ доход* валовóй дохóд; *~ продукт* совокýпный продýкт || *сущ. жарг.* общежúтие; *университет ~е* университéтское общежúтие

тулак *сущ.* **1.** шкýра, кóжа, употребля́емая в цéльном вúде (*как коврик*); *ат авырса, ~, ир авырса, әрвах* (*посл.*) заболéет лóшадь — (вот и бýдет) кóврик пóд ноги; заболéет муж — (вот и бýдет) дух-защúтник **2.** *ист.* чýчело лóшади, котóрое стáвили на могúлу вóина **3.** *спец.* лóшадь на пя́том годý

тулачы *сущ.* **1.** суконна́льщик **2.** уча́стник по́мощи при валя́нии сукна́; *~лар җыелып бетте* суконна́льщики в сбо́ре (собрали́сь все уча́стники валя́ния сукна́)

тулга *сущ.* **1.** *ист.* шлем **2.** *диал.* котело́к, котёл (*на трёх ножках*); *~* **тутырып (ащ) кую** ста́вить по́лный котёл на костёр

тулга|к *сущ.* **1.** предродовы́е схва́тки; поту́ги; *икенче ~к* вторы́е схва́тки (*перед родами*) **2.** родовы́е схва́тки, поту́ги, су́дороги при ро́дах (*вообще*); *~к белән яту* лежа́ть с природово́й боле́знью □ **~к (~гы) тоту 1.** испы́тывать родовы́е схва́тки, схва́тывать, крути́ть живо́т (пе́ред ро́дами); *бер хатынны ~к тотса, бөтен күрше хатыннарының эче авырта, ди* (*посл.*) говоря́т, е́сли одна́ же́нщина испы́тывает родовы́е схва́тки, у всех сосе́док животы́ боля́т **2.** *ирон. об очередном припадке злобы, нервности у кого-л.*; ◊ **~гы тота** моча́ ему́ в го́лову уда́рила; он не в ду́хе; он в припа́дке

тулгакла|у *неперех.* **1.** испы́тывать родовы́е и́ли предродовы́е схва́тки; *~п йөри* хо́дит, испы́тывая предродовы́е схва́тки **2.** *разг. см.* **тулгану** 2

тулгандыру *понуд. от* **тулгану**; заставля́ть крути́ться, верте́ться, ёрзать

тулган|у *неперех.* **1.** *уст. диал.* крути́ться, верте́ться (*прям. и перен.*); *көзге алдында ~у* верте́ться пе́ред зе́ркалом **2.** воро́чаться, перевора́чиваться; ёрзать, извива́ться, мета́ться || ёрзание (*от беспокойных чувств, мыслей и т. п.*); *йокламыйча ~ып яту* лежа́ть без сна, ворочаясь с бо́ку на́ бок **3.** снова́ть, ходи́ть/хожде́ние, снова́ние взад и вперёд (*от множества дел, забот*)

тулга́у I *перех. диал.* **1.** крути́ть, верте́ть, враща́ть, извива́ть **2.** накру́чивать, нама́тывать || нама́тывание; *җеп ~* нама́тывать беспоря́дочно (*нитку*)

тулга́|у II *сущ. лит.* **1.** импровизи́ровать; излага́ть || импровиза́ция, изложе́ние хо́да мы́слей в поэти́ческой фо́рме (*особенно с вопросами к самому себе*); *~п сөйләү* объясня́ть при по́мощи рито́рики **2.** исходи́ть (*при рассуждении, доказывании*) от проти́вного; лука́во му́дрствовать; *син бик ~ма* ты не о́чень-то му́дрствуй (лука́во)

тулга́у III *сущ. фольк.* ду́ма, поэ́ма на конкре́тную те́му (*о случившемся событии и т. п., делая обобщения и назидания*)

тулгын *диал. прил.* набу́хший, по́лный; *~ болыт* набу́хшее о́блако

тулка *сущ. диал.* **1.** кру́глая подста́вка; кру́глый о́стов; *казан ~сы* кру́глая подста́вка котла́ **2.** ву́тулка колеса́; *көпчәк ~сы* ву́тулка колеса́ (ступи́цы)

тулк|у *неперех. диал.* волнова́ться, колеба́ться (*о воде и т. п.*), би́ться о бе́рег; *~ып торган дулкыннар* во́лны, бью́щиеся о бе́рег

тулкыт|у *перех. диал.* волнова́ть, колеба́ть; *су төбендә асылташ, су ~саң чыгадыр* (*песня*) под водо́ю драгоце́нный ка́мень, волну́й во́ду — и обнару́жится он

тулма *сущ.* **1.** фарш; *ит ~сы* мясно́й фарш **2.** голубцы́; *~ пешерү* испе́чь голубцы́; *~ ураү* де́лать голубцы́ **3.** *уст.* же́нский куша́к, простёганный с ше́рстью и́ли ва́той

ту́лмаучылы|к *сущ.* недоста́ча (*обнаруживаемая при проверке*); *~гын түләтү* заста́вить плати́ть недоста́чу

тулпан *прил. диал.* корена́стый; конду́вый, то́лстый, кре́пкий (*о деревьях, также о лошади*); *~ каен* конду́вая берёза

тулпар (толпар) *сущ. поэт.* **1.** боево́й конь; хоро́ший, си́льный, выно́сливый и бы́стрый конь; *ябаганы мактау белән ~ булмас, ябалакны сыйпау белән шонкар булмас* (*посл.*) ско́лько ни хвали́ кля́чу — не ста́нет боевы́м конём, ско́лько ни ласка́й сову́, не превати́тся в кре́чета **2.** *перен.* пега́с; *~ы албырга менә* его́ пега́с восхо́дит к бе́лым облака́м (*о чрезмерно высокопарном поэте*) **3.** *миф.* крыла́тый конь □ **~ ат** *см.* **тулпар** 1

тултырук *нареч. диал.* **1.** по́лностью, сполна́; *см. тж.* **тулысы белән**; *~ бирү* дать сполна́ **2.** полно́; *см. тж.* **туп-тулы**; *урамда халык ~* на у́лице полно́ наро́ду **3.** мно́го, нава́лом; *магазинда бөтен әйбер ~* в магази́не това́ра нава́лом **4.** полнёхонько; с накла́дом; *~ салу* наложи́ть с накла́дом

тул|у *неперех.* **1.** 1) станови́ться/стать по́лным; *чиләк ~ды* ведро́ напо́лнилось 2) **(-га ~у, белән ~у)** заполня́ться/запо́лниться || заполне́ние *чем; зал халык белән ~ды* зал запо́лнился наро́дом; *өйгә төтен ~ды* дом запо́лнился ды́мом **2.** заполня́ть/запо́лнить наполня́ть || заполне́ние; *өйгә чебен ~а* му́хи заполня́ют дом; *пассажирлар вагонга ~ды* пассажи́ры напо́лнили ваго́н **3. (-га ~у)** 1) (*обычно со словом* **бер** оди́н *перед названием вместилища*) набива́ться/наби́ться *во что; бер булмәгә ~у* набива́ться в одну́ ко́мнату 2) забива́ться/заби́ться; *бүрәнәләр арасында кар ~ган* ме́жду брёвнами заби́лся снег; промежу́тки ме́жду брёвнами заби́ты сне́гом **4.** доходи́ть/дойти́ (*до определённой меры веса, длины, объёма и т. п.*); *биш килограммга ~ды* дошло́ до пяти́ (по́лных) килогра́ммов; *ун литрга ~гач* по́сле того́, как бу́дет де́сять (по́лных) ли́тров **5.** *перен. в разн. знач.* по́лниться, переполня́ться/перепо́лниться, быть объя́тым *чем; шәһәр яңа хәбәрләр белән ~а* го́род переполня́ется но́выми вести́ми; *күңелем шатлык белән ~ды* моя́ душа́ объя́та ра́достью **6.** налива́ться/нали́ться (*о плодах и т. п.*); (*хорошо*) созрева́ть/созре́ть; *башаклар ~дылар* коло́сья (хорошо́) созре́ли (налили́сь) **7.** *перен.* истека́ть/исте́чь, выходи́ть/вы́йти (*о сроках, лимитах*); *мөтдәте ~ды* срок его́ истёк **8.** исполня́ться/испо́лниться; ми́нуть, сту́кнуть (*о годах, летах, месяцах и т. п.*); *биш яше ~ды* ему́ испо́лнилось пять лет; *өч ай ~а инде* ско́ро исполня́ется три ме́сяца **9.** выполня́ться/вы́полниться, быть вы́полненным || выполне́ние (*само собой, о планах, заданиях и т. п.*); *нормам ~ды* моя́ но́рма вы́полнена **10.** округля́ться/округли́ться || округле́ние (луны́); *ай ~уга (~гач та)* как то́лько луна́ округли́тся **11.** *см.* **тулышу**; *мин ~а башладым* я стал (*слишком*) по́лным **12.** *в отриц. ф.* **ту́лмау** не досчита́ться; *унга бер ~мый* без одного́ де́сять □ **~ган ай 1.** по́лная луна́ **2.** *перен.* краса́вица; *~ган аем* = со́лнышко моё; **~ып җиту** по́лностью созре́ть; созрева́ть/созре́ть (*в хорошем виде*); **~ып ташу** переплива́ться/перели́ться че́рез край; **~ып үтү** (*уже давно*) ми́нуть (*о количестве лет*); *аңа егерме яшь ~ып үтте* ему́ уже́ ми́нуло два́дцать лет ◊ **~ып ашкан 1.** перепо́лнен че́рез край (*о радости, горестях и т. п.*) **2.** с избы́тком, вполне́; **~ып яту** быть в изоби́лии, быть нава́лом

тулы *прил.* **1.** *в разн. знач.* по́лный; *~ чиләк* по́лное ведро́; *~ савыт* по́лный сосу́д; *~ җыелма* по́лное собра́ние; *~ җиңү* по́лная побе́да; *~ әйләнеш* по́лный оборо́т; *~ ирек* по́лная свобо́да; *аның ~ исеме* его́ по́лное и́мя; *~ исемлек* по́лный спи́сок; *~ ачыклык* по́лная я́сность (*в вопросе, в сообщении*) **2.** *в определит. слож. сочет.* полно-; *~ күкрәкле* полногру́дый; *~ сулы* полново́дный; *~ тәнле* полноте́лый; *~ хокуклы* полнопра́вный **3.** *в постпозиции к сущ., обозначающему место, вместилище и т. п.* полно́, по́лный (по́лон) *чего, чем, в чём;*

амбар ~ бодай амба́р, по́лный пшени́цей; *авыл ~ кыз* дере́вня полна́ де́вушками; в дере́вне де́вушек полно́; *урам ~ халык* по́лная у́лица наро́ду; *күкрәге ~ орден* грудь покры́та ордена́ми; вся грудь в орденах; *эче ~ явызлык* его́ нутро́ полно́ зло́бы **4.** запо́лненный, напо́лненный *чем; су белән ~* запо́лненный водо́й; *вакыйгалар белән ~ гомер* жизнь, напо́лненная собы́тиями **5.** по́лных, це́лых; *алда әле ~ өч ай* впереди́ ещё це́лых три ме́сяца || *нареч.* **1.** *см.* **тулысынча**; *~ күрсәтү* показа́ть со всей полното́й; *~ әйтү* сказа́ть со всей я́сностью; *ишекне ~ ачу* откры́ть две́ри до конца́ (на́стежь) **2.** в по́лном, запо́лненном ви́де; *машиналар бик ~ килә* маши́ны иду́т в перепо́лненном ви́де □ **~ булмаган урта мәктәп** непо́лная сре́дняя шко́ла; **~ вәкаләтле** полномо́чный (*посол*); *~ дистәләр мат.* кру́глые деся́тки; **~ канлы** полнокро́вный; **~ квадрат** *мат.* по́лный квадра́т; **~ квадрат сан** по́лное квадра́тное число́; **~ көенчә** в по́лном ви́де, по́лностью; **~ көч белән (көчкә)** в по́лную си́лу; **~ кыйммәтле** полноце́нный; **~ метражлы** полнометра́жные (*о фильмах*); **~ почмак** *мат.* у́гол в 360°; **~ терсәк** по́лный ло́коть (*мера длины*); **~ хаким** полновла́стный; **~ хакимият** полновла́стие; **~ ход** по́лный ход; **~ ходка 1.** на по́лный ход **2.** по́лным хо́дом; **~ ходта 1.** на по́лном ходу́ **2.** *перен.* во всю́; со всей си́лой; **~ хокуклы** полнопра́вный; **~ тавыш белән (~ тавыштан)** единогла́сно; *см. тж.* **бертавыштан**; **~ ышаныч** по́лная уве́ренность; **~ үлчәүле** полнове́сный; **~сы белән** по́лностью; целико́м и по́лностью; весь; *см. тж.* **тулысынча**

тулыксу, тулыксá|у *неперех. редко* **1.** 1) переполня́ться/перепо́лниться || переполне́ние 2) полне́ть, увели́чиваться в объёме **2.** разлива́ться/разли́ться, вздува́ться (*о реке*); *туксанның бере тулса, ~ган Идел катар* (*посл.*) вздува́вшаяся (*в низовьях*) Во́лга замерза́ет по́сле того́, как насту́пит пе́рвый пери́од тукса́на (*т. е. зимних месяцев*)

тулыксыз *прил. диал.* непо́лный; *~ савыт* непо́лный сосу́д

тулыландыр|у *перех.* **1.** восполня́ть/воспо́лнить; дополня́ть/допо́лнить || восполне́ние, дополне́ние; *шатлыгыбызны ~ды* воспо́лнил на́шу ра́дость **2.** пополня́ть/попо́лнить, доукомплектова́ть || пополне́ние; *полкны ~у* пополня́ть полк

тулылан|у *возвр. от* **тулылау 1.** пополня́ться/попо́лниться, восполня́ться/воспо́лниться; дополня́ться/допо́лниться || пополне́ние **2.** полне́ть, пополне́ть, станови́ться/стать по́лным **3.** налива́ться/нали́ться (*о плодах*)

тулыл|áу *перех.* **1.** дополня́ть/допо́лнить, восполня́ть/воспо́лнить || дополне́ние; *матурлыгын холкы ~ый* его́ (её) красоту́ дополня́ет поведе́ние **2.** *см.* **тулыкландыру** 2

тулылаучы: тулылаучы почмак *мат.* дополня́ющий у́гол

тулылы|к *сущ.* **1.** *в разн. знач.* полнота́; *гәүдәсенең ~гы* полнота́ его́ (её) те́ла; *бөтен ~гы белән* со всей полното́й **2.** *перен.* жажи́точность; *тормыш ~гы* жажи́точность жи́зни

тулым I *сущ. диал.* валу́н (*камень или кряж, торчащий из воды*)

тулым II *сущ. в притяж. ф.* о напо́лненности, запо́лненности, наполне́нии *чего; стакан ~ы* по́лный стака́н чего́; по́лным стака́ном; в по́лный стака́н; *уч ~ы* в по́лную горсть; по́лной го́рстью; *чиләк ~ы он* по́лное ведро́ муки́

тулымса *прил.* дово́льно по́лный, полнова́тый; полне́ющий, *~ хатын* полнова́тая (полне́ющая) же́нщина

тулын *сущ. ист.* тулу́н (*кожаный мешок для хранения припасов в дороге*); *~га су тутыру* напо́лнить водо́ю тулу́н

тулынкы *прил.* **1.** *см.* **тулымса**; *~ тәнле* с полне́ющим те́лом **2.** одутлова́тый (*о лице*); *~ битле* с одутлова́тым лицо́м

тулынкылан|у *неперех.* полне́ть, пополне́ть || пополне́ние; *~а башлаган* на́чал полне́ть

тулырт|у *перех. разг.* **1.** переполня́ть; *~ып сату* продава́ть — с перево́сом (с похо́дом, с га́ком) **2.** дополня́ть/допо́лнить

тулыру *неперех. разг.* переполня́ться (*о взвешиваемом*)

тулысы́нча *нареч.* **1.** по́лностью; со всей полното́й; *~ азат итү* по́лностью освободи́ть; *~ түләдек* уплати́ли по́лностью; *~ сөйлә* расска́зывай по́лностью **2.** до конца́; *~ үтәү* вы́полнить до конца́

тулыш|у *неперех.* **1.** опуха́ть || опуха́ние; раздува́ться/разду́ться, вздува́ться/вздо́ться; *шеше ~а* о́пухоль его́ раздува́ется; *~ып тишелү* прорва́ться **2.** станови́ться/стать по́лным; поправля́ться, толсте́ть, раздава́ться вширь; *~а башлаган* стал(а) полне́ть, стал раздава́ться вширь **3.** *см.* **тулыксу**; *~кан елга* вздо́вшаяся река́ **4.** *перен.* доходи́ть/дойти́ до преде́ла (*об исподволь накоплявшихся чувствах, общественных явлениях*); *ачуы ~кан — шартламагае* гнев его́ дошёл до преде́ла, как бы не ло́пнул

тума *сущ.* **1.** о́тпрыск; пото́мство; *кем ~сы?* чьё пото́мство? *ялгыз ~* еди́нственный о́тпрыск; еди́нственный насле́дник **2.** 1) урожене́ц го́рода 2) порожде́ние; *капитализм ~сы* порожде́ние капитали́зма **3.** *диал.* ро́дственник тре́тьего поколе́ния; *безгә ул ~ тиешле* он нам прихо́дится ро́дственником тре́тьего поколе́ния || *прил.* **1.** 1) ро́дственный по прямо́й ли́нии; родно́й, единокро́вный; *~ туган* единокро́вный (прямо́й) ро́дственник; *~ ана* единокро́вная (но не родна́я) ста́ршая сестра́ 2) явля́ющийся представи́телем тре́тьего поколе́ния; *~ кардәш* ро́дственник тре́тьего поколе́ния **2.** врождённый; от рожде́ния; *эт белән буре туган булса да, ~ дошман* (*посл.*) соба́ка и волк, хотя́ и ро́дственники, одна́ко врождённые враги́ || *нареч. диал.* о́т роду; соверше́нно; *~ булганы юк* о́т роду не́ было

тумак I *прил.* **1.** 1. расту́щий самосе́вом, самосе́вный; *~ арыш* рожь, расту́щая самосе́вом (*на паровом поле*) 2) паразита́рный (*о ветвях, отростках*) **2.** незаконнорождённый; *~ бала* незаконнорождённое дитя́ □ **~тан туган** *груб.* незаконнорождённый

тумак II *прил.* большо́й, кру́глый; с большим кру́глым концо́м (носко́м); *~ (башлы) итек* сапо́г с кру́глым носко́м

тумалак *сущ. диал.* то́лстое поле́но; кру́глый кряж; *~ яру* расколо́ть кру́глое поле́но

туман *сущ. ист.* **1.** тума́н (*круглая единица счёта денег в древних тюркских и иранских государствах, равная 10000 динарам или 60000 дирхемам*) **2.** тума́н (*золотая монета в Иране*) **3.** *см.* **төмән**

тумар *сущ.* **1.** большо́й деревя́нный мо́лот, деревя́нная кува́лда; *~ ярдәмендә утын яру* коло́ть дрова́ при по́мощи деревя́нной кува́лды **2.** *см.* **тумран**

тумарбаш *сущ. бот. см.* **чабыр**

тумарла́|у *перех.* придава́ть/прида́ть кру́глый вид (*дереву, деревяшке*); *~ган туп сыман* как деревя́нный мяч

тумача *сущ.* **1.** ро́дственница тре́тьего-четвёртого поколе́ния (*от общих предков*); *яшь ~* молода́я ро́дственница тре́тьего поколе́ния **2.** *см.* **тумачи** 1

тумачи *сущ.* **1.** фо́рма ласка́тельного обраще́ния к же́нщине-ро́дственнице тре́тьего-четвёртого поколе́ний (*см.* **тумача**) **2.** двою́родная мла́дшая сестра́ □ *~ әни* мла́дшая сестра́ отца́ и́ли ма́тери; *~ җиңги* жена́ двою́родного бра́та (*если он старше говорящего*)

ту́мба *сущ.* ту́мба; *~га аркан элдерү* заки́нуть арка́н на ту́мбу (*при причаливании*)

ту́мбочка *сущ.* ту́мбочка (*простейший, невысокий шкафчик*)

тумпа *прил. разг.* вы́пуклый, вздо́тый (*о щеках, губах и т. п.*); *~ битле* со вздо́той щеко́й

тумпайт|у *перех. диал.* вздува́ть/вздо́ть || вздо́тие (*щёк и т. п.*); *~ып кую* вы́ставить во вздо́том ви́де

тумпак *прил. диал.* **1.** *см.* **тумпа 2.** *см.* **тупак** 2 округлённо-тупо́й; *~ танаулы* с притуплённой мо́рдой

тумпаклану *неперех. разг.* станови́ться/стать || становле́ние окру́гло-пу́хлым

тумпаклык *сущ. разг.* окру́глая пу́хлость; округлённость

тумпа|ю *неперех. диал.* выдава́ться вы́пуклостью; вспуха́ть/вспу́хнуть || вспуха́ние (*в виде полусферы*); *~еп чыгу* пу́хло выдава́ться

тумран *сущ.* **1.** (отпи́ленный) ко́мель де́рева; чурба́н с корневи́щами; большо́й обру́бок то́лстого де́рева; *~ яру* расколо́ть чурба́н с корневи́щами **2.** *диал. см.* **түмгәк 3.** *перен.* дуби́на, болва́н, остоло́п, охламо́н (*о рослом, но малосообразительном, медлительном человеке*) □ *~ башлы* дурно́й, несообрази́тельный, тупова́тый

тумранлап *нареч.* чурба́нами (*при счёте дров*); *~ утын ташу* таска́ть дрова́ чурба́нами; *~ ягу* топи́ть (це́лыми) чурба́нами

тумра́|у *перех.* **1.** выкорчёвывать/вы́корчевать, выворáчивать || выкорчёвывание, выворáчивание пней; *төпне ~у* выворáчивать пень **2.** отпи́ливать/отпили́ть || отпи́ливание больши́х коло́д, ко́млей; *~п ташладык* отпили́ли большо́й чурба́н

тум-тулы *прил. превосх. ст. см.* **туп-тулы**

тумырга *сущ. диал.* колоко́льчик, наве́шиваемый на оде́жду

тумырка *сущ.* большо́й дя́тел (*в Сибири*); *~ сандалы* ку́зница дя́тла

тумырттыр|у *перех.* отка́лывать, отку́сывать/отку-си́ть || отка́лывание, отку́сывание больши́ми куска́ми; *~ып алды* отколо́л большо́й кусо́к

тумырт|у **1.** *понуд. от* **тумыру 2.** *перен. диал.* ста́вить у́дочку на́ ночь

тумыр|у I *перех.* **1.** отка́лывать/отколо́ть, отреза́ть/отре́зать (*большими кусками*); *см.* **тумырттыру 2.** обраба́тывать/обрабо́тать || обраба́тывание (*топором кое-как*); гру́бо отде́лывать/отде́лать || гру́бое отде́лывание, гру́бая отде́лка, тя́п-ля́п; *~ган да сөягән* (*погов.*) тя́п-ля́п и гото́в

тумыр|у II *перех.* **1.** *см.* **томыру** 2 **2.** *перен. прост.* присоба́чить, пристро́ить; о́птом отпра́вить, прода́ть и т. п.; *кая ~абыз?* куда́ пристро́им?

тумырыл|у *страд. от* **тумыру** 1

тумыш *сущ. разг.* рожде́ние, происхожде́ние; *~ы нинди — тормышы шундый* (*посл.*) каково́ происхожде́ние, такова́ и его́ жизнь; како́в род, тако́в и наро́д || *прил.* роди́вшийся, появи́вшийся на свет; *һәр ~ көн* ка́ждый бо́жий (*букв.* роди́вшийся) день

тумыштан *нареч.* от рожде́ния, о́т роду; от приро́ды; *~ сукыр* слепо́й от рожде́ния

тун *сущ.* **1.** шу́ба, шу́бка; *билле тун* шу́бка с та́лией; притáленная шу́ба; *кама тун* шу́ба из шку́рок вы́дры; *кыска тун* полушу́бок **2.** *уст.* сва́дебная оде́жда, пра́здничный наря́д (убо́р); *туе узган, туны тузган* (*посл.*) сва́дьба (*давно*) прошла́, и сва́дебный наря́д (*давно*) износи́лся (*т. е. судьба давно решена*) **3.** *разг. перен.* покро́в ше́рсти у живо́тных

тунал|у *страд. от* **тунау 1.** снима́ться, сдира́ться (*о шкуре*) **2.** быть обо́дранным, огра́бленным; *тунарга барган, ~ып кайткан* (*посл.*) пошли́ по шерсть, верну́лись стри́женными

тунат|у *понуд. от* **тунау**; позволя́ть гра́бить, огра́бить, ободра́ть *кого-л.*; *үзеңне ~ма* не позволя́й себя́ обдира́ть

туна́у *перех.* **1.** сдира́ть/содра́ть || сдира́ние; снима́ть/снять || сня́тие шку́ры; *аю ~* снять шку́ру медве́дя **2.** *перен. разг.* 1) обдира́ть/ободра́ть (*в знач.* огра́бить), обира́ть/обобра́ть 2) разгра́бить; брать всё без разбо́ра; *бакчаны ~* разгра́бить сад (*снимая все фрукты*) **3.** *перен. разг.* бить, лупи́ть || битьё **4.** *в знач. сущ.* **тунаучы**; *перен.* граби́тель; эксплуата́тор; *кеше ~чы* обдира́тель челове́ка, разбо́йник

тунашу *взаимно-совм. от* **тунау**

тунг *сущ. бот* тунг || ту́нговый; *~ мае* ту́нговое ма́сло

тунгус *сущ.* **1.** тунгу́с, представи́тель тунгу́сской наро́дности **2.** *собир.* тунгу́сы || тунгу́сский; *~ арасында* среди́ тунгу́сов; *~ теле* тунгу́сский язы́к, оди́н из тунгу́сских языко́в

тунгус-маньчжур: тунгус-маньчжур телләре тунгу́со-маньчжу́рские языки́

ту́ндра *сущ.* ту́ндра || ту́ндровый; *~ куяны* ту́ндровый за́яц; *~ милләте* ту́ндровое населе́ние, ту́ндровый наро́д

тунец *сущ. зоол.* тунец

тунислы *сущ.* туни́сец; урожéнец и́ли жи́тель Туни́са

тунлы *прил.* **1.** с шу́бой, шубе́йкой; име́ющий шу́бу **2.** *уст.* с пра́здничным наря́дом

тунлык *сущ.* материа́л, предназна́ченный для шитья́ шу́бы; *~ алу* купи́ть материа́л для шу́бы || *прил.* приго́дный и́ли доста́точный для шитья́; *бер ~ тире* мех, доста́точный для одно́й шу́бы

туннель *сущ. см.* **тоннель**

тунчы *сущ.* **1.** ма́стер по шитью́ шуб, шу́бник **2.** *уст.* швец, портно́й

туң I *прил.* **1.** мёрзлый, смёрзшийся; *туң җир* мёрзлая земля́ **2.** неспе́лый, ещё твёрдый (*о фруктах, ягодах и т. п.*) **3.** *перен.* 1) тупо́й, нера́звитый, неве́жественный; *туң фикер* нера́звитая мысль 2) дрему́чий, непробива́емый; *туң бюрократ* непробива́емый бюрокра́т 3) необщи́тельный; эмоциона́льно холо́дный, неэмоциона́льный **4.** *перен.* бессо́вестный, бессерде́чный (*о человеке*) **5.** застоя́вшийся (*о жизни*) **6.** *перен.* глухо́й, ту́склый (*о голосе*)

туң II *сущ.* 1) мерзлота́; мёрзлость; *кара туң* осе́нняя (*бесснежная*) мерзлота́; *мәңгелек ~* ве́чная мерзлота́ 2) мёрзлое ме́сто; наст; *туңнан атлау* шага́ть по мёрзлым места́м (по на́сту); *туң май* перето́пленное са́ло; *туң тимер* 1) чугу́нный сли́ток 2) *перен.* болва́н, о́лух; неве́жественный и упря́мый челове́к; *туңга сөру* вспа́шка под зябь □ **туңга калдыру** оставля́ть/оста́вить под зябь ◊ **туң авыз** *см.* **агач авыз**; **туң агач** *см.* **туң тимер** 2; **туң бүкән (маңгай)** дура́к, болва́н, о́лух, глупе́ц; **туң йөрәк (күңел)** бесчу́вственный челове́к; чёрствая ли́чность; **туң колак** *см.* **туңколак**; **туң күчән (тумран, түмәр)**

безда́рный и чёрствый; недалёкий и бездея́тельный челове́к; **туң моржа** челове́к, лишённый душе́вной теплоты́; бездýшный челове́к; **туң тавыш** глухóй, носовóй гóлос; **туң тавышлы** гундóсый, с носовы́м гóлосом; **туң тишек** не вника́ющий в суть; недога́дливый

туңаяк I *сущ.* незва́ный гость, нежела́тельный посети́тель

туңаяк II *прил.* непро́шеный (*о госте, посетителе и т. п.*); *~ кунаклар* непро́шеные гóсти

туңбаш *сущ. см.* **туң күчән**

туңбашлык *сущ.* неве́жественность и ту́пость; *~ курсәту* проявля́ть (выска́зывать) неве́жественность и ту́пость

туңгак *сущ. разг.* **1.** наст; *~ өслəтеп* по на́сту **2.** мёрзлая пове́рхность; мерзлота́; *көзге ~та* по осе́нней мерзлоте́ || *прил.* **1.** мёрзлый (*о комьях*); *~ балчык* мёрзлая гли́на (ко́мья гли́ны) **2.** на́стовый (*о снеге*); мёрзлый, затверде́вший (*о дороге*); *~ юл* мёрзлая, засты́вшая в ко́мьях доро́га

туңгалак *сущ.* **1.** мёрзлый ком **2.** замёрзшая грязь (*на дороге, на полях*); *~тан бару* идти́ по замёрзшей гря́зи || *прил. см.* мёрзлый

туңдырма *сущ.* моро́женое

туңколак *сущ.* **1.** туго́й на́ ухо, тугоу́хий **2.** невнима́тельный; не услы́шавший то, что уже́ все услы́шали || *сущ.* 1) глухо́й челове́к 2) челове́к, не зна́ющий то, что все зна́ют

туңлы|к *сущ.* **1.** мерзлота́; мёрзлость; *балчыкның ~гы* мёрзлость гли́ны; *мәңгелек ~к* ве́чная мерзлота́ **2.** необщи́тельность, за́мкнутость, несгово́рчивость **3.** неве́жество, гру́бость; догмати́зм, засты́лость; *Урта гасырлар ~гы* средневеко́вое неве́жество

туң|у 1. 1) мёрзнуть, замерза́ть/замёрзнуть, вымерза́ть/вы́мерзнуть, твердéть/затвердéть || замерза́ние, твердéние от хóлода; *су ~ган* вода́ замёрзла 2) замёрзнуть и испóртиться от хóлода 3) покрыва́ться/покры́ться сне́гом и льдóм (*об окнах*) **2.** зя́бнуть/озя́бнуть; замерза́ть, мёрзнуть || замерза́ние; *см. тж.* **өшү, күшегү**; *~а башладым я* стал замерза́ть (мёрзнуть) **3.** застыва́ть/засты́ть || застыва́ние (*прям. и перен.*); *~ган май* засты́вший жир **4.** *разг.* покрыва́ть/покры́ть || покрыва́ние (*льдом*); обраста́ть/обрасти́ (*льдом*); *җиргә боз ~ды* лёд покры́л зéмлю □ **~у ноктасы** то́чка замерза́ния

туңучан *прил. разг.* зя́бкий (*о человеке*)

туңучанлык *сущ.* зя́бкость

ту|п I *сущ.* мяч; *волейбол тубы* волейбóльный мяч; *резин туп* рези́новый мяч; *футбол тубы* футбóльный мяч; *туп уйнау* игра́ть в мяч □ **туп уены** *см.* **туплы; туп чөю** вид игры́ в мяч (*состоит в подбрасывании мяча высоко вверх*)

ту|п II *сущ.* **1.** пу́шечное ядро́, артиллери́йский снаря́д; *туп ату* стреля́ть ядро́м, снаря́дом; *туп яудыру* осыпа́ть (обстре́ливать) снаря́дами **2.** пу́шка, артиллери́йское ору́дие; *туп көпшәсе (көбәге)* ствол пу́шки; *авыр туп* тяжёлое ору́дие; *кыр тубы* полевóе ору́дие □ **тупка тоту** обстре́ливать снаря́дами; подвергáть/подве́ргнуть артиллери́йскому обстре́лу ◊ **туп азыгы (ите)** пу́шечное мя́со

ту|п III *сущ.* **1.** *уст.* скопле́ние, сбóрище; отря́д, гру́ппа (*путников и т. п.*); *бер туп кеше* гру́ппа люде́й (*только в конкретном знач.*); *тубы белән* гуртóм, гру́ппой **2.** *диал. см.* **табыр**; *малларны тупка җыю* согна́ть скот в ме́сто сбóра **3.** *диал.* тюк; рулóн, свя́зка; *бер туп тал кабыгы* свя́зка коры́ и́вы

туп IV *подр. глухому стуку (при спрыгивании человека с небольшой возвышенности)*; *туп-туп (тупта туп)* о глухи́х уда́рах, сту́ках □ **туп итү** глу́хо сту́кнуть: *туп-туп итү* глу́хо стуча́ть ◊ **туп итеп** вдруг, неожи́данно, бы́стренько

тупа *прил.* **1.** тупóй (*о режущих предметах*); *~ пычак* тупóй нож; *~ балта* тупóй топóр **2.** *диал. см.* **тупак**

тупак *прил.* тупóй, зату́пленный, не óстрый, не заострённый; *~ башлы* с тупы́м концóм || *нареч.* ту́по, зату́пленно

тупакай *сущ. диал.* **1.** стёсанный а́льчик **2.** просте́йшая ша́пка, ермóлка

тупаклану *неперех.* **1.** округля́ться/округли́ться || округле́ние (*острого конца чего-л.*) **2.** *см.* **тупалану**

тупаклы *перех.* округля́ть, закругля́ть (*конец чего-л.*)

тупаклык *сущ.* **1.** округлённость, закруглённость **2.** затуплённость

тупал *прил. диал.* **1.** небольшóй, но плóтный те́лом, плóтненький (*о мужчине*) **2.** пу́хленький, пóлненький (*о женщинах и детях*); *~ кыз* небольшóго ро́ста пóлненькая де́вушка

тупалан|у *неперех.* **1.** затупля́ться/затупи́ться || затупле́ние; *~ган кырый* зату́пленный кра́ешек *чего-л.* **2.** *см.* **тупару**

тупалык *сущ.* **1.** затуплённость, притуплённость (*топора*) **2.** *перен.* ту́пость

тупарту *перех.* затупля́ть/затупи́ть, притупля́ть/притупи́ть

тупар|у *неперех.* притупля́ться/притупи́ться, затупля́ться/затупи́ться || притупле́ние, затупле́ние; *~ган балта* притуплённый топóр; *см. тж.* **үтмәслəнү**

тупас *прил.* **1.** 1) *в разн. знач.* гру́бый; *~ кием* гру́бая оде́жда; *~ корал* гру́бое ору́дие; *~ йөз* гру́бое лицó; *~ тавыш* гру́бый гóлос; *~ кыланыш* гру́бая вы́ходка; *~ хата* гру́бая оши́бка; *~ сүз* гру́бое слóво 2) неве́жливый, гру́бый; *~ мөгамәлә* гру́бое обраще́ние **2.** 1) неуклю́жий; *~ хәрәкәт* неуклю́жее движе́ние; *~ кына кеше* неуклю́жий (неуклю́женький) челове́к; *~ хәйлә* неуклю́жая хи́трость 2) неуклю́жий, аляпова́тый (*об одежде, игрушке, о подделках и т. п.*); *~ эш* аляпова́тая рабóта **3.** *диал. см.* **тупа, тупак**; *ломның ~ башы* тупóй конéц лóма || *нареч.* 1) *в разн. знач.* гру́бо; *~ юнылган* гру́бо обтёсанный 2) гру́бо, неве́жливо; *~ сөйләшү* разгова́ривать неве́жливо □ **~ азык** гру́бый корм

тупасландыру *понуд. от* **тупаслану**: де́лать/сде́лать гру́бым

тупаслан|у *неперех.* **1.** 1) грубе́ть/огрубе́ть, погрубе́ть || огрубле́ние; *тавышы ~ган* гóлос (его́, её) огрубе́л 2) обезобра́зиться || обезобра́живание; *йөзе ~ды* лицó его́ обезобра́зилось **2.** груби́ть, вести́ себя́ гру́бо; *алай ~ма* не веди́ себя́ столь гру́бо **3.** *диал. см.* **тупару**

тупаслы|к *сущ.* **1.** *в разн. знач.* гру́бость; *~к курсәту* проявля́ть гру́бость; *тавышының ~гы* гру́бость гóлоса; *эшкәртелешнең ~гы* гру́бость отде́лки **2.** неуклю́жесть (*движения*)

тупа|у *перех. разг.* бить || битьё (*тупым округлым предметом*)

тупик *сущ. в разн. знач.* **тупик**; *~ка керү* входи́ть, войти́ в тупи́к; *~та* в тупике́; *~тан чыгу* вы́ход из тупика́

туплавы|к *сущ.* **1.** полевóе сто́йбище скота́; *см. тж.* **табыр, туп** III-2; *~кта торган терлек* скот, находя́щийся на полевóм сто́йбище скота́ **2.** *зоол.* ле́жбище; *моржлар ~гы* ле́жбище морже́й

туплам *сущ.* **1.** строй, гру́ппа; скопле́ние; *тыгыз ~* пло́тный строй **2.** свод, собра́ние, сбо́рник; цикл; *кулъязмалар ~ы* свод ру́кописей; *шигырьләр ~ы* цикл стихо́в **3.** *мат.* мно́жество; *~нар теориясе* тео́рия мно́жеств

тумламлы *прил.* упоря́доченный, сведённый в свод, цикл; *~ кулъязмалар* упоря́доченные ру́кописи

туплан *сущ. ист.* ко́нный отря́д; ко́нный строй; ко́нница; *тулпарлы кеше ~да* (*посл.*) у кого́ есть боево́й конь, тот в ко́нном отря́де; *тай менсәң, ~га кермә* (*посл.*) на жеребёнке-двухле́тке не пристра́ивайся к ко́нному стро́ю

тупланма *сущ.* **1.** скопле́ние; *газ ~сы* скопле́ние га́за (га́зов) **2.** собра́ние, колле́кция

туплан|у *неперех.* **1.** 1) собира́ться (*в одно место*); ска́пливаться/скопля́ться/скопи́ться || скопле́ние; *халык басу капкасы төбендә ~ган* наро́д собра́лся у полевы́х воро́т 2) группирова́ться/сгруппирова́ться || группирова́ние **2.** организо́вываться (*в коллектив*); *көчле состав ~ды* организова́лся си́льный соста́в **3.** сосредото́чиваться/сосредото́читься (*в одном месте*); *интеллигенция район үзәгендә ~ган* интеллиге́нция сосредото́чена в райо́нном це́нтре **4.** нака́пливаться, накопля́ться/накопи́ться, поднакопля́тся/поднакопи́ться || накопле́ние; *бераз тәҗрибә дә ~ды* немно́жко накопи́лся и о́пыт **5.** *перен.* концентри́роваться/сконцентри́роваться (*о силе, внимании и т. п.*), сосредото́чиваться || концентра́ция; сосредоточе́ние; *шигырьдә ~ган рух* дух, сконцентри́рованный в стихотворе́нии **6.** *перен.* спла́чиваться/сплоти́ться || сплоче́ние; *бер булып ~у* сплоти́ться в еди́ное

тупланыш *сущ.* **1.** 1) скопле́ние, ку́ча 2) сосредоточе́ние (*войск*); *~ пункты* пункт сосредоточе́ния **2.** *экон.* накопле́ние; *башлангыч ~* первонача́льное накопле́ние; *~ фонды* фонд накопле́ния

тупла́|у I *перех.* **1.** собира́ть/собра́ть, ска́пливать/скопи́ть || собира́ние, скопле́ние (*в одно место*); *терлекләрне ~у* собра́ть скот в одно́ ме́сто; *материал ~у* собира́ть (скопи́ть) материа́л (*для сооружения чего*); *мәгълүмат ~у* собира́ть све́дения **2.** группирова́ть/сгруппирова́ть, организо́вывать/организова́ть группирова́ние в оди́н отря́д **3.** *экон.* копи́ть/скопи́ть, нака́пливать/накопи́ть; поднакопи́ть || накопле́ние; *акча ~дык* мы поднакопи́ли де́ньги **4.** концентри́ровать/сконцентри́ровать, сосредото́чивать/сосредото́чить || концентри́рование, сосредоточе́ние **5.** спла́чивать/сплоти́ть/спла́чивание; *үз тирәсенә ~у* сплоти́ть вокру́г себя́

тупла́у II *сущ. см.* **туплавык** 1

тупла́удагы *прил.* находя́щийся на ле́тнем па́стбище; па́стбищный, сто́йбищный (*о скоте*); *~ терлек* скоти́на, находя́щаяся на ле́тнем па́стбище

туплаучы *сущ.* **1.** состави́тель (*сборника, свода и т. п.*); *җыентыкның туплаучысы* состави́тель сбо́рника **2.** собира́тель, коллекционе́р

туплаучылык *сущ.* собира́ние, собира́тельство *чего* (*книг, рукописей, фольклорных произведений и т. п.*); коллекциони́рование

туплы I *прил.* с пу́шкой (пу́шками); име́ющий пу́шку (пу́шки); *~ отряд* отря́д с пу́шкой (пу́шками)

туплы II: **туплы уен** игра́ в мяч; *~ уйнау* игра́ть в мяч; *~ хоккей* хокке́й с мячо́м

тупрак *сущ.* **1.** *диал. и уст. см.* **туфрак** **2.** *книжн.* террито́рия, земля́; *Татарстан тупрагында* на террито́рии Татарста́на

тупракчы *сущ. ист.* сторо́нник территориа́льной автоно́мии

туписа *сущ.* **1.** шарни́р, петля́; *ишек ~сы* дверно́й шарни́р **2.** *диал.* поро́г и́ли подоко́нник; присту́пок; *тәрәзә ~сы* подоко́нник; *ишек ~сы* поро́г две́ри **3.** *диал.* подпя́тник (*у ворот*) **4.** *бот.* у́зел (*кольцевое утолщение на стебле злаков*) **5.** *с.-х.* пята́, пя́тка (*косы*) ◊ **~ төшеру (төшереп кайту)** обива́ть поро́ги; **~га утыру** *см.* **тупсалану**

тупсалану *неперех.* остебеля́ться/остебели́ться (*об образовании колец у злаков*)

тупсалы *прил.* шарни́рный; устро́енный на шарни́рах; *~ беләзек* шарни́рный брасле́т; *~ каптырма* шарни́рная пря́жка; *~ вал тех.* шарни́рный вал

туп-тулы *прил. превосх. ст. от* **тулы**; о́чень по́лный, полны́м-полно́; *клубта халык туп-тулы* в клу́бе наро́ду полны́м-полно́

туп-туп *подр. звуку частых шагов или бега (человека, лошади)* топ-топ; тип-топ; *туп-туп йөгерү* бежа́ть то́потом (*о детях*) □ **туп-туп итү** то́пать, пото́пать (*частыми шагами*)

туп-туры *нареч.* **1.** *превосх. ст. от нареч.* **туры**; соверше́нно пря́мо, прямолине́йно, прямёхонько; ро́вненько; *төтен туп-туры күтәрелә* дым поднима́ется соверше́нно пря́мо; *туп-туры барабыз* мы идём прямолине́йно (*прямёхонько*) (*к цели*) **2.** без обиняко́в, пря́мо, напрями́к; *туп-туры әйтү* сказа́ть пря́мо, без обиняко́в; сказа́ть напрями́к **3.** с хо́ду, сра́зу; *туп-туры сезгә килдем* с хо́ду яви́лся к вам || *прил. превосх. ст.* соверше́нно прямо́й; прямёхонький; *туп-туры юл* соверше́нно прама́я доро́га

туп-турыдан *нареч.* **1.** прямёхонько **2.** *перен.* без подгото́вки

тупчу *перех.* што́пать || што́панье

тупчы *сущ.* артиллери́ст, пушка́рь; *~лар командасы* кома́нда пушкаре́й

тупчык *сущ. уменьш. от* **туп**; мя́чик

тупчыла́|у *перех. диал.* **1.** *см.* **тупчу** **2.** вышива́ть/вы́шить || вышива́ние (*особым способом*); *~ган яка* вы́шитый воротни́к

тупчыл|у *страд. от* **туплау**; *кат-кат ~ган* многокра́тно што́панный

тупчын *сущ.* **1.** мя́чик-клубо́к; тряпи́чный мяч, мя́чик (*сделанный наматыванием шнуров, ремешков и т. п. в клубок*); *~ белән уйнау* игра́ть тряпи́чным мя́чиком **2.** узелко́вая пу́говица, пу́говица-узело́к **3.** *диал.* буто́н, буто́нчик (*цветка*) ◊ **~ кебек** 1. пло́тно оде́тый 2. то́лстенький, пу́хленький (*о ребёнке*)

тупчынбаш *сущ. бот.* **1.** вид кле́вера **2.** *см.* **тупыйбаш**

тупый *сущ. этногр.* ша́пка с мехово́й оторо́чкой по тулье́ □ **~ бүрек** *см.* **тупый**

тупыйбаш *сущ. бот.* бука́шник го́рный

тупыйк *прил.* **1.** с тупы́м концо́м, тупоконе́чный, тупоно́сый; *~ ботинка* тупоно́сый боти́нок **2.** *см.* **тупак**

тупыл *сущ.* то́поль || тополи́ный; *~ мамыгы* тополи́ный пух (*при цветении тополей летом*) || *прил.* то́полевый, сде́ланный из древеси́ны то́поля; *~ бүрәнә* то́полевое бревно́

тупылдат|у *неперех.* **1.** трепа́ть/потрепа́ть; хло́пать/похло́пать **2.** *см.* **тупырдату** □ **~ып сөю** похло́пывая, ласка́ть (*ребёнка*)

тупылда́|у *неперех.* **1.** подто́пывать/подто́пать, прито́пывать/прито́пать || подто́пывание, прито́пывание; *~п йөгерү* бежа́ть, бе́гать с прито́пом **2.** *разг.* то́пать,

пото́пать; *авылга карап, ~дык* мы пото́пали в сто́рону дере́вни ◊ **~п килеп төшү** неожи́данно заяви́ться (прие́хать, зае́хать); **~п торган** по́лный и здоро́вый (*о ребёнке*)

тупылдаш|у *взаимно-совм. от* **тупылдау** подто́пывать, притопывать на ме́сте; *бәпкәләр ~ып торалар* утя́та (*все вместе*) подто́пывают (ла́пками); утя́та припля́сывают

тупылдык *прил.* **1.** притопывающий, стуча́щий копы́тами (*о лошади*); *~ атлар* стуча́щие копы́тами ло́шади **2.** бе́гающий с шу́мом (*о ребёнке*) || *сущ. разг.* **1.** конь, коня́га, лоша́дка **2.** ре́звый ребёнок

тупыллы *прил. разг.* то́полевый, тополи́ный (*о местности*); *~ аллея* то́полевая алле́я

тупыллык *сущ. разг.* то́полёвая ро́ща; *юл ~ буйлап бара* доро́га идёт вдоль то́полевой ро́щи

тупы́лсыман *прил.* **1.** похо́жий на то́поль; *~ агач* 1) де́рево ти́па то́поля 2) тополи́ное, древе́сное расте́ние; **2.** *мн.* **тупылсыманнар** *бот.* тополи́ные (*семейство растений*)

тупырдап *нареч. см.* **тупырдашып**

тупырдат|у *перех.* **1.** притопывать, перестукивать || перестук (*глухой и частый*); *ат аякларын ~а* ло́шадь глу́хо и ча́сто перестукивает копы́тами **2.** *в знач. нареч.* **тупырдатып** с глухова́тым сту́ком, шу́мом, гро́хотом; *~ып балчык төшерү* с глухи́м гро́хотом сва́ливать гли́ну; *~ып яңгыр ява башлау* застуча́л дождь **3.** *см.* **тыпырдату** □ **~ып бала табу** рожа́ть одного́ за други́м мно́го (*здоровых*) дете́й

тупырда́|у *неперех.* **1.** пры́гать, попры́гивать || попры́гивание от избы́тка сил (*о детях*); пляса́ть на ме́сте (*от радости или нетерпения*) **2.** стуча́ть, перестукивать

тупырдаш|у *неперех.* **1.** то́пать, стуча́ть нога́ми, копы́тами; притопывать; *абзарда маллар ~а* в хлеву́ скот стучи́т копы́тами; *биючеләр төрлечә ~тылар* плясуны́ по-ра́зному притопывали **2.** *в знач. нареч.* **тупырдашып** 1) оживлённо вме́сте; гурто́м, ста́йкой; *балалар ~ып уйнап йөриләр* де́ти оживлённо игра́ют 2) *перен.* оди́н за други́м; *~ып туып торалар* рожда́ются оди́н за други́м (*о детях*); *~ып килеп керү* заходи́ть оди́н за други́м; *~ып алмалар коела* одно́ за други́м па́дают я́блоки

тупырдашып *нареч.* оживлённо (*топая*) вме́сте, в гру́ппе, в ви́де (*оживлённой*) гру́ппы; гурто́м; ста́йкой; *балалар ~ үстеләр* де́ти росли́ оживлённой гру́ппой (*один за другим*)

тупырсык *прил.* то́лстый и подви́жный; полнокро́вный толстя́к; *~ малай* то́лстый и здоро́вый ма́льчик

тупырсыклан|у *неперех.* **1.** де́латься/сде́латься то́лстым и подви́жным **2.** *диал.* выпя́чиваться (*от здоровья, полнокровия — о частях тела*); налива́ться; *~ган иңнәре* нали́тые (его́) пле́чи

тупыр-тупыр *подр.* 1) *частому перестуку ног или копыт; тупыр-тупыр итеп* издава́я ча́стый перестук; стуча́ ноги́ (копы́тами) 2) *звуку падения множества камней и т. п.; тупыр-тупыр алма коела* дождём па́дают я́блоки

тур I *сущ.* **1.** сеть (*для ловли птиц*); *ир әйләнеп кулга төшәр, кош әйләнеп турга төшәр* (*посл.*) мужчи́на покру́жится, покру́жится, да и попадёт в ру́ки же́нщины, пти́ца покру́жится, покру́жится, да и попадёт в се́ти **2.** *мед.* катара́кта; *күзгә тур төште* появи́лась катара́кта в глазу́ **3.** узо́р, рису́нок на ко́же, тка́ни и т. п. (*выполненный только строчками, прямыми линиями*)

тур II *сущ. диал.* ме́сто; пря́мо; *кояш чыккан тур* ме́сто, где всхо́дит со́лнце; *шул турга бар* иди́ пря́мо туда́

тур III *разг. послелог; см.* **турында**; *бу тур сөйләмиләр* об э́том не говоря́т

тур IV *сущ.* **1.** *спец. спорт.* тур, круг, эта́п (*переговоров, выборов, отборочных игр и т. п.*); *беренче турда төшеп калу* вы́пасть в пе́рвом ту́ре (*о кандидате, спортсмене*) **2.** *спец.* тур (*в танце*); *вальс туры* тур ва́льса

тур V *сущ. зоол.* **1.** тур (*горный кавказский козёл*) **2.** тур (*вымерший дикий бык*)

тур VI *сущ. тех.* тур (*пирамида из камней, складываемая альпинистами*); *тур ясау* сооруди́ть тур

тура I *сущ. этногр. кул.* **1.** осо́бого ви́да тво́ро́г, сыро́к; *~ кайнату* выва́ривать тво́ро́г (сыро́к) **2.** сы́рники (*оладьи из смеси творога, яйца, сметаны, масла и немного муки*); *~ ясау* де́лать сы́рники

тура II *сущ.* **1.** 1) *ист.* передвижна́я ба́шня (*для осады городов*) 2) передвижна́я стена́ (*как защитное сооружение*) **2.** *шахм.* тура́, ладья́; *~ белән йөрү* ходи́ть туро́й

турагыч *сущ.* **1.** реза́к (*как кухонная утварь*) **2.** -ре́зка; *салым турагыч* соломоре́зка; *силос ~* силосоре́зка || *прил.* размельча́ющий; *~ машина* размельча́ющая (*сено, солому и т. п.*) маши́на

турай I *прил. диал. см.* **туры** 1

турай II *сущ. зоол.* детёныш кабана́

турайткыч *сущ. тех.* выпрями́тель; *ток ~* выпрями́тель то́ка || *прил.* выпрями́тельный; *~ җайланма* выпрями́тельное устро́йство

турайт|у *перех.* выпрямля́ть/вы́прямить || выпрямле́ние; *сынын ~ты* он вы́прямил стан; *алмаш токны ~у* выпрямле́ние переме́нного то́ка

турак I *сущ. бот.* **1.** толокня́нка **2.** укро́п; *~ чәчү* се́ять укро́п □ **~ уты** толокня́нка (*как лекарство*); *~ үләне см.* **турак** 1, 2

турак II *сущ. диал.* **1.** но́жка, ла́пка; копы́тце; *см.* **тәпи-турак 2.** *пчел.* обно́жка

тураклагыч *сущ. см.* **турагыч**

тураклан|у *возвр.-страд. от* **тураклау**; *~ган кәгазь* раскро́мсанная бума́га

тураклату *понуд. от* **тураклау**

тураклá|у *перех.* **1.** разруба́ть/разруби́ть, изруба́ть/изруби́ть; руби́ть, кромса́ть, кроши́ть (*на куски*) || ру́бка, кромса́ние; *утын ~у* (мелко) руби́ть дрова́ **2.** *перен. разг.* кроши́ть (*из пулемёта*); поруби́ть, заруби́ть *кого-л.* || ру́бка (*на войне*) □ **~п бетерү** (всех) переруби́ть; **~п ташлау** понаруби́ть, раскромса́ть

туралма *сущ.* кро́шево, се́чка; *салам ~сы* кро́шево соло́мы || *прил.* накро́шенный

туралы I *прил.* творо́жный; с тво́рого́м тура́; *~ май* творо́жное ма́сло

туралы II *прил. ист.* обу́ченный (*о ловчих птицах*); *~ кош баласы* обу́ченный птене́ц

турам *сущ.* кусо́чек, ло́мтик; *бер ~ ит* кусо́чек ме́лко нарезанного мя́са

турама *прил.* накро́шенный, (ме́лко) наре́занный || *сущ.* **1.** се́чка, кро́шево; ме́лко наре́занная соло́ма, трава́ и т. п. **2.** *диал. см.* **турамыш**

турамлану *страд. от* **турамлау**

турамла́|у *перех.* наре́зать одина́ковыми куска́ми; *ипи ~* наре́зать хлеб (*на одинаковые куски*)

турамчык *сущ. уменьш. к* **турам**; кусо́чек, кро́шка

турамыш *сущ. диал. кул.* окро́шка

туран I *сущ. ист. этногр.* **1.** тура́нец, тура́нцы (*жители евразийских степей и пустынь; скифы, тюрки, монголы и т. п.*) || тура́нский; ~ *телләре* тура́нские (тю́рко-монго́льские) языки́ **2.** *уст.* тюрк || тю́ркский

туран II *сущ. бот.* (~ **үләне**) укро́п; ди́кий укро́п

турангы *сущ. бот.* **1.** тамари́ск (*южный кустарник*) **2.** *см.* **турангы**

туранты *сущ.* **1.** обре́зки *чего-л.* **2.** *разг.* окро́шка

туранчы *сущ. ист.* сторо́нник еди́нства тура́нцев (*преимущ. тюрков, а также монголов*)

туранчылык *сущ. ист. см.* **пантюркизм**

турат *сущ. разг.* гнёдка, гнеда́я (*лошадь*)

турату *понуд. от* **турау**; заставля́ть/заста́вить поруби́ть, искроши́ть, измельчи́ть *что-л.*

тура|у *перех.* **1.** нареза́ть/наре́зать, разреза́ть/разре́зать; сечь || нареза́ние, наре́зка (*на мелкие куски*); *кишер ~у* нареза́ть морко́вь **2.** кромса́ть; разреза́ть на ча́сти (*без плана*) **3.** 1) распи́ливать/распили́ть || распи́ливание, распи́лка; *утын ~у* распили́ть (*ствол дерева*) на дрова́ 2) руба́ть, разруба́ть/разруби́ть (*на большие куски*) **4.** кроши́ть, накроши́ть, размельча́ть; шинкова́ть; *ашка суган ~у* накроши́ть лу́ку в суп; *кәбестә ~у* шинкова́ть капу́сту **5.** *см.* **тураклау** 2; *дошманны ~у* раскромса́ть врагов □ **~п ташлау** *см.* **тураклап ташлау**

турач *сущ. зоол.* тура́ч (*птица семейства фазановых*)

тураш|у *взаимно-совм. от* **турау**; помога́ть/помо́чь измельча́ть

тура|ю *неперех.* выпрямля́ться/вы́прямиться || выпрямле́ние □ **~еп басу** встать, вы́прямившись во весь рост

турба́за *сущ. спорт.* турба́за (тури́стская ба́за)

турби́на *сущ. тех.* турби́на

турби́налы *прил.* турби́нный; ~ *двигатель* турби́нный дви́гатель

турби́начы *сущ.* **1.** специали́ст по турби́нам **2.** рабо́чий по эксплуата́ции турби́н

турбобур *сущ.* турбобу́р

турбовинтлы *прил.* турбовинтово́й; ~ *самолёт* турбовинтово́й самолёт

турбогенера́тор *сущ.* турбогенера́тор

турбореакти́в *прил.* турбореакти́вный; ~ *двигатель* турбореакти́вный дви́гатель

турбулент *прил. спец.* турбуле́нтный; ~ *агым* турбуле́нтное движе́ние

турга *сущ. ист.* **1.** *см.* **тугра 2.** монограмма, напи́санная ва́зью ара́бскими бу́квами (*на обложках книг, на некоторых документах и т. п.*)

тургай *сущ. зоол.* **1.** жа́воронок; ~ *сайравы* пе́ние жа́воронка; ~ *булып сайрау* петь жа́воронком **2.** *диал.* воробе́й **3.** *диал. о различных мелких птичках;* **карабаш** ~ конопля́нка; **сары** ~ и́волга; **бүз** ~ степно́й жа́воронок □ **~ борчагы** *бот.* астрага́л да́тский; ~ **җитене** *бот.* звездча́тка злаково́йдная; ~ **эләге** *бот.* спа́ржа

тургач *сущ. спец.* подста́вка (нана́ст) для ло́вчей пти́цы; соколи́ный постаме́нт ◊ **~ка кундыру** жени́ть мо́лодца

турда *послелог разг. см.* **турыда**; *бу* ~ об э́том

туризм *сущ.* тури́зм; *тау ~ы* го́рный тури́зм

турист *сущ.* тури́ст; *~лар дирбиясе* снаряже́ние тури́стов

тури́стик *прил.* туристи́ческий; тури́стский; ~ *поход* туристи́ческий похо́д

туристлык *сущ.* **1.** тури́зм || туристи́ческий; тури́стский; ~ *белән мавыгу* увлека́ться тури́змом; ~ *маршруты* туристи́ческий маршру́т; ~ *дәрте* тури́стский энтузиа́зм **2.** положе́ние и́ли заня́тие тури́ста; *~та йөрү* ходи́ть в тури́стах (тури́стом)

турка I *сущ. ист.* **1.** пло́тный китайский шёлк, шёлковая ткань; ~ *белән чапан тышлау* обшива́ть, крыть чапа́н пло́тным шёлком **2.** ва́тная броня́ ры́царя (*обшитая шёлком*); ва́тная подсти́лка шле́ма; ~ *кигән баһадир* богаты́рь в ва́тной броне́ || *прил.* шёлковый, сде́ланный, сши́тый из пло́тного шёлка; обши́тый пло́тным шёлком; *туйга барсаң туеп бар, ~ туның киеп бар* (*посл.*) идёшь на сва́дьбу — иди́ сы́тым, наде́вши шёлковую сва́дебную оде́жду (*т. е., идучи на свадьбу, не надейся на угощение и на подарки*)

турка II *прил. диал.* **1.** крупнозерни́стый; ~ *бодай* крупнозерни́стая пшени́ца **2.** произведённый на прода́жу, ры́ночный

турлану *диал. неперех.* **1.** покрыва́ться/покры́ться се́ткой, штриха́ми **2.** извива́ться, ви́ться (*о линиях*) **3.** *перен.* 1) беспреры́вно, беспреста́нно меня́ться; *явар көндәй ~* меня́ться, как дождли́вый день 2) появля́ть/появи́ть непостоя́нство; *тугызга ~* де́вять раз в день меня́ть реше́ние

турла|у *перех. диал.* **1.** 1) обводи́ть/обвести́, опу́тывать/опу́тать 2) окружа́ть/окружи́ть (*всем необходимым*) **2.** покрыва́ть/покры́ть са́мку (*о домашних птицах: петухе, гусаке, селезне*) **3.** переплета́ть/переплести́; обмота́ть || переплете́ние, обмо́тка (*шнуром, проволокой и т. п. что-л.*); *~ган тасаяк* переплетённое (*проволокой*) блю́дце

турлы *прил.* **1.** узо́рчатый, вы́шитый вензеля́ми; ~ *читек* вы́шитые вензеля́ми и́чиги; ~ *киез* во́йлок, укра́шенный лине́йными узо́рами **2.** покры́тый катара́ктой (*о глазе*); *күзем нурлы иде, ~ булды* глаза́ мои́ бы́ли (*в молодости*) лучи́стыми, тепе́рь покры́лись катара́ктой

турмалин *сущ.* турмали́н (*полудрагоценный камень*); *кара ~* чёрный турмали́н; *алсу ~* а́лый турмали́н || *прил.* турмали́новый; ~ *кулон* турмали́новый кулон

ту́рман I *сущ. диал.* **1.** обстано́вка, обставле́ние (*квартиры и т. п.*); *өй ~ы* обстано́вка до́ма, дома́шняя у́тварь **2.** причинда́лы, принадле́жности; *ат ~ы* ко́нская сбру́я, теле́га и т. п.

ту́рман II *сущ. зоол.* ту́рман (*порода голубей*)

турне *сущ.* турне́ (*круговое путешествие*); ~ *ясау* соверши́ть турне́, быть в турне́

турнепс *сущ. с.-х.* турне́пс; ~ *орлыгы* се́мя турне́пса

турник *сущ. спорт.* турни́к; переклади́на; *~та эйләну* крути́ться на переклади́не

турникет *сущ.* турнике́т (*вертящаяся крестовина на входе в здание, стадион и т. п.*)

турнир *сущ. спорт.* турни́р || турни́рный; ~ *таблицасы* турни́рная табли́ца

турнирлы *прил.* турни́рный, в ви́де турни́ра; ~ *ярыш* турни́рное соревнова́ние

турсаеш|у *взаимно-совм. от* **турсаю**: 1) наду́ться, оби́деться, обижа́ться (*о многих*); *әйтсәң ~алар* ска́жешь — оби́женно выпя́чивают гу́бы 2) ду́ться друг на дру́га; *икесе дә ~каннар* у обо́их наду́тый вид

турсайт|у *перех.* надува́ть/наду́ть (*губы в знак недовольства, обиды*); *иренен ~ып тора* стои́т, вы́пятив гу́бы (наду́вшись)

турса|ю *неперех.* **1.** ду́ться, наду́ться (*о губах*) **2.** *перен.* ду́ться, фуфы́риться *прост.; кемгә ~ясың?* на кого́ ду́ешься?

турсаюлы *прил.* оби́женный, недово́льный, выража́ющий недово́льство; ~ *караш* оби́женный взгляд

турсаючан *прил.* оби́дчивый; скло́нный обижа́ться, ду́ться

турсаючанлы|к *сущ.* оби́дчивость; *~гы бар* ему́ (ей) прису́ща оби́дчивость

турсык I *сущ. обл.* турсу́к, (*небольшой*) бурдю́к; коше́ль; *~та сөт оемый* в турсуке́ молоко́ не ки́снет ◊ **~ка тулган** си́льно оби́делся, си́льно ду́ется

турсык II *прил.* **1.** наду́тый, пу́хлый (*о лице, губах и т. п.*); *~ битле* с пу́хлым, одутлова́тым лицо́м **2.** оби́женный; *~ чырай* оби́женное лицо́, оби́женное выраже́ние лица́ **3.** ча́сто обижа́ющийся, оби́дчивый; *~ кеше* оби́дчивый челове́к

турта *сущ.* **1.** вы́топки; оса́док по́сле топле́ния (*масла, жира*); *сары май ~сы* вы́топки ма́сла, оса́док по́сле топле́ния коро́вьего ма́сла **2.** *диал.* шкова́рки; со́ус со шкова́рками; *см. тж.* **сызык 3.** *диал.* нава́р; *см. тж.* **өре** □ **~ кумәч** лепёшка, испечённая на вы́топках

турталы *прил.* **1.** нетоплёный; *~ май* нетоплёное ма́сло **2.** с больши́м вы́ходом вы́топок

турун *сущ. книжн.* внук, вну́чка; *тугыз угыл анасы, туксан ~ әбисе* (*погов.*) мать девяти́ сынове́й и девяно́ста внуча́т (вну́ков, вну́чек)

туры *прил.* **1.** прямо́й, прямолине́йный; ро́вный (*о линии*); *~ сызык* прямо́я ли́ния; *~ сын* прямо́й стан; *~ юл* прямо́я доро́га **2.** *перен.* ве́рный, пра́вильный; то́чный и просто́й; *~ җавап* ве́рный отве́т; *~ фикер* ве́рная мысль; *~ хисап* то́чный (просто́й) расчёт **3.** *перен. разг.* правди́вый, справедли́вый, че́стный; *~ кәсеп* че́стный про́мысел; *~ кеше иде* был справедли́вым челове́ком **4.** откры́тый; откровенный, прямо́й, нелицеприя́тный, непосре́дственный; *~ сүз* откровенное выска́зывание; *~ холык* откровенный (непосре́дственный) нрав **5.** *см.* **тугры, тугрылыклы**; *~ булып калучы* остающийся ве́рным || *нареч.* **1.** пря́мо, прямолине́йно; *~ бару* идти́ пря́мо; *~ тоту* держа́ть пря́мо; *~ безгә кил* приходи́ пря́мо к нам; *сызыгыңны ~ сыз* ли́нию черти́ пря́мо **2.** *разг.* ве́рно, пра́вильно, то́чно; *~ сөйли* ве́рно говори́т; *~ билгеләде* ве́рно (то́чно) определи́л **3.** *разг.* правди́во, че́стно, справедли́во; *~ өләшү* справедли́во распредели́ть **4.** откровенно, пря́мо; *~ әйтү* откровенно вы́сказать/вы́сказаться **5.** пря́мо, то́чно, отрица́тельно (*о наводке, стрельбе и т. п.*); *~ ату* то́чно стреля́ть; *~ тидерү* то́чно попада́ть (*при стрельбе*); *~ төзәү* то́чно прице́литься || *сущ. в косв. п.* **1.** *разг.* вообража́емая прямо́я, вообража́емая то́чка (*относительно какого-л. предмета, о котором идёт речь*); *мич ~сында* о́коло пе́чи; во́зле пе́чи; *кояш чыккан ~да* в направле́нии восхо́да со́лнца; *шул ~га бар да бар* иди́ и иди́ в э́том направле́нии **2.** *мат.* прямо́я; *ике ~ның өченче туры белән кисешүе* пересече́ние двух прямы́х с тре́тьей прямо́й □ **~ атыш** *спец.* прямо́й вы́стрел, прямо́я стрельба́; **~ канатлы** *зоол.* прямокры́лое; **~ канатлылар** (*насекомые*) отряд прямокры́лых; **~ көчәнеш** *тех.* прямо́е напряже́ние; **~ мәгънә** прямо́е значе́ние; **~ мәрәтә** *см.* **чүрәкәй**; **~ салым** прямо́й нало́г; **~ почмак** *мат.* прямо́й у́гол; **~ почмаклы** *мат.* прямоуго́льный; **~ призма** *мат.* прямо́я при́зма; **~ реакция** *спец.* прямо́я реа́кция; **~ сабак** *бот.* прямо́й сте́бель; **~ сайлау** прямы́е вы́боры; **~ санау** *мат.* прямо́й счёт; **~ сөйләм** *лингв.* прямо́я речь; **~ сызык** *мат.* прямо́я ли́ния; **~ сызыклы** прямолине́йный; **~ тәмамлык** *лингв.* прямо́е дополне́ние; **~ тигезләмәсе** *мат.* уравне́ние прямо́й; **~ ток** *физ.* прямо́й ток; **~ токлы** *физ.* прямото́чный; **~ эчәк** *анат.* прямо́я кишка́; **~ яка** прямо́й воротни́к ◊ **~ бәрү 1.** *см.* **турыдан бәрү 2.** идти́ напроло́м; *~ бәреп ерак китә алмассың* иди́ напроло́м, далёко не уйдёшь; **~ килгәндә** при слу́чае; **~ килү 1.** встре́тить, встре́титься; *ул миңа урамда ~ килде* он мне встре́тился на у́лице **2.** подверну́ться, попада́ться **3.** приходи́ться/прийти́сь; быть вы́нужденным; *кабат кайтырга ~ килде* пришло́сь повто́рно верну́ться **4.** выпада́ть/вы́пасть (*на долю и т. п.*); *бәхетенә ~ килгән* вы́пало ему́ на (счастли́вую) до́лю **5.** приходи́ться (по счёту); *бер урынга өч претендент ~ килә* на одно́ ме́сто прихо́дится три претенде́нта **6.** попада́ть/попа́сть *во что, куда; икебез дә бер полкка ~ килдек* мы о́ба попа́ли в оди́н (и тот же) полк **7.** совпада́ть/совпа́сть ме́жду собо́й *с чем; теләкләребез ~ килә* на́ши жела́ния совпада́ют **8.** соответствовать (*по размеру*) **9.** приходи́ться, доводи́ться *кому-л. кем; ул безгә агай ~ килә* он дово́дится нам дя́дей; **~ китерү 1.** заста́вить/заста́ть *кого-л. где; вендә ~ китерү* заста́ть его́ до́ма **2.** приводи́ть/привести́ в совпаде́ние и́ли соответствие; подгоня́ть/подогна́ть; *вакытына ~ китереп* совмеща́я во вре́мени; **~ куллы** че́стный (*в отношении чужих вещей*); **~ сүзле; ~ төтенле** не му́дрствующий лука́во; просто́го и я́сного обраще́ния с людьми́ **1.** откровенный, скло́нный выска́зываться напрями́к **2.** правди́вый; **~ тутай** *ирон.* же́нщина бестактного, недипломати́ческого поведе́ния; **~ юл белән** прямы́м путём; прямёхонько; **~ (~дан) яру** говори́ть откровенно и пря́мо, ре́зать пра́вдуму́тку; **~ ярып сөйли** говори́т пря́мо; ре́жет пра́вдуму́тку (*в глаза*) || *послелог. диал. см.* **турында**; *бу ~ сөйләшмик инде* не бу́дем говори́ть об э́том || *прил.* **1.** гнедо́й; *~ алаша* гнедо́й ме́рин; *~ кашка* гнеда́я со звёздочкой (отме́тинкой); *~ соры* се́ро-гнедо́й **2.** *в знач. сущ.* гнёдка, гнедо́й, гнеда́я (ло́шадь); *~ны жик* запряга́й гнеду́ю

турыда *послелог. разг. с личн. и указ. мест. см.* **турында**; *бу ~* об э́том; *шул ~* о том; *минем ~* обо мне́

турыдагы *послелог. разг. с личн. и указ. мест. см.* **турындагы**; *минем ~ сүзләр* слова́ (име́ющие хожде́ние) обо мне́

турыдан I *нареч.* **1.** по прямо́й, напрями́к, прямико́м; *~ китү* пойти́ по прямо́й (прямико́м) **2.** *перен.* напрями́к, откровенно, откры́то; *~ сөйләшергә кирәк* на́до говори́ть откровенно (в откры́тую) ◊ **~ бәрү (суктыру) 1.** идти́ напроло́м **2.** откровенно вы́сказаться, сказа́ть в глаза́

турыдан II *послелог. разг. с ограничительным оттенком* о, об, обо, про; *бу ~ ни әйтим инде?* что мне сказа́ть об э́том? что я могу́ об э́том сказа́ть?

турыдан-туры *нареч.* **1.** непосре́дственно; без посре́дников; *турыдан-туры инглизчәдән тәрҗемәләү* переводи́ть непосре́дственно с англи́йского **2.** пря́мо, прямико́м, без осо́бой подгото́вки, сра́зу; *турыдан-туры эшкә күчү* перейти́ пря́мо к де́лу **3.** откровенно, в откры́тую; *~турыдан-туры сөйләшик* поговори́м в откры́тую || *прил.* непосре́дственный; *турыдан-туры башлык* непосре́дственный нача́льник

турылабрак *нареч.* соответственно, сообра́зно; сообразу́ясь; *шул вакытка ~ кил* приходи́, сообразу́ясь с тем вре́менем

турыландыру *перех.* де́лать/сде́лать прямы́м; *см. тж.* **турайту**

турылан|у *возвр. от* **турылау**; станови́ться/стать прямы́м; *см. тж.* **тураю**

турылап *нареч. разг.* **1.** в сто́рону; *авылга ~ китте* пошёл в сто́рону дере́вни **2.** *см.* **туп-туры**; *урманга ~ бару* идти́ пря́мо в лес

турыларында *послелог разг.* понемно́гу о (об, обо), про, относи́тельно, каса́тельно *кого, чего; утын ~ сөйләштек* поговори́ли каса́тельно дров (дрови́шек)

турылата *нареч. см.* **турылатып**

турылату *перех.* **1.** *см.* **турайту 2.** направля́ть/напра́вить пря́мо *куда, к чему*

турылатып: турылатып әйткәндә пря́мо (откро́венно) говоря́; одни́м сло́вом; *~ әйткәндә, эшләр шәп түгел* говоря́ пря́мо, дела́ нева́жны

турыла́у *перех.* **1.** выпрямля́ть/вы́прямить, распрямля́ть/распрями́ть || выпрямле́ние, распрямле́ние (*пути, проволоки*) **2.** поправля́ть/попра́вить; подправля́ть/подпра́вить || поправле́ние, подправле́ние, приведе́ние в ну́жное (норма́льное, прямо́е) положе́ние; *кыйшайганны ~* попра́вить покоси́вшееся **3.** пра́вить, направля́ть/напра́вить (*лодку к берегу*) **4.** наводи́ть/навести́, нацели́вать/нацели́ть (*винтовку в мишень*) **5.** *разг. см.* **дөресләү** 2; *сәгать ~* попра́вить часы́ **6.** *разг.* подда́кивать (*не вникая в суть, но говоря* туры, туры)

турылы|к *сущ.* **1.** прямизна́; *багананың ~гы* прямизна́ столба́ **2.** прямота́, пра́вильность (*слов, поведения и т. п.*); *~гы өчен яратам* люблю́ (*его, её*) за прямоту́ **3.** *см.* **тугрылык 4.** *уст. разг. см.* **дөреслек**; *~к өчен* за пра́вду и справедли́вость

турылыклы *прил.* **1.** ве́рный, пре́данный; *халыкка ~* пре́данный своему́ наро́ду; *~ булып калу* остава́ться ве́рным **2.** *разг.* че́стный; справедли́вый; *см. тж.* **тугрылыклы**

турылыклылык *сущ.* **1.** ве́рность, пре́данность; *туган илгә ~* пре́данность Ро́дине **2.** *редко* правди́вость

турылыксыз *прил.* **1.** неве́рный, преда́тельский; *~ булып чыгу* оказа́ться неве́рным; *~ характер* преда́тельский хара́ктер **2.** несправедли́вый, нече́стный; *~ кеше* нече́стный челове́к

турылыксызлык *сущ.* неве́рность; преда́тельство; *~ күрсәтү* вы́казать неве́рность; оказа́ться неве́рным

турында *послелог* о, об, обо; про; *җыр ~ җыр* пе́сня о пе́сне; *минем ~* про меня́, обо мне́; *барысы ~ да* обо всём

турындагы *прил.* относя́щийся *к чему*; *ср. тж.* **турында**; *эш ~ доклад* докла́д, относя́щийся к рабо́те

турындагылы|к, турындалы|к *сущ.* то, что речь идёт *о чём*; *сүзнең эш ~гы* то, что речь идёт (шла) о рабо́те

турыпочмак *сущ. см.* **турыпочмаклык**

турыпочмаклап *нареч.* под прямы́м угло́м; наперере́з; *урам аша ~ чыгу* переходи́ть че́рез у́лицу под прямы́м угло́м

турыпочмаклы *прил. мат.* прямоуго́льный; *~ параллелепипед* прямоуго́льный параллелепи́пед

турыпочмаклык *сущ. мат.* прямоуго́льник; *тигезьянлы ~* равносторо́нний прямоуго́льник

турысы *сущ. разг.* **1.** пра́вда; вся пра́вда; *~ шул* вся пра́вда в э́том (вот в чём); *һәрвакыт ~н әйтергә кирәк* всегда́ на́до говори́ть пра́вду напрями́к **2.** *в знач. вводн. сл.* по пра́вде говоря́; *~, ул ишетми калды* по правде говоря́, он недослы́шал **3.** *в знач. послелога в косв. п.* **1. турысында** *разг. см.* **турында 2. турысыннан** *разг.* насчёт; *эш ~нан* насчёт рабо́ты □ (*нәрсә*) **~на килгәндә** каса́тельно того́, что; что каса́ется *чего;* **~н (гына) әйткәндә** е́сли говори́ть пра́вду; че́стно говоря́; по пра́вде сказа́ть

турысында *послелог разг.* у, по́дле; *агач ~* у де́рева

турысындагы *послелог разг. см.* **турындагы**

турытын *диал. нареч.* напрями́к, прямико́м (*о дороге, курсе*); *~ бару* идти́ напрями́к || *прил.* прямо́й (*о дороге, маршруте*); *~ юл* доро́га прямико́м

тускын *сущ. диал.* прегражде́ние, прегра́да; *~ булу* быть прегра́дой *кому, чему*

тусрый *прил. разг.* мяси́стый; пу́хлый, одутлова́тый (*о лице*); *~ битле* с мяси́стым лицо́м

тустаган *сущ.* **1.** *диал.* деревя́нный ковш, деревя́нная поварёшка; **поло́вник** (*вырезанный из цельной древесины*); *~ белән су сибү* поливать водо́й деревя́нным поло́вником **2.** деревя́нный стака́н, деревя́нный бока́л; *бер ~ эчемлек* по́лный деревя́нный стака́н напи́тка **3.** *см.* **тустак ◊ ~ эчү** договариваться о бра́ке ме́жду детьми́ (*об отцах*); **~ы тулган** *см.* **турсыгы тулган**

тустак *сущ. диал.* **1.** деревя́нное блюдо, вы́точенное из це́льной древеси́ны (*из утолщения ствола березы и т. п.*); *~тан ашау* есть из деревя́нного блю́да; *~ка тутыру* накла́сть на деревя́нное блю́до **2.** любо́е блю́до и́ли блю́дце; *~тан ашау* есть из блю́да ◊ **~ (тустаган) күзле** лупогла́зый

туснак, тоснак *сущ. ист. диал.* долгово́й раб; челове́к, до́лжный отраба́тывать за долги́ ◊ **~ кебек карау** смотре́ть с печа́лью в глаза́х

тустыру *перех.* держа́ть ребёнка (*над горшком и т. п.*); *бәбине ~* держа́ть младе́нца

тут I *сущ.* тут, ту́то́вник || ту́товый; *тут агачы* ту́то́вник; *тут җиләге* ту́товая я́года □ **тут ефәкчесе** *зоол.* ту́товый шелкопря́д

тут II *сущ.* **1.** ржа, тёмное пятно́ (*на поверхности чего-л.*); *яфракларга тут төшкән* ли́стья покры́лись ржой, тёмными пя́тнами (*осенью, при увядании, а также от различных заболеваний*) **2. 1)** весну́шка, пя́тна на лице́; *йөзендә туты булса да, күзендә уты бар* (*погов.*) хоть на лице́ и пя́тна, зато́ в глаза́х — ого́нь 2) тёмный налёт, загар (*на лице*) **3.** *см.* **тутык 4.** *перен.* оса́док в душе́, след недово́льства собо́й и т. п.

тута *сущ. диал.* ста́ршая сестра́ по отноше́нию к мла́дшей (*младший брат называет старшую сестру обычно словом* апа); *~сы өчен кайгырмыйбыз, сеңелләре тагы үсә* (*песня*) не горю́ем из-за ста́ршей сестры́, вслед расту́т мла́дшие (сёстры)

тутай *сущ.* **1.** *уст.* аристокра́тка, же́нщина вы́сшего кру́га; княжна́ **2. 1)** *диал.* тутай (*форма уважительного названия и обращения к старшей сестре, обычно употребляется после имени собственного*); *Миңлезифа ~* ста́ршая сестра́ Минлезифа́ 2) *см.* **апа** 2

тутакай *сущ.* тутака́й **1.** *ласк. к* **тута, тутай** (*форма официального обращения к женщине старше себя*); *Хәнифә ~* сестри́ца Ханифа́ **2.** *диал.* же́нщина из ро́дственников му́жа (*немного старше говорящего*): тётя, тётушка

туталы-сеңелле *прил. см.* **апалы-сеңелле**

туташ *сущ.* ба́рышня, де́вушка, девица, де́ва, мисс, мадемуазе́ль; *Хәдичә ~* мадемуазе́ль Хадича́

туткыл *сущ.* конопа́тость; *йөзенә кара ~ төшкән* с тёмными пя́тнами на лице́ || *прил.* с больши́ми весну́шками; с пя́тнами; конопа́тый; *~ бит* конопа́тое лицо́

туткыллан|у *неперех.* покрыва́ться/покры́ться весну́шками, тёмными пя́тнами (*о лице*); *җилдә йөреп, ~ган* (лицо́) покры́лось тёмными пя́тнами от постоя́нного пребыва́ния на ветру́

туткыллы *прил. см.* **тутлы**; *~ димиләр мине, сипкелле диләр мине* (*песня*) про меня́ говоря́т не конопа́тая, а говоря́т — весну́шчатая

тутлан|у *страд.-возвр. от* **тутлау**; *~ган киндер* побелённый холст

тутлату *перех. см.* **тутлау 1**

тутла́|у 1. *перех.* бели́ть/побели́ть || беле́ние, побе́лка (*холста, белья и т. п. на снегу, на морозе*); *~рга җәю* расстели́ть для беле́ния **2.** *неперех.* беле́ть/побеле́ть (*очиститься от грязи*) на снегу́, на моро́зе; *~нган киндер* побелёвший на моро́зе холст

тутлы *прил.* **1.** слегка́ ржа́вый, покры́тый пя́тнами ржа́вчины; *~ калай* жесть с (то́нкими) пя́тнами ржа́вчины **2.** конопа́тый, весну́шчатый, с пя́тнами (*о лице*); име́ющий конопа́тое лицо́; *кара ~* сму́глый, сму́гло-весну́шчатый; *сары ~* све́тло-конопа́тый; све́тло-весну́шчатый

ту-ту *подр.* зву́кам го́рна, клаксо́на, гудка́ автомаши́ны и т. п.; *см. тж.* **тү-тү**

туту *сущ. диал.* **1.** фимиа́м, ла́дан **2.** прия́тный за́пах вы́стиранного

тутчылык *сущ.* тутово́дство || тутово́дческий; *~ хуҗалыгы* тутово́дческое хозя́йство

туты|гу *неперех.* **1.** ржаве́ть/заржаве́ть, поржаве́ть || ржавле́ние, корро́зия; *~кган тимер* ржа́вое желе́зо; *~гу процессы* проце́сс корро́зии **2.** темне́ть/потемне́ть, жу́хнуть/пожу́хнуть || потемне́ние; *~кган көзге* потемне́вшее зе́ркало **3.** *перен.* плесневе́ть, ржаве́ть (*о душе*); *күңел ~га башлады* душа́ ста́ла плесневе́ть

тутыгучан *прил.* ржаве́ющий, поддающийся корро́зии; *~ металл* мета́лл, подве́рженный корро́зии

тутыгучанлык *сущ.* подве́рженность корро́зии

тутый *сущ.* **1.** попуга́й; *~ аягын күреп хурлана, каурыен күреп сырлана* (*посл.*) попуга́й посмо́трит на свою́ но́жку — опеча́лится, посмо́трит на пе́рья — прихора́шивается; *~ теле аркасында читлеккә керә* (*посл.*) язы́к мой — враг мой (*букв.* попуга́й попада́ет за решётку из-за своего́ языка́) **2.** *перен.* попуга́й, жа́лкий эпиго́н □ **~ кош 1.** *см.* **тутый 1-2 2.** челове́к в кричу́щей оде́жде, пижо́н; **~ күз** *зоол.* павли́ний глаз (*вид бабочки*) ◊ **~ каурые 1.** кричу́щая оде́жда, одея́ние **2.** неосмы́сленные фра́зы; бахва́льство, шарлата́нство, пустозво́нство; **~ тоту** *см.* **кош тоту**

тутыйлан|у *неперех.* попуга́йничать || попуга́йничанье; эпиго́нствовать; *гелән ~ма* не попуга́йничай постоя́нно (не повторя́й всё вре́мя чужо́е)

тутык *сущ.* **1.** ржа, ржа́вчина; *тимерне ~ ашый, күңелне көклык ашый* (*погов.*) желе́зо заеда́ет ржа, ду́шу заеда́ет бе́дность **2.** тёмный нале́т (*на листьях, зеркале и т. п.*), пожу́хлость, почерне́ние; черноте́ **3.** боло́тная руда́, боло́тная ржа́вчина || *прил. разг.* ржа́вый; *~ кыңгырау* ржа́вый колоко́льчик □ **~ гөмбәсе** *бот.* ржа́вчина; **~ үләне** *бот.* ве́йник

тутыклан|у *неперех.* поржаве́ть, приня́ть ржа́вый цвет; *~ган көзге* поржаве́лое, пожу́хлое зе́ркало

тутыклы *прил. см.* **тутлы 1.** со ржа́вчиной, поржаве́лый; со ржа́вым пятно́м; *~ өслек* пове́рхность со ржа́вым пятно́м (со ржа́вчиной) **2.** ржа́вчинный; *~ яфрак* ржа́вчинный лист; лист со ржа́выми пя́тнами

тутыклы|к *сущ.* ржа́вость; *суның ~гы* ржа́вость воды́

тутыкмас *прил. прям., перен.* нержаве́ющий; *~ корыч* нержаве́ющая сталь; *мәдәниятебезнең ~ җәүһәрләре* нержаве́ющие жемчу́жины на́шей культу́ры

тутыктыргыч *прил.* коррози́рующий, спосо́бствующий ржа́влению; *~ тиреләк* спосо́бствующая ржа́влению среда́; *~ матдәләр* коррози́рующие вещества́

тутыктыр|у *перех.* ржа́вить; *нигә ~ып яткырасыз* заче́м оставля́ете ржаве́ть (*букв.* лежа́ть и ржаве́ть); *тоз тимерне тутыктыра* соль спосо́бствует ржа́влению желе́за

тутыктыручан *предик. прил.* коррози́рующий

тутыктыручы *прил. см.* **тутыктыргыч**

тутыргыч *сущ. тех.* **1.** заполни́тель; *буяу ~ы* заполни́тель кра́ски **2.** *см.* **төягеч**

тутырлы *прил.* конопа́тый, пятни́стый, с кру́пными весну́шками на лице́; *чутырлы һәм ~* ряба́я и конопа́тый

тутырма *сущ.* вид ли́верной колбасы́ (*национальное блюдо*); *~ пешеру* свари́ть ли́верную колбасу́ || *прил.* с начи́нкой, начинённый, запо́лненный *чем-л.*; *~ тавык* (жа́реная) ку́рица, запо́лненная начи́нкой

тутырту *понуд. от* **тутыру**; *бланкны ~* проси́ть, веле́ть запо́лнить бланк

тутыр|у *перех.* **1.** *в разн. знач.* наполня́ть/напо́лнить, заполня́ть/запо́лнить || наполне́ние, заполне́ние; *өяләмә ~у* напо́лнить с лихво́й; *кырларны ~ып ускән ашлыклар* хлеба́, запо́лнившие (в своём ро́сте) поля́; *бакчаны агач белән ~ды* он обсади́л (запо́лнил) весь сад дере́вьями; *күк йөзен ~ып болыт килә* надвига́ются ту́чи, запо́лнив всё не́бо; *ислемай бөтен өйне ис белән ~ды* весь дом запо́лнился за́пахом духо́в; *анкета ~у* запо́лнить анке́ту **2.** *в разн. знач.* набива́ть/наби́ть, начиня́ть/начини́ть || набива́ние, начи́нка; *мендәргә мамык ~у* наби́ть поду́шку пу́хом; *базга кар ~у* запо́лнить (наби́ть) по́греб сне́гом; *тутырма ~у* начини́ть колбасу́ **3.** накла́дывать, наложи́ть, накла́сть *прост.* (во мно́жестве); сы́пать/насы́пать; лить/нали́ть; грузи́ть, нагружа́ть/нагрузи́ть || накла́дывание, насыпа́ние, наliва́ние, нагру́зка *чего-л. во что-л.*; *арбага ~у* накла́дывать на теле́гу (*мешки, капусту*); *капчыкка ~у* набива́ть в мешо́к **4.** *перен.* нава́ливать/навали́ть; дава́ть/дать нава́лом, во мно́жестве; *миңа ~ганнар гына* ну и навали́ли мне (*что-л. не всегда желательное*) **5.** (*полностью*) выполня́ть || выполне́ние (*планов и т. п.*); *бурыч ~у* вы́полнить обяза́тельства; *норма ~у* вы́полнить но́рму (*в работе*) **6.** доводи́ть/довести́ || доведе́ние (*до определённого состояния, уровня и т. п.*); *көзгә чаклы эш көннәре санын йөз иллегә ~ам* до о́сени число́ рабо́чих дней доведу́ до ста пяти́десяти **7.** исполня́ться/испо́лниться, дожи́ть, дослужи́ть (*до определённого количества лет*); *биел мин иллене ~дым* в э́том году́ я дожи́л до пяти́десяти лет (мне испо́лнилось пятьдеся́т лет)

тутыручы *сущ.* насыпа́льщик, наliва́льщик, гру́зчик-упако́вщик

тутырын|у *неперех.* нагружа́ться (*на дорогу*); *син бик ~ма эле* ты не о́чень-то нагружа́йся

тутырып *нареч.* **1.** 1) дополна́; до́верху; *~ салу* нагрузи́ть (*машину*) дополна́ (до́верху) 2) по́лностью; *см. тж.* **тулысынча**; *бурычны ~ кайтардым* я отда́л свой долг по́лностью **2.** *перен. разг.* на весь, во весь; *урам ~ кычкыру* кричать на всю у́лицу; *авыз ~ әйтү* сказа́ть во весь го́лос; *күзне ~ карау* смотре́ть (гляде́ть) во все глаза́; *~ ачу* открыва́ть/откры́ть во всю (*двери*) **3.** *перен. разг.* мно́го; о́чень мно́го; *~ кучтәнәч бирдем* я дал мно́го гости́нцев

тутырыш|у *взаимно-совм. от* **тутыру**; помога́ть/помо́чь нагружа́ть, насыпа́ть и т. п.

тутыш *сущ. кул.* вид пирога́, пирожко́в (с мя́сом)

тутыя *сущ.* 1. *книжн.-поэт.* квинтэссе́нция *чего-л.*, са́мая драгоце́нная составна́я часть *чего-л.*; *җанымның ~сы* су́щность мое́й души́ (*о любимом человеке*) 2. *уст.* цинк 3. ци́нковые лека́рства; *күз ~сы* ци́нковая мазь для глаз

ту|у I *неперех.* 1. рожда́ться/роди́ться || рожде́ние; *бала туу шатлыгы* ра́дость по слу́чаю рожде́ния ребёнка; *туу турында таныклык* свиде́тельство о рожде́нии 2. *перен.* зарожда́ться/зароди́ться; *миндә җылы хисләр туды* во мне зароди́лись тёплые чу́вства 3. возника́ть/возни́кнуть, появля́ться/появи́ться || возникнове́ние, появле́ние; *яңа мөмкинлек туды* появи́лась но́вая возмо́жность 4. 1) *поэт.* восходи́ть || восхожде́ние (*небесных тел и явлений*); *таң туа* восхо́дит (занима́ется) заря́; *кояш туды* взошло́ со́лнце 2) наступа́ть/наступи́ть (*о единицах времени*); *яңа көннәр туа* наступа́ют но́вые дни 5. *перен.* пробужда́ться/пробуди́ться; *теләк туу* пробужде́ние жела́ния □ **туган ел** год рожде́ния; **туып килү** зарожда́ться/зароди́ться; постепе́нно появля́ться/появи́ться; приближа́ться/прибли́зиться; постепе́нно наступа́ть; *туып килгән вакыйгалар* приближа́ющиеся собы́тия ◊ **туганнан бирле** со дня рожде́ния, о́т роду; **тумаган балага (малайга) күлмәк тегү** выдава́ть жела́емое за действи́тельное (*букв.* гото́вить оде́жду нероди́вшемуся сы́ну); **тумаган тайга нукта уру (камыт ясау)** *см.* **тумаган балага күлмәк тегү; тумаган тайны дагалау, тумаган тайның билен сындыру** перестрахова́ться, чрезме́рно опаса́ться, сли́шком ра́но гото́виться к тому́, что вряд ли случи́тся; **тумаган туры алаша** с безоснова́тельной наде́ждой на хоро́шее, что мо́жет и не полу́чится; **тумас борын картайган** *ирон.* молодо́й старика́шка (старичо́к)

туу II *межд.* тпру; *на! дисәң — бармый, туу! дисәң — туктамый* (*загадка о времени*) ска́жешь ноо! — не ускоря́ется, ска́жешь тпру! — не остана́вливается

туф *сущ. геол.* туф || ту́фовый; *туф яткылыклары* за́лежи ту́фа; ту́фовые за́лежи || *прил.* ту́фовый (*блок*)

туфан *сущ.* 1. *миф.* всеми́рный пото́п; *~га кадәр* до всеми́рного пото́па 2. *перен. разг.* сильне́йший дождь; буря с дождём; *~ котыра* бушу́ет бу́ря с дождём 3. наводне́ние, пото́п, полово́дье; *~ баскан җирләр* зе́мли, за́ли́тые полово́дьем

туфани *прил. книжн.* 1. сильне́йший (*о дожде*) 2. допото́пный; *~ заманнар* допото́пные времена́

туфли *сущ.* ту́фли, ту́фельки; *~ кигән* в ту́флях, наде́вший ту́фли (ту́фельки)

туфлиле *прил.* с ту́флями, в ту́флях; *~ кыз* де́вушка в ту́флях

туфрагас *прил. спец.* подпо́чвенный; *~ ком* подпо́чвенный песо́к; *~ катлам* подпо́чвенный слой; *~ сулар* подпо́чвенные во́ды

туфра|к *сущ.* 1. по́чва; по́чвенный; *комлы ~к* песча́ная по́чва; *уңдырышлы ~к* плодоро́дная по́чва; *~к картасы* по́чвенная ка́рта; *кара ~к* чернозём 2. земля́, гли́на; *гөл ~гы* земля́ для ко́мнатных расте́ний; *авыр ~гы җиңел булсын* пусть земля́ ему́ бу́дет пу́хом 3. *прост.* земля́, по́чва; *Татарстан ~гында* на земле́ Татарста́на 4. *поэт.* страна́, сторона́, край; *безнең ~кта* в на́ших края́х 5. *перен.* моги́ла; прах; *~к булу* рассы́паться в прах; *~гым читтә булмасын иде* не хоте́лось бы, что́бы моя́ моги́ла была́ на чужби́не □ **~к алҗу** истоща́ться (*о почве*); **~к асты 1.** то, что под по́чвой 2. подпо́чвенный; **~к асты грунт** подпо́чвенный грунт; **~к белгече** почвове́д; *см. тж.* **туфракчы; ~к гыйлеме** почвове́дение; **~к йомшарткыч** рыхли́тель; **~к тирәнәйткеч** почвоуглуби́тель ◊ **~к булу** 1. услужи́ть с гото́вностью; *см. тж.* **аяк астында ~к булыйм** 2. пойти́ пра́хом; *см. тж.* **көл булу, тузан булу; ~к ит(ү)** *см.* **көл ит(ү), көлен күккә очыру**

туфракла|н|у *неперех. см.* **балчыкланы(у)**; *~ган киемнәр* запа́чканные землёй оде́жды

туфраклы *прил.* 1. земли́стый, с при́месью земли́; *~ ашлык* зерно́ с при́месью земли́ 2. *в определительных словосочет.* -зёмный; *кара ~* чернозёмный; *кызыл ~* краснозёмный 3. загрязнённый землёй, гли́ной (*об одежде*)

туфракса *сущ.* подволо́ка, вне́шнее утепле́ние потолка́; *~га туфрак мендерү* подня́ть на подволо́ку ры́хлую зе́млю для утепле́ния □ **~ салу** засыпа́ть подволо́ку, подва́ливать

туфракчы *сущ.* 1. почвове́д; по́чвенник; *~ галим* учёный-почвове́д 2. *ист.* сторо́нник сою́за тюркоязы́чных наро́дностей Пово́лжья (*в противоположность* **Туранчы**)

туфракчылык *сущ.* почвове́дение || почвове́дческий; *~ конференциясе* почвове́дческая конфере́нция

туч *прил. диал.* 1. *см.* **точ** *прил.* 2. жи́рный, состоя́щий почти́ то́лько из жи́ра (*о мясе*); *туч ит* о́чень жи́рное мя́со

туча *сущ.* трёхле́тняя коро́ва; коро́ва пе́рвого отёла; *~ асрау* содержа́ть молоду́ю коро́ву || *прил.* трёхле́тняя, пе́рвого отёла; *~ сыер* коро́ва пе́рвого отёла

тучкыл *прил. диал.* 1. чрезме́рно жи́рный; истека́ющий жи́ром, са́льный; *~ ит* чрезме́рно жи́рное мя́со (*преимущ. о варёном мясе*) 2. *см.* **тучкыллы**

тучкылда́у *перех. см.* **чупылдату, чәпелдәтү**

тучкылда́|у 1. *см.* **чупылдау, чәпелдәү** 2. истека́ть жи́ром; быть чрезме́рно жи́рным (*о мясе, а также о живом организме*); *~ган ит* чрезме́рно жи́рное мя́со

тучкыллы *прил.* 1. жи́рный (*о теле человека*) 2. пло́тный и тёмный (*о дождевой туче*), гото́вой проли́ться дождём

туч-туч *подр. звукам шлёпания замасленным предметом:* шлёп-шлёп; *туч-туч итү* пошлёпывать (*замасленными, размусоленными губами*)

тучылдату *перех.* пришлёпывать || пришлёпывание (*губами*); *иреннәрне ~* пришлёпывать губа́ми

тучылда́|у *неперех.* издава́ть || издава́ние зву́ков, пришлёпывание губа́ми; *~п тора* (всё вре́мя) пришлёпывает (губа́ми)

туш I *сущ.* 1. на́ледь, полынья́; *туш чыгу* образова́ние на́леди 2. втори́чный, намёрзший лёд (*у колодца, у кромки проруби*); *тушка абыну* споткну́ться о втори́чный лёд

туш II: **туш булу** попа́сть (в ру́ки), встре́титься на пути́; *ялгыз булыр егеткә имгәк хатын туш булыр* (*посл.*) одино́кому (лю́бящему одино́чество) попадётся беспо́мощная жена́

туш III *сущ. см.* **түшкә**

туш IV *сущ. муз.* туш; *туш уйнау* игра́ть туш

туше *сущ.* 1. *муз.* туше́; *йомшак ~* мя́гкое туше́ 2. *спорт.* туше́; *~гә китерү* тушева́ть, привести́ к туше́

тушкырыл|у *неперех. диал.* лосни́ться/залосни́ться || залосне́ние; *~ган җиң* залосни́вшийся рука́в

тушлап *нареч.* ту́шами, ту́шками; *итне ~ ташу* перевози́ть мя́со ту́шами

тушлы *прил.* с на́ледью (*поверх замёрзшего водоёма*); *~ елга* река́ с на́ледью

тушыгу *неперех.* попáсть в óбщество *кого*; *см. тж.* **туш булу**; **тыныгу**

тушым *сущ. мед.* плод в утрóбе мáтери (*особенно перед родами*) □ **~ суы** околоплóдная жúдкость

тушыр|áу *неперех.* **1.** выступáть/вы́ступить повéрх льда (*о воде*); *язын елга ~ый* веснóй водá (рекá) выступáет повéрх льда **2.** образóвываться/образовáться || образовáние втори́чного льда

туш|ь *сущ.* тушь; *кытай ~е* китáйская тушь

тушьлá|у *перех.* тушевáть, затушевáть || затушёвка; *~п чыгу* сплошь затушевáть

туып-үскән *прил. разг.* роднóй, роди́мый, óтчий (*о местности*); *туып-үскән йорт* роднóй дом; óтчий дом

туыш *сущ.* **1.** рождéние; *~ыма сәбәпче* винóвный в моём рождéнии **2.** *см.* **тумыш**

ту|ю *неперех.* **1.** наедáться/наéсться, насыщáться/насы́титься || насыщéние; *туярлык ризык* едá, достáточная для насыщéния; *җир дымга туйды* земля́ насы́тилась влáгой; *бай малга туймас* (*погов.*) богáч не насы́тится богáтством **2.** имéть, займéть *что-л.*; располагáть, обладáть *чем* в достáточном колúчестве, в достáточной стéпени; *саулыкка туймау* не имéть удовлетворúтельного здорóвья **3. (-дан тую)** пресыщáться/пресы́титься *чем*; отвращáться/отврати́ться *от чего*; *дөньядан тую* пресы́титься жúзнью; *туйдым инде бу тавыштан!* до чегó надоéл мне э́тот шум! **4.** *разг. см.* **тугаю 5.** *в знач. вспом. гл. обозначает удовлетворённость действием и переводится приставками* **на-**, **вы-**; *эшләп тую* наработáться; *йоклап тую* вы́спаться; *укып тую* начитáться; *сөйләшеп тую* наговори́ться; *елап тую* вы́плакаться **6.** *в знач. нареч.* **тýйганчы** 1) вдóволь, дóсыта, вво́лю; *тýйганчы ашау* поéсть дóсыта 2) *в составных гл. обозначает удовлетворённость завершённым действием и переводится приставками* **на-**, **вы-**; *туйганчы карау* насмотрéться; *туйганчы йоклау* вы́спаться, поспáть вво́лю □ **туеп бетү** окончáтельно пресыщáться, пресы́титься вконéц (пóлностью); отвращáться; **туеп китү** нéсколько пресы́титься; **туя белмәү** *прям., перен.* не насыщáться; быть áлчным, жáдным; **туеп сикерү** дури́ть от пресыщéния; беси́ться с жúру

туя I *нареч. разг.* дóсыта; до удовлетворéния, вдóволь; *туя ашау* есть дóсыта; *аклы кулмәгем туя кимәдем, газиз әнкәмне туя күрмәдем* (*баит, былина*) бéлую свою́ рубáху вдóволь не поноси́л, на дорогýю мáму вдóволь не нагляде́лся

ту́я II *сущ. бот.* ту́я; *туя куагы* куст ту́и

туяр-туймас *прил.* полусы́тый, полуголóдный || *нареч.* впрóголодь; *туяр-туймас ашап йөрү* ходúть, питáясь впрóголодь

тү *сущ. диал.* пшенó || пшённый, просянóй; *тү белене* пшённый (просянóй) блин; *тү буткасы* пшённая кáша

түаш *сущ.* пшённая похлёбка, пшённый суп

түбә I *сущ.* **1.** вершúна, макýшка; верх, пик; мáковка; *тау ~ләре* вершúны гор; пúки гор **2.** *разг.* холм; хóлмик; *әнә теге ~дә* вон на том холмé **3.** кры́ша; кры́ша и потолóк (*рассматриваемые вместе*), крóвля; *калай ~* жестянáя кры́ша; *салам ~* солóменная кры́ша; *өй ~се* крóвля дóма **4.** *разг.* свод, потолóк; *~гә кара* смотри́ на потолóк **5.** *разг.* нéбо, зенúт **6.** *разг.* тéмя; макýшка **7.** *разг.* кýпол □ **~ такта** перекры́тие; потолóк; **~ туклыгы** полнотá кóлоса (*полнота зёрен до самого верха колоса, что случается не всегда*) ◊ **~ асты** *редко* мозг; головá (*об уме, знаниях и т. п.*); **~гә менеп төшү** *см.* **ипи шүрлегенә менеп төшү**; **~се салам белән ябылган, ~се тишек** понимáет нáшу речь; **~се түшәмгә тигән (тия)** сверх мéры рад (*букв.* макýшкой касáется потолкá); **~ сеннән ашкан** *см.* **башыннан ашкан**

түбә II *сущ. этногр.* **1.** подрóд; грýппа рóдственников, поселúвшихся вмéсте **2.** околóток, часть селá

түбәҗир *сущ.* **1.** грéбень, голь, высóкое мéсто в откры́том пóле (*где почва смывается и выступают подстилающие породы*) **2. юр** (*открытое возвышенное место*); *~дә тора* стоúт на юрý

түбәк *сущ. диал.* небольшóй холм, курга́н; *кырмыска ~ге* муравьúная кýча, муравéйник

түбәләмә *нареч.* с вéрхом, вы́ше краёв; *~ тутыру* класть (наложúть) с вéрхом, вы́ше краёв

түбәлән|үү *неперех.* поднимáться кýполом; *~еп тора* выступáет в вúде кýпола

түбәлә́|үү I *перех.* **1.** соорудúть || сооружéние кры́ши, крóвли **2.** наверши́ть; *кибәнне ~п куй* наверши́ стог

түбәлә́|үү II *перех. разг.* **1.** бить, дубáсить по головé; *егылганны ~миләр* лежáчего не бьют (*по голове*) **2.** *перен.* жестóко критикováть

түбәләш *сущ. разг.* **1.** дрáка, дебóш; потасóвка **2.** *перен.* 1) спор, пререкáние, сóра 2) крúтика, удáры; *тәнкыйтьчеләрнең ~е* удáры крúтиков

түбәләш|үү *взаимно-совм. от* **түбәләү 1.** устрáивать, устрóить || устрóйство потасóвок, драк, дебóшей; дубáсить/отдубáсить друг дрýга (по головáм); *без ~еп алдык* мы подубáсили друг дрýга **2.** *перен.* жестóко критикováть друг дрýга

түбәлдәк *сущ.* **1.** специáльно сдéланный верх шалашá; *~ кидерү* надéть (соорудúть) верх (шалашý) **2.** *ист.* (*остроконечная*) меховáя шáпка; капюшóн; *~ кигән* в остроконéчном капюшóне

түбәлек I *прил.* предназнáченный, пригóдный и́ли достáточный для крóвли, кры́ши и́ли потолкá; *~ такта* дóски, достáточные и́ли пригóдные для изготовлéния потолкá

түбәлек II *сущ.* **1.** (*малозаметная*) вершúна холмá; плóская вершúна; *~тә өйләр куренә* на плóской вершúне холмá видны́ домá **2.** высь, высотá (*как элемент ландшафта*)

түбән *прил.* **1.** 1) нúзкий, низкорасположенный, низкоопýщенный; *~ болытлар* нúзкие облакá 2) нúзкий (*о ценах, сортах и т. п.*); *~ бәяләргә* за нúзкие цéны 3) *перен.* нúзкий, свóйственный необразóванным лю́дям; вульгáрный; *~ зәвыкъ* нúзкий вкус; *~ культуралы* низкокультýрный 4) *перен.* нúзкий, пóдлый, не знáющий чéсти, чéстности; *~ җан* нúзкая душá; *~ сүзләр* нúзкие словá **2.** 1) нúжний; *~ агым* нúжнее течéние; *~ тартма* нúжний я́щик; *~ катлам* нúжний слой 2) нúзменный, поними́женный; *~ җир* поними́женное мéсто **3.** *перен. прост.* нúзменный; живóтный; *~ дәртләр* нúзменные стрáсти; *~ ләззәт* нúзменное наслажде́ние **4.** *тех. биол.* поними́женный; *~ тишелеш* поними́женная всхóжесть **5.** *разг. в отдельных выраж.* млáдший; *~ офицерлар* млáдшие офицéры **6.** *перен.* 1) неквалифици́рованный; *~ белгеч* неквалифици́рованный специали́ст 2) нека́чественный; низкопрóбный; *~ товар* нека́чественный товáр **7.** *перен.* нúзкий (*о голосе, температуре и т. п.*) || *нареч.* **1.** *в разн. знач.* 1) нúзко; *~ төшү* нúзко опускáться 2) нúзко-; *~ сыйфатлы* низкокáчественный; *~ төзелешле* низкоорганизóванный (*об организмах*) **2.** *прост.* вниз; *~ китик* пойдём вниз || *сущ. в притяж. ф. или в косв. п.* **1.** низ; подно́жие; *тау ~е* подно́жье горы́; *тау ~енә* вниз

по скло́ну, к ни́зу горы́ 2. низо́вье (реки́); *Идел ~енә* к низо́вьям Во́лги 3. низы́ (*нижние слои, прослойки общества*); из низо́в, из масс; *без ~нән күтәрелдек* мы подняли́сь с низо́в 4. *перен.* низ; ни́зкое, ни́зменное положе́ние; *~гә тәгәрәгәнсез* вы скати́лись вниз (*по служебной иерархии*) □ **~ кимәл (тәцгәл, дәрәҗә)** ни́зкий у́ровень *чего-л.*; **~ стиль** ни́зкий стиль; *~нән югарыга кадәр* сни́зу до́верху ◊ **~ авыл этләре өрү** о чу́встве го́лода, о жела́нии пое́сть (*букв.* лай соба́к ни́жней дере́вни); **~ күз белән карау** *см.* **кимсетеп карау**

түбәнәйтел|ү *страд. от* **түбәнәйтү**; понижа́ться, снижа́ться *кем-л.*; быть пони́женным, сни́женным; подверга́ться/подве́ргнуться понижа́нию (сниже́нию); *~гән бәя* сни́женная цена́

түбәнәйт|ү *перех.* 1. понижа́ть/пони́зить, снижа́ть/сни́зить; *дәрәҗәсен ~ү* пони́зить чин (ста́тус); *тавышын ~ү* пони́зить го́лос 2. *разг. см.* **түбәнсетү**; *нигә үзеңне ~әсең?* почему́ так унижа́ешь себя́?

түбәнә|ю *неперех.* 1. понижа́ться/пони́зиться || понижа́ние; *кояш ~я* со́лнце понижа́ется 2. снижа́ться/сни́зиться || сниже́ние; *бәяләрнең ~юе* сниже́ние цен

түбәнгә *нареч.* вниз; *~ төштеләр* спусти́лись вниз

түбәнгәрәк *сравн. ст. от нареч.* **түбән**; пони́же, ещё ни́же; *~ төшер* опусти́ пони́же

түбәнге *прил.* 1. ни́жний, находя́щийся ни́же и́ли внизу́; *~ этаж* ни́жний эта́ж; *~ катлам* ни́жний слой; ни́жняя просло́йка 2. низово́й; *~ оешмалар* низовы́е организа́ции; *~ палата* ни́жняя пала́та (*парламента*)

түбәнгәчә *нареч. разг. см.* **түбәндәгечә**

түбәндә *нареч.* ни́же; *~ әле моңа тукталачакбыз* ни́же мы ещё останови́мся на э́том

түбәндәге *прил.* 1. *редко* 1) находя́щийся внизу́, в низи́не, ни́же; *~ авыл* находя́щаяся в низи́не дере́вня 2) *прям., перен.* тот, кто (что) нахо́дится ни́же; *~ләргә кара* смотри́ на тех, кто (что) ни́же 2. *канц.* сле́дующий; *~ сүзләр* нижесле́дующие слова́

түбәндәгәчә *нареч.* сле́дующим (нижесле́дующим) о́бразом; *бу эшне ~ тасвирлыйлар* э́то де́ло опи́сывают сле́дующим о́бразом

түбәнләнү *неперех.* 1. *см.* **түбәнәю** 2. *перен. разг. см.* **түбәнсену**

түбәнләт|ү *перех.* понижа́ть/пони́зить; *см. тж.* **түбәнәйтү** 1; *очышын ~те* пони́зил свой полёт

түбәнл|әү *неперех.* 1. понижа́ться/пони́зиться || понижа́ние (*летающих предметов; птиц, самолётов*) 2. *диал.* идти́ ни́зом, по ни́зу; *әйдә, ~әдек* айда́, пошли́ по ни́зу (ни́зом)

түбәнлек *сущ. геогр.* 1. ни́зменность; низи́на; *Көнбатыш Себер ~ге* За́падно-Сиби́рская ни́зменность; *~ктә урнашкан авыл* село́, располо́женное в низи́не 2. *разг.* ни́зость, низкорасположенность; *урынның ~ге* низкорасположенность ме́ста 3. *перен.* 1) ни́зменность; *ниятенең ~ге* ни́зменность его́ по́мыслов 2) низкопро́бность; низкока́чественность 3) ни́зкость (*цен, температуры и т. п.*); ни́зкий у́ровень (*знаний и т. п.*) 4. ни́зость, по́длость; *бу нинди ~к?* что э́то за ни́зость?

түбәнлектә *нареч.* в уни́женном состоя́нии; на дне; *~ яшәү* жить в уни́женном состоя́нии

түбәнсен|ү *неперех.* 1. унижа́ться/уни́зиться || униже́ние (*перед кем-л.*); самоунижение; *юкка ~мә* не унижа́йся зря 2. прибедня́ться/прибедни́ться || прибедне́ние

түбәнсенүле *прил.* уни́женный; прибеднённый; *~ тавыш белән* уни́женным (прибеднённым) го́лосом

түбәнсетелү *страд.-возвр. от* **түбәнсетү** 1. унижа́ться, быть уни́женным (*со стороны кого-л.*) 2. чу́вствовать себя́ уни́женным

түбәнсеттер|ү *понуд. от* **түбәнсетү**; позволя́ть/позво́лить и́ли веле́ть, заставля́ть унижа́ть/уни́зить *кого-л.*; *үзеңне ~мә* не позволя́й себя́ унижа́ть

түбәнсет|ү *перех.* унижа́ть/уни́зить || униже́ние *кого-л.*; *кызгану белән ~мәгез* не унижа́йте жа́лостью

түбәнсү *прил.* низи́нный; низово́й; *~ җирләр* низи́нные (низовы́е) зе́мли

түбәнсулык *сущ.* низи́на; (*малозаметная*) ни́зменность, пони́женность

түбәнтен *нареч.* 1. ни́зко, ни́зом, по́низу; *~ очып үтте* пролете́л ни́зом 2. *диал.* внизу́; *~ тора* стои́т (располо́жен) внизу́

түбәнчел *прил.* (*о начальниках*) демократи́чный, откры́тый, него́рдый; *~ түрә күпне күрә* (*посл.*) него́рдый нача́льник ви́дит мно́гое

түбәнчелек *сущ.* 1. 1) снисходи́тельность 2) почти́тельность, всепоко́рность; *~ түбәнлек түгел* почти́тельность не ни́зость 2. *диал. уст. см.* **түбәнлек** 2 □ **~ белән** поко́рнейше, почти́тельно; *~ белән үтенәм* поко́рнейше прошу́

түбәнчелекле *прил.* 1. 1) снисходи́тельный 2) почти́тельный, всепоко́рный 2. *см.* **түбәнчел**

түбәсеннән *нареч. разг. см.* **түбәләмә**

түбәтәй *сущ.* 1. тюбете́йка; ермо́лка; *хәтфә ~ кию* надева́ть (носи́ть) ба́рхатную тюбете́йку 2. *ист.* желе́зный шлем, надева́емый под ша́пку □ **~ алу** *см.* **пештеле** (*вид игры*); **~ карта** *биол.* се́тка (*часть желудка жвачных животных*) ◊ **~ җыеп калу** отстава́ть от други́х; приходи́ть по́зже други́х (*букв.* подбира́ть шлем)

түбәтәйле *прил.* 1. с тюбете́йкой; име́ющий тюбете́йку; в тюбете́йке; *~ егет* джиги́т в тюбете́йке 2. проше́дший в тюбете́йке; *~ балачак* де́тство, проше́дшее (проведённое) в тюбете́йке

түбәтәйчән *предик. прил.* в тюбете́йке; с тюбете́йкой на голове́; *~ йөри* хо́дит в тюбете́йке

түбә-түшәм *сущ. собир.* потоло́к; потоло́к с кры́шей; *түбә-түшәме әйбәт булсын* что́бы потоло́к и кры́ша бы́ли добро́тные

түбер *сущ. диал.* 1. *см.* **түп** 2. труха́, очёстки, костри́ка; *җитен ~е* костри́ка льна

түгә *сущ. прост. см.* **түгәнәй** || *межд., которым отгоняют коров, см. тж.* **һәш**

түгәнәй *сущ. разг. ласк.* коро́вушка, бурёнушка, бурёнка; *~ләрне көтүгә ку* гони́ коро́вушек в ста́до

түгәрәк *прил.* 1. 1) кру́глый, окру́глый; *~к күл* кру́глое о́зеро; *~к көзге* кру́глое зе́ркало; *~к бүлмә* окру́глая (ова́льная) ко́мната 2) круго́вой; *~к оборона* круго́вая оборо́на 2. полукру́глый; полукру́гом; *~к сакал* борода́ полукру́гом 3. *в отдельных выраж.* кру́гленький; *~к сумма* кру́глая су́мма; *~к пот* кру́гленький (*т.е. более чем полный*) пуд 4. *перен.* 1) по́лный (*достигший полноты проявления*); *~к хатыннар инде без* мы по́лные (в по́лном смы́сле) же́нщины 2) комплекто́ванный, по́лный, име́ющий все обы́чные (*необходимые*) атрибу́ты; *~к гаилә* по́лная семья́ (*т.е. есть и отец, и мать, и дети*) 5. *перен.* норма́льный; хорошо́ устро́енный; в доста́тке; *тормышыбыз ~к* на́ша жизнь хорошо́ устро́ена || *сущ.* 1. 1) круг, окру́жность; *мәйдан ~ге* окру́жность пло́щади 2) танцева́льный и т. п. круг; *~к уртасында бию* пляса́ть в це́нтре кру́га 2. круг (*площадь, ограниченная окружностью*); *~кнең мәйданы* пло́щадь кру́га; *~к*

квадратурасы квадрату́ра кру́га **3.** *перен.* кружо́к; *әдәби ~к* литературный кружо́к; *драма ~ге* драмати́чесий кружо́к; *~к әгъзалары* чле́ны кружка́ □ **~к авызлылар** *зоол.* круглоро́тые; **~к булып (ясап)** кру́гом; **~к дата** кру́глая да́та; **~к дулкыннар** *физ.* концентри́ческие во́лны; **~к өстәл** кру́глый стол; **~к өстәл артында** за кру́глым столо́м; **~к саннар** це́лые чи́сла; **~к яфрак** *бот. диал. см.* **герань**

түгәрәкләнеп *нареч.* кру́гом; *~ утырдылар* се́ли кру́гом

түгәрәкләнеш *сущ.* **1.** округле́ние; ка́чество округле́ния; ка́чество округле́ния чи́сел **2.** закругле́ние; *кискен ~* ре́зкое закругле́ние

түгәрәкләнү *возвр. от* **түгәрәкләү 1.** закругля́ться/закругли́ться, круглі́ться || закругле́ние; *читләре ~гән* края́ его́ закругли́лись (закруглены́) **2.** образова́ться || образова́ние кру́га; *~деләр дә уйнарга тотындылар* образова́ли круг и ста́ли игра́ть **3.** округля́ться/округли́ться || округле́ние (*частей тела*); *иңсәләре ~гән* пле́чи его́ округли́лись; *күзләре ~де* глаза́ его́ округли́лись **4.** *перен.* закругля́ться/закругли́ться (*о деле, о работающем*); *эшләр ~ә* дела́ закругля́ются; *тизрәк ~* быстре́е закругля́йся **5.** *перен.* 1) станови́ться/стать по́лным, соверше́нным, норма́льным; *тормышыбыз ~де* жизнь на́ша ста́ла по́лной 2) удовлетворя́ться/удовлетвори́ться, приходи́ть в удовлетворённое (дово́льное) состоя́ние; *күңелем ~де* душа́ моя́ удовлетвори́лась (удовлетворена́)

түгәрәкләп *нареч.* **1.** *см.* **түгәрәкләнеп 2.** округлённо; приближённо, приблизи́тельно; *~ әйткәндә* е́сли вы́разиться приблизи́тельно □ **~ алу** окружа́ть/окружи́ть (*со всех сторон*)

түгәрәкләү|ү *перех.* **1.** де́лать/сде́лать кру́глым; кругли́ть, округля́ть/округли́ть; *~п сызу* черти́ть, образу́я окру́жность **2.** 1) закругля́ть/закругли́ть || закругле́ние (*краёв, углов и т. п.*); *почмакларын ~ү* закругля́ть углы́; *күзләрне ~ү* округли́ть глаза́ 2) *мат.* округля́ть/округли́ть (*десятичную дробь*) **3.** *перен.* закругля́ть/закругли́ть, заверша́ть/заверши́ть || заверше́ние; *эшне ~ү* заверши́ть де́ло; *утырышны ~ү* закругли́ть заседа́ние **4.** *перен.* де́лать/сде́лать по́лным, устро́енным, зажи́точным; *үз тормышын ~ү* сде́лать устро́енным (хорошо́ устро́ить) свою́ жизнь

түгәрәкле *прил.* кругово́й; *~ уеннар* круговы́е и́гры || *сущ.* игра́ в круг (*образуя круг*); *~ уйнау* игра́ть в круг (*образуя круг*)

түгәрәкле|к *сущ.* **1.** кру́глость; окру́глость; *җирнең ~ге* окру́глость земли́ (земно́го ша́ра) **2.** круг (*рассматриваемый как площадь*); *шушы ~тә* в э́том (да́нном) кругу́

түгәрәкле-табынлы *прил. этногр.* разнови́дность игры́ в круг (*посреди круга ходит водящий, вне круга — остальные участники игры*)

түгәрәкчә *сущ.* кружо́чек

түгәрәкче *сущ.* кружко́вец, член кружка́; *~ләрнең бер өлеше* (*одна*) часть кружко́вцев

түгәрәкчек *уменьш. от* **түгәрәк**; кружо́чек

түгәрәкчелек *сущ. неодобр.* кружко́вщи́на; *~ белән генә шөгыльләнү* занима́ться то́лько кружко́вщи́ной

түгел *частица* **1.** *отриц.* 1) *в постпозиции к именным частям речи, а также к причастиям и деепричастиям* не, ни; *ул бала ~* он (уже́) не ребёнок; *берсе дә ~* ни оди́н из них; *ул барачак ~* он ни за что не пойдёт (не пое́дет); *әйбәт ~* нехорошо́; *мөмкин ~* невозмо́жно; *шәп ~* нева́жно 2) *в сочет. с сущ. в исх. п.* не из...; *куркаклардан ~* не из трусли́вых; *бурыч җиңелдән ~* зада́ча не из лёгких **2.** *против.* 1) ни перед ..., а...; *бармадык ~, бардык* ни не ходи́ли, а ходи́ли 2) не ..., а...; *яшьлек яшь белән ~, йөрәк белән улчәнә* мо́лодость определя́ется не года́ми, а се́рдцем **3.** *усил.* (*иногда в препозитивном положении*) не то́лько ... но и; не то́лько что; не то́кмо (что); *кеше ~, фил дә бата монда* здесь не то́лько челове́к, но и слон уто́нет; *син ~, мин дә курыктым* не то́лько ты, но и я испуга́лся; *кыз мактала эш белән, ~ энҗе теш белән* (*посл.*) де́вушка сла́вится рабо́той, а не жемчу́жными зуба́ми **4.** *в функ. сложного сказуемого* **түгел түгелен** не ... оно́, коне́чно, не ... (но ...); *зур ~ ~ен* не велико́-то (оно́) не велико́; *безнеке ~ ~ен* не на́ше-то (оно́) не на́ше, (но ...)

түгелгә *союз против. от* **түгел**; оттого́ что не...; потому́ что не...; *матур ~* оттого́ что некраси́во

түгелдән *отвл. нареч. от* **түгел**; оттого́ что не...; потому́ что не...; *әйбәт ~* оттого́ что нехорошо́

түгелдер|ү *понуд. от* **түгелү**; дава́ть/дать возмо́жность расплеска́ться, ли́ться, выплива́ться; *билләреңне бөгелдермә, суларыңны ~мә язмаган ярлар өчен* (*песня*) не кла́няйся в пояс, не расплёскивай во́ду (*из ведра, что на коромысле твоём*) из-за несу́женых

түгелеп *нареч.* **1.** вы́ложив всю ду́шу; *~ сөйләштеләр* поговори́ли, изложи́в (вы́ложив всю) ду́шу **2.** навзры́д; *~ елау* пла́кать навзры́д

түгеллек *отвл. сущ. от* **түгел 1.** то, что не ..., отсу́тствие (*определённого качества, принадлежности и т. п.*); *яхшы ~* отсу́тствие хоро́шего ка́чества; *син ~не беләм* я зна́ю, что не ты (*сделал то, известное*); *тиң ~не сизәм* чу́вствую, что не па́ра (ей); *безнеке ~* то, что не наш (нам не принадлежи́т) **2.** *в. ф.* **түгеллектән** *отвл. нареч.* оттого́, что не...; *шәп ~тән* оттого́, что нехорошо́

түгелме *частица вопр.* (*усиливается также частицами* **ни, әллә**) ра́зве не...; *матур ~?* ра́зве не краси́во?

түгел|ү *страд.-возвр. от* **түгү 1.** высыпа́ться, рассыпа́ться, ссыпа́ться; быть вы́сыпанным, рассы́панным, ссы́панным; *~гән ашлык* вы́сыпавшееся зерно́ **2.** выплива́ться/вы́литься; проплива́ться/прол и́ться || проплива́ние; *иелмә, баш, ~мә, яшь, ике тиенлек яр өчен* (*песня*) не клони́сь, голова́, не проплива́йтесь, слёзы, из-за несто́ящего дружка́ **3.** *перен.* ли́ться, струи́ться (*о речи, стихах*); *гармуннан моңнар ~ә* из гармо́ни струя́тся мело́дии

түгелү-чәчелү *неперех. разг.* **1.** рассыпа́ться (*во всю*); высыпа́ться, разли́ться (*и пропадать зря*); *түгелеп-чәчелеп калган әйберләр* рассы́павшиеся (*во все стороны*) ве́щи **2.** *в знач. нареч. разг.* **түгелеп-чәчелеп** до дна вы́ложив всю ду́шу; *түгелеп-чәчелеп сөйләсәң, соңыннын үкенәсең* расска́жешь, вы́ложив всю ду́шу, пото́м раска́иваешься □ **түгелеп-чәчелеп бетү 1.** вы́сыпаться, рассы́паться **2.** *перен.* рассы́паться

түгем *сущ. этногр.* (*у крещёных татар*) опла́кивание; поми́нки (*в пасху и покров*)

түгем-чәчем *сущ. собир.* **1.** всё то, что рассы́пано, упа́ло и т. п. **2.** *уст.* всё то, что раздаётся на поми́нках

түгенте *прил.* помо́йный; сто́чный; *~ сулар* сто́чные во́ды || *сущ.* помо́и; сток

түгү *перех.* **1.** 1) вы́сыпать, рассы́пать (*что-л. нужное*); *онны ~кмәгез* не рассы́пьте муку́; *көл ~гү* вы́сыпать золу́ 2) выплива́ть/вы́лить, прол и́ть || проплива́ние *чего-л.*; *сөт ~гү* проплива́ть молоко́; *яшь ~ктем* я лил (проплива́л) слёзы **2.** *перен.* 1) (*целиком*) изплива́ть/изли́ть

‖ излия́ние (*душевных переживаний*); *серен ~кте* изли́л ду́шу (все свои́ секре́ты) 2) *поэт.* (*непрерывно*) импровизи́ровать, рожда́ть (*стихи, музыку и т. п.*); *энҗе кебек юллар ~кте* рожда́л стро́ки, подо́бные жемчуга́м **3.** лить, пролива́ть свет (*о светилах*); *кояш нур ~гә* со́лнце льёт свет **4.** тра́тить/истра́тить, затра́чивать/затра́тить, приложи́ть (*не жалея, без меры*) *что-л.*; *купме көч ~ктем мин моның өчен* ско́лько сил приложи́л я ра́ди э́того (на э́то) **5.** израсхо́довать, транжи́рить, растра́чивать/растра́тить ‖ тра́та; *акча ~гү* транжи́рить де́ньги **6.** *разг.* вывози́ть; удаля́ть/удали́ть (*отходы, мусор и т. п.*) □ **~геп салу** рассы́пать ра́зом; рассы́пать вдруг; разброса́ть (широ́ким же́стом, ще́дро и т. п.); **~геп ташлау** разброса́ть; **~геп җибәрү** рассы́пать (*нечаянно, ненамеренно*)

түз *сущ. диал.* **1.** 1) основа́ние, подно́жие *чего-л.* 2) пень, ко́мель (*дерева*); кочеры́жка капу́сты; *картлар сүзе — кәбестә түзе* сло́во старико́в — кочеры́жка капу́сты **2.** у́стье (реки́); разви́лка рек; *елга түзендә* в у́стье реки́ **3.** перено́сица

түзгесез *прил.* непереноси́мый; *~ азаплар* непереноси́мые му́ки

түздер|ү *понуд. от* **түзү 1.** заставля́ть, веле́ть, проси́ть терпе́ть/потерпе́ть **2.** *преимущ. в отриц. ф.* **түздермәү** не дава́ть возмо́жности и сро́ка; *мин түзәр идем дә, эш ~ми* я бы потерпе́л, да вот де́ло не те́рпит

түзел|ү *безличн.* натерпе́ться; приходи́ться/прийти́сь терпе́ть, вы́терпеть; *күп ~де инде* мно́го уж пришло́сь терпе́ть, мно́го уж терпе́ли; уже́ мно́го натерпе́лись

түзем *сущ.* терпе́ние; вы́держка, выно́сливость, сто́йкость, кре́пость; *~ен җую* теря́ть терпе́ние ‖ *прил.* терпели́вый, сто́йкий, выно́сливый ‖ *нареч.* терпели́во, сто́йко, выно́сливо; *~ генә көтеп торды* терпели́во ожида́л

түземле *прил.* **1.** 1) терпели́вый; *~ дә соң безнең халык* терпели́в же наш наро́д 2) выно́сливый **2.** упо́рный; *~ көрәш* упо́рная борьба́ **3.** *диал.* кре́пкий, про́чный (*об одежде и обуви*); *~ аякчу* про́чные портя́нки; *~ тукыма* про́чная ткань

түземле|к *сущ.* **1.** терпели́вость, терпе́ние; вы́держка; *~гем җитмәде (калмады)* не хвати́ло (у меня́) терпе́ния **2.** *см.* **түземлелек** 2, 3

түземлекле *прил.* сто́йкий, про́чный (*о материалах, веществах и т. п.*); *~ түбәлек* сто́йкая (*к осадкам*) кро́вля

түземлеле|к *сущ.* **1.** 1) терпели́вость; *~к белән аңлата* объясня́ет терпели́востью 2) выно́сливость; *кешенең ~ге карашына да карый* выно́сливость челове́ка зави́сит и от его́ взгля́дов **2.** упо́рство, сто́йкость **3.** *диал.* кре́пость, про́чность (*одежды и обуви*)

түземсезләнеп *нареч.* нетерпели́во; беспоко́йно; *~ карану* беспоко́йно огля́дываться □ **~ тору 1.** рва́ться, мета́ться; быть в нетерпе́нии **2.** быть в беспоко́йстве

түземсезләнү *неперех.* **1.** проявля́ть/прояви́ть ‖ проявле́ние нетерпели́вости; вести́ (себя́) нетерпели́во; *~ә башладым* я стал проявля́ть нетерпели́вость (нетерпе́ние); я потеря́л терпе́ние **2.** *редко* становиться/стать невыно́сливым (сто́йким)

түземсезле|к *сущ.* **1.** нетерпели́вость; *~ге бар аның* есть у него́ така́я черта́ — нетерпели́вость **2.** невыно́сливость, сто́йкость □ **~к белән** нетерпели́во, с нетерпе́нием; **~к белән көтә** ожида́ет с нетерпе́нием; ждёт не дождётся

түземчел *прил.* стара́ющийся терпе́ть, вы́терпеть; терпели́вый

түземчелек *сущ. редко* взыва́ние к терпе́нию; тео́рия о по́льзе терпе́ния; *~ аптыраштан килә* взыва́ние к терпе́нию возника́ет от незна́ния (*того, что надо делать*)

түзен *сущ. ист.* кли́ка; аристокра́тия; пра́вящая гру́ппа (*в Золотой Орде*)

түзле|к *сущ.* **1.** корневи́ще (*от которого вырастает новое растение*); *кузгалак ~ге* корневи́ще щавеля́ **2.** *что-л.* оста́вленное на разво́д

түзлекле *прил.* с (*многолетним*) корневи́щем (*о растениях*)

түзмер *прил. диал.* упо́рно-терпели́вый; выно́сливый, закалённый; *мин ~ кеше, түзәрмен* я челове́к закалённый, вы́терплю

түз|ү *неперех.* терпе́ть/вы́терпеть, потерпе́ть, стерпе́ть, переноси́ть/перенести́ ‖ терпе́ние; *кыенлыкка ~ү* вы́терпеть тру́дности (в тру́дностях); противостоя́ть тру́дностям; *~мәдем, көлеп җибәрдем* я не вы́терпел — засмея́лся; выде́рживать/вы́держать, продержа́ться; *см.* **чыдау**; *озакка ~мәс* до́лго не проде́ржится (*разрушится, истреплется и т. п.*); до́лго не вы́терпит □ **~әр хәл калмады** терпе́ние ло́пнуло; нет сил терпе́ть; **~гән ~инде** терпи́ поку́да те́рпится; **~еп кенә тор, ~сәң түз!** то́лько держи́сь!; **~еп тору** мири́ться, примири́ться *с чем-л.*

түк *подр. звуку короткого удара топором* тюк

түкәлә *сущ. диал. см.* **түкән**

түкән *сущ. диал.* коротыш, карапу́з, карапу́зик (*о детях*); *~ем, ~ем* карапу́зик, карапу́зик мой

түкелдәтү *перех.* **1.** ча́сто-ча́сто тю́кать **2.** затю́кать

түкелдә|ү *перех.* тю́кать ‖ тю́канье (*топором*); *~и дә ~и* тю́кает и тю́кает (*топором*)

түкмән *сущ.* **1.** *этногр.* вид (разнови́дность) каду́шки; *базда батман, түрдә ~* (*погов.*) в подпо́лье — батма́н, в го́рнице каду́шка **2.** *перен. прост.* балда́, дуби́на, осто́лоп, сво́лочь; *тик тор, ~* замолчи́, дуби́на (сво́лочь)

түкмә-түк *нареч. диал. см.* **төп-төгәл**

түкмичә-чәчмичә *нареч. см.* **түкми-чәчми**

түкми-чәчми *нареч.* всеце́ло, целико́м, не роня́я ни крупи́нки (*об изложении кем-л. какого-л. события*); *түкми-чәчми сөйләп бирде* изложи́л всё как есть (*не упуская, не опуская ничего*)

түктер|ү *понуд. от* **түгү 1.** заставля́ть высыпа́ть, проливать и т. п.; *онны ~дең* ты заста́вил (меня́) вы́сыпать муку́; *яшемне ~мә* не заставля́й меня́ проливать слёзы **2.** заставля́ть/заста́вить, прилага́ть/приложи́ть си́лы и́ли тра́тить, растра́чивать (*деньги и т. п.*)

түк-түк (түк тә түк) *подр. частым и коротким ударам топором, а также частым шагам по асфальту*; тюк-тюк; *түк-түк чабу* бить (*топором*) тюк-тюк

түл *сущ.* **1.** заро́дыш, зача́точное яйцо́, зача́ток у птиц; *түле бар аның* есть у неё зача́точное яйцо́ **2.** нагу́л, упи́танность скота́ (*рассматриваемые с точки зрения готовности оплодотворять или оплодотворяться*) **3.** *диал.* припло́д (скота́) **4.** *перен.* доста́ток; запа́сы, капита́л (*достаточные для начала определённого предприятия*); *см. тж.* **сәмән** □ **түл җыю 1.** нагуля́ть жир; стать гото́вым к оплодотворе́нию (*о скоте*) **2.** копи́ть/накопи́ть капита́л (*запасы, сумму*)

түләгесез *прил.* неопла́тный; *~ бурыч* неопла́тный долг

түләк I *собир. сущ.* **1.** ягня́та и козля́та; молодня́к ме́лкого рога́того скота́ **2.** живо́тные в пери́од ли́ньки

түләк II *прил.* **1.** линя́ющий (*о животных*) **2.** *перен.* ти́хий, сми́рный; безоби́дный

түләк III *сущ. диал.* **1.** *разг.* штраф; *~ түләтү* заставля́ть плати́ть штраф **2.** *см.* **салым**

түләм *сущ. разг.* **1.** опла́та, распла́та **2.** припла́та; *~ен түләрсеңме?* припла́ту-то дашь?

түләмә *сущ.* сиби́рская я́зва (*у скота*); *~дән үлде* издо́х от сиби́рской я́звы

түләмәле *прил.* **1.** я́звенный, больно́й сиби́рской я́звой (*о скоте*) **2.** заражённый, зараже́ющий сиби́рской я́звой; *~ көтү* ста́до, заражённое сиби́рской я́звой

түләнгән *прил.* опла́ченный; *~ товар* опла́ченный това́р; *~ урын* опла́ченное ме́сто

түләнү *страд. от* **түләү**; оплати́ться, быть опла́ченным; *хакы ~гән* сто́имость его́ уже́ опла́чена

түләтелү *страд. от* **түләтү**; быть взима́емым; взима́ться; *хәражәте ~ә* взима́ется сто́имость накладны́х расхо́дов

түләтү **1.** *понуд. от* **түләү**; заста́вить плати́ть; *акча ~ү* заста́вить плати́ть де́ньги **2.** *перен.* заста́вить распла́чиваться (*за содеянное*); нака́зывать/наказа́ть штра́фом

түләү *перех.* **1.** плати́ть/заплати́ть; опла́чивать/оплати́ть || пла́та, опла́та; *натуралата ~ү* плати́ть нату́рой; *налог ~ү* плати́ть нало́ги; *бише белән ~ү* заплати́ть пятикра́тно **2.** *перен.* распла́чиваться (*за содеянное*) □ **~п алу** купи́ть, закупи́ть; брать/взять с опла́той; *аракы — ~п алынган бәла* (*посл.*) во́дка — ку́пленная беда́; **~п бетерү** расплати́ться (до конца́, сполна́, по́лностью); **~п кую** оплати́ть зара́нее (вперёд, ава́нсом) || *сущ. прост.* **1.** нало́г, обложе́ние, побо́ры; *һәр төрле ~үләр* вса́ческие побо́ры **2.** пла́та (*за услуги и т. п.*); *~вен түләргә кирәк* на́до производи́ть/произвести́ опла́ту (внести́ пла́ту)

түләүле *прил.* пла́тный; *~ шифаханә* пла́тная больни́ца; *~ концерт* пла́тный конце́рт

түләүсез *прил.* беспла́тный; *~ дәвалау* беспла́тное лече́ние; *~ концерт* беспла́тный конце́рт || *нареч.* беспла́тно, без опла́ты; *~ керү* входи́ть беспла́тно; *~ генә эшли* рабо́тает без опла́ты

түләүче *сущ.* плате́льщик; *налог ~ләр* налогопла́тельщики

түлләнү *неперех.* **1.** быть с гото́выми зача́точными я́йцами; образова́ть в себе́ зача́точное яйцо́ (*о птицах*) **2.** нагуля́ть || нагу́л жи́ра, упи́танности; быть гото́вым к оплодотворе́нию; *~гән терлек* нагуля́вший жир (и поэ́тому беспоко́йный) скот

түлләү *неперех. разг. см.* **түлләнү**

түлле *прил.* **1.** с заро́дышем, с зача́точным яйцо́м (*о птицах*) **2.** жи́рный, упи́танный; гото́вый оплодотвори́ться и́ли оплодотвори́ть; *~ мал* упи́танный (здоро́вый) скот (гото́вый к размноже́нию)

түмәр *сущ.* **1.** коло́да, чурба́н, обру́бок; *~гә бәрү* уда́рить по чурба́ну **2.** *диал.* ко́мель де́рева; *~еннән пычу* пили́ть по ко́мелю **3.** *перен., прост.* дуби́на, о́лух, дурачо́к

түмәркә *сущ.* **1.** то́лстый обру́бок де́рева (*валяющийся где попало*) **2.** коря́га, ко́чка с пнём

түмәркәле *прил.* коря́жистый, кочкова́тый; *~ җир* кочкова́тая земля́

түмгәк *сущ.* **1.** ко́чка; бугоро́к; коря́га; *саздагы ~клар* ко́чки на боло́те **2.** *диал.* пень, колода, чурба́н (*употребляемый в хозяйстве*); *балта чапканчы ~к ял итә* (*посл.*) пока́ суд да де́ло, всё и прошло́ (*букв.* пока́ топо́р не уда́рит, колода отдыха́ет) || *прил. см.* **түмгәкле**

түмгәкләнү *неперех.* де́латься/сде́латься кочкова́тым, бугри́стым (*о земле*); *~еп катканнан (туңган)* замёрзла комка́ми (земля́)

түмгәкле *прил.* с ко́чками, бугорка́ми; бугорча́тый (*о земле*)

түмгәклек *сущ.* кочка́рник, кочкова́тое ме́сто; *~тә печән чабу* коси́ть се́но на кочка́рнике

түм-түгәрәк *прил. превосх. ст. от* **түгәрәк**; кру́глый-кру́глый, соверше́нно кру́глый

түн I *сущ. редко* зад, за́дняя сторона́; *түнгә тарта* тя́нет наза́д

түн II *сущ. спец.* **1.** тон, рыболо́вный не́вод (*оставляемый неподвижно в воде*) **2.** *перен.* рыболо́вный сезо́н, пути́на; *язгы түн* весе́нняя пути́на

түнгеле *прил.* обрати́мый

түнгесез *прил.* необрати́мый; *~ процесс* необрати́мый проце́сс

түндәк I *сущ.* **1.** *диал. см.* **түмгәк 2.** клу́мба; ва́за с цвета́ми во дворе́; *бакчадагы ~лар* клу́мбы, что в саду́

түндәк II *прил. см.* **түндәкле**; *~ җир* кочкова́тое ме́сто □ **~ алыш** *см.* **түндәкле** II

түндәкле I *прил. см.* **түмгәкле**

түндәкле II *сущ.* де́тская игра́ (*в которой дети поперемонно сидят кочками в кругу, в котором волк ловит зайца*)

түндер *прил. диал.* перевёрнутый вверх дном; *~ стакан* перевёрнутый вверх дном стака́н

түндербаш *сущ. бот.* **1.** болиголо́в (*ядовитое растение*) **2.** цику́та (ядови́тое расте́ние)

түндерек *прил. диал.* перевёрнутый; *~ ай* перевёрнутый ме́сяц

түндерү *перех.* **1.** перевернуть, опроки́дывать/опроки́нуть (*на бок*); свали́ть (*бочку, столб и т. п.*) **2.** *перен.* моро́чить (го́лову) **3.** *диал. см.* **дүндерү**

түнеү *неперех. диал.* (немно́жко) сва́ливаться/свали́ться в одну́ сто́рону; *~кән читән* немно́жко свали́вшийся в одну́ сто́рону плете́нь

түнектерү *перех. диал.* сва́ливать/свали́ть (*в одну сторону*); *агачны ~дем я* свали́л (*в одну сторону*)

түнеш *прил. диал.* зазна́вшийся, возгорди́вшийся (*от похвалы*); *~ кыз* возгорди́вшаяся де́вушка

түнкә *прил. диал.* опроки́нутый

түнкәрелеш *сущ. прост.* катава́сия, перево́рот; *революцион ~* революцио́нный перево́рот

түнкәрелешү *взаимн.-совм. от* **түнкәрелү**; перевора́чиваться/перевернуться (*все вместе*)

түнкәрелү *страд. от* **түнкәрү**; перевора́чиваться вверх дном; вали́ться; *~гән арба* перевернувшаяся теле́га; *~гән тартма* свали́вшаяся коро́бка

түнкәреш *сущ.* **1.** перевёртывание (*вверх дном*) **2.** *см.* **түнкәрелеш**

түнкәртү **1.** *понуд. от* **түнкәрү**; веле́ть и́ли заста́вить перевернуть вверх дном (*преимущ. в букв. знач.*) **2.** *разг. см.* **түнкәрү**; *~еп кую* ста́вить вверх дном (и оста́вить в тако́м ви́де)

түнкәрү *перех.* **1.** перевора́чивать/переворо́тить, перевёртывать/перевернуть || перевора́чивание, перевёртывание; ста́вить/поста́вить вверх дном; *стаканын ~еп куйды* поста́вил (свой) стака́н вверх дном **2.** *перен. прост. см.* **дөмектерү**

түнкәю *неперех.* вали́ться/свали́ться на́бок; наклоня́ться/наклони́ться; стоя́ть ко́со, с наклоно́м и́ли набекре́нь (*о головном уборе*); *~йган өй* повали́вшийся на́бок дом

түнтәргеч *сущ.* самосва́л; самосва́льное устро́йство; опроки́дыватель

түнтәрелү *неперех.* **1.** опроки́дываться/опроки́нуться (*с размахом*) **2.** *перен.* кру́то изменя́ться/измени́ться ||

крутóе изменéние (*в семье, в государстве*); *кырыкка ~ер әле* изменится ещё на сóрок ладóв

түнтәрмә *сущ. кул.* тунтермé (*кушанье из конопляных семян с мёдом*)

түнтәр|ү *перех.* **1.** нечáянно и́ли грýбо валúть/свалúть; опрокúдывать/опрокúнуть || опрокúдывание (*с размахом*); *төртеп ~у* опрокúнуть (сúльным) толчкóм; толкнýть и опрокúнуть; *тауны ~у* свалúть гóру (*перен.* дéлать большúе делá) **2.** *перен.* опорожнúть/опорожнúть || опорожнéние содержúмого до дна; *бер самавыр ~дек* мы опорожнúли цéлый самовáр **3.** *разг.* закáтывать/закатúть || закáтывание (*глаз*) **4.** *перен.* свергáть/свéргнуть, сбрáсывать/сбрóсить, скúдывать/скúнуть || свержéние, сбрáсывание, скúдывание; *патшаны ~у* скúнуть царя́ **5.** *перен. диал.* изменя́ть/изменúть (*положение дел*) **6.** *перен. диал. см.* **майтару**

түнтәү *неперех.* **1.** *см.* **түнкәю** **2.** *диал.* выступáть/выступить (*о пружинах дивана*)

түн|ү *неперех.* **1.** пáдать (*на бок*), валúться, опрокúдываться (*о сосудах*) || падéние, опрокúдывание (*само собой*); *~гән стакан* опрокúнувшийся (*на бок*) стакáн **2.** *диал.* 1) пáдать, валúться (*о телеге, заборе и т. п., обычно стоящих вертикально предметах*) 2) пáдать, валúться, полегáть (*о хлебах, траве и т. п.*) **3.** 1) *см.* **дүңү** 1; 2) откáтываться/откатúться || откáтывание назáд (*о наступающих войсках*); *яу ~гәндә батыр күп булыр* (*посл.*) пóсле бóя мнóго храбрецóв (*букв.* когдá нашéствие отбúто, проявля́ется мнóго герóев) **4.** оглушáться/оглушúться || оглушéние (*рыбы*); *~гән балыклар* оглушённые ры́бы **5.** *перен.* идтú крýгом (*о голове*); быть как бы оглушённым (*о человеке*); *башым ~де* головá моя́ крýгом пошлá; я стал как оглушённый **6.** **(-га ~у)** *перен. редко* 1) переходúть || перехóд из одногó состоя́ния в другóе; видоизменя́ться, видоизменúться; *см. тж.* **дүңү** 2 2) срáзу заснýть; *яткач ук ~де* как лёг, так и заснýл 3) *книжн.* умирáть/умерéть **7.** *перен. прост.* сходúть/сойтú с умá; рехнýться; трóнуться; *син әллә ~деңме?* ты что, рехнýлся, что ли?

түң *сущ. диал.* **1.** пень с отрóстками; пóросль, куст, вы́росший вокрýг пня **2.** чáхлый кустáрник

түңгәләк *сущ. диал. см.* **дүңгәләк**

түңелдерү *многокр. от* **түңелү**; нéсколько раз (раз за рáзом) отворáчиваться

түңелдерт|ү *понуд. от* **түңелү**; застáвить отвернýться (*от кого-л.*), отвергáть/отвéргнуть

түңел|ү *неперех.* отворáчиваться/отворотúться, отвернýться *от кого-л;* отказáться, отвратúться *от чего-л; дустан ~мә* (*посл.*) не отворáчивайся от тогó, кто тебé друг; *искедән ~гән, яңага абынган* (*погов.*) отказáлся от стáрого — поскользнýлся на нóвом

түңлек *сущ.* вы́рубка; земля́ на мéсте вы́рубки (*с пнями*)

түп I *сущ.* **1.** вы́жимки; гýща, осáдок, остáтки; бардá; *җиләк түбе* вы́жимки я́год; *сыра түбе* гýща пúва; *чөгендер түбе* бардá сáхарной свёклы **2.** *см.* **түбер**; *җитен түбе* очёски льна ◻ **түп ваклагыч** *тех.* жмыхорéзка

түп II *подр. звуку падения ребёнка* óпля! ◻ **түп итү** *см.* **түпәй булу (итү)**

түпәй: түпәй булу (итү) упáсть (*о ребёнке*); *~ була күрмә* тóлько берегúсь — не упади́; смотри́ не упади́

түпәлә́ү *перех. диал. см.* **тәпәләү**; бить, побивáть (*по голове и т. п.*); *егылганны ~* бить упáвшего (лежáчего)

түпәч: түпәч булу (итү) *диал. см.* **түпәй булу**

түпрә *сущ.* **1.** *см.* **түп** 1 **2.** отхóд, отхóды

түп-түгәрәк *превосх. ст. прил. от* **түгәрәк**; кру́глый-прекру́глый; кру́гленький (*о детях, девушках и т. п.*); *түп-түгәрәк битле* с кру́гленьким лицóм

түр *сущ.* **1.** *этногр.* 1) почётное мéсто в кóмнате (*обычно место против двери в глубине комнаты*); крáсный у́гол; *түрәнең урыны түрдә* (*погов.*) мéсто начáльника — в глубинé кóмнаты 2) *диал.* гóрница, внýтренняя кóмната в дóме **2.** 1) мéсто в глубинé огранúченной, огражденной плóщади, противополóжное двéри, вхóду, воротам и т. п.; *йорт түрендә* в глубинé двора́ 2) середúна, центрáльная часть *какой-л.* (*замкнутой, огражденной*) плóщади; *басу туре* середúна пóля **3.** специáльное сидéнье экипáжа; *чана туре* (специáльное) сидéнье санéй **4.** *перен.* глубúна (*души, сердца и т. п.*), нутрó; *күңел түрендә* в глубинé душú **5.** *редко* перéдний план, фасáд; *бина туре белән кулга карый* здáние фасáдом смóтрит на óзеро || *прил.* **1)** располóженный в глубинé кóмнаты, напрóтив двéри; слýжащий почётным мéстом; *түр як* располóженная в глубинé кóмнаты сторонá; *түр тәрәзә* окнó напрóтив двéри 2) внýтренний (*о комнате в помещении и т. п.*); *түр бүлмә* внýтренняя кóмната 3) располóженный в глубинé и́ли в цéнтре плóщади, напрóтив вхóда; *түр келәт* располóженная в глубинé двора́ клеть ◻ **түр бакча** сáдик у фасáда здáния; **түр башы** (любóе) почётное мéсто; *синең өчен түр башы әзер* для тебя́ готóво почётное мéсто; **түр буе (буйлыгы)** *см.* **түрләмә**; **түр күрсәтү** *этногр.* приглашáть в гóсти родúтелей невéсты (*букв.* показáть почётное мéсто); **түргә (түрдән) узу** пройтú внутрь кóмнаты; не стоя́ть у двéрей; **түрдән уз!** пройдú, пожáлуйста (*в глубь комнаты*)

түрә *сущ.* **1.** главá́, головá́, управля́ющий; *түрдә утырган ~ бүрәнә аркылы бүре күрә* (*посл.*) высокопостáвленный чинóвник дáже сквозь стéны вúдит вóлка (*т. е. видит не то, что есть; выдаёт желаемое за действительное*) **2.** *перен.* чинýша, спесúвый начáльник **3.** *ист. см.* **түрәче** **4.** *перен.* уважáемый господúн; *син минем ~м* ты мой уважáемый господúн **5.** *ист. диал.* закóн; прáвило; обы́чай; *тилегә ~ юк* (*посл.*) глýпому нет закóна; дуракý закóн не пúсан

түрә-кара *сущ. собир.* рáзные (*низшие*) начáльники (*низшее*) начáльство; *түрә-кара җыелды* собралóсь рáзное начáльство

түрәләну *неперех.* (*по-начальнически*) курáжиться; вести́ себя́ как вáжный начáльник; вáжничать

түрәлә́рчә *нареч.* как чинýша; спесúво, как начáльник; по-вельмóжному; по-госпóдски; *~ кылану* вести́ себя́ спесúво

түрәлек *сущ.* **1.** дóлжность и́ли обя́занность главы́, начáльника, чинóвника (*тж.* судьú) **2.** *перен.* начáльственность, спесúвость (начáльника, вельмóжи) ◻ **~итү** исполня́ть дóлжность и́ли обя́занность начáльника, чинóвника; **~ кылу** проявля́ть начáльственную спесь

түрәтү *понуд. от* **түрәү** **1.** принимáть рóды **2.** *перен.* производúть/произвести́, размножáть/размнóжить || произведéние, размножéние; воспроизвóдство

түрә́|ү *перех. диал.* **1.** зачáть || зачáтие **2.** рожáть, родúть (*детей, детёнышей*); *ике малай ~де* родилá двух мáльчиков

түрәче *сущ.* **1.** *ист.* судья́, закóнник, знатóк закóнов и обы́чаев **2.** защúтник в судé; *~м бул* будь моúм защúтником (*в суде*) **3.** *диал.* распорядúтель на свáдьбе (*который решает и спорные вопросы*)

түрге *прил.* располо́женный в глубине́ ко́мнаты; пере́дник; ~ *өстәл* стол (располо́женный) в глубине́ ко́мнаты; ~ *почмак* пере́дний у́гол; ~ *якка узу* пройти́ в середи́ну (глубину́) ко́мнаты

түрем *прил. диал.* **1.** то́лстый (*об орудиях и предметах шитья*); ~ *энә* то́лстая игла́; ~ *җеп* то́лстая ни́тка **2.** *редко* то́лстый, доро́дный (*о человеке*) □ ~ **туташ** то́лстая де́вушка, толсту́шка

түремәю *неперех. диал.* **1.** потолсте́ть, стать доро́дным **2.** *эвф.* забере́менеть

түркен *сущ. диал. этногр.* **1.** родно́й, отцо́вский дом заму́жней же́нщины, ро́дина; *~гә бару* посеща́ть родны́х (*о новобрачной*) || обря́д посеще́ния родно́го до́ма новобра́чной **2.** прие́зд родны́х неве́стки

түрләмә *сущ. этногр. диал.* мате́рчатый расши́тый бордю́р, наве́шиваемый ли́бо вдоль ма́тицы, ли́бо по ве́рхнему кра́ю стен

түрләмәле *прил.* с бордю́ром; снабжённый бордю́ром; ~ *чаршау* пло́тный за́навес с бордю́ром све́рху

түрләү *неперех. диал.* окаймля́ть (*потолок*); обше́шивать бордю́ром (*верхнюю часть стены и матицу дома*)

түрле *прил. диал.* име́ющий специа́льное сиде́нье (*об экипаже*); ~ *чана* са́ни со специа́льным сиде́ньем (со спи́нкой — за́дником)

түрлек *прил.* предназна́ченный для (*украшения, убранства*) ко́мнаты и́ли почётного ме́ста в ко́мнате; ~ *мендәр* поду́шка для почётного (кра́сного) угла́; ~ *палас* ковёр для вну́тренней (гостево́й) ко́мнаты

түрле-почмаклы *нареч. см.* **ишекле-түрле**

түтә I *сущ.* **1.** о́бух, обушо́к (*топора*) **2.** прикла́д (*ружья*)

түтә II *сущ. разг.* ста́ршая сестра́; *~се өчен кайгырмыйбыз, сеңелләре тагы үсә* (*песня*) не горю́ем из-за сестры́ ста́ршей — подраста́ют мла́дшие

түтә III *прил. диал.* **1.** прямо́й, не обходно́й (*о дороге*); ~ *юл* прама́я доро́га **2.** *перен.* согла́сный, покла́дистый

түтәй *сущ. разг.* **1.** *см.* **түти 2.** *диал. см.* **тутай 3.** *диал. см.* **абыстай**

түтәкәй *сущ. см.* **түткәй**

түтәл *сущ.* гряда́, гря́дка (*в огороде*); ~ *күтәрү* поднима́ть гря́дку; *~гә утырту* посади́ть(о́вощи) в гря́дку

түтәлләү *перех.* **1.** сде́лать гря́дки, обрабо́тать зе́млю в ви́де гря́док **2.** *в знач. нареч.* **түтәлләп** гря́дами, гря́дками; *~п утырту (чәчү)* посади́ть (посе́ять) гря́дками

түтәлле *прил.* **1.** с гря́дками, име́ющий гря́дки; ~ *җир* земля́ с гря́дками **2.** в гря́дках; ~ *кишер* морко́вь в гря́дках

түтәллек *сущ.* огоро́д с гря́дками; ме́сто, где распло́жены гря́дки

түтәл-түтәл *нареч.* в ви́де гря́док, в гря́дках; це́лыми гря́дками; *түтәл-түтәл суган* лук це́лыми гря́дками

түтәнә *сущ. диал.* **1.** *уст.* большо́й мешо́к и́ли полотнище для увя́зывания вещей в у́зел (*при переселении*) **2.** *перен.* обжо́ра; *~гә түп тә талкан* (*посл.*) обжо́ре и жмы́хи — толокно́ || *прил.* прожо́рливый; неразбо́рчивый в еде́

түтә|п *сущ. диал.* **1.** жи́зненность, жизнь, жи́зненная си́ла (*в организме*); *~бе бар әле* ещё есть жи́зненная си́ла (ещё проживёт) **2.** по́лный вес, полновёсный

түтәрәм *сущ.* **1.** че́тверть; четверти́нка; *бер ~ ипи* че́тверть (карава́я) хле́ба **2.** *ист.* едини́ца измере́ния ве́са — приме́рно фунт (*400 граммов*) **3.** *ист.* едини́ца измере́ния земли́ — о́коло че́тверти десяти́ны

түтәрәмләп *нареч.* **1.** по четверти́м **2.** *перен.* по части́м; ~ *җыю* собира́ть по части́м (четверти́м)

түте|к *сущ.* **1.** свисту́лька **2.** *диал.* рожо́к; *көтүче ~ге* пасту́ший рожо́к

түтелдәт|ү **1.** *перех. разг.* развлека́ть, ласка́ть || ла́ска; *баланы ~ү* ласка́ть ребёнка; *~еп йөртү* ба́ловать ребёнка, развлека́ть **2.** *перен.* вози́ться, сюсю́каться *с кем;* води́ть на по́мочах

түтелдәү *неперех. прост.* **1.** *см.* **тәтелдәү**; лепета́ть || (младе́нческий) ле́пет **2.** сюсю́кать || сюсю́канье; *бала белән* ~ сюсю́кать с ребёнком

түтеш *сущ. диал.* тётенька, тётечка

түти *сущ.* **1.** 1) тётя; тётка 2) тётя (*употребляется в ка́честве слова обращения к имени собственному*); *Сара* ~ тётя Сара́ **2.** *диал.* ста́ршая сестра́

түткәй *сущ.* **1.** *разг. ласк. от* **түти (түтәй) 2.** *диал.* жена́ ста́ршего бра́та

ту-ту I *подр. звукам флейты, свистульки и т. п.*

ту-ту II *межд. в знач.* всё уже́ прошло́, по́езд ушёл

ту-ту-тут *подр. звукам рожка, сигнала машины* пип-пип; *машина тавышлана: ту-ту-тут* маши́на сигна́лит: пип-пип

тут-тут *подр. отрывистым звукам флейты, свистульки*

тучә *межд., которым отгоняют коров, быков, телят:* вон, *см. тж.* **тугә**

түш I *сущ.* **1.** 1) грудь, пове́рхность груди́; *түшендә шуа* по́лзает на груди́ (*о ребёнке*); *түшендә йон үсә* на груди́ расту́т во́лосы 2) бюст, же́нская грудь 3) часть оде́жды, кото́рая покрыва́ет грудь; ла́цканы; *мин булырмын зәңгәр чәчкә, ал да түшеңә када* (*песня*) я бу́ду голубы́м цвето́чком, возьми́ и приколи́ себе́ на грудь **2.** груди́нка; *куян түше* за́ячья груди́нка; *сыер түше* коро́вья (говя́жья) груди́нка || *прил.* грудно́й, нагру́дный; *түш кесә* нагру́дный карма́н □ **түш бау** *диал. см.* **чөелдерек**; **түш киереп** выпя́чивая грудь; грудь горо́й; *түш киереп сөйләшә* разгова́ривает — грудь горо́й; **түш киерү** выпя́чивать грудь (*утверждая своё превосходство*); наступа́ть гру́дью; хва́статься

түш II *сущ.* **1.** наковáленка, наковáльня (*для отбивания косы*); *см. тж.* **тапавыч 2.** *диал.* наковáльня; *см. тж.* **сандал 3.** *диал.* 1) попере́чный брус, попере́чина (*для складывания брёвен*) 2) *см.* **арба күкрәге**

түш III *сущ. редко см.* **түшкә**

түшәк *сущ.* **1.** *этногр.* широ́кая, на всю посте́ль поду́шка; матра́ц; *ишәк ~тә дә ишәк* (*посл.*) осёл и на поду́шке остаётся осло́м **2.** *перен.* 1) супру́жеское ло́же 2) ло́же для новобра́чных ◊ ~ **саклау** жить вдово́й (вдовцо́м); жить целому́дренно (*о вдовах, вдовцах; ирон. также и о тех, чей супруг в отлучке*); ~ **яңарту** жени́ться (*реже* — вы́йти за́муж) втори́чно; **~кә (~ өстенә) егылу** серьёзно заболе́ть; **~тә (~ өстендә) яту** тяжело́ боле́ть; до́лго боле́ть

түшәкләп|ү *неперех.* **1.** взбива́ться/взби́ться (*подобно тюфяку*); *~гән болытлар* вспу́хшие, взби́тые (подо́бно тюфяку́) облака́ **2.** приобрета́ть/приобрести́ тюфя́к

түшәкле *прил.* с тюфяко́м, с матра́сом; ~ *ятак* ло́же с тюфяко́м

түшәк-түшәк *прил.* в ви́де (*взбитых*) тюфяко́в; *түшәк-түшәк кар* снег в ви́де тюфяко́в, поду́шек

түшәк-юрган *сущ. собир. см.* **түшәк-ястык**

түшәк-ястык *сущ. собир.* посте́льные принадле́жности, (*всякие*) поду́шки, тюфяки́ и матра́сы; *сандык*

өстенә түшәк-ястык өелгән на сундуке́ сло́жены тюфяки́ и матра́сы

түшәлдер|ү *понуд. от* **түшәлү**; выстила́ть/вы́стелить; оку́тать, обда́ть; *парын җиргә ~еп паровоз үтте* прошёл парово́з, оку́тав зе́млю па́ром

түшәлмә *прил.* **1.** сте́лющийся; *~ каен* сте́лющаяся берёза; *~ сабак* сте́лющийся черено́к (*растения*) **2.** на́стланный, настилённый; *~ юл* на́стланная доро́га **3.** выстила́ющий; *~ катлам* выстила́ющий слой || *сущ. см.* **түшәмә**

түшәл|ү *страд.-возвр. от* **түшәү** **1.** стели́ться, стла́ться, постели́ться (*в прям. и перен. знач.*); *~гән ятак* по́стланное ло́же; *җиргә төтен ~де* на земле́ (по земле́) сте́лется дым **2.** *перен.* устила́ться/устла́ться; покрыва́ться/покры́ться сплошь; *аланга чәчәк ~гән* поля́на сплошь у́стлана цвета́ми

түшәм *сущ.* **1.** потоло́к (*здания, комнаты и т. п.*); *идәннән ~гә кадәр* от по́ла до потолка́ **2.** *перен.* потоло́к, вы́сшая то́чка, вы́сший возмо́жный у́ровень *чего-л.*; *гыйлемнең ~енә җиту* дости́гнуть вы́сшей то́чки зна́ний **3.** *перен. тех.* потоло́к лета́тельных аппара́тов (*наибольшая высота полёта самолётов и дирижаблей*) □ **~ санаш** вид шутли́вой игры́ (*незнакомого с этой игрой заставляют лёжа считать доски потолка через рукав и внезапно льют воду в рукав*) ◊ **~ санап (~гә төкереп) яту** ничего́ не де́лать; безде́льничать (*букв.* лежа́ть и счита́ть до́ски на потолке́; лежа́ть и плева́ть на потоло́к); **~нән алу** взять с потолка́; вы́сосать из па́льца; **~нән туфрак кою** устро́ить скандал (*в семье*) (*букв.* вытря́хивать земляно́й насти́л че́рез потоло́к); *см. тж.* **савыт-саба шалтырату**

түшәмә *сущ.* **1.** насти́л; *бүрәнәләр ~се* насти́л брёвен **2.** гать; *сазга ~ салу* на боло́те настила́ть гать; га́тить боло́то

түшәмдәге *прил.* потоло́чный (*в знач.* находя́щийся на потолке́); *~ такталар* потоло́чные до́ски; *~ бизәкләр* потоло́чные украше́ния

түшәмле *прил.* с потолко́м, име́ющий потоло́к; кры́тый, с перекры́тием, име́ющий перекры́тие; *~ абзар* хлев с потолко́м (*с перекрытием*)

түшәмлек *прил.* **1.** приго́дный и́ли предназна́ченный для (устро́йства) потолка́; *~ такталар* предназна́ченные для потолка́ до́ски **2.** *диал.* потоло́чный; *~ өрлек* потоло́чная ба́лка || *сущ.* **1.** потоло́чная доска́ **2.** *диал. см.* **түшәм**

түшән|ү *возвр. от* **түшәү**; стлать/стели́ть (*себе*) ло́же; *~ер түшәге юк* нет (да́же) того́, чем постла́ть себе́ ло́же (*т.е. постельных принадлежностей*)

түшәт|ү *понуд. от* **түшәү**; веле́ть и́ли заставля́ть/заста́вить стели́ть; *кәникәдән түшәк ~кән батыр* богаты́рь, заста́вивший принце́ссу стели́ть (бра́чную) посте́ль

түшә́ү *перех.* **1.** стлать/постла́ть; расстила́ть/расстели́ть; стели́ть/постели́ть, выстила́ть/вы́стлать; *салам ~* стели́ть соло́му; *келәм ~* вы́стлать ковра́ми **2.** настила́ть/настла́ть; *бүрәнә ~* настила́ть брёвна (брёвнами) **3.** мости́ть, зама́щивать/замости́ть (*дорогу*) **4.** *перен. разг.* истребля́ть, уничтожа́ть/уничто́жить (*врагов*)

түшәүле *прил.* сте́ленный, посте́ленный; *~ урын* посте́ленная посте́ль

түшбикә *сущ. прост.* **1.** же́нщина с пы́шными груда́ми **2.** *перен.* ста́тная и го́рдая же́нщина

түшелдере|к *сущ.* **1.** *этногр.* укра́шенный шитьём, позуме́нтами и т. п. же́нский нагру́дник; пелери́на; *күлмәк ~ге* нагру́дник пла́тья **2.** подбрю́шник; *см. тж.* **түшлек**

түшкә *сущ.* **туша**; *бер ~ сарык* це́лая ове́чья ту́ша (*туша овцы*)

түшке *прил.* нагру́дный; *~ кесә* нагру́дный карма́н; *~ билге* нагру́дный знак; *~ аел* нагру́дная пря́жка-тройча́тка (*в конской сбруе*)

түшле *прил.* **1.** с гру́дью (груда́ми) определённого ка́чества **2.** -гру́дый; *киң ~* широкогру́дый (мужчи́на)

түшле|к *сущ.* **1.** нагру́дник; нагру́дный фа́ртук; нагру́дная часть пла́тья; *алъяпкыч ~ге* нагру́дник фа́ртука **2.** *см.* **түшелдерек** **3.** *диал. см.* **күкрәкчә** || *прил.* нагру́дный, грудно́й; предназна́ченный для нагру́дной ча́сти оде́жды; *~ кисем* нагру́дный (грудно́й) вы́рез (*платья*)

түшсез *прил.* без груде́й; плоскогру́дый (*человек*)

тфу *межд. в разн. знач.* тьфу (*при зареканию, отгораживании себя от наваждения, соблазна и т. п.*)

тыбырсык *прил.* **1.** нетерпели́вый, непосе́дливый, суетли́вый; мяту́щийся, трево́жный; *~ булса да, акыллы* хоть и суетли́в, но умён; *~тан туң артык* (*посл.*) лу́чше флегмати́чный, чем суетли́вый **2.** *см.* **кыбырсык**

тыбырчык *прил. разг. см.* **тыбырсык**

тыбырчынгалау *многокр. от* **тыбырчыну**; перебира́ть нога́ми вре́мя от вре́мени

тыбырчыну *неперех.* **1.** перебира́ть || перебира́ние нога́ми на ме́сте (*о лошади*) и́ли лёжа (*о ребёнке*) **2.** *см.* **тыпырчыну, тиберчену**

ты|гу **1.** 1) сова́ть/су́нуть, все́вывать/всу́нуть || все́вывание; *сумкага ~гу* су́нуть в су́мку 2) заса́вывать/засу́нуть || заса́вывание (*руки в карман*) **2.** втыка́ть/воткну́ть || втыка́ние; *көрәкне җиргә ~гу* воткну́ть лопа́ту в зе́млю; *карга ~гу* воткну́ть в снег **3.** впи́хивать/впихну́ть; запи́хивать/запихну́ть || впи́хивание, запи́хивание; *әйберләрне капчыкка тык* запи́хивай ве́щи в мешо́к **4.** *разг.* 1) *в разн. знач.* затыка́ть/заткну́ть || затыка́ние; *колакка ~гып* заткну́в у́ши; *тишекне ~гу* затыка́ть дыру́ 2) заку́поривать/заку́порить || заку́поривание; *мичкәне ~ктылар* заку́порили бо́чку **5.** *в разн. знач.* вта́лкивать/втолкну́ть; зата́лкивать/затолкну́ть, запи́хивать/запихну́ть || вта́лкивание; зата́лкивание; *төрмәгә ~гу* засади́ть в тюрьму́ **6.** *разг.* все́вывать/проса́вывать/просу́нуть; высо́вывать/вы́сунуть || просо́вывание, высо́вывание; *ишекә башын ~гып* просу́нув го́лову в две́ри; *ишектән башын ~гып* вы́сунув го́лову из двере́й **7.** вводи́ть/ввести́, втыка́ть/воткну́ть, вти́скивать/вти́снуть || введе́ние, вти́скивание (*во что-л. густое, частое*); *үләнгә чалгы ~гар хәл юк* в траву́ невозмо́жно воткну́ть косу́ **8.** *перен.* вти́скивать/вти́снуть || вти́скивание; *бөтен проблемаларны бер рамкага ~гу* вти́скивать все пробле́мы в одну́ ра́мку **9.** *перен.* навя́зывать/навяза́ть; все́вывать/всу́нуть, всучи́ть || навя́зывание, все́вывание, всу́чивание (*обманным путём*); *начар товар ~гу* навяза́ть (всучи́ть) плохо́й това́р **10.** *перен. прост.* **(илтеп тыгу)** *разг.* дева́ть/деть, задева́ть, пря́тать; *әллә кая (илтеп) ~кты* чёрт зна́ет куда́ дел (засу́нул, спря́тал) **11.** *перен. прост.* деть, расхо́довать/израсхо́довать, затра́чивать/затра́тить || расхо́дование; *кая ~тың шул кадәр акчаны?* куда́ (на что) израсхо́довал сто́лько де́нег **12.** *груб. прост. см.* **тыгыну** □ **~гып керту** зата́лкивать/затолкну́ть || *прям., перен.* зата́лкивание; **~гып кую** затыка́ть || затыка́ние

тыгулы *прил. разг.* за́ткнутый

тыгы *сущ. диал.* **1.** ни́зкий насе́ст; насе́ст на сто́лбиках **2.** *см.* **тигә**

тыгыз *прил.* **1.** *в разн. знач.* пло́тный; ~ *матдә* пло́тное вещество́; ~ *сафлар* пло́тные ряды́; ~ *тукыма* пло́тная ткань; ~ *бөҗра* пло́тное кольцо́; ~ *тән* пло́тное те́ло **2.** у́зкий; *прям., перен.* те́сный; ~ *бүлмә* те́сная ко́мната; ~ *бәйләнеш* те́сная связь **3.** туго́й, наби́тый; ~ *башаклар* туги́е коло́сья; ~ *капчык* наби́тый мешо́к **4.** *перен.* напряжённый; ~ *эш вакыты* напряжённое рабо́чее вре́мя || *нареч.* **1.** пло́тно; те́сно; ~ *ябылган ишек* пло́тно закры́тая дверь; ~ *туку* пло́тно ткать **2.** те́сно; ~ *багланышлы* те́сно свя́занный **3.** ту́го; ~ *тутырылган* ту́го наби́тый (заби́тый) ◊ **~га килү (китү)** станови́ться/стать в обре́з (*о времени, возможностях*)

тыгызайт|у *перех.* набива́ть/наби́ть пло́тно (ту́го)

тыгыза|ю *неперех.* станови́ться/стать пло́тным (туги́м, те́сным); уплотня́ться/уплотни́ться; *см. тж.* **тыгызлану** 1; *һава ~я* во́здух уплотня́ется

тыгызлагыч *сущ. см.* **тыгызлаткыч**

тыгызландыру *перех.* уплотня́ть/уплотни́ть; *см. тж.* **тыгызлау** 1

тыгызлан|у *возвр. от* **тыгызлау 1.** уплотня́ться/уплотни́ться || уплотне́ние; *кар ~ып басыла төшкән* снег слежа́лся, уплотни́лся **2.** 1) станови́ться/стать те́сным; *халык тулды, бүлмә ~ды* наро́д запо́лнил помеще́ние, ста́ло те́сно 2) тесни́ться/потесни́ться; *бераз ~ыгыз* немно́го потесни́тесь **3.** 1) станови́ться/стать напряжённым; осложня́ться/осложни́ться || осложне́ние; *эшләр ~ды* дела́ осложни́лись (ста́ли напряжёнными) 2) станови́ться/стать в обре́з (*о времени на что-л.*) **4.** *разг.* напряжённо занима́ться *чем-л.*; *туй эшләре белән ~у* напряжённо занима́ться устро́йством сва́дьбы **5.** *диал. перен.* стесня́ться/постесня́ться; затрудня́ться/затрудни́ться || затрудне́ние; стесне́ние; *җавабында ~ды* затрудни́лся в отве́те □ **~ган хәлдә** в стеснённом положе́нии

тыгызланыш|у *совм. от* **тыгызлану** (*о многих*); *~ып утырдылар се́ли* потесни́вшись

тыгызлаткыч *сущ. тех.* уплотни́тель || *прил.* уплотни́тельный, уплотня́ющий

тыгызлату *перех. см.* **тыгызлау**

тыгызла́|у *перех.* **1.** уплотня́ть/уплотни́ть || уплотне́ние; *туфракны ~у* уплотня́ть по́чву || уплотне́ние по́чвы; *массаны ~у* уплотни́ть ма́ссу **2.** *в знач. нареч.* **тыгызлап** ту́го, пло́тно; битко́м; *~п тутырылган* битко́м наби́тый **3.** стесня́ть/стесни́ть || стесне́ние; *~п тору* всё вре́мя стесня́ть, занима́ть ме́сто; *юлны ~п тору* стесня́ть (загора́живать) доро́гу **4.** *разг.* обступи́ть (*со всех сторон*) **5.** *разг.* меша́ть/помеша́ть; *~п йөрмәгез* не меша́йте тут **6.** *диал.* 1) подгоня́ть, торопи́ть (*в работе*) 2) угова́ривать, увеща́ть с угро́зами (*добиваясь чего-л.*); *~п карасак та, күнмәде* как мы ни угова́ривали, не согласи́лся

тыгызлы|к *сущ.* **1.** 1) пло́тность, уплотнённость (*почвы и т. п.*) 2) пло́тность (*сложение тела*) **2.** теснота́; *~кта яшәү* жить в тесноте́ **3.** *перен.* стеснённость, затруднённость, затрудне́ние; *см. тж.* **кысынкылык 4.** спе́шка, спе́шность; э́кстренность; *вакыт ~гы* отсу́тствие, недоста́ток вре́мени; *эхвәл ~гы* авра́л □ **~к итү (кылу)** затрудня́ть/затрудни́ть; меша́ть, стесня́ть/стесни́ть; *кешегә ~к итмә* не меша́й челове́ку (*своим присутствием*)

тыгылдыру *перех.* **1.** засоря́ть/засори́ть || засоре́ние (*отверстия, канала и т. п.*); *торбаны ~* засори́ть трубу́ до непроходи́мости **2.** *см.* **тыгындыру 3.** *перен. груб.* откупи́ться (*от взяточника, вымогателя и т. п.*); затыка́ть/заткну́ть; *авызын ~* заткну́ть рот (*деньгами и т. п.*)

тыгыл|у *возвр.-страд. от* **тыгу 1.** 1) сова́ться/су́нуться; лезть/поле́зть (*рукой*) *во что-л.*; *кесәсенә ~ды* поле́з (*рукой*) в (свой) карма́н 2) всо́вываться/всу́нуться, лезть/поле́зть (*в отверстие, проход и т. п.*); *тәрәзәгә ~у* лезть в окно́ **2.** *разг.* сова́ться/су́нуться, лезть/поле́зть, вме́шиваться/вмеша́ться || вмеша́тельство (*в чужие дела*); *сорамаганга ~ма* не про́сят — не вме́шивайся; *кеше эшенә ~ма* не су́йся в чужи́е дела́ **3.** 1) заку́поривать/заку́порить || заку́поривание; *торба ~ган* труба́ заку́порилась 2) застрева́ть/застря́ть; набива́ться/наби́ться; *торбага чүп ~ган* в трубу́ наби́лся му́сор **4.** сгру́диться, забива́ться/заби́ться, тесни́ться (*у отверстия, прохода и т. п.*); *елгага боз ~ган* река́ заби́та льдом **5.** дави́ться/подави́ться (*пищей, слезами и т. п.*) **6.** *груб.* околе́ть, подави́ться и умере́ть

тыгылыш *сущ.* **1.** теснота́, да́вка; толку́чка, про́бка; *~ка эләгү* попа́сть в про́бку (*на дороге*) **2.** зато́р (*на реке*); *~ны шартлату* взорва́ть зато́р

тыгылыш|у *совм. от* **тыгылу** (*о многих*); сгру́диться, забива́ться, тесни́ться

тыгын I *сущ.* **1.** про́бка, заты́чка; *тишеккә ~ булу* (*погов.*) быть заты́чкой к дыре́; *мичкәгә ~ ясау* сде́лать заты́чку к бо́чке **2.** *см.* **тыгылыш; *~га эләгү*** попа́сть в да́вку (зато́р)

тыгын II *прил. см.* **тыгыз** 1-2 || *нареч.* те́сно; *анда бик ~ икән* там, ока́зывается, так те́сно, така́я да́вка

тыгындыр|у *перех. прост.* прика́рмливать; дать возмо́жность обожра́ться

тыгынлык *сущ.* да́вка, теснота́, толку́чка; *трамвайдагы ~* да́вка в трамва́е

тыгын|у *неперех. груб. прост.* обжира́ться/обожра́ться; *~ып утыру* обжира́ться, занима́ться обжо́рством, чревоугоди́ем

тыгынчык *сущ.* **1.** про́бка, заты́чка; *тыгыз җирдә ~* (*погов.*) нену́жная заты́чка к буты́лке (*о ненужном вмешательстве*); к ка́ждой бо́чке заты́чка; пя́тое колесо́ к теле́ге **2.** во́йлочная заты́чка дымохо́да; *~ тыгу* затыка́ть заты́чкой

тыгынчыкла́|у *перех.* затыка́ть/заткну́ть || затыка́ние (*затычкой*) □ **~п кую** заткну́ть специа́льной заты́чкой

тыгынчыклы *прил.* с заты́чкой, с про́бкой; за́ткнутый заты́чкой, про́бкой

тыелган *прил.* запрещённый, запре́тный; *см. тж.* **тыюлы**; *~ китап* запрещённая кни́га; *~ алым* запрещённый приём

тыелгысыз *прил.* безу́держный, неудержи́мый; *~ дәртләр* безу́держные стра́сти; *~ көч белән* с неудержи́мой си́лой || *нареч.* безу́держно, неудержи́мо; *~ тәгәрәп төшү* неудержи́мо скати́ться вниз

тыелгысызлык *вниз сущ.* неудержи́мость; безу́держность *чего-л.*

тыелдыргысыз *прил. редко см.* **тыелгысыз**

тыелдыргыч *прил.* сде́рживающий, уде́рживающий; *~ фактор* сде́рживающий фа́ктор

тыелдыр|у *понуд. от* **тыелу 1.** заста́вить сдержа́ться **2.** *разг.* уде́рживать/удержа́ть, сде́рживать/сдержа́ть || уде́рживание, сде́рживание; *атны ~ып таудан төшү* спуска́ться с горы́, сде́рживая ло́шадь

тыелмыш *прил. книжн.* запре́тный, запрещённый

тыел|у *страд.-возвр. от* **тыю 1.** *страд.* запреща́ться, быть запрещённым; *катгый ~а* стро́го запреща́ется;

стро́го запрещено́ **2.** *возвр.* воздéрживаться/воздержáться, сдéрживаться/сдержáться, удéрживаться/удержáться || воздержáние (*при искушении, от запретного и т. п.*); *көчкә -ды* éле удержáлся □ **~ып калу** удéрживаться/удержáться, сдéрживаться/сдержáться; **~ып килү** запрещáться/запретúться *кем;* бывáть/быть под спýдом; *~ып килгән* бывший (*на время*) под спýдом; **~ып кына** нарочúто сдéржанно; сдéрживаясь; *~ып кына көлде* сдéржанно засмеялся; **~ып тору** сдéрживаться/сдержáться (*на какое-то время*)

тыелулы *прил.* **1.** запрéтный; *~ зона* запрéтная зóна **2.** недозвóленный; *~ алымнар* недозвóленные приёмы

тыенкы *прил.* воздéржанный, сдéржанный, смирéнный; *~ җавап* смирéнный ответ || *нареч.* воздéржанно, смирéнно; *~ сөйләү* говорúть сдéржанно, без эмóций; *~ гына* скрóмно, но с достóинством

тыенкылык *сущ.* воздéржанность, смирéнность □ **~ белән** воздéржанно, смирéнно

тыз (тыз-з) *подр. звуку полёта насекомых (мух, пчёл)* □ **тыз-з итү (килү)** жужжáть; шипéть с дребезжáнием

тыз-быз 1. *подр. беспорядочной беготне, суетливым движениям многих* **2.** *в знач. сущ.* суетá, беготнá; *урамдагы тыз-быз* ýличная беготнá **3.** *в знач. нареч.* суматóшно; *машиналар тыз-быз чабыша* машúны суматóшно нóсятся (*во все стороны*) □ **тыз-быз йөрү** новáть; **тыз-быз (тыз да быз) килү (итү)** беспорядочно метáться, суетúться

тызгый-бызгый *нареч.* суматóшно; беспорядочно

тызгылд|áу *неперех.* **1.** *см.* **тызылдау**; жужжáть, прожужжáть **2.** *перен. прост.* сердúто и тороплúво говорúть (*выражая недовольство*); брюзжáть; *нәрсә -ыйсың?* что ты брюзжúшь?

тызылд|áу *неперех.* **1.** издавáть/издáть слáбо дребезжáщий звук || слáбое дребезжáние (*оконного стекла от сильного шума небольших электромоторов*) **2.** жужжáть || жужжáние (*мух, шмелей, жуков, а также некоторых механизмов*)

тыйб *сущ. см.* **тыйп**

тыйбби *прил. уст.* медицúнский; *~ мәктәп* медицúнская шкóла; *~ ярдәм* медицúнская пóмощь; *~ белем (гыйлем)* медицúнское образовáние

тыйлыг|у *неперех.* **1.** éле-éле, насúлу сдéрживаться/сдержáться; удéрживаться/удержáться; напряжённо подавлять/подавúть желáние **2.** *в знач. нареч.* **тыйлыкмастан, тыйлыкмыйча** не сдéрживаясь; несдéржанно **3.** *диал.* (*немного*) утихáть/утúхнуть, затихáть/затúхнуть, унимáться/унять*ся* (*о боли, ветре, дожде*) **4.** *диал.* тормозúться || торможéние □ **~ып калу** сдержáться; **~ып тору** удéрживаться (*еле, пока*)

тыйлык *сущ. диал.* слегá; гнёт; запóр; упóр (*под колёса, чтобы не было откатки*) □ **~ салу** *прям., перен.* затормáживать/затормозúть; *эшкә ~ салу* затормозúть дéло (*каким-л. подвохом, поводом, выходкой и т. п.*)

тыйлыксыз *прил.* **1.** безýдержный, ничéм не сдéрживаемый; *~ сүз* безýдержное многорéчие **2.** *мед.* страдáющий недержáнием мочú **3.** *перен. разг. см.* **тотнаксыз**

тыйлыксызлан|у *неперех. диал.* **1.** 1) *см.* **тотнаксызлану** 2) становúться/стать безýдержным **2.** страдáть недержáнием мочú □ **~ып калу** (надóлго) заболéть недержáнием мочú

тыйлыктыр|у *перех. диал.* затормозúть; страховáть от откáтки (*с помощью упора*)

тыйнак *прил.* **1.** скрóмный, сдéржанный, пристóйный; *~ холык* скрóмный нрав; *кунак булсаң ~ бул* (*посл.*) éсли ты гость — будь сдéржанным **2.** скрóмный, непритязáтельный; *~ шартларда* в непритязáтельных услóвиях; *~ җиһазлар* скрóмная обстановка (мéбель) || *нареч.* **1.** скрóмно, сдéржанно; не хвастлúво; *~ кылану* вестú себя́ скрóмно, сдéржанно **2.** скрóмно, непритязáтельно; *~ бизәлгән бүлмә* скрóмно украшенная кóмната □ **~ кына** скрóмно, сдéржанно, скрóмненько; *~ кына көлү* сдéржанно смея́ться (засмея́ться); *~ кына әйткәндә* скрóмно говоря́

тыйнаклан|у *неперех.* становúться/стать скрóмным (*сдержанным, непритязательным*) □ **~ып китү** стать (совсéм) скрóмным

тыйнаклы *прил. редко* сдéржанный, дисциплинúрованный; *~ гаскәри* дисциплинúрованный вóин

тыйнаклы|к *сущ.* скрóмность, сдéржанность; *~гы белән билгеле* извéстный (извéстен) своéй скрóмностью; *~кка ни җитә* нет ничегó лýчше скрóмности

тыйнаксыз *прил.* **1.** нескрóмный; несдéржанный; *~ кеше* нескрóмный человéк **2.** невоспúтанный, недисциплинúрованный; *~ балалар* невоспúтанные дéти **3.** непристóйный; *~ кыланыш* непристóйное поведéние **4.** неуёмный; *~ нәфес* неуёмная жáдность; неуёмное желáние || *нареч.* **1.** нескрóмно, несдéржанно; *~ йөренү* нескрóмно бродúть, разгýливать **2.** непристóйно; распýщенно; *~ киенү* непристóйно одевáться; *үз-үзен ~ тоту* вестú себя́ развя́зно

тыйнаксызландыру *понуд. от* **тыйнаксызлану**; допускáть/допустúть несдéржанность, непристóйность, недисциплинúрованность *кого*

тыйнаксызлан|у *неперех.* **1.** становúться/стать нескрóмным (несдéржанным, недисциплинúрованным, распýщенным); распускáться/распустúться || распýщенность **2.** проявля́ть/проявúть нескрóмность, несдéржанность, недисциплинúрованность, распýщенность, неприлúчие; *~ма эле* не будь распýщенным; не проявля́й распýщенность; *аның ~лары күп булды* он мнóго раз проявля́л нескрóмность

тыйнаксызлык *сущ.* **1.** нескрóмность, несдéржанность, неприлúчие **2.** невоспúтанность; недисциплинúрованность; *нинди ~ бу?* что э́то за недисциплинúрованность? **3.** непристóйность, распýщенность; *~ күрсәтү* проявля́ть/проявúть нескрóмность (невоспúтанность, распýщенность); *бу инде ~ була* э́то уже́ распýщенность

тыйп *сущ. уст., книжн.* медицúна, медицúнское дéло; *~ китабы* книга по медицúне, медицúнская книга; *~ галиме* учёный-мéдик; *~ гыйлеме* медицúна (*как наука*)

тык *подр. глуховатому звуку не очень слабого удара твёрдым предметом по твёрдому* (*менее отчётливый, чем* тук, *и более сильный, чем* тек) □ **~ итү** стýкнуть (*твёрдым предметом по твёрдому, напр., ломиком по льду, толстым карандашом по столу и т. п.*); *~ итеп бәрелү* удáриться со стýком

тыккыч *сущ.* **1.** *см.* **тыгынчык 2.** деревя́нная лопáточка (*которой набивают мох в щели между брёвнами*); шпáтель; конопáтка; *~ белән тыгу* набивáть шпáтелем

тык-тык *подр. глуховатому постукиванию, перестуку* тык-тык □ **тык итү** глуховáто постýкивать (*менее отчётливо, чем* тук-тук, *и более сильно, чем* тек-тек)

тыкшын|у *неперех.* **1.** лезть в толкотню́, дáвку и т. п.; совáться/сýнуться; *кая -асың, күрмисеңмени?* куда́ ты суёшься, не ви́дишь рáзве? *кая ~макчы буласың?* куда́

ты хо́чешь проле́зть? **2.** 1) лезть, вме́шиваться/вмеша́ться ‖ вмеша́тельство; *~ып йөрмә* не вме́шивайся (куда́ не сле́дует); *чит илнең эчке эшләренә ~у* вме́шиваться во вну́тренние дела́ иностра́нного госуда́рства 2) вме́шиваться/вмеша́ться (*в разговор и т. п.*); встрева́ть; *өлкәннәр сүзенә ~ма* не вме́шивайся в разгово́р взро́слых **3.** *диал.* (*безуспешно*) пыта́ться, попро́бовать *что-л.* сде́лать

тыкшынучан *прил.* скло́нный вме́шиваться; *кеше эшенә ~* скло́нный вме́шиваться в чужи́е дела́

тыкшынучанлык *сущ. см.* **тыкшынучылык**

тыкшынучы *сущ. и прил.* вме́шивающийся (*о человеке*); незва́ный помо́щник; *~лар кирәкми* незва́ных помо́щников не ну́жно

тыкшынучылык *сущ.* вмеша́тельство (*как постоянное свойство*); *~ белән шөгыльләнү* занима́ться вмеша́тельством

тыкылдат|у *неперех.* стуча́ть, постуча́ть, посту́кивать ‖ стук, посту́кивание; *юан бармаклары белән өстәлгә ~ты* постуча́л по столу́ то́лстыми па́льцами

тыкылда́|у *неперех.* **1.** (непроизво́льно) глухова́то стуча́ть ‖ глухова́тый стук, стуча́ние, переста́ук; *тәгәрмәч ~вы* глухова́тый стук колёс (*поезда*); *~п әйләнү* враща́ться со сту́ком **2.** *см.* **такылдау**

тыкылдаш|у *взаимн.-совм. от* **тыкылдау**

тыкылт *подр. одиночному стуку, удару мягким предметом по твёрдому (при этом звук слышится как бы дальше, чем в случае, выражаемом словом* тык*)*

тыкыр, тыгыр *сущ. ист.* дли́нная (*до колен*) холщо́вая мужска́я руба́шка

тыкырдат|у *перех.* **1.** дро́бно и́ли со скри́пом стуча́ть, посту́кивать; *~ып туглау* взба́лтывать со сту́ком (*ударяя ложкой по дну и стенкам посуды*); *~ып өстерәү* волочи́ть со скри́пом (*жердь по земле*) **2.** *перен. разг.* донима́ть, зава́ливать вопро́сами, замеча́ниями *и т. п.*; *нәрсә бу да нәрсә бу, дип ~ты* (он) донима́л вопро́сами что э́то? да что э́то **3.** *перен. разг.* 1) торопи́ть; тормоши́ть/потормоши́ть; побужда́ть *к чему*; *~ син аны, тиз булсын* ты потормоши́ его́, пусть пошевели́вается 2) постоя́нно напомина́ть (*об обязанности, об обещании и т. п.*); *бу турыда начальникка ~ырга кирәк* об э́том непрестанно на́до напомина́ть нача́льнику

тыкырд|а́у *неперех.* (непроизво́льно) дро́бно стуча́ть, посту́кивать; *таш юлда тәгәрмәчләр ~ый башлады* на вы́мощенной ка́мнем доро́ге колёса ста́ли дро́бно стуча́ть

тыкырт *подр. однократному, краткому шуму от стука со скрипом* □ **~ итү** *однокр.* сту́кнуть и скри́пнуть; дро́бно сту́кнуть (*и остановиться*)

тыкыр-тыкыр *подр. продолжительному стучанию, перестуку (со скрипом, шуршанием); ~ тәгәрәү* кати́ться с переста́ук □ **тыкыр-тыкыр итү (килү)** продолжи́тельно (*то и дело*) стуча́ть (*со скрипом*)

тыкырык *сущ.* **1.** переу́лок; *~тан үтү* проходи́ть по переу́лку **2.** *диал. этногр.* промежу́ток ме́жду уса́дьбами (*при круговом расселении, бывшем в древности*); радиа́льный вы́ход из поселе́ния **3.** *диал.* тупи́к; зако́улок

тыкы-тыкы *подр. сверхпродолжительному глуховатому перестуку; тыкы-тыкы тыкылдый* всё вре́мя глу́хо стучи́т □ **тыкы-тыкы килү** **1.** *см.* **тыкылдау 2.** (ну́дно) болта́ть; ну́дно говори́ть

тыл *сущ. в разн. знач.* тыл *тылы нык* тыл его́ кре́пок; *тирән тыл* глубо́кий тыл; *армия тылы* тыл а́рмии; *тылга чыгару* выводи́ть в тыл

тылакай *прил. диал.* невы́держанный на язы́к; болтли́вый

тылакайлан|у *неперех. диал.* **1.** станови́ться/стать невы́держанным на язы́к; распуска́ться/распусти́ться (*в речи*) **2.** выба́лтывать/вы́болтать ли́шнее; *~ма инде* не болта́й ли́шнее (*отсебятину, домыслы и т. п.*)

тылакайлык *сущ. диал.* **1.** болтли́вость, невы́держанность на язы́к; распу́щенность (*в речах*); *~гы бар* ему́ сво́йственна болтли́вость **2.** проявле́ние распу́щенности; *~к күрсәтү* проявля́ть распу́щенность (*в речи*); говори́ть что попа́ло

тылдагы *прил.* тылово́й, находя́щийся в тылу́; *~ начальниклар* тыловы́е нача́льники; *~ ныгытмалар* тыловы́е укрепле́ния

тылк|у *перех. диал.* **1.** валя́ть, поваля́ть языко́м во рту; *телсез кеше ~ып ашар* беззу́бый валя́ет языко́м (и съеда́ет) **2.** *перен.* 1) распина́ться; говори́ть мно́го об одно́м и том же 2) мно́го говори́ть о ма́лой прови́нности *кого-л.*; наби́ть оско́мину (*разговорами на недостойную тему*); *күп ~ыма* не набива́й оско́мину (*разговорами об одном и том же*) **3.** *диал.* говори́ть невня́тно (*как с кашей во рту*); с трудо́м поворачивать язы́к

тылкыш *сущ. диал. см.* **тыгылыш** ‖ *прил.* те́сный; многолю́дный; *~ урын* многолю́дное ме́сто

тылкышлык *сущ. диал.* толкотня́, толку́чка, да́вка, многолю́дье; *базардагы ~* многолю́дье на база́ре

тылкыш|у *неперех. диал.* **1.** *см.* **тыкшыну 2.** *перен.* **(дип-)** стара́ться, стреми́ться; тщи́ться (*попасть в определённый круг людей*); *бай булам дип ~у* стреми́ться слыть/прослы́ть богачо́м; тщи́ться попа́сть в круг богаче́й

тылмач *сущ. прост.* толма́ч, перево́дчик; *~ булу* быть толмачо́м (*переводчиком*)

тылмачла́|у *перех. прост.* **1.** переводи́ть с одного́ языка́ на друго́й **2.** объясня́ть сло́жные те́ксты, докуме́нты, разъясня́ть; доводи́ть до све́дения кого́; комменти́ровать; *син ~п торма, үзебез дә аңлыйбыз* ты не коммента́ируй, мы и са́ми понима́ем

тылмачлык *сущ.* заня́тие, профе́ссия перево́дчика; *~та йөрү* ходи́ть в перево́дчиках; быть (*по профессии и положению*) перево́дчиком □ **~ итү** выполня́ть/вы́полнить роль перево́дчика при перегово́рах; толма́чить; толма́чествовать

тылсым *сущ.* **1.** волше́бство́; *~ көче белән* си́лой волше́бства́ **2.** *уст.* талисма́н **3.** ча́ры; *сөю ~ы* ча́ры любви́

тылсымлагыч *прил.* очаро́вывающий, зачаро́вывающий; *сәнгатьнең ~ көче* чару́ющая си́ла иску́сства

тылсымлан|у *возвр. от* **тылсымлау** **1.** очаро́вываться/очарова́ться, зачаро́вываться; быть очаро́ванным ‖ состоя́ние очарова́ния; *җаны ~ган* его́ (её) душа́ очаро́вана (зачаро́вана); *ягымлы сүздән ~ып* зачаро́ванный до́брым сло́вом **2.** *см.* **сихерләнү**

тылсымл|ау *перех.* **1.** очарова́ть/очаро́вывать; зачаро́вывать/зачарова́ть; *сүзе белән ~ый* он (она́) чару́ет сло́вом **2.** *см.* **сихерләү**; *кемдер ~ап киткән* кто-то заколдова́л

тылсымлы *прил.* **1.** волше́бный, колдовско́й; *~ көч* колдовска́я си́ла; *~ әйберләр* волше́бные предме́ты (*в сказке*) **2.** обольсти́тельный, чару́ющий; *~ караш* чару́ющий взгляд **3.** восхити́тельный; *~ таң* восхити́тельная заря́, восхити́тельный рассве́т **4.** *лит.* волше́бный; *~ әкиятләр* волше́бные ска́зки

тылсымчы *сущ.* **1.** волше́бник, маг; *~ карт* стари́к-волше́бник **2.** *перен.* ма́стер сло́жного де́ла, сверхма́стер; *полимер ~лары* мастера́ полиме́ра

тылсымчылык *сущ.* волшебство́, заня́тие волшебством; ма́гия, заня́тие ма́гией; ~ *белән шөгыльләну* заня́тие ма́гией

тылчы *сущ.* тыловик (*военнослужащий, работающий в тылу*)

тыма: тыма итү *диал.* ходи́ть по нужде́ самому́ (*о ребёнке*); ~ *итә башлады* на́чал ходи́ть по нужде́ сам

тымай: тымай итү *диал.* де́лать пе́рвые шаги́ (*о младенце*)

тымат *прил. прост.* **1.** аккура́тный; ~ *егет* аккура́тный джиги́т **2.** исполни́тельный, корре́ктный; ~ *эшче* исполни́тельный рабо́чий **3.** по́лный, полноце́нный; ~ *биш пот* по́лных пять пудо́в **4.** зако́нченный; завершённый; добро́тный; доведённый до конца́; ~ *эш бу* э́то зако́нченная, добро́тная рабо́та || *нареч.* **1.** аккура́тно, аккура́тненько; *см. тж.* **ыктымат**; ~ *киенү* аккура́тно, чи́сто одева́ться **2.** ве́жливо и с досто́инством; ~ *сөйләшә* разгова́ривает ве́жливо, но с досто́инством **3.** добро́тно, с полното́й; до конца́, до заверше́ния; добросо́вестно; ~ *эшли* он де́лает добро́тно (*без огрехов и недоделок*)

тыматлы *прил. диал.* добро́тный, зако́нченный (*о работе*); ~ *эш кыйммәтле* добро́тная рабо́та дорога́

тыматлы|к *сущ. диал.* **1.** аккура́тность; ~*гы куренеп тора* видна́ (его́, её) аккура́тность; ~*к сыйфаты* сво́йство аккура́тности **2.** завершённость; ~*к белән* с завершённостью **3.** добросо́вестность; ~*к күрсәтү* проявля́ть добросо́вестность

тымызык *прил.* ти́хий (*о погоде, водоёмах и т. п.*); ~ *иртә* ти́хое у́тро; ~ *күл* ти́хое о́зеро; ~ *һава* ти́хий во́здух; ти́хая пого́да || *нареч.* ти́хо, о́чень ме́дленно (*о ветре, о течении и т. п.*); ~ *искән җил* о́чень ти́хо ве́ющий ве́тер; ~ *аккан елга* ме́дленно теку́щая река́

тымызыклан|у *неперех.* **1.** утиха́ть/ути́хнуть; затиха́ть/зати́хнуть, станови́ться/стать о́чень ти́хим **2.** *см.* **талгынлану**

тымызыклы|к *сущ.* **1.** тишина́, тишь (*в природе*); *һаваның ~гы* утихоми́ренность приро́ды **2.** *см.* **талгынлык**

тымык *прил.* о́блачно-безве́тренный; ~ *көн* о́блачно-безве́тренный день

тын I *сущ.* **1.** дыха́ние, вздох; вдох || дыха́тельный; *тынны буа торган* затрудня́ющий дыха́ние; *тын көпшәсе* дыха́тельная тру́бка **2.** *прост.* во́здух; *камераның тыны чыккан* во́здух из ка́меры (*велосипедной*) весь вы́шел **3.** пар вы́хода, выдыха́ния (*в прохладно-влажную погоду*); *тын беленә башлаган* стал заме́тен пар дыха́ния (*при низкой температуре*) **4.** *перен.* воздде́йствие, влия́ние; дух; *революциянең кайнар тыны* горя́чее дыха́ние революции **5.** *диал.* душа́, дух; *тыны барның өне бар* (*посл.*) име́ющий ду́шу име́ет и го́лос (*т.е. может и протестовать, и голосить*) □ **тын алу** **1.** вдыха́ть/вдохну́ть **2.** дыша́ть; *имезүчеләр һава белән тын ала* млекопита́ющие ды́шат во́здухом; *тын алып булмый* невозмо́жно дыша́ть; дыша́ть не́чем **3.** отдыша́ться, передохну́ть; **тын алыш** **1.** вдох; вдыха́ние **2.** дыха́ние **3.** *см.* **тыналыш 2**; **тын бету** задыха́ться/задохну́ться (*от быстрого бега у нетренированного человека*); *тын бетте — көн бетте* (*посл.*) раз начала́сь ады́шка — и дням (*т. е. жизни*) коне́ц; **тын куырылдыру (куыру)** **1.** обжига́ть рот (*о горячей пище*) **2.** спира́ть дыха́ние (*при быстром беге*) **3.** *перен.* си́льно торопи́ть *кого*; *см. тж.* **тын да алдырмау**; **тын кысылу** спира́ться (*о дыхании*); ады́шка; **тын өрү** *см.* **тын(ны) чыгару**; **тын тарту** *диал.* **1.** *см.* **тын алу 2.** облегчённо вздохну́ть; **тын тарыгу** спира́ться (*о дыхании*); **тын юлы (юллары)** дыха́тельные пути́; **тынны тарыктыру** спира́ться (*о дыхании*); **тын(ны) чыгару** выдыха́ть || вы́дох; ◊ **тын алган тавыш та чыкмау (ишетелмәү, сизелмәү)** быть соверше́нно беззву́чным (*букв.* не слы́шать и зву́ка дыха́ния); **тын алганны (алганын, алганыңны и т. п.) да сизү (белү)** знать всю подноготну́ю (*букв.* знать и то, как ды́шится кому́; кто, как, чем ды́шит и т. п.); **тын алгысыз** **1.** не продохну́ть **2.** непродыха́емый; *тын алгысыз эссе* непродыха́емая жара́; **тын (да) алдырмау, тын (да) алырга (да) бирмәү** не дава́ть переды́шки; **тын (да) алдырмыйча** не дава́я передохну́ть; без переды́шки; **тын алмастан, тын да алмыйча (чыгармыйча, тартмыйча), тын алырга (алуны) да онытып** **1.** затаи́в дыха́ние; *тын да алмыйча тыңлап тору* слу́шать, затаи́в дыха́ние **2.** без переды́шки, без ро́здыха, без о́тдыха; **тын кабу (кысу, тоту)** затрудня́ть/затрудни́ть дыха́ние; **тын кысу** сде́рживать дыха́ние (*от страха и т. п.*); ~*ын кысып* е́ле дыша́; боя́сь и дыша́ть; **тын(ны) (тынын) да чыгармау** **1.** быть соверше́нно безмо́лвным (*букв.* даже не выдыха́ть) **2.** быть в стра́хе; пря́таться; не дава́ть о себе́ изве́стий; **тынны (тынын, тыныңны) арттан (эчтән) алу** *груб.-прост.* дыша́ть че́рез зад, отма́лчиваться от стра́ха, выжида́ть молчко́м, ждать забве́ния просту́пка; **тыны да чыкмый** **1.** отма́лчивается; не даёт знать о себе́ **2.** о нём ни слу́ху ни ду́ху; **тының (да) чыкмасын, тыныңны да чыгарма (чыгарасы булма)** **1.** замолчи́ (же); не смей пода́ть го́лос; знай себе́ молчи́ **2.** (*об этом*) молчо́к!

тын II *сущ.* **1.** *прост.* коро́ткий промежу́ток вре́мени; *бер тын эшләп алу* немно́го пораба́тать **2.** *диал. см.* **тына, тынап**

тын III *прил.* **1.** *в разн. знач.* ти́хий; *тын һава* ти́хая пого́да (*букв.* во́здух); *тын елга* ти́хая река́; *тын урын* ти́хое ме́сто; *тын почмак* ти́хий у́гол (уголо́к); *тын төн* ти́хая ночь; *урман тын* лес тих, в лесу́ ти́хо **2.** ти́хий, молчали́вый; *бик тын кеше* о́чень ти́хий челове́к; *ул гел тын* он всегда́ молчали́в || *нареч.* ти́хо; молчали́во; *урамда тын* на у́лице ти́хо; *шул кадәр тын ки ...* так ти́хо, что ... □ **тын булу (калу)** **1.** зати́хнуть, сти́хнуть, ути́хнуть; *бөтен дөнья тын калды* весь мир (всё окружа́ющее) зати́х **2.** *см.* **шым булу**; **тын гына** тихо́нько; соблюда́я тишину́; *тын гына тору* ти́хо стоя́ть **3.** о́чень споко́йно; *тын гына сөйли* говори́т о́чень споко́йно (*тихим голосом*) || *сущ. редко* **1.** *см.* **тынлык**; *урман тынында* в тиши́ ле́са **2.** поко́й, успоко́ение; *тынымны, көнемне бозма* (*погов.*) не наруша́й мой поко́й (*говорится нежелательному жениху*)

тын IV *диал. прил.* перело́жный; *тын җир* перело́жная земля́ || *сущ.* перело́г; *тынга калдыру* оста́вить на (как) перело́г

тына *союзн. сл. диал.* раз; *ике ~ суга бардым* два ра́за сходи́л (я) за водо́й

тыналыш *сущ.* **1.** вдох; *бер ~ белән* на одно́м дыха́нии; одни́м вдо́хом **2.** о́тдых; переды́шка, коро́ткий переры́в; *бер ~тан соң* по́сле коро́ткого переры́ва

тын|а́у *неперех. диал.* **1.** дыша́ть, дохну́ть; *борыны белән ~ый* ды́шит но́сом; *бер ~а әле* отдохни́-ка разо́к **2.** передохну́ть (немно́го); *~ап алыйк* немно́го передохнём

тына|ю *неперех. редко* **1.** утиха́ть/ути́хнуть, стиха́ть/сти́хнуть; затиха́ть/зати́хнуть; *бераз ~йды* немно́го сти́хло **2.** *диал.* передохну́ть

тын-баш: тыны-башы бетү 1. лиши́ться дыха́ния (*от волнения*) 2. оста́ться бездыха́нным

тын-бу: тыны-буы чыкмый отма́лчиваться; скрыва́ться и не подава́ть при́знаков о своём существова́нии

тынгы *сущ.* 1. поко́й, споко́йное состоя́ние; *~м бетте* ко́нчился мой поко́й; *~сын җуйды* (он) потеря́л поко́й; *~ юк* нет поко́я 2. споко́йная жизнь; споко́йный уголо́к; *~ эзләү* иска́ть споко́йный уголо́к, споко́йную жизнь (*в старости*) □ **~ белмәү** быть беспоко́йным; не знать поко́я; **~ бирмәү** не дава́ть поко́я; беспоко́ить

тынгылы|к *сущ.* 1. (душе́вный) поко́й, успокое́ние; *уз ~гыңны гына уйлау* ду́мать то́лько о своём душе́вном поко́е; *~гы юк* нет у него́ споко́йствия 2. *см.* **тынгы**

тынгылыклы *прил. редко* 1. споко́йный, бесхло́потный (*о человеке, о работе и т. п.*) 2. споко́йный, не пла́чущий (*о младенце*)

тынгылыксыз *прил.* 1. беспоко́йный; плакси́вый, беспоко́ящий (*о младенце*); *бигрәк ~ булды* оказа́лся о́чень плакси́вым 2. *см.* **тынгысыз**; *~ кеше* беспоко́йный челове́к

тынгысыз *прил.* 1. 1) беспоко́йный, непосе́дливый, неугомо́нный (*о человеке*) 2) егозли́вый, подви́жный, прока́зливый (*о детях*) 2. беспоко́йный, бу́рный, бурли́вый, напо́лненный собы́тиями; *~ көн* беспоко́йный день; *~ заман* бу́рное вре́мя || *нареч.* беспоко́йно, трево́жно, бу́рно, бурли́во; *төн ~ үтте* ночь прошла́ беспоко́йно

тынгысызлан|у *возвр. от* **тынгысызлау** 1. беспоко́иться; *нигә юкка ~асың?* заче́м зря беспоко́ишься? 2. станови́ться/стать беспоко́йным; *бөтенләй ~у* станови́ться совсе́м беспоко́йным 3. капри́зничать, не спать (*о младенце*); *~а да тора* то и де́ло капри́зничает

тынгысызла|у *перех.* беспоко́ить, причиня́ть/причини́ть беспоко́йство; не дава́ть поко́я; *~ма әле* не причиня́й, пожа́луйста, беспоко́йства

тынгысызлы|к *сущ.* 1. беспоко́йство, отсу́тствие поко́я; суета́; су́толока 2. беспоко́йный нрав; *~ картайта диләр* беспоко́йный нрав, говоря́т, ста́рит (*человека*)

тындыр|у *перех. разг.* 1. утихоми́ривать/утихоми́рить, сде́лать ти́хим и́ли беззву́чным 2. оставля́ть/оста́вить в поко́е *кого* 3. *в отриц. ф.* **тындырмау** 1) не дава́ть поко́я, надоеда́ть, доним а́ть/доня́ть || надоеда́ние; *эссе сөяк сындырмый, суык җанны ~мый* (*посл.*) жар косте́й не ло́мит, а вот хо́лод ду́шу доним а́ет 2) тормоши́ть, то и де́ло брать в ру́ки; *ник ~мыйсың шул пәкене?* что ты всё во́зишься с э́тим но́жиком?

тын-көн *сущ. см.* **тын-сөр**

тынлан|у *неперех.* 1. *редко* переста́ть/переста́ть (*о звуках, голосах*); умолка́ть/умо́лкнуть; *кичен шәһәр аз-азлап ~а* ве́чером го́род понемно́гу умолка́ет 2. *см.* **тымызыклану**

тынлы *прил. спец.* духово́й; *~ оркестр* духово́й орке́стр; *~ музыка әсбаплары* духовы́е музыка́льные инструме́нты

тынлык *сущ.* 1. тишина́, тишь; поко́й; *~ урнаштыру* водвори́ть тишину́; *~ны бозу* наруша́ть/нару́шить тишину́; *тирән ~* глубо́кая тишина́; *~ авазы* го́лос тишины́ 2. переды́шка; *фронтта ~ булып торды* на фро́нте была́ переды́шка

тынмас *прил.* 1. неугомо́нный, неутоми́мый; беспоко́йный; *~ җырчы — сабан тургайлары* неугомо́нные певцы́ — весе́нние жа́воронки; *~ йөрәк, талмас кул* неутоми́мое се́рдце, неуста́нная рука́ 2. непреста́нный, беспреста́нный; *бу ни ~ гауга?* что э́то за беспреста́нная ссо́ра?

тын-өн *прост. о создании определённой атмосферы кем-л.; тыны-өне белән куркыту* пуга́ть люде́й (*уже*) свои́м прису́тствием; *тыны-өне дә беленми* его́ и не заме́тишь (*настолько тих и скромен*)

тын-сөр *сущ. миф.* душа́, дух (*состоящий из* тын — *физиологической жизни и* сөр — *духовности, духовной субстанции*) □ **тыны-сөре бетеп** 1. изо все́й мо́чи; слома́ го́лову (*о беге в спешке*); *тыны-сөре бетеп килеп җитте* прибежа́л, вы́сунув язы́к (*от изнеможения*) 2. от всей души́; *тыны-сөре бетеп сөенә* ра́дуется от всей души́

тынсу *прил.* прити́хший; гнету́ще-ти́хий; *~ һава* гнету́ще-ти́хий во́здух; *~ манзара* прити́хший вид (пейза́ж)

тынсулан|у *неперех.* притиха́ть/прити́хнуть (*только о явлениях природы*); *көн ~ды* прити́хло (*о погоде*)

тынсулык *сущ.* гнету́щая тишина́

тынсыз *прил.* 1. *редко* бездыха́нный; *~ гәүдәләр* бездыха́нные тела́ 2. без во́здуха, не нака́чанный; *~ камера* ка́мера (*колеса*) без во́здуха || *нареч.* 1. 1) без дыха́ния; *~ яшәп булмый* без дыха́ния нельзя́ жить 2) *разг.* без во́здуха 2. бездыха́нно; *~ егылу* упа́сть бездыха́нно 3. совсе́м ти́хо; так, что неслы́шно и дыха́ния; *~ йоклау* спать совсе́м ти́хо □ **~ булу (калу)** 1. теря́ть/потеря́ть дар ре́чи; *см. тж.* **өнсез булу (калу)**; *шуны ишетеп, ~ булдым* услы́шав э́то, я потеря́л дар ре́чи 2. умира́ть/умере́ть; **~ итү (ясау)** 1. отнима́ть/отня́ть дар ре́чи 2. уби́ть, умертви́ть 3. согну́ть в бара́ний рог, жесто́ко подавля́ть/подави́ть

тынсыз-өнсез *прил.* (соверше́нно) безмо́лвный; лишённый (*как бы*) да́ра ре́чи; *тынсыз-өнсез таулар* безмо́лвные го́ры □ **тынсыз-өнсез булу (калу)** *см.* **тынсыз булу (калу); өнсез булу (калу); тынсыз-өнсез итү (ясау)** *см.* **тынсыз итү (ясау); өнсез итү (ясау)**

тын|у *неперех.* 1. 1) замолка́ть/замо́лкнуть; *сөйләде, сөйләде дә ~ды* говори́л, говори́л и замо́лк 2) утиха́ть, затиха́ть, стиха́ть; *урамда тавыш ~ды* шум на у́лице сти́х (ути́х) 2. *в разн. знач.* переста́ть/переста́ть; прекраща́ться/прекрати́ться || прекраще́ние; *буран ~ды* бура́н (мете́ль) прекрати́лся; *кичке ыгы-зыгы ~гач* по́сле того́, как прекрати́тся вече́рняя сумато́ха; *сугыш ~а шикелле* ка́жется, война́ прекраща́ется (би́тва стиха́ет); *халык арасында имеш-мимеш тә ~ды* прекрати́лась и молва́ в наро́де; *кайгы-сагышым ~ган кебек иде* каза́лось, прекрати́лись мои́ го́рестные пережива́ния 3. *прост. диал.* передохну́ть; останови́ться || останóвка, переры́в; *әйдә, беразга ~ып алыйк* дава́й останóвимся ненадóлго; *ул өченче катка ~мыйча күтәрелде* он без переды́шки подня́лся на тре́тий эта́ж 4. успока́иваться/успокóиться || успокое́ние; *эшен бетермичә җаны ~мый* душа́ его́ не успокóится, пока́ он не заверши́т рабóту; *юлярлянде, юлярлянде дә ~ды* дури́л, дури́л и успокóился 5. освобожда́ться/освободи́ться (*от того, что беспокоит, не даёт покоя и т. п.*); *гаугадан ~дым* освободи́лся (наконе́ц) от шу́ма (гва́лта); *сүзеннән ~дык* изба́вились от его́ упрёков; *авыл бандитлардан ~ды* а́ул (дере́вня, село́) освободи́лся от банди́тов 6. *в знач. нареч.* **тынмастан, тынмыйча** не переста́я, беспреста́нно; без у́стали, без о́тдыха; *~мый эшләү* рабóтать без у́стали

тынусыз *нареч.* без о́тдыха, без останóвки; без переры́ва; *~ атлау* шага́ть без останóвки || *прил.* 1. неумóлчный; *~ тавыш* неумóлчный шум 2. беспреры́вный, безостанóвочный; *~ хәрәкәт* беспреры́вное движе́ние 3. *см.* **тынгысыз**

тынч|у *неперех.* **1.** засте́иваться/застоя́ться || засте́ивание (*воды*); *җилсез һава да ~ый* без ве́тра и во́здух засте́ивается **2.** станови́ться/стать спёртым, за́тхлым, ду́шным; *бүлмәбез ~ыды* в ко́мнате на́шей сте́ало ду́шно **3.** *диал.* ту́хнуть (*о яйцах*) □ **~ыган һава** засто́йный, спёртый во́здух || *прил.* **1.** за́тхлый, спёртый; ду́шный (*о воздухе в помещении*); *~у бүлмә* ду́шная ко́мната **2.** застоя́вшийся, засто́йный (*о воде*); *~ күл* застоя́вшееся о́зеро **3.** *перен.* засто́йный, ко́сный, косне́ющий; *~у тормыш* засто́йная жизнь

тынчулан|у *неперех. см.* **тынчу** 1, 2; *~ган баз* за́тхлый по́греб

тынчулык *сущ.* **1.** за́тхлость, спёртость (*воздуха, помещения*); *коточкыч ~* ужа́сная спёртость **2.** засто́йность (*воды*)

тынчык *прил. диал. см.* **тынчу** 2

тынчыту *перех.* де́лать/сде́лать ду́шным; допуска́ть/допусти́ть за́тхлость (*в помещении, подвале и т. п.*); *тәмәке тартып ~* задыми́ть дом куре́нием табака́

тыны|гу **1.** *неперех. диал.* (понемно́гу) утиха́ть/ути́хнуть, стиха́ть/сти́хнуть (*о ветре*); станови́ться/стать ти́хим; *көн ~кты* пого́да сти́хла **2.** отдыха́ть/отдохну́ть, передохну́ть; *йөреп чәрчәгән торып ~га, торып чәрчәгән утырып ~га, утырып чәрчәгән ничек ~гыр?* (*посл.*) уста́вший от ходьбы́ передохнёт сто́я, уста́вший стоя́ть передохнёт си́дя, уста́вший си́дя как передохнёт?

тыны|к *сущ. диал.* дыха́ние; *~гы авыр* дыха́ние его́ тру́дное

тыныч *прил.* **1.** 1) споко́йный, уравнове́шенный, ро́вный (*о характере человека*); *~ кеше* споко́йный челове́к; *~ холыклы* со споко́йным нра́вом 2) споко́йный, выража́ющий споко́йствие; *~ тавыш* споко́йный го́лос; *~ йөз* споко́йное лицо́; *~ адымнар* споко́йные шаги́; *~ тон* споко́йный тон **2.** споко́йный, ми́рный; *~ картлык* споко́йная ста́рость **3.** *см.* **тымызык**; *~ көн* споко́йный, ти́хий день; *~ төн* ти́хая ночь || *нареч.* **1.** споко́йно, уравнове́шенно; *~ яшәү* споко́йно жить; *~ сөйли* говори́т споко́йно; *бу турыда ничек ~ яза аласың?* как ты об э́том мо́жешь писа́ть споко́йно? **2.** споко́йно, ми́рно; ро́вно; *~ йоклау* споко́йно спать □ **~ бул(ыгыз)** будь(те) споко́йны, не беспоко́йтесь; *~ йокы* споко́йного сна (*пожелание на ночь*); **~ карау** быть (остава́ться) равноду́шным || равноду́шие; *~ карый алмыйм* не могу́ остава́ться равноду́шным; **~ кую (калдыру, яткыру, яшәтү)** дава́ть/дать споко́йно жить; дава́ть/дать переды́шку; **~ күңел белән** со споко́йной со́вестью; **~ мөгамәлә** хоро́шее (дру́жественное) обраще́ние *с кем-л.*; **~ ният** ми́рное наме́рение; **~ шартлар** ми́рные усло́вия; **~ шартларда** в усло́виях ми́ра (споко́йствия); ми́рно, споко́йно ◊ **~ аяк белән** с до́брым, с до́брыми вести́ями; *~ аяк белән кайту* верну́ться с до́брыми вести́ями || *сущ. диал.* споко́йствие; мир, ми́рное вре́мя; *без ~та аттан артык эшлибез* в ми́рное вре́мя мы тру́димся бо́льше ло́шади

тынычаю *неперех. прост. см.* **тынычлану**

тынычлагыч *сущ. см.* **тынычландыргыч** II; *~ ритуаллар* успока́ивающие ритуа́лы

тынычландыргыч *сущ.* **1.** 1) успока́ивающее сна́добье, транквилиза́тор 2) успокои́тель; *что-л.* успока́ивающее **2.** де́мпфер; устро́йство для устране́ния вибра́ции (*в приборах*) || *прил.* успока́ивающий; *~ препарат* успока́ивающий препара́т

тынычландырылу *страд. от* **тынычландыру** быть успоко́енным

тынычландыру *перех.* **1.** успока́ивать/успоко́ить || успока́ивание, успоко́ение *кого-л.; йомшак сүзләр белән ~* успока́ивать до́брым сло́вом **2.** замири́ть, смиря́ть/смири́ть; *халыкны ~* смири́ть наро́д **3.** унима́ть/уня́ть; *ярсыган атларны ~* унима́ть бу́йных (заупря́мившихся) лошаде́й

тынычлан|у *неперех.* **1.** 1) успока́иваться/успоко́иться || успоко́ение; *күңел (җан) ~уы* успоко́ение души́; *халык ~ды* наро́д успоко́ился 2) затиха́ть, стиха́ть (*о движении, шуме и т. п.*); *зал ~а башлады* зал стал затиха́ть **2.** *перен.* довóльствоваться, удовлетворя́ться/удовлетвори́ться; *бары белән ~у* удовлетвори́ться тем, что есть **3.** прекраща́ться/прекрати́ться || прекраще́ние (*бури, дождя и т. п. природных явлений*); *давыл ~ды* бу́ря прекрати́лась

тынычланусыз *нареч.* не успоко́ившись; пока́ не успоко́ится (устано́вится); *көн ~ юлга чыкма* не отправля́йся в доро́гу, пока́ пого́да не устано́вится

тынычлап *нареч.* споко́йненько, успоко́ившись; в поко́е; *чәй эчик әле ~* дава́йте споко́йненько попьём чайку́

тынычлат|у *перех.* **1.** (*решительно*) успока́ивать/успоко́ить || успоко́ение *кого; баланы ~* (бы́стренько) успоко́й ребёнка *чем-л. (безотказно действующим средством)* **2.** *перен.* подавля́ть/подави́ть || подавле́ние (*противника*); усмиря́ть/усмири́ть || усмире́ние; *милләтне ~у* усмиря́ть на́цию

тынычла|у **1.** *перех. редко см.* **тынычлату, тынычландыру** **2.** *неперех.* (*наконец*) успока́иваться/успоко́иться || успоко́ение (*от длительных беспокойств*); спаса́ться/спасти́сь || спасе́ние (себя) от мыта́рств, забо́т, посяга́тельств и т. п.; *монда килеп ~дык* здесь то́лько и успоко́ились

тынычлы|к *сущ.* **1.** 1) споко́йствие; *холыкның ~гы* споко́йствие его́ хара́ктера 2) *см.* **тынлык**; *табигатьтә ~ урнашты* в приро́де установи́лась тишина́ **2.** *в разн. знач.* поко́й; *~кта яшәү* жить в поко́е; *~к хәле* состоя́ние поко́я (*жидкости*); *~гын җую (югалту)* теря́ть/потеря́ть поко́й, разволнова́ться; *~к бирмәү* не дава́ть, не дать поко́я; *чын кайгы ~к бирми* настоя́щее го́ре не даёт поко́я; *~к тапмау (таба алмау)* не находи́ть поко́я, быть не в состоя́нии успоко́иться **3.** мир; *~к өчен көрәш* борьба́ за мир; *~к байрагы* зна́мя ми́ра

тынычлыклы *прил.* миролюби́вый; *~ илләр* миролюби́вые стра́ны; *~ акция* миролюби́вая а́кция

тынычлыксыз *прил.* неми́рный; *~ ният* неми́рные наме́рения

тынычсыз *нареч.* **1.** беспоко́йно, обеспоко́енно; *үзен ~ сизү* чу́вствовать себя́ беспоко́йно; *~ йоклау* беспоко́йно спать **2.** неспоко́йно; *ул җирдә ~* в том ме́сте неспоко́йно || *прил.* **1.** беспоко́йный; обеспоко́енный; *мин ~мын* я беспоко́ен; *~ йөрәк* беспоко́йное се́рдце; *~ караш* беспоко́йный взгляд; *~ уйлар* беспоко́йные мы́сли **2.** 1) неспоко́йный; трево́жный; *~ тормыш* неспоко́йная (трево́жная) жизнь; *~ төн* неспоко́йная ночь 2) бу́рный; *~ диңгез* бу́рное мо́ре **3.** мяте́жный; *~ күңелләр* мяте́жные ду́ши; *~ полк* мяте́жный полк □ **~ җан** беспоко́йная душа́ (*о человеке с беспокойно-деятельным характером*)

тынычсызлан|у *возвр. от* **тынычсызлау** **1.** 1) беспоко́иться, забеспоко́иться; обеспоко́иться; *халык ~а* наро́д беспоко́ится; *күршем ~ды* сосе́д мой забеспоко́ился 2) трево́житься; *күңел ~а* душа́ трево́жится **2.** станови́ться/стать беспоко́йным; *бабай ~ды бу арада* за после́днее вре́мя дед стал беспоко́йным

тынычсызланучан *прил.* беспоко́йный (хара́ктером); трево́жный; трево́жно-мни́тельный

тынычсызланучанлык *сущ.* беспоко́йство; беспоко́йный хара́ктер

тынычсызл|а́у *перех.* **1.** причиня́ть/причини́ть беспоко́йство; беспоко́ить/побеспоко́ить; раздража́ть || раздраже́ние *кого; бу тавыш мине ~ый* э́тот звук меня́ раздража́ет **2.** трево́жить □ **~ап тору** трево́жить (*постоянно*)

тынычсызлы|к *сущ.* **1.** беспоко́йство; обеспоко́енность; *кыяфәтендә ~к сизелә* в его́ о́блике чу́вствуется беспоко́йство **2.** заинтрига́нность; *~к белән ни буласын көтү* заинтрига́нно жда́ть разви́тия собы́тий **3.** шум, волне́ние; бурле́ние (*в природе*); *диңгезнең ~гы* волне́ние мо́ря **4.** волне́ние, мятёж; *илдәге ~к* волне́ния в стране́

тыныш *сущ.* **1.** *редко* дыха́ние; *иркен ~* свобо́дное дыха́ние **2.** переры́в; *шактый ~тан соң* по́сле значи́тельного переры́ва; *~ ясау* де́лать переры́в, прерыва́ться **3.** *лит.* 1) па́уза, цезу́ра; *~лар ясап укый* чита́ет с па́узами 2) зна́ки препина́ния **4.** *спец.* 1) предложе́ние в Кора́не, *см.* **аять**; *бер ~та ятламау* не вы́учить наизу́сть ни одного́ предложе́ния из Кора́на 2) знак, обознача́ющий коне́ц предложе́ния в Кора́не; рису́нок пятилепестко́вого цветка́ (*вместо точки*); *~тан ~ка чаклы* от то́чки до то́чки (*в Коране*) □ **~ билгесе** знак препина́ния; **~ галәмәте (тамгасы)** **1.** *см.* **тыныш билгесе** **2.** сакн (*знак отсутствия гласного в кораническом письме*)

тыны́шмаучан *прил.* неужи́вчивый; *~ холыклы* с неужи́вчивым хара́ктером

тыны́шмаучанлы|к *сущ.* неужи́вчивость; *~гы аркасында* из-за свое́й неужи́вчивости

тыныш|у *неперех.* **1.** 1) мири́ться/помири́ться; *яулашу да ~у* воева́ть и мири́ться 2) жить в ми́ре и согла́сии (*с соседями*) **2.** *в отриц. ф.* **тынышмау** не ла́дить, (постоя́нно) ссо́риться, вздо́рить (*между собой*); *бер дә ~мадылар инде* ника́к они́ не могли́ ужи́ться

тын I *сущ.* **1.** слух, спосо́бность слу́шать и пра́вильно воспринима́ть; *тыңы бар* у него́ есть слух **2.** подслу́шивание, слу́шание; *тыңы белән* подслу́шиванием □ **тыңга йөрү (чыгу, бару)** *этногр.* ходи́ть, идти́ на подслу́шивание разгово́ров в дома́х (*в целях гадания в новогоднюю ночь и т. п.*)

тын II *подр. звукам удара металлом по металлу или по дереву* □ **тын-ң итү** зво́нко звене́ть (*о длинном металлическом предмете*) при уда́ре; *см.* **зың-ң итү**

тын III *частица усил.* (*к некоторым прилагательным и наречиям*) *разг.* соверше́нно, совсе́м, о́чень; *тын тулы* соверше́нно по́лный; *тын тыгыз* соверше́нно пло́тный, совсе́м пло́тный

тыңгычла́у *перех. диал. см.* **дыңгычлау**

тыңка́у *прил. диал. см.* **тыңкыш**

тыңкыш *прил.* **1.** на́сморочный; *~ борын* на́сморочный нос **2.** гундо́сый, гнуса́вый; *~ тавыш* гнуса́вый го́лос || *нареч.* гнуса́во; *тавышы ~ чыга* го́лос (его́) слы́шится гнуса́во

тыңкышлан|у *неперех.* **1.** гнуса́вить **2.** станови́ться/стать гундо́сым (гнуса́вым); *тавышы ~ган* го́лос его́ стал гнуса́вым

тыңкышлык *сущ.* на́сморочность (*носа*); гнуса́вость (*голоса*)

тыңлагыч *сущ. спец.* **1.** нау́шник; аппара́т для подслу́шивания (*в армии*) **2.** слуха́ч (*радиосвязист, принимающий сигналы*)

тыңламас *прил.* непослу́шный; упря́мый; *~ бала* непослу́шный ребёнок; *~ үтерсәң дә аңламас* (*погов.*) упря́мый умрёт — никто́ его́ не уймёт

тыңлан|у **1.** *страд. от* **тыңлау**; *доклад диккать белән ~ды* докла́д был прослу́шан с внима́нием (внима́тельно) **2.** *возвр. редко* прослу́шиваться; *~ып утыру* сиде́ть, прослу́шиваясь *к чему-л.*

тыңлаттыр|у *понуд. от* **тыңлату**

тыңлат|у **1.** *понуд. от* **тыңлау**; *йөрәген ~ты* дал (разреши́л) прослу́шать се́рдце **2.** заста́вить слу́шаться; *мин аны ~ырмын* я заста́влю его́ слу́шаться **3.** *этногр.* **(сабак) ~у** говори́ть, расска́зывать уро́к (уче́бное зада́ние) учи́телю; чита́ть, прочита́ть рефера́т на за́данную те́му

тыңла́|у *перех.* **1.** 1) слу́шать/послу́шать || слу́шание; *музыка ~у* слу́шать му́зыку; *әкият ~у* слу́шать ска́зку 2) *мед.* проверя́ть слух, прослу́шивать; выслу́шивать/вы́слушать || выслу́шивание, прослу́шивание; *авыруның кукрәген ~у* прослу́шать грудь больно́го 3) *спец.* слу́шать, заслу́шивать/заслу́шать; прослу́шивать/прослу́шать || заслу́шивание, прослу́шивание (*дела, доклада, отчёта, информации и т. п.*) **2.** прослу́шивать/прослу́шать, слу́шать (*уроки, курс лекций*); *сабагын ~у* прослу́шать уро́к *кого* **3.** 1) слу́шаться, повинова́ться || послуша́ние; *ни кушса, шуны ~у* что бы он ни повеле́л, слу́шайся 2) *перен.* слу́шаться, послу́шно дви́гаться (*о машинах, о частях тела*); *аяклары ~мый башлады* но́ги его́ переста́ли слу́шаться 3) внять (*чему-л.*), приня́ть *что-л.* во внима́ние; прислу́шиваться/прислу́шаться; *сүзен ~п* вняв его́ про́сьбе; *врачлар киңәшен ~п* приня́в сове́т враче́й 4) обраща́ть внима́ние (*на слова кого-л.*); *~магыз сез аны* вы не обраща́йте внима́ние на его́ слова́ (не слу́шайте вы его́) □ **~п тору** **1.** прислу́шиваться **2.** подслу́шивать/подслу́шать; **~п тын калу** заслу́шиваться/заслу́шаться

тыңлаулы *прил. прост.* послу́шный, дисциплини́рованный; *~ малай* послу́шный ма́льчик; *~га бер әйт* (*погов.*) послу́шному скажи́ то́лько раз

тыңлаусыз *прил.* непослу́шный, недисциплини́рованный || не́слух *прост.; аягың сызлаусыз булсын, балаларың ~ булсын* (*шутливое пожелание*) пусть твои́ ру́ки-но́ги бу́дут здоро́выми, а де́ти — непослу́шными; *~га төмән әйт* (*погов.*) непослу́шному говори́ хоть де́сять ты́сяч раз

тыңлаусызлан|у *неперех.* станови́ться/стать непослу́шным (недисциплини́рованным); *~а башлады* стано́вится непослу́шным

тыңлаусызлы|к *сущ.* непослу́шность, недисциплини́рованность, непослуша́ние; *~гы аркасында* из-за своего́ непослуша́ния

тыңлаучан *прил.* послу́шный, дисциплини́рованный; *~ кыз* послу́шная де́вочка; *~ бул* будь послу́шным □ **~гына** послу́шно; дово́льно послу́шный

тыңлаучанлы|к *сущ.* послу́шность; послуша́ние; *~гы белән* свои́м послуша́нием

тыңлаучы *сущ.* слу́шатель; -слу́шатель; *курсларны ~лар* слу́шатели ку́рсов; *радиотыңлаучы* (пи́шется та́кже разде́льно: *радио тыңлаучы*) радиослу́шатель

тыңлыклы *прил. диал.* послу́шный; *~ кеше* послу́шный челове́к

тыңчан *прил. диал.* **1.** *см.* **тыңлаучан** **2.** скло́нный подслу́шивать, подслу́шивающий; *~ кеше* челове́к, скло́нный подслу́шивать, внима́ть чужи́м разгово́рам

тыңчы *сущ.* **1.** подслу́шивающий; подслу́шиватель; *~ булып йөри* хо́дит подслу́шивает **2.** шпик, лазу́тчик

тып *подр.* **1.** *падению капли* плюх, кап **2.** *топанью ногой* топ □ **тып иттерү, тып итү 1.** плю́хнуться (*о капле*); ка́пнуть **2.** то́пнуть но́жкой (*о детях*); *тып итеп җиргә төште* со сту́ком упа́л на зе́млю; *тып итеп сикерү* пры́гнуть с лёгким сту́ком (*о ребенке, козленке и т. п.*); **тып туктау** внеза́пно останови́ться (*о лошади, повозке*)

тыпанл|а́у *неперех. разг.* шага́ть, едва́ переступа́я ногу́й (*о ребёнке*); *~ый башлаган инде* стал (сто́я) переступа́ть но́жками (*о младенце*)

тыпан-тыпан *нареч.* **1.** *см.* **тыпын-тыпын 2.** *см.* **тәпи-тәпи**; *тыпан-тыпан кайтып җитәрбез әле* ка́к-нибудь доплетёмся до́ дому

тыпранлан|у *неперех. см.* **тыпрану** 2; *бик артык ~ма* не сли́шком торопи́сь

тыпранла́у *неперех. диал.* попры́гивать от нетерпе́ния (*о детях*); ча́сто ступа́ть, переступа́ть нога́ми на ме́сте (*о лошади*)

тыпрану *неперех.* **1.** *см.* **тыпранлау 2.** торопи́ться, проявля́ть нетерпе́ние (*желая отправиться в путь*)

тыпру *межд.* **тпру** *возглас, которым останавливают лошадей*

тып-тыгыз *превосх. ст. от* **тыгыз** о́чень ту́го, туго́й; соверше́нно ту́го, туго́й; соверше́нно пло́тный

тып-тымат *превосх. ст. от* **тымат**; соверше́нно аккура́тный, аккура́тно; полне́йший, полне́йшим о́бразом; *тып-тымат биш пот* ро́вненько пять пудо́в

тып-тын *превосх. ст. от* **тын**; соверше́нно ти́хий, ти́хо; *тирә-юнь тып-тын* круго́м соверше́нно ти́хо

тып-тыныч *превосх. ст. от* **тыныч** соверше́нно споко́йный, споко́йно; *тып-тыныч утырам* сижу́ соверше́нно споко́йно

тып-тып (тып та тып) *подр.* 1) *частому падению капель и т. п. предметов* кап-кап 2) *частому ритмичному переступанию ногой; тып-тып бию (басу)* пляса́ть, ча́сто перебира́я нога́ми □ **тып-тып итү 1.** ча́сто па́дает (*о каплях и т. п.*) **2.** ча́сто ступа́ть, переступа́ть нога́ми; **тып-тып килү** ритми́чно переступа́ть нога́ми

тыпылда|у *неперех.* **1.** ка́пать/ка́пнуть; плю́хаться/плю́хнуться (*о каплях и т. п.*); *нәрсәдер ~ды* что́-то ка́пнуло; что́-то плю́хнулось; *тамчылар ~п тора* ка́пли (непрерывно) ка́пают **2.** ритми́чно то́пать (*ногами в чулках или о ребёнке, козлёнке и т. п.*)

тыпылдаш|у *совм. от* **тыпылдау** (*о многих*); *тамчылар ~ып тама* ритми́чно ка́пают ка́пли

тыпылдык *сущ.* топу́ша, топу́н (*ребёнок, который много, но не очень быстро бегает босиком*); *шап-шап шапылдык, басма өстендә ~* (*загадка о гусях*) шлёп-шлёп шлепки́; топуны́ на мо́стике || *прил.* то́пающий (*голыми ногами*)

тыпын-тыпын *нареч. разг.* не торопя́сь, вразва́лку (*о хождении ребёнка*)

тыпырдавык *сущ.* **1.** коле́но та́нца, состоя́щее из отбива́ния дро́би, чечётки; отбива́ние дро́би (*при пляске*); чечётка **2.** *см.* **тыпырдык**

тыпырдан|у *неперех.* отбива́ть дробь, топта́ться на ме́сте || дробь, отбива́ние дро́би (нога́ми); *туземсезлектән ~ып тора* отбива́ет нога́ми дробь от нетерпе́ния

тыпырдат|у *неперех.* **1.** выстýкивать каблука́ми, отбива́ть чечётку, выбива́ть дробь (*при пляске*); *~ып бию* пляса́ть с перестýком, дро́бью, чечёткой **2.** издава́ть/изда́ть перестýк копы́т; *~ып чаба* ска́чет с перестýком копы́т

тыпырд|а́у *неперех.* **1.** 1) учащённо топта́ться, переста́птываться (*на одном месте*); *аяклары ~ап тора* но́ги его́ так и хо́дят ходуно́м 2) выпля́сывать (пляса́ть), отбива́я дробь (такт) || выпля́сывание, дробь (*тж. о лошади*); *бер урында ~ый* пля́шет на ме́сте **2.** учащённо посту́кивать/постуча́ть, стуча́ть (*о чём-то сыплющемся*); *тузанлы җиргә ~ап яңгыр ява башлады* учащённо застуча́л о пы́льную зе́млю дождь **3.** стуча́ть, ча́сто-ча́сто би́ться || ча́стое бие́ние (*сердца — от радости, волнения*); *йөрәккәем ~ап тора* серде́чко моё так и стучи́т **4.** 1) переступа́ть нога́ми от нетерпе́ния 2) нетерпели́во ожида́ть (*переступая ногами*); *эшкә барырга ~ап торалар* с нетерпе́нием рвýтся на рабóту

тыпырдаш|у *совм. от* **тыпырдау** (*нетерпеливо*) стуча́ть нога́ми, отбива́ть дробь (*о многих*); *үрдәкәчләр ~алар* отбива́ют дробь ла́пками утя́та

тыпырдык *прил.* **1.** нетерпели́во пля́шущий на ме́сте (*о детях, о лошади и т. п.*) **2.** нетерпели́вый, неспоко́йный в ожида́нии (*о детях*); *шул кадәр ~* до чего́ нетерпели́в || *сущ.* пляcу́н (*о коне*)

тыпыр-тыпыр (тыпыр да тыпыр) *подр.* **1.** *стуканью, стуку, перестуку множества ног* **2.** *пляске с выбиванием дроби, выстукиванию каблуками; туктаусыз тыпыр-тыпыр* перепля́с без конца́ □ **тыпыр-тыпыр басу (бию)** пляса́ть, отбива́я дробь; отбива́ть дробь; *тыпыр-тыпыр биергә имән идәннәр кирәк* (*песня*) что́бы отбива́ть дробь, нужны́ дубóвые полы́; **тыпыр-тыпыр итү (килү)** *см.* **тыпырдату 1** || *сущ.* топ-перето́п; *биючеләрнең тыпыр-тыпырлары басылды* ути́хли наконе́ц перето́пы плясуно́в

тыпырчын|у *неперех.* **1.** нетерпели́во переступа́ть || переступа́ние нога́ми, припля́сывать на ме́сте; *атлар ~ып тора* ко́ни припля́сывают на ме́сте **2.** би́ться, трепыха́ться (*стараясь освободиться от пут, от когтей кого*); *~ма юкса* зря не трепыха́йся **3.** *диал. см.* **тиберчену**

тырай *сущ.* деревя́нный ша́рик для игры́ в тырайлы́ □ **~ тибү (уйнау) 1.** игра́ть в тырайлы́; игра́ть с деревя́нным мячо́м; *~ уйнап йөргәнче, сабагыңны кара* лу́чше де́лай дома́шние зада́ния, чем игра́ть с деревя́нным мячо́м **2.** *перен.* бить баклу́ши

тырайлы *сущ.* игра́, заключа́ющаяся в пробива́нии ного́й в определённый круг деревя́нного ша́рика тыра́й; *~ уйнау* игра́ть в тырайлы́

тыра-тырай *сущ. прост. см.* **тырайлы**

тыракай *сущ.* **1.** игра́ в кла́ссы (*заключается в перепрыгивании на одной ноге определённых линий, полос*); *~ уйнау* игра́ть в кла́ссы **2.** бег на одно́й ноге́ (*прыжками*)

тыракайлану *неперех. разг.* **1.** 1) *см.* **тыраклау** 2) бе́гать, пры́гая на одно́й ноге́, попереме́нно меня́я но́ги **2.** ходи́ть, че́рез шаг опира́ясь на па́лку

тыракайлы *сущ.* игра́-соревнова́ние в бе́ге на одно́й ноге́ (*прыжками*)

тыраклату *понуд. от* **тыраклау**; заста́вить и́ли веле́ть пры́гать, скака́ть на одно́й ноге́

тыракл|а́у *неперех. разг.* **1.** бе́гать, скака́ть || бег прыжка́ми на одно́й ноге́ и́ли обе́ими нога́ми вме́сте; *~аудан узышу* соревнова́ться в прыжка́х на одно́й ноге́ и́ли обе́ими нога́ми вме́сте **2.** ходи́ть, идти́, бе́гать/бежа́ть вприпры́жку (*неестественным образом: припадая на одну ногу*); бы́стро ковыля́ть; *кая ~ыйсың?* куда́ ска́чешь (ковыля́ешь)? куда́ заковыля́л; *~ап чаба* ска́чет вприпры́жку **3.** *перен.* суетли́во дви́гаться (*в спешке*)

тырак-тырак *нареч. диал.* на одно́й ноге́ (*о беге*); припада́я на одну́ но́гу (*о быстрой ходьбе*); *тырак-тырак чабу* нести́сь, бежа́ть, припада́я на одну́ но́гу || *сущ. диал.* игра́ в прыжки́ (*на одной ноге или обеими ногами одновременно*); *тырак-тырак уйныйкмы?* бу́дем игра́ть в кла́ссы (*прыжки на одной ноге*)

тыранҗа: тыранҗа балык *зоол.* мино́га

тырбагай *прил. диал.* чванли́вый, кичли́вый, спеси́во-гру́бый; бесцеремо́нно спеси́вый; *берсеннән-берсе ~* оди́н грубе́е друго́го

тырбагайлык *сущ.* спеси́вость; гру́бость (*в обращении*)

тырбайчык *диал. сущ.* спеси́вец; спеси́вый грубия́н; *~ка суз катма* не обраща́йся к чванли́вому грубия́ну || *прил.* чванли́вый, спеси́вый

тырбаю *неперех. см.* **тырпаю**

тыркылда́у I *неперех. разг. см.* **тыракайлап**

тыркылда|у II *неперех. см.* **дыркылдау**; *арба ~п бара* теле́га шуми́т, греми́т (*на ходу*)

тыркын *сущ. диал. см.* **тыракай** 2; *~да ярышу* соревнова́ться в бе́ге на одно́й ноге́ || *прил.* дви́гающийся бы́стро, но неуклю́же (*хромая, вприпрыжку и т. п.*); *~ кеше* бы́стрый в движе́ниях, но неуклю́жий челове́к

тыркыш *прил. диал.* 1. нечи́стый, гря́зный; *~ куллар белән* гря́зными рука́ми 2. нечистопло́тный; *~ малай* нечистопло́тный ма́льчик

тырла́у *неперех. см.* **тырылдау**

тырма *сущ.* 1. борона́ (*различных видов и конструкций*); *атлы ~* ко́нная борона́; *трактор ~сы* тра́кторная борона́; *дисклы ~* ди́сковая борона́ 2. *в косв. п.* боронова́ние; *~дан кайту* возвраща́тья с боронова́ния; *~ны бетердек* мы зако́нчили боронова́ние □ *~* **тырмалау (тырмату)** боронова́ть зе́млю под посе́вы; дискова́ть

тырмавыч *сущ.* (*грубые*) гра́бли (*различных видов и конструкций*); *кул ~ы* ручны́е гра́бли; *асылма ~* подвесны́е гра́бли; *ян ~* боковы́е гра́бли

тырмавычла́у *перех.* рабо́тать, убира́ть гра́блями || граблéние; *печәнне ~* сгреба́ть се́но гра́блями

тырмавычлы *прил.* 1. име́ющий гра́бли, с гра́блями; *~ кеше* челове́к, име́ющий гра́бли 2. снабжённый гра́блями; *~ комбайн* комба́йн, снабжённый гра́блями

тырмалан|у *страд. от* **тырмалау**; 1. боронова́ться; быть боронованным; *~ган җир* боронованная земля́ 2. сгреба́ться гра́блями (*о сене, соломе и т. п.*)

тырмалату 1. *понуд. от* **тырмалау**; веле́ть и́ли проси́ть, и́ли поручи́ть обрабо́тать зе́млю гра́блями 2. невро́льно проборонова́ть (*сучьями при трелевке деревьев*)

тырмала́|у *перех.* 1. боронова́ть/борони́ть, проборонова́ть || боронова́ние; *җирне аз-маз ~п чәчкән идем, урган идем* боронова́л я зе́млю, се́ял не́когда и жал 2. грести́, сгреба́ть/сгрести́ || сгреба́ние; граблéние; *пакусларны ~у* сгреба́ть поко́сы

тырмалашу *совм. от* **тырмалау**; помога́ть боронова́ть, ока́зывать по́мощь в боронова́нии

тырман|у *неперех.* 1. 1) цара́пать, скрести́; точи́ть ко́гти (*о кошке*); *мәче ~са, яңгырга* ко́шка цара́пается (скребётся) — к дождю́ 2) копа́ться (*о курах*); *җирдә ~у* копа́ться в земле́ 2. *см.* **тырмашу** 3. *диал. см.* **тырнану** 1; *~ып утыра* сиди́т и почёсывается

тырмату *перех.* боронова́ть || боронова́ние; *җир ~* боронова́ть зе́млю

тырма́|у *перех.* 1. *диал. см.* **тырмалау** 1—2; *тырмавыч белән ~п йөри* рабо́тает (боронуёт или сгреба́ет) гра́блями 2. цара́пать когтя́ми

тырмачла́у *перех. разг.* раздира́ть зе́млю; гру́бо, ко́е-как боронова́ть

тырмачы *сущ.* 1. боронова́льщик, борони́льщик; *~ малайлар* ма́льчики-боронова́льщики 2. *редко* тот, кто де́лает бо́роны и гра́бли; ма́стер по борона́м и гра́блям

тырмашу I *взаимно-совм. от* **тырмау** 1. помога́ть, помо́чь борони́ть 2. цара́пать друг дру́га

тырмаш|у II *неперех.* 1. кара́бкаться; цепля́ться (*ногтями, когтями*); *~ып менү* кара́бкаясь, цепля́ясь, взбира́ться 2. *разг. см.* **тырышу-тырмашу**

тырнавыч *сущ.* 1. скребо́к, когото́к (*для поскрёбывания*) 2. *диал. см.* **тырмавыч**

тырна|к *сущ.* 1. ко́готь, но́готь; *~к кисү* остriга́ть но́гти; *~к үстерү* расти́ть но́гти 2. 1) ко́готь, ко́гти; когото́к, коготки́; *~гын батырды* вонзи́л ко́гти 2) *перен.* ко́гти (*в знач.* жесто́кая власть, тирания́); *ачлык ~гында* в когтя́х го́лода 3. *перен. об острых деталях, заострённых предметах* рога́тка, рогу́лька; у́сик, шпи́лька, чека́ *и т. п.* 4. ко́шка (*устройство для лазания на столбы, на гору и т. п.*); *аягына ~к киеп* наде́в на́ ноги ко́шки 5. *лингв.* кавы́чка, кавы́чки; *~клар эчендә* в кавы́чках □ **~к гөл** *бот.* 1. ма́льва 2. *см.* **пәйгамбәр тырнагы; ~к тәпи** ла́па, ла́пка с когтя́ми, коготка́ми; *~к тәпиле хайваннар* живо́тные с когтя́ми; **~к уты** *бот.* ястреби́нка ◊ **~к астына алу** захва́тывать/захвати́ть, подчиня́ть/подчини́ть под свою́ власть; **~к (~гы** и т. п.**) астында** под (жесто́кой) вла́стью *у кого-л.*; **~к астыннан кер эзләү (табу)** разузнава́ть/разузна́ть подного́тную; разузнава́ть (знать) скры́тые грехи́, изъя́ны и т. п. *у кого-л.*; **~к басарлык урын юк** *см.* **энә төртерлек урын юк; ~к (~гын) батыру** вонза́ть ко́гти *прям. и перен.*; **~к башы (карасы, очы) кадәр (хәтле, чаклы) дә** ни мале́йшей (ни с кра́пинку; ни ка́пли; ни чу́точку); *~к очы кадәр дә гаебе юк* ни мале́йшей вины́ его́ нет; **~к очы белән дә тимәү (чиертмәү)** не тро́гать/тро́нуть и па́льцем; **~к тирләтү** си́льно пристыди́ть (*букв.* поте́ть от стыда́ до ногте́й)

тырнакла́|у *перех.* 1. *редко* схва́тывать/схвати́ть когтя́ми (*о ловчей птице*); *бөркет куянны ~ды* орёл схвати́л за́йца когтя́ми; *~п алу* кре́пко схвати́ть в ко́гти 2. *разг.* цара́пать, поцара́пать; *см. тж.* **тырнау**

тырнаклы *прил.* 1. с ногтя́ми, име́ющий но́гти; *озын ~* с дли́нными ногтя́ми; *буялган ~* с кра́шеными ногтя́ми 2. с когтя́ми; когти́стый; *см. тж.* **чәңгәлле**; *~ җәнлек* когти́стый зверь; *уткен ~ кош* пти́ца с о́стрыми когтя́ми 3. *перен. разг.* зуба́стый, де́рзкий; *~ адәм турәне кол итәр* (*посл.*) зуба́стый челове́к своего́ нача́льника сде́лает рабо́м 4. *в знач. сущ.* **тырнаклылар** *зоол.* коготко́вые (*в различных классификационных разрядах*)

тырнаклырак *прил. сравн. ст. от* **тырнаклы** (*чаще от 3 знач.*); *~ булып чыкты* оказа́лся бо́лее де́рзким

тырнак-тырнак *нареч.* в ви́де ря́да ногте́й; *тырнак-тырнак таплар* пя́тна в ви́де когте́й

тырнан|у *возвр. от* **тырнау** 1. чеса́ться, почёсываться || почёсывание (себя́); *нигә ~ып утырасың?* чего́ ты почёсываешься? 2. *см.* **тырману**; *тавыклар тирестә ~а* ку́ры копа́ются в навозе 3. *см.* **тырмашу** 2

тырнату *понуд. от* **тырнау**; веле́ть, заста́вить и́ли позво́лить цара́пать/цара́пнуть

тырн|а́у *перех.* 1. 1) цара́пать/цара́пнуть, скрести́, поскрёбывать || цара́пание, поскрёбывание; *мәче ишекне ~ады* ко́шка цара́пнула дверь; *камыл аякны ~ый* стерня́ цара́пает но́ги 2) соскреба́ть/соскрести́, скрести́, соскрёбывать; *бер фикер җанны ~ый* одна́ мысль скребёт

ду́шу **2.** чеса́ть, почёсывать/почеса́ть || чеса́ние, почёсывание (*когтями и т. п.*); *арканы ~ау* чеса́ть спи́ну; *кычытмаган җирне ~ау* чеса́ть то ме́сто, где не че́шется (*о неуместной тревоге, критике и т. п.*) **3.** *перен. прост.* писа́ть ко́е-как

тырнаш|у 1. *взаимно-совм. от* **тырнау** 1) цара́паться ме́жду собо́й, цара́пать друг дру́га 2) помога́ть скрести́, выскрёбывать *что-л.* (*о зверьках*) **2.** *возвр. от* **тырнау 3.** *см.* **тырнану**; *~ып утыра* сиди́т-почёсывается

тырпа *прил.* **1.** растопы́ренный, встопо́рщенный; торча́щий, стоя́щий торчко́м; *~ мыек* встопо́рщенные усы́; *~ ботаклар* торча́щие (во все сто́роны) ве́тви **2.** *перен.* неприве́тливый; гру́бо отвеча́ющий на любо́е сло́во; *см. тж.* **терпэ, төрпә**

тырпагай *прил.* **1.** с торча́щими, растопы́ренными (го́лыми) ветвя́ми (*о дереве*); *~ агачлар* дере́вья с торча́щими ветвя́ми **2.** *перен. разг.* занóсчивый; гру́бый, ре́зкий, неве́жливый (*о слове и ответе*); *елмаеп әйтсәң ялагай, турсаеп әйтсәң ~* (*погов.*) ска́жешь с улы́бкой — подли́за, ска́жешь су́хо (*букв.* наду́вшись) — грубия́н

тырпай *прил. диал.* **1.** эконо́мный, бережли́вый, расчётливый; *~ кеше* бережли́вый челове́к **2.** *см.* **тәрбагый**

тырпайт|у *перех.* **1.** растопы́ривать/растопы́рить, топо́рщить; выставля́ть/вы́ставить торчко́м, выпя́чивать/вы́пятить; *бармакларын ~ты* растопы́рил па́льцы; *мыегын ~ты* встопо́рщил усы́ **2.** *см.* **турсайту**

тырпайтыл|у *страд. от* **тырпайту**; выставля́ться/вы́ставиться в растопы́ренном ви́де

тырпа|ю *неперех.* **1.** 1) растопы́риваться/растопы́риться; *бармаклары ~йган* па́льцы его́ растопы́рены 2) топо́рщиться (*об усах*); *мыегы ~еп тора* усы́ его́ топо́рщатся 3) еро́шиться/взъеро́шиться (*о волосах*); *чәчләре ~йган* во́лосы его́ взъеро́шены **2.** торча́ть, стоя́ть торчко́м; *~йган ботаклар* торча́щие су́чья **3.** *перен. разг.* обижа́ться/оби́деться; ду́ться/наду́ться □ **~еп тору** быть растопы́ренным (встопо́рщенным, взъеро́шенным)

тырпылда́|у *неперех.* **1.** 1) би́ться, трепыха́ться (*короткими движениями*) || бие́ние, трепыха́ние 2) су́дорожно би́ться || бие́ние; *йөрәк ~у* су́дорожное бие́ние се́рдца **2.** *перен.* нетерпели́во дёргаться, суети́ться, де́лать беспоря́дочные движе́ния (*в ожидании чего-л.*); дрожа́ть от нетерпе́ния

тырпылдык *сущ.* беспоко́йный, суетли́вый челове́к || *прил.* беспоко́йный, нетерпели́вый в ожида́нии

тыр-пыр 1. *подр. быстрому и шумному* (*часто — вращающемуся*) *движению машин, устройств; комбайнның җилгәргече тыр-пыр әйләнә* вéялка комба́йна враща́ется бы́стро и шу́мно; *мотоциклар тыр-пыр узып киттеләр* с шу́мом и тре́ском промча́лись мотоци́клы **2.** *в. ф.* **тыр да пыр** о вспы́льчивом хара́ктере; *бер сүз әйтсәң тыр да пыр* ска́жешь сло́во — сра́зу вспы́хивает как по́рох □ **тыр-пыр итү (килү) 1.** неро́вно тарахте́ть; с (неро́вным) шу́мом враща́ться **2.** *перен.* ерепе́ниться, разбушева́ться; вспы́хивать; *тыр-пыр китерү* разгоня́ть/разогна́ть с тре́ском (*группу птиц или людей*)

тыр-р I *межд.* тпру

тыр-р II 1. *подр. дребезжанию, дрожащим звукам* дзинь; *тәрәзә пыялалары — тыр-р!* око́нные сте́кла — дзинь! **2.** *подр.* бы́строму и шу́мному однокра́тному прохожде́нию, враще́нию и т. п. □ **тыр-р итеп 1.** бы́стро и шу́мно; *тыр-р итеп үтеп китте* бы́стро и шу́мно промча́лся ми́мо **2.** *перен.* недо́лго ду́мая, сгоряча́; *тыр-р итеп карарга килү* сгоряча́ реши́ться; *тыр-р итеп уйлап алды* бы́стренько (*и легкомысленно*) заду́мал; **тыр-р итү 1.** дребезжа́ть, задрожа́ть (*о стёклах*) **2.** бы́стро и шу́мно пронести́сь (*мимо*)

тырта|ю *неперех. разг.* **1.** вдруг разоби́деться; неожи́данно наду́ться; рассерди́ться; *җиңгәбезнең гадәте шул: ~я да пылтая* (*песня*) у неве́стки на́шей привы́чка такова́: вдруг разоби́дится, заупря́мится да се́рдится **2.** пы́житься, ва́жничать

тырт-пырт I *подр. говорится* **1.** *о капризах, угловатых движениях*; *тырт-пырт эшли* рабо́тает с ре́зкими, угрова́тыми движе́ниями **2.** *о резких, неловких движениях*

тырт-пырт II *прил.* капри́зный, оби́дчивый; *тырт-пырт кеше* капри́зный челове́к □ **тырт-пырт итену (кылану, тору)** вести́ себя́ я́вно выража́я недово́льство, де́лать ре́зкие, серди́тые движе́ния; **тырт-пырт итү** закапри́зничать

тырт-тырт *подр. говорится* **1.** *о быстрых шагах, вздрагивая всем телом*; *тырт-тырт басу* бы́стро вышага́ивать (*вздрагивая телом*); части́ть в ходьбе́ **2.** *о кратком тарахтении*; *мотор тырт-тырт итте дә туктады* мото́р чуть потарахте́л и останови́лся

тыртык I *прил. диал.* о́чень коро́ткий, укоро́ченный; *см.* **көтек**

тыртык II *прил. диал.* капри́зный, скло́нный, закапри́зничать, скло́нный вдруг разоби́деться; *~ кеше* капри́зный челове́к; легкомы́сленный капри́зник

тыр-тыр 1. *подр.* **1)** *быстрой суетливой ходьбе или бегу с перерывами* 2) *тарахтению моторов* так-так **2.** *в знач. нареч.* бы́стро и трусцо́й; *тыр-тыр йөгерү* бе́гать трусцо́й □ **тыр-тыр итү (килү) 1.** тарахте́ть/затарахте́ть **2.** беспоко́йно бе́гать || беготня́ (туда́-сюда́); забе́гать, мета́ться, носи́ться взад и вперёд

тырык-тырык *подр.* **1.** *быстрому движению лошади, быстрым шагам человека* (*взрослого, тяжёлого — в отличие от* терек-терек); *ат тырык-тырык юырта* ло́шадь неторопли́во, но бы́стро бежи́т **2.** *см.* **дырык-дырык**

тырылдавык *сущ.* трещо́тка; *~лар тырылдый* трещат трещо́тки || *прил. см.* **тырылдык**

тырылдат|у 1. *понуд. от* **тырылдау** 1) тарахте́ть, затарахте́ть *чем*; *моторны ~ты* заста́вил мото́р затарахте́ть; затарахте́л мото́ром 2) строчи́ть, застрочи́ть, стреля́ть с шу́мом *из чего*; *пулемёт ~у* строчи́ть из пулемёта 3) заставля́ть/заста́вить дребезжа́ть **2.** *в знач. нареч.* **тырылдатып** бы́стро и вла́стно (увёл) **3.** *см.* **тыкырдату** □ **~ып алу** потарахте́ть, построчи́ть *чем*; заста́вить не́которое вре́мя дребезжа́ть (*оконные стёкла*); **~ып йөрү** носи́ться (*на мотоцикле*); **~ып узу** проноси́ться (*на мотоцикле и т. п.*); **~ып чыгу** бы́стро простроч и́ть на шве́йной маши́нке

тырылда|у *неперех.* **1.** тарахте́ть, шуме́ть, рокота́ть (*о моторе и т. п.*); *трактор ~п утыра* тра́ктор тарахти́т **2.** 1) строчи́ть, застрочи́ть, 2) стреля́ть/постреля́ть (*о пулемёте, автомате и т. п.*); *пулемёт ~п алды* пулемёт немно́го построчи́л **3.** *диал.* 1) дребезжа́ть (*о стёклах*) 2) строчи́ть (*о швейной машинке*) **4.** *перен.* тарато́рить, трещать, неумо́лчно говори́ть, болта́ть; *~ма сли́шком* не тарато́рь **5.** *диал.* бы́стро проноси́ться; носи́ться, забе́гать (*туда-сюда*)

тырылдык *прил.* тако́й, что тарахти́т, трещи́т, рокочет и т. п.; рокочущий; *~ пулемёт* пулемёт, кото́рый постоя́нно тарахти́т || *сущ. прост.* не́что, кото́рое тарахти́т; тарахте́лка (*о мотоцикле*); *бу ~ны төзәтергә кирәк* на́до отремонти́ровать э́ту тарахте́лку

тырым-тырагай I *нареч. разг.* **1.** в беспоря́дке; беспоря́дочно, как попа́ло; *әйберләре тырым-тырагай ята* ве́щи лежа́т беспоря́дочно **2.** в ра́зные сто́роны; врассыпну́ю; *дошманнар тырым-тырагай качтылар* враги́ разбежа́лись врассыпну́ю **3.** 1) на разва́ле; *безнең хәл тырым-тырагай* на́ше положе́ние — разва́л 2) ни ша́тко ни ва́лко; *эш тырым-тырагай бара* дела́ идут ни ша́тко ни ва́лко || *прил.* несо́бранный, неаккура́тный, несоли́дный; *тырым-тырагай хатын* несо́бранная, пуста́я же́нщина

тырым-тырагай II *сущ. прост.* вся́кий сброд

тырым-тырагайга *нареч. диал.* на разва́л; *эш тырым-тырагайга китте* де́ло пошло́ на разва́л

тырыс *сущ.* ту́ес, туесо́к; бура́к, берестяно́й ко́роб; *~ка җыю* собира́ть/собра́ть в туесо́к; *бер ~ җиләк* по́лный туесо́к я́год

тырыслык *сущ.* материа́л, приго́дный и́ли доста́точный для выде́лывания туеска́, ко́роба из бересты́; *бер ~ туз* береста́, доста́точная для изготовле́ния одного́ туеска́ || *прил.* **1.** приго́дный и́ли доста́точный для выде́лывания туеска́; **2.** доста́точный для заполне́ния туеска́

тырыш *прил.* **1.** стара́тельный, усе́рдный, приле́жный; упо́рный, насто́йчивый, энерги́чный (*о человеке, о личности*); *~ бул* будь стара́тельным; *ялкау кеше кайдерәсен бәйләгәнче ~ эшче бетерер* (*посл.*) пока́ ленти́й завя́жет обо́рки лапте́й, усе́рдный зако́нчит рабо́ту **2.** упо́рный, насто́йчивый, приле́жный (*о труде, деятельности*); *~ хезмәт* упо́рный труд || *нареч.* упо́рно, усе́рдно, приле́жно; *~ эшли* он рабо́тает усе́рдно

тырыша-тырмаша *нареч. разг.* усе́рдствуя, стара́ясь изо всех си́л; *тырыша-тырмаша үргә үрмәләү* изо всех (после́дних) сил взбира́ться вверх; *тырыша-тырмаша укып бетерү* стара́ясь из после́дних возмо́жностей, (всё-таки) зако́нчить учёбу

тырышлы *прил. разг.* **1.** *см.* **тырыш 2.** рачи́тельный; и́стовый

тырышлы|к *сущ.* стара́ние, усе́рдие, прилежа́ние; насто́йчивость, упо́рство; *ялкаулык — хурлык, ~к — зурлык* (*посл.*) лень — позо́р, прилежа́ние — вели́чие; *аның ~гы аркасында (~гы белән)* благодаря́ его́ стара́ниям

тырышлыклы *прил.* упо́рный, насто́йчивый

тырыштыр|у **1.** *понуд. от* **тырышу**; заста́вить стара́ться, заста́вить прилага́ть уси́лия **2.** *неперех. разг.* прилага́ть уси́лия, стара́ться (*по мере сил и возможностей*); *һаман ~ам инде* постоя́нно прилага́ю (*все*) уси́лия

тырыш|у *неперех.* **1.** стара́ться/постара́ться, усе́рдствовать; прилага́ть/приложи́ть уси́лия || стара́ние, усе́рдие; *~ырбыз инде* уж постара́емся; *~кан табар* стара́ющийся добьётся (*своего*) **2.** (**-ырга ~у**) стреми́ться (хоте́ть) де́лать/сде́лать, выполня́ть/вы́полнить, соверша́ть/соверши́ть *что-л.; белергә ~ты* стреми́лся разузна́ть; *укырга ~а* хо́чет учи́ться (да́льше); *кичегергә ~ма* постара́йся не опа́здывать **3.** (**өчен ~у, дип ~у**) 1) забо́титься, проявля́ть забо́ту *о ком, о чём-л.; ил өчен ~у* проявля́ть забо́ту о стране́ 2) выступа́ть/вы́ступить, стоя́ть *за кого, что-л.; хаклык өчен ~ам* стою́ за пра́вду

тырыш|у-тырмаш|у *неперех. разг.* усе́рдствовать, упо́рно стреми́ться, стара́ться изо всех сил (*из всей мочи*); лезть из ко́жи вон; си́литься; ту́житься; *тырышты-тырмашты һәм эшләп чыгарды* си́лился, ту́жился, усе́рдствовал и вот довёл де́ло до конца́

тырышучан *прил.* **1.** *см.* **тырыш 2.** забо́тливый (*относительно кого-л.*), пеку́щийся *о ком-л.; халык өчен ~* пеку́щийся о наро́де

тырышучанлы|к *сущ.* **1.** *см.* **тырышлык 2.** забо́тливость; коллекти́вность; *~гы нәтиҗәсендә* благодаря́ забо́тливости

тырышчан *прил. разг.* усе́рдный, приле́жный, рачи́тельный; *~ хуҗа* рачи́тельный хозя́ин

тырышчанлык *сущ.* усе́рдие, усе́рдность; прилежа́ние, приле́жность; рачи́тельность; *~ белән* с усе́рдием (*с рачительностью*)

тырышып *нареч.* упо́рно, насто́йчиво; стара́тельно, приле́жно, усе́рдно; *~ укыйк* бу́дем учи́ться приле́жно (*настойчиво, упорно*)

тырышып-тырмашып *нареч.* усе́рдствуя, стара́ясь изо всех си́л; упо́рно и насто́йчиво; *тырышып-тырмашып эшләде* рабо́тал, стара́ясь изо всех си́л

тыс *подр.* щиканью

тысылда́у *неперех.* ши́кать/ши́кнуть (*призывая замолчать, помолчать*)

тысырдату *неперех. диал. см.* **тасырдату**

тысыр-тасыр *подр. приглушённым звукам торопливых шагов, беготне и т. п.; тысыр-тасыр качып киттеләр* убежа́ли торопли́выми шага́ми

тыт *сущ. бот.* сиби́рская ли́ственница

тытылда́у *неперех. разг. см.* **татылдау, тәтелдәү**

тытып *частица усил. диал.* то́чно; точь-в-точь; *~ анасы* то́чно мать, точь-в-точь мать

тычкан *сущ.* мышь, мы́шка; *см. тж.* **сычкан**; *ак ~* бе́лая мышь; *кыр ~ы* полева́я мышь; *~га үлем — мәчегә көлке* (*посл.*) ко́шке поте́ха — мы́шке слёзки (*букв.* мы́шке смерть, ко́шке смех) □ **~ борчагы** *бот.* мыши́ный горо́шек; ви́ка многоцве́тная; **~ елы** *см.* **сычкан елы**; **~ йөгертү (чыгару)** гоня́ть мы́шцы (*заставлять взбухать мышцы ударами ладони*); **~ койрык** *бот.* мышехво́стник; **~ сарымсагы** *см.* **юа**; **~ тарысы** *бот.* мыше́й, щети́нник зелёный ◊ **~ азыгы** мыши́ная снедь (*о неубранных остатках еды*); **~ ашарлык (кимерерлек, туярлык)** с гу́лькин нос (*о запасах пищи*); **~ башы ярылырлык (~ башын ярырлык)** хоть шаро́м покати́ (*об отсутствии продуктов и вещей там, где они обычно хранятся; букв.* мы́шка го́лову свою́ разобьёт о го́лую до́ску); **~ бәбәк** об о́чень ма́леньких глаза́х (*человека*); **~ күзе** *см.* **тычкан уты**; **~ күзенә сибәрлек** щепо́тка (*очень маленькое количество — соли, лекарства и т. п.*); **~ лампасы** *см.* **тычкан уты 4**; **~ сыртлы 1.** мша́стый (*о лошади*) **2.** стропти́вый (*о человеке*); **~ таяк белән йөри торган чак** стра́шный гололёд (*букв.* вре́мя, когда́ мы́шки и те хо́дят с па́лочками); **~ тәбесе** *эвф.* тюрьма́, темни́ца (*букв.* мыши́ная западня́); **~ урынына (~ кебек) буып ташлау** задави́ть как во́шку (*букв.* задуши́ть как мы́шку); **~ уты 1.** ива́новский ого́нь (*светящийся червячок*), светлячо́к **2.** светлячо́к-гнилу́шка **3.** е́ле заме́тный огонёк **4.** ла́мпа-конти́лка

тычканлы-мәчеле: тычканлы-мәчеле уйнау 1. игра́ть в ко́шки-мы́шки **2.** *редко* заводи́ть ша́шни

тычканчы *сущ. диал. зоол.* пустельга́

тычканчык *сущ.* **1.** ко́лики (*у лошадей*); *~ булган* заболе́л ко́ликами **2.** мы́шцы (*взбухание мышечной ткани при ударе*); *~ ясау* уда́рить по мы́шцам так, что они́ взбуха́ют

тычт *межд. о плевке через зубы; ~ иттереп төкерде* плю́нул (вы́плюнул) че́рез зу́бы

тыш I *сущ.* **1.** 1) простра́нство и́ли ме́сто вне помеще́ния; двор, у́лица, подво́рье; *тышта калу* оста́ться на у́лице, снару́жи; *тышта кар ява* на у́лице идёт снег 2) мир вне помеще́ния; *тышта нинди хәбәрләр йөри?*

что но́вого в ми́ре (*вне помещения, где идёт разговор*)? 3) *в знач. нареч.* **тышка** нару́жу; *тышка йөгерү* выбега́ть нару́жу **2.** 1) вне́шность, вне́шняя сторона́; нару́жность, нару́жная сторона́ (*противоп.* **эч**); *тышына такта кадаклау* оби́ть снару́жи до́ска́ми 2) вне́шность, нару́жность; вне́шний вид; *шатлыгы тышына чыккан* его́ распира́ет ра́дость; *эчендәге тышында* (*погов.*) что внутри́ (на душе́), то и снару́жи (во вне́шности); *тышыннан белеп булмый* нельзя́ позна́ть по вне́шности **3.** 1) окре́стность (*населённого пункта, района, страны и т. п.*); *авыл тышында* в окре́стностях дере́вни; *шәһәр тышында* в окре́стностях го́рода; 2) *в знач. послелога* **тышында** за (*пределами*), вне *чего-л.*; *киртә тышында* за преде́лами огра́ды; *игътибар тышында* вне внима́ния **4.** *разг. в притяж. ф.* **тышы** *см.* **тышлык**; *тун тышы* верх шу́бы; *бишмәт тышына ярый* годи́тся на верх бешме́та (пальто́); *өй тышы* облицо́вка (штукату́рка) до́ма || *прил. см.* **тышкы**; *тыш як* вне́шняя сторона́ □ **тышка чыгу** *эвф.* идти́ во двор; сходи́ть по нужде́

тыш II *послелог* **1.** кро́ме; окроме́; *бу саналганнардан тыш* кро́ме перечи́сленного (перечи́сленных); *синең теләгеңнән тыш дөнья да бар бит әле* кро́ме твоего́ жела́ния существу́ет ещё и реа́льный мир **2.** 1) сверх; *шуннан тыш* сверх того́; *чамадан тыш* сверх ме́ры 2) *переводится приставками* сверх-, че́рез-, чрез-; *вакытыннан тыш* сверх вре́мени, сверхуро́чный; *гадәттән тыш* чрезвыча́йно; чрезвыча́йный; *чиктән тыш* чрезме́рный, чрезме́рно; чересчу́р **3.** 1) вне, поми́мо; *үз ихтыярымнан тыш* вне своего́ жела́ния (во́ли); *чираттан тыш* вне о́череди 2) *переводится приставкой* вне-; *класстан тыш* внекла́ссный; *штаттан тыш хәбәрче* внешта́тный корреспонде́нт

тышал|у *неперех. диал. см.* **тышаулану**; *~ган ат* стрено́женный конь

тыша́|у I *перех. диал.* **1.** *см.* **тышаулау**; *атны ~п болынга җибәрү* коня́, стрено́жив, пуска́ть на луг **2.** *перен.* зако́вывать/закова́ть в кандалы́; *см. тж.* **богаулау**

тыша́|у II *сущ.* **1.** пу́ты; *ат ~вы* ко́нские пу́ты; *~уны салдыру* снима́ть/снять пу́ты; *~у кидерү* надева́ть пу́ты, спу́тывать **2.** око́вы; *см. тж.* **богау**; *тимер ~у* желе́зные око́вы

тышаулан|у *страд. от* **тышаулау** быть стрено́женным, спу́танным; *~ган терлекләр* стрено́женный скот

тышаул|а́у *перех.* **1.** трено́жить, стрено́живать/стрено́жить, спу́тывать/спу́тать; *~ап жибәрү* стрено́жить и пусти́ть **2.** *перен.* опу́тывать; ско́вывать де́йствия || опу́тывание; ско́вывание де́йствий (*кого-л.*); *бәла-каза ~ый* вся́кие бе́дствия ско́вывают (*дело*)

тышаулашу *взаимно-совм. от* **тышаулау**

тышаулы *прил.* стрено́женный, спу́танный; *аягы ~* но́ги стрено́жены; *~ ат ерак китмәс* (*погов.*) стрено́женная ло́шадь далеко́ не уйдёт (*говоря так, выдают замуж или женят слишком бойких молодых людей*)

тышаусыз *прил.* **1.** не стрено́женный, не спу́танный; *~ атлар* не стрено́женные ло́шади **2.** *перен.* разну́зданный, (*чрезмерно*) свобо́дный; *ирсез хатын — ~ ат* же́нщина без му́жа что ло́шадь без пут (*чрезмерно свободна*) || *нареч.* без пут; *~ йөри* хо́дит без пут (*о лошади*)

тышкаргы, тышкарыгы *прил. диал.* вне́шний; *~ яктан* с вне́шней стороны́

тышкары I *нареч.* нару́жу; *~ чыгу* выходи́ть нару́жу || *сущ.* вне́шняя сторона́; *~ яктан караганда* е́сли смотре́ть с вне́шней стороны́ (извне́)

тышкары II *послелог* **1.** *разг. см.* **тыш** 2; *шуннан ~* кро́ме того́ **2.** *разг.* вне; *тоpактан ~* вне помеще́ния

тышкы *прил.* **1.** *в разн. знач.* 1) вне́шний; *~ дөнья* вне́шний мир; *~ кыяфәт* вне́шний вид 2) нару́жный, вне́шний; лицево́й; *~ ишек* нару́жная дверь; *~ батырлык* вне́шняя хра́брость; *~ як* лицева́я сторона́ **2.** ве́рхний (*об одежде*) **3.** *перен. редко* пове́рхностный; *~ гыйлем* пове́рхностные зна́ния □ **~ политика** вне́шняя поли́тика; **~ почмак** *мат.* вне́шний у́гол

тышлама *сущ.* **1.** опа́лубка; *бетон кою өчен ~* опа́лубка для кла́дки бето́на **2.** обши́вка; *кораб ~сы* обши́вка корабля́

тышламалы *прил.* **1.** обши́тый; *~ өй* обши́тый дом **2.** снабжённый опа́лубкой

тышлан|у *страд. от* **тышлау**; *~ган дивар* обши́тая (оби́тая) стена́

тышлату *понуд. от* **тышлау**; заказа́ть, сде́лать зака́з на обши́вку (переплёт) *чего*

тышла́у *перех.* **1.** 1) обшива́ть/обши́ть, обива́ть/оби́ть, обтя́гивать/обтяну́ть, крыть/покры́ть || обшива́ние, оби́вка, обтя́гивание; *өй ~* обшива́ть дом (до́ска́ми); *ишек ~* обива́ть дверь 2) оштукату́рить **2.** облицева́ть || облицо́вка **3.** обвёртывать/обверну́ть; переплета́ть/переплести́ || обвёртывание, обвёртка, переплете́ние; *китап ~* переплете́ние кни́ги

тышлы *прил. см.* **тышлыклы**; *~ ишек* дверь с обши́вкой

тышлы|к *сущ.* **1.** верх (*одежды*), обши́вка; *бүрек ~гы* верх ша́пки **2.** *см.* **сүрү**; *мендәр ~гы* на́волочка поду́шки **3.** обло́жка (кни́ги), переплёт; *журнал ~гы* обло́жка журна́ла; *китап ~гы* переплёт кни́ги || *прил.* **1.** обши́вочный, приго́дный для ве́рха, обши́вки, оболо́чки, для шитья́ на́волочки (*о тканях*); *~к постау* обши́вочное сукно́ **2.** обло́жечный, обвёрточный, переплётный; приго́дный для обло́жки, переплёта; *~к ледерин* обло́жечный (переплётный) ледери́н

тышлыклы *прил.* **1.** с обло́жкой, с обши́вкой, с переплётом; обтя́нутый на́волочкой **2.** с определённого ка́чества обло́жкой, на́волочкой, переплётом; *зәңгәр ~ китап* кни́га с си́ней обло́жкой (*в синем переплёте*)

тышлыксыз *прил.* без обло́жки; без на́волочки, без обши́вки (*переплёта и т. п.*); *~ китап* кни́га без обло́жки

тышмак I *сущ.* **1.** ве́рхние рукави́цы (*противоп.* **эчмәк**) **2.** верхо́нки *обл.*; мохна́тая оде́жда, мохна́тая попо́на; *~ кигән* оде́тый в верхо́нки

тышмак II *прил.* ше́рстью нару́жу; *~ тун* шу́ба ме́хом нару́жу; доха́

тышсыз *прил. прост. см.* **тышлыксыз**; *~ тун* наго́льная шу́ба

тыштагы *прил.* **1.** нару́жный, находя́щийся снару́жи (*вне помещения, дома и т. п.*); *~ такталар* до́ски, находя́щиеся вне помеще́ния, двора́ и т. п.; *~ утын* дрова́, находя́щиеся вне двора́ **2.** надво́рный; *~ җиһазлар* надво́рные пристро́йки

тыштан *нареч.* **1.** снару́жи; *~ сыланган* оштукату́ренный снару́жи; *~ бикле* за́пертый снару́жи; *~ тыгыз, эчтән буш* (*загадка о дыне*) снару́жи пло́тно, внутри́ ры́хло **2.** снару́жи, вне́шне, по ви́димости, с ви́ду; *~ тыныч кына* вне́шне дово́льно споко́йный **3.** для ви́ду, для отво́да глаз; *~ гына әйтелгән сүз* сло́во, ска́занное для отво́да глаз; *~ карашка* на вид; на пе́рвый взгляд; вне́шне; ◊ **~ ялтырау, эчтән калтырау** ≈ напуска́ть на себя́ невозмути́мый вид; де́лать хоро́шую ми́ну при плохо́й игре́

тыштангы *прил.* **1.** нару́жный, вне́шний; не затра́гивающий осно́ву; ~ *ялтырау* вне́шний лоск (*букв.* блеск) **2.** пове́рхностный; ~ *караш* пове́рхностный взгляд

тышча *сущ.* **1.** *в разн. знач.* оболо́чка; *дирижабль ~сы* оболо́чка дирижа́бля **2.** ко́жица; *кузәнәк ~сы* ко́жица кле́тки

тыю *перех.* **1.** 1) уде́рживать/удержа́ть, отгова́ривать || уде́рживание, отгова́ривание (*от какого-л. действия, поступка и т. п.*); *көчкә тыеп калдым я* е́ле удержа́л; *басымны тыю* уде́рживать напо́р 2) сде́рживать/сдержа́ть || сде́рживание; *яшьләрен тыеп* сде́рживая слёзы **2.** *перех., неперех.* запреща́ть/запрети́ть || запреще́ние; воспреща́ть/воспрети́ть || воспреще́ние; *көлүдән тыю* запрети́ть смея́ться; *катгый тыю* стро́гое запреще́ние **3.** 1) унима́ть/уня́ть; укроща́ть || укроще́ние; *мәхәббәтне тыеп булмый* нельзя́ укроща́ть любо́вь 2) замедля́ть/заме́длить || замедле́ние; *йөрешне тыю* (*тыя төшү*) замедля́ть/заме́длить ход (ско́рость) **4.** приде́рживать/придержа́ть (*коня*)

тыюлы *прил.* **1.** запрещённый (*правилами, законами*); ~ *алымнар* запрещённые приёмы **2.** запове́дный; ~ *урыннар* запове́дные места́ **3.** *предик. прил.* запрещён, запрещено́; *керү* ~ вход запрещён

тыюлы|к *сущ.* запове́дник; *Башкортстан ~гы* запове́дник Башкортста́на

тыю *подр. свисту пули* □ **тыю итү** просвисте́ть (*о пуле*)

тю́бик *сущ.* тю́бик; ~ *эчендә* в тю́бике, внутри́ тю́бика

тю́биклы *прил.* в тю́бике (тю́биках); ~ *дару* лека́рство в тю́бике

тю́бинг *сущ. тех.* тю́бинг (*металлическая или железобетонная плита в ф. сегмента; применяется в креплении шахт, туннелей*)

тюк *сущ. разг.* тюк (*соломы, пакли, товаров*); *бер тюк печән* тюк се́на; *йон тюклары* тюки́ ше́рсти □ **тюк (тюгы, тюклары) белән** в тюка́х, тюка́ми

тюклан|у *страд. от* **тюкла́у**; тюкова́ться, запаковáться; быть упако́ванным; *~ган товарлар* (уже́) тюко́ванные, (уже́) упако́ванные това́ры

тюклап *нареч.* **1.** в тюка́х; *товар ~ озатыла* това́р отправля́ется в тюка́х **2.** *в сочет. с числ. колич.* о́коло, приме́рно определённого коли́чества тюко́в; *биш ~ булыр* бу́дет о́коло пяти́ тюко́в

тюклат|у *понуд. от* **тюклау**; заста́вить и́ли веле́ть (зака́зывать) тюкова́ть

тюкла́у *перех.* тюкова́ть/затюкова́ть, запако́вывать/запакова́ть (*солому, шерсть, мануфактуру*) || тюко́вка

тюклаучы *сущ.* тюко́вщик

тюклы *прил.* в тюке́, в тюка́х, свя́занный в тюк (тюки́); ~ *печән* се́но в тюка́х

тюлень *сущ. зоол.* тюле́нь || тюле́невый; тюле́ний; ~ *утравы* тюле́ний о́стров; ~ *мехы* тюле́ний мех □ ~ **баласы** тюленёнок; белёк; ~ **ите** тюле́нина

тюленьле *прил.* тюле́ний (*о местах и т. п.*); ~ *утрау* тюле́ний о́стров

тюль *сущ.* тюль; ~ *сатып алу* покупа́ть тюль || *прил.* тю́левый; ~ *пәрдә* тю́левый за́навес

тюльпан *сущ.* тюльпа́н; *см. тж.* **лалә**

тюрко́лог *сущ. спец.* тюрко́лог, специали́ст по тюрколо́гии

тюрколо́гик *прил.* тюркологи́ческий; ~ *конференция* тюркологи́ческая конфере́нция

тюрколо́гия *сущ.* тюрколо́гия (*наука, изучающая языки, литературу, историю и культуру тюркских народов*)

тягач *сущ. разг.* тяга́ч; *см. тж.* **тарткыч**; *~та эшләү* рабо́тать на тягаче́ (*о трактористе*)

У

у I *подр.* (*обычно произносится протяжно у-у, у-у-у*) **1.** *вою, завыванию, гудению* (*ветра*) **2.** *вою зверей, собаки*

у II *межд.* (*обычно произносится протяжно у-у, у-у-у*) **1.** *выраж. укоризну, угрозу, негодование* у; *у, усал!* у, злы́день!; *у, бирэн!* у, обжо́ра! **2.** *выраж. испуг, страх и т. п.* у-у, о-о, ой; *у-у-у, нинди куркыныч!* О-о, како́й стра́шный!; *у-у, нинди биек!* о-о, как высоко́!; *у-у, озын икэн* ой, како́й дли́нный!; *у-у, кара ничек карый!* у-у, как (на меня́) смо́трит! **3.** *выраж. одобрение, восторг, восхищение, удивление* у-у, ой, о-о, ого́; *у-у, нинди яхшы!* ой, как хорошо́!; *у-у, Равил дэ монда икэн!* о-о, ока́зывается и Рави́ль здесь!; *у-у, соңга калабыз!* ой, опа́здываем!; *у, рэхэт!* ой, как хорошо́!

у III *сущ. диал.* **1.** яд, отра́ва; *см. тж.* **агу 2.** по́рча (*насланная со стороны*)

уа I *сущ. уст.* рахи́т; *балага уа булды* ребёнок заболе́л рахи́том ◊ **уа чыгу** станови́ться/стать горба́тым

уа II *подр. вскрику плачущего ребёнка; см. тж.* **вэ**

уалан|у *возвр.-страд. от* **уалау 1.** *возвр.* кроши́ться/раскроши́ться, искроши́ться, распада́ться/распа́сться (*на кусочки*), измельчи́ться, размельча́ться; *печенье ~ып беткэн* пече́нье искроши́лось; *сохари ~ган* сухари́ раскроши́лись **2.** *от* **уалау** мять, размина́ть/размя́ть себя́ (*свой живот при болях*) **3.** *перен.* убива́ться, пережива́ть; сокруша́ться, огорча́ться; *~удан ни файда* не́чего убива́ться; *кыш буе ~ып чыкты* всю зи́му сокруша́лся **4.** *страд.* кроши́ться, быть раскро́шенным □ **~ып бетү** раскроши́ться, искроши́ться, превраща́ться в кро́шево

уаланучан *прил.* хру́пкий, ло́мкий; крошащийся; *~ кирпеч* хру́пкий кирпи́ч

уалату *понуд. от* **уалау**

уалау *перех.* **1.** тере́ть, растира́ть/растере́ть, протира́ть/протере́ть, мять, размина́ть/разма́ть || растира́ние, расти́рка; размина́ние; *күзләрне ~* тере́ть глаза́; *бармак белән папирос ~* размина́ть па́льцами папиро́су **2.** кроши́ть, мельчи́ть, размельча́ть/размельчи́ть, измельча́ть/измельчи́ть || размельче́ние, измельче́ние; *ипине ~* кроши́ть хлеб

уалган *прил. диал.* разби́тый

уал|у *неперех.* **1.** кроши́ться/раскроши́ться, дроби́ться, би́ться/разбива́ться/разби́ться, раска́лываться, размельча́ться, лома́ться, разла́мываться/разлома́ться || крошéние, дроблéние, разби́тие, раска́лывание; *аяк астында боз ~а* под нога́ми кроши́тся лёд; *кирпеч тиз ~а* кирпи́ч бы́стро разла́мывается; *пыяла ~а* стекло́ бьётся **2.** рассыпа́ться/рассы́паться; *туфрак ~ып тузанга әйләнгән* земля́, рассы́павшись, преврати́лась в пыль **3.** вывéтриваться/вы́ветриться, эроди́ровать || вывéтривание; *җил-яңгырдан ~ган* эроди́рованный от вéтра и дождя́ □ **~ып бетү** раскроши́ться, разлома́ться; *печенье ~ып беткэн* пече́нье раскроши́лось; **~ып тору** рассыпа́ться (*земля, картошка*); **~ып төшү** развали́ться, рассы́паться

уалучан *прил.* **1.** ло́мкий, хру́пкий, бью́щийся; салкыннан ~ хру́пкий от моро́за **2.** ры́хлый, рассы́пчатый; *~ туфрак* рассы́пчатая земля́

уалучанлы|к *сущ.* **1.** ло́мкость, хру́пкость; *кирпечнең ~гы* ло́мкость кирпича́; *корычның ~гы* хру́пкость ста́ли **2.** ры́хлость, рассы́пчатость; *туфракның ~гы* ры́хлость по́чвы; *җиңел ~к* лёгкая рассы́пчатость

уба *сущ.* **1.** *этногр.* небольшо́й курга́н, оба́ **2.** *диал.* небольша́я возвы́шенность; хо́лмик; *убага салынган* постро́енный на хо́лмике **3.** *диал.* углубле́ние, я́ма; *буре убасы* во́лчья я́ма, во́лчья нора́ (*т.е. яма, нора, вырытая волком*)

убежище *сущ. разг. воен.* убе́жище; укры́тие; *~га төшү* спуска́ться в убе́жище

убу *неперех.* **1.** прова́ливаться/провали́ться (*о земле*); *аның астында җир уба* под ним прова́ливается земля́ **2.** *перен.* загла́тывать/заглота́ть, прогла́тывать/проглоти́ть, поглоща́ть/поглоти́ть; *сукқыч көлтәләрне убып кына тора* молоти́лка так и прогла́тывает снопы́; *ничек җир упмый үзен!* как его́ земля́ де́ржит (не прогла́тывает) **3.** *перен. прост.* поглоща́ть/поглоти́ть; жрать/пожра́ть, ло́пать; *алдына куйганны убу* жа́дно поглоща́ть всё по́данное

убылма *сущ. геол.* обва́л, сброс, прова́л, о́ползень; *зур ~лар барлыкка килү* происхо́дят больши́е обва́лы; *Көнчыгыш Африка ~лары* Восто́чно-Африка́нские прова́лы || *прил.* сбро́совый; *~ иңкүлек* сбро́совая впа́дина

убыл|у *неперех.* ввáливаться/ввали́ться, обвáливаться/обвали́ться; прова́ливаться/провали́ться (*о земле*) || обвáливание, обвáл; провáл; *җир ~а* земля́ прова́ливается; *геологик ~у* геологи́ческий обвáл □ **~ып китү** провали́ться; **~ып тору** зия́ть; **~ып төшү** обвали́ться

убылучан *прил.* подвéрженный обвáлам; обвáлистый; *бу тау ~* э́та гора́ подвéржена обвáлам; *~ яр* обвáлистый бéрег

убыр *сущ.* **1.** *миф.* о́боротень, вампи́р; вурдала́к, упы́рь; *~лар әбиләр әкиятендә генә* о́боротни (оста́лись) то́лько в ба́бушкиных ска́зках **2.** *перен. прост.* обжо́ра, про́рва; *бу ~ларга ашарга җиткерә алмассың!* э́тим обжо́рам не напасёшься!; *~ның үзе туйса да күзе туймый* (*погов.*) обжо́ра сам сыт, а глаза́ го́лодны **3.** *бран.* прокля́тый, нечи́стый; *ни эзли торгандыр ~ !* что и́щет, прокля́тый! □ **~ зэхмәте** *уст.* са́харная боле́знь; **~ уты 1.** блужда́ющий огонёк **2.** *бот.* чертополо́х; *см. тж.* **шайтан таягы** ◊ **~ карчыгы** *см.* **убырлы карчык**

убырлы *прил. миф.* нечи́стый, с нечи́стой си́лой || нечи́стая си́ла, ве́дьма, колду́нья; *~ мунча* ба́ня с нечи́стой си́лой; *~ урын* нечи́стое ме́сто; *~ өй* дом с нечи́стой си́лой; *~ның баш түбәсе тишек була икән* ока́зывается, у нечи́стого голова́ с ды́ркой ◊ **~ карчык** нечи́стая си́ла, колду́нья, ве́дьма

убырыл|у *неперех. диал.* **1.** ва́лом вали́ть **2.** *в знач. нареч.* **убырылып** *см.* **ургылып**; *ишектән ~ып пар керә* из две́рей клуба́ми ва́лит пар

увертю́ра *сущ. муз.* **1.** увертю́ра (*музыкальное вступление к опере, балету, кинофильму и т. п.*); *«Җәлил» операсына ~* увертю́ра к о́перe «Джали́ль» **2.** увертю́ра (*концертное оркестровое произведение в сонатной форме*); *Глинканың «Испан ~сы»* «Испа́нская увертю́ра» Гли́нки

увуляр *прил. лингв.* увуля́рный; *~ тартыклар* увуля́рные согла́сные

угаландыру *понуд. от* **угалану**

угалан|у **1.** *возвр. от* **угалау**; натира́ться/натере́ться, растира́ться/растере́ться; *камфара мае белән ~у* натира́ться ка́мфарным ма́слом **2.** *перен.* увива́ться, верте́ться; *мәче баласы аяк арасынды ~а* котёнок увива́ется под нога́ми; *аның кырыенда миннән башка да ~ып йөручеләр күп* и без меня́ о́коло неё мно́гие увива́ются **3.** *перен.* горева́ть, убива́ться; *шуның өчен ~масаң соң* сто́ит ли убива́ться из-за него́ **4.** проявля́ть/прояви́ть нетерпе́ние; *юкка-барга ~у* убива́ться из-за пустяко́в **5.** *перен. разг.* зайскивать, уго́дничать *перед кем*; ви́ться вьюно́м *около кого* || зайскивание; *түрәләр каршында ~ып йөрү* зайскивать пе́ред нача́льством

угаланышу *взаимно-совм. от* **угалану**

угалату *понуд. от* **угалау** 2, 3

угала|у **1.** *многокр. от* **уу**; *кер ~у* пости́рывать бельё; *күзне ~у* вре́мя от вре́мени тере́ть глаза́ **2.** тере́ть, потира́ть, натира́ть || потира́ние, натира́ние; *чигәләрне ~у* тере́ть виски́; *кулларны ~у* потира́ть ру́ки **3.** растира́ть (*табак*); мять, размина́ть || растира́ние, размина́ние; *кулындагы башакны ~у* размина́ть ко́лос в рука́х ◻ **~п алу** **1.** протере́ть **2.** простирну́ть

угалашу *взаимно-совм. от* **угалау** 2, 3

угата *нареч. диал.* **1.** осо́бенно; *йон оек кисәң ~ җылы* в шерстяны́х чулка́х осо́бенно тепло́ **2.** ещё бо́лее, ещё бо́льше; *тормыш мине ~ түбән өстери* а жизнь меня́ ещё бо́льше тя́нет вниз

углан *сущ.* **1.** *уст.* сын; *и ~!* о сын! **2.** *ист.* во́ин гва́рдии, гвардее́ц; *~нар килә* иду́т во́ины гва́рдии **3.** ещё не жена́тый молодо́й челове́к

углевод *сущ. хим.* углево́д || углево́дный ◻ **~ кушылмасы** углево́дное соедине́ние

углеводлы *прил. хим.* углево́дный, содержа́щий углево́ды; *~ азыклар* корма́, содержа́щие углево́ды

углеводород *сущ. хим.* углеводоро́д || углеводоро́дный ◻ **~ кушылмалары** углеводоро́дные соедине́ния

углеводородлы *прил. хим.* углеводоро́дный

углекислота *сущ. хим.* углекислота́

углекислоталы *прил.* углеки́слый ◻ **~ газ** *хим.* углеки́слый газ; **~ кушылма** углеки́слое соедине́ние; **~ тозлар** *хим.* углеки́слые со́ли; *см. тж.* **карбонатлар**

углерод *сущ. хим.* углеро́д || углеро́дный

углеродлы *прил. хим.* углеро́дистый, содержа́щий углеро́д; *~ корыч* углеро́дистая сталь ◻ **~ оксид** *хим.* окси́д углеро́да

угра|у *неперех.* име́ть де́ло; *күп бәлаләргә ~ды* име́л де́л со мно́гими бе́дствиями (*обрушившимися на его голову*)

уграш|у *неперех. уст. книжн.* свя́зываться/связа́ться; пу́таться/спу́таться; *аның берлә ~ма* не свя́зывайся с ним

угро-фин *сущ.* у́гро-фи́нны || у́гро-фи́нский; *угро-фин телләре* у́гро-фи́нские языки́; *угро-фин кабиләләре* у́гро-фи́нские племена́

угры *сущ. книжн.* вор; *см. тж.* **карак**; *~ тоттым* во́ра поймал ◻ **~ краб** *зоол.* краб-разбо́йник, па́льмовый вор

угрылык *сущ. книжн. см.* **караклык**; *~та гомере үтте* жизнь его́ прошла́ в воровстве́

угрында *послелог уст. книжн.* ра́ди

угыз *сущ.* моло́зиво (*после отёла*) || моло́зивый ◻ **~ ашы** **1.** ку́шанье из моло́зива **2.** угоще́ние по слу́чаю благополу́чного отёла коро́вы; **~ сөте** моло́зиво, сдо́йное молоко́

угыз *сущ.* огу́з || огу́зский; *~ телләре* огу́зские языки́; *~ кабиләләре* огу́зские племена́

угызлы *прил.* сдо́йный; *~ сөт* сдо́йное молоко́

угыл *сущ.* **1.** *книжн. см.* **ул** **2.** *в притяж. ф. 3 л.* **углы** *употр. при обозначении отчества* -ович, -евич, -ич; *Шакир углы* Шаки́рович; *патша углы* царе́вич ◻ **~ уты** *бот.* медо́вка

угырлау *перех. уст. книжн.* **1.** воспо́льзоваться слу́чаем **2.** *см.* **урлау**

угыч *сущ.* **1.** тёрка; *кишерне ~тан чыгару* пропусти́ть морко́вь че́рез тёрку **2.** *с.-х.* ша́сталка (*барабан в сложных молотилках для шастания зерна*)

удар I *сущ. прям., перен.* уда́р; *гаскәрне ~ астында калдыру* оста́вить войска́ под уда́ром; *әнисенә кинәттән ~ ясыйсы килмәде* не хоте́лось сде́лать ма́тери неожи́данный уда́р

удар II *прил.* уда́рный; *~ төзелеш* уда́рная стро́йка; *~ эш* уда́рный труд

ударни|к I *сущ. в разн. знач.* уда́рник; *винтовканың ~гына басу* нажа́ть на уда́рник винто́вки

ударник II *сущ.* уда́рник; *укуда ~* уда́рник в учёбе ◻ **~ хатын (кыз)** *ист.* уда́рница; **~лар хәрәкәте** *ист.* уда́рничество

ударникларча *нареч. ист.* по-уда́рному, как уда́рник; *өмәдә ~ эшләү* рабо́тать на суббо́тнике по-уда́рному

ударниклык *сущ. ист.* уда́рничество; *~ турында язу* писа́ть об уда́рничестве

ударница *сущ.* уда́рница

ударчы *сущ. уст. см.* **ударник**; *~ колхозчылар съезды* съезд колхо́зников-уда́рников

ударчылык *сущ. уст. см.* **ударниклык**

удел *сущ. ист.* уде́л || уде́льный; *см. тж.* **инҗе**; *~ кенәзе* уде́льный князь; *~ җирләре* уде́льные зе́мли

удмурт *сущ.* удму́рт || удму́ртский; *~ авылы* удму́ртская дере́вня; *~ теле* удму́ртский язы́к ◻ **~ хатыны (кызы)** удму́ртка

удму́ртча *нареч.* по-удму́ртски, на удму́ртском языке́; *~ сөйләшә* говори́т по-удму́ртски || *прил.* удму́ртский; *~ бию* удму́ртская пля́ска

удырту *понуд. от* **удыру**

удыру *понуд. от* **уу**; *кер ~* заста́вить стира́ть бельё

удэге *сущ.* удэге́ || удэге́йский; *~ теле* удэге́йский язы́к ◻ **~ хатыны (кызы)** удэге́йка

удэге́йча *нареч.* по-удэге́йски, на удэге́йском языке́; *~ сөйләшә* говори́т на удэге́йском языке́ || *прил.* удэге́йский; *~ бию* удэге́йская пля́ска

уел *сущ.* **1.** *диал.* река́ в широ́кой доли́не **2.** кана́л

уелгалау *многокр. от* **уелу**

уелдык *сущ.* вы́боина, вмя́тина; лу́нка; *стенада снаряд ~лары* на стене́ вмя́тина от снаря́дов

уелма *сущ.* **1.** впа́дина, вы́ем, вы́емка, котлови́на; углубле́ние; *ике тау арасындагы ~* впа́дина меж двух гор; *язгы ташкын зур ~ ясаган* весе́нний пото́к сде́лал большу́ю котлови́ну **2.** вы́рез; *~ яка* воротни́к с вы́резом; *җиң ~сы* вы́емка для рукаво́в || *прил. см.* **уелмалы**; *~ итәк* подо́л с вы́резом; *~ чәчәк* цвето́к с вы́резом

уелмалы *прил.* вы́емчатый (*лист*), с углубле́ниями, вы́емками; вырезно́й; *~ яка* вырезно́й воротни́к

уел|у **1.** *страд. от* **ую** **2.** сре́зываться/среза́ться, вы́резываться/выреза́ться **3.** *перен.* вре́зываться/вреза́ться; *хатирәләр күңелгә ~ып калган* вре́завшиеся

в па́мять собы́тия; *бу урын ~ган* э́то ме́сто сре́зано □ **~ып китү** ужасну́ться, растеря́ться

уелып *сущ.* разре́з; *күз ~ы* разре́з глаз

уем *сущ.* **1.** вы́емка, вы́ем; *таш уемы* вы́емка ка́мня **2.** вы́боина; *стенадагы пуля уемнары* вы́боины на стене́ от пуль **3.** *горн.* вруб (*узкая щель в горной породе*) **4.** *биол.* вы́резка; *агач кабыгындагы уем* вы́резка на коре́ де́рева **5.** вы́рез, про́йма (*в одежде*); *яка уемы* вы́рез воротника́; *җиң уемы* про́йма **6.** проём; *ишек уемы* дверно́й проём; *тәрәзә уемында* в проёме окна́ **7.** *воен.* про́резь (*в прицельном приспособлении огнестрельного оружия*); *төзәгеч уемы* про́резь прице́ла **8.** разре́з; *күз уемы* разре́з глаз **9.** ни́ша; *коридорның ике ягындагы уемнар* ни́ши по обе́им сторона́м коридо́ра **10.** *спец.* гнездо́; *патрон уемы* гнездо́ для патро́на **11.** уча́сток, клочо́к земли́; *алда бер уем болын* впереди́ небольшо́й уча́сток лу́га

уемлау *перех.* **1.** углубля́ть/углуби́ть *что*, де́лать/сде́лать вы́ем **2.** де́лать/сде́лать вы́рез; *күлмәкне ~* сде́лать вы́рез на пла́тье **3.** де́лать/сде́лать проём; зару́бки, вы́боину; *тәрәзә ~* сде́лать проём окна́

уемлы *прил.* **1.** вы́емчатый; *~ бизәкләр* вы́емчатые узо́ры **2.** с вы́резом; *~ күлмәк* пла́тье с вы́резом

уемты *сущ. см.* **уем** 1—2, 4—5, 10; *җирдәге ~* вы́емка на земле́; *күлмәк ~сы* вы́рез пла́тья

уемты|к *сущ. см.* **уем**; *агачтагы ~к* вы́емка в стволе́ де́рева; *күз ~гы* про́резь глаз

уемтыклы *прил.* **1.** вы́емчатый; с вы́емками; име́ющий проёмы; *~ яфрак* лист вы́емчатый; *~ такта* доска́ с вы́емками **2.** вырезно́й; с вы́резами, име́ющий вы́резы **3.** с про́резями, име́ющий про́рези

уем-уем *прил.* **1.** вы́емчатый, с вы́емками **2.** уча́стками, состоя́щий из ме́лких непра́вильной фо́рмы уча́стков; *уем-уем болын* луг, состоя́щий из ме́лких уча́стков

уен *сущ.* **1.** *в разн. знач.* игра́ || игра́льный; игрово́й; *балалар уены* де́тская игра́; *ашык уены* игра́ в ба́бки; *спорт уеннары* спорти́вные и́гры; *комарлы уеннар* аза́ртные и́гры; *уен белән мавыгу* заигра́ться; *уеннан чыгару* вы́вести из игры́; *уеннан төшеп калу* вы́пасть из игры́; *уен мәйданчыгы* игрова́я площа́дка; *уен җырлары* игровы́е пе́сни **2.** *этногр.* и́грище; *яшьләр уеннары* молодёжное и́грище **3.** *перен.* шу́тка, поте́ха; *уен эшмени!* шу́тка ли; шу́тка сказа́ть! **4.** музыка́льное исполне́ние || музыка́льный; *аның уены тамашачыларга ошады* его́ исполне́ние зри́телям понра́вилось; *уен коралы* музыка́льный инструме́нт **5.** представле́ние, зре́лище; *уен тәмам булды* представле́ние око́нчилось **6.** *разг.* ко́зырь || козырно́й; *уен кәрте* козырна́я ка́рта; *уен белән йөрү* ходи́ть с ко́зыря (*с козырной карты, с козырного*); *уен тугызлысы* козырна́я девя́тка **7.** *воен. в ф.* **уеннар** (*военные*) учёния; маневры *мн.*; *хәрби уенда булу* находи́ться на вое́нных учёниях (*маневрах*) || *прил.* **1.** шутли́вый; *уен сүз* шутли́вое сло́во **2.** шу́точный; *уен эш түгел!* не шу́точное де́ло, шу́точное ли де́ло!; *уен эшмени!* шу́точное ли де́ло! □ **уен куючылар** *уст.* арти́сты; **уен оештыручы** зате́йник; **уен остасы** массови́к, организа́тор ма́ссовых игр; **уенга бирелү** увлека́ться/увле́чься игро́й; **уенда булган** и́граный; *уенда булган колода* и́граная коло́да ◊ **уен гына** раз плю́нуть; **уен муенга тия** *см.* **уеннан уймак чыга**; **уен түгел (уенмыни)** не игра́; **уенга алу** принима́ть/приня́ть за шу́тку; **уенга бору (әйләндерү)** обраща́ть/обрати́ть в шу́тку; **уеннан уймак чыгару** доигра́ться (*до беды*)

уен-җыен *сущ. собир.* молодёжное гуля́нье; *уен-җыенда катнашу* уча́ствовать в молодёжном гуля́нье

уен-җыр *сущ. собир.* пе́сни и пля́ски, развлече́ния; *уен-җыр белән кунәл ачу* развлека́ть пе́сней и пля́ской

уен-көлке *сущ.* весе́лье, увеселе́ние, развлече́ние; поте́ха, заба́ва; *уен-көлке башланды* начало́сь весе́лье □ **уен-көлке кичәсе** ве́чер развлече́ний; вечери́нка; **уен-көлке сөйләүче** шутни́к, весельча́к ◊ **уен-көлке бер якта (калып) торсын** шу́тки в сто́рону; **уен-көлкегә бору (әйләндерү)** *см.* **уенга бору**

уен-көлкеле *прил.* весёлый; увеселя́тельный; *уен-көлкеле комедия* весёлая коме́дия; *уен-көлкеле сәйран* увеселя́тельная прогу́лка

уен-көлкесез *прил. и нареч.* серьёзный || серьёзно; без шу́ток; *уен-көлкесез әйтәм* говорю́ без шу́ток

уен-көлкечел *прил.* весёлый, весёлого нра́ва, с ю́мором; *уен-көлкечел кеше* челове́к весёлого нра́ва; весельча́к

уенкы *прил.* име́ющий вы́емки, вы́резы, углубле́ния; вы́емчатый; вырезно́й; *~ җир* вы́емчатая земля́; *~ сызыклар* вырезны́е ли́нии

уенлы *прил.* сопровожда́ющийся подви́жными и́грами; игрово́й; *~ җыр* игрова́я пе́сня

уенлык *сущ. разг.* ме́сто для игры́, ме́сто для гуля́нья; гу́льбище *уст.*; *түбәнлектәге ~* гу́льбище, находя́щееся в низи́не; *~ була торган җир* ме́сто для гуля́нья

уенлы-чынлы *прил.* полушутли́вый, полусерьёзный; *уенлы-чынлы сөйләшү* полушутли́вый разгово́р; *уенлы-чынлы аңлашу* полусерьёзное объясне́ние || *нареч. уенлы-чынлы әйтү* сказа́ть полушутя́

уенсыз *нареч. разг.* кро́ме шу́ток, соверше́нно серьёзно; *чын, чын, ~, дөресен әйтәм* пра́вда, кро́ме шу́ток, пра́вду говорю́

уенты *сущ. см.* **уен** 1—2, 4—5

уентык *сущ. см.* **уемтык**

уентылан|у *неперех.* образова́ние (образова́ться) вы́боин, ры́твин, ям, углубле́ний; *бит урталары ~дылар* появи́лись я́мочки на щека́х

уентылы *прил.* **1.** с я́мами, в я́мах, неро́вный, вы́битый, с вы́боинами (*с рытвинами*); *~ юл* вы́битая доро́га; *~ басу* неро́вное по́ле **2.** с я́мами; *аның бит урталары ~ у* неё щёки с я́мочками

уенчак *прил.* игри́вый; шаловли́вый, озорно́й, лука́вый || игру́н *разг.*; шалу́н, озорни́к, лука́вый; *шаян, ~ егет* весёлый, озорно́й па́рень; *~ песи баласы* игри́вый котёнок; *~ караш* лука́вый (*игривый*) взгляд

уенчаклык *сущ.* игри́вость, шаловли́вость., *тавышындагы ~* игри́вость в го́лосе; *аның табигатенә ~ хас* его́ нату́ре прису́ща игри́вость

уенчан *прил. см.* **уенчак**; *~ кеше* игри́вый челове́к; *~ тавыш* игри́вый го́лос

уенчы *сущ.* **1.** игро́к; *җыелма командадан берничә ~* не́сколько игроко́в из сбо́рной; *~лар составы яңарды* соста́в игроко́в обнови́лся **2.** *разг.* музыка́нт; арти́ст; *сәхнәгә ~лар чыкты* на сце́ну вы́шли музыка́нты; *~лар рольләрне бик оста башкардылар* арти́сты испо́лнили ро́ли ма́стерски

уенчык *сущ.* **1.** игру́шка || игру́шечный; *матур ~лар* краси́вые игру́шки; *~ кибете* магази́н игру́шек **2.** укра́шение; *ёлка ~лары* ёлочные украше́ния **3.** *перен.* игру́шка; *усал язмыш кулында ~ка әйләну* преврати́ться в игру́шку у злой судьбы́; *ире кулында ~ булу* быть игру́шкой в рука́х му́жа || *прил. прям., перен.*

игру́шечный; ~ *аю* игру́шечный медвежо́нок; ~ *машина* игру́шечная маши́на; ~ *өй* игру́шечный дом □ ~ **ясаучы (сатучы)** игру́шечник ◊ ~ **кебек (шикелле)** как игру́шка, игру́шечный

уены-чыны(н): **уены-чыны(н) бергә** полушутя́, полусерьёзно; где в шу́тку, где всерьёз; *уены-чыны(н) бергә әйтү* сказа́ть полушутя́, полусерьёзно

уҗарлан|у *неперех. диал.* **1.** разъяря́ться/разъяри́ться, неи́стовствовать **2.** *в знач. нареч.* **уҗарланып** неи́стово; разъярённо; *~ып ташлану* ки́нуться разъярённо

уҗу: **уҗу җитми** *диал.* ника́к ру́ки не дохо́дят

уҗар *прил. диал.* злой, зло́бный, свире́пый; ~ *эт* зла́я соба́ка

уҗарлан|у *неперех. диал.* станови́ться/стать злым, свирепе́ть; рассвирепе́ть, озлобля́ться/озло́биться

уҗау *сущ.* **1.** *ист.* пло́шка свети́льника **2.** *диал.* поло́вник; ~ *белән аш бүлү* разлива́ть поло́вником суп

уҗым *сущ.* **1.** о́зимь, зи́мые *мн.* || зи́мый; ~ *яшәрде* о́зимь позелене́ла; ~ *басуы* зи́мое по́ле; ~ *бодае* зи́мая пшени́ца; ~ *арышы* зи́мая рожь; ~ *уңышы* урожа́й зи́мых; *~нар әйбәт кышлаган* зи́мые хорошо́ перенесли́ зи́му **2.** всхо́ды; *~нар яхшы күренәләр* всхо́ды (о́зими) хоро́шие □ ~ **байгышы (корты)** *зоол.* зи́мая со́вка; ~ **күбәләге** *см.* **уҗым ябалакчыгы**; ~ **күгәрәге (тутыгы)** *бот.* сне́жная пле́сень; ~ **ябалагы (ябалашбашы)** *зоол.* со́вка яровáя ◊ ~ **бозавы** мя́мля, размазня́

уҗымлаштыру *перех. с.-х.* озимизи́ровать || озимиза́ция

уҗымлаштырылу *страд. от* **уҗымлаштыру**; озимизи́роваться

уза: **уза китү** сли́шком далеко́ зайти́; ударя́ться/уда́риться, впада́ть/впасть в кра́йность; хвата́ть/хвати́ть че́рез край; перегиба́ть/перегну́ть па́лку

узаман *сущ.* **1.** завади́ла, зате́йник; коново́д *прост.*; *уенда ~ булу* быть заводи́лой в и́грах **2.** главáрь; *усалның ~ы* злоде́й из злоде́ев

узаманлык *сущ.* главе́нство, коново́дство (*в делах, играх*) □ ~ **итү** **1.** главе́нствовать **2.** води́ть (*в детских играх*)

узардан *нареч. диал. см.* **уздырыштан**; ~ *йөгерү* бежа́ть наперегонки́

узар-узмас, узар-узмастан *нареч.* не прошло́ и ...; *бер ел узар-узмас, узар-узмастан* не прошло́ и го́да; *бер атна узар-узмас* не прошло́ и неде́ли

узгалау *многокр. от* **узу**

узган *прил.* **1.** мину́вший, исте́кший, про́шлый, проше́дший; ~ *заманда* в былы́е времена́; в пре́жние времена́; ~ *көннәр* мину́вшие дни; ~ *елда* в про́шлом году́; ~ *уку елында* в мину́вшем уче́бном году́; ~ *эш* де́ло про́шлое **2.** про́житый; ~ *гомер* про́житая жизнь □ ~ **елгы** прошлого́дний; ~ **заман** *грамм.* проше́дшее вре́мя; ~ **заман хикәя фигыль** проше́дшее вре́мя изъяви́тельного наклоне́ния ◊ ~ **бер** вся́кий встре́чный-попере́чный; ~ **болытны тотып булмый** про́житое что про́литое — не воротишь; ~ **эш** де́ло про́шлое; ~ **эшкә салават** кто ста́рое помя́нет, тому́ глаз вон

узган-барган *прил.* **1.** прохо́жий, прое́зжий, проходя́щий; *узган-барган кешеләр* проходя́щие лю́ди **2.** *в знач. сущ.* 1) прое́зжий, проходя́щий; *узган-барганнарның кайберләре белдеруне укый* не́которые прохо́жие чита́ют объявле́ние 2) вся́кий встре́чный-попере́чный; *һәр узган-барган сине төртеп китә* вся́кий встре́чный-попере́чный тебя́ толка́ет; *узган-барганны карап тору* сиде́ть, рассма́тривая ка́ждого встре́чного-попере́чного

узган-барганда *нареч. см.* **узганда-барганда**

узганда-барганда *нареч.* по пути́, мимохо́дом; прое́здом; *узганда-барганда аңа кереп чыккалау* по пути́ заха́живать к нему́

узгын *предик. сл.* превосхо́дит *кого*; (*индив.*: *похуже, получше; первый*); *козгын баласы козгын, анасыннан ~* (*посл.*) *букв.* детёныш ворóны — ворóна, да ещё похýже, чем мать; *һәр эштә ~* в ка́ждом де́ле — пе́рвый

узгынчы *прил.* **1.** прохо́жий, прое́зжий, проезжа́ющий, зае́зжий; ~ *кеше* зае́зжий челове́к **2.** проходя́щий; вре́менный; ~ *хисләр* проходя́щие чу́вства || *сущ.* **1.** прохо́жий; зае́зжий **2.** стра́нник; *~ны карап калды* проследи́л за прохо́жим; ~ *авылга кереп тормады* стра́нник не стал заходи́ть в дере́вню

уздырту *понуд. от* **уздыру**

уздыр|у *перех.* **1.** пропуска́ть/пропусти́ть *через, мимо*; *күпер аркылы ~у* пропусти́ть че́рез мост; *колак яныннан ~у* пропусти́ть ми́мо уше́й **2.** дава́ть/дать возмо́жность, опережа́ть/опереди́ть (*обойти*); *йөгерүдә ~мау* не дать обойти́ в бе́ге **3.** *перен.* превзойти́, превосходи́ть, перещеголя́ть *кого* **4.** проводи́ть/провести́, корота́ть (*о времени, отпуске*); *вакытны бушка ~магыз* не проводи́те вре́мя впусту́ю **5.** справля́ть/спра́вить (*новоселье, день рождения, свадьбу, поминки, праздники*) **6.** *перен.* переноси́ть/перенести́, переживáть/пережи́ть *что*; *см. тж.* **кичерү** □ **~ып җибәрү** **1.** пропуска́ть/пропусти́ть ми́мо **2.** перещеголя́ть, затыка́ть/заткну́ть за по́яс **3.** перехитри́ть

уздырылу *страд. от* **уздыру**; пропуска́ться (*мимо*), проводи́ться (*о времени*), справля́ться (*о торжественных мероприятиях*)

уздырыш *сущ.* соревнова́ния; *ат ~ы* ко́нные соревнова́ния, ска́чки; *~та катнашу* уча́ствовать в соревнова́ниях

уздырыштан *нареч.* **1.** вперегонки́, вперего́нку; наперегонки́; *әйдә ~* дава́й наперегонки́ **2.** наперебо́й; *~ сөйләү* говори́ть наперебо́й

уздырышу **1.** *взаимно-совм. от* **уздыру** **2.** *в знач. нареч.* **уздырышып** *см.* **уздырыштан**

узел I *сущ.* **1.** у́зел || узлово́й; *почта-телеграф ~ы* почто́во-телегра́фный у́зел; ~ *станциясе* узлова́я ста́нция **2.** *тех.* у́зел (*часть механизма*); *трактор ~ы* у́зел тра́ктора

узел II *сущ. мор.* у́зел (*мера скорости движения судов*); *егерме ~ тизлектә* со ско́ростью в два́дцать узло́в

узмыш **1.** *уст. причастие от* **узу** **2.** *в знач. сущ.* прохожде́ние; ухо́д; *язмыштан ~ юк* от судьбы́ не уйдёшь

уз|у *неперех.* **1.** проходи́ть/пройти́, проезжа́ть/прое́хать; проплыва́ть/проплы́ть; пролета́ть *куда, как, через что* || прохожде́ние, проплыва́ние, пролёт; *җәяү ~у* проходи́ть пешко́м; *бүлмәгә ~у* проходи́ть в ко́мнату; *строй аша ~у* пройти́ че́рез строй **2.** *прям., перен.* минова́ть; *күперне уздык* мы мину́ли мост; *йортларны уздык* прое́хали ми́мо домо́в **3.** обгоня́ть/обогна́ть, перегоня́ть/перегна́ть, объезжа́ть/объе́хать || обго́н, объе́зд; *җәяулеләрне ~у* обогна́ть пешехо́дов; *~у тыела* обго́н запрещён **4.** опережа́ть/опереди́ть || опереже́ние; *ярышта уздык* мы опереди́ли в соревнова́нии **5.** переходи́ть/перейти́ че́рез *что*; *чикне ~у* перейти́ грани́цу; *бусаганы ~у* перейти́ (*через*) поро́г **6.** проходи́ть/пройти́ *по чему*; *авырту умыртка буенча уздык* боль прошла́ по позвоно́чнику; *күз алдыннан бөтен бүгенге көн уздык* пе́ред глаза́ми прошёл весь сего́дняшний день

унөч *числ. колич.* тринáдцать; *~ тирәсендә* гдé-то óколо тринáдцати

унөченче *числ. порядк.* тринáдцатый; *~ гасыр* тринáдцатый век

унпочмак *сущ. мат.* десятиугóльник

унпочмаклы *прил. мат.* десятиугóльный

унсигез *числ. колич.* восемнáдцать; *~ километр* восемнáдцать километ́ров; *~ яшь* восемнáдцать лет

унсигезенче *числ. порядк.* восемнáдцатый; *~ ел* восемнáдцатый год

ýнта *сущ.* унт, ýнты (*меховая обувь*); *~дан йөрү* ходúть в ýнтах

ýнтер *сущ. воен. разг. см.* **унтер-офицер**

ýнтерлык *сущ. разг.* обя́занность ýнтера|| ýнтерский; *~ дәрәҗәсе* ýнтерское зва́ние; *~ нашивкалары* ýнтерские нашúвки

ýнтер-офицер *сущ. воен. ист.* ýнтер-офицéр || ýнтер-офицéрский; *унтер-офицер булып хезмәт итү* служúть ýнтер-офицéром; *унтер-офицер чины* ýнтер-офицéрский чин

ýнтер-офицерлык *сущ. воен. ист.* ýнтер-офицéрство || ýнтер-офицéрский

унтугыз *числ. колич.* девятнáдцать

унтугызынчы *числ. порядк.* девятнáдцатый; *аңа ~ яшь* емý девятнáдцатый год

ун-унбиш *числ. прибл.* дéсять-пятнáдцать; óколо десятú-пятнáдцати; *ун-унбиш минутлар чамасы* приблизúтельно дéсять-пятнáдцать минýт

у́нция *сущ. в разн. знач.* у́нция; *бер ~ алтын* у́нция зо́лота

унъеллык *сущ.* **1.** десятиле́тие; *соңгы ~тагы фән* нау́ка в после́днее десятиле́тие **2.** десятиле́тка; *~ мәктәп* шко́ла-десятиле́тка || *прил.* десятиле́тний; *~ план* десятиле́тний план

унынчы *числ. порядк.* деся́тый; *~ бишьеллык* деся́тая пятиле́тка; *~ көнендә* на деся́тый день; *~ класс укучысы* учени́к деся́того кла́сса; десятикла́ссник

унынчыдан *вводн. сл.* в-деся́тых

уң I *прил.* **1.** *прям., перен.* пра́вый; право-; *уң як* пра́вая сторона́; *уң аяк* пра́вая нога́; *уң колак* пра́вое у́хо; *уң тайпылыш* пра́вый укло́н; *уң партияләр* пра́вые па́ртии; *уң флангтагы* правофланго́вый **2.** 1) лицево́й; *тукыманың уң ягы* лицева́я сторона́ тка́ни 2) *в знач. сущ.* лицева́я сторона́, верх (мате́рии); *тукыманың уңы* лицева́я сторона́ тка́ни; *уңын сулга әйләндерү* перелицева́ть (мате́рию) □ **уң кулда (уң кул якта)** спра́ва, с пра́вой стороны́; на пра́вой стороне́; **уң як** право-; **уң як яр буендагы** правобере́жный; **уң як хәрәкәте** правосторо́ннее движе́ние; **уң якка** впра́во, напра́во ◊ **уңга (да), сулга (да)** напра́во и нале́во; **уңнан да, сулдан да** спра́ва и сле́ва, со всех сторо́н; **уң кулы (канаты)** пра́вая рука́, опо́ра; са́мый надёжный челове́к; *ул аның уң кулы* он пра́вая рука́; *уң кулың булыр идем* я был бы тебе́ опо́рой; **уң күзе** са́мый бли́зкий челове́к

уң II *прил.* уда́чный, успе́шный; *эшләрегез ~ булсын* пусть бу́дут успе́шными ва́ши дела́; *юлларыгыз уң булсын* счастли́вого пути́

уңагай *прил. редко* правору́кий || правша́

уңаена *послелог* по; *агым ~ йөзү* плыть по тече́нию; *җил ~* по ве́тру; *юл ~ керү* зайти́ по пути́ || *нареч.* **1.** хо́дом; *атны үз уңаена җибәрү* пусти́ть ло́шадь свои́м хо́дом **2.** в такт; *адым ~* в такт ходьбы́; *атның ялкау гына атлавы ~* в такт лени́вым шага́м ло́шади

уңаенда *послелог* к; *сүз ~* к сло́ву

уңа|й *прил.* **1.** удо́бный, сподру́чный; *~й урын* удо́бное ме́сто; *~й позиция* удо́бная пози́ция; *эшкә ~й кием* удо́бная для рабо́ты оде́жда **2.** удо́бный благоприя́тный, подходя́щий; *~й вакыт туры китереп* улучи́в подходя́щий моме́нт; *~й вакытта* в удо́бное вре́мя **3.** удо́бный, нала́женный; *~й тормыш* удо́бная (нала́женная) жизнь **4.** положи́тельный, утверди́тельный; позити́вный; *~й җавап* утверди́тельный отве́т; *~й бәяләмә алу* получи́ть положи́тельный о́тзыв; *мәсьәләнең ~й ягы* положи́тельная сторона́ вопро́са **5.** положи́тельный; вполне́ хоро́ший; *бик ~й кеше* о́чень положи́тельный челове́к; *~й үрнәк* положи́тельный приме́р; *~й сыйфатлар* положи́тельные ка́чества **6.** *спец.* положи́тельный; *~й корылма физ.* положи́тельный заря́д; *~й саннар* положи́тельные чи́сла; *~й герой лит.* положи́тельный геро́й **7.** прие́млемый, досту́пный, схо́дный, вы́годный; *~й шартлар* прие́млемые усло́вия; *үзеңә ~й эш эзләү* иска́ть себе́ вы́годную рабо́ту || *нареч.* **1.** удо́бно, сподру́чно, с руки́; *үзләреңә ничек ~й, шулай эшлилләр* они́ де́лают так, как им сподру́чно **2.** вы́годно, на́ руку; *каршы килүе миңа бик ~й булды* его́ отка́з оказа́лся мне на́ руку **3.** положи́тельно, утверди́тельно; позити́вно; *мәсьәләне ~й хәл итү* реши́ть вопро́с положи́тельно **4.** в лу́чшую сто́рону, лу́чше; *үзен ~й хис итү* чу́вствовать себя́ (по)лу́чше **5.** прие́млемо, досту́пно, схо́дно (*о цене*) || *сущ. в косв. п.* **1)** направле́ние, сторона́; *Әтнә, Мәңгәр — һәммәсе бер ~да* Атня́, Менге́р — все в одно́м направле́нии (*на одной стороне*) 2) лад; *эшләр ~йга китте* дела́ пошли́ на лад 3) вре́мя; *кичке ~йда* в вече́рнее вре́мя; *җәйге ~йда* в ле́тнее вре́мя, ле́том □ **~е белән** в связи́; по слу́чаю; *бәйрәм ~е белән* в связи́ с пра́здником, по слу́чаю пра́здника; **~е килгәндә (уңае килгән саен)** в подходя́щий моме́нт; **~ен карау** ка́к бы; *качу ~ен карау* ка́к бы убежа́ть; **~ен табу** найти́ подходя́щий (удо́бный) моме́нт ◊ **~ена тору** не пере́чить; не идти́ про́тив; гла́дить по ше́рсти; **~й килү** везти́/повезти́, посчастли́виться

уңайга *послелог* **1.** с; *килгән ~* с хо́ду **2.** *в знач. союза* как то́лько; *ул әйткән ~ үк без йөгердек* мы побежа́ли сра́зу же, как то́лько он сказа́л

уңайдан *нареч.* попу́тно; по пути́; (*бер*) *~ безгә дә кереп чык* попу́тно зайди́ и к нам

уңайландыру *перех.* де́лать/сде́лать удо́бным

уңайлан|у *возвр. от* **уңайлау 1.** становя́ться/стать удо́бным; *юл ~ды* доро́га ста́ла удо́бной **2.** нала́живаться/нала́диться, устра́иваться/устро́иться; *тормыш акрынлап ~а бара* постепе́нно жизнь нала́живается; *эш ~ды* де́ло нала́дилось **3.** поправля́ться/попра́виться, улучша́ться/улу́чшиться; *аның хәле ~ды* состоя́ние его́ улу́чшилось

уңайлап *нареч.* удо́бно, поудо́бнее; *~ утыру* сесть поудо́бнее

уңайлату *перех. см.* **уңайландыру**

уңайлау *перех.* **1.** де́лать/сде́лать, поправля́ть/попра́вить *что*; *мендәрне ~* попра́вить поду́шку **2.** нала́живать/нала́дить, улучша́ть/улу́чшить || нала́живание, улучше́ние; *эшне ~* нала́дить рабо́ту **3.** приспоса́бливать/приспосо́бить, устра́ивать/устро́ить *что* || приспоса́бливание

уңайлаштыру *перех. см.* **уңайлау**

уңайлаш|у *неперех. см.* **уңайлану**; *яшәү шартлары ~у* улучше́ние усло́вий жи́зни; *эшләр ~ты* дела́ нала́дились; дела́ пошли́ на лад

уңайлы *прил.* **1.** удо́бный, сподру́чный; подходя́щий; *бик ~ көрәк* о́чень удо́бная лопа́та; *~ юл* удо́бная доро́га; *синнән дә ~ кеше тапмадык* не нашли́ бо́лее подходя́щего челове́ка, чем ты **2.** ую́тный, комфорта́бельный; *җылы һәм ~ булмә* тёплая и ую́тная ко́мната **3.** благоприя́тный; *~ шартлар* благоприя́тные усло́вия **4.** удо́бный, подходя́щий; *~ моментта* в подходя́щий моме́нт; *~ вакыт* удо́бное вре́мя; *~ урын* подходя́щее ме́сто || *в знач. нареч.* удо́бно, ло́вко, сподру́чно; *~ утыру* удо́бно сиде́ть

уңайлы|к *сущ.* **1.** удо́бство, комфо́рт; *бөтен ~клары булган квартира* кварти́ра со все́ми удо́бствами **2.** лад, нала́женность; *эш ~гы* нала́женность рабо́ты

уңайлыландыру *понуд. от* **уңайлану**; де́лать/сде́лать удо́бным

уңайлылану *неперех. см.* **уңайлану**

уңайлылы|к *сущ.* **1.** удо́бство; *~к өчен* для удо́бства **2.** удо́бство, комфо́рт, уют; удо́бность; комфорта́бельность; *яңа квартираның ~гы* удо́бство но́вой кварти́ры **3.** благоприя́тность, благоприя́тное усло́вие; *уку өчен барлык ~клар тудыру* созда́ть все усло́вия для учёбы

уңайсыз *прил.* **1.** неудо́бный; *~ урын* неудо́бное ме́сто **2.** нело́вкий; *~ паузадан соң* по́сле нело́вкой па́узы; *~ хәл* нело́вкое положе́ние; *~ хәлдә калдыру* оста́вить в нело́вком положе́нии **3.** неблагоприя́тный; *~ шартлар* неблагоприя́тные усло́вия **4.** неподходя́щий, неудо́бный; *~ вакытта* в неподходя́щий моме́нт **5.** *предик. сл.* неудо́бно; нело́вко; *әйтергә дә ~* неудо́бно и сказа́ть; *кешедән ~* неудо́бно от люде́й (пе́ред людьми́) || *нареч.*

неудóбно; ~ *егылу* нелóвко упáсть; *бу ботинка белән йөрергә* ~ в э́тих ботúнках неудóбно ходúть □ ~ **булмаса (~ димәсәгез)** éсли вас не затрудни́т

уңайсызландыру *понуд. от* **уңайсызлану**; стесня́ть/стесни́ть; конфу́зить; ста́вить/поста́вить в нелóвкое положéние

уңайсызлан|у *возвр. от* **уңайсызлау 1.** смуща́ться/смути́ться, стесня́ться/стесни́ться, постесня́ться, конфу́зиться/сконфу́зиться; чу́вствовать/почу́вствовать нелóвкость (неудóбство) || смущéние, стеснéние; *~ыр идең бераз* хоть бы постеснялся; *күренергә ~у* стесня́ться показа́ться; *ул сезнең янга чыгарга ~а* онá стесня́ется вы́йти к вам; *безнең ~уны сизү* почу́вствовать нáше смущéние **2.** затрудня́ться/затрудни́ться, тяготи́ться *чем, чего*; *йомыштан ул ~ды* он тяготúлся э́тим поручéнием

уңайсызлату *перех. см.* **уңайсызлау**

уңайсызл|ау *перех.* **1.** мешáть/помешáть, затрудня́ть/затрудни́ть || затруднéние; *сулыш алырга ~ау* затрудня́ть дыхáние; *хәрәкәтләнергә ~ый* затрудня́ет движéние **2.** стесня́ть/стесни́ть *кого* || стеснéние **3.** *редко* беспокóить/обеспокóить, трево́жить *кого*

уңайсызлы|к *сущ.* **1.** неудóбство; *урынның ~гы* неудóбство мéста **2.** нелóвкость, нелóвкое положéние, стеснéние; *~к сизү* чу́вствовать нелóвкость **3.** *редко* затруднéние, тру́дность; *эштәге ~клар* затруднéние в рабóте; *азык-төлек белән тәэмин итүдә ~клар* тру́дности в обеспечéнии проду́ктами питáния

уңалдыру *перех. диал.* залéчивать/залечúть *что* || залéчивание

уңалмас(лык) *прил. диал.* неизлечúмый; *~ җәрәхәт* неизлечúмая рáна

уңал|у *неперех. диал.* поправля́ться/попрáвиться, выздорáвливать/вы́здороветь, вылéчиваться/вы́лечиться, излéчиваться/излечúться, исцеля́ться/исцели́ться; становúться/стать нá ноги; *кылыч ярасы ~ыр, тел ярасы ~мас (посл.)* сáбельная рáна излечúма, а рáна, нанесённая языкóм, неизлечúма

уңаш *сущ. диал.* согласовáние (*планов, дел*)

уңаштыру *понуд. от* **уңашу**

уңашу *неперех. диал.* согласовáть, согласовáться || согласовáние (*дел*); *киңәшү һәм ~* совéтоваться и согласóвывать

уңга *нареч.* впрáво, напрáво; *~ бору* повернýть впрáво; *~ борылу* свернýться напрáво; *~ тайпылу* уклони́ться впрáво; *~ да, сулга да* напрáво и налéво

уңган I *прил.* **1.** дéльный, деловóй, делови́тый, дéятельный; *~ кеше* дéльный человéк **2.** умéлый, лóвкий, спосóбный; *~ бала* спосóбный ребёнок; *~ куллар* умéлые рýки

уңган II *прил.* линя́лый, слиня́вший; блéклый, вы́цветший; потеря́вший свой первонача́льный цвет, вы́горевший; *~ күлмәк* вы́цветшая рубáха; *~ төс* блéклый цвет

уңганлык *сущ.* дéльность, делови́тость, лóвкость, умéние, умéлость; *~ сыйфаты* свóйство делови́тости

уңга-сулга *нареч. прям., перен.* напрáво и налéво; *рульне уңга-сулга бору* поворáчивать руль впрáво и влéво; *уңга-сулга акча туздыру* сори́ть деньгáми напрáво и налéво □ **уңга-сулга карамый(ча)** **1.** ничегó не замечáя, ничегó не разбирáя **2.** очертя́ гóлову; **уңга-сулга карап** с огля́дкой, учúтывая (окружáющие) услóвия

уңдыр|у I *перех.* **1.** спосóбствовать подня́тию урожáйности; *тирес иген ~а* навóз поднимáет урожáйность зернá **2.** спосóбствовать подня́тию кáчества тéста; *кипкән чүпрә камырны ~мый* вы́сохшие дрóжжи не поднимáют тéста **3.** приготáвливать/приготóвить кáчественную пúщу; *ипине ~у* испéчь вкýсный хлеб

уңдыру II *понуд. от* **уңу**; подвергáть/подвéргнуть дéйствиям сóлнечных лучéй; спосóбствовать линя́нию, потéре первонача́льного вúда

уңдыручан *прил. см.* **уңдырышлы**; *~ туфрак* плодоро́дная пóчва

уңдыручанлы|к *сущ. с.-х.* плодоро́дие, плодоро́дность, урожáйность; *туфракның ~гы* плодоро́дие пóчвы

уңдырышлы *прил.* плодоро́дный; *~ туфрак* плодоро́дная пóчва; *~ җирләр* плодоро́дные зéмли

уңдырышлылы|к *сущ.* **1.** плодоро́дность, плодоро́дие; *туфракның ~гы* плодоро́дие пóчвы **2.** урожáйность, продукти́вность; *яшелчәләрнең ~гын арттыру* повы́сить урожáйность овощéй

уңлашу *неперех. полит.* правéть/поправéть, становúться/стать бóлее прáвым (*о партиях, общественных организациях и их отдельных деятелях*)

уңкы *сущ.* **1.** *диал.* 1) кольцó (*на ремне*) 2) заклёпка **2.** *перен.* союз сосéдей, совмéстно обрабáтывающих свои́ зéмли; круг испóльщиков; звенó

уңкыдаш *сущ.* тот, кто совмéстно обрабáтывает свою́ зéмлю; сотовáрищ по крýгу испóльщиков

уңлы-суллы *нареч.* **1.** *прям., перен.* напрáво и налéво; то напрáво, то налéво; *акчаны уңлы-суллы чәчү* раздавáть (трáтить) дéньги напрáво и налéво **2.** *прям., перен.* спрáва и слéва, со всех сторóн; *уңлы-суллы яңаклау* бить по щекáм спрáва и слéва; *уңлы-суллы тәнкыйтләү* критиковáть со всех сторóн

уңлы-тиресле *нареч. диал.* шúворот-навы́ворот; *уңлы-тиресле эшләү* дéлать шúворот-навы́ворот

уңмаган *прил. неодобр.* бестолкóвый, тупóй, неумéлый, неспосóбный, нелóвкий; *шуны да эшли алмыйсың, ~ !* дáже э́то не мóжешь вы́полнить, бестолкóвый!

уңмаганлык *сущ.* бестолкóвость, тýпость; неумéлость, неумéние, нелóвкость, неспосóбность

уңнар *сущ. полит.* прáвые *мн.* || прáвый; *~ партиясе* пáртия прáвых, прáвая пáртия

уң-сул *сущ. собир.* верх (*лицевая сторона*) и изнáнка *чего-л.*; *тукыманың уңы-сулы бер* верх и изнáнка ткáни одинáковые ◊ **уңны-сулны аермау (абайламау, белмәү)** ничегó не смы́слить; не знать где прáво, где лéво; **уңны-сулны белмәү** ничегó не признавáть; **уңны-сулны карамыйча (белмичә, күрмичә)** *см.* **уңга-сулга карамыйча**

уң|у I *перех.* **1.** роди́ться, уроди́ться; *монда бәрәңге яхшы уңа* здесь хорошó роди́тся картóфель; *быел карабодай яхшы уңды* в э́том годý гречúха хорошó уроди́лась **2.** удава́ться/уда́ться, получáться/получúться удáчным; *камыр уңды* тéсто удалóсь; *юл уңды* пое́здка былá удáчной **3.** *с исх. п.* везти́/повезти́; *ул мал-туардан уңды* емý повезлó со скотóм; *хатыннан уңу* удáчно жени́ться, повезти́ с женóй ◊ **я уңам, я туңам** (*погов.*) и́ли пан, и́ли пропáл

уң|у II *неперех.* линя́ть/полиня́ть; выцвета́ть/вы́цвести, выгора́ть/вы́гореть; теря́ть/потеря́ть первонача́льный цвет; *уңган гимнастёрка* вы́линявшая гимнастёрка; *ялулык кояшта уңды* платóк вы́горел на сóлнце

уңучан *прил.* линю́чий

уңучанлык *сущ.* линю́честь

уңыш *сущ.* **1.** урожáй; *начар* ~ плохóй урожáй; *~ бирү* дава́ть урожáй; *~ алу* получáть урожáй **2.** успéх, удáча, достижéние; зур *~ка ирешү* доби́ться высóких

успе́хов; *укудагы ~лар* успе́хи в учёбе; ~ *бәйрәме* пра́здник урожа́я; *~ка очраучан* уда́чливый; ~ *казану* доби́ться успе́ха

уңышлы *прил.* 1. урожа́йный; ~ *ел* урожа́йный год 2. успе́шный, уда́чный; ~ *операция* успе́шная (уда́чная) опера́ция; ~ *җырлар* уда́чные пе́сни || *нареч.* успе́шно, уда́чно; благополу́чно; *имтиханнарны ~ тапшыру* успе́шно сдать экза́мены; ~ *эшләнгән* сде́лано уда́чно; ~ *бетте* зако́нчилось уда́чно □ ~ **булу** быть успе́шным, име́ть успе́х; ~ **итеп** 1. успе́шно 2. благополу́чно; ~ **чыгу** благополу́чно разреши́ться 3. *перен.* повезти́

уңышлык *сущ.* успе́х, уда́ча; *зур ~лар телим* жела́ю больши́х успе́хов

уңышлылык *сущ.* 1. урожа́йность 2. успе́шность

уңышсыз *прил.* неуда́чный, безуспе́шный; неблагополу́чный; ~ *фоторәсем* неуда́чный фотосни́мок; ~ *җавап* неуда́чный отве́т; ~ *атака* неуда́чная ата́ка; ~ *фразалар* неуда́чные фра́зы || *нареч.* неуда́чно, безуспе́шно, неблагополу́чно; ~ *чыкты* получи́лось неуда́чно

уңышсызлык *сущ.* неуда́ча, неуспе́х; ~ *белән* неуда́чно; *~ка очрау* терпе́ть неуда́чу (*фиаско*)

уңыш-табыш *сущ. собир.* дохо́д, при́быль, бары́ш, вы́года; *уңыш-табышны бергә бүләләр* дохо́д де́лят все вме́сте

упкын *сущ.* 1. *прям., перен.* про́пасть, бе́здна; расще́лина; прова́л; *сулда — коточкыч ~* нале́во — стра́шная про́пасть; *алар арасында тирән ~* ме́жду ни́ми глубо́кая про́пасть 2. пучи́на, о́мут, водоворо́т; *ул ~га эләккән* он попа́л в водоворо́т; *диңгез ~ы* морска́я пучи́на

упкынлы *прил.* име́ющий про́пасть, про́пасти (*бездны*); име́ющий о́мут (*омуты*)

управа *сущ. ист.* управа́ (*учреждение, контора*); *земский ~* зе́мская управа́; *шәһәр ~сы* городска́я управа́

управдом *сущ. разг.* управдо́м (*управляющий домами*)

управля́ющи|й *сущ.* управля́ющий; *совхоз ~е* управля́ющий совхо́зом; *трест ~е* управля́ющий тре́стом

уптым *нареч. разг.* о́птом; гурто́м || опто́вый; ~ *сату* продава́ть о́птом; продава́ть гурто́м; ~ *сату бәяләре* опто́вые це́ны ◊ ~ **илаһи** 1. целико́м, гурто́м 2. огу́льно; ~ *илаһи гаепләү* огу́льно обвиня́ть

упчу *неперех. диал.* 1. мо́рщиться, съёживаться (*о плёнке на молоке, супе и т. п.*) 2. перекиса́ть (*с образованием плёнки на поверхности*)

ур *сущ.* 1. вал (*со рвом*) 2. *диал.* ко́паный ров; око́п; глубо́кая кана́ва; *ур казу* вы́копать ров

ура *межд.* 1. *воен.* ура́ (*боевой клич при атаке*); *минем арттан! ура!* за мной! ура́! 2. ура́ (*восклицание, выражающее одобрение, восторг*); *Салиховка ура!* Са́лихову ура́! ◊ **ура кычкырып** на ура́; **урага күтәрү** на ура́

уравыч I *прил.* 1. кругово́й; око́льный, обходно́й, не прямо́й; *см. тж.* **урау** II; ~ *юл* око́льный путь; ~ *юл белән* кружны́м путём 2. *в знач. нареч.* **уравычтан** в обхо́д, в объе́зд; *~тан йөрү* е́здить в объе́зд; ходи́ть в обхо́д || *сущ.* обхо́д, объе́зд; *см. тж.* **әйләнеч**; ~ *ясау* де́лать обхо́д (объе́зд)

уравыч II *сущ.* о́нучи, портя́нки; *ул ак ~лардан* он в бе́лых портя́нках; *~ларны киптерергә кую* пове́сить о́нучи суши́ться

урагыч *сущ.* мотови́ло; *комбайн ~ы* мотови́ло комба́йна; *җеп ~* мотови́ло для нама́тывания пря́жи

ураз *сущ.* 1. *уст.* сча́стье, уда́ча 2. *миф. см.* **уразман** ◊ ~ **уты** *бот.* лаба́зник шестилепестно́й

ураза *сущ. рел.* 1. ураза́, мусульма́нский пост; *уны-сында ~га керәләр* с деся́того начина́ется ураза́ 2. ме́сяц рамаза́н (*девятый месяц мусульманского лунного года*); *~да гошер бирү* дать ми́лостыню в ме́сяц рамаза́н 3. *перен.* пост, го́лод; *көне буе ~мы?* ты це́лый день голо́дный? □ ~ **ачу** прекрати́ть гове́ть (*поститься*), разгове́ться; ~ **бәйрәме (гаете)** пра́здник поста́ (*отмечается по окончании поста*); ~ **тоту** 1. пости́ться, гове́ть, соблюда́ть (*блюсти*) пост 2. *перен.* голода́ть; ~ **тотучы** пости́щийся, соблюда́ющий пост; *~га керү* 1. о наступле́нии уразы́ 2. нача́ть гове́ть, пости́ться

уразман *сущ. миф.* бог сча́стья

урай *сущ.* 1. *см.* **ур** 2. *ист.* крепостно́й вал

урак *сущ.* 1. серп; ~ *йөзе* ле́звие серпа́; ~ *тешләре* зу́бчики серпа́; ~ *тешәү* зу́брить серп 2. жа́тва; *~ны тизрәк бетерү* скоре́е зако́нчить жа́тву; *~ка төшү* приступи́ть к жа́тве □ ~ **машинасы** *с.-х.* жа́тка, жне́йка; ~ **өсте** 1. жа́тва 2. *прям., перен.* страда́, стра́дная пора́; ~ **сабы** серпови́ще, рукоя́тка серпа́; ~ **уру** 1. жать (*хлеб*) 2. жа́тва; ~ **уручы** *см.* **ураксы**

ураксыман *прил.* серпови́дный; ~ *ай* серпови́дная луна́ □ ~ **мөгезбаш** *бот.* рогогла́вник серпови́дный (*трава*)

урак-чүкеч *сущ.* серп и мо́лот (*эмблема*)

ураксы *сущ.* жнец, жни́ца; жне́я; *~лар уралар да уралар* жнецы́ всё жнут да жнут □ ~ **хатын (кыз)** жни́ца

уралма *сущ.* вито́к; *тимерчыбык ~сы* вито́к про́волоки *прил.* 1. вью́щийся; ~ *сабаклар* вью́щиеся стебельки́; ~ *үсемлекләр* вью́щиеся расте́ния 2. *бот.* вьюнко́вый (*о растениях*) □ ~ **көпшә** *тех.* змееви́к; ~ **сабаклылар** *бот.* вьюнко́вые

уралмалы *прил.* 1. вью́щийся, вьюнко́вый 2. змееви́дный; ~ *көпшә* змееви́дная труба́ □ ~ **кырлач** *бот.* гречи́шка вьюнко́вая (*сорная трава*)

урал|у 1. 1) *страд.-возвр. от* **урау**; мота́ться, нама́тываться/намота́ться; навора́чиваться/навёртываться, обма́тываться/обмота́ться (*само собой*) || нама́тывание, обма́тывание *чем*; *башы бинт белән ~ган* голова́ у него́ обмо́тана бинто́м; *канат барабанга ~ган* кана́т намота́лся на бараба́н 2) навива́ться/нави́ться; накру́чиваться/накрути́ться || накру́чивание 3) обвива́ться/обви́ться; сплета́ться/сплести́сь 4) завора́чиваться, обвёртываться, упако́вываться || за́ворот; *эчәкләр ~у* за́ворот кишо́к 5) оку́тываться/оку́таться; *тузан белән ~у* оку́тываться пы́лью 2. запу́тываться/запу́таться *в чём*; *бозау арканга ~ган* телёнок запу́тался в арка́не 3. *перен.* пу́таться между *кем, чем*, крути́ться, верте́ться около *кого-л.*; пу́таться под нога́ми, меша́ть; *бала әнисе янында ~а* ребёнок ве́ртится во́зле ма́тери □ ~**ып бетү** 1. перевива́ться 2. запу́таться; ~**ып үсү** ви́ться, перевива́ться (*о растениях*)

уралучан *прил.* вью́щийся (*о растениях*)

уралчык I *сущ. бот.* завито́к

уралчык II *прил. см.* **уралучан**

урам I *сущ. в разн. знач.* у́лица || у́личный; *үзәк ~* гла́вная у́лица; ~ *аркылы чыгу* перейти́ че́рез у́лицу; *бөтен ~ны аякка бастыру* подня́ть всю у́лицу на́ ноги; ~ *тәэсире* (*дурное*) влия́ние у́лицы; ~ *коесы* у́личный коло́дец □ ~ **әйләнү** прогуля́ться (пройти́сь) по у́лице; ~ **башы** 1. нача́ло у́лицы 2. око́лица; ~ **буе** 1. у́лица 2. малокульту́рная среда́; ~ **буена** по всей у́лице; ~ **ишеге** пара́дная, пара́дный вход; ~ **саен** на ка́ждой у́лице; ~ **ташы** булы́жник; ~ **тыкрыгы** переу́лок; проу́лок; ~ **үләне** *бот.* гречи́шка пти́чья; ~ **чаты** перекрёсток; ◊ ~ **авыз** сплётник, болту́н; ~ **әдәбияты** 1. вульга́рная литерату́ра; жёлтая пре́сса 2. лубо́чная литерату́ра;

~ баласы (малае) у́личный (невоспи́танный) мальчи́шка; **~ кызы** у́личная де́вка, проститу́тка; **~ себеркесе (тастымалы)** шлю́ха; **~ сүзе 1.** площадна́я брань **2.** сплéтни, слу́хи; **~ теле 1.** у́личный (вульга́рный) язы́к **2.** брань; **~ телендэ 1.** по-наро́дному **2.** среди́ наро́да, в наро́де; **~ тутырып 1.** на всю у́лицу; **~ *тутырып кычкыру*** крича́ть на всю у́лицу **2.** на всю ширину́ у́лицы; **~ *тутырып йөрү*** ходи́ть, занима́я всю ширину́ у́лицы; **~ уртасында калдыру 1.** оста́вить без присмо́тра **2.** оста́вить без кола́ и двора́; **~ хәбәре** у́личные спле́тни; **~ эте 1.** броди́чая соба́ка **2.** бося́к, хулига́н; **~га чыгарып ташлау 1.** вы́гнать (вы́бросить, вы́кинуть) на у́лицу **2.** оста́вить без кола́ и двора́; **~да (~ уртасында) калу** оказа́ться (очути́ться) на у́лице **3.** быть бро́шенным на у́лицу

урам II *сущ. редко* мото́к, вито́к; *тимерчыбык ~ы* мото́к про́волоки; *спираль ~ы* вито́к спира́ли; *бер ~ җеп* мото́к ни́ток

урама *сущ.* **1.** обмо́тка, обвя́зка **2.** *кул.* урама́ (*национальное мучное изделие в виде свёрнутых в трубку лент сдобного теста, жаренных в масле*); *~ пешерү* испе́чь урами́

урамал *сущ.* **1.** *диал.* плато́к **2.** тёплый плато́к осо́бого ви́да

урамдаш *сущ.* челове́к с одно́й у́лицы; *без аның белән ~лар* мы с ним с одно́й у́лицы

ура́мча *нареч.* **1.** по-у́личному, простонаро́дно; вульга́рно; *~ сөйләшү* говори́ть по-у́личному **2.** *в знач. прил.* у́личный, вульга́рный; *~ гадәтләр* у́личные пова́дки

урамчалаштыру *перех. разг.* вульгаризи́ровать || вульгариза́ция; *телне ~* вульгаризи́ровать язы́к

уран *сущ. хим.* ура́н || ура́новый; *~ рудасы* ура́новая руда́

уран|у *возвр. от* **урау 1.** ку́таться/заку́тываться/заку́таться, уку́тываться/уку́таться, завора́чиваться/завёртываться, обма́тываться/обмота́ться || заку́тывание, уку́тывание; завёртывание, обма́тывание; *мамык шалгә ~у* уку́таться в пухо́вый плато́к; *~ып яту* лежа́ть заку́тавшись **2.** оку́тываться/оку́таться

ура-патриотлык *сущ.* ура́-патриоти́зм; *ура-патриотлык белән ерак китеп булмый* на ура́-патриоти́зме далеко́ не уе́дешь

ураткыч *прил.* кру́жный, обходно́й; *~ юл белән* кружны́м путём

ураттыру *понуд. от* **урату** 1, **урау** 3—5

урат|у 1. *понуд. от* **урау** 1—2 **2.** *перех.* отгора́живать/отгороди́ть, ограждáть/огради́ть *что чем*; *бакчаны койма белән ~у* огради́ть огоро́д забо́ром **3.** окружа́ть/окружи́ть, обступа́ть/обступи́ть; *сугышчылар аны ~ып алдылар* бойцы́ обступи́ли его́ **4.** обходи́ть, объе́хать, объе́здить *что*; *бакчаны ~ып чыгу* обойти́ сад; *күлне ~у* объе́хать о́зеро **5.** *в знач. нареч.* **уратып 1)** кру́жным путём, в обхо́д, в объе́зд; *~ып бару* пое́хать кру́жным путём; *~ып йөрү* ходи́ть (е́здить) в обхо́д (в объе́зд) **2)** круга́ми по спира́ли; *~ып буяу* кра́сить круга́ми по спира́ли (*стойки крыльца*) □ **~ып алу 1.** отгороди́ть, огради́ть **2.** окружи́ть, обступи́ть **3.** оцепи́ть; *мәйданны ~ып алу* оцепи́ть пло́щадь ◊ **~ып сөйләү** говори́ть намёками; нача́ть разгово́р издалека́

уратыл|у *страд. от* **урату**; огора́живаться/огороди́ться; быть огоро́женным; *текмә белән ~ган* огоро́жен ты́ном (частоко́лом)

ура|у I *перех.* **1.** мота́ть, нама́тывать/намота́ть *что на что* || нама́тывание; *йонны йомгакка ~у* мота́ть шерсть в клубо́к; *чолгау ~у* намота́ть портя́нки; *кәтүккә җеп ~у* нама́тывать ни́тки на кату́шку **2.** обма́тывать/обмота́ть, навива́ть/нави́ть, накру́чивать/накрути́ть, обнива́ть/обви́ть || обма́тывание, обмо́тка, навива́ние, накру́чивание; *барабанга канатны ~у* накрути́ть кана́т на бараба́н; *муенын шарф белән ~у* обмота́ть ше́ю ша́рфом; *чүпрәк белән ~у* обмота́ть тря́пкой **3.** завёртывать/заверну́ть, обёртывать/оберну́ть *что во что* || завёртывание, обёртывание; *сөлгегә ~у* заверну́ть в поло́тенце; *кәгазь белән ~у* оберну́ть бума́гой **4.** ку́тать, заку́тывать/заку́тать, уку́тывать/уку́тать, оку́тывать/оку́тать || заку́тывание, уку́тывание, оку́тывание; *шәлгә ~у* уку́тывать в шаль **5.** окружа́ть/окружи́ть, охва́тывать/охвати́ть, обступа́ть/обступи́ть *кого* || окруже́ние, охва́тывание; *гаскәр белән ~у* окружи́ть войска́ми **6.** обходи́ть, объе́хать; ходи́ть кру́жным путём; *бакчаны ~у* обходи́ть сад □ **~п алу** окружи́ть, обступи́ть *кого, что*; **~п алыну** быть окружённым, попа́сть в окруже́ние; **~п кайту 1.** прие́хать кру́жным путём **2.** соверши́ть проги́лку; прогуля́ться **3.** обойти́, пройти́сь; **авылны ~п кайттым** я обошёл всю дере́вню; **~п үтү** объе́хать, обойти́; **~п чыгу** обходи́ть, обойти́

урау II *прил.* обхо́дный, кру́жный; *~ юл* обхо́дный путь

ураулы *прил.* **1.** кру́жный, обхо́дный; *~ юл* кру́жный путь **2.** изви́листый

ураулык *сущ.* кру́жный путь

урашу *взаимно-совм. от* **урау**

урбанизм *сущ.* урбани́зм; *сәнгатьтәге ~* урбани́зм в иску́сстве

урбанист *сущ.* урбани́ст (*сторонник урбанизма*)

урбани́стик *прил.* урбанисти́ческий; *~ музыка* урбанисти́ческая му́зыка; *~ поэзия* урбанисти́ческая поэ́зия

урбанистлык *сущ.* урбани́зм || урбанисти́ческий; урбани́стский

ург|у *неперех. разг. см.* **ургылу**; *моржадан төтен ~ый* из трубы́ ва́ли́т дым; *астан су ~ый* вода́ бьёт ключо́м

ургыл *сущ.* быстрина́; стремни́на; стре́жень; *~ өстендәге күбекләр* пе́на на стремни́не

ургыллык *сущ.* **1.** *см.* **ургыл 2.** перека́т

ургыл|у 1. рва́ться, порыва́ться, устремля́ться/устреми́ться || рве́ние, поры́в, устремле́ние; *тишектән су ~у* вода́ рвётся в пробо́ину; *атлар алга ~дылар* ко́ни устреми́лись вперёд **2.** бурли́ть, бушева́ть, клокота́ть || бурле́ние, клокота́ние; *аста су ~а* внизу́ клоко́чет вода́ **3.** бить, изверга́ться || бие́ние, изверже́ние; *лава ~у* изверже́ние ла́вы **4.** вали́ть, вало́м вали́ть; *тәрәзәдән ~ып төтен чыга* дым ва́ли́т из окна́; *кешеләр ташкыны мәйданга ~ды* людско́й пото́к повали́л на пло́щадь □ **~ып кайнау** клокота́ть; кипе́ть с клокота́нием

ургылып-ургылып *нареч.* **1.** ключо́м, с клокота́нием, с бурле́нием; бурля́, клокоча́; *ургылып-ургылып су ага* вода́ бьёт ключо́м **2.** вало́м; *төтен ургылып-ургылып чыга* дым вали́т вало́м

ургылыш *сущ.* **1.** бурле́ние, бу́рное клокота́ние **2.** изверже́ние

ургылышу *совм. от* **ургылу** (*о многих*)

ургыч *сущ. с.-х.* жа́тка, жне́йка; лобогре́йка; *лафетлы ~* лафе́тная жа́тка; *биредән ~ узган* здесь прошла́ жа́тка □ **~ машина** лобогре́йка

урда *сущ. ист.* **1.** ха́нская ю́рта, пала́тка прави́теля **2.** орда́ (*государство кочевников*) || ордынский; *Алтын Урда* Золота́я Орда́

урдачы *сущ. ист.* ордынец, представитель орды, житель орды

урду *сущ.* урду́ (*государственный язык Пакистана, один из официальных языков Индии*); *~ теле* язык урду́

урдык *сущ. диал.* 1. *см.* **сәке** 2. ткацкий стано́к

урдыру *понуд. от* **уру**

уремия *сущ. мед.* уремия || уремический; *~дән саклану чаралары* средства предосторожности от уремии; *~ авыруы* уремическое заболевание

уркыллы|к *сущ. с.-х.* укрюк; *см. тж.* **корык**; *~гы булса, атын табарбыз* был бы укрюк, коня добудем

урландык *прил. разг.* краденый; *~ мал* краденое имущество

урлан|у 1. *страд. от* **урлау**; похищаться, быть похищенным (*краденым, украденным*) 2. *в знач. прил.* **урланган** краденый, ворованный; *~ган әйбер* краденая вещь, краденое □ **~ып югалу** расхищаться

урлат|у 1. *понуд. от* **урлау**; 2. допускать/допустить кражу; *ул акчасын ~кан* у него украли деньги

урла|у *перех.* 1. воровать, красть/украсть, похищать/похитить, таскать/тащить *кого, чего* || воровство, кража, хищение; *кеше әйберен ~у* воровать чужое; *кесәдән акча ~у* вытащить из кармана деньги; *хөкүмәт акчаларын ~у* похитить государственные деньги 2. *этногр.* умыкать/умыкнуть, похитить (*девушку*) || умыкание, похищение; *кәләш ~у* умыкать невесту □ **~п алып китү** 1. украсть, похитить, утащить *что* 2. угнать; *атларны ~п алып китү* угнать лошадей; **~п бетерү** обворовать, разворовать *что*; **~п чыгу** обворовать, обокрасть *кого, что*

урлаучан *прил.* склонный к воровству; *~ кеше* человек, склонный к воровству

урлаучылык *сущ.* хищение; воровство, кража; *~ка каршы көрәш* борьба с хищениями; *~ белән шөгыльләнү* заниматься хищением

урлаштыру *многокр. от* **урлау**

урлаш|у *возвр. от* **урлау**; заниматься воровством, кражей; воровать, обворовывать; *~ып тамак туйдыру* жить воровством

урлашучы *сущ.* 1. *прич. от* **урлашу** 2. *сущ.* соучастник в воровстве, сообщник

урман *сущ. в разн. знач.* лес || лесной; лесо-, *катнаш ~* смешанный лес; *яфраклы ~* лиственный лес; *ылыслы ~* хвойный лес; *вак ~* мелкий лес; *каен ~ы* берёзовый лес; березняк; *нарат ~ы* сосновый лес; сосняк; *~ ташу* возить лес; *нефть вышкалары ~ы* лес нефтяных вышек; *~ кошлары* лесные птицы; *~ үсемлекләре* лесные растения; *~ сукмагы* лесная тропинка; *~ булеметтеге* лесосека; *~ техникасы институты* лесотехнический институт; *~га утын ташымыйлар* (*посл.*) в Тулу со своим самоваром не ездят (*букв.* в лес дрова не возят) □ **~ авызы (алды, бите, кырые)** опушка леса; **~ ахагы** *см.* **нарат җиләге**; **~ ачыклыгы** поляна, прогалина; **~ баганасы** лесовод; **~ бете** *зоол.* клещ; *см. тж.* **талпан**; **~ бөргәне** *бот.* жерушник (жеруха) лесной; **~ бүлеметтеге** делянка; **~ иясе** лесовик; **~ йолдызагы** *бот.* звездчатка лесная; **~ какысы** *бот.* 1. свербига 2. свербига сибирская; **~ кандаласы** *зоол.* щетик; **~ каравылчысы** лесник; **~ каратәне** чернотелка лесная; **~ караучы** лесничий; **~ каргасы** *зоол.* ронжа; **~ кипкәре** *бот.* сушеница лесная; **~ кисентесе** вырубка, лесосека || лесосечный; **~ кисү** 1. рубка (валка) леса 2. лесорубный, лесорубочный; *~ кисү кораллары* лесорубные инструменты; **~ кисүче** лесоруб; **~ көпшәсе** *бот.* дудник лесной; **~ куелыгы** гуща (чаща) леса, чащоба, дебри; **~ күгәрчене** *зоол.* 1. горлинка, горлица 2. вяхирь; **~ мәчесе** рысь; **~ саесканы** *зоол.* сойка; **~ саклау** 1. лесозащита 2. лесозащитный; *~ саклау зонасы* лесозащитная зона; **~ сыеры** *см.* **поши**; **~ тавыгы** глухарь; **~ төпләү** 1. корчёвка леса 2. корчевальный; **~ төпләү машинасы** корчевальная машина; **~ тургае** *зоол.* юла, лесной конёк; **~ өрәге** *диал.* тёрн, терновник; **~ утырту** 1. лесонасаждение; лесопосадка 2. лесопосадочный; **~ утырту эшләре** лесопосадочные работы; **~ үрдәге** *зоол.* дупель; **~ хуҗалыгы** 1. лесничество, лесное хозяйство; лесхоз 2. лесхозный, лесхозовский; **~ хуҗалыгы җирләре** лесхозовские земли; **~ чыгару** 1. трелевать лес 2. трелёвка леса; **~ чыпчыгы** *зоол.* завирушка лесная; **~ шөлдие** *зоол.* вальдшнеп; **~ эчләп** лесом; **~да үскән** 1. дикий, дикорастущий 2. *перен.* дикий, одичавший (о человеке) ◊ **~ әүлиясе** простак, простофиля; **~ иясе (сарыгы, хуҗасы)** *миф.* леший

урман-дала *сущ.* лесостепь || лесостепной; *урман-дала өчен* для лесостепи; *урман-дала зонасы* лесостепная зона

урмандагы *прил.* находящийся в лесу, лесной; *~ авыл* лесная деревня

урманландыру *перех. редко* облесить || облесение

урманлау *перех. редко* облесить, покрывать лесными насаждениями

урманлы *прил.* лесной, лесистый, покрытый лесом; *~ урын* лесистое место; *~ тау* гора, поросшая лесом; *~ җирләр* лесистая местность; *~ як* лесная сторона

урманлык *сущ.* лес, леса, лесистая местность; *куе ~* густой лес; *авыл ~та урнашкан* деревня расположена в лесистой местности; *авылның бер ягы ~* с одной стороны села лес

урман-парк *сущ.* лесопарк || лесопарковый; *урман-парк хуҗалыгы* лесопарковое хозяйство

урмансыз *прил.* безлесный, лысый, без леса; *~ тау* лысая гора; *~ җирләр* безлесье, безлесные края

урмансызландыру *перех.* обезлесить || обезлесение

урмансызлан|у *неперех.* обезлесеться || обезлесение (*само собой*); *~ган җирләр* обезлесенные земли

урман-тундра *сущ.* лесотундра || лесотундровый; *урман-тундра зонасы* лесотундровая зона

урманчы *сущ.* 1. лесовод 2. лесник; *~ булып эшләү* работать лесником 3. работник лесной промышленности; *~лар көне* день работы лесной промышленности

урманчык *сущ.* небольшой лес; рощица; *аргы якта кечерәк ~ күренә* на другой стороне виднеется рощица

урманчылы|к *сущ.* 1. лесоводство || лесоводческий, лесной; *~к эше* лесное (*лесоводческое*) дело 2. лесной промысел; *~к һөнәренә өйрәтү* учить лесному промыслу 3. лесничество; *Саба ~гы* Сабинское лесничество

урна *сущ. в разн. знач.* урна (*сосуд*); *аның ~сын Кремль стенасына урнаштырдылар* урну с его прахом поместили в Кремлёвскую стену; *сайлау ~сы* избирательная урна; *чүпне ~га салырга* бросать мусор в урну

урналыш *сущ. диал.* 1. расположение; *йортның ~ы* расположение дома 2. экспозиция

урнашу *перех. диал. см.* **урнаштыру**

урнаш *сущ. диал. этногр.* посиделки; вечеринка; *~ кичәсенә җыелу* собраться на посиделки □ **~ боткасы** каша, которую девушки варят в складчину на посиделках

урнаштыру *понуд. от* **урнаштыру**

урнаштыр|у *перех.* 1. помещать/поместить, размещать/разместить, расположить || помещение, размещение; *туристларны кунакханәгә ~у* разместить туристов в гостинице; *товарларны киштәләргә ~у* размещать

това́ры на по́лках; *яралыларны палатага ~у* помеще́ние больны́х в пала́ту **2.** *разг.* помеща́ть/помести́ть; *мәкаләне журналга ~у* помести́ть статью́ в журна́ле **3.** укла́дывать/уложи́ть, скла́дывать/сложи́ть || укла́дывание, скла́дывание; *ул әйберләрне сандыкка ~ды* она́ уложи́ла ве́щи в сунду́к **4.** *в разн. знач.* устана́вливать/установи́ть *что* || установле́ние; *турбинаны ~у* установи́ть турби́ну; *прибор ~у* установи́ть прибо́р; *власть ~у* установи́ть власть **5.** водворя́ть/водвори́ть, укрепля́ть/укрепи́ть || водворе́ние; укрепле́ние; *тәртип ~у* водвори́ть поря́док **6.** *разг.* устра́ивать/устро́ить *что*; *кызымны укырга ~дым* устро́ила до́чку учи́ться; *улын заводка слесарь итеп ~ды* он устро́ил сы́на на заво́д сле́сарем □ **~ып чыгу** размести́ть (всё)

урнаштырылу *страд. от* **урнаштыру**

урнаштырылыш *сущ.* расположе́ние; *җөмләдә сүзләрнең ~ы* расположе́ние слов в предложе́нии; *электродлар ~ы* расположе́ние электро́дов

урнаштырышу *взаимно-совм. от* **урнаштыру**

урнаш|у *неперех.* **1.** помеща́ться/помести́ться, размеща́ться/размести́ться; располага́ться/расположи́ться || помеще́ние, размеще́ние; расположе́ние; *җитештеруче көчләрнең ~уы* расположе́ние произво́дственных сил; *кешеләр вагоннарга ~тылар* лю́ди размести́лись в ваго́нах **2.** укла́дываться/уложи́ться, устра́иваться/устро́иться || укла́дывание, устро́йство; *ул кунаклар янында ~ты* он устро́ился ря́дом с гостя́ми; *әйберләр әрҗәләрдә ~ты* ве́щи уложи́лись в я́щиках **3.** 1) *в разн. знач.* устана́вливаться/установи́ться || установле́ние; *яңа власть ~у* установле́ние но́вой вла́сти; *тынлык ~ты* установи́лась тишина́; *язгы җылы көннәр ~ты* установи́лись тёплые весе́нние дни; *ике арада дуслык ~ты* ме́жду ни́ми установи́лась дру́жба 2) скла́дываться/сложи́ться; устана́вливаться/установи́ться; *билгеле бер гадәт ~ты* сложи́лась определённая привы́чка **4.** устра́иваться/устро́иться, поступа́ть/поступи́ть || устро́йство, поступле́ние; *заводка эшкә ~у* устро́иться (рабо́тать) на заво́д; *институтка ~у* поступи́ть в институ́т **5.** обосно́вываться/обоснова́ться, обжива́ться/обжи́ться || обоснова́ние; *яңа җирләргә ~у* обоснова́ться на но́вых зе́млях; *авылда ~ып калу* обоснова́ться в дере́вне **6.** *перен.* вреза́ться/вре́заться, засе́сть, запечатлева́ться/запечатле́ться в *чём*; *бу фикер башымда нык ~ып калды* э́та мысль кре́пко засе́ла у меня́ в голове́

уро́лог *сущ. мед.* уро́лог; *~ка күрену* показа́ться уро́логу

уроло́гия *сущ. мед.* уроло́гия || урологи́ческий; *~ бүлеге* урологи́ческое отделе́ние

уротропин *сущ. фарм.* уротропи́н

урпанла|у *перех. уст.* определя́ться, прики́дывать на глаз (на глазоме́р); *ул ~п бүлде* он разделя́л на глаз

урт *сущ.* десна́; *теш уртлары каный* дёсны кровото́чат; *тешсез урт* десна́ без зубо́в □ **урт ите** дёсны; **урт теш** коренно́й зуб ◊ **уртын ашау, уртын суыру (чәйнәү)** скрежета́ть зуба́ми; со скре́жетом зубо́вным

урта *сущ.* **1.** *в разн. знач.* середи́на; *басу ~сы* середи́на по́ля; *җәй ~сы* середи́на ле́та; *җыелыш ~сында* в середи́не собра́ния; *төн ~сы* середи́на но́чи; глубо́кая ночь; *уен ~сы* середи́на игры́ **2.** середня́к; челове́к сре́днего доста́тка; *Гали ~лар рәтенә басты* Гали́ вы́шел в середняки́ **3.** *диал.* центр; *шәһәр ~сы* центр го́рода **4.** *первая часть составных слов* средне-; *Урта Азия республикалары* среднеазиа́тские респу́блики **5.** *в знач. послелога в направит. п.* **уртасына** 1) в (на) середи́ну; *бүлмә ~сына чыгу* вы́йти на середи́ну ко́мнаты; *елга ~сына керү* войти́ в середи́ну реки́ 2) меж, ме́жду; *икесенең ~сына басу* вста́ть ме́жду ни́ми 3) к середи́не; *җәй ~сына* к середи́не ле́та **6.** *в знач. послелога в местновр. п.* **уртасында** 1) посреди́, среди́, средь; в середи́не; *кыш ~сында* среди́ зимы́; *төн ~сында* среди́ но́чи 2) в це́нтре; *шәһәр ~сында тору (яшәү)* жить в це́нтре го́рода 3) *редко* ме́жду, меж; *см.* **арасында**; *агачлар ~сында* меж дере́вьев **7.** *в знач. послелога в исх. п.* **уртасыннан** 1) с середи́ны; *кыш ~сыннан бирле авыру* боле́ть с середи́ны зимы́ 2) из; *шәһәр ~сыннан хәрәкәт итә башлау* нача́ть движе́ние из це́нтра го́рода 3) по середи́не; *урам ~сыннан бару* идти́ по середи́не у́лицы || *прил.* **1.** *в разн. знач.* сре́дний; *елганың ~ агымы* сре́днее тече́ние реки́; *~ тәрәзә* сре́днее окно́; *~ буйлы* сре́днего ро́ста; *~ мәктәп* сре́дняя шко́ла; *~ авырлык* сре́дний вес; *~ белем* сре́днее образова́ние **2.** *диал.* центра́льный; *~ урам* центра́льная у́лица □ **~ бармак** сре́дний па́лец; **~ бер җир** середи́на; це́нтр; **~ гасырлар** **1.** сре́дние века́; средневеко́вье **2.** средневеко́вый; **~ гасырлар шәһәре** средневеко́вый го́род; **~ дулкын** *физ.* сре́дняя волна́; **~ колак** *анат.* сре́днее у́хо; **~ ми** *анат.* сре́дний мозг; **~ хәлле** середня́к; **~ яшьтәге** сре́дних лет; **~га алу** окружа́ть/окружи́ть, обступа́ть/обступи́ть со всех сторо́н ◊ **~ бармак кебек** **1.** стро́йный **2.** первосо́ртный, весьма́ подходя́щий; **~га салу (кую)** ста́вить (поста́вить) на обсужде́ние, выноси́ть (вы́нести) на о́бщий суд; **~да тору** быть в ро́ли примири́теля

уртагыннан *нареч. см.* **уртакка**; *малны ~ сую* ре́зать скот совме́стно; *җирне ~ эшкәртү* обраба́тывать зе́млю и́сполу

уртада *нареч.* посреди́не, в середи́не; *нәкъ ~* точь-в-точь посреди́не; *~ тору* стоя́ть посреди́не

уртак *прил.* **1.** совме́стный; *~ тырышлык белән* совме́стными уси́лиями; *~ хат* совме́стное письмо́ **2.** о́бщий; *~ акча* о́бщие де́ньги; *~ хәсрәт* о́бщее го́ре; *~ мал* о́бщая со́бственность, о́бщее досто́яние; *~ сыйфатлар* о́бщие черты́ || *нареч.* **1.** совме́стно; *~ эшләү* рабо́тать совме́стно **2.** по́ровну, попола́м; *тапкан мал ~* что на́йдено — попола́м; *~ бүлү* дели́ть попола́м □ **~ бүленүче** *мат.* о́бщее дели́мое; *~ бүлүче* *мат.* о́бщий дели́тель; *~ ташкырлаучы* *мат.* о́бщий мно́житель ◊ **~ тел (сүз) табу** находи́ть/найти́ о́бщий язы́к

уртакка *нареч.* **1.** попола́м, на паях, в ра́вных до́лях *с кем-л.*; *берәр нәрсәне ~ка сатып алу* купи́ть попола́м *что-л.*; *~ печән чабу* коси́ть се́но на паях **2.** *ист.* и́сполу; *җирне ~ка эшкәртү* обраба́тывать зе́млю и́сполу

уртакла|у дели́ть/раздели́ть попола́м || деле́ние (*разделение*) попола́м; *табышның барысын да ~дылар* всю добы́чу (они́) раздели́ли попола́м

уртаклашу *перех. прям., перен.* **1.** дели́ться/подели́ться *чем*; разделя́ть/раздели́ть *что*; *икмәк сыныгын ~* дели́ться куско́м хле́ба; *шатлыгыңны иптәшең белән ~* подели́ться ра́достью с това́рищем; *кайгыны ~* раздели́ть го́ре, соболе́зновать **2.** обме́ниваться/обменя́ться || обме́н; *фикер ~* обменя́ться мне́ниями; *тәҗрибә ~* обме́н о́пытом

уртаклы|к *сущ.* **1.** о́бщность; *тел ~гы* о́бщность языка́; *карашлар ~гы* о́бщность взгля́дов **2.** о́бщее; *безнең арада бернинди ~к юк* ме́жду на́ми нет ничего́ о́бщего □ **~к исем** *грамм.* нарица́тельное и́мя; **~ юнәлеше** *взаимно-совм. залог (глагола)*

уртактан *нареч. см.* **уртакка** 1; *~ эшләргә* рабо́тать на паях

уртакул *прил.* посре́дственный; *~ белгеч* посре́дственный специали́ст □ *~* **бәндә** посре́дственность (*о человеке*)

уртакчы *сущ.* **1.** *разг.* па́йщик; издо́льщик **2.** *ист.* испо́льщик

уртакчылык *сущ.* **1.** издо́льщина **2.** испо́льщина

урталай *нареч.* пополам, вдво́е, на́двое, на две ра́вные ча́сти; *карбызны ~ кису* разре́зать арбу́з пополам; *~ яру* расколо́ть на́двое; *кыл ~* то́чно пополам

урталайга *нареч. см.* **урталай**; *~ чабу* разруби́ть пополам; *~ бөкләнгән хат* письмо́, сло́женное вдво́е

урталы: ни урталы, ни пурталы ни туда́ ни сюда́

урталы|к *сущ.* **1.** середи́на, середи́нка, средина, сре́днее ме́сто; *бүлмә ~гы* середи́на ко́мнаты; *~кка басып* встав на середи́ну **2.** *перен.* уме́ренность || уме́ренный; *~к политикасы* поли́тика уме́ренности, уме́ренная поли́тика **3.** *уст.* окруже́ние, среда́ **4.** *диал.* центр □ **~к юлы** *диал.* про́сека

уртанчы *прил.* сре́дний (*по возрасту*); *аларның ~ уллары* их сре́дний сын; *~ килен* неве́стка, жена́ сре́днего сы́на

уртача *прил.* **1.** сре́дний; *~ яшьтәге кеше* челове́к сре́дних лет; *~ буйлы кеше* челове́к сре́днего ро́ста; *~ зурлык* сре́дняя величина́; *~ калынлыктагы такта* доска́ сре́дней толщины́; *~ тизлек* сре́дняя ско́рость; *айлык ~ температура* среднеме́сячная температу́ра **2.** сре́дний; посре́дственный, удовлетвори́тельный; *~ сәләт* сре́дние спосо́бности; *~ бәя* сре́дняя цена́ **3.** уме́ренный; *~ һава* уме́ренный кли́мат; *~ эсселек* уме́ренная жара́ || *нареч.* **1.** сре́дне, посре́дственно; *~ уку* учи́ться посре́дственно **2.** в сре́днем; на круг; *гектардан ~ утыз центнер ашлык җыю* собира́ть с гекта́ра в сре́днем по три́дцать це́нтнеров зерна́; *көнгә ~ ун километр йөгерү* бе́гать в день в сре́днем по де́сять киломе́тров **3.** *в знач. сущ.* оце́нка «посре́дственно»; *диктанттан ~ алу* получи́ть «посре́дственно» □ **~ хәлле** середня́к; **~дан түбән** ни́же сре́днего

уртачаландыру *перех. редко* умеря́ть/уме́рить, де́лать/сде́лать уме́ренным

уртачалан|у *неперех.* де́латься/сде́латься уме́ренным, сно́сным; входи́ть/войти́ в сре́днюю но́рму; *хәлем ~ды* состоя́ние моё вошло́ в но́рму

уртачалык *сущ.* **1.** посре́дственность **2.** уме́ренность

урталам *сущ. разг.* глото́к; *бер ~ су* глото́к воды́

уртла|у *перех.* глота́ть; пить больши́ми глотка́ми || глота́ние; *ул стаканнан чәй ~п куйды* он глотну́л из стака́на чай

уртын *нареч. диал. см.* **орынтын**

уру 1. жать/сжать; убира́ть/убра́ть урожа́й || жа́тва, убо́рка; *арыш уру* жать рожь; *аерым уру* разде́льная убо́рка; *ни чәчсәң, шуны урырсың* (*погов.*) что посе́ешь, то и пожнёшь **2.** *перен. простореч.* лупи́ть, молоти́ть, колоши́ма́тить; *әйдәгез, урыгыз үзләрен!* отлупи́те их! **3.** *перен. прост.* ло́пать, упи́сывать, руба́ть; *урабыз гына үрдәк итен* так и упи́сываем утя́тину □ **уру машинасы** *с.-х.* жа́тка, жне́йка; **урып алу** сжать

уру-сугу *сущ. собир.* молотьба́; *уру-сугу вакыты килеп җитте* наступи́ло вре́мя молотьбы́

уручы *сущ.* жнец, жни́ца

уршу *неперех.* прораста́ть/прорасти́ (*картофель в погребе*)

урык-сурык *нареч.* уры́вками, ре́дко, от слу́чая к слу́чаю; *урык-сурык очрашу* встреча́ться от слу́чая к слу́чаю; *урык-сурык ашау* есть уры́вками

урыл|у 1. *страд. от* **уру** 1 **2.** *в знач. прил.* **урылган** у́бранный, сжа́тый; *~ган басу* у́бранное по́ле

урым *сущ. диал.* **1.** жа́тва **2.** поко́с, косьба́

урын *сущ.* **1.** *в разн. знач.* ме́сто; *иң биек ~* са́мое высо́кое ме́сто; са́мая высо́кая то́чка; *эш ~ы* рабо́чее ме́сто; *вакыйга булган ~* ме́сто происше́ствия; *хикәянең иң кызыклы ~ы* са́мое интере́сное ме́сто в расска́зе; *авырткан ~* больно́е ме́сто; *~ алу* занима́ть ме́сто; *бер ~нан икенче ~га күчү* переходи́ть с ме́ста на ме́сто; *дүрт ~ багаж тапшыру* сдать четы́ре ме́ста багажа́; *үз ~ына утыру* занима́ть своё ме́сто; *беренче ~га чыгу* вы́йти на пе́рвое ме́сто **2.** ме́сто, уча́сток, пло́щадь; *йорт ~ы* уча́сток под дом; *бакча ~ы* ме́сто для са́да **3.** ме́стность; *см. тж.* **як, төбәк**; *таулы ~* гори́стая ме́стность; *таныш ~га килеп чыгу* вы́йти на знако́мую ме́стность; *калку ~* возвы́шенная ме́стность **4.** *перен.* ме́сто, положе́ние; *җәмгыятьтә үз ~ын табу* найти́ своё ме́сто в о́бществе **5.** *обычно мн.* **урыннар** 1) места́; *матур ~нар* краси́вые места́ 2) места́; периферия́; *~нарга хәбәр итү* сообщи́ть на места́; *~нардан килгән делегатлар* делега́ты с мест (*из периферии*) **6.** *разг.* до́лжность, ме́сто, пост; *зур ~да эшләү* занима́ть высо́кий пост; *укытучы ~ы* ме́сто учи́теля; *җаваплы ~* отве́тственная до́лжность, отве́тственный пост; *~га билгеләү* определи́ть (*назначить*) на до́лжность **7.** посте́ль, ло́же; *~ын җыю* убира́ть посте́ль; *~га яту* лечь в посте́ль; *~ җәю* стлать посте́ль **8.** *перен.* основа́ние, причи́на, по́вод; *аны сүгәр өчен ~ юк* нет основа́ния его́ руга́ть; *икеләнер ~ юк* для сомне́ния нет причи́н; *~ бирү* уступа́ть/уступи́ть ме́сто; *~ хастасы* лежа́чий больно́й; *~ хастасы булу* надо́лго слечь; *~да эшләү* служи́ть, рабо́тать, состоя́ть на слу́жбе; *~ы белән* места́ми ◊ **~ өстенә яту** продолжи́тельно боле́ть; **~ тапмау** не находи́ть ме́ста; **~ тоту** занима́ть определённое ме́сто (положе́ние); **~ үгиләү (~ үзгиләү)** не спа́ться на но́вом ме́сте; *шәрәфле ~ тоту* занима́ть почётное ме́сто; **~ы белән 1.** места́ми ко́е-где́ **2.** в не́которых места́х; **~ы җәннәттә булсын** ца́рство ему́ небе́сное; **~ы килгәндә (чыкканда)** кста́ти, к ме́сту; **~ына калу** замеща́ть *кого-л.*; **~ыннан алу** освободи́ть от занима́емой до́лжности, снять с рабо́ты; **~ыңнан кузгалма!** ни с ме́ста!

урынбасар *сущ.* замести́тель; *директор ~ы* замести́тель дире́ктора

урынбасарлык *сущ.* замести́тельство, положе́ние замести́теля

урын-вакыт: урын-вакыт килеше *лингв.* ме́стно-временно́й паде́ж

урынга *союз подчин. употр. в сочет. с глагольной формой* на **-сы/-се** вме́сто того́ что́бы; *эшлисе ~ ул йоклап ята* он спит, вме́сто того́ что́бы рабо́тать; *магазинга барасы ~* вме́сто того́, что́бы идти́ в магази́н

урында *нареч.* на ме́сте; *мәсьәләне ~ хәл итү* реши́ть вопро́с на ме́сте || *союз см.* **урынга**; *укыйсы ~* вме́сто того́, что́бы учи́ться

урындагы *прил.* ме́стный; *~ хакимият органнары* ме́стные о́рганы вла́сти; *~ комитет* ме́стный комите́т; местко́м; *~ халык* ме́стные жи́тели; *~ чимал* ме́стное сырьё □ **~ кеше** *разг.* слу́жащий

урындаш *сущ.* сосе́д по до́му (*квартире, комнате*) и́ли купе́

урынды|к *сущ.* стул, табуре́т, табуре́тка; *артсыз ~к* табуре́т; *артлы ~к* стул; *терсәкле ~к* кре́сло; *тирбәлмә ~к* каче́лка; *электр ~гы* электри́ческий стул

урынлаштыру *перех. см.* **урнаштыру**

урынлашу 1. *неперех.* оседáть/осéсть на нóвом мéсте; освáиваться/освóиться с (*новым*) мéстом прожива́ния 2. *разг. см.* **урнашу**

урынлы *прил.* 1. имéющий (*столько-то*) мест, рассчи́танный на (*столько-то*) мест; -местный; *биш йөз ~ зал* зал на пятьсóт мест; *өч ~ номер* трёхмéстный нóмер; *ике ~ койка* двухмéстная (*двухспальная*) кóйка 2. умéстный, подходя́щий; *~ сүз* умéстное слóво; *~ киңәш* умéстный совéт 3. дóлжный, обоснóванный, справедли́вый; *~ тәнкыйть* справедли́вая крúтика; *~ мактау* заслýженная похвалá; *~ таләп* справедли́вое трéбование || *нареч.* 1. умéстно, кстáти, поделóм; *ярдәм бик ~ булды* пóмощь óчень кстáти; *очрашу ~ булды* встрéча оказáлась кстáти 2. справедли́во, обоснóванно; *аны эштән чыгаруны ~ саныйм* считáю освобождéние егó от рабóты справедли́вым 3. на мéсте, по назначéнию; *әйберне ~ фадалану* испóльзовать вещь по назначéнию

урынлылы|к *сущ.* 1. умéстность, сообрáзность; *кисәтүнең ~гы* умéстность замечáния 2. справедли́вость; целесообрáзность, обоснóванность

урынлы-урынсыз *нареч.* 1. неумéстно, без нáдобности, некстáти, невпопáд; *урынлы-урынсыз сүзгә кысылу* некстáти вмéшиваться в разговóр; *авыруны урынлы-урынсыз борчу* беспокóить больнóго без нáдобности 2. как попáло; *урынлы-урынсыз кую* стáвить где попáло; *агачларны урынлы-урынсыз утырту* посадúть дерéвья как попáло

урынсыз *прил.* 1. ненýжный, неумéстный; *~ сорау* неумéстный вопрóс 2. необоснóванный, незаслýженный, беспричи́нный, напрáсный; *~ курку* беспричи́нный страх; *~ җәберләр* незаслýженные обúды 3. *в функции сказ.* ни к чемý; *бәхәсләшү биредә ~* спóры тут ни к чемý || *нареч. см.* **урынсызга**; *~ шатлану* напрáсно рáдоваться; *~ үпкәләү* обижáться беспричи́нно; *~ кaударлану* суети́ться без нáдобности

урынсызга *нареч.* 1. неумéстно, незаслýженно, напрáсно; *~ тавышланасың* напрáсно скандáлишь; *~ тиргәү* ругáть незаслýженно 2. без нáдобности, без причúны, беспричи́нно; *~ кулыңны күтәрмә* без нáдобности не поднимáй рýку

урынты *сущ. диал.* жни́во, жнивьё, жнитвó

урынтын *диал.* 1. *нареч.* тáйно, тайкóм, втихомóлку; *см. тж.* **орынтын** 1; *~ эшләү* дéлать втихомóлку (*тайком*) || *прил.* тáйный, скры́тный; *~ эш* тáйное дéло 2. тúхий, укрóмный, глухóй; *~ юлдан бару* идтú глухóй дорóгой; *~ җир* (*төш*) глухóе мéсто, укрóмный уголóк

урынчылы|к *сущ.* 1. мéстничество || мéстнический; *см. тж.* **төбәкчелек**; *~кка каршы көрәш* борьбá прóтив мéстничества; *~к карашлары* мéстнические взгля́ды 2. *лингв.* подгóвор; *Зәй-Каратай ~гы* Зай-Каратáевский подгóвор; *Казан арты сөйләшенең Дөбьяз ~гы* Дубья́зский подгóвор заказáнского гóвора

урынына *послелог* 1. вмéсто, взамéн, за; *икмәк ~ акча бирү* дать дéнег вмéсто хлéба (*зерна*); *атасы ~ эшли* он рабóтает вмéсто отцá; *әнисе ~ калган* остáлась вмéсто мáтери; *алар ~* вмéсто них; *аның ~* вмéсто негó 2. *союз* 1) *поясним.* вмéсто тогó чтóбы; *эшләү ~ йоклый* он спит, вмéсто тогó чтóбы рабóтать 2) *сравн.* слóвно, как *кто, что*; *ул үгез ~ эшли* он рабóтает как вол; *аны эт ~ сүктеләр* егó отругáли как собáку

урын-җир *сущ. собир.* постéль || постéльный; *см. тж.* **җәймән**; *урын-җирне җыю* убирáть постéль; *урын-җир әйберләре* постéльные принадлéжности

урып-җыю *сущ. с.-х.* убóрка, страда́ || убóрочный, стра́дный; *урып-җыю вакыты* стра́дная пора́; *урып-җыю озакка сузылды* убóрка хлебóв затянýлась

урып-сугу *сущ. собир. разг. см.* **урып-җыю**

урыс *сущ. разг. см.* **рус** □ ~ **капка** большúе воротá с вéрхом; ~ **көянтәсе** *см.* **энә карагы**

урысча *нареч. разг.* по-рýсски, на рýсском языкé; *~ беләсеңме?* знáешь ли ты по-рýсски?

урышу *взаимно-совм. от* **уру**; жать вмéсте *с кем-л.*; помогáть *кому-л.* жать

уря́дни|к *сущ. ист.* уря́дник || уря́дничий; *казак ~гы* казáчий уря́дник; уря́дничья сáбля

уса́дьба *сущ. разг. см.* **утар, ихата**; *совхоз ~сы* совхóзная усáдьба; *колхозның төп ~сы* центрáльная усáдьба колхóза

усак *сущ.* осúна || осúновый; *~ утыны* осúновые дровá; *~ кайрысы* осúновая корá □ ~ **гөмбәсе** подосúновик; осúновик; ~ **урманы** осúнник, осúновый лес ◊ ~ **яфрагы** непосéда; ~ **яфрагы кебек калтырау** дрожáть как осúновый лист

усаклы *прил.* 1. имéющий осúну (*осины*); с осúной; *~ йорт* дом с осúной (*рядом*) 2. осúновый; *~ урман* осúновый лес

усаклык *сущ.* осúнник, осúновая рóща, осúновый лес; *вак ~* мéлкий осúнник

усал *прил.* 1. *в разн. знач.* злой, злóбный; сердúтый; *~ холык* злой нрав; *~ кешеләр* злы́е лю́ди; *~ караш* злóбный взгляд; *~ күзләр* сердúтые глазá; *~ эт* злáя собáка 2. злой, дурнóй, плохóй; *~ ният* злóе (*дурное*) намéрение; *~ холык* дурнóй харáктер 3. *прям., перен.* свирéпый, лю́тый; *~ җәнлек* лю́тый зверь; *~ җил* свирéпый вéтер 4. жестóкий, злой, безжáлостный, беспощáдный, сурóвый; *~ язмыш* сурóвая судьбá; *тормышның ~ яклары* сурóвые стóроны жúзни 5. злой, язви́тельный, éдкий, кóлкий; *~ сүз* язви́тельное слóво; *~ фельетон* язви́тельный фельетóн; *~ карикатура* злáя карикатýра 6. *разг. перен.* (*очень*) крéпкий, óстрый, éдкий; *бик ~ аракы* óчень крéпкая вóдка 7. *диал.* озорнóй; *~ балалар* озорны́е дéти || *нареч.* 1. зло, злóбно, сердúто; *~ карау* смотрéть злóбно 2. безжáлостно, беспощáдно, жестóко 3. кóлко, язви́тельно, éдко 4. крéпко, óстро 5. дýрно, непристóйно; *~ сүгенү* ругáться непристóйными словáми || *сущ.* 1. *миф. см.* **ушал** 2. злю́ка, злодéйка, злоумы́шленник 3. озорни́к, шалýн (*о детях*) □ ~ **итеп** зло, злóбно; язви́тельно; ~ **көлү** 1. язви́тельная насмéшка 2. саркáзм; ~ **ният белән** злонамéренно, злóстно; ~ **ниятлелек** злонамéренность; ~ **теллəнү** брани́ться, сквернослóвить; ~ **телләр** злы́е языкú; ~ **холыклы** злонрáвный

усалландыру *понуд. от* **усаллану**

усалла|ну *неперех.* 1. станови́ться/стать злым, злóбным, сердúтым, гнéвным; зли́ться/разозли́ться, свирепéть/рассвирепéть, озлóбиться; *йөзе ~ланды* лицó егó стáло злым (*сердитым*); *~ма, зинһар* не злись, пожáлуйста 2. *перен.* бушевáть, свирéпствовать; *тауга менгән саен, җил ~а бара* чем вы́ше поднимáешься в гóру, тем бóльше свирéпствует вéтер 3. *перен.* ссóриться, брани́ться, ругáться, скандáлить; *кеше белән ~ма!* не скандáль с людьмú!; *өйдә ~мыйк!* давáй не бýдем ругáться! 4. озорничáть, шали́ть (*обычно о детях*); *малайлар ~алар* мальчúшки озорничáют 5. *перен.* злодéйствовать □ ~**а төшү** ещё бóлее свирепéть, озлóбиться; ~**ып китү** разозли́ться, рассвирепéть

усаллы|к *сущ.* 1. зло, злость, злóба, злóбность; *~гы йөзенә чыккан* егó злость проявля́ется на лицé 2. зло-

де́йство, злодея́ние, злонра́вие; *ул кылмаган ~кларын калдырмады!* каки́х то́лько злодея́ний он не соверша́л! **3.** плохо́е; *нинди ~гым тиде сиңа?* что плохо́го сде́лал я тебе́?; *нинди ~к эшләдең тагын?* что ты ещё натвори́л? □ **~к белән 1.** со зло́стью (*злобой*); **~к белән карау** смотре́ть со зло́стью (*злобой*) **2.** зло́стно, злонаме́ренно, со злым у́мыслом; **~к итү (кылу)** де́лать (соверша́ть) зло (*злодеяние*); злоде́йствовать; **~к саклау** таи́ть зло́бу; **~к саклаучы** вре́дный, зловре́дный, злопа́мятный, тая́щий зло́бу; **~к теләү 1.** злопыха́тельствовать; жела́ть *кому-л.* зло (*недоброе*) **2.** недоброжела́тельство; **~к теләүче 1.** недоброжела́тель, злопыха́тель **2.** недоброжела́тельный, злопыха́тельский; **~к эшләү** де́лать зло, зловре́дничать ◊ **~кка калса (китсә)** е́сли уж по-плохо́му, то...

усал-унтагай *сущ. собир. неодобр.* злоде́и, разбо́йники, во́ры

усану *неперех. диал.* получа́ть/получи́ть отвраще́ние; *усал йөздән ~* получа́ть отвраще́ние от неприве́тливого лица́

усма *сущ. этногр.* разнови́дность кра́ски для воло́с

устав *сущ.* уста́в ‖ уста́вный; *партия ~ы* уста́в па́ртии; *хәрби ~* во́инский уста́в; *~ка буйсыну* подчиня́ться уста́ву □ **~тан тыш** внеуста́вный

уста́вча *нареч.* по уста́ву, по-уста́вному

устын *сущ. диал.* **1.** деревя́нная ра́ма основа́ния пе́чи **2.** шесто́к **3.** основа́ние, пьедеста́л **4.** стано́к (*для установления чего-л.*), стани́на

ут I *сущ.* **1.** ого́нь, огонёк; пла́мя ‖ о́гненный; *җемҗем килеп, утлар яна* сверка́ют огни́; *чыршы утлары* огни́ ёлки; *йортны ут чорнап алган* дом объя́т пла́менем; *учакка ут ягып җибәрү* развести́ ого́нь в очаге́ **2.** пожа́р; *урманда ут чыккан* в лесу́ возни́к пожа́р; *утны сүндерү* потуши́ть пожа́р; *ут чыгару* вы́звать пожа́р **3.** *воен.* ого́нь; стрельба́, пальба́ ‖ огнево́й; *артиллерия уты* артиллери́йский ого́нь; *ут ачу* откры́ть ого́нь; *ут астында калу* попада́ть под обстре́л **4.** *перен.* ого́нь, бой; *утка керәм* иду́ в бой (*в огонь*) **5.** *перен.* ого́нь, пыл, пла́мя ‖ о́гненный, пла́менный; *мәхәббәт уты* пла́мя любви́; *йөрәккә ут кабызу* зажечь пла́мя в се́рдце; *күзләрендә ут* в глаза́х огонько́в; *сугыш уты* пла́мя войны́ **6.** *перен.* жар, (*высокая*) температу́ра; лихора́дка; *бала ут эчендә* ребёнок весь в жару́; *ул ут эчендә саташып ята* он бре́дит с высо́кой температу́рой **7.** свет; *тәрәзәдәге ут яктысы* свет в окне́; *ут кабызу* зажечь свет; *ут сүндерү* погаси́ть свет **8.** *разг.* электри́чество; *ут кертү* проводи́ть (*провести*) электри́чество; *ут өчен түләү* заплати́ть за электри́чество **9.** *в знач. прил. перен.* горя́чий, отча́янный; *ут хатын* отча́янная же́нщина; *ут холык* горя́чий хара́ктер □ **ут алу 1.** зажечь (включи́ть) свет **2.** охвати́ть огнём, загоре́ться, запыла́ть; *өйнең эчен ут алды* дом изнутри́ охвати́ло огнём; **ут ачу** *воен.* открыва́ть/откры́ть ого́нь; **ут кабу** загоре́ться; **ут корты** светля́к, светлячо́к; **ут кутыры** *мед. разг.* золоту́ха; **ут куршесе** сосе́д; **ут ноктасы** огнева́я то́чка; **ут салу 1.** поджига́ть/подже́чь **2.** зажига́ть/зажечь; **ут сүндергеч** огнетуши́тель; **ут тавы** вулка́н; **ут ташы** *уст.* ка́мень; **ут төртү** поджига́ть/подже́чь, подпали́ть, вы́звать пожа́р; поджо́г; **ут төртүче** поджига́тель; **ут үләне** *бот.* пла́менник; **ут чаткысы** и́скра; **ут чыгару 1.** вы́звать пожа́р **2.** *перен.* рабо́тать спо́ро **3.** *перен.* говори́ть бы́стро, сме́ло, горячо́; **ут шәүләсе 1.** свет огня́ **2.** за́рево пожа́ра; **ут яктысында** при све́те; **утка күренү** *разг.* пока́зываться/показа́ться на рентге́н; **утка табынучы** огнепокло́нник; **утка чыдам(лы)** огнеупо́рный; **утка чыдамлы материаллар** огнеупо́рные материа́лы, огнеупо́ры; **утка чыдамлылык** огнесто́йкость ◊ **ут белән су арасында** меж двух огне́й; **ут борчасы** палу́н, непосе́да; **ут йоту** си́льно горева́ть, кручи́ниться; кручи́на; **ут йөгерү** появле́ние стра́ха, боя́знь; **ут капкан кебек, ут капкандай** как угоре́лый; **ут кебек 1.** как ого́нь; подо́бно огню́; **ут кебек кайнар** горя́ч как ого́нь **2.** о́гненный, горя́чий, отча́янный; **ут күз, ут күзле 1.** живо́й, прово́рный, де́ятельный, как ого́нь **2.** смышлёный; **ут өермәсе** о́гненный шквал; **ут уйнату** де́лать спо́ро, рабо́тать с огонько́м; **ут чәчү 1.** говори́ть сме́ло, горячо́, пла́менно **2.** рвать и мета́ть **3.** пыла́ть огнём; **күзләре ут чәчә** его́ (её) взгляд пыла́ет огнём; **ут чыккан кебек 1.** *см.* **ут капкан кебек 2.** как на пожа́р; **ут чыккан кебек ашыгу** спеши́ть, как на пожа́р; **ут чыкканмы әллә?** не на пожа́р ведь?; **ут ягып талашу** руга́тельски руга́ться; **ут яну** горе́ть пла́менем, пыла́ть; **утка баскан мәче шикелле** *см.* **ут капкан кебек**; **утка бастыру** зада́ть жа́ру, зада́ть пе́рцу; **утка керосин сибү** (под)ли́ть ма́сла в ого́нь; **утка салу 1.** обрека́ть/обре́чь на страда́ние **2.** броса́ть/бро́сить в жар; **утсыз төтен булмый** (*посл.*) нет ды́ма без огня́; где дым, там и ого́нь; **уттай яна** гори́т огнём (*пламенем*); **уттан алып суга салу** (*кинуть*) из огня́ да в по́лымя; **уттан котылу, суга төшү** (*попа́сть*) из огня́ да в по́лымя; **уттан курыккандай курку** боя́ться как огня́

ут II *сущ. уст.* трава́, травяни́стое расте́ние (*встречается в составных названиях растений*) □ **ут агасы** *ист.* фураж и́р (*в войсках*)

утагыч *сущ. с.-х.* поло́льник

уталу *страд. от* **утау**; поло́ться, пропа́лываться; быть пропо́лотым

утаман *сущ. диал.* **1.** заводи́ла, зачи́нщик, глава́рь в игре́; *см. тж.* **узаман 2.** костро́вой (*тот, кто разжигает и поддерживает костёр*) **3.** атама́н

утар *сущ.* **1.** уса́дьба, име́ние; *алпавыт ~ы* поме́щичье име́ние **2.** *редко* ху́тор; *крестьяннар ~ булып урнашканнар* крестья́не расположи́лись хутора́ми **3.** заго́н; *җәен сарыкларны ~да асрау* держа́ть ове́ц ле́том в загоне; *атларны ~га ябу* запере́ть лошаде́й в загон

утау *понуд. от* **утау**; веле́ть (*поручать, заставлять*) поло́ть, пропа́лывать

ута|у I *перех.* **1.** поло́ть, пропа́лывать/прополо́ть, выпа́лывать/вы́полоть; *чөгендер ~у* прополо́ть свёклу; **чүп ~у** вы́полоть сорня́к **2.** вырыва́ть, выдёргивать *что*; *тюльпаннарны суганчалары белән ~ганнар* тюльпа́ны вы́рвали с лу́ковицами **3.** *перен.* вы́красть, очи́стить (*огурцы с грядки*); *күршеләрнең кишерен ~ганнар* у сосе́дей очи́стили с гря́док морко́вь **4.** *перен. разг.* съесть, сожра́ть **5.** *в знач. сущ.* пропо́лка, по́лка ‖ поло́льный; *~га чыгу* вы́йти на пропо́лку; *кишер ~у* пропо́лка морко́ви □ **~у алу** немно́го поло́ть; **~п чыгу 1.** прополо́ть всё **2.** *перен.* очи́стить; **~у машинасы** поло́льная маши́на

утау II *сущ. диал.* сва́дебная ю́рта; ко́мната для бра́чной но́чи

утаучы *сущ. с.-х.* поло́льщик

уташу *взаимно-совм. от* **утау**; помога́ть/помо́чь поло́ть, пропа́лывать/прополо́ть; поло́ть/пропа́лывать (*вместе*)

утилиза́тор *сущ.* **1.** утилиза́тор (*машина, устройство*) **2.** утилиза́тор (*работник утилизации*)

утилиза́торлык *сущ. книжн.* утилиза́торство, утилиза́ция

утилиза́ция *сущ. см.* **утильләштерү**

утилиза́циялəу *перех. см.* **утильлəштерү**; *сəнəгə калдыкларын ~* утилизи́ровать промы́шленные отхо́ды; *җылыны ~* утилиза́ция тепла́

утилитар *прил. книжн.* утилита́рный; *~ караштан чыгып* исходя́ из утилита́рных соображе́ний; *~ белемнəр* утилита́рные зна́ния

утилитаризм *сущ. книжн. см.* **утилитарлык**; *~ белəн сугарылган* прони́кнутый утилитари́змом; *~ тарафдары* утилитари́ст

утилитарист *сущ. книжн.* утилитари́ст || утилитари́стский

утилитарлык *сущ. книжн.* утилитари́зм, утилита́рность || утилитари́стский; *~ карашлар* утилитари́стские взгля́ды

утиль *сущ.* ути́ль; *~ җыю* собира́ть ути́ль □ **~ җыючы** ути́льщик

утильləштерү *перех.* утилизи́ровать || утилиза́ция

уткабызгыч *сущ. неол.* зажига́лка

ут-күз *сущ. собир.* **1.** пожа́р; *ут-күздəн саклану чаралары* ме́ры от пожа́ра; *ут-күз чыкмасын* ка́к бы не случи́лся пожа́р **2.** ого́нь; горя́щие у́гли; *ут-күздəн сак булырга кирəк* на́до с огнём обраща́ться осторо́жно; *идəнгə ут-күз төшə күрмəсен* ка́к бы не урони́ть на́ пол горя́щие у́гли

утлавык *сущ.* вы́гон, вы́пас; *см.* **утлау** I; *су буендагы ~* вы́гон у реки́

утлан|у *неперех.* горе́ть огнём (*чаще о глазах*); *ярсудан күзləре ~а* от я́рости (гне́ва) глаза́ горя́т огнём; *шатлыктан күзləре ~ды* от ра́дости глаза́ загоре́лись

утлату *перех.* пасти́, пуска́ть/пусти́ть на подно́жный корм; *кəҗəне чирəмдə ~* пасти́ на лужа́йке козу́

утлау I *сущ.* вы́гон, вы́гул, вы́пас, па́стбище

утла|у II *неперех.* пасти́сь, щипа́ть траву́; быть на подно́жном корму́; *атларны ~рга җибəру* пусти́ть коне́й пасти́сь

утлач *прил.* **1.** горя́щий огнём (*о глазах*) **2.** *перен. редко* бо́йкий, сме́лый, си́льный; как ого́нь; *~ егет* бо́йкий па́рень

утлачландыру *понуд. от* **утлачлану**

утлачлану *неперех.* загора́ться/загоре́ться огнём (*о глазах*)

утлы *прил.* **1.** *прям., перен.* горя́чий; *~ кумер* горя́щие у́гли; *~ тəмəке* горя́щая папиро́са; *~ күзлəр* горя́щие глаза́ **2.** *прям., перен.* пла́менный, о́гненный, стра́стный; *~ масса ыргыла* изверга́ется о́гненная ма́сса; *~ еллар* пла́менные го́ды; *~ караш* стра́стный (о́гненный) взгля́д □ **~ бөҗəк (коңгыз)** *зоол.* светлячо́к; **~ корал** огнестре́льное ору́жие ◊ **~ табага бастыру** показа́ть, где ра́ки зиму́ют; зада́ть жа́ру, разде́лать под оре́х

утлыг|у *неперех.* **1.** прова́ливаться/провали́ться, запада́ть/запа́сть (*о глазах*); *күзлəре ~ып калган* глаза́ у него́ запа́ли **2.** *разг.* си́льно проголода́ться (*о скотине*)

утлык I *сущ.* я́сли, корму́шка для скота́; *~ тулы солы* по́лная корму́шка овса́; *сыерлар өчен ~* корму́шка для коро́в

утлык II *сущ.* **1.** (*поддон самоварный*) то́пки (*ниже колосников*) **2.** то́пка (*паровоза, котла*) **3.** слепо́й оча́г (*ниша в печи, куда сгребают горящие угли, чтобы дольше сохранилось тепло*)

утлы-кызыллы *прил.* о́гненно-кра́сный, багря́ный; *утлы-кызыллы болытлар* о́гненно-кра́сные облака́; *утлы-кызыллы төс* багря́ный цвет

утлы-сарылы *прил.* о́гненно-жёлтый, я́рко-жёлтый; *утлы-сарылы нəркислəр* о́гненно-жёлтые нарци́ссы; *утлы-сарылы басу* о́гненно-жёлтое по́ле

утлы-ялкынлы *прил.* искри́стый, пла́менный, о́гненный

утлы-яшелле *прил.* **1.** кра́сно-зелёный; *утлы-яшелле салават күпере* кра́сно-зелёная ра́дуга **2.** *перен.* ре́зкий, пронзи́тельный; гне́вный; *утлы-яшелле тавыш* ре́зкий го́лос

утлы-яшенле *прил.* **1.** искря́щийся; *утлы-яшенле төсləр* искря́щиеся цвета́ **2.** *перен.* гне́вный, свире́пый; *утлы-яшенле тавыш* свире́пый го́лос

утопизм *сущ. филос.* утопи́зм; *народникларның ~ы* утопи́зм наро́дников

уто́пик *прил.* утопи́ческий, утопи́чный; *~ социализм* утопи́ческий социали́зм

уто́пиклы|к *сущ.* утопи́чность; *теориянең ~гы* утопи́чность тео́рии

уто́пия *сущ. в разн. знач.* уто́пия

уто́пиялелек *сущ.* утопи́чность

уто́пияче *сущ.* утопи́ст

утрак *прил.* осе́длый; *~ тормыш* осе́длый о́браз жи́зни; *~ халык* осе́длый наро́д || *сущ. уст.* постоя́нное ме́сто жи́тельства; *~ларын ташлап китү* бро́сить постоя́нное ме́сто жи́тельства

утракландыру *перех.* де́лать/сде́лать осе́длым, переводи́ть/перевести́ на осе́длый о́браз жи́зни

утраклану *неперех.* переходи́ть/перейти́ на осе́длый о́браз жи́зни; де́латься/сде́латься осе́длым

утраклашу *неперех. см.* **утраклану**

утраклык *сущ.* осе́длость, осе́длый о́браз жи́зни; *~ка күчү* перейти́ на осе́длость; *~ чиге ист.* черта́ осе́длости

утракса *сущ. анат.* седа́лище || седа́лищный; *~ нервасы* седа́лищный нерв; *~ сөяге* седа́лищная кость

утрау *сущ.* о́стров || островно́й; *кечкенə ~* острово́к; *зур ~* большо́й о́стров; *кешесез ~* необита́емый о́стров; *~ булып калган* оста́лся в ви́де о́строва □ **~ халкы** островитя́не; **~да яшəүче** островитя́нин

утраулы *прил.* с острова́ми, име́ющий острова́; островно́й; *~ ил* островна́я страна́

утраулык *сущ.* архипела́г, гру́ппа острово́в

утрау-утрау *нареч.* островка́ми; *утрау-утрау булып сузылу* простира́ться островка́ми

утраучык *сущ.* острово́к

ут-су: утка-суга керү идти́ в ого́нь и во́ду; **утны-суны (утларны-суларны) кичү** пройти́ сквозь ого́нь и во́ду; пройти́ огни́ и во́ды

утчəчək *сущ. бот.* горицве́т, лю́тик боло́тный

утчык *сущ.* **1.** ма́ленький огонёк; *караңгы урамда ~лар айкала* на тёмной у́лице блужда́ют огоньки́ **2.** *бот.* огонёк (*растение*)

утчыл *сущ. зоол.* огнёвка (*вид бабочки*)

утыз *числ. колич.* **1.** три́дцать; *~ сум* три́дцать рубле́й; *~дан бер* одна́ тридца́тая; *биш алтың — утыз* пя́тью шесть — три́дцать; *~ теш арасыннан чыкса — кешегə җитə* (*посл.*) то, что прохо́дит через три́дцать зубо́в, дохо́дит до тридцати́ люде́й; *~лар тирəсендəге ир* мужчи́на лет тридцати́ **2.** *в знач. сущ. в косв.ф.* три́дцать лет, *~га җитеп өйлəну* жени́ться в три́дцать лет; *~ында ук атмаган, кырыгында кылыч чапмас* (*посл.*) кто в три́дцать (лет) не стреля́л из лу́ка, тот в со́рок лет са́блей не взмахнёт □ **~ еллык** 1. тридцатиле́тие 2. тридцатиле́тний; *~ еллык хезмəт* тридцатиле́тний труд ◊ **~ тугыз(лы)** ненорма́льный; ви́нтика не хвата́ет

утызар *числ. разд.* 1. по тридцати́, по три́дцать; *гектардан уртача ~ центнер бөртек алынды* со́брано в сре́днем по три́дцать це́нтнеров зерна́ с гекта́ра 2. *в опред. сочет.* три́дцать-; по три́дцать, по тридцати́; *~ килограммлы тартмалар* тридцатикилогра́ммо́вые я́щики; я́щики по три́дцать килогра́ммов

утызлап *числ. прибл.* приблизи́тельно (*примерно*) три́дцать; о́коло тридцати́; *~ кеше килгән* пришло́ о́коло тридцати́ челове́к

утызлы *числ.* тридца́тый (*о размере, номере*); *~ җеп* тридца́тый но́мер ни́тки; *~ размер* тридца́тый разме́р (о́буви) □ **~ лампа** ла́мпа-тридца́тка

утызлык *сущ. ист.* тридца́тка (*о деньгах*); *~ны вакларга* разменя́ть тридца́тку

утызменче *сущ. ист. полит.* тридцатиты́сячник; *~лар хәрәкәте* движе́ние тридцатиты́сячников

утызынчы *числ. порядк.* тридца́тый; *~ еллар* тридца́тые го́ды

утын *сущ.* 1. дрова́ || дровяно́й; *каен ~ы* берёзовые дрова́; *имән ~ы* дубо́вые дрова́; *коры ~* сухи́е дрова́; *~ яру* коло́ть дрова́; *ботак ~* верши́нник 2. *перен. прост. см.* **утын түмәре** □ **~ агачы** 1. поле́но 2. *перен. прост.* дуби́на, о́лух, чурба́н (*о тупом человеке*); **~ эрдәнәсе** поле́нница; *см. тж.* **эрдәнә**; **~ балтасы** колу́н; **~ кисүче** дровосе́к; пи́льщик дров; **~ сарае** дровя́ник, дровяно́й сара́й; **~ тукмагы** колоту́шка для ко́лки дров; **~ хәзерләү** дровозагото́вки; **~ чанасы** дро́вни; **~ яручы** дровоко́л; ◊ **~ вату** *неол.* наколо́ть дров; **~ түмәре** чурба́н (*о тупом человеке*)

утынлык *сущ.* дровяни́к, ме́сто (*помещение*) для дров; дровяно́й склад || *прил.* дровяно́й; предназна́ченный на дрова́; *~ агачлар* дровяно́й лес; *~ каен* берёза на дрова́

утынчы *сущ.* 1. дровосе́к, пи́льщик дров; *~ утын кисә* дровосе́к пи́лит дрова́ 2. торго́вец дрова́ми

утыргыч *сущ.* 1. сиде́нье, стул, табуре́тка; *артсыз ~* сиде́нье без спи́нки 2. чурба́н; *бүрәнәдән ~лар ясап куйдык* из брёвен смастери́ли чурба́ны 3. *перен. редко* «кресло» — ме́сто, до́лжность; *~ өчен көрәш* борьба́ за «кресло» (*за должность*); *~ыннан очкан* он слете́л с до́лжности

утырдаш *сущ.* собесе́дник; *игътибарлы ~* внима́тельный собесе́дник □ **~ булу** бесе́довать, вести́ бесе́ду

утырдашчы *сущ. см.* **утырдаш**

утырма I *сущ.* оса́док, отложе́ние, отсто́й; муть, подо́нки; *организмдагы тоз ~сы* отложе́ние соле́й в органи́зме; *үсемлек маендагы ~* оса́док в расти́тельном ма́сле || *прил. геол.* оса́дочный; *~ тау токымнары* оса́дочные го́рные поро́ды

утырма II *прил.* стоя́чий; *~ яка* стоя́чий воротни́к

утырма III *сущ. этногр.* 1. обы́чай де́вушек гости́ть продолжи́тельное вре́мя у ро́дственников и занима́ться там рукоде́лием 2. посиде́лки; вечери́нка; *кызлар ~га килгән* де́вушки пришли́ на посиде́лки

утырмалы *прил.* насто́льный; *~ көзге* насто́льное зе́ркало

утырмачы *сущ.* прису́тствующий на посиде́лках, уча́стница посиде́лок

утырткыч *сущ. тех.* сажа́лка; -сажалка; *бәрәңге ~* картофелесажа́лка; *усенте ~* рассадосажа́лка

утыртма *прил. см.* **утырма** III; *~ яка* стоя́чий воротни́к □ **~ читән** частоко́л, тын

утырттыру *понуд. от* **утырту**

утырт|у *перех.* 1. сажа́ть, посади́ть *что* || поса́дка; *агач ~у* посади́ть де́рево; *чәчәк ~у* посади́ть цветы́; *бәрәңге ~у* поса́дка карто́феля; *күлмәккә кара табы ~у* сажа́ть кля́ксу на пла́тье 2. *прям., перен.* сажа́ть, посади́ть, уса́живать/усади́ть *кого во (на) что* || поса́дка; *урындыкка ~у* посади́ть на стул; *поездга ~у* посади́ть в по́езд; *өстәлгә ~у* приглаша́ть к столу́; *баланы дәрес хәзерләргә ~у* посади́ть ребёнка за уро́ки; *ипи белән суга ~у* посади́ть на хлеб и во́ду; *самолётка ~у башланды* начала́сь поса́дка на самолёт; *диетага ~у* сажа́ть на дие́ту 3. *в разн. знач.* сажа́ть, посади́ть *кого во (на) что* (*в порядке наказания или для выполнения обязанностей*); *төрмәгә ~у* посади́ть в тюрьму́; *кошны читлеккә ~у* посади́ть пти́чку в кле́тку; *этне бәйгә ~у* сажа́ть соба́ку на цепь; *кортлы тавыкны чеби чыгарыргa ~у* сажа́ть ку́рицу-насе́дку на я́йца 4. сажа́ть, посади́ть *что на (во) что* || поса́дка; *пароходны комга ~у* посади́ть парохо́д на мель; *самолётны җиргә уңышлы ~у* благополу́чно посади́ть самолёт 5. наса́живать/насади́ть *что на (во) что*; *балта сабы ~у* насади́ть топо́р на топори́ще 6. *перен. прост.* всади́ть; посади́ть; *күз төбенә ~у* посади́ть под глаз; *яңагына ~у* влепи́ть пощёчину; *башка ~у* сту́кнуть по голове́ 7. ста́вить/поста́вить *что на (во) что*; *чүлмәкне өстәлгә ~у* поста́вить горшо́к на стол; *чәчәкләрне суга ~у* поста́вить цветы́ в во́ду; *аш ~у* поста́вить вари́ть суп; 8. ста́вить/поста́вить, устана́вливать/установи́ть *что*; *терәк ~у* ста́вить подпо́рку; *багана ~у* поста́вить столб; *тәрәзә яңакларын ~у* устана́вливать око́нные косяки́ 9. прита́чивать/притача́ть, вшива́ть/вшить, пришива́ть/приши́ть *что*; *җиң ~у* притача́ть рука́в; *яка ~у* приши́ть воротни́к 10. *прям., перен.* вправля́ть/впра́вить; *тайганны ~у* впра́вить вы́вих; *акылга ~у* впра́вить мозги́ 11. *перен. прост.* надува́ть/наду́ть, обмишу́ливать/обмишу́лить, обмишу́ривать/обмишу́рить, обы́грывать/обыгра́ть *кого*; *беркатлы кешене ~у* наду́ть простофи́лю; *мин аны картада ~тым* я его́ обыгра́л в ка́рты □ **~ып бетерү (чыгу)** 1. посади́ть, засади́ть всё 2. усади́ть всех; **~п кую** 1. *в разн. знач.* посади́ть 2. поста́вить (*столб*)

утыртылу *страд. от* **утырту** (*в знач. 1—5, 7—10*)

утыртышу *взаимно-совм. от* **утырту**

утыр|у *неперех.* 1. *в разн. знач.* сади́ться, уса́живаться, сесть || сиде́ние, прися́ст; *ашарга ~у* сади́ться ку́шать; *ял итәргә ~у* уса́живаться поудо́бнее на скаме́йку; *бер ~уда* за оди́н прися́ст; *самолётка ~у* сесть в самолёт 2. *перен. разг.* сади́ться/сесть, заня́ть (ме́сто, до́лжность); *председатель урынына ~у* заня́ть ме́сто председа́теля 3. сади́ться/сесть, приземля́ться/приземли́ться, соверша́ть/соверши́ть поса́дку; *күбәләк чәчәккә ~ды* ба́бочка се́ла на цветок; *самолёт төшеп ~ды* самолёт соверши́л поса́дку; *кош ботакка ~ды* пти́ца се́ла на ве́тку 4. сесть (*в тюрьму и т. п.*), сиде́ть (*в тюрьме и т. п.*), сиде́ть, лиша́ться/лиши́ться свобо́ды; отсиде́ть (*в заключении*) 5. сиде́ть, находи́ться в сидя́чем положе́нии; *алда ~у* сиде́ть впереди́; *ул өстәл артында ~а* он сиди́т за столо́м 6. *в разн. знач.* сиде́ть, быть, находи́ться, пребыва́ть в *каком-л.* состоя́нии *где-л.*; *эшсез ~у* сиде́ть без де́ла; *җыелышта ~у* сиде́ть на собра́нии; *өйдә ~у* сиде́ть до́ма; *концертта ~у* сиде́ть на конце́рте; *кунакта ~у* сиде́ть в гостя́х; *бер класста ике ел ~у* сиде́ть в одно́м кла́ссе два го́да 7. *перен.* сесть, сле́довать *какому-л.* режи́му; *диетада ~у* сиде́ть на дие́те; *бәрәңгедә генә ~у* сиде́ть на одно́й карто́шке 8. сиде́ть (*на яйцах*), выси́живать птенцо́в; *ана каз йомыркада ~а* гусы́ня выси́живает птенцо́в (*сидит на яйцах*) 9. *перен.*

засиде́ться (*о девках*) **10.** стоя́ть, располага́ться/расположи́ться; *шәһәр елга буенда ~ган* го́род располо́жен на берегу́ реки́ **11.** селя́ться, расселя́ться, поселя́ться/поселя́ться; *алар авыл кырыена ~ганнар* они́ поселя́лись на краю́ дере́вни **12.** засе́сть, застрева́ть; сади́ться, сиде́ть; *үпкәдә пуля ~а* пу́ля застря́ла в лёгких; *баржа комга ~ган* ба́ржа се́ла на мель **13.** оседа́ть/осе́сть, ложи́ться/лечь на *что*; покрыва́ться/покры́ться *чем*; *китапларга тузан ~ган* кни́ги покры́лись пы́лью; *стенага корым ~ган* стена́ закопте́ла; *елга төбенә ләм катлавы ~ган* на дне реки́ лежи́т слой и́ла **14.** *перен.* лежа́ть/лечь; *йөрәккә таш булып ~у* лечь ка́мнем на се́рдце; *бу эшкә күңел ~мый* к э́той рабо́те душа́ не лежи́т **15.** *индив.* оседа́ть/осе́сть, сади́ться/сесть || оса́дка; *кар күзгә күренеп ~ды* снег на глаза́ осе́л; *йорт торган саен ~а* дом (проседа́ет) оседа́ет всё бо́лее **16.** подходи́ть/подойти́, быть к лицу́, сиде́ть (*об одежде*); *гаскәри кием аның өстендә яхшы ~а* вое́нная фо́рма на нём сиди́т о́чень хорошо́ **17.** впада́ть/впа́сть, вва́ливаться/ввали́ться (*о глазах, щеках*); *аның күзләре ~ган* у неё глаза́ ввали́лись **18.** сади́ться/сесть, укора́чиваться/укороти́ться; *бу ситса ~а* э́тот си́тец сади́тся; *йон һәм ярым йон әйберләре юганда ~а* шерстяны́е и полушерстяны́е ве́щи при сти́рке сада́тся **19.** *в разн. знач.* устана́вливаться/установи́ться; *көннәр ~ып китте* пого́да установи́лась; *юллар ~гач барырбыз* пое́дем, когда́ устано́вится доро́га; *чана юллары ~ды* установи́лся са́нный путь; *аның холкы ~а төшкән* хара́ктер его́ немно́го установи́лся **20.** вправля́ться/впра́виться, станови́ться/стать на ме́сто (*о вывихе*) **21.** вступа́ть/вступи́ть в определённую фа́зу (*роста, цветения, колошения*); *серкәгә ~у* опыля́ться; *тупсага ~у с.-х.* пойти́ в тру́бку; *алмагачлар шау чәчәктә ~алар* я́блони бу́йно цвету́т; *басу ямь-яшел ~а* поля́ покры́лись зелёными всхо́дами **22.** *перен. прост.* обма́нываться/обману́ться, просчита́ть, прогада́ть, оказа́ться в убы́тке (в дурака́х) □ **~ган бал** стоя́лый мёд; **~ган йомырка** наси́женное я́йцо́; **~ган килеш** в сидя́чем положе́нии; **~ган кыз** засиде́вшаяся де́вушка, ста́рая де́ва; **~ган тавык** насе́дка, клу́ша; **~ып баручы** пассажи́р-попу́тчик; **~ып калу 1.** засе́сть; застря́ть; *пуля үпкәдә ~ып калган* пу́ля засе́ла в лёгких **2.** засиде́ться; *кыз килеш ~ып калу* засиде́ться в де́вках **3.** оста́ться (*на второй год в одном классе*); **~ып чыгу** отсиде́ться, отбы́ть наказа́ние в тюрьме́; **~ып эшләү** рабо́тать (*на сидячей работе*) без переры́ва, не отвлека́ясь на други́е дела́; **~ып яву** беспреста́нно лить (*о дожде*)

утыручан *прил.* уси́дчивый; *күңеле эшкә ~* уси́дчивый в рабо́те

утырым *сущ. прям., перен.* оса́док; *күңелдәге ~* оса́док на душе́

утырыш I *сущ.* заседа́ние; *булекнең киңәйтелгән ~ы* расши́ренное заседа́ние отде́ла; *~ үткәрү* провести́ заседа́ние; *~ залы* зал заседа́ний

утырыш II *сущ.* мане́ра сиде́ть, по́за; *~ына гына карагыз!* посмотри́те на его́ по́зу; *~ кыяфәте* мане́ра сиде́ть

утырыш|у *совм. от* **утыру** (*о многих*) **1.** рассе́живаться/рассе́сться, уса́живаться/усе́сться; *урыннарга ~у* рассе́сться по места́м; *диванга җайлап ~тылар* они́ поудо́бнее усе́лись на дива́не **2.** заседа́ть || заседа́ние; *иртәгә ~ып алырбыз* за́втра проведём заседа́ние

утырышчы *сущ. юр.* заседа́тель; *халык ~сы* наро́дный заседа́тель

уу *перех.* **1.** тере́ть, протира́ть/протере́ть *что*; *чигәләрен уу* тере́ть виски́; *күзләрен уу* протира́ть глаза́; *арканы мунчала белән уу* тере́ть спи́ну моча́лкой **2.** тере́ть, растира́ть/растере́ть, натира́ть/натере́ть *что чем*; масси́ровать, де́лать/сде́лать масса́ж || растира́ние, натира́ние, масси́рование; *ул аның битен кар белән уа* он трёт его́ щёки сне́гом; *бәрелгән урынны уу* потира́ть ушибленное ме́сто; *кулны уу* растира́ть ру́ку; *кипкән яфракларны уу* растере́ть вы́сохшие (*сухие*) ли́стья **3.** тере́ть, размина́ть/размя́ть *что*; *папирос уу* размя́ть папиро́су **4.** тере́ть; протира́ть/протере́ть; *кишерне кыргычтан уу* тере́ть (протира́ть) морко́вь че́рез тёрку (*на терке*) **5.** стира́ть, прости́рывать/простира́ть, вы́стирать || сти́рка; *кер уу* стира́ть бельё; сти́рка белья́

у-у *межд. служит для выражения укоризны, угрозы* у!; *у-у мин сине!* у, я тебя́!

уф *межд. выраж. тяжелый, горестный вздох, усталость, утомление, истому, облегчение* уф!, ох!, ой!; *уф, арыдым!* уф, устал!; *уф, әллә соңга калдым инде* ой, ка́жется, опозда́л! □ **уф ору** вздохну́ть; **«уф алла» арбасы** *см.* **уфалла**

уфалла *сущ. разг.* ручна́я теле́жка; *~га калу* быть вы́нужденным перевози́ть гру́зы ручно́й теле́жкой на да́льние расстоя́ния

уфлау *неперех.* о́хать, а́хать; вздыха́ть/вздохну́ть, испуска́ть/испусти́ть вздо́хи || о́ханье, а́ханье; *~ып утырырга вакыт чак* не́когда сиде́ть о́хать-а́хать **2.** го́рько сожале́ть (*о своих ошибках*) **3.** жа́ловаться, се́товать; *чал ана ~масын* пусть ста́рая мать не се́тует на свою́ жизнь □ **~ып кую** о́хнуть

уфтанышу *взаимно-совм. от* **уфтану**

уфылдату *понуд. от* **уфылдау**

уфылд|ау *неперех.* **1.** о́хать, а́хать, вздыха́ть, тяжело́ дыша́ть, испуска́ть вздо́хи || о́ханье, а́ханье, вздо́хи; *алар ~ыйлар* они́ вздыха́ют **2.** горева́ть; *урынсызга ~амагыз* не горю́йте впусту́ю □ **~ап кую** вздохну́ть

уфылдашу *взаимно-совм. от* **уфылдау**

уфыр|у *неперех.* с шу́мом вздыха́ть/вздохну́ть; *ник болай ~асың?* отчего́ так глубоко́ вздыха́ешь? □ **~ып кую** *разг.* глубоко́ вздохну́ть

ух *межд.* **1.** *выраж. сильное желание* ох, ой; *ух, салкын су эчәсе килә* ох, хо́чется холо́дной воды́ **2.** *выраж. восхищение, удивление, радость* ах, ай-ай, ай, ох, ого; *ух, нинди рәхәт!* ах, как хорошо́!; *ух, нинди зур!* ох, како́й большо́й! **3.** *выраж. испуг, возмущение, досаду, горе, боль и т. п.* уф, ой, ох, ай, ах; *ух, ничек куркыттың!* ой, как ты меня́ напуга́л!

ухват *сущ.* ухва́т; *~ белән чүлмәк алу* доста́ть ухва́том горшо́к

ухлау *неперех. см.* **ухылдау**

ух-пух *межд.* **ух-пух**

ухылд|ау *неперех.* о́хать, а́хать, вздыха́ть || о́ханье, а́ханье, вздыха́ние; *эшкә ~ап килеп керү* прийти́ на рабо́ту о́хая и а́хая; *~ап утыру* сиде́ть о́хая и а́хая; *ул ~ый* он вздыха́ет □ **~ап алу 1.** пооха́ть **2.** повздыха́ть; **~ап кую** о́хнуть; **~ап тору** продолжи́тельно о́хать

ухылдату *понуд. от* **ухылдау**

уһу *межд.* **1.** *выраж. утвердительный ответ* угу́; *— Алмаз институтка киттеме? — Уһу!* — Алмаз ушёл в институ́т? — Угу́! **2.** *выраж. удивление, изумление,*

одобрение ого́! ой-о́й!, ну и ну! здо́рово!; *уһу, сиңа бик зуры әләккән* ну и ну! тебе́ попа́лся са́мый большо́й; *уһу, кояш бик тубәнәйгән* ого́, со́лнце уже́ совсе́м ни́зко!

уһылдату *понуд. от* **уһылдау**

уһылда|у о́хать, а́хать || о́ханье, а́ханье; *пушкалар ~ды* а́хнули пу́шки; *ул ~п килеп керде* он вошёл о́хая и а́хая

уһылдашу *совм. от* **уһылдау**; а́хать, о́хать, вздыха́ть (*о многих*)

уч *сущ.* **1.** ладо́нь || ладо́нный; *киң уч* широ́кая ладо́нь; *учы белән маңгаена сугу* уда́рить (*хлопнуть*) ладо́нью по лбу (*по себе*) **2.** горсть, при́горшня; *бер уч бодай* горсть пшени́цы □ **уч сөякләре** *анат.* па́стные ко́сти; **уч төбе** ладо́нь; **уч тоту** держа́ть ладо́нь го́рстью; **уч төбе кадәр (кадәрле, хәтле)** величино́й с ладо́нь; **уч тутырып** при́горшнями; ◊ **уч төбе җылыту** дать на чай; **уч төбендә генә йөртү, учка утыртып йөртү** носи́ть на рука́х; **уч төбендәге кебек** как на ладо́ни; **учында кысып тоту** быть расчётливым, расхо́довать о́чень эконо́мно

уча|к *сущ.* **1.** оча́г, пе́чка; *~ктагы ут* ого́нь в очаге́ **2.** костёр; *~к янында утыру* сиде́ть у костра́ **3.** горн (*в кузнице*); *тимерче ~гы* кузне́чный горн **4.** одна́ из ка́мер тата́рской печи́; *олы ~к* больша́я ка́мера (*где пекут хлеб*); *кече ~к* ка́мера с вма́занным котло́м **5.** *перен.* оча́г, ку́зница, средото́чие; центр; *белем ~гы* оча́г зна́ний; *кадрлар ~гы* ку́зница ка́дров; *мәдәният ~гы* оча́г культу́ры; *сугыш ~гы* оча́г войны́ **6.** *перен.* оча́г, семья́, родно́й дом; *гаилә ~гының җылысы* тепло́ дома́шнего очага́ **7.** *уст.* ша́хта; *күмер ~гы* у́гольная ша́хта

учаклы *прил.* с очагом; име́ющий оча́г; *~ мич* печь, име́ющая отде́льные ка́меры (подто́пки)

учаклык *прил.* предназна́ченный для очага́; на одну́ то́пку; *бер ~ утын* дрова́ на одну́ то́пку

учар *сущ.* **1.** гру́ппа, ку́ча (*деревьев*) **2.** ме́сто сбо́ра; сбо́рный пу́нкт; *~га җыелу* собира́ться на сбо́рный пункт || *прил.* разветвлённый; ветви́стый; *~ мөгезле пошилар* ло́си с ветви́стыми рога́ми

учарлан|у *неперех.* разветвля́ться/разветви́ться || разветвле́ние; *карамалар ~ып үскән* ва́язы разветви́лись

учарлы *прил.* ветви́стый, разветвлённый; *~ куаклар* ветви́стые кусты́; *~ фикус* ветви́стый фи́кус

уча́сто|к *сущ.* **1.** *в разн. знач.* уча́сток; *см. тж.* **кишәрлек**; *җир ~гы* земе́льный уча́сток; *полкның оборона тоткан ~гы* уча́сток оборо́ны полка́; *эшнең мөһим ~гы* ва́жный уча́сток рабо́ты **2.** уча́сток, отделе́ние || участко́вый; *сайлау ~гы* избира́тельный уча́сток; *~к врачы* участко́вый врач; *~к милиционеры* участко́вый милиционе́р

учёт *сущ.* учёт || учётный; *кибеттә ~ үткәрү* провести́ учёт в магази́не; *~ ясау* проводи́ть учёт □ **~ карточкасы** учётная ка́рточка; **~ка алу** взять (*поставить*) на учёт; **~та тору** стоя́ть (состоя́ть) на учёте; **~тан төшерү** снима́ть/сня́ть с учёта; **~тан төшү** снима́ться/сня́ться с учёта

учётсыз *прил.* (*что, который*) без учёта, без регистра́ции; *~ оешма — ишексез өй* (*посл.*) организа́ция без учёта, что дом без дверей́

учёттагы *прил.* **1.** находя́щийся на учёте **2.** учтённый

учётчы *сущ.* учётчик; *см. тж.* **хисапчы**

учи́лище *сущ.* учи́лище || учи́лищный; *хәрби ~* вое́нное учи́лище; *педагогия ~сы* педагоги́ческое учи́лище

учлам *сущ.* **1.** клок, пучо́к, пук; *бер ~ йон* клок ше́рсти; *бер ~ печән* пучо́к се́на **2.** горсть; *бер ~ бодай* горсть пшени́цы

учлап *нареч.* при́горшнями, горстя́ми; *~ алу* брать при́горшнями

учла|у *перех.* брать/взять го́рстью, при́горшней, забира́ть/забра́ть в горсть; зажима́ть/зажа́ть в руке́ (*в кулаке*); *ул улының кулын ике кул белән ~ды* он зажа́л ру́ку сы́на двумя́ рука́ми; *печән учмасын ~у* зажа́ть в руке́ пучо́к се́на

учма *сущ.* **1.** пучо́к, пук; *бер ~ салам* пук соло́мы **2.** прядь, клок; *бер ~ чәч* клок воло́с; *бер ~ йон* клок ше́рсти

учмалану *страд. от* **учмалау**

учмалату *понуд. от* **учмалау**

учмала|у *перех.* держа́ть/брать (захва́тывать) свя́зками, пучка́ми; *арыш ~рга өйрәтә* нау́чит брать (захва́тывать) рожь пучка́ми

учмарлау *перех.* **1.** зажима́ть/зажа́ть в ладо́ни; жа́дно хвата́ть руко́й **2.** *редко* брать/взять горстя́ми

учреди́тельный *прил.* учреди́тельный; *~ собрание ист.* учреди́тельное собра́ние

учрежде́ние *сущ.* учрежде́ние || учрежде́нческий; *медицина ~се* медици́нское учрежде́ние; *~дә эшләү* рабо́тать в учрежде́нии

уш *сущ.* ум, сообрази́тельность; *ушы бар* он сообрази́телен

ушал I *сущ.* ла́вочка вдоль печи́; *тар ~* у́зкая ла́вочка

ушал II *сущ. миф. диал.* озорно́й дух-домово́й; озорно́й водяно́й (*который особенно вредит девушкам*)

ушандак *союз соед. уст. книжн.* а та́кже; *ике китап һәм ~ бер бит кәгазь* две кни́ги, а та́кже лист бума́ги

ушлы *прил.* сообрази́тельный, у́мный; *~ бала* сообрази́тельный ребёнок; *см. тж.* **һутлы**

уык *сущ.* **1.** уни́на, жердь ку́пола ю́рты **2.** *перен.* ра́диус **3.** *бот.* стрелоли́ст || *прил.* ради́альный; *~ сызыклар* ради́альные ли́нии

уыл *сущ. пчел.* **1.** детва́ **2.** де́тка

уылда|у *неперех.* выть, завыва́ть; подвыва́ть; *җил ~ап котыра* нейстово завыва́ет ве́тер; *этләр ~ый* соба́ки подвыва́ют

уылдык|к *сущ. зоол.* икра́ || ико́рный, икряно́й; *балык ~гы* ры́бья икра́; *бака ~гы* лягуша́чья икра́; *кызыл ~к* кра́сная икра́; *кара ~к* чёрная икра́; *бөртекле ~к* зерни́стая икра́; *~к бөртеге* икри́нка; *~к сүрүе* паю́с □ **~к чәчү** **1.** нерести́ться, отнерести́ться, мета́ть икру́ || икромета́ние, не́рест **2.** *перен. прост.* разъяря́ться/разъяри́ться, мета́ться (*о человеке*)

уылдыклы *прил.* икряно́й, икри́стый; *~ балык* икри́стая ры́ба; *~ чуртан* икри́стая щу́ка

уылу *страд. от* **уу**

уындыру *понуд. от* **уыну**

уыну *возвр. от* **уу** **1.** тере́ться, натира́ться/натере́ться; *мазь белән ~* натере́ться ма́зью **2.** *перен. разг.* ка́яться, раска́иваться/раска́яться

уыштыру *многокр. от* **уу**; пости́рывать *что*

уышу *взаимно-совм. от* **уу**

ую *перех.* **1.** долби́ть, выда́лбливать/вы́долбить *что чем* || долбле́ние, выда́лбливание; *ырмау ую* вы́долбить глаз **2.** пробива́ть/проби́ть отве́рстие, прорубать/прорубить || прорубание; *тәрәзә ую* прорубить окно́; *бәке ую* прорубить про́рубь **3.** выреза́ть/вы́резать, гравирова́ть || вырезание, гравирование; *медальонга исемен уеп язу* вырезать (*его*) имя́ на медальо́не; *уеп портрет*

ясау гравирова́ть портре́т; *тактага хәрефләр ую* вырезáть на доске́ бу́квы **4.** срезáть/сре́зать || срезáние □ **уеп алу (төшерү)** сре́зать, вы́резать; *бармак битен уеп төшеру* сре́зать поду́шечку па́льца

уяз *сущ. диал.* дол, доли́на (*пригодная для земледелия*)

уянгалау *многокр. от* **уяну**; иногда́ просыпáться

уян|у *неперех.* **1.** просыпáться/проснýться, пробуждáться/пробуди́ться от спя́чки || пробужде́ние; *йокыдан иртә ~у* рáно проснýться; *сискәнеп ~у* проснýться от испу́га; *~у сәгате* час пробужде́ния **2.** *перен.* проснýться, возника́ть/возни́кнуть, появля́ться/появи́ться; пробуждáться/пробуди́ться; *мәхәббәт (хисе) ~ды* проснýлась любóвь; *аның шахматта уйнарга өйрәнү теләге ~ды* у негó пробуди́лся интерéс к шáхматам **3.** *перен.* оживáть/ожи́ть, пробуждáться/пробуди́ться, просыпáться/проснýться; *урман ~ды* лес проснýлся; *табигать ~а* приро́да оживáет **4.** *в знач. прил.* **уянмас** беспробу́дный, непробу́дный; беспросы́пный; *~мас йокы* непробу́дный сон; *~мас йокыга китү (талу)* уснýть вéчным сном; уснýть навéки **5.** *в знач. нареч.* **уянмастан** беспробу́дно, без прóсыпу; не просыпáясь; *~мастан тоташ өч тәүлек йоклау* беспробу́дно проспáть трóе сýток подря́д

уяныр-уянмас *нареч.* спросóнок, спросóнья, впросóнках, в полусне́, в полусóнном состоя́нии, в полудрёме; *уяныр-уянмас ишетү* слы́шать сквозь полудрёму

уяныш|у *совм. от* **уяну**; просыпáться/проснýться, пробуждáться/пробуди́ться (*о многих*); *авыл халкы ~ып бетте* жи́тели дере́вни проснýлись

уяткыч *прил.* возбуждáющий || возбуди́тель

уяттыру *понуд. от* **уяту**

уят|у *перех.* **1.** буди́ть, разбуди́ть *кого*; *иртәгә сәгать алтыда ~ыгыз* разбуди́те зáвтра в шесть часóв; *баланы ~у* буди́ть ребёнка **2.** *перен.* пробуждáть/пробуди́ть, возбуждáть/возбуди́ть *что* || пробужде́ние, возбужде́ние; *йөрәгендә ышаныч ~у* пробуди́ть в егó сéрдце наде́жду; *эшкә дәрт ~у* пробуди́ть охóту к рабóте; *нәфрәт ~у* возбуди́ть нéнависть

уятылу *страд. от* **уяту** 1

уятышу *взаимно-совм. от* **уяту**

уяу *прил.* **1.** бóдрствующий, не спя́щий; *йоклыймы, уяумы?* спит он (онá) и́ли бóдрствует? **2.** *перен.* бди́тельный, чýткий, неусы́пный; *уяу халык* бди́тельный нарóд; *уяу кеше* бди́тельный человéк || *нареч.* бди́тельно, чýтко, неусы́пно; *уяу карау* смотре́ть бди́тельно □ **уяу булу 1.** бóдрствовать, не спать **2.** *перен.* быть бди́тельным, держáть ýхо востро́

уяулы-йокылы *прил.* **1.** полусóнный; *уяулы-йокылы хәл* полусóнное состоя́ние **2.** *в знач. нареч.* полусóнно; *ул уяулы-йокылы ята* он лежи́т полусóнный

уяулык *сущ.* **1.** бóдрствование **2.** *перен.* бди́тельность, чýткость; *~ күрсәтү* прояви́ть бди́тельность

Ү

үбеш *сущ.* поцелу́й, лобза́ние *уст.*

үбештерү *понуд. от* **үбешү**

үбешү *совм. от* **үбү**; целова́ться, поцелова́ться || поцелу́й

үбү *перех.* целова́ть, поцелова́ть (*ребёнка, любимого человека, руку, боевое знамя и т. п.*) || поцелу́й; *аналарча үбү* материнский поцелу́й; *кайнар үбү* горя́чий поцелу́й; *кат-кат үбү* расцелова́ть, осы́пать поцелу́ями □ **үбеп алу** *однокр.* поцелова́ть

үбү-кочу *перех.* обнима́ть и целова́ть, обнима́я и целу́я ласка́ть; *үпкән-кочкан, җилгә очкан* (*погов.*) бы́ло, быльём поросло́ (*букв.* целова́лись-обнима́лись — ве́тром унесло́)

үгәй *прил. диал. см.* **үги**

үгәйсенү *неперех. диал. см.* **үгисенү**

үгәйсетү *перех. диал. см.* **үгисетү**

үгәч *сущ.* хо́лка (*лошади и других упряжных животных*)

үгез *сущ.* бык, бога́й || бы́чий, быча́чий; *нәселле ~* поро́дистый бык; *~ тиресе* бы́чья шку́ра □ **~ бәбәк** *бот.* волчо́к; **~ бозау** бычо́к; **~ ите** воло́вина (*бычатина*); **~ күзе** *бот.* а́рника; **~ талпаны** клещ бы́чий; **~ теле** *бот.* воловиќ ◊ **~ кебек (шикелле, төсле)** си́льный, здоро́вый как бык; **~ кебек карау** гляде́ть бычко́м; **~ кебек кире** упря́мый как бык; **~ кебек эшләү** рабо́тать как вол; **~не мөгезеннән эләктерү (алу)** взять быка́ за рога́

үгезкүз *прил.* волоо́кий

үгет *сущ.* наставле́ние, поуче́ние, нравоуче́ние, нота́ция; назида́ние, увеща́ние *книжн.*; *ата-ана ~е* увеща́ние роди́телей; *кеше ~ен тыңламау* не слу́шаться наставле́ний други́х ◊ **~ бирү** *см.* **үгетләү**; **~ керү** подава́ться наставле́ниям (поуче́ниям)

үгетләтү *понуд. от* **үгетләү**

үгетләү *перех.* **1.** наставля́ть/наста́вить, дава́ть/дать наставле́ния; чита́ть нравоуче́ние; увеща́ть/увеща́ть || 1) наставле́ние, нравоуче́ние, увеща́ние, увеща́ние, назида́ние *книжн.* 2) настави́тельный, увеща́тельный, назида́тельный; *~ тоны* настави́тельный (наста́внический) тон; *хәл ~дән узган инде* увеща́ния уже́ не помо́гут **2.** увеща́ть, угова́ривать/уговори́ть || увеща́ние, угова́ривание; *укырга керергә ~* угова́ривать поступи́ть учи́ться; *бернинди ~ләр дә ярдәм итмәде* никаки́е увеща́ния не помогли́

үгетләшү *взаимн.-совм. от* **үгетләү**

үгет-нәсыйхәт *сущ. собир.* **1.** наставле́ния, поуче́ния, назида́ния, нравоуче́ния; *ата-ана үгет-нәсыйхәте* роди́тельские наставле́ния; *ул үгет-нәсыйхәткә мохтаҗ түгел* он в назида́ниях (поучениях) не нужда́ется **2.** увеща́ния, уговоры, увеща́ния □ **үгет-нәсыйхәт бирү** наставля́ть/наста́вить, чита́ть нота́цию, увеща́ть, угова́ривать; **үгет-нәсыйхәт бирүче** наста́вник, увеща́тель

үгет-нәсыйхәтле *прил.* наста́внический, поучи́тельный, нравоучи́тельный, назида́тельный; *үгет-нәсыйхәт сөйләшү* поучи́тельный разгово́р

үги *прил.* **1.** неродно́й, сво́дный, не свой; *үги бала* неродно́е дитя́, не свой ребёнок; *үги ана (сеңел)* сво́дная сестра́; *үги килен* сво́дная сноха́ (*жена неродного сына*) **2.** *перен.* чужо́й, чу́ждый; *шигърият миңа үги түгел* поэ́зия мне не чужда́; *туган авылым миңа үги икән* моя́ родна́я дере́вня оказа́лась чужо́й □ **үги ана** ма́чеха; **үги ана яфрагы** *бот.* мать-и-ма́чеха; **үги ата** о́тчим; **үги ботак** *бот.* волчо́к, па́сынок; **үги итү (күрү)** *см.* **үгисетү**; **үги кыз** па́дчерица; **үги ул** па́сынок; **үги туганлык** сво́йство

үгилек *сущ.* сиротли́вость, сиро́тство; заби́тость (*в семье*); *~тә үткән балачак* де́тство, проше́дшее в сиро́тстве

үгисенү *неперех.* чу́вствовать, почу́вствовать себя́ сиротой́ (*неродным, обиженным*)

үгисетү *перех.* обижа́ть/оби́деть, относи́ться/отнести́сь как к чужо́му

үҗәт *прил.* **1.** насто́йчивый, упо́рный, напо́ристый **2.** упря́мый, непода́тливый; *~ кеше* упря́мый челове́к

үҗәтләнү *неперех.* упря́миться, упира́ться, упере́ться

үҗәтлек *сущ.* **1.** насто́йчивость, упо́рство, напо́ристость; *аерым бер ~к белән эшләү* рабо́тать с осо́бым упо́рством **2.** упря́мство, непода́тливость; *кызның ~ге бар* де́вушка упря́ма

үз I *мест.* свой, своя́, своё; *үз урындыгым* свой стул; *үз урыным* своё ме́сто; *һәркемнең үз бәхете үзенә* (*погов.*) вся́кому своё сча́стье

үз II *прил.* **1.** свой, со́бственный, ли́чный; *үз хуҗалыгың белән яшәү* жить свои́м ли́чным хозя́йством; *үз йортыңны салу* постро́ить свой дом **2.** свой, родно́й, ро́дственный, бли́зкий; *үз анасы* его́ родна́я мать; *үз кешеләр* свой (бли́зкие) лю́ди **3.** свой, осо́бый, своеобра́зный; *бала үз телендә нидер әйтә* ребёнок на своём языке́ что́-то говори́т; *үз аңлавыңда* в своём понима́нии (*жизни*) □ **үз авыруы** эпиле́псия, припа́док; **үз чире тоту** *см.* **үз авыруы** ◊ **үз акылыңда (булу)** в своём уме́, без потери́ па́мяти и́ли созна́ния; **үз алдына** само́ по себе́; самостоя́тельно; **үз аршыныңа үлчәү** ме́рить на свой арши́н; **үз аягы белән 1.** прийти́ без по́мощи, дойти́ *куда-л.* самостоя́тельно **2.** доброво́льно, без принужде́ния, без приглаше́ния **3.** неожи́данно, нега́данно, без хлопо́т (*получить, приобрести богатство, счастье и т. п.*); **үз башына 1.** отде́льно, самостоя́тельно (*учить уроки, читать что-л., учиться чему-то*) **2.** обосо́бленно (*жить, трудиться и т. п.*) **3.** на свою́ го́лову, на свою́ поги́бель, на своё несча́стье; **үз башыннан чыгару** выду́мывать, сочиня́ть небыли́цу; **үз белдеге белән, үз белдегенчә** по своему́ усмотре́нию; без разреше́ния, самово́льно; **үз вакытында** своевре́менно, в своё вре́мя; в по́ру, во́время; **үз дигәне 1.** люби́мый челове́к **2.** по своему́ жела́нию, по своей́ во́ле (*сделать что-л.*); **үз дигәнен итү (эшләү)** настоя́ть на своём, доби́ться своего́ (жела́емого); **үз дигәненә ирешү** доби́ться своего́; **үз дигәнендә тору** наста́ивать на своём, упо́рствовать; **үз дигәнеңчә** по-сво́ему, по своему́ жела́нию, по своей́ во́ле; **үз җае белән** свои́м хо́дом, свои́м чередо́м; **үз җаена кую.** *см.* **үз иркенә кую**; **үз җилкәсенә алу** брать (взять) под свою́ ответственность, приня́ть на свои́ пле́чи; **үз җилкәсендә тату** испыта́ть на своей́ шку́ре; **үз ирке белән** доброво́льно, по своей́ во́ле; **үз иркенә кую 1.** не противоре́чить, не меша́ть *кому, чему-л.* **2.** пусти́ть на самотёк; **үз итү (күрү)** счита́ть свои́м (бли́зким,

ро́дственным), поступа́ть *с кем-л.* по-сво́йски; **үз кабыңа бикләнү** уходи́ть в свою́ скорлупу́; **үз казаныңда кайнау** вари́ться в со́бственном соку́; **үз кайгысы кайгы** то́лько своё, до чужо́го (посторо́ннего) де́ла нет; **үз каны (сөяге)** свой ро́дственник; **үз кеше** свой челове́к; свой брат, свой в до́ску; **үз колагың белән, үз күзең белән** свои́ми уша́ми (*слышать*), свои́ми глаза́ми (*увидеть*); **үз колагыңа (үз күзеңә) үзең ышанмау** не ве́рить свои́м уша́м (глаза́м); **үз көне** ли́чная, самостоя́тельная жизнь; **үз көчеңә керү** взять си́лу, войти́ в си́лу, стать жизнеспосо́бным, окре́пнуть; **үз көчендә калу** в си́ле (в си́лах); **үз кулы белән** добровóльно, по своéй вóле; **үз кулыңа алу** 1. брать (взять) в свои́ ру́ки, стать хозя́ином *чего-л.* 2. взять отве́тственность на себя́; **үз күзлегеннән карау** смотре́ть со своéй колоко́льни; **үз манарасыннан торып сөйләү (карау)** говори́ть (смотре́ть) со своéй колоко́льни; **үз өстеңә** на себя́, на свою́ го́лову; **үз сүзе сүз, үз бер тиене (бер) тиен, үз кырыгы кырык, үз туксаны туксан** *см.* **үзсүзле**; **үз сүзен итү** сде́лать по-сво́ему, по своему́ жела́нию; **үз сүзең белән (сөйләү)** рассказа́ть свои́ми слова́ми (*прочитанное*); **үз сүзеңдә тору** 1. сдержа́ть своё сло́во 2. наста́ивать на своём; **үз сүзеңне әйтү** сказа́ть своё сло́во, прояви́ть себя́ *в чём-л.*; **үз урынына кую (утырту)** поста́вить на (своё) ме́сто, указа́ть (его́) ме́сто; **үз урыныңны белү** знать своё ме́сто; **үз урыныңда** 1. по-ста́рому, без измене́ния 2. к ме́сту, кста́ти, уме́стно 3. на своём ме́сте (*человек*); **үз үлеме белән үлү** умере́ть своéй сме́ртью; **үз хәле хәл** не до други́х; до други́х де́ла нет; **үз чиратыңда (нәүбәтеңдә)** в свою́ о́чередь; **үз эченә бикләнү** замкну́ться; становúться необщи́тельным; **үз эшеңдә булу** де́лать своё де́ло; не обраща́ть внима́ния на другóе; **үз юлыңда (йөрү)** идти́ своéй доро́гой (свои́м путём); **үз юлың белән бару** идти́ своéй доро́гой (свои́м путём); поступа́ть самостоя́тельно (независи́мо, по своему́ жела́нию, по своéй вóле); **үз ягына аудару** перетяну́ть на свою́ сто́рону

үзагач *сущ.* древеси́на; *беренчел ~ спец.* первúчная древеси́на; *икенчел ~ спец.* вторúчная древеси́на

үзагым *сущ.* самотёк; *эшне ~ына кую* пусти́ть де́ло на самотёк

үзагымлы *прил.* самоте́чный; *~ сугару* самоте́чное орошéние

үзалдау *сущ.* самообма́н; *~ белән тынычлану* успоко́иться самообма́ном

үзалдына *нареч.* 1. про себя́; *~ сөйләну* разгова́ривать про себя́ 2. самостоя́тельно, сам по себе́; *~ яшәү* жить самостоя́тельно 3. сам собóй, невóльно, непроизвóльно; *см. тж.* **үзеннән-үзе** 2; *~ көлеп җибәрү* невóльно засмея́ться

үзаң *сущ.* самосозна́ние; *яңа ~ формалаша* форми́руется нóвое самосозна́ние

үзаңлылы|к *сущ. книжн.* самосозна́ние; *халыкның ~гы үсә* растёт самосозна́ние наро́да

үзаллы *прил. диал.* самостоя́тельный; *~ эш* самостоя́тельная рабóта || *нареч. диал.* самостоя́тельно; *~ эшләү* самостоя́тельно рабóтать

үзара *нареч.* ме́жду собóй, взаúмно, обою́дно; *~ ярышып эшләү* рабóтать соревну́ясь ме́жду собóй; *~ килешү* догова́риваться ме́жду собóй || *прил.* взаúмный, обою́дный; *~ билгеләгечләр мат.* взаúмные определи́тели; *~ бурычлар* взаúмные долги́ □ **~ бәйләнеш** *филос.* взаимосвя́зь; взаúмная обусло́вленность; **~ йогынты (тәэсир)** взаимовлия́ние, взаимоде́йствие; **~ талаш (сугыш, ызгыш)** междоусóбица; **~ ярдәм** взаимопóмощь; **~ ярдәмләшү** *см.* **үзара ярдәм** ◊ **~ гына әйткәндә** ме́жду на́ми говоря́

үзаралай *нареч. разг. см.* **үзара**

хәвеф *сущ.* 1. опа́сность, угро́за; *~ якынлашуы турында хәбәр итү* извести́ть о приближе́нии угро́зы 2. опасе́ние, боя́знь, страх; *аның кайтмау ~е бар* есть опасе́ние, что он не вернётся □ **~ астында калу (яшәү)** находи́ться (жить) в опа́сности, под угро́зой, в стра́хе; **~ итү** опаса́ться, боя́ться *чего-л.* ◊ **~(кә) салу (төшерү)** внуша́ть (вызыва́ть) беспоко́йство (страх, у́жас, трево́гу, опасе́ние) *у кого-л.*; наводи́ть страх, у́жас *на кого-л.*

хәвефләндерү *понуд. от* **хәвефләнү**; трево́жить, беспоко́ить *кого-л.*; вызыва́ть опасе́ния, страх *у кого-л.*

хәвефлән|ү *неперех.* опаса́ться, трево́житься; си́льно беспоко́иться || опасе́ния, боя́знь; *~еп көтеп тору* ждать в трево́ге, в состоя́нии си́льного беспоко́йства

хәвефле *прил.* опа́сный, стра́шный, риско́ванный; вызыва́ющий опасе́ния, пуга́ющий, трево́жный || стра́шно, опа́сно, риско́ванно; *~ эш* опа́сное, риско́ванное де́ло; *~ хәбәр* трево́жная весть; *авыруның хәле ~* состоя́ние больно́го вызыва́ет опасе́ния

хәвефсез, хәвефсез-нисез *нареч. см.* **хәвеф-хәтәрсез**

хәвефсезләндерү *перех.* обезопа́сить

хәвефсезләнү *неперех.* станови́ться/стать безопа́сным

хәвефсезлек *сущ.* безопа́сность (*на работе*); *~ бүлеге* отде́л безопа́сности

хәвеф-хәтәр *сущ. собир.* опа́сность, риск; угро́за, беда́; *хәвеф-хәтәр чыга күрмәсен* ка́к бы не вы́шло беды́ □ **хәвеф-хәтәрдән саклау** охраня́ть, оберега́ть от опа́сностей, обезопа́сить

хәвеф-хәтәрле *прил.* опа́сный, угрожа́ющий, трево́жный, риско́ванный; *хәвеф-хәтәрле сугыш еллары* трево́жные вое́нные го́ды

хәвеф(сез)-хәтәрсез *прил.* 1. безопа́сный, неопа́сный; *хәвеф(сез)-хәтәрсез эш* безопа́сная рабо́та 2. благополу́чный || *нареч.* благополу́чно; *хәвеф(сез)-хәтәрсез барып җитү* добра́ться благополу́чно

хәдис *сущ. рел.* хади́с (*предания о словах, деяниях и поступках пророка Мухаммеда*)

хәер I *сущ.* 1. бла́го, добро́; по́льза, прок; *моның ~е булмас* от э́того добра́ не жди 2. *в знач. сказ.* хорошо́, ла́дно; *алай ук булса, бик ~* е́сли так, то о́чень хорошо́; *ярдәмнең ~ен күрү* получи́ть по́льзу (бла́го) от по́мощи 3. ми́лостыня, пода́яние, поже́ртвование; пода́чка; *~ акчасы* де́ньги, полу́ченные в ка́честве ми́лостыни; *~ эстәп көн күрү* жить пода́чками, побира́ться 4. *в знач. нареч.* **хәердән** как ми́лость; *~дән булсын* пусть пойдёт в ка́честве вспомоществова́ния, ми́лостыни □ **~ бирү** (по)дава́ть ми́лостыню, пода́яние; **~ сорау (сорашу, эстәү)** проси́ть ми́лостыню, пода́яние; попроша́йничать || попроша́йничество; **~ сорашучы (эстәүче)** попроша́йка, ни́щий; *см. тж.* **хәерче, теләнче**; **~гә бирү** поже́ртвовать, дава́ть/дать как благодея́ние ◊ **~е (белән) булсын!** *см.* **хәерле(гә) булсын**; **~ен күр!** по́льзуйся на здоро́вье!

хәер II *вводн. сл.* впро́чем; *~, андый хәл булырга да мөмкин* впро́чем, тако́е не исключено́

хәер-дога *сущ. рел.* благослове́ние; *ата-ана хәер-догасы* благослове́ние роди́телей

хәерле *прил.* 1. благополу́чный, до́брый, счастли́вый (*в пожеланиях, приветствиях*) 2. *предик.* хорошо́, лу́чше; *аның килмәве ~* пусть он (она́) лу́чше не прихо́дит; лу́чше бы он (она́) не приходи́л (-ла) ◊ **~ булсын** 1. *см.* **хәерлегә булсын** 2. ла́дно уж, что поде́лаешь; **~ иртә!** до́брое у́тро!; **~ каза булсын** (*говорится, если с человеком произошло несчастье, неприятность*) не́т ху́да без добра́ (*букв.* пусть э́та беда́ обернётся бла́гом); **~ кич!** до́брый ве́чер; **~ сәгатьтә** в до́брый час; **~ төн (йокы)!** споко́йной но́чи!; **~ юл (сәфәр)** счастли́вого пути́, счастли́вой доро́ги; **~гә булмас, ~гә түгел** не к добру́; **~гә булсын** пусть всё бу́дет хорошо́, в до́брый час (*пожелание удачи при начинании какого-л. дела, мероприятия*)

хәерсез *прил. разг.* 1. недо́брый (несчастли́вый, неуда́чный); *~ сәгатьтә* в недо́брый час 2. *в знач. сущ. бран.* него́дный, непутёвый, незада́чливый, бестолко́вый, него́дник, бе́столочь *прост.*; *кара аларны, ~ләрне!* вы то́лько погляди́те на э́тих него́дников

хәер-садака *сущ. собир. см.* **хәер** 3; *хәер-садака өләшү* раздава́ть ми́лостыню

хәер-фатиха *сущ.* благослове́ние; *хәер-фатихасын алу* получа́ть/получи́ть благослове́ние; *хәер-фатиха сорау* проси́ть благослове́ние (*на брак*); *хәер-фатиха бирү* благословля́ть, дава́ть благослове́ние

хәер-фатихалы *прил.* благожела́тельный; *кешеләргә хәер-фатыйхалы карау* благожела́тельное отноше́ние к лю́дям

хәерхаһ *сущ.* доброжела́тель, благожела́тель; *~ чырай белән каршы алу* оказа́ть тёплый приём, доброжела́тельно встре́тить

хәерхаһлы *прил.* доброжела́тельный, благожела́тельный; *~ остаз* благожела́тельный наста́вник

хәерхаһлык *сущ.* доброжела́тельность, благожела́тельность; сочу́вствие; *~ күрсәтү* прояви́ть доброжела́тельность (сочу́вствие)

хәерче *сущ.* ни́щий; *уничиж.* попроша́йка, побиру́шка *прост.* || ни́щенский; *см. тж.* **теләнче**; *~ хатын (кыз)* ни́щенка; *~ тормышы* ни́щенское существова́ние; *~гә якты чырай күрсәтсәң — ямаулык сорый* (*погов.*) дай ни́щему с ногото́к — попро́сит с локото́к (*букв.* сто́ит взгляну́ть на ни́щего — начнёт проси́ть на запла́тку); *~гә кыяр биргәннәр — кәкре икән, дигән* (*посл.*) дай го́лому холст, а он ска́жет: толст; *~гә җил каршы* (*посл.*) бе́дному Ва́нюшке везде́ ка́мушки (*букв.* ни́щему и ве́тер навстре́чу) || *прил.* 1. ни́щий, обнища́вший; *~ авыл* ни́щая дере́вня 2. *бран.* бестолко́вый; *и ~, шуны да аңламый* ну, бестолко́вый, да́же э́того не понима́ет □ **~ капчыгы** 1. ни́щенская сума́ 2. *перен.* ни́щий, попроша́йка ◊ **~ көненә калу** бе́дствовать, ни́щенствовать

хәерчеләндерү *перен.* разоря́ть/разори́ть, доводи́ть/довести́ до нищеты́, пусти́ть по́ миру || разоре́ние

хәерчелән|ү *неперех.* 1. нища́ть, обнища́ть, разори́ться, пойти́ по́ миру || обнища́ние 2. попроша́йничать, ни́щенствовать; *~еп акча сорау* выкля́нчивать де́ньги

хәерчелек *сущ.* нищета́; ни́щенство, попроша́йничество; *см. тж.* **теләнчелек**; *~тә яшәү* жить в нищете́; ни́щенствовать ◊ **~ көненә калу** оконча́тельно разори́ться, впасть в нищету́; **~кә бату** погря́знуть в нищете́; **~кә төшерү (калдыру)** разоря́ть, пусти́ть по́ миру; **~кә төшү (калу)** (об)нища́ть, впасть в нищету́; *см. тж.* **хәерчеләнү**

хә́зер *нареч.* 1. сейча́с, тепе́рь, ны́нче, ны́не; *~ инде ни эшлибез?* что тепе́рь де́лать бу́дем? 2. *в знач. межд. разг. ирон.* ка́к же, держи́ карма́н ши́ре; *~ көтеп тор, килә ул!* ка́к же, жди, придёт он! □ **~ генә** то́лько что, вот-во́т; *ул ~ генә биредә иде* он то́лько что был здесь; *~ дә* и тепе́рь; *ул әле ~ дә мине искә төшерә* он (она́) и тепе́рь меня́ вспомина́ет; **~ үк** сейча́с же, неме́дленно; *китапны ~ үк илтеп бир* сейча́с же отнеси́ кни́гу; **~гә чаклы (кадәр)** до настоя́щего вре́мени

хәзе́р *предик. см.* **әзер**

хә́зергә *нареч.* пока́, пока́ что; *~ бер нәрсә дә билгеле түгел* пока́ ничего́ не изве́стно; *~ канәгать* пока́ что дово́лен; *~ хуш!* пока́! (*при расставании ненадолго*)

хә́зергәчә *нареч.* до сих по́р, до настоя́щего вре́мени; *~ оныттмау* до сих по́р по́мнить

хәзерге *прил.* совреме́нный, ны́нешний, настоя́щий, теку́щий; *~ вакытта (көндә)* в да́нное (настоя́щее) вре́мя; *~ татар әдәби теле* совреме́нный тата́рский литерату́рный язы́к; *~ заман техникасы* совреме́нная те́хника; *~ чор* совреме́нная эпо́ха; *~ шартларда* в совреме́нных усло́виях □ **~ заман** *грам.* настоя́щее вре́мя; *~ заман фигыле грам.* глаго́л настоя́щего вре́мени

хә́зергечә *нареч.* по-совреме́нному; *см. тж.* **заманча**; *~ киенү* одева́ться по-совреме́нному

хәзерләнгәнлек *сущ.* подгото́вленность; *~ күрсәтү* продемонстри́ровать подгото́вленность

хәзерләндерү *понуд. от* **хәзерләнү**

хәзерлән|ү *возвр.-страд. от* **хәзерләү** 1. *возвр.* гото́виться, приготовиться, приготовля́ться, приготавливаться/подготовля́ться, подготавливаться/подгото́виться *к чему-л.* || приготовле́ния, подгото́вка *к чему-л.*; *чәчүгә ~ү* приготовиться к се́ву || подгото́вка к се́ву; *китәргә ~ү* приготовиться к съе́зду 2. *в сочетании с основным глаголом в ф. на* **~(ы)рга**; *театрга барырга ~ү* собира́ться пойти́ в теа́тр 3. *страд.* подготовля́ться, подготавливаться; *алдан ~гән* подгото́вленный зара́нее (*ответ, доклад*) □ **(алдан) ~ен кую** приготовиться, подгото́виться (зара́нее)

хәзерләтү *понуд. от* **хәзерләү**

хәзерлә|ү *перех.* 1. *в разн. знач.* гото́вить, приготовить; приготовля́ть, подготовля́ть/подгото́вить || приготовле́ние, подгото́вка || подготови́тельный, приготови́тельный; *см. тж.* **әзерләү**; *~ү группасы* подготови́тельная гру́ппа; *ашарга ~ү* гото́вить (стря́пать) еду́; *дәрес ~ү* гото́вить уро́ки; *китапны бастырырга ~ү* подгото́вить кни́гу к печа́ти; *студентны имтиханга ~ү* гото́вить студе́нта к экза́мену; *ятак ~ү* приготовить, (за)стели́ть посте́ль; *өстәл ~ү* накры́ть на стол; *кадрлар ~ү* гото́вить ка́дры; подгото́вка ка́дров; *укытучылар ~п чыгару* выпуска́ть (гото́вить) учителе́й 2. заготовля́ть/заготовить (запаса́ть) || 1) заготовка 2) заготови́тельный; *авыл хуҗалыгы азыкларын ~ү* заготовка сельскохозя́йственных проду́ктов; *~ү бәясе* заготови́тельная цена́; *~ү планы* заготови́тельный план □ **~п кую** 1. подгото́вить, приготовить; *барлык белешмәләрне ~п кую* подгото́вить все спра́вки 2. запасти́сь, заготовить; *кышка утын ~п кую* заготовить дрова́ (запасти́сь дрова́ми) на́ зиму

хәзерләүче *сущ.* заготови́тель, заготовщик (*человек или организация*); *агач ~* заготови́тель древеси́ны

хәзерләшү *взаимно-совм. от* **хәзерләү**

хәзерле|к *сущ.* 1. приготовле́ние, подгото́вка || подготови́тельный; *туй ~кләре* сва́дебные приготовле́ния; *сайлау алды ~ге (~кләре)* подгото́вка к вы́борам, предвы́борная компа́ния; *аның ~ге бик яхшы* у него́ о́чень хоро́шая подгото́вка; *~к эшләре* подготови́тельные рабо́ты; *~к курслары* подготови́тельные ку́рсы 2. подготови́тельность, гото́вность; *сугышчан ~к* боева́я гото́вность; *~к дәрәҗәсе* сте́пень, у́ровень подгото́вленности □ **~к күрү (алыш бару)** *см.* **хәзерләнү** 2

хәзерлекле *прил.* подгото́вленный; *яхшы ~ белгеч* хорошо́ подгото́вленный специали́ст; *теоретик яктан аз ~* с недоста́точной теорети́ческой подгото́вкой, теорети́чески недоста́точно подгото́вленный

хәзерлеклелек *сущ. см.* **хәзерләнгәнлек**

хәзерлексез *прил.* неподгото́вленный, без подгото́вки; *дәрескә ~ килү* прийти́ на заня́тия неподгото́вленным (без подгото́вки)

хәзерлексезлек *сущ.* неподгото́вленность; *~ белән* без подгото́вки

хәзинә *сущ.* 1. достоя́ние, бога́тство, добро́, иму́щество; *сандык тулы ~ це́лый сунду́к добра́ (бога́тства); ~дә бары белән сыйлау* угоща́ть чем бог послал (*букв.* угоща́ть всем тем, что име́ется в запа́се); *~дә булганны өстәленә куй (погов.)* что есть в печи́, всё на стол мечи́; *~ күктән төшми — хезмәттән (посл.)* бога́тство с не́ба не па́дает, а добыва́ется трудо́м 2. казна́; *дәүләт ~се* госуда́рственная казна́ 3. *прям., перен.* клад, сокро́вище; *~ табу* найти́ клад; *җир асты ~ләре* подзе́мные кла́ды; сокро́вища земны́х недр; *бу белгеч — безнең өчен көтелмәгән ~* э́тот специали́ст для нас неожи́данный клад 4. сокро́вищница (*хранилище сокровищ*) 5. *перен.* сокро́вище, сокро́вищница, бога́тство (*о совокупности каких-л. культурных, духовных ценностей*); *тел ~се* бога́тство языка́; *дөнья мәдәнияте ~се* сокро́вищница мирово́й культу́ры; *рухи матурлык ~се* бога́тство духо́вной красоты́ 6. *перен.* бла́го, бла́га; исто́чник существова́ния; *җәй жимеше — кыш ~се (посл.)* ле́тние плоды́ — зи́мние бла́га ◊ **~дә барынча, ~дә бары белән** чем бога́ты, тем и ра́ды

хәзинәдар *сущ. уст. книжн.* 1. владе́лец сокро́вищ 2. казначе́й

хәзинәче *сущ.* казначе́й

хәзрәт *сущ.* 1. *рел.* мулла́ 2. вели́чество, высо́чество, сия́тельство, све́тлость, преподо́бие, преосвяще́нство (*титул, прибавляемый к имени пророков, святых монархов, высокопоставленных лиц*)

хәйлә *сущ.* 1. хи́трость, уло́вка, увёртка, ухищре́ние; ко́зни; плутовство́; лука́вство; *~ кору* устро́ить ко́зни; *~гә оста* ло́вкий на увёртки, изворо́тливый; *~не сизү* поня́ть (разгада́ть) хи́трость, уло́вку; *~гә элгү* попа́сться на хи́трость; *хәрби ~* вое́нная хи́трость; *һәртөрле ~ләр куллану* прибега́ть к разли́чным ухищре́ниям; *~ белән әйтү* сказа́ть с хитрецо́й; *аз гына ~ белән* с лука́винкой; *аның ~се юк түгел* он не без лука́вства, он не та́к-то прост 2. по́вод, предло́г, отгово́рка; *~ эзләү* иска́ть по́вод 3. *разг.* секре́т, та́йна, хи́трость; *см. тж.* **хикмәт** 3; *ул машинаның ~сен белеп алган* он изучи́л (раскры́л) секре́т (устро́йства) э́той маши́ны □ **~ белән** с (хи́трым) у́мыслом; хи́трым о́бразом; **~ кору** хитри́ть, стро́ить ко́зни, интригова́ть, плести́ интри́ги; **~гә керешү** пусти́ться на хи́трость; **~сен табу** 1. найти́ предло́г, по́вод 2. ухитря́ться/ухитри́ться, умудри́ться *что-л.* сде́лать

хәйләи-шәргыя *сущ. книжн.* опра́вданная, вполне́ допусти́мая хи́трость; свята́я ложь, ложь во бла́го

хәйләкәр *прил.* хи́трый, хитроу́мный, лука́вый, кова́рный; плутова́тый || *сущ.* хитре́ц, плут; пройдо́ха, хитрю́га; *~ кыз (хатын)* плуто́вка; *төлке кебек ~* хи́трый,

как лисá (*главн. обр. о человеке*); ~ *дошман* ковáрный враг || *нареч.* хи́тро, лукáво, плутовáто; ~ *елмаеп алу* хи́тро улыбну́ться ◊ ~ **таз** *фольк.* нахóдчивый, неунывáющий, смекáлистый геро́й скáзок (*обычно шакирд*); ~ **төлке** *перен.* хитре́ц, плут; Лисá Патрике́евна

хәйләкәрләнү *неперех.* **1.** становúться/стать хúтрым **2.** хитрúть, пускáться на хúтрости □ **~еп китү** *см.* **хәйләкәрләнү** 1

хәйләкәрлек *сущ.* хúтрость, лукáвство, хитроýмие; ухищре́ния, плутовствó; *нинди ~!* какóе лукáвство!

хәйләл|әү *неперех.* **1.** хитрúть, схитрúть, лукáвить, слукáвить, плутовáть, сплутовáть, обмáнывать; интриговáть, строúть кóзни; *~и, ышанма!* обмáнывает, не верь! **2.** *в знач. нареч.* **хәйләләп** хúтростью, обмáном; *~әп китерү* привестú *кого-л.* хúтростью; заманúть; *~әп котылу* отдéлаться *от кого, чего-л.* хúтростью, увильнýть *от кого, чего-л.*

хәйләләшү **1.** *совм. от* **хәйләләү** (*о многих*) **2.** *см.* **хәйләләү**

хәйләле *прил.* хúтрый, хитроýмный, ухищрённый; плутовскóй, лукáвый; *см.* **хәйләкәр**; ~ *политика* хитроýмная полúтика; ~ *караш* лукáвый взгляд; ~ *ният* хитроýмный зáмысел; ~ *җавап бирү* ответúть с хитрецóй; ~ *эшләр* плýтни || *нареч.* хúтро, лукáво; плутовскú, с хитрецóй; ~ *җавап бирү* отвечáть хúтро; ~ *күз кысу* лукáво подмигнýть

хәйләлелек *сущ.* **1.** *см.* **хәйләкәрлек** **2.** *разг.* изворóтливость, нахóдчивость

хәйлә-мәкер *сущ. собир.* хúтрость и ковáрство; кóзни; интрúги; □ **хәйлә-мәкер белән** хúтростью; с пóмощью интрúг

хәйләсез *прил.* **1.** бесхúтростный, простовáтый, простодýшный, неискушённый, наúвный; недалёкий (*о человеке*); ~ *бала* наúвный ребёнок; ~ *дөнья файдасыз* (*погов.*) не соврёшь — зоб не набьёшь (*букв.* без хúтрости мир бесполéзен) **2.** *нареч.* простодýшно, бесхúтростно; добросóвестно; ~ *эшләү* дéлать добросóвестно; ~ *күренү* показáться простодýшным

хәйләсезлек *сущ.* простодýшие, наúвность, бесхúтростность, неискушённость

хәйләсез-нисез *нареч.* простодýшно, наúвно, бесхúтростно; *дөньяга хәйләсез-нисез карау* смотрéть на мир простодýшно, сквозь рóзовые очкú

хәйләче *сущ.* хитрéц, мáстер на хúтрости; плут; *ул шундый ~ , диләр* говоря́т, он такóй плут

хәйләчелек *сущ.* склóнность к плутовствý, плутовствó, плýтни; *~кә бару* пускáться на хúтрости; хитрúть, плутовáть

хәйран *прил.* **1.** удивúтельный, дúвный, чýдный, чудéсный, изумúтельный; *менә ~ тамаша, менә әкәмәт!* что за дúвное зрéлище, что за чýдо! **2.** удивлённый, изумúтельный, растéрянный; ~ *күзләр* изумлённые глазá || *нареч. разг.* хорошó, замечáтельно, на слáву; изря́дно, поря́дочно; *игеннәр ~ уңган* хлебá уродúлись на слáву □ **~(га) булу (калу)** поражáться/поразúться, изумля́ться/изумúться, удивля́ться/удивúться || удивлéние, изумлéние; ~ **итү (калдыру)** изумля́ть/изумúть, поражáть/поразúть, удивля́ть/удивúть; *матурлыгы белән ~ итү* поражáть, изумля́ть своéй красотóй ◊ ~ **гына** **1.** довóльно мнóго **2.** довóльно-таки хорошó; ~ **калырлык** восхитúтельный, изумúтельный || изумúтельно, восхитúтельно

хәйранлану *см.* **хәйран булу (калу)**

хәйранлык *сущ.* удивлéние, изумлéние; *алар ~та калдылар* онú остáлись (засты́ли) в изумлéнии

хәйрия *сущ.* благотворúтельность || благотворúтельный; ~ *концерты* благотворúтельный концéрт

хәйрият *сущ.* благотворúтельность, благотворúтельные делá

хәкарәт *сущ. уст. книжн.* оскорблéние, поношéние; глумлéние, посрамлéние; *тиешсез ~* незаслýженное оскорблéние □ **~ итү (кылу)** унижáть, оскорбля́ть, глумúться, срамúть; **~ күзе белән карау** смотрéть с презрéнием

хәкарәтлә|ү *перех. см.* **хәкарәт итү**; *~п чыгару* с позóром выставить за дверь

хәкарәтле *прил.* оскорбúтельный, унижáющий *чьё-л.* достóинство (*о словах, взгляде*)

хәким *сущ. книжн.* **1.** учёный, мудрéц, филóсоф; *ак сакаллы ~* седоборóдый мудрéц **2.** *см.* **хаким** 1

хәкыйрь|ь *сущ. книжн.* **1.** уни́женный, оскорблённый; презрéнный, пóдлый; жáлкий, ничтóжный; *фәкыйрь вә ~ь* бéдный и презрéнный **2.** *перен.* покóрный слугá; *сәлам белән сезнең ~егез* с привéтом ваш покóрный слугá

хәкыйрьлек *сущ.* **1.** уни́женное, угнетённое положéние, состоя́ние **2.** покóрность, смирéнность

хәл *сущ.* **1.** *в разн. знач.* состоя́ние (*чьё-л., кого, чего-л.*); *авыруның хәле бик авыр* состоя́ние больнóго óчень тяжёлое; *син минем хәлемне аңламыйсың* ты не понимáешь моегó состоя́ния; *мин укырлык хәлдә түгел* я не в состоя́нии читáть; *яраксыз хәлгә килү* прийти́ в негóдное состоя́ние; *аның хәле рәтләнә башлаган* егó состоя́ние нáчало улучша́ться; *әйбернең сыек хәлдән каты хәлгә күчүе физ.* переход из жúдкого состоя́ния в твёрдое **2.** положéние, ситуáция, обстановка, обстоя́тельства; *халыкара хәл* междунарóдное положéние (ситуáция, обстановка); *гаилә хәле* семéйное положéние; *социаль хәл* социáльное положéние; *авыр хәлгә төшү* попáсть в безвы́ходное положéние (ситуáцию); *булган хәлләргә карап* смотря́ по обстоя́тельствам **3.** сúла (*физическая*), сúлы; самочýвствие; мощь, *прост.* мочь; *хәл(ем) юк* (у меня́) нет сил, плóхо себя́ чýвствую; *күз ачарга хәлем юк хәтта* нет сил дáже откры́ть глазá; *түзәр хәл(ем) калмады, чыдар хәл(ем) юк* (у меня́) нет мóчи, нет сил терпéть; *ни хәлләрегез бар?* как вáше самочýвствие? как себя́ чýвствуете? **4.** происшéствие, слýчай, событие; дéло, делá; *аерым хәлләрдә* в отдéльных слýчаях; *күңелсез хәл* неприя́тный слýчай; *урамда булган хәл* ýличное происшéствие, слýчай на ýлице; *соңгы көннәрдә булган хәлләр* собы́тия послéдних дней; *ни хәл?* как делá?; *хәлләр шәптән түгел* делá идýт невáжно, дéло обстои́т не лýчшим óбразом **5.** *лингв.* обстоя́тельство || обстоя́тельственный; *урын хәле* обстоя́тельство мéста; *иярчен хәл җөмлә* придáточное обстоя́тельственное предложéние; *рәвеш хәле* обстоя́тельство óбраза дéйствия □ **хәл әйләнмәсе** *грам.* деепричáстный оборóт; **хәл белү (белешү, сорашу)** справля́ться/спра́виться; навещáть, навéдываться **хәл бетү (калмау, китү)** устáть, обессúлеть, изнемóчь; **хәл итү** решáть/решúть, разрешáть/разрешúть; *ул мәсьәләне экспертиза хәл итәчәк* э́тот вопрóс разрешúт экспертúза; **хәл итәрлек** разреши́мый; **хәл фигыль** *грам.* деепричáстие ◊ **хәл алу** **1.** отдохнýть, передохнýть, отдышáться, собрáться с сúлами, набрáться сил **2.** попрáвить своё материáльное положéние; **хәл барынча, хәл кадәре(нчә)** в мéру сил, по мéре возмóжностей, по возмóжности; **хәл җитмәслек** непосúльный; *см. тж.* **көч җитмәслек**; **хәл җыю** *см.* **хәл алу** 1; **хәл керү** **1.** набирáться сил, крéпнуть,

окре́пнуть 2. выздора́вливать, поправля́ться; **хәл эчендә** при́ смерти; **... хәл юк** 1. невозмо́жно ..., нельзя́ не ...; *ышанмаска (ышанмый) хәлем юк* не могу́ не пове́рить; *көтми хәл юк* ничего́ не поде́лаешь, придётся ждать (нельзя́ не подожда́ть) 2. сто́ит (сто́ило) то́лько, лишь то́лько ...; не успе́л я (*передаёт быструю смену действий*); **хәлгә (хәленә) керү** сочу́вствовать, сострада́ть; войти́ *в чьё-л.* положе́ние; **хәлгә керүчән** уча́стливый; **хәлдән килгәнче** по ме́ре (в ме́ру) возмо́жностей; **хәлдән килү** спра́виться; быть в си́лах, в состоя́нии, иметь возмо́жность *что-л.* сде́лать; **хәлдән тайганчы** до изнеможе́ния, до упа́ду; **хәлдән тайдыру** изма́тывать/измота́ть, изнуря́ть/изнури́ть; **хәлдән таю** выбива́ться/вы́биться из сил, обесси́леть; **хәле (хәлләр) хәл** де́ло пло́хо, пло́хи дела́, дела́ в плаче́вном состоя́нии

хәләл *прил. книжн.* 1. *рел.* дозво́ленный, разрешённый, допусти́мый, незапрещённый (шариа́том); *противоп. см.* **харам**; *авыруга елан ите дә ~* (*посл.*) больно́му дозво́лено есть да́же змеи́ное мя́со 2. 1) че́стный, че́стно приобретённый (зараб6танный); кро́вный (*состояние*); *~ акча* че́стно зараб6танные де́ньги; *~ мал* че́стно нажито́е состоя́ние; *~ ашны урамда ашасаң да ярый* (*погов.*) че́стно зараб6танный хлеб мо́жно есть и на у́лице (при всех) 2) пра́ведный; *~ тормыш* пра́ведная жизнь; *~ хезмәтләр* пра́ведные труды́ 3. свяще́нный || *предик.* свяще́нно, свя́то; *кара икмәк ана сөте кебек ~* чёрный хлеб свят, как матери́нское молоко́ 4. *в знач. сущ. в притяж. ф.* **хәләлем** *разг.* зако́нный супру́г; *минем ~ем* моя́ зако́нная жена́, моя́ благове́рная (*в устах мужчины*); мой зако́нный муж (*в устах женщины*) □ **~ җефет (җәмәгать)** зако́нная жена́, дража́йшая полови́на, подру́га (спу́тница) жи́зни, благове́рная; **~ җефетлеккә алу** брать в супру́ги, в жёны

хәләл-хәрәм *прил. собир. разг. имеет индив. переводы*; *хәләл-хәрәм эшләр* тёмные (*букв.* дозво́ленные и недозво́ленные) дела́, дели́шки; *хәләл-хәрәм байлык* добро́, нажито́е нече́стным (*букв.* дозво́ленным и недозво́ленным) путём

хәл-әхвәл *сущ. собир.* житьё-бытьё □ **хәл-әхвәл сорашу (сорау)** расспра́шивать о дела́х, житьё-бытье́

хәлбуки *союз книжн.* одна́ко, ме́жду тем; тогда́ как, в то вре́мя как

хәлвә *сущ.* халва́ || халво́вый (*цех*); *чикләвек ~се* оре́ховая халва́; *~ ясый торган масса* халво́вая ма́сса; *~ хакимгә, таяк ятимгә* (*погов.*) халва́ достаётся судье́, а па́лка — сироте́

хәлвәле *прил.* содержа́щий халву́, с халво́й

хәлвәфрүш *сущ. книжн.* челове́к, изготовля́ющий и продаю́щий халву́; халви́чник

хәлвәче *сущ. см.* **хәлвәфрүш**

хәлгәт *сущ. уст.* 1. бе́лая плащева́я ткань || из бе́лой плащево́й тка́ни; *~ хәллә* дорого́й плащ из бе́лой тка́ни 2. хала́т, ри́за

хәлдә, хәлендә *послелог* в ви́де (состоя́нии, положе́нии); *утырган ~* си́дя, в сидя́чем положе́нии; *төзәтелгән ~* в испра́вленном ви́де; *бу ~* в тако́м ви́де (состоя́нии)

хәле́нчә *нареч.* по свои́м возмо́жностям; *хәлле ~* ка́ждый по ме́ре свои́х возмо́жностей

хәлиткеч *прил.* реша́ющий (*момент, фактор*), реши́тельный, име́ющий первостепе́нное значе́ние; *~ көчкә әйләнү* превраща́ться в реша́ющую си́лу; *~ сүз әйтү* сказа́ть реша́ющее сло́во; *~ момент* реши́тельный (реша́ющий) моме́нт

хәлифә *сущ. ист.* хали́ф (*титул феодального верховного правителя мусульман в странах Ближнего и Среднего Востока*) || хали́фский

хәлифәлек *сущ. ист.* 1. халифа́т (*система государственного устройства с теократической властью в мусульманских странах в эпоху феодализма*) 2. халифа́т (*феодальное государство, образовавшееся в результате арабских завоеваний, во главе которого стоял халиф*) || относя́щийся к халифа́ту; *Багдад ~ге* Багда́дский халифа́т 3. власть, правле́ние, положе́ние хали́фа; хали́фство

хәлләндерү *понуд. от* **хәлләнү** 1. помога́ть, спосо́бствовать *кому-л.* в укрепле́нии хозя́йства, спосо́бствовать вы́ходу из нужды́ 2. подкрепля́ть, подкрепи́ть *кого-л.* (*больного*)

хәлләнү *непереx.* 1. поправля́ться/попра́виться, выздора́вливать/вы́здороветь; кре́пнуть, окре́пнуть; набира́ться/набра́ться сил (*после болезни*) 2. *перен.* кре́пнуть, окре́пнуть; попра́вить своё материа́льное положе́ние, выходи́ть/вы́йти из нужды́, встава́ть/встать на́ ноги □ **~еп китү** *см.* **хәлләнү** (*все глаголы совершенного вида*)

хәлле *прил.* 1. си́льный, здоро́вый, кре́пкий; в си́ле; *~ чагында* когда́ в си́ле 2. *перен.* зажи́точный, состоя́тельный; *~ кеше* состоя́тельный челове́к; *урта ~ крестьян* крестья́нин-середня́к; *~ хәленчә, юк ~ дәрманынча* (*посл.*) бога́тому — как хо́чется, а бе́дному — как мо́жется ◊ **~ хәленчә** кто как мо́жет; ка́ждый по ме́ре свои́х возмо́жностей

хәллелек *сущ.* состоя́тельность, зажи́точность

хәлсез *прил.* 1. бесси́льный, сла́бый, не́мощный; *картның ~ куллары* сла́бые (не́мощные) ру́ки старика́ 2. *перен.* бе́дный, ни́щий, разорённый; пришёдший в упа́док, несостоя́тельный; *~ крестьян хуҗалыгы* бе́дное (ни́щее) крестья́нское хозя́йство

хәлсезләндерү *понуд. от* **хәлсезләнү** 1. обесси́ливать/обесси́лить, лиша́ть сил; ослабля́ть/осла́бить, изма́тывать/измота́ть || ослабле́ние, обесси́ливание, изма́тывание 2. *перен.* приводи́ть/привести́ в упа́док, разоря́ть/разори́ть || разоре́ние

хәлсезләнү *непереx.* 1. слабе́ть, ослабева́ть/ослабе́ть; *куллар ~ә* ру́ки слабе́ют 2. *перен.* беднеть, обедне́ть, приходи́ть/прийти́ в упа́док; *сугыш вакытында ~гән хуҗалыклар* в войну́ пришёдшие в упа́док (разорённые войно́й) хозя́йства

хәлсезлек *сущ.* 1. сла́бость, бесси́лие, упа́док сил; *организмның гомуми ~ге* о́бщая сла́бость организ́ма 2. утомле́ние, утомлённость, уста́лость; *физик ~к* физи́ческая уста́лость 3. *перен.* бе́дность, несостоя́тельность; *хуҗалыкның ~ге* бе́дность хозя́йства

хәлфә *сущ. уст.* учи́тель (*в дореволюционных медресе*), настáвник

хәлфәлек *сущ. уст.* до́лжность, обя́занность, положе́ние учи́теля □ **~ итү** *книжн.* учи́тельствовать, исполня́ть обя́занности учи́теля

хәлчә *нареч.* по ме́ре сил, по возмо́жности; *~ тырышу* стара́ться по ме́ре сил

хәмәл *сущ.* 1. 1) зодиака́льное созве́здие Ове́н 2) знак о́вна 2. *диал.* апре́ль

хәмел *сущ. уст.* предположе́ние, дога́дка □ **~ итү (кылу)** гада́ть, нагада́ть; предска́зывать/предсказа́ть (*будущее*); **~ садакасы** *рел.* де́ньги, подава́емые тем, кто несёт поко́йника на кла́дбище

хәмер *сущ.* алкого́ль, спиртно́е; во́дка; *~нең зыяны* вред алкого́ля

хәнҗәр *сущ.* кинжа́л || кинжа́льный; *~ кыны* кинжа́льные но́жны; *~ сабы (тоткасы)* рукоя́тка кинжа́ла, эфе́с

хәнҗәрләшү *неперех.* дра́ться *с кем-л.* на кинжа́лах (ножа́х)

хәнҗәрле *прил.* вооружённый кинжа́лом, име́ющий кинжа́л, с кинжа́лом

хәрабә *сущ. книжн.* разва́лины, руи́ны *чего-л.*; *борынгы шәһәр ~ләре* руи́ны дре́внего го́рода

хәрабәле *прил.* лежа́щий в разва́линах; руи́нный; *~ пейзаж* руи́нный пейза́ж

хәрабәлек *сущ. книжн.* забро́шенные (разру́шенные) места́; разва́лины; руи́ны

хәрәҗәт *сущ. см.* **харәҗәт**

хәрәкә *сущ.* диакрити́ческий знак (*в арабском алфавите*)

хәрәкәт *сущ.* **1.** *в разн. знач.* движе́ние || дви́гательный; *автобуслар ~е* авто́бусное движе́ние; *кооперация ~е* кооперати́вное движе́ние; *кул-аяк ~ләре* движе́ния рук и ног; *материянең ~е филос.* движе́ние мате́рии; *милли-азатлык ~е* национа́льно-освободи́тельное движе́ние; *планеталар ~е* движе́ние плане́т; *революцион ~* революцио́нное движе́ние; *тынычлык яклаучылар ~е* движе́ние сторо́нников ми́ра; *урам ~е кагыйдәләре* пра́вила у́личного движе́ния; *әйләнмә ~ физ.* враща́тельное движе́ние; *~ неврлары анат.* дви́гательные не́рвы; *~ хәвефсезлеге (куркынычсызлыгы)* безопа́сность движе́ния **2.** де́йствие, а́кция; *~ бердәмлеге* еди́нство де́йствий; *сугыш ~ләре* вое́нные де́йствия; *кыю ~* сме́лое де́йствие (-ия); *~тә — бәрәкәт (посл.)* изоби́лие — в де́йствии □ **~ иттерү** дви́гать, приводи́ть/привести́ в движе́ние; **~ иттерүче, ~кә китерүче** дви́жущий, дви́гающий; **~ итү 1.** дви́гаться, передвига́ться **2.** де́йствовать; *сәгать теле циферблат буйлап ~ итә* стре́лка дви́жется по цифербла́ту; **~кә килү** приходи́ть/прийти́ в движе́ние; задви́гаться; **~кә китерү** приводи́ть/привести́ в движе́ние; заде́йствовать *кого, что-л.*; *см. тж.* **хәрәкәтләндерү**

хәрәкәтләндерү *перех.* **1.** дви́гать, приводи́ть/привести́ в движе́ние (в де́йствие) **2.** *в знач. прил.* **хәрәкәтләндерүче** 1) дви́жущий, приводя́щий в движе́ние; *~че рычаг* дви́жущий рыча́г 2) дви́гательный; *~че нервлар анат.* дви́гательные не́рвы

хәрәкәтләнмәүчән *прил. см.* **хәрәкәтсез**

хәрәкәтләнү *неперех.* дви́гаться, приходи́ть/прийти́ в движе́ние || движе́ние; *аның бармаклары ~ә башлады* па́льцы его́ на́чали дви́гаться (задви́гались, зашевели́лись, пришли́ в движе́ние) □ **~еп тору** быть (находи́ться) в движе́нии, дви́гаться

хәрәкәтле *прил.* **1.** подви́жный; *~ уеннар* подви́жные и́гры; *аз ~* малоподви́жный; *акрын ~* медли́тельный **2.** дви́гающийся (*обычно с предшествующим определением*); *җитез ~* бы́стро, ло́вко дви́гающийся; *нәфис ~* с краси́выми движе́ниями

хәрәкәтсез *прил.* **1.** неподви́жный; засты́вший, оцепене́лый, недви́жимый; *~ күзләр* засты́вшие (неподви́жные) глаза́ || *нареч.* неподви́жно, без движе́ния, оцепене́ло; *~ утыру* сиде́ть неподви́жно **2.** *перен.* пасси́вный, ине́ртный, безде́ятельный, безынициати́вный || *нареч. перен.* пасси́вно, ине́ртно, безде́ятельно

хәрәкәтсезләндерү *перех.* обездви́жить || обездви́жение *кого, чего-л.*

хәрәкәтсезләнү *неперех.* переста́ть/переста́ть дви́гаться

хәрәкәтсезлек *сущ.* **1.** неподви́жность, поко́й; *табигатьтә абсолют ~ юк* в приро́де нет абсолю́тного поко́я **2.** *перен.* пасси́вность, ине́ртность, безде́ятельность, безынициати́вность

хәрәкәттәге *прил.* де́йствующий, находя́щийся в движе́нии; *~ поезд* дви́жущийся, иду́щий по́езд; *~ армия* де́йствующая а́рмия

хәрәкәтчән *прил.* живо́й, подви́жный (подвижно́й), раство́рпный; *~ күзле кеше* челове́к с живы́ми (вырази́тельными) глаза́ми; *гаскәрнең ~ төркемнәре* подви́жные гру́ппы войск

хәрәкәтчәнлек *сущ.* жи́вость, подви́жность; *аңа ~ хас* ему́ сво́йственна (для него́ характе́рна) подви́жность

хәрәкәтчел *прил.* **1.** *см.* **хәрәкәтчән 2.** де́ятельный, энерги́чный

хәрәм I *прил.* **1.** *диал. см.* **харам 2.** нече́стный, незако́нный; добы́тый нече́стным, незако́нным путём (*о деньгах, состоянии*); *~ малның хәере юк (посл.)* нече́стно нажито́е добро́ сча́стья не прино́сит **3.** *в знач. сущ. перен.* жу́льничество в игре́; *~е тотты* жу́льничество подвело́

хәрәм II *сущ.* **1.** храм **2.** гаре́м; *Гәрәй мирзаның ~е* гаре́м Гара́й-мирзы́ □ **~ агасы** страж гаре́ма, е́внух; **~ (өй)** же́нская полови́на в до́ме

хәрәмзә *сущ. см.* **хәрәмче**

хәрәмләү *неперех. разг.* плутова́ть, моше́нничать, жу́льничать (*в игре*)

хәрәмләшү 1. *взаимно-совм. от* **хәрәмләү 2.** *см.* **хәрәмләү**

хәрәмлек *сущ.* плутовство́, моше́нничество, жу́льничество; нече́стные, недозво́ленные приёмы; *уендагы ~* моше́нничество в игре́

хәрәмче *сущ. редко* моше́нник, шу́лер, плут; нече́стный в игре́ челове́к

хәрәмчел *прил.* **1.** моше́ннический **2.** скло́нный к нече́стности

хәрби *прил.* **1.** вое́нный, во́инский || *в знач. сущ.* вое́нный; *~ госпиталь* вое́нный го́спиталь; *~ антвое́нная присяга; ~ бурыч* во́инский долг; *~ устав* во́инский уста́в; *~ләр хәзерләү* гото́вить (обуча́ть) вое́нных **2.** боево́й, строево́й; *~ тревога* боева́я трево́га; *~ хәзерлек* боева́я подгото́вка **3.** *в терминологических словосоч.* вое́нно-, воен-; *~ белем укытучысы* военру́к; *~ диңгез көчләре* вое́нно-морски́е си́лы □ **~ исәптә торучы** вое́нно-обя́занный; **~ корреспондент** военко́р; **~-кыр хирургиясе** вое́нно-полева́я хирурги́я; **~ хезмәткәр** военнослу́жащий; **~-һава флоты** вое́нно-возду́шный флот

хәрбиләрчә *нареч.* по-вое́нному; как вое́нный; *~ киенгән* оде́тый по-вое́нному

хәрбиләштерел|ү *страд. от* **хәрбиләштү**; *~гән янгын командасы* военизи́рованная пожа́рная кома́нда

хәрбиләштер|ү *перех.* военизи́ровать, переводи́ть/перевести́ на вое́нное положе́ние, перестра́ивать на вое́нный лад || воениза́ция; *сәнәгате ~ү* переводи́ть промы́шленность на вое́нные ре́льсы □ **~еп бетерү** по́лностью военизи́ровать

хәрбиләшү *неперех.* военизи́роваться, переходи́ть/перейти́ на вое́нное положе́ние, перестра́иваться/перестро́иться на вое́нный лад || воениза́ция

хәрби-полити́к *прил.* вое́нно-полити́ческий

хәрби-те́хник *прил.* вое́нно-техни́ческий

хәрәҗ *сущ.* **1.** *уст.* нало́г, обложе́ние, по́дать **2.** *уст. книжн.* расхо́д(ы), тра́та, изде́ржки; *юл ~е* расхо́ды на доро́гу, путевы́е изде́ржки, доро́жные расхо́ды **3.** *диал.* харчи́; *казна ~енә* на казённые харчи́

хәреф *сущ.* бу́ква, шрифт; ли́тера || бу́квенный, шрифтово́й; *басма ~* печа́тная бу́ква; *баш ~* загла́вная (прописна́я) бу́ква; *вак ~* ме́лкий шрифт; *курсив ~ләр* курси́вный шрифт; *юл ~е* строчна́я бу́ква; *~ кассасы* типогра́фская ка́сса; *~ җыю полигр.* набира́ть шрифт, производи́ть набо́р || **1.** набо́р **2.** набо́рный; *~ җыю цехы* набо́рный цех □ **~ җыючы** набо́рщик ◊ **~ тану** уме́ть чита́ть (*букв.* разбира́ть бу́квы); **~кә-** ~ буква́льно, досло́вно; **~кә- ~ туры килү** совпада́ть в то́чности, сло́во в сло́во; **~кә ~не ялгый белү** уме́ть чита́ть и писа́ть (*букв.* уме́ть соединя́ть бу́квы); **~кә ябышып яту, ~ колы булу** буквали́зм, формали́зм, буквое́дство *ирон.*; занима́ться буквое́дством, быть формали́стом, цепля́ться за бу́кву; **~кә ябышып ятучы** буквое́д *ирон.*, формали́ст; **~ ятлаучылык** начётничество; **~ ятлаучы** начётчик

хәрефле *прил.* бу́квенный; *~ кыскартмалар* бу́квенные сокраще́ния

хәс *диал. нареч.* (*хәстә*) то́чно, (в то́чности) как; соверше́нно ...; *см. тж.* **нәкъ**; *хәстә атасы* то́чно как оте́ц

хәсис *прил. уничиж.* **1.** по́длый, ни́зменный, гну́сный || подле́ц, мерза́вец; *~ зат* гну́сная ли́чность **2.** жа́дный, скупо́й || скря́га, скупе́ц

хәсисләндерү *понуд. от* **хәсисләнү**

хәсисләнү *неперех.* **1.** становиться/стать по́длым, презре́нным, ни́зким; *бөтенләй ~гән* совсе́м опусти́лся **2.** становиться/стать жа́дным, скупы́м; скупи́ться, скря́жничать

хәсислек *сущ.* **1.** по́длость, ни́зость, гну́сность **2.** жа́дность, ску́пость, ска́редность

хәситә *сущ. этногр.* **1.** хаси́та (*женское нагрудное украшение, надеваемое через плечо*) **2.** амуле́т в ви́де карма́нчика, в кото́ром нахо́дится ру́копись хвале́бного стихотворе́ния в а́дрес де́вушки

хәсрәт *сущ.* **1.** го́ре, печа́ль, кручи́на *поэт.*, тоска́; *~не тарату* разве́ять печа́ль; *олы ~* большо́е го́ре; *авыр ~ кичерү* переноси́ть тя́жкое го́ре **2.** го́ре, беда́, несча́стье; *~ белән бәла эзеңә басып кына йөри* (*погов.*) го́ре да беда́ хо́дят по пята́м **3.** *перен. бран. и шутл.* го́ре, го́рюшко, несча́стье; *и ~, югал күземнән* исче́зни с глаз, го́ре ты моё □ **~ күрү** испы́тывать/испыта́ть го́ре; *~ чигү* го́ре мы́кать, постоя́нно пребыва́ть в печа́ли, тоске́, го́ре; **~кә чуму** унывать, пребыва́ть в уны́нии, тоске́ ◊ **~ капчыгы** горемы́ка; **~ уты йоту** горева́ть, убива́ться, си́льно пережива́ть

хәсрәтләндерү *понуд. от* **хәсрәтләнү**

хәсрәтләнеш|ү *совм. от* **хәсрәтләнү**; *~еп утыру* сиде́ть (вме́сте) пригорю́нившись

хәсрәтлән|ү *неперех.* горева́ть, печа́литься, скорбе́ть, кручи́ниться *поэт.*; *~еп утыру* сиде́ть пригорю́нившись, опеча́лившись

хәсрәтле *прил.* печа́льный, го́рестный, уны́лый, ско́рбный; *~ уйлар* печа́льные ду́мы; *~ күз карашы* уны́лый взгляд

хәсрәтлелек *сущ.* состоя́ние ско́рби, го́ря, печа́ли; го́рестный, ско́рбный вид; *йөзенең ~ге* ско́рбное (го́рестное) выраже́ние лица́

хәсрәтсез *прил.* беззабо́тный, беспе́чный, не омрачённый печа́лью, го́рем; не зна́ющий го́ря; *~ чак* беззабо́тное вре́мя || *нареч.* беззабо́тно, беспеча́льно

хәсрәтсезлек *сущ.* беззабо́тность, беспе́чность, отсу́тствие го́ря, печа́ли

хәсрәтсенү *неперех. редко см.* **хәсрәтләнү**

хәстә *сущ. разг.* боле́знь, недомога́ние, неду́г, хворь *прост.*; *тир ~се* тиф; *түшәк (урын) ~се* **1.** боле́знь, непозволя́ющая встава́ть **2.** лежа́чий, прико́ванный к посте́ли больно́й || *прил.* **1.** больно́й, боле́зненный; хво́рый, не́мощный; *~ хатын* больна́я же́нщина; *~ чырайлы егет* па́рень с боле́зненным лицо́м **2.** *в знач. сущ.* больно́й (челове́к); *~ урыны* ме́сто, посте́ль больно́го; *~ янында* во́зле больно́го □ **~ итү (кылу)** довести́ *кого-л.* до боле́зни, заста́вить заболе́ть *кого-л.* (*своим поведением, обращением*); **~гә егылу** тяжело́ заболе́ть, слечь (*в постель*), стать больны́м, прико́ванным к посте́ли

хәстәләнү *неперех. разг.* заболе́ть, приболе́ть, прихворну́ть, занемо́чь, занеду́жить; *көтелмәгәндә ~* неожи́данно заболе́ть

хәстәлек *сущ. разг.* состоя́ние, положе́ние больно́го; недомога́ние; *~ аркасында бер җиргә дә бара алмадым* из-за недомога́ния никуда́ не мог сходи́ть

хәстәр *сущ. разг.* заблаговре́менные ме́ры, приготовле́ния, хло́поты; *туй ~ләре* приготовле́ния к сва́дьбе; предсва́дебные хло́поты □ **~ен күрү, ~енә керү (керешү)** зара́нее (заблаговре́менно, предвари́тельно) позабо́титься *о чём-л.*, приступи́ть к подгото́вке зара́нее; **~ен күрүчән** предусмотри́тельный, забо́тливый; **~ен күрүчәнлек** предусмотри́тельность, забо́тливость

хәстәрләнү *разг.* **1.** *страд. от* **хәстәләү 2.** *см.* **хәзерләнү** 2

хәстәрлә|ү *перех. разг.* **1.** *см.* **хәзерләү** 1, 2; *табын ~ү* накрыва́ть стол; *юлга әйберләр ~ү* гото́вить (собира́ть) ве́щи в доро́гу; *кышка утын ~ү* заготавливать на́ зиму дрова́ **2.** *диал.* забо́титься *о ком-л.*, воспи́тывать *кого-л.* (*ребёнка*) □ **~әп кую** подгото́вить, загото́вить *что-л.* зара́нее

хәстәрле *прил.* предусмотри́тельный, внима́тельный, забо́тливый; *~ ирнең хатыны башына калфак кияр* (*погов.*) у забо́тливого му́жа и жена́ в наря́дах (*букв.* жена́ калфа́к но́сит)

хәстәрле|к *сущ. см.* **хәстәр**; *юл ~ге* приготовле́ния в доро́гу; доро́жные хло́поты; *~к күрсәтү* проявля́ть забо́ту

хәстәрлелек *сущ.* забо́тливость, предусмотри́тельность, внима́тельность

хәстәханә *сущ.* больни́ца, го́спиталь

хәт *сущ. уст.* грани́ца, преде́л ◊ **хәттән (хәттин) ашу (узу)** переходи́ть грань (грани́цу), выходи́ть за ра́мки (за преде́лы); *см. тж.* **чик**

хәтәр *прил.* **1.** 1) опа́сный, риско́ванный (*маршрут, путь*); *бик ~ эш* о́чень риско́ванное де́ло 2) *предик.* опа́сно, риско́ванно; *сезнең белән эш йөртү ~* име́ть де́ло с ва́ми опа́сно || *сущ.* опа́сность, угро́за; риск; *~ аяк астында* (*погов.*) ≈ беда́ по пята́м хо́дит (*букв.* опа́сность под нога́ми) **2.** *перен.* бесшаба́шный, безрассу́дный, лихо́й (*о человеке*) **3.** *разг. перен.* важне́цкий, что на́до; *~ итеп төзегәнсең өйне* дом ты постро́ил важне́цкий (что на́до)

хәтәрле *прил.* опа́сный, риско́ванный

хәтәрле|к *сущ.* опа́сность; *юлларның ~ге* опа́сность доро́г

хәтем *сущ. рел.* заключи́тельная часть панихи́ды, моле́ния, поми́нок и т. п. □ **~ уку (кылу, итү, әйтү, чыгу)** **1.** чита́ть Коран в конце́ панихи́ды (*уже на кладбище*) **2.** *перен. разг.* заверша́ть, зака́нчивать *что-л.* || заверше́ние, оконча́ние; *бу эшкә ~ укыдым инде* с э́тим я уже́ поко́нчил **3.** *перен. бран.* проклина́ть/прокля́сть *кого-л.* (*желая смерти*)

хәтер *сущ.* **1.** па́мять || па́мятный; *күрү ~е* зри́тельная па́мять; *яхшы ~* хоро́шая па́мять; *~ дәфтәре* записна́я

(па́мятная) кни́жка; *~ем начар* па́мять у меня́ плоха́я **2.** *местно-вр. п.* **хәтердә, хәтеремдә** 1) *предик.* по́мню, по́мнится; *аны күргәнем ~емдә* по́мню, как я его́ ви́дел 2) *в знач. вводн. сл.* по́мнится, припомина́ется; *~емдә, бу хәл кич белән булган иде* по́мнится (мне), де́ло бы́ло ве́чером ◊ **~ калдыру** обижа́ть/оби́деть; **~ калдырырлык** оби́дный; **~ калу** обижа́ться/оби́деться; **~гез калмасын** не в оби́ду будь ска́зано, не обижа́йтесь; **~ калучанлык** оби́дчивость; **~ капчыгы (сандыгы) 1.** па́мять; *~ капчыкларында эзләну* копа́ться в па́мяти **2.** челове́к с хоро́шей па́мятью; *ул — авылның беренче ~ сандыгы* у него́ па́мять лу́чше всех в дере́вне; **~ кырылу** *см.* **кәеф кырылу**; **~ саклау** стара́ться не обижа́ть, не огорча́ть; **~ чуалу** станови́ться рассе́янным, забы́вчивым; **~гә алу** принима́ть во внима́ние; *см. тж.* **искә алу**; **~гә беркетү 1.** *см.* **хәтергә алу 2.** *см.* **хәтердә калдыру**; **~гә килү** приходи́ть/прийти́ в го́лову, вспомина́ться/вспо́мниться, припо́мниться; восстана́вливаться/восстанови́ться в па́мяти, всплыть в па́мяти; **~гә китерү** вспо́мнить, припо́мнить, восстанови́ть в па́мяти; **~гә салу (салып кую)** *см.* **хәтердә калдыру**; **~гә сеңү (сеңеп калу)** вре́заться в па́мять, хорошо́ запо́мниться; **~гә төшерү** *см.* **хәтергә китерү**; **~дә булу** по́мниться; храни́ться, сохраня́ться/сохрани́ться в па́мяти; **~дә калдыру** запомина́ть/запо́мнить; сохрани́ть в па́мяти *кого, что-л.*; **~дә калу** запомина́ться/запо́мниться; остава́ться/оста́ться в па́мяти; *~дә калган көн* запо́мнившийся (па́мятный, оста́вшийся в па́мяти) день; достопа́мятный день; **~дә саклау (тоту)** по́мнить *что-л., о чём-л.*, запо́мнить *что-л.*, (со)храни́ть (держа́ть) в па́мяти *что-л.*; **~дән чыгару** забыва́ть/забы́ть, позабы́ть, запа́мятовать; вы́бросить из головы́; **~дән чыгу** забыва́ться/забы́ться, позабы́ться; стира́ться/стере́ться в па́мяти; **~е калучан** оби́дчивый; **~е өчен (генә)** ра́ди прили́чия, то́лько что́бы не оби́деть *кого-л.*; *сезнең ~гез өчен* ра́ди вас; **~ен күрү (табу)** угожда́ть/угоди́ть *кому-л.*; **~енә төшерү** напомина́ть/напо́мнить *кому-л. о чём-л.*; **~ең бар булсын** (*говорится человеку, который что-л. забыл и не может вовремя вспомнить*) дай бог па́мяти

хәтердән *нареч.* по па́мяти, наизу́сть; *шигырьне ~ сөйләү* расска́зывать (чита́ть) стихотворе́ние по па́мяти, наизу́сть

хәтерләт|ү *перех.* напомина́ть/напо́мнить; *см. тж.* **искә төшерү**; *ул миңа иске дуслыкны ~те* он напо́мнил мне о ста́рой дру́жбе

хәтерлә|ү *перех.* по́мнить, вспомина́ть/вспо́мнить *кого, что-л., о ком, о чём-л.*; припомина́ть/припо́мнить *кого, что-л.*; *яшь чакларны ~ү* вспо́мнить молоды́е го́ды ◊ **~п калу** запо́мнить, сохрани́ть в па́мяти *кого, что-л.*

хәтерле *прил.* па́мятливый *на что-л.*, с хоро́шей па́мятью; *~ укучы* учени́к с хоро́шей па́мятью

хәтерсез *прил.* забы́вчивый, рассе́янный, беспа́мятный

хәтерсезләнү теря́ть, потеря́ть, утра́чивать/утра́тить па́мять || поте́ря, утра́та па́мяти □ **~еп бару** теря́ть па́мять, (постепе́нно) станови́ться рассе́янным, забы́вчивым

хәтерсезлек *сущ.* беспа́мятность, забы́вчивость, сла́бая па́мять

хәтле *послелог см.* **чаклы**

хәтлеге *послелог* величино́й с; *бармак ~* величино́й с па́лец

хәтлегендәге *послелог см.* **хәтлеге**

хәтлек *см.* **хәтлеге**

хәтсез *нареч. разг. см.* **байтак**

хәтта *частица усил., а тж. в знач. союза* да́же; *~ ул мине ташлап китте* да́же он меня́ бро́сил □ **~ ки** *книжн.* да́же

хәттан: хәттан ашу *см.* **хәттин ашу**

хәттат *сущ. уст. книжн. см.* **каллиграф**

хәттин: хәттин аш|у (узу), хәттин тыш булу переходи́ть/перейти́ грани́цы, выходи́ть/вы́йти за ра́мки дозво́ленного; *эшем хәттин ашкан* у меня́ рабо́ты через кра́й

хәтфә *сущ.* ба́рхат, плюш || ба́рхатный, плю́щевый; *~ белән тышланган диван* оби́тый ба́рхатом дива́н □ **~ гөл** *бот.* петуши́ный гребешо́к; **~ үләне** *бот.* амара́нт

хәтфәләнү *неперех.* станови́ться ба́рхатным, бархати́стым, похо́жим на ба́рхат; *кыр ямь-яшел булды, ~де* по́ле как бу́дто покры́лось зелёным ба́рхатом

хәчтерүш *сущ.* **1.** *ист.* крестоно́сец **2.** *разг. пренебр.* 1) незада́чливый хвасту́н 2) замухры́шка, замо́рыш, михрю́тка *прост.*

хәшәп *сущ. уст. уничиж.* глупе́ц, бе́столочь, темнота́, неве́жа

хәшәр *сущ. этногр.* **1.** хаша́р (*бесплатная работа, выполняемая всем миром*) **2.** ополче́ние

хәшәрәт *сущ.* **1.** гад, га́ды (*змеи, ящерицы*); насеко́мые (*паразитирующие на человеке блохи, вши*) **2.** *перен. прост.* гад, мерза́вец, ме́рзость (*о человеке*) || ме́рзкий, ме́рзостный, га́дкий, па́костный

хәя *сущ. уст. см.* **хая**

хәят *сущ. книжн.* жизнь, бытие́, существова́ние

хәяти *прил. книжн.* жи́зненный; *~ тәҗрибә* жи́зненный о́пыт

хе́дер *сущ. спец.* хе́дер (*жатвенная часть зерноуборочного комбайна*)

хезмәт *сущ.* **1.** *в разн. знач.* труд (*как процесс*), трудова́я де́ятельность || трудово́й; *~ җитештерүчәнлеге* производи́тельность труда́; *акыл ~е* у́мственный труд; *мәҗбури ~* принуди́тельный труд; *кул ~е* ручно́й труд; *физик ~* физи́ческий труд; *яллы ~* наёмный труд; *~ герое* геро́й Труда́; *~е юкның хөрмәте юк* (*посл.*) кто не тру́дится, тот не в почёте; *чын бәхет — намуслы ~тә* (*погов.*) по́длинное сча́стье — в добросо́вестном труде́; *~ батырлыгы* трудово́й по́двиг; *~ даны* трудова́я сла́ва; *~ дисциплинасы* трудова́я дисципли́на; *~ кереме* трудово́й дохо́д; *~ күнекмәләре* трудовы́е на́выки; *~ стажы* трудово́й стаж; *~ тәрбиясе* трудово́е воспита́ние; *~ халкы* трудово́й наро́д **2.** труд, рабо́та (*как результат, произведение*); *фәнни ~* нау́чный труд (рабо́та) **3.** труд (*количество труда*); уси́лия, стара́ния; эне́рги...; *үз ~е бушка китмәгән* его́ уси́лия не пропа́ли да́ром; *зур ~кую* вложи́ть (затра́тить) мно́го труда́, мно́го сил; *~сез җиләктә ләззәт юк* (*посл.*) я́года, добы́тая без труда́, не доставля́ет наслажде́ния **4.** 1) *разг.* рабо́та, до́лжность; слу́жба, служе́бная обя́занность || служе́бный, рабо́чий, должностно́й; *аңа бригадир ~ен йөкләү* возложи́ть на него́ обя́занности бригади́ра; *~ вакыты* служе́бное (рабо́чее) вре́мя; *~ йомышы* должностно́е (служе́бное) поруче́ние 2) слу́жба (во́инские обя́занности); *солдат ~е* солда́тская слу́жба **5.** заслу́га, заслу́ги; *аның фәндә ~е зур* его́ заслу́ги в нау́ке велики́ **6.** слу́жба, обслу́живание, услу́га (-ги); *хәвефсезлек ~е* слу́жба безопа́сности; *диспетчерлык ~е* диспе́тчерская слу́жба □ **~ җимеше** плоды́, результа́т труда́; *күпьеллык ~ җимеше* плоды́ многоле́тнего труда́; **~ итү 1.** труди́ться, рабо́тать *на кого-л.*; *для кого-л.*; служи́ть *кому-л.*, *у кого-л.*

2. *халыкка ~ итү* 1) служи́ть наро́ду 2) нести́ слу́жбу (арме́йскую), служи́ть; *флотта ~ итү* служи́ть на фло́те; слу́жба на фло́те; **~ иясе** труда́ющийся, тру́женик || трудово́й; **~ иясе халкы** трудово́й наро́д; **~ кенәгәсе (дәфтәре)** трудова́я кни́жка; **~ көне** трудоде́нь (*до 1966 года*); **~ күрсәтү 1.** *см.* **хезмәт итү** 1 **2.** обслу́живать, ока́зывать услу́ги || обслу́живание; *~ күрсәтү сферасы* сфе́ра обслу́живания; *көнкүреш ~е күрсәтү* бытово́е обслу́живание **3.** удружи́ть, услужи́ть, ока́зывать услу́гу; **~ күрсәтүчән** услу́жливый; **~ күрсәтүчәнлек** услу́жливость; **~ тутыру** отслужи́ть (*в армии*); **~ урыны** служе́бное ме́сто, до́лжность, пост; **~ хакы 1.** за́работная пла́та **2.** опла́та за услу́гу; **~кә сәләтле** трудоспосо́бный; **~кә сәләтлелек** трудоспосо́бность; **~тән тыш** внеслужебный

хезмәткәр *сущ.* **1.** слу́жащий, слу́жащая, рабо́тник, рабо́тница, сотру́дник, сотру́дница; *гыйльми ~* нау́чный сотру́дник **2.** *уст. см.* **хезмәтче** 1

хезмәтсез *прил.* нетрудово́й; не тре́бующий труда́, стара́ний; *~ керем* нетрудово́й дохо́д || *нареч.* без труда́, не прилага́я уси́лий, стара́ний; *~ яшәп булмый* без труда́ не прожи́ть

хезмәттәге *прил.* служе́бный, должностно́й; *~ җинаять* должностно́е преступле́ние

хезмәттәш *сущ.* сослужи́вец, сослужи́вица; това́рищ по рабо́те, колле́га, сотру́дник, сотру́дница; *~ләр белән очрашу* встре́ча с колле́гами (сослужи́вцами)

хезмәттәшлек *сущ.* **1.** соде́йствие, по́мощь; *~ күрсәтү* оказа́ть соде́йствие, по́мощь *в чём-л.* **2.** сотру́дничество, совме́стная де́ятельность; *ике яклы ~* двусторо́ннее сотру́дничество; *халыкара ~* междунаро́дное сотру́дничество; *икътисади ~* экономи́ческое сотру́дничество; *үзара ~* взаи́мное сотру́дничество □ **~ итү 1.** сотру́дничать *с кем-л.* **2.** рабо́тать вме́сте (*в каком-л. учреждении*)

хезмәтчән *прил.* трудя́щийся, трудово́й; трудолюби́вый; *~ халык* трудово́й наро́д; *~ сыйныф* трудя́щийся класс || трудя́щийся; тру́женик, рабо́тник; *авыл хуҗалыгы ~нәре* тру́женики се́льского хозя́йства; *культура ~нәре* рабо́тники культу́ры

хезмәтче *сущ.* **1.** слуга́, рабо́тник (*в сфере физического труда*); *~ хатын (кыз)* служа́нка, дома́шняя прислу́га, домрабо́тница, го́рничная; *~ булып яллану* нанима́ться в слу́ги (рабо́тники); *~ малай уст.* ма́льчик (*в лавке, при магазине*); *~ тоту* держа́ть рабо́тника (слугу́) **2.** *перен.* слуга́, служи́тель; *халык ~се* слуга́ наро́да; *фән ~се* служи́тель нау́ки; *дин ~се* служи́тель ку́льта

хезмәтчел *прил.* услу́жливый; *~ кеше* услу́жливый челове́к

хезмәтчелек *сущ.* положе́ние слуги́, рабо́тника; *гомерне ~тә үткәрү* прорабо́тать, прослужи́ть всю жизнь слуго́й

хек *сущ. зоол.* хек (*рыба*)

хет *союз уступ. разг.* хоть; *хет берегез килегез* приходи́те хоть кто́-нибудь

хетт *сущ.* хе́тты || хе́ттский (*язык*); *~ хатын-кызы* хеттея́нка

хе́ттча *нареч.* по-хе́ттски; *~ язылган* напи́сан по-хе́ттски || *прил.* хе́ттский, на хе́ттском языке́

хе-хе-хе *межд. подр. разг.* хе-хе-хе́ (*для обозначения звуков при негромком или тонком смехе, а также для передачи шутливого или иронического посмеивания*)

хибес *сущ. уст. см.* **хәбес**

хибесханә *сущ. уст. см.* **хәбесханә**

хиҗап *сущ. уст.* **1.** вуа́ль, покрыва́ло, чадра́, паранжа́ **2.** стыдли́вость, засте́нчивость

хиҗапсыз *нареч. уст.* без покрыва́ла (паранджи́, чадры́), с откры́тым лицо́м; *~ йөрү* ходи́ть без покрыва́ла || *прил.* бесстыжий, бессо́вестный, беззасте́нчивый

хикәя *сущ.* **1.** *лит.* расска́з, нове́лла, по́весть; *озын ~* по́весть; *~ләр җыентыгы* сбо́рник расска́зов **2.** повествова́ние, расска́з (*как процесс*), по́весть (*жизни, страданий и т. п.*); у́стное изложе́ние *чего-л.* || повествова́тельный; *ул ~сен тәмам итте* он зако́нчил свой расска́з (повествова́ние); *~ жанры* повествова́тельный жанр □ **~ җөмлә** *грам.* повествова́тельное предложе́ние; **~ итү (сөйләү)** *см.* **хикәяләү**; **~ итүче (сөйләүче)** расска́зчик, повествова́тель; **~ кылу** *см.* **хикәяләү**; **~ фигыль** *грам.* изъяви́тельное наклоне́ние

хикәяләнү *страд. от* **хикәяләү**; расска́зываться, повествова́ться

хикәяләү *перех.* расска́зывать/рассказа́ть (*подробно, обстоятельно*) *что-л., о чём-л.*, повествова́ть *о чём-л.*; излага́ть/изложи́ть *что-л.*; обрисо́вывать/обрисова́ть, опи́сывать/описа́ть *что-л.*; распи́сывать/расписа́ть || повествова́ние, изложе́ние; *шәһәргә бару турында ~* расска́зывать о пое́здке в го́род

хикәяләүче *сущ. см.* **хикәяче** 2

хикәят *сущ. уст. разг.* сказ, сказа́ние, леге́нда

хикәятче *сущ. уст.* расска́зчик

хикәяче *сущ.* **1.** а́втор, сочини́тель расска́зов, новелли́ст; писа́тель, рабо́тающий в жа́нре расска́зов **2.** расска́зчик, расска́зчица; повествова́тель, повествова́тельница

хикмәт *сущ.* **1.** му́дрость, прему́дрость; зна́ние; *халык ~е* наро́дная му́дрость; *зур ~ иясе* вели́кий мудре́ц **2.** *уст.* филосо́фское учёние, филосо́фия **3.** сокрове́нный (та́йный) смысл; скры́тая причи́на (моти́в); та́йна, секре́т; *~енә төшенү* разгада́ть, пости́чь смысл *чего-л.*; *монда ниндидер бер ~ бар* здесь кро́ется кака́я-то та́йна, здесь что́-то нечи́сто; *менә кайда (нәрсәдә) ~* вот в чём, ока́зывается, всё дело (загво́здка); вот где соба́ка зары́та; *китапның һәрбер сүзендә зур ~ ята* в ка́ждом сло́ве кни́ги зало́жен большо́й смысл; *~ анда тугел* причи́на (де́ло) не в э́том **4.** *перен.* чу́до; интере́сное зре́лище; *ниндидер ~ белән исән калды* каки́м-то чу́дом он оста́лся жив; *менә нинди ~ләр бар икән!* вот каки́е, ока́зывается, быва́ют чудеса́; *бу нинди ~?* это что за чудеса́? чу́дно! удиви́тельно! стра́нно! **5.** 1) *лит.* хикме́т, стихотво́рная при́тча (*форма средневековой лирической поэзии с философско-дидактическим содержанием*); *Мәүла Колый ~ләре* хикме́ты Мавля́ Колы́я 2) *фольк.* коро́ткий прозаи́ческий расска́з филосо́фского и́ли назида́тельного хара́ктера □ **~ кору (сату)** у́мничать, му́дрствовать, мудри́ть

хикмәти: хикмәти хода *см.* **ходаның хикмәте**

хикмәтләү *неперех. разг. ирон.* мудри́ть, му́дрствовать; *нәрсәләр ~исең?* что ты там мудри́шь? *артык ~әү* перемудри́ть □ **~әп җибәрү** намудри́ть

хикмәтле *прил.* **1.** чуде́сный, чудоде́йственный, волше́бный; таи́нственный **2.** замыслова́тый; причу́дливый **3.** му́дрый; по́лный глубо́кого смы́сла □ **~ сүз** афори́зм, крыла́тое сло́во, нравоучи́тельное изрече́ние, сенте́нция

хилаф *прил. книжн.* **1.** противореч и́вый, противоре́чащий *чему-л.*; *~ сүз әйтү* сказа́ть сло́во прóтив, возрази́ть; *кеше табигатенә ~* противоре́чащий челове́ческой

приро́де; *фәнгә ~* антинау́чный, противоре́чащий нау́ке **2.** *в функ. сказ.* про́тив *чего-л.*, вопреки́ *чему-л.*; *законга ~ рәвештә* вопреки́ зако́ну; *ул аның гадәтенә ~* э́то про́тив его́ привы́чек (противоре́чит его́ привы́чкам)

хилафлык *сущ. книжн.* противоречи́вость, противополо́жность, несогласо́ванность; *фәнгә ~* антинау́чность □ **~ итү (кылу)** противоре́чить, проти́виться, противостоя́ть *кому, чему-л.*

хилка, хыйлка *сущ. уст. книжн.* **1.** круг (люде́й); *алар ярты ~ түгәрәк булып утырдылар* они́ се́ли полукру́гом **2.** просло́йка; сосло́вие

химая (химайә) *книжн.* **1.** покрови́тельство, протекция, ше́фство; опе́ка *над кем-л.*, забо́та *о ком-л.*, подде́ржка *кого-л.*; *ата ~се* опе́ка, покрови́тельство отца́ **2.** защи́та, охра́на *кого-л.*; *хөкүмәт ~сендә* быть под охра́ной (защи́той) госуда́рства □ **~ итү 1.** покрови́тельствовать *кому-л.*; брать ше́фство *над кем-л.*; ока́зывать подде́ржку *кому-л.* **2.** защища́ть, охраня́ть *кого-л.*

химаяләү *перех. см.* **химая итү**

химаяле *прил. книжн.* находя́щийся *под чьим-л.* покрови́тельством, защи́той

химаяче *сущ. книжн.* защи́тник, покрови́тель

химаячел *прил. книжн.* покрови́тельственный; *~ кыяфәт белән* с покрови́тельственным ви́дом

химаячелек *сущ. книжн.* протекциони́зм

химаясез *прил. книжн.* не име́ющий защи́ты, подде́ржки; беззащи́тный || без защи́ты; *~ калу* остава́ться без защи́ты

хи́мик I *сущ.* хи́мик; *~лар съезды* съезд хи́миков

хи́мик II *прил.* хими́ческий; *~ ашлама* хими́ческое удобре́ние; *~ корал* хими́ческое ору́жие; *металлны ~ эшкәртү* хими́ческая обрабо́тка мета́лла; *~ элементлар* хими́ческие элеме́нты

химика́лийлар *сущ. спец.* химика́лии; *туфракны ~ белән эшкәртү* обраба́тывать по́чву химика́лиями

химикат *сущ. спец.* химика́т, химика́ты

химиотерапия *сущ. мед.* химиотерапи́я

хи́мия *сущ.* хи́мия || хими́ческий; *аналитик ~* аналити́ческая хи́мия; *~ укытучысы* учи́тель хи́мии; *~ заводы* хими́ческий заво́д; *~ лабораториясе* хими́ческая лаборато́рия; *~ факультеты* хими́ческий факульте́т; *~ тәҗрибәләре үткәрү* проводи́ть хими́ческие о́пыты; *~ галиме* учёный-хи́мик

химияләштерелү *страд. от* **химияләштерү**

химияләштерү *перех.* проводи́ть химиза́цию, химизи́ровать || химиза́ция; *авыл хуҗалыгын ~* химиза́ция се́льского хозя́йства

хи́н(а) *сущ.* хи́на (*то же, что и хинин*) || хи́нный; *~ сабыны* хи́нное мы́ло ⊔ **~ агачы** хи́нное де́рево

хинин *сущ. фарм.* хини́н

хинлы *прил.* хи́нный, содержа́щий хи́ну

хирург *сущ.* хиру́рг

хирургик *прил.* хирурги́ческий (*пинцет, инструмент*)

хирургия *сущ.* хирурги́я || хирурги́ческий; *эксперименталь ~* эксперимента́льная хирурги́я; *~ бүлеге* хирурги́ческое отделе́ние; *~ юлы белән дәвалау* лече́ние хирурги́ческим путём, путём хирурги́ческого вмеша́тельства

хирыс *сущ. книжн.* **1.** *редко* си́льное жела́ние, безу́де́ржная страсть, пристра́стие *к чему-л.*; *~ка бирелү* отда́ться *какой-л.* (*не любовной*) стра́сти; *шундый ~ы бар* есть у него́ така́я страсть **2.** а́лчность, жа́дность, корыстолю́бие, корысть || *прил. книжн.* **1.** стра́стный, относя́щийся *к чему-л.* со стра́стью; увлечённый *чем-л.*, скло́нный *к чему-л.*; жа́ждущий *чего-л.*, па́дкий *на что-л.*; *ул атка бик ~* он па́док на лошаде́й; *музыкага ~* стра́стно лю́бящий му́зыку **2.** *см.* **хирыслы** 1

хирыслан|у *неперех.* **1.** быть (станови́ться/стать) а́лчным, жа́дным, корыстным; жа́дничать; *юкка ~ма* не жа́дничай понапра́сну **2.** пристрасти́ться *к чему-л.*, увлека́ться/увле́чься *чем-л.*, стра́стно жела́ть, жа́ждать *чего-л.* **3.** *в знач. нареч.* **хирысланып** увлечённо, стра́стно; *~ып музыка тыңлау* увлечённо слу́шать му́зыку

хирыслы *прил.* **1.** а́лчный, жа́дный; корыстолюби́вый, корыстный; *~ күзләр* а́лчные глаза́; *акчага ~* жа́дный до де́нег; *~ кеше* корыстолюби́вый челове́к; *~ максат* корыстная цель **2.** *см.* **хирыс**

хирыслы|к *сущ. книжн. см.* **хирыс**; *сөйләргә ~гым юк* у меня́ нет жела́ния расска́зывать; *~к белән концертларга йөрү* со стра́стью, увлечённо посеща́ть конце́рты

хис *сущ.* **1.** чу́вство, ощуще́ние || чу́вственный; *аналык хисе* материнское чу́вство; *ватанчылык хисе* чу́вство патриоти́зма; *ил хуҗасы булу хисе* чу́вство хозя́ина страны́; *иптәшлек (дуслык) хисе* чу́вство дру́жбы; *көнләшү хисе* чу́вство за́висти (ре́вности); *курку хисе* ощуще́ние (чу́вство) стра́ха; *кызгану хисе* чу́вство жа́лости; *олы хис* большо́е чу́вство (любо́вь); *яңалык хисе* чу́вство но́вого; *хисләр ташкыны* прили́в, подъём чувств; *хискә бай* эмоциона́льный, чувстви́тельный; *хис уята торган* возбужда́ющий чу́вство, чу́вственный; *хис ләззәтләре* чу́вственные наслажде́ния **2.** эмо́ция; *ачу хисе* эмо́ция гне́ва □ **хис итә башлау** почу́вствовать *что-л.*; *үзеңне яхшырак хис итә башлау* почу́вствовать себя́ лу́чше; **хис итү** чу́вствовать *что-л.*, испы́тывать *какое-л.* чу́вство; *уңайсызлык хис итү* чу́вствовать (испы́тывать) нело́вкость, смуще́ние; **хискә бирелү (чуму)** предава́ться/преда́ться чу́вству, дать во́лю чу́вствам; расчу́вствоваться, растро́гаться; **хискә бирелүчәнлек** эмоциона́льность, чувстви́тельность, сентимента́льность; чу́вственность; **хискә тиз бирелүчән** чувстви́тельный; впечатли́тельный, сентимента́льный

хисамә: хисамә уты *бот. см.* **ала миләүшә**

хиса|п I *сущ.* **1.** счёт, подсчёт, расчёт; учёт; исчисле́ние, чи́сленность, число́ (коли́чество) *кого, чего-л.* || счётный, расчётный, учётный; *~п хатасы* оши́бка в расчёте, в подсчётах; *кара ~п белән, кара ~птан чыгып разг.* по приблизи́тельным подсчётам (расчётам); *минем ~бымча* по мои́м подсчётам (расчётам); *эшчеләрнең ~бы* чи́сленность рабо́чих; *~п дәфтәре* учётная тетра́дь **2.** счёт, расчёт (де́нежный); *~п ачу* откры́ть счёт; *~п буенча түләү* оплати́ть по счёту (согла́сно счёту); *мин аның белән ~бымны бетердем* я с ним рассчита́лся; мы с ним в расчёте **3.** *прям., перен.* отчёт || отчётный; *~п доклады* отчётный докла́д **4.** *в ф. направит. п.* **хисабына, хисапка** за (*на, в*) *чей-л.* счёт; *кеше ~бына яшәү* жить за чужо́й счёт; *минем ~пка* за мой счёт; *яңа ел ~бына эшләү* рабо́тать в счёт но́вого го́да **5.** *в ф. места вр. п.* **хисабында** на счету́ *кого-л.*; *аның ~бында биш отыш* на его́ счету́ пять вы́игрышей (побе́д) **6.** *в ф. исх. п.* **хисабыннан** в счёт *чего-л.*; *киләсе ел ~быннан* в счёт бу́дущего го́да □ *~бына керү* входи́ть в число́ *кого, чего-л.*; *~бын югалту* теря́ть счёт *кому, чему-л.*; **~п (~бын) алу 1.** подсчи́тывать **2.** принима́ть счёт; **~п бирү 1.** отчи́тываться *перед кем-л.*; отдава́ть отчёт *кому-л.* **2.** дать *кому-л.* расчёт (де́нежный); рассчита́ть *кому-л.*; **~п итү** *см.* **хисаплау** 1, 3; **~пка алу 1.** учи́тывать, брать на учёт **2.** принима́ть *кого, что-л.* во внима́ние, брать *кого, что-л.* в расчёт; **~пка алучы** учётчик; **~пка кертү** засчи́тывать,

зачисля́ть; включи́ть в число́ *кого, чего-л.*; **~пка тулмау** недосчи́тывать/недосчита́ться; **~пка (~бына) чыкмау** 1. не знать то́чного учёта, не суме́ть сосчита́ть 2. не разобра́ться *в чём-л.*; **~итан тыш** вне учёта, внеучётный, внепла́новый ◊ **~бы юк** не счесть *кого, чего-л.*, нет числа́ *кому, чему-л.*, бесчи́сленное мно́жество *кого, чего-л.*; **(үзенә) ~п бирмичә (бирмәстән)** не отдава́я (себе́) отчёта *в чём-л.*, безотчётно, механи́чески; **~пны өзү** 1. взять у *кого-л.* расчёт, рассчи́тываться, прекрати́ть (прерва́ть) де́нежные отноше́ния 2. ко́нчить/поко́нчить счёты *с кем-л.*; прерва́ть отноше́ния *с кем-л.* 3. свести́ *с кем-л.* счёты (отомсти́ть); разде́латься, рассчита́ться *с кем-л.*; **~птан чыгару (чыгарып ташлау)** исключи́ть из числа́ *кого, чего-л.*

хисап II *сущ. уст.* арифме́тика || арифмети́ческий; *~ китабы* уче́бник по арифме́тике; *~ чыгару* производи́ть арифмети́ческие де́йствия, реша́ть приме́ры

хисаплама *сущ.* расчёт *чего-л.*; *күпернең ~сын чыгару* произвести́ расчёт мо́ста́

хисаплан|у *страд. от* **хисаплау** 1. счита́ться, подсчи́тываться, учи́тываться, вычисля́ться 2. *перен.* принима́ться, быть при́нятым *за кого, что-л.*, счита́ться *кем, чем-л.*, слыть *кем, чем-л.*; *ул әйбәт инженер ~а* он счита́ется (его́ счита́ют) хоро́шим инжене́ром

хисаплату *понуд. от* **хисаплау**

хисапла|у *перех.* 1. счита́ть, сосчита́ть, подсчи́тывать/подсчита́ть; учи́тывать/уче́сть; исчисля́ть/исчи́слить, вычисля́ть/вы́числить || 1) счёт, подсчёт, исчисле́ние, вычисле́ние 2) счётный; вычисли́тельный; *бурычларны ~у* подсчи́тывать долги́; *~у техникасы* вычисли́тельная те́хника 2. рассчи́тывать/рассчита́ть *что-л.*; *көчен ~п эш итү* де́лать *что-л.*, рассчита́в свои́ си́лы 3. *перен.* счита́ть *кого, что-л. кем, чем-л.*; ду́мать, поду́мать *о ком, о чём*, как *о ком-чём*; принима́ть *кого, что* за *кого, что*; *мине үлгәнгә ~ганнар* меня́ счита́ли пои́бшим; полага́ли, что я пои́б □ **~п бирү** подсчита́ть, отсчита́ть *что-л.* (*кому-л.*, для *кого-л.*); **~п кую** подсчита́ть, вы́считать *что-л.* (зара́нее); **~п чыгару** вы́числить *что-л.*; **~п чыгу** подсчита́ть *что-л.*

хисаплаш|у *взаимно-совм. от* **хисаплау** 1. помога́ть в подсчётах 2. *разг.* рассчи́тываться *с кем-л.*, производи́ть взаи́мные расчёты 3. *неперех. перен.* счита́ться *с кем-л.*; принима́ть во внима́ние (в расчёт, в счёт) *кого, что-л.*; *аның белән берәү дә ~ырга уйламады* никто́ и не ду́мал о том, что́бы приня́ть его в расчёт 4. *неперех. перен.* своди́ть/свести́ счёты *с кем-л.* || сведе́ние счётов

хисаплы *прил.* 1. *прям., перен.* счи́танный, сосчи́танный; име́ющийся в ограни́ченном коли́честве; учтённый, находя́щийся на учёте; *~ көннәр* счи́танные дни 2. экономи́чный, расчётливый; *~ның малы исәпле* (*погов.*) у расчётливого (хозя́ина) добро́ всегда́ на учёте

хисапсыз *прил.* 1. бесчи́сленный, бессчётный, несме́тный; не ограни́ченный; неучтённый; *~ күп йолдызлар* бесчи́сленное мно́жество звёзд 2. нерасчётливый, неэкономи́чный; *~ хуҗа* нерасчётливый хозя́ин ◊ **~ киң** необъя́тный

хисапчан *см.* **хисаплы** 2

хисапчы *сущ.* счетово́д; учётчик; *колхоз ~сы* колхо́зный счетово́д

хисапчыл *прил.* лю́бящий счита́ть, подсчи́тывать *что-л.*

хисапчылык *сущ.* счетово́дство || счетово́дческий; *~ курслары* счетово́дческие ку́рсы

хисләнү *неперех.* расчу́вствоваться, си́льно пережива́ть || эмоциона́льность, пережива́ния (*преимущественно положительные*)

хисле *прил.* чувстви́тельный, воспри́имчивый; эмоциона́льный, впечатли́тельный

хислелек *сущ.* чувстви́тельность, воспри́имчивость; впечатли́тельность; эмоциона́льность

хисса *сущ.* 1. *уст.* до́ля, причита́ющаяся *кому-л.* часть *от чего-л.*; пай; *үз ~ңы ал* возьми́ свою́ до́лю 2. *лит.* резюме́, заключе́ние, вы́вод

хиссез *прил.* бесчу́вственный, безрази́чный, равноду́шный

хиссезлек *сущ.* бесчу́вственность, безду́шность, безду́шие; безрази́чие, равноду́шие

хисси *прил. книжн.* чу́вственный, ощути́мый; стра́стный; *аның чыгышы ~ иде* его́ выступле́ние бы́ло стра́стным

хиссият *сущ. книжн.* чувстви́тельность, пережива́ния; *~ дөньясында гизү* вита́ть в ми́ре чувств

хиссиятләнү *неперех. книжн. см.* **хисләнү**

хиссиятле *прил. уст. см.* **хисле**

хитап *сущ. уст. книжн.* 1. восклица́ние, во́згласа, о́крик 2. обраще́ние, воззва́ние (*устное*), речь □ **~ галәмәте** *уст.* восклица́тельный знак; **~ итү (кылу)** обраща́ться с воззва́нием, ре́чью; произноси́ть речь

хитапнамә *сущ. уст.* воззва́ние, обраще́ние (*письменное*)

хитон *сущ.* хито́н (*вид широкой, свободной одежды*)

хиффәт *сущ. уст. книжн.* легкомы́слие, легкове́сность, несерьёзность, ве́тренность

хиффәтләнү *неперех. уст.* сойти́ с ума́, помеша́ться (*в уме, в рассудке; умом, рассудком*), лиши́ться рассу́дка; *бу кеше ~мәгән микән?* не сошёл ли э́тот челове́к с ума́?

хи-ха-хай *подр. громкому раскатистому смеху* ха-ха-ха́ (*передаёт громкий раскатистый смех*)

хихайлау *неперех. прост.* гоготать, реготать *диал.* || го́гот, гоготание (*громкий несдержанный смех*)

хи-хи, хи-хи-хи *подр. тонкому негромкому, обычно в чей-л. адрес, смеху исподтишка* хи-хи, хи-хи-хи́

хихылда|у *неперех. разг.* хихи́кать *над кем, чем-л.* || хихи́канье, хи́ханьки; хи́хоньки-ха́ханьки; *~п көлеп җибәрү* хихи́кнуть

хламидомона́да *сущ. биол.* хламидомона́да (*одноклеточная зелёная водоросль*)

хлор *сущ. хим.* хлор || хло́рный; *~ кислотасы* хло́рная кислота́

хлора́тор *сущ.* хлора́тор (*аппарат для хлорирования воды*)

хлорвинил *сущ.* хлорвини́л (*синтетический полимер*) || *прил.* хлорвини́ловый; *~ клеёнкасы* хлорвини́ловая клеёнка

хлоре́лла *сущ. бот.* хлоре́лла

хлорид *сущ. хим.* хлори́д; *металл ~лар* металли́ческие хлори́ды

хло́рка *сущ. разг.* хло́рка (хло́рная и́звесть)

хлорландыру *перех. см.* **хлорлау**

хлорландырылу *страд. от* **хлорландыру**; хлори́ровать

хлорлану *возвр.-страд.* хлори́роваться, станови́ться/стать хлори́рованным

хлорлату *понуд. от* **хлорлау**

хлорлау *перех.* 1. хлори́ровать (*воду*) || хлори́рование 2. *спец.* хлори́ровать (*вводить хлор в органические и неорганические соединения*); *термик ысул белән ~* хлори́ровать терми́ческим спо́собом

хлорлы *прил.* хло́рный, хло́ристый; ~ *натрий* хло́ристый на́трий; ~ *известь* хло́рная и́звесть

хлорофилл *сущ. бот.* хлорофи́лл || хлорофи́лловый; ~ *бөртекләре* хлорофи́лловые зёрна

хлороформ *сущ. мед.* хлорофо́рм; ~ *биреп йоклату* усыпля́ть с по́мощью хлорофо́рма, хлороформи́ровать

хлороформлау *перех.* пропи́тывать хлорофо́рмом

хлороформлы *прил.* с хлорофо́рмом, содержа́щий хлорофо́рм

хлорофос *сущ. хим.* хлорофо́с || хлорофо́сный

хлорпикрин *сущ. хим.* хлорпикри́н || хлорпикри́новый

хо́бби *сущ.* хо́бби; *минем ~ — кактус үстерү* моё хо́бби — разведе́ние ка́ктусов

хода *сущ. см.* **ходай, алла**; *атны ~га тапшыр, дилбегәне үзең тот* (*посл.*) на бо́га наде́йся, а сам не плоша́й (*букв.* ло́шадь переда́й во́ле бо́га, а вожжа́ми управля́й сам) ◊ **я ~, и-и ~ем!** о го́споди, бо́же мой, бог ты мой! (*восклицание, выражающее испуг, изумление, восхищение, сожаление и т. п.*); ~ **(алла) бәндәсе** *разг:* раб бо́жий; ~ **(алла) белсен!** бог его́ зна́ет!; ~ **кушса (кушып бирсә, боерса)** *см.* **алла бирсә**; ~ **сакласын** *см.* **алла сакласын**; **~га тапшыру** *см.* **аллага тапшыру**; **~га шөкер** *см.* **аллага шөкер**; **~ның боерыгы** бо́жье повеле́ние; **~ның хикмәте** бо́жья ми́лость

ходаи *прил. уст.* блаже́нный, не от ми́ра сего́; ~ *бәндә* челове́чишка не от ми́ра сего́

ходай *сущ.* бог, всевы́шний; ~ *миңа бала бирмәгән* бог не дал (не посла́л) мне дете́й ◊ ~ **бәндәсе** *см.* **алла бәндәсе**; ~ **кушса (бирсә, боерса, язса)** *см.* **алла бирсә**; ~ **күрсәтмәсен** не приведи́ госпо́дь, не дай бог, упаси́ бо́же; ~ **орган (каргаган)** *бран.* про́клятый бо́гом; ~ **(хакы) өчен** ра́ди бо́га, ра́ди всего́ свято́го; ~ **сакласын** *см.* **алла сакласын**; **~га тапшыру** *см.* **аллага тапшыру**; **~ның биргән (бирмеш) көне** ка́ждый бо́жий день, ежедне́вно

ходай тәгалә *сущ. см.* **ходай**

хозур *сущ.* **1.** удово́льствие, наслажде́ние, развлече́ние, заба́ва, весе́лье; отра́да, усла́да; *күңелемнең ~ы* отра́да души́ мое́й **2.** *в знач. послелога* **хозурына** к, на, пе́ред; *синең ~ыңа килдек* мы пришли́ к тебе́ (на покло́н); *хөкем ~ына басу* предста́ть пе́ред судо́м **3.** *в знач. послелога* **хозурында** пе́ред, о́коло, у, при; *министр ~ында булу* быть (на приёме) у мини́стра **4.** *в знач. послелога* **хозурында** пе́ред, от || *прил.* доставля́ющий (принося́щий) удово́льствие, наслажде́ние; весёлый, ра́достный, прия́тный, испо́лненный сча́стья, ра́дости, дово́льства; сла́достный, благода́тный; ~ *көннәрне хәтерләү* вспомина́ть счастли́вые, ра́достные дни; ~ *минутлар кичерү* пережива́ть прия́тные, счастли́вые мину́ты || *нареч.* ве́село, ра́достно, прия́тно; *кичләрне бик ~ уздыру* проводи́ть вечера́ о́чень ве́село (в развлече́ниях) □ ~ **кылу (итү)** весели́ться, развлека́ться; блаже́нствовать, наслажда́ться; **~га чыгу 1.** выходи́ть/вы́йти на прогу́лку **2.** отправля́ть/отпра́виться на пикни́к

хозурлан|у *неперех.* **1.** любова́ться *кем, чем-л.*, наслажда́ться лицезре́нием *кого, чего-л.* **2.** весели́ться, повеселя́ться, развлека́ться/развле́чься, забавля́ться, позаба́виться, блаже́нствовать; наслажда́ться/наслади́ться *чем-л.*; испы́тывать (испыта́ть, получа́ть/получи́ть) удово́льствие *от кого, чего-л.* || наслажде́ние; *табигать белән ~у* наслажда́ться приро́дой; *музыка тыңлап ~у* наслажда́ться му́зыкой; получа́ть удово́льствие от му́зыки **3.** *в знач. нареч.* **хозурланып** с наслажде́нием, с удово́льствием; *~ып тыңлау* слу́шать с наслажде́нием; *~ып утыру* блаже́нствовать (*в данный момент*)

хозурландыру *перех.* развлека́ть/развле́чь, весели́ть, повеселя́ть, развеселя́ть *кого-л.*; *җыр, уеннар белән ~* развле́чь *кого-л.* пе́снями, и́грами

хозурлы *прил. см.* **хозур**; ~ *иркенлек* свобо́да

хозурлык *сущ.* весе́лье; весёлое, ра́достное настрое́ние; блаже́нство, благода́ть, наслажде́ние; *иң югары ~та булу* быть на верху́ блаже́нства

Хозыр *сущ. см.* **Хозыр Ильяс** □ **Хозыр бабай** *то же, что* **Хозыр Ильяс** ◊ **Хозыр төкергән** нескончаемый, неубыва́ющий; ≈ неразме́нный рубль

Хозыр Ильяс *сущ. миф.* Хызр Ильяс (*легендарный пророк, по преданию, испивший «живой воды» из источника жизни и обретший вечную жизнь; появляется в образе нищего, пастуха или путника, даёт добрые советы, дарит богатство или указывает место клада*) ◊ **Хозыр Ильяс булсын юлдашың** счастли́вого пути́ (*букв.* пусть бу́дет твои́м спу́тником Хызр Ильяс)

Хозыр Ильяслык *сущ.* благи́е деяния (*подобно деяниям Хызр Ильяса*)

хоккей *сущ. спорт.* хокке́й || хокке́йный; *боз ~е* хокке́й на льду́; *шайбалы (туплы) ~й* хокке́й с ша́йбой (мячо́м); *~й командасы* хокке́йная кома́нда; *~й кәшәкәсе* хокке́йная клю́шка; *~й ярышы* хокке́йный матч

хоккейчы *сущ. спорт.* хоккеи́ст

хокук *сущ.* **1.** *юр.* пра́во || правово́й, юриди́ческий; *белем алу ~ы* пра́во на образова́ние; *варислык ~ы* пра́во насле́дования; *гражданлык ~ы буенча лекцияләр* ле́кции по граждáнскому пра́ву; *крепостнойлык ~ы* крепостно́е пра́во; *сайлау ~ы* избира́тельное пра́во; *тавыш бирү ~ы* пра́во го́лоса; *халыкара ~ буенча белгеч* специали́ст по международно́му пра́ву; *яклану ~ы* пра́во на защи́ту; *ял итәргә ~* пра́во на о́тдых; ~ *мөнәсәбәтләре* правовы́е отноше́ния; ~ *нигезе* правова́я осно́ва; ~ *нормалары* правовы́е но́рмы; ~ *фәннәре* юриди́ческие нау́ки **2.** пра́во (*возможность, основание действовать каким-л. образом*); *см. тж.* **хак** III; *эштәге кимчелекләрне тәнкыйтьләү ~ы* пра́во критикова́ть недоста́тки в рабо́те **3.** пра́во, полномо́чие; *см. тж.* **вәкаләт**; *депутатлык ~ы* депута́тское полномо́чие; *чикләнмәгән ~лар* неограни́ченные полномо́чия □ ~ **аңы, ~ларны аңлау** правосозна́ние; ~ **белгече** правове́д, законове́д, юри́ст; ~ **белеме** правове́дение; ~ **гыйлеме** *см.* **хокук белеме**; ~ **киңәшчесе** юриско́нсульт; ~ **тәртибе** правопоря́док

хокуклы *прил.* правомо́чный, полномо́чный; облечённый права́ми, с пра́вом *на что-л.*; -пра́вный; ~ *кеше* лицо́, облечённое права́ми; *ялга ~* облада́ющий пра́вом на о́тдых; *тигез ~* равнопра́вный; *тулы ~* полнопра́вный; ~ *булу* быть правомо́чным (правоспосо́бным)

хокуклылык *сущ. юр.* правомо́чие, облада́ние права́ми; -пра́вие; *тигез ~* облада́ние ра́вными права́ми, равнопра́вие

хокуксыз *прил.* беспра́вный, не име́ющий (лишённый) прав; неполнопра́вный

хокуксызлык *сущ.* беспра́вие, беспра́вность; неправомо́чность; неполнопра́вие

хокукчы *сущ.* юри́ст, специали́ст пра́ва, правове́д

хокукчылык *сущ.* юриспруде́нция, правове́дение

хокукый *прил.* правово́й; ~ *аң* правово́е созна́ние, правосозна́ние; ~ *дәүләт* правово́е госуда́рство; ~ *нигез* правова́я осно́ва

холера *сущ. мед.* холе́ра || холе́рный; *см. тж.* **ваба**; *~дан үлү* умере́ть от холе́ры; ~ *эпидемиясе* холе́рная эпиде́мия

холе́ралы *прил.* холе́рный; ~ *авырулар* холе́рные больны́е

холе́рик I *сущ.* холе́рик

холе́рик II *прил.* холери́ческий (*темперамент*)

колестерин *сущ. биол.* холестери́н

холецистит *сущ. мед.* холецисти́т

холоп *сущ.* **1.** *ист.* холо́п (*в Древней Руси лицо, находившееся почти в рабской зависимости*) **2.** *уст.* холо́п (*крепостной слуга*)

холопла́рча *нареч.* по-холо́пски || холо́пский □ ~ **кылану** холо́пствовать, выслу́живаться *перед кем-л.*

холоплык *сущ. уст.* **1.** холо́пство (*форма феодальной зависимости, близкая к рабству*) **2.** холо́пство (*состояние, положение холопа*)

холуй *сущ.* **1.** *уст.* холу́й (*лакей, слуга*) **2.** *бран. презр.* холу́й (*чей-л. приспешник, прислужник*); *см. тж.* **ялагай**

холуйла́рча *нареч. презр.* холу́йски, по-холу́йски; ~ *хезмәт итү* служи́ть по холу́йски || холу́йский; ~ *хезмәтчелек* холу́йское прислу́жничество □ ~ **кылану** холу́йствовать, выслу́живаться *перед кем-л.*

холык (холкы) *сущ.* **1.** хара́ктер, нату́ра, нрав, но́ров *прост.*; *йомшак* ~ мя́гкий хара́ктер; *кыю* ~ сме́лый (реши́тельный) хара́ктер; ~ *күрсәтү* проявля́ть, пока́зывать свой но́ров; *һәркемнең үз холкы* у ка́ждого свой нрав **2.** пова́дка (**-и**), накло́нности, поведе́ние, мане́ры; *начар ~ларны иярту* перенима́ть дурны́е накло́нности (мане́ры)

холыклы *прил.* **1.** с определённым хара́ктером, нра́вом; име́ющий *какой-л.* хара́ктер, нрав; *авыр* ~ с тяжёлым хара́ктером; *кызу* ~ со вспы́льчивым хара́ктером; *каты* ~ с крутым нра́вом; *киң* ~ *кеше* челове́к с широ́кой нату́рой **2.** *разг.* с хоро́шим (лёгким) хара́ктером (нра́вом); *ул бик* ~ *кеше* у него́ хоро́ший (лёгкий) хара́ктер

холыксыз *прил.* **1.** с плохи́м (дурны́м, тяжёлым, сквёрным) хара́ктером, нра́вом; несде́ржанный, неуравнове́шенный, неужи́вчивый, сварли́вый, скандальный; *андый* ~ *кешене күргәнем юк иде* тако́го несде́ржанного челове́ка я ещё не ви́дел(а); ~ *каенана* сварли́вая свекро́вь **2.** своево́льный, вздо́рный, капри́зный

холыксызлан|у *неперех.* **1.** вести́ себя́ несде́ржанно, раздража́ться, бу́йствовать, дебоши́рить, пока́зывать дурно́й хара́ктер; по́ртиться (*о характере*); *ул бигрәк ~ып бара* у него́ стал си́льно по́ртиться хара́ктер **2.** упря́миться, капри́зничать, проявля́ть непоко́рность, непослуша́ние

холыксызлык *сущ.* **1.** плохо́й хара́ктер, дурно́й нрав; несде́ржанность, неуравнове́шенность; неужи́вчивость, сварли́вость **2.** своево́лие, вздо́рность

холык-фигыль (холыклы-фигыле) *сущ. собир.* хара́ктер, нрав, нату́ра, пова́дка; *хатын алганда, холык-фигылен белеп ал* выбира́й жену́ по хара́ктеру (*букв.* бери́ жену́, узна́в её хара́ктер)

хонса *сущ.* гермафроди́т

хонсалык *сущ.* гермафродити́зм

хор *сущ.* хор || хорово́й; *студентлар хоры* хор студе́нтов; *халык хоры* наро́дный хор; *куптавышлы хор* многоголо́сый хор; *тавышлар хоры* хор голосо́в; *хор түгәрәге* хорово́й кружо́к; *хорга дирижёрлык итү* дирижи́ровать хо́ром □ **хор белән** хо́ром (*петь, кричать*); *хор белән жавап бирү* отвеча́ть хо́ром

хорафат *сущ.* **1.** суеве́рие, предрассу́док || суеве́рный; *дини ~лар* религио́зные предрассу́дки; ~ *йолалары* суеве́рные обря́ды **2.** вы́мысел, вы́думка, небыли́ца; ~*лар сөйләү* расска́зывать небыли́цы □ ~**ка ышанучы** суеве́рный челове́к

хорафатчан *прил.* суеве́рный, подве́рженный предрассу́дкам, ве́рящий в приме́ты (*о человеке*)

хорафатчанлык *сущ. см.* **хорафатчылык**

хорафатчы *сущ.* суеве́рный челове́к

хорафатчыл *прил.* **1.** *см.* **хорафатчан 2.** осно́ванный на суеве́рии, предрассу́дках

хорафатчылык *сущ.* суеве́рность

хорват *сущ.* хорва́т || хорва́тский (*народ, язык, танец*); ~ *хатын-кызы* хорва́тка

хорва́тча *нареч.* по-хорва́тски; ~ *язу* писа́ть по-хорва́тски || *прил.* хорва́тский, на хорва́тском языке́ (*газета, разговор*)

хо́рда *сущ.* **1.** *мат.* хо́рда (*прямая, соединяющая две точки кривой линии или поверхности*) **2.** *зоол.* хо́рда (*осевой скелет, спинная струна у некоторых животных и у зародыша человека*)

хо́рдалы *прил. зоол.* хо́рдовый (*тип животных*)

хорей *сущ. лит.* хоре́й (*один из основных стихотворных размеров*) || хореи́ческий (*размер*); ~ *белән язылган шигырь* стихотворе́ние, напи́санное хоре́ем

хореб́граф *сущ.* хореб́граф

хореогра́фик *прил.* хореографи́ческий; ~ *сәнгать* хореографи́ческое иску́сство

хореогра́фия *сущ.* хореогра́фия || хореографи́ческий; ~ *дәресләре* уро́ки хореогра́фии; ~ *түгәрәге* хореографи́ческий кружо́к

хормейстер *сущ.* хормейстер || хормейстерский; *җыр һәм бию ансамбле(нең) ~ы* хормейстер ансамбля пе́сни и пля́ски

хо́ртум *сущ.* хо́бот

хо́ртумлы *прил. зоол.* **1.** хоботно́й, име́ющий хо́бот; ~ *хайваннар* хоботны́е живо́тные **2.** *в знач. сущ. мн.* **хортумлылар** хоботны́е

хортумчык *сущ. зоол.* **1.** *уменьш. см.* **хортум 2.** хобото́к (*у насекомых*); *көпшәсыман* ~ тру́бчатый хобото́к

хорчы *сущ.* хори́ст; ~ *хатын (кыз)* хори́стка

хосус *сущ. уст. книжн.* **1.** отноше́ние, слу́чай; *бу ~та ул хаклы түгел иде* в да́нном слу́чае он был не прав **2.** *в знач. послелога* **хосусында** в отноше́нии *кого, чего*, что каса́ется; о, об, обо, про; *эш ~ында сөйләшү* говори́ть о рабо́те; *ул — акча ~ында комсызрак кеше* в отноше́нии де́нег (что каса́ется де́нег) он дово́льно жа́дный челове́к

хосусан *вводн. сл. книжн.* осо́бенно, в осо́бенности, в ча́стности; *ул кешеләргә, ~, яшьләргә игътибарлы* он внима́телен к лю́дям, осо́бенно к молодёжи

хосусән *вводн. сл. см.* **хосусан**

хосусият *сущ. книжн.* специфи́чность, осо́бенность, своеобра́зность; *милли ~* национа́льная осо́бенность; *сәүдә капиталы ~ләре* осо́бенности торго́вого капита́ла

хосусый *прил.* **1.** *в разн. знач.* ча́стный, осо́бый; ~ *шәхес* ча́стное лицо́; *гомуми һәм ~ мәсьәләләр* о́бщие и ча́стные вопро́сы; ~ *очрак* осо́бый (ча́стный) слу́чай; ~ *гаепләү* ча́стное обвине́ние; *судның ~ билгеләмәсе* ча́стное определе́ние суда́; *мәсьәләне ~ итеп алу* рассма́тривать вопро́с в ча́стном (у́зком) пла́не **2.** ча́стный, частновладе́льческий, частнособственнический, частнопредприним́ательский; ~ *сәүдә* ча́стная торго́вля; ~ *хуҗалык* ча́стное хозя́йство; ~ *милек* ча́стная со́бственность; ~ *эшчәнлек* частнопредприним́ательская де́ятельность **3.** ли́чный; *см. тж.* **шәхси**; ~ *тормыш* ча́стная жизнь; ~ *хатлар* ли́чные пи́сьма **4.** осо́бый, осо́бенный, спе-

циа́льный; *см. тж.* **аерым, махсус**; ~ *чакыру* специа́льное приглаше́ние; ~ *бер дәрт белән* с осо́бым пы́лом (чу́вством, подъёмом); ~ *бер кәефлек белән* с осо́бенным настрое́нием || *нареч.* осо́бо, специа́льно; ~ *чакырылган кунаклар* осо́бо приглашённые го́сти □ ~ **биләмәдәге (карамактагы)** частносо́бственнический, частновладе́льческий; ~ **милек иясе** со́бственник, ча́стник

хосусыйлаштыру *перех.* приватизи́ровать || **1.** приватиза́ция; *дәүләт милкен* ~ приватиза́ция госуда́рственного иму́щества **2.** приватизацио́нный; ~ *чегы* приватизацио́нный чек

хосусыйлы|к *сущ.* ча́стность (едини́чность); *очракның ~гы* ча́стность слу́чая

хосусыйчы *сущ.* ча́стник, ча́стный предпринима́тель

хөббе: хөббе нәфес себялю́бие, эгои́зм, самовлюблённость

хөҗрә *сущ. книжн.* ке́лья, оби́тель (*комната в общежитиях старых медресе*)

хөкем *сущ.* **1.** суд (*как государственный, юридический орган*) || суде́бный, суде́йский; *гадел* ~ правосу́дие; ~ *каршында җавап бирү* отвеча́ть пе́ред суло́м; ~ *карары* суде́бное реше́ние; ~ *коллегиясе* суде́йская колле́гия; ~ *залы* зал суда́ **2.** суд (*как процесс, разбирательство*); ~ *бара* идёт суд **3.** суд (*мнение, суждение о ком, о чём-л.*; оце́нка *кого, чего-л.*; *напр., суд истории, общественности, потомков*); *~енә бирү* (*тапшыру*) отда́ть *на чей-л.* суд **4.** *юр.* реше́ние, определе́ние (*судебное*); приговор; ~ *чыгару* вы́нести приговор (реше́ние); *суд ~ен тормышка ашыру* привести́ приговор в испо́лнение **5.** *лог.* сужде́ние; ~ *кисәкләре* ча́сти сужде́ния **6.** *редко* власть, госпо́дство; *капитал ~е* власть (госпо́дство) капита́ла **7.** *в косв. ф.* во́ля, жела́ние, усмотре́ние; *үз ~енә буйсындыру* подчини́ть свое́й во́ле; **8.** *в знач. послелога* **хөкемендә** как, всё равно́ что; вме́сто; *туган сеңел ~ендә* вме́сто родно́й сестры́; *туксан яшьлек карт тугыз яшьлек бала ~ендә* (*погов.*) (*букв.* девяно́столе́тний стари́к всё равно́ что девятиле́тний ребёнок) ≈ ста́рый что ма́лый □ ~ **ителгән кеше** осуждённый; ~ **ителгәнлек** суди́мость; ~ **итү 1.** *см.* **хөкем йөртү 2.** *перех.* оце́нивать *кого, что-л.* **3.** обвиня́ть/обвини́ть *кого-л. в чём-л.* **4.** *только несов.* суди́ть *кого-л.*; ~ **итүче** судья́ **5.** *юр.* суди́ть, осуди́ть, приго́варивать/приговори́ть, вы́нести приговор; ~ **йөртү 1.** приде́рживаться, быть *какого-л.* мне́ния *о ком-л.* **2.** *см.* **хөкем сөрү** 1; ~ **мәҗлесе** *уст.* заседа́ние суда́; ~ **сөрү 1.** госпо́дствовать, пра́вить, ца́рствовать, вла́ствовать, цари́ть **2.** *перен.* хозя́йничать, цари́ть, вла́ствовать; *залда тынычлык ~ сөрә иде* в за́але цари́ла тишина́; ~ **сөрүчәнлек** госпо́дство; ~ **сөрүче** госпо́дствующий; ~ **чыгару** *см.* **хөкем итү** 2, 5; ~ **ясау** выноси́ть приговор; **~гә тарту** привлека́ть *кого-л.* к суду́

хөкемдар *сущ. книжн. прям., перен.* повели́тель, прави́тель, государь, властели́н, власти́тель

хөкемдарлы|к *сущ. книжн.* положе́ние повели́теля; правле́ние, власть; *Ибраһим ханның ~гы* правле́ние Ибраги́м-ха́на

хөкемләшү *неперех. книжн.* суди́ться *с кем-л.*

хөкемнамә *сущ. книжн.* кни́га протоко́лов, протоко́л суде́бного реше́ния

хөкемче *сущ. см.* **хөкем итүче**

хөкүмәт *сущ.* прави́тельство || прави́тельственный; *Татарстан ~е* прави́тельство Татарста́на; ~ *органнары* прави́тельственные о́рганы; ~ *карары* прави́тельственное постановле́ние

хөллә *сущ.* **1.** *особый вид изысканной верхней одежды, напоминающий чапан* **2.** *перен.* одея́ние, оде́жда; ~ *тун* тёплое (стёганое) одея́ние

хөнса *сущ. см.* **хонса**

хөнсалык *сущ. см.* **хонсалык**

хөр *прил.* свобо́дный, во́льный, незави́симый || *нареч.* свобо́дно, во́льно; *хөр фикерле* свободомы́слящий; *хөр фикерлелек* свободомы́слие; *хөр яшәү* жить во́льно (свобо́дно)

хөрәсән *сущ. ирон., пренебр.* безде́льник, ло́дырь, дармое́д (*первоначально — выпускник медресе из Хорасана, где были религиозные секты, проповедовавшие философию бездеятельности как благо*) ◊ ~ **ялкавы** ло́дырь из ло́дырей, безде́льник из безде́льников

хөрәсәнләнү *разг.* ло́дырничать, безде́льничать, бить баклу́ши; лени́ться; облени́ваться/облени́ться

хөрлек *сущ. см.* **хөррият**

хөрмә *сущ.* **1.** фи́ник || фи́никовый; ~ *агачы* фи́никовая па́льма; ~ *җимеше* фи́ник, фи́ники (*съедобные плоды финика*) **2.** хурма́ (плод и де́рево) ◊ ~ **кебек** краси́вый, хоро́шенький; ~ **талы** фи́никовое де́рево (*приводится для сравнения со стройным станом*)

хөрмәт *сущ.* **1.** уваже́ние, почёт, почте́ние, честь || почётный; ~ *иясе* почётный, заслу́женный, уважа́емый челове́к; *~кә лаеклы* досто́йный уваже́ния, почте́нный, уважа́емый; *хезмәт итсәң, ~ күрерсең* (*погов.*) бу́дешь трудиться, заслу́жишь почёт; *геройларга ~ һәм дан!* честь и сла́ва геро́ям! **2.** *разг.* угоще́ние; *см.* **сый-хөрмәт 3.** *в знач. послелога* **хөрмәтенә** в честь *кого, чего-л.*; *зур кунак ~енә* в честь большо́го го́стя □ ~ **белән** с почте́нием, с по́честями, уважи́тельно, почти́тельно; ~ *белән күмү* похорони́ть с по́честями; ~ **итәрлек** досто́йный уваже́ния (почита́ния); ~ **ителә торган** уважа́емый, почита́емый; ~ **итү (күрсәтү) 1.** уважа́ть, чтить, почита́ть *кого-л.*; ока́зывать уваже́ние, почте́ние *кому-л.* **2.** угоща́ть *кого-л.*; принима́ть (*в качестве гостя*); ~ **итүчән (күрсәтүчән)** уважи́тельный

хөрмәтләнү *страд. от* **хөрмәтләү**; по́льзоваться уваже́нием (почётом)

хөрмәтлә|ү *перех.* **1.** чтить, почита́ть, уважа́ть, ува́жить *разг. кого, что-л.*; ока́зывать/оказа́ть почте́ние, уваже́ние || почита́ние, уваже́ние; *карт кешене ~ү* ува́жить старика́, отнести́сь к нему́ с почте́нием, уваже́нием **2.** че́ствовать, ока́зывать по́чести || че́ствование; *~ү җыелышы* че́ствование (*т. е. собрание, посвящённое чествованию кого-л.*) □ **~п искә алу** чтить, почти́ть *чью-л.* па́мять

хөрмәтләүчән *прил.* **1.** уважи́тельный, почти́тельный **2.** гостеприи́мный

хөрмәтле *прил.* уважа́емый, почита́емый, почте́нный, почётный; ~ *кунак* уважа́емый, почте́нный гость

хөрмәтлелек *сущ. см.* **хөрмәт**

хөррият *сущ. уст. книжн.* свобо́да, во́ля, незави́симость; ~ *өчен көрәш* борьба́ за свобо́ду

хөрриятпәрвәр *прил. уст. книжн.* свободолюби́вый

хөрт(и) *предик. прост.* плохо́й, дрянно́й, нева́жный, него́дный, захуда́лый; *эшләр ~* пло́хи дела́

хөртилән|ү *прил. прост.* ухудша́ться/уху́дшиться || ухудше́ние; *аның эшләре ~де* дела́ его́ уху́дшились

хөсен *сущ. уст. книжн.* **1.** краса́, красота́ **2.** хоро́шее ка́чество, положи́тельная сторона́

хөсет *сущ. книжн.* за́висть □ ~ **итү** *см.* **хөсетләнү**

хөсетләнү *неперех. книжн.* зави́довать *кому, чему-л.* (*богатству, успехам*); мстить от за́висти

хөсетле *прил. книжн.* зави́стливый; *ул андый ~ кеше тугел* он (она́) во́все не зави́стливый челове́к

хөсетлек *сущ. книжн.* зави́стливость

хөсетчел *прил. см.* **хөсетле**

хөсне *прил.* к **хөсеи** □ **~ әдәп** благовоспи́танность, учти́вость; прили́чие, хоро́шие мане́ры; **~ әхлак** благонра́вие; **~ тәрбия** благовоспи́танность; **~ хат** чистописа́ние, краси́вый по́черк; ◊ **~ зан** хоро́шее, высо́кое мне́ние *о ком, о чём-л.*; хоро́шее отноше́ние *к кому, чему-л.*

хөтбә *сущ. книжн.* **1.** хутба́ (*молитва, читаемая при бракосочетании*) **2.** *рел.* про́поведь в мече́ти □ **~ уку** чита́ть про́поведь, пропове́довать

храм *сущ.* **1.** *рел.* зда́ние, предназна́ченное для выслу́живания религио́зных обря́дов; храм (*в честь какого-л. бога, богини или святого*) **2.** *перен.* храм; *сәнгать ~ы* храм иску́сства

хрестома́тия *сущ.* хрестома́тия (*историческая, музыкальная*) || хрестомати́йный (*материал, пример*)

хризанте́ма *сущ.* хризанте́ма; *см. тж.* **алтын чәчәк (гөл)**; *ак ~лар бәйләме* буке́т бе́лых хризанте́м

хризоберилл *сущ. мин.* хризобери́лл (*золотисто-жёлтый драгоценный камень*) || хризобери́лловый (*брошь, колье*)

хризобери́ллы *прил.* хризобери́лловый, с хризобери́ллом; **~ йөзек** пе́рстень с хризобери́ллом

хризолит *сущ. мин.* хризоли́т (*общее название золотисто-зелёных прозрачных камней*) || хризоли́товый, сде́ланный из хризоли́та

хризолитлы *прил.* хризоли́товый, с хризоли́том; **~ алка** серёжки с хризоли́том

христиан *сущ.* христиани́н || христиа́нский; **~ бәйрәмнәре** христиа́нские пра́здники; **~ дине** христиа́нская рели́гия; **~ динендәге кеше** христиани́н; **~ динен тоту** испове́довать христиа́нскую ве́ру; **~ динен тарату** распространя́ть христиа́нство; **~ диненә күчү** перейти́ в христиа́нскую ве́ру, приня́ть христиа́нство

христианлаштыру *перех. ист.* обраща́ть/обрати́ть *кого-л.* в христиа́нство, в христиа́нскую ве́ру, христианизи́ровать *кого-л.* || обраще́ние в христиа́нство, христианиза́ция; *Идел буе халыкларын ~* христианиза́ция наро́дов Пово́лжья

христианлашу *неперех.* принима́ть/приня́ть христиа́нство

христианлык *сущ.* христиа́нское вероуче́ние, христиа́нство || христиа́нский; **~ йолалары** христиа́нские обы́чаи (обря́ды); **~ дине** христиа́нская ве́ра, христиа́нство

христианнарча *нареч.* по-христиа́нски, христиа́нски || христиа́нский; **~ күму йоласы** христиа́нский обы́чай погребе́ния

хром *сущ.* **1.** хром (*химический элемент*); **~ катыш** (*катнашкан*) *см.* **хромлы 2.** хром (*сорт кожи*); **~ итек** хро́мовые сапоги́ (из хро́мовой ко́жи) **3.** хром (*минеральная краска*) || хро́мовый; **~ әчесе** (*әчелеге*) *хим.* хро́мовая кислота́; **~ белән каплау** *см.* **хромлау**; **~ белән капланган** покры́тый хро́мом, хроми́рованный

хроматизм *сущ.* **1.** *физ.* хромати́зм (*свойство белого луча разлагаться на лучи разных цветов*); **нурларның ~га нигезләнгән таркалышы** хромати́ческое разложе́ние луче́й **2.** *муз.* хромати́зм (*восходящее или нисходящее мелодическое движение по полутонам*)

хрома́тик *прил. физ., муз.* хромати́ческий; **~ тынлы уен кораллары** хромати́ческие духо́вные инструме́нты; **~ төсләр** хромати́ческие цвета́

хромит *сущ. мин.* хроми́т (*материал, содержащий хром и железо*); хро́мистый железня́к

хромлату *понуд. от* **хромлау**

хромлау *перех.* хроми́ровать (*металл*), покрыва́ть/покры́ть хро́мом || хроми́рование, хромиро́вка || хромиро́вочный (*материал, цех*)

хромлаучы *сущ. спец.* хромиро́вщик

хромлы *прил. хим.* хро́мистый, хро́мовый; **~ корыч** хро́мистая сталь; **~ тимер рудасы** хро́мистый железня́к; **~ руда** хро́мистая руда́

хромосо́ма *сущ. биол.* хромосо́ма (*элемент клеточного ядра, содержащий в себе наследственные коды*) || хромосо́мный

хромосфе́ра *сущ. астр.* хромосфе́ра (*слой атмосферы вокруг Солнца*)

хро́ник I *сущ. мед. разг.* хро́ник (*хронический больной*)

хро́ник II *прил.* хрони́ческий (*продолжительный, постоянный*); **~ авырулар** хрони́ческие боле́зни

хро́ника *сущ.* **1.** хро́ника *ист.* (*запись исторических событий в их временной последовательности*) **2.** хро́ника *лит.* (*литературное произведение, заключающее в себе историю общественных, политических, семейных и т. п. событий*); *Бөек Ватан сугышы ~сы* хро́ника Вели́кой Оте́чественной войны́ **3.** хро́ника *только ед.* (*краткая информация в периодической печати о текущих событиях*); *спорт ~сы* спорти́вная хро́ника **4.** хро́ника (*документальный фильм о текущих событиях*) || хроника́льный; **~ жанры** хроника́льный жанр □ **~ язучы** *см.* **хроникачы**

хроникаль *прил.* хроника́льный (*фильм, материал*)

хро́никачы *сущ.* хроникёр (*сотрудник газеты, журнала, радио, дающий информацию в отдел хроники*) || хроникёрский; *газета ~сы* газе́тный хроникёр; **~ язмалары** хроникёрские запи́ски

хроно́граф I *сущ. ист.* хроно́граф (*памятник древней письменности, содержащий хронику какой-л. страны*)

хроно́граф II *сущ. тех.* хроно́граф (*прибор для измерения и графической регистрации времени*)

хронографи́к *прил.* хронографи́ческий; **~ язмалар** хронографи́ческие запи́ски

хроно́лог *сущ.* хроно́лог (*составитель хронологии*)

хронологи́к *прил.* хронологи́ческий; **~ эзлеклелектә** в хронологи́ческой после́довательности; **~ таблица** хронологи́ческая табли́ца; **~ тикшеренүләр** хронологи́ческие иссле́дования

хронология *сущ.* **1.** хронология (*последовательность исторических событий во времени*) **2.** хронология (*вспомогательная историческая дисциплина, устанавливающая даты исторических событий и документов*) || хронологи́ческий; *геологик ~* геологи́ческая хронология; **~ тәртибендә** в хронологи́ческом поря́дке

хроно́метр *сущ.* хроно́метр (*особо точные часы, применяющиеся в астрономии, геодезии, морском деле*); **~ кебек эшләү** рабо́тать как хроно́метр (*о машине, механизме*)

хронометраж *сущ.* хронометра́ж; *көннең ~ы* хронометра́ж трудово́го дня || хронометри́ческий (*о наблюдении*) □ **~ ясау** *см.* **хронометражлау**

хронометражлану *страд. от* **хронометражлау**; хронометри́роваться

хронометражлату *понуд. от* **хронометражлау**

хронометражлау *перех.* хронометри́ровать (*производственные процессы*)

хронометражчы *сущ.* хронометри́ст (*работник, занимающийся хронометражем*)

хрономе́трик *прил.* хронометри́ческий; *~ төгәллек* хронометри́ческая то́чность

хрусталь *сущ.* **1.** хруста́ль (*особый вид высококачественного стекла*) **2.** хруста́ль *собир.* (*изделия из хрусталя*) || хруста́льный; *см. тж.* **бәллүр**; *~ ваза* хруста́льная ва́за; *~ заводы* хруста́льный завод

худо́жество *сущ.* худо́жество || худо́жественный; *см. тж.* **сәнгатьчәлек**; *~ академиясе* Акаде́мия худо́жеств; *~ алымы* худо́жественный приём; *театрның ~ җитәкчесе* худо́жественный руководи́тель теа́тра

худо́жестволы *прил.* худо́жественный; *см. тж.* **сәнгатьле, сәнгатьчә**; *~ образ* худо́жественный о́браз; *~ сөйләм* худо́жественная речь; *~ гимнастика* худо́жественная гимна́стика

худо́жестволылык *сущ.* худо́жественность; *см. тж.* **сәнгатьлелек, сәнгатьчәлек**; *әсәрнең ~ көче* си́ла худо́жественности произведе́ния

худо́жник *сущ.* **1.** *см.* **рәссам 2.** 1) худо́жник (*тот, кто достиг высокого совершенства в искусстве*); *ул — классик язучы, зур ~* он — писа́тель-кла́ссик, большо́й худо́жник 2) худо́жник *перен.* (*тот, кто выполняет что-л. с большим мастерством*)

худо́жниклык *сущ.* заня́тие, профе́ссия худо́жника || худо́жнический, худо́жественный; *см. тж.* **рәссамчылык**; *~ка уку* учи́ться худо́жественному ремеслу́, учи́ться на худо́жника; *~ сәләте* худо́жественное дарова́ние; худо́жественные спосо́бности

хуҗа *сущ.* **1.** *в разн. знач.* хозя́ин, со́бственник, владе́лец, обладатель *книжн.*, содержа́тель *уст.* || хозя́йский; *йорт ~сы* хозя́ин до́ма; *уз язмышының ~сы* хозя́ин свое́й судьбы́; *эт ~сы* хозя́ин (владе́лец) соба́ки; *трактир ~сы* владе́лец, содержа́тель трактира, трактирщик; *~м сугыштан кайтмады* хозя́ин у меня́ (*т. е. муж*) не верну́лся с войны́; *~ кызы* хозя́йская до́чка **2.** *рел. разг. см.* **алла, ходай 3.** *книжн.* учёный наста́вник, мэтр (*обычно прибавляется к имени впереди и после*); *~ Әхмәт Ясәви* учёный наста́вник Ахме́д Ясави; *Ишмехәммәт ~* (наш) мэтр Ишмухаме́д ◻ **~ булу** *прям.*, *перен.* быть хозя́ином, владе́льцем; хозя́йничать, владе́ть; *мөлкәткә ~ булу* владе́ть иму́ществом; **~ хатын** хозя́йка (*квартирная*), владе́лица, обладательница *чего-л.*, жена́ хозя́ина

хуҗабикә *сущ. разг. см.* **хуҗа хатын**

хуҗала́рча *нареч.* по-хозя́йски, как хозя́ин || хозя́йский; *уз-үзен ~ тоту* вести́ себя́ по-хозя́йски || *прил.* хозя́йский; *эшкә ~ караш* хозя́йское отноше́ние к де́лу

хуҗалы|к *сущ.* *в разн. знач.* хозя́йство, эконо́мика || хозя́йственный; хозя́йственно-, хоз- *разг.*; *авыл ~гы* се́льское хозя́йство; *аерым ~к* единоли́чное хозя́йство; *балыкчылык ~гы* ры́бное хозя́йство; *завод ~гы* заводско́е хозя́йство; *йорт ~гы* дома́шнее хозя́йство; *планлы ~к* пла́новое хозя́йство; *социалистик ~к* социалисти́ческое хозя́йство; *ярдәмче шәхси ~к* ли́чное подсо́бное хозя́йство; *~к мәшәкатьләре* хло́поты по хозя́йству; *~к кирәк-яраклары* хозя́йственный инвента́рь, предме́ты дома́шнего обихо́да; *~к кирәк-яраклары булдыру* обзавести́сь хозя́йством; *илнең ~к тормышы* хозя́йственная жизнь страны́; *~к товарлары кибете* магази́н хозя́йственных това́ров; *~к юлы белән* хозя́йственным спо́собом; *~к аппараты* хозаппара́т; *~к договоры* хоздогово́р; *районның хуҗалык-икътисад хәле* хозя́йственно-экономи́ческое состоя́ние райо́на ◻ **~к алыш бару** *см.* **хуҗалык итү 1**; **~к елы** хозя́йственный год; *~к елына йомгак ясау* подвести́ ито́ги хозя́йственного го́да; **~к исәбе** хозя́йственный расчёт, хозрасчёт || хозрасчётный; **~к итү (сөрү) 1.** вести́ хозя́йство, хозя́йствовать || хозя́йствование **2.** *неодобр.* хозя́йничать, вести́ себя́ по-хозя́йски || хозя́йничанье

хуҗалыклы *прил.* **1.** име́ющий, насчи́тывающий определённое коли́чество хозя́йств; *өч йөз ~ авыл* село́, насчи́тывающее три́ста хозя́йств (дворо́в) **2.** *см.* **хуҗалыкчыл**

хуҗалыклылык *сущ.* хозя́йственность, уме́ние вести́ хозя́йство, домови́тость; *зур ~ күрсәтү* прояви́ть большу́ю хозя́йственность

хуҗалыксыз *прил.* *редко* бесхозя́йственный, не уме́ющий вести́ хозя́йство

хуҗалыкчыл *прил.* хозя́йственный, домови́тый (*о человеке*)

хуҗалыкчан *прил.* хозя́йственный; *җирдән ~ файдалану* хозя́йственное испо́льзование земли́; по́льзование землёй по-хозя́йски

хуҗалыкчы *сущ.* **1.** хозя́йственник (*руководящий работник в народном хозяйстве*) **2.** *разг.* хозя́йственник (*лицо, занимающееся хозяйственными делами какого-л. предприятия и т. п.*)

хуҗасыз *прил.* **1.** не име́ющей хозя́ина, владе́льца; забро́шенный (*дом*); бесхо́зный, бесхозя́йственный **2.** *перен.* име́ющий плохо́го, неради́вого хозя́ина; *~ йортта бәрәкәт юк* (*посл.*) в до́ме (у плохо́го хозя́ина) доста́тка не быва́ет

хуҗасызлык *сущ.* **1.** отсу́тствие хозя́ина **2.** бесхозя́йственность, беспоря́док в хозя́йстве

хулиган *сущ.* **1.** хулига́н, хулига́нка **2.** *мн.* **хулиганнар** *собир.* хулиганьё *разг.*

хулиганлану *неперех.* хулига́нить, занима́ться хулига́нством

хулиганлык *сущ.* хулига́нство || хулига́нский; *~ка каршы көрәш* борьба́ с хулига́нством; *~ гадәте* хулига́нская привы́чка ◻ **~ итү** хулига́нить, хулига́нствовать, занима́ться хулига́нством

хулиганнарча *нареч.* по-хулига́нски, хулига́нски; *үзүзен ~ тоту* вести́ себя́ по-хулига́нски || *прил.* хулига́нский; *~ кыланыш* хулига́нский посту́пок

ху́нта *сущ.* **1.** ху́нта (*название различного рода объединений, союзов, государственных органов в испаноязычных странах*) **2.** ху́нта (*военное правительство в некоторых странах Латинской Америки, пришедшее к власти в результате государственного переворота*)

хуп *предик.* **1.** *разг.* хорошо́, ла́дно, здо́рово; *вакытында эшне тапшыра алсаң, бик хуп* е́сли суме́ешь во́время сдать рабо́ту, о́чень хорошо́ **2.** *перен.* хорошо́, пра́вильно; *хуп сөйлисең* пра́вильно говори́шь ◻ **хуп күрү (табу)** *см.* **хуплау**

хуплан|у *страд. от* **хуплау**; одобря́ться, быть одо́бренным; *чәчү планы ~ды* план се́ва одо́брен

хуплату *понуд. от* **хуплау**

хупла|у *перех.* одобря́ть/одо́брить *что-л.*, выража́ть/вы́разить одобре́ние, относи́ться/отнести́сь *к чему-л.* одобри́тельно; *тәкъдимне ~у* одо́брить предложе́ние ◻ **~п кую** одо́брить; **~п тору** одобря́ть

хупсынм|ау *неперех. диал.* относи́ться/отнести́сь неодобри́тельно *к чему-л.*, не одобря́ть/одо́брить *что-л.*

хур *сущ. см.* **хурия** ◻ **хур кызы 1.** *см.* **хурия 2.** *перен.* краса́вица; **хур кызы кебек** пи́саная краса́вица; краси́вая, как гу́рия

хур: хур булу опозо́риться, осрами́ться, оскандали́ться; сади́ться в лу́жу (в кало́шу) *прост.*; **хур ителү** 1. быть обесчещенным (посрамлённым, уни́женным, оскорблённым) 2. быть поруганным; **хур итү** 1. *см.* **хурлау**; *кешене хур итмә, үзеңне зурлама* (*посл.*) люде́й не унижа́й, себя́ не возвыша́й 2. наси́ловать, изнаси́ловать || изнаси́лование

хурал *сущ.* хура́л (*наименование органов государственной власти в МНР*); *Бөек халык ~ы* Вели́кий наро́дный хура́л

хурия *сущ. миф.* гу́рия (*в мусульманской мифологии: райская красавица, услаждающая попавших в рай праведников*)

хури *сущ. см.* **хурия**

хурландыр|у *перех.* 1. стыди́ть, пристыди́ть *кого-л.* 2. вызыва́ть/вы́звать чу́вство стыда́ *в ком-л.* □ **~а торган** посты́дный, зазо́рный, унизи́тельный; *см.* **хурлыклы**

хурлан|у 1. *возвр.-страд. от* **хурлау** 2. *возвр.* стыди́ться, устыди́ться *чего-л.*; испы́тывать/испыта́ть стыд, конфу́зиться, оконфу́зиться, сконфу́зиться, осрами́ться; *үз сүзләреннән ~у* стыди́ться свои́х слов 3. оскорбля́ться/оскорби́ться, обижа́ться/оби́деться; счита́ть для себя́ унизи́тельным (зазо́рным), сде́лать *что-л.*; *ул каравылчы булуыннан ~мый* он не счита́ет для себя́ зазо́рным быть сто́рожем 4. *страд.* быть оскорблённым, посрамлённым, поруганным, обесчещенным, уни́женным, оха́янным *кем-л.*; *дошман тарафыннан ~ган җир* поруганная врагом земля́ ◊ **~ып үлә язу** смерте́льно оби́деться, оскорби́ться до кра́йней сте́пени

хурлату *понуд. от* **хурлау**

хурла|у *перех.* 1. оскобля́ть/оскорби́ть, унижа́ть/уни́зить *кого-л.*; позо́рить, опозо́рить, бесче́стить, обесче́стить, срами́ть, осрами́ть *кого-л.*; высме́ивать/вы́смеять *кого-л.*; издева́ться *над кем-л.* || оскорбле́ние, ущемле́ние, высме́ивание *кого-л.*; *дустын ~у* оскорби́ть дру́га 2. хули́ть, брани́ть (незаслу́женно); поро́чить/опоро́чить, черни́ть, очерни́ть, очерня́ть/очерни́ть *кого-л.*, наговáривать/наговори́ть *на кого-л.*, поноси́ть, чести́ть, оха́ивать, ха́ять, оговáривать/оговори́ть *кого-л.* || поноше́ние, хуле́ние, хула́, оха́ивание, очерне́ние; *иптәшләрен ~у* оха́ивать (хули́ть, черни́ть) това́рищей □ **~п көлү** насмеха́ться *над кем-л.*, высме́ивать *кого-л.*; **~п ташлау** осыпа́ть оскорбле́ниями; **~у сүзләре** хула́

хурлаучы *сущ.* оскорби́тель, унизи́тель, очерни́тель, хули́тель, поноси́тель; *яңа тәртипне ~лар* очерни́тели (хули́тели) но́вого поря́дка

хурлаш|у 1. *взаимно-совм. от* **хурлау** 2. *диал.* со́риться, брани́ться, гры́зться || со́ра, брань, перебра́нка, грызня́; *урлаша белгән ~а да белә* (*посл.*) кто уме́ет вора́ть, тот и брани́ться гора́зд

чакыргала́у *многокр. от* **чакыру** звать, приглаша́ть (*время от времени, изредка*)

чакыргыч *прил.* вызывно́й, позывно́й; ~ *аппарат физ.* вызывно́й аппара́т; ~ *сигнал* позывно́й сигна́л, позывны́е

чакырту *перех.* звать, позва́ть, вызыва́ть/вы́звать (*письмом, телеграммой, через кого-л.*); выпи́сывать/вы́писать; *шәһәргә гаиләсен ~* вы́звать семью́ в го́род

чакыртылу *страд. от* **чакырту**

чакыр|у *перех.* 1. звать/позва́ть, вызыва́ть/вы́звать ‖ 1) вы́зов, зов, клик 2) позывно́й; *өйгә врач ~у* вы́звать врача́ на́ дом; *куршене ярдәмгә ~у* позва́ть сосе́да на по́мощь □ **~у сигналы** позывно́й (вызывно́й) сигна́л 2. приглаша́ть/пригласи́ть, созыва́ть/созва́ть ‖ 1) приглаше́ние, созы́в 2) пригласи́тельный; *кунакка ~у* пригласи́ть в го́сти; *~ билеты* пригласи́тельный биле́т 3. призыва́ть/призва́ть ‖ 1) призы́в 2) призывно́й; *тәртипкә ~у* призва́ть к поря́дку; *уяулыкка ~у* призва́ть к бди́тельности; *тынычлыкны яклаучылар комитеты ~уы буенча* по призы́ву комите́та защи́ты ми́ра; **~ып алу (китеру)** 1. позва́ть, вызыва́ть/вы́звать, подзыва́ть/подозва́ть 2. отзыва́ть/отозва́ть

чакырулы *прил.* зва́ный; ~ *кунак* зва́ный гость; *мин рәис янына ~* я зван к председа́телю

чакырылу *страд. от* **чакыру** 1. вызыва́ться 2. приглаша́ться, созыва́ться 3. призыва́ться (*в армию*) 4. *в знач. прил.* **чакыртылган** зва́ный, зва́нный, приглашённый; ~ *кунаклар килеп җитте* зва́ные го́сти (все) при́были, пришли́

чакырылыш *сущ.* 1. созы́в; *Югары Советның беренче ~ сессиясе* се́ссия Верхо́вного Сове́та пе́рвого созы́ва 2. призы́в (*в армию*)

чакырышу *взаимно-совм. от* **чакыру** звать, приглаша́ть друг дру́га; *кунакка ~* приглаша́ть друг дру́га в го́сти

ча́кы-чокы *подр. см.* **чык-чык**

чал *прил.* 1. седо́й, с про́седью; *чал баш* седа́я голова́; *чал чәч* седо́й во́лос; *чал чәчле* седовла́сый; с седы́ми волоса́ми; *чал сакал* седа́я борода́; *чал сакаллы* седоборо́дый; с седо́й бородо́й 2. *перен. поэт.* седо́й (дре́вний); *чал Урал* седо́й Ура́л; *чал тарих* седа́я старина́ (исто́рия) 3. ча́лый, серова́то-бе́лый, беле́сый (*о масти лошади*); ~ *ат* ча́лая ло́шадь ‖ *сущ.* седина́, про́седь; серебро́, и́ней (*перен. поэт*); *чал кергән чәч* во́лосы с про́седью; *чал кергән баш* голова́ с про́седью; *сакалында чал күренә* в бороде́ прогля́дывает седина́ □ **чал керү (төшү)** седе́ть/поседе́ть; *см. тж.* **чаллану**

чала *диал.* 1. *см.* **аралаш**; *болыт ала булса яңгыр ~ була* (*погов.*) коль облака́ пе́гие, то дождь перемéнчивый 2. *см.* **чәлә**

чалак *прил.* бы́стрый; норови́стый (*о лошади; тж. о людях*)

чаларт|у *понуд. от* **чалару**; *см. тж.* **агарту**

чалбар *сущ.* 1. брю́ки ‖ брю́чный; ~ *каешы* брю́чный реме́нь 2. шарова́ры, штаны́ *разг.* □ **~ балагы** штани́на; **~ төбе** мотня́

чалбарлы *прил.* 1. брю́чный; **~ костюм** брю́чный костю́м 2. в брю́ках; **~ кыз** де́вушка в брю́ках □ **~ әтәч (тавык)** *см.* **балаклы әтәч (тавык)**

чалбарлык *прил.* брю́чный; ~ *тукыма* брю́чная ткань; ~ *материал* брю́чный материа́л ‖ *сущ.* ткань, материа́л (*предназначенный*) для брюк; ~ *сатып алу* купи́ть материа́л на брю́ки

чалгы I *сущ.* коса́; ~ *алымы* прико́с; ~ *бөгәрҗесе* (*тоткасы*) рукоя́тка (*поперечная ручка*) на косови́це; ~ *кайрагы* оселко́вый брусо́к для пра́вки косы́; ~ *калагы* брусо́к для пра́вки косы́ (*деревянная лопатка с песком на смоле*); ~ *корычы* сталь (для) косы́; ~ *очы* носо́к косы́; ~ *пычак* (*пычагы*), ~ *пәке* (*пәкесе*) нож, но́жик (*сделанный*) из ле́звия косы́; ~ *сабы* косови́ще, око́сье; ~ *селтәме см.* **чалгы алымы**; ~ *сырты см.* **чалгы тұтәсе**; ~ *таптау* отбива́ть косу́; ~ *тұтәсе* о́бух косы́; ~ *чабу* коси́ть се́но; ~ *чүкече* молото́к для отбива́ния косы́ ◊ **~ ташка бәрелде, ~ очы җиргә кадалды** нашла́ коса́ на ка́мень

чалгы II *сущ. ист.* стру́нный музыка́льный инструме́нт; ~ *чалу* игра́ть на стру́нном инструме́нте

чалгый *сущ. см.* **чылгый**

чалгыч I *сущ. бот.* гуля́вник, гуля́вник Лезе́ля, гуля́вник высо́кий, гуля́вник во́лжский

чалгыч II: **чалгыч пычак** нож для забо́я (зака́лывания) скота́

чалгычы *сущ. разг.* коса́рь, косе́ц; *см. тж.* **печәнче**

чалдыра́у *неперех. см.* **чылтыра́у**

чалдыр|у 1. *понуд. от* **чалу** I 2. *перех.* захва́тывать/захвати́ть, охва́тывать/охвати́ть (*серпом при жатве хлебов*); *зур ~ып уру* жать с больши́ми захва́тами

чалдыр-чолдыр *подр. позвякиванию монет, стекла*; *см. тж.* **чылтыр-чылтыр**

ча́лка *сущ. спец.* ча́лка (*причальная цепь*)

чалкан *нареч.* на́взничь, на спи́ну (на спине́), лицо́м вверх; ~ *йөзү* пла́вать на спине́; ~ *яту* лежа́ть на спине́ (на́взничь); ~ *әйләндерү* перевора́чивать на́ спину □ **~ барып (килеп, әйләнеп) төшү** опроки́нуться, шлёпнуться, плю́хнуться, ре́зко упа́сть на́ спину; ~ **егылу (төшү)** упа́сть на́взничь; ~ **салу** 1. повали́ть (положи́ть) на́ спину 2. *перен.* класть (положи́ть) на (о́бе) лопа́тки

чалкаю *неперех.* отки́дываться/отки́нуться наза́д

чаллану *неперех. редко см.* **чал керү**

чалма *сущ.* чалма́, тюрба́н (*головной убор из ткани, который обёртывается вокруг головы*); ~ *чалу* (*урау*) надева́ть (*букв.* намота́ть) чалму́; ~ *чәчәк бот. см.* **чалмабаш**

чалмабаш *сущ. бот.* пио́н

чалмалану *неперех. редко* принима́ть вид чалмы́ (*о бутонах цветов*)

чалмалы *прил.* с чалмо́й, в чалме́, в тюрба́не; ~ *кеше* челове́к в чалме́, с чалмо́й; *бохари ~ хәзрәт* священнослужи́тель в буха́рской чалме́; ~ *башын түбән игән*

көенчә ни́зко склони́в го́лову в чалме́ □ ~ **баш** 1. *пренебр.* духо́вное лицо́, служи́тель религио́зного ку́льта, мулла́ 2. *разг.* одува́нчик по́здний (*отцветший цветок одуванчика с пушистыми семенами*) 3. *перен.* о ви́нной буты́лке, запеча́танной бе́лым сургучо́м; ~ **песнәк** *зоол.* вид сини́цы с хохолко́м; ~ **чәчәк** *бот. см.* **чалма чәчәк** ◊ ~ **карак** прожжённый вор, ло́вкий мошéнник (*букв.* вор в чалме́)

чалма-чапан *сущ. собир.* оде́жда, состоя́щая из чалмы́ и чапа́на (*у служителей мусульманской религии*); *чалма-чапаннан намазга йөрү* ходи́ть на моли́тву (богослуже́ние) в чалме́ и чапа́не

чалма-чапанлы *прил.* оде́тый в чалму́ и чапа́н, в чалме́ и чапа́не

чалмаштыру *перех. разг. см.* **чалыштыру**; *аякларын ~ып утыру* сесть, скрести́в но́ги

чалмаш|у *диал. перех.* скрести́ться, спу́тываться, пу́таться, перепу́таться, переплести́сь; *см. тж.* **чуалу**; *юлчылар арган, аяклары ~а* пу́тники уста́ли, но́ги переплета́ются

чалпаю *неперех. диал.* 1. потучне́ть, попра́виться, стать полне́е; *см. тж.* **җалпаю, ялпаю** 1, **көрәю** 2. накрени́ться на оди́н бок, скособо́читься; *см. тж.* **янтаю, авышу, кыегаю**

чалпу: чалпу салдыру (салу) *уст.* вид заклина́ния, загова́ривания, колдовства́ (*заговаривание места, где человек упал и ушибся, или закапывание в это место заговорённой, молитвенной записки*)

чалт I *подр. внезапной пощёчине, удару* бац, шлёп; ~ *яңагына* шлёп — по щеке́; ~ *итү* (*иттерү*) уда́рить; шлёпнуть, влепи́ть пощёчину

чалт II: **чалт аяз** соверше́нно чи́стый, безо́блачный, я́сный, со́лнечный; *көн чалт аяз* день соверше́нно я́сный (со́лнечный); *төннәре чалт аяз* но́чи соверше́нно све́тлые

чалт-чалт *подр. см.* **чалт-чолт**

чалт-чолт *подр. быстрому передвижению костяшек на счетах и т. п.*

чалтыр *подр. звону* (*треску*) *разбивающегося стекла*; ~ *итеп тәрәзә ватылды* со зво́ном (с тре́ском) разби́лось стекло́ (окно́)

чалтырат|у 1. *перех.* бренча́ть, зва́кать/зва́кнуть; *амбар ишеген ачкычлар ~ып бикләү* запере́ть, позва́кивая ключа́ми, амба́рную дверь 2. *перен. разг.* шлёпнуть, хло́пнуть, зво́нко уда́рить, дать пощёчину, влепи́ть (отве́сить) зво́нкую оплеу́ху; *яңагына ~у* дать пощёчину

чалтыр|ау *неперех. см. тж.* **чылтырау** 1. бренча́ть || бренча́ние; *чылбыр ~авы* бренча́ние цепи́ 2. зва́кать/зва́кнуть || зва́канье (*о стеклянной, фарфоровой посуде*); *чынаяклар ~ый башлады* зазва́кали ча́шки 3. *тау чишмәсе ~ап ага* го́рный родни́к течёт с журча́нием

чалтыр-чолтыр *подр.* 1. *звону стекла* 2. *см.* **шалтор-шолтыр**

чалу I *перех.* ре́зать, заре́зать, бить, забива́ть; коло́ть, зака́лывать/заколо́ть || забива́ние, зака́лывание, уби́й; *см. тж.* **сую** 1; *сарык ~* заре́зать овцу́ □ ~ **сөяге** узело́к хряща́ дыха́тельного го́рла; *см. тж.* **бугаз төене, калкан**

чалу II: **аяк чалу** ста́вить подно́жку, подста́вить но́гу || подно́жка □ **~ып егу** 1. повали́ть, подста́вив но́гу, повали́ть подно́жкой 2. *перен.* меша́ть *чему-н.*; тормози́ть де́ло

чал|у III *перех.* захлёстывать/захлестну́ть || захлёстывание; *элмәк ~у* сде́лать (намета́ть) пе́тлю, захлёстывая ни́ткой □ **~ып бәйләү** 1. вяза́ть, наки́дывая ни́тку на спи́цу 2. свя́зывать захлёстом; **~ып тегү** шить через край, заде́лывая срез; **~ып чигү** вышива́ть пе́тельным швом; **чалма ~у** нама́тывать || нама́тывание чалмы́ (*захлёстывая концы на специальную шапку*); носи́ть чалму́

чалу IV *перех. уст.* игра́ть на музыка́льных инструме́нтах; *курай ~* выводи́ть мело́дию на кура́е; **играть** на кура́е; *см. тж.* **уйнау** I

чалу V *сущ.* ухаб, раска́т, я́ма на зи́мней (са́нной) доро́ге; *см. тж.* **салу**

чалу VI *сущ. диал. см.* **чалулык**

чалулату *понуд. от* **чалулау**

чалулау *неперех.* вихля́ть, съезжа́ть с доро́ги на раска́тах (*о санях*); *см. тж.* **салулау**

чалулы *прил.* раска́тистый, с раска́том (*о дороге*)

чалулык *сущ. см.* **чабулык**

чалчык *прил. диал. см.* **сазламыклы**

чалшайту *перех. разг. см.* **чалышайту**; *ишек үкчәсен ~* перекоси́ть поро́г

чалша|ю *неперех. разг. см.* **чалышаю**; *бабайның авызы ~йган* у де́да переко́шен рот; де́ду перекоси́ло рот

чалым *сущ.* ли́нии, очерта́ния, черты́ лица́, при́знаки схо́дства в о́блике; осо́бенности; *баланың йөзендә әбисе ~нары сизелә* на лице́ ребёнка уга́дываются при́знаки схо́дства с ба́бушкой

чалын|у I 1. попада́ться/попа́сться (*под ноги, на глаза*); каса́ться/коснýться (*слуха*); *аякка ~у* попада́ться по́д ноги; *күзгә ~у* попа́сться на глаза́; *кемнеңдер пышылдаганы колакка ~ды* че́й-то шёпот коснýлся слýха 2. спотыка́ться/споткнýться, оказа́ться спу́танным (*верёвкой, путами и т. п.*), спу́таться, запу́таться; *~ып егылу* упа́сть, споткнýвшись (*обо что-то*), запу́тавшись (*в чём-то*)

чалыну II *страд. от* **чалу** I быть заре́занным; *корбанга ~* быть заре́занным для жертвоприноше́ния

чалыш *прил.* криво́й, косо́й; *см. тж.* **кыек, кылый, авыш**; *~ авыз* криво́й рот, косо́й рот; *~ аяклы* кривоно́гий, с криви́ми нога́ми; *~ муен* крива́я ше́я; *~ муенлы* кривоше́ий; *~ күз* косо́й глаз, косы́е глаза́; *~ күзле* косогла́зый, *авызың ~ булса көзгегә үпкәләмә* (*погов.*) не пеня́й на зе́ркало, ко́ли ро́жа крива́ || *нареч.* ко́со, кри́во, вкось, вкривь; *~ атлау* шага́ть ко́со; *~ карау* смотре́ть ко́со; *~ ясау* де́лать (стро́ить) ко́со, кри́во; *~ кисү* крои́ть ко́со, кри́во □ **~ аяк** 1. *диал.* подста́вка (но́жка) ворóба, крестови́на 2. размёт (*у лошадей*) 3. *перен.* медве́дь; ~ **килү** не ла́диться; вы́йти бо́ком, пойти́ вкривь и вкось; ~ **көзге** криво́е зе́ркало

чалышайту *перех.* коси́ть, скоси́ть, перека́шивать/перекоси́ть; крини́ть, искривля́ть/искриви́ть; *см. тж.* **кыегайту**; *авызын ~* криви́ть рот; *итек үкчәләрен ~* стопта́ть каблуки́ сапо́г

чалыша|ю *неперех.* коси́ться, криви́ться, искривля́ться/искриви́ться, перека́шиваться/перекоси́ться; покоси́ться, скоси́ться; *см. тж.* **кыегаю, кыеклану** || переко́с, искривле́ние; *тубәсе ~ю* переко́с кры́ши □ **~еп бетү** перекоси́ться, скоси́ться, искриви́ться (*совсем*); **~еп китү** покоси́ться, искриви́ться (*неожиданно, вдруг*)

чалышландыру *перех. см.* **чалышайту**

чалышлану *перех. см.* **чалышаю**

чалышлы|к *сущ.* 1. переко́с, искривле́ние; *см. тж.* **кәкрелек, авышлык** 2. переко́шенность, искривлённость, накло́нность; *утын әрдәнәсенең ~гын төзәтү* исправля́ть накло́нность дровяно́го шта́беля

чалышма *прил. мат.* перекре́щивающийся, скре́щивающийся; ~ **турылар** скре́щивающиеся прямы́е

чалыштыр|у *перех.* де́лать крест-на́крест; перекре́щивать *что-л.; аякларны ~ып утыру* сиде́ть, скрести́в но́ги; *~ып бәйләү* перевяза́ть захле́стом (перекрести́в) □ **~ып чәчү** *с.-х.* се́ять перекрёстным спо́собом

чалышу I *взаимно-совм. от* **чалу** I

чалышу II *неперех. см.* **чалыну** I

чалыш-чолыш *прил.* крибо́й, искривлённый || *нареч.* кри́во, ко́со, вкривь и вкось

чалышыну *неперех.* перехлёстываться

чама *сущ.* 1. предположе́ние, подсчёт, прики́дка, дога́дка; ~ *~га туры килми* раз на раз не прихо́дится (*букв.* предположе́ние не соответствует действи́тельности); ~ *~дан ерак китмәде* предположе́ние почти́ совпа́ло с действи́тельностью 2. *прям., перен.* возмо́жность; *туй уздырырга быел ~быз килми* в э́том году́ у нас нет возмо́жности сыгра́ть сва́дьбу; *саклап тотсак, кышка җитәрлек ~быз бар* е́сли эконо́мно расхо́довать, на́ших возмо́жностей хва́тит на всю зи́му; *тузәрлек ~ калмады* нет возмо́жности до́льше терпе́ть; *уз ~ыңы үзең бел* знай свои́ возмо́жности; *уз ~ыңы үзып китмә* не переоце́нивай свои́ возмо́жности 3. *разг.* величина́, коли́чество, объём, разме́р; *иген уңышының ~сын белү* определи́ть коли́чество (объём) урожа́я хле́ба 4. состоя́ние, положе́ние; *атымның ~сын беләм* состоя́ние своего́ коня́ зна́ю; *эшнең ~сы* положе́ние дел; *кешенең хәлен, ~сын белеп эш йөкләргә кирәк* на́до поруча́ть де́ло, снача́ла узна́в состоя́ние, спосо́бность челове́ка 5. наме́рение, за́мысел, план, соображе́ние; *бирешер ~сы юк, бирешергә ~сы юк* у него́ нет наме́рения сдава́ться; *эшләр ~сы юк* у него́ нет наме́рения рабо́тать; *дошманның ~сын сизү* угада́ть за́мысел (наме́рение) проти́вника 6. *в знач. послелога* **чама(лар)да, чама(лар)дагы** приме́рно, приблизи́тельно; *ул яшь ягыннан безнең чамаларда* он приблизи́тельно на́шего во́зраста ◊ **~ белән (генә)** (то́лько) предположи́тельно, приме́рно, приблизи́тельно; ~ **тойгысы** чу́вство ме́ры; **~га сыймау** не совпада́ть с предположе́нием; **~дан артык, ~дан тыш** сверх ме́ры, чрезме́рно, чересчу́р; сли́шком; *~дан тыш ару* сли́шком (чересчу́р, чрезме́рно) устава́ть; **~дан (~сыннан) узмау** не переходи́ть грани́цы (предположе́ния)

чамалану *страд. от* **чамала́у** быть рассчи́танным

чамала́|у *перех.* 1. предложи́ть, предлага́ть || предположе́ние; *эш алар ~ганча булып чыкмады* де́ло оберну́лось не так, как они́ предполага́ли; *~у җитми, төгәл белергә кирәк* одного́ то́лько предположе́ния недоста́точно, ну́жно то́чно знать 2. прики́дывать/прики́нуть || прики́дывание, прики́дка; *амбардагы ашлыкның үлчәвен ~у* прики́нуть ме́ру зерна́ в амба́ре; *булачак чыгымнарның күләмен ~у* прики́нуть объём бу́дущих расхо́дов 3. рассчи́тывать || расчёт; *төшкә кайтып җитәргә ~у* рассчи́тывать возврати́ться к обе́ду; *авылда нигезләнергә ~у* рассчи́тывать обоснова́ться в дере́вне; *аның китәргә ~вы барып чыкмады* его́ расчёт на отъе́зд не оправда́лся 4. дога́дываться/догада́ться; *чакырылуның сәбәбен ~у* догада́ться о причи́не вы́зова 5. намерева́ться, вознаме́риться *уст.*; (*что-л. делать*); *эштән китәргә ~у* намерева́ться уйти́ с рабо́ты 6. определя́ть/определи́ть (приблизи́тельно); *йөкнең авырлыгын ~у* определи́ть (приблизи́тельно) вес (тя́жесть); *туфракның дымын ~у* определи́ть вла́жность по́чвы 7. про́бовать, попро́бовать, пыта́ться, попыта́ться; *көлергә ~у* про́бовать смея́ться; *булышырга ~у* пыта́ться помо́чь 8. гото́виться, собира́ться, ду́мать, поду́мывать; *шелтәләргә ~у* собира́ться (ду́мать) пожури́ть; *гәзиткә язарга ~у* ду́мать писа́ть в газе́ту 9. *в знач. нареч.* **чамалап** с осторо́жностью, осторо́жно; соблюда́я ме́ру, с огля́дкой; *~п сөйләү* говори́ть осторо́жно; *~п ашау* есть в ме́ру □ **~п алу** бы́стро (мгнове́нно) прики́нуть, догада́ться; **~п булу** мо́жно догада́ться, предполага́ть/предположи́ть; **~п йөрү** 1. быть осторо́жным 2. *перен.* карау́лить, сторожи́ть; подкарау́ливать, наблюда́ть; **~п карау** про́бовать; попыта́ться, прики́дывать; *аңлатырга ~п карау* про́бовать объясни́ть; **~п кую** наме́тить, приме́тить; определи́ть; **~п тору** 1. гото́виться, намерева́ться; собира́ться *что-то делать* 2. похо́же, быть ...; чу́вствуется, бу́дет ...; *яңгыр яварга ~п тора* похо́же, быть дождю́; чу́вствуется, бу́дет дождь 3. *перен.* наблюда́ть, подстерега́ть, карау́лить, сторожи́ть, поджида́ть; **~брак тору** поду́мывать, рассчи́тывать, намерева́ться; *см. тж.* **чамалап тору**

чамалы *нареч.* 1. уме́ренно, в ме́ру; *акчаны ~ тоту* расхо́довать де́ньги уме́ренно 2. *в знач. послелога см.* **чамасы** 2 || *прил.* ограни́ченный, уме́ренный; относи́тельный; *аның белеме ~* его́ зна́ния ограни́чены; *багажы ~* бага́ж его́ уме́ренный (невели́к)

чаман *прил. уст. см.* **ялка́у, үшән**; *ат ~ына менгәнче ике табаныңа ялын* (*погов.*) чем е́хать верхо́м на лени́вом коне́, лу́чше идти́ на свои́х двои́х

чамасы *послелог* 1. о́коло, приблизи́тельно, приме́рно; *ср. тж.* **тирәсе**; *вакыт сәгать икеләр ~* вре́мя о́коло двух часо́в; *ун кило ~* о́коло десяти́ килогра́ммов 2. приблизи́тельно (приме́рно) *с кого-чего*; *буйга минем ~* ро́стом приме́рно с меня́; *бер чакрым ~* приблизи́тельно с версту́ 3. *вводн. сл.* ка́жется, похо́же; наве́рно, наве́рное, по-ви́димому, очеви́дно; *хәтерең начарланган ~* ка́жется, па́мять твоя́ ухуди́лась; (*көн*) *суытыр ~* похо́же, (день) похолода́ет

чамасыз *прил.* безграни́чный, безме́рный, чрезме́рный, непоме́рный, неограни́ченный; ~ *шатлык* (*хәсрәт, газап, ләззәт, ачу h. б.*) безграни́чная ра́дость (го́ре, муче́ние, наслажде́ние, гнев и т. п.) □ **~ тоткарлану** *бот.* торможе́ние запреде́льное || *нареч.* безграни́чно, чрезме́рно, непоме́рно; о́чень си́льно, без ме́ры; ~ *шатлану* (*борчылу, ярату*) чрезме́рно ра́доваться (беспоко́иться, люби́ть); ~ *бурычка керү* чересчу́р задолжа́ть; ~ *арту* безме́рно увели́чиваться; ~ *сызлану* си́льно страда́ть; ~ *баю* чрезме́рно обогаща́ться; ~ *күп* о́чень мно́го

чамасында(гы) *послелог, нареч.* приблизи́тельно, приме́рно; *ярты потлар ~гы балык* ры́ба приблизи́тельно с полпу́да (ве́сом); *утыз яшь чамасында(гы) кеше* челове́к приме́рно тридцати́ лет

чамбыр *сущ. диал. см.* **чабыр**

чан *сущ.* чан; *см. тж.* **шан**; *тире җебетә торган чан* чан для моче́ния шкур

чана *сущ.* са́ни, са́нки || са́нный; ~ *тәртәсе* огло́бля сане́й; *~га җигелгән ат* ло́шадь, запряжённая в са́ни; ~ *үрәчәсе* гря́дка сане́й; ~ *эзе* са́нный след; ~ *шуу* ката́ться на са́нках; *беренче ~ юлы* са́нный первопу́ток; *кем ~сына утырсаң, шуның җырын җырларсың* в чьи са́ни ся́дешь — того́ и пе́сню запя́нешь □ **~ бавы** гуж сане́й; ~ **карамасы** свя́зка сане́й; ~ **сөяге** *зоол.* ду́жка (ви́лка, грудна́я кость) у птиц; *см. тж.* **ядәч**; ~ **табанлау** посади́ть са́ни на поло́зья; ~ **табаны** по́лоз; ~ **теше (тырнагы)** копы́л; ~ **юлы** са́нный путь

чанача *сущ. диал.* 1. са́нки 2. *см.* **ядәч**

чандыр *прил.* сухощáвый, сухопáрый, худощáвый, худóй, жúлистый, поджáрый; *см. тж.* **какча** □ **~ гәудәле** худощáвый, сухощáвый; **~ тәнле** сухотéлый

чандырлану *неперех.* становúться/стать худощáвым; худéть, похудéть; *см. тж.* **ябыгу**

чандырлык *сущ.* худобá, худощáвость, сухощáвость; *см. тж.* **ябыклык**

чаң I *сущ.* **1.** кóлокол || колокóльный; *чиркәү ~ы* кóлокол цéркви; *чаң тавышы* колокóльный звон; *чаң кагу (сугу)* звонúть в кóлокол **2.** *разг.* звон, набáт □ **чаң кагучы** звонáрь ◊ **чаң сугу (кагу)** бить в набáт

чаң II *сущ. диал.* пыль (*поднятая в воздух*); пылевáя бýря; *чаң эчендә* в пылú

чаңгы *сущ.* лы́жи || лы́жный; *~ таяклары* лы́жные пáлки; *~ походы* лы́жный похóд; *аучы ~сы* охóтничьи лы́жи; *сыңар ~* однá лы́жа; лы́жина; *самолёт ~сы* самолётные лы́жи; *~да йөрү* ходúть на лы́жах; *~ кию* надевáть лы́жи; *~ табаны* полóзья лыж; *~ эзе салу* прокладывать лыжнú □ **су ~сы** вóдные лы́жи

чаңгылдату *перех. см.* **чыңгылдату**

чаңгылдáу *неперех. см.* **чыңгылдау**

чаңгыл-чоңгыл *подр. звукам удара металлом о металл (о буферах между вагонами); см. тж.* **чаң-чаң**

чаңгырáу *неперех. см.* **чыңлáу**

чаңгычы *сущ.* лы́жник, лы́жница; *~лар ярышы* соревновáние лы́жников

чаңнáу *уст. неперех.* испы́тывать жáжду

чаң-чаң *подр. звукам удара металлом, камнем и т. п. по металлу (когда точат косы, звонят в колокол и т. п.)*

чаң-чоң, чаң-чың *подр. см.* **чаң-чаң**

ча|п I *сущ. уст.* извéстность, слáва; *см. тж.* **дан**; *ераста — чап, якында — чап чак (погов.)* вдалú (издалекá) — хорóший, вблизú — плохóй; *яхшы кызның чабы китәр, начарның яманаты китәр* хорóшая дéвушка прослáвится, плохáя ослáвится

чап II *подр. звуку удара плоским предметом (по воде, по щеке)*; шлёп □ **чап итү** звóнко шлёпнуть, хлестнýть; *яңакка чап итеп сугу* дать звóнкую пощёчину, оплеýху; **чап-чап итү** шлёпать по водé (*ребёнок руками при купании*)

чапак *прил. диал.* остроýмный, способный; *см. тж.* **оста, тапкыр**

чапалак *сущ. разг.* **1.** пощёчина, оплеýха; *~ бирү* дать пощёчину **2.** самодéльная хлопýшка для мух; *см. тж.* **шапалак 3.** *перен.* удáр, потрясéние, несчáстье

чапалану *неперех. диал. см.* **чәбәләнү**

чапан *сущ.* чапáн (*верхняя одежда в виде халата*); *сырган ~* стёганый чапáн; *ефәк ~* шёлковый чапáн

чапанлы *прил.* одéтый в чапáн

чапанлык *прил.* достáточный на чапáн, предназнáченный для чапáна (*шёлк*) || *сущ.* ткань, материáл на халáт

чапан-чалма *сущ. собир.* чапáн и чалмá (*в знач.* одéжда для соблюдéния мусульмáнского кýльта)

чапкалáу I *многокр. от* **чабу** I

чапкалáу II *перех. многокр. от* **чабу II**

чапкалáу III *перех. многокр. от* **чабу III** бéгать тудá-сюдá

чапкы I *сущ.* тя́пка, сéчка (*для рубки капусты и т. п.*)

чапкы II *сущ. диал.* пощёчина; *~ бирү* дать пощёчину, *~ чапаның кидерү* дать пощёчину, удáрить по щекé

чапкы III *сущ. уст.* **1.** назвáние болéзни, при котóрой я́кобы нýжно дать человéку неожúданную оплеýху, чтóбы болéзнь прошлá **2.** *диал.* пощёчина; *ана балага: «тагын ~ кирәкме, сүз тыңламасаң бирәм»* мать ребёнку: «пощёчину захотéл, éсли не бýдешь слýшаться — полýчишь»

чапкылáу *перех.* рубúть тя́пкой || рýбка (*капусты, моркови и т. п.*)

чапкын I *сущ.* **1.** гонéц, нáрочный, кóнный, посы́льный со спéшным поручéнием; курьéр; *~ җибәрү* послáть нáрочного **2.** *разг.* скакýн

чапкын II *прил.* **1.** беговóй (*о лошади*); *~ ат* беговáя лóшадь, рéзвый конь **2.** *диал.* провóрный, пры́ткий, бы́стрый; *~ малай* провóрный мáльчик

чапкынлану *неперех. диал.* становúться/стать провóрным, пры́тким

чапкынлык *сущ. диал.* провóрность, пры́ткость

чапкыр *диал.* **1.** пры́ткий, беговóй, рéзвый; *~ атларга атланган сугышчылар* вóины на рéзвых конях **2.** *перен.* быстротéчный (*о времени, жизни и т. п.*); *~ тормыш артыннан җитеп булмый* за быстротéчной жúзнью не угнáться

чапкыч *сущ.* **1.** *см.* **чапкы 2.** косúлка, сенокосúлка; *печән ~* сенокосúлка

чаплы *прил.* **1.** *диал. см.* **ятышлы** подходя́щий; *үзенә чаплы тун* шýба ей к лицý (по ней) **2.** *уст.* слáвный, знамени́тый, прослáвленный

чапрак *сущ.* чепрáк (*суконная или ковровая подстилка под седло*); *см.* **чүпрәк-чапрак**

чапракчы *сущ.* чепрáчник

чапрыш *нареч.* **1.** нáискось, наискосóк; *~ кую* постáвить наискосóк **2.** кóсо, неровно, *~ атлау* шагáть неровно || *прил. диал.* косóй; *~ аяк* косолáпый

чаптар I *прил.* **1.** игрéневый; *~ ат* игрéневой мáсти (*лошадь*) **2.** *разг.* лóшадь такóй мáсти

чаптар II *сущ. бот.* быстря́к

чаптырдату *перех.* **1.** *см.* **пычтырдату 2.** хлю́пать; *см. тж.* **чапырдату**

чаптырдáу *неперех.* **1.** *см.* **пычтырдáу 2.** хлю́пать; *см. тж.* **чапырдáу**

чаптыру I *понуд. от* **чабу** I проси́ть (застáвить, нанимáть) косúть; *яллап печән ~* нанимáть косúть сéно

чаптыру II *понуд. от* **чабу II**

чаптыру III *перех.* спáривать/спáрить, случáть/случúть, припускáть/припустúть || спáривание, слýчка; *~ урыны* случнóй пункт

чаптыр|у IV 1. *понуд. от* **чабу III 2.** проводúть/провестú скáчки; *Сабантуйда ат ~у* провестú скáчки на Сабантýе **3.** отправля́ть/отпрáвить, посылáть/послáть (*кого-л. верхом с каким-л. срочным посланием, вестью и т. п.*); *районга атлы ~у* послáть в райóн верховóго **4.** *в знач. нареч.* **чаптырып** вскачь; *~ып бару* скакáть (нестúсь, мчáться, éхать) вскачь; *~ып килү* прискакáть (нестúсь) вскачь; *~ып китү* уéхать (умчáться, отъéхать) вскачь; *~ып йөртү* **1.** пускáть (*всё время*) вскачь **2.** заставля́ть *кого-л.* бéгать (*по делам*); *~ып йөрү* носúться вскачь; *~ып узу (узып китү)* проскакáть (промчáться) вскачь

чаптыр|у V: чаптырып агу бить, течь струёй (*о жидкостях*), хлестáть

чаптыр-чоптыр *подр. звуку хлюпанья; пычрактан чаптыр-чоптыр атлау (бару)* хлю́пать по гря́зи

чапчак *сущ. диал.* кáдка, бóчка || кáдочный, бóчечный; *~ка су тутыру* напóлнить кáдку водóй; *~ коршавы* кáдочный óбруч

чапчакчы *сущ. диал.* кáдочник, бóндарь

чапылдат|у *перех.* 1. ча́вкать, почáвкать || ча́вканье; *~ып ашау* ча́вкать при еде́; *~ып йоту* глота́ть с чмо́каньем 2. чмо́кать, почмо́кать, причмо́кивать || чмо́канье, причмо́кивание; *иреннәрне ~у* причмо́кивать губа́ми; *~ып үбү* чмо́кать, зву́чно целова́ть 3. плеска́ть, хлю́пать (*ударами по воде*) 4. шлёпать *по чему* □ **~ыш кую** 1. причмо́кнуть 2. шлёпнуть

чапылт-чопылт *подр. звукам чавканья, чмоканья*

чапыл-чопыл *подр. см.* **чаптыр-чоптыр**

чапырдату *перех. см.* **чапылдату** 3

чапырд|а́у *неперех.* 1. хлю́пать, хлю́паться; *аяк астында баткак ~ый* под нога́ми хлю́пает боло́то 2. плеска́ться (*о рыбе, волнах*)

чар I *сущ.* 1. точи́ло, точи́льный круг; *балтаны чарга тоту* точи́ть топо́р на точи́льном кру́ге 2. *диал. см.* **чарык** I

чар II *сущ. уст.* ру́сский царь

чара I *сущ.* 1. сре́дство (*действие или совокупность действий, средств для осуществления чего-л.*); *шахта хуҗасының эшчеләргә каршы эшләгән ~ларыннан берсе — провокация* одно́ из де́йствий хозя́ина ша́хты про́тив рабо́чих — провока́ция 2. ме́ра, сре́дство, возмо́жность; *башка ~ булмау* не име́ть друго́го сре́дства; *бер ~ да юк* нет ни еди́ной (никако́й) возмо́жности 3. мероприя́тие, план; *бу ~ яшь композиторның талантын ачты* э́то мероприя́тие откры́ло тала́нт молодо́го компози́тора; *~ларның тормышка ашырылуына шатлану* ра́доваться претворе́нию в жизнь пла́нов □ **~ күрү** принима́ть/приня́ть ме́ры; **~сына керешү (керү)**, **~ эзләү** иска́ть сре́дства, име́ть вы́ход, нача́ть де́йствовать, нача́ть принима́ть ме́ры

чара II *сущ.* 1. ча́ша, плетённая из пру́тьев, соло́мы, иногда́ сши́тая из ко́жи и употребля́ющаяся как хле́бница 2. больша́я деревя́нная ча́ша; *ипи ~сы* ча́ша для вы́печки хле́ба □ **~ табак** *см.* **чара**

чарасыз *прил.* 1. безвы́ходный (*о положении*) 2. бе́дный, невóльный, несча́стный; *бу мескен, ~ адәмгә ярдәм кулы сузу* протяну́ть ру́ку по́мощи э́тому бе́дному, несча́стному челове́ку || *нареч. см.* **чарасыздан**

чарасыздан *нареч.* невóльно, вóлей-невóлей, безвы́ходно; *~ язмышка буйсыну* невóльно подчиня́ться судьбе́; *~ килешү* вóлей-невóлей согласи́ться

чарасызлык *сущ.* безвы́ходность, невозмóжность, безвы́ходное положе́ние, нужда́; *~ мәҗбүр итә* нужда́ заставля́ет

чарача *сущ. диал.* 1. *см.* **мунча алды**, **мунча алачыгы** 2. сéни, фли́гель

чаргәл *бот.* лапча́тка (*используется в медицине и для дубления кож*); *см. тж.* **каз тәпие**, **ак тәпичә**, **каз үләне**, **янтәфил**

чардак *сущ.* 1. черда́к; манса́рда, мезони́н || черда́чный; *см. тж.* **чарлак**; *~ тәрәзәсе* черда́чное окно́ 2. *диал. см.* **чардуган**

чардаклы *прил.* 1. с черда́чком, черда́чный, с мезони́ном; *~ йорт* дом с мезони́ном; *~ түбә* черда́чное перекры́тие 2. *перен. диал.* рассуди́тельный, у́мный, ду́мающий; *~ кеше* у́мный челове́к

ча́рдаш *сущ.* ча́рдаш (*венгерский танец и музыка этого танца*)

чардуган *сущ.* огра́да вокру́г моги́лы; *агач ~* деревя́нная огра́да; *~ кору* огради́ть моги́лу

чарка *сущ. диал.* 1. блю́дце, ча́ша 2. ча́рка, бока́л

чарлак I *сущ. зоол.* 1. сиби́рская (чёрная) ча́йка 2. *уст. см.* **акчарлак**

чарлак II *сущ. см.* **чардак**

чарлан|у 1. *страд. от* **чарла́у** точи́ться; *см. тж.* **кайралу** 2. 1) *перен. разг.* станови́ться/стать быва́лым, о́пытным челове́ком; *армиядән ~ып кайту* прие́хать из а́рмии возмужа́лым; *~ган (кеше)* тёртый кала́ч; *ераста ~ган* в да́льних края́х пообтёрся 2) станови́ться/стать обрабо́танным, отто́ченным (*о языке, речи*); *аның сөйләме ~ган* речь его́ ста́ла отто́ченной; *ул бу эштә ~ган* в э́том де́ле он уже́ навостри́лся 3) навостри́ться

чарлату *понуд. от* **чарла́у** отдава́ть/отда́ть *кому-л.* на зато́чку (*нож, топор*); *см. тж.* **кайрату**

чарлатылу *страд. от* **чарлату** отдава́ться на зато́чку

чарла́у *перех.* 1. точи́ть, зата́чивать, ната́чивать/наточи́ть (*на точильном бруске, круге, станке*) || точе́ние, то́чка, зато́чка || точи́льный; точи́ть топо́р, ко́сы; *~ станогы* точи́льный стано́к 2. *перен.* отта́чивать/отточи́ть, усоверше́нствовать, улу́чшить, укрепи́ть || усоверше́нствование, усиле́ние, улучше́ние, укрепле́ние; *кешеләрнең уяулыгын ~* уси́лить бди́тельность люде́й; *стилен (сөйләмен, телен) ~* улу́чшить стиль (речь, язы́к) 3. *диал.* критикова́ть, де́лать вы́говор; *см. тж.* **кыздыру**

чарлаучы *сущ.* точи́льщик; *см. тж.* **кайраучы**

чарлашу *взаимно-совм. от* **чарла́у**: помога́ть точи́ть

чар-начар *нареч.* невóльно, не́хотя, вóлей-невóлей; *см. тж.* **чарасыздан**, **ихтыярсыздан**; *чар-начар риза булу* вóлей-невóлей согласи́ться

чарпалан|у *неперех. диал. см.* **чәрдәкләнү**; *гасырлар җиленнән ~ып беткән Урал таулары* эроди́рованные вековы́ми ветра́ми Ура́льские го́ры

чарпаланыш *сущ. диал. см.* **бәрелеш**; *иске һәм яңа идеяләрнең ~ы* столкнове́ние ста́рых и но́вых иде́й

чарпалату *перех. диал. см.* **чәрдәкләндерү**

чарпалау *перех. диал. см.* **чәрдәклә́ү**

чарпалу *неперех. диал. см.* **ватылу**, **чәрдәкләнү**

чарпу *неперех. диал. см.* **өтәлә́ү**, **чабырту**

чарпулану *неперех. диал. см.* **чабыру**

чарпы *сущ. диал. см.* **бүкән** обру́бок, пенёк

чарпылу *неперех. уст.* 1. ре́зко, с шу́мом ударя́ться (би́ться) *обо что* (*волны о лодку*) 2. разбива́ться/разби́ться вдре́безги

чарпылыш *сущ. уст. см.* **бәрелеш**, **каршылык** конфли́кт, столкнове́ние

чарпылыш|у *взаимно-совм. уст. см.* **бәрелешү**, **буталышу**, **аралашу**; *~ып беткән электр чыбыклары* запу́танные электри́ческие провода́; *күз карашлары ~ты* взо́ры встре́тились

чарпыш *сущ. диал. см.* **бәрелеш**, **каршылык**

чарпыш|у *неперех. диал.* 1. би́ться нога́ми (*о животных*) 2. дра́ться, боро́ться, ста́лкиваться/столкну́ться; *см. тж.* **бәрелешү**, **көрәшү**; *үзара кискен ~лар* о́стрые схва́тки (сты́чки) ме́жду собо́й

чарт *подр. треску молнии, сломанной ветки* □ **~ итү** тре́снуть

чартизм *сущ. ист.* чарти́зм (*революционное движение рабочих в Англии в 30—40-х гг. XIX века*)

чартист *сущ. ист.* чарти́ст (*сторонник чартизма, участник чартизма*)

чартлату *понуд. от* **чартла́у** заставля́ть тре́скать/тре́снуть; производи́ть/произвести́ треск

чартла́у *неперех. диал. см.* **чыртла́у**

чартна́у *неперех. диал. см.* **чатна́у**

чарт-чорт *подр. треску горящего хвороста, ломающихся сухих веток и т. п.*; *см. тж.* **чарт-чырт (шарт-шорт)**

чар-чар *подр. см.* **чәр-чәр**

чаршá|у *сущ.* **1.** пóлог; зáнавес, завéса, занавéска || занавéсочный; *бишек ~вы* зáнавес лю́льки; *~у бавы* занавéсочная верёвка; *~у ачу* откры́ть зáнавес; *~у каплау (кору, тарту)* занавéсить (повéсить) пóлог; *~у күтәрү* поднимáть/поднять зáнавес; *~у төшерү* опусти́ть зáнавес; *~у ябу* закры́ть зáнавес; занавéсить **2.** *перен.* пелена́; *караңгы төн ~вы* пелена́ тёмной нóчи □ **~ бикә** *прост.* любóвница; проститу́тка

чаршаулы *прил.* с пóлогом, с занавéской (*дверь, кровать, люлька*)

чаршаулык *прил.* занавéсочный; *~ плюш алу* купи́ть занавéсочный плюш || *сущ.* ткань (материа́л) для пóлога, зáнавеса

чаршел *сущ. бот. см.* **чаргәл** лапча́тка серебри́стая

чаршын *сущ. пчел. см.* **чыршын**

чаршу *сущ. ист.* **1.** кры́тый ры́нок, пассáж **2.** ры́нок вообще́

чары|к I *сущ.* **1.** колесó с лóпастя́ми; *тегермән ~гы* мéльничное колесó; *пароход ~гы* колесó парохóда **2.** шестерня́, шестерёнка, зу́бчатое колесó, зубча́тка, звёздочка; *сәгать ~гы* шестерёнка часóв **3.** цветно́й узóр татáрских кóжаных сапóжек (и́чигов), внéшними кóнтурами напомина́ющий шестерню́

чарык II *сущ. уст.* ча́рки, ча́рыки, чакчу́ры (*суконная обувь на кожаной подошве*)

чарыклы *прил.* обу́тый в ча́рыки

чарылдáу *неперех. см.* **чырылдáу, череллдэ́у**

чарылдык *сущ. см.* **чырылдык**

чарыс *прил. диал.* **1.** ре́звый, горя́чий (*лошадь*) **2.** прово́рный, стара́тельный (*человек*)

часовой *сущ.* часово́й, вооружённый карау́льный; охра́нник; *~лар алмашу* сме́на часовы́х

часть *сущ.* **1.** *тех.* часть (*механизма, инструмента, орудия*); дета́ль (*машины*); *пулемёт ~ләре* ча́сти (дета́ли) пулемёта; *запас ~* запасна́я часть **2.** *воен.* часть (*войсковая единица*); *хәрби ~* во́инская часть; *сугышчан ~* боева́я часть, *санитар ~* санита́рная часть; *генерал Чанышев ~ләре* ча́сти генера́ла Ча́нышева **3.** *ист.* часть (*полицейский участок*)

чат I *сущ.* **1.** перекрёсток; *урам(нар) чаты* перекрёсток у́лиц; *чат саен* на всех перекрёстках **2.** перекрёсток доро́г, путе́й; перепу́тье; разви́лка, разви́лина; *ике юл чатындагы күрсәткеч* указа́тель на перекрёстке двух доро́г; *юл чатында аерылыштылар* на разви́лке доро́г расста́лись **3.** *диал.* разви́лка, разви́лина вил; *см. тж.* **япь**; *сәнәк чатын сындыру* слома́ть разви́лку вил **4.** *диал.* у́гол; *өй чаты тузган* у́гол до́ма обветша́л; *тур чатына утырып тор* посиди́ в пере́днем углу́; *~ башы* у́гол ме́жду перекрёстками

чат II: **чат сөяге (сөякләре)** *анат.* лобко́вые ко́сти (*таза*), ло́нное сочлене́ние лобко́вых косте́й; **чаты (чат сөяге) ачылу** раздвиже́ние лобко́вых косте́й (*о яйцекладущих птицах в период яйцекладки*)

чат III *диал. прил.* су́щий, настоя́щий; *чат ялган* су́щий (настоя́щий) обма́н; су́щая ложь, непра́вда || *нареч.* **1.** постоя́нно, ча́сто, всегда́; *ул чат безгә килә* он всегда́ прихо́дит к нам **2.** соверше́нно, по́лностью, совсе́м, целико́м; *чат аяз* соверше́нно я́сный (безо́блачный) (*день*); *чат агачтан ясалган* целико́м сде́лан из де́рева; *идән чат борчак* пол весь усы́пан горо́хом **3.** *в знач. частицы усил.* 1) то́чно, сло́вно, как; *см. тж.* **нәкъ**; *чат ут йомгагы* то́чно о́гненный клубо́к; *малай чат әтисе (инде)* ма́льчик то́чно оте́ц (то́чная ко́пия отца́) 2) то́лько, исключи́тельно; *бу эш аңа чат файда гына булды* э́та рабо́та оказа́лась ему́ то́лько на по́льзу ◊ **чат ябышу 1.** уцепи́ться *за что-л.* (*за какую-л. идею, мысль*) **2.** прилипа́ть, прилепи́ться (*как банный лист*), не отставáть ни на шаг; **чат яту** о́чень да́же подходи́ть; быть как раз тем, что ну́жно; *чат ята бу безгә* э́то как раз то, что нам ну́жно

чата *сущ. диал. см.* **чатак** I

чатай-ботай *прил. см.* **чатлы-ботлы**

чатак I *сущ. диал.* **1.** сук с разви́лкой; *кәкре агачтан ~ кәкерчек, чатлы агачтан ~ чата* (*погов.*) от крибо́го де́рева — кривýлька, от суковáтого — сук с разви́лкой **2.** разви́лка; *см. тж.* **чат** I **3.** проме́жность (*часть тела*)

чатак II *прил. диал.* плохо́й, уро́дливый, неполноце́нный; *см. тж.* **чак, начар, кимчелекле**; *~ эш* плохо́е де́ло

чатак-ботак *прил. см.* **чатлы-ботлы**

чатаклык *сущ.* ненорма́льность, недоста́ток, непра́вильность; *см. тж.* **начарлык, кимчелек, җитешсезлек**

чатал *сущ. уст.* ви́лы с двумя́ зу́бьями

чатан *прил.* хромо́й, хромоно́гий; *сукыр күп күрер, ~ күп йөрер* (*погов.*) слепо́й мно́го ви́дит, хромо́й мно́го хо́дит

чатанлату *понуд. от* **чатанла́у** заставля́ть/заста́вить хрома́ть

чатанл|а́у *неперех.* хрома́ть, ковыля́ть, ходи́ть ковыля́я; *~ый башлау* захрома́ть; *см. тж.* **аксау**; *~ап атлау* прихра́мывать

чатанлык *сущ.* хромота́, колчено́гость

чаткы *сущ.* **1.** *в разн. знач.* и́скра || искрово́й; *~ җемелдәве* искрово́е мерца́ние; *~дан ялкын кабына* из и́скры возгора́ется пла́мя; *~лар чәчелде* посы́пались и́скры **2.** блестя́щая, свети́щаяся то́чка (*дождевых капель на солнце, драгоценных камней, украшений*) **3.** *перен.* про́блеск, лу́чик, зача́ток како́го-то чу́вства (*надежды, счастья, таланта, свободы*); *өмет ~сы* и́скра наде́жды; *күзләрендәге шаян ~лар* шаловли́вые и́скры в глаза́х □ **~ үлчәвеч** *физ.* искроме́р **~ чыгару 1.** искри́ть **2.** искре́ние; **~ чыгу** искри́ться; *см. тж.* **очкын**

чаткылан|у *неперех.* **1.** искри́ть, дава́ть, рассе́ивать и́скры; искри́ться || искрово́й; *см. тж.* **очкынлану**; *~ып яну* горе́ть, рассе́ивая и́скры **2.** *перен.* блесте́ть, искри́ться под влия́нием *каких-л.* чу́вств (*о глазах, взгляде*); *күзләре ~ып китте* глаза́ заискри́лись □ *~у* **потенциалы** *физ.* искрово́й потенциа́л

чаткыла́у *неперех. разг. см.* **чаткылану**

чаткылы *прил. перен.* искри́стый, искря́щийся, сверка́ющий и́скрами (*о глазах, взгляде*); *~ күзләр* искря́щиеся глаза́

чатлама *прил. см.* **чатнама**

чатлану *неперех. диал.* разветвля́ться || разветвле́ние; *см. тж.* **тармаклану, аерчалану**

чатлап *нареч. диал. см.* **тармаклап, аерчалап**; *биш ~ үргән чыбыркы* кнут, сви́тый из пяти́ ремешко́в

чатлатып *нареч. разг.* твёрдо, вня́тно, я́сно, убеди́тельно, не боя́сь (*говорить, сказать*); *~ әйтеп бирү (әйтеп салу)* вы́ложить всю пра́вду; сказа́ть пря́мо; сказа́ть без ута́йки

чатлаш *нареч.* наискосо́к (*через перекрёсток*); *китеткә ~ торган клуб* клуб, кото́рый (нахо́дится) наискосо́к (че́рез перекрёсток) от магази́на; *урманга ~ (торган) җир кишәрлеге* уча́сток земли́, кото́рый (нахо́дится) на́искось от ле́са

чатлаштыру *понуд. от* **чатлашу**

чатлаш|у *неперех.* **1.** пересека́ться || пересече́ние (*дорог*) **2.** сочета́ться || сочета́ние

чатлы *прил. диал.* раздвоённый, разви́листый; *см. тж.* **тармаклы, япьле (җәпле)**; *~ таяк* разви́льчатая па́лка; *~ рәт* раздвоённый ряд; *өч ~ чыбыркы* кнут из трёх плете́й; *өч ~ сәнәк* ви́лы-трёхро́жки; ви́лы-трой-ча́тки

чатлы-ботлы *прил. разг.* разветвлённый, ветви́стый; *см. тж.* **чатлы-чатлы**; *чатлы-ботлы сукмаклар* разветвлённые тропи́нки

чатлы|к *сущ.* **1.** перекрёсток; *ике юл ~гы* перекрёсток двух доро́г **2.** ме́сто, у́гол между пересека́ющимися ли́ниями; *~клар кышын юешләнә* углы́ (до́ма) зимо́й сыре́ют

чатлы-чатлы, чатлы-чотлы *прил. см.* **чатлы-ботлы**

чатма *сущ.* **1.** парча́; *камзуллык ~* парча́ на камзо́л **2.** аппликáция (*на ткани*) || *прил.* парчо́вый; *~ кафтан* парчо́вый кафта́н

чатмаш *прил. диал. см.* **аркылы-торкылы**

чатмаштыру *перех.* располага́ть/расположи́ть крест-на́крест

чатмаш|у *неперех.* **1.** располага́ться крест-на́крест **2.** *см.* **чатлашу** 2

чатнама *прил.* треску́чий; *см. тж.* **чатлама**; *~ суык* треску́чий моро́з

чатнат|у *перех.* **1.** надла́мывать, надломи́ть; *балтыр сөяген ~у* надломи́ть берцо́вую кость; *тешне ~у* надломи́ть зуб **2.** *в знач. нареч.* **чатнатып** я́сно, вня́тно, чётко, уве́ренно; *~ып җавап бирү* отве́тить чётко; *~ып уку* чита́ть вня́тно (уве́ренно)

чатн|ау *неперех. в разн. знач.* **1.** тре́скаться/тре́снуть, надтре́снуть, треща́ть, подтре́скаться || тре́скание (*о стеклянных, керамических предметах, деревьях, высохшей земле и т. п.*); *иреннәр ~ады* гу́бы растре́скались; *тел ~ап кибә* язы́к растре́скивается (*от сухости, жары*) **2.** *перен.* треща́ть, ломи́ть, ныть; *баш ~ый* голова́ треща́т; *иңсәләрем ~ый* в плеча́х ло́мит; *колак ~ый* в у́хе стреля́ет □ **~ап бетү** истре́скаться, растре́скаться, перетре́скаться; **~ап китү** тре́снуть; **~ап торган** **1.** треску́чий; *см. тж.* **чатнама** **2.** чи́стый; *~ап торган таш* чи́стый (го́лый) ка́мень; **~ап тору** потре́скивать

чатный-чатный *нареч. см.* **чыртлый-чыртлый**

чаттагы *прил.* углово́й, находя́щийся на перекрёстке (*столб, дом и т. п.*)

чат-чат *подр. лёгкому удару твёрдых предметов обо что-нибудь*; *чат-чат итү* кла́цнуть (*о затворе*) ◊ **чат-чат итеп тору** *см.* **чәтердәп тору** (*о бойких и резко говорящих людях*)

чатый-ботый *прил. разг. см.* **чатлы-ботлы**

чатый-чотый: **чатый-чотый атлау** косола́пить, шага́ть (ходи́ть) косола́пя; *см. тж.* **алпан-тилпән**

чатыр I *сущ.* **1.** шатёр; пала́тка || шатро́вый; *ефәк ~* шёлковый шатёр; *~ кору* разби́ть шатёр; *~ түбә* шатро́вая кры́ша; *вакытлы ~* вре́менная пала́тка **2.** тент; шатёр; *балконга ~ тарту* натяну́ть тент над балко́ном **3.** *уст.* зонт **4.** *уст.* па́рус; паруса́; *см. тж.* **җилкән** **5.** *этногр.* носи́лки с балдахи́ном для похоро́н □ **~ чәчәк** *бот.* **1.** зо́нтичный цвето́к **2.** зимолю́бка зо́нтичная; **~ чәчәкле** *бот.* зо́нтичный; *~ чәчәкләр* зо́нтичные (*укроп, сныть, морковь, анис и т. п.*)

чатыр II: **чатыр чабу** **1.** бежа́ть во весь дух (изо все́х си́л) **2.** *перен.* хлопота́ть (*о чём-л. неустанно*)

чатырдавык I *сущ. см.* **чытырдавык**

чатырдавык II *прил.* треску́чий (*хворост*)

чатырдату **1.** *понуд. от* **чатырдау** *см.* **чытырдату** **2.** *в знач. нареч.* **чатырдатып** кре́пко, си́льно; *~ып тоту* кре́пко держа́ть; *~ып кысу* си́льно сжима́ть

чатырда|у *неперех. см.* **чытырдау** ◊ **~п ябышу** кре́пко вцепи́ться, прицепи́ться (*о край стула, за подол матери и т. п.*); *см. тж. фон. вариант* **чытырдап ябышу**

чатырлы *прил.* **1.** кры́тый (*об экипаже*) **2.** шатро́вый, шатро́м; *~ түбә* шатро́вая кры́ша **3.** с те́нтом; *~ балкон* балко́н с те́нтом **4.** па́русный; *см. тж.* **җилкәнле**; *~ кораб* па́русный кора́бль

чатыр-чотыр *подр. треску, хрусту ломающихся сучьев, веток или горящих сухих дров и т. п.*; *чатыр-чотыр күк күкрәде* с тре́ском прогреме́л гром

чатыр-чытыр *нареч.* **1.** торопли́во, бы́стро **2.** *см.* **чәт-чәт**

чатырык *сущ. ист.* **1.** склеп (*над могилой*) **2.** шала́ш, до́мик на разви́лке доро́г **3.** *диал.* сара́йчик

чаука *сущ. диал.* **1.** куст, по́росль берёз **2.** куста́рник на косого́ре

чаукалык *сущ. диал.* молодо́й березня́к, берёзовый куста́рник

чаукан *сущ. бот.* осо́т полево́й

чахо́тка *сущ. разг.* чахо́тка, туберкулёз лёгких; *см. тж.* **үпкә авыруы**

чахо́ткалы *прил. разг.* чахо́точный, туберкулёзный; *см. тж.* **үпкә авырулы**

чача|к *сущ.* **1.** бахрома́; *ука ~к* бахрома́ из позуме́нта **2.** кисть, ки́сточка; *см. тж.* **чук**; *ефәк ~к* шёлковая бахрома́; *шәл ~гы* бахрома́ ша́ли; *шарф башларындагы ~к* бахрома́ на концах ша́рфа; *~к тоту* (*тегү, тагу*) приши́ть бахрому́; *~к тотылган* (*тегелгән*) *ашъяулык* бахро́мчатая ска́терть; *~клы япма* покрыва́ло с бахромо́й **3.** *перен.* изо́рванные, обтрёпанные края́ тка́ни (*платка, полы и т. п.*); *~гын кисеп ташлау* ре́зать бахрому́

чачакландыру *перех.* излохма́тить, износи́ть (*платок, фартук и т. п.*)

чачаклану **1.** *страд. от* **чачакла́у** **2.** *неперех.* излохма́титься, преврати́ться в кло́чья (*об одежде*)

чачаклату **1.** *понуд. от* **чачакла́у** **2.** *диал. см.* **чачакландыру**; **чачак тоту**

чачакла́у *перех.* приши́ть бахрому́; украша́ть/укра́сить бахромо́й; *күлмәк итәге ~* к подо́лу пла́тья приши́ть бахрому́; подо́л пла́тья украша́ть бахромо́й

чачаклы *прил.* **1.** бахро́мчатый, с бахромо́й, име́ющий бахрому́ (*шаль, скатерть, платок*) **2.** *диал.* махро́вый; *см. тж.* **чуклы** 2

чачак-чук *сущ. собир.* вся́кая бахрома́ (*букв.* бахрома́ и кисть); *чачагы-чугы белән күлмәклек тукыма* ткань на пла́тье со вся́кой бахромо́й

чачаклы-чуклы *прил.* бахро́мчатый, со вся́кой бахромо́й

чаш *сущ. бот.* осо́ка Буксма́ума

чаштырда́у *неперех.* шурша́ть, шелесте́ть; *см. тж.* **кыштырдау**

чаштырдык *прил. см.* **кыштырдык**

чаштыр-чоштыр **1.** *подр. шуршанию высокой травы, когда идёшь по ней*; *чаштыр-чоштыр атлау* идти́, шурша́ травой́ **2.** *см.* **кыштыр-кыштыр**

чаш-чаш *подр. см.* **чаж-чож**

чая *прил.* **1.** *прям., перен.* бо́йкий, отча́янный, лихо́й, шаловли́во-сме́лый; *~ тел* о́стрый язы́к; *~ күз(ләр)*

искри́стые (игри́вые) глаза́; ~ *тавыш* бо́йкий (шаловли́вый) го́лос; ~ *дулкын* игри́вая волна́ 2. *в знач. нареч.* бо́йко, ли́хо, отча́янно; ~ *гына җавап бирү* отве́тить бо́йко

чаяландыру *понуд. от* **чаялану**

чаялану *неперех.* станови́ться/стать бо́йким, лихи́м, отча́янным; превати́ться в бо́йкого, лихо́го, отча́янного

чаялы|к *сущ.* бо́йкость, ли́хость, отча́янность, шаловли́вость, сме́лость; *матурлыклары сөйдерә, ~гы көйдерә* (*песня*) красото́й свое́й привлека́ет, шаловли́востью му́чает

чаян I *сущ. зоол.* скорпио́н; ~ *чага үзен соңгы чиктә, бөркет ярдан түбән ташлана* скорпио́н в безвы́ходном положе́нии себя́ жа́лит, а бе́ркут броса́ется с кру́чи вниз □ ~ **чебеннәр** *зоол.* скорпио́новые му́хи

чаян II *прил. см.* **чая**

чаянчы *сущ. зоол.* скорпио́нница (*насекомое*)

чәбә *межд. возглас, которым отгоняют собак* тубо́!

чәбәй: чәбәй кузна *диал.* назва́ние ви́да игры́ в а́льчик (*в бабки*)

чәбәйкә: чәбәйкә әт *диал. см.* **бәйләнчек (әт)**

чәбәк *сущ.* **1.** хлопо́к (*похлопывание руками*); ~ *ике кулдан чыга* (*погов.*) хлопо́к образу́ется двумя́ рука́ми (ладо́нями) □ ~ **уены** ла́душки **2.** *дет.* шлепо́к, пощёчина; *сүз тыңламасаң ~ бирермен* не послу́шаешься — шлёпну (*букв.* дам пощёчину); *см. тж.* **чәпәк**

чәбәклә|ү *перех.* **1.** шлёпать, пошлёпать, бить, поби́ть; хло́пать, похло́пать || шлёпанье, хло́панье; *см. тж.* **чабаклау 2.** бить в ладо́ши, рукоплеска́ть, хло́пать || рукоплеска́ние, хло́пание: *см. тж.* **кул чабу** □ **~п алу** пошлёпать

чәбәкле *сущ.* игра́ в ла́душки; ~ *уйнау* игра́ть в ла́душки; ~ *уены* игра́ в хлопки́, игра́ в ла́душки

чәбәк-чабак *подр. звуку рукоплескания, пощёчины; чәбәк-чәбәк уйнау* игра́ть, хло́пая в ладо́ши; игра́ть в ла́душки; *чәбәк-чәбәк чәптеки, түбән авыл әптеки* при́сказка, употребля́емая при игре́ в ла́душки □ **чәбәк-чәбәк итү** *дет.* хло́пать, бить в ладо́ши, ладо́шки; **чәбәк-чәбәк уены** игра́ в ла́душки

чәбәләнгән *прил.* запу́танный, спу́танный (*о волосах, пряже*); *см. тж.* **чуалган**

чәбәләнгәнлек *сущ.* запу́танность, спу́танность; *см. тж.* **чуалганлык**

чәбәләндерелү *страд. от* **чәбәләндерү**

чәбәләндерү *перех. прям., перен.* запу́тывать/запу́тать, спу́тывать/спу́тать, пу́тать; *см. тж.* **чуалту**; *бауны ~* запу́тать верёвку; *фикерне ~* запу́тывать мы́сли

чәбәләнә|ү *неперех.* **1.** запу́тываться/запу́таться, спу́тываться/спу́таться; *см. тж.* **чуалу** (*о нитке, волосах и т. п.*) **2.** отбива́ться/отби́ться; би́ться рука́ми и нога́ми (*от пчёл и т. п.*); *~сәң, бал корты чакмас җирдән дә чага ди* говоря́т, е́сли бу́дешь отбива́ться, то пчела́ мо́жет жа́лить тебя́ нево́льно **3.** *перен. разг.* мета́ться, суети́ться; *арлы-бирле ~ү* мета́ться в ра́зные сто́роны; *сәяхәткә китәм дип ~ү* суети́ться при подгото́вке к путеше́ствию □ **~еп бетү** запу́таться, спу́таться ◊ **~еп калу** растеря́ться, оторопе́ть

чәбәләнчек *прил. диал.* **1.** суетли́вый, не́рвный; ~ *хатын* суетли́вая же́нщина **2.** *см.* **чуалчык, буталчык**; ~ *эш* запу́танное де́ло

чәбе: чәбе таягы (агачы, чыбыгы) *спец.* цеп (*деталь ткацкого станка — палка, прокладываемая нитчёнками между нитями основы*)

чәбегү *неперех. диал. см.* **чәбәләнү, чуалу**

чәберчек I *прил.* беспло́дный, неоплодотворённый, неосеменённый (*о яйце, которое попало под курицу-наседку*); ~ *көкәй* беспло́дное яйцо́; яйцо́ без плода́

чәберчек II *сущ. зоол.* трясогу́зка жёлтая; *см. тж.* **чәперчек**

чәберчекләнә|ү *диал.* ту́хнуть, протуха́ть (*о яйцах*) || протуха́ние

чәберчеклек *сущ.* беспло́дность (*о яйцах кур, гусей*)

чәер *сущ.* **1.** *диал.* живи́ца; *см. тж.* **сагыз 2.** каме́дь, гу́ммиарабик □ ~ **үләне** *бот.* смо́лка обыкнове́нная; *см. тж.* **дегет чәчәге, чыпчык җилеме**

чәерләнә|ү *неперех. см.* **сагызлану**

чәй *сущ.* **1.** чай (*растение*) || ча́йный; *чәй куагы* ча́йный куст; *чәй плантациясе* планта́ция ча́я; *чәй үстерү* разведе́ние (выра́щивание) ча́я; *чәй үстерүчелек* чаево́дство **2.** чай (*продукт*) || ча́йный; *бөртек(ле) чәй* ба́йховый чай; *такта чәй* пли́точный чай; *грузин чәе* грузи́нский чай; *яшел чәй* зелёный чай **3.** чай (*напиток*) || ча́йный; *чәй пешерү* зава́ривать чай; *чәй агызу* (*ясау*) налива́ть чай; *чәй эчү* пить чай, чаёвничать; чаепи́тие; *чыгышлы чәй* наста́ивающийся (зава́ривающийся) чай □ **чәй ашы (ашлары)** вы́печка, мучны́е изде́лия к ча́ю (*чак-чак, баурсак, хворост и т. п. национальные кушанья*); **чәй бөртеге** чайнка; **чәй гөмбәсе** ча́йный гриб, япо́нский гриб (*слизистая плёнка, напоминающая медузу*); **чәй дирбиясе** ча́йный серви́з; **чәй йорты** ча́йная; *см. тж.* **чәйханә**; **чәй кашыгы** ча́йная ло́жка; *см. тж.* **бал кашыгы**; **чәй розасы** *бот.* ча́йная ро́за (*сорт роз*); **чәй савыты** ча́йница; **чәй содасы** ча́йная со́да; **чәй суы** питьева́я вода́; **чәй сырганагы** *бот.* облепи́ха крушинови́дная; **чәй табыны** засто́лье с чаепи́тием; **чәй тәлинкәсе** ча́йное блю́дце, ча́йная таре́лочка; *см. тж.* **чәй яны; чәй яны** *см.* **чәй табыны; чәй яратучы** чаёвник, чаёвница, люби́тель (люби́тельница) пить чай; **чәйгә алу, чәйгә чакыру** приглаша́ть (звать) в го́сти на чаепи́тие; приглаша́ть на чай (на ча́шку ча́я) ◊ **чәеннән кала күренә** чай о́чень жи́дкий (*букв.* сквозь чай ви́ден го́род); **чәегез тәмле булсын** ве́жливое пожела́ние за́нятым чаепи́тием, прия́тного чаепи́тия

чәйгүн *сущ. диал.* **1.** *см.* **чәйнек 2.** *см.* **парник**

чәйдәш *сущ.* компаньо́н по чаепи́тию; тот, с кем пьёшь (пил) чай; тот, с кем сиди́шь (сиде́л) за столо́м

чәйлә|ү *разг.* пить чай, занима́ться чаепи́тием □ **~п алу** попи́ть ча́ю; **~п утыру** сиде́ть за ча́ем, быть за́нятым чаепи́тием

чәйлек *сущ.* чаево́й, чаевы́е; ~ *бирү* дава́ть чаевы́е; дава́ть на чай

чәйнәвек *сущ.* жва́чка; *см. тж.* **күшәм**

чәйнәвеч *сущ. диал. см.* **чәйнәвек**

чәйнәкл|ә́ү *перех.* **1.** разгрыза́ть/разгры́зть **2.** *см.* **чәйнә́ү** ◊ **~әп ыргыту** (*о ярой ненависти*) гото́в зуба́ми загры́зть

чәйнәлү *страд. от* **чәйна́ү 1.** быть прожёванным **2.** *перен. прост.* быть мно́го обсужда́емым □ **~ авыруы** зае́д, зае́да (*из-за редких и неправильно расположенных зубов у лошади*)

чәйн|ә́ү *перех.* **1.** жева́ть, пожева́ть, разжёвывать/разжева́ть || жева́ние; *азык ~әү* жева́ть пи́щу; *сагыз ~әү* жева́ть жва́чку; *~әү мускуллары* жева́тельные му́скулы **2.** *перен.* грызть; трепа́ть и́мя, сплетничать *о ком-л.*, злосло́вить; *берәр кешене ~әү* трепа́ть чьё-*л.* и́мя; *~и башлау* зажева́ть; *см. тж.* **чәйнәргә тотыну** □ **~әп алу** пожева́ть || пожёвывание; **~әп бетерү** разжева́ть (*хоро-*

шенько) || разжёвывание, сжева́ть; **~әп бозу** изжёвывать/изжева́ть || изжева́ние; *бозау керләрне әп бозган* телёнок изжева́л бельё; **~әп җиткерү** прожёвывать/прожева́ть, разжёвывать/разжева́ть; **~әп кую** нажева́ть (*хлебный мякиш для котёнка, в старину для ребёнка*); **~әп тору** пожева́ть (*некоторое время*); **~әргә тотыну** зажева́ть; **~әү авыруы** *см.* **чәйнәлү авыруы** ◊ **~әп бирү (кәнтыру, салу)** (*букв.* разжева́ть и положи́ть в рот) преподнести́ на таре́лочке

чәйнәш|ү *совм. от* **чәйнәү** 1. жева́ть (*о многих*) 2. куса́ться, гры́зться; *см. тж.* **тешләшү** 3. *перен. прост.* дра́ться, ссо́риться; воева́ть; *күрше белән ~ү* ссо́риться с сосе́дом

чәйне|к *сущ.* ча́йник; *чәй ~ге* зава́рочный ча́йник; *су ~ге* ча́йник для кипяче́ния воды́; *кофе ~ге* кофе́йник, ча́йник для ко́фе

чәйханә *сущ.* ча́йная, дом ча́я; *~ хуҗасы* хозя́ин, хозя́йка ча́йной; *см. тж.* **чәй йорты**

чәйханәче *сущ. уст.* содержа́тель (хозя́ин) ча́йной

чәйхур *сущ.* люби́тель пить чай; чаёвник, чаёвница

чәйче *сущ.* 1. чаево́д (*выращивающий чай, занимающийся разведением чая; специалист по чаеводству*); *Грузия ~ләре* чаево́ды Гру́зии 2. чаеторго́вец, торго́вец ча́ем; *базардагы ~лар* база́рные чаеторго́вцы 3. *разг.* люби́тель ча́я; чаёвник; *см. тж.* **чәйхур**

чәйчелек *сущ.* чаево́дство || чаево́дческий; *~ районнары* чаево́дческие райо́ны; *~ тармагы* о́трасль чаево́дства

чәкә *сущ. диал.* 1. у́шко, у́хо (*ведра и т. п.*) 2. уклю́чина 3. чека́, чеку́шка

чәкәләш|ү *неперех. разг.* 1. дра́ться, подра́ться, сцепи́ться || сты́чка, дра́ка; *см. тж.* **якалашу, яңаклашу** 2. *перен.* руга́ться, ссо́риться; *см. тж.* **әйткәләшү**

чәкән I *сущ.* почато́к; *кукуруз ~е* почато́к кукуру́зы □ **~ чәчәклеләр** *бот.* початкоцве́тные

чәкән II *сущ.* вы́шитый узо́р в ви́де цветка́; вид вы́шивки гла́дью; чека́н

чәкән III *сущ. ист.* 1. чека́н (*слесарный инструмент*) 2. кисте́нь; *см. тж.* **чукмар, чукмарбаш** □ **~ шар сугу** (*уены*) вид игры́ на траве́ с клю́шкой и шаро́м

чәкәнбаш *сущ. см.* **чәкән** I

чәкәнләү *перех. см.* **бизәкләү, бизәклән чигү (туку)**

чәкәнле I *прил.* с почато́ком, име́ющий почато́к; *~ кукуруз сабакларын урып алу* сжать сте́бли кукуру́зы с початками

чәкәнле II *прил. диал. см.* **бизәкле, нәкышле**

чәкәштерү *перех. см.* **чәкештерү**

чәкәш|ү *неперех.* 1. *см.* **чәкешү** 1 2. *см.* **чәкәләшү**

чәкелдәтү *перех. разг.* 1. *см.* **чекелдәтү** 2. *см.* **чәкештерү**

чәкештерү *перех.* чо́каться/чо́кнуться || чо́канье; *см. тж.* **чәкешү**; *стаканнарны ~* чо́кнуться стака́нами

чәкеш|ү *перех. см.* **чәкештерү**; *дуслар ~еп эчтеләр* прия́тели, чо́кнувшись, вы́пили

чәки *сущ.* 1. *диал. см.* **чирек, чүлли** 2. *см.* **чүрәкәй**

чәкмәрә: чәкмәрә килү *диал. см.* **чәлпәрәмә килү**

чәкмәшә *сущ. диал. см.* **кәшәкә**

чәкү *перех.* 1. высека́ть; *см. тж.* **чагу** II 2. *см.* **чекелдәтү**

чәкүшкә *сущ.* 1. чека́, чеку́шка, клин, сте́ржень; *см. тж.* **чигә чәй**; *арба ~се* чека́ теле́жки 2. четверти́нка, четверту́шка, чеку́шка *прост.* ◊ **~ләре элэгешү** поссо́риться, заде́ть друг дру́га; выясня́ть отноше́ния

чәкчәги *сущ. разг. см.* **чәкчәк**

чәкчәк *сущ. кул.* чакча́к, чак-ча́к; *см. тж.* **баллы төш** (*праздничное мучное изделие в виде шариков величиной с лесной орех или лапши, жаренное в масле и политое кипяченым мёдом*) □ **~ мәҗлесе (ашы)** *этногр.* обря́довый обе́д с чакча́ком для жениха́ с его́ друзья́ми

чәлә *прил. уст.* непо́лный, незавершённый, ущёрбный; *~ кеше* неполноце́нный челове́к

чәлдерү *перех. прост.* 1. *см.* **урлау** 2. уйти́ (убежа́ть) тайко́м

чәлпәк I *сущ. кул.* чельпе́к (*тонкая лепёшка из сдобного теста*)

чәлпәк II *прил. см.* **җәлпәк**

чәлпәрәмә *нареч. см.* **челпәрәмә** □ **~ килү** *см.* **челпәрәмә килү**

чәлтер *сущ.* 1. *диал. см.* **сыйрак** 2. го́лень пти́цы

чәл|ү *сущ. прост. см.* **урлау**; *кайсыгыз ~де акчамны?* кто стяну́л (мой) де́ньги?

чәм *сущ.* 1. *ист.* цам, религио́зная систе́рия 2. *перен. диал.* страсть; аза́рт

чәмән I *прил. см.* **чаман**

чәмән II *сущ. диал.* 1. дикораст у́щая трава́; бурья́н 2. лека́рственная трава́

чәмәнзар *сущ.* 1. *диал.* разнотра́вье 2. *уст.* травни́к (*каталог лекарственных трав*)

чәмләнү *неперех. диал.* 1. горячи́ться; горячо́ (аза́ртно) взя́ться *за что-л.* 2. *диал.* серди́ться

чәмле *прил. диал.* 1. увлека́ющийся, аза́ртный 2. *см.* **көнчел, гарьчел**

чәмчә *сущ. диал.* 1. *уст.* шумо́вка, дурпла́г; *см. тж.* **тишекле чүмеч**; **чулпы** 2. узо́р; аппликация; *читек ~се* узо́ры и́чигов (сапо́жек) 3. камзо́л (*с характерными линейными узорами*)

чәмчәле *прил. диал. см.* **каюлы, чигүле, бизәкле**

чәмчел *прил. диал. см.* **чәмле**

чәнәшкә *сущ. диал.* са́нки, подса́нки (*специальные ручные грузовые сани*); *~дә тау шуу* ката́ться на са́нках с горы́

чәнечкәк *прил.* колю́чий; *~ гөләп* колю́чий шипо́вник || *сущ.* ме́лкая колю́чка

чәнечкәлә|ү *многокр. от* **чәнчү** □ **~п бетерү (чыгу)** исколо́ть всего́ (всё, всю)

чәнечке *сущ.* 1. ви́лка || ви́лочный; *~ белән ашау* есть ви́лкой 2. колю́чка *разг.* (колю́чая про́волока) 3. острога́ (*рыболовное орудие в виде вил*) 4. колю́чка, шип, игла́ (*у некоторых растений*) 5. *перен.* ко́лкость; *~ җибәрү* говори́ть ко́лкости; поддева́ть *кого-л.* □ **~ канатлы балык** *см.* **чәнечкеле балык**; **~ койрык** *зоол.* шилохво́ст (*вид южных пресмыкающихся*); **~ койрыклы тиен** *зоол.* бе́лка колючехво́стая

чәнечкеле *прил.* 1. колю́чий, игли́стый, с колю́чками, шипа́ми, терни́стый, с те́рниями; *~ тимерчыбык* колю́чая про́волока; *~ җәнлек* игли́стый зверёк; *~ куак* терни́стый куст (*тёрн, облепиха*); *роза — ~ гөл* ро́за — цвето́к с шипа́ми 2. *мн. в знач. сущ.* **чәнечкеләр** *бот.* колю́чие 3. *перен.* язви́тельный, ко́лкий, бо́стрый; *~ шаяру* язви́тельная шу́тка, *~ сүз (сүзләр)* ко́лкие слова́ □ **~ балык** *зоол.* колю́чка; **~ гөл** колю́чий цвето́к; алоэ́; ка́ктус; **~ чаш** *бот.* осо́ка колючкова́тая

чәнечкеләнү *неперех.* покрыва́ться колю́чками

чәнечкеч *прил.* 1. *см.* **чәнечкеле** 2. *см.* **чәнечке** 1

чәнти: чәнти бармак *диал.* мизи́нец; *см. тж.* **чәнчә бармак**

чәнчә: чәнчә бармак мизи́нец

чәнчек: чәнчек үләи *бот.* колю́чник сре́дний

чәнчелдер|ү *перех. бран.* 1. разби́ть, слома́ть; *см. тж.* **кыру, вату** 2. отправля́ть/отпра́вить на тот свет (*к праотцам*); *см. тж.* **үтерү, һәлак итү, юк итү**

чәнчел|ү *страд.-возвр. от* **чәнчү** 1. коло́ться, уколо́ться (*иголкой, вилкой, гвоздём*) 2. втыка́ться/воткну́ться, вонза́ться/вонзи́ться; *сәнәк сандалны тишеп, аякка ~де* ви́лы проколо́ли сандале́ты и вонзи́лись в но́гу 3. *перен. бран.* подыха́ть/подо́хнуть, сдо́хнуть, издыха́ть/издо́хнуть 4. *в знач. нареч.* **чәнчелгәнче** до упа́ду, до издыха́ния; *~ йөгерү* бежа́ть до упа́ду; *~ эчү* пить до издыха́ния; ◊ **~гере, ~еп беткере (киткере)** чтоб сдох, пропади́ про́падом; **~еп (кенә) бетсен (китсен)** пусть сдо́хнет, пусть пропадёт (он) про́падом

чәнчем *сущ.* 1. прокол, ды́рочка; *см. тж.* **тишем**; *кадак ~нәре белән ясалган калай иләк* жестяно́е си́то, сде́ланное проко́лами гвозде́й 2. стежо́к (*расстояние между двумя проколами иголки при шитье*); *см. тж.* **атлам**; *вак ~нәр белән тегү* шить ме́лкими стежка́ми; *~ арасын озайту* удлини́ть расстоя́ние ме́жду стежка́ми

чәнчетү *понуд. от* **чәнчү**

чәнчешәк *бот.* крапи́ва жгу́чая; *см. тж.* **чәнечкәк**

чәнчешү 1. *взаимно-совм. от* **чәнчү** (1, 3) коло́ть друг дру́га; *штыклар белән ~* коло́ться штыка́ми, коло́ть друг дру́га штыка́ми 2. *в знач. сущ.* колотьё (*о резкой, колющей боли*); *бил ~* колотьё в поясни́це

чәнч|ү *перех.* 1. коло́ть, уколо́ть; вка́лывать/вколо́ть, вонза́ть/вонзи́ть, пронза́ть/пронзи́ть, втыка́ть/воткну́ть || ука́лывание, втыка́ние, вонза́ние; *штык белән ~ү* коло́ть штыко́м; *энә белән ~ү* уколо́ть иго́лкой 2. коло́ть || ко́лики, резь, простре́л, колотьё; *см. тж.* **чәнчешү** 2; *йөрәк ~ә* ко́лет се́рдце; *бил тирәләремдә ~ү сизәм* в поясни́чной о́бласти чу́вствую ко́лики 3. *безл.* коло́ться; *ылыс ~ә* хво́я ко́лется; *см. тж.* **кадалу** 4. *перен.* язви́ть, съязви́ть, кольну́ть, сде́лать ко́лкое замеча́ние, подде́ть; *~еп әйтү* кольну́ть, съязви́ть □ **~еп авырту** коло́ть || резь, ре́жущая боль, ко́лики; *см. тж.* **чәнчү алу**; **~еп алу** 1. уколо́ть, кольну́ть 2. *перен.* кольну́ть, подде́ть, подковырну́ть, съязви́ть, съехи́дничать; **~еп бетерү** исколо́ть, исты́кать, перетыкать, перекололь; **~еп елмаю** ехи́дно улыба́ться (улыбну́ться); **~еп карау** 1. попро́бовать кольну́ть 2. *перен.* пронзи́ть взгля́дом, вонзи́ть взор; **~еп кую** вонзи́ть, приколо́ть, наколо́ть (*бабочку на доску*), воткну́ть; **~еп тишү** проколо́ть, проткну́ть, пронзи́ть, вы́колоть; **~еп үтерү** заколо́ть (*штыком, ножом*); **~еп чыгару** проколо́ть (*лист бумаги*); *см. тж.* **чәнчеп тишү**; **~еп чыгу** надколо́ть (*помидоры перед стерилизацией*); обколо́ть, коло́ть (*узоры на коже*); **~ү алу** *см.* **чәнчеп авырту, чәнчешү**; **~ү үләне (уты)** *бот.* синеголо́вник равни́нный (*сорняк*)

чәнчүле *прил.* язви́тельный, колю́чий, ко́лкий, ехи́дный, е́дкий; *см. тж.* **чәнечкеле** 2; *~ сүз* ко́лкое (язви́тельное, е́дкое) сло́во; шпи́лька; *~ караш* пронзи́тельный взор; *~ кисәтү* е́дкое замеча́ние

чәнчүчән *прил.* колю́чий, ко́лкий

чәнчүчәнлек *сущ.* 1. колю́честь, ко́лкость 2. *перен.* язви́тельность, ко́лкость, ехи́дность

чәңгелдәтү *понуд. от* **чеңгелдәү**

чәңгелдә|ү *неперех.* 1. ля́ять, тя́вкать (*о собаке*) 2. *перен. неодобр.* говори́ть на высо́ких тона́х, говори́ть зво́нким то́нким го́лосом, ля́ять, тя́вкать

чәңгелдәшү *взаимно-совм. от* **чәңгелдәү** (*о многих*)

чәңгелдек *прил.* писклявый, визгли́вый (*о высоком звонком голосе*); *~ тавыш белән сөйләү* говори́ть писклявым го́лосом

чәп: чәп итү (иттерү) *подр. звуку* 1. *чмоканья*; *чәп иттереп үбеп алу* чмо́кнуть 2. *пощёчины*; *чәп итеп сугу* зво́нко уда́рить (*ладонью*), *яңагына чәп итү* дать пощёчину

чәпәк *сущ.* 1. *диал.* шлепо́к; *см. тж.* **чәбәк** 2; *~ алу* получи́ть шлепо́к 2. *диал.* валёк; *см. тж.* **бәләк**; *керләрне ~ белән чәпәләп юу* стира́ть бельё, шлёпая валько́м

чәпәләк *сущ. диал. см.* **чапкы** II—2

чәпәләнү *неперех. см.* **чәбәләнү** 3

чәпәлә́ү *перех.* 1. шлёпать, бить (*бельё вальком*) 2. *разг. см.* **чәпә́ү** 2

чәпәләш|ү *взаимно-совм. диал. см.* **талашу, ызгышу**

чәпәмә *сущ. диал. см.* **бәләк** □ **~ туп** игра́ с мячо́м (*наподобие хоккея с мячом*)

чәпә́|ү *перех.* 1. шлёпнуть, шмя́кнуть, положи́ть *что-л.* ре́зким движе́нием (*раствор при кладке кирпича*) 2. *прост.* напя́лить, наде́ть (*на голову*); *башка бүрек ~ү* напя́лить ша́пку на го́лову 3. *разг.* броса́ть/бро́сить внеза́пно, ре́зко; *башыннан салып кепкасын эскәмиягә ~де* сняв ке́пку с головы́, бро́сил на скамью́ 4. *разг.* шлёпать/шлёпнуть

чәпелдәтә-чәпелдәтә *нареч.* с ча́вканьем, причмо́кивая, издава́я чмо́кающие зву́ки (*есть*)

чәпелдәт|ү *перех.* 1. производи́ть зву́ки всплесков 2. ча́вкать, почáвкать || ча́вканье; *~еп су эчү* пить во́ду с ча́вканьем, ча́вкая (*языком*) 3. *неперех.* чмо́кать, почмо́кать, причмо́кивать || чмо́канье, причмо́кивание 4. *перех.* ударя́ть по щеке́, шлёпнуть по мя́гкому ме́сту; *см. тж.* **чапылдату**; *~ артына сугу* (*баланың*) шлёпнуть по мя́гкому ме́сту (*ребёнка*)

чәпелд|әү *неперех.* 1. плеска́ться 2. ча́вкать, чмо́кать || ча́вканье, чмо́канье; *см. тж.* **чапылдату**

чәперчек *зоол.* трясогу́зка (*птица из семейства воробьиных*); *см. тж.* **чәберчек, сиртмә койрык**

чәперчен|ү *неперех.* горячи́ться, кипяти́ться, выходи́ть из себя́; *см. тж.* **чәпчү** 2 □ **~еп алу** погорячи́ться; **~еп китү** вскипе́ть, вы́йти из себя́

чәп-чәп *подр.* 1. *звукам всплесков воды* 2. *звуку чавканья* (*языком — при еде, ногами — при ходьбе по грязи*); *песи чәп-чәп сөт эчә* ча́вкая, ко́шка пьёт (лака́ет) молоко́ □ **чәп-чәп итү** 1. ча́вкать, хлю́пать 2. хло́пать (*ручонками*) 3. па́рить ве́ником (*ребёнка*); *~ килү см.* **чәп-чәп итү**; *см. тж.* **чап-чап**

чәпчек *сущ. см.* **чәперчек**

чәпчет|ү 1. *понуд. от* **чәпчү** приводи́ть/привести́ в состоя́ние вспы́льчивости, дава́ть/дать по́вод горячи́ться, вспыли́ть; серди́ть, гневи́ть 2. *диал. см.* **чәчрәтү**

чәп-чәп *см.* **чап-чап**

чәпч|ү *неперех.* 1. 1) плеска́ться (*о воде у берега и т. п.*) 2) выплёскиваться/вы́плеснуться 2. *перен.* вспыли́ть, выходи́ть из себя́, горячи́ться, кипяти́ться; *см. тж.* **кызу (кызып китү)**; *хатын ~ергә тотынды* же́нщина начала́ горячи́ться 3. *диал.* болта́ть/болтну́ть, проговори́ться, вы́болтать/вы́болтнуть; *бу турыда кешегә ~емә* об э́том не вы́болтай (не проговори́сь) други́м

чәрдәк *сущ.* 1. берцо́, берцо́вая кость 2. ма́лая берцо́вая кость

чәрдәкләндер|ү *перех.* раздробля́ть/раздроби́ть, размозжи́ть, разбива́ть/разби́ть вдре́безги || раздробле́ние,

разбива́ние; *яшен агачны ~еп бетергән* мо́лния раздроби́ла де́рево

чәрдәкләнү *возвр. от* **чәрдәкләү**: раздробля́ться/раздроби́ться, разбива́ться/разби́ться вдре́безги, размозжи́ться || раздробле́ние; *сугышчының аягы ~гән* у бойца́ размозжены но́ги

чәрдәкләү *перех. см.* **чәрдәкләндерү**

чәрек *сущ.* **1.** *пчел.* распо́рка (*деталь бортевого колодочного улья*) **2.** *спец.* распо́рка (*лодки, судна и т. п.*)

чәрексез *прил. диал. см.* **чыдамсыз, түземсез**

чәрелдәтү *перех. см.* **чырылдату**

чәрелдәшү *совм. от* **чырылдашу**

чәрелдәү *неперех. см.* **чырылдау**

чәрелдек *прил.* визгли́вый, писклю́вый, писклявый *разг.*; *~ тавыш белән кычкыру* крича́ть визгли́вым го́лосом; *~ сыбызгы тавышы* писклю́вый звук свистка́

чәрем *сущ. диал. см.* **күн**

чәркә *сущ. диал.* **1.** заты́лок **2.** ча́рка, ча́шка; *см. тж.* **чокыр (чынаяк чокыры)**

чәрмә *сущ. этногр.* (ко́жаная) су́мка для пода́рков во вре́мя сва́дьбы □ *~* **төбе 1.** са́мый лу́чший пода́рок неве́сты (*обычно для будущей свекрови*) **2.** пе́сня, с кото́рой обраща́ется неве́ста к свекро́ви **3.** прибау́тка, исполня́емая во вре́мя сва́дьбы

чәрмәк *уст. уст.* сыромя́тный двухсло́йный реме́нь; *см. тж.* **чи каеш**

чәрнәй *сущ. диал.* суре́пка

чәрпәләнү *неперех. диал. см.* **чәрдәкләнү**

чәрпәләү *перех. диал. см.* **чәрдәкләү**

чәр-чәр *подр. писку, визгу*; **чәр-чәр (итеп) кычкыру** визжа́ть, пища́ть

чәрчәрле *сущ.* вид де́тской игры́

чәршәмбе *сущ.* среда́ (*день недели*); *бер күзе ~гә, икенчесе якшәмбегә караган* (*погов.*) оди́н глаз на нас, друго́й на Арзама́с (*букв.* оди́н глаз смо́трит на сре́ду, друго́й — на воскресе́нье)

чәтердәвек *прил. разг.* ре́зкий, повели́тельный, зво́нкий (*голос*)

чәтердә|ү *неперех.* **1.** *см.* **четердәү 2.** *разг.* говори́ть бы́стро и горячо́ (*о женщине*) □ *~п тору* так и сы́пать слова́ми

чәтертән *прил. диал.* бо́йкий, сме́лый, о́стрый на язы́к; «трещо́тка»; *~ кыз* бо́йкая де́вушка

чәтертәү *неперех. см.* **чәтердәү**

чәтер-чәтер *нареч. диал. см.* **чәт-чәт**

чәтләкн *сущ. диал.* **1.** *см.* **чәтертән 2.** *см.* **чүрәкәй**

чәт-чәт I *нареч.* чётко, бы́стро, жи́во (*о речи, разговоре*); *чәт-чәт сөйләү* говори́ть чётко, вня́тно и бы́стро

чәт-чәт II *подр.* зву́кам пошлёпывания, шлепко́в (*быстрых, коротких*); *чәт-чәт сугу* шлёпать, ударя́ть; шлёп-шлёп

чәүкә *сущ.* га́лка || га́лочий; *бер көтү ~ өянкеләргә кунган* ста́я га́лок сиди́т на и́вах; *~ оясы* га́лочье гнездо́ □ *~* **баласы** галчо́нок; *~* **баш** *бот.* кле́вер; *см. тж.* **тукранбаш**

чәүчәләк *прил. диал.* беспоко́йный, не́рвный; *см.* **борчылучан, тынычсыз; көйгәнәк**; *атасы үтә сабыр, анасы ~* оте́ц о́чень споко́йный, а мать не́рвная

чәүчәләкләнү *неперех.* не́рвничать, беспоко́иться

чәһаршәмбе *сущ. книжн. см.* **чәршәмбе**

чәһрә *сущ.* **1.** ли́чико **2.** *уст. см.* **чырай, йөз**

чәч *сущ.* **1.** во́лос, волоси́нка, волосо́к || волосяно́й; *ак ~ләр* седы́е во́лосы; *чәч капламы* волосяно́й покро́в **2.** во́лосы; *чәч үстерү* (*җибәрү*) отрасти́ть/отра́щивать во́лосы; *чәч кистерү* подстрига́ться/подстри́чься; *чәч кисү* отреза́ть во́лосы; *чәч тарау* расчеса́ть во́лосы; *чәч алдыру* стри́чься, подстрига́ться; *чәч туздыру* взлохма́тить во́лосы; *чәч тузу* лохма́титься (*о волосах*) □ **чәч алучы** парикма́хер; **чәч бавы** *см.* **чәчбау**; **чәч бөдрәләтү** завива́ть во́лосы; **чәч бөртеге** во́лос, волосо́к, волоси́нка; **чәч бөтеркәсе** завито́к, завиту́шка *разг.*, ло́кон, завита́я прядь; **чәч мае** мазь (крем) для воло́с; **чәч өретү** *рел.* покрыва́ть во́лосы платко́м; **чәч пәкесе** бри́тва («опа́сная»); **чәч толымы** коса́; **чәч төбе 1.** ко́рни воло́с **2.** *уст.* амуле́т с моли́твами (*прикреплённый к середине шнура, приплетаемого к косам*); **чәч үргече** *см.* **чәчүргеч**; **чәч юлы** пробо́р (*обычно прямой пробор*) ◊ **чәч агару** седе́ть; **чәч(ләр)е бәйләнгән, чәч(ләр)е чәчкә бәйләнгән** (*погов.*) им сужде́но быть вме́сте, судьба́ их связа́ла вме́сте (*букв.* во́лосы их свя́заны вме́сте); *чәч төпләренә кадәр кызарып* (*тирләп*) *чыгу* покрасне́ть (вспоте́ть) до корне́й воло́с (*от волнения, переживания, стыда и т. п.*); **чәчең җитмәс (төтмәс) түләргә** и воло́с не хва́тит расплати́ться; **чәчен йолкый-йолкый елау (үкенү)** рвать на себе́ во́лосы; си́льно пережива́ть (ка́яться, раска́иваться, жале́ть, сожале́ть)

чәчәгашар *сущ. зоол.* жук-цветое́д

чәчә|к I *сущ. бот.* цвет, цвето́к || цвето́чный; *болын ~кләре* луговы́е цветы́; *кәнәфер ~ге* цвет сире́ни; *гөл ~ге* цвето́к ко́мнатного цветка́ (ко́мнатного расте́ния); *оешма* (*укмаш*) *~к* соцве́тие; *~к ата башлау* зацвести́; *~к атып бетерү* отцвести́; *табигый ~к* приро́дный цвето́к; *тере ~к* живо́й цвето́к; *чын ~к* настоя́щий цвето́к; *~к аттыру* дожда́ться цвете́ния; *кода-кодагый-лык ~к ата* расцвета́ет кумовство́; *ясалма ~к* иску́сственный цвето́к; *бер ~к белән яз булмый* (*погов.*) одна́ ла́сточка весны́ не де́лает (*букв.* один цвето́к весны́ не де́лает) □ **~к ату** *прям., перен.* расцвета́ть, цвести́; *алмагач ~ атты* расцвела́ я́блоня; *даны ~к атканда* в расцве́те сла́вы; **~к баганачыгы** *бот.* сто́лбик цветка́; **~к бакчасы** цветни́к; **~к бәйләме** буке́т; **~к бөресе (төймәсе)** буто́н; **~к кибете (киоскы)** цвето́чный магази́н (кио́ск); **~к коңгызы** *зоол.* жук-цветое́д; *см. тж.* **чәчәгашар**; **~к (~ген) кою** *прям., перен.* отцвести́; **~к сабагы, ~к сабы** *бот.* цветоно́с, цветоно́жка, сте́бель, стебелёк цветка́; **~к сатучы** продаве́ц (продавщи́ца) цвето́в; цвето́чник, цвето́чница; **~к табанчасы** *бот.* щито́к цветка́; **~к тиряләре** *бот.* околоцве́тник; **~к төбе** *бот.* цветоло́же; **~к төплеге** *бот.* плю́ска, обёртка; *см. тж.* **кәшәнкә**; **~к туганы** *бот.* пыльца́; **~к түтәле** клу́мба, цветни́к; **~к үстерүче** цветово́д, цвето́чник; **~к үстерүчелек** цветово́дство || цветово́дческий; **~к яны яфрагы** *бот.* околоцве́тник; **~к япмалары** покро́вы цветка́; **~ккә бөреләнү** образова́ние буто́на (*почки цветка*); **~ккә төймәләнү** *бот.* бутониза́ция ◊ **~к кебек чагы** во цве́те лет

чәчә|к II *сущ. мед.* о́спа || о́спенный; *жил ~ге* ветряна́я о́спа; *~к микробы* о́спенный микро́б; *~к салу* (*салдыру*) прививать о́спу, оспопрививание □ **~к авыруы** о́спа; **~к бетчәсе** о́спенный прыщ, о́спина; **~к чыгу 1.** заболе́ть о́спой **2.** прививаться (*об оспе*); **~к шадрасы** рябинка

чәчәкләндер|ү 1. *понуд. от* **чәчәкләнү 2.** *перен.* довести́ до цвете́ния; *см. тж.* **чәчәк аттыру**

чәчәкләү *перех.* украша́ть цвета́ми

чәчәкләч *сущ. зоол.* жук-цветолю́б

чәчәкле *прил.* **1.** цветко́вый; *~ үсемлекләр* цветко́вые расте́ния; *~ гөлләр* цветко́вые цветы́ **2.** цвету́щий,

с цвета́ми; ~ *бакча* сад с цвета́ми, цвету́щий сад **3.** цвети́стый (*о платье*); ~ *кәбестә бот.* цветна́я капу́ста □ ~ **камыш** *бот.* суса́к зо́нтичный

чәчәкле-гөлле *прил.* цвета́стый, цвети́стый; *чәчәкле-гөлле ситсы* цвета́стый си́тец; *чәчәкле-гөлле болын* цвети́стый луг

чәчәклек *сущ.* цветни́к, клу́мба

чәчәкче *сущ. разг.* цветово́д; *см. тж.* ~ **үстерүче**

чәчәкчелек *сущ.* цветово́дство || цветово́дческий

чәчәлән|ү *неперех. диал.* вспыли́ть, вспы́хивать/вспы́хнуть, горячи́ться; *см. тж.* **кызу, тузыну** □ ~**еп китү** вспы́хнуть, горячи́ться; возбужда́ться, раздража́ться; *см. тж.* **кызып китү, кабынып китү**

чәчәмә: чәчәмә ютәл *см.* **бума ютәл**

чәчән *сущ. диал. см.* **чичән**

чәчәнлек *сущ. см.* **чичәнлек**

чәч|әү *неперех. диал.* поперхну́ться, зака́шливаться/зака́шляться

чәчбаг *сущ. уст. см.* **чәчүргеч**

чәчбай *сущ. бот.* ве́йник; *см. тж.* **тутык үләне**

чәчбәй *сущ. бот. см.* **чәчбай**

чәчбаш *сущ. зоол.* власогла́в, хлыстови́к (*червь, паразитирующий в кишечнике человека*)

чәчбәү *сущ. диал. см.* **чәчүргеч**

чәчби *сущ. разг.* де́вочка, де́вушка (*с кудрявыми или завитыми волосами*); лохма́тая де́вушка

чәчван *сущ. уст.* чачва́н (*сетка из конского волоса как часть паранджи среднеазиатских и кавказских женщин-мусульманок*)

чәче *сущ. диал.* стожа́р; шест (*поставленный в середину стога*); *см. тж.* **шеш**

чәчелгән *прил.* **1.** рассы́панный, рассе́янный; ~ **яктылык** *физ.* рассе́янный свет; *см. тж.* **сибелгән 2.** засе́янный, посе́янный; ~ *җир* засе́янный уча́сток

чәчелдерү *понуд. от* **чәчелү**

чәчелеп *нареч.* вразбро́с, врассыпну́ю, вразбро́д; *см. тж.* **сибелеп, таралып**; *бөтен әйберләр* ~ *ята* ве́щи лежа́т вразбро́с

чәчелеш *сущ.* **1.** засе́ивание (*зерна, кукурузы, гороха и т. п.*) **2.** *физ.* рассе́яние, излуче́ние □ ~ **амплитудасы** *физ.* амплиту́да рассе́яния

чәчелмә *сущ.* ро́ссыпь; *алтын комы ~ләре* ро́ссыпи золото́го песка́ || *прил. см.* **чәчелгән 1**

чәчелмәле *прил. диал.* распусти́вшийся (*цветок ромашки*)

чәчел|ү 1. *страд. от* **чәчү**; се́яться, высева́ться, засева́ться; *арыш вакытында ~де* рожь се́ялась во́время; *чүп үләне үзеннән-үзе ~еп үскән* сорня́к проро́с само́севом **2.** 1) рассыпа́ться/рассы́паться; *әрҗә әчендәге алмалар ~де* из я́щика рассы́пались я́блоки; *янчыгыннан акчалар ~де* из кошелька́ рассы́пались моне́ты 2) рассе́иваться/рассе́яться, разлива́ться/разли́ться || рассе́яние, излуче́ние; *см. тж.* **сибелү, таралу, коелу**; **яктылык ~ү** светорассе́яние; *кояш нурлары ~де* разли́лись лучи́ со́лнца **3.** разлета́ться/разлете́ться; *листовкалар җиргә ~де* листо́вки разлете́лись по земле́; *кәгазьләр идәнгә ~де* бума́ги разлете́лись по́ полу **4.** *перен.* разойти́сь, разбежа́ться, рассы́паться; *см. тж.* **сибелү, таралышу 5.** распространя́ться/распространи́ться; *см. тж.* **таралу**; *даны ераккa ~де* его́ сла́ва далеко́ распространи́лась **6.** *перен.* находи́ться, располага́ться/расположи́ться места́ми то там, то сям; вкра́пливаться; *тал-тирәкләр арасында анда-санда балан куаклары ~гән* среди́ за́рослей тальника́ то там, то сям вкра́плены кусты́ кали́ны **7.** разбры́згиваться/разбры́згаться; бры́згаться, бры́згать; *см. тж.* **чәчрәп**; *авызыннан төкерекләре ~ә* изо рта́ бры́зжет слюна́; *чиләктәге сулары ~ә* из ведра́ разбры́згивается вода́ □ ~**еп бетү** высева́ться; ~**еп калу** засева́ться, засе́иваться, просы́паться, просе́яться

чәчелү-түгелү *неперех. собир. см.* **чәчелү 1, 2**

чәчемлек *сущ. этногр.* де́ньги, раздава́емые по́сле похоро́н моги́льщикам

чәчергәләнеп *нареч. диал. см.* **ачыргаланып**

чәчкап *сущ. ист.* чачка́п (*украшение для женских волос*)

чәчкә *сущ. разг. поэт. см.* **чәчәк**

чәчкәләнү *неперех. см.* **чәчәкләнү**

чәчкәләү *многокр. от* **чәчү**

чәчкен *сущ.* **1.** се́янец; *см. тж.* **үренте**; *алма, чия ~нәре* се́янцы я́блони и ви́шни **2.** всхо́ды; *см. тж.* **тишем**; ~*нар тигез чыккан* всхо́ды пробили́сь дру́жно

чәчкеч *сущ. с.-х.* се́ялка || се́ялочный; *колхозга яңа ~ алып кайттылар* колхо́зу привезли́ но́вую се́ялку; ~ *әрҗәсе* се́ялочный я́щик; ~ *агрегатлары* се́ялочные агрега́ты; ~*тә эшләүче* се́яльщик

чәчкояр *сущ. зоол.* власое́д (*паразитирующий жук*)

чәчле *прил.* **1.** с волоса́ми, име́ющий во́лосы; *ак* ~ седо́й, седовла́сый, с седы́ми волоса́ми (*букв.* с бе́лыми волоса́ми); *бөдрә* ~ кудря́вый, с курча́выми волоса́ми **2.** волосяно́й □ ~**ле гидрометр** волосяно́й гидроме́тр

чәчмә *прил.* прозаи́ческий; ~ *әсәр* прозаи́ческое произведе́ние

чәчми-түкми *нареч. прям., перен.* так, как есть; в це́лости-сохра́нности, целико́м и по́лностью; *чиләктәге сулары чәчми-түкми генә алып кайт* принеси́ воды́ в вёдрах не проливая́ ни ка́пли; *игеннәрне чәчми-түкми җыеп алырга* собра́ть урожа́й без поте́рь (*не оставляя на поле*); *сүзләреңне чәчми-түкми китереп җиткерделәр* твои́ слова́ донесли́ (переда́ли) все как есть

чәчрәвек *сущ.* бры́зги

чәчрәмә *сущ. см.* **чәчрәвек**; *су ~се* бры́зги воды́

чәчрәтелү *страд. от* **чәчрәтү**; разбры́згиваться, расплёскиваться

чәчрәтеш|ү *взаимно-совм. от* **чәчрәтү** плеска́ться, бры́згаться, побры́згаться □ ~**еп алу** побры́згаться

чәчрәткәләү *многокр.* (*иногда, изредка, время от времени*) побры́згивать, бры́згаться

чәчрәткеч *сущ.* разбры́згиватель; *см. тж.* **сиптергеч**

чәчрәттерү *понуд. от* **чәчрәтү**

чәчрәт|ү *перех.* **1.** бры́згать/бры́знуть, бры́згаться *чем-л.*, разбры́згивать/разбры́згать, побры́згать, плеска́ть/плесну́ть || бры́зганье, разбры́згивание; *балалар су ~еп уйныйлар* де́ти игра́ют, бры́згаясь водо́й; *өскә ~ү* бры́згаться □ ~**еп алу** побры́згать **2.** *диал.* излуча́ть, излучи́ть, излива́ть, изли́ть; *см. тж.* **чәчү**; *караңгылык эчендә яктылык ~еп торган фонарьлар* фонари́, излива́ющие свет в темноте́; ~**еп бетерү** обры́згать, разбры́згать; ~**еп җибәрү** бры́знуть, плесну́ть

чәчрә|ү *неперех.* **1.** бры́згать/бры́знуть, разбры́згивать/разбры́згать, побры́згать; плеска́ть/плесну́ть || бры́зганье, разбры́згивание 1) *см.* **чәпәлү 2)** *перен.* прояви́ть бо́йкость, жи́вость, сме́лость **2.** разлета́ться/разлете́ться, рассы́паться (*зёрна при молотьбе*) **3.** *в знач. нареч.* **чәчрәп 1)** стреми́тельно, ре́зко, с си́лой; ~*п сикереп торды* ре́зко вскочи́л с ме́ста; ~*п барып төште* ре́зко упа́л, гро́хнулся 2) *перен.* сверка́я луча́ми; ~*п кояш*

чыкты сверка́я луча́ми, взошло́ со́лнце ◊ **~п китим** *разг.* ей-бо́гу, да чтоб мне провали́ться; пусть разрази́т меня́ гром; **~п китсен** пусть пропадёт про́падом; *см. тж.* **чәнчелеп китсен**; **~п чыгу** *перен.* вы́скочить, ре́зко вы́ступить

чәчтәңкә *сущ. этногр.* подве́ска (*украшение для волос — монеты, подвешенные к тесьме, заплетаемой в косы*)

чәчтамыр *сущ.* **1.** *бот.* корневы́е волоски́; *см. тж.* **тамыр төкчәләре** **2.** лу́ковица во́лоса

чәчтараш *сущ. уст.* брадобре́й, парикма́хер; *см. тж.* **чәч алучы**

чәчтерү *понуд. от* **чәчү**; вынужда́ть/вы́нудить, заставля́ть се́ять

чәч|ү *перех.* **1.** се́ять, засе́ивать/засе́ять, высева́ть, высе́ивать/вы́сеять, посе́ять || 1) сев, посе́в, вы́сев, засе́в 2) посевно́й; *~үгә төшү* приступа́ть/приступи́ть к се́ву; *~үне тәмамлау* зако́нчить сев; *язгы ~ү* весе́нний сев; *алмаш ~ү* плодосме́н; *кабат ~ү* пересева́ть; пересе́в; *арыш ~сәң — көлгә ~, сабан ~сәң — суга ~* (*погов.*) сей рожь в золу́, а пшени́цу в во́ду; *ни ~сәң, шуны урырсың* (*посл.*) что посе́ешь, то и пожнёшь; *җил ~сәң, давыл урырсың* (*посл.*) посе́ешь ве́тер, пожнёшь бу́рю **2.** засе́ять, заня́ть посе́вами (*какой-л. участок*); *Апанаев җирләренә крестьяннар ~кәннәр* Апана́евские зе́мли засе́яли крестья́не **3.** рассыпа́ть/рассы́пать, просыпа́ть/просы́пать || рассыпа́ние, просыпа́ние **4.** роня́ть; *см. тж.* **төшерү**; *ипи валчыкларын чәчеп, ашарга тотынды* роня́я кро́шки хле́ба, на́чал есть **5.** *перен.* рассе́ять, разброса́ть, раски́дывать/раскида́ть; *см. тж.* **тарату**; *язмыш безне төрле якларга ~те* судьба́ раскида́ла нас в ра́зные сто́роны **6.** рассе́ивать/рассе́ять, излива́ть/изли́ть, излуча́ть/излучи́ть, разлива́ть/разли́ть, искри́ться; *см. тж.* **сибү**; *җылылык ~ү* излуча́ть теплоту́; *моң ~ү* излива́ть грусть, *меңнәрчә шәм нуры ~ә* ты́сячи свече́й излуча́ют свет **7.** распространя́ть/распространи́ть; *сер ~ү* разглаша́ть та́йну, вы́болтать секре́т; *гайбәт ~ү* распространя́ть спле́тни **8.** *прям., перен.* мета́ть, наметá ть || мета́ние; *балык уылдык ~ә* ры́ба ме́чет икру́; *уылдык ~ү вакыты* пери́од мета́ния икры́; *авызыннан ут ~ү* мета́ть гром и мо́лнии; *пулемёт ут ~ә* пулемёт ме́чет ого́нь □ **~еп бетерү** **1.** зако́нчить се́ять, заверши́ть сев **2.** рассы́пать; **~еп җибәрү** рассы́пать, просы́пать; **~ү әйләнеше** севооборо́т; *өч басулы ~ү әйләнеше* трёхпо́льный севооборо́т; **~ү машинасы** се́ялка; **~ү орлыгы (орлыклары)** семенны́е зёрна; **~ү өсте** вре́мя (пери́од, сезо́н) се́ва; посевна́я кампа́ния; **~үгә чыгу (төшү)** нача́ть сев (посевну́ю кампа́нию)

чәчүлек *прил.* посевно́й, предназна́ченный, подгото́вленный к се́ву; *~ җирләр* посевны́е зе́мли; *~ бодай* посевна́я пшени́ца; *~ орлык* посевны́е семена́ || *сущ.* посе́в, посевна́я; посе́янная (посевна́я) земля́, уча́сток; *~ләрне таптату* трави́ть посе́вы

чәчүрә *сущ. жарг.* **1.** без вку́са, аляпова́то разря́женная же́нщина **2.** *см.* **сөяркә** □ **~ кебек** как пу́гало (чу́чело) огоро́дное (*об аляповато наряженной женщине*)

чәчүргеч I *сущ.* тесьма́ (ле́нта, шнур и *т. п.*), заплета́емая в ко́сы

чәчүргеч II *сущ. анат.* ше́йная свя́зка, ше́йное сухожи́лие

чәчүче *сущ.* се́ялькщик, се́ялькщица, тот, кто се́ет семена́, засева́ет зе́млю; *басуга ~ләр дә килеп җитте* на по́ле появи́лись и се́ялькщики □ **~ линза** *физ.* ли́нза рассе́ивающая

чәшке *сущ. зоол.* но́рка || *прил.* но́рковый; *~ бүрек* но́рковая ша́пка; *~ яка* но́рковый воротни́к; *~ мехы* но́рковый мех

чебәләп|ү *неперех. диал. см.* **чияләнү**; *~гән чөелдерек* запу́танная супо́нь

чебен *сущ.* му́ха || муши́ный; *урман ~е бызылдавы* жужжа́ние лесно́й му́хи; *нинди ~ тешләде?* кака́я му́ха укуси́ла?; *~ таплары* муши́ные пя́тна □ **~ гөмбәсе** мухомо́р; **~ даруы** яд для мух, муши́ный яд (*букв.* лека́рство от мух); **~ кош** *зоол.* коли́бри; **~ үләне** *бот.* спа́ржа; **~ чыпчыгы** *зоол.* пе́ночка мухоло́вка; *см. тж.* **чебенче** ◊ **~ дә рәнҗетмәс** и му́хи не оби́дит; **~ дә очмасын** чтоб му́ха не пролета́ла; **~ дулап тәрәзә вата алмас** пле́тью о́буха не перешибёшь; **~ җан** трус; **чебен очканы да ишетелә** (така́я тишина́, что) слы́шно, как му́ха пролети́т; **~ тимәс чер итәр** недотро́га; **~ тоту** безде́льничать; **~гә чукмар күтәрү** стреля́ть из пу́шки по воробья́м (*букв.* поднять дуби́ну на му́ху); **~нән фил ясау** де́лать из му́хи слона́

чебенлә́ү *неперех.* **1.** покры́ться му́хами (*обычно клубящимися кучей над животными*) **2.** *разг.* отма́хиваться от мух, вести́ себя́ беспоко́йно **3.** *перен.* суети́ться, мота́ться; *машина тирәсендә ~п йөргән кеше* челове́к, суети́вшийся о́коло маши́ны

чебен-мазар *сущ. собир.* му́хи и тому́ подо́бное; *ишегеңне ябып йөр, чебен-мазар тулмасын* закрыва́й за собо́й дверь, что́бы в ко́мнату не залете́ли му́хи

чебентоткыч *сущ. бот. см.* **чебенчел**

чебенче *сущ. зоол.* пе́ночка

чебенчел *сущ. бот.* мухоло́вка

чебен-черки *сущ. собир.* мо́шки; мошкара́; *карлыгач чебен-черки белән туена* ла́сточка пита́ется мо́шками (му́хами и комара́ми)

чебеш *сущ.* **1.** цыплёнок; цыпля́та || цыпля́чий; *язгы ~ләр* весе́нние цыпля́та; *бер ояның ~* одна́ вы́сидка цыпля́т; *көзге ~ләр* осе́нние цыпля́та; *~ мамыгы* цыпля́чий пух; *~ азыгы* цыпля́чий корм **2.** *перен. прост.* замухры́шка □ **~ борынлау** вы́лупиться (*о цыплёнке*); **~ ите** мя́со цыплёнка; **~ чыгару** выси́живать цыпля́т ◊ **~ алырга килгән тилгән кебек** как ко́ршун, налете́вший на цыплёнка; **~ләрен алдырган тавык кебек** как насе́дка, у кото́рой ко́ршун схвати́л цыпля́т; **~ләрне көзли (көзен, көз көне) саныйлар** цыпля́т по о́сени счита́ют

чебешке *сущ. диал. см.* **чеби** 2

чебешкелә́ү *неперех. диал. см.* **чебилә́ү** 2

чебешханә *сущ. неол.* фе́рма-куря́тник, фе́рма-цыпля́тник; цыпля́тник, куря́тник

чеби *сущ.* **1.** цыплёнок; *~ләр* цыпля́та; *см. тж.* **чебеш**; *бер ояның ~ләре* цыпля́та одного́ вы́водка; *язгы ~* весе́нний цыплёнок, молода́я ку́рица; *әнәч* (*ана*) *~* цыплёнок-са́мка, цыплёнок-ку́рица; *әтәч ~* цыплёнок-пету́х, цыплёнок-самец **2.** цы́пки (*трещинки, мелкие ранки на руках и ногах, появляющиеся от воды, грязи и обветривания*) □ **~ анасы (тавык)** насе́дка, цыпля́тница *диал.*; **~ борынлау** вы́лупиться (*о цыплёнке*); **~ ите** мя́со цыплёнка (*или молодой курицы, молодая курятина*); **~ караучы** цыпля́тница; **~ фермасы (сарае, абзары)** цыпля́тник, сара́й для цыпля́т

чебилә́п|ү *неперех.* появле́ние цы́пок; *см. тж.* **чебилә́ү**; *~еп бетү* оконча́тельно, оби́льно покры́ться цы́пками

чебилә́т|ү *понуд. от* **чебилә́ү**; допуска́ть появле́ние цы́пок; *аякларын ~еп бетергән балалар* де́ти с оби́льными цы́пками на нога́х

чебилә|ү *неперех.* покрыва́ться/покры́ться цы́пками || появле́ние цы́пок; *куллар (аяклар) ~де* на рука́х (нога́х) появи́лись цы́пки; ру́ки (но́ги) покры́лись цы́пками

чебиле *прил.* 1. с цыпля́тами; име́ющий цыплёнка, цыпля́т; *~ тавык* ку́рица-насе́дка с цыпля́тами 2. с цы́пками, име́ющий цы́пки; *малайның аяклары ~* покры́тые цы́пками но́ги ма́льчика

чебурек *сущ.* чебуре́к

чегән *сущ.* цыга́н || цыга́нский; *~ кызы (хатыны)* цыга́нка; *~ малае* цыганёнок; *~ таборы* цыга́нский та́бор; *~ теле* цыга́нский язы́к; *~ романсы (җыры)* цыга́нский рома́нс ◊ **~ арбасыннан төшеп калган** цыга́нистый (*букв.* вы́павший из цыга́нской киби́тки); **~ тормышы** кочева́я (цыга́нская) жизнь

чегәнчә *нареч.* по-цыга́нски; *~ сөйләшү* говори́ть по-цыга́нски

чегет *сущ. диал.* сы́рник; *см. тж.* **чыгыт**

чек *сущ.* чек || че́ковый; *акча алу өчен чек* чек на получе́ние де́нег; *товарга чек яздырып алу* вы́писать чек на това́р; *чек кенәгәсе* че́ковая кни́жка

чека *сущ. ист.* чека́ (*Чрезвычайная комиссия*)

чекелдәтү *перех.* чи́кать/чи́кнуть || чи́канье; *см. тж.* **чек-чек иттерү** (*ножницами, ружьём*) 2. чо́каться/чо́кнуться; *см. тж.* **чәкештерү**

чекелдәү *неперех.* чи́кать/чи́кнуть || чи́канье; *см. тж.* **чек-чек итү (килү)**

чекери *прил. диал.* беззасте́нчивый, сме́лый, бо́йкий; *см. тж.* **кыю, әрсез**; *бу бала ~ түгел, тартынучан* э́тот ребёнок не бо́йкий, а засте́нчивый ◊ **~ күз** 1. остроглазый; *см. тж.* **очлы күз** 2. всеви́дящие, любопы́тные глаза́

чекерәешеп: чекерәешеп тору *см.* **чекерәеп тору** (*о многих*)

чекерәйтү *перех.* вытара́щивать/вы́таращить, выпу́чивать/вы́пучить, выка́тывать/вы́катить глаза́

чекерә|ю *неперех.* вы́таращиться, **выпу́чиваться**/вы́пучиться, выка́тываться/вы́катиться (*о глазах*) □ **~еп тору** *разг.* броса́ться в глаза́, выделя́ться; я́рко выделя́ться, выступа́ть

чекри *прил.* 1. прищу́ренный (*о глазах*) 2. с прищу́ренными глаза́ми

чек-чек *подр. звуку удара металлом о металл* □ **чек-чек иттерү** чи́кать; **чек-чек итү (килү)** чи́кать || чи́канье

чел *сущ.* купопа́тка (*зимой*); *чәче челдәй агарган* седо́й как лунь (*букв.* как куропа́тка зимо́й)

челәйгән: челәйгән күз *неодобр.* сверля́щие, немига́ющие глаза́

челәйтү: күз челәйтү *прост.* вы́лупить глаза́; *см. тж.* **текәү**; устреми́ть взгляд; уста́виться, вперить взор

челән *сущ. зоол.* ца́пля; *~ каурыйлары* пе́рья ца́пли; *~ кебек озын, ябык егет* худо́й и высо́кий, как ца́пля, па́рень

челәштерү *перех. лингв.* чо́канье; *см. тж.* **чылаштыру**

челә|ю *неперех. неодобр.* смотре́ть широко́ откры́тыми немига́ющими глаза́ми, смотре́ть бесцеремо́нно; вы́лупить, тара́щить глаза́; *см. тж.* **акаю**; *~еп карап тора* смо́трит бесцеремо́нно

челдерәү *неперех. см.* **челтерәү**

челдерәтү *неперех. см.* **челтерәтү**

челдерәү *неперех. см.* **челтерәү**

челдер-челдер *подр. см.* **челтер-челтер**

челди-чеби *диал. см.* **килде-китте, барлы-юклы**

челегү *неперех.* высыха́ть/вы́сохнуть на корню́ (*о деревьях*)

челек *сущ. бот.* 1. чили́га || чили́говый; *~ чәчәге* цветы́ чили́ги 2. *диал.* сухосто́й, сушня́к

челем *сущ.* 1. *бот.* чили́м (*водяное растение и его орехи*); водяны́е оре́хи 2. кури́тельная тру́бочка

челемче *сущ.* кури́льщик; куря́щий тру́бку; *~нең эче дә яна, кесәсе дә яна* (*погов.*) кури́льщик тле́ет и внутри́, и в карма́не

челк: челки күз *разг. см.* **челәйгән күз**

челлә *сущ.* 1. пора́, разга́р *чего-н.*; *кышкы ~* разга́р зимы́, пора́ са́мых си́льных моро́зов (*с 25 декабря по 5 февраля*); *җәйге ~* разга́р ле́та, са́мая жа́ркая пора́ ле́та (*с 25 июня по 5 августа*) 2. *перен.* горя́чая пора́; подходя́щий, удо́бный моме́нт для *какой-л.* рабо́ты; *балык тоту ~се җиткән* наста́л са́мый подходя́щий моме́нт для ры́бной ло́вли 3. *диал.* сорокадне́вный пери́од по́сле ро́дов ◊ **~ кигәвене** надое́дливый, назо́йливый челове́к (*букв.* полу́денный о́вод)

челпәрәмә *нареч.* вдре́безги; *~ килү* 1) разби́ться, рассы́паться вдре́безги (*о стеклянных предметах*) 2) разби́ться, развали́ться, разруша́ться/разру́шиться, разлета́ться/разлете́ться в ще́пки (*о деревянных и др. предметах*); *агач яшен сугудан ~ килгән* от уда́ра мо́лнии де́рево разби́лось в ще́пки □ **~ китерү** 1. разби́ть вдре́безги (*оконное стекло, посуду*) 2. разби́ть, развали́ть, разруша́ть/разру́шить до основа́ния (*о строении, мебели и т. п.*) 3. *перен.* уничтожа́ть/уничто́жить, расстра́ивать/расстро́ить (*жизнь, дружбу, мечты*)

челт *нареч. подр. падению мелкого предмета в жидкость* □ **~ итү** упа́сть, плю́хнуться с лёгким шу́мом в жи́дкость

челтәр *сущ.* 1. кру́жево, кру́жевце, кружевцо́ *уменьш.-ласк.* || кружевно́й; *~ бәйләү* вяза́ние кру́жева; *~ бәйләүче* вяза́льщица кру́жева; *~ тагу (тоту, тегү)* приши́ть (наши́ть) кружева́; *~ үрү* плете́ние кру́жева; *~ әйберләр* кружевны́е изде́лия 2. тюль || тю́левый; *пәрдәлек ~* тюль для штор; *тәрәзә ~е* око́нный тюль 3. гипю́р (*кружева с выпуклым узором*); *~ эшләп чыгару (җитештерү)* произво́дство гипю́ра 4. се́тка, сеть, решётка; *чәнечкеле тимерчыбык ~е* се́тка из колю́чей про́волоки; *яфракның тамырлар ~е* се́тка прожи́лок листа́ 5. *разг.* се́тка; *бер кулында чемодан, икенчесендә ~* в одно́й руке́ чемода́н, в друго́й — се́тка 6. решётка, обрешётка; *тәрәзәләргә тимер ~ беркетелгән* на о́кнах устано́влены желе́зные решётки 7. *перен.* сеть || сетево́й; *мәктәпләр ~е* сеть школ; *тимер юл ~е* сеть железноборо́жных путе́й; *квартираны ~ газына тоташтыру* подключи́ть кварти́ру к сетево́му га́зу || *прил.* 1. кружевно́й; *см. тж.* **челтәрле** 2. тю́левый, гипю́ровый; *~ пәрдә* тю́левый за́навес; *~ яка* гипю́ровый воротни́к 3. се́тчатый, реше́тчатый; *см. тж.* **челтәрле** □ **~ бәйләүче** кружевни́ца; **~ канатлылар** *зоол.* сетчатокры́лые; **~ сөяк** *анат.* реше́тчатая кость

челтәркойрык *сущ. зоол.* вуалехво́ст (*аквариумная рыба*)

челтәрләндерелү *страд. от* **челтәрләнү**; изреше́чиваться

челтәрләндертү *понуд. от* **челтәрләндерү**

челтәрләндер|ү *перех.* превраща́ть/преврати́ть в кру́жево; в не́что кружевоподо́бное; изреше́чивать/изреше́тить □ **~еп бетерү** изреше́тить

челтәрләнүү *возвр.-страд. от* **челтәрләү** 1. *возвр.* изрешéчиваться/изрешетúться; *тузып ~гән ситсы күлмәк* сúтцевое плáтье изнóшено до дыр, изрешéчено 2. *страд.* отдéлываться (оторáчиваться, обшивáться) крýжевом □ **~еп бетү** изрешéчиваться/изрешетúться

челтәрләттерү *понуд. от* **челтәрләтү**

челтәрләтү *понуд. от* **челтәрләү**; просúть úли застáвить *кого-л.* отдéлать крýжевом

челтәрләү *перех.* 1. украшáть/укрáсить крýжевом, обвязáть крýжевом; пришивáть/пришúть крýжево, нашивáть/нашúть крýжево; *см. тж.* **челтәр тоту** || обвя́зывание (обвя́зка, украше́ние) крýжевом; пришива́ние, нашива́ние крýжева; *яка ~ү* обвя́зывание крýжевом воротника́ (*платья*); *кулъяулык читләрен ~ү* обвя́зывать крýжевом края́ носово́го платка́ 2. решетúть, изрешéчивать/изрешетúть *чем-л.*; *ал байракларны пулялар ~гән* а́лые знамёна изрешетúли пу́ли

челтәрле *прил.* 1. кружевно́й, с крýжевом; *~ ашъяулык* ска́терть с крýжевом; *~ шәл* шаль с кружевно́й каймо́й 2. сéтчатый; *сыгылма ~ тимер карават* желéзная крова́ть с пружúнистой сéткой; *~ чүмеч* шумóвка, дурша́г; *см. тж. диал.* **чулпы** 3. резно́й, украшенный резны́м орна́ментом; *~ койма* забóр с резны́ми узóрами; *~ кәрниз* карни́з резно́й (с резны́ми узóрами); *~ тәрәзә йөзлеге* нали́чник с резны́ми узóрами 4. решéтчатый; *~ ишек* решéтчатая дверь; *~ күпер* мост с решéтчатыми пери́лами

челтәрче *сущ.* кружевни́ца; *см. тж.* **челтәр бәйләүче**; *оста ~* иску́сная кружевни́ца

челтер *сущ.* выделéния пéред отёлом и́ли в пери́од отёла (*у коров*)

челтерәү *неперех.* журчáть || журчáние; *язгы гөрләвекләрнең ~әве* журчáние весéнних ручейкóв

челтер-белтер *звукоподр. см.* **челтер-челтер**

челтер-челтер *подр.* 1. *журчанию ручья*; *челтер-челтер чишмә ага* с журчáнием течёт ручеёк 2. звя́канью твёрдых предмéтов (*железа, стекла и т. п.*)

челт-мелт *см.* **елт-елт** 2

челт-челт *подр.* 1. *падению капель*: кап-кáп; *см. тж.* **чылт-чылт**; *челт-челт су тама* водá кáпает кап-кáп 2. *морганию, миганию*; *см. тж.* **мелт-мелт**; *челт-челт күзләрен йомгалап алды* он поморгáл глазáми □ **челт-челт итү** 1. кáпать (*о каплях, жидкости*) 2. мигáть

чем I *сущ. диал.* 1. стéбель плодá, плодонóжка; *см. тж.* **җимеш сабагы, җимеш сабы**; **тәлгәш**; *чеменнән өзмәгез алманы* не отрывáйте я́блоки от плодонóжки; *чия чеме* плодонóжка ви́шни 2. *перен.* дýжка (*у серёжки*)

чем II *частица усил.* óчень, сверх, чрезвычáйно; *чем кара* черны́м-чернó, сверхчёрный; чёрный-пречёрный, óчень чёрный; *чем ак* белы́м-белó; *см. тж.* **ап-ак**

чемердә́ү *неперех. см.* **чымырдáу**; *~п торган ачы эчемлек* ки́слый с шипéнием напúток; *аркам ~де* по спинé прошлú мурáшки

чемер-чемер: **чемер-чемер итү (килү)** 1) шипéть (*о кислых напитках*) 2) почýвствовать дрожь, лёгкий ознóб

чеметел|ү 1. *страд. от* **чеметү** 1 2. *спец. в знач. прил.* **чеметелгән** сособренный, присóбренный; *см. тж.* **җыерылган**; *җиң очлары ~гән* (*чеметеп тегелгән*) концы́ рукавóв сособрены

чеметем *сущ.* щепóть, щепóтка; *ике чеметем чәй* две щепóтки чáя; *бер чеметем тоз* щепóтка сóли

чеметеш|ү 1. *взаимно-совм. от* **чеметү**; щипáть друг дрýга, щипáться; *балалар бер-берсен ~әләр* дéти щúплются 2. *перен.* говорúть друг дрýгу кóлкости; *~ми генә сөйләшегез әле* разговáривайте, пожáлуйста, без кóлкостей

чеметкәл|әү 1. *многокр. от* **чеметү**; пощúпывать (*время от времени, иногда*) || пощúпывание 2. *перен.* 1) болéть, беспокóить; сжимáть, стúскивать, щемúть; *авыр хәбәрләр йөрәкне ~и* тяжёлые вéсти щемя́т сéрдце 2) задевáть, говорúть кóлкости, критиковáть

чеметтер|ү 1. *понуд. от* **чеметү** 1 2. *перех.* щипáть, зудéть, щекотáть, першúть в гóрле; *шәраб бугазларны ~ә* винó щекóчет гóрло 3. *перен.* болéть, ныть (*на сердце, на душе*) 4. *перен.* колóть, задевáть/задéть кóлкими замечáниями; язвúть, язвúтельно упрекáть □ **~еп алу** 1. ущипнýть 2. язвúть, уколóть

чемет|ү *перех.* 1. щипáть/щипнýть, ущипнýть || щипáние || щипóк, щúпка; *беләген ~ү* ущипнýть рýку *кого* 2. *перен.* щипáть || щипнýть, ущипнýть, вызывáть/вы́звать ощущéние бóли, жжéния || щипáние; *салкын колакларны ~ә* морóз щúплет ýши 3. *перен.* бóльно задéть, кольнýть *кого-что*; *бу сүз аның йөрәген ~те* э́то слóво кольнýло егó в сéрдце 4. *спец.* дéлать сбóрки, присбóривать/присбóрить (*оборки, занавески*); *см. тж.* **бөрү, җыеру** □ **~еп алу** 1. щипнýть, ущипнýть 2. *перен.* кольнýть, бóльно задéть; **~еп бетерү** 1. исщипáть 2. закóнчить дéлать сбóрки; **~еп кую** *см.* **чеметеп алу**; **~еп өзү** отщипнýть, щипкóм отделúть, оторвáть; **~еп тегү** шить со сбóрками; шить, дéлая щипкú; **~еп тоту** придéрживать, брать, взять, держáть кóнчиками пáльцев ◊ **~еп~~еп алу** пощúпывать (*о холоде*); **~еп~~еп кенә** *перен.* понемнóжку, осторóжненько; *см. тж.* **аз-азлап**; *~еп~~еп кенә әйтеп бару* выскáзывать понемнóжку (*обо всём*); *~еп~~еп кенә басып бару* шагáть мéлкими шажкáми, на цы́почках

чемләү *перех.* очищáть (отделя́ть) я́годы от плодонóжек

чемле *прил.* с плодонóжками (*фрукты и ягоды*)

чемодан *сущ.* чемодáн || чемодáнный (*ключ, замок, чехол*); *~ әчендә* в чемодáне, внутрú чемодáна; *юл ~ы* дорóжный чемодáн

чемоданчы *сущ.* 1. чемодáнщик; мáстер, изготовля́ющий чемодáны 2. *перен.* занимáющийся кра́жей чемодáнов, вокза́льный вор

чемпион *сущ. спорт* чемпиóн || чемпиóнский; *дөнья ~ы* чемпиóн мúра; *олимпиада ~ы* чемпиóн олимпиáды; *~ исеме* чемпиóнское зва́ние

чемпионат *сущ.* чемпионáт; *җиңел атлетика буенча Европа ~ы* чемпионáт Евро́пы по лёгкой атлéтике

чемпионлык *сущ.* чемпиóнство || чемпиóнский; *~ исеме* чемпиóнское зва́ние

чемчекләнү *неперех. диал. см.* **чемчеңү**; *бакчадагы кәҗә ~ендә булды* коза́ в садý продолжáла пощúпывать травý

чемчекләү *перех.* ковыря́ть, выковы́ривать

чемчеп|ү *перех.* 1. приверéдничать, есть неохóтно; *ашамлыкларны ~еп кенә ашый* ест неохóтно, перебира́я пи́щу 2. щипáть, пощúпывать травý (*о животных*); *карт алаша йортка чәчелеп калган яшел печәнне ~еп йөри иде* стáрый мéрин перебирáл на дворé просы́панную зелёную травý

чемч|ү *перех.* щипáть, пощúпывать (*траву — о животных*); *каз бәбкәсе чирәм ~еп йөри* гусёнок пощúпывает травý; *см. тж.* **чемчеңү**

чеңгелдәтү *неперех.* бренча́ть, тре́нькать (*на мандолине, гитаре*); звене́ть, зва́кать

чеңгел-чеңгел *подр. см.* **чың-чың**

чеңлә́ү *неперех.* **1.** *см.* **чыңлау 2.** *уст.* петь || пе́ние (*у татар-мишарей при проводах невесты в дом жениха*)

чең-чең *подр. см.* **чың-чың**

чепек *прил.* ту́склый, потускне́вший, ма́товый; *~ тәрәзә* потускне́вшее окно́; *~ пыяла* ма́товое стекло́ □ **~ күз** *см.* **чепи күз**

чепелдәтү *перех.* прищу́ривать, мига́ть; *күзләрне ~* прищу́ривать глаза́

чепелт: чепелт күз *см.* **чепи күз**

чепелт-чепелт *подр. морганию больных глаз; см. тж.* **мелт-мелт**; *күзләрен чепелт-чепелт китерү* морга́ть

чепер *сущ. диал.* тарака́н □ **~ май** *см.* **чыпыр май**

чепер-чепер *подр. звуку питья, когда воду зачерпывают языком (о некоторых животных)* □ **чепер-чепер итү** ча́вкать

чепи: чепи күз(ләр) 1. ма́ленькие, у́зкие, бу́дто прищу́ренные глаза́ **2.** (*обычно*) больны́е, трахомато́зные глаза́

чеп-чеп 1. *межд. писк цыплят* цып-цып-цып **2.** *возглас, которым скликивают цыплят; чеп-чеп, чебиләр!* цып-цып, цыпля́тки!

чеп-чи *превосх. ст. прил. от* **чи 1.** соверше́нно сыро́й, непропечённый, непрова́ренный; *ипи чеп-чи* хлеб соверше́нно сыро́й; *бәрәңге чеп-чи* карто́фель соверше́нно сыро́й **2.** *перен.* вопию́щий, по́лный, кру́глый, соверше́нный; *чеп-чи ялган* вопию́щая ложь; *чеп-чи надан* кру́глый неве́жда; *чеп-чи мещанка* соверше́нная меща́нка; *чеп-чи юләр* кру́глый дура́к

чер: чер итү пища́ть; *чебен тисә — чер итә* му́ха уку́сит — уже́ запища́т (*о недотроге, о слабом, нестойком человеке*)

черәшеп *нареч.* с большо́м напряже́нием, изо все́х сил, о́чень стара́тельно, нату́жно; *күмәк эшләр — тырышып, ялгыз эшләр ~* (*эшләнер*) (*погов.*) о́бщие дела́ (де́лаются) со стара́нием, а одино́чные с напряже́нием ◊ **~ ябышу** це́пко ухвати́ться

черәш|ү *неперех. диал.* **1.** напряга́ться, стара́ться; *омтылган — ирешер, омтылмаган — ~ер* **2.** *в знач. нареч.* **черәшеп** изо все́х сил, с большо́м напряже́нием; *~еп ябышу* ухвати́ться изо все́х сил; *~еп тарту* тяну́ть с большо́м напряже́нием; *~еп утыру* сиде́ть до́лго, напряжённо (*над какой-л. работой*); корпе́ть

червон, цервон *сущ.* **1.** *уст.* черво́нец (*иностранная золотая монета в допетровской Руси; с XVIII века русская золотая монета достоинством в 3 рубля*) **2.** *ист.* черво́нец (*денежный кредитный билет номиналом в десять рублей, находившийся в обращении в СССР с 1922 по 1947 г.*) || *прил.* черво́нный, вы́раженный в черво́нцах; десятирублёвые бума́жные де́ньги; *~ акчаларны алтынга әйләндерү* (*алыштыру*) меня́ть бума́жные десятирублёвые де́ньги на золоты́е моне́ты

черегән *прил. см.* **черек** 1—4; *~ салам* перепре́вшая соло́ма; *~ бәрәңге* гнило́й карто́фель; *~ төп* трухля́вый пень

черек *прил.* **1.** гнило́й, разлага́ющийся (*картофель, лук, капуста и т. п.*) **2.** прогни́вший, трухля́вый; *~ багана* прогни́вший столб; *~ идән* прогни́вший пол; *коры ~ агач* сухо́е трухля́вое де́рево **3.** испо́рченный, ту́хлый, гнило́й; *~ йомырка* ту́хлое яйцо́; *~ теш* гнило́й зуб **4.** перепре́вший, загни́вший; *~ салам* перепре́вшая соло́ма **5.** *перен.* гнило́й, прогни́вший, поро́чный, обще́ственно вре́дный; *~ фәлсәфә* поро́чная филосо́фия; *~ буржуа җәмгыяте* гнило́е буржуа́зное о́бщество □ **~ авыруы** гнило́ец (*болезнь пчелиных личинок*); **~ оны (көле)** труха́ || *сущ.* **1.** гнилу́шка; *см. тж.* **коры черек**; *пыскып янган ~* дымя́щая гнилу́шка **2.** труха́; *см. тж.* **черек оны**

черекле|к *сущ.* **1.** гни́лость, испо́рченность, трухля́вость; *бәрәңгенең ~ге кәефне бозды* гни́лость карто́феля огорчи́ла; *тәпнең ~ге күренеп тора* гни́лость пня заме́тна **2.** *перен.* гни́лость, поро́чность, за́тхлость; *буржуамещан тормышының ~ге* поро́чность буржуа́зно-мещан́ской жи́зни

черек-чарык *сущ. собир.* гниль, гнильё, гнилу́шки; гнилы́е ве́тки (*деревья, сучья*); *урман аланында черек-чарык аунап ята иде* на лесно́й поля́нке валя́лось гнильё

черелдәвек *сущ. зоол.* **1.** свириста́ль **2.** *перен. разг.* писку́н, писку́нья; *см. тж.* **чәрелдек**

черелдәтү 1. *понуд. от* **черелдә́ү 2.** *перех.* свиста́ть, свисте́ть || свист; *сыбызгы ~* свисте́ть в свире́ль

черелд|әү *неперех.* **1.** чири́кать, пища́ть, стрекота́ть; *чикерткәләр ~и* кузне́чики стрекочут **2.** *разг. см.* **чырылдау**

черелдәшү *совм. от* **черелдә́ү** (*о многих*)

черем: черем итү подрема́ть, вздремну́ть, поспа́ть, прикорну́ть

черемә *сущ.* перегно́й; *туфракка ~ кертү* внести́ в по́чву перегно́й; *тирес ~гә әйләнде* навоз перегни́л, навоз преврати́лся в перегно́й

черемәле *прил.* перегно́йный, с перегно́ем; *~ ашламалар* перегно́йные удобре́ния; *~ туфрак* по́чва с перегно́ем

череткеч *прил.* **1.** гни́лостный, разлага́ющий, спосо́бствующий разложе́нию; *~ бактерияләр* гни́лостные бакте́рии **2.** *перен.* тлетво́рный, разлага́ющий; *~ тәэсир* тлетво́рное влия́ние

черет|ү *перех.* **1.** *прям., перен.* гнои́ть, сгнои́ть, сгна́ивать, подверга́ть гние́нию (*сено, навоз, дерево, чью-л. жизнь, здоровье*) **2.** *перен.* погуби́ть, напра́сно истра́тить, бесполе́зно провести́; погуби́ть жизнь **3.** *диал.* поноси́ть; *см. тж.* **хурлау** □ **~ә торган** гни́лостный, вызыва́ющий гние́ние; **~еп бетерү** сгнои́ть

черик-черик *подр. чириканью воробьёв; см. тж.* **чырык-чырык**

черилә́ү *неперех.* пища́ть, запища́ть (*слабым голосом, о птенцах воробья, о комаре и т. п.*)

чери-чери *подр. см.* **чыр-чыр, чырый-чырый**

черкәм *прил. диал. см.* **булдыклы, тырыш**

шаңгыравык II *сущ.* кóлокол, колокóльчик (*с глухим звуком*); *чыңгылдавыклар бəйлəгəн, ~лар таккан атлар* кóни с бубéнчиками и колокóльчиками

шаңгыра|у *неперех.* **1.** звенéть (*о металле*) || звон; *кыңгырау ~вы* звон кóлокола **2.** *см.* **шаңгырдау**

шаңгырдат|у *перех.* издавáть/издáть грóхот, гýлкий шум (*ударяя чем-л. о металл*) □ **~ып сугу** бить с глухúм гýлом (*о часах*)

шаңгырда|у *неперех.* **1.** гудéть, издавáть перекáтывающийся глухóй звук, прогремéть; раздавáться, прозвучáть с большóй сúлой, с грóхотом; *тимер мичкə ~п тəгəри* желéзная бóчка кáтится с грóхотом **2.** гýлко отвечáть э́хом, отражáть звук; *э-he-he! урман ~п куя* э-хе-хе! лес отвечáет гýлким э́хом □ **~п торган** **1.** гýлкий (*имеющий сильный резонанс*) **2.** звóнкий (*издающий громкие звуки*); *~п торган яңа нарат бүрəнəлəре* звóнкие сосновые брёвна

шаңгырдык *прил. неодобр. см.* **шаңгырдап торган** 1

шандау *сущ. диал. см.* **кайтаваз**

шаңка|ю *неперех.* **1.** *см.* **шакыраеп кату (туңу)** **2.** остолбенéть, оцепенéть, замерéть, засты́ть || остолбенéние, оцепенéние; *нəрсə шаңкаеп калдың?* что остолбенéл?

шаңк|у *неперех. диал.* быть оглушённым; ничегó не соображáть; *баш ~ып китү* ничегó не сообрази́ть

шап *подр.* **1.** *однократному удару плоским предметом*: шлёп, хлоп **2.** *звуку захлопывания; хлопка, пощёчины и т. п.*; *шап берне яңагына* хлоп егó по щеке́ **3.** *в функ. сказ.* неожúданно, внезáпно хватáть, схватúть, ловúть, поймáть, хвать!; *шап без моны, ут салам дигəндə* а мы хвать егó, когдá он собирáлся поджéчь □ **шап итеп егылу** грóхнуться, хлóпнуться; **шап иттерү, шап итү** *см.* **шапылдату**; *балта түтəсе белəн шап*

иттерү бу́хнуть топоро́м (о́бухом топора́); **шап итеп сугу** хло́пнуть, а́хнуть (*по спине*)

шапа: шапа авыз *диал.* **1.** 1) большо́й рот 2) большеро́тый **2.** болту́н, пустоме́ля; балабо́лка

шапалак *сущ. диал.* **1.** челове́к, говоря́щий необду́манно и́ли бы́стро и невня́тно, тарато́р, тарато́рка **2.** неря́ха, неря́шливый, нечистопло́тный челове́к **3.** удар (*рукой, ладонью*); пощёчина, оплеу́ха, плю́ха *прост.*, затре́щина **4.** хлопу́шка (*мухобойка*) ◊ **~ бирү** уда́рить; бить (*обычно ладонью*), дать пощёчину

ша́пка *сущ. разг.* **1.** ша́пка (*головной убор*); *мех* (*каракуль, мохер*) ~ мехова́я (кара́кулевая, мохе́ровая) ша́пка; *бәйләнгән* ~ вя́заная ша́пка; *балалар ~сы* де́тская ша́пка (ша́почка) **2.** *разг.* ша́пка (*в газете*); *см. тж.* **баш**; *мәкаләнең икесен дә бер ~ астында бирү* о́бе статьи́ дать под одно́й ша́пкой

шаптырдату *перех.* плеска́ть водо́й

шаптырд|ау *неперех.* хло́пать (*о воде, жидкости*); плеска́ться; *авыр ишкәкләр астында су ~ый* под тяжёлыми вёслами пле́щется вода́

шаптыр-шоптыр *подр. шуму, хлюпанью, плеску воды при переходе через неё или при взбалтывании её с шумом*; *шаптыр-шоптыр су ерып бару* пробира́ться че́рез ре́ку, плеска́я во́ду

шапшак *прил.* **1.** неря́шливый, нечистопло́тный, неопря́тный (*человек*); *~ бала* неопря́тный ребёнок; *~ киленнең себеркесе чүп астында булыр* (*посл.*) у неря́шливой неве́стки ве́ник (оста́нется) под му́сором **2.** гря́зный, нечи́стый, неря́шливый (*о белье, одежде, теле*); *өстендә ~ кием* на нём гря́зная оде́жда **3.** неприли́чный, непристо́йный, сквёрный (*о словах, выражениях, стиле, разговоре и т. п.*); *үзе ~ның теле ~* у неря́хи и язы́к сквёрный ◊ **~ телле, ~ сүзлелек** скверносло́вие || *нареч.* неря́шливо (*одеваться*); неаккура́тно, неопря́тно (*сшит*); гря́зно; нечи́сто (*ходит, живёт*); *~ эшләнгән эш* пачкотня́

шапшаклан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать неря́шливым, неопря́тным, нечистопло́тным (*о человеке*) **2.** загрязня́ться/загрязни́ться; *эштә ~ган киемне салып кую* снять загрязнённую на рабо́те оде́жду

шапшаклык *сущ.* **1.** нечистопло́тность, неря́шество; неря́шливость, неопря́тность, неаккура́тность, грязь; *бүлмәдәге ~* грязь в ко́мнате; *~ка өйрәнмә* не приуча́йся к неря́шливости **2.** *перен. разг.* нечистопло́тность (*поступка*); нече́стность; непоря́дочность *кого-л.*; *эшендәге ~лар* нечистопло́тность в рабо́те

шап-шап *подр. см.* **шап-шоп**

шап-шоп *подр.* **1.** *повторяющемуся глухому удару, стуку*: шлёп-шлёп, хлоп-хлоп; хляск *обл.*; *шап-шоп төшү* (*коелу*) па́дать с шу́мом (производя́ зву́ки «хлоп-хлоп»); *шап-шоп кул чабалар* шу́мно хло́пают (аплоди́руют) **2.** *топоту ног; шап-шоп атлау* то́пать, шага́ть, гро́мко стуча́ ногами́ (*по асфальту или по мостовой*); шага́ть «чека́нным» ша́гом □ **шап та шоп** то и де́ло глу́хо стуча́

шапылдавык *сущ.* **1.** хлопу́шка; *күн ~* ко́жаная хлопу́шка (*для битья мух*) **2.** *разг.* шлёпанцы; *аягында ~* на его́ нога́х шлёпанцы

шапылдат|у *перех.* **1.** шлёпать, хло́пать *чем-л.* || шлёпанье, хло́панье; ша́рканье; *~ып аркасына сугу* хло́пать по спине́; *ишекне ~ып ябу* хло́пнуть две́рью; *кызлар шап-шоп ~ып кер бәләкиләр* де́вушки шлёпают валько́м бельё **2.** *перен. прост.* шлёпнуть, хло́пнуть (уби́ть) *кого*

шапылда|у *неперех.* **1.** шлёпать, шлёпаться, хло́пать, хло́паться (*шумно ударяясь обо что-л.*) || хло́панье, шлёпанье; *~п егылу* (*төшү, ау*) шлёпнуться, баба́хнуться; *~п ишек ябылды* захло́пнулась дверь; *аягың ~маса, авызың чапылдамас* (*посл.*) как пото́паешь, так и поло́паешь (*букв.* не пото́паешь нога́ми, не почáвкаешь ртом) **2.** *перен.* болта́ть, увлека́ться разгово́рами и́ли проговори́ться; *ул хакта бик ~ма әле* об э́том пока́ не болта́й

шапылдык *сущ. разг.* болту́н, болтли́вый челове́к; балабо́лка, пустосло́в, хвасту́н

шапырт *подр. шуму при высыпании мелких предметов* (*гороха, картошек, щебня*)

шапырдат|у *перех. см.* **шаптырдату**; *суны ~ып, балыклар уйный* с всплёсками игра́ет ры́ба □ **~ып эчү** пить с шу́мом, больши́ми глотка́ми, хлеба́ть

шапырдат|у *неперех.* **1.** *см.* **шаптырдату**; *аяк астында пычрак ~ый* под нога́ми хло́пает грязь; *буада үрдәкләр ~ый* в пруду́ пле́щутся у́тки **2.** с шу́мом высыпа́ться, осыпа́ться; па́дать; *см. тж.* **шыбырдау**; *алма ~ап коела* с шу́мом па́дают я́блоки

шапырма: шапырма тиргә бату *см.* **шабыр тиргә бату**

шапырт|у *перех.* преувели́чивать/преувели́чить || преувели́чивание, преувеличе́ние; *~мый гына сөйлә* говори́ без преувеличе́ния; *артык ~у* слишком преувели́чивать

шапыр|у I *неперех. см.* **шапырыну**; *син йөрисең акырып та ~ып* ты всё кричи́шь да хва́лишься

шапыр|у II *неперех.* **1.** взба́лтывать, болта́ть (*чтобы не осаживался кумыс*) **2.** *диал.* ве́ять (*ручным способом — лотком*); *см. тж.* **җилгәрү**; *ярма ~у* ве́ять (чи́стить) крупу́

шапыр-шопыр *подр.* **1.** *шуму во время еды жидкой пищи или питья*; *шапыр-шопыр ашау* есть с шу́мом, хлеба́ть, гро́мко ча́вкая **2.** *см.* **шаптыр-шоптыр**; *шапыр-шопыр пычрак еру* шлёпать по гря́зи

шапырык *сущ. разг.* хвасту́н, хвасту́нья, хвастуни́шка; бахва́л *прост.*

шапырыл|у *неперех.* **1.** бурли́ть, бушева́ть, бу́рно и стреми́тельно течь (*во время половодья, ледохода*); *мартта — шарт, апрельдә ~а* в ма́рте — треск, а в апре́ле — полово́дье **2.** *перен.* идти́ лави́ной, ла́вой, сплошны́м пото́ком; вали́ть ва́лом; *бәла килсә ~ып килә* (*посл.*) беда́ не прихо́дит одна́ (*букв.* беда́ идёт ла́вой)

шапырындык *прил. разг.* **1.** *см.* **шапырык 2.** *см.* **шапырынкы**; *~ сүзләр* пусты́е слова́

шапырынкы *прил.* хвастли́вый (*тон*); *~ зиннәт белән бизәү* украша́ть хвастли́вой (крикли́вой) ро́скошью

шапырын|у *неперех.* хвали́ться, хвастли́во говори́ть; бахва́литься; кичи́ться || хвастовство́, бахва́льство; *~ып әйтелгән сүзләр* хвастли́во ска́занные слова́, хвастли́вые слова́; *~ып вәгъдә бирү* хвастли́во обеща́ть (*что-л. сделать*), наобеща́ть це́лый ко́роб; *артык ~ып ташлау* нахва́статься; *яратмыйм шул ~уыңны* не люблю́ твоё хвастовство́

шапырынучан *прил.* скло́нный к хвастовству́ (бахва́льству) || хвастли́вый челове́к, хвасту́н, бахва́л; *~ башына бәла шапырылучан* (*погов.*) хвасту́н накли́кает на себя́ беду́

шапырынучанлык *сущ.* хвастовство́, бахва́льство; скло́нность к хвастовству́ (бахва́льству); *~ белән* хвастли́во, с хвастовство́м, с бахва́льством

шапы-шопы *подр. см.* **шап-шоп**; *казлар канатлары белән суга шапы-шопы бәрәләр* гу́си бьют по воде́ кры́льями: хлоп-хлоп

шар I *сущ. в разн. знач.* шар || шарово́й; *шар радиусы мат.* ра́диус ша́ра; *уенчык шар* игру́шечный шар; *бильярд шары* биль я́рдный шар; *һава шары* возду́шный шар (*игрушка*); *җир шары* земно́й шар, земля́; *шар өслеге* пове́рхность ша́ра; *шар сегменты* шарово́й сегме́нт; *шар катламы* шарово́й слой; округля́ться/округли́ться □ **шар сугу 1.** игра́ть в хокке́й **2.** ходи́ть без де́ла, слоня́ться, шата́ться; безде́льничать; бить баклу́ши; **шар тибү 1.** *см.* **шар сугу 2.** *разг.* игра́ть в футбо́л; **шар уены 1.** игра́ в мяч **2.** *разг.* игра́ в хокке́й; **шар уйнау** *см.* **шар сугу** I ◊ **шар булу** быть вы́таращенным, широко́ раскры́тым (*о глазах*); **шар итү** вы́пучить, вы́таращить (*глаза*); **шар күз(ле)** большегла́зый, глаза́стый; пучегла́зый, лупогла́зый; глаза́ навы́кате; **шар салу 1.** броса́ть жре́бий **2.** *уст.* голосова́ть, баллоти́ровать; *ак шар салу* голосова́ть за, избира́ть, выбира́ть; *кара шар салу* голосова́ть про́тив, забаллоти́ровать, отве́ргнуть, отвести́ на вы́борах; **шар тәгәрәтерлек, шар тәгәрәтеп уйнарлык** хоть шаро́м покати́ (просто́рный, обши́рный и пусто́й)

шар II: шар ачу распахну́ть; раскры́ть на́стежь, во всю́ ширь (*дверь, окно, ворота, ящик, сундук и т. п.*); **шар ачык** 1) распа́хнутый, широко́ откры́тый; раскры́тый на́стежь; *ишек, тәрәзәләре шар ачык* две́ри и о́кна откры́ты на́стежь 2) *перен.* откры́тый, откровенный; и́скренний; *шар ачык күңелле* широко́ откры́тая душа́ ◊ **шар ярып көлү 1.** смея́ться гро́мко, расхохота́ться **2.** вы́смеять соверше́нно откро́венно, саркасти́чески; **шар ярып сөйләү 1.** говори́ть гро́мко, во весь го́лос **2.** говори́ть соверше́нно откро́венно (*не боясь и не таясь*); *см. тж.* **шарран яру**

шара *сущ. разг.* **1.** дерева́нный шар (*для одноименной игры*) **2.** игра́ с дерева́нными шара́ми (*разновидность хоккея на траве*); ~ *уйнау* игра́ть в шары́ □ ~ **уены** *см.* **шара** 2 ◊ ~ **күзле** пучегла́зый, глаза́стый, лупогла́зый

шарабан *сущ.* шараба́н (*экипаж*); *резин шинлы читән* ~ плетёный шараба́н на рези́новых ши́нах

шара-бара *сущ. собир. прост.* **1.** вся́кая ме́лочь, шуру́м-буру́м; вся́кое старьё, барахло́; *вак-төяк, шара-бара сатып утыручылар* торго́вцы вся́кой ме́лочью; *шара-бара җыючы* собира́ющий вся́кую ме́лочь; старьёвщик, ути́льщик **2.** детвора́; вся́кие (ме́лкие) лю́ди; ме́лочь; мелюзга́; *җыелган шунда әллә нинди шара-баралар* собрала́сь тут вся́кая ме́лочь (мелюзга́) **3.** вздор, ерунда́; пустя́к; небыли́ца, бессмы́слица, неле́пость; чепуха́; *ташлыйк әле шара-бараны* бро́сьте ерунду́; прекрати́ть моло́ть вздор; не на́до занима́ться чепухо́й

шара́да *сущ. прям., перен.* шара́да (*игра-загадка*); ~ *чишү* разгада́ть шара́ду; ~*лар белән сөйләшүне яратмыйм* не люблю́, когда́ говоря́т зага́дками (шара́дами)

шарайт|у *перех.* де́лать/сде́лать кру́глыми (*как шар*); вы́катить, вы́таращить (*глаза*); *күзләрне* ~*ып катып калдык* засты́ли, вы́таращив глаза́

шаралы *сущ.* игра́ в (дерева́нный) мяч; ~ *уйнау* игра́ть в мяч

шара|ю *неперех.* станови́ться/стать кру́глыми (*как шар*) (*о глазах — от удивления, изумления, восхищения, зависти или страха*); *см. тж.* **акаю**; *машинаны күреп, күзләре* ~*йды* уви́дев маши́ну, вы́таращил глаза́

шарж *сущ. в разн. знач.* шарж; *үз-үзенә* ~ автоша́рж; ~*га бирелү* впада́ть в шарж, изобража́я *что-л.*; шаржи́ровать

шаржландыр|у *перех.* шаржи́ровать || шаржи́рование; шаржиро́вка; *артык* ~*ырга ярату* люби́ть чересчу́р шаржи́ровать

шаржлаштыр|у *перех. см.* **шаржландыру**; *образны* ~*ып бирү* шаржи́ровать о́браз

шаржчы *сущ.* шаржи́ст

ша́риклы *прил.* ша́риковый; ~ *конвейер* ша́риковый конве́йер □ ~ **авторучка** ша́риковая автору́чка, ша́риковая ру́чка; ~ **бомба** ша́риковая бо́мба; ~ **подшипник** шарикоподши́пник; ~ **үкчә** *тех.* ша́риковая пята́

шаркылдавык *прил. см.* **шаркылдык**; ~ *кызлар* де́вушки-хохоту́шки, хохоту́ньи

шаркылда|у *неперех. разг. см.* **шаркылдап көлү**; *зал гөр килеп* ~*ды* зал (гро́мко) расхохота́лся □ ~**п көлү** хохота́ть; гоготать, ржать *прост.*; гро́мко и раска́тисто смея́ться

шаркылдаш|у *совм. от* **шаркылдау** (*о многих*); *ишек артында* ~*алар* за две́рью хохо́чут; ~*ып көлеп җибәрү* вдруг расхохота́ться

шаркылдык *прил. разг.* лю́бящий хохота́ть, смея́ться; смешли́вый || хохоту́н, хохоту́нья; хохоту́шка; ~ *кызлар* хохоту́ньи, хохоту́шки; *ни кирәк бу* ~*ларга?* что на́до э́тим хохоту́шкам?

шарлавы|к *сущ.* **1.** водопа́д (*на реке*); *үзән* ~*гы да арба аудара* (*посл.*) и пересека́т доли́ны мо́жет опроки́нуть теле́гу (*т. е. и в долине может быть сильное течение реки*) **2.** *см.* **шарлама 3.** *тех.* водосбро́с плоти́ны

шарлавыклы *прил.* **1.** поро́жистый; с перека́тами, име́ющий водопа́ды; перека́ты (*о реке*) **2.** проходя́щий че́рез перека́ты

шарлама *сущ.* **1.** перека́т (*на реке*); каска́д; водоска́т; *шаулап аккан* ~*лар кебек* как гу́лкие водопа́ды; *тау* ~*лары* го́рные каска́ды (водопа́ды) **2.** *см.* **гөрләвек**

шарландыр|у *перех.* де́лать/сде́лать как шар; вы́катить, вы́таращить (*глаза*); *күзләрне* ~*ып карап тору* смотре́ть, вы́таращив глаза́

шарлан|у *неперех.* станови́ться/стать кру́глыми (*как шар*); вы́пучиться, вы́катиться, широко́ раскры́ться (*о глазах*); *бүләкне күргәч, күзләре* ~*ды* при ви́де пода́рка его́ глаза́ широко́ раскры́лись

шарлатан *сущ. разг.* шарлата́н, шарлата́нка || шарлата́нский; *им-томчы* ~*нар* зна́хари-шарлата́ны; *сәяси* ~ полити́ческий шарлата́н; ~*га әйләну* (*әверелү*) станови́ться шарлата́ном; ~ *кыланышлары* шарлата́нские зама́шки (ухи́щрения)

шарлатанлан|у *неперех.* шарлата́нить, шарлата́нствовать, поступа́ть/поступи́ть как шарлата́н; *йөри шунда* ~*ып* так, бро́дит как шарлата́н

шарлатанлык *сущ.* шарлата́нство || шарлата́нский; *оятсыз* ~ бесстыдное шарлата́нство; ~ *алымы* шарлата́нский приём □ ~ **итү (кылу)** шарлата́нить, обма́нывать други́х; занима́ться шарлата́нством

шарлатанна́рча *нареч.* шарлата́нски, по-шарлата́нски; как шарлата́н; ~ *эш итү* поступа́ть по-шарлата́нски, шарлата́нить; *халык җырларының ямен* ~ *җибәрү* шарлата́нски искажа́ть красоту́ наро́дных пе́сен || *прил.* шарлата́нский; ~ *хәйләләр* шарлата́нские ухи́щрения

шарлат|у *перех. разг. см.* **шарландыру**; *күзләрен* ~*ып карап тора* смо́трит, вы́таращив глаза́

шарла|у *неперех.* клокота́ть, бурли́ть, шуме́ть, журча́ть (*о воде, жидкости*); *см. тж.* **шарылдау**; ~*ган су*

тавышы астында под шум бурля́щей воды́ □ **~п агу** **1.** течь с шу́мом (*о воде*) **2.** ли́ться с шу́мом, хлеста́ть (*о воде из крана*) **3.** хлы́нуть, поте́чь пото́ком; *борыныннан ~п кан ага* из но́са хле́щет кровь; **~п (агып) китү** *см.* **шарлап агу** 3; **~п аккан** быстроте́чный, стреми́тельный; бу́рный, бурля́щий (*о реке, струе жидкости*); **~п тору** клокота́ть, бурли́ть (*продолжительное время*)

шарло́тка *сущ. кул.* шарло́тка

шарлы *прил.* **1.** с ша́ром, име́ющий шар; *ак ~ тимер кровать* желе́зная крова́ть с бе́лыми шара́ми **2.** *спец.* шарово́й; *~ тегермән* шарова́я ме́льница; *~ шарнир физ.* шарово́й шарни́р □ **~ бушандыргыч** *физ.* шарово́й разря́дник; *~ подшипник* шарикоподши́пник; **~ уйнау** игра́ть в мяч; *см. тж.* **шаралы уйнау**

шарма́нка *сущ.* шарма́нка; *~ның гади көйләре* просты́е мело́дии шарма́нки; *~ уйнату* крути́ть шарма́нку

шарма́нкачы *сущ.* шарма́нщик

шарнир *сущ. тех.* шарни́р; *см. тж.* **тупса** 1; *ишек ~ы* дверно́й шарни́р; *шарлы ~лар* шаровы́е шарни́ры

шарнирлы *прил. тех.* шарни́рный; *~ терәк* шарни́рный креп, шарни́рная опо́ра; *~ дурт буын* шарни́рный четырёхзве́нник

шаровар *сущ.* шарова́ры

шаровкалау *перех. с.-х.* шарова́ть || шаро́вка; *трактор белән ~* шарова́ть тра́ктором, шаро́вка тра́ктором

шароскоп *сущ.* шароско́п

шаро́шка *сущ. тех.* шаро́шка; *бурау ~сы* шаро́шка долота́ (*при бурении*)

шарошкалы *прил. тех.* шаро́шечный; *~ бораулау* шаро́шечное буре́ние; *өч ~ бурау* долото́ трёхшарошёчное

шарсыман *прил.* шарови́дный, шарово́й; *~ буын* шарови́дный суста́в; *~ кактуслар* шарови́дные ка́ктусы; *~ яшен* шарова́я (шарови́дная) мо́лния

шарт I *сущ.* **1.** усло́вие, уговор, тре́бование *чего или чьё-л.*; *~ буенча* по усло́вию, согла́сно усло́виям (уго́вору); *~ кую* ста́вить усло́вие; (*кемнең*) *~ына* (*шарты белән*) *килешү* согласи́ться *на какое-л.* усло́вие, согласи́ться с *каким-л.* усло́вием; *договор ~лары белән килешмәү* не согласи́ться с усло́виями догово́ра **2.** усло́вия (*только мн. ч.*), обстоя́тельства; *яхшы ~лар* хоро́шие усло́вия; *тормыш ~лары* усло́вия жи́зни; *хезмәт ~ларын яхшырту* улу́чшить усло́вия труда́; *~ларның торышына карап* по обстоя́тельствам; *башка ~ларда* в други́х усло́виях **3.** усло́вия (*только мн. ч.*), возмо́жности (*способствующие чему-л.*); *эшләү өчен барлык ~лар тудырылган* со́зданы все усло́вия для рабо́ты; *сынаулар үткәрергә ~лар булмау сәбәпле* по причи́не отсу́тствия усло́вий (возмо́жностей) для эксперименто́в **4.** усло́вие, осно́ва, предпосы́лка *для чего-л.*; *җиңүгә ирешүнең төп ~лары* гла́вные усло́вия успе́ха (побе́ды); гла́вные предпосы́лки успе́ха; *кирәкле (уңайлы) ~лар булдыру* (*тудыру*) созда́ть необходи́мые предпосы́лки; благоприя́тствовать, содействовать **5.** *спец.* усло́вия (*только мн. ч.*); исхо́дные да́нные (положе́ния, лежа́щие в осно́ве *чего-л.*); *мәсьәләнең ~ы* усло́вия зада́чи; *теореманың ~ы* усло́вия теоре́мы □ **~ белән** с усло́вием, при усло́вии *чего*; *кире кайтару ~ы белән* с усло́вием возвра́та; **~ җөмлә** *грам.* усло́вное предложе́ние (*нәрсә*); **~ теркәгече** *грам.* усло́вный сою́з ◊ **~ын(а) җиткереп** как сле́дует, чин чи́ном; *см. тж.* **җиренә җиткереп**; **~ын(а) китереп** до́лжным о́бразом, как сле́дует; **~ын(а) китерү** приводи́ть/привести́ в соответствие с тре́бованиями; де́лать/сде́лать как тре́буется (как поло́жено, чин чи́ном)

шарт II *подр. сильному резкому звуку, треску, вызванных ударом, выстрелом или издаваемых ломающимся, лопающимся, разрываемым предметом* трах, бах; бабах, паф □ **~ итү** тре́снуть, произвести́ треск; *см. тж.* **шартлау** 1—4 ◊ **~ итеп (иттереп)** **1.** с тре́ском; *~ итеп сыну* обломáться (переломáться) с тре́ском **2.** си́льно, ре́зко; *~ иттереп сугу* тра́хнуть, си́льно ударя́ть; **шарт сындыру** рискну́ть (*о решительном человеке*); *см. тж.* **шартлатып сындыру**; **~ сыну** обломáться, переломáться с тре́ском (*вдруг*); *каты агач ~ сынар, черегәне кырык ел чыдар* (*посл.*) ≈ скрипу́чее де́рево до́лго стои́т (*букв.* твёрдое де́рево вдруг с тре́ском перело́мится, а гнило́е де́рево простои́т со́рок лет) **3.** скоропости́жно конча́ться

шартаяк *сущ.* клюка́, клю́шка (*палка для игры в мяч, в шары*)

шартлавык *сущ.* **1.** *бот.* хлопу́шка; смолёвка-хлопу́шка (*сорная трава*) **2.** *перен.* болту́н, хвасту́н; *коры ~* пустозво́н, пустоме́ля ◊ **~ шартлатып йөрү** **1.** ходи́ть без де́ла, безде́льничать **2.** хвали́ться, хва́статься, бахва́литься

шартлагыч *прил.* взры́вчатый, разрывно́й; грему́чий; *~ газ* взры́вчатый газ; грему́чий газ; *~ матдә* взры́вчатое вещество́, взрывча́тка; *~ пуля* разрывна́я пу́ля

шартлама I *прил. разг. см.* **чатнама**; си́льный, жёсткий, лю́тый, треску́чий (*о морозе*); моро́зный; *~ суыкта* в треску́чие моро́зы, в сту́жу

шартлама II *сущ. диал.* клубни́ка; *см. тж.* **җир җиләге**

шартлаткыч *сущ.* **1.** взрывча́тка; *~ белән кыяларны вату* взрывча́ткой разруша́ть (взрыва́ть) ска́лы; *көчле ~ салынган бомбалар* бо́мбы, начинённые си́льной взрывча́ткой **2.** взрыва́тель, ка́псюля (*взрывная часть гранаты, мины, бомбы, снаряда*); *бөрмә ~* уда́рный взрыва́тель; *дистанцион (ерактан) ~* дистанцио́нный взрыва́тель || *прил.* взрывно́й, подрывно́й; *~ материал* подрывно́й материа́л; *~ миналар* подрывны́е ми́ны; *~ җайланма* взрывно́е устро́йство □ **~ капсюль** *спец.* детона́тор

шартлат|у *перех.* **1.** взрыва́ть/взорва́ть, подрыва́ть/подорва́ть, производи́ть/произвести́ взрыв; разруша́ть/разру́шить взры́вом || 1) взрыв, взрыва́ние, подрыва́ние 2) взрывно́й, подрывно́й; *куперне ~у* взорва́ть (подорва́ть) мост; *тау токымнарын ~ып вату* взрыва́ть (подрыва́ть) го́рные поро́ды; *~у эшләре* подрывны́е (взрывны́е) рабо́ты **2.** *разг.* стреля́ть; *мылтык ~у* стреля́ть из ружья́; *пугач ~у* стреля́ть из пугача́ **3.** щёлкать/щёлкнуть, прищёлкивать/прищёлкнуть || щёлканье, прищёлкивание; *тел ~у* щёлкать языко́м; *бармак ~у* щёлкать па́льцами; *кырык ел көтү көткән, чыбыркы ~а белмәгән* (*посл.*) со́рок лет был пастухо́м, а щёлкать кнуто́м не научи́лся **4.** производи́ть/произвести́; вызыва́ть/вы́звать тре́щину, разби́ть, расколо́ть (*обычно стеклянную посуду*); *кайнар су белән стаканны ~у* расколо́ть стака́н горя́чей водо́й

шартлатучы *сущ.* подрывни́к; взрывни́к; *~лар группасы* гру́ппа подрывнико́в

шартлатыл|у *страд. от* **шартлату**; взрыва́ться, подрыва́ться, дорва́ться *кем-чем*; быть взо́рванным, подо́рванным; *~ган күперләр* взо́рванные мосты́

шартлатып *нареч.* **1.** я́сно и ко́ротко; чётко и вня́тно, бы́стро и гро́мко; чека́нно; *см. тж.* **чатнатып**; *~ укып бирү* прочита́ть чётко и вня́тно; *~ җавап бирү* отве́тить чека́нно **2.** ре́зко, стро́го; *~ карар чыгарырлар да эштән куарлар* (стро́го) вы́несут приго́вор и вы́гонят с рабо́ты

3. бы́стро, ми́гом; *~ бер кубометрлап утынны кисеп тә ташладылар* ми́гом распили́ли почти́ кубоме́тр дров 4. ре́зко, с шу́мом; с тре́ском; *ишекне ~ ябып чыгып китте* ре́зко хло́пнул две́рью и ушёл □ **~ сындыру** реши́ть *что-л.* ре́зко и бесповоро́тно (*о человеке резкого, решительного характера*)

шартл|ау *неперех.* 1. трещáть, издавáть треск; тре́снуть (*однокр.*), стреля́ть || треск; *аяк астында чыбык-чабык ~ау* треск су́чьев (хво́роста) под нога́ми; *мичтә коры утын ~ый (~ап яна)* в пе́чи стреля́ют (трещáт, с тре́ском горя́т) сухи́е дрова́ 2. стреля́ть, производи́ть/произвести́ вы́стрелы (*о звуке во время выстрела*); *сәхнә артыннан револьвер ~ый* за сце́ной звук вы́стрела (вы́стрел из револьве́ра) 3. тре́скаться, тре́снуть, лома́ться, ло́пнуться; расколо́ться (*о бревне, деревьях от холода; о стеклянной посуде от горячей или холодной воды или молока; о семенных коробочках, стручках или набухших почках деревьев, растений и т. п.*) 4. 1) лома́ться, ло́пнуть; наду́вшись разорва́ться (*о воздушном шаре, мыльном пузыре*); *сабын куыгы ~ганда́й* как ло́пается мы́льный пузы́рь 2) *перен.* дойти́ до кра́йнего состоя́ния, тре́снуть, ло́пнуть (*со смеху, от злости, возмущения, зависти, горя и т. п.*); *дошманнар көнләшеп ~асын* пусть ло́пнут от за́висти враги́; *сабырлыгы ~ады* терпе́ние (его́) ло́пнуло 5. взрыва́ться/взорва́ться, разрыва́ться/разорва́ться || взрыв || взрывно́й; *термоатом ~авы* термоя́дерный взрыв; *ялкынсыз ~ау* беспла́менный взрыв; *~ау көче* взрывна́я си́ла; *~ау дулкыны* взрывна́я (уда́рная) волна́ 6. подрыва́ться/подорва́ться, взрыва́ться/взорва́ться; *см. тж.* **шартлатылу**; *безнең алда янган авыллар, ~аган күперләр* пе́ред на́ми подожжённые дере́вни, взо́рванные мосты́ 7. *перен. разг.* ло́паться, банкро́титься/обанкро́титься, потерпе́ть банкро́тство; разори́ться || банкро́тство, разоре́ние; *фәлән бай ~аган* тако́й-то бога́ч обанкро́тился; *кызыл мал кибете ~аган* мануфакту́рный магази́н разори́лся 8. *перен. прост.* ло́паться (*от переедания или от жару, с жиру*) □ **~ап җимерелү** взрыва́ться, взорва́ться; **~ап өзелү** ло́пнуть, разорва́ться с тре́ском (*от сильного напряжения*); **~ап ярылу** расколо́ться, тре́снуть (*лёд, деревья, земля от холода или другой причины*) ◊ **~аганчы ашау** объеда́ться/объе́сться, наеда́ться до отва́ла, съеда́ть ли́шнее; **~аганчы эчү** вдо́воль напива́ться, пить ли́шнее, напива́ться вдре́безги; напива́ться до положе́ния риз; **~ый язу** невзви́деть (*от гнева*)

шартлаулы *прил.* 1. взрывно́й; *~ дулкын* взрывна́я волна́ 2. *лингв.* взрывно́й, смы́чный; *~ тартыклар* взрывны́е согла́сные

шартлаучан *сущ.* взры́вчатый (*способный взрываться*); *~ матдәләр* взры́вчатые вещества́

шартлаучанлык *сущ.* взры́вчатость (*способность взрываться*)

шартлы *прил.* 1. услóвный, зара́нее определённый; *~ сигнал буенча җыелу* собра́ться по услóвному сигна́лу; *кәгазьдәге ~ билгеләр* услóвные зна́ки на бума́ге 2. услóвленный, обуслóвленный, договорённый (*о месте, времени и т. п.*); *~ сәгатькә (вакытка) өлгерергә кирәк* на́до успе́ть к услóвленному ча́су (вре́мени); *ачкыч ~ урында* ключ на услóвном ме́сте 3. услóвный; относи́тельный; *~ сызыкка кадәр* до услóвной черты́; *вакытлы һәм ~ характердагы күренешләр* явле́ния вре́менного и услóвного (относи́тельного) хара́ктера 4. услóвный (*связанный каким-л. условием и имеющий силу только при наличии этого условия*); *~ килешү* услóвное согла́сие 5. приблизи́тельный; *яшь үзенчәлекләренә карап ~ буленеш* услóвное (приблизи́тельное) деле́ние по возрастны́м осо́бенностям || *нареч.* услóвно; относи́тельно; приблизи́тельно; *~ гына булса да, дәверләргә буләргә мөмкин* (хоть) услóвно (приблизи́тельно) мóжно дели́ть на пери́оды □ **~ булу** обуслóвленность (*зависимость от каких-л. условий*); **~ ихтималлык** *мат.* услóвная вероя́тность; **~ рәвештә** услóвно; **~ рефлекс** *физиол.* услóвный рефле́кс; **~ тигезләмәләр** *мат.* услóвные уравне́ния; **~ тоткарлану** *физиол.* услóвное торможе́ние; **~ көкем** *юр.* услóвный приговóр, услóвное суждéние; **~ ярсыткыч** *физиол.* услóвный раздражи́тель

шартлылык *сущ. в разн. знач.* услóвность; обуслóвленность; *үзара ~* взаимообуслóвленность; *ул — һәртөрле ~ларның дошманы* он враг всяких услóвностей; *бу буленешнең нигезендә билгеле бер ~ бар* в осно́ве э́той классифика́ции име́ется определённая услóвность

шарт-март: шарт-март кеше *разг.* откровéнный, откры́тый человéк; простóй человéк; *шарт-мартта ни дә юк, тымызык күлдә корт уйный* (*посл.*) у откры́того всё я́сно, в ти́хом о́зере че́рти во́дятся (*т. е. у открытого человека никакой тайны, а тихий, скрытный человек как тихое озеро, где черти водятся*)

шартнамә *сущ.* договóр, соглашéние (пи́сьменное); договóрная гра́мота *уст.*

шарт-порт *подр. беспорядочной стрельбе* трах-трах, бах-бах, трах-бах; *шарт-порт ату* стреля́ть беспоря́дочно: трах-бах; *шарт-порт яну* горе́ть с тре́ском; *усак агачы шарт-порт атар (янар), җылысы булмас* оси́на гори́т с тре́ском (стреля́ет), но тепло́ не даёт; (от оси́ны) мно́го шу́ма, а то́лку ма́ло

шартсыз *нареч.* без осóбых услóвий; *~ килешү* соглашéние без осóбых услóвий || *прил.* 1. не имéющий услóвий (*о договорах и т. п.*) 2. безусло́вный, безогово́рочный; необуслóвленный; *~ йөкләмә (договор)* безусло́вное обяза́тельство (договóр); *~ капитуляция* безогово́рочная капитуля́ция; *~ ярдәм* безогово́рочная (безусло́вная) по́мощь □ **~ рефлекс** *физиол.* безусло́вный рефле́кс; **~ ярсыткыч** *физиол.* безусло́вный раздражи́тель

шарт-шарт *подр. см.* **шарт-шорт**

шарт-шорт *подр. повторяющемуся звуку, треску, вызванному ударом, выстрелом или издаваемому ломающимся, лопающимся предметом; шарт-шорт сыну* обломи́ться с тре́ском; *чатлы-ботлы карама булыр, шарт-шорт янган усак булыр* (*посл.*) вяз суковáт, а оси́на гори́т с тре́ском (*в смысле*: ка́ждая вещь име́ет свои́ ка́чества, че́м-то отлича́ется); *шарт-шорт ату* стреля́ть беспреста́нно; стреля́ть бах-баба́х □ **шарт-шорт итү (килү)** трещáть; стреля́ть; **шарт та шорт** с тре́ском, трескотнёй

шарт-шырт *подр. см.* **шарт-шорт**

шарф *сущ.* шарф; *мамык ~* пухóвый шарф; *муенга ~ урау* обмотáть шарф вокру́г ше́и

шарчыклы *прил.* ша́риковый; *~ калəм* ша́риковая ру́чка

шар-шар *подр. бурному течению, потоку (жидкости, воды)* □ **шар-шар агу** *см.* **шарылдап агу**

шарык-шарык: шарык-шарык көлү гро́мко смея́ться, хохота́ть, гогота́ть; ржать *прост.*

шарык-шорык *см.* **шарык-шарык**

шарылдавык *сущ.* 1. *см.* **шакылдавык** 1 2. *перен.* шумли́вый, изли́шне говорли́вый; изли́шне откровéнный человéк

шарылда|у *неперех.* 1. клокота́ть, бурли́ть, шуме́ть (*о воде*); *~п тору* клокота́ть, бурли́ть (*постоянно*) 2. *перен. прост.* шуме́ть, мно́го говори́ть (*комментируя каждую мелочь*); изли́шне откровéнничать □ **~п агу** 1. бу́рно (шу́мно) течь (*о текучей, проточной воде*) 2. пото́ком, струёй, с си́лой бежа́ть, течь (*кровь из носа, из раны*); **~п кычкыру (кычкырып җибәрү)** кри́кнуть гро́мко (*во весь голос, истошным голосом*)

шасси *сущ. тех.* шасси́ (*ср. нескл.*); *автомобиль ~е* шасси́ автомоби́ля; *җыелмалы (алына торган) ~* убира́ющееся шасси́ (*самолёта*); *үзйөрешле ~* самохо́дное шасси́ (*трактора*)

шат *прил.* 1. весёлый, ра́достный, жизнера́достный (*человек, друг, мальчик*) 2. ра́достный, весёлый, дово́льный (*вид, взгляд, крик, возглас, голос, смех*); *балаларның шат көлүләре өчен* за ра́достный смех дете́й || *нареч.* ве́село, ра́достно, жизнера́достно; дово́льно; *шат яшибез* живём ве́село (жизнера́достно); *шат елмайды* ве́село (ра́достно) улыбну́лся || *предик.* дово́лен, рад *кому, чему*; *килүеңә бик шатмын* о́чень рад твоему́ прие́зду; *сезнең өчен шатмын* рад за вас □ **шат күңелле** жизнера́достный, до́брый, весёлый; *шат күңелле кеше* весельча́к, челове́к весёлый, весёлого хара́ктера, не уныва́ющий; **шат күңеллелек** жизнера́достность

шаталак I *сущ., прил. прост.* 1. 1) балагу́р, балагу́рка; шалу́н, шалу́нья, непосе́да, егоза́, бедоку́р, бедоку́рка; *~ булып үсү* расти́ бедоку́ром (шалуно́м) 2) весельча́к 2. хвасту́н, хвасту́нья, хвастуни́шка; болту́н, болту́нья, болту́шка; словоохо́тливый; *~ның теле уйный, кыбырсыкның арты уйный* (*погов.*) хвасту́н (болту́н) не уме́ет молча́ть, а непосе́да — споко́йно сиде́ть 3. легкомы́сленный, несерьёзный; ве́треный (*о человеке*); *яшь чак үзе ~* мо́лодость сама́ несерьёзная пора́

шаталак II *сущ. диал. см.* **тубык**; *~ сөяге* лоды́жка, щи́колотка

шаталаклану *неперех. прост.* куроле́сить, озорнича́ть, прока́зничать

шатен *сущ. и прил.* шате́н, шате́нка; *озын гәүдәле чибәр генә ~* высо́кий, дово́льно симпати́чный шате́н

ша́тия *сущ. прост. пренебр.* ша́тия (*компания праздношатающихся*); *монда җыен ~ җыела* здесь собира́ется вся́кая ша́тия

шатландыру *перех.* ра́довать, пора́довать, обра́довать *кого-л. чем-л.*; весели́ть *кого-л. чем-л.*; *зур уңышлар белән ата-ананы ~* пора́довать роди́телей больши́ми успе́хами; *күңелне ~* весели́ть, ра́довать ду́шу; *бик нык ~* восторга́ть *кого-л. чем-л.*

шатлан|у *неперех.* 1. ра́доваться, пора́доваться, обра́доваться; ликова́ть, восторга́ться, прийти́ в восто́рг || ра́дость; ликова́ние, восто́рг, восто́рженность; *уңышларга ~у* ра́доваться успе́хам; *чын күңелдән ~у* ра́доваться от всей души́; *~удан нишләргә белмәү* прийти́ в восто́рг; от ра́дости потеря́ть го́лову; *балаларча ~у* де́тский восто́рг (ликова́ние); де́тская восто́рженность; *гомуми ~у* всео́бщее ликова́ние (восто́рг) 2. *в знач. нареч.* **шатланып** с удово́льствием, с ра́достью, с охо́той (жела́нием); ра́достно, восто́рженно; *бик ~ып риза булу* согласи́ться с больши́м удово́льствием; *~ып каршы алу* встреча́ть восто́рженно

шатланыш|у 1. *совм. от* **шатлану** (*о многих*); *сугыш беткән, халык ~а* война́ ко́нчилась, наро́д лику́ет 2. *в знач. нареч.* **шатланышып** *см.* **шатланып**; *~ып эшкә тотыну* с ра́достью приступи́ть к рабо́те

шатлы|к *сущ.* 1. ра́дость, удово́льствие; восто́рг, *иҗат ~гы* ра́дость твóрчества; *бала ~гы — ана ~гы* (*погов.*) ра́дость ребёнка — ра́дость ма́тери; *~к яшьләре* слёзы ра́дости; *~к китерү* приноси́ть *кому-л.* ра́дость, удово́льствие; *картлык ~к тугел* (*погов.*) ста́рость не ра́дость 2. *в знач. нареч.* **шатланып** на ра́достях; от ра́дости; *~ктан елап җибәрде* запла́кал от ра́дости; *~гы эченә сыймау* захлебну́ться от ра́дости, чу́вствовать себя́ на седьмо́м не́бе; *~ктан нишләргә белмәү* быть вне себя́ от ра́дости

шатлыклы *прил.* 1. ра́достный, отра́дный; *~ көннәрнең берсендә* в один из ра́достных дней; *~ хәбәрләр* до́брые ве́сти; *~ тавышлар яңгырап китте* раздали́сь ра́достные во́згласы 2. ра́достный, весёлый; *~ кәеф* весёлое настрое́ние; *~ көйгә җырлау* петь весёлую пе́сню (мело́дию) || *нареч.* ра́достно, отра́дно, ве́село; *~ елмаю* ра́достно улыба́ться; *~ күрешү* ра́достно встре́титься

шатлыксыз *прил.* безра́достный, безотра́дный; невесёлый; беспросве́тный, безрассве́тный; *~ көннәр* безра́достные дни, непригля́дные дни; *~ күренеш* безотра́дная (непригля́дная) карти́на (жи́зни) || *нареч.* безра́достно, безотра́дно, невесело; без ра́дости (*жить, работать, творить и т. п.*)

шатман I *сущ. этногр.* зна́мя пра́здника Науру́з

шатман II *прил. диал.* весёлый, ра́достный

шатманлык *сущ. диал.* пра́здничное весе́лье, пра́здничное настрое́ние

шатрач *сущ. уст. см.* **шахмат**; *~ уйнау* игра́ть в ша́хматы; *юлдан бабаем барды, ~ тактасы төшеп калды* (*загадка*) дед идёт по доро́ге, за собо́ю остав ля́ет ша́хматную до́ску

шатрун *сущ.* кры́ша шатро́м || шатро́вый; *~ йорт* дом под кры́шей шатро́м; *~ түбәле* покры́тый шатро́вой кры́шей

шатун I *сущ. тех.* шату́н; *корыч ~* стально́й шату́н

шатун II *сущ.* боле́знь лошаде́й; воспале́ние мо́зга (мозговы́х оболо́чек); менинги́т; *атка ~ булган* ло́шадь заболе́ла воспале́нием мо́зга (менинги́том)

шатунлы *прил. тех.* шату́нный, с шатуно́м; *~ механизм* шату́нный механи́зм

шатыр *подр. треску, хрусту* (*когда не очень резко ломается дерево, рвётся ткань и т. п.*) □ **~ итеп** с хру́стом, с тре́ском; *~ итеп сыну* слома́ться с тре́ском; **~ итү** хру́стнуть

шатырдавык(лы) *прил. см.* **шытырдавык, шытырдавыклы**; *~ кәгазь* хрустя́щая (шурша́щая) бума́га

шатырдаган *прил. разг.* треску́чий (*мороз, холод, буран*); *~ суык төн иде* была́ холо́дная (с треску́чим моро́зом) ночь

шатырдап *нареч.* кре́пко, на́мертво; *~ кату* кре́пко затверде́ть, засо́хнуть; пересо́хнуть; *буяу ~ каткан краска* кре́пко засо́хла; *~ кибү* си́льно вы́сохнуть (*о белье*); перезре́ть (*о зерне*); *~ ябышу* кре́пко прили́пнуть, прилепи́ться; кре́пко (си́льно) прикле́иться; *см. тж.* **чытырдап ябышу**

шатырдату *перех.* производи́ть/произвести́ хруст, треск, шум *чем-л.*; хрусте́ть *чем-л.*; шурша́ть (*одеждой, платьем, бумагой*); *см. тж.* **шытырдату**

шатырдатып *нареч.* 1. с тре́ском; хру́стко, с хру́стом; *~ сындыру* слома́ть с тре́ском (*палку*); *~ киерелү* потяну́ться до хру́ста в суста́вах; *~ шалкан ашау* с хру́стом есть ре́пу; *шикәрне ~ чәйнәү* хрусте́ть са́харом, жева́ть с хру́стом са́хар 2. 1) я́сно и чётко, бы́стро и гро́мко, чека́нно (*читать, писать*), без запи́нки

(*рассказывать или читать наизусть*) 2) без ута́йки, не боя́сь (*рассказать всю правду*)

шатырд|ау *неперех.* треща́ть, хруте́ть; де́лать, производи́ться с тре́ском || треск, хруст; хруте́ние; *салкыннан бурәнәләр ~ый* от хо́лода треща́т брёвна; *коры ~ау ишетелде* послы́шался сухо́й треск □ **~ап торган** совсе́м но́вый, не изно́шенный, не мя́тый; хруста́щий; шурша́щий; с шурша́нием; *~ап торган яңа костюм* совсе́м но́вый костю́м; *~ап торган йөзлекләр* хруста́щие сторублёвки

шатыр-потыр, шатыр-пытыр *подр. см.* **шатыр-шотыр**; *шатыр-потыр яну* горе́ть с тре́ском, стреля́ть; *шатыр-потыр сөйләү* говори́ть бы́стро; треща́ть, болта́ть

шатырт *подр. резкому хрусту, треску* □ **~ итеп** с тре́ском; *таяк ~ итеп сынды* па́лка с тре́ском слома́лась; **~ итү** затреща́ть, захруте́ть

шатырт-шотырт *подр. повторяющемуся сильному треску, хрусту*; *шатырт-шотырт аталар* стреля́ют бах! бух!; *см. тж.* **шарт-шорт**

шатыр-шотыр, шатыр-пытыр *подр.* **1.** *повторяющемуся треску, потрескиванию*; *шатыр-шотыр ертыла* рвётся с тре́ском (*о крепкой ткани*); *шатыр-шотыр чыршы утыны яна* с тре́ском горя́т ело́вые дрова́; *шатыр-шотыр кук кукри* раска́тисто греми́т гром; *шатыр-шотыр килеп агач ауды* с потре́скиванием повали́лось де́рево **2.** *см.* **шарт-шорт**; *шатыр-шотыр мылтыклар атыла* раздаю́тся вы́стрелы: бах! бух!; *күпер шатыр-шотыр килде, ләкин җимерелмәде* мост треща́л, но вы́держал (не ру́хнул)

ша|у I *подр. шуму, беспорядочному гулу голосов, гаму* || *сущ.* шум, гам; *агачларның төнге шавы* ночно́й шум дере́вьев; *камыш шавы* шум камыше́й; *диңгез шавы* шум мо́ря; *машиналар шавы* шум маши́н □ **шау итү** шуме́ть, волнова́ться, поднима́ть/подня́ть шум; **шау килеп 1.** шу́мно, оживлённо (*спорить, разговаривать*) **2.** прекра́сно, хорошо́ (*жить, работать*); ве́село, дру́жно, бу́йно (*расти, созреть — о растениях*); **шау килү 1.** *см.* **шаулау 2.** *см.* **шау итү** ◊ **шау кубу** *см.* **шау итү**; зашуме́ть, заволнова́ться; **шау салу (куптару)** подня́ть шум, скандал

шау II *нареч.* **1.** целико́м, по́лностью; сплошь, весь; оди́н; *ишегалды шау камыш* во дворе́ одни́ камыши́; *алмагач шау чәчәктә* я́блоня в цвету́; *безнең район шау урман* наш райо́н сплошь в лесах, в на́шем райо́не сплошь леса́ **2.** совсе́м, соверше́нно; кру́глый; *шау ятим калу* оста́ться совсе́м (кру́глой) сиротой

шау III *прил. редко* чи́стый (без при́меси); *чыгарабыз шау алтын* добыва́ем чи́стое зо́лото; *шау көмеш кашык* ло́жка исключи́тельно из серебра́ (из чи́стого серебра́) □ **шау кайнар** горя́чий, кипя́щий (*о воде, молоке, супе и т. п.*); *шау кайнар су белән пешекләп алу* пропа́ривать крутым кипятко́м

шауберле *диал.* **I** *сущ.* реди́на *обл.*, ре́дкая (неплотная) ткань (*обычно домашнего производства; её готовили для савана*)

шауберле II *прил.* сли́шком просто́й, простова́тый до легкомы́сленности, простоду́шный; душа́ нараспа́шку; *~нең киеменә кадәр ~* (*погов.*) у просто́го челове́ка да́же пла́тье из реди́ны (*просвечивает, все видно*)

шау-гөж *подр. см.* **шау-гөр** □ **шау-гөж килү** *см.* **шау-гөр килү**

шау-гөр *подр. шуму и гаму, беспорядочному звучанию многих голосов* || *сущ.* шум и гам; *шәһәр шау-гөре артта калды* оста́лся позади́ городско́й шум и гам □ **шау-гөр килү** шуме́ть, галде́ть; *ишегалдында балалар шау-гөр килә* во дворе́ де́ти шумя́т (и галдя́т); **шау-гөр китерү** *см.* **шау-гөрләтү**

шау-гөрләтү *перех. см.* **шаулату**

шау-гөрләшү *неперех. см.* **шаулашу**

шау-гү *сущ. см.* **шау-гөр II**; *залдагы шау-гү* шум и гам в за́ле

шаударай I *сущ.* **1.** *ист.* шама́нская оде́жда-хала́т с побряку́шками, колоко́льчиками и т. п. **2.** *диал.* **1)** побряку́шка 2) (*~лар*) о бубенца́х и колоко́льчиках в сбру́е; *~лар тагып* нацепи́в бубенцы́ и колоко́льчики (*на сбруе*)

шаударай II *прил. уст.* просто́рный, обши́рный, широча́йший (*об одежде*); *~ чалбар* широча́йшие шарова́ры

шаудыр *сущ. см.* **шөлдер** (*бубенец*)

шаукым *сущ.* **1.** влия́ние, де́йствие, возде́йствие (*обычно отрицательное*); след, после́дствие *чего-л. или какого-л.* собы́тия; *см. тж.* **кәсәфәт**; *камалышта калуның ~ы* после́дствия окруже́ния; *гриппның ~ы бөердә калды* грипп дал осложне́ние на по́чки **2.** *уст.* боле́знь, по́сланная сверхъесте́ственной си́лой; влия́ние зло́го ду́ха; *~ булса, өшкертмичә китми* е́сли влия́ние зло́го ду́ха, то на́до вы́гнать за́говорами **3.** *перен. разг.* страсть, нестерпи́мое стремле́ние *к чему-л.*; увлече́ние *чем-л.*; зуд *прост.*; *ат ~ы кагылу* (*тию, төшү*) страсть к лошадя́м; увлече́ние лошадьми́; *иҗат ~ы* твóрческое увлече́ние ◊ **~ белән 1.** не поду́мав; ни с того́ ни с сего́, с бу́хты-бара́хты **2.** под впечатле́нием; взволно́ванно (*говорить, предложить*); *~ белән сөйләү* взволно́ванно расска́зывать; **~ кагылу (тию, сугу) 1.** заболе́ть (*под влиянием злого духа*), подве́ргнуться влия́нию зло́го ду́ха; *см. тж.* **зәхмәт кагылу 2.** влия́ть, возде́йствовать, оказа́ть (*отрицательное*) влия́ние; **~ салу 1.** повреди́ть; подверга́ть вре́дному возде́йствию **2.** соблазня́ть, искуша́ть; дья́вольски влия́ть; **~га ияреп (эләгеп)** под влия́нием (*мод, какого-л. течения и т. п.*); **~га эләгү (ияру) 1.** попада́ть под влия́ние *кого-чего-л.*; поддава́ться, подверга́ться влия́нию *кого-чего-л.* **2.** впада́ть в искуше́ние (в собла́зн)

шаукымлан|у *неперех.* **1.** *см.* **шаукым кагылу**; *юеш җирдә йоклап ~ган* заболе́л по́сле сна на сыро́й земле́ **2.** *в знач. нареч.* **шаукымланып** *в знач. нареч. см.* **шаукым белән**; *~ып сөйли бирде* взволно́ванно всё говори́л и говори́л

шаукымлы *прил. разг.* **1.** вре́дно (*отрицательно*) де́йствующий; нерви́рующий; по́ртящий настрое́ние (*о слове, тайне, случае и т. п.*); *~ хәл* нерви́рующая обстано́вка **2.** трево́жный, тяжёлый, рокову́ю; *шул ~ елларда* в те роковы́е го́ды

шаулама *сущ. разг.* медо́к, бра́га (*хмельная, домашнего приготовления на дрожжах*)

шаулап *нареч.* **1.** бу́йно, бу́рно, дру́жно (*расти, цвести, распускать почки, покрываться и т. п.*); *~ яфрак яра ак каен* бу́рно распуска́ет бе́лая берёза ли́стья **2.** оби́льно, в огро́мном коли́честве; пото́ком, си́льно (*течь, идти*); *~ яңгыр коя* идёт проливно́й дождь; *ярадан ~ кан ага* из ра́ны пото́ком течёт кровь

шаулат|у *перех.* **1.** *понуд. от* **шаулау**; *агачларны җил ~а* ве́тер вызыва́ет шум дере́вьев **2.** поднима́ть/подня́ть шум; вызыва́ть/вы́звать *где-н.*; *урамнарны ~у* подня́ть шум на у́лицах **3.** нашуме́ть; вызыва́ть/вы́звать шум (то́лки, разгово́ры); привле́чь всео́бщее внима́ние;

бөтен шәһәрне ~у взбудора́жить весь го́род; *дөньяны ~кан вакыйга* гро́мкое собы́тие **4.** *разг.* подогре́ть; *тиз генә самавыр ~тылар* бы́стренько подогре́ли самова́р

шаулатып *нареч.* **1.** шу́мно, с шу́мом; дру́жно; *~ яңгыр коярга тотынды* с шу́мом начался́ ли́вень; *~ кул чаптылар* дру́жно (шу́мно) аплоди́ровали **2.** *перен. разг.* сла́вно, прекра́сно, превосхо́дно, отли́чно; *~ туй иттек* прекра́сно спра́вили сва́дьбу; *машинаң ~ тегә* маши́на твоя́ шьёт отли́чно

шаул|ау *неперех.* **1.** шу́мно разгова́ривать, шуме́ть, галде́ть *прост.* || шум, галдёж *прост.*; *~амагыз әле, иптәшләр* не шуми́те (ти́ше), това́рищи; *~ап алу* пошуме́ть, погалде́ть; *~амыйча бал да ачымый* (*погов.*) без шу́ма и бра́га не заки́снет **2.** гро́мко шелесте́ть, си́льно шурша́ть, издава́ть шум; гуде́ть (*о лесе*); *агачлар ~ый* шумя́т дере́вья **3.** рокота́ть, грохота́ть, громыха́ть || ро́кот, гро́хот; *ерактан трактор ~авы ишетелде* издалека́ слы́шен ро́кот тра́ктора **4.** закипа́ть; закипа́я, петь; гуде́ть, шипе́ть до вскипа́ния; *см. тж.* **гөжләү**; *самавыр ~ый башлады* самова́р загуде́л **5.** *перен. разг.* шуме́ть, брани́ться, скандали́ть, тре́бовать; *ни дип ~ыйсың?* что ты шуми́шь (скандали́шь)? *~ар да туктар* пошуми́т да и переста́нет **6.** *перен. разг.* шуме́ть, подня́ть шум *о чём*, подня́ть вопро́с *о чём*, мно́го говори́ть *о чем*; трезво́нить, звони́ть во все колокола́; *аның батырлыгы турында газеталарда ~адылар* о его́ герои́зме шуме́ли (мно́го писа́ли) в газе́тах; *булыр-буллмас эш турында алдан ~ама* (*посл.*) ≈ не говори́ гоп, пока́ не перепры́гнешь; де́ло знай, а по́пусту не болта́й **7.** *перен.* просла́виться, станови́ться/стать популя́рным, изве́стным; *артистканың ~аган еллары иде* то бы́ли го́ды, когда́ арти́стка ста́ла популя́рной **8.** звене́ть, шуме́ть (*в ушах, в голове*) || звон, шум, трезво́н (*в ушах, в голове, в мозгу*); *колагым ~ый* шуми́т (звени́т) в уша́х, чу́вствую шум в уша́х **9.** *в отриц. ф.* **шаулама** 1) молча́ть, промолча́ть, храни́ть в та́йне *что-л.* || молча́ние *о чём*; *син ~амасаң, мин ~амам* если ты промолчи́шь, смолчу́ и я; 2) *разг. в знач. вводн. сл.* **шаулама** ти́хо, молчо́к, молчи́!; погоди́; *~ама, без дигәнчә була* погоди́, всё бу́дет по-на́шему □ **~ый башлау** зашуме́ть, загалде́ть ◊ **~ап йөрү** 1. шуме́ть, поднима́ть шум 2. раструби́ть, болта́ть *о чём*; **~ап торган** 1. шу́мный, бу́йный, бу́рный (*о жизни*) 2. сли́шком горя́чий, кипя́щий (*чай, суп и т. п.*); **~ап тору** кипе́ть жи́знью (*о коллективе, каком-л. заведении*)

шаулаучан *прил.* шумли́вый, скло́нный (лю́бящий) пошуме́ть, поскандали́ть; *хатын-кыз — ~ халык* же́нщины — наро́д, лю́бящий поскандали́ть

шаулаш *сущ. разг.* шум, гам, галдёж *прост.*; *бүлмәдә көнозын көлеш, ~* в ко́мнате це́лый день смех, галдёж; *сөйләш китте, ~ китте* пошли́ разгово́ры, шум

шаулаш|у *совм.* **1.** *от* **шаулау** 1, 6 (*о многих*); *халык ~а башлады* наро́д зашуме́л; *~магыз* не шуми́те, ти́ше **2.** *разг. см.* **талашу**; сосо́риться, поссо́риться, скандали́ть, поскандали́ть, пошуме́ть; *нигә ~тыгыз, нигә бозылыштыгыз тагын?* из-за чего́ поскандали́ли, отчего́ произошёл разла́д?

шаулы *прил.* **1.** шу́мный, шумли́вый; *~ уеннар* шу́мные и́гры **2.** бу́рный, бурли́вый; бушу́ющий **3.** шу́мный, скандали́ный, спо́рный (*вопрос и т. п.*); *~ мәсьәләләрне хәл итү* реши́ть спо́рные вопро́сы **4.** трево́жный, беспоко́йный, бу́рный (*день, год, момент и т. п.*); *безнең яшьлек ~ елларга туры килде* на́ша ю́ность пришла́сь на трево́жные го́ды

шау-шу *сущ. собир.* **1.** шум, гам, шум-гам, гвалт, го́мон, галдёж, бу́ча *прост.*; *тормыш шау-шуы* жите́йский шум; *базардагы шау-шу* шум на база́ре **2.** сумато́ха, сумя́тица, суета́, беспоря́док, возня́, катава́сия *прост.*; *бәйрәм шау-шуында* в пра́здничной сумя́тице; *бугенге көн шау-шү эчендә үтте* сего́дняшний день прошёл в сумато́хе **3.** спор, диску́ссия (*шумная*), препира́тельство; перебра́нка, скандал, дебо́ш, буза́ *прост.*; *шау-шу китәр, буталырлар* пойду́т спо́ры, возни́кнет замеша́тельство **4.** *разг.* шуми́ха; бум, ажиота́ж; *газеталар шау-шуы* газе́тная шуми́ха; газе́тный бум ◊ **шау-шу арасында** под шумо́к; **шау-шу килү** *см.* **шаулашу**; **шау-шу китү** *см.* **шау-шу кубу**; **шау-шу кубу** 1. подня́ться (*о шуме, гаме, гвалте*) 2. подня́ться (*о ссоре, скандале*), загора́ться (*о споре*), разыгра́ться (*о скандале*) 3. подня́ться (*о суматохе, переполохе*); загоре́ться (*о сыр-боре*); **шау-шу кузгалу (күтәрелү)** *см.* **шау-шу кубу**; **шау-шу күтәрү (куптару)** 1. поднима́ть/подня́ть шум (возню́); шуме́ть, всполоши́ться, взгомони́ться *прост.* 2. поднима́ть/подня́ть скандал (перепол6х, бу́чу *прост.*); вызыва́ть/вы́звать ссо́ру, спор; скандали́ть, бузи́ть 3. раструби́ть, наде́лать шу́му; *бу әсәр турында шау-шу күтәрделәр* вокру́г э́того произведе́ния подня́ли шуми́ху

шау-шулану *неперех. см.* **шау-шуга күмелү**; *өй эче шау-шулана* дом наполня́ется шу́мом

шау-шулау *неперех.* подня́ть шум-гам; шуме́ть, галде́ть □ **шау-шулап алу** пошуме́ть, погалде́ть; **шау-шулап үтү (үтеп китү)** проходи́ть/пройти́ шу́мно (с шу́мом); *бәйрәмнәр шау-шулап үтеп тә китте* уже́ прошуме́ли пра́здники

шау-шулы *прил.* **1.** 1) шу́мный, шумли́вый; *шау-шулы бала* шумли́вый ребёнок; *шау-шулы бәхәс* шу́мный спор 2) шу́мный, напо́лненный шу́мом, оживле́нием (*день, город, дом, вечер и т. п.*) **2.** скандальный; спо́рный; *шау-шулы вакыйга* скандальный слу́чай **3.** беспоко́йный, трево́жный, су́етный; *шау-шулы вә мәшәкатьле көннәр* беспоко́йные и хлопотли́вые дни; *шау-шулы бер чорда яшәү* жить в са́мое беспоко́йное вре́мя

шау-шусыз *нареч.* **1.** ти́хо, бесшу́мно, незаме́тно (*пройти, подойти, остановиться и т. п.*) **2.** ти́хо, ми́рно, без скандало́в, без спо́ров; *җыелыш шау-шусыз гына үтте* собра́ние прошло́ без спо́ров; *шау-шусыз гына яшәү* жить ти́хо и ми́рно || *прил.* **1.** ти́хий, бесшу́мный; *шау-шусыз урам* ти́хая у́лица **2.** ти́хий, споко́йный, ми́рный; *шау-шусыз тормыш* ти́хая (споко́йная) жизнь

шафран *сущ.* шафра́н (*сорт яблони и её яблоки*) || шафра́нный; *~ алма* шафра́нное я́блоко

шах *сущ.* шах (*в шахматной игре*); *корольгә шах* шах королю́; *шах ясау* (*бирү, белдерү*) дать (сде́лать, объяви́ть) шах; шахова́ть

шахер-махер, шахыр-махыр *сущ. прост.* ша́хер-ма́хер (*мошенническая сделка*) || ша́хер-ма́херский; *менә сиңа шахер-махер кенәгән* вот тебе́ твоя́ ша́хер-ма́херская кни́жка (*записи*) □ **шахер-махер китерү (кору)** 1. занима́ться ша́хер-ма́херством, моше́нничеством; моше́нничать 2. ша́хер-ма́херство

ша́хмат *сущ.* ша́хматы (*игра и набор фигур*) || ша́хматный; *~ны төзеп чыгу* расста́вить ша́хматы; *~ буенча мастер* ма́стер по ша́хматам; *~ уйнау* игра́ть в ша́хматы; *~ фигуралары* ша́хматные фигу́ры; *~ партиясе* ша́хматная па́ртия; *~ ярышы* ша́хматный матч, ша́хматный турни́р □ **~ сәгате** ша́хматные часы́; **~ тактасы** ша́хматная доска́, ша́хматница ◊ **~ йөреше** ша́хматный ход;

~ йөреше белән ша́хматным хо́дом; **~ тәртибендә (тәртибе белән)** ша́хматный, в ша́хматном поря́дке; *~ тәртибендә урнашу* ша́хматное расположе́ние

ша́хматлы *сущ.* игра́ в ша́хматы; *~ уйнау разг.* игра́ть (игра́) в ша́хматы

ша́хматчы *сущ.* шахмати́ст, шахмати́стка; *мәктәп ~лары* шко́льные шахмати́сты; *разрядлы ~* шахмати́ст-разря́дник

ша́хта *сущ.* **1.** *в разн. знач.* ша́хта || ша́хтный, ша́хтенный, ша́хтовый; *Донбасс ~лары* доне́цкие ша́хты; ша́хты Донба́сса; *метро төзелеше ~сы* ша́хта строи́тельства метро́; *лифт ~сы* ша́хта ли́фта; *~га төшү* спусти́ться в ша́хту; *~ транспорты* ша́хтный тра́нспорт; *~ эшчесе* ша́хтовый рабо́чий; шахтёр **2.** шахто-; *~ идарәсе* шахтоуправле́ние; *~ төзүче* шахтострои́тель ◻ **~ авызы** у́стье ша́хтового ствола́; **~ үзәге** ствол ша́хты; ша́хтовый ствол

ша́хталы *прил.* ша́хтный, с ша́хтой; *~ мич* ша́хтная печь

шахтёр *сущ.* шахтёр, шахтёрка || шахтёрский; *~ лампасы* шахтёрская ла́мпа, шахтёрка; *~лар посёлогы* посёлок шахтёров; шахтёрский посёлок

шахтёрка *сущ.* шахтёрка (*шахтёрская лампа и шахтёрская одежда, спецовка*)

шаһ *сущ.* **1.** *ист.* 1) шах || ша́хский; *Иран шаһы* шах Ира́на; *шаһ төхете* ша́хский престо́л 2) любо́й мона́рх; царь; *Борис шаһ* царь Бори́с (Годуно́в) **2.** *перен.* патриа́рх, глава́; са́мое гла́вное лицо́; гла́вный представи́тель; коро́ль, королева; царь, царица; *роза — гөлләр шаһы* ро́за — королева цвето́в; *татар поэзиясенең шаһы* патриа́рх тата́рской поэ́зии ◻ **шаһлар шаһы** шахиншах; главне́йший шах, царь царе́й

шаһәдәт *сущ. уст. см.* **шаһитлык**; *кемгә кирәк ~ең?* кому́ ну́жно твоё свиде́тельство (засвиде́тельствование)? ◻ **~ бармагы** *уст.* указа́тельный па́лец; **~ бирү** *уст. см.* **шаһитлык бирү**; **~ китерү**; произноси́ть слова́ исповеда́ния ислама́; *см. тж.* **иман китерү**

шаһәдәтнамә *сущ. уст.* свиде́тельство (*документ*), удостовере́ние; *туу ~се* свиде́тельство о рожде́нии; *белем ~се уст.* свиде́тельство об образова́нии; дипло́м, аттеста́т

шаһбаз *сущ. уст. в разн. знач.* **1.** со́кол || соко́лий, соколи́ный; *см. тж.* **лачын**; *ау ~ы см.* **шаһин 2.** *перен.* хра́брый мо́лодец; *~ ирләр* со́колы, молодцы́, храбрецы́, удальцы́

шаһзадә *сущ. уст.* сын, пото́мок (обы́чно насле́дник) ша́ха, принц

шаһи I *прил.* ша́хский, ца́рский; *~ мәҗлес* ца́рский сове́т

шаһи II *сущ. ист.* роско́шный хала́т — ца́рский (ха́нский) пода́рок

шаһин *сущ. уст.* охо́тничий со́кол; бе́лый со́кол

шаһинә *сущ.* шахи́ня (*жена шаха*)

шаһиншаһ *сущ.* шахиншах, главне́йший шах, царь царе́й || шахиншаха́ский

шаһит *сущ.* **1.** *юр.* свиде́тель, свиде́тельница || свиде́тельский; *~ларны чакырту* затре́бовать свиде́телей; *җинаятьнең ~ы* очеви́дец (свиде́тель) преступле́ния; *ялган ~* лжесвиде́тель; *~ курсәтүләре* свиде́тельские показа́ния **2.** свиде́тель, свиде́тельница; очеви́дец, очеви́дица; наблюда́тель, наблюда́тельница *чего-л.*; *бу тарихи көннәр ~ы* очеви́дец э́тих истори́ческих дне́й **3.** *перен.* свиде́тель (*о предметах*); *яшьләр мәхәббәтенең ~ы булган бу өянкеләр* э́ти и́вы — свиде́тели любви́ молоды́х; *минем балачакның ~ы булган урыннар* места́, кото́рые бы́ли свиде́телями моего́ де́тства **4.** *перен.* свиде́тельство; доказа́тельство (*подтверждающее что-л., явление, предмет*); *күз яшьләре аның хаклыгына ~* слёзы подтвержда́ют, что он прав, доказа́тельство его́ правоты́ **5.** *этногр.* свиде́тель, свиде́тельница (*во время бракосочетания*); *кызның ризалыгы турында ~ның җавабы* слова́ свиде́теля о согла́сии неве́сты; *кияү ягыннан килгән ~* свиде́тель со стороны́ жениха́

шаһитлык *сущ.* **1.** свиде́тельство; свиде́тельские показа́ния; свиде́тельствование || свиде́тельский; *~ бурычлары* свиде́тельские обя́занности; *ялган ~* лжесвиде́тельствование ◻ **~ бирү (итү) 1.** *юр.* быть свиде́телем на суде́ **2.** свиде́тельствовать, засвиде́тельствовать, подтвержда́ть *что-л.*; дава́ть/дать свиде́тельские показа́ния; **~ка чакыру** приглаша́ть (вызыва́ть) свиде́телем (в свиде́тели)

шаһлы|к *сущ. ист.* **1.** ша́хство, положе́ние ша́ха; ца́рствование || ша́хский; *~гында озак тормады* не до́лго был ша́хом; *~к дәрәҗәсе* ша́хское зва́ние **2.** ша́хство; владе́ния (госуда́рство) ша́ха ◻ **~к сөрү 1.** быть ша́хом, ца́рствовать **2.** *перен.* хозя́йничать; госпо́дствовать, главе́нствовать

шаһнамә *сущ. ист.* шахнаме́, кни́га царе́й (*историческое описание династии и отдельного правителя*)

шаһнамәче *сущ. ист.* историо́граф, опи́сывающий (*обычно в стихах*) исто́рию *какой-л.* дина́стии прави́телей

ша́шка I *сущ.* ша́шки (*игра*) || ша́шечный; *~ уйнау* игра́ть в ша́шки; игра́ в ша́шки; ша́шка (*фигура в игре*); *~ турниры* ша́шечный турни́р ◻ **~ тактасы** ша́шечная доска́; ша́шечница *уст.*

ша́шка II *сущ. спец.* ша́шка; *шартлаткыч ~* подрывна́я ша́шка; *төтен ~сы* дымова́я ша́шка; *динамит ~сы* динами́тная ша́шка

ша́шкачы *сущ. спорт.* шаши́ст, шаши́стка; *~лар һәм шахматчылар турниры* турни́р шаши́стов и шахмати́стов

шашкын *прил.* **1.** бу́рный, стра́стный, пы́лкий, поры́вистый; *~ йөрәк* пы́лкая душа́; *~ хисләр* пы́лкие чу́вства; *~ дәрт* бу́рные стра́сти; *~ мәхәббәт* стра́стная любо́вь; *~ холык* поры́вистый хара́ктер **2.** бе́шеный, нейстовый; *~ кыяфәттә* как бе́шеный; *~ халык төркеме* бе́шеная толпа́; *~ комсызлык* нейстовая жа́дность; *~ кирелек* нейстовое упо́рство **3.** бу́рный, поры́вистый, стреми́тельный, я́ростный, неукроти́мый; *~ тау дәрьясы* бу́рная го́рная река́; *~ җилләр* я́ростные ве́тры

шашкынлык *сущ.* **1.** страсть, стра́стный поры́в; *тыелгысыз ~* необу́зданная страсть; непреодоли́мый пыл (поры́в) **2.** ди́кая быстрота́, стреми́тельность (*течения, движения, ручья, горной реки*) ◻ **~ белән** со стра́стью, стра́стно

шашлык *сущ.* шашлы́к || шашлы́чный; *сарык итеннән кыздырылган ~* шашлы́к из бара́нины; *~ка гарнир* гарни́р к шашлыку́; *~ ите* шашлы́чное мя́со, мя́со на шашлы́к

шашлыкчы *сущ.* ма́стер по приготовле́нию шашлыка́; тот, кто гото́вит (жа́рит) шашлы́к и продаёт; рабо́тник шашлы́чной

шаштырдавык(лы) *прил. см.* **шыштырдавык(лы)**

шаштырдату *перех. см.* **шыштырдату**

шаштырдау *неперех. см.* **шыштырдау**

шаштырдашу *совм. от* **шыштырдау**

шаштыр|у 1. *понуд. от* **шашу**; *акылдан ~у* свести́ с ума́; *шул сүзләрең белән ~ырсың инде мине* э́тими слова́ми ты меня́ с ума́ сведёшь 2. *перех.* беси́ть, взбеси́ть, взбелени́ть, выводи́ть/вы́вести *кого-л.* из себя́; *см. тж.* **җенләндерү**

шаштыр-поштыр 1. *подр.* шурша́нию, ша́рканью, шо́роху от движе́ния, тре́ния, соприкоснове́ния *чего-л. с чем-л.*; *см. тж.* **чаштыр-чоштыр**; *агачлар арасында кемдер шаштыр-поштыр йөри* ме́жду дере́вьями кто́-то шу́мно хо́дит; *шаштыр-поштыр атлау* ходи́ть ша́ркающими шага́ми 2. *см.* **шыштыр-шыштыр**; *шаштыр-поштыр китап актару* с шу́мом перели́стывать кни́гу; *шаштыр-поштыр йөрү* ходи́ть шурша́

шаш|у *неперех.* 1. сойти́ с ума́, лиши́ться здра́вого рассу́дка, ума́; помеша́ться; одуре́ть, ошале́ть; *кайгыдан ~а язу* чуть не помеша́ться от го́ря 2. беси́ться, беснова́ться (*от радости, гнева, горя и т. п.*), приходи́ть/прийти́ в бе́шенство, в я́рость (*от гнева*); разъяря́ться/разъяри́ться; выходи́ть/вы́йти из себя́, быть вне себя́; *ачудан ~у* разъяри́ться от гне́ва; *шатлыгым чиксез, ашкынам, ~ам* ра́дость моя́ безграни́чна, рвусь и бешу́сь я 3. бушева́ть, разбушева́ться, свире́пствовать, яри́ться (*о стихиях, о природных явлениях*); *урынсызга, җилләр, ~магыз* без причи́ны не свире́пствуйте, ве́тры; *диңгез дулый, диңгез ~а* бушу́ет мо́ре, свире́пствует 4. беси́ться, резви́ться, дура́читься, вози́ться, шали́ть без у́держу, вести́ себя́ бу́йно (*обычно о детях, молодежи*); *~магыз әле, балалар* не беси́тесь, де́ти 5. си́льно увлека́ться *чем-л.*; быть одержи́мым; *фән дип ~у* быть одержи́мым стра́стью к нау́ке 6. *диал.* торопи́ться, заторопи́ться; *тукта, ~ма* погоди́, не торопи́сь; *~ырсың, җилкәңне кашырсың* (*посл.*) бу́дешь торопи́ться — придётся почеса́ть заты́лок (т.е. раска́яться) 7. *в знач. нареч.* **шашып** 1) с аза́ртом, с задо́ром, задо́рно, увлечённо; бе́шено, с исступле́нием, со стра́стью, с я́ростью; *~ып бию* плеса́ть с аза́ртом, с исступле́нием; *~ып җырлау* петь со стра́стью; *~ып гармунда уйнау* с аза́ртом игра́ть на гармо́ни; *~ып эшләү* рабо́тать исступлённо 2) стра́стно, безу́мно, до безу́мия; *~ып ярату* (*сөю*) люби́ть безу́мно (до безу́мия); *~ып үбү* осыпа́ть (покрыва́ть) стра́стными поцелу́ями 3) я́ростно, неукроти́мо; нейстово; *~ып искән җил* нейстовый ве́тер; *тау елгасы ~ып ага* го́рная река́ течёт неукроти́мо □ **~ып алу** побеси́ться, подури́ть, пошали́ть (*немного*); **~ып китү** 1. взбеси́ться; забы́ться, вы́йти из себя́; переборщи́ть 2. раздура́читься, расшали́ться

шашынганлык *сущ.* исступлённость

шашындыр|у 1. *понуд. от* **шашыну**; дать возмо́жность (позво́лить) нейстовствовать, зве́рствовать 2. *см.* **шаштыру**; *аның соңгы сүзе мине ~ып җибәрде* его́ после́днее сло́во меня́ соверше́нно взбеси́ло

шашын|у *неперех.* 1. нейстовствовать, проявля́ть/прояви́ть нейстовство, зве́рство; распоя́сываться/распоя́саться (*об отряде карателей и т. п.*) || нейстовство 2. беси́ться, беснова́ться; приходи́ть/прийти́ в бе́шенство (в я́рость), разъяри́ться; рассвирепе́ть; *~ган халык төркеме* разъяри́вшаяся толпа́ наро́да □ **~ган хәлдә** в исступле́нии, исступлённый; кра́йне возбуждённый, нейстовствующий; в исте́рике, в бе́шенстве; **~ып китү** разбеси́ться, рассвирепе́ть

шашынулы *прил.* истери́ческий, истери́чный (*смех, хохот, плач и т. п.*)

шаян *прил.* 1. шаловли́вый, озорно́й; шутли́вый (*о человеке*); ре́звый *разг.*; *~ малай* озорно́й (шаловли́вый) ма́льчик; *~ мәче* шаловли́вая ко́шка 2. шутли́вый, шаловли́вый, озорно́й, лука́вый; *~ елмаю* лука́вая улы́бка; *~ күзләр* озорны́е глаза́; *~ табигатьле кеше* челове́к шутли́вого нра́ва (скла́да); челове́к, лю́бящий шути́ть; *~ тонда* в шутли́вом то́не 3. шу́точный, шутли́вый; *~ җырлар* шу́точные пе́сни, пе́сни-прибау́тки 4. о́стрый, злой; *~ телләр* о́стрые языки́ 5. *перех.* озорно́й, шаловли́вый, скло́нный к ша́лостям, шально́й; *язмышның ~ җилләре* шальны́е ве́тры судьбы́; *кояшның ~ нурлары* озорны́е лучи́ со́лнца || *сущ.* шутни́к, шутни́ца, шалу́н, шалу́нья, прока́зник, прока́зница; резву́нья, резву́шка; *авылның ~нары* дереве́нские шутники́ || *нареч.* шутли́во, лука́во (*смотреть, улыбаться и т. п.*); *~ елмаю* улыба́ться лука́во

шаянлан|у *неперех.* 1. станови́ться/стать шаловли́вым, озорны́м, 2. шали́ть, озорнича́ть, прока́зничать, балова́ться; *~ырга тотыну* нача́ть шали́ть (озорнича́ть); *~ып чәчтән тарту* прока́зничая, дёргать за во́лосы 3. отража́ть/отрази́ть, выража́ть/вы́разить озорство́, лука́вство (*о глазах*) || озорство́, лука́вство, ша́лость; *күзләре ~ып яна* глаза́ горя́т с озорство́м (лука́во) □ **~а төшү** станови́ться/стать бо́лее шаловли́вым (озорны́м, ре́звым); **~ып китү** стать озорны́м, шалуно́м;

шаянлы|к *сущ.* 1. шаловли́вость, озорство́, ре́звость; *балалар ~гы белән* де́тским (ребя́ческим) озорство́м 2. озорство́, лука́вство (*в конкретном проявлении*), лука́винка; *кызның карашындагы ~к* озорство́ во взгля́де де́вушки; *ягымлы ~к белән* с ми́лым лука́вством 3. ша́лость, озорство́; заба́ва, баловство́, прока́за; проде́лки; *балачакның гамьсез ~клары* неви́нные ша́лости де́тства

шаяргала|у *многокр. от* **шаяру** 1—10; *~рга ярата* лю́бит поозорнича́ть; *җил ~п куя* времена́ми ве́тер поша́ливает; *йөрәк ~п тора* се́рдце поша́ливает

шаяргалаштыру *многокр. см.* **шаяргалау**; *тәмәке белән ~* поку́ривать (*иногда*)

шаярткала|у *многокр. от* **шаярту** I; *~у гадәте* привы́чка пошути́ть □ **~п кую** пошу́чивать

шаярт|у I *перех.* 1. *понуд. от* **шаяру** 1, 2; *баланы ~у* игра́ть с ребёнком (*букв.* дать ребёнку поигра́ть) 2. игра́ть, шути́ть; *~алар дип уйладым* ду́мал, что шу́тят 3. зайгрывать, шути́ть, шуткова́ть *прост.*, подшу́чивать/подшути́ть *над кем-л., чем-л.*; подтру́нивать/подтруни́ть, насмеха́ться *над кем-л., чем-л.*; *~а белү* уме́ть шути́ть (пошути́ть, подшути́ть); *~ырга ярату* люби́ть подшути́ть (подтру́нивать, посмея́ться) 4. *разг. в отриц. ф.* **шаяртмау** I; не дава́ть во́льничать; бы́стро унима́ть/уня́ть; пристру́нивать/пристру́нить; *ул сезне бик ~мас* он вас бы́стро уймёт □ **~кан булу** подтру́нивать/подтруни́ть (*нарочно*); **~ып алу** пошути́ть (подшути́ть) *над кем-чем-л.*

шаярту II *сущ.* 1. шу́тка; (*сүзне*) *~га алу* приня́ть (*чьё-то слово*) за шу́тку; (*сүзне*) *~га бору* обрати́ть *что* (*чьё-то слово*) в шу́тку; *усал ~* зла́я шу́тка; *~ларны куеп торыйк* шу́тки в сто́рону, не до шу́ток; шу́тка шу́ткой (шу́тки шу́тками) 2. игри́вость; *самими ~* наи́вная игри́вость

шаяртулы *прил.* шутли́вый, шу́точный, игри́вый; *~ тонда* в шу́точном то́не; *~ сорау* шутли́вый вопро́с; *~ сүз* шутли́вое сло́во

шаяртусыз *нареч.* серьёзно, на (по́лном) серьёзе; без шу́ток, кро́ме шу́ток; не шутя́; без сме́ха; *~ гына эйт әле, дөресме?* скажи́, пожа́луйста, без шу́ток, пра́вда ли (э́то)?

шаяртучан *прил.* лю́бящий подшути́ть, име́ющий привы́чку подшути́ть (посмея́ться, насмеха́ться) *над кем-л., чем-л.*

шаяртучы *сущ.* шутни́к; тот, кто лю́бит подшу́чивать, посмея́ться *над кем-л., чем-л.*

шаяртучылык *сущ.* 1. сво́йство быть шутнико́м, люби́ть подшути́ть *над кем-л., чем-л.* 2. шу́тка, шу́тки; *~ны яратмау* не люби́ть шу́ток

шаяртып *нареч.* шутя́, в шу́тку; для шу́тки, ра́ди шу́ток (сме́ха, заба́вы); *~ кына әйтү* говори́ть шутя́

шаяртыш|у *взаимно-совм. от* **шаярту**; шути́ть, игра́ть; подшу́чивать, подтру́нивать друг над дру́гом; обме́ниваться (переки́дываться) шу́тками, перешу́чиваться; *~а башлау* нача́ть перешу́чиваться

шаяр|у *неперех.* 1. игра́ть, резви́ться, весели́ться || игра́, весе́лье; *балалар кебек ~у* весели́ться, как де́ти; *ишегалдында ~у* резви́ться во дворе́ 2. шали́ть, озорнича́ть; дура́читься, дури́ть || ша́лость, озорство́, баловство́; *әнисе улын киендерә, малай ~а* мать одева́ет сы́на, а он шали́т 3. шути́ть (*говорить или делать ради шутки, забавы*) || шу́тка; *~ма, үпкәләтерсең* не шути́, оби́дишь; *~ыр вакыт түгел* не до шу́ток; не́когда шути́ть; *~ырга яратсаң, ~тканга түзәрсең* (*посл.*) лю́бишь шути́ть, люби́ и шу́тки над собо́й; *~уларыңны куеп тор* шу́тки в сто́рону 4. шути́ть *чем-л.*; пренебрега́ть, пренебре́чь || шу́тка; пренебреже́ние; *халык ышанычы белән ~мыйлар* наро́дным дове́рием не шу́тят; *мәхәббәт белән ~ырга ярамый* нельзя́ шути́ть любо́вью; любо́вью не шу́тят 5. *перен.* игра́ть/пойгрывать, бушева́ть, капри́зничать (*чаще о природных явлениях*) || игра́, капри́з; *язмыш ~уы* игра́ судьбы́ (слу́чая); *табигать ~уы* капри́зы приро́ды; *агач башларында җил ~а* на верху́шках дере́вьев игра́ет ве́тер; *бүген диңгез ~а* сего́дня мо́ре игра́ет 6. *см.* **шаярту** 3; *яратасыңмы, ~мыйсыңмы?* лю́бишь, не шу́тишь? 7. *перен.* шути́ть, игра́ть, вести́ (*злую, опасную игру*) *с кем* || (*злая, опасная*) игра; пристанание *к кому-л.*; *башың иске булмаса, минем белән ~ма* е́сли жизнь не надое́ла, со мной не шути́ 8. *перен. разг.* шали́ть, пло́хо де́йствовать, пло́хо рабо́тать; *йөрәк ~а* се́рдце шали́т; *бавыр һәм бөерләр ~а башлаган* не́чень и по́чки на́чали шали́ть 9. *перен. прост.* зайгрывать; пошáливать, шали́ть (*быть в любовных отношениях*) || зайгрывание; *егетләр белән ~у* зайгрывать с парня́ми 10. *прост.* увлека́ться, ба́ловаться (*чем-л. предосудительным*) || увлече́ние, баловство́; *аракы белән ~у* люби́ть выпива́ть; *кесәгә керү белән ~у* люби́ть вороваáть, увлека́ться карма́нной кра́жей 11. *в отриц. ф.* **шаярмау** не шути́ть, относи́ться серьёзно *к кому-чему-л.*; *ут белән ~мыйлар, ук белән уйнамыйлар* (*погов.*) с огнём не шу́тят, со стрело́й не игра́ют 12. *в повел. ф. с отриц.* **шаярма** *вводн. сл.* шали́шь; не шали́, не дури́; не забыва́йся; *~ма, мин алдатмам* шали́шь, меня́ не обману́ть; *~ма, ул хәзер зур кеше* не забыва́йся, он тепе́рь большо́й челове́к (нача́льник)

шаярулы *прил.* 1. *см.* **шаяртулы**; *~ тон* шутли́вый тон; *~ җыр* шу́точная пе́сня 2. игри́вый, шутли́вый; несерьёзный (*взгляд*); *~ елмаю* шутли́вая улы́бка

шаярусыз *нареч. см.* **шаяртусыз**; *һич ~ әйтәм* говорю́ на по́лном серьёзе

шаяручан *прил.* 1. лю́бящий поигра́ть (порезви́ться); лю́бящий озорнича́ть; *~ малайларны алдагы парталарга күчереп утырту* пересади́ть озорны́х ма́льчиков за пере́дние па́рты 2. шаловли́вый, шутли́вый; лю́бящий шали́ть, прока́зничать, скло́нный к ша́лостям, к шу́ткам (*о человеке*)

шаяручанлык *сущ.* 1. игри́вость; живо́й (весёлый) нрав; ре́звость 2. ша́лость, озорство́

шаяручы *сущ.* озорни́к; шутни́к; *~ларга кисәтү ясау* сде́лать замеча́ние озорника́м

шаярын|у *неперех. см.* **шаяру**, **шаяргалау**; *~ып барганга юл кыска тоелды* с шу́тками доро́га показа́лась коро́ткой

шаярып *нареч.* (*преимущ. с частицей* кына) 1. шутя́, легко́, без труда́, без уси́лий, не замеча́я тя́гот; *капчыкларны ~ кына алып ыргыта* легко́ (без уси́лий) перекла́дывает мешки́; *~ кына эшләнгән эш* нетру́дная, шутя́ вы́полненная рабо́та; плёвое де́ло 2. наро́чно, шутя́, в шу́тку; *~ кына әйткән идем* сказа́л про́сто в шу́тку; *~ әйтмим!* кро́ме шу́ток! без шу́ток! серьёзно

шаярышу *совм. от* **шаяру**; игра́ть, шали́ть, озорнича́ть, шути́ть (*о многих*)

шаять *вводн. сл.* наве́рно, наве́рное, вероя́тно, по́видимому; мо́жет быть, возмо́жно; ано́сь; *~, ишеткәнсеңдер дә инде* возмо́жно, и слы́шал уже́; *~, сез дә катнашырсыз* мо́жет быть, и вы́ бу́дете уча́ствовать

шәбәйтү *перех.* 1. уси́ливать/уси́лить (*темп, звук, движение и т. п.*); ускоря́ть/уско́рить, убыстря́ть/убыстри́ть (*процесс, шаг, движение, ход и т. п.*); *йөрешне ~* уско́рить ход, подда́ть хо́ду 2. *разг.* улучша́ть/улу́чшить (*жизнь, качество работы и т. п.*)

шәбәлә *сущ. диал.* ло́жка с дли́нной ру́чкой; *см.* **шабала**

шәбәр|ү *неперех.* вы́мокнуть соверше́нно, промо́кнуть до ни́тки (*под дождём*); *~еп күшегү* промо́кнуть и продро́гнуть

шәбә|ю *неперех.* 1. уси́ливаться/уси́литься; ускоря́ться/уско́риться; убыстря́ться/убыстри́ться || уси́ление, ускоре́ние, убыстре́ние; *тавыш бер ~я, бер әкренәя* шум то уси́ливается, то уменьша́ется; *атның адымнары ~йде* шаги́ коня́ убыстря́лись 2. улучша́ться/улу́чшиться, станови́ться/стать лу́чше || улучше́ние; *шәһәр үсә, ~я бара* го́род развива́ется и стано́вится лу́чше 3. *разг. см.* **шәпләнү**; *сине бик ~еп йөри диләр* говоря́т, что задаёшься

шәбкә *сущ. уст.* сеть, се́тка, тенёта; *~дән ычкыну* освободи́ться от тенёт

шәгъбан *сущ. уст.* ша(г)ба́н (*название восьмого месяца мусульманского лунного года*); *см. тж.* **шогъбан**

шәгъбә *сущ. уст.* отде́л, отделе́ние, се́ктор; гру́ппа; *см. тж.* **шөгъбә**; *юридик факультетның хокук ~се* отделе́ние пра́ва юриди́ческого факульте́та

шәех *сущ.* 1. *рел.* шейх (*глава племени, предводитель*) 2. шейх (*представитель высшего мусульманского духовенства*) 3. *перен.* патриа́рх (*в какой-л. сфере, области*)

шәехлек *сущ. рел.* положе́ние ше́йха

шәҗәрә *сущ.* родосло́вное дре́во, родосло́вие; родосло́вная || родосло́вный; *~ төзү* составля́ть родосло́вную табли́цу, кни́гу; *һәркем дурт буынга кадәр үз ~сен яхшы белергә тиеш* ка́ждый до́лжен хорошо́ знать свою́ родосло́вную до четвёртого коле́на

шәҗәрәле *прил.* родови́тый, знамени́тый, с родосло́вной; *зур ~ нәсел* (*фамилия*) с большо́й родосло́вной; родови́тая фами́лия

шәй *сущ.* 1. *книжн.* предме́т, вещь; шту́ка; *һәр шәйгә тәэсир итә* влия́ет на все ве́щи; *тагын ни шәй бар?* что (тут) ещё (кака́я вещь)?; *ялган — койты шәй-*

дер ложь — плоха́я вещь (шту́ка) **2.** ока́зия; слу́чай; *бу ни шәй?* что за ока́зия? **3.** *диал.* причи́на; *пошиман булырлык шәй юк* для стра́ха (беспоко́йства) нет причи́ны

шәйләп|ү *страд. от* **шәйләү**; *ераста бер атлы ~ә* вдалеке́ видне́ется вса́дник; *авылның утлары ~ә башлады* уже́ видны́ огни́ дере́вни

шәйләп *нареч.* осторо́жно, осмотри́тельно; *~ атлау* шага́ть осторо́жно; *авызыңны ~ ач, ~ сөйлә* говори́ осторо́жно; не распуска́й язы́к

шәйлә|ү *перех.* **1.** подмеча́ть/подме́тить (*наблюдая*), замеча́ть/заме́тить, обнару́жить, ви́деть *что-л.*; *караңгы, берни ~п булмый* темно́, ничего́ не ви́дно **2.** дога́дываться/дога́даться, ула́вливать/улови́ть, чу́ять/почу́ять; *эшнең нәрсәдә икәнлеген ~ү* дога́даться в чём де́ло; *сүзләренең мәгънәсен ~ү* улови́ть смысл (его́) слов; *ерактан ~ү* почу́ять издалека́ ◻ **~ми калу 1.** не заме́тить **2.** *перен.* оплоша́ть, проморга́ть; упуска́ть и́з виду; не обраща́ть внима́ние **~п алу 1.** заме́тить, подме́тить **2.** дога́дать, улови́ть; почу́ять

шәйхеислам *сущ. уст.* шейх-уль-ислам, богосло́в-правове́д у мусульма́н

шәйше *сущ. диал.* стог (*для просушивания проса или гречихи*); *тары ~се* стог про́са; *~ кую* стогова́ть, мета́ть стог (*гречихи*)

шәк *сущ.* **1.** *ист.* чек (*памятная палочка, клочок бумаги и т. п. с записью долга и т. п.*) **2.** *диал.* игра́ с па́лочками (*где главным элементом является быстрое нахождение двух половинок одних и тех же переломанных пополам палочек*)

шәкәләй *сущ. диал.* уклейка; *см. тж.* **җилем-балык**

шәкел *сущ. уст.* фо́рма; вид (*наружный, внешний*); *тышкы ~е* вне́шний вид *чего-л.*; *~ен үзгәртү* измени́ть фо́рму (*очертания*); *аңгәмә акыл өйрәтү ~енә керде* бесе́да приняла́ фо́рму назида́ния

шәкелдәш *прил. уст.* единообра́зный, схо́дный; одина́ковый по фо́рме, одина́ковой фо́рмы; *см. тж.* **охшаш**; *~ өчпочмаклар* подо́бные треуго́льники

шәкелдәшлек *сущ. уст.* единообра́зие, схо́дство форм

шәкелле *прил. уст.* **1.** *какой-л.* фо́рмы; в ви́де *чего-л., кого-л.*; *аю ~ болытлар* ту́чи в фо́рме медве́дя; *төрле ~* ра́зной фо́рмы **2.** *см.* **шикелле**

шәкелмә *сущ.* **1.** визи́рная нить, фикса́тор рейсши́ны (*чертёжной линейки*) **2.** *уст.* крючо́к на конце́ ля́мки для захва́та тро́са (*у бурлаков или рыбаков*)

шәкерт *сущ.* **1.** шаки́рд, уча́щийся медресе́ **2.** учени́к, подмасте́рье; *~ булмый, оста була алмассың* (*погов.*) не побыва́в в ученика́х, ма́стером не ста́нешь; *~ остазыннан узарга тиеш* (*погов.*) ученик до́лжен превзойти́ своего́ наста́вника **3.** после́дователь, сторо́нник (*учения и практической деятельности*); *Мичурин ~ләре* после́дователи Мичу́рина; мичу́ринцы

шәкертлек *сущ.* ученичество; *~ еллары* (*чоры*) го́ды ученичества

шәкертмә *сущ. диал.* педа́ль ручно́го тка́цкого станка́; *см. тж.* **тәбәлдерек**

шәкләп *нареч. уст.* по фо́рме, по ви́ду; *~ ярыйсы гына күренә* по фо́рме вро́де всё в поря́дке

шәкли *прил. книжн.* форма́льный; *~ грамматика лингв.* форма́льная грамма́тика; *сүзне ~ (яктан) өйрәнү* изуче́ние сло́ва с форма́льной стороны́

шәкшәкәр *сущ.* чехарда́ ◻ **~ уены** игра́ в чехарду́; **~ уйнау** игра́ть в чехарду́

шәл I *сущ.* шаль || ша́левый; *бизәкле ~* цвета́стая шаль; *бәйләгән ~* вя́заная шаль; *каймалы ~* шаль с каймо́й; *~ мамыгы* ша́левый пух

шәл II *сущ. диал.* крюк (*у грузчиков*)

шәлберәү *неперех. разг. см.* **шәлперәю**

шәле *сущ.* шала́, неочи́щенный рис

шәлия *сущ.* **1.** *см.* **шал 2.** *ист.* дорога́я ко́жаная сбру́я

шәлкем *сущ.* **1.** гроздь, кисть; пучо́к, гирля́нда (*цветов*) **2.** коло́да (*карт*); компле́кт однообра́зных предме́тов **3.** *перен.* сбо́рник (*стихов*)

шәлпә|ю *неперех. разг.* **1.** *см.* **шәлперәю**; *карабодай яфраклары ~йгән* ли́стья гречи́хи завя́ли **2.** *см.* **шәпкәю** ◻ **~еп төшү** *см.* **шәлперәеп төшү**

шәлпек *прил. разг.* **1.** отви́слый; обви́слый; *~ ирен* отви́сшая губа́; *~ колаклы эт* соба́ка с отви́слыми уша́ми **2.** дря́блый, вя́лый (*потерявший свежесть*); *~ яфраклар* вя́лые ли́стья (*увядающего растения*) ◊ **~ авыз** мя́мля, тря́пка; ротозе́й, рази́ня; *см. тж.* **мәми авыз**

шәлперә|ю *неперех.* **1.** отвиса́ть/отви́снуть (*о губах, ушах*); обвиса́ть/обви́снуть (*об усах, плечах и т. п.*) **2.** увяда́ть/увя́нуть, вя́нуть/завя́нуть || увяда́ние (*о растениях, листьях и цветах*); *эсседән помидорлар ~йгән* от жары́ помидо́ры завя́ли; *кырау көчле булган, бәрәңге яфраклары ~йгән* моро́з был си́льный, поби́л карто́фельную ботву́ (*букв.* ли́стья карто́феля завя́ли) **3.** слабе́ть, ослабева́ть/ослабе́ть; расслабе́ть/расслабну́ть; станови́ться/стать дря́блым (*о крыльях птицы, руках больного человека, о теле от усталости и голода и т. п.*); *~йгән гәүдә* дря́блое те́ло **4.** *перен.* раскиса́ть/раски́снуть (*о человеке*); *эштән туктадым дип, ~ергә ярамый* нельзя́ раскиса́ть из-за того́, что переста́л рабо́тать ◻ **~еп төшү 1.** отви́снуть, обви́снуть **2.** увя́нуть, завя́нуть **3.** ослабе́ть, рассла́бнуть

шәлсыман *прил.* ша́левый; в ви́де (наподо́бие) ша́ли; *~ япма* наки́дка наподо́бие ша́ли ◻ **~ яка** ша́левый воротни́к, воротни́к ша́лью, пелери́на

шәлтә|ү *сущ.* реме́нь, по́яс с ра́зными подве́шенными карма́шками, крючка́ми, но́жнами и т. п. ◊ **~ве төшкән** *см.* **балтасы суга төшкән**

шәлче *сущ.* **1.** вяза́льщик ша́ли **2.** торго́вец ша́лью

шәлчелек *сущ.* ша́левый про́мысел (*был распространён у татар-мишарей*)

шәлше *сущ. диал. см.* **шәйше**

шәльяулы|к *сущ.* плато́к (*для головы, преимущественно с крупными цветами и чуть больше обычного*); *~гым чуклы-чуклы, чуклы түгел — чәчәкле* (*песня*) плато́к мой с кистя́ми, нет, не с кистя́ми — с бахромо́й

шәм I *сущ.* **1.** 1) свеча́, све́чка || свечно́й; *балавыз шәме* восковáя свеча́; *шәм уты кабызу* (*алу*) зажéчь свечу́; засвети́ть све́чку; *шәл мае* свечно́е са́ло; *шәл исе* свечна́я гарь 2) *мед.* свеча́ (*геморроидальная*) **2.** *тех.* свеча́; *кабызу шәме* запа́льная свеча́; *кыздыру шәме* свеча́ нака́ливания; *бораулау шәме* буровáя свеча́ **3.** *спец.* свеча́ (*единица измерения силы света*); *шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың* (*погов.*) днём с огнём не сыскать ◻ **шәм кебек 1.** стро́йный, ста́тный **2.** стро́йно, пря́мо (*расти, стоять, сидеть и т. п.*) **3.** свечо́й, све́чкой (*взлетать, подниматься, пойти в высоту*); **шәм кебек катып калу (тору)** оста́ться (стоя́ть) как вко́панный; засты́ть как све́чка; **шәм кебек яну** сгоре́ть (та́ять) как свеча́, сгора́ть, угаса́ть; **шәм төпчеге** ога́рок (*свечи*)

шәм II *сущ.* 1. (*шәм агачы*) корабе́льная сосна́ 2. дли́нный прямо́й ствол де́рева, дли́нное бревно́

шәмаил *сущ.* 1. карти́на с ви́дом свяще́нных для мусульма́н мест и с те́кстами религио́зного содержа́ния; *см. тж.* **шамаил** 2. те́ксты, напи́санные хоро́шим по́черком на осно́ве ара́бской гра́фики, с афори́змами ара́бских поэ́тов и́ли моли́твы

шәмәй *сущ. диал.* вид игры́ в а́льчики

шәмәхә *прил.* фиоле́товый; ~ (*төстәге*) *бәрхет* фиоле́товый (фиоле́тового цве́та) ба́рхат □ **аксыл-~** лило́вый; **аксыл-~ төскә керү** лилове́ть

шәмәхәләнү *неперех.* приобрета́ть/приобрести́ фиоле́товый цвет, станови́ться/стать фиоле́товым; *томан аша океан ~еп күренә* сквозь тума́н океа́н ка́жется фиоле́товым

шәмдәл, шәндәл *сущ. уст.* подсве́чник, све́чник; *биш тармаклы ~* пятисве́чник; *түгәрәк ~* кру́глый све́чник; *шәмнең яме ~ белән* (*погов.*) све́чи краси́вы, когда́ краси́в подсве́чник

шәмле *прил.* 1. со свечо́й (све́чкой), име́ющий све́чку; *~ шәмдәл* подсве́чник со свечо́й 2. свечо́вый, в... свече́й; *йөз ~ лампочка* ла́мпочка в сто свече́й, стосвечо́вая ла́мпочка

шәмлек *сущ.* 1. карка́с кры́ши 2. стропи́ла; *~кә яраклык агач* лес (брёвна), го́дный на стропи́ла

шәмрәйтү: колак шәмрәйтү навостри́ть у́ши, прясть уша́ми; насторожи́ться, насторожи́ть у́ши (слух)

шәмсия *сущ. уст. книжн.* 1. со́лнечный год; со́лнечное летосчисле́ние 2. зонт, зо́нтик □ **~ хәрефләр** *лингв.* со́лнечные бу́квы (*арабского алфавита*)

шәмче *сущ. уст.* све́чник; тот, кто изготовля́ет и́ли торгу́ет свеча́ми

шәмчырак *сущ. ист.* 1. лучи́нка, свете́ц 2. *уст.* мая́к, мая́чный огонёк 3. *зоол.* светлячо́к (*вид жуков*) 4. *этногр.* молодёжная игра́ в ко́мнате (*во время посиделок*)

шәнгә *сущ. кул.* ша́ньга, шане́тка; *бәрәңге ~се* ша́ньга с карто́шкой (с карто́фельным пюре́)

шәнкәйтү *понуд. от* **шәнкәю**; *колакларны ~еп тыңлау* слу́шать с кра́йним внима́нием

шәнкәю *неперех.* ва́нуть; обвиса́ть (*об ушах*)

шәңгә *сущ. кул.* ша́ньга, ша́нежка (*в виде перемяча с картошкой*); *иртәнге ашка ~ пешерү* на за́втрак гото́вить ша́ньгу

шәп *нареч.* 1. хорошо́; отли́чно; замеча́тельно, блестя́ще, сла́вно; *шәп җырлый* сла́вно поёт; *шәп яшиләр* отли́чно живу́т; *рәсем шәп чыккан* карти́на получи́лась хорошо́; *бик шәп* блестя́ще, великоле́пно; здо́рово *прост.*; *эшләр бик шәп* дела́ на мази́; дела́ в ажу́ре 2. бы́стро, стреми́тельно, с большо́й ско́ростью; *шәп йөрешле* быстроно́дный; *шәп бару* идти́ (е́хать) бы́стро 3. *перен.* хорошо́, си́льно, кре́пко; *учак шәп яна* костёр хорошо́ гори́т; *шәп әйтте бу* э́тот сказа́л си́льно; *шәп яңгырый* звуча́ть си́льно || *прил.* 1. 1) хоро́ший; отли́чный, замеча́тельный, сла́вный; блестя́щий, блиста́тельный (*успех*); *бик шәп балалар үстергәнсез* вы́растили вы сла́вных дете́й; *аның хәтере шәп* у него́ хоро́шая па́мять; *шәп белгеч* отли́чный специали́ст; *шәп китап* замеча́тельная кни́га; *шәп хикәя* хоро́ший расска́з; *шәп егет* мирово́й па́рень 2) большо́й, кру́пный; мо́щный; *шәп йорт* большо́й дом; *шәп хуҗалык* мо́щное хозя́йство 2. бы́стрый, стреми́тельный; *шәп агым* бы́строе тече́ние; *шәп йөреш* ско́рый ход; стреми́тельный ход 3. *перен.* хоро́ший, кре́пкий, си́льный, мо́щный; *басым шәп чакта* пока́ напо́р си́льный; *шәп тавыш белән* си́льным (мо́щным) го́лосом □ **шәп(тән) түгел** не а́хти како́й; не о́чень хорошо́; *сәламәтлеге шәптән түгел* здоро́вье его́ нева́жное; у него́ со здоро́вьем нела́дно; *эшләр шәп түгел* дела́-то таба́к

шәпкә I *сущ. см.* небольшо́й не́вод; *~ белән балык тоту спец.* не́водить, лови́ть ры́бу не́водом; *~ белән балык тотучы* не́водчик, рыба́к-не́водчик; *~ тарту* (*җыю*) выбира́ть не́вод

шәпкә II *послелог с дееприч.* на **-ган** 1. попу́тно, одновреме́нно, наряду́ с каки́м-ли́бо де́йствием; на ходу́; *очып барган ~* налету́, с налёта; *кызу килгән ~* на ско́рости; *барган ~ ике-өч сүз әйтү* вы́сказать два-три сло́ва; *чабып барган ~ату* стреля́ть на скаку́ 2. как то́лько; то́тчас, сра́зу, неме́дленно; *кайткан ~* то́тчас по возвраще́нии; *килеп җиткән ~ эшкә тотынды* как то́лько пришёл, принялся́ за рабо́ту

шәпкүр *прил. книжн.* близору́кий; *см. тж.* **күррә**

шәпләндерү *понуд. от* **шәпләнү** *разг.*; позволя́ть/позво́лить ва́жничать, форси́ть

шәпләнү *неперех.* вести́ себя́ ва́жно, горделиво, ва́жничать; зазнава́ться/зазна́ться; *~еп йөрү* ходи́ть ва́жно, горделиво

шәпләп *нареч.* 1. хорошо́, хорошо́нько; как сле́дует; по-настоя́щему, до́лжным о́бразом; *йортны ~ кору* постро́ить дом как сле́дует; *~ кенә җавап бирү* отве́тить как сле́дует (хорошо́нько) 2. ва́жно; го́рдо, высокоме́рно, надме́нно; важне́цки *прост.*; *~ үтеп бару* проходи́ть с ва́жным ви́дом

шәп-шәп *прил., нареч.* больши́е, хоро́шие, замеча́тельные; *шәп-шәп йортлар салалар* стро́ят больши́е, замеча́тельные дома́; *шәп-шәп атлап* кру́пными (бы́стрыми) шага́ми; бы́стро шага́я

шәпле *прил.* молоде́цкий, молодцо́м (*часто ирон.*); молодцева́тый; форси́стый, хвастли́вый; *~ кеше* геро́й

шәпләк *сущ.* 1. хоро́шее ка́чество; *тормышларының ~ген сөйләү* расска́зывать о свое́й прекра́сной жи́зни; *кызларның ~ге күренеп тора* сра́зу ви́дно, что де́вушки сла́вные 2. быстрота́; пры́ткость; *йөрү ~ге* быстрота́ ходьбы́ (движе́ния); *хәрәкәт ~ген арттыру* приба́вить ско́рость движе́ния 3. си́ла; интенси́вность; *тавышлар элекке ~кләрен югалткан* голоса́ потеря́ли былу́ю си́лу 4. *перен.* велича́вость, вели́чественность; ва́жность; *кая киткән элеккеге ~ге?* куда́ исче́зла (его́) пре́жняя велича́вость?

шәп-шәрә *прил., нареч. превосх. ст. от* **шәрә**; *шәп-шәрә кыр* совсе́м го́лое по́ле; *шәп-шәрә балалар* соверше́нно го́лые де́ти

шәр(р) *сущ. уст.* зло, зло́ба; злоде́йство, злодея́ние; *үзең сакла шайтан шәр(р)еннән* сохрани́ бог от злодея́ния сатаны́

шәраб *сущ.* 1. горя́чий (сла́дкий) напи́ток 2. вино́ || ви́нный; *кызыл ~* кра́сное вино́; *~ шешәсе* ви́нная бутылка; *~ исе* ви́нный за́пах; *~ откысы* ви́нные дро́жжи 3. вообще́ алкого́ль, спиртны́е напи́тки; *~ аны харап итте* его́ погуби́л алкого́ль; *мәхәббәт ~ы перен.* любо́вный напи́ток

шәрабдар *сущ. уст.* виноче́рпий

шәрабсыз *нареч., прил.* всуху́ю, без алкого́ля; *~ туй үткәрү* отпра́здновать сва́дьбу всуху́ю (*без алкоголя*)

шәрабханә *сущ. уст.* 1. пите́йный дом, пите́йное заведе́ние; *см. тж.* **мәйханә** 2. ви́нный магази́н

шәрә *прил.* 1. го́лый, не прикры́тый оде́ждой; нагой́; *~ балалар* го́лые де́ти 2. 1) го́лый, оголённый, обнажённый; обле́злый; *~ урман* оголённый лес (оголённые

дере́вья); *корыган ~ ботаклар* вы́сохшие го́лые ве́тки (обнажённые ве́тки) 2) го́лый, ничем не покры́тый, *~ сәкедә йоклау* спать на го́лых на́рах 3. го́лый, нагóй; откры́тый (*о местности*); *~ кыялар* го́лые ска́лы; *~ кыр* откры́тое по́ле; *~ боз өстендә* на откры́том льду 4. го́лый (не обста́вленный); бе́дный; *~ өй* го́лый дом; *~ стеналар* го́лые сте́ны 5. *перен.* обнажённый; я́вный, откры́тый; *~ фикерләр* обнажённые мы́сли; *~ оятсызлык* с откры́тым цини́зом □ **~ килеш** голышóм; нагóй, в нату́ре *разг. шутл.*; *~* **орлыклылар** *бот.* голосеменны́е, открытосеменны́е; *~* **чыбык, ~ үткәргеч** го́лый (оголённый) про́вод ◊ *~* **калдыру** обобра́ть до ни́тки, ничего́ не оста́вить; ободра́ть как ли́пку; *~* **калу** 1. раздева́ться догола́ (донага́); снять всё 2. оста́ться го́лым; оголя́ться, оголе́ть (*о деревьях, поле и т. п.*) 3. оста́ться бе́дным, ни́щим

шәрәкәй *прил. разг.* го́ленький; *см. тж.* **шәрә**; *~ бәби* го́ленькое дитя́ || *сущ.* го́лый челове́к, голы́ш

шәрәләндерелү *страд. от* **шәрәләндерү**

шәрәләндер|ү *перех.* 1. оголя́ть/оголи́ть, обнажа́ть/обнажи́ть || оголе́ние, обнаже́ние; *тамырын ~сәң, агачы корый* ко́рни обнажи́шь, де́рево засо́хнет; *көзге җил агач ботакларын ~ә* осе́нний ве́тер оголя́ет дере́вья 2. *перен.* обнажи́ть, упрости́ть; *фикерләрне ~еп бирү* преподнести́ мы́сли обнажёнными

шәрәләнү *неперех.* оголя́ться/оголи́ться, обнажа́ться/обнажи́ться || оголе́ние, обнаже́ние; *~гән кырлар* оголи́вшиеся поля́; *~гән тавыклар* обле́злые (квёлые) ку́ры; *бакча көннән-көн ~ә бара* с ка́ждым днём сад всё бóльше оголя́ется

шәрәлә|ү *перех. см.* **шәрәләндерү**; *тамырны ~ү* оголя́ть ко́рни; *терсәккә кадәр кулын ~де* обнажи́л ру́ку до локте́й

шәрәле|к *сущ.* 1. нагота́; *~ген яшерү* (*күрсәтмәс*) *өчен* что́бы прикры́ть наготу́; *~геннән оялып* стесня́ясь свое́й наготы́ 2. нагота́, обнажённость (*местности, скал, береговой гальки, деревьев и т. п.*) 3. голь, го́лая ме́стность; *алда дала, һәркайда ~к* впереди́ степь, всю́ду го́лая ме́стность 4. *во мн. ч.* **~кләр** *геогр.* голяки́, го́лые верши́ны гор (*в Сибири*)

шәрәтән *прил.* го́лый, го́ленький (*о людях*) || *нареч.* го́лым, голышóм; *~ йөгерәләр* бе́гают голышóм

шәраф *сущ. книжн.* 1. честь; *бәйрәм ~ендә* в честь пра́здника; *кайту ~енә* в честь прие́зда; почёт; *ватан өчен корбан булуны үзенә ~ санады* смерть за ро́дину счита́л для себя́ че́стью 2. *уст.* авторите́т, прести́ж; *үзләренең ~ен саклау өчен* для поддержа́ния прести́жа; *~енә кагылу* (*тию*) заде́ть (подрыва́ть) *чей-л.* авторите́т □ **(нәрсә) ~енә, (нинди) ~кә ирешү** удоста́иваться/удосто́иться *какой* че́сти (че́сти быть каки́м)

шәрәфә *сущ.* 1. 1) балко́н вокру́г минаре́та и́ли окно́ на минаре́те для призы́ва на моли́тву 2) кру́жная галере́я, кру́жный балко́н в мечёти (*предназначенный для женщин*); *матур-матур ~ләр* краси́вые кру́жные балко́ны в мечёти 2. *перен.* обходно́й лист

шәрәфәт *сущ. уст.* 1. че́ствование 2. прести́ж

шәрәфәтле *прил.* 1. просла́вленный; *~ рус гаскәре* просла́вленная ру́сская а́рмия 2. прести́жный

шәрәфле *прил. уст. книжн.* почётный, сла́вный; знамени́тый, заслу́женный; *инсан дигән ~ мәхлук* сла́вная тварь по и́мени челове́к; *халкымызның ~ үткәне* сла́вное про́шлое на́шего наро́да

шәрәфсез *прил.* бесслáвный; *империянең ~ һәлакате* бесслáвная ги́бель импе́рии

шәргый *прил. уст. книжн.* зако́нный, позволи́тельный; дозво́ленный духо́вным зако́ном, шариа́тский, согла́сный с шариа́том; *~ хакым бар* име́ю зако́нное (согла́сное с шариа́том) пра́во; *~ хөкем* приговóр, вы́несенный в соответствии с шариа́том

шәре *сущ. диал.* полынь

шәрегән *прил. диал.* ту́хлый, проту́хлый; *см. тж.* **чәберчек**; *~ йомырка* ту́хлое яйцо́

шәрекъ *сущ.* 1. восто́к; *гареп вә ~* за́пад и восто́к; *~тән гарепкә* с восто́ка на за́пад 2. *ист. этногр.* Бли́жний Восто́к || ближневосто́чный; *~ илләре* ближневосто́чные стра́ны; *~ телләре* ближневосто́чные языки́; *~ мәдәнияте* ближневосто́чная культу́ра

шәрекъле *сущ. уст.* представи́тель восто́чных наро́дов; жи́тель Бли́жнего Восто́ка; *~ ханым* же́нщина с Восто́ка

шәрекъче *сущ.* востоковéд, ориентали́ст; восто́чник

шәрекъчелек *сущ.* 1. востоковéдение, ориентали́стика || востоковéдческий; *~ мәсьәләләре* востоковéдческие пробле́мы 2. *ист.* восто́чничество, ориентали́зм (*направление, отстаивающее для татар подражание восточной культуре*)

шәрем *сущ. уст. книжн.* стыд, срам, позóр

шәрех *сущ. книжн.* 1. объясне́ние, разъясне́ние, толкова́ние, коммента́рий; *~ таләп ителми* коммента́рии не тре́буются, коммента́рии изли́шни 2. объясни́тельная сно́ска; изъясни́тельная вы́носка; *«дуслар» мәгънәсендә аңларга дигән ~ төшерде* дал объясни́тельную сно́ску, что да́нное сло́во употребля́ется в смы́сле «друзья́»

шәрехләнү *страд. от* **шәрехләү**; толкова́ться, объясня́ться, разъясня́ться; быть объя́сненным, коммента́рованным; коммента́роваться; *~гән сүзләр* (*текст*) коммента́рованный текст

шәрехләү *перех. уст. книжн.* 1. толкова́ть, объясня́ть/объясни́ть, разъясня́ть/разъясни́ть, поясня́ть/поясни́ть; коммента́ровать; дать объясне́ние, поясне́ние, коммента́рии || толкова́ние, коммента́рование; *идея эчтәлеген ~ү* объясни́ть иде́йное содержа́ние; *~п бирү* объясни́ть, разъясни́ть 2. дава́ть/дать сно́ску (сно́ски), коммента́рии (*письменно*); де́лать изъясни́тельную вы́носку (сно́ску); *автор сүзен ~ү* дать сно́ску на слова́ а́втора

шәрехләүче *сущ. см.* **шәрехче**

шәрехле *прил. уст. книжн.* с коммента́риями, снабжённый толкова́нием (разъясне́нием); коммента́рованный

шәрехче *сущ. уст. книжн.* коммента́тор

шәригать *сущ. рел.* шариа́т (*письменный свод мусульманских законов*); *~не бозу — зур гөнаһ* наруша́ть шариа́т (идти́ про́тив шариа́та и́ли не выполня́ть его́ кано́нов) — вели́кий грех □ **~кә хилаф** *уст.* 1. незако́нный, противозако́нный 2. незако́нно, про́тив зако́на

шәригáтьчә *нареч. рел.* 1. по шариа́ту, согла́сно шариа́ту, сле́дуя зако́нам шариа́та; зако́нно, по зако́ну; узако́ненный поря́дком; *~ яшәү* жить, сле́дуя зако́нам шариа́та; *~ өйләнү* бракосочета́ние по шариа́ту 2. *в знач.* шариа́тский, зако́нный; согла́сный с шариа́том 3. *в знач. прил.* шариа́тский, зако́нный; согла́сный с шариа́том (по шариа́ту); *~ туй* сва́дьба по шариа́ту (согла́сно с шариа́том); *~ хатыны* зако́нная жена́, жена́ по шариа́ту, его́ со́бственная жена́

шәри|к *сущ. уст.* 1. компаньóн, совладе́лец; па́йщик; *һәркем үз тиңе, үз ~ге белән аралаша* ка́ждый обща́ется

с ра́вным себе́, со свои́м компаньо́ном; *алла бар, ~ге юк* (*погов.*) бог есть (оди́н), а компаньо́на (его́) нет **2.** однокла́ссник, однока́шник; соучени́к, шко́льный това́рищ; *~гемне очраттым* встре́тился с однока́шником; *см. тж.* **шәриктәш**

шәриклек *сущ. уст.* **1.** о́бщество, това́рищество (*на паях*), компа́ния **2.** состоя́ние однока́шника, быть однока́шником; това́рищеские отноше́ния

шәриктәш *сущ. книжн.* однокла́ссник; однока́шник, това́рищ по учёбе, шко́льный това́рищ; *~лярне кунакка чакыру* приглаша́ть в го́сти однокла́ссников; *алар ~ләр икән бит* ока́зывается, они́ однока́шники (однокла́ссники)

шәриф *сущ. уст.* **1.** *редко* свяще́нный, свято́й; *~ рухлы* свято́й ду́хом, со свято́й душо́й **2.** *книжн.* по́сле определя́емого сло́ва 1) зна́тный, благоро́дный; знамени́тый, сла́вный; *исем ~лярегез ничек?* как Ва́ше сла́вное и́мя? (как Вас зову́т?) 2) свяще́нный, благослове́нный; *Коръән ~* свято́й Кора́н

шәрифле *сущ. уст. книжн.* свято́й; свяще́нный; *бүген ~ көн* сего́дня свято́й день; *~ сәгатьләр булсын! ~ сәгатьләрдә!* в до́брый час! (*пожелание удачи*)

шәркан *прил. уст. книжн.* с восто́ка, с восто́чной стороны́; *~ җил безгә аркан* ве́тер с восто́ка нам попу́тный (*со спины*)

шәркый *прил. уст. книжн.* восто́чный; *~ Галиция* восто́чная Гали́ция; *~ халыклар* восто́чные наро́ды

шәрран: шәрран яра *книжн.* **1.** откры́тый во всю ширь, на́стежь распа́хнутый, широко́ раскры́тый; *шәрран яра тәрәзәләрдән музыка яңгырый* из распа́хнутых о́кон звучи́т му́зыка **2.** откры́тый, го́лый, обнажённый; ничём не ограждённый, не защищённый; *йортның арт ягы шәрран яра* за́дняя сторона́ двора́ откры́тая; *тылны шәрран яра калдырырга ярамый* нельзя́ оставля́ть тыл откры́тым **3.** я́вный, откры́тый; я́сный, изве́стный для всех; *шәрран яра ялчы бит ул* он же я́вный холу́й; *шәрран яра дошман кулында* на рука́х я́вного врага́ **4.** откры́то, откровенно (*не стесняясь, не боясь*); пря́мо в лицо́; *шәрран яра, халык алдында хур итте* пря́мо пе́ред наро́дом опозо́рил **5.** откры́то, в откры́тую, не боя́сь; без ута́йки; *урланган әйберләрне шәрран яра сата башлады* в откры́тую на́чал сбыва́ть кра́деное **6.** целико́м, всецело́; всё подря́д, до мелочей; *зәлне* (*эшне*) *шәрран яра белү* знать положе́ние до мелочей; *шәрран яра алу* распахну́ть, раскры́ть на́стежь, во всю ширь, откры́ть широко́; *см. тж.* **шар ачу**; **шәрран яра ачык** **1.** распа́хнутый, широко́ откры́тый, раскры́тый; на́стежь; *ишек-тәрәзәләрне шәрран яра ачык калдырган* оста́вил все две́ри, о́кна распа́хнутыми **2.** откры́тый, откровенный, и́скренний, чу́ждый скры́тности; **шәрран яру** **1.** сли́шком гро́мко говори́ть, говори́ть во весь го́лос, горла́нить *прост.*, крича́ть, ора́ть; *ни дип шәрран ярасың?* что ты крича́шь? **2.** говори́ть совершенно откровенно, пря́мо; говори́ть без намёков, без обинако́в; *яшьләр шәрран яра* молоды́е говоря́т пря́мо; *шәрран ярып көлү* **1.** расхохота́ться, смея́ться гро́мко **2.** смея́ться в лицо́, высмея́ть откры́то; **шәрран ярып сөйләү** *см.* **шәрран яру** 2

шәрри *прил. книжн.* зло́бный, зло́стный; вре́дный

шәррир *прил. уст. книжн.* злой, зловре́дный челове́к, злоде́й

шәр|ү *неперех. диал.* **1.** подта́ивать/подта́ять || подта́ивание (и размягче́ние) льда; появля́ться/появи́ться || появле́ние подта́явших мест, полыне́й надо льдо́м; *~егән боз* подта́явший лёд; лёд с лу́жами до́верху (све́рху) **2.** *перен.* разжижа́ться от гние́ния, ту́хнуть; протуха́ть/проту́хнуть || протуха́ние (*яйца*); *см. тж.* **чәберчекләнү**

шәт *модальн. сл. разг.* наве́рное, по-ви́димому; чай *уст.*; *см. тж.* **шаять**; *шәт, ишеткәнсездер* наве́рное (мо́жет), услы́шали; *шәт, кайтырга да вакыттыр* чай, пора́ и домо́й

шәтер *сущ. диал.* зо́нтик (*небольшого размера*)

шәүвәл *сущ. уст.* шавва́ль (*название десятого месяца мусульманского лунного календаря*)

шәүкәт *сущ. уст. книжн.* вели́чие, могу́щество, великоле́пие; *~ югалту* потеря́ть своё вели́чие, могу́щество

шәүкәтле *прил. уст. книжн.* **1.** вели́чественный, могу́щественный; *~ хан* вели́чественный хан **2.** побе́дный, победоно́сный; выража́ющий превосхо́дство (*вид, клич, смех и т. п.*)

шәүлә *сущ.* **1.** о́тблеск, о́тсвет, отража́ющий свет *чего-л.* на не́бе; за́рево; *ут* (*ялкын*) *~се* о́тблеск огня́ (пла́мени); *янгын ~се* о́тсвет пожа́ра, за́рево пожа́ра; *кичке шәфәкъ ~се* за́рево зака́та **2.** блик; светово́е пятно́, луч на тёмном фо́не; *кояш ~се* луч со́лнца **3.** за́йчик; све́тлое пятно́ от отраже́ния со́лнечного луча́; *көзге ~се төшерү* навести́ (пуска́ть) за́йчика **4.** силуэ́т, тень; нея́сное очерта́ние в темноте́; фигу́ра *чего-л.* вдали́ и́ли в темноте́; *караңгылык эчендә ниндидер ~ләр күренә* в темноте́ видны́ *какие-то* фигу́ры (те́ни) **5.** отраже́ние *чего-л.* на гла́дкой пове́рхности; *күл өстендә гигант агачларының ~се* отраже́ния гига́нтских дере́вьев на пове́рхности о́зера **6.** о́браз, о́блик, возника́ющий в па́мяти; при́зрак; *күзем йомсам, ~ң күз алдымда* закро́ю глаза́, о́блик твой пе́ред глаза́ми **7.** *перен.* тень, о́тсвет, отраже́ние *каких-л.* чувств; *йөзендә сөю ~се* на лице́ о́тсвет любви́ **8.** *перен.* иде́я, дух; при́зрак **9.** *диал.* тень *чего-л.*, затемне́ние, на неосвещённой стороне́ предме́та; *см. тж.* **күләгә** 3; *болытлар ~се* те́ни облако́в ◊ **~ генә калу** оста́лась одна́ тень, оста́лись одни́ ко́сти (оди́н скеле́т), си́льно похуде́ть; **~ кебек** **1.** как тень *кого-л.*; неотсту́пно ходи́ть *за кем-л.*; быть всегда́ вме́сте *с кем-л.* **2.** незаме́тно, неприме́тно; ти́хо, втихомо́лку; укра́дкой (*идти, ползти и т. п.*); **~ төшерү** *см.* **күләгә төшерү**

шәүләләнү *неперех.* **1.** быть едва́ заме́тным, появля́ться из темноты́, обнару́живаться, видне́ться, замеча́ться, наблюда́ться (*о контурах*) *чего*; *үң яктан бер атлы ~ә* на пра́вой стороне́ наблюда́ется (е́ле ви́дно) вса́дник; *офык өстендә авыл утлары ~ә башлады* над горизо́нтом завиднелись деревенские огни́ **2.** 1) отража́ться/отрази́ться || отраже́ние, появле́ние изображе́ния на гла́дкой, блестя́щей пове́рхности; *см. тж.* **чагылу**; *күл өстендә куш каен ~ә* на пове́рхности отража́ется сро́сшаяся берёза 2) *перен.* отража́ться/отрази́ться (*о внешнем проявлении внутренних чувств, состояния*); *йөзендә курку билгесе ~де* на лице́ отрази́лся испу́г **3.** *перен.* возника́ть/возни́кнуть (*в воображении или перед глазами*) представля́ться/предста́виться в созна́нии; *күз алдымда ~де бала чакларым* пе́ред глаза́ми возни́кло моё де́тство

шәүлегән *сущ. зоол.* и́волга; *~ су чәчрәткән, карга кинәнгән* (*посл.*) и́волга плеска́лась водо́й, и воро́на напила́сь

шәфәгать|ь *сущ. уст. книжн.* **1.** ходата́йство, засту́пничество; покрови́тельство, защи́та; *~еңнән ташлама, раббем* го́споди, будь ми́лостив **2.** благодея́ние, благотвори́тельность, филантро́пия || благотвори́тельный, филантропи́ческий; *~ь җәмгыяте* благотвори́тельное о́бщество;

~ь акчасы благотвори́тельные де́ньги, де́ньги для по́мощи □ **~ендә булу** быть под защи́той *кого-л.*; быть под покрови́тельством *кого-л.*; быть в фавóре, под эги́дой *чьей книжн.*; **~ь итү (кылу)** 1. покрови́тельствовать 2. подде́рживать, защища́ть *кого*; ходата́йствовать; заступа́ться, вступа́ть *за кого*; **~ь сорау (эстәү)** проси́ть по́мощи, проси́ть защи́ты (покрови́тельства);

шәфәгатьле *прил. уст. книжн.* благоде́тельный, благотвори́тельный, покрови́тельствующий

шәфәгатьче *сущ. уст. книжн.* 1. благоде́тель, покрови́тель 2. помóщник, засту́пник; ходата́й; *көчсез-зәгыйфьләрнең ~се бул* будь засту́пником сла́бых

шәфәкъ *сущ.* заря́, за́рево, зака́т; óтсвет зака́та || зака́тный; *кичке ~ яктысы* освеще́ние зака́тное; *кичке ~ балкышы* зака́тное сия́ние □ **~ бату (сүнү)** пога́снуть (*о вечерней заре*); *~ батты* заря́ догоре́ла; **~ чыпчыгы** *зоол.* заря́нка, мали́новка; **~ ярылу (агару)** занима́ться (*об утренней заре*), рассвета́ть

шәфкат|ь *сущ.* ми́лость, милосе́рдие, пощáда, сочу́вствие, сострада́ние; благодея́ние, благотворе́ние *уст. книжн.*, благотвори́тельность; *~ь өмет итеп күзләренә карау* смотре́ть в глаза́ в ожида́нии милосе́рдия; *бу халыктан ~ь көтмә* не жди ми́лости (пощáды) от э́тих люде́й □ **~е белән** по ми́лости *чьей*; **~ь итү (кылу)** милосе́рдствовать, проявля́ть милосе́рдие, ока́зывать ми́лость, милосе́рдие; сочу́вствовать, сострада́ть; **~ь иясе** 1. 1) милосе́рдный; ми́лостивый, мягкосерде́чный 2) ми́лостивец *уст.* **~ь йөзеннән** из жа́лости, в ви́де снисхожде́ния; **~ь күрсәтү** 1. *см.* **шәфкать итү (килү)** 2. покрови́тельствовать, благотвори́ть, благодéтельствовать *уст. книжн.*; **~ь күрсәтүче** благодéтель, ми́лостивец *уст.*; **~ь сорау** проси́ть проще́ния, проси́ть пощáды; умоля́ть, моли́ть, упра́шивать; **~ь туташы** медици́нская сестра́; сестра́ милосе́рдия *уст.* ◊ **~е килү** сми́лостивиться, сми́ловаться; оказа́ть ми́лость; **~ен салу** *см.* **шәфкать итү, шәфкать күрсәтү**

шәфкатьләнү *см.* **шәфкатьләләнү**; *~еп кулын сузды* сми́лостивился и дал ру́ку

шәфкатьле *прил.* милосе́рдный, милосерде́чный; сердобóльный; доброжела́тельный, великоду́шный; дóбрый, уча́стливый, сострада́тельный; ми́лостивый *уст.*; *~ кеше* милосе́рдный челове́к; *~ сүз* ми́лостивое сло́во; *~ мөнәсәбәт* доброжела́тельное отноше́ние □ **~ әфәнде** *уст.* ми́лостивый госуда́рь

шәфкатьләндерү *перех.* уми́лостивить; де́лать/сде́лать милосе́рдным, мягкосерде́чным, жа́лостливым; склоня́ть/склони́ть к милосе́рдию; *алланы ~ теләге белән* что́бы уми́лостивить бóга

шәфкатьләнә|ү *неперех.* уми́лостивиться, станови́ться/стать милосе́рдным; подобре́ть □ **~еп китү** станови́ться (бóлее) милосе́рдным

шәфкатьлелек *сущ.* 1. милосе́рдие, мягкосерде́чие, доброта́, отзы́вчивость; великоду́шие; доброжела́тельство, снисходи́тельность 2. уча́стливость, сострада́тельность, мягкосерде́чность; снисходи́тельность □ **~ күрсәтү** ока́зывать ми́лость, проявля́ть милосе́рдие

шәфкатьсез *прил.* безжа́лостный, бессерде́чный; бездýшный, чёрствый; беспоща́дный, нища́дный; бесчелове́чный; *~ кеше* безжа́лостный челове́к; *~ язмыш* жесто́кая судьба́ || *нареч.* безжа́лостно; беспоща́дно, нища́дно; жесто́ко; *дошманны ~ кыйнарга* беспоща́дно бить врага́ □ **~ рәвештә** безжа́лостным óбразом, безжа́лостно

шәфкатьсезләндерү *перех.* ожесточа́ть/ожесточи́ть, де́лать/сде́лать *кого-л.* безжа́лостным, бессерде́чным, жесто́ким; превраща́ть/преврати́ть *кого-л.* в безжа́лостного челове́ка

шәфкатьсезләнү *неперех.* ожесточа́ться/ожесточи́ться; станови́ться/стать безжа́лостным, бессерде́чным, жесто́ким; теря́ть/потеря́ть доброту́, душе́вную мя́гкость, отзы́вчивость

шәфкатьсезлек *сущ.* безжа́лостность, бессерде́чность; беспоща́дность, жесто́кость; бесчелове́чность; бессерде́чие, жестокосе́рдие; *см. тж.* **кансызлык**; *~ белән* с беспоща́дностью; беспоща́дно, жесто́ко

шәфкатьчән *прил.* мягкосерде́чный, доброжела́тельный, сочу́вствующий

шәфкатьче *сущ.* благодéтель, благодéтельница, благотвори́тель, благотвори́тельница, покрови́тель, покрови́тельница

шәфкатьчелек *сущ.* благодея́ние; вхожде́ние в положе́ние □ **~ итү** ока́зывать благодея́ние; входи́ть в положе́ние

шәфталу *сущ. бот.* 1. пе́рсик (*дерево и плод*); *ваза тулы алма, ~* по́лная ва́за я́блок, пе́рсиков 2. шепта́ла (*высушенные на солнце абрикосы или персики*)

шәффаф *сущ. уст. книжн.* прозра́чный; просве́чивающий насквóзь; *~ шәраб* бе́лое винó

шәхес *сущ.* ли́чность; (отде́льное) лицó; челове́к, осóба, персóна; субъ́ект || ли́чный, ли́чностный; индиви́дуум *книжн.*; *юридик ~* юриди́ческое лицó; *физик ~* физи́ческое лицó; *жәмгыятьтә ~нең тоткан урыны* ме́сто челове́ка (ли́чности) в óбществе; *~нең үсеше* разви́тие ли́чности; *аерым ~кә мөнәсәбәт* отноше́ние к отде́льному индиви́дууму (челове́ку); *~ иреге* свобóда ли́чности; *~нең кагылгысызлыгы юр.* неприкосновéнность ли́чности; *~ статусы юр.* ли́чностный ста́тус □ **~ культы** культ ли́чности; **~кә сыгыну (табыну)** *уст. см.* **шәхес культы**

шәхесара *прил. книжн.* межли́чностный; *~ килешүчәнлек* межли́чностная совмести́мость; *~ мөнәсәбәтләрне аңлау* осозна́ние межли́чностных отноше́ний

шәхсән *нареч.* ли́чно; персона́льно; *~, мин үзем каршы түгел* ли́чно я не про́тив □ **~ үзе** сóбственной персóной, сóбственной осóбой; ли́чно сам

шәхси *прил.* 1. ли́чный; индивидуа́льный, персона́льный, сóбственный; *~ мәнфәгать* ли́чный интере́с; *~ үрнәк* ли́чный приме́р; *~ хуҗалык* ли́чное (индивидуа́льное) хозя́йство 2. *см.* **хосусый**; *~ бакчалар* индивидуа́льные сады́; *~ йорт* ча́стный дом □ **~ милек (мөлкәт)** ли́чная сóбственность; **~ фикер (караш)** ли́чное мне́ние

шәхсиле|к *сущ.* ли́чность || ли́чностный; ли́чные (индивидуа́льные) осóбенности, индивидуа́льность; *~ген югалту* обезли́чиваться

шәхсиян *нареч. уст. см.* **шәхсән**; *~ теләмәгән дә идем* ли́чно да́же и не хоте́л

шәхсият *сущ. книжн.* 1. (*юридическое*) лицó, челове́к, ли́чность, индиви́дуум; *см. тж.* **шәхес** 2. индивидуа́льность; ли́чность (*как особенность, свойство индивидуума*); лицó

шәһәр *сущ.* 1. гóрод (*обычно большой, с пригородами*) || городскóй; *Казан ~е* гóрод Каза́нь; *~не яшелләндерү* озелене́ние гóрода; *зур ~* большóй гóрод, городи́ще; *~ советы* городскóй сове́т, горсове́т 2. *разг.* центр (*города*); *~гә чыгу* пойти́ в центр, в гóрод; *~ белән бистәне тоташтыра торган юл* дорóга ме́жду гóродом и слободóй (*между центром и окраиной*) □ **~ кешесе** горожа́нин, городскóй; **~ тирәсе (яны)** при́город; **~ халкы** горожа́не,

городско́е населе́ние; ~ **чите** окра́ина го́рода; ~ *читендә* за го́родом, в окре́стностях го́рода; ~ **читендәге (янындагы)** за́городный

шәһәрара *прил.* междугоро́дный; ~ *элемтә* междугоро́дная связь; ~ *сөйләшү пункты* междугоро́дный перегово́рный пункт

шәһәрләш|ү *неперех.* 1. приобрета́ть/приобрести́ городски́е черты́, превраща́ться/преврати́ться в го́род (*о населенных пунктах, рабочих посёлках*) 2. превраща́ться/преврати́ться в городско́го челове́ка, станови́ться/стать городски́м; *кызлар тизрәк ~ә* де́вушки быстре́е стано́вятся городски́ми 3. урбаниза́ция; *~ү күренеше* явле́ние урбаниза́ции

шәһәрле I *сущ. редко* горожа́нин, горожа́нка, жи́тель, жи́тельница го́рода, городско́й, городска́я

шәһәрле II *прил.* име́ющий определённое число́ городо́в; *күп ~* со мно́гими города́ми (*область, регион*)

шәһәрле|к *сущ. археол.* городи́ще; *Болгар һәм Биләр ~ләре* городи́ща Бу́лгар и Биля́р

шәһәрчә *нареч.* по-городско́му, как в го́роде; как горожа́не || *прил.* городско́й, как в го́роде; ~ *йортлар* городски́е дома́; дома́, вы́строенные как в го́роде; ~ *парклар* па́рки по-городско́му

шәһәрчәләнү *неперех.* приобрета́ть/приобрести́ вид (хара́ктер, сво́йство) го́рода

шәһәрчәлек *сущ.* состоя́ние, сво́йство быть по-городско́му; городско́й хара́ктер; *киенүдәге ~* городско́й хара́ктер в оде́жде; *~не сакларга тырышу* постара́ться быть как городски́е

шәһәрче *сущ. редко* 1. архите́ктор-градострои́тель 2. урбани́ст, после́дователь урбани́зма

шәһәрчек *сущ.* 1. городо́к, городи́шко, небольшо́й го́род 2. городо́к (*военный, детский, молодёжный, медицинский, университетский, палаточный и т. п.*)

шәһәрчелек *сущ. книжн.* 1. урбани́зм (*в литературе, музыке, живописи*); ~ *мотивлары* моти́вы урбани́зма 2. градострои́тельство || градострои́тельный

шәһвәт *сущ. уст. книжн.* вожделе́ние, сладостра́стие, по́хоть, полово́е влече́ние, страсть; либи́до *книжн.*; ~ *илә күз атты* посмотре́л с вожделе́нием (стра́стно)

шәһвәтле *прил. уст. книжн.* сластолюби́вый, сладостра́стный, с вожделе́нием, с похотли́вым влече́нием; похотли́вый

шәһит *сущ.* 1. *уст. рел.* шахи́т, му́ченик, па́вший за ве́ру (*мусульманскую*); *атасы, хаҗдан кайтканда юлда үлеп, ~ булган* оте́ц его́ у́мер в пути́ по́сле пало́мничества в Каа́бу и стал шахи́том 2. *разг. поэт.* уби́тый на войне́, поги́бший, па́вший в бою́ за пра́вое де́ло; *~ләрнең мөкатдәс каннары* свята́я кровь поги́бших □ ~ **булу** быть уби́тым на войне́; ~ **китү** 1. *см.* **шәһит булу** 2. поги́бнуть сме́ртью геро́я, поги́бнуть на по́ле бра́ни

шәбәбра *сущ. мор.* шва́бра; ~ *белән юу* мыть шва́брой (*палубу*)

швед *сущ.* швед, шве́дка || шве́дский; ~ *халкы* шве́ды; ~ *офицеры* шве́дский офице́р □ ~ **чебене** *зоол.* шве́дская му́ха

шведча *нареч.* по-шве́дски, на шве́дском языке́ (*говорить, писать, читать, учиться и т. п.*) || *прил.* шве́дский (*язык, корабль, акцент*) на шве́дском языке́; по-шве́дски (*разговор, радиопередачи, учебник, книга и т. п.*)

шведчалап *нареч. разг.* (нарочи́то) по-шве́дски, на шве́дском языке́ (*запеть, заговорить*)

швейцар I *сущ.* швейца́р || швейца́рский; ~ *булып эшләү* рабо́тать швейца́ром; ~ *киеме* швейца́рская ливре́я; ~ *бүлмәсе* швейца́рская ко́мната, швейца́рская (*сущ.*)

швейцар II: **швейцар сыры** швейца́рский сыр

швейца́рияле *сущ.* швейца́рец, швейца́рка || швейца́рский; *~ләр* швейца́рцы; *~ләр зәвыгы* в швейца́рском вку́се

шеббуй *сущ. бот.* левко́й || левко́йный; ~ *исе* левко́йный за́пах (арома́т), за́пах (арома́т) левко́я

шеббуйсыман: шеббуйсыман сарыбаш *бот.* желту́шник левко́йный

шевиот *сущ.* шевио́т; *костюмлык ~* шевио́т на костю́м || шевио́товый; ~ *юбка* шевио́товая ю́бка

шевро *сущ.* шевро́ || шевро́вый; ~ *белән тышланган диван* дива́н, обши́тый шевро́, ко́жаный дива́н из шевро́

шеврон *сущ. воен.* шевро́н (*знак сверхсрочной службы или ранения*) || шевро́нный

шедевр *сущ.* шеде́вр (*в поэзии, архитектуре, искусстве*)

шезлонг *сущ.* шезло́нг || шезло́нговый; ~ *киндере* шезло́нговая паруси́на

шейк *сущ. неол.* шейк; ~ *бию* танцева́ть шейк

шекә *сущ. миф.* гном, шиши́га, шишо́к; *~дән курку* боя́ться гно́ма (гно́мов) □ ~ **пәрие** *см.* **шекә**

шеле *сущ.* лы́ко, пригото́вленное для плете́ния лапте́й

шелтә *сущ.* 1. упрёк, укор, укори́зна, порица́ние || укори́зненный; *күзләрендә ~*, *телендә үпкә* в глаза́х укор, на языке́ оби́да (слова́ оби́ды); ~ *белән каршы алу* встреча́ть с упрёком; ~ *тавышы* укори́зненный во́зглас (го́лос); ~ *сүзләре* укори́зненные слова́, слова́ с упрёком (с уко́ром) 2. вы́говор; замеча́ние, порица́ние; взыска́ние; нагоня́й, нахлобу́чка *прост.*; взбу́чка, вздрю́чка; *административ ~* администрати́вное замеча́ние (порица́ние); *җәмәгатьчелек ~се* обще́ственное порица́ние; *каты ~* стро́гий вы́говор; *җитди ~* вы́говор с предупрежде́нием □ ~ **алу** получа́ть/получи́ть вы́говор; ~ **белән** с упрёком, с уко́ром, укори́зненно; ~ **белдерү** объявля́ть/объяви́ть вы́говор; ~ **бирү** 1. *см.* **шелтә белдерү** 2. наложи́ть взыска́ние; ~ **чәпәү** *прост.* влепи́ть вы́говор; ~ **ясау (ташлау)** 1. броса́ть/бро́сить упрёк *кому-л.*; упрека́ть/упрекну́ть *кого-л. чем-л.*; ста́вить в уко́р *кому, что*; кори́ть, укоря́ть, попрека́ть/попрекну́ть 2. сде́лать замеча́ние; сде́лать вы́говор

шелтәлә|ү 1. укоря́ть/укори́ть, кори́ть, попрека́ть/попрекну́ть, упрека́ть/упрекну́ть, вини́ть || уко́р, упрёк, попрёк; *соңга калган өчен ~у* упрека́ть за опозда́ние; *~үгә карамастан* несмотря́ на упрёк 2. отчи́тывать/отчита́ть, порица́ть, намы́лить го́лову; жури́ть, дать нагоня́й □ ~**п алу** упрекну́ть; ~**п кую** попрекну́ть

шелтәле *прил.* укори́зненный; с уко́ром, с упрёком; неодобри́тельный; ~ *караш* неодобри́тельный взгляд; укори́зненный взгляд; ~ *сүзләр* укори́зненные слова́, упрёки; порица́ния || *нареч.* укори́зненно, с уко́ром, с упрёком; ~ *карау* посмотре́ть с упрёком; ~ *итеп әйтү* сказа́ть укори́зненно

шепкән *сущ. бот.* ры́жик; суре́пица культу́рная || ры́жиковый; суре́пный; *төкле ~* волоси́стый ры́жик; *вак җимешле ~* мелкоплодный ры́жик; *уҗым ~е* озимая суре́пица; ~ *орлыгы* ры́жиковое (суре́пное) се́мя; ~ *мае* ры́жиковое ма́сло

шере́нга *сущ. воен.* шере́нга || шере́нговый; *~ булып бару* идти́ в шере́нгу; *~ строе* шере́нговый стро́й, шере́нговое постро́ение

шерхе́бель *сущ. спец.* шерхе́бель (*род рубанка*)

шестерня *сущ. тех.* шестерня́ (*зубчатое колесо*); *см. тж.* **алтаяк**, *төшле тәгәрмәч*; *агач ~лары* деревя́нные шестерни́ ме́льницы; *кыек төшле ~* косозу́бая шестерня́

шестернялы *прил. тех.* шестерённый, шестерёнчатый (*механизм, насос*)

шеф *сущ.* **1.** шеф (*тот, кто шефствует над кем-л.*) || ше́фский; *шефлар ярдәмендә* с по́мощью ше́фов; *шеф вазифалары* ше́фские обя́занности **2.** *разг.* шеф, руководи́тель (*группы, коллектива*), нача́льник; *шефына охшарга тырыша* стара́ется походи́ть на своего́ ше́фа **3.** *первая составная часть названия должностей, обозначающая* руководи́тель, ста́рший *и т.д.*: **шеф-пилот, шеф-по́вар** □ **шефка алу** *см.* **шефлыкка алу**; **шефка алынган** подше́фный (*колхоз, школа и т. п.*)

шефлы|к *сущ.* ше́фство || ше́фский; *заводның колхозларга ~гы* ше́фство заво́да над колхо́зами; *~к эше* ше́фская рабо́та; *~к ярдәме күрсәтү* оказа́ть ше́фскую по́мощь □ **~к итү** ше́фствовать *над кем-л.*; *чем-л.*; ше́фство; **~кка алу** взять ше́фство *над кем-л., чем-л.*; быть ше́фом

шефчы *сущ. разг. см.* **шеф** 1; *~лар ярдәме* по́мощь ше́фов; ше́фская по́мощь

шеш I *сущ.* **1.** о́пухоль; *каты шеш* твёрдая (пло́тная) о́пухоль; *яман шеш* злока́чественная о́пухоль, рак; *эчтә калган сүз шешкә эйләнә, ди* (*погов.*) невы́сказанное сло́во (упрёк) превраща́ется в о́пухоль; *май шеш* жирови́к **2.** ши́шка; (*малайның*) *маңгаенда йодрык кадәр шеш* на лбу (ма́льчика) ши́шка с кула́к **3.** наро́ст, наплы́в (*обычно, на стволах деревьев*); *см. тж.* **оры**; *сөяк шеше* наплы́в, нали́в, надко́стница (*у лошадей*); *агач шеше* наро́ст, наплы́в, болона́ □ **шеш гөле** *бот. разг.* ало́э; **шеш тулу** **1.** нарыва́ть, нагнои́ться (*об опухоли*), назре́ть (нары́в) **2.** *перен.* давно́ наболе́ло, назре́ло; ста́ло невтерпёж, перепо́лнилось че́рез край (*о чем-л. предосудительном*) ◊ **шеш өстенә чөш** ≈ из огня́ да в по́лымя (*букв.* на о́пухоль да ещё нары́в)

шеш II *сущ.* **1.** стожа́р; остро́вье *обл.* (*шест в середине стога*); *кибән шеше* стожа́р; *тары шеше* ты́чка (остро́вье, шест) (*для закрепления и проветривания просяных снопов*) **2.** ве́ртел, шампу́р (*для жарения шашлыка*); *тимер мич өстендә шешкә кидерелгән сарык ите* на желе́зной пе́чи бара́нина на ве́ртеле; *шешкә кидерү* наса́живать на ве́ртел □ **шеш кебек** прямо́й как стожа́р, как шест, как ве́ртел; *агач башы шеш кебек* верху́шка де́рева как шест (торчи́т как стожа́р); **шеш колак** у́ши торчко́м

шешә *сущ.* буты́лка || буты́лочный; *зур ~* буты́ль; *кечкенә ~* буты́лочка, пузырёк, флако́н; *дару ~се* пузырёк для лека́рств; *~ төбе* дно буты́лки; *~ ватыклары* буты́лочные оско́лки; *~ пыяласы* буты́лочное стекло́ □ **~ бүкесе** про́бка ◊ **~ төбе ялау** *прост.* **1.** подбира́ть чужи́е оста́тки **2.** прислу́живать *кому*, холу́йствовать *перед кем*, уго́дничать; **~ төбе ялаучы** прислу́жник, прислу́жница, холу́й; **~ ялау** пья́нствовать, преда́ться пья́нству, люби́ть выпива́ть; **~ ялаучы** алкого́лик, пья́ница, пропо́йца

шешәдәш *сущ.* собуты́льник; *~ дуслар* друзья́-собуты́льники; *~ләр шешә бушаганчы гына дус була* собуты́льники дру́жат, пока́ буты́лка не пуста́

шешәк *прил.* **1.** в во́зрасте по́сле второ́го око́та и́ли вы́вода птенцо́в; *~ каз* гусы́ня на второ́й год по́сле вы́вода птенцо́в (*на первый год* — **бала каз**); *~ сарык* овца́ в во́зрасте по́сле второ́го око́та (*после первого окота* — **бәрән сарык**) **2.** *диал.* **1)** двухле́тний, двухгодова́лый; по второ́му го́ду (*гусыня, овца, коза*) **2)** пе́рвый год не да́вший пото́мства по́сле пе́рвого око́та и́ли вы́вода птенцо́в (*овца, коза, гусыня*); *~ сыер* коро́ва, пе́рвый год оста́вшаяся я́ловой по́сле пе́рвого отёла

шешәле *прил.* буты́лочный (*в бутылках*); *~ сөт* буты́лочное (не разливно́е) молоко́; *~ сыра* буты́лочное пи́во

шешбалык *сущ. кул.* ры́ба, жа́ренная над костро́м (*в нанизанном на прут виде*); копчёная ры́ба

шешбәррә *сущ. кул.* **1.** шашлы́к; *см. тж.* **шешлек** 2. пельме́нь; пельме́ни, жа́ренные на пру́те **3.** пельме́нь, пельме́ни (*вообще*)

шешек *сущ. разг.* нары́в, гнойни́к; чи́рей, фуру́нкул; боля́чка || нарывно́й; *үлекле ~* гно́йный нары́в; абсце́сс; *бөтен тәнен ~ баскан* всё те́ло покры́то чи́рьями (фуру́нкулами); *~ пластыре* нарывно́й пла́стырь; *~ авырта дип, аны ярмый тормыйлар* (*посл.*) хотя́ нары́в (чи́рей) боли́т, но всё равно́ его́ удаля́ть (опери́ровать)

шешемсерә|ү *неперех. см.* **шешенкерәү**; *күз төпләре ~п тора* под глаза́ми слегка́ отекло́ (небольшо́й отёк)

шешенке *прил.* опу́хлый, припу́хлый, отёчный, опу́хший, отёкший; одутлова́тый, обрю́зглый; *~ чырайлы кеше* челове́к с одутлова́тым лицо́м; *~ күз кабагы* отёкшие ве́ки; *~ яңак* опу́хшая щека́

шешенкеләнү *неперех.* (слегка́) отека́ть, опуха́ть, де́латься/сде́латься одутлова́тым; появля́ться (об отёках); *йокысызлыктан күз тирәсе ~* появле́ние отёков под глаза́ми от бессо́ницы

шешенкелек *сущ.* отёчность, опу́хлость; одутлова́тость (*щек, лица*)

шешенкерә|ү *неперех.* слегка́ опуха́ть/опу́хнуть, слегка́ отека́ть/оте́чь; припуха́ть/припу́хнуть || отёк, опуха́ние; *чырае ~п киткән* лицо́ припу́хло

шешен|ү *неперех.* **1.** пу́хнуть, опуха́ть/опу́хнуть, распуха́ть/распу́хнуть (*от голода, от болезни*); брю́згнуть/обрю́згнуть; *ачлыктан ~ү* пу́хнуть от го́лода **2.** пу́хнуть, опуха́ть/опу́хнуть, отека́ть/оте́чь || опуха́ние, отёк; *елый-елый күзләре ~гән* от слёз опу́хли глаза́; *аяклар ~ә* но́ги отека́ют; *күз төпләре ~гән* под глаза́ми мешки́, под глаза́ми отёки □ **~еп китү** опу́хнуть, оте́чь

шешенүле *прил. см.* **шешле**

шешке *сущ. разг.* ши́шка, ши́шечка (*на головном уборе*)

шешләү *перех.* наса́живать на ве́ртел (*мясо, дичь, рыбу и т. п.*)

шешле *прил.* воспали́тельный; крупо́зный

шешмә *прил. см.* **шешенке**; *~ кабаклы күз* глаза́ с припу́хлыми ве́ками

шешмәк *прил.* слегка́ опу́хший

шешмәклән|ү *неперех. см.* **шешенкеләү**; *йокысызлыктан күз кабаклары ~гән* ве́ки распу́хли от бессо́ницы

шешмән *прил.* пу́хлый, то́лстый || *сущ.* пухля́к (*только о мужчине*)

шештергеч *сущ. зоол.* нары́вник (*жук*); *дала ~е* степно́й нары́вник; *нәни ~* ма́ленький нары́вник

шештер|ү *перех.* вызыва́ть/вы́звать, возбужда́ть/возбуди́ть нары́в, гное́ние, о́пухоль; *бармагын ~гән* его́ па́лец нарыва́ет, гнои́тся; *җәрәхәткә пычрак керсә, ~ер* е́сли в ра́ну попадёт грязь, то вы́зовет гное́ние

шеш|ү *неперех.* **1.** нарыва́ть/нарва́ть, опуха́ть и нагнои́ться || нары́в, нагное́ние; *кулы ~кән* ру́ку нарва́ло;

па́лец нарва́л (вспух) 2. воспаля́ться/воспали́ться || воспале́ние; круп; *үпкә ~ү* воспале́ние лёгких; *колак ~ү* воспале́ние (сре́днего) у́ха; *тамак төбе ~ү* воспале́ние го́рла, анги́на 3. *см.* **шешенү**; *күз төпләре ~кән* появи́лись отёки под глаза́ми; *күз кабаклары ~кән* опу́хли ве́ки □ **~ еп китү (чыгу)** напуха́ть, опуха́ть, распуха́ть (неожи́данно); *яңагы ~еп чыкты* щека́ наду́лась

шешүле *прил.* воспали́тельный, крупо́зный; *~ процесс* воспали́тельный проце́сс

шиблет *сущ. разг. см.* **штиблет**; *аягында хром ~лар* на нога́х (у него́) хро́мовые штибле́ты

шивә *сущ.* 1. наре́чие; *һәр кешенең үз теле, үз ~се* у ка́ждого свой язы́к, своё наре́чие 2. *уст.* го́вор; диале́кт; язы́к; *мишәр ~се* мишарский диале́кт

шивәле *прил. уст.* диалекта́льный; *~ сүз* диалекта́льное сло́во

шивәчелек *сущ. уст.* диалекти́зм; *матур әдәбият-та ~ мәсьәләләре* вопро́сы диалекти́зма в худо́жественной литерату́ре

шига *сущ. рел.* 1. ши́зм (*направление в исламе*) || ши́йтский; *~ имамы* ши́йтский има́м 2. *см. тж.* **шагыйлек**

шиган *сущ. диал.* со́пка в степи́, шиха́н *обл.*

шигар *сущ. уст. книжн.* 1. ло́зунг; клич; *хөрлек, тигезлек аның ~е* ло́зунг его́ — свобо́да и ра́венство 2. цель; деви́з; *бөтен халыкның уртак ~е* о́бщая цель всего́ наро́да

шигә|ю *неперех.* настора́живаться/насторожи́ться; *~йде, ахры, сагаеп калды* ви́димо, заподо́зрил, насторожи́лся; *~еп карау* смотре́ть, рассма́триваться с подозре́нием

шигәюле *прил.* недове́рчивый, подозри́тельный; *~ караш* подозри́тельный взгляд

шигри *сущ.* шагре́нь; *~ белән тышланган калын китап* то́лстая кни́га в шагре́невом переплёте (переплетённая в шагре́нь) || *прил.* шагре́невый; *~ күн* шагре́невая ко́жа

шигъри *прил.* 1. поэти́ческий; *~ форма* поэти́ческая фо́рма; *~ әсәр* поэти́ческое произведе́ние; *~ сөйләм* поэти́ческая речь 2. поэти́ческий, поэти́чный; *~ матурлык* поэти́ческая красота́; *~ хисләр* поэти́ческие чу́вства; *~ табигать* поэти́чная нату́ра

шигърән *нареч. уст. книжн.* в стихотво́рной фо́рме; *фикерне ~ әйтеп бирү сәләте* спосо́бность переда́ть свои́ мы́сли в стихотво́рной фо́рме

шигърилек *сущ.* поэти́чность (*чувства, природы, речи, образа и т. п.*)

шигърият *сущ. книжн.* 1. поэ́зия; *~ һәм сәнгать* поэ́зия и иску́сство; *~ һәм тормыш* поэ́зия и жизнь 2. поэти́чность; поэ́зия (*природы, жизни, труда, дальних странствий, туризма и т. п.*)

шигъриятле *прил. книжн.* поэти́ческий, поэти́чный; *~ музыка* (*җыр*) поэти́чная му́зыка (*песня*)

шигъриятлелек *сущ. книжн.* поэти́чность (*поэмы, городского сада, осеннего леса и т. п.*)

шигый *прил. рел.* 1. ши́йтский 2. *в знач. сущ.* ши́йт (*последователь шиизма*); *~лар мәзһәбе* ши́изм; *см. тж.* **шига**; *~лар белән сөннилəр арасындагы көрəш* борьба́ ме́жду ши́итами и сунни́тами

шигыйлек *сущ. рел.* ши́изм; *см. тж.* **шига**; *~кү күчү* переходи́ть/перейти́ в ши́изм, станови́ться/стать ши́итом (*сторонником шиизма*)

шигырь *сущ.* 1. стих; стихотворе́ние || стихотво́рный; *лирик ~* лири́ческое стихотворе́ние; *~ сөйләү* (*уку*) чита́ть стихи́; *~ ятлау* вы́учить наизу́сть стихотворе́ние; *~ төзелеше* стихосложе́ние; *~ үлчәме* стихотво́рный разме́р; разме́р стиха́; *~ юллары* стихотво́рные стро́ки 2. поэ́зия; *~гә яшьләр килүе күңелле* отра́дно, что в поэ́зию идёт молодёжь

шигырьлек *сущ.* сво́йство быть (называ́ться) стихотворе́нием, поэ́зией

шигырьче *сущ.* 1. стихотво́рец; *см. тж.* **шагыйрь**; *язганыңны ~лар карамагына тапшырдым* твою́ ру́копись переда́л поэ́там (занима́ющимся поэ́зией) 2. *пренебр.* рифма́ч, стихоплёт (*о плохом поэте*)

шизофре́ник *сущ.* шизофре́ник, шизофрени́чка (*человек, больной шизофренией*) || *прил.* шизофрени́ческий; *~ психология* шизофрени́ческая психоло́гия

шизофрения *сущ. мед.* шизофрени́я || шизофрени́ческий; *~ белән авыручы* шизофре́ник, больно́й шизофрени́ей

ший I *подр.* 1. *свистящему звуку ветра, возникшему при полёте пуль, при ударе прутиком или кнутом, при косьбе*; *ший килеп пуллялар оча* свистя́т пу́ли; со сви́стом пролета́ют пу́ли 2. *визгу, писку птичек*; *чыпчык балалары ший килеп ашарга көтәләр* пте́нчики воробья́ пища́т, ждут корм 3. *свисту крыльев птиц при быстром полёте*

ший II *межд. возглас, которым шугают, пугают, отгоняют коршуна* шш; *балалар ший кычкырып тилгән куалар* де́ти с кри́ком «шш» отгоня́ют ко́ршуна

шик *сущ.* 1. подозре́ние; *шик белән карау* смотре́ть с подозре́нием; подозрева́ть, не ве́рить 2. сомне́ние (*в ком-л., в чём-л.*); недове́рие, недоуме́ние; *шик белдерү* вы́разить сомне́ние, недове́рие; *эшне уңышлы тәмамлаячагыбызга шик булырга мөмкин түгел* не мо́жет быть сомне́ний в том, что де́ло не заверши́м благополу́чно 3. *разг.* страх, испу́г; опасе́ние, опа́ска; трево́га; *см. тж.* **шом** □ **шик астына алу** брать/взять под сомне́ние; подверга́ть сомне́нию; относи́ться недове́рчиво; **шик астындагы кеше** неблагонадёжный челове́к; **шик басу** быть охва́ченным стра́хом; **шик керү (төшү)** вселе́ние, появле́ние сомне́ния; захва́тывание стра́хом; **шик салу** 1. се́ять сму́ту, мути́ть 2. вызыва́ть/вы́звать подозре́ние 3. вызыва́ть/вы́звать страх (трево́гу); трево́жить; **шик тота башлау** заподо́зрить; **шик тоту** сомнева́ться, подозрева́ть; **шик тудыру** 1. вы́звать/вы́звать сомне́ние; наводи́ть/навести́ на сомне́ние 2. вызыва́ть/вы́звать подозре́ние; **шик юк** *вводн. сл.* сомне́ний нет, без сомне́ния, вне вся́кого сомне́ния; несомне́нно, бесспо́рно; **шиккә калу (төшү)** 1. впасть в сомне́ние; заподо́зрить; сомнева́ться, не твёрдо ве́рить *во что-л.* 2. испуга́ться, испы́тывать опасе́ния; **шиккә төшерү** вызыва́ть/вы́звать подозре́ние, ввергать в сомне́ние

шикаять *сущ. книжн.* 1. жа́лоба || жа́лобный; *~лар кабул итү* принима́ть жа́лобы; *~лар дәфтәре* жа́лобная кни́га 2. доно́с; клевета́, кля́уза || клеветни́ческий, кля́узный; *~ хаты* (*язуы*) клеветни́ческое письмо́ 3. недово́льство, се́тование по по́воду *чего-л.*, выраже́ние недово́льства; *бәхетеңнән ~ ул алладан ~ була* недово́льство свои́м сча́стьем — э́то есть недово́льство бо́гом □ **~ итү (кылу)** 1. жа́ловаться, пода́ть жа́лобу *на кого* 2. доноси́ть; я́бедничать 3. се́товать, ропта́ть *на кого-что*; огорча́ться, печа́литься *по какому-л. поводу*

шикаятьле *прил. книжн.* жа́лобный, име́ющий жа́лобы и се́тования; жа́лостный; *~ тавыш* жа́лобный го́лос

шикаятьнамә *сущ. уст. книжн.* жа́лоба (*официальное письменное заявление*); *~ язу* писа́ть жа́лобу

шикәр *сущ.* **1.** са́хар || са́харный; *башлы ~* са́хар в голо́вках; *~ вату* коло́ть са́хар; *шакмак(лы) ~* пилёный са́хар, са́хар-рафина́д; *~ кабып чәй эчү* пить чай вприку́ску; *~ заводы* са́харный заво́д; *~ комы* са́харный песо́к; *~ камышы* са́харный тростни́к **2.** *спец.* са́хар (*мн.* сахара́) *кандагы ~* (*матдәсе*) са́хар в крови́; *сөттәге ~* (*матдәсе*) моло́чный са́хар; *виноградтагы ~* (*матдәсе*); *виноград ~е* виногра́дный са́хар □ **~ авыруы** *мед.* диабе́т, са́харная боле́знь; **~ авырулылар** *мед.* диабе́тики; **~ бете** *зоол.* са́харный клещ; **~ диабеты** *см.* **шикәр авыруы**; **~ кайнату** сахароваре́ние; **~ чөгендере** са́харная свёкла, свекло́вица; **~ ширбәте** глазу́рь

шикәрләндерелү *страд. от* **шикәрләндерү**

шикәрләндерү *перех.* заса́харивать/заса́харить, превраща́ть/преврати́ть *что-л.* в са́хар (*мёд, варенье*); *крахмалны сульфат кислотасы ярдәмендә ~* заса́харить крахма́л сульфа́тной кислото́й

шикәрләну *неперех.* **1.** заса́риваться/заса́риться, загусте́ть, кристаллизова́ться, превати́ться в са́хар (*о мёде, варенье*) **2.** *страд. от* **шикәрләү**

шикәрләп *нареч.* с са́харом; *~ чәй эчү* пить чай с са́харом

шикәрләү *перех.* **1.** наса́харить, положи́ть (класть) *во что-л.* са́хару; посы́пать са́харом; са́харить *что-л.*; заса́ривать/заса́харить; держа́ть в са́харном сиро́пе (*фрукты, ягоды*); обса́харить, посы́пать са́харом **2.** подсла́щивать/подсласти́ть, са́харить *что-л.* (*кефир, катык*)

шикәрле *прил.* **1.** с са́харом; подслащённый са́харом; *~ чәй* чай с са́харом; чай, подслащённый са́харом; *~ камыр* те́сто, подслащённое са́харом **2.** сла́дкий, вку́сный, са́харный; сахари́стый; *бу каеннарның ~ каеп суы* сахари́стый берёзовый сок; *чишмә сулары ~, эчсәм җанга җитәрме?* (*песня*) вкусна́ (сладка́) вода́ из родника́, но уто́лит ли ду́шу она́?

шикәрлелек *сущ.* содержа́ние са́хара *в чём-л.*, сахари́стость *чего-л.*; *~ дәрәҗәсе* сте́пень сахари́стости, сте́пень содержа́ния са́хара (*ягод, свёклы и т. п.*)

шикелле *послелог* **1.** 1) *с осн. п.* как, сло́вно, то́чно; *диңгез ~ киң һәм тигез дала* обши́рная и ро́вная, как мо́ре, степь; *мәче күзләре ~ яшел күзләр* зелёные, как у ко́шки, глаза́; *кәгазь ~ ап-ак чырай* бе́лое, сло́вно бума́га, лицо́ 2) *в сочет. с гл. на* **-ган**; как, бу́дто, как бу́дто, сло́вно; ка́к бы; *корт чыккан ~* как ужа́ленный; *кадакланган ~ утыра* сиди́т, сло́вно вко́панный **2.** *в именных словосочет.* подо́бный *кому-чему-л.*; наподо́бие *кого*; схо́дный *с кем-чем-л.*; похо́жий *на кого-что-л.*; *сезнең ~ләр* подо́бные вам (лю́ди) **3.** *в знач. вводн. сл.* ка́жется, как бу́дто, вро́де, по-ви́димому; *элегрәк алай түгел иде ~* ра́ньше, ка́жется, бы́ло не так; *бер тавыш та юк ~* как бу́дто, никако́го шу́ма нет; *мин сезне кичә күрдем ~* я, ка́жется, ви́дел вас вчера́

шикләндер|ү *понуд. от* **шикләну 1.** вы́звать сомне́ние, подозре́ние; *соңгы сүзләре ~де* после́дние слова́ (его́) вы́звали подозре́ние; показа́лись подозри́тельными **2.** трево́жить; вызыва́ть/вы́звать трево́гу (опасе́ние)

шикләнеп *нареч.* недове́рчиво, с подозре́нием (*смотреть, относиться и т. п.*)

шикләнерлек *прил.* подозри́тельный, сомни́тельный; вызыва́ющий сомне́ние (подозре́ние); *~ нәрсә тапмау* не найти́ ничего́ подозри́тельного; *бер дә ~ булмасын* что́бы не вы́звало подозре́ния; *~ нәрсә* то, что вызыва́ет подозре́ние; подозри́тельная вещь (явле́ние)

шикләнешү *взаимно-совм. от* **шикләну**

шикләнмичә *нареч.* уве́ренно, без сомне́ний; не сомнева́ясь, без подозре́ний

шикләну|ү *неперех.* **1.** подозрева́ть, заподазривать/заподозрить || подозре́ние; *бер-береңә ~еп карау* подозрева́ть друг дру́га; *урлаган дип ~ү* заподо́зрить в воровстве́; *~үләрнең нигезсезлеге* беспо́чвенность подозре́ний **2.** 1) сомнева́ться *в ком-л.*; усомни́ться *в ком-л., чём-л.* || сомне́ние; колеба́ться, быть в нереши́тельности; *аның хаклы булуына ~ү* усомни́ться в его́ правоте́; *мин ~мим, син җиңәрсең* я не сомнева́юсь, что ты победи́шь; *~үнең әсәре дә юк* нет и те́ни сомне́ния 2) сомнева́ться *в ком-л.*; не быть уве́ренным *в ком-л.*; не вполне́ дове́рять *кому-л.*; недоумева́ть, испы́тывать недоуме́ние, недове́рие || неуве́ренность, недове́рие; *~еп карау* относи́ться с недове́рием, смотре́ть с сомне́нием **3.** опаса́ться, испы́тывать опасе́ние, боя́ться; беспоко́иться (*по поводу чего-л.*), трево́житься (*ожидая что-л.*) || опасе́ние; трево́га; *шомлы ~ү* трево́жные опасе́ния; *киллмәс дип ~ү* опаса́ться, что не придёт; *ялгыз калырга ~ү* боя́ться остава́ться одному́ □ **~ә башлау** засомнева́ться; **~еп йөрү** быть в сомне́нии, сомнева́ться; **~еп калу** заколеба́ться; **~еп кую** усомни́ться ◊ **~ү корты** червь сомне́ния

шикләнүле *прил.* подозри́тельный, недове́рчивый; *~ мөнәсәбәт* недове́рчивое отноше́ние

шикләнүсез *нареч.* без сомне́ний и стра́ха; *~ эшкә керешү* принима́ться за рабо́ту без стра́ха

шикләнүчән *прил.* **1.** подозри́тельный (*видящий всегда во всем для себя неблагоприятное*), мни́тельный; недове́рчивый; *~ кеше* недове́рчивый челове́к; *артык ~* сли́шком мни́тельный; *~ караш* недове́рчивый взгляд **2.** (часто) сомнева́ющийся, нереши́тельный; (*обычно*) коле́блющийся

шикләнүчәнлек *сущ.* подозри́тельность, недове́рчивость, мни́тельность; нереши́тельность

шикләнүче *сущ.* тот, кто не ве́рит; кто сомнева́ется; *~ләр булса,* (*бу эшкә*) *тотынмагыз да* кто не ве́рит, пусть и не берётся (за э́то де́ло)

шикләнчек *прил. разг.* мни́тельный; *~ икәнсең* ты, ока́зывается, мни́тельный

шикле *прил.* **1.** 1) подозри́тельный, внуша́ющий подозре́ние, опасе́ние; *~ кеше* подозри́тельный челове́к; подозри́тельная ли́чность 2) подозрева́ющий, недове́рчивый (*взгляд, характер*) **2.** сомни́тельный, подозри́тельный, предосуди́тельный, неблагови́дный (*о прошлом, о репутации и т. п.*); *~ юлга басу* встать на сомни́тельный путь; *~ метод куллану* испо́льзовать подозри́тельный ме́тод (*работы*) **3.** сомни́тельный, нея́сный, не совсе́м поня́тный (*случай правописания*); *хатның ~ урыннарын кабат-кабат укыды* сомни́тельные (непоня́тные) места́ в письме́ чита́л и переча́тывал **4.** *см.* **шик астындагы (кеше)**; *~ кешеләр исемлеге* спи́сок неблагонадёжных; *~ дип исәпләү* счита́ть неблагонадёжным **5.** *в функ. сказ.* сомни́тельно, маловероя́тно; вряд ли; ви́лами на воде́ (по воде́) пи́сано; *бу китапның быел чыгуы ~* вряд ли в э́том году́ вы́йдет э́та кни́га

шиклелек *сущ.* подозри́тельность (*кого, чего-л.*); сомни́тельность *чего-л.*

шикмә *сущ.* **1.** подреше́тина; обреше́тина; *~ләр түшәмәсе* подреше́тник, обрешётка; *~ такталары* до́ски обрешётки **2.** *диал.* мо́стик

шикмәле *прил.* с подреше́тником, с обреше́тиной

шикмәлек *прил.* назна́ченный на реше́тник; *~ материал сатыла* продаётся (материа́л на) реше́тник

шиксез *прил.* **1.** я́сный; то́чный; соверше́нный, бесспо́рный; опеределённый, конкре́тный; *~ бер фикергә килү* прийти́ к определённому вы́воду; *~ максат булганда* когда́ есть конкре́тная цель; *~ дөреслек* соверше́нная пра́вда **2.** неизбе́жный, ве́рный; *алда ~ һәлакәт* впереди́ ве́рная ги́бель || *нареч.* **1.** то́чно, определённо, бесспо́рно, несомне́нно, обяза́тельно; *см. тж.* **һичшиксез**; *җиңәрбез, ~ җиңәрбез* победи́м, несомне́нно, победи́м; *~ кирәкле нәрсә* бесспо́рно ну́жная вещь **2.** без сомне́ния, не сомнева́ясь, без подозре́ний; *аллага ~ ышану* ве́рить в бо́га без сомне́ния **3.** *в знач. вводн. сл.* без сомне́ния, несомне́нно; безусло́вно, бесспо́рно, непреме́нно; наверняка́; то́чно, ве́рно; коне́чно

шиксен|ү *неперех. см.* **шикләнү**; (слегка́) сомнева́ться; не доверя́ть

шикчән *прил. см.* **шикләнүчән**; *~ караш* недове́рчивый взгляд

шикчел *прил. см.* **шикләнүчән**; *~ кеше* мни́тельный челове́к; *авыру кеше ~гә әйләнә* больно́й челове́к стано́вится мни́тельным

шикчеллек *сущ. см.* **шикләнүчәнлек**; *холкындагы ~* подозри́тельность в его́ хара́ктере

шик-шөбһә *сущ. собир.* вся́кие подозре́ния, сомне́ния; *шик-шөбһәдән арыну* освободи́ться от вся́кого подозре́ния

шик-шөбһәле *прил. собир. см.* **шикле, шөбһәле**

шил *сущ. диал.* **1.** впа́дина, углублённое, вда́вшееся внутрь ме́сто, углубле́ние; низи́нка, я́мка, я́мочка **2.** глухо́е и́ли укро́мное ме́сто □ **шил булу** *диал.* **1.** впада́ть; ввали́ться, впада́ть внутрь, образова́ть я́мочки, впа́дины; *орган җире шил булган* от его́ уда́ра образова́лась впа́дина **2.** затиха́ть/зати́хнуть; превраща́ться/преврати́ться (*о движении, ходьбе*); *кеше аягы шил булгач* когда́ зати́хнут шаги́ (хожде́ние); **шил калу** *диал.* остава́ться/оста́ться (быть) безлю́дным, погрузи́ться в тишину́

шила|у *неперех. диал.* **1.** производи́ть/произвести́, вызыва́ть свиста́щий звук, свисте́ть; *аркасында сыек чыбык ~ды* над его́ спино́й свисте́л ги́бкий прут **2.** умча́ться со сви́стом, промча́ться со сви́стом, стрело́й

шилек *сущ. бот.* чили́га; чили́зник *обл.* || чили́говый; *тау битләрендә ~ үсә* на скло́нах гор растёт чили́га; *~ куагы* чили́говый куст; куста́рник чили́зника (чили́ги); *~ кузагы* чили́говый стручо́к; стручо́к чили́ги

ши́ллинг *сущ.* ши́ллинг (*английская монета*)

шил|ү *неперех.* **1.** впада́ть/впасть, ва́ливаться/ввали́ться, вдава́ться/вда́ться внутрь; образова́ться (*о впадинах, ямочках, котловинах и т. п.*); *җир ~гән урын* ме́сто, где по́чва опусти́лась **2.** спада́ть/спасть; уменьша́ться/уме́ньшиться в объёме (*о надувном мяче, шаре, об опухоли*); *шеше ~гән* о́пухоль спа́ла **3.** *перен. прост.* худе́ть, похуде́ть; *см. тж.* **шиңү**; *корсагы ~гән* брю́хо его́ похуде́ло (уба́вилось) **4.** *см.* **шил булу** 2; *кеше аягы ~ү* зати́хнуть (*о шагах*); станови́ться ти́хо, безлю́дно

шилык *сущ. см.* **шилек**

шим *сущ. диал.* **1.** ме́шень **2.** *перен.* дурачо́к; вы́живший из ума́

шимали *прил. уст.* се́верный; *~ Америка* Се́верная Аме́рика; *~ җилләре* се́верные ве́тры □ **~ төркиләр** тата́ры и башки́ры

шималь *сущ. уст.* се́вер || се́верный; *~дән искән салкын җил* холо́дный ве́тер с се́вера; се́верный холо́дный ве́тер; *~ диңгезе* се́верное мо́ре; *~ тарафыннан* с се́верной стороны́

шимбә *сущ.* суббо́та || суббо́тний; *~ көн кич белән* в суббо́ту ве́чером; *~ көн* суббо́тний день, суббо́та □ **~ өмәсе** суббо́тник

шимбәлек *сущ.* суббо́тник; *см. тж.* **шимбә өмәсе**

шимдә *нареч. книжн. уст.* тепе́рь; по́сле ска́занного; *~ аңлашылса кирәк* по́сле всего́ ска́занного, наде́юсь, поня́тно

шимпанзе *сущ.* шимпанзе́

шимсу I *диал. сущ. см.* **шим** 1

шимсу II *прил.* у́тлый, приспосо́бленный для ме́лкой воды́ (*о лодке*)

шин *сущ.* **1.** ши́на (*железный или резиновый обруч*); *тәгәрмәчкә тимер шин тарту* обтяну́ть колесо́ желе́зной ши́ной; *шин тимере* ши́нное желе́зо; *машина шины* маши́нная ши́на; *резин шин* рези́новая ши́на; *шинга һава тутыру* нака́чивать ши́ну **2.** *мед.* ши́на (*приспособление, служащее для повязки*); *сынган аякка шин салу* наложи́ть ши́ну на перело́м ноги́

шинел|ь *сущ.* шине́ль || шине́льный; *солдат ~е* солда́тская шине́ль; *~ь кайтармасы* ла́цкан шине́ли ◊ **~ь кию** (*букв.* надева́ть шине́ль) станови́ться/стать вое́нным; **~ь(не) салу** (*букв.* снять шине́ль) демобилизова́ться, станови́ться/стать шта́тским

шинельле *прил.* **1.** (*который*) в шине́ли; *в какой-л.* шине́ли; *сары ~* в се́рой шине́ли; *~ солдат* солда́т в шине́ли **2.** *перен. разг.* в шине́ли; вое́нный (*о человеке*); военнослу́жащий; *~ кыз* военнослу́жащая (де́вушка); *~ халык* вое́нные, военнослу́жащие; *~ләр белән урам тулган* у́лица полна́ вое́нных

шинельлек *прил.* **1.** шине́льный; на шине́ль, приго́дный для шитья́ шине́ли; *~ сукно* шине́льное сукно́; *~ материалдан пальто тегү* шить пальто́ из шине́льного материа́ла **2.** необходи́мый (доста́точный) на шине́ль; *бер ~ кенә калган* оста́лось то́лько на одну́ шине́ль

шинкар *сущ. уст.* шинка́рь, шинка́рка (*продавец спиртных напитков*)

шинлан|у *страд. от* **шинлау**; шинова́ться

шинлату *понуд. от* **шинлау**

шинлау *перех.* шинова́ть, обтя́гивать/обтяну́ть ши́ной, око́вывать/окова́ть ши́ной колесо́, надева́ть/наде́ть ши́ны на колёса || шино́вка; *тәгәрмәч тугызынарын ~* шинова́ть обо́дья колёс

шинлы *прил.* шино́ванный, с ши́ной; на ши́нах; *~ тәгәрмәчләр* шино́ванные колёса; *резин ~ йомшак фаэтон* мя́гкий фаэто́н на рези́новых ши́нах

шиншилла *сущ. зоол.* шиншилла || шиншилловый (*грызун, похожий на белку*); *Таҗикстан ~лары* шиншилловый Таджикиста́на; *~ мехы* шиншилловый мех; *~ мехыннан яка* шиншилловый воротни́к

шиньон *сущ.* шиньо́н; *~ кию* носи́ть шиньо́н; *~ эзерләү цехы* цех по изготовле́нию шиньо́нов

шиңгәк *прил. диал.* хи́лый, боле́зненный, сла́бый, увя́дший; *~ үлән ашаган мал ~ булыр* (*погов.*) скот, вскормленный увя́дшей травой, бу́дет хи́лым

шиңгән *прил.* вя́лый; увя́дший; завя́дший, завя́нувший, утра́тивший све́жесть; *~ чәчәк* увя́дший цвето́к

шиңдерү *понуд. от* **шиңү**

шиңмәс *прил.* неувяда́емый, неувяда́ющий □ **~ үлән** бессме́ртник, цмин *~* **чәчәк (гөл)** *бот.* сухоцве́т (*растение с сухими, не вянущими цветками*)

шиң|ү *неперех.* **1.** *прям., перен.* вя́нуть, завя́нуть, увяда́ть/увя́нуть, со́хнуть, засо́хнуть; бле́кнуть, побле́кнуть (*о цветах, растениях; о лице, красоте*); *чәчәкләр ~де* цветы́ завя́ли; *йөзе ~гән* лицо́ (его́, её) побле́кло

2. спада́ть/спасть (*об опухоли*); уменьша́ться в объёме, сжа́ться (*лишаясь своего содержимого*); *см. тж.* **шилү** 2; *корсагы ~гән* похуде́л (*букв.* брю́хо спа́ло); *кесәсе ~гән* карма́н его́ отоща́л (т. е. обезде́нежил); *тубың ~гән* мяч твой спусти́л (во́здух)

шип *сущ. тех.* шип; *яшерен шип* потайно́й шип; *утәли шип* сквозно́й шип □ **шип бәләнә ялгау** шипово́е соедине́ние, шипова́я свя́зка; **шип өтерге** шипово́е долото́

шиплы *прил. тех.* шипово́й; ~ **ялганма** шипова́я свя́зка

ширә *сущ. уст.* густо́й сок (*обычно растительный, сладкий*)

ширәле *прил. уст.* с со́ком, со́чный, содержа́щий мно́го со́ка (*о яблоках, груше, ягодах и т. п.*)

ширбәт *сущ.* 1. шербе́т, фрукто́вый напи́ток, компо́т; *чия ~е* вишнёвый напи́ток; *өченчегә ~ әзерләү* на тре́тье (блю́до) пригото́вить шербе́т (фрукто́вый напи́ток); *никах (туй) ~е этногр.* сва́дебный шербе́т (*специально приготовленный на свадьбу сладкий напиток*) 2. шербе́т; сыта́ медо́вая (*сладкий, безалкогольный напиток из мёда*) 3. шербе́т, помáдка; глазу́рь, *өйдә әзерләнгән* ~ шербе́т дома́шнего приготовле́ния; ~ *ягу* глазирова́ть 4. *бот.* нектáр; *см. тж.* **чәчәк балы**; *татлы ~ эзләп бал кортлары оча* лета́ют пчёлы в по́исках нектáра 5. *перен.* 1) вино́ (*вообще*), алкого́льный напи́ток; *кызыл* ~ кра́сное вино́; вино́ 2) *поэт.* нектáр *чего*; напи́ток *чего*; наслажде́ние *от чего-л.*; *мәхәббәт ~ен эчү* наслажда́ться любо́вью; *дан ~е* напи́ток сла́вы; наслажде́ние сла́вой; *яшәү ~е* напи́ток жи́зни; наслажде́ние жи́знью 6. *диал.* берёзовый сок □ ~ **ае** медо́вый ме́сяц; *см. тж.* **бал ае**; ~ **сону** *этногр.* угоща́ть сва́дебным шербе́том (*собирая за это у приглашённых гостей деньги*); ~ **суы** 1. сла́дкий напи́ток; фрукто́вый напи́ток, компо́т 2. берёзовый сок 3. *перен.* вино́, во́дка; спиртны́е напи́тки, алкого́ль

ширбәтләнү *страд. от* **ширбәтләү**; сласти́ться, подсла́щиваться/подсласти́ться; *~гән шәраб* подслащённое вино́

ширбәтләү *перех.* сласти́ть, подсла́щивать/подсласти́ть, де́лать, сде́лать сла́дким (*прибавляя сахар, мёд, варенье и т. п.*); *камырны* ~ сласти́ть те́сто

ширбәтле *прил. прям., перен.* сла́дкий, о́чень вку́сный; с са́харом и́ли мёдом; ~ *чәй* сла́дкий чай, чай с са́харом; ~ *су* сла́дкая вода́, сла́дкий напи́ток; сыта́ *уст.*; фрукто́вый и́ли подслащённый сок; вода́; ~ *су сусаганны басмый* сла́дкий напи́ток не утоля́ет жа́жду □ ~ **ай** *см.* **ширбәт ае**

ширин *прил. уст. см.* **ширбәтле**; сла́дкий, сла́денький; *шикәрдән дә* ~ сла́ще, чем са́хар

ширкәт *сущ.* това́рищество; сообщество; объедине́ние; компа́ния, ассоциа́ция; *авыл хуҗалыгы ~е* се́льскохозя́йственное това́рищество; *пароходчылык ~е* парохо́дное объедине́ние; парохо́дство; *акционерлык ~е* акционе́рная компа́ния

ширкәтче *сущ.* компаньо́н, компаньо́нка; член това́рищества, сообщества

ширлек *сущ. диал.* 1. о́страя, небезоби́дная шу́тка; зла́я шу́тка 2. шутовство́ □ ~ **салу** о́стро пошути́ть; наро́чно навреди́ть

ширлекле *прил. диал.* 1. озорно́й, шаловли́вый; лю́бящий о́стро пошути́ть (*о человеке*); компане́йский 2. шутли́вый, шу́точный; игри́вый; ~ *тавыш белән* игри́вым го́лосом; ~ *гадәт* шутли́вая привы́чка, привы́чка подшути́ть

ширма *сущ. прям., перен. см.* **иргәнәк**; ~ *белән бүленгән* разделённый ши́рмой; ~ *итеп (өчен) файдалану* испо́льзовать как ши́рму (для ши́рмы); ~ *хезмәтен үтәү* быть, служи́ть ши́рмой, ши́рмами ◊ ~ **арты** то, что за ши́рмой, за кули́сами; тенева́я сторона́ *чего-л.*

ширпотреб *сущ. разг.* ширпотре́б || ширпотре́бовский; ~ *кибете* магази́н ширпотре́ба; ~ *товарлары* това́ры ширпотре́ба, предме́ты ширпотре́ба; ширпотре́бовские това́ры (предме́ты)

ширт I *сущ. уст. книжн.* кля́тва; *см. тж.* **ант** ◊ ~ **итү (эчү)** кля́сться, божи́ться

ширт II *сущ. уст.* го́рькая соль; *см. тж.* **тоз** □ ~ **тоз** 1. морска́я соль (*соль, выпаренная из морской воды*) 2. морска́я вода́ вме́сто со́ли ◊ ~ **тоз ясау** пересоли́ть, де́лать, сде́лать сли́шком солёным

шит *сущ. ист.* 1. че́тверть арши́на, пядь 2. четь, че́тверть земли́

шифа *сущ.* 1. по́льза от лече́ния; исцеле́ние, выздоровле́ние; *дарудан ~ табу* получи́ть исцеле́ние от лека́рства 2. целе́бное сво́йство; целе́бность, цели́тельность; *төштән соң улыннең ~сы тамырына төшә* целе́бность (цели́тельное сво́йство) травы́ по́сле обе́да перехо́дит в ко́рень 3. *перен.* ка́чество *чего-л.*, принося́щее по́льзу, бла́го; *яңгыр түгел, чыкның да ~сы бар* (*погов.*) не только до́ждь, но и роса́ благода́тна □ ~ **бирү** исцеля́ть (избавля́ть) от боле́зни, неду́га; дава́ть (дать) исцеле́ние, выздоровле́ние; ~ **булу** благоприя́тно де́йствовать (*на здоровье, на самочувствие*); ~**га булу** на здоро́вье; ~**сы тию** вы́здороветь (опра́виться) от боле́зни, неду́га; исцели́ться

шифалы *прил.* 1. целе́бный, цели́тельный, име́ющий целе́бные сво́йства; ~ *кайнар чишмәләр* целе́бные горя́чие ключи́; *йөгерүнең ~ тәэсире* цели́тельное де́йствие бе́га 2. лека́рственный, име́ющий лече́бные сво́йства; лече́бный; ~ *үләннәр* лека́рственные расте́ния (тра́вы); ~ *май* лече́бная мазь 3. целе́бный, благоде́тельный, благотво́рный; благода́тный; ~ *урман һавасы* целе́бный лесно́й во́здух; *климатның ~ тәэсире* благоде́тельное (благотво́рное) влия́ние кли́мата; ~ *яңгырлар* благода́тные дожди́ □ ~ **су** 1. лече́бная минера́льная вода́ 2. *перен.* вино́, спиртно́й напи́ток

шифалык *сущ. см.* **шифалылык**; ~ *сыйфаты* лече́бное сво́йство, целе́бность

шифалылы|к *сущ.* целе́бность, цели́тельность, лече́бность; благоде́тельность, благотво́рность; *үләндәге ~к* целе́бность расте́ний; *~к дәрәҗәсе* сте́пень целе́бности; *дарудың ~гы* цели́тельность лека́рства

шифасыз *прил. уст.* неизлечи́мый; ~ *хасталыклар* неизлечи́мые боле́зни

шифаханә *сущ.* 1. больни́ца, лече́бница; лече́бное заведе́ние || больни́чный; *шәһәр ~ләре* городски́е больни́цы; *җүләрләр ~се* жёлтый дом *прост.*; ~ *хезмәткәрләре* больни́чные рабо́тники 2. санато́рий; *~гә юллама* путёвка в санато́рий

ши́фер *сущ.* ши́фер || ши́ферный; *асбестлы* ~ асбоши́фер, асбе́стный ши́фер; ~ *тубәле йортлар* дома́, покры́тые ши́фером || ~ *заводы* ши́ферный заво́д; ~ *тубә* ши́ферная кры́ша

ши́ферлы *прил.* ши́ферный; покры́тый ши́фером; ~ *тубәләр* ши́ферные кры́ши; ~ *йортлар* дома́, покры́тые ши́фером

шифон *сущ.* шифо́н || шифо́новый, из шифо́на; *күлмәклек* ~ шифо́н на пла́тье

шифоньер *сущ.* шифонье́р, шифонье́рка; *көзгеле* ~ шифонье́р с зе́ркалом; зерка́льный шифонье́р

шифр *сущ. в разн. знач.* шифр; та́йнопись; *хәрефле ~* бу́квенный шифр; *~ ачкычы* ключ к ши́фру; *кулъязмалар ~ы* шифр ру́кописей □ **~ белән язу** шифрова́ть, зашифрова́ть (*телеграмму*); **~ын ачу (сутү) найти́** ключ к *какому-л.* сло́жному де́лу; расшифро́вывать/расшифрова́ть

шифрлан|у *страд. от* **шифрлау**; шифрова́ться, зашифро́вываться, быть зашифро́ванным; *~ган телеграмма* шифро́ванная телегра́мма

шифрла|у *перех.* шифрова́ть, зашифро́вывать/зашифрова́ть || шифрова́ние, зашифро́вывание, шифро́вка, зашифро́вка; *~ булеге* отде́л шифро́вки

шифрлаучы *сущ.* шифрова́льщик, шифрова́льщица, шифро́вщик, шифро́вщица || шифрова́льный; *~ бүлек* шифрова́льный отде́л

шифрлы *прил.* шифро́ванный, зашифро́ванный, усло́вный; засекре́ченный; *~ телеграмма* шифро́ванная телегра́мма

шифрогра́мма *сущ.* шифрогра́мма; *үзәктән ~ алу* получа́ть (принима́ть) шифрогра́мму из це́нтра

шифрсызландыру *перех.* расшифро́вывать/расшифрова́ть || дешифро́вка, расшифро́вка

шифрсызлану *неперех.* расшифро́вываться/расшифрова́ться

шифырт *прил. прост.* щеголева́тый, пижо́нистый, франтова́тый (*о человеке*); *~ егет* франт, щёголь; пижо́н *прост.* || *нареч.* щегольски́, щеголева́то, франтова́то; *~ киенгән* оде́т франтова́то

шифырт-фифырт *нареч. прост.* щегольски́, щеголева́то, франтова́то; *ниндидер әфәнделәр шифырт-фифырт йөренәләр* каки́е-то господа́ щегольски́ проха́живаются

ши́хта *сущ. спец.* ши́хта || ши́хтовый, шихтово́й; *~ цехы* ши́хтовый цех; *~ материаллары* ши́хтовые материа́лы

шишак *сущ. ист. воен.* шиша́к; *см. тж.* **шешке**; *~ кигән сугышчы* во́ин в шишаке́

шишара *сущ. кул.* **1.** небольшо́й хлеб, хле́бец; *юлга дип ~лар салдым* на доро́гу испекла́ хле́бцы **2.** *этногр.* ма́ленький кру́глый хле́бец из вы́скребков квашни́ для подаяния **3.** *диал.* дома́шние бу́блики и́ли по́нчики (*из пресного сдобного теста*)

шкала *сущ.* шкала́ (*термометра, радиоприёмника, заработной платы, электромагнитных волн и т. п.*); *~ның тигез буленмәве тех.* неравноме́рность шкалы́; *ераклык ~сы* шкала́ расстоя́ний; *көйләү ~сы* шкала́ настро́йки

шкалалы *прил.* име́ющий шкалу́, шка́льный; *~ үлчәү* шка́льные весы́

шка́лик *сущ. разг.* **1.** шка́лик (*мера объёма в 0,06 л*) **2.** шка́лик (*бутылка с водкой или стопка такого объёма*)

шкату́лка *сущ.* шкату́лка, шкату́лочка; *акча ~сы* шкату́лочка для хране́ния де́нег; *агач ~* деревя́нная шкату́лка

шкатур *сущ. разг. см.* штукату́рка || штукату́рный; *~ коелган стена* стена́ с облупи́вшейся штукату́ркой; *~ эшләре* штукату́рные рабо́ты

шкатурлау *перех. разг. см.* **штукатурлау**; *кухняның тушәмен ~* штукату́рить потоло́к ку́хни

шкатурлы *прил. разг.* штукату́ренный, покры́тый штукату́ркой; со штукату́ркой; *~ стеналар* штукату́ренные сте́ны

шкатурчы *сущ. разг.* штукату́р, штукату́рщик *уст.*; *~лар бригадасы* брига́да штукату́ров

шкаф *сущ.* шкаф || шка́фный; *кием ~ы* шкаф для оде́жды, шифонье́р; *китап(лар) ~ы* кни́жный шкаф; *савыт-саба ~ы* шкаф для посу́ды; буфе́т; *кечкенә ~* шка́фик, шка́фчик; *суытқыч ~* холоди́льный шкаф

шкафлы *прил.* со шка́фом, име́ющий шкаф; *~ бүлмә* ко́мната со шка́фом

шквал *сущ. прям., перен.* шквал; *кар ~ы* сне́жный шквал; *снарядлар ~ы* шквал снаря́дов

шкив *сущ. тех.* шкив; *двигатель ~ы* шкив дви́гателя; *киртләч ~* ступе́нчатый шкив

шки́пер *сущ. мор.* шки́пер || шки́перский; *баржа ~ы* шки́пер ба́ржи; *~ киеме* шки́перский костю́м

шку́рка *сущ.* шку́рка, наждак; *см. тж.* **шмарткыч**

шку́рник *сущ. прост. бран.* шку́рник || шку́рный; шку́рнический; *~ икәнен фаш итү* разоблачи́ть его́ как шку́рника; *~ интереслары* шку́рнические интере́сы

шлагба́ум *сущ.* шлагба́ум; *~ны ябу* спусти́ть (закры́ть) шлагба́ум

шла|к *сущ.* шлак || шла́ковый; *домна ~гы* до́менный шлак; *~ тузаны* шла́ковая пыль

шлаклану *неперех.* шлакова́ться, превраща́ться в шлак

шлаклы *прил.* шла́ковый; *~ җир* шла́ковая (со шла́ком) земля́; *~ бетон* шла́ковый бето́н, шлакобето́н; *~ руда* шла́ковый железня́к

шлакобетон *сущ.* шлакобето́н || шлакобето́нный; *~нан салынган* (постро́енный) из шлакобето́на, шлакобето́нный; *~ панельләр* шлакобето́нные пане́ли

шлакоблок *сущ.* шлакобло́к || шлакобло́чный; *~ заводы* шлакобло́чный заво́д; *~ йорт* шлакобло́чный дом; *~ корылмалар* шлакобло́чные сооруже́ния

шлам *сущ. спец.* шлам; *марганецлы ~* шлам, содержа́щий ма́рганец

шланг, шлангы *сущ.* шланг || шла́нговый; *резин ~* рези́новый шланг; *пожар ~сы* пожа́рный шланг; *суыргыч ~* всасывающий шланг

шланглы *прил.* шла́нговый; *~ насос* шла́нговый насо́с

шлафыр, шлапыр *сущ. этногр.* широ́кая обо́рка на плеча́х пла́тья и́ли пере́дника

шлафырла|у *перех.* пришива́ть/приши́ть широ́кую обо́рку (*на плечах*); *~п теккән күлмәк* пла́тье с широ́кими обо́рками (на плеча́х)

шлафырлы *прил.* с широ́кими обо́рками на плеча́х (*платье или передник*)

шлейф *сущ.* **1.** *прям., перен.* шлейф; *бәрхет күлмәк ~ы* шлейф ба́рхатного пла́тья; *самолёт артыннан көмеш ~ булып юл сузылып калды* за самолётом оста́лась полоса́ серебри́стого шле́йфа **2.** *с.-х.* шлейф, волоку́ша; *җирне ~ белән тигезләү* разровня́ть по́чву шле́йфом

шлейфлау *перех. с.-х.* шлейфова́ть || шлейфова́ние (*почвы, зяби*)

шлейфлы *прил.* шле́йфный; со шле́йфом; *~ күлмәк* шле́йфное пла́тье, пла́тье со шле́йфом; *~ итеп тегү* шить со шле́йфом

шлем *сущ. в разн. знач.* шлем; *тимер ~* желе́зный шлем; *кызыл йолдызлы ~* шлем с кра́сной звездо́й; *космонавтлар ~ы* шлем космона́втов; *бөкеле ~* про́бковый шлем

шлемофон *сущ.* шлемофо́н (*космонавтов, лётчиков, танкистов и т. п.*)

шлея *сущ.* шлея́; *см. тж.* **шәлия, эшлия**; *каеш ~* ремешко́вая шлея́

шлифова́льщик *сущ. спец.* шлифова́льщик, шлифова́льщица; шлифо́вщик, шлифо́вщица

шлифо́вка *сущ. спец.* шлифо́вка || шлифова́льный (*прибор, станок*); *~ның сыйфатын тикшеру* прове́рка ка́чества шлифо́вки

шлифо́вкала|у *перех. спец.* шлифова́ть || шлифова́ние, шлифо́вка (*металла, дерева, стекла*); *~ остасы* ма́стер по шлифо́вке, шлифова́льщик, шлифо́вщик

шлюз *сущ.* шлюз || шлю́зный, шлюзово́й; *~ны ачу* откры́ть шлюз; *~ның киңлеге* широта́ шлю́за; *Волгоград ГЭСы ~лары* шлю́зы Волгогра́дской ГЭС; *~ камерасы* шлю́зная ка́мера; *~ капкасы* шлюзовы́е воро́та

шлюзлау *перех.* **1.** шлюзова́ть || шлюзова́ние (*судов*) **2.** шлюзова́ть, устра́ивать шлю́зы || шлюзова́ние (*реки, канала*)

шлюзлы *прил.* шлюзово́й, со шлю́зами; *~ канал* шлюзово́й кана́л, кана́л со шлю́зами

шлю́пка *сущ. мор.* шлю́пка || шлю́почный; *ишкәкле ~* вёсельная (гребна́я) шлю́пка; *~ ярышлары* шлю́почные го́нки

шля́гер *сущ.* шля́гер (*модная эстрадная песня, мелодия*) || шля́герный; *көнбатыш ~ларына ияреп* подража́я за́падным шля́герам; *~ җырлар* шля́герные пе́сни; *~ җырларны җырлаучы* исполни́тель шля́герных пе́сен

шлямбур *сущ. тех.* шля́мбур; *~ белән тишек ясау* пробива́ть отве́рстие шля́мбуром

шля́хта *сущ. ист.* шля́хта, дворя́нство; *поляк ~сы* по́льская шля́хта

шля́хтич *сущ. ист.* шля́хтич (*мелкопоместный польский дворянин*); *поляк ~ гаиләсеннән* из семьи́ по́льского шля́хтича

шнапс *сущ. разг.* шнапс, неме́цкая во́дка; *бер рюмка ~* рю́мочка шна́пса

шни́цель *сущ. кул.* шни́цель; *сыер итеннән ~ ясау* де́лать шни́цель из говя́дины

шнур *сущ. в разн. знач.* шнур; *нечкә ~* то́нкий шнур; *телефон ~ы* телефо́нный шнур; *бикфорд ~ы* бикфо́рдов шнур

шнурлау *перех.* шнурова́ть, зашнурова́ть || шнурова́ние, шнуро́вка (*ботинок, корсета и т. п.*)

шнурлы *прил.* **1.** шнурово́й; *егет ~ ботинкалардан* па́рень в шнуровы́х боти́нках **2.** шнуро́ванный, зашнуро́ванный (*корсет, пояс и т. п.*)

шобага *сущ.* **1.** 1) жре́бий; *~ белән бүлү* дели́ть по жре́бию; *~ чыккан кеше барыр* пое́дет тот, кому́ вы́пал жре́бий 2) *перен.* жре́бий, судьба́, у́часть, до́ля; *авыр төште башка ~* у́часть была́ тяжёлая; *бәхет ~сы көтә сине* тебя́ ждёт счастли́вый жре́бий (счастли́вая судьба́) **2.** жеребьёвка; *малай ~ны карарга йөгерде* ма́льчик побежа́л смотре́ть на жеребьёвку **3.** *ист.* жре́бий (*участок земли обычно на восемь душ*); *ярлылар җыйналып бер ~ җир алдылар* бе́дные собрали́сь и купи́ли жре́бий □ **~ салу (тоту, тотышу, тарту)** **1.** мета́ть (броса́ть, кида́ть, тяну́ть) жре́бий **2.** жеребьёвка

шобагачы *сущ.* жеребьёвщик (*участник в жеребьёвке*); *~лар исемлеген төзү* соста́вить спи́сок жеребьёвщиков

шовинизм *сущ. полит.* шовини́зм; *бөек державачылык (дәүләтчелек) ~ы* великодержа́вный шовини́зм

шовинист *сущ. полит.* шовини́ст, шовини́стка; *ата ~* матёрый шовини́ст

шовини́стик *прил.* шовинисти́ческий; *~ чыгыш* шовинисти́ческое выступле́ние

шовинистлык *сущ.* шовини́зм; проявле́ние шовини́зма || шовинисти́ческий; *~та гаепләү* обвиня́ть в шовини́зме

шогъбан *сущ. уст.* шаба́н (*название восьмого месяца мусульманского лунного года*)

шоҗык *сущ. кул.* шужу́к (*варёное мясо с жиром, завёрнутое в тоненькие лепёшки*)

шок *сущ. мед.* шок || шо́ковый; *психик шок* психи́ческий шок; *нерв шогы* не́рвный шок; *шок хәлендә булу* быть в шо́ковом состоя́нии

шоколад *сущ.* шокола́д || шокола́дный; *ванильле ~* вани́льный шокола́д; *~ фабрикасы* шокола́дная фа́брика; *~ ашап теш чыкмый* (*погов.*) от шокола́да зуб не вы́растет (*в смысле: от сладкой еды особого толку нет*); *~ массасы* шокола́дная ма́сса □ **~ агачы** шокола́дное де́рево; **~ төсе** шокола́дный цвет

шоколадлы *прил.* шокола́дный, с шокола́дом, содержа́щий (*или имеющий в составе*) шокола́д; *~ торт* шокола́дный торт

шолган *сущ. зоол.* землеро́йка

шом *сущ.* **1.** суеве́рный страх; опасе́ние, трево́га; предчу́вствие бе́дствий; *бүгенге көн ниндидер шом эчендә үтте* (э́тот) день прошёл в како́й-то трево́ге; *шом катыш курку* суеве́рный страх; страх с трево́гой; *күңелемне шом басты* меня́ охвати́ла трево́га **2.** *диал.* страши́лище, чудо́вище; чёрт **3.** 1) опа́сность, угро́за; бе́дствие; напа́сть; *ил өстенә кара шом* напа́сть на страну́; *нинди шомнан хәбәр бирде ул?* о како́м бе́дствии он извести́л? 2) *диал.* пове́трие, боле́зни; лихора́дка || *прил. диал.* **1.** отврати́тельный **2.** несча́стный, нося́щий клеймо́ несча́стья; злосча́стный; *шом бала* злосча́стный ребёнок □ **шом салу** трево́жить, встрево́жить, растрево́жить, вызыва́ть трево́гу (страх); **шом тоту** боле́ть, заболе́ть лихора́дкой (маляри́ей); **шомга төшү (калу)** трево́житься, встрево́житься, оказа́ться в трево́жном состоя́нии ◊ **шом канчыгы** зложела́тель, злопыха́тель

э́тник *прил.* этни́ческий; *халыкның ~ составы* этни́ческий соста́в населе́ния; *көнкурештәге ~ үзенчәлекләр* этни́ческие осо́бенности в быту́

этногенез *сущ.* этногене́з; *татар халкының ~ы* этногене́з татарского наро́да

этно́граф *сущ.* этно́граф (*специалист по этнографии*)

этнографизм *сущ. книжн.* этнографи́зм (*наличие этнографических описаний, деталей*)

этногра́фик *прил.* этнографи́ческий (*музей, атлас*)

этногра́фия *сущ.* этногра́фия || этнографи́ческий; *Урта Азия халыкларының ~се* этногра́фия наро́дов Сре́дней А́зии; *~ җәмгыяте* этнографи́ческое о́бщество; *~ фәне* этнографи́ческая нау́ка

э́тнос *сущ.* э́тнос (*этнически однородная масса*)

э́тносара *прил.* межэтни́ческий; *~ мөнәсәбәтләр* межэтни́ческие отноше́ния

этөрер *сущ. диал. миф.* де́рево сча́стья (*которое якобы растёт в глубине тайги; увидевшему это дерево обеспечена постоянная удача в охоте*)

э́тсыманнар *сущ. мн. зоол.* соба́чьи (*название семейства*)

эттерү *перех.* **1.** *понуд. от* **этү 2.** протáлкивать/протолкну́ть, подтáлкивать/подтолкну́ть (*бульдозером*)

этче *сущ. разг.* соба́чник (*занимающийся ловлей собак*)

этюд *сущ. в разн. знач.* этю́д; *картинага ~лар* этю́ды к карти́не; *философик ~лар* филосо́фские этю́ды; *шахмат ~ларын өйрәнү* изуча́ть ша́хматные этю́ды; *скрипка өчен ~лар* этю́ды для скри́пки

этү *перех.* **1.** толка́ть/толкну́ть, подтáлкивать/подтолкну́ть || толка́ние, подтáлкивание; *машинаны этү* толка́ть маши́ну; *ишеккә таба этү* подтáлкивать к две́ри **2.** отодвига́ть/отодви́нуть; *встәл-урындыкларны стена янына этү* отодви́нуть столы́, сту́лья к стене́ **3.** *перен.* оттáлкивать, отстраня́ть (*от себя*) □ **этеп җибәрү** оттолкну́ть, подтолкну́ть, отпихну́ть; **этеп кертү** затолкну́ть, протолкну́ть, задви́нуть; **этеп кузгалып китү** оттолкну́ться; **этеп кую** отодви́нуть, задви́нуть; **этеп төшерү** столкну́ть, спихну́ть; **этеп уяту** растолка́ть (*спящего*)

эфе́дра *сущ. бот.* эфе́дра (*вечнозелёное кустарниковое растение*)

эфедрин *сущ. мед.* эфедри́н (*алкалоид, содержащийся в эфедре, применяется как средство при воспалительных процессах*)

эфиоп *сущ.* эфио́п || эфио́пский; *~ теле* эфио́пский язы́к; *~ халкы* эфио́пы, эфио́пский наро́д

эфир *сущ. в разн. знач.* эфи́р || эфи́рный; *күкерт ~* се́рный эфи́р; *зәңгәр ~ бушлыгы* простра́нство си́него эфи́ра; *~га чыгу* вы́йти в эфи́р □ **~ мае** эфи́рное ма́сло; **~-майлы** эфи́ро-ма́сличный

эффект *сущ. в разн. знач.* эффе́кт; *тышкы ~лар белән мавыгу* увлека́ться вне́шними эффе́ктами; *яктылык ~ы* светово́й эффе́кт; *даруның ~ы* эффе́кт лека́рства; *экономик ~* экономи́ческий эффе́кт

эффе́ктлы *прил.* **1.** эффекти́вный; *~ ысул* эффекти́вный ме́тод **2.** эффекти́вный, производя́щий эффе́кт; *~ чагыштырулар* эффе́ктные сравне́ния; *~ чаралар күру* принима́ть эффекти́вные ме́ры || *нареч.* **1.** эффекти́вно; *~ файдалану* испо́льзовать эффекти́вно **2.** эффе́ктно; *үзен ~ күрсәтә белү* эффе́ктно пода́ть себя́

эффе́ктлылык *сущ.* эффекти́вность; *дәвалауның ~ы* эффекти́вность лече́ния; *тикшеренүләрнең ~ы* эффекти́вность иссле́дований

эх *межд.* **1.** *выраж. сожаление, досаду, упрёк, озабоченность* эх, ах; *эх, соңга калдым!* эх, опозда́л! *эх, син, юләр!* эх, ты, ненорма́льный! **2.** *выраж. восхищение, изумление, удивление* о, ох, ах; *эх, нинди күңелле сезнең белән!* ох, как ве́село (хорошо́) с ва́ми!

эхинококк *сущ. зоол. мед.* эхинокóкк (*маленький ленточный глист, а также личинка, зародыш этого глиста*); *талак ~ы* эхинокóкк селезёнки

эх-ма *межд. см.* **эх**

эхолот *сущ.* эхоло́т (*прибор для измерения глубины моря*)

эһ *межд.* **1.** *выраж. сожаление* эх; *эһ, кайтып җитә алмадыгыз!* эх, не успе́ли верну́ться **2.** *см.* эх ◊ **эһ дигәнче (дигәндә), эһ диргә (итергә) дә өлгермичә** в оди́н миг, в одно́ мгнове́ние; **эһ тә итми (итмичә, ди́ми, ди́мичә)** *см.* **ыһ та итми (дими)**

эһе *межд. выраж. утверждение* эге́, да; *эһе, кайтты̆ңмы?* — эге́, верну́лся?

эһелдәү *неперех.* слегка́ вздыха́ть, о́хать

эһем 1. *межд. выраж. растерянность, озабоченность, нерешительность* гм; *эһем, эһем, тиз килерләр микән?* гм, гм, ско́ро ли прибу́т? *эһем, ачуланмассызмы?* гм, не рассе́рдитесь? **2.** *подр. звуку покрякивания, покашливания* кхе

эһик-мәһик: эһик-мәһик килү 1. жема́нничать, коке́тничать **2.** капри́зничать

эч *сущ.* **1.** вну́тренности, нутро́ *прост.* || нутряно́й; *хайванның эче* вну́тренности живо́тного; *бөтен эчем авырта* боли́т всё нутро́; *балыкның эчен чистарту* чи́стить вну́тренности ры́бы; *эч мае* нутряно́й жир; сма́лец **2.** вну́тренность, вну́тренняя часть (*вообще*) || вну́тренний; *бүлмә эче* вну́тренняя часть ко́мнаты; *кавынның эчен алу* убра́ть вну́тренность ды́ни; *тәрәзәнең эч ягы* вну́тренняя часть окна́ **3.** вну́тренняя сторона́ оде́жды, подкла́дка; *см. тж.* **эчлек; бүрекнең эче** подкла́дка ша́пки **4.** живо́т; брю́хо *прост. см. тж.* **корсак**; *эчне сылау* масси́ровать живо́т; *эч авыртуы* бо́ли в желу́дке; *эч кубу* вздутие живота́ **5.** *кул.* начи́нка, фарш; *бәлеш эче* начи́нка пирога́ **6.** *в знач. нареч.* **эчендә** в гу́ще; *халык эчендә булу* быть в гу́ще наро́да; *шаулы вакыйгалар эчендә* в гу́ще (водоворо́те) бу́рных собы́тий **7.** *в знач. нареч.* **эчкә** внутрь, вглубь; *эчкә керү* войти́ внутрь; *эчкә хәрәкәт итү* продвига́ться вглубь **8.** *перен.* душа́, се́рдце || душе́вный, серде́чный; *шатлыгы эченә сыймый* душа́ полна́ ра́дости; *эчтә моң һәм сагыш* в се́рдце грусть и тоска́; *эч серләре* серде́чные та́йны **9.** *в знач. послелога в местно-вр. п.* **эчендә** 1) в, то, внутри́; *мәгарә эчендә* в пеще́ре 2) в, при (*каких условиях*); *кыен шартлар эчендә* в тяжёлых усло́виях 3) в, ме́жду, среди́; *коллектив эчендә* в коллекти́ве, среди́ коллекти́ва; *алар эчендә* среди́ них, ме́жду ни́ми; *куаклар эчендә* в куста́х, среди́ куто́в, ме́жду куста́ми **10.** *в знач. послелога в исх. п.* **эченнән** 1) из, изнутри́; *су эченнән чыгару* вытащить из воды́; *бүлмә эченнән* из (изнутри́) ко́мнаты; *халык эченнән чыккан* вы́ходец из наро́да 2) по; *урман эченнән бару* идти́ ле́сом (по ле́су); *траншея эченнән йөгерү* бежа́ть по тране́е 3) под; *пальто эченнән кию* наде́ть под пальто́ 4) че́рез, сквозь; *самолёт болытлар эченнән оча* самолёт лети́т сквозь (че́рез) облака́ **11.** *в знач. послелога направит. п.* **эченә** в, внутрь; *портфель эченә салу* положи́ть в портфе́ль; *музей эченә керү* войти́ в музе́й; *тема эченә керү* войти́ в те́му □ **эч кату** запо́р; **эч китү (бару)** сла́бить, расстро́иться (*о желудке, кишечнике*); поно́с; **эч мае** са́льник; **эч төшү** *анат.* опуще́ние живота́; **эченә алу 1.** *см.* **эченә сендерү 2.** включа́ть (включи́ть) в себя́, охва́тывать/охвати́ть; **эченә сендерү** впи́тывать/впита́ть, вса́сывать/всоса́ть; **эчкә бату** ввáливаться/ввали́ться; *эчкә сулау* вдыха́ть/вдохну́ть ◊ **эч аркага (эчкә) ябышу 1.** проголода́ться **2.** си́льно похуде́ть, отоща́ть, ввали́ться (*о животе*); **эч эрнү** *см.* **йөрәк эрнү; эч бора, эчне борып ала** живо́т скрути́ло; **эч бушату** вы́говориться, отвести́ ду́шу; излива́ть/изли́ть ду́шу; **эч**

бушау (бушану) отлегло́ от се́рдца; **эч жу итү** *см.* **йөрәк жу итү; эч катып (катканчы) көлү** захлёбываться (ката́ться) от сме́ха, смея́ться до ко́лик; *см.* **йөрәк яну; эч өзгеч** *см.* **йөрәк өзгеч; эч өзелү** *см.* **йөрәк өзелү; эч пошканнан** от не́чего де́лать, от ску́ки; **эч пошу** не споко́йно (му́торно) на душе́; **эч сызлану** *см.* **эч пошу; эч уу** сожале́ть, доса́довать; **эч яну** *см.* **йөрәк яну; эче кара** *см.* **кара эчле; эченә май булып төшү (яту)** прийти́сь по нутру́ (по душе́); **эченә керү** 1. вдава́ться в дета́ли; *см. тж.* **тирәнгә керү** 2. *см.* **эч-бавырына керү; эченә тию** заде́ть за живо́е; **эченә тияр, эчең тишелер** жи́рно бу́дет; **эченнән елау** переживать мо́лча (скры́тно); **эченнән энә үтәрлек** *прост.* то́щий как спи́чка; **эчкә йому** утаи́ть, держа́ть в себе́; **эчкә йомылу** *см.* **эчтән йомылу; эчкә җылы керү** отлегло́ от се́рдца; **эчкә корт керү** всели́ться/всели́ться, закра́дываться, запада́ть в ду́шу (*о подозрении, сомнении*); **эчкә пошаман керү** сомнева́ться, трево́житься, ко́шки скребу́т на се́рдце (на душе́) *у кого;* **эчкә салкын йөгерү** 1. продро́гнуть, озя́бнуть, замёрзнуть насквозь 2. *см.* **эчкә пошаман төшү; эчкә салып кую, эчкә җыю** скрыва́ть в душе́; **эчкә сыймау** переполня́ться *чем* (*о сердце*); **эчкә тимәс** *см.* **эчне тишмәс; эчне тырный (тырнап тора)** скребёт на душе́ (на се́рдце); **эчтә бүре асрау** име́ть зуб *на кого;* **эчтә бүре улау** си́льно проголода́ться; **эчтә мәче(ләр) кычкыру** 1. *см.* **эчтә бүре улау** 2. за́висть берёт, зави́довать; **эчтә төен калу (яту)** ка́мень на душе́; **эчтән беркетү (беркетеп кую)** реши́ть про себя́; **эчтән йомылу** затаи́ться в себе́; замкну́ться в себе́; **эчтән сукрану** глухо́й ро́пот; **эчтән сызу** *см.* **эчтән яну; эчтән тыну (тынып калу)** замолча́ть, затаи́ться (не подава́ть ви́ду); **эчтән яну** си́льно переживать

эчәге *сущ. анат.* вну́тренности

эчә|к *сущ.* 1. кишка́ || кише́чный; *юан ~клар* то́лстые кишки́; *туры ~к* прямая́ кишка́; *~к авырулары* кише́чные заболева́ния; *~к бәлеше* пиро́г из кишо́к (требухи́); *~к сыекчасы* кише́чный сок 2. шланг, рука́в, кишка́; *насос ~гесе* рука́в (кишка́) насо́са □ **~клар уралу** *анат.* за́ворот кишо́к ◊ **~гең өзелер** *прост.* кишка́ тонка́; **~кләрен чыгару** *прост.* вы́пус-тить кишки́; **~кләрне актару** *прост.* вы́мотать (все) кишки́

эчәк-бавыр *сущ. собир. см.* **эчәк-карын**

эчәк-карын *сущ. собир.* требуха́; *сыерның эчәк-карыннарын юу* чи́стить (мыть) требуху́ коро́вы

эчәккуышлылар *сущ. мн. зоол.* кишечнополостны́е

эчәклек *сущ.* кише́чник

эч-бавыр *сущ. собир.* потроха́ (*преимущественно птицы*); *тавык эч-бавыры* потроха́ ку́рицы ◊ **эч-бавырына керү** лезть в ду́шу; **эченә-бавырына керү (керер)** в ду́шу ле́зет (*о подхалиме*)

эч-баш *сущ. собир.* го́льё, вну́тренности

эчек *сущ. уст.* мех; *~ сәүдәсе* торго́вля ме́хом

эчел|ү 1. *страд. от* **эчү** выпива́ться, пи́ться, быть вы́питым 2. *безл.* пи́ться; *~гәндә эчегез* пе́йте, пока́ пьётся

эчемлек *сущ.* 1. напи́ток, питьё; *азлы ~лар* газиро́ванные напи́тки; *салкын ~лар* прохлади́тельные напи́тки; *спиртлы ~лар* спиртны́е напи́тки, спиртно́е; *исерткеч ~лар* алкого́льные напи́тки 2. вы́пивка (*о спиртных напитках*) □ **~ калдыгы** опи́вки

эчендә *послелог* в тече́ние, за; *бер җәй ~* в тече́ние одного́ ле́та; *өч көн ~* за́ три дня

эчендәге *прил.* находя́щийся (содержа́щийся) в (внутри́) *чего-л.*; *читлек ~ кош кебек* как пти́ца (содержа́щаяся) в кле́тке ◊ **~ тышында** душа́ нараспа́шку; что на уме́, то на языке́

эченнән *нареч. см.* **эчтән**

эчерге *сущ.* 1. подсти́лка под седло́ 2. вы́шитый и́ли худо́жественно отде́ланный во́йлок; во́йлочные изде́лия (*коврик, матрац и т. п.*)

эчерелү *страд. от* **эчерү** напа́иваться, спа́иваться

эчертелү *страд. от* **эчертү**; *см. тж.* **эчерелү**

эчертү *перех. см.* **эчерү**

эчер|ү *перех.* 1. 1) пои́ть/напои́ть || пое́ние; *чәй ~ү* пои́ть ча́ем; *атларны ~ү* напои́ть лошаде́й; *балага кашыктан сөт ~ү* пои́ть ребёнка молоко́м с ло́жечки; *малларны ~ү* пое́ние скота́ 2) пои́ть, вы́поить (*телёнка, поросёнка молоком*) 2. пои́ть, напа́ивать; *үсемлекләргә дым ~ү* пои́ть расте́ния вла́гой 3. пои́ть, напа́ивать/напои́ть, спа́ивать/спои́ть || пое́ние, напа́ивание, спа́ивание; *исергәнче ~ү* напои́ть допьяна́ □ **~еп бетерү** напои́ть/спои́ть всю (*до дна*); **~еп исертү** упои́ть; напои́ть допьяна́

эче-тышы *сущ. собир. разг.* 1. изнутри́ и снару́жи (*букв.* вну́тренность и нару́жность, вну́тренняя и нару́жная сто́роны); *яңа йортның эчен-тышын җентеклəп карау* внима́тельно рассма́тривать но́вый дом изнутри́ и снару́жи; *эче-тышы ефәк юрган* одея́ло шёлковое све́рху и сни́зу (*с обеих сторон*) 2. *перен.* о хара́ктере, привы́чках челове́ка; *аның эче-тышы ялган* он наскво́зь пропи́тан ло́жью (*круглый обманщик*); *мин аның эчен-тышын яхшы беләм* я его́ ви́жу насквозь

эч-карын *сущ. собир. см.* **эчәк-карын**

эчкәлəү *многокр. от* **эчү** *см.* **эчкәләштерү**

эчкәләштерү *многокр. от* **эчү** попива́ть; выпива́ть (*иногда, время от времени*)

эчкәрге, эчкәреге *прил.* отдалённый, глуби́нный; *~ авыллар* отдалённые дере́вни

эчкәре *нареч.* 1. внутрь; *~ күз төшерү* загляну́ть внутрь; *см. тж.* **эчкә** 2. далеко́, вглубь; *~ яшерү* спря́тать далеко́ (вглубь) || *прил. см.* **эчкәрге**

эчке I *прил.* 1. *в разн. знач.* вну́тренний; *~ бүлмә* вну́тренняя ко́мната; *~ катлам* вну́тренний слой; *~ ресурслар* вну́тренние ресу́рсы; *~ мөмкинлекләр* вну́тренние возмо́жности; *~ каршылыклар* вну́тренние противоре́чия; *~ мәгънә* вну́тренний смысл, вну́треннее значе́ние; *~ бәйләнешләр* вну́тренние свя́зи 2. внутри-, вну́тренний (*о жизни и деятельности внутри государства, учреждения*); *~ икътисади үсеш* внутриэкономи́ческое разви́тие; *~ сәяси хәл* внутриполити́ческая обстано́вка; *~ гаскәр берләшмәләре* внутривойсковы́е соедине́ния; *Эчке эшләр министрлыгы* Министе́рство вну́тренних дел; *~ базар* вну́тренний база́р 3. ни́жний, нате́льный; испо́дний *прост.*; *эчке кием* ни́жнее бельё; *~ күлмәк* нате́льная руба́шка; соро́чка (*женская*) 4. *перен.* вну́тренний, душе́вный, духо́вный; *~ сизем (тоем)* вну́треннее чу́вство; *~ күтәренкелек* душе́вный подъём; *~ матурлык* вну́тренняя (душе́вная) красота́; *~ җылылык* душе́вная теплота́; *кешенең ~ дөньясы* вну́тренний (духо́вный) мир челове́ка; *~ якынлык* духо́вная бли́зость □ **~ авырулар** *мед.* вну́тренние боле́зни; **~ колак** *анат.* вну́треннее у́хо; **~ почмак** *мат.* вну́тренний у́гол; **~ сөйләм** *лингв.* вну́тренняя речь; **~ сулар** территориа́льные во́ды; **~ сыну** *анат.* закры́тый перело́м; **~ янулы двигатель** *физ.* дви́гатель вну́треннего сгора́ния

эчке II *сущ. диал.* пи́ршество, вы́пивка, попо́йка, пья́нство; *~дән башы чыкмый* то́лько и за́нят пья́н-

ством; всё пья́нствует □ ~ **мәҗлесе** засто́льная компа́ния (с вы́пивкой); пир, кутёж

эчкелек *сущ. см.* **эчкечелек**

эчкен *сущ. ист.* 1. инозе́мные по происхожде́нию войска́, несу́щие охра́ну дворца́ 2. солда́т наёмной (и́ли иноземной) гва́рдии

эчкерле *прил.* злопа́мятный, кова́рный, нейскренний; *см. тж.* **кинәчел**; ~ *булу* быть злопа́мятным

эчкерлелек *сущ.* злопа́мятство, злопа́мятность, кова́рность, нейскренность

эчкерсез *прил.* 1. и́скренний, открове́нный, прямоду́шный, чистосерде́чный, душе́вный, задуше́вный, бесхи́тростный, простоду́шный; ~ *саф мәхәббәт* и́скренняя, чи́стая любо́вь; ~ *туганлык хисләре* чистосерде́чные бра́тские чу́вства; ~ *сүзләр* бесхи́тростные слова́ 2. бескоры́стный; ~ *дуслык* бескоры́стная дру́жба; *тугандаш халыкларга ~ ярдәм* бескоры́стная по́мощь бра́тским наро́дам

эчкерсезлек *сущ.* и́скренность, открове́нность, чистосерде́чность, душе́вность, задуше́вность, прямоду́шие; простоду́шие; *хисләрнең ~ге* и́скренность чувств; *теләкләрнең ~ге* чистосерде́чность жела́ний

эчкече *сущ.* пья́ница, кути́ла, алкого́лик ◊ ~ **баш** *см.* **исерекбаш**

эчкечелек *сущ.* пья́нство, алкоголи́зм; *~кә каршы көрәш* борьба́ про́тив алкоголи́зма □ ~ **мәҗлесе** *см.* **эчке мәҗлесе**; ~**кә бирелү** пья́нствовать, предава́ться пья́нству, загуля́ть

эчләп *послелог* по; *урман ~ бару* идти́ по ле́су; *траншея ~ йөгерү* бежа́ть по транше́е

эчләт|ү *понуд. от* **эчләү**; *пальто ~ергә бирү* отда́ть пальто́ на подби́вку

эчләү *перех. спец.* подшива́ть (подби́ть) подкла́дки, подбива́ть/подби́ть || подшива́ние (подши́вка) подкла́дки; подби́вка; *пальтоны ефәк белән ~* подби́ть пальто́ шёлком

эчле *прил.* 1. с подкла́дкой; *мех ~ пальто* пальто́ с мехово́й подкла́дкой 2. с начи́нкой, начинённый *чем; йөзем ~ бәлеш* пиро́г, начинённый изю́мом (с начи́нкой из изю́ма) 3. *перен. разг. см.* **эчкерле** 4. *перен. см.* **кара эчле**

эчле|к *сущ.* 1. подкла́дка; *костюм эчлеге* подкла́дка для костю́ма 2. поднаря́д (*обуви*) □ ~ **кую** подби́ть (*шёлком*); *см. тж.* **эчләү** || *прил.* подкла́дочный; ~ *ефәк* подкла́дочный шёлк

эчмәк *сущ.* 1. подкла́дка под потни́к; *см. тж.* **эчерге** 2. жиле́т; камзо́л; пиджа́к и т. п. (*которые надеваются внутрь верхней одежды*) 3. мя́гкие ва́режки (*которые надеваются внутрь грубых варежек*); *см.* **тышмак**

э́чпошыргыч *прил.* 1. ску́чный, ну́дный, меланхоли́ческий, тоскли́вый, то́шный, му́торный, гнету́щий; ~ *кеше* ну́дный челове́к; ~ *көннәр башланды* начали́сь тоскли́вые дни 2. утоми́тельный, моното́нный, однообра́зный; ~ *яңгырлы һава* утоми́тельная дождли́вая пого́да; ~ *көй* моното́нный напе́в □ ~ **кеше** зану́да *прост.*

эчтәлек *сущ.* 1. содержа́ние; *романның ~ген сөйләү* рассказа́ть содержа́ние рома́на; *хатның ~ге белән таныштыру* ознако́мить с содержа́нием письма́ 2. оглавле́ние (*книги*) 3. *филос. лог.* су́щность, суть, смысл, содержа́ние; *империалистик сугышның ~ген фаш итү* разоблачи́ть су́щность империалисти́ческой войны́; *төшенчәнең ~ге* смысл поня́тия 4. *редко* содержи́мое *чего-л.; төргәкнең ~ге* содержи́мое узелка́ (упако́вки)

эчтәлекле *прил.* 1. содержа́тельный; ~ *әдәби кичә* содержа́тельный литерату́рный ве́чер; ~ *музыка* содержа́тельное музыка́льное произведе́ние 2. *в сочет. с прил.* -содержа́тельный, с ... содержа́нием; *тирән ~ әңгәмә* глубокосодержа́тельная бесе́да; разгово́р с глубо́ким содержа́нием; *сай ~ лекция* малосодержа́тельная ле́кция || *нареч.* содержа́тельно; ~ *язылган* напи́сано содержа́тельно; *бик ~ сөйләү* говори́ть о́чень содержа́тельно

эчтән *нареч.* 1. изнутри́; ~ *сигнал бирү* подава́ть сигна́л изнутри́; ~ *бикләү* запере́ть изнутри́ 2. вну́тренне, про себя́, в душе́ (*мыслить, думать*); ~ *хәзер булу* вну́тренне быть гото́вым *к чему-л.*; ~ *моңа шатлана иде* в душе́ был рад э́тому ◊ ~ **тыну** зама́лчивать/замолча́ть

эчү *перех.* 1. пить, вы́пить || питьё; *сөт эчү* пить молоко́; *кымыз эчү* пить кумы́с; *өч стакан чәй эчү* вы́пить три стака́на ча́ю; *кабып эчү* вприку́ску; *сыйлаганда су эч* (*погов.*) когда́ угоща́ют, пей и во́ду 2. принима́ть/приня́ть, вы́пить (*какое-л. лекарство*); *аспирин эчү* приня́ть аспири́н 3. *перех. и неперех.* пить (*спиртное*); выпива́ть, напива́ться, пья́нствовать, кути́ть || питьё, вы́пивка, выпива́ние, пья́нство; *кунаклар исәнлегенә эчү* пить за здоро́вье (за здра́вие) госте́й; *чәкешеп эчү* пить чо́каясь 4. *перен.* пить, вдыха́ть; *урманның хуш исле һавасын эчү* вдыха́ть арома́тный лесно́й во́здух □ **эчә торган, эчәргә яраклы** питьево́й; **эчәргә сабышу (салыну)** *см.* **эчкечелеккә бирелү**; **эчеп бетерү** 1. вы́пить (*до конца*), допи́ть, осуши́ть 2. пропи́ть (*деньги*); **эчеп җибәрү** вы́пить; **эчеп кую** вы́пить, допи́ть; **эчү мәҗлесе** *см.* **эчке мәҗлесе** ◊ **эчеп илерү (иләсләнү)** доходи́ть до бе́лой горя́чки (зелёного зми́я)

эчүчелек *сущ. см.* **эчкечелек**

эш *сущ.* 1. *в разн. знач.* рабо́та, де́ятельность, заня́тие, труд, де́ло || рабо́чий, трудово́й; *эшкә алу* приня́ть на рабо́ту; *эшкә башлау (керешү)* приступи́ть к рабо́те (заня́тиям); принима́ться за де́ло; *эш белән тәэмин итү* обеспе́чивать рабо́той; *төзелеш эшләре* строи́тельные рабо́ты; *урып-җыю эшләре* убо́рочные рабо́ты; *тикшерү эшләре* иссле́довательские труды́; *эшеннән бүлү (бүлдерү)* отрва́ть от рабо́ты (де́ла, заня́тия); *йорт эшләре* рабо́ты (дела́) по до́му (хозя́йству); *файдалы эш белән шөгыльләнү* занима́ться поле́зным трудо́м; *эш кораллары* ору́дия труда́; *эш шартлары* усло́вия труда́; *эш вакыты* рабо́чее вре́мя; *эш бүлмәсе* рабо́чий кабине́т; *эш дәрте* трудово́й энтузиа́зм; *эш башында мактанма, эш беткәч мактан* (*погов.*) не хвали́сь нача́лом де́ла, хвали́сь его́ концо́м; *эш беткәч уйнарга ярый* (*погов.*) ко́нчил де́ло, гуля́й сме́ло; *эше юкның ашы юк* кто без рабо́ты, тот без хле́ба; *эшләрең уңышлы булсын!* пусть дела́ твои́ бу́дут уда́чными 2. де́ло, положе́ние, обстано́вка, обстоя́тельство; *эшләр ничек?* как дела́? *эш җайланды* де́ло (положе́ние) ула́дилось; *эшләр катлауланды* обстано́вка осложни́лась; *кеше эшенә катнашмау* не вме́шиваться в чужи́е дела́; *эш шуңа бара* де́ло идёт к э́тому 3. де́ло, вопро́с, пробле́ма; *эш әле хәл ителмәгән* де́ло (вопро́с) ещё не решено́; *җир эшләре идарәсе* управле́ние земе́льными дела́ми; *эш белән килү* прийти́ по де́лу; *финанс эшләре* фина́нсовые дела́ (пробле́мы); *эшне тыныч юл белән хәл итү* ула́дить де́ло (вопро́с) ми́рным путём; *эшкә рәсми төс бирү* прида́ть де́лу официа́льный хара́ктер 4. 1) профе́ссия, заня́тие, слу́жба || служе́бный; *нинди эштә эшлисең?* что у тебя́ за слу́жба (профе́ссия)? *эшеннән алу* снять с рабо́ты,

отстрани́ть от слу́жбы; *укытучылык эше* профе́ссия учи́теля; *хәрби эшкә күчерү* перевести́ на вое́нную слу́жбу; *эш адресы* служе́бный а́дрес; *эш телефоны* служе́бный телефо́н 2) до́лжность, пост; *җаваплы эштә эшләү* занима́ть отве́тственную до́лжность; *директорлык эшенә билгеләү* назна́чить на пост дире́ктора **5.** де́ло, де́йствие, пра́ктика; *эш нәрсә күрсәтер* что пока́жет пра́ктика (де́ло); *сүз түгел, конкрет эш кирәк* нужны́ не слова́, а конкре́тные дела́ (де́йствия); *эштә сынау* прове́рить в де́ле (на пра́ктике) **6.** 1) рабо́та, произведе́ние, изде́лие; *күргәзмәдә рәссамның яңа эшләре* на вы́ставке но́вые рабо́ты (произведе́ния) худо́жника; *кул эшләре* ручны́е изде́лия; *фәнни-тикшеренү эше* нау́чно-иссле́довательская рабо́та; *диплом эше* дипло́мная рабо́та 2) произво́дство; *тире эшкәртү эше* кожевенное произво́дство; *Бохара келәмчеләре эше* произво́дство бухарских ковро́вщиков **7.** собы́тие, происше́ствие, слу́чай, де́ло; *көтелмәгән эш килеп чыгу* случи́лось непредви́денное де́ло (происше́ствие); *күз алдында булган эш* слу́чай, происше́дший на глаза́х; слу́чай, кото́рый произошёл (в его́) прису́тствии; *эш кичкә таба булды* де́ло бы́ло бли́же к ве́черу; *бу эшкә аның катнашы юк* он не име́ет отноше́ния к э́тому происше́ствию **8.** *юр.* де́ло || делово́й; *җинаять эше* уголо́вное де́ло; *суд эшләре материаллары* материа́лы суде́бных дел; *эш хаты* деловóе письмó **9.** *высок., юр.* дея́ние, де́йствие; де́ло, посту́пок; *ерак бабаларыбызның эшләре* дея́ния на́ших далёких пре́дков; *бөек эшләр* вели́кие дея́ния; *егет эшеннән беленер* (*погов.*) мо́лодец узнаётся по посту́пкам (дела́м); *явыз эш* зловре́дный посту́пок **10.** *лингв.* де́йствие, проце́сс; *эшнең билгесен белдерү* ука́зывать при́знак де́йствия □ **эш арасында** ме́жду де́лом; **эш атнасы** рабо́чая неде́ля; **эш аты 1.** рабо́чая ло́шадь **2.** *перен.* коня́га *прост.*; **эш башында торучы** руководи́тель; *см. тж.* **эш хуҗасы**; **эш белән мавыгу** увлека́ться/увле́чься рабо́той, зарабо́таться; **эш берәмлеге** *физ.* едини́ца рабо́ты; **эш вакыты** рабо́чее вре́мя; **эш кәгазьләре** деловы́е бума́ги, докуме́нты; **эш киеме 1.** рабо́чая оде́жда, спецоде́жда **2.** бу́дничная оде́жда, пла́тье на ка́ждый день; **эш көне 1.** рабо́чий день, бу́дни **2.** *см.* **хезмәт көне**; **эш көче 1.** *экон.* рабо́чая си́ла **2.** рабо́чие; **эш кылу** де́лать/сде́лать *что-л.*; **эш остасы** ма́стер своего́ де́ла, до́ка; **эш өстәле** рабо́чий стол; **эш сәгате** *см.* **эш вакыты**; **эш сөюче** трудолюби́вый; **эш ташлау** бастова́ть || забасто́вка; **эш ташлаучы** забасто́вщик; **эш хайваны (терлеге)** рабо́чий скот; **эш хакы (ялы)** за́работная пла́та, зарпла́та; вы́работка, за́работок, жа́лованье *уст.*; **эш хуҗасы** работода́тель, хозя́ин, предпринима́тель; **эшкә алыну (тотыну)** бра́ться (взя́ться) за рабо́ту; **эшкә сәләтле** работоспосо́бный, дееспосо́бный; **эшкә сәләтлелек** работоспосо́бность, дееспосо́бность; **эшнең башы** нача́ло де́ла, почи́н, зачи́н *прост.*; **эшсез булу (калу) 1.** оказа́ться безрабо́тным **2.** быть не у дел; **эштән куу (чөю)** вы́гнать (вы́швырнуть) с рабо́ты; **эштән чыгару 1.** увóлить с рабо́ты **2.** *перен.* вы́вести из стро́я, привести́ в него́дное состоя́ние; изводи́ть/извести́ *кого* **3.** объявля́ть/объяви́ть никуды́шным (никуда́ него́дным); **эштән чыгу** уходи́ть с рабо́ты, увольня́ться с рабо́ты □ **эш алга бармау** дела́ (де́ло) ни с ме́ста, де́ло стои́т на ме́сте; **эш анда түгел** де́ло не в э́том; **эш (майлагандай) бара** де́ло идёт (как по ма́слу), де́ло пошло́; **эш барып чыкмау** не получа́ться, быть безрезульта́тным; **эш башка** де́ло друго́е (ино́е); **эш баштан ашкан** *см.* **эш бугаздан**; **эш башы** хозя́ин, организа́тор де́ла; **эш башына килү (менү) 1.** заня́ть руководя́щее положе́ние, стать во главе́ *какого-л.* де́ла **2.** стать главо́й вла́сти, государства; **эш башына кую (мендерү)** поста́вить у руково́дства, назна́чить на руководя́щий пост; **эш башында** во главе́; **эш башынчан** сде́льный, сде́льно; **эш белү** знать рабо́ту (де́ло), понима́ть в рабо́те (в де́ле); быть о́пытным (иску́сным, уме́лым); **эш бетерү** занима́ться *каким-л.* де́лом; верши́ть де́ло; **эш бугаздан (бугазга терәлгән)** дел по го́рло, хлопо́т по́лон рот; **эш булдыру** быть уме́лым/предприи́мчивым, быть смека́листым (иску́сным) в рабо́те; уме́ть прова́чивать дела́; **эш булсын дип** добросо́вестно; на со́весть (де́лать, рабо́тать); не за страх, а на со́весть; **эш бүрттерү** пока́зывать вид де́льного челове́ка; **эш җайда** всё в поря́дке; дела́ иду́т хорошо́; **эш итү 1.** де́йствовать, де́лать *чем;* занима́ться де́лом при по́мощи *чего; балта белән эш итү* де́йствовать топоро́м; *китап белән эш итү* рабо́тать с кни́гами **2.** манипули́ровать *чем;* рабо́тать, име́ть де́ло *с кем, чем; корал белән эш итү* име́ть де́ло с ору́жием; *аның белән эш итү авыр* тру́дно рабо́тать (име́ть де́ло) с ним **3.** завершáть/заверши́ть; приводи́ть/привести́ в завершённый вид; *эшне эш итәргә кирәк* на́до по́лностью заверша́ть (ка́ждое) де́ло; **эш йөртү 1.** провёртывать, проводи́ть *какое-л.* де́ло **2.** *см.* **эш итү** 1, 2; **эш каеру (майтару)** верши́ть больши́е дела́; воро́чать дела́ми; **эш калдырып** впусту́ю, по́пусту; **эш качмас** рабо́та подождёт; рабо́та не волк, в лес не убежи́т; **эш кузгату (күтәрү) 1.** стро́ить ко́зни, плести́ интри́ги *против кого* **2.** возбуди́ть де́ло (суде́бное) || возбужде́ние де́ла; **эш кулы (куллары)** рабо́чие ру́ки; *см. тж.* **эш көче** 2; **эш күндерү (тоҗыру)** *см.* **эш каеру (майтару)**; **эш күрсәтү** пока́зывать/показа́ть себя́ в де́ле; **эш күрү** име́ть де́ло с *кем, чем-л.*; **эш кыру** *ирон.* де́лать/сде́лать *что-л.*; **эш(ләр) мөшкел (начар, харап, хөрти, яман, шәптән түгел)** дела́ пло́хи, де́ло дрянь, де́ло таба́к *прост.*; **эш муеннан** *см.* **эш бугаздан**; **эш нәрсәдә (соң)?** в чём де́ло, за чем (кем) де́ло ста́ло? **эш өсте** страда́, стра́дная пора́, разга́р рабо́ты; **эш пешерү** свари́ть ка́шу *с кем;* **эш пешү 1.** удава́ться/уда́ться, получа́ться/получи́ться (*о деле, работе*) **2.** име́ть успе́х; де́ло в шля́пе; **эш сөю** быть трудолюби́вым; **эш ташлау 1.** броса́ть рабо́ту, отказа́ться от рабо́ты **2.** *полит.* бастова́ть, забастова́ть; **эш (нәрсәгә) терәлү 1.** упира́ться *во что (о деле)* **2.** засто́риться *(о деле);* **эш торгынлыгы** засто́й в рабо́те; **эш тормас** де́ло не ста́нет (не постои́т) *за кем, чем-л.*; **эш төшү** *кемгә* **1.** име́ть де́ло *с кем-л., к кому*; быть вы́нужденным пойти́ по де́лу *к кому-л., куда* **2.** обрати́ться за сове́том (по́мощью) *к кому-л.*; **эш түгел** (э́то) не де́ло, су́щий пустя́к; па́ра пустяко́в; плёвое де́ло *прост.*; **эш тыгызга килү (терәлү)** станови́ться/стать ту́го; **эш узган (үткән)** уже́ по́здно, слу́чай (моме́нт) упу́щен, всё ко́нчено; **эш чыгару** вызыва́ть/вы́звать ли́шние хло́поты; **эш чыгара алмау** зава́ливать/завали́ть де́ло; **эш чуалу** осложня́ться, запу́тываться (*о деле*); станови́ться неа́сным; **эш (китереп) чыгару** завари́ть ка́шу; затева́ть *что-л.*; **эш эшләү** де́ло де́лать; **эш эштән үткән (узган)** де́ло уже́ сде́лано; вопро́с уже́ разрешён; **эш юктан (эш булсын дип)** от не́чего де́лать; **эш ясау** наде́лать хлопо́т (дел); **эше беткән** (его́) пе́сенка спе́та, (его́) ка́рта би́та, ему́ кры́шка *прост.*; **эше көлеп тора** отли́чная рабо́та; **эшем киясе (кешесе)** *ирон.* работя́га, трудя́га; **эшем(не) кырган кешедәй** *ирон.* бу́дто го́ры своротúл; **эшен белү 1.** знать своё де́ло **2.** име́ть (ви́деть) свою́ вы́году, пресле́довать

свои́ це́ли; **эшен бетерү** *прост.* **1.** поко́нчить *с чем-л.* **2.** прико́нчить, укоко́шить *прост.*; **эшен китерү** *редко* вы́пать *кому-л.*, проучи́ть; показа́ть ку́зькину мать *прост.*; **эшең бетте, кодагый** и де́лу коне́ц; **эшең түгел** не твоё де́ло, не твоего́ ума́ де́ло; **эшкә а́шмаслык** неосуществи́мый, несбы́точный; **эшкә ашыру** осуществля́ть/осуществи́ть, воплоща́ть/воплоти́ть в жизнь; **эшкә ашу 1.** осуществля́ться/осуществи́ться; воплоща́ться/воплоти́ться в жизнь **2.** *редко* испо́льзоваться, употребля́ться; **эшкә җигү 1.** испо́льзовать, употребля́ть **2.** зад**е**йствовать, пусти́ть (подключи́ть) в де́ло (в оборо́т); **эшкә кертү** де́лать/сде́лать приго́дным (*что-л. испорченное*); **эшкә салкын карау** манки́ровать рабо́той; **эшкә тарту (катнаштыру, җәлеп итү) 1.** привлека́ть/привле́чь, приобща́ть/приобщи́ть *кого* к *какому-л.* де́лу, вводи́ть/ввести́ в де́ло **2.** вну́тывать/вну́тать *кого* в *какое-л.* де́ло; **эшкә чуму** уйти́ (погрузи́ться) в рабо́ту; погрузи́ться в *какое-л.* заня́тие; **эшкә яраклы 1.** работоспосо́бный, дееспосо́бный **2.** приго́дный *к чему-л.*; **эшкә яраксыз 1.** нетрудоспосо́бный **2.** непригодный *к чему-л.*; **эшкә ярату** пусти́ть (употреби́ть) в де́ло; **эшкә ярау 1.** идти́ (пойти́) в де́ло; быть поле́зным (приго́дным) *к чему-л.* **2.** оказа́ться/подверну́ться, кста́ти; *аның эше харап* де́ло его́ труба́; **эшне аңлау** разбира́ться в де́ле; быть све́дущим (компете́нтным) *в чём*; знать (понима́ть) толк *в чём*; **эшне бетерү** разде́латься *с кем, чем-л.*; **эшне бозу (сүтү, җимерү)** расстро́ить (испо́ртить), испога́нить *прост.*, развали́ть, разла́дить де́ло; завари́ть ка́шу; **эшне бутау (буташтыру, чуалту)** запу́тать де́ло, запу́тать ка́рты, замета́ть следы́; **эшне зурга җибәрү** раздува́ть, сгуща́ть кра́ски; де́лать из му́хи слона́; **эштә исә** на де́ле, на са́мом де́ле; **эштә сыналган** испы́танный в де́ле; **эштән калдыру** меша́ть рабо́тать, отвлека́ть от рабо́ты; **эштән чыгарып** на всю катýшку; в пух и прах (*бить, ругать*); **эштән чыгу 1.** заболе́ть, искале́читься **2.** обесси́леть, утоми́ться, изму́читься, вы́биться из сил, завёртеться **3.** вы́йти из стро́я, сраб**о**таться; прийти́ в него́дность (*об одежде*); **эштән чыгып 1.** до изнеможе́ния (*уставать*) **2.** *прост.* до сте́льки, до бесчу́вствия (*быть пьяным*); **эштән чыгып йөрү** *прост.* опуска́ться/опусти́ться; теря́ть/потеря́ть челове́ческий о́блик

эшафот *сущ.* эшафо́т (*помост для казни*)

эшбашкаручы *сущ.* делопроизводи́тель

эшелон *сущ.* **1.** эшело́н *воен. (в боевом или походном порядке — группа, подразделение, расположенное в глубину или уступом за предыдущим)* **2.** эшело́н *(поезд или автоколонна специального назначения; группа самолётов для массовых перевозок)* || эшело́нный; *~ командиры* эшело́нный команди́р; *баш ~* головно́й эшело́н; *хәрби ~* вое́нный эшело́н; *йөк ~ы* грузово́й эшело́н

эшелонлаштыру *перех.* эшелони́ровать || эшелони́рование; *гаскәрләрне ~* эшелони́ровать войска́

эшергеч *сущ. см.* **эшермә**

эшерелмәле *прил. см.* **эшермәле**

эшерелү *страд. от* **эшерү 1.** задви́нуться **2.** запира́ться

эшермә *сущ.* засо́в, задви́жка, запо́р, шпингале́т; *агач ~* деревя́нный засо́в; *ишекне ~ белән бикләү* закры́ть дверь на задви́жку; *капкада тимер ~* на воро́тах желе́зный запо́р; *тәрәзә эшермәләре* око́нные шпингале́ты □ **~ бик** задви́жка

эшермәле *прил.* **1.** с запо́ром, с задви́жкой **2.** задвижно́й; *~ тәрәзә* задвижно́е окно́

эшерү *перех.* **1.** задвига́ть/задви́нуть (*шторы, засов, раму*) **2.** запира́ть/запере́ть на засо́в (*задвижку, запор*)

эш-йомыш *собир.* (ра́зные) дела́-поруче́ния; *мәктәп эш-йомышлары белән йөрү* ходи́ть по шко́льным дела́м-поруче́ниям

эшкәртелгәнлек *сущ.* обрабо́танность, возде́ланность

эшкәртелеш *сущ.* вы́делка, обрабо́тка; разрабо́тка; *тиренең ~ сыйфаты* ка́чество вы́делки ко́жи; *бизәнү әйберләренең ~е* обрабо́тка изде́лий украше́ния; *ачык ~* откры́тая разрабо́тка

эшкәртелү *страд. от* **эшкәртү 1.** *в разн. знач.* обраба́тываться, возде́лываться, разраба́тываться, перераба́тываться, разде́лываться, отде́лываться **2.** *в знач. прил.* **эшкәртелгән** обрабо́танный, возде́ланный, вы́деланный

эшкәртешү *взаимно-совм. от* **эшкәртү**

эшкәрткеч *прил.* обраба́тывающий, прораба́тывающий, перераб**о́**точный

эшкәртмә *сущ.* перераб**о́**тка, обрабо́тка; *дастанның әдәби ~се* литерату́рная перераб**о́**тка дста́на; *шигъри ~* поэти́ческая обрабо́тка

эшкәрттерү *понуд. от* **эшкәртү**; *тире ~* дать обрабо́тать шку́ру

эшкәртү *перех.* **1.** *в разн. знач.* обраба́тывать/обрабо́тать, выде́лывать/вы́делать, возде́лывать/возде́лать, разраба́тывать/разрабо́тать, перераба́тывать/перераб**о́**тать, разде́лывать/разде́лать || обрабо́тка, обраба́тывание, вы́делка, выде́лывание, возде́лывание, разрабо́тка, разраба́тывание, перераб**о́**тка, перераба́тывание, разде́лка, разде́лывание || обраба́тывающий; перераба́тывающий, перераб**о́**точный; *туфракны ~* обраба́тывать (возде́лывать) по́чву; *кулъязманы ~* обрабо́тать (отде́лать) ру́копись; *кыздырып ~* терми́ческая обрабо́тка; *пар белән ~* обрабо́тка па́ром; *җирне чәчүлек өчен ~* разраба́тывать зе́млю под па́шню; *орфографияне ~* разрабо́тка орфогра́фии; *чималны комплекслы ~* ко́мплексная разрабо́тка сырья́; *сарык түшкәсен ~* разде́лать бара́нью ту́шу; *түтәл ~* разде́лка гря́док; *~ эшләре* отде́лочные рабо́ты; *~ пункты* перераб**о́**точный пункт **2.** *спец.* выде́лывать/вы́делать || вы́делка; *тире ~* вы́делать ко́жу **3.** *перен. разг.* обраба́тывать/обрабо́тать, склоня́ть/склони́ть *к чему* || обрабо́тка, обраба́тывание **4.** *перен. прост.* разде́лывать/разде́лать, отде́лывать/отде́лать (*в знач.* изби́ть, отдубасить)

эшкуар *сущ.* деле́ц, деля́га; воротила, заправила

эшкуарлык *сущ.* деля́чество

эшләки *сущ. зоол. см.* **песнәк**

эшләмәү *неперех.* забарахли́ть *прост.* (*о двигателе*)

эшләнеш *сущ.* вы́делка, отде́лка, оформле́ние; *бүлмәнең эчке ~е* вну́тренняя отде́лка ко́мнаты; *китап тышының ~е* оформле́ние обло́жки кни́ги

эшләнелү *страд. от* **эшләнү**

эшләнмә *сущ.* изде́лие, проду́кция; *урындагы ~ләр* ме́стные изде́лия; *әзер ~ләр* гото́вые изде́лия; *алтын-көмеш ~ләр* изде́лия из зо́лота и серебра́; *~нең кыйммәтен билгеләү* определи́ть сто́имость проду́кции

эшләнү *страд. от* **эшләү 1.** де́латься, выде́лываться, выраба́тываться, выполня́ться, исполня́ться; быть сде́ланным/совершённым; *оста ~гән портрет* хорошо́ вы́полненный портре́т; *~гән җинаять өчен җавап бирү* отвеча́ть за совершённое преступле́ние **2.** отде́лываться, украша́ться, инкруст**и́**роваться; *асылташлар белән ~гән беләзек* брасле́т, украшенный драгоце́нными камня́ми □ **~еп беткән** зако́нченный; **~еп бетү** заверши́ться, зако́нчиться

эшләпә *сущ.* **1.** шля́па, шля́пка (*фетровая, соломенная, камышовая*) || шля́пный, шля́почный; *~ тубәсе* тулья́ шля́пы; *хатын-кыз ~се* да́мская шля́пка; *~ калыбы* шля́пный шабло́н; *~ астары* шля́пная подкла́дка; *~ лентасы* шля́почная ле́нта **2.** шля́пка (*гвоздя, подсолнуха, гриба*) || шля́почный; *~ уемы* шля́почный вы́ем **3.** *перен. разг.* шля́па, расте́ря

эшләпәле *прил.* **1.** в шля́пе (шля́почке), со шля́пой (шля́почкой) **2.** име́ющий шля́пку, со шля́пкой **3.** шля́почный, шля́пный □ **~ гөмбәләр** *бот.* шля́почные грибы́

эшләпәче *сущ.* шля́пник, шля́пница

эшләтә: эшләтә түлә́ү отраба́тывать долг || отрабо́тка до́лга

эшләтелү *страд. от* **эшләтү**

эшләтү 1. *понуд. от* **эшлә́ү** заставля́ть рабо́тать, эксплуати́ровать; разреша́ть (позволя́ть) рабо́тать *как, где; көн-төн ~* заставля́ть рабо́тать день и ночь; *яллап ~* эксплуати́ровать по на́йму; *үзе телә́гәнчә ~* дать возмо́жность рабо́тать по своему́ усмотре́нию; *өйдә эшләтү* разреши́ть рабо́тать до́ма **2.** *перех.* рабо́тать, дви́гать *чем; башны ~* рабо́тать (мы́слить, ду́мать) голово́й; *аяк-кулларны ~* рабо́тать (дви́гать) нога́ми и рука́ми **3.** *перех.* включа́ть/включи́ть (*телевизор, электроплитку, мотор*); *радионы ~* включи́ть ра́дио **4.** приводи́ть/привести́ в де́йствие, заводи́ть/завести́ (*машину, часы*); запуска́ть/запусти́ть, пуска́ть/пусти́ть (*станок, электростанцию, мотор, часы и т. п.*)

эшлә́ү *неперех.* **1.** *в разн. знач.* рабо́тать, труди́ться (*кем, где, на кого, над чем, как*); *укытучы булып ~ә* рабо́тать учи́телем; *колхозда ~ә* труди́ться в колхо́зе; *өйдә ~ә* рабо́тать до́ма; *кулъязмалар өстендә ~ә* рабо́тать над ру́кописями; *ялланып ~ә* рабо́тать по на́йму; *~әп үсү* расти́ в труде́; *кешегә ~ә* рабо́тать на чужи́х; *ил файдасына ~ә* труди́ться на бла́го страны́; *кем ~әми, шул ашамый* (*погов.*) кто не рабо́тает, тот не ест; *тирләп ~әсәң тәмләп ашарсың* (*посл.*) рабо́тай до по́ту, так и пое́шь в охо́ту; *кеше ~әп үлми, чирләп үлә* (*посл.*) *букв.* челове́к умира́ет от боле́зни, а не от труда́ **2.** рабо́тать, де́йствовать, функциони́ровать; *музей вакытлыча ~әми* музе́й вре́менно не рабо́тает; *түгәрәк өченче ел ~и* кружо́к функциони́рует тре́тий год **3.** *с послелогом* **белән** 1) рабо́тать, занима́ться *с кем-чем; балалар белән ~ә* рабо́тать с детьми́; *кадрлар белән ~ә* занима́ться (с) ка́драми; *сүзлек белән ~ә* рабо́тать со словарём; *компьютер белән ~ә* рабо́тать (занима́ться) с компью́тером 2) рабо́тать *на чём*, приводи́ться (привести́сь) в де́йствие *чем; электр белән ~ә* приводи́ться в де́йствие электри́чеством; *торф белән ~ә* рабо́тать на то́рфе **4.** дви́гаться, де́йствовать; *куллар-аяклар ~әми* ру́ки-но́ги не дви́гаются; *куллар белән ~ә* де́йствовать рука́ми **5.** сообража́ть, рабо́тать (*о голове*); *башың ~әмәсә, аягың ял итмәс* (*посл.*) дурна́я голова́ нога́м поко́я не даёт (*букв.* е́сли голова́ не сообража́ет, нога́м поко́я не бу́дет) **6.** *неперех. перех.* де́лать/сде́лать, поступа́ть/поступи́ть; *нәрсә ~исең инде аның белән?* что с ним сде́лаешь? *ничек телисең, шулай ~ә* как хо́чешь, так и поступа́й (де́лай); *дөрес ~ә* поступи́ть (сде́лать) пра́вильно **7.** *перех.* де́лать/сде́лать, изгота́вливать, изготовля́ть/изгото́вить, выраба́тывать/вы́работать || изгота́вливание, изготовле́ние, выраба́тывание, вы́работка; *таблицалар ~ә* де́лать (изготовля́ть) табли́цы; *агач әйберләре ~ә* де́лать (изгота́вливать) деревя́нные изде́лия; *уенчыклар ~ә* де́лать (мастери́ть) игру́шки; *ярымфабрикатлар ~ә* изготовля́ть полуфабрика́ты, изгота́вливание полуфабрика́тов **8.** зараба́тывать/зарабо́тать || зараба́тывание; *өч йөз хезмәт көне ~ә* вы́работать три́ста трудодне́й; *ни ~исең, шуны ашыйсың* (*погов.*) что зарабо́таешь (вы́работаешь), то и пое́шь; *~әгәнеңне ал* получа́й, что зарабо́тал **9.** де́лать/сде́лать, твори́ть, соверша́ть/соверши́ть; *изге эш ~ә* соверши́ть благо́е де́ло; *гаҗәеп эшләр ~ә* твори́ть чудеса́; *җинаять ~ә* соверши́ть преступле́ние; *элек үйла, аннан ~ә* (*погов.*) снача́ла поду́май, а пото́м сде́лай □ **~әп алу 1.** рабо́тать **2.** *см.* **эшләп табу; ~әп ару** зарабо́таться; **~әп бетерү** зако́нчить (заверши́ть) рабо́ту (де́ло), дорабо́тать; **~әп бирү** вы́работать (*план*); **~әп табу** зараба́тывать, подзараба́тывать/подзарабо́тать; **~әп тору** рабо́тать, де́йствовать, функциони́ровать; **~әп чыгару** производи́ть/произвести́, перераба́тывать/перераба́тывать, выраба́тывать/вы́работать, изготовля́ть/изгото́вить, выпуска́ть/вы́пустить || произво́дственный (*план*); **~әп чыгару кораллары** *см.* **җитештерү кораллары; ~әп чыгаручы** производи́тель; **~әп чыгу 1.** разраба́тывать **2.** прораба́тывать; **~әргә тотыну** нача́ть рабо́тать, приступа́ть/приступи́ть к рабо́те; **~и башлау 1.** бра́ться, взя́ться за де́ло, приступа́ть/приступи́ть к рабо́те **2.** зарабо́тать, завести́сь (*о машине*) ◊ **~әмәгән эше юк** ма́стер на все ру́ки; **~әп ташлау** провернуть *какое-л.* де́ло

эшләштергәлә́ү *многокр. от* **эшлә́ү 1.** поде́лывать, де́лать (*время от времени, иногда*) **2.** зараба́тывать, подраба́тывать (*иногда, немного*)

эшләштерү *многокр. от* **эшлә́ү** *см.* **эшләштергәлә́ү**

эшләшү *взаимно-совм. от* **эшлә́ү**

эшле *прил. разг.* за́нятый (*делом*); *~ булу* за́нятость □ **~ кеше 1.** делови́тый челове́к **2.** должностно́е лицо́ **3.** бизнесме́н

эшлек *сущ. диал.* до́лжность

эшлекле *прил.* **1.** делово́й, делови́тый, предприи́мчивый; *~ сөйләшү* делово́й разгово́р; *~ элемтәләр урнаштыру* установи́ть деловы́е конта́кты (свя́зи); *~ җитәкче* делови́тый (предприи́мчивый) руководи́тель; *~ кешеләр клубы* клуб деловы́х люде́й **2.** энерги́чный, де́ятельный, жизнеде́ятельный; уме́лый, трудолюби́вый; *үзен ~ җитәкче итеп тануты* проявить себя́ энерги́чным (де́ятельным) руководи́телем **3.** *в знач. сущ. чаще в притяж. ф.* **эшлеклесе** де́ятель, рабо́тник; *атказанган фән ~се* заслу́женный де́ятель нау́ки; *дәүләт ~се* государственный де́ятель; *мәдәният эшлеклеләре* рабо́тники культу́ры

эшлеклелә|ү *неперех.* **1.** станови́ться/стать де́ятельным (предприи́мчивым) **2.** *в знач. нареч.* **эшлеклеләнеп** делови́то, по-делово́му; *бик ~еп сөйләшү* разгова́ривать о́чень делови́то

эшлеклелек *сущ.* делови́тость, предприи́мчивость; *яшь белгечләрнең ~ сыйфатлары* ка́чество делови́тости молоды́х специали́стов

эшлексез *прил.* безда́рный, лени́вый; пра́здный, праздношата́ющийся || *сущ.* безде́льник, лентя́й, разгильдя́й, ло́дырь; *эшлеклене иген басар, ~не йокы басар* (*погов.*) трудолюби́вый погру́зится в хлеб (*т. е.* вы́растит хоро́ший урожа́й), а безде́льник в сон

эшлексезле|к *сущ.* безде́йствие, безде́ятельность; *җитәкчеләрнең ~ген тәнкыйтьләү* критикова́ть безде́ятельность руководи́телей

эшлея *сущ. разг.* шлея́

эшмә *нареч. диал. см.* **эш башыннан**

эшмәкәр *сущ.* **1.** *диал. см.* **эшчән, эшлекле 2.** делово́й челове́к, бизнесме́н, предпринима́тель; босс **3.** *диал.* зате́йник

эшмәкәрләнеп: эшмәкәрләнеп йөрү пока́зывать вид делово́го челове́ка

эшмәкәрлек *сущ.* деля́чество □ ~ **күрсәтү** проявля́ть/прояви́ть делови́тость

эшмән *сущ.* делово́й челове́к, бизнесме́н

эшсез *прил.* **1.** не име́ющий рабо́ты, безрабо́тный; ~ *кешеләр исемлеге* спи́сок безрабо́тных люде́й || *нареч.* **2.** без де́ла, без рабо́ты; ~ *калдыру* оста́вить без рабо́ты; ~ *күңелсез* ску́чно без де́ла **3.** *перен.* без нужды́, без на́добности; ~ *борчып йөрмәсеннәр* пусть не беспоко́ят без нужды́ □ ~ **йөрү** слоня́ться, шата́ться без де́ла, бить баклу́ши; ~ **тору** быть безрабо́тным, жить безрабо́тным; ~ **утыру** безде́льничать, загора́ть, сиде́ть сложа́ ру́ки; ~ **яту** безде́льничать, лежа́ть на боку́ || *сущ.* **1.** безрабо́тный, безрабо́тная; ~*ләр проблемасы* пробле́ма безрабо́тных **2.** *разг.* безде́льник, разгильдя́й, лентя́й, ло́дырь; *бу* ~*ләргә ни кирәк?* что ну́жно э́тим безде́льникам?

эшсезлек *сущ.* **1.** безрабо́тица; *даими* ~ хрони́ческая безрабо́тица; *яшерен* ~ скры́тая безрабо́тица; ~*не кимету* уме́ньшить безрабо́тицу **2.** безде́лье; ~*тән йөдәү* страда́ть от безде́лья

эшсөяр *сущ.* трудолюби́вый, де́ятельный

эшти *сущ. разг.* щи; ~ *пешерү* свари́ть щи

эшханә *сущ.* **1.** рабо́чее помеще́ние, зда́ние (*предприятия, учреждения*); цех; *типография* ~*се* рабо́чее помеще́ние типогра́фии **2.** *уст.* предприя́тие, канцеля́рия

эш-хәл *сущ. собир.* **1.** дела́, обстоя́тельства **2.** *лингв.* де́йствие

эшчән *прил.* работя́щий, трудолюби́вый; делово́й, делови́тый, де́ятельный; ~ *куллар* трудолюби́вые ру́ки; ~ *оештыручы* делово́й (де́ятельный) организа́тор || *сущ.* тру́женик, тру́женица, рабо́тник, рабо́тница; *ферма* ~*нәре* тру́женики фе́рмы; *авыл хуҗалыгы* ~*нәре* рабо́тники (тру́женики) се́льского хозя́йства

эшчәнле|к *сущ.* **1.** трудолю́бие, работоспосо́бность, делови́тость; *тырышлыгы,* ~*ге белән аерылып тора* отлича́ется стара́тельностью, трудолю́бием **2.** де́ятельность, жизнеде́ятельность; *фәнни-тикшерену* ~*ге* нау́чно-иссле́довательская де́ятельность; *ашкайнату бизләре* ~*ге* де́ятельность желёз пищевари́тельных; ~*к өлкәсе* круг де́ятельности

эшче *сущ.* **1.** рабо́чий, пролета́рий || рабо́чий; *заводфабрика* ~*ләре* фабри́чно-заводски́е рабо́чие; *яллы* ~*ләр* наёмные рабо́чие; ~*ләрне революцион көрәшкә күтәрү* подня́ть рабо́чих на революцио́нную борьбу́; ~ *сыйныфы* рабо́чий класс; ~ *халык* рабо́чий наро́д, трудя́щиеся ма́ссы, рабо́чие; ~ *яшьләр* рабо́чая молодёжь; ~*ләр хәрәкәте* рабо́чее движе́ние **2.** рабо́тник, слу́жащий; *см. тж.* **хезмәткәр**; *партия-профсоюз* ~*ләре* парти́йно-профсою́зные рабо́тники; *контора* ~*се* слу́жащий конто́ры □ ~ **корт** рабо́чая пчела́; ~ **көчләр** рабо́чие си́лы; ~ **кул** *см.* **эш кулы**; ~ **күләм** *физ.* рабо́чий объём; ~ **тәгәрмәч** *физ.* рабо́чее колесо́; ~ **хатын-кыз** рабо́тница

эшче-крестьян *сущ. собир.* рабо́чие и крестья́не || рабо́че-крестья́нский; *эшче-крестьян хөкүмәте* рабо́че-крестья́нское прави́тельство

Ю

юа *сущ. бот.* ди́кий лук; *юа суганы* лу́ковица ди́кого лу́ка; *юа кыяклары* стрецы́ (ли́стья) ди́кого лу́ка; *юага бару* идти́ собира́ть ди́кий лук

юак *сущ. диал.* **1.** досу́г **2.** развлече́ние; весе́лье || *прил. диал.* **1.** свобо́дный; досу́жий **2.** развлека́тельный, весёлый; *юак әңгәмә* развлека́тельная бесе́да

юак-йомак *сущ. диал.* досу́жие развлече́ния

юалы *прил.* с ди́ким лу́ком; поро́сший ди́ким лу́ком; где растёт ди́кий лук (*о луге, поле*)

юалык *сущ.* **1.** ме́сто, где (*в изобилии*) растёт ди́кий лук; «окно́» ди́кого лу́ка; *~ таптым* нашёл «окно́» ди́кого лу́ка **2.** *этногр.* языческий весе́нний пра́здник (*коллективный выход молодёжи за диким луком*)

юан *прил.* **1.** 1) то́лстый, утолщённый (*о круглых предметах*); *юан кәүсә* то́лстый ствол 2) то́лстый, раздобре́вший, доро́дный (*о человеке*); *юан карчык* то́лстая стару́ха 3) то́лстый, выпира́ющий (*о животе*) **2.** *перен. диал. см.* **калын** (*в перен. знач.*); *юан тавыш* ни́зкий го́лос; *юан кесә* туго́й кошелёк; то́лстая сума́; толстосу́м (*букв.* то́лстый карма́н) □ **юан савырлы** толстоза́дый; *юан эчәк* то́лстая кишка́ ◊ **юан корсак** бога́ч, буржу́й

юанайту *перех.* утолща́ть/утолсти́ть; *см. тж.* **калынайту**; *торбаларны ~* утолща́ть тру́бы; *корсак ~* отрасти́ть живо́т

юанайтылу *страд. от* **юанайту**; утолща́ться/утолсти́ться, быть утолщённым (*при воздействии со стороны*)

юана|ю *неперех.* **1.** утолща́ться/утолсти́ться || утолще́ние; *язын агачлар ~я* весно́й дере́вья утолща́ются **2.** толсте́ть, растолсте́ть; *~ябыз инде* мы уже́ толсте́ем; *көннән-көн ~еп бара* толсте́ет изо дня́ в день

юандыргыч *прил.* **1.** утеши́тельный, успокои́тельный **2.** 1) занима́тельный, увлека́тельный 2) завлека́тельный; *~ уен* увлека́тельная игра́ **3.** *диал.* вызыва́ющий ску́ку, апа́тию, лень

юандыру **1.** *понуд. от* **юану**; заставля́ть/заста́вить утеша́ться/уте́шиться, завлека́ться **2.** *перех. см.* **юату** **3.** *диал.* быть ску́чным, вызыва́ть ску́ку, апа́тию, лень

юанлану *возвр. от* **юанлау**; *см.* **юанаю**

юанлау *перех.* де́лать/сде́лать (сравни́тельно) то́лстым; утолща́ть/утолсти́ть || утолще́ние

юанлыгы *см.* **юанлыгындагы**; *бармак ~* толщино́й с па́лец

юанлыгындагы *послелог* толщино́й *с кого, что*; *самавыр ~* толщино́й с самова́р

юанлы|к *сущ.* **1.** толщина́ (*предметов круглого сечения*); *агачның ~гы* толщина́ де́рева **2.** толщина́, толстова́тость (*человека*); *~гыннан (~гы аркасында)* из-за толщины́ (толстова́тости) **3.** *разг. см.* **юанлыгындагы**; *биле мичкә ~гында* та́лия (его́, её) толщино́й с бо́чку

юанлыктагы *прил. после определительных слов* (*прил., указ. местоимений и частиц*) име́ющий определённую толщину́, определённой толщины́; *зур ~* большо́й толщины́; о́чень то́лстый; *шул ук ~* тако́й же толщины́

юантык *прил.* **1.** то́лстый, толстова́тый, призе́мистый (*о человеке*); *~ гәүдә* толстова́тое ту́ловище **2.** *разг.* толсте́нный; *~ бүрәнәләр* толсте́нные брёвна

юан|у *неперех.* **1.** 1) утеша́ться/уте́шиться || уте́ха; успока́иваться/успоко́иться || успокое́ние; *киләчәкне уйлап ~у* утеша́ться мы́слью о бу́дущем (*думая о будущем*) 2) те́шиться (*о ребёнке, детях*); *бала уйнап ~а* ребёнок те́шится игро́й **2.** *диал.* развлека́ться || развлече́ние; забавля́ться пустяка́ми **3.** увлека́ться/увле́чься || увлече́ние; *эш белән ~у* увлека́ться рабо́той **4.** зря проводи́ть вре́мя; ме́шкать; *озак ~ма* не ме́шкай; **5.** *диал.* мири́ться/примири́ться, смиря́ться/смири́ться || примире́ние, смире́ние; *барын уйла да ~* поду́май обо всём и смири́сь

юанчы|к *сущ. диал.* предме́т утеше́ния; *баланың ~гы — уенчык* (*погов.*) предме́т утеше́ния ребёнка — игру́шка

юаныч *сущ.* **1.** утеше́ние, заба́ва **2.** отра́да, усла́да; *бар ~ым шул* вся моя́ отра́да в э́том **3.** развлече́ние, уте́ха; *~ булсын* пусть бу́дет для уте́хи || *прил.* утеши́тельный; *~ сүзләр* утеши́тельные слова́

юанычлы *прил.* утеша́ющий, утеши́тельный, успока́ивающий; *~ хәбәрләр* утеши́тельные ве́сти

юанычсыз *прил.* безуте́шный; неуте́шный; *~ кайгы* безуте́шное го́ре

юаткыч *сущ.* **1.** усла́да, отра́да; то, что утеша́ет, успока́ивает; *күңел ~ы* отра́да для души́ **2.** *фольк.* жанр утеши́тельных прибау́ток для дете́й **3.** уте́ха, развлече́ние || *прил.* утеши́тельный, утеша́ющий, облегча́ющий (*горе*); *~ сүзләр* утеша́ющие слова́

юат|у *перех.* **1.** утеша́ть/уте́шить || утеше́ние; унима́ть/уня́ть, успока́ивать/успоко́ить || успокое́ние; *баланы ~у* успока́ивать (унима́ть) ребёнка **2.** *диал.* отвлека́ть/отвле́чь (*от дела*); завлека́ть/завле́чь || отвлече́ние (*от дела*), завлече́ние в заба́ву, в пусто́е времяпрепровожде́ние

юатучы *сущ.* утеши́тель; *елатсалар елатырлар, ~лар булмас* (*песня*) пла́кать-то нас заста́вят, да утеша́ть не́кому

юач *сущ. диал.* **1.** заре́чье; *юач ягы* заре́чная сторона́ **2.** луг на излу́чине реки́

юача I *сущ.* **1.** *этногр. кул.* вид сдо́бных ша́риков (баурса́ков), лепёшек, жа́реных на ма́сле; пря́женец **2.** сва́дебные сдо́бные пече́нья (*коврижки, пироги, ватрушки и т. п.*)

юача II *сущ. диал. см.* **юа**

юллы|к III *сущ.* дымохо́д; *мич ~гы* дымохо́д печи́ □ **~кка кычкыру** *этногр.* крича́ть в дымохо́д печи́ (*исходя из языческих представлений о том, что бог общается с нижним миром через дымоход*) о сокрове́нном своём жела́нии, а та́кже о рожде́нии и́ли сме́рти *кого-л.*

юллык IV *сущ.* доро́жка, полови́к (*узкий длинный ковёр, ткань и т. п. на лестнице, у дверей и т. п.*); *хәтфә ~* во́рсовая доро́жка

юллы-юллы *прил. разг.* полоса́тый; со мно́гими полоса́ми, поло́сками (*о ткани и пр. поверхностях*); *юллы-юллы җыерчыклар* морщи́ны поло́сками

юллы-юлсыз *прил. прост.* **1.** почти́ бездоро́жный; с е́ле заме́тными доро́гами (тропи́нками, следа́ми); *юллы-юлсыз җирләр* почти́ бездоро́жные места́ **2.** ра́зные, с доро́гами и без доро́г (*места*) **3.** *перен.* ра́зные, путёвые и непутёвые (*люди*)

юлма-юл *прил.* подстро́чный; *юлма-юл тәрҗемә* подстро́чный перево́д || *нареч.* подстро́чно; *юлма-юл тәрҗемәләү* переводи́ть подстро́чно

юлма-юллык *сущ. редко* подстро́чник, подстро́чный перево́д

юлсабыш *сущ. диал.* **1.** разви́лка доро́г; *~ка җиткәч* дойдя́ до разви́лки доро́г **2.** указа́тель пути́ на разви́лке доро́г

юлсыз *прил.* **1.** бездоро́жный; *~ кыр* бездоро́жное по́ле **2.** *перен.* беспу́тный, непутёвый; *кулсыздан ~ битәр* (*посл.*) непутёвый ху́же безру́кого || *нареч.* без доро́ги; без пути́; по бездоро́жью; *~ бару* идти́ без доро́ги; идти́ по бездоро́жью

юлсызлык *сущ.* **1.** бездоро́жье; распу́тица; *язгы ~* весе́нняя распу́тица **2.** *перен.* безвы́ходность; безвы́ходное положе́ние; *бу ~тан ничек чыгарга?* как вы́йти из э́того безвы́ходного положе́ния?

юлтый *сущ. диал.* **1.** авантюри́ст, иска́тель уда́чи; *~ юлламый торалмый* (*посл.*) авантюри́ст не мо́жет жить без авантю́р (афёр) **2.** (*слишком везучий*) счастли́вчик; тот, кому́ повезло́ и́ли везёт; *~ үз үлеме белән үлми, ди* (*шутл. посл.*) говоря́т, сли́шком везу́чие) счастли́вчики умира́ют не свое́й сме́ртью || *прил.* везу́чий, (незаслу́женно) уда́чливый; *ну, ~ да инде син!* ну и везу́чий же ты!

юлтыйлы|к *сущ. диал.* **1.** авантюри́зм; изворо́тливость, проны́рливость **2.** уда́чливость; везе́ние; *~гы белән* благодаря́ уда́чливости

юлча *нареч.* по-доро́жному; как пу́тник; *~ киенгән* оде́тый по-доро́жному

юлчабар *сущ.* ве́стник, гоне́ц (*на дальние расстояния — в отличие от* **чапкын**); *~ җибәрү* посла́ть гонца́

юлчы *сущ.* **1.** пу́тник, стра́нник **2.** пассажи́р; *~лар вагонга керә башлады* пассажи́ры ста́ли заходи́ть в ваго́н **3.** доро́жник (*специалист, рабочий на строительстве и эксплуатации дорог*); *~лар клубы* клуб доро́жников (*обычно железнодорожников и автодорожников*)

юлы *союз с мест. указ.* раз; *бу ~* в э́тот раз (на э́тот раз); *теге ~* в тот раз

юлы|гу *неперех.* **1.** (*неожиданно*) встреча́ть(ся)/встре́тить(ся), попада́ться/попа́сться навстре́чу || 1) (*неожиданная*) встре́ча; *танышыма ~ктым* я (*неожиданно*) встре́тил знако́мого (встре́тился со знако́мым) 2) (*неожиданно*) сходи́ться/сойти́сь || схожде́ние *с кем* 3) наткну́ться *на что*; случа́йно находи́ть/найти́ *что*; *яңа (сәрин) эзгә ~гу* наткну́ться на све́жий след; найти́ след (*зверя*) **2.** налете́ть, наткну́ться, подзалете́ть, попа́сть, подверну́ться *под что*; *бәлагә ~гу* попа́сть в беду́ **3.** находи́ть/найти́ *на кого-что*; *байлыкка ~гу* найти́ на бога́тство; *бәхеткә ~гу* найти́ на сча́стье **4.** *диал.* заезжа́ть, заходи́ть/зайти́; *кайтышлый киветкә ~кты* по доро́ге зашёл в магази́н **5.** доходи́ть/дойти́ (*о посылке, письме*); *см. тж.* **ирешү**; *хатыгыз безгә килеп ~кты* ва́ше письмо́ (всё же) дошло́ до нас

юлыгышу *взаимно-совм. от* **юлыгу**; встреча́ться/встре́титься (*неожиданно*)

юлы|к *сущ. этногр.* праправнук; *~гын кургән* уви́девший праправнука (*т. е. долгожитель*)

юлыктыр|у *перех.* **1.** наводи́ть/навести́ *кого на кого-что*; *байлыкка ~у* наводи́ть на бога́тство **2.** своди́ть/свести́ *кого с кем*; спосо́бствовать встре́че, соедине́нию и т. п.; *кызның яры кырыктыр, ише чыкса ~* (*посл.*) у де́вушки со́рок ми́лых, подвернётся досто́йный — спосо́бствуй соедине́нию её (бра́ком)

юл-юл *прил.* полоса́тый (*со многими полосами*); чересполо́сный; *юл-юл сыртлар* чересполо́сные го́рные хребты́ || *нареч.* полоса́ми; *юл-юл тир ага* полоса́ми течёт пот

юл-юллы *прил. см.* **юллы-юллы**

юм *сущ. диал.* обслу́живание; обхожде́ние; *юм белән алдыру* взять хоро́шим обхожде́нием

юма I *прил.* льсти́вый, подхали́мский (*о слове, речи и т. п.*); *~ сүз* льсти́вое сло́во; *~ тел* льсти́вый язы́к (*в знач.* льстец)

юма II *сущ. диал.* пло́ская верёвка о трёх и бо́лее пря́дях

юмакай *прил.* 1. льсти́вый; скло́нный домога́ться *чего-л.* ле́стью, обха́живанием (*о человеке*) || льстец, подхали́м; *~ кеше* льсти́вый челове́к 2. подхали́мствующий 3. *см.* **юма** I

юмакайлан|у *неперех.* 1. подхали́мствовать, льстить, подли́зываться, уго́дничать || подхали́мство, уго́дничание; *ул һаман ~а* он всё подхали́мствует 2. *редко* превраща́ться/преврати́ться в подхали́ма, льстеца́, уго́дника; *ничек болай ~дың эле син?* ка́к же ты стал льстецо́м?

юмакайла|у 1. *перех. см.* **юмала́у** 2. *неперех.* говори́ть льсти́вые слова́; юли́ть; *~п эшен җайлый* добива́ется своего́ льсти́выми речами

юмакайлык *сущ.* 1. подхали́мство, уго́дничество; *~ күрсәту* проявля́ть/прояви́ть подхали́мство 2. льсти́вость

юмал *прил. диал.* 1. пре́сный, без со́ли 2. недосолёный

юмалан|у *неперех.* 1. подли́зываться/подлиза́ться *к кому*; льстить, льнуть; *син миңа ~ма* ты под меня́ не подла́живайся 2. *диал.* ла́ститься, ласка́ться

юмал|а́у *перех.* 1. льстить, притво́рно хвали́ть; ле́стью, уго́дничанием, ла́ской домога́ться своего́; *~ап алу* взять домога́тельством *что* 2. обха́живать, успока́ивать || обха́живание, успока́ивание (*обиженного*); *үзе ~ый, үзе юнгалый* (*погов.*) сам утеша́ет, сам же сдира́ет

юмарт *прил.* 1. *в разн. знач.* ще́дрый; тарова́тый, не скупо́й; *~ табигать* ще́драя приро́да; *~ кешедә мал тормас* (*посл.*) у ще́дрого челове́ка добро́ не заде́ржится 2. *уст.* великоду́шный || *нареч.* 1. ще́дро, по-ще́дрому; *~ кылану* вести́ себя́ по-ще́дрому (*щедро раскошелиться*) 2. раду́шно, серде́чно; *~ елмая* ще́дро (раду́шно) улыба́ется

юмартландыр|у *понуд. от* **юмартлану**; де́лать/сде́лать ще́дрым *кого-что*; *шатлык ~а* ра́дость де́лает ще́дрым

юмартлан|у *неперех.* 1. станови́ться/стать ще́дрым, тарова́тым 2. расще́дриться, раскоше́литься; *артык ~ма* ты сли́шком не расще́дривайся □ **~ып китү** 1. станови́ться ще́дрым 2. расще́дриться, раскоше́литься

юмартлы|к *сущ.* 1. ще́дрость; *күңел ~гы* ще́дрость души́; *~к күрсәту* проявля́ть ще́дрость 2. *уст.* великоду́шие □ **~к итү (кылу)** расще́дриться

юмартчылык *сущ.* 1. *разг. см.* **юмартлык** 2. щедрови́тость, изли́шняя ще́дрость; стремле́ние заслужи́ть сла́ву ще́дрого; тщесла́вная расточи́тельность; *~ күрсәту* прояви́ть изли́шнюю ще́дрость □ **~ итү (кылу)** изли́шне расще́дриться (раскоше́литься)

юмару *перех. диал.* мять, поми́ять, умина́ть; *кул белән ~* умина́ть руко́й (рука́ми)

юмор *сущ.* 1. ю́мор; *җиңелчә ~* лёгкий ю́мор; *~ белән* с ю́мором 2. *лит. редко* юмористи́ческое произведе́ние; *аның бер ~ы басылды* напеча́тали его́ одно́ юмористи́ческое произведе́ние

юморе́ска *сущ. лит.* юморе́ска; *~лар авторы* а́втор юморе́сок

юморист *сущ. лит.* юмори́ст; *бөек ~ Марк Твен* вели́кий юмори́ст Марк Твен

юмори́стик *прил.* юмористи́ческий (*образ, рассказ, журнал и т. п.*)

юмори́стика *сущ.* 1. *собир.* юмори́стика (*совокупность юмористических произведений*) 2. *разг.* юмори́стика (*смешное, комическое*)

юнан *сущ. ист. книжн.* грек, иони́ец || гре́ческий, иони́ческий; *~ һәйкәлләре* гре́ческие скульпту́ры

юнани *прил. книжн.* гре́ческий; *~ фәлсәфә* гре́ческая филосо́фия

юнәйтү *перех. см.* **арзанайту**

юнәлдергеч *прил.* направля́ющий; *~ көч* направля́ющая си́ла

юнәлдерелү *страд. от* **юнәлдерү**; быть напра́вленным, обращённым (*куда-л., в какую-то сторону*)

юнәлдер|ү *перех.* 1. направля́ть/напра́вить || направле́ние (*как действие*); *машинаны уңга ~ү* напра́вить маши́ну напра́во 2. обраща́ть/обрати́ть || обраще́ние (*внимания в сторону чего-л.*); *карашын безгә ~де* обрати́л свой взор на нас

юнәлеш I *сущ.* 1. *в разн. знач.* направле́ние; *әдәбият ~ләре* литерату́рные направле́ния; *демократик ~тә үсеш алу* развива́ться в демократи́ческом направле́нии; *шул ~тә* в том направле́нии 2. *см.* **юнәлешлек**; *әсәрнең сатирик ~е* сатири́ческая напра́вленность произведе́ния □ **~ алу** приня́ть направле́ние; *агым икенче бер ~ алды* тече́ние при́няло (не́сколько) друго́е направле́ние; *~ килеш(е) лингв.* направи́тельный паде́ж

юнәлеш II *сущ. грам.* зало́г; *төп ~* действи́тельный зало́г; *йөкләтү ~е* понуди́тельный зало́г; *кайтым ~е* возвра́тный зало́г; *төшем ~е* страда́тельный зало́г; *уртаклык ~е* взаи́мный зало́г; *фигыльдә ~ аермалары* зало́говые разли́чия в глаго́ле

юнәлешендәге *прил. в изафетн. сочет. см.* **юнәлештәге**; *агым* – по направле́нию тече́ния

юнәлешле *прил. в разн. знач.* напра́вленный; *демократик ~ иҗтимагый үзгәрешләр* демократи́чески напра́вленные обще́ственные измене́ния; *~ хәрәкәт* напра́вленное движе́ние (*в физике*)

юнәлешлек *сущ.* напра́вленность, о́бщее направле́ние движе́ния, измене́ний и т. п.

юнәлешлелек *сущ.* напра́вленность (*движения, изменения и т. п.*); *сыйнфый ~* кла́ссовая напра́вленность

юнәлешсез *прил.* ненапра́вленный; *~ үзгәрешләр* ненапра́вленные измене́ния

юнәлешсезлек *сущ.* ненапра́вленность

юнәлештәге *прил.* **(фәлән ~)** находя́щийся в определённом (да́нном) направле́нии (по направле́нию *чего*); *барган ~* находя́щийся по направле́нию движе́ния

юнәлешчән *нареч.* напра́вленно; *~ үсү* напра́вленно развива́ться

юнәлтелү *страд. от* **юнәлтү**

юнәлткеч *прил. см.* **юнәлдергеч**

юнәлт|ү *перех. разг.* 1. *см.* **юнәлдерү** 2; 2. адресова́ть || адресова́ние (*слова, высказывания и т. п.*); *см. тж.* **төбәү** 2; 3. устремля́ть/устреми́ть || устремле́ние (*взора*)

юнәл|ү I *неперех.* 1. 1) направля́ться/напра́виться || направле́ние в *какую-л.* сто́рону 2) отправля́ться/отпра́виться || отправле́ние *куда*; *венә ~де* отпра́вился домо́й 2. обраща́ться/обрати́ться; устремля́ться/устреми́ться || обраще́ние, устремле́ние *к чему, куда*; *карашлар алга ~де* взгля́ды устреми́лись вперёд 3. сосредото́чиваться/сосредото́читься || сосредоточе́ние (*внимания*); *аның мәхәббәте балага ~де* любо́вь её сосредото́чилась на ребёнке

юнәл|ү II *неперех. см.* **юнәю**

юнәт|ү *неперех. диал. см.* **юнәю** I; *ул ~еп бара инде* он уже́ поправля́ется

юнәттер|ү *понуд. от* **юнәтү**; *акча ~ү* заста́вить сколоти́ть (доста́ть) де́ньги

юнәт|ү *перех.* 1. устро́ить, сколоти́ть, сооруди́ть; изгото́вить || изготовле́ние, сооруже́ние; *өй ~ү* сооруди́ть (*разными путями*) дом; осуществи́ть постро́йку до́ма; сколоти́ть дом 2. доставля́ть/доста́ть; находи́ть/найти́, приобрета́ть/приобрести́ || нахожде́ние, приобрете́ние; *акча ~ү* доставля́ть де́ньги; *сәмән ~ү* находи́ть (де́нежные) сре́дства; *кием ~ү* приобрета́ть оде́жду 3. *диал.* исправля́ть/испра́вить; поправля́ть/попра́вить, нала́живать/нала́дить, ремонти́ровать || исправле́ние; попра́вка, нала́дка, ремо́нт; *бозылган йозакны ~ү* ремонти́ровать испо́рченный замо́к; *~еп бирде* нала́дил (*что кому*) 4. *диал.* 1) вы́лечить; *тәки ~те бит шул бәтине* вы́лечил-таки того́ козлёнка 2) перевоспита́ть (*блудного, невоспитанного, бестолкового и т. п.*) 5. *разг.* оформля́ть/офо́рмить || оформле́ние (*билета, путёвки в дом отдыха*); *документларны ~ү* оформле́ние докуме́нтов

юнә|ю I *неперех. диал.* 1. улучша́ться/улу́чшиться, поправля́ться/попра́виться || улучше́ние, поправле́ние (*дел, положения*); встава́ть/встать на́ ноги (*о хозяйстве, людях, стране*) 2. *см.* **исәю**; *малай инде ~йгән* ма́льчик уже́ дово́льно окре́п; *юньсезнең ~юе шикле* (*погов.*) горба́того моги́ла испра́вит (*букв.* сомни́тельно, что ду́рень испра́вится)

юнә|ю II *неперех. разг. см.* **арзанаю, җүнәю**; *базарда ашлык ~йгән* зерно́ на база́ре подешеве́ло

юнга *сущ. спец.* ю́нга; *~лар мәктәбе* шко́ла юнг

юнгала́у *многокр. от* **юну** 1. обтёсывать, обстру́гивать, стёсывать (*со всех сторон*) 2. (*понемногу*) отщи́пывать (*щепу, лучину*)

юнгы *сущ.* отще́п, отще́пок; ще́па, ще́пка; стру́жка; *таш ~сы* отще́п ка́мня; *агач ~сы* древе́сная стру́жка; ще́пка; *бала — җанның ~сы* (*посл.*) дита́ — отще́пок души́

юнгыч *сущ.* 1. нож (*для отщепывания лучины*) 2. (*грубый*) руба́нок; *~ белән юну* стёсывать руба́нком

юндыру 1. *понуд. от* **юну**; заставля́ть/заста́вить и́ли веле́ть, проси́ть, стёсывать/стеса́ть *что-л.* 2. сре́зывать/сре́зать (*поверхность металла, дерева, земли и т. п.*)

ю́нкер *сущ. в разн. знач.* 1. ю́нкер (*крупный помещик в Германии*) 2. ю́нкер (*курсант военного училища в России*) || ю́нкерский; *~лар мәктәбе* ю́нкерская шко́ла (*в царской России*)

ю́нкерлык *сущ.* ю́нкерство; положе́ние и обя́занности ю́нкера; *~та йөрү* ходи́ть в юнкера́х

юну *неперех.* 1. теса́ть, строга́ть; обтёсывать || теса́ние, строга́ние, обтёсывание; *агач юну* теса́ть/обтёсывать де́рево; *таш юну* обтёсывать ка́мень; *туң ит юну* строга́ть мёрзлое мя́со 2. стёсывать/стеса́ть, щепа́ть, выстру́гивать || стёсывание, щепа́ние (*щепы, лучины*); *чыра юну* щепа́ть лучи́ну □ **юныш алу** 1. выстру́гивать/вы́стругать 2. сре́зывать/сре́зать; **юныш ясау (эшләү)** вы́строгать, вы́тесать *что-л. из чего* ◊ **юныш алгандай булды** как руко́й сняло́ (*букв.* как бу́дто вы́строгали — следа́ не оста́лось; сло́вно стеса́ли)

юнык *прил. разг.* обтёсанный, обто́ченный; отёсанный; *~ бүрәнә* отёсанное бревно́

юныл|у *возвр.-страд. от* **юну** 1. *возвр.* теса́ться, строга́ться (*иметь такое свойство, что данный материал можно тесать, строгать*) 2. обтёсываться/обтеса́ться 3. стёсываться/стеса́ться; *кабыгы җиңел юныла* кора́ его́ стёсывается легко́ 4. *страд.* быть стёсанным, вы́строганным; *агачтан ~ган орчык* веретено́, вы́строганное из де́рева 5. быть стёсанным, вы́струганным *с чего-л.*; *бүрәндән ~ган йомычка* ще́пка, вы́струганная с де́рева

юныш|у 1. *взаимно-совм. от* **юну**; помога́ть/помо́чь теса́ть, строга́ть; *балтачыга бүрәнә ~у* помога́ть пло́тнику обтёсывать бревно́ 2. *разг.* занима́ться стёсыванием, обтёсыванием, выстру́гиванием и т. п.; *~ып утыра* сиди́т и занима́ется выстру́гиванием

юн|ь I *сущ.* 1. *с указ. мест.* сторона́, направле́ние (*движения*); *бу юньгә* в э́ту сто́рону; *теге юньгә* в ту сто́рону 2. поря́док, испра́вность (*во внешнем виде*); поря́дочность, прили́чие (*в поведении*); осмы́сленность, целесообра́зность (*в движении, деятельности*); *бүлмәнең юне* испра́вность ко́мнаты; *кешенең юне* поря́дочность челове́ка; *эшенең юне юк* нет то́лку (целесообра́зности) в его́ рабо́те 3. толк; результа́т; *юнь чыгамы бу эштән?* есть ли толк от э́той рабо́ты? 4. *перен.* материа́льная возмо́жность (*деньги и т. п.*); *түләргә юнь юк* нет возмо́жности плати́ть; *(Алла) җан биргәнгә юнь бирә* (*посл.*) (бог) е́сли дал ду́шу, то даёт и возмо́жность (жить) 5. *перен. диал.* си́ла, спосо́бность, мочь; *бу эшкә юнең җитәме?* хвата́ет (хва́тит) у тебя́ сил на э́ту рабо́ту? □ **юньгә кертү (китерү)** 1. приводи́ть/привести́ в поря́док, надлежа́щий (прили́чный) вид 2. нала́живать/нала́дить (*дела*) 3. убира́ть/убра́ть; украша́ть/укра́сить 4. выха́живать/вы́ходить (*больного, ребёнка и т. п.*) 5. воспи́тывать/воспита́ть; перевоспи́тывать/перевоспита́ть (*невоспитанного*); *тәки юньгә керттем бит* всё-таки я его́ перевоспита́л; **юньгә керү (килү)** 1. приводи́ться/привести́сь в поря́док (*о делах, о работе*); пойти́ на лад; нала́живаться/нала́диться 2. (*о чём-л., имеющем внешний вид*) заиме́ть прили́чный вид 3. (*о больном, слабом*) пойти́ на попра́вку; входи́ть/войти́ в си́лу 4. (*о человеке, личности*) взять в толк; *юләр юньгә килмәс* (*посл.*) ду́рень в толк неймёт; **юньгә салу** *см.* **юньгә кертү**; **юньгә түгел, түнгә** не к хоро́шему, не к добру́

юнь II *прил. редко* поря́дочный, толко́вый; *юнь кеше* поря́дочный челове́к

юнь III *прил. разг.* недорого́й, дешёвый; *см.* **җүн**; *юнь бәягә* за недорогу́ю це́ну, по дешёвке

юньләнү *неперех. см.* **юньлеләнү**

юньләп *нареч.* 1. то́лком; *~ кенә сөйлә!* говори́ то́лком 2. учти́во, прили́чно; *~ кылану* вести́ себя́ прили́чно 3. хорошо́нько; как сле́дует; *~ белмәү* как сле́дует не знать; *~ ишетмәү* хорошо́нько не рассы́шать

юньле *прил.* 1. толко́вый; де́льный; поле́зный; *~ белгеч* де́льный специали́ст; *~ киңәш* толко́вый сове́т; *~ фикер* поле́зная мысль 2. поря́дочный, воспи́танный; *~ кешедән ~ сүз чыга* (*посл.*) от поря́дочного челове́ка услы́шишь и де́льное сло́во 3. прили́чный, вполне́ хоро́ший, неплохо́й; *~ өй* прили́чный дом; *~ ризык* вполне́ хоро́шая пи́ща; *~ эш* неплоха́я рабо́та; прили́чное ме́сто рабо́ты || *нареч.* толко́во, с то́лком, де́льно; прили́чно; учти́во; *~ сөйлә* говори́ то́лком; *~ кылан!* веди́ себя́ прили́чно □ **~гә түгел** не к добру́

юньле-башлы *прил.* 1. (*более или менее*) приго́дный, поле́зный, толко́вый; *юньле-башлы план* бо́лее и́ли ме́нее толко́вый план; *юньле-башлы җавап* бо́лее и́ли ме́нее толко́вый отве́т 2. (*более или менее*) прили́чный; *юньле-башлы кием* бо́лее и́ли ме́нее прили́чная оде́жда || *нареч.*

1. бóлее и́ли мéнее толкóво 2. бóлее и́ли мéнее прили́чно

юньлелэн|ү *неперех.* 1. улучша́ться, устра́иваться (*о делах*), нала́живаться/нала́диться || улучше́ние, нала́живание 2. станови́ться/стать толко́вым, де́льным; поря́дочным, воспи́танным; *~гэн инде ул* он уже́ стал воспи́танным

юньлеле|к *сущ.* 1. толк; толкóвость, дéльность; *~ге бар* толк в нём есть 2. поря́дочность, воспи́танность; прили́чие; *~к мисалы* приме́р поря́дочности

юньсез *прил.* 1. бестолко́вый; дура́цкий; идио́тский; *~ киңәш* бестолко́вый сове́т 2. 1) бестолко́вый, неуме́лый, беспóмощный, неподгото́вленный (*о человеке*) 2) как руга́тельное сло́во: дрянно́й, недоде́ланный, непутёвый 3. неприли́чный (*о слове, выходке*) 4. злой, злóбный (*человек*) || *редко* бестолко́во; *~ эшләнгән* сде́лано бестолко́во

юньсезлек *сущ.* 1. бестолко́вость; беспóмощность; *~тән чыккан бәла* беда́, происше́дшая из-за бестолко́вости 2. неприли́чие, невоспи́танность; неучти́вость, гру́бость; *сәлам кайтармау* — *~* не отвеча́ть на приве́тствие — невоспи́танность 3. 1) разгильдя́йство; головотя́пство; безобра́зие 2) бестолко́вое и́ли неприли́чное де́ло, вы́ходка, сло́во и т. п. □ **~ эшләү (кылу)** 1. соверша́ть/соверши́ть бестолко́вое и́ли неприли́чное де́ло 2. проявля́ть/прояви́ть разгильдя́йство, головотя́пство

юньсезләндер|ү *понуд. от* **юньсезләнү**; *~мә шуны* не позволя́й ему́ безобра́зничать

юньсезлән|ү *неперех.* 1. де́латься/сде́латься бестолко́вым, разну́зданным; опуска́ться/опусти́ться (*в перен. знач.*) 2. проявля́ть/прояви́ть бестолко́вость и́ли разну́зданность, безобра́зничать; *~еп йөри* всё вре́мя безобра́зничает 3. теря́ть/потеря́ть вид || поте́ря ви́да (лица́, поря́дка); *эшләр ~де* дела́ потеря́ли надлежа́щий поря́док

юньчел *прил. разг.* рачи́тельный, хозя́йственный; *ил терәге — яучыл ир белән ~ хатын* (*посл.*) опóра страны́ — вои́нственный муж и хозя́йственная жена́

юньчеллек *сущ. разг.* рачи́тельность, хозя́йственность

юра *сущ.* юра́ (*геологическая эпоха*) || ю́рский; *~ чоры* ю́рская эпóха; *~ катламнары* ю́рские отложе́ния

юрал|у *страд. от* **юрау**; толкова́ться, объясня́ться; *төштә кар күрү яхшылыкка ~а* ви́деть снег во сне толку́ется как дóброе зна́мение

юралыш *сущ.* толкова́ние, объясне́ние, разъясне́ние (*какого-л. слова, явления*); *мәкальнең ~ы* толкова́ние посло́вицы; *бу күренеш төрлечә ~ таба* э́то явле́ние нахóдит разли́чное объясне́ние

юрамал *нареч. см.* **юрамалый** || *сущ. уст.* толкова́ние, разъясне́ние (*сна, приметы*)

юрамалга *нареч. см.* **юрамалый**; *~ әйтәм* говорю́ не всерьёз

юрамалый *нареч.* 1. не всерьёз; несерьёзно; в шу́тку 2. *см.* **юри** 3. *диал.* предположи́тельно, гипотети́чески

юрамыш *сущ.* 1. предсказа́ние на осно́ве толкова́ния приме́ты (*сна и т. п.*); *~ың юш килсен* пусть твоё предсказа́ние сбу́дется 2. дога́дка 3. пожела́ние (*в изысканных выражениях*)

юран|у *неперех.* гада́ть, де́лать разли́чные предположе́ния; *~ып юрау тапмадым* гадáл, но не догадáлся

юрату *понуд. от* **юрау**; *төш ~* попроси́ть истолкова́ть сон

юратучы *сущ.* **(төш ~)** челове́к, обраща́ющийся к толкова́телю снов

юра́|у I *сущ.* предсказа́ние; *~вың юш килсен!* пусть твоё предсказа́ние сбу́дется!

юра́|у II *неперех.* 1. предска́зывать/предсказа́ть; предвеща́ть, гада́ть || предска́зывание, гада́ние; предвеща́ние (*по приметам*); *фажига ~у* предска́зывать недóброе (*на основе данной приметы*) 2. *перех.* толкова́ть || толкова́ние (сна) 3. *уст.* предназнача́ть, определя́ть; предопредели́ть || предназначе́ние, предопредéление, определе́ние; *аны авыр эшкә ~дылар* его́ определи́ли на тяжёлую рабóту 4. прóчить, предска́зывать || предска́зывание (*хорошего будущего, успехов и т. п.*) 5. пожела́ть || пожела́ние (*успехов*)

юраулы *прил.* гада́тельный; гипотети́ческий; *~ фикер* гада́тельная мысль || *нареч.* гада́тельно; *бу фараз бик ~ әйтелгән* э́то предположе́ние вы́сказано весьмá гада́тельно

юраунамә *сущ. см.* **тәгъбирнамә**; *~ карау* смотре́ть в сóнник

юраучы *сущ.* толкова́тель, предсказа́тель; *төшләр ~* толкова́тель снов

юрга *сущ.* 1. ло́шадь-инохóдец; *~сына күрә дугасы* (*посл.*) какóв инохóдец, такова́ и дугá; по Сéньке и ша́пка 2. *уст.* и́ноходь; *атны ~сына карап алалар* ло́шадь покупа́ют, испыта́в (прове́рив) её ход (шаг) 3. *перен. разг.* нетерпели́вый, непосéдливый челове́к; лету́н; вьюн, верту́н || *прил.* 1. бегу́щий (обладáющий) и́ноходью (*о лошади*) 2. *перен.* игри́вый (*и быстрый в движениях*); вертля́вый; *~ хатын* вертля́вая же́нщина 3. *перен.* трусли́вый и непосéдливый

юргалату *понуд. от* **юргала́у**

юргала́|у *неперех.* 1. бежа́ть и́ноходью; *~ган атлар —асыл затлар* (*песня*) ло́шади-инохóдцы (*бегущие иноходью*) — благорóдные существа́ 2. (*о человеке*) семени́ть, труси́ть, идти́ ме́лкими шажка́ми, бы́стро перебира́ть нога́ми; *~п йөрү* идти́ бы́стрыми ме́лкими шажка́ми 3. *перен.* бéгать зря; бéгать туда́ и сюда́ (*без повода или без результатов*); *нәрсә ~п йөрисең?* чего́ бéгаешь зря? 4. *перен. ирон.* юли́ть; подли́зываться

юргалаш *сущ.* беготня́, суетли́вое хожде́ние

юргалы *прил.* с инохóдцем; име́ющий инохóдца; *~ белән юлдаш булма, наданга нәдим булма* (*посл.*) не будь попу́тчиком всáднику на инохóдце (*он может ехать целый день, что на обычной лошади почти невозможно*), не будь собесéдником невéжде

юрган *сущ.* стёганое одея́ло; *~ ябыну* накрыва́ться стёганым одея́лом □ **~ аслыгы** пододея́льник ◊ **~ыңа карап аяк сузу** протя́гивать нóжки по одёжке (*букв.* по одея́лу)

юрганлы *прил.* со стёганым одея́лом; име́ющий стёганое одея́ло

юрганлык *сущ.* материа́л для шитья́ одея́ла || *прил.* предназна́ченный для изготовле́ния (*о ткани*) и́ли приобрете́ния (*о деньгах*) стёганого одея́ла

юргáнча *сущ. диал. см.* **юрганлык**

юрганчык *сущ. уменьш. от* **юрган** одея́льце, ма́ленькое стёганое одея́ло

юри *нареч.* 1. умы́шленно; *юри шулай эшләү* умы́шленно де́лать так 2. нарочи́то, нарóчно; *юри үртәү* нарóчно дразни́ть 3. в шу́тку; *чынлапмы, юриме?* всерьёз и́ли в шу́тку? □ **юри генә** в шу́точку; **юри кылану** притворя́ться

юри́дик *прил. в разн. знач.* юриди́ческий; *~ гыйлем* юриди́ческое образова́ние; *~ факультет* юриди́ческий факульте́т; *~ документ* юриди́ческий докуме́нт || *нареч.*

юриди́чески; ~ *хаклы* юриди́чески прав □ ~ **зат** юриди́ческое лицо́ (*человек или организация, выступающая как носитель определённых прав и обязанностей*)

юри-марый *нареч. разг.* шутя́, не всерьёз; *юри-марый кӧрәшү* боро́ться шутя́

юрисди́кция *сущ.* юрисди́кция, пра́во производи́ть суд

юриско́нсульт *сущ.* юриско́нсульт (*знаток и защитник прав и обязанностей юридического лица*)

юрист *сущ.* юри́ст || юриди́ческий; *~лар мәктәбе* шко́ла юри́стов, юриди́ческая шко́ла

юристла́рча *нареч.* юриди́чески, по-юриди́чески; как юри́ст; *~ фикер йӧрткәндә* е́сли рассужда́ть юриди́чески

юристлык *сущ.* юриди́ческая пра́ктика; заня́тие, профе́ссия юри́ста; *~ белән шөгыльләнү* занима́ться юриди́ческой пра́ктикой; *~та йӧрү* ходи́ть в юри́стах; *~ка уку* учи́ться на юри́ста

юртак *сущ.* и *прил.* рыса́к/рыси́стый

юртакл|а́у *неперех.* бе́гать, бежа́ть || бег ры́сью, рысцо́й; рыси́ть; *ә ат ~ый бирә* а ло́шадь бежи́т себе́ рысцо́й

юртан *прил. диал.* **1.** пры́ткий; непосе́дливый; *~ кеше* пры́ткий челове́к; *~ карт* непосе́дливый стари́к **2.** *перен.* хи́трый, виля́ющий, непрямо́й (*в ответах*) **3.** непостоя́нный; не заслу́живающий дове́рия (*из-за непостоянства*)

юртанл|а́у *неперех. диал.* **1.** бежа́ть зигза́гами, уви́ливая (*от преследуемого*) **2.** виля́ть, уви́ливать || виля́ние, уви́ливание (*от ответственности, от прямого ответа*); юли́ть; *юк инде, син ~ама* нет уж, ты не виля́й

юртанлык *сущ.* пры́ткость, прыть, прово́рность (*в беге, в обслуживании*)

юрттыр|у *понуд. от* **юырту** **1.** заста́вить бе́гать, пуска́ть/пусти́ть ме́лкой ры́сью; *атын ~у* пусти́ть коня́ ме́лкой ры́сью **2.** легко́, лего́нько бежа́ть, рыси́ть; трусить (*рысью*); *~а гына* так и бежи́т рысцо́й (рыси́т)

юрту *неперех. разг. см.* **юырту**

юртыш *сущ.* **1.** рысь, рысца́, аллю́р (*лошади*); *~ы матур* рысь её (*лошади*) краси́ва **2.** *разг.* рыси́стая ло́шадь (*непородистая*) **3.** *перен. пренебр.* 1) шату́н, рыску́н; броди́га; лету́н 2) голь перека́тная || *прил. см.* **юртышлы**; *~ ат* рыси́стая ло́шадь

юртышл|а́у *неперех.* **1.** трю́хать (*о лошади*); *юртмый, ә ~ый гына* не рыси́т, а трю́хает **2.** переходи́ть/перейти́ на рысь; *~ый инде* уже́ перехо́дит на рысь

юртышлы *прил.* рыси́стый (*о лошади*); *~ бия* рыси́стая кобы́ла

юрык *сущ. диал.* **1.** *см.* **юсык** **2.** *ист.* обще́ственная систе́ма, режи́м; *~ белән тугел, ә боерык белән* (*погов.*) не систе́мой управле́ния, а прика́зом

юсти́ция *сущ.* юсти́ция; правосу́дие; *~ органнары* о́рганы юсти́ции; *~ гыйлеме* нау́ка юсти́ции, юриспруде́нция

юсы *диал. союз с мест. указ.* раз; *бер юсы* оди́н раз

юсы|к *сущ.* **1.** *ист.* 1) предписа́ние (*относительно поведения*); пра́вила поведе́ния; *ал ~к* пра́вила поведе́ния во дворце́ (*правителя*); *кара ~к* пра́вила поведе́ния среди́ просто́го наро́да 2) уста́в, зако́н; положе́ние 3) церемониа́л; *хан кутәру (сайлау) ~гы* церемониа́л подня́тия (*т.е. выборов*) ха́на **2.** *диал.* поря́док, форма́льности; *~гы шундый* тако́в уж поря́док; так поло́жено; *ясалмаган ~кка кысылма* в чужо́й монасты́рь со свои́м уста́вом не лезь (*букв.* без прика́за не вме́шивайся в установленный поря́док) **3.** *диал.* (**үз ~гы**) свой ход, свой поря́док; *үз ~гы белән* свои́м поря́дком, свои́м хо́дом, без вмеша́тельства со стороны́ || *прил. диал.* поря́дочный, усто́йчивый; ве́жливый; *~к кеше аякка карамас, йӧзгә карар* (*посл.*) поря́дочный челове́к смо́трит чужо́му не в но́ги, а в лицо́

юсыкка *нареч. диал.* **1.** форма́льно, сле́дуя официа́льному поря́дку (предписа́нию); *~ йӧрү* ходи́ть ра́ди форма́льности (*следуя предписанию*) **2.** педанти́чно; *~ тикшеру* проверя́ть педанти́чно, соблюда́я все форма́льности

юсыклы *прил. диал.* **1.** соверша́емый по пра́вилам, по поря́дку, в соответствии с уста́вом (*предписаниям, законам*); *~ туй* сва́дьба по пра́вилам **2.** *см.* **юсынлы**

юсыксыз *прил. диал.* **1.** не по пра́вилам, беззако́нный **2.** *см.* **юсынсыз** || *нареч.* беззако́нно, незако́нно

юсыкчыл *прил.* педанти́чный, букваль но сле́дующий поря́дку

юсык-юрык *сущ. собир. ист.* вся́кие (официа́льные) предписа́ния; ритуа́л, церемониа́л

юсын *сущ. диал.* **1.** *см.* **юсык** 1; *юлчыга сусын бирү — ~!* (*погов.*) подава́ть пу́тнику питьё — (обяза́тельный) зако́н **2.** воспи́танность, зна́ние пра́вил прили́чия, ве́жливость

юсынлы *прил. диал.* воспи́танный, учти́вый; ве́жливый; зна́ющий пра́вила прили́чия; *~ кунакны югары утырт* (*посл.*) воспи́танного го́стя сажа́й повы́ше (*т.е. на виду*)

юсынсыз *прил. диал.* невоспи́танный, гру́бый, бесцеремо́нный в обраще́нии; неве́жливый || *нареч. диал.* невоспи́танно; бесцеремо́нно, неве́жливо; *~ кылану* вести́ себя́ неве́жливо (бесцеремо́нно)

ютәл *сущ.* ка́шель (*как болезнь*) □ **~ тоту** до́лго ка́шлять (*в приступе болезни*) || при́ступ ка́шля; *~ чире (сырхавы, хастасы)* туберкулёз, чахо́тка

ютәлләт|ү **1.** *понуд. от* **ютәлләү**; вызыва́ть/вы́звать ка́шель; приводи́ть, привести́ к ка́шлю; *суык су ~ә* студёная вода́ вызыва́ет ка́шель (приво́дит к ка́шлю) **2.** *безл.* зака́шляться; *туганда бик тиз ~ә* в пыли́ бы́стро зака́шляешься

ютәлләү *неперех.* ка́шлять (*постоянно или приступами*) || ка́шель; *~гән тавыш ишетелде* послы́шались зву́ки ка́шля □ **~п авыру** боле́знь с ка́шлем

ютәлле *прил.* с ка́шлем; сопровожда́емый ка́шлем; *~ авыру* боле́знь с ка́шлем

ютәлсез *прил.* без ка́шля, не име́ющий ка́шля; *~ авырулар* боле́зни без ка́шля || *нареч.* без ка́шля; *~ үзмый* без ка́шля не прохо́дит (*о болезни*)

ю|у *перех.* **1.** мыть, промыва́ть/промы́ть, вымыва́ть/вы́мыть || мытьё, промыва́ние; *идән юу* мыть полы́; *савыт-саба юу* вы́мыть посу́ду **2.** смыва́ть/смыть || смыва́ние (*чаще перен.*); *гөнаһыңны юу* смыва́ть грехи́ (вину́) **3.** умыва́ть/умы́ть || умыва́ние; *кул юу* умыва́ть ру́ки; *бит юу* умы́ть лицо́ **4.** стира́ть/вы́стирать || сти́рка; *кер юу* стира́ть бельё **5.** *перен.* обмыва́ть/обмы́ть || обмыва́ние □ **юу машинасы (җайланмасы)** мо́ечная и́ли стира́льная маши́на; **юу цехы** мо́ечный цех; **юып чистарту (тазарту, сафландыру, пакьләндерү)** обмыва́ть/обмы́ть

юучы *сущ.* **1.** мо́йщик; *йон ~* мо́йщик ше́рсти; *идән ~* мо́йщик поло́в; поломо́йка; *савыт-саба ~* посудомо́йщик **2.** (**кер ~**) пра́чка

юха *этногр.* **1.** юха́ (*мифологический образ женщины-оборотня, в которую превращается дракон тысячелетнего возраста*); *юханың кендеге булмас*

(*посл.*) у юхи́ не быва́ет пупа́ **2.** *перен.* подли́за (*красивая и угодливая женщина, которая вертит мужчинами, умело заставляет служить своим интересам*) **3.** *перен.* двули́чный челове́к; подхали́м, блюдоли́з || *прил.* **1.** уго́дливый, льсти́вый; *юха хатын* уго́дливая же́нщина; *юха тел* льсти́вый язы́к **2.** двуру́шнический ◻ **юха елан** *см.* **юха**

юхаландыру *понуд. от* **юхалану**; позволя́ть/позво́лить ла́ститься

юхалан|у *неперех.* **1.** (*коварно*) подли́зываться, ла́ститься, ласка́ться (*вымогая, выпрашивая что-л. — о женщине*) || подли́зывание; *кайчак ~ырга, кайчак юмаланырга тотына* начина́ет то подли́зываться, то ла́ститься **2.** двуру́шничать, двули́чничать || двуру́шничество

юхалык *сущ.* двули́чность, двули́чие; двуру́шничество; двули́чное уго́дничество; *юньсез ~ны да булдыра алмас* (*посл.*) бестолко́вый не суме́ет и двули́чным быть

юш *предик.* подходя́щ, подхо́дит; соответствует; *бу мәкаль заманга юш* э́та посло́вица соответствует (на́шему) вре́мени ◻ **юш килү (булу) 1.** сбыва́ться/сбы́ться (*о предсказании, гадании, толковании примет, сна и т. п.*); *юравы юш килде* его́ предсказа́ние сбыло́сь **2.** подходи́ть, соответствовать (*случаю, назначению*); быть как раз ко вре́мени, быть кста́ти; *килүең юш әле* твой прие́зд оказа́лся как раз кста́ти

юша *сущ. зоол.* **1.** молодо́й лось (*лось до двух лет*) **2.** *диал.* се́верный оле́нь

юшан *сущ. бот.* емша́н (*степная трава*)

юшату *перех.* (подо́лгу) корми́ть скот в по́ле; дать нагуля́ть жи́ру; дать отдохну́ть (*лошади*) в по́ле

юша|у *перех.* **1.** пережёвывать || пережёвывание (*о жвачных животных*); *торлаксыз мал мизгелсез утлар да мизгелсез ~р* (*посл.*) скоти́на без приста́нища не во́время пасётся и не во́время пережёвывает **2.** отдыха́ть, дрема́ть || о́тдых, дрёма (*лошади*)

юшкә *сущ.* **1.** вью́шка, задви́жка (*о дымоходе*); *мич ~се* вью́шка печи́ **2.** *тех.* задви́жка в трубе́, кана́ле и т. п.

юшкын *сущ.* **1.** на́кипь (*прилипшая к стенкам сосуда*); *калын ~* то́лстая на́кипь **2.** ти́на, ил, оса́док, муть; *суның ~ы күп* в воде́ мно́го оса́дка **3.** *прям., перен.* нано́с, оса́док; *күңелдәге ~* оса́док в душе́ || *прил. диал.* бурли́вый, кипу́чий, клубя́щийся (*о мутной воде*); *~ елга* му́тная и бу́рная река́ ◻ **~ утыру 1.** накипа́ть (*на стенках сосуда*) **2.** отлага́ться/отложи́ться; оса́живаться (*о наносах, осадках*) **3.** *перен.* **(йөрәккә ~)** оставля́ть тяжёлый, тя́гостный след (*в душе*); зачерстве́ть (*от грубостей людей, от беспощадности судьбы*)

юшкынландыру *понуд. от* **юшкынлану**

юшкынлану *перех.* **1.** взбаламу́титься, мутне́ть; станови́ться/стать отлага́ющим со́ли (*о воде*) **2.** бурли́ть, кипе́ть (*мутными струями — о воде*); забурли́ть, закипе́ть (*мутными клубами*)

юшкынлы *прил.* **1.** засо́ленный, немя́гкий; отлага́ющий со́ли (*о воде*) **2.** взбаламу́ченный, му́тный; замутнённый; *см. тж.* **куерык 3.** *редко* бурля́щий, кипя́щий (*мутными струями*); *~ елга* бурля́щая му́тная река́

юшкынсыз *прил.* незасо́ленный, мя́гкий (*о воде*)

юык *прил. диал.* **1.** бли́зкий (*о родственных отношениях*); *юыклыкка ~, ара гына суык* (*посл.*) бли́зко-то (оно́) бли́зко, но отноше́ния холо́дные **2.** сро́дный

юыклык *сущ. диал.* **1.** ро́дственная бли́зость **2.** сродство́

юылдыру *перех.* **1.** вымыва́ть/вы́мыть || вымыва́ние; *туфрактан тозларны ~* вымыва́ние соле́й из по́чвы **2.** размыва́ть/размы́ть || размыва́ние; размы́в; *ярларны ~* размыва́ть берега́

юыл|у *страд.-возвр. от* **юу**; **1.** мы́ться, стира́ться; *~маган кер* невы́стиранное бельё **2.** вымыва́ться/вы́мыться || вымыва́ние; смыва́ться/смы́ться || смыва́ние (*само собой*) с пове́рхности и́ли из соста́ва; *буявы ~ган* покра́ска смы́та; со смы́той кра́ской **3.** *редко* размыва́ться/размы́ться (*о берегах и т. п.*)

юылулы *прил. редко* **1.** вы́мытый (*о полях*) **2.** вы́стиранный (*о белье*)

юынгыч *сущ.* рукомо́йник, умыва́льник; *~та юыну* умыва́ться из умыва́льника, под умыва́льником

юындырыл|у *страд. от* **юындыру**; быть вы́мытым, умы́тым (*кем-л.*); *~ган бала* умы́тый ребёнок

юындырышу *взаимно-совм. от* **юындыру**; помога́ть купа́ть, вы́мыть *кого-л.*

юындыр|у *понуд. от* **юыну 1.** заставля́ть/заста́вить умыва́ться **2.** *перех.* купа́ть (*ребёнка и т. п.*); *баланы ~у* купа́ть ребёнка

юынты *сущ.* помо́и, ополо́ски; *кухня ~лары* ку́хонные помо́и

юынтык *прил.* помо́йный (*о воде*); *~ су* помо́йная вода́ *сущ.* ме́сто для выплива́ния помо́ев

юын|у *возвр. от* **юу**: умыва́ться/умы́ться || умыва́ние (*себя*); вы́мыться; *кошчыгым тазарынды, ~ды* пти́чка моя́ почи́стилась, умы́лась

юырттыр|у *понуд. от* **юырту 1.** пуска́ть/пусти́ть (*лошадь*) ры́сью; *атыңны ~!* погоня́й ло́шадь (ры́сью) **2.** *разг. см.* **юырту** 2

юырт|у *неперех.* **1.** бе́гать/бежа́ть || бег ры́сью **2.** труси́ть, бежа́ть || бег трусцо́й; *ат жиңелчә ~ып барды* ло́шадь бежа́ла лёгкой трусцо́й **3.** *перен.* ходи́ть || ходьба́ бы́стрыми шажка́ми, трусцо́й; *~ып атлый* хо́дит бы́стрыми шага́ми

юыштыр|у *многокр. от* **юу**; пости́рывать, мыть (*изредка*), иногда́ мыть, стира́ть; *ул инде идән ~а* он уже́ иногда́ и полы́ мо́ет

юыш|у *взаимно-совм. от* **юу**; помога́ть мыть/вы́мыть и́ли стира́ть; *идән ~у* помога́ть мыть полы́; *кер ~у* помога́ть стира́ть бельё; *кер ~саң иде* помогла́ бы вы́стирать бельё

Я

я I *межд.* **1.** (йә, йәгез, йәгезче) ну, ну́-ка, дава́й(те), ну дава́йте; *я, утырыгыз инде* дава́йте уж ся́дьте; *ягез, тиз генә укып чыгыйк* а ну, дава́йте, бы́стренько прочтём **2.** *употр. в составе вопр. предл.* ну, ну что; *я, әйт, нишлибез инде синең белән?* ну, скажи́, что нам де́лать с тобо́й; *я, үз файдаңа нәрсә әйтә аласың?* ну, что смо́жешь сказа́ть в свою́ по́льзу? **3.** *усилит. частица* ну; *я, нинди тормыш инде бу: ни тыныч лык, ни шатлык!* ну, что э́то за жизнь: ни поко́я, ни ра́дости! □ **я инде, я сәнә** ну ла́дно, да уж ла́дно; **я әле** ну́-ка

я II *союз разделит.* и́ли, и́ли же, ли́бо; *аның я укытучы, я врач буласы килә* он хо́чет стать и́ли учи́телем, и́ли врачо́м; *я үләсең, я каласың* ли́бо пан, ли́бо пропа́л

я (йа) *межд. со словами* **алла, хода(й), илаһи, раббе(м)** *выражает удивление, восхищение, недовольство, ропот, мольбу, а также употребляется в риторическом вопросе* о, ах, эх; *я ходай, мондагы матурлык!* о бо́же, кака́я здесь красота́! *я раббем, нигә мин шундый бәхетсез?* о бо́же, почему́ я тако́й несчастли́вый?

ябага *сущ.* вы́ленявшая шерсть; ли́нька (*весенняя*) □ **~ кою 1.** линя́ть || ли́нька (*животных*) **2.** *перен.* поплясáть (*разок*); **~ тай** жеребёнок-стригунóк; стригу́н, одноле́ток

ябалак *сущ. зоол.* **1.** сова́ || сови́ный; *~ канаты* сови́ное крыло́ **2.** *перен.* чурба́н с глаза́ми (*о невнимательном, неумелом человеке*); *ул аңгыра ~ нәрсә белә соң?* да что он зна́ет, э́тот чурба́н с глаза́ми □ **~ баласы** совёнок ◊ **~ кар** снег хло́пьями; **~ күз** *см.* **акай күз**; **~ шулпасы** *прост.* во́дка, алкого́льный напи́ток

ябалакбаш *сущ. зоол. см.* **ябалакчык** 1

ябалакчы|к *сущ. зоол.* **1.** со́вка **2.** со́вка, ночни́ца; *кәбестә ~гы* капу́стная со́вка (*вид бабочки*)

ябалдаш *сущ.* **1.** кро́на; *алма агачының ~ы* кро́на я́блони; *~ка кису* обреза́ть для образова́ния кро́ны || *прил.* ни́зкий, призе́мистый, корена́стый; *~ агач* ни́зкое, но ветви́стое де́рево; *~ өй* ни́зкий, но большо́й дом

ябалдашлану *неперех.* образо́вывать/образова́ть кро́ну || образова́ние, формирова́ние кро́ны

ябалдашлы *прил.* име́ющий кро́ну, с кро́ной; *куе ~ юкә* ли́па с густо́й кро́ной

яб|у I *перех.* **1.** 1) закрыва́ть/закры́ть, затворя́ть/затвори́ть, притворя́ть/притвори́ть, прикрыва́ть/прикры́ть || закрыва́ние (*окна, ворот и т. п.*); *ишекне кемдер бик каты итеп япты* кто́-то о́чень пло́тно закры́л дверь 2) запа́хивать/запахну́ть, захло́пывать/захло́пнуть; *пианино капкачын шап итеп ябу* захло́пнуть кры́шку пиани́но **2.** крыть, покрыва́ть/покры́ть || покры́тие; *шифер белән ябу* крыть ши́ферем; *өй түбәсен калай белән ябу* покры́ть кры́шу до́ма желе́зом **3.** покрыва́ть/покры́ть, накрыва́ть/накры́ть, наки́дывать/наки́нуть, набра́сывать/набро́сить || покры́тие, накры́тие, наки́дывание, набро́ска; *җилкәгә шәл ябу* набро́сить на пле́чи шаль; *бала өстенә юрган ябу* накры́ть ребёнка одея́лом; *иген өстенә брезент ябу* набро́сить брезе́нт на хлеб; *караватка җәймә ябу* наки́нуть на крова́ть покрыва́ло **4.** 1) закрыва́ть/закры́ть, скла́дывать/сложи́ть *что-л.*; *китапны ябу* закры́ть кни́гу; *зонтны ябып кую* сложи́ть зонт 2) закрыва́ть/закры́ть, сомкну́ть (*рот, створчатые предметы*); *ул тиз генә авызын япты* он мгнове́нно закры́л рот; *тәрәзә капкачларын ябу* закры́ть ство́рки ста́вней **5.** запира́ть/запере́ть, загоня́ть/загна́ть || заго́н; *сарыкларны сарайга ябу* загна́ть ове́ц в сара́й; *куяннарны читлеккә ябу* запере́ть кро́ликов в кле́тку **6.** помеща́ть/помести́ть, заключа́ть/заключи́ть || заключе́ние; *төрмәгә ябу* заключа́ть в тюрьму́; *кошны читлеккә ябу* помести́ть пти́цу в кле́тку **7.** 1) закрыва́ть/закры́ть, перекрыва́ть/перекры́ть (*газ, воду*) 2) закрыва́ть/закры́ть, перекрыва́ть/перекры́ть, прекраща́ть/прекрати́ть до́ступ *чего-л.* || закры́тие, перекры́тие, прекраще́ние; *чикне ябу* закры́ть грани́цу; *кичүгә юлны ябу* закры́ть доро́гу к перепра́ве; перекры́ть до́ступ к перепра́ве **8.** 1) закрыва́ть/закры́ть, прикрыва́ть/прикры́ть, ликвиди́ровать, прерва́ть (*деятельность чего-л.*) || закры́тие, прикры́тие, ликвида́ция (*фабрики, мастерской, буровой и т. п.*) 2) закрыва́ть/закры́ть; зако́нчить, заверша́ть/заверши́ть || закры́тие (*собрания, заседания, конференции и т. п.*) 3) закрыва́ть/закры́ть, подыто́живать/подыто́жить || закры́тие, подыто́живание; *акча ведомостен ябу* закры́ть де́нежную ве́домость; *нарядны ябу* закры́ть наря́д **9.** закрыва́ть/закры́ть, накла́дывать/наложи́ть, накрыва́ть/накры́ть || закры́тие, накры́тие; *шешкә әрекмән яфрагын ябу* наложи́ть лопу́х на о́пухоль **10.** повя́зывать/повяза́ть; надева́ть/наде́ть; *алъяпкыч ябу* повяза́ть пере́дник **11.** *уст.* закрыва́ть/закры́ть; скрыва́ть/скрыть *что*; *йөзне ябып йөрү* ходи́ть, закры́в лицо́ (*паранджой*) **12.** *перен. разг.* припря́тывать /припря́тать, скрыва́ть/скрыть, присва́ивать/присво́ить; укра́сть || присва́ивание, кра́жа **13.** крыть, покры́ть, бить (*в картёжной игре*); *козырь тузын ябып булмый* нельзя́ крыть козырно́го туза́ **14.** *перен. разг.* припи́сывать/приписа́ть, возводи́ть/возвести́ (*напраслину*) ◊ **ябуда тоту 1.** держа́ть взаперти́ **2.** держа́ть в заключе́нии; **ябып калу** замя́ть (*дело*); **ябып кую 1.** (преднаме́ренно, кре́пко) накры́ть, запере́ть **2.** заключи́ть в тюрьму́

ябу II *сущ. см.* **япма** 1, 2

ябула́у *перех. диал.* покрыва́ть попо́ной (*коня*)

ябулы *прил.* **1.** кры́тый, име́ющий наве́с, кры́шу, с наве́сом, с кры́шей; *~ машина* кры́тая маши́на; *өсте ~ ындыр* кры́тый (*с навесом*) ток **2.** кры́тый, покры́тый, име́ющий покрыва́ло (попо́ну); *атның өсте ~* ло́шадь покры́та попо́ной **3.** *см.* **ябык** II

ябулык *сущ. см.* **япма** 2 || *прил.* предназна́ченный для изготовле́ния попо́ны и т. п.

ябучы *сущ.* тот, кто кро́ет, покрыва́ет; *түбә ~* кро́вельщик

ябыҥу худе́ть, похуде́ть, теря́ть в ве́се (*сильно*), та́ять, высыха́ть; со́хнуть, усыха́ть, тоща́ть; *көннән-көн ~у* худе́ть с ка́ждым днём □ **~ып бетү** исхуда́ть; **~ып китү** похуде́ть; стать худы́м, то́щим

ябыгышу *совм. от* **ябыгу** (*о многих*)

ябык I *прил.* худо́й, худоща́вый, сухо́й, сухоща́вый, исхуда́лый, жи́листый, поджа́рый, то́щий, костля́вый; сухопа́рый, отоща́лый; *~ кеше* худо́й (поджа́рый, худоща́вый) челове́к; *~ куллар* худы́е (жи́листые, исхуда́лые) ру́ки; *~ ат* то́щая ло́шадь □ **~ кына** ху́денький

ябык II *прил.* **1.** закры́тый, за́пертый; *~ ишек* закры́тая дверь **2.** кры́тый, закры́тый, име́ющий наве́с, кры́шу; *~ базар* кры́тый ры́нок; *~ машина* закры́тая маши́на **3.** *перен.* закры́тый; *~ утырыш* закры́тое заседа́ние; *~ конкурс* закры́тый ко́нкурс **4.** *мед.* закры́тый, вну́тренний; скры́тый; *~ сыну* закры́тый перело́м; *упкә авыруының ~ формасы* закры́тая фо́рма туберкулёза **5.** закры́тый, глухо́й; *~ яка* глухо́й воротни́к; *~ күлмәк* закры́тое пла́тье □ *~* **диңгез** закры́тое мо́ре; *~* **зона** запре́тная зо́на; *~* **иҗек** закры́тый слог; *~* **орлыклар** *бот.* покрытосеменны́е; *~* **туфли** закры́тые ту́фли; *~* **уку йорты** закры́тое учёбное заведе́ние; *~* **хат** закры́тое письмо́

ябыклы|к *сущ.* худоба́, худоща́вость, сухоща́вость, исхуда́лость; *кулларның ~гы* исхуда́лость рук; *баланың артык ~гы* си́льная худоба́ ребёнка

ябыктыр|у *перех.* **1.** истоща́ть/истощи́ть, де́лать, сде́лать то́щим, худы́м; *аны авыру ~ган* его́ истощи́ла боле́знь; он похуде́л от боле́зни **2.** *безл.* приходи́ться/прийти́сь похуде́ть; *юлда ~а* в доро́ге прихо́дится худе́ть

ябылмалы *прил.* **1.** закрыва́ющийся, име́ющий кры́шку, с кры́шкой; *~ чиләк* ведро́ с кры́шкой; *~ парта* па́рта с откидно́й кры́шкой **2.** складно́й; *~ пәке* складно́й но́жик

ябыл|у **1.** *страд.* закрыва́ться, быть за́пертым; *тәрәзәләр ~ган* о́кна закры́ты **2.** *возвр.* закрыва́ться/закры́ться; *кичкә таба күп кенә чәчәкләр ~а* мно́гие цветы́ к ве́черу закрыва́ются **3.** закрыва́ться/закры́ться, заживать/зажи́ть (*о ранах*) || закры́тие, закрыва́ние **4.** замыка́ться/замкну́ться; *түгәрәк ~ды* круг замкну́лся ◊ **~ып яту** **1.** сиде́ть в тюрьме́, быть в заключе́нии **2.** замкну́ться, жить за́мкнуто; **~ып яшәү** жить за́мкнуто

ябылучы *сущ.* аресто́ванный, заключённый; *~лар төркеме* гру́ппа заключённых

ябылыр-ябылмас *нареч.* полузакры́то, непло́тно закры́то

ябынгыч *сущ. разг.* **1.** то, чем укрыва́ются (*одеяло*) **2.** наки́дка, епанча́

ябыну *возвр. от* **ябу** I; накрыва́ться/накры́ться, закрыва́ться/закры́ться, укрыва́ться/укры́ться; *юрган ~* укры́ться одея́лом; *шәл ~* накрыва́ться ша́лью

ябынча *сущ.* наки́дка; *~ кадере яңгырда беленер* (*погов.*) цена́ наки́дки узна́ётся в дождь

ябыныш *совм. от* **ябыну** (*о многих*)

ябыру *перех. диал.* вали́ть (*траву, хлеба*) в одну́ сто́рону (*о ветре*)

ябырылма *сущ.* **1.** лави́на; *кар ~сы* сне́жная лави́на (*несущаяся с горы*) **2.** *перен.* лави́на (*людей, животных и т. п.*); *гаскәр ~сы* лави́на войск

ябырыл|у *неперех.* **1.** *прям., перен.* броса́ться/бро́ситься, кида́ться/ки́нуться, наки́дываться/наки́нуться, набра́сываться/набро́ситься; налета́ть/налете́ть *на кого-что* (*стремительно и во множестве, скопом*); *ашауга ~у* наки́нуться на еду́; *малайлар тупка ~дылар* ма́льчики набро́сились на мяч; *чыпчыклар бөртеккә ~дылар* воробьи́ налете́ли на зерно́; *эт колбасага ~ды* соба́ка набро́силась на колбасу́ **2.** броса́ться/бро́ситься, обру́шиваться/обру́шиться, наки́дываться/наки́нуться, нападать/напа́сть *на кого-л.* (*с упрёками, бранью, жалобами и т. п.*) **3.** *перен.* 1) (*стремительно, во множестве*) броса́ться/бро́ситься, кида́ться/ки́нуться, устремля́ться/устреми́ться, обру́шиваться/обру́шиться, хлы́нуть, нахлы́нуть, набра́сываться/набро́ситься, нападать/напа́сть || наше́ствие, нападе́ние ма́ссой; *халык платформага ~ды* наро́д хлы́нул на платфо́рму; *дошманга җәяуле гаскәр ~ды* на врага́ обру́шилась пехо́та 2) обру́шиваться/обру́шиться, нападать/напа́сть, неожи́данно свали́ться *на кого-л., что-л.*; *башка бәла ~ды* на го́лову обру́шилась беда́ □ **~ып килү** налета́ть, хлы́нуть пото́ком; идти́, дви́гаться це́лой вата́гой ◊ **~ып ашау** есть с жа́дностью; есть с поспе́шностью; **~ып килү** нападать стено́й, сплошно́й ма́ссой; **~ып төшү** набро́ситься, наки́нуться стреми́тельно во мно́жестве *на что-л.*

ябырылучан *прил. разг.* па́дкий *на что-л.*, скло́нный *к чему-л.*; *татлыга ~* па́дкий на сла́дкое

ябырылышу *совм. от* **ябырылу** (*о многих*)

ябышкак *прил.* **1.** прили́пчивый, ли́пкий, кле́йкий; це́пкий, вя́зкий; *~ кәгазь* кле́йкая бума́га; *~ балчык* вя́зкая гли́на **2.** *перен. разг.* прили́пчивый, привя́зчивый, навя́зчивый, назо́йливый, насты́рный, надое́дливый; *~ чебеннәр* прили́пчивые му́хи; *~ булу* быть навя́зчивым, надое́дливым **3.** *перен.* навя́зчивый, назо́йливый; неотсту́пный; *~ уйлар* навя́зчивые мы́сли; *~ көй* назо́йливая мело́дия || *сущ.* **1.** прилипа́ла, прилипа́ло **2.** *бот.* липу́чка

ябышкаклан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать прили́пчивым; ли́пким, кле́йким; *туфрак яңгырдан соң бик нык ~ган* земля́ по́сле дождя́ ста́ла о́чень ли́пкой **2.** *перен. разг.* быть, стать прили́пчивым, привя́зчивым, навя́зчивым, назо́йливым, насты́рным, надое́дливым

ябышкаклы|к *сущ. разг.* **1.** прили́пчивость, ли́пкость, кле́йкость **2.** *перен.* прили́пчивость, привя́зчивость, навя́зчивость, назо́йливость, насты́рность, надое́дливость; *кешенең ~гы үзеннән биздерә* назо́йливость челове́ка отта́лкивает от себя́

ябыштыргыч *сущ. разг.* пла́стырь

ябыштырту *понуд. от* **ябыштыру**

ябыштыр|у *перех.* **1.** кле́ить, прикле́ивать/прикле́ить, накле́ивать/накле́ить, прилепля́ть/прилепи́ть || накле́ивание, накле́йка, прикле́ивание, прикле́йка; *конвертка марка ~у* накле́ить ма́рку на конве́рт; *стенага рәсемнәр ~у* прикле́ить рису́нки на сте́нку **2.** закле́ивать/закле́ить; залепля́ть/залепи́ть || закле́йка (*щели, отверстия, прорези*); *кышка тәрәзәләрне ~у* закле́ить о́кна на́ зиму; *ярыкларны кәгазь белән ~у* закле́ить ще́ли бума́гой; *җәрәхәткә пластырь ~у* залепи́ть ра́ну пла́стырем **3.** скле́ивать/скле́ить, слепи́ть || скле́ивание; *катыргыларны ~ып тартма ясау* скле́ив карто́нки, сде́лать коро́бку; *дәфтәр битләрен ~у* скле́ить листы́ тетра́ди; *ватылган вазаны ~у* скле́ить разби́тую ва́зу **4.** *перен. разг.* прикле́ивать/прикле́ить, прилепля́ть/прилепи́ть, закрепля́ть/закрепи́ть *за кем-чем-л.* (*прозвище, название, какое-л. слово и т. п.*); *кушамат ~у* прикле́ить про́звище; *берничә вакыйга аңа «ялганчы» исемен ~ды* не́сколько собы́тий закрепи́ло за ним про́звище «обма́нщик» **5.** 1) *перен. прост.* залепля́ть/залепи́ть, влепля́ть/влепи́ть, припа́ивать/припая́ть (*наказание, выговор, обвинение и т. п.*); *каты шелтә ~у* влепи́ть стро́гий вы́говор; *өч ел төрмә ~у* припая́ть три го́да тюрьмы́ 2) *перен. прост.* залепля́ть/залепи́ть, влепля́ть/влепи́ть; *яңагына берне ~у* влепи́ть пощёчину ◊ **~ып алу (чыгару)** *этногр.* увести́ де́вушку без согла́сия её роди́телей

ябыштыручы *сущ. спец.* скле́йщик

ябыштырылу *страд. от* **ябыштыру**

ябыштырышу *взаимно-совм. от* **ябыштыру**

ябыш|у I *взаимно-совм. от* **ябу** I

ябыш|у II *неперех.* **1.** ли́пнуть, прилипа́ть/прили́пнуть; *идәннең буявы кипмәгән әле, бик ~а* кра́ска по́ла не вы́сохла ещё, си́льно прилипа́ет **2.** скле́иваться/скле́иться, слипа́ться/сли́пнуться, слепля́ться/слепи́ться ‖ скле́ивание; *киселгән икмәк кире ~мый (посл.)* отре́занный ломо́ть не скле́ишь **3.** 1) прилепля́ться/прилепи́ться; ли́пнуть, прилипа́ть/прили́пнуть; приставáть/приста́ть; *юеш күлмәк тәнгә ~ты* мо́крое пла́тье прили́пло к те́лу; *чәчләр маңгайга ~ты* во́лосы прили́пли ко лбу; *киемгә юеш яфраклар ~а* к оде́жде пристаю́т мо́крые ли́стья 2) прикле́иваться/прикле́иться, прилепля́ться/прилепи́ться; *обойлар яхшы ~ты* обо́и хорошо́ прикле́ились **4.** *перен. разг.* прикле́иваться/прикле́иться, закрепля́ться/закрепи́ться *за кем-л., чем-л.* (*обычно о прозвище, кличке и т. п.*) **5.** *перен. разг.* ли́пнуть, прилипа́ть/прили́пнуть, привя́зываться/привяза́ться к *кому-л.*; *балалар вожатыйга ~тылар, ул кая барса, шунда баралар* де́ти прили́пли к вожа́тому, куда́ он, туда́ и они́ **6.** схва́тываться/схвати́ться, хвата́ться, ухвати́ться, уцепи́ться, цепля́ться, зацепля́ться/зацепи́ться *за кого-что*; вцепля́ться/вцепи́ться *во что*; *чәчкә ~у* вцепи́ться в во́лосы; *кулга ~у* ухвати́ться за́ руку; *әнисенең күлмәк итәгенә ~у* вцепи́ться в подо́л ма́тери (*о ребёнке*) **7.** *прям., перен.* цепля́ться, хвата́ться, держа́ть *за что-л.*; *агач тамырларына ~ып тауга мену* цепля́ясь за ко́рни дере́вьев, поднима́ться в го́ру; *суга батучы саламга ~а (посл.)* утопа́ющий хвата́ется за соло́минку **8.** ухва́тываться/ухвати́ться, (горячо́) бра́ться/ взя́ться, принима́ться/приня́ться *за что-л.*; *зур теләк белән укырга ~у* с большо́й жела́нием приня́ться за учёбу; *авылга кайту белән йорт салырга ~ты* как то́лько прие́хал в дере́вню, взя́лся стро́ить дом **9.** *разг.* 1) напада́ть/напа́сть 2) хвата́ть, схва́тывать/ схвати́ть, брать/взять *за что-л.*; вцепля́ться/вцепи́ться *во что*; *бугазга ~у* брать за го́рло; *тагын килеп ~у* вцепи́ться опя́ть 3) *прост.* цепля́ться, прицепля́ться/ прицепи́ться, придира́ться/придра́ться; приставáть/ приста́ть ‖ прида́рка, приставáние; *~ты бит миңа, ничек тә ярап булмый* приста́л ко мне, ника́к не угоди́шь **10.** *перен. разг.* принима́ться/приня́ться, бра́ться/ взя́ться; вгрыза́ться/вгры́зться; *тормышка теш-тырнак белән ~у* вгры́зться в жизнь зуба́ми **11.** *перен. разг.* прилипа́ть/прили́пнуть; *китабына ~кан, аерып алып булмый* прили́п к свое́й кни́ге, ника́к не оторвёшь □ **~ып калу** сли́пнуться; **~ып тору 1.** ли́пнуть, прилипа́ть **2.** *перен.* быть в по́ру, подходи́ть (*об одежде*) ◊ **~ып чыгу** *этногр.* выходи́ть за́муж убе́гом; **~ып яту** прилипа́ть *к кому-чему*

ябышчан *прил. см.* **ябышкак**

ябышчанлык *сущ. см.* **ябышкаклык**

я|ву *неперех.* **1.** па́дать, лить, идти́, сы́пать, сы́паться (*об атмосферных осадках*); *юеш кар ява* идёт мо́крый снег; *далада да яңгырлар ява* и над сте́пью иду́т дожди́ **2.** 1) па́дать, лете́ть ту́чей, сплошно́й густо́й ма́ссой (*о пулях, снарядах и т. п.*); *шәһәр өстенә бомба ява* на го́род сплошно́й ма́ссой лета́т бо́мбы 2) *перен.* идти́, течь, посы́паться, сы́паться, собира́ться/собра́ться, поступа́ть во мно́жестве (*отовсюду со всех сторон*); *аңа акча явып кына тора* де́ньги так и теку́т к нему́; *докладчыга сораулар яуды* докла́дчика засы́пали вопро́сами

явыз *прил.* **1.** 1) злой, зло́бный, зловре́дный; *~ кешеләргә тап булу* наткну́ться на злых люде́й; *~ үги ана* зловре́дная ма́чеха 2) свире́пый, кровожа́дный, хи́щный, лю́тый (*о животных*); *~ бүре балалары* свире́пые волча́та **2.** зло́бный, гро́зный, закля́тый; *~ дошман* закля́тый враг **3.** злой, зло́стный; злонаме́ренный *книжн.*; *~ ният* зло́стное наме́рение; *~ уйлар килә башка* зло́стные мы́сли прихо́дят в го́лову **4.** злой, зло́бный, свире́пый, гне́вный, суро́вый (*взгляд, вид, нрав и т. п.*) **5.** злой, о́стрый, язви́тельный, ехи́дный (*язык, разговор и т. п.*); *~ телле хатын* о́страя на язы́к же́нщина **6.** *перен.* злой, недо́брый, суро́вый, чёрный; *~ көчләр* злы́е си́лы ‖ *сущ.* 1) злоде́й, злоумы́шленник; *~лар тиешле җәзаларын алдылар* злоде́и получи́ли до́лжную ка́ру 2) злоде́й, ше́льма, шельме́ц (*как бранное слово*); *әх син, ~, ништләдең?* ах ты, ше́льма, что ты наде́лал? ‖ *нареч.* зло, зло́бно; *~ елмаю* зло́бно улыба́ться; *~ гына карап алу* зло́бно взгляну́ть □ **~ ният белән** злонаме́ренно, зло́стно; **~ ниятле** злонаме́ренный; зловре́дный, зло́стный; **~ ниятлелек** злонаме́ренность; зловре́дность; **~ телле** злой (о́стрый) на язы́к; **~ның ~ы** зле́йший из зле́йших

явызландыру *понуд. от* **явызлану**

явызлан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать злым (*более злым, злобным, зловредным*); зли́ться, озлобля́ться/ озло́биться **2.** *в знач. нареч.* **явызланып** озло́бленно, со зло́стью

явызланышу *взаимно-совм. от* **явызлану**

явызла́рча *нареч.* злоде́йски, зве́рски; *~ мыскыл итү* издева́ться злоде́йски; *ул ~ утерелгән* он зве́рски уби́т

явызлашу *неперех. разг.* **1.** превраща́ться/преврати́ться в зло́бного челове́ка, станови́ться/стать зло́бным, озлобля́ться/озло́биться **2.** станови́ться/стать жесто́ким, ожесточа́ться/ожесточи́ться **3.** *см.* **дошманлашу**

явызлы|к *сущ.* **1.** зло, зло́ба, зло́бность; *ит яхшылык — көт ~к (погов.)* де́лай добро́ — дождёшься зла; *аңарда көчле ~к кайный* в нём кипи́т си́льная зло́ба **2.** злость, зло́стность, злоде́йство, злодея́ния; лю́тость; зло; *ниятләренең ~гы* зло́стность наме́рений; *~кларын фаш итү* разоблачи́ть (его́) злодея́ния

явызлыклы *прил. разг.* зло́стный, зло́бный, злонаме́ренный; *~ уйлар* зло́стные мы́сли; *~ хисләр* зло́бные чу́вства

явым *сущ.* оса́дки; *яшенле-күкрәүле ~нар* грозовы́е оса́дки; *~нарның уртача еллык күләме* среднегодово́е коли́чество оса́дков; *вакытсыз ~нар* несвоевре́менные оса́дки □ **~ үлчәгеч** дождеме́р

явымлы *прил.* нена́стный, дождли́вый, па́смурный, с оса́дками; *~ көннәр* нена́стные дни; *~ кыш* зима́ с оби́льными оса́дками

явымсызлык *сущ.* бездо́ждье; *~тан җәфалану* му́читься от бездо́ждья

явым-төшем *сущ. собир.* атмосфе́рные оса́дки, дожди́; *бәрәкәтле явым-төшемнәр* благода́тные оса́дки; *явым-төшемсез чак* пери́од без оса́дков

явым-төшемле *прил. см.* **явымлы**

явым-чәчем *сущ. собир разг. см.* **явым-төшем**

явыштыргалау *многокр. от* **яву**; покра́пывать, идти́ и́зредка (*о дожде, снеге*)

яга *сущ. диал.* **1.** край; *диңгез ~сы* край мо́ря **2.** 1) сторона́, ме́сто, ме́стность в отдале́нии 2) чужа́я сторона́ **3.** защи́тник, защи́та; приста́нище; *агасы барның ~сы бар (погов.)* у кого́ есть родня́, у того́ есть защи́та

ягалай, ягалый *диал.* **1.** *послелог* о́коло; *мич ~* о́коло пе́чи; *елга ~* о́коло реки́ **2.** *в знач. нареч.* сторо́нкой, ми́мо; *өйне ~ узу* пройти́ ми́мо до́ма; *яңгыр ~ үтте* дождь прошёл сторо́нкой

ягала́у *перех. диал.* едва́ приступа́ть/приступи́ть

ягу I *перех.* **1.** топи́ть, зата́пливать/затопи́ть, ста́пливать/истопи́ть || 1) то́пка 2) отопи́тельный; *ягу сезоны* отопи́тельный сезо́н; *мичкә ягу* топи́ть печь **2.** *разг.* топи́ть, ота́пливать/отопи́ть || отопле́ние, то́пка; *больницаны ягу* отопи́ть больни́цу; *мунча ягу* топи́ть ба́ню **3.** *перен.* зажига́ть, зажёчь, воспламеня́ть/воспламени́ть, окрыля́ть/окрыли́ть; поднима́ть/подня́ть дух *кого* || вдохнове́ние, воодушевле́ние; *йөрәккә ут ягу* воодушеви́ть, зажёчь се́рдце □ **ягу мае** *уст. см.* **сыек ягулык; ягып бетерү** сжечь

ягу II *перех.* **1.** ма́зать, нама́зывать/нама́зать || нама́зывание; *ипигә май ~* нама́зать ма́сло на хлеб; *булкага икра ~* нама́зать бу́лку икро́й **2.** кра́сить, накра́шивать/накра́сить, ма́зать, нама́зывать/нама́зать || накра́шивание, нама́зывание; *иренгә иннек ~* накра́сить гу́бы пома́дой; *биткә грим ~* ма́зать гри́мом лицо́ **3.** *перен.* припи́сывать/приписа́ть (*кому-л. какое-л. предосудительное действие*); возводи́ть/возвести́ *на кого* (*обвинение, клевету, ложь и т. п.*); обвиня́ть/обвини́ть, оклевета́ть, клевета́ть || припи́сывание, возведе́ние (*напраслины*); *бәла ~* возвести́ напра́слину; *хезмәттәшенә ялa ~* оклевета́ть сослужи́вца

ягулы *прил.* то́пящийся (*который в настоящее время топится: печь*); *мунча ~* ба́ня то́пится

ягулык *сущ.* то́пливо, горю́чее; *сыек ~* жи́дкое то́пливо; *~ бәяләрен күтәрү* подня́ть це́ны на то́пливо

ягъмур *сущ. уст. см.* **яңгыр**

я́гъни *союз* то́ есть; *интеллигенциянең алдынгы көчләре, ~ менә сез* передовы́е си́лы интеллиге́нции, то́ есть вот вы

ягылбай *сущ. зоол.* перепеля́тник, ко́бчик

ягыл|у I *страд. от* **ягу** I топи́ться, ота́пливаться

ягыл|у II *страд. от* **ягу** II **1.** ма́заться, нама́зываться; *ипигә май ~ган* на хлеб нама́зано ма́сло **2.** кра́ситься, накра́шиваться, ма́заться *разг.*; *иреннәренә иннек ~ган* гу́бы накра́шены пома́дой **3.** *перен.* припи́сываться, возводи́ться; *аңа әллә нинди гаепләр ~ды* ему́ припи́сывались вся́кие грехи́ **4.** *неперех.* каса́ться/косну́ться *кого-л., чего-л.*, прикаса́ться/прикосну́ться, притра́гиваться/притро́нуться *к кому-чему*; *өстәлдәге әйберләргә балалар ~масын* пусть де́ти не притра́гиваются к вещам на столе́

ягым *сущ. диал.* **1.** мазо́к (*масла*) **2.** *перен.* обая́ние; *~ы бар* у него́ (неё) есть обая́ние

ягымлы *прил.* **1.** прия́тный, симпати́чный; привлека́тельный, милови́дный, обая́тельный; *~ бала* милови́дный ребёнок **2.** прия́тный, приве́тливый, ла́сковый, любе́зный; *~ сүзләр* любе́зные слова́; любе́зности; *~ караш* ла́сковый взгляд; *~ тавыш белән җырлау* петь прия́тным го́лосом || *нареч.* прия́тно, ла́сково, приве́тливо, любе́зно (*сказать, позвать, посмотреть, улыбнуться и т. п.*)

ягымлыландыру *перех.* де́лать, сде́лать прия́тным, привлека́тельным, симпати́чным, придава́ть/прида́ть прия́тный (симпати́чный) вид

ягымлыланы|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать прия́тным, симпати́чным, привлека́тельным, милови́дным, обая́тельным; *кыз көннән-көн ~а бара* де́вушка изо дня в день стано́вится привлека́тельнее **2.** станови́ться/стать прия́тным, приве́тливым, ла́сковым, любе́зным; *ананың күзләре ~ып китә* взгляд ма́тери стано́вится ла́сковым

ягымлылы|к *сущ.* **1.** прия́тность, обая́ние, симпати́чность, привлека́тельность, милови́дность; *үзенең ~гы белән сихерләү* обвора́живать свое́й привлека́тельностью **2.** прия́тность, приве́тливость, ла́сковость, любе́зность (*голоса, взгляда, улыбки и т. п.*)

ягымсыз *прил.* неприя́тный, непривлека́тельный, несимпати́чный; *~ кеше* неприя́тный челове́к

ягымсызлану *неперех.* станови́ться/стать неприя́тным, непривлека́тельным

ягыну *возвр. от* **ягу** II накра́шиваться/накра́ситься, нама́зываться/нама́заться *разг.*; *иннек ~* накра́ситься пома́дой; *пудра ~* нама́заться пу́дрой, пу́дриться

ягыш|у I *взаимно-совм. от* **ягу** I

ягыш|у II *взаимно-совм. от* **ягу** II

яд *сущ. книжн.* па́мять; воспомина́ния □ **яд итү (кылу, әйләү)** вспомина́ть ◊ **ядка алу 1.** *см.* **ятлау 2.** обогаща́ть созна́ние, воспринима́ть, изуча́ть **3.** вспомина́ть, помина́ть; **ядка килү (төшү)** вспомина́ться, припомина́ться, приходи́ть на па́мять; **ядтан чыгу** забыва́ться, быть забы́тым; **ядына керсә (тә) чыкмау** и не ду́мать, и не вспомина́ть (помина́ть)

ядау *прил. диал.* худо́й, то́щий, изнурённый; *~ атлар* то́щие ло́шади; *~ сарык* худа́я овца́

ядәч *сущ.* ду́жка (*птичья кость*); *~ аерышу* лома́ть ду́жку; держа́ть пари́, лома́я ду́жку (*особый род пари, когда два человека ломают дужку, после чего друг у друга ничего не берут без употребления слова «ядемдә» — «помню», «беру, но помню», в противном случае тот человек, который предлагает какую-л. вещь, произносит «ядәч» и считается выигравшим*) □ **~ сөяге** ду́жка; ◊ **~(ен) киерү** выставля́ть грудь колесо́м

ядкәр *сущ. книжн.* **1.** па́мятник; *тарих ~е* истори́ческий па́мятник **2.** вещь, пода́ренная на па́мять; па́мятный пода́рок, сувени́р; рели́квия; *бу сәгать әтием ~е* э́ти часы́ — па́мять моего́ отца́ □ **~ итү 1.** дари́ть на па́мять **2.** счита́ть *что-л.* па́мятью *о ком-л.*

ядкәрлек *сущ.* вещь, предназна́ченная на па́мять; вещь, пода́ренная на па́мять; предме́т, явля́ющийся па́мятью *о ком-л.*, сувени́р; рели́квия

ядрә *сущ.* **1.** ядро́, дробь (для ружья́); *~ бөртеге* дроби́нка **2.** *спорт.* ядро́; *~ ыргыту* толка́ть ядро́ **3.** *уст.* ядро́, артиллери́йский снаря́д; *туп ~се* пу́шечное ядро́ □ **~ савыты** дробни́ца

ядрәле *сущ.* дробово́й; *~ мылтык* дробова́я берда́нка □ **~ снаряд** бриза́нтный снаря́д

яз *сущ.* весна́ || весе́нний; *бер карлыгач яз китермәс* (*посл.*) одна́ ла́сточка весны́ не де́лает; *яз исе* весе́нний за́пах □ **яз гөле** *бот. диал. см.* **нәүрүз; яз йолдызы** *бот.* хохла́тка; **яз көне 1.** весе́нний день **2.** весно́й; **яз нуры** *бот.* проле́ска; **яз чәчкәсе** *бот. см.* **күкебаш**

язгала́у *многокр. от* **язу** I

язгалаштыр|у *многокр. от* **язгала́у**; иногда́, и́зредка писа́ть, попи́сывать; *ара-тирә газетага мәкаләләр ~ам* иногда́ пишу́ статьи́ для газе́ты

язгы *прил.* **1.** весе́нний; ве́шний; *~ көннәр* весе́нние дни; *~ сулар* ве́шние во́ды; *~ бер көн ел туйдыра* (*посл.*) весе́нний день год ко́рмит **2.** весе́нний, яровы́е (*о полевых работах*); *~ чәчү* весе́нний сев; *~ сөрү* яровáя па́хота □ **~ бизгәк** ве́шняя лихора́дка, весну́ха, весе́нница; **~ бодай** *с.-х.* яровáя пшени́ца; **~ йон (сарык йоны)** весе́нняя шерсть, весни́на; **~ күбәләк** ба́бочка-весня́нка

язгы-көзге *прил.* весе́нне-осе́нний; *язгы-көзге эшләр* весе́нне-осе́нние рабо́ты; *язгы-көзге юлсызлык* осе́нне-весе́ннее бездоро́жье; *язгы-көзге пальто* демисезо́нное пальто́

язгылык *сущ.* весе́ннее вре́мя; *~ка калдыру* оставля́ть на весе́ннее вре́мя || *прил.* весе́нний, предназна́ченный на весе́ннее вре́мя, на весе́нний сезо́н; *~ пальто* весе́ннее пальто́

язгылыкта *нареч. разг.* весно́й, весе́нними дня́ми; *~ ялга китү* уйти́ в о́тпуск весно́й

язгыч: май язгыч маслобо́йка

яздыру I *понуд. от* **язу** I (в 2, 5, 8 знач.)

яздыру II *понуд. от* **язу** III

яздыру III *понуд. от* **язу** IV

язлый *нареч. см.* **язын**

язлык *прил.* предназна́ченный на весе́нний пери́од; доста́точный на весну́ (на весе́нний пери́од); *~ печән* се́но, доста́точное на весну́

язлы-көзле *нареч.* весно́й и о́сенью; *язлы-көзле кия торган пальто* демисезо́нное пальто́; пальто́, кото́рое но́сится весно́й и о́сенью

язлыкта *нареч. разг. см.* **язгылыкта**

язма *сущ.* **1.** за́пись; *лекция ~лары* за́писи ле́кции; *язучы ~лары* запи́ски писа́теля **2.** ру́копись; *см. тж.* **кулъязма**; *нәшир ~ларны алып калды* реда́ктор оста́вил ру́кописи у себя́ **3.** на́дпись; *Борынгы Египет ~лары* древнеегипе́тские на́дписи; *чөйсыман ~лар* клинопи́сные на́дписи; *каберташ ~лары* надгро́бные на́дписи || *прил.* пи́сьменный; *~ гариза* пи́сьменное заявле́ние; *укучыларның ~ эшләре* пи́сьменные рабо́ты ученико́в □ **~ рәвештә** пи́сьменно

язмыш *сущ.* **1.** судьба́, фа́тум *книжн.*, рок *высок.* (*обычно грозящий бедами, несчастьями и т. п.*); *~ка буйсыну* покори́ться судьбе́; *каһәрле ~* жесто́кий фа́тум; *усал ~* злой рок **2.** 1) у́часть, до́ля, уде́л; *бәхетле ~* счастли́вая у́часть 2) жи́зненный путь; *минем ~ымда бик күп үзгәрешләр булды* в мое́й судьбе́ (на моём жи́зненном пути́) произошло́ о́чень мно́го измене́ний **3.** судьба́ (бу́дущность, бу́дущее); *халык җырларының ~ы* су́дьбы наро́дных пе́сен; *Каспий диңгезенең экологик ~ы* экологи́ческая судьба́ Каспи́йского мо́ря; *ил ~ы* судьба́ страны́; *кешелек дөньясының ~ы* судьба́ (бу́дущность) челове́чества; *революция ~ы* судьба́ револю́ции ◊ **~ ихтыяры белән** во́лею су́деб; **~ кочагына ташлау** бро́сить на произво́л судьбы́; **~ка баш ию** примири́ться с судьбо́й; **~тан узмыш юк** от судьбы́ не уйдёшь; чему́ быть, того́ не минова́ть; **~ы шул** на роду́ напи́сано; такова́ судьба́

язрак *нареч. разг.* ещё весно́й; ещё по весне́; *~ килергә кирәк иде* на́до бы́ло прийти́ ещё весно́й

язу I *перех.* **1.** писа́ть, написа́ть || 1) написа́ние, писа́ние 2) пи́счий; *кара белән язу* писа́ть черни́лами; *тактага акбур белән язу* писа́ть ме́лом на доске́; *мемуарлар язу белән шөгыльләну* занима́ться писа́нием мемуа́ров; *язу кәгазе* пи́счая бума́га; *язу әсбаплары* пи́сьменные принадле́жности **2.** писа́ть, написа́ть, запи́сывать/записа́ть || написа́ние, запи́сывание, за́пись; *доклад язу* писа́ть докла́д; *гариза язу* написа́ть заявле́ние; *хат язу* писа́ть письмо́ **3.** писа́ть, написа́ть, сообща́ть/сообщи́ть || написа́ние, сообще́ние; *хатында нәрсәләр язган?* что (он) написа́л в письме́, о чём сообщи́л в письме́? *ул турыда газеталар нәрсә яза?* что пи́шут об э́том газе́ты **4.** 1) писа́ть, написа́ть, сочиня́ть/сочини́ть, создава́ть/созда́ть, твори́ть || сочине́ние, созда́ние, творе́ние; *китап язу* написа́ть кни́гу; *тарихи пьеса язу* написа́ть истори́ческую пье́су 2) опи́сывать/описа́ть || описа́ние; *авыл тормышын язу* писа́ть о дереве́нской жи́зни **5.** писа́ть, написа́ть, сочиня́ть/сочини́ть, создава́ть/созда́ть, слага́ть/сложи́ть (*музыкальное произведение*) || написа́ние, сочине́ние, созда́ние, сложе́ние; *опера язу* писа́ть о́перу; *романс язу* сочини́ть рома́нс; *симфония язу* созда́ть симфо́нию **6.** выпи́сывать/вы́писать, пропи́сывать/прописа́ть (*лечение, лекарство, рецепт и т. п.*); *врач өч төрле дару язган* врач прописа́л три ви́да лека́рства **7.** запи́сывать/записа́ть (*песню, музыку, разговор на плёнку, пластинку*) || написа́ние, за́пись; *концертны язу* записа́ть конце́рт; *тасмага язу* записа́ть на плёнку **8.** впи́сывать/вписа́ть, включа́ть/включи́ть, запи́сывать/записа́ть, зачисля́ть/зачи́слить, вноси́ть/внести́ || зачисле́ние; *бию түгәрәгенә язу* записа́ть в хореографи́ческий кружо́к; *чиратка язу* включи́ть в о́чередь; *археология экспедициясенә язу* зачи́слить в археологи́ческую экспеди́цию; *мәктәпкә язу* записа́ть в шко́лу **9.** запи́сывать/записа́ть, сде́лать за́пись, составля́ть/соста́вить докуме́нт; *милекне улына язу* записа́ть иму́щество на сы́на **10.** *рел. обычно со словами «ходай, алла» и др.* предназна́чено, предопределено́ бо́гом, судьбо́й; *үзеңә язган мал кайта ул* (*погов.*) бога́тство (добро́), кото́рое тебе́ суждено́, вернётся; *алла (ходай) язган* бог дал; предопределено́ бо́гом; *алла язган булса, эшләрбез* бог даст, сде́лаем □ **язып алу (кую)** записа́ть; **язып бару (тору)** запи́сывать; **язып тутыру** исписа́ть ◊ **~ язган булса** (е́сли) бог даст

язу II *сущ.* **1.** пи́сьменность; письмо́; *славян язуы* славя́нское письмо́; *гарәп язуы* ара́бская пи́сьменность || пи́сьменный; *язу билгеләре* пи́сьменные зна́ки; письмена́ **2.** по́черк; *таныш язу* знако́мый по́черк; *вак язу* ме́лкий по́черк; *балалар язуы белән язылган хат* письмо́, напи́санное де́тским по́черком **3.** *мн. ч. язулар* письмена́; *Мисыр язулары* еги́петские письмена́; *рун язулары* руни́ческие письмена́ **4.** 1) за́пись, запи́ска; бума́га; *президиумга язу җибәрү* переда́ть запи́ску в през́идиум; *өстәл өстендәге язуларны тәртипкә китерү* привести́ в поря́док за́писи (бума́ги) на столе́ 2) за́пись; по́дпись, на́дпись; *дәфтәр читендәге язу* за́пись на поля́х тетра́ди; *таш плитә өстендәге язу* на́дпись на ка́менной плите́; *йөзектәге язу* на́дпись на коле́чке; *рәсем астындагы язу* по́дпись под рису́нком **5.** *разг.* бума́га, докуме́нт; *налог язуы* бума́га о нало́ге; *җыелышка чакырып язу җибәргәннәр* присла́ли бума́гу с приглаше́нием на собра́ние □ **язу тану** уме́ть чита́ть, быть гра́мотным; **язу эше 1.** у́мственная рабо́та **2.** писа́тельский труд; **язу үрнәге** про́пись; **язу булмаган** бесписьменный

язу III *неперех.* **1.** лиша́ться/лиши́ться *кого-чего-л.*; теря́ть/потеря́ть *кого-что-л.* || лише́ние, поте́ря; *күздән язу* лиши́ться зре́ния, потеря́ть зре́ние; *акылдан язу* лиши́ться ума́, сойти́ с ума́; *кызыңнан язу* лиши́ться до́чери, потеря́ть дочь; *иштан язу* потеря́ть созна́ние **2.** *в роли вспом. гл. обозн., что действие, выраженное основным глаголом, едва не произошло, соотв. русскому* чуть, чуть-чу́ть, едва́ не...; чуть бы́ло не, почти́...; *абына яздым* чуть не споткну́лся; *үлә яздым* чуть бы́ло не у́мер; *агарып бетә язган чәч* почти́ поседе́вшие во́лосы

язу IV *перех.* **1.** расправля́ть/распра́вить (*плечи, крылья*); выпрямля́ть/вы́прямить, расправля́ть/распра́вить, разгиба́ть/разогну́ть (*согнутое*) || расправле́ние, выпрямле́ние, распрямле́ние **2.** трепа́ть, растрепа́ть (*шерсть*) || трепа́ние

язу V *перех.* сбива́ть/сбить, па́хтать || **1)** сбива́ние, сби́вка, па́хтанье 2) сбива́льный, сбива́тельный; *май язу*

па́хтать ма́сло; *су язып май төшми* (*посл.*) е́сли во́ду сбива́ть, ма́сло не полу́чится; во́ду толо́чь, вода́ и бу́дет

язулы *прил.* с за́писью, на́дписью; име́ющий за́пись, на́дпись; с за́писями; на́дписями; ~ *кәгазь* бума́га с за́писями; ~ *кабер ташы* надгро́бный ка́мень с на́дписью; ~ *глобус* гло́бус с на́дписями □ ~ **борчак** *диал. бот.* бобы́

язу-сызу *сущ. собир.* писа́ть и черти́ть || 1) письмо́, писа́ние, писани́на *уст.* 2) пи́сьменный; гра́мотный; *язу-сызу кирәк-яраклары* пи́сьменные принадле́жности □ **язу-сызу эшләрен башкаручы (алып баручы)** пи́сарь; письмоводи́тель *уст.*; **язу-сызу әйберләре** писчебума́жные предме́ты

язучы *сущ.* писа́тель || писа́тельский; ~ *хезмәте* писа́тельский труд; *татар әдәбиятының классик ~лары* писа́тели-кла́ссики татарской литерату́ры

язучылык *сущ.* профе́ссия (*занятие*) писа́теля, писа́тельство || писа́тельский; ~ *таланты* писа́тельский тала́нт

язы|к (язын) *сущ. рел.* грех, грехо́вность; *~гын кая куярсың?* грех-то куда́ де́нешь? (*говорится в предостережение от чего-л. предосудительного*); *сер тота белмәү ~к санала* неуме́ние храни́ть та́йну счита́ется грехо́м || *прил.* гре́шный, грехо́вный *уст.*; *~к эш* гре́шное де́ло

языклы *прил. рел.* гре́шный, грехо́вный *уст.*; ~ *кеше* гре́шный челове́к; гре́шник □ ~ **булу** греши́ть, согреши́ть; *утка төкермә – булырсың* не плюй на ого́нь — согреши́шь; грешно́ плева́ть на ого́нь

языксыз *прил.* безгре́шный, неви́нный

язылдыру *перех.* размина́ть/разма́ть, промя́ть (*лошадь*); выпрямля́ть/вы́прямить, разгиба́ть/разогну́ть (*тело*); отгиба́ть/отогну́ть, распрямля́ть/распрями́ть || разми́нка; выпрямле́ние, разгиба́ние, отгиба́ние; *см. тж.* **язу** IV

язылу I **1.** *страд. от* **язу** I **2.** *возвр.* подпи́сываться || подпи́ска; *газета-журналларга* ~ подпи́ска на газе́ты и журна́лы **3.** *см.* **язылышу** 1

язылу II *страд. от* **язу** IV

язылыш *сущ.* написа́ние; *ике төрле* ~ двоя́кое написа́ние; *сүзләрнең дөрес ~ы* правописа́ние слов

язылыш|у *неперех.* **1.** регистри́роваться, зарегистри́роваться (*в загсе*) || регистра́ция **2.** *совм. от* **язылу** I 2 (*о многих*)

язымга: язымга таем случа́йно; к сча́стью

язын *нареч.* весно́й, весе́нними дня́ми; ~ *яңгырлар ява башлый* весно́й начина́ются дожди́

язын-көзен *нареч.* весно́й и о́сенью; *язын-көзен кырда эшләү* весно́й и о́сенью рабо́тать в по́ле

язын|у *возвр. от* **язу**; занима́ться письмо́м, писа́нием, писани́ной; строчи́ть; *~ып утыра* сиди́т и что́-то строчи́т

языну-сызыну *неперех. редко* занима́ться/заня́ться писани́ной, попи́сывать

язышма *сущ. редко* перепи́ска; *~ларны гарәп телендә алып бару* вести́ перепи́ску на ара́бском языке́

языштыр|у *многокр. от* **язу** I; и́зредка, иногда́, временами писа́ть

языш|у I **1.** *взаимно-совм. от* **язу** I **2.** перепи́сываться, име́ть перепи́ску || перепи́ска; *ике дус хат ~а башлады* два дру́га на́чали перепи́сываться **3.** выступа́ть в печа́ти, писа́ть иногда́ статьи́

язышу II *взаимно-совм. от* **язу** V

я́исә *союз* и́ли, и́ли же; *көндез ~ кичен* днём и́ли ве́чером; *хат ~ телефон аша хәбәр итәрбез* сообщи́м письмо́м и́ли же по телефо́ну

як I *сущ.* **1.** 1) сторона́, направле́ние; *кыр ягыннан* со стороны́ по́ля; *төрле якка йөгерешү* разбежа́ться в ра́зных направле́ниях; *һәр якка* по всем направле́ниям, во все сто́роны 2) сторона́, простра́нство, ме́сто (*вправо или влево от середины*), направле́ние (*вправо или влево от кого-чего-л.*); *урамның уң ягы* пра́вая сторона́ у́лицы; *елганың ар ягы* друга́я сторона́ реки́ 3) сторона́, бок; *күкрәкнең сул ягы* ле́вая сторона́ груди́; *уң якта гына йоклау* спать то́лько на пра́вом боку́; *күләгә якка чыгу* вы́йти на теневу́ю сто́рону 4) *с определ.* сторона́, боковая́ часть, бок *кого-чего-л.*; *тукыманың уң ягы* лицева́я сторона́ мате́рии; *кыя ягы белән тау диңгезгә терәлгән* гора́ упира́лась скали́стой стороно́й в мо́ре **2.** сторона́, полови́на; *хатын-кыз ягы* же́нская полови́на; *өйнең алгы ягында үзебез яшибез* в пере́дней полови́не до́ма са́ми живём **3.** сторона́, край, ме́стность, ме́сто (*чаще* места́); страна́, земля́; *туган як* родна́я сторона́; родны́е места́; *җылы яклар* тёплые страны́ (края́) **4.** *мат.* сторона́, грань (*многоугольника, треугольника, трапеции и т. п.*) **5.** 1) сторона́, ла́герь, стан *книжн.*; *күпчелек ягында булу* быть на стороне́ большинства́; *дошман яклар* вражду́ющие сто́роны; *ике дошман як* два вражду́ющих ла́геря 2) *разг.* сторона́ (*степень родства, о родственных отношениях*); *эти ягыннан туганнар күп* со стороны́ отца́ ро́дственников мно́го **6.** 1) сторона́, аспе́кт, составна́я часть, элеме́нт *чего-л.*; *шагыйрь иҗатының бер ягы белән генә кызыксыну* интересова́ться то́лько одно́й стороно́й тво́рчества поэ́та; *юридик яктан сез хаклы* с юриди́ческой стороны́ вы пра́вы 2) сторона́, отде́льная черта́, сво́йство, осо́бенность; *проектның техник ягы* техни́ческая сторона́ прое́кта; *докладның йомшак яклары* сла́бые сто́роны докла́да **7.** *разг. в знач. предик. сл.* **ягында** за; сторо́нник *чего*; *ул килешү ягында* он за примире́ние; *җыелыш тәкъдимне раслау ягында* собра́ние за одобре́ние предложе́ния

як II *сущ. зоол.* як (*крупное рогатое животное, обитающее в горных областях Центральной Азии*)

яка *сущ.* во́рот, воротни́к (*рубашки, пальто, костюма и т. п.*); *утырма (утыртма) яка* стоя́чий воротни́к; *шәлсыман яка* ша́левый воротни́к, воротни́к ша́лью □ **яка чылбыры** металли́ческое нагру́дное украше́ние ◊ **якага яка килү** схвати́ться, я́ростно би́ться; *якадан алышу* дра́ться; *якасыннан алу* брать (взять, схвати́ть) за во́рот (за го́рло); *якасыннан тотып селкү* трясти́ (схвати́ть) за во́рот

якала́у *перех. разг.* бить, избива́ть, лупи́ть

якалаш|у *совм. от* **якала́у** *разг.* **1.** дра́ться, подра́ться; хвата́ть (схвати́ть) друг дру́га за во́рот **2.** *перен.* боро́ться, дра́ться (*в особо трудных случаях*); *~тык явыз үлем белән* боро́лись со злой сме́ртью

якалы *прил.* с воротнико́м (*платье, пальто, шуба и т. п.*)

якалык *сущ.* **1.** материа́л, предназна́ченный и́ли доста́точный для воротника́ (*мех и т. п.*) **2.** *прил.* го́дный для воротника́

я́ки *союз* и́ли, и́ли же, ли́бо; ~ *мин, яки син* ли́бо я, ли́бо ты; *кичләрен улыма китап укыйм ~ әкият сөйлим* вечера́ми чита́ю сы́ну кни́гу и́ли (же) расска́зываю ска́зку

яккала́у I *многокр. от* **ягу** I

яккала́у II *многокр. от* **ягу** II

яклану *разг.* **1.** *страд. от* **якла́у** **2.** *неперех.* злоупотребля́ть защи́той, покрови́тельством *кого-л.* **3.** *диал. см.* **кылану**

якланыш *сущ.* защи́та; *яңа проектның ~ы* защи́та но́вого прое́кта

яклату *понуд. от* **яклáу** 3 позволя́ть защища́ть *(диссертацию, диплом и т. п.)*

яклáу *перех.* **1.** защища́ть/защити́ть *кого-л., что-л.*; заступа́ться/заступи́ться, покрови́тельствовать || защи́та; засту́пничество, покрови́тельство **2.** *перен. разг.* подде́рживать/поддержа́ть || подде́ржка; *аның фикерен ~* подде́рживать его́ мне́ние **3.** защища́ть/защити́ть *(диплом, диссертацию, проект и т. п.)* || защи́та **4.** *юр.* защища́ть/защити́ть *(на суде)* || защи́та

яклаучы *сущ.* **1.** защи́тник; засту́пник, покрови́тель; *кимсетелгәннәрне ~* засту́пник оби́женных **2.** сторо́нник, после́дователь, приве́рженец; *тынычлык ~лар хәрәкәте* движе́ние сторо́нников ми́ра; *Дарвин теориясен ~* приве́рженец тео́рии Да́рвина **3.** *юр.* защи́тник, адвока́т

яклаштыру *многокр. от* **яклáу** иногда́ *(время от времени)* защища́ть *кого*

яклашу *взаимно-совм. от* **яклáу** защища́ть друг дру́га

яклы *прил.* **1.** *в сочет. с колич. числ.* -сторо́нний; *бер ~* односторо́нний; *ике ~ драп* двухсторо́нний драп **2.** *предик. сл.* на стороне́, сторо́нник; *без тынычлык һәм хаклык ~* мы сторо́нники ми́ра и справедли́вости

я́корь *сущ.* я́корь || я́корный; *~ чылбыры* я́корная цепь □ **~ калкавычы** томбу́й; **~ салу** встать на я́корь; зая́кориться; **~ төшерү** отда́ть я́корь; **~да тору** стоя́ть на я́коре

якташ *сущ.* земля́к; *үземнең ~ымны очраттым* встре́тил своего́ земляка́ □ **~лар оешмасы** *см.* **якташлык җәмгыяте**

якташлык *сущ.* земля́чество || земля́ческий; *~ мөнәсәбәтләре* земля́ческие отноше́ния □ **~ җәмгыяте** земля́чество

якты *сущ.* **1.** свет; *лампа ~сы* свет ла́мпы; *кояш ~сы* со́лнечный свет; *таң ~сы* свет зари́; *ут ~сы* свет огня́ **2.** свет, све́тлое ме́сто, освещённое ме́сто; *коридор башында ~ куренә* в конце́ коридо́ра ви́ден свет **3.** *перен.* свет (*как символ справедливости, ума, сознания, счастья и радостной жизни*); *матур киләчәккә, ~га омтылу* стреми́ться к прекра́сному бу́дущему, к све́ту || *прил.* **1.** 1) све́тлый, освещённый, напо́лненный све́том 2) све́тлый, я́ркий, со́лнечный **2.** *перен.* све́тлый, я́сный, чи́стый (*глаза*); просветлённый (*взгляд*) **3.** *перен.* све́тлый, счастли́вый, ра́достный, ничем не омрачённый; *~ тормыш* све́тлая (счастли́вая) жизнь; *~ киләчәк* све́тлое бу́дущее; *~ истәлекләр* ра́достные воспомина́ния **4.** *перен.* све́тлый, просветлённый, ра́достный, сия́ющий (*о человеке, его виде, улыбке и т. п.*); *шундый ~ йөз* тако́е сия́ющее лицо́; *~ елмаю* све́тлая улы́бка **5.** *перен.* све́тлый, прекра́сный, высо́кий; *шагыйрьнең ~ образы* све́тлый о́браз поэ́та **6.** *перен.* све́тлый, я́сный, логи́чный (*об уме, мыслях*); *~ фикер, ~ уйлар белән яшәү* жить я́сными мы́слями, све́тлыми разду́мьями || *нареч.* светло́, я́рко; *лампа ~ яна* ла́мпа гори́т я́рко □ **~ сизүчәнлек** светочувстви́тельность; **~ чакта (көздә)** за́светло, пока́ светло́; **~га куеп карау** просве́чивать/просвети́ть (*яйцо*); **~га сизгер** светочувстви́тельный; **~га чыдамлык** светоусто́йчивость; **~дан курку, ~га түзмәү** *мед.* светобоя́знь ◊ **~ дөнья 1.** свет, бе́лый свет, мир **2.** счастли́вая (све́тлая) жизнь; *~ дөньяга килү* появи́ться на свет; роди́ться; *~ исем* до́брое и́мя; **~ йөз (чырай)** приве́тливость, раду́шие; *~ йөз белән* приве́тливо, раду́шно, гостеприи́мно; **~ йөзле (чырайлы)** приве́тливый, гостеприи́мный; **~ көн бирмәү (күрсәтмәү)** не дава́ть/дать жить; изводи́ть/извести́; **~ көн күрмәү** све́та бе́лого не ви́деть (*всю жизнь плохо жить*); **~ күздә (чакта)** за́светло, пока́ светло́

яктылы|к *сущ.* **1.** свет, огонёк || светово́й; *кичке ~* вече́рний свет; *~к дулкыннары физ.* световы́е во́лны; *авылда бер ~к та күренми* не ви́дно ни одного́ огонька́ в дере́вне **2.** све́тлость, я́ркость; *йолдыз ~гы* я́ркость звезды́; *электр ~гы* я́ркость электри́чества; *кышкы кичләрнең ~гы* све́тлость зи́мних вечеро́в **3.** *перен.* све́тлость, просве́т; *болытлар арасындагы ~к* просве́т в ту́чах **4.** *перен.* просве́т, облегче́ние, улучше́ние; *аның тормышында бернинди дә ~к булмады* в его́ жи́зни не́ было никако́го просве́та (*облегчения, улучшения*) **5.** *перен.* све́тлость, просветлённость (*взгляда, лица, мыслей, ума, будущего и т. п.*); *йөз ~гы* све́тлость лица́; *акыл ~гы* просветлённость ума́ **6.** *перен.* свет, све́тлая жизнь; *~кка омтылу* стреми́ться к све́ту, к све́тлой жи́зни □ **~к белән дәвалау** лечи́ть све́том; светолече́ние; **~к көче** *физ.* светоси́ла; **~к күләгәсе** *иск.* светоте́нь; **~к нурланышы** светоизлуче́ние; **~к үткәрми торган** светонепроница́емый; **~к үткәрмәүчәнлек (үткәрмәү)** светонепроница́емость; **~к чәчелү** светорассе́яние

яктылы-караңгылы *прил.* **1.** су́меречный; *кичке яктылы-караңгылы вакыт* вече́рнее су́меречное вре́мя; вече́рние су́мерки; полумра́к **2.** полусве́тлый, полутёмный; *яктылы-караңгылы кабинет* полутёмный кабине́т

яктырганчы *нареч.* за́темно, пока́ не рассвело́; *~ юлга чыгарга кирәк* пока́ не рассвело́, на́до вы́ехать; за́темно ну́жно тро́гаться в путь

яктырмас *прил.* беспросве́тный; *~ төн* беспросве́тная ночь □ **~ борын** за́темно, пока́ не рассвело́

яктырткыч *сущ.* **1.** свети́льник, исто́чник све́та; осветя́тель; *операция ясау бүлмәсендәге ~лар* свети́льники в операцио́нной **2.** *прям., перен.* свети́ло; *күк ~лары* небе́сные свети́ла; *төн ~лары* свети́ла но́чи; ночно́е свети́ло (*луна*); *әдәбият күгенең ~ы* свети́ло литерату́рного не́ба; *тормыш юлын ~ым була алмадың* не смог ты стать свети́лом на моём жи́зненном пути́ || *прил.* **1.** осветя́тельный; *~ бомбалар* осветя́тельные бо́мбы; *~ ракеталар* осветя́тельные раке́ты **2.** трасси́рующий; *~ пуля* трасси́рующая пу́ля

яктырттыру *понуд. от* **яктырту**

яктырт|у *перех.* **1.** освеща́ть/осветя́ть, озаря́ть/озари́ть || 1) освеще́ние, озаре́ние 2) осветя́тельный; *урамнарны электричество белән ~у* освеща́ть у́лицы электри́чеством; *фонарь белән юлны ~у* освеща́ть доро́гу фонарём; *~у әсбабы* осветя́тельный прибо́р; *кояш нурлары урманны ~ты* со́лнечные лучи́ озари́ли лес **2.** *перен.* освеща́ть/осветя́ть, оживля́ть/оживи́ть, озаря́ть/озари́ть, осия́ть; сде́лать просветлённым, ра́достным || озаре́ние; *күңелне ~у* озаря́ть ду́шу; *елмаю аның йөзен ~ты* улы́бка осветя́ла (оживи́ла) его́ лицо́ **3.** *перен.* освеща́ть/осветя́ть, излага́ть/изложи́ть, истолко́вывать/истолкова́ть *что-л.* || освеще́ние, толкова́ние; *мәкалә әһәмиятле мәсьәләләрне ~а* статья́ освеща́ет актуа́льные вопро́сы

яктыртучанлык *сущ. астр.* свети́мость

яктыртучы *сущ. спец.* осветя́тель; *~ булып эшләү* рабо́тать осветя́телем

яктыртыл|у *страд. от* **яктырту 1.** освеща́ться (*об улице, доме, кабинете и т. п.*) || освеще́ние, освещённость **2.** *перен.* освеща́ться, излага́ться, истолко́вываться; *фактлар дөрес ~ган* фа́кты освещены́ пра́вильно

яктыртылыш *сущ.* 1. освеще́ние, сте́пень освеще́ния 2. *перен.* объясне́ние, освеще́ние, толкова́ние *чего-л.*; *романда вакыйгаларны тарихи ~та сурәтләү* в рома́не опи́сывать собы́тия в истори́ческом освеще́нии

яктыртышу *взаимно-совм. от* **яктырту**

яктыр|у I 1. *безл.* света́ть, рассвета́ть, рассвести́ || рассве́т; *инде ~а да башлады* на́чало уже́ света́ть (рассвета́ть); *~у белән юлга чыгу* с рассве́том тро́гаться в путь 2. *неперех.* светле́ть, просветле́ть, станови́ться/стать све́тлым, освещённым; *күк йөзе ~ды* не́бо просветле́ло; *буран басылды, көн дә ~гандай булды* метёль сти́хла, и день как бу́дто стал светле́е 3. светле́ть, видне́ться (*о чём-л. светлом, светящемся*); *куктә ай ~ып күренә* ме́сяц светле́ет на не́бе 4. *перен.* просветле́ть, станови́ться/стать я́сным, ра́достным; *алдагы көннәр генә берүк ~сын* предстоя́щие дни бы то́лько бы́ли ра́достными 5. *перен.* светле́ть, просветле́ть, освеща́ться/освети́ться, оживля́ться/ожи́виться, проясня́ться/проясни́ться, озаря́ться/озари́ться (*о человеке, глазах, лице, сознании, душе и т. п.*) || просветле́ние, оживле́ние, проясне́ние мы́слей; *малайның йөзе өмет белән ~ды* лицо́ ма́льчика озари́лось наде́ждой □ **~а башлау** забре́зжить; **~ып китү** посвете́ть; **~ып күренү** засвети́ться

яктыр|у II *понуд. от* **ягу** I заставля́ть, проси́ть топи́ть, ота́пливать

яктырылыш *сущ.* 1. *физ. см.* **яктырыш** 2. *иск.* освеще́ние (*распределение света на картине, фотоснимке*)

яктырыш *сущ. физ.* свече́ние; *анод ~ы* ано́дное свече́ние

якут I *сущ.* я́хонт || я́хонтовый; *~ йолдызлар* я́хонтовые звёзды; *зәңгәр ~* голубо́й я́хонт (*сапфир*); *кызыл ~* кра́сный я́хонт (*рубин*); *~лар табыла вакыт белән, вакытлар табылмый ~ белән* вре́мя — зо́лото

якут II *сущ.* яку́т || яку́тский; *см. тж.* **саха**; *~ теле* яку́тский язы́к □ **~ хатыны (кызы)** яку́тка

яку́тча *нареч.* по-яку́тски, на яку́тском языке́, как яку́т; *~ киену* одева́ться как яку́т; *~ сөйләшү* говори́ть по-яку́тски || *прил.* яку́тский; на яку́тском языке́; *~ көнкүреш* яку́тский быт; *~ журнал* журна́л на яку́тском языке́

якшәмбе *сущ.* воскресе́нье || воскре́сный; *~ көн* воскре́сный день □ **~ өмәсе** воскре́сник

якын *прил.* 1. *прям., перен.* бли́зкий, бли́жний, ближа́йший, недалёкий, неда́льний; *~ урманга гына бару* ходи́ть то́лько в бли́жний лес; *~ юл* бли́зкая доро́га; *~ киләчәктә* в недалёком бу́дущем; *~ өметләр* ближа́йшие наде́жды 2. бли́зкий, ближа́йший, свой, родно́й, недалёкий, неда́льний (*о родне, друзьях*); *~ туган* бли́зкий ро́дственник; *иң ~ дус* ближа́йший друг; *~ кешем юк минем* нет у меня́ родно́го челове́ка 3. *в знач. сущ. мн. в притяж. ф.* **якыннары** 1) бли́зкие, родня́, ро́дственники; *ана ягыннан ~нары* ро́дственники по матери́нской ли́нии 2) приближённые; *директорның ~нары* приближённые дире́ктора 4. бли́зкий, сме́жный, свя́занный *чем-л.*; *җыелышта эшкә ~ мәсьәләләр каралды* на собра́нии рассма́тривались бли́зкие к рабо́те зада́чи 5. бли́зкий, дорого́й *кому-чему-л.*; *анага баладан да ~ кеше юк* для ма́тери доро́же её дитя́ти нет челове́ка 6. бли́зкий, схо́дный, похо́жий, аналоги́чный *чему*; *эчтәлекләре белән ~ әсәрләр* произведе́ния, бли́зкие по содержа́нию; *стильләре белән ~ язучылар* писа́тели, схо́дные по сти́лю; *метеориттагы минерал составы белән җирдәге минералга ~* минера́л в метеори́те по соста́ву аналоги́чен минера́лу земно́му || *нареч.* бли́зко, бли́же; *авылга ~ урнашу* расположи́ться бли́зко к дере́вне || *послелог* 1. бли́зкий, схо́жий, похо́жий; подо́бно, наподо́бие, вро́де, почти́; *яратуга ~ бер хис* чу́вство, бли́зкое к любви́; *елауга ~ тавыш белән сорау* проси́ть почти́ пла́ча 2. о́коло, с, почти́, приме́рно; *сәгатькә ~* о́коло ча́са; *атнага ~* о́коло неде́ли; с неде́лю; *йөзгә ~ кеше* приме́рно сто челове́к; *өч айга ~ вакыт үткән* прошло́ почти́ три ме́сяца □ **~ арада (көннәрдә)** в ближа́йшее вре́мя, на днях, ско́ро, в ско́ром вре́мени; **~ бару юлы** по́дступ *к чему-л.*; **~ җибәрү** подпуска́ть/подпусти́ть; **~ итү (күрү)** счита́ть свои́м; счита́ть за бли́зкого, родно́го; **~ килү** приближа́ться/прибли́зиться, сближа́ться/сбли́зиться, пододвига́ться/пододви́нуться, подступа́ть/подступи́ть, бли́зиться, подходи́ть/подойти́, подъезжа́ть, надвига́ться *на кого-что*; **~ китерү** приближа́ть/прибли́зить, сближа́ть/сбли́зить, придвига́ть/придви́нуть, подпуска́ть/подпусти́ть || приближе́ние, сближе́ние; **~ мөнәсәбәт** 1. дру́жеские отноше́ния 2. *перен.* любо́вная связь; **~ тирәдә** неподалёку, побли́зости ◊ **~ барырлык (килерлек) түгел** нельзя́ подступи́ться, не приступи́ться, не подступи́ться *к кому-л., чему-л.*, нет по́дступа; **~ да килми** 1. не соглаша́ется, и слу́шать не хо́чет 2. быть не похо́жим, не схо́жим; ничего́ о́бщего *с кем-л., чем-л.* 3. не подходи́ть (*об одежде, обуви*); **~ да китермәү** 1. проти́виться, не брать (*вещей, денег, продуктов и т. п.*) 2. бли́зко не подпуска́ть *к кому-л.*

якынаешу *взаимно-совм. от* **якынаю** сближа́ться/сбли́зиться

якынайттыру *понуд. от* **якынайту**

якынайт|у *перех.* 1. приближа́ть/прибли́зить, придвига́ть/придви́нуть || приближе́ние; *урындыкны өстәлгә ~у* передви́нуть стул к столу́; *промышленность предприятиеләрен чимал һәм ягулык чыганакларына ~у* прибли́зить промы́шленные предприя́тия к исто́чникам сырья́ и то́плива 2. *перен.* сближа́ть/сбли́зить, приближа́ть/прибли́зить || сближе́ние, приближе́ние; *акыл хезмәте белән физик хезмәтне ~у* сближе́ние у́мственного и физи́ческого труда́; *әдәбиятны тормышка ~у* прибли́зить литерату́ру к жи́зни; *теория белән практиканы ~у* сбли́зить тео́рию с пра́ктикой 3. сокраща́ть/сократи́ть (*расстояние*) 4. приближа́ть/прибли́зить срок, ускоря́ть/уско́рить, торопи́ть || приближе́ние, ускоре́ние; *чишелешне ~у* прибли́зить развя́зку; *картлыкны ~у* прибли́зить ста́рость 5. *перен.* сближа́ть/сбли́зить, сродни́ть, сдружи́ть, подружи́ть *кого-л. с кем-л.* || сближе́ние; *мөнәсәбәтләрне ~у* сбли́зить отноше́ния; сбли́зиться, подружи́ться; *бу вакыйга безне тагын да ~ты* э́то собы́тие ещё сильне́е сбли́зило нас; *~ып күрсәтү* приближа́ть (*об оптических приборах*); *~а төшү* пододвига́ть/пододви́нуть

якына|ю *неперех.* 1. приближа́ться/прибли́зиться, сближа́ться/сбли́зиться, подступа́ть/подступи́ть, бли́зиться, подходи́ть/подойти́, подъезжа́ть; надвига́ться *на кого-что* || приближе́ние, сближе́ние; *аяк тавышлары ~йды* зву́ки шаго́в (шаги́) прибли́зились; *траншеяларга танклар якынлаша* на транше́и надвига́ются та́нки 2. приближа́ться/прибли́зиться, бли́зиться, подходи́ть/подойти́, придвига́ться/придви́нуться (*о времени, событии*); *киту көне ~йды* прибли́зился (подошёл) день отъе́зда, *эшне бетерү срогы ~йды* подошёл срок оконча́ния рабо́ты; *аерылышу ~я* бли́зится расстава́ние 3. *перен.* сближа́ться/сбли́зиться, родни́ться, сродни́ться; сдружа́ться/сдружи́ться, подружи́ться *с кем-л.*

|| сближе́ние; *егетләр үзара бик ~йдылар* ребя́та о́чень сродни́лись ме́жду собо́й; *соңгы вакытта ата улы белән бик ~йды* в после́днее вре́мя оте́ц о́чень сбли́зился с сы́ном □ **~я төшү** пододвига́ться/пододви́нуться, придвига́ться/придви́нуться

якында *нареч.* **1.** бли́зко, недалеко́, невдалеке́, неподалёку, побли́зости, вблизи́, по́дле, ря́дом, во́зле, о́коло, по сосе́дству; *~ гына урман* побли́зости лес; *~ тору* жить вблизи́ **2.** *редко* в ближа́йшее вре́мя, на днях, ско́ро; *~ сайлаулар булачак* в ближа́йшее вре́мя бу́дут вы́боры

якындагы *прил.* **1.** бли́зкий, бли́жний, ближа́йший, близлежа́щий, недалёкий, неда́льний, сосе́дний, окре́стный (*местность, здание и т. п.*); *~ урманда гына булдык* бы́ли то́лько в ближа́йшем лесу́ **2.** *перен.* бли́зкий, ближа́йший, первоочередно́й, неотло́жный, сле́дующий; *~ бурычлар* неотло́жные зада́чи

якынлату *перех. редко см.* **якынайту**

якынлау *неперех.* **1.** пододвига́ться/пододви́нуться **2.** *см.* **якынлашу**

якынлаштыру *перех. см.* **якынайту**

якынлаш|у **1.** 1) приближа́ться/прибли́зиться, подступа́ть/подступи́ть, бли́зиться, подходи́ть/подойти́, подъезжа́ть, пододвига́ться/пододви́нуться, придвига́ться/придви́нуться, надвига́ться/надви́нуться *на кого-что* || приближе́ние, по́дступ, подхо́д 2) приближа́ться/прибли́зиться незаме́тно, подкра́дываться; *әкрен генә ишеккә ~у* ти́хо подкра́дываться к двери́ 3) *перен.* приближа́ться, прибли́зиться, бли́зиться, подходи́ть (*к цели, тайне, открытию и т. п.*); *идеалга ~у* прибли́зиться к идеа́лу **2.** приближа́ться/прибли́зиться, бли́зиться, надвига́ться/надви́нуться, наступа́ть/наступи́ть, подходи́ть/подойти́; придвига́ться/придви́нуться *разг.* (*о времени, событии*), гото́виться, назрева́ть (*о событии*); *хәлиткеч минутлар ~а* приближа́ются реша́ющие мину́ты; *кризис ~а* назрева́ет кри́зис; *кич ~ты* надви́нулся ве́чер; *аерылышыр минутлар ~а* бли́зятся мину́ты расстава́ния **3.** *перен.* сближа́ться/сбли́зиться, станови́ться/стать бли́зким; родни́ться, сродни́ться, сдружа́ться/сдружи́ться, подружи́ться *с кем-л.*; *поездлар саны йөзгә ~ты* коли́чество поездо́в приближа́ется к ста □ **~у юлы** по́дступ

якынлы|к *сущ.* **1.** *в разн. знач.* бли́зость; *шәһәр ~гы* бли́зость го́рода; *җәй ~гы* бли́зость ле́та; *карашлар ~гы* бли́зость взгля́дов; *тәрҗемәнең оригиналга ~гы* бли́зость перево́да к оригина́лу **2.** бли́зость, бли́зкие отноше́ния, дру́жба; инти́мность

якыннан *нареч.* **1.** бли́зко; с бли́зкого расстоя́ния; *~ гына кош очып китте* о́чень бли́зко пролете́ла пти́ца; *ераккарак куйсаң ~ алырсың* (*погов.*) да́льше поло́жишь, бли́же возьмёшь; да́льше спря́чешь, скоре́е найдёшь **2.** бли́зко, хорошо́; подро́бно, дета́льно; *план белән ~ танышу* подро́бно ознако́миться с пла́ном; *~ катнашы белән* при ближа́йшем уча́стии *кого-л.*; *мин аны ~ белмим* я его́ бли́зко (хорошо́) не зна́ю; *~ таныш кеше* бли́зко знако́мый челове́к □ **~ гына күрү** близору́кость

якын-тирә *сущ. собир.* **1.** окре́стности *чего-л.*, окруже́ние; то, что располо́жено вблизи́, побли́зости, неподалёку; *лагерьның якын-тирәсе* окре́стности ла́геря; *якын-тирәдә кеше күренми* побли́зости никого́ нет **2.** *перен. разг.* окружа́ющая среда́, лю́ди; бли́зкие; *якын-тирә нәрсә әйтер бит?* что ещё ска́жут бли́зкие? || *прил.* **1.** окре́стный, окружа́ющий; *якын-тирә авыллар* окре́стные дере́вни **2.** *перен.* бли́зкий, знако́мый; окружа́ющий; *якын-тирә кешеләр* бли́зкие лю́ди

якын-тирәдә *нареч.* побли́зости, вблизи́; неподалёку; *якын-тирәдә бер кем дә күренми* побли́зости никого́ не ви́дно

якын-тирәдәге *прил.* **1.** окре́стный, близлежа́щий, ближа́йший, сосе́дний (*о местности, здании и т. п.*); *якын-тирәдәге завод-фабрикалар* близлежа́щие заво́ды и фа́брики **2.** *в знач. сущ.* **якын-тирәдәгеләр** окружа́ющая среда́; бли́зкие; знако́мые; *якын-тирәдәгеләр киңәше белән* по сове́ту бли́зких

якынтын *нареч.* **1.** бли́зко; *~ килү* подходи́ть бли́зко **2.** *перен.* по-дру́жески; *~ сөйләшү* разгова́ривать по-дру́жески

якы́нча *нареч.* **1.** приблизи́тельно, приме́рно; *~ биш сәгать вакыт үтте* прошло́ приме́рно пять часо́в; *~ йөз сум акча тоту* истра́тить приблизи́тельно сто рубле́й || *прил.* приблизи́тельный, приме́рный; *~ саннар* приблизи́тельные ци́фры; *~ исәп-хисап* приблизи́тельные подсчёты; *~ күзаллау* приме́рное представле́ние **2.** *мат.* приближённый, приблизи́тельный; *тигезләмәнең ~ чишелеше* (*мат.*) приблизи́тельное реше́ние уравне́ния □ **~ зурлык** *мат.* приближённая величина́

якынчалы|к *сущ.* **1.** приблизи́тельность, приме́рность; *исәп-хисапның ~гы* приблизи́тельность подсчётов **2.** *мат.* приближе́ние, приближённость, приблизи́тельность; *кыйммәтнең ~гы* приближённость величины́; *~к дәрәҗәсе* сте́пень приближе́ния

як-якка *нареч.* **1.** по сторона́м, в ра́зные сто́роны; *як-якка карану* озира́ться по сторона́м; *чебиләр як-якка сибелделәр* цыпля́та рассы́пались (разбежа́лись) в ра́зные сто́роны **2.** в о́бе сто́роны; *як-якка ачылмалы ишек* открыва́ющаяся в о́бе сто́роны дверь; ство́рчатая дверь **3.** из стороны́ в сто́рону, с бо́ку на́ бок; *як-якка әйләндерү* перевора́чивать с бо́ку на́ бок

ял I *сущ.* **1.** о́тдых; переды́шка (*краткий отдых*); переры́в || выходно́й, нераббчий день; *ял көне* выходно́й (нераббчий) день; *көндезге ял* дневно́й переры́в; *ял итәргә туктау* останови́ться на переры́в **2.** о́тпуск; о́тдых || отпускно́й; *җәйге ял вакыты* пери́од ле́тнего о́тпуска; *ял акчасы* отпускны́е де́ньги □ **ял итеп алу** отдохну́ть, передохну́ть; **ял итү** отдыха́ть; **ял итүче** отдыха́ющий

ял II *сущ. уст.* мзда, вознагражде́ние, пла́та (*за услуги, работу*); *аяк ялы* вознагражде́ние за услу́гу

ял III *сущ.* гри́ва; *ат ялы* лошади́ная гри́ва

яла *сущ.* клевета́; поклёп, наговор; *пычрак яла* гря́зная клевета́ □ **яла ягу (ябу)** оклевета́ть, клевета́ть; возводи́ть/возвести́ клевету́; нагова́ривать *на кого-л.*; **яла ягучы** клеветни́к, клеветни́ца

ялагай *прил.* льсти́вый, подхали́мистый, лаке́йский, зайскивающий, подобостра́стный, раболе́пный; вкра́дчивый; уго́дливый, прислу́жнический || льстец, подхали́м, лаке́й, подли́за, прислу́жник; уго́дник; *~ елмаю* льсти́вая улы́бка; *~ тавыш белән* зайскивающим го́лосом; *~ кеше* раболе́пный челове́к; *~ гадәтләр* подобостра́стные пова́дки

ялагайлан|у *неперех.* льстить *кому-л.*, лаке́йствовать, зайскивать, раболе́пствовать, подли́зываться/подлиза́ться *к кому-л.*, уго́дничать, подхали́мничать || льсти́вость, лаке́йство, подхали́мство, зайскивание, раболе́пство, уго́дничество □ **~ып йөрү** льстить, лаке́йствовать, зайскивать

ялагайланулы *прил.* льсти́вый, зайскивающий, подобостра́стный, раболе́пный, уго́дливый; *~ караш* зайскивающий взгляд; *~ тавыш* льсти́вый (раболе́пный) го́лос

ялагайлануча́н *прил.* скло́нный к подхали́мству

ялагайлануча́нлык *сущ.* скло́нность к подхали́мству, льсти́вость

ялагайланышу *взаимно-совм. от* **ялагайлану**

ялагайлык *сущ.* льсти́вость, подхали́мство, зайскивание, подобостра́стие, подобостра́стность, раболе́пство, прислу́жничество; уго́дничество, уго́дливость □ ~ **итү (күрсәтү)** льстить, подхали́мничать, подли́зываться, зайскивать, уго́дничать

ялама: ялама тоз *спец.* ка́менная соль

яламсак *прил. разг.* ненасы́тный, обжо́ристый; ~ *кеше* ненасы́тный челове́к; обжо́ра

ялан I **1.** *сущ.* откры́тое по́ле; откры́тая равни́на; *яшьләр ~га чыга* молодёжь выхо́дит на луга́ **2.** *разг.* го́лый, лы́сый, откры́тый (*без деревьев, строений и т. п.*); ~ *тау* го́лая (лы́сая) гора́; ~ *җир* го́лая земля́, откры́тая ме́стность □ ~ **кадәр** просто́рный, о́чень большо́й (*зал, кабинет и т. п.*); ~ **мәгә** мак-самосе́йка, ди́кий мак; ~ **эше** полева́я рабо́та

ялан II *нареч. диал. см.* **һаман, һәрвакыт**

яланаяк *нареч.* на бо́су но́гу, на го́лую но́гу, босико́м; ~ *йөрү* ходи́ть босико́м || *прил.* босо́й, босоно́гий, необу́тый, голоно́гий; ~ *малайлар* босоно́гие ма́льчики

яланаяклы *прил.* босо́й, босоно́гий

яланаяктан *нареч.* на бо́су но́гу, на го́лую но́гу, босико́м, с го́лыми нога́ми; ~ *чыгып йөгерү* вы́бежать босико́м

яланбаш *нареч.* без ша́пки, без головно́го убо́ра, с обнажённой голово́й, с непокры́той голово́й; ~ *урамга чыгу* вы́йти на у́лицу без головно́го убо́ра

яланбаштан *нареч. см.* **яланбаш**

яланбашлы *прил.* без ша́пки, без головно́го убо́ра, с непокры́той голово́й, простоволо́сый; ~ *кыз* де́вочка без головно́го убо́ра

ялангала́у *многокр. от* **ялану**

ялангач *прил.* **1.** го́лый, обнажённый, нагой, оголённый (*о теле, частях человеческого тела*); ~ *балалар* го́лые де́ти; ~ *судан курыкмас* (*погов.*) го́лый воды́ не бои́тся; ~ *иңбаш* обнажённое плечо́; ~ *муен* оголённая ше́я **2.** 1) го́лый, оголённый, безли́стный, безли́стый, безли́ственный (*о деревьях*); ~ *ботак* оголённая ве́тка 2) го́лый, оголённый, откры́тый (*о местности, холме*); ~ *тау* лы́сая гора́; ~ *җир* оголённая земля́; откры́тая ме́стность **3.** 1) ниче́м не покры́тый, го́лый; ~ *идәндә йоклау* спать на го́лом полу́ 2) не обста́вленный, не меблиро́ванный; ничем не укра́шенный, го́лый; ~ *бүлмә* необста́вленная (го́лая) ко́мната; ~ *стеналар* го́лые сте́ны **4.** обнажённый, оголённый (*ничем не прикрытый*); ~ *тамырлар* обнажённые ко́рни; ~ *таш кумер катламнары* обнажённые пласты́ ка́менного у́гля; ~ *тимер-чыбык* оголённый про́вод; ~ *кылыч* обнажённый меч **5.** *перен.* неиму́щий, малоиму́щий, нужда́ющийся, обезде́ленный, бе́дный, го́лый *разг.*; *ачлар һәм ~лар турында кайгырту* забо́титься о голо́дных и обезде́ленных **6.** *перен.* го́лый; ~ *фактлар* го́лые фа́кты; ~ *саннар* го́лые ци́фры || *нареч.* голышо́м, нагишо́м, неодётым; раздётым; *урамга ~ чыгу* вы́йти на у́лицу неодётым; *шыр ~ йөрү* ходи́ть совершённо го́лым □ ~ **балык** голе́ц; ~ **килеш** голышо́м, нагишо́м ◊ ~ **калдыру 1.** оста́вить го́лым, нагим, оголи́ть **2.** *перен.* оста́вить го́лым, без ничего́, обобра́ть, обчи́стить; ~ **калу 1.** остава́ться го́лым, нагим, оголи́ться **2.** *перен.* остава́ться без ничего́

ялангачландыру *перех.* оголя́ть/оголи́ть, обнажа́ть/обнажи́ть (*тело, поле, деревья и т. п.*) || оголе́ние, обнаже́ние

ялангачландырылу *страд. от* **ялангачландыру**

ялангачлан|у *перех.* оголя́ться/оголи́ться, обнажа́ться/обнажи́ться; *агач тамырлары ~ган* ко́рни дере́вьев обнажи́лись

ялангачла́у *перех. см.* **ялангачландыру**

ялангачлы|к *сущ.* **1.** обнажённость, нагота́, оголённость **2.** *перен.* бе́дность, нищета́, нужда́, обезде́ленность **3.** оголённость, обнажённость (*местности, деревьев и т. п.*) **4.** обнажённость, оголённость (*корней деревьев, пластов каменного угля и т. п.*)

яланкул *нареч.* **1.** го́лыми рука́ми; без рукави́ц **2.** *перен.* 1) без инструме́нта, го́лыми рука́ми (*что-то сделать*) 2) без ору́жия

яланлык *сущ.* откры́тая ро́вная ме́стность (*без насаждений и построек*), равни́на, по́ле

яланнос *нареч.* без ве́рхней оде́жды; ~ *йөрү* ходи́ть без ве́рхней оде́жды, ходи́ть неодётым

ялантән *нареч.* нагишо́м, голышо́м; ~ *йөрү* ходи́ть нагишо́м || *прил.* го́лый, нагой, неодётый, раздётый; ~ *кешеләр* раздётые (го́лые, неодётые) лю́ди

ялану 1. *страд. от* **ялау I 1 2.** *возвр.* обли́зываться/облизну́ться

ялан-япан *сущ. разг. см.* **яланлык**

ялату *понуд. от* **ялау** I 1 дава́ть/дать возмо́жность лиза́ть, облиза́ть; *бозауны әнисеннән ~* дать возмо́жность коро́ве облиза́ть телёнка

ял|ау I *перех.* **1.** лиза́ть, вылизывать/вы́лизать, обли́зывать/облиза́ть, сли́зывать/слиза́ть || лиза́ние, обли́зывание; *иреннәрне ялау* обли́зывать гу́бы; *кашыкны ялау* лиза́ть ло́жку; *песи баласын ялый* ко́шка обли́зывает котёнка **2.** *перен. разг.* вылизывать/вы́лизать, тща́тельно вы́чистить; *түтәллар ялаган кебек чиста* гря́дки чи́стые, сло́вно вы́лизаны **3.** *перен.* лиза́ть, сли́зывать/слиза́ть, каса́ться, покрыва́ть, обдава́ть (*волной, пламенем и т. п.*); *ялкын түбәне ялый башлады* пла́мя на́чало лиза́ть кры́шу; *дулкыннар кыяны ялый* во́лны ли́жут скалу́ **4.** *прост.* (*обычно пренебр.*) лиза́ть, целова́ть || лиза́ние; *баласын ялап кына тора* всё ли́жет своего́ ребёнка; *түрәләрнең табанын ялау* лиза́ть пя́тки нача́льству □ **ялап алу** лизну́ть, облизну́ть, слизну́ть; **ялап бетерү** вы́лизать, слиза́ть; **ялап кую** лизну́ть, облизну́ть, слизну́ть ◊ **ялап куйган кебек** о́чень чи́сто (гла́дко)

ялау II *сущ.* **1.** *ист.* ма́ленький флажо́к и́ли кисть на верху́шке ша́пки у во́инов как знак отли́чия **2.** *уст. см.* **байрак**

ялау III *сущ. диал.* ве́шалка, застёжка (*на одежде*), пе́телька (*для застёгивания, пристёгивания*)

ялаштыргалау *многокр. от* **ялаштыру** поли́зывать, и́зредка лиза́ть, иногда́ лиза́ть

ялаштыру *многокр. от* **ялау** I

ялаш|у 1. *взаимно-совм. от* **ялау** I **2.** *перен.* целова́ться; *дуслар талашсалар да, ~алар* (*погов.*) ми́лые бранятся, то́лько те́шатся

ялбыр *прил. диал.* косма́тый, кудла́тый; ~ *баш* мохна́тая голова́; ~ *чәч* косма́тые во́лосы

ялбырда́|у *неперех.* **1.** развева́ться (*о лохмотьях, космах и т. п.*) **2.** разлохма́титься; *~ган кием* разлохма́тившаяся оде́жда **3.** *диал. см.* **җилферде́ү**

ялварту *понуд. от* **ялвару**

ялвар|у *неперех.* моли́ть, умоля́ть/умоли́ть, заклина́ть, проси́ть, упра́шивать/упроси́ть (*униженно*), кла́няться *кому* || мольба́, заклина́ние, упра́шивание □ **~ып сорау** упра́шивать

ялварулы *прил.* с мольбо́й, выража́ющий мольбу́, про́сьбу; ~ *тавыш* го́лос с мольбо́й

ялварыну *возвр.-страд. от* **ялвару** обраща́ться с мольбо́й

ялган *прил.* **1.** ло́жный, лжи́вый, обма́нный, неправди́вый; притво́рный, мни́мый; ~ *юллар белән* обма́нным спо́собом; ~ *авыру* мни́мый больно́й; ~ *вәгъдә* притво́рное обеща́ние; ~ *хәбәрләр* неправди́вые (ло́жные) све́дения; ~ *атака* ло́жная ата́ка || *сущ.* ложь, обма́н, непра́вда, измышле́ния; враньё, фальшь; *болар барысы да* ~ всё э́то ложь, враньё; ~*ы ачылды* обнару́жилась ложь (непра́вда); ~ *белән ерак китә алмассың* (*посл.*) на обма́не далеко́ не уе́дешь **2.** подде́льный; подло́жный, фальши́вый, фикти́вный; ~ *документ* фикти́вный докуме́нт; ~ *акча* фальши́вые де́ньги; ~ *паспорт* подло́жный па́спорт **3.** *в составе сложных слов переводится компонентом* лже-; ~ *тәгълимат* лжеуче́ние; ~ *шаһит* лжесвиде́тель || *нареч.* ло́жно, лжи́во, неправди́во, притво́рно □ ~ **катыштыру (кушу)** приви́рать; ~ **сүз** брехня́; ~**га чыгу** оказа́ться ло́жью (непра́вдой, обма́ном) ◊ ~ **капчыгы** лгун, лжец, врун, обма́нщик; ~**ын тоту (ачу)** уличи́ть во лжи, обнару́жить ложь (непра́вду)

ялганл|а́у *неперех.* **1.** лгать, солга́ть, обма́нывать/обману́ть, врать, навра́ть, привира́ть, завира́ться; говори́ть ложь, непра́вду; криви́ть душо́й || ложь, обма́н, враньё; *бер ~асаң, гомер буе ышанмаслар* (*погов.*) раз солга́л, на век лгуно́м стал **2.** лгать, налга́ть, клевета́ть *на кого*; *сез аңа карата ~ыйсыз* вы клеве́щете на него́

ялганлаштыру *многокр. от* **ялганла́у**

ялганлашу 1. *взаимно-совм. от* **ялганла́у 2.** *неперех. см.* **ялганла́у 1**

ялганлы|к *сущ.* **1.** ло́жность, лжи́вость, неправди́вость; *хәбәрнең ~гы* неправди́вость сообще́ния; *сүзләрнең ~гы* ло́жность слов **2.** фальши́вость, подде́льность; *документларның ~гы ачылды* обнару́жилась подде́льность докуме́нтов **3.** *разг.* ложь, обма́н; ~*к белән* ло́жью (обма́ном)

ялганма *сущ.* **1.** *бот.* приво́й; *алмагачтагы* ~ приво́й на я́блоне **2.** соедине́ние, сраще́ние; *фразеологик* ~ фразеологи́ческое сраще́ние || *прил.* **1.** *бот.* приви́тый; ~ *ботак* приви́тая ве́тка **2.** приставно́й, накладно́й; ~ *толым* накладна́я коса́ **3.** соединённый, сращённый; *торбаның ~ урыннары* соединённые места́ трубы́

ялганмалы *прил.* **1.** *спец.* агглютинати́вный; ~ *телләр* агглютинати́вные языки́ **2.** *бот.* приви́тый; ~ *груша* приви́тая гру́ша

ялганмалылы|к *сущ. лингв.* агглютинати́вность; *татар теленең ~гы* агглютинати́вность тата́рского языка́

ялган|у *страд.-возвр. от* **ялга́у 1.** *страд.* присоединя́ться, соединя́ться, скрепля́ться, свя́зываться, сопряга́ться *книжн.*; *чылбырлар ~ган* це́пи соединены́; *өйгә ~ып салынган мунча* пристро́енная к до́му ба́ня; *тимерчыбык ике урында ~ган* про́волока скреплена́ в двух места́х **2.** наставля́ться, надставля́ться; *күлмәк ике урыннан ~ган* пла́тье в двух места́х наста́влено **3.** *возвр.* присоединя́ться/присоедини́ться, подключа́ться/подключи́ться, устана́вливаться/установи́ться || присоедине́ние, подключе́ние, установле́ние (*связи и т. п.*); *телефон ~ды* подключи́лся телефо́н **4.** сра́щиваться/срасти́ться, срастáться/срасти́сь (*о костях, секциях труб, кабеле и т. п.*) || сра́щивание, срастáние, сращéние; *җәрәхәт кырыйлары ~ды* края́ ра́ны сросли́сь; *сынганнан соң аякның ~уы* срастáние ноги́ по́сле перело́ма **5.** *спец.* прививáться/привúться || привúвка; *кыргый алма антоновка белән ~ды* к ди́кой я́блоне привила́сь анто́новка **6.** *перен.* добавля́ться/доба́виться, прибавля́ться/приба́виться || добавле́ние, прибавле́ние; *бер хәбәргә икенче хәбәр ~ды* к одному́ изве́стию доба́вилось друго́е **7.** *лингв.* присоединя́ться/присоедини́ться || присоедине́ние, агглютина́ция; *сүз ясагыч кушымча ~у* присоедине́ние словообразова́тельного а́ффикса

ялганчы *сущ.* лгун, лгу́нья; лжец, враль, врун, вру́нья ◊ ~ **чокыры** *см.* **җилкәсе чокырлы**

ялганчылык *сущ.* лжи́вость; скло́нность ко лжи

ялганыш *сущ. спец.* стык, шов, ме́сто соедине́ния || стыково́й; *палубада ~ урыннары* стыковы́е места́ на па́лубе

ялгату *понуд. от* **ялга́у** 1—5

ялга|у *перех.* **1.** присоедини́ть/присоединя́ть, соедини́ть/соединя́ть, скрепи́ть/скрепля́ть, свя́зывать/связа́ть, сочлени́ть/сочленя́ть *книжн.*, сопряга́ть/сопря́чь *книжн.* || присоедине́ние, соедине́ние, скрепле́ние, свя́зывание, сочлене́ние, сопряже́ние; *взелган бауны ~у* связа́ть разо́рванную верёвку; *механизм өлешләрен ~у* сопряга́ть ча́сти механи́зма **2.** наставля́ть/наста́вить, надставля́ть/надста́вить || наста́вка, надста́вка; *җиңгә тукыма ~у* надста́вить к рукаву́ ткань; *чылбырга бөжәралар ~у* надста́вить к це́пи ко́льца **3.** присоедини́ть/присоединя́ть, подключа́ть/подключи́ть || присоедине́ние, подключе́ние; *электр челтәренә чыбыкны ~у* присоедини́ть про́вод к электри́ческой се́ти; *телефон ~у* подключи́ть телефо́н **4.** сра́щивать/срасти́ть || сра́щивание; *сынган сөякне ~у* (*~п үстеру*) срасти́ть сло́манную кость; *кабель ~у* сра́щивать ка́бель; сраще́ние ка́беля; *трубаларны эретеп ~у* сра́щивать тру́бы сва́ркой **5.** *спец.* прививáть/привúть || привúвка; *сиреньне чыбыкчалап ~у* прививáть сире́нь черенко́м; *кабык астына ~у* прививáть под кору́ **6.** *перен.* соединя́ть/соедини́ть, свя́зывать/связа́ть || соедине́ние, свя́зывание; *сүзне сүзгә ~у* связа́ть сло́во со сло́вом **7.** *перен.* продолжа́ть/продо́лжить, добавля́ть/доба́вить || продолже́ние, добавле́ние; *синең фикереңә ~п, тагын шуны әйтә алам* продолжа́я твоё мне́ние, могу́ ещё сказа́ть сле́дующее **8.** *перен.* присоедини́ть/присоединя́ть, включа́ть/включи́ть, добавля́ть/доба́вить || присоедине́ние, включе́ние, добавле́ние; *соңгы җөмләгә тагын бер сүз ~у* доба́вить к после́днему предложе́нию ещё одно́ сло́во

ялгаулы *прил.* **1.** со швом, со сты́ком; ~ *торба* труба́ со сты́ком **2.** с надста́вкой, надставно́й, со вста́вкой, вставно́й; ~ *җиң* надставно́й рука́в; ~ *итәк* подо́л с надста́вкой **3.** составно́й; ~ *каеш* составно́й реме́нь; ~ *пыяла* составно́е стекло́ **4.** *бот.* с приво́ем, приви́тый; ~ *алмагач* я́блоня с приво́ем; ~ *ботак* приви́тая ве́тка

ялгаулы|к *сущ.* **1.** *спец.* наста́вка, надста́вка; то, что надставля́ется; *җиң ~гы* надста́вка для рукава́ **2.** *бот.* приво́й

ялгаш *сущ. диал.* корыто (*для стирки*); колóда (*для пойла*)

ялгашлану *неперех.* принима́ть/приня́ть фо́рму коры́та; коро́биться, покоро́биться

ялгаштыру 1. *многокр. от* **ялга́у 2.** *разг.* надставля́ть/надста́вить *кое-как* || надста́вка, наста́вка **3.** *разг.* соединя́ть, присоединя́ть, свя́зывать, скрепля́ть *кое-как* || соедине́ние, присоедине́ние, свя́зывание, скрепле́ние

ялгашу 1. *взаимно-совм. от* **ялга́у 2.** *возвр. см.* **ялгану 4, 5**

ялгыз *прил.* 1. одино́чный; одино́кий (*человек, дом, дуб*); ~ *юлчы* одино́кий пу́тник 2. одино́кий, сиротли́вый, бессеме́йный ~ *картлык* одино́кая ста́рость; ~ *хатын* одино́кая (бессеме́йная) же́нщина; ~ *тормыш* сиротли́вая жизнь; ~ *ир-егет* одино́кий (бессеме́йный) мужчи́на; бобы́ль || *в знач. сущ. мн.* **ялгызлар** одино́кие, одино́чки *разг.*; ~*лар тулай торагы* общежи́тие для одино́ких 3. одино́кий, одино́чный; -одино́чка; ~ *һөнәрче* кустарь-одино́чка; ~ *атыш* одино́чная стрельба́; ~ *яшәүче-челек* уединённый о́браз жи́зни 4. единоли́чный; ~ *хуҗалык* единоли́чное хозя́йство || *нареч.* одино́ко, оди́н, сиротли́во, в одино́чку, наедине́; ~ *гына калдык* оста́лись наедине́; ~ *йөрү* ходи́ть в одино́чку; ~ *яшәү* жить одино́ко; жить бобылём; ~ *эш йөртү* де́йствовать в одино́чку □ ~ **ана** мать-одино́чка; ~ **бүре** бирю́к; ~ **идарә итү** единовла́стие, единонача́лие; ~ **хуҗалыкчы** единоли́чник ◊ ~ **башы** оди́н-одинёхонек, оди́н-одинёшенек

ялгыза|к *сущ.* 1. одино́кий, одино́чка, бессеме́йный, бобы́ль *разг.* 2. еди́нственный ребёнок; *аның ~гы күптән үлде* у неё еди́нственный ребёнок давно́ у́мер 3. единоли́чник || единоли́чный; ~ *хуҗалыгы* единоли́чное хозя́йство

ялгызлык *сущ.* одино́чество, уедине́ние, сиротли́вость, сиро́тство || одино́кий, прошедший в одино́честве; *көннән-көн ~ үзен сиздерә* изо дня́ в день одино́чество даёт о себе́ знать; ~ *еллары* одино́кие (проше́дшие в одино́честве) го́ды; го́ды одино́чества □ ~ **исем** *лингв.* и́мя со́бственное

ялгыз-ялгага *сущ. собир.* одино́кие; одино́чки

ялгыз-ятим *прил. разг.* одино́кий, сиротли́вый; *ялгыз-ятим балалар* сиротли́вые де́ти; *ялгыз-ятим карчыклар* одино́кие стару́хи || *нареч. разг.* одино́ко, в одино́честве, в сиро́тстве, сиротли́во; *тормыш ялгыз-ятим үтә* жизнь прохо́дит в одино́честве

ялгыш *сущ.* оши́бка; просчёт, про́мах, оплошность; *тормыштагы ~лар* про́махи (оплошности) в жи́зни; *конспекттагы ~лар* оши́бки в конспе́кте; *сызымдагы ~лар* просчёты в чертеже́ || *прил.* 1. оши́бочный, непра́вильный, невёрный, нето́чный, не соответствующий действи́тельности (*взгляд, расчёт*) 2. поро́чный, ло́жный, искажённый, превра́тный (*путь, пример, способ, поступок и т. п.*) 3. нечая́нный, нево́льный, случа́йный; неумы́шленный, непреднаме́ренный (*ход, шаг*); ~ *хәрәкәт* нечая́нное движе́ние || *нареч.* 1. оши́бочно, непра́вильно, невёрно, ло́жно, искажённо, приврáтно; *сүзне ~ уку* искажённо (непра́вильно) чита́ть сло́во; ~ *кию* наде́ть непра́вильно; ~ *әйтү* сказа́ть невёрно; ~ *аңлау* поня́ть приврáтно 2. нечая́нно, нево́льно, случа́йно; неумы́шленно, непреднаме́ренно; ~ *орынып китү* нечая́нно заде́ть; ~ *бәрелү* случа́йно уда́риться; ~ *сугу* уда́рить нево́льно (неумы́шленно) □ ~ **басу** оступи́ться; ~ **ишетү** ослы́шаться ◊ ~ **карашта булу** ошиба́ться, заблужда́ться; ~ **китү** сби́ться с пути́; ~ **санау** обсчита́ться; ~ **юлга кертү** ввести́ в заблужде́ние, дезориенти́ровать; ~ **юлга керү** 1. допусти́ть оши́бку в рабо́те 2. сби́ться с пути́; идти́ по ло́жному пути́; де́йствовать непра́вильно, оши́бочно

ялгыш-йолгыш *сущ. собир. разг.* оши́бки; *һәркемнең тормышында ялгыш-йолгышлар була* у ка́ждого в жи́зни быва́ют оши́бки

ялгышкала́у *многокр. от* **ялгышу** иногда́ (временáми, вре́мя от вре́мени) ошиба́ться

ялгышлы|к *сущ.* 1. оши́бка, оши́бочность, невéрность, нето́чность, непра́вильность; поро́чность, ло́жность, искажённость, погре́шность; ля́псус (*в работе, написании, речи, действиях, суждениях и т. п.*); *фикер ~гы* оши́бочность мне́ния; ~*к эшләү* сде́лать оши́бку 2. оши́бка, просчёт, про́мах, оплóшность (*в расчётах, изысканиях, планах и т. п.*) ◊ ~**к белән** по оши́бке, невзнача́й; гре́шным де́лом; ~**кка төшү** впасть в заблужде́ние

ялгыштыру *перех.* 1. вводи́ть/ввести́ в заблужде́ние 2. сбива́ть/сбить, пу́тать, спу́тать, запу́тывать/запу́тать; *санаганда ~* сбить при счёте (*в вычислении*); *әйтеп торып ~* запу́тать при подска́зке 3. *разг.* сбива́ться/сби́ться, ошиба́ться/ошиби́ться; *исәпне ~* сби́ться со счёта; ошиба́ться при счёте; *аякны ~* сби́ться с ноги́ (*о ритме*); *көйне ~* сби́ться с мело́дии

ялгыш|у *неперех.* 1. ошиба́ться/ошиби́ться, допуска́ть/допусти́ть (и́ли соверша́ть/соверши́ть) оши́бку; впасть в оши́бку || оши́бка; *эшләгән бер ~а, эшләмәгән гел ~а* (*посл.*) кто рабо́тает — ошиба́ется (оди́н) раз, кто не рабо́тает — всегда́; *аның ~уы аркасында эш барып чыкмады* из-за его́ оши́бки де́ло не пошло́ 2. пу́тать, напу́тать, пу́таться, спу́тываться/спу́таться, сбива́ться/сби́ться, заблужда́ться (*в работе, в речи*) 3. обсчи́тываться/обсчита́ться, сбива́ться/сби́ться со счёта; *бала йөзгә хәтле саный белми әле, ~а* ребёнок ещё не мо́жет счита́ть до ста, сбива́ется со счёта 4. ошиба́ться/ошиби́ться, просчи́тываться/просчита́ться, промáхиваться/промахну́ться, сплохова́ть, плоша́ть, оплоша́ть (*в расчётах, планах*) 5. обману́ться, соста́вить (себе́) невéрное мне́ние (представле́ние) *о ком-чём*; заблужда́ться (*в друге, товарище, начальнике, коллеге, опыте, успехе, исследовании и т. п.*) 6. ошиба́ться/ошиби́ться, обознава́ться/обозна́ться || оши́бка; *син дип торам, юк икән, ~тым* показа́лось — бу́дто ты, но обозна́лся

ялгышучан *прил.* скло́нный ошиба́ться

ялдáу I *перех. диал.* купáть, искупáть лошадéй, скот || купáние лошадéй, скотá

ялдáу II *сущ. диал.* 1. глубóкое мéсто в мéлкой рекé 2. óзеро с протекáющим ручейкóм

я́ле (я әле) *межд.* ну́-ка, а ну́-ка

ялкáу *прил.* 1. лени́вый, неради́вый; с ленцо́й || лентя́й, лени́вец, ло́дырь; бездéльник; ~ *хатын* лени́вая же́нщина; ~ *укучы* неради́вый учени́к; *исәрнең иште булмас, ~ның эше булмас* (*погов.*) у глу́пого не бу́дет това́рища, у лентя́я — рабо́ты; *тырыштан тир кипмәс, ~дан чир китмәс* (*посл.*) на тру́женике пот не вы́сохнет, а ло́дырю всегда́ нездоро́вится || *нареч. чаще* **ялкау гына** 1. 1) лени́во, неохо́тно, не́хотя, без жела́ния 2) лени́во, неохо́тно, неради́во; ~ *эшләү* рабо́тать неради́во; ~ *урыннан тору* неохо́тно встать с ме́ста 2. *перен.* ме́дленно, лени́во (*о течении рек, движении облаков, дыма и т. п.*); *дулкыннар ~ ярга бәрелә́ләр* во́лны лени́во ударя́ются о бе́рег

ялкауландыр|у 1. *понуд. от* **ялкаулану** 2. *безл. никтер ~а* почему́-то лень напа́ла

ялкауран|у *неперех.* 1. лени́ться, лентя́йничать, облени́ться, разлени́ться, ло́дырничать; станови́ться/стать лени́вым, ло́дырем; *балаң булганда ~ып булмый ул* когда́ у тебя́ ребёнок — лентя́йничать не прихо́дится 2. *в знач. нареч.* **ялкауланып** лени́во, неохо́тно, не́хотя, без жела́ния; ~*ып эшләү* рабо́тать не́хотя □ ~**ып бетү** облени́ться

ялкаулык *сущ.* лень, ле́ность, неради́вость, ло́дырничанье; *ярлылыкның башы — ~* (*погов.*) нача́ло

бе́дности — лень; лень — мать всех поро́ков □ **~ка салышу (сабышу)** разлени́ться, преда́ться ле́ни

ялку *диал. см.* **ялыгу**

ялкылда́|у *неперех.* **1.** блесте́ть, блиста́ть, сверка́ть, сия́ть, горе́ть, переliва́ться, искри́ться, игра́ть || блеск, сверка́ние, сия́ние; *алтын алкалар ~вы* блеск золоты́х серёг; *яшен ~у* сверка́ние мо́лнии; *~ган халат* перелива́ющийся хала́т **2.** *перен.* блесте́ть, блиста́ть, отлича́ться, выделя́ться, быть заме́тным || блеск; *булмә бай җиһазлары белән ~п тора* ко́мната бле́щет бога́тым убра́нством □ **~п китү (кую)** сверкну́ть; **~п тору** сверка́ть, сия́ть

ялкын *сущ.* **1.** пла́мя, ого́нь; *~ телләре* языки́ пла́мени; *очкыннан ~ кабыныр* из и́скры возгори́тся пла́мя **2.** *перен.* пла́мя, пыл, страсть, пы́лкость, жар, ого́нь (*о чувстве, ласке и т. п.*); *йөрәк ~ы* страсть се́рдца; *күңел ~ы* пы́лкость души́; *дуслык ~ы* ого́нь дру́жбы; *сөю ~ы* пла́мя любви́

ялкынландыру *прям., перен.* воспламеня́ть/воспламени́ть || воспламене́ние; *учактагы утны ~* воспламени́ть ого́нь на костре́; *күңелне ~* воспламени́ть ду́шу

ялкынлан|у *неперех.* **1.** пламене́ть, пыла́ть, полыха́ть *разг.* (*о дровах в печи, камине, о костре и т. п.*) **2.** свети́ться, излуча́ть (испуска́ть) свет, свети́ть, сверка́ть, сия́ть, горе́ть, луци́ться; *кояш нурында болытлар ~а* в луча́х со́лнца сверка́ют облака́ **3.** *перен.* 1) горе́ть, пыла́ть, полыха́ть, сверка́ть, блесте́ть; *аның бит урталары, күзләре ~алар* у него́ щёки, глаза́ пыла́ют 2) *поэт.* бре́дить, загоре́ться, горе́ть, жить, отдава́ться/отда́ться со стра́стью (*целиком, всецело*) **4.** *в знач. нареч.* **ялкынланып** воодушевлённо, с воодушевле́нием, вдохнове́нно, с вдохнове́нием, пы́лко; *~ып сөйләү* говори́ть вдохнове́нно; *~ып сөю* пы́лко люби́ть; люби́ть пы́лкой любо́вью

ялкынлы *прил.* **1.** с пла́менем, пыла́ющий, полыха́ющий; *~ кояш нурлары* пыла́ющие со́лнечные лучи́; *~ ут* ого́нь с пла́менем **2.** *перен.* пла́менный, пы́лкий, горя́чий, стра́стный, жгу́чий, жа́ркий; *~ мәхәббәт* стра́стная любо́вь; *~ тойгылар* пы́лкие чу́вства; *~ сәлам* пла́менный приве́т **3.** *перен.* стра́стный, пы́лкий, горя́чий (*организатор, оратор и т. п.*)

ялкынлы|к *сущ.* пла́менность, пы́лкость, стра́стность, горя́чность, пыл, задо́р; *эштәге ~к* задо́р в рабо́те; *хыялларның ~гы* пы́лкость воображе́ния

ялкынсын|у *неперех. мед.* воспаля́ться/воспали́ться || воспале́ние; *үпкәләр ~уы* воспале́ние лёгких; *күзләр ~ды* воспали́лись глаза́; *урта колак ~уы* воспале́ние сре́днего у́ха

ялкыттыру *неперех.* **1.** *понуд. от* **ялкыту** **2.** *безл. см.* **ялкыту** 1

ялкыт|у *редко безл.* **1.** надоеда́ть/надое́сть (*о какой-л. деятельности, работе*); *гел бер эш ~а* однообра́зная рабо́та надоеда́ет **2.** *безл.* ***~а*** (*~ты*) надое́ло; опроти́вело

ялланма *прил. диал. см.* **яллы** I

яллану *неперех.* нанима́ться/наня́ться, вербова́ться, завербова́ться, подряжа́ться/подряди́ться; *төньякка эшкә ~* вербова́ться на се́вер; *печән чабарга ~* наня́ться коси́ть се́но

яллату *понуд. от* **яллау**

яллау *перех.* **1.** нанима́ть/наня́ть, вербова́ть, завербова́ть, подряжа́ть/подряди́ть || наём, вербо́вка, подря́д; *ремонт ясарга кеше ~* наня́ть челове́ка для ремо́нтных рабо́т **2.** 1) нанима́ть/наня́ть, брать/взять (*что-л. на прокат*); *көймә ~* наня́ть ло́дку 2) *редко* снима́ть/снять; *дача ~* снять да́чу

яллаучы *сущ.* нанима́тель, вербо́вщик, вербо́вщица; *эшчеләр ~* вербо́вщик рабо́чих

яллы I *прил.* наёмный; *~ хезмәт* наёмный труд; *~ эшчеләр* наёмные рабо́чие

яллы II *прил.* **1.** име́ющий гри́ву, с гри́вой **2.** грива́стый; *~ бүре* грива́стый волк

ялмавыз *сущ.* **1.** *миф.* чудо́вище, мифи́ческое существо́ (*пожирающее всё, что попадается ему на глаза*) **2.** *перен., прост.* обжо́ра; ненасы́тный

ялман|у *неперех. разг.* **1.** *см.* **ялану** **2.** обли́зывать/облиза́ть; за́риться, поза́риться *на что-л.*, смотре́ть (гляде́ть) с за́вистью *на что-л.*; *ашаучыларга карап ~ып утыру* за́риться на обе́дающих **3.** *перен.* обли́зываться/облиза́ться; предвкуша́ть, жела́ть, наде́яться *на что-л.* ◊ **~ып йөрү** верте́ться *около кого-чего* (*с надеждой на что*)

ялма́|у *перех.* **1.** бы́стро сли́зывать **2.** бы́стро есть, съеда́ть; *~п йотар* (*погов.*) прогло́тит и ещё облизнётся

ялмача *сущ. бот.* скабио́за (*травянистое растение*)

ялпак **1.** *прил. диал. см.* **җәлпәк** **2.** *см.* **ялпы** 1

ялпакландыр|у *понуд. от* **ялпаклану** *диал. см.* **җәлпәкләндерү**

ялпаклан|у *неперех. диал. см.* **җәлпәкләнү**

ялпаю *неперех. диал.* **1.** *см.* **ялпаклану** **2.** скособо́читься; накрени́ться на оди́н бок

ялпы *прил.* **1.** пло́ский и широ́кий (*земля, равнина*) **2.** *ист.* о́бщий для не́скольких родо́в, племён (*пастбище*)

ялпылык *сущ. диал.* **1.** пло́скость **2.** пло́ская равни́на; ро́вное плато́

ялсыз *нареч.* без выходны́х; безостано́вочно, не остана́вливаясь, не прекраща́я, беспреры́вно (*работать, читать, косить, плясать и т. п.*)

ялт **1.** *подр.* вспы́шке све́та **2.** *в знач. нареч.* вдруг, внеза́пно; бы́стро, ре́зко; *ялт сикереп тору* бы́стро вскочи́ть; *башын ялт (итеп) күтәрде* ре́зко по́днял го́лову **3.** *в функ. сказ.* хлоп, шлёп; *яңагына ялт* шлёп по щеке́; *күземә бер уч туфрак ялт!* в глаз горсть земли́ хлоп! ◊ **ялт итеп (иттереп)** о́чень бы́стро, ту́т же, момента́льно, ре́зко; **ялт итеп тору** **1.** быть чи́стым, блесте́ть, сверка́ть (*об одежде, обуви, доме, полах, мебели и т. п.*) **2.** выделя́ться, броса́ться в глаза́ (*среди других предметов, вещей, людей*); **ялт иттерү** **1.** сде́лать о́чень бы́стро, момента́льно, в оди́н моме́нт **2.** о́чень бы́стро вы́пить, съесть **3.** чи́стить, сде́лать чи́стым, блестя́щим **4.** бы́стро, ре́зко дать пощёчину *кому-л.*; **ялт итү (итеп китү)** сверкну́ть (*о молнии*)

ялт-йолт *подр.* поблёскиванию, ча́стым вспы́шкам све́та □ **ялт-йолт итү (килү)** **1.** мерца́ть, поблёскивать вре́мя от вре́мени || поблёскивание, мерца́ние **2.** блесте́ть, сверка́ть, искри́ться, игра́ть (*о стекле на солнце и т. п.*) **3.** *перен.* бе́гать (*о глазах*); **ялт-йолт карау (карану)** бы́стро огля́дываться, озира́ться; **ялт-йолт карашу** бы́стро перегляну́ться

ялтыр I *прил.* **1.** блестя́щий, с блёстками; *~ кара чәч* блестя́щие чёрные во́лосы; *~ итекләр* блестя́щие сапоги́; *~ күлмәк* пла́тье с блёстками **2.** блестя́щий, бе́гающий (*о глазах*) **3.** *перен.* лы́сый; *~ баш* лы́сая голова́

ялтыр II *сущ. зоол.* зла́тка (*вид жука*)

ялтыр III *подр.* **1.** бле́ску мо́лнии, зарни́цы **2.** *прост.* внеза́пному уда́ру, внеза́пной пощёчине □ **~итү** блесну́ть

ялтыравы|к *сущ.* **1.** блеск, блёстки, лоск; *алтын ~гы* блеск зо́лота; *фосфорлы ~клар* фо́сфористые блёстки **2.** гля́нец, глазу́рь, мурава́, поли́ва; обли́вка; *чынаякны*

~к белән каплау ча́шку покры́ть глазу́рью; *~к йөгертү* глянцева́ть, наглянцева́ть, глазирова́ть, мура́вить; покрыва́ть/покры́ть глазу́рью, гля́нцем **3.** *перен.* лоск; *тышкы ~к* вне́шний лоск || *прил.* **1.** блестя́щий, глянцеви́тый, гля́нцевый, лощёный, лосня́щийся, лосни́стый *разг.*; с ло́ском, сверка́ющий; *~к итекләр* сапоги́ с ло́ском; *ап-ак ~к тешләр* бе́лые-пребе́лые блестя́щие зу́бы; *~к кәгазь* лощёная бума́га; *~к сәдәф* блестя́щая пу́говица **2.** сверка́ющий, блестя́щий, блиста́ющий, сия́ющий, горя́щий, искря́щийся, искри́стый (*снег, драгоценный камень, взгляд и т. п.*) **3.** *перен.* блестя́щий, лосня́щийся, лосни́стый *разг.*, упи́танный; *~к битле* с лосни́стым (упи́танным) лицо́м □ **~к коңгыз** *зоол.* светлячо́к

ялтыравыклан|у *возвр. от* **ялтыравыкла́у 1.** де́латься, сде́латься блестя́щим **2.** *в знач. прил. спец.* **ялтыравыкланган** обливно́й, поли́венный, поли́ванный, глазуро́ванный; покры́тый обли́вкой, поли́вой; *~ган чүлмәк* обливно́й горшо́к; *~ган кувшин* поли́венный кувши́н

ялтыравыклату *перех.* покрыва́ть/покры́ть гля́нцем (глазу́рью, обли́вкой, поли́вой); наглянцева́ть

ялтыравыкла́у *перех. разг.* **1.** *спец.* облива́ть/обли́ть, покрыва́ть/покры́ть гля́нцем (глазу́рью, обли́вкой, поли́вой); *чүлмәкне ~* обли́ть горшо́к глазу́рью **2.** *см.* **ялтырату 1**

ялтыравыклы *прил.* **1.** блестя́щий, сверка́ющий, я́ркий; *~ күзләр* блестя́щие глаза́; *~ уенчыклар* сверка́ющие игру́шки **2.** глянцеви́тый, гля́нцевый, лощёный, лосня́щийся; лосни́стый (*о красивом блеске*), атла́сный; *~ кәгазь* глянцеви́тая (атла́сная) бума́га **3.** *спец.* обливно́й, поли́вный (поли́венный, поли́ванный), глазуро́ванный, покры́тый обли́вкой, поли́вой, глазу́рью; *~ чыныяк* глазуро́ванная ча́шка; *~ значок* поли́вный значо́к □ **~ эйберләр** блёстки

ялтырак *прил. неодобр.* блестя́щий, я́ркий (*только внешне*); *~ кием* я́ркая (*но не дорогая*) оде́жда

ялтыраткыч *сущ. тех.* лощи́лка

ялтыраттыру *понуд. от* **ялтырату**

ялтырат|у *перех.* **1.** освеща́ть/осве́тить, озаря́ть/озари́ть || освеще́ние, озаре́ние; *яшен күкне-җирне ~а* мо́лния освеща́ет не́бо и зе́млю **2.** 1) де́лать, сде́лать блестя́щим, придава́ть/прида́ть блеск, наводи́ть/навести́ лоск, гля́нец || прида́ние бле́ска, наведе́ние ло́ска, гля́нца; *самавырны ~у* вы́чистить самова́р до бле́ска; *туфлиләрне ~у* навести́ лоск на ту́фли 2) *спец.* лощи́ть, вы́лощить, шлифова́ть, отшлифова́ть, полирова́ть, отполирова́ть, наводи́ть/навести́ лоск, гля́нец || лощёние, шлифо́вка, полиро́вка; наведе́ние ло́ска, гля́нца; *паркетны ~у* вы́лощить парке́т; *кәгазьне ~у* лощи́ть бума́гу; *детальне ~у* отшлифова́ть дета́ль **3.** *в знач. нареч.* **ялтыратып** чи́сто, блестя́ще, до бле́ска (*вымыть, убираться, чистить и т. п.*) **4.** *перен.* пока́зывать/показа́ть, обнажа́ть/обнажи́ть, оголя́ть/оголи́ть (*спину, плечо*) || пока́з, обнаже́ние, оголе́ние; *тешләрне ~у* обнажи́ть зу́бы **5.** обнажа́ть/обнажи́ть, вынима́ть/вы́нуть из но́жен (*штык, меч и т. п.*) || обнаже́ние **6.** *перен.* блесте́ть, сверка́ть, игра́ть глаза́ми **7.** *перен. разг.* сту́кнуть, тра́хнуть, дви́нуть (*по щеке*), дава́ть/дать пощёчину **8.** *перен. разг.* бы́стро съесть (вы́пить), слизну́ть; уплета́ть/уплести́; *бер таба бәрәңгене ~у* уплета́ть сковоро́дку карто́шки **9.** *перен. разг.* дать пощёчину □ **~ып кую (җибәрү) 1.** вы́ложить, отполирова́ть **2.** *перен.* слизну́ть, уплести́; **~ып чыгу** отполирова́ть

ялтыратылу *страд. от* **ялтырату** быть доведённым до бле́ска, быть начи́щенным; отшлифо́вываться, отполиро́вываться

ялтыр|а́у *неперех.* **1.** 1) блесте́ть, блиста́ть, свети́ться, сия́ть, сверка́ть, сверкну́ть, и́скри́ться, игра́ть, переliва́ться || блеск, блиста́ние, сверка́ние; *кар бөртекләренең ~авы* сверка́ние снежи́нок; *бармагында йозек ~ый* на па́льце блести́т пе́рстень; *ераста ут ~ый* вдали́ све́тится ого́нь; *өмет чаткысы ~ады* блесну́ла и́скра наде́жды; *һәр ~аган алтын тугел* (*погов.*) не всё то зо́лото, что блести́т 2) *перен.* сия́ть, сверка́ть (*о глазах*) **2.** блесте́ть, лосни́ться, отсве́чивать, отсве́чиваться (*о гладкой поверхности*) || блеск, о́тсвет; *ефәк ~авы* блеск шёлка; *пеләш башы ~ый* лы́сая голова́ его́ лосни́тся; *полировкалы өстәл кояшта ~ый* полиро́ванный стол отсве́чивает на со́лнце **3.** 1) блесте́ть, свети́ться, прогля́дывать (*о чём-л. светлом*); *башында ак чәчләр ~ый* на голове́ просве́чивают седы́е во́лосы 2) свети́ться, видне́ться *сквозь что-л.*, просве́чивать □ **~ап китү** блесну́ть, сверкну́ть; **~ап (~ый) торган** блестя́щий, сверка́ющий; **~ап тору** блесте́ть, блиста́ть, сверка́ть, сия́ть

ялтырбаш *прил. разг.* лы́сый, плеши́вый || лы́сый, челове́к с лы́сой голово́й

ялтыр-йолтыр *подр.* спо́лохам, поблёскиванию мо́лнии, зарни́цы

ялтыркүз *сущ. зоол.* златогла́зик, нестря́к (*жук с пёстрыми надкрыльями*)

ялчы *сущ.* **1.** *уст.* наёмник, наёмный рабо́тник (рабо́чий); наёмщик, наймит, батра́к; *тегермәндәге ~* батра́к на ме́льнице; *~лар яллау* нанима́ть наёмников **2.** *перен. пренебр.* слуга́, наёмник, холу́й, наймит; *капитал ~лары* наёмники капита́ла; *директор ~сы* дире́кторский холу́й; *фашист ~лары* фаши́стские наймиты

ялчылык *сущ. ут.* положе́ние наёмника (наёмщика, наймита, батрака́) □ **~ итү** батра́чить

ялы|гу *неперех.* **1.** устава́ть/уста́ть, утомля́ться/утоми́ться, изнуря́ться/изнури́ться || уста́лость, утомле́ние, изнуре́ние; *халыкка хезмәт итәм ~кмый* служу́ наро́ду не устава́я; *ат ерак юлдан ~ккан* ло́шадь утоми́лась от да́льней доро́ги **2.** утомля́ться/утоми́ться *от чего*, надоеда́ть/надое́сть, наску́чить, опроти́веть || утомле́ние; *лекцияне ~кмый гына тыңлау* слу́шать ле́кцию без утомле́ния; *балалар күп сүздән ~гып беттеләр* де́тям наску́чило многосло́вие

ялык-йолык *подр.* сверка́нию, перелива́нию све́та || *прил.* сверка́ющий, перелива́ющийся; *ялык-йолык кулмәк* перелива́ющееся пла́тье; *ялык-йолык алкалар* сверка́ющие се́рьги; *ялык-йолык җемелдәү* мерца́ть перелива́ясь □ **ялык-йолык итү (килү)** перелива́ться, сверка́ть, игра́ть все́ми цвета́ми

ялыкканлык *сущ.* уста́лость, утомлённость; *һәр хәрәкәтендә ~ сизелә* в ка́ждом его́ движе́нии чу́вствуется утомлённость

ялыктыргыч *прил.* **1.** утоми́тельный; *~ авыр эш* утоми́тельная тяжёлая рабо́та; *~ сәяхәт* утоми́тельное путеше́ствие **2.** утоми́тельный, ну́дный, ску́чный; *~ сөйләнүләр* ну́дные разгово́ры; *~ тынлык* утоми́тельная тишина́; *~ кеше* ску́чный (ну́дный) челове́к

ялыктырту *понуд. от* **ялыктыру**

ялыктыр|у *перех.* **1.** утомля́ть/утоми́ть || утомле́ние; *озын юл ~ды* дли́нная доро́га утоми́ла; *көчле кояш күзләрне ~ды* я́ркое со́лнце утоми́ло глаза́ **2.** утомля́ть/утоми́ть, надоеда́ть/надое́сть, докуча́ть, наску́чить,

опроти́веть || утомле́ние; *юк-бар сораулар белән ~у* докуча́ть (надоеда́ть) пустяко́выми вопро́сами □ **~а торган** 1. утоми́тельный 2. надое́дливый, доку́чливый

ялынгала́у *многокр. от* **ялыну** иногда́, и́зредка, вре́мя от вре́мени упра́шивать, умоля́ть, кла́няться

ялындырт|у *понуд. см.* **ялындыру**

ялындыру *понуд. от* **ялыну** заставля́ть, упра́шивать себя́, лома́ться, упря́миться

ялын|у *неперех.* моли́ть, умоля́ть, проси́ть, заклина́ть, (уни́женно) кла́няться *кому* || мольба́, про́сьба, заклина́ние; *~у тавышы белән* го́лосом мольбы́; *~ып күндерү* упра́шивать, упроси́ть; *~ып сорау* упра́шивать/упроси́ть

ялынулы *прил.* умоля́ющий, выража́ющий мольбу́, про́сьбу; *~ караш* умоля́ющий взгляд; *~ тавыш* умоля́ющий го́лос; *~ кыяфәт* вид, выража́ющий мольбу́

ялыну-ялвару *неперех. разг.* вся́чески умоля́ть, настоя́тельно проси́ть, заклина́ть, уни́женно моли́ть, кла́няться || настоя́тельная про́сьба, заклина́ние; *ялыну-ялварулар да аны йомшартмады* да́же настоя́тельные про́сьбы (заклина́ния) не смягчи́ли его́

ялынчак *прил. разг.* тот, кто име́ет привы́чку проси́ть, умоля́ть

ялынчаклык *сущ. разг.* привы́чка умоля́ть, проси́ть

ялыныч *сущ.* про́сьба, мольба́, заклина́ние; *зур ~ белән мөрәҗәгать итү* обраща́ться с большо́й про́сьбой; *ярлы көне — ~* (*посл.*) в бе́дности жить — всё вре́мя проси́ть □ **~ калмау** не нужда́ться *в ком-л., чём-л.*; **~ төшү** нужда́ться *в ком-л., чём-л.*, в *чьей-л.* по́мощи

ялынычлы *прил. см.* **ялынулы**

ям *сущ. ист.* почто́вая ста́нция; ста́нция, где меня́ли лошаде́й □ **ям өе** ям (*почтовая станция или посёлок с почтовой станцией, где проезжающие меняли лошадей*); **ям чабу** 1. выполня́ть ямску́ю пови́нность 2. ямщи́на 3. ямско́й; **ям чабу йөкләмәсе** ямска́я пови́нность; ямщи́на

ямал|у *страд. от* **яма́у** 1. починя́ться, быть починённым; лата́ться *разг.*, быть зала́танным; *киемнәр юылды, ~ды* оде́жда пости́рана, почи́нена 2. заживáть/зажи́ть, закрыва́ться, зата́гиваться/затяну́ться, зарубцо́вываться/зарубцева́ться (*о ране, язве и т. п.*) || заживле́ние, заживáние; *җәрәхәт ~ды диярлек* ра́на почти́ затяну́лась

яман *прил.* 1. плохо́й, нехоро́ший, скве́рный, дурно́й, худо́й, дрянно́й, него́дный; *~ эш* скве́рное де́ло; скве́рный посту́пок; *~ ис* дурно́й за́пах; *~ кешеләр* нехоро́шие лю́ди; *~ урнэк* дурно́й приме́р; *~ хәбәр озын аяклы* (*погов.*) до́брая сла́ва лежи́т, а худа́я по све́ту бежи́т; *~ чир тиз йога* (*погов.*) дурно́й приме́р зарази́телен (*букв.* плоха́я боле́знь бы́стро пристаёт) 2. злой, зло́бный, ехи́дный, недо́брый; *~ ният* злой у́мысел, зло́е наме́рение; *~ телле* с ехи́дным языко́м; *~ кеше* недо́брый (зло́бный, злой) челове́к 3. *в функ. сказ.* тяжело́, тя́гостно; *сине аңламаулары ~* когда́ тебя́ не понима́ют — тя́гостно || *нареч.* 1. пло́хо, нехорошо́, скве́рно; *~ сөйләү* говори́ть пло́хо (нехорошо́) 2. *разг.* о́чень, сли́шком, ужа́сно, си́льно, сверх, кра́йне, чрезме́рно; *~ зур* сли́шком большо́й; *~ караңгы* о́чень темно́; *~ кимәтү* чрезме́рно уме́ньшить; *~ кыйбат* о́чень до́рого □ **~ чир** *разг.* рак, боле́знь ра́ка; **~ шеш** злока́чественная о́пухоль, саркóма ◊ **~ күз** дурно́й глаз; **~ тел** 1. спле́тник, спле́тница 2. скверносло́в; **~ телләнү** 1. спле́тничать 2. скверносло́вить, выража́ться нецензу́рными слова́ми

яманат *сущ.* 1. дурна́я сла́ва, бесслáвие, бесче́стие 2. спле́тни, нехоро́шие ве́сти (*о человеке*) □ **~ калдыру, ~лы итү** позо́рить, поро́чить, компромети́ровать; **~ы чыккан** опоро́ченный, опозо́ренный, скомпромети́рованный; **~ын сату** прослáвить, распуска́ть дурну́ю слáву *о ком-л.*, бесслáвить *кого-л.*

яманатлы *прил.* име́ющий дурну́ю слáву, опоро́ченный, опозо́ренный, скомпромети́рованный

яманлан|у I *неперех.* станови́ться/стать плохи́м, нехоро́шим, скве́рным, дурны́м; *кешеләр ~а бара* лю́ди стано́вятся всё бóлее плохи́ми

яманлан|у II *страд. от* **яманла́у**

яманлату *понуд. от* **яманла́у** дать возмóжность хули́ть, опоро́чивать/опоро́чить, поноси́ть

яманла́у *перех.* хули́ть, поро́чить, опоро́чивать/опоро́чить, ре́зко осужда́ть, поноси́ть; ха́ять, оха́ивать/оха́ять || хула́, хуле́ние; *кешеләрне ~* хули́ть люде́й; *тәртипне ~* осужда́ть дисципли́ну; *киленне ~* ха́ять неве́стку

яманлашу *взаимно-совм. от* **яманла́у** хули́ть, поро́чить друг дру́га и́ли *кого-л.*

яманлык *сущ.* зло, злодея́ние; плохóе (худóе, дурнóе, скве́рное) де́ло; *~ эшләү* причиня́ть зло; *~лар күп булды* злодея́ний бы́ло доста́точно; *яхшылык тиз онытыла, ~ онытылмый* (*погов.*) добро́ ско́ро забыва́ется, а худóе в па́мяти сохраня́ется □ **~ белән искә алма!** не поминáй ли́хом!

ямансу *прил.* гру́стный, печа́льный, ску́чный, тоскли́вый, невесёлый, зауны́вный, уны́лый (*вид, взгляд, мотив и т. п.*); *никтер ~* что́-то гру́стно, тоскли́во

ямансуландыру *понуд. см.* **ямансулату**

ямансулану *возвр. от* **ямансулау** станови́ться/стать гру́стным; загрусти́ть

ямансулат|у 1. *понуд. от* **ямансула́у** 2. *безл.* гру́стно, печа́льно, ску́чно, тоскли́во, уны́ло; *кичләрен ~а* вечера́ми быва́ет гру́стно

ямансул|а́у *неперех.* 1. грусти́ть, взгрустну́ть, печа́литься, опеча́литься, скуча́ть, тосковáть || грусть, печа́ль, тоска́; *~ама, дустым* не грусти́ (не печа́лься), друг мой 2. *в знач. нареч.* **ямансулап** гру́стно, печа́льно, ску́чно, тоскли́во; *~ап утыру* сиде́ть гру́стным; *~ап йөрү* ходи́ть печа́льным □ **~ап китү** загрусти́ть, затосковáть, заскуча́ть; **~ый башлау** загрусти́ть

ямансулык *сущ.* состоя́ние гру́сти, печа́ли, тоски́, ску́ки, уны́ния

яману *возвр. от* **яма́у** *разг.* чини́ть, почини́ть, лата́ть, залата́ть (*свои вещи*), занима́ться/заня́ться почи́нкой (*своих вещей*) || заня́тие почи́нкой, почи́нка

ямат|у 1. *понуд. от* **яма́у** 2. отдавáть/отда́ть *кому-л.* чини́ть, почини́ть *у кого-л.*; *итек ~у* почини́ть сапоги́ (*у сапожника*) □ **~ып алу** почини́ть (*у сапожника*)

ямау I *перех.* 1. чини́ть, почини́ть, ремонти́ровать, отремонти́ровать, накла́дывать/наложи́ть запла́тку || почи́нка, ремóнт (*одежды и обуви*) 2. *перен. разг.* лата́ть, залата́ть, затыка́ть/заткну́ть ды́ры, бре́ши (*в финансах*) 3. *прост.* вре́зать, залепи́ть (*пощёчину*)

яма́у II *сущ.* 1. запла́та, ла́тка; *~ өстенә ~* запла́та на запла́те, весь зала́танный; *~ салу* наложи́ть запла́ту 2. *разг.* шрам, рубе́ц; *биттәге ~* шрам на лице́

ямаулы *прил.* с запла́той, запла́танный, зала́танный; *~ кием* запла́танная оде́жда; *~ капчык* мешóк с запла́той

ямаулык *сущ.* 1. материа́л, го́дный на запла́ту 2. запла́та; *см. тж.* **яма́у**; наложи́ть запла́ту на пла́тье

ямаштыр|у 1. *многокр. от* **ямау** 2. лата́ть, залата́ть, чини́ть, почини́ть; накла́дывать/наложи́ть запла́ту

как-нибудь, кое-как, кое-где (на одежду, обувь, строение, домашнюю утварь и т. п.)

ямаштыру-йөрмәштерү *перех. разг.* латáть, залатáть, чинúть, починúть, приводúть/привестú в порядóк *кое-как, как-нибудь, кое-где (одежду, обувь, посуду, крышу сарая, дома и т. п.)*

ямашу *взаимно-совм. от* **ямáу I**

ямб *сущ. лит.* ямб; *ямб белән язылган шигырьләр* стихú, напúсанные я́мбом

я́мблы *прил. лит.* ямбúческий; ~ *шигырьләр* ямбúческие стихú

я́ме (йәме) *предик. сл. разг.* лáдно, хорошó, да; *театрга бергә барырбыз, яме?* в теáтр вмéсте пойдём, лáдно?

ямин *сущ. уст. книжн.* клáтва, обéт, зарóк □ ~ **итү** клáсться, давáть клáтву (обéт), клáтвенно обещáть; *алла белән ~ итәмен* клянýсь бóгом

ямчы *сущ. уст.* ямщúк, ямскóй; ~ *хезмәте* ямскáя слýжба; ямскáя повúнность

ямчылык *сущ. ист.* ямщúна || ямскóй, ямщúцкий □ ~ **итү** выполнúть ямскýю повúнность

ямщи|к *сущ. ист.* ямщúк || ямщúцкий; ямскóй; *почта ~гы* почтóвый ямщúк; *~к атлары* ямщúцкие лóшади; *~клар бистәсе* ямскáя слободá

ямь *сущ.* **1.** красотá (*обычно мн.*); прéлести; *җәйге табигатьнең яме* красотá лéтней природы; *авыл тормышының яме* прéлести сéльской жúзни **2.** уют; благоустрóенность; *бүлмә яме* уют кóмнаты; *өйдә бер ямь юк* дóма совсéм нет уюта □ **ямь бирү** украшáть/украсúть, дéлать, сдéлать красúвым; дéлать, сдéлать уютным; **ямь кертү** *см.* **ямь бирү**; **ямь керү** становúться/стать красúвым, уютным; **яме китү (бетү)** становúться/стать некрасúвым; терять прéлесть, красотý; **ямен җибәрү (китерү)** лишáть/лишúть прéлести, красоты́, уюта; испóртить *что-л. (вечер, веселье, свадьбу и т. п.)*

ямьләндер|ү *перех.* **1.** украшáть/украсúть; дéлать, сдéлать красúвым, прекрáсным, прелéстным, живопúсным || украшéние; *мәхәббәт тормышны ~ә* любóвь украшáет жизнь (*делает прекрасным*) **2.** дéлать, сдéлать уютным, благоустрóенным

ямьлән|ү *неперех.* **1.** становúться/стать красúвым, прекрáсным, прелéстным, прúятным; становúться/стать живопúсным; *тормыш ~де* жизнь стáла прекрáсной; *көннәр ~де* дни стáли прелéстными (погóжими); *табигать тагы да ~гән* природа стáла ещё живопúснее **2.** становúться/стать уютным, благоустрóенным □ **~еп китү** **1.** становúться/стать красúвым, живопúсным, прелéстным **2.** становúться/стать уютным, благоустрóенным

ямьләтү *перех. см.* **ямьләндерү**

ямьләү *перех. разг. см.* **ямьләндерү**

ямьле *прил.* **1.** красúвый; прелéстный, прекрáсный; живопúсный (*о пейзаже, виде*); ~ *җирләр* живопúсные (красúвые) местá; ~ *көннәр* прекрáсные дни **2.** уютный, благоустрóенный; ~ *бүлмә* уютная кóмната □ **~ итеп** **1.** красúво, прелéстно, прекрáсно; живопúсно; ~ *яшәү* жить красúво; ~ *итеп ял итү* прекрáсно отдохнýть **2.** уютно, благоустрóенно; ~ *итеп җыештырылган каюта* уютно обстáвленная каюта

ямьләндерү *перех. см.* **ямьләндерү**

ямьлән|ү *неперех. см.* **ямьләнү**

ямьләле|к *сущ.* **1.** красотá, прéлесть; живопúсность; *тирә юньнең ~ге* красотá окрéстности; *җәйнең ~ге* прéлести лéта **2.** уют, благоустрóенность (*комнаты, дома, дачи и т. п.*)

ямьсез *прил.* **1.** некрасúвый, непригóжий, несимпатúчный, неприглядный, невзрáчный; безобрáзный, неказúстый; ~ *тышкы кыяфәт* неприглядная внéшность; ~ *авыл* невзрáчная дерéвня; ~ *күк* невзрáчное нéбо **2.** неуютный, неприя́тный, нехорóший, неблагоприя́тный (*случай, момент и т. п.*); ~ *һава* неблагоприя́тная погóда; ~ *вакыйга* неприя́тное событие; ~ *шартлар* неуютная обстанóвка **3.** некрасúвый, непристóйный, безобрáзный, непозволúтельный, неприéмлемый, неблаговúдный, предосудúтельный (*поступок*); ~ *сүзләр* непристóйные словá **4.** неблагозвýчный, неприя́тный (*для слуха*); ~ *исем* некрасúвое (неблагозвýчное) úмя; ~ *шигырьләр* неблагозвýчные стихú; ~ *тавыш* неприя́тный гóлос || *нареч.* **1.** некрасúво, несимпатúчно, непривлекáтельно, неприглядно, невзрáчно, безобрáзно, неказúсто, дýрно (*выглядеть, ходить, сидеть и т. п.*) **2.** непристóйно, непозволúтельно, непригóже, дýрно, нехорошó (*говорить, ругаться, рассказывать и т. п.*)

ямьсезләндерү *перех.* дéлать, сдéлать некрасúвым, непригóжим, несимпатúчным, неприглядным, невзрáчным, безобрáзным, неказúстым, дурны́м; обезобрáживать/обезобрáзить (*об одежде, шляпе, очках, холоде, загаре, болезни и т. п.*)

ямьсезләнешү *неперех.* пóртить, испóртить отношéния; ругáться, поругáться, поссóриться; *күршеләр белән ~* поссóриться с сосéдями

ямьсезләнү *неперех.* становúться/стать некрасúвым, непригóжим, несимпатúчным, неприглядным, невзрáчным, безобрáзным, неказúстым, дурны́м; *еллар үткәч ~у* с годáми стать некрасúвым; *чәчәкләр ~гән* цветы́ стáли неприглядными

ямьсезләтелү *страд. от* **ямьсезләнү**

ямьсезләтү *перех. разг. см.* **ямьсезләндерү**

ямьсезләү *перех. см.* **ямьсезләндерү**

ямьсезләшү **1.** *взаимно-совм. от* **ямьсезләү** **2.** *перен. разг. см.* **ямьсезләнешү**

ямьсезлек *сущ.* **1.** некрасúвость, непригóжесть, несимпатúчность, безобрáзность, неказúстость (*вида, внешности, лица и т. п.*) **2.** неуютность, неприя́тность, неблагоприя́тность (*обстановки, момента, случая и т. п.*) **3.** некрасúвость, непристóйность, недопустúмость, непозволúтельность, неприéмлемость, неблаговúдность, предосудúтельность (*поведения, поступка, дела и т. п.*) **4.** неблагозвýчность, неприя́тность (*голоса, имени и т. п.*)

ямь-тәм: ямь-тәм тапмау чýвствовать грусть (тоскý, скýку), печáлиться, загрустúть; не находúть удовлетворéния, чýвствовать себя́ бесприю́тным

ямьшәйтелү *страд. от* **ямьшәйтү** быть, стать сплю́щенным, сплю́щиваться/сплю́щиться

ямьшәйтү *перех.* **1.** сплю́щивать/сплю́щить, приплю́снуть, смять, помя́ть, измя́ть (*ведро, кастрюлю, чайник и т. п.*) || сплю́щивание; *эшләпәне ~* сплю́щить (измя́ть, смять) шля́пу **2.** ста́птывать/стоптáть, сбива́ть/сбить (*сапоги, ботинки, тапочки и т. п.*) || ста́птывание **3.** *перен.* искривúть, кривúть, скривúть, покривúть || искривлéние, кривлéние, скривлéние; *авызны ~* скривúть рот

ямьшәю *неперех.* **1.** сплю́щиваться/сплю́щиться, приплю́снуться, смя́ться, помя́ться, измя́ться (*о фуражке, шапке, кружке, ведре и т. п.*) **2.** ста́птываться/стоптáться, сбива́ться/сбúться (*о тапочках, ботинках, сапогах и т. п.*)

ямьшек *прил.* **1.** плóский, сплю́щенный, приплю́снутый, сплю́снутый, смя́тый, помя́тый, измя́тый, мя́тый; ~ *чәйнек* сплю́щенный чáйник; ~ *борын* приплю́снутый

нос **2.** сби́тый, сто́птанный, покриви́вшийся (*об обуви*); *~ чүәкләр* сто́птанные та́почки

ямь-яшел *прил.* о́чень зелёный, зелёный-презелёный; *~ бакча* зелёный-презелёный сад

ян *сущ.* **1.** бок; *янга борылып яту* повернýться на́ бок; *ян белән утыру* сесть бо́ком; *уң янны массажлау* массажи́ровать пра́вый бок; *көймә яны белән борылды* ло́дка повернýлась бо́ком **2.** *в знач. послелога в направит. п.* **янына** к, ко, на; *өстәл янына утыру* сесть к столý; *директор янына керү* войти́ к дире́ктору; *ут янына юнәлү* напра́виться на ого́нь; *минем яныма (янга)!* ко мне! **3.** *в знач. послелога в местно-вр. п.* **янында** у, при, о́коло, во́зле, по́дле, вблизи́; *кое янында* у коло́дца; *учак янында кайнашу* вози́ться о́коло костра́; *шаһитләр янында сорау алу* допра́шивать при свиде́телях **4.** *в знач. послелога* **янындагы** находя́щийся о́коло (во́зле) при-; *вокзал янындагы мәйдан* привокза́льная пло́щадь; *өй янындагы кишәрлек* приуса́дебный уча́сток; *шәһәр янындагы* при́городный **5.** *в знач. послелога в исх. п.* **яныннан** ми́мо, от; *кибет яныннан* ми́мо магази́на; *өстәл яныннан* от (из-за) стола́ || *прил.* боковóй; *ян кесә* боковóй карма́н; *ян ишек* бокова́я дверь; *ян тәрәзә* боковóе окнó □ **янга җигү** запряга́ть/запря́чь в пристя́жку; **янда йөртү 1.** носи́ть при себе́ **2.** води́ть за собóй ◊ **ян бирү 1.** повернýться бóком **2.** сиде́ть бóком и́ли спино́й (оби́девшись); **янга калдыру** эконóмить; сэконóмить; оставля́ть при себе́; **янга калу** эконóмиться, не расхóдоваться

янавыч *сущ.* брус, брусóк, оселóк (*для заточки кос*)

янагай *сущ.* шу́рин (*старший брат жены*)

яналʼу *страд. от* **яна́у** II зата́чиваться, направля́ться; *чалгылар ~ган* кóсы напра́влены

янар *прил.* о́гненный, горя́щий; *~ тау* о́гненная гора́, вулка́н □ **~ йолдыз** *поэт.* метеóр; **~ чәчәк** *бот.* горицве́т

янату *понуд. от* **яна́у** II

яна́у I *неперех.* грози́ть, погрози́ть, угрожа́ть, грози́ться, погрози́ться || угро́за; *өйдән куу белән ~* грози́ться вы́гнать из до́ма; *төрмә белән ~* угрожа́ть тюрьмóй

яна́у II *перех.* точи́ть, заточи́ть, пра́вить, направля́ть/напра́вить || зато́чка, пра́вка; *чалгы ~* точи́ть косý; пра́вить косý

янаулы *прил.* угрожа́ющий; *~ караш* угрожа́ющий взгляд; *~ тавыш* угрожа́ющий го́лос

янаучы *сущ. и прил.* тот, кото́рый угрожа́ет || угрожа́ющий; *суд белән ~лар да булды* бы́ли и угрожа́ющие судóм

янаштыру *многокр. от* **яна́у** и́зредка (иногда́, вре́мя от вре́мени) угрожа́ть

я́нә *нареч.* **1.** ещё, опя́ть, сно́ва, вновь, опя́ть-таки; *янә кыш килде* сно́ва пришла́ зима́; *янә тыңламадың мине* опя́ть меня́ не послýшался || *союз. соедин.* (*употребляется в сложносочин. предл., указывающих на повторяющиеся действия*) сно́ва, опя́ть; *янә җил кузгалды, янә коеп яңгыр ява башлады* сно́ва подня́лся ве́тер, сно́ва начался́ проливно́й дождь □ **~ килеп 1.** и сно́ва, и опя́ть **2.** опя́ть-таки

я́нәдән *нареч.* **1.** *см.* **янә 2.** ещё раз (разóк)

янәсе *вводн. сл.* де́скать, бýдто бы, мол, я́кобы, де; *~, эш майтарып йөри* бýдто бы за́нят де́лом

янәшә *нареч.* **1.** ря́дом, бок о́ бок; *~ яшәү* жить бок о́ бок; *~ бару* идти́ ря́дом **2.** ря́дом, по сосе́дству, бли́зко; *йортларыбыз ~ салынган* дома́ на́ши постро́ены по сосе́дству (ря́дом); *мәктәп ~ генә безгә* шко́ла к нам бли́зко (с на́ми ря́дом) || *прил.* **1.** сме́жный, сосе́дний; бли́зкий, бли́жний, ближа́йший; *~ бүлмәләр* сме́жные ко́мнаты; *~ куршеләр* бли́зкие сосе́ди; *~ авыллар* ближа́йшие дере́вни **2.** паралле́льный (*о линиях, улицах и т. п.*) □ **~ булу 1.** быть ря́дом **2.** сосе́дство; **~ кую 1.** ста́вить ря́дом (бли́зко, бок о́ бок) **2.** *перен.* сопоставля́ть, ста́вить на одну́ до́ску; **~ тыныч яшәү** ми́рное сосуществова́ние; **~ үк** вплотну́ю

янәшәләп *нареч. разг.* ря́дом, по сосе́дству; *мәктәпкә ~ төзелгән йөзү бассейны* пла́вательный бассе́йн, постро́енный ря́дом со шко́лой

янәшәлек *сущ.* **1.** сосе́дство, сме́жность, бли́зость (*домов, леса, реки, друзей, родственников и т. п.*) **2.** паралле́льность (*линий, улиц и т. п.*) **3.** *грам.* примыка́ние; *сүзләрнең ~ бәйләнеше* примыка́ние слов

янәшә-тирә *сущ. собир.* **1.** окре́стности, окру́жность, окруже́ние, окружа́ющая среда́; *янәшә-тирә яшеллектә* окре́стности в зе́лени **2.** сосе́ди; окружа́ющие; *янәшә-тирә күрер инде* уви́дят окружа́ющие (сосе́ди) || *прил.* окружа́ющий, сосе́дний; *янәшә-тирә авыллар* сосе́дние дере́вни

янбаш *сущ.* бок, бедро́ || боковóй, бе́дренный; *озак ятудан ~ авырта* от до́лгого лежа́ния боли́т бок; *~ сөяге* бе́дренная кость

январь *сущ. см.* **гыйнвар**

янгын *сущ.* ого́нь, пожа́р || пожа́рный; *дала ~ы* степнóй пожа́р; пал; *~ чыгу* возникнове́ние пожа́ра; *~ сигналы* сигна́л о пожа́ре; пожа́рный сигна́л; *~ машинасы* пожа́рная маши́на □ **~ сүндергеч** огнетуши́тель; **~ сүндерүче** пожа́рник; **~ урыны (хәрабәсе)** пожа́рище, пепели́ще; **~га каршы** противопожа́рный; **~нан хәвефле** огнеопа́сный

янгынчы *сущ. спец.* пожа́рник || пожа́рный; *~лар командасы* пожа́рная кома́нда; кома́нда пожа́рников

яндавыл *сущ. ист.* боковóе охране́ние (*в боевом походе*)

яндаш *прил.* **1.** сме́жный; *см. тж.* **эргәдәш**; *~ бүлмә* сме́жная ко́мната **2.** пристяжнóй; *~ ат* пристяжна́я ло́шадь, пристя́жка

яндыргалау *многокр. от* **яндыру**

яндыргыч *прил.* зажига́тельный, зажига́ющий; *~ бомба* зажига́тельная бóмба

яндырту *понуд. от* **яндыру**

яндырʼу *перех.* **1.** зажига́ть/зажéчь, засвети́ть (*свечу, лампу, электричество, огонь и т. п.*) || зажига́ние **2.** 1) жечь, поджига́ть/подже́чь, сжига́ть/сжечь, спали́ть (*дом, солому, письмо, книгу и т. п.*) || поджига́ние, сжига́ние 2) обжига́ть/обже́чь, ожéчь, опáливать/опали́ть, спали́ть || обжига́ние, опáливание; *кашларны, чәчне ~у* спали́ть бро́ви, во́лосы; *кулны йод белән ~у* обже́чь ру́ку йóдом; *таякның очын ~у* обже́чь коне́ц па́лки **3.** жечь, обжига́ть/обже́чь, щипа́ть, вызыва́ть ощуще́ние жже́ния, бóли (*о холоде, лекарстве, перце и т. п.*) || обжига́ние; *салкын колакларны ~а* моро́з щи́плет ýши **4.** сжига́ть/сжечь, пережáривать/пережáрить; печь, жáрить, вари́ть до пригора́ния; *бәлешне ~у* сжечь пирóг; *бәрәңгене ~у* вари́ть карто́шку до пригора́ния **5.** 1) жечь, пали́ть, опáливать/опали́ть, печь, припека́ть (*о солнечных лучах*) || пале́ние, опáливание; *кояш бик нык ~а* со́лнце óчень си́льно пали́т 2) сжига́ть/сжечь, выжига́ть/вы́жечь, спали́ть || сжига́ние, выжига́ние; *кояш үләнне ~ды* со́лнце вы́жгло (спали́ло) траву́ **6.** *спец.* жечь, выжига́ть/вы́жечь, обжига́ть/обже́чь (*керамические изделия, руду, строительные материалы и т. п.*) || выжига́ние, óбжиг; *кирпеч ~у* óбжиг кирпича́; *агач*

күмере ~у выжига́ть древе́сный у́голь **7.** 1) выжи́га́ть/вы́жечь, прожига́ть/проже́чь (*чем-л. раскалённым или едким веществом*) || выжига́ние, прожига́ние; *күлмәкне кислота белән ~у* проже́чь пла́тье кислото́й; *одеялны ~у* проже́чь одея́ло 2) выжига́ть/вы́жечь || выжига́ние; *~ып тамга салу* вы́жечь тавро́; *~ып (бизәк) төшеру* вы́жечь (узо́р) **8.** выжига́ть/вы́жечь, очи́стить обжига́нием || выжига́ние, очи́стка обжига́нием; *таба ~у* вы́жечь сковоро́дку; *мич торбаларын ~у* очи́стить печны́е тру́бы выжига́нием **9.** загоня́ть/загна́ть, пали́ть, запа́ливать/запали́ть; *атны ~у* запали́ть (загна́ть) ло́шадь (*быстрой ездой*) **10.** *перен.* зажига́ть, заже́чь, заставля́ть/заста́вить страда́ть, пробужда́ть/пробуди́ть (*о чувствах любви*) □ **~ып алу** обже́чь, вы́жечь, сжечь, опали́ть, спали́ть; **~ып җибәрү** разжига́ть/разже́чь; **~ып чыныктыру** обжига́ть/обже́чь

яндыручы: кумер яндыручы *спец.* углежо́г; *кирпеч ~ спец.* обжига́ла, обжига́льщик кирпича́

яндырыл|у *страд. от* **яндыру** **1.** зажига́ться, свети́ться (*о свече, лампе, электричестве и т. п.*) **2.** поджига́ться, сжига́ться (*о бумаге, книге, доме, сарае, одежде и т. п.*) **3.** *спец.* выжига́ться, обжига́ться (*о керамических изделиях, руде, строительных материалах и т. п.*) **4.** выжига́ться, прожига́ться (*чем-л. раскалённым или едким веществом*)

яндырышу *взаимно-совм. от* **яндыру**

я́нкапка *сущ.* кали́тка; *~дан керү* войти́ в кали́тку

янмаучанлык *сущ. спец.* огнесто́йкость, огнеупо́рность, несгора́емость (*шкафа, кирпича, глины и т. п.*)

яннан *нареч.* **1.** сбо́ку; *җил ~ исә* ве́тер ду́ет сбо́ку; *якты ~ төшә* свет па́дает сбо́ку **2.** *разг.* со стороны́; *үзеңә ~ карау* смотре́ть на себя́ со стороны́ **3.** ря́дом; *пулялар ~ гына очып үттеләр* пу́ли пролете́ли совсе́м ря́дом

я́нсәке *сущ. разг.* широ́кая ла́вка (*обычно на кухне*)

янтаешу *совм. от* **янтаю** (*о многих*)

янтайту *перех.* крени́ть, накреня́ть/накрени́ть, наклоня́ть/наклони́ть на́бок (*судно, повозку и т. п.*) || крен, наклон на́бок; *көймәне ~* накрени́ть ло́дку; *бала арбасын ~* накрени́ть де́тскую коля́ску

я́нтармак *сущ. бот.* боково́й побе́г, бокова́я ветвь

янтау *сущ. диал.* **1.** *см.* **янтык** **2.** склон горы́ (*подступающий к реке, дому*)

янта|ю *неперех.* **1.** крени́ться, накреня́ться/накрени́ться, наклоня́ться/наклони́ться на́бок (*о судне, повозке и т. п.*) || крен, наклон на́бок; *уң якка ~ю* наклони́ться впра́во **2.** сбива́ться/сби́ться на́бок (*о шапке, шляпе и т. п.*) **3.** *авиа.* крени́ться, накреня́ться/накрени́ться, скользи́ть на крыло́ (*о самолёте*) || крен, скольже́ние на крыло́

янтерә|к *сущ. разг.* опо́ра, пра́вая рука́; *кызым — минем ~гем* дочь — моя́ опо́ра

яны|к *сущ.* **1.** бок (*правая или левая часть туловища человека, животных и т. п.*); *уң ~кта йоклау* спать на пра́вом боку́; *этнең аркасы ~кларына караганда куерак төстә* спина́ соба́ки бо́лее тёмного цве́та, чем бока́ **2.** бок, сторона́ (*какого-л. предмета, корабля, дома и т. п.*); *өстәл ~гы* сторона́ стола́; *көймә ~гына авышты* ло́дка накрени́лась на́ бок **3.** склон; *авыл тау ~гында урнашкан* дере́вня располо́жена на скло́не горы́ || *прил.* **1.** *разг.* боково́й; *см. тж.* **ян**; *~к урын* боково́е ме́сто; *~к капка* боковы́е воро́та **2.** кривобо́кий, кособо́кий; *~к кеше* кривобо́кий челове́к; *~к өй* кособо́кая изба́

янтыклай, янтыклый *нареч. диал. см.* **янтыктан**

янтыктан *нареч.* **1.** сбо́ку; *~ исә торган җил* ве́тер, ду́ющий сбо́ку; *~ баручы* иду́щий сбо́ку **2.** в про́филь, сбо́ку; *~ карау* смотре́ть в про́филь (сбо́ку)

яну *перех.* **1.** горе́ть, сгора́ть, сгоре́ть || горе́ние, сгора́ние; *төнлә пожар булды, күп өйләр янды* но́чью был пожа́р, сгоре́ло мно́го домо́в; *мичтә утын яна* в печи́ горя́т дрова́ **2.** топи́ться, горе́ть (*о печи, камине и т. п.*); *бүлмә уртасында тимер мич яна* в середи́не ко́мнаты то́пится желе́зная пе́чка; *яр буенда учаклар яна* на берегу́ горя́т костры́ **3.** *разг.* 1) подгора́ть/подгоре́ть, пригора́ть/пригоре́ть; перегора́ть/перегоре́ть (*о жареном картофеле, мясе*) 2) *в знач. прил.* **янган** горе́лый, подгоре́лый; *янган ипи* горе́лый хлеб; *янган ботка* подгоре́лая ка́ша; *янган урман* горе́лый лес; *янган ис килә* па́хнет горе́лым **4.** горе́ть, свети́ть; свети́ться, сия́ть; *лампа яна* ла́мпа гори́т; *прожектор яна* све́тит проже́ктор; *куктә йолдызлар яна* на не́бе сия́ют звёзды **5.** перегора́ть/перегоре́ть, сгора́ть/сгоре́ть, испо́ртиться (*об электрических приборах, аппаратах*); *бүлмәдәге лампочкалар янган* ла́мпочки в ко́мнате перегоре́ли **6.** *разг.* загоре́ть, обгоре́ть (*на солнце*); *кояшта яну* загоре́ть на со́лнце **7.** выгора́ть/вы́гореть, выцвета́ть/вы́цвести (*на солнце, на свету*); *күлмәк кояшта янган* пла́тье вы́горело на со́лнце **8.** горе́ть, быть (находи́ться) в жару́; *бала төне буе янды* ребёнок всю ночь был в жару́; *башы яна* у него́ голова́ гори́т **9.** горе́ть, быть разгорячённым (*от мороза, жары, стыда и т. п.*); *бит яна* лицо́ гори́т; *колаклар ут кебек яна* у́ши горя́т как ого́нь **10.** запали́ться, быть за́гнанным (*о лошади*) **11.** *перен.* 1) горе́ть *чем*; отдава́ться со стра́стью (*целиком, всецело и т. п.*) *чему-л.*; *нәфрәт уты белән яну* горе́ть не́навистью; *уку дәрте белән яну* горе́ть жела́нием учи́ться 2) горе́ть, пыла́ть, люби́ть; *мәхәббәт утында яну* пыла́ть в огне́ любви́ **12.** горе́ть, томи́ться, му́читься, страда́ть, ма́яться; боле́ть душо́й, пережива́ть; *йөрәк яна* се́рдце гори́т, душо́й боли́т **13.** *перен.* горе́ть, сверка́ть, блесте́ть, сия́ть; перелива́ться, искри́ться || горе́ние, сверка́ние, блеск, сия́ние; *чык бөртекләре кояшта яна* роси́нки сверка́ют на со́лнце; *рубин кашлы алкалар ут кебек яна* руби́новые се́рьги горя́т огнём; *күзләре шатлык белән яна* глаза́ его́ сия́ют ра́достью **14.** горе́ть, сгоре́ть, погоре́ть, перегоре́ть, преть, сопре́ть, гнить, загнива́ть, разлага́ться, тлеть, истлева́ть (*о зерне, сене и т. п.*) || сгора́ние, гние́ние, загнива́ние; *юеш печән кибәндә яна* мо́крое се́но в стога́х пре́ет; *тирес яхшы янган* навоз хорошо́ перепре́л **15.** *перен.* сгора́ть/сгоре́ть; поги́бнуть (*от чрезмерного напряжения сил, от быстро протекающей болезни и т. п.*); *эштә яну* сгоре́ть на рабо́те **16.** *перен. разг.* горе́ть, пропа́сть; *план яна* план гори́т; *путёвка яна* путёвка гори́т **17.** *перен. разг.* погоре́ть, быть разоблачённым, уличённым; оста́ться (оказа́ться) в безвы́ходном, тяжёлом положе́нии; *ришвәт алып янды* погоре́л на взя́тке **18.** *перен. разг.* пропа́сть да́ром (*напрасно, зря, за бесценок*); истра́титься непроизводи́тельно (*о деньгах, богатстве и т. п.*) **19.** *перен.* горе́ть || горе́ние; *бит яна* гори́т лицо́ (*от стыда или радости*) □ **яна башлау, яныш китү** разгоре́ться, загоре́ться; **янмый торган** несгора́емый, огнеупо́рный, огнесто́йкий; **янмый торган материаллар** *тех.* огнеупо́ры; **яныш бетү** сгоре́ть, перегоре́ть; истопи́ться ◊ **яныш тору** быть в по́лном соку́ (расцве́те сил)

яну-көю *неперех.* **1.** горе́ть; горева́ть, страда́ть, томи́ться || го́ре, страда́ние **2.** люби́ть, страда́ть, ма́яться

янулы *прил.* зажжённый, горя́щий, включённый, светя́щийся; *~ лампа* зажжённая ла́мпа; *~ мич* горя́щая печь

янут *сущ. зоол.* ено́т; *~ мехы* мех ено́та || *прил.* ено́товый; *~ бүрек* ено́товая ша́пка; *~ тун* ено́товая шу́ба

янучан *прил. спец.* горю́чий, горя́щий, сгора́емый; *~ газ* горю́чий газ; *~ сланецлар* горю́чие сла́нцы; *~ матдәләр* сгора́емые вещества́

янучанлы|к *сущ. спец.* горю́честь, сгора́емость; *газның ~гы* горю́честь га́за

янчы|к *сущ.* мешо́чек, мошна́; кисе́т; *тәмәке ~гы* кисе́т; *җәяүлегә ~к та авыр* (*посл.*) пе́шему и мошна́ тяжела́

янчыклы *прил.* с мешко́м, с мешо́чком; с мошно́й ◊ **~ кеше** челове́к с деньга́ми; бога́тый, де́нежный челове́к

янчыклык *сущ.* 1. доста́точный на оди́н кисе́т (на оди́н мешо́чек); *бер ~ тәмәке* таба́к, доста́точный на оди́н кисе́т 2. материа́л, доста́точный и́ли предназна́ченный для одного́ кисе́та, для одного́ мешо́чка

яны|к *сущ.* 1. гарь, нага́р; *что-л.* горе́лое; *дары яныгы* пороховáя гарь; *шәм яныгы* свечно́й нага́р 2. гарь, пал (*выгоревшее или выжженное место*); пепели́ще; *урмандагы яныклар җансыз булып күренәләр* га́ри в лесу́ име́ют безжи́зненный вид 3. прога́р; *казан төбендәге яныкк* прога́р на дне котла́ 4. *с.-х.* огни́ще (*лесной участок после пала*)

яныш-пешеш *нареч.* 1. проливáя пот 2. *перен.* стара́тельно, спе́шно, спеша́

янычар *сущ. ист.* яныча́р, яныча́ры || яныча́рский; *~лар отряды* яныча́рский отря́д; отря́д яныча́р

янычек *прил.* вмя́тый, вдáвленный, помя́тый || вмя́тина, вдáвленное ме́сто; *~ чиләк* помя́тое ведро́

яныч елдерү *перех.* вдáвливать/вдави́ть, вмина́ть/вмять; помя́ть; раздáвливать/раздави́ть || вдáвливание; раздáвливание; *чиләкне ~* помя́ть ведро́

яныч ел|ү *страд.-возвр. от* **яныч ү** 1. мя́ться, смя́ться, вмина́ться, вдáвливаться || вдáвливание; *чәйнекнең яны ~де* бок ча́йника вмя́лся 2. сплю́щиваться/сплю́щиться, расплю́щиваться/расплю́щиться (*о шляпе, фуражке и т. п.*); *~гән урын* вмя́тина, вмя́тость, углубле́ние

яныч етү *понуд. от* **яныч ү**

яныч ү *перех.* вмина́ть/вмять, мять, смять, сплю́щивать/сплю́щить || сплю́щивание, расплю́щивание (*ведра, кастрюли, шляпы и т. п.*)

ян-як *сущ. см.* **тирә-як**

яңа *прил.* 1. *в разн. знач.* но́вый; *яңа өй* но́вый дом; *яңа күлмәк* но́вое пла́тье; *яңа танышлар* но́вые знако́мые; *яңа дару* но́вое лека́рство; *яңа сорт бодай* но́вый сорт пшени́цы; *яңа көй* но́вая мело́дия 2. све́жий (*об овощах, газете, хлебе и т. п.*) 3. парно́й; *яңа сауган сөт* парно́е молоко́; *яңа суйган ит* парно́е мя́со 4. *в слож. сл. переводится компонентом* **ново-**: *яңа туган бала* новорождённый ребёнок; *яңа уйлап табылган* новоизобретённый 5. но́вый, ны́нешний (*урожай*) 6. *в знач. нареч.* то́лько что, вновь; *яңа килдем* то́лько что пришёл; *яңа килгән* вновь пришéдший 7. *в знач. сущ.* новь, но́вый урожáй; *бәрәңгене яңага җиткерү* дотяну́ть карто́фель до но́вого урожáя; *яңага җитәрлек* доста́точный до но́ви □ **яңа ай** новолу́ние, молодо́й ме́сяц; **яңа баштан** за́ново, сы́знова; **яңа җир** нови́на, новь; **яңа кеше** новичо́к; **яңа кием** обно́ва; **яңа өйләнешкәннәр** молодожёны, новобра́чные; **яңа хәбәр** но́вость ◊ **яңа авыздан иске сүз** повторя́ть (раздýть) ста́рое; **яңа көйгә иске җыр** ста́рая пе́сня на но́вый моти́в; **яңа себерке яхшы себерә** (*погов.*) но́вая метла́ хорошо́ метёт; **яңа сүз** но́вое сло́во (*в науке*); **яңа туган ай кебек** прекра́сная, как светоза́рная луна́ (*о девушке*)

яңабаштан *нареч. см.* **яңадан**

яңадан *нареч.* 1. сно́ва, опя́ть, ещё раз, вновь, за́ново, снача́ла; на́ново, сы́знова; *~ яши башлаган кебек* как бýдто сно́ва на́чал жить; *~ ясау* сде́лать за́ново; *~ кыш җитте* опя́ть пришла́ зима́; *~ кабатла әле* повтори́-ка ещё раз 2. *в слож. сл. переводится приставкой* пере-; *~ планлаштырырга* перепланúровать; *~ исәпләү* перерасчёт; *~ бәяләү* переоце́нивать; *~ кору* преобразóвывать/преобразова́ть, переде́лывать/переде́лать || преобразова́ние, переде́лывание; *~* **торгызу (барлыкка китерү, аякка бастыру)** возрожда́ть/возроди́ть || возрожде́ние

яңадан-яңа *прил.* но́вые и но́вые; *яңадан-яңа йортлар төзелә* стро́ятся но́вые и но́вые дома́; *яңадан-яңа бурычлар куела* ста́вятся но́вые и но́вые зада́чи

яңа|к *сущ.* 1. щека́ || щёчный; *~к мускуллары* щёчные му́скулы; *~гыннан сөю* потрепа́ть по щеке́ 2. коса́к; *ишек ~гы* дверно́й коса́к; *тәрәзә ~гы* око́нный коса́к □ **~к калкымнары (чыгынтылары)** *анат.* ску́лы; **~к сөяге** *анат.* че́люсть; **~к тамырлары** желваки́; **~к шешү** *мед.* флюс ◊ **~к биетү** за о́бе щеки́ уплета́ть (упи́сывать); **~гы суырылу (тартылу, эчкә бату)**; **~гы ~гына ябышу** си́льно похуде́ть; **~гына менеп төшү (берне утырту)**, **~гыннан ут чәчрәтү** залепи́ть (закати́ть, влепи́ть) пощёчину, съе́здить в мо́рду

яңаклану *страд. от* **яңакла́ү** получа́ть/получи́ть пощёчину *от кого*

яңаклату *понуд. от* **яңакла́ү**

яңакла́|ү *перех.* дава́ть/дать, залепи́ть пощёчину || пощёчина, оплеу́ха

яңаклык *сущ.* 1. доста́точный для коса́к материа́л 2. го́дный, приго́дный на коса́к материа́л

яңалиф *сущ. лингв.* яналúф (*татарская письменность на латинской основе, существовавшая в 1929—1939 гг.*)

яңалифләштерелү *страд. от* **яңалифләштерү**

яңалифләштерү *перех.* переводи́ть на яналúф

яңалифләшү *неперех.* переходи́ть на яналúф

яңалифчә *нареч.* по алфави́ту яналúфа; *~ укый белү* уме́ть чита́ть по алфави́ту яналúфа

яңалифче *сущ. ист.* сторóнник яналúфа

яңалифчелек *сущ. ист.* защи́та яналúфа; движе́ние в по́льзу яналúфа

яңалык *сущ.* 1. но́вость, но́вшество, новизна́, нововведе́ние; *авыл хуҗалыгындагы ~лар* но́вшества в се́льском хозя́йстве; *инженер керткән ~лар* нововведе́ния инжене́ра; *фән һәм техника ~лары* но́вости нау́ки и те́хники 2. но́вость, но́вое сообще́ние, изве́стие; *күңелле ~* прия́тная но́вость; *газетадагы ~лар* газе́тные но́вости 3. но́вость, новúнка, (что́-то) но́вое, необы́чность; непривы́чность; *радиоалгыч ул елларда ~ иде әле* радиоприёмник в те го́ды был ещё новúнкой; *спектакль безнең өчен ~ булды* спекта́кль был для нас но́востью

яңалыкчы *сущ. неол.* нова́тор

яңалыкчылык *сущ. неол.* нова́торство

яңарак *нареч.* неда́вно, совсе́м неда́вно, незадóлго (*до этого*); то́лько что; *ут ~ сүнде* свет пога́с неда́вно; *~ кайтып кердем* то́лько что прищёл

яңарт|у *перех.* 1. обновля́ть/обнови́ть, подновля́ть/подновúть; освежа́ть/освежúть || обновле́ние, подновле́ние, освеже́ние; *мебельне ~у* подновле́ние ме́бели; *идәннең буявын ~у* освежúть кра́ску по́ла; *урын-җирләрне ~у* подновúть посте́ль 2. обновля́ть/обновúть,

вноси́ть/внести́ но́вое || обновле́ние, внесе́ние но́вого; *тактиканы ~у* обнови́ть та́ктику; *мәктәпләрдә укытуны ~у* вноси́ть но́вое в преподава́ние в шко́лах; *репертуарны ~у* обнови́ть репертуа́р; *тормышны ~у* обнови́ть жизнь **3.** обновля́ть/обнови́ть, освежа́ть/освежи́ть, совершéнствовать, усовершéнствовать || обновле́ние, освеже́ние, совершéнствование, совершéнство; *белемеңне ~у* освежи́ть свои́ зна́ния (позна́ния) **4.** *перен.* 1) воссоздава́ть/воссозда́ть, воспроизводи́ть/воспроизвести́, освежа́ть/освежи́ть, восстана́вливать/восстанови́ть, воскреша́ть/воскреси́ть (*в памяти*) || воссозда́ние, воспроизведе́ние, освеже́ние, восстановле́ние, воскресе́ние; *күңелдә ~у* воссозда́ть в па́мяти *что-л.*; *истәлекләрне ~у* освежи́ть воспомина́ния 2) обновля́ть/обнови́ть, возрожда́ть/возроди́ть, воскреша́ть/воскреси́ть, де́лать, сде́лать ины́м, оживля́ть/оживи́ть || обновле́ние, возрожде́ние, воскреше́ние, оживле́ние; *мәхәббәт кенә сине ~ыр* то́лько любо́вь тебя́ воскреси́т (оживи́т); *урман һавасы безне ~ып җибәрде* лесно́й во́здух возроди́л нас **5.** подогре́ть, разогре́ть, подта́пливать/подтопи́ть (*остывшую баню, печь, пищу и т. п. дополнительно, вновь*); *самавыр ~у* разогре́ть самова́р **6.** *перен.* возобновля́ть/возобнови́ть, начина́ть/нача́ть вновь; верну́ться, возвраща́ться/возврати́ться *к чему*, восстана́вливать/восстанови́ть (*занятия, беседу, отношения, связи*) || возобновле́ние, возвраще́ние *к чему*, восстановле́ние *чего*; *авыл белән бәйләнешләрне ~у* восстанови́ть свя́зи с дере́вней; *өзелгән сөйләшүләрне ~у* возобнови́ть пре́рванный разгово́р

яңар|у *неперех.* **1.** обновля́ться/обнови́ться, подновля́ться/поднови́ться || обновле́ние; *ремонттан соң бүлмә ~ган* по́сле ремо́нта ко́мната обнови́лась **2.** обновля́ться/обнови́ться, подновля́ться/поднови́ться, меня́ться, изменя́ться/ измени́ться || обновле́ние, подновле́ние, измене́ние; *программалар ~ды* програ́ммы обнови́лись; *труппаның составы ~ды* соста́в тру́ппы подновился; *тормыш көннән-көн ~а* жизнь меня́ется с ка́ждым днём **3.** обновля́ться/обнови́ться, совершéнствоваться (*о знаниях, познаниях, сведениях и т. п.*) || обновле́ние, совершéнствование **4.** *перен.* 1) воссоздава́ться/воссозда́ться, воспроизводи́ться/воспроизвести́сь, освежа́ться/освежи́ться, восстана́вливаться/восстанови́ться, воскреса́ть/воскре́снуть (*в памяти, воображении*) || воссозда́ние, воспроизведе́ние, освеже́ние, восстановле́ние; *хәтердә ~у* восстанови́ться в па́мяти 2) обновля́ться/обнови́ться, оживля́ться/оживи́ться || обновле́ние, оживле́ние; *табигать тә ~ды* и приро́да обнови́лась **5.** *перен.* возобновля́ться/возобнови́ться, начина́ться/нача́ться, вновь верну́ться *к чему*, восстана́вливаться/восстанови́ться (*о разговоре, беседе, занятии и т. п.*)

яңарыш *сущ.* **1.** обновле́ние; *~ җиле* ве́тер обновле́ния; *илдә хуҗалык ~ы* обновле́ние хозя́йства в стране́; *әдәбияттагы ~лар* обновле́ния в литерату́ре **2.** *ист.* Возрожде́ние, Ренесса́нс; *Яңарыш чоры* эпо́ха Возрожде́ния

яңа́ча *нареч.* **1.** по-совре́менному; в соответствии с вре́менем (*с эпохой*); злободне́вно; *~ киену* одева́ться по-совре́менному; *туйны ~ уткәру* сыгра́ть сва́дьбу по-совре́менному **2.** по-но́вому; *эшне ~ кору* организова́ть рабо́ту по-но́вому; *~ фикерләү* мы́слить по-но́вому.|| *прил.* но́вый; *~ тормыш башлау* нача́ть но́вую жизнь; *мәсьәләгә ~ караш* но́вый подхо́д к вопро́су

яңгыр *сущ. прям., перен.* дождь || дождево́й; *~га эләгү* попа́сть под дождь; *~ болыты* дождева́я ту́ча; *~ суы* дождева́я вода́; *йолдыз ~ы* звёздный дождь □ **~ башмагы** *бот.* дождеви́к (*гриб*); **~ теләнчесе** *зоол.* и́волга; **~ чыпчыгы** *зоол.* зуёк, **~ яудыру** дождева́ние || дождева́льный

яңгыравык *прил. см.* **яңгыравыклы**; *~ тавышлы* звонкоголо́сый

яңгыравыклы *прил.* зво́нкий, зву́чный, гро́мкий, зали́вистый, раска́тистый; *~ тавыш* зво́нкий го́лос; *~ көлү* зали́вистый смех; *~ җыр* зву́чная пе́сня; *~ чаң* зву́чный ко́локол

яңгырату *перех.* **1.** оглаша́ть/огласи́ть; *җыр белән урам ~* огласи́ть у́лицу пе́сней **2.** оглуша́ть/оглуши́ть, отдава́ться/отда́ться бо́лью (*в ухе, от сотрясающего звука, удара*) **3.** *перен.* де́лать изве́стным *что*, распространя́ть сла́ву, молву́ *о ком*

яңгыр|ау *неперех.* **1.** греме́ть, прогреме́ть, раздава́ться/разда́ться, оглаша́ться/огласи́ться, раска́тываться/раскати́ться, гря́нуть (*громко, внезапно*) || раска́т, раска́ты (*грома*); *гудок ~ады* разда́лся гудо́к; *урманда ату тавышы ~ады* лес огласи́лся вы́стрелом; *залда көчле музыка ~ый* в за́ле греми́т му́зыка **2.** звуча́ть, зазвуча́ть, слы́шаться, ли́ться, звене́ть, разноси́ться, раздава́ться/разда́ться || звуча́ние, звон; *урамда балалар тавышы ~ый* на у́лице звеня́т де́тские голоса́; *җыр матур ~ый* пе́сня звучи́т краси́во **3.** *перен.* звуча́ть, прозвуча́ть, звене́ть, слы́шаться, послы́шаться; *аның тавышында үпкәләү ~ады* в его́ го́лосе прозвуча́ла оби́да; *аның сүзләре һаман да колакта ~ый* его́ слова́ всё ещё звуча́т в уша́х **4.** *перен.* греме́ть, прогреме́ть, разноси́ться; *геройның исеме бөтен илгә ~ады* и́мя геро́я прогреме́ло на всю страну́ □ **~ап китү** прогреме́ть, прозвуча́ть; **~ап тору** греме́ть, звуча́ть, раздава́ться; **~ый башлау** зазвуча́ть

яңгыраулы *прил.* **1.** *см.* **яңгыравыклы 2.** гу́лкий; *~ гөмбәзләр* гу́лкие сво́ды; *~ зал* гу́лкий зал

яңгыраш *сущ. прям., перен.* э́хо, о́тзвук, звуча́ние; резона́нс, о́тклик; отголо́сок; *киң иҗтимагый ~* широ́кий обще́ственный резона́нс; *йөрәктә ~ табу* найти́ о́тклик в се́рдце (душе́)

яңгырашлы *прил.* даю́щий о́тзвук, резона́нс, о́тклик, отголо́сок

яңгырла|у *неперех.* накра́пывать, дожди́ть || накра́пывание; *~п тору* накра́пывать (немно́го)

яңгырлы *прил.* дождли́вый; *~ җәй* дождли́вое ле́то; *~ көннәр* дождли́вые дни

яңгырсыз *прил.* без дождя́, засу́шливый; *~ җәй* засу́шливое ле́то

яңгырсызлык *сущ.* бездо́ждье, за́суха

япан *сущ. диал.* степь, откры́тая ме́стность; по́ле; *җансыз буш ~* безжи́зненная, пусты́нная ме́стность; *атлар ~да йөри* ко́ни пасу́тся в по́ле || *прил.* откры́тый, го́лый; *~ кыр* откры́тое по́ле

япанча *сущ. ист.* епанча́; *см. тж.* **ябынча**

я́па-ялгыз *прил.* соверше́нно одино́кий || *нареч.* оди́н-одинёшенек; *япа-ялгыз яшәү* жить оди́н-одинёшенек

япкала́у *многокр. от* **ябу** I

япкын *сущ. разг.* тюрьма́; ме́сто заключе́ния; заключе́ние; *~нан чыгу* освободи́ться из тюрьмы́

япкыч *сущ.* **1.** кры́шка *чего-л.*, покры́шка; *чиләк ~ы* кры́шка ведра́ **2.** *тех.* кла́пан, колпа́к; затво́р (*плотины*) **3.** *см.* **япма 4.** *диал.* фа́ртук

япма *сущ.* **1.** покрыва́ло; *карават ~сы* покрыва́ло для крова́ти **2.** попо́на; *ат ~сы* ко́нская попо́на, покрыва́ло для ло́шади **3.** наве́с; *ындыр ~сы* наве́с над гумно́м; *~ ябу* де́лать наве́с

япмалык *сущ.* **1.** *см.* **япма 2.** доста́точный на покрыва́ло

япон *сущ.* япо́нец, япо́нка || япо́нский; *~ теле* япо́нский язы́к; *~ хатыны (кызы)* япо́нка □ **~ гөле** горте́нзия

япо́нияле *сущ.* япо́нец, жи́тель Япо́нии

япо́нча *нареч.* по-япо́нски, на япо́нском языке́; *~ сөйләшү* говори́ть по-япо́нски, говори́ть на япо́нском языке́ || *прил.* япо́нский; *~ бию* япо́нский та́нец

япсар|у *перех. диал.* **1.** припи́сывать/приписа́ть *кому-л.*, сва́ливать/свали́ть (*вину на кого-что-л.*) **2.** защища́ть/защити́ть (*обычно провинившегося*); *аны ~ма* не защища́й его́

япсарылу *страд. от* **япсару** припи́сываться/приписа́ться *кому*

яптырту *понуд. от* **яптыру**

яптыру *понуд. от* **ябу** II

яптырылу *страд. от* **яптыру**

япь *сущ.* разви́лка, разви́лина; *агач ябе* разви́лка де́рева; *сәнәк ябе* разви́лина вил

япьле *прил.* **1.** с разви́линой, име́ющий разви́лину, рожо́к; *ике ~ сәнәк* двуро́гие ви́лы **2.** разви́листый; *~ нарат* разви́листая сосна́

япьлекә *сущ.* разви́листый сук

япьлекәле *прил.* разви́листый, раздво́енный, раздвоённый; *~ агач ботаклары* разви́листые ве́тки дере́вьев

япьтәш *прил. разг.* **1.** сноровистый, ло́вкий, уме́лый; *~ малай* ло́вкий ма́льчик **2.** охо́чий, скло́нный *к чему-л.*; *сату-алуга ~ кеше* скло́нный к торго́вле челове́к

япьтәшле|к *сущ.* сноровистость, сноро́вка, ло́вкость, уме́ние; *~ге белән аерылып тора* выделя́ется свое́й сноровистостью

япь-яшь *превосх. ст. прил. от* **яшь** о́чень молодо́й, моло́денький; *япь-яшь кыз* моло́денькая де́вушка

яп-якты *прил. превосх. ст.* све́тлый-пресве́тлый, о́чень све́тлый; *яп-якты бүлмә* све́тлая-пресве́тлая ко́мната || *нареч. превосх. ст.* о́чень светло́; *яп-якты булды* ста́ло о́чень светло́

яп-якын *прил. превосх. ст.* о́чень бли́зкий; *яп-якын урман* о́чень бли́зкий лес || *нареч. превосх. ст.* о́чень бли́зко, под бо́ком; *яп-якын булып күренү* показа́ться о́чень бли́зко

яп-ялангач *прил. превосх. ст.* соверше́нно го́лый, соверше́нно разде́тый, совсе́м го́лый, голёхонький; *яп-ялангач бала* соверше́нно го́лый ребёнок || *нареч. превосх. ст.* соверше́нно го́ло, совсе́м го́ло; *яп-ялангач калу* оста́ться соверше́нно го́лым

яп-яссы *прил. превосх. ст.* о́чень пло́ский, си́льно приплю́снутый; *яп-яссы күкрәк* о́чень пло́ская грудь || *нареч. превосх. ст.* о́чень пло́ско, си́льно приплю́снуто; *яп-яссы булып тору* быть си́льно приплю́снутым

яп-ят *прил. превосх. ст.* совсе́м чужо́й (чу́ждый), соверше́нно чужо́й (чу́ждый), соверше́нно посторо́нний, совсе́м незнако́мый; *яп-ят тәм* соверше́нно посторо́нний вкус (при́вкус); *яп-ят кеше* соверше́нно чужо́й (посторо́нний, незнако́мый) челове́к

яп-яңа *прил. превосх. ст.* соверше́нно но́вый, совсе́м но́вый, нове́йший; *яп-яңа кием* совсе́м но́вая оде́жда (*обнова*); *яп-яңа хәбәр* соверше́нно но́вая весть

яр I *сущ.* бе́рег, яр || береговой; *яр сызыгы* береговая ли́ния □ **яр буе 1.** побере́жье, прибре́жье **2.** прибре́жный; *яр буе бозы* закра́ина льда; **яр кандалалары** клопы́-прибре́жники; **яр карлыгачы** см. **керәшә**

яр II *сущ.* возлю́бленный, люби́мый; зазно́ба, зазно́бушка; *ялкау яр тапмас* (*погов.*) лента́й зазно́бы не найдёт

яр III *уст.*: **яр салу** объявля́ть/объяви́ть (*громогласно*)

яра *сущ.* **1.** ра́на, ране́ние || ранево́й; *тәндәге яралар* ра́ны на те́ле; *пычак ярасы* ножево́е ране́ние; *пуля ярасы* пулева́я ра́на; *яра азуы* раneва́я инфе́кция; *яра йөзе* раневая пове́рхность **2.** *перен.* ра́на; *сугыш яраларын төзәту* зале́чивать ра́ны войны́; *күңелдәге яра* душе́вная ра́на □ **яра авызы** свищ; **яра гөле** ало́э; **яра ташы** ля́пис; **яра үләне** *бот.* подоро́жник; **яра эзе** шрам, рубе́ц ◊ **ярага тоз сибү (салу)** разбереди́ть (*душевную*) ра́ну

ярабай *сущ. бот. см.* **сары мәтрүшкә**

ярабби, яраббем *межд. употр. для выражения удивления, негодования, досады, радости и т. п. или при пожелании чего-л.* бо́же, го́споди; *~ , нинди зур үскән!* бо́же, как он вы́рос! ; *~ , нинди сүз инде ул?* го́споди, что э́то за сло́во?; *~ , барсы да яхшы гына булсын инде!* бо́же, пусть бы всё бы́ло хорошо́!

ярак *сущ. редко см.* **кирәк-ярак**

яраклаштыру *перех.* **1.** приспоса́бливать, приспособля́ть/приспосо́бить || приспособле́ние; *усемлекне урындагы шартларга ~* приспосо́бить расте́ние к ме́стным усло́виям **2.** подла́живать/подла́дить, приспоса́бливать/приспосо́бить, принора́вливать/приноровить || подла́живание, приспособле́ние; *адымны аның адымына ~* приноровить шаг к его́ шага́м; *чоланны йокы бүлмәсенә ~* приспосо́бить чула́н под спа́льню

яраклашу *неперех.* **1.** приспоса́бливаться/приспосо́биться || приспособле́ние; *яңа климатка ~* приспособле́ние к но́вому кли́мату **2.** подла́живаться/подла́диться, приспособля́ться/приспосо́биться, приноровля́ться/приноровиться, примени́ться || подла́живание, приспособле́ние; *тормыш шартларына ~* приноровиться к жи́зненным усло́виям

яраклы *прил.* **1.** го́дный, приго́дный; *нигезгә ~ кирпечләр* го́дные для фунда́мента кирпичи́; *~ түмәр җирдә ятмас* (*посл.*) добро́ на земле́ не валя́ется (*букв.* приго́дный чурба́н не бу́дет валя́ться на земле́) **2.** подходя́щий, отвеча́ющий (определённым) тре́бованиям; прие́млемый *книжн.*; *укыту эшенә ~ кулланмалар* посо́бия, отвеча́ющие тре́бованиям уче́бной рабо́ты; *балаларга ~ киемнәр* оде́жда, подходя́щая де́тям □ **~ булу** годи́ться; **~ итү 1.** де́лать, сде́лать приго́дным **2.** приспоса́бливать/приспосо́бить; **~ (дип) табу 1.** счита́ть приго́дным **2.** одо́брить

яраксыз *прил.* **1.** него́дный, неприго́дный; *~ такта* неприго́дная для де́ла доска́; *хәрби хезмәткә ~ кеше* челове́к, него́дный к вое́нной слу́жбе **2.** неподходя́щий, неиспра́вный; *~ хәлгә килү* прийти́ в него́дность; вы́йти из стро́я □ **~га чыгару, ~ дип табу** браковать, забраковать

яраксызлан|у *неперех.* **1.** станови́ться/стать него́дным, неприго́дным **2.** станови́ться/стать неподходя́щим, неиспра́вным

яраксызлы|к *сущ.* него́дность, неприго́дность; *дәфтәрләрнең ~гы* неприго́дность тетра́дей

яраландыру *перех. см.* **яралау**

яралану *возвр. от* **яралау** пора́ниться, получа́ть/получи́ть ране́ние, быть ра́неным || ране́ние

яралау *перех.* **1.** ра́нить, пора́нить, наноси́ть/нанести́ ра́ну || ране́ние, нанесе́ние ра́ны; *аягын ~у* ра́нить

в но́гу; *пычак кадап ~у* нанести́ ножеву́ю ра́ну 2. *перен.* ра́нить, пора́нить, уязвля́ть/уязви́ть, наноси́ть/нанести́ душе́вную ра́ну; *йөрәкне ~у* ра́нить се́рдце □ **~н бетеру** изра́нить

яралгы *сущ.* 1. заро́дыш, плод, эмбрио́н *книжн.* || заро́дышевый, *чеби ~сы* заро́дыш цыплёнка; *бөртектәге ~* заро́дыш в зёрнышке; *~ күзәнәкләре* заро́дышевые кле́тки 2. *перен.* заро́дыш, зача́ток, нача́ло || заро́дышевый, зача́точный, нача́льный; *авыруның ~сы* заро́дыш (нача́ло) боле́зни; *~ хәлендә булу* быть в зача́тке (заро́дыше); быть (находи́ться) в зача́точном состоя́нии; *~ күзәнәкләре* заро́дышевые кле́тки

яра|у *неперех.* 1. зарожда́ться/зароди́ться, быть зача́тым, появля́ться/появи́ться || зарожде́ние, появле́ние; *күз алдында бөҗәк ~а* на глаза́х появля́ется насеко́мое 2. *перен.* зарожда́ться/зароди́ться, рожда́ться/роди́ться, возника́ть/возни́кнуть || зарожде́ние, рожде́ние, возникнове́ние; *күңелдә шик ~у* зарожде́ние подозре́ния в душе́; *яңа идея ~у* возникнове́ние но́вой иде́и

яралы *прил.* ра́неный, име́ющий ра́ну (ране́ние), с ра́ной; *~ кул* ра́неная рука́; *~ аяк белән* с ра́неной ного́й

яралыш *сущ.* зарожде́ние, возникнове́ние; зача́тие

ярамсак *прил. диал. см.* **ялагай**

ярамсаклану *неперех. диал. см.* **ялагайлану**

ярамсаклык *сущ. диал. см.* **ялагайлык**

яран I *сущ.* 1. приве́рженец, сторо́нник; *~нары белән* со свои́ми приве́рженцами; со свое́й сви́той 2. уго́дник, льстец

яран II *сущ. бот.* гера́нь; *~ гөле* гера́нь (*комнатное растение*)

яра́нга *сущ.* яра́нга (*жилище*)

ярар *предик. сл.* ла́дно; *~ инде* да ла́дно, ла́дно уж

яраклык *прил.* го́дный, приго́дный, подходя́щий, примени́мый; *коймага ~ такталар* до́ски, го́дные для забо́ра; *укытучыга ~* подходя́щий для учи́теля □ **~ булу** го́дность, приго́дность

яраткан *прил.* 1. люби́мый; полюби́вшийся, излю́бленный; *~ язучым* мой люби́мый писа́тель; *~ китаплар* люби́мые кни́ги; *~ урын* излю́бленное (полюби́вшееся) ме́сто; *~ тема* излю́бленная (люби́мая) те́ма 2. люби́мый, возлю́бленный; *аның ~ кешесе бармы?* есть ли у него́ люби́мый (возлю́бленный)?

яраттыру *понуд. от* **ярату** заставля́ть люби́ть

ярат|у I 1. *перех. в разн. знач.* люби́ть, полюби́ть || люо́вь (*к родине, матери, детям, цветам, природе, искусству и т. п.*); *вәгъдә бирергә ~а* лю́бит обеща́ть; *каймак ~* люби́ть смета́ну 2. люби́ть (*о животных, растениях*); *роза ярымкүләгә урынны ~а* ро́за лю́бит полуте́нь; *чәчәкләр су ~а* цветы́ лю́бят во́ду 3. одобря́ть/одо́брить (*работу, действие, поведение, поступок*)

ярат|у II *неперех.* создава́ть/созда́ть, твори́ть (*человеческий род*) || созда́ние, твoréние

ярат|у III *перех.* 1. подгоня́ть/подогна́ть; де́лать/сде́лать соответствующим по разме́ру || подго́нка (*деталей друг к другу, одежды по фигуре и т. п.*) 2. подбира́ть/подобра́ть (*ключ к замку, галстук к рубашке и т. п.*)

яратучан *прил.* лю́бящий, име́ющий скло́нность (пристра́стие) *к чему-л.*; *тәмлене ~* лю́бящий вку́сные ку́шанья; *сөйләшергә ~* лю́бящий поговори́ть; словоохо́тливый, говору́н

яратучы I люби́тель; *музыка ~* люби́тель му́зыки; *китап ~* люби́тель книг; книголю́б; библиофи́л

яратучы II *сущ.* созда́тель, творе́ц

яратылу I *страд. от* **ярату** I быть люби́мым

яратылу II *страд. от* **ярату** II быть сотворённым, сотвори́ться; быть со́зданным

яратылыш *сущ.* 1. сотворе́ние, творе́ние; *дөнья ~ы* сотворе́ние ми́ра 2. нату́ра, приро́да (*человека*); *ул ~ы буенча укытучы* он по нату́ре — учи́тель

яратырлык *прил.* досто́йный, сто́ящий любви́; *~ җыр* сто́ящая пе́сня; *~ бер нәрсәсе дә юк* в нём нет ничего́ досто́йного любви́

яратышу *взаимно-совм. от* **ярату** I

яра́у I *неперех.* 1. годи́ться, пригоди́ться, быть го́дным, приго́дным *на что-л., к чему-л.* || го́дность, приго́дность; *бу йорт торырга ярый* э́тот дом для жилья́ приго́ден; *бәйләгән әт ауга ярамый* (*посл.*) цепна́я соба́ка для охо́ты не годи́тся 2. *перен.* уго́дничать, угожда́ть *кому*, угоди́ть, зайскивать || уго́дливость, зайскивание; *мөдиргә яраргa тырышу* стара́ться угожда́ть заве́дующему 3. подходи́ть/подойти́, приходи́ться/прийти́сь, соответствовать, совпада́ть || соответствие (*по размеру, по качеству и т. п.*); *ачкыч ярый* ключ подхо́дит; *бүрек ярады* ша́пка подошла́ □ **ярап җитми** 1. не совсе́м годи́тся 2. не о́чень подхо́дит **ярап кую** пригоди́ться; **ярап тору** пригоди́ться на вре́мя; не помеша́ет

яра́у II *прил. диал.* 1. мо́щный, си́льный, ре́звый, здоро́вый, отва́жный; *~ атлар* ре́звые ко́ни; *~ егет* здоро́вый па́рень 2. прохла́дный, слегка́ ве́треный || прохла́да; *~ җирдә утыру* сиде́ть в прохла́дном ме́сте; *кичке ~* вечёрняя прохла́да 3. добро́тный, высокока́чественный; *~ азык* высокока́чественная (калори́йная) пи́ща □ **~ алдыру** *см.* **яраулау**; **~ алу** 1. передохну́ть по́сле тяжёлой рабо́ты, по́сле да́льней доро́ги 2. гото́виться к ска́чкам (*о лошади*); **~ ат** специа́льно подгото́вленный к ска́чкам конь ◊ **~ яру** становиться/стать о́пытным, искушённым, быва́лым челове́ком

ярауландыру *перех.* 1. гото́вить к ска́чкам, разминать/размя́ть (*перед скачками*) 2. дать передохну́ть, осты́ть, дать переды́шку по́сле бы́строй езды́

яраулану *страд.-возвр. от* **яраулау** 1. быть гото́вым к ска́чкам; разминаться/размя́ться (*перед скачками*) || разми́нка 2. *перен.* станови́ться/стать быва́лым, искушённым

яраула́у *перех.* 1. гото́вить, пригото́вить (*лошадь к скачкам*) осо́бенным ухо́дом, разминать, води́ть её до ска́чек || разми́нка 2. дать отдохну́ть (передохну́ть, остыва́ть/осты́ть) ло́шади по́сле бы́строй езды́ и́ли да́льнего пути́

яраулы *прил.* 1. подходя́щий, соответствующий; *~ эш табу* найти́ подходя́щую рабо́ту 2. подходя́щий, удо́бный; *~ кием* подходя́щая оде́жда; *~ бүлмә* удо́бная (подходя́щая) ко́мната

яраусыз *прил.* неу́мный, глу́пый; *~ кешегә сүз әйтсәң, ярыла-ярыла илгә җәяр* (*посл.*) ска́жешь неу́мному сло́во, он разнесёт по всему́ све́ту

яршкан *прил.* 1. приспосо́бившийся, приспосо́бленный 2. *лингв.* согласо́ванный 3. гармони́чный, соответствующий

яршлы *прил.* соответствующий, созву́чный, сообра́зный, соразме́рный; гармони́рующий, соответственный; адеква́тный *чему книжн.*; *максатка ~* соответствующий це́ли □ **~ рәвештә** соответственно; созву́чно, гармони́чно, сообра́зно

яршлылы|к *сущ.* соответствие, созву́чность, сообра́зность, гармо́ния, гармони́чность, соразме́рность;

максатка ~гы соответствие цели, целесообразность; *тавышларның ~гы* созвучность голосов

яраштыр|у *перех.* 1. подгонять/подогнать || подгонка; *рамны тәрәзәгә ~у* подогнать раму к окну; *ачкыч ~у* подогнать ключ 2. согласовывать/согласовать *что-л.* || согласование *чего-л.* 3. *перен.* примирять/примирить || примирение; *барлык ~а, юклык талаштыра* (*погов.*) достаток мирит, бедность ссорит

яраш|у *неперех.* 1. приспосабливаться, приспособляться/приспособиться || приспособленность; *тормышка ~* приспособиться к жизни; *яңа шартларга ~* приспособиться к новым условиям 2. соответствовать, гармонировать || соответствие, гармония; *мөмкинлек белән ихтыяҗның ~ы* соответствие возможности с потребностью 3. *лингв.* согласовываться/согласоваться || согласование, согласованность (*в числе*) 4. *перен. разг.* мириться, помириться *с кем-л.* || примирение

яр|әшел|ү *неперех.* быть наречённой, помолвленной, сосватанной; *~гән кыз* наречённая (помолвленная) девушка; невеста

яр|әшү *перех.* просватывать/просватать, обручать, помолвить || 1) просватывание, обручение, помолвка, сговор 2) обручальный; *кыз ~* помолвить девушку; *~ йоласы* обручальный обряд; обряд обручения

яргак I *сущ. разг.* болтун; хвастливый человек

яргак II *сущ.* 1. шкура без шерсти, облезлая шкура 2. плёнка (*на молоке и т. п.*); перепонка

яргалан|у *неперех.* 1. трескаться, потрескаться, растрескиваться/растрескаться (*краска на чём-л., почва, асфальт, глиняная, фарфоровая посуда и т. п.*); расщепляться/расщепиться (*о дереве, доске и т. п.*); истрескиваться/истрескаться (*о шпаклёвке, покраске и т. п.*) || растрескивание, расщепление; *алма ~ган* яблоко потрескалось; *стенаның буявы ~ган* краска на стене растрескалась 2. *перен.* трескаться, потрескаться, растрескиваться/растрескаться (*о губах, коже рук, ног и т. п.*) || растрескивание; *куллар салкыннан ~а* руки от холода трескаются

яргалау *многокр. от* **яру** 1—3, 5, 6

яргыч *сущ.* второй компонент составных терминов, имеет индив. переводы, напр.: *буразна ~* бороздник; *такта ~* лесопилка; *тары ~* просорушка; *ярма ~* крупорушка

ярд *сущ.* ярд (*в англоязычных странах: мера длины, равная 0,91 см*)

ярдәм *сущ.* 1. помощь, поддержка, содействие; подспорье; подмога; *ашыгыч ~ машинасы* машина скорой помощи; *~гә мохтаҗлык* нужда в поддержке; *ходай ~е белән* с помощью бога; *хуҗалыкны алып бару өчен ~* подспорье для ведения хозяйства 2. *в знач. послелога* **ярдәмендә** при помощи, с помощью, посредством, благодаря, при поддержке (содействии); *кеше ~ендә аякка басу* благодаря посторонней помощи встать на ноги; *ашламалар ~ендә яхшы уңыш алу* получить хороший урожай при помощи удобрений □ **~ итү (күрсәтү)** помогать/помочь, содействовать, способствовать; оказывать/оказать помощь; приходить/прийти на помощь; поддерживать/поддержать *кого*, посодействовать; **~гә килү** *см.* **~ итү** ◊ **~ кулы сузу** протянуть руку помощи

ярдәмләш|ү *взаимно-совм.* помогать/помочь друг другу, оказывать/оказать помощь друг другу, содействовать друг другу, поддерживать друг друга || взаимопомощь; *Экономик ярдәмләшү советы* Совет экономической взаимопомощи; *~ өчен* в целях взаимопомощи

ярдәмле *прил. см.* **ярдәмчел**

ярдәмлек *сущ.* пособие; *уку-укыту ~ләре* учебные пособия □ **~ сүз** *лингв.* служебное слово

ярдәмлелек *сущ. см.* **ярдәмчеллек**

ярдәмсез *прил.* 1. неотзывчивый, нечуткий, неучастливый, недушевный; *~ бәндә* неотзывчивый человек 2. беспомощный; *см. тж.* **имгәк** || *нареч.* без помощи, без поддержки; *~ калу* остаться без помощи

ярдәмсезлек *сущ.* неотзывчивость, нечуткость

ярдәмче *сущ.* 1. помощник, поддержка, опора (*в жизни, в учёбе, в освоении специальности, в поисках чего-л.*); *~м булырмын минутта* будь опорой моей в трудные минуты 2. помощник, заместитель (*директора, инженера, председателя, начальника и т. п.*); ассистент (*при операциях, в научной работе*) 3. подсобник 4. *прил.* 1) *лингв.* вспомогательный; *~ фигыль* вспомогательный глагол 2) подручный, вспомогательный, подсобный, служебный || *~ отряд* вспомогательный отряд; *~ эшче* подсобный рабочий

ярдәмчел *прил.* отзывчивый, идущий навстречу (*на помощь*), готовый помочь; *~ кеше* отзывчивый человек

ярдәмчеллек *сущ.* отзывчивость; *~ күрсәтү* проявить отзывчивость

ярдәмчесез *прил.* 1. беспомощный, не имеющий помощи, поддержки, опоры; *~ карт* не имеющий поддержки старик; беспомощный старик 2. не имеющий помощника (заместителя, ассистента); *~ директор* директор, не имеющий заместителя; *~ хирург* хирург, не имеющий ассистента || беспомощно; *~ яшәү* жить беспомощно 3. без помощника, заместителя, ассистента; *~ калу* остаться без помощника

ярдыргыч *сущ. разг. см.* **яргыч**

ярдыру 1. *понуд. от* **яру** 1—6 2. обдирать || обдирка; *ярма ~* обдирать зерно на крупу

яренгә *нареч. диал.* на будущий год; *бала ~ укырга керә* ребёнок на будущий год пойдёт учиться

ярендә *нареч. диал.* в будущем году; *~ йорт салабыз* в будущем году построим дом

ярка I *сущ. диал.* ярка (*молодая, ещё не ягнившаяся овца*)

ярка II *сущ.* 1. плаха, полено; обрубок 2. половинка *чего-л.* (*картофелины*) □ **~ бүрәнә** *спец.* развал, пластина □ **~ кебек** здоровый, сильный

ярканат *сущ. зоол.* летучая мышь; *~ теләге белән төн йөрми* (*посл.*) всему своё время (*букв.* ночь не зависит от пожелания летучей мыши)

ярлавык *сущ. диал.* обрыв (*береговой*) || *прил.* обрывистый (*о береге*)

ярлау *сущ. диал. см.* **ярлавык**

ярлы *прил.* 1. бедный, нищий, неимущий, малоимущий, обездоленный || бедный; *~ халык* бедный народ; *~ ~га булыша* бедный бедному помогает 2. *в знач. сущ.* бедняк; беднота || бедняцкий; *~лар комитеты ист.* комитет бедноты 3. бедный, нищенский, убогий; скудный (*о хозяйстве, жизни, обстановке*); *~ җиһаз* бедное имущество; *~ йорт* нищенский дом; *~ тормыш* убогая жизнь 4. *перен.* бедный, убогий, скудный, неинтересный, невыразительный; *образларга ~ пьеса* пьеса, бедная образами; *бик ~ хыял* убогое воображение; *~ табигать* скудная природа 5. бедный, скудный *чем-л.*; *азотка ~ туфрак* почва, бедная азотом; *су чыганаклары ~ район* район, скудный водными источниками || *нареч.* бедно, скудно, убого; *~ яшәү* жить бедно

ярлы|к *сущ.* **1.** *ист.* ярлы́к; ха́нская гра́мота, пи́сьменный ука́з; *килешү ~гы уст.* ря́дная гра́мота **2.** этике́тка, ярлы́к; *аптека ~гы* апте́чный ярлы́к; *товардагы ~к* этике́тка на това́ре **3.** *перен.* ярлы́к, шабло́нное про́звище; *кешегә ~клар ябыштырырга яратучылар* люби́тели ве́шать ярлыки́ на челове́ка

ярлыкалану *рел. страд. от* **ярлыка́у** быть поми́лованным

ярлыкану *возвр. от* **ярлыка́у** добива́ться/доби́ться поми́лования

ярлыка́|у *перех. рел. разр.* проща́ть/прости́ть, ми́ловать, поми́ловать; отпуска́ть/отпусти́ть грехи́ || проще́ние, поми́лование, отпуще́ние грехо́в; *алла үзе ~сын* пусть бог поми́лует

ярлыкла́у *перех.* **1.** снабди́ть *кого* охра́нной гра́мотой **2.** прикле́ивать/прикле́ить этике́тку, ярлы́к (*на товары*)

ярлыландыр|у *перех.* **1.** де́лать, сде́лать бе́дным, ни́щим, обедня́ть/обедни́ть || обедне́ние; *сугышлар илне ~а* во́йны обедня́ют страну́ **2.** обедня́ть/обедни́ть || обедне́ние; *туфракны ~у* обедня́ть по́чву; *әдәби образларны ~у* обедня́ть литерату́рные о́бразы

ярлылан|у *неперех.* **1.** бедне́ть, обедне́ть, нища́ть, обнища́ть, впада́ть в бе́дность, в нищету́ (*о государстве, народе, человеке, семье и т. п.*) || обедне́ние, обнища́ние **2.** *перен.* бедне́ть, нища́ть, скуде́ть, оскудева́ть/оскуде́ть, скудне́ть; *табигать ~а бара* приро́да нища́ет; *фикерләрем ~ды* мы́сли мои́ оскуде́ли □ **~ып бетү** обнища́ть

ярлылы|к *сущ.* **1.** бе́дность, нищета́, беднота́; нужда́, необеспе́ченность, недоста́ток; *~кта яшәү* жить в нужде́; *~кка дару юк, ялкаулык белән кушылса* (*посл.*) про́тив нищеты́ нет лека́рства, е́сли к ней присоедини́лась лень **2.** бе́дность, убо́жество (*обстановки*) **3.** *перен.* бе́дность, убо́гость, убо́жество *чего-л.*, ску́дость *в чём-л.*; *фикер ~гы* ску́дость мы́слей; *поэзия ~гы* бе́дность поэ́зии; *эчке дөньяның ~гы* убо́жество вну́треннего ми́ра; *әсәр телене ~гы* бе́дность языка́ произведе́ния; *туфракның ~гы* бе́дность по́чвы

ярлы-ябагай *сущ. собир. разг.* беднота́

ярма *сущ.* крупа́ || крупяно́й; *тары ~сы* пшённая крупа́; *карабодай ~сы* гре́чневая крупа́ □ **~ бертеге** крупи́нка; **~ җилгәргеч** крупове́йка; **~ кар** крупа́, зерни́стый снег; **~ яргыч** крупору́шка, круподёрка; **~ яру** **1.** обдира́ть семена́ **2.** *перен.* бесстыдно врать, лгать; хва́статься

ярмалан|у *неперех.* **1.** зерни́ться, де́латься, сде́латься зерни́стым, гранули́роваться || гранули́рование, грануля́ция; *язын кар ~а* весно́й снег де́лается зерни́стым **2.** станови́ться/стать, де́латься, сде́латься крупча́тым (*о льде*) **3.** станови́ться/стать рассы́пчатым (*о картофеле*)

ярмалы *прил.* **1.** крупяно́й, с крупо́й; *~ аш* крупяно́й суп; *~ бәлеш* пиро́г с крупо́й, крупяно́й пиро́г **2.** крупча́тый, зерни́стый; *~ туфрак* зерни́стая по́чва; *~ бал* зерни́стый мёд **3.** рассы́пчатый (*картофель*)

ярмалылык *сущ.* зерни́стость

ярминкә *сущ.* я́рмарка || я́рмарочный; *бәйрәм алды ~ләре* предпра́здничные я́рмарки; *~ көннәре* я́рмарочные дни

яровойлаштыру *неперех. с.-х.* яровизи́ровать || яровиза́ция; *орлыкларны чәчү алдыннан ~* яровизи́ровать семена́ пе́ред посе́вом

яровойлаштырылу *с.-х. страд. от* **яровойлаштыру**

яровойлашу *неперех. с.-х.* яровизи́роваться

ярпач *прил. диал.* хвастли́вый || хвасту́н, бахва́л

ярпачлану *неперех. диал.* станови́ться/стать хвастли́вым

ярпа|ю *неперех. диал.* **1.** потучне́ть, попра́виться, хороше́ть, похороше́ть; станови́ться/стать здорове́е, полне́е; *кыз яхшы җиргә төшсә — ~я, яман җиргә төшсә — картая* (*посл.*) е́сли де́вушка попада́ет в хоро́шую семью́ — хороше́ет, е́сли в плоху́ю семью́ — старе́ет **2.** хва́статься; ва́жничать, зазнава́ться, держа́ть себя́ ва́жно || ва́жничать, зазна́йство ◊ **~еп утыру** сиде́ть чи́нно-ва́жно

ярс|у *неперех.* **1.** разъяря́ться/разъяри́ться, прийти́ в я́рость (в бе́шенство), свирепе́ть, рассвирепе́ть, взбеси́ться, остервене́ть, остервени́ться, разгне́ваться *высок.* || я́рость, си́льный гнев, бе́шенство, свире́пость; *чиксез ~у* кра́йне разъяри́ться; *~уын баса алмыйча* в си́льном гне́ве **2.** *перен.* безу́мствовать, бу́йствовать, бушева́ть; *~ып елау* пла́кать навзры́д, рыда́ть; *~ып кычкыру* крича́ть с надры́вом **3.** быть в я́рости, станови́ться кра́йне насто́йчивым, напо́ристым (*в работе, в каких-л. действиях*); *~ып эшкә тотыну* с я́ростью приступи́ть к рабо́те □ **~ып китү** вспыли́ть, вскипе́ть, взвинти́ться, взбеси́ться, взорва́ться

ярсуландыру *перех. см.* **ярсыту**

ярсулану *неперех. см.* **ярсу** 1

ярсулы *прил.* **1.** я́ростный, разъярённый, остервене́лый, исступлённый; *~ караш* я́ростный взгляд; *~ тавыш* разъярённый го́лос **2.** я́ростный, бе́шеный, нейстовый, бу́рный; бурли́вый, бу́йный (*ветер, буран*); *~ җил* бу́йный ве́тер; *~ һөҗүм* я́ростная ата́ка; *елганың ~ агымы* бу́рное тече́ние реки́ **3.** бу́йный, пы́лкий, стра́стный, возбуждённый, взволно́ванный, безу́держный; *~ тойгылар* бу́йные чу́вства; *~ теләк* стра́стное жела́ние; *~ омтылыш* пы́лкий поры́в

ярсучан *прил.* вспы́льчивый, запа́льчивый

ярсучанлы|к *сущ.* **1.** вспы́льчивость, запа́льчивость **2.** возбуди́мость, раздражи́мость; *нерв системасының ~гын кимету* сни́зить возбуди́мость не́рвной систе́мы

ярсын|у **1.** *возвр. от* **ярсу** кипяти́ться, разъяри́ться, приходи́ть в я́рость **2.** *в знач. прил.* **ярсынган** возбуждённый, разъярённый; *~ган кыяфәт* разъярённый вид

ярсынучан *прил.* легко́ возбуди́мый, импульси́вный

ярсынучанлык *сущ. мед.* возбуди́мость

ярсыткыч *сущ. мед.* возбуди́тель, раздражи́тель; *тышкы ~лар* вне́шние раздражи́тели || *прил.* возбуди́тельный, возбужда́ющий

ярсыт|у *перех.* **1.** разъяря́ть/разъяри́ть, приводи́ть в я́рость, в бе́шенство, взбеси́ть; выводи́ть/вы́вести из себя́; *кешеләрне ~у* разъяри́ть люде́й **2.** будора́жить, взбудора́живать/взбудора́жить, возбужда́ть/возбуди́ть, горячи́ть, распаля́ть/распали́ть || возбужде́ние; *күңелне ~у* будора́жить ду́шу; *нинди хисләр аны ~кан?* каки́е чу́вства распали́ли его́? **3.** *мед.* раздража́ть/раздражи́ть; возбужда́ть || раздраже́ние, возбужде́ние; *авыруны тавыш ~а* больно́го раздража́ет шум

ярсытылу *страд. от* **ярсыту** разъяри́ться *чем*, быть разъярённым *чем*; взбудора́житься, быть взбудора́женным; возбужда́ться, быть возбуждённым

ярты *сущ.* **1.** полови́на, полови́нка; *алманың ~сы* полови́на я́блока; *юлның ~сы* полови́на пути́; *гомер ~сы* полови́на жи́зни; *җәй ~сы* полови́на ле́та **2.** *числ.* полови́на, пол; *сәгать унынчы ~* вре́мя полови́на деся́того **3.** *в сложн. сл. переводится компонентом* пол-, поло-, полу-; *~ сәгать* полчаса́; *~ литрлы* поллитро́вка; *~ потлы* полупудо́вый **4.** *разг.* пол-ли́тра (*водки*) || *прил.*

полови́нный; ~ *бәя* полови́нная цена́; ~ *эш хакы* полови́нный окла́д □ ~ **ел** полуго́дие; ~ **еллык** полугоди́чный (*запас*), полугодово́й (*отчёт, план*) ◊ ~ **акыл(лы)** полоу́мный; ~ **җаның алу** довести́ до полусме́рти (*побив, напугав*); ~ **сүздән** с полусло́ва; ~ **улек, ~ жаны чыккан** полумёртвый: ни жив ни мёртв; ~ **юлда** на полдоро́ге, на полпути́

ярты-йорты *нареч.* 1. наполови́ну, полови́нчато || полови́нчатый; *ярты-йорты эшләү* сде́лать наполови́ну; *ярты-йорты җавап* полови́нчатый отве́т 2. *перен.* ко́е-ка́к, с грехо́м попола́м; *ярты-йорты уку* учи́ться ко́е-ка́к

ярты|ла́у *перех. разг.* 1. раздели́ть, подели́ть попола́м 2. прожи́ть полови́ну от определённого коли́чества лет

ярты|лаш, ярты|лай *нареч.* 1. наполови́ну, попола́м, вполови́ну; ~ *суга керү* наполови́ну войти́ в во́ду; *алманы ~ бүлү* раздели́ть я́блоко попола́м 2. *в сложн. сл. переводится компонентом* полу-; ~ *ачык* полуоткры́тый; ~ *онытылган* полузабы́тый

ярты|лы *прил.* 1. полови́нный; ~ *өлеш* полови́нная до́ля 2. *перен. разг.* полоу́мный

ярты|шар *нареч.* по полови́нке; ~ *тия* достаётся по полови́нке

ярты|шарлап *нареч.* по полови́нке

яру *перех.* 1. коло́ть, раска́лывать/расколо́ть || ко́лка, раска́лывание (*дров*) 2. пили́ть, распи́ливать/распили́ть || распило́вка (*доски*) 3. щепа́ть, расщепля́ть/расщепи́ть || щепа́ние; *чыра яру* щепа́ть лучи́ну 4. *мед.* вскрыва́ть/вскрыть, рассека́ть/рассе́чь (*труп, опухоль*) || вскры́тие, рассече́ние 5. грызть (*семечки*), лущи́ть, обдира́ть (*крупу*) || луще́ние, обди́рка 6. прокла́дывать/проложи́ть, пробива́ть/проби́ть, рассека́ть/рассе́чь || прокла́дывание; *буразна яру* бороздить, прокла́дывать бо́розду; *юл яру* проби́ть доро́гу; *дулкын яру* рассека́ть волну́ 7. *перен.* сечь, рассека́ть/рассе́чь (*губы, лоб*) 8. *перен. разг.* сечь, лупи́ть, отлупи́ть, бить, поби́ть || битьё; *эт урынына яру* отлупи́ть как соба́ку 9. образова́ть тре́щину, щель и т. п.; спосо́бствовать образова́нию тре́щины (*на коже лица, рук*) 10. распуска́ться/распусти́ться, раскрыва́ться/раскры́ться || распуска́ние (*листьев, почек, цветков и т. п.*) 11. *перен.* ре́зать (*ухо, слух, воздух*) ◊ **ярып керү** 1. пробива́ться (*о запахе*) 2. ре́зать у́хо (*о звуке*); **ярып салу (әйтү, сөйләү)** говори́ть пря́мо в глаза́; ре́зать пра́вду-ма́тку

я́рус *сущ.* 1. я́рус; *беренче ~ ложасы* ло́жа пе́рвого я́руса; *Сөембикә манарасының ~лары* я́русы ба́шни Сююмбике́ 2. *уст.* эта́ж; *өйнең өске ~ы* ве́рхний эта́ж до́ма

я́руслап *нареч.* я́русами; *алмагач ботакларын ~ үстерү* расти́ть ве́тки я́блони я́русами

я́руслы *прил.* я́русный; -я́русный; *ике ~* двухъя́русный; ~ *төзелеш* я́русное строи́тельство

ярут *сущ. бот.* яру́тка (*сорняк*); *кыр ~ы* яру́тка полева́я

яручы: такта яручы пи́льщик досо́к; *утын ~* дровоко́л

ярчык|к *сущ.* оско́лок; *мина ~гы* ми́нный оско́лок

